СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
КАЗАН ФИЛИАЛЫ
ГАЛИМҖАН ИБРАһИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һӘМ
ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

ӨЧ ТОМДА



А-Й

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1977

С (Тат) (03)
Т 23

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйльми советы карары нигезендә басыла

Редколлегия:

Л. Т. Махмутова, М. Г. Мөхәммәдиев, К. С. Сабиров, Ш. С. Ханбикова

Нәшрият редакторлары:

Р. А. Зиляева, Г. Г. Абдрахманова

Т $\frac{0715-111}{М\ 132(03)-77}$ 282—76

© Татарстан китап нәшрияты, 1977

СҮЗ БАШЫ

Теге яки бу телнең аңлатмалы сүзлеген төзеп дөньяга чыгару халыкның культура үсеше тарихында әһәмиятле вакыйга булып тора, чөнки мондый сүзлек шул халыкның иҗтимагый-политик тормышында, культура һәм тел өлкәсендә ирешкән уңышларын аермачык чагылдыра.

Билгеле булганча, В. И. Ленин 1920 елда ук инде рус теленең Пушкиннан алып Горькийга кадәрге чорга караган аңлатмалы сүзлеген төзүне оештыруга зур игътибар бирә.

Хәзерге көндә Советлар Союзында яшәүче күп кенә халыклар үз телләренең аңлатмалы сүзлекләрен булдыру бәхетенә ирештеләр. Мәсәлән, 30 нчы елларда башлап рус теленең берничә аңлатмалы сүзлеге басылып чыкты: Д. Н. Ушаков редакциясендәге 4 томлык сүзлек (1935—1940 ее.); С. И. Ожегов тарафыннан төзелгән сүзлек (ул 1949—1970 елларда сигез тапкыр басылды); 1957—1965 елларда рус теленең 4 томлык сүзлеге; 1950—1965 елларда хәзерге рус әдәби теленең 17 томлык сүзлеге дөнья күрде. Шулай ук грузин, белорус, литва, украин һ. б. телләрнең күп томлы сүзлекләре дә басылып чыкты.

Төрки телләрдән казах, төрекмән, кыргыз, азербайҗан телләренең аңлатмалы сүзлекләре басылды; үзбәк, башкорт, балкар һ. б. телләрнең аңлатмалы сүзлекләре дә әзерләнә.

Татар теле лексикографиясе традициясендә тәрҗемә (русча-татарча, татарча-русча, гарәпчә-фарсыча-татарча) сүзлекләр зур урын алып тора. Шуның белән бергә татар теленең аңлатмалы сүзлекләре дә төзелә башлый. Боларның беренчесе, татар халкының мәшһүр галиме һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйри тарафыннан төзелеп, 1896 елда „Ләһҗәи татари" исемендә басылып чыккан. Бу — төрки телләр сүзлекләре арасында да иң беренче аңлатмалы сүзлек.

Икенче тапкыр татар теленең аңлатмалы сүзлеген тудыруга омтылыш 20 нче елларның ахырында ясала һәм берничә хәрефкә Ж. Вәлиди тарафыннан төзелеп, „Татар теленең тулы сүзлеге" исемендә ике кисәктә (I кис. — 1927, II кис. — 1929) бастырып чыгарыла.

Тәкъдим ителә торган аңлатмалы сүзлек киң катлау укучылар өчен чыгарыла. Ул өч томнан тора: I том — А — Й, II том — К — С, III том—Т—һ хәрефләрен эченә ала.

Бу сүзлекнең төп бурычы — татар әдәби теленең XIX гасырның ахырыннан алып хәзерге көнгә кадәр гомумкулланышта булган лексик һәм фразеологик байлыгын туплап бирү; сүзләрнең мәгънәләрен һәм мәгънә төсмерләрен ачу, аларга грамматик-стилистик характеристика бирү, кулланыш үзенчәлекләрен күрсәтү.

Сүзлектә кайбер грамматик формалар ясалышындагы һәм аерым сүзләр әйтелешендәге үзенчәлекләр күрсәтелде; кирәк булган очракларда басым билгеләре дә куелды. Сүзгә яки фразеологик берәмлеккә бирелгән аңлатмалар матур әдәбияттан, иҗтимагый-политик, публицистик һәм фәнни-популяр әсәрләрдән, дәреслек һ. б. чыганаклардан китерелгән мисаллар белән дәлилләнде. Болар барысы да сүзләрне дөрес кулланыга, аларның мәгънә төрлелекләрен һәм стилистик үзенчәлекләрен ачуга һичшиксез ярдәм итәр дип ышанабыз.

Сүзлекнең нигезен СССР ФА Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының XX йөз башы татар әдәбияты классиклары һәм хәзерге чор язучыларының әсәрләре буенча төзелгән картотека тәшкил итә.

Сүзлекне төзегәндә татар лексикографиясенең күпьеллык бай традициясе һәм аның барлык казанышлары, шулай ук башка төрки телләрнең һәм аеруча рус теленең алдынгы лексикографик тәҗрибәсе киң файдаланылды.

Аңлатмалы сүзлек тел секторы гыйльми хезмәткәрләре тарафыннан Л. Т. Махмутованың фәнни җитәкчелегендә төзелде һәм редакцияләнде.

I томны төзүдә катнаштылар: И. А. Абдуллин — В, Ж, И хәрефләре, Г. Х. Ахунҗанов — Б („божра" сүзеннән — „бүтәнчә" сүзенә кадәр), Д хәрефләре, Ф. М. Газизова — А хәрефе, Л. Р. Гайнанова — Б хәрефе („бер" сүзеннән — „бит" сүзенә кадәр),

М. Г. Мөхәммәдиев — Е, Й хәрефләре, Р. К. Рәхимова — Б хәрефе („битараф“ сүзеннән — „бояр“ сүзенә кадәр), Ш. С. Ханбикова — Г, З хәрефләре, Р. Г. Әхмәтьянов — Б хәрефе („б“ дан — „бенуар“ сүзенә кадәр).

Сүзлекнең I томын редакцияләделәр: Л. Т. Махмутова — А хәрефен („а“ дан — „агу“ сүзенә кадәр), Б хәреферннән Й хәрефенә кадәр тоташтан, М. Г. Мөхәммәдиев, К. С. Сабиров һәм Ш. С. Ханбикова — А хәреферннән Й хәрефенә кадәр тулысынча.

Аңлатмалы сүзлекнең картотека базасын булдыруда Казан Дәүләт университетының, Казан һәм Алабуга педагогик институтларының тел-әдәбият бүлекләре һәм Арча педагогия училищесы студентлары, ТАССР районнарындагы, шулай ук БАССРның Салават; Куйбышев өлкәсенең Похвистнево; Пермь өлкәсенең Барда, Октябрьск; Ульяновск өлкәсенең Чардаклы; Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк, Коншак районнарындагы урта һәм сигезьеллык мәктәпләрнең тел-әдәбият укытучылары һәм укучылары актив катнашты. Институт бу иптәшләрнең барысына да рәхмәт сүзләре житкерүне үзенең бурычы дип саный.

„Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә“не, 1964 елда басылып чыккан „Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү инструкциясе“нә һәм Сүзлекне төзү дәвамында тупланган коллектив фикерләргә таянып, М. Г. Мөхәммәдиев әзерләде.

Файдаланылган махсус әдәбият-сүзлекләр исемлеген Р. Р. Абдуллина төзеде.

Сүзлекне матбугатка әзерләүдә С. Б. Вахитова, Р. Р. Абдуллина, Н. Х. Зарипова, М. В. Гайнетдинова зур ярдәм күрсәттеләр. Бу эштә шулай ук З. Р. Садыйкова, М. М. Фәррәхова, Т. Х. Хәйретдинова, М. З. Шәрәфетдинова, Р. Б. Яхин һ. б. иптәшләр катнашты.

„Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү инструкциясе“н һәм Сүзлекнең кулъязмасын тикшерүдә актив катнашкан язучыларга, журналистларга, нәшрият хезмәткәрләренә, укытучыларга, Казан югары уку йортларының галимнәренә, Институтның фәнни хезмәткәрләренә, шулай ук рәсми бәяләмә-рецензияләр язган филолог-белгечләргә файдалы киңәшләре өчен Институт чын күңелдән рәхмәт белдерә.

Сүзлеккә кагылышлы фикер һәм теләкләрне түбәндәге адреслар белән жибәрергә мөмкин:

Казань — 420111, Лобачевского, 2/31, Институт языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова Казанского филиала Академии наук СССР яки Казань — 420084, Баумана, 19, Татарское книжное издательство.

I. ФАЙДАЛАНЫЛГАН СҮЗЛЕКЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Аңлатмалы сүзлекләр

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы сүзлеге. I җилд. I кисәк, Казан, 1927; II кисәк, Казан, 1929.

Насыйри К. Ләһҗәи татари. 2 томда. 1—2 т. Казан, 1895—1896.

Ханбикова Ш. С. Синонимнар сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1962.

Диалектологик сүзлекләр

Диалектологик сүзлек. 1—2 чыгарылышлар. Казан, Татгосиздат, 1948—1953; III кисәк. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1958.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1969.

Татарча-русча сүзлекләр

Катанов Н. Ф. Краткий татарско-русский словарь. Казань, 1912.

Корбангалиев М., Газизов Р., Кулиев И. Татарча-русча сүзлек. Казан, Татиздат, 1931.

Насыйри К. Татарча-русча лөгать китабы. Казан, 1878.

Остроумов Н. П. Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии. Казань, 1876.

Остроумов Н. П. Татарско-русский словарь. Казань, 1892.

Рахманколый С. Татарча-русча лөгать. Казан, 1913.

Татарско-русский словарь. М., „Сов. энциклопедия", 1966.

Татарча-русча сүзлек. Төзүчеләре: *Р. Газизов, Н. Исәнбәт, Г. Ишмухаметов.* Казан, Татгосиздат, 1950.

Троянский А. Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских. В 2-х т. Т. 1—2. Казань, 1833—1835.

Русча-татарча сүзлекләр

Воскресенский А. Русско-татарский словарь. Казань, 1894.

Насыри К. Полный русско-татарский словарь. Казань, 1892.

Русско-татарский словарь. В 4-х т. Т. 1—4. Казань, Таткнигоиздат, 1955—1959.

Русча-татарча мөкәммәл лөгать. Төзүчеләре: *С. Рахманколый, Г. Кәрам.* Казан, „Гасыр" нәшрият ширкәте, 1920.

Русча-татарча сүзлек. Казан, Татгосиздат, 1938.

Русча-татарча яңа лөгать. Казан, „Яңа китап" нәшрият кооперативы, 1929.

Гарәпчә-фарсыча-татарча сүзлекләр

Беляев Г. Керәшенләргә татар-гарәп сүзләрен аңлату өчен сүзлек. Казан, „Яңалиф" нәшрияты, 1929.

Хәмзин К. З., Мәхмүтов М. И., Сәйфуллин Г. Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1965.

Җантурин С. Лөгать. Уфа, „Шәрык" мәтбагасы, 1911.

Фразеологик сүзлекләр

Борһанова Н. Б., Мәхмүтова Л. Т. Русча-татарча фразеологик сүзлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1959.

Татар халык мәкальләре. 3 томда. Җыючысы һәм төзүчесе *Н. Исәнбәт.* 1—3 том. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1959—1967.

Җәлә Л., Борһанова Н. Б., Мәхмүтова Л. Т. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. Казан, Таткнигоиздат, 1957.

Терминологик сүзлекләр

Атамалар сүзлеге. XI серия. Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары. Казан, Татиздат, 1931.

Ахметов Г., Гимадиев М. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге. Казан, Татгосиздат, 1950.

Вәлитов Г. Химия атамалары. I бүлек. Анорганик җыелмаларның яңа номенклатурасы. Казан, Татиздат, 1931.

Габитов Г. Русча-татарча сәяси лөгать. Оренбург, 1918.

Гали М. Газета укучыларга кесә сүзлеге. Казан, Татиздат, 1928.

Галиев М., Мөштәри Х., Хөснуллин Х. Физика һәм метеорология терминнары. Казан, Татгосиздат, 1939.

Дистанов Г., Вәлитов Г. Химия терминнары. Русча-татарча сүзлек. Казан, Татгосиздат, 1934.

Дусаев З. С. Русча-татарча география сүзлеге. Казан, Таткнигоиздат, 1953.

Закиров В. З., Муртазин З. Г. Русча-татарча математик терминнар сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1970.

Камал Г. Кесә өчен русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать. Казан, „Васита" көтепханәсе, 1918.

Краткий русско-татарский словарь военных терминов (толмач). М., 1926.

Математика атамалары. Русча-татарча сүзлек. Казан, 1934.

Медицинадан татарча атамалар. I кисәк. Нормаль анатомия атамалары. Казан, 1929.

Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар китабына сүзлек. Казан, 1894.

Политик сүзлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1958.

Политик-экономик терминнар (русча-татарча һәм татарча-русча). Төзүчеләре: *Ф. Махиянов, Г. Шәфиев, Г. Нугайбәк.* Казан, Татгосиздат, 1941.

Русча, латинча һәм татарча атамалар сүзлеге. 3 серия. Кеше морфологиясе (анатомия, гистология). Казан, Татиздат, 1931.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге. Төзүчеләре: *А. К. Тимергалин, Г. Г. Ахметов, Ш. Г. Садыйков.* Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1971.

Русча-татарча атамалар сүзлеге. I серия. Физика, математика, астрономия. Казан, Татиздат, 1931.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1972.

Русча-татарча математик терминнар сүзлеге. Казан, Татгосиздат, 1949.

Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге. Төзүчеләре: *В. Горохов, А. Касимов, В. Хангилдин.* Казан, Татгосиздат, 1950.

Русча-татарча физика терминнары сүзлеге. Төзүчесе *М. Галеев.* Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1972.

Русча-татарча физика һәм геофизика терминнары сүзлеге. Төзүчесе *М. С. Галеев.* Казан, Татгосиздат, 1949.

Сәяси лөгать. Төзүчеләре: *Г. Нигъмәти, М. Мөхәммәдев, С. Шәрәфетдинов.* М., СССР халыкларының үзәк нәшрияты, 1925.

Табигать һәм биология терминнары. Казан, Татгосиздат, 1935.

Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге. Казан, Татгосиздат, 1953.

Тимергалин А. К., Галеев М. Русча-татарча техника терминнары сүзлеге. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1963.

Физика атамалары. Казан, 1927.

Халиков Х., Алексеев И., Исаев З. Элементар математика терминнары җыентыгы. Казан, Татгосиздат, 1935.

Әдәбият белеме сүзлеге. Төзүчесе *Н. Гыйззәтуллин.* Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1958.

Орфографик сүзлек

Хисмәтуллин Х., Гимадиев М. Татар әдәби теленең орфография сүзлеге. Казан, Татгосиздат, 1948.

Башка телләрнең сүзлекләре

Ağakay M. A. Türkçe sözlük. Ankara, Türk Tarih Kurumu basimevi, 1966.

Азәрбайҹан дилинин изаһлы лүғәти. 1 жилд. Бакы, Азәрбайҹан ССР Елмләр акаденијасы нәшрижјаты, 1966.

Азәрбайҹанча-русча лүғәт. Бакы, Азәрбайҹан ССР Елмләр академијасы нәшрижјаты, 1962.

Александрова З. Е. Словарь синонимов русского языка. М., „Сов. энциклопедия", 1969.

Арабско-русский словарь. Сост. *Х. К. Баранов.* М., ГИС, 1958.

Ахманова О. С. Словарь лингвистических терминов. М., „Сов. энциклопедия", 1966.

Башкирско-русский словарь. М., ГИС, 1958.

Бегалиев Г., Махмудов Х., Мусабаев Г. Краткий казахско-русский словарь. Алма-Ата, Казахское гос. издательство, 1959.

Большая советская энциклопедия. Изд. второе. Т. 1—51, М., Гос. научное изд-во „Большая сов. энциклопедия", 1949—1958.

Будагов Л. З. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. В 2-х т. Т. 1—2. Спб, 1869—1871.

Даль В. Толковый словарь живого великорусского языка. В 4-х т. Т. 1—4 М., ГИС, 1955.

Древнетюркский словарь. Л., „Наука", 1969.

Қазақ тілінің түсіндірме сөздігі. 2 томдық. 1—2 т. Алматы, Қазақ ССР Ғылым академиясының баспасы, 1959—1961.

Каракалпакско-русский словарь М., ГИС, 1958.

Киргизско-русский словарь. Сост. К. К. Юдахин. М., „Сов. энциклопедия", 1965.

Қошғарий М. Девону луғотит турк. 3 томлик. 1—3 т. Тошкент, Ўзбекистон ССР Фанлар академияси нашриёти, 1960—1963.

Краткий политехнический словарь. М., Гостехиздат, 1955.

Краткий политический словарь. М., Политиздат, 1971.

Малая советская энциклопедия. Изд. третье. Т. 1—10. М., Гос. научное изд-во „Большая сов. энциклопедия", 1958—1960.

Новые слова и значения. Словарь-справочник. М., „Сов. энциклопедия", 1971.

Ожегов С. И. Словарь русского языка. М., „Сов. энциклопедия", 1962.

Персидско-русский словарь. Сост. *Б. В. Миллер.* М., ГИС, 1953.

Радлов В. В. Опыт словаря тюркских наречий. В 4-х т. Т. 1—4. Спб, 1888—1911.

Словарь иностранных слов. М., ГИС, 1954.

Словарь русского языка. В 4-х т. Т. 1—4. М., ГИС, 1957—1961.

Словарь современного русского литературного языка. В 17 т. Т. 1—17. М.—Л., Изд-во АН СССР—„Наука", 1950—1965.

Толковый словарь русского языка. Под редакцией проф. *Д. Н. Ушакова.* В 4-х т. Т. 1—4. М. „Сов. энциклопедия" — ГИС, 1935—1940.

Турецко-русский словарь. Сост. Д. А. Магазаник. М., ГИС, 1945.

Түркмен дилиниң сөзлүги. Ашгабат, Туркменистан ССР Ылымлар академиясының нешириаты, 1962.

Узбекско-русский словарь. М., ГИС, 1959.

II. СҮЗЛЕКТӘ ФАЙДАЛАНЫЛГАН БАШКА ЧЫГАНАКЛАР ТУРЫНДА

1. Югарыда әйтеп кителгәнчә, иллюстратив материал, ягъни сүзнең мәгънәсен яки мәгънә төсмерен ачыклау, дәлилләү өчен китерелгән мисаллар төрле чыганаклардан, шул исәптән әдәби, ижтимагый-политик, публицистик һәм фәнни-популяр әсәрләрдән, дәреслекләрдән алынды. Мисаллар документлаштырылды, ләкин алар янында, кагыйдә буларак, әсәрнең авторы гына күрсәтелде. Мәсәлән: Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Г. Бәширов, Ә. Еники, М. Әмир, З. Нури, Г. Ахунов һ. б. Авторларның фамилияләре һәм инициаллары (яки псевдонимнары) бер үк төрле булган очракларда, алар түбәндәгечә бирелде: Г. Рәхим (Гали Рәхим) һәм Гәр. Рәхим (Гәрәй Рәхим), М. Рафиков (Мәҗит Рафиков) һәм Мәр. Рафиков (Мәрди Рафиков), М. Хәсәнов (Мәхмүт Хәсәнов) һәм Ман. Хәсәнов (Мансур Хәсәнов).

2. Дәреслекләрдән китерелгән мисаллар янында китапның исеме генә күрсәтелде. Аларның кайберләре кыскартып бирелде:

Бор. зам. тарихы — «Борынгы заман тарихы»,
Дөнья кис. геогр. — «Дөнья кисәкләре географиясе»,
СССР физ. геогр. — «СССРның физик географиясе»,
СССР экон. геогр. — «СССРның экономик географиясе»,
Урта гас. тарихы — «Урта гасырлар тарихы»,
Физ. геогр. — «Физик география»,
Чит ил. экон. геогр. — «Чит илләрнең экономик географиясе».

3. Аерым очракларда газета-журналларның да исемнәре кыскартып бирелде:

Каз. утл. — «Казан утлары» журналы
Сов. мәк. — «Совет мәктәбе» —»—
Сов. әд. — «Совет әдәбияты» —»—
Соц. Тат. — «Социалистик Татарстан» газетасы
Тат. Ком. — «Татарстан Коммунисты» журналы
Тат. яшь. — «Татарстан яшьләре» газетасы.

4. Шулай ук кайбер чыганак-әсәрләрнең дә исемнәре кыскартылды. Алар түбәндәгеләр:

Авыл рационализаторлары — Курнышев В. М. Татарстанның авыл рационализаторлары Казан, 1963.

А.-х. маш. йөртү — Кобезский В. Л., Нищук С. М. Тракторлар, автомобильләр һәм үзйөрешле авыл хуҗалыгы машиналарын йөртү.

Атомнар дөньясында — Вәлиев К. А., Тимеров Р. Х. Атомнар һәм элементар кисәкчәләр дөньясында. Казан, 1963.

Атом энергиясе — Зарипов М. М. һәм Салихов С. Г. Атом энергиясе кешегә хезмәт итә. Казан, 1960.

Дин. кил. чыгуы — Никольский В. Диннең килеп чыгуы. Казан, 1950.

Дин һ. көнкүреш — Беляев К. И. Дин һәм көнкүреш. Казан, 1959.

Дуңгыз асрау... — Ротермель З. А., Әскәров Р. Ш. Дуңгыз асрауда нәсел эше. Казан, 1964.

Йорт эшләре — Йорт эшләре. Казан, 1959.

Кибернетика тур. — Гринилев Л. Кибернетика турында. Казан, 1961.

Космик ракеталар — Казневский В. П. Космик ракеталар. Казан, 1963.

Куз. культ. игү — Шәкүров В. З. Кузаклы культуралар игү тәжрибәсе. Казан, 1962.

Күк җисемнәре — Воронцов-Вельяминов Б. А. Күк җисемнәреңең килеп чыгышы. Казан, 1964.

Механизаторга ярдәмгә — Курнышев В., Любарский П. Татарстан авыл хуҗалыгы механизаторына ярдәмгә. Казан, 1962.

Нефть тур. хик. — Лалетин А. һәм Абдуллин Р. Нефть турында хикәяләр. Казан, 1961.

Радиолокация — Хәбибуллин Н. Ф. һәм Зиннәтов М. З. Радиолокация. Казан, 1958.

Радио сөюче... — Хәбибуллин Н. Ф. Радио сөюченең белешмә китабы. Казан, 1961.

Робинзон эзл. — Верзилин Н. Робинзон эзләренән. Казан, 1958.

РСДРП проклама- циясе — 1903—1907 елларда РСДРПның Казан комитеты чыгарган прокламацияләр.

Сайл. партияләр — Нәҗметдинов Р. Сайланма партияләр. Казан, 1962.

Сер пәрдәсен ачсак... — Комаров В. Сер пәрдәсен ачсак... Казан, 1966.

Серле кристаллар — Шахмуратова Р. А. Серле кристаллар. Казан, 1958.

Сөт терлекчелеге... — Долгобородов И. В. Сөт терлекчелеге турында кыскача белешмә. Казан, 1962.

Табиг. буйс. юл — Бублейников Ф. Табигатьне буйсындыру юлында. Казан, 1963.

Тат. театры — Татар театры. 1906—1926. Төзүчеләре: М. Парсин, М. Мутин, З. Баязитский. Казан, 1926.

Тракторлар — Максудов Н. Г. Хәзерге тракторлар. Казан, 1963.

Уйлаучы машиналар — Рейнберг М. Г. Уйлаучы машиналар. Казан, 1960.

Файдалы киңәшләр — Файдалы киңәшләр. Казан, 1961.

Хал. ашлары. — Әхмәтҗанов Ю. Татар халык ашлары. Казан, 1960.

Химияне а.-х. куллану — Валитова Ф. Г. Химияне авыл хуҗалыгында куллану. Казан, 1956.

Химиянең киләчәге — Ляпунов Б. В. Химиянең киләчәге. Казан, 1969.

Ясалма иярченнәр... — Штернфельд А. Ясалма иярченнәрдән планетаара очышларга. Казан, 1959.

Яшен — Зиннәтов М. З. Яшен һәм аннан саклану. Казан, 1963.

Үтк. зам. сәяхәт. — Голосницкий Л. Үткән заманга сәяхәт. Казан, 1960.

Җиләк-җимеш.., — Җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы. Казан, 1959.

СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

I. Сүзлеккә сүзләр алу

§ 1. Сүзлекнең нигезен хәзерге татар әдәби телененең гомуми кулланыштагы лексика һәм фразеологиясе тәшкил итә.

§ 2. Сүзлеккә түбәндәге төркем сүзләр дә кертелде:

а) әдәби әсәрләрдә очраган яки хәзерге телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре, шул исәптән, классик әдәбиятта очраган кайбер тупас һәм жаргон сүзләр;

б) тарихи фактларны һәм электәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган сүзләр. Мәсәлән: *ханлык, би, бояз, губерна, кантон, урядник, вәзир, кәләпүшче, лашманчы, асламчы* һ. б. ш.;

в) XX йөзнең аерым чорларында матур әдәбият әсәрләре һәм матбугат битләрендә еш очрап, хәзер архаиклашкан яки искереп барган сүзләр һәм формалар, шул исәптән, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынмалар. Мәсәлән: *мөгаллим, мөгаллимә, инкыйлап, рәис, сәясәт, мәдәният, көлле, шифаханә, илә, илән* һ. б. ш.;

г) дингә, мифологиягә, ырым-йолаларга бәйләнешле һ. б. ш. төшенчәләрне белдергән сүзләрнең хәзерге жанлы сөйләү телендә һәм атеистик әдәбиятта кулланыла торганнары. Мәсәлән: *алла, гает, сихер, убыр, чиркәү, шүрәле, албасты, дога, ураза, гөнаһ* һ. б. ш.;

д) киң кулланышка кергән терминнар һәм махсус сүзләр (иҗтимагый-политик һәм публицистик терминнарны һәм атамаларны чагыштырмача тулырак алу күздә тотылды);

е) әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган *жәйдак, буйдак, мизгел, өрфия, онта, күлдәвек, болдыр, күбә, аҗаган, тумачы, игәч, тудыка* кебек диалектальсүзләр;

ж) киң кулланышка кергән неологизмнар (*иярчен, континентара, космос, космонавт, космик, квадратлап-оялап, планетаара* һ. б. ш.).

§ 3. Сүзлек берәмлекләре сыйфатында барлык грамматик сүз төркемнәре алынды. Шул исәптән:

а) урта мәктәп дәреслекләрендә һәм гомуми матбугатта еш очрый торган төрле ил халыкларының һәм милләтләрнең исемнәре *(рус, үзбәк, инглиз, европалы, кореялы, кыпчак, һун, скиф, франк, француз, япон* һ. б.); шулай ук, күмәклек мәгънәсе алып, киң кулланышка кергән ялгызлык исемнәр (*ампер, маузер, ом, иблис, дәҗҗәл* һ. б.);

б) төп һәм кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатлар, шулай ук сыйфатларның үзләреннән кыскарып килеп чыккан хосусый кисәкчәләр ярдәмендә ясалган артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар *(кызыл, кызгылт, алсу, кып-кызыл* һ. б.);

в) барлык гади саннарны, дистәләрне белдергән төп сан исемнәре; шулардан ясалган бүлем, чама, тәртип һәм жыю саннары (*биш, бишәр, бишләп, бишенче, бишәү; егерменче, йөзәрләп, миллионлап* һ. б.);

г) фигыльләрнең, төп юнәлештән тыш, *-ымсыра (-мсыра) // -емсерә (-мсерә), -ынкыра (-нкыра) // -енкерә (-нкерә)* формалары һәм, яңа мәгънәгә, мәгънә төсмерена яки тотрыклы семантик, стилистик үзенчәлеккә ия булган очракта, башка юнәлеш формалары да Сүзлеккә алынды. Мәсәлән: *котырту, беленү сугылу, көлешү* һ. б.;

д) исемләшкән исем һәм сыйфат фигыльләр *(көтү, сайлау, буяу, укытучы, сатучы),* сыйфатлашкан сыйфат фигыль *(кайнар, укыган, бетмәс-төкәнмәс)* һәм рәвешләшкән хәл фигыльләр *(егыла-тора, качапоса).*

§ 4. *-гы // -ге, -кы // -ке, -кай // -кәй, -гай // -гәй, -лы // -ле, -лык // -лек, -сыз // -сез, -учы // -үче, -ча // -чә, -чан // -чән, -чык // -чек* һ. б. кайбер кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләрнең тик мөстәкыйль (туры яки күчмә) мәгънә яки мәгънә төсмере алганнары гына Сүзлеккә кертелде. Мәсәлән: *акыллы, тыныч-сыз, жәйге, кызыклы, санаучы, печәнлек, эшчән, сугышчан* һ. б. ш.

§ 5. XX йөз башларындагы пуристик агым тудырган сүзләр, Октябрьдан соңгы елларда ясалган кайбер неологизмнар яки аерым бер автор тарафыннан гына кулланылган, ләкин әдәби телгә кереп, халыклашып китә алмаган сүзләр, шул исәптән, индивидуаль калькалар Сүзлеккә кертелмәде. Мәсәлән: *берләшмәк* (хезмәттәшлек), *тәлинкәче* („ялагайланучы" мәгънәсендә — Г. Ибраһимовта); *коммунчы* (М. Фәйзидә); *дулкынчы* (Ф. Кәримдә); *мататсы, хәтәрстан, колхозбай* (Н. Исәнбәттә); *бүрекбай* (Ф. Хөснидә).

§ 6. Тамыр сүзләр белән берәттән Сүзлеккә төрле типтагы ясалма сүзләр дә алынды. Шул исәптән:

а) саф кушма сүзләр *(билбау, һәркем, ашъяулык, бозваткыч* һ. б.);

б) кыскартылган кушма сүзләр *(партком, совхоз, драмтүгәрәк* һ. б.);

в) матур әдәбиятта һәм гомуми матбугатта еш очрый торган хәрефле кыскартмалар: *КПСС, РСДРП, СССР* һ. б.;

г) парлы сүзләр *(ару-талу, урынлы-урынсыз, чут-чут, ай-һай, исәп-хисап, кием-салым, сөяк-санак, сирәк-мирәк* һ. б.).

§ 7. Киң кулланышлы һәм продуктив булган алкушымчалар, шулай ук кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәге сыйфатында килгән интернациональ һәм оригиналь терминологик һ. б. ш. элементлар Сүзлеккә кертелде. Мәсәлән: *агро-, би-, био-, гео-, дис-, гомум-, -метр, -мазар* һ. б. ш.

II. Сүзлекнең төзелеше

§ 8. Сүзлек аерым сүзләргә караган мәкаләләрдән тора. Сүзлеккә кертелгән һәр баш сүзгә аерым мәкалә төзелде.

§ 9. Баш сүздән соң аның грамматик һәм стилистик үзенчәлекләрен характерлый торган билгеләр куелды (бу турыда V бүлекне карагыз). Шуннан соң мәгънәгә аңлатма бирелде һәм иллюстрация материалы китерелде. Сүзнең барлык мәгънәләре ачылганнан соң, кызыл юлдан тезмә сүзләр һәм фразеологик әйтелмәләр теркәлде (бу турыда IV бүлекне карагыз).

Һәр мәгънә, ноктадан гарәп цифры белән аерылып, кызыл юлдан бирелде. Мөстәкыйль мәгънәле сүзләрнең ярдәмлек (мәсәлән, фигыльләрнең — ярдәмче фигыль, кайбер исемнәрнең — бәйлек функциясендә кулланылган) мәгънәләре, кызыл юлга чыгарылмыйча, жәяле гарәп цифры белән генә аерылдылар.

Сүзнең мәгънә төсмерләре параллель сызыклар // белән, ә аның теге яки бу мәгънәсендәге грамматик һәм стилистик кулланыш үзенчәлекләре бер сызык / белән аерып күрсәтелделәр. Мәсәлән:

САЙЛАУ *ф.* **1.** Яхшырагын яки кирәгрәген өзләү-карау яисә аерып алу. *Сыерчыкларның оя сайлавы. Эш сайлау. Баскетбол командасына озынрак буйлы егетләр сайлау.* □ *Кыз егетне, егет кызны Бик яхшылап сайласын.* Жыр. // Өстенрәк, яхшырак, дөресрәк дип табу. — *Мин кулымнан килгән чараларның иң соңгысын сайладым.* К. Нәҗми.

ЗИЛЗИЛӘ *и.* **1.** Көчле жир селкенү, жир тетрәү. // *күч.* Тетрәү, давыллану. *Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күче-*

нүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына ... тагын күтәрелә. Г. Кутуй.

ОЧЫНУ *ф.* ... 5. *күч.* Дәртләну, ашкыну. [*Зәйтүнәнең*] *рухи кузгалышын белмәгән кешеләр өчен бу һәрхәлдә аңлаешсыз бер очыну иде.* Ф. Хөсни. / *рәв. мәгъ. Бу җырларны җырлый безнең эшче Йөрәксенеп һәм дә очынып.* М. Гафури.

§ 10. Исем, сыйфат, сан һәм алмашлык баш килештә, берлек санда бирелде. Төрләнеше үзенчәлекле булган алмашлыкларның, җәяләр эчендә, кыек килеш формалары да күрсәтелде. Мәсәлән:

ШУЛ (шуның, шуңа, шуны, шуннан, шунда) *а.* ...

§ 11. Фигыль *-у // -ү* формасында алынды.

§ 12. Тигез хокуклы грамматик һәм фонетик вариантлар *(барлы-юклы, юклы-барлы; аяк-кул, кулаяк; аз, әз; ачы, әче* һ. б.) мөстәкыйль сүзлек берәмлекләре итеп алындылар һәм һәркайсы, алфавит тәртибендә, үз урынында бирелде.

§ 13. Омонимнар, бер-берсеннән рим цифрлары белән аерылып, мөстәкыйль мәкаләләр рәвешендә бирелде. Мәсәлән:

АЙ I *и.* 1. Җирнең иң якын табигый иярчене булган һәм кояш нурлары яктылыгын чагылдыра торган күк җисеме.

АЙ II *ы.* 1. Авыртуны, сызлану-сыкрануны, куркуны һ. б. ш. белдерә.

§ 14. Омонимнарны үзара урнаштыру тәртибе 19 нчы § та бирелгән принциплардан чыгып билгеләнде.

III. Сүзләрнең мәгънәләрен билгеләү һәм аңлату

Мәгънәләрне алу һәм урнаштыру

§ 15. Сүзлеккә сүзләрнең хәзерге әдәби телдә кулланыла торган барлык мәгънәләре алына. Мәгънәләрне алу сүзләрне алу принципларына туры китереп эшләнде (*к.* §§ 1, 2, 5).

§ 16. Алынма сүзләрнең тик татар телендә кулланылган мәгънәләре генә Сүзлеккә кертелде.

§ 17. Күчмә мәгънә *күч.* билгесе белән күрсәтелде. Ләкин сүздәге образлылык ачык сизелмәгән очракларда бу билге куелмады. Мәсәлән:

КӘГАЗЬ *и.* 1. Чүпрәк-чапрактан, агачтан яки башка әйберләрдән ясалып, язу, китап басу, әйберләр төрү һ. б. максатлар өчен кулланыла торган юка табаклардан гыйбарәт материал.

2. *сөйл.* Рәсми характердагы язма документ.

§ 18. Сүзләрнең тотрыклы эмоциональ мәгънәләре яки төсмерләре *ирон.* (ироник), *шелт.* (шелтәләү), *кимс.* (кимсетү) кебек билгеләр ярдәмендә күрсәтелде.

§ 19. Күп мәгънәле сүзгә характеристика биргәндә, сүзнең бөтен семантик структурасы исәпкә алынып, аның аерым мәгънәләре билгеле бер тәртиптә урнаштырылды:

а) мәгънәләрнең үзара бәйләнеше аларның хәзерге әдәби телдә кулланышына карап билгеләнде; мәгънәләр логик эзлеклелекне һәм генетик бәйләнешне мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырылды;

б) мәгънәләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне хәзерге тел материаллары ачык күрсәтеп торганда, сүзнең мәгънә төзелешен аңлауны жиңеләйтердәй очракларда, беренчел мәгънәләр, искергән булсалар да, алдан бирелде. Барлык башка очракларда искергән мәгънә, кагыйдә буларак, хәзерге мәгънәләрдән соң теркәлде;

в) конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алда урнаштырылды;

г) киң кулланыштагы мәгънә таррак кулланышлы (сөйләү теле яки гади сөйләм өчен генә хас булган, диалекталь, терминологик һ. б.) мәгънәләрдән алда бирелде. Диалекталь мәгънәләр гомуми һәм махсус кулланыштагы мәгънәләрдән соң теркәлде;

д) күчмә мәгънә үзе караган туры мәгънәдән соң ук бирелде;

е) бер үк стилистик төсмергә ия булган мәгънәләрнең ешрак кулланыла торганы алдан китерелде;

ж) сүзнең башка сүз төркеме функциясендә килгән яки аерым синтаксик позициядә ачылган мәгънәләре төп мәгънәләрдән соң урнаштырылды;

з) мөстәкыйль сүзнең ярдәмлек функциясендә кулланыла торган мәгънәсе (яки мәгънәләре) аның мөстәкыйль мәгънәләреннән соң бирелде.

§ 20. Сүзнең берәр кыек грамматик формасы өчен генә хас булган мәгънә (яки мәгънә төсмере) шул ук сүз мәкаләсе эчендә гомуми кагыйдә нигезендә бирелде. Мәсәлән:

АРТ *и.* ... 11. *бәйл. функ. юн. килеш. форм.* **артына.** 1) хәрәкәтнең предметның арткы ягына, арткы өлешенә юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Китап диван артына төшү.* □ — *Мин, кечкенә бер агачлыкны сикереп үтеп, юлым өстендә торган җәенке карама артына барып постым.* А. Шамов; 2) берәр төрле эш башкарганда кем дә булса янына урнашкан предметны белдерү өчен кулланыла. *Өстәл артына утыру. Штурвал артына басу.*

КЫЗЫЛ *с.* ... 5. *күч...* // *и. мәгъ. күпл. тар.* **кызыллар.** 1) совет, социалистик төзелеш яклы кешеләр, коммунистлар, революционерлар, революцион гаскәрләр.

§ 21. Алынма сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибе татар телендә кулланылган мәгънәләрнең үзара бәйләнешеннән чыгып билгеләнде.

Мәгънәләргә аңлатма бирү

§ 22. Сүзлек берәмлеге итеп алынган барлык төр сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә тиешле аңлатма бирелде.

§ 23. Мәгънәләргә һәм мәгънә төсмерләренә аңлатма биргәндә, стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр генә файдаланылды, тар кулланышлы (гади сөйләмдәге, поэтик, диалекталь, махсус һ. б.), сирәк очрый торган, искергән яки күчмә мәгънәдәге, шулай ук бу Сүзлеккә кертелми торган сүзләр кулланылмады.

§ 24. Сүзлектә өч төрле аңлатма кулланылды.

1) Тасвирлаулы аңлатма. Мәгънәләргә һәм мәгънә төсмерләренә билгеләмә бирүнең бу төп формасы түбәндәге очракларны эченә ала:

а) чынбарлыктагы предметларны яки күренешләрне белдерә торган сүзләрнең төп билгеләрен чагылдырган аңлатма (мөстәкыйль сүз төркемнәре һәм ымлыклар, аваз ияртемнәре янында).

Мәсәлән:

БҮРЕК *и.* Җылы баш киеме.

ЯШЕЛ *с.* Төсләр спектрында зәңгәр белән сары арасындагы төстә булган; үсеп утырган үлән яки яфрак төсендәге.

ЕГЕРМЕ *Төп сан.* 20 санын һәм микъдарын белдерә торган сүз.

ЫРГЫТУ *ф.* 1. Кулдагы әйберне куәт белән кемгә яки нәрсәгә төбәп очыру, ату, ташлау.

ЖУ *аваз ияр.* Бөҗәкләр очуыннан, кешеләр һ. б.

шаулавыннан яки механизмнарның зур тизлек белән хәрәкәт итүеннән барлыкка килә торган тавышларны белдерә.

б) сүзләрнең төрле грамматик мәнәсәбәтләрен һ. б. ш. чагылдырган аңлатмалар; болар алмашлыкларда, хәбәрлек һәм ярдәмлек сүзләрдә кулланылды. Мәсәлән:

СИН *а. 2-зат, берл.* **1.** Берәр кешегә турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә кулланыла.

ТҮГЕЛ *юкл. кис.* **1.** Барлык мәстәкыйль сүз төркемнәре һәм кайбер модаль сүзләр янында килеп, шулардан аңлашылган нәрсәләрнең юклыгын белдерә.

ӨЧЕН *бәйл.* **1.** Эш-хәрәкәтнең максатын белдергәндә кулланыла.

ДИМӘК II *кер. сүз.* Соңрак әйтелгән сүзнең, фикернең башта әйтелгәнгә карата йомгаклау яки нәтиҗә мәнәсәбәтендә торганлыгын белдереп, „шуңа күрә“ „шулай булгач“ дигән мәгънәдә кулланыла.

2) Синонимик билгеләмә, ягъни бер сүзнең мәгънәсен ачу өчен аның синонимын (яки синонимнарын) файдалану. Мондый аңлатма гадәттә нинди дә булса бер стилистик төсмере булган (искергән, диалекталь, гади сөйләмнән булган һ. б.) сүзнең яки кайбер алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланылды. Мәсәлән:

БҮТӘНЧӘ *рәв. сөйл.* Бүтән рәвештә, башкача.

ГЫЙЛЕМ *и.* **1.** Белем.

САРЫФ I *и. иск. лингв.* Морфология.

3) Икенче сүзгә кайтару. Бу рәвешчә түбәндәге төркем сүзләр аңлатылдылар:

а) кимлек һәм артыклык сыйфатлары. Мәсәлән:

ЗӘП-ЗӘҢГӘР *с. Артык. дәр. к.* зәңгәр.

САРГЫЛТ *с. Кимл. дәр. к.* сары I.

б) ясалма саннар. Мәсәлән:

УНАР **1.** *Бүл. саны. к.* ун.

БИШЕНЧЕ *Тәрт. саны. к.* биш (1 мәгъ.).

СИГЕЗЛӘП *Чама саны. к.* сигез.

ҖИДӘҮ *Җыю саны. к.* җиде.

в) кайбер фигыль формалары. Мәсәлән:

КИСКӘЛӘҮ *ф.* **1.** *Каб. дәр. к.* кисү.

2. Кисеп, вак кисәкләргә, кисәкчекләргә бүлү, аеру.

г) кайбер төрдәге стилистик чикләнгән сүзләр. Мәсәлән:

ИНСАНИЯТЛЕК *и. иск. кит. к.* кешелеклелек.

САЧ *и. иск. шигъ. к.* чәч.

ЮКЛЫ-БАРЛЫ *с. к.* барлы-юклы.

ӘЗ *рәв. к.* аз.

Күп мәгънәле сүзләргә яки омонимнарга кайтару очракларында сүзнең кайсы мәгънәсенә яки кайсы омонимга кайтаруны күрсәткән билгеләр куелды. Мәсәлән:

ШАШЫНУ *к.* шашу (1, 2, 5 мәгъ.)...

§ 25. Әгәр сүзнең мәгънәсе тасвирлау юлы белән ачылып җитмәсә, аңлатма шул сүзнең синонимнары белән тулыландырылды. Мәсәлән:

КЫЮ *с.* Курку хисенә бирелми торган, курыкмый торган; батыр, тәвәккәл.

Катнаш аңлатмада антонимнар да кулланылды. Антонимнар аңлатма ахырында ноктасы өтер белән аерып бирелделәр. Мәсәлән:

АК I *с.* **1.** Кар, сөт, акбур төсендәге; *киресе*: кара.

§ 26. Предметның яки күренешнең гомуми кулланыштагы исемен белдергән һәм шул ук вакытта аның терминологик атамасы да булып торган сүзгә аңлатма биргәндә, бу сүзнең гомуми кулланыштагы мәгънәсе нигез итеп алынып, аңлатма фәнни билгеләмәгә яраклаштырылды. Мәсәлән:

ҖИЛ *и.* **1.** Һава агымының горизонталь юнәлештәге хәрәкәте.

§ 27. Киң кулланыштагы сүзнең яки мәгънәнең бәйләнеш сферасы чикләнгән булуы аңлатмада түбәндәгечә күрсәтелде:

ҖИБӘРҮ *ф.* ... **21.** Чыгару (тамыр, бөре, үренте һ. б. ш. турында). *Бөреләр җибәргән инде Койма буйларында каен.* С. Хәким. // Үстерү (чәч, мыек, сакал турында). *Шәкертләр бер-бер артлы чәч җибәрергә тотындылар.* Ә. Фәйзи.

IV. Тезмә сүзләр. Фразеология

Тезмә сүзләрне Сүзлеккә алу

§ 28. Сүзлеккә тезмә сүзләрнең түбәндәге төрләре алынды:

а) исем (сирәгрәк сыйфат, рәвеш) һәм аваз ияртемнәре + ярдәмче фигыль өлгесендә ясалган тезмә фигыльләр: *ярдәм итү, азат итү, үч алу, искә төшү, аңга килү, жу итү, төр килү* һ. б.;

б) фигыль + *килү, китү, чыгу, җитү, керү* ярдәмче фигыльләре белән ясалган параллель яки эзлекле хәрәкәтне белдергән тезмә фигыльләр: *килеп керү, чыгып китү, кайтып килү, төшеп китү, менеп җитү, куып җитү, килеп чыгу, йөреп чыгу* һ. б.

Шул ук өлгедә *җитү, китү* ярдәмче фигыльләре белән ясалып, эш-хәлнең нәтиҗәсен, төгәлләнүен яки көтмәгәндә, бик тиз башкарылуын белдерә торган тезмә фигыльләр: *үсеп җитү, пешеп җитү, җылынып җитү, айнып җитү, сискәнеп китү, агарып китү, янып китү, үлеп китү* һ. б.

Искәрмә. Тезмә фигыльләрнең шундый ук өлгедә ясалган *укып бару, укып тору, укып китү, укып кую, укып чыгу, укып җибәрү* кебек төрләре, күләм чикле булу сәбәпле, Сүзлеккә кертелмәделәр;

в) терминологик характердагы тезмә сүзләр: *кызыл почмак, яктылык елы, кызыл балык, йокы артериясе, мүк җиләге, кычыткан чыпчыгы, кәҗә сакалы, эт эчәгесе* һ. б.

Фразеологик әйтелмәләрне Сүзлеккә алу

§ 29. Сүзлеккә фразеологик әйтелмәләрнең түбәндәге төрләре алынды:

а) төрле сүз төркемнәре функциясендә йөри торган идиомалар: *кара алтын, юл ачу; күз күрмәгән, колак ишетмәгән, колактан колакка, көннәрдән бер көнне;*

б) төрле кереш-модаль сүзләр функциясендә йөри торган тезмәләр: *озын сүзнең кыскасы, әлеге дә баягы, бәхеткә каршы*;

в) *менә сиңа кирәк булса, каян килеп кая китмәгән, булмаса булган икән* тибындагы эмоциональ җөмләләр;

г) *миннән киткәнче, иясенә җиткәнче; (аның белән яки аңа) каберең якын булмасын, ---димәсәң хәтере калыр* тибындагы предикатив тезмәләр;,

д) *эш муеннан, бала җанлы, җан дуслар куркак җан, кан дошманы* тибындагы, ягъни туры һәм күчмә мәгънәдәге компонентлардан торган тотрыклы сүз тезмәләре.

§ 30. Мәстәкыйль һәм ярдәмлек сүздән төзелгән идиоматик төзелешле тотрыклы тезмәләр: *аның саен, чүп тә түгел, борын төбендә, май кебек, бише белән.*

§ 31. Сүзлеккә тезмә сүзләрне һәм фразеологик берәмлекләрне алу аерым сүзләрне алу принципларына туры китереп эшләнде (*к.* §§ 1, 2, 5).

§ 32. Тезмә фигыльләр һәм терминологик тезмә исемнәр баш сүз мәкаләсе эчендә кызыл юлдан урнаштырылдылар. Ә фразеологик әйтелмәләр (шулай ук кызыл юлдан) ромб ◇ билгесеннән соң бирелделәр.

§ 33. Тезмә сүз яки фразеологик әйтелмә үзенең беренче сүзе мәкаләсенә кертелде.

Беренче компоненты аерым рәвештә кулланылмый торган тезмә сүз яки фразеологик әйтелмә өчен мөстәкыйль мәкалә төзелде һәм ул түбәндәгечә теркәлде:

ВАЗ: ваз кичү — ...

ИГЕ-ЧИГЕ: иге-чиге булмау — ...

§ 34. Тезмә сүзләр һәм фразеологик әйтелмәләр үз эчләрендә алфавит тәртибендә бирелде.

§ 35. Тезмә сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең вариантлары Сүзлектә түбәндәгечә бирелде:

а) бер-берсеннән компонентлары белән аерылып торган вариант тезмә сүзләр һәм фразеологик әйтелмәләр иң актив кулланыштагы вариант урынында (синоним компонентларны җәя эчендә күрсәтү юлы белән) бирелде: *өскә (тәнгә) салкын су сипкәндәй булу, кот очу (чыгу, алыну), ык-мык итү (килү).*

б) факультатив компонентлар да җәя эченә алынды: *(авызда) сүз тормау.*

§ 36. Тезмә сүзләрнең һәм фразеологик берәмлекләрнең мәгънәләре җәяле гарәп цифры белән аерылды, ләкин кызыл юлдан бирелмәде.

V. Сүзләргә грамматик һәм стилистик характеристика бирү

§ 37. Сүзләргә грамматик һәм стилистик характеристика бирү махсус билгеләр (пометалар) ярдәмендә башкарылды.

§ 38. Грамматик билгеләр сүзнең а) кайсы сүз төркеменә караган булуын, б) аның кайбер грамматик формаларын, в) башка сүз төркеме яки ярдәмче сүз функциясендә кулланылу очракларын һәм г) тиешле урыннарда синтаксик функциясен күрсәтәләр:

ТАНУ I *ф.* (таны, таный, таныр, таныячак)...

ТАНУ II *ф.* (тан, тана, танар, таначак)...

БӘЛКИ 1. *терк.* ... 2. *кер. сүз.* ...

§ 39. Саннар, алмашлыклар һәм ярдәмлек сүзләр янында аларның морфологик төркемчәләрен күрсәткән грамматик билгеләр дә куелды: **БЕР** *сан;* **ӨЧӘР** *Бүл. саны;* **МИН** *а. 1-зат, берл.;* **БИТ** *расл. кис.*

§ 40. Грамматик билгеләр белән шулай ук куш сүзләрнең (исемнәрнең) җыймалык төсмере; сыйфатларның кимлек, артыклык дәрәҗәләре; фигыль юнәлешләре һ. б. күрсәтелде:

АШ-СУ *җыйм. и.*

БАЛА-ЧАГА *җыйм. и.*

КАРАЛҖЫМ *с. Ким. дәр.*

ЯМЬ-ЯШЕЛ *с. Артык. дәр.*

ЯЗЫШУ *ф* 1. *Урт. юн. к.* язу (1—3 мәгъ).

§ 41. Сүз кулланышның хәзерге нормаларына нигезләнеп, сүзләргә стилистик характеристика бирелде, аларның кулланыш чикләре, эмоциональ төсмерләре күрсәтелде. Мәсәлән: *кит.* (китап теле сүзе), *диал.* (диалекталь сүз), *күч.* (күчмә мәгънәдә), *мыск.* (мыскыллап әйтү), *махс.* (махсус термин), *лингв.* (лингвистик термин) һ. б.

§ 42. Гомумкулланыштагы (стилистик нейтраль) сүзләр янында бернинди дә стилистик билге куелмады.

§ 43. Фразеологик әйтелмәләргә стилистик характеристика бирү дә шул ук принциплардан чыгып эшләнде:

Кызыл авыз — 1) *иск.* ...; **Агач авыз** *гади с.*

Фразеологик әйтелмәләрнең күпчелеге сөйләү теленә караганлыктан, алар янында *сөйл.* дигән стилистик билге куелмады.

§ 44. Стилистик билгеләр грамматик характеристикадан соң, сүзләрнең мәгънәләренә бирелә торган аңлатмадан алда куелды. Әгәр стилистик төсмер сүзнең аерым мәгънәсенә генә караса, билге шул мәгънәнең аңлатмасы алдыннан куелды:

АГАЧ *и.* ... 3. *күч. гади с. хур.* Аңсыз, аңгыра, надан.

ТӨШЕРҮ *ф.* ... 16. *күч. гади с.* Берәр нәрсәне хәйлә яки җиңел юл белән үз милкенә алу, үзләштерү.

VI. Иллюстратив материал

§ 45. Сүзләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә бирелгән аңлатмалар, аерым очракларны исәпкә алмаганда (*к.* § 50), һәрвакытта да иллюстратив материал, ягъни мисаллар белән ныгытып барылды. Алар сүзнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә бирелгән аңлатмаларны, шул сүзгә караган грамматик-стилистик характеристиканы раслый.

§ 46. Иллюстрация итеп китерелгән җөмләләр, нигездә, матур әдәбияттан, шулай ук иҗтимагый-политик, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән һәм дәреслекләрдән алынды.

§ 47. Аерым очракларда иллюстратив материал сыйфатында сүз тезмәләре генә дә файдаланылды. Мәсәлән: **ТҮГӘРӘК** сүзенең бер мәгънәсенә—*Политик түгәрәк. Әдәбият түгәрәге. Драма түгәрәге;* **АЛУ** фигыленең бер мәгънәсенә — *Чәч алу. Сөт өстен алу. Юкә кабыгын алу* һ. б. ш. кебек сүз тезмәләре китерелде.

§ 48. Сүзнең мәгънә һәм кулланыш үзенчәлекләрен тулырак ачу максаты белән, еш кына сүз тезмәләреннән соң җөмләләр дә китерелде. Сүз тезмәләре һәм җөмләләр рәттән килгәндә, алар арасында озынчык □ билгесе куелды. Мәсәлән:

КЫЗЫЛ *с.* 1. ... *Кызыл флаг. Кызыл чәчәк.* □ *Вафа кызыл күлмәк өстеннән каеш буган.* М. Фәйзи.

§ 49. Икенче сүзгә кайтару юлы белән аңлатыла торган (диалекталь, искергән, гади сөйләм һ. б.) стилистик чикләнгән сүзләргә дә иллюстрация бирелде:

ТҮГРЫ II *рәв. иск. к.* туры I. *Түгры әйтергә яраганда, кинаяләргә сыгыну нәрсәгә?* Г. Тукай.

§ 50. Халык һәм милләт атамаларына, профессия исемнәренең, терминнарның һәм кыскартылган кушма сүзләрнең күпчелегенә, хәрефле кыскартылмаларга, кайтару юлы белән аңлатыла торган кайбер сүзләргә иллюстрация бирү мәҗбүри итеп куелмады.

§ 51. Җөмлә уртасында сүзләр төшереп калдыру очраклары өч сызыкча (- - -) белән күрсәтелде: *Җәүдәт - - - революция давылы эченә бик яшьләй килеп керде.* Г. Бәширов.

Әгәр җөмләнең башы яки ахыры кыскартылса, сызыкчалар куелмады.

§ 52. Җөмләдә алмашлык алыштырган сүзне, репликаның кемгә төбәлгән булуын яисә кем тарафыннан әйтелүен һ. б. ачыклау өчен кирәкле искәрмәләр квадрат җәяләр [...] эчендә бирелде: — *Рус, чуваш, мари, татар батраклары барыбыз да аңа [байга] бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләдек.* Г. Әпсәләмов. [*Бәбкәле каз бәбкәсезенә:*] *Нишләп ялгыз башыңны каңкайтып, минем балаларым янында йөрисең?* —

ди. Г. Галиев. [*Исәнбай:*] *Әйдә, Байтирәк абый, безнең якка, Урал заводларына, эшкә китәбез.* Т. Гыйззәт.

Әгәр алмашлык җөмлә башында килсә, ул бөтенләй төшерелеп, аны алыштырган сүз квадрат җәяләр эчендә үзе генә бирелде: [*Җәүдәткә*] *семьясының җылы куенында озак назланырга туры килмәде.* Г. Бәширов.

§ 53. Җөмләләрдә тыныш билгеләре оригиналдагыча калдырылды.

Әгәр оригиналда аларның дөрес куелмавы ачык сизелеп торса, төзүче гамәлдәге тыныш билгеләре кагыйдәләренә таянып эш итте.

§ 54. Һәр җөмлә янында чыганакның авторы күрсәтелде.

VII. Орфография һәм басым

§ 55. Сүзлек гамәлдәге орфография кагыйдәләре нигезендә төзелде.

§ 56. Сүзнең мәгънә һәм мәгънә төсмерләренә караган аңлатмалар, сүзлек мәкаләсе эчендә бирелгән тезмә лексик берәмлекләр, фразеологик әйтелмәләр, шулай ук иллюстрация мисаллары баш хәрефтән бирелде.

§ 57. Басым сүзнең соңгы иҗегенә төшмәгән очракларда гына куелды. Мәсәлән: **ТАТА'РЧА, Ә'ММА, ЧӨ'НКИ, БӘ'ЛКИ, А'ЙСБЕРГ, ИНКУБА'ТОР, СОЦИАЛИ'СТИК** һ. б.

Чыгарма. 1. Мәгънәләре басым ярдәмендә генә аерыла торган бердәй язылышлы сүзләрдә соңгы иҗеккә төшкән басым да күрсәтелде. Мәсәлән: **БАРЛЫ'К** *и* ..., **БА'РЛЫК** *а.* ...; **КИСӘКЧӘ'** *и.* ..., **КИСӘ'КЧӘ** *рәв.* ...; **ХӘЕ'Р** *и.* ..., **ХӘ'ЕР** *кер. сүз.* ...; **О'РГАН** *и* (мәсәлән, кан әйләнеше органнары), **ОРГА'Н** *и.* (музыка коралы).

2. Омографларда (язылыш формалары бер булып, мәгънәләре әйтелеш һәм басым белән аерылган сүзләрдә) басым шулай ук соңгы иҗектә дә куелды. Әйтелеше үзгә булган сүзнең җәяләр эчендә транскрипциясе дә бирелде. Мәсәлән: **АРКА'** [арқа] *и* ..., **А'РКА** *и.* ...; **КОЙКА'** [қойқа] *и.* ..., **КО'ЙКА** *и.* ....

3. Сөйләү телендә сүзнең басымын бутау ихтималы булган очракларда, соңгы иҗеккә төшүгә карамастан, басым күрсәтелде. Мәсәлән: **ПОРТФЕ'ЛЬ** *(пóртфель* түгел), **КВАРТА'Л** *(квáртал* түгел), **ДОГОВО'Р** *(дóговор* түгел) һ. б.

4. Кайбер алынма сүзләр ике төрле басым белән әйтеләләр. Сүзлектә һәр ике очрагы да (беренче урында тәкъдим ителә торган басым) күрсәтелде. Мәсәлән: **АНА'ПЕСТ, АНАПЕ'СТ; О'БЩИНА, ОБЩИ'НА** һ. б.

ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

а. — алмашлык
аваз ияр. — аваз ияртеме
авиа. — авиация
артык. — артыклык (дәрәҗәсе)
а.-х. — авыл хуҗалыгы
аз. — азайту (дәрәҗәсе)
анат. — анатомия
анык. — аныклау (кисәкчәсе яки теркәгече)
археол. — археология
астр. — астрономия
баш килеш. бәйл. — баш килеше белән килгән бәйлек
берл. — берлек сан
бил. — билгеләү (алмашлыгы)
биол. — биология
бор. — борынгы (сүз)
бот. — ботаника
б-сез. — билгесезлек (алмашлыгы)
бәйл. — бәйлек
бүл. — бүлем (саны).
бүлг. — бүлгәләүче (теркәгеч)
гади с. — гади сөйләм
геогр. — география
геол. — геология
геом. — геометрия
диал. — диалекталь сүз
дини — дини сүз
дәр. — дәрәҗә
жарг. — жаргон
зат — зат (алмашлыгы)
зоол. — зоология
з-сыз — затланышсыз (фигыль)
и. — исем
игътб. — игътибарсыз караш
ик. — икеләнү (кисәкчәсе)
инк. — инкяр (кисәкчәсе)
ирк. — иркәләү сүзе
ирон. — ироник мәгънәдә
иск. — искергән (сүз)
иял. килеш. бәйл. — иялек килеше белән килгән бәйлек
йөкл. — йөкләтү (юнәлеше)
к. — кара
каб. — кабатлау (дәрәҗәсе)
каб. форм. — кабатлаулы формада
кайт. — кайтым (юнәлеше)
карг. — каргау (каргыш) сүзе
карш. — каршылык (теркәгече)
кер. сүз — кереш сүз
кеч. — кечерәйтү
килеш — килеш (формасында)
ким. — кимлек дәрәҗәсе
кимс. — кимсетеп әйтү
кис. — кисәкчә
кит. — китап теле
көч. — көчәйткеч (кисәкчә)
күпл. — күплек (сан)
күрс. — күрсәтү (алмашлыгы)
күч. — күчмә мәгънәдә
лингв. — лингвистика
лог. — логика

мат. — математика
махс. — махсус термин (антропология, архитектура, аучылык, бакчачылык, бактериология, биохимия, бухгалтерия, ветеринария, геодезия, гидрология, гидромеханика, дипломатия, диңгезчелек, кинематография, коммерция, кортчылык, кулинария, метеорология, механика, минералогия, оптика, полиграфия, радиотехника, тимер юл, типография, топография, тукучылык эше, фармакология, шахмат уены, юридик һ. б. өлкәләргә караган терминнар)
мед. — медицина
миф. — мифология
муз. — музыка
мыск. — мыскыллау
мәгъ. — мәгънәдә
мөн. — мөнәсәбәтлек (сүз)
неол. — неологизм
обр.ияр. — образлы иярtem
пед. — педагогика
психол. — психология
ритор. — риторик
рәв. — рәвеш
рәс. — рәсми
с. — сыйфат
сан — сан
сир. — сирәк кулланышта
сор. — сорау (алмашлыгы)
спорт — физкультура һәм спорт
сын. — сынлы (сәнгать)
сәб. — сәбәп (теркәгеч)
сәнг. — сәнгать
сөйл. — сөйләү телендә
тар. — тарихи
тарт. — тартым (алмашлыгы)
театр — театр сәнгатенә караган сүз
терк. — теркәгеч
тех. — техника термины
тирг. — тиргәү сүзе
туп. — тупас сүз
тәрт. — тәртип (саны)
төш. — төшем (юнәлеше)
урт. — уртаклык (юнәлеше)
у.-вак. — урын-вакыт килеше
ф. — фигыль
физ. — физика
физиол. — физиология
филос. — философия
фольк. — фольклор
форм. — формасында
функ. — функция
хим. — химия
хупл. — хупламау
хур. — хурлау
хәб. — хәбәр (функциясендә)
хәб. сүз — хәбәрлек сүз
хәрби — хәрби сүз
чама — чама (саны)
чаг. — чагыштыру
чик. — чикләү (кисәкчәсе)
чыг. килеш. бәйл. — чыгыш килеше белән килгән бәйлек
шаярт. — шаярту сүзе
шарт — шарт (теркәгече)
шелт. — шелтәләү сүзе
шигъ. — шигъри сөйләмдә
шөбһ. — шөбһәләнү
энд. — эндәш сүз
эвф. — эвфемизм
экон. — экономика
эпис. — эпистоляр стиль
этн. — этнография
юг. — югары стиль
юкл. — юклык (алмашлыгы)
юн. — юнәлеш
ярд. — ярдәмче (фигыль яки сүз)
ы. — ымлык
әд. — әдәбият термины
җыйм. — җыйма (исем)
җыр — халык җыры
җыю. — җыючы (теркәгеч)

ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

// — сүзнең мәгънә төсмерләрен аера торган билге (к. § 9).
/ — сүзнең грамматик һәм стилистик кулланыш үзенчәлекләрен аерып күрсәтә торган билге (к. § 9).
◇ — фразеологик әйтелмәләрне аерып бирү билгесе (к. § 32).
▭ — иллюстрация мисалларында сүз тезмәләрен җөмләләрдән аера торган билге (к. § 48).
- - - — җөмләләрне кыскарту билгесе (к. § 51).

АЛФАВИТ

А а	И и	Р р	Ш ш	Ә ә
Б б	Й й	С с	Щ щ	Ө ө
В в	К к	Т т	Ъ ъ	Ү ү
Г г	Л л	У у	Ы ы	Җ җ
Д д	М м	Ф ф	Ь ь	Ң ң
Е е	Н н	Х х	Э э	Һ һ
Ж ж	О о	Ц ц	Ю ю	
З з	П п	Ч ч	Я я	

А

А I Татар алфавитында беренче хәреф.

А II *ы.* 1. Нәрсәнедер хәтерләүне, кинәт булган бер хәлгә гаҗәпләнүне белдерә. [*Хәзрәт:*] *Ааа ... без, сүз белән, килеп җиткәнне тоймый да калганбыз.* Г. Ибраһимов. // Кемне дә булса очратканда таныганлыкны белдерә. — *А! Габдулла агай! Әйдә, түргә уз.* Һ. Такташ. // Кемне яки нәрсәне дә булса күргәндә шатлык, канәгатьлек хисен белдерә. — *А, килдегез, яхшы, бик яхшы, хәзер менә, аз гына көтеп торыгыз, ярыймы.* Ш. Камал.

2. Нәфрәтләнүне яки кеше кайгысына сөенүне белдерә. [*Хан:*] *А, килгән өчен тагын каршыма, Уз кылычың төшәр башыңа!* Ф. Бурнаш.

3. Өметсезлекне, кайгыдан сыкрануны, үкенүне белдерә. *Хәтерлимсең, сөйгән идең, Кайтырмын, дип киткән идең. А... киткән идең.* Һ. Такташ. [*Зөһрә:*] *Ике күзем!.. А, нигә килми бу үлем... Җәбер, золым тулган җир өстенә, Дәрья булып яшьләр түгелә.* Ф. Бурнаш.

4. Үкенү катыш кыюлык, батырлык, тәвәккәллекне белдерә. *Алар өчен түккән күз яшьләрем Тагын шулай җиргә агармы? А, юк! Беркем агыза алмый аларны.* Һ. Такташ.

ААЙ *ы.* Берәр нәрсәдән яки әшәке истән җирәнгәндә чырайны сытып әйтелә (күбрәк балалар телендә кулланыла).

АБАГА *и. бот.* Җәенкеләнеп, тармакланып торган, челтәр сыман зур яфраклы споралы үсемлек. [*Бозланган тәрәзәдәге бизәкләр*] *абага яфракларын хәтерләтәләр.* Ә. Фәйзи. *Нарский кулындагы абага үләнен чәчәкләр янына куйды.* А. Әхмәт.

АБАГА'СЫМАННАР *и. бот.* Югары төзелешле споралы үләнһәм агач үсемлек төре (күбесенчә җир өстендә үсә, тик су абагалары гына суда үсә). *Абагасыманнарның төзелеше мүкләргә караганда катлаулырак.* Ботаника.

АБАЖУР *и.* Яктылык күзне чагылдырмасын һәм тиешле урынга гына җыелып төшсен өчен лампага куела торган җайланма, япкыч, калпак.

АБАЖУРЛЫ *с.* Абажур куелган. *Алсу күлмәкле бер яшь кыз, кулына зәңгәр абажурлы лампа тотып, коридорга килеп чыкты.* А. Шамов.

АБАЙ: абай булу *сөйл.* — сак (сизгер) булу, сак тору, сак эш итү. [*Илдус:*] *Тимергалиев миченә барып килим.* [*Миша:*] *Юллыкны кара! Син анда абайрак бул, малай.* Н. Исәнбәт. — *Тәмле суларга алданып стансаларда адашып калмас өчен, абай булырга кирәк.* А. Гыйләҗев.

АБАЙЛАУ *ф.* 1. Сизү, сизенү, чамалау. [*Айсылу:*] *Син шуны абайлыйсыңмы, эшләрең бик начарга бара бит?* Г. Бәширов. // Уйлау, чамалау. [*Ирбулат:*] *Сүзеңне абайлап сөйлә, Мәхмүзә апа.* Р. Ишморат. *Сәләйманов, аны-моны абайламыйча, беркатлылык белән күңелдән һаман сөйләнә бирә.* Ә. Еники. // Искәрү. [*Габделхәй:*] *Ул безнең болай итеп кызулык белән чокырга төшкәнне абайламаган булырга кирәк.* Ш. Камал. *Кунаклар бар икән, абайламыйча калдым.* М. Фәйзи.

2. Күреп булу, ачык күрү. *Тузан, таралмыйча, юл өстендә асылынып тора, шунлыктан нәрсә килгәнен абайлап та булмый.* Ә. Еники.

3. *рәв. мәгъ.* **абайлап.** Җайлап, уңайлап, сак кына.

АБАЛАНУ *ф. сир.* Ашыгу, кабалану. *Ул, юлның күп өлешен абаланып кайтканга, арыган, мышкылдаган һәм нәрсәдәндер каушаган иде.* А. Шамов.

АБАЛАУ *ф. диал.* Бер алга, бер артка төшеп юл бирмичә тору (этләр турында). *Курыкканны этләр дә абалый.* Мәкаль. / *рәв. мәгъ. Миңа эт абалап өрә башлады.* М. Гафури.

АБАУ *ы.* Нинди интонация белән әйтелүенә карап, соклану, курку, гаҗәпләнү, жирәнү һ. б. ш. хисләрне белдерә. *Зөбәйдәнең сеңеле уйнап йөри, Абау матур! Күзем тимәсен.* Һ. Такташ — *Абау, абау! Бу асрау дигән нәрсәләрдә һич оят юк.* Г. Камал.

АББАТ *и. дини.* 1. Католикларда: ирләр монастыре башлыгы.

2. Франциядә: католиклар рухание.

АББАТЛЫК *и.* 1. Аббат вазифасы.

2. Аббат биләмәсе.

АББРЕВИАТУ'РА *и. кит.* Кыскартылган кушма сүз. Мәсәлән: колхоз, райком, компартия; шулай ук берничә сүзнең хәреф кыскартмасы, мәсәлән: СССР, КПСС, КДУ һ. б. ш.

АБЕРРАЦИОН *с.* Аберрациягә бәйләнешле. *Аберрацион күренеш.*

АБЕРРА'ЦИЯ *и.* 1. Оптик приборлар аша алына торган сурәтнең тиешле дәрәҗәдә ачык булмавы, бозылып күренүе.

2. *астр.* Җирнең кояш тирәсендә әйләнүе тәэсирендә йолдызларның күк йөзендә урыннарыннан авышкан булып күренүләре.

АБЗАР *и.* Терлек һәм кош-корт яба яки асрый торган каралты. *Амбар тулы ашлык, абзар тулы мал-туар дигәндәй, эшләр майланган шикелле тәгәрәп кенә бара.* Г. Бәширов.

АБЗАР-КУ́РА *и.* Өй һәм мунчадан башка барлык каралты. — *Менә Нургали туган фермага килгәч абзар-кура тирәләрен рәтләп җибәрде.* Ә. Еники.

АБЗАЦ *и.* 1. *махс.* Текстның яки аның аерым өлешенең эчкәрәк кертеп башланган беренче юлы, кызыл юл, яңа юл.

2. Текстның ике кызыл юл арасындагы өлеше.

АБЗЫЙ *и.* 1. Үзеннән олырак ир туган; абый. [*Әти белән әни*] *үлгәч, мин абзый белән җиңги кулында калдым.* М. Гафури.

2. Яшь ягыннан үзеңнән олы ир кеше исеменә кушып әйтелә. — *Син Бәдри абзыйның улы түгелмеҙ Мәрхүм Бәдри абзыйга охшагансың.* Һ. Такташ. *Ахырда Сабир абзый түзмәде, башын читкә борып, тимер читле күзлеген салды һәм яшьләнгән күзләрен кул сырты белән сөртеп алды.* Ә. Еники. // Олы яшьтәге ир кешегә мөрәҗәгать сүзе. *Абзый, абзый! Булмаган син, пешмәгән, Корсагың үскән, д гакылың үсмәгән.* Г. Тукай. *Абзый, атың юрга булса, мин дә утырыйм әле.* Җыр.

Абзый кеше *сөйл.* — якыннан таныш булмаган олырак яшьтәге ир кешегә эндәшкәндә әйтелә.

АБИССИ'НИЯЛЕ *и.* Эфиопия халкының элекке атамасы. *Абиссиниялеләр итальян гаскәрләрен Адуа шәһәрчеге янындагы сугышта туздырып ташлыйлар.* Яңа тарих.

АБИТУРИЕНТ *и.* 1. *иск.* Урта мәктәпне тәмамлаучы.

2. Вузга керер өчен имтиханнар тапшыручы кеше. *Август башларында Казанга абитуриент кызлар килеп тулганда шәп була иде!!* А. Гыйләжев.

АБОНЕ́МЕНТ *и.* 1. Билгеле бер вакыт эчендә берәр нәрсәдән (мәсәлән, телефоннан) хак түләп файдалану хокукы. // Шул хокукны раслый торган документ.

2. Билгеле бер вакыт эчендә концертларга, театрларга йөрү өчен бирелгән документ.

АБОНЕ́НТ *и.* 1. Абонементы булган кеше. // *с. мәгъ. күпл.* **абонентлар**. Абонентларга хезмәт күрсәтә торган. *Абонентлар бүлеге.*

2. Газета-журнал алдырып торучы.

АБОРИГЕ́Н *и. кит.* Берәр илнең яки өлкәнең төп халкы, җирле халык.

АБОРТ *и. мед.* Яралгының берәр сәбәп аркасында зарарлануы нәтиҗәсендә йөклелекнең вакытыннан элек тукталуы. // Бала төшерү, ясалма юл белән йөклелекне туктату.

АБОРТИВ *с. мед.* Берәр процесснын үсешен, авыруның барышын кискен үзгәртә яки туктата торган. *Абортив метод. Абортив дәвалау.*

АБРАЗИВ *и.* Металл, пыяла, агач һ. б. ш. нәрсәләрнең өстен эшкәртү, шомарту, тигезләү, ялтырату өчен файдаланыла торган вак бөртекле яки порошок сыман бик каты матдә. // *с. мәгъ.* Абразивка бәйләнешле. *Катылыгы ягыннан карборунд алмазга якынлаша һәм абразив материаллар хәзерләү өчен кулланыла.* Химия.

АБРИКОС *и.* 1. Өрек агачы.

2. Шул агачның эре төшле, кызгылт-сары төстәге жимеше. // *с. мәгъ.* Шул жимештән ясалган. *Абрикос вареньесы.*

АБРУЙ *и.* 1. Авторитет; дәрәҗә. *Абруй казану Абруй югалту.* □ [*Хаҗи:*] *Рәхмәт, рәхмәт, жаннарым, яхшы сүзегезгә, бәрәкалла, мин сездән бик риза, жаннарым, бик риза, ходай абруй бирсен үзегезгә.* Ш. Камал. *Ниһаять, урам сүзләре белән ваксынса, килене каршында абруен югалтачагын тоеп, [ана] сүзне Нәфисәнең йөрәгенә якын урыннан башлап жибәрде.* Г. Бәширов.

2. Намус, сафлык. *Кыз баланың абруе кыл өстендә, кылдан төшсә — юл өстендә.* Мәкаль.

3. Берәр коллектив, төркем һ. б. ш. эчендә дәрәҗәле, хөрмәт ителә торган, авторитетлы кеше. [*Муса*], *без сиңа, илнең абруе күреп ышанганга күрә, моны тапшырдык.* Ф. Бурнаш.

АБРУЙЛЫ *с.* Авторитетлы, ышаныч казанган. *Абруйлы кеше.* □ — *Бәхетсез ялчы идең. Кем булдың? Абруйлы кеше булдың.* Ә. Айдар. // Намуслы, саф. *Абруйлы кыз.*

АБСОЛЮТ *и. филос.* Идеалистик философиядә: галәмнең мәңгелек, үзгәрмәс, беренчел нигезе — рух, идея; диндә: алла, тәнре. // *с. мәгъ.* Үзгәрми торган, үзгәрешсез. *Без әдәбияттагы форманы туңган — абсолют бер төстә алмыйбыз.* Һ. Такташ.

Абсолют зурлык — математикада: + һәм — (плюс һәм минус) билгеләреннән башка алынган зурлык, күләм. **Абсолют күпчелек** — иң зур күпчелек. **Абсолют монархия** — чикләнмәгән монархия, самодержавие. **Абсолют нуль** *физ.* — мөмкин булган иң түбән температура. **Абсолют тынычлык** — тулы тынычлык. **Абсолют хата** *мат.* — үлчәнелә торган зурлыкның төгәл кыйммәте белән аның якынча кыйммәте арасындагы аерма. **Абсолют чемпион** — бер төр спорт ярышларының барлык разрядлары буенча жиңүче. **Абсолют үсеш** *экон.* — гомуми тулы үсеш. *Жидееллык план халык хуҗалыгының барлык тармакларында югары үсеш темпларын һәм продукция житештерүнең зур абсолют үсешен күздә тота.* КПСС тарихы. **Абсолют өстәмә кыйммәт** *экон.* — эш көнен озынайту юлы белән алына торган өстәмә кыйммәт.

АБСОЛЮТИЗМ *и. полит.* Властьның бер генә кеше тарафыннан идарә ителү формасы — самодержавие, чикләнмәгән монархия.

АБСОРБИР *и. махс.* Газны жыю һәм эшкәртү аппараты.

АБСО'РБЦИЯЛӘҮ *ф. физ., хим.* Йоту, сендерү, суыру.

АБСТРАКТ *с. филос.* Конкрет булмаган, гомуми. *Кешенең гомумилаштерү сәләте абстракт фикерләүнең асылын тәшкил итә һәм кешене хайваннардан аерып тора.* Анатомия. *Тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итми.* Һ. Такташ.

АБСТРАКТЛАШТЫРУ *ф. кит.* Абстракция ясау.

АБСТРАКТЛАШУ *ф. кит.* Абстрактка әйләнү, конкретлыгын югалту.

АБСТРАКТЛЫК *и кит.* Конкрет булмау, гомумилек, абстракт булу. *Дөньяны сәнгатьчә сизмләүнең абстрактлыгы язучыларның шәхси, субъектив теләк һәм омтылышларыннан түгел.* Г. Халит.

АБСТРА'КЦИЯ *и. кит.* 1. Фикерләгәндә предметның мөһим гомуми үзенчәлекләрен аерып күрсәтү өчен, аның конкрет сыйфатларын, үзлекләрен, бәйләнешләрен аң белән читләтеп тору.

2. Абстракт төшенчә.

АБСТРА'КЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Конкрет предметлардан гомуми, абстракт фикергә күчү, абстрактлаштыру.

АБСУРД *и.* Мәгънәсезлек, акылга сыймый торган, ятышсыз нәрсә. — *Яраткан кешеңә ышанмыйча мөмкин түгел, абсурд бу!..* Ә. Еники.

АБСУРДЛЫК *и.* Мәгънәсезлек, мәгънәсез булу, акылга сыймаслык булу. *Нәтиҗәләрнең абсурдлыгы.*

АБСЦЕСС *и. мед.* Тәндә яки берәр әгъзада эрен жыелу, эренле шеш, эренле чуан.

АБСЦИ'ССА *и. мат.* Пространстводагы ноктаның торышын билгели торган өч координатның берсе.

АБУНӘ *и. иск.* Абонемент.

АБУНӘЧЕ *и. иск.* Абонент. *Газета шәһәр абунәчеләренә таралып өлгерсә дә, авылларга жибәреләсе саннар китеп бетмәгән иде әле.* Г. Минский.

АБХАЗ *и.* Абхазия АССРда яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. // *с. мәгъ.* Шул халыкка бәйләнешле. *Абхаз теле. Абхаз авылы.*

АБХА'ЗЧА *рәв.* 1. Абхаз телендә. *Абхазча сөйләшү.* // *с. мәгъ.* Абхаз телендәге. *Абхазча газета.*

2. Абхаз милләтенә хас булганча. *Абхазча киенү.*

АБЫЗ *и. иск.* Укымышлы. *Галиәкбәр шулай бик абыз кешегә әйләнде.* Г. Мөхәммәтшин.

АБЫЙ *и.* 1. Үзеңнән олырак ир туган. — *Сигез абыемнан үлмичә калган бердәнбер абыем ул минем.* М. Әмир.

2. Яшь ягыннан үзеңнән олы ир кеше исеменә кушып әйтелә. *Минем колакны борган кеше шул сельсовет председателе Фәрхетдин абый түгелме иде икән?* Ш. Камал. // Олырак ир кешегә мөрәҗәгать сүзе. — *Абый, без дә сезне тәбрик итәбез!* — *диделәр балалар.* А. Әхмәт. // Абый кеше. — *Д менә болары әшче абыйларың, әшче апаларың.* А. Алиш.

АБЫЛ-КОБЫЛ *рәв.* Ашык-пошык, бик ашыгып, әштер-өштер. *Иртәнге чәйне дә ул көндәгечә абыл-кобыл эчеп, өстәл яныннан торып китәргә ашыкмады.* Г. Минский.

АБЫНА-ЕГЫЛА *рәв.* Ашыгып, кабаланып, юлдагы нәрсәләргә бәрелеп, сөртенеп; абына-сөртенә.

АБЫНА-СӨРЕНӘ *рәв. сир. к.* абына-сөртенә.

АБЫНА-СӨРТЕНӘ *рәв.* 1. Ашыгып, йөргәндә төрле нәрсәләргә бәрелеп, абынып, сөртенеп. *Менә [Зәйтүнә] тигезле-тигезсез көзге юлдан абына-сөртенә алга бара.* Ф. Хөсни. [*Шәкертләр:*] — *Хәлфә абый килә!* — *дип кычкырып, бәйләнмәгән чабаталарына абына-сөртенә ишеккә йөгерделәр.* М. Гали.

2. *күч.* Күп төрле ялгышлыклар ясап, ялгышып, кыенлыклар белән, тырышып-тырмашып. *Юк, бу кызый бүтәннәр салган сукмактан барырга гына риза түгел, ул, абына-сөртенә, адаша-ялгыша булса да, үз сызыгы белән китәчәк.* Г. Бәширов.

АБЫНКЫ *с. сөйл.* 1. Сүлпән, сүрән; дәртсез (кешегә карата).

2. Абынучан, сөртенүчән, абына торган, сөртенә торган. *Үзе салынкының аты абынкы.* Мәкаль.

АБЫНМАЛЫ *с.* Тигезсез, түмгәкле, чокыр-чакырлы. *Иске интеллигент [Ф. К.] ның бик катлаулы чорларда абынмалы юллардан гражданлык хисенә тап төшермичә уза алуы да ихтирамга лаек.* М. Госманов.

АБЫНУ *ф.* 1. Атлап барганда, йөгергәндә аяк белән нәрсәгә дә булса бәрелеп яки әләгеп, тигезлекне югалту; сөртенү. *Сәхипҗамал өйгә кереп барганда абынып егыла, кулындагы ящигы җиргә төшә.* А. Әхмәт. *Урам аша чыккан чакта Бүрәнәгә абындым.* Җыр.

2. *күч.* Эштә, тормышта ялгышу. — [*Егетне*] *мин бер дә ошатмадым, вак кеше булырга кирәк, Гөлшат абынып куймаса ярар иде.* Т. Гыйззәт. *Гәрәйнең иртәнге күтәренкелеге ярсу белән алышынды... Эшчеләр аның абынганын гына көтеп торалар түгелме?* А. Гыйләҗев.

3. *күч. сөйл.* Сынату. [*Мирсәет:*] *Сәләхи абзый белән ярышасың икән, кара аны, аягыңны ныклабрак киен. Абынуың бар.* Р. Ишморат

АБЫСТАЙ *и. иск.* 1. Мулла, мәзин яки бай хатыны. *Абыстайның бер-ике асрау кызы һәм аш пешерүче, сыер савучы хатыннары да буладыр.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Дини мәктәпләрдә сабак, дәрес бирүче хатын, күбесенчә мулла, мәзин хатыны. — *Аның белән телгәгенә каршы килеп булмады, ул елны мин кыш буе мәзин абыстаена йөреп чыктым.* М. Гали. *Татар кызын сабак абыстаена бирделәр.* Ф. Әмирхан. *Ул елларда муллабикә абыстай авыл кызларына сабак укыта иде.* Г. Минский.

3. *сөйл.* Гомумән таныш булмаган хатын-кыз. [*Йосыф:*] *Әй, кассир әфәнде, самовар биргән абыстаңа акча түлә.* Ф. Әмирхан. // Өлкәнрәк хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе. — *Туктагыз әле, абыстайлар, җыелыш бетмәгән бит!* — *диде шәлле хатын, гажәпләнеп.* А. Шамов. // Олы яшьтәге хатын-кызны ихтирам итү, зурлау йөзеннән, исеменә кушып әйтелә. *Өйдәге һәммә нәрсәне идарә итү Маһитап абыстайга тапшырылган булса да, чәй-шикәрне Сәмигулла абзый һәрвакыт үзенең хосусый химаясе астында тота иде.* Ф. Әмирхан.

АВА-ЕГЫЛА *рәв.* Ашыгып, кабаланып, егыла-егыла. [*Эзләүчеләр*] *әйберләрне шул зур имән төбендә күләгәдә калдырдылар да текә ярдан, ава-егыла, зур кыенлык белән түбәнгә, Яманкулның төбенә, Фәхри табылган җиргә төштеләр.* Г. Ибраһимов.

АВАЗ *и.* 1. Тамак ярыларының сулыш ярдәмендә тирбәлүеннән барлыкка килә торган тавыш. *Ишекнең тышкы тарафында ике хатынның сөйләшкән авазлары ишетелә.* Г. Камал. *Нинди өн? Чү! Кайда ишетелде йөрәк өзгеч аваз?* Һ. Такташ.

2. Һава тирбәлүләре нәтиҗәсендә була торган яңгыраш. *Мондый айлы кичләрдә, әгәр дә азрак җил дә булса, урман эче җанлы кебек тоела — бөтен җирдә күләгәләр уйный, төрле авазлар ишетелә.* Г. Әпсәләмов. *Бөтен тирә-як мең төрле нечкә авазлар белән үзалдына гүләп тора.* Г. Бәширов. // Музыка коралларында уйнаганда чыга торган тавыш, яңгыраш. — *Шунда сизәм, скрипкамның авазы һаман тупаслана бара, имештер, мин көйнең иң назлы урыннарын бозып үтәм.* Г. Бәширов. — *Гармонь диләрме, нидер, шул шайтан авазы туктагач, йокыдан уянган шикелле булып китәм.* Г. Ибраһимов.

3. *лингв.* Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге. *Сузык һәм тартык авазлар.* □ *Ул, Газинурга карап алаала, басымнарны һәм авазларны мөмкин кадәр ачыграк бирергә тырышып, кычкырып әйтеп тора.* Г. Әпсәләмов.

Аваз ияртеме *лингв.* — нәрсәнең дә булса табигый тавышына, яңгырашына охшатып ясалган сүз, мәсәлән: *голт-голт, чут-чут, гөр-гөр, мияу* һ. б. *Аваз ияртеме хайван тавышларын, кошлар сайравын, урман шаулавын һ. б. бирү өчен кулланыла.* Әд. терм. сүзлеге. **Аваз язымы** *махс.* — сөйләмнең тәэсир итү көчен үстерү максаты белән, сүзләрнең аваз составыннан һәм яңгырашыннан файдалану (аллитерация кебек күренешләр).

◇ **Аваз бирү** — 1) эндәшү, дәшү. *Әле генә җанланып, язын иленә кайткан кош кебек сайрап сөйләгән Шәвәли кинәт аваз бирмәс булды.* С. Рафиков; 2) җавап бирү. **Аваз салу** — 1) бик каты кычкыру. *Айтуганның әйтеп бетерүен дә көтмәделәр, берничә хатын-кыз белән яшүсмер берьюлы аваз салды.* Г. Бәширов; 2) хәбәр итү, хәбәр тарату. — *Я, ишетим тавышыңны, бер аваз сал, җый халыкны, патша төшерәбез!* Г. Бәширов.

АВАЗДАШ *с.* 1. *махс.* Охшаш, бердәй яңгырашлы (шигырьдә кабатланып килә торган бердәй яңгырашлы сузык авазлар, шигырь юлларының бердәй яңгырап тәмамланулары турында).

2. *лингв.* Авазлар яңгырашы буенча охшаш, тәңгәл, бердәй; омонимик.

3. Билгеле таләпләргә җавап бирә торган, туры килә торган; аһәңдәш. *Гомумән алганда, концерт эчтәлеге белән заманга аваздаш, тамашачыга эстетик зәвык бирерлек төзелгән.* Л. Ихсанова. *Кеше кешегә дус һәм туган! Шушы принципны һәркемнең яшәү нормасы итү өчен киренке көрәш барган безнең көннәрдә әлеге проблематика заман таләбенә, чор сулышына бик тә аваздаш.* Соц. Тат. // Эчке охшашлык, уртаклык турында. [*Х. Мөҗәйнең*] *бу елларда гы шигырьләре Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян шигырьләре белән аваздаш.* С. Шакир.

АВАЗДАШЛЫК *и.* 1. *әд.* Шигырьдә сузык авазларның кабатланып килүе, шулай ук шигырь юллары

бетемнәренең охшаш яңгырашлыгы, ассонанс, рифма. *Басымлы иҗеккә тәмамлана торган юлларның аваздашлыгы.*

2. *лингв.* Мәгънәсе белән төрле булган сүзләрдә авазлар яңгырашының охшашлыгы, тәңгәллеге; омонимия.

3. Туры килү, эчке охшашлык, аһәңдәшлек.

АВАНГАРД *и.* **1.** Гаскәрнең яки флотның төп көчләрдән алда бара торган отряды. — *Беренче батальонны нығыту өчен тагын бер авангард җибәрергә приказ бирдем.* Х. Мөҗәй. // *с. мәгъ.* Авангардка бәйләнешле. *Авангард сугышлар.* // *с. мәгъ.* Төп көчләрдән алда бара торган. *Авангард отряд.*

2. *күч.* Нинди дә булса иҗтимагый группаның, сыйныфның алдынгы, җитәкләп алып баручы өлеше. *Коммунистлар партиясе — Совет халкының көрәшләрдә чыныккан авангарды.* □ *Ш. Камал икеләнмишикләнми пролетариат ягында булды һәм пролетариатның авангарды — коммунистик партия сафында торып --- хезмәт итте. М. Җәлил.*

АВАНГАРДЛЫК *и.* Авангард булу, алдынгылык, җитәкчелек. / *с. мәгъ. Коммунистларның авангардлык роле.*

АВАНПОСТ *и.* Кайбер армияләрдә (шул исәптән патша армиясендә дә), дошманның кинәт һөҗүмен хәбәр итү өчен, төп көчләрдән алга чыгарып куелган каравыл, сакчы отряд, алдагы пост. / *күч. Европа белән Азия чигендә күп еллар буенча Россия капитализмының аванпосты булып торган бу шәһәр чиновниклар, сәүдәгәрләр, спекулянтлар, колонизаторлар белән тулган идә.* Ш. Усманов.

АВАНС *и.* Алачак хезмәт хакы исәбенә алдан бирелгән өлеш (акча яки продукт). — *Днә дсма кодачалар алып кайтканнар ич әле дүртәр пот аванс.* Ф. Бурнаш. — *Язылмаган әсәрләр өчен авансларалып башымны да, тормышымны да бәйлисем килми.* К. Тинчурин. // Бераз расход өчен алдан бирелгән акча. *Командировка өчен аванс алу.* □ — *Булачак газет өчен тагын сиңнән аванс сорарга торадыр идем.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АВА'НСЛАУ *ф. экон.* Оборотка җибәрү, кертү. *Капиталист тарафыннан авансланган, ягъни оборотка җибәрелгән капитал үзенең хуҗасына билгеле дәрәҗәдә артып кайта.* Политэкономия.

АВАНСЦЕ'НА *и. театр.* Пәрдә төшкәч, сәхнәнең тамашачылар залы ягында кала торган ачык өлеше, сәхнә алды. [*Булат*] *авансценаның иң кырыена чыгып баскан да Сылуга карый.* Ш. Хөсәенов.

АВАНТЮ'РА *и.* **1.** Реаль көчләрне һәм шартларны исәпкә алмыйча, ахырын алдан уйлап җиткермичә, тәвәккәллеккә, очраклыкка ышанып корылган, принципсыз эш. *Сул эсерлар авантюрасы аларның Советка каршы партия икәнлеген тәмам фаш итте.* КПСС тарихы. *3 нче атлы корпус командиры генерал Крымов, авантюраның барып чыкмавын күреп, үзен үзе атып үтерде.* И. Гази.

2. Алдауга корылган эш. [*Татар буржуазиясе*] *халыкны алдау өчен „дин", „милләт" әләмен күтәреп, „Идел-Урал" штаты дигән пантюркистик авантюрасын корды.* М. Җәлил. *Бер үк вакытта буржуазия, властьны үз кулында саклап калу өчен, яңа авантюралар оештыра.* К. Нәҗми.

3. *әд.* Мажара. *Дсәрдә авантюра элементлары бар. Ә болар яшеренкелекне, башта әйтелмәүне, билгесезлекне телиләр.* Г. Нигъмәти.

АВАНТЮ'РАЛЫ *с.* **1.** Авантюрага (1, 2 мәгъ.) корылган. *Авантюралы эш.*

2. Мажараларга бай, мажаралы. *Авантюралы роман.*

АВАНТЮ'РАЧЫ *и. к.* авантюрист.

АВАНТЮРИЗМ *и.* Иҗтимагый һәм политик эшләрдә принципсызлык, авантюраларга һәвәслек.

АВАНТЮРИСТ *и.* Авантюрага һәвәс, принципсыз кеше, алдакчы. *Урамнар — купецлар, банкирлар, вояжерлар, караклар, авантюристлар белән тулган.* К. Тинчурин. [*Нәби:*] *Теге авантюрист Сатаев шушы кызның кулына ябышып тәхеткә менмәкче буламы?* Н. Исәнбәт.

АВАНТЮРИ'СТИК *с.* Авантюрага корылган, авантюристларга хас.

АВАНТЮРИСТЛЫК *и. к.* авантюризм. *Совет фәненә авантюристлык рухы — чит нәрсә.* Космик ракеталар.

АВАР *и.* **1.** Дагстанда яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. // *с. мәгъ.* Аварга мөнәсәбәтле. *Авар теле.*

2. *тар.* VI гасырда Дунай тирәсендәге өлкәләрне басып алып, шунда үз дәүләтләрен оештырып, X гасыргача яшәгән төрки кабиләләр. *Славяннар һәрвакыт куркыныч астында яшәгәннәр. Көнчыгыштан аларга еш кына күчмә халыклар — гуннар, аварлар һөҗүм итеп торган.* СССР тарихы.

АВАР-АУМАС *рәв.* Аварлык булып, кыйшаеп, аварлык хәлгә җитеп. *Җитмеш яшькә җиткән картлар кебек, Авар-аумас тора йортлары.* М. Гафури.

АВА'РИЯ *и.* **1.** Эш, хәрәкәт вакытында машинаның һ. б. ш. нинди дә булса механизмы ватылу, бозылу. — *Ничек итеп эшне беркайчан да, бернинди дә авария булдырмыйча алып барырга?* Р. Ишморат. — *Бу аварияне бетерү өчен барыбызга да өч көн, өч төн эшләргә кирәк булачак.* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Авариягә мөнәсәбәтле. *Авария командасы. Авария сигналы.* □ *Ул арада аксыл плафоннарда ут сүнеп, кызыл авария лампалары кабынды.* А. Тимергалин.

2. Һәлакәт, зур җимерелү, үлемнәр белән бәйләнгән хәл, бәхетсезлек. *Чирмешәндә торган чаклары-нда Мәрьям, әниләре авылыннан машинада кайтып килешли, аварияга очрап, өч яшьлек кызы белән бергә һәлак булды.* Ә. Еники.

3. *күч. сөйл.* Нинди дә булса бер эшнең, планның көтмәгәндә таркалуы, челпәрәмә килүе, барып чыкмавы, уңышсызлык.

АВА-ТҮНӘ *рәв.* Алпан-тилпән килеп, як-якка чайкалып. [*Җолкынбай*] *кыйналган, ватылган зур гәүдәсе белән ава-түнә байның ялчылар өчен корылган кечкенә кара тирмәсенә керде дә әйберләрен җыя башлады.* Г. Ибраһимов. *Иртә белән юлга чыккач, йоклый-йоклый барасың. Бозау кебек ава-түнә, һаман артта каласың.* Һ. Такташ. // *күч.* Әкрен генә, кыенлык белән, тырмашып.

А'ВГУСТ *и.* Календарь елының сигезенче ае. *Ялкау гына сибә кызгылт нурын август кояшы.* М. Җәлил. *Август ае; өй түрендәге сәрви агачларының яфраклары аз гына саргая башлаган.* М. Фәйзи.

АВИА- Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) „авиация" мәгънәсенә бәйләнешле, мәсәлән: **авиабензин, авиабомба, авиадвигатель, авиазавод, авиамотор, авиапарк** һ. б.; 2) „һава" мәгънәсенә бәйләнешле, мәсәлән: **авиадесант, авиаразведка, авиаспорт, авиатранспорт** һ. б.

АВИАБА'ЗА *и. авиа.* Авиация эшләренә хезмәт күрсәтү өчен складлары, ремонт мастерскойлары, подразделениеләре булган аэродром.

АВИАДЕСАНТ *и.* Дошман территориясенә самолеттан төшерелгән гаскәр, һава десанты. *Разия үзенең бу хатында авиадесант операцияләрендә катнашуын*

бер „эш" өчен хәтта медаль дә алып өлгерүен язган иде. И. Гази.

АВИАДЕСАНТЧЫ *и.* һава десанты частьларында хезмәт итүче. *Кыш көннәренең берсендә авиадесантчыларны дошман тылына төшерәләр.* И. Гази.

АВИАКОНСТРУ'КТОР *и.* Самолетлар яки авиация двигательләре конструкторы. [*Акчурин*] *егет чагында очучы яки авиаконструктор булу турында хыялланды.* Г. Әпсәләмов.

АВИАМОДЕЛИЗМ *и.* Авиаспортта оча торган аппарат модельләрен ясау һәм очырту белән шөгыльләнү.

АВИАМОДЕЛИСТ *и. к.* авиамодельче.

АВИАМОДЕЛЬ *и.* Оча торган аппарат моделе.

АВИАМОДЕЛЬЧЕ *и.* Оча торган аппаратларның модельләрен ясаучы, авиамоделизм белән шөгыльләнүче. *Бездә, Советлар Союзында, яшь очучылар күп, мин авиамодельче, планерчы балаларны, самолетлардагы яшүсмерләрне шулай атыйм.* Космик ракеталар.

АВИАНО'СЕЦ *и.* Самолетларны палубадан очырту һәм төшерү өчен махсус мәйданчыгы, шулай ук аларны саклау корылмасы булган хәрби корабль.

АВИАПО'ЧТА *и.* 1. Посылка, бандероль, хат кебек почта әйберләрен самолет белән йөртү эше.

2. Самолетта ташыла, күчерелә торган почта әйберләре.

АВИА'ТОР *и.* 1. Очучы. — *Пехотаның кадерен белмәгән авиатор — начар авиатор ул!* Г. Латыйп. *Алар безнең авиаторларның бомба ударларын күзәтәләр дә яңадан ярга таба киттеләр.* Г. Әпсәләмов.

2. Гомумән авиация эшендәге, авиациягә мөнәсәбәтле кеше.

АВИА'ТОРЛЫК *и.* Очучылык, авиатор булу.

АВИА'ЦИЯ *и.* 1. Оча торган аппаратларның һавада хәрәкәтләнү теориясе һәм практикасы. *Авиация таңында самолетның берничә минутка сузылган очышы да зур вакыйга булып санала.* Космик ракеталар.

2. Оча торган аппаратлар җыелмасы; һава флоты. *Һәр тамганың беренче хәрефе „А" булса, ул бүрәнәләр авиациягә китә.* Г. Әпсәләмов. *Һавада — безнең авиация, өзеклекләр безнең пехота оныла, безнең танклар килеп керәләр.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Авиациягә мөнәсәбәтле. *Авиация промышленносте. Авиация лейтенанты.*

АВИТАМИНОЗ *и. мед.* Азыкта теге яки бу витаминнар җитмәү сәбәпле була торган авыру.

АВРАЛ *и.* 1. *хәрби.* Корабльдә барлык команда катнашы белән үткәрелә торган эш. // *с. мәгъ.* Авралга мөнәсәбәтле. *Аврал тревогасы.*

2. *куч. сөйл.* Планнсызлыктан үз вакытында үтәлмәве сәбәпле барлык коллектив катнашы белән ашыгыч рәвештә башкарыла торган эш. // *с. мәгъ.* Кисәтүле һәм ашыгыч. *Памир тауларының биек сөнгеләрендәге метеорология станцияләре соңгы көннәрдә һава хәле турында аврал сигналлары бирә башлаган иделәр.* Ә. Айдар.

АВСТРА'ЛИЯЛЕ *и.* 1. Австралиядә яшәүче жирле халык. // Австралиядә яшәүче хәзерге халык.

2. Шул халыкның бер кешесе.

А'ВСТРИЯЛЕ *и.* 1. Австриядә яшәүче жирле халык. [*Семен*] *немецлар белән австриялеләр тора торган бараста яши.* Каз. утл. //Австриядә яшәүче хәзерге халык. *Леманның завхозлыгына бер австрияле куелды.* Ш. Усманов.

2. Шул халыкның бер кешесе.

АВТО' *и. сир.* Автомобиль. *Такыр юлдан совхоз автолары Ашлык ташый хәзер калага.* М. Җәлил.

АВТО- I. Кушма сүзләрдә „автомобиль" мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **автогараж, автозавод, автоинспектор, автокамера, автоколонна, автопарк, автосклад, автотранспорт.**

АВТО- II Кушма сүзләрдә „автомат" мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **автосварка.**

АВТО- III Кушма сүзләрдә „үзйөрешле" мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **автовагон, автогрейдер, автодрезина.**

АВТО- IV Кушма сүзләрдә „үз", „үзенең", „үз кулы белән язылган" мәгънәләрен аңлата торган беренче кисәк, мәсәлән: **автобиография, автопортрет, автограф.**

АВТОБА'ЗА *и.* Автомобильләр хәрәкәтен тәртипкә сала торган предприятие; автомобильләрнең даими тукталу һәм ремонт урыны. — *Әллә безнең заводны автобаза дип беләләрме?. Транспорт сорар урын тапкан!* М. Әмир.

АВТОБИОГРА'ФИК *с.* Авторның тормыш юлын, тәржемәи хәлен чагылдырган. *Автобиографик белешмә. Автобиографик әдәбият.* □ *М. Гафуриның „Шагыйрьнең алтын приискасында" дигән әсәре — автобиографик әсәр.*

АВТОБИОГРА'ФИЯ *и.* Тәржемәи хәл, берәүнең үз тормыш юлы турындагы язмасы. *Хезмәткәрнең автобиографиясе.*

АВТО'БУС *и.* Пассажирлар йөртү өчен күп урынлы ябык автомобиль. *Автобус тукталышы.* □ [*Югарыдан*] *өзлексез йөреп торган автомобильләр, автобуслар, трамвайлар шырпы тартмалары шикелле кечкенә генә булып күренәләр.* А. Шамов.

АВТО'ГРАФ *и.* Авторның үз кулъязмасы, үз кулы белән язылган текст. // Кемнең дә булса үз кулъязмасы яки имзасы.

АВТОГРА'ФИК *с.* Автор үзе язган, авторның үз кулы белән язылган. *Автографик нөсхә.*

АВТОКАР *и. махс.* Вокзалларда, цехларда һ. б. ш. урыннарда йөк ташу өчен файдаланыла торган үзйөрешле арба. *Алда завод мәйданын тазарту һәм автокарлар өчен тиз генә асфальт юллар ясау бурычы тора.* А. Расих.

АВТОКЛАВ *и. махс.* Югары басым астында төрле физик-химик процессларны үткәрү, шулай ук медицина коралларын стерильләштерү өчен хезмәт итә торган герметик капкачлы савыт. *Сульфат кислотасы белән агач ташландыкларын автоклавта җылыталар.* Химия.

АВТОКРАН *и. тех.* Авыр йөкләрне күтәреп күчерү өчен махсус автомобильгә җайлап куелган кран.

АВТОЛ *и.* Нефтьтән эшләп чыгарыла һәм автомобиль, трактор двигательләрен майлау өчен кулланыла торган май. *Бер тапкыр Илдар комбайн астында шулкадәр аунады, өйгә кайтып кергәндә бердәнбер пиджагы эштән чыгып, автолга буялып беткән иде.* Г. Гобәй.

АВТОЛА'ВКА *и. сөйл.* Көнкүреш әйберләрен, күчеп йөреп, кырда, базарда сату өчен өсте ябулы махсус автомашина. *Тракторлар сырлап үткән эздән бастырып ук райпотребсоюзның автолавкасы килеп төште.* Соц. Тат.

АВТОМАГИСТРАЛЬ *и.* Автомобильләрнең тиз һәм күпләп йөрүен тәэмин итәрлек юл. *Мәскәү — Ленинград автомагистрале.*

АВТОМАТ *и.* 1. Кешенең турыдан-туры катнашыннан башка, махсус эчке механизмнар ярдәмендә эшли торган аппарат (машина, прибор). *Телефон-автомат.* // *с. мәгъ.* Механик рәвештә, үзеннән-үзе эшли торган. *Искәндәрев папиросын автомат зажигалка белән кабыза һәм күп итеп, тирән суырып бөтен алдын ак төтен белән тутыра.* Ә. Еники. *Билет сатып*

ятучы автомат машиналар да әллә ни артыкны бирмиләр. Г. Гобәй.

2. *хәрби.* Автомат рәвештә тиз ата торган кул коралы — пистолет-пулемет. *Бераздан соң бер автоматтан, ике винтовкадан залп бирдек.* А. Шамов. *Күпме дәвам иткәндер бу хәл, тик бераздан гына ул үзенә төбәлгән бер пистолет, ике автомат көпшәсен күреп алды.* Ә. Еники.

3. *күч. сөйл.* Уйламыйча, аңсыз рәвештә эш итүче (кеше турында). [*Дәүләтшин:*] *Әйтик, менә мин, солдат, корылган автомат кына булырга тиеш түгел. Мин — кеше.* И. Гази [*Хәйдәр:*] *Мин машинамы, автоматмы?* [*Булат:*] *Син машина түгел. Автомат түгел, син партия әгъзасы!* Г. Ибраһимов.

Автомат рәвештә — эчке механизм ярдәмендә, кеше катнашыннан башка. *Аэродром капкасына җитү белән, капка автомат рәвештә, үзеннән-үзе ачылды.* А. Алиш.

АВТОМА'ТИК *с.* Автомат рәвештә эшли торган, автоматка корылган, эчке механизмнар ярдәмендә эшли торган.

Автоматик идарә — автомат механизмнар ярдәмендә читтән торып идарә итү. *Автоматик идарә очышның бирелгән траекториясен һәм тигезлеген төгәл саклар.* Космик ракеталар.

АВТОМА'ТИКА *и.* **1.** Производство процессларын автоматлаштыру методларын, чараларын, юлларын эзләп табу өстендә эшли торган фән һәм техника тармагы.

2. Автоматик рәвештә эшли торган барлык механизмнар, җайланмалар җыелмасы.

АВТОМАТЛАШТЫРУ *ф.* **1.** Хуҗалыкка, производствога автомат приборлар, җайланмалар, машиналар кертү. [*Җәүдәт тә*] *нефть чыгаруны автоматлаштыруда яңа зур планнар, хыяллар белән янып яши.* Р. Төхфәтуллин.

2. *күч. сөйл.* Автоматка әйләндерү, автоматик рәвештә эшләтү (кешегә карата).

АВТОМАТЛАШУ *ф.* **1.** Хуҗалыкка, производствога автомат приборлар, җайланмалар, машиналар кертелү.

2. *күч. сөйл.* Автоматка әйләнү, автоматик рәвештә эшләү (кешегә карата).

АВТОМАТЛЫ *с.* Автомат (2 мәгъ.) белән коралланган. *Лагерь почмаклары саен пулеметлы һәм автоматлы сакчылар өчен биек вышкалар үсеп чыкты.* Ш. Маннур.

АВТОМАТЧЫ *и.* **1.** Автомат (1 мәгъ.) аппаратта эшләүче эшче.

2. *сөйл.* Автомат (2 мәгъ.) белән коралланган сугышчы. [*Дошманнар*], *уттан битләрен каплап. җиргә сикерәләр, ләкин безнең автоматчылар шунда ук аларның эшен бетерә.* И. Гази. [*Камил*] *дошман автоматчыларын пулемет уты белән көйдерергә тотынды.* М. Әмир.

АВТОМАШИ'НА *и. к.* автомобиль. *Биек озын сарайның икенче башыннан ашлык төягән олаулар, автомашиналар чыгып китәләр.* Г. Әпсәләмов.

АВТОМОБИЛЬ *и.* Рельссыз юлларда пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган эчке янулы двигательле үзйөрешле экипаж. *Шул арада әллә кайдан ыжгырып МТСның йөк һәм җиңел автомобильләре килеп чыга.* М. Гали. [*Галин:*] *Фабкомның әйтүенә караганда, сез миңа премия итеп автомобиль алып бирү турында сөйләшкәнсез икән.* Ш. Камал. // *с. мәгъ.* Автомобильгә мөнәсәбәтле. *Автомобиль промышленносте. Автомобиль транспорты.*

АВТОНО'МИЯ *и.* Идарә итүдә бәйсезлек, үзидарә.

АВТОНО'МИЯЛЕ *с.* Автономиягә ия булган, автономия алган. *Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы.*

АВТОПАРК *и.* Автомобильләр куела һәм ремонтлана торган урын. *Ул хәзерге Киров урамында, автопарк янындагы бакча каршында тора иде.* Ф. Хөсни.

АВТОПИЛОТ *и.* Самолет, очу аппаратлары белән автоматик рәвештә идарә итә торган җайланма. *Самолетның автопилоты бар. Кнопкага бастың исә, эшли башлый.* Г. Латыйп.

АВТОПО'ЕЗД *и.* Бер яки берничә тагылмасы (прицебы) булган автомобиль яки тягач.

АВТОПОРТРЕТ *и.* Кемнең дә булса үз кулы белән эшләгән (үз) портреты. *Крамской автопортреты. Кипренский автопортреты.*

А'ВТОР *и.* Нинди дә булса әдәби әсәр, фәнни хезмәт, проект һ. б. ш. ижат итүче яки берәр нәрсә уйлап чыгаручы, уйлап табучы. [*Укытучы:*] *„Чаткылар" авторының тормыш юлын сөйләп кара инде, алайса.* А. Әхмәт. [*Хәйдәр:*] *Сүз сезгә бирелә, Әлфия! Моның* [*панораманың*] *авторы сез икәнсез бит!* Г. Бәширов.

Автор сөйләме *әд.* — әсәрдәге геройларга автор тарафыннан бирелгән характеристика, шулай ук авторның вакыйгаларны, күренешләрне, пейзажны сурәтләве.

АВТОРДАШ *и.* Кем белән дә булса бергә берәр нәрсәнең (әсәр, фәнни хезмәт, проект һ. б. ш.) авторы булган кеше.

АВТОРДАШЛЫК *и.* Икенче кеше (яки кешеләр) белән бергә нәрсәнең дә булса (әсәр, фәнни хезмәт, проект һ. б. ш.) авторы булу.

АВТОРЕФЕРАТ *и.* Нинди дә булса фәнни хезмәтнең автор тарафыннан язылган кыскача эчтәлеге, рефераты. *Диссертация автореферәты.*

АВТОРИТЕТ *и.* **1.** Җәмгыятьтә, коллективта, халык арасында әһәмияте, роле, ышанычлылыгы, башкаларга йогынты ясавы, башкаларны үзенә ияртә алуы һ. б. ш. сыйфатлары белән танылганлык; ышаныч, зур ихтирам казанганлык; абруй. [*Идият абзый*] *зур сабырлык белән үз чиратын көтеп алды, хәзер инде ир кеше авторитеты белән хатынының әйткәннәрен ныгытырга тиеш иде.* Ә. Еники. [*Мортазинның*] *сүзе закон, авторитеты тиңдәшсез, даны күзләрне чагылдыра иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Гомумтанылган, сүзе үтүчән, ышанычлы, башкаларны үзенә ияртә алучан, башкаларга йогынты ясаучан, абруйлы кеше. *Барысы да Гришаны авторитет санап, аның әмерен җиренә җиткерә.* Ш. Усманов. — *Басыйров та, инженер Петров та миңа авторитет түгел.* Р. Ишморат.

АВТОРИТЕТЛЫ *с.* Авторитет казанган, авторитетка ия булган, абруйлы. *Бу егет, әллә ни зур белемле булмаса да, өлкәнлеге һәм тыйнаклыгы аркасында иптәшләре арасында авторитетлы иде.* Г. Бакиров. // Тулы ышаныч тудыра торган, ышанычлы. *Авторитетлы чыганак.* □ *Авторитетлы, ышанычлы сүз кирәк монда.* А. Әхмәт. *Малайлар Хәлимнең авторитетлы сүзен көттеләр.* Г. Гобәй.

Авторитетлы рәвештә — тулы ышаныч тудырырлык итеп, каршы сүз әйтмәслек итеп, каршы әйтергә урын калдырмаслык итеп. *Идият абзый авторитетлы рәвештә белдерә: — Тәвәккәлләп тотынганда, әллә кая китми,* [*өйне*] *бер җәйдә өлгертеп була.* Ә. Еники.

АВТОРЛАШТЫРУ *ф. кит.* Үз әсәреннең копиясен тәрҗемәсен, репродукциясен һ. б. ш. бастырып чыгару өчен рәсми рәвештә хуплату, рәсмиләштерү.

АВТОРЛЫК*и.* Берәр әдәби әсәрнең, фәнни хезмәтнең, проектның һ. б. ш. авторы булу. *Авторлык*

хокуклы. □ *Ачышларың өчен сиңа югарыдан авторлык таныклыгы җибәрәләр.* Ш. Бикчурин.

АВТОСТРАДА *и.* Автомобильләрнең тиз һәм күплап йөрүен тәэмин итү өчен махсус төзелгән киң шоссе.

АВТОТӨЯГЕЧ *и.* Йөкне автомат рәвештә төйи торган машина. *Афзал — хәзер кранчы. Кирәк чакта автотөягеч белән идарә итә.* З. Шәфигуллин.

АВТОЭЧЕРГЕЧ *и.* Терлекне эчерү өчен автомат рәвештә су биреп тора торган махсус җайланма.

АВУ *ф.* 1. Үсеп утырган яки утыртып куелган, вертикаль хәлдә булган нәрсә егылу, горизонталь хәлгә килү. *Менә боз ява, агачлар ава.* Ш. Камал. *Лыш та лыш селтәнгән саен, ашлык башаклары авып кына торалар.* Г. Минский.

2. Бер якка янтаю, төз, туры торган хәлдән кыегаеп, янтаеп китү. *Әйдүк, Караборынны кочаклап, авып килә торган йортларының эргәсенә утырды.* Һ. Такташ. // Әйләнеп төшү. *Көлтәдән кайтканда арбам авып, үрәчә астында калып, билемне имгәткән идем.* М. Гафури.

3. *сөйл.* Кинәт егылып китү, егылу. [*Рәхилә*] *әнисенең аяклары өстенә ава, күкрәгеннән ярсу ычкына.* Ә. Еники. [*Мидхәт*] *кинәт мәлҗәп төште һәм, рәтләп чишенеп тә тормыйча, кроватька килеп ауды.* Ф. Хөсни. // Йокларга, ял итәргә яту. — *Иртән тугызда чыгып китә, ярты төннәрдә арып, ватылып, эштән чыгып кайтып ава.* Г. Ибраһимов. — *Күрше әбисе пешереп куйган карабодай боткасын ашап, бакчадагы беседкага чыгып аварга иде.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Фикере, карашы үзгәрү, авышу; икенче берәүнең карашын яклый башлау, шул кеше ягына күчү. *Сания, ятимнең күңелсезләнгәнен күреп, аны иҗнәреннән кочып алды һәм, әллә инде әнисен Илдар ягына авар дип шикләндеме, шыңшып куйды.* Г. Гобәй.

5. *күч.* Череп җимерелү, таркалу, юкка чыгу. *Художник оформлениедә әсәрнең эчтәлеген ачарга ярдәм иткән: Хаҗия һәм Шәехзаман өйләре тышкы бизәк астында пыскып янган мещанлыкны, аварга хәзер торган искелекне тасвирлый.* М. Җәлил.

6. Узу, үтү, авышу. *Шәңгәрәйләр, Җиһанша бабайлар җыелып килделәр дә, иртәнчәк кояш белән бергә тотынып, төш авуга өйне аякка бастырдылар.* Г. Ибраһимов.

◇ **Авып йөрү** — 1) алпан-тилпән килеп йөрү; 2) бер якка янтаебрак йөрү; 3) күңеле төшеп, яратып йөрү. — *Тукта әле, көең Гүзәл, язганың Гүзәл, үзең шул кызга авып йөрүең түгелме, бала?* Н. Исәнбәт.

АВЫЗ *и.* 1. Өске һәм аскы казналыклар арасыннан йоткылыкка кадәр куышланып киткән, сөйләү һәм ашау функциясен башкаруга ярдәм итә торган эгъза. *Авыз мускуллары.* □ *Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә.* Мәкаль.

2. *күч., гади с.* Семья тәрбиясендәге кеше, ашаучы. *Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызы булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кәргәнмен.* Г. Тукай.

3. Мич, шалаш, оя һ. б. ш. кебек эче куыш нәрсәләрнең алгы өлешендәге тишек. *Хәлим керергә дип шалаш авызына килде һәм анда сөйләшкән тавышларны ишетеп туктап калды.* Г. Гобәй. *Нургали тартып бетермәгән тәмәкесен сүндермичә мич авызына ыргытты.* Ә. Еники. *Шул стенада тау куышыдай булып шахта авызы күренә.* А. Расих.

4. Янар тау түбәсендә лава агып яки атылып чыга торган тар һәм тирән тишек. *Без янар тау авызыннан атылган утлы туфрак һәм көл булып һавага ыргылдык.* Ә. Еники. // Бомба яки снаряд шартлаудан барлыкка килгән чокырның өсте.

5. Ваза, кувшин, шешә кебек савытларның тараеп килгән ачык башы. [*Миңнур карт*] *җиң эченнән бер шешә чыгарып, аның авызындагы сургучын коярга кереште.* А. Шамов. *Чуен чүлмәк авызы тар—Пешә солдат ашлары.* Бор. җыр. // Чиләк, стакан һ. б. ш. кебек эче куыш тирән әйберләрнең өсте, каплана, ябыла торган өске өлеше. *Дә сырма өстеннән ак халат кигән өч хатын киң авызлы, өсте ябык чиләкләрдә иртәнге сөтләрен ферма өенә китерәләр.* Ә. Еники. *Бал кортлары кереп беткәч, бабай тубалның авызын бәйләп куя.* А. Алиш.

6. Ату кораллары көпшәсенең снаряд, пуля атылып чыга торган тишеге. // Самовар торбасының төтен чыга торган тишеге. *Су китерелгән, күмер тутырылган, чыра яндырып салынган самовар[ның] торбасы авызы белән мич юлына куелган.* Ә. Фәйзи.

7. Капчык, пакет кебек нәрсәләрнең бәйләнә, ябыла торган өске ягы. — *Күмәч салган капчыкның авызын чишәргә керештек.* М. Гафури.

8. Урман, әрәмәлек кебек нәрсәләрнең чите, кырые, башланган яки беткән урыны. *Урман авызы.* □ — *Захаров аларны, ашыктырып, әрәмәлек авызына алып чыгып китте.* А. Шамов. *Каенлык авызында аларны --- чандыр немец офицеры каршы алды.* Ә. Еники. // *күч. сөйл.* Фронтның, сугышның алгы позициясенә карата әйтелә. [*Гайшә:*] *Теге Колчак Казанга якынлашып килгәндә, фронт авызында Советка каршы агитация белән маташкан өчен, Садыйк абзый шпионны аттырган булган икән.* Г. Ибраһимов.

9. Елга, инеш коя торган урын, тамак. *Елга авызы.* □ *Без пароход йөртеп уйнаган ермак авызында пристань була.* Г. Гобәй.

Авыз гармоне — иреннәр арасына куеп өрү өчен тишекләре булган кечкенә генә озынча тартма формасындагы музыка коралы. *Бер вояжерыбыз, яшел чирәмгә утырып, авыз гармоне уйный.* Г. Тукай. **Авыз куышлыгы** — авыз эче. **Авыз тәмәкесе** — тел астына сала торган вак тәмәке.

◇ **Авыз ачу** — 1) сүз кузгату, сүз башлау, сүз кушу, сүз әйтү, эндәшү, сөйләү. *Үземнең уңайсызланулымны бетерергә теләп, аларга авыз ачарга да ирек бирмичә, сөйләп киттем.* А. Шамов. *Ин кадерле, җылы сүзләреңне дәтергә дип авыз ачасың.* Ш. Маннур; 2) *дини.* ураза вакытында көн буе ашамый торганнан соң, кояш баегач, аз гына тоз һәм җимеш кабып, уразаны өзү (шуннан соң кичке ашау вакыты башлана). *Элек тәравихларда коръән хәтем итә башлагач, аны авыз ачарга — ифтарга чакыра.* Г. Ибраһимов; 3) *шаярт.* киеп, тузып ертылу, сүтелү турында. — *Дә теккән бияләйләреңә авызларын ачканнар, ашарга сорыйлар!* Г. Гобәй. **Авыз ачып йөрү (тору)** — сизгер, уяу булмау, сак булмау. — *Ярый алайса, бар, эшлә, тик моннан соң авызыңны ачып йөрмә!* Ә. Еники. **Авыз ачып калу** — гафил булу, гафил булып калу, сизми калу; өлешсез калу. — *Тукта әле, мин тагы бу якта утырып, авызымны ачып, юл сәдакасыннан колак кагып калмыйм.* Г. Камал. **Авыз ачып көтеп тору** — хәстәрен күрмичә, булыр әле дип ышанып, гамьсез генә көтеп тору. **Авыз ачып тыңлау (карау)** — гаҗәпләнеп, бирелеп, йотылып, мөкиббән китеп тыңлау (карау). **Авыз ачып тору (утыру)** — 1) гаҗәпләнеп, сокланып карап тору (утыру). *Авызларын ачып утырган мужикларның, бу вакыйгадан соң, булачак мулланың зур гыйлем иясе икәнлегенә шикләре калмады.* Ә. Фәйзи; 2) дөньяны оныту, игътибарсыз, ваемсыз булу. — *Карлыгач! Нәрсә анда авызыңны ачып торасың? Дә бит атларың кая*

бара! Г. Бәширов. **Авыз ачып хәйран булып кату (катып калу)** — чиктән тыш гаҗәпләнү, шаккату. *Берничә сәгать үтмәде, вакытның соң булуына карамастан, бу урамнар, койма, капка буйлары, күрше йортлар балалар белән тулган, баласын күтәргән кызыл яулыклы хатыннар авызын ачып хәйран булып каткан.* Г. Ибраһимов. *Сәлим, бик кызык спектакль карагандагы шикелле, авызын ачып катып калды.* Г. Гобәй. **Авыз белән карау** — игътибарсыз булу, саксыз эш итү. *Инде [рулевой] авыз белән карасаң, бетте диген. Борылганда, дулкын буена калып, шомарак әйләнмәделәрме — бәрә дә каплый.* Табиг. буйс. юл. **Авыз белән кош аулап йөрү** — *к.* авыз ачып йөрү (тору) — *Авызың белән кош аулап йөрисең. Бу вакыт эчендә син түгел, мин үземә каратыр идем инде.* Ш. Бикчурин. **Авыз белән кош тоту** — 1) бик булдыклы, җитез, зирәк булу. *Фәхетдинов өчен ул аяклы хәзинә, табыш, авызы белән кош тотучы, тагын әллә нәрсә, тагын әллә кем иде.* Ф. Хөсни; 2) телгә оста булу; 3) *к.* авыз ачып йөрү (тору). **Авыз да ачмау** — бер сүз дә әйтмәү, эндәшмәү, бөтенләй сөйләшмәү. *Нәбиуллин авыз да ачмады. Аркасындагы тулы капчыгын тиз генә сәкегә куеп чишә башлады.* А. Әхмәт. **Авыз да аччтырмау, авыз ачарга да ирек бирмәү** — 1) бер сүз дә әйттермәү, сүз әйтергә дә бирмәү; 2) берәр мәсьәләдә ник тору, башкаларны тынламау, үзенекен итү. **Авыз еру** — елмаю, көлү. *Хәзер дә әнә, Хәкимҗанны күрүгә үк, ни өчендер, авызын ерып җибәрде.* А. Әхмәт. **Авыз икмәккә тую** — тамак тую, тук булу. **Авыз итү** — бераз гына ашау яки эчү. — *Аштан олы түгелсең бит, Шәрифулла туган, утыр, безнең нигъмәттән дә авыз итеп кара.* А. Шамов. [*Локман:*] *Курыкма, сеңел, җиңгәң үзе дә авыз итте.* Ш. Камал. **Авыз йомып тору (утыру, калу)** — сүзгә катнашмау, эндәшмәү. — *Наташа белән ярышу алай ансат булса, синнән олыраклар авызын йомып утырыр идемени?* Г. Бәширов. **Авыз йому** — сүзсез калу, сөйләүдән туктау. *Кызның соңгы сүзләрен ишеткәч, ул авызын йомды һәм уңайсызланып командирга күз төшереп алды.* А. Шамов. **Авыз кибү** — эчәсе килү, сусау. *Хәлем бетте... Күз алларым караңгыланды. Авызым кипте.* Г. Ибраһимов. **Авыз колакка (кадәр ерылу) җиту** *сөйл.* — бик куану, шатлану. *Әнинең авызы колакларына җиткән, киленне ошаткан, янәсе.* Ф. Хөсни. *Кәефләре дә шәп булса кирәк: авызлары колакларына кадәр ерылган.* Ә. Еники. **Авыз күтәреп** — ачыктан-ачык, яшермичә, кеше алдында, оялмыйча (җырлау, елау кебек хисләрне чагылдыра торган эш башкару). — *Авыз күтәреп, урам буйлап җырлап йөргәнем, аулакларда вакыт үткәргәнем бармы минем?* А. Шамов. — *Кеше шатланып туй иткәндә, син тагын авыз күтәреп елап торасың!* Г. Камал. **Авыз күтәреп йөрү** *сөйл.* — 1) эшсез йөрү. — *Әй син, Картлач! Йөрмә бушка авыз күтәреп!.. Акча аласың кеше исәбеннән.* М. Гафури; 2) бернәрсә турында да уйламау, кайгыртмау, гамьсез яшәү. **Авыз күтәреп калу** — *к.* авыз ачып калу. — *Без барыбыз да җирен дә алырбыз, урманын да кисәрбез, ә син авызыңны күтәреп калырсың әле.* И. Гази. **Авыз күтәреп сөйләү** — юк кына нәрсәне дә зур итеп сөйләү, зур вакыйгага әйләндерү. **Авыз пешү** — алдану, уңайсыз хәлгә очрау. **Авыз пычрату** — 1) азга да риза булу; 2) тәнкыйтьтән дә түбән нәрсәне яки яман кешене телгә алып сөйләү турында. **Авыз салындыру (салу)** — күңелсезләнү, кәеф кырылу, сөмсере коелу, үпкәләү. *Ул көнне Казан китапчылары, бер тиен дә сату итә алмыйча, авызларын салындырып, өйләренә кайттылар.* Г. Тукай. **Авыз суларын китерү** — кызыктыру. *Каты пешкән күкәй Маратның авыз суларын китерде.* Г. Гобәй. **Авыз суы кору (корыту)** — кемне яки нәрсәне дә булса яратып күп мәртәбә телгә алу; кызыгып сөйләү. — *Җәдитләр музей дип авыз суларын корытып сөйлиләр иде, шушы пулат була икән инде ул музей дигәннәре.* Ф. Әмирхан. **Авыз тидерү** — кабып (эчеп) карау, татып карау. *Мәҗлестәгеләр бәлешкә авыз тидерү белән: „Телеңне йотарсың, шундый тәмле", — диешеп, үзлексез сөйләнеп, мактап, күтәреп шаулаштылар.* Г. Ибраһимов. **Авыз турсайту (бүлтәйту)** *сөйл.* — үпкәләү, ачулану, хәтере калу. *Хәзрәт, ачуланып, авызын турсайтты, ләкин җавап бирмәде.* Ф. Әмирхан. *Берәүләребез бу почмакта авыз бүлтәйтеп, икенчеләребез теге почмакта каш җимереп торуда ни файда?!* И. Гази. **Авыз тутырып ашау** — туйганчы ашау. *Әллә кайчаннан бирле инде рәхәтләнеп авыз тутырып кызыл кесәл дә ашаганым юк.* Г. Камал. **Авыз тутырып әйтү** — курыкмыйча туры әйтү, күзенә карап әйтү. **Авыз тәме** — аппетит. *Аның каты авырудан соң авыз тәме аз гына да юк иде.* Г. Гобәй. *Әшләп тапкан Хәләл ипи дигән нәрсә Авыз тәме, Яшәү яме бирде миңа.* З. Мансур. **Авыз тәмен җибәрү** — 1) аппетитны бозу; 2) кәефне бозу, кәефне кыру. **Авыз төртү** — тәмен тату, рәхәтен, табышлы булуын сизенү. *Рәсәйнең бәрәкәтле туфрагына авыз төрткән комсыз колонистлар бик тиз үрчегәннәр.* Каз. утл. **Авыз чайкау** *гади с.* — 1) гайбәт сөйләү, кеше исемен яман яктан телгә алу, кешенең яман атын сату. — *Син, малай, Хәйрүш, минем белән күп авызыңны чайкама!* Ф. Сәйфи-Казанлы; 2) кат-кат телгә алу. *Татар халкы белән авыз чайкарга яраткан Курманаев әфәнде бүген революциядән һәм большевиклардан качып китеп бара иде.* Ф. Хөсни. **Авыз эчендә ботка пешерү** *кимс.* — 1) үз фикереңне аңлата алмау, аңлаешлы итеп сөйли алмау; 2) мыгырдану, үзалдына гына сөйләү. — *Җенләнеп кердеңме әллә? Сорауганга җавап бирмичә, берөзлексез авыз эчендә ботка пешерәсең?* Ф. Хөсни. **Авыз чылату (җебетү)** — бераз эчеп алу. **Авыз эченнән** — үзалдына, башкаларга ишеттермичә. — *Карт авыз эченнән минем юлыма багышлап хәер-дога ларны укыгач та, чыгып киттек.* Г. Минский. **Авызга авыз сөйләшү** — бер-береңә бик якын килеп, бик бирелеп сөйләшү, серләшү. **Авызга алу** — 1) телгә алып сөйләү, искә алу. [*Гайни:*] *Мондагыларны авызга да алып сөйләргә ярамый.* Г. Камал; 2) татып карау, кабып карау. — *Эчемә сыймас шатлыгым, дөньяга сыймас кайгым булса да, [аракының] тамчысын да авызга алмаска ант иттем, иптәшләр.* Г. Гобәй. **Авызга да алмаслык, авызга алгысыз (капкысыз)** — 1) тәмсез, ашарлык түгел; 2) оятсыз, кабахәт (сүз турында). *Кәлимулла агай авызга алмаслык сүзләр белән сүгенә.* М. Гафури. **Авызга йөзек яшерү** — *к.* авызга су кабу. *Җыр тынган арада, солдатларның берсе, старшинага мөрәҗәгать итеп: — Ә разведчик нишләп авызына йөзек яшереп тора! — диде.* Г. Әпсәләмов. **Авызга карату** — бик оста, ягымлы сөйләү, сүз белән үзенә җәлеп итү. — *Мәхмүт бөтен кешене авызына караткан... ул анда нәрсә сөйли дип беләсең?* Ш. Камал. **Авызга ни килсә, шуны сөйләү (кычкыру)** — уйламыйча сөйләү, теләсә ни сөйләү (кычкыру). *Һәркайсы авызына нәрсә килсә, шуны кычкыра, көлешәләр.* Ш. Камал. **Авызга су кабу, авызга су капкан төсле (капкандай) булу** — сөйләшмәү, дәшмәү, җавап бирмәү. *Чуртан Халикъ авызына су капкан төсле утыра.* Ш. Камал. *Газинур, моштым Газзә кебек, авызына су капкандай, дәшми-тынмый*

гына эшли торган кеше түгел. Г. Әпсәләмов. **Авызга хуҗа (ия) булу** — сер һәм сүз саклый белү, юкбарны сөйләмәү, чамалап, уйлап сөйләү. **Авызга чәйнәп салу** — бик җентекләп, бәйнә-бәйнә аңлатып бирү. *Дөрес нәтиҗәне укучы үзе ясый алыр дип уйлыйм мин, авызына чәйнәп салганны көтеп утыра торган яшьтә түгел ул хәзер.* Ф. Хөсни. **Авызга чөй кагып** — тавышны ишеттермичә. — *Авызыңа чөй кагып җырласаң, һичберкем дә сүз әйтмәс.* Г. Коләхметов. **Авызда чебен уйнату** — *к.* авыз ачып йөрү. *Алар синең улың кебек авызларында чебеннәр уйнатмыйлар.* Һ. Такташ. **Авыздан авызга** — 1) буыннан буынга, кешедән кешегә (сөйләп, язмыйча). *Халык әдәбияты дип --- авыздан авызга сөйләнеп йөртелгән нәрсәләргә генә әйтелә.* Г. Тукай; 2) үзара гына, шыпырт кына, сер итеп, авызга-авыз. *Икә ел буе агрылышып торган бу икә дус бакчаның аулак бер җирендә, күзгә-күз карашып, авыздан авызга бик озак сөйләштеләр.* Г. Ибраһимов. **Авыздан сулар килә (китерә, китерерлек)** — 1) бик тәмле нәрсәне күргәндә яки тәмле ризык исен сизгәндә әйтелә. *Итле, борычлы кайнар тозмач исе борыннарны кытыклап, авызлардан сулар китерде.* Г. Гобәй; 2) бик сөйкемле кешегә яки берәр кызыктыргыч матур нәрсәгә йотылып карау, бик нык тәэсирләнү, ләззәтләнү турында. *Һәммә шәкерт ул йортлар вә андагы кызлар хакында авызыннан сулар китерерлек мәртәбәдә кызышып, яратып сөйләде.* Г. Ибраһимов. **Авыздан тартып алу** — 1) берәр нәрсәдән мәхрүм итү, көчләп алу. *Вәли Хәсәнов совхоздагы эшләрне боларның авызыннан тартып алып, кулакка бирә.* Г. Ибраһимов; 2) кешене берәр таянычыннан, ышанычыннан, хыялыннан мәхрүм итү; 3) максатына ирешкәндә генә аяк чалу, комачаулау. *Ә бит без аны [кызны] киявенең авызыннан диярлек тартып алып китәбез.* Ф. Хөсни; 4) күз алдында алып китү. — *Моннан ун еллар элек, Хаҗиның исән чагында, менә шул мәгәнәгез сынлы асыл юргасын каракларның авызыннан тартып алып биргән идем.* Г. Ибраһимов. **Авыздан төшмәү** — 1) берәр нәрсә яки кеше турында һәрвакыт сөйләп тору, һич тә онытмау. — *Җыелыш саен авызыбыздан төшми торган „социализм" сүзенең мәгънәсен күз алдына китерүдә Гаязга караганда никадәр түбән торуымны сиздем.* М. Әмир; 2) кабатлап тору (мәс., җырны). **Авыздан ут чәчү** — 1) бик оста, гайрәтләнеп сөйләү, матур сөйләү. [*Мотыйкның*] *һич телгә телгә йокмый инде, авызыннан ут чәчә, каян бу кадәр һәммәсен белеп бетергән.* М. Гали; 2) бик каты талашу. **Авыздан җан чыгу** — үлү. *Җаным чыкканчы авызымнан, Йөрермен һәрвакыт бергә.* М. Гафури. **Авызны чөйгә элү** — 1) ашамау, ач тору; 2) сөйләшмәү, ачуланып, үпкәләп сүзгә катнашмау. — *Я, — диде анасы да, — нигә авызыңны чөйгә элеп куйдың?* А. Шамов. **Авызны үлчәп ачу** — артык сүз ычкындырмау, уйлап, чамалап сөйләү. **Авызны җыю** — сөйләүдән, көлүдән һ. б. ш. туктау. *Авызыгызны җыя төшегез, малайлар!* Г. Камал. **Авызы томалану (тыгылу, бикләнү, капланау)** — 1) сүз әйтә, каршы җавап кайтара алмас хәлдә калу, җиңелүеңне аңлау. *Хәлимнең авызы томаланганны күреп көлгән малай өстәп куйды: — Ләкин, карагыз аны, фил булырга йөргән бака хәленә калмагыз!* Г. Гобәй. — *Җәдит син, җәдит. Аягыңа кара, хи-хи-хи!.. Авызы тыгылдымы малаеңның?* Г. Камал; 2) берәр сүз, фикер һ. б. ш. белән килешү, дәгъвалашудан, тавышланудан туктау. **Авызы тулы кара кан булу** — кайгы-хәсрәте зур булу. [*Ана*], *тукта, диде, улым кеше арасында кешечә булсын, диде, авызы тулы кара кан булса да, төкермәде.* Ш. Хөсәенов. **Авызын ачса' үпкәсе күренү** — 1) арык, артык ябык; 2) бик ярлы' хәерче тормышлы. — *Әгәр дә хәзер шунда артель оештырып, авызын ачса, үпкәсе күренергә торган Имәлиләр адәм рәтенә кереп китсә?* М. Әмир. **Авызын майлау (тыгу)** — ришвәт бирә яки башкача җайлап үз ягына аудару, берәр мәсьәләне үз файдасына хәл итү. *Бер кешенең авызын майларга мөмкин, ике кешенең, күп дигәндә, өч кешенең, ә урамның авызын майларга мөмкин түгел иде.* Ф. Хөсни. *Ул малайның акча белән авызын тыксаң?* М. Фәйзи. **Авызын каплау (ябу, томалау)** — 1) нинди дә булса тапкыр сүз я эш белән уңайсыз хәлдә калдыру, артык сүз дәшмәслек хәлгә кую. *Ул Сәлимнең авызын капларлык кына сүз тапкан булыр иде, ләкин бүген аның һич тә әрләнәсе килми иде.* Г. Әпсәләмов. *Җирәнбай үсенеп китте: — Афәрин, нәни абый! Менә моның белән җәдитләрнең авызын яптың!* Ә. Фәйзи; 2) *к.* авызын майлау. *Аның авызын каплар өчен теге аңа өч йөз сум акча биреп куйган.* Ш. Камал; 3) авызына сугу, кыйнау. *Солдат аның авызын капларга сузылган иде, әләкмәде.* Ш. Камал. **Авызын кызылга буяу** *гади с.* — авызына сугып канату, кыйнау. — *Теге сүзләрең өчен [аның] йодрыгы авызыңны кызылга буяганда яраган булыр иде.* М. Фәйзи. **Авызын тоту** — сөйләтмәү, сөйләргә ирек бирмәү. — *Кешегә сөйләп бетерергә ирек бирегез. Без сезнең авызны тотмадык бит.* М. Әмир. **Авызына карап тору** — 1) хәйран булып яки бик яратып, күз дә алмыйча карап тыңлау. *Аның әйләнә-тирәсенә иңнәренә эти-әниләренең киемнәрен салган бала-чагалар чүмәкләшкәннәр дә, таң калып, бабайның авызына карап торалар.* Г. Әпсәләмов; 2) кемнең дә булса берәр нәрсә өмет итүе турында. *Бу һаман әле үзенең чалбар тектерүеннән алып Думага кемне сайлау кеби саф дөнья эшләрен мулла авызына карап көтеп торучы бер кыйсем халык эшенә генә охшый иде.* Г. Тукай. **Авызына керердәй булып** — зур игътибар белән, бирелеп, йотылып (тыңлау). *Гадәттә гел шаярып утыра торган яшь малай-шалай да, тыннарын чыгармыйча, Каюмның авызына керердәй булып тыңлап утырдылар.* Ш. Камал. **Авызына менү (менеп төшү, утырту, кую, бәрү).** — авызына сугу. *Ул, үзенең буе җитмәслегенең күренеп торуына да карамыйча, шул агайның авызына менде әле.* Ф. Әмирхан. **Авызына теле сыймау** — сер тота белмәү, сер саклый белмәү, теле тик тормау, сүз тотмау; артык күп сөйләү. — *Авызыңа телең сыймыймы әллә? Нәрсә лыгырдаган буласың!* Г. Камал. **Авызына җен (шайтан, иблис, саескан) төкергән** — 1) күп һәм оста сөйләүчегә карата әйтелә. — *Бу Бикмулланың авызына җен төкергәндер, каян таба, гыйбрәт!* Ә Еники. — *Товарын мактарга дисәң, авызына шайтан төкергән инде!* Ф. Хөсни. — *Трактор Шәяхмәт дигән малайның, әйтерсең, авызына иблис төкергән инде. Шулай әрләнеп-әрләнеп талашып бара.* Г. Ибраһимов; 2) начар, әдәпсез, оятсыз сүзләр сөйләүчегә карата әйтелә. *Булат дус, авызларына саескан төкергән бу халыкны сүз белән җиңә алмассың.* К. Тинчурин. **Авызыннан (ана) сөте дә кипмәгән** — бик яшь, тәҗрибәсез. — *Авызыннан ана сөте кипмәгән берәүдән үлем турында ишет тә, аптырамый кара син!* Г. Минский. **Авызындагын (авызыннан чыкканны) эт җыймас (ягъни: җимәс, йимәс, ашамас)** — начар сүзле, сүгенүчән, тупас телле кеше турында. **Авызыннан сүз тартып ала алмассың** — күп сөйләмәүчән, аз сүзле кеше турында.—*Бу кадәр әтиең булырсың икән, авызыңнан һичбер сүз тартып ала алмассың!* Г. Гобәй. **Авызыннан төшермәү (ташламау)** — 1) гел бер нәрсәне бертуктаусыз кабатлау. *Авыл урамнарында*

егетләр, көз көне никрутлар яңа көйдән тәмам ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар. Г. Тукай; 2) яратып, мактап сөйләү, гел искә алу. **Авызыннан өзеп бирү** — кеше яки үз өлешен башкага бирү. [*Сафура*] *кечкенәләрнең авызыннан өзеп, барлык тәмлеләрен иренә куйды.* Г. Ибраһимов. **Авызы әйткәнне колагы ишетми!** — уйлап, чамалап сөйләми дигән мәгънәне белдерә. **Авызыңа бал (да май)** — яхшы, күңелгә хуш килә торган сүзләр сөйләүчегә яки хәбәр алып килүчегә карата әйтелә.—*Авызыңа бал, авызыңа май. Ходай бирсен дә, шулай була күрсен инде.* М. Фәйзи. **Авызыңнан җил алсын** — күңелгә ятышсыз сүз сөйләүчеләргә яки теләк теләүчегә карата әйтелә. — *Чү, чү, балам, авызыңнан җил алсын, андый юкбар сүз сөйләмә.* Р. Ишморат.

АВЫЗ-БОРЫН *җый. и.* Авыз һәм борын. [*Гаяз*] *авыз-борын тирәсен сөртеп алгач, тагын тәмләп ашарга кереште.* М. Шабай. *Авызы-борыны корымга буялган зур башлы бер шадра малай, итәкләренә салып, бәрәңгене чокыр ягасына менгезеп куйды.* И. Гази.

АВЫЗЛАНДЫРУ *ф.* Яңа туган балага беренче мәртәбә ризык (баллы май) каптыру. *Хан тугач та, аны, башка балаларны авызландырган кебек, бал белән дә, май белән дә авызландырмаганнар, бәлки агу белән авызландырганнар, дип сөйлилләр.* Г. Гали.

АВЫЗЛЫК *и.* **1.** Ат авызына кидерү өчен йөгән каешына беркетелгән тимер җайланма. *Туктагач, атлар пошкырырга, авызлыкларын салырга теләп шылтыратырга, бер-берләренә ышкыныргa, киерелгәләргә тотындылар.* А. Шамов. *Гомеренә авызлык кимәгән ул атны инде ямщик арба үрәчәсенә ике аягын терәп тартып та туктата алмый.* М. Гали.

2. *күч.* Буйсындыручы, билгеле бер кысада тотучы көч. *Ә Сәлмән карт дилбегәне кулдан ычкындырмый һәм, яшьләр буразнадан чыга башласалар, аларның авызлыгын вакытында һәм бик нык тарта белә.* Ф. Хөсни.

3. *сөйл.* Авыз тирәләре бозылудан гыйбарәт авыру.

АВЫЗЛЫКЛАУ *ф.* **1.** Авызлык кидерү. *Атларны авызлыклап, аркалык белән бавыргалыкларын яңадан ныгыттылар.* М. Гафури.

2. *күч.* Үз иркенә буйсындыру, башбаштаклыкка юл куймау, кулда нык тоту, каты тоту.—[*Минем остам*] *хаклы булып калды, ул мине тагы да ныграк авызлыклады. Хәзер минем бер сүзем дә өстен чыкмаячак.* А. Расих. [*Мулла:*] *Юк, юл бирмәскә кирәк аларга* [*халыкка*], *дилбегәне ныгытып тотарга кирәк, авызлыкларга кирәк аларны!* А. Шамов. // *күч.* Тәртипкә салу, законлаштыру, стихиягә юл куймау. *Бүгенгенең чиксез ашкынуы, авызлыклап тормыш агымын, Алгы көрәшләрне күздә тотып, Кызулатты корыч адымын.* Һ. Такташ.

АВЫЗЛЫКЛЫ *с.* 1. Авызлыкланган, авызлык кидерелгән. *Авызлыклы атны икәү тыеп, Тау битеннән төштек болынга.* Ф. Кәрим.

2. Авызлыгы булган, авызлык беркетелгән. [*Габдулла*] *учына төкергәләп, йөгәннең авызлыклы башы белән Зәйтүнгә селтәнде.* Ф. Хөсни.

АВЫЗСЫН *и. диал. к.* зәңгелә.

АВЫЗ-ТЕЛ: авыз-тел бәйләнү — аптыраудан сүзсез калу, сүз әйтә алмый тору. *Менә аның шундый ягымлылыклары мине бөтенләй әретеп бетерде. Авызым-телем бәйләнеп, әйтә торган сүземне әйтә алмадым.* М. Гали.

АВЫЗЧЫК *бот.* Үсемлек яфрагы тиречегенең яшел төстәге парлы күзәнәкләре арасындагы ярык. // Чәчәк уртасында бер башы чукмарланып торган, икенче башы җимеш белән тоташкан таякчык сыман җимеш лек, чәчәк аналыгы; *русчасы:* пестик. *Җил белән яки бөҗәкләр ярдәмендә теге я бу чәчәкнең авызчыгына серкә күчерелә.* Биология.

АВЫЗ-ШИГЫРЬ *җый. и.:* **авыз-шигырь иҗаты** — халык шигырь иҗаты әсәрләре. *Авыз-шигырь иҗатының фантастик геройлары Тукай уенда да калмый ияреп йөриләр.* Г. Нигъмәти.

АВЫЛ *и.* **1.** Авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче халык яши торган урын, торак пункт. *Авылны чыккач, Хәлим малайларга пилоткаларын салып бүрек кияргә кушты.* Г. Гобәй.

2. Авылда яшәүчеләр, авыл халкы. *Бөтен авылның диярлек бу спектакльне кызыксынып көтүе безнең болай да канатланган йөрәкләребезне җилкендерә.* М. Әмир. *Авыл уянды. Өй түреннән, урам тутырып, көтү үтеп китте.* Г. Гобәй.

Авыл агае — 1) авыл кешесе. *Авыл агайларының ел саен горурланып сөйли торган берәр яңалыклары була.* Г. Ахунов; 2) *кимс. иск.* грамота ягыннан түбән булуга ишарә иткәндә әйтелә. **Авыл хуҗалыгы** — игенчелек, терлекчелек һәм яшелчәчелек эшләре.

АВЫЛДАШ *и.* Кем белән булса да бер үк авылдан булган кеше. *Ләкин Сәфәргали авылдашларыннан берәүне дә күрмәде.* Ф. Хөсни. *Авылдашлары һәм укытучылары, Хәйдәрнең батырлыгына сокланып, аның белән горурландылар һәм котлап хат яздылар.* Г. Бәширов.

АВЫЛДАШЛЫК *и.* Авылдаш булу. — *Зинһар, кем, Мортаза туган, агачның адәм рәтләрәкләрен бирә күр инде. Авылдашлык хакына гына булса да, кимхур итә күрмә.* М. Хәсәнов.

АВЫЛЛАШУ *ф. сир.* Авылга, авыл тормышына ияләнү, авыл кешесе булып китү. *Ул бөтен табигате белән каланы ярата, шул дәрәҗәдә ки, Гәрәй Мирзага иргә килеп, утыз еллап торса да, авыллаша, авыл тормышын үз итә алмасы.* Г. Ибраһимов

АВЫЛЧЫ *с. сөйл.* Өйдән өйгә эшсез-йомышсыз йөрергә яратучы кеше; *к.* биләмче. *Авылчы хатынның колагы озын, теле аннан да озын.* Мәкаль.

АВЫНКЫ *с. сөйл.* Бер якка таба ава, янтая төшкән, авышып тора торган. *Диңгез ягасында, суга кермәскә тырышып торган аякларын алга терәгән шикелле, тышка таба авынкы бер казык күренә иде.* Ш. Камал.

АВЫНКЫЛЫК *и.* Бер якка таба янтайган булу, янтайганлык.

АВЫНКЫРАУ *ф. сөйл.* Бераз авышу, янтаебрак, авыбрак тору.

АВЫР I *с.* **1.** Үлчәүгә күп тарта торган, зур үлчәүле; *киресе:* җиңел. [*Мусаның*] *бәләкәй һәм җиңел чемоданы хәзер күтәреп баруы мөмкин булмаган дәрәҗәдә авыр иде.* Ш. Маннур. *Авыр машина кисәкләре төялгән әрҗәләрне ыргак белән эләктереп тартуларын күргәч, ул бар кайгысын онытты.* К. Нәҗми.

2. Кайгылы, хәсрәтле, борчулы. *Еллар авыр иде. Ике ел рәттән иген уңмады.* С. Җәләл. *Авыр чорда халкым „улым" дисен, „Таянычым" дисен туган ил.* Ф. Кәрим. // Материаль яктан кыенлашкан, җитмәүчелек булган, начар; бәхетсез (тормыш, язмыш турында). — *Сабыйларым минем, балаларым Авыр тормышларны күрмәде.* Н. Баян.

3. Авыр сөякле, салмак, акрын кыймылдаучан, иренчәк. — *Ул тере булсын, артык җанлы булсын, мин үзем дә авыр, басынкы кеше.* Г. Ибраһимов // *рәв. мәгъ.* Акрын, ашыкмыйча, салмак. *Асрау, Хәятның салган киемнәрен элеп куйды да, бер сүз дә әйтмичә,*

авыр вә ялкау гына атлап чыгып китте. Ф. Әмирхан. [*Егет*] *йөткереп бетергәч, хәлсезләнеп, авыр гына дәвам итте.* А. Шамов.

4. Каты, җитди. *Давыл тынды, ләкин тәнебездә Сызлап тора авыр яралар.* Ә. Ерикәй. *Санитарлар авыр яралыларны җыеп бетерүгә, яңадан туптан аткан тавышлар яңгырады.* М. Гали. / *рәв. мәгъ. Авыр яраланган батыр Егет сыкранганда, түзми киләсең, Башын салып йомшак кулларыңа, Син егетнең хәлен беләсең.* Ф. Кәрим.

5. Зур хезмәт, физик яки акыл көче түгүне сорый торган, мәшәкать белән башкарыла торган. — *Эшем авыр түгел, җиңел, командир да үземне ярата.* Ә. Айдар. *Сугыш елларында аңа төрле авыр эшләрдә эшләргә туры килде.* Г. Минский. // Кыен, читен, мәшәкатле. *Максатның ачык булуы нинди авыр юлларны да җиңел үтәрлек, батырларча җиңеп үтәрлек көч бирә.* М. Әмир. *Карлар яусын йөргән юлларыңа, Авыр юлда атың армасын; Кичер мине усал сүзем өчен, Ходай өчен, хәтерең калмасын.* Һ. Такташ // *рәв. мәгъ.* Кыенлык белән, мәшәкать белән. *Ул үзенең хатында башта заводта эшләрнең һаман да авыр барганлыгыннан, материал җитештерүдә әледән-әле тоткарлыклар килеп чыгудан зарлана да, шуннан гомуми сәяси хәлләргә күчә.* Ш. Камал. // Тиз генә аңлап, төшенеп булмый торган, зур акыл көче яки тәҗрибә, белем сорый торган. [*Унлап кеше*] *һәммәсе дә, авыр бер математик мәсьәлә чишеп утырган кебек, артык тирән уйландылар.* Г. Ибраһимов. // Чишүе, хәл итүе кыен булган. — *Тимерче мәсьәләсе — --- иң җитди һәм авыр мәсьәлә.* Т. Гыйззәт.

6. Күңелгә начар тәэсир итә торган, кешенең психикасына, рухына газап китерә, кәефен боза торган; кайгылы. *Бу сүзләрне әйткәч, теге бушлык, теге авыр тойгы бераз җиңелләп китте.* Ф. Әмирхан. *Авыр хәбәр тиз арада бөтен Зәңгәр чишмә буена яшен тизлеге белән* [*таралды*]. Г. Ибраһимов.

7. Организмга начар тәэсир итә, сулауны кыенлаштыра торган, тынчу. *Борынга әллә нинди авыр, күңел болгаткыч көек исе керә, күз алдында ялкын телләре уйный.* Г. Бәширов.

8. Аңлаешсыз, буталчык, катлаулы (тел-стиль турында). [*Дсәрдә*] *балалар теле эшләнмәгән... Озын авыр җөмләләр күп очрый.* М. Җәлил. / *рәв. мәгъ. Элегрәк чорларда аның речьләре, докладлары шома чыкмый, авыр бара иде.* Ш. Камал.

9. Тупас, кимсетүле, хәтерне калдыра торган. *Авыр сүзләр әйтмә миңа, йөрәгемә ярамый.* Җыр.

10. *и. мәгъ.* Авыр эш. — *Я аллә, эшләр бераз җиңеләя, иң авырлары үзды.* Г. Камал. — *Ни булса булыр, авырга җиктермим, менәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм.* Г. Ибраһимов. // Авырлык. *Валда егермешәр, утызар кеше генә чиратлашып эшләгәндә, күп халык арасында аның авыры боларга тими дә иде.* Ш. Камал. — *Алайга киткәч, авырны да җиңеп чыгарга кирәк шул, кызым.* Г. Бәширов.

Авыр артиллерия — ераккa ата торган зур калибрлы туплар, бик куәтле, зур габаритлы кораллар. *Кинәт немецларның авыр артиллериясе ата башлады.* Г. Әпсәләмов. **Авыр атлетика** *спорт.* — авырлыклар күтәрүдән гыйбарәт булган спорт төре. *Гали солдатта чакта авыр атлетика белән шөгыльләнгән иде.* Г. Мөхәммәтшин. **Авыр водород** — водородның изотопларыннан берсе; аның массасы изотоп атом массасыннан ике тапкырга авыррак була. *Авыр водород атомының төше дейтон (яки дейтрон) дип атала.* Физика. **Авыр промышленность (индустрия)** — промышленностьның эшләп чыгару средстволары барлыкка китерә торган тармагы. **Авыр су** — молекуласы составында гади водород урынына авыр водород булган су. *Авыр суның тыгызлыгы гади суныкыннан 12 тапкыр артыграк. Күп кенә терек организмнар авыр су тәэсире белән үләләр.* Физика.

◇ **Авыр аяклы** — 1) йортка яки эшкә уңышсызлык китергән кешегә әйтелә; 2) *диал.* авырга узган, йөкле. — *Кастелянша да авыр аяклы бугай. Сестраларның берсе шулай түгелме икән дип мин шикләнә төшәм.* Ш. Камал. **Авыр булу** — 1) күңелгә, кәефкә начар тәэсир итү. — *Элекке ирем бик усал булып чыкты, сүзем авыр булмасын.* Ш. Камал; 2) кыен булу, кыенлык китерү, мәшәкать булу. — *Дгәр сиңа авыр булмаса, минем папкаларымны һәм кулъязма дәфтәремне алып кил.* М. Җәлил. **Авыр гәүдә(ле)** — 1) бик симез, таза кеше турында. [*Әпипәнең*] *чәчләре битенә төшкән, ул авыр гәүдәсе белән әүмәкләнеп шуыша иде.* Г. Бәширов; 2) иренчәк, акрын кыймылдаучы, хәрәкәтләнүче кеше турында әйтелә. **Авыр йөк** — күңелгә, җанга тынычсызлык китереп тора торган зур мәшәкатьләр. **Авыр йөк төшкәндәй (булу, калу)** — нәрсәдәндер арынып, җиңеләеп, иркенәеп калу. *Ул, гүя өстеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел генә китәр уңаена атлады.* Г. Бәширов. **Авыр кеше** — *к.* авыр табигатьле (холыклы). **Авыр куллы (кулы авыр)** — эшнең уңмавын башлап җибәрүчегә сылтаганда кулланыла. **Авыр сөякле** — *к.* авыр гәүдәле (2 мәгъ.) **Авыр табигатьле (холыклы)** — сабыр, төпле. *Ул минем күңелдә әллә ничек басынкы, авыр табигатьле кеше булып калган.* Г. Гобәй. **Авыр тарту** — үлчәүгә авыр килү. *Алтын алка авыр тарта, Алты мыскалдан арта.* Җыр. **Авыр туфрагы җиңел булсын!** — үлгән кешене искә алганда әйтелә. **Авыр тынлык** — кайгы, борчу яки аңлашылмаучылык, канәгатьсезлек аркасында туган сүзсезлек. *Председатель Сөләйманов халыкның хәрәкәткә килүен бераз көтеп торганнан соң, ниһаять, бу авыр тынлыкны үзе бозды.* Ә. Еники. **Авыр чир** — котылуы, арынуы бик читен булган нәрсә. *Мәгъри белән Гайни типлары — капитализм шартларында кешелек җәмгыятендә булган авыр чирләр.* М. Гали. **Авыр яту** — бик каты авыру. *Хәлимнәр ротасыннан килгән Мифтах исемле бер егет берничә көннән бирле бик авыр ята иде.* А. Шамов. **Авыр(га) алу** — сүзне үзе өчен бик рәнҗетүле итеп кабул итү, рәнҗү. — *Тик, Харрас җаный, хәтереңә авыр алма, минем сиңа гашыйк булганым юк әле.* Ә. Айдар. — *Гуктале, мин әйтәм, абзый кеше. Нигә алай авырга аласың?* М. Әмир. **Авырга калу** — авырлашу, кыенлашу. *Аларның язмышлары бик авырга калды.* Г. Ибраһимов. **Авырга килү** — төрле кыенлыклар, авырлыклар тудыру. *Шәп-шәрә урынга тормыш корып җибәрүе бик авырга килсә дә, Тимери рәнҗемәде.* Г. Бәширов.

АВЫР II *и.* Йөк, корсак, көмән. *Авыры бар.* □ *Күрәсең,* [*Гафифәгә*] *юл йөрү килешмәде. Җиденче ай белән барган авыры вакытсыз дөньяга килде.* Х. Садрый.

◇ **Авырга калу (узу)** — балага узу, йөккә калу.

АВЫРАЙТУ *ф.* **1.** Авырландыру, авыр итү, авырлыгын, үлчәвен арттыру.

2. Кыенлату, начарлату. // Кыенлаштыру, читенләштерү; катлауландыру. [*Чулпани*] *үзенең шигырьләрен гарәп һәм фарсы сүзләре белән авырайта барды.* Ә. Фәйзи.

3. *күч.* Хәлсез итү, хәлсезләндерү. *Яңгыр түгел, гүя терекөмеш яуды Сәлим өстенә, һәрбер тамчы аның гәүдәсен авырайтты.* Г. Гобәй.

АВЫРАЮ *ф.* **1.** Авырлану, авырлыгы арту. *Шактый авырайган арба акрын гына кузгалды.* К. Нәҗми.

2. Авырлашу, начарлану. *Көннәрнең берендә, илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң, заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан зарланып, әңгәмә ачылды.* Г. Ибраһимов. // Кыенлашу, читенләшү, кыен, читен эшкә әверелү. *Таймыйча атлау торган саен авырая барды.* И. Гази. *Габдуллага җавап кайтару авырая төште һәм, ниһаять, ул Чулпаниның бар шигыренә җавап бирә алмый тукталып калды.* Ә. Фәйзи.

3. Хәлсезләнү, нормаль хәрәкәт итүдән туктау. *Илсөяр калтыранып куйды, гәүдәсе авыраеп китте, ул алга атларга телә́де, ләкин кузгала алмады.* Г. Гобәй. *Ул күзләрен ачарга тырыша, әмма күз кабаклары авыраеп басып төшәләр, күзләр йомыла.* Ә. Фәйзи. *Туктап, атларны ашарга кушу белән, берьюлы авыраеп киткән аякларын көч-хәл белән сөйрәп, кайсы-кая барып тунделәр.* Г. Бәширов.

4. *сөйл.* Йөкле хатыннарның бала табар вакыты җитү. // Авыруның хәле начарлану. — *Хәлең бик авыраеп киткән, читтән доктор китерттек.* Г. Гобәй.

5. *күч.* Начарлану, бозылу (һава турында). *Ал вә кызыл чәчәкләр --- дәва исләре белән авырайган һаваны үзләренең гөллек исләре белән җиңеләйткәннәр, хәятландырганнар, бүлмәгә шигърият керткәннәр иде.* Ф. Әмирхан.

АВЫРЛАТУ *ф.* Авырайту (1, 2 мәгъ.). *Дүрт атның икәвесенең яшь булып, сабанга өйрәнмәгән булулары безнең эшне чиксез авырлатты.* М. Гафури.

АВЫРЛАШУ *ф.* • Кыенлашу; кыен, читен хәлгә килү. *Эш авырлашу.* // Начарлану. — *Минем уку ягы яхшы, ләкин азык мәсьәләсе барган саен авырлашты.* М. Гафури.

АВЫРЛЫ *с.* Балага узган, йөкле, көмәнле. — *Авырлы хатын җир бишына килеп, авырлыгын калдырып китте, дип уйлама тагын син.* М. Шабай. — *Авырлы вакытымда ук аның юньле бала булмаслыгы төшемә кергән иде.* Г. Камал. / *и. мәгъ. Авырлылар палатасы.*

АВЫРЛЫК *и.* 1. *физ.* Әйбернең үлчәүгә салып билгеләнә торган үзлеге. *Тарыда тары төсле үк, аның авырлыгындагы үк, тик бик әз генә ваграк лисохвостка дигән чүп бар иде.* Г. Гобәй. *Бер якта үз авырлыгына үзе сыгылып торган, табак хәтле көнбагыш башлары* [*тезелгән*]. Г. Бәширов.

2. Күтәрүгә, тартуга авыр булу, җиңел булмау. [*Госман*], *утын алып кергәндә, утынның авырлыгыннан, ишек алдының пычраклыгыннан --- зарланды.* *А. Шамов.*

3. Кыенлык, мәшәкать. *Бөтенесенә үзен җаваплы санап, бөтен авырлыкны иң беренче булып үзе күтәрергә өйрәнгән бу кызга Мансуров сокланып карап торды.* Г. Бәширов. *Ул авылда туды, Батрак улы, Бик күп авырлыклар күрде ул. Көтүче дә булды, фронтларда Партизан да булып йөрде ул.* Һ. Такташ. // Кыен, мәшәкатьле эш булу. *Мин бала карауның авырлыгын ятим калып җиңгәйнең балаларын караганда бик ачык белдем.* М. Гафури. // Катлаулы булу, катлаулылык. *Лабиринттай тормыш күп серле. Ул үзенчә уза сызып юл, Катлаулыгы белән күңелле, Авырлыгы белән кызык ул.* М. Хөсәен. // Кайгы, хәсрәт, газап, зур борчу. *Авырлыкның ачы көннәрендә Таһир килде сугыш сафына, Килде мәхәббәттән юллар урап Үз халкының биргән антына.* Ф. Бурнаш. *Авырлык төшсә, туз, сер бирми-нитми, Ни хәллəр яшь егеткә килми-китми?* Г. Тукай.

4. Акрынлык, акрын кыймылдаучанлык, иренчәклек. *Ялкаулык дип әйтеп булмаса да,* [*Вәгыйзьдә*] *нинди-дер гамьсезлек, авырлык сизелә башлады.* Н. Фәттах.

5. Арыганлык, хәлсезлек. *Мохтар үзендә әллә нинди бертөрле авырлык сизә иде.* Ш. Камал. [*Гали:*] *Үземдә --- авырлык сизә башладым, күз алларым караңгыланган кебек булып китте.* М. Гафури.

6. Кеше күңелен борчый, кайгы-хәсрәткә сала торган, җанына тия торган булу (сүз, хәбәр турында). [*Нәфисә*] *бөтен барлыгына берьюлы китереп баскан бу куркыныч сүзләрнең авырлыгы астында башын иеп --- кереп китте.* Г. Бәширов. // Тупаслык, кимсетә, хәтер калдыра торган булу (сүз, хәбәр турында).

7. Күңел тынычсызлыгы, уй-хәсрәт, пошыну кебек психик халәт. *Сүзләрен аңламадым, ләкин җаным киңәя, йөрәгемдәге авырлык үзеннән-үзе тарала.* Г. Ибраһимов.

8. Катлаулы, мәшәкатьле булу; хәл итүе, чишүе кыен булу. *Син сөйләгән тормыш авырлыгын Сизми йөрим диеп белдеңмә?* Һ. Такташ. *Бу изге максат эшнең авырлыгын оныттырды.* Г. Гобәй.

9. *спорт.* Күтәрү өчен спорт җиһазы. *Авырлык күтәрү буенча ярышлар.*

10. Җирнең тарту көче, тарту үзлеге. *Авырлыксыз шартларда сулыш алу мәсьәләсен хәл итү кыенрак.* Планетаара очышлар.

Авырлык үзәге — 1) *физ.* җисем нинди торышта булуга карамастан, аны тигезләнеш хәленә китерә торган нокта. *Шарның авырлык үзәге — аның геометрик үзәгендә, параллелепипедның — диагональләре кисешү ноктасында була.* Физика; 2) *күч.* берәр нәрсәнең нигезе, үзәге, асылы. **Авырлык үлчәүләре** — грамм, килограмм, пот, центнер һ. б. ш. кебек берәмлекләр.

◇ **Авырлык белән** — 1) җәфаланып, интегеп. *Ләкин шулай авырлыклар белән яулап алынганга күрәме, яшәү бик тәмле, уку аеруча тәмле иде.* Г. Гобәй; 2) мәшәкать белән, кыенлык белән. *Рабига зур авырлык белән җитештергән нәрсәләрен* [*Нуруллингә*] *ашатырга тырыша.* А. Шамов; 3) теләмичә, читенсенеп, авырсынып. *Аңа бик озак ялыныргә туры килде, Җамал әби бик авырлык белән генә күнде.* А. Алиш.

АВЫРСЫ *с. диал.* Авыр, күңелгә тия торган ашамлык, ис турында. — *Кәҗә сөте куерак, баллырак һәм авырсы була.* Г. Галиев.

АВЫРСЫНУ *ф.* 1. Авыр, кыен, мәшәкатьле эшкә санау, читенсенү. *Бара торгач, Песи Тычкан тотуны да авырсынды.* М. Гафури. — *Иртән үк син безгә кайт, мин сине элек ничек тәрбия иткән булсам, хәзер дә һич авырсынмыйча тәрбия итәчәкмен.* Ш. Камал. // Теләп җиткермәү; теләмәү. — [*Китәргә теләүчеләрне*] *без көчләп тотарга теләмибез. Алар безнең алдагы көрәшне авырсыналар икән — әйтсеннәр.* Ш. Усманов. *Ул забой астыннан күмер тартуны да авырсынып эшли иде.* Ш. Камал.

2. Уңайсызлану, кыенсыну. *Кәрзин тулы сырабыз, Аны бездән сорагыз! Тагын күбрәк куяр идек, Бераз авырсынабыз.* М. Җәлил. [*Шәриф*] *бигрәк буш кул кайтырга авырсынып, яңа йорт бина кылып торган җирдән йомычкалар җыеп, күтәреп алып кайтып керде.* М. Гафури.

3. *диал.* Бераз авырып тору, кәеф китү. [*Г. Тукай*] *кайчакны, бигрәк тә --- явым-чәчемле көннәрне, авырсынып ята.* И. Рәмиев.

АВЫРТТЫРУ *ф.* Бәрү, имгәтү һ. б. сәбәп аркасында авырту барлыкка китерү. *Курыкма, курыкма, җаным, авырттырмыйм, — диде Газинур, атның авыру аягын бөгеп тезенә куйды.* Г. Әпсәләмов. / *рәв. мәгъ. Аның мие сызлый, коточкыч авырттырып колаклары шаулый, әйтерсең, башын өзлексез утта кыздырып торалар.* Г. Бәширов.

АВЫРТУ *ф.* 1. Берәр авыру аркасында физик газап туу. *Башымның авыртканына һич чыдар хәлем юк.* Г. Камал. *Әтәч әйтә: — Эчем авырта! — Менә бөгәрләнеп сызлана башлады.* Дәрдмәнд.

2. *диал.* Авыру. *Атам бер елдан бирле авыртып ята икән.* Г. Тукай. // *и. мәгъ. диал.* Авыру, чир, хаста. *Доктор [Төхфәтнең] авыртуы куркынычлы дип тә, куркынычсыз дип тә ачык әйтмәгән.* Ш. Камал.

◇ **Авырткан җир** — зур кичерештән, бәхетсезлектән соң калган йөрәк ярасы. — *Нәфисә, әгәр синең авырткан җиреңә кагылсам, син гафу ит.* Г. Бәширов. — *Бу сүзләре белән Гаяз минем иң авырткан җиремә сукты.* М. Әмир.

АВЫРТУЛЫ *с.* Авырта торган, авырту хисе сиздерә (тудыра) торган. *Тын рәвештә шигырь тыңларга хәзерләнгән зал алдына килеп чыгу йөрәктә тагын авыртулы, газаплы уйларны кабатлый.* Һ. Такташ.

АВЫРУ I *ф.* Хаста булу, чирләү, чирле булу, нинди дә булса авыруга дучар булу, нинди дә булса әгъза авырту. — *Сукранмый гына авырырга карар биргән идем.* Г. Тукай. [*Бибиҗамал:*] *Безнең яшьтә авырсаң да килешә. Яшьләр авыргач, күңелсез менә.* Ш. Хөсәенов.

АВЫРУ II *и.* 1. Чир, хаста. *Нәфисә, баласына каты авыру эләккән анадай, йөрәгенә ут кабызып агроном янына чапты.* Г. Бәширов. *Авыруын яшергән үләр, бурычын яшергән бөләр.* Мәкаль.

2. Авырган кеше, авыручы, чирле кеше, сәламәтлеген югалткан, сырхау кеше. — *Бердән, сез авыруны терелтә аласыз, икенчедән, миңа бик зур шөһрәт була.* Г. Камал. // *с. мәгъ.* Чирле, сәламәт булмаган. *Боларга ул авыру кешегә караган күз белән карады.* Ф. Әмирхан.

◇ **Авыруга сабышу** — берәр сәбәп (борчу, кайгы-хәсрәт, салкын тию һ. б.) аркасында авырый башлау, сәламәтлеген жую. *Көн авыша, төн авыша, Безнең яшьләр кавыша. Сөйгәне илә кавыша алмаган Авыруга сабыша.* Җыр.

АВЫРУЛЫ *с.* (Нинди дә булса) авыруы булган. — [*Аристократия дамаларының*] *гомердә авырмаганы да, кирәк вакытта назлану, иркәләнү өчен, үзен мигрень авырулы итеп күрсәтә.* Ш. Камал.

АВЫРЫКСЫНУ *ф. диал.* 1. *к.* авырсыну (1, 2 мәгъ.). [*Мин аны*] *авырыксынмыйча үземдә саклап йөртермен.* Ф. Хөсни. [*Хәлимә түти*] *бик уңайсызланып, бик авырыксынып кына чыгып киткән иде.* Р. Төхфәтуллин.

2. Бераз авырып, хәлсезләнеп тору. *Волостьтан кайтканнан соң, Рәүфә берничә көн авырыксынып торды.* А. Шамов. [*Хәбир*], *җитмәсә, әни авырыксына әле, дигән була.* Ш. Хөсәенов. // Авырга килү; бераз авырту. [*Каюм:*] *Чәчүгә мин барыр идем, ләкин аяк авырыксыныр дип куркам.* Ш. Камал.

АВЫШ *с.* Бер якка авып тора торган, бер якка янтайган, кыеш. *Италиянең Пиза шәһәрендәге авыш манара бөтен дөньяга билгеле.* Табиг. буйс. юл. / *рәв. мәгъ. Җәелә кырда, иркен океан сыман, Башакланып яткан арышлар, Айлар буена җилгә буйсынудан, Барсы кырын, барсы да авыш[лар].* Ш. Мөдәррис.

Авыш призма *геом.* — кабыргалары нигезләренә авыш булган призма.

АВЫШ-КЫЕШ *рәв. к.* авыш-түеш. — *Шөкер әле, бер көе генә авыш-кыеш китергәләп, гомер итеп килгән булам шунда.* Г. Камал.

АВЫШЛЫК *и.* 1. Авыш булу; авыш хәл. *Су бүлгеч каналлар үткәргәндә --- елганың уртача авышлыгын белү кирәк була.* СССР физ. геогр.

2. Авыш урын, сөзәк урын, сөзәклек. *Табигый авышлык почмагы.*

АВЫШМА *и.* 1. *геом.* Бирелгән ноктадан икенче туры белән кисешү ноктасына кадәрге кисемтә.

2. *с. мәгъ.* Авыш. *Ике авышма рельска беркетелгән скип-чүмеч әйбәт кенә йөри башлармы, юкмы?* А. Гыйләҗев.

АВЫШТЫРУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса бер якка янтайту, бер якка кыйшайту. *Гафифә, бераз вакыт хәрәкәтсез яткач, башын азрак Мусага авыштырды.* Ш. Камал.

2. Уздыру, үткәрү (вакыт турында). *Мәсьәлә, иртәнге бераз авыштырып җибәреп, Саррәнең башка җирдә очравы мөмкин булырлык вакытны җиткерүдә.* Ф. Әмирхан. // *сөйл.* Бик авырлык белән җиткерү, очын очка ялгау. — *Көнлекне көнгә мең бәла белән авыштыра торган ул хатын бу кадәр акчаны кайдан тапсын?* Г. Камал.

3. *күч. к.* аудару (3 мәгъ.). [*Мохтар*] *полкның --- корал запасы шактый күп булырга тиешлеген һәм, полкны революция ягына авыштыра алган тәкъдирдә, шул кораллар белән файдаланырга мөмкинлекне уйлап, йоклап китте.* Ш. Камал. [*Җәдитчеләр*] *диндар мөселман байларын ысул җәдиткә авыштыра алмаячакларына тәмам ышанып җиттеләр.* Ф. Әмирхан.

4. *күч. сөйл.* Көнкүрештә, бигрәк тә сәүдәдә эшне оста йөртү.

5. *сөйл.* Бер савыттан икенче савытка бушату, бер урыннан икенче урынга күчерү. *Бу чәйне авыштыр, ягъни чынаяктан чәйнеккә сал.* К. Насыйри.

6. *сөйл.* Тәрҗемә итү. — *Ирем кайбер сүзләрне миңа үзебезчәгә авыштырып әйтә тора.* Г. Ибраһимов.

АВЫШ-ТҮЕШ, АВЫШ-ТӨЕШ 1. *рәв.* Тәртипсез, авып-кыйшаеп, алпан-тилпән. *Кечкенә мие алып ташланган хайваннарда хәрәкәтләр чуалчык була. Йөрүе ышанычсыз, авыш-түеш килеп чыга.* Анатомия.

2. *с.* Тигезсез. *Агыйделкәй яры авыш-түеш, Колагыма килә бер тавыш.* Җыр.

◇ **Авыш-түеш килү** — 1) авышып бетү, аралашып бетү, урыннары алмашыну, буталу, чуалу, буталышу; 2) алпан-тилпән килү, алпан-тилпән йөрү. **Авыш-түеш китерү** — 1) берсе урынына икенчесен кую, бутау, чуалту. — *Кара әле, әти, прахут китәргә бары ярты сәгать вакыт калган, син монда чәй-шикәрне авыш-түеш китереп азапланасың.* Ф. Әмирхан; 2) алыш-бireш итү, алу-сату белән шөгыльләнү; 3) әвәләү (тиз генә эшләп ташлау турында).

АВЫШУ *ф.* 1. Янтаю, бер якка кыегаю, аву. [*Сафа белән солдат*] *бер алга, бер артка авышып, көчле дулкында чайкалган көймәдә басып торган шикелле, егылмаска тырыша иделәр.* Ш. Камал.

2. Урыны күчү. *Бераздан атышлар икенче якка авыша башлады.* Г. Әпсәләмов. // Шуышу. *Ачык хәтерләмим, аяк астындагы җирнең каядыр авышып, кроватька таба ауганыбызны гына беләм.* Г. Ибраһимов. [*Сөембикә*] *икегә аерып таралган чем-кара чәче өстеннән артка таба авышкан шәлен алга таба тартып куйды.* Ә. Еники. // Тайпылу. *Малай --- бары тик читкәрәк кенә авышты.* Г. Гобәй. *Хатыннар, яулык почмакларын авызларына тартып, бер якка авыштылар да атлыга юл бирделәр.* И. Гази.

3. Узу, үтү (вакытка карата). *Гөлсем, --- ярты төннәр авышкач, Байтирәккә кайтырга чыкты.* Г. Бәширов. *Сәгыйтов колхоз идарәсенә яңадан борылып кайтканда, төш авышкан иде инде.* С. Рафиков. // Вакытның бер өлеше яки фасылы үтеп, икен-

чесенә (өлешенә яки фасылына) керүне аңлата. *Көзгә авышкан көннәрнең берендә Йомагылларга, читкән арбага утырып, --- бер карт башкорт килеп төште.* М. Әмир. // Кояш турында. *Кызарып чыккан кояш Төшлекләргә авыша.* Җыр. *Ниһаять, кояш баюга таба авышканда, Фатыйманың кайту сәгате җитте.* Г. Минский.

4. *күч.* Нинди дә булса фикерне, карашны кабул итү, тану; шул фикергә, карашка күчү, кушылу. *Күңелләре яңа фикергә авышкан, эчләреннән көрәшче эшчеләргә якынлык сизгән солдатлар арасында шушы яңа сүзләр яшерен генә сөйләнеп үтте.* М. Гафури. *Нургали крестьяннар ягына авышты.* Т. Гыйззәт. // Берәр фикер белән килешү, риза булу (үгет-нәсихәтләргә, ышандыруга буйсынып). — *Зифа, кара әле, син Галләмгә белми-нитми генә вәгъдә бирдем дип үкенәдер идең, моңа тагы белми-нитми генә авышмасаң?* М. Фәйзи.

АГА *и.* **1.** Яшь ягыннан олы ир туган, абый. — [*Сәхәү*] *атасы дөнья куюга ук ике агасын куып чыгарган да төп йортта калган.* М. Әмир.

2. Үзеңнән олырак, өлкән ир кеше. *Зурларның, агаларның каһарманлыклары* [*Шәяхмәтнең*] *күз алдыннан үттеләр.* Г. Ибраһимов. // Үзеңнән олырак ир кешенең исеменә кушып әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. — *Гыймади ага, әйт әле: әйтик, менә Маһирә кияүгә чыгармы миңа?* М. Җәлил.

АГА'ВА *и. бот.* Сүс бирә торган бик эре, каты яфраклы тропик үлән үсемлек. *Агава озын сабак чыгарып, аны чәчәкләргә төрү һәм орлык бирү өчен берничә ел буе көч туплый кебек. Ә чәчәк атып, орлык биргәч, ул корый.* Дөнья кис. геогр.

АГАЙ *и.* **1.** *к.* ага (2 мәгъ.). *Беркөнне, „Бәдри кайтмадымы әле?“ дип, авылның бай һәм куштан кешесе Ситдикъ агай боларга керде һәм сәлам бирде.* Ә. Фәйзи. — *Бабайка сугу түгел бу, Мөхетдин агай, Иделдә сал утыра башлагач, бурлаклар гына бертоташ бабайка сугарга керешәләр аны.* М. Гали.

2. *сөйл.* Авыл кешесе, крестьян. [*Хатын*] *секретарьның үзенә һәм идәнгә чүгәләп утырган агайларга күз төшереп алды.* А. Шамов. // *ымл. функ. сөйл.* Сүз арасында әйтелеп, гажәпләнүне яки берәр нәрсәдән риза булмауны белдерә. *Атлары да көр икән, тигез җиргә чыккач, ах, җилдерәләр генә, агай.* М. Шабай. *Ярты дистә кеше килде дә: „Нигә безнең печәнлек болыныбызны таптатасың?“ дип, менә тотындылар, агаем, менә тотындылар.* Ф. Хөсни.

АГАЙНЕ *и. к.* агай-эне (3 мәгъ.) — *Инде, агайне, яшеренү практикасын сайлагансың икән, аны ахырынача җиткер!* А. Расих.

АГАЙ-ЭНЕ *и.* **1.** Ага һәм эне, агалы-энеле, бертуган ике ир кардәш. *Закир белән Шакир — агай-энеләр.* // Кардәш-ыру, бер нәсел ир кардәшләр. *Агай-энеләр арасында бер генә шәкерт булганлыктан, ул йорт эшләренә йөрми, өйгә кайткач кунак сыманрак булып тора иде.* Ф. Әмирхан. *Кайсы үзенеке өчен, кайсы агай-энесе, дус-ише, кода-фәләненеке өчен, кайсы үз сүзен өскә чыгару өчен тынычсызлана.* М. Гали.

2. Үз кешеләр, үзебезнең кешеләр. — *Менә бүгеннән һәйбәт кенә кибеткә төшеп, чибәр генә агай-эне арасына катышып тора башласаң!* Ф. Әмирхан. // Иптәшләр, дуслар, якын кешеләр, бергә эшләүчеләр. — *Биредә утырган бергә эшләүче агай-энеләргә шуны әйтәсе килә.* Соц. Тат. // Шуларга мөрәҗәгать сүзе. — *Кая, агай-эне, сырага акча әрәм иткәнче, бер айлык газетка языл, белем арттырырсың!..* К. Әмири—*Белеп ашарга кирәк, агай-эне, ерак җирнең җимеше ул!* Ш. Камал.

3. Ят яки исеме билгесез ир кешегә мөрәҗәгать сүзе. — *Син, агай-эне, утырсаң, кеше төсле тыңлап кына утыр, утырмасаң, чыгып кит!* М. Гали. — *Алай дип әйтмә, агай-эне, дим тегеңә, нишләп сәдака булсын. Син бит эшләдең. Миңа никадәр хезмәт күрсәттең. Мә ал, берәр эшеңә ярар.* М. Әмир.

АГАЙ-ЭНЕЛЕК *и.* **1.** Кардәшлек, туганлык, туган-тумачалык. *Каты-каты абынулардан, үзенең агай-энелек кулын сузып, Шәрифуллин тартып торгызды аны.* С. Рафиков.

2. Кода-кодагыйлык, әшнәчелек. *Агай-энелек мөнәсәбәтләре.*

АГАЛАУ *ф. сир.* Ага дип исәпләү, олылау. *Үз агасын агаламаган кеше агасын агаламас.* Мәкаль.

АГАЛЫ-СЕҢЕЛЛЕ *с.* Ага белән сеңел, абый белән сеңел. — *Безгә агалы-сеңелле дуслар кеби карыйлар.* Г. Ибраһимов.

АГАЛЫ-ЭНЕЛЕ *с.* Ага белән эне, абый белән эне. *Агалы-энеле Котельниковлар икенче сменада эшлиләр иде.* Г. Әпсәләмов.

АГАРТУ *ф.* **1.** Аксыл яки ак төскә кертү, ак итү. *Биек тауда гөлбакчада Кызлар киндер агарта.* Җыр. *Иртә белән өй түбәләрен, каралты башларын, урамнарны агартып ап-ак кырау төшә.* Г. Бәширов.

2. Акшарлау, акбурлау, акка буяу. *Кайберләре морҗаларын агартып, лапас түбәләрен ябып куярга да өлгергән.* Г. Бәширов. — *Ай алла, яңа гына агартканмичемне харап иткәнсең икән, ник аны алай итеп сызгаладың?* М. Гали. // Әйбернең өстен берәр нәрсә белән каплап, буяп ялтырату. *Автоген аппараты белән тимер, чуен ямау һәм никель белән җиз, бакыр нәрсәләрен агарту һөнәрен өйрәндем.* Х. Садрый.

3. Кердән арындыру, чистарту, чистартып ялтыравык хәлгә китерү. *Ишек янында, ак тимер ләгән эченә, яңа гына агартып, су тутырылган зур җиз комган куелган.* М. Гали. — *Самовар агарта белсәң, әйдә әле самовар агартып кара.* М. Гафури. // Керләнгән ак яки аклы әйберне юып нәкъ үз төсенә кайтару, ап-ак булганчы юу. *Аклы ситсы күлмәгемне Зәй буенда агартам.* Җыр.

4. *күч.* Культуралаштыру, аң-белемле итү, гыйлем бирү. *Халыкны агарту эшләре.* □ — *Авыл халкының тормышын агарту юлында сезнең белән бергә эшләргә дигән әллә никадәр планнарым бар минем.* М. Фәйзи. // Дин сөременнән арындыру, искелектән арындыру. // Тәрбияләп сафландыру, пакьләү (күңелне).

АГАРУ *ф.* **1.** Аксыл яки ак төскә керү. *Бөтен дөнья ап-ак булып кар яуганда, Ишек алды, урам, түбә агарганда, Ап-ак булып кайтып килә безнең бабай, Безгә төрле-төрле уенчык алган да.* Г. Тукай.

2. Керләрдән арыну, керсезләнү, чистару, арулану. — *Минем битләрем агармас инде!* М. Гафури. // Юганнан соң нәкъ үз төсенә кайту, ап-ак булу (керләнгән яки аклы әйбер турында). *Минем калган кульяулыгым Агарыр әле, юсаң.* Бәет.

3. *диал.* Озак киюдән, кояш ашаудан яки юганнан соң әйбернең төсе уңу, төссезләнү, буявы китү. *Мәгъсүм үзенең сукно чалбарын юа-юа агарып беткән, эт өрде исә тетелеп китәргә торган юка яшел галифега алмашты.* Г. Гобәй. *Чишенмичә йокыга киткән кызының аягындагы борыннары агара башлаган туфлиләрен күргәч, ана гажәпкә калды.* Г. Минский.

4. Чал төскә керү, ак төскә керү, чалару (чәч, сакал, мыек турында). *Бу картның сакалы тегермәндә генә агармаган: Башы да кар төсле агарган.* Г. Тукай. *Аның битен вак җыерчыклар каплаган,*

чәче агарган. Г. Бәширов. *Агарса да чәчләр Көмеш кебек, Кырау төшмәс Безнең йөрәккә.* М. Җәлил.

5. Ерактан аксыл булып күренү, аксылланып күренү. *Болытлар сәер итә анда, алара, Алар артында зур таулар агара.* Г. Тукай. // Көн яктылыгы турында: яктыру. *Көнчыгыш ягындагы күк итәге инде агарып килә, йолдызлар да, нурларын югалтып, тоныклана баралар.* А. Шамов. [*Ярканат*] *оча дип, төн агармас һәм кояш кайтмас кире.* Ш. Бабич.

6. Куркудан, кайгыдан яки авырудан төсе югалу төсе китү, чырай ак булу, ак төскә керү. — *Син бит нигәдер агаргансың, төсләрең киткән. Ни булды сиңа?* Г. Бәширов. [*Рәүфәнең*] *күз төпләре күгәргән, яңаклары ничектер бер төн эчендә агарып китеп, суырылып кергән.* А. Шамов. [*Һәдия*] *агарып ук китте, берьюлы мескенәеп, ишетелер-ишетелмәс нидер әйтеп акланырга тотынды.* Ә. Еники.

7. *күч. сөйл.* Культуралашу, аң-белем алу, гыйлем белән кораллану. *Безнең күрше Фатихны бик үзгәреп, бик агарып кайткан диләр.* Каз. утл. // Сафлану, пакьләнү, тәрбия алу. *Кояш чыкса — табигать яңара, китап укысаң — күңел агара.* Мәкаль.

8. Салкыннан кан тамырлары кысылу сәбәпле ак төскә керү, бик нык туңу (мәсәлән, борын, колак, бит, бармак очы һ. б. ш. турында). *Кешеләр суыкта кызарган борыннарын һәм агарган бармак очларын уа-уа өйләренә кайтып киттеләр.* Ф. Әмирхан.

АГАРЫНУ *ф.* Артык күрку яки ачудан төс китү, чырайдан кан качу. *Аның яңак тамырлары еш-еш чиертеп алгач, болай да төссез чырае тагын да агарынган иде.* Г. Бәширов. *Хат иясе Сәйфуллин, агарынып, ни эшләргә белми катып торды да кинәт кәгазьне авызына кабып чәйнй башлады.* Г. Ибраһимов.

АГАЧ *и.* **1.** Каты кәүсәле, ботаклары ябалдашланып торган күпьеллык үсемлек. *Яфраклы агачлар. Ылыслы агачлар. Җимеш агачлары.* □ *Агач — җимеше белән, адәм — эше белән.* Мәкаль. // Шул үсемлекнең ботакларыннан арындырылган кәүсәсе; бүрәнә.—*Кем, Минһаҗетдин энем, кайрысында кипкән агач чатнамый ул.* К. Тинчурин. // *с. мәгъ.* Агачтан салынган, агачтан ясалган. *Агач чиләккә бал ага, кәрәз күзәнәкләре бушап кала.* А. Алиш. *Алар искергән, җимерелеп барган агач баскычтан тиз-тиз генә өскә күтәрелделәр.* А. Шамов.

2. Төзүгә һәм әйберләр ясауга китә торган агач материал; үзагач. *Илебез бездән — агач хәзерләүчеләрдән агачны мөмкин кадәр күбрәк бирүне таләп итә.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч. гади с. хур.* Аңсыз, аңгыра, надан. — *Д син шуны да уйламыйсың, агач!* Ш. Камал.

Агач аяк — 1) урта бер җиренә кадакланган шакмакларына басып, югары башларына кул белән тотынып атлап йөрелә торган озын таяклар. Гадәттә балалар язгы ташу вакытында кулланалар; *русчасы:* ходули; 2) аягы киселгән кешеләр өчен ясалма аяк, протез. *Вак шадрасы, хәтта агач аягы да килешле булып күренде аңар.* Г. Гобәй. **Агач бакасы** *зоол.* — койрыксызлар семьялыгыннан күбрәк агачта яши торган бака. **Агач башмак** *этн.* — агачны чокып, кәвеш формасында эшләнгән аяк киеме. *Шау-шу килеп, агач башмакларын шакылдатып, шәкертләр кайтып керә.* Т. Гыйззәт. **Агач заводы** — агачтан төрле әйберләр эшләү заводы. — *Шул, ярлыланып бетеп, авылдан өмет өзеп, үзенең эшләп йөргән җиренә — агач заводына бөтенләй күчеп китте.* Г. Ибраһимов. **Агач корты** — 1) *зоол.* күбәләктән яралган, агачның кайры астын, үзәген ашап юллар ясый торган корт; *к.* кабыкчы; 2) коңгызның агач боза торган төре — кисмән; *русчасы:* древоед; 3) *күч. ирон.* тиктормас, тынгысыз кеше. **Агач (бүрәнә) гөмбәсе** — үсеп торган агачта, бүрәнәдә дымгудан була һәм аны черетә торган гөмбә; *русчасы:* трутовик. [*Бу йортның*] *почмакларында ящел агач гөмбәләре дә күренгәли, тәрәзә пыялалары да ящелле-зәңгәрле таплар белән капланган.* Г. Бакиров. **Агач мае** — зәйтүн маеның түбән сорты. — *Кара мулладан өшкертеп алган агач маен ул эссе мунчада һәм мунчадан соң да кабат-кабат сөртте.* Ш. Камал. **Агач остасы** — *к.* балта остасы.

◇ **Агач авыз** *гади с.* — кирәкле сүзен дә сөйли алмаган яки тәртипле итеп, чамалап сөйләшә белмәгән, тупас телле кешегә карата әйтелә. — *Агач авыз, яхшыллап сөйләшә дә белмисең.* Һ. Такташ. [*Шәрәфи карт, Сафаны күрсәтеп:*] — *Дә шундый агач авызларга күп лыгырдарга бирмидер иде ул.* Ш. Камал. **Агач ат** — 1) ясалма ат, уенчык ат. *Маратны кайчандыр агач атка атланып авылга барырга чыккан Марат димәссең хәзер, тәмам буйга җитеп беткән.* Г. Гобәй; 2) *күч.* алдар өчен ясалган нәрсәне яки хәйлә белән корылган эшне аңлата. **Агач атка атландыру**—берәр кешене алдау, өметләндереп хәйлә кору. **Агач атка атлану** — алдану, өметләнеп көткәнгә ирешә алмау. *Ләкин белмим: алар ничек Үткәннәрдер кайтыр юлны, Тик билгеле Нурыйҗанның Агач атка атлануы.* Н. Мадьяров.

АГАЧЛЫК *и.* Агачлар үскән урын, кечкенә урман. *Ул алдан бераз читтәрәк каралып күренгән агачлык төркемен күрсәтте.* Г. Бәширов. [*Елга кырыенда*] *агачлык тагын да куерак, --- агач күләгәләре тагын да тыгызрак һәм зәңгәрсу төстә күренәләр.* Ш. Камал.

АГАЧЛАНУ *ф.* **1.** Агач кебек катылану (мәсәлән, үсемлек көпшәсе).

2. *күч. хур.* Надан булып калу, тупаслану (кешегә карата). [*Илшат*] *үзенең ничектер тупаслана, агачлана баруын әйтте.* Г. Әпсәләмов.

АГАЧЧЫЛ *с.* Үзагачлы; агач сыман тукымалы. *Каенның сабаклары каты һәм агаччыл, ул ак кайры белән капланган.* Ботаника.

АГА-ҖИҢГӘ *җыйд. и.* Ага белән җиңгә. — *Без тагын борынгыча ага-җиңгә кулында калдык.* М. Гафури.

АГГЛЮТИНАТИВ *с.* Сүзләргә кушымчалар ялгап ясала һәм төрләнә торган, ялганмалы. *Татар теле агглютинатив телләр системасына керә.*

АГГЛЮТИНАТИВЛЫК *и.* Ялганмалы булу, ялганмалылык. *Телнең агглютинативлыгы.*

АГГЛЮТИНА'ЦИЯ *и.* **1.** *лингв.* Кайбер телләрнең (мәсәлән, төрки телләрнең) грамматик төзелешенә хас үзенчәлек — сүзнең тамырына, тамыр үзгәрмәгән хәлдә, кушымчаларның бер-бер артлы ялгануыннан гыйбарәт күренеш.

2. *биол.* Сыеклыкта төпкә утырган кисәкчекләр (кызыл һәм ак кан тәнчекләре, микроблар һ. б.) бергә укмашу.

АГЕНТ *и.* **1.** Берәр кешенең, учреждениенең яки предприятиенең тапшыруы буенча эш итүче вәкил. *Тире җыючы агент.* □ *Почта агенты колхозга һәр көнне бер кочак газета кайтара.* Г. Гали. // Кемнеңдер интересыннан чыгып эш итүче, кемнеңдер интересы өчен тырышучы, астыртын эш йөртүче. *Вәли бай җир эшләре идарәсендәге агентлары аркылы бармак йөртеп, [совхозның] бөтен байлыгын --- суырып яткан.* Г. Нигъмәти. *Баязит әйтә иде, өйрәнмәгәнрәк тоткыннарның серләрен алыр өчен күрше камерага охранка агентын утырталар да, стена аркылы шулай сөйләшеп, материал суыралар, ди торган иде.* Г. Ибраһимов.

2. Шпион, диверсант. *Кайвакытта дошман агентлары, Утеп кереп безнең арага, Сөйли төрле ялган хәбәрләрне, Әйләндереп акны караға.* Э. Исхак.

АГЕНТЛЫК *и.* 1. Агент булу, агент вазифасы. *Закир — әүвәл учитель булган, соңыннан аны ташлап, страховой агентлык итә башлаган, өйләнмәгән бер егет.* Ф. Әмирхан.

2. Нинди дә булса учреждениенең урындагы бүлеге; шулай ук кайбер арадашлык учреждениеләренең атамасы. *Почта агентлыгы. Телеграф агентлыгы.* □ *Ул бу юлы Атбасар стансасына барып, Россия транспорт һәм страховка җәмгыятенең агентлыгына яллана.* И. Салахов.

3. *махс. к.* агентура (1 мәгъ).— *Юк шул, коры бүләк түгел, агентлык өчен «эш» хакы.* Ш. Камал.

АГЕНТУ'РА *и.* 1. Шпионлык һәм диверсантлык хезмәте.

2. *җый. и.* Агентлар. *Бу эшче аристократия оппортунизмның төп таянычына, эшчеләр сыйныфы арасында буржуазиянең агентурасына әйләнә.* Яңа тарих. // *с. мәгъ.* Агентура җыйган, агентура тапшырган. *Агентура мәгълүматлары.*

АГИТ- Кушма сүзләрдә «агитация» мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **агитбригада, агитвагон, агитколлектив, агитпоезд.**

АГИТА'ТОР *и.* Агитация эше белән шөгыльләнүче, агитация алып баручы, агитацияләүче. *Агитаторлар Нәфисәләрнең эшен башкаларга үрнәк итеп сөйли торган булдылар.* Г. Бәширов. *Партбюро сине алар арасында агитатор итеп билгеләргә карар чыгарды.* Г. Әпсәләмов.

АГИТА'ТОРЛЫК *и.* Агитатор булу. — *Мин, партиянең кушуы буенча, завод эшчеләре арасында агитаторлык хезмәтен дә үти башладым.* Х. Садрый.

АГИТА'ЦИЯ *и.* 1. Агитацияләү (1 мәгъ). [*Г. Камалның*] *революциядән соң язган шигырьләре поэзия өлкәсендә зур агитация һәм революцион сатира үрнәкләре булып торалар.* М. Гали.

2. Массаларны политик тәрбияләү максаты белән телдән яки басма рәвештә идеяләр тарату эшчәнлеге.

АГИТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Агитация эше белән шөгыльләнү, агитация алып бару.

2. *сөйл.* Кемне дә булса берәр нәрсәгә ышандырырга, берәр фикер, караш ягына аударырга тырышу.— *Безне [әсирләрне] агитацияләү һәм пропагандалау туктатылды. Фашистлар башка методка күчтеләр.* Каз. утл.

АГИТА'ЦИЯ-МА'ССА (агит-масса) *с.* Массалар арасында агитация алып баруга, ижтимагый-политик эшләргә мөнәсәбәтле, бәйләнешле. *Бригадада агитация-масса эше дә бик яхшы куелган.*

АГИТБРИГА'ДА *и.* Халык арасында агитация эшләрен алып бара торган бригада. *Агитбригада членнары.*

АГИТПУ'НКТ *и.* Агитация пункты, халык арасында агит-масса эшләрен үткәрү буенча урындагы ижтимагый-политик учреждение.

АГЛАУ *ф. иск. к.* елау. *Аглыйдыр һәркем күзеннән яшь сыгып, Аглый кибеттән кәләпүшләр чыгып.* Г. Тукай.

АГНО'СТИК *и.* Агностицизм тарафдары.

АГНОСТИЦИЗМ *и. филос.* Объектив дөньяны һәм аның закончалыкларын танып белү мөмкин түгел дип раслый торган идеалистик философик тәгълимат.

АГО'НИЯ *и. кит.* Үлем газабы, организмның үлем алдындагы хәле. *Зәйнәп әллә нинди бер агониядә ята, куллары белән әллә нәрсәләр күрсәтә иде.* Г. Газиз.

АГРАР *с.* 1. Җир турындагы, җирдән файдалану турындагы. *Аграр реформа.* □ *Аграр кризислар авылны һаман бөлгенлеккә төшерә.* КПСС Прогр.

2. Авыл хуҗалыгындагы; авыл хуҗалыгына бәйләнешле. *Аграр кризисларның иң зур авырлыгы крестьяннарның төп массалары өстенә төшә.* Политэкономия.

АГРЕГАТ *и. махс.* Гомуми эш башкару өчен төрле типтагы машиналарның җыелмасы (мәсәлән, трактор һәм комбайн). *Механизаторларның күптәннән зарыгып торган куллары, рульләрне боргалый-боргалый, агрегатларны бер-бер артлы басуга чыгаралар.* Каз. утл. // *җый. и.* Шундый тип машиналарда эшләүче кешеләр. *Һарун агрегатында үзенә күрә бер яңалык барлыкка килде. --- Кешеләр үз сменалары өчен генә түгел, бәлки бүтәннәр сменасы өчен дә үзләрен җаваплы итеп сизделәр.* Н. Фәттах. // Катлаулы машиналарда нинди дә булса махсус операцияне башкару өчен җайланган детальләр җыелмасы. *Тиздән колхозда «Ёлочка» тибындагы сыер саву агрегаты куелып бетәчәк икән.* М. Хәсәнов. *Якын басудагы өч комбайнны Чапай күле буена үзәк мастерскойга кайтарганнар да агрегатларга махсус җайланмалар куеп яталар.* Г. Ахунов.

АГРЕГАТЛАШТЫРУ *ф.* Эш төрләренә, төрле операциягә карап махсус агрегатлар булдыру; *к.* агрегат.

АГРЕССИВ *с.* Агрессиягә бәйләнешле. *Агрессив политика.* // Дошманлыкны сиздереп торган, һөҗүмчән. *Агрессив тон. Агрессив хәрәкәт.*

АГРЕССИВЛЫК *и.* Басып алучылык, һөҗүм итүчелек.

АГРЕ!ССИЯ *и.* Тар-мар итү яки бәйсезлеген чикләү, демократияне бетерү һәм реакция режимы кертү максаты белән, икенче бер дәүләткә һөҗүм итү, территориясен басып алу. *Союзниклар алдына агрессия учагын бетерү бурычы килеп басты.* СССР тарихы.

АГРЕ'ССОР *и.* Агрессияне тормышка ашыручы, һөҗүм итүче як, басып алучы. *Нәфрәт агыла бөтен илләрдән Агрессорның башы өстенә. Китәр беркөн килгән ягына, Китәр, әгәр китеп өлгерсә!* Х. Туфан.

АГРО- Кушма сүзләрдә «агрономик» мәгънәсендәге беренче кисәк: мәсәлән: **агротехника, агропункт, агроуку.**

АГРОБИОЛО'ГИЯ *и.* Игенчелек һәм терлекчелек буенча гомуми биологик закончалыклар турындагы фән. *Колхоз строеның җиңүе --- совет агробиология фәненә дәүләт тарафыннан куелган таләпләрне бик нык күтәрде.* СССР тарихы.

АГРОНОМ *и.* Агрономия буенча белгеч, авыл хуҗалыгы белгече. *Тары Хәлимгә бу юлы, ничектер, сирәгрәк күренде, һәм ул өенә кереп тормады, күңел ачуны болынны да онытты, туп-туры районга, агроном янына китеп барды.* Г. Гобәй.

АГРОНО'МИК *с.* Агрономия буенча булган. *Крестьян хуҗалыкларын күтәрүдә дәүләт тарафыннан оештырылган агрономик ярдәмнең --- зур әһәмияте булды.* Политэкономия. // Агрономиягә бәйләнешле, агрономиягә мөнәсәбәтле.

АГРОНО'МИЯ *и.* Игенчелек, авыл хуҗалыгы турындагы фән. *Бигрәк тә авыл хуҗалыгы, агрономия мәсьәләләренә ул зур әһәмият бирә.* Ш. Камал.

АГРОНОМЛЫК *и.* Агроном булу. [*Захарның*] *олы улы — бригадир, читтән торып агрономлыкка укый.* М. Әмир.

АГРОТЕ'ХНИК I *и.* Агротехника буенча белгеч. — *Газиз «Чулпан»да агротехник булып эшли башлаганнан бирле, иген эшләре дә әллә ничек бик үзгәреп китте.* Г. Бәширов.

АГРОТЕ'ХНИК II *с.* Агретехникага бәйләнешле. *Агротехник чаралар.*

АГРОТЕ'ХНИКА *и.* Авыл хуҗалыгы культураларын игү алымнары системасы. [*Колхозчылар*] *кичләрен җыелышып агротехника өйрәнделәр.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Агротехника өйрәнү буенча булган. *Маннур җитәкчелек иткән агротехника курсларында занятиеләр аеруча җанлы барды.* М. Хәсәнов.

АГУ I *и.* 1. Тере организмны зарарлый, үтерә торган матдә. *Агу химикатлары.* □ [*Елан*] *эзһәрле телен чыгарып, агуын чәчеп карады, кырмыскаларны чагарга уйлады.* А. Алиш. *Бервакыт һич уйламаганда ул Хәйриянең агу эчкән хәбәрен ишетте.* Ш. Камал. // *күч.* Кемгә дә булса кире йогынты ясый, күңелне борчый,

әрнетә торган, зарарлы нәрсә. *Без хезмәт ияләренең башын дин агуыннан чистарту өчен көрәш алып барабыз.* М. Әмир. *Ашың аш түгел, йокың йокы түгел — һәммәсе дә йөрәгеңә агу булып урнаша.* М. Гали.

2. *күч.* Явызлык, зәһәрлек, мәкер. *Безгә яшерен нәфрәт хисе белән Агу ага аның [дошман] канында.* Һ. Такташ. // *с. мәгъ.* Явыз, мәкерле, зәһәр. *Матур, үткен, агу телле җан дусы хәзер кулбашлары салынган, йөзе кара-сары булып кипкән, күзләре нурсыз, үзе дәртсез җай бер казакъ хатыны булып әверелгән иде.* Г. Ибраһимов.

Агу үләне — *к.* түндербаш.

◇ **(Күңелгә, йөрәккә) агу булып төшү** — әрнетү, зарарлы тәэсир итү. *Бу сүзләр авыруның йөрәгенә агу булып төштеләр.* Г. Ибраһимов. **Агу йоткан** — һәрвакыт зарар итәргә генә торган, зәһәр, явыз. *Безнең уңыш сезгә тыныч бирми, Агу йоткан капиталистлар!* Ә. Ерикәй. **Агуын чәчү** — 1) мәкерлек эшләү, зарарлы, мәкерле эшләрен җәелдерү. [*Кулак калдыгы*] *бераз тамыр җәю белән Чәчә башлый үзенең агуын.* М. Гафури; 2) зәһәр сүзләр белән сүгү, йөрәккә кадарлык итеп ачулану.

АГУ II *ф.* **1.** Берәр төрле юнәлештә бер агым булып хәрәкәт итү (сыеклык турында). *Канаулардан шарлап су ага.* □ *Тау астында салкын чишмә Чылтыр-чылтыр агадыр.* Җыр. // Сыеклык өстендә яки эчендә булган хәлдә аңа ияреп күчү, сыеклык агымы буенча бару, хәрәкәт итү. *Су өстендә, балдак кебек түгәрәкләнеп, тимгел-тимгел булып, нефть ага иде.* А. Әхмәт.

2. Тишек яки ярыктан чыгып җәелү, түгелү. *Мичкәң кыршау аткан, юл буена суы агып килә, ник аны карамадың?* М. Гали. // Савыттан яки берәр урыннан күп булып коелу (он, ярма, ком кебек чәчелә, тарала, сибелә торган нәрсәләр турында). *Ул док-док басып килеп җиткәнче, байтак кына бодай җиргә агып өлгергән иде.* Г. Гобәй. // Бер урынга күпләп туплану, җыелу. *Тук бодайлар иркен амбарларга Җырлап актылар.* М. Җәлил. *Гүләп торган мартеннардан Ахактай корыч акты.* Г. Хужиев.

3. Күз яше, тир, канның күпләп чыгуы турында. *Алар өчен түккән күз яшьләрем Тагын шулай җиргә агармы? А, юк! Беркем агыза алмас аларны!* Һ. Такташ. *Тик бүген минем ярамнан Бертуктаусыз кан ага.* Ә. Ерикәй. *Аның битләре кып-кызыл булып чыккан, ә чигәләреннән, муеннарыннан шарлап тир ага.* И. Гази.

4. *күч. шигъ.* Яктылык бирә яки кайтара торган әйбердән нурның агым булып таралуы, сибелүе турында. *Айдан якты нур ага.* Ә. Ерикәй. *Күзләреңнән нурлар ага, Кыймыйм туры карарга.* Җыр.

5. *күч.* Салмак кына, ашыкмыйча өзлексез хәрәкәт итеп тору, күчү. *Көмеш төсле ак болытлар һавада бер-берсе артыннан агып баралар.* Ш. Камал. // *күч.* Күпләп, тоташ масса, дулкын-дулкын булып өзлексез бару, хәрәкәт итү, таралу. *Музыка яңгырый, биюче парлар берсе артыннан берсе хыялый дулкыннар шикелле агалар.* Ф. Әмирхан. *Такта төяп, тагын туктаусыз Такта вагоннары агып тора, Такмагына биеп утәрсең!* М. Җәлил. // Бер-бер артлы өзлексез дәвам итү (сөйләү, сүз, уй турында). *Кайгы, шатлык тагын бергә кушылып акты.* Г. Ибраһимов. *Аның сүзләре хәвефсезнисез көмеш улактан аккан саф су кебек агып тора.* Ш. Камал.

6. *күч.* Узу, үтү (вакыт, гомер турында). *Шулай ел артыннан ел Иделдәге су кебек агып кына торды.* И. Гази. *Шау да гөр килеп аккан бу гүзәл тормыш көннәрнең берендә аз гына янып көлгә әйләнмичә калды.* Г. Минский.

7. *күч.* Юкка чыгу, исраф ителү, әрәм булып бетү. *— Кесадән меңсумнар ага, гүя Урал сулары.* Ш. Мөхәммәдев.

8. *күч.* Бик күп булып килү, керү (ашамлык, байлык һ. б. ш. турында).— *Кеше тук булганда, без дә ач булмабыз. Йортыбыз-җиребез хәзергә төгәл. Узган-барганнардан акмаса да тама.* Ш. Камал.

АГУЛАГЫЧ *махс.* **1.** *и.* Агулый торган матдә, агу I (1 мәгъ.). *Агулагыч куллану.*

2. *с.* Агулый торган. *Орлык агулагыч машина.*

АГУЛАНУ *ф. Кайт. юн. к. агулау.* **1.** Үз-үзен үтерү максаты белән агу эчү. // Агулы яки бозылган матдәләрнең организмга йогынтысы нәтиҗәсендә авыру. *Карт, [ризыкны] ашап, агуланмый сәламәт калса, бөтен семья утырып ашый.* Г. Нигъмәти.

2. Агу катнаштырылу, агу кушылу, агу салыну. *Агуланган су.* // Организмны зарарларлык хәлгә, агуларлык хәлгә килү.— *Күмер мае, куй мае, гатырша мае исләреннән җыелган сулышлар белән агуланган һава сиңа бөтен җир йөзендәге һава урынына булыр.* Ф. Әмирхан. // Агулы матдәләр йогынтысында зарарлану. [*Баш агроном*] *хәбәр итте: орлык, чәчкән чакта, формалинда күбрәк тотылган. Артык агуланган һәм бозылган. Тишелмәве аның шушыннан!* М. Җәлил.

3. *Төш, юн. к. агулау* (3, 4 мәгъ). [*Нәгыймә*], *аннан да бигрәк, шундый матур бәхет белән башланган бу яңа, күңелле тормышның гомергә агулануыннан, иренең күңелендә кара кер, авыр шик калудан курка иде.* Г. Ибраһимов. *Ул заман кешесенең [искелек белән] бөтен мие, каны, җаны агуланып калган.* Г. Бәширов.

АГУЛАУ *ф.* **1.** Агу эчереп үтерү. // Агу, агулы матдә кебек зарарлау, сәламәтлекне какшату. *Организмны аракы белән агулау.* □ *Сивашның тозлы суы уланнең тамырын корыта, җан иясенең канын агулый.* Г. Бәширов.

2. Агу катнаштыру, агу салу, агулы итү. *Һәм әйтте сердәше, дип: «Кичә шушыннан Үтте ил дошманы, Яшеренеп, яр буйлап, Минем саф, шифалы Суымны агулап.* М. Җәлил.— *Капка астын казып йортка керәсең дә, салават укып, агулаган икмәк, ит кисәкләрен эткә ташлыйсың.* К. Тинчурин. // Чүп үләннәренең орлыгын, тамырын корыту, бөҗәкләрне бетерү, зарарсызландыру өчен агу белән эшкәртү. *Чәчү орлыгын агулау.* □ *Туфрагыгызда чүп үлән орлыгы күп... Кар киткәч тә җирне агуларга туры киләчәк.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Кире йогынты ясау, начар йогынты ясау, зарарлы фикер белән сугару. [*Мәдрәсәдә*] *иске схоластика белән, чүп-чар белән, --- кирәксез нәрсәләр белән яшь буынны агулыйлар.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Тормышны бозу, ямен җибәрү, шатлыктан мәхрүм итү.— *Агаларың безнең бөтен гомеребезне агуладылар, --- хәзер сине котырталар, синнән агулатмакчы булалар.* Ф. Әмирхан. [*Мансуров*] *яшүсмер чагын сары мыеклы тупас урядниклары, кара сакаллы кулак атаманнары белән агулап узган иске тормышны яшьтән үк күрә алмас булды.* Г. Бәширов. // Күңелен, йөрәген сызлату, әрнетү, бик нык борчуга төшерү. *Агулады шәүләң бу атаны, Зәһәрләде исемең ананы.* Ф. Бурнаш. *Соңгы ай эчендә булган ике вакыйга аны аеруча агулады.* Г. Ибраһимов.

АГУЛЫ *с.* **1.** Агулый торган. *Агулы газ.* // Үзендә агу булган. *Алар нәкъ матур гөл, ләкин агулы ул.* **М. Җәлил.** // *Агу бүлеп чыгара торган. Агулы чебен.* □ *Анда ерткыч бүреләр, хәйләкәр төлкеләр, куркак куяннар, агулы еланнар яшиләр.* А. Алиш. *Ждданаңың зәһәр агулы Башың кисәргә!* М. Җәлил. // Агу кушылган, агу салынган, агуга манылган, агу сеңгән, агу сеңдерелгән, агулый торган. *Суыгызга агулы дәва кушып куйгансыз икән.* Ф. Әмирхан. // Агуланган, агу сеңеп бозылган, агу белән зарарланган. [*Шахтада эшләүчеләрнең*] *тән тамырларындагы кызыл каннары агулы сары сулараа әйләнгәнгә күрә, яңа гына озак авырудан терелеп чыккан кешеләр кебек, сарғылт булып күренәләр иде.* М. Гафури.

2. *күч.* Мәкерле, үзендә мәкер, явызлык саклаган. *Колагымда --- мәсхәрәләп әйткән агулы сүзләр.* Ф. Кәрим.

◇ **Агулы елан** — зәһәр, эчкерле, мәкерле кеше.

АГЫЗУ *ф.* **1.** Агарга юл ачу. *Күпер башында малайлар, көрәкләр күтәреп, гөрләвек агызып йөриләр.* И. Гази. *«Зәңгәр күзләр» көен көйли-көйли, Сулар агызам тирән күлләрдән.* Һ. Такташ. *Канау труба төшерер өчен, нефть агызыр өчен кирәк икән.* А. Әхмәт.

2. Бер савыттан икенчесенә күчерү, бушату, салу. *Мунча стенасы артына, яр эченә кертеп, кечкенә генә такта бура ясалган, бодайны бурага агызу өчен, мунча чормасыннан труба сузылган иде.* Г. Гобәй. *Мич алдына куелган чәйнектән ул стаканнарга чәй агызды.* А. Шамов.

3. Нәрсәне дә булса сыеклык өстеннән яки эченнән бер юнәлештә агып барырлык итеп җибәрү, хәрәкәт иттерү. *Сал агызу.* □ *Хәбәр итеп сиңа, Идел буйлап Мин агызырмын аккош мамыгын.* М. Җәлил.— *Гөрләвектә йомычкалар агызып, көймә җибәреп уйнарга керештек.* М. Гали. // Үзе белән, агым белән алып китү. — *Бөтен авылны су агызып китәчәк, ди техник.* К. Тинчурин. *Агым сулар ташысыннар, ашыксыннар, Дошманнарның үләксәсен агызсыннар.* Ә. Ерикәй.

4. *күч.* Нәрсәне дә булса күпләп-күпләп җибәрү яки үзенә алу (материаль байлыкның кереме яки чыгымы турында). *Әнә шул ресторанларның, кабакларның бер-бер сәгатьләре Берлин аристократиясе кесәсеннән йөз мең маркаларны үзләренә агызалар.* Г. Гали.

АГЫЛУ *ф.* **1.** *Кайт. юн. к.* агу II (2 мәгъ.). *Бодайның машина артына шаулап агылуы ишетелгән сыман тоела.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Күпләп-күпләп барысы бер якка хәрәкәт итү, бару (мәсәлән, кешеләр яки хайваннар).— *Театрның беренче башлана торган көне. Шулай булгач инде анда бөтен шәһәр халкы агылыр. Г. Камал.* // Салмак кына өзлексез хәрәкәт итеп тору. *Аларның түбәләренә тияртимәс кенә булып, көзге авыр болытлар агыла.* Г. Әпсәләмов. *Улән төпләрендә чык тамчылары ялтырый, кояш нуры шундый булып агылып тора, аннан күзләр чагыла.* Г. Бәширов.

АГЫЛЫЙГА-ТАГЫЛЫЙ *рәв.* Һәрвакыт бергә, бер-берсеннән аерылмыйча.— *Кызык бер юньсезгә ияргән. Һаман агылыйга-тагылый йөриләр.* Б. Камалов.

АГЫЛЫШ *и.* **1.** *к.* агым. [*Очерк*] --- *заманыбызның алдынгы идеяләре белән сугарылырга, тормыш агылышына турыдан-туры һәм бик тиз йогынты ясарга --- тиеш.* Г. Иделле. *Яңгыр уттай эш өстендәге авыл тормышының бөтен ритмын, тигез агылышын бозды.* С. Рафиков.

2. *күч.* Агылу, агып тору; күпләп, агым булып китү яки килү. — *Безгә бүген иң яхшы сыйфатлы продукциянең ике өлеш булып өзлексез агылышы кирәк.* Р. Ишморат.

АГЫМ *и.* **1.** Елга үзәне буенча су агышы, хәрәкәте. *Агыйдел дә безгә табан кысылып тарая һәм агымын тизләтә.* М. Әмир. *Суның агымы мине бер минуттан соң үзе белән алып китте.* М. Гафури. // *с. мәгъ.* Ага торган. *Агым су ялтыравыклы күксел бозга уралып ята.* Ш. Камал. *Киң басулар, шаян агым сулар Язгы җилгә дулкынлансыннар.* М. Җәлил. // Көчле ага торган, ташкын. *Агым сулы Иртыш буенда Тубылгылар өзә Сабира.* Ә. Ерикәй.

2. Диңгезләрдә, океаннарда су массасының, ташкынның хәрәкәте. *Салкын агым. Гольфстрим агымы.* □ *Агымнар башлыча һәрвакыт бер үк юнәлештә исә торган җилләр тәэсирендә барлыкка киләләр.* Физ. геогр.

3. Һава дулкыны. *Саргылт төтен, әйләнмәле дулкыннары белән җир өстенә орына-орына, киң агым булып, урам буена таба сузыла.* Г. Бәширов. *Аркаларга суыкча агым тигәләве җиргә әкрен генә чык төшүне хәбәр итә кебек.* С. Рафиков.

4. Суның өстендә агып бару, хәрәкәтләнү, барыш. *Хыялымны ерак алып китә Шаулап килгән бозлар агымы.* Ф. Кәрим.

5. *күч.* Бер-бер артлы, өзлексез хәрәкәт итеп торган *әйберләр теземе. Кара елан төсле тимер эздән Яшьнәп үтсен инде уртабыздан Кызыл паровозлар агымы.* М. Җәлил. // Бер-берсеннән калмыйча туктаусыз бер якка баручылар хәрәкәте. *Шәһәр белән бистә арасындагы җанлы стеналарның беренче рәтен ерып эчкә үткән халык агымы адым саен үсә барды.* К. Нәҗми.

6. *күч.* Тормыш, фикер, уй һ. б. ш. кебек нәрсәләрнең юнәлеше, барышы. *Укучы яшьләр төркеме белән очрашу минем хатирәләрем агымына тагы бер төр өстәп җибәрде.* Ф. Әмирхан. *Ләкин бу борчулар, йөделгә килеп кушылган тонык сулы кечкенә инешләр кебек, торабара күңел дәрьясының саф агымында эреп югалалар иде.* Г. Бәширов.

7. *күч.* Әдәби яки иҗтимагый-политик юнәлеш. *80 нче еллар реакциясе иҗтимагый омтылышны буганга, әдәбиятта --- вак эстетизмга бирелү агымы туды.* Г. Ибраһимов. *Революция тәэсире астында укучылар арасында төрле агымнар, үзара кызу политик бәхәсләр башлана.* М. Гали.

Агым системасы *махс.*— өзлексез, тоташ, конвейер системасы белән башкарыла торган җитештерү ысулы; *русчасы:* поточный метод.

◇ **Агымга ияртү** — заманча кылану, башкалар ни эшләсә, шуны эшләү, күпчелеккә ияртү. *Батырхан: Шулай да Колчакта карательный отряд башында торып, Себер авылларында крестьяннарны бугазлап йөргәнсез, дисәләр? Давыт: Мин ул эшләрне агымга ияреп эшләнгән акылсызлык дип кенә карыйм.* К. Тинчурин. **Агымга каршы йөзү (бару)** — 1) каршылыклар белән көрәшеп, тормышта үз юлыңны салу. *Аларда язмышның бу агымына каршы барырлык куәт юк.* Г. Ибраһимов; 2) үч итеп, тискәреләнеп, бар нәрсәгә каршы бару. **Агым уңаена йөзү** — тормыш барышына буйсынып, үзеңнең активлыгыңны күрсәтмәү, пассив рәвештә яшәү. **(Үз) агымына кайту (төшү)** — эшләр рәткә салыну, җайлану, элеккечә тәртип белән бара башлау турында. *Эшләр рәтләнде, яңадан үз агымына кайтты.* С. Баттал.

АГЫМДАГЫ *с.* **1.** Хәзерге, шушы көнгә, шушы вакытка караган.— *Син җыелышларны яратмыйсың, агымдагы сәясәт түгәрәкләренә күңел бирмисең.* М. Әмир.

2. Көн саен кабатланып торган, көндәлек. [*Фәтхи*] *партиягә керергә теләгән кешеләрнең гаризаларын кабул итү һәм тикшерү агымдагы мәсьәләләр рәтендә каралачагын белдерде.* Ш. Камал. *Иртә-кич кабинетыннан чыкмыйча, ул райкомның агымдагы эшләре белән шөгыльләнде.* Ә. Еники.

Агымдагы счёт — банкка яки саклык кассасына акча кертүченең теләгән вакыта салырга һәм алырга хокук бирә торган счеты. *Предприятиеләрнең агымдагы счётлары төрле банкларда була.* Политэкономия.

АГЫМЛЫ *с.* Ага торган, торгын булмаган. *Үзләреннән инешләр, кечкенә һәм зур елгалар агып чыга торган күлларне агымлы күлләр дип атыйлар. Агымсыз күлләрдән су агып чыкмый.* Физ. геогр.

АГЫНТЫ *и.* **1.** Сыеклык яки һаваның нинди дә булса савыттан, ярыктан бәреп чыккан тар агымы. *Су агынтысы. Саф һава агынтысы. Пар агынтысы.* □ *Лафет көпшәсеннән атылып чыккан кайнар агынты, ут булып, [Арсланның] битен, күзләрен пешерә.* Г. Ахунов.

2. Агып, сыгылып чыгып яки тамып җыелган сыеклык.

АГЫШ *и.* **1.** Ару, агып тору. *Әйтеп кийды Вафин башкаларга: Матур да соң суның агышы!..* Ш. Мөдәррис. *Тау буенда, чәчәк арасына Утырып тыңла чишмә агышын.* Ф. Кәрим. // *күч.* Җыр, музыканың билгеле бер эзлеклелектә баруы, таралуы турында. *Нәфисә, кулла-*

рын алъяпкыч күкрәгенә яшереп, урман куелыгына караган килеш, җырының агышы уңаена салмак кына башын чайкый, озын керфекләре яртылай йомыла. Г. Бәширов. *Мин, [көйнең] әкрен генә, зәгыйфь кенә чыккан моңлы агышына бирелеп, дөньядагы барлык нәрсәмне оныттым, берничә минут шулай басып тордым.* А. Шамов. // Гомумән эзлеклелек, эзлекле дәвам итү.

2. *к.* агым 1. *Елганың югары агышына таба агачлар арасыннан киткән сукмак бик аз тапталган.* Ш. Камал. // Агу юлы, хәрәкәт юлы. *Шул тирәгә җиткәч, Агыйдел үзенең агышын борып, бераз кояш батышына табарак китә.* М. Гафури.

3. Нинди дә булса эш, хәл, вакыйганың барышы. [*Гаепләнүчеләрнең*] *каты торулары судның агышын үзгәртә алмый.* Һ. Такташ. *Вакыт — безнең гүзәл тормышыбызның шаулы агышы ул.* Р. Ишморат.

4. *күч.* Алмашынып тору, нәрсәнең дә булса составы үзгәрү. [*Дирекция*] *җилкуар, очраклы кешеләрне студиягә күп тартты. Ләкин алар составта озак калмыйча, килеп-китеп, студиядә агыш тудырдылар.* М. Җәлил.

АДА'ЖИО *махс.* **1.** *рәв.* Музыка әсәренең башкарылу темпы турында: әкрен, сузып.

2. *и.* Әкрен темп белән башкарыла торган музыка әсәре яки аның бер кисәге. *Хәбир музыка язып утырганда: «Бу — Мәдинә белән минем дуэт», «Бу — Мәдинәнең адажиосы»,— дип хыялланып китә иде.* Ш. Хөсәенов.

АДАРЫНУ *ф.* 1. Алдан багышлап кую, вәгъдә биреп кую, нәзер. әйтү. [*Рим купецлары*] *берәр бәлагә юлыксалар, «Ходаем, коткарсана бу бәламнән, илле баш корбан чалыр идем»,— дип адарыналар икән дә, бәладән котылгач, илле баш чебен суялар икән.* И. Гази. *Берсе, кызым баладан исән-сау котылса, дип, икенчесе, сыерым тана бозау китерсә, дип адарынган икән.* Г. Бәширов.

2. *иск. кит.* Җилкенү, ярсу, ялкынлану. *Рәшатның күзләре инде әүвәлге ихлассызлык, ялкаулыкларын [югалтып], гадәттәгечә шатлыклы адарына, хәятлы сикеренә башлаганнар иде.* Ф. Әмирхан.

3. *иск. кит.* Мавыгу, бөтен җаны-тәне белән бирелү, табыну. *Аның тормышында адарынган, киләчәктә буйсынырга уйлаган әмәле дә [сөйгәне] иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АДАШ *и.* Кем белән дә булса бер үк исемдәге кеше. *Миңа адаш булган ул язучы белән эти таныш түгел.* А. Шамов. // Шул кешегә мөрәҗәгать сүзе. / *с. мәгъ. Җәен ишек алдында әткәйләрнең: «Менә адаш абзыең белән күреш»,— дип, аның белән күрештергәне дә бераз гына исемдә калган.* М. Гали.

АДАШЛЫК *и.* Икенче бер кешегә адаш булу, бер исемдә булу.

АДАШТЫРГЫЧ *с.* Адаштыра торган, адаштырырлык. *Чыкты соң кайдан адаштыргыч буран — бу куркыныч.* Г. Тукай.

АДАШТЫРУ *ф.* **1.** Берәр кешене яки хайванны, өйгә борылып кайтмасын өчен, таныш булмаган юлдан җибәрү, илтеп ташлап калдыру. *Ничек итеп үз балаңны үзең кара урманда адаштырып калдырырга кирәк?* А. Әхмәт. *— Бик күп көлмә, мин әйтәм, үзеңне яшь хатынлыкка алырмын да калага алып барып адаштырырмын, адәм мәсхәрәсе булырсың, дим.* М. Гали. // Туган илдән аеру, ераккә җибәреп олактыру. *Бу каһәр суккан Мостафа башыбызны әллә кайларга илтеп адаштыра бит!* Ш. Камал. // *күч.* Үзеңнән калдыру, котылу. *Хәйдәр, бу сихерле сурәтне онытырга яисә адаштырып калдырырга теләгәндәй, кашларын җыергалап, таягы белән чыклы үләннәргә суга-суга, кызулап чатанлый.* Г. Бәширов.

2. Юлдан яздыру, юлдан читкә җибәрү, юлын югалтыру. *Куе томаннар адаштырырга гына торалар.* А. Алиш. // *күч.* Ялгыш юлга, начар юлга кертү.

3. *күч.* Зиһен, үй-фикер, хисап кебек нәрсәләрне чуалту. *Тау өстендә ике җил тегермәне бик ерактан күренә иделәр. Алар минем зиһенемне адаштыралар. Миңа алар җанлы кебек тоела иделәр.* Ш. Камал.

АДАШУ. *ф.* **1.** Юлны югалту, ялгышып юлдан читкә чыгып китү, юлдан язу. *Кышын монда күз ачкысыз бураннар була, Идел өстендә кешеләр адашып йөри.* М. Гали. *Разведчиклар далада адашып калган төя баласын тотып алып кайталар.* Ш. Усманов. // *күч. сөйл.* Чит, ерак җирләргә китү, туган яктан, туганнардан аерылып яшәү. [*Мотый:*] *Бу сеңелкәш тә безнең кебек илләреннән адашып йөргән егетләрнең күңелен табарга тырышыр.* М. Фәйзи.

2. *күч.* Уй, фикер, хисап һ. б. ш. ялгышу, буталу. *Бер, ике, дүрт, адаштым, Ун... егерме, ах, тагын Мин югалттым шомлы көннәрнең, Гасырларның санын.* Һ. Такташ.

3. *күч.* Туры, дөрес юлдан язу, начар юлга керү, ялгышу. *Бар җирдә тигезсезлек чиктән ашкан... Күп кешеләр туры юлыннан адашкан...* Г. Камал. // *күч.* Дөньяда тору, яшәү өчен үзенә билгеле юл сайлый алмыйча аптырау. *Мин бит монда адашкан кеше. Без бит һәммәбез дә адашканнар.* Ш. Камал. [*Кара фикер Давытка:*] *Бүгенгә чаклы адашып йөрдең, ныклап мин күрсәткән туры юлга баса алмадың.* Г. Коләхметов.

АДВОКАТ *и.* **1.** *махс.* Судта гаепләнүчене яклаучы юрист. *Алдан үк хәзерләнгән планы буенча, карт адвокат Мәрьямбикә белән Мостафа алдында өмет яктысы ачты.* Г. Ибраһимов. // Хокук мәсьәләләре буенча киңәшләр бирүче югары белемле юрист.— *Менә сез адвокат икән, бу казакъ егетенең хокукын яклап чыгарга тиеш.* Ә. Фәйзи.— *Хатын-кыз укысын, табибә булсын, адвокат булсын, Авропада нинди гыйлем бар, һәммәсен алсын.* Ф. Әмирхан.

2. *күч. сөйл.* Яклаучы, арага керүче. [*Хафиз:*] *Ә син Гөлзадәгә дә, Рәшиткә дә адвокат булма.* Р. Ишморат.

АДВОКАТЛЫК *и.* Адвокат хезмәте.

АДЕКВАТ *с.* Тәңгәл, тиңдәш, бер төрле үк, туры килгән. *Адекват төшенчәләр.*

АДМИНИСТРАТИВ *с.* **1.** Администрациягә бәйләнешле. *Административ чаралар. Административ бүленеш. Административ үзәк.* □ *Шәһәрдә административ властьны үз кулына алганнан соң, Мөхәммәт яһүдләргә карата мөнәсәбәтне тамырыннан үзгәртә.* Г. Гобәй.

2. *рәв. мәгъ. күч. хурл.* Формаль, эшнең асылына төшенмичә, бюрократларча.

◇ **Административ тәртиптә (рәвештә)** — башкарма власть органнары кушу буенча. *Әлбәттә, бу тематик план авторларга административ рәвештә югарыдан задание бирү дигән сүз түгел.* М. Җәлил. *Күбрәк вакытта политик эшләр административ тәртиптә хәл ителгәннәр.* СССР тарихы.

АДМИНИСТРА'ТОР *и.* Идарә итүгә җаваплы кеше, администрация кешесе. [*Хәсән*] *бер төркем инженерлар, администраторлар белән цехларны карап йөргән.* Г. Әпсәләмов.

АДМИНИСТРА'ТОРЛЫК *и.* **1.** Администратор вазифасы, хезмәте. *Администраторлыктан төшерү.*

2. *күч.* Җитәкчелектә мәсьәләнең асылына төшенмичә эш итү, формалистлык, бюрократлык. *Газизовка эчпошыргыч администраторлык чире йоккан, «боердың — эше бетте» дигән нәрсә сеңгән.* А. Тимергалин.

◇ **Администраторлык итү** — конкрет җитәкчелек урынына, бюрократларча боеру, кушулар белән генә идарә итү.

АДМИНИСТРА'ЦИЯ *и.* **1.** Башкарма власть органнары. // Учреждение, предприятие һәм оешманың җитәкче органы. [*Госманга*] *сәгать туғыздан да калмый учреждениедә булырга, завод-фабрика администрациясеннән килгән кешеләрне кабул итәргә кирәк.* А. Шамов.

2. *җый.* Власть кешеләре, учреждениегә, предприятиегә җитәкчелек итүчеләр, администраторлар, җаваплы башкаручылар. *Забастовка уңышлы бетте. Администра-*

ция башта бик каты торса да, соңыннан чигенергә мәҗбүр булды. И. Гази.

◇ **Администрация тәртибендә (тәртибе белән)** — *к.* административ тәртиптә. *Галимовны кичә, администрация тәртибе белән, егерме дүрт сәгать эчендә шәһәрдән сөрделәр.* Г. Ибраһимов.

АДМИРАЛ *и.* Хәрби Диңгез Флотында иң югары хәрби дәрәҗә. [*Анатолий:*] *Безнең матрос үзенең адмирал белән бәхәсләшү турында сөйли.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Адмиралныкы, адмирал карамагындагы. *Адмирал корабле. Адмирал флагы.*

АДМИРАЛТЕ'ЙСТВО *и.* 1. Хәрби суднолар төзү, коралландыру һәм ремонтлау урыны.

2. Патша Россиясендә һәм Англиядә: диңгез көчләренең иң югары идарә органы; диңгез ведомствосы.

3. Ленинградта элекке хәрби флот баш идарәсенең бинасы.

АДО'НИС *и.* 1. *бот.* Казаяк.

2. *махс.* Шул үсемлектән ясалган дару. *Мәдинә тапкырлау таблицасы кебек ятланган дозаларны исенә төшерә алмады. Күпме адонис, күпме бром? — Һәммәсе хәтердән чыккан иде.* Ш. Хөсәенов.

АДРЕНАЛИН *и. анат.* Бөер өсте бизләрендә эшләнеп чыга торган секрет; йөрәкнең кыскаруларын йомшарта һәм көчәйтә.

А'ДРЕС *и.* 1. Почта аша җибәрелә торган конверт, посылка, бандероль һ. б. ш. әйберләрнең тышында кайда һәм кемгә тапшырылырга тиешлеген күрсәткән язу. *Хатның адресын ниндидер чит кул язуы* [*Нәфисәне*] *шикләндерә, ул бер хатка, бер әнисенә карап, бу шиген аңа әйтергә базмыйча, кашын җыера иде.* Г. Бәширов. // Берәр кешенең яшәү урыны яки учреждение урнашкан урын. *Элек тә хатлар бик озак килә иде, хәзер, адрес алмашынгач, тагын да озаграк йөрер инде.* Г. Әпсәләмов. *Хатны алырга тиеш булган ул кешенең Исемен, Адресын Белмим.* Һ. Такташ.

2. Берәр кеше тормышындагы зур вакыйганы билгеләгәндә шул кешегә бирелә торган язма тәбрик. *Татар драматурглары тарафыннан бер зур юбилей мәҗлесе ясалып, Закир Сәедзадәгә бик күп һәдияләр бирелергә һәм --- адрес тәкъдим ителергә тиештер.* Ф. Әмирхан.

Адреслар өстәле — шәһәрдә яшәүчеләрнең адреслары барлап, аларның тору урыннары турында белешмәләр бирә торган учреждение.

◇ **Адресына (карата)** — кемгә, кемнең дә булса исеменә (карата), төбәп. *Бурсык Аптул моны үз адресына карата төрттереп әйтелгән сүз дип уйлап булса кирәк, --- эченә җыеп йөргән рәнҗүләрен дә берьюлы сиздереп, дуамал гына кызып китте.* Ф. Хөсни. *Шул арада болар берсе-берсенең адресына үткен-үткен --- сүзләр дә җибәрешеп алдылар.* Г. Тукай.

АДРЕСАНТ *и.* Хат, посылка, телеграмма һ. б. ш. нәрсәне почта аша кемнеңдер адресына җибәрүче кеше.

АДРЕСАТ *и.* Почта аша килә торган хат, посылка һ. б. ш. нәрсәне алырга тиешле кеше.— *Менә хәзер инде мин, ерактан килгән хатны адресатның үз кулына тапшырдым дип, тынычланып йөри алам,— диде почтальон.* А. Әхмәт.

АДРЕСЛАНУ *ф.* Кемнеңдер исеменә язылу, аталу. *Аннан клеёнка тышлы, берсе язып тутырылган, икенчесе әле башланган гына ике дәфтәр, Рабига исеменә адресланган күп кенә хатлар һәм бер рәсем килеп чыкты.* А. Шамов. *Губком секретарена адресланган рәсми хатта ул үзен авызлыклап, объектив булырга тырышып язды.* И. Гази.

АДРЕСЛАУ *ф.* 1. Хат, посылка һ. б. ш. нәрсәләрне адрес буенча җибәрү. *Шуның өчен хатларны мин Адресладым аңарга.* М. Җәлил. // Каядыр, кемнеңдер исеменә атап җибәрү, атап мөрәҗәгать итү. [*Сания:*] *Төгәл механизм заводына бирелгән нарядка үзем кул куйдым һәм аны үз кулым белән сезгә адреслядым.* М. Әмир.

2. Кемгә дә булса атап эшләү, багышлау. *Ул шигырь-өндәмә яза, аны киң массаларга адреслап, большевиклар партиясе биргән идеяләрне җитәкче итеп ала.* Г. Хисмәтуллин.

АДСО'РБЕНТЛАР *и. хим.* Өстендә адсорбция була торган матдәләр. *Агач күмере актив адсорбентларның берсе булып санала.* Химия.

АДСО'РБЦИЯ *и. хим.* 1. Каты матдә өслегенең газ сыман яки эрегән матдәләрне үзенә сеңдерү күренеше.

2. Күмернең пар һәм эрегән матдә кисәкчекләрен тотып тора алу үзлеге.

АДЪЮ'НКТ *и.* 1. Югары хәрби уку йортларында: аспирант. *Хәрби-һава инженерлык академиясе адъюнкты.*

2. Революциягә кадәрге Россиядә һәм Көнбатыш Европада: кайбер гыйльми учреждениеләрдәге кече гыйльми дәрәҗә һәм шул дәрәҗәдәге кеше. // Югары уку йортларында: профессор ярдәмчесе. [*И. Хәлфин*], *татарлардан беренче буларак, адъюнкт дигән гыйльми дәрәҗә ала.* И. Рәмиев.

АДЪЮНКТУ'РА *и.* Югары хәрби уку йортларында: аспирантура.

АДЪЮТАНТ *и.* Хәрби начальник карамагында кайбер вазифаларны яки штаб эшләрен үтәүче офицер. *Аның каршысында хәрби шура председателенең адъютанты Вәлиханов басып тора иде.* К. Тинчурин.

АДЪЮТАНТЛЫК *и.* Адъютант хезмәте.—*Адъютантлыкка поручик Марковны билгеләрсез.* Т. Гыйззәт.

АДЫМ *и.* 1. Аякның алга, артка яки янга таба бер атлавы. *Бер адым алга басам да Әйләнәм мин артыма.* М. Гафури. *Үзен бик тыныч тотарга тырышкан Мортаза бай, үзе дә сизмәстән, ярты адым артка чигенеп куйды.* Ә. Фәйзи. // Йөргәндә яки йөгергәндә бер аякның алга таба бер хәрәкәте. *Ашыгып иркәмә киттем, Өч адымны бер иттем дә Иркәмә барып җиттем.* М. Җәлил. // Шундый хәрәкәт вакытында чыга торган тавыш, аяк атлау тавышы. [*Хәят*] *Лизаның бу серле үбүеннән һәм йөгереп китүеннән аптырашта калып, нәрсә дип уйларга белми барганда, үз артыннан Михаилның адымнарын ишетте.* Ф. Әмирхан. *Хәлим* [*сестраның*] *адымнарын, аның, ничектер, аз гына каушый төшеп сулавын ишетә.* А. Шамов.

2. Атлау рәвеше, йөреш. *Алар дөя адымы белән, тавыш-тынсыз җай вә мәһабәт йөреш белән якынлашалар.* Н. Исәнбәт. *Балаларча түгел, Бетон тәнле Батырларча алар адымы.* М. Җәлил. *Кыз адымын үзгәртә: юргалап кына үтә.* М. Фәйзи. // Ат йөрешендә иң салмак хәрәкәт, атлап бару; аллюр. *Извозчик Шәяхмәт бүген башка көндәге кебек атына сукмый, тиргәнми, атының ялкау адымына риза булган хәлдә, кузласында изрәп бара.* Ә. Фәйзи.

3. Озынлык үлчәве (атлаган вакытта ике аяк табаны арасы кадәр). *Хәлим тәрәзә турысыннан биш-алты адым шуышкач, бераз тынычланып артына әйләнеп карады.* Г. Гобәй.

4. күч. Эшләгән эш, кыланыш. [*Гөлсем апа:*] *Шулай да, акыллы адым ideме соң бу? Әллә хис дигән нәрсәгә артык бирелеп китеп, акыл чыгып торган чакларда була торган бер кабынып китү генәме?* Г. Гобәй.

5. күч. Берәр нәрсәнең, хәрәкәтнең үсешендә бер этап, чор, баскыч. *Торган җиремнән беренче адым итеп менә тагын шушы шәһәргә килдем.* Ш. Камал. *Ниһаять, югары уңышка таба тагы бер зур һәм кыю адым атландым.* Г. Гобәй.

◇ **Адым саен** — 1) эзлекле рәвештә, һәрвакыт (алга, үсешкә бару яки артка китү турында). *Бездә кеше адым саен Бәхеткә таба бара.* Ә. Ерикәй; 2) еш кына, гел, һәрвакыт. *Сәнди ич ул. Ә андыйлар һәр ел саен туып тормыйлар. Очрамыйлар алар адым саен, Кадерләрен кирәк белергә!* З. Мансур; 3) һәр эштә, һәр

адымда, нинди эш башласаң да. *Безнең юлга дошман куелы белән Адым саен киртә салына.* М. Җәлил.

АДЫМЛАУ *ф.* 1. Атлау, атлап үтү, атлап бару. *Ул бара, чак-чак адымлый, Алга яткан гәүдәсе.* Н. Исәнбәт.

2. Адым белән үлчәү.

3. *рәв. мәгъ.* **адымлап**. Әкрен генә, атлап кына. *Атлар юыртудан туктадылар, адымлап кына килә башладылар.* Ш. Камал. *Акыллы хайван — кара туры да эшне сизде, адымлап бара башлады.* Г. Толымбай. // Җәяү, җәяүләп. [*Степанов:*] *Ул ботинка белән мин Германияне адымлап таптап чыктым.* А. Шамов.

АДЫМЛЫ *с.* 1. Кеше яки хайванның йөреш рәвешен биргәндә кулланыла. *Артистка --- аю адымлы, комсыз Тутакайны күз алдыбызга бастырды.* М. Җәлил.

2. Яхшы йөри торган, зур алдыра, тиз алга китә торган (ат турында). *Адымлы ат — алымлы ат.* Мәкаль.

АДЫМЛЫК *с.* Ничәдер адым ераклыкта яки зурлыкта булган. [*Габдулла:*] *Аның [кибеткә барунык] ни мәшәкате бар? Ике адымлык җир ул [кибет].* Г. Ибраһимов.

АДӘМ *и.* 1. *миф.* Коръән һәм мифик язмалардагыча — җир йөзендә иң башлап яратылган кеше. *Адәм, Хава бу җиргә ыргытылгач, Хәкыйрь хис итте алла һәммәсен дә.* М. Гафури.

2. Кеше. *Адәм түгел, хайван түгел, Карагызчы, бу ни бу? Кул-аягы ботлы-чатлы, үзе адәм сынлы бу...* Н. Исәнбәт. // Билгесез ир кеше, таныш булмаган ир кеше. *Керергә дип аяк атлаганда гына өй эченнән өч адәм килеп чыкты.* Г. Ибраһимов. // *кимс.* Бәндә. *— Байбуров берлән Баязитов дигән адәмнәр --- закускага дуңгыз ите сата башладылар.* Ш. Мөхәммәдев.

◊ **Адәм актыгы (калдыгы)** *кимс.*—кешене кимсетеп әйтелә.— *Аларның --- адәм актыгы кызларына кияү чыксын да, синең бердәнбер алма шикелле балаңа кияү чыкмасын имеш!* Г. Камал. **Адәм акыллы** — 1) кешеләрчә уй, фикер йөртә торган, аңлы.— *Шундый малайга бармаса, юньлерәк, адәм акыллырак, кеше төсле рәк кеше беткән иде микәнни?* Г. Камал; 2) акылга сыя торган, акыллы, рәтле (сүз, фикер).— *Берәр игъланны төшереп калдырырга да, заглавиесен зуррак һәм адәм акыллыракны куярга кирәк.* Ш. Камал. **Адәм баласы**— гомумән кеше мәгънәсен бирә. *Адәм баласы үзе дә җаен таба, тик менә бичара хайван гына кеше кулына карап тора.* Ә. Еники. **Адәм башлы булу** — акыллы, аңлы булу.— *Балык башлы булырсың да булырсың. Адәм башлы булырга гына читенрәк.* Ф. Бурнаш. **Адәм башы** — кеше. **Адәм булу** — 1) кеше булу, кешелекле булу.— *Сез адәм булсагыз, атагыздан гыйбрәт алыр идегез!* Г. Ибраһимов; 2) каты авырудан терелү, савыгу, аякка басу; 3) тормышка яраклы, тормыш итәрлек кеше булу.—*Адәм булдым дигәндә генә әрәм булырсың.* И. Гази; 4) кеше арасына керү, кеше булып танылу. *Байбәтчәләр адәм булды, менгәннәре велосипед.* Ш. Мөхәммәдев. **Адәм диңгезе** — бик зур төркем булып бара торган яки бер урынга җыйналган халык. *«Ай-һай, мәгъзум, уразаны бик каты тоткансың бугай», дип юләреннән качу өчен [Зыя] ---кайнап торган адәм диңгезе эченә кереп югалды.* Г. Ибраһимов. **Адәм заты**—*к.* адәми зат. *Юлларда адәм заты күренмәгәч, кешеләр бер урынгарак җыйналдылар.* Ш. Камал. **Адәм имгәге** *кимс.*— яшәү сәләте булмаган, башкалар ярдәме белән генә көн күрә торган, башкаларга йөк булып яши торган кешегә карата әйтелә.— *Тегесе тагын кайда йөри, адәм имгәге?* Ф. Бурнаш. **Адәм (итен) чәйнәү** — гайбәт сату, кеше сөйләү. [*Себер бае:*] *Ә адәм итен чәйнәү, көн буе гайбәт сатып утыру — анысы хәрам түгел?* Г. Камал. **Адәм итү** — кеше арасына керерлек, тормышны алып барырлык дәрәҗәгә үстереп җиткерү. **Адәм көеге** — *к.* адәм имгәге. *Адәм көеге булганчы урман киеге бул.* Мәкаль. **Адәм көлкесенә (хурлыгына) калу, адәм көлкесе булу** — хур булу, хурлыкка калу, оятка калу, оятлы булу. *Шушы яшемә җитеп, бервакытта да адәм көлкесенә калганым юк әле.* Ш. Камал. *— Бу урында елап эш чыкмый, адәм көлкесе булабыз бит без, һаман Газизләрнең бу этлекләренә чыдасак?* Ф. Әмирхан. **Адәм күзенә күренерлеген (адәм йөзенә чыгарлыгын) калдырмау** — хур итү, оятка калдыру. *Ул: — адәм йөзенә чыгарлыгымны калдырмады бит!— дип сүгенде.* Г. Ибраһимов: **Адәм күтәрмәслек** — бик авыр, кыен, башкарып чыгарга көч җитмәслек. **Адәм мәсхәрәсе булу** — хур булу, мәсхәрәгә (көлкегә) калу. *Әллә --- безнең карт шулай картайган көндә адәм мәсхәрәсе булып өйләнергә йөриме?* Г. Камал. **Адәм мәсхәрәсе итү** — хур итү, мәсхәрәләү, мыскыллау. **Адәм рәтле** — 1) әйбәт, уңган, булган, юньле (кеше турында). [*Мәдинә Шихрайга:*] *Без сине адәм рәтле юньле кеше дип, Совет председательлегенә сайлаган идек.* Ш. Камал. *Ичмасам, адәм рәтле кешегә дә чыкмаган.* Ф. Бурнаш; 2) яхшы, затлы (әйбер, кием яки мал турында). [*Җиһан:*] *Хәзер халык бик сайлана башлады, кеше арасына чыкканда адәм рәтлерәген дә киясе килә.* М. Шабай; 3) эшкә, файдага яраклык. *Ул бүлмәне адәм рәтле лаборатория хәленә китерергә кирәк булыр.* Ш. Камал; 4) яхшы, рәхәт (яшәү, тормыш турында); 5) яхшылап, әйбәт итеп.— *Адәм рәтле яза-сыза белсәм, авыл Советы түгел, ВИК председателе итеп сайласагыз да отказ бирмәс идем.* Ш. Камал. **Адәм рәтенә керү** — 1) яхшы якка үзгәрү, яхшыру.—*Бәлки, улыбыз адәм рәтенә керә дип шатланып та куяр иделәр.* Ш. Камал; 2) кеше арасына керү, кешеләр белән аралашу; 3) яхшыра төшү, әйбәт дип санарлык хәлгә килү; элеккеге хәленә кайту. *Салкын су белән битләребезне югач кына, бераз адәм рәтенә кергәндәй булдык.* М. Әмир. **Адәм санына керү** — 1) кеше булып (итеп) исәпләнү, ихтирам күрү.— *Әле мине адәм санына керткән кеше калганмыни?* М. Гафури. *Тик колхозда гына без дә күрдек Адәм санына кергән көннәрне.* Ш. Маннур; 2) *кимс.* сан исәбенә генә керү. **Адәм түгел** *кимс.*— кешелексез, миһербансыз, кеше түгел. **Адәм углы** *кит.*— адәм баласы, кеше.— *Курыкма миннән, мин дә адәм углы, чибәрем.* Ф. Бурнаш. **Адәм хуры булу** — *к.* адәм мәсхәрәсе булу.— *Мулла башың белән, карт көннәреңдә картуслар киеп, адәм хуры булып йөрисең.* Ф. Әмирхан. **Адәм шайтаны** — аздыручы, туры юлдан чыгаручы, котыртучы кеше. **Адәм ышанмаслык** — 1) гаҗәп, искиткеч, шаккатарлык. [*Игеннәр*] *адәм ышанмаслык мәртәбәдә буйга да үскән, башка да искиткеч дәрәҗәдә утырган иде.* Г. Ибраһимов; 2) ялган икәнлеге апачык булган, уйдырма (сүзгә карата). **Адәм әйтеп ышанмаслык** — *к.* адәм ышанмаслык (1 мәгъ.)— *Адәм әйтеп ышанмаслык бит, сары майның кадагы сигез сум илле тиен, ди, шикәрне әйтмә дә инде.* Г. Камал. **Адәм үләксәсе** — *к.* адәм актыгы. **Адәм җәфасы** *кимс.*— *к.* адәм имгәге.— *Әйдә, бар, кит өеңә, адәм җәфасы.* Ф. Әмирхан.

АДӘМИ: **адәми зат** *кит.*— кеше, кеше заты. [*Мәүлиха түти Әпипәгә:*] *Тфу! Адәми зат түгелсең лә син, Иблис токымыннандыр син...* Г. Бәширов.

АДӘМЧЕК *и.* Кешегә карата кимсетү, мыскыллау сүзе (аның көчсезлегенә басым ясый). *Әллә ниткән рельсларга бау тагып, Арлы-бирле йөртеп атсыз арбалар, Нишли анда ул адәмчекләр, син әйт, Нәкъ чыбык тарткан кебек кырмыскалар?* Н. Исәнбәт.

АДӘ'МЧӘ *рәв.* Кешеләргә хас булганча, яхшы гына, тәртипле итеп. *Үзеңне адәмчә тоту.* // Кеше телендә, кешечә; кешегә аңлаешлы итеп. *Азымбай, адәмчә сөйләнеп, коръык буйлап барып, биянең муенына кул салды.* Г. Ибраһимов.

АЕК *с.* 1. Исерткеч эчемлек эчмәгән, исермәгән; исерек булмаган. *Бу кеше миңа аз эчеп исергән адәмнәр арасындагы бердәнбер аек кеше шикелле күренә.* Ф. Әмирхан. *Аек чакта аның авызыннан*

сүзне аркан белән тартып та чыгарып булмаса, исергәч, ул күп һәм зарланып сөйли. Г. Әпсәләмов. // *сөйл.* Гомумән исерткеч эчемлекләр, аракы эчми торган.

2. Фикер йөртердәй хәлдә, уйлау сәләтен югалтмаган, аңлы. *Автомобиль кузгалып киткәч кенә, хәзрәтебез аңга килде: бу вакытка кадәр ул, Сабиржан мулланың Ишми алдында сигарка тартуыннан аптырап, ярым аек, ярым исерек хәлдә иде.* Ф. Әмирхан.— *Һәм аек, һәм булдыклы кешеләр алар — алтын. Ә алтын — аяк аста тәгәрәп ятмый.* Ш. Камал.

3. *күч.* Акыллы, уйлап эш итә торган. *Җәләл борыннан ук бик артык аек адәм* [*түгел*]. Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* Акыл белән, уйлап. *Аек хөкем йөртү.* // Дөрес, туры, төпле, ачык (фикер, акыл, караш турында). *Аек тәнкыйть.* □ *Гөлсем апаның асрамага бала алуын аек фикерле күршеләре мактап сөйләделәр.* Г. Гобәй.

4. Сак, сизгер, уяу. *Аклар исереп йөргәндә, кызыллар булды аек.* Г. Камал.

◇ **Аек баштан (баш белән)** — 1) аек көенчә, аек була торып, эчмәгән көенчә.— *Тик ул сүзләрнең аек баштан сөйләнмәве безне уңайсызландырды.* М. Әмир; 2) акыл белән уйлап.— *Акыллы кешеләр аек баш белән төрлесе төрле эшкә керештеләр. Сиңа да шуны уйларга вакыт.* Ш. Камал.

АЕҠЛАНУ *диал. к.* айну (1, 4 мәгъ.).

АЕҠЛЫҠ *и.* **1.** Аек булу, исерткеч эчемлек эчмәгән булу, исерек булмау. *Бу кеше --- бердәнбер аек кеше шикелле күренә вә үзенең шул аеклыгы белән минем исереклегемне оялта иде.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Төпле фикерле булу, төпле фикерлелек, уйлап эш йөртүчәнлек.

АЕЛ *и.* **1.** Ыңгырчакның һәм иярнең ат корсагы астыннан алып бәйли торган бавы, каешы, тасмасы. *Аелны каты тартып бәйләгәндә, ала айгыр бөтенләй шашты.* Г. Ибраһимов. *Бригадир каеш тезгенне кулына алды, аелларның ничек каптырылуын, иярнең ат сыртында ничек ятып торуын үз кулы белән тотып капшап карады.* Н. Фәттах.

2. Прәшкә. *Туфлиемнең каешын эләктерә торган аелы бозылган.* Г. Галиев.

АЕМ *с. иск.* Матур, сөйкемле. *Аем кыздан ай бизәр, яман кыздан яу бизәр.* Мәкаль.

АЕНДА *рәв.* Бер ай эчендә, бер ай вакыт арасында. *Ат аенда, ир елында танылыр.* Мәкаль.

АЕРА'ТА *рәв.* Барыннан да бигрәк, бик, бигрәк тә, аеруча. *Публицистика һәм журналистика өлкәсендә Г. Камалның хезмәтләре аерата зур.* М. Гали. *Катя* [*Газинурга*] *һәр мисалны иренмичә, аерата зур түземлелек белән аңлата һәм русча сөйләгәндә татарчаны онытып торырга куша иде.* Г. Әпсәләмов.

АЕРГЫСЫЗ *с.* Аера алмаслык, аерырлык түгел, бердәй, бер-берсенә бик нык охшаган. *Шуның белән ул* [*Сиражи*] *мораль яктан «Бәхетсез егет»тәге Камали жулик белән «Уйнаш»тагы Фәтхерахман маклердан аергысыз бер типка әйләнә дә кала.* М. Гали.

АЕРГЫЧ I : **орлык аергыч** *махс.* — ашлыкны төрле сортка аера торган машина.

АЕРГЫЧ II *и. лингв.* Җөмләдә исем белән белдерелгән кисәкне ачыклап, нинди? кайсы? ничә? ничәнче? кемнең? нәрсәнең? сорауларына җавап булган иярчен кисәк.

АЕРМА *и.* **1.** Башкалык, үзгәлек. *Шәһәр һәм авыл арасында социаль-экономик һәм культура-көнкүреш аермаларын бетерү — коммунизм төзелешенең иң бөек нәтиҗәләреннән берсе булачак.* КПСС Программасы. *Ул бик яшьтән үк мохитның шул ике катлавы арасындагы аерманы күрә килде.* Г. Ибраһимов. // Нәрсәне дә булса бүтәннәргә охшатмый, алардан аера, башкачарак итеп күрсәтә торган сыйфат. *Аныңча бит атлар барысы да агачтан ясалган булалар, тик аерма аларның* [*чын атларның*] *зур булуларында гына.* Г. Гобәй. // (Үлчәүдә, санда һ. б. ш.) туры килмәү, аерымлык. *Ләкин монысы да нәкъ Сәйфидәгечә язылган, бер генә килога да аерма юк иде.* Г. Бәширов.

2. Нәрсәнең дә булса тармакланып, аерылып киткән урыны (мәсәлән, юлның). *Аңа каршы берничә кеше, көлешеп:— Әнә, наратлык аермасына җитеп киләләр инде!—диештеләр.* М. Гали. [*Атны*] *башта бик каулама, аерманың бу ягына чыккач, кызганма, ныкс ук.* Г. Ибраһимов. [*Айдар:*] *Тагын шул: тегә аермадан узып бер ике генә сикердем, Госманның артына килеп бастым.* Ф. Хөсни. // Чәч юлы, чәчне ике якка тарап куйганда ясала торган юл.

3. *мат.* Ике сан, сумма, зурлык арасында берсен икенчесеннән алу гамәле башкарганда барлыкка килә торган сан, сумма, зурлык. *Ике сан аермасы.*

АЕРМАЛЫ *с.* **1.** Аермасы булган, башка, үзгә, аерылып торган. *Бу тактика гадәттә тотыла торган тактикадан шактый аермалы булырга мөмкиндер.* Ф. Әмирхан.

2. Тармакланган, аерылып киткән (юл турында). [*Паларусов*] *аермалы юлга килеп чыгып, кайсы белән китәргә икеләнгән кеше кебек хәлдә калды.* Г. Ибраһимов.

АЕРМАЛЫҠ *и.* Башкалык, үзгәлек. *Милли аермалык.*□[*Шахтерлар*] *безгә милләт, тел аермалыгына карамый, сыйнфый күзлектән карап, интернациональ әдәбият тудырырга заказ бирделәр.* Һ. Такташ.

А'ЕРМАЧЫҠ *рәв.* Бик ачык. *Фашистлар якынлашалар, төнге зәңгәрсу караңгылыкта аларның карачкыл шәүләләре аермачык күренә иде.* А. Шамов. *Алар никадәр шыпырт сөйләшергә тырышсалар да, Габдулланың урыны Иргалинеке белән янәшә булганга, чаршау аша һәммәсе аермачык ишетелеп торды.* Ә. Фәйзи.

АЕРТУ *ф. Йөкл. юн. к.* аеру (5, 11 мәгъ.). *Уткән ел Нурый кызын да шул гына аертты.* М. Гафури.

Аерткан сөт — сепарат сөте, сыек сөт.— *Мин үземнең пешергәндә камырга аерткан сөт салып басам.* С. Рафиков.

АЕРУ *ф.* **1.** Бөтенне яки тоташ нәрсәне ике яки берничә кисәккә, өлешкә бүлү, яру, ике яки берничә итү. *Бозлар чатнап-чатнап ярылдылар, баракны урталайга аердылар.* А. Алиш.

2. Ике яки берничә нәрсә арасында чик булдыру, чик ясау; әйберләрне бүлү, бүлеп тору. *Яшел болынлыкны аерып, борыла-борыла сузылып киткән яп-якты киң су янындагы тигезлеккә утырган гади авыл.* М. Гали. // Төркем булып бергә торган әйберләр яки кешеләрнең арасыннан юл яру, як-якка тайпылдырып, ачык ара ясау. *Ул, төнбоекларны як-якка аерып, күлдән куш учлап су эчте һәм имән төбенә, аның алтынланып килгән яфракларына карап сузылып ятты да җырлады.* Г. Гобәй. *Гали мөдәррис сүзен аңлый алмыйча, шәкертләрне ике төркемгә аерып, аның каршына Җиһангир килеп басты.* Г. Ибраһимов. // Чәч аермасы, чәч юлы ясау. *Хуш исле чүмеч гөлләр арасыннан чәчен уртадан аерып, ике толым итеп үргән яшь кыз күренде.* Г. Әпсәләмов.

3. Бергә, янәшә булган ике яки берничә кешене (яки нәрсәне) бер-береннән ераклаштыру. [*Газинур:*] *Безне бер-беребездән аермагыз, безгә элекке урыныбызда эш табып бирегез.* Г. Әпсәләмов. *Адәмне генә түгел, кошларны да Еллар үз иленнән аера.* Һ. Такташ.

4. Бер бөтеннең аерым кисәген яки төркемнән кайберләрен генә алу, бүлеп алу, чыгару.— *Ул миңа водокачканың насосын гына аерып бирмәкче була.* Ш. Камал. *Аклар бераздан егермеләп сыерны көтүдән аерырга маташа башладылар.* Һ. Такташ.

5. Нәрсәне дә булса сортларга һәм төрләргә бүлү, категорияләрен билгеләү. *Сабира һәм берничә кыз, алмаларны сортларга аерып, ящикларга тутыралар.*

М. Җәлил. // Орлык, җимеш һ. б. ш. нәрсәләрне чистарту, нәрсәдән дә булса арындыру (мәсәлән, чүпләрдән). *Бераз гына арырак зур җилгәргеч машина, «быз... гыз...» килеп, орлыкны кибәктән аера тора.* Г. Ибраһимов. *Маһи әби, каравылчыны каргый-каргый, күлмәк итәгенә җиләген салып, чүпләрен аерды.* М. Гали.

6. Аерма барлыкка китерү, төрле-төрле итү. *Безне аерган нәрсә — телләр аерымлыгы, ләкин бу аерымлык безгә бөек пролетариат культурасын тудыруга комачауламый.* Һ. Такташ. // Башкалардан үзгә итеп күрсәтү, үз төрдәшләре, ишләре белән бутау мөмкинлеген юкка чыгару. *Чем-кара йон өстеннән аркасында ялдан алып койрыккача бераз гына дулкынланып сузылган буй эз, шундый ук ак авыз белән ак аяклар бу юрганы мең баш мал арасыннан бер күрүдә танырлык итеп аерып торалар.* Г. Ибраһимов. *Аны биек каракүл папахасы да башка командирлардан аерып тора.* Г. Бәширов.

7. Кешеләр яки әйберләр арасындагы аерманы белү, күрү, бутамау. *Баланың рухын бик ачык аңлау өчен, һаман аның хәрәкәтләрен күзләп, аның яхшы вә яман холыкларының һәммәсен дә аерып белергә тырышырга кирәк.* Г. Тукай. *Монда тамашачы белән уйнаучыны аеру кыен иде.* Г. Ибраһимов. // Тану, күреп тану, башкалар белән бутамау. *Ул хәзер җәнлекләрне эзләренә карап та аера белә иде.* Г. Гобәй. *Тыныч бул, иптәш начальник, Фәйзерахман бабаңның күзләре әле дус белән дошманны гына аерырлык.* А. Әхмәт.

8. Ачык күрү, ишетү, сизү турында. *Егетләр бик тиз ераклаштылар да, ни җырлаганнарын аерып булмый башлады.* Г. Ибраһимов. *Караңгылык иңә. Шуа торган Кабак тавында казылмаларны да, калкулыкларны да аера алмый башлыйсың.* Г. Бәширов. // Тану, укый алу.

9. Кешеләр яки әйберләр арасында берсен артык күрү, өстен күрү. *Авыл халкы --- аны башка кызлардан, башка Мәрьямнәрдән аерып, «Мәрьям туташ» дип йөртә.* Г. Ибраһимов.

10. Кыерсыту, җәберсетү, ким күрү, чит итү; кагу. [*Әби*] *табын янында* [*Маратны*] *гел аерды, җитмәсә, тегене тегеләй итмә, моны болай итмә, дип кычкырып торды.* Г. Гобәй.

11. Ир турында: хатын белән никахны (2 мәгъ.) бозу. *Кызларга күз төшкән саен хатын аера барсаң, аның очы да, кырые да булмас!* Ш. Камал. // Кемнең дә булса никахын (2 мәгъ.) рәсми рәвештә бозу (судта, загста).

12. Үрчү, арту, ишәю сәбәпле, ил, аерым оя итеп чыгару (кортлар турында). *Умарта кортлары бала аера башлады.* М. Гафури. *Умарта башына ак таш я сөяк куйсаң, бердән, умартага күз тими, икенчедән, корт аерса — ераккa сармый, диләр.* М. Гали.

13. Сугыша яки талаша торган кешеләрнең арасына керү, аралау. *Ул арада зурлар катнашып, безне аердылар, кем кыйнады моны, дип тикшерә башладылар.* Г. Ибраһимов.

14. Нинди дә булса авыр хәлдән коткару, кемнең дә булса йогынтысыннан саклап калу. *Бер дә шиксез, сиңа акылың әйтер: Большевиклар юлы хәерле, дип, Җаның телләр шунда: «И ходаем! Дутовлардан мәңге аер!»— дип.* Ш. Бабич.

15. Җәю, бер-беренән ерагайту (мәсәлән, куллар, аяклар, колач турында). [*Хатын*] *колачын аера төшеп, тагын да кулларын бергә китереп кушты да артка чигенде.* М. Гафури. *Бия, бер-ике тарткач та, рәхәтләнеп, аякларын ике якка аерды, имчәкләрдән сөт агып китте.* Г. Ибраһимов.

16. Кешене эшеннән яки уеннан бүлдерү, өздерү, игътибарын башкага юнәлтү. *Сөләйман абый, мин сезне шулкадәр яхшы сөйләшеп утырган җирегездән аердым бугай.* Ф. Әмирхан. *Сезнең трубаларыгыз күмелмәгән дип, мин колхозчыларны үз эшләреннән аера алмыйм.* А. Әхмәт.

17. Нәрсәне дә булса тартып, кисеп өзү. [*Хан:*] *Ахмак! Шундый матур кызны Ычкындырдың кулыңнан! (Кылычын суырып алып:) Узем синең башыңны Аерам хәзер муеныңнан!* М. Җәлил. // Өзгәләү, тураклау, теткәләү. // Ерту, ертып чыгару. *Киемне аеру.*

18. Нәрсәдән дә булса мәхрүм итү.— *Илаһи, туры юлдан аерма!* Ф. Әмирхан.— *Ходай пәрәмәчтән аермасын, диген!* Ш. Камал.

19.. *рәв. мәгъ.* **аерып.** Башкалар рәтендә, сүз уңаенда гына түгел, махсус. *«Базарга чыктым» шигыре --- «Эшче» поэмасына килеп тоташа. Шунлыктан без аңа да аерып тукталып китик.* Г. Нигъмәти. // Турыдан-туры, ачык итеп (читләтеп түгел). *Килмәс булсаң, аерып яз, елар димә...* З. Мансур.

◇ **Аерып алганда** *кер. сүз*—бигрәк тә, аеруча. *Беренче Татар опера театрының төзелүе — татар совет культурасының һәм, аерып алганда, татар совет музыкасының яңа баскычка күтәрелүен күрсәткән факт.* М. Җәлил. **Аерып чыгару**—1) *мат.* нинди дә булса санның тамырын табу турында; 2) өлешенә тигән әйберләре белән башка торак йортка чыгару; башка чыгару. *— Рәүфәне полный йорт-жир белән аерып чыгарырга ясаганнар бит!* А. Шамов. **Аерып әйтү**—1) аеруча басым ясап әйтү, ассызыклап китү. *Бу хәбәрне аерып әйтми түзә алмыйм мин.* М. Җәлил; 2) аныклы, кискен итеп, ныклышанып әйтү. *Кайсы акылга бик камил — Аерып әйтә алмыйм, ди.* Ә. Исхак.

АЕРУ'ЧА 1. *рәв.* Бик, бигрәк, бигрәк тә. *Бу китапта язылган мәсьәлә Гыймадиның күңелен аеруча кытыклаган мәсьәлә булып чыкты.* Ә. Фәйзи. *Илдар, әллә инде сөйләгәнен онытып, әллә аеруча яратып, бу җирен катkат сөйли.* Г. Гобәй. // Аерым рәвештә, башкалардан аерып, махсус. *Сугышчылар аның үзен тотуын, сөйләшүләрен аеруча кызыксынып күзәтәләр иде.* Г. Бәширов.

2. *кер. сүз. функ.* Басым ясарга кирәк булганда, күбесенчә өстәмә сүз янында кулланыла. Кулаклар, икмәк яшереп һәм икмәк белән спекуляция ясап, илдә, аеруча үзәктә, икмәксезлек кыенлыгын көчәйтәләр. М. Җәлил. *Тукайның --- кайбер шигырьләрендә, аеруча прозасында, Гейнега ияру --- күренгәли.* Г. Нигъмәти.

АЕРЧА *и.* Аерылып торган өлеш, япь. *Чәчәк аерчасы. Көйрык аерчасы.*

АЕРЧАЛЫ *с.* Аерылып торган, аеры, япьле. *Аерчалы яфрак. Аерчалы йөзгеч.*

АЕРЫ *с.* **1.** Аерылып торган, бүленеп торган, аерым-аерым торган. *Аеры яфракчыклы чәчәк. Аеры тояклылар. // рәв. мәгъ.* Аерым-аерым. *Ана сөтен аеры имә Бала, игез булмаса.* Дәрдмәнд.

2. Чатлы, япьле. *Учакта — аеры башлы ике казык башындагы аркылы агачка асып куелган зур гына казанның астында — коры чыбык-чабык яна.* Ш. Камал.

Аеры (ысул белән) уру — ашлыкны балавыз сыман өлгереш чорында ук лафет белән урып, кипкәннән соң гына сугу. *Аеры ысул белән уру — инде ныкмамыр җәйгән ысул.* С. Рафиков.

АЕРЫ-АЕРЫ *рәв. к.* аерым-аерым. *Һәр ел ахырында гомуми бер хисап кылып, эшләр ни дәрәҗәдә бара, алар һәммәсен аеры-аеры язып күрсәтәләр.* Ш. Мөхәммәдев.

АЕРЫЛГЫСЫЗ *рәв.* Аерылмаслык рәвештә. *Ил язмышы аның шәхси язмышы белән аерылгысыз бәйләнде.* Г. Әпсәләмов.

АЕРЫЛМАС *с.* Аерылгысыз, нык, якын. *Аерылмас дуслыкны күреп, Дошманнар көнли бирсен.* С. Хәким.

АЕРЫЛМАСЛЫК *с. к.* аерылмас. *Аерылмаслык туганы без Данлыклы рус халкының.* Ә. Ерикәй. // *рәв. мәгъ.* Якын итеп, аерылмаслык рәвештә. [*Алга куйган*] *бурычларны үтәү татар язучылары белән чуваш язучыларын аерылмаслык берләштерә.* Һ. Такташ.

АЕРЫЛМЫШ *и. лингв.* Аергыч белән ачыкланып килә торган сүз.

АЕРЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к. аеру* (1, 3, 11—14 мәгъ.). *Авыр булды миңа аерылу, Рәхәт булыр кайткач күрешү.* М. Җәлил. *Нургали аның эштән озак аерылып торырга яратмаганын белә иде.* Ә. Еники. *Икенче якта агач төбендә, күкрәккә кадәр ярты кулбашы аерылып, кан эчендә ята торган гәүдәне Җамали шунда ук танып алды.* М. Гали.

2. Аерма булу, башкаларда булмаган нинди дә булса бер сыйфатка ия булу. [*Зарифулла*] *аеруча яшь хуҗа Хисами каршында колларча бирелгәнлеге белән дә аерыла иде.* Г. Минский. *Ләкин* [*бу иске вагоннар*] *Мәскәү-Рига вагоннарыннан үзләренең эшәкерәк булулары белән аерылалар.* Г. Гали. // *рәв. мәгъ.* **аерылып.** Аермачык булып. [*Камалиның*] *кемнәрнедер тиргәп, инәлеп әйткән сүзләре шау-шулы ярминкәдә ай-вай салып каравыл кычкырган төрле* [*тавышлар арасында*] *аерылып яңгырадылар.* Қ. Нәҗми. *Ят кызлар арасыннан аерылып Артыкбикә күренде.* М. Әмир.

3. Аерым кисәкләр, өлешләр барлыкка килү, бүленү. *Бүлмә, җыйнак кына җыелып, ширма белән икегә аерылган.* Һ. Такташ. //Бүленеп, төрле юнәлештә дәвам итү, төрле якка китү. *Саша белән безнең юлларыбыз Аерылалар тәмам бүгеннән.* Г. Хуҗиев.

4. Ир белән хатын турында: никахны (2 мәгъ.) бозып, семья мөнәсәбәтләрен өзү.—*Юк белән йөрмә, бар кайт, ирең ярата торып, аерылырга йөрү яхшы эш түгел.* Г. Қамал.

5. *к.* аерылып чыгу. [*Кунакларны*] *Нуриның күптән аерылган зур улы Төхфәт белән аның хатыны Мәрфуга каршылады.* Г. Ибраһимов. // Қоллективтан, төркемнән, элек бергә булган иптәшләрдән аерылып китү, читләшү. *Ә мин очам ниндидер кош канатында, Дусларымнан ник аерылдым, нәрсә эзлим?* З. Мансур. *Аерылганны дә ашар, бүленгәнне бүре ашар.* Мәкаль. // Үзбашына, мөстәкыйль яши, көн күрә башлау. *Чебешләр инде тавыктай зур булдылар, әниләреннән аерылдылар.* А. Алиш. // Бөтен әйбернең бер өлеше ярылып яки кителәп төшү. [*Хәлим*] *алмагачларның төбен таптады, кар авырлыгыннан аерылып төшкән ике ботакны күтәреп, бәйләп куйды.* И. Гази.

6. Мәхрүм калу. *Бик күп байлар, --- моның корган тозагына элгеп, малыннан, җир-суыннан аерылып, --- аңарга малай, хезмәтче, дворник булып калганнар иде.* Ш. Мөхәммәдев.

7. *рәв. мәгъ. юкл. форм.* **аерылмый(ча).** Нинди дә булса эш белән берәрттән, бергә. *Ул әтиләр белән бергә заводта эшли, производстводан аерылмыйча очучылар мәктәбендә укый.* Т. Гыйззәт.

◇ **Аерылып тору** — башкалардан үзгә буларак күзгә ташлану, ниндидер сыйфаты белән калкулану. [*Сибгать абзый*] *хәрәкәтчән күзләреннән башка бернәрсәсе белән дә аерылып тормый торган, илле-илле биш яшьләр чамасындагы бер карт иде.* А. Шамов. **Аерылып чыгу** — 1) бүленеп чыгу, ата нигезеннән китеп, мөстәкыйль көн итә башлау; *к.* башка чыгу. *Ул аңа дәү абыйсының әтисе белән килешә алмыйча төп йорттан аерылып чыгуын --- сөйләде.* Г. Бәширов; 2) зур төркемнән бүленеп китеп, мөстәкыйль бер төркем, группа булып яши башлау. *Бу авылның кешеләре, җир җитмәгәнгә күрә, Акбуа исемле бер зур авылдан аерылып чыгалар.* Г. Гобәй.

АЕРЫЛЫ *с.* Аерысы булган, чатлы, япьле. *Ике аерылы имән агачы.*

АЕРЫЛЫШ *и.* Юл аерылып киткән урын, юл чаты. — *Бурсык ермагындагы юл аерылышында көтеп торсак уңайрак булмасмы?* И. Гази.

АЕРЫЛЫШУ *ф.* 1. Бер-береннән аерылу, китү, ераклашу. *Караборын да, Әйдүк белән бик озакка аерылышасын сизгән кебек, җиргә ятып ауный башлады.* Һ. Такташ. // Мөнәсәбәтләрне өзү. — *Атаң-анаң белән бер-береңне аңлаша алмаганлыктан аерылыш икән дә, шул рәхәт булсын имеш!* Ф. Әмирхан. // Төрле якка китү, таралышу (ике яки берничә кеше турында). *Алар, иртәгә партия комитетына бару вакытын билгеләп, аерылыштылар.* Ш. Қамал. // *рәв. мәгъ.* **аерылышып.** Аерым-аерым, бер-береннән читтә. *Рокыя белән Сәлимә бер-берсеннән аерылышыбрак утыралар.* Ф. Әмирхан.

2. Ир белән хатын турында: никахны (2 мәгъ.) бозып, семья мөнәсәбәтләрен өзү, бер гаилә булудан туктау.

АЕРЫМ *рәв.* 1. Аеры-чөере, һәркайсы үзе генә. *Монда шулай туры килде, эшкә ирләр үзалларына, хатыннар үзалларына аерым йөриләр.* Ш. Қамал. // *с. мәгъ.* Башкалар белән бергә булмаган, уртак булмаган, берүзенә бер. *Һәрберсен аерым бүлмәгә ябыгыз!* Қ. Нәҗми. *Ике-өч көнгә бер эш эшләвеңә аерым өйләр биләп тормасаң да ярар.* М. Фәйзи.

2. Ялгыз. *Аерым үткән еллар хатирәсен Бергәләшеп искә алырга.* Ш. Маннур. /*с. мәгъ. Аерым кешеләр дә, төркем-төркем булып та әле бер, әле икенче якка акырып-бакырып үтә тордылар.* Г. Ибраһимов.

3. Башкалардан аерып, үзен (үзләрен) генә. *Моннан соң сөтле сыерлардан туган бозауларны аерым тәрбияләргә күчәбез.* Ә. Еники. *Син* [*бу бодайны*] *аерым сугарга тиеш, син аны бөртегенә хәтле үлчәп алырга тиеш.* Г. Бәширов.

4. Махсус, махсус рәвештә. *Бу урында* [*Г. Камалның*] *кайбер сәхнә әсәрләренә аерым тукталып китәргә кирәк булачак.* М. Гали. // Үзен генә аерып алып, икәүдән-икәү, күзгә-күз. — *Синең белән аерым сөйләшәсе бар.* Ш. Қамал. *Директор үз кабинетына чакырып, ишек биклап, аерым алып үгетләде.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Бары тик шуның өчен генә билгеләнгән, махсус. [*Әсәрдәге образларның*] *кайберләре аерым мәкалә язуны сораган типлар галереясы бирәләр.* М. Җәлил. // *с. мәгъ.* Башкалардан үзгә, үзенә башка. *Менә «Көзгыннар оясында» торучыларның аерымрак урын тоткаларны шушылар инде.* Ш. Қамал.

5. Гаять, бик, искиткеч, бигрәк тә, аеруча. *Шунлыктан аңар бу бүлмәсендә әүвәлге чәе аерым тәмле, аерым яхшы тоелды.* Ф. Әмирхан. *Бу хезмәтләр татар совет музыкасының үсешендә аерым хәлиткеч роль уйнадылар.* М. Җәлил.

6. Бер-берсеннән ерак. *Урак белән Чүкеч бу вакытта Аерым булсалар да, бер иде.* М. Гафури. *Аерым тору белән генә күңел сүреләмени?* Җыр.

7. *с. мәгъ.* Башка, үзгә, үзенә генә хас, үзенчәлекле. *Аның карашларында ниндидер аерым бер җылылык, ягымлылык бар кебек.* Г. Ибраһимов. *Гармоньчы, һәрвакыттагы кебек, бу юлы да операциягә китәр алдыннан аеруча бирелеп, аерым бер моң белән уйный иде.* А. Әхмәт.

8. *с. мәгъ.* Қайбер, кайсыбер. *Хәтта аның аерым әсәрләренә карата булган вак рецензияләр дә матбугатта сирәк очрый.* М. Гали. *Сәхип, аерым көйләрне артык озынга сузмыйча, бер-бер артлы өч-дүрт көй уйнады.* Ш. Қамал.

9. *с. мәгъ. хәрби.* Тактик берәмлек буларак мөстәкыйль, башка хәрби частьларга керми торган. *Чит илләрдән килгән ирекләләр, Аерым частьлар булып берләшеп, Халык белән бергә йөри алар, Фашистларга каршы көрәшеп.* Ә. Исхак.

◇ **Аерым оя кору** — үз йортын, үз хуҗалыгын булдыру. *Шул арада инде Гайшә үзенә аерым оя кору чарасына төште.* Г. Ибраһимов. **Аерым хуҗалык** — ялгыз, колхозга кермәгән, колхозлашмаган. *Анысы дөрес, Рәхим абзый, аерым хуҗалыктан файда юк.* Һ. Такташ.

АЕРЫМ-АЕРЫМ *рәв.* 1. Һәрберсен аерып, берәрләп (берьюлы түгел).— *Ярар,— диде Мостафа,— ул чагында һәр кандидатны аерым-аерым тавышка куям.* Ш. Қамал. *Бу язучыларның конкрет урыннарын билгеләү өчен*

аларның һәркайсын аерым-аерым тикшерергә кирәк. М. Җәлил.

2. Бер төркем, оя һ. б. ш. эчендә, составында булмыйча, ялгыз. *Аерым-аерым барган йөкләр очраштыргалый.* А. Шамов.

3. Берәмләп, аерып алып. [*Балалар*] *һәркайсының җыйган башагын аерым-аерым үлчәп, аерым өемнәргә өя бардылар.* Г. Гобәй.

АЕРЫМЛАНУ *ф.* Кайбер үзенчәлекләре белән башкалардан аерылып тору, башка, үзгә булу.

Аерымланган кисәк *лингв.*— җөмләдә үзе караган кисәктән ераклашып, логик басым һәм интонациясе белән аерылып торган иярчен кисәк. *Аерымланган аергыч. Аерымланган хәл.*

АЕРЫМЛЫК *и.* **1.** Аерым булу, бергә булмау. *Колхоз да өч: димәк, берсе — «Чаткы», Берсе — «Очкын», берсе — «Нур» иде. Вакыт җитте, без бу аерымлыкны «Безгә киртә» диеп атадык.* Ш. Мөдәррис.

2. *к.* аерма (1 мәгъ.). *Димәк, «стиль» дигәннән тар мәгънәдә кулланылган һәм әдәби әсәрнең тел төзелеше аерымлыкларын гына аңлаткан күренеш алынмый.* Г. Нигъмәти. — *Безнең арада сыйнфый аерымлык билгесе бик зәгыйфь.* Қ. Нәҗми. // Әйбернең яки затның үзенә генә хас сыйфаты, үзлеге, үзенчәлеге. *Һәрбер язучының теге я бу идеяне формалаштыруда --- субъектив аерымлыклары шиксез зур бер роль уйный.* Һ. Такташ.

АЕРЫ-ҮӨЕРЕ *рәв.* Аерым, аерылып, төрлесе төрле җирдә. *Сәйдә җиңгинең улын үз янынан беркая да җибәрәсе, аеры-үөере торасы килмәде.* С. Рафиков.

АЖГЫР *с.* Усал, явыз, мәрхәмәтсез. Элекке яшь *ажгыр надзирательләр --- каядыр юкка чыгып, алар урынына --- карт солдатлар пәйда булды.* Ш. Маннур.

АЖГЫРТЫП: ажгыртып эшләү *сөйл.* — гайрәт белән, ярсып, ут чәчеп эшләү; бик тиз эшләү.

АЖГЫРУ *ф.* **1.** *к.* ыжгыру (җил турында). *Көнетөне кар ява, җил ажгыра, туктаусыз буран уйный.* Г. Ибраһимов.

2. Усалланып, зәһәрен чәчеп ж-ж-ж иткән тавыш чыгару, ыжылдау, ыжгыру (елан турында). *Ырылдый аңа. Ажгыра елан. Зәһәрен чәчә Чытырлы урман.* З. Мансур.

3. *рәв. мәгъ.* **ажгырып.** Ярсып, атлыгып, ашкынып, көчен кая куярга белмичә.— *Янып, ажгырып тора егетең.* Р. Ишморат.— *Ул, мин сиңа әйтим, ажгырып торган чабышкыларда кайсысы төлке туннан, кайсысы чапанчалмадан әллә кемнәр килеп туктый да, ниндидер кәгазь күрсәтеп, әре генә кереп китәләр.* Қ. Нәҗми. // Ярсып, котырынып, гайрәт орып.— *Бөтен авыл җир дип ажгырып тора иче.* И. Гази. *Искәндәр, йодрыгын төйнәп, ажгырып өсләренә килә.* М. Фәйзи. // Дәһшәт чәчеп, ут бөркеп. *Ажгырып торган амбразурадан берничә адымда Газинур кинәт тукталып калды.* Г. Әпсәләмов. // Қөчле, шәп. *Җиз самовар барлык тишекләреннән бу бәреп, ажгырып кайнап утыра.* Ф. Хөсни.

АҖДАһА *и.* **1.** *миф.* Әкиятләрдә сөйләнә торган, берничә башлы, гаять зур һәм бик куркыныч елан. *Кызның җаны кыл өстендә генә, тагын бер суырса, шул аждаһаның авызына кереп китәчәк иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *күч.* Бик усал, зәһәр кешегә карата әйтелә. — *Аждаһа шикелле ул, алар үлән астыннан ут йөртә торган халык.* Г. Камал. // Дошман.— *Син әйткән аждаһаларга каршы да, Тәкъва Сәхәүләргә каршы да сугыш ачарга кирәк.* М. Әмир.

АҖУР *и.* Бик нәфис, челтәрләп эшләнгән юка тукыма. // Бик нәфис, үтә күренмәле бәйләм, чигеш.

АҖУРЛЫ *с.* Бик нәфис челтәрле һәм үтә күренмәле. [*Закир*] *пароходның өске кат палубасындагы хатыннарның ажурлы оекларына шаккатып торды.* Ф. Сәйфи-Қазанлы.

АЗ *рев.* **1.** Саны ким, микъдары зур түгел; *киресе:* күп. [*Сабир*] *аз сөйли, бер дә мактанмый, үз эшләре хакында хикәя кылырга бик аз ярата, ләкин күп уйлый, күп эшли.* Г. Ибраһимов.— Син [*язганнарың турында*] *аз гына уйлыйсыңмы?* Ш. Қамал. // *и. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса кечкенә өлеше, кечкенә нәрсә. — *Бик азга төшенгәнсең. Ә мин аларга гына түгел, кичә Имәли әйткән сүзләргә дә төшендем.* М. Әмир.

2. *хәб. функ.* Җитәрлек яки канәгатьләнерлек түгел, көткәнгә, уйлаганга караганда ким, түбән. *Турыдан-туры зур операларга керешү өчен композиторларның да әзерлекләре аз иде.* М. Җәлил.

3. Сирәк, әллә нидә бер. *Хәзер инде андый кирәмәтләр Бик аз очрый дала ягында.* Ш. Мөдәррис.

◇ **Аз гына да** — һич тә, бер дә, бөтенләй.— *Дөньяда шундый могҗиза булыр дип аз гына да башыма китерә алмый идем.* Г. Ибраһимов. **Аз дигәндә** — кимендә, ким дигәндә, минимум. *Аз дигәндә көнгә ике тапкыр --- атларны карап китте* [*Шәйхаттар бабай*]. Г. Гобәй.

АЗА: аза кубу *диал.*— шаяру, уйнау, азу.

АЗАГЫНА'ЧА *рәв.* Ахырынача, ахырына кадәр, бетькәнче. *Буржуазия --- монархияне яңадан кайтару планын азагынача җиткерергә маташты.* ҚПСС тарихы.

АЗ-АЗ *рәв.* Бик аз, азлап. *Юлда аз-аз җыелып тора торган сулар да күренгәли.* М. Гали *Ялвару кирәкмәс, кирәк наз гына, Ул да урыны белән аз-аз гына.* Дәрдмәнд.

АЗ-АЗДАН *рәв. сөйл.* Азлап кына.—*Тартынып торма гыз, җәмәгать, аз-аздан капкаларга ярый, зарар юк.* Ш. Қамал.

АЗ-АЗЛАП *рәв.* Аз гына күләмдә; әкренләп. [*Мич*] *аз-азлап кына булса да утынны бик күп ашый, ә җылыны җитәрлек бирми иде.* А. Шамов. // Бик аз итеп, анда-санда. [*Ай:*] *«Фәкать үз йөземә сөртим Шуның төсле матур миңне»,—Диде дә, ак нур өстенә Аз-азлап кара сөртте.* М. Гафури.

АЗАЙТУ *ф.* Аз калдыру, киметү.— *Бөтенләй башкача, нәкъ кырык тартмачы Шәрәфи абзый булып киенүем, чәч-мыекны да шулай ясатуым миңа куркынычны тагын да азайта.* Г. Ибраһимов. *Тазарту гаскәрне сан ягыннан азайтса да, дисциплина ныгыды, күтәрелде.* Ш. Усманов.

АЗАҚ *и.* **1.** Бер бөтеннең (предмет яки күренешнең) иң соңгы кисәге, ахыры; бетү, туктау алдыннан булганы, актыккы өлеше. *Егет гармонен бик нык тартып уйный, башкалар җырның азагын кабатлап куялар.* А. Әхмәт. *Габделбасыйр июль азагында үк инде авылдан китәр өчен юллар хәзерләргә тотынды.* Ф. Әмирхан. *Мин җыелышның азакларына булса да өлгерергә тырышырмын.* Ш. Қамал.

АЗАҚҚЫ *с.* Иң ахырда була торган, бетү алдындагы; актыккы, ахыргы, соңгы. [*Шагыйрь*] *үзенең кара көчләргә каршы килүен һәм үзенең өметләре берәмләп сүнүен күрсәтеп килә дә, азаккы ике юлда шуңача сөйләп килгәннәренә йомгак ясый.* Г. Нигъмәти. // Иң соңгы, бүтән кабатланмый торган. *Азаккы килүебез.*

АЗАҚТАН *рәв.* Соңыннан, ахырдан; башка эшләр үтәлеп беткәч яки билгеле бер вакыт үткәч. *Төн үтеп, күңелле Көн туган, азактан Берсе дә булмаган шикелле тоела.* М. Җәлил.

АЗАМАТ *и.* **1.** *иск.* Гаскәри хезмәткә иң беренче барырга тиешле таза, озын буйлы ир кеше. *Телемездә* [*ир*]*кәк балалар 10—20 яшь арасында бүз бала, 20—30 арасында азамат, 30—40 арасында ир уртасы, 40—50 арасында ир, 50—60 арасында ут агасы, 60 тан соң баба һәм бабай аталадыр.* Шура.

2. *күч.* Батыр, кыю, үткен кешегә, батыр сугышчыга карата әйтелә. *Балтик буйларында үлде, дисең, каторгада үлде Салават... Алдыйсың ла, тарих, бутыйсың син: Үләмени анда азамат.* Х. Туфан. *Җыенда азаматлар — ир-егетләр көч сынашкан.* И. Рәмиев.

АЗАН *и.* **1.** *дини.* Намазга чакыру өчен гадәттә манарадан кычкырып укыла торган дога. *Кичке азан.*

Мәзин, манарадан азан кычкырып, мөселманнарны йокыларыннан уята, коллыкка чакыра башлады. Ш. Камал. // *дини.* Сәфәргә озатканда, янгын чыкканда, балага исем кушканда яки зәхмәтле чир элэккәндә (аның җеннәрен качыру өчен) җомгада хөтбә алдыннан әйтелә торган дога. *Пароход кузгалып киткәч, Тимергали, конторның баш тарафынарак китеп, кычкырып азан әйтеп калды.* Ш. Мөхәммәдев.— *Малаеңның әллә зиандаш зәхмәте микән дип, мәдрәсәдән җиде шәкерт чакырып, җиде азан да кычкырттык.* М. Гали.

2. *күч. шигъ.* Аваз, тавыш. *Шартласын, шартласын Буржуйлар казаны; Яңгыра, яңгыра Дөньяга, ирек азаны.* Г. Камал.

АЗАНЧЫ *и.* 1. *дини.* Мәзин, азан әйтүче. *Тимай бай булсаң да, азанчы күмәр.* Г. Тукай.

2. *күч.* Хәбәрче. Ала карга — **азанчы,** кара карга — *казанчы.* Мәкаль.

АЗАП *и.* 1. Авыр мәшәкать, кыенлык, авырлык, михнәт. *Авыл хуҗалыгы артеле аның өчен тормышның бөтен җәфаларыннан, азапларыннан котылдырачак бердәнбер юл иде.* Г. Ибраһимов.— *Шахтада күргән азаплар оныгылды.* Ф. Хөсни.

2. Газап, рухи интегү, психик газап.— *Нишләтим соң, йөрәгемә кан булып укмашкан бит бу явыздан татыган азапларым.* К. Нәҗми.

◇ **Азап чигү** — күп авыр мәшәкатьләр күрү, михнәт чигү, азаплану, җәфалану. *Бу уен-көлке арасында түгел, әнә шул гавам арасында яшисе, аның белән бергә азап чигәсе, аның белән бергә үләсе килә.* Г. Колэхметов.

АЗАПЛАНУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса авырлык, кыенлык, зур мәшәкатьләр белән башкару, җәфа күрү. *Көтүче, әле кушылып, әле дулаган атын тыя алмыйча дала буенча чабып, күп азапланды.* Г. Ибраһимов. // Тырышу, тырмашу. *Егет урыныннан торырга азаплана, ләкин тора алмый иде.* А. Шамов.

2. Интегү, газаплану, рухи яки физик газап кичерү. *Менә мин үзем дә әллә кайчаннан бирле эч белән азапланам.* Ш. Камал. *Хәдичәне әйтәм, бик борчыла, бик тә азаплана.* Г. Бәширов.

3. Маташу.— *Уенга борырга азапланма, Гаяз, син аларны чынлап әйттең һәм дөрес әйттең, дөрес характеристика бирдең син миңа.* М. Әмир.— *Әхлаклы булган булып азапланасыңмыни инде?* Ф. Әмирхан.

АЗАПЛАУ *ф.* 1. Азап күрсәтү, җәфалау, михнәт чиктерү, интектерү. *Тик, бөеклек солтаны, син азаплама Кабилне!* Һ. Такташ.— *Алайса, нигә мине монда алты сәгать көттереп азапладыгыз?* Г. Ибраһимов.

2. Газаплау, газап чиктерү, рухи һәм физик газапка дучар итү, җәфалау. *Фашистлар* [*Зояны*] *шулай таң атканчы азаплаганнар, сораганнар: — Әйт, партизаннар кайда?— дигәннәр.* Г. Бәширов. // Борчу, аптыратып бетерү, тынычсызлап тору. *Гәрәй уйлый, мышный, борын тарта, Яна, борчыла. Чыга алмый күңелен азаплаган Уйның очына.* М. Җәлил.

АЗАПЛАУЧЫ *и.* Кемгә дә булса азап күрсәтүче, җәфалаучы, интектерүче.— *Хәзер инде минем яннан торып киткән теге студент та кансыз, адәм азаплаучыларга барып кушылды.* Ф. Әмирхан.

АЗАПЛЫ *с.* 1. Азап, җәфа, интегү белән башкарыла торган, нинди дә булса физик һәм рухи борчулар таләп ителә торган. *Тимербулат кулындагы исемлеккә билге куелган саен, аның янындагы кешеләр үз басуларына — шул хәтле көтелеп, шундый азаплы көрәшләр белән яулап алынган кырларга акрынлап тарала торганнардыр.* К. Нәҗми.

2. *к.* газаплы. [*Нәфисәнең*] *йөрәге кыз чагындагы кебек җилкенеп, рәхәтләнеп тә һәм азаплы да бер тилпенү белән ашыгып тибә башлый.* Г. Бәширов.

АЗАПЛЫК *и. к.* азап (1 мәгъ.). *Җәяү баручы солдатларга да билдән кар ярып, бик зур азаплык белән барырга туры килде.* М. Гали.

АЗАПСЫЗ *рәв.* Мәшәкатьсез, ансат, җиңел, кыенлыклар күрмичә. *Азапсыз килгән мал затсыз була.* Мәкаль.

АЗАР-БИЗӘР: азар-бизәр китерү *сөйл.* 1) аздырып бетерү. *Балаларны азар-бизәр китерү;* 2) мал-мөлкәтне туздыру; юкка тотып бетерү, пыран-заран китерү; 3) күңелне җилкендерү. *Чәчәк клумбалары эченә чумып утырган дәва йортлары күңелне азар-бизәр китерә башлый.* Г. Ахунов.

АЗАРТ *и. сөйл.* Бик нык мавыгучанлык, дәрт; комар.

Азарт белән — мавыгып, дәртләнеп. [*Фатих ага*] *преферанс уйнарга ярата иде, бер башлагач, азарт белән уйный.* Каз. утл. **Азартка бирелү** *сөйл.*— нәрсә белән дә булса артык мавыгып китү.— *Ләкин сез, иптәш подполковник, урынлы-урынсыз бик азартка да бирелеп китмәгез. Сезнең җилкәгездә бөтен полк.* Ф. Кәрим.

АЗАРТЛАНУ *ф. сөйл.* Азартка бирелү, комарлану.

АЗАРТЛЫ *с.* Бик мавыктыргыч, дәртле, комарлы. *Азартлы уен.*

АЗАРТЧЫ *и.* Азартлы, комарлы уеннарга бирелгән кеше, азартлы уеннар уйнаучы.— *Мин андый азартчыларны күрәсем дә килми, алардан нә дөньяга, нә ахирәткә!* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АЗАТ *с.* 1. Ирекле, хөр, бәйсез. *Алтын иркем, азат тормышым Кая очты, киек кош булып.* М. Җәлил. *Алар үзләрен баскан, бәхетсез ясаган иске кара тормыштан мәңгегә котылдылар да яңа, якты, азат, матур көннәргә килеп чыктылар.* Г. Ибраһимов. *Яңгырасын мәңге яшьлек җыры, Күкрәп торсын азат, шат хезмәт!* Ш. Маннур. *Шашам, ашкынам... Шатланам чиксез, Азат мин, азат! Бәхтем офыксыз!* Ш. Бабич. / *рәв. мәгъ. Татарларның батыр көрәш даны бар, Азат яшәү, азат хезмәт өчен Идел кебек түккән каны бар.* Ә. Ерикәй.

2. Нәрсәдән дә булса котылган, арынган. *Бар канун, диннән азат күңлем минем, ишетәсеңме?* Һ. Такташ.

3. *хәб. функ.* Нинди дә булса бер начар сыйфатның яки кире йогынтының булмавы, шундый сыйфат яки йогынтыга бирелмәгән булу турында. *Алар мещаннарга, обывательләргә хас булган тар эгоистлык, карунлык, мал өчен җан сатарга хәзер торучанлык сыйфатларыннан азатлар.* М. Җәлил.

Азат булу — 1) иреккә чыгу, тоткынлыктан яки коллыктан котылу. *Гавам коллыкка элэкмәс өчен, элэкәч азат булыр өчен көрәшә, кулына салынган богауларны өзеп ташларга тели.* Г. Колэхметов; 2) нинди дә булса эштән яки мәшәкатьтән котылу, бушау, арыну. *Гаять зур җаваплылыктан азат булу, икенче дәрәҗәдә торып, икенче чиратта җавап бирү* [*Мостафин өчен*] *уңайсызрак та булып күренде.* Ә. Еники. **Азат итү** — 1) иреккә чыгару, тоткынлыктан яки коллыктан коткару. *1917 ел революциясен* [*М. Гафури*] *эшчеләрне азат итү, капитализм системасын җимерү фикере белән каршылады.* М. Җәлил; 2) дошман басып алган җирне кире сугышып алу, дошманны ул җирдән куып чыгару. *Кырык өченче елны без Калинин фронтында немецлар кулыннан берничә шәһәрне азат иттек.* А. Шамов; 3) нинди дә булса эштән яки мәшәкатьтән коткару, **ягъни** мәҗбүр итмәү. *Фронтовик семьялары налогтан азат ителә.* Г. Гобәй; 4) кешене үз теләге белән яки сроглы тулып эштән бушату, хезмәт урыныннан чыгару. *Эшеннән азат ителүенә Гыйльманов ул хәтле җәберсенмәде.* Ш. Камал.

АЗАТЛЫК *и.* Ирек, иреклелек, хөрлек, бәйсезлек. *Әгәр мин үләм икән, илем өчен, аның азатлыгы өчен, аның киләчәге өчен үләм.* Г. Бәширов. *Алар кешеләрнең бәхете һәм азатлыгы өчен газиз гомерләрен кызганмадылар.* Г. Әпсәләмов. // *с. мәгъ.* Ирек өчен булган, хөрлек өчен булган, бәйсезлек өчен булган. *Азатлык сугышы.* □ *Бу революция вакытындагы милли азатлык хәрәкәтләренең идеяләре булачак шагыйрьне үзләренә*

тарталар. Г. Нигъмәти. // *с. мәгъ.* Ирек турындагы, хөрлек, бәйсезлек турындагы. *Җырлыйлар бердән азатлык җырлары.* М. Гафури.

АЗАУ: **азау тешләр** — 1) аслы-өсле, чәйни торган яссы өслекле тешләр, урт тешләр. *Анда барган, ямьсез кара бер көч, Шыкырдатып азау тешләрен, Ачу белән карап сөйли иде Аның моннан соңгы эшләрен.* М. Гафури.— *Азау тешләреңне суырып кара әле, кемнең икмәк тәме килә икән?* Қ. Тинчурин; 2) *диал.* акыл тешләре.

◇ **Азау (теш) яру** — 1) акыл теше чыгу, **балигъ** булу, зурлар рәтенә керү.— *Инде аларның Гөлҗамалларының азау теш ярганына да ун ел булды.* Г. Камал; 2) үткенләнү, усаллану. *Үткен күзле Сәрби, Закирның йомышка каршылыгын күреп, «мыштым, азау теше яра башлаган» дип уйлап, башыннан тәрбия чарасының планын да уздырды.* Ф. Сәйфи-Қазанлы. **Азау тешләрен җимерү (кою, суырып алу)** — бик нык кыйнау. *Тик бер бурыч [хәзер ил алдында]: бронь йодрык белән фашизмның азау тешләрен коеп бетерү...* М. Җәлил. *Шиңдердек без [дошман] кикриген, Азау тешен алдык суырып.* Ш. Маннур. [*Дошманның*] *азау тешләрен җимереп кайтыгыз!* Р. Ишморат.

АЗАУЛАНУ *ф. күч. сөйл.* Шомару, үткенләнү. *Төзелешләрдә эшләп теше азауланып беткән --- Туркин бүген берни дәшми.* А. Гыйләҗев. // Усаллану.

АЗАУЛЫ *с. күч. сөйл.* Сүзен үткәрүчән, үткен, усал (кеше).— *Газыйм азаулы егет ул,— дип сөйлиләр иде аның турында.* Х. Садрый.

АЗАЮ *ф.* Аз калу, кимү. *Вакыт бик азайды, безгә ашыгырга кирәк.* Г. Ибраһимов. *Шәһәр урамнары тынганнан-тына бардылар, кешеләр азайганнан-азайдылар, хәрәкәт кимегәннән-кимеде.* Г. Минский.

АЗБЕ'СТ *и. махс.* Утка һәм кислотага чыдам сүс сыман минерал, тау сүсе. // *с. мәгъ.* Азбестка бәйләнешле. *Азбест рудниклары. Азбест ятмалары.* // *с. мәгъ.* Азбесттан ясалган. *Азбест шнур.*

АЗГЫН *с.* **1.** Мораль тотнаксыз, әхлаксыз, бозык. [*Хаҗиның*] *азгын хыяллары мәсхәрәле хәлгә килү белән җимерелә[лә]р.* Г. Нигъмәти. *Азгын кеше, әшәке кеше булып чыкты ул [Сәйфи].* Г. Бәширов. // Җилкенчәк, дәртле; җилкенчәкләнеп торган, җилкенчәк булган. *Инде... Тәүбә иттем бу эшләрдән, Азгын күңел күпкә басылды.* Һ. Такташ. // *и. мәгъ.* Әхлаксыз кеше, мораль тотнаксыз кеше. [*Зыяга*] *андый азгыннар җыенына бару, әлбәттә, әлбәттә, килешми.* Г. Ибраһимов. *Ул азгыннарга нинди җәза бирик?* М. Җәлил.

2. Тәрбиясез, тыңлаусыз, шук (бала турында ачулану сүзе). *Ул алай азгын бала түгел.* Ф. Бурнаш. — *Кайда йөрисең, азгын малай?* М. Фәйзи. // *күч. шигъ.* Шаян. *Гасырларча азгын, коры җилләр Искән һаман җиргә орынып.* Ш. Мөдәррис.

3. *сөйл.* Тире авыруларына тиз бирелүчән тән турында. *Азгын тән.*

4. *сөйл.* Қөтүчесен, хуҗасын санламый торган (хайван турында). *Ул арада азгынрак сыерлар, елгага су эчәбез дип барып, сазга төшеп баталар.* М. Гали.

Азгын бөркет *зоол.*— кара кош, кара бөркет.

АЗГЫНЛАНУ *ф.* **1.** Азгынлыкка төшү, әхлаксызлану, юлдан язу, бозыклыкка бирелү.

2. Тәрбиясезләнү; тыңлаусызлану, шуклану. [*Картинада*] *болан, башын күтәреп, колакларын сагайтып, нәрсәдер тыңлый, ә баласы, азгынланып, анасына үрелә, имәргә тели.* А. Шамов.

3. *сөйл.* Аза торганга, ярасы төзәлми торганга әйләнү (тән турында).

АЗГЫНЛЫК *и.* **1.** Азгын булу, бозыклык, юлдан язган булу, әхлаксызлык.— *Менә болар [сезнең балаларыгыз] һәр иске — мөкатдәс, һәр яңа — азгынлык дип йөри торган сез чын мөселманнарның балалары, дияр идем.* Ф. Әмирхан.

2. Тәрбиясезлек, тыңлаусызлык, тыңлаусыз булу, шук булу, шуклык.

АЗДАН *рәв. сөйл.* Аз дигәндә, иң кимендә. *Аздан биш метр кирәк. Аздан бер ай үтәр.*

АЗДЫРУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* азу I (1—2 мәгъ.). Начар, бозык юлга, әхлаксызлыкка тарту, юлдан яздыру. [*Шөҗәг*] *аздырмаган булса, мин бу хәлгә төшмәгән булыр идем.* Г. Камал. *Нәфес, шайтан — бик явыз ул, һәр адәмне аздыра. Аздыра торгач, адәмнәрне юлыннан яздыра.* Ш. Бабич.

2. Тәрбиясезлеккә, шуклыкка юл кую, бозу.— *Эшләр шәп кенә, рәте белән бара. Мөгаллим балаларны аздырмый, мәхәллә һәм аны бик ярата.* Ш. Камал.

3. Җилкетү, иләсләндерү.—*Мондагы юк-барга алданып, күңелеңне аздырма.* Г. Қоләхметов. // *күч.* Қызыктырып котырту. *Маратның кулында эт күңелен аздыра торган әйбер бар.* Г. Гобәй.

4. Инфекция кертеп яки башка юл белән авыруны, яраны көчәйтү. *Мин авырып, гриппларп йөргән идем, шуны аздырдым булса кирәк.* А. Расих.

5. *сөйл.* Үстерү, җиткерү.—*Бабай сиңа, сакал аздырып җибәрерсең, дигән иде, тыңламадың бит.* Г. Гобәй.

АЗЕРБАЙҖАН *и.* Азербайҗан ССРда яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. // *с. мәгъ.* Шул халыкка бәйләнешле. *Азербайҗан теле. Азербайҗан авылы.*

АЗЕРБАЙҖАНЛЫ *и.* Азербайҗан ССРда туып үскән кеше. // Азербайҗан ССРда яшәүче.

АЗЕРБАЙҖА'НЧА *рәв.* **1.** Азербайҗан телендә. *Азербайҗанча сөйләшү.* // *с. мәгъ.* Азербайҗан телендәге. *Азербайҗанча журнал.*

АЗИАТ *и.* **1.** Азиядә яшәүче җирле халык. // Азиядә яшәүче хәзерге халык.

2. *иск. кимс.* Надан, иске карашлы кеше; миһербансыз, тупас кеше.

А'ЗИМУТ. *и.* **1.** *астр.* Меридиан яссылыгы белән берәр планета аша үтә торган вертикаль яссылыклар арасындагы почмак. *Ничек артта синнән [Җирдән] Сатурннар, Ничек ярлы синең каршыда; Ишетми дә алар, Күрмиләр дә Ниләр барын синең йөзеңдә; Азимутсыз һәм максатсыз хәлдә Гизәләр тик Галәм эчендә...* Х. Туфан.

2. *хәрби.* Бирелгән юнәлеш белән төньякка табә булган юнәлеш арасындагы почмак. // Җир өсте яссылыгы буенча карта һәм компас ярдәмендә билгеләнгән хәрәкәт юнәлеше. *Взводның иң яхшы азимутчылары Қасаткин һәм Лихеев алга чыктылар. Урманов аларга нинди азимут белән барырга кирәклеген әйтте.* Г. Әпсәләмов.

А'ЗИМУТЧЫ *и.* Азимут билгеләүче. *Һәр ротада азимутчылар булдырылды.* Ф. Булатов.

А'ЗИЯЛЕ *и. к.* азиат (1 мәгъ).

АЗҚАНЛЫЛЫК *и.* Қан массасы үзгәрү, кызыл кан тәнчекләренең һәм гемоглобинның кимүе белән характерлана торган авыру — анемия.

АЗЛАП, АЗЛАП-АЗЛАП *рәв.* **1.** Аз-аз гына итеп, бүлеп-бүлеп. *Карт кайдандыр кызыл аракы алып килеп, очучының авызына чәй кашыгы белән азлап-азлап кына сала башлады.* А. Шамов.

2. Акрынлап, тора-бара. *Тормыш җиле белән яшьлек азлап-азлап [Нәфисәнең] күз яшен дә киптерде.* Г. Бәширов.

АЗЛЫҚ *и.* Аз булу, җитәрлек булмау. *Җир азлык, шуның өстенә ачлык крестьяннарны шәһәрләргә, фабрика-завод районнарына батраклыкка, эшчелеккә куды.* Г. Нигъмәти.

АЗ-МАЗ *рәв.* Бераз, беркадәр. *Аз-маз һушына килә башлап, күзен ачканда, иң беренче күргәне — ап-ак сакаллы, зур гәүдәле бер бабай булды.* Г. Бәширов. *Узе аз-маз язу эше белән дә шөгыльләнә.* М. Гали.

АЗ-МАЗЛАП *рәв. к.* аз-азлап.— *Аллага шөкер дигән-*

дәй, аз-мазлап булса да [*файда*] *килә торсын. Кеше хакына тимибез, тырышып тапкан мал.* А. Әхмәт.

АЗМАН *и.* 1. *зоол.* Зур зәңгәрсу кара корт, төклетураның зурысы; божан.

2. *сөйл.* Азгын, буйсынмаучы, башбаштак.

3. *сөйл.* Ике төрле хайван кушылудан туган яңа токым хайван (мәсәлән, ат белән ишәк кушылудан).

АЗМЫ-КҮПМЕ *рәв.* Бераз, беркадәр, азрак. *Үз хакында әйтелгән яхшы сүздән һәркем азмы-күпме күңеллеләнә.* Г. Ибраһимов. *Шуның янына тагын әдәбиятка азмы-күпме катнашым барлыгын да белгәч, ул миңа үзендә саклана торган бер дәфтәрне бирергә булды.* Ф. Хөсни.

АЗНАУ *ф. диал.* Айгылдап, көчле тавыш белән кешнәү. *Азнаган айгырның өрен күр.* Мәкаль. *Азнаган айгырны өрдә сына.* Мәкаль.

АЗОЙ: азой эрасы — Җирнең геологик тарихында органик тормыш булмаган эра, иң борынгы эра.

АЗОТ *хим.* Һаваның зур өлешен тәшкил итә һәм үсемлекләр азыкланы өчен төп чыганак булып торган иссез, төссез газ. *Үсемлекләрнең нормаль үсүе өчен фосфор, азот, кальций кирәк.* Химия.

Азот кислотасы *хим.*— Һавада төтенли, кайвакыт, өлешчә таркалу сәбәпле, сары төскә керә, тәнне яндыра һәм агулый торган, исле, төссез сыеклык формасындагы бер составлы көчле кислота.

АЗОТЛЫ *с.* Азот катнашкан, составында азот булган. *Азотлы ашламалар.*

АЗСЫНУ *ф.* Аз күрү, канәгатьләнмәү.— *Безнең ахун бик комсыз, ач күз нәрсә, бер сумны азсыныр.* Г. Ибраһимов.

АЗУ I *ф.* 1. Азгынлыкка бирелү, бозыклыкка бирелү, әхлаксызлану. *Мин, имеш, азам, Мин, имеш, тузам; Гөнаһым тузан, Тау кебек җәзам...* Ш. Бабич.— *Сине бөтен полкта иң яхшы кеше дип йөргән идем, мин югында аза башлагансың түгелме соң?* Г. Бәширов.

2. Артык ирек алу, усалланы, узыну. *Соңгы көннәрдә байлар бик китте азып, Алтын-көмешне күмәләр җиргә казып.* Г. Камал. // Артыгын уйнау, шаяру, шуклану, тәртипсезләнү, азыну. [*Мулла:*] *Уткән елгы хәлфәмез дә яхшы кеше иде. --- Кыш буе ник кенә бер баланы чиертсен! Балалар, ягъни мәсәлән, тәмам азып беттеләр.* Ш. Камал. // Ярсып китү, җилкенү, тынычлыгын югалту (күңел турында).— *Аларның үкертеп йөргәннәрен күреп күңеле азгандыр* М. Фәйзи.

3. Начарлану, көчәеп китү (авыру, яра турында). [*Фәттах:*] *Ярчык утыра мичем күкрәктә, Габтелмән абзый, мина ярчыгы.* [*Габтелмән:*] *Докторларга барырга кирәк иде, энем, азып китүе бардыр бит.* Р. Ишморат.

4. Хайваннарда, нәсел үзгәреп, яңа токым, гибрид барлыкка килү. // *күч.* Берәр нәрсә нигезендә яңа әйбер, яңа төр туу, нәрсәне дә булса үзгәртеп эшләү. *Дөрес, «Яшь Ленинчы», «Кызыл яшьләр» газеталарында минем халык җырларыннан азган шигырьләрем әледәнәле чыккалый тора.* Ф. Хөсни.

АЗУ II *и. к.* азау. *Карт кешедә азу тормас.* Мәкаль.

◇ **Азу (теш) яру** — *к.* азау (теш) яру.— *Син әле һаман да шул элеккеге азу ярган мәгърифәтчеме?* Г. Бәширов.

АЗУ-ТУЗУ *ф.* Азып эштән чыгу, бозыклыкка бирелү. [*Фатих, халыкка карап:*] *Муллагыз да --- бер азган-тузган нәрсәдер шунда.* Г. Камал. [*Картның төпчек улы*] *яман юлга басып, азып-тузып киткән, атасының акчасын урлап качып, еллар буенча югалып йөргән, ди.* М. Әмир.

АЗЧЫЛЫК *и.* Нинди дә булса бер бөтеннең, берәр төрле группаның азрак, кимрәк өлеше. *Бердән, алар үзләренең азчылык булуларын сизделәр, икенчедән, Габдулланың теленнән курыктылар.* Ә. Фәйзи. *Указ, әлбәттә, азчылык булган прогулчыларга каршы юнәлтелә.* М. Җәлил.

Азчылык милләтләр — илнең төп халык массасына караганда аз санны тәшкил итә торган милләт. *Бу революция вакытында царизм тарафыннан изелгән азчылык милләтләр арасында да иреккә чыгу өчен көчле хәрәкәт башланды.* М. Гали.

АЗЫК *и.* 1. Ашарга, эчәргә ярый торган, ашамлык хәзерләүгә китә торган нәрсә. *Үлән азыгы. Ит азыгы. Юл азыгы.* □ *Боз өстеннән утыз километрга сузылган юл буйлап героик шәһәргә азык төялгән олаулар агылды.* Г. Гобәй. *Быел фермаларда малны ишәйтәбез, терлек азыгы бик күп кирәк булачак.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Азыкка мөнәсәбәтле. *Азык магазины. Азык үләннәр.* □ *Бүген азык складлары янындагы* [*халык төркемен*] *тараткан чагында запас полкның бер ротасы солдаткаларга каршы ут ачудан баш тартты.* К. Нәҗми. // Ашамлык, ашарга хәзерләнгән нәрсә. *Чәчү карт табындагы азыкка кулын сузмады.* А. Шамов.

2. Берәр эшчәнлек, эш өчен материал, берәр нәрсә өчен чыганак. *Бервакыт бардым Печән базарына, Анда мин таптым азык язарыма.* Г. Тукай. // *күч. кит.* Рухи азык, рух үсеше, үз культурасын үстерү өчен мөмкинлек, рухи канәгатьләнү турында.— *Бер тапкыр мәктәптә оештырылган «Әдәбият кичәсе»нә барды, Каюм көтепханәсеннән ике кечкенә брошюра алып укыды. Менә аның бөтен кыш буенча алган культура азыгы.* Ш. Камал.— *Китаплардан, шөбһәсез, җаныңа азык табарсың.* Г. Коләхметов.

Азык ногыты — ике өлешлеләр классына керә һәм терлек азыгы итеп файдаланыла торган үсемлек. **Азык отряды** — хәрби коммунизм чорында азык разверсткасын үтәү буенча эшләгән эшче һәм крестьяннарның кораллы отряды. *Азык отрядлары килеп, күмгән җирдән* [*Шәйхи бабайның*] *күп игенен табып* [*алды*]. М. Гали. **Азык разверсткасы** — хәрби коммунизм чорында (1918—1921 елларда) Совет дәүләте тарафыннан авыл хуҗалыгы азык-төлекләре хәзерләү системасы. **Азык салымы** — 1921 елда азык разверсткасы урынына кертелгән һәм азык-төлек әйберләреннән натуралата алына торган налог — продналог. **Азык чөгендере** — терлек азыгы өчен, терлеккә ашату өчен игелә торган чөгендер.— *Кем соң бездә азык чөгендере чәчүне башлап кертте?* Ә. Еники.

АЗЫКЛАНДЫРУ *ф. сир.* Азык белән тәэмин итү, азык бирү, тукландыру.— *Башка ирләр — атларны туарып, азыкландыру, хатын-кызлар өй әйберләрен рәтләп урнаштыру белән шөгыльләнәләр.* Ш. Камал.

АЗЫКЛАНУ *ф.* 1. Азык алу, тукланы.

2. *күч.* Белем алу, тәрбия алу, тәрбияләнү. *Рус әдәбияты, рус мәдәнияте эчендә азыкланганга, аңа* [*Пала-русовка*] *татар теленнән русныкы күп җиңел иде.* Г. Ибраһимов.

АЗЫКЛЫ *с.* Азык белән тәэмин ителгән, азыгы булган, азыгы житәрлек булган. *Азыклы ат армас.* Мәкаль.

АЗЫКЛЫК *и.* 1. Азык булу.— *Сөтнең азыклыгы корсын, ди иде бабай.* Сов. әд.

2. *с. мәгъ.* Азык өчен билгеләнгән, сугымга симертелә торган. *Азыклык хайваннары, күп булмаса да, бар. Печән һәм урак өсләрендә бер тана, ике-өч сарык суярга чамалап торалар.* Ш. Камал.

АЗЫК-ТӨЛЕК *җый. и.* Ашамлык әйберләре, ашауэчү продуктлары. *Сугыш припаслары, азык-төлек төягән йөк машиналары куып җитеп, узып китәләр.* Г. Әпсәләмов. *Ул самолет Ленинградка килеп төшеп, азык-төлек тиешле кулларга тапшырылды.* Г. Гобәй. // *с. мәгъ.* Азык-төлеккә мөнәсәбәтле.

АЗЫНДЫРУ *ф. к.* аздыру.

АЗЫНУ *ф.* 1. Азгынлану, азгынлыкка, бозыклыкка бирелү, юлдан язу.— [*Сафа кебек*] *кабахәт җаннарга шулай кирәк, ярлы кызларын мыскыл итмәсеннәр. Бик*

азынып киткәннәр иде. А. Шамов. *Дөньяда икенче төр «хыялчылар» да бар. Алар тук корсактан, акыл бушлыгыннан, эшсезлектән, эч пошудан азынып хыялланучылар.* Г. Нигъмәти.

2. *сөйл.* Артык шукланып, шаянланып, тәртипсезләнеп китү (балалар турында).

АЙ I *и.* 1. Җирнең иң якын табигый иярчене булган һәм кояш нурлары яктылыгын чагылдыра торган күк җисеме. *Караңгы дип килми калма, Ай булмаса, йолдыз бар.* М. Җәлил.

2. Астрономик елның уникедән бер өлеше (унике айның һәрберсе аерым исем белән йөртелә: январь, февраль, март, апрель, май, июнь, июль, август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь).— *Ни әйтерсең, Гәрәй, елны айларга телемләгәндә белеп эш иткәннәр бит, э?* А. Гыйләҗев. // Бер календарь ай чамасындагы вакыт арасы. *Казаннан кайтканына хәзер биш ай бардыр инде.* Г. Камал.

3. *дини.* Мәчет манарасының очына калайдан эшләп куйган урак сыман эмблема. *Мулла кызы — мәчет ае.* Әйтем. *Җил манараның аена утырып сызгыра.* Һ. Такташ. // Кайбер илләрнең (мәс., Төркиянең) флагына төшерелгән ай рәсеме. // Кызыл Хач һәм Ярым Кызыл Ай җәмгыятенең эмблема детале.

Ай арасы — иске ай югалып, яңа ай туганчы булган айсыз вакыт; иске айның ахыры, яңа айның башы. **Ай елы** — айның хәрәкәте белән исәпләнә торган ел (мәс., Әфганстанда, Иранда). *Ай елы кояш елына караганда 11 көн чамасы ким.*

◇ **Ай (айдай) йөзле** — матур, ягымлы, ачык чырайлы кеше турында.— *Йолдыз күзле, ай йөзле, Зифа буйлы бер кыз бар.* М. Җәлил. *Әллә уйлый күл буенда суырып упкән Айдай йөзле, ялкын күзле сөйгән ярын.* Н. Исәнбәт. **Ай күрде, кояш алды** — күренеп кенә китү, бик тиз юкка чыгу. *Ай күрде, кояш алды дигәндәй, көннәрнең берендә чуар тавык каядыр югалды.* А. Алиш.— *Әнкәйнең токмачын да көтмичә клубка чаптым. Ә сине анда ай күргән, кояш алган.* Г. Әпсәләмов. **Ай тотылу** — айның җир күләгәсенә кереп караңгыланыннан барлыкка килә торган астрономик күренеш. **Айга сикерү** — артык масаю, дәрәҗәсеннән артык кылану, үз чамасын белми кылану.— *Уз чамагызны оныгып, ахмак арысландай айга сикерәсез.* Г. Ибраһимов. *Арыслан дип белеп үзеңне, Айга сикереп, егылып төшкән чакта кемнәр җыяр иде көлеңне?* Ш. Маннур. **Айның ундүртенче кичәсе (тулган ай) кебек (төсле)** — бик сөйкемле һәм чибәр йөзле яки шат чырайлы кеше турында әйтелә. [*Әмирхан:*] *Йөзе ничек, бик ачулы түгелмә?* [*Ризван:*] *Айның ундүртенче кичәсе кебек.* Т. Гыйззәт.

АЙ II *ы.* 1. Авыртуны, сызлану-сыкрануны, куркуны һ. б. ш. белдерә. *Алла! Ай! Билләрем авырта.* Г. Камал.— *Ай, бәбкәм, харап булдык! Карасана зинһар: Дәүлиләрнең өй тубәләреннән бөркелеп кара төтен чыкты.* М. Гали. *Акбүз посып кына килде дә тегенең арт сыйрагыннан шундый каптырып алды, кеше: «Ай!» — дип кычкырырга гына өлгерде.* Г. Гобәй.

2. Кызгану, үпкә, канәгатьсезлек, икеләнү һ. б. ш. хисләрне белдерә. *Ай, Алмасым, 13 яшь тулганда гына харап булырсың микәнни!* А. Әхмәт. [*Шәмсия:*] *Ай, улым, нишләп алай бик тиз булды соң әле бу?* Р. Ишморат. *Ай алла, яңа гына агарткан мичемне харап иткәнсең икән, ник аны алай итеп сызгаладың?* М. Гали.

3. Гаҗәпләнү, горурлану, мактау, хуплауны белдерә. *Ай, нинди хәйләкәр бабай, дип уйлады Илсөяр эченнән генә.* Г. Гобәй.— *Ай, нинди килешә!* А. Әхмәт.

4. Җырларда, озын көйгә туры китерү өчен, сүз арасына кыстырыла яки алдагы сүзгә күшылып әйтелә. *Җирәнчеккәй атның, ай, ялларын Кыйблалардан искән җил тарый.* Җыр.

АЙАРА: айара көн — ике ай арасы, иске ай бетеп яңа ай туганчы булган ара, вакыт.

АЙБАГАР *и. диал. к.* көнбагыш. *Йөзләрчә авыз бер дә туктаусыз айбагар ярып, --- төфелдәтеп бара.* Ф. Әмирхан.

АЙБАЛТА *и. тар.* Тулмаган ай формасына охшаган, балта сыман үткен йөзле, озын саплы борынгы сугыш коралы. *Кымыз эчә ханнар кырын ятып, Айбалтаны элеп югары; Тыгыз янбашларын уйнаклатып, Суга төшә болгар кызлары.* Г. Афзал.

АЙБАЛЫК *и.* Гәүдәсе бик зур тәбикмәккә охшаган, медузалар белән туклана һәм һәрвакыт су өстендә йөзә торган урак сыман йөзгечле океан балыгы; *русчасы:* луна-рыба.

АЙВА *и.* 1. Алмагачлар семьялыгыннан эре, каты һәм ачы җимеш бирә торган көньяк агачы.

2. Шул агачның җимеше. // *с. мәгъ.* Айва җимешеннән ясалган, айвадан хәзерләнгән. *Айва вареньесы.*

АЙ-ВАЙ *ы.* Нәрсәдән дә булса ризасызлык, теләмәү яки авырту, әрнү һ. б. ш. хәлләрдә әйтелә торган аваз-ны белдерә.— *Ай-вай! Әле син капкынга электердеңмени мине?* Д. Аппакова. [*Камалиның*] *сүзләре шау-шулы ярминкәдә ай-вай салып «караул» кычкырган төсле аерылып яңгырадылар.* К. Нәҗми.

◇ **Ай-вай килү (итү)** — 1) берәр нәрсәгә каршы килү, риза булмыйча еламсырап кычкыру. *Иртәгесен сыерым җитәкләп мин Алып киттем күрше базарга; «Ай-вай!» итеп, үкереп-үкереп елап, Хатын егылып калды абзарда.* Ш. Маннур; 2) сөрән салу, кычкыру; 3) авыртудан ыңгырашу. **Ай-вайга карамыйча (карамастан)** — бернәрсәгә карамыйча, ризасызлык яки каршылыклар белән хисаплашмыйча. *Вәли бай Мәфтухасына да кереп чыктым, ул да ай-вайга карамыйча чәй эчертте.* Г. Камал. *Мәрданша бабайны, аның ай-ваена карамыйча, шалаштан туп-туры больницага илтеп салдылар.* Г. Гобәй.

АЙ-ВАЙЛАУ *ф. к.* ай-вай килү. *Кычкырып, ай-вайлап, ай-вай салдырып, һәммәсен куып кайтардылар.* Г. Ибраһимов.

АЙГЫЛДАУ *ф.* 1. Көчле, көр тавыш белән кешнәп аваз салу (айгыр яки колынын чакырган бия турында).

2. *рәв. мәгъ. гади с.* **айгылдап.** Ихахайлап, авыз күтәреп, ямьсез тавышланып (көлү турында). *Тирә-якка утыручы кешеләр айгылдап көлә башладылар.* Р. Батуллин.

АЙГЫР *и.* Ата җенестәге печтерелмәгән ат. *Шул сылу кара айгыр һәм аның иясе быел, бөтен тирә-якларга дан чәчеп, [сабан туенда] барын да аста калдырачак.* Г. Ибраһимов.

АЙДАН-АЙГА *рәв.* Һәр ай саен, регуляр рәвештә.

АЙДАР-АЙДАР *с.* Тап-тап, ала-кола. *Бите айдар-айдар икән.*

АЙДАРЛАНУ *ф. сир.* Бөдрәләнү, алка-алка, бөдрә-бөдрә булып тору, бөтеркәләнү. *Айдарсылу, маңгай чәчең айдарланган, Күзләреңдә гыйшык буы кайнарлаккан.* Ш. Бабич.

АЙКАЛУ *ф.* 1. Дулкынлану, көчле чайкалу, болгану. *Илсөяр ыңгырашырга теләп тыпырчынды, э күзләре асты өстенә килеп айкалган Агыйделдән әле һаман да әтисен эзли иде.* Г. Гобәй. // Актарылу, асты өскә килү. [*Борисовның*] *тәне ничектер оеп китте. Җир, айкалып, аңа таба авып төшкән кебек булды.* Г. Бәширов. *Ике яктан да башланып киткән көчле атыштан соң бөтен тирә-як айкала, актарыла иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Ары-бире сугылу, йөренү; ыгы-зыгы килү, кайнашу.— *Әйберләремне сакларга биргәч, мин дә [вокзал тирәсендә] мәгънәсез айкалырга тотындым.* А. Шамов.

3. Селтәнеп, селкенеп күз алдында буталу. *Арбалар тирәсендә винтовкалар, балталар, кыска мылтыклар айкала башлады.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Кайнау, буталу (уй, фикер турында). [*Сәлим-*

нең] башында [нинди] уйлар айкалуын берәү дә белми. Г. Әпсәләмов. *Давылдагы диңгез дулкыныдай, Айкалалар уйлар башымда.* Ф. Кәрим. // *рәв. мәгъ.* **айкалып.** Дулкынланып, борчылып; ашкынып. *Йөрәге айкалып типкән хәлдә, [Гомәр] агитаторлар исемлегендә үз исемен көтте.* Р. Шәйхетдинов.

АЙҠАЛУ-ЧАЙҠАЛУ *ф.* 1. Айкалу һәм чайкалу, буталу.

2. Ян якка аву, як-якка сугылу, тигез бармау, алпан-тилпән килү. // *рәв. мәгъ.* Күз алдында буталып, як-якка селкенгәләп. *Дистә ярымлап тимер тырма, урам киңлегедәй араны иңләп, дулкын өстендә баргандай айкала-чайкала җир өстенә кереп китте.* Г. Бәширов.

АЙҠАЛЫШ *и.* Болганыш, актарылыш. *Дулкыннар айкалышы.*

АЙҠАЛЫШУ *ф.* Ыгы-зыгы килү, болгану, кайнашу, буталышу. *Югарыда көмеш самолетлар айкалыша.*

АЙҠАНУ *ф.* Селтәнү. *Егет гөрзине алып бер айканды да, ди, дүнең баш түбәсенә берне биргән иде, ди, шул минутта дию, җиргә кереп, гаип булды, ди.* Әкият.

АЙҠАУ *ф.* 1. Дулкыннар хасил итеп айкалдыру, айкалырга-чайкалырга мәҗбүр итү, болгату. *Айка, давыл, диңгез өстен, Сал кырларга тавышың.* М. Җәлил.

2. Актарып, астын өскә китереп эзләнү.—*Уф, ардым, айкадым Бөтен йортны, абзарны; Табалмадым, дускаем, Синең әйткән мордарны.* Ш. Камал. *Фашистларның, аңнарына килеп, зуррак көч белән чыгып, урманны айкарга --- тотынулары мөмкин.* А. Шамов.

3. Йөреп чыгу, йөреп күп җирләр, юллар үтү. *Менә бу безнең Мостафа иптәш ... фронтларны айкаган егет.* Ш. Камал. *Нинди ике-өч кибет[тә генә булу]? Әллә ничә урамны айкап чыктым.* С. Рафиков.

4. Нәрсәне дә булса селтәү, бутау, болгау. *Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады.* Ф. Хөсни. *Айкап җибәр, чайкап җибәр Шул казакның камчысын.* Җыр. // Чайкау, селкү. *Һәркем [үгезгә] якын килергә курка, шуны сизгән кебек, ул үзе дә, тубалдай башын гайрәтле айкап, очраган берсен һавага чөеп атарга әзер тора иде.* М. Шабай. // Актарып ташлагандай ярып, кисеп үтү. *Кичләрен көнбатышның куе зәңгәр болытларын буйдан-буйга айкап елдырым камчысы селтәгәндә, ул совет халкының ачы нәфрәте һәм нәләтедер, ул --- кара еланнарны [фашистларны] шулай камчылыйдыр кебек иде.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Болгату, астын өскә китерү, ыгы-зыгы тудыру. *Бакты аллага [иблис] Шушы ялыныч белән: «Дөнья беткәнче җиһанны айкарым, Бар иман, вәжданнарыңны чайкарым».* Ш. Бабич.

6. Үтәли күрерлек итеп барысын да җентекләп карап чыгу. [*Әпипә*] *сикереп торды да, үз тирәсендәгеләрне усалланган күзләре белән бер айкап чыккач, үз-үзенә исе киткәндәй: «Канатым...» — дип сузды.* Г. Бәширов.

7. *күч.* Үткәннәрне искә төшерү турында. *Каенана белән килен арасындагы бу талашлар һәр икесенең үткән тормышларын иңеннән-буена айкап чыгалар иде.* Г. Ибраһимов. // Нинди дә булса көчле хисләр кузгату турында. *Газинур үз гомерендә күп җырлар җырлаган һәм ишеткән кеше, әмма разведчиклар шикелле йөрәкне өздереп, үзәкләрне айкап җырлаганны моңарчы күргәне дә, ишеткәне дә юк иде.* Г. Әпсәләмов.

АЙ-ҖӨН: ае-көне белән — үз вакытында, срогы җиткәч тә. **Ае-көне җиту** — билгеләнгән вакыт җиту.

АЙЛАП *рәв.* 1. Ай буенча, айга якын. *1907 елда ул «Йолдыз» газетасыннан Мәкәрҗә ярминкәсенә корреспондент булып бара, анда айлап тора.* М. Гали.

2. Берничә айлар буена, берничә ай; айлар санынча. *Айлап торсам [да], тормам еллап, Сагынырсыз — мин булмам.* Җыр.

3. Айлыклап, аерым айларга гына килешеп. *Җәй көне айлап трактордa эшләүче бер егет бар.* Г. Ибраһимов.

АЙЛАУ *ф. сөйл.* Берәр урында бер ай (яки берничә ай) буена булу, тору. *Айлаган кунак — кунак саналмый.* Әйтем.

АЙ-ЛИ *ы.* Қайбер җырларның кушымтасында әйтелә. *Ай-ли, Гөлмәрфуга, бар суга. Гөлмәрфуга, барсаң суга, Сөйләшербез барсын да.* Җыр.

АЙЛЫ *с.* Ай яктыртып торган. *Аяз, матур, тын айлы кич иде.* Г. Ибраһимов.

АЙЛЫК *с.* 1. Күпмедер айга җитәрлек (булган). *Ике айлык азык-төлек. / хәб. функ. Сиражиның байлыгы бер айлык.* Г. Камал.

2. Ай эчендә үтәлергә тиешле, бер айга билгеләнгән. *Аның районы дәүләткә ашлык тапшыруның айлык планын тутырып, райком югарыдан рәхмәт алды.* Г. Бәширов.

3. Күпмедер айга сузыла торган, күпмедер ай буе дәвам итә торган. *Өч айлык курслар.* □ *Әмиржан Февраль революциясе алдыннан гына алты айлык прапорщиклар мәктәбен бетергән иде.* Ш. Камал.

4. Туганнан соң күпмедер ай яшәгәнлек турында сөйләгәндә кулланыла. *Биш айлык бала.* □ *Берничә айлык Фатыйма исемле кыз баласын Хәлимәнең әнкәсе үз тәрбиясенә алган иде.* Ш. Камал. // Нәрсәнең дә булса үсү вакытын билгеләү өчен кулланыла. *Бай кызы, карынындагы ике айлык баласы белән, япанда ялгыз калган кебек хәлгә төшә.* Г. Ибраһимов.

5. Бер ай өчен бирелә торган. *Заһид кичләтеп кенә колхоз идарәсенә айлык аванс акчасы алырга килгән иде.* Г. Галиев. *Бу салкынлык әниләре карточкага алып кайткан ярты айлык конфетны бер утыруда өчесенә ашатып бетергәч тә бетмәде.* Г. Гобәй. // *и. мәгъ. сөйл.* Эш хакы, хезмәт хакы. *Парижда яшәр өчен аз жалованье алып эшләүче кыз-хатыннарның айлыклары җитми.* Г. Гали.

6. *и. мәгъ.* Берәр эшне башкару өчен билгеләнгән бер ай вакыт арасы. *Агач утырту айлыгы.* □ *Колхозда кырларны ашлау буенча удар айлык игълан ителде.* Соц. Тат.

АЙЛЫҠЛАП *рәв.* Ай исәбеннән (эш күләменнән түгел). *Хаҗи баба хезмәтне алса да, айлыклап бирелә торган жалуньяны [кире какты].* Г. Ибраһимов. *Тачка эшләрен аларга берничә иптәшкә вагон башыннан бирмәкче булганнар. Болар, разый булмыйча, айлыклап керешкәннәр.* Ш. Камал.

АЙЛЫҠЧЫ *и.* Айлыклап эшләүче.— *Алар болай [гади] айлыкчы булып түгел, «сдельно» керешкәннәр бит.* Ш. Камал.

АЙМАҠ *и. иск. сөйл.* 1. Җир, урын, төбәк, участок. *Гата абзый сызгыра-сызгыра урам буйлап түбән аймакка таба узды.* Н. Булат.— *Безнең авыл шундый матур, шундый күңелле. Һәрбер аймагы, һәрбер урамы, һәрбер кешесе сөйкемле күренә.* Т. Гыйззәт.

2. *диал.* Нәсел, ыру, кабилә. *Аларның бабалары бер аймактан булган.*

3. *иск.* Төркем, даирә. *Синең урының үлекләр аймагында.* Дәрдмәнд.

АЙМАҠЛАП *рәв. диал.* Бергәләп, бер төркем булып, группа белән.

АЙМЫЛ: аймыл булу *диал. к.* аймылыш булу.

АЙМЫЛЫШ *рәв.* Аркылы-торкылы. *Күкрәкчәнең баулары аймылыш тезелә.*

Аймылыш булу — очрашмау, туры килмәү, бер юлда булып та бер-берен күрмәү. *Рифкать Миләүшә белән аймылыш булмыйм дип тә курыкты.* М. Әмир.

АЙМЫЛЫШУ *ф.* 1. *к.* аймылыш булу.

2. Аркылы-торкылы булу.

3. *күч.* Юлдан чыгу, читкә китү.

4. Саташу, зиһене чуалу, буталу. [*Зәбих:*] *Син ни сөйлисең, әни, аймылыша башладыңмы әллә?* Н. Исәнбәт.

АЙНУ *ф.* **1.** Эчкән исерткечнең тәэсире бетү, аек хәлгә килү. — *Эчкән кеше ул айный да, тагын ук иске эзенә төшә.* Ш. Камал. *Мидхәт үзе ике авыз сүзне дә оештырып әйтә алмаслык исерек иде, --- [аны], айнып та җитмәгән көенә, салкын кладовойга ябып, ачкычны карт үзенә алды.* Ф. Хөсни. // Исерткеч, дару, чәй һ. б. ш. нәрсәләрнең озак һәм ачык тору нәтиҗәсендә тәэсир итү көче, куәте бетү.— *Мин сиңа һәрвакыт чәй җыеп кайтма дим, күп торгач, айный да торгандыр ул.* Ф. Әмирхан.

2. Авырудан терелү, савыгу. *Элек ел буе чирдән айнымый торган йомшак кына кеше иде, хәзер әнә аркаҗилкәгә дә киңәеп, күз карашлары да үткенәйгән кебек күренә.* Г. Бәширов.

3. Һуштан язганнан, аңын җуйганнан соң аңга килү; тирән кичерешләрдән, югалып, аптырап калудан арыну, тыныч, аңлы фикер йөртү хәленә кайту, нормаль эзгә төшү. *Ана беренче тетрәнүдән айныргә өлгермәс борын ук, Зариф тимер юл буйлап йөгерә-йөгерә китеп тә барды.* Ә. Еники. *Зәйтүнә чиләк-көянтәләрен иңенә күтәрә башлагач кына, [Сәфәргали] кинәт айнып китте.* Ф. Хөсни. *Беренче аптыраудан айныган казаклар атларына атландылар.* Ш. Усманов.

4. *күч.* Караш үзгәрү, әлекке фикердән, нияттән кире кайту. *Икърар итми хәл юк — Зифа айныган. Айнуы айну — булуы мөмкин. Әмма бер авыл малаена алмаштырып айну, менә шунысы бигрәк тә үкенечле.* М. Фәйзи.

5. *күч. сөйл.* Нинди дә булса эштән, шөгыльдән туктау, арыну, бушау. *Безнең заманда мондый малайлар урлап көлгә бәрәңге күмүдән, сугышып баш ярудан айнымадылар.* Г. Гобәй.

АЙНЫҚ *с. сөйл. к.* аек. *Исерекләрме, айныклармы — йөгенә керә алмыйм.* Г. Ибраһимов. *Кабинеттан Гәрәй айнык бер фикер белән чыкты.* А. Гыйләҗев. [*Әлбидә:*] *Тукта, хисләр колы булма! Мусага синең айнык акылың һәм ярдәмең кирәк!* Ш. Маннур.

АЙНЫҚЛАНУ *ф. сөйл. к.* айну (3 мәгъ.). *Еллар үзган саен айныкланам, Акны күктән аера башладым; Эльбрус белән Саташтырмыйм инде Иңкү җирнең карсак кашлагын.* Ә. Ерикәй.

АЙНЫҚЛЫҚ *и. сөйл. к.* **аеклык.**

АЙНЫТҚЫЧ *и.* Айныту йорты.— *Бәхетең — без бакчада йөри идек. Ялварып, аралап алып калдык. Югыйсә, айныткычка элгеңә, башың хур була иде.* Ф. Исәнгулов.

АЙНЫТУ *ф.* **1.** Аек хәлгә китерү.— *Исәнбай, булыш миңа, хәзер [Әмирханны] айнытабыз, чәчен уыгыз.* Т. Гыйззәт. [*Яшьләр*] *Фәхринең алгын, кулын бәйлиләр. Коедан чиләкләп салкын су сибеп айныталар.* Г. Ибраһимов.

2. Зур кичереш, хыял дөньясыннан чыгару, аңга китерү. *Киленнең зур ачыгган очкынланган күзләре, гарьләнеп калтыраган газаплы тавышы карчыкны айныта төште.* Г. Бәширов. [*Мәктәп бинасы әчендәге*] *тынлык Нургалине үйларыннан айнытып җибәргәндәй итте.* Ә. Еники.

3. Берәр фикереннән, ниятеннән кайтару.— *Инде мине һичкем бу уемнан, бу юлымнан айныта алмас.* М. Фәйзи.— *Әхәт хаклы, мең тапкыр хаклы: дөнья халкы бердәм булып бер-берсен аңлашканда гына сугыш чукмарларын айнытырга җай табылачак.* А. Гыйләҗев. // Агарту; аңлы итү. [*Нурулла*] *авылны иске тормыш томаннарыннан айнытуда бөтен көчен куеп, төпкә җигелгән ат шикелле, эшкә чумды.* С. Рафиков.

Айныту йорты — исерекләрне айныту белән шөгыльләнә торган санитария-медицина учреждениесе. *Ачып җибәрсәм мин шунда күземне, Айныту йортында күрәм үземне.* Н. Гобәй.

АЙРАВЫК *и. бот.* Күпьеллык азык үләне; *к.* сарут.

АЙСБЕРГ *и.* Диңгездә, океанда йөзеп йөри торган боз тавы. *Уртача зурлыктагы 2—3 айсбергны эретсәң, 252 куб км су барлыкка киләчәк. Бу Иделдәге бер ел аккан суга тигез.* Сов. мәк.

Ай-Яй *ы. к.* ай-һай.— *Ай-яй әйбәт котылдың бит бая син, Гарифулла.* Г. Минский.

АЙ-ҺАЙ *ы.* Нинди интонация белән әйтелүенә карап, гаҗәпләнү, соклану, шикләнү һ. б. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Ай-һай без, Әхмәт, аңар сатабыз сатуын да, ул безнең акчаны ябып калмас микән?* Г. Камал.— *Нәфисә кәтеп утыра утыруын да,— диләр имеш,— ай-һай, авыл кызына өйләнер төсле күренми ул егет!* Г. Бәширов.

АЙҺАЙЛАУ *ф.* **1.** Ай-һай дип гаҗәпләнүне, соклануны яки шикләнүне белдерә.

2. *рәв. мәгъ.* **айһайлап.** Ай-һайй, ай-яййй кебек аваз-лар чыгарып. *Қилен килә, килен...— дип сузып, айһайлап акыргән күмәк тавыш күтәрелде.* Г. Ибраһимов. *Алар, айһайлап, кырык тамактан кычкырып, кранны утыртып та куйдылар.* А. Гыйләҗев.

АҚ I *с.* **1.** Кар, сөт, акбур төсендәге; *киресе:* кара. *Сикереп торды, тиз-тиз ак халатын киде.* М. Җәлил. *Манжет алган ун тиенгә, Биш тиенгә ак яка.* Г. Тукай. *Ак булмаса да пакь булсын. Әйтем.* // *и. мәгъ.* Ак материя. *Башны аска иеп озак тордылар Өстәл янында; Акка төргән табут ята кебек Алар алдында.* Ф. Қәрим.

2. Қар, сөт һәм акбур төсенә якын ачык төс. *Әнә күренә кыйбла яклап Бик матур ак шәүләсе.* Ш. Бабич. *Күңелемә хуш килмәде Ак йөзең акбур иткәнең.* Дәрдмәнд.

3. Чал. *Авылда бер ак сакаллы карттан бу туғрыда сораша башлый.* Г. Тукай. *Ике чигәдә ара-тирә ялтыраган ак чәчләр.* Г. Ибраһимов.

4. Чиста, керсез.— *Анда ук бара тормыйм инде мин, идәнең бик ак икән, тыштан кергән аякларым белән пычратырмын, я ачулана башларсың.* М. Гали.— *Кара әле, минем яулыгым каралган икән, кая миңа бер ак яулык бир әле.* Г. Камал. // *күч.* Эчкерсез, саф, гөнаһсыз. *Елатма ак жаныңны, вөжданыңны.* М. Җәлил. [*Алмас:*] *Сезнең кебек гакыллы, ак күңелле татар кызларының агасы булу миңа нинди күңелле, нинди бәхетле бер эш булыр иде.* Ш. Әхмәдиев.

5. Қонтрреволюцион, Совет хөкүмәтенә каршы булган. *Ак армия. Ак офицер.* □ [*М. Гафури*] *интервенциягә һәм ак бандалар һөҗүменә каршы ачы нәфрәт һәм дошманлык белән, аларны фаш итеп язган әсәрләрен бирде.* М. Җәлил. // *и. мәгъ. күпл.* **аклар.** Қонтрреволюционерлар, акгвардиячеләр, революция һәм Совет хөкүмәтенең дошманнары. *Әсәрнең бу урыннары аклар күтәрелеше вакытындагы типик күренешне бирәләр.* Г. Нигъмәти. *Тар-мар иттек аклар токымын.* М. Җәлил.

6. Ягымлы, җылы. *Ак сүз белән, ачык йөз белән каршы алу.*

7. *күч.* Бәхетле, рәхәт, кайгы-хәсрәтсез.— *Ходай ак тормышлар бирсен инде.* М. Фәйзи. *Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым, Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.* Г. Тукай.

8. *и. мәгъ. күпл.* **аклар.** Шашка, шахматның ак яки ачык төстәге фигуралары.

9. Ике яки өч сүздән торган кайбер зоология һәм ботаника атамаларының беренче кисәге. *Ак әрем. Ак гөмбә. Ак борчак. Ак чыршы. Ак тычкан. Ак төлке. Ак аю.*

Ак алтын — 1) бик каты һәм алтынга караганда авыррак металл; *русчасы:* платина. *Саф тимер тышкы күренеше белән ак алтынны хәтерләтә.* Химия; 2) *күч.* Су энергиясе; 3) *күч.* мамык. **Ак аракы** — икмәктән яки бәрәңгедән ясалган, су төсендәге исерткеч эчемлек. *Зәйни абый сиңа кызыл белән ак аракының ике бутылка-*

сын гына кушарга әйткән иде ич, ә син барысын да кушкансың. Ф. Бурнаш. **Ак аш** *сөйл.*— сөт ашлары (сөт, катык, эремчек, каймак һ. б.). *Аның ашказаны авырта башлаган икән, докторлар аңа «ак аш» --- белән генә торырга кушканнар.* Ә. Еники. **Ак балчык** — 1) чынаяк ясый торган яхшы сортлы балчык — каолин; 2) ак төстәге уалучан тау токымы, известь. *Сәйдә җиңги --- ак балчык изеп, көздән кул тимәгән мичне, куян тәпие* белән агартып, кар төсенә кертте. С. Рафиков. **Ак баш** — 1) *бот.* Күкебаш, баллы ботка; 2) дулкын өстенә күтәрелгән күбек, дулкын башы. [*Зөбәрҗәт*] *ак башлы дуамал дулкыннарны күзәтеп торды.* А. Расих; 3) *гади с.* Чал яки аксыл чәчле кеше (карт кеше турында); 4) *гади с.* Аракы; 5) *иск.* Башына ак чалма ураган дин әһеле. **Ак билет** — гаскәри хезмәттән азат ителү турында таныклык. *Сигезен алдылар, калганнары кайсы яшелгә* [*өч елга*], *кайсы кызылга* [*бер ай барып өйрәнергә*], *кайсы ак билет алып бөтенләй котылып чыкты.* М. Гали. **Ак келәт** — җәй көне торыр өчен җайлаштырып эшләнгән тәрәзәле келәт, өйдән аерым торган каралты. *Әни ак келәткә бик әйбәтләп урын җәеп куйган, узганда-барганда кырын күзне салып йөрим.* Ф. Хөсни. **Ак кул** — *к.* аксөяк. *Ул инде хәзер кызын калага, ак кул мирзага бирү, шулай итеп, аны бу җәһәннәмнән коткару хыялы белән җенләнә иде.* Г. Ибраһимов. **Ак күмер** *махс.*— югарыдан төшә торган суның гидроэлектростанция турбиналарын хәрәкәткә китерә торган көче. *Советлар Союзында ак күмер энергиясеннән файдалану проблемасына аеруча зур игътибар ителә.* Физика. **Ак май** — атлан май, сөт өстен туглап *ясала торган май. Газизә өстәмә итеп чәй янына сумсалар һәм ак май куйды, шкафтан тагын ике чынаяк алды.* Ш. Камал. **Ак мунча** — моржалы мунча. *Агач бакча эчендә утырасы өч бүлмәле, челтәр пәрдәле ак мунча төшләренә кереп йөдәтте.* Г. Бәширов. **Ак нәсел** — *к.* аксөяк.— *Алар гына минем ак нәселдән һәм нинди семьядан чыкканымны әйтә алалар.* М. Җәлил. **Ак он** — вак тартылган, кәрпәсез, югары сорт бодай оны. **Ак патша** *иск.*— Россиядә Көнчыгыш халыклары телендә: рус патшасы.— *Арысланбайның сөргенгә дучар булуын хаксыз күрәбез, без аны яхшы беләбез, ул ак патшага яман тел әйтә торган адәм түгел.* Г. Ибраһимов. **Ак самовар** — никель самовар. *Хатыны гөрләп торган ак самоварны яшел чәчәк төшерелгән кечкенә поднос өстенә кертеп куйды.* А. Шамов. **Ак тал** — *к.* песиле тал. *Яр буендагы нәзек талларның кайрылары астына әчкелтем мәмәч йөгерер... ак тал бәбкәләре үзләренең баллы тузаннарын җилгә бөркеп, яңа дөньяга чыккан умарта кортларын бал белән сыйлар.* И. Гази. **Ак таң** — иртә, таңның яктырган вакыты, көн алды. *Ак таң белән алар сәфәр чыгар.* Ф. Бурнаш. **Ак теләк**— изге теләк. *Ак теләкләр тели-тели, Озатканда карап калам Күз керфегем талганчы.* М. Фәйзи. **Ак тәнле** — ак раса кешеләре, «европалы», цивилизацияле кеше мәгънәсендә. *Уолл-Стритта — ак тәнлеләр әнә, Ләкин шуны ачык әйтәм мин: Йөрәкләре кара тирес булгач, Ни мәгънәсе бар ул ак тәннең?!* З. Мансур. **Ак төн** — төньяк поляр түгәрәктә кояш нурлары тәүлек буе югалмый торган көннәрдәге якты төн. *Утеп китәр апрель* озакламый, *Башланырлар тиздән ак төннәр.* Г. Хуҗиев. **Ак чәчәк** — *к.* ромашка. *Чормасына төрле дару үсемлекләре — бәйләм-бәйләм ак әрем, юкә чәчәге, үги ана яфрагы, мәтрүшкә, ак чәчәк, яшь кычыткан һәм сирень чәчәкләре кибәргә элеп куелган.* Г. Әпсәләмов. **Ак шар** *иск.*— яшерен сайлау вакытында берәүнең файдасына салына торган шар. *Бервакыт ул шәһәр сайлауларында үзенең кандидатурасын куя, табигый, берничә үнлап кара шарга каршы икеме, өчме ак шар алып, мөнһәзим була (җиңелә).* Ф. Әмирхан. **Ак эш** — җиңел эш, күп көч түгүне, физик энергияне һәм өс-кием пычрануны таләп итми торган чиста эш. [*Идән*] *җимерелсә, кияү иртәгә үк төзәтер дә куяр, аның осталыгы кара эшне дә ак эшкә әйләндерде.* Г. Мөхәммәтшин. **Ак юл**—1) кая да булса киткәндә яки яңа бер эш башлаганда уңыш теләп әйтелә торган сүз. *Җиһангәрәй агай, кул күтәреп: хода ак юл бирсен, диеп дога да кылып куйды.* Ш. Мөхәммәдев. — *Ак юл сезгә, егетләр!* М. Җәлил; 2) *к.* туры (туры юл). *Канлы кырларда сугышканда, Синең шәүләң һаман Безгә ак юллар сызып торды, Азатлыкка табан!* Һ. Такташ. **Ак яка** — 1) *иск. ирон.* Кадимчеләр, дин әһелләре җәдитчеләрне шулай атаганнар; 2) *ирон.* Эшче халык Совет хөкүмәтенең беренче елларында мещаннарны, интеллигент булып йөргән төрле эшлексезләрне нәфрәт белән «ак яка» дип атаган. *Антракт вакыты, Тәти зал уртасында, гөрләшеп, Ак якалар, Пудралар Сәнгать хакында сөрләшеп әйләнәләр.* Һ. Такташ. **Ак өй (як, бүлмә)** — җыештырылып, юылып тотыла торган өй (як, бүлмә, зал), кунак өе (татар авылларында гадәттә кара-каршы ике өйнең берсе шундый була). [*Балалар*] *ак өй киштәсеннән әтиләренең кураен алып, озаклап уйнап-җырлап утыралар иде.* М. Гали. *Бу — терлек-туар кертелми торган ак як иде.* А. Шамов.

◇ **Ак белән караны аеру (аера белү)** — бераз гына аңлау, төшенү, нәрсә — яхшыга, нәрсә яманга илтүне белү, аңлы булу.— *Хәзерге заманда, бигрәк тә безгә, ак белән караны гына аеру җитми, Кәримов абый, икмәк белән нефтьне дә аера белергә кирәк.* А. Әхмәт. *Шулай маташа* [*укый*] *торгач, ул ак белән караны аерырлык булган иде.* Г. Ибраһимов. **Ак димәү, кара димәү** — эндәшмәү, сүз әйтмәү, бер сүз дә кушмау мәгънәләрендә йөртелә. **Ак йөз** — 1) намус, вөҗдан. *Дөньядан ак йөз белән үтте;* 2) хәлсез, чырайсыз, төссез, нурсыз (йөз турында). **Акка калдыру** — 1) хәрби хезмәттән азат итү, ак билет бирү. *Тукта әле, егет, нигә бик ашыгасың, акка калдырдылармы әллә?* М. Гали; 2) аклау, гаепсез итеп калдыру. **Акка (ак кәгазьгә) кара белән язылган** — 1) ап-ачык, аңлаешлы, күзгә яки аңга бәрелеп тора торган; 2) чын, ышанырлык, законлашкан (китапка кергән). **Акка күчерү** — ашыгып, сызып-бозып беренче тапкыр язган текстны чистарак итеп икенче кәгазьгә күчереп язу. *Женни Маркс әсәрләрен акка күчергән, аларны массага таратырга булышкан.* Г. Кутуй. **Акны кара дип әйтү (акны карага әйләндерү)** — яхшыны яман итеп күрсәтү. *Кайвакытта дошман агентлары, Үтеп кереп безнең арага, Сөйли төрле ялган хәбәрләрне, Әйләндереп акны карага.* Ә. Исхак. **Акны карадан аера белү** — *к.* ак белән караны аеру (аера белү).

АК II *и.* 1. *мед.* Күзнең нәрсә белән дә булса зарарлануыннан яки авырудан соң мөгез катлавында була торган аксыл тап. [*Каюм*] *китаптан күзен алып, күзлегенең пыяласыз ягыннан ак төшкән күзен ялтыратып, туп-туры миңа карады.* М. Гали.

2. *күч. гади с.* Ак аракы.— *Син акны эчәргә яратуын яратмыйсың, шулай да отпускаң хөрмәтенә берәрне төшерербез әле.* А. Шамов.

3. *сөйл.* Сөт һәм сөт продуктлары. [*Әни:*] *Өс-башы тагын бер хәл, кечкенәрәк булса да сыер алып кала алсак яхшы булыр, балалар акка туярлар, үзебез иркенләп калыр идек.* М. Гафури.

АКАДЕМИЗМ *и.* 1. Фәндә, укуда, сәнгатьтә практика һәм тормыш таләпләре белән аз бәйләнешле, башлыча теориягә корылган юнәлеш.

2. Сынлы сәнгать өлкәсендә аерым классик (антик) үрнәкләргә иярүнең яшәп килгән традицияләрен саклый һәм сәнгатьтәге реалистик агымнарга каршы көрәшә торган юнәлеш.

АКАДЕ'МИК I *и.* 1. Академиянең (1 мәгъ.) действительный члены.— *Кайчан гына чабаталы малай Шакир Гайфетдинов — академик.* Р. Ишморат. *Съезднең көн тәртибендә төрле профессорлар, академиклар тарафын-*

нан ясалырга тиешле зур фәнни докладлар тора. М. Гали.

2. *махс.* Нинди дә булса академиягә сайланган галим, художник, скульптор һ. б. ш. кешеләрнең гыйльми исеме.

АКАДЕ'МИК II *с.* 1. Академиягә мөнәсәбәтле, академиягә караган. *Академик басма.*

2. Академизм (2 мәгъ.) принципларына иярә торган. *Академик сынлы сәнгать.*

3. *күч.* Теориягә генә корылган, практик әһәмияте булмаган, тормыштан ерак торган. *Академик бәхәс.*

Академик ел — тугыз ай вакытны эченә алган уку елы. **Академик сәгать** — лекция өчен билгеләнгән 45—50 минутлык вакыт, дәрес. **Академик ял** — мәктәптә яки югары уку йортында укучыларга авыру сәбәпле бирелә торган озак сроклы ял. *Ана кешенең күзенә яшь бәреп чыкты: берәр елга академик ялга чыгыйм мәллә дип, юкка гына сөйләнми бу бала.* М. Әмир. *Институттан ул бер елга академик ял алды.* Г. Әпсәләмов.

АКАДЕ'МИЯ *и.* 1. Фән һәм сәнгатьне үстерү эше белән җитәкчелек итә торган югары дәүләт учреждениесе. *СССР Фәннәр академиясе.* □ [*Китап*] *Саматовның Фәннәр академиясе бастырып чыгарган гыйльми хезмәтләренең берсе.* Г. Минский.

2. Кайбер югары уку йортларының исеме. *Хәрби медицина академиясе.* □ *Хәйдәр яшь кызның Художество академиясенә керергә уйлавы турында дәртләнеп сөйләвен тыңлый-тыңлый күңелле уйлар уйлый иде.* Г. Бәширов.

Академия театры—1) үрнәк булырлык эш өчен дәүләт театрына бирелә торган югары исем; 2) шул исемгә, дәрәҗәгә ия булган театр. *Музыканы сәхнәләштерү тәҗрибәләрен ясаган Татар дәүләт академия театры татар совет операсының тууында аерым күренекле урынны тота.* М. Җәлил.

АКАЙ *с. гади с.* Акаеп торган, чыгынкы, кабарынкы (күз турында). *Акай күзле ат.*

◇ **Акай күз** *гади с.*— 1) **күз алдында торган** нәрсәне дә күрми торган, игътибарсыз кешегә карата ачуланып әйтелә; 2) кирәкмәгәнне дә күрә торган, яшереп калдырырга тырышылган нәрсәгә дә игътибар иткән кешегә әйтелә.

АКАЙТУ: күз акайту — 1) ачулы һәм усал итеп карау. [*Дошманнар*] *күз акайталар... «Сезнеме—сезне!..» дигәндәй, тешләрен ыржайталар.* М. Гафури. *Соры кәҗә утлы-яшелле күзләрен акайтып бер карап алды да ачык тәрәзәдән урамга сикерде.* Г. Бәширов; 2) гажәпләнүдән һ. б. ш. хисләрдән күзләрне зур ачып карап тору. *Күзеңне акайтып торма монда, кит!* Д. Аппакова.

АКАЙ-ШАКАЙ: акай-шакай килү *сөйл.*— тәртипсезләнү, тәүфыйксызлану.— *Акай-шакай килмәсәң, илнең күзе очлы аның, күрерләр, бәхет күгәрченең үзе үк иңбашыңа килеп кунар.* Ф. Хөсни.

АКА'ЦИЯ *и.* Кузаклылар семьялыгына керә торган агач сыман яки куак үсемлек; *к.* сәрви агачы. *Ак акация. Сары акация.* □ *Рәшәткә буендагы акациягә охшаган бер агач сап-сары булып чәчәк атып утыра иде.* А. Алиш.

АКАЮ *ф. гади с.* 1. Авыртудан, эчке газаптан күзләрнең агы әйләнеп, хәрәкәтсез бер хәлдә калуы. *Әле генә яңадан чаткылана башлаган коңгырт күзләре, атылып чыгарлык булып акаеп, тонып калды.* А. Шамов. // Курку, гажәпләнү, аптырау һ. б. хисләр билгесе буларак, күзләрнең, зур ачылып, хәрәкәтсез бер хәлдә калуы. *Иртә белән майга дип Керсәм, күзем акайды: Явыз песи берүзе Ялт иттергән ак майны!* М. Җәлил. // Ачулы һәм усал итеп карау. *Эт күзле кеше, кунаклаган җиреннән торып, Сөләйманга акайды.* К. Тинчурин.

2. *сөйл.* Ачудан яки ярсудан тону, пыялалану (күзләр турында). *Ул да түгел, күзләре акайган бер төркем кеше, шау-гөр килеп, боларның ат башына килеп ябыштылар.* Г. Бәширов. // Берәр эш яки кеше белән артык мавыгып, башка нәрсәләргә игътибар итмәү.— *Тәмам акаюы җиткән икән, күзенә ак-кара күренми икән.* Г. Камал.— *Күзеңә күренә торгандыр, синең күзләрең акайган инде.* Ш. Камал.

3. *күч. сөйл.* Артык күзгә бәрелеп, чекерәеп тору (нәрсәнең дә булса төсе, бизәге яки формасы турында).— *Белмим инде, миңа, кодагыйлар белән илгә-көнгә чыгарга дип, бер күлмәк алмасаң?! Бик акаеп тора торган булмасын.* Г. Ибраһимов.

АҚБАЙ *и.* Ак төстәге этләргә бирелә торган исем.

АҚБУР *и.* 1. Промышленностьның химия, резина һәм башка өлкәләрендә кулланыла торган ак төстәге йомшак известь. *Табигатьтә акбур һәм известьташ борынгы вак тереклек ияләренең кабырчыклары калдыкларыннан барлыкка килгән.* Химия. // Шул известьның язусызу, акшарлау, чистарту өчен китә торган шакмак, таяк, порошок һ. б. формадагы төрләре. *Дүрт-биш хатын-кыз терлек абзарларын акбур белән буйый.* Г. Әпсәләмов. *Ул арада зур иске киез итек кигән озын гына малай торып кара такта янына килде дә, акбурны алып, ниндидер цифрлар сызды.* Ә. Фәйзи.

2. *кимс., ирон.* Кершән, пудра. *Йөзеңә тоташ акбур салгансың.* М. Җәлил. *Йөзен якты күреп, сан[а]дым аны нур. Булыр нур, баксам — ул инлек тә акбур.* Дәрдмәнд.

Акбур чоры *геол.*— Мезозой эрасының өченче геологик чоры. *Акбур чорында диңгезләрдә амебага охшаган, ләкин известь кабырчыклы тамыраяклылар төркеменнән иң гади төзелешле хайваннар бик күп яшәгән.* Биология.

АҚБУРЛАУ *ф.* Акбур белән агарту, акшарлау. // Артык шомалыкны киметү өчен акбур буяу, порошок хәлендәге акбур сөртү. [*Биллиардчылар*] *кийны буйдан буйга гына түгел, очындагы бер тиен зурлыгындагы күненә кадәр мул итеп акбурлыйлар, һәм, ниһаять, уен башлана.* М. Хәсәнов.

АҚБҮЗ 1. *с.* Сизелер-сизелмәс кенә күк төсмере булган ак төс.

2. *и.* Ак төстәге юка киҗе-мамык тукыма. *Поезддан, берсе акбүз илә үң кулын муенына аскан, икенчесе култык таягы илә таянып, ике мөселман солдаты чыкты.* Ш. Мөхәммәдев. // *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Акбүз пәрдә аркылы булмә эче күренми.* Ш. Камал. *Акты кырга акбүз чатырлардан Дәртле җыр һәм шаян чаткылар.* М. Җәлил.

Акбүз ат — ак бүз төсендәге ат. *Бүген төнлә бер төш күрдем, Акбүз атка атландым.* Җыр.

АҚВАЛАНГ *и.* Кеше су астында йөзгәндә файдаланыла торган махсус сулау аппараты.

АҚВАЛАНГИСТ *и.* Акваланг киеп су астын, су төбен тикшерүче, су төбенә төшүче. // Спортның су астында йөзү төре белән шөгыльләнүче. [*Көмеш койрык:*] *Телевизордан күрсәттеләр лә андый ишеләрне— акваланғист дигән кешеләрне.* Ж. Тәрҗеманов.

АҚВАМАРИН *и. махс.* Зәңгәрсу-яшькелт төстәге асылташ. *Аквамарин алка.*

АҚВАРЕЛЬ *и.* 1. Су белән изелә, эретелә торган буяу. *Урам ераккa-ераккa кушылып киткән дә, бер караганда, акварель белән ясалган гаҗәеп рәсемгә, икенче караганда, - - - хыялый шәһәргә охшый.* Г. Әпсәләмов. // Сынлы сәнгатьнең шул буяу белән эшләнә торган бер төре.

2. Акварель белән эшләнгән картина яки рәсем.

АҚВА'РИУМ *и.* Балыклар, су хайваннары һәм суүсемнәр саклау, үрчетү һәм аларның тормышын күзәтү өчен махсус пыяла савыт яки ясалма бассейн, сулык. *Ул балыклы аквариумнарга, чәчәк, муляж, гербарийларга кызыксынып карап йөрде.* Г. Әпсәләмов.

АҚВАТО'РИЯ *и. махс.* Берәр максат белән билгеләнгән һәм җиһазландырылган су участогы, мәйданы.

Гидроаэропорт акваториясе. □ *Порт-Сәетнең эчке акваториясе төрле флаг астында йөзүче пароходлар белән шыгрым тулган.* Сов. әд.

АКГВА'РДИЯ *и. тар.* Контрреволюцион армия, ак армия. / *с. мәгъ.* Контрреволюцион. *Вәли бай активы --- сәнәк сугышларында, акгвардия кузгалышларында катнашкан кешеләрдән тора.* Г. Нигъмәти.

АКГВА'РДИЯЧЕ *и. тар.* Советка каршы булган хәрби контрреволюцион оешма әгъзасы һәм акгвардия сафларында Совет властена каршы көрәшкән кеше, контрреволюционер. *Мәскәү эшчеләренең акгвардияче фетнәчеләргә каршы сугышлары 3 ноябрьга каршы төндә җиңү белән тәмам булды.* КПСС тарихы.

АККАНЛЫЛЫК *и. мед.* Кан составында ак кан шарчыкларының (лейкоцитларның) бик күбәюе белән билгеләнә торган авыру — лейкемия.

АК-КАРА: акка-карага карамыйча (ис китмичә) — бернигә карамыйча, каршылыкларны җиңеп. *Зачетлар бетү белән, акка-карага карамый өйгә ашкындым.* Ш. Камал.— *Яшьлек мавыгуыдыр, бәетләр, такмаклар, шигырьләр яза идем, дөньяның агына-карасына исем китмәстән, китаплар дөньясына чумдым.* Б. Камалов. **Ак-кара күрмәү, (күзенә) ак-кара күренмәү** — 1) шатлыктан, дулкынланудан, ашкынудан яки ашыгудан берни күрмәү, абайламау.— *Киленнең, бичараның, күзенә ак-кара күренмәде, юлаучы бер машинага утырды да китте.* А. Расих. *Мескен мәхлуклар [атлар], колакларын сыртларына салып, акны-караны күрмичә элдертәләр.* А. Шамов; 2) *күч.* нәрсә белән дә булса артык мавыгу сәбәпле башкаларга игътибарсыз булу, игътибар бирмәү, күрмәү.— *Моның анда-монда эше юк, бары тик аңар матур хатын гына булсын, аннан соң һич күзенә ак-кара күренми.* Г. Камал.

АККОМПАНЕМЕНТ *и. муз.* Җырлаучыга яки икенче музыка коралында көйне төп башкаручыга кушылып уйнау. *Гармонь тавышы да, башкаларның җыры да [егет белән кыз җыры янында] үзенә бер матур аккомпанемент булып кына яңгырый.* С. Сабиров.

АККОМПАНИА'ТОР *и. муз.* Аккомпанемент башкаручы, кушмалык итүче.

АККОРД *и.* Берничә музыкаль авазның, тоннарның гармонияле рәвештә кушылып яңгыравы. *Ярсу аккорд кагып җырлар идем Бөек гасыр җырын кешеләргә!* Ш. Маннур.

◇ **Аккорд алу (бирү)** — көйне уен коралында башлап җибәрү. *Ир кеше, бер-ике аккорд алды да, башын кага-кага, ниндидер бер көй уйнап чыкты.* И. Туктар. [*Кәрим*] *кинәт кенә бөтен кылларын бәреп аккорд бирде.* М. Мәһдиев.

АККОРДЕОН *и.* Клавиатурасы фортепьяно тибында эшләнгән гармонь. [*Гармоньчы Коля*] *алдына аккордеон китереп куйдылар, һәм шундук --- вальс бию башланып китте.* Н. Фәттах.

АККОШ *и.* Йөзүче кошлар семьялыгыннан казга охшашлы, озын аяклы, салмак хәрәкәтле күчмә кош. *Аккош аталар микән, итен саталар микән?* Җыр. *Күк йөзендә болыт әсәре юк Очып йөргән аккош чаклы да.* М. Гафури.

◇ **Аккош кебек (төсле) йөрү — йөрешең матурлыгына,** хәрәкәтләрнең нәфислегенә һәм мәһабәтлегенә ишарә итеп әйтелә. *Аккош төсле очып йөргәнеңне Күргән идем кичә сәхнәдә.* М. Җәлил.

АККРЕДИТИВ *и.* Бер кредит учреждениесенең икенчесенә акча түләргә кушып җибәргән рәсми язуы.

Аккредитив грамота — чит илгә җибәрелүче вәкилгә бирелә торган ышаныч кәгазе.

АККУМУЛЯ'ТОР *и. тех.* Соңыннан файдалану максаты белән, электр энергиясен яки җылылыкны туплау приборы.

АККУМУЛЯ'ТОРЧЫ *и.* Аккумулятор белән эш итүче. *Мансур — аккумуляторчы.*

АККУРАТ *с. сөйл.* 1. Җыйнак, пөхтә.

2. Кием үлчәменә карата: таман.

3. Эшне вакытында һәм төгәл үти торган.

АККУРАТЛАНУ *ф. сөйл.* 1. Җыйнаклану, пөхтәләнү. [*Аның*] *өстендәге киеме генә түгел, хәтта үзе дә, кайнар үтүк астыннан узган шикелле, тагын да пөхтәләнә, тагын да аккуратлана төшкән иде.* И. Гази.

2. Кием размерына карата: таманлану, ятышып тору.

3. Эшне төгәл үти башлау.

АККУРГАШ *и.* Җиңел чүкелүчән, көмеш сыман йомшак ак металл — химик элемент; *русчасы:* олово. *Борынгы металлургнар бакырга аккургаш кушып ясалган кораллар ясый башлаганнар.* Табиг. буйс. юл.

АКЛАМА *и. сир.* Эшнең акка күчерелгән нөсхәсе; *киресе:* каралама.

АКЛАН *и. диал.* Урман тирәсендәге яки урман эчендәге зур булмаган ачыклык, алан. *Алар көннәрнең берендә урманнан чыктылар да --- бер акланга, яшел чирәм өстенә утырдылар.* Г. Ибраһимов.

АКЛАНУ I *ф. к.* агару (1—3 мәгъ.). *Яңа киемнәр кигән, Пакьләнгән, акланган.* Г. Тукай.

АКЛАНУ II *ф.* 1. Үзеңнең хаклы булуыңа, гаепсезлегеңә дәлилләр китерү, үзеңнең хаклылыгыңны, гаепсезлегеңне расларга тырышу. *Хәер, Мостафин акланыр торуны кирәк тапмады.* Ә. Еники.

2. Биргән бәянең, әйтелгән фикернең дөрес булып чыгуы, урынлы булуы, нәрсәнең дә булса дөреслеге кирәклеге фактлар белән раслану. [*Либреттода Гөлгенәнең кайтуы*] *берни белән дә акланмый һәм шуның өстенә беренче актта ук барлык вакыйганы тәмамлый иде.* М. Җәлил. // Өметнең яки хыялның тормышка ашуы. [*Сәлмән*] *Мидхәтне үз янына чакырып, бар белгәнен белән үгетләде. --- Ләкин атаның сәгатьләр буенча сабак биреп торуы бушка китте, көткәне акланмады.* Ф. Хөсни.

3. Гаепсез табылу, хөкемнән котылу.— *Әгәр кулаклар бу судтан акланып кайтсалар, аннан авылны бөтенләй ташлап кит.* Һ. Такташ.

АКЛАУ I *ф.* Ак итү, агарту. *Ябалактай яуган кар аклар Аклый микән кырларны?* Җыр.

АКЛАУ II *ф.* 1. Гаепсез дип, хаклы дип раслау, гаепсез табу, гаепсез дип күрсәтү. *Аларның күбесе Галимә апа белән Закир абыйчы аклау ягын тоткан кебек күренде.* М. Гафури. // Гаепсез дип хөкемнән коткару. *Судлар һәм безче аклый, барлык былчыраклан пакьли.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Үзеңнең нәрсәгә дә булса лаек булуыңны эш белән күрсәтү, раслау.— *Сезнең бу кадер-хөрмәтегезне, фронтта булсын, әдәбиятта булсын, чын эш белән акларга сүз бирәм.* М. Җәлил.— *Юк, син шушы эшең белән генә дә әтиеңнең, бүген син анда кирәклерәк, дигән сүзләрен акладың.* Г. Гобәй.

3. Яклау, хуплау, дөрес дип табу. *Суд карарын аклый кайнар алкыш, Ак сакаллы картлар, балалар.* Ф. Кәрим.

4. Кире кайтару, каплау. *Тотылган чыгымнарны аклау.*

5. Акка күчерү. *Кулымда [«Казакъ кызы»ның] караламасы бар иде. Шуның буенча 1912—1913 елларда мин моны яңадан аклап чыктым.* Г. Ибраһимов.

АКЛАШУ *ф. иск.* Өйләнешкәнче кыз ягы белән егет ягының вәгъдәләшүе; кыз ярәшү.— [*Нигъмәтҗанның*] *өйләнер заманнары. Ишан кызын аклашып торабыз.* Н. Исәнбәт.

АКЛЫ I *с.* Агы булган, ак төс катнаш. *Һәм ул үт чиксез матур: Күкле, кызыллы, аклы, ди.* Г. Тукай. // Җирлеге ак, ачык чуар, ак катнаш чуар. *Аклы күлмәк ник тектердең, Атна саен кимәгәч?* Җыр. [*Галимә апа*] *көн дә кия торган вак кына кызыл бөрчекле аклы*

күлмәген, аның өстеннән бу ел гына тектергән бишмәтен кигән иде. М. Гафури. // *и. мәгъ.* Ак яки аклы тукымадан тегелгән кием. *Аклы кимә, аклы димә, Аклы кер күтәрми ул.* Җыр.

АҠЛЫ II *с.* Ак төшкән; *к.* ак II (1 мәгъ.). *Кайчагында Фәйзулла агай миңа аклы күзен генә әйләндереп, калын тавыш белән әйтә.* Ш. Ҡамал.

АҠЛЫҠ *и.* 1. Ак булу.— *Энҗе чәчәкләр китерегез миңа! [Алар] аклыклары белән күзләрне чагылдырсыннар.* Ф. Әмирхан.

2. Яктылык. *Таң атканын шуннан беләм — Күктәге аклык белән.* Җыр. // Ак төс. *Таңнан башланган кар туктамады, яуды да яуды. Җир йөзе йомшак аклык белән капланды.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Вөжданлылык, намуслылык, сафлык. *Ул яна, бу дөньяны күрмәк булып аклык белән.* Ш. Бабич.

АҠМА *с.* Ага торган, агып тора торган. *Акма колак.* // *и. мәгъ.* Ага торган шеш.— *Аннан соң чишеп караганда күр дә тор менә, алла теләсә, шул дару салган җир бөтенләй акмага әйләнә.* Г. Гали.

АҠМЕИЗМ *и. тар.* Рус әдәбиятында 1912—1913 елларда формалашып, индивидуализмга өндәгән, «сәнгать — сәнгать өчен» дигән карашны күтәреп чыккан чиктән тыш реакцион агым.

АҠМЕИСТ *и. тар.* Акмеизм тарафдары, акмеизмга ияруче. *Акмеистлар поэзиясе.*

АҠР *и.* Англиядә һәм Америкада 4047 кв. метрга тигез булган җир үлчәве.

АҠРИХИН *и.* Бизгәккә каршы кулланыла торган дару. *Ефимыч бизгәк белән җәфалана икән. «Акрихиным бар, аның бит бөтен дарусы — хинин да акрихин»,— ди.* А. Расих.

АҠРОБАТ *и.* Циркта катлаулы гимнастика номерларын башкаручы артист.

АҠРОБА'ТИҠА *и.* Акробатлык сәнгате.

АҠРЫН рәв. 1. Хәрәкәт тизлеге җитәрлек булмау, гадәти тизлектән түбән булу турында.— *Юлда шофер белән талашып беттем... Акрын китергән кебек тоела.* Т. Гыйззәт. *Карт, эчпошыргыч рәвештә акрын кыймылдап, Сивашка таба борылды.* Г. Бәширов. / *с. мәгъ. Бераз юл яздыру булсын дип, ул акрын, борчулы адымнар белән шәһәр бакчасына табан юнәлде.* Г. Ибраһимов. // Көчсез (хәрәкәт, тәэсир турында). *Җил исә башлады, акрын гына башланган җил күәтләнә барды.* Ф. Әмирхан. *Ул, авыл өстенә йомшак канатын җәйгән таң һавасының акрын гына агылып торуын бөтен тәне белән тоеп, балалардай сулкылдап куя.* Г. Бәширов.

2. Ашыкмыйча, кабаланмыйча. *Бәдәр торып басты, Акрын гына өстен кагынды.* Ш. Мөдәррис. // *с. мәгъ.* Ашыкмый торган, кабаланмый торган, салмак, авыр хәрәкәтле. *Акрын кеше.* // Җайлап, ипләп. *Су алганда акрын ал ла, Батырып алсаң, болгана.* Җыр.

3. Тавышсыз, тавыш чыгармыйча. *Акрын гына басып, як-ягына карана-карана, сакланып кына Хәлил килеп керә.* М. Фәйзи. *Зөһрә белән Хәйри берәм-берәм акрын гына чыгып югалалар.* Г. Ибраһимов.

4. Пышылдап, тавышны күтәрмичә.— *Акрынрак сөйлә, монда һади Атласов бик якын утыра; ул ишетмәсен.* Ш. Мөхәммәдев. // Ишетелер-ишетелмәс итеп, йомшак кына.— *Син килгәч, акрын гына сызгырырсың.* М. Фәйзи. / *с. мәгъ. Мостафин, ашыкмыйча, никадәр ихлас күңелдән сөйләвен сиздереп торган акрын, йомшак тавыш белән Нәҗиягә үзенең үткән тормышын кыскача гына сөйләп бирде.* Ә. Еники. // Тыныч, шаушусыз.— *Акрын гына утырсагыз ла, тавышланмасагыз ла.* Г. Ҡамал.

5. Озак, көттереп (вакыт, гомер турында). *Караңгы төн акрын уза иде.* Г. Бәширов.

6. Акрынлап, вакыт үткән саен, торган саен, тора-бара (арта яки кими бару турында). *Акрын гына куера барган караңгылык иңә бүлмәгә.* Ә. Еники. *Йөрәгемдә саклап ялкыныңны, Акрын-акрын тәнем суынса, Хуш, акыллым.* М. Җәлил.

7. Сизелер-сизелмәс, аз гына, бераз. *Бала куркуычнан акрын гына калтырана башлады.* Ә. Еники.

АҠРЫНАЙТУ *ф.* Нәрсәнең дә булса хәрәкәт тизлеген, темпын акрын итү, киметү. *Чокырга җитәрәк тезгеннәрен тартып, атларның йөрешен акрынайттылар, нәрсәгәдер көлешә-көлешә, салмак кына атлатып килә башладылар.* И. Гази. *Ул тау итәгенә җитәрәк йөрешен акрынайта.* А. Шамов.

АҠРЫНАЮ *ф.* 1. Нәрсәнең дә булса тизлеге, темпы, ритмы кимү. *Аның адымнары кинәт акрыная башладылар.* А. Әхмәт. *Йөрәгемнең тибүе акрыная, мин үземдә гаҗәп тәмле хәлсезлек сизәм, йокым килә, бик йокым килә.* Ә. Айдар. *Бичара ат инде бөтенләй акрынайды: менә, менә туктарга җыена кебек иде.* И. Гази.

2. Тавыш йомшару, ишетелер-ишетелмәс хәлгә килү. *Гармонь тавышы торган саен акрыная бара.* Г. Бәширов.

АҠРЫНЛАНУ *ф. к.* акрынаю. *Моннан соң эш тагын акрынланды.* Ш. Ҡамал.

АҠРЫНЛАП *рәв.* 1. Ашыкмыйча, эзлеклелек белән, акрын гына. *Сафура су салып, чыра яндырып маташканда, кунак карчык, гадәте буенча аягын бөкләп утырды да, акрынлап, санап сүз башлады.* Г. Ибраһимов. // Саклык белән, сакланып кына. *Әлеге көтеп утыручыларның һәммәсе дә акрынлап, тавыш-тынсыз гына берәм-берәм үзләренең урындыкларын Гыйльмановның өстәле тирәсенә күчерделәр.* Ш. Ҡамал.

2. Торган саен, вакыт үтү белән (эзлекле үсеш, алга бару процессы турында). [*Эштә Нәфисәнең*] *авыр уйлары, төн караңгысы кебек, акрынлап тарала башлыйлар, ул эшенә мавыгып тынычлана төшә иде.* Г. Бәширов.

3. Акрынлык белән, озак, зарыктырып. *Минутлар бик акрынлап, эч пошырып үтәләр иде.* Ф. Әмирхан.

АҠРЫНЛАТУ *ф. к.* акрынайту.— *Алай булгач, сүз бетте,— диде Халикъ, тавышын акрынлатып.* Ш. Ҡамал. *Атларыбызны бераз акрынлатып, аларның артына юлга төштек.* Ф. Әмирхан.

АҠРЫНЛАУ *ф. к.* акрынаю. *Тавыш, чыр-чу, шаулау хөкем сөрә; соңга таба акрынлый.* М. Фәйзи. *Нәфисә --- сүз арасында акрынлый төшеп, нидер уйлап та алгалый иде.* Г. Бәширов.

АҠРЫНЛЫҠ *и.* Акрын булу; сүлпәнлек хәле. *Безгә хас түгел эштә акрынлык.* М. Җәлил.

Акрынлык белән — 1) ашыкмыйча, салмак кына, сүлпән генә, җай гына. *Яз җиле --- аерым бер акрынлык вә тынычлык белән исә дә дөньяга яңару вә яшәү исләре чәчә.* Ф. Әмирхан; 2) саклык белән. *Бик акрынлык белән шунда тышаулап шәп кара атны, [Батыр] карый башлый тирә-якны.* М. Гафури; 3) акрынлап, эзлекле рәвештә, торган саен. *Бала акрынлык белән генә булса да миңа ияләнә иде.* Каз. утл.

АҠСАҠ *с.* Аксап йөри торган, чатан (аяк авырту яисә имгәнү аркасында). *Аксак карт алаша да, арбага утырып килүчеләрдән озын соры чәчле Петров та аңа фронт юлдашлары иде.* Г. Ибраһимов. // *сөйл.* Аксый торган, икенчесенә караганда кыскарак, гарип, зәгыйфь (аяк). *Кырый урамнарга аяк бастымы, Шәмсетдиннең күзе мутлана, кашлары уйнаклый, хәтта аксак аягына хәтле сикертеп-сикертеп атлый иде.* Г. Бәширов. // *и. мәгъ.* Аксап йөри торган кеше, чатан кеше. *Аксак күп йөрер, күзсез күп күрер.* Мәкаль. // *сөйл.* Мебель турында: ватык, сыныҡ яки кыска аяклы, селкенә торган. *Аксак урындык.*

АҠСАҠАЛ *и.* 1. *тар.* Ыруг башлыгы. *Ыруг общинасын --- аксакаллар --- идарә иткән.* Урта гас. тарихы.

2. Авторитетлы, ихтирамга лаек карт. *Арысланбай авылның бае, аксакалы Дирбисал карт белән үзенең*

кайларда булуы, сөргеннән ничек кайтуы турында сөйләште. Г. Ибраһимов. // Гомумән карт кеше, олы яшьтәге кеше. *Кырда эшләүче сабанчылар, көтү булып килгән бу аксакалларны күргәч, башта бернәрсә дә төшенмәделәр.* М. Җәлил.

АКСАҚЛАУ *ф. к.* аксау (1 мәгъ.). *Актүш, Илсөярнең сүзләрен аңларга теләгән сыман, колакларын торгызып карап торды да башын тагын аска иеп аксаклап китеп тә барды.* Г. Гобәй.

АКСАҚЛЫҚ *и.* Аксак булу, аксап йөрү сыйфаты. *Хәзер [Абдуллин] бераз аксап йөри. Ләкин бу аксаклык аның төз буен бозмый.* А. Шамов.

АКСАҚ-ТУКСАҚ *сөйл.* **1.** *с.* Аксак, гарип. *Үзем һаман аксак-туксак әле, Эчтә кисәү һаман төтенли.* Ш. Маннур.

2. *җыйг. и.* Аксаклар, гарипләр, гарип-гораба.— *Аксак-туксагын, сукыр-чулагын — барын да төяп озаттылар.* Т. Гыйззәт.

АКСАТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* аксау (1 мәгъ.). *Шакир Зифа әбине янына утыртты да зур күк атны аксата-аксата басу капкасына таба чаптырды.* Г. Ибраһимов.

2. Кемнең яки нәрсәнең дә булса аягын имгәтү, зәгыйфьләндерү. *Сары малайны инде ул әллә ничә мәртәбә елатты, хәтта бер мәртәбә аның аягын да аксатты.* А. Шамов.

3. *күч.* Нинди дә булса эшкә тоткарлык ясау, кимчелек китерү, эшнең рәтен җибәрү, бозу. *Транспортны аксату, чыгырыннан чыгару өчен паровозларны чүкеч белән ватып ташлауның һич тә кирәге юк.* Ш. Камал.

АКСАУ *ф.* **1.** Аякның авыртуы яки гарип булуы аркасында йөргәндә бер якка янтаеп-янтаеп алу. [*Шәмсетдин*], *уң аягына бераз аксый төшеп, урамның кыл уртасыннан атлый иде.* Г. Бәширов.

2. Авырту, аксак хәлгә килү (аяк турында). *Аягың аксаса, таякка таянырсың, күзләрең күрми башласа, күзлек киярсең, мәхәббәтең сүрелә башласа, нишләрсең?* Ш. Хөсәенов.

3. *күч.* Нинди дә булса бер сыйфатның канәгатьләнерлек булмавы, кимчелекле булуы. [*Драматургның*] *пьесаларында иң мөһим як* [*табигыйлек*] *аксый.* М. Җәлил. // *с. мәгъ.* **аксаган.** Начар, сыйфаты түбән; кимчелекле, артта калган. *Корал мәсьәләсенә килгәндә, безнең иң нык аксаган җиребез шушы.* Ш. Камал. *Рифма ягыннан аксаган җырлар да җыентыкта байтак очрый.* М. Җәлил.

4. *күч.* **Алга** бик акрын бару, артта калу (тормыш, эш һ. б. турында). *Бик күп язучыларыбыз* [*үзләренең эшләрендә*] *бик аксыйлар. Алар тормышны аз беләләр.* Һ. Такташ.

АКСАУ-ТУКСАУ *ф. сөйл. к.* аксау (1 мәгъ.). *Мәдинәгә килү-килмәү турында ихтыяр бирелгән булса да, ул да, таяк тоткан килеш, аксый-туксый акрынлап килде.* Ш. Камал.

АКСЕЛЬБАНТ *и.* Кайбер армияләрдә генералларның, штабта хезмәт итүче офицерларның, адъютантларның хәрби киемнәрендә җилкә аша үткәрелә торган ука шнурлар. *Хәтта* [*Сәфәргалине*] *генералның күкрәгендәге крестлары, алтынланган погоннары, ука чуклы аксельбантлары да әллә ни айныта алмады.* Ф. Хөсни.— *Ә син, Нәфисә, шалтыравыклы шпора, укалы аксельбантлардан башыңны әйләндертмә.* Ш. Усманов.

АКСИОМА *и.* Дәреслеген исбат итеп торуның кирәге булмаган хакыйкать. *Табигать турындагы фәндә аксиомалар юк.* Д. Менделеев.

АКСЫЛ *с.* **1.** Ак төскә тартым ачык төс. [*Самовардан*] *күтәрелгән аксыл бу тәрәзә пыялаларын томалады.* С. Рафиков. // Якты. *Аксыл нурлары белән өметләндереп, ак таң килә.* Г. Ибраһимов.

2. Төссез. *Ниндидер көрәк сакаллы бер кеше аксыл гына чырайлы, шәһәрчә, ләкин бик тәкәллефсез генә киенгән бер кызны шәһәргә алып бара.* Ф. Әмирхан.

3. Төсне атаган сүзләр янында шул төснең сыек булуын, ак төскә тартым булуын белдереп килә. [*Тургай*] *күкнең аксыл зәңгәр тирәнлегеннән карлыгачның үзенә дә төклетура хәтле генә булып күренде.* Г. Бәширов.

АКСЫЛЛАНУ *ф.* Аксыл төскә керү. *Яфраклар җәйге карасу яшеллекләрен югалтып, аз гына аксыллана башлыйлар.* Г. Галиев. // Кара төстән яки караңгы хәлдән агара, яктыра бару. *Тәрәзә пыялалары аз гына аксылланды.* Г. Әпсәләмов. *Инде күк йөзе аксыллангannан-аксыллана бара.* А. Шамов.

АКСЫЛЛЫК *и.* **1.** Аксыл булу.

2. Ак төс. *Бүген иртән ап-ак кырау төшкән, Ил өстендә көмеш аксыллык.* М. Җәлил.

АҚСЫМ *и.* Организмдагы күзәнәкләрнең протоплазмасын һәм төшен төзи торган төп материал. *Аксымнар аминокислоталардан торалар.* Анатомия.

АҚСЫМЛЫ *с.* Аксымга бай, составында аксым күп булган. *Аксымлы азык.*

АҚСЫРГАК *и.* Лаләчәләр семьялыгыннан юан тамырлы, эре яфраклы, себерке сыман чәчәкле агулы кыр үсемлеге; *русчасы:* чемерица. *Аксыргак бар җирдә ат үлмәс.* Мәкаль. *Әбиләр тамыр-томыр, аксыргак, дарудәрман үләннәре җыярга киттеләр.* И. Рәмиев. // *с. мәгъ.* Аксыргакка мөнәсәбәтле. *Аксыргак тамыры.* // *күч.* Агу. *Ул карт күсегә* [*Габкаһарга*] *әллә кайчан аксыргак бирергә кирәк иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АҚСӨЯК *и.* **1.** *иск.* Затлы, югары нәселдән булган кеше, аристократ.— *Яшермә әйт, егет, син бары көтүче генәмә? Яки шул киемнәр астына яшеренгән бер аксөякме?* М. Фәйзи.

2. *күч.* Эшне сәйми, чистаны, тәмлене, йомшакны гына ярата торган артык назлы кеше.— *Зөфәр аксөяк бит ул, аның үзен карарга бер кеше кирәк.* Ә. Еники.

АҚСӨЯҚЛЕҚ *и.* Аксөяк булу. *Штабс-капитан озын буйлы, таза гәүдәле, һәрнәрсәне үзенең аксөяклек вкусына карап эшләргә ярата торган чын аристократ табигатьле бер офицер иде.* М. Гали.

АКТ *и.* **1.** Дәүләт, җәмгыять күләмендә зур әһәмияте булган указ, карар.

2. Нинди дә булса юридик факт турында документ, беркетмә. *Язылган актны суд тикшерүчесе: буталчык һәм бик томанлы язылган, диде.* Ш. Камал.— *Кеше өстенә яла ягып торсаң, үз өстеңнән акт төзермен.* Р. Ишморат.

3. Драма әсәренең яки спектакльнең тәмамланган бер өлеше; пәрдә. [*Балетның*] *икенче һәм өченче актлары тагын да зуррак уңыш белән барды.* Ш. Хөсәенов.

4. *сир.* Уку йортларында уку елы тәмамланганнан соң үткәрелә торган тантаналы җыелыш.— *Берсекөнгә* [*университетта*] *тантаналы акт була дип ишеттем.* Р. Ишморат.

Актлар залы — уку йортларында тантаналы җыелышлар уздырыла торган зур зал.

АКТАМЫР *и. бот. к.* сарут. *Актамыр атка булган үчен сабаннан алыр.* Мәкаль.

АКТАРУ *ф.* **1.** Бергә торган әйберләрнең астын өскә китереп бутау, элеккеге тәртибен бозу. *Кулына кисәү агачы тотып мич актара торган Гөлбаһар абыстай үзенең корымга буялган кулларын аларга күрсәтәсе килмичә, оялып, алъяпкыч аша гына сузды.* М. Гали.

2. Әйберләр арасыннан нәрсә дә булса эзләү. *Бу вакыт Зыя, кәнәфисеннән торып, китаплар шкафы янында нидер актара иде.* Г. Ибраһимов. // Нәрсә дә булса эзләп, әйбернең астын өскә китерү.— *Минем өйне, идән асларын да актарырлар микәнни?* Ш. Камал.

3. Казып, сөреп бозу (җир, юл турында). *Газинур --- автомашиналарның тәгәрмәчләре һәм чылбырлы трактор актарып бетергән киң урамның аргы башына таба йөгереп китте.* Г. Әпсәләмов. // Төен, төргәк кебек әйберләрне чишеп, эчен тикшерү. *Зиннәт, үз*

квартираларына төшкәч, төргәкне актарып карады. А. Шамов.

4. Нәрсәне дә булса тузгыту, сибү, тарату. *Янган өйләр көлен актара җил, Зур кайгы бар төсле аңарда.* З. Мансур. // Туздыру, пыран-заран китерү, юк итү. [*Хан:*] *Ясак түләүдән баш тарткан башкорт, Нугай илләрен барып актардым.* М. Җәлил. // Юк итү, юкка чыгару. *Эш кенә безне богаудан коткара, Эш кенә барлык канунны актара.* Н. Исәнбәт.

5. Аста, эчтә ятканнарны казып чыгару. [*Дуңгызлар*] *үзләре актарган туфракка ятканнар да әкрен генә мыркылдыйлар.* Г. Әпсәләмов. [*Фашистларның*] *гәүдәләрен ач бүреләр сөйрәр, ә күзләрен козгын актарыр.* Ш. Маннур. // Вату, казу; ишү (җир асты байлыкларын чыгару турында). *Кайберләре ташлар актаралар, Кәйлә белән сугып, көч белән.* М. Гафури.

6. Китап, дәфтәр кебек нәрсәләрне ачып-ачып карау, битләрен бер-бер артлы ачу. *Шул вакытта мин кулыма китап алам, Аның изге сәхифәләрен актарам.* Г. Тукай. *Бикмулла куен кесәсеннән чуар тышлы озынча бер дәфтәр чыгарды да, бармакларын төкереклəп, актарырга тотынды.* Г. Бәширов. // Төрле кәгазьләр, язмалар, китаплар арасында эзләнү. *Кәримов кәгазьләр актара башлый.* А. Әхмәт.

7. *күч.* Узган гомердән кайбер вакыйгаларны искә төшерү, хәтерне барлау. *Иске хатирә дәфтәрен актарган адәм кеби, артта калган күренешләрне актара башлыйм.* Г. Ибраһимов.

8. *күч.* Күздән кичерү, күзләр ярдәмендә тикшереп, айкап чыгу. *Күзләрем бөтен пароходны актардылар, - - - пристаньга төштеләр һәм анда Хөршитне таптылар.* Ф. Әмирхан.

9. *диал.* Коеп яңгыр яву. *Менә инде бер атнадан бирле халык иген сугарга аяз көннәр көтә, ә ул чиләкләп кенә актара.* К. Нәҗми.

Актарып ташлау—1) җыйнак торган әйберне тарату, таратып ташлау, сибү. *Хәят, гадәтенчә, комод тартмаларын актарып ташлады да, йөз кат күргән нәрсәләрен йөз дә беренче кат күздән үткәреп чыкмакчы булды.* Ф. Әмирхан; 2) өемнең өстен алып ташлау, ишеп төшерү. *Ул, күз ачып йомганчы, өстендәге саламнарын актарып ташлады.* Г. Ибраһимов. **Актарып чыгару** — 1) күмелеп аста калган, югалган яки онытылган нәрсәне эзләп табу. [*Нәгыйм*] *мич башыннан күгәреп беткән ышкы актарып чыгарды.* Г. Ибраһимов; 2) үткән, элек булган вакыйганы, эшне казып чыгару, аның асылын чишү. *Моннан биш ел элек булган бер эшне актарып чыгарып, хөкемгә биргәннәр;* 3) әйбернең эч ягын әйләндереп чыгару.

АКТАРЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* актару (4 мәгъ.). [*Тырмалаганда*] *дымлы кара туфрак, күңелне рәхәтләндереп, тәмле ис аңкытып актарыла башлады.* И. Гази. // Эче тышка әйләнеп чыгу, бүселү.

2. Ватылып, җимерелеп, әйләнеп, авып төшү. *Тупка эләккән мәчет манарасы Актарылып төшкән бөтенләй.* Ф. Кәрим.

3. Ишерелеп агу, айкалу, кайнап болганган кебек хәрәкәттә булу (сыеклык, һава, болыт һ. б. турында). *Киң Иделдә актарылып бозлар актылар.* Г. Хуҗиев. *Жил котырган Давыл булып, Актарылган кара болыт Жирнең өстендә.* Ә. Исхак.

АКТАРЫНУ *ф. Кайт. юн. к.* актару (2 мәгъ.). Әйберләрне актарып, нәрсә дә булса эзләү.— *Нилəр актарынасың анда, Шәмси туган?* Г. Бәширов. *Мәрхәбә туктамады, тагы бирнә сандыкларында актарынырга тотынды.* Г. Ибраһимов. // Тикшеренү, өйрәнү, эзләнү. *Кем ул сары Хисмәт, нинди кеше,, Кем малае булган туганда? — Бу турыда автор байтак кына Актарынды төрле урында.* Ш. Маннур.

АКТЁР *и.* Театр яки кинода рольләр башкаручы, артист. *Туган-үскән кырын ныграк сөйде* [*Харис*], *Бик килсә дә актёр буласы.* Ш. Мөдәррис.

АКТЁРЛЫК *и.* Актёр профессиясе, хезмәте; актёр (артист) булу. *Татар театрын тудыру, хәзерге татар әдәби телен барлыкка китерү кебек бөек хезмәтләре өстенә,* [*Г. Камалның*] *актёрлык, карикатурачылык һәм каллиграфчылык кебек хезмәтләрен дә онытырга ярамый.* М. Гали.

АКТИВ I *и.* 1. Партия һәм җәмәгать оешмасы членнарының яки берәр коллективның иң алдынгы, эшлекле, политик яктан чыныккан җитәкче өлеше. *Утырышта колхозның бөтен активы диярлек җыелган иде.* Г. Бәширов. *Авылга кайтып китү алдыннан, комсомол активын җыеп, шәһәр күләмендә җыелыш уздырылган иде.* М. Әмир.

2. *с. мәгъ.* Һәрвакыт җәмәгать эшләрендә катнаша торган, алдынгы, эшчән, энергияле; *киресе:* пассив. *Бу төркемнән М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал һ. б. социализм төзелешенең актив эшчеләре булып киттеләр.* М. Җәлил. // *рәв. мәгъ.* Турыдан-туры, бик нык, бөтен көчен, энергиясен биреп. *Большевистик газеталарда эшләү һәм революция дошманнарына каршы сатирик шигырьләрен язу белән бергә,* [*Г. Камал*] *татар совет театрын үстерү эшендә актив катнашты.* М. Гали.

АКТИВ II *и.* Предприятие балансының бер өлеше (материаль кыйммәтләрнең бөтен төрен дә кертеп).

АКТИВИСТ *и.* Политик көрәштә, төрле оешма һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашучы.

АКТИВИ'СТКА *и.* Хатын-кыз активист. [*Мисалга*] *активистка Гайшәнең һәм шәһәрдә партия эшчесе Нәгыймә типларын алыгыз.* Г. Нигъмәти.

АКТИВЛАНУ *ф.* Актив булып китү; активист булып китү.

АКТИВЛАШТЫРУ *ф.* Тагын да активрак итү.

Активлаштырылган күмер *хим.*— сеңдерү сәләтен көчәйтү өчен, кайнар пар белән эшкәртелгән күмер. *Активлаштырылган күмер шикәр согын чистарту, төрле газларны йоттыру һәм чистарту өчен, шулай ук сулыш органнарын агулый торган матдәләрдән саклау өчен противогазларда кулланыла.* Химия.

АКТИВЛАШУ *ф.* Активлану, актив булып китү, эштә активлык күрсәтә башлау. *Ибрай, Имәли, Күчәрбай кебекләрнең активлашулары һәм алар рәтенә кергән башка крестьяннарның да яхты йөз күрсәтүләре безгә батырлык бирәләр.* М. Әмир.

АКТИВЛЫК *и.* 1. Актив I (1 мәгъ.) булу, активист булу.

2. Актив эшчәнлек. *Шагыйрь Әхмәт Ерикәйнең җыр-романс өлкәсендәге активлыгы аеруча шушы* [*30—40 нчы*] *елларда күтәрелде.* М. Җәлил. *Нәсимә белән Миңсылу бу эштә активлык күрсәтәләр.* Ш. Камал.

А'КТЛЫ *с.* Күпмедер акттан торган, бүлектән торган. *2 актлы опера.*

А'КТОВЫЙ: актовый зал *сөйл. к.* актлар залы. *Казан университетының актовый залы.*

АКТРИ'СА *и.* Хатын-кыз актёр, артистка. [*Байбәтчә*] *актрисаларга* [*бүләк итә*] *алтын йөзек һәм браслет.* Ш. Мөхәммәдев.

АКТУАЛЬ *с.* Хәзерге чор, шушы момент өчен бик мөһим, әһәмиятле; заман таләпләренә җавап бирә торган. *Ш. Камал чорның зур актуаль мәсьәләләрен алып, пьесада шуны бөтен кискенлеге белән ачык куярга ярата.* Г. Нигъмәти.

АКТУАЛЬЛЕК *и.* Актуаль булу, әһәмиятле булу, мөһим булу. *Чыннан да, Г. Камал биргән типлар — хәзерге көн өчен дә үзләренең актуальлеген югалтмаган, реаль, җанлы кешеләр.* М. Гали.

АКТЫГЫНДА *рәв. сөйл.* Ахыр чиктә, соңгы чиктә. *Нәкъ шушы ел көз көне ул Нәфисәнең күңелен аулап, башын чуалтып, актыгында аңар йортка керде.* Ш. Камал.

АКТЫК 1. *и.* Ахыр, азак, соң. *Бу авылда социализм төзелешен актыгына кадәр алып барырбыз.* Һ. Такташ.

2. *с.* Ахыргы, азаккы, соңгы. *Кызыл гвардия, үзе генә калып булса да, туган шәһәрен актык тамчы канга кадәр саклаячак.* Ш. Усманов.

3. *и.* Нәрсәнең дә булса иң соңгысы. [*Михайлов:*] *Куй! Күрәсең бит, актыгы. Әнә, күрмисеңмени, винтовка алырга йөгереп киләләр.* А. Шамов. // Төпчек, иң кечкенә бала.— *Кайттыңмы, улым, алтыным! Куанычым минем, актыгым.* М. Җәлил. / *с. мәгъ.* [*Гөлниса Газизгә:*] *Син бит минем актык улым, төпчек улым.* А. Әхмәт.

◇ **Актыгы булсын (булыр)** — нинди дә булса эшне яңадан кабатламаска кушып кисәтү яки кабатламаска сүз бирү.—*Таң белән җир астына төшеп, көн буе күмер чабасы юк инде. Шушы актыгы булсын.* И. Гази. **Актык сулыш** — үлем алды. [*Бала*] *анасының актык сулышында актык бурычын түләргә килгән, имеш.* Ш. Камал. **Актык сүз** — 1) доклад яки беседаны тәмамлау рәвешендә әйтелә торган нәтиҗә, йомгаклау чыгышы.— *Актык сүзем шул: бүген икмәк — җиңү ул! Бүген сугышчы синнән икмәк көтә!* Г. Бәширов; 2) *махс.* гаепләнүчегә бирелә торган соңгы сүз. *Шуның белән биш гаепләнүченең актык сүзләре бетте.* Г. Ибраһимов; 3) бәхилләшү сүзе, бәхиллек. *Актык сүзләреңне әйтә алмый Яткансыңдыр, туган, тилмереп.* М. Гафури. **Актык чиктә** — башка ышаныч, мөмкинлек калмагач, башкача булдыра алмагач, ахырда.— *Актык чиктә, губком аркылы булса да, аны эшләтү чарасын күрергә кирәк.* Ш. Камал. **Актык җавап** — катгый җавап. *Нч булса да булыр, иртәгә сиңа актык җавабымны җибәрермен.* Г. Коләхметов.

АКТЫККЫ *с.* Ахыргы, соңгы. *Рәүфә куначадагы этәчнең актыккы кычкыруы белән тора.* А. Шамов. *Актыккы ике курсның күбрәк өлеше тәҗрибә өстендә үтелде.* Ш. Камал.

АКТЫКТА *рәв.* Ахырда, азакта. *Шул кичне без, бергә туры килеп, Чирәмлеккә сузылып яттык та, Әкрен генә көлешеп, сер бүлештек... Тирән уйга баттык актыкта.* Ш. Маннур. // *кер. сүз функ.* Актыгында, ахыр чиктә.

АКТЫКТАН *рәв.* Соңыннан, нәрсә дә булса хәл ителгәннән соң, эш үткәч.—*Актыктан ишетелсә, эти буран туздырыр бит.* Ф. Әмирхан. // Ахырдан, соңыннан. *Алар шулай итеп таныштылар, актыктан бик дуслаштылар.* Һ. Такташ. [*Җәяүлеләр*] *артыннан тачанкаларга көйләнгән пулеметлар, иң актыктан тупчылар кузгалды.* Г. Бәширов.

АКУ'ЛА *и. зоол.* 1. Башының аскы өлешенә урнашкан зур авызлы, бик зур гәүдәле ерткыч диңгез балыгы. *Йөри Мортый вак малайлар арасында, Акуладай куркыныч бер балык төсле.* З. Мансур.

2. *күч.* Эксплуатация, конкуренция хөкем сөргән җәмгыятьтә ерткычлык, барысын да үзенә аулау, йоту мәгънәсен белдерү өчен кулланыла: иң зур монополист яки иң куркыныч капкын.— *Семенов шикелле аумакай меньшевик этләрнең революцион демократия дигәннәре шул әлеге Михаил Степаныч, Федор Спиридонович шикелле юан корсак акула балыклары ич.* Ш. Камал.

АКУ'СТИК I *и.* 1. Акустика буенча белгеч.

2. *сөйл.* Тавыш тоткыч аппаратлар белән эш итүче. *Көймә су төбеннән бара иде, Шаховский акустикның донесениесен тыңлап тора.* Г. Әпсәләмов.

АКУ'СТИК II *с.* Акустикага мөнәсәбәтле. *Акустик аппарат. Залның акустик шартлары.*

АКУ'СТИКА *и.* 1. Физиканың тавышны өйрәнә торган бүлеге.

2. Биналарда музыканың яки сөйләүнең ишетелүчәнлек шартлары. *Әллә рояле чынлап та артык шәп иде инде, әллә залның акустикасы яхшы иде.* Соц. Тат.

АКУШЕР *и.* Акушерлык буенча врач-белгеч.

АКУШЕ'РКА *и.* Хатын-кыз акушер.

АКУШЕРЛЫК *и.* 1. Медицинаның йөкле хатыннарга ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен карый торган бүлеге.

2. Акушер яки акушерка профессиясе; акушер булу. // *с. мәгъ.* Акушерлар хәзерли торган. *Акушерлык курслары.*

АКЦЕНТ *и.* 1. *махс.* Сүздәге басым. // Басым билгесе.

2. Бер тел авазларын һәм сүзләрен икенче бер тел законнары тәэсирендә бозып, үзгәртеп әйтү. *Яковның аз гына акцент белән булса да бик оста татарча сөйләшә белүе аларны бер-берсенә тагын да якынайта төште.* М. Әмир. // Диалект яки сөйләшләрдәге әдәби тел нормаларыннан аерымрак булган әйтелеш. *Рәхим итегез! — диде ул саф татарчалап, ләкин берникадәр мишәр акценты белән.* А. Шамов.

3. *муз.* Ритмик басым.

АКЦЕНТА'ЦИЯ *и. махс.* 1. Билгеле бер телгә хас басымнарны дөрес кую.

2. *күч.* Нәрсәгә дә булса басым ясау, игътибарны көчәйтү. *Хәзерге өлкән мастерларыбызның новаторлыгына, метод, стиль, проблематика һәм жанрлар өлкәсендәге казанышларына акцентация көчлерәк ясалса, безнеңчә, отышлырак булыр иде.* Каз. утл.

АКЦИЗ *и.* 1. Капиталистик илләрдә һәм патша Россиясендә: илдә эшләп чыгарылган товарларга, бигрәк тә киң куллану әйберләренә салына торган өстәмә налог.

2. Шундый налогларны җыю учреждениесе.

АКЦИОНЕР *и.* Акцияләр хуҗасы, капиталист. // *с. мәгъ.* Акционерга мөнәсәбәтле. *Акционерлар җәмгыяте.*

А'КЦИЯ I *и.* Капиталистик предприятиеләргә билгеле бер пай взносы кертелгәнне раслый торган кыйммәтле кәгазь — пай документы. *Француз капиталистлары үзләре чит мәмләкәттәге нәрсәләрнең акцияләрен вә шул җөмләдән Румыния нефте акцияләрен дә сатарга мәҗбүр.* Ф. Әмирхан.

А'КЦИЯ II *и.* Берәр максатка ирешү өчен башкарылган эш, хәрәкәт. *Дипломатик акция.*

АКЧА *и.* 1. Дәүләт тарафыннан чыгарылган, сатуалуда әйбер бәясенең үлчәве булып хезмәт итә торган металл һәм кәгазь билетлар. [*Габдулла*], *сынатмас өчен, акчасы беткәнлекне әйтмәде.* Ә. Фәйзи.

2. *күч.* Капитал; байлык.— *Әле менә теге юләр Йосыф хатыны акча белән калды да, әнә нинди чибәр кешегә барды.* Г. Камал. // Кадерле нәрсә. *Вакыт — акча, кадерен белмәсәң — кача.* Мәкаль.

◇ **Акча дусты** — акча ярата торган кеше, акча запасы туплый торган кеше. *Ул ничаклы саран, ничаклы акча дусты булса да, хатын вә балаларын да киендерде.* Г. Ибраһимов. **Акча колы** — акчага табынган кеше, акчаны бар нәрсәдән өстен куючы. *Сатылганнар французлар — Акча коллары, комсызлар.* Г. Камал. **Акча сугу** — 1) акча эшләп чыгару; 2) күплән акча алу, кулга күп акча төшерү.— *Беләсеңме, яз көне базарда күпме акча сугып була аннан* [*бодайдан*]. Г. Бәширов. **Акча тозагы** — артык эшкә ярамый торган, ләкин бәясе бик кыйммәт булган нәрсә. **Акча тору** — 1) акчага сатып алган әйбер булу, бәһале булу (әрәм-шәрәм итәргә ярамауны кисәткәндә кулланыла); 2) акчага сатарга, акча эшләргә мөмкин булу (әйбернең сатарга яраклы булуы турында).— *Миңа бит бүген яшәргә мөмкин* [*шешәне күрсәтеп*]. *Бу бит акча тора. Моңар бит бер кадак икмәк алып ашап тамак туйдырырга мөмкин.* Г. Камал. **Акча төшерү (табу)** — эшләп акча алу, кулга акча керү. *Кайтыр идем өемә, кар яугандыр юлыма. Кар яуса да, машина бар — акча төшми кулыма.* Җыр. *Акча табуы бик уңай эш түгел.* М. Гафури. **Акча эше** — хезмәт хакы акча белән түләнә торган эш. **Акча чөеп уйнау** — акчаның иләк яки күн ягы белән төшүенә карап, оту һәм отылудан гыйбарәт булган отыш уены. *Бер төркем егет, читкә китеп, акча чөеп уйнарга керешкән.*

те. М. Гали. **Акча эшләү** — эшләп акча табу, акчалы булу.— *Син борчылма, әни, мин ике-өч ай эшләгәч үк әйләнеп кайтырмын. Акча эшләп баеп кайтырмын.* Р. Ишморат. **Акча җимеше** — акчага алынган, сатып алынган әйбер турында (әрәм-шәрәм итүгә каршы әйтелә). **Акча җимеше түгел, бакча җимеше** — азыкны ашарга кыстаганда, **тартынмый** ашарга өндәп әйтелә. **Акчадан уйнау** — акча отышлы уен уйнау.— *Мондагы татар бай угылларын, яшь байларны да карта уйнарга өйрәтә башладым.— Акчадан уйныйлармы?* Ш. Мөхәммәдев. **Акчасыз комедия** — тормышта комедиягә охшаш вакыйга турында. *Хәзергә кадәр Миңлесылу белән хәзрәтнең акчасыз комедияләреннән көлеп карап утырган балалар бабаларының болай бер дә көтелмәгән җирдә елап җибәрүеннән аптырашта калдылар.* Ф. Әмирхан. **Акчасыз фатир** — төрмә.— *Элгерләр әле, акчасыз фатирга кергәннәрен сизми дә калырлар.* Г. Камал.

АКЧАЛАТА *рәв.* Акча белән, акча кылеш, натуралата түгел. [*Колхоз*] *колхозчыларына итен, сөтен мул итеп бирү генә түгел, акчалата да өләшә икән.* Ә. Еники. // Акчага әйләндереп, акча исәбе белән (исәпләгәндә), акча исәбенә салганда. [*Бакча*] *ел саен колхозга 100 мең сум чамасы акчалата доход китерә башлады.* Г. Галиев.

АКЧАЛЫ *с.* 1. Акчасы бар, акчага бай, дәүләтле.— *Булганым бар анда* [*Парижда*], *матур шәһәр, бигрәк тә акчалы кешеләргә. Ләкин Ленинградны мин аңа гомердә алмаштырмас идем.* Г. Әпсәләмов. // *и. мәгъ.* Акчасы булган кеше. *Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный.* Мәкаль.

2. Түләүле, акчалата түли торган. *Яңа елдан үк акчалы хезмәткә күчерелгән сыер савучыларга түләү ни сәбәптәндер тоткарланды.* М. Шабай. // Акча күп (күбрәк) түли торган.— *Юк, акчалы эш эзләп беркая да китәчәк түгелмен, абый! Миңа шушы үз җирем кадерле!* Ф. Хөсни.

Акчалы уйнау — отышлы уеннарда акчалата түләп уйнау. [*Эшчеләр*] *аз гына эштән бушаган арада да, карта белән яхут «орлянка» чөеп, акчалы уйный иделәр.* Ш. Камал.

АКЧАРЛАК *и.* Йөзүче кошлар семьялыгыннан озын канатлы һәм озын томшыклы, ак яки соры төстәге куе йомшак мамыклы, балык белән туклана торган кош. *Бер менеп, тагын уктай төшеп, Балык аулый җитез акчарлак.* Ш. Мөдәррис. *Дулкыннарда йөзгән акчарлакка Мин охшатам сине дә.* М. Җәлил.

АКЧАСЫЗЛЫК *и.* Акчага мохтаҗлык.

АКШАР *и.* 1. Акшарлау, агарту өчен китә торган ак балчык, акбур. [*Гайшә*], *Шәмсетдингә утыз кадак* [*он*] *биреп, мичне дә чыгартты. Акшары күптән бар иде.* Г. Ибраһимов. // Ак балчыктан, акбурдан хәзерләнгән куе сыекча һәм шулар белән берәр өслекне агартканнан соң кипкән катлам. *Акшары коелып беткән, бер якка кыйшайган мичнең корымлы авызы шомлы гына ыржаеп тора.* А. Шамов.

2. *күч. ирон.* Пудра, кершән. [*Мидхәтнең*] *таш курчак кебек акшарга буялган «тәти апалар» белән эше барып* [*чыкмады*]. Ф. Хөсни.

АКШАРЛАУ *ф.* 1. Акшар белән буяу, агарту.— *Заводтан бераз акбур сорап ал. Өйне яхшылап акшарламыйча, юмыйча кермибез.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч. ирон.* Пудра ягу, кершән ягу, пудралау.

АКШАРЛЫ *с.* 1. Акшарланган, агартылган, акшарга буялган. *Инде күк йөзе аксыланганнан-аксыллана бара, авыл читләрендәге акшарлы йортлар, көрләп үсеп торган бакчалар төн пәрдәсе астыннан чыгып, беленер-беленмәс кенә шәүләләнә башладылар.* А. Шамов.

2. *күч. ирон.* кершән сөртенгән, бик нык кершәнгә буянган. *Китерттек берничә акшарлы кыз да.* Г. Тукай.

АКЫЛ *и.* 1. Кешенең уйлау, фикер йөртү сәләте, аңлылык дәрәҗәсе. *Акыл яшьтә түгел — башта.* Мәкаль. [*Бирем әкә:*] *Акылың бар, уйларга чамаң бар, ничек итеп шундый бер ярамаган эшне башыңа керттең син?* Г. Ибраһимов. // *шигъ.* Галим, бөек акыл иясе кеше. *Ә дөньяның якты акыллары Омтылганнар аңар* [*бәхеткә*] *җитәргә.* Ш. Маннур.

2. Иҗтимагый аң, иҗтимагый фикер.

3. Киңәш. [*Тәзкирә Сәйфигә:*] *Яшьләргә акыл бирәсе урында, тешләреңне ыржайтып, карт алашадай кешнәп утырасың?* Г. Бәширов.

4. Уй, фикер.— *Чишмәне буралап, өстен каплап зерә дә яхшы эшләгәннәр, кайсы изге бәндәнең башына килде бу акыл?* Ф. Хөсни. *Бармаклары белән туфракны казыштырып йөри торгач,* [*Тимеринең*] *башына бер акыл килде.* Г. Бәширов.

5. *сөйл.* Акыллылык.— *Узең яп-яшь малай гына, Сүзең шундый акыллы... Сезнең походка катнашмый, Читтә калу акылмы?!* М. Җәлил.

6. Алдын-артын уйлау, уйлап эш итү, кешенең үзенә, үз хисләренә контроле.— *Ак кулыннан тотыйм-тотыйм;— Җибәр, диеп, Шул вакытта акыл белән кул талаша.* Г. Тукай. *Акыл аны юатса да «Шикләнәсең юкка!» дип, Ул хат килгән көнне Булат Төн үткәрә йокламый.* М. Җәлил.

7. *күч.* Сабак. *Моннан соң алай эшләмәскә акыл булыр.*

Акыл теше — егерме яшьләрдә чыга торган иң кырыйдагы азау тешләр. *Гадәттә акыл тешләре 18—25 яшьләрдә чыга, еш кына алар бик кечкенә булалар һәм тиз бозылалар.* Анатомия. **Акыл теше чыгу** — балигъ булу. **Акыл хезмәте** — физик энергиядән башка, киеренке уй, фикер йөртүне, аң эшен таләп итә торган хезмәт.

◇ **Акыл белән** — 1) төптән уйлап, җентекле тикшереп. *Оешкан рәвештә, акыл белән эшләргә кирәк.* К. Нәҗми; 2) белемгә нигезләнеп. *Әмма* [*балаларыбызның балалары*] *ипине акыл белән үстерерләр, машина белән эшләрләр.* Г. Бәширов; 3) Күңел хисләренә, хискә бирелүгә каршы куеп әйтелә. *Ләкин* [*Шакировта*] *күңел хисләренә караганда, акыл белән эш итү һәрвакыт өстенлек ала торган иде.* А. Шамов.— *Гаилә мәсьәләсен кайнар тойгылар кушуыннан чыгып кына түгел, бәлки --- акыл белән хәл кылырга кирәк.* Р. Ишморат; 4) нинди дә булса максатны истә тотып, шул максат өчен. *Ләкин бу өстән генә, акыл белән генә ярату булса кирәк.* Г. Ибраһимов. **Акыл бирү** — киңәш бирү, киңәш итү.— *Айсылу белән Тимери абзыйга тагын да рәхмәт, алар акыл бирделәр, булышып тордылар.* Г. Бәширов. **Акыл ирешә алмаслык (алмый торган)** — аңлый, төшенә алмаслык.— *Кеше акылы ирешә алмый торган бернәрсә дә юк.* Г. Әпсәләмов. **Акыл иясе** — 1) зирәк акыллы кеше; 2) галим. *Айлы кичтә яуган береңче кар тәңкәләрен син чәчәкләргә охшатып, сүзне --- тирән хисле зур акыл ияләренә бордың.* Г. Кутуй. **Акыл йөртү** — уйлау, фикерләү. **Акыл казаны бушау** *кимс.*— аңы, акылы кимү, зиһене таралу.— *Картның акыл казаны бераз бушаган әле аның, уйлап җиткерә алмый ул.* М. Гали. **Акыл керү** — 1) тормышны аңлый, аера алырлык хәлгә килү, аңлылану; тормышка җитди карый башлау, җитдиләнү. [*Шәмсия:*] *Картайганчы акыл кермәде, җиткән улларың, үскән кызларың бар, ә син, юләр, эчеп йөрисең.* Т. Гыйззәт; 2) сабак алу, авызы пешү, ялгышын аңлап, башка кабатламаслык хәлгә килү.— *Төрмәдә ятып та акыл кермәгән икән үзеңә.* Ш. Камал. **Акыл китү (чыгу)** — 1) картлык яки авыру сәбәпле уй, фикер йөртү сәләте кимү. *Кайберәүләр: моның картлыгы җиткән, акылы китеп калган, диделәр.* Г. Ибраһимов; 2) артык киеренке хисләр аркасында салкын канлылык күрсәтү, үзенә һәм эшенә, сүзләренә контрольлек кимү, нишләгәнен белмәү. *Әллә хис дигән нәрсәгә артык бирелеп китеп, акыл чыгып торган чакларда була торган бер кабынып китү генәме бу?* Г. Гобәй. **Акыл көче** — аң-белем, гыйлемнәр җыелма-

сы.— [*Тауны актарып ташларга*] *электрик көче белән акыл көче генә кирәк. Электрик көче* [*Агыйделнең*] *үзендә бар. Акыл көче — үзебездә.* М. Әмир. **Акыл сату** — 1) артык күп сөйләү.— *Әйдә, әйдә, акыл сатма, - - - йолкыш малай.* А. Әхмәт; 2) фикер йөртү, уйлау һәм үз карашыңны башкаларга сөйләү, белгән булып, кешегә киңәш бирү. *Нәфисә китеп барганда, Сәйфи якты чырай күрсәтеп акыл сатарга тотынды.* Г. Бәширов. **Акыл сыекланy** — зиһене кимү, уй, фикер йөртү сәләте начарлану. [*Искелек*], *яшерен чир төсле, яңадан бәреп чыга инде ул. Бигрәк тә Бикбулат шикелле акылы сыеклана башлаган борынгы картларда.* Г. Бәширов. **Акыл сыйдырмау** — ышанып булмау. **Акыл утыру** — яшьлек юләрлекләрен ташлап, җитдиләну, акыллылану; балигъ булу. *Гомер утә, туры килгән форсатлар, яумыйча узган болыт кебек, уза баралар, күңел салкыная, акыл утыра бара.* Ф. Хөсни. **Акыл чуалу** — зиһен таралу.— *А, чуалтмагыз минем акылымны!* Ф. Бурнаш. **Акыл өйрәтү** — 1) киңәш бирү.— *Киңәш дип килгәнегез өчен генә сезгә акыл өйрәтә идем.* Д. Аппакова; 2) *ирон.* Акыл бирү, акыл сату.— *Атаңа акыл өйрәтә башладыңмыни?* А. Алиш. **Акыл өләшү** — *к.* акыл сату. «*Мин беләм*»*не тотырып әйтә белә, Кеше саен акыл өләшә.* М. Җәлил. **Акыл өләшкәндә (мунча да, мич башында) пумала астында калган** *кимс.*— акылсыз мәгънәсендә әйтелә.— *Кызым, безнең арада акыл өләшкәндә пумала астында калган бер җан иясе бар, кушаматы — Тавык. Шуңа күрә гел элгәре кытаклый ул* [*Тавык Мортый турында*]. Г. Әпсәләмов. **Акыл үлчәшү** — сүз көрәштерү, бер-береңне тәнкыйтьләп бәхәсләшү.— *Акылларны үлчәшеп, вакытны уздырмыйк, туганкай.* Г. Бәширов. **Акыл үсү** — тәҗрибә арту, акыл туплану. *Яше үсү, буе үсү белән бергә, аның фикере дә, акылы да үсә, - - - тормышның ачысын-төчесен яшьли бик нык тату аның дөньяга карашын шактый үзгәртә.* М. Гали. **Акыл үткенләү (үткерләү)** — акыл үсешен камилләштерү, аңы үсү, аңлы кешегә әйләнү. [*Яңа тормышка килдек без*] *Батырлык һәм көрәш аркылы, Шунда чыныктырдык без йөрәкне, Шунда үткерләдек акылны.* М. Җәлил. **Акыл җитенкерәмәү** — тиле-милерәк булу, акылы ким булу (авыру булу).— *Менә бәндә инде, бичара, уйнамас, көлмәс, ачуланмас, сүгенмәс, дурак та түгел, акылы да җитенкерәми, күрәсең.* М. Әмир. **Акыл җитмәү** — 1) башына килмәү, уена килмәү, уйлап җиткермәү. [*Мәхмүт*] *үзенең шул укытучы кебек сорашырга да акылы җитмәвен уйлап, үз-үзен шелтәләде.* М. Гафури; 2) аңламау, аңлап булмау.— *Тик менә Хафизаның гына миңа күз төшермичә, шул шыр-яланғач Хафизны сөюгә генә бер дә акылым җитми.* Г. Камал; 3) кешелек җәмгыяте, дөнья күрмәгән искиткеч бер хәл, күренеш турында. [*Фрунзе*] *Петербургта, Мәскәүдә идән астында акыл җитмәслек хәтәр эшләр башкарган.* Г. Бәширов. *Юк, планета! Мондый вәхшилеккә Акыл җитми исем табарга!* Ш. Маннур. **Акыл җую (югалту)** — нинди дә булса бер хәл алдында аптырап калу, шашып калу. *Баштан салкын су сипкән тесле, калтыранып алдым, йөрәгем жуу итте, акылымны җуйгандай булдым.* Г. Минский. **Акыл җыю (туплау)** — 1) зур кичерешләрдән, киренке хисләрдән соң нормаль хәлгә, уйлый, фикер йөртә алу хәленә килү. *Мин болай да инде шатлыгымнан Акылымны җыя алмадым; Идел-сылу аша кичкән чакта Яшьләремне тыя алмадым.* Ш. Маннур; 2) булган хәлне аңларга, төшенергә тырышып, уйлау сәләтен эшкә җигү. *Нәфисә күлындагы салам кисәген өзгәли, акылын башына җыярга, коточкыч бу хәлнең серен аңларга теләгәндәй, - - - Фирдәвескә карап ала иде.* Г. Бәширов. **Акылга зарар килү** — акылдан язу, психик авыруга дучар булу.— *Доктор әфәнде, алайса Сез Сираҗетдин әфәнденең акылына зарар килү хак дисез?* Г. Камал. **Акылга килү** — 1) акылын җуеп авырганнан соң савыгу, сәламәтләнү; 2) аңга килү, зиһене ачылу. *Бу ариядә* [*Галимә*] *үз-үзен үтерергә карар кыла, ләкин акылына килеп, арияне бик оптимистик рухта, дәртләнеп, көр күңел белән тәмамлый.* М. Җәлил; 3) уйлау, башка килү; 4) сабак алу, уйлабрак, акыл белән эш итә башлау. *Инде Хисамый Әсмасы да акылга килер.* М. Фәйзи; 5) исәпләү, алданрак уйлап, белеп тору. *Бөтен тирә-якта дан тоткан күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.* Г. Ибраһимов. **Акылга көч килү (китерү)** — мигә зарар килү. *Чамалап укыгыз, гыйлемне кирәгеннән артык алып, акылыгызга көч китерә күрмәгез.* Ә. Фәйзи. **Акылга сай** — *к.* акылга таман. **Акылга сыймаслык (сыймастай, сыймый торган)** — ышанмаслык, ышанып булмастай; мөмкин булмаган. *Ниһаять, янындагы хатын-кызлар елаша башлагач, ул тетрәнеп китте, гүя акылга сыймастай бу эшне әле төзәтергә соң түгел - - - [дигән кебек], атын куып авылга таба чапты.* Г. Бәширов. **Акылга таман(ча)** — акылсыз, тиле-миле, акылга зәгыйфь. [*Ана*] *акылга таманчарак кешеләрчә була башлады.* М. Гафури. **Акылга тулы түгел (тулмаган)** — *к.* акылга таман. *Хәбибрахман — үсеп буйга җитеп, өйләнеп тә акылга тулмаган, кулыннан бер эш тә килми торган бер байбәтчә.* М. Гали. **Акылга түгәрәк түгел** — *к.* акылга тулы түгел.— *Безнең авылда бер* [*абый*] *бар иде. Дивана дип әйтимме? Кыскасы, акылга түгәрәк түгел.* И. Гази. **Акылга утырту** — сабак бирү, дөрес юлга кертү.— *Минем пәһләваным Кулупай бу башсыз егетне тиз акылга утыртыр.* М. Җәлил. **Акылга утыру** — 1) вакытлы юләрлекләр бетеп, тыйнаклану, акыллылану. *Карт эченнән каргады, тышыннан сер бирмәде: йөрсен, дөньяның ачысын-төчесен татыр, акылга утырыр, дип сөйләде.* Г. Ибраһимов; 2) сабак алу.— *Менә бу - - - кызны сарайга кертеп яп. Чыгарлык итмә. Азрак акылга утырсын.* Д. Аппакова. **Акылга чамалы** — *к.* акылга таман. [*Ул безне*] *авылдагы үзе чукрак, үзе ялкау, акылга да чамалырак Мортаза белән куркыта.* Г. Минский. **Акылга яту** — ышанырлык булу, акылга сыю.— *Әйе, бер уйлаганда, акылга яткан төсле тоела бу фикер.* Ш. Камал. **Акылга өйрәтү** — акыл бирү. **Акылга җиңел** — *к.* акылга таман. *Эштә ялкау, акылга да җиңелрәк Зариф, Сафиянең җылы сүзләренә алданып, серне ача.* Г. Нигъмәти. **Акылга җиңелəю** — акылдан язу, саташу, белешми башлау.— *Әллә, абыстай, син дә инде акылга җиңеләя башладыңмы?* Г. Камал. **Акылдан сапкан (тайган)** — акылын җуйган. *Зиннәт, кәбам, акылыңнанмы тайдың?* Г. Бәширов.— *Маржа сарафаны кияргә кешене* ***әллә акылдан сапкан дип*** *белдегезме?* Ф. Әмирхан. **Акылдан шашу** — *к.* акылдан язу.— *Ярый әле, Булат исән икән, утергәннәрдер дип уйлый-уйлый акылдан шаша яздым.* К. Тинчурин. *Төхфәт бала чакта аларның авыл мәзине Кәҗә Хәмит акылдан шашкан иде.* Ш. Камал. **Акылдан язу** — 1) акылын югалту, тилерү, юләрләнү (авыру). *Биредә* [*бу күренештә*] *Галимәгә иң көчле удар булырга һәм аңарда акылдан язуның беренче билгеләре күренә башларга тиеш.* М. Җәлил; 2) берәр нәрсә яки кеше белән артык мавыгып китү. [*Иван Никитич*] *баш килгән җирән кашканы күреп бөтенләй акылыннан язды инде. Аерып алыр хәл юк, артыннан калмый йөри.* М. Гали. **Акылны алу** — бөтен күңелне биләп алу. *Ул, йөрәкләргә үтә төшеп, акылларны алып, Дим, Агыйдел буйларының кураен уйнады.* Г. Ибраһимов. **Акылны җигү** — бөтен игътибарны туплау. *Берничә секунд ул бөтен акылын җигеп уйланды.* Ә. Еники. **Акылы алтын** — 1) бик акыллы. *Тапкыр икән ләкин кыз, Алтын икән акылы, Дөрес җавап егеткә Табып бирде ахыры.* Ә. Исхак; 2) кемнең дә булса соравына, фикеренә каршы төшеп әйтелә.— *Әллә, акылың алтын икән. Элек башлаган кеше элек әйтә.* М. Фәйзи. **Акылы кыска** — 1) *к.* акылга таман; 2) тиз кызучан, кызу характерлы кеше турында. *Акыллары*

кыска бит аларның, акыл дигән хәзинәләре бик чак. Ф. Бурнаш. **Акылы үзе белән булу** — холыксыз булу. **Акылы үсмичә калган** — юләр, акылсыз, тиле. *Бу — яше унтугызга җиткән егет булып үссә дә, акылы үсмичә калган чукрак һәм телсез Зарифулла иде.* Г. Минский. **Акылы(на) килгәндә** — кәефе яхшы булганда.

АКЫЛЛЫ *с.* 1. Аңлы, зиһенле. *Мин бу акыллы студентта — бөтен фәннәрдән иң алда барган укучыда --- кыюлык, батырлык сыйфатларын күрмәдем.* Г. Кутуй. // Тәрбияле, яхшы холыклы, тыңлаучан, үзен тота белә торган. *Миннән һаҗәргә һәм акыллы балаларыгызга сәлам тапшыр.* М. Җәлил. // *и. мәгъ. тарт. форм.* **акыллым.** Яратып, иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Кил, акыллым, кил, кадерлем, Күңелемә бәйрәм китер.* Ә. Ерикәй. *Син инде миңа, карт кешегә, үпкәләмә, акыллым.* А. Шамов.

2. Ачык фикерле, төпле, уйлап эш итә торган. *Акыллы егет булса, тилертеп йөреп ташлап калдырган рәхимсез ярны шунда ук оныткандыр.* М. Фәйзи. // *күч.* Кешенең тышкы кыяфәтенә карата: акыллылык сизелеп, күренеп, аңкып торган. *Секретарьның якты йөзендә, акыллы күз карашында, уң кашының уйчанланып өскә таба тилпенүендә тирән фикерләр чагылып киткәндәй тоела иде.* Г. Бәширов.

3. Акылга муафыйк, акылга сыешлы, акылга туры килә торган. *Акыллы эш.* □ — *Һа, кара син аны, акыллы сүз бит бу, Газинур.* Г. Әпсәләмов. // Эчтәлекле, фикергә бай, нигезле, логикалы. *Акыллы чыгыш.* □ [*Миңнурның*] *картларча йомшак тавышы, акыллы сүзләре кешеләргә гажәп нык тәэсир итә иде.* А. Шамов.

Акыллы баш *ирон.* — бик белгән булып кыланучы, үзен белгәнгә санап, белер-белмәс килеш башкаларга акыл бирүче. *Ул утырган бик матурлап һәм акыллы башланып, Уйга чумган, җиргә күз теккән, җиһаннан баш алып.* Г. Тукай.

АКЫЛЛЫЛАНУ *ф.* Акыллыга әйләнү; *к.* акыллы (1, 2 мәгъ.). *Ул акыллыланган, олыгайган һәм үзенә хөрмәт уяттыра ала иде.* Г. Әпсәләмов.— *Балаларыбыз да көпә-көндез илдән качып читләрдә йөрми. Отыры ипләнеп, акыллыланып кына киттеләр.* М. Фәйзи.

АКЫЛЛЫЛЫК *и.* Акыллы булу. *Бүген ул кыл бары тик Миңнур картның акыллылыгы, сабырлыгы һәм кирәк урында аның оста маневр ясый белүе аркасында гына өзелмәде.* А. Шамов.

АКЫЛСЫЗ *с.* 1. Ахмак, юләр, уйламыйча эш итүчән.— *Белмим, кемгә охшап бу кадәр мисез, акылсыз булгандыр.* Г. Камал.— *Хәмдияң мәхәббәт белән дәрәҗәне алыштырырлык акылсыз да түгел.* М. Фәйзи.

2. Тәрбиясез, холыксыз.— *Менә бу кунак кызлары үзеңне акылсыз малай икән дип китәрләр.* Ф. Әмирхан.

АКЫЛСЫЗЛАНУ *ф.* 1. Ахмаклану, юләрләнү. // Акылдан язу. *Аның күзләре яна, ул акылсызланыр хәлгә җитә.* Г. Нигъмәти.

2. Холыксызлану, тәрбиясезләнү.— *Солтан, син нигә алай акылсызланасың?* Г. Ибраһимов.

АКЫЛСЫЗЛЫК *и.* Акылсыз булу.— *Күз яше файдасыз, артык өзгәләнү акылсызлык булыр иде.* Г. Бәширов.

АКЫН *и.* Казакъ, кыргыз һәм башка кайбер халыкларда шагыйрь-импровизатор һәм җырчы. *Казакъча киемле, ябык йөзле, дивана йөрешле, хыялый күзле бу кеше тирә-якның мәшһүр акыннарыннан Тылсымҗан иде.* Г. Ибраһимов.

АКЫРТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* акыру (1 мәгъ).

2. *ирон.* Гармонь, труба кебек уен коралларында артык көчле уйнау, кычкырту.

3. *рәв. мәгъ. күч.* **акыртып.** Көчләп, ирексезләп; **айвайга карамыйча, кычкыртып.** [*Тентүчеләрнең берсе:*] *Нәрсә анда гөнаһсыз карчыкны азаплыйсыз? Менә кая бит, диде дә, сәке астыннан берәүне акыртып өстери башлады.* Г. Ибраһимов.

АКЫРТЫН *рәв. сөйл. к.* акрын (1—4 мәгъ). *Шул вакытта Вәли дә Галинең артына акыртын гына килеп поса, Гали сизми.* **Г. Коләхметов.**

АКЫРУ *ф.* 1. Бик көчле кычкыру. *Офицер шунда немецчалап акырды һәм кызып, котырынып, кулларын бутап баш очындагы ботакка күрсәтте.* А. Шамов. / *рәв. мәгъ. Ак бандитлар, кылычларын, сәнәкләрен айкый-айкый, улап, акырып, Җәүдәтләрнең артына төштеләр.* Г. Бәширов. // Җикеренү, сүгү. *Сорау алучы өстәлне сугып акырырга тотынды.* Г. Гобәй.

2. *ирон. сөйл.* Бик кычкырып җырлаган сыман итү. // Музыка коралында уйнау турында.— *Ай-яй шәп акыра икән. Мөхәммәдия көйләрен дә чиертерә беләсеңме әллә, җанкаем?* Ш. Камал.

АКЫРУ-БАКЫРУ *ф. сөйл.* Тупас сүзләр кычкыру, сүгенү. [*Шәмгун*] *карый әфәнденең холкы бик начар, бераз эчеп алдымы — акырырга-бакырырга, сугышырга, әйбер ватарга керешә.* Т. Гыйззәт. / *рәв. мәгъ. Акырып-бакырып килеп кергәннәр дә Нәҗибәне өстерәп алып чыгып киткәннәр.* А. Шамов.

АКЫРЫНУ *ф.* Күп һәм озак акыру. *Гайнетдиннең башка чакта да чиртсәң кан чыгардай кызыл булган йөзе бу акырынудан тагын яман бүртенеп каралды, күзләрен кан басты.* Г. Ибраһимов.

АКЫРЫШУ *ф.* 1. Берьюлы ике яки берничә кеше яисә хайван акыруы турында. *Немецлар якын гына акырышалар кебек.* И. Гази. *Сыерлар акырышып, уйнашып сикерәләр.* Ш. Камал.

2. Бер-береңә җикеренү, бер-береңә тупас кычкыру, акыру.

АЛ I *с.* 1. Аксыл кызыл, сыек кызыл, кызгылт ак төс. *Разия, бөгелеп, берничә ал, кызыл чәчәк өзде дә минем күлмәгемә кадап куйды.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Матур, гүзәл. *Һәр караңгы төннең ал таңы бар, Һәрбер кышның кайнар язы бар.* М. Җәлил. // *и. мәгъ.* Матурым, гүзәлем. *И алым син, алым син, Алым түгел, гөлем син.* Җыр.

◇ **Ал да гөл** — бик яхшы, шәп. *Я, исәнмесез, шәп яшисезме, ал да гөлме, әллә түгелме?* Г. Бәширов. **Ал (да гөл) итү** — матур итү, матурлау, чибәр итү.— *Бу, кунак өе булганнан гына түгел, кызлы өй булганга бигрәк тә пөхтә. Безнең кызлар һәрнәрсәне ал да гөл итәселәре килә бит.* Г. Ибраһимов. *Ябалактай яуган карлар Аклый микән кырларны, Тракторга сабан җигеп, Ал итәрбез кырларны.* Һ. Такташ.

АЛ II *и. гадәттә кыек килеш формаларында.* 1. Пространствода: күз караган як; *киресе:* арт. *Уңда да, сулда да, алда да, артта да биек-биек нефть вышкалары.* А. Әхмәт. *Алларында туп-туры сузылып киткән тигез юл.* Ә. Еники.

2. Кеше гәүдәсендә һәм аның киемендә йөз, күкрәк ягы; *киресе:* арт. *Ашыгып киенә торгач, Хәмит күлмәкнең артын алга кигән икән.* А. Әхмәт. / *с. мәгъ. Ул куе, озын, тәртипсез, ләкин матур таралган чәчләрен ал якка, күкрәк өстенә чыгарып куйды һәм, көзгедән карап, үз сурәтеннән үзе кәефләнде.* Ф. Әмирхан. // *с. мәгъ.* Хайван гәүдәсендә һәм арбада: алгы, алдагы. *Шунда ук --- Сарбай килеп ятты һәм, дәү башын ал аякларына куеп, койрыгын ялкау гына селкергә тотынды.* Г. Әпсәләмов. *Ал көпчәк кайдан барса, арт көпчәк шуннан бара.* Мәкаль.

3. Кыр эшләрендә бер кеше эшләргә тиешле кишәрлек, бүлем. *Артта калган тутагызның алдын килеп утагыз.* Җыр. *Мин апа белән әни уртасыннан [урак урырга] ал алдым.* М. Гафури.

4. Утыргач кеше утырырлык, баш куеп торырлык яки әйбер куярлык итеп җайланган тез өсте. *Кайчак мин, кичләрен эштән арып кайткач, аның алдына башымны куеп ятып тора торган идем.* А Шамов. // Нәрсә булса

да җыяр, салыр өчен (бераз күтәрә төшеп, җайлап тотылган) күлмәк итәге яки алъяпкыч. *Кызарып пешкән җиләкне алларыма җыямын.* Җыр. // Өстәлдә, табында һ. б. ш. һәр кеше каршына, турысына килгән урын. [*Дәүләтшин*] *бер калай кружканы — минем алга, икенчесен — үз алдына куйды.* И. Гази. // Утырып яки басып торган кешенең каршысы, карап торган ягы. *Ул кызлар алдына барып төрле матур кыланышлар ясый, биергә чакыра.* М. Фәйзи.

5. Бер-бер артлы тәртип белән тезелгән сафларның алгы рәте, беренчесе. *Алдарак басып торганнар берберсенә карашып, җилкәләрен кашып куйдылар.* А. Шамов. *Ул утырды килеп иң алга.* Ф. Кәрим. // Сафларның, төркемнең башы, төркемне алып баручы урыны (беренче баручы кеше яки хайван турында). *Күрше ротаның алдында батальон командирының кылыч айкаганы күренде.* Г. Бәширов. // Киләчәк, киләсе көн. *Алсу чәчкәне ак көнгә юрап, Алдагын уйлап-санап шатландык.* М. Җәлил.

6. *бәйл. функ.* **алды.** Берәр эш-хәл башланганчы, башкарылганчы булган вакыт аралыгын белдерү өчен кулланыла. *Бәйрәм алды хәзерлекләре. Революция алды еллары.*

7. *бәйл. функ. юн. килеш форм.* **алдына.** Эш-хәлнең предметка, аның алгы, йөз ягына яки кемгә дә булса юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Капка алдына килеп туктау.* □ *Хөкүмәт безнең алдыбызга бик зур бурычлар куйды.* А. Шамов.

8. *бәйл. функ. чыг. килеш форм.* **алдыннан.** 1) Хәрәкәтнең берәр нәрсә яныннан, аның алгы ягыннан башланып китүен белдерү өчен кулланыла. *Ишек алдыннан килеп керү. Вокзал алдыннан кузгалып китү;* 2) кемнең яки нәрсәнең дә булса алгы ягында башкарылган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Җилфердәтеп җилдә галстугын, Саф алдыннан атлый вожатый.* Г. Хуҗиев; 3) эш-хәлнең, вакыйганың икенче бер эш-хәлдән элек булуын белдерү өчен кулланыла. *Язгы чәчү алдыннан зур җыелыш үткәрү.* □ *— Без әле син кайтыр алдыннан гына ашап алдык.* А. Әхмәт.

9. *бәйл. функ. у.-в. килеш форм.* **алдында.** 1) кемнең-нәрсәнең **булу** урынын яки эш-хәлнең кем-нәрсә каршында, янында башкарылуын белдерү өчен кулланыла.— *Синең белән мин анда, кешеләр алдында, рәхәтләнеп саубуллаша алмадым.* А. Шамов. *Ул арада Ибрай беседка алдындагы чирәмгә чәй урыны хәзерләтеп өлгергән иде инде.* М. Әмир; 2) кемгә яки нәрсәгә дә булса мөнәсәбәтле эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Кыенлыклар алдында туктап калмау. Авыл хуҗалыгы алдында торган бурычлар.* □ *Хәлимнең ышанычлы сүзләре алар алдында көчләрен җуйдылар.* Г. Гобәй; 3) эш-хәлнең шаһит буларак катнашучы кеше булган җирдә башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Бала-чага алдында сак булырга кирәк икән, дим үз-үземә.* Ш. Камал; 4) кемнең яки нәрсәнең дә булса каршында икенче берәүнең сыйфатын, хәлен **белдерү өчен кулланыла.** ***Коллектив алдында үзен гаепле санау.*** □ *Ил язмышы өчен тарих алдында без җаваплы.* Г. Хуҗиев.— *Булмастайны өстемә алып, халык алдында оятлы булыр хәлем юк.* Г. Бәширов; 5) берәр эш-хәл башланганчы, башкарылганчы булган вакыт аралыгын белдерү өчен кулланыла. *Хәзер алар үзләрен бик зур вакыйга алдында торган кебек хис иттеләр.* Г. Гобәй.

Ал як — 1) алда, каршыда булган як. *Бер карыйм-мын шатланып ал якка мин, Җилфердәп килгән кызыл байракка мин.* М. Гафури; 2) алгы як, алгы бүлмә; *киресе:* түр як. *Ал якта минем кавалерым да бар бит әле.* Ф. Әмирхан.

◇ **Ал бирү** — юл сабу, юл бирү, үзеңнән алга китәргә мөмкинлек бирү. *Ал биргәнче җан бир.* Мәкаль. *Ут чыгаргандай каты, үткен, тиз баса торган йомры, кечкенә ялтыр тояклар* [*атның*] *бу киң далада бик күп елкыларга алын бирмәс йөгереклеген күрсәтәләр.* Г. Ибраһимов. **Алга алу** — [кемнең яки нәрсәнең дә булса файдасын] максат итү, күз алдында тоту. **Алга бару (китү, атлау)** — 1) тукталып калмау, дәвам итү (эш, тормыш). *Эш алга барган саен, аның күңеле үсте.* Г. Гобәй. *Ару-талу, иркәләнү белми, һаман эштә алга атладык.* Ш. Маннур; 2) башкаларны үзү, башкалардан алга чыгу, өстән булу, җиңү.— *Син быел гына укый башласаң да миннән алга киттең, икенче класска күчтең, кызым.* М. Гали; 3) фронтта, сугышта дошманны җиңеп, куып, территорияләрне азат итү, шәһәрләр һ. б. ш. алу. *Мин зарыгып алга... алга карыйм: Җиргә тетрәткән дошман тупларын, Дошман миналары өермәсен Ерып, алга бара дусларым.* Ф. Кәрим; 4) үсү, үсештә яңа уңышларга ирешү. *Тавышының матур, яңгыравыклы булуы да аның бу юлда алга китүенә ярдәм итте.* Ш. Камал. **Алга басу (килү)** — 1) нинди дә булса куркыныч хәл, үлем һ. б. белән бәйләнгән хәлиткеч моментның килүе. *Үлем алга килеп баскан.* М. Гафури; 2) күз алдына килү, кабат гәүдәләнү. *Баса үткән гомер алга.* Н. Исәнбәт; 3) реаль чынбарлыкка әйләнү, чын тормышында тату. *Уйга килгән алга килә.* Мәкаль; 4) актуаль мәсьәлә булып көн тәртибенә куелу. *Җәй көнен кайда һәм ничек, нинди эш белән үткәрү мәсьәләсе алга килеп басты.* М. Гафури; 5) үсү, алга китү, яхшыра бару. *Егет кеше көннән-көн алга баса, Башлаган һәрбер эшне тәмамласа.* М. Гафури. **Алга бастыру** — җанландыру, гәүдәләндерү (аерым образларны бирү турында). *Моңда «Безнең көннәр» һәм «Кызыл чәчәкләр»дә күрелмәгән яңа типлар да алга бастырылган.* Г. Нигъмәти. **Алга карау** — киләчәк белән яшәү, киләчәкне уйлау, мәсьәләне киләчәк күзлегеннән карап чишү турында. *Бүгенге көн белән генә яшәп булмый, иртәгә, киләсе елга, йөз елга алга карарга кирәк.* Г. Әпсәләмов. **Алга кую** — 1) актуаль мәсьәлә, төп бурыч итеп санау. *Театр каршында студия төзү һәм иң талантлы яшьләрне шунда тәрбияләү, театрга солист хәзерләүне алга куярга кирәк.* М. Җәлил. *Меңмең башлар киңәш кордылар, Илнең хәлен алга куйдылар.* Ф. Бурнаш; 2) башкалардан артыграк күрү, өстенлек бирү.— *Зифа мине бөтен күңеле белән сөеп торганда, бөтен байлыктан күл селтәп, авылны, крестьян тормышын алга куеп торганда, аның юлында башымны җуярмын, әмма Галләмгә биреп җибәрмәм.* М. Фәйзи. **Алга сөрү** — 1) алга җибәрергә, үстерергә тырышу; алга кую. *Ул чордагы язма әдәбиятта татарның сөйләү телен алга сөрүче тик Каюм Насыйри гына була.* М. Гали; 2) тәкъдим итү һәм берәр фикерне яклау, куәтләү. *Урал ягына китү вариантын да бар иде. Аны Блюхер белән Каширин алга сөрделәр.* Ш. Усманов. **Алга чыгу** — 1) нәрсәне дә булса үтәргә әзерләнү яки әзер булуыңны белдерү өчен башкалардан аерылып алгарак күчү. *Бары да аякка басалар, егетләр төркеме алга чыга.* М. Фәйзи; 2) нинди дә булса эштә беренче булып алдан бару, җиңү.— *Урак беткәнче берәүне дә алга чыгармыйм дигән идең, сүзеңдә тора алмадың бит! Газизә үзеңне узган иң! М. Гали.* **Алга яту** — алга бару, омтылу билгесе буларак, гәүдәне бераз алга авыштыру, алга сөрлегү. *Ул бара, чак-чак адымлый. Алга яткан гәүдәсе.* Н. Исәнбәт. **Алда тору** — эшләнәчәк, башкарылачак, үтәләчәк эш, бурыч турында. *Мин алдыбызда торган эшләрнең күплегеннән һәм зурлыгыннан чын-чынлап курка башладым.* М. Әмир. *Эшләр тыгыз, менә алда язгы чәчүләр тора.* М. Җәлил. **Алда тоту** — 1) истә тоту, күздә тоту, актуаль мәсьәлә итеп санау; 2) башкага караганда өстенрәк, артыграк күрү. *Хакыйкатьтән сары алтынны бик күп алда тотканнар.* М. Гафури. **Алдан калу** *сөйл.*— бик мул, күп булу. *Аларның ашау-эчүләре дә мул иде, һәрвакыт алларыннан калды.* А. Алиш. **Алдан күрү** — киләчәкне

белеп, чамалап тору. **Алдыннан калганчы ашау (эчү)** — бик күп ашау (эчү) турында әйтелә.

АЛА *с.* Ак һәм кара яки ачык һәм тоныk төсләрдән торган. *Аттан ала да туа, кола да туа.* Мәкаль. *Ала каз ишек төбеннән китмичә бу өч солдатны җентеклəп күзәтə башлады.* Ə. Еники. // Чуар. Ак, күк, кызыл һ. б. төсләр аралаштырылып ялганып ясалган, тегелгән. *Романовларның туган, кəлəш алган көннəрендə һəрбер капка башына эленеп, җиргə салынып төшкəн ала флагларны күреп өйрəнгəн кешеләр өчен бу кызыл флаг бик сəер тоелды.* М. Гафури.

Ала балык — сөләйман балыгы семьялыгыннан тау елгаларында, күлләрдә үрчи торган, кызыл һәм кара тимгелле балык; *русчасы:* форель.— *Севан күленə ала балыклар тотарга менəрбез.* Г. Əпсəләмов. **Ала карга** — козгыннар семьялыгыннан аралаш кара һәм сары йонлы кош. *Бер ала карга таш өстендə балык чукый.* И. Гази. **Ала миләүшə** *бот.*— миләүшәнең бер төре, бакчада үсә, һәрбер чәчәге өч төстән тора. **Ала кар** — язын кырларның ачыла башлаган, җирнең алаланган вакыты. *Яшь балалар чаңгы шуа ала карда.* М. Җәлил. **Ала кардан** — иртə яздан. **Ала күз** — *к.* акай күз. *Яшь елкы дерелди, аның зур ала күзлəрендə куркулы дошманлык уты яна иде.* Г. Ибраһимов.

АЛАБУГА *и. зоол.* Чәнечке канатлылар төркеменнән кызгылт йөзгечле, буй-буй таплары булган ерткыч балык; *русчасы:* окунь. *Күз алдымда кызыл канатларын кабарткан, авызын ачкан алабуга торса да, сүзем икенче булды.* А. Əхмəт.

АЛАБУТА *бот.* **1.** Яфраклары ончыл куныk белəн капланган үсемлек, чүп үләне. *Иптəшем, читəн буенда үскəн алабуталар арасына посып, тыш якта калды.* М. Əмир.

2. Шул үләннең орлыгы, бөртеге. // *с. мәгъ.* Шул орлыкны тартып **хəзерлəнгəн (он турында).** *Ябыгып, тиресе сөягенə ябышып беткəн тимеркүкне пот ярым алабута онына алмаштырдылар.* Г. Ибраһимов. // *с. мəгъ.* Шул оннан пешерелгəн. *Олаучы абый* [*Габдуллага*] *өйдəн алып чыккан кечкенə алабута күмəченең бер читен сындырып бирде.* Ə. Фəйзи.

А'ЛАГАЕМ(ГА) *диал.* Бик артык, искиткеч, чамадан тыш. [*Газизов*] *алагаем озын буйлы, чыгынкы яңаклы.* А. Тимергалин. // Чамадан тыш, бик ныk, бар көчкə. [*Минһаж*], *күлларын алагаемга җəеп, Зəйтүнəне кочагына ала.* Т. Гыйззəт. [*Хəзерге председатель*] *эшен дə эшлəтə белə, иллə мəгəр, элекке председательлəр кебек, алагаемга күтəрелеп тə бəрелми.* Г. Ахунов.

АЛАЙ *а.* **1.** Алда әйтелгән туры сөйләмне алмаштыра (рәвеш алмашлыгы). *Бер эшеңə биш кат акча алдың, Алай алу кыйммəт димəдең.* Ф. Кəрим. *Минем алай дигəнем юк, Сабир бабай.* Г. Əпсəләмов. // Нинди дә булса бер эш, күренешкә күрсәтү өчен, чагыштыру өчен кулланыла. *Безнең монда алай йөрү килешми.* М. Гафури.

2. *рәв. мәгъ.* Ул кадәр, ул дәрәҗәдә. *Алай аягың бик кычытса, бар, алдан тəпили тор.* Г. Бəширов. *Ул Нурый белəн Челем бабай арасында алай мəҗлескə чакырышып, кодалык күрсəтү кебек хəлларнең була алмавын ачык белə иде.* Г. Ибраһимов.

3. *ы. функ.* Берәр кеше белән сөйләшкәндә аннан ишеткәннәрдән соң уйга калып, аптырап торганда әйтелә. [*Тимеркəй:*] *Минһаҗетдин, кая болай?* [*Минһаж:*] *Районга.* [*Тимеркəй:*] *Алай...* К. Тинчурин. *Алай... Син дə аңа тəлинкə тота башладыңмыни?* Т. Гыйззəт.

◇ **Алаен алай да** — әйтелгән сүз, фикер белән килешеп бетмәүне белдереп, каршы фикер, дәлил китергәндә кулланыла. *Ул мондагы тук тормышны мактап сөйлисөйли иде дə:— Алаен алай да бит, Караюргага берсе дə җитə алмый шул,— дип куя иде.* Г. Ибраһимов. **Алай булгач** — *к.* алайса. *Алай булгач, син ирең кияргə кушкан киемне кимисең икəн?* Ф. Əмирхан. **Алай булса** — *к.* алайса. *Алай булса, мин дə əйтим Чыныңа яшерми.* М. Җәлил. **Алай гына** — 1) бернинди эзсез, җәзасыз. *Бу эш алай гына узмас;* 2) көч, тырышлык куймыйча.— *Ләкин бит, түтəйләр, ул алай гына эшләнə торган эш түгел.* Т. Гыйззəт. **Алай гына да түгел** — алда әйтелгән фикерләргә өстәмә итеп китерелгән фикер алдыннан килә; шуның өстәвенә. *Алай гына да түгел, һəр сугышчы, барыннан да бигрəк, шуңа* [*төнге сугышка*] *хəзерлəнə.* Г. Бəширов. **Алай да** — 1) алда әйтелгән фикер белән килешсә дə, искәрмә буларак бу фикер дә бар, дип өстәгәндә кулланыла. *Алай да, безгə ничек тору яхшы булыр икəн дип уйлыйсың син?* Ф. Əмирхан; 2) кире җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла: барыбер. **Алай дисəң** — алай дип уйлар булсаң; хәлбуки, ләкин.— *Алай дисəң, шөпшəнең күзləре кара булмый бугай.* Ф. Хөсни. **Алайга китсə (калса)** — юкса, ул очракта (кисәтүне белдерә).— *Кулың озаймасын, тəкъва шайтан, алайга китсə, бездə куллар күбрəк булыр.* М. Əмир.— *Ник аз булсын: əле яртысы да бетмəгəн.— Юк, алайга калгач күпкə бармый инде ул.* Ф. Əмирхан.

АЛАЙ-БОЛАЙ *рəв.* **1.** Ничек кирәк алай, ничек булса да. *Мине үткəн елгы кебек хəзерлəп озатучы булмаса да, алай-болай əзерлəнеп, авылдан ычкындым.* М. Гафури. // *с. мəгъ.* Нинди дә булса, һәртөрле.— *Мин алай-болай сүз ишетсəм, мəсьəлəне кабыргасы белəн куярмын.* С. Рафиков.

2. Əгəр дə, əгəр дə мəгəр; көтмәгәндә. *Алай-болай төнлə кисəк кенə яңгыр яугандa берəр сəбəп белəн өйдəн чыгып китəргə туры килсə дип, ул безгə өстебезгə киенеп ятарга кушты.* М. Гали. // Ахыр чиктә, əгəр. *Алай-болай, табалмасак җаен, Узебезгə актык гранат.* М. Җәлил.

3. *к.* алан-йолан.— *Риза түгелме син бу тормышыңнан? Китəр төсле алай-болай карыйсың.* М. Гафури.

◇ **Алай-болай булу** — юкка чыгу, әрәм булу (әйбер турында), үлү яки бик авыр хәлдә калу (кеше турында).— *Хуш, кызым,— диде ул, бусагадан атлаганда,— алай-болай була калсам, бəхил бул.* Г. Гобәй. **Алай-болай гына түгел** — әйбернең яки берәр эшнең ролен, бәясен күтәребрәк яки катлаулы икәнен белдереп әйткәндә кулланыла.— *Концерт бүлеген без тулысынча өстебезгə алабыз. Һəм алай-болай гына түгел, бик киң күләмдə.* Ш. Камал. **Алай-болай итү** — ни дә булса эшләү. *Əткəй туры барды да* [*биянең*] *муенына нуктаны ташлады, алай-болай иткəнче, бурлы биянең башы калын нукта эченə кереп тə өлгерде.* Г. Ибраһимов. *Җил, хəерсез, ятып йокламаса, җирдə алай-болай иткəли.* Һ. Такташ.

АЛАЙСА *кер. сүз.* Алай булса; андый очракта. *Хак сүз əйткəнгə — киң күңелең тарайса, Урыныңнан кузгалма — йоклый күр, алайса.* Г. Тукай. *Алайса, син, сеңел, җыена тор инде, мин --- барып, кəгазьləрнe əзерли торырга кушыйм.* Г. Бəширов.

АЛАҠАЙ *и. диал.* Акай күзле кеше.— *Я, бу тикле алагай булыр икəн, җенем сөйми шул алакайны.* Ə. Камал.

АЛАҠАНАТ *и. гади с. иск.* Авылдан шәһәргә килеп, производтвода вакытлы эшләүче кеше. [*Əхмəт бай фабрикасында*] *квалификация сорамаган эштə эшлəучеларнең күпчелеге — алаканатлар. Яз җитеп, җир кибү белəн, алар үз авылларына, кыр эшенə кайтып китəләр.* К. Тинчурин.

АЛАҠАЮ *ф. диал. к.* акаю. *Аларның да шул сезнеке шикелле күзе-башы алакайган бер асраулары бар.* Г. Камал.

АЛА-КОЛА *с.* Ак һәм кара төсләрдән торган, ала. *Ə бит тау башлары ачылуга инде кайчан, хəтта əрəмəлекләр һəм туғайлар да күптəн ала-кола булып калганнар.* М. Шабай. // Төрле төсле, чуар. *Ала-кола, карачуар бары бетеп, Кызыл байрак кына калыр Җир ша-*

рында. М. Гафури. [*Сәйфи*] *төсе уңган ала-кола күлмәгенең итәген тарткалап, сөйләнә-сөйләнә тәмәке төргергә тотынды.* Г. Бәширов.

АЛА-ҚОЛАЛАНУ *ф.* Ала-кола төскә керү.

АЛА-ҚОЛАЛЫҚ *и.* Ала-кола булу. *Бик байлык, --- пөхтәлек белән эшләнгәнлеге күренеп тора торган бу йортның хәзерге кыяфәте, ала-колалыгы, купкалап, җимерелгәләгәнлеге --- күңелемне каралта, моңландыра, әллә нишләтә иде.* Ф. Әмирхан.

АЛАҚ-ШАЛАҚ *с. диал.* Җилбәзәк, җиңел генә уйлаучы. *Бер дә алак-шалак кешегә охшамый.* // *рәв. мәгъ.* Җилбәзәкләнеп. *Алак-шалак йөрү.*

АЛАҚ-ЯЛАҚ *рәв. к.* алан-йолан. [*Фәйзерахман:*] *Нәрсә алак-ялак каранасың? Ул бит монда юк инде хәзер.* А. Әхмәт.

АЛАЛАНУ *ф.* Ала, ала-кола төскә керү, ала-колалану. *Хатын үзенең вәхши күзләрен дәһшәттән алалангән изге угылның күзләренә текәгән иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АЛАЛЫ-ТИЛӘЛЕ *с. к.* ала-тилә. *Калкулык һәм ызаннар күбесенчә алалы-тиләле булып яталар.* С. Рафиков.

АЛАМА *с.* **1.** Иске, тузган, бик сәләмә. *Тәрәзәдән карама, бүрек читең алама.* Җыр. // *и. мәгъ. күч. кимс.* Предмет яки зат исеме соңында килеп, кемне яки нәрсәне дә булса начар, түбән итеп, мыскыллап әйтелә. *Ул кое янындагы зур таһаректан кепка аламасы белән су чүмереп алып килгән арада, малай тракторын төзәтеп маташты.* Г. Гобәй. *Малайның күлмәге ертылып китә, --- Хәлимне гаепли: янәсе, көтүче аламасы юри шулай каты тотты, кеше кебек уйный белми ул, чыксын уеннан!* И. Гази. *Әйтерсең исерек кул белән чәчелгән, шундый тигезсез чыккан дүрт дисәтинә арыш аламасы ята.* Г. Ибраһимов.

2. *и. мәгъ.* Тузган, иске әйберләр, чүпрәк-чапрак.

3. Ярлы, хәерче.— *Сөнгатьләр шикелле алама егетләр кулында түгел бит син, егетнең асылы кулында.* М. Фәйзи.

4. *күч.* Начар, әшәке. *Аның, җаным, характеры бик алама.* Қ. Нәҗми. *Кайбер алама эшләр эшләгән кешеләр гадәттә кинәт җимерелеп төшәләр.* Ә. Еники. *Андый алама гадәт безнең өйгә кермәде.* М. Гафури. // Начар, яман гадәтле (кеше турында). *Биктимер бабайның угыллары арасында бик аламалары булганга, ул үз исеменең җир йөзеннән бөтенләйгә югалуыннан курка башлады.* К. Тинчурин. // Начар, күңелсез.— *Бездә бик алама вакыйга булып алды.* Ш. Камал.

АЛАМАЛАНУ *ф.* Алама хәлгә килү.

АЛАМАЛЫҚ *и.* Алама булу. *Киемнең аламалыгы.*

АЛАМАЧЫ *и.* Чүпрәк-чапрак җыючы, алама җыючы.

АЛАМ-САЛАМ *җый. и.* **1.** Иске-москы, сәләмә нәрсәләр.

2. *с. мәгъ.* Алама, иске. *Күрендем үз-үземә бик зур кебек; Алам-салам ак якалар куелмаса, Була инде гүяки бер* [*кимчелек*] *кебек.* М. Гафури.

АЛАН *и.* Урман эчендәге агачсыз, ачыграк урын. *Аргы якның аланы — ачы була баланы.* Җыр. *Ял иттек без палаткалар корып, Җиләк җыйдык яшел аланда.* З. Мансур.

АЛАН-ЙОЛАН: алан-йолан карану (килү) — туктаусыз як-якка карану.

АЛАНЛЫҚ *и.* Урман эчендәге ачыклык, алан. *Бөтен аланлык ак, сары, кызыл, зәңгәр төстәге төрле чәчәкләр белән бизәлгән.* М. Гали.

АЛАП *и.* **1.** Ашлык, кибәк ташу өчен кабыктан эшләнгән зур әрҗә яки тубал. [*Шәйхелләрнең*] *ишкән, иштергән арканнары, ясаткан --- алап, чуман чиләкләре --- зур базарларга таба юл алды.* Г. Ибраһимов.

2. *с. мәгъ. күч.* Артык зур, бик зур булуга ишарә итеп әйтелә. *Яклаучысы да табылган, бикә. Алап авыз, әлеге Батырҗан.* Т. Гыйззәт.

АЛАПАЙ *с.* Қилешсез зур, җыйнаксыз, тупас зур. —*Әле менә өченче ел гына алапай олы мичне сүтеп, заманча җыйнаклап чыгарттык.* С. Рафиков.

Алапай белән шалапай *кимс.*— Һәрвакыт бергә йөрүче ике кеше турында әйтелә.

АЛАР *а.* 3-зат күплек сандагы зат алмашлыгы, сөйләмдә әйтелгән затны, предметны алмаштыра. *Көндезгечә шаулашмыйлар Күл буенда камышлар; Алар утыра тирән уйга Чумган төсле сагышган.* М. Җәлил.

АЛАРТУ I *ф.* Ала төскә кертү.

АЛАРТУ II. *ф.* Күзне акайту, күзнең агы белән генә усал итеп карау.

АЛАРУ I *ф.* Ала төскә керү, алалану. *Болытлар сәер итә, анда алара. Алар артында зур таулар агара.* Г. Тукай.

АЛАРУ II *ф.* Ямьсез, куркынычлы итеп карау, куркыныч кыяфәткә керү, күзнең агы белән генә акаеп карау. *Акчаны күргәч, хатынның күзләре аларды, төшемме, өнемме дип, кире чигенде, шулай да тиз генә эләктерде дә, нинди гөнаһысы өчендер, миннән гафу үтенә башлады.* Г. Ибраһимов.

АЛА-ТИЛӘ *с.* Таплы; ала-кола, чуар. *Бер кар явып, бер эретеп торганга, җир өстенә ала-тилә ямаулыклар салынды.* С. Рафиков.

АЛАЧА *и. этн.* **1.** Төрле төстән буй-буй сугылган киндер (күбесенчә ак һәм кызылдан сугыла). *Ашъяулыклар, тастымаллар, чаршаулар гадәттә алачадан була.* Ф. Вәлиев. // *с. мәгъ.* Шундый киндердән тегелгән яки эшләнгән. *Алача чаршау, комач бау, Кор дисәң дә — кормамын.* Җыр. *Борын-борын заманнарда хәзергә картларның бабалары озын киндер күлмәк белән алача штан* [*кигән*]. Г. Бәширов.

2. *диал.* Буй-буй итеп сугылган палас, келәм.

АЛАЧАҚ *и.* Биреп торучыга кире кайтачак бурыч; *киресе:* бирәчәк. *Ала каргада алачагың булсын.* Мәкаль. *Галиәкбәр ағайның Максудовта алачагыннан актык өмете өзелде.* Ш. Мөхәммәдев.

АЛА-ЧОЛА *с.* **1.** *к.* ала-кола, ала-тилә.

2. *рәв. мәгъ. сир.* Аз-маз, аннан-моннан гына. [*Мәрьям*] *үзе ала-чола аңлаган төрек романнарыннан көннәр, төннәр башын ала алмый утыра.* Г. Ибраһимов.

АЛАЧЫК *и.* **1.** Төрле эшләр өчен кабык, такта һ. б. материаллардан оештырылган кечкенә каралты. *Тегермән янына ук алар тагын тәгәрмәч туғымы һәм чана табаны бөгә торган алачык ясаганнар.* М. Гали. *Көпчәкләр аунап яткан тимерче алачыгы яныннан үтеп, Якуп икенче урамга килеп чыкты.* И. Гази.

2. *иск.* Җәй айларында вакытлыча яшәү өчен куыш. шалаш. *Мостафа --- өянке агачлар артында, читәннән үреп, алачык эшли иде.* Ш. Камал. *Ул матур кыз Сакчы кыз иде, Алачыкта үскән, урманда.* Ә. Ерикәй. // Начар, җимерек кечкенә өй яки бүлмә турында. *Син беләсең безнең «алачыкны», Қәҗәсез дә гомер иткәнне.* Ш. Маннур.

АЛАША *и.* Печтерелгән айгыр. *Авылга якынлашып барганны күргән җирән алаша, тагын колакларын торгызып, дәртләнеп, үзеннән-үзе чаба башлый.* М. Гали.

◇ **Алашасы колынлау** — эше, тормышы алга китү, гел бәхет килеп тору турында. *Галиәкбәр абзагыз вафат мулланың ак тәнле абыстаена һәм, шуңа ияртеп, алты почмаклы таудай өенә --- хуҗа булды да куйды. Шуннан соң алашасы колынлады Галиәкбәрнең.* Г. Мөхәммәтшин.

АЛБАН *и.* Албания Халык Республикасында яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Нинди милләт кешеләре генә юк бу Дахауда!.. Испаннар да, белгиялеләр дә, албаннар да, болгарлар да... Хәтта негрларга тикле бар монда.* Каз. утл. // *с. мәгъ.* Шул

халыкка бәйләнешле, шул халыкка караган. *Албан теле.*

АЛБА'НИЯЛЕ *и.* 1. *к.* албан.

2. Албания Халык Республикасында яшәүче хәзерге халык.

АЛБАСТЫ *и.* 1. Халык ышануларында: йоклаганда кешене саташтыра, баса торган җен, явыз рух.— *Бер вакытны мин шулай йоклап ятадыр идем, албасты өстемне бөтенләй каплап алган, әй тырышам, әй тырышам котылырга.* Г. Камал. *Бик куе булганга, монда [урманда] --- Төрле албасты, убырлар, шүрәләләр бар, диләр.* Г. Тукай.

2. *күч.* Явыз көч, явызлык эшләүче, аждаһа (2 мәгъ.). *Мин шат бүген, Милли албастылар чәнчелгәнгә төшеп баш түбән.* Ш. Маннур. *Хәлең мөшкел, кыз бала, Шундый гүзәл яшьлегеңә бер албасты кул сала.* Т. Гыйззәт.

АЛГАЙ-САЛГАЙ *рәв.* Эленке-салынкы, ничек җитте шулай, тәртипсез (кешенең гәүдә торышы, йөреше турында).

АЛГАРУ *ф. иск.* 1. Алга китү, алга атлау (эштә).

2. Алга этәрү, алга җибәрү. *Ләкин һөҗүм дәвам итте һаман, Яшь батырның данын алгарып.* Ш. Маннур.

АЛГАРЫШ *и. к.* прогресс.

А'ЛГЕБРА *и.* Математикада: сан берәмлекләренең нинди булуына карамастан, хәрефләр белән билгеләнгән зурлыкларның үзлекләрен өйрәнү бүлеге.

АЛГЕБРАИК *с.* Алгебра ысуллары белән чишелә торган. *Алгебраик мәсьәлә.*

АЛГЫ *с.* 1. Алдагы, ал яктагы. *Алгы аяклар. Алгы рәт.* □ *Атлар тузанлы юл буйлап ашыкмый гына, әкрен генә атлыйлар, алгы көпчәкнең берсе, елаган кебек, нечкә генә, моң гына чыелдый.* А. Шамов.

2. Алдагы, киләчәк, киләсе. *Алгы айга уңыш ныгытылсын, Тагын күбрәк чуен бирелсен!* Ш. Маннур. *Паларусов, --- тикшерүченең алгы планы турында уйлана-уйлана, келәттән капкага таба юнәлде.* Г. Ибраһимов. // *и. мәгъ.* Алдагы көн, киләчәк. *Күп заводлар безнең күптән инде Планнарын тутырып ташлады, Алгы өчен эшли башлады.* Һ. Такташ.

3. *сөйл. сир.* Алдынгы, культуралы. [*Хәйрулла:*] *Әле Сабит бит каланың бердәнбер алгы егете хисапланып йөри.* М. Фәйзи.

Алгы бүлмә (як) — *к.* ал як. *Ул өстенә пальтосын киде дә, агач башмакларын кулына тотып, яланаяк көенчә генә алгы бүлмәгә чыкты.* А. Шамов. *Чемоданнар, кышкы пальтосы, иске галошлары, күчәргә әзерләнгәндәге төсле, алгы якка чыгарылып куелганнар.* Г. Минский. **Алгы саф** — 1) нинди дә булса эшнең, хәрәкәтнең үзәге. *Мәдрәсә яшьләре хәрәкәте әчендә Җиһангирның алгы сафта беренче булып арысландай сугышып баруына эче янгандыр этнең.* Г. Ибраһимов; 2) *к.* алгы сызык. **Алгы сызык (кырый, позиция)** — хәрәкәттәге армиядә дошманга иң якын позиция, иң алдагы окоплар. *Яшь капитан, корал кысып, Алгы сызыкта ята.* Г. Хуҗи. *Лейтенант Иванов ротасы урман эче буйлап зур саклык белән алгы позициягә бара.* Ә. Еники.

АЛГЫР *с.* Зирәк, үткен, җитез, уңган. *Үзе сүзгә дә бик алгыр, бик чапак.* Г. Ибраһимов.

АЛГЫ-САЛГЫ *рәв. к.* алкы-салкы.— *Ударниклар шул! Синең шикелле алгы-салгы гомер уздырып, чабата туздырып йөрмибез.* Т. Гыйззәт.

АЛГЫСАУ, АЛГЫСУ *ф. сөйл.* Җилкенү, ашкыну. *Соңгы мәртәбә күрешеп калу ният белән алгысыган яшь кызны тыеп калу мөмкинме соң!* Ф. Хөсни.

АЛГЫСЫТУ *ф. сөйл.* Җилкендерү, ашкындыру.— *Ичмасам, берөзлексез күңелне алгысытып торучы кешедән ераграк булыр, узганда-барганда күлгәсе күзгә чалынмас, күңел дә алай иләсләнмәс.* Ф. Хөсни.

АЛДА *рәв.* 1. Ал якта, каршыда. *Ул арада алда бүреләр улаган, кабан дуңгызлары мыркылдаган бик яман тавышлар ишетелә башлады.* М. Гали. *Алда, инеш күперенә җитәрәк, --- шалаш кебегрәк ике-өч нәрсә күренә иде.* Г. Гобәй. // *бәйл. функ.* Каршыда.— *Син минем алда үзеңне хәрбиләрчә тотарга тырыш.* М. Гали.

2. Киләчәктә.— *Минем алда эшләргә торган бер эшем бар.* М. Фәйзи. *Инде минем кызым — комсомолка, Чәчләремә бара чал кереп; Ә күңел яшь, әле башланмаган Бер яшь гомерем алда бар кебек.* Г. Хуҗи.

3. Кемнән яки нәрсәдән дә булса элек. *Чуртан Халикъ бөтен кешедән алда гаризасын сузды.* Ш. Камал. *Дәүләткә ашлык тапшыруны срогыннан алда үтәгән өчен колхоз председателе Хәнәфине патефон белән бүләкләүләрен әйткән.* Г. Әпсәләмов.

4. Беренче булып, сафның, төркемнең башында (бару, килү). *Карлыгач, аларга каршы барып, алда кайтучы --- яшь бер киленнең иңендәге көрәген килеп алды.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Эштә, хезмәттә кемнән дә булса өстен, алдынгы. *Ул элек Сәхипкә караганда бик күп дәрәҗәдә алда, үткен егет иде.* Г. Ибраһимов.

5. *хәб. функ.* Алга киткән. *Сәгать 10 минут алда.*

◇ **Алда йөрү** — 1) башлап йөрү, инициатор булу; 2) кадерле булу; хөрмәтләнү.— *Зәйнәпне алгач, аның карт хатыннарына нинди сан калыр дип беләсең? Яшь хатын кайда булса да алда йөри ул!* М. Гафури. **Алда күрү (тоту)** — өстенлек бирү, өстен күрү, иң киреклесе дип санау. [*Г. Тукай*] *тормышында садәлекне һәрнәрсәдән алда күрә торган кеше иде.* Ф. Әмирхан. *Үзен, мәртәбәсен башка һәрнәрсәдән алда тотучы тәэҗрибәле бикә икенче төрле җавап бирде.* Г. Ибраһимов. **Алда тору** — 1) алдынгы булу, өстен булып, башкалардан аерылып тору. *Газет-журнал таратуда, халыкны агартуда Булат иптәш арабызда Күпләрдән алда тора.* М. Җәлил; 2) беренче чиратта эшләнергә тиешле эш булып планда тору.

АЛДАВЫЧ *и.* Балык, кош һәм хайваннарны алдап ауларга, тотарга яки үтерергә ярдәм итә торган нәрсәләр. *Зарарлы кимерүчеләрне төбе һәм капкыннар белән тоталар, өннәрендә үтерәләр, агулы алдавычлар [мәсәлән, агуланган солы бөртекләре] белән агулыйлар.* Зоология. // *с. мәгъ.* Ялган, алдый торган, бутый торган. *Алдавыч күренеш.*

АЛДАГЫ *с.* 1. Алгы яктагы, алгы якта урнашкан. алда урнашкан, алгы, алгы пландагы, алгы рәттәге. *Алдагы сафлардан Нәфисә бригадасында эшләүче яшьләр күтәрелеп чыкты.* Г. Бәширов. *Егет тышкы ишекне ачып алдагы бүлмәгә керү белән сәлам бирде.* Г. Ибраһимов.

2. Киләчәктәге, киләсе. *Берәүләр алдагы тормыш планын уйлады.* М. Гафури.— *Быел, авыррак булса да, кышны чыгып киләбез, ә алдагы ел өчен азык хәзерләү хәстәренә язга аяк басу белән үк керешербез.* Ә. Еники. // Алда торган, киләчәктә үтәлергә тиешле. *Бу хәбәребез --- алдагы бөек эшләрнең башы гына.* Ш. Усманов. // *и. мәгъ.* Киләчәк.— *Сынатырга тиеш түгел кебек тә, --- белеп булмый бит алдагыны.* Г. Әпсәләмов. *Алдагым өметле, Бүгенгем күрекле.* М. Җәлил.

АЛДАГЫЧ *с.* Алдый торган, алдандыра торган. [*Нуруллин*] *егылмас өчен сул кулы белән тотынырга теләде: гаҗәп алдагыч, тиз оныталмый торган хәрәкәт, һәм бу хәрәкәт аны харап итте [сул кулы төптән юк иде].* А. Шамов.

АЛДАКЧЫ *и.* Алдый торган кеше, ялган сөйләүче. ялганчы. *Мондый кешенең алдакчы булуы мөмкин түгел.* Каз. утл. / *с. мәгъ. Мин үземне синең каршыңда алдакчы кеше итеп калдырасым килми.* Т. Гыйззәт.

АЛДАҚЧЫЛЫК *и.* Алдакчы булу. [*Мөгълифә*] *үзенең хәйләкәрлеге, мәкерлелеге, алдакчылыгы, явызлыгы һәм әшәке теллелеге белән Г. Камал әсәрләрендәге шундый тип карчыкларның һәммәсеннән өстен.* М. Гали.

АЛДАЛАУ *ф. сөйл. к.* алдау.— *Сөеклем, бәгърем син минем, син мине гафу кичер, гафу ит, мин сине алдаладым, мин син күргән егет түгел, мин бөтенләй икенче кеше.* А. Шамов.

АЛДАН *рәв.* 1. Элек, беренче булып, әүвәл. [*Гайнетдин*] *алдан кереп, иелеп Сабитны каршылый.* М. Фәйзи.

2. Башта ук. *Аңа мәшәкатьләнеп озатып бармаса да ярый икәнен әйтергә теләсәм дә, файдасыз булачагына алдан ышангач, әйтмәскә булдым.* Г. Минский.

АЛДАН-АЛА *рәв. сөйл.* Вакыты җитмичә, ашыгып, уйламыйча. — *Сиңа да, Бикмулла абзый, ала каргадай алдан-ала кычкырмаска кирәк иде.* Г. Бәширов.

АЛДАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* алдау (1—5 мәгъ.). *Аю, ахмак, ике елда да гакыллы карттан алданды.* М. Гафури.

2. Ялганга ышанып ялгышу. *Тоткыннар үзләренең алданганлыкларын сизеп ишеккә килгәндә, тимерле калын шәк бикләнеп өлгергән иде инде.* Г. Гобәй. // Берәр кеше яки берәр нәрсә турында ялгыш уйда булу.— *Мин бу көнгә кадәр [Гайнинең] алдалап сөйләгән сүзләренә, үзен гыйффәтле итеп күрсәткән кыланышларына алданып йөргән икәнмен.* Г. Камал.

3. Кызыгу.— *Мондагы юк-барга алданып, күңелеңне аздырма!* Г. Коләхметов.

4. Отылу. [*Поплар, сәүдәгәрләр*] *һәммәсе алалар, саталар, алдыйлар, алданалар, үзара гөж киләләр.* Г. Ибраһимов.

АЛДАР *с.* Алдашырга, ялганларга күнеккән, алдашырга оста булган.— *Вакытлы хөкүмәт алдар таздан да болайрак булып чыкты түгелме?* Т. Гыйззәт.

АЛДАТУ *ф. к.* алдау (1—5, 7 мәгъ.). [*Закир, күкрәгенә сугып:*] *Бу алай сезнең шикелле жуликларга гына алдата торган кеше түгел!* Г. Камал.

АЛДАУ *ф.* 1. Хәйләләү, хәйләләп нәрсәсен дә булса алу. *Спекулянт йөри мыштым гына, Уйлап сине алдау хакында.* З. Мансур. // Хәйләләп, кешене авыр хәлдә калдыру; кешегә начарлык эшләү.— *Крестьяннарның күпчелеге, һичшиксез, безнең арттан барачак, чөнки эсерлар аларны алдадылар, җир бирмәделәр.* И. Гази.

2. Ялганлау, ялган сөйләү. *Сөяксез тел кайчак алдаса да, Күз карашы, җаным, алдамас.* М. Җәлил.

3. Ялган сөйләп кешене ялгыштыру, ялгыш фикергә китерү, ялганга ышандыру.— *Сез, Хажи әфәнде, кыланып маташмагыз. Бүтән кешене сез кырык тапкыр алдарга мөмкин, ләкин мине --- бер тапкырдан ары алдый алмассыз.* Ш. Камал.

4. Кызыктыру. *Алдама мине Ярың күрсәтеп, Аулама мине Кызың күрсәтеп.* Ш. Бабич.

5. Саташтыру, ялгыштыру, башкача булып күренү яки ишетелү. [*Йолдызларның шәүләләре,*] *диңгезнең төбенә куәтле һәм гаять матур электрик лампаларын меңәрләп яндырып куйган шикелле, күзләрне алдый иде.* Ф. Әмирхан.

6. Вәгъдә бозу, хыянәт итү. *Нигә янмасын йөрәк, Алдап йөргәч сөйгәне.* М. Җәлил. // Көчләү, намусына кагылу. *Ул моннан биш ел элек Зәйнәпне алдап киткән бай баласы Гали әфәнде иде.* М. Гафури.

7. Ялгышу.— *Хәтерем алдамаса, мәктәптә моны сигезле дип укытканнар иде.* Г. Гобәй.

АЛДАУ-ЙОЛДАУ *ф.* 1. *сөйл.* Алдау, хәйләләү.— *Куй, зинһар, андый алдау-йолдаулар булырлык булганда, мин соң олы башымны кече итеп андый юк-бар эшләргә катышып йөримме?* Г. Камал.

2. *рәв. мәгъ.* **алдап-йолдап.** Төрле хәйләләр белән, юк-барга кызыктырып. *Еллар үткәч, явыз ният белән, Әллә нинди юллар аркылы, Алдап-йолдап безнең арабызга Килеп кергән, шайтан алгыры!* Һ. Такташ. // «Ничек кирәк алай», «тырышып-тырышып» кебек мәгънәләрдә кулланыла. *Ә терелеп чыккач, үлемне тагы бер кабат алдап-йолдап озаткач, һәркайчан шат күңелле бу бабайны --- кыр бригадасына агротехник итеп беркеттеләр.* Г. Гобәй.

АЛДАШУ *ф. сөйл.* 1. Хәйләләү, хәрәмләү, башкаларны алдау. *Алдашып маллар җыясың да, үзең «дин, дин» дисең!..* М. Гафури.

2. Алдау, ялган сөйләү.— *Мин сине бит, Рәшит, тузан кадәр дә алдаша белми торган комсомолец дип уйлап йөри идем.* Р. Ишморат.

АЛДЫ-АРТЛЫ *рәв. к.* аллы-артлы. *Җәләлне озатып өйгә керүгә, алды-артлы ике бала килде.* Г. Ибраһимов.

АЛДЫ-АРТЫ *җый. и.* 1. Ал һәм арт, тирә-як. *Кара урманда карак бар, алдың-артың карап бар.* Җыр.

2. Ахыры, нәтиҗәсе. *Мин алдын-артын уйламастан, телгә килгән беренче күршенең исемен әйттем.* Г. Бәширов. *Ул бу көнгә чаклы бер дә алдын-артын, киләчәген уйламый йөрде.* М. Гафури.

АЛДЫМ-БИРДЕМ: алдым-бирдем ясау — 1) сатуалу, товар алмашу; 2) кыз яратышкәндә килешү.— *Кирәк булса, хәзер үк берәребезгә «алдым-бирдем» ясап, яучылык кылып, туй ясап алырга була.* Ф. Бурнаш.

АЛДЫН *с.* 1. *к.* алдынгы. *Алдын ударниклардан, Бөтен Татарстаннан Без ун кеше сайландык.* Ф. Бурнаш.

2. Өстен. *Хаклык алдын барчадан, Өстен барча нәрсәдән.* М. Җәлил.

АЛДЫНГЫ *с.* 1. Иң алдагы, беренче. *Менә алдынгы сафта үк Кадыйрның иптәшләре утыралар.* А. Алиш. *Җамалилар ротасы да җир асты юлларын үтеп, алдынгы линия окопларына кереп урнашты.* М. Гали. / *и. мәгъ. Атлыларның алдынгылары килеп тә җиттеләр.* Ш. Усманов.

2. Башкалардан алда бара торган, үрнәк. *Нурулла абзый алдынгы крестьян булган кебек, алдынгы колхозчы да була белер.* Каз. утл. // Укымышлы, прогрессив. *Ул әйткән заманның нинди заман булуы һәм ул заманның алдынгы кешеләре кемнәр икәнлеге минем өчен бик томанлы иде.* М. Әмир. *Хезмәт ияләренең алдынгы өлеше, партизан отрядлары оештырып, Кызыл Армиягә ярдәмгә чыкты.* Г. Гобәй. // *и. мәгъ.* Эштә, укуда башкалардан алда баручы, хезмәткә карата социалистик мөнәсәбәт үрнәкләрен күрсәтүче. *Өстәвенә, Шаһгәрәй абзый тимурчылар турында сөйләгәндә алдынгылар рәтеннән Хәлимне дә кат-кат мактап телгә алды.* Г. Гобәй. *Трибунага берәм-берәм яңа ел вахтасының алдынгылары чыга башлады.* Г. Минский.

3. Хәзерге таләпләргә җавап бирә торган, прогрессив. *Алдынгы техчика. Алдынгы тәҗрибәләр белән уртаклашу.*

АЛДЫНГЫЛЫК *и.* 1. Алдынгы булу, алда булу. *Ауда мәргәнлеге өчен, Яуда алдынгылыгы өчен Халык аны Мәргән батыр дип исәпләде.* М. Җәлил. / *с. мәгъ. Народниклар эшчеләр сыйныфының алдынгылык ролен аңламаганнар.* СССР тарихы.

2. Ярышта, көрәштә жиңүче булу, беренчелек. *Алдынгылык өчен көрәш.* □ — *«Чулпан» халкы быел алдынгылыкны үзенең маңгай тире белән казганын алды!* Г. Бәширов.

АЛДЫРТУ *ф. к.* алдыру (1—2 мәгъ.).— *Калада берәүнең кулымы, аягымы чыккан икән, --- Карамалы остасын алдыртканнар.* Г. Ибраһимов. *Илдар бармагына кергән шырпыны әнисеннән алдырта да сүзен дәвам итә.* Г. Гобәй.

АЛДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* алу (1—6 мәгъ.). [*Жәүдәт Мансуров*] *нидер исәпләтә, туфрак төрләрен алдыра, нәселле хайваннарны карап уздыра, нидер уйлап ка-*

рарга, план сызарга киңәш итә. Г. Бәширов.— *Миркәй, хәзрәтнең указын алдырам, дип әйтә, ди.* Н. Исәнбәт.

2. Кунакка, эшкә, яшәргә һ. б. ш. сәбәп белән читтән чакырып китерү. *Берәр ел эшләгәннән соң, ул үз янына бөтен семьяларын алдырды.* Һ. Такташ.

3. Алга китү, алга чыгу; нәрсәне дә булса башкарып, жиңеп чыгу. *Безгә хәзер күбрәк хәйлә белән алдырырга кала,— диде Гарифулла.* Г. Минский. // *сөйл.* Кызу, шәп бару. *Яхшы ат соңыннан алдыра.* Мәкаль. *Пароход иса, Гаяз күңеледәй ашкынып, чапкан ат тизлеге белән алдыра гына.* Х. Сарьян.

4. (Газета, журналны) язылып алу. *Рифгатьнең газета алдырып, анда-санда газеталар күзәткәләп баруы картны малайларына беркадәр соклану белән карарга мәҗбүр итә.* Ф. Хөсни.— *Булат көн дә бригадама Газет китерә иде. Газет алдыру юлларын Аңлатып бирә иде.* М. Җәлил.

5. (Ихтыярсыз) кулдан ычкындыру яки урлату. *Кулъяулыкларым күп иде, Берсен җилгә алдырдым.* Жыр.— *Ничек итеп хафаланмассың, ичмасам акчасын алдырмый гына кайткан булса, тагын бер хәл иде.* Г. Камал.

АЛДЫРЫКЛЫ: зур (олы) алдырыклы — кызу йөри торган, зур атлый торган, алымлы, йөгерек. *Әгъләм юыртырга керешкән олы торыклы, зур алдырыклы туры атның дилбегәсен бушатыбрак җибәрде.* С. Рафиков.

АЛЕБАСТР *и.* Төзү эшләрендә файдаланыла торган гипслы таш. // *с. мәгъ.* Алебастр эшкәртә торган. *Каратунда алебастр заводында эшләүче әҗем кешесенең хатыны бәбиләгән булган икән.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Алебастрдан ясалган. *Алебастр бюст.*

АЛЖИРЛЫ *и.* Алжирда яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе.

АЛИБИ *махс.* Берәр жинаять ясауда гаепләнүченең гаепсезлегенә төп дәлил буларак, жинаять ясалган вакытта аның башка урында булуы.— *Сыйнфый көрәш гаять кискенләшкән хәзерге шартларда политик гаепне өстеңнән төшерү бик авыр эш ул. Монда алиби юк...* Ә. Еники.

АЛИЗАРИН *и.* Марена тамырыннан алынган яки ясалма юл белән хәзерләнгән буяу матдәсе. // *с. мәгъ.* Ализариннан ясалган, ализаринлы. *Ализарин буяулар.*

АЛИЗАРИНЛЫ *с.* Ализариннан ясалган, ализарин катнаштырып ясалган, составында ализарин булган.

АЛИМЕНТ *и.* Аерым яшәүче, хезмәткә яраксыз семья членнарына (балаларга, ата-анага) туганлык мөнәсәбәтендә булган кешеләр тарафыннан закон буенча түләнә торган акча. *Фәрдәнә, шактый зур үскәч, [әнисенең] югалган иренең эзенә төшеп, алимент юллап чыгарганын да яхшы хәтерли.* М. Әмир.

АЛИһӘ *и. иск. дини.* Хатын-кыз алла. *Алиһә миһрабы. Мәхәббәт алиһәсе.* □ *Грекларның ышануы буенча, аларны чолгап алган табигать аллалар һәм алиһәләр белән тулы.* Бор. зам. тар. / *күч. Аллалар һәм алиһәләр дип саналган атаклы актерлар — хәзер [Хәбирнең] иптәшләре.* Ш. Хөсәенов.

АЛКА *и.* 1. Гадәттә металлдан эшләнгән коршау формасындагы бөгәлҗә, божра. *Газинур [калтыранган атның] тимер чылбырыннан эләктереп өлгерде һәм чылбырны алка аркылы үткәреп, ике кулы белән аңа асылынды.* Г. Әпсәләмов. *Дугадагы алканың деңгердәве авермачык булып ишетелә, атның башы якын гына селкенә башлады.* И. Гази. // Божра формасындагы нәрсә. *Кызыл, яшел алкалар белән чуарланып беткән картага бармагы белән төртә-төртә, Дәүләтшин атака планын ачыклый.* И. Гази. // *кит.* Кемне яки нәрсәне дә булса әйләндереп, чолган алган нәрсә. [*Туташ һәм ханымнар*], *Мәдинәләрне бер читтә калдырып, Хәбирне алка эченә кысты.* Ш. Хөсәенов.

2. Колак йомшагына тага торган асылма бизәнү әйбере. *Тамчылы алка.* □ — *Менә сиңа бүләк итеп бер алтын алка алып килдем.* Г. Камал. // *с. мәгъ.* Колак алкасы кебек асылынып торган. *Сарана — алка чәчәкле, суган төпле үлән.* Н. Исәнбәт. // *бот.* Кайбер үсемлекләрдә колак алкасына охшашлы орлыкча. *Июльдә каеннының алкалары соры төскә керә, ә бер айдан инде орлыгы өлгерә.* Соц. Тат.

3. *спорт.* Югарыга беркетелгән ике бауның түбәнге очына асылган ике божрадан гыйбарәт спорт жиһазы. [*Кыз*] *алкаларда шундый жиңел атынырга тотына, минем исем китә.* Г. Әпсәләмов.

4. *спорт.* Хоккей уенында кулланыла торган түгәрәк яссы резина; *русчасы:* шайба.

АЛКАЛАНУ *ф.* Алка-алка булу, божралану; бөдрәләнү. *Әминә аның башындагы косынкасы кырыйларыннан алкаланып чыккан чәч бөдрәсен күрде.* Г. Минский.

АЛҚАЛАУ *ф. сир.* Әйләндерү, чолгап, уратып алу. *Иртә белән күк битенә нечкә генә аксыл болытлар кунып, кояшны алкалап алганнар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АЛҚАЛЫ *с.* Махсус бортлар белән чикләнгән бозлы мәйданда алка (4 мәгъ.) сугып уйный торган. *Алкалы хоккей.*

АЛҚОГОЛИЗМ *и.* Эчкечелеккә сабышу, эчкечелек (авыруы).

АЛҚОГО'ЛИҚ *и.* Эчкечелеккә сабышкан кеше, эчкече, исерек баш.— *Тик торганда берүзем [эчеп] утырырга алкоголик түгел бит мин.* Г. Мөхәммәтшин.

АЛҚОГО'ЛЬ *и.* 1. *махс.* Спирт.

2. Гомумән аракы, спиртлы исерткеч эчемлекләр. *Күпләрнең башын әйләндергән мәшһүр алкогольнең тәэсирен үз тәҗрибәм белән татып карыйсы килү телә эчәргә көчли иде.* М. Әмир.

АЛҚОГОЛЬЛЕ *с.* Спиртлы, исерткеч. *Алкогольле эчемлекләр.*

АЛҚУШЫМЧА *и. лингв.* Сүзнең тамыр алдындагы кисәге, префикс.

АЛҚЫН I *с.* Мул сулы, көчле агымлы. *Агыйделкәй алкын, сулары салкын, Дулкыннары килеп какмасын.* Жыр.

АЛҚЫН II *и. диал.* Күн итек, киез итек, читек һ. б. ш. аяк киемнәренең тамагы.

АЛҚЫ-САЛҚЫ *рәв.* 1. Теләмичә, иренеп. *Ул Хәйдәр мулланы да һич ялкынсыз, һичбер утсыз, алкы-салкы гына тыңлады.* С. Рафиков. // Эленке-салынкы. *Алкы-салкы йөрү.*

2. *сөйл.* Бер төрле түгел, бер алай, бер болай үзгәрүчән. *Бу арада көннәр алкы-салкырак тора.*

АЛҚЫШ *и.* Хуплау яки котлау билгесе итеп кул чабу. [*Съездда*] *колхоз вәкилләре сүз ала, Зал алкышка күмелеп дулкынлана, Зал аякка баса, кузгала.* Һ. Такташ. // *күч. шигъ.* Алкышка охшаган тавыш, шаулау турында. *Без тыңлыйбыз кичле-иртәле Шат жилләрнең дәртле алкышын. Күлләр тыңлый кичле-иртәлә Камышларның дәртле алкышын.* М. Җәлил.

АЛҚЫШЛАУ *ф.* Мактап, хуплап яки котлау билгесе итеп кул чабу. *Аның сүзен бүлеп берничә мәртәбә алкышладылар.* М. Гали. / *рәв. мәгъ. Жыелыш бу эшне алкышлап каршы алды.* А. Алиш.

АЛЛА *и.* 1. Ислам динендә «бар вә бер» итеп таныла һәм табына торган затның исеме, тәңре, хода.— *Ничек алладан курыкмыйсың да бәндәдән оялмыйсың!* А. Шамов. // Мәҗүсилек чорында төрле өлкәләргә **караган илаһи көч. Ут алласы. Су алласы.** □ *Ул сорады күк алласыннан: «Бетсен,— диеп,— жирдә коллык, Күзьяшь һәм кан!»* Һ. Такташ. // Табыну предметы. [*Буржуйга:*] *Аллаң синең — акчаң иде, акчаң иде, Динең булды мал гына, мал гына.* Г. Камал.

2. *күч.* Күпчелек тарафыннан ихтирам ителә торган, абруйлы, авторитетлы кеше. — *Сугыш вакытында Гыймади абзый авылның алласы иде. Тик күтәреп кенә йөртмәделәр үзен.* И. Гази. // Нинди дә булса эшне

башлап җибәрүче һәм җитәкләүче. *Поселокны яшелләндерү алласы дип атый* [*Зифаны*] *Гәрәй.* А. Гыйләҗев.

3. *ы. функ.* Гаҗәпләнү, соклану, әрнү яки нәфрәт кебек хисләрне белдерә.— *Алла, син бигрәк икәнсең, «егылганны түбәлә» дигән кебек, бар нәрсәдә хатын-кызларны гаепле ясыйсың икән.* С. Рәмиев.— *Я алла, нинди гөнаһларым өчен чал чәчле башыма бәла булып килдең икән!* А. Шамов.

Алла йорты *дини.*— мәчет.— *Тукта, сабыр ит, алла йортында сүгенмә.* Һ. Такташ.

◇ **Алла белсен (белә)** *кер. сүз функ.*— белмим, билгесез, кем белсен.— *Инде хәзер* [*Галинең*] *һичбер хәбәре юк, алла белсен, әллә адәм суеп каторгага китте, әллә җәһәннәм төбенә чумды.* Г. Ибраһимов. **Алла биргән** — бушлай килгән. **Алла бирсә, алла боерса (кушса, насыйп итсә, теләсә)** — ни дә булса теләп, өметләнеп әйтелә.— *Алла боерса, ул арада заманнары да рәтләнеп китәр иде.* А. Шамов.— *Син, Нәҗия, бер дә борчылма, бар да җайланыр, бар да үзенең эзенә төшәр, алла бирсә.* Ә. Еники.— *Үзем сәламәт булсам, алла теләсә, тамагым туяр!* Г. Коләхметов. **Алла бозавы (мәхлугы)** *кимс.*— бик булдыксыз һәм артык юаш кеше турында. [*Садыйк*] *алла бозауларының берсе инде ул.* К. Тинчурин. **Алла диген** *кер. сүз функ.*— *бик үзынма, алладан уза алмассың* мәгънәсендә. **Алла кабул итсен (күрсен), алла рәхмәтендә булсын** — яхшылык эшләүчегә рәхмәт догасы урынында әйтелә. **Алла каргаган** — 1) бер-бер артлы бәхетсезлек булып торган (урын, нигез); 2) икмәк уңмый торган (җир).— *Ышна җиребезне алпут талап алды, без шуны да кайтарып ала алмадык, җыен ташлык, җыен комлык, алла каргаган җир бездә.* И. Гази. **Алла кунагы** — чакырылмыйча, ләкин бик вакытлы килгән кунак. **Алла колы (бәндәсе)** — 1) шаярып яки кимсетеп мөрәҗәгать итеп әйтелә.— *Бер тылсым да юк, Алла бәндәсе, Бел, һәрнәрсәдә Атом зәррәсе.* Н. Исәнбәт; 2) юаш кешегә карата әйтелә. **Алла куят (ярдәм) бирсен** — эш эшләп торучыга яки авыр хәлдәге кешегә яхшы теләк формасында әйтелә.— *Алла куят бирсен! — дияргә өлгерә алмады, мин шәрә да башладым.* Г. Ибраһимов. **Алла сакласын (язмасын, күрсәтмәсен)** — нәрсәне дә булса теләмәү.— *Кысынкылыкны алла күрсәтмәсен.* М. Гафури.— *Үзен генә очраткан булсам, алла сакласын, мин аның янына тукталган булыр идем бит.* Ф. Әмирхан. **Алла хакы өчен** — үтенүне, ялваруны белдерә. *Шулай да әле, кызлар, Алла хакы өчен, Миннән бераз читтә йөрегез.* Һ. Такташ. **Алла тәкъдире** — язмыш.— *Бәхетсез була икән, алланың тәкъдиреннән күрсен!* М. Гафури. **Алла юлы** — дин. [*Хәзрәт:*] *Алла юлыннан, патша сүзеннән чыкмагыз.* Ф. Бурнаш. **Алла юлындагы кеше** — дин әһеле.— *Рәнҗеттем, ахры, алла юлындагы кешене,— дип борчылып, карчык суфый янына килгән.* Ә. Фәйзи. **Алла язган** — язмыш.— *Алла язганнан узып булмас, дим, ләүхелмәхфүздә безгә кардәш булырга язган булса, аны бозып булмас.* К. Тинчурин. **Аллага да юк, муллага да юк** — бик ялкау, эшлексез кешегә карата әйтелә. **Аллага кайту** — бик диниләнү, тәкъваләнү. **Аллага мәгълүм (билгеле)** — *к.* алла белсен. **Аллага тапшыру (тәвәккәлләү)** — берәр эш башлау яки эшне тормышка ашыру.— *Аллага тапшырып, теге Солтангәрәй мирзаның үзе белән хаҗдан алып кайткан аргамагын сынап карарга туры килер, ахрысы.* К. Тинчурин. **Аллага шөкер** — нәрсәдән булса да канәгать булуны белдерә.— *Аллага шөкер, дигәндәй, кеше хакына тигәнебез юк.* А. Әхмәт. **Алланың каһәре төшсен** — каргау, тиргәү сүзе.

АЛЛАЛАШТЫРУ *ф.* Алла дип тану, табынырлык дәрәҗәдә олылау. *Сынга табынучылар дине табигатьне аллалаштыра, ата-бабалар культын тудыра.* Табиг. буйс. юл.

АЛЛАНУ *ф.* Ал төскә керү, алсулану. *«Карасана, бигрәк шикле бит моның яңаклары» дип уйлады* [*ана*], *Мәдинәнең дулкынланудан алланган йөзенә карап.* Ш. Хөсәенов. *Матур булып кырлар яшәрәләр, Ал чәчәкләр тагын аллана.* Ә. Ерикәй. *Алмалары аллана, Алга бетеп баллана.* Н. Исәнбәт.

АЛЛАСЫЗ *с.* Аллага ышанмый торган, динсез, дәһри.— *Исемем Ибраһим, яшь чагымда «алласыз Ибраһим» дип кушамат биргәннәр иде.* Соц. Тат. // *и. мәгъ. сөйл.* Дингә каршы пропаганда алып баручы, атеист.

АЛЛАУ *ф.* Алга буяу, алга ману. // Иннек сөртү, ал сөртү. *Ал битләреңне аллама, телең белән баллама.* М. Фәйзи.

АЛЛАҺ *и. кит.* Алла.

АЛЛЕГО'РИК *с.* Аллегория кулланып язылган, кинаяле.

АЛЛЕГО'РИЯ *и.* Конкрет художество образлары ярдәмендә абстракт төшенчәләр белдерү, киная. [*Әсәрдә*] *тагын ике символик тип — аллегория рәвешендә китерелгән сурәтләр бар.* Г. Нигъмәти.

АЛЛЕ'Я *и.* Як-ягына агачлар, куаклар утыртылган юл. *Каен аллеясы. Тополь аллеясы.* □ Павел белән Дамирә, култыклашкан хәлдә, бер аллеядан икенчесенә үттеләр. С. Рафиков.

АЛЛИТЕРА'ЦИЯ *и.* Художестволы сөйләмнең аһәңлелеген тәэмин итү өчен бер төрле тартык авазларның еш кабатлануы. Мәсәлән: *Сөйсәң — сөй, сөймәсәң — сөймә, Сөймәсәң — сөймәсәнә* җырында «с» авазы кабатлана.

АЛЛО Телефонда сөйләшкәндә *«тыңлыйм», «тыңлагыз»* мәгънәсендә әйтелә.— *Алло, --- миңа Иоганн Альфредович кирәк.* К. Нәҗми.

АЛЛЫ *с.* Ал төстәге, алсу. *Аллы күлмәккәеңне ки, Бит очларың аллансын!* Җыр.

АЛЛЫ-АРТЛЫ *рәв.* 1. Берсе артыннан икенчесе. *Мансуров белән Нәфисә йомшак туфрак өстеннән сузылган тар гына сукмактан аллы-артлы бодай җиренә таба киттеләр.* Г. Бәширов.

2. Бераз вакыт үткән саен, бер-бер артлы, рәттән. *Шуннан соң аллы-артлы берничә мәртәбә Рифгатьнең мәктәпкә күтәреп йөри торган сумкасын --- кешеләр китереп бирделәр.* Ф. Хөсни.

АЛЛЫ-ГӨЛЛЕ *с.* Искиткеч матур, ачык, төрле төстәге. *Картның кулында аллы-гөлле ситсы яулыкка бик пөхтәләп бәйләп торган ниндидер төенчек.* Каз. утл.

АЛЛЮР *и.* 1. Ат йәреше, атның йөреш рәвеше.

2. Донесениенең тиз тапшырылырга тиешлеген аңлата торган шартлы билге. *Өч аллюрлы пакет.*□ [*Корнеев, Ланцеттига соры конверт сузып:*] *Иптәш Тихиров, дивизия штабына, иптәш Постышев кулына, икенче аллюр!* И. Туктар.

АЛМА *и.* Алмагачның җимеше. *Урманнан иң кызыл алмалар сайладым, сезнең өчен генә саргаеп беткән чикләвекләр җыя алдым, бәхетегез мул икән, ризыгыгыз мул икән.* А. Алиш. // Алмагач. *Туган илебездә кояш җылы, туфрак яхшы, алма, йөзем үсә.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Алмага мөнәсәбәтле. *Кичке бакча тәмле алма исе белән тулган.* И. Гази. *Батальон торган җирдән сигез-ун километр чамасы читтә алма бакчаларына күмелеп утырган шәһәрчек бар иде.* Ә. Еники. // *с. мәгъ.* Алмадан хәзерләнгән. *Алма кагы.* □ — *Юлга ашарга уникә кәтлит, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем.* Г. Камал.

Алма күбәләге *зоол.*— вак күбәләкләр төркеменнән корткыч күбәләк. **Алма үләне** *бот.*— медицинада кулланыла торган сары чәчәкле исле үлән; *русчасы:* ромашка пахучая. *Алма үләне чәе белән өшегән милләш бик килешә диләр андый чиргә.* Р. Төхфәтуллин.

◇ **Алма бае** *иск.*— авылдан авылга йөреп алма сатучы. *Сабан урагы бетеп тә җитмәде, авылга алма байлары килә башлады.* И. Гази. **Алма бит(ле)**

йөз(ле) — матур, гүзәл, бик чибәр. *Фонарь яна, фонарь яктысыннан Алма йөзләр күбрәк балкыйлар.* Ш. Маннур. *Ул күркәм сынлы, алма битле, яшь һәм чая ефрейторларны, өлкән һәм кече сержантларны, солдатларны күрде.* Г. Минский. **Алма кебек (төсле, шикелле)** — матур, карап кына торырлык, тулып, пешеп торган, сәламәт. *Аларның - - - адәм актыгы кызларына кияү чыксын да, синең бердәнбер алма шикелле балаңа кияү чыкмасын имеш.* Г. Камал.— *Без сиңа бердәнбер алма кебек кызыбызны бирергә йөрибез тагы.* М. Фәйзи.

АЛМАГАЧ *и.* Розачалар семьялыгыннан алма бирә торган җимеш агачы. *Бакчаның алмагачларыннан куәтле бер ис аңкый.* Г. Ибраһимов.

АЛМАЗ *и.* 1. Ялтыравы һәм катылыгы белән башка барлык минераллардан өстен тора торган үтә күренмәле кыйммәтле таш (сырлы алмаз бриллиант дип йөртелә). *Ул: «Менә син бу нәрсәне таныйсыңмы?» — дип, очына алмаз беркетелгән бер сапны күрсәтә.* Д. Аппакова. // *с. мәгъ.* Алмаздан эшләнгән. *Әбинең сандыгында алтын беләзекләре белән алмаз кашлы йөзекләре һәм ике билеты бар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Тоткычка алмазның үткен бер кечкенә кисәге беркетелеп, пыяла кисү өчен махсус эшләнгән корал. *Кызның кулында ак саплы алмаз.* М. Сөндекле.

3. *с. мәгъ. күч.* Алмаз кебек каты һәм нык. *Алып кайтты алмаз кылычында ил саулыгын.* М. Җәлил. *Сүзем алмаз, күңлем ихлас Минем бөек халкыма.* Ә. Ерикәй.

АЛМАЗЛАНУ *ф. күч.* Нәрсәнең дә булса ялтыр-йолтыр килеп төрле төскә кереп алмазга охшап торуы. *Яланнар, урманнар, болыннар иртәнге чык белән алмазландылар.* Г. Ибраһимов.

АЛМАЗЧЫ *и.* Алмаз производствосында эшләүче. *Алмазчыларны бүләкләү.*

АЛМАЛАНУ *ф.* Алмагач чәчәге коелганнан соң, вак-вак алмалар барлыкка килү, җимешләнү. *Алмагачлар алмаланган, Алмалары бал гына.* М. Җәлил. // Кайбер җимеш яки яшелчә үсемлекләрнең (мәс., помидор, кыярның) чәчәк коеп, җимешләнүе.

АЛМАЛЫ *с.* 1. Алмасы булган, алманган. *Алмалы агач.*

2. Алма-алма итеп бизәк төшерелгән; эре бизәкле. *Сания апа суга бара, Көнтәсе алмалы.* Җыр. *Мин дә сабан туена дип тегелгән күк киндер күлмәк белән алмалы чуар штанымны һәм кызыл кәләпүшемне киеп - - - урамга чыктым.* М. Гали. // Алма кебек. *Алмагөл, аһ, пешеп җиткән алмалы бит.* Ш. Бабич.

АЛМАСАР: алмасар булу *сөйл.*— билгеле бер карарга килә алмыйча озак икеләнеп, әйле-шәйлерәк булу. *Ярый ла, күңеле Булмаса алмасар.* С. Хәким. *Алмасар булма, жәнашым, Насыйп түгел яр өчен.* Җыр.

АЛМАЧУАР *с.* Аксыл таплары булган җирән яки күк (ат төсе). *Синең атың алмачуар иде, Минем атым тимеркүк иде.* Ә. Ерикәй. *Дөньяны күп күргән, күп елкы асраган картлар колынның да [туганда башка төстәрәк булса да], азрак үскәч, алмачуарга әйләнәчәгән белләләр икән.* Г. Ибраһимов.

АЛМАЧЫ *и.* 1. Алма үстерүче. *Әнә утыра безнең алмачылар, Начармыни, әйтеп карагыз!* М. Җәлил.

2. Алма сатучы.

АЛМАШ *и.* 1. Кемне яки нәрсәне дә булса алмаштыручы кеше (кешеләр төркеме). *Очкан утка каршы барганда, Сиңа алмаш барын онытма.* М. Җәлил. // Берәр нәрсә урынына кулланырдай, шул нәрсәне алмаштырырдай әйбер. *Чәйдән соң Ленинград чәчәкләренә дә алмаш табылды — умырзая чәчәкләре.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Нинди дә булса эштә өлкән буын кешеләрен алмаштыручы (мәс., яшь буын). *Революциянең яшь көчләре, көннән-көн күбәеп, алмашны тутыра баралар.* Г. Нигъмәти.

3. Вакыт-вакыт алмаштыра торган нинди дә булса кием комплекты.— *Алмашка булмаса да, күлмәк-штан бездән булыр.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Алмаштыра торган, алмашка кия торган. *Алмаш кием.* □ *Алмаш күлмәкнең ертыкларын ямадылар.* М. Гафури.

4. *иск. к.* алмашлык. *Декламация тибындагы шигырьләргә күз салсак, аларда күбесенчә «без», «сез» кебек алмашларны күрәбез.* Г. Нигъмәти.

АЛМАШЛАП *рәв.* Чиратлап, чиратлашып, берсен икенчесе алмаштырып яки башка кешеләр белән алмашлашып, алмаш-тилмәш. *Хәзер безнең уртак тормыш башланды. Аш пешерү һәм чәй кайнату өчен алмашлап беребез палаткада кала, калганнарыбыз эшкә бара иде.* М. Гафури. *Әле Бикмуш бабай, әле Илсөяр, кешемазар килеп чыкмасын дип, алмашлап әйләнә-тирәне күзәтеп килделәр.* Г. Гобәй. // Кулалмаш эшләү.— *Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булганнар.* Г. Ибраһимов.

АЛМАШЛАУ *ф. сөйл.* Кемне дә булса алмаштыру, аның урынына басып, эшен дәвам иттерү.

АЛМАШЛАШЫП *рәв. к.* алмашлап. *Габделхәй белән Гобәй, баскыч култыгындагы чиләктән кружка белән су алып, алмашлашып битләрен юалар.* Ш. Камал.

АЛМАШЛЫК *и. лингв.* Исемен атамыйча гына, зат яки предметны, билге һәм микъдарны күрсәтеп килә торган сүз төркеме.

АЛМАШ-ТИЛМӘШ *рәв.* Алмашлап, чиратлап, чират белән, берсе артыннан икенчесе. *Шактый чаларган чәчле бер майор, алмаш-тилмәш сәгатенә һәм кабинет ишегенә карый-карый, ишекле-түрле йөренә.* Г. Бәширов.

АЛМАШТЫРУ *ф.* 1. Берәр әйбер биреп, аның урынына икенче бернәрсә алу. *Ябыгып, тиресе сөягенә ябышып беткән тимеркүкне пот ярым алабута онына алмаштырдылар.* Г. Ибраһимов.

2. Нәрсәдән дә булса файдаланудан туктап, аның урынына икенчене алу, кую. *Тимери аңа көлтә ташырга, сыерларны җигәргә, машинада эшләүче атларны ешрак алмаштырып, ай яктысында урырга куштым.* Г. Бәширов. *Икенче бер казак бераз суккан саен чыбыкларын алмаштырып, - - - яңа чыбык биреп тора.* М. Гали. // Үзгәртү, башкача итү.— *Минем хәзер исемем Мингаян түгел, алмаштырдым — Йолдыз.* А. Алиш.

3. Кемне дә булса хезмәтеннән азат итеп, чыгарып, аның урынына икенче кеше алу. *[Типография хуҗасы] управляющийны алмаштырырга күнмәде.* Ш. Камал. // Үлгән, һәлак булган, яраланган яки картайганнарга алмашка килү, алмашчы булу.— *Шәйхаттар абыең, мәрхүм, үз ватанын саклауда җан бирде, аның урынын алмаштырырга Солтан абыең үз теләге белән язылды.* Т. Гыйззәт. // Эштә, хезмәттә бер кеше урынына икенчесе алмашка килү; смена, пост алмашыну. *Без бер-беребезне алмаштырып, нәүбәт белән йоклап, төнне уздырдык.* Ф. Әмирхан.

4. Кием турында: берсе урынына икенчесен кию. *Өс-башны алмаштыру.* □ *Леспромхозга алар дүртенче көнне кайттылар, һәм Газинур, юл киемен дә алмаштырмыйча, Карп Васильевич янына йөгерде.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Танытмас өчен башка кыяфәткә керү. ***Син, Хамелеон, төсең алмаштырып,*** *Безнең арабызда калгансың. Кулакларны яклап, һәр эшеңдә Жимерү юлын алып баргансың.* Һ. Такташ. // Нинди дә булса бер әйбер урынына башканы кую, жәю һ. б. ш. *Диван җәймәсен алмаштыру.*

5. Акча турында: ваклау яки әрәләү. *Вак акчаларны бөтен ике йөзлеккә алмаштырып, Зәңгәр Чишмәгә таба юл тоттым.* Г. Ибраһимов.

6. Яңарту, искесен ташлап, аның урынына яңаны алу. *Ул алты почмаклы өй салып җибәрә, каралтылар торгызса, өс-баш киемнәрен, өй җиһазларын өр-яңадан*

алмаштыра, балалары укырга керәләр. Г. Әпсәләмов. // Яңарту, чистарту. *Һава алмаштыру.*

7. Юкка чыгып, яшәүдән туктап бара торган нәрсә урынына барлыкка килү; нинди дә булса өлкәгә яңалык кертү турында. *Колбиләүчелек җәмгыятен феодализм алмаштыра.* □ *Без кәкре борынлы суканы Тракторга алмаштырабыз.* Һ. Такташ.

8. Тиң булу, тәңгәл килү, тору. *Галиәхмәт эштә ялкын кебек, Алмаштырыр ялгыз икеңне.* Ш. Мөдәррис. *Туфрагын ничек кенә ашлама син аның, нинди генә банкаларга утыртма, боларның берсе дә кояшны алмаштыра алмый.* Г. Гобәй.

9. Карашыңны, илеңне, урыныңны, динеңне һ. б. ш. ташлап, башкага күчү, хыянәт итү.— *Матур бер елан өчен дин алмаштырып, әткәй-әнкәйне, Гайнияне ташлап йөрер хәлем юк.* Г. Ибраһимов. *Илемне һәм сине алмаштыргач, Җирдә миңа тагын ни кала?* М. Җәлил. // Бер нәрсәдән (эштән, урыннан, шөгыльдән) икенчесенә күчү, нәрсәне булса да үзгәртү. *Авылдан чыккан бу кеше үз гомерендә күп төрле кәсеп алмаштырды.* Ш. Камал.

АЛМАШУ *ф.* 1. *к.* алмаштыру (1 мәгъ.). *Килене рәнҗетүгә йөдәгән Миңзифа әби актык сәләмәләрен җыеп, берничә кадак онга, майга алмашып булмасмы дип, авылга китә.* Г. Нигъмәти.— *Әйдә алмашабыз урыннарны, мин синең урынга кухняга эшләргә кайтам, син минем урынга денщик булып тор.* М. Гали.

2. Үзгәрү.— *Исемегез алмашкан булырга мөмкин.* Ш. Камал. // Нәрсәләрнең дә булса берсе арты берсе килү, алмашыну. *Бертуктаусыз алмашып торган ышану, шатлану һәм көенүләрнең ни мәртәбәгә җиткәнен бер ходай үзең генә белерсең.* Г. Ибраһимов. *Күлмәк сөйгән назлы кызлар кебек, Дон һавасы бик тиз алмаша.* Ш. Маннур.

3. Бер кешенең эш, хезмәт урының, постын икенче бер кеше алмаштыру. *Урман авызындагы фураж саклана торган урынга каравылга җибәрелгән Васька төнге сәгать уникеләрдә [смена] алмашырга тиеш иде.* М. Гали.

4. Кием турында: берсен салып, икенчесен кию; *к.* алмаштыру (4 мәгъ.). *Кызлар эштән туктый, Өс-баш алмашалар.* Ф. Кәрим.

5. Бер нәрсәне икенчесеннән өстен кую.— *Берсенең дә бездән артык җирләре юк. Мин үземне [бай кызларының] кырыгына да алмашмам.* Г. Камал. *Авылның табигый, кәрсез күренешләрен, садә тормышын шәһәрнең чуарлыклары белән алмашасым килми.* М. Фәйзи.

6. *рәв. мәгъ.* **алмашып.** Чиратлашып, алмашлап. *[Ялчылар] берничә тапкыр, алмашып, абзарга карарга чыгалар, сыер бозауласа, сарыклар бәрәнләсә — туңмасын дип, өйгә кертәләр иде.* Г. Ибраһимов.

АЛМАШЧЫ *и.* 1. Берәр кешенең эш, хезмәт урынын алмаштырырга тиешле, аңа алмашка калып эшләргә тиешле кеше. *Инде Хәбибуллинның да Хәдичә янына кайтыр сәгате җитә. Озакламаслар, алмашчылар килеп җитәр.* И. Гази.

2. Нинди дә булса эштә, көрәштә олы буынга алмашка килгән (киләсе) яшь буын. *Кайгырмагыз, үз урыныма Алмашчы да табармын.* М. Җәлил.

АЛМАШЫНУ *ф.* 1. Берәр нәрсә, эш-хәл урынына икенчесе килү. *Сугыш тирәсендәге авылларда моңарчы власть перчаткадай алмашынып торды.* Г. Бәширов. // Эштә, хезмәттә бер кеше урынына икенче кеше килү. *Карыйбыз, ишек төбендәгеләр алмашынган.* К. Нәҗми.

2. Киемнең башкасы (яңасы яки чистасы) киелү турында. *Иртәгә басуга чыгасы дигән көнне Хәдичә түти мунча яктырды, бәтенесенең өс-башы алмашынып, кыр эшенә киеләсе киемнәр төзәтелде.* Г. Бәширов.

3. Дежур булу яки эшләү сәгате тулгач, урынына кеше килеп, эштән туктау. *Ул әле генә дежурдан алмашынган.* А. Шамов.

4. Үзгәрү, бер хәлдән икенче хәлгә күчү. *Табигать алмашыну. Һава алмашыну.* □ *Сәгыйдәнең уйлары яшен тизлеге белән алмашына, аның адымнары тизләгән саен, йөрәк тибүе көчәя.* Һ. Такташ. // *и. мәгъ.* Үзгәреш. *Габделбасыйрның тормышына гаҗәеп күңелле вә гаҗәеп файдалы алмашыну бирәчәк бу зур вакыйганы сөйлисе килә иде.* Ф. Әмирхан. // Кешенең рухи халәте, үз-үзен тотышы кинәт үзгәрү, башкачалану турында. *[Повар] газета өстенә иелгән генә иде, кинәт алмашынып китте.* Г. Гобәй.

5. Билгеле бер тәртип белән берсе артыннан берсе килеп тору, берсе урынына икенчесен алу, чиратлашу. *Биюләр җыр белән, җырлар биюләр белән алмашынды.* Г. Әпсәләмов.— *Ни өчен яз, җәй, көз, кыш була, ни өчен көн, төн тәртипле алмашынып торалар?* Ф. Әмирхан.

АЛОЭ *и. бот. к.* йөзьяшәр. Озынча һәм калын итләч яфраклы көньяк үсемлеге.— *[Алоэ] базарда тамыртомыр сатучы карчыкларда булыр. Алар сиңа алоэ[ны] түгел, әҗәл даруын табып бирерләр.* Н. Фәттах.

АЛПАВЫТ *и.* Феодаллык мөнәсәбәтләре булган илләрдә — эре җир биләүче, дворян. *Алпавыт утары.* □ *Алпавыт Уразмановның җирен бүлешүдә, имениесен Советка алуда бабай башлап йөрүчеләрнең берсе булды.* Г. Гобәй.

АЛПАМША *и.* 1. Әкиятләрдә сөйләнә торган бер батыр образы.

2. *күч.* Зур, баһадир гәүдәле, аруны белми торган кешегә карата әйтәләр.

АЛПАН-ТИЛПӘН *рәв. сөйл.* Йөргәндә як-якка авып, ава-түнә. *Ул, үрдәк кебек алпан-тилпән бер-ике атлауга, ачыргаланып кычкырып җибәрде.* Г. Бәширов. *Илсөяр, хәлсез аяклары белән алпан-тилпән атлап, әтисе артыннан ашыкты.* Г. Гобәй.

АЛПАР *и. иск.* Батыр сугышчы, рыцарь. *Алпарына күрә тулпары.* Әйтем.

АЛПЫ-САЛПЫ *с. сөйл.* Ялкау, иренчәк, алкы-салкы. *Ул бик алпы-салпы кеше. // рәв. мәгъ.* Ялкауланып, иренеп кенә, эленке-салынкы. *Алпы-салпы йөрү.*

АЛСУ *с.* Аксыл ал, сыек ал төс. *Алъяпкычың алсу-алсу, Алсуга мандыңмы әллә?* Җыр. *Без үстергән алмагачның Алмасы алсу гына.* М. Җәлил. *Сәрвәр туташ! Алсу йөзең, күзең күркәм, Тудыңмы әллә алсу нурлы җәйге иртән?* Ш. Бабич. // *и. мәгъ.* Алсулык. *Хинган тауларының башларыннан Таң алсуы күккә таралды.* Ш. Маннур.

◇ **Алсу күзлек аша карау, алсу күзлек киеп фикер йөртү** — кемне, нәрсәне дә булса идеаллаштыру, кимчелекләрне күрмәү. *[Илгиз:] Балаланмагыз, Рәхилә, алсу күзлекләр киеп фикер йөртмәгез. Тормышка аек карау хәерлерәк.* Б. Камалов.

АЛСУЛАНУ *ф.* 1. Алсу төскә керү, аллану. *Лизаның йөзе бер генә секундка алсуланып китте.* Ф. Әмирхан. *Көнчыгыш ягы әкрен генә алсулана, кызара башлый.* А. Шамов.

2. Алсу булып күренү. *Кызарып кояш чыкканда, Алсулана пәрдәләр.* Җыр.

АЛСУЛЫК *и.* Алсу төс. *Мәк чәчәге алсу-алсу, Алсулыгы сөйкемле.* Җыр. *Кояш яңарак баеган, күрәсең, бүлмәгә матур да, моңсу да булып шәфәкъ алсулыгы җәелде.* К. Нәҗми. *Аның бит алмаларына, чыраена, ягымлылык арттырып, алсулык йөгерде.* С. Рафиков.

АЛТАКТА *и.* Киемнең алгы өлеше, гәүдәнең алгы ягын каплый торган өлеше. *Менә чикмәннең алтактасы булды, арттактасы, аннары җиңнәре белән зур кайтарма якасы киселде.* Г. Бәширов.

АЛТАРЬ *и.* Православие чиркәвендә иконостас белән бүленгән түр як. *Киләсе буыннар иконаларга баш ияргә дә, алтарьдан уйналган музыканы тыңларга да килмәсләр.* Г. Гали.

АЛТАТАР *и. иск.* Наган, револьвер. *Зыя корулы алтатарын алды да, зур толыпны җилкәсенә салып, тышка чыкты.* Г. Ибраһимов.

АЛТАУ *Җыю саны. к.* алты. *Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җиде җиңгәм бар минем.* М. Фәйзи.

АЛТАЯК *и.* Тегермәндә ташны әйләндерә торган орчыкның кырык чәйгә тоташкан югары башы. // Алты кигеле көпчәк. *Алтаякның белә һәр зыңлавын, Шул зыңына куша җырларын.* Н. Исәнбәт.

АЛТМЫШ *сан.* 60 санын һәм микъдарын белдерә. *Аның алтмыш еллык гомере эчендә бервакытта да болай бәхетле булганы юк иде.* Г. Бәширов.

АЛТМЫШАР *Бүлем саны. к.* алтмыш.

АЛТМЫШЛАП *Чама саны. к.* алтмыш.

АЛТМЫШЫНЧЫ *Тәрт. саны. к.* алтмыш.

АЛТЫ *сан.* Биштән соң килеп, 6 санын, микъдарын һәм цифрын белдерә. *Алганга алты да аз, биргәнгә биш тә күп.* Мәкаль.

АЛТЫ-БИШ *с. сөйл.* Аңгыра, юләр сыман, тилемиле, аңгы-миңге. *Трофим дәдәсе аңа әллә нинди алты-бишрәк кеше булып тоела.* И. Гази.

АЛТЫЛАП *Чама саны. к.* алты.

АЛТЫЛЫ *с.* 1. Алтыны белдергән. *Ул сызыкның өске ягына бик матурлап кына алтылы цифр язып куя.* Ф. Әмирхан.

2. Үлчәве, размеры алты булган. *Алтылы галош. Алтылы куык.*

АЛТЫЛЫК *и.* Алты очколы уен картасы яки домино. *Давыт тагы бер карта алды, алтылык буби астына тыкты да, озаклап, мәшәкатьләнеп, бер читеннән генә карады.* Г. Ибраһимов.

АЛТЫН *и.* 1. Сары төстәге затлы металлдан гыйбарәт химик элемент. *Җир астыннан тапкан алтыннары күзне чагылдырып торалар.* М. Гафури. // *с. мәгъ.* Алтынга мөнәсәбәтле. *Алтын запасы.* □ — *Безгә шундый алтын тавына барырга туры килсә, баеп кайтыр идек тә соң.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Алтыннан коеп эшләнгән. *Һич тә көтмәгәндә Һажәрнең асравы килә дә, ишан кызы Сажидәгә тапшырырга дип, алтын йөзек биреп китә.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ. күч.* Алтын төсле, ачык сары төстәге. *Алтын чәч.* □ *Бу алтын игеннәр табигать мәрхәмәте буенча гына үсмәгән бит, аларны кеше үстергән.* Г. Әпсәләмов.

2. Шундый металлдан коелган әйберләр.— *Киявем булган кешемне мин --- алтын белән ефәккә күмәчәкмен.* Р. Ишморат. *Бай кырык мең сумлык алтын аласы урында, үзе өч мең сум акчасыннан колак кагып кала.* М. Гали. // Шундый металлдан коелган акча. *Ишек бавы бер алтын, безнең апай мең алтын.* М. Фәйзи. / *с. мәгъ. Алтын акча.* // Гомумән акча турында әйтелә. *Саф көмештин җырларымны Җырламыйм алтын өчен, Җырлаем тик саф көмештин Саф йөрәк халкым өчен.* Ш. Бабич. // Гомумән байлык турында. *Минем атам мирас итеп Алтыннар калдырмаган.* Ә. Еникәй.

3. Алтынга манылган ефәк җеп. *Алтын белән чигү.* // *с. мәгъ.* Алтынга манылган. *Якты электр утында байракның йолдызы, алтын чуклары һәм куе кызыл төстәге хәтфәсе җем-җем итеп торды.* Г. Әпсәләмов.

4. Алтынлы яки алтын төсендәге буяу. *Үтә күренмәле юка чынаяк китегенең нәфис бизәкләре өстенә --- алтын белән нәрсәдер язган булган, ләкин заман үтү белән сүзләре ашалып беткән иде.* Г. Гобәй. // *с. мәгъ.* Шундый буяу белән язылган. *Гарәфи абзый, алтын язулы папиросны бармак очларында әйләндерә-әйләндерә, --- Газинурга текәлде.* Г. Әпсәләмов.

5. *с. мәгъ. күч.* Бик яхшы яклары, сыйфатлары белән аерылып торган кеше яки берәр нәрсә турында.— *Менә, ичмасам, безнең эшче халыкны әйтсәң дә ярый, алтын бит алар.* Ш. Камал. // Бик акыллы, игътибарга лаек (сүз, фикергә карата). *Алтын сүзләреңне вакытсыз сипми тор, дускай.* А. Шамов. // *күч.* Кыйммәтле, яхшы, кадерле. *Яшь чагым, алтын чагым, Ялкын чагым булсын фида, Халкым алдында минем Биргән таза антым өчен.* Ш. Бабич. *Алтын иркем, азат тормышым, Кая очтың кинәт кош булып?* М. Җәлил.— *Арысланбай, бу җәйләүләрнең алтын көннәрен сагынып, ерак илләрдә күп моңлык кылды.* Г. Ибраһимов. /*хәб. функ. Сүзең көмеш булса, тик торуың алтын.* Мәкаль. *Бүген әле безгә һәрбер эшче кулы мең алтын.* Р. Ишморат.

6. *и. мәгъ. тарт. форм.* **алтыным.** Кадерләп, иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе. [*Әнвәр:*] *Анысы инде, алтыным, кайчакта дагалы ат та абына.* Р. Ишморат.

Алтын агач — мәңге яшел куак; *русчасы:* аукуба. *Алтын агачны яхшы туклыклы туфракка күчереп утырталар.* Йорт эшләре. **Алтын казык** — поляр йолдызы. **Алтын корсак** — корткыч бөҗәк. *СССРның көньяк полоса районнарында бакчаларга зарар китерә торган төп корткычлар булып --- алтын корсак --- һ. б. санала.* Йорт эшләре. **Алтын чәчәк** — ак, ал яки кызыл чәчәк ата, бакчада үсә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* маргаритка.

◇ **Алтын буяу** — ялган, ясалма, өсте ялтыравыклы нәрсә. *Иелмә, бирмә баш алтын буяуга! Сүрәнләтмә, йөрәгең очкынын ат Биек айга, сарайга, ташлы тауга.* М. Җәлил. **Алтын кул(лы)** — уңган, булдыклы.— *Их, рәхмәт яугырлары, кайсы алтын куллар утыртты икән бу алмагачларны.* Р. Төхфәтуллин. **Алтын көз** — көз көнендә яфракларның сары, кызыл һ. б. бик матур төсләргә кереп чуарланган, саргайган вакыты. *Авылга алтын көз килде.* Г. Гобәй. **Алтын таулар вәгъдә итү** — тормышка ашмастай нәрсәләр вәгъдә итү. *Халидә, телдән алтын таулары вәгъдә итмәсә дә, йорт һәм хуҗалык кирәкләрен күңеленнән бик нык кичереп йөри иде.* Ф. Хөсни. **Алтын остасы** — ювелир.— *Минем чишмәдә алмазың юк синең,— ди алтын остасы.* Д. Аппакова. **Алтын погоннар** *җыйл. и.*— ак офицерлар, патша армиясе офицерлары.— *Инде бу зур корсаклар, бу алтын погоннар ут эчендә янып ята торган иптәшләребез өчен хисап бирергә тиешләр.* Һ. Такташ. **Алтын су** — алтын йөгертү өчен хәзерләнгән сыекча. **Алтын туй** — семья корып тора башлауның илле еллыгы. **Алтын (хәрефләр) белән язу (басу)** — мәңгеләшү, тарихка керү. *Бу бөек каһарманнарның олуг хезмәтләре безнең милли азатлыгыбыз тарихында алтын хәрефләр белән язылачак.* Г. Ибраһимов. **Алтын эченда йөзү** — бик бай яшәү. **Алтынга ману** — 1) алтын-сары төскә кертү. *Куе болыт арасыннан ай чыгып, бодайларны алтынга манды.* Г. Гобәй; 2) бай яшәтү, кирәгеннән артык байлык белән тәэмин итү. **Алтынга (да) табып булмый** — юк, бернинди бәягә дә юк. *Мондый елларда андый хезмәтчене алтынга да табып булмый.* А. Шамов. **Алтынга яллану** — бик күп акча алу исәбенә яллану, күп акча алу өчен нәрсә дә булса эшләргә алыну. *Алтынга яланган төрекмән атлылары Чарджоуга якынлаша башладылар.* Ш. Усманов.

АЛТЫН-КӨМЕШ *җыйл. и.* Алтын белән көмеш. *Кайберләре, сукыр тычкан кебек, Җиргә күмә алтын-көмеш.* М. Гафури. // Гомумән кыйммәтле нәрсәләр, асылташлар, затлы әйберләр.— *Әгәр ул минем хатыным булса, мин аны башыннан аягына кадәр алтын-көмешкә чумдырыр идем, гомер буена киендереп-ясандырып, бик рәхәт итеп тотар идем.* Г. Камал.

АЛТЫНЛАНУ *ф.* 1. Алтын белән йөгертелү, алтынга манылу. [*Сәфәргалинең*] *генералның алтынланган погоннары, ука чуклы аксельбантлары да әллә ни айныта алмады.* Ф. Хөсни.

2. Алтынга манылган ефәк җеп белән тегелү, чигелү, бизәлү. *Алтынланган түбәтәйләр кигән* [*кешеләрнең*] *килгәне күренде.* Ш. Усманов.

3. Алтын сыман сары төскә керү, саргаю. *Ул имән төбенә, аның алтынланып килгән яфракларына карап*

сузылып ятты да җырлады. Г. Гобәй. *Баеп бара кояш тау артына. Алтынланган кырлар, урманнар.* М. Җәлил. // Алтынга охшап ялтырау, алтын сыман булып күренү турында. *Чәчрәгән су тамчылары ай сипкән нурлар белән алтынланып җемелдиләр.* Г. Гобәй.

АЛТЫНЛАУ *ф.* 1. Алтын белән бизәү, алтын йөгертү.

2. Алтын төсенә кертү, алтын-сары төсе бирү. *Без уянганда, кояш чыгып, безнең артта калган тауның башын алтынлаган иде инде.* М. Гафури.

АЛТЫНЛЫ *с.* 1. Составында алтын булган, алтын белән катнаш. *Күкрәгендә медаль алтынлы.* М. Җәлил.

2. Алтын йөгертелгән. [*Хәмдия*] *алтынлы хәситәләр, чәчтәңкә, кара алтынлы көмеш беләзек, алтын йөзекләр белән бизәнгән.* М. Фәйзи.

АЛТЫН-САРЫ *с.* Алтын сыман сары, алтынга тартым төстәге. *Алтын-сары дулкыннарын тирбәлдереп яткан бодай кыры* [*күренә*]. Г. Бәширов.

АЛТЫНСУ *с.* Сыек сары (төс). *Төне буе күбәләк-күбәләк карлар яуганнан соң, ындырлардагы алтынсу кибәннәрнең башлары, йомшак мамык бүрек кигән шикелле, күперенке булып калдылар.* С. Рафиков. *Тәрәзәдән агылган иртәнге кояш яктысында кызның чәче алтынсу нур белән чолганган.* И. Гази.

АЛТЫНЧЫ I *Тәрт. саны. к.* алты. *Алтынчы класс. Алтынчы күренеш. Алтынчы рәт.*

АЛТЫНЧЫ II *и.* Алтын-көмеш нәрсәләр эшләүче, коючы, алтын остасы; ювелир.— *Имештер, Чулпан аввылына читтән бик оста бер алтынчы килгән.* Г. Бәширов. // Гомумән алтын производствосында эшләүче.

АЛТЫШАР *Бул. саны. к.* алты. *Барысының да күкрәгендә бишәр, алтышар йолдыз.* Ә. Исхак.

АЛУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса кул белән тоту. *Ряков паспортларны алып, аларны бик озак әйләндереп карады, битләрне тәрәзә яктысына тотып, андагы һәрбер язудан берәр гаеп табарга тырышты.* Ә. Фәйзи. *Ул өстәл өстендәге папиросларның берсен алып, ашыкмый гына кабызды.* А. Шамов. // Эләктерү.— *Мин шулай басып торам, кем дә кем биеп кулымдагын алса, шәл шуңа булыр.* Қ. Тинчурин. // Көрәшкән, сугышкан кешеләрнең бер-берсенә тотынуы, берәр җиреннән эләктереп, ябышып тотуы турында. *Ике ир каһарман ярты сәгать буенча, бер-берсенең билләреннән алган хәлдә, мәйданны урап йөриләр.* Г. Ибраһимов.

2. (Үзе белән) йөртү, иярту, үзеннән калдырмау.— *Андрей,— дидем мин аңа ялынып,— ал мине үзең белән!* А. Шамов. *Тешсез иске урак ларын кулга тоткан, Ат куарга чыбык алган яшел талдан.* М. Гафури.

3. Башкару, үтәү, үз өстенә алу максаты белән эш яки йомыш кабул итү. *Боерык алу.*□— *Сез социалистик ярыш байрагын беренче булып күтәрдегез, өстегезгә бик зур йөкләмәләр алдыгыз.* Г. Бәширов. — *Берәр задание алсам, башкарып чыкмый торып, рәтләп тамагыма да капмыйм.* И. Гази. *Ул Бозаулык төбендә чехларга каршы сугышучы гаскәрнең командалыгын алды.* Ш. Усманов. // күч. Тикшерү, өйрәнү өчен нинди дә булса өлкәне, проблеманы сайлау. *Диссертация темасы алу.* // Нәрсәгә дә булса мөмкинлек булдыру турында.— *Икебез дә* [*яралану сәбәпле*] *өйгә кайтырга рөхсәт алдык.* Ш. Мөхәммәдев.— *Моңарчы да аларның ризалыкларын алабыз дип, кара җәяүгә калып беттек инде.* Г. Камал.

4. Бирелгән, җибәрелгән нәрсә кулга керү, ирешү. *Бу хатны алганыбызга ике атна булып узды.* Қ. Тинчурин. *Карт укытучы үзенең элекке шәкертләреннән уннарча котлау телеграммалары алды.* Г. Минский. // Кабул итү (сәлам, сүз, киңәш һ. б. турында). // Яңадан үзендә булдыру, кире кайтару. *Документларны алу.* // Телдән яки язма рәвештә билгеле булу (хәбәр, хәл).— *Мәүлиха апа, җаным, тагын ни булды? Кайгылы хәбәр алмагансың бит?* Г. Бәширов.

5. Нәрсә белән дә булса бүләкләнү. *Мактау грамотасы алу.* □ [*Әсәрдә*] *Гөлгенәнең җиңүе, орден алуы турында сүз арасында әйтелгәләп кителә.* М. Җәлил.— *Эшебез өчен зур бүләкләр, орденнар, медальләр алдык.* Г. Гали. // Нинди дә булса дәрәҗәгә, хәлгә ирешү, ия булу. *Кандидатлык дәрәҗәсе алу.*□— *Бөтенсоюз күләмендә Беренчелек алырбыз, Чөкердәшеп, гөрләшеп, Шул съездга барырбыз.* Ф. Бурнаш. *Бер эштә дә сынатмый ул, һәрбер эштә дан ала.* Ә. Ерикәй.

6. Белемле, мәгълүматлы, тәрбияле булу, белемгә, мәгълүматка һ. б. ш. ия булу.— *Сезнең арада кайнап күп нәрсә алдым.* Г. Ибраһимов. [*Командующийның*] *кайсы академияне тәмамлавын хәтерләмим, әмма чыраеннан ук күренеп тора: зур тәрбия алган укымышлы кеше.* Г. Бәширов.— *Кадерле атам, юкка гына мине бу мәдрәсәгә җибәрдең, монда тәртип-низам юк, гыйлем алуны уйларга да ярамый.* Т. Гыйззәт.

7. Файдалану өчен үз карамагында булдыру. *Бурычка алу. Библиотекадан китап алу.* // Яллау. *Ул ашыгып кием элгечкә килде, пальтосын алды, өстенә киде, клубтан чыкты да, троллейбус та көтмичә, такси алып редакциягә чапты.* Г. Минский. *Гөлбикә карышмады, извозчик алдылар да туры егетнең номерына киттеләр.* Г. Ибраһимов.

8. Нәрсәне дә булса акчага алмаштыру, акча түләп үзеңнеке итү (сатып алу).— *Куяннарны сатабыз да алма алып ашыйбыз, симәнке дә алабыз.* Г. Гобәй.— *Әнием, син миңа яңа күлмәк алырсыңмы?* Г. Минский. *Хәерле юл телә, иркәм, миңа, Билет алдым, бүген китәм мин.* Ә. Ерикәй.

9. Берәр нәрсә өчен түләтү. *Налог алу. Штраф алу.* □ *Ремонт өчен бик аз алдылар.* // Түләү тәртибендә кабул итү. *Күпме бәя алсаң да риза, тик сат кына.* // күч. Берәр нәрсәгә бурычлы итү. *Иртәгә үк китерергә вәгъдә алып, карчык малайны капкадан озатып җибәрде.* И. Гази.

10. Кулга төшерү, ия булу.— *Өйрәнмәгәнрәк тоткыннарның серләрен алыр өчен, күрше камерага охранка агентын утырталар да, стена аркылы сөйләшеп, материал суыралар.* Г. Ибраһимов.— *Нигә соң әүвәле рәхәт яшәгән Тәкъва Сәхәүләр, шул ук Низамыйлар рәхәт яшәгән дә, власть алабыз дип кан түгеп йөргән мин болай мыскыл ителәм?* М. Әмир. // Дошманнан коткарып, үзеңнеке итү, хуҗа булу.— [*Нәҗибә*не] *күрергә тырыштым. Смоленскины кире алганнан соң, госпитальдән кайтышлый, аларга тагын кердем.* А. Шамов.

11. Қаплау; биләү. *Кырны, тугайларны алды язгы сулар ташкыны.* Дәрдмәнд. *Миңнур карт аңа үз янында урын бирде, ул аксак аягын сузып җибәреп, ярты эскәмияне алып, җәелеп утырды.* А. Шамов. // күч. Төрле психик кичерешләр турында: чолгау, биләү. *Курку алу.* □— *Сөйләр идем барын, миһербаным, Хәсрәт алыр сезне — куркамын.* Ф. Бурнаш. *Хәдичә тутинең бөтен тәнен ут алды, күз алды караңгыланды.* Г. Бәширов. // Нинди дә булса физик үзгәреш барлыкка килү. *Арба янына килеп ятып, йоклау хәстәрен күрә башлагач, мине бизгәк кебек калтырау алды.* Г. Ибраһимов.

12. Қитү, бару, үтү. *Минем атым күк ала, Әкрен басып күп ала.* Җыр.

13. Җитештерү, чыгару, табу. *Нефтьтән бензин алу. Күмердән кокс алу. Тимер рудасы алу.* // Өлгергән жыю (иген, яшелчә һ. б. ш. турында). *Бәрәңге алу.* □— *Белмим шул. Ә нигә сиңа бармаска? Быел уңышны син миннән дә күбрәк алдың бит.* Г. Бәширов.

14. *сөйл.* Қайбер эш коралларының сыйфаты, эшне ничек башкаруы турында. *Бритва яхшы ала. Сабан төрәне киң ала.*□ [*Әти*] *өч саженьнан ала торган, үзе белән яшьтәш чыбыркысын бөтен авыл буен яңгыратып бер шартлата да - - - көтүгә кузгалырга әмер бирә.* Г. Ибраһимов. // Җитү, тию (ату коралы турында).— [*Төрекләрнең*] *туплары да бик ерактан ала, ди.* Г. Камал.

15. Кемнең дә булса эшенә комачаулау, берәр эш яки йомыш белән эшен бүлү.— *Сез, зинһар, гафу итегез, Сезне урынсыз борчыдык, ахры. Вакытыгызны гына алдык.* Г. Минский. // [Вакыт, хезмәт] таләп итү, сорау. *Бу эш бик күп вакыт алачак.*

16. Эшеннән чыгару, эш урыныннан азат итү. // Мәхрүм итү.— *Уткән ел халык буталышы уңае белән Карасу авылында өч мулланың указын алганнар иде бит.* Т. Гыйззәт. // *сөйл.* Урлау, үзләштерү.— *Акча шкатулкасын алганнар!* Г. Камал.

17. Кемне дә булса (эшкә, урынга) кабул итү.— *Миңлебаев өйләнгән. Авылда тимерче булып торып кала икән! Шуның буенча дүшәмбе көн үк аның урынына кеше алганнар.* Г. Ибраһимов.

18. Өйләнү. *Ләкин көзен өйләнергә Өлгерми калды Аман: «Көз күңелле вакыт түгел, Кызны мин язын алам!»* З. Мансур.

19. Үзеңне нинди дә булса гигиеник яки дәвалау эшенә дучар итү. *Укол алу. Кояш ваннасы алу.* // Нинди дә булса сәбәп аркасында авыру. *Ангина алу.* □ *Мич башында катлы-катлы бөркәнеп яткан әби: «Салкын алды, калтырыйм, терелер идем»,— дип, тир көтә.* Ш. Бабич.— *Әй, бәбкәм, бер аягың җирдә, икенчесе кабердә булгач, җәй көне дә суык ала икән.* А. Әхмәт.

20. Үзеннән алда килгән исем белдергәнчә дип исәпләү, дип уйлау. *Уенга алу. Шаяруга алу. Көлкегә алу.* □ *Кайберләрнең, бу сүзләрне чынга алып, муеннарын суза-суза болытлар астыннан Кырымны күрмәкче булып маташуларыннан* [*Пахомов*] *үзе үк көлеп җибәрде.* Г. Бәширов.

21. *сөйл.* Кисү, кыскарту, тарайту, киметү. *Пальтоның ян ягыннан бераз алырга кирәк.*

22. Бетерү, юк итү, юкка чыгару. *Гаепне алу. Шелтәне алу.* □ *Син килдең дә... тыныч йөрәгемнең Тынычлыгын алдың, бетердең.* М. Җәлил.

23. Һәлак итү, бозу. *Карабодайны кырау алды, борчак җир өстендә үк ярылып, орлыгын да кайтармады, солы чүмәләләренең байтагы кар астында калды.* Г. Бәширов.

24. Әйберне өстен каплап торган, өске катламын тәшкил иткән нәрсәләрдән кыркып, кубарып, йолкып, җыеп, кисеп һ. б. ш. юллар белән арындыру. *Чәч алу. Сөт өстен алу. Юкә кабыгын алу.* □ *Ай буена* **больницада** *ятканнан соң, инде ике атнадан гипсыңны алабыз, диде хирург.* Г. Гобәй.

25. Берәр оешмага, нәрсәнең дә булса составына кертү, кабул итү; нәрсәгә дә булса катнашырга мөмкинлек бирү. *Комсомолга алу. Консерваториягә алу. Командага алу.* // Армия сафына кабул итү. *Сугышның беренче көннәрендә үк Хәлимнең атасын алдылар.* Г. Гобәй. // Үз коллективыңа, гаиләгә яки даирәгә кертү. *Бер ятимне тәрбиягә алу.* □ *Нәфисә* [*Әпипәне*] *үз бригадасына алды.* Г. Бәширов.

26. Тоткын итү, кулга алу.— *Эшне озакка сузуда файда юк. Ягез, димен, мине алырга дип килүегезме?* С. Баттал. *Дошманның дүртесе үтерелгән, берсе, күзе яралысы, пленга алынган.* Г. Минский. // Балык тоту, эләктерү, каптыру турында. *Малайлар, килү бушка китмәде, диештеләр, унар-унбишәр балык алганнар.* Г. Ибраһимов.

27. *күч.* Күчереп, файдаланып үзләштерү, кулланышка кертү. *Чит телдән сүзләр алу.* // Берәр максат белән файдалану. [*Г. Тукай*] *фольклорны феодаль крепостнойлык калдыкларына каршы көрәштә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г. Нигъмәти.

28. *ярд. ф. функ.* Кайбер эш-хәл белдерә торган исем янында килгәндә, шул исемнән аңлашылган эш яки хәрәкәтне башкаруны, үтәүне аңлата. *Исәпкә алу.* □ *Бөтен Союз кырыннан эш хисабын алырга Бөтен туган илләрдән ударниклар килделәр.* Ф. Бурнаш. *Кайгылы хәбәр килгән көнне үк Илдарда әтисе өчен үч алу теләге туган иде.* Г. Гобәй.

29. Кайбер исемнәр белән килгәндә кушма фигыль ясый һәм шул исем белдергән хәлгә дучар ителүне белдерә. [*Эчуе аркасында Шәяхмәт*] *контроль комиссиягә эләгеп, бик каты шелтә алды.* Г. Ибраһимов.

30. *боерык ф. форм.* Аерым игътибар, тукталып үтү кирәклеген искәртү өчен кулланыла.— *Менә минем хатыны гына алыйк, мин анда-монда китсәм, бөтенләй зарыгып көтеп тора, ашамый-эчми.* А. Шамов.

31. *бәйл. функ.* **алып.** 1) вакыт мөнәсәбәтен белдереп, эш-хәлнең, вакыйганың башлану моментын күрсәтү өчен кулланыла. *Чәчкәннән алып амбарга кайтарып салганчы үзем үстергән бодайга мин үзем җаваплы.* Г. Бәширов. *Ул иртәдән алып кичкә кадәр кер юа торган иде.* А. Шамов; 2) берәр күренешнең, эш-хәлнең башлангыч чиген белдерү өчен кулланыла. *Зурысыннан алып кечесенә кадәр. Уралдан алып Байкал күленә барып җиткәнче.* □ *Гөлбану, үндүрт яшеннән алып, һәр яз берничә ай киндер сукты.* Г. Ибраһимов.

32. *ярд. ф. функ.* 1) кайбер хәл фигыльләрдән соң килгәндә, фигыльгә тизлек-кинәтлек төсмере өсти. [*Бәдерниса*] *чыра кебек ябык белгән суза да сарфинка яулыкны эләктереп ала.* А. Алиш; 2) хәл фигыльләрдән соң килеп, тәмамлану төсмере өсти. *Әйдүккә алар менә хәзер килерләр дә аның атасын коткарып алырлар төсле тоелды.* Һ. Такташ; 3) хәзерге заман фигыльләреннән соң килеп, «булдыру», «кулдан килү» мәгънәләрен белдерә.— *Шушындый файдалы эшне кайсыгыз башкара ала?* А. Алиш.

Алып бару — 1) үзең белән алу, кая да булса күтәреп, атта яки машинада илтү. *Ул әйберләрен күтәрешеп алып барган өчен дә уникә тиен акча биргән.* М. Гафури; 2) нинди дә булса хәрәкәтләнә торган предмет (судно, автомашина, самолет һ. б. ш.) белән идарә итү, йөртү. *Мин Узбәккә пароходны бөтен көче белән алып барырга куштым.* Ф. Әмирхан; 3) берәр хәлгә китерү, дучар итү. *Бу, бәлки, авыр бер нәтиҗәгә алып барыр иде, тик шул көзне Сабирның язга авылына кайту хәбәрен ишетү белән генә ул-бу булмый калды.* Г. Ибраһимов; 4) юл күрсәтеп, юнәлеш биреп, артыннан иярту, әйдәү. *Җитәкчебез — партиябез Безгә сызып бирде юл. Җиңүләрдән җиңүләргә Алып бара безне ул.* Ә. Ерикәй; 5) сөйрәү. *Вакытлы хөкүмәт илне упкынга таба алып бара!* И. Гази; 6) берәр эшне башкаруга, оештыруга җитәкчелек итү. *Җыелышны алып бару.* □ *Разияның үзенә ликбезны алып барырга тапшырдылар.* Г. Минский; 7) үтәү, башкару. *Көндәлек алып бару.* ***Агарту эшләре алып бару.*** □ *Ул консерваториядә укуын студиядәге производство һәм иҗат эше белән бергә алып бара.* М. Җәлил; 8) кая да булса китереп чыгару, китереп җиткерү. *Ул мине, үз артыннан иярткән, түтәлләрнең аргы башынарак алып барды.* М. Әмир; 9) эш-хәлне белдерә торган исемнәр белән килгәндә шул эш-хәлне башкаруны эченә алган тасвирлы тәгъбир төзи. *Сөйләшү алып бару. Сугыш алып бару. Көрәш алып бару.* **Алып тору** — 1) вакытлыча файдаланырга алу; файдаланып тору. *Нигъмәт казыйдан алып торган сәгатьне өстәлгә алып куйды.* Г. Ибраһимов; 2) биләү, үз эченә алу. *Чөгендер биш га мәйданны алып тора.* **Алып чыгу** — 1) кайдан да булса, нәрсәнең дә булса тышкы ягына үзең белән яки берәр нәрсә аша чыгару. *Мине икенче бүлмәгә алып чыктылар.* Г. Ибраһимов. *Малай утка атылып барып керә һәм сеңелесен алып чыга.* Г. Гобәй; 2) юнәлеш бирү, илтү.— *Әйдәгез, менә бу сукмак белән киттек: туп-туры безнең баракка алып чыга.* И. Гази.

◇ **Алып мактарлык түгел, салып таптарлык түгел** — уртача. **Алып узу** — узыну. *Гафи бай бөтенләй алып узган, Кибәнбайларны кешегә дә санамый, теләсә урам уртасында тотып куйный, теләсә башкача мыскыл итә.* Ш. Маннур.

АЛУ-САТУ *җый. и.* Алу һәм сату эшләре, сәүдә; *к.* сату-алу. *Аның язуына караганда, шәһәрдә эшләр көннән-көн җанлана, әйбер арта, алу-сату көчәя.* Ш. Камал.

АЛФАВИТ *и.* Язуда кулланыла торган хәрефләрнең кабул ителгән тәртиптә төзелгән җыелмасы; әлифба. *Гадәттә алгебрада саннарны билгеләү өчен латин алфавиты хәрефләреннән файдаланалар.* Алгебра.

АЛХИ'МИК *и.* Алхимия белән шөгыльләнүче кеше. *Бүгенге химия борынгы алхимикларның иң кыю хыялларын да нык артта калдырды.* Каз. утл.

АЛХИ'МИКЛЫК *и.* Алхимик булу.

АЛХИ'МИЯ *и.* Гади металларны алтынга әверелдерү юлларын эзләүгә юнәлдерелгән, урта гасырда фәнни химиягә кадәр таралган мистик тәгълимат.

АЛЧАК *с. диал.* 1. Явыз, оятсыз. [*Әсфәндияровның*] *шулкадәр алчак, кансызлыгын күреп, чәчләрем үрә торды.* К. Тинчурин. *Күрдем мин Деникин, Колчагын да, Шулар күк тагы ничә алчагын да...* Г. Камал.

2. Жилкенеп, ашкынып тора торган. *Әллә күңелем алчак булгангамы, Чуар төсле көзне яратам.* Н. Арсланов.

3. Ачык йөзле, якты чырайлы; түбәнчелекле, кече күңелле. *Мин сине --- болай ук алчактыр дип уйламыйдыр идем.* М. Фәйзи.

АЛЧАКЛАНУ *ф. диал.* 1. Явызлану, оятсызлану, алчак хәлгә килү.

2. (Эшкә) ашкынып, жилкенеп, ярсып тору.

3. Ачык йөз күрсәтү, кече күңеллеләнү.

АЛЧАКЛЫК *и. диал.* 1. Алчак (1 мәгъ.) булу.— *Риза әфәнде! Мин сездән мондый алчаклык көтмәгән идем. Сез, үзегезгә булган ышанычтан файдаланып, безнең йортка кердегез дә, шпионлык итәсез.* Ш. Усманов.

2. Ярсып, ашкынып тора торган булу. [*Сәбилә*] *үзенең артык житезлеге, алчаклыгы белән кечкенә генә колхоз өчен шундый зур эш оештырган.* Каз. утл.

3. Ачык йөзлелек, кече күңеллелек, кунакчыллык.

АЛШАРТ *и. кит.* Нинди дә булса эшнең уңай хәл ителүе өчен мөмкинлекләр, алгы шарт.

АЛЪЙОТ *с. иск.* Ахмак, акылсыз. *Менә синең, күрәм, байыйсың килми, суксаң тимер өзәрлек чагында Тәкъва Сәхәүне баетып ятасың, алъйот.* М. Әмир.

АЛЪЯПКЫЧ *и.* Күлмәкнең алдын пычранудан, тапланудан, тиз тузудан саклау өчен киелә торган кием. *Кулына кисәү агачы тотып мич актара торган Гөлбаһар абыстай, үзенең корымга буялган кулларын күрсәтәсе килмичә, оялып, алъяпкыч аша гына сузды.* М. Гали.

АЛЪЯПКЫЧЛЫК *и.* Алъяпкыч тегәрлек (яки бер алъяпкычка житәрлек) материя.— *Менә алъяпкычларым тузып беткән, бер алъяпкычлык алып бир.* Г. Камал.

АЛЪЯПМА *и. сөйл. к.* алъяпкыч. *Чәчләреңне тарап үреп, Алъяпмалар бугансың...* Жыр.

АЛЫМ *и.* 1. Берәр нәрсәне тормышка ашыру ысуллы, юлы, методы.— *Спектакльдә указның, факелның һәм курайның кулдан-кулга йөрүе кебек параллелизм — бер үк алымны кабатлаулар — шулай үк уңышсыз.* М. Жәлил. *Урыны-урыны белән шагыйрьнең бу алымы тере булмаган нәрсәгә тереклек төсен бирү, аны тере нәрсәләргә охшатуга барып житә.* Г. Нигъмәти.

2. Атлау рәвеше. *Бу атның алымы зур.*

3. Нинди дә булса эшчәнлекнең, хәрәкәтнең күләмлелеге, зурлыгы турында; *к.* колач (2 мәгъ.). *Әле бу әсәрнең икенче басмасы чыкканда да татар әдәбиятында киң алым белән эшләнгән андый жулик типлары юк иде.* М. Гали. *Киңрәк алымнар белән, Удар адымнар белән Уткәрербез чәчүен, Каршыларбыз җәй көнен.* Ф. Бурнаш.

АЛЫМЛЫ *с.* 1. *тех.* Киң итеп иңләп бара торган. *Авылга киң алымлы сабаннар, зигзаг --- тимер тырмалар күбрәк кайта башлады.* Соц. Тат.

2. *к.* алдырыклы. *Алымлы ат.*

АЛЫН *и.* Кыр эшләрендә: эшкәртеләсе басуның бер башыннан икенче башына кадәр бер кеше алып барырга тиешле кишәрлек. *Без дә, кызып тотынып, берике минутта алынчы юк итеп ташладык.* Г. Ибраһимов.

АЛЫНМА *с.* Башка телдән алынган. *Алынма сүз / и. мәгъ. Гарәп-фарсы алынмалары.*

АЛЫНМАЛЫ *с.* Алына торган, алынып куела торган. *Алынмалы рам.*

АЛЫНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* алу (13, 17, 25, 26 мәгъ.). *Теге ике шәкертнең [солдатка] алынуы Зыяга үзенең эләгү ихтималын бик якынайтты.* Г. Ибраһимов. *Киндер йолкынган, бәрәңгеләр алынган, ындырдагы кайбер эшләр дә беткән иде.* А. Шамов. *Либреттоның сюжет чыганаклары татар халкы арасында йөри торган әкиятләрдән алынды.* М. Жәлил.

2. Нәрсәне дә булса эшләргә, башкарырга риза булу, риза булып башлау.— *Син нигә бу эшкә алындың?* Ф. Бурнаш.— *Директор урынбасары итәләр дигәч тә, ни әйттем сиңа, Рәхим, шундый жаваплы эшкә алынма, дидем.* Р. Ишморат.

АЛЫНЧА *и. этн.* Вак тәңкәләр белән бизәлгән һәм күлмәк өстеннән киелә торган күкрәкчә.

АЛЫП: алып батыр — әкиятләрдә сөйләнелә торган гадәттән тыш зур гәүдәле кеше образы. Батырлыкка, көчлелеккә ишарә итеп әйтелә.— [*Шәмси*] *алып батыр бит ул безнең. Заводларында штанга күтәреп беренче урынга чыкты.* Г. Мөхәммәтшин.

АЛЫПСАТАР (алып-сатар) *и. сөйл.* Берәүдән алып, табыш белән икенче берәүгә сатучы, спекулянт. *Урамнар купецлар, банкирлар, алыпсатарлар, караклар белән тулган.* К. Тинчурин.

АЛЫПСАТАРЛЫК *и.* Спекулянтлык. *Алыпсатарлык белән даны чыккан Нәгыймәнең шөгыленә чик житте. Дәүләт гаепләүчесе аны биш елга иркеннән мәхрүм итүне сораган.* Б. Камалов.

АЛЫС *и. диал.* Ерак жир, ерак урын. *Алыста ла жирдән әй күренә жемелдәгән Чаный күлкәе.* Бәет. *Салават тиңсез арыслан, Салават тиңсез арыслан! Арысландай алышкан, Угы алган алыстан.* Ш. Бабич. *Алыс булса — кешнәмә, якын булса — тешләмә.* Әйтем.

АЛЫЧА *и. к.* әлүчә. *Әүвәл мунча, аннан алыча.* Әйтем. *Алычаларның аллары, тамып тора баллары.* Жыр.

АЛЫШ-БИРЕШ *җый. и.* 1. Алачак һәм бирәчәк. [*Сәлмән*] *Габдулла абзый белән булган алыш-бирешләренең хәтта зуррак ларын да болай гына --- уздырып жибәрә торган булып китте.* Ф. Хөсни.

2. Сату-алу; сәүдә. *Мал алыштыручыларыбыз, үзебездән арткан нәрсәләр белән башка атауларга йөреп, алыш-биреш итә бирәләр иде.* Ф. Әмирхан. *Күпме эш күрдең, алыш-биреш, сатуда алдашып, Нәрсәнең бер тиенлегең унбиш, егермегә сатып.* М. Гафури.— *Әҗерең күренеп торса, вак-төяк алыш-бирештән дә баш тартмыйм. Хәл кадәренчә инде, ягъни мәсәлән.* А. Расих.

3. Мөнәсәбәт, бәйләнеш, эш (итү). *Нәсимәнең дин белән артык алыш-бирешә юк.* Ш. Камал. *Кызганычка каршымы, акыл белән бер тиенлек алыш-бирешә булмаган ул тойгыларыбызның гомере кыска булды.* М. Әмир.

Алыш-биреш итү — сату-алу белән шөгыльләнү, сәүдә эшләре алып бару. *Шәйхел, алтын-тимер казуны ташлап, башкорт эчендә аз-маз алыш-биреш итеп маташты.* Г. Ибраһимов.

АЛЫШ-БИРЕШЛЕ *с.* Сату-алу, сәүдә эшләре булган, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә торган. *Эш яхшы булса да, яман булса да, алыш-бирешле кешеләр Мәкәржәгә бармый калмыйлар.* Ш. Мөхәммәдев.

АЛЫШТЫРУ *ф. к.* алмаштыру. *Күз ачып-йомганчы бер картаны икенче карта белән алыштырып куям.* Ф. Хөсни. *Искеләрне яңалар белән алыштырырга вакыт!*

Ф. Әмирхан. [*Урыс авылына*] *барып, илле сумлык бакыр акча алыштырып кайттылар.* Т. Гыйззәт. *Ул башындагы яулыгын алыштырып та тормаган.* М. Гафури.

АЛЫШУ *ф.* **1.** *Урт, юн. к. алу* (1, 7, 8, 24, 25 мәгъ). *Хат алышу.* □ [*Газинур*] *ат башында да йөрде, урак та урды, борчак та, бәрәңге дә алышты, ашлык та сукты.* Г. Әпсәләмов.

2. *сөйл. к.* алмашу (1 мәгъ.). *Неплюйко — алдан, Сөләйманов белән Коненко аның артыннан бер-берсенең аркаларына ышыкланып бер ун минут бардылар да тагын урыннарын алыштылар.* И. Гази. *Утмәс малны сатарга яки, һич булмаса, башка нәрсәгә алышырга янә приказчиклар кирәк буладыр.* Ш. Мөхәммәдев.

3. Көрәшү, көч сынашу. *Ул якынайган вакытта теге малайлар көрмәкләшеп алыша да башлаганнар иде инде.* А. Әхмәт. *Теге малай Камали абзыйга:— Ул аяк чалды, мин аның белән яңадан алышам,— диде.* М. Гали.

АЛЫШЫНУ *ф. к.* алмашыну. *Смена алышыну.* □ *Заман уткән саен, табигать хәле алышына.* Ш. Камал. [*М. Гафури*] *Октябрьдан соң тормышның ничек алышынып, хезмәт цияләренә бәхет китерүен --- чагылдырды.* М. Җәлил.— *Николай Иваныч, --- сезнең адресыгыз алышынган дип ишеттем.* Ф. Әмирхан.

АЛЬБАТРОС *и. зоол.* Очы кәкрәеп килгән озын томшыклы һәм тар озын канатлы зур диңгез кошы. *Диңгез өстендә альбатрослар һәм диңгез акчарлаклары кычкырып очып йөриләр.* Дөнья кис. геогр.

АЛЬБОМ *и.* Шигырь, фотокарточка, рәсем һәм башка нәрсәләрнең коллекциясен җыю өчен төпләнгән махсус китап яки дәфтәр. [*Сергей Петрович*] *малайның кулыннан* [*марка*] *альбомын алды да сакланып кына актарып чыкты.* Л. Ихсанова. [*Марат*] *узенең тумбочкасы өстендәге альбомнан күргәзмәдәге рәсемнең копиясен алып күрсәтте.* Г. Гобәй. *Зөбәйдәнең рәсеме Альбомымның Күзгә бәрелеп торган урынында, Альбомымны карап чыккан кешеләр һаман сорый аның турында.* Һ. Такташ.

АЛЬМАНАХ *и.* Бер чорда яшәгән төрле авторларның әдәби, тарихи һәм публицистик характердагы әсәрләр җыентыгы. *Чыгачак альманахлар өчен ничек булса да яхшы әйберләр тудырырга тырышам.* М. Җәлил.

АЛЬПЕНШТОК *и.* Биек тауларга, бозлыкларга менү өчен кулланыла торган, бер башына очлы тимер беркетелгән таяк. *Штурмда катнашучылар күтәрелү һәм төшү өчен кирәкле альпеноштоклар, баулар һәм альпинист ботинкалары белән тәэмин ителмәгәннәр.* Чаян.

АЛЬПИНИЗМ *и.* Бик биек тауларда үткәрелә торган туризм. *Виктор альпинизм буенча, Татарстанда беренче булып, СССРның спорт мастеры исемен алуга иреште.* Сов. мәк.

АЛЬПИНИСТ *и.* Альпинизм белән шөгыльләнүче спортчы.

АЛЬПИНИСТЛЫК *и.* Альпинист булу, альпинизм белән шөгыльләнү.

АЛЬТ *и. муз.* **1.** Җырлаганда балаларның яки хатын-кызларның калын тавышы.

2. Скрипкадан зуррак кыллы музыка коралы.

А'ЛЬФА (α) *и.* Грек алфавитында беренче хәреф исеме. // *күч.* Нәрсәнең дә булса нигезе, башлангычы.

А'ЛЬФА-НУРЛАР *и. физ.*— Уңай корылмадагы кисәкчекләрнең таркалган вакытта радиоактив матдәләр тәэсирендә бик зур тизлек белән ыргытылган ташкыны.

АЛЮМИН *и. сөйл. к.* алюминий. *Сиңа каршы булган аэропланнар Гади алюминнан коелыр.* Һ. Такташ. *Шәфкать туташы алюмин кружкадан* [*егеткә*] *бер йотым су эчерде.* Ә. Еники.

АЛЮМИ'НИЙ *и. хим.* Көмешсыман ак төстәге, тиз чүкелә торган җиңел металл. *Алюминий самолет төзелешендә киң кулланыла.* СССР экон. геогр. [*Алюминийның*] *химик активлыгы магнийныкына караганда да түбәнрәк.* Химия. // *с. мәгъ.* Алюминийдан ясалган (мәсәлән, чыбык, савыт-саба).

АЛЮМОСИЛИКАТ *и. хим.* Анионнары составында алюминий һәм кремний булган тоз. *Алюмосиликатлар җир кабыгының төп массасын тәшкил итәләр.* Химия.

АЛ-ЯЛ: ал-ял белмәү — күп эшләү, ял итмәү, аруталуны белмәү турында.— *Бер дә ал-ял белмисең шул, кызым, кояш чыкканнан алып кояш баеганга кадәр кырда буласың.* Р. Ишморат.

АЛЖУ *ф. сөйл.* Ару, хәлдән таю, бик ялыгу. *Тау битендәге юл чатына менеп җиткәч, ул туктады, эштән чыгып арыган, алҗыган хәлендә юл кырыена ауды.* Г. Бәширов. // Аптырап бетү; тилмерү. *Сания Маратны өйгә алып кайта алмыйча алҗып бетте.* Г. Гобәй.— *Әйдә, сине кыз көтә-көтә алҗып бетте инде.* Г. Колэхметов.

АЛЖЫТУ *ф.* Хәлдән тайдыру, ардыру, талчыктыру. *Күселәр* [*песи баласын*] *куа-куа алҗытып бетергәннәр.* А. Алиш. // Йөдәтү, аптырату.— [*Гафият*] *жалуние сорап алҗыткан.* И. Гази.

АМАН *диал.* Имин.— *Кунагым хафа булмасын, малҗан аман, йорт-ил исән.* Г. Ибраһимов.

АМАНЛЫК *и. диал.* Иминлек. *Я китсен суфый мәктәптән аманлык белән, Я ку кәҗәне бакчадан яманлык белән.* Дәрдмәнд.

АМБАР *и.* Ашлык, он, товар һ. б. ш. төрле кирәк-яракларны саклау өчен корылма. *Амбар тулы ашлык, абзар тулы мал-туар дигәндәй, эшләр майлаган шикелле тәгәрәп кенә бара.* Г. Бәширов. [*Газинур*] *колхоз амбарларыннан читтәрәк берьялгызы торган сарайның дөрләп яна башлавын күрде.* Г. Әпсәләмов

Амбар кебек — бик зур, буш, җылы тормый торган, шыксыз, җыйнаксыз булуга ишарә итеп әйтелә (өй яки бүлмә турында).

АМБАРЧЫ *и.* **1.** Амбар мөдире.

2. Амбар каравылчысы.

АМБИ'ЦИЯ *и. кит. ирон.* Үз-үзеңне артык ярату хисе, тәкәбберлек, мин-минлек.

◇ **Амбициягә бирелү** — үпкәләп чәпчеп китү.— *Сезнең мәзәкчел кеше икәнлекне аңламаган берәү булса, әлбәттә, бик нык амбициягә бирелер иде, Ибраһим әфәнде.* Ә. Фәйзи.

АМБРАЗУ'РА *и.* **1.** *махс.* Стенада тәрәзә яки ишек уемы.

2. Хәрби ныгытмаларның стеналарында яки хәрби судно башиясында ату өчен ясалган махсус тишек. [*Матросов*] *ут чәчеп торган амбразурага күкрәге белән килеп* [*капланды*]. Г. Әпсәләмов.

АМБУЛАТО'РИЯ *и. мед.* Авыруларга медицина ярдәме күрсәтә торган дәвалау учреждениесе. *Ул арада Сабир абзыйның колхоз амбулаториясендә фельдшер булып эшли торган кызы Мәдинә кайтып керде.* Ә. Еники.

АМЁБА *и. зоол.* Бер күзәнәкле иң гади тереклек иясе. [*Табигать*] *галәмдәге бар нәрсәне — йолдызлардан алып иң гади амёбага кадәр — искиткеч камиллек белән яраткан.* Х. Сарьян.

АМЕ'РИКАЛЫ *и.* Америкада яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе.— *Бу җирләрне, энекәш, безгә хәтле америкалылар да, англичаннар да, немецлар да тикшереп киткәннәр.* А. Әхмәт.

АМЕРИКАН: американ күн *этн.*— яхшы сорт күн. *Ул ялт итеп тора торган американ күннән тегелгән штиблет өстеннән кара постау чалбарны чыгарып салган.* Ә. Фәйзи. **Американ читек** *этн.*— американ күннән тегелгән читек. [*Җәлал мулланың*] *аягында шәһәр эше яхшы галош пима. Аның өс ягыннан американ читекнең кунычы ялтырап тора.* Г. Ибраһимов.

АМЕТИСТ *и. хим.* Шәмәхә яки зәңгәрсу шәмәхә төстәге кыйммәтле асылташ. *Аметист кашлы алка.*

АМИН *дини, иск.* Теләк теләгәндә яки хәер-дога кылганда, вәгазь сөйләгәндә «шулай булсын», «кабул булсын» мәгънәсендә соңгы сүз итеп әйтелә.— *Аллаһе тәгаләнең каһәрле ачуы безнең өскә төшә күрмәсен, амин.* К. Нәҗми. [*Картлар:*] *Бирсен инде ходай, фәрештәнең «амин» диган чагына туры килсен.* Ә. Фәйзи.

Амин тоту *иск.*— ашаганнан соң кул күтәреп дога кылу.— *Бичара, ашагач амин да тота белмисең, җитмәсә тагы надан диган буласың.* Т. Гыйззәт.

АМИНОКИСЛОТА *и.* NH_2 группасы булган органик кислоталар; аксым составындагы матдә. *Һәрбер аминокислотаның үз исеме һәм барлык хайваннар өчен бер үк булган составы бар.* Анатомия.

АММИАК *и. хим.* Азот белән водород кушылмасыннан гыйбарәт бик ачы исле төссез газ, суда эреткәндә нашатырь спирты барлыкка килә. *Әле бик күп еллар элек Фарбер концерны бу тауларны тишеп кереп аммиак чыгарган.* Н. Дәүли. // *с. мәгъ.* Аммиак эшләп чыгара торган. *Аммиак заводы.*

АММИАКЛЫ *с.* Составында аммиак булган, аммиак катнашкан. *Аммиаклы эремә.*

АММОНАЛ *и. тех.* Составында аммоний селитрасы, порошок сыман аллюминий булган шартлагыч матдә (тау, юл эшләрендә һәм хәрби эшләрдә кулланыла). *Аммоналлар тауны актара.* Ш. Мөдәррис.

АММО'НИЙ *и. хим.* 1. Аммиак белән водородка таркалган атомнар төркеменнән торган химик матдә.

2. Чүпрә урынына файдаланыла торган порошок.

АММОФОС *и. хим.* Составында азот һәм фосфор булган җир ашламасы.

АМНИ'СТИЯ *и. махс.* Югары властьлар тарафыннан чыгарылган, суд хөкеменнән өлешчә яки бөтенләйгә азат итү турындагы указ. *Хисаметдин Сәгыйдуллин, сәламәтлеге начарлану сәбәпле, амнистиягә эләккән булып чыкты.* Ш. Хөсәенов.

АМНИ'СТИЯЛӘҮ *ф. махс.* Амнистия буенча азат итү.

АМОРАЛЬ *с. кит.* Моральгә каршы килә торган, әхлаксыз.

АМОРТИЗА'ТОР *и. тех.* Автомобильләрдә, самолетларда бәрелү-сугылу тәэсирен йомшарткыч җайланма.

АМОРТИЗАЦИОН *с.* Амортизация (2 мәгъ.) өчен хезмәт итә торган. *Амортизацион җайланма.*

АМОРТИЗА'ЦИЯ *и.* 1. Тузу сәбәпле, милекнең, әйбернең кыйммәте кими бару (машина, бина һ. б. ш. турында). *Комбайн амортизациясе.* □ *Амортизация өчен чигерүләр производство аппаратын техник яктан даими яңартып торуны тәэмин итәргә тиеш.* Политэкономия.

2. *тех.* Махсус җайланмалар ярдәмендә (автомобильләрдә, самолетларда) бәрелү-сугылу тәэсирен йомшарту.

АМОРФ *с.* 1. *махс.* Төзелеше кристаллик булмаган, кристаллик түгел. *Аморф матдәләр.* □ Агач күмерен *гадәттә аморф күмер дип атыйлар.* Химия.

2. *лингв.* Морфологик категорияләре булмаган. *Аморф телләр* (мәсәлән, кытай теле). *Аморф система.*

А'МПЕР *и. физ.* Электр тогы көчен үлчәү берәмлеге.

АМПЕРМЕТР *и. физ.* Электр тогы көчен үлчәү приборы.

АМПЛИТУ'ДА *и.* 1. *физ.* Тирбәлү киңлеге, тирбәлү колачы. *Амплитудалар кечкенә булганда, маятникның авырлык көче тәэсирендә тирбәнүе гармоник, яки гади тирбәнү була.* Физика.

АМПЛУА *и. театр.* Бер актер тарафыннан башкарыла торган бер тип рольләр. *Артист амплуа дигән нәрсәне белмәде, нинди генә характерлы рольне башкарса да, ул аны тулы канлы, җанлы образ итеп күз алдына бастыра алды.* Х. Сәлимҗанов.

А'МПУЛА *и.* Зур булмаган дозаларда дару саклау өчен герметик ябыштырылган, нечкә муенлы пыяла савыт.

АМПУТА'ЦИЯ *и.* Тәндәге берәр әгъзаны яки аның бер өлешен, авыру сәбәпле, операция юлы белән кисеп алу. *Аяк ампутациясе ул кечкенә нәрсә түгел.* А. Шамов.

АМПУТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ампутация ясау.

АМУНИ'ЦИЯ *и. иск.* Хәрби хезмәткәрнең кием һәм коралларыннан башка кирәк-яраклары. *Зариф агай — Европа сугышының беренче айларыннан башлап окопта үткәргән, аркасына тулы амуниция тагып, Польша — Галиция кырларын үткән фронтовик.* Ш. Усманов.

АМФИ'БИЯ *и.* 1. *зоол.* Кечкенә вакытта саңаклар аша, зурайгач үпкә белән сулый торган умырткалы җир-су хайваны.

2. *бот.* Җир-су үсемлеге.

3. Җиргә дә, суга да төшә һәм күтәрелеп китә ала торган самолет, гидроплан. // Җирдә дә, суда да йөри ала торган танк, автомобиль.

АМФИТЕАТР *и.* 1. Борынгы грекларда һәм римлыларда: төрле тамашалар өчен түбәсе ачык корылма (анда тамашачыларның урыннары арена тирәли ярым түгәрәк яки түгәрәк ясап төзелгән).

2. Хәзерге театрда яки циркта: партер артында яки ложалар өстендәге ярым түгәрәк булып урнашкан урыннар. // Шул урында утырган халык. *Күп тә үтмәде, «Автор!» дигән тавышлар партерның әле бер, әле икенче почмагыннан ишетелә башлады. Аларга амфитеатр белән яруслар кушылды.* Ш. Хөсәенов.

АНА *и.* 1. Балага карата: тудырган хатын, әни. *Балалар йорты хезмәткәрләре барысы да ана белән баланың шатлыкларын уртаклашып, зур капкага кадәр аларны озата килделәр.* Г. Минский. *Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс.* Мәкаль. // *тарт. форм.* **анасы.** Ирнең хатынына карата мөрәҗәгать сүзе.— *Шулай, анасы, юкка кәҗәләнеп йөрмә, хәзер үк үзенә: «Киленем!» диген дә, дуслашыгыз. Моңайтма киленне.* А. Әхмәт. // Балалы хатын. *Ана — Бөек исем. Нәрсә җитә ана булуга!* Һ. Такташ. // *с. мәгъ.* Анага бәйләнешле. *Ана мәхәббәте.*

2. *с.* Ана женестән булган (төр); *киресе:* ата. *Ана дуңгыз. Ана бүре.*□ *Тегермән буасында, эри башлаган боз өстендә, ана казлар гаңгылдаша.* И. Гази. *Ике ана кош, бер ата кош Килә Агыйдел буйлап.* Җыр.

3. Гадәттә өстәмә сүз яки аергыч урынында: иң кадерле, мөкатдәс, якын булган нәрсә турында. *Җир-ана. Идел-ана.* □ [*Дөнья*], *Аерып мине Анам-Ватанымнан, Кай җирләргә китереп ташладың?!* М. Җәлил. *Анабыз-җирне кочаклап, Бәлки, үләрмен.* Ф. Кәрим.

4. *күч.* Тудыручы, барлыкка китерүче. *Безнең тупас куллар — киләчәктә Туар матурлыкның анасы.* Һ. Такташ.

Ана корт *зоол.* — озынча корсаклы иң зур умарта корты. *Соры корт күзәнәкләренә ана корт — аталанмаган күкәйләр, ә башка күзәнәкләргә аталанган күкәйләр сала.* Зоология. **Ана каптырма** — каптырманың элмәкле ягы. **Ана теле** — туган тел. **Ана эрем** — көпшәсез тәбәнәк эрем, ак эрем.

◇ **Анадан тума** — 1) тумыштан. *Анадан тума сукыр. Анадан тума саңгырау;* 2) шәрә, ялангач. *Асылганнарның барысы да анадан тума булып, аларны җил әле уңга, әле сулга әйләндерә иде.* Г. Гобәй; 3) бернәрсәсез, ялангач, хәерче. *Бар да янганнар, шулай итеп, безнең әтиләр, әниләр анадан тума, бер кат күлмәк-штан белән генә калганнар.* М. Гали.

АНАГРА'ММА *и.* Сүздәге хәрефләрнең урынын алмаштырып, башка сүз ясау. (Мәсәлән, таш — шат, тарак — карат).

АНАКАЙ *и.* Олы яшьтәге хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе. *Булмады, биргән сәдакаларың җилгә очты, анакай.* Ф. Хөсни.

АНА'ЛИЗ *и.* 1. Предметны яки күренешне аерым өлешләргә, кисәкләргә бүлеп, таркатып өйрәнү методы; *киресе:* синтез.

2. Нинди дә булса берәр матдәне аерым элементларга таркату, аларны тикшерү. *Ул анализларны ахрына кадәр җиткерми, әллә никадәр материал әрәм итә.* И. Гази.

3. Әйбер, күренеш турында тулаем хөкем йөртү өчен аның аерым кисәкләрен тикшерү. *Грамматик анализ.* // Анализ ясау. *Революциядән соң Г. Камал иҗатына --- күп кенә тәнкыйть һәм анализлар булып үтте.* М. Гали.

◇ **Анализ ясау** — нәрсәне дә булса җентекләп тикшерү, өйрәнү. *Аның шулай иҗат юлына кыскача гына анализ ясауны бурыч итеп куябыз.* М. Җәлил.

АНАЛИЗА'ТОР *и.* 1. *махс.* Матдәләрне, күренешләрне анализларга ярдәм итә торган приборлар исеме.

2. *анат.* Тынычсызлануларны сизү һәм аеруны тәэмин итә торган органнар. *Һәрбер анализатор өч өлештән тора: периферия өлеше, урта өлеш һәм үзәк өлеш.* Анатомия.

АНА'ЛИЗЛАУ *ф.* Анализ ясау. *Хәбир --- юрганын башыннан үк бөркәнеп ятты да әле генә булып үткәннәрне анализлый башлады.* Ш. Хөсәенов.

АНАЛИ'ТИК I *и.* Нәрсәне дә булса тикшергәндә анализ методлары белән эш итүче, яхшы анализлаучы белгеч.

АНАЛИ'ТИК II *с.* Анализга нигезләнгән. *Аналитик метод.*

АНА'ЛОГ *и. кит.* Нинди дә булса предмет яки күренешкә тәңгәллеге, охшашлыгы булган башка предмет яки күренеш.

АНАЛО'ГИК *с.* 1. Аналогиягә нигезләнгән.

2. Аналогия тәшкил иткән, охшаш, бердәй, тәңгәл. *Аналогик күренеш.*

АНАЛО'ГИЯ *и.* Предметлар яки күренешләр арасында берәр яктан охшашлык.

АНАЛЫ-БАЛАЛЫ *рәв.* Ана белән бала бергәләп.

АНАЛЫК *и.* 1. Ана булу. [*Шәмсияне*] *беркем аналык хокукыннан мәхрүм итмәгән.* М. Ханнанов. // *с. мәгъ.* Балага карата туганлык мөнәсәбәтендә бары тик анага гына хас булган (хис). [*Гөлниса ханымның*] *аналык хисләре тулысы белән өстенлек алды.* М. Әмир. *Нур кебек балкый йөзендә Аналык мәхәббәте. Сүрелмәслек һәм сүнмәслек Мәрхәмәте, шәфкате.* Ә. Ерикәй.

2. *анат.* Хатын-кызның һәм бала тудыра торган хайваннарның яралгы үсә торган эчке органы.

АНАЛЫ-ҚЫЗЛЫ *рәв.* Ана белән кыз бергә. *Аналы-кызлы аларның монда беренче мәртәбә килүләре иде.* Ш. Камал.

АНАЛЫ-УЛЛЫ *рәв.* Ана белән ул (ир бала) бергә. *Шул вакыт --- аналы-уллы күздән югалганчы икәү күл болгап калулары — бөтенесе дә искә төшеп, Сөләймановның күңелен телгәли башлады.* И. Гази.

АНАНАС *и.* 1. Озынча түгәрәк формалы, эре һәм татлы, калын кабыклы җимеш бирә торган көньяк агачы.

2. Шул агачның җимеше.

АНА'ПЕСТ, АНАПЕ'СТ *и. махс.* Силлабо-тоник шигырь төзелешендә ике басымсыз иҗектән соң бер басымлы иҗек килгән өч иҗекле стопа (мәсәлән: *Әйт әле, Күбәләк, Сөйләшик бергәләп.* Г. Тукай).

АНАР *и.* 1. Әчкелтем-баллы җимеш бирә торган көньяк агачы; *русчасы:* гранат. *Кырымның көньяк яр буеның көнбатыш өлешендә кипарислар, анар, зәйтүн, серкә агачлары, гүзәл лавр һәм башка агачлар үсә.* Ботаника.

2. Шул агачның җимеше.

АНАРХИ'ЗМ *и. тар.* 1. Марксизмга, фәнни социализмга дошман булган, һәртөрле дәүләт властен, политик көрәшне танымый һәм анархияне яклый торган вак буржуаз реакцион иҗтимагый-политик агым. *Заманында Тангатаров анархизм теоретикларыннан Кропоткинны күп укый иде.* Г. Ибраһимов.

2. Властьны, авторитетны танымау, башбаштаклык.

АНА'РХИК *с.* Анархизмга бәйләнешле. *Футуристлар --- телне һәм шигырь төзелешен ныкъ җимерделәр. Асылда бу әдәбият өлкәсендәге анархик башбаштаклык иде.* Х. Госман.

АНАРХИ'СТ *и. тар.* 1. Анархизм тарафдары; анархистлар оешмасының члены. *Анархистлар, революцион пролетариатның дәүләт властен социализм төзү өчен файдалануына каршы чыгып, шуның белән пролетариатның революцион диктатурасын инкяр итәләр.* КПСС тарихы.— *Мин анархистларның һичбер оешмасында әгъза булмадым.* Г. Ибраһимов.

2. Властька, авторитетка буйсынмаучы, башбаштак (кеше). *Буйсынырга яратмаган анархистлар --- аның әмерен --- җиренә җиткерә ideләр.* Ш. Усманов. *Алай итмә,— дип кисәтте Якуб,— анархист диярләр үзеңә, трибуналга бирерләр.* И. Гази.

АНАРХИСТЛЫК *и.* 1. *к.* анархизм. *Вак буржуачылык анархистлыгы анархист бунтарьлык идеяләрен кабатлаучы хезмәтен генә үтн.* Г. Нигъмәти.

2. Анархист булу.— *Хәерлегә алып бармый синең бу анархистлыгың, дип әйтмәдемме? Ә син колак салырга теләмәдең.* И. Гази.

АНА'РХИЯ *и.* 1. Властьсызлык.

2. Тәртипсезлек, башбаштаклык.— *Материаллар белән тәэмин итү бик начар! Ныклы график юк. Бөтен җирдә анархия.* А. Гыйләҗев.

АНА'РХО-СИНДИҠАЛИЗМ *и. тар.* Халыкара профсоюзлар хәрәкәтендә идеологик һәм политик мәсьәләләр буенча анархизм йогынтысында торган вак буржуаз реакцион оппортунистик агым.

АНА'РХО-СИНДИҠАЛИСТ *и. тар.* Анархо-синдикализм тарафдары.

АНА'РХО-СИНДИҠАЛИ'СТИК *с.* Анархо-синдикализмга бәйләнешле. *Анархо-синдикалистик группа.*

АНАСЫ-АТАСЫ *и.* Анасы һәм атасы.

◇ **Анасы-атасы белән сүгү** — тупас сүзләр белән бик әшәке итеп сүгү. *Солдат башына тау төшкән кебек каты сулап куя, кышны, Иделне, бозны анасы-атасы белән сүгә дә Булатка карый.* Г. Ибраһимов.

АНА'ТОМ *и.* Анатомия белгече.

АНАТО'МИК: анатомик театр — мәетләрне суд экспертизасы һәм фәнни максатлар белән яру өчен махсус җиһазландырылган бина.

АНАТОМИ'ЧКА *и. сөйл. к.* анатомик театр.

АНАТО'МИЯ *и.* Тере организмнарның тышкы һәм эчке төзелешләре турындагы фән. *Ахырында ул гыйлем иясе, анатомиядән тирән тәҗрибәле белгеч, дипломсыз галим булып җитешә.* И. Рәмиев. // Берәр органның төзелеше. *Кеше анатомиясе. Үсемлекләр анатомиясе.*

АНА'ФЕМ(А) *и. гади с.* Ләгънәт, мәлгунь, ләгънәт төшкән нәрсә һ. б. ш. мәгънәдәге хурлау, тиргәү сүзе.— *Нишләвегез бу, иблис токымнары! Мәлгуньнәр. Анафемнар!* И. Гази.— *Я, әйтегез, бу анафемаларга кем бу хәтле иркенлек бирде?* К. Нәҗми.

АНА'ФОРА *и. махс.* Сөйләмнең ике яки берничә кисәге башында бер үк сүзнең яки авазның кабатлануыннан гыйбарәт булган поэтик алым (мәсәлән: *Бер җирдә юк андый ак каеннар, Бер җирдә юк андый урманнар.* Һ. Такташ). *Аңарда шигъри әсәрләр өчен кирәк булган бертөсле башлау — анафора алымы да* [*бар*]. М. Гайнуллин.

АНАХРОНИЗМ *и.* Бер эпохага караган әйберләрне, күренеш-вакыйгаларны, ялгышып, башка эпоханыкы дип карау.

АНАЭРОБ *и. биол.* Ирекле кислородтан башка яшәүче, нормаль һавасыз яши торган микроблар; *киресе:* аэроб. *Мөнирә анаэробларның — газ гангренасының иң*

куркынычлы микробларының серенә төшенергә тели. Г. Әпсәләмов.

АНГАР *и.* Самолетларны саклау һәм ремонтлау өчен махсус корылма.

АНГИ!НА *и. мед.* Йоткылыктагы лайлалы катлауның, бигрәк тә тамак бизләренең ялкынсынуы.— *Мороженое төче, ул салкын, аннан ангина эләктерү мөмкин.* Ш. Хөсәенов.

АНГЛИЧАН *и. к.* инглиз. *Америка империалистлары үзләренең англичан «коллегаларыннан» чимал һәм ягулыкның иң әһәмиятле чыганакларын тартып алалар.* Иң яңа тарих.

А!НГЛИЯЛЕ *с.* Англиядә туып үскән яки шунда яшәүче кеше.

АНГЛОМАН *и.* Тормышта гореф-гадәтләре белән һәм башка күп нәрсәдә инглизләргә ияруче, Англиядә эшләнгән әйберләрне өстен күрүче, артык яратучы.

АНГЛОФИЛ *и.* Инглиз милләтен һәм культурасын яратучы, яклаучы; *киресе:* англофоб.

АНГЛОФОБ *и.* Инглиз милләтен һәм культурасын яратмаучы; *киресе:* англофил.

АНГЛЯН *и.* Ат токымы. *Өч яшьлек алаша сатыла, төсе күк, зур гәүдәле, англян токымыннан, бер дә җигелмәгән.* СССР тарихы.

АНГО!РА *с. зоол. Ангора мәчесе, ангора кәҗәсе, ангора куяны (кролигы)* кебек тезмәләрдә озын йомшак йонлы токымны белдерә.

АНДА *а.* 1. Урынны күрсәтә һәм аның сөйләүчедән ераграк икәнлеген белдерә; ул урында; *киресе:* монда, биредә.— *Нишләмәкче буласың анда, Зөя ягында?— дип сорады Якуб.* И. Гази. *Анда якты, анда ирек, анда кояш һәм дә нур.* Г. Камал. *Китмибез без, безгә анда [Төркиядә] мондагыдан эш кыен.* Г. Тукай.

2. *сөйл.* «Ул» алмашлыгының урын-вакыт килешендәге формасы: ул кешедә, аңарда. *Бригадирның борчуы берьюлы әреп китте, анда Нәфисә эше өчен дә горурлык тойгысы кузгалды.* Г. Бәширов. // Нинди дә булса әйбергә, мәсьәләгә яки кешегә ишарә итеп әйтелә. *Хәзергесе көнне мәсьәлә андамыни?* Г. Бәширов. — *Анда синең эшең булмасын!* Г. Камал.

3. Шунда, шул очракта, шул вакытта.— *Менә сиңа кирәк булса, гомеремдә бер ялганлаган идем, анда да эләктем.* Р. Ишморат.

4. *кис. функ. сөйл.* Боерулы җөмләдә боеру төсмерен көчәйтә, сөйләмгә беркадәр тупасрак тон кертә. *Тизрәк кыймылдагыз анда!*

5. Мөнәсәбәтле сүзләр составында: кайда — анда. *Иртә белән кайнамакта бу базар, Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.* Г. Тукай.

АНДА-МОНДА *рәв.* 1. Анда-санда, сирәк-мирәк. *Агыйдел өстендә анда-монда маяклар яналар иде.* Г. Гобәй.

2. Тегендә дә, монда да; тегендә-монда, төрле җирдә, төрле урында. *Анда-монда чабам, ямщик куам, Күңел һаман акча эшләүдә.* Ш. Маннур. [*Ул*] *угылы Хәсәншага һәм приказчикларына вакытлы-вакытсыз шәһәргә чыгып, анда-монда йөрергә рөхсәт бирмәде.* Ш. Мөхәммәдев. // Кая да булса. [*Хәнифә:*] *Әгәр анда-монда чыксаң, менә йозак, өйне биклəп чыгарсың.* Р. Ишморат.

АНДА-САНДА *рәв.* Ара-тирә, сирәк кенә, сирәк-мирәк. *Анда-санда әтәчләр кычкыра иде.* Ш. Камал. *Анда-санда ялтыр көзге төсле Җемелдәшеп калды буалар.* Ш. Мәдәррис.

АНДАУ, АНДУ *ф. диал.* Сагалау, саклап-күзәтеп тору. *Йомылып та атың чапкан чакта, Тезгеннәрен тотма, буш җибәр. Андыса да дошман алдыра алмас, Буш җибәргән атка кош диләр.* Җыр. *Юлдагы таш аксакның аягын андый имеш.* Мәкаль.

АНДЫЗ *и. бот.* Болында үсә торган сары чәчәкле үлән; *русчасы:* девясил. *Егет үләр кыз-кыз дип, Тәвә үләр тоз-тоз дип, Ат үләр кара андыз дип.* Мәкаль.

АНДЫЗЛЫК *и.* Андыз күп булган урын. *Кенәлекәй буе яшел сазлык, Сазлыгында — андызлык.* Җыр.

АНДЫЙ *а.* Элек сөйләнгән яки нинди дә булса хәлләр, ситуацияләр белән билгеләнгән үзлеккә, сыйфатка ишарәли.— *Мин сиңа, абзый, булырмын файдалы, Сәүдәгәргә андый файда кайдале?* Г. Тукай.

АНДЫЙ-МОНДЫЙ *с. сөйл.* 1. Берәр, нинди дә булса. *Исемдә чагымда шуны да әйтим әле, ярминкә үткәнче андый-мондый хезмәтче-фәлəнеңне ачу белән хисабын биреп чыгара күрмә.* Ш. Мөхәммәдев.— *Әгәр дә андый-мондый зуррак эш чыксa, комиссар кайткач аңар да белдерәбез.* Г. Камал.

2. Тегенди-мондый, ни җитте (бик мөһим түгел мәгънәсендә). *Әле безнеке андый-мондый эш кенә түгел.* М. Фәйзи. // Юк-бар, имеш-мимеш. *Буржуазиянең немецны Петроградка кертергә уйлавы чынмы, яисә андый-мондый хәбәр генәме?* И. Гази.

3. Начар, бозык, шикле.— *Кемлегемне кергәч күрерсең әле, андый-мондый кеше түгел, кызлар өчен уңайлы кеше.* Г. Камал.— *Андый-мондый җирләргә йөртергә, күңелен илəсләндерергә кара.* М. Фәйзи.

4. Берәр төрле, көтелмәгән. *Андый-мондый хәл була калса, алар мине якларлар.* Д. Аппакова.

АНЕКДОТ *и.* 1. Кызыклы, көлке вакыйга турында кыска хикәя, мәзәк. *Алар шаярдылар, анекдотлар сөйләделәр, җырладылар, көлделәр.* Ш. Хөсәенов.

2. *күч.* Кеше ышанмаслык вакыйга. *Дөресен әйтергә кирәк, татар-башкорт мещан семьяларының гайбәтләрен анекдот дәрәҗәсенә күтәрүдә аның «хезмәте» бик зур булды.* К. Тинчурин.

АНЕРО!ИД *и.* Барометрның бер төре. *Анероидлар басым үзгәруне бик яхшы сизәләр, ләкин алардагы пружиналарның эластиклыгы тора-бара кими.* Физика.

АНИЛИН *и.* Буяу һәм дарулар хәзерләгәндә кулланыла торган май сыман төссез агулы органик сыеклык.

АНИОН *и. хим.* Тискәре корылган ион. *Бу металларның ионнарыннан һәм бер валентлы анионнардан хасил булган барлык тозлар [дип әйтерлек] суда яхшы эриләр.* Химия.

АНКЕ!ТА *и.* Кем турында да булса мәгълүматлар алу өчен сорауларга җаваплар рәвешендә тутырыла торган кәгазь. *Мин гомеремдә бик күп анкеталар тутырдым.* Һ. Такташ.

АНЛЫК *с.* Аңа җитәрлек, аңа җавап бирерлек. *Хәлимдә анлык көч юк иде шул инде.* Г. Гобәй.— *Иоган Альфредович! Казан өчен тыныч булыгыз. Анлык кына көч табармын.* К. Нәҗми.

АННАЛЛАР *и. иск.* Борынгы Римда, Мисырда һ. б. халыкларда тарихи вакыйгаларны еллап язып бару, елъязма. *Нәфрәт агыла бөтен илләрдән Агрессорның башы өстенә. Бу зур вәхшәт язылып куелачак Иртәге көн анналларына.* Х. Туфан.

АННАН *рәв.* 1. «Ул» алмашлыгының чыгыш килеш формасы: ул урыннан. *Алар тышка чыга торган зур ишек янына өелешкәннәр, аннан үтәрлек түгел.* А. Шамов.

2. *к.* аңардан. *Барып аннан киңәш сораучылар Үткен диләр аның акылы.* Ш. Маннур. // Нәрсәгә дә булса ишарә итеп кулланыла: аңардан, ул әйбердән.— *Куксагыз безнең армиягә бик кирәк нәрсә, аннан резина ясыйлар.* Г. Бәширов.

3. Соңыннан, бер эштән соң яки берникадәр вакыттан соң; аннары. *Кыз тагын сукты, аннан чөй какты да чөйгә тукмак белән сукты.* Г. Гобәй.— *Аннан тагын бер тапкыр язгы чәчү планын карап чыгарбыз.* Р. Ишморат. // Нәрсәнең дә булса үтәлеш тәртибен санаганда кулланыла. *Билдәмә артыннан симез каз ите белән симез үрдәк, аннан бәлеш, иң ахырдан никах ширбәте килде.* Г. Ибраһимов. *Өйнең ишеге ачылып, иң алдан түбән оч мулласы, аннан хәлфәләр, соңра мәзин өйгә керде.* М. Гафури.

4. *кер. сүз функ.* Инде, ахырда, соңгы чиктә.— *Аннан, Басыйров сүзе синең өчен авторитетмыни?* Р. Ишморат.

Аннан ары — аннан соң, аннары.— *Аннан ары, ди, - - - боларның һәммәсен дә, ди, безнең кулдан тартып алып, - - - урыс монах-попларына өлгештеләр, ди.* Г. Ибраһимов. **Аннан (да) бигрәк** — бигрәк тә, иң әһәмиятлесе. **Аннан кала** — аннан башка, аны санамаганда, исәпләмәгәндә. *Аннан кала, кем бар — күзе ачык.* Н. Исәнбәт; **Аннан соң** — 1) аннары, соңыннан. *Аннан соң, арбагызны җигеп, сезгә печән ташырга гына эш кала.* Һ. Такташ; 2) аңардан башка, тагын.— *Хәзрәт, аннан соң Сәйфулла белән Гәрәй күрделәр.* М. Гафури; 3) *кер. сүз функ.* Нәрсәне дә булса кисәтеп, басым ясап әйткәндә кулланыла. *Аннан соң бит, кантоннан килгән кешеләр кемнең кем икәнен белмиләр.* Һ. Такташ.

АННАН-МОННАН *рәв.* 1. Төрле җирдән, теләсә кайдан, тегеннән дә, моннан да.

2. Җиренә җиткермичә, тиз-тиз, ашык-пошык, килдекитте, өстән-өстән генә. *Аннан-моннан гына киендем дә урамга чыктым.* М. Әмир. *Вакыт бик соң булу сәбәпле, аннан-моннан гына капкалап, йокларга яттылар.* И. Гази. // Көчкә, ничек кирәк алай. *Аннан-моннан җыеп кәфен дә алдылар.* М. Гафури. *Ул - - - революция килгәч кенә, мең төрле эшләр, мәшәкатьләр арасында вакытны аннан-моннан йолкып, наданлык белән көрәш түгәрәгендә биш атна кайнашты.* Г. Ибраһимов.

3. *сөйл.* Берәр начар ният белән, әллә нинди шикле сәбәп белән.— *Аннан-моннан сөйләвем түгел, күңелеңә авыр алма.* Г. Бәширов.

АННА'РЫ *рәв.* Нинди дә булса бер эш яки вакыйгадан соң, аның артыннан, соңыннан. *Алдан кавалерия, аннары, саф-саф тезелеп, пехота, тупка җигелгән атлар экрен генә басу капкасыннан чыга башлады.* И. Гази. // *кер. сүз функ. к.* аннан (4 мәгъ.). *Аннары, утын кисү генә димәгән.* Г. Гобәй.

АННЕ'КСИЯ *и. махс.* Берәр илне яки аның бер өлешен башка илгә көчләп кушу. *Съезд барлык сугышучы халыкларга аннексияләрсез гадел, демократик солых төзергә тәкъдим итте.* СССР тарихы.

АННЕ'КСИЯЛӘҮ *ф. махс.* Аннексия политикасын үткәрү. *1898 елда АКШ, җирле халыкны бөтенләй коллыкка төшереп, бөтен Гавай архипелагын рәсми рәвештә аннексияли.* Яңа тарих.

АННОТА'ЦИЯ *и. махс.* Берәр мәкалә яки китапның төп эчтәлеген ача торган кыскача характеристика.

АНОД *и. махс.* Уңай корылган электрод; *киресе:* катод. *Никельләнгән тимер пластинка анод дип йөртелә.* Серле кристаллар.

АНОМА'ЛИЯ *и. кит.* Нормадан, гомум закончалыктан тайпылыш.

АНОМАЛЬ *с. кит.* Нормадан тайпылган, гадәти булмаган. *Аномаль үсеш. Аномаль күренеш.*

АНОНИМ *и. кит.* 1. Үзенең исемен яшерүче автор. // *с. мәгъ.* Исеме билгеле булмаган, үз исемен күрсәтмәгән. *Аноним автор.*

2. Авторы күрсәтелмәгән хат, мәкалә. // *с. мәгъ.* Авторы күрсәтелмәгән, авторсыз. *Рәхим дәресең гадәттәгедән начаррак үздырды. Аның күңелен әле һаман да аноним хат сыкрата иде.* А. Расих.

АНОНИ'МКА *и. гади с.* Авторы билгесез булган хат, имзасыз хат.

АНОНИМЧЫ *и.* Аноним хатлар язучы. *Анонимчыдан тел саклауны, дәреслекне генә сөйләүне талап итеп булмый инде анысы.* Каз. утл.

АНОНС *и. кит.* Булачак спектакль, концерт, кинофильм һ. б. ш. турында алдан ясалган белдерү, игълан.

АНСА'МБЛЬ *и.* 1. Нинди дә булса бер бөтеннең төрле кисәкләре арасында үзара ярашканлык, гармониялелек. *Шәһәрнең архитектура ансамбле.* □ *Әнә ул киң урамнар, ерактан ук сәламләп торучы ул йортлар ансамбле монда халыкның кунакчыллыгына, аның иркен күңеллелегенә тагын да киңрәк юл ачылуын күрсәтә.* Г. Бәширов.

2. *театр.* Спектакльне башкаручылар составы. // Җырчылар, биючеләр яки музыкантлар составы. *Совет Армиясенең җыр һәм бию ансамбле.*

3. Берничә кеше тарафыннан бергә башкарыла торган музыкаль әсәр (трио, квартет һ. б.). *Соңрак җырчылар, ария һәм романслардан үтеп, ансамбльләр һәм опера өзекләре өстендә эшли башладылар.* М. Җәлил.

АНСАТ *с.* Җиңел, кыен булмаган, гади. *Ансат юл сайлау — Дан эше түгел.* З. Мансур. / *рәв. мәгъ.— Бик ансат кына баер идең бугай.* И. Гази.

◇ **Ансатка килү** — җиңел бару, җиңеләю.— *Минемчә, Майпәрвәз дөрес әйтә, үз өең булса, яхшы була инде ул, тормышта ансаткарак килә.* Ә. Еники.

АНСАТЛАНУ *ф.* Җиңеләю, ансатка әйләнү; үтәү, башкару, әйтү яки яшәү ансат хәлгә килү.

АНСАТЛАШТЫРУ *ф.* Җиңеләйтү. *Татар халкы Макарьевканы ансатлаштырып Мәкәрҗә дип атаган.* И. Рәмиев.

АНСАТЛАШУ *ф. к.* ансатлану. *Йөрү үзе дә хәзер бик ансатлашты — самолетка утырсаң, биш-алты сәгатьтән, әйтик, Казанда буласың.* Э. Еники.

АНСАТЛЫК *и.* Ансат булу. *Тормыш ансатлыгы.*

АНСЫЗ *а.* «Ул» тамырыннан күрсәтү алмашлыгы: аңардан (аннан) башка, ул булмаганда.— *Син, гажәп, эти, кредиттан куркасың. Хәзерге заманның сәүдәсе ансыз бөтенләй мөмкин дә түгел.* Ф. Әмирхан.

АНТ *и.* 1. Ил, халык алдында биргән тантаналы вәгъдә; *русчасы:* присяга. *Соңгы тамчы каным тамса тамсын, Тик антыма таплар кунмасын.* М. Җәлил. *Бу анттан Хәйрулла белән Трофимның күзләрендә дуслык ялкыны һәм шушы бөек антны бергәләп үтәү хәзерлегенең тирән билгеләре чагылып үттеләр.* К. Нәҗми.

2. Изге дип саналган әйберне (җир, ана, ил, ипи һ. б.) шаһитлеккә чакырып әйтелгән вәгъдә сүзе; нәрсәне дә булса үтәргә ышандыру сүзе.— *Мине антларың, елауларың белән генә ышандыра алмассың.* Г. Камал.— *Атакайга һәм башкаларга бу турыда берәр нәрсә белдерүгә синең телең ант белән бәйле!* М. Фәйзи.

◇ **Ант бозу** — вәгъдә бозу, хыянәт итү.—*Әгәр мин бу антымны боза калсам, иптәшләрем мине тотып алып үтергәнче кыйнасыннар.* Г. Гобәй. **Ант итү (бирү)** — 1) тантаналы вәгъдә бирү, тантаналы рәвештә ышандыру. *Сикереп менеп туры атларга, Антлар биреп илне сакларга, Байракларны селкеп җилләргә, Сез киттегез ерак җирләргә.* Ә. Исхак; 2) сүз бирү. **Ант ору** — *к.* ант итү. *Ишетәсеңме, әй, Җир-ана, Антлар орам мин сиңа.* Н. Исәнбәт. **Ант эчү** — 1) к. ант итү. *Без хәзербез антлар эчәргә... Бер-беребезне янып сөяргә.* Ф. Бурнаш; 2) *к.* ант бозу. *Син, егет, Лиза тирәсендә бик йөри башладың, антыңны да эчеп куйма.* Г. Ибраһимов.

АНТАГОНИЗМ *и. филос.* Килешә алмаслык каршылык. *Совет җәмгыяте ике дус сыйныфтан — эшчеләрдән һәм крестьяннардан тора. Болар арасында сыйнфый аерымлыклар әлегә кадәр сакланса да, антагонизм юк.* СССР тарихы.

АНТАГОНИСТ *и.* 1. Килешә алмаслык дошман.

2. *биол.* Тәэсир һәм функцияләре бер-беренә капма-каршы булган матдәләр яки әгъзалар.

АНТАГОНИ'СТИК *с.* Антагонизм белән характерлы, килешә алмаслык. *Капитализм вакытында җитештерү мөнәсәбәтләре дә капиталистлар белән эшчеләр арасында антагонистик каршылыклар булу белән характерланалар.* Политэкономия.— *Ике антагонистик сыйныф яшәгән илдә дә - - - безгә, совет җитәкчеләренә, дорфа булу килешми.* Г. Ахунов.

АНТА'РКТИКА *и.* Җир шарының Көньяк поляр түгәрәк аръягындагы өлеше.

АНТЕ'ННА *и.* Радио дулкыннарын тотып алу яки тарату өчен колгаларга эленә торган металл чыбыклар

системасы. *Элемтәчеләр ашыгып тимер чыбык суза, антенна күтәрә.* И. Гази. *Түбәләр янында антенналы ике радио баганасы мәчет манараларыннан да биек булып утыралар.* С. Рафиков.

АНТИ-«Капма-каршылык», «дошманлык» мәгънәләрен бирә торган алкушымча, мәсәлән: **антидемократик, антидиалектик, антиимпериалистик, антисанитар** һ. б.

АНТИБИО'ТИК *и. махс.* Бактерияләр, микроблар үтерергә сәләтле булган химик матдә. [*Мәдинә*] *«Россия» совхозында яңа төр препаратларга, антибиотикларга тәҗрибә ясый икән.* М. Хәсәнов.

АНТИК *с.* 1. Борынгы грек һәм рим тарихына, культурасына бәйле. *Антик философия. Антик сәнгать. Антик әдәбият.*

2. Классик дөрес төзелешле, матурлыгы белән антик дөнья сыннарын хәтерләтүче (йөз, тән төзелеше һ. б. турында). [*Табигать аңа*] *матур профильле антик борын һәм киң маңгай бүләк иткән.* И. Рәмиев.

АНТИКВАР *и. иск.* Сирәк очрый торган борынгы сәнгать әйберләре, китаплар һәвәскәре, шуларны җыючы. // Борынгы, сирәк очрый торган әйберләр белән сату итүче. // *с. мәгъ.* Борынгы һәм кыйммәтле. *Антиквар ваза.* // *с. мәгъ.* Антиквар әйберләр белән сату итә торган. *Әлбәттә, Зөфәр күреп тора, бу әле зәвыклы, культуралы итеп җиһазлау түгел, өе аның антиквар кибетенә охшабрак китте.* Ә. Еники.

АНТИКЛЕРИКАЛЬ *с.* Чиркәүгә һәм руханиларга каршы юнәлдерелгән, ләкин диннең үзенә каршы булмаган. *Радикаллар үзләренең шау-шулы антиклерикаль политикалары белән эшчеләрне капитализмга каршы көрәштән читләтергә тырышалар.* Яңа тарих.

АНТИЛЕ'НИНЧЫЛ *с.* Ленинизмга каршы булган. *Антиленинчыл элементлар.*

АНТИЛО'ПА *и.* Куыш мөгезләләр семьялыгыннан пар тояклы, матур гәүдәле күшәүче хайван.

АНТИПА'РТИЯЧЕЛ *с.* Партиянең идея һәм оештыру принципларына каршы юнәлтелгән, капма-каршы эш алып бара торган.

АНТИПА'ТИЯ *и. кит.* Яратмау, нәфрәтләнү хисе; *киресе:* симпатия. *Г. Әпсәләмов әсәрләрен укып чыккач, язучының үз геройларына булган симпатиясендә яки антипатиясендә бернинди шик калмый.* Р. Мостафин.

АНТИПА'ТИЯЛЕ *с. кит.* Сөйкемсез, мәхәббәтсез; *киресе:* симпатияле.

АНТИПОД *и.* 1. Җир шарының бер-беренә капма-каршы ике ягында яшәүчеләр.

2. *күч.* Үзенең карашлары, үзенчәлекләре, зәвыклары буенча башка бер кешегә капма-каршы кеше. *Татар халык әкиятләрендә* [*әшәкелек эшләүче залимнәрнең*] *антиподы булган намуслы, гадел кеше нинди генә кыен көрәшләрдә дә һәрвакыт өстен чыга, морадына ирешеп, бәхетле тормышта яши.* Г. Бәширов.

АНТИСЕМИТ *и. кит.* Антисемитизм тарафдары, еврейләрне дошман күрүче кеше.

АНТИСЕМИТИЗМ *и. кит.* Антагонистик җәмгыятьтә реакционерлар тарафыннан сыйнфый һәм политик максат белән еврейләргә карата ясалма рәвештә барлыкка китерелгән милли дошманлык политикасы. *Национал-социалистлар Версаль договорын юк итүне талап иттеләр, шовинизм һәм антисемитизмны җәелдерделәр.* Иң яңа тарих.

АНТИСЕМИ'ТИК *с. кит.* Еврейләргә каршы юнәлтелгән, еврейләрне дошман күргән. *Антисемитик караш.*

АНТИТЕ'ЗА *и. кит.* 1. Каршы кую; каршылык.

2. Капма-каршы булган яки кискен аерылып торган төшенчә һәм образларны бирүдән гыйбарәт әдәби стилистик алым. *Дөньяны ике лагерьга аерып ташлаган революцион чынлыкның сурәте поэзиядә антитезага корылган образларда чагылды.* Х. Госман.

АНТИТЕ'ЗИС *и. кит.* Һер тезиска каршы куелган тезис, фикер.

АНТЛЫ *с.* 1. Ант биргән, анты булган. *Солдат, антлы солдат! Котылырга нинди чара бар?* Х. Туфан.

2. Ант белән ныгытылган. *Антлы вәгъдә.*

АНТОЛО'ГИК *с. кит.* Борынгы грек лирикасы рухында язылган. *Антологик поэзия.*

АНТОЛО'ГИЯ *и. кит.* Төрле авторларның сайланма (башлыча шигъри) әсәрләре җыентыгы. *Татар поэзиясе антологиясе.*

АНТО'НИМ *и. лингв.* Мәгънәсе белән башка бер сүзнең капма-каршысын белдерә торган сүз (мәсәлән: *ак — кара, бару — кайту, өстә — аста).*

АНТО'НОВКА *и.* Алмагач төре, шулай ук аның соңа өлгерә торган хуш исле, әчкелтем тәмле алмасы. *Хуш исле сарғылт антоновкалар алмагач төпләрендә өелде.* И. Гази.

АНТРАКТ *и. махс.* 1. Спектакль пәрдәләре яки концерт бүлекләре арасындагы тәнәфес. *Икенче тапкыр без аны антракт вакытында театр фойесында кешеләр белән йөргәндә күрдек.* М. Гали.

2. Пьесаның ике акты арасында уйнала торган зур булмаган музыкаль әсәр. *Икенче пәрдә башындагы антрактны* [*Хәбир*] *алып эшләгән иде.* Ш. Хөсәенов.

АНТРАЦИТ *и. геол.* Ташкүмернең җылылыкны күп бирә торган кара һәм ялтыравыклы иң яхшы төре. *Мин бер кисәк антрацит таптым һәм өстәдем аны утынга. Учак яна кырда, яр читендә, матдә яна анда тын гына.* Х. Туфан. / *с. мәгъ.* [*Кызның күзләре*] *антрацит күмердәй чем-кара иде.* Ә. Еники.

АНТРЕКОТ *и. махс.* Сыерның кабырга ите. //Кыздырылган кабырга ите. // Сыерның кабырга итеннән тапап пешерелгән котлет.

АНТРЕПРЕНЁР *и.* Капиталистик илләрдә шәхси театр, цирк тотучы.

АНТРОПО'ИД *и.* Кешесыман маймыл. *Антропоидларда койрык юк; алар озын кулларына таянып булса да, арткы очлыкларында басып йөри алалар.* Биология.

АНТРОПО'ЛОГ *и.* Антропология белгече.

АНТРОПОЛО'ГИК *с.* Антропологиягә мөнәсәбәтле, антропологиягә бәйләнешле.

АНТРОПОЛО'ГИЯ *и.* Кешенең биологик табигате турындагы фән. *Антропология кабинеты. Антропология музее.*

АНФАС *и.* Йөз белән караган, алгы як. *Рәсемгә анфас белән төшү.* □ *Икенче кәгазьдә шул план буенча төзеләчәк объектның профиль һәм анфас күренешләре иде.* И. Салахов.

АНЧАК *терк. иск.* Фәкать, бары тик. *Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга, Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.* Г. Тукай.

АНЧАР *и.* Агулы тропик үсемлек.

АНШЛАГ *и.* Театрда, кинода һ. б. билет сатылып бету. [*Укучы:*] *Интәшләр, аншлаг! --- Зал шыгрым тулы.* Г. Әпсәләмов. [*Интәшләрнең*] *күңелләре күтәрелеп китте, димәк, бүген аншлаг тәэмин ителгән икән! диделәр.* Каз. утл. // Билетларның сатылып бетүен белдереп язган игълан.

АНЫ *а.* «Ул» алмашлыгының төшем килеш формасы.— *Степанов дигәннән, бүген тагы күрәм бит мин аны.* Ф. Әмирхан. *Айга күптән инде миллион тулган, ә ул үзе аны оныткан.* Һ. Такташ.

АНЫК *рәв.* 1. Ачык, дөрес. [*Большевиклар*] *бар нәрсәне дә белеп, аныкһәм төгәл исәплиләр.* К. Нәҗми. *Кемнәр килгән — аныкмәгълум түгел.* Ф. Бурнаш. / *с. мәгъ. Ә Мәрьяме аның кирәгенчә тигез, сабыр холыклы, аныкакыллы хатын иде.* Ә. Еники. // Ачыктан-ачык, ачык, төгәл. *Атларның купшы чабып, дагалары белән урам ташларын сугулары — һәммәсе аныкишетелеп, Хәятның башына каба башлады.* Ф. Әмирхан.

2. *с. мәгъ.* Алдан хәзерләнгән, әзер. [*Сәлмән карт:*] *Әгәр дүрт ел буена аныкыкмәккә укып алган белемең бары шушы гына булса, бик ераккa китә алмагансың икән, энекәш.* Ф. Хөсни. / *хәб. функ. Ләкин хәйләкәрнең җавабы аныкыде.* Ак юл.

Аныкка таныкбулу — әзергә хәзер булу, көч куймыйча, көч түкми генә яшәү, башкалар тапканга хуҗа булу.

АНЫҚЛАНУ *ф.* Ачыклану, барлану. *Дәлилләрнең дәреслеге аныкланы.* □ *Кайсы участокларга ничаклы һәм нинди ашлама кирәклеге аныкланды.* Соц. Тат.

АНЫҚЛАУ *ф.* 1. Төгәлрәк итеп белү, яхшылап барлау, ачыклау, төгәллек кертү. *3 нче батальон дошман оборонасын капшарга, ут ноктaларын барларга, җанлы көчләрен аныкларга приказ алды.* Ә. Айдар. *Керүчеләрдән берсенең шофер икәнлеге күренеп торса да, икенчесенең кем булуын аныклау читен иде.* Г. Минский.

2. *диал.* Алдан әзерләү, әзер итү. *Арыслан ящик эченә кергәч, хәйләкәр балтачы ящикның тишеген алдан ук аныклап куйган такталар белән каплап, кадаклап та өлгерде.* Ак юл.

АНЫҚЛЫК *и.* Ачыклык; төгәллек, дөреслек, аныклыбулу. [*Сүзнең*] *аныклыгы чамалы, конкрет түгел.* Г. Гобәй.

АНЫҚЫ *а.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса берәр кешегә яки предметка мөнәсәбәтле (шуңа караган) булуын күрсәтә. *Дәүләтшинныкы кебек буй белән, аныкы кебек тазалык белән урамда күренү оят була башлый.* И. Гази.

АНЫ-МОНЫ *а.* 1. «Ул-бу»ның төшем килеш формасы. *Тизрәк кайтып җитәргә тырыш. - - - Аны-моны кыстырып кайтырга да онытма.* М. Әмир.

2. Теге яки бу әйбер турында. *Аны-моны сөйләшкәч, теге кеше әйтә куйган: Җәлил, - - - бер пар киез итек әвәләп бирмәссеңме икән?* И. Гази. // Юклык формасындагы хәл фигыльләрдән алда килгәндә *берни, бернәрсә, һичнәрсә* мәгънәләрен белдерә (мәсәлән, аны-моны белештерми(чә), аны-моны тикшерми(чә), аны-моны уйламый(ча), аны-моны сими(чә) һ. б.). *Шубин, аны-моны тикшермәстән, юлдашының артыннан пароходка кергән иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Ул аны-моны уйламыйча тизрәк эшкә тотынды.* Ә. Еники.

АНЫСЫ *а.* 1. Пространствода предметларның ераграк, читтәрәк урнашканына күрсәтә; *киресе:* монысы. *Монысы — минеке, анысы — сеңлемнеке.*

2. Элек сөйләнгән предмет, зат яки берәр хәл турында ишарә буларак кулланыла. *Беренчелекне ала алабызмы-юкмы, анысын менә шушы ашлыкларны җыеп алу, көзге чәчү, туңга сөрү күрсәтер.* М. Гали.

АНЫСЫ-АНЫСЫ *кер. сүз.* Элек сөйләнгән предметка, хәлгә, вакыйгага, затка караганда җитдирәк, гаҗәбрәк, артыграк яки кимрәк башка предмет, хәл, вакыйга, зат булуны белдергәндә кулланыла: *«анысы әле аның кечкенә хәл, зуррагы бар»* мәгънәсендә. *Анысы-анысы, утырткан бәрәңгесе, савар кәҗәсе дә булмаган өч бала анасына* [*сугыш вакытында*] *тормыш алып бару яман кыен иде.* Г. Гобәй.

АНЫСЫ-МОНЫСЫ *а.* Төрлесе, вак-төяк нәрсә. [*Колхоз идарәсендә*] *агайлар анысын-монысын сөйләшеп утыралар.* Ә. Еники.— *Мин анысын-монысын - - - сатып, бер атлык җыйнармын дип уйлыйм. Фәрихә минем сүзгә каршы килми ул.* Ш. Камал.

АНЫҢ *а.* «Ул» алмашлыгының иялек килеше формасы. *Аның иптәшләре ишек алдында саклап торган шикелле көтеп торалар.* Г. Камал. // Күбесенчә җөмлә азагында «инде» сүзе белән килеп, мәгънәне, фикерне көчәйтү, басым ясау өчен кулланыла. *Мулласы нинди булса, мәхәлләсе дә шундый була инде аның.* Ш. Усманов.— *Бу чакта заманы шул инде аның, заманы шул.* Ф. Әмирхан.

◇ **Аның каравы** *сөйл.*— әмма, шулай да, шулай булса да. *Таңнан-таңга ара бик кыска, Адымнар киң аның каравы.* М. Хөсәен. *Күп эшләргә туры килде, аның каравы заданиене үтәдем.* Каз. утл. **Аның саен** — торган саен, һаман, һаман да. *Үз фикерләренең каршылыкка очрамый, һәрвакыт дөресләнеп торуы аңа горурлык һәм күңел рәхәте бирә, аның саен ул үзенең үгетләрен дәвам иттерә иде.* Ә. Фәйзи. **Аның өстенә** — шуның белән бергә, өстәмә рәвештә, өстәвенә.— *Көне-төне эшлисең дә, аның өстенә һәр көн орыш та талаш.* Г. Камал.

АОРТА *и. анат.* Йөрәкнең сул ягыннан башланып, тәннең үпкәдән башка барлык әгъзаларын кан белән тукландыра торган иң юан төп кан тамыры.

АП- *кис.* «А»га башланган кайбер сыйфат һәм рәвешләрнең артыклык дәрәҗәсен ясау өчен хезмәт итә, мәсәлән: *ап-аз, ап-ак, ап-арык, ап-ачык.*

АПА *и.* 1. Үзеңнән олырак яшьтәге кыз туган.— *Үзем өчен генә түгел, сугыштагы ирем, фашистлар үтергән апам өчен дә көчемне аямый эшләргә сүз бирдем.* Г. Бәширов.

2. Яшь ягыннан үзеңнән олырак хатын-кыз исеменә кушып әйтелә. *Газизә апа да, Мөхәммәтвәли абзый да бүген Габдуллага бөтен булган җылылыкларын бирергә, аңа чын ата һәм ана булырга тырыштылар.* Ә. Фәйзи. // *сөйл.* Яшь ягыннан олырак хатын-кызның профессиясенә кушып әйтелә. *Врач апа.* □ *Укытучы апасы аны үз янына чакырып алды.* А. Әхмәт. *Тәрбияче апалары аларны бу эштән бик тиз туктатты.* А. Алиш. // Гомумән олы яшьтәге хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе.— *Алар бит* [*игеннәрне*], *апа бәгърем, миңа Сафаның никахлы хатыны итеп түгел, әялчы итеп бирделәр.* А. Шамов.

АПАЙ *и. диал.* 1. Апа.— *Миңзифа апай кулыдыр, бәлешегез бик тәмле.* Г. Ибраһимов. [*Сылу:*] *Куй әле, Зифа, Зөләйха апай белән алай үчләшмә, бик күңелсез.* М. Фәйзи.

2. Кечерәк яшьтәге ир һәм кыз туган. *Апай миңа әйтә: «Менә сиңа җизнәкәйнең хатлары».* К. Нәҗми. // Үзеңнән кечерәкләргә мөрәҗәгать сүзе. [*Хатын:*] *Миңа бит, апаем, ике көнгә генә* [*кайтып килергә иде*]. А. Гыйләҗев.

АП-АК *с. Арт. дәр. к.* ак (1—4 мәгъ). *Җир өстен ап-ак кар каплаган.* Г. Гобәй. *Күргәнем юк иде каштаннарның Ап-ак булып чәчәк аткaнын.* З. Мансур. // Үтә чаларган. *Болар, акрын гына атлап килеп, вокзал алдында торучы ап-ак сакаллы бер картка сәлам бирделәр.* Ш. Мөхәммәдев.

АПАЛЫ-СЕҢЕЛЛЕ *с.* Апа белән сеңел.

АПАРА *и. сөйл.* 1. Камыр башы, ачыган камыр. *Апара чилләге.*

2. Он суы, малга эчерү өчен он болгатып хәзерләгән куе су. *Тизрәк үссен дип, өйдәгеләрдән яшереп кенә,* [*колынга*] *апара эчертәм, җай килгән саен ипи сыныклары каптырам.* Г. Бәширов. [*Илсояр*] *эт өчен кайнар суда апара болгата башлады.* Г. Гобәй. // *кимс.* Тәмсез, сыек яки озак кайнаудан куерык массага әйләнгән аш. *Минһаҗетдин һәркөнне изрәп апарага әйләнә язган токмачны ашап, бу көнгә кадәр яшәде.* Қ. Тинчурин.

◇ **Апара корсак** *ирон.*— 1) күп ашый торган кешегә карата әйтелә; 2) гомумән кимсетү сүзе.

АПАРТАМЕНТ, АПАРТАМЕНТ *и. сир.* Берничә бүлмәдән торган, бик зиннәтле итеп эшләнгән бина. // Зур йортларда бай итеп җиһазландырылган иркен бүлмә, зал. // *күч.* Өй, квартира; гомумән тору урыны.— *Хәзер, дустым, мин сиңа апартаментларымны күрсәтим әле.* Ә. Еники.

АПАРТЕИД *и. махс.* Кара тәнлеләрне ак тәнлеләрдән аеру политикасы.

АП-АРЫҚ *рәв. Арт. дәр. к.* арык I.

АПАТИТ *и. махс.* Суперфосфат, фосфор кислотасы һәм башка шундый нәрсәләр хәзерләүгә китә торган

минерал. *Фосфорлы ашламалар җитештерү өчен төп чимал итеп апатит минералларын файдаланалар.* Химия.

АПА'ТИЯ *и.* Сүлпәнлек, рухсызлык, күңел төшенкелеге.

АП-АЧЫК *рәв.* 1. Тулысынча ачылып беткән, шар ачык. *Ап-ачык тор һәрвакытта, И китап, багам сиңа.* Ш. Бабич.

2. Аныкъ, бик ачык рәвештә. *Татар реакциясе хәзер үз кулыннан бернәрсә дә килмәгәнен ап-ачык белде инде.* Ф. Әмирхан. *Бик якында гына кебек ап-ачык булып пулемет тавышы ишетелә башлады.* Г. Бәширов.

3. Бөтен тулылыгы белән, ачыктан-ачык. *Бөтен нәрсә, уч төбендәге төсле, ап-ачык булып өстә ялтырап ята иде.* Сов. әд. // *күч.* Яшермичә, турыдан-туры.— *Нигә бу турыларда ап-ачык итеп аның белән сөйләшмисең?* Г. Ибраһимов.

4. *хәб. функ.* Билгеле булу, нәрсәнең дә булса булу-булмавына шик калмау. *Спектакльнең харап булачагы ап-ачык иде.* Г. Бәширов. *Тимер баулы таш капчык, Хәлең җитсә, ташлап чык! Үзең ташлап чыкмасаң, Үлә-чәгең ап-ачык!* М. Җәлил.

5. *с. мәгъ.* Бик якты. *Ап-ачык нурлар чәчеп, күренеп тора һәр яклары.* Ш. Бабич. // Аяз, чалт аяз. *Бер яктан, ап-ачык һаваның әйбәтлегенә ышанып җитмисең, икенче яктан, арба тавышын нәкъ сандугач тавышы дип тыңлыйсың.* Ш. Камал.

АПАШ(И) *и.* Ачык һәм киң якалы күлмәк. *Яңа апашемның сыныпсыныпторган бөкләм эзләре бетсен дип, кроватька ятып аунадым.* М. Әмир.

АПЕЛЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. *махс.* Суд карарыннан риза булмыйча югары суд органына бирелә торган жалоба. *Суд башта бер атна ябарга хөкем итә, ләкин апелляция ясалу аркасында - - - штраф белән алмаштырыла.* М. Гали.

2. *кит.* Нәрсә турында да булса сорап, үтенеп мөрәҗәгать итү.

АПЕЛЬСИН *и. к.* әфлисун.

АПОГЕЙ *и.* 1. *астр.* Ай, ясалма иярчен һ. б. орбитасының җирдән иң ерак ноктасы.

2. *күч.* Иң югары нокта, иң югары баскыч. *Кызларның [Хәбир белән] кызыксынулары үзенең апогеена җитте.* Ш. Хөсәенов.

АПОКО'ПА *и. лингв.* Ике сүзне кушып әйткәндә бер яки берничә авазның төшеп калуы (мәсәлән: *кайта алмады — кайталмады*).

АПОЛОГЕТ *и. кит.* Кемне яки нәрсәне дә булса чамадан тыш мактап, яклап чыгучы.

АПОРТ *и.* Эре, әчкелтем-баллы, сусыл алма төре.

АПО'СТРОФ *и. лингв. иск.* Хәрефләр арасында аеру билгесе (ъ, ь) барлыгын белдерүче яки төшеп калган хәреф урынына куела торган өтер сыман тамга.

АППАГЫМ *и.* Яратып, сөеп, иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе. *Укы, аппагым, нәкъ укыр чагың.* М. Гафури. *Аю да үзенең баласына аппагым ди.* Мәкаль.

АППАРАТ *и.* 1. Билгеле бер эш башкару өчен механик җайланма, прибор. *Клубка тавышлы кино аппараты да алып куярга ниятләп торабыз.* Э. Еники. *Эле язга абый миңа бик яхшы бер фотография аппараты бүләк итмәкче була.* Ф. Әмирхан. // Телефон яки телеграф аппараты. *Бераздан чыбык ялганып, аппарат янә эшли башлады.* Ш. Усманов.

2. Организмда нинди дә булса аерым бер функцияне үти торган эгъзалар җыелмасы. *Аш кайнату аппараты.*

3. Хуҗалыкның нинди дә булса бер өлкәсенә хезмәт итә торган учреждениеләр җыелмасы. *Советларның өяз конференциясендә Якубны - - - өяз башкарма комитет аппаратына эшкә алырга карар чыгарганнар иде.* И. Гази. // Берәр учреждение яки оешманың хезмәткәрләре, *Җиң сызганып ала бар аппарат — Һәр бүлеккә, һәрбер урынга Кәгазь ява башлый — Волокитаны бетерү турында.* З. Мансур.

АППАРАТУ'РА *и. к.* аппарат (1 мәгъ.).

АППАРАТЧЫ *и.* Бер яки берничә аппаратта (1 мәгъ.) эшләүче эшче; аппаратларның (1 мәгъ.) эшен күзәтеп торучы, аларны җайлаучы, төзәтүче эшче.

АППЕ'НДИКС *и.* 1. *анат.* Көшенең сукыр эчәгендәге суалчан сыман кечкенә үсенте.

2. *тех.* Һава шары тышчасының аскы өлешендә газ кертү һәм чыгару өчен кыска шланг (труба).

АППЕНДИЦИТ *и. мед.* Сукыр эчәк үсентесенең (аппендиксның) ялкынсынуы, шешүе. *Үсентегә эчәклектән кайбер бактерияләр керсә, үсенте шешеп, аппендицит авыруы булырга мөмкин.* Анатомия.

АППЕТИТ *и.* Ашыйсы килү. *Кешеләр зур аппетит белән тәлинкәләргә үрелделәр.* Г. Гобәй.

АППЕТИТЛАП *рәв.* Аппетит белән, бик тәмләп. *Мөхәммәтҗан бабай, кесәсеннән трубкасын чыгарып, тәмәке тутырып, бик аппетитлап кына трубка тарта башлый.* М. Гали.

АППЛИКА'ЦИЯ *и.* 1. Кәгазьгә яки тукымага төрле төстәге кәгазь, күн яки тукыма кисәкләре ябыштыру яисә тегеп күю юлы белән орнаментлар, художестволы рәсемнәр ясау.

2. Шул юл белән ясалган сурәт, рәсем, орнамент.

АПРЕ'ЛЬ *и.* Календарь елының дүртенче ае. *Кар белән бер вакытта бетәдер март, Апрель туса, дөнья була суга юмарт.* М. Гафури.

АПРИОР *с. филос.* Тәҗрибәгә нигезләнмәгән.

АПРИО'РИ *рәв. филос.* Тәҗрибәгә нигезләнмичә.— *Мин үземнең теоретик положениеләремне априори тудырмадым, ә күп тапкырлар үздырылган экспериментлар нәтиҗәсендә китереп чыгардым.* А. Расих.

АПРОБА'ЦИЯ *и.* 1. *кит.* Сынау яки тикшерүләр нигезендә берәр нәрсәнең яки эшнең сыйфатын, яраклылыгын рәсми рәвештә хуплау, раслау.

2. *а.-х.* Ашлыкның сортын, чисталыгын, корылыгын тикшерү өчен проба алып, чәчү орлыкларының сыйфатын билгеләү.

АПРОБА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. *кит.* Апробация ясау, рәсми рәвештә раслау.

2. *а.-х.* Апробация (2 мәгъ.) ясау, проба алу.

АПТЕ'КА *и.* Дарулар (ясап) сата торган учреждение.— *Кара син аны, үзе кадим булса да, аптека тота икән.* Г. Камал.— *Кайткан чакта аптекага кагыл, хуҗага әйт: больница сораганнарның бөтенесен бирсен* И. Гази.

АПТЕ'К(А)ЧЫ *и.* 1. Аптека хезмәткәре.

2. *иск.* Аптека тотучы. [*Себер бае:*] *Татарда аптекачы бар дип уйламый идем мин.* Г. Камал.

АПТЕ'ЧКА *и.* Өй шартларында, учреждениеләрдә дарулар саклый торган махсус тартма яки кечкенә шкаф.

АПТЫРАНУ *ф.* Ни эшләргә белми аптырап калу. *Тәмам аптыранып калган хәзрәт аңар:— Син тәмам кабахәтләнүнең ниһаясенә җиткән икәнсең инде,— диде.* Ф. Әмирхан. *Гарифның иптәшләре дә аптыранып Шәрәфи агай янына җыелышканнар.* Ш. Камал.

АПТЫРАТУ *ф. Йөкл. юн. к.* аптырау (1 мәгъ.). Җәфалау, интектерү; борчу, йөдәтү, тынычлык бирмәү. *Закирҗанов өстәлгә ярым ятып, маңгаена төшеп аптыраткан кара куе чәчен артка сыпыра-сыпыра, каләмен кыштырдатып язарга кереште.* С. Рафиков.— *Ишекне дөбердәтеп аптыраттылар.* Г. Камал.

АПТЫРАУ *ф.* 1. Җәфалану, интегү, йөдәү, гажиз булу.— *Әнә шул, бар ич әле бер адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем.* Г. Камал.— *Белмим инде, нишләргә дә аптырадым бу хатын белән.* М. Гали.

2. Мохтаҗ булу.— *Ходайга шөкер, бу арада бер дә аптыраганыбыз юк.* М. Гафури.

3. Нинди дә булса бер хәл алдында каушап калу, авыр хәлдә калу, ни эшләргә белмәү. *Галләметдин кинәт*

бирелгән бу сорауга ничек җавап бирергә белмичә азрак аптырап калды. Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Вакытлыча туган таркаулык хәле, югалып калу, паника. *Беренче аптыраудан айныган казаклар атларына атландылар.* Ш. Усманов. *Һәммәсенең йөзендә шатлык һәм аптырау.* Һ. Такташ.

4. Гаҗәпләнү, гажәпкә калу. *Һич туктап тормый сөйләвенә аптырыйм.* М. Гафури.

АПТЫРАУЛЫ *с.* Аптыраган, аптырау хәлендәге. [*Матвей Яковлевич*], *карчыгының җавабыннан элек аптыраулы карашын күреп, өйдә чит кеше юклыгын төшенеп алды.* Г. Әпсәләмов.

АПТЫРАШ *и. сөйл.* Аптырау фигыленнән ясалган исем. *Аптыраш белән йөдәш кергәннәр, ди, өйдәш.* Әйтем. *Мең төрле уй, катты баш, нишләргә дә аптыраш.* Ш. Бабич.

Аптырашка калу, аптырашта калу — аптыраган хәлдә булу. *Һәркем байларның комсызлыкларына аптырашка калды.* М. Гафури. *Ашлык урлаучылар аптырашта калалар.* А. Алиш.

АПТЫРАШЛЫ *с. сөйл. к.* аптыраулы. *Өлкән сержант аптырашлы караш белән кулларын җәеп җибәрде.* А. Шамов.

АПТЫРАШУ *ф. Урт. юн. к.* аптырау (3, 4 мәгъ.). *Алар, нәрсә әйтергә дә белми, байтак шулай аптырашып тордылар.* М. Гали.— *Бу малайга ни булды?— дигән сыман барысы да аңа карап аптырашып калдылар.* Д. Аппакова.

АПУЙКА *и. сөйл.* Бозау тиресеннән эшләнгән күн. // *с. мәгъ.* Апуйкадан тегелгән. [*Фәсхинең*] *апуйка итеге, кыршылып беткән күн тужуркасы һәм техник кыяфәтен, һәм җир төзүче төсен бирә иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АР I *и. иск.* Удмурт. *Татармы, армы син — белмим үзеңне.* Дәрдмәнд.

АР II *с. к.* аргы. *Мәликә илленең ар ягына чыккан булса да, картыннан әле һаман көнли иде.* А. Шамов. *Ар урамда мылтык шартлады.* Н. Баян.

АР III *и. мат.* 100 кв. метрга тигез җир үлчәве берәмлеге.

А'РА *и. зоол.* Попугайларның авыл хуҗалыгына зарар китерә торган бер төре (кызыл, зәңгәр һ. б. төсләреле була). *Ара дигән зур попугайлар йон-каурыйларының гадәттән тыш ачык төсе белән аерылалар.* Физ. геогр.

АРА' *и.* 1. Ике нәрсә арасындагы бушлык, буш урын, ачыклык. *Мич арасы. Тәрәзә арасы.* □ *Садыйк ике лабаз арасын сынамаган күз сизмәслек итеп кенә бүлеп алган да, игенен шунда яшергән.* Г. Гобәй. *Кечкенәләргә килгәндә, эш җиңел, башын ике аяк арасына кыстыра да:— Икенче усал булма!..— дип бирепме бирә.* Қ. Нәжми. // Ике предмет яки ике кешене аерган урталык.— *Ике арага минем чаршауны корып куй әле,— диде Җәмилә.* М. Гафури.

2. Бер объекттан икенче объектка кадәрге юлны (ераклыкны), ике ноктаның бәйләнешен аңлатканда кулланыла. *Ерак араларны якын итеп, Килерсеңме, әгәр кил дисәм?* Җыр. *Сигез километр — йөрмәгән ара түгел, үземчә сәгать ярым, ике сәгатьтә килеп җитәргә тиеш идем.* Ә. Еники.

3. *с. мәгъ.* Ике категория, төр һ. б. ш. уртасындагы, арадаш. *Ара күренешләр.* □ *Иске төр яңа төрне бернинди күчешсез һәм ара формаларсыз гына китереп чыгара.* Биология.

4. *бәйл. функ. у.-вак. килеш. форм.* **арада.** Вакыт мәнәсәбәте белдереп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Малай чаптырып барып килгән арада, апасы бер көлтәлек солыны урып та өлгергән иде инде.* И. Гази. *Җиңги кеше өстәлләренә тәлинкәләр тезгән арада, без, урыныбыздан торып, идән буенча йөри башладык.* М. Әмир.

5. *бәйл. функ. юн. килеш. форм.* **арасына.** 1) пространство мәнәсәбәте белдереп, эш-хәлнең берничә яки күп зат эченә, теге яки бу мохиткә юнәлгәнлеген күрсәтү өчен кулланыла. *Агачлар арасына керү. Халык арасына таралу.* □ *Әхмәт башын иеп җавап биргәч, кыз халык төркеме арасына кереп китте.* Г. Минский. *Шәриф шәһәр арасына керү белән әллә ничә эш тапты.* М. Гафури; 2) кемнәр яки нәрсәләр рәтендә, дәрәҗәсендә булу-булмауны белдерү өчен кулланыла. *Анда шигырьләре басылган шагыйрьләр арасына мин дә кергәнмен.* М. Җәлил.

6. *бәйл. функ. чыг. килеш. форм.* **арасыннан.** Эш-хәлнең предметлар яки нинди дә булса затлар аралыгындагы пространство аша үтеп башкарылганлыгын күрсәтү өчен кулланыла. *Куаклар арасыннан күренеп калу.* □ *Хәлим сәхнә артында өелеп яткан киемнәр арасыннан үзенең сумкасын тартып чыгара.* Г. Гобәй.

7. *бәйл. функ. у.-вак. килеш. форм.* **арасында.** 1) эш-хәлнең ике яки берничә предметка, затка бәйләнешле рәвештә, теге яки бу мохит эчендә башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Төрле милләт халыклары арасында дуслык мөнәсәбәтләрен үстерү. Шәһәр белән авыл арасында бәйләнеш.* □ *Кызлар белән танышып беткәч, яшьләр арасында тагын сүз куерды.* М. Әмир. *Голиков — мәрхүм — Казан купецлары арасында атаклы кеше булган.* Қ. Нәҗми; 2) үзара мөнәсәбәттәш предмет яки затларның, күренешләрнең охшашлык яки аерымлыкларын күрсәтү өчен кулланыла. *Гали белән Вәли арасында зур аерма — тормышка төрлечә карауларында.* □ *Алар ике тормыш арасындагы аермаларның сәбәпләрен эзләргә яңадан юл ачтылар.* М. Гафури; 3) теге яки бу затларның үзара нинди дә булса мөнәсәбәт характерын белдерү өчен кулланыла. *Алар арасында дуслык юк.* □ *Госман белән Салих арасында ниндидер аңлашылмаучылык чыккан.* Каз. утл.; 4) кемнең дә булса алдында, каршында.— *Тырыштым, укыттым баланы, кеше арасында абруй булыр, дидем.* Ә. Айдар; 5) эш-хәлнең үтәлү вакытын белдерү өчен кулланыла. *Эш арасында гына кереп чыгу.* □ *Көлүләр арасында Миңнулланың үпкәле тавышы ишетелде.* И. Гази.

◇ **Арага алу—тиң итеп, санга санап, үз ишләре рәтенә кертү. Ара бозу** — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне бозу (дошманлаштыру). *Алар ара бозыштырыр өчен генә йөриләр.* А. Шамов. **Ара бутау** — *к.* ара бозу. [*Һәдия*] *сарыкларын әйбәтләп карыйсы урында, ялган таратып, ара бутап йөри икән, Нургали абыйдан үзебез сорап фермадан кудырырбыз.* Ә. Еники. **Арага керү (төшү)** — 1) нинди дә булса коллективның үз кешесе булып китәргә тырышу, шуларга катнашу.— *Чит хатын-кызларның безнең арага керүләрен теләмим мин.* А. Шамов; 2) берәр эш эшләп яки берәр нәрсә сөйләп торучы ике кеше янына өченче кешенең килеп катнашуы. *Ул Якубтан нидер сорамакчы иде ахры, арага Шәрифҗан кереп бүлдерде.* И. Гази; 3) талашып яки сугышып тора торган ике кешене аерып, килештерергә тырышу, аралау. *Фәхри бабай, берничә кеше арага төшүгә карамастан, һаман Галимә апага таба тартыла һәм аны кыйнамакчы була иде.* М. Гафури; 4) дус булып йөргән ике кешенең яки яратышып йөргән егет белән кызның мөнәсәбәтен бозу.— *Бел шуны, башың ике булса, кер безнең арага.* М. Фәйзи. **Араны өзү** — 1) мөнәсәбәтне өзү, бозылышу; 2) алыш-бирешне туктату; алачак, бирәчәкләр калмау.

- АРА Кушма сүзләрдә кем яки нәрсәләргә уртак мөнәсәбәте булган, шулар арасында була торган, башкарыла торган кебек мәгънәләрне белдерүче икенче кисәк, мәсәлән: **халыкара, милләтара, шәһәрара, колхозара.**

АРАДАШ 1. *с.* Теге яки бу төргә (категориягә) кермичә, шул ике төр (категория) арасында, урталыкта торган. *Арадаш күренешләр.*

2. *и. к.* арадашчы (1—2 мәгъ.). *Арадаш хезмәтен үтәү.*

АРАДАШЛЫК *и.* 1. Якларның үзара килешүенә, алыш-биреш алып баруына ярдәм итү эше. *Европаның Көнчыгыш белән сәүдәсе гарәпләр арадашлыгы белән алып барылган.* Урта гас. тарихы.

2. *махс.* Бәхәсләшүче, дәгъвалашучы, сугыш алып баручы якларны үзара килештерергә ярдәм итү эше.

АРАДАШЧЫ *и.* 1. *сөйл.* Арадашлык итүче, маклер. *Сәүдәгәр башта вак җитештерүченең - - - товарларын алмашканда һәм феодаллар үзләре үзләштергән өстәмә продуктның бер өлешен сатканда арадашчы булып эш иткән.* Политэкономия.

2. *махс.* Бәхәсле, дәгъвалы эшләрдә каршы якларны килештерергә ярдәм итүче.

3. Судья, арбитр (хәрби маневрларда).

АРАҚЧЕЕВ: аракчеев режимы — *к.* аракчеевчылык.

АРАҚЧЕЕВЧЫЛЫК *и.* 1. Россиядә 19 нчы йөз башындагы полиция деспотизмы режимы.

2. *күч.* Нинди дә булса ижтимагый-политик өлкәдә аерым кешеләрнең деспотларча эш итүе.

АРАҚЫ *и.* Спирт һәм су катнашмасыннан торган исерткеч. // *с. мәгъ.* Аракыга мөнәсәбәтле. *Аракы шешәсе.* □ *Ул чагында Бөгелмәдә атлаган саен трактир да, аракы кибете иде.* Г. Әпсәләмов. // *с. мәгъ.* Аракы эшкәртә торган.— *Мин хәзер - - - Петроградта барган вакыйгалар турында аракы заводы эшчеләренә хәбәр итәргә китәм.* Т. Гыйззәт.

◇ **Аракы мичкәсе — алкоголик.**

АРАҚЫЛЫ *с.* Аракысы булган, аракы тутырган. *Ә келәттән тәгәриләр Аракылы мичкәләр.* М. Җәлил.

АРАҚЫЧЫ *и.* 1. Эчкече. *Кем белә, бәлки, ул аракычы ире кулында мәҗбүрилектән генә яши торгандыр.* А. Шамов.

2. Аракы ясаучы. // Аракы белән сату итүче.

АРАЛАУ *ф.* 1. Җыелып торган кешеләрне яки тыгыз булып утырган нәрсәләрне як-якка этәреп юл ачу, ара (1 мәгъ.) булдыру. *Якуб, көчле куллары белән кешеләрне аралап, коридордагы сары ишек янына килде.* И. Гази. *Чикләвек агачларын сакланып кына аралап, тирә-юньгә карадым.* А. Шамов.

2. Сугышып яки бәхәсләшеп торучыларны аеру, сугышудан яки бәхәсләшүдән туктату. // Сугышучылар арасыннан берсен аерып алу, коткару. *Шуңа күрә дә Гаязның мине исереккә исәплән Низамилардан араларга тырышуы миңа бераз тынычлык бирде һәм мин юри башымны исереккә салдым.* М. Әмир. // Нинди дә булса хәлдән йолып алып калу. *Ярый әле, Гайфи әфәнде минем күзләрем турында начальство белән сөйләшеп, сугышка китүдән аралап калды.* К. Нәҗми. // Яклау, кимсетергә бирмәү, кимсеттермәү; үз итү.— *Көчсезләрне аралаган өчен генә «көтүче яры» дип хурлавыңа мин түзә алмыйм, атакай.* М. Фәйзи.— *Әнкәй өчен йөрәгем әрни, моңар күңелемдәге ачу вә нәфрәт катыш бернәрсә туа, әнкәйне аралыйсым вә бар көчем белән берәр сүз кычкырасым килә.* Ш. Камал. *Миңнурый Газинурның күкрәгенә башын куйды һәм, иркәләнеп:— Газинур, син, ичмасам, мине шул Сәлимнән аралар идең,— диде.* Г. Әпсәләмов.

3. Берәр әйберне чит нәрсәләрдән арындыру, тазарту. *Ул учындагы бодайны аралаган булды, өф-өф диде, башын чайкап куйды.* Г. Бәширов. // Орлык, яшелчә, җиләк-җимеш турында: сортларга аеру.

4. Бармакларны чәч, йон, сакал, чук кебек нәрсәләр арасыннан йөртү, уздыру турында. *Ул, бармаклары белән сакалын аралый-аралый, кыз янына килеп утырды.* А. Шамов // Берәр нәрсә өстеннән кулны йөртеп, шуның кисәкләрен, өлешләрен бер-бер артлы урыннарыннан күчергәләү. *Ул, муенсасының гәрәбәләрен аралый-аралый, күз алдында җәелеп яткан киң табигать күренешенә хәйран калып, исе китеп карый иде.* Г. Бәширов.

АРАЛАУЧЫ *и.* Коткаручы, йолучы. *Син килерсеңме аралаучы булып шунда мине?* Һ. Такташ.

АРАЛАШ *рәв.* 1. Аралаштырып. *Елганың уң ягында гелән бодай гына чәчелгән, сул ягында, җирне вак-вак кисәкләргә бүлгәләп, тары, бодай, борай, карабодай, солы кебек төрле ашлыкларны аралаш чәчкән басулар ята иде.* М. Гафури. *Күп кенә районнарда татар һәм рус авыллары яисә татар һәм чуваш-мордва, мари авыллары аралаш салынганнар.* М. Максуд. // Аралашып. *Урман авызында пионерлар белән аралаш, өчәр-өчәр булып тезелгән кече яшьтәге укучы балалар күренде.* Г. Гобәй. // Катнаш. *Дәрес китаплары башка китаплар белән аралаш булганлыктан, аларны алыр өчен Хәсәнгә корзиндагы бөтен китапларны кузгатырга туры килде.* Ф. Әмирхан. [*Алтын кисәкләре*] *тимер рудасы кебек кызгылт тузанга манчылган таш белән аралаш* [*иде*]. М. Гафури.

2. *бәйл. функ.* Билгеле бер вакыт арасы үткән саен кабатлана торган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Марат көн аралаш Казанкага су коенырга йөри.* Т. Гыйззәт.

3. *бәйл. функ.* Икенче бер эш-хәл белән аралаштырылып яки бүлдерелеп башкарыла торган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Сәкегә сузылып яткан Хәлим әнкәсенең сүзләрен йокы аралаш кына ишетә.* И. Гази.— *Син минем сорауга мине шатландырырлык җавап бирергә телисең, әйе бит?—дигәндәй, моң аралаш елмайды ул.* Һ. Такташ. *Без аталы-кызлы кавышырбыз Яшь аралаш көлеп, шатланып.* М. Җәлил. // Нинди дә булса эш-хәлнең, күренешләрнең башка күренешләргә яки эш-хәлгә вакыт-вакыт аралашып, катнашып китүе турында. *Йомшак кына искән салкынча җил аралаш сирәк-сирәк әре яңгыр тамчылары төшә.* Ш. Камал.

Аралаш вакланма *мат.*— санаучысы ваклаучысына тигез яки аннан зуррак булган вакланма.

АРАЛАШТЫРУ *ф.* 1. Катнаштыру, кушу. *Ул, хәтергә төшкән Сәгыйть Рәмиев шигырьләренә үз сүзләрен аралаштырып, бүлмә буенча йөрергә тотынды.* К. Нәҗми. *Сәүдәгәрләр дә көя ашаган - - - тиреләрен, керосин белән майлап, яхшы тирегә аралаштырып сатарга тырышалар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Нинди дә булса эш-хәлне башка эш-хәл барышында кушып, катнаштырып җибәрү. *Кемдер, хатынкыз чырылдавына аралаштырып, яшь тай кешнәгән төсле итеп, озак хихылдады.* К. Нәҗми. // Әйберләрнең берсе арасына икенчесен кыстыру. [*Борһан абзый*] *кул бармакларын аралаштырган да, аш өлгергәнен көтеп утыра.* Ф. Әмирхан.

3. Бутау, болгату, актару. *Ул дәү кулы белән туфракны иркәләп сыпыра, аралаштырып карый.* Г. Бәширов. // Катнаштыру. *Чиксез күп һәм гадәттән тыш зур бозлар бер сәгать эчендә урылмый калган бөтен игеннәрне туфрак белән аралаштырып китте.* М. Гафури.

4. Берсе артыннан берсен кую, чиратлаштыру. [*Хәй*] *егет-кызларны аралаштырып тезә.* М. Фәйзи.

5. Бармакларны чәч, йон, сакал, чук кебек нәрсәләр арасыннан йөртү; *к.* аралау (4 мәгъ.).— *Колхозыбызның хәле, улым,— диде ул, кечкенә сакалын бармаклары белән аралаштырып,— бик күркәм бара.* Г. Әпсәләмов. // Берәр нәрсә өстеннән кулны йөртеп, шуның кисәкләрен яки өлешләрен бер-бер артлы кузгату, күчергәләү, хәрәкәтләндерү. *Ул пианино өстендә бармакларын аралаштырып, ниндидер тавыш табарга азапланa.* Ф. Әмирхан.

6. Карта уенында: бутау, буташтыру. *Гыйльманов*

--- җир идәнгә [шинелен] җәеп килеп утырды да картасын чыгарып аралаштыра башлады. М. Гали.

АРАЛАШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* аралау (2 мәгъ.).

2. Кемнәр белән дә булса очрашып-күрешкәләп тору, бәйләнеш тоту, катнашу. *Бала авылдан читтә, үз ип-тәшләрен күрмичә, алар белән аралашмыйча, тегермәндә яши.* Г. Минский. *Өйләнгәннән соң Мостафин район җитәкчеләре белән якыннан аралашып, кунакка йөрешеп китүдән аеруча саклана иде.* Ә. Еники. // Тыгыз бәйләнеш тоту, бергә-бергә булу. *Бер-берсеннән бер-ике километр җирдә генә яшәгән рус, татар, чуваш яшьләре клубтагы кичәләрендә һәрвакыт диярлек аралашып торалар, бергә уйныйлар, бергә бииләр иде.* Г. Әпсәләмов.

3. Кушылу. *Сепаратор тавышы һәм шуңа аралашып хатын-кыз сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелеп тора.* Ә. Еники. *Мылтык тавышына ат пошкырулары, кемнәрнеңдер соңгы чиккә җиткән ачу белән сүгенүләре аралашты.* К. Нәҗми. // Икенче бер нәрсә белән буталу, кушылу, кушылып китү. *Вак-вак кар чүмәләләре кебек авыл морҗаларыннан чыккан төтен, һавага күтәрелә алмыйча, бәс белән аралашып, җиргә ята.* М. Гали. *Кояш нурлары, агач яфраклары белән аралашып, хәтфә төсле яшел чирәм өстенә матур аксыл бизәкләр чәчеп торалар.* Ф. Әмирхан.

4. Бер-береңне аңлау, фикер алышу. [*Тукай*] *телне иң элек аралашу, аңлашу, тәрбия һәм үсү коралы итеп таныган.* М. Зәкиев.

Аралашу юллары — 1) тимер юл, су юлы, һава юлы кебек бәйләнеш, элемтә, транспорт юллары; 2) *хәрби.* йөрү, бер урыннан икенчесенә чыгу, хәбәр йөртү өчен әзерләнгән тар чокыр. *Алар траншеяларга, аралашу юлларына тулган карны көриләр иде.* Г. Әпсәләмов.

АРА'ЛИЯ *и. бот.* Эре яфраклы һәм себерке сыман чәчәкле куак үсемлек. *Ул миңа тәрәзә төбендәге гөлләрне — кактус, абага гөле, аралия, бегония дип исемнәрен әйтә-әйтә күрсәтте.* Г. Мөхәммәтшин.

АРАЛЫК *и.* 1. Ике нәрсә арасындагы урын, ачыклык. *Фанердан бүлеп эшләнгән, бер үк вакытта кухня булып та саналган бу тар гына аралык, ут янмаганга, караңгы иде.* Г. Минский. *МТМга җитмәс борын бер буш аралык бар.* Ә. Еники. // Авыл өйләрендә мич белән стена арасында калдырылган ачыклык. *Абзардан өйгә әйләнеп керү белән, ул, җәелгән урынга ятмыйча, әле аралыкка барып нидер актарды, әле тула оегын эзләде.* С. Рафиков.

2. *диал.* Ике каралты арасына салынган сарай. *Әнвәр тиз генә тәрәзәдән чыгып аралыкка кача.* Г. Камал.

АРАН *и.* Җылы абзар эчендә бер ат яки сыер өчен киртә яки бура белән бүлеп алынган урын. *Кыз арангa кереп сыерның янбашына учы белән каты итеп сукты.* Ә. Еники. [*Апрель ае*] *ялга куелган атларның, көчләрен кая куярга белмичә, аран агачларын кимерүләрендә дә, --- бөтен җирдә һәм бөтен нәрсәдә үзен күрсәтте.* Ф. Хөсни.

АРАНЖИРО'ВКА *и. махс.* Берәр музыкаль әсәрне башка бер музыка коралы яки икенче тавыш өчен яраклаштыру.

АРАНЖИРО'ВКАЛАУ *ф. махс.* Аранжировка ясау.

АРАТ *и.* Монголия Халык Республикасында: крестьян, хезмәт иясе вәкиле. *Арат хуҗалыкларының зур күпчелеге производство кооперативларына берләшкән.* Иң яңа тарих.

АРАТА *и.* 1. Ике башы махсус беркетелгән аркылы агач. [*Җил капканың*] *араталары таралу хәленә килгән. Өстәвенә, орчыгы да ярылган иде.* Г. Галиев. *Ул урындык аратасын матурлап маташа.* Г. Бәширов.

2. *диал.* Өрлек.

АРАТАЛАУ *ф.* 1. Арата кую, араталы итү.

2. *сөйл.* Ниңди дә булса әйберне икенче әйбергә аркылы кую. *Бер таза егет белән ишекне араталады.* М. Хуҗин.

АРАТАЛЫ *с.* Араталап эшләнгән, арата белән эшләнгән. *Ишек алдында да кызык юк иде. Араталы такта капка, салам түбәле озынчарак абзар. Бүтән әйбер юк.* Г. Мөхәммәтшин.

АРА-ТИРӘ *рәв.* 1. Кайчак, кай арада, кайвакыт, вакыт-вакыт. *Ара-тирә ерактан граммофон тавышлары ишетелә.* Г. Камал. *Нәфисә сөйләгәндә, Мансуров, торган саен ныграк кызыксына барып, ара-тирә аңа күз төшергәләп алгалый.* Г. Бәширов.

2. Анда-санда, урыны-урыны белән. *Ара-тирә кар астыннан чыккан кара җир өстендә --- табан эзләре ярылып яталар.* Ә. Еники.

АРАУ *ф. диал.* Көтү, күрергә теләү. *Ah, чәчәкләр, былтыр, сезне өзеп, Кемнең күкрәгенә кададым, Кемгә кадап, кемгә моңлы карап, Күзләреннән җавап арадым?* Ш. Бабич.

АРА'ХИС *и.* Кузаклылар семьялыгыннан май бирә торган көньяк үсемлеге. *Арахис чәчүлекләре Олы Кытай тигезлегендә һәм Шаньдунда тупланган.* Чит ил. экон. геогр. // Шул үсемлекнең орлыгы.

АРБА *и.* Ат яки үгез җигеп йөк ташый торган дүрт яки ике тәгәрмәчле хуҗалык әйберсе. *Җиңел арба.* □ *Хәлим дилбегәсен арба башына бәйләп куйды да гармонь уйнады.* Г. Гобәй. *Ашлык төягән арбалар шыгырдый, бертуктаусыз яңгыр шыбырдый.* А. Алиш. // Сугыш кырында туп, снаряд ташу өчен файдаланыла торган җайланма. *Хәзер инде барысына да тәбәнәк атларга җигелгән нечкә көпшәле ике пушка белән снаряд арбасы ачык [күренә].* К. Нәҗми.

Арба алды — арбаның төп арбага кендек белән тоташтырыла торган алгы өлеше. **Арба карамалары** — арбаның төбен тоташтырып тора торган, бер яктан икенче якка сыгылып килгән агачлар. **Арба кендеге** — арба алдын төп арбага тоташтырып тора торган озынча юан тимер. *Ул кулына арба кендеге тоткан: торалыгыз, ди, аю күрдегезме әллә?* И. Гази. **Арба күкрәге** — арбаның алгы күчәренә кендек ярдәмендә тоташа торган өлеше. **Арба юлы** — тәгәрмәч юлы, җәйге юл; *киресе:* чана юлы. *Апрель ахырларында, арба юлы төшү белән, Вәли абзыйларга Өчиледән әлеге чыптачы килеп төште.* Ә. Фәйзи.

АРБАЛЕТ *и. тар.* Борынгы ыргыту коралы; укны механик көч белән тарттырып җибәрү җайланмасы.

АРБАЛЫ *с.* 1. Җигүле арбага утырган. *Безнең капкага арбалы кеше килеп туктады.* Г. Тукай. // *и. мәгъ.* Җигүле арбага утырган кеше. *Шәрифҗан абыйлар урамына арбалылар җыелган.* И. Гази.

2. *күч. сөйл.* Нәрсә генә эшләсә дә, хәрәкәтләре җыйнаксыз булу сәбәпле, дөбер-шатыр килеп, бәрелепсугылып, орынып йөри торган кеше турында. [*Кызлар:*] *Камилдер инде, аңардан башка тагын нинди арбалы булсын,— диләр.* Каз. утл. // Шундый кешегә карата тиргәү сүзе.

АРБАЛЫК *с.* 1. Арба ясарга яраклык (нинди дә булса материал).

2. Бер арбага сыярлык.— *Кырда калдырмабыз. Күп булса ике арбалык көлтәсе бардыр.* И. Гази. // *и. мәгъ.* Бер арбага сыярлык итеп куелган көлтә өеме, кечкенә зурат. [*Карчыклар*], *кыштырдый торгач, шактый гына эш эшләп ташлаганнар: кысып-кысып бәйләнгән көлтәләре пөхтә итеп куелган арбалыклар --- тезелешеп-тезелешеп торалар иде.* Ф. Хөсни.

АРБАУ *сөйл.* 1. *ф.* Кемне дә булса үзенә тарту, үз ихтыярына буйсындыру, йомшарту, карату.— *Авылыбызга чибәр-чибәр кешеләр килә. --- Мондагы яраларны ачып салырга өлгермисең, шул ждаһалар [дошман элементлар] арбап өлгерәләр.* М. Әмир. *Ягымлы эндәшеп һәм серле елмаеп Арбадың микәнни син мине шу-*

лай ук? М. Җәлил. *Яманның авызыннан елан чыгар, арбый алмый җаны чыгар.* Н. Исәнбәт.

2. *и.* Тылсымлы сүз, тылсым. *Арбавын белсәң, кара елан да карышмый.* Мәкаль. *Карчыклар тарафыннан яшь киленгә әйтелгән арбауны тыңлап карыйк: — Исән генә килдеңме, балам? Ак күңелдән сиңа арбау салам әле.* Ф. Туйкә.

АРБИТР *и.* 1. Бәхәсләшүчеләрне килештерү эшләрен хәл итә торган арадашчы; третейский судья.

2. Арбитраж (1 мәгъ.) члены.

3. СССРда учреждениеләр, предприятиеләр арасындагы бәхәсле мәсьәләләрне тикшереп хәл итүче хезмәткәр.

АРБИТРАЖ *и.* 1. Бәхәсләрне арбитрлар тарафыннан третейский судта хәл итү. // Төрле бәхәсләрне шундый юл белән хәл итә торган орган. *Фабрика директоры штрафка каршы килеп, арбитражга хат җибәрде.* Соц. Тат.

2. Дәүләтләр арасындагы бәхәсне тыныч юл белән хәл итүнең бер ысулы. *Халыкара арбитраж.*

АРГАМАК *и.* Чабышкы ат. *Атам биргән аргамагым Үргә каршы сөрлегә. Көтеп алган туйлар килә Яшь гомергә бер генә.* Ф. Бурнаш.

АРГЕНТИ'НАЛЫ *и.* Аргентинада туып үскән һәм шунда яшәүче халык, шул халыкның бер кешесе.

АРГО *и. лингв.* Аерым бер социаль төркем кешеләре арасында гына кулланыла торган сүзләр, шартлы тәгъбирләр; жаргон.

АРГОН *и.* Төссез һәм иссез газ; химик элемент (электр лампалары һәм реклама яктырткыч приборлар өчен файдаланыла).

АРГОТИЗМ *и. лингв.* Телдә стилистик алым буларак кулланыла торган арго сүзләр, сүз тезмәләре.

АРГУМЕНТ *и.* Дәлил, нигез. *Баш инженер [Уразгөлгә] нигезле аргументлар китереп куйгач, алар күчеп китәргә мәҗбүр булдылар.* Ә. Айдар. *[Хәлимә] бер-берсен яраткан ике кешене яңадан бәхетле итү өчен юл эзли башлады. Моңа аның үзенең аргументлары бар иде.* Ш. Хөсәенов.

АРГУМЕНТЛАУ *ф.* Дәлилләр китерү, исбат итү, нигезләү.

АРГЫ *с.* Теге, каршыдагы; *киресе:* бирге. *Аргы яктан болыт килә, Яшен яшьнәп, камчылап.* Җыр. *Ишекнең аргы ягыннан акрын гына сөйләшкән бер ир кеше тавышы ишетелә.* Г. Камал.

АРДАК *и. диал.* Кадер-хөрмәт. *Асрадың, әнкәй, син ардакта, ятыр урыным югары чардакта.* Җыр. // Кадер-хөрмәт күргән кеше, кадерле кеше турында. *Утта янып харап булган Илдә кызның ардагы.* Бәет.

АРДАКЛАНУ *ф. диал.* Иркәләнү. *Кемгә ардаклана-сың?* // Кадер-хөрмәт күрү.

АРДАКЛАУ *ф. диал.* Иркәләү, сөю. [*Бакый:*] *Менә ул синең колың! Аны ардаклап куандыра торган яр мин.* М. Фәйзи. // Кадер-хөрмәт күрсәтү.

АРДАКЛЫ *с. диал.* Кадерле, хөрмәтле, газиз. *Ардаклы ир бала. / хәб. функ. Байга мал ардаклы, ярлыга бала ардаклы.* Мәкаль. *Аталы бала ардаклы.* Мәкаль.

АРДАКСЫЗ *с. диал. Кадерсез. Ардаксызның аркасы туза.* Мәкаль.

АРДЫРТУ *ф.* Арыту.— *Бергәләп эшләү ардыртамы соң? Монда көннең үткәне сизелми дә кала.* С. Рафиков.

АРДЫРУ *ф.* Арыту, талчыктыру. *Кичнең әүвәлге караңгылыгы төшә башлап, урамга бертөрле шау-шулы тынычлык һәм күзләрне ардыра --- торган яктылы-караңгылы төс биргән иде.* Ф. Әмирхан.

АРЕ'НА *и.* 1. Төрле номерлар башкару өчен цирк уртасындагы зур түгәрәк мәйдан.

2. *күч.* Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсе. *Яңа җырлар белән аренага яңа кешеләр килде.* Һ. Такташ.

АРЕ'НДА *и.* 1. Бина, җир һ. б. ш. кебек күчми торган милектән вакытлыча хак түләп файдалану. [*Крестьяннар*] *өчләтә түләп бояр җирен арендага алырга мәҗбүр булдылар.* Г. Нигъмәти.

2. Шундый рәвештә файдалану өчен түләү. *Аренданы киметү. / с. мәгъ. Аренда хакларын төрле урында төрлечә билгеләрләр.* Урал.

АРЕ'НДАЛАУ *ф.* Арендага алу. *Күп кенә бәйле илләрдә җирне арендалауда өлешчә эшләп натуралата түләү өстенлек итүче форма булып кала.* Политэкономия.

АРЕНДА'ТОР *и.* Арендага алучы, арендалаучы.

АРЕ'НДАЧЫ *и. к.* арендатор. *«Амур»ның арендачысы Рамазановлар булса да, төп хуҗасы Юнусовлар иде.* И. Рәмиев.

АРЕО'МЕТР *и.* Сыеклыкның тыгызлыгын билгеләү һәм чагыштырма авырлыгын үлчәү приборы.

АРЕСТ *и.* Кулга алу, сак астына алу. *Суд [Шубинны] ике йөз сум штраф илә ике атна арестка хөкем итте.* Ш. Мөхәммәдев.

АРЕСТАНТ *и. сөйл.* Кулга алынган кеше, төрмәгә ябылган кеше, тоткын.

АРЗАН *с.* Кыйммәт түгел, юнь, түбән бәяле, очсыз. *— Мин бит малны үзем тапкан, Арзан бәһагә алган да Яхшы файда итеп саткан.* Г. Камал. *Үткән базардагы хакны сорыйм, Бирмим, имеш, шуннан арзанга.* З. Мансур.

◇ **Арзанга төшмәү (килмәү)** — җиңел булмау, авыргa килү, күп көч һәм энергия таләп итү. [*Контрреволюциягә каршы*] *көрәш арзанга төшми.* Ш. Камал. **Арзан бирү** — 1) аз түләү.— *Дөбьязныкылар [читек өчен] безгә арзан бирәләр.* Ә. Фәйзи; 2) нәрсәне дә булса түбән бәягә бирү, сату. *Мин сиңа квартирны арзан биргән идем.* Г. Камал.

АРЗАНАЙТУ *ф.* Бәясен төшерү, бәясен киметү, юнәйтү, очсызлату.

АРЗАНАЮ *ф.* Бәясе төшү, бәясе кимү, юнәю, очсызлану.

АРЗАНЛАНУ *ф. к.* арзанаю.

АРЗАНЛЫ *с.* 1. Кыйммәт (ле) түгел, түбән бәяле, юнь, очсыз, арзан. *Арзанлы брошка.* □ *Аның башындагы арзанлы, бәйләгән бүрек белән өстендәге иске генә кышлык пальто да ничектер килешле күренә иде.* Ш. Камал. *Ул арада арзанлы номерның начар, кечкенә, пычраграк самовары гөжләп килеп утырды.* Г. Ибраһимов.

2. Күп көч куелмый, җиңел юл белән табыла яки башкарыла торган. *Арзанлы кәсеп.*

3. Нигезсез, нигезе булмаган, буш. *Арзанлы демагогия.* □ *Беркемгә кирәксез арзанлы фикерләргә мисал итеп шул ук югарыда әйтелгән шигырьләрне [алырга мөмкин].* Һ. Такташ.

АРЗАНЛЫК *и.* Арзан булу. *Товарның арзанлыгы.*

АРЗАНЧЫЛЫК *и.* Очсызлык, әйберләрнең арзан, юнь булуы.

АРЗУ *и. иск. кит.* Кызыксыну, кызыгу, дәрт, азарт. *Гаип казна дигән сүз Тудыра һәркемдә бер арзу.* М. Гафури. // Теләк, омтылыш. *Сезнең белән юлыкмакны [күрешүне] күптән арзу кыладыр идем.* М. Акъегетзадә.

АРИ'(ЛАР) *и.* Һинд-Европа телләрендә сөйләшүче халыкларның шартлы атамасы.

АРИО'ЗО *и. муз.* Зур булмаган лирик ария. *Ариозо һәм җыр.*

АРИСТОКРАТ *и.* 1. Аристократия вәкиле, аксөяк.

2. *күч. ирон.* Нинди дә булса сыйныфның яки нинди дә булса төркемнең үзен башкалардан алдынгырак дип исәпләгән кешесе.

АРИСТОКРА'ТИК *с.* 1. Аристократлардан торган, аристократлар өчен булган. *Аристократик җәмгыять.*

2. Аристократларга хас булган. *Аристократик кыланышлар.*

АРИСТОКРА'ТИЯ *и.* **1.** Сыйнфый җәмгыятьтә хаким сыйныф вәкилләре, югары, өстен катлау, аксөякләр. // Нинди дә булса ижтимагый группаның өстен катлавы. *Финанс аристократиясе.*

2. *тар.* Власть башында хаким сыйныфның бер төркем ин югары катлау кешеләре торган дәүләт идарәсе формасы. *Югары катлау греклар үз идарәләрен аристократия дип атаганнар, ул «иң яхшылар власте» дигәнне аңлаткан.* Бор. зам. тар.

АРИСТОКРАТЛАНУ *ф. күч. сөйл.* Кылану, масаю, ясалма рәвештә үзен эре тоту, аристократларча булып кыланчыклану. [*Хәсәнгә*] *мәҗлестә булачак кызыл вә кара күлмәкле студентлар «бу шәкерт тә үзенчә аристократланган булып йөри икән» дип уйларлар шикелле тоела иде.* Ф. Әмирхан.

АРИФМЕ'ТИК *с.* Арифметика белән бәйләнешле, арифметика ысуллары белән чишелә торган. *Арифметик гамәл. Арифметик мәсьәлә.*

АРИФМЕ'ТИКА *и.* Саннар, цифрлар турындагы һәм алар белән эш итәргә, гамәлләр чишәргә өйрәтә торган фән; математиканың төп өлеше, нигезе.

АРИФМО'ГРАФ *и.* Арифметик гамәлләрне механик юл белән башкара торган исәп-хисап машинасы.

АРИФМО'МЕТР *и.* Арифметик гамәлләрне механик рәвештә исәпләп чыгару приборы.

А'РИЯ *и. муз.* Оркестрга кушылып бер генә кеше җырлый торган әсәр: операда геройның сүзен, эчке кичерешләрен, тойгыларын ялгыз җыр аша бирү формасы. *Тугзак ариясе. Илдар ариясе.* □ *— Минем тавыш баритон булмаганга күрә, бу ариягә бөтенләй туры килми.* Ф. Әмирхан. *Җырчылар, ария һәм романслардан үтеп, ансамбльләр һәм опера өзекләре өстендә эшли башладылар.* М. Җәлил.

А'РКА *и. махс.* **1.** Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсәләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме). *Бүлмәнең бер башында тәрәзә, икенче башында кухня миченең аркасы күренеп тора.* Ф. Әмирхан.

2. Көймәләп, дуга сыман итеп ясалган декоратив корылма. *Рим төзүчеләре оста итеп гөмбәз түбәле йортлар һәм аркалар салганнар.* Бор. зам. тар. *Дачаның капкасы шактый зур арка рәвешендә эшләнгән.* Ш. Камал. *Бүлмәне арка белән дә бүлеп куярга ярый.* Г. Коләхметов.

АРКА' [арҗа] *и.* **1.** Гәүдәнең муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы як (хайваннарда, кош-кортларда — югарыгы, сырт як) өлеше. *Сабый юлчының җылы сүз әйтеп, аркасыннан сөеп, битеннән үбеп калырлык эте-нисе булмаса да, изге теләк телэп калган бердәнбер якыны — укытучы Гөлниса апасы булды.* Г. Минский. *Ул кәҗәсенең аркасыннан сыйпап, сөйләнә-сөйләнә өенә таба кереп китте.* Г. Бәширов. [*Песнәкнең*] *аркасы яшел, түше сары, муены кара, яңаклары җете ак.* Г. Гобәй. / *с. мәгъ. Арка сөякләрем дә төне буе сызлады.* Г. Әпсәләмов. // *сөйл.* Киемнең арканы каплый торган өлеше, арты, арттактасы. *Фәйзулла агайның керле аркасы, кара җилкәсе миңа тагын да сөйкемлерәк күренә.* Ш. Камал.

2. Пычак, чалгы кебек нәрсәләрнең йөзенә каршы ягы, кисми торган ягы, сырты.

3. Кулның учка кире ягы, арты. *Хәлим иптәшен кул аркасы белән генә бер якка этеп җибәрде.* Г. Гобәй. *Ул, борынын еш-еш тарткалап, яңаклары буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен кул аркасы белән сыпырып алды.* А. Шамов. // Биялэй һәм перчатканың кул аркасын каплый торган өлеше. *Ул биялэй аркасы белән Николайның беләгенә* [*сукты*]. Ш. Камал.

4. Урындык, диван кебек нәрсәләрнең арҗа **терәп** утыру өчен эшләнгән өлеше, арты. *Ул башын диванның аркасына тери.* Г. Камал. *Мәршидә урындык аркасында эленеп торган мамык шәлен алып, җилкәсенә сала.* Р. Ишморат.

5. *сир.* Арт I (1 мәгъ.), арт як. *Агач башкайлары шаулыйдыр, Аркалардан җилләр искәндә.* Г. Тукай.

6. *диал.* Биеклек, калкулык. *Елгадан үтеп, арыш басуы аша аркага менгәч, кояш та чыкты.* М. Гафури.

7. *бәйл. функ.* **аркада, аркамда, аркаңда, аркасында.** Эш-хәлнең башкарылуына сәбәпче, ярдәмче булган затны, предметны, күренешне белдерү өчен кулланыла. *— Менә синең аркаңда безнең симертүдәге маллар тизрәк көрәйде, безне мактадылар.* А. Расих. *Айлар буенча берга ут астында йөрү аркасында безнең арада шактый җылы бер мөнәсәбәт урнашкан.* И. Гази.

Арка канаты *зоол.*— балыкларның сыртларындагы йөзгече. **Арка мие (желеге)** — умыртка сөяге эчендәге желек. *Арка мие умырткалык каналында ята һәм, цилиндрик бау рәвешендә булып, өстә баш мие белән тоташа.* Анатомия. **Арка сугыш(лы)** — яшьләр уенының бер төре: берәү аркасын куеп иелергә һәм кем сукканын белергә тиеш; белсә — тотылган кеше аркасын куя, белмәсә — үз аркасына суктыруны дәвам итә. *Аулакта инде, билгеле, җырлашасың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың.* А. Шамов. [*Аулак өйдә*] *җыр-такмак әйтү, шаярту сүзләре белән «кул бирешле», «кулъяулык югалтышлы», «арка сугышлы» уеннары уйналалар.* Ә. Рафиков.

◇ **Арка бирү (кую)** — 1) кемгә яки нәрсәгә дә булса арт белән борылу, ана карамау. *Шуннан соң Мәхдүмә тагын да катырак ачу илә: «Мин синең илә сөйләшмим!» — дип, пырлап табынга аркасын бирепутырыйм дигәндә, аз гына табындагы ашны башка кунаклар өстенә аудармады!* Ш. Мөхәммәдев. *Уртага алып балаларын, баш иялэр, куеп арка җил ягына.* Дәрдмәнд; 2) нәрсәгә дә булса каршы килү, ризалашмау; яратмау, өнәмәү; 3) артка чигенү, качу (мәсәлән, сугышта). *Барырмын һәрвакыт алга, сугышта бирмәмен арка.* М. Гафури. **Арка йонын кабарту (торгызу)** — усаллану, ачулану, зәһәрләнү. *Караборын, бу көтелмәгән шәһәр киемендәге кунакларны куркытырга телэп, арка йоннарын торгызып, аларга ташланды.* Һ. Такташ. **Арка кашу** — кыйнау.— *Алпут җиренә ташлана-нитә калсак, бишенче елдагы кебек арканы кашымаслармы?* И. Гази. **Арка кочтырып алу** *этн.*— ата-ана ризалыгыннан башка хатынлыкка алып китү, ябыштырып алу. [*Сәфәргали*] *арка кочтырып алып китәргә әзер иде, ләкин Зәйтүнә* риза булмады. Ф. Хөсни. **Арка кочтыру** — аркага атландырып күтәрү. **Арка кыздыру (киптерү)** — тик яту (тик тору, эшсез яту, эшсез йөрү). **Арка кымыржу (чымырдау)** — нинди дә булса сәбәп белән тәннең чиркаңган кебек яки эсселе-суыклы булу хәле. [*Дилэфрүз турында*] *хис иткәч, Габделбасыйрның аркасы кымыржып китте.* Ф. Әмирхан. *Менә хәзер дошман тау башыннан пулемет белән сиптерә башлар, дигән уйдан аркам чымырдап китте.* И. Гази. **Арка сөяксез** — принципсыз, үзенең төпле фикере булмаган, илэс-милэс (кешегә карата). **Арка таянычы (терәк)** — беренче ярдәмче, ярдәм кулын сузучы.— *Синең киңәшең белән иң ышанычлы саналган ике арка таянычымнан коры калдым.* К. Насыйри. [*Шибай картны*] *--- рус түрәләре дә бөтенләй ташламадылар. Кирәк чакта арка терәк булдылар.* Г. Ибраһимов. **Арка тиресен тунау** — 1) бик нык кыйнау, яру.— *Мин бер дәшмәм, ике дәшмәм, аннан соң, юк, мин синең, тотып, арка тиреңне тунармын.* Ә. Фәйзи; 2) бик нык изү, эксплуатацияләү. *Ул вакыттагы арка тиребезне тунаучы Франс кебек капиталистлар кулында да эшләмибез инде.* Һ. Такташ. **Арка өстенә** — чалкан. *Ул арка өстенә сузылып ятты.* Ш. Камал. **Аркага арка куеп яшәү** — янәшә һәм дус яшәү. *Монда татар, рус, мари авыллары аркага арка куеп яши.* С. Хәким. **Аркадан килеп пычак кадау** — көтмәгәндә һөҗүм итү, уңай моменттан файдаланып һөҗүмгә ташлану (ачыктан-ачык көрәшүгә каршы куела).— *Контрреволюция хәзер иң әшәке чараларга — аркадан*

килеп пычак кадарга кереште. Қ. Нәҗми. **Аркадан сыйпау** — *к.* баштан сыйпау. *Мин дә аның аркасыннан сыйпарга җыенмыйм.* Г. Бәширов. **Аркасына ышыклану** — аркалану. *Элекке шикелле Солтангәрәең аркасына ышыкланыр чакмыни?* Г. Бәширов.

АРКАДАШ *и. иск.* Иптәш, дус. *Уземнең мәктәп аркадашымнан мәктүп алдым.* Г. Газиз. *Минем уемча болай булырга кирәк: борын заманда безнең милләт, үзенең иптәшләре вә аркадашлары булган башка милләтләр илә, фәкыйрь генә, тыныч кына, күңелсез генә яшәгән.* Г. Тукай.

АРКАЛАНУ *ф.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса ярдәменә ышану, таяну.— *Хәзер инде колхозчылар, тракторга бик тә аркаланып, күкрәк киеребрәк йөриләр.* Ф. Хөсни. [*Кияү*]*чыгып керә базарына, Иртүк чәен кайната. Кызым, аңа аркаланып, Юрган астында ята.* Н. Гобәй. // Кемнең дә булса яклавына ышанып, үзен иркен тоту. *Мине яклыйлар. Ә мин, аларга аркаланып, югары оч Рәхимҗанның сүзен тагын тыңламый башлыйм.* Г. Мөхәммәтшин.

АРКАЛАУ *ф. сир.* Аркага күтәрү. *Ул шулай мендәр-фәләннәр аркалап, Алды оҗмахтан шәраблар тартмалап.* Ш. Бабич.

АРКАЛАШ *рәв.* Арканы аркага куеп, аркага арка. *Тар бүлмәнең иң аргы, караңгы мөешендә* [*почмагында*] *бер-берсенә аркалаш ике тоткын нәрсәдер җөйләп утыралар иде.* Қ. Нәҗми.

АРКАЛЫК *и.* Ыңгырчак өстеннән үткәрелеп, ике тәртәне күтәреп бәйли торган каеш бау. *Низами атын тугармаган, тик аркалыгын бушатып, абзар эчендә улакка гына куйган иде.* Г. Ибраһимов.

АРКАН I *и.* Ишеп эшләнгән, бер башы элмәкле озын юан бау. [*Пароходка керү өчен куелган*] *басмалар инде алынган, юеш арканнарның элмәкләрен генә ычкындырасы калган иде.* К. Нәҗми. *Төрле эштә йөри, сабан сөрә, Аркан ишә кайчак колхозда.* З. Мансур.

АРКАН II *с.* **1.** Аркага исә торган, юл уңаена исә торган (җил турында).

2. *рәв. мәгъ.* Арка белән, аркасын куеп. *Разия инде аңа аркан борыла, чәчләрен төзәтә башлый.* М. Фәйзи. *Безнең бакча шәһәр үзәгенә бик якын булса да, ул ничектер калага аркан утырган кебек.* Г. Әпсәләмов. // Аркага яткан хәлдә, чалкан. *Аркан йөзү.*

3. *диал.* Аркылы. *Һаман әле аркан сузылган Шул бәдбәхет минем юлымда.* Ф. Бурнаш.

АРКАНЛАУ *ф.* **1.** Аркан белән бәйләп кую. *Бозау арканлау.* // Гомумән нинди дә булса бау белән бәйләү. // Аркан белән тоту, аулау (мәсәлән, яшь тайларны).

2. *иск.* Аркан тарту, печәнлекне яки басу җирләрен аркан белән үлчәү.

3. *рәв. мәгъ.* **арканлап.** Көчләп, мәҗбүр итеп, айваена карамыйча.— *Без эш белән генә, ашыгыч кына килеп киттек, Мәдинә. Мин иптәшләрне арканлап дигәндәй китердем.* А. Расих.

4. *күч.* Тыю; *к.* авызлыклау (2 мәгъ.).

АРКАНЧЫ *и.* **1.** Аркан ишүче. // Арканнар белән сату итүче.

2. Аркан белән эш итүче вазифасын башкаручы (мәсәлән, пароходларда).

АРКАУ *и.* Тукыманың аркылы җебе. *Ак тулалар тиз керешә Аркау буен тигез эрләгәч.* Җыр. *Аркавын атсаң, буен алырсың.* Мәкаль.

АРКАУЛЫК *и.* Аркау өчен хәзерләнгән, аркау өчен билгеләп куелган материал, җеп.

АРКА-ҖИЛКӘ *җыйд. и.* Арка һәм җилкә бергә.— *Картлык баса ахрысы, җиденче дистәгә атлый башлагач, сиздерә икән ул,— дигәләп, арка-җилкә сызлавы, тыны кысылуы турында зарлангалый башлады ул.* Г. Бәширов.

АРКЫЛАУ *ф. сир.* Нәрсәне дә булса аркылы чыгу, үтү. [*Бүреләр*] *салмак кына, тыныч кына адымнар белән юлны аркыладылар да, читкәрәк китеп, дүртесе дә арт аякларына чүктеләр.* А. Расих.

АРКЫЛУ *ф. сөйл.* Күп булып сибелү, берьюлы күп булып агылу (яктылык, һава дулкыны һ. б. ш. турында). *Кояш чыкты, нур балыкты, тәрәзәдән өйгә аркылды.* Бәет. *Ул буадан арык аркылы Бик күп, бик күп сулар аркылды.* Н. Исәнбәт.

АРКЫЛЫ I **1.** *рәв.* Нәрсәнең дә булса ине, киңлеге буенча; буйны иңгә кисеп үтә торган юнәлештә. *Юллар, террасалардан ерак түгел җирдә, аркылы үтә торган сукмак белән бер-берсенә бәйләнгәннәр.* Ф. Әмирхан. / *юн. килеш. форм.*— *Һаркемнең үз аршыны: теләсә аркылыга үлчи, теләсә буйга.* Р. Ишморат.

2. *с.* Буйны иңгә кисеп үтә торган юнәлештә бер кетелгән, куелган, эшләнгән. *Агачның аркылы кисемендәге бозралар. Кишәрлекнең аркылы үлчәме. Баганада аркылы агач.* // *и. мәгъ.* Иң, киңлек. *Аркылысы буена тиң булу.*

Аркылы балта — балта эшендә ырмау ясау өчен кулланыла торган корал, ырмау алгыч. **Аркылы (га) бүлү** — бер урынны икегә бүлү, аеру. *Зур кижеле кызыл чаршауларның берсен мич алды яныннан каршы стенага тартып, өйне түрдән ишеккә таба аркылы бүлделәр.* Г. Ибраһимов. **Аркылы пычкы** — ике башыннан ике кеше тотып агачны аркылыга кисә торган пычкы. **Аркылы тимер** *сөйл.*— гимнастика ясау өчен җайланма; турник. *Мышкылдашып беткән Хәлим белән Биктәш, герләрне олыларга биреп, үзләре аркылы тимердә мәтәлчек атарга керештеләр.* И. Гази.

◇ **Аркылы төшү (килү)** — 1) кеше сөйләгәннең киресен сөйләү, каршы сөйләү. *Бибинур гел минем сүзгә аркылы төшеп, теңкәмә тия, мыскыл итә.* Ш. Камал.— *Нәрсәдер гел миңа аркылы килеп торасың әле син бүген, хатын?* Ф. Хөсни; 2) нинди дә булса эшкә комачаулау, аяк чалу.— *Бу — илаһи эш бит, туташ. Сезнең юлыгызга аркылы төшәргә теләмим.* М. Фәйзи. **Аркылыга-буйга (аркылысын-буен) гизү (йөреп чыгу)** — бик күп җирләрдә булу, сәяхәт итү. *Баштарак Хәлим малайларга, сез инде миңа иш түгел, мин дөньяның аркылысын-буен гизеп кайткан кеше дияргә телгәндәй, биш сорауга бер генә җавап бирде.* И. Гази. **Аркылыга үсү (җәелү)** — юанаю, тазару. *Күренә, бер бәрәңгедә генә үсмәгән бу кыз, авыр кара эш аны аркылыга җәймәгән.* Ә. Еники. **Аркылыны (аркылы ятканны) буйга салмау** — ялкау булу, бер эш эшләмәү (гадәттә өй тирәсендә). *Гомер буйларына аркылыны буйга алып салмаган кешеләрнең гәүдәләре шулай булмый ничек булсын?* М. Гафури.

АРКЫЛЫ II *бәйл.* **1.** Бер яктан икенче якка кисеп үтү белән бәйләнешле эш-хәрәкәтнең урынын белдерү өчен кулланыла. *Күпер аркылы чыгу.* □ *Безнең урам аркылы ага суның салкыны.* Җыр. *Авыл аркылы кызыл гаскәр үтү халыкны сөендерде: болай булгач, аклар килә алмас инде.* И. Гази.

2. Эш-хәлнең нәрсәнең дә булса бөтен киңлегенә юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Елга аркылы күпер салу. Тайга аркылы юл ачу.*

3. Өстеннән, шуның аша эш-хәрәкәт башкарылган берәр предметны, урынны белдерү өчен кулланыла. *Киртә аркылы сикерү.* □ *Беркөн төнлә койма аркылы ишек алдына кердем.* Ф. Әмирхан.

4. Эш-хәрәкәт булып үтә торган ике нокта арасындагы урынны белдерү өчен кулланыла. *Казанга Арча аркылы кайту.*

5. Нәрсә дә булса үтәли күренә, ишетелә торган, тишеп, ерып, саркып үтә торган һ. б. ш. пространстволы, урынны, предметны белдерү өчен кулланыла. *Стена ар-*

кылы ишетү. Юка кием аркылы җил үтү. Пәрдә аркылы яктылык төшү. Түшәм аркылы су сарку. □ *Әле күптән түгел генә Хөснулланың тәрәзә аркылы күзләрен акайтып карап калуының мәгънәсен Каюм хәзер генә аңлаган төсле булды.* Ш. Камал. *Яңгыр пәрдәсе аркылы чагылган тоныk ут күзеннән башка бернәрсә дә күренмәде.* Г. Минский.

6. Кем яки нәрсәнең дә булса башка зат яки предметны узып, шул заттан, предметтан соң урнашкан булуын белдерү өчен кулланыла. *Минем бала чагымда иң җылы, иң якты, күңелле истәлекләр калдыручылар бездән ике генә йорт аркылы яшәгән Әхтәм бабай белән аның карчыгы Гөләндәм әби булдылар.* Г. Гали.

7. Эш-хәлне башкаруга ярдәм иткән предметны, чараны, җайланманы һ. б. ш. белдерү өчен кулланыла. *Иген орлыкларын триер аркылы уздыру. Телефон аркылы сөйләшү. Хат аркылы хәбәрләшү.* □ *Дөньяда күп нәрсә белдем Син туган тел аркылы.* Г. Тукай. *Билгесезне билгеле цифрлар аркылы белеп була.* Һ. Такташ.

8. Эш-хәлнең башкарылуына сәбәпче булган предметны яки затны белдерү өчен кулланыла: аркасында. [*Музыка Зыяга*] *бер афәт тә кебек, чөнки хәят юлында аның аркылы ничаклы газаплар күргән.* Г. Ибраһимов. *Күп халыклар Мәскәү малы аркылы кеше рәтенә керәләр вә бик күп адәмнәр шул ук Мәскәү малы аркасында морҗадан очалар.* Ш. Мөхәммәдев.

АРКЫЛЫ-ТОРКЫЛЫ **1.** *рәв.* Бер-берсенә аркылы итеп, берсе өстенә икенчесен атландырып. *Гали мулла киткәннән соң, Садыйк хаҗи Нәгыймгә кәгазьгә төрүле, нечкә җеп белән аркылы-торкылы бәйләнгән озынчарак бер төенчек тоттырды.* Ш. Камал. *Аларның тәрәзәләренә, ишекләренә аркылы-торкылы такталар кадакланган.* Г. Гобәй. / *с. мәгъ. Койрык көймәсен аркылы-торкылы бауларга эленгән юеш керләр* [*каплаган*]. К. Нәҗми.

2. Тәртипсез рәвештә, ничек эләкте шулай; төрле юнәлештә, берсе өстенә берсе туры килеп. *Агачлар арасын тутырып аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр.* А. Шамов.

АРЛЫ-БИРЛЕ *рәв.* Әле бер, әле икенче юнәлештә, төрле якка, як-якка. *Каюм, кулына тимер көрәк тоткан килеш, кәбестә түтәлләре арасында арлы-бирле кабаланып йөри.* Ш. Камал. *Сәгать икеләр чамасында урамда арлы-бирле йөргән халыклар күбәя башлады.* Г. Ибраһимов.

◇ **Арлы-бирле сугылу** — нишләргә белмичә аптырап йөрү, эч пошып йөрү. *Малай шунда ук йөгереп чыгып китмәкче иде, түбәтәен таба алмыйча арлы-бирле сугыла башлады.* И. Гази.

АРМА'НДА *и. иск. кит.* Үкенеч белән катыш өмет, теләк. *Бабалар кабере янында күңел зар, Аталар рухының армандасы бар.* Дәрдмәнд.

АРМАТУ'РА *и. тех.* **1.** Нинди дә булса аппарат, машина һәм электр җиһазларының вак приборлары, кирәк-яраклары һәм төрле җайланмалары.

2. Тимер-бетон корылмаларда — корыч каркас, шулай ук нинди дә булса корылманың, төзелешнең ныклыгын арттыру өчен катнаштырыла торган металл частьлар, чыбыклар җыелмасы. *Уңда да, сулда да, ал якта да, артта да биек-биек нефть вышкалары, тавышсыз-тынсыз гына җир астыннан нефть суручы ап-ак фонтан арматуралары тезелгән.* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Арматура хәзерли торган. *Арматура цехы янында эшләүчеләр Шаминга кул болгадылар.* А. Гыйләҗев.

3. *махс.* Корал һәм сугыш киемнәрен сурәтли торган декоратив скульптура.

АРМАТУРЧЫ *и.* Арматура хәзерләүче, коручы яки арматура белән эш итүче. *Балта осталарының, арматурчыларның, ташчыларның бер-берсенә кычкырып эндәшүләре, йөк автомобильләренең тавышлары, барысы бергә кушылып, тәртипсез шау-шу булып һаваға күтәрелә.* А. Шамов.

АРМАТУ'РЩИК *и. сөйл. к.* арматурчы.

АРМЕ'ЕЦ *и. сөйл.* **1.** Армиядә хезмәт итүче гаскәри, солдат.— *Нинди армеец син, шуңарга да түзмәгәч,— диюләре бар.* Г. Гобәй. *Башта Хисмәт гади армеец булган.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Революциягә кадәрге Россиядә: коры җир кораллы көчләре сафында хезмәт итүче.

А'РМИЯ *и.* **1.** Дәүләтнең барлык (коры җир, диңгез, һава) кораллы көчләре. *Шакир Ватан сугышының беренче көннәрендә үк армиягә алынды.* Г. Минский. // *с. мәгъ.* Армиягә мөнәсәбәтле. *Армия штабы, моннан берничә көн элек, саклыкны арттыру турында лазаретка аерым хәбәр иткән иде.* А. Шамов. // *с. мәгъ.* Армиядәге. *Алар үзләре озын солдат юлын узган кешеләр булып, армия тормышы белән гаять кызыксыналар.* Ә. Еники.

2. Диңгез һәм һава кораллы көчләреннән аермалы буларак, коры җир гаскәре. *Армия һәм флот сафындагы күпчелек большевикларны яклый.* К. Нәҗми.

3. Бер яки берничә төрдәге хәрби корпуслардан яки дивизияләрдән торган берләшмә. *Беренче атлы армия. Ленинград фронты армиясе.* □ *Буденныйның атлы армиясе* [*акларны*] *камап алып кырып бетергән дә, алар Кырымга чигенә алмыйча калганнар.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Нинди дә булса гомуми эш буенча берләшкән күп халык төркеме. [*Фәхри*] *безнең --- каләм армиясенең беренче коммунары иде.* Г. Ибраһимов. *Социализм армиясенең язучылары менә шушы мәсьәләгә* [*социалистик милекнең изгелеге мәсьәләсенә*] *төп игътибарларын бирергә тиешләр.* М. Җәлил. // Бер урында җыелып, тезелеп торган бик күп бер төрле нәрсәләр турында әйтелә. *Сансыз тезелеп киткән рельслар өстендә сансыз вагоннар армиясе кала.* Г. Гали.

А'РМЫЙ-ТА'ЛМЫЙ *рәв.* Тырышып. *Армый-талмый эшләгәндә, һәр теләккә ирешелә.* М. Гафури. // Бертуктаусыз, өзлексез. *Ул артык кызу темп белән эшләмәсә дә, армый-талмый бертоташ озаклап һәм пөхтәләп эшләп утыра ала иде.* М. Гали. *Алар армый-талмый һаман көнчыгышка таба барсалар да, олы юлга чыгарга җөрьәт итмәделәр.* Ә. Еники.

АРПА I *и.* **1.** Орлыгы ярма, сыра һәм фураж хәзерләүгә файдаланыла торган башаклы үсемлек. *Печән артына ялганып ук арыш, арпа да кибә һәм бодайлар да сарган башладылар.* Ш. Камал. *Солдат юл буендагы арпа чүмәләләренә, борчак өемнәренә күз төшереп ала.* Г. Бәширов.

2. Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. *Капчыкта әллә арпа, әллә бодай иде.* Г. Гобәй. // *с. мәгъ.* Шул орлыктан эзерләнгән. *Арпа ярмасы.*

Арпа кикрик — арпа башагы кебек җәелеп торган зур кикрик.— *Шушы гөнаһ шомлыклары дөньяны корытып бетергәннәр икән,— дип, бер аягыннан тотып, арпа кикрикле ак әтәчне чыгарып бирде.* М. Гали. **Арпа суы** — сыра. *Бәгъзысына мал киләдер Бохарадан, Хивадан; «Арпа суы файдалы» дип, җибәрәләр ул пиводан.* Ш. Мөхәммәдев.

АРПА II *и. мед.* Күз кабагындагы май бизләренең эренле ялкынсынуы. [*Мәрфуга апа күзләренең*] *икесенә дә арпа чыгар да, кеп-кечкенә булып калырлар.* Ф. Әмирхан.

АРПАГАН *и. бот.* Кыргый арпа.

АРСЕНАЛ *и. хәрби.* **1.** Сугыш кораллары һәм хәрби кирәк-яраклар склады. *Арсеналдан Калединга җибәргә хәзерләнгән ун мең винтовканы хәрби революционный комитет җибәртми калдырган.* Ш. Камал. *Армиянең үз арсеналы да булдырылып килә. Арсеналда берничә дистә мылтык, кул гранаталары, хәтта* [*пулемет та*] *бар.* Н. Дәүли. // *күч.* Запас турында. [*В. Мессинг:*]

Минем һөнәрләр арсеналында үземне каталепсия хәленә китерә алу сәләте дә бар. Соц. Тат.

2. *иск.* Сугыш кораллары һ. б. кирәк-яраклар хәзерли, ремонтлый торган учреждение. // *иск.* Сугыш кораллары музее.

АРТ I *и.* 1. Пространствода: күз караган якка капма-каршы як; *киресе:* ал. *Ул, ни эшләргә белмичә, артка-мы, алгамы атларга аптыраган минутта, әллә кайдан шунда бер күләгә ясалды.* Г. Ибраһимов. *Безнең артта зур-зур ике пароход күренде.* Ф. Әмирхан. // *с. мәгъ.* Арттагы, арткы, артта торган. *Казарма белән бараклның арт ягыннан шахтерларның салмак кына адым белән эштән кайтулары күренә.* Ш. Камал. *Куе кара чәчле, кызыл битле бер бәндә өйалдыннан атылып чыкты да арт якка сызды.* Г. Бәширов.

2. Кеше гәүдәсендә һәм аның киемендә: арка ягы; *киресе:* ал. *Арты белән борылган арада шәленең салынып торган озын чуклары арасыннан толым очлары күренеп-күренеп китә.* А. Шамов. *Зурлар кебек, кулны артка куеп, йөри идек таптап болынны...* Һ. Такташ. *— Үзләре, бичаралар, кия дә белмиләр икән: ал ягын --- артка, арт ягын алга киеп куйганнар!* Ф. Әмирхан.

3. Хайван гәүдәсендә: баш ягына капма-каршы як, артсан. *Ат артын сикертеп чаба.* // *с. мәгъ.* Хайван гәүдәсендә һәм арба кебек нәрсәләрдә: арткы, арттагы. *Икенче яктан арбаның арт тәгәрмәчләре күренеп тора.* А. Әхмәт. *Караңгы абзардан көн яктысына чыккан айгыр, арт аякларына басып, үрә торырга --- ашкына иде.* Г. Әпсәләмов.

4. Нәрсәнең дә булса ал ягының каршысындагы өлеше, арткы өлеше. *Мин, кинәт канатланып китеп, кузлага сикереп менеп утырдым, алар чана артына --- утырдылар.* А. Шамов. // Урындык, диван һ. б. ш. нәрсәләрнең арка терәп утыра торган өлеше. *Мостафин гажәпләнеп хәтта урындыгы артына ауды.* Ә. Еники.

5. Берәр каралтының, өй, абзар-кура кебек нәрсәләрнең ишеге, капкасы урнашкан ягына каршы як. *Сәхнә артыннан мылтык тавышы ишетелә.* А. Әхмәт. [*Шәйбәк*] *аклар качкан яктан, контора артыннан килеп чыкты.* Г. Ибраһимов.

6. *гади с.* Кеше гәүдәсенең арка ягындагы билдән түбән (йомшак) итчел урыны, утыра торган әгъзасы. *Хатын фырт кына артын борып кереп китте.* А. Гыйләҗев. *Ул — юлбасар* [*самурай*], *төнлә кереп баса, Кайда тын һәм кайда караңгы. Тик артына типкәч итек белән, Кая керер тишек табалмый.* М. Җәлил.

7. *күч. рәв. мәгъ.* **арты(нда).** Кемнең дә булса үзе булмаган вакытында. *Аның исеме Агзаметтин, ләкин аны үз артында бөтен авыл халкы Аждаһеттин дип атый.* А. Шамов.— *Хет алды, иптәшләр, хет арты, минем сүзем бер генә: уңмадык председательдән, уңмадык.* Г. Бәширов.

8. Узган, үткән юл. *Артта хуш исле үләннәр, Сафсаф булып, дулкынланып, Җиргә ятып калалар.* Ә. Исхак.

9. Тәртип белән тезелгән сафларның соңгылары, ахыргылары. *Артта утыручылар, тегене якыннанрак күрү, якыннанрак сүзен ишетү өчен, алгарак үтмәкче булдылар.* М. Гали.

10. *бәйл. функ. тарт. форм.* **арты.** Берәр эш-хәлнең, күренешнең һ. б. эзлекле рәвештә икенче эш-хәл, күренеш һ. б. белән алмашынуын белдерү өчен кулланыла. *Сүз арты сүз китү.* □ *Шулай итеп, безнең көннәр берсе арты берсе үтә баралар.* М. Гали. *Яңгыр арты булуга карамастан, һава җылы.* Г. Әпсәләмов.

11. *бәйл. функ. юн. килеш. форм.* **артына.** 1) хәрәкәтнең предметның арткы ягына, арткы өлешенә юнәлгән белдерү өчен кулланыла. *Китап диван артына төшү.* □ *Мин, кечкенә бер агачлыкны сикереп үтеп, юлым өстендә торган җәенке карама артына барып лостым.* А. Шамов; 2) берәр төрле эш башкарганда кем дә булса янына урнашкан предметны белдерү өчен кулланыла. *Өстәл артына утыру. Штурвал артына басу.*

12. *бәйл. функ. чыг. килеш. форм.* **артыннан.** 1) эш-хәлнең ераклашучы зат яки предмет ягына таба юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Чигенүче дошманны артыннан куып китү.* □ *Мин дә аның артыннан китәрмен, күрә-күрә барырмын.* Ф. Әмирхан. *Әпипә* [*Тимери*] *артыннан кашын җыерып карап калды.* Г. Бәширов; 2) берәү башкара торган эш-хәлгә икенче берәүнең кушылып китүен, шундый ук эш-хәл башкарырга керешүен белдерү өчен кулланыла. *Көйне бик тиз отып алып, ул иптәшләре артыннан җырга кушылды.* Г. Әпсәләмов; 3) бер эш-хәлнең, күренешнең, затның, предметның эзлекле рәвештә икенче эш-хәл, күренеш, зат, предмет белән яисә бер затның эш-хәрәкәте икенче берәүнең эш-хәрәкәте белән алмашынуын белдерү өчен кулланыла.— *Менә печән җитә, аның артыннан урагы куып килә.* Г. Бәширов. *Әтиләр дә --- хат артыннан хат тупырдатып торалар.* Ф. Хөсни; 4) берәр максатка юнәлтелгән эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Байлар һаман комсызлыктан туймый иде, Акча артыннан чабуын куймый иде.* М. Гафури; 5) аркылы, аша.— *Егет* [*өч көн элгәре*] *Айбала җиңгәм артыннан хәбәр иттергән.* Г. Ибраһимов.

13. *бәйл. функ. у.-вак. килеш. форм.* **артында.** Предмет яки затның предметның күренми торган арткы өлешендә, арткы ягында булуын яки эш-хәлнең шундый урында баруын белдерү өчен кулланыла. *Хат көзге артында саклана. Шкаф артында яшеренеп тору.* □ *Шушы көннәрдә алар урман артында, Батурин авылы янында, бүреләр күргәннәр.* Г. Әпсәләмов.

Арт очлыклар — аяклар. **Арт чүмеч** — башның арткы өлеше. *Сарим аптыраулы кыяфәттә арт чүмечен кашып алды.* С. Рафиков.

◇ **Арт аяклары белән тәпиләп тору** — ялагайлану, тәлинкә тоту. *Сүзем авыр булмасын, мәрхүм гел байлар тирәсендә арт аяклары белән тәпиләп тору, ярлыларны --- йөдәтүдән башканы белмидер иде.* Ш. Камал. **Арт бирү** — 1) нәрсәгә дә булса күңел бирмәү, игътибарсыз калдыру, салкын карау. *Кызык кына бу Гөлсем, шул Әмин тәэсиредерме. Йорт дими, ни дими, барысына да арт биргән.* Каз. утл.; 2) бизү, читләшү. **Арт сабагын укыту (өйрәтү, тыңлату)** — 1) кыйнап, җавапка тартып һ. б. ш. юллар белән җәза бирү. *Хәзер ул мәртәтнең арт сабагын укыта башлаганнар ди инде.* А. Әхмәт.— *Арт сабагыңны тыңлатырга хәзер кыйбат алмам.* А. Шамов; 2) к. күрмәгәнен күрсәтү— *Мин клубта да шулай әүвәл бераз оттырам, ә аннан соң арт сабакларын укытам.* Ф. Әмирхан. **Артка китү** — начарлану. *Галимә апаның хәле көннән-көн артка китә.* М. Гафури. **Артка (артта) калу** — 1) эш начарлану, эш барышы начар булу, башкалардан калышу. *Чулпанның бер-ике көн эчендә шулкадәр артка калуы бер Тимерине генә борчымый иде.* Г. Бәширов; 2) надан калу, тормыш таләпләренә җавап бирерлек хәлдә булмау.— *Ансы зур бәла түгел, тормыштан артта калуың бәла.* А. Әхмәт. *Халыкның артта калган күпчелек өлеше, байлар, куштаннар һәм муллалар коткысына бирелеп, яшьләрне көкем итә.* М. Җәлил. **Артта тору** — 1) исемлектә яки сафта иң артта булу; 2) икенче планда булу, игътибар үзәгендә булмау.— *Акча теләнүдән башка эшләре юк, намаз-нияз, дин-диянәт артта тора, бары акча. Акча гына бир аларга.* Ш. Камал. **Арты белән тору** — 1) тискәреләнү, киреләнү, җайга килмәү; 2) тормыш турында: һәрвакыт каршылыклы булып, авырлыклар китереп тору. *Тормыш Сибайга гел арты белән генә торды.* Г. Бәширов. **Артына төшү** — эзәрлекләү, үч алу, акылга утырту. *Андый-мондый артык сүз сөйләсә, Тиз төшәләр аның артына.* М. Крыймов.— *Дәүлигә юк-бар сүз катып, әллә нинди адәм ышанмас-*

лык ялалар ягып йөрсәләр, артларына төшәр Дәүли. Зәмирнекеләр диләр аны. М. Гали. **Артыннан бару (иярү)** — 1) кемнең дә булса юлдашы, фикердәше, тарафдары булу. *Мәхмүтләр артыннан барсаң, шулай булыр.* Ш. Камал. *Кеше артыннан иярсәң дә, белеп ияр.* М. Гафури; 2) кемнән яки нәрсәдән үрнәк алу. *Ул шәһәр артыннан барып авылның кайчан да булса бервакыт кырларында тракторлар шаулавына ышана.* Г. Нигъмәти. **Артыннан йөрү (чабу)** — 1) нинди дә булса эшнең хәстәрен күрү.— *Тукта әле, кем туе артыннан йөри соң ул?* А. Шамов.— *Азык кытлыгыннан чыгасың килсә, кырчылык бригадаларына салынып торма, үзең башлап артыннан йөр.* Ә. Еники; 2) нинди дә булса эш башкару.— *Аягы юк дигәнем шушы инде— яман эш артыннан йөрмәде.* М. Фәйзи; 3) кемне дә булса яратып, үзенә каратырга йөрү. [*Сания Маратка:*] *Моннан соң минем артымнан йөрисе булма, сабагыңны тырышып укы.* Т. Гыйззәт.— *Яшермим, аның артыннан йөрергә теләүчеләр дә аз булмады.* А. Шамов. **Артыннан тере саескан очыру** — алдау, ялган сөйләү. [*Гаяз, аучы турында:*] *Ул бүрәнә аркылы бүре күрә. Артыннан тере саескан очыра ул.* М. Әмир. **Артыннан куу** — нәрсәгә дә булса артык игътибар итеп, башкаларын читтә калдыру. *Сүз артыннан куу.* □ [*«Качкын»да*] *тышкы эффект артыннан куулар, урынсыз кабатлаулар, плакатчылык элементлары* [*күп*]. М. Җәлил.— *Сан артыннан гына кума, сыйфат турында да кайгырт.* Р. Ишморат.

АРТ- II Кушма сүзләрдә «артиллерия» мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **артбаза, артдивизион, артполк.**

АРТЕЗИАН *с.* Тирән су катламыннан килә торган һәм табигый басым астында булган; зур тирәнлектәге. *Артезиан сулары.*

Артезиан коесы — суы җир астыннан труба буйлап үз басымы белән күтәрелә торган кое. *Имәнлек башында артезиан коесын әле генә казып яталар.* Х. Сарьян.

АРТЕЛЬ *и.* 1. Нинди дә булса һөнәр, профессия кешеләренең гомуми җаваплылыкны өсләренә алып бергә эшләү һәм табышны уртаклашу турында килешеп оештырылган берләшмәләре. *Балыкчылар артеле. Артель уставы.* □ *Аптырагач, болардан аерылып, җиде йорт бергә оешып, артель төзергә булдык.* Ш. Камал. / *с. мәгъ. Курыкма, бездә артель акчасы бар.* Һ. Такташ.

2. *гади с.* Нинди дә булса бер максат белән җыелган халык төркеме. *Шул мунчада егерме кешелек бер артель юынып чыкканчы, башкалары салкында көтеп торалар.* М. Гали.

АРТЕЛЬДӘШ *и.* Кем белән дә булса бер артельдә эшләүче, бер артель кешесе. *Шулай да артельдәшләрем республикабызның иҗат шәһәрен шактый яхшы белә-ләр.* Қ. Басыйров.

АРТЕЛЬЛӘШҮ *ф.* Артельгә берләшү.

АРТЕЛЬЧЕ *и.* 1. Артель члены. [*Асадуллин*] *артельчене чакыртып менгезде.* С. Сабиров.

2. Артель өчен җаваплы кеше, артель башлыгы.

АРТЕ'ЛЬЩИК *и. сөйл. к.* артельче. *Гариф үзенең артельщик булып китүенә шактый аптырый һәм көләсе килә иде.* Ш. Камал. // Артельнең яки нинди дә булса төркемнең тукланыш оештыручы кеше. *Ул арада артельщик — солдат аркасына капчык белән сохари күтәреп керде.* М. Гали.

АРТЕРИАЛЬ *с.* Артериягә (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле. *Артериаль кан.*

АРТЕРИОСКЛЕРОЗ *мед.* Артерия стеналарының калынаюы һәм катыланыуыннан гыйбарәт (хроник) авыру. *Артериосклероз, гипертония һәм инфаркт миокарда кебек авырулар килеп чыгуына инфекция генә түгел, хезмәт, ял, тукланы һ. б. ның элементар кагыйдәләрен бозу да сәбәпче була.* Соц. Тат.

АРТЕ'РИЯ *и.* 1. *анат.* Йөрәктән чыккан канны тәннең бөтен әгъзаларына тарата торган калын стеналы кан тамыры.

2. *күч.* Әһәмияте зур булган бәйләнеш юлы. *Төньякның бердәнбер тормыш артериясе булып Киров тимер юлы сузыла.* Г. Әпсәләмов.

АРТИКЛЬ *и. лингв.* Кайбер телләрдә грамматик исемнәрнең родларын аеру өчен сүз алдында килә торган кисәкчә.

АРТИ'КУЛ *и.* 1. *кит. иск.* Закон, договор, боерык, карар һ. б. ш. кебек язмаларда аерым параграф, статья.

2. Товарның, эшләнгән әйберләрнең төре, тибы.

АРТИКУЛЯЦИОН *с. лингв.* Артикуляциягә мөнәсәбәтле. *Авазның артикуляцион үзгәреше.*

АРТИКУЛЯ'ЦИЯ *и. лингв.* Сөйләмдә теге яки бу авазны әйткән вакытта сөйләү органнарының торышы, хәле.

АРТИЛЛЕРИСТ *и.* Артиллериядә хезмәт итүче гаскәри; тупчы. *Ул герман сугышында да, гражданнар сугышы вакытында да артиллерист булган.* М. Гали.

АРТИЛЛЕ'РИЯ *и.* 1. Төрле конструкцияле һәм төрле калибрлы утлы ату кораллары. *Авыр артиллерия. Үзйөрешле артиллерия.* □ *Яктыра башлау белән, рус гаскәрләре берничә чакрымнарга сузылган фронт буйлап* [*дошманга*] *каршы артиллериядән ут ачтылар.* М. Гали. / *с. мәгъ. Кайдадыр якында гына артиллерия атышы башланды.* Ә. Еники. *Янгын шрапнель вагоннарына, аннан артиллерия складларына күчте.* Қ. Нәҗми.

2. Шундый кораллар белән эш итүче гаскәр төре. *Артиллериядә хезмәт итү.* □ *Мин артиллерияне яратам, артиллериядән китәсем килми.* М. Җәлил. *Сугышта ул артиллерия командиры булган.* Г. Бәширов.

3. Утлы ату коралларының төзелеше һәм алардан файдалану турындагы фән.

АРТИСТ *и.* 1. Сәнгать әсәрләрен халык алдында башкаручы (актер, җырчы, музыкант һ. б.).— *Синең талантың йомылып ята, аны үстерергә кирәк, синнән зур артист чыгуы мөмкин, диләр.* Г. Бәширов. *Артист өчен телнең үзенчәлекләрен нык төшенү һәм үзләштерү иң кирәк шартларның берсе.* М. Җәлил.

2. *күч. сөйл.* Берәр эштә зур һөнәр иясе, нинди дә булса эшне бик оста башкаручы.

3. *күч. гади с. шаярт.* Бик кыланчык һәм уенчак кеше турында.

АРТИ'СТКА *и.* Хатын-кыз артист. *Кара хәтфә чалътолы, ак мамык шәлле яшь кенә артистканы сугышчылар кул чабып каршы алдылар.* Г. Әпсәләмов.

АРТИСТЛАНУ *ф. сөйл.* Артистларча кылану, үзеңне ясалма тоту. *Чыгып сөйләүчеләр — заводның инженерлары, эшчеләре, бер дә артистланмыйча, үзләренең әйтергә теләгән фикерләрен --- тыңлаучыларга җиткерергә тырыштылар.* Ә. Еники.

АРТИСТЛА'РЧА *рәв. сөйл.* 1. Бик яхшы белеп, оста.— *Нәкъ артистларча булды бу, Сәлим абзый.* Ш. Камал.

2. *күч. гади с.* Сәхнәдә уйнаганча, ясалма.

АРТИСТЛЫК *и.* Артист булу. *Г. Камалның, драматурглык, шагыйрьлек һәм артистлыктан тыш, сәнгатьнең башка* [*өлкәләренә караган*] *хезмәтләре дә бар.* М. Гали.

АРТКУРА *җый. и.* 1. Абзар, келәт һ. б. каралтылар барысы бергә.

2. *күч.* Бай йортының хезмәтчеләр тору өчен эшләнгән алачыклардан гыйбарәт урыны. *Кайчандыр үзенең беркатлы, күңелле табигате белән бөтен арткурага ямь биреп торучы --- акыллы кызны, Нәсимәне, ул беренче күрүдән үк ошаткан иде.* Қ. Нәҗми.

АРТКЫ *с.* Арттагы. [*Бәдретдин*] *атны олы юлдан уңга каерды да --- иң арткы урамга таба алып китте.* Ә. Еники.

АРТЛЫ *с.* Арка терәп утырылык итеп эшләнгән, арты булган. *Артлы урындык.* □ *Председатель артлы чанада кабартып салынган печән өстендә кукыраеп утыручы елтыр күзле кешегә якты елмаеп өстәп куйды.* М. Әмир.

АРТРИТ *и. мед.* Буыннарның ялкынсынуы.

АРТСАН *и.* Түшкәнең билдәмә һәм арт ботларыннан торган өлеше.

АРТТАКТА *и.* Киемнең арканы каплый торган өлеше. / *с. мәгъ.* [*Бу сезонда*] *иркенәйтелгән арттакталы күлмәк модалы дип исәпләнә.* Соц. Тат.

АРТТАЛЫК *и.* 1. Артта булу, артта калу (эштә һ. б.).

2. Наданлык.— *Анысы белән син, карчык, артталыгыңа барасың. Йөргән, дөнья күргән кешегә хәзер бөтен җирдә туган ил.* Ф. Хөсни.

АРТТЫРУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса сан, күләм, көч, тизлек һ. б. ш. яктан артык итү, күбәйтү, өстәү. [*Автор*] *халык шигырендә кайбер күренешләрне кимету, кайберсен арттыру аша аның үсешен күрсәтеп китә.* Г. Нигъмәти. [*Норманы*] *кайсы йөз егермегә тутыра, кайсы йөз илледән дә арттырып җибәрә.* Г. Бәширов. // Бәя һәм хезмәт хакы турында: күтәрү. *Алмачы шундук бәяне арттырды.* И. Гази. *Мастеровойлар* [*эш хакын*] *арттыруны сорап эш ташлаганнар.* Т. Гыйззәт.

2. Дәрәҗәсе, көче, интенсивлыгы ягыннан зуррак итү, үстерү; көчәйтү. *Данын арттыру. Кызыксынуын арттыру.* □ *— Наданлыкны бетерербез, белемнәрне арттырырбыз, яшьләрне яңа тормышка өндәрбез.* Ф. Бурнаш.

3. *сөйл.* Берәр хәлне, вакыйганы сөйләгәндә (язганда) үзеннән өстәп, күпертеп сөйләү (язу). *Юк ла, хәзрәт, азрак арттырасың инде, хатыйп кына бугай (анда).* Г. Ибраһимов.— *Ихтимал, аларның кайберләре арттырып та әйтелгәндер.* Ә. Еники. // Билгеле бер чиктән, чамадан читкә чыгу. *Аның белән бераз шаярып сөйләшергә ярый. Ләкин арттырыбрак җибәрсәң, аның кәефе китә.* Ш. Камал.

4. Нәрсәдән дә булса өлеш чыгару, үзеңә дигәнне беркадәр бүлеп бирү. *Өйнең бер бүлемендә Хаҗиның тол сеңелесе — Гыйззениса карчык үзе тора, икенче бүлемен, хаҗиның эше тыгызга терәлгәч,* [*Садыйкка*] *арттырган иде.* Ш. Камал. *«Өч булса да, дүрт булса да — берсен дә үзеңнән арттырасың килми»,— диде Бибиганбәр абыстай, улына карап.* М. Гали.

5. Өстәмә табыш, керем булдыру; янга калдыру, экономия ясап файда итү. *Тагы берничә атналар эшләгәч, ике йөз тәңкәне тутырып, аның өстәвенә юллык, өйгә вак-төяк бүләклек тә арттырдым.* Г. Ибраһимов.

6. *сөйл.* Кылтаю; масаю.— *Шунда ук мактамакчы идем үзеңне, арттырып җибәрә башларсың дип курыктым.* М. Әмир.

АРТУ *ф.* 1. Нәрсәнең дә булса саны, күләме, үлчәве күбәю. *Табигатьнең иркен күкрәгендә мәңге көрәш, Мәңге хәрәкәт, Мәңге туу, Мәңге артып тору белән бергә үлем — һәлакәт...* Һ. Такташ. *Хат яз, ничек, әле дә элеккедәй саумы улыгыз, һаман артамы?* М. Җәлил. // Өстәлү. *Әгәр Сәмигулла абзый чәй янына чәй чәйнеккә салынмас борын чыкса, Маһитап абыстайның башына бер мәшәкать арта иде.* Ф. Әмирхан. *Айсылуның бу картка торган саен ихтирамы арта бара, ил кайгысын шулай чын күңелдән кайгыртуы аңа аеруча ошый иде.* Г. Бәширов. // Бәя һәм хезмәт хакы турында: күтәрелү. // Артымлы булу. *Юк, бәбкәм,— ди карчык,— тары ярмасы сөттә җитмеш җиде кисәккә ярыла бит ул, бик арта ул.* И. Гази.

2. Көчәю. *Аның авыруы бетү урынына арта барды.* М. Гафури. *Аларны тыңлаган саен, күңелне хәвеф басты, башта кайгы артты.* Г. Минский.

3. Кемнән яки нәрсәдән дә булса калу, кирәгеннән артык булу. *Ашлыгым барыбер үземнән арта.* М. Җәлил. *Ул кичә Корбангали картка квартира һәм ашаган өчен акча түләде, шуннан җиде сум акчасы артып калды.* Ш. Камал. // Кирәкмәс дип табылу, ташлану.— *Менә хәзер минем кулымда кемнәндер арткан, ташланган икмәк кисәге түгел, ә күпереп торган, йоп-йомшак, җып-җылы икмәк булса иде.* А. Әхмәт.

4. Сан, ел, яшь һ. б. ш. исәбе турында: узып китү, үтеп китү.— *Тукта, син кайчан дөнья көтә башларга әйтәсең, яшең утыздан артты.* Г. Ибраһимов.— *Кровать, урындыкларың үз урынында торып торсыннар, саткан тәкъдирдә дә аларның акчасы бер кәҗә хакыннан күп артмас.* Ш. Камал. *Минем бу җиргә аяк басуыма сиксән елдан артып китте инде.* Г. Бәширов.

АРТЧА *и. этн.* Тукыма кисәгенә берничә рәт тәңкә тезеп ясалган, хатыннарның чәченә тагыла торган бизәү әйбере; тезмә.

АРТЪЯПМА *и. этн.*— хатын-кызларның баш киемена ялгап эшләнгән һәм чәч толымын каплап тора торган бизәү әйбере. [*Музейда*] *көмеш җеп белән үрелгән маңгай бизәге дә, --- сәйләп тезеп ясалган артъяпма да бар.* Соц. Тат.

АРТЫК *с.* 1. Кирәгеннән яки билгеләнгәннән артып киткән, артып калган. *Артык игеннәрен, артык сыерларын кызыл гаскәрләргә биргән крестьян агайлар советка килгән саен аның йөзенә карыйлар.* Һ. Такташ. / *и. мәгъ. Артыгын алгансың.*

2. Кирәксез, хаҗәте булмаган, булуы мәҗбүри түгел. *Без, артык нәрсәләребезне ташлап калдырып, елганы кичтек.* А. Шамов. // Кылмәве, булмавы яхшырак булган (кеше турында). *Үзен монда артык кеше итеп сизү.*

3. *рәв.* Бик, бик нык, чамасыз, чамадан тыш. *Кояш бүген артык юмартланган, Күз чагыла көчле яктыда.* М. Гафури. *Мин җир өстен артык сөйдем бугай, Артык сөйдем аның гөлләрен.* Һ. Такташ. // Әйтерлек, сизелерлек, әллә ни. *Ул киткәннән соң артык үзгәрешләр булмады.* Ш. Камал.

4. *рәв.* Күп, күбрәк.— *Атларга бер солы көлтәсен артык биргән өчен дә ул дөнья чаклы тавыш куптара торган иде.* Г. Ибраһимов.— *Ни өчен ул болай хәйләли, әллә миннән артыграк алмакчы буламы икән? — дип уйладым мин эчемнән.* А. Шамов. / *и. мәгъ.*— *Шуннан артыгы безнең кулдан килми инде.* Г. Камал.

5. *рәв.* Өстен, югары. *Мин сине өзелеп сөйдем, күз нурым, җаным нан артык күреп сөйдем.* Г. Бәширов. *Аларның һәркайсы үзен Сафадан артык күрә иде.* А. Шамов. // *хәб. функ.* Яхшы, яхшырак. *Менә бу сахра байларның сараеннан артык миңа.* М. Фәйзи. *Һәркайчан тик тор, берәр ахмак адәм суз сөйләсә, Бел, аңа суз кайтарудан тик тору артык лабаса.* Ш. Бабич.

6. *рәв.* Башкача, яңадан; кабат. *Чәй эчкән вакытта шинель белән итекләр мәсьәләсе артык телгә алынмады.* Ш. Камал. *Мин сезне артык тотмыйм.* И. Гази.

7. *бәйл. функ.* Микъдарның нинди дә булса күләмнән, үлчәүдән артып китүен, күбрәк булуын белдерү өчен кулланыла. *Яурышкан җиренең моңарчы берәүгә дә сиксән поттан артык бодай биргәне юк әле.* Г. Бәширов.

Артык өстәмә кыйммәт — өстәмә кыйммәтнең гадәттәге нормадан артык өлеше. *Артык өстәмә кыйммәт капиталистлар тарафыннан үз предприятиеләрендә җитештерелә торган товарларның индивидуаль кыйммәтен кимету нәтиҗәсендә алына.* Политэкономия.

◇ **Артык күз** — астыртын, яшерен эшләрне күрергә тиеш булмаган кешеләргә ишарә.— *Минем үземнең дә җыеп бетерәсе әйберләрем бар, тире-йоннарны артык күзләрдән ерак озатасы бар.* С. Рафиков. **Артыгы бе-**

ләп — кирәгеннән артык. *Анысы шәп, ләкин артыгы белән оптимист булырга да ярамый.* А. Әхмәт. **Артык тамак (кашык)** — мохтаҗлыкта яшәгән гаиләдә кирәксез, эшләмичә ашап ятучы кеше турында. *Укымыйча, эшләмичә кыш буе семья эчендә артык тамак булып яту мәсьәләсе аны борчый башлады.* М. Гали.

АРТЫҚЛЫҚ *и.* Артык булу.

Артыклык дәрәҗәсе *лингв.*— сыйфат һәм рәвешләрдә иң югары дәрәҗәне белдерә торган форма (мәсәлән: *кып-кызыл, бик тиз*).

АРТЫҚ-ПОРТЫҚ *с. сөйл.* Кирәксез, үзеннән артканы. *Артык-портык сөлгеләрең юкмы, әнкәй?* Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Вак-төяк, юк-бар. *Кәеф корып яшәүчеләр, Көн буе кырын ятып, Көн итәләр толчокларда Артык-портыкны сатып.* Г. Камал.

АРТЫҚСЫНУ *ф.* Артык дип, кирәксез дип исәпләү.

АРТЫМ *и.* Күләм ягыннан үсеш; арткан өлеш; өстәлгән авырлык. *Бозау караучылар арасында моңа кадәр көненә өчәр-дүртәр йөз грамм артым алу бик табигый хәл иде, Хәдичәнең бозаулары исә көненә кило ярымшар артым биргән.* М. Хәсәнов.

АРТЫШ *и.* Җимеше медицинада кулланыла торган, һәрвакыт яшел ылыслы куак яки агач. // *с. мәгъ.* Артышка бәйләнешле. [*Камил белән Фоат*] *күл яры буйлап узып, артыш әрәмәлегенә керделәр.* М. Әмир. // *с. мәгъ.* Артыштан ясалган яки артыштан киселгән. *Әтинең башында чалма, өстендә яшел сыман чапан, кулында артыш таяк.* Ш. Әхмәдиев.

АРТЫШЛЫҚ *и.* Артыш үсә торган урын. *Тау артышлыгыннан* [*балалар*] *үз куллары белән* [*җиләк*] *җыеп та кайттылар.* Э. Касыймов.

АРУ I *ф.* **1.** Хәл бетү, талчыгу, хәлсезләнү; көч, егәр бетү. *Болар арыган гына түгел, берсенең хәстә икәнлеге дә күренеп тора иде.* Ш. Камал. *Өчесе дә аяктан егылырлык булып арыганнар иде.* И. Гази.

2. Туеп бетү, ялыгу, ялыгып бетү.— *Я, зинһар, җитәр инде, тыңлап торып та арып беттем.* Г. Камал.

АРУ II *с. диал.* **1.** Яхшы, әйбәт. *Җамалый карт тирә-якның ару гына адәме иде.* Г. Ибраһимов. *Өйләнергә яшь әле, унбиш белән бара бугай. Яше җитүен җитсә, ару гына җирдән кыз бирерләр иде үзенә.* М. Фәйзи. / *рәв. мәгъ.*— *Без үзебез ару яшибез.* Г. Гали.

2. Чиста, таза.— *Әллә берәрсе минем чабатамны алып киткән, әллә мондагы ару урында чабатаның ятуына ачуланып, чыгарып ыргытканнар.* М. Гафури. // *рәв. диал.* **аруга.** Кеш(е)леккә, чистага. *Күлмәгемнең монсын аруга киям.*

3. Ярыйсы, җитәрлек. *Аның байлыгы да ару, өй җиһазы да шәп кенә.* Г. Ибраһимов.

АРУЛАНУ *ф. диал.* **1.** Материаль яктан яки берәр авырудан соң яхшыру, әйбәтләнү, рәтләнү.

2. Чистару, сафлану. *Даланың һавасы - - - аруланды.* Ш. Усманов.

3. *Төш. юн. к.* арулау.

АРУЛАУ *ф. диал.* Чистарту, сафлау, пакьләү.

АРУЛЫҚ *и. диал.* Чисталык, пакьлек.— *Кәфен тегәндә, инә-җепнең тотылмаганы кирәк — арулык өчен.* Г. Ахунов.— [*Кое суының*] *бит арулыгы шикле! Ихтимал, анда бер-бер зур хайван төшеп үлгәндер.* Г. Газиз.

АРУ-ТАЛУ *ф.* Бик нык ару һәм йончу. *Ярымы-бирме чакрымнар киткәч,* [*бүре*] *телен салындырган, арган-талган хәлдә тагы кар өстенә утыра.* С. Рафиков.

◇ **Ару-талуны белмичә (армый-талмый)** — 1) бөтен көчне куеп тырышып, көчеңне кызганмыйча. *Ару-талуны белмичә көн-төн эшләргә туры килә.* Г. Гобәй; 2) бертуктаусыз, өзлексез. *Шундый кеше белән армый-талмый тик эшлисе килә, эшлисе!* М. Җәлил.

А'РФА *и. муз.* Өчпочмаклы рам формасындагы чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы. *Сержантның хисләре Шулкадәр киеренке: Кагылсаң, арфа күк Чыңгылдар шикелле.* Ф. Кәрим.

АРХАИЗМ *и.* **1.** *иск.* Искергән күренеш, искелек калдыгы, борынгылык.

2. *лингв.* Актив кулланыштан чыккан, телдән төшеп калган искергән сүз, сүз әйләнмәсе яки грамматик форма.

АРХА'ИК *с.* Искергән, кулланыштан төшкән. *Архаик күренеш.*

АРХА'ИКА *и.* Борынгылык, искелек.

АРХАР *и.* Кыргый тау сарыгы. *Европа кыргый сарыгы — муфлон һәм Азия кыргый сарыкларының икесе — архар һәм аргалиның әһәмияте зур булган.* Биология.

АРХАР-МЕРИНОС *и. биол.* Казахстанда үрчетелә торган иң нечкә йонлы сарык токымы.

АРХЕО'ЛОГ *и.* Археология белгече. *Археологлар борынгы кеше яшәгән урыннарга очраганнар һәм, казый торгач, таштан өеп ясалган учак, борынгы мастерской тапканнар.* Соц. Тат.

АРХЕОЛО'ГИК *с.* Археологиягә мөнәсәбәтле.

АРХЕОЛО'ГИЯ *и.* Сакланып калган памятниклар, казып табылган әйберләр буенча борынгы халыкларның тормыш-көнкүрешләрен һәм культураларын өйрәнә торган фән.

АРХИВ *и.* **1.** Иске документларны системага салып саклый торган махсус учреждение. *Шуның өчен бу газета сәхифәләре көннәребезгә нәмүнә өчен архивта сакланалар.* Ш. Мөхәммәдев. // Ниңди дә булса учреждениедә иске документлар, тәмамланган хезмәтләр сакланa торган бүлек яки бүлмә.

2. Берәр учреждениенең, оешманың яки шәхеснең эшчәнлеге белән бәйле булган документлар, хатлар, кулъязма һәм фотографияләр. *Миңа революциядән соңгы 15—16 ел эчендә иске охранканың архивын күп тикшерергә туры килде.* Г. Ибраһимов.

АРХИВА'РИУС *и.* Архив хезмәткәре; архивны саклаучы.

АРХИВЧЫ *и.* Архив эше буенча белгеч.

АРХИЕПИ'СКОП *и.* Епископ белән митрополит арасындагы рухани дәрәҗәсе; шундый дәрәҗәдәге кеше.

АРХИЕРЕЙ *и.* Христиан динендә югары чиндагы руханиларның (епископ, архиепископ, митрополитларның) гомуми атамасы. *Ул аякларын көчкә сөйрәтеп ишектән кергән озын кара киемле архиерейны күрде.* Қ. Нәҗми.

АРХИМАНДРИТ *и.* Монастырь башлыгы.

АРХИПА'СТЫРЬ *и.* Христиан динендә югары дәрәҗәле руханиларга, патриархларга, митрополитларга, епископларга хөрмәт белән әйтелә торган атама; өлкән пастырь.

АРХИПЕЛАГ *и. геогр.* Бер-берсенә якын урнашкан утраулар төркеме. *Төньяк Американың төньяк ярлары ныграк кискәләнгән. Биредә Арктика архипелагының күп санлы эре һәм вак утраулары - - - урнашкан.* Дөнья кис. геогр.

АРХИТЕКТО'НИК *с.* Архитектоникага мөнәсәбәтле.

АРХИТЕКТО'НИКА *и.* **1.** *махс.* Кисәкләрнең, өлешләрнең үзара гармоник ярашып, матур, төзек бер бөтен тәшкил итүләре. // Сәнгать әсәренең композициясе.

2. *геол.* Теге яки бу урындагы тау катламнары яту, урнашу үзенчәлекләренең, аларның геологик төзелешенең гомуми картинасы.

АРХИТЕ'КТОР *и.* Архитектура белгече, зодчий. *Ә син, гөлем, эшең дәвам иттер, Фәннәр баскычыннан өскә мең, Килер җәйдә сине үз яныма Архитектор итеп көтәмен.* Ш. Маннур.

АРХИТЕКТУ'РА *и.* **1.** Биналар проектлаштыру, салу һәм художестволы итеп бизәү сәнгате, зодчество. *Византия йогынтысы көчле булуга карамастан, гомумән алганда, әкренләп, үзенчәлекле яңа рус рәсем сәнгате*

һәм архитектурасы формалаша башлый. СССР тарихы. // Төзелешнең, корылманың характеры, стиле. *Вокзалның матур архитектура белән ясалган ак таш бинасы, чисталык белән ялтырап торган тигез платформасы --- барысы да минем өчен гаҗәп тоелалар иде.* Ш. Усманов.

АРЧА *и. бот.* Артыш. *Тянь-Шань таулыгыннан искән ачы салкын җил тау сыртларындагы коргаксыган үләннәрне, арча, кыргый алма, чикләвек агачларыннан коелган яфракларны уйсулыкларга илтеп тутыра.* Ә. Айдар.

АРЧАН *и. бот.* Бик вак яфраклы һәм алсу шәмәхә чәчәк ата торган мәңге яшел төбәнәк куак үсемлек. *Анда-санда гына артыш, арчан куаклары, түбәләре меңгә бөгәрләнеп беткән гарип наратлар үсеп тора.* Г. Әпсәләмов.

АРЧИ *и. этн.* Кызны кияү йортына озата баручы ирле-хатынлы кешеләр яки кызлар. *Кияү, кызым Мәршидә, әйдәгез чәйгә, аннан арчи көтәбез.* Т. Гыйззәт. / *с. мәгъ.— Карагыз инде, ичмасам килен төшкән йортка да охшамаган. --- Бер дә күңелле түгел. Үзең арчи кызы, күңеллерәк итәргә иде.* Ф. Бурнаш.

Арчи атнасы — килен төшерү атнасы (гадәттә җәйге урып-җыю эшләре алдыннан була).

АРЧИЛАУ *ф. этн.* Кызны кияү йортына арчи булып озата бару.

АРЧИЛЫК *и.* Арчи булу хәле. *Китәсе киленгә арчилык итмә.* Әйтем.

АРЧУ *ф.* 1. Чүп, пычрак һ. б. ш. нәрсәләрдән чистарту, арындыру. *Ул --- мичнең бер өлешен сүтте, төтен юлларын көлдән, корымнан арчыды, аларның ныклыгын, суыру көчен тикшерде.* А. Шамов. *Колхозчылар, амбарларны ачып, Орлыкларны кабат тикшереп, Тутырдылар өр-яңадан арчып, Күз нурлары кебек иттереп.* Ш. Маннур. *Без кояшка килдек өмәгә, Кардан-боздан җирне арчырга.* М. Җәлил. // *күч.* Искергән, чит яки бозуга алып бара торган нәрсәләрдән арындыру. *Телне искергән сүзләрдән арчу.*

2. Өске катламын, тышчасын алып ташлау, чистарту. [*Өстәлдә*] *берничә йомырка, арчып куелган воблалар* [*ята*]. Г. Камал.— *Кухня буенда бәрәңге арчырга булса да ярарсың.* А. Алиш.

3. Нинди дә булса урынны дошманнан азат итү, дошманны куу.— *Казанка күперен юнкерлардан арчыйсыз.* К. Нәҗми. *Сез кичә немец явыннан Арчыган җирдә Гөрләвек гөрли.* М. Җәлил. // Нинди дә булса төркем, коллектив эчендә, кадрлар арасында чистарту үткәрү. *Мәгариф башлыгының эше укытучылар арасын --- арчып, көрәшкә ярдәм итәрлекләрен Кызыл Армия сафына җәлеп итүдән гыйбарәт.* Ш. Усманов.

4. *күч. сөйл.* Урлау, талау. *Кесәсен арчу.*

АРЧЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* арчу (1—3 мәгъ.). *Диңгез култыгы дошман минасыннан арчылып бетмәгән.* Г. Минский.

2. *күч.* Арыну, котылу. *Ул, күздән тамган яшьләрнең ачылыгыннан арчыла алмыйча, елау аралаш юл буенча клиндер кимереп барды.* Қ. Нәҗми.

АРШЫН *и.* Метр системасы кертелгәнгә кадәрге озынлык үлчәү берәмлеге, 71 см. га тигез. *Бөтен тирәякны күмеп киткән көрт, өйнең ишеге, стенасы буйлап ярты аршын киңлегендә бушлык калдыра килгән.* Г. Ибраһимов. // Чирек белән вершокларга бүленгән бер аршын озынлыгындагы үлчәү таягы. *Әлегә кадәр тукталып торган кибет сәүдәләре, шул француз аршыны белән үлчәп сата башлагач, хикмәте хода, көннән-көн алга* [*китә*]. Ш. Мөхәммәдев. [*Ибраһимның әтисе*] *аршыны белән кайчысын, бер шакмак акбурын, инәсен, җебен, киндер алъяпкычына төреп, чана башына куя да авылларга чыгып китә.* Г. Гобәй. // Шул үлчәү озынлыгындагы кисәк, өлеш. *Трикосының матурлыгын күрсәң, исең дә китәр, сыек зәңгәр төсле, аршыны җиде сум утыз тиен тора.* Г. Камал.

◇ **Аршынга сату** — үлчәп сату, аршынлап сату. *Башмагымның хәтфәләре Сатыла микән аршынга?* Т. Гыйззәт. **(Үз) аршыныңа үлчәү** — кем яки нәрсә турында да булса үзеңнең шәхси карашыңнан чыгып кына хөкем итү.

АРШЫНЛЫ *с.* 1. *сөйл.* Аршын белән үлчәнә торган. *Аршынлы товар.*

2. Бер аршын озынлыгындагы. // Күпмедер аршын озынлыгында, күпмедер аршыннан торган. *Хәйретдиннең өе кечкенә генә тәрәзәле, балчык түбәле, кара мунчага охшаган биш аршынлы өй иде.* М. Гали.

АРЪЯҚ *и.* Каршы як, аргы як. *Бу куәтле тавыш --- елганың аръягында кара күгәреп яткан нарат урманнарына барып барелде.* Г. Ибраһимов. *Кайдадыр, Днепрның аръягындамы, әллә авыл тирәсендәме, бәйдән ычкынган этләр кебек һаулап, винтовкалар шартлый.* А. Шамов.

АРЫ *рәв.* 1. Нинди дә булса бер урыннан читкәрәк, ераграк. *Шул күбә төбеннән бер адым гына ары атласам, мин егылып үләдер идем.* М. Фәйзи. *Минем: «Иптәшләр!» дип кычкыруым үз янымнан ары китә алмады.* М. Әмир.

2. Артык, күбрәк.— *Кем аңа кырык бишне бирер? Утыз биштән ары берәү дә бирмәс.* Ә. Фәйзи. *Әле төн бик иртә иде, сәгать уннардан ары булмагандыр.* М. Гали.

3. *с. мәгъ.* Каршы, теге, аргы, арьяк. *Балыкчылардан бер көймә алдык та, ярдан ярга тулышып аккан Агыйделнең көчле дулкыннары белән көрәшә-көрәшә, ары ярга чыктык.* Г. Ибраһимов.

4. *бәйл. функ. сөйл.* Чыгыш килеше формасындагы күрсәтү алмашлыклары белән килеп, «соң» мәгънәсен бирә. *Моннан ары көт тә тор: җан биздергеч көзге яңгырлар, көзге пычраклар башланып китәчәк.* И. Гази.— *Син боларны ничек булса да чыгарып җибәр дә, аннан ары бүлешербез.* Г. Камал.

◇ **Ары кагылу (бәрелү), бире сугылу** — аптыраган хәлдә булу. *Галиулла ары бәрелде, бире сугылды. Бер җирдән бер рәтле нәрсә чыгара алмады.* И. Гази.

АРЫ-БИРЕ *рәв.* 1. Арлы-бирле, ары да бире. *Ары-бире йөрүче балыкчы көймәләренең кечкенә-кечкенә дулкыны да бик ерактан аермачык булып күренәдер иде.* Ш. Мөхәммәдев. // Як-якка, төрле якка, алан-йолан. *Ләкин ары-бире карангаласам да, андый нәрсәләр күзгә күренмәде.* Һ. Такташ.

2. Тегеләй-болай. [*Алтынны*] *икәү бергә алып, бергә бүлешкәндә, ул башка мәсьәлә. Анда инде* [*Нәгыймгә*] *ары-бире селкенергә юл калмый.* Ш. Камал.

3. Нинди дә булса эш-хәлнең урынын конкретлаштырмый гына сөйләгәндә кулланыла: кая да булса, анда-монда, берәр кайда (кая). *Ары-бире барасың юкмы?* □ *Сугыш чукмары Исмай агай Мәскәүгә барып, ары-бире сәүдә итеп, киемнәрен рәтләп кайткан да, авылда кулларын кесәсенә тыгып йөри.* Һ. Такташ.

АРЫ-БИРЕЛЕК *и.* Җиренә җиткермичә эшләгән эш турында. *Паровоз әкрен йөгерә, рельслар өстендә сикәлтәләр сизелә, гомумән, тимер юл төзелешендә --- нинди дидер ары-бирелек сизелә.* Г. Гобәй.

АРЫГАЮ *ф. сөйл. к.* арыклану, ябыгу.

АРЫК I *с. сөйл.* Ябык. *Кыш буе тик ятып, хәлсезләнеп беткән арык кырмыскалар кояшка җылынырга чыгалар.* И. Гази. *Иң артка калып, арык кына, ямьсез генә бер туры ат килде.* М. Гали.

АРЫК II *и.* 1. Буадан артык суны агызу яки тегермән чарыгын әйләндерергә су җибәрү өчен эшләнгән ачылмалы-ябылмалы улак сыман корылма. *Әкияттәге кебек матур төндә, Югарыда — арык өстендә, Җырлый-*

җырлый, безнең бригадабыз Блокларга бетон төшерә. Ш. Маннур. *Ул буадан арык аркылы Бик күп, бик күп сулар аркылды.* Н. Исәнбәт.

2. Сугару каналы. *Урта Азиядә кечерәк каналлар арык дип аталалар.* СССР физ. геогр.

АРЫКЛАНУ *ф.* Ябыгу. *Кайчагында ул: — «Сезнең мулла бик арыкланган, кем, начар ашатасыз ахры»,— дип шаярта.* Ш. Камал.

АРЫКЛЫК *и.* Арык булу, ябык булу. *Коеп куелган шикелле матур иңнәре, тулырак кына, ләкин арыклыктан ерак түгел кулчыклар көзгедән күренгән матур йөзнең гүзәл кушылмалары иде.* Ф. Әмирхан.

АРЫК-ТОРЫК *с.* Бик ябык, чандыр. *Карганып калды ул юлдан читкә туктап, Ачуыннан арык-торык атын тукмап!* М. Гафури.

АРЫЛУ *ф. з-сыз.* Хәл бетү, хәл китү турында. *Арылган, 3 көн шуып, 3 көн аяк очы белән генә атлап, Амурны йөзеп чыгып, чик үтелгәнгә арылган.* А. Әхмәт.

АРЫНДЫРУ *ф.* Коткару, азат итү. *Шәһәрне дошманнардан арындыру. / күч. Зур шәһәрнең партия мәктәбе аның башын яшьлек буталчыгыннан арындырып, анда төпле бер караш оештырып чыгарды.* Г. Бәширов. // Айныту, азат итү. *Якубның гади һәм хак сүзләре аларны шик-шөбһәдән арындыра, күңелләрендә өмет үрләтә һәм йөрәкләренә кыюлык сала иде.* И. Гази.

АРЫНУ *ф.* 1. Коты лу, азат булу. *Язмыш сукмаклары безне фашизмнан арынган Европага, ирекле Европага алып бара.* А. Шамов. *Илсәяр күкрәген кысып торган авыр әйбердән арынган шикелле булды.* Г. Гобәй. // Бушау, котылу. *Шул эшләремнән арына алмадым.* Ш. Мөхәммәдев. *Фронттагы хәлләрдән бераз арына башлау белән илне төзүгә, аны җимереклектән чыгарырга керешелде.* Г. Нигъмәти. // *күч.* Айну, аңга килү. [*Шәмсетдин*] *таң йокысыннан арына алмаган яшь киленнәрне* [*уятты*]. Г. Бәширов. // *күч.* Иске формаларны, эшкә комачаулый торган нәрсәләрне бетерү, жимерү, ташлау турында. *Театрның гомумән эш методына карата төп әйтә торган сүз: «Җанлы газетчылык», «курчак ueны» методыннан арынып, психологик образлар бирүгә күчәргә --- кирәк.* М. Җәлил.

2. Чистарыну. *Миңнур карт йөткерә-йөткерә чишенде, сакал-мыекларындагы боз кисәкләреннән ашыкмый гына арынды.* А. Шамов. // Чистару, арчылу. *Болытлардан арынып калган күк йөзендә йолдызлар җемелдәде.* Г. Гобәй.

АРЫСЛАН *и.* 1. Мәчесыманнар семьялыгыннан кыска йонлы (ата арысланнар — күпереп торган йомшак яллы), бик зур гәүдәле имезүче ерткыч хайван. *Арысланнар һәм капланнар ерткыч җәнлекләрнең иң зурлары исәбенә керәләр.* Физ. геогр.

2. *күч.* Зур һәм көчле, батыр кешегә карата әйтелә. *Җиңеп кайткан сугышлардан Курку белмәс арысланнар — Ютазы егетләре.* Җыр. *Арыслан егеткә кызның да чәчрәп торганы кирәк.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Арыслан йөрәкле** — батыр, кыю, курку белмәс. *Сәләхетдин — арыслан йөрәкле, турылыклы ир.* Ш. Рәкыйпов. **Арыслан сөте** — аракы. [*Өстәлдә*] *ике-өч бутылка арыслан сөте илә төрле закускалар да хәзер иде.* Ш. Мөхәммәдев.

АРЫТУ *ф. Йөкл. юн. к.* ару I. Ялыктыру, хәлдән тайдыру. *Ул йокысыз үткәргән ике төннең гадәттән тыш арытуына карамады, Баязитны үзенә сорап алды.* Г. Ибраһимов. / *з-сыз ф. Инде әлекке кебек арытмый да.* Каз. утл.

АРЫШ *и.* 1. Орлыгын онга әйләндереп кара икмәк пешерүгә китә торган башаклы үсемлек.— *Киләсе елга үзенә тиярлек җирдән арышын урып алырсыз.* А. Шамов. *Әти белән икәүләп ике зур арба арыш төяп, хәзрәтнең ындырына алып барып, кибәнгә салып, дога кылдырып кайта торган идек.* М. Гафури. // *с. мәгъ.* Арышка мөнәсәбәтле. *Арыш басулары алтын төсле, Бодай дулкыннары ялкын төсле.* Ә. Ерикәй. *Башак тулды арыш кырларында.* Ш. Маннур. // Шул үсемлекнең орлыгы. *Яшел арышны башагыннан аеру кыен икән.* И. Гази.— *Бу ел биш мең пот арыш җыйдым.* Г. Камал. // *с. мәгъ.* Шул орлыкны тартып хәзерләнгән. [*Галиуллалар*] *калган акчага --- солы белән уртак тарттырган биш пот арыш оны алдылар.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Арыш оныннан пешерелгән, хәзерләнгән.— *Арыш икмәге кирәк, арыш икмәге тотрыклы ул.* Ш. Камал.— *Син пешергән арыш салмасын кара-каршы аякларны бөкләп утырып ашаулары ни тора.* Ә. Айдар.

2. Арыш басуы, арыш чәчелгән җир.— *Ничә гектар арышыгыз бар?* Т. Гыйззәт.

Арыш анасы *бот.*— арыш башагына ябышып үсә һәм арыш белән бергә өлгерә торган карасу шәмәхә төстәге паразит гөмбә. **Арыш боламыгы** — бик булдыксыз, җебегән кешегә карата әйтелә. *Әллә шул җебегән арыш боламыгыннан куркып торасыңмы?* Г. Камал. **Арыш камчылау** — җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен күренә торган күкрәүсез яшен, ажаган, нәҗәгай. **Арыш мае** — аракы.— *Соң сез* [*Әхмәтне*] *ни эшләп бераз арыш майлары белән чылатып җебетмисез, аннан соң ул бераз йомшар иде.* Г. Камал. **Арыш урагы** — 1) арыш уру (эше). *Арыш урагын бетереп, сабанга төшәргә торганда, авылда* [*яңа*] *хәбәр таралды.* Г. Ибраһимов; 2) арыш ура торган вакыт. *Арыш урагы да җитә.*

АРЬЕРГАРД *и.* Гаскәрнең яки флотның төп көчләрдән артта барып, тылның куркынычсызлыгын тәэмин итә торган частьлары. *Оборона үзәге булган Уразово шәһәреннән иң соңгы булып Исаев полкы китәргә тиеш булды. Бу полкка арьергард булып чигенү йөкләнде.* Г. Сафиуллин. // *с. мәгъ.* Арьергардка мөнәсәбәтле. *Безнең батальон Сакмар күпере төбендәге арьергард сугышыннан чыккач та вагоннарга утырган иде.* Ш. Усманов.

АС I *и.* 1. Нәрсәдән дә булса түбән урын; *киресе:* өс. *Габдулла акыллым, --- аякларыңны сандыкка күтәреп утырчы, я булмаса аска абыең янына төш.* Ә. Фәйзи. *Яр буйлата бару бик кыенайгач, аска төшеп, боз өслән бармакчы булдылар.* И. Гази.

2. Берәр нәрсәнең эче. *Яулык асты. Плащ асты.* ▭ *Сәйфи, кыска бишмәте астына кулларын яшергән килеш, акрын атлый.* Г. Бәширов. *Ул диван артыннан чирекле шешәне алып, шәле астына кыстырып чыгып китә.* Г. Камал. / *с. мәгъ. Туның аскы ягыннан ап-ак алъяпкычы күренеп бара.* Ф. Әмирхан.

3. Нәрсәнең дә булса тирәсе. *Кызлар, егетләр каравыл өе янындагы чирәмлектә таган астына җыелдылар.* М. Гали.

4. Яткан яки утырган урын. *Кызлар бозауларның, бәрәннәрнең асларын җыеп, идәнне себереп, мичне томалаганчы, шунда утырып тордым.* М. Гали.— *Дус, син минем янда ятарсың, җәмәгать сәкесендә сиңа салкындыр, астыңа юк.* Т. Гыйззәт.

5. Аяк киеменең җиргә басып йөри торган өлеше. *Аягында астына салынган киез итек, өстендә иске сары тун.* Ф. Хөсни. // *сөйл.* Олтан. *Ул, калын гына аслар салган зур киез итекләренә сырышкан карларны какка-лап алгач, зур бүрегән маңгаена баса төшеп, алга атлады.* Ш. Камал. // Төп (икмәк, бәлеш һ. б. ш. турында). [*Мичебезгә*] *нихәтле күп яксаң да, икмәкнең асты килми.* М. Гали.

6. *бәйл. функ. юн. килеш форм.* астына. 1) эш-хәлнең предметның аскы ягына юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Су астына китү. Тел астына насвай салу.* ▭ *Габдулла китапның ике данәсен мендәр астына салып куйды.* Ә. Фәйзи. *Ул трубаларның җир астына күмеләчәген һәм алар эченнән нефть агып торачагын яхшы белә.* А. Әхмәт; 2) берәр нәрсәнең хәрәкәт

сферасын, кем дә булса юлыккан шартларны белдерү өчен кулланыла. *Яңгыр астына элгү. Күзәтү астына алу.* □ *Күчәрбай җәза астына алып барылган кеше төсле тартылды.* М. Әмир. *Беренче тапкыр ут астына эләккән Мисбах аптырап калды.* Г. Әпсәләмов.

7. *бәйл. функ. чыг. килеш форм.* **астыннан.** 1) эш-хәл, хәрәкәт аскы ягыннан, түбәнге өлешеннән башкарылган предметны, урынны белдерү өчен кулланыла. *Машина астыннан чыгу.* □ *Кикрикләрен канга батырып сугышып торган ике әтәч куркып, аның аяк астыннан икесе ике якка очты.* Г. Әпсәләмов. *Серебряков кровать астыннан яшел сандык тартып чыгарды.* И. Гази; 2) кемнең яки нәрсәнең дә булса карамагыннан азат ителгән, коткарылган берәр хәл-торышны белдерү өчен кулланыла. *Сак астыннан качу. Капитализм изүе астыннан котылу.* □ *Солдатлары ут астыннан Чыгалар алып аны.* Г. Хуҗи.

8. *бәйл. функ. у.-вак. килеш форм.* **астында.** 1) аскы ягында кемдер яки нәрсәдер булган яисә берәр эш-хәл башкарылган предметны, урынны белдерү өчен кулланыла. *Агач күләгәсе астында утыру.* □ *Караңгы сәке астында, бер-беребезгә сүз кушмыйча, шактый вакыт хәрәкәтсез яттык.* М. Әмир. *Шул вакыт яфрак астындагы оясыннан куян чыга да әтәч каршына килеп утыра.* А. Алиш; 2) кемне яки нәрсәне дә булса үз тәэсиренә дучар итә торган предметны, күренешне, коралны белдерү өчен кулланыла. *Кар астында калып черү. Яңгыр астында юешләну.* □ *Су астында калды тугайлар.* Г. Хуҗи. *Җил астында оста гына итеп учак ягып җибәрәм.* М. Шабай; 3) кемдер-нәрсәдер тап булган яки берәү нәрсә дә булса башкарган вакыттагы хәл-торышны белдерү өчен кулланыла. *Коммунистлар партиясе җитәкчелеге астында алга бару. Күзәтү астында тотарга кушу. Сак астында булу.* □ *— Якташлар, безне үлемнән коткарырга тырышып, үзегезне үлем куркынычы астында калдыруыгыз өчен сезгә ни әйтергә дә -- белмибез.* М. Гали; 4) эш-хәлгә кушылып башкарыла торган тавышны яки эш-хәлгә кушылып тавыш чыгара торган предметны белдерү өчен кулланыла. *Музыка тавышлары астында йокыга талу.* □ *Володя Бушуев --- уннарча кешеләрнең алкышлары астында байрак янына килде.* Г. Әпсәләмов. *Байрак, йөзләрчә тавышлар күтәреп алган җыр астында чайкалып, Вәлишиннәр фабрикасына таба үрләп килүче ялкын төсле, алга йөзеп китте.* К. Нәҗми; 5) эш-хәлнең сәбәбен белдерү өчен кулланыла: аркасында, нәтиҗәсендә. *Җылылык тәэсире астында киңәю. Каты һөҗүм астында дошман чигенә башлау;* 6) затны, предметны, төшенчәне икенче затлар, предметлар, төшенчәләр рәтеннән аерымлый торган характерлы билгене күрсәтү өчен кулланыла. *Аларны моңарчы бүтән исем астында яшәгән большевик Халявин алып килгән.* К. Нәҗми. [*Ул 1912 елда*] *«Истамбул хатлары» исеме астында --- газетада бик күп очерк-мәкаләләр бастыра.* М. Гали; 7) мәгънәсе ачыла торган яки ачылырга тиешле сүзне, атаманы һ. б. ш. белдерү өчен кулланыла. *Бу сүзләр астында нинди мәгънә ята соң?* Каз. утл.

◇ **Аска су керү (үтү)** — 1) эшнең бик ашыгыч булуы турында.— *Экзаменнарга без семестр башыннан ук хәзерләнә башлыйбыз, ә спорт ярышларына астыбызга су кергәч кенә әтәләнергә тотынабыз.* Г. Ахунов; 2) авыр хәлдә калу, ни эшләргә белмәү.— *Борчылма, тиздән аларның асларына су керә башлый.* Ш. Камал. *Аларның асларына хәзер шундаен итеп су үткән, йомраннар төсле, башларын кая качырырга белмиләр.* К. Тинчурин. **Аста калдыру** — 1) кемнең дә булса сүзен, үтенечен тыңламау, үтәмәү; 2) башка вакыйга, күренеш һәм эш-хәлләрнең әһәмиятен, урынын киметеп күрсәтү. [*Эшләрнең, хәбәрләрнең*] *зурракларын да чүп итеп аста калдыра торган зур бер вакыйга — 1914 елгы сугыш килеп чыкты.* Ф. Хөсни. **Астан киседен, өстән ямау** — хәйләкәр һәм усал булу турында. *Гайшә апа: «Сак бул, сеңелем. Астан киседен, өстән ямый торган кыз ул»,— диде аның турында.* Н. Фәттах. **Астан карау** — яшереп кенә, астыртын карау. **Астан тешләү** — берәр кешегә карата астыртын әшәкелек эшләү. **Асты өскә килү** — зур чуалчык, буталчык барлыкка килү, әйберләрнең тәртибе югалу.— *Ай, улым! Бодаебыз чыкмый бит! Әллә ни булды, бөтенесенең асты өскә килде.* Г. Бәширов.

АС II *и. зоол.* Сусарлар семьялыгыннан кыйммәтле мех бирә торган кечерәк кенә җәнлек; *русчасы:* горностай. *Сайгак астыннан чыгып, шаулап йөрергә башлады Барча тычканнар, комаклар, ас вә әрлән, ләтчәләр.* Ш. Бабич. *Кара койрыклы, ак корсаклы ас, соры таш өстенә менеп, мәзәк кенә итеп арт аякларына баскан.* Г. Әпсәләмов. // Шул җәнлекнең мехы.

АС III *и.* Һава сугышларында үзенең батырлыгы һәм осталыгы белән танылган очучы-истребитель.

АСА *и.* 1. Киндер сукканда рәтләр кыекланып китмәсен өчен кыстырыла торган җеп. *Аса хәзерләү. Аса кыстыру.*

2. Тукыма сукканда җеп кыстырып эшләнә торган бизәк. *Аса, чүпләм дип йөртелә торган тукыма бизәкләр, тукү техникасына буйсындырылганлыктан, киртләчкиртләч геометрик фигура рәвешен алганнар.* Каз. утл.

АСАЛАУ *ф.* Аса кыстыру, асалап сугу. / *рәв. мәгъ. Алача сугу әллә ни катлаулы булмаса, бизәкләп тукуның башка төрләре: чүпләмләп сугу, асалап сугу кебекләре катлаулырак.* Каз. утл.

АСАБА *и.* 1. *тар.* Җирле халык, төп халык. // Вотчина биләүче, вотчина хуҗасы.

2. Ата ягыннан булган барлык ир туганнар.

3. *диал.* Нигез иясе, төп нигездә калырга тиеш кеше, варис; // Ата-ананы караучы ир бала.

АСАЛЫ *с.* Аса кыстырылган. [*Милиционерлар*] *сәкегә җәелгән асалы паласны, палас астындагы калын ак киезне күтәреп, сәке такталарын ачып карадылар.* М. Әмир. *Асалы тукымаларның иң күркәме — кызыл башлы сөлгеләр.* Каз. утл.

АСАТ *с. сөйл.* Ансат, җиңел.— *Асат кәсепкә керешкәнсең икән.* Г. Гобәй. / *хәб. функ. Аның чарасы бик асат, бер дә аптырасы юк.* Ш. Мөхәммәдев.

АСАТЛАНУ *ф. сөйл.* Ансатлану, җиңеләю.

АСАТЛЫК *и. сөйл.* Ансатлык, җиңеллек, ансат булу, җиңел булу.

АСБЕСТ *и.* 1. *махс.* Промышленностьта изоляция тасмасы, төрле картон, фильтр, прокладка һ. б. ш. тукымалар эшләү өчен файдаланыла торган, утка, кислотага чыдам сүс сыман минераллар төркеме; тау сүсе. // *с. мәгъ.* Асбест эшкәртә торган. *Асбест заводы.* // *с. мәгъ.* Асбесттан эшләнгән, ясалган. *Асбест труба. Асбест фанер.*

2. Асбест сүсеннән эшләнгән тукыма, асбестит. // *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Өслəренə асбест плащлар кигән, гаять зур асбест җәймәне як-ягыннан тоткан унөч кеше --- дөрләп янган ут эченə кереп киттеләр.* Г. Ахунов.

АСИММЕТРИ'Я *и.* Симметриянең бозылуы яки бөтенләй булмавы.

АСКАРИ'ДА *и.* Кеше һәм имезүче хайваннарның эчәкләрендә тереклек итә торган паразит. *Аскарида күкәйләре гадәттә азыкка яки авыз куышлыгына кулдан эләгәләр.* Анатомия.

АСКЕТ *и.* Дөнья рәхәтеннән ваз кичкән, баш тартканы, бик авыр, кырыс тормыш алып бара торган кеше. *Кешеләр [Арсланны] аскет дип, чамадан тыш коры, күңелсез яшәүче дип уйлыйлар иде.* Г. Ахунов. // Борынгы заманда: үзен ураза тотып интектергән христиан динендәге кеше.

АСКЕТЛЫК *и.* Дөнья рәхәтеннән ваз кичү, баш тарту — дәрвишлек, суфыйлык, тәкъвалык, аскет булу.

— *Сез бүген мине аскетлыкта гаеплисез; көлеп, мыскыллап, монахлыкка язылырга тәкъдим итәсез.* А. Шамов.

АСКОРБИН: аскорбин кислотасы — организмда матдәләр алмашуның нормаль булуы өчен кирәкле органик матдә (С витамины).

АСҚЫ *с.* Ас яктагы, астагы; *киресе:* өске, югарыгы. *Саматов, каютасыннан чыгып, баскычтан аскы катка төшеп китте.* Г. Минский. *Аның зур авызының аскы ирене, эсседән әлсерәп, салынып төшкән.* Ә. Фәйзи. *Менә [Зиннәт] аскы урамга төшкәннән соң дулкынландырып бер сыздырып куя да бөтенләй тына.* Г. Бәширов.

АСҚЫЛЫҚ *и. сөйл.* Кырда аш пешергәндә, чәй кайнатканда чиләкне, чәйнекне ут өстенә элеп (асып) кую өчен кулланыла торган таяк, колга.

АСЛА *кис. иск.* Бер дә, һич тә, һичбер. *Анасының ниһаясез зур бәхетенә каршы, Зыя да моңа асла илтифат итмәгән кыяфәт белән җавап бирде.* Г. Ибраһимов. *— Аның баштан бирле миндә асла мәхәббәте булмаган икән.* Г. Камал.

АСЛАМ: асламга салу — түлисе бурыч урынына вакытлыча әйберне биреп тору.— *Хуҗа нишли ала ул? Йортына чаклы миңа асламга салынган бит... Теләсәм, йортын саттырам да иртәгә зинданга утыртам.* Н. Исәнбәт.

АСЛАМЧЫ *и.* Төрле товарларны йөреп сатучы, кырык тартмачы. *Асламчы килгән урамга, Асыл алыйк юрганга.* Җыр. *Баш өстенә зур төен куеп, асламчы карчык Җиһан керә.* Т. Гыйззәт.

АСЛАМЧЫЛЫҚ *и.* Асламчы хезмәте. *Андый чакта Сәфәргали үзенең асламчылыкта булганлыгын оныта, теленә ни килсә, шуны такылдый бирә.* Ф. Хөсни.

АСЛАН *кис. иск. к.* асла. *Асыл тугры акыл белән уйлаганда, аслан ят кешене китерерлек түгел иде.* Ә. Фәйзи.

АСЛЫҚ *и.* 1. Нәрсәнең дә булса астына куела торган әйбер; *русчасы:* подставка. *Чәйнек аслыгы.* ▭ *Арткы палубада тәбәнәк кенә аслыкка утыртылган кечкенә каек бар иде.* С. Сабиров. // Аяқ киеменең табанына тегелә, кагыла торган нәрсә. *Итек аслыгы.*

2. *сөйл.* Астар. *Пальто аслыгы.*

3. *этн.* Элекке заманда өйне чыра белән яктыртканда чыра астына куела торган әйбер.

АСЛЫ-ӨСЛЕ *с.* Ике катлы, берсе өстенә икенчесе урнашкан. *Аслы-өсле йорт.* ▭ *Аслы-өсле нарларда эшчеләр кайсы утырып, кайберләре ятып торалар.* Ш. Камал. // Астагы һәм өстәге. [*Бала*], *аслы-өсле өч тешең күрсәтеп, әтисенә карап көлеп җибәрде.* М. Гали. // *рәв. мәгъ.* Берсе өстенә икенчесен, кат-кат итеп. *Абзый кеше, мәдрәсә ишеге янындагы аслы-өсле куелган таш өстенә утырып, кесәсен актара башлады.* Ә. Фәйзи.

АСМА *с.* 1. *к.* асылмалы. *Газизәнең матур борыны белән килешле алсу иреннәре якты гына яна торган асма лампа яктысында гадәттән тыш матур күренә иделәр.* Ш. Камал.

2. *физ. иск.* Югарыдан түбәнгә таба төшерелгән, вертикаль. *Асма сызык.*

АСМАЛЫ *с. к.* асылмалы.

АСМАН *и. кит.* Күк, күк йөзе. *«Нан!» дип тилмерәп, калтырап Куллары асманга сузылган.* Һ. Такташ.

АСПЕКТ *и. кит.* Предмет, төшенчә һәм күренешләргә бәя бирүдәге караш, юнәлеш. *Мәсьәләгә фәнни аспектта якын килү.*

АСПИРАНТ *и.* Фәнни-тикшеренү институты, шулай ук югары уку йорты карамагында гыйльми яки педагогик хезмәткә хәзерләнүче кеше. *Ул Киев шәһәрендәге нинди дер институтта аспирант иде.* А. Шамов.

АСПИРАНТЛЫҚ *и.* 1. Аспирант булу хәле.

2. Аспирантура. *Деканат [аны] аспирантлыкка калдырырга карар бирде.* М. Гали.

АСПИРАНТУ'РА *и.* Фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары каршында гыйльми һәм фәнни-педагогик кадрлар хәзерләү системасы. [*Мөнирә*] *институт бетереп, врач булган икән. Хәзер тагын да зуррак җирдә — аспирантура дигән җирдә укый икән.* М. Хәсәнов.

АСПИРА'ЦИЯ *и. мед.* 1. Махсус аппарат яки шприц ярдәмендә берәр органнан җыелган су; эрен суырту.

2. Ашамлык, кан һ. б. ш. чит нәрсәләрнең ялгышлык белән сулыш юлына эләгүе. *Консилиум аның ике үпкәсендә дә аспирация аркасында пневмония башланган дигән карарга килде.* Сов. әд.

АСПИРИН *и. махс.* Тәннең температурасын төшерү һәм авыртуны җиңеләйтү өчен кулланыла торган дару.

АСРАМА: асрамага алу — *к.* асрауга алу.— *Калада асрамага алучы бар...— диде олаучы һәм артына әйләнеп малайга дәште.* Ә. Фәйзи. *Ул Маратны асрамага алган ятим бала итеп түгел, тумыштан үз баласы кебек итеп үстерергә булды.* Г. Гобәй.

АСРАУ I *и. иск.* Өй эшләрен башкаручы хезмәтче хатын-кыз. *Сәгать уникә сугып чирек булганда, асрау кыз кереп: «Мулла абзый өйләгә азан әйтте!» — диде.* Ш. Мөхәммәдев.

АСРАУ II *ф.* 1. Карап, тәрбияләп, үстереп, үрчетеп тоту (мал, кош-корт турында). *Очраклы бер вакыйга аркасында Җәләш чабышкы аты асраудан бөтенләй кул селки.* Г. Нигъмәти. *Бәгъзы адәм ат асрыйдыр, аттан ләззәт табадыр.* Ш. Мөхәммәдев. // Ашатып-эчертеп үз янында тоту, яшәтү. *Кыз баланы гомер буена асрап булмый.* Г. Камал. *Жырчы Габдулланы Шәйхаттар бай моңы өчен генә үзеннән җибәрми асраган, ди бит.* Ә. Фәйзи. // Карап, тәрбияләп үстерү. *Балалар асрадым, берсе күз алдымда юк.* Һ. Такташ.

2. *сөйл. иск.* Материаль яктан тәэмин итеп тору. *Ул, янәсе, үз милкендәге җирләрне, урманнарны, болынарны Казанда яңа мәчет белән мәдрәсә асрау өчен вәкыф итеп бирәчәк имеш, дигән ялган хәбәр таратгырды.* Қ. Нәҗми. // Үз өендә урын бирү, яшәтү, яшәргә мөмкинлек бирү.— *Син өеңдә студентлар асрыйсың икән. Алар яшерен җыелышлар ясый икән.* Г. Ибраһимов. // Хезмәттә тоту, эшләтү. *Бу кеше кибеттә жалованьесыз вак малайлар асрап, жалованье сораганнарын куып чыгара.* Ш. Мөхәммәдев.— *Әйбәт, чиста булмәләрдә торгач, син тагын, эшчеләр, экономкалар асрап, бояр булып торалар, дип уйлама.* Һ. Такташ.

3. *күч.* Саклап тоту. *Ахры, чыгарып сатулар яхшы булыр, Күп файда өмет итеп асраганчы.* Г. Камал.

4. *күч.* Нинди дә булса хисләр, уйлар турында: саклау, күнелдә, йөрәктә булу. *Ул үзе дә кайчандыр күңелендә Булатка каршы бер дулкын асрый иде.* Г. Ибраһимов. *Һәм күңеленда үзең ниндидер бер өмет яктылыгы асрадың.* М. Җәлил.

◇ **Асрауга алу** — карап, тәрбияләп үстерү өчен үзенә алу. *Өч яшьлек Фатыйманы күршеләрендәге Хәбирә карчык асрауга алды.* Ш. Камал.

АСРАУЛЫҚ *и.* Асрау булу.— *Миңа асраулыкка кеше кирәк иде.* Т. Гыйззәт.

АСРАУЧЫЛЫҚ: мал (хайван) асраучылык — авыл хуҗалыгында эшчәнлекнең бер төре. *Авыл хуҗалыгы коммунасы игенчелек, бакчачылык, хайван асраучылык алып барачак.* Ш. Камал.

АССАМБЛЕ'Я *и.* 1. Нинди дә булса халыкара оешма членнарының гомуми җыелышы. *Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясы.*

2. *тар.* Петр I заманында бөтен җәмәгатьчелек катнашы белән үткәрелә торган җыелыш, бал.

АССЕНИЗА'ТОР *и.* Ассенизация эшен башкаручы.

АССЕНИЗА'ЦИЯ *и.* Халык яши торган урыннарны шакшылардан, ташландыклардан чистарту һәм шул эшне башкару өчен билгеләнгән чаралар системасы; урыннарда гигиена шартларын яхшырту.

АССИГНА'ЦИЯ *и.* 1. Россиядә 1769 елдан 1843 елга кадәр чыгарылган кәгазь акча.

2. *сөйл. иск.* Гомумән кәгазь акча.

АССИГНОВА'НИЕ *и. кит.* Билгеләнгән, сметага кертелгән акча. *Механика цехын реконструкцияләү принципта хәл ителде. Министр яңа елның беренче кварталында тиешле ассигнование җибәртергә вәгъдә итте.* Г. Әпсәләмов.

АССИГНО'ВКА *и. махс.* Сметага кертелгән, билгеләнгән акчаны ала торган документ.— *Акчаның булуына һичкем шикләнми: ассигновка кесәдә.* Ш. Камал.

АССИМИЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. *лингв.* Сөйләмдә янәшә килгән авазларның берсе икенчесенә охшавы, охшашлануы. *Авазлар ассимиляциясе.*

2. *биол.* Тереклек иясе яки үсемлек организмының үзенә кергән матдәләрне эшкәртеп үзләштерүе, сеңдерүе. *Протоплазманың таркалган өлеше тыштан [каннан, лимфадан яки тукыма сыекчаларыннан] керә торган матдәләрнең ассимиляциясе хисабына яңара.* Биология. // Күзәнәкләргә кергән гади матдәләрнең катлаулы органик кушылмаларга әверелү процесслары.

АССИРИОЛО'ГИЯ *и.* Борынгы Ассириянең һәм Вавилониянең культурасын һәм чөй сыман язмаларын өйрәнә торган фән.

АССИРИ'ЯЛЕ *и.* 1. Алгы Азиядә безнең эрага кадәр 3 меңенче елдан VII йөз ахырынача яшәгән иң борынгы дәүләтләрнең берсе — Ассирия дәүләтенең халкы.

2. Ираква, Төркиядә һәм СССРда Кавказның кайбер авыл һәм шәһәрләрендә аерым группалар булып яшәүче, семит телендә сөйләшә торган халык.// Шул халыкның бер кешесе.

АССИСТЕНТ *и.* 1. Гыйльми хезмәт өстендә эшләгәндә яки операция вакытында профессорның, врачның ярдәмчесе. // Театрда, кинода нинди дә булса өлкән вазифалы кешенең ярдәмчесе. *Режиссер ассистенты. Балетмейстер ассистенты.*

2. Югары уку йортларында кече дәрәҗәдәге укытучы вазифасы һәм шул вазифаны башкаручы.— *Бервакыт шулай университетның бер ассистенты белән сөйләшеп киттек.* Ф. Әмирхан.

АССИСТЕНТЛЫК *и.* Ассистент вазифасы, хезмәте. *Павел Даниловичның [Мансур белән Юматшаны] үзенә ассистентлыкка алуы гажәп зур шатлык иде.* Г. Әпсәләмов.

Ассистентлык итү — ассистент вазифасын үтәү.— *Рәхим Миңлебаевичның оста кулларына карап тагы бер киңәним, үзем ассистентлык итәм!* А. Расих.

АССОРТИМЕНТ *и. махс.* Сәүдә яки эшләп чыгару предприятиеләрендә төрле сортлы күп төрле әйберләр, товарлар җыелмасы. *Кредит алган дәүләтләр ул кредитларны һәм аларга өстәлгән процентларны --- гадәттәге товар ассортименты белән түлиләр.* Политэкономия. // Бер үк төрле, ләкин төрле сорттагы әйберләр җыелмасы.

АССОЦИА'ЦИЯ *и.* 1. Бер үк характердагы эш алып бара торган учреждениеләрнең яки кешеләрнең берләшмәсе. *Гыйльми сотрудниклар ассоциациясе. Крайны өйрәнүчеләр ассоциациясе.*

2. Нәрсәләрнең дә булса төркеме. *Молекулалар ассоциациясе. Үсемлекләр ассоциациясе. Йолдызлар ассоциациясе.*

3. *махс.* Нерв-ми эшчәнлегенә нигезләнгән буларак, аерым төшенчәләр, төрле психик хәлләр (күзаллау, фикерләү, хисләр) арасындагы бәйләнеш; бер төшенчәгә охшатып, шуңа бәйле буларак, икенчесен искә төшерү. *Хәтерләр ассоциациясе.* □ *Димәк, теге сүзләр белән чирту арасында нинди дер ассоциация туып өлгергән.* Ш. Камал.

АСТАР *и.* 1. Киемнең тышы белән эче арасына салынган материя (марля, киндер һ. б. ш.). *Аннан бик зур иске калын шәл, нечкә астар, ярты кадак төя йоны, дүрт төймә, зәңгәрсу тышлы ике каптырма, бер тәгәрмәч җеп чыкты.* Г. Ибраһимов. *Мостафа да френче тотып-тотып карады: — Материясе юкарак, астар куйганда әйбәт буласы икән, диде.* Ш. Камал.

2. Нәрсәне дә булса ныгыту, беркетү өчен аскы якка куела торган әйбер.— *Син анда икенче номерлы станокның кысасын астар куеп беркетмәгәнсең икән.* Х. Җәмил.

АСТАРЛАУ *ф.* Астар кую, астар салу. *Астарлап тегү.*

АСТАРЛЫ *с.* Астар (1 мәгъ.) белән тегелгән. *Өстән салына торган кесәләр бер катлы, ике катлы һәм астарлы булалар.* Йорт эшләре.

АСТАРЛЫК *и.* 1. Астар өчен махсус материя. // Астар кую өчен җитәрлек әйбер.

2. *күч.* Яшерен нигез, чыганак. *Бу куркү-шомлану [Зөфәрнең] тырыш, уңган, хәйләкәр, ялагай табигатенең астарлыгы булып кала бирде.* Ә. Еники.

АСТЕРО'ИД *и. астр.* Кояш тирәсендә әйләнеп йөри торган вак планеталарның берсе. *Астероидлар галәм киңлегендә йөри торган җисем ватыкларыннан гыйбарәт.* Космик ракеталар.

А'СТМА *и. мед.* Йөрәкнең һәм бронхларның сәламәт булмавы нәтиҗәсендә кабатланып торган тын бетү, буылу өянәкләреннән гыйбарәт авыру.

АСТМА'ТИК *и. мед.* Астма белән авыручы.— *Сезгә астматикларга операция ясарга туры килгәне бармы?* Г. Әпсәләмов.

А'СТРА *и. бот.* Төрле төстәге иссез чәчәк ата торган декоратив үсемлек, бакча гөле, кашкарый (йолдыз дип тә йөртәләр). *Көз иде. Астралар, гөлләр кыраулы, Каеннар сары иде.* Х. Туфан. *Терраса алдында гына — балкып янган куе кызыл, ак, сары георгин, астра чәчәкләре.* Ә. Еники.

АСТРОБИОЛО'ГИЯ *и.* Башка планеталарда тереклек булу мөмкинлеген өйрәнә торган фән.

АСТРО'ГРАФ *и. астр.* Күктәге йолдызларның рәсемен ала торган астрономик труба.

АСТРО'ЛОГ *и. иск.* Астрология белән шөгыльләнүче, фалчы.

АСТРОЛО'ГИЯ *и. иск.* Йолдызларның торышына карап кешенең язмышын алдан әйтеп була дип раслаган ялган тәгълимат.

АСТРОЛЯ'БИЯ *и.* Астрономиядә XVIII гасырга кадәр озынлык һәм киңлекне үлчәү приборы.

АСТРОМЕ'ТРИЯ *и.* Астрономиянең күк йөзендәге җисемнәр торышын билгели һәм вакыт үлчи торган бүлеге.

АСТРОНАВТ *и.* 1. Астронавтика белгече.

2. Космонавт. *Аерыла ала торган герметик кабина астронавтны атмосферада гына түгел, ә җир өстендә дә саклаячак.* Космик ракеталар.

АСТРОНА'ВТИКА *и.* Очу аппаратларының галәмгә очышы турындагы фән. // *с. мәгъ.* Астронавтикага мөнәсәбәтле. *[Пилот] астронавтика кагыйдәләрен бозып, авыр киемне салып ташлады.* А. Тимергалин.

АСТРОНОМ *и.* Астрономия белгече, астрономия галиме. *Физиклар астрономнарга күктәге яктырткычларны өйрәнүдә яңа юллар табарга булышалар.* Астрономия.

АСТРОНО'МИК *с.* 1. Астрономия буенча, астрономиягә мөнәсәбәтле. *Астрономик күзәтүләр. Астрономик ачыш.* □ *— Айларны алай теләк белән тезмәгәннәр. Җирнең әйләнешен, башка бик күп астрономик законнарны исәпкә алганнар.* А. Гыйләҗев.

2. *күч.* Бик зур, исәпсез, исәбенә чыга алмаслык. *Астрономик саннар.*

АСТРОНО'МИЯ *и.* Йолдызларның һәм планеталарның төзелешен, килеп чыгышын, табигатен һәм хәрәкәт итү законнарын өйрәнә торган фән. *Астрономия белгән кешегә көн тотылу алдан мәгълүм эш.* Н. Исәнбәт.

АСТРОФИ'ЗИКА *и.* Астрономиянең күк йөзендәге җисемнәрнең физик хәлен һәм химик составын өйрәнә торган бүлеге.

АСТЫРТЫН *рәв.* Яшертен, сиздермичә генә, сиздермәскә тырышып. *Бу сүзләрнең ничек тәэсир итүен беләсе килеп, Сәйфи астыртын гына як-ягына күз төшереп алды.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Хәйләкәр, яшертен эш итүче. *Астыртын кеше. Астыртын караш.* □ *Завмаг Шәкүревнең астыртын эшләре дә фаш ителде.* А. Расих. // *с. мәгъ.* Яшертен булган. *Авыл белән алпавыт арасындагы астыртын дошманлык ачык дошманлыкка әйләнеп киткән.* И. Гази.

АСУ *ф.* **1.** Нәрсәне дә булса түбән таба салындырып бәйләп, тагып, әлеп кую яки берәр нәрсәгә беркетү. *Без утырып байрак тегәбез. Читләренә асылмалар асып, Ука белән читен бөгәбез.* Һ. Такташ. // Нәрсәне дә булса түбән салындырып, аркага, җилкәгә, кулга күтәрү. *Жамали керә, кулында блокнот, карандаш; фотоаппарат аскан.* А. Әхмәт. *Аркаларына капчыклар, винтовкалар аскан егетләр, кулларындагы көрәкләренә таянып, бер урында басып калдылар.* И. Гази.

2. Үлем җәзасының бер ысулы (кешене, муенына элмәкле бау кидереп, түбән таба салындырып кую). *Төн уртасы. Әнкәй, мин дар ясыйм: Әмер булган мине асарга.* А. Әхмәт.— *Асып куймаслар әле, бер рәнҗерләр, бер каргарлар да, бер туктарлар,—дип уйланып, ул үзенең сөйгән егете Лотфыйга ябышып чыгарга күңелен беркетте.* Г. Ибраһимов.

АСУ-КИСҮ *ф.* Күпләп үтерү, кыру, үлем җәзасына дучар итү. [*Кара реакция елларында*] *революцион карашлы кешеләрне аяусыз рәвештә асу-кисү* [*булды*]. М. Җәлил.

АСФАЛЬТ *и.* Юл һәм тротуарларга җәю өчен, шулай ук промышленностьның кайбер өлкәләреңдә кулланыла торган, сумала сыман кара соры төстәге табигый һәм ясалма масса.— *Дүрт йөз квадрат метр асфальт җәйдердек, быелга җитеп торыр, Локман абзый.* Ш. Камал. // Шул масса җәелгән, түшәлгән тротуар, юл. *Махсус эшләнгән автомобильләр бу урамнарны щеткалап, бензинлап юалар — асфальт безнең кустарьлар тарафыннан хәзерләнгән көзгегә охшый.* Г. Гобәй. *Куе салкын яңгырның ядрә кебек тамчылары перрон асфальтын кыйный башлады.* Ш. Хөсәенов.

АСФАЛЬТЛАУ *ф.* Асфальт җәю, асфальт белән каплау. *Асфальтламый калган уч төбе кадәр җирдә дә төрле чәчәкләр үсеп утыра.* Каз. утл.

АСФАЛЬТЛЫ *с.* Асфальт җәелгән, асфальтланган. *Асфальтлы зур урамнан пыяла ишекне ачып кергән җирдә хатын швейцар каршы алды.* Г. Ибраһимов.

АСЫЛ I *и.* **1.** Әйберне (яки күренешне) шул әйбер итеп таныткан төп сыйфат, аның үзенчәлеге, җисеме. *Кара, егет, эшнең астына, Һәрнәрсәнең иреш аслына.* Н. Исәнбәт. *Асыл — күренешләрнең иң гомуми, иң төп һәм хәлиткеч ягы.* М. Абдрахманов. // *с. мәгъ.* Төп. *Урыны белән, шигырьнең буеннан-буена асыл мәгънәне күп сурәтләр, кинаяле --- җөмләләр арасыннан эзәрләп барырга туры килә.* Г. Нигъмәти.

2. Нәрсәнең дә булса нигезе.— *Байтүрәнең җеназасына чакырып, атчабар чыккан, диделәр, бу хәбәрнең асылы бармы?* Г. Ибраһимов. *Эшнең асылын белдем, Ышанмадым.* М. Гафури.

◇ **Асылына кайту** — элекке хәлгә килү. *Озак сагышлана, төшенкелеккә бирелә белми торган шат күңелле Газинур, бара торгач, яңадан үзенең асылына кайтты.* Г. Әпсәләмов.

АСЫЛ II *и.* **1.** Затлы ефәк тукыма. *Асламчы килгән урамга, Асыл алыйк юрганга.* Җыр.— *Аның кебек сизгән беткән асыллар минем үземдә дә бетәсе юк.* Г. Камал. // *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән.— *Ата-баба күрмәгән асыл күлмәкне киеп карыйм әле, килешер микән?* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Кыйммәтле, затлы. *Этисенә чиккән билбау Асыл кызыл ефәктән.* Җыр. *Егет асыл киемнәрен киде.* Г. Ибраһимов.

2. *с. мәгъ.* Яхшы, менә дигән (кеше турында).— *Үземнең дә шундый бер өметем бар иде, башта ук уйлап куйган идем, мондый асыл кешеләр белән беркайчан да хур булмабыз, дигән идем.* Г. Бәширов. *Илнең асыл егетләре ай йөзенә сокланган.* Җыр. // Яхшы нәсел, нәселле (хайваннар турында).— *Атның асылын алдыгыз.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Матур, яхшы; изге (сүз, теләк). *Күңелләребездәге иң асыл теләкләрне, иң яшерен хисләрне бер-беребезгә сиздереп, белгертеп киткән бу ялгыз кошчыкны без тирән хөрмәт һәм рәхмәт белән озатып калдык.* Ә. Еники.

◇ **Асыл зат** — 1) бик затлы һәм кыйммәтле нәрсә. *Калымлык өчен биш йөз сум акча, ике сандык асыл зат алып куйганнар.* Г. Ибраһимов; 2) *иск.* югары сыйныф кешесе, аристократия вәкиле. *Илнең асыл затлары өчен генә яралган кызыңның пакь исемен буявыңны мин күтәрә алмыйм, атакай.* М. Фәйзи; 3) яхшы нәселдән, нәселле, токымлы (мал). *Гөлнарга кырын гына карап куям, янәсе, аңлый микән бу хайваннарның асыл зат икәнен.* Ә. Айдар. **Асыл кош** — 1) матур сайрый торган кош. *Асыл кошлар канат какгылар да Ботакларга чыгып бастылар.* М. Җәлил; 2) *ирон.* чибәр кыз (яки егет).— *И-hи-hи-hи! Менә синең шикелле егетләр шул асыл кошларны әләктерергә бакчага чыгалар.* Г. Камал. **Асыл сөяк** — 1) аксөяк, аристократ; 2) нәселле, яхшы нәселдән булган (хайван турында). *Бары да авызларын ачып, хәйран булып, бу асыл сөяк колынга карап каталар.* Г. Ибраһимов.

АСЫЛДА *кер. сүз.* Нигездә, төбендә, чынбарлыкта, дөресендә. *Асылда исә, Захаров та, сестра да бераз шикләнә, тик алар моны сиздермиләр һәм башкалар турында нәкъ Хәлим уйлаганча уйлыйлар иде.* А. Шамов. *Батыргали агай үзе, асылда, Казан губернасында М. карьясеннән булса да, Казанда тормакта иде.* Ш. Мөхәммәдев.

АСЫЛЛЫК *и.* Асыл булу. *Тирә-якта асыллыгы, җитез, килешле һәм акыллы уйнавы белән Алмачуарга тиңдәш булырлык колын күренми дә, ишетелми дә.* Г. Ибраһимов.

АСЫЛМА **1.** *с. к.* асылмалы. *Ул, бер кулы белән асылма лампага тотынган килеш, сөйкемле һәм назлы күзләре белән Газинурга карады.* Г. Әпсәләмов.

2. *и.* Чүк. *Шуның өчен дә без Бүген төндә аны* [*байракны*] *матур итеп тегәбез, Читләренә асылмалар асып, Ука белән читен бөгәбез.* Һ. Такташ.

АСЫЛМАЛЫ *с.* Асып куела торган, асма. *Асылмалы бишек.* □ *Сафия абыстай асылмалы лампаны кабызып җибәрде.* А. Шамов. *Уфалардан алып кайттым Асылмалы зур көзге.* Җыр. *Азык ташу өчен асылмалы юллар --- күпләр өчен яңалык иде.* С. Рафиков.

АСЫЛСЫЗ *с.* Начар, юньсез. / *и. мәгъ. Асылсызны катыштырсаң, уен бозар; Хәрәмзәне катыштырсаң, җыен бозар.* Н. Исәнбәт.

АСЫЛТАШ *и.* Кыйммәтле таш. *Анда ялангач балалар, киеме тездән генә, Монда бай кызы асылташ, алтының тезгән генә.* Г. Камал. [*Йолдызлар*] *егерме тиен көмеш акча зурлыгындагы асылташлар кебек җемелдиләр.* Г. Әпсәләмов.

АСЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* асу. *Стенага асылган --- картиналарны күреп, ул хәйран калды.* М. Гали. *Югары тәрәзәгә читлек белән сандугач асылган.* Г. Ибраһимов. *Балтик буе шәһәрләрендә көпә-көндез фонарь баганаларына асылган эшчеләр һәм Рига*

контрреволюциясеннән соң атылган меңләп иптәшләр — барысы да күз алдыннан кичәләр. Г. Гобәй.

2. *диал. к.* асылыну (3—4 мәгъ.). *Алар агу эчәләр имеш, тегә хатын да шуның ачуыннан үз муенына җеп салган, асыла имеш.* Ш. Камал. *Мин машина өстеннән сикереп төшүгә, бер карчык муенына килеп асылды.* М. Әмир.

АСЫЛЫНУ *ф.* 1. Түбән таба салыну. *Шул вакыт урман буенда, тамчы-тамчы булып асылынып торган каен яфракларына үрелә-үрелә, моңлы бер көй дулкынлана башлый.* Г. Бәширов. *Шушма буйларының, ай, чиясе, Асылынгач җирләргә тиясе.* Җыр. *Бик риза булган кыяфәт белән, ул ике якка асылынып төшкән ак мыегын кул сырты белән уңга-сулга сыпырып куйды.* Ә. Еники. // Эленү. *Хәстә ягында бер читкә тартып куйган күк чаршау вә берничә күлмәк асылынып торалар.* Ш. Камал.

2. Үзеңнән югары берәр нәрсәгә тотынып, гәүдәне түбән таба салындырып тору. [*Сәлим*] *аркылы агачка асылынып, аякларын югары куярга* [*азапланды*]. Ш. Камал. // Бара торган машина, чана, арба кебек нәрсәләргә тагылу, тотынып, тагылып бару. *Чыгыйм мин дә олы юлга, Асылыныйм арбага.* Н. Исәнбәт. *Дулкын эчкә кайткан арада, Гариф, сикереп торып, көймәгә ташланды һәм көймәнең читенә барып асылынды.* Ш. Камал. // Нәрсәне дә булса (тотынып, тешләп) түбән таба тарту. *Малай ары-бире йөгерган чакта, эт баласы, малайның күлмәк чабуыннан тешләп, асылынып, өч-дүрт җиреннән күлмәген ерткан иде.* Ш. Мөхәммәдев.

3. Үлү максаты белән үз муенына бау салу.— *Минем урында башка берәү булса, әлләкайчан асылынып үлгән - - - булыр иде.* А. Шамов.

4. *күч.* Берәр кешегә барып сарылу, кочаклау; ялынып тагылу.— *Хатын-кыз бервакытта да синең муеныңа килеп асылынмас.* Г. Бәширов. // Сагынып, иркәләнеп сарылу.— *Әни, абый кайткан,— дип кычкырып, ул Газинурның муенына килеп асылынды.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч.* Асылынган кебек булып күренү. *Тузан, таралмыйча, юл өстендә асылынып тора, шунлыктан нәрсә килгәнен абайлап та булмый.* Ә. Еники.

АТ I *и.* 1. Кешеләр йөртү һәм йөк тәшү өчен файдаланыла торган йорт хайваны, эре терлек. *Илгизәр нидер кычкырып җибәрде, йөгереп барып атына атланды да кире авылга чапты.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Атка мөнәсәбәтле. *Гали өйдән ат тиресе алып чыга.* Д. Аппакова. *Алар ат ите ашамый башлаганнар имеш.* Ш. Камал.

2. *спорт.* Ат башлы шахмат фигурасы. *Ат белән йөрү.* □ [*Хатын:*] *Әтисе, син аңа атыңны бир! Әтисе, син аның пешкасын аша хәзер!* М. Мәһдиев.

3. *спорт.* Юан бүрәнәне күн белән тышлап, дүрт аякка ныгытылган гимнастика җайланмасы; *русчасы:* конь.

Ат базары — 1) атлар белән сату итә торган махсус базар.— *Ат базарыннан берәр Сембер тае алырга ниятләп торам.* Т. Гыйззәт; 2) шау-шулы, тавышлы булу, кычкырып сөйләшү турында.— *Тукта дим, ат базары ясама син безнең утырышны.* К. Тинчурин. **Ат башы** — 1) тарантаста кучер утыра торган урын.— *Ә мин, кучер булып, ат башына* [*утырдым*]. Р. Ишморат; 2) ат йөртүче.— *Була ул,— диде Чиртан,— ат башында йөрергә малае да үсеп килә бугай.* Ш. Камал. **Ат докторы (врачы)** — ветеринар, атларны дәвалау буенча белгеч.—*Ат докторы,—диде Миңнурый һәм кычкырып көлеп жибәрде.* Г. Әпсәләмов. *Аның әтисе авылда ветеринар булып эшли. Халыкта* [*татар авылында*] *ветеринар дигән сүз юк, «ат врачы» дигән сүз генә бар.* М. Мәһдиев. **Ат заводы** — чабыш атлары, нәсел атлары хәзерли торган учреждение. *Өч җирдә зур имениеләре, ике спирт заводы һәм зур ат заводы аның милкендә иде.* Ш. Камал. **Ат кормасы**—ат өстенә яба торган япма; *русчасы:* попона. *Гайнулла ямщикның ат кормасы Чамбар болынында талларда.* Бәет. **Ат кузгалагы**—карабодайчалар семьялыгыннан зур озынча яфраклы һәм себеркәч чәчәкле үсемлек. [*Сестра*] *зур булып, аерылып үсеп торган бер ат кузгалагын сындырып алды һәм шуның белән тынгысыз чебеннәрне куарга тотынды.* А. Шамов. **Ат кәмите** *иск.*— цирк. *Хәсәнша - - - ат кәмитенә барам диеп чыгып киткән иде.* Ш. Мөхәммәдев. **Ат көче**—1) атның тарту көче, егәрлеге. *Гадәттә төрле машиналарның эшләү егәрлеген ат көче белән үлчиләр.* Физика; 2) авыл хуҗалыгында: «атлар» мәгънәсендә. *Оланнар, орлык ташырга ат көче җитешми, чәчү сузыла; чәчү сузылган саен, туфракта дым кими.* Г. Бәширов. **Ат тартымы** — бер ат тартырлык, бер ат йөге. *Ул элекке көннән үк ат тартымы ике йөк китереп аударды.* Г. Ибраһимов. **Ат тегермәне** — ат көче белән эшли торган тегермән. **Ат язуы** — атның төсе, кыяфәте, кайдан алынганлыгы һәм нәселе күрсәтелгән карточка, паспорт. **Ат барышнигы** *иск.*— атлар белән сату итүче, ат алу-сату белән шөгыльләнүче кеше, маклер. *Янә бер ат барышнигы — Мөхәммәтша исемле мишәр кушылып, шәкертләрне урысча сүкте.* Ш. Мөхәммәдев. **Ат карагы** *иск.*— 1) ат урлап сатуны кәсеп иткән кеше; 2) бик оста алдаучы, хәйләкәр кеше турында.— *Киткәндә ул ат карагы белән исәпне бетереп китәргә кирәк.* К. Тинчурин.

◇ **Ат кебек** — бик зур гәүдәле булуга ишарә итеп әйтелә.— *Хәзер дә әле ат кебек таза, көчле дисезме?* А. Шамов. **Ат койрыгын кису** — элекке заманда: туй барганда кияү яки кодалар җигеп килгән атның койрыгын кисеп, кәләшең кыз түгел иде дип, кияүне хурлау. *Карт коданың төпкә җигеп килгән зур күк атының койрыгын кискәннәр, диләр.* Г. Ибраһимов. **Ат күз** — зур акай күзле кешегә карата әйтелә. *Ат күз Шәрәфиләрнең эт баласы һаман шыңшый иде әле.* А. Шамов. **Ат менү** — атка атлану. *Ат менгән ике кеше биргә таба чабып килә.* И. Гази. **Ат тотучы** — җиккән атның дилбегәсен тотып, билгеле бер юл белән алып баручы. **Ат урынына (ат кебек) эшләү** — авыр эшләрдә һәм армый-талмый эшләү.— *Җәй буена ат урыңына эшлаткәнсең дә, аерып җибәргәнсең.* А. Шамов. **Ат җене кагылу** — атны карап тәрбияләп, ат белән йөреп, аның тирәсендә бик күп вакыт уздыра торган, ат яратучы кешегә карата әйтелә. *Әйтерсең аңа, карт сугышчы Вәлитов әйтмешли, ат җене кагылган.* Г. Бәширов.

АТ II *и. сөйл.* Исем. *Мендем тауның башына, атым яздым ташына.* Бәет. *Чакырып килгәннең аты зур, сөеп килгәннең хакы зур.* Мәкаль. // Кушамат, атама. *Аңа балалар «Челем бабай» дип ат та куштылар.* Г. Ибраһимов.

Атсыз бармак — урта һәм чәнчә бармаклар арасындагы бармак. *Аның чәнчә һәм атсыз бармаклары бик ямьсез кәкраеп, тырпаеп торалар.* Ә. Фәйзи. [*Дускаев*] *Сөембикәнең атсыз бармагына көмеш йөзек кигән кара тутлы кулын кысты да ашыкмыйча гына китеп барды.* Ә. Еники.

◇ **Ат казану (алу)** — дан алу, дан казану, танылу. *Янды Фәрһат, янды Ширин, Бер янып ат алдылар.* Дәрдмәнд. [*Фазыл МТСта*] *ат казанды бит.* А. Шамов. **Ат калдыру** — нинди дә булса эш белән исеменне мәңгеләштерү. *Ат калдырдык бергә туган илгә Сагынып яд итәргә гомергә.* Ф. Бурнаш. **Атка калу** — яманатлы булу, оятка калу, оятлы булу. **Аты коргыры** — кешенең яки эйбернең исемен искә төшерә алмаганда, сукранып әйтелә.— *Менә инде, аты коргыры, тел очымда гына тора бит.* Т. Гыйззәт. **Аты чыгу** — яманаты чыгу, нәрсә белән булса да телгә керү, начар яктан танылу. *Ялкау дип аты чыгу.* □ *Бәдига — яучы булу белән аты чыккан карчык.* М. Фәйзи.

АТА *и.* 1. Гаиләдә: балалары булган ир кеше; әти. *Идрис тагын атасының тавышын ишетте.* К. Нәҗми. *Җаным, мин беләм, син атаңның рәнҗүеннән куркасың.* Г. Коләхметов. // *тарт. форм.* **атасы**. Хатынның иренә карата мөрәҗәгать сүзе.— *Быел үзең дә бик зур эшкә алындың, атасы, киленгә җиңел булмас инде.* Г. Бәширов. *«Син кая югалдың, атасы?» — дип, күрку катыш аптыраулы сорау белән каршы алды Шәмәҗамалы.* Ф. Хөсни. // *күч. сөйл.* Кемгә дә булса игътибар, ярдәм, тәрбия күрсәтүче кеше турында.

2. Нәрсәгә дә булса башлап нигез салучы. *Г. Тукай — татар поэзиясенең атасы.*

3. Өлкән буын, элгәре буын. *Аталар һәм балалар мәсьәләсе.*

4. *с. мәгъ.* Хайваннар дөньясында: ир җенесеннән булган. *Ата үрдәк белән ана үрдәк эре генә бакылдап куйдылар.* А. Шамов. *Хәлим юлда очраган ата казга буш чиләк белән кизәнеп, әкрен генә узып китте.* И. Гази.

5. *с. мәгъ. сөйл.* Бик, үтә, атаклы. *Ата ялганчы. Ата карак. Ата бай. Ата куштан.* □ *— Җыен ата ялкау, башка эшкә чыдамаган, тел болгап яшәргә генә өйрәнгән туң түмәрләр эшли бит анда!* А. Гыйләҗев.

Ата йорты — туган йорт. *Мин Яңа бистәдә атам йортында тора идем.* Ф. Әмирхан. **Ата кайчы** — өй түбәсе кыегына куелган кара-каршы ике кайчының киртләнмәгәне (киртләнгәне «ана кайчы» дип йөртелә). **Ата каптырма** — каптырманың ыргаклысы. *Ул, олылар сүзенә ышанып, кармак урынына ата каптырма тагылган җеп белән балык тотып азапланучы өч яшьлек сабый шикелле, күңелсезләнгән иде.* М. Әмир. **Ата малы** — атадан калган мирас, үз көчең түгелмәгән, әзер мал мәгънәсендә кулланыла. *Ата(й) малы катай.* Әйтем. **Ата сакал** — ирен асты чокырындагы сакал. *Чулак Сәйфи, келәт бусагасына җәелеп утырган килеш, ата сакалын сыпыргалап, кет-кет көлә иде.* Г. Бәширов. **Ата ягы** — атаның кардәшләре. *Ата ягыннан аның бабасы крепостной крестьян иде.* Г. Нигъмәти. **Ата эрем** *бот.*— озын көпшәле эрем.

◇ **Ата баласы** — 1) кеше, адәм баласы. *Сез дә ата баласы, без дә ата баласы, Сөймәгәнгә сөйкәнмибез, Сөйсәң, ярлар табыласы.* Җыр; 2) ата кулында тәрбияләнгән, тәрбияле, инсафлы. *Кичер, ханым, күзем карасын, Аяу кирәк ата баласын.* Ф. Бурнаш. **Ата каз муены булу** *сөйл.*— салкын тию яки башка сәбәп аркасында муен нервларының авыртуыннан гыйбарәт авыру. **Ата казың күкәй саламы?** — сүз югында сүз булсын диебрәк әйтелә торган тәгъбир.— *Исән торасыңмы, Газинур, ата казың күкәй саламы?— Ачуы килмәгәндә [сала],— диде Газинур һәм кроватька сузылып ятты.* Г. Әпсәләмов. **Ата канаты астында яту** — ата тәрбиясендә, ата йортында, авырлык күрмичә яшәү. *Мыек тибә башлаган егет кеше гомер буе ата канаты астында ятмас.* С. Рафиков. **Атаң башы** — 1) тиргәү сүзе. *Галошларың салмый, ни дип инде Килеп кердең атаң башына.* Һ. Такташ; 2) берәрсенең фикеренә каршы ирония белән әйтелә.— *Нигә менә монда да таш кала — баш кала булмый?— Нигә булмасын, бик була!— Була, атаң башы!* Г. Ибраһимов.

АТА-АНА *җый. и.* Ата белән ана. *Зыя Мәрьямне сөя, өйләнергә дә хәзер, ләкин шул чакта ата-аналарына яки Фатыйма бикәгә барып бер сүз әйтә алмый.* Г. Нигъмәти. *Ул ачлык елны, ун яшенә чыкканда, өй тулы эне һәм сеңелләре белән ата-анадан ятим калды.* Г. Бәширов.

◇ **Ата(сы)-анасы юк** — тәртибе, җае, рәте юк.— *Безнең якта Балтун Шәрәфие бар иде, мәрхүм. Сүзенең бер дә атасы-анасы булмас иде.* М. Хәсәнов.— *Атлары бар, сбруйның ата-анасы юк. Сабанның үзе бар, төрәне ремонтта.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **(Монда) атаң-анаң гына юк** — һәммә нәрсә булуга ишарәли.

АТА(СЫЗ)-АНАСЫЗ *с.* Ятим, үксез. *Антонио — ата-анасыз калган 12—13 яшьлек малай.* А. Әхмәт.

АТА-БАБА *и.* Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Ата-баба йоласы.*□*— Ата-баба күрмәгән асыл күлмәкне киеп карыйк әле, килешер микән?* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Туган, төп. *Инешне дә үзып зур урамга менгәч, солдат, гимнастерка итәген тарткалап, үзе туып-үскән ата-баба нигезенә таба атлады.* Г. Бәширов.

◇ **Ата-бабадан килгән (калган)** — борынгыдан килгән, борынгылардан калган, буыннан буынга күчкән. *Ата-бабадан килгән тәҗрибә аңа бу мәсьәләдә ачык аңлашылы сабак бирә килгән.* Г. Нигъмәти.— *Ата-бабадан калган йола булгач инде, яшь чакта шулайрак булганы яхшы.* М. Фәйзи. **Ата-бабасы(ның кабере) белән сүгү** — бик начар сүзләр белән сүгү. [*Ул тегеләрне:*] *«Китегез, хулиганнар! Үзегезгә эләкмәгәч, ачудан кеше исеме пычратып йөрисез!»— дип, ата-бабалары белән сүгеп тараттты.* Г. Ибраһимов.

АТАВИЗМ *и. биол.* Борынгы бабаларда булып та, хәзер югалган билгеләрнең организмда яңадан килеп чыгуы. *Элек Хәбир сакал-мыекны борынгы бабалардан калган атавизм күренеше дип саный иде.* Ш. Хөсәенов.

АТАЙ *и. сөйл.* Әти, ата. *Үзебез тапкан мал түгел, атай тапкан жәл түгел.* Әйтем.— *Ибраһим мәрхүм, --- өйгә килеп, Иске Казан һәм Пугач явы турында атай мәрхүмнең сөйләгәннәрен, балачакта үземнең күргәннәрне миннән сөйләтеп язып алып китте.* М. Гали.

АТАК: атак чыгу *сөйл.— к.* аты чыгу. [*Баязит*] *үзе гаҗәп зирәк булды. Моның белән атагы чыкты.* Г. Ибраһимов. **Атакка алып сөйләү** *сөйл.*— көлеп, мыскыллап, телгә алып сөйләү. [*Хәтерсез Хәлләр:*] *Төшкә хәтле сөргән җиремне төштән соң таба алмыйча, плуг эзләп йөргәнемне атакка алып сөйли бит!* Ф. Хөсни.

АТАҒА *и.* Гаскәрнең дошманга каршы көчле омтылышлы һөҗүме. *Газиз бит сугыш кырында атакага барган чагында үлгән.* Г. Бәширов. // *күч. сөйл.* Берәр кешегә каршы яки нинди дә булса максатка ирешү өчен эшләнгән тәвәккәл эш, хәрәкәт.

АТАҠАЙ *и.* 1. Атага яратып яки ялынып әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе.— *Әпипә түтәй, дир, атакай йортыннан ана каз алып килдем, дир.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Өлкән яшьтәге ир кешегә мөрәҗәгать сүзе.

3. *ымл. функ. сөйл.* Кисәктән булган бер эшкә гаҗәпләнгәндә яки курыкканда әйтелә.— *Булмас, атакай гынам! Бу кан эчендә бер минут торырга да хәлем калмады.* Г. Ибраһимов.

АТАҒАЛАУ *ф.* Һөҗүм итү, һөҗүм ясау. *Перекопны атакалау һаман да уңышсыз чыга икән, чөнки пушкалар җитешми, снаряд та бик аз.* Г. Бәширов. // *күч.* Сүгү, ачулану. [*Низам абзый*] *хәзер конюхны абзардагыча турыдан-туры атакаламады, башта тегене-моны сорашып утырган булды.* Г. Гобәй.

АТАҠЛЫ *с.* Нинди дә булса өлкәдә киң танылган, күренекле, дан казанган. *Гафур Казанның атаклы бер врачы дачасында дәваланып ята иде.* К. Нәҗми. // Берәр вакыйга уңае белән танылган, киң таралган. *«Азатлык» исемендәге шигырь революциягә кадәр атаклы булган «Алма китабы» исемле бер кечкенә көйле китапка ияреп язылган.* М. Гали.

АТАЛАНДЫРУ *ф. Йөкл. юн. к.* аталану. *Ясалма аталандыру ысуллары.* □ *— Игеннәр серкәләнер чак җиткәч, аталандырабызмы, нәмәстәкәйме дип әйтеп, доктор кайчысы белән бодайның мыекларын кыркып йөри торган булдылар.* Г. Бәширов.

АТАЛАНУ *ф. бот.* Серкә күзәнәге белән күкәй күзәнәкнең үзара кушылуы, серкәләнү. *Аталанганнан соң ике төрле күзәнәктән тереклеккә сәләтле яңа бер күзәнәк барлыкка килә.* Ботаника.

АТАЛГЫ *и. диал.* 1. Ышкы.

2. Чапкы, тәпке.

3. Тәгәрмәч ясаганда бүкәнец эчен бораулап ала торган зур борау.

АТАЛМА *и. иск.* Атама. *Хәзер «обломовщина», «бюрократизм», «оппортунизм» кебек аталмалар берсе дә калмады.* М. Әмир.

АТАЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* атау I (1 мәгъ.). Исемләнү, йөртелү. *Бу инде элекке Идел генә түгел, бу хәзер Бөек Идел дип атала икән.* Г. Бәширов.

2. Багышлану. *Теләгән көеңә, теләгән җырыңны җырла, тик берәүгә дә аталган көй булмасын.* М. Фәйзи.

АТАЛЫ-АНАЛЫ 1. *с.* Атасы һәм анасы булган. *Миннән ерак түгел генә урында аталы-аналы бер ояүрдәк балалары үзләренчә шатланышып, шаулап йөзеп йөриләр.* А. Шамов.

2. *рәв.* Ата белән ана бергәләп. *Анда инде күптән аталы-аналы ике сыерчык оялаганнар иде.* Ак юл.

АТАЛЫ-БАЛАЛЫ *рәв.* Ата белән бала бергәләп.

АТАЛЫК *и.* 1. Ата булу. / *с. мәгъ. «Миндә дә аталык хисе кузгалды», дисең.* Г. Кутуй.— *Һәрбер намуслы карт эшләргә тиеш булган аталык бурычымны гына үтим мин.* Т. Гыйззәт.

2. Нәсел өчен калдырылган, ир женесеннән булган кош-корт яки хайван.

3. *бот.* Чәчәкләрдә серкә күзәнәге.

АТАЛЫ-ҚЫЗЛЫ *рәв.* Ата белән кыз бергәләп. *Без аталы-кызлы кавышырбыз. Яшь аралаш көлеп, шатланып.* М. Җәлил.

АТАЛЫ-УЛЛЫ *рәв.* Ата белән ул бергәләп.— *Әллә инде эчемнең ярсуларын бушатудан да аталы-уллы тыймакчы буласызмы?* Ш. Камал. *Малай үсә төшкәч, җәй көннәрендә алар, аталы-уллы иртүк торып, бакчага алмагачлар янына чыга торган булдылар.* И. Гази.

АТАМА *и.* 1. Предмет, күренеш һ. б. ш. исеме.

2. Термин. *Гыйльми атамаларга, фән, китап исемнәре кебек авыр мәсьәләгә килгәч,* [*Кәрим Гайфинең*] *теле көрмәкләнә, күз алды караңгыланып китә.* Г. Ибраһимов.

АТАМАН *и.* 1. Борынгыда: ирекле казак дружиналарының сайлап куелган җитәкчесе.

2. Революциягә кадәр казак гаскәрләрендә яки авылларында төрле хәрби, административ эшләрне һәм полиция эшләрен башкару өчен билгеләнеп яки сайланып куелган начальник, башлык.— *Мондый атаманы булган казачий гаскәргә хәзер бернинди дошман алдында да куркыныч түгел иде.* Ә. Фәйзи.

3. Юлбасарлар шайкасының башлыгы. *Юк иттек атаманнарын, Яуларын алдык басып.* Жыр.

4. *сөйл. күч.* Нәрсәне дә булса оештырып, башлап йөрүче ,башлык. / *с. мәгъ.* [*Айдаров*] *бездә банкет оештыру* [*эшләрендә*] *иң атаман кеше иде.* Х. Сәлимҗанов

5. *күч. ирон.* Сугыш чукмары, канечкеч. *Яшүсмер чагын сары мыеклы тупас урядниклары, кара сакаллы кулак атаманнары белән агулап узган иске тормышны ул яшьтән үк күрә алмас булды.* Г. Бәширов.

АТАМАНЛЫК *и.* 1. Атаман вазифасы.

2. Атаман булу.

◇ **Атаманлык итү** — 1) атаман булу; атаман вазифасын үтәү; 2) нәрсәләрдер оештыру, нәрсәгә дә булса җитәкчелек итү.— *Хәзер шул Малик авыл өстеннән атаманлык итеп ята имеш.* И. Гази.

АТАН *и.* Печкән дөя. *Алтмыш көн атан булганчы, алты көн бура* [*үгез дөя*] *бул.* Мәкаль.

АТ-АРБА *и.* Ат һәм арба-чанадан гыйбарәт тарту көче, транспорт.— *Кем белә, бәлки, ата күңеле йомшарып китәр дә, ат-арбасын да биреп куяр.* Г. Минский.— *Боярга урак-печән эшләсәк, --- икенче җәйгә ат-арба алырбыз.* Г. Ибраһимов.

АТ-АТ: ат-ат уйнау — балаларның берсен бау белән яки итәгеннән ат итеп тотып, шулай ук чыбыкка атланып йөгерүдән гыйбарәт уеннары. *Без уйнарга тотындык: ат-ат уйнадык.* Ф. Әмирхан. *Үтәр туплар сикертүләр, Үтәр уйнаулар ат-атлар.* М. Гафури.

АТАУ I *ф.* 1. Кемгә яки нәрсәгә дә булса исем бирү, исем кушу, атама бирү. *Ул тыкрыкны аның исеме белән атап, тешсез Ибрай тыкрыгы дип йөртәләр.* М. Әмир. // Кем яки нәрсә дип исемләү, **йөртү**,— *Якташкаем, ул аның «кычыткан тавыгы» дип яратып атавы бит мине.* Ә. Айдар.

2. *рәв. мәгъ.* **атап.** Нәрсәне дә булса берәр кешегә махсус билгеләп, багышлап, хаслап. *Авылныкы — авылча булсын диптер инде, кунакларның үзләренә атап мунча да ягылды.* Ф. Хөсни. // Багышлап, төбәп.— *Бибкәй Солтанга атап шәһәрдә бәет чыккан икән, сезне шуны әйтергә чакырды.* Н. Исәнбәт. // Адреслап. *Ул арада Мәскәү белән Казанның үзеннән, өстенә: «Байтирәкнең Тимергали Сәйфетдин углы Акбитовка» дип, туптуры аның үз исеменә атап, төрле-төрле газеталар, китаплар килә башлады.* Г. Бәширов. // Исемен әйтеп. *Солдат авылын атап сөйли бит.* Ш. Камал. *Атап җырлыйк тагын аларның Иң батыр булганнарын.* Ә. Исхак.

Атау килеше *иск. лингв. к.* баш килеш.

◇ **Атап кую** — нинди дә булса бер максат белән билгеләп кую, шуның өчен дип саклау. *Гөлбану моңа* [*киявгә чыгарга*] *хәзерләнеп килә иде. Яшерен акча җыйнады. Үзенең иң яхшы бер сөлгесен аерып атап куйды.* Г. Ибраһимов. **Атап әйткәндә** — исемләп әйткәндә, исеме белән әйткәндә.

АТАУ II *и. иск. к.* утрау: *Ә бу җирдә менә атаулар, Зур диңгезләр, Күлләр...* Һ. Такташ. *Пароход үз җае белән бара, без атауга якынлашканнан-якынлашабыз.* Ф. Әмирхан.

АТАУЛЫ *с.* Билгеләнгән, билгеләп куелган, кемгәдер аталган, хасланган, исемләнгән.

АТБАГАР *и.* Ат караучы.

АТЕИЗМ *и.* Аллага, дингә ышанмаучылык, аллысызлык.

АТЕИСТ *и.* Аллысыз, дәһри, аллага ышанмаучы, атеизм тарафдары.

АТЕИСТИК *с.* Аллага каршы, дини хорафатларга каршы. *Атеистик пропаганда.*

АТЕИСТЛЫК *и. к.* атеизм.

АТЕИСТ-ПРОПАГАНДИСТ *и.* Массалар арасында дингә каршы марксистик пропаганда алып баручы.

АТЕЛЬЕ *и.* 1. Скульптор, фотограф яки художникның мастерское; киностудия павильоны.

2. Өс яки аяк киемнәре тегә торган мастерской. *Көнкүреш хезмәте күрсәтү ателъесы.*

АТЕРОСКЛЕРОЗ *и. мед.* Йөрәк һәм кан тамырлары системасы авыруы, артериосклерозның иң таралган формасы.

АТКАЗАНУ *ф.* 1. Дан казану, данга ирешү.

2. *с. мәгъ.* **атказанган.** Бик зур хезмәт күрсәткән, хөрмәткә лаек. *Атказанган эшче.* // Зур хезмәтләр өчен дәүләт тарафыннан бирелә торган мактаулы исем составында кулланыла. *Атказанган фән эшлеклесе. Татарстанның атказанган артисты.*

АТКАРУ *ф. диал.* Ыргыту, ташлау. // Кая да булса урнаштыру, жибәрү, озату, олактыру.

АТКЫ *и.* Кузна, ашык үеннарында кузна яки шакмакларга төбәп ыргыту өчен кулланыла торган таяк; шәмәй. *Ашыклар кырылу тавышы урынына үз аткының коры җир өстенә дөп итеп сугылу тавышыннан тыш берни ишетелми.* Ә. Фәйзи.

АТКЫЙ *и. сөйл.* 1. *к.* ат кузгалагы; атлык II. [*Газзнының*] *этисе белән әнисе колхоз болынына печән җыярга киткәндә тавыкларга аткый белән көрпә болгатып бирергә кушып калдырдылар.* Г. Галиев.

2. Зур шәмәй, аткы.

АТКЫЧ *с.* 1. Ата торган. *Һич көтелмәгәндә, күпер астыннан кинәт күтәрелеп чыккан төсле, тиз аткыч ике пушка, туры бәрдереп, бульвардагы юнкерларга юл ачты.*

К. Нәҗми. *Камалган шәһәргә махсус аткыч кораллардан авыр ташлар атканнар.* СССР тарихы.

2. *к.* аткы.

АТЛАГЫЧ, АТЛАВЫЧ *и.* Гөбе пешкәге.— *Маема кашык та тидермәм,— дип көлеп куйды Газинур һәм, учларын бер-берсенә ышкып, атлагычка тотынды.* Г. Әпсәләмов.

АТЛАМ *и. сөйл.* Адым. // Тегү машинасы энәсе белән материя өстендә бер атлаткан ара, тегү машинасы энәсенең адымы. [*Тегелә торган*] *детальләрнең бер-берсе белән тоташу урыннарына билгеләр куела, ягъни бер-берсенә капма-каршы 2—3 атлам атлатыла.* Йорт эшләре.

АТЛАМА I *и.* Беркеткеч (ишек һәм капка кебек әйберләрдә).

АТЛАМА II *и.* Сарафан, юбка кебек киемнәрне тотып тору өчен җилкә аша үткәрелгән тасма. *Атламаларны тукыманың буй җебе буйлап кисәләр.* Йорт эшләре.

АТЛАНДЫРУ *ф.* 1. Атка атланырга ярдәм итү, атка утырту. *Елкычы атаны, ике көтүче булышлык кылып, атландырдылар.* Г. Ибраһимов. *Зәйнәгыттинне чикмәннәре белән атка менгереп атландырдык та, кулына чыбыркы тоттырып, базар уртасыннан җибәрдек.* М. Гали.

2. Үз өстеңә менгереп утырту, җилкәңә, аркаңа күтәрү. *Әтисе ахырдан Илдарны күкрәгенә атландырып утыртты да чәченнән сөйде.* Г. Гобәй. *Данилов аз гына иелде дә, Митричевне җитез генә аркасына атландырып, яр буена таба китте.* Г. Бәширов. // *күч.* Үзеңә хуҗа итү, ни теләсә шуны эшләргә рөхсәт бирү. *Жирне кире алмасыннар иде дә алпавытны яңадан җилкәгә атландырмаска иде.* И. Гази.

3. *рәв. мәгъ.* **атландырып.** Берсе өстенә берсен аркылы китереп. *Атландырып чигү.*

АТЛАНМАЙ *и.* Ак май. *Өстәлдә сый да шактый мул иде: атланмай, бал, әйбәт бодай икмәге, хәтта телемләп кисеп куйган сыр да бар иде.* Ә. Еники.

АТЛАНУ I *ф.* 1. Берәр нәрсәнең өстенә менеп, аякларны ике якка салындырып утыру. [*Балалар*] *агач ботакларына менеп атланалар.* Д. Аппакова. *Илгизәр нидер кычкырып җибәрде, йөгереп барып атына атланды да кире авылга чапты.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Кемнең дә булса ирегенә хуҗа булу, иреген бетерү.— *Жилкәгә атланып алгач, Майпәрвәз тезгенне тота белгән инде.* Ә. Еники. // *күч.* Даими рәвештә сиздереп тору.— *Кая барсаң да кара сакалың өстеңә менеп атланган инде.* Ә. Фәйзи. *Әйләнеп кararга өлгермисең, картлык җилкәгә менеп тә атлана.* И. Гази.

◇ **Атланып талау** — бик нык талау; оятсыз рәвештә талау. *Авылның старосталары һәм аның тирәсендә йөрүче куштаннар юаш, фәкыйрь халыкны атланып талыйлар.* Ш. Әхмәдиев.

АТЛАНУ II *ф. Кайт. юн. к.* атлау II — *Әнкәй, әллә нишләп маем атланмый.* Т. Гыйззәт.

АТЛАНУ III *ф. Төш. юн. к.* атлау I (1, 2 мәгъ.). *Адымнар әллә ничек авыр һәм уңайсыз атланалар иде.* Ф. Әмирхан. *Югары уңышка таба тагы бер зур һәм кыю адым атланды.* Г. Гобәй.

АТЛАС *и.* 1. Уң ягы шома, ялтыравыклы булган ефәк материя төре. *Асыл киемнәргә өртелеп, Атлас ефәкләргә төренгән.* М. Гафури. *Ак атласым җитмәде, Алмаз кайчым үтмәде.* Җыр. // *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Атлас халат. Атлас юрган. Атлас тартма.* □ *Мин синең кайтуыңа атлас күлмәкләр чигеп куярмын.* М. Фәйзи.

2. Ефәк җепнең бер төре. *Атлас белән кайсы ул якасын, Ука белән тота җиң очын.* М. Җәлил // *с. мәгъ.* Шундый җептән эшләнгән. *Балдак булсын, алтын булсын, Атлас бавы ал булсын.* Җыр.

АТЛАТУ *ф. Йөкл. юн. к.* атлау I. *Богау салды дошман кулларыма һәм хурлыклы юлдан атлатты.* М. Җәлил.

АТЛАУ I *ф.* 1. Аяклар белән адымнар ясау, адымлау. *Вәлитов сикереп торды да, кызу-кызу атлап, урамга чыгып китте.* Г. Бәширов. // Нәрсәне дә булса аркылы үтү, аша үтү. *Әткәй мәчет бусагасын атлап, дүрт почмаклы караңгылыкта югалды.* Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Йөреш, хәрәкәт турында. *Югары очтан бирәү килә, Хафизаның атлавы.* Г. Камал.

2. Бару, китү. *Ул, кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады.* М. Әмир. // *күч.* Нинди дә булса юнәлештә алга бару, үсү. *Аланбаш бит быелларда әнә кая таба атлады.* Г. Бәширов. // *күч.* Күчү, керү. *Башьеллыкның дүртенче елына атлау.* □ *Бердәм басып, атлый коммунизмга Илебезнең барлык дус халкы.* Ә. Исхак.

◇ **Атлаган саен** — һәрвакыт, әледән-әле.— *Атлаган саен гафу үтенү, рәхмәт әйтү башлана, пардон, мерси... сүзләре күералар.* Г. Гали.

АТЛАУ II: **май атлау** — май язу. *Урак урмак — уйнамак, гөбе* [*май*] *атламак — җан чыкмак.* Мәкаль.— *Газинур, сиңа юлга май атлыйлар бит,— диде мич янында казан асып маташкан әнисе.* Г. Әпсәләмов.

АТЛЕТ *и.* 1. Цирк артисты, профессиональ көрәшче. // *күч. сөйл.* Таза гәүдәле, физик көчле кеше. *Ул үзенең атлет гәүдәсенә Килешеп торган гади киемне Кагыштырды, перчаткасын салды, Папиросын алды.* Х. Туфан.

2. Атлетика белән шөгыльләнүче спортчы.

АТЛЕ'ТИКА *и.* Организмда егәрлек, көч, чыдамлык тәрбияли торган физик күнегүләр системасы. *Авыр атлетика. Жиңел атлетика.*

АТЛЫ I *с.* 1. Аты бар, аты булган. *«Табигать балалары»нда төп кәһарман — өч атлы, ике сыерлы, ун баш сарыклы, ару көн итә торган Хафиз.* Г. Нигъмәти.

2. Ат җигелгән. *Атлы чаналар берәм-берәм кереп, сыйганнары бөркәүле лапас эченә, сыймаганнары ачык ишек алдына гына тезеләләр.* М. Гали. // *и. мәгъ.* Ат менгән яки ат җигелгән арбага [чанага] утырган кеше. *Капка алдында сыекча караңгылык аркылы берничә атлы күренде.* Ш. Камал. *Урамнан атыша-атыша атлылар чабып үттеләр.* Һ. Такташ.

3. Ат көче ярдәмендә эшли торган. *Атлы эш.* □ *Өч ташлы әнә шул тегермәне, ике атлы яргычы, өч сугу станы, бер йон тегү машинасы бар иде.* Т. Гыйззәт.— *Бер елны Сәхәп картка атлы молотилка белән ашлык* [*суктык*]. С. Рафиков.

Атлы гаскәр (армия)—кавалерия. *Советларның атлы гаскәреннән Азмы дошман куркып тетрәде.* М. Гафури.

◇ **Атлы уйнау** — *к.* ат-ат уйнау.— *Малайлар белән атлы уйнаган булып, урманга алып барсыннар.* Г. Гобәй.

АТЛЫ II *с. сөйл.* 1. Исемле.— *Монда, безнең авылда, Хафаза атлы матур кыз бар.* Г. Камал. // ...дип атала торган, дигән. *Иделнең* [*биек ярлары эчендә*] *Яманкул атлы озын, тирән чокыр бар.* Г. Ибраһимов.— *Үзең, зур үскәч, менә шушы мәктәп атлы йортка килеп укый башларсың.* А. Алиш.

2. *бәйл. функ. сөйл.* Сыман, кебек. *Күргән, белгән атлы булып кылану. Эшләгән атлы күренергә тырышу.*

АТЛЫГУ *ф. сөйл.* 1. Берәр эш башкарырга, кая да булса барырга ярсу, дәртләну, ашкыну.— *Тик бик яхшы белегез: авылга атлыгу — миндә бер идеал.* М. Фәйзи.

2. Ташлану, ыргылу, томырылып чабу. *Атын ул камчылап, Атлыга тагын караңгы, Тын урамнарга табан.* Һ. Такташ.

3. *рәв. мәгъ.* **атлыгып.** Түземсезләнеп, ашкынып. [*Без*] *алдыбызга алган эшебезне чиксез дәрт белән башкарып чыгарга атлыгып тора идек.* М. Әмир. // Бик ашыгып, кабаланып. *Разия атлыгып керде дә, иң элек Давыт янына барып утырды.* Г. Ибраһимов.

АТЛЫК I *с.* 1. Бер ат сатып алырлык.— *Бөтен ният: көн-төн эшли-эшли, Атлык акча җыю кирәк.* Ш. Маннур.

2. Бер атка җитәрлек (мәсәлән, азык).

АТЛЫК II *и. сөйл.* Ат кузгалагының чәчәкләре кипкәннән соң хасил була торган орлыгы. *Бәләкәй чаклары мында җимешкә дә йөрмәдем, йорт кошлары өчен атлык та җыймадым.* Г. Галиев.

АТЛЫ-ТУНЛЫ *с.* Хәлле, урта хәлле. *Атлы-тунлы дөнья тоткасы кешеләр өчен ишек яңагы ни дә, Шәмсетдин ни — икесе дә бер иде.* Г. Бәширов.

АТМЕНӘР *и. сир.* Атка атланган кеше, җайдак. *Кырыкка якын коралланган атменәр ияртеп, хан баскак «йөрәклеләр иленә» килеп җитте.* Әкият.

АТМОСФЕ'РА *и.* 1. Җир шарын һәм кайбер башка планеталарны чолгап алган газсыман тышча. *Атмосфераның калынлыгы 1000 км чамасы.* Физ. геогр.

2. *сөйл.* Һава, һава торышы. *Атмосфера үзгәруе.*

3. *күч.* Чолганыш, шартлар. *Биредә Җамали да, Гыйльми дә, башкалар да фактны теләсә ничек күпертәләр, гайбәт чәчәләр, Закирга каршы ясалма рәвештә нәфрәт һәм дошманлык атмосферасы тудыралар.* М. Җәлил.

4. *физ.* Газсыман җисемнәрнең басымнарын үлчәү берәмлеге.

АТНА *и.* Бер дүшәмбедән алып икенче дүшәмбегә кадәр исәпләнә торган җиде көнлек вакытны үлчәү берәмлеге. // Нинди дә булса бер көннән алып исәпләгәндә җиде көнлек вакыт арасы. *Бер атнадан соң тагын Минҗамалны очраттым, ялгызын гына.* А. Шамов. // Нинди дә булса эшкә, вакыйгага билгеләнгән җиде көнлек вакыт арасы. [*Монда*] *«Чулпан»ның «Сталинград атнасында» фронтка күпме ашлык, күпме бүтән төрле бүләк бирүе турында* [*язылган*]. Г. Бәширов.

Атна-ун көн — чама белән 7—8, 9—10 көн. *Атна-ун көн дигәндә, Илдар, мәктәп атын җигеп, әнисен станциягә озата китте.* Г. Гобәй.

АТНАКИЧ *и. диал.* Пәнҗешәмбе. *Кайбер атнакичләрдә аны хәлфәләр үз бүлмәләренә чакырып, алдына төрле әйбер куеп, аның җырлавын үтенәләр.* Ә. Фәйзи.

АТНАКӨН *и. диал.* Җомга.

АТНАЛАП *рәв.* (Бер яки берничә) атна буена. *Атналап эчеп йөрсә дә, байны эчә димиләр, Ишетеп хәтере калыр дип, «бай кәефсез» дип сөйлиләр.* Ш. Мөхәммәдев.

АТНАЛЫК *с.* 1. Атнага җитәрлек, бер атнага исәпләнгән. *Атналык азык.*

2. Атна буена дәвам итә торган, бер атнага билгеләнгән. *Атналык расписание.* □ *Менә яз көне тимер юлның мастерскоенда, металл җитешмәү сәбәпле, слесарьларның бер өлешенә үз хисапларына бер атналык отпуск тәкъдим иттеләр.* Ш. Камал. // (Бер) атна дәвамында эшләнгән, алынган. *Атналык савым.* □ — *Минем атналык доходым бер сум.* М. Гафури.

3. Атна саен чыга торган, атнага бер чыга торган. *Большевикларның атналык легаль газетасы «Звезда» масса арасында зур эш алып барды.* КПСС тарихы. // *и. мәгъ.* Берәр төрле эшкә, вакыйгага багышланган җиде көн вакыт арасы. *Китап атналыгы.* □ *Татарстанның Лениногорск районында татар әдәбияты атналыгы булып үтте.* Каз. утл.

Атналык мәктәп — *к.* интернат. *Рәхимнең күңеленә, балаларны интернатка — атналык мәктәпкә урнаштырырга кирәк, дигән уй килде.* А. Расих.

А'ТОМ *и.* Химик элементның төш һәм электроннардан торган бик кечкенә кисәге. *Егерменче гасыр Бөек гакылы белән уйлап тапты сине — атомны. Ләкин япон шәһәрендә американнар Чыгардылар яман атыңны.* И. Юзеев. // *с. мәгъ.* Атомга мөнәсәбәтле. *Атом ядрәсе.* □ *Химик элементларның үзлекләрен чагыштырып карау өчен Д. И. Менделеев нигез итеп атом авырлыгын ала.* Химия. // *с. мәгъ.* Атом энергиясе ярдәмендә эшли торган. *Атом бозваткычы. Атом электростанциясе. Атом бомбасы.*

АТОМИЗМ *и. филос.* Кристаллар симметрик урнашкан атомнардан торалар дигән материалистик караш.

А'ТОМ-ТӨШ *с.* Атом төшенең энергиясен файдалануга бәйләнешле, атом төшенә мөнәсәбәтле. *Атом-төш коралы. Атом-төш физикасы институты.* □ *Атом-төш сугышы куркынычын сугышның бердәнбер чыганагы — империализм тудыра.* Соц. Тат.

А'ТОМЧЫ *и.* 1. Атом энергиясе буенча белгеч, галим.

2. Атом бомбасын кулланууны яклаучы. *Атомчылар, онытмагыз, Атомчылар, уйлагыз: Юл куймабыз коллыкка без, Үлемгә юл куймабыз.* З. Нури.

АТРИБУТ *и.* 1. *филос.* Бер нәрсәнең аны башка нәрсәләрдән аерып тора торган төп билгесе. *Столыпин реакциясе чорында студент фуражкасы, Горький эшләпәсе, озын чәч, кызыл күлмәк полициянең нервысына тия торган атрибутлар иде.* И. Рәмиев.

2. *сир.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса хас булган характерлы билгеләр.

3. *лингв.* Аергыч.

АТРОПИН *и.* Эт җиләге, тиле бәрән орлыгы кебек үсемлекләрдән алына торган агулы матдә (медицинада авыртуны баса торган дару буларак кулланыла).

АТРОФИ'Я *и.* Туклану начарлану яки озак вакыт хәрәкәтсез тору аркасында аерым органнарның кечерәюе яки бөтенләй сафтан чыгуы.

АТТАШЕ *и. махс.* Илчелектә махсус хезмәт йөкләтелгән хезмәткәр, консультант-белгеч. *Хәрби атташе.* // Чит ил эшләре ведомствосында кече дипломат рангысы.

АТТЕСТАТ *и.* 1. Уку йортын тәмамлау турында рәсми документ. *Өлгергәнлек аттестаты.* □ — *Сания, тукта әле, мин сиңа аттестатымны күрсәтим.* Т. Гыйззәт. // Гыйльми звание яки дәрәҗә бирелү турындагы таныклык. *Профессорлык аттестаты.*

2. Хәрби хезмәткәрләрнең акча, кием һ. б. әйберләр ала торган документлары. // Хәрби хезмәткәр семьясына аның акчасының бер өлешен алырга хокук бирә торган документ.

3. *иск.* Отставкага чыкканда офицерларга хәрби хезмәттә булганлыклары турында бирелә торган таныклык. // *иск.* Хезмәт иткән урыннан бирелә торган рекомендация, бәяләмә, характеристика.

4. Хайваннарның нәселе турында бирелә торган таныклык.

АТТЕСТА'ТНИК *и. кит.* Өлгергәнлек аттестатына имтихан тотарга хәзерләнүче.

АТТЕСТА'ЦИЯ *и.* 1. Аттестацияләү (1 мәгъ.) эше. // *с. мәгъ.* Аттестациягә бәйләнешле. *Аттестация комиссиясе. Аттестация документлары.*

2. Характеристика, бәяләмә.

АТТЕСТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Звание бирү, исем бирү.

2. Кемгә яки нәрсәгә дә булса характеристика, бәяләмә бирү. *Техник контроль бүлегенең барлык эшчеләрен һәм контролерларын яңадан аттестацияләделәр.* Соц. Тат.

АТТРАКЦИОН *и.* 1. Цирк яки эстрада программасында тамашачыларның дикъкатен үзенә тарта торган иң эффектлы номер.

2. Паркларда, бакчаларда һ. б. ш. ял итү урынларында карусель, тир, таган кебек төрле күңел ачу уеннары.

АТ-ТУАР җый. *и.* Ат һәм җигүгә яраклы башка хайваннар.— *Пример, без колхозга кергәч, ат-туарлар һәммәбезнең күмәк ителде.* Һ. Такташ.

АТ-ТУН *җый. и.* Мал-туар; байлык. *Йорт-җир, ат-тун егерме сигез мең чамасы булыр.* Ш. Мөхәммәдев. *Галимә апаң һаман борынгыча... Ат-тун исән булса, калага алып барып кайтырга исәпләп торабыз.* М. Гафури.

АТТЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* ату (1—3 мәгъ.).— *Без аның агасын, бер заговорга катнашканлыгы өчен, хөкем белән аттырдык.* Г. Ибраһимов.

2. *махс.* Җир астындагы нефть торбага бәреп керсен өчен, торбаның стеналарын эчтән тиштерү.— *Кич белән 214 нчене аттырырга барам.* И. Гази.

3. *күч.* Көч белән бәрдереп, читкә, өскә ыргыту. *Хуҗа бер шешәнең төбенә учы белән сугып, бөкене аттырды да, шалт, табынга куйды.* И. Гази.

АТУ *ф.* 1. Кулда булган әйберне ыргыту, ташлау. *Ул рәсемне ертып учакка атты, әмма яшьтән сөйгән егетен алай тиз генә йөрәгеннән чыгарып ата алмады.* Г Бәширов. // Берәр әйберне, игътибарсыз гына, кискен хәрәкәт ясап ыргыту, ташлау.— *Мине төртеп ектылар, мин үзем егылмадым,— диде Хәмит, бишмәтен, бүрегән мич башына атты.* И. Гази. // Кемнең дә булса өстенә берәр нәрсә ыргыту. *Сезне, [кошлар], без куркытмыйбыз һәм Таш, агач та атмабыз.* М. Гафури. // Кемне дә булса көч белән күтәреп алып читкә ташлау яки егып салу.— *Я телеңә салынмыйча гына утырасың, я мин сине тәрәзәдән атам.* Ф. Хөсни.

2. Мылтык, автомат һ. б. ш. кораллардан ядрә, пуля, туп, снаряд кебек нәрсәләр җибәрү. [*Җәүдәт*] *әтисенең наганын алып, җан ачуы белән аргы якка атарга тотынды.* Г. Бәширов. // Ату коралыннан файдалана белү.— *Мин вак калибрлыдан яхшы атам.* Г. Гобәй. *Исемем белән кече лейтенант мин, Оста гына атам шикелле.* М. Җәлил. / *с. мәгъ. Өченче көндә инде ату техникасын өйрәнделәр.* Ш. Камал. // Ату коралының көче турында.— *Кара әле, улым, безнең совет пушкалары ничә чакрымга аталар?* Т. Гыйззәт.

3. Аулау максаты белән коралдан атып үтерү. *Землемер ике үрдәк атты, бу — берне; ләкин моның атканы әллә кая камышлар арасына төшеп югалды.* Ш. Камал. // Атып җәза бирү. *Аталар бит, әнием, яшер мине, Әнием, бәгърем, килми үләсем.* М. Җәлил.

4. *күч.* Коралдан аткан кебек өзек-өзек һәм көчле тавышлар чыгару. *Болыт чыгып, күк күкрәп, атты яшен!* М. Гафури.

5. *күч.* Эчке көч белән бәреп, ташып чыгу, югарыга ургу. *Янар таулар ут атып тора.* Һ. Такташ. *Ватан өчен безнең йөрәкләрдә Диңгез ярындагы таш таулар Җимереп аткан вулкан көче бар.* Ф. Кәрим. // Нинди дә булса эчке энергия, көч белән читкә чөю, ыргыту (бөке, кыршау кебек нәрсә турында). *Шампанское ату.* □ — *Миңкәң кыршау аткан, юл буена суы агып килә, ник аны карамадың?* М. Гали.

6. *күч. гади с.* Сорап алу. [*Иптәшем Вәли*] *төпчек атарга бик ярата.* А. Расих. // *күч. сөйл.* Аулау, үзенә карату. *Ул пудра ягынган, һәрбер яшь егетне атып йөрүче ханымнардан түгел.* Һ. Такташ.

7. *күч. сөйл.* Бик кызу сөйләү турында. *Сүзеңне сорап бетмисең, ул, ут кебек чәчрәтеп, әллә кайчан җавабын аткан була.* Г. Ибраһимов.

8. *ярд. ф. функ.* Фигыльнең тизлек-кинәтлек һәм тәмамлану дәрәҗәләрен ясый. *Укып ату. Язып ату.* □ *Сакалны кырып аттым.* М. Җәлил. *Рәүфәнең сердәше киңәшләрне пыр туздырып атты.* А Шамов.

АТЧАБАР *и.* Атлы хәбәрче, хәбәр йөртүче. *Күл ягыннан бер атчабар килде.* Г. Ибраһимов.

АТЧЫ *и.* Ат караучы. *Ул Ерак Себердә, Байкал буйларында юл салучыга атчы булып ялланып йөри.* Г. Ибраһимов.

АТЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к. ату* (1—3, 5 мәгъ.). *Вәли Хәсәнов караңгы төндә урманга чыгарылып атылды.* Г. Ибраһимов.

2. *Кайт. юн. к.* ату (3 мәгъ.).— *Ничек соң ул элек сине атмакчы булып, соңыннан үзе атылды?* М. Фәйзи.

3. Ташып бәреп чыгу, ургылып чыгу. *Вулкан атылу.*

4. Бик ашыгып кая да булса юнәлү, ташлану. *Ул, әрнүе һәм ярсуы белән өй эченә сыя алмыйча, бәрелеп-сугылып тышка атылды.* Г. Бәширов. // *күч.* Кемгә дә булса сарылу өчен омтылу, ташлану. *Ал чәчәккә кунган бал корты күк, синең кочагыңа атылдым.* М. Җәлил.

Атылып чыгу — күз яше, су һ. б. ш. нәрсәләрнең кинәт бәреп чыгуы турында. *Миңнулланың исән күзеннән чак кына яшь атылып чыкмады.* И. Гази.

АТЫЛЫП-БӘРЕЛЕП, АТЫЛА-БӘРЕЛӘ *рәв.* Бик ашыгып, кабаланып. [*Сәфәргали*] *атылып-бәрелеп Зәйтүнә янына килде.* Ф. Хөсни.

АТЫНУ *ф.* 1. Төрле якка селкенү, тирбәлү. *Менә өрлеккә асылынган үлчәү көянтәсе әле бер якка, әле икенче якка атынгалап торды да тынып калды.* Г. Бәширов.

2. Тирбәнү. *Кызлар таган атынудан туктап, әрҗәләреннән төшәргә өлгермәгәннәр, көтмәгәндә ике каеннының да башлары күл өстенә иелгәннәр.* Г. Гали.

АТЫ-ЧАБЫ: аты-чабы чыгу — яманаты чыгу. *Кызының яман телләргә азык булып аты-чабы чыкмагае дип гел сагаеп килгән ана мондый хат алышуны яхшы күрмәде.* Г. Минский.— *Әнә, егетләр белән тотылып аты-чабы чыккан Бәдрелхәят.* Г. Ибраһимов.

АТЫШ *и.* Берьюлы бик күп һәм кара-каршы яки төрле яктан ату.— *Майнила тирәсендә урнашкан безнең гаскәрләргә көтмәгәндә Финляндия ягыннан артиллериядән атыш башланган.* Т. Гыйззәт.

АТЫШУ *ф. Урт. юн. к.* ату (1, 2 мәгъ.). *Һәммәсе аяк өсте торып, бер-берсен кисешәләр, атышалар.* Ш. Камал.

АТЫ-ЮЛЫ: аты-юлы белән әйтү (сүгү) — әдәпсез, оятсыз сүзләр әйтү (сүгү, сүгенү). [*Мәсрүрә инде*] *җене чыкканда сүзләрне бик сайлап тормый, аты-юлы белән әйтүдән дә тартынмый иде.* Ф. Хөсни.

АУ (АУУУ) I *ы.* Бер-береңне эзләгәндә бирелә торган аваз, кычкырык. *Ерактан, әллә кайдан «Ауу!» дигән аваз да яңгырап куйгалый.* Ф. Әмирхан.

АУ II *и.* 1. Тоту яки үтерү максаты белән кыргый җәнлек яки кош-кортларны эзләү, эзәрлекләү эше.— *Буш вакытларда шахмат уйныйм, ауга йөрим.* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Ауга йөри торган, җәнлек аулый торган. *Ау сөнгесе.* □ *Егетнең ау мылтыгы да ул-бу булмагае дип кенә алынган булса кирәк.* Г. Әпсәләмов. // *с. мәгъ.* Ауга мөнәсәбәтле. *Малиновкадагы соңгы ау картиналары күз алдына килеп, күңелдәге борчуларны яңарталар гына иде.* А. Шамов.

2. Эзәрлекләнә, аулана торган җәнлек, хайван, кошкорт. *Ау артыннан кырдан кырга узып йөргәндә, җир сөреп, иген игеп торган бер сукачыга очрадым.* Дәрдмәнд. // *күч. сөйл.* Сугыш вакытында әсир төшерелгән дошман солдаты, тел.

3. Җәнлек, хайван һәм кош-кортларны тотар өчен корып куела торган тозак. *Төн буе тауларда йөрдем, Нинди аулар салмадым.* Һ. Такташ. *Шүрәле фөрьят итәдер, аудан ычкынмак була.* Г. Тукай. // Балык тота торган зур җәтмә. *Ашказар суына аулар салдым — Табаннарга түгел, сазанга.* Җыр. *Иван Никитич Иделгә балык аулары карарга төшеп китте.* М. Гали.

4. *күч.* Кемгә дә булса начар уй белән корылган хәйлә, тозак.— *Читкә җибәрүләрендә бер хәйлә булмасын дип никадәр сакландым,— шулай да ауларына төшкәнмен.* М. Фәйзи.

◇ **Ауга чыгу** — сугышта «тел» алырга, әсир алырга бару.— *Дүрт ай госпитальдә яттым, дүрт ай ауга чыкмадым, иптәш командир.* А. Әхмәт.

АУДАРУ *ф.* 1. (Утыртып куелган яки үсеп утырган нәрсәне) көч белән бер якка таба әйләндереп ташлау, егу. *Тракторчысын югалткан ялгыз трактор, өч төрәнле сабаның өстерәгән хәлдә, кибәннәрне аударып, читәннәрне, киртәләрне җимерә-җимерә авылга кереп килә иде.* М. Әмир. *«Оста аудара безнең Володя» дип уйлап ала Газинур. Чөнки агачларны бу рәвешчә аудару бүрәнә*

сөйрәтүчеләрнең эшен бермә-бер җиңеләйтә һәм тизләтә. Г. Әпсәләмов. // Бер якка кыегайту, янтайту. *Тәртә сынды, арба авып китте, сыер үзе, читәнне аударып, арт якка чыгып чапты.* Г. Бәширов. *Староста, теге колганы аударып, колганың очына беренче булып килгәнгә дип кызыл башлы зур сөлге, икенче килүчегә дип аннан кечерәк сөлге бәйләп куйды.* М. Гали. // Егу. *Ул, Шәмсинең җавабын да көтмичә, киң җилкәсе белән бер селкенеп, Даниловны төртеп аударды.* Г. Бәширов.

2. Нәрсәне дә булса икенче урынга бушату, илтеп ташлау. *Күпме бәрәңгесен казып алып, аны Хафизның келәтенә аудардылар.* Ә. Фәйзи. *Аларны аклар март числосында шәһәр читендә тирес аудара торган чокыр янына чыгарып аттылар.* Ш. Камал. // *күч. сөйл.* Кемгә дә булса кайгысын, борчуын, ачуын һ. б. ш. сөйләү, күңелендәгесен бушату, чыгарып салу. // *күч.* Күчерү, ыргыту. *Көчәеп бара торган җил ялкын баганасын Хәйриләрнең салам түбәләренә аударды да, күз ачып йомганчы аны ут камап алды.* М. Гали.

3. *күч.* Берәүнең фикерен үзгәртеп, икенче як файдасына юнәлтү, авыштыру. *Без кайбер аңлырак крестьяннарны үз ягыбызга аудару өчен халык арасына киттек.* Һ. Такташ. *Хуҗаның кодасы, бер чама белән, сайлауда үз ягына аударыр өчен, кемгә нәрсә бирергә тиешле булачагын исәпләп чыгарды.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Берәр гаепне икенче берәүгә сылтау, ягу. *Аңламаган халык гаепне Зәйнәп өстенә аудара иде.* М. Гафури. *Нургали, Сөләйманов үзе гаепле, үзе мине шушы хәлгә китереп җиткерде, дип, гаепне аның өстенә дә аударып карады.* Ә. Еники.

5. *сөйл.* Тәрҗемә итү. *Ник балаларга театр язмый Мирхәйдәр, диләр, Бар икән русчаң язарлык, әйдә тик аудар, диләр, диләр.* Ш. Бабич.

6. *сөйл.* Эчү. *Галәү белән Гайнетдинов, күк киемнәре тышыннан пальто кия-кия, тагын берәрне аударды-лар.* Г. Ибраһимов.

АУДИЕ'НЦИЯ *и.* Югары дәрәҗәле дәүләт эшлеклесенең рәсми рәвештә кабул итүе. *Гауптман: «Фюрерның бөтен вак милләт вәкилләрен бергә җыеп махсус лагерьга озатырга дигән боерыгы бар»,— диде. Аудиенция шуның белән тәмам булды.* Каз. утл.

АУДИТО'РИЯ *и.* 1. Лекция, доклад уку өчен билгеләнгән зал яки бүлмә. *Икенче көн иртән сәгать унарда Әхмәт һәм Фәткулла хәзрәт университетка килделәр һәм бер аудиториягә кәрдәләр.* Ф. Әмирхан.

2. Лекция, доклад, чыгышны тыңлаучылар, аудиториядә утыручылар. *Аудитория гөрләп кул чапты.*

АУҚАН *и. иск. кит.* Иркен. *Каңгылдап аккош йөзә аукан күлдә.* Дәрдмәнд.

АУҢЦИОН *и.* Берәр мөлкәтне яки әйберне халык алдында иң югары бәя бирүчегә сату. *Былтыр Ленинградтагы халыкара аукционда [Тамара] үстергән төлкеләр югары бәя алдылар.* Ә. Еники.

АУЛАҚ 1. *с.* Тыныч, кеше йөрми торган, кешесез. *Тирә-юнь ничектер тын һәм аулак иде.* Қ. Нәҗми. — *Ә, исәнмесез, менә монда рәхим итегез, бик шәп кабинет, үзе яхшы, үзе аулак.* Г. Камал. /*рәв. мәгъ.*— *Шул усал сүзләрегезне үйлап, аулак калган чакларда үзем ислах өчен планнар корып маташам.* М. Фәйзи.

2. *и.* Юнәлеш һәм урын-вакыт килешләрендә: кешесез, тыныч урын. *Аулакка чакырып сөйләшү.* □ — *Сезнеңчә, шулай нәмәхрәм белән аулакта төнлә утырырга ярый?* М. Гафури. // Аулак өй.— *Авыз күтәреп урам буйлап җырлап йөргәнем, аулакларда вакыт үткәргәнем бармы минем?* А. Шамов.

Аулак сүз *диал.*— сер, яшерен сүз. *Сиңа аулак сүзем бар.* **Аулак өй** — ата-ана, олылар берәр җиргә киткәч, ялгыз калган йорт; шундый йортта кич утыру яки егетләр-кызлар белән уен мәҗлесе.— *Мин мәхәббәтемне аулак өй саен өләшеп йөрмәдем.* Г. Бәширов.

АУЛАҚЛАУ *ф. сөйл.* Аулакта калу, ялгыз калу. / *рәв. мәгъ.* [*Гашия һәм Әхмәтша*] *икәүдән-икәү, үзләренчә аулаклап кына булса кирәк, өйалдында сөйләшеп торалар иде.* М. Әмир. // Аулак өйгә йөрү.

АУЛЫАУ *ф.* 1. Берәр җәнлекне, кош-кортны эзәрлекләп, ау корып кулга төшерү, тоту. *Балыкчылар, зур сөзгечләренең озын саплары югалып беткәнче суга чумдыра-чумдыра, балык аулыйлар.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Урлау. *Төннәрен сал туктап торганда, усалрак бурлаклар якын-тирәдәге авылларга барып, бераз кәсепләнеп, тавык-чебеш, каз-үрдәк аулап кайталар.* М. Гали.

2. *сөйл.* Эзәрлекләү. *Хәзер монда мине аулый башладылар.* Г. Ибраһимов. // Эзәрлекләп тозакка төшерү. *Бер хатында ул ничек итеп немец снайперын аулавын язган.* И. Гази. // *күч.* Хәйлә белән үзенә карату, кулга төшерү.— *Заһидулла мулла ул — татар Распутины, хатыннарга вәгазь сөйләү сылтавы белән аларны акрынлап аулап тора.* Ш. Камал. *Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы; Назы белән аулап ала ир-шаһбазны.* Ш. Бабич.— *Зифа буйларың, явыз уйларың белән ауладың — мине алдадың.* К. Нәҗми.

АУМА *с. к.* аумакай.— *Барысы да аума халыклар.* Г. Камал.

АУМАҚАЙ *с.* Фикерен үзгәртеп, алмаштырып, башка якка тиз ава, тиз бирелә торган, тотрыксыз, принципсыз.— *Ә бит Семенов шикелле аумакай меньшевик этләрнең революцион демократия дигәннәре шул әлеге Михаил Степаныч шикелле юан корсак, акула балыклары ич!* Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Принципсыз кеше. *Аумакайлардан, ялагайлардан, - - - Тинтәк ялкаудан Арыныйк, туган.* К. Тинчурин.

АУМАҚАЙЛАНУ *ф.* Аумакайлык күрсәтү. /*рәв. мәгъ.* — *Утырып тор, апаем,— диде Ниса, аумакайланып.* А. Гыйләҗев.

АУМАҚАЙЛЫҚ *и.* Аумакай булу сыйфаты, принципсызлык.

АУМАЛЫ *с. сөйл.* Кеше сүзенә тиз бирелүчән, аумакай.— *Безнең әти бик аумалы кеше ул.* М. Фәйзи.

АУНАҚЛАУ *ф.* Як-якка чайкалу, алпан-тилпән килү. *Ишектән, зур кулларын кая куярга белми, селтәнгәләп һәм аунаклап, Талипның атасы килеп керде.* Ә. Фәйзи.

АУНАЛУ *ф. диал.* Тәртипсез хәлдә булу, кадерсезләнеп яту. *Илай, урамда йөргәндә, җирдә ауналып яткан һичбер нәрсәне тотып әйләндерә-әйләндерә карамыйча китми иде.* Ак юл.

АУНАТУ *ф.* 1. Тәгәрәтү, бер яктан икенче якка әйләндерү. *Эт, ялт борылып, Маратны чанасыннан төртеп төшереп, карда ауната башлый.* Г. Гобәй.

2. Нәрсәне дә булса җыймыйча, аяк астында тузанда йөртү, тәртипсез яткыру, кадерсезләү.

АУНАУ *ф.* 1. Яткан килеш әле бер якка, әле икенче якка боргалану, тәгәрәү. *Караборын да, Әйдүк белән бик озакка аерылышасын сизгән кебек, җиргә ятып ауный башлады.* Һ. Такташ. // Өс-башын нәрсәгә дә булса ятып пычрату.— *Шулхәтле карда аунамасаң!* И. Гази. // Қайда да булса уйнап ятып, тәгәрәп, вакыт үткәрү турында. *Эсселәп китсәк, су коенабыз, судан арынгач, көйгән комга чыгып ауныйбыз.* М. Гали. // Авырып яки ялкауланып берни эшләмичә яту, эшсез үткәрү. *Ул өйдә вакытта көн буе йомшак түшәкләр өстендә ауный.* Г. Тукай. *Яктырды, кояш та чыкты, ә мин, йоклый алмыйча, урын өстендә аунап ятам.* А. Шамов.

2. Әйберләр турында: озак вакытлар файдаланылмау, кайда да булса яту. *Акча биреп әйбер сатып алучы кеше дә мододан чыккан, кибеттә аунаган үтмәс товарны аласы килмидер.* Ш. Мөхәммәдев. // Қайда да булса кадерсезләнеп йөрү (яту). *Аяк астында кып-кызыл алмалар ауный.* И. Гази. // Тәртипсез яту. [*Булат*] *ишектән керә-керүгә Ризванның мендәре-чикмәне янында аунаган китап белән берничә кәгазь кисәгенә ташланды.— Нәрсә укыйсың бу арада?* Г. Ибраһимов.

АУЧЫ *и.* Ау белән шөгыльләнүче, җәнлек аулаучы, сунарчы. *Моны ишеткәч, Аучы чиксез ачуланды, Ертыкчларның бу эшенә көйде, янды.* М. Гафури. *Бу күл буена кеше аягы бер дә басмаган, ул тирәләрдә аучыларның мылтыклары да шартламаган.* А. Алиш.

АУЧЫЛЫК *и.* Аучы профессиясе.— *Минем аучылыкны ташлавымның сере шунда, дуслар.* А. Шамов. /*с. мәгъ. Бию көе атасында ничек дәрт кузгатса, аучы карт өчен дә мылтык тавышы шундый булды: аучылык комарын уятып җибәрде аның.* Г. Минский.

АФГАН *и.* Афганстандагы төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. //*с. мәгъ.* Афганга бәйләнешле, мөнәсәбәтле. *Афган теле.*

АФЕ!РА *и. сөйл.* Хәйләле, хыянәтле, алдаулы эш.

АФЕРИСТ *и.* Афера белән шөгыльләнүче. [*Жоржик*] *инженер түгел, ә аферист. Ялган документлар белән яшәүче бер кеше ул.* А. Расих.

АФЕРИСТЛЫК *и.* Аферист булу. *Алар эчәләр, кәефсафа табалар, жуликлык һәм аферистлык юллары белән махинацияләр коралар, халыкны алдыйлар.* М. Гали.

АФИ!ША *и.* Спектакль, кино, концерт һ. б. ш. турында язма белдерү, игълан. *Әгәр читтән килгән артистлар булса, типография баскан афиша эленгән булыр.* Ә. Еники. *Икенче көнне шәһәр урамнары безнең афишалар белән тулды.* Г. Ибраһимов.

АФОРИЗМ *и.* Тирән мәгънәле кыска тәгъбир, хикмәтле сүз (төгәлләнгән җөмлә рәвешендә була).— [*Китапта*] *нинди дер кызыклы фикер, укучыны дулкынландырырлык мәгънә яки афоризм булырлык җөмлә очратасың.* М. Хәсәнов.

А!ФРИКАЛЫ *и.* Африкада яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе.

АФФЕКТ *и. махс.* Артык ярсу, курку һ. б. ш. кебек кискен психологик кичерешләр вакытында өянәк (приступ) тоту.

А!ФФИКС *и. лингв.* Тамыр яки нигез сүзгә ялганган кушымча.

АФФРИКА!ТА *и. лингв.* Ике тартык авазның кушылуыннан барлыкка килгән аваз (мәсәлән, ц, щ аваз-лары).

АФӘРИН *ы. иск. кит.* «Бик шәп», «бик яхшы», «яшә» мәгънәсендәге хуплау сүзе.— *Афәрин, афәрин, сездә дә шундый һиммәтле яшьләр бар икән.* Г. Камал.

АФӘТ *и.* Һәлакәт, бәла-каза, бәла, зур бәхетсезлек. *Үз башыма афәт итеп, Мал җыясым калмаган.* Г. Камал. *Башка төшкән афәт икән, бирешеп тормыйм.* Ә. Айдар.

АФӘТЛЕ *с.* Һәлакәтле, бәла-каза китерә торган; фаҗигале. *Афәтле җил.* □ *Афәтле болытлар бу.* М. Гафури.

АХ *ы.* 1. Үкенечне, ачынуны, кайгыруны аңлата. *Ах, мин җир өстен артык сөйдем бугай, Артык сөйдем аның гөлләрен.* Һ. Такташ. *Ах, әни, бу көннәрдә минем никадәр йөрәгем кайнаганын белсәң иде!* Ф. Әмирхан. // Берәр кешедән, әйбердән яки эштән ризасызлык төсмере белдерә. *Ах, йөзе кара, оятсыз! Ниләр кылан-макчы була бит!* Г. Камал. *Ах, уңмаган юләр сарык, надан сарык, Моннан зуррак бүре башын китер табып.* Г. Тукай. // Шатлану, әсәрләнү, куану, соклану кебек төсмерләр белдерә.— *Ах, сердәшем, шундый сагындым, шундый сагындым менә!* А. Шамов.— *Ах, Хәят, нинди матур син! Син бәхетле, бик бәхетле!* Ф. Әмирхан.

2. Кинәт куркуны, өркүне белдерә. *Зөһрә «Ах, аю!» дип кычкырып җибәрә.* А. Әхмәт.— *Ах! Кан! Кан! Күз алдымда әллә нинди каннар күренә!* Г. Камал.

АХАК *и.* Кыйммәтле таш буларак, бизәү әйберләре өчен файдаланыла торган, төрле төстәге берничә катламнан гыйбарәт каты минерал. *Тау башында төрле-төрле кыйммәтле ташлар: зөбәрҗәтләр, якутлар, ахаклар һәм башка эре-эре матур ташлар бик күп икән.* А. Алиш. /*с. мәгъ. Олы кешеләргә фирүзә, я булмаса дәү генә ахак кашлы алка да хәйран килешеп тора.* Ш. Хөсәенов. // *с. мәгъ.* Ахакка охшаган, ахак төсле (нурлы). *Без барыр юлларны яктыртып, Яндылар чын ахак йолдызлар.* М. Җәлил.

АХАКЛАНУ *ф. шигъ.* Ахак төсенә керү, ахакка охшап тору. *Менә тиздән, таң офыгын ярып, Кояш янартавы атылыр, Ахакланган чыклар белән юылып, Чәчәкләрнең күзе ачылыр.* Ш. Маннур.

АХ-ВАХ: ах-вах итү (килү)— ахылдау. *Беркөнне әби ах-вах итеп ишектән килеп керде.* А. Алиш.

АХИРИ *и. сөйл. к.* ахирәт (2 мәгъ.). *Нәгыйм, Илсөярнең дә, Шәмсинең дә ахирие булганга, бу сүзләргә авызын ерып, кулын гына селтәп куйды.* Г. Мөхәммәтшин.

АХИРӘТ *и.* 1. *дини.* Ислам диненчә: үлгәннән соң булачак «теге дөнья». [*Хәзрәт:*] *Сез өч көнлек дөнья өчен бөтен ахирәтне оныткагыз.* Ф. Әмирхан.

2. *сөйл.* Үлгәч тә «аерылмаска», бер-берсенең гөнаһларын өчен бергәләп җавап бирергә ант иткән бик якын ике дусның берсе. *Инде васыятькә калган, ахирәтем биргән чүлмәкне дә ваткач, тагын әллә нинди гөнаһ шомлыклары китерер.* А. Шамов. // Бик якын дусларның бер-берсенә эндәшү сүзе.— *Әйтмә инде, ахирәткенәм, кайтып кергәч, үзем дә танымадым.* Г. Ибраһимов.

АХМАК *с.* Акылсыз, юләр, аңгыра. *Һәркайчан тик тор, берәр ахмак адәм сүз сөйләсә. Бел: аңа сүз кайтарудан тик тору артык* [*лабаса*]. Ш. Бабич. // *и. мәгъ.* Акылсыз, юләр, аңгыра кеше.— *Ул унике ахмакны бүген, менә хәзерге сәгатьтән калдырмый куыгыз!* Г. Ибраһимов.

АХМАКЛАНУ *ф.* Акылсызлану, юләрләнү, ахмакларча кылану.

АХМАКЛА!РЧА *рәв.* Ахмак кешеләргә хас булганча.

АХМАКЛЫК *и.* Акылсызлык, юләрлек, аңгыралык.— *Гаяз, әйт инде, мин нинди ахмаклык эшләдем?* М. Әмир.

АХРЫ *кер. сүз.* Сөйләмгә икеләнү, төгәлсезлек, шикләнү төсмерләрен өсти: ихтимал, күрәсең, бугай, шулай булса кирәк. *Ахры, кечкенә вакытымда мин үзем дә киперәк булганмындыр инде; ничектер, әнинең үгетләве минем колагыма бер дә кермәде.* М. Гали. *Алмагачы бүген бөреләнгән, Чәчәк атар, ахры, иртәгә.* М. Җәлил.

АХРЫСЫ *кер. сүз. к.* ахры.— *Картлык баса, ахрысы, җиденче дистәгә атлый башлагач, сиздерә икән ул!* Г. Бәширов.

АХУН *и. дини.* Мөселманнарда өлкән рухани. *Ярты сәгать эчендә ахун хәзрәт өенең тирәсе халык белән тулып өлгерде.* М. Гафури.

АХУНЛЫК *и. дини.* Ахун булу дәрәҗәсе һәм вазифасы. [*Милли уллары турында:*] *Укысалар да, барыбер мөдәррис тә булмыйлар, ахунлыкны да алмыйлар.* Г. Ибраһимов.

АХ-УХ: ах-ух итү — ахылдау, уфылдау.

АХШАМ *и. иск.* Кичке эңгер-меңгер вакыт. *Исеңдә, Гайшә, әле дә исеңдә? Чәчкә җыйнарга бардык шул кичә. Таңнан ахшамга кадәре йөреп, Тамаклар кибеп, яндык без кичә.* М. Җәлил. *Кич җитте, мәдрәсә ахшам чәеннән бушанып, уку тавышы белән гөрли башлады.* Ф. Әмирхан. // *иск.* Кичә. *«Сәяр труппасы», һәр җиргә йөреп, театрлар уйный, төрле шәһәрләрдә әдәбият ахшамнары да булдырганалый.* Г. Ибраһимов.

Ахшам намазы — биш вакыт намазның дүртенчесе, кичке эңгер-меңгер вакытта укыла торган намаз. *Тиз генә кереп, мәчет капкасы турысына килеп җиттем. Анда ахшам намазыннан чыгучылардан мәдрәсәне сорап, шул минутта мәдрәсәгә барып кердем.* М. Гафури. **Ахшам чәчәге** — *к.* төн гөле. *Бер почмакта көндез күренми торган ахшам чәчәкләре ап-ак булып атып чыктылар.* Г. Ибраһимов.

АХШАРУ *и. диал.* Күмәк җырлы әйлән-бәйлән уеннарыннан берсе, яз көне балалар арасында уйнала.

АХЫЛДАУ *ф.* Сыкрану, сызлану, зарлану. [*Мәликәнең*] *ахылдауларыннан өйдә дә туеп беттеләр.* А. Шамов. // Арып, хәлсезләнеп, вах-вах итү, ах-вах килү. *Дүртенче тәүлеккә чыкканда, Фәхринең куптәнге юлдашы Акбай, арып, ахылдап, телләрен салындырып кайтты.* Г. Ибраһимов. // Гажәпләну, соклану.— *Бар икән безнең мөселманнардан да шундый мәһабәт кешеләр!— дип ахылдадылар шәкертләр.* Ә. Фәйзи.

АХЫР *и.* 1. Нәрсәнең дә булса чиге, беткән, тәмамланган урыны. *Юл ахыры.* □ *Мәкаләнең ахыры тагы да җитди вә тагы да гүзәл иде.* Ф. Әмирхан. [*Ана*] *дәфтәрне баштан алып ахырына кадәр җентекләп карап чыкты.* А. Шамов.

2. Нинди дә булса вакыт арасының соңгы моменты, беткән чагы, азагы. *Икенче көннең ахырына шәһәрдән чыккан поездларның саны йөзгә якынлашты.* Ш. Усманов. *Беркөнне, октябрь ахырларындамы икән, ноябрь башларындамы,* [*коридорга*] *бер авыл егете килеп керде.* Г. Әпсәләмов.

3. Нәтиҗә.— *Эшнең ахыры алай булып чыкмады: абый курайны минем кулдан тартып алды да үземне этеп җибәрде.* Ф. Әмирхан. *Ахыры хәерлегә була күрсен, ничбер көтелмәгән эш булып чыкты бу, балам.* Г. Ибраһимов.

4. *с. мәгъ.* Ахыргы, соңгы, азаккы, актыккы. *Ахыр сүз.* □ *Улыгыздан сезгә кайнар сәлам, Кайнар сәлам чикләр буеннан. Улыгыз сезнең ахыр сулышта да Чыгармады сезне уеннан.* Ш. Маннур.

5. *кер. сүз.* Ниһаять. [*Нәгыймә*], *ахыр, чыдамады, кулындагы алты айлык кызы Фатихәне Гайшәгә тоттырды да ире артыннан тимерлеккә таба йөгерде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Ахыр килеп (барып)** — 1) ниһаять. [*Хаҗи*], *ахыр килеп, кызның кияүгә чыгарга ризалык хәбәрен ала.* Г. Нигъмәти; 2) ахырда, соңыннан. *Ахыр килеп, сез мине матур итеп озаттыгыз.* М. Җәлил. **Ахыр заман** — 1) *дини.* Имештер, дөнья бетәр алдыннан булган вакыт, дөнья ахыры.— *Ахыр заман җитә дип сүли-сүли кайберәүләрнең авыз сулары гына корымады... Күрәбез, барысы чеп-чи ялган булды.* Г. Әпсәләмов; 2) *күч.* Артык тәртипсезлек, ыгы-зыгы турында.— *Кригерны талыйлар. Башлап безнең авыллар чыктылар. Алардан күреп Каенсар, Спасово авыллары килеп җиттеләр. Ахыр заман анда, кыямәт!* Т. Гыйззәт. **Ахыр заман баласы** — һәрнәрсәне белүгә, югары үсешкә ия булуга ишарә итеп кулланыла. *Сәфәр бабай да шакката: «Вәт ахыр заман баласы нишли бит!»— ди.* Ә. Фәйзи. **Ахыр чиктә** — 1) нәтиҗәдә. *Ярый, ахыр чиктә, сул кулың скрипкада уйнарлык булып тазармасын да ди?* Г. Бәширов; 2) бик нык, үтә, тәмам. *Өметбаев ахыр чиктә йончыган идә.* Г. Гобәй; 3) соңыннан, ахырда. *Тау кадәр газап йотып. ахыр чиктә* [*Мостафин*] *үзенең язмышы белән килеште.* Ә. Еники. **Ахыр чиккә җитеп** — 1) бик нык, үтә, тәмам. *Ул үзенең ахыр чиккә җитеп арыганын һәм йокысы килгәнен белде.* Г. Гобәй; 2) түзә алмаслык хәлдә, бик авыр хәлдә.

АХЫРГА'ЧА, АХЫРЫНА'ЧА *рәв.* Азакка кадәр, ахырга кадәр, ахырына кадәр. *Мостафа бөтен бу вакыйганы баштан ахыргача карап утырды.* Г. Ибраһимов.

АХЫРГЫ *с.* Соңгы, азаккы, актыккы. *Августның ахыргы көннәре.* □ *Шулай да үткән көз, Казанга китәр алдыннан, Хәят белән ахыргы күрешүендә Михаил үзе аңламый торган бер тойгыдан әсәрләнгән иде.* Ф. Әмирхан. *«Бу булыр иң ахыргы, иң кискен зур сугыш» тавышларына җиз трубалары белән яңгыраган оркестр кушылды.* К. Нәҗми.

Ахыр(гы) сүз — соңгы сүз. *Аның драмаларында алынган типлар, чынлап караганда, үзләре көлкеле типлар булып чыгалар. «Бәхетсез егет»нең беренче басмасына язган ахыр сүзендә Г. Камал үзе дә шуны аңлата.* М. Гали.

АХЫРДА *рәв.* 1. Соңыннан, азакта. *Ул башта байтак кына Гали турысында, Гали кайгысын кайгырып сөйләсә дә, ахырда акрынлап үзенең хосусый тормышына күчеп сөйләп китте.* Ш. Камал.

2. Актыгында, ахыр чиктә, башка чара калмагач; ниһаять. *Ахырда Сабир абзый түзмәде, башын читкә борып, тимер читле күзлеген салды һәм яшьләнгән күзләрен кул сырты белән сөртеп алды.* Ә. Еники. *Карчык ни әйтергә белми, иреннәрен кыймылдата, ахырда тизрәк чыгып китү ягын карый.* Ә. Фәйзи.

АХЫРДАН *рәв.* Соңыннан, азактан, нәрсәдән дә булса соң. *Ахырдан, теге егеттән сорашып, бу хәлфәнең Казанның иң искелек ягындагы мәдрәсәләреннән икәнен белдем.* Ф. Әмирхан.

АХЫРЫНДА *рәв.* Ахырда, ахырдан. *Ахырында* [*Фазыл*] *тәүбә итә, чын күңеленнән Советка килеп эшкә тотына, партиягә керә.* Г. Нигъмәти.

АЦЕТАТ *и. хим.* Серкә кислотасының тозы.

Ацетат ефәк — ясалма сүстән тукылган, эшләнгән ефәк. **Ацетат сүсе** — табигый матдәне — целлюлозаны химик эшкәртү юлы белән алына торган ясалма сүс.

АЦЕТИЛЕН *и. хим., тех.* Углерод һәм водород катнашмасыннан торган, янучан, агулы төссез газ.

АЦЕТОН *и. хим., тех.* Органик кушылма рәвешендәге төссез сыекча (производствода эреткеч буларак файдаланыла).

АЧ *с.* 1. Ачыккан, ашау вакыты җиткәнлектән ашыйсы килгән. *Ач корсакка аракы эчү — бик хәтәр бит ул.* Ә. Еники. // *рәв. мәгъ.* Ашамыйча, ач көенчә. [*Бәһави*], *безгә монда бервакытта да сарык итеннән пешкән шулпа бирмәсләр, аны көтсәң, ач калырсың дип, үзенә тигән порцияне ашарга тотынды.* М. Гали.

2. Туйганчы ашарына булмаган, ачлыктан интеккән. *Ач тамагым — тыныч колагым.* Әйтем. *Күңеленнән кумәч кайгысы чыкмаган бу ач шәкертнең хыялыннан бар да кычкырып көлделәр.* Ә. Фәйзи. // Күпмедер вакытлар ач тору сәбәпле, ачлык аркасында була торган, ачлыктан туган. *Җил еламый, ач үлемнең куркусыннан ил елый.* Г. Тукай. *Булып үткән кытлык еллардагы ач үлемнәрдә алар Советның иң авыр йөкләренә җигелеп тарткан хезмәтчеләр иделәр.* Г. Ибраһимов. /*хәб. функ.* *Аңа кайда да бер, төрмәдә дә ач, монда да ач.* И. Газиз. // *и. мәгъ.* Ачыккан кеше, ашыйсы килгән кеше. *Ачның хәлен тук белмәс.* Әйтем. *И калын корсаклы бай һәм «инсафлы» бай, Ай буена ач торып, ачлар хәлен сиздеңме, әй?* Ш. Бабич. // Ярлы, фәкыйрь. *Ач тормыш.*

3. *күч.* Рухи канәгатьсезлек турында. *Синең өчен өзелә эчем көнен-кичен, Ач үзәктә гыйшык уты яна, туташ!* Ш. Бабич.

4. Өлгермәгән, тук түгел (орлык турында). *Ач чикләвек. Ач көнбагыш.*

◇ **Ач бет** — фәкыйрь, ярлы кешегә карата кимсетү сүзе.— *Кем белән сөйләшкәнебезне бик яхшы беләбез, ач бет! Хәерче!* Г. Камал. **Ач кернә (әрвах)** — 1) үтә ябык кеше турында әйтелә; 2) комсыз, туймас, канәгатьсез мәгънәсендә. *Ак сакаллы картлач Таганай* [*тавы*]*да аннан куркып торгандай тора: «Бу ач кернә минем ташларны да йотар», дигән төсле утыра.* М. Гафури. *Атасы бар — ат сорый, анасы бар — тун сорый, Бер ач әрвах җиңгәсе бар — бер салырлык он сорый.* Әйтем. **Ач күз(ле)** — 1) ябык кешедә була торган эчкә баткан күз турында. *Ябык, кара-сары йөзле, нурсыз ач күзле бер киленчәк керде.* Г. Ибраһимов; 2) комсыз, туймас, канәгатьләнә белми торган (кеше). *Капиталның нигезләре череде, Калмады эзләре, Ләхет туфраклары белән Түйсын инде ач күзләре.* Г. Камал. **Ач күзләнү** — комсызлану, туймастай кылану. **Ач тору** — 1) озак вакытлар буена туйганчы ашамау. *Ул хәзер Мәрдәнша бабайның: йокы күрмәү — ач торудан яман, дигәнен бик әйбәт төшенде.* Г. Гобәй; 2) берәр максат белән ашамый яшәү, азыктан,

ашамлыктан баш тарту. *Ач та торма, йокыңны да калдырма, каралырга керер алдыннан менә шул даруны гына эч тә җибәр.* Г. Ибраһимов; 3) төрмәдә утыручыларның нәрсәгә дә булса протест йөзеннән бирелгән азыктан баш тартулары. **Ач яңаклы** — бик ябык, яңаклары батып кергән (кеше). *Шул арада озын гына буйлы, ач яңаклы бер кеше белән Фәтхи мәзин килеп чыктылар.* Ш. Камал. **Ачка (ачтан) үлү** — даими рәвештә ашау җитмәүдән үлү. *Ул ачка үлсә үләр — теләнергә бармас!* И. Гази.— *Сыерларыбыз да ачтан үлгәне юк, үзебез дә ач тормыйбыз.* һ. Такташ.

АЧАЛАҚ-ЙОМАЛАҚ: ачалак-йомалак килү — 1) күз турында: бер ачылып, бер йомылып тору. *Аның каршында утырган Йөзлебикә түзмәде, Сәйфинең ачалак-йомалак килгән күзләренә текәлеп: «Күпертмәсәнә инде, Сәйфи абый!»— диде.* Г. Бәширов; 2) *диал.* Көн турында: бер болытлап, бер аязлап тору.

АЧАМАЙ *диал.* 1. *и.* Өй, каралты түбәсендәге кайчы, атлама.

2. *с.* Бер-берсенә кыйгач, чатлаш; аркылы-торкылы.

АЧҚЫСЫЗ: күз ачкысыз — бик каты, бик көчле (буран, тузан һ. б. турында). *Күз ачкысыз бураннарда да сугышчылар җылы землянкаларда утырмыйлар.* Г. Әпсәләмов.

АЧҚЫЧ *и.* 1. Йозакны бикли һәм ача торган махсус тимер җайланма. *Нәсимә - - -ишекне бикләде дә, ачкычын күршеләргә биреп, Саимә янына юнәлде.* Қ. Нәҗми.

2. Берәр нәрсәне җыйганда, сүткәндә яки төзәткәндә гайкаларны, болтларны бору, ныгыту өчен файдаланыла торган корал. *Әхмәт насос белән шанны тоташтырган тимер көпшәләрне зур газ ачкычы белән сүтеп маташа.* Ш. Камал. *Мин ишек алдына чыкканда, Сәгыйть, аптырап, автомобильнең арткы көпчәгенә карап басып тора иде. Җирдә насос, күтәрткеч һәм ачкычлар таралып ята.* А. Шамов. // Арфа, фортепьяно, гитара кебек музыка кораллларының кылларын тарттыру өчен файдаланыла торган махсус корал.

3. *күч.* Нәрсәне дә булса аңлау, чишү өчен чара. *Ярышны кабындырып җибәрү өчен колхозчының күңел ачкычын табарга кирәк.* Г. Бәширов. // Нинди дә булса шифрлы текстны уку өчен ярдәмче булып хезмәт итә торган, хәреф һәм цифрлардан гыйбарәт билгеләр системасы. // Чит телдә язылган текстның юлга-юл тәрҗемәсе һәм шулай ук сорауларга җаваплар җыентыгы.

4. *хәрби.* Нинди дә булса әһәмиятле урын яулап алуга юл ача торган, җиңүне тәэмин итәрлек пункт. *Донбасс капкасының ачкычлары безнең кулда* [*бит*]. И. Гази.

5. *махс.* Радио-телеграф элемтәсендә электрны тиз генә тоташтыру яки өзү җайланмасы. *Телеграфист морзе ачкычын бер-ике мәртәбә шакылдатып алган иде, эштән туктады.* Ш. Усманов.

6. *муз.* Һәр нота юлының башында ноталарның югарылыгын шартлы рәвештә күрсәтү өчен куела торган билге.

Ачкыч балтасы — ачкыч очындагы чыгынты; *русчасы:* бородок.

◇ **Ачкыч ярату** — 1) биккә, йозакка башка ачкыч туры китереп ачу. *Келәт янына киләләр, ачкыч яратып йозакны ачалар.* Т. Гыйззәт; 2) шул юл белән урлау; караклык итү.

АЧҚЫЧЧЫ *и.* Ачкыч ясаучы.

АЧЛАЙ, АЧЛЫЙ *рәв.* Ачтан, ач көенчә, ачтан интегеп. *Байлар өчен берни түгел ялчыларның ачлай үлгәне.* Бәет.

АЧЛЫҚ *и.* 1. Бик нык ашыйсы килү, өзелеп ашыйсы килү, ач булу. *Эч ачлыктан бик бора башлаган чакларда* [*Челем карт*] *челем кабызып тарта, шуның белән карын бераз тыныч лаңып киткән кебек була иде.* Г. Ибраһимов.

2. Иген уңмау сәбәпле азыкка мохтаҗлык, кытлык. *Байтак кына халык җыелып, кышка ачлык булу куркынычы турында сөйләшеп утыралар иде.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Иген уңмаган, азыкка мохтаҗлык зур булган. *Ул ачлык елны, ун яшенә чыкканда, өй тулы эне һәм сеңелләре белән ата-анадан ятим калды.* Г. Бәширов. // Ашамлык, ризык, азык җитмәү сәбәпле озак вакытлар туярлык итеп, туйганчы ашамау хәле.

3. *күч.* Бушлык, рухи азыкка мохтаҗлык, эч пошу. *Хәят кызлык вакытын күңел ачлыгы белән үткәрде.* Ф. Әмирхан.

АЧЛЫҚ-ЯЛАНГАЧЛЫҚ *җый. и.* Ач һәм ялангач булу, бик зур фәкыйрьлек, мохтаҗлык.

АЧЛЫ-ТУКЛЫ *с.* Ярым ач яши торган, туяр-туймас яши торган. // *рәв. мәгъ.* Ярым ач, ярым тук; туяр-туймас. *Әхмәди абзасы ашау-эчү мәсьәләсендә алай комагай түгел, күп вакытны ачлы-туклы торуга да түзә торган кеше иде.* Г. Бәширов.

АЧУ I *ф.* 1. Нәрсәнең дә булса капкачын, каплаган нәрсәсен күтәреп яки читкә алып, читкә этәреп эчен карарга, әйбер алырга мөмкинлек булдыру. *Сандык ачу. Рояльне ачу. Кастрюльне ачу.* □ *Бикмуш бабай идәннең бер тактасын каерып ачты да, аннан бүрек хәтле бер төргәк алып, Мәрдән абзыйга бирде.* Г. Гобәй. *Мәфтуха өйгә кайтканда теге әби әнә шул кара сандыкны бирде, өеңә кайтмыйча ачма, диде.* А. Әхмәт. // Ябылган, печатьләнгән нәрсәләрнең капкачын, бөкесен һ. б. ш. алу. *Консерв банкасы ачу.* □ [*Шөҗәг*] *шешәләрнең авызын ачып, кара сыраны бер стаканга бераз бушатып, аның урынына акны сала.* Г. Камал. *Камил хатларны ачып, тиз генә укый башлый, йөзенә шатлык билгесе чыга.* һ. Такташ.

2. (Ишек, капка, тәрәзә һ. б. ш.ны) як-якка яки читкә этәреп, керергә-чыгарга яки һава алмаштырырга мөмкинлек бирү. *Газинур җилкапканы ачып, ишек алдына йөгереп килеп керде.* Г. Әпсәләмов. *Җәйге кичтә тәрәзә ачып куйсаң, Өйгә тула шомырт исләре.* Ә. Ерикәй. // Бикле ишек, капка һ. б. ш.ны биктән азат итү. *Мөхәммәтша абзый, бик озак эзләнеп, зур бер ачкыч чыгарды да, ишекне ачып, мине түргә уздырды.* Қ. Нәҗми.

3. Бәйләнгән, төйнәлгән, җыелган нәрсәне чишеп, ычкындырып, җәеп салу. [*Газиз*] *төргәкне ача, эчендә алтын беләзек, брошка, йөзекләр.* Ф. Әмирхан. *Сара йомарланган учын ачып караса, уч төбендә этисенең алмазын, янында ефәк яулыгын күрә.* Д. Аппакова. // Җәю, язу. *Җилпәзәне ачу. Парашютны ачу.* □ *Канатың ач, вакыт җитте бугай.* Г. Тукай. // Күз, авыз турында: ябык, йомык хәлдән ачык хәлгә китерү. *Марат, уянып күзләрен ачуына, төшен Саниягә сөйләде.* Г. Гобәй.

4. Қаплап, ышыклап торган нәрсәне читкә алу. *Пәрдәне ачу.* □ [*Ана*] *улына сорау күзләре белән карап алды да, аның яралы аягы өстендәге одеялны саклык белән генә ачты.* А. Шамов. [*Кызлар*] *чаршау почмакларын зур итеп ачып, капылт ябалар.* М. Фәйзи. // Яшермәү, күренерлек итү.— *Биләмгә чапкансыңдыр әле! Ир-атка йөзеңне ачкансыңдыр!— дип кычкырды «әти» кеше.* Ә. Фәйзи. // Китап һәм дәфтәрнең кирәкле битен укырлык, язарлык итеп хәзерләү. [*Паларусов*] *аерым тип сүзләрне язгалый барыр өчен блокнот битен ачып куйды.* Г. Ибраһимов. *Өстәл янында, алдына бер китап ачып, яланбашлы, кыска гына чәчле Газиз утыра.* Ф. Әмирхан.

5. Нәрсәгә дә булса үтеп керергә яки алга барырга ирек, мөмкинлек бирү. *Чикне ачу.* □ *Киләчәккә юллар ачтык Бөек Октябрьда без.* Ә. Исхак // Хәрәкәтне буып, туктатып торган киртәне алу, юл бирү. *Арыкны ачу. Газны ачу.*

6. Берәр учреждение, предприятие һ. б. ш.ның эшчәнлеген башлап җибәрү. *Көтепханә, шифаханә, тагы бел-*

мим, әллә нинди хәнәләр ачарга мөмкин. Г. Камал. *Бу кибетне ачудан аның төп теләге сәүдә итү, табыш итү булмый, бәлки халык арасына культура орлыгын чәчү була.* М. Гали. // (Җыелыш, киңәшмә һ. б. ш. ны) башлау, башлап җибәрү. *Гадәттәгечә авыл советы председателе яки колхоз председателе ачмады бу җыелышны.* Г. Гобәй. // Нәрсәгә дә булса башлангыч булу яки нәрсәне дә булса беренче булып башлау. *Син колхозга каршы көрәш ачтың, Яшәү нурын сөя идең син.* Ә. Ерикәй.

7. *күч.* Кемнең дә булса аңына җиткерү, аңлатып, ачыклап бирү. *Бу урында шагыйрь Такташ күтәргән бер мәсьәләне дә ачу кирәк булыр.* Г. Нигъмәти. *Автор үз геройларының характерын җанлы сөйләшү теле аркылы ача алган.* М. Җәлил. //Әлек билгесез яки яшерен сер булган нәрсәне билгеле итү, сәбәбенә төшенү, ачыклау. *Бу тауларның каршылыгын сындырырбыз, серен ачарбыз дип ышанам.* А. Әхмәт. *Нинаять, бер вакыйга бу табышмакның серен ачарга ярдәм итте.* Ә. Фәйзи. // Фаш итү. *Аның Уралда ике экспроприациягә катнашкан Әхмәт Хәйруллин исемендә йөргән кеше икәнен монда ачтылар.* Г. Ибраһимов. *Үз гомерендә әллә никадәр, әллә ни төрле җинаятьләр ачкан зур тәҗрибәле милиционер да* [*бу хәлгә*] *шаккатып, гел башын чайкап торды.* Г. Гобәй. // Нәрсәгә дә булса ачыклык кертү, билгеләү. *Абыйның эчен яручы доктор аның эчү-эчмәвен ачачак.* Һ. Такташ.

8. Чәч турында: аеру, яру, як-якка тарау. *Гади генә киенгән, чәчләрен урталай ачып, иңбашына ак шәл салган урта яшьләрдәге хатын килде.* А. Шамов. *Апасы алга таба тарап төшергән кара, шома чәчен маңгай турысыннан ачып җибәрде.* И. Гази.

9. *күч.* Аңлы, тәҗрибәле итү, аң-карашын үстерү, агарту.— *Йөргән таш шомара, диләр бугай. Дөрес, ахрысы, йөрү, эшчеләр белән аралашу сине тагын да ачкан.* Х. Садрый. *Чын күңелдән синең язганнарың Карт көнемдә ачты тагын да аңым.* Ә. Исхак. // Күңелен, кәефен күтәрү. *Газизә башта хәзер торып китәргә генә уйлаган төсле аптырап торса да, сүзнең соңгысы аны бераз ачып җибәрде.* Ш. Камал. *Матур кызга гашыйк булсам, Гармонь ача күңелемне.* Ә. Ерикәй.

◇ **Ачып салу** — 1) сөйләп бирү. *Иптәшләр судына үзенең йөрәктәге барлык нәрсәләрен ачып салырга уйлады, һаман сер саклап йөрергә теләмәде.* А. Алиш; 2) сурәтләү, тасвирлау. *Чехов үзенең әсәрләрендә тормыш каршылыкларын зәһәрле көлү аша ачып салган.* Г. Нигъмәти; 3) аңлатып бирү. *Г. Камал иҗатын киң рәвештә ачып салырлык зур тәнкыйть мәкаләләре бөтенләй күренми.* М. Гали.

АЧУ II *и.* Бик тирән нәфрәтләну хисе, бик нык ярсу тойгысы. *Ела, ела, бераз эчләрең бушар, ачуларың басылыр.* Г. Камал. // Ризасызлык, үпкәләү хисе, эчтәге үпкә, нөктә. *Фазыйл хакында бу кызның теге вакыттагы ачуы — үзен алырга теләмәве — йөрәгендә нык саклана булса кирәк.* Г. Ибраһимов.

◇ **Ачу алу** — ачуны басарлык берәр эш эшләү, явызлыкка каршы явызлык итү, үч алу.— *Миңа хыянәт кылганлыгы өчен аннан ачуымны алдыммы?* Г. Камал. **Ачу итү** — үч алырга теләү, үчләну, үч итү. *Беткә ачу итеп тунны утка якмыйлар.* Мәкаль. *Нәфисәгә бу явыз бәндә бөтенесен дә белә, аны усал ният белән, ачу итеп юри шулай үчекли кебек тоела башлады.* Г. Бәширов. **Ачу йоту** — ачу килгәндә аны кешегә белдермәү, кешегә сиздермәү. *Ачу йоту — тау йоту.* Мәкаль. **Ачу кабару** — берәр кешегә яки нәрсәгә карата бик нык ярсып, көчле ачу тойгысы кичерү, көчле ачу белән яну. *Ачуы кабарып җиткән Акбүз ят кешенең каршысына сикереп килеп басты.* Г. Гобәй. **Ачу килү** — берәр сәбәптән ачу тойгысы барлыкка килү, ачулану. **Ачу куу** — ачу итү, ачу итеп эшләү.— *Аның белән ул хакта сөйләшә башласаң, ачу куа, үч ала, диячәк.* Ә. Баянов. **Ачу саклау (тоту, куу)**—ачуланып йөрү. *Мужик булып язам, йөрәктә дә Англиягә ачу сакламыйм.* Һ. Такташ. *Мин соңыннан аңа ачу тотып йөрдем.* Г. Гобәй. **Ачуым — ачу...**— кемнәндер үч алырга кызып, ашкынып торганда әйтелә: ачуымны китермәсен (китерсә)! [*Нәфисә*], *ачуым — ачу, интектерәм әле мин аны, дип әйтеп әйтәдер, ди.* Г. Бәширов. **Ачуым килмәгәс** *сөйл.*— бик ачуланып, ярсып берәр кешене яки әйберне кимсетеп сөйләгәндә сүз арасына кыстырыла. *Ә сиңа орлыкларның да яхшысын гына бир, кыш буе кешеләрең-не дә укыт, тәҗрибә ясарга дип, ачуым килмәгәс, әллә нинди нәмәстәкәйләр дә кайтарт!* Г. Бәширов.

АЧУ III *ф.* 1. Органик матдәләрнең ачы тәм керү, бозылудан гыйбарәт булган таркалу процессы. *Суытылмаган сөт сауганнан соң 2—4 сәгатьтән үк ачый башлый.* Йорт эшләре.

2. Махсус ачыткы яки чүпрә салудан әйбернең ачы хәлгә килүе. *Ачыган камыр.* □ *Камырны чүпрә салып изгәч, өстенә чиста сөлге яисә тастымал каплап, ачу өчен җылы урынга куярга кирәк.* Йорт эшләре.

3. Тире, йон турында: ию, черү. *Аның тез буыннары калтырый, аяклары ачыган йоннан басылган киез катаны чак кына өстери иде.* А. Шамов. *Ачыган тире исе дә, тагын әллә ниләр исе дә килә иде.* Г. Бәширов.

АЧУ IV: **карын (тамак) ачу** — ачыгу.— *Карын бик ачып кайткан иде, аннан шундый җылы сүзне ишеткәч, теге сабакны тагын ике-өч тапкыр кычкырып кабатлап алдым.* М. Гали.

АЧУЛАНДЫРУ *ф.* Кемнең дә булса ачуын китерү. *Шуңа күрә дә аны мыскыл итү, ачуландыру өчен бездә бу кушамат өстенә тагын бер кушамат табарга туры килде.* М. Әмир. // Үпкәләтү. *Картны бер дә кирәксезгә ачуландырырга теләмичә, ул сүзне икенче якка борып җибәрергә тиеш тапты.* Ш. Камал.

АЧУЛАНУ *ф.* 1. Берәр кешегә яки нәрсәгә дә булса ачу килү, кызып китү. *Ул кайчак бер сүз дә эндәшмичә урыныннан тора, нәрсәгәдер ачуланган, кәефе киткән кебек, кашларын җыера.* А. Шамов. // *рәв. мәгъ.* **ачуланып.** Ачу белән, кызып-ярсып. *Печәнчеләргә дә нидер булган, алар, башларын да күтәрмичә, ярсып, хәтта ачуланып эшлиләр.* Г. Бәширов. *Йомагыл, ачуланып, - - - каты-каты сүзләр әйтеп карады — берсенең дә файдасы булмады.* М. Әмир. // Үпкәләү. *Миһриҗиһан белән дә сөйләшмим, ул миңа ачулангач, мин дә аңа ачуланган булдым.* М. Гали.— *Мин, әнкәй, сиңа беркайчан да ачуланганым юк һәм ачуланмам да.* Р. Ишморат.

2. Әрләү, орышу. *Ул башта әлеге яшь кызны чакыртып алып, җелегенә сеңдергәнче ачуланды.* Г. Гобәй.— *Ачуланма, әткәй, мал дауларга кайтмадым.* Г. Ибраһимов.

АЧУЛАНЫШУ *ф.* Үпкәләшү, кычкырышу.— *Без үзебез дә ул кушаматны ачуланышкан чакларда гына исенә төшерә идек.* М. Әмир.

АЧУЛЫ *с.* Ачуланган, кемгә яки нәрсәгә дә булса ачуы килгән; усал. *Стена артыннан Хөсәеннең ачулы тавышы ишетелә.* Ф. Әмирхан. *Хәйдәр, элеккечә ачулы чырай белән, булачак Галиябануга акыл өйрәтергә кереште.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Ачу белән, усал итеп, усалланып, ачуланып. *Мәүлиха түти кызын китте, аның - - - күзләре ачулы карыйлар иде.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Усал, куркыныч. *Ул ачыгып кайтса, ифрат ачулы була.* Ш. Камал.

АЧУТАШ *и. хим.* Марганец, алюминий кебек күкерт тозларының исеме; составында шундый тозларның кристаллары булган, дезинфекцияләү һәм кан туктату өчен кулланыла торган таш. *Гомерен ачуташлар, нашатырьлар сатып үткәргән Хәсби карчык Хәлимнәр ишеген ачты.* Г. Гали. *Керосин диеп киндер мае, - - - шикәр диеп ачуташ җибәргәнсез.* Ш. Мөхәммәдев.

АЧЫ *с.* **1.** Лимон, мүк җиләге, серкә кебек нәрсәләрнең ачылыгын хәтерләтә торган бер тәм. *Ачы алма. Ачы кызыл аракы. /хәб. сүз. Җир җиләге ачы була, Үз вакытында пешмәсә.* Җыр.

2. Әрем, борыч, хинин тәме кебек тәм. *Ачы дару.*

3. Сизү органнарына бик начар тәэсир итә торган, агулы. *Һавада ачы төтен исе, дары исе һәм саз исе аңкый.* А. Шамов. // *и. мәгъ.* Нинди дә булса әйберләр составында булып, сизү яки кайбер башка органнарга начар тәэсир итә торган тәм яки ис. *Төтен ачысы. Тәмәке ачысы.* □ *Без эшләп чыгарган сабынның ачысы ашаган [синең кулыңны].* Ә. Фәйзи.

4. Ачыган, бозылган, искергән. *Ачы бәрәңге.* □ *Ачы катык кирәк булса, асраулардан сорарсың.* Т. Гыйззәт.

5. Махсус ачытылган. *Ачы камыр.*

6. Җир, туфрак турында: кислотасы артыграк булган.— *Безнең үз колхозыбызда гына да әллә ничә төрле туфрак бар. Берсе ачы аның, берсе төче дигәндәй, берсе структуралы, икенче төрлесе тузан гына.* Г. Бәширов.

7. Кайгы тулы, кайгылы, моң-зарлы, бик күңелсез, бик авыр. *Ачы язмыш.* □ *Алар икесе дә, ачы ятимлекне татып, ана иркәләвен күрмичә үскәннәр.* Г. Әпсәләмов. // *и. мәгъ.* Бәхетсезлек, уңышсызлык, кимсетелүләр тәэсирендә булган авыр хис. *Ялгызлык ачысы. Нәфрәт ачысы.* □ *[Халык] нәфрәтеннән, йөрәк ачысыннан Көзге урман шашып шаулады.* М. Җәлил. // Кайгы аркасында булган, кайгы китергән. *Элеккеге ачы күз яшьләре хәзергенең тәмле ашларына таммасыннар әле.* А. Әхмәт. // Каты авыртулы, үзәккә үтәрлек. *Тик Борисов шул минутта ук күкрәгендә кинәт бер ачы сызлау сизде.* Г. Бәширов.

8. Бик авыр, физик һәм рухи яктан зур түземлек сорый торган. *Шулкадәр азапларга чыдап, ачы сынауларга түзеп, бөек әмәлләр өчен көрәшеп дөньяда яшәүнең дә зур бер мәгънәсе шунда [шул якты тойгыда] түгелме соң?* К. Нәҗми. // *и. мәгъ.* Михнәт, кайгы-хәсрәт тәэсирендә булган авыр хәл, авырлык турында. *Ачыны татымаган — татлының тәмен белмәс.* Мәкаль.— *Ярый, туган, дөньяның ачысы да булды, төчесе дә булды.* Г. Ибраһимов.

9. Үзәк өзгеч, бик каты, ярсулы.— *Әнинең: «Әхмәтшакир бәгърем, үтерәсең бит!» — дигән ачы һәм әрнүле тавышы ишетелде.* Ә. Фәйзи. *Минем йомшак дәшүемне ишеткәч, ул тагын да ачырак тавыш белән кычкыра башлады.* М. Әмир. */рәв. мәгъ. Шул вакыт кинәт Алтынчәчнең ачы кычкырган тавышы ишетелә.* М. Җәлил.

10. Бик көчле, үзәккә үтә торган. *Бушап калган көзге авыл урамының ачы җиле баланың юка шәлгә төрелгән чандыр тәнен куырып алгандай булды.* Г. Минский.

11. *күч.* Ачулы, усал, үткен. *Назыйр кереп китүгә, Җиһангир тагы ачы сүзләр ата башлады.* Г. Ибраһимов. *Баштарак Хәлим орышырга, ачы иттереп сүгеп ташларга уйлаган иде.* А. Шамов. */хәб. сүз. Келт-келт итеп Гөлкәй көлеп куйды, Ай-һай телең ачы, Харис!— дип.* М. Җәлил. // *күч.* Үткен, көчле. *Г. Камал ачы сатирасы аркылы буржуа-мещан тормышындагы ваклыкларны, җитешсезлекләрне, тискәрелекләрне рәхимсез тәнкыйть уты астына ала.* М. Гали. // *и. мәгъ.* Кислота. *Ачы бирү. Күкерт ачысы эшли торган камера.*

Ачы бал — бал яки шикәр суына чүпрә яисә башка ачытқыч салып ачытылган исерткеч эчемлек.— *Шундый сагындырып, шундый көттереп килгән сөенеч, ачы бал шикелле, азрак башны әйләндерә иде.* Г. Бәширов. **Ачы какы** *бот.*— күбесенчә кырда, уҗым арасында үсә торган, озынча яфраклы, вак кына сары чәчәкле чүп үлән; сабагы ашарга ярый. *Хәтфә үләнле, кояшлы аланнарда балтырганнар өлгерә. Балтырганнарга ияреп ачы какылар, кәҗә сакаллары күтәрелә.* А. Гыйләҗев. **Ачы су** *сөйл.*— 1) составында углекислота булган минераль су; 2) аракы, гомумән исерткеч эчемлек. **Ачы тоз** — эч йомшарткыч дару; *русчасы:* английская соль. **Ачы торма** — 1) тамыразыклы бакча үсемлеге, яшелчә төре; *русчасы:* редька; 2) шул үсемлекнең зәһәр исле һәм бик ачы тамыры.

◇ **Ачы белән авызлану** — 1) михнәтле, авыр тормышта туу, үсү. *Василий ачы белән авызланды. Шактый озак татыды ул ачыны.* А. Гыйләҗев; 2) телгә ачы, усал булу. **Ачы телле** — усал, чәнчеп әйтә торган (кеше турында). *Гөлләр, ап-ак сакаллы картның бу кадәр ачы телле булуына гаҗәпләнеп, сүзен дәвам иттерде.* Г. Әпсәләмов. **Ачы тир** — авыр физик хезмәт турында.— *Безнең күпме ачы тир сыгылып салынган ул сабынга.* Ә. Фәйзи. **Ачы тәҗрибә** — авыр сынаулар, баштан үткән нәрсәләр турында; гомумән тормыш тәҗрибәсе.

АЧЫГУ *ф.* **1.** Ашыйсы килү.— *Әни, әнә Рокыяң ачыгып кайткан, арып кайткан, син аны тагы аркасыннан да сөймәгән, чәченнән дә сыйпамагансың.* Ф. Әмирхан. *Ачыгып ау эзләгән ялгыз бүре урман буйлап барган чакта моны күрде.* М. Гафури.

2. *күч.* Бик нык мохтаҗлыкта яшәү, ач яшәү. *Узган җәй күп кенә җирдә ашлык булмаган, халык ачыккан.* М. Гали.

АЧЫК *с.* **1.** Ябылмаган, ачылган. *Ачык тәрәзәдән керган төн һавасы, гөлләрнең хуш исен аңкытып, иң кадерле, иң газиз истәлекләрне уятты.* Г. Бәширов. // Йомык түгел, йомылмаган. *Ул, һаман зинданның авыр тынлыгын тыңлап, ачык күз белән ята.* Г. Ибраһимов. // Ачып калдырылган. *Өстәл өстендә ачык бер китап тора.* Г. Камал.

2. Бикләнмәгән, биксез, йозаксыз. // *рәв. мәгъ.* Бикләмичә, япмыйча.— *Кладовой ишеген ачык калдырганнар.* Г. Камал.

3. Түбәсез, ябусыз; каплавычсыз. *Шунда үк сыерлар һәм атларга җәен куну өчен өсте капланмаган, ачык абзарлар эшләнгән.* М. Гали. *Анда, урам туҗырып, Америка гаскәрләре узып бара, ачык машиналарда арлы-бирле олы чиновниклар йөреп тора иде.* Г. Гобәй. // *рәв. мәгъ.* Капланмыйча, ябылмыйча. *Силос базының өсте ачык калган да, ул бозылган.* Г. Бәширов.

4. Бернәрсә белән дә ышыкланмаган, тау-чокырлары, урман-болыннары булмаган. *Ачык кырда ат гәүдәләре сибелеп ята.* Ш. Усманов. *Икәве дә ике яккарак китеп, агачларны үтеп, бөтенләй ачык урынга килеп чыктылар.* М. Гали. // Иркен, сахра. *Ак чәчәкле ачык җирләрдә янып-пешеп тора икән лә чыпчык башы хәтле җиләкләр.* Ш. Маннур. *Ачык ялан, ямьле тугайларда бик күңелле үтәр гомерләр.* Ш. Бабич. //*махс.* Дошман һөҗүменнән саклану чаралары күрелмәгән, яшеренмичә турыдан-туры көрәшә торган. *Батарея хәзер ачык позициягә күчте.* К. Нәҗми.

5. Тәннең муен, күкрәк, җилкә тирәләре бераз күренерлек итеп тегелгән, ябык түгел.— *Мин үй-хисләремә генә түгел, хәтта дүрт елдан соң беренче тапкыр кигән ачык якалы ак күлмәгемә дә иялэшеп җитә алмадым.* Ә. Еники. // Шәрә, ябылмаган, төймәләнмәгән. *Җил кояш исен, дымлы туфрак исен китереп, борыннарны кытыклый, җиңел канаты белән битләргә, ачык муеннарга сыйпалып китә.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Япмыйча, төймәләмичә; ачык, шәрә. *Тәне эсселәнеп китте, кулы якасын ычкындырырга сузылды,— ул яканы ачык йөртергә ярата иде.* Г. Әпсәләмов.

6. Аяз, болытсыз. *Ачык көн, якты кояш астында кырыгар-кырыгар кешелек табыннар ясалды.* Г. Ибраһимов. *Талпына-талпына тургайлар сайрый, саф, ачык күк йөзендә кояш йөзә.* А. Шамов. *Көзнең ачык күгендә йолдызлар аеруча кыю җемелдиләр.* Ә. Фәйзи.

7. Яхшы таныла, күренә торган, аңлаешлы. *Кәгазьгә ачык, матур хәрефләр белән язылган иде.* Г. Гали. // *рәв. мәгъ.* Аермачык, яхшы, аңларлык итеп. *[Язуның] сул почмагында бик үк ачык төшмәгән штамп бар иде.*

Ә. Еники.— *Күрдеңме,— диде ул үз хезмәтеннән тәм тапкан тавыш белән,— тамга нинди ачык төште.* Г. Әпсәләмов. // *рәв. мәгъ.* Бик яхшы, аермачык итеп (күрү, искәрү, ишетү, хәтерләү һ. б.). *Соңыннан ниләр булганын ачык хәтерли алмыйм.* Г. Ибраһимов. *Төркемдәгеләрнең кем булулары ачык күренми, шулай да, тавышларына караганда, күбесе карт-коры, хатын-кыз булырга охшый иде.* Г. Бәширов. *Аргы яктан ачык ишетелә Затворларның кырыс тавышы.* Ә. Исхак.

8. Ачыктан-ачык; беркем өчен дә яшерен, сер булмаган. *Шуннан авыл белән алпавыт арасындагы астыртын дошманлык ачык дошманлыкка әйләнеп китә.* И. Гази.— *Шулкадәр ачык хыянәтләреңне ни белән капламак булып яныма кердең?* М. Фәйзи. // Шиксез, шөбһәсез; билгеле булган. *Кеше шундый кояш шикелле ачык нәрсәләрне аңламый азапланса, минем каным кыза башлый.* Ф. Әмирхан. *Әйтергә ирендеме, әллә бу бөтенесе өчен болай да ачык мәсьәлә идеме, ул сүзен дәвам иттермәде.* Ә. Фәйзи.

9. Дөрес, туры; конкрет. *Шәмгун карт ачык җавап бирмәде.* А. Шамов. *Булат турында ачык сүзне ул да әйтмәде.* Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* Дөрес итеп, турыдан-туры, яшермичә, ихлас күңелдән.— *Болай ачык бер дә әйткәне юк.* Ф. Әмирхан.

10. Барлык теләгән кеше керергә, катнашырга мөмкин булган. *Ачык дәрес. Ачык суд.* □ *Без бүген комсомол оешмасының ачык җыелышын үткәрәбез.* Р. Ишморат. // Легаль, яшерен булмаган. *Татар эшчеләренең беренче зур ачык митингларында ул меньшевикларга, эсерларга каршы сугыш ача.* Г. Ибраһимов.

11. Башка төсләр белән буталмаган, тонык булмаган, саф төс. *Ул өстенә җәйге, ачык соры төстәге шакмаклы костюм кигән, башына кызыл ефәк яулык бәйләгән.* А. Шамов. *Мәһабәт төз наратларның очлары ачык яшеллек белән яналар.* Ә. Еники. // Яңгырап торган, тонык булмаган (тавыш турында).— *Ипташләр!— диде ул сөйкемле ачык тавыш белән.* Г. Әпсәләмов.

12. Мөлаем, көләч.— *Ачык чырай булганда, аннан да тәмле сый-хөрмәт юк инде, диде шәлле хатын.* А. Шамов. *Ул үзе аю кебек дәү вә көчле һәм бик ачык егет иде.* Ш. Камал. // *рәв. мәгъ.* Кәефле, күтәренке күңелле, мөлаем булу турында.— *Өч көн ачык булсаң, дүрт көн боек буласың.* М. Фәйзи.

Ачык диңгез — барлык илләрнең дә бердәй файдалануындагы диңгез. **Ачык иҗек** *лингв.*— сузык авазга бетә торган иҗек. *Соңгы елларына чаклы Тукай үз шигырьләренең күп кенәсендә ачык һәм ябык иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә нәүбәтләнүләренә игътибар итте.* Г. Нигъмәти. **Ачык маңгай** — киң маңгай. *Нәфисә кояш белән язгы җилдә алсуланган озынча битен һәм ачык маңгаен яулык чите белән сөрткәләп алды.* Г. Бәширов. **Ачык хат** — 1) бер ягына (өлешенә) адрес, икенче ягына (өлешенә) хат языла торган конвертсыз карточка. *Хәсән матур күренеш яки матур хатын-кыз рәсемнәре төшерелгән ачык хатларны тезде.* Ф. Әмирхан; 2) кемгә дә булса аталып, газета-журналда басылган хат. [*Г. Камал*] *«Кызыл Татарстан» газетасының 1929 елда чыккан 93 нче номерында --- ачык хатны бастыра.* М. Гали.

◇ **Ачык авыз** — 1) булмаган, жебегән, булдыксыз. *Мин сез уйлаганча ук гамьсез һәм ачык авыз булып чыкмадым.* А. Шамов; 2) гамьсез, игътибарсыз.— *Ул ачык авызлар малайның коега төшкәнен сизми дә калырлар.* И. Гази; 3) уйламыйча күп сөйләүчән кеше турында. *Авылдан кайткач, минем борчылып сөйләгән сүзләремне Хафаза, ачык авыз, аны-моны абайламыйча, Басыйрга әйткәләгән булырга кирәк.* Ә. Еники. **Ачык итеп** — 1) яшермичә, турыдан-туры, дөрес итеп.— *Жыелышта син барын да ачык итеп әйт, ялгышыңны төзәтергә сүз бир һәм төзәт.* Р. Ишморат; 2) гади һәм аңлаешлы итеп. *Ул тиз һәм ачык итеп җавап бирде.* М. Әмир; 3) бутамыйча.— *Ачыграк итеп әйт, Нуретдин абзый,— диде арткы рәттән кемдер, каты гына кычкырып.* Ә. Еники. **Ачык йөзле (чырайлы)** — мөлаем, сөйкемле; көләч. *Күзлек кигән, гаҗәп ачык йөзле, сүзгә һәвәс карт доктор килеп керде.* Г. Минский. *Аның элекке көр, ачык чырайлы йөзенә ваем күләгәсе тартылды.* Қ. Нәҗми. **Ачык калу** — хәл кылынмаган, билгеле бер карар чыгарылмаган килеш калу, чишелмәү.— *Хәзергә аны коммунадан чыгару-чыгармау мәсьәләсе ачык калды.* Ш. Қамал. **Ачык карашлы (фикерле)** — укымышлы, алдынгы карашлы; аңлы. *Ул анда аңлы, ачык карашлы кызлар, китаплар, сөйләнгән яңалыклар эчендә үзенең кызлыгын, кыз йөрәклеген сизә башлады.* Г. Ибраһимов. **Ачык һава** — 1) саф һава, тыш. *Без, пароходыбызның корыч кабыгын ачып, тизрәк ачык һавага чыгарга ашыктык.* Ф. Әмирхан; 2) ялан, кыр. *Землянкага кире кайтырга мөмкин түгел, юлда адашып, бөтенләй ачык һавада калуың бар.* М. Гали.

АЧЫҚЛАНУ *ф.* **1.** Билгеле булу, беленү, хәл ителү. *Вакыт — шифалы нәрсә, күп тә үтмәс, бар да ачыкланыр, бар да үзенең эзенә төшәр.* Ә. Еники. *Партизаннарның җиңәселәре, хәвеф-хәтәрсез кузгалып китәселәре ачыкланды.* Г. Гобәй.

2. Яхшырак, ачыграк ишетелү яки күренү. *Көй якынайган саен ачыклана барды.* Г. Бәширов. *Хәсәннең тавышы ачыклана бара.* Қ. Нәҗми.

3. Ачылу, яктыру, ачыграк, яктырак хәлгә килү. *Төсе уңа төшкән күк көймәсе [йөзе] тагын да биегәйде һәм ачыкланды.* Г. Бәширов.

АЧЫҚЛАУ *ф.* **1.** Ачу, ачык, аныклык билгеле итү; ачыклык кертү. [*Хәсән бай белән Закир*] *арасындагы конфликтны ачыклау өчен бу сүзләр генә җитми.* М. Җәлил. // Кемне яки нәрсәне дә булса аныклык белү. *Исерекне айнытып чыгару пунктына озаттылар, шикләне ачыклау өчен милициягә тапшырдылар.* Г. Минский.

2. Белү, өйрәнү.— *Әле бит безнең кыя башына менәсебез, һөҗүм позициясенә урнашасыбыз һәм атаканың кайбер моментларын ачыклыйсыбыз бар.* И. Гази. *Укчы ротадан разведкага җибәрелгән Газинур отделениесенең бурычы һөҗүм алдыннан дошман оборонасының характерын ачыклау иде.* Г. Әпсәләмов.

АЧЫҚЛЫК *и.* **1.** Ачык булу, ябылмаган, капланмаган булу.

2. Урмансыз, агачсыз урын, алан, аланлык. *Мин, кечкенә бер ачыклыкны сикереп үтеп, юлым өстендә торган җәенке карама артына барып постым.* А. Шамов. // Ачык урын, бушлык, аралык. *Буран өйнең тирәсенә сылап салмый, бәлки кар белән өй бүрәнәсе арасында ярты аршын чаклы ачыклык калдыра.* Г. Ибраһимов. /*с. мәгъ. Бер ачыклык җирдән каравылчы безне күрде дә, аты белән безгә таба килә башлады.* М. Гали.

3. Мөлаемлык, ачык йөзлелек. *Ул Зиннәткә ниндидер бер риясыз ачыклык һәм аеруча игътибар белән кызыксынып карап утырды.* Г. Бәширов. *Фатыйманың матур йөзендәге ачыклык һәм тавышындагы самимият Шакирга аны һәм дус, һәм якын итеп күрсәтә.* Ф. Әмирхан.

АЧЫКТАН-АЧЫҚ *рәв.* Яшермичә, кеше алдында. *Ачыктан-ачык сөйләү.* □ *— Хәят! Сез мине болай ачыктан-ачык үз тойгыларымны язганга гаепләмәгез.* Ф. Әмирхан. *Бу сүзне пышылдап түгел, һәркем ишетерлек итеп ачыктан-ачык сөйләргә кирәк.* Р. Ишморат. // Күзгә күренеп, күз алдында. *Ул балалыкның соңгы елларында була торган дәвердән чыгып, ачыктан-ачык кызлар ягына аерылды.* Г. Ибраһимов. // Бик яхшы, аермачык. *Атларның бөтенләй буш йөргән төсле җиңел йөргәнлекләре ачыктан-ачык күренеп тора.* Ш. Камал.

АЧЫҚ-ТИШЕҚ *җыйм. и.* **1.** Қаралты, җиһаз, киемсалым һ. б. ш. нәрсәләрдәге ватылып ачылган-тишелгән, ертылган-сәләмәләнгән урыннар.

2. *күч.* Җитмәүчелек, мохтаҗлык.

◇ **Ачык-тишекне ямау** — 1) иске-москыны төзәтү,

рәтләү, ямаштыру; 2) материаль яктан җитмәүчелекне нинди дә булса юллар белән рәтләү, каплау, бетерү.

АЧЫЛМАЛЫ *с.* Ачыла торган, ачыла торган итеп эшләнгән. *Кыз, кечкенә, җыйнак, чибәр өйләренең таш баскычына җитеп, ике якка ачылмалы ишеккә туктагач та бер сүз әйтмәде, кесәсеннән ачкычын алды да ишегенә таба килде.* Г. Ибраһимов. [*Кешеләр*] *яшел галифе чалбар, ачылмалы кесәле яшел бостон френч кигән Дәүләтъяровка карый башладылар.* И. Гази.

АЧЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* ачу I (1—6 мәгъ.). *Менә хәзер ишек ачыла да аннан, әйтерсең, хатыны түгел, бәхет үзе килеп керә.* Ә. Фәйзи. *Бик күп парашют ачылды һавада.* Г. Гобәй. *Мин аның ул елларны Казанда ачылган күп санлы хәрби госпитальләрнең берсендә эшләүче военврач икәнлеген белеп алдым.* Ф. Хөсни.— *Столовой ачылсын, ашап-эчеп китәрсез.* И. Гази. *Ишек алдына чыккач, үткән заманнар турында сүз ачыла.* К. Нәҗми.

2. Күз алдында булу, киңәеп күренү. *Идел ярына чыгу белән аларның алдында искиткеч бер картина ачылды.* М. Гали. *Безнең алда чит-читләре урман белән чикләнгән кыр күренеше ачылды.* Ф. Әмирхан. // Күз алдына басу, күз алдына килү. *Шәрәфи сөйли, аның алдында авыл белән каланың багланышлы моментлары ачыла торалар.* Г. Ибраһимов.

3. Төзәлмәү, яңадан начарлану, көчәю, төзәлүдән туктау.— *Яраң ачылдымы әллә? — Ачылмады ачылуын, аз гына сыкрап тора.* Р. Ишморат.

4. *сөйл.* Чистару, агару, пычрактан арыну, үз төсенә кайту (кер һ. б. ш. нәрсәләр турында).

5. *күч.* Яктыру, ачыклану, агару (уй, фикер турында). *Яңа эштә яхшы ук ачылган егет.* Каз. утл. *Мәржани хәлфә булганчы байтак китап укыган, фикере яхшы гына ачылган була.* Аң.— *Уйларым тагын да ачылып, яктырып киткән кебек булдылар.* М. Әмир. // Күңеле, кәефе күтәрелү, көләчләнү. *Кыз, Шакировны литвача белә дип уйлап, бөтенләй ачылып китте һәм кызыкызы гына нилләрдер әйтеп куйды.* А. Әхмәт. *Ул бераз тартынып, бераз кыюсызлык белән башласа да, тиз ачылды.* Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* Ачылып, эчкерсез, бернәрсә дә яшермичә. *Ул карт белән ачылып сөйләшә, баштан үткән хәлләрен сөйли һәм аның хәлләрен сорашса.* Ш. Камал.

6. Үсемлекләрнең яфрак яруы, чәчәк атуы турында. *Ул [чәчәкнең] иң матурын, яңа ачылып килгәнен Шаһгәрәй абзыйның күкрәгенә китереп кадады һәм кочып алды.* Г. Гобәй. *Гөлләрнең күбесе әле яңа ачылып килә, бәгъзеләре бөре хәлендә генә.* Ф. Әмирхан.

7. Болытлардан арыну, аязу. [*Малай*], *ачылып килә торган офык читенә күз төшереп: — Эх, яңгыр артыннан балык шәп тә әләгәчәк соң! — дип куйды.* А. Алиш. *Тик менә соңгы көннәрдә генә күк йөзе матурланып ачылды.* Г. Ибраһимов. // Җирнең кардан, елганың бозлардан арынуы турында. *Яз килер, Карлар эрер, Бозлар китәрләр, Тау битләре ачылыр.* һ. Такташ. *Ул яз җиту, Идел ачылу белән үзенең элекке кәсебенә китәргә ашыга.* М. Гали. *Кар эреп, кырлар ачылды, таудан исте хуш җилләс.* Дәрдмәнд.

8. Яхшыру, рәтләнү, рәтләнеп китү. *Аппетит ачылу.*

9. Таралу, бетү, үтү. *Тәне җиңеләйгән, ул әле һаман оча кебек, йокысы тәмам ачылган, күңеле әлеге гаҗәеп төштәгечә биеккә-биеккә очу тәэсиреннән канатланган.* Г. Әпсәләмов.

10. *Төш. юн. к.* ачу I (7 мәгъ.). *Бүген булмаса — иртәгә, иртәгә булмый икән — берсекөнгә Бизмән-тауның сере ачылыр.* А. Әхмәт. *Хәзер исә, Тавык Мортыйның дошманлыгы ачылгач һәм аның барлык атларны харап итеп ташлау мөмкинлеген күз алдына китергәч, ул, калтыранып, икенче тапкыр: — Ах, әнә нәрсә! — дип кычкырды.* Г. Әпсәләмов.

11. *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса киртә, каршылыклар бетү турында (*мөмкинлек, юл һ. б. ш. сүзләр белән килә*). *Нихәтле күп продукция бирсәк, шулхәтле безгә иркен сулыш алырга мөмкинлек ачыла.* Ш. Камал.— *Иртәгә тагын нихәл булса да булыр. Бәлки, иртәгә юлым ачылыр да, бәлки, тагын рәхәт-рәхәт яши башлармын.* Г. Камал.

АЧЫЛЫК I *и.* Химик элементның кислород белән кушылмасы; оксид.— *Күл төбен карарга кирәк. Күл төбе тимер ачылыгы бүлеп чыгара.* Г. Ахунов.

АЧЫЛЫК II *и.* Ачы булу. *Алманың ачылыгы. Хыянәтнең ачылыгы.*

АЧЫЛЫК III *и. диал.* Өйгә кергәндә аяк сөртү өчен ишек төбенә җәелгән әйбер.

АЧЫЛЫШЛЫ: ачылышлы булу — кем белән дә булса ачуланышып, мөнәсәбәтләрне үзү. *Эче тулы вәсвәсәдән юньле йокы күрмәгәнгә, сеңелесе Зәкия белән сүзгә килеп, ачылышлы булганга, Бибиҗамал апа ялыккан һәм йончыган иде.* Ш. Хөсәенов.

АЧЫНУ *ф.* **1.** Бик нык кайгыру, борчылу, рухи газаплану. *Башын иеп, вакытсыз килүе өчен ачынып торган чакта, ул каршыдан тәрәзә чиерткән тавыш ишетеп алды.* Ә. Еники.

2. Нәрсәгә дә булса үкенеп, кызганып, борчылып көенү, өзгәләнү.— *Их, патрон юк бит, патрон! — дип ачынып куйды солдат.* А. Әхмәт.

АЧЫНУЛЫ *с.* Йөрәк өзгеч, кызганычлы (тавыш турында). *Якында гына «Әнекәем!» дигән ачынулы тавыш ишетелде.* Каз. утл. // Борчылу, көенү катнаш. [*Әсгәрдә*] *авыр, салмак атлап түбәнгә төшә торган шахтерлар музыкада да шулай ук авыр, йончыган, эчке ачынулы [хисләр белән тулы] итеп бирелгәннәр.* М. Җәлил.

АЧЫНЫШЛЫ *с. сөйл. к.* ачынулы.— *Караул! — дигән ачынышлы тавышка Гөлбикә, сискәнеп уянып, урынныннан сикереп торды.* Г. Ибелле.

АЧЫРГАЛАНУ *ф.* Өзгәләнү, ачыну. *Ана: йөрәктәгесен, үзәктәгесен аңлата алмадым, дип ачыргаланды.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* **ачыргаланып.** Ярсып, усалланып. [*Эт*] *җан ачысы белән өрергә, ачыргаланып чинарга, ярдәмгә хуҗасын чакырырга тотынды.* Г. Гобәй.

АЧЫСЫ-ТӨЧЕСЕ *җый. и.* Ачы һәм төче, ачы һәм төче нәрсәләр. *Өстәлдә бар да бар: кайнары, салкыны, ачысы-төчесе.* Каз. утл.

◇ **Ачысын-төчесен тату — рәхәтен дә, михнәтен дә,** шатлыгын да, кайгысын да күрү. *Карт эченнән каргады, тышыннан сер бирмәде: йөрсен, дөньяның ачысын-төчесен татыр, акылга утырыр, дип сөйләнде.* Г. Ибраһимов.

АЧЫТКЫ *и. сөйл.* Чүпрә; камыр башы.

АЧЫТТЫРУ *ф.* Үзәккә үтәрлек итеп, бик нык әрнетеп авырттыру. *Тәмәке төтене күзне ачыттыра.*

АЧЫТУ I *ф.* Бик нык әрнеп авырту. *Сул аягының үзәккә үтеп ачытуы бөтен тәненә таралды, йөрәген сыкрата башлады.* Г. Бәширов.

АЧЫТУ II *ф.* Ачыткы салып ачы хәлгә китерү. *Камыр ачыту.* □ *Колхозлар оешкач, сабан туйларын язгы эшләр беткәннән соң уздыру гадәте кереп киткәнлектән, балны да чәчү бетүгә ачыта башладылар.* Г. Бәширов.

АЧЫШ *и.* Тикшеренүләр, эзләнүләр нәтиҗәсендә билгеле булган нәрсә, яңа фәнни нәтиҗә. *Химия буенча ачышлар.* □ *Төрләрнең яратылуы һәм үзгәрмәве турында идеалистик һәм метафизик тәгълимат биологиядә XIX гасыр башларына кадәр, эволюцияне исбатлаучы күп кенә ачышлар нәтиҗәсендә юкка чыгарылганга кадәр хөкем сөреп килде.* Дарвинизм нигезләре. // Яңа җирләрне үзләштерү. *Географик ачыш.* // *күч. ирон.* Кем өчен дә булса көтмәгәндә билгеле булган нәрсә. *Мин аны баштанаяк күздән кичердем һәм шушы минутта бер ачыш ясадым: Маратның гәүдәсе рюмка сыман түбән таба очлаеп төшкән иде.* Х. Сарьян.

АЧЫШУ *ф. к.* ачу III (3 мәгъ.). *Аралык --- мич башына ташланган киез итекләр, иске туннарның ачышкан исләре белән аңкып тора иде.* Ә. Фәйзи.

АЧ-ЯЛАНГАЧ *с.* Ач һәм ялангач, бик ярлы, фәкыйрь, мохтаж. *Ул елны елап-сыкрап төннәр уздыручы аналар, ач-ялангач балалар белән җир өсте капланган иде.* А. Алиш. / *рәв. мәгъ.— Шуннан соң менә бер ел буена балаларым белән ач-ялангач тордым!* Г. Ибраһимов. // *и. мәгъ. күпл.* Ярлылар, ярлы халык. *Тук торып рәхәткә күнгән эчләрең кыйналдымы, Ач-ялангачларга шәфкать хисең уйгандымы?* Ш. Бабич.

АЧ-ЯЛАНГАЧЛЫК *и.* Ач һәм ялангач хәлдә булу, фәкыйрьлек, мохтаҗлык. — *Ач-ялангачлыктан саклау өчен ирек һәм җир алыгыз безгә.* Ш. Мөхәммәдев.

АШ I *и.* **1.** Нинди дә булса юл белән (пешереп, кыздырып) хәзерләнгән, ашарга яки эчәргә яраклы ашамлык, азык.— *Кеше кешедән өстен, әмма берәү дә аштан өстен түгел,— дип, фәлсәфәгә керешеп китте Гыймади.* Ә. Фәйзи. *Төрле ашлар, закускалар тезеп өстәл хәзерләнгән.* М. Фәйзи. // *с. мәгъ.* Ашау вакытында хезмәт итә торган. *Аш тәлинкәсе.* □ *Аш өстәлендә бик бай табын хәзерләнгән.* М. Җәлил.

2. Беренчегә бирелә торган шулпалы аш. *Поход кухнялары, урамнарны төтенләтеп, итле аш һәм карабодай боткасы пешерә башладылар.* Г. Бәширов.— *Ашны икмәк белән ашасаң, көчең артыр.* И. Гази.— *Сыер ите шулпасында пешкән кәбестә ашыннан да ким булмый бу.* Г. Гобәй.

3. Гомумән ашауны, ризык кабул итүне аңлата. *Минем бик хәтерем калып, ашка чыкмый башладым.* Ш. Камал. // *Иртәнге, көндезге, кичке* сүзләре белән килгәндә, билгеле бер ашау вакытын белдерә. *Көнлекчеләр, шаулашып, көлешеп, ял сәгате җиткәнгә шатланышып, көндезге ашка кайтып киттеләр.* А. Шамов. [*Балыкның*] *көндезге аштан кичке ашка кадәр тотылганын иртәнге ашка уха итеп пешерәләр.* Ш. Камал. // Шул вакытларга билгеләп хәзерләнгән ашамлык. *Тегермән тавы артыннан түгәрәк ай килеп чыккан чакта, аларның кичке ашлары өлгермәгән иде әле.* И. Гази.

4. Кунак мәҗлесе. *Ул, авылның бөтен халкын диярлек җыеп, олуг ашлар ясау белән данлыклы булса да, чит авыл халкын чакыру гадәте юк иде.* Г. Ибраһимов.— *Минем дүрт кулым юк бит, күрәсең, абыстайга ашка барырга карета җигәмен.* Ш. Мөхәммәдев.

Аш арты ашлары — шулпалы аштан соң бирелә торган, пешереп, кыздырып яки бүтәнчә хәзерләнгән балык, ит, бәрәнге, яшелчә, ботка кебек ашамлыклар һәм чәй яны ризыклары. *Гадәттә шулпадан соң аш арты ашлары бирелә.* Соц. Тат. **Аш бүлмәсе** — ашау-эчү бүлмәсе. *Ул аш бүлмәсендәге ашамлык нәрсәләрне күзеннән кичерде.* М. Гафури. **Аш суы**—малга эчерә торган юынтык су. **Аш тәмләткеч** — борыч, лавр яфрагы, бөтнек һ. б. ш. нәрсәләр. **Аш юлы**—*к.* үңәч. **Аш өе**—аш хәзерләү бүлмәсе, кухня. **Аш җәймәсе** — эскәтер, ашъяулык. **Аш чанасы** *этн.*— туйга килгәндә күчтәнәчләр, гомумән азык-төлек төялгән чана. *Туйга килә торган кодалар аш чанасын алдан җибәрәләр.* Г. Ибраһимов.

◇ **Аш белән каршы алу (озату) — ачык йөз күрсәтү.** *Кызың киткәч, киявең килер, Озат, әнием, син аш белән.* Җыр. **Аш булу** — 1) берәр кешегә карата кирәкле җәза турында әйтелә.— *Шушы җирдә авызыңны ямьшәйтеп җибәргәндә дә аш булыр иде инде сиңа.* М. Фәйзи; 2) файдалы ризык булу, азык булу, күңелгә хуш килү. *Аш буладыр миңа чәчәкләр хуш исе.* Г. Тукай. **Аш бу сиңа** — «сиңа шул кирәк» мәгънәсендә.— *Минем Ибраһимымны бөтенләй үзеңә багындырып бетердең, Ибраһимны сарыга сабыштырып бетердең! Аш бу [хурлыклар] сиңа!* Г. Камал. **Аш кайтару — 1) кунакка барганнан соң хуҗаларны үзенә ашка, кунакка чакырып** алу; 2) *иск.* Аштан соң дога кылу. **Аш төрләндерү** — 1) төрле-төрле ризыкларны аралаштырып хәзерләү; 2) аш талымлау, сайлау (йөкле хатын турында); 3) *ирон.* бозык ирләр турында.— *Шулай, кызым, ирләргә бер вакытта да ышанып бетәргә ярамый, аш төрләндерергә яраталар алар.* Ә. Еники. **Аш үтмәү (тамакка, эчкә)** — 1) аппетит булмау.— *Гөлнарымның хаты башымнан чыкмый. Тамагыма аш үтми башлады, ябыктым.* Ә. Айдар; 2) үңәчтән аш китмәү яки ашказанына кабул ителмәү рәвешендә була торган авыру. *Анасы Мәргыя карчыкның авыруы, кылтамак чирен, эченә аш үтмәвен, капкан бер нәрсәсе кире чыга торуын Мәрхәбә тегендә чагында ук ишеткән иде.* Г. Ибраһимов. **Ашка таракан төшү** — 1) нинди дә булса эшнең бозылуы, начарлануы, планның җимерелүе; 2) көтмәгәндә мәҗлескә чит яки яратмаган кешенең килеп керүе. [*Зөфәр, юл киемнәре киенгән бер егет белән бер ханым керүен күреп:*] *Ашка таракан төшәргә йөриме? — диде.* М. Фәйзи. **Аштан калу** — аш үтмәү, ашый алмау авыруы. [*Патша кызы*] *көннән-көн сула, саргая, йөкысызлыкка бирелә, аштан кала барадыр.* Аң. **Аштан олы булу** — ризыкны хөрмәт итмәүгә ишарә буларак әйтелә.— *Аштан олы түгелсең бит, Шәрифулла туган,— диде карчык,— утыр, безнең нигъмәттән дә авыз итеп кара.* А. Шамов. **Ашым аш түгел** — нинди дә булса рухи тынычсызлыкны аңлата.— *Ашың аш түгел, йокың йокы түгел — һәммәсе дә йөрәгеңә агу булып урнаша.* М. Гали. **Ашын ашаган, яшен яшәгән** — 1) бик карт.— *Безнең инде ашыбыз ашаган, яшебез яшәгән, кызым, авырлыклар күрергә алла сезгә боермасын!* М. Гали; 2) бик иске, тузган, искергән.— *Бик иске завод; ашын ашаган, яшен яшәгән, димәк.* Ш. Камал.

АШ II *и. сөйл.* Җеп яки тукымаларны ныклы бер формага китерү өчен файдаланыла торган, бәрәңге яки башка нәрсә онынан ясалган сыеклык, крахмал. *Эскәтернең ашы беткән, ашлыйсы бар.*

АША *бәйл.* **1.** *к.* аркылы II (1—7 мәгъ.). *Сабир абзый елга аша яңа агач күпердән чыкканда су буе тулы казларга игътибар итте.* Ә. Еники. *Габдулла тәрәзә аша өй эчендә утыручыларны күзәтә иде.* Ә. Фәйзи. *Яңгыр суы Шәмсинең юка шинеле аша үтеп аркасын чиркандырды.* Г. Бәширов. *Хәбәр Маратның күрешергә килгән иптәшләре аша шунда ук бөтен авылга таралып өлгерде.* Г. Гобәй. *Ә мин, азга туктап, үтеп барам Москва аша туган авылга.* С. Хәким.

2. *к.* аралаш (2 мәгъ.). *Ул минем кулларыма ябышты, күз яшьләре аша миңа текәлеп карады.* Ә. Айдар.

3. Эш яки хәлнең, хәрәкәтнең нинди дә булса затны, предметны һ. б. ш. узып башкарылуы турында сөйләгәндә кулланыла. [*Газетада*] *«Интернационал» колхозының, шушы ике көн эчендә ун колхоз аша сикереп, районда бишенче урынга менүе әйтелгән.* Г. Бәширов.

4. Қайбер абстракт исемнәр янында килеп, эш-хәлнең үтәлү рәвешен, характерын белдерү өчен кулланыла. *Зур кыенлыклар аша теләккә ирешү.* □ — *Инде ят кеше була торып, мине үзегезгә ул өткәнсез икән, авыр еллар аша алып чыгып, шушы көнгә китереп җиткергәнсез икән, мин сезгә мең бурычлы.* Г. Гобәй.

◇ **Аша китү (узу)** — нәрсәнең дә булса нормаль хәлдән артып китүе турында.— *Әмма ул оятсызның [Алтынбайның] бүгенге эше инде Сабираның башыннан аша китте.* Г. Ибраһимов.

АШАЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* ашау (1 мәгъ.). *Өстәл өстендәге ашамлыклар инде шактый ашалды.* А. Шамов. / *з-сыз ф.* [*Фазыл*] *юлда күп ашала дигән булды.* Г. Гобәй.

2. Нәрсәнең дә булса кояш, җил яки башка нәрсә тәэсиреннән үзгәрүе. *Сыер савучының җилдә, кояштa ашалган, ләкин матурлыгын югалтмаган йөзен кинәт бәхетле елмаю нурландырып җибәрде.* А. Расих.

3. Қыршылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ул ашалган үкчәләрен дә төзәткән иде.* А. Шамов. *Ул читләре*

ашалып беткән карталарны югары чөйде. К. Нәҗми. *Өйнең бүрәнәләре шома балавыздай сары-көрән иде әле, тапталып, кырылып ашалган идәне дә чип-чиста иде.* Ә. Еники.

4. Агымсу, яңгыр тәэсиреннән юылу, яргалану, җимерелү (су яры, тау токымы турында).

АШАМЛЫК *и.* Ашый торган, ашарга яраклы, ашау өчен яраклык хәлгә китерелгән азык. *Болар кергәндә шул идәндәге табынлыкка чәй, ашамлыклар куелган, зур ак самовар гөжләп кайнап тора иде.* Г. Ибраһимов. *Аннан соң ашамлык төрелгән ашъяулык чишелеп табынга җәелде.* Ә. Фәйзи.

АШАМСАК, АШАМЧАК *с.* Күп ашый торган, ашарга ярата торган.— *Кайбер кеше шулай ашамсак була инде ул.* Г. Бәширов.

АШАРЛЫК *с.* Ашарга яраклык (яраклы).— *Әйдәгез, башка җирдә әле кыяр чәчәк атарга да өлгермәгән, ә миндә ашарлыклары да бар инде аның.* М. Әмир.

АШАСЫННАН 1. *рәв. сөйл.* Түбәләмә итеп, артты-рып (тутыру, төяү).

2. *бәйл.* Аша, аркылы. *Фатихә үзенә яхшы таныш юллар буенча күрше рус йорты ашасыннан Һаҗәрне озата китте.* Г. Ибраһимов.

АШАТУ *ф.* 1. Ашарга ашамлык, азык бирү.— *Бая әниең бәлеш төбе ашаткан иде, сусап та кителде.* М. Фәйзи. *Аклар отряды авылга, гаскәргә ашатырга дип, крестьяннарның соңгы сыерларын алырга килде.* Һ. Такташ. // Ашарга ярдәм итү, авызына ашамлык каптыру. *Бала ашату.* // Яшь баланы күкрәк сөте белән туйдыру.

2. Тәрбияләү, карау, туйдыру.— *Безнең әти үзган ел көз, кыш ашатып чыгарга печән дә, салам да юк дип, чаптар бияне сатты.* М. Гали. // Симертү, көрәйтү.

3. *күч.* Туену чарасы, табыш чыганагы булып хезмәт итү. *Һөнәр ашата да, киендерә дә.* Әйтем.

АШАТУЧЫ *и.* Туйдыручы.— *Ашатучылары бер син генә булгач, нишләсеннәр соң мескеннәр.* Ф. Бурнаш.

АШАУ *ф.* 1. Ашамлык, азык кабул итү.— *Тамагыгыз ачкандыр, әйдә ашый башлагыз.* Г. Гобәй.— *Күрше әбисе пешереп куйган карабодай боткасын ашап, бакчадагы беседкага чыгып аварга иде.* Г. Бәширов. // Туклану, туену.— *Яхшы ашаганда, яхшы эчкәндә бер дә алай сөйләмидер идең.* Һ. Такташ. // Азык, ашамлык итеп файдалану. *Ит ашамау.* □ *Безнең әни талымсыз кеше: ни туры килсә, шуны ашый.* Г. Ибраһимов.— *Ашарга ярамый бит аның итен* [*керосин салып бозганнар*]. Г. Минский. // Аппетиты яхшы булу.— *Ашаган кешенең нервысы нык була аның.* Р. Ишморат.

2. *сөйл.* Тешләү, чагу, кимерү. *Мин, чебен ашый дигән булып, якындагы куак астына күләгәгә кердем.* Г. Ибраһимов. // Кисү, тишкәләп бетерү (көя, җимеш кортлары һ. б. ш. турында). *Посылкасы эченнән тарак, канат, күзлек, көя ашаган фуфайкалары чыкты.* Ш. Мөхәммәдев. // Химик реакциягә кереп (яки башка нәрсә тәэсирендә) кисү, эретү, тишү турында. *Кислота белән селтеләр өс һәм аяк киемнәрен ашыйлар.* Химия. *Элемтә өзелде, Сиваш суы телефон кабелен ашый.* Г. Бәширов.

3. *күч. сөйл.* Ашау-эчү әйберләренә, азык-төлеккә тотып бетерү. *Алар актык әйберләрен сатып ашадылар.* Г. Ибраһимов. *Болары тапкан акчаларын ашап, бетереп баралар.* Г. Камал. // Үзләштерү, әрәм-шәрәм итеп бетерү, урлау. *Директор ОРС малын кая куйган, кем белән ашаган — ул аны инде үзе генә белә.* Ә. Еники. // Бетерү, күпләп куллану, исраф итү. *Фабрика машиналары да нефтьне күп ашыйлар.* Ш. Камал.

4. Тәннең һәм киемнең кояш, җил һәм көн яктылыгы тәэсирендә төсе үзгәрү турында. *Аларның каршысына яулыгын артка чөереп бәйләгән, битен, беләкләрен кояш ашаган, озын керфекле яшь кенә бер кыз килеп керде.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Юу, җимерү. *Чик сызыгы булып ага елга, Ярны астан ашый упкыннар.* Ф. Кәрим.

6. *күч. сөйл.* Авыру, кайгы, сагыш турында: борчу, интектерү, тынычлык бирмәү. *Бала сагышы ашады инде бу ананы.* Каз. утл.

7. *күч.* Кыйналу. *Тукмак ашау. Йодрык ашау.* □ *Кол булу берәүгә дә күңелле түгел. Ләкин адәм табигате белән хөр булып та, коллыкта яшәргә мәҗбүр булса, үз хуҗасыннан таяклар ашаса, аның трагедиясе дөньяның иң зур каһәрләреннән саналырга тиеш.* Г. Ибраһимов. *Күпме тал чыбыгы ашадык.* Һ. Такташ.

8. *күч. гади с.* Тиргәү, орышу яки урынсыз таләпләр белән җанын борчу, газаплау.— *Нәсимә җиңги кайтса, ашап үтерер.* Ш. Камал.— *Я, Разия туташ, син нәрсә Булатка палачка караган кебек куркып карыйсың. Ул ашамас, әйдә, башлаган сүзеңне туктатма!* Г. Ибраһимов.

◇ **Ашардай булып (итеп) карау** — үтә дикъкать белән карау, кызыгып карау.— *И, бар иде Бибиҗамал апаның яшь вакытлары! Узган-барган егетләр ашардай итеп карап узалар иде.* Ш. Хөсәенов.

АШАУ-ЭЧҮ *ф.* Тамак туйдыру, ашау, туклану. *Ул әле юлдан кайтып ашагач-эчкәч, бераз ятып торган иде.* М. Гали.

АШБАЗ *и. иск.* Повар, ашчы. *Фәсхи, гаҗәп оста бер ашбаз шикелле җиңнәрен сызганып, шашлык хәзерләргә тотынды.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

АШҚАЗАНЫ *и.* Кеше һәм хайваннарда аш кайнату органы. *Син чынлап торып ашказаны белән авырып, больницада ятасың икән.* М. Җәлил.

Ашказаны асты бизе *анат.*— ашказаны артында ята торган озынча биз, үзеннән чыккан ике канал аны унике илле эчәк белән тоташтыра.

АШҚАЗАНЫ-ЭЧӘК: ашказаны-эчәк авырулары — аш кайнату белән бәйле органнарда була торган авырулар.

АШҚЫН *с.* 1. Ашкынып, җилкенеп, алга омтылып торган. *Әллә ничек кинәт аерылдык без, Ашыкты ла ашкын паровоз.* Ш. Маннур. [*Галәм*] *бөек, көчле, ашкын бу төркемне Бер күрсен дә, күреп көрсенсен.* М. Җәлил.

2. Югарыга, биеккә күтәрелгән, күккә, биеккә омтылган, ашкан. *Әйтегез лә, салкын болытлар, Ашкын таулар, миңа әйтегез... Бу яралар җанга җитәрме?* Ф. Бурнаш.

АШҚЫНДЫРУ *ф.* Җилкендерү, нәрсәгә дә булса омтылу хисе тудыру, дәртләндерү. *Моңлы сигнал җыры яшь йөрәкне Ашкындыра никтер жу-у итеп.* Ш. Маннур.

АШҚЫНУ *ф.* Нәрсәгә дә булса җилкенү, омтылу, дәртләнү, дулкынлану. *Салкын яңгырлар да, аяк астының пычрагы да революция белән ашкынган халыкларны өйләренә бикли алмадылар.* Г. Ибраһимов. // *и. мәгъ. Хисләремдә давыл, Уйларымда өермә, Йөрәгемдә Идел ташкыны, Ә үземдә әле һичбер кичерелмәгән Тиңсез шатлык, көчле ашкыну.* Ш. Маннур.

АШҚЫНУЛЫ *с.* Ашкындыра торган, дәртле, җилкендерә торган. *Ашкынулы хисләр.* □ *Ак өйгә чыкканнан соң да Нәфисәне ашкынулы, дәртле бер омтылу, нигәдер өнди торган бер тынгысызлык һаман дулкынландырып тора иде әле.* Г. Бәширов.

АШЛАМА *и.* Үсемлекләрне тукландыру һәм иген уңышын күтәрү максаты белән туфракка катнаштырыла торган матдә (тирес, компост, минераль тозлар). *Химик ашлама.* □ *Басуга көн саен уннарча тонна ашлама чыгарыла. Ашламалар төрле участокта төрле дозада кертелгән.* Соц. Тат.

АШЛАУ I *ф.* **1.** Туфракка (җиргә) ашлама кертү. *Туфрагын ничек кенә ашлама син аның, нинди генә матур банкаларга утыртма, боларның берсе дә кояшны алмаштыра алмый бит.* Г. Гобәй.

2. Тукыма, җеп яки киндерне агарту өчен махсус җеп ашында кайнатып, кояшка тотып киптерү юлы белән эшкәртү. *Таулар башында, карга җәеп, авыл кызлары киндер ашлыйдыр.* С. Баттал. // Агачка сыгылмалылык бирү өчен пешекләү, парлау. *Кышлар үтеп, карлар эрегәч тә, Ашлап бөккән чана табаның.* М. Гафури.

АШЛАУ II *и. диал.* Агачны уеп ясалган зур кашык.

АШЛЫК *и.* **1.** Орлыгыннан он һәм ярма хәзерләнә торган башаклы үсемлекләр, үсеп утырган иген. *Ашлык сугу.* □ *Урылып бетмәгән сабан ашлыкларын сыгылдырып-сыгылдырып салкын яңгыр җиле исә.* А. Шамов. *Колхозчылар кайсы урылган ашлыкны ташып, кайсы көлтә бәйләп, кайсылары бәйләнгән көлтәләрне өемнәргә өеп баралар.* М. Гали.

2. Орлык хәлендәге икмәк. *Ашлык киптергеч.* □ *Транспорт бригадасына җитәрлек итеп ашлык хәзерләп куйдылармы икән?* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Ашлык саклана торган. *Ашлык амбары. Ашлык бурасы.*

Ашлык сугу — азык өчен игелгән бодай, арыш һ. б. ның орлыкларын башагыннан аерып алу.

АШЛЫК-ТАРУ *җыйг. и.* Ашлык, иген.— *Мин бит иген игә торган, я булмаса ашлык җыеп, ашлык-тару белән сату итә торган кеше дә түгел.* Г. Камал.

АШЛЫ-СУЛЫ *с.* Материаль яктан яхшы, иркен тормышлы, барлыкта яши торган. *Кодагый булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле.* Г. Камал.

АШ-СУ *җыйг. и.* Табынга хәзерләнгән ашамлык, сый.— *Минем аш-суларым да суынып беткәндер инде.* А. Әхмәт. *Тупасрак, саграк тормыш белән көн иткән карагургалар алдында көяз бикъярларның аш-сулары чыннан да искитәрлек булды.* Г. Ибраһимов.

АШ-СУЛЫ *с. к.* ашлы-сулы. *Аш-сулы, киң куллы бай Вахит агайның йортында болар өчен азык җитәрлек иде.* Ак юл.

АШУ *ф.* **1.** Арту, билгеле бер чиктән узып китү, чыгу; ташу. *Йөздән ашкан милләт халкының Уч, ачуын, нәфрәт ялкынын Төяп алып китә самолет.* Ф. Кәрим. *Елгаларның суы ярдан ашкан, Тирбәләләр таллар тын гына.* З. Мансур. // Чыгыш килешендәге кайбер сүзләр янында: чиксез күп, артык күп (булу). *Шакир турындагы һәртөрле шикле-микле уйларының кайвакытта нигезсез булуын да, артык күп уйлый торгач чамадан ашып китүен дә яхшы белә иде Әминә.* Г. Минский. *Җиңгәсенең эше башыннан ашкан иде.* Г. Ибраһимов.

2. *шигъ.* Менү, күтәрелү, җитү. *Телим нурга чумарга, Серле күкләргә ашарга мин.* Н. Исәнбәт. *Кайчак күзләреңнән көчләр алып, Бөеклеккә табан ашам мин.* һ. Такташ. *Һаваларга ашып торган агачлар арасын тутырып аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр.* А. Шамов.

3. Юнәлеш килешендә чынбарлыкка мөнәсәбәтле сүзләр белән килгәндә: үтәлү, башкарылу, чынга әйләнү. *Гөл түгел ул — чәчәк атмаса, Теләк түгел — чынга ашмаса!* Ш. Маннур.— *Хыялыгызның шундый матур булып эшкә ашуы белән тәбрик итәм!* Г. Бәширов. // Дәрәҗә яки максат мәгънәләрендәге сүзләр янында: ирешү, җитү.— *Теге ятим Салих зур мәртәбәгә ашкан икән.* Г. Ибраһимов.

АШУГ *и.* Кавказ халыкларында: шагыйрь-җырчы.

АШХАНӘ *и.* **1.** Җәмәгать тукланыу учреждениесе.— *Әйдә, алай, мин сине үзебезнең ашханәгә алып барыйм.* М. Әмир.

2. Квартирада, йортта ашау-эчү өчен махсус бүлмә. *Аннан соң ашханәгә, утын бүлмәләренә, ятакханәгә төшеп, ташландык кара керләргәчә актаралар.* Г. Ибраһимов.

АШЧЫ *и.* Аш пешерүче. / *с. мәгъ. Мине Мәгъруфә карчык, ә бабайны Мансур байның ашчы хатыны Сабира апай үз яннарына сыйдырганнар.* Ә. Айдар.

АШЪЯУЛЫК *и.* Аш өстәленә, табынга җәя торган җәймә, эскәтер. *Ашамлык төрелгән ашъяулык чишелеп табынга җәелде, аның өстенә юача, чикләвек, көнбагыш, чуклы конфетлар чәчелде.* Ә. Фәйзи.

АШЫГУ *ф.* Нәрсәне дә булса тизрәк башкарырга, срогыннан алда эшләргә тырышу. *Исмаев барысын да кызыксындырган бу зур мәсьәләне тизрәк ачыкландырырга ашыкты.* Г. Бәширов.— *Тик нигә соң әле ашыгасыз, безнең авыллар иртәгә генә юлга чыгалар.* Т. Гыйззәт. // Вакыт тар булганда, өлгерергә тырышу, кабалану. *Халык, көннең аязлыгыннан файдаланып калырга дип, кырга ашыга.* А. Шамов. // *рәв. мәгъ.* **ашыгып.** Тиз арада, иртә һәм уйламыйча. *Мин хәзер ашыгып өйләнгәнгә үкенә дә башладым.* М. Гали.

АШЫГЫЧ *с.* **1.** Ашыгып эшләүне, тиз башкаруны таләп итә торган, тиз эшләнергә тиешле.— *Дөресен әйткәндә, газета кешесенә керергә ярамый торган җир юк. Мин ашыгыч эш белән, бабай.* А. Әхмәт. / *хәб. функ. Нәфисәнең эше ашыгыч иде булса кирәк, Айсылу белән сөйләште дә тагын тарантасына менеп утырды.* Г. Бәширов.

2. Ашыгулы, кызу, җәһәт, тиз-тиз. *Кызлар, хатыннар арасында ашыгыч хәрәкәтләр башлана.* М. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* Тиз арада, кыска вакыт эчендә, ашыгып. *Габденнасыйргә бик ашыгыч кына Казанга чыгып китәргә туры килде.* М. Гали.

Ашыгыч ярдәм — авыруларга бик тиз арада күрсәтелә торган медицина ярдәме. *Аның хәле бик үк начардан түгел, организмы да көрәшкә сәләтлерәк, ә әнисе ашыгыч ярдәмгә мохтаҗ.* Г. Гобәй.

АШЫГЫЧЛЫК *и.* Ашыгыч булу. *Эшнең ашыгычлыгы.* // Ашыгу, ашыгып эшләү. *Ашыгычлык аркасында ул, намаз эчендә, төрле уйларга төшеп бетте.* Ф. Әмирхан.

АШЫК *и. диал.* **1.** *к.* тубык. *Ашыкканның ашыгы чыккан.* Мәкаль.

2. Кузна. *Арслан, аның башыннан сыйпап, йөзеннән сөйде дә, кулындагы ашыкларын карап, кайдан алуын сорашып, ике конфет бирде.* Г. Ибраһимов. *Беркөнне Габдулла берьюлы дүрт ашыкны бәреп екты.* Ә. Фәйзи.

АШЫК-ПОШЫК *рәв.* Бик ашыгып, кабаланып, бик тиз генә. *Мосафирлар ашык-пошык атка чыгып утырыштылар.* Ф. Әмирхан. *Карчык ашык-пошык җыена калды, Хәлим Гөлҗамал абысталарына чапты.* И. Гази.

АШЫКТЫРУ *ф.* Нәрсәне дә булса тизрәк башкарырга мәҗбүр итү. *Кемнәрнеңдер ямьсез ачы тавыш белән кычкырып сүгенүләре ерактан үк ишетелеп, безне ашыктырдылар.* М. Әмир. // Кая да булса тизрәк кузгалырга, китәргә, барырга, тизрәк хәрәкәтләнергә әйдәү. *Әхмәт, өйдә эшләре бар икәнен сөйләп, атасын ашыктырды.* Ф. Әмирхан. *Батальон командиры, бер кырыйда туктап, колоннаны ашыктырып торды.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* **ашыктырып.** Вакыты җитмичә, алдан. *Авылга килеп төшүгә, Якуб, ашыктырып, Совет членнарын җыйды.* И. Гази.

АШЫНУ *ф. сөйл.* Үзсенеп узыну, чамадан тыш кылану.

АШЫРУ *ф.* **1.** Арттыру, уздыру. *Эш нормасын йөздән ашыру.*

2. *шигъ.* Күтәрү. *Уткән һәрбер минут минем куәтемне, урынымны югары ашыра бара иде.* Г. Ибраһимов.

3. Юнәлеш килеш формасындагы *эш, тормыш* кебек исемнәр белән янәшә килгәндә нәрсәне дә булса башкаруны, үтәүне аңлата. *Тормышка ашыру.* □ *Вәгъдә иткәч, аны бит эшкә ашырырга кирәк инде!* Г. Бәширов. *Советның карарын гамәлгә ашырырга кирәк.* И. Гази.

АЭРА'РИЙ *и.* һава ваннасы алу өчен җайлаштырылган махсус мәйданчык.

АЭРО- Кайбер кушма сүзләрдә «авиация», «һава» мәгънәсендәге беренче кисәк; мәсәлән: **аэроклуб, аэромаяк, аэронавигация.**

АЭРОБ *и. биол.* Ирекле кислород булган шартларда гына яшәргә сәләтле организм.

АЭРОВОКЗАЛ *и.* Аэропорт вокзалы. *Халисә карчыкны аэровокзалда күрмәгән.* С. Рафиков.

АЭРОДИНА'МИКА *и. физ.* Һава һәм башка газларның хәрәкәтен, шулай ук үзләре чолгап алган каты җисемнәргә һава һәм газларның каршылык күрсәтүен тикшерә торган фән. *Аэродинамика институты.* □ *Жуковский хәзерге аэродинамиканың һәм авиациянең нигезен салды.* СССР тарихы.

АЭРОДРОМ *и.* Самолетлар һәм башка очу аппаратларының торуы, очып китүе, очып төшүе һәм шулай ук аларга ремонт ясау өчен җайланмалары булган мәйдан. *Очкычларны кабул итәр өчен хәзерләнгән аэродромны кар күмеп китте.* А. Алиш.

АЭРОЛИТ *и. астр.* Күк пространствосыннан җиргә төшкән таш сыман масса, таш метеорит.

АЭРОЛО'ГИК *с.* Аэрологиягә мөнәсәбәтле. *Аэрологик күзәтүләр.*

АЭРОЛО'ГИЯ *и.* Атмосфераның югары катлауларындагы физик, химик һәм башка үзенчәлекләрне өйрәнә торган фән. / *с. мәгъ. Аэрология станциясе.*

АЭРОНАВИГА'ЦИЯ *и.* Очу аппаратларын билгеләнгән һава юлы буенча йөртү турындагы фән, һава навигациясе.

АЭРОНАВТ *и.* Очучы.

АЭРОНА'ВТИКА *и.* Очу аппаратларында һавада хәрәкәт итүнең теориясе һәм практикасы.

АЭРОПЛАН *и. иск.* Самолет. *Аэроплан ниндидер зур шәһәр читендәге аэродромга килеп төште.* А. Алиш.

АЭРОПОРТ *и.* Транспорт самолетларының даими очышын тәэмин итү өчен барлык кирәк-яраклар белән җиһазландырылган һәм һава юллары трассасында урнашкан аэродром. *Казан аэропорты.*

АЭРОСТАТ *и.* Һава шары (һавадан җиңел газ белән тутырылган очкыч аппарат). *Аэростатлар тирбәләләр тоныкк үктә.* Ш. Мөдәррис.

АЭРОФОТОСЪЕМКА *и.* 1. Берәр урынны, җир өстен, пунктны самолеттан фотога төшерү.

2. Шундый юл белән алынган рәсем.

АЭРОЧАНА *и.* Эчке янулы двигатель ярдәмендә эшли торган пропеллерлы чана. *Эңгер-меңгер вакытында финнарга, аэрочаналарга утырып, өстәмә ярдәм килде.* Г. Әпсәләмов.

АЮ *и.* 1. Куе йонлы, авыр гәүдәле имезүче ерткыч хайван. *Ак аю. Кара аю.* □ *Тау битләренә, коточкыч кара урманнар эченнән чыгып, төннәрен куркынычлы тавышлар белән акырынып йөрүче аю, бүреләр, кабан дуңгызлары һәм башка ерткычлар* [*тарала*]. М. Гали. // *с. мәгъ.* Аю тиресеннән тегелгән.— *Менә, дустым, сиңа аю бүрек! — диде* [*Чернозубов*] *һәм бүрекне дустының башына чәпәп тә куйды.* Ә. Маликов.

2. *с. мәгъ. күч. сөйл.* Зур гәүдәле, таза (кеше турында).— *Уйлап карасаң, түзәрлек түгел: аю-аю ике улы сугышка бармады, заводта калды.* А. Шамов.

Аю баланы *бот.*— кыргый балан, мәржән куагы да диләр; *русчасы:* бузина. **Аю балыгы** *зоол. иск.*— тюлень. **Аю биетү** — тамашачыларга мәзәк күрсәтү өчен аюдан төрле хәрәкәтләр ясату.— *Аннан Вәлишә кордаш кубызда уйнар, аннан камыр бит күрсәтү, аю биетүләр булыр.* Т. Гыйззәт. **Аю биетүче** — кулга ияләндерелгән аю белән кәмит күрсәтеп йөрүче кеше. *Аю биетүче юктыр бит!* М. Гафури. **Аю камыры** *диал.*— гөлҗимеш, гөләп җимеше. **Аю кырмыска** — эре кырмыска. **Аю көпшәсе** *бот.*— эре, куе яшел яфраклы, юан һәм озын көпшәле үсемлек, ашарга ярамый: *русчасы:* борец жёлтый. *Бала-чага да аю көпшәсен кисеп насос ясый да су сибешә, нәниләр күбәләк куа.* И. Рәмиев. **Аю табан** — *к.* яссы табан. *Мөхәммәтҗан белән Шәймәрдәнне* [*солдатка*] *алмаганнар. Мөхәммәтҗанның күкрәгендә бар, ди, Шәймәрдәнне аю табан дип әйтәләр, ди.* М. Әмир.

◇ **Аю күрдеңме (биетәләрме) әллә?** — бик гажәпләнеп, әсәрләнеп карап торганда әйтелә.— *Таралыгыз, аю күрдегезме әллә?* И. Гази. **Аю хезмәте күрсәтү** — белмичә, урынсыз ярдәм күрсәтеп, күңелсезлек китереп чыгару. *Алар иптәшләренә «аю хезмәте» күрсәтергә теләмиләр.* А. Әхмәт.

АЮБАШ *и. махс.* Туку станогында буй җепне ныгытып кую һәм сугылган киндерне урау өчен кечкенә вал.

АЮҠОЛАҠ *и. бот.* Нәүрүз чәчәкләләр семьялыгыннан сары чәчәкле бик матур үсемлек; *русчасы:* медвежье ушко.

АЮТАБАН *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан вак сары чәчәкле агулы үлән үсемлек; *русчасы:* лютик.

АЮЧЫ *и.* 1. Аю аулаучы, аю аучысы.

2. *иск. к.* аю биетүче. *Безнең әти аючы, эшләмичә баючы.* Н. Исәнбәт. *Юлда дәү генә кара һималай аюларын иярткән аючылар очрый.* М. Мәхмүтов.

АЯ *и. этн.* Кәҗә мамыгын аялый торган тарак.

АЯГҮРӘ *рәв.* 1. Аякка басып, аякка баскан килеш, утырмыйча. *Тарантастагы кеше бераз килгәч, аягүрә басып, як-ягына карана башлады.* Г. Гобәй. // Ихтирам, зурлау билгесе буларак яки куелган тәртип буенча, яшь яки чин ягыннан үзеңнән зурларны каршылаганда һәм сөйләшкәндә басып тору турында.— *Синең иште кеше белән хәзер аягүрә сөйләшергә тиешләр.* Ф. Хөсни. *Ул көнне зиндан башлыгының урынбасары камераларга йөреп, тоткыннарны карап чыкканда, Гриша аягүрә каршы алмаган.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Ашыгып кына, ашыгыч, бик тиз арада гына; эш арасында. [*Чеховның*] *аягүрә генә дәфтәргә теркәп куйган язмалары да әдәби яктан эшләнгәннәр, кызык итеп бирелгәннәр.* Г. Нигъмәти.

◇ **Аягүрә төш күрү** — аңгы-миңге булып, аңгыраеп йөрү.— *Ашаганым аш түгел, йоклаганым йокы түгел, аягүрә төш күреп йөрим.* А. Шамов.

АЯЗ *с.* 1. Болытсыз, явым-төшемсез, ачык, томансыз. *Бураннар бетеп, аяз көннәр, ачык һавалар, кышкы челләдәге кебек чатлама суыклар башланды.* Г. Ибраһимов. *Аяз төннең зәңгәр күгендә Очкынланып яна йолдызлар.* М. Җәлил.

2. *күч.* Кайгысыз, хәсрәтсез, тыныч. *Башың таз булса да, күңелең аяз булсын.* Мәкаль. // *и. мәгъ.* Тыныч һәм ирекле көн, тынычлык. *Куркытма син, алла, яшен белән, Барыбер мин курыкмый яши беләм, Куркытсаң да курыкмыйм мин: Аязымны сатып алдым яшем белән.* Г. Тукай.

◇ **Аяз көндә яшен суккан кебек (суккандай)** — көтмәгәндә килеп чыккан күңелсезлек турында әйтелә. *Аяз көндә яшен суккандай, кинәт башына төшкән бу фаҗига Мостафин гаять авыр кичерде.* Э. Еники.

АЯЗЛАНУ *ф. сөйл. к.* аязу. *Көннәр аязлануга бара.*

АЯЗЛАТУ *ф. к.* аязу. *Тышта аязлаткан.* Ш. Камал.

АЯЗЛЫҠ *и.* 1. Аяз булу. *Халык, көннең аязлыгыннан файдаланып калырга дип, кырга ашыга.* А. Шамов.

2. *күч.* Кайгысызлык, хәсрәтсезлек, тынычлык, кайгысыз, хәсрәтсез булу. *Бүгенге җыелыштан чыкканда Шәвәли, моңарга хәтле һич булмаганча, җилкәсендә җиңеллек, күңелендә аязлык сизде.* С. Рафиков.

АЯЗУ *ф.* 1. Болыт, томан таралу, күк йөзе ачылу. *Иртә аязмаса, кич аязмас, кич аязмаса, һич аязмас.* Мәкаль.

2. *күч.* Кайгы-хәсрәттән, күңелсез хисләрдән арыну, кайгы-хәсрәт таралу турында. *Кара болыт үтеп киткән-*

нән соң күк йөзе аяза барган кебек, Газинурның да күңел күге әкренләп аяза барды. Г. Әпсәләмов.

АЯК I *и.* **1.** Кешенең, кошларның һәм хайваннарның йөрү өчен хезмәт итә торган очлыгы. *Акбүз хуҗасының күкрәгенә алгы аякларын куйды да, арт аяклары белән таптанып, салмак койрыгы белән җирне себереп торды.* Г. Гобәй. // Ясалма аяк, протез. *Күннән, агачтан, резиннан миңа аяк ясадылар.* Г. Ибраһимов. *Ике якка асылынып торган җирән мыегы, киң кырыйлы салам эшләпәсе, вак шадрасы, хәтта агач аягы да килешле булып күренде аңар.* Г. Гобәй.

2. Мебель, механизм кебек нәрсәләрнең идәнгә, җиргә һ. б. ш. утыртып, бастырып, терәп куя торган җайланмасы. *Урындык аягымы, нәрсәнеңдер кузгалганы ишетелде.* А. Шамов. *Шунда ук күмерне бушатып, трубага су салу да файда итмәгән, самоварның аягы кубып төшкән.* Ә. Фәйзи.

3. *сөйл.* Күп һәм озын итеп (күпмедер метр кертеп) уралган җеп басмасы.

Аяк бите (йөзе) — аякның өсте. [*Эт*] *әле берсенең, әле икенчесенең аяк йөзен исни-исни бик зәгыйфь, бик кызганыч чинады.* Г. Гобәй. **Аяк киеме** — күннән яки башка әйберләрдән тегелгән, күбесенчә каты табанлы читек, ботинка, чүәк һ. б. ш. *Маһибикә, ишек алдына чыгу белән, аяк киемен рәтләгән булып тукталды.* М. Әмир. **Аяк машинасы** — аяк ярдәмендә әйләндерелә торган тегү машинасы. **Аяк очы** — 1) аякның бармаклар тирәсе; 2) сузылып яткан кешенең аяк ягы, аяк тирәсе. *Ул, җилкәсенә салган сары тунын җыя төшеп, сәкегә, Әхмәдулланың аяк очына утырды.* А. Шамов; 3) хуҗалыкта бакча арты яки каралтылар артындагы урын. *Мунчасы аяк очында гына.* **Аяк чолгавы** — *к.* аякчу.— *Мөселман кызы булып, аяк чолгавы да, тәһарәт чүпрәге дә чикмәсә, үзе дә килешмәс иде.* Ф. Әмирхан.

◇ **Аяк асты** — 1) атлап барган җир, бара торган юл. *Бераздан соң салкын кар яңгырга әйләнеп, аяк асты бозланды.* И. Гази; 2) кеше күп йөри торган урын, юл өсте, кеше күз алды.— *Кайсы анда аяк астына көлтә ташлады?* Г. Бәширов; 3) кимсетелгәннәр турында. *Гареп-шәрык милләтенә караганда, безләр булып торып калдык аяк асты.* М. Гафури. **Аяк асты (ның ныклыгы) ның булу** — шик, икеләнү туарлык сәбәп булмау, җәмәгать каршында ышанычлы позициядә тору.— *Аллага шөкер,— диде [Шәмгун], аяк астының ныклыгын сизеп һәм шатланып.* А. Шамов. **Аяк астына салу (таптау, калдыру)** — игътибарга алмау, санамау.— *Бригадирлар, әйдә, сузмагыз, яхшы сүзне аяк астына салырга ярамас, тәвәккәлләргә кирәк.* Г. Бәширов.— *Ал, чибәр егет, минем кебек фәкыйрь бер картның телгән аяк астына салып таптама.* Г. Гобәй. **Аяк астында (арасында) буталу (йөрү)** — комачаулау, эшсез йөрү. [*Мәрхәбә*] *иң элек шунда аяк арасында файдасызга буталып йөргән назлы килен Гыйззелбанатны моннан матурлап куды.* Г. Ибраһимов. **Аяк астында туфрак булу** — баш иеп, буйсынып яшәү.— *Кызым, иреңнең сүзеннән чыкма, аяк астында туфрак бул!* Ф. Әмирхан. **Аяк астыннан чыгу** — уйламаган җирдән, юк кына сәбәп аркасында, көтмәгәндә булу (бәла, бәхетсезлек). *Ул бәлаләр дә көтелмәгән җирдән, --- тәмам аяк астыннан килеп чыкты.* Ак юл. **Аяк атлау (басу)** — 1) атлау, йөреш рәвеше. *Аның тырма тотуына, аяк басуына кадәр ниндидер бер нәфислек, үзенең җырларындагы шикелле бер матурлык бар.* Г. Бәширов; 2) кая да булса бару, керү, чыгу. *Менә шулай сәфәргә аяк атлаган сәгатьтә тагын хат килеп төшмәсме!* Г. Ибраһимов; 3) бер вакыт арасы бетеп, икенчесенә күчү, чыгу турында әйтелә.— *Алдагы ел өчен азык хәзерләү хәстәренә язга аяк басу белән үк керешербез.* Ә. Еники; 4) нинди дә булса эштә, өлкәдә эшчәнлек күрсәтә башлау, нәрсәгә дә булса ирешү. *Фән дөньясына аяк атлау.* □ *Иң югары дәрәҗәгә аяк басты.* М. Гафури. **Аяк бастырмау** — кемнедә булса (үз өенә) кертмәү, китермәү, кем белән дә булса араны өзү.— *Кертмә шуларны, аякларын бастырма безнең якка!* Г. Ибраһимов. **Аяк итен туздыру** — кирәкмәгәнгә йөрү, файдасыз эш артыннан йөрү турында. *Юк, жаным, йөрмә фалчыга, Туздырма аяк итең. Ышансин! Хатлар алдамый; Аерылу, белэм, читен...* Г. Латыйп. **Аяк ите ашалу** — күп йөрү аркасында аяклар ару, эштән чыгу. *Күпме телефон шалтырады, күпме аяк итләре ашалды, күпме нерв кырылды, ләкин нәтиҗәсе булмады.* Соц. Тат. **Аяк киенү** — (алдан) хәзерләнү.— *Эшнең җитди төс алуы мөмкин. Моны белеп торыгыз һәм алдан аяк киенегез.* А. Расих. **Аяк очына гына басып** — сиздермәскә тырышып, әкрен генә. *Ул, кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады.* М. Әмир. **Аяк сузу** — үлү, вафат булу. *Монда синең әнкәң ачтан аяк сузды, атаң исән, әле яңа гына сукрана-сукрана тимерлеккә китте.* Г. Ибраһимов. **Аяк суыту** — чапканнан соң атны арлы-бирле йөртү. **Аяк тартмау** — кая да булса барырга җыенганда яки берәр эш башлаганда уңышсызлык, күңелсезлек булыр кебек шик туып, икеләнеп тору. *Габдулла абзый, аягы бик үк тартмаса да, башка йөкчеләрдән калмады.* Ф. Хөсни. **Аяк терәп** — бик нык каршы торып, нык каршылык күрсәтеп, катгый рәвештә. [*Кулакларның*] *иген тапшырудан аяк терәп баш тартулары --- бар да Шәрифҗанга билгеле булганга, аның йөрәге ярсый.* И. Гази. **Аяк терәп сөйләшү** — курыкмыйча, үз сүзендә нык торып сөйләшү турында. *Шәкертләр мәдрәсәдәге уку һәм тормыш тәртипләрен кычкырып, курыкмый тәнкыйть итә башлыйлар. Хәмидулла абзый белән аяк терәп сөйләштеләр.* Ә. Фәйзи. **Аяк уңу** — берәр кешенең башлап кая да булса керүе белән эш уңу, эш уңайга китү турында әйтелә. *Киленнең аягы уңмады, ахры, ел да яңгырлы туры килде, эшләр дә бәрәкәтсез.* А. Шамов. **Аяк чалу** — 1) аяк белән кемнең дә булса аягын эләктереп, җиргә егу; 2) эшкә аркылы төшү, комачаулык итү.— *Минем бәхетемә аяк чалмагыз.* М. Фәйзи. **Аяк ялы (хакы)**—кая да булса барып йомыш үтәгән, эш башкарган өчен бирелә торган акча яки берәр әйбер. *Шул эшне безнең файдага башкарып чыгарса, аяк ялы күчтәнәчен бирерсез.* Т. Гыйззәт. **Аяк өстендә булу** — 1) йокыдан тору, уяу булу, йокламау. *Ерактан ак таң беленгәндә, җәйләү аяк өстендә иде инде.* Г. Ибраһимов; 2) һәрнәрсәгә әзер тору, әзер хәлдә көтү. **Аяк өстендә килеш, аяк өсте генә, аяк өсли** — ашыкпошык, утырмыйча, аягүрә генә (сөйләшү, эшләү). *Екатерина Павловнаның эш вакыты булганга, аяк өстегенә сөйләштеләр.* Г. Әпсәләмов. *Анасы белән икәү капка төбендә аяк өстендә килеш кенә сөйләшеп торганда, Мәликә, тәрәзәдән башын чыгарып, Рәүфәне чакырды.* А. Шамов. **Аяк өстенә тору, аякка калку** — басу. *Утырыштагы кешеләрнең күпчелеге, аякка калкып, ораторның фикерләренә кушылуларын белдереп, бик озак кул чаптылар.* К. Тинчурин. **Аяк җиргә тимәү** — 1) җитезлек, кызу-кызу йөрү, йөгерү турында. *Сулы вә пычрак урамнардан кайтып килгәндә гүя аякларым җиргә дә тими очып киләм.* Ш. Камал; 2) ниндидер эчке дәрт белән, күтәренке күңел белән йөрү. *Йөрәгендә ялкын арта, Бер дә кимеми иде. Атлаганда аяклары Җиргә дә тими иде.* М. Җәлил. **Аягы черегән** — әкрен һәм абынып, бәрелеп-сугылып йөри торган кешегә карата әйтелә. [*Сәхипҗамал абынып егылгач, Җамали:*] *Һәй, аягың черегән нәрсә.* А. Әхмәт. **Бер аягың җирдә, икенчесе кабердә (гүрдә)** — үлем якын булу, үлем якынайган булу, авыр хәлдә булу.— *Әй, бәбкәм, бер аягың җирдә, икенчесе кабердә булгач, җәй көне дә суык ала икән.* А. Әхмәт. **Аягың (аягым, аягы) җиңел булсын** — яңа эш башлаганда, я берәр эш вакытында, яисә авыру янына кем дә булса килеп киткәндә яхшы теләк формасында әйтелә.— *Эшнең башы әйбәт күренә, аягың*

җиңел булсын, килен! Г. Бәширов. **Аякка бастыру** — 1) эшкә яраклы хәлгә китерү, көрәйтү, авырудан терелтү, сәламәтләндерү.— *Чулпан тернәкләнеп китсен дибез икән, иң элек атларны аякка бастырыйк без, Хәерниса сеңел!* Г. Бәширов; 2) тормышны материаль яктан яхшырту, эшне юлга салу, нормаль хәлгә китерү.— *Закир, бәхетең зур икән, башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды.* Г. Ибраһимов; 3) төзекләндерү, тергызу, нормаль эшләтә башлау. *Сугыш вакытында җимерелгән завод-фабрикаларны аякка бастыру;* 4) ниңди дә булса эшкә кузгату, оештыру.— *Киңәшем шул: сугышның иң кыен вакыты икәнен онытма, бөтен көчеңне җый, бөтен халкыңны аякка бастыр.* Г. Бәширов. **Аякка басу** — 1) авырудан соң сәламәтләнеп йөри башлау. *Әнкәй дә авырды, апайлар да авырды, --- барысы да әкренләп аякка бастылар.* Ә. Еники; 2) материаль яктан тормыш яхшыру; авырлыкларны җиңү. *Ул канатланып китә, чиксез зур шатлык аңа аякка басарга ярдәм итә.* Г. Әпсәләмов; 3) нинди дә булса әһәмиятле эшне үтәү өчен актив кузгалу, күтәрелү.— *Берме, икеме кешенең колагына салынган бу сүз яшен тизлеге белән телдән телгә күчә, бөтен татар аякка баса.* Ә. Фәйзи. **Аякка бәйләгән таш кебек** — алга китәргә, үсәргә мөмкинлек бирми, бәлки артка гына сөйри торган берәр кеше яки нәрсә хакында әйтелә. [*Сәйфи*], *колхоз аягына бәйләгән таш кебек, гел шулай артка сөйри, аның аркасында оятка калырга туры килә.* Г. Бәширов. **Аякка егылу** — ялынып, ялварып, инәлеп, гозерләнеп нәрсәдер сорау, гафу үтенү яки хисләрен белдерү. *Мин елаганмын, Шаһбазның аягына егылып, гафу үтенгәнмен.* Г. Ибраһимов. *Мескеннәр, шатлыкларыннан нишләргә белмичә, елый-елый рәхмәтләр әйтеп, безне кочарга, үбәргә тотындылар, хәтта аякларыбызга егылдылар.* А. Шамов. **Аякны озын сузу** — иркенәю, иркен яшәү. *Чөнки Шәвәлинең чүлмәк сатудан килгән барлыюклы акчалары аякны ул кадәр озын сузарга мөмкинлек бирмиләр.* С. Рафиков. **Аяктан егарлык** — шаккатырлык, искиткеч.— *Ә син бик матурлап, аяктан егарлык итеп, эскизыңны яса.* М. Маликова. **Аяктан егу** — 1) хәлдән тайдыру. *Хезмәт каты, хак начар, эш вакыты хәлләреңне бетереп аяктан егарлык озын иде.* Г. Ибраһимов; 2) материаль яктан авыр хәлгә төшерү. *Аның теге мактаулы мөгезсез сыерының тизәк авыруыннан, сабан туйларында иң шәп сөлгене әләктерә торган ак кашкасының эч авыруыннан үлүләре дә аны аяктан екмады.* К. Тинчурин; 3) рухи төшенкелеккә бирелергә мәҗбүр итү, мораль яктан авыр хәлгә төшерү. *Ә менә бу --- улы кайгысы аны аяктан еккан.* Каз. утл.; 4) эшне бозу; артка сөйрәү. [*Сәлахиев:*] *Син бөтен Волга буенда беренче үрнәк саналган совхозны аяктан егарга маташасың.* Г. Ибраһимов; 5) үлемгә сәбәп булу турында. *Туксан беренче елгы ачлык иң башлап аны аяктан екты.* К. Нәҗми; 6) зур комачау булу, эшли алу мөмкинлегеннән мәхрүм итү. *Ул тагын да яхшы уйнар иде, телсезлеге аяктан ега.* М. Гафури. **(Бер) аяктан йөрү (булу)** — кем белән дә булса килешеп яшәү, бер фикердә булу.— *Әгәр син монда юньле эшлисең килсә, безнең совет егетләре белән бер аяктан йөре,— дидем.* Г. Ибраһимов.

АЯК II *и. иск.* Чәй чынаягы яки шуңа охшашлы тоткасыз савыт, касә.— *Безнең ачыткан бал ширбәте бар бит әле, аяклар кирәк булыр әчәргә.* К. Тинчурин.

АЯК-КҮЛ *җыйд. и.* Аяклар һәм күллар. *Егетнең зыян-зәүрәте юк, аяк-кулы исән-сау.* А. Шамов. *Әйтерсең, аяк-кулларым үзем теләсәм дә яңадан урыннарына килә алмаслык булып таралганнар, шулчаклы басылганмын, шулчаклы кузгала алмыйм.* Г. Ибраһимов.

◇ **Аяк-кул бәйдә булу** — ташлап китә алмау, котыла алмау.

АЯКЛАНДЫРУ *ф. Йөкл. юн. к.* аяклану. [*Искәндәр*], *ахыр килеп, сеңелесе Галияне Рәүфкә каршы тәмам аякландыра.* Г. Нигъмәти. [*Таһир*] *үзен үзе тотышы белән җыелышны үзенә каршы аякландырган булып чыкты.* Г. Ахунов.

АЯКЛАНУ *ф.* **1.** Аякка басу, йөреп китү, **йөри** башлау (йөри алмаган гарип кешеләр яки кечкенә балалар турында). *Мәхәббәттән сукырлар күзле булган, Аксаклар аякланган.* Н. Думави.— *Кайвакыт аяксызлар да аякланалар икән шул.* А. Алиш. // Йокыдан уянып йөри башлау, йокыдан тору. [*Көн яктырып*] *халык аякланган, мин клубка йөгердем.* М. Әмир.

2. *күч.* Сәламәтләнү, тернәкләнү, хәлләнү. *Ире эш эзләп Бакуга киткәч, беренче балалары үлде. Шуның кайгысыннан* [*Нәгыймә*] *яңа аякланып бара иде.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Кемгә яки нәрсәгә карата булса да кирелек эшләү, баш күтәрү, каршы чыгыш ясау. [*Габдулла*] *бүген үз чорының алдынгы кешесе икәнен күрсәтте. Традициягә каршы аякланды бит ул бүген.* Ә. Фәйзи.

4. *күч.* Югалган яки урланган нәрсә турында әйтелә. [*Нәфисә:*] *Кичәге бодай табылмаган бит әле!* [*Айсылу:*] *Анысына пошынма. Табылыр, инә түгел. Аякланып кына өлгергән булмаса.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Таралу, кешедән кешегә күчү (сүз, **хәбәр** турында).— *Яралар, имеш, яргач, кем үтергәнен шунда ук белгәләр, имеш, белгәч, тотып алалар, имеш...— дигән хәбәрләр, урамның бер башыннан кузгалып, Рәгыя аркылы аякланып киттеләр.* Г. Ибраһимов.

АЯКЛАУ *ф. сөйл.* Хайванны аяк санынча дүрткә бүлеп, уртаклашыю сую.

АЯКЛЫ *с.* **1.** Аякларына бастырып, утыртып куярлык итеп эшләнгән.— *Аяклы көзге белән бер йорт сатып аласың гына бар.* Ә. Фәйзи.

2. Аяк ярдәмендә эшли торган. *Укытучы кызлары ак шарлы, сыгылма челтәрле тимер кровать белән аяклы тегү машинасы кертеп утырттылар.* Г. Бәширов.

◇ **Аяклы келәт**—1) астын ачык калдырып, баганалар өстенә утыртып салынган келәт, амбар; 2) *күч.* ни ашаса да бер дә симерми торган бик зур арык ат. **Аяклы каза** *кимс.*— булдыксыз, эшкә яраксыз, имгәк.— *Бик ямьсез, бик аңгыра булып, аяклы каза булса, мин нишләрмен?* Г. Камал. **Аяклы китапханә** — бик күп китап укыган һәм күп нәрсәләрне хәтерли торган кеше. **Аяклы мал** — терлек, мал-туар, йорт хайваннары. *Ишек алдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тызбыз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк.* Ә. Еники. **Аяклы тарих** — күп тарихи истәлекләр, күп фактларны белә торган яхшы хәтерле кешегә карата әйтелә. *Әптери агай фабриканың язылмаган аяклы тарихы инде. Аның хәтере яшь егетнеке төсле. Һичнәрсәне онытмаган.* Ш. Усманов. **Аяклы энциклопедия (китапханә)** — теләсә нинди мәсьәлә буенча белешмә алырга мөмкин булган, һәрьяклап белеме булган кеше турында. *Идрисне аның белән беренче кабат таныштырганда китапханә мөдире аны «Аяклы энциклопедиягә» дип әйткән иде.* Х. Сарьян.

АЯКСЫЗ *с.* Аягын өздергән, бер яки ике аягы да булмаган, аягы юк. *Әле тачанкага утырган аяксыз пулеметчы, әле Лениннан килгән матрос күз алдына килеп баса.* Г. Әпсәләмов. / *и. мәгъ.— Болай да дөньяда аяксызлар бик күп хәзер.* А. Шамов.

АЯКСЫЗЛАНУ *ф.* **1.** Аякны өздерү, кистерү һ. б. ш. сәбәпләр аркасында аяксыз калу, гарипләнү.

2. Аяклар авырту сәбәпле, йөри алмаслык хәлгә килү. // Нинди дә булса психик халәттән аяк буыннары йомшару, хәлсезләнү. *Тәкъва кинәт аяксызланды.* М. Әмир.

АЯҚЧУ *и.* Аяк чолгавы, ыштыр. *Хәлим мич куышыннан аякчуларын алып чолгарга торганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына ачылып китте.* Г. Гобәй.

АЯЛАУ *ф.* Кәҗә мамыгын каты кылларыннан тарап арындыру.

АЯНЫЧ *с.* **1.** Кызганыч. *Мондый аяныч хәлне ишеткәч, һәммәсе аһылдап авыр сулады.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Күңелсез, авыр, йөрәк әрнеткеч. *Бала өчен аяныч күңел китеклеген — аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г. Гобәй. // *рәв. мәгъ.* Актык дәрәҗәдә начар, мөшкел.— *Мин үзем фермабызның хәлен, кайберәүләр кебек, бик аяныч итеп күрмим.* Ә. Еники. / *хәб. функ. Сөйкемле әнкәсенең хәзер әнә шулай вак сүзле, кырыс чырайлы, көнче һәм бәйләнчек каенанага әверелә баруы бик аяныч иде.* Г. Бәширов.

АЯНЫЧЛЫ *с.* **1.** Аяныч булган, кызганычлы. *Капитализмны фаш итеп, изелүче халыкның аянычлы тормышын сурәтләп, аның киләчәгенә өмет һәм омтылыш тудыру — бары реализм аша гына мөмкин иде.* М. Җәлил. *Ул, уйга калып, аянычлы бер тавыш белән үзалдына сөйләнеп куйды.* Каз. утл.

2. Йөрәк әрнеткеч, үзәк өзгеч. *Мәдинәнең аянычлы тавышы йокыга талган урам буйлап китте дә кайтаваз булып яңгырады.* Ш. Хөсәенов.

АЯТЕЛКӨРСИ *и. дини, иск.* Ислам диненчә: сихердән саклый торган дога. [*Бәдретдин*] *авыру-сырхауларга догалыклар, аятелкөрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде.* Ә. Еники.

АЯТЬ *и. дини, иск.* Коръән сүрәсендә тәмамланган шигъри җөмлә. *Соңра мулла бер аятьме, догамы укыды да аминга кул күтәрде.* Г. Ибраһимов. *Яшел ефәк өстенә укалар белән ай, йолдыз һәм әллә нинди аятьләр, яңа чәчәкләр тегеп куйганнар.* Ш. Камал.

АЯУ *ф.* Кызгану, жәлләү, аңлау, хәленә керү. *Кунмасын дип коллык сөреме, Аямадык канны, гомерне.* Ф. Кәрим. *Кашың — җәя, керфегең — ук, Өммелхәя! Йөрәгемә угың керде! Мине ая!* Ш. Бабич.— *Уз иленә кайтсаң, берәр дус-ишең аяр иде әле.* М. Фәйзи.

АЯУСЫЗ *с.* **1.** Рәхимсез, шәфкатьсез. *Аяусыз син, сөю! Ачыдыр рәхәтең, Яшьледер шатлыгың. Татлыдыр хәсрәтең!* Н. Исәнбәт. *Аяусыз үлемнән тузан кадәр дә курыкмавы аны рухландырды.* Г. Бәширов. / *рәв. мәгъ. Патша --- восстание күтәрүчеләрне аяусыз җәзалаган.* СССР тарихы.

2. Дәһшәтле, каты, коточкыч. *Аяусыз сугыш.* □ *Иртән бик аяусыз салкыннар булып, су өсләре бер төндә адәм йөрерлек мәртәбәдә боз белән түшәлде.* Г. Ибраһимов.

3. *рәв. мәгъ.* Бик артык, чиксез, туктаусыз. *Әсәрдә капитализм системасында үз кул көче белән көн күрүче ярлының нинди авыр шартларда яшәве, аның киләчәгенең никадәр өметсез булуы, аның аяусыз изелүе гәүдәләндерелгән.* М. Җәлил.

АЯУСЫЗЛАНУ *ф.* Аяусыз кешегә әверелү, шәфкатьсезләну.

АЯУСЫЗЛЫК *и.* Аяусыз булу. *Сыйнфый көрәш, аяусызлык сорап, --- җиңү астында Каршылаган еллар каршысына Җавап белән безне бастыра.* Ф. Кәрим.

АҖАГАН *и.* Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен бик ерактан күренә торган күкрәүсез яшен. *Менә әтәч тавышы, тагын әтәч, яшьнәп үтте тагын ажаган.* Н. Исәнбәт. *Ерактагы ажаган яктылары белән тулып торган җәйге тымызык төн аларны* [*Сәгыйдә белән Арсланны*] *үз кочагына ала.* Г. Ахунов.

АҖАУ *и. диал. к.* кушбаш. *Камыш төпләренә качкан чуртаннар су өстенә чыгачак чабакларның, ажауларның ялтыравын көтәләр.* М. Әмир. *Ажауның иң яраткан азыгы чикерткә икәненә дә без ышанган идек.* Ак юл.

АҢ *и.* **1.** Кешегә хас буларак, чынбарлыкны фикерләп кабул итү, уйлый белү сәләте. *Рәхиләнең аңын бер секундка томан каплады һәм аның йомык күзләре алдына бик ачык булып тугаиы Хәсән килде.* Ә. Еники. *Кыскасы, нәрсә булгандыр, Нуруллин аңыннан болар бик томанлы гына узып киттеләр.* А. Шамов. // Дөньяга караш, иҗтимагый тормыш барышын төшенү. *Ул феодал руханиларның һәм диннең, иске мәдрәсә схоластикасы һәм дини уйдырмаларның халык массасы аңын агулавын күрә, ачыграк төшенә килде.* Г. Нигъмәти.

2. *филос.* Кеше миендә чынбарлыкның, кешенең барлык психик эшчәнлегенең чагылыш процессы. *Аң — минең функциясе. Материя — беренчел, аң — икенчел.* // Нинди дә булса бер иҗтимагый сыйныф вәкиле буларак, кешеләрнең психологиясе, аларның политик, философик һ. б. карашлары. [*«Тормыш баскычлары»*] *әсәрендә --- сыйнфый аңы ачыла барган, ахыр килеп, революциягә һәм гражданнар сугышына кызыл командир булып катнашкан Вахит образы матур, җанлы бирелгән.* М. Җәлил.

3. Аек караш, акыл; белем, аң-белем. *Мохтарның сынавына караганда, Гыйльмулланың аң, тапкырлык дәрәҗәсе Сәхипнекенә караганда күп түбән.* Ш. Камал. — *Дөньяның уңын-сулын белдереп, аң бирә торган җирдә укырга кирәк икән, мин солдатта йөреп, шул тәҗрибәне алдым.* М. Гафури.

◇ **Аң бул** — исеңдә тот, сизгер, уяу бул (нәрсәне дә булса кисәтеп әйткәндә кулланыла).— *Ярый, бар, юлыңда бул! Ләкин, кара аны, аң бул! Бер юлга кичерәм.* Г. Камал.— *Дөньяда торырга исәбең булса, аң бул, бала: ничек өйрәнсәң — шуңа китә...* Г. Гобәй. **Аңга кертү** — акыл бирү, аң бирү.— *Габдулла абзыйны мин үзем аңга керттем дип уйлый идем — хәзер ул да бит Гәрәйләр койрыгына тагылып авып бара.* Г. Ибраһимов. **Аңга килү** — 1) авырып аңсыз ятканнан соң, сиземли, фикер йөртә башлау.— *Аңыма килгәндә, мин инде Микитаның алдында, ат өстендә идем.* Г. Гобәй; 2) аңлап алу, мәсьәләнең серенә төшенү, хәлне аңлау. *Галиулла аңына килеп өлгермәде, су аны бөтереп алды һәм ташлар өстенә китереп бәрде.* И. Гази. *Дошманга тын алырга, аңга килергә ирек бирмәскә кирәк.* Г. Әпсәләмов; 3) *к.* акылга утыру. **Аңын ачу** — фикерен ачу, нәрсәне дә булса аңлау дәрәҗәсенә җиткерү. *Чын күңелдән укып синең язганнарыңны, Карт көнемдә ачтым тагын да аңым. Ачык күрдем дошманнарымны һәм таныдым дусларымны.* Ә. Исхак. **Аңына кайту** — *к.* аңга килү. *Рәхилә куркынып күзләрен ачты, башын селкеп куйды, һәм аңына кайту белән башына килгән беренче уй: --- «ни өчен бу гаделсезлек?» дигән уй булды.* Ә. Еники.

АҢА *а.* «Ул» алмашлыгының юнәлеш килеш формасы. *Күпме вакыт яткандыр, Мисбах белә алмый иде, аңа ул менә шушы куаклар арасында мәңге ята кебек тоелды.* Г. Әпсәләмов.

АҢАРДАН *а.* «Ул» алмашлыгының чыгыш килеш формасы: аннан (ләкин кешегә карата гына кулланыла). *Газинур бервакытта да аңардан [Миңнурыйдан] тартынып тормый иде.* Г. Әпсәләмов.

АҢАРЧЫ *рәв.* Аңа кадәр, нинди дә булса бер вакытка яки вакыйгага чаклы.— *Соң бит сез аңарчы тормассыз?* Г. Гобәй. *Аңарчы яшь укытучы үзен авыл халкына уңай яктан танытып өлгергән иде инде.* Ә. Еники.

АҢ-БЕЛЕМ *җыйд. и.* Гомумән белем, гыйлем. *Эшлә, укы! Укып, аң-белем ал, Янып торган эшчән кеше бул!* М. Гафури.

АҢГАРМАСТАН *рәв. сөйл.* **1.** Искәрмәстән, искәрмичә; абайламастан, сизмәстән.

2. Аңлап, белеп җиткермичә, яхшылап уйламыйча.

АҢГАРТУ *ф.* **1.** *иск. к.* аңлату. *Ул хәлфәсенең рәсемле китапларын иптәшләренә күрсәтә, белгән җирләрен аларга аңгартып бирә.* Ак юл.

2. Ничек тә булса сиздертү (ишарә яки киная белән).

АҢГАРУ *ф.* 1. *иск.* Аңлау.— *Әби, --- мин бит син укыганнарны аңгарам,— дидем.* Ак юл.

2. Абайлау. *Без аңгарып та өлгермәдек.* Ә. Айдар.

АҢГЫ-МИҢГЕ *с.* Аңгыра, миңгерәү, юләр сымак. [*Хәлимнең*] *авызының тәме юк, күзләре ачыта, башы аңгы-миңге иде.* Г. Гобәй. / *рәв. мәгъ. Шулай аңгы-миңге ята торгач, чын-чынлап йокыга киткәнлегемне сизми дә калганмын.* Н. Фәттах.

◇ **Аңгы-миңге килү (яту, йөрү, булу)** — аңгыра сымак бер хәлдә булу. *Төнебуена клубта утыралар да, аннан ары көн буена аңгы-миңге килеп йөриләр.* Г. Камал.

АҢГЫРА *с. сөйл.* 1. Аңсыз, миңгерәү, надан, ахмак. *Миңлебай яшь, аңгыра, бернәрсә белмидер.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Акылга зәгыйфь, тулы акыллы түгел. *Биби — Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.* Г. Камал. *Хөснижамал Мохтарны бөтенләй тиле, аңгыра кешеме әллә дип тә исәпләп алды.* Ш. Камал.

◇ **Аңгыра бәрән (бәрәк, сарык, тавык, ябалак)** — хурлап, кимсетеп әйтелә.— *Әй аңгыра ябалак, матур булмагач мин сиңа китерәмме соң аны!* Г. Камал. *Менә бит, аңгыра бәрәк, шуны да күрми!* Г. Бәширов. **Аңгыра катык** *сөйл.*— оеткысыз яки оеткы салып та начар оеган катык.

АҢГЫРАЛАНУ *ф.* Аңсызлану, аңсызга әйләнү, миңгерәүләнү. *Аңгыраланып китү.*

АҢГЫРАЛАТУ *ф.* Аңгыра итү, миңгерәүләтү.

АҢГЫРАЛЫК *и.* Аңгыра булу. *Аңгыралыкның да байтак кына зарары тия бит кешегә.* Ш. Камал.

АҢГЫРАЮ *ф. сөйл.* Миңгерәүләнү, вакытлыча аңлау, төшенү сәләтен югалту.— *Юк, башыма күсәк төшеп, аңгыраеп утырам.* Ф. Бурнаш.

АҢДАУ, АҢДУ *ф. диал. к.* андау. *Аңдып кына йөргән каргалар берничә чебешне тибеп тә өлгергәннәр.* М. Гафури.

АҢДЫРУ *ф.* Искә төшерү, теге яки бу сыйфаты белән нәрсәне дә булса хәтерләтү, хәтергә төшерү. *Аның үзе дә, сүзе дә, йөзе дә, күзе дә миңа әллә нинди авыр суыкны аңдыралар.* Г. Ибраһимов. *Күксел урманнар ераклта әллә ниләр аңдыра.* Н. Исәнбәт.

АҢКАУ I *и.* Авыз куышлыгының өске стенасы. *Аның теле, тибрәнә дә алмыйча, аңкавына ябышты.* Г. Гобәй.

АҢКАУ II *и. иск.* Аңгыра, миңгерәү. *Аңкау аңламас, үзсүзле тыңламас.* Мәкаль.

АҢКАУЛЫК *и. иск.* Аңгыралык, миңгерәүлек. *Үзеңдә ялкаулык, Хатыныңда аңкаулык, Кайда кышка азык, Ачлыктан саклармык?* Г. Тукай.

АҢКУ *ф.* 1. Көчле рәвештә чыгу, таралу, бөркелү (ис турында). *Һавадан кара туфрак исе, яңа киселгән нарат агачы исе, черегән яфрак исе аңкый.* И. Гази. *Абзар эче ярым караңгы, җылы тирес һәм сөт исе аңкый.* Ә. Еники. *Бүлмәдә балык һәм кер сабыны исләре аңкый.* Ш. Камал.

2. *күч.* Бик көчле сизелү, беленү (хисләр, кичерешләр турында). *Гади генә киенгән, чәчләрен урталай ачып, иңбашына ак шәл салган урта яшьләрдәге хатынның күзләрендә исә рәсем аша да сагыну, ирен юксыну моңнары аңкып тора.* А. Шамов. *Аның кыланышында да ниндидер ясалмалык, койрыклы сүзләрендә үзалдына бер төрле икейөзлелек аңкый иде.* Ш. Камал.

3. Берәр нәрсәгә хас билгеләр чагылу. *Музей эчендә рыцарьлар рухы аңкый.* Г. Гали.

АҢКЫ-МИҢКЕ *с. диал. к.* аңгы-миңге. *Хәбир* [*йокыдан*] *аңкы-миңке көенчә сикереп торды.* Ш. Хөсәенов.

АҢКЫТУ *ф.* 1. Чыгару, тарату (ис турында). *Алар үзенә генә хас бер хуш ис аңкытып торган салам кибәне кырына барып утырдылар.* Г. Бәширов. *Өй мораҗаларыннан, урам буенча бәлеш исен аңкытып, җылы төтен тарала.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Сиздерү, белдерү. *Ул яхшылык аңкытып торган мөлаем күзләре белән залдагы халыкны сөзеп карап чыкты.* А. Шамов.

АҢЛАЕШЛЫ *с.* Аңлашыла торган, гади, ачык, аныклы; буталчык түгел. *Сөйләгән вакытта, әйтергә телләгән әйберен аңлату өчен, ачык, аңлаешлы сүзләр сайлый-сайлый ул күбесенчә аптырана.* Ш. Камал. // *рәв. мәгъ.* Ачык итеп, гади итеп. *Артта утыручылар арасында аның оста һәм аңлаешлы сөйләвенә сокландылар.* М. Гали.

АҢЛАЕШЛЫЛЫК *и.* Аңлаешлы булу.

АҢЛАМАМЫШ: аңламамышка салыну — аңламаган кебек кылану, аңламаган булып күренергә тырышу. *Мин аңламамышка салынып тордым, Разия да, йокым килде дигән булып, чыкмаячагын сөйләде.* Ф. Әмирхан.

АҢЛАМАСТАН *рәв.* Көтмәгәндә, искәрмәстән. *Сискәнеп безнең егет катып кала аягүрә, Аңламастан каршысында әллә нинди «ят» күрә.* Г. Тукай.

АҢЛАТМА *и.* 1. Аңлатып, тәфтишләп сөйләп биргән нәрсә. *Әхмәтнең аңлатмасы утырдашларын тулысынча канәгатьләндерде.* Ш. Камал. *Солтан баш зоотехникның аңлатмаларын тыңлады да алдынгы колхоз булган «Коммунизм маягы»на китеп барды.* А. Расих.

2. Нинди дә булса мәсьәләгә яки хезмәткә карата бирелгән ачыклау, комментарий. *Җырны җыйнап алучы тарафыннан аңлатма бирелгән, җырларның язылып алу вакытлары, районнары күрсәтелгән.* М. Җәлил. // Сүзнең теге я бу мәгънәсен ачыклый торган текст. [*Г. Камал*] *китабының тышында ук --- «Өч бәдбәхет» сүзенә аңлатма биргән.* М. Гали.

АҢЛАТМАЛЫ *с. лингв.* Аңлатма бирелгән, мәгънәсе аңлатылган. *Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.*

АҢЛАТУ *ф.* 1. Аңлатма бирү, төшендерү, ачыклау, аңлаешлы итү. *Марат белән Шамил бригадирның сүзенә төшенмәделәр, ә Фәрит аңлатып биргәч, кинәт күңелсезләнеп киттеләр.* Г. Гобәй. *Газинур, иптәшләренең көлүенә карамыйча, караңгы түшәмгә текәлгән килеш, үз фикерен аңлатырга тотынды.* Г. Әпсәләмов. // Нәрсәнең дә булса сәбәбен, закончалыгын ачып бирү, билгеләү. *Эшнең нәрсәдә икәнен* [*без Артыкбикәгә*] *тиз аңлаттык.* М. Әмир.

2. Ишарә итү, белдерү. *Сәлимов Тангатаровка, күз кысып, «сүз башла» дигәнне аңлатты.* Г. Ибраһимов. *Зәңгәр күктә йөзә март кояшы, Ул аңлата иде яз башын.* Г. Хуҗи. *Хәзер аның күз алдында бу кыланышлар бөтенләй икенче мәгънә аңлата башладылар.* Ф. Әмирхан. // Сүз, тамга, билге һ. б. ш. турында: белдерү, чагылдыру, мәгънә бирү.— [*Карп абый*] *тамгаңдагы беренче хәреф нәрсәне аңлата?* Г. Әпсәләмов. *Хәятнең йөзе һәрвакыттагы шикелле матур, тыныч һәм ачык иде, яңа бер тойгы аңлатмый иде.* Ф. Әмирхан.

АҢЛАУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса төшенү, эчтәлеген, мәгънәсен ачыклау. *Безнең уйны әби ярты сүздән аңлап алды: — Заманның үз кешеләре — яшьләр аңласа, без аңладык ни, аңламадык ни.* М. Фәйзи. *Аңлашырлык сөйләгәч, аңлый торганнардыр бит?* А. Шамов. // Нәрсәне дә булса белү, аның асылына төшенү.— *Бу эштә нинди булса да берәр төрле сер булырга кирәк, минем шул серне аңлыйсым килә.* Г. Камал.

2. Бәяләү, тану (кешене хезмәтне һ. б. ш.). *Менә шул, син дә ул чакта мине аңламадың.* Ш. Камал.

3. Уйлау, күз алдына китерү, күзаллау. *Шунсыз* [*мораль сафлыктан башка*] *мин аңлаган семьяның бәхетле булуы мөмкин дә түгел.* Г. Кутуй.

4. *рәв. мәгъ.* **аңлап.** Белә торып, аңлы рәвештә, юри. *Биредә* [*«Таулар» пьесасында*] *сурәтләр гомумиләштерә төшеп бирелгәннәр, кешеләр авторның теге яки бу идеясен ачуда чара буларак аны кызыктыралар. Автор моны аңлап шулай ала.* Г. Нигъмәти.

АҢЛАШУ *ф.* 1. Үзара уртак бер фикергә килү, килешү, бер-береңне аңлау.— *Кайчан булса да этиләр белән бер-беребезне аңлаша алырбызмы без?* Ф. Әмирхан. // Нинди дә булса мәсьәләне ачыклау, мөнәсәбәткә ачыклык керту.— *Мин синең белән аңлашырга телим, әнвәр.* Р. Ишморат.

2. Фикер алышу, сөйләшү. *Учредительный собраниегә сайлау кампаниясе турында сәгать ярымга сузылган докладтан соң ике сәгатькә якын аңлашулар булды.* Ш. Камал. *Читенлек белән булса да аның белән русча аңлашырга мөмкин иде.* М. Гали.

3. *рәв. мәгъ.* **аңлашып.** Бер фикердә булып, килешеп, берләшеп, бер сүздә булып. *Корткычлык эшендә [Лутов], үзе кебек корткычлар белән аңлашып, дирекциягә, партия эшчеләренә каршы көрәш алып бара.* Г. Нигъмәти.— *Без синең белән аңлашып эш итәбез.* Ш. Камал.

АҢЛАШЫ'ЛМАУ *и. к.* аңлашылмаучылык. *Пароходлар төшкәч тә җибәрелгән иген баржалары белән ниндидер аңлашылмау чыккан икән.* Г. Ибраһимов.

АҢЛАШЫЛМАУЧАНЛЫК *и. к.* аңлашылмаучылык. *Күрүебезчә, бу җитди каршылык түгел, аңлашылмаучанлык кына.* М. Җәлил.

АҢЛАШЫЛМАУЧЫЛЫК *и.* Бер-береңне дөрес аңламау аркасында туган каршылык; аңлашылмау.— *Сөйләмә инде, Мирзахан, бик зур аңлашылмаучылык туды.* Т. Гыйззәт.

АҢЛАШЫЛУ *ф.* Ачыклану, аңга барып җитү. *Бу сүзләрнең мәгънәсе Газинурга аңлашыла да кебек, ләкин шул ук вакытта аларда әле ул белеп җиткермәгән тагын ниндидер тирән бер сер дә бар кебек.* Г. Әпсәләмов.— *Мәсьәлә яхшырак аңлашылсын өчен, мин сине бер вакыйга белән таныштырып үтәм.* Г. Камал.

АҢЛЫ *с.* 1. Уйлау сәләте булган, аңы булган, зиһенле.— *Менә син, аңлы икәнсең, безнең сүзне тыңла, ата-ана догасын ал.* Ф. Әмирхан.— *Күрсәгез иде сез [улымны]: гаҗәп шаян һәм аңлы малай.* А. Шамов. // Төпле, уйлап эш итә торган. *Садри әфәнде бик аңлы егет, әйбәт егет ул.* Ш. Камал.

2. Политик аңы үскән. *Артамонов — күрше рус авылының аңлы кешесе, Мирвәлинең якын дусты.* Т. Гыйззәт. *Әсәрдә Әхмәди шактый аңлы һәм революцион настроениеле эшче итеп бирелә.* М. Гали. *Пролетариатның иң аңлы өлеше үз партиясе сафларында [дошманнарга каршы] көрәште.* Г. Нигъмәти.

3. Акыл белән аңлап, уйлап, аңлы рәвештә эшләнгән. *1912 елның 4 апрель вакыйгасы аның күңелендә гомергә онытылмаслык эз калдырган һәм асылда аның аңлы көрәш юлын билгеләгән.* Г. Әпсәләмов. *Социализм чоры --- аңлы хезмәт дисциплинасын тудырды.* М. Җәлил.

Аңлы рәвештә — аңлап, күрәләтә, юри. *Китапның тел төзелешендә М. Әмирнең аңлы рәвештә кулланган бер «яңалыгы» бар.* М Җәлил.

АҢЛЫЛЫК *и.* Аңлы булу.

АҢСЫЗ *с.* 1. Акылы булмаган, акылсыз, аңгыра, юләр, тиле. *Алар бик тупаслар, аңсызлар.* Г. Ибраһимов.

2. Надан, иске, кара фикерле.— *Мин сиңа беренче очраганда аңсыз идем.* М. Гафури. *Бу эштә «яшел тавышлы Гыймади» картлар урталык урынын тотып, ярлы, ләкин аңсыз, эчкече Әхмиләр корал хезмәтен үтиләр.* Г. Нигъмәти. *Аңсыз кеше булып калмас өчен укыйм.* Ф. Әмирхан.

Аңсыз рәвештә — уйламыйча. *Ул башта аңсыз рәвештә, бара-тора аңлап, физкультура белән шөгыльләнә.* Г. Гобәй.

◇ **(Башын) аңсызга салу** — юләр сыман, тиле сыман кылану.— *Болай юри простой кылану һәм башын аңсызга салу пәрдәсе астында хәйләкәрлек саклый торган кеше төсле тоелды ул миңа.* Ш. Камал.

АҢСЫЗДАН *рәв.* 1. Көтмәгәндә, уйламаганда, искәрмәстән. *Аңсыздан бер көн каты җилләр исте, Урмәкүчнең пәрәвезен төтен кисте.* Г. Камал. *Аңсыздан атның берсе пошкырып җибәрде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Уйламыйча, аңсыз, механик рәвештә. *Аңсыздан гына эшләнгән эш бит бу.*

АҢСЫЗЛЫК *и.* Аңсыз булу хәле, аң булмау. *Ун елы балалык аңсызлыгында үткән булса, иң көчле, иң таза чагы кешегә эшләп узды.* И. Гази.

АҢЫНЧЫ *рәв. сөйл.* Аңа кадәр, ул вакыт җиткәнче.— *Өч-дүрт көннән дә соңга калмыйча килсеннәр, аңынчы мин башка кешеләр алмам.* Ш. Камал.

АҢЫ'ШМЫЙЧА *рәв. сөйл.* Аңлап җитмичә, төшенеп җитмичә. *Ярулла, аңышмыйча: «Нәрсәне? Кая алып китәргә? — дип сорады.* Ф. Бурнаш. *Малайлар бер секунд аңышмыйча, нишләргә белмичә тордылар.* Г. Гобәй.

АҢЫШУ *ф. сөйл.* 1. Аңлап алу; абайлау. *Гүзәл, каушавы белән, сусыз самоварга мичтән утлы күмер тутыра башлады, шундук аңышып, өй алдыннан су алып керде.* Г. Гобәй. [*Зәйтүнә*], *аңышырга тырышып та аңына килә алмагандай, аптырап калган, янында беркем дә юк.* Ф. Хөсни.

2. Аңлашу. [*Таһирҗан:*] — *Йә, аңыштык ич инде, бетте инде, йә, бетте,— дип, Гүзәлне юата иде.* Г. Гобәй.

Аһ *ы.* 1. Күрку, кинәт гаҗәпләнү, кайгы-хәсрәт, шатлану һ. б. ш. хисләрне белдерә. [*Сәрбиҗамал:*] *Аһ, нихәл итим, кая гына барыйм?* Г. Камал. *Вакыт соң. Урамнар, тыкрыклар тын. Һичбер фонарь юк. Үтереп, суеп китсәләр, «аһ» дип эндәшерлек адәм табылмас.* Г. Ибраһимов.

2. Түземсезлек, сабырсызлык катнаш борчылуны, шулай ук дулкынлануны белдерә.— *Җиңел тоям хәзер үземне, Аһ, тиз, аһ, тиз сөйлә.* Н. Исәнбәт. *Аһ, хәзер дә ул, элекке кебек, ялкынланып, дәртләнеп уйнап җибәрсен иде!* Г. Бәширов.

3. Зур кайгы-хәсрәттән уфыру, ахылдауны белдерә. *Аһ! дигәндә якын торма, янарсың ялкыныма.* Җыр. // *и. мәгъ.* Аһ-зар, кайгы-хәсрәт, газап. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә. Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.* Г. Тукай. *Таныш түгел безгә кайгы, аһлар.* Ә. Фәйзи.

◇ **Аһ итү** — *аһ* тавышлары чыгарып, кайгыру, борчылу һ. б. ш. хисләрне белдерү.— *Син аһ итсәң, яна йөрәгем; Кулым тотсаң, яна беләгем.* Н. Исәнбәт. *Бу да, гүя, бүген озатылган Садыйкның китүе өчен аглаган йөрәкнең аһ итеп куюы кебек тоела иде.* Г. Ибраһимов. **Аһ ору** *иск.*— бик нык кайгыру, өзгәләнү. *Союзниклар аһ ора, чәчләре үрә тора, Кычкырганга безнең Мәскәү һәрбер мәйданда «ура!».* Г. Камал. *Бөтен барлыгымны бер мәхрүмлек тойгысы каплап ала; аһ орасы, елыйсы килгән шикелле була.* Ф. Әмирхан.

АҺА-ҺА-ҺА-ҺА *аваз. иәр.* Ә дашып, югалып эзләгәндә тавыш бирүгә аваз ияртеме. *Ул аргы яктан кабат «көймә» дигән тавышка, кулларын авыз кырыена куеп, аһа-һа-һа-һа-а! дип эндәште.* Г. Гобәй.

Аһ-ВАһ *и. к.* аһ-зар. [*Автор*] *кешеләрнең аһ-вәһларын, газаплы тормышларын ачып сала алмый.* М. Җәлил.

◇ **Аһ-вәһ (итү, килү)** — 1) аһ итү, вәһ итү, борчылу, кайгыру. *Һәммәсе бик табигый бер төс алганга, берәү дә аһ-вәһ килми, һәркем тыныч кына тәмәкесен тарта.* Г. Бәширов. *Бай хатыны мәҗлескә китәдер, ябынып ефәк шәлләрен. Ире йөри аһ-вәһ итеп, белмидер аның хәлләрен.* Ш. Мөхәммәдев; 2) ашыгудан яки арудан хәл бетү, аһылдау. *Чуар тавык, чебешләрен генә ияртеп, аһ-вәһ итеп кайтып керде.* А. Алиш.

Аһ-ЗАР *җыйк. и.* Кайгы-хәсрәт. *Шәриф Камал турыдан-туры әнә шул капитализм корбаннары арасына*

кереп, аларның аянычлы тормышларын, аларның күз яшьләрен һәм аһ-зарларын чагылдырды. М. Җәлил.

АҺЛАУ *ф.* Аһ итү, аһылдау, кайгыру. *Аһлыйсың: «Яшьлек үтә!» — дип, Син минем хәлне кара: Кая яшьлек! Минем инде Картлыгым үтеп бара.* Ә. Исхак.

АҺЫЛДАУ *ф.* Аһ итү, аһ-ваһ итү; кайгыру, борчылу. *Өйгә кайтып, тырналган битен карчыгына күрсәткәч, хатын аптырап китте, вакыйганы сөйләп биргәч, аһылдады, сукранды.* И. Гази.

АҺӘҢ *и. шигъ.* **1.** Яңгыраш. *Б. Эйхенбаум «Шигырь методикасы» дигән әсәрендә лирика әсәрләрен аһәң ягыннан өч типка бүлә.* Г. Нигъмәти. *Әллә нинди бер моң, әллә нинди бер аһәң бар бу көйдә.* А. Әхмәт.

2. Тавыш, тон. *Ул тавышындагы әмер итү аһәңен үзгәртеп, тәмам бер ялыну тавышы белән: — Әсма туташ, әйдәгез инде, әйдәгез инде,— диде.* Ф. Әмирхан. *Ул тагын да кулын йодрыклап, Үчле аһәң белән сөйләде.* Ш. Маннур. *Аның тавышы әллә кай төше белән йөрәккә үтеп керә торган ягымлы, аңлаешлы тавыш, халыкның үз аһәңе иде.* Г. Бәширов.

3. Моң; ләззәтле кичереш, тойгы. *Зыя ул гажәеп аһәңгә секунды белән җиңелгән, алдындагы картны да тыңламый, сүзен дә ишетми иде.* Г. Ибраһимов.

АҺӘҢДӘШ *с.* **1.** *муз.* Яңгырашы белән охшаш, бердәй яңгырашлы.

2. *к.* аваздаш (2 мәгъ.).

АҺӘҢДӘШЛЕК *и.* Аһәңдәш булу. *Заманга аһәңдәшлек.*

АҺӘҢЛЕ *с. шигъ.* Аһәңе булган; моңлы. *Бу аһәңле җыр мине сихерләде, күп вакытлардан бирле туп, пулемет тавышларын гына ишетеп тупасланган колакта бу бик җылы яңгырады.* Ә. Айдар. // Дулкынланулы, тирән кичерешле. *Сузынкы, эчке аһәңле моң белән баласын юаткан ана авазы ишетелә.* Ә. Айдар.

АҺӘҢЛЕЛЕК *и.* Аһәңле булу. *Сүздә дә, музыкада да мөмкин кадәр гадилек, халыкчанлык, җиңеллек һәм аһәңлелекне сакларга тырыштык.* М. Җәлил.

АҺӘҢЛӘШТЕРҮ *ф.* Аһәңле итү. *Рус музыкант вә композиторлары --- тарафыннан татар көйләрен аһәңләштерү турында азмы-күпме уңышлы тәҗрибәләр ясалгач иде.* Тат. театры.

Б

Б Татар алфавитында икенче хәреф.

БА I *и.* Гарәп алфавитында икенче хәрефнең атамасы (әлиф хәрефеннән соң килә). *„Мужикны әлифтән үткәрмә, бага җиткермә, күп укыса, күп белә, муллаңың хәйләсенә төшенә", — ди Вәлид хәзрәт.* З. Һади. *Кулыбызда безнең яңа әлифба. Менә монсы „а", менә монсы „ба".* М. Җәлил.

БА II *ы.* Көтелмәгән хәлгә гаҗәпләнүне белдерә.— *Бу кем тагын? Ни бар? Ба, ни эш бу?* Ш. Мөдәррис. [*Хуҗи*] *килеп тә керде, өстәл янында утырган Борһанны күреп катып та калды: — Ба-а! Кемне күрәм?* М. Хәсәнов.

БАБ *и. кит.* 1. Әдәби әсәр, китап, җыентык бүлеге (бүлекчәсе). *Әсәрнең [„Тирән тамырлар"] дүртенче һәм бишенче баблары Фәхринең үткән тормышын --- гәүдәләндерәләр.* Г. Нәгъмәти. *Мин монда җырларыбызның матур, мәгънәлерәкләрен сайлап җыеп, „Кайгы-хәсрәт", „Сабыр", „Дәрт-моң", „Дуслар", „Сөешү-гыйшык", „Аерылу-горбәт" бабларына аердым.* М. Фәйзи.

2. *иск.* Сөйләшү темасы. *Халыкның бер бүлеге, сәкегә кырын төшкән хәлдә, төрле бабтан гәп сугарга тотындылар.* Г Ибраһимов. *Без, мунча бабына күчеп, полковникның мунча яратуы турында фикер алыштык.* М. Шәйми.

3. Мәсьәлә, эш; эшчәнлек өлкәсе. [*Һади Максуди*] *сәясәт бабында да халыкны өйрәтергә, гыйлем чәчәргә кереште.* Г. Тукай. *Драматургия бабында ул [М. Фәйзи] барлыгы унбиш пьеса тудыра.* Г. Кутуй.

4. *иск.* Капка, ишек. *Һәм болар [ярлылар] байлар кебек түгел: ачык һәр көндә баб.* М. Гафури.

5. *лингв.* Гарәп телендә фигыль төре. *Гарәп телендә фигыльләр унбиш бабка бүленәләр.* М. Мәхмүтов.

БАБА[1] *и.* 1. *к.* бабай (1—3 мәгъ.). *Оныгым миңа карап, яңгыравык тавыш белән әйтте: — Баба, сине горкомнан [чакыралар].* А. Шамов. *— Башкода булып килдек без сиңа. Кызыңны бирәсең, Насретдин, баба буласың.* Н. Исәнбәт.

2. *юг.* Хөрмәтле карт ир кеше: үткән буыннарның аеруча билгеле, хөрмәтле вәкиле. *Мәчеткә килүчеләр арасында --- бере Габдеррәзак бабадыр.* З. Бигиев. // Нәселнең, халыкның борынгы чыгыш нигезен тәшкил иткән кабилә, ыруг, кеше һ. б. *Кеше ачуланганда, кызганда аның канында моннан мең еллар элек яшәгән бабалары уяна.* А. Гыйләҗев.

3. Биологик ыругның (семьялыкның, классның) борынгы бер вәкиле. *Бер үк төргә кергән үсемлекләр үзара якын кардәшлектә булалар; алар уртак бабалардан килеп чыкканнар.* Ботаника.

4. *сөйл.* Сөннәтче карт. *Әбит бар иде заманнар — аның ул авылдагы урыны түр башы иде. „Сөннәтче бабай килгән", „Бабачы килгән", „Гали баба килгән" дип, үлеп торалар иде ул килгәч.* Ф. Хөсни.

5. *сир.* Чиертлек уенында басып торган чиертләләр. *Чиертлекләрнең утызлабы тек басып торалар. Аларны „баба" дип йөртәләр.* З. Бәшири.

Баба гөл — *к.* гөлбаба. **Баба елан** *диал.* — агусыз, тешсез елан. **Баба кош(ы)** — гаять озын һәм киң томшыклы зур су кошы; *русчасы:* пеликан. **Баба тел** — берничә яңа телнең формалашуына уртак нигез булып хезмәт иткән борынгы бер тел. **Бабага бирү** *диал.* — сөннәткә утырту, сөннәткә бирү. **Бабалар (бабайлар) баласы** — бабалардан калган традицияне дәвам иттерүче, бабаларына охшашлы. — *Мин кылыч ясадым, мин бабаларымның баласы булырлык гаҗәп бер эш эшләдем.* Ш. Әхмәдиев. **Бабалар (бабайлар) сукмагы (юлы)** — бабалардан килгән традиция, йола. *Сәмигулла --- изге бәндәләрдән, бабаларыбыз сукмагыннан бара.* С. Рафиков. [*Сабур:*] *Шулай ук бабаңнар юлын ташларсың микәнни, әй?* М. Фәйзи. **Бабалар (бабайлар) сүзе** — буыннан буынга килә торган афоризм. **Бабалар (бабайлар) тамыры** — шәҗәрә баганасы, ата-уллык буенча буыннар теземе. *Әллә ничә бабалар тамырыннан бирле алар ишек алдында үсеп утырган --- имәнгә дә күз төшермичә, Габдрахман Фәйзуллин ишеккә атлады.* С. Рафиков.

БА[1]БА *и. махс.* Баганаларны кагып, сугып утыртканда кулланыла торган корал — тоткалар беркетелгән авыр кискә. — *Менә син мондагы субай суга торган бабаны күздән югалганчы күккә чөйсәң, ашлыгыңны тартырмын, — ди җен.* Әкият. // *тех.* Багана кага торган механизмнарның бәрмә өлешләре.

БАБАЙ *и.* 1. Атаның яки ананың атасы. *Бу вакытта атамның ата-анасы (бабай вә әби) күптән вафат булып, авылда башка туганнарым булмаган.* Г. Тукай.

2. *диал.* Атаның яки ананың олы ир туганы (абый, абзый, ага). *Зыяның бер бабасы (атасының агасы) бар. Исеме — Ярулла.* Г. Ибраһимов.

3. *диал.* Кияү өчен — хатыннын, кәләшнең атасы. *Бер заман кияве кайтып керсә, бабай кешебез инде белгән сызганып, бик матурлап кына бәрәңге әрчеп утыра ди икән.* Н. Исәнбәт.

4. Хөрмәтле карт ир кеше; гомумән карт ир кеше.— *Бабай! — диләр миңа сүз кушканда, Картлар рәтенә тезәләр.* М. Гафури. *Без, еш кына Гөләндәм әби янына җыелып, дхтәм бабайны искә ала торган булдык.* Г. Гобәй.

5. *сөйл.* **бабаң, бабасы.** Башкаларга (мәсәлән, үз оныкларына) бабай тиешле кешене атау яки әндәшү сүзе. *Аны [картны] бер генә минутка да күздән ычкындырмыйча саклап торган Гыйльметдин: — әй, бабасы, каргышың үз башыңа төшмәгәе! — диде.* И. Гази.

6. Гаиләнең, кардәш-ыруның, нәселнең чыгыш шәҗәрәсендә ата-анадан элгәре булып үткән һәрбер ир заты, баба (3 мәгъ.). — *Әби патша боларның [Кригерның] бабаларын дворян ясап, безнең бабайларның җирләренә утырткан.* Т. Гыйззәт. *„Батыр егет— яу күрке", — дигән бабайлар.* М. Максуд.

Бабай башы *диал.* — зур тузганак. *Бабай башын мин күрдем, әби чәчен мин үрдем.* Әйтем.

БАБАЙКА *и. махс.* Салда, паромда, баркаста зур ишкәк.

Бабайка сугу — бабайка белән ишү. — *Иделдә сал утыра башлагач, бурлаклар гына бертоташ бабайка сугарга керешәләр.* М. Гали.

БАБАЙЛА'РЧА *рәв.* **1.** Борынгыдан килгән гадәт буенча, борынгыча. — *Һәр адәмнең үз эше. Дөтик, ягъни шулай икән, бабайларча торыйк.* С. Рафиков.

2. Хөрмәтле карт ир кешеләр сыман. *Бабайларча үгетләү.*

БАБАЙЛЫК *и.* Бабай дип аталырлык чак; картлык.— *Гариф бабай, өеңдәге ике хатының белән канәгать итеп тор, мине өмет итмә. Бабайлыгыңны күңелеңнән чыгарма.* М. Гафури.

БАБАЛЫК *и. сир.* 1. Баба кеше булу.

2. Сөннәтче булу.

БАБАСЫР *и.* Кешенең туры эчәгендә яшәүче вак кына паразитлар (нематодлар).

Бабасыр авыруы — бабасыр суалчанының зарарлы тәэсире нәтиҗәсендә килеп чыккан авыру. **Бабасыр уты** — шул ук исемдәге семьялыктан, күбесенчә таулы урыннарда үсә торган зәп-зәңгәр чәчәкле күпьеллык үлән; *русчасы:* горечавка (бабасырдан котылу өчен кайнатып эчелә).

◇ **Бабасыр кергән (мәллә)** *туп.* — тик кенә утырмаган, кыбырсынган кеше турында. — *Нигә тыныч кына утырмыйлар соң [эсирләр]? Бабасыр кергән мәллә?* Ш. Маннур.

БАБАЧЫ *и. диал.* Балаларны сөннәткә утырту белән шөгыльләнүче кеше, сөннәтче. *Менә ул [Гали баба] тавышын кыса төшеп кенә сүзгә кереште: — Ә, миңа әйткәннәр ие, сезнең авылда бабачы көтеп тилмереп торучылар бар, дигәннәр ие.* Ф. Хөсни.

БАБАЧЫЛЫК *и. сир.* Сөннәтче кәсебе.

БАББИТ *и.* Кургашның бакыр һәм сөрмә катнаш эретмәсе (машина киселәренең ышкылучан өсйөзләренең ашалуын киметү өчен ягыла). *Подшипникларга кою өчен аккургаш нигезендәге баббит һәм каракургашлы бронза кулланыла.* Тракторлар. // Баббиттан коелган деталь—подшипник балдагы. *Май сыекландымы — подшипниклар кыза башлый. Баббитлар эри. Терсәкле валның муены ашала.* Х. Госман. // *с. мәгъ.* Баббиттан коелган, баббиттан торган. *Баббит ярымбалдак.*

БАБЕР *и. к.* чабыр.

БАБЛАУ *ф. иск.* Бабларга (1 мәгъ.) бүлү, бүлекләү; классификацияләү. *Китапны баблау.*

Баблап сөйләү — логик тәртиптә, җиренә җиткереп, бәйнә-бәйнә сөйләү. *Картлар тәртип белән бик баблап, сабанчыларга карап, берәм-берәм сөйли башладылар.* М. Җәлил.

БАВЫР *и.* **1.** Кеше һәм хайван организмында үт бүлеп чыгара һәм матдәләр алмашуга бәйләнешле башка кайбер процессларны башкара торган эчке орган. *Казның йөрәге кечкенә, бавыры зур.* Г. Әпсәләмов.

2. Түш, күкрәк; гәүдәнең алгы өлеше. *Елан бавыры белән ил гизәр, койрыгы белән кое казыр.* Мәкаль. *Баланы бавырга кысып күтәрәләр (үстерәләр).* Мәкаль.

3. *күч.* Йөрәк; күңел, бәгырь. *Ташта тамыр юк, түрәдә бавыр юк.* Мәкаль. *Алтын ияр, штоф мендәр Акбүз атның савырында. Шул җаныйның әйткән сүзе Телләремдә түгел, бавырымда.* Җыр. // Үзәк, эч. *Җәй үтте. Кар-яңгырлы көз урнашты. Күк тугайның бавырына боз урнашты.* Дәрдмәнд.

Бавыр колбасасы — үпкә-бавыр һәм эчәкләрдән ясалган колбаса. *Акчаң арта төшсә, ярты кило бавыр колбасасын да аласың.* Г. Минский. **Бавыр мүге** — мүкнең шул ук исемдәге класска керә торган бер төре. *Яфрак формасы белән бавырга охшаган бавыр мүкләре бавыр авыруыннан терелтә дип уйлаганнар.* Робинзон әзл.

◇ **Бавыр ите** *диал.* — күңелгә бик кадерле нәрсә; йөрәк ите. *Бала — бавыр ите.* Мәкаль. **Бавыр тавышы** — көр атларның юырткан чакта эчке органнары селкенүдән чыккан тавыш. *Бераз чана чыжлавын һәм туктаусыз гөрт-гөрт итеп торган бавыр тавышын тыңлап барганнан соң, Солтан сорашмый түзмәде.* А. Расих. **Бавырга керү** — эч серләрен белергә тырышу; эч серләрен белү. *Дус хәленә керер, дошман бавырына керер.* Мәкаль. **Бавырга төшү** — бик нык җәфалау, үзәккә үтү, теңкәгә тию. *Авыр эш бавырга төшә.* Мәкаль. **Бавыры бала басмаган** — дөнья күрмәгән, тәҗрибәсез (хатын-кыз турында).

БАВЫРГАЛЫК *и.* Җигелгән атның корсак астыннан бер тәртәдән икенче тәртәгә бәйләнә торган каеш, бау. [*Хуҗаның энесе*] *иң әлек дуганы селкетеп карый. Аркалык белән бавыргалыкны, аннан соң тәҗәләрне тикшерә.* М. Гафури. *Текә тау бармы? Шуннан төшеп килгәндә атымның бавыргалыгы үзелде.* Г. Ибраһимов.

БАВЫРСАК *и. махс.* Махсус әзерләнгән камырны вак-вак турап, майда кайнатып пешерелә торган сыйламлыгы. *Чәй табынына ак он камырыннан майда куырылган сап-сары бавырсак өелде. Аның һәрбере балалар такыясы төсле кабарып, түгәрәкләнеп пешкән.* Ш. Маннур.

БАГ *и. иск.* Җимеш бакчасы. *Таулар, баглар, бакчалар Нурга гарык булганнар.* Г. Тукай. *Әллә син гөлләр өздеңме Гөлйөзем багларында?* Ә. Ерикәй.

Баг алмасы — 1) *к.* багалма. *Баг алмасы ашап үстеңме әллә? Ак йөзкәең, алсу битләрең.* Җыр; 2) *күч.* бик чибәр яшь кеше. *Кызы — баг алмасы. Юк, алай гына түгел, тулган ай шикелле иде. Бер күргән егет гашыйк булмый калмый иде аңа.* А. Шамов.

БАГАЖ *и.* **1.** Пассажирларның төннәргә төйнәлгән, сумкаларга, чемоданнарга һ. б. салынган әйберләре. *Кулым ике, багажым дүрт, ничек кайтып җитәрмен инде.* М. Фәйзи. *Кемнәрдер кабалана-кабалана Мирвәлинең багажын — ике дәү генә чемоданны, Шәмсегаянның сумкасын һәм зур гына төенне алып чыгып арба янына тезеп куйдылар.* А. Гыйләҗев. // Багаж белән җибәрү. *Багажга тапшыру.*

2. *күч.* Белем запасы; рухи байлык. *Әдәби тәҗрибәм бик аз, сәяси багажым бик чамалы иде ул чагында.* Ш. Камал.

Багаж арбасы — почта бүлекләрендә, станция һәм портларда, пристаньнарда багажларны урыннан урынга күчереп йөртү өчен махсус арба. *Өч кызылармеец тәп-тәбәнәк багаж арбасына төялгән туп ядрәләрен туп артыннан өстерәп алып киттеләр.* К. Тинчурин.

БАГА'ЖНИК *и.* Автомобиль, велосипед, мотоцикл кебек транспорт машиналарында багаж кую өчен махсус урын. *Дүрт дә велосипедчы рюкзагында яки багажнигында шактый күп авыр әйбер алып барса, шиннарга һава өстәргә кирәк.* Файдалы киңәшләр.

БАГАЛМА *и.* **1.** Алланып пешә торган алма сорты. *Багалма белән сыйлау. Багалма үстерү.*

2. *күч. башлыча тарт. форм.* Бик матур яки якын, сөекле кеше. *Кил, былбылым, кил, багалмам, кил!..* Ф. Әмирхан. — *Д мин сөям, Сөям багалмамны,*

Шашып сөям. Ф. Бурнаш. / *ирон.* — *И абыем, җаныем, беседаларыңны куеп тор, багалмам. Иртәгә сыерларга ашатырга җитәрлек саламыбыз юк.* А. Расих.

БАГАНА *и.* 1. Вертикаль торышта кузгалмаслык итеп җиргә беркетелгән бүрәнә, юан терәү һ. б. *Капка баганасы. Кое баганасы. Багана утырту.* □ *Абзар янындагы баганага әлегә әшкә китми калган дүрт ат бәйләнгән.* Г. Әпсәләмов. *Килү-китү юлларында, шәһәр кырыйларында, мәйданнарда танкларга каршы тимер баганалар тезелеп тора.* Каз. утл. // Һавага текә күтәрелгән ялкын, төтен, тузан һ. б. турында. *Көчәеп бара торган җил ялкын баганасын Хәйриләрнең салам түбәләренә аударды.* М. Гали. *Еракта, олы юл өстендә, тузан баганалары күтәрелә.* И. Гази.

2. *күч.* Берәр яссылык яки өсйөздә буй-буй төшкән нәрсәләр: юллар, сызыклар; мәсәлән, чигүдә, бәйләүдә һ. б. орнаментлы предметларда тасма сыман сузылган фигура. // Газета-журналларда һәм китап-дәфтәр битләрендә буй-буй төшкән текст яки текст язылачак урын. *Айсылу, цифр баганалары белән янәшә карандаш белән ясаган ниндидер билгеләр күреп, елмаеп куйды.* Г. Бәширов. *Бу унынчы номер газета фәкать минем көчем белән генә чыкты диярлек. Фәкать бер генә баганасы башка каләм белән үтәлде.* М. Фәйзи.

3. *күч. ирон.* Озын буйлы кеше турында. — *Үбеп тә алган булыр идем үзеңне, син баганага буем җитмәс, — диде Валя.* М. Хуҗин.

4. *күч.* Чорның күренекле вәкиле, берәр иҗтимагый, фәнни һ. б. эшчәнлек өлкәсендә танылган шәхес. *Рус революциячел әдәбиятның карт баганаларыннан булган Максим Горький сүзләрен күчереп китү бик урынлы булачак.* Г. Нигъмәти.

Багана умарта — куыш кәүсәнең эчен киңәйтеп ясалган умарта, дадан. *Бабай шушы таш белән багана умарта башын каплап куя торган булган.* Г. Галиев.

◇ **Багана булып (баганадай) кату** — хәрәкәтсез калып басып тору, шаккату. *Ул [Кадыйр], багана булып катканхәлдә, берни белмичә, соры мыеклы сакчы каршында басып тора иде.* А. Алиш. **Багана саклау** — эшсез басып тору, тик тору. *Бөтен кешенең үзенә күрә эше бар, ә менә Нәҗиянең бер эше дә юк: капка төбендә, багана саклап торгандай, тик басып тора.* Ф. Хөсни. **Баганага сәлам бирү** — бик түбәнчелекле булырга мәҗбүр булу. *Семьяда булып үткән фаҗига Сәҗидәкәйнең күтәрелгән борынын түбәнрәк төшерде. Замана үз җырын җырлатты, баганага сәлам бирдерде.* Г. Иделле.

БАГАНА-БАГАНА *с.* Күп кенә баганаларның бергәрәк торуына охшашлы. *Моржалардан багана-багана төтеннәр күренә, чана табаннары астында шытыр-шытыр кар тавышы ишетелә башлады.* Г. Тукай. *Тәрәзәләрдән төшкән иртәнге кояш яктысында мастерскойэчендә багана-багана тузан күренеп тора.* Г. Әпсәләмов.

БАГАНАЛАНЫП *рәв.* Багана-багана яки багана сыман булып. *Урамда баганаланып тузан күтәрелә.* А. Шамов.

БАГАНАЛАП *рәв.* 1. Баганалы итеп, баганалар утыртып. [*Хуторчылар*] *имән баганалап рус капка кордылар.* Г. Толымбай.

2. Баганалар (2 мәгъ.) берәмлегенчә яки тәртибенчә. *Оекны баганалап бәйләү. Баганалап уку (мәс., газетаны).*

3. Багана сыман яки багана-багана итеп. *Баганалап өю* (мәс., китапны). *Баганалап сызу* (мәс., дәфтәр битен). □ *Кенәгәләргә баганалап тезелгән очсыз-кырыйсыз саннарга карап, аның [дхмәдинең] күзләре тона.* Г. Иделле.

БАГАНАЛЫ *с.* Баганасы булган, баганалап эшләнгән. *Баганалы чат. Баганалы капка.*

Баганалы көзге — стенага терәтелә яки идәнгә бастырыла торган зур көзге, трюмо. [*Хәмидә:*] *Көзгесе --- шкафлы булсын, хәзер инде баганалы көзгенең мудысы бетте, дип әйтәләр, ди.* Г. Камал. **Баганалы юл** — 1) чакрым баганалары, телеграмм баганалары яки маяклар утыртылган юл, олы юл. *Гыйльметдин адашудан курыкмый иде: аты юлны белә, ара ерак түгел, озакламый баганалы юлга, шәһәр юлына алып чыгарлар, аннан соң инде күзне бәйләп тә кайтып җитеп була.* И. Гази; 2) *күч.* уңышка илтә торган, сыналган төп юнәлеш. *Такташ --- социалистик реализмның баганалы юлына аяк басты.* Х. Госман.

БАГАНАЛЫК *и.* 1. Багана ясауга ярый торган нәрсә (агач, таш). *Сәфәр --- урман аша үткән чакта баганалыклар карый.* С. Баттал.

2. *с. мәгъ.* Баганага яраклы, багана булырлык. *Баганалык имән.*

БАГАНАЧЫК *и.* 1. *сир.* Кечкенә багана.

2. *бот.* Җимешлекнең авызчык белән җимшән арасындагы өлеше. *Чәчәкнең нәкъ уртасында җимешлек була. Җимешлекнең түбәнге өлеше—җимшән. Җимшәннән баганачык күтәрелә.* Ботаника.

БАГБАН *и. иск.* Бакчачы, бакча караучы. — *Икесен күрдем, әмма баг эчендә, Бере Зөһрә ирер, бересе Таһир, Диде багбан.* Таһир-Зөһрә.

БАГ-БОСТАН *и. шигъ.* Чәчәкле бакча, баг. *Нинди матур, шулай чәчкә, гөлләр, Баг-бостаннар кочса гомерне.* Ф. Бурнаш.

БАГЕТ *и.* Бер ягына орнамент ясалып, матурлап буялган һәм тәрәзә, картина, көзге һ. б. рамнары ясау, кәрниз, түшәм, стеналарны бизәү өчен кулланыла торган тар планка, сырлы такта.

БАГЛАНУ *ф. иск. кит.* 1. *Кайт. юн. к.* баглау (1—3 мәгъ.). *Кадыйрның атлас-ефәкләре һаҗәрнең аягына богау булып багланырлар.* Г. Ибраһимов.

2. *Төш. юн. к.* баглау. *Аяк-кулы бау белән багланган.*

3. *юг.* Эчке һәм якын бәйләнештә тору. *Димәк, Габбасның уңыш-уңышсызлыгы бөтен ил интересы белән багланган.* Г. Нигъмәти. *Мәхәббәт һәм дуслык җебе белән Багланганда керсез күңелләр... Кинәт кенә ачы язмыш җиле Аера сине якын дусыңнан.* М. Җәлил.

4. *кит.* Бәйле булу. — *Инде --- дөньяда торуым сезгә багланды.* М. Гафури.

5. *сир.* Беркетелү, раслану. *Польша сәүдә җәмгыяте, солых багланубәйләнешләре белән, Польшадан Россиягә нинди маллар кертергә мөмкин икәнлек хакында сорый.* Ф. Әмирхан.

БАГЛАНЫШ *и.* 1. Бәйләнеш, элемтә. *Багланышка керү. Багланышта тору.* □ *Сугыш өермәсе үтеп китү белән, авылда ниндидер куркыныч тынлык урнашты. Район үзәге белән багланыш өзелгән, шул ук вакытта фашистлар да күренми иде.* М. Әмир.

2. Аралашу, катнашу, якыннан киңәшләшү, ярдәмләшү бәйләнеше. *Массалар белән багланыш.* □ *Укымышлылар иҗаты белән халык иҗаты билгеле дәрәҗәдә багланышка кергән.* Х. Госман. // Үзара эчке мөнәсәбәт. *Ул [Нәгыймә] шунда Садыйк белән үзе арасында тирән бер багланыш барлыгын бөтен җаны белән сизенде.* Г. Ибраһимов.

БАГЛАНЫШЛЫ *с.* 1. Багланышы булган. *Шәрәфи сөйли, аның алдында авыл белән каланың багланышлы моментлары ачыла торалар.* Г. Ибраһимов.

2. Билгеле бер нәрсәгә кагылышлы, мөнәсәбәтле. *Эшчеләр вакыйганың турыдан-туры үзләренең язмышларына багланышлы икәнлеген ачык сизәләр.* Ш. Камал.

БАГЛАНЫШЧЫ *и. иск.* Оешма членнары арасында хәбәрдарлык һәм әлемтә булдыру эше йөкләтелгән кеше, әлемтәче. *Кызыл Гвардия багланышчылары юлдагы отрядларга әйтә узганнар, күрәсең, дугасына зур ак флаг элеңгән сәер тарантасны берәү дә туктатмады.* К. Нәҗми.

БАГЛАУ *ф. кит.* 1. *иск.* Бәйләү, бау белән берәр нәрсәгә яки бер-берсенә беркетү. *Йосыфның кулын баглап, каты беркеттеләр.* Колгали. *Гүя тәңре үз кулы белән Зыяны аңа [Мәрьямгә] баглап куйды.* Г. Ибраһимов. // Тоташтыру, кушыру. *Фарыз безгә кисек җепне баглашырга (урт. юн.).* Г. Камал. [*Бала*] *ике кулын берен-берсенә баглап, чыгып китте кәефсез хәлдә аглап.* М. Гафури.

2. Буу, уратып бәйләү. — *Синең картуз киеп, биленә зиннар баглап йөрүеңә без риза була алмабыз.* Ф. Әмирхан.

3. Тоткарлау, киртәләү. *Утеп китте бу юллар Байкал күлен, Баглады һәр яктан дошман юлын.* М. Гафури. *Шул тәэсир гүя аның [Зыяның] тавышын каплаган, телен баглаган.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Эчке кичерешләрне берәр нияткә яки тышкы сәэәпкә, сәбәпчегә юнәлтү. *Ихлас баглау. Күңел баглау. Ышаныч баглау. Өмет баглау.* □ *Әткәй ачуланмый, ике өлкән баласының хәсрәтеннән соң бөтен йөрәген миңа баглаган булса кирәк, ул мине ярата, сүземне тыңлый, һәрвакыт иркәли.* Г. Ибраһимов. *Бу кызны күрү белән, мин аңарга чын хөрмәт багладым.* Г. Газиз.

5. *сир.* Беркетү. *Иман баглау. Солых баглау.*

БАГЛЫ *с. кит.* 1. Бәйләнгән, богауланган. *Анда [дию бүлмәсендә] биш йөзләп мөселманнар тулы, Баглыюыр һәрберсенең аяк-кулы.* Г. Тукай.

2. Буйсынган, бәйле; тыгыз бәйләнештә торган.

3. Эчке, сәбәпле бәйләнештә булган. *Нинидер бер җитди үзгәреш бар аңарда [Саниядә]: аның күңеле, йөрәге белән баглы үзгәреш.* М. Әмир. // Багланган (*к.* баглау 4 мәгъ.). *Туган җирең ... Улы син аның. Аңа баглы өмет-хыялың.* Г. Хуҗи.

4. *к.* багланышлы (2 мәгъ.). *Гыймазов аның [Котдус] белән еш-еш очраша, игенчелек-терлекчелеккә баглы мәсьәләләр турында киңәшә, сораша иде.* С. Рафиков.

5. *күч. сир.* Кайгы-хәсрәт һ. б. нәтиҗәсендә боекканган, басынкыланган. *Баглы күңелдә дәрт юк.* Мәкаль.

БАГОР *и.* Озын сапка беркетелгән тимер ыргак. — *Егетләр, түбәне каерып ташлагыз, түбәне! Багорлар белән! — дип кычкырды Гафиятулла бабай.* Г. Әпсәләмов.

БАГСТАН *и. шигъ.* Бакчалары күп булган ил, як; бакчалар иле. — *Үзбәкстан — багстан ул, ә аның чибәрләрен күрсәң, һушыңнан язарсың.* Ә. Еники.

БАГУ I *ф.* 1. *диал. к.* карау I (1 мәгъ.). *Баксаң багардай, базардагы товардай.* Әйтем. *Нигә, нигә синең шаян күзләр Күзләремә болай багалар?* һ. Такташ. — *Дидә, хәзер яңа салган тегермәнне карарбыз, урманнарны, болыннарны багарбыз.* Т. Гыйззәт.

2. *диал.* Карау, тәрбияләү. *Тик син генә, әнкәй, Тик син генә сабый чактан мине баккансың.* Г. Латыйп. // Ашатып, эчертеп һәм күзәтеп тору. *Әхмәтсафа армиягә алынганнан бирле, сыерларны, сарыкларны хатын-кыз бага.* И. Гази. *Тавык багарга Мөдәррис картның Нәсимәсен куярга!* Ә. Айдар.

3. *ы. мәгъ.* **бак, баксана.** „Кара әле, кара син аны" мәгънәсендә, аеруча игътибар итәргә кирәклекне белдерә. *Бак, кырмыска йөк ташый.* Дәрдмәнд. [*Бер хатын*] *бер дә юкка шакката, яңа бер сүз ишетсә, „баксана!" да „баксана!" дип, бот чаба икән.* Н. Исәнбәт.

4. *кер. сүз. мәгъ. сөйл.* **баксаң, бактың исә.** Тикшереп, дикъкать итеп карасаң. *Баксаң, тормыш әллә кайчан алмашынып, үзгәреп беткән.* А. Гыйләҗев. — *Галләм дисең син, бактың исә, бәлкем, синең ул кешене илдән сөрүең дә законга хилаф килеп эшләнгән эштер әле.* Ф. Хөсни. // Беленүенчә, соңыннан беленгәнчә. *Бактың исә, штаб әллә каида түгел, ә якында, ниндидер ярым җимерек подвалда икән.* А. Шамов.

5. *ярд. ф. функ. к.* карау I (22 мәгъ.). — *Мә әле, карап бак, менә бу корыч булмагае.* Г. Галиев. — *Гарәфи, малай, каенар чакта авыз итеп бакмыйсыңмы?* Г. Гобәй.

БАГУ II *ф.* Күрәзәлек итү. — *Багучы булып бага-бага, имгә ярамаган гыйлемем белән имли-имли ялыктым инде.* Г. Мөхәммәтшин.

БАГУ III *и.* Билгесез язмышның яки авыруның, бәлакәзаның сәбәбен юрап әйтелгән хөкем. *Соры кортлар гомер итә Багу багып, фал ачып.* Ә. Исхак.

БАГУЧЫ *и.* Күрәзәлек итүче, фалчы. — *Бу арада безгә карт муллалар, багучылар йөри.* Ш. Камал. *Тормышка аек караучы кешеләр бервакытта да багучыларга мөрәҗәгать итмиләр.* Соц. Тат. // Авыруларны төрле ырымнар белән дәвалаучы, сихер кайтаручы. *Багучыга барма, башыңа кайгы алма.* Мәкаль. *Өшкерүче, багучылар — Хәйлә белән баючылар...* Н. Исәнбәт.

БАГУЧЫЛЫК *и.* Багучы шөгыле (кәсебе). *Хәтирә --- им-том һәм багучылык белән даны таралган фалчы Маһи карчыкка китте.* Г. Минский.

Багучылык итү — *к.* күрәзәлек итү. *Йолдызларга карап багучылык итүче берәү, өенә кайтып кергәч, хатынының билгесез бер ир белән утырганын күргән.* Ә. Исхак.

БАГЪЧЫ *и. иск.* Бакчачы. — *Бакчаңыз харап булган, һәлак булган! [диделәр].* — *Бу сүздән багъчыларда тәкать бетә, Авыздан утлы ачу чәчрәп китә.* Ш. Бабич.

БАГЫЛУ *ф. диал.* 1. *Төш. юн. к.* багу I (1, 2 мәгъ.).

2. *к.* каралу II (2 мәгъ.). *Ул [Дилбәр] багылырга барса, врачлары да суык тиюгә, ютәлгә каршы гына дару язып җибәрә торганнар иде.* Э. Касыймов.

БАГЫНДЫРУ *ф.* Үзенә карату, буйсындыру. [*Бәдигылаҗамал — килененә:*] *Минем Ибраһимымны бөтенләй үзеңә багындырып бетердең.* Г. Камал. // Сокландыру, җәлеп итү, үзенә тарту. *Казан яклары матур. Агыйделләре, Кама, Волгалары, шәһәрләре, зур авыллары мине багындыралар.* М. Фәйзи.

БАГЫНУ *ф.* 1. *Кайт. юн. к.* багу (1 мәгъ.). *Көзгедән багыну.*

2. Кемгә, нәрсәгә дә булса табыну, төп игътибарны юнәлдереп, ник мавыгу. *Байлыкка багыну.* □ *Бар кануннан башым алдым, Багынамын тик аңа! Бар кызыктан кул селектем, Табынамын тик аңа.* С. Рәмиев.

3. Буйсыну, бәйле булу. *Николай дигән поляк бик батыр, көчле, куәтле, хәйләкәр кеше булган. Тирәяк кешеләре аңар күбесе баш биреп, багынып торганнар.* К. Насыйри.

БАГЫШ *и. иск.* Караш, күз каравы. *Буйларыдыр Идел камышы, Бәгыремне яккы багышы, Колагымда, аһ, былбыл түгел, аһ, Яңрап калды аның тавышы.* Н. Исәнбәт.

БАГЫШЛАНУ *ф.* 1. *Кайт. юн. к.* багышлау.

2. Кемгә, нәрсәгә дә булса атап эшләнү. *Әдәбият тарихына багышланган мәкалә.* □ *Бүген Габдулла Тукай --- истәлегенә багышланган әдәби кичә була.* Г. Гобәй.

БАГЫШЛАУ *ф.* 1. *юг.* Материаль яки рухи ярдәм бирү; бүләк итү, атау, билгеләү. *Бар җырымны илгә багышладым, Гомеремне дә бирәм халкыма.* М. Җәлил. // Берәр нәрсәгә сарыф итү, бирү. *Бу һөнәргә тормышының ун елын багышлагач, Авыру безнең Зиннур дусны урынга егармыни?* Г. Хуҗи.

2. *рәв. мәгъ.* **багышлап**. Махсус атап, аерым максат итеп. *Фәүзия җиңги каз бәбкәләрен үстергән вакытында ук, берничәсен шушы юлга [Вахитның солдатка китүенә] багышлап, билгеләп үстерде.* М. Гафури. *Багышлап кузгалып килмисез дә, китмисез дә, кода, ичмасам, менә йомышлый килү сылтавы белән бер сугылыр идең.* Р. Төхфәтуллин.

3. *сир.* Карарга килү, нәтиҗә чыгару, фараз итү. *Купеда бер симез гәүдәле абый (нигәдер мин аны сәүдә кешесе дип багышладым) һәм мин.* Б. Камалов.

БАДЕ: баде-саба *и. иск.* Саф җил, саба җиле. *Сөйләшкән сүзләре гөлдәй тамадыр, Сулаган сулышы баде-сабадыр.* Г. Тукай.

БАДМИНГТОН *и.* Воланны (койрыклы тупны) җиргә төшермичә ракетка (махсус чәпәмә, калак) белән каршы якка атып уйнала торган командалы уен. *Казан шәһәре беренчелегенә бадмингтон ярышлары тәмамланды.* Соц. Тат.

БАДМИНГТОНЧЫ *и.* Бадмингтон уйнаучы спортчы.

БАДРАН *к.* гөлбадран.

БАДЪЯ *и.* Мичкә сыман колаклы агач савыт, зур чиләк. *Идрис белән Мухин тагын бер бадъяны тартып чыгарып тукмач, Мухин чыгырның тоткасыннан кулын алды.* Ә. Айдар. *Бетон төяп, ашыкмый гына беренче бадъя төшә.* М. Хөсәен. // Кое чиләге. *Рәхилә коеның зур һәм авыр бадъясына үрелгән җирендә туктап калды.* И. Туктар.

БАДЪЯН I *и. диал.* Агачтан чокып ясалган савыт. *Гыйфрит ике бадъян, ягъни җамаяк илә эчемлек китереп бирде.* Ф. Халиди. *Карчык күкәйләрне салкын сулы агач бадъянга батырды, кечкенә савыт белән тоз китерде.* С. Рафиков.

БАДЪЯН II *и.* 1. Әнис үләненең бер төре. *Бадъян да чәчтем тамырга, Тамырдан тартып алырга.* Җыр. // Шул үсемлекнең орлыклары (аш тәмләткеч сыйфатында файдаланыла). *Садыйк картның постау бишмәтеннән гел канәфер, бадъян исләре аңкып тора торган иде.* Ш. Камал. *Канәфер ачы, бадъян төче; Яшем унбиштән кече.* М. Фәйзи.

2. Әнис алма агачы. *Басмас идем баскычыңа, Баскычларың бадъян агачы.* Җыр.

Бадъян гөл — гөл сыйфатында үстерелгән әнис үләне. *Бадъян гөлләр чәчәк ата, Кояш көлеп караса, Күңелләрдә ялкын арта, Кызлар сөеп караса.* М. Җәлил. **Бадъян төс** — саргылт көрән төс. *[Әсир Мөхәммәт] уңып, кызыл төстән бадъян төсенә әверелгән --- башлыгын купшылап җилкәсенә салды.* К. Тинчурин.

БАДӘМ *и.* Розачәчәкләләр семьялыгыннан көньякта үсә торган куак үсемлек, миндаль. *Көнгә зәйтүн маенда кыздырылган, чикләвек кадәр генә берәр бадәм җимеше ашап, ел буена тау тишегендә укып яткан дбүгалисина белән дбелхарис аның [Габделкаюмның] исенә төште.* М. Гали.

БАЕК I *и. этн.* Башкорт халык биюе.

БАЕК II *рәв. иск.* Анык билгеле; һичшиксез. *Йосыф --- һич гөмансыз, баек колдыр.* Колгали. // Тәмам, бөтенләй. *Остазым бу җиһандин баек бизде.* М. Колый.

БАЕКЛАУ *ф. иск.* Тәгаенләү, сайлап, билгеләп кую. *Йөгерергә ике кешене баекладылар. Берсе патшаныкы, икенчесе Аю-Дппәзнеке.* Әкият.

БАЕКТЫРУ *ф. диал. к.* баету (2 мәгъ.). *Тау рудаларын баектыру комбинаты.*

БАЕТКЫЧ *и. тех.* Катнашманы баета торган махсус җайланма, механизм. *Двигательне җибәргәндә цилиндрларга ягулыкны күбрәк бирү өчен регуляторның баеткычы хезмәт итә.* Тракторлар.

БАЕТУ *ф.* 1. Бай итү, байлыгын арттыру. *Ярлы байны баета.* Мәкаль.

2. *махс.* Катнашма составындагы кирәкле компонентны арттыру. *Баету фабрикасы.* □ *Еш кына чималны алдан баеталар, ягъни андагы кыйммәтле матдәләрнең концентрациясен арттыралар.* Химия.

БАЕШ *и. сир.* Кояш, ай, йолдызлар байый торган як, көнбатыш. *Беребез кояш чыгышында, беребез баешларында.* Җыр.

БАЗ *и.* 1. Казып ясалган зур чокыр. *Урман кырыенда яңа гына казылган баз янына килеп җиткәч, атны туктаттылар.* М. Гали. // Нәрсәне дә булса урнаштыру өчен җайлаштырган чокыр. *Дары базы. Кар базы. Силос базы.* □ *Чан дигәннәре --- төп һәм стеналары цементтан койган дүрт почмаклы зур гына базлардан гыйбарәт иде.* Ш. Камал. // Җирдәге чокыр-чакыр, казылма. *Ай бу юллар! Безнең [машина] бер баздан сикереп чыга, икенчесенә сикереп төшә.* И. Гази. *Әлбәттә, искелек мираслары булып калган бу нәләтле межа базларын --- колхозлашуның беренче елында ук юкка чыгарып булмый.* Г. Иделле.

2. Идән асты чокыры (куышлыгы). *Карчык тиз генә идән тактасын ачты да миңа базга төшәргә ымлады.* Ф. Кәрим. *Бүтән вакыт булса, Хәлим базга төшеп тормас иде, хәзер анда караңгы, пычрак.* И. Гази.

3. *иск.* Җирне казып ясалган борынгы зиндан. *Рәшәткәле чуен баз койдырып, Алпамшаны шул зинданга ябып китәләр.* Әкият.

4. *этн.* Өсте чыбык-чабык белән каплап куела торган тирән чокыр рәвешендәге ау корылмасы. *Бүре базларын беләм, төрлечә була. Кайсына бүре төшә торган юл да ясала, баз уртасына ишек куеп, эчкә, казыкка сарык та бәйләп куялар.* Н. Исәнбәт.

5. Балчык, таш, руда кебек нәрсәләр казып алына торган яки элек казып алынган урын. *Идел тирәсендә язгы су тулып калган ком базлары бар иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. // Шахта, штольня турында. *Тезләнеп ятып тирән базларда, Кәйлә уйнатып эшлиләр анда [шахтада].* К. Тинчурин.

Баз бакасы — өй, каралты-кура тирәсендә күбрәк очрый торган бер төр бака; җир бакасы, гөберле бака. *Шул арада Котдусның колагына бака чурлавы ишетелде, менә баз бакасы үзе дә күренде.* С. Рафиков. **Баз казу** — 1) ау базы кору; 2) *күч.* хәйлә, мәкер кулланып, һәлакәт хәзерләү; һәлакәткә илтү. *Кешегә баз казысаң, үзең төшәрсең.* Мәкаль. *[Мансур:] Дус-иш аша гаебеңне ябып калырга тырышу үзең өчен дә, дустың өчен дә баз казу ул.* Р. Ишморат. **Баз өсте** — баз өстенә корылган куыш, япма, кыек. *Мүкле абзар, лапас, баз өсте, утын сарае, тоташтан тезелеп китеп, мин сиңа әйтим, чыпчык та очып чыкмаслык булган.* Р. Төхфәтуллин. *[Әби] Гарифәгә кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты.* Ә. Еники.

БА'ЗА *и.* 1. *махс. к.* базис (1 мәгъ.). *Колонна базасы.*

2. Нигез, җирлек; кирәкле материаль шартлар. *Колхозның терлек азыгы базасы.* □ *Коммунистик җәмгыятьнең материаль-техник базасын булдыру процессында кешеләр рухи яктан да үзгәрәләр.* Соц. Тат. // Берәр процесс, үсеш, иҗат өчен нигез, чыганак булып хезмәт иткән материаль яки рухи байлык. *Гарәп һәм фарсы сүзләре, төп татар сүзләре кебек үк, [татар теленда] яңа сүзләр ясау өчен лексик*

база хезмәтен үтиләр. М. Нугман. // Чимал хәзерләүче яки продукт җитештерүче экономик район, предприятие, хуҗалык тармагы. *Колхозлар бит безнең пролетариатның азык, икмәк базасы.* Т. Гыйззәт.

3. Төрле материаль кыйммәтләрне, товарларны һәм продуктларны кабул итү, җыю һәм бүлү (өләшү) урыны, склад. *Ул [Идият абзый] районара йомырка базасының директоры.* Ә. Еники. *Ак май белән дөге ярмасы азрак булды. Муса агай иртәгә базага барып алып киләм ди.* И. Салахов. // Вакытлы яки сезонлы склад. *Чаңгы базасы. Экспедицион база.* // Хәрби корылмалар, хәрби складлар җыелган урын. *Хәрби диңгез базасы.* □ *[Бандитлар] базага һөҗүм иткән булсалар кирәк. Лазаретка килеп чыгулары да бик ихтимал.* А. Шамов.

4. Билгеле бер физиологик процессны башкаруда катнаша торган органнар системасы. *Артикуляцион база.*

5. Төп үлчәм, габарит. *Тракторны авыр асылма машиналар белән эшләтергә кирәк булганда, аның буй базасын озынайтып, тотрыклылыгын арттыру яхшырак.* Тракторлар.

БАЗАЛЬТ *и.* Составы катлаулы булган вулканик тау токымы. Гадәттә кара төстә; табигый хәлендә яки эретелеп, төзү материалы сыйфатында файдаланыла. *Суынган лава төрле төстәге кристаллик гранит, кара-кучкыл базальт катламнары хасил итә.* Үтк. зам. сәяхәт. / *с. мәгъ. Базальт кыя. Базальт пьедестал.*

БАЗАР *и.* **1.** Сатучы һәм алучыларның гадәттә периодик рәвештә бергә җыелып сәүдә итүе, шул сәүдә урынына җыелган халык. *Колхоз базары. Базарга мал чыгару.* □ *Товарына күрә базары.* Мәкаль. *Авылның уртасында зур базар кайный.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Шау-шулы күренеш, ыгы-зыгы. *Минем алда тирән ут базары.* М. Җәлил.

2. Базар җыела торган махсус урын, мәйдан. *Җирнең йөзен баскан тирән йокы, Тынлык урамнарда, базарда.* М. Гафури. *Базар. Базарда магазиннар. Сәүдәгәрләр план корып ята таларга.* Һ. Такташ.

3. Сату-алу мөмкин булган географик өлкә яки хуҗалык тармагы; товар әйләнеше сферасы. *Бөтендөнья базары. Тышкы базар. Эчке базар.*

4. *күч.* Базардагы бәя турында. — *Хәзер базарны арзан диләр диюен.* М. Фәйзи. // Сатылыш; сату табышы. *Боларны [кавырсыннарны] саткач, базары уңышлы булса, бәлки, бик зәһәр берничә корыч кармак алып булыр.* Г. Ибраһимов. // Бәяләнерлек кыйммәт. *Дй, Базаргөл, матурлыкта базарың бар.* Ш. Бабич.

5. *күч.* Абруй, авторитет; кирәклек, хаҗәт. *Хәзер мулла-мәзиннең базары бетте инде.* Ф. Бурнаш.

6. *күч.* Болагайлы, этеш-төртешле уен турында. *Бер кыз „базар!" дип минем баштагы бүрекне алып, пычрак идәнгә ташлады.* М. Гали.

Базар авылы — базарлы авыл, базар җыела торган авыл. *Менә ул [Гарифның әтисе] базар авылыннан пар ат яллап --- җырлап кайта.* Ш. Камал. **Базар баганасы** *иск.* — базар мәйданы уртасына утыртылган һәм базар үзәген белдереп, символлаштырып торган багана. *Базар баганасына дүрт кешене аскан Галигә --- ярыйсы әләккән.* Г. Ибраһимов. **Базар бәясе** — товарларның базар стихиясендә үзгәреп торган уртача бәясе, базар хакы. *Көннәрдән беркөнне хәрчәүнектә базар бәяләре урынына герман сугышы турында сөйли башладылар.* К. Нәҗми. **Базар калачы (күмәче)** *иск.* — ипи пешерү предприятиеләрендә пешерелгән ак ипи, булка, батон. *Ашар аш кынам—базар калачы, Минем каенанам — Пенза палачы.* Борынгы җыр. **Базар конкуренциясе** *экон.* — базарда сатучылар яки алучылар арасында барган конкуренция. **Базар конъюнктурасы** *экон.* — товар әйләнешенең билгеле вакыттагы гомуми хәле: сату-алу җанлылыгы, бәяләр торышы һ. б. *Дөньякүләм социализм системасы — базар конъюнктурасы тирбәлүләренә бирелми торган тотрыклы базар.* Политэкономия. **Базар кич** — базар көненнән алдагы көн. *Мондагы халык базар буласы көнне түземсезлек белән көтә. Көтеп алынган базар алды көнне — базар кич дип йөртәләр.* С. Рафиков. **Базар кору** — 1) сату-алу оештыру. *Татар „агай-эне" юктан базар кора. Учка тезеп кенә күрсәтелә торган асыл таш төймәләрен, алтын күзле инәләрен, машина җепләрен күтәрәләр дә мәйданга рәт-рәт тезелиләр.* Г. Ибраһимов; 2) *күч.* эшсез, максатсыз җыелып тору. *Баскычта һәм өйалдында аны-моны сөйләшеп --- торучы эшсез бүрекбайлар күренгәли иде, Гафи иң элек аларга ташланды: — Дөньягыз түгәрәкләндемени, монда килеп базар кормасагыз!* Ф. Хөсни. **Базар көн(е)** —1) базар җыела торган көн. *Кызу урак өсләре булганга, [малайларга] якын арада очрашырга туры килмәде. Тик базар көннәрдә генә бергә-бергә җыелып ала идек.* Г. Ибраһимов; 2) *сөйл.* якшәмбе көн, ял көне. *Көн бара, төн бара егет, бара торгач зур бер калага барып җитә. Базар көн, якшәмбе көн була.* Әкият. **Базар мәйданы** — базар җыела торган махсус мәйдан. *Хәер, без килгәндә базар диярлек җире калмаган, халык таралган, берничә яктан тузан туздырып базар мәйданын себерә башлаганнар иде.* Ф. Хөсни. **Базар продукциясе** — базарга чыгарыла торган махсус продукция; тулай продукциянең базарга чыгарыла торган өлеше. **Базар оегы** — фабрикада бәйләнгән мамык оек. — *Әй суык, тез башларым туңа башлады. Мин бит бер кат базар оегы гына кигән.* С. Рафиков. **Базар оны** — пар тегермәнендә тарттырылган ак он. **Базар хакы** — 1) сату иткән өчен базар идарәсенә түләнә торган акча, урын хакы; 2) товарга базарда бирелгән уртача бәя. *Итекләрнең кыйммәте әүвәлгечә калды (ягъни дүрт тәңкә — ике көн хезмәт), әмма итекләрнең базар хакы (базарда итекләр күпмегә сатылдылар) төрле-төрле булды.* Г. Тукай.

◇ **Базар бозу** — базарда урнашкан бәяләрдән түбәнрәк хакка товар сату, базар хакын төшерү. *Базымсыз базар бозар.* Мәкаль. **Базар йөрү** *диал.* — 1) базардагы товарларны, базар тамашаларын карап йөрү. *Колхозчылар йокларга, базар йөрергә калдылар.* К. Басыйров; 2) *иск. к.* базар чабу. *Базар йөреп сату.* **Базар кертү** *иск., диал.* — базарчыларны кундыру, ашату-эчертү белән кәсеп итү. *Базар керткән — баеган.* Мәкаль. **Базар кычкыру** *иск.* — мөһим (бигрәк тә сәүдәгә кагылышлы) хәбәрләрне халыкка базарда кычкырып әйтү, белдерү. **Базар тору** —1) базарда товар сатып тору. *Ул [Шәвәли] көне буе базар торып, бары өч-дүрт кенә чүлмәк саткан, шуңарга күрә аның кәефе әйтеп бетермәслек начар иде.* С. Рафиков; 2) ил күзендә абруйлы, күрекле, иң шәп, матур булган чагың үтү. *Буласы булган, базарын торган.* Мәкаль. **Базар тоту** — 1) базарда бик уңышлы сәүдә итү; 2) базарлыклы, үтемле булу (товар турында). *Базар тоткан товар.* **Базары узу (үтү)** — 1) кыйммәтле, абруйлы яки әһәмиятле булган чагы артта калу. *Д мондыйларның [иске динчеләрнең] базары үтте инде.* К. Нәҗми; 2) *к.* базар тору (2 мәгъ.). *Базарың үткәч, ялкының беткәч, Тагын бер кат килми яз.* М. Максуд. **Базар халкы** — базар әһелләре, базарга еш йөри торган кешеләр. — *Шул, шул, базар халкы инде моны әллә кайчаннан бирле белеп тора.*

Ш. Камал. **Базар хәбәре** — базар халкы арасында таралган хәбәр, имеш-мимеш. **Базар чабу (йөрү)** — базардан базарга йөреп сәүдә итү. *Сәлмән --- йөк өстенә утырып базар чаба.* Ф. Хөсни.

БАЗАРЛАНУ *сир.* Базар корып жыелып тору. [*Агайэнеләр*] *гөж килеп, кайнарга, шауларга, алдарга, алданырга тотыналар. Шулай базарланып торганда, ерактан берәр атлы, кораллы адәм күренә.* Г. Ибраһимов.

БАЗАРЛЫК *с.* **1.** Базарда сатарга билгеләнгән; базарда сатылырлык. *Байныкы — базарлык, ярлыныкы — казанлык.* Мәкаль. / *и. мәгъ. Сабагыннан сыдырып* [*алганда*] *--- карлыган сытыла, аның базарлыгы китә.* Г. Галиев.

2. Базарга чыгып нәрсә булса да сатып алырга билгеләнгән (акча турында). *Шәйхел --- атасы белән туп-туры: — Үзең базарлык бер тиен бирмәгәч, урламый ни эшлим? — дип телләште.* Г. Ибраһимов.

БАЗАРЛЫКЛЫ *с.* Базарда сатылырлык, үтемле. — [*Май*] *базда озак торган, каксыган, базарлыклы түгел.* Г. Бәширов. *Карабодай чәчәргә уйлап торам әле. Дәе, уңа-нитә калса, базарлыклы да нәрсә үзе.* М. Шабай.

БАЗАРЧЫ *и.* Сату-алу йомышы белән базарга килгән кеше. *Без атны кертеп туарып ашарга кушкан арада, шактый яктырды, базарчылар да җыела башладылар.* М. Гали. // Базар тирәсендә чуалып, сатуалу эше белән кәсеп итүче, алыпсатар. — *Атаклы базарчы булып киттек, алыш-бireш, теге-бу!* Г. Мөхәммәтшин.

БАЗИЛИК *и.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан булган берьеллык үсемлек, рәйхан (көньяк районнарда аш тәмләткеч сыйфатында үстерелә).

БА'ЗИС *и.* **1.** *махс.* Колоннаның төбе, төрле архитектур бизәкләрнең аскы өлеше, нигезе. // *геом.* Фигураның аскы, нигез өлеше. // *геол.* Жир өстендәге торышы (координатлары) анык билгеләнгән һәм озынлыгы төгәл үлчәнгән туры сызык; тирә-юньдәге башка пунктларның координатлары шул линиягә нисбәтән хисаплап чыгарыла яки билгеләнә.

2. *филос.* Җәмгыятьнең житештерүче көчләрне һәм аларга тәңгәл килә торган житештерү мөнәсәбәтләрен органик берлектә эченә алган экономик структурасы. *Галә Ходаяров марксизмның базис һәм өскорма турындагы өйрәтмәсенә мөрәҗәгать итте.* Х. Госман.

БАЗЛЫ *с.* **1.** Базы (2 мәгъ.) булган. *Базлы өй.*

2. Чокыр-чакырлы, сикәлтәле, казылмалы. *Ә аннары ялларын тузгытып чапкан партизан атлары, базлы, чокырлы юллар, кара урман.* Г. Әпсәләмов.

БАЗЛЫК *и.* Чокыр-чакыр күп булган урын. *Ә аюлар сазлыкларны, Баткаклык һәм базлыкларны Таптап йөргәннәр.* Ә. Исхак.

БАЗУ I *ф.* Батырчылык итү, кыю. [*Гарәп:*] *Сезне борчырга да базмас идем, Сөйлим ләкин вөҗдан кушканын.* Ф. Бурнаш. *Газизә анасының кемне --- шулай кызганганлыгын беләсе килсә дә, сорарга базмады.* Ш. Камал.

БАЗУ II *с.* Артык кыю, тартынусыз. — *Бик базу икәнсез. Я, хода...* Б. Камалов.

БАЗЫК *с.* Тәбәнәк юан, төптән юан яки җәенке калын; ник. *Тирәк ни базык булса да пычкыдан котылмас.* Мәкаль. // Эре сөякле, кин җилкәле, атлет. *„Эшче“ редакциясенә хәбәр тотып килгән базык егет Шиһап Шәһәретдинов иде.* М. Җәлил. *Бу егет базык буе-сыны белән атасына охшаса да, кыска.* А. Шамов.

БАЗЫКЛАНУ *ф.* Базыкка әверелү. *Усеп базыклану.*

БАЗЫКЛЫК *и.* **1.** Базык булу.

2. *күч.* Ныклык, какшамаслык. *Корбюзье, бирешмәс базыклык белән, реакцион схоластикага каршы көрәшә.* Каз. утл.

БАЗЫМЛЫ *с.* Кыю, кыюлыкка ия булган. / *рәв. мәгъ. Колонналар, Адымнарны базымлырак!* Ф. Бурнаш.

БАЗЫМСЫЗ *с.* Кыюсыз, тартынучан. *Берсе базымсыз, икенчесе чая, әмма хезмәттә үзләре бигрәк тә пар килгәннәр.* М. Шабай. *Гали болай юаш кына, базымсыз гына булса да, сүзгә артык саран түгел иде.* Э. Касыймов.

БАЗЫМЧАК, БАЗЫМЧАН *с.* Кыю, тәвәккәл. *Базымчан кеше.* □ *Базык булганчы базымчан (базымчак) бул.* Мәкаль.

БАЗЫМЧАНЛЫК *и.* Кыюлык, тәвәккәллек. *Базымчанлык күрсәтү.* □ — *Алар* [*Хөсәен мирза һәм яраннары*] *шулкадәр күп халык җыелган җиргә килергә базымчанлык итәрләрме икән?* Ф. Бурнаш.

БАЗЫМЧЫЛЫК *и. к.* базымчанлык. [*Сәрби:*] *Кара син безнен оялчан егетне! Ничек базымчылык иттең?* Н. Исәнбәт.

БАЗЫНУ *ф.* Кыюлык күрсәтү; тәвәккәлләү. *Базынмаган бозга басмас.* Мәкаль. // Әрсезләнеп китү, кыюлыгы житү. — *Юк инде, ансы булмас! Син инде артыграк базынасың... — диде* [*Зөһрә*]. Ш. Камал. *Әгъләм аз гына сүздән тукталып, мыек очларын бөтергәләп алды: — Сезгә килергә исәп бар иде күптән. Ничектер базынмадым.* С. Рафиков.

БАЙ *с.* **1.** Зур мал-мөлкәткә, материаль кыйммәткә ия булган. *Бай йорт. Бай тормыш.* □ *Бу зур, бай авыл — Акташ.* Г. Ибраһимов. *„Илшат“ — элек-электән бай колхоз.* Г. Гобәй. / *рәв. мәгъ. Бай яшәү.* □ *Шахтаның управляющие бик бай тора торган бер рус иде.* Г. Ибраһимов. // Нәрсәнең дә булса күп микъдарына, санына ия булган. — *Үзең беләсең, без болынга бик бай түгел.* Ә. Еники. *Җырлыймын тик чәчкәдәй Кызларга бай халкым өчен.* Ш. Бабич.

2. Мул, күп. *Өйнең эченә керсәң — адашырлык. Бай итеп җиһазландырылган берничә бүлмә.* М. Хәсәнов. // Кирәкле, файдалы компоненты күп булган (төрле катнашмалар, минераллар турында). *Бай руда.*

3. *сир.* Яхшы, затлы; кыйбат тора торган. *Бай кием.* □ [*Бакчада*] *халык артык күп булмаса да, бай туалетлы чыркылдык дамалар шактый күренәләр иде.* Ф. Әмирхан.

4. Мәгънәви яки рухи кыйммәтләре зур булган. *Эшче әйтә: мин баймын, бөтен көч-куәт миндә.* Г. Камал. *Һәйбәт егет иде, бичара, үзе ярлы булса да, намусы бай иде.* Г. Бәширов. // Зур нәтиҗәле, киң масштаблы; эчтәлекле. *Кави Нәҗми — үзенең күпьяклы һәм бай иҗаты белән татар совет әдәбияты тарихында якты эз калдырган язучы.* Н. Гыйззәтуллин. *Бай тарихлы Казан, данлы Казан!* Ә. Ерикәй.

5. *и. мәгъ.* Зур милеккә хуҗа кеше, эксплуататор сыйныфлар вәкиле. *Бер бай бөлә, бер бай көлә.* Мәкаль. *Йомры тояк тайларда, Алтын-көмеш байларда.* Жыр. // *күч. диал.* Хуҗа. *Ашау — байдан, үлем — ходайдан.* Мәкаль. *Үз бәхеткәйләрең, ай, булмаса, Байга хезмәт итеп кем ярый.* Жыр. // Революциягә кадәр бай кешене (руханилардан башкасын) исеменә өстәп атау сүзе. *Сәгыйть байның төп идеясе дә, Кәрим байныкы кебек үк, мал җыю.* М. Гали.

БАЙБАК *и.* Суырның зуррак төре — далада яшәүче кимерүче җәнлек. *Елның җылы вакытында хәрәкәтчән йомраннар, байбаклар һәм кайбер башка җәнлекләр салкын чорда йокыга талалар.* Соц. Тат.

БАЙБИКӘ *и.* Бай хатыны. *Ашау-эчү, кәеф кору — байбикәнең уйлары.* Г. Камал. *Аларны күпертмә*

җилкәле ак алъяпкыч япкан зур һәм таза гәүдәле чибәр генә хатын каршы алды. „Шушы икән байбикә", — дип уйлады Габдулла. Ләкин бу байбикә түгел, аның асравы гына иде әле. Ә. Фәйзи.

БАЙБИЧӘ *и.* 1. *диал.* Байбикә, бай хатыны.

2. *этн.* Казакъ яки кыргыз бае хатыны; байның хатыннары арасында өлкәне. *Бу тирмә йортның ак өе санала, байбичәнең даими торуы шунда була.* Г. Ибраһимов.

БАЙБӘТЧӘ *и. сөйл.* Байның буйга житкән улы; бай, тәкәббер һәм гадәттә азгын яшь кеше. *Байның улы — байбәтчә, Ашау-эчү — гадәтчә.* Г. Камал. *Татар купецлары, татар мещаннары, байбәтчәләр, байбикәләр, беренче буларак, Г. Камал әсәрләре аша әдәбиятта һәм сәхнәдә үзләренең чын йөзләрен күрделәр.* М. Гали. // *ирон.* Буржуаз интеллигент. *Дутов, Колчак әйтә: законнарны Байбәтчәләр язып торсын, дип; Ярлы, эшче халык әүвәлгечә Байбәтчәгә хезмәт кылсын, дип.* Ш. Бабич.

БАЙБӘТЧӘЛӘРЧӘ *рәв.* Байбәтчәләр кебек кәпрәеп. *Байбәтчәләрчә кылану.*

БАЙГУРА *и. сөйл.* Типик бай; бай һәм саран кеше. [*Әхмәт:*] *Фәлән байның һиммәте, фәлән байгураның шәфкате дип кәгазь буяганчы, шул фәләннәрнең ничек итеп кеше эшләгәнне ашаганлыкларын языгыз.* Ф. Әмирхан. *Тик Гомәр байгураның яшел түбәле йорты гына, ояда утырган тавык төсле, авыл өстендә канатларын җәеп, кәпрәеп утыра иде.* К. Тинчурин.

БАЙГЫШ *и.* 1. Ябалаклар семьялыгыннан урта зурлыктагы кош. *Байгыш та үз баласына лачын дип исем кушкан.* Мәкаль. *Кайдадыр ачы тавыш белән байгыш кычкыра башлады.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Күп кайгы-хәсрәт кичергән юаш, мескен кеше. *Байгыш түйганчы бер ашаса да „баедым" дияр.* Мәкаль. *Ишле байгыш байны басар.* Мәкаль. / *с. мәгъ. Байгыш бала, ул ничек өметсез!* М. Фәйзи.

БАЙГЫШЛАНУ *ф.* Төксе, сүзсез һәм хәрәкәтсез булу; төмсәләнү. *Байгышланып утыру.*

БАЙДА'РКА *и.* Ябык өсле спорт көймәсе; күбесенчә бер кешелек була һәм ике башы да калаклы бер ишкәк белән йөртелә. *Минем Кабан күлендә байдаркада бер-ике мәртәбә йөреп караганым бар иде.* Ә. Касыймов.

БАЙДА'РКАЧЫ *и.* Байдаркада оста йөрүче спортчы.

БА'ЙКА *и.* Тыгыз һәм йонлач тукымаларның бер төре. // *с. мәгъ.* Шул тукымадан эшләнгән (тегелгән). *Ап-ак простыняле, калын байка одеяллы кроватьларга каршы почмакта, радиоприемник өстәле тирәсендә утырган кызылармеецлар Хәмитне күрү белән елмайдылар.* К. Нәҗми.

БАЙКАУ *ф. диал.* Игътибар белән карау; чамалау. *Батман алсаң, сайлап ал, эчен-тышын байкап ал.* Мәкаль. *Оратор --- шылу ягын байкап, Тәрәзгә таба елышты.* Х. Туфан.

БАЙЛА'РЧА *рәв.* Байларга охшатып, байлар гадәтенчә. *Мәхмүтгәрәй абзыйларның йортлары зур, шәп; тормыш байларча.* М. Фәйзи. *Байларныкы байларча, --- керәсе юлга хәтфә палас түшәлә.* Ф. Хөсни.

БАЙЛЫК *и.* 1. Бай булу („бай" сүзенең сыйфат мәгънәләреннән). *Игенгә байлык.*

2. Бай кеше булу җәһәте. [*Гайни:*] *Исмәгыйльнең атасы байлыкка байдыр инде анысы.* Г. Камал. *Аларның* [*Рәмиевләрнең*] *зур кара мыеклары байлыкларын күрсәтеп торгандай күренә.* М. Гафури.

3. Тупланган мал, җыелган кыйммәтләр. *Галиәсгар Казаннан бик күп байлык белән кайтты.* Ә. Фәйзи. *Ни әйтсәң дә, завод-фабрикалар халык кулына күчәсе байлык бит.* К. Нәҗми. // *күч.* Билгеле бер яктан кыйммәте булган нәрсәләр җыелмасы. [*Волком секретаре*] *авыллардан олаулар килгәнне көтмичә, шундук, булган транспорт байлыкларын җигеп, безне билгеләнгән авылларга озатып куярга кушты.* Ф. Хөсни.

4. Кирәкле нәрсәнең җитәрлек булуы; җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе:* ярлылык, мохтаҗлык. *Һәркем шулай бу байлыктан* [*игеннән*] *үзенең дөньясын рәтләп калырга уйлый.* Г. Ибраһимов. *Дни мәрхүмнең миңа әледән-әле әйтүенә караганда, мин көзге байлыкта туган кеше.* Ф. Хөсни. // Канәгатьләнерлек материаль хәл. [*Артем:*] *Мондый вакытта ипигә аптырамасаң, зур байлык инде ул.* Ф. Кәрим. //*күч.* Нәрсәнең дә булса иң кыйммәтле ягы. *Саулыгың — байлыгың.* Мәкаль. *Язның байлыгы — кояш, көзнең байлыгы — уңыш.* Мәкаль.

5. Берәр яктан мәгънәви кыйммәте булган нәрсәләр җыелмасы турында. *Рухи байлык. Күңел байлыгы.* □ *Капитализм хәзерге вакытта һичбер төрле культура байлыгы бирә алмый.* М. Җәлил. *Һәрбер аерым телнең үзенең сүз байлыгы була.* В. Хангилдин. // Күптөрлелек, күпьяклылык; эчтәлеклелек. *Тел чараларының байлыгы.*

БАЙЛЫКЛЫ *с.* Мал-мөлкәте, материаль байлыгы булган. *Казакъның уртача байлыклы, күп адәмле ике ыругы бар иде.* Г. Ибраһимов. *Элек бу авылда төп хуҗа — күп җирле, зур байлыклы дхмәтҗан булган.* Г. Иделле.

БАЙРАК *и.* 1. Формасы, төсе, бизәге махсус билгеләнгән һәм, гадәттә бер кырыеннан сапка беркетелеп, дәүләтнең яки оешманың билгесе сыйфатында йөртелә торган материя кисәге; әләм, флаг. *Совет байрагы. Полк байрагы.* □ *Без утырып байрак тегәбез. Байрак битләренә бронзадан Ялкынланган сүзләр тезәбез.* Һ. Такташ.

2. *күч.* Иҗтимагый идея турында. *Азатлык байрагы. Туганлык байрагы.*

Байрак йөртүче — 1) оешманың, гаскәри бүлекнең махсус байрагын күтәреп йөртү һәм саклау йөкләтелгән кеше, байракчы. *Байрак йөртүче „Бөтен дөнья пролетарийлары, берләшегез!" һәм „Кызыл беркетләр" дип язылган комач байракны югары күтәреп, егетләр алдына килеп басты.* И. Туктар; 2) *күч.* идея белән рухландыручы, юлбашчы. *Эшче халык кумә иптәшен, Юлбашчысын, Байрак йөртүчесен, Поста үлгән дустын, Ильичын.* К. Нәжми. **Байрак күтәрү** — 1) байракны махсус колгага (флагштокка, мачтага) менгезү; 2) *күч.* иҗтимагый идея өчен көрәш башлау. *Ленин кешелек дөньясының бәхете өчен шушында беренче мәртәбә байрак күтәргән.* Ф. Хөсни.

БАЙРАКЧЫ *и.* Байрак йөртүче, байрак күтәреп йөрүче кеше. *Байракчылар трибунага юнәлделәр һәм үзләренең байракларын утыртып куйдылар.* Г. Әпсәләмов. *Аны --- байракчы Сафи буларак белеләр, чөнки һәр бәйрәмдә фабрика байрагы аның кулында җилферди.* М. Шәйми. // *күч.* Юлбашчы, уртак идеяне белдерүче. [*Мәскәү*] *үнбер республика байракчысы, Илебезнең яшәү чаткысы.* М. Җәлил.

БАЙРОНИЗМ *и.* XIX гасыр башында шәхси һәм милли азатлык идеяләре белән бергә пессимизм, төшенкелек белән дә характерлана торган әдәби-иҗтимагый агым (инглиз шагыйре Байрон исеменнән). *Менә шушы бөтен дөньяга „байронизм" мәзһәбен тудырган --- кешенең кулга алырлык берәр эсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме?* Г. Тукай.

БАЙТАК *рәв.* Күп кенә; шактый күп. — *Синең кебек укырга теләүчеләр бездә байтак, Газинур.* Г. Әпсәләмов. *Дәүли бабай уйнап бетергәч, бүлмәдә байтак вакыт тынлык хөкем сөрде.* А. Әхмәт.

БАЙТАЛ *и.* Яшь бия, өч яшьлек бия. *Тимери, туры байталының абзарында керт-керт печән ашавын тыңлый-тыңлый, күп төннәрен күзен йокы алмыйча уфылдап уздырды.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Яшь, картаймаган (бия турында). *Байтал бия.*

БАЙТИРӘК *и.* Бик зур карт тирәк яки өянке. *Байтирәкнең чайкалуы җилдән.* Мәкаль.

БАК I *и.* 1. *тех.* Куб яки цилиндр формасындагы зур металл савыт, гадәттә аңа сыеклыклар салына. *Шофер машинаны кабат карап чыкты, бушап калган бакка бензин тутырды, моторны тикшерде.* Г. Иделле. // Зур металл казан. *Ихата түрендәге ферма алачыгының моржасыннан ишелеп-ишелеп куе төтен чыга; анда зур бакларда бозаулар, буаз сыерлар өчен су җылыталар.* Ә. Еники.

2. Көнкүреш кирәге өчен су тутырыла торган калай савыт. *Сулыш алырга туктаган минутларда бөтен кешедән элек бак янына йөгереп, рәттән икенче чүмеч салкын су чөмерүче кем дисәң, ул — Саттар булып чыга.* Ф. Хөсни.

БАК II *и. махс.* Корабның борын өлеше.

БАК (бак) *аваз изл.* 1. Үрдәкләр чыгара торган кискен тамак авазын белдерә. *Бак итү. Бак-бак килү.* □ *Ул [ата үрдәк] җиз башын алгарак сузып „бак!" дип бер кычкырды да, яшен ташыдай, һавага күтәрелде.* М. Шәйми.

2. Бакалар чыгара торган яңгыравыклы өзек авазны белдерә. *Бак-бак итеп, карт бакалар Күл өстенә ник калкалар?* Н. Думави.

БАКА *и.* 1. Арткы озын аяклары йөзәргә һәм сикерергә җайланган койрыксыз җир-су хайваны. *Аулак күлгә бака хуҗа.* Мәкаль. *Елга читендәдерме, канауның елгага төшкән башындадырмы, яңгыр теләп бакалар сайраша.* Г. Гобәй.

2. Кабырчык эчендә яшәүче хайван (моллюск) турында. *Кабырчык бакасы.*

3. Ялкынсынулы, шешенкеле авыруларның гомуми атамасы. *Күкрәк бакасы. Тамак бакасы. Теш бакасы.*

4. Капкада яки ишектә уртасына кагылган кадак тирәсендә әйләнә торган кыска тубырчыктан гыйбарәт булган бик. *Ишекнең бакасын бору.* // Капка баганасы төбендә капканың орчык башы кереп утырырлык уемы булган һәм җиргә яки баганага беркетелгән кискә, таш, металл кисәге. // Тегермәндә: аскы ташка кагылган орчыкка кидерү өчен уртасында тишеге булган һәм баш-башы өске ташка беркетелгән металл пластинка. *Тегермәндә таш тешәү, бака утырту дисеңме — барысын да ул [Гайнан] берүзе эшләп җиткерә торган иде.* Ш. Маннур.

5. Лампа челтәренең асты. // *күч.* Челтәрсез, куыксыз лампа. *Яңа әзгә басты тормыш та, Бака белән бетмәс күз нурлары Аяклар да талмас тормозда.* М. Крыймов.

6. Гармоньның калын тавышлы сул күл клавишы. *Гармоньның теле бер якта, бакасы икенче якта аунап, тапталып калды.* Ф. Хөсни. *Әүхәди, гармоньны алып: — Тукта, бер генә кычкыртып карыйм әле! Бакасын гына, — [диде].* Н. Исәнбәт.

Бака ефәге (шәле, яулыгы) — сай сулыкларны яшькелт төстәге җепсел калын пәрдә рәвешендә каплап ала торган суүсем. *Ике авыл арасындагы шул бака ефәге белән капланып, күпчеп беткән бу күлдән бер елны бизгәк чире тарала.* К. Нәҗми. **Бака кабырчыгы** — кабырчык эчендә яши торган су хайваны — анадонтаның кабыгы, кабырчыгы. *Аның [Рәшитнең] бер кулында чәчәкләр, бер кулында әкәмтөкәмнәр, бака кабырчыклары.* Р. Ишморат. **Бака кашыгы (казаны)** — *к.* бака кабырчыгы. *Кечкенә балалар комда бака кашыгы җыялар.* А. Расих. **Бака күле** — 1) бакалар уылдык салырга ярата торган сай һәм тыныч күл яки култык; бакалары күп булган күл, буа; 2) *күч.* тәртипсез шау-шу; аңлаешсыз нотык. *Хаттагы сүзләрнең күбесен аңлый алмагач, бака күле башлана. Төрлесе төрлечә юрап, буталчык сүзләрдән һәрберсе үзенчә мөгез чыгара.* К. Нәҗми. **Бака пәрәвезе** — *к.* бака ефәге. **Бака сакалы** — су өстен төрле төсләргә буйый торган вак суүсемнәр, бака ефәгенең бер төре, субуяр. **Бака тәңкәсе** — вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; *русчасы:* ряска. *Чыннан да күл һәм буа төпләрендә аякларга чолганырлык булып үсә торган элодия үсемлеге, тын урыннарда су өстен каплап китә торган вак яфраклы „бака тәңкәсе" — болар барысы да терлек өчен азык була ала.* А. Расих. **Бака уты** — челтәре урынына уртасы тишекле калай куелган куыксыз керосин лампасы. **Бака яфрагы (үләне)** — җиргә түшәлеп үсә торган киң яфраклы һәм нечкә генә сабакта башак сыман ак чәчәге — җимешлеге булган үлән үсемлек; *русчасы:* подорожник. *Чокырның төбендә, бака яфраклары арасында, челтерәп салкын су ага.* И. Гази.

◊ **Бака башлы** — киң башлы (аяк киеме турында). *Хәзер Гарәфи абзагыз — курьер. Бака башлы шиблет бирделәр.* Г. Гобәй. **Бака телле** — күп һәм аңлаешсыз сөйләүче; такылдык, лыгырдык. **Бака туе** — 1) язгы буаларда, күл һәм күлдәвекләрдә бакаларның хор белән бакылдаулары. *Бака туе баткакта.* Мәкаль; 2) *күч.* шау-шулы ыгы-зыгылы, кычкырышлы җыен. — *Туктагыз әле бака туе ясамагыз өйне.* К. Нәҗми.

БАКАЙ *и.* Атның тояк өсте сөяге, ат ашыгы.

БАКАЙЛЫ *и.* Ашык уенының бер төре (бакай белән уйнала). *Бакайлы уйнап баемассың.* Әйтем.

БАКАКЫЙ *и. диал.* Кабырчык эчендә яши торган су хайваны, моллюск-анадонта; *русчасы:* перловица. *[Гәрәй] тар гына елганың баткаклы ярларын, бакакыйлар белән чуарланган күпер төбен --- күрде.* А. Гыйләҗев.

БА-КА-КА, БАКАКАК *аваз изр.* Бакаларның тавышны төрлечә үзгәртеп бакылдау авазын белдерә. *Бакакак итү.* □ *Гатаны үртәгән төсле кычкырды бака: —Ба-ка-ка, ба-ка-ка.* А. Алиш.

БАКАЛАВР *и.* Кайбер илләрдә (революциягә кадәр Россиядә дә) кече гыйльми дәрәҗә. *Мәктәптә ике ел эшләгәннән соң, кайтып, колледжның соңгы ике курсын тәмамлыйлар. Шуннан соң гына студентка бакалавр дәрәҗәсе бирелә.* М. Мәхмүтов.

БАКАЛЕ'Я *и.* Аш-су пешерүгә тотыла торган һәм аш-су тәмләткеч продуктлар (он, ярма, борыч, йөзем, чәй-шикәр һ. б.). *Бакалея товарлары.* □ *Складларда саклап тоткан аракы-виноларны, азмы-күпме кондитер, бакалея нәрсәләрен тизрәк точкаларга чыгарырга кирәк.* Ә. Еники.

БАКАЛЕ'ЯЧЫ *и.* Бакалея товарлары белән сату итүче.

БА'КЕН *и.* Зур көймәләргә фарватерны күрсәтеп тору өчен су төбенә беркетелгән зур калкавычтан гыйбарәт фонарьлы маяк. *Бакеннар кала Уңда һәм сулда, Саллар, баржалар Очрыйлар юлда.* К. Нәҗми.

БАКЕНБАРД *и.* Ияк һәм ияк асты кырылып, чигә һәм яңакларда тасма сыман калдырылган сакал. // Гомумән чигә-яңак сакалы.

БА'КЕНЧЫ *и.* Маякчы, бакеннарны карап, утларын яндырып-сүндереп торучы. *Хәлим бакенчы карт һәм*

аның ике иптәше белән Иделнең аръягына балык тотарга чыкты. И. Гази.

БАКЛАЖАН *и.* Эт жиләгесыманнар семьялыгыннан берьеллык үлән-яшелчә үсемлеге. *Борыч һәм баклажан утыртылган участокны кояш яхшы яктыртырга һәм ул салкын җилләрдән ышыкланган булырга тиеш.* Җиләк-җимеш ... // Шул үсемлекнең шәмәхә яки куе зәңгәр төстәге кыяр сыман зур җимеше. *Баклажанны җимшән сабы әле өлгереп җитмәгән вакытта җыярга кирәк, чөнки өлгереп җиткән баклажаннар тәмле булмый.* Җиләк-җимеш ...

БАКРА *и.* Канәферсыманнар семьялыгыннан алсу чәчәкле үсемлек — чүп үләне. *Безнең уйчан авыл кырларында Бакралар чәчәк атканнар.* Н. Баян. // Шул үсемлекнең орлыгы — кара-көрән төстәге агулы бөртек. *Сукыр тавыкка бакра да бодай.* Мәкаль.

БАКРАВЫК *с.* Күп бакыра, кычкыра торган. *Ялгыз бәрән бакравык була.* Мәкаль.

БАКРАЧ *и.* 1. *иск.* Бакыр шлем. *Томан эченнән борынгы батырлар киемендә: башына бакрач, өстенә кирәүкә кигән берәү шәйләнә.* Н. Исәнбәт.

2. *диал.* Озын саплы зур чүмеч; бакыр чүлмәк. *Песнәкнең үзенә күрә бизмәне, бүдәнәнең үзенә күрә бакрачы.* Мәкаль. *Фәлән жирдә казан бар, барып карасаң, бакрач та юк.* Мәкаль.

3. *күч.* Кара тутлы кеше. *Чуенның унбишенче кичәсе төсле кара булганга, егеткә „бакрач" кушканнар.* И. Гази.

БАКТЕРИАЛЬ *с.* Бактерияләргә мөнәсәбәтле. *Бактериаль агулар. Бактериаль авыру.*

Бактериаль ашлама — составында туфракны уңдырышлы матдәләргә баетучы бактерияләр оеткысы булган махсус катнашма. *Бу завод Татарстан һәм күршe өлкәләрнең колхоз һәм совхозлары өчен бактериаль ашлама — нитрагин житештерәчәк.* Соц. Тат.

БАКТЕРИЗА'ЦИЯ *и.* Бактерияләр йоктыру, бактерияләр тәэсиренә калдыру процессы.

БАКТЕРИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Бактеризация ясау, бактерияләр тәэсирендә тоту.

БАКТЕРИОЗ *и.* Бактерияләр белән агулану, бактерияләр йогу нәтиҗәсендә килеп чыккан авыру, шеш, күгәрек (бигрәк тә үсемлекләрдә). *Кыярларның аеруча күп таралган авырулары — соры тап, ончыл чык, бактериоз ...* Җиләк-җимеш ...

БАКТЕРИО'ЛОГ *и.* Бактериология фәне белән шөгыльләнүче галим.

БАКТЕРИОЛО'ГИК *с.* 1. Бактериологиягә мөнәсәбәтле. *Бактериологик тикшерену.*

2. Бактерияләр куллануга мөнәсәбәтле. *Бактериологик корал. Бактериологик сугыш.*

БАКТЕРИОЛО'ГИЯ *и.* Бактерияләрне өйрәнә торган фән.

БАКТЕРИОФАГ *и.* 1. Бактерияләрне һәлак итә, кыра торган вирус (иң вак микроорганизм).

2. Бактерияләрне юк итүче матдә, препарат.

БАКТЕРИЦИД *и. биол.* Тере организмнар тарафыннан бактерияләргә каршы саклану (иммунитет) чарасы буларак бүлеп чыгарыла торган матдәләр. *Яңа савылган сөттә бактерицид үзлеге, ягъни сөтне әчетә торган микроорганизмнарның үрчүен тоткарлау сәләте бар.* Сөт терлекчелеге...

БАКТЕ'РИЯ *и.* Бер күзәнәкле микроскопик организм, микроб. *Борчак, ясмык, вика, клевер, люцерна шикелле кузаклы үсемлекләр генә, тамырларындагы бактерияләре ярдәмендә, һавадагы азотны үзләштерәләр.* Химияне а.-х. куллану.

БАКЧА *и.* 1. Башлыча утыртып үстерелгән агачлык, куаклык яки чәчәклек (күбесенчә жиләк-жимеш үсемлекләреннән тора.) *Шомырт бакчасы. Гөл бакчасы.* □ *Алма бакчаларына төренгән зур авыл бик матур.* И. Гази. *Госпиталь бакчасында үсеп утырган өрек, чия агачлары ап-ак чәчәккә күмелгәннәр.* Ә. Айдар. // Парк, сквер. *Ераста, шәһәр бакчасында, музыка уйный.* И. Гази.

2. Яшелчә яки жир жиләге утыртып үстерелә торган участок. *Яшелчә бакчасы. Жиләк бакчасы.* □ *Мәдинә, бәрәңгесе казылган бакчаның авыр, сыланчык туфрагына бата-бата, алга карап йөгерде.* Г. Минский.

Бакча гөле — бакчада үстерелә торган гөл. *Менә аның [Салихҗан абзыйның] үз кулы белән утыртылган бакча гөлләре: кашкарый, хәтфә гөл, алтын керфек.* Р. Төхфәтуллин. **Бакча кайчысы** — бакча үсемлекләрен тиешле формага китереп кырку өчен кулланыла торган озын саплы зур кайчы, секатор. *Бакча кайчысы юанлыгы 15 миллиметрга чаклы булган ботакларны һәм чыбыкларны кисүгә хезмәт итә.* Жиләк-жимеш ...

Бакча пычагы — ялгамлыкка кирт ясау, ялгамга чыбыкча яки бөре (ашыт) кисеп алу һәм башка шундый бакча эшләрендә кулланыла торган пычак яки пәке. **Бакча тәмәкесе** — махорка; түтәлдә үстерелә торган махорка яфрагыннан киптереп төелгән ачы тәмәке. *Шул арада Талип кесәсеннән кечкенә итеп кәгазьгә төргән бакча тәмәкесе һәм шырпы чыгарып күрсәтте.* Ә. Фәйзи.

◇ **Бакча жимеше** — үзеңнең бакчаңда үстерелгән, сатып алынмаган жиләк-жимеш яки яшелчә. *Акча жимеше түгел, бакча жимеше.* Әйтем. **Бакчага таяк (таш) ыргыту (ату)** — 1) берәр кешегә яки группага карата кинаяләп, төрттереп әйтү. — *Хәзер аңлыйм, Әлфия, кем бакчасына таяк ыргытканыңны.* Г. Әпсәләмов. *Сәфәргали кызларның бу сүзләрен үз бакчасына атылган таш дип кабул итте.* Ф. Хөсни; 2) кыеклатып зыян китерү. — *Мортаза түгел син, ә аяклы каза! Үз бакчасына үзе таш аткан нәрсә.* М. Хәсәнов.

БАКЧАЛЫК *и.* 1. Ихатада бакча урыны; бакча булган жир. *Ак алма чәчәге белән өртелгән бакчалык та, саф һава да --- мине исертәләр.* М. Фәйзи. *Карталиния буйлап бара юлым, Бакчалыклар монда, болыннар.* Ш. Маннур.

2. *с. мәгъ.* Бакчага ярарлык, бакчага житәрлек. *Минем үземнең дә шәһәр читеннән бакчалык жир сорап язган гаризамның Шикаятуллин кулында ятуына, жиде булмаса да, бер дүрт ай бардыр.* Г. Минский.

БАКЧАЧЫ *и.* 1. Бакча (1 мәгъ.) карап үстерүче һәм тиешенчә тәрбияләп торучы кеше — белгеч. *Гүяки, бу бакчаның бакчачысы Сәмигулла абзый үзе имеш.* Ф. Әмирхан. — *Мин үзем бакчачы, колхозда жиләк-жимеш үстерә идем.* Г. Әпсәләмов. / *с. мәгъ. Бакчачы карт һәрбер агачның Кәүсәсеннән сыйпап сөйгәндер.* Г. Афзал.

2. *сир.* Яшелчә үстерүче, яшелчә бакчасында эшләүче. *Бакчачының бакчасы, утап кына баксачы.* Әйтем.

БАКЧАЧЫЛЫК *и.* Жиләк-жимеш үстерү һәм шуның белән шөгыльләнә торган хуҗалык тармагы. *Бакчачылык фәне.* □ *Бакчачылык бригадасы берүзе генә эшләсә, бу хәтле карлыганны бер атна утыртканбулырлар иде.* И. Гази.

БАКЧИ, БАКЧЫ *кер. сүз. гади с.* Кызыксынып, гаҗәпләнеп яки әсәрләнеп игътибар итүне (иттерүне) белдерә. *Бакчы! Дошман үлмәгән, ул кузгала.* М. Гафури. *Егетләрне уштан яздырган Нәфисә, бакчи, шул үзе инде.* Г. Бәширов. // Сәбәпкә сылтауны белдерә. *Быел игеннәр начар булды шул. Житмәсә, яңгыр да, бакчи.* Г. Толымбай.

БАКЫЙ *с. иск.* Мәңгелек, мәңге яшәүче; *киресе:* фани. *Дөнья фани — хакыйкать бакый.* Мәкаль. // *рәв. мәгъ.* Мәңге. *Бакый калыр бу җиһанда яхшы ат* [*исем*]. Мөхәммәдъяр.

◇ **Бакый йорт** *дини* — ахирәт дөньясы, теге дөнья. *Үлеп яткан ике шаһзадә бакый йортка күчкәннәр.* Г. Тукай.

БАКЫЙЛЫК *и. иск.* Бакый булу, үлмәүчәнлек. *Гомер бакыйлыгы — балада.* Мәкаль. // *с. мәгъ.* Мәңгелек. [*Туганнар*] *хат язып җибәрсәң,алмыйлар; Ат җигеп җибәрсәң, кайтмыйлар; Чыгарга ишек тә юк диеп, Бакыйлык йортларда йоклыйлар.* Г. Сәмитова.

БАКЫЛДАУ *ф.* 1. Бак-бак итү (үрдәкләрнең һәм бакаларның хәбәр бирешеп аваз чыгарулары). *Ерактa, камышлы күлдә, озак юллар очып килеп, бүген ач калган кыр үрдәге тынгысыз бакылдый.* Г. Гобәй. *Казларың каңгылдап, үрдәкләрең бакылдап йөрмәгәч, миллионер булудан ни кызык?* М. Шәйми.

2. *күч.* Көчле тавыш белән күп һәм мәгънәсез сүз сөйләү.

БАКЫЛДАШУ *ф. Урт. юн. к.* бакылдау; бер үк вакытта берничә урында яки сирәкләп, торып-торып бакылдау. *Шул бакалар ярга чыгып бакылдаша.* Г. Тукай.

БАКЫЛДЫК *с.* 1. Күп бакылдаучы (бака яки үрдәк турында). / *и. мәгъ. сөйл.* Бака яки үрдәк. *Аккош — чукып алды бакылдыкның бөреннән, Чак котылып, чумды бака күл төбенә.* Ш. Маннур.

2. *күч.* Кирәкмәгәнне тавыш күтәреп сөйләүче кеше. *Бакылдамый торса, бакылдыкның эче поша, кеше бакылдык димиме дип, үзенең коты оча.* Мәкаль.

БАКЫР *и.* 1. Көрәнсу-кызгылт төстәге чүкелүчән пластик металл. *Без Урал таулары арасында, бер бакыр руднигында.* М. Фәйзи. // *с. мәгъ.* Бакырдан торган, бакырдан эшләнгән. *Бакыр дегаль. Бакыр савыт.* □ *Ишняз тиз генә кулына бакыр чүкеч алды.* Г. Әпсәләмов. *Зур чыршы төбенә учак ягып, бакыр чәйнектә чәй кайнаттык.* М. Усманов.

2. *күч. сөйл.* Бакырдан коелган тәңкә, вак акча. *Мә, сиңа биш тиен, минем киберткә керен прәннек алырсың, — диде ул* [*Ситдикъ*] *һәм, тимер бикле күн янчыгын актарып, Габдуллага зур гына бакыр тоттырды.* Ә. Фәйзи. *Ике тиен бакырым да төшеп калган янчыктан.* Я. Емельянов.

3. *с. мәгъ.* Бакыр төсендәге. *Сиңмени инде ул Марат — бакыр чәч?* Г. Гобәй. *Агачларның алсу, бакыр, кызгылт сары яфраклары йомшак кына искән җилдән селкенәләр.* И. Туктар.

4. *с. мәгъ. күч.* Артык әһәмиятле яки артык шәптән булмауга ишарә итеп әйтелә. *Узең бакыр булсаң да, сүзең алтын.* Мәкаль.

Бакыр елан — тузбашсыманнар семьялыгыннан көрән яки соры төстәге зур булмаган агусыз елан (ул җылы якларда яши). **Бакыр-таш гасыры** — кешелек җәмгыяте үсешендә кораллар башлыча таштан һәм табигый хәлендә табылган бакырдан эшләнгән дәвер. *Шул рәвешчә, таш гасырыннан соң бакыр-таш гасыры, аннары бронза гасыры һәм, ниһаять, тимер гасыры килә.* Политэкономия.

◇ **Бакыр бугаз(лы)** — 1) тавышы бик көчле булган һәм күп сөйли ала торган кеше турында. *Сизеп торам, Кондаковка бакыр бугазлы, корыч куллы егетләр генә түгел, аңа чын кешеләр кирәк.* А. Гыйләҗев; 2) *күч.* гауга, тавыш чыгарырга яратучы, җәнҗалчы. **Бакыр күз** — 1) бакыр төсле кызгылт һәм ямьсез карашлы күз. *Ә аннан соң чокыр кырыена Тезделәр дә хәлсез халыкны, Зур борынлы, ямьсез бакыр күзле Исрек майор өскә калыкты.* М. Җәлил; 2) атларда: усал карый торган көрәнсу күз. *Йомры тояк, бакыр күз — ару белмәс толпарым.* Җыр.

БАКЫР-БОКЫР *аваз ияр.* Казанда нык кайнаган сыеклык тавышын белдерә. *Бакыр-бокыр килү.* □ *Бакыр-бокыр ботка пешә, Килгән кунак безгә төшә.* Такмак.

БАКЫРДАУ *ф.* Бакыр-бокыр килү. // Быкырдау. *— Әйдә монда, юләр кызый, нигә бака шикелле анда бакырдап ятасың!* Г. Бәширов. *Тымызык култыкта, куе камыш арасында, кыр үрдәкләре бакырдый.* Э. Касыймов.

БАКЫР-КЫЗЫЛ *с.* Ачык җирән яки кызгылт көрән. [*Каюмның*] *бакыр-кызыл чәчләре тагы да кызарыбрак киткән.* Г. Гобәй.

БАКЫРЛАУ *ф.* Бакыр белән каплату, бакыр йөгертү. *Бакырлап ямау* [*металл савытны*].

БАКЫРУ *ф.* 1. Көчле, калын һәм тупас тавыш чыгару (гадәттә хайваннар турында). *Килде ямьсез, куркынычлы бер тавыш — бер көтү ишәк бакырганда.* Г. Тукай. *Һәр көн иртән торып башка сыерлар белән көтүгә китә торган кызыл сыер бүген абзарда ялгыз калып, моңаеп бакыра иде.* М. Гафури.

2. *күч.* Кычкырып сүгү, битәрләү. [*Бай*] *йөзләп кода чакыра, Акыра һәм бакыра.* Ш. Мөхәммәдев.

БАКЫРХАНӘ *и. иск.* Бакырдан һәм җиздән төрле әйберләр коела, ясала, төзәтелә торган цех, мастерской. *Бакырханә эче тузан вә бакырчы хезмәткәрләр илә тулмыш.* М. Акъегетзадә.

БАКЫРЧЫ *и.* 1. Бакырдан һәм җиздән көнкүреш кирәк-яраклары ясау һәм шундый предметларны төзәтү белән шөгыльләнүче һөнәрче. *Әтинең эше бик күп: — пыяла аласы, бакырчыда самовар борынын төзәттереп чыгасы бар.* Г. Бәширов.

2. Бакыр чыгару яки бакыр эретү һәм бакыр эшкәртү белән шөгыльләнүче белгеч яки эшче. *Билгеләнгән көндә Синдбад иртән үк тауга килә. Бакырчы да анда була.* Мең дә бер кичә.

БАКЫРЧЫЛЫК *и.* Бакырчы һөнәре, бакырчы эше. *Гайса Зурколаков егерме алты яшьлек бер җегет улып, сонгате бакырчылык иде.* М. Акъегетзадә.

БАКЫРЫНУ *ф.* Бакырып сүгенү, җикеренү. *Һәр бакырынган—ишәк.* Мәкаль. *Бакырдан көмеш булмый, бакырынып эш булмый.* Мәкаль.

БАЛ I *и.* 1. Бал кортлары (умарта кортлары) чәчәкләр нектарыннан хәзерли торган куе, татлы сыекча. *Юкә балы. Чәчәк балы.* □ *Бал ару, җитмеш төрле авыруга дару.* Мәкаль. *Гәрәбәдәй сары бал Тора табын балкытып.* Ә. Фәйзи. // Чәчәкләрдәге татлы сыекча, нектар. *Күбәләк һәм умарта корты чәчәкләрдән бал имәләр.* Г. Тукай. // Җиләк-җимешнең татлы суты. *Алмаларның аллары, Тамып тора баллары.* Җыр.

2. Балдан әчетелгән исерткеч эчемлек, хәмер. *Савыт-савыт баллар эчелде, Бал эчелгәч, телләр чишелде.* Н. Арсланов. *Баллар куйдым кисмәкләп, Син җизнине хөрмәтләп.* К. Тинчурин.

Бал алу — нектар җыеп умартага ташу (бал кортлары турында). *Умарта кортлары шул аланлыкны бизәгән матур чәчәкләргә бал алырга, үзләренә кышлык азык хәзерләргә төшкәннәр.* М. Гали. **Бал икмәге** — *к.* чаршын. *Көз һәм кыш көннәрендә, шулай ук яз башында оядагы күп кенә урын кортларның азык запасы — бал һәм чәчәк серкәсеннән ясалган бал икмәге (чаршын) белән тулы була.* Умартачылык. **Бал калагы** — 1) балны туглый торган калак; 2) *диал. к.* балкашык. *Сусасаң, самовар алдында гөжләп утыра, стаканы, бал калагы да китерелгән.* Г. Ибраһимов. **Бал карагы** — йонлач юан гәүдәле, саргылт-кара бизәкле төнге күбәләк. **Бал кашыгы** — *к.* балкашык. *Я, Газинур, колхозга кайтабызмы? — диде Павел Иванович, бал кашыгы белән*

үтә куе чәйне болгатып. Г. Әпсәләмов. **Бал корты** — әлпәканатлылар отрядыннан чәчәк нектарын эшкәртеп бал ясый торган бөҗәк; умарта корты. *Бал кортлары --- татлыдан татлы бал җыялар, шәмгә яраклы балавыз коялар.* А. Алиш. **Бал кую (кою)** — әчемлек бал әчетү. *Урман кортларының балын ашап, бал коеп, эчеп, өйдән өйгә йөрешеп, кунаклашып кына гомерен үткәргән халык --- бүгенә чыгарып көн итә башлый.* Т. Госман. **Бал мичкәсе** — бал әчетә торган махсус мичкә. *Хәллерәк кешеләрнең мич башларына әче бал мичкәләре менеп утырды.* Ф. Хөсни. **Бал мәҗлесе** — хәмер, бал әчелә торган мәҗлес (кунак табыны). *Җаекның үзендә торучы бер олы шәкертнең өендә бал мәҗлесе оештырылды.* Э. Фәйзи. **Бал суырту** — балны кәрәздәге күзәнәкләрдән бал суыртқычларда суыртып алу. [*Умарта караучы*] *Һәртөрле системадагы умарталардан һәм вак-төяк кораллардан башлап бал суырту машиналарына кадәр һәммәсен үзе ясаган.* М. Гали. **Бал тәпәне** — бал салып кую һәм саклау өчен ясалган кечерәк агач савыт, капкачлы агач чиләк. *Тарантаста бер бал тәпәне генә --- булмаска тиешлеге билгеле иде.* Ф. Хөсни. **Бал чыгы (җавы)** — яфраклар, кыяклар өстенә җыела торган баллы сыекча—үлән бетләренең бүленмәләре. *Умарта кортлары --- үлән үсемлекләр арасында яшеренеп калган бал чыкларын эзлиләр иде.* С. Рафиков.

◇ **Бал авыз** — ягымлы сүзле, татлы телле кеше. *Яхшы эшне мактап сөйлим — бал авыз мин.* Г. Тукай. **Бал ае** — кияү белән кәләшнең өйләнешкәннән соң үткән беренче ае. *— Ике көн, өч көн туй иттеләр. Өч атнадан соң егетемне тагын очратам. Я, мин әйтәм, ничек бал ае?!* Р. Ишморат. **Бал гына** *шигъ.* — 1) бик нык баллы, артык баллы. *Ишеккә сыймый кабаклар, Бал гына карбызлары.* Н. Гайсин. *Дон буйлары тал гына, Яфраклары бал гына.* Җыр; 2) бик татлы, ягымлы. *Куеннары җәннәт түре, Иренәре бал гына.* Җыр.

БАЛ II *и.* Зур танцы кичәсе. *Миңа һәр кич дип әйтерлек* [*кичәләрдә*], *балларда йөрергә туры килә.* Ф. Әмирхан.

БАЛА *и.* 1. Үсмерлек чорына кадәр булган малай яки кыз. *Бала күңеле никадәр тиз яраланучан булса, шулкадәр тиз төзәлүчән дә.* А. Расих. *Арысландай егет түгел, Өч яшьлек бала чагым.* З. Мансур. // Балигъ булмаган яки гомумән тәжрибәсез, беркатлы кеше турында. *Хәят моңа кадәр бала иде бит әле ул.* Ф. Әмирхан.

2. Бәби, нарасый, кечкенә малай яки кызчык. *Бала тирбәтү. Бала табу.* □ *Еламаган баланы имезмиләр.* Мәкаль. // Яңарак туган яки әле үсеп җитмәгән һәрбер җан иясе. *Аю баласы. Песи баласы.* □ *Карга үз баласына аппагым дип, керпе үз баласына йомшагым дип әйтә ди.* Мәкаль. *Бөтен кошлар Җырлап оя коралар, Балалары туганда ук Җырчы булып туалар.* Ә. Бикчәнтәева.

3. Бер ата-анадан туган бер буын кешесе, ул яки кыз. *Ана күңеле балада, бала күңеле далада.* Мәкаль. *Гасырлар буенча бабадан атага, атадан балага мирас булып килгән ызан калкуларын җимереп, алтын орлык чәчеп, мул уңыш алу өчен колхозчылар килә.* С. Рафиков. // Нәсел, токым, халык яки чорның, социаль катламның төп билгеләрен чагылдырган шәхес. *Замана баласы. Табигать баласы.*

4. *шигъ.* Яшь кеше (егет яки кыз) турында. *Мин гакыллы бала, узгынчылар, Шашкан бала бу дип белмәгез.* Һ. Такташ. *Аталардан калган, ай, яшь бала Күкрәк көче белән мал таба.* Җыр.

5. *с. мәгъ. диал.* Кечкенә, яшь, үсеп җитмәгән; җитлекмәгән. *Бала кошның авызы зур булыр.* Мәкаль. *Бала кыярны әрчеп торасы юк, уртага яки дүрткә ярып, тоз гына сибәсе.* М. Шабай. *Агыйделкәй алкын, суы салкын, Бала үрдәкләр каршы йөзалмый.* Җыр. // *диал.* Иптәшләреннән, төрдәшләреннән күп кечерәк; зуррагына буйсынган, зуррагының эчендәге яки системасындагы (җансыз нәрсәләр турында). *Бала елга.* □ *Тарлавык икегә аерыла. Үз нәүбәтендә зур „ботаклар“ --- тагын берничәгә тармакланалар. Бу кечкенә бала тарлавыклар --- ямь-яшел.* М. Госманов. *Ак бүктәр эченнән майланып беткән янчык килеп чыкты. Янчык эченнән — бала янчык.* И. Гази.

Бала итәк(ле) — хатын-кыз күлмәгенең итәге тирәли матурлык өчен тотылган өстәмә итәк. [*Суфия апаның*] *өстендә кат-кат бала итәкле озын ак күлмәк.* Г. Гобәй. **Бала йон, бала мамык (мамыгы)** — 1) кеше тәнендәге вак-вак төкләр. *Су буена төшәсең дә иреннәрең күгәргәнче, бала йоннарың кабарып чыкканчы су коенасың.* Л. Ихсанова; 2) яшүсмерләрнең булачак сакал-мыек урыннарына чыга торган йомшак төкләр. *Юлаучыларның икенчесе — борын төбендәге бала йоны яңа каралып килгән яшь кенә бер егет.* Г. Гобәй; 3) йомыркадан яңа чыккан кош тәнендәге бик йомшак йончалар; 4) *күч.* җитлекмәгән, ныгымаган, дөнья күрмәгән яшь кеше. [*Гафиятулла карт*] *„Син буяулы чебешкә ни сөйләп торган булам соң мин, ни аңлыйсың син, бала йон“ дигән кыяфәт белән урындыкка барып утырды.* Ф. Хөсни. **Бала караучы** — бала карарга махсус билгеләнгән яки ялланган кеше. [*Мәрьям*] *үзләрендә бала караучы булып торган Бәдри әбинең шома вә килешле рәвештә сөйләгән әкиятләрен бала чагында бик яратып тыңлый.* Г. Ибраһимов. **Бала корт** *диал.* — 1) яңарак аерылып чыккан яшь умарта күче һәм шул күчне тәшкил итүче бөҗәкләр турында. *Карт --- кәрәзле бал алып керде. Ни җитте бал гына да түгел, бала корт балы иде.* М. Әмир. *Бала кортлар очар бал өчен, Яшь егетләр йөрер дан өчен.* Җыр; 2) кыргый умарта кортларының ваграк бер төре. **Бала кычыткан** *диал.* — кычытканның вак яфраклы һәм тәбәнәк төре. **Бала очыру** — җитлегә башлаган балаларын очарга өйрәтү өчен оядан чыгару (кош-кортлар турында). *Юл читендәге чирәм араларында чыпчык балалары чыелдаша—чыпчыклар бала очыра иделәр.* Г. Гобәй. **Бала суганча** — 1) сугансыманнарның орлыктан үскән һәм бер җәйдә генә җитлекми торган вак суганчалары. *Гладиолуслар бүлбе-суганчалардан һәм бала суганчалардан үрчиләр.* Җиләк-җимеш...; 2) бер зур суганчадан бүленеп, укмашып үскән вак суганчаларның берсе. **Бала умарта** — яшь умарта. *Бала умарталар — ярлы умарта, Бал кушыек аның кортына.* Җыр. **Бала чүбе** — *к.* соңгылык. **Бала чүпрәге** — бәбинең астына сала торган биләү-төрү җәймәсе. **Бала өе** *иск.* — *к.* балалар бакчасы. *Садыйк нык уйланды. Нәгыймәнең үзе белән озак киңәште: — Балаларны яслегә, бала өйләренә бирик.* Г. Ибраһимов. **Балалар бакчасы** — мәктәп яшенә кадәрге балаларны карау-тәрбияләү учреждениесе, оешмасы һәм шуның биналары, корылмалары. *Колхоз булгач, иптәш Гыймазов әйткәнчә, яслесе дә, балалар бакчасы да булыр.* С. Рафиков. **Балалар бүлмәсе** — 1) өйдә, квартирада балалар өчен билгеләнгән бүлмә; 2) зур шәһәрләрдә, вокзалларда адашкан яки җинаять эшләгән балаларны вакытлыча җыю, тәрбияләү белән шөгыльләнә торган милиция оешмасы һәм шул оешманың эш бүлмәсе. **Балалар йорты** — ятим яки тәрбиячесез балаларны тәрбияләү учреждениесе һәм шуның биналары. *Мирсәй әле малай чагында ук, әткәсе һәм әнкәсе үлеп киткәннән соң, балалар йортында тәрбияләнә.* Г. Иделле. **Балалар хезмәте** — ящь

балаларның фабрика-заводларда өлкәннәр белән берраттән эшләве (капиталистик илләргә хас күренеш). *Капитал балалар хезмәтен тыелгысыз эксплуатацияләү юлы белән өстәмә кыйммәт сыгып ала.* Политэкономия. **Балалар язучысы** — балалар һәм үсмерләр өчен сәнгать әсәрләре язучы әдип. *Аркадий Гайдар, атаклы балалар язучысы, уналты яшеннән полк белән командовать иткән.* Г. Ахунов.

◇ **Бала аеру** — умартадагы яшь күч аерылып чыгу. *Умарта кортлары бала аера башлагач, умарта бакчасына барып көн үткәрү күңелле иде.* М. Гафури. **Бала анасы** — ана булган яки балага ана тәрбиясе бирүче хатын-кыз. *Гөлсем, --- бала анасы булганчы ук, шундый хакыйкатьне ныкъ үзләштерде: тормыш көрәштән гыйбарәт һәм бу көрәшкә бала чактан хәзерләнергә кирәк.* Г. Гобәй. **Бала атасы** — балага ата булган яки аңа карата аталык вазифаларын үтәүче ир заты. *Инде аның [Җәләл мулланың] яше дә байтакка килгән. Ничә бала атасы.* Г. Ибраһимов. **Бала булу** — балаларча кылану, балалык күрсәтү. *Гайфул --- икеләнебрәк калгач, карт кистереп кенә өстәп тә куйды: — Бала булма алай!* Ф. Хөсни. **Бала каз** — өлкәннәр рәтенә кереп тә, әле төпле акылы, тәжрибәсе булмаган кеше. *Халык та әле күбрәк аны [Сөләймановны] „яшь председатель" дип кенә йөртә. Я, Нургали Миңгалиев шушы бала казны үзе белән тиң күрә аламы?* Ә. Еники. **Бала китерү** — бала табу, бала тудыру. — *Хатын бала китергән иде, исем кушарга рәхим итегез.* Ш. Камал. **Балага авыру** — бала табу алдыннан табигый хасталык кичерү. *[Ходайдатның] хатыны, балага авырып, җирдән хәзер генә өзеп алынган яңа җир җилләге тели башлаган.* Г. Ибраһимов. **Балага узу (калу)** — авырлы булып калу. *Балага әллә кайчан узганын Айсылу үзе дә сизмәгән, күрәсең.* М. Шабай. — *Ул [Сәгыйдә] балага калган булса, аның атасы мин булырмын.* Һ. Такташ. **Баладан котылу** — бала тудыру. *Вакыт үтте, Зәйтүнәнең баладан котылыр вакыты җитте.* Ф. Хөсни. **Балалар әкияте** — беркатлы уйдырма; ялганлыгы күренеп торган сүз, хәбәр. *[Нәгыйм:] Кемнең нәрсәгә төренгәнен ерактан ук күрә алабыз һәм балалар әкиятенә дә ышанып карый алмыйбыз.* Ш. Камал.

БАЛАБАН *и. к.* балпан. *Хан баласы ханга охшар, балабан шоңкарга охшар.* Мәкаль.

БАЛАВЫЗ *и.* 1. Кәрәз төзү өчен умарта кортлары эшләп чыгара торган аксыл сары пластик матдә. *Бик борынгы заманнарда безнең илебез куе урманнар белән капланган булган һәм анда умарта кортлары күп булган, безнең бабаларыбыз агач куышларыннан бал һәм балавыз алганнар.* Умартачылык. // *с. мәгъ.* Балавыздан ясалган (коелган); балавыздан торган. *Балавыз курчак. Балавыз шәм.* □ *Бал корты, балавыз сараеннан чыгып, канаткайларын төзәтте.* Дәрдмәнд.

2. Составы яки үзлекләре буенча балавызга охшашлы органик һәм минераль матдәләр. *Тау балавызы [минерал].*

Балавыз капчыгы — эченә баллы кәрәз тутырып, балын сыгу өчен кулланыла торган капчык. **Балавыз (балавыз сыман) хәл** — бөртекле ашлыкларның, тулышкач, кату алдыннан, үзле, пластик масса булган чагы. *Су чыкмаса, бармакка бертөрле ябышып торса — шул инде игеннең балавыз хәле була.* Г. Гобәй. *Орлыкларның өч төрле өлгереш хәлен билгелиләр: сөтсыман, балавызсыман һәм тулы өлгереш.* Ботаника.

◇ **Балавыз кебек (шикелле)** — сап-сары, балавыз төсендәге. — *Кырып юмый ни. Балавыз кебек булсын идәне дә, түшәме дә, — диде Шәмсенур апа.* Э. Касыймов. *Мөнирә, балавыз шикелле саргайган кулын сузып, бармаклары белән чәчәкләргә орына.* Г. Әпсәләмов. **Балавыз (балавыз капчыгы) сыгу** — пышык-пышык елау. *Бикмуш бабай, башта Илсөярне еламаска өндәп маташса да, үзе дә бик тиз балавыз сыга башлады.* Г. Гобәй. *Без гармонь уйнап кайгы җырларын сибәбез, өйдәгеләр балавыз капчыгы сыгалар гына.* М. Крыймов. **(Гүя) балавыз сөяк(ле)** — бик сыгылмалы гәүдәле кеше турында. *Галиулла абзый да кереп биеп чыккалый. Ну бии картлач! Гүя балавыз сөяк.* М. Фәйзи.

БАЛАВЫЗЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* балавызлау. *Өч көн үткәннән соң, кич белән, Тарасов бөтен отрядны балавызланган идәнле озын коридорга тезде.* К. Нәҗми. *Паларусов картузын киде. Балавызланган киндер кожанны җилкәсенә салды.* Г. Ибраһимов.

2. Балавыз сыман булу; балавыз сыман өлгереш хәленә килү (ашлыклар турында).

БАЛАВЫЗЛАУ *ф.* Ныклык, чыдамлык өчен балавыз сендерү. *Җеп балавызлау. Такта балавызлау.*

БАЛАВЫЗЛЫ *с.* 1. Балавызы булган. *Балавызлы рам* [умартада].

2. Балавызланган, балавыз сендерелгән. *Миндә бик әйбәт кәгазь бар — балавызлы пергамент, су үткәрми.* Ш. Маннур. *Алма өзсәң, җепкә тезсәң, Балавызлы җепкә тез.* Җыр.

БАЛАВЫЗЛЫК *и.* Кош балаларының томшык читендә балавыз төсендәге яры. *Балавызлыгы кипмәгән бәбкә.*

БАЛАВЫЗЛЫЛАР *и. бот.* Балавызсыман чәер бүлеп чыгара торган үсемлекләр семьялыгы.

БАЛАГАН *и. иск.* 1. Ярминкәләрдә, зур базарларда, сабан туйларында тамаша оештыру өчен корылган зур чатыр яки корылма. *Җен төсле булып киенгән дураклар [клоуннар], шундагы балаганнарның башына чыгып, әллә нинди, дөньяда булмаган тилелекләр күрсәтәләр, имеш.* Г. Ибраһимов. // Циркның гадирәге, кәмит. *Мин кече яшьтән үк балаганнар һәм курчак театрларын яратып карый идем.* Г. Камал.

2. Мир яки артель кирәге өчен төзелгән, еш кына төзек күппочмак формасындагы лапас. *Без каравыл өенә барып җиткәндә, насослар, пожар мичкәләре куя торган балаганга байтак кына халык җыелып, кышка ачлык булу куркынычы турында сөйләшеп утыралар иде.* М. Гали.

3. *диал.* Саман яки кәз өй. *Калын-калын кәсләрдән әйбәтләп салынган балаган эче такталар белән икегә бүленгән.* И. Туктар.

◇ **Балаган кору** *иск. шелт.* Уен-җыр оештыру. — *Д бу мәдрәсәдә --- кәмит һәм балаган коралар икән.* С. Кудаш.

БАЛАК *и.* Чалбар, штан, кальсон һәм башка шуның кебек киемнәрнең һәрбер аякка аерым кидерелә торган түбәнге өлеше. *Степаныч бер сыңар күн итеген салды һәм чалбар балагын капшап карады.* А. Шамов. *Харитон агай, --- балакларын тездән сызганып, иртәдән кичкә кадәр аягы белән кызыл балчык изә.* Г. Гобәй.

БАЛАКЛЫ: балаклы тавык (әтәч) — ботына каурый йоны үскән тавык (әтәч). *Кәкре койрыклы, балаклы, кылыч кикрикле, кызыллы-яшелле салават күпере төсле әтәчне чырылдатып күтәреп чыктылар.* М. Гали. **Балаклы тәре** — чиркәү байрагы (хоругвь). *Керәшен ягының побы, балаклы тәреләр белән чыгып, бик озак игеннәр арасында улап йөрде.* Г. Бәширов.

БАЛАЛА'ЙКА *и.* 1. Резонатор куышлыгы өчпочмак формасында ясалган өч кыллы музыкаль инструмент. *Җәйге тымызык төн. Якында гына кемдер балалайка чиертә.* А. Расих.

2. *күч. сөйл.* Трактор белән сөрелгән җир башында өчпочмак рәвешендә чи калган урын. *Хәйдәров сөргән участокта --- баш-башлары аркылыга йөрелгән, чи калган урыннар, тракторчыларның үз сүзләре белән әйткәндә, „балалайкалар" күренми иде.* Ф. Хөсни.

БАЛАЛА'ЙКАЧЫ *и.* 1. Балалайкада уйнаучы музыкант.

2. Балалайкалар ясау белән шөгыльләнүче оста.

БАЛАЛАНУ *ф.* 1. Балаларча кылану. [*Һилал, янап:*] *Үзеңне кызгансаң, мине харап итәргә теләмәсәң, урыныңнан кузгалма!* [*Акбирдин:*] *Балаланма, Һилал иптәш!* К. Тинчурин. *Ир йөрәк үзе белән гомер үткәргән хатынының бу чаклы балалануына чыдый алмады.* Г. Гали.

2. Бер төптән яңа сабаклар чыгарып үрчү, курпылау (үсемлекләр турында). *Игеннәр буыннан буынга сикереп, һаман саен буйга омтылып үсәләр, балаланып, төптән куера баралар.* М. Шабай.

БАЛАЛА'РЧА *рәв.* Балаларга хас булганча. *Аның [Зөһрәнең] --- балаларча садә вә бәйләнешсез сүзләрен тыңлау миңа әллә нинди нечкә музыкадан да күңеллерәк иде.* Ш. Камал. / *с. мәгъ. Кыз, балаларча чынлык белән, бөтен вакыйганы яңадан каушап, кызуланып сөйләп бирде.* Г. Ибраһимов.

БАЛАЛАУ *ф.* 1. Бала тудыру (хайваннар турында). *Таһир --- әле таң алдыннан гына балалаган дуңгызы янында чуала.* М. Хәсәнов. *Куяннарның балалап, куян балаларының теләсә кайда адашып йөргән чаклары иде.* Т. Миңнуллин. / *гади с. туп.* Бала табу (хатын-кыз турында). — *Мәрхүм бай беркөн мине чакырды да: бар әле, яшьтәш, ди, минем хатын балаларга итә бугай, ди. Фәхри карчыкны чакырып кил әле, ди.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. сөйл.* Күбәю, ишәю. *Юа башласаң, кер балалый.* Әйтем. — *Күрдегезме, акча балалатабыз. Бер тиенгә — бер тиен балалый.* Ш. Маннур.

3. *күч. туп.* Озак маташу, мыштырдау. *Хатын [миңа] килеп төртә. — Җә, тизрәк, бик озак балалыйсың, малларны карап кер, ди.* М. Әмир.

БАЛАЛЫК *и.* 1. Балаларга хас сыйфатлар. *Малайлар --- вакыты-вакыты белән онытылып китәләр, балалыкларына бирелеп, шаярып ташлыйлар.* Л. Ихсанова. // *күч.* Сабырсызлык, кызулык; җавапсызлык. *Аксакал [Арысланбайның] үзенә генә: — Акылга утырыр чагың җиткән, балалык кылма! — дип, каты кисеп әйтте.* Г. Ибраһимов. // Беркатлылык, юләрлек, тилелек. [*Газиз:*] *Чынлап сөйләшкәндә, балалык катыштыру сакал чыга башлаган кешеләргә килешми.* Ф. Әмирхан. *Атабаев Сәҗидәкәйдән мондый балалыкны, юләрлекне көтмәгән иде.* Г. Иделле.

2. Бала вакыт, бала булган дәвер. *Бар иде бер чак бабаңның, һәй, балалык чаклары.* Н. Исәнбәт.

3. Кемгә дә булса ул яки кыз булу хәле. *Бу карт [бабай] малайга әйткән, ди: Син алайсаң миңа уллыкка-балалыкка керче! — дигән, ди.* Әкият.

4. *с. мәгъ.* Балага җитәрлек. *Безнең урын йөз алтмыш балалык, биредә инде ике йөздән дә артып китте.* Г. Гобәй.

Балалык капчыгы — соңгылык сүрүе.

БАЛАМУТ *и. гади с.* Юньсез, тәртипсез һәм тыйнаксыз кеше. *Бәлки әти мактагандыр: „Минем балам — ут!" диеп; Башкалар кул селти иде: "Беләм — баламут", — диеп.* Ш. Галиев.

БАЛАН *и.* Чәчәк һәм җимешләре зонтсыман тәлгәш хасил итә торган аксыл кайрылы куак. *Иртә килгән кошлар сайрый, Басып яшь баланнарга.* Ш. Маннур. [*Әшчеләр*], *кояш баеп, күк йөзенә түгәрәк ай калыккач, Идел тавындагы чикләвек һәм балан куаклары арасына җыелыштылар.* И. Гази. // Шул агачның ачы, кызыл җимеше. *Балан бәлеше. Балан кагы.* □ *Миләш диеп капкан идем, балан булып чыкты бу.* Мәкаль.

Балан бармак *диал.* — *к.* имән бармак. *Солдат, балан бармагын маңгаена куеп, тагын нәрсәдер уйлады.* Х. Госман.

◇ **Балан кабу, балан капкан кебек (балан каптыңмы әллә?)** — чытык чырайлы кеше турында. *Бариев йөзен чытты, әйтерсең аңа балан каптырдылар.* Х. Камалов.

БАЛА'НДА *и. гади с.* Сыек һәм туклыксыз шулпа. *Икенче көнне караңгы төшкәч, Йозеф бер котелок баланда — шалкан шулпасы алып килде.* Г. Әпсәләмов. *Иртән кузгалганда бер тапкыр бирелгән баланда белән әсирләр көн буе атлыйлар.* Ш. Маннур.

БАЛАНЛЫК *и.* Балан үскән, балан куагы күп булган урын. *Көз көнендә, комач җәйгән сыман, Ераклардан күренә баланлык.* Г. Хуҗиев. *Аргы якта аланлык, Тирә-ягы баланлык.* Җыр.

БАЛАНС *и.* 1. Тигезлек, тотрыклылык; үлчәү көянтәсенең тигез торышы.

2. *тех.* Тигезләгеч авырлык—балансирның хәрәкәтчән кисәге. *Рычаг буенча баланс йөри. Әгәр дә балансны рычагның башынарак күтәрсәң, ул вакытта клапанны күтәрер өчен көч күбрәк кирәк була.* Т. Госман.

3. *махс.* Бер эш буенча яки беркадәр вакыт эчендә керем белән чыгымның чагыштырма йомгагын чагылдырган хисап. *Айлык баланс.* □ *Кирәкле пропорцияләрне халык хуҗалыгы планында тәэмин итү өчен, халыкның акча доходлары белән акча расходлары балансы төзелә.* Политэкономия. *Шәйхи абзаңның өстәл тартмасында ашъяулык кадәр баланс ята — анда бары да исәпләнгән.* Ә. Еники. // Берәр эш яки эшчәнлек өлкәсендә барысы бергә бер бөтен тәшкил итәргә, бер-берсен тутырырга, тигезләргә тиеш булган өлешләрнең чагыштырмача яки саннар белән билгеләнгән зурлыгы. *Менә әле районның икмәк-фураж балансын очлап бетермәгәннәр.* Г. Толымбай.

Баланска керү, баланста тору — кыйммәте исәпкә алынган нәрсәләр исемлегенә керү яки шул исемлектә тору. *Абзарлар --- һәммәсе колхоз балансында торалар.* С. Рафиков.

БАЛАНСИР *и.* 1. Арканда биюче циркачның тигезлек саклау колгасы (циркач аны уртасыннан тотып йөри). // Көймәнең тотрыклылыгын арттыру өчен, аңа параллель торышта колга ярдәмендә беркетелгән озынча зур калкавыч.

2. *тех.* Үлчәүләрдә, насосларда, төрле механизмнарда көч һәм хәрәкәтне тиешле юнәлештә күчерү, тапшыру өчен хезмәт итә торган көянтә. *Балансир астан өскә, өстән аска тирбәлеп, гаять зур кош кебек җирне чукыган.* Нефть тур. хик.

БАЛА'НСЛАУ *ф.* 1. Берәр төрле чара белән керем-чыгымнарны тигезләү.

2. Баланс ясау яки баланс чыгару.

БАЛАСЫТУ *ф.* Бала хөкемендә йөртү, балага санау. *Нәфисә бу картның аңа ышанып бетмәвен, баласытып каравын сизә.* Г. Бәширов. // Тәҗрибәсезгә, беркатлыга санау. [*Павлик*] *биредә үзе өчен чиксез авыр, гарьлекле, аны баласыта, кимсетә торган бер хәйлә барлыгын аңлап алгандай булды.* М. Әмир.

БАЛА-ЧАГА *җый. и.* Эреле-ваклы балалар, күп бала. *Авыл ире, хатыны, баласы-чагасы — бары берлектә дуу килә.* Г. Ибраһимов. // Балаларны зурларга

каршы куеп сөйләгәндә. — *Уйнап сөйләшергә мин бала-чага түгел.* Р. Ишморат.

БАЛА-ЧАГАЛАНУ *ф. к.* балалану. *Дөнья җимерелгәне юк, иптәш Саркисян гына бала-чагалана.* Б. Камалов.

БАЛА-ЧАГАЛЫК *и.* Тәжрибәсезлек, беркатлылык, балалык. [*Нәҗия*] *бала-чагалыгына бара. Янәсе, Вафин абыйсын котыртмакчы.* Ф. Хөсни.

БАЛАЧАК *и.* Кешенең бала булган чагы, сабыйлык (нарасыйлык) белән яшүсмерлек арасындагы дәвере. *Газинурның балачагы авыр елларга туры килде.* Г. Әпсәләмов. *Туган җирләргә, ваемсыз балачак узган илләргә кайтучының күңеле ничек ашкынмасын!* Г. Минский.

БАЛАЧЫЛ *с.* 1. Балаларча эшләнгән, балаларга хас. *Фәррахбануны яшьләргә хас балачыл тойгылар басып алдылар.* К. Насыйри.

2. Балаларны ярата торган. *Балачылга — бала, бәлачелгә — бәла.* Әйтем.

БАЛГА *и. иск.* Хәрби балта, гөрзи; зур чүкеч, кувалда. *Туң тимергә балга бар, туң кешегә хөкем бар.* Мәкаль. *Туры юллы көрәштем мин алла белән, Гарше көрси ваттым сүздән балга белән.* С. Рәмиев.

Балга баш — алдан артка таба озынча баш.

БАЛДАК *и.* 1. Кашсыз йөзек. *Балдак бармакка күрә, яр йөрәккә күрә.* Мәкаль. [*Тегүчеләрнең*] *күбесе сакалларын кырып, мыекны җиткереп, уң кул бармакларына фирәзә кашлы йөзек я киң көмеш балдак киеп йөриләр.* М. Гали. // *сөйл.* Гомумән һәртөрле йөзек. *Алтын балдак ал кашлы.* Җыр.

2. *күч.* Бөжра; түгәрәк, әйләнә. *Уйнады чабаклар күлнең өстендә, Ясалды балдаклар балдак эченда.* Ә. Исхак.

3. Көнкүрештә һәм техникада кулланыла торган алка. *Верстакта төрле зурлыктагы корыч балдаклар ята иде.* Г. Әпсәләмов. *Чалгың корыч, балдаклары көмеш, Элмәләрдән ясап куй сапларын.* Җыр.

Балдак салыш — *к.* йөзек салыш. *Дсма, бармагындагы яшел фирәзә кашлы йөзеген салып: — дйдәгез, балдак салыш уйныйбыз,—дип, ашъяулыкка куйды.* М. Гали.

БАЛДАК-БАЛДАК *с.* Бер-бер артлы тезелгән балдаклар сыман. *Балдак-балдак төтен, чәчне ыслап үтеп, форточкага барып асылына.* М. Җәлил. *Шул беретка астыннан балдак-балдак булып чыгып торган чәч очларында, төшәм, төшәм дигәндәй, күбәләк кар асылынып тора.* Х. Госман.

БАЛДАКЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* балдаклау. *Балдакланган кош. Балдакланган агач.*

2. Балдак сыман формага керү, бөжралану. *Елтыр чабаклар башларын судан чыгарып алалар да, балдакланган дулкыннар ераклрга таралып югалалар.* Ф. Кәрим.

БАЛДАКЛАУ *ф.* 1. Кыргый хайваннарның күченү юлларын өйрәнү максаты белән, кош-кортның һәм вак җәнлекләрнең аягына, балыкларның сынак капкачына махсус балдак кидереп тамгалау. *Кыргый кошларны тотып, аякларына җиңел алюминий балдак кидертәләр; балдакка номер куелган һәм балдаклаучы учреждениенең исеме күрсәтелгән була.* Зоология.

2. Агачны җирдән менә торган корткыч бөҗәкләрдән саклау өчен, кәүсә әйләнәсен билгеле бер киңлектә махсус состав белән сылап чыгу яки шундый состав сендерелгән материя белән урап кую. *Алмагачларны балдаклау.*

3. Балдак сыман итү, бөжралау. *Тимер чыбыкны балдаклап бөгү.*

БАЛДЫЗ *и.* Ир (кияү) өчен хатынының сеңелесе. *Җизнәсе белән тынышмаган балдыз апасына да ят.* Мәкаль. *Мирзанур дус! Ай-һай, балдызың ла... Нигә безгә бажа булмаска?* Р. Гәрәй.

БАЛЕРИ'НА *и.* Балетта биюче артистка. *Сыртланов букетын Хәлимә Баязитовага — балетның төп каһарманын биегән балеринага сузды.* Ш. Хөсәенов.

БАЛЕТ *и.* 1. Театраль бию сәнгате.

2. Әчтәлеге махсус музыкага биюләр һәм мимик хәрәкәтләр аркылы ачыла торган сәнгать әсәре — театр тамашасы. *Опера театры --- яңа милли опералар һәм балетлар хәзерли.* М. Җәлил. // Операда, музыкаль драмада биюле, мимикалы күренеш. *Салих Сәйдәшев бу спектакльгә [„Зәңгәр шәл"] унлап яңа әсәр иҗат итте, береңче пәрдәгә саф татар балеты тудырды.* Х. Сәлимҗанов.

БАЛЕТМЕ'ЙСТЕР *и.* Балетта биюләр җитәкчесе; балет биюләренә өйрәтүче. *Культура сараенда балетмейстер булып эшләүче Кәрим --- үзешчән сәнгать коллективында биюләр куйгалый иде.* М. Хәсәнов.

БАЛЕТМЕ'ЙСТЕРЛЫК *и.* Балетмейстер һөнәре, балетмейстер вазифасы.

БАЛИГЪ: балигъ булу — җитлегү, өлгерү, балалыктан чыгу (бигрәк тә рухи, җенси яки рәсми яктан). *Ул [Корбанов] --- балигъ булып унсигезгә чыкканда инде, кулына корал тотып, гражданнар сугышына китте.* Г. Ахунов.

БАЛИГЪЛЫК *и.* Балигъ булу хәле; җитлеккәнлек, өлгергәнлек. *Балигълыкка чыгу. Балигълыкка җитү.*

БАЛИМӘР, БАЛАШАР *и.* Чәчәкләрдән бал суырып, ялап тукланучы кечкенә көньяк кошы; *русчасы:* медоед.

БАЛИТӘК *и. сөйл. к.* бала итәк. *Аклы ситсы күлмәгемнең Балитәге өч кенә; Бәләкәй дип хурламагыз, Сандугач та кечкенә.* Җыр.

БАЛКАЛАК *и. к.* балкашык. *Бер саранга дусы килгән. Саран чәй янына бал белән кечкенә балкалак куйган.* Н. Исәнбәт.

БАЛКАШЫК *и.* Кечкенә кашык, чәй кашыгы. *Мөнирә балкашык белән куе чәен болгата-болгата аска карап торды.* Г. Әпсәләмов.

БАЛКОН *и.* 1. Култыкса яки рәшәткә белән киртәләнгән һәм өске катларда биналарның стенасына беркетелгән ачык мәйданчык. *Өченче этаж балконнары.* □ *Больницаның икенче катыннан елга ягына балкон чыга.* Т. Госман.

2. Театр залындагы өске яруслар. *Балкондагы урынга бирелгән билет.*

БАЛКУ *ф.* 1. Берәр нәрсәнең өсйөзе яп-якты булып тору, яп-якты булып күренү. *Ялтырый иртүк кояш, һәрбер урында балкый нур.* М. Гафури. *Тик төн буе шагыйрь бүлмәсендә ут балкыды көннән яктырак.* М. Җәлил. // *күч.* Ачык төсләр белән күз карашын җәлеп итү. *Зәйтүнә су сибеп үстергән гөлләр-чәчәкләр балкып утыра.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *күч.* Җанлану, нурлану, мөлаемлану (кеше йөзе турында). *Мисбахның бу сүзләрен ишеткәч, Газинурның йөзе балкып китте.* Г. Әпсәләмов. // Йөзгә чыгып, ачык беленеп тору (кәеф, характер, хис турында). [*Нәгыймәнең*] *йөзендә, күзендә үткенлек, катылык балкып тора.* Г. Ибраһимов.

БАЛКЫЛДАУ *ф. сир.* Көчле һәм үзгәрешле рәвештә балку (балкып тору). *Зур өлгеле киң тәрәзәләрнең һәммәсе ерактан балкылдап торалар.* Г. Ибраһимов.

БАЛКЫТУ *ф.* 1. Нурландыру, яктырту. *Тимергалин йорты. Ятмаганнар. Нур балкыта тышта утлары.* Ш. Мөдәррис.

2. Яктылык чыганагын көчәйтү, яктырак яна торган итү. [*Камәр*] *йөгереп барып кучкардагы лампа утын балкытыбрак чыгарып куйды.* Р. Төхфәтуллин.

БАЛКЫШ *и.* Көчле яктылык, нурлы чагылыш. *Күктәге балкыш кабынып яки сүнеп киткән чагында, күл өсте дә үзгәрә.* Г. Әпсәләмов.

БАЛЛ *и.* **1.** Төрле стихияле күренешләрнең (давыл, җир тетрәү һ. б.) көчен үлчәү берәмлеге. *Бүгенге көндә тау районнарында, аеруча безнең участок тирәсендә, ун-унбер балл көчендә кар буранлары көтелә.* Ә. Айдар.

2. Укучының белемен яки үз-үзен тотуын бәяләү берәмлеге. *Малай конкурстан үтмәде — бер балл җитмәде.* А. Сәләхетдинов. // Спортчының осталыгын бәяләү берәмлеге.

БАЛЛА'ДА *и.* Эчтәлеге героик яки фантастик характердагы гыйбрәтле очракны хикәяләүгә багышланган сюжетлы шигырь яки музыкаль әсәр. *Балладада сөйләм бик эмоциональ һәм күтәренке була.* Т. Галиуллин.

БАЛЛАНУ *ф.* **1.** Баллылану, татлылану. *Бал, бал дип кенә авыз балланмый.* Мәкаль. *Балан-миләш аллана, Алга бетеп баллана.* Н. Исәнбәт. *Шушы бик аз вакытта бу җиләк алланды, балланды.* М. Гафури.

2. *күч.* Төчеләнү, куштанлану. *Дөньяда бар бит оятсыз кешеләр: ирен көтми китеп барган, ә хәзер балланып каршы алган була.* М. Максуд.

3. Бал белән тулу (умарта турында). *Зәки йөридер бакча буенча: Умарталар җитмәгән балланып.* Бәет.

БАЛЛАП *рәв.* **1.** Бал ягып, бал кушып, бал белән. *Баллап ипи ашау.* □ *Биредә күп сыйлар өстенә тагын --- баллап катырган чәкчәк тә бар иде.* Ә. Еники. *Кыз утырды безнең каршыбызга, Баллап, сөтләп күк чәй эчерде.* М. Җәлил.

2. *күч.* Төчеләнеп, татлы тел белән. *Баллап сөйләү.* □ *Шул баллап язылган төрек романнарын уку --- [Мәрьям] рухының бертуктаусыз телән тора торган бер ризыгы.* Г. Ибраһимов.

3. Бал җыеп, бал биреп (умарталар турында). *Умарталар һәр ел яхшы гына үрчеп, баллап килгәннәр.* М. Гали.

БАЛЛАСТ *и. тех.* **1.** Көймәләрнең һәм очкычларның (мәсәлән, кораб, дирижабль) тотрыклылыгын арттыру өчен төялгән махсус авырлык. *Немецлар ... су асты көймәсенең балласт цистерналарын өрдереп чистарталар иде.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Кирәксез, файдасыз яки артык йөк, мал; берәр оешмада, эштә һ. б. артык кешеләр. — *Соң бит ул сатылырга тиешле терлек бары сан гына, балласт кына!* А. Расих. *Язучыларның озак еллар буе бер урында таптанулары аларның „әдәби балластка" әверелү куркынычын тудыра.* М. Җәлил.

2. *махс.* Тимер юл түшәмәсе, өстенә шпаллар тезәр өчен тигезләп өелгән ком һәм чуерташ. *Макаренко, балластка таянып, тезләрен шпалга, колакларын рельска куйды да: „Поезд якынлаша", — диде.* Г. Гали.

БАЛЛИ'СТИК *с.* Баллистика фәнендә карала торган. *Баллистик траектория.*

БАЛЛИ'СТИКА *и. хәрби.* Горизонтка билгеле бер почмак ясап ыргытылган җисемнең (пуляның, снарядның) инерцияле хәрәкәтен өйрәнә торган фән (теоретик механиканың бер бүлеге). *Батарея командиры булу өчен математика, баллистика һәм механиканы белергә кирәк.* А. Шамов.

БАЛЛОН *и. тех.* **1.** Газ яки сыеклык тутыру өчен шар яки цилиндр формасындагы савыт. *Резин баллон. Металл баллон.* □ *Бер чакрымга якын җирне әллә нәрсәләр белән тутырганнар: калай мичкәләр, зур пыяла баллоннар, тау-тау өлгән тоз, тагын әллә ниткән ташлар, мәгъдәннәр.* Ш. Камал.

2. Аэростат, дирижабль яки һава шарының газ үткәрми торган сүрүе.

3. Эченә һава тутырыла торган автомобиль һ. б. ш. шины; эче куыш металл көпчәк. *Машинаны этә башлаганнар иде, аның көпчәге шартлаган булып чыкты. Баллоны бөтенләй сытылган.* С. Шакир. *Тракторларның кайберләре тимер баллоннар-катоклар таккан.* И. Салахов.

БАЛЛЫ *с.* **1.** Балы булган; бал кушылган. — *Баллы чәй бир, Тәзкирә, — дип кычкырды Илгиз, кружкасы белән өстәл шакылдатып.* Н. Фәттах. // Нектары яки татлы чәере, суты булган, бал тәменә ия булган. *Тополькләрдән баллы кайры ислөре аңкый.* Ш. Камал. *Яз иде ... дымлы җил исә, тал бәбекләренең төчкелт баллы исе бәреп тора иде.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Ягымлы, татлы (сүз яки мөгамәлә турында). *Әче балы — кунакка, Баллы сүзе — хуҗага.* Ә. Маликов.

Баллы баба (бабай) — иренчәчәклеләр семьялыгыннан ак яки таплы ак чәчәкле күпьеллык үлән; *русчасы:* яснотка. *Койма буенда күпереп утырган баллы бабай чәчәкләре өстендә алтын сыман йөгерткән төклетуралар, бал кортлары оча.* А. Гыйләҗев. **Баллы гөмбә** — эшләпәле гөмбәләрнең ашарга яраклы бер төре; *русчасы:* опёнок. *Иң тәмлесе баллы гөмбә. Ул киселгән агач төпләрендә үсә торган паразит үсемлек.* Робинзон эзл. **Баллы какы** — какының ашый торган төре. *Монысы баллы какы — канны күбәйтә, диләр.* Ш. Маннур. **Баллы кузак** — кузаклылар семьялыгыннан субтропик климатта үсә торган агач һәм шуның татлы борчагы; „кәжә мөгезе"; *русчасы:* царьградские стручки. *Ярминкәдә --- балалар төрле уенчыклар алып кычкырталар, сыбызгылар сызгыртадар. Кайберләре баллы кузак, прәннекләр ашыйлар.* Х. Садрый. **Баллы чәчәк** — сиреньчәчәклеләр семьялыгыннан күгелҗем-шәмәхә яки аксыл чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы:* Иван да Марья. *Җир өстенә бераз ислемай сипкән шикелле, әллә кайдан баллы чәчәк исе килә.* Ш. Усманов.

БАЛЛЫК *и.* Чәчәкнең бал ясап чыгара торган әгъзасы.

БАЛ-МАЙ *җыйм. и.* Бал һәм май; баллы һәм майлы ашамлыклар. *Бал-май үземдә күп була. Башкорттан мичкәләп кымыз алдырам.* Г. Ибраһимов. — *Нигъмәт иптәш, бал-майдан Хәйри бабайга да авыз иттер.* Г. Камал.

◇ **Бал-май гына ашап тору** — сыйланып, бик яхшы ашап тору.

БАЛ-МАСКАРАД *и.* Катнашучылар маска һәм махсус костюмнар киеп күңел ача торган бал.

БАЛПАН *и.* **1.** *иск.* Ауга өйрәтелгән ерткыч кош (бигрәк тә бөркет) баласы. *Егет булсаң, балпандай талпын.* Мәкаль.

2. *диал.* Тилгәннең бер төре; *русчасы:* балабон.

БАЛТА *и.* **1.** Гадәттә агач саплы, яссы киң чөй рәвешендәге, үткен йөзле чабып кисү коралы. *Ул эшкә өйрәнмәгән Габделкаюм өчен көне буе балта тотып агач юну бик авырга туры килде.* М. Гали. *Әкмәл --- шома өрәңге саплы, кечкенә, әмма бик үткен балтасын алып килде.* А. Гыйләҗев.

2. Балта йөзе сыман чыгып торган нәрсә. *Ачкыч балтасы.*

Балта остасы — балта эше белән шөгыльләнүче кеше. *Кайда шаулы төзелеш бара — Балта остасы шунда; Түбә, түшәмнәр эшли ул, Япмалар кора кырда.* М. Сөндекле. **Балта эше** — балта ярдәмендә агачтан кирәкле нәрсәләр ясау эше, һөнәре. *Фәритләрнең этиләре балта эшен белә икән, кораллар белән ничек эш итәргә өйрәтеп торды.* Г. Гобәй.

◇ **Балта асарлык (асып куярдай)** — бик куе, катлам-катлам (төтен, томан, пар турында). *Җыелыш барган бинада Балта асарлык төтен.* С. Баттал. **Балта белән агач арасы** — бик хәтәр урын, хәтәр эш. [*Минһаҗ:*] *Балта белән агач арасына бармак тыгарга картлар кушмаганнар.* К. Тинчурин. **Балта кермәс (кермәгән, керерлек түгел)** — бик куе, бик еш (урман, ешлык турында). *Балта кермәгән кара урманнар бар бит безнең бу якларда.* Г. Галиев. **Балта күтәрү** — балта белән коралланып һөҗүм итү яки каршы тору. *Баш өстендә фашист палачлары Балта күтәргәндә, Син антыңны төгәл саклагансың Үлем көткән хәлдә.* Н. Арсланов. **Балта сабы кыска** — тиз ачуланучан; тиз кызып китүчән. **Балта суга төшү, балтасы суга төшкән (балтаң суга төштеме?)** — бәла-казага очраган, авыр хәлгә калган кебек боегып, күңел төшеп йөрү турында. *Билал абзый күршесен: «Әллә балтаң суга төштеме, нигә болай борыныңны салдың? — дип шаярыбрак каршыларга иткән иде дә, бу ук бик тиз сүнде.* Г. Толымбай. — *Нигә син башыңны аска иеп, балтаңны суга төшереп йөрисең?* Г. Иделле. **Балта тоту** — хуҗалык эшләрен белү, балта белән эш итә белү. — *Балта тота беләсең икән үзең,яхшымы-яманмы, ир заты шул.* Ф. Хөсни. **Балта чабу** — 1) балтаны селтәп, агачка йөзен батыру яки батырып кую. [*Мастерскойда*] *балта чабарга юан бүкән тора.* Р. Төхфәтуллин; 2) балтачылык белән шөгыльләнү, балта эше эшләү. *Юнарга, балта чабарга бик иртә тотынган ул* [*балта остасы*]. С. Хәким.

БАЛТАЧЫ *и.* Һәртөрле балта эше белән шөгыльләнүче һөнәрче, балта остасы. *Балтачы Әхмәтҗан Олы Шырданнан Казанга килеп урнашып, берничә елдан бирле шунда балта остасы булып эшләүче кустарь иде.* М. Гали.

БАЛТАЧЫЛЫК *и.* Балтачы һөнәре; балтачы булу. *Балтачылык белән шөгыльләнү. Балтачылык белән көн күрү.*

БАЛТЫР *и.* 1. Аякның тубыктан тезгә кадәр булган өлеше (йомры, мускуллы ягы турында). [*Көймәдә*] *су инде Илсөярнең балтырына кадәр күтәрелде.* Г. Гобәй.

2. *к.* куныч. *Шәрифҗан, кайнар котелокны тезенә куеп, итек балтырыннан тимер кашык тартып чыгарды.* И. Гази. [*Сирайның*] *аягында балтыры киселгән киез итек.* К. Нәҗми.

БАЛТЫРГАН *и.* Зонтиклылар семьялыгыннан эре яфраклы үлән (бәбәкләрен һәм яшь көпшәсен ашыйлар); *рус часы:* борщевик.— *Балтырган белән зәрдәдән пешергән аш шундый тәмле була ул!.. Телеңне йотарсың.* З. Бәшири. *Хәлим көн саен --- балтырган, кузгалак җыеп кайта.* И. Гази.

БАЛТЫРДАН *рәв.* Балтырга кадәр, балтыр турысына, балтыр тәңгәленә кадәр. *Итек кунычы балтырдан.* □ *Алга китте* [*Карәхмәт*] *бата-чума балтырдан.* Ә. Исхак.

БАЛЧЫ *и.* 1. *тар.* Кунакларга әче бал өләшүче; аякчы. *Балны башлап балчы авыз итә.* Мәкаль.

2. Умартачы. *Балчы кызы балдан татлы.* Мәкаль. *Малчы мал карар, балчы бал карар.* Н. Исәнбәт.

БАЛЧЫК *и.* 1. Су сеңгәндә үзле масса булып әверелә һәм суы парланганда ката торган минерал. *Балчык катламы.* □ *Туфрак асты—балчык, ком асты—таш.* Мәкаль. *Менә күпер. Сары балчыклары Актарылып торган яр башы.* Ш. Мөдәррис. // *с. мәгъ.* Балчыктан яки махсус измәдән эшләнгән; балчыктан торган. *Балчык моржа. Балчык дивар.* □ *Берсе балчык өйгә терәп, берсе аерым салынган тәбәнәк, киң балчык абзарларда атларның ашавы, сыерларның акрын гына күшәве ишетелде.* Г. Ибраһимов.

2. Сылау, штукатурлау өчен махсус хәзерләнгән масса, измә. *Яңа гына салынган мичтән киоеп барган дымлы балчык исе аңкый.* А. Шамов.

Балчыктан ясалмаган (әвәләмәгән) — җансыз түгел, тере, үз-үзен якларга сәләтле. *Без бит инде балчыктан ясалмаган. Кистереп искән җил чыга калганда, аңа арканы куеп булмыймыни?!* С. Рафиков.

БАЛЧЫКЛАНУ *ф.* 1. Балчык хәленә килү, үзләләнү. *Туфрак балчыклану.*

2. Балчыкка буялу. *Хәбиб, бетәр-бетмәс йокысын басып, сикереп торды да, балчыкланып, беткән ыштырларын кагып, аягына киенде.* Т. Госман.

БАЛЧЫКЛЫ *с.* 1. Балчыгы булган; составында балчык булган. *Балчыклы урын. Балчыклы туфрак.*

2. Балчыкка буялган. *Эти ишек бусагасына утырып балчыклы итеген салды.* Г. Мөхәммәтшин.

БАЛЧЫКЛЫК *и.* Сылау яки керамика өчен кирәкле балчыклар ятмасы; шундый балчыкны казып алу урыны.

БАЛЧЫКСЫЛ *с.* Бераз балчык катыш. *Известьне тирес белән яки тирес һәм минераль ашламалар белән куллану --- балчыксыл һәм балчыклы туфракларда яхшы нәтиҗә бирә.* Соц. Тат.

БАЛЫК *и.* Очлыклары канат рәвешендә булган һәм саңаклары ярдәмендә сулый торган суык канлы су хайваны. *Балык тоту. Балык кебек йөзү.* □ *Балыкны йөзәргә өйрәтмиләр.* Мәкаль. // Ашамлык итеп хәзерләнгән балык. *Тозлы балык.* □ [*Шәмгун*] *Казнадан ярмасын, онын, итен, балыгын, маен алып кайтты.* А. Шамов.

Балык агы, балык сөте — ата (иркәк) балыкның орлык сыекчасы. **Балык койрыгы** *тех.*— буровой бораның очы калаклы булган төре. *Токым йомшак булган көньяк районнарда балык койрыгы дип атала торган борау белән боралар.* Нефть тур. хик. **Балык күле** — балык үрчетү яки балык симертү өчен махсус күл. *Фәсхи төзеп җибәргән балык күле инде проекттан узып эшкә әйләнгән.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Балык мае** — тәрәч бавырыннан алына торган витаминлы май. **Балык түне**— зур сулыкларда киң күләмдә балык сөзү сезоны (путина). *Әстерханда бер мең тугыз йөз унынчы елларда мин язгы балык түненә яландым.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БАЛЫККӘЛТӘ *и.* Күптән үлеп беткән борынгы сөйрәлүче хайваннарның бер төре. *Җирнең урта эра чорындагы диңгезләрдә балыккәлтәләр яшәгәннәр.* Зоология.

БАЛЫКЛЫ *с.* Балыгы күп булган, балык күп үрчи торган. *Бармакларын сөлгегә сөртә-сөртә, Гыймазов: Минзәлә суы балыклымы? — дип сорады.* С. Рафиков.— *Күлебез балыклы безнең. Тик, хәерсез, ауга кәрәкә балыгы гына әләгә.* М. Хәсәнов.

БАЛЫКЧЫ *и.* 1. Һөнәре балык тоту булган кеше. *Балыкчы күлен мактар.* Мәкаль. *Балыкчы тоткан балыгына, сунарчы аткан җәнлегенә карап куана.* Ш. Бикчурин. // Балык тоту һәвәскәре.

2. Балык белән эш итүче; балык белән сәүдә итүче.— *Аннан балыкны күп итеп тота башлыйм да, теге үлчәү янындагы балыкчы Хисмәтнеке кебек кибет ачам.* Ә. Фәйзи.

Балыкчы көймәсе — яссы төпле кечерәк такта көймә. *Рифгать --- балыкчы көймәсенә утырып бире якка чыгып килүче бер төркем ялангач яшьләрне күреп алды.* М. Әмир. **Балыкчы эшләпәсе** — киң кырлы түгәрәк эшләпә. *Хәйбүш үзенең балыкчы эшләпәсен кыңгыр сала да көн буена совхоз йортыннан керми.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БАЛЫКЧЫЛЫК *и.* 1. Хуҗалыкның балык тоту, балык үрчетү белән шөгыльләнүче тармагы. *Камбоджа — балыкка бай илләрнең берсе. Балыкчылык белән илнең барлык өлкәләрендә шөгыльләнәләр.* Каз. утл.

2. Балык тоту шөгыле. *Хатыны --- кармагын өзеп алган. Шуның белән балыкчылык карьерасы гомергә өзелгән* [*аның*]. М. Әмир.

БАМБУК *и.* Кыяклылар семьялыгыннан буын-буын куыш сабаклы, җылы якларда биек булып үсә торган агач сыман үсемлек. *Хуҗалык ягыннан бамбукның әһәмияте бик зур. Аның куыш эчле юан сабагы җиңел, ләкин бик нык була, ул йорт-каралты төзелешендә, мебельләр ясауда кулланыла, су үткәргеч труба булып хезмәт итә.* Дөнья кис. геогр. // *с. мәгъ.* Бамбуктан ясалган; бамбук сабагыннан торган. *Бер читтә савыт-сабалар урнаштырылган бамбук этажерка.* Ә. Айдар.

Бамбук аюы — янутсыманнар семьялыгыннан җылы якларда яшәүче җәнлек.

БАНАЛЬ *с.* Күп сөйләнгән һәм шул сәбәпле тәэсир көчен югалткан, оригиналь булмаган (фикер, сүз һ. б. турында). *Баналь фикерләр, теләсә нинди үткен соуска кушып бирелсәләр дә, барыбер баналь булып калалар.* Сов. әд.

БАНАН *и.* Җылы якларда сүсе һәм җимеше өчен үстерелә торган эре яфраклы күпьеллык үләнчел үсемлек. *Бананнар һәм күркәм кипарислар Кала кебек сыйпап башыңнан.* Г. Хуҗи. // Шул үсемлекнең калын кабыклы, ончыл, озынчарак татлы җимеше. *Поезд туктаган арада, вагон тәрәзәсеннән банан тәкъдим итәләр.* Г. Гали.

БАНАРАС *и. иск.* Ярым ефәк юка ак тукыма. // *с. мәгъ.* Шул тукымадан эшләнгән. *Бүлмә тәрәзәсе алдыннан --- банарас чапаннлы бер кешенең җәһәтләп үткәнен күргәч, Закир ниһаять дәрәҗәдә куанды.* Ф. Әмирхан.

БА'НДА *и.* Коралланган җинаятьчел группа яки оешма, шайка. *Махно банда җыйган, Махно Совет йөрәгенә сузыла.* М. Җәлил. *Төнлә белән аклар бандасы авылга басып кергән.* М. Шабай. // *күч.* Һәртөрле шикле төркем. *Урман эче төрле киемдәге, күбесенчә сакалмыеклы, атналар буенча юылмаган чытык битле, шикле кешеләр белән тулды. Озакламыйча бу бандага --- төрле җирдән качып кайтучы дезертирлар кушылдылар.* Қ. Нәҗми. // *хур.* Дисциплинасыз группа турында. *Отряд түгел, банда бу!* Ш. Усманов.

БАНДАЖ *и.* 1. *мед.* Корсакны яки тәннең башка өлешен тиешле формада кысып тота торган махсус биләүсә. [*Ярминкәдә*] *корсетлар, бандажлар, елан тиресеннән эшләнгән бер аршын озынлыгындагы перчаткалар --- — бар да бар.* Қ. Тинчурин.

2. *тех.* Машина һәм конструкцияләрнең буынлы өлешләренә ныклык өчен кидерелә торган металл балдак; тугым. *Мең сигез йөз егерме җиденче елларда Вуд дигән кеше паровозларның тәгәрмәчләренә бандаж кидерергә тәкъдим иткән.* Т. Госман.

БАНДАЖЧЫ *и. мед. тех.* 1. Төрле бандажлар ясаучы.

2. *тех.* Бандаж кидерүче.

БАНДЕРОЛЬ *и.* Почта аркылы җибәрелә торган кечерәк төргәк, күбесенчә китап-журнал. *Өстәлдә бүгенге почта — газеталар, пакетлар, бандерольләр һәм берничә хат.* И. Салахов.

БАНДЕРОЛЬЛӘҮ *ф.* Бандероль итеп төрү.

БАНДИТ *и.* Банда члены; юлбасар, башкисәр.— *Нокта Вәли — кырыкмаса-кырык тапкыр төрмәдән качкан бандит.* Ш. Қамал. // *күч.* Илбасар, басып алучы гаскәр солдаты. *Бу көннәрдә без, илебезнең тынычлыгын бозарга маташучы бандитларны нык кына тыздырып, чик буйларын тагын да ныгыта төшеп кайттык.* Қ. Нәҗми.

БАНДИТЛА'РЧА *рәв.* Бандитларга хас булганча, бандитларга охшатып. *Бандитларча һөҗүм итү.*

БАНДИТЛЫК *и.* Талаучылык, юлбасарлык; бандит булу. *Бандитлык юлына басу.* □ *Рәшитнең караклыгы да, урам баласы булып йөрүе дә, бандитлыгы да — берсе дә яшерен түгел.* Л. Гыйльми.

БАНДУ'РА *и.* Поляклларда һәм украиналыларда сызмасыз (чиртеп уйнала торган) кыллы музыкаль инструмент.

БАНИ *и. иск.* Төзүче, архитектор. *Дая әйтер: Банилар хазыйр кәлсен, Сәңа лаек бер сарай бина кылсын.* Қолгали.

БАНИЛЫК *и. иск.* 1. Төзүче яки архитектор һөнәре.

2. Мәчет, мәдрәсә кебек учреждениеләрнең биналарын төзү, ягулык һ. б. белән тәэмин итү, чыгымнарын күтәрүдә катнашучылык. *Мәдрәсәгә банилык итеп, бүгенге тышкы идарәгә килгән байлар да аңа [Кадыйр байга] ияр деләр.* Г. Ибраһимов.

БАНҚ *и.* 1. *экон.* Түләү, бурычка бирү һәм акча туплау яки акча бүлү эшләреңдә арадашчылык итеп, саф акчаны үзәкләштерелгән әйләнешкә кертә торган учреждение. *Дәүләт банкысы. Капиталистик банк.* □ *Революциядән соң Кытай ягына сыпырткан купец Ярмолкинның Алабуга банкысында алтыннары ятканны белүчеләр ревкомга килеп әйткәннәр иде.* И. Гази. // Шул учреждениенең эш бинасы.

2. Отышлы карта (кәрт) уенында конга куелган акчалар суммасы. *Банкка кую.* □ *Банкта акча күп кенә җыела башлады. Уйнаучылар бөтенләй ашау-эчүләрен, көннең кай вакыты җиткәнен оныттылар.* М. Гали.

3. *күч.* Отышлы карта (кәрт) уенының бер төре; шул уенның бер уйналышы (туры). *Тәзкирә апа атлас карталарны --- таратырга кереште. — Әйдә, Сөләйман. Киләсе банкка син дә катнашырсың.* Қ. Тинчурин.

Банк капиталы — банкта яткан капитал. **Банк кредиты** — банклар тарафыннан махсус билгеләнгән шарт белән бирелә торган кредит. *Банк кредиты бирелү — социалистик халык хуҗалыгын планлаштыруның кирәкле коралы.* Политэкономия.

◇ **Банк сугу** — банкка (2 мәгъ.) җыелган акчаны отып алу. *Банк сугучылар һәм, зуррак банкларны сугып, уенны ташлап китүчеләр белән уйнаучылар арасында кычкырышлар, талашлар да булып алды.* М. Гали. **Банк тоту** — акчаны банкка куеп, уенда катнашучыларның һәрберсенә каршы уйнау. *Арада берсе аягүрә баскан, кулында бер колода карта, исерегрәк тавыш белән банк тота.* Г. Ибраһимов.

БА'НКА *и.* 1. Цилиндрик формадагы металл яки пыяла савыт. *Шәмси шкафтан бер-бер артлы пыяла банкалар чыгара башлады. Бераздан шул банкалардан җәмаякларга тозланган гөмбәләр салырга кереште.* А. Расих.

2. *мед.* Кан тарату яки кан суырту өчен, эчендәге һаваны чыгарып, тәнгә авызы белән ябыштырыла торган кечерәк пыяла савыт.

Банка салу — медицина банкасын тәнгә ябыштыру. *Кислород биреп, банкалар салып, әллә нинди тәмсез дарулар белән сыйлап, ниһаять --- басымымны кайтардылар.* Қ. Нәҗми. *Күкрәк, арка тирәләренә салынган банкалар аның [Идриснең] тәнен тимгел-тимгел кара-күгелҗәм төскә керткәннәр.* Ә. Айдар.

БАНҚАЛЫ *с.* Банкага тутырылган хәлдәге. *Александра Ивановна кулындагы сумкасыннан берничә пакет белән лимон, әфлисун, алма, конфет, печенье, банкалы варенье чыгарып, сәкенең буш урынына тараттыр.* М. Гали.

БАНҚЕТ I *и.* Тантаналы сый мәҗлесе. [*Хәлил казый*] *үзендә банкет оештыра. Бу банкет министрларга ясала торган банкетлардан бик нык аерыла: анда речьләр сөйләнми, тостлар күтәрелми.* Қ. Тинчурин. *Бу егерме беренче бүлмә. Анда банкет. Хөсәен үзенең туган көнен үзе оештыра.* А. Расих.

БАНҚЕТ II *и. махс.* Балчык һәм таш, ком өеп ясалган калкулык, вал. *Иделнең көчле агышы Юлын бора без теләгән якка, Банкет салгач елга төбенә.* С. Урайский.

БАНҠИР *и.* 1. Капиталистик илләрдә банк хуҗасы яки зур акцияләргә ия булган акционер. *Урамнар купецлар, банкирлар, фабрикантлар, вояжерлар, алып-сатарлар, исерекләр, караклар, аферистлар, авантюристлар, фахишәләр белән тулган.* Қ. Тинчурин.

2. Банк уенында карта таратучы, банк тотучы.

БАНҠИРЛЫҠ *и.* Банкир (1 мәгъ.) булу. *Банкирлык белән шөгыльләнү.*

БАНҠНОТ *и.* СССРда банк тарафыннан чыгарылган һәм акча урынына йөри торган процентсыз кредит билеты. // Капиталистик илләрдә: эмиссия банклары чыгара торган кредит акчалары.

БАНҠРОТ *и.* 1. Бурычларын түли алмаучы, бөлгенлеккә төшкән капиталист (бай, банкир); казалы сәүдәгәр. *Бай хатыннары симерә; Ирләре банкрот булгач, Кара икмәк кимерә.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *күч.* Исәбеңдә ялгышкан, карьерасы җимерелгән һ. б. ш. кешеләр, партияләр, группалар турында. *Политик банкрот. Банкротка чыккан буржуаз партияләр.*

БАНҠРОТЛЫҠ *и.* 1. Банкрот булу хәле. *Татар сәүдә буржуазиясе арасында, Москва фабрикантларыннан көтәргә күпләп мал алып, соңыннан шартлаган булып, банкротлык игълан кылу --- бик модадагы әйбер иде.* М. Гали.

2. *күч.* Уңышсызлык, ялгышлык, хаталык. *Политик банкротлык.* □ *Абстракцион сәнгать капитализмның кризисын, аның рухи банкротлыгын күрсәтеп тора.* М. Хәсәнов.

БАНТ *и.* Қат-кат бөкләп, уртадан элмәкле төен белән бәйләнгән бизәнү тасмасы. *Бу вакыт Иркинә күкрәгендәге кечкенә кызыл бант бигрәк яз чәчәген хәтерләтә.* М. Шабай. [*Артистларда*] *дулкынланып торган озын чәч, муенда җилфердәп торган зур бант.* И. Рәмиев.

БАНТЛАП *рәв.* Бант ясап. *Тасманы бантлап бәйләү.*

БАНТЛАНУ *ф.* Бант шикелле булып, бөрелеп, катланып тору. [*Шакирда*] *чит-читләре юри кыландырып сызылган шикелле бантланып торган тулы, кызыл иренәр бер-берсенә кысылган.* М. Әмир.

БАНТУ *и.* Үзәк һәм Көньяк Африкада яши торган һәм үзара кардәш телләрдә сөйләшүче халыкларның гомуми атамасы. *Банту телләре семьялыгы.*

БАОБАБ *и.* Африкада үсә торган бик юан кәүсәле һәм бик киң ябалдашлы агач. *Баобаблар ашарга яраклы җимеш бирәләр, ә сусле кайрылары тупас тукымалар хәзерләү өчен кулланыла.* Дөнья кис. геогр.

БАП I *и. к.* баб.

БАП II *рәв. сир.* Бик ярашлы, таман. *Ите тамагыңа бап, тиресе аягыңа кап, мөгезе пычагыңа сап, эчәгесен аршынга тарт, скрипкәчегә сат* [*кәҗә турында*]. Н. Исәнбәт.

Бап килү, бап төшү — ярап кую, уңай туры килү.

БАПТИЗМ *и.* Христиан диненең бер мәзһәбе (балигъ булган кешеләрне генә чукындыру йоласы белән башка мәзһәбләрдән аерылып тора).

БАПТИСТ *и.* Баптизм мәзһәбендәге кеше.

БАПТИ'СТҠА *и.* Баптист хатын-кыз.

БАР I *хәб. сүз.* 1. Берәр нәрсәнең булганлыгын яки булырлыгын, булып торуын белдерә; *киресе:* юк.— *Калач бармы? — дип сорады Сәмигулла.— Бар,*— [*диде сатучы*]. С. Рафиков. *Бар иде бездә Сафый атлы кеше.* Т. Тукай. / *и. мәгъ. Гомерем булса, онытмамын Җир шарында син барын.* Җыр.

2. Исем фигыльләр белән бәйләнеп, «мөмкин, ихтимал» мәгънәсендә.— *Күрше-коланның әллә нәрсә уйлавы бар.* Р. Ишморат.

3. Фигыльнең *-асы, -әсе* формасына өстәлеп, эшләнергә, башкарылырга тиешлелекне белдерә. *Күрмәгәннең күрәсе бар.* Мәкаль. *Кошкайның көзләр җитүгә Аппагы-баласы бар! Дөньяның шушы хәленнән Гыйбрәтләр аласы бар.* Х. Туфан.

4. *рәв. мәгъ.* **барда.** Булган чакта (очракта), булганда.— *Галиябану кебек кызың барда йөз кияү табып була.* М. Фәйзи.

Бар дип тә белмәү — 1) исәпкә алмау, ис китмәү. *Мәрьям абыстай --- поездларга күптән иярләшкәнгә күрә, аларны бар дип тә белми.* Ә. Еники; 2) санашмау, санга сукмау. *Мин шуңа күрә башка малайларны бар дип тә белмим.* Г. Мөхәммәтшин. **Бар икән** — 1) гаепләүне, гаеп итүне белдерә.— *Бар икән йокыга туймас кеше!* Ш. Усманов; 2) гаҗәпләнү һәм соклануны белдерә. *Ну, көч бар икән соң малның* [*атның*] *үзендә!* Г. Ибраһимов. **Бар итү** — китереп чыгару, булдыру. *Бюрократны кем бар иткән юктан, Кемнәр аны багып үстергән?* Н. Арсланов. **Бары белән** — хәлдән килгәнчә, булганынча. *Бары белән — базар, бары белән — бай.* Мәкаль.

БАР II *и. мәгъ.* Байлык, барлык. *Бар өстенә бар яхшы, бал өстенә май яхшы.* Мәкаль. // Булган кыйммәт, барлык күзгә күренгән әйбер. *Хәзинәмдә бары шулкадәр генә иде шул.* Ф. Әмирхан. / *с. мәгъ. Бар нәрсә балдан татлы.* Мәкаль.

БАР III *а.* Барлык, барча, һәммә. *Илсөяр бар кайгыларын онытып, шат елмаеп куйды.* Г. Гобәй. // Барлык, бөтен.— *Бар ышанычым синдә генә, энекәем.* Ш. Қамал. *Гармонь җырлый яшьлегемнең Бар шатлыгын, бар моңын.* Ә. Ерикәй.

◇ **Бар белгән (булган, торган)**—1) бөтен, җыен; барлык, барча. *Бар булган киемнәрне киеп алдым.* М. Гафури. *Ә Шәйхаттар бабай бар белгән иркә сүзләрен әйтә-әйтә аның* [*атның*] *муеныннан, каш араларыннан сөеп тора иде.* Г. Гобәй; 2) нибары, тик бер.— *Егетләрнең, яшь-җилбәзәкләрнең, беләсең инде, аларның бар белгәннәре кыз гына.* Г. Қамал. **Бар кебек** — бөтен булган, барлык. *Ананың бар кебек шатлык вә өметләре җимерелгән, бигрәк тә Газизә өчен кайгыра, аны кызгана иде.* Ш. Қамал. *Бар кебек кайгыруларым Гел синең өчен генә.* Җыр. **Бар көчкә (хәлгә, тынга һ. б.)** — җан-фәрманга, бик тырышып. *«Соңга калам, ахры!» дип, бар көченә йөгереп Нечкәбил тышкы якка чыкты.* А. Алиш. *Қомлы җил белән уралып, бар хәленә чабып, шәһәрнең бер читеннән эскадрон килеп чыга.* А. Шамов.

БАР IV *и.* Прилавка алдында гына хезмәт күрсәтелә торган кечерәк ресторан. *Кафе һәм барларда сыра чөмереп кәефләнүче бизнесменнар медальонлы кыз --- шәрәфенә бокал күтәрделәр.* Г. Минский.

БАР V *и. физ.* Атмосфера басымын үлчәү берәмлеге (750,1 *мм* терекөмеш баганасы авырлыгына тигез).

БАРАБАН *и.* 1. Төбенә һәм өстенә тире тарттырылган куыш цилиндр — бәрмә музыка коралы. *Якында гына барабан тавышы ишетелде.* Г. Гобәй. *Барабаннар гөрселдиләр, Күк күкрәгендәй була.* Ж. Фәйзи.

2. *махс.* Механизмнарның һәм машиналарның куыш цилиндрдан гыйбарәт булган кисәге; чыгырларда: аркан уратыла торган зур кәтүк рәвешендәге деталь. *Ротордан ерак түгел зур, авыр чыгыр тора. Аның барабанына бик нөхтә итеп корыч аркан уралган.* Нефть тур. хик. // Комбайнда, ашлык сугу машинасында: урылган ашлыкны эләктереп, сугу камерасына җибәрә торган тешле көпчәк яки вал. *Машина калын тавыш белән үкерә башлады, барабан тешләре, ялт-йолт килеп, зырылдап әйләнергә тотындылар. Нәфисә кул астында таралып яткан эре башаклы беренче көлтәне, селкетә-селкетә, барабанга бирде.* Г. Бәширов. // Төрле казаннарда, киптергечләрдә һ. б.: зур диаметрлы труба яки конус формасындагы камера. *Бетон болгаткычларның зур барабаннары әйләнеп тора.* М. Хәсәнов. // Револьверда: патрон кую өчен оялары булган әйләнмәле магазин, соса. *Галләм, тун якаларын ычкындырып, чабу астыннан, кайдандыр иске системадагы барабанлы һәм барабанында алты патроны да булган револьвер чыгарды.* Ф. Хөсни. // Лото, лотереяда һәм башка шундый уен-

нарда: эченә номерлар салып, аларны буташтыру өчен көйләнгән әйләнмәле савыт. *Клубның бер бүлмәсе. Өстәлләр, урындыклар тезелгән. Бер почмакта лото барабаны куелган.* Г. Камал.

Барабан кагу (сугу, бәрү) — 1) барабанга махсус таякчыклар белән бәргәләп, бер тактка дөпелдәтү яки тырылдату. *Каяндыр ерактан барабан кагып, бырғы кычкырткан тавышлар ишетелде.* К. Нәҗми. *Без барабан сугып мәктәпнең икенче бүлмәсеннән җыелыш бүлмәсенә кердек.* Г. Лотфи; 2) *күч.* шакылдау, шакылдату. *Ул [Кожанов], озак кына бер ноктага төбәлеп, өстәлгә бармаклары белән барабан кагып утырды.* Г. Ахунов. **Барабан пәрдәсе** *анат.* — колак эчендә мембрана хезмәтен үти торган яры. *Тавыш юлының түрендә эластик тоташтыргыч тукымадан торган барабан пәрдәсе тартылган.* Анатомия.

БАРАБАНЛАУ *ф.* Барабан суккан шикелле тиз-тиз, еш-еш сугу, дөбердәтү. *Бүген Тимер түбәләрне Барабанлап үтте ак болыт.* Х. Туфан.

БАРАБАНЧЫ *и.* **1.** Барабан кагучы; барабанда уйнаучы музыкант. *Барабанчы, барабанчы, шакы барабан! Октябрятлар, яшь отрядлар, поход баралар.* М. Крыймов.

2. Комбайн яки ашлык сугу машинасы барабанына көлтә биреп торучы. *Барабанчыдан башлап салам вючеләргәчә җанланып киткәндәй булдылар.* К. Басыйров.

БАРА-БАРА *рәв.* **1.** Барышлый, барган вакытта; күп мәртәбә барып. *Уфаларга бара-бара Аягымны талдырам.* Җыр.

2. Тора-бара, бара торгач. *Эшләр, бара-бара нишләр.* Әйтем. *Күп эшләде иренмичә; бара-бара Чыгарды ул [карлыгач] матур-матур балалар да.* Г. Тукай.

БАРАБЫЗ *и. иск.* Авылдан килеп, шәһәр урамнарында артсыз чана белән кеше ташып йөрүче. *Шәһәргә барабызлар килеп тулды — кыш җитте дигән сүз.* Г. Иделле. *Почмактан тырпайган мыеклы околодочный килеп чыкты. Аның артыннан җигүле барабыз чанасы күренде.* К. Тинчурин.

БАРАБЫЗЧЫ *и. иск. к.* барабыз. *Чана юлы төшүгә, атлыларның --- зур гына күпчелеге, сукага хәтле ат асрап чыгу өчен, Казан урамнарында барабызчы булып йөргә ашыгалар.* К. Нәҗми.

БАРАҖ *и.* Тупасрак итеп салынган һәм, нигездә, вакытлыча файдаланыга исәпләнгән күп квартиралы яки бик зур уртак бүлмәле торак йорт. *Кичен урман кисүчеләр барагына Газинур күтәренке күңел белән кайтып керде.* Г. Әпсәләмов. *Барак дигәннәре бер ягы җиргә иңеп кергән --- зур такта каралты икән.* Г. Гобәй.

БАРА'НКА *и.* **1.** Божра рәвешендә камырдан пешерелгән ашамлык. *Баранка пешерү.*

2. Автомашиналарның руль тәгәрмәче.— *Хезмәтеңне гел шофер булып үткәрдеңме? — Шулай булды. Башыннан ахырына кадәр баранканы ташламадым.* М. Шәрифуллин.

◇ **Баранка итеп бөгү, баранка ясау** — 1) кемнән булса да көчтә бик өстен булу турында; 2) каты җәзалау, кирәген бирү. [*Тургаев:*] *китерегез сез миңа аны [Тангатаровны]. Мин аңардан баранка ясыйм хәзер.* Ә. Фәйзи.

БАРА-ТОРА *рәв. к.* тора-бара. *Хәсәннең канаты каерылган коштай каңгыравын күреп, Гөлниса җиңги бара-тора үзе дә тамактан язды.* М. Шабай. *Бара-тора җыелыш гади сөйләшеп утыруга әйләнеп китте.* И. Гази.

БАРБАРИС *и.* Барбариссыманнар семьялыгыннан чәнечкеле куак. *Бакча ышыклау утыртмаларына имән, барбарис һәм дүләнә агачларын утыртырга ярамый.* А. Вәлиуллин. // Шул агачның әче кызыл җиләге. *Барбарис — әмир ярысы — эссе авыруга, эссе бизгәккә, тир сырхавына дәва.* К. Насыйри.

БАРДА *и.* **1.** Сыра түбе.

2. Бөртекле ашлыкларны һәм бәрәңгене крахмалга, чөгендерне шикәргә кайнату калдыгы (мал азыгы сыйфатында кулланыла). *Ифрат, кара айгырын җиктереп, Тараклы спирт заводына барда алу мөмкинлеген белешергә китте.* А. Расих.

Барда пычыргысы — һәрвакыт барда ашату нәтиҗәсендә терлекнең арт аякларына чыга торган чуан (пычыргы).

БАРДАК *и.* **1.** *иск. туп.* Фәхешханә.

2. *күч. гади с.* Пычрак һәм җыйнаксыз бүлмә (яки бүлмәдәге җыйнаксызлык) турында. *Бардакка әверелү.*

БАРЕЛЬЕФ *и. махс.* Стенадан, фоннан яртылаш калкып чыгып торган скульптур сурәт, сын. *Без --- кызыл ташларга уеп ясалган Ленин барельефына тын гына карап тордык.* Г. Мөхәммәтшин.

БА'РЖА *и.* Күп йөк сыйдырышлы яссы төпле судно. *Буксир баржасы. Үзйөрешле баржа.* □ *Нева елгасы кискен рәвештә ага да ага. Аның май, нефть белән зәңгәрләнгән суы өстендә пароход, пароходчыклар, баржалар, моторлы көймәләр арлы-бирле йөреп торалар.* Г. Толымбай.

Баржа тарту *иск.*— баржаларны агымга каршы тартып бару (механик двигательләр булмаган чакларда). *Киң Идел буенда баржа тарттым, Сал өстендә койрык тоттым мин.* Җыр.

БА'РЖАЧЫ *и.* Баржаны карап йөртүче матрос. *Арматур илтә баржалар, Турбиннар илтә; Баржачының төнге җыры Еракка китә.* С. Урайский.

БА'РИЙ *и.* Көмеш сыман төстәге йомшак металл. *Барий оксиды.*

БА'РИН *и. иск.* **1.** Патша Россиясендә дворян, алпавыт, крепостной крестьяннар хуҗасы, шулай ук һәрбер хуҗа, бай кеше. [*Сөләйман:*] *коллык психологиясе!.. Барин шәп... һәммә нәрсә баринныкы яхшы!* Ф. Әмирхан.

2. *күч. сөйл.* Үз-үзен тәкәббер тотучы, үзен хөрмәтләгәнне, үзенә хезмәт иткәнне яратучы кеше турында. [*Касыймхан:*] *Син тәмам барин булдың, Мирзахан.* Т. Гыйззәт.

БА'РИНЛЫК *и.* Бариннарга хас сыйфат(лар). *Мохтар Мутинга [М. Горькийның «Дошманнар» пьесасындагы] Захар Бардин роле бирелде. Ләкин ул бу образның баринлыгын бирә алмады.* Х. Салимҗанов. // Тәкәбберлек, башкаларны санга сукмаучанлык. *Үзәк Комитет язучылар алдында «әдәбияттагы баринлык гадәтләрен бетерү» кебек сугышчан бурычлар куйды.* Х. Госман.

БА'РИННАРЧА *рәв.* Бариннар шикелле, бариннарга охшатып; эре генә.— *Бер чыгып йөреп керәбезме? Бариннарча гына, кесәгә кулны тыгып кына, кеше эшләгәнне карап кына?* Г. Гобәй.

БАРИТ *и.* Ак төстәге бөртек-бөртек кристаллик минерал — барий сульфаты.

БАРИТОН *и.* **1.** Тенор һәм бас урталыгындагы ирләр тавышы. *Ул [Салих] тәрәзә аркылы керер... Кергәч, билгеле инде, Хәятның матурлыгын мактап, баритон тавыш белән җырлар.* Ф. Әмирхан. / *с. мәгъ. Г. Кариев гөрләп торган матур баритон тавышка ия иде.* Х. Сәлимҗанов.

2. Шундый тавышлы артист, җырчы. [*Җырчы*] *Ф. Маннапов — баритон.* М. Җәлил.

БАРКАС *и.* Берничә пар ишкәкле зур шлюпка; күбесенчә порт тирәсендә йөри торган үзйөрешле көймә. *Дулкыннарга биреп корыч түшен, Баркас ашыга эчкә, иркенгә.* М. Җәлил. *Биредә тирән — пароход, буксир, баркаслар ярга якын гына уза.* Г. Гобәй.

БАРЛАМА *и.* Хисапка алынган берәр нәрсәнең барлыгын дөресләү өчен үткәрелгән тикшерү, санау. *Барлама ясау.*

БАРЛАУ I *ф.* **1.** Барлыгын дөресләп тикшерү.— *Баш килгән атларга, батыр калган көрәшчеләргә дип*

җыелган сөлге, тастымаллар, күкәйләр әзерме, аларны барладыгызмы? М. Гали. *Авылдан китәсе көнне кичтән үк Гөлчирә - - - төйнисен төйнәп, барлыйсын барлап куйды.* С. Рафиков.

2. Гаскәри бүлектә яки башка төркем, группаларда шәхси составның тулылыгын аныклау. *Микола, командирның приказын алу белән, тиз генә взводны җыя, тезә, барлый.* М. Җәлил. *Акларны - - - сафка тезеп озатканда Айбакты барлап торды.* Ш. Маннур.

3. Бар итү, булдыру. *Кулмәк тузса, күлмәк барлап була, Җанга нәрсә кирәк — бар да була.* Ә. Ерикәй. *Партия эшчесе авылга барганда киемен рәтли инде ул: аякка күн итек, өскә бер кожан кию — шуларны барлау гына зур нәрсә түгел.* Г. Толымбай.

БАРЛАУ II *и. к.* барлама. *Төн үтеп, яңа көн тугач, безне гадәттәгечә тагын сафка тезеп, барлау үткәрергә булдылар.* М. Әмир.

БАРЛЫ *с.* Маллы, байлыклы; җитеш тормышлы. *Хәлле кеше хәленчә, барлы кеше барынча.* Мәкаль. // *и. мәгъ.* Бай, хәлле. *Барлы — барлы белән, ярлы — ярлы белән.* Мәкаль. *Телгә йозак, кулга кешән ташладылар, Мактамасаң мордар корсак барлы хәлен.* З. Бәширн.

БАРЛЫГЫ *а.* Һәммәсе бергә. *Бу ике полкта барлыгы биш мең кеше бар.* Ш. Усманов. // Барысы да. *Хатын-кызларның барлыгы диярлек көлтә бәйләү эшендәләр.* Ш. Камал.

БАРЛЫ'К *и.* 1. Бар булу сыйфаты, юк түгеллек (берәр нәрсәнең булуы турында). *Тукай үзенең миңа сөйлисе сүзләре барлыгын әйтте.* Ф. Әмирхан.— *Төяп кайтырлык нәрсә бар инде барлыкка.* Ә. Фәйзи. *Кызлар карый ярыктан, Өметләре барлыктан.* Җыр.

2. Байлык, хәллелек; муллык, тәэмин ителгәнлек. *Барлык ярәштерә, юклык чәкәштерә.* Мәкаль. *Сафый уртача барлык — байлык белән тора. Кеше-фәлән белән күп чуалмый.* Г. Гали.

3. Чынбарлык, тормыш. *Өзгәләнә, кайный бөтен барлык, Мин генә тик юаш, тып-тыныч.* Н. Исәнбәт.

4. *лингв.* Әйтелгәннең расланuын яки аның дөреслеген белдерә торган формалар; *киресе:* юклык.

Барлыкка килү — ясалу, яралу, туу.— *Иптәшләр, мин хәзер сезгә дөньяның иң элек ничек итеп барлыкка килгәнлеге турында сөйләмәкче булам.* Ш. Камал.

БА'РЛЫК *а.* Бөтен, һәммә. *Дуслык — кешенең күңелен сафландыра, димәк, ул кешенең барлык башка хисләрен тәрбияли.* Г. Әпсәләмов. *Кызның әйтүенә караганда, сыер саву — дөньяда булган барлык һөнәрләрнең иң авыры.* М. Хәсәнов. // Бөтен булган. *Бу вакыйга барлык халыкны аякка бастырды.* Г. Минский.

Барлык педальләргә басу *сөйл.*— бөтен көчне бирү, бик тырышу (берәр коллектив эш эшләү турында). *Төнге сменада эшләүчеләр, ял итеп килгән иптәшләренә машиналарны тапшырып, бүген барлык педальләргә басарга наказ бирделәр.* И. Салахов.

БАРЛЫКЛЫ *с.* Запаслы, бай. *Барлыклы кеше.*

БАРЛЫК-ЮКЛЫК *и. лингв.* Сүздән аңлашылган төшенчәнең реаль яшәештә булу-булмавын белдерә торган грамматик категория.

БАРЛЫ-КӨРЛЕ *с.* Хәлле, җитеш тормышлы. *Ул көнне солдатларга бу дөньяда үк җәннәт булды. Җомгадан чыгышка байлар, барлы-көрлерәкләр бөтенесен чәйгә алдылар.* Г. Гобәй.

БАРЛЫ-ЮКЛЫ *с.* Бик аз; аз-маз. *Тагын кыш килеп җитә. Хәйретдингә барлы-юклы шул биш-ун тиенне эшләп табарга урын да калмый.* М. Гали. // Бердәнбер һәм начар гына; өзек-тәтек. *Җитмәса, нәкъ шул вакыт үзебезнең барлы-юклы орудиебез дә атудан туктады.* А. Шамов.

БАРМАК *и.* 1. Кешенең һәр аягында һәм һәр кулында нормаль очракта бишәр була торган капшау һәм тоту органы. *Бармак ишарәсе. Бармак озынлыгы. Зиннәт тетрәнгән нечкә бармаклары белән әле төймәсенә, әле күкрәгенә тотына иде.* Г. Бәширов. *Шәмгун, бармагы белән генә әйдәп, мине үз янына чакырып китерде.* Г. Гобәй.

2. Умырткалы хайваннарның аяк, тәпи очларында өч-биш данә була торган тырнаклы әгъза. *Билгеле булганча, тавык дүрт бармаклы. Ә картайган саен бишенче бармак үсә башлый.* С. Рәфиков.

3. Бияләйнең, перчатканың бармакка кидерелә торган өлеше, бармакча. *Ал чукларым, гөл чукларым Перчатка бармагында.* Җыр.

4. Клавиш, тел. *Анда мин беренче мәртәбә пианино күрдем һәм музыка мәктәбенең мөдире күрмәгәндә генә пианино бармакларына баса башладым.* Һ. Такташ.

5. *күч.* Кагылыш, мөнәсәбәт, йогынты турында. *Бу афәтләрне тудырган иблис мәлгуньнең каһәрле бармагы талды.* Г. Ибраһимов. *Зәки яхшыланган, рәтләнгән. «Гөлсем иптәш!» дип сөйли. Гөлсем монда да Фәсхинең бармагы барын күрәсе килә.* Ф. Сәйфи-Казанлы. // Астыртын эш. *Аларның [Бәйдек байларының] бармагы шулай советка каршы тәмәке белән кызыктыруга хәтле барып җитте.* Г. Толымбай.

6. *тех.* Машина һәм механизмнарның йомры таякчык рәвешендәге детале, кисәге. *Сафа: җиде данә цилиндр, йөз илле данә поршень балдаклары, кырык данә поршень бармаклары - - - дип, запас частьларны санап китте.* Х. Госман.

7. Мулине, тамбур җебе кебек җепләрне үлчәү берәмлеге итеп йөртелгән кечкенә киләп. [*Галиябану:*] *Әтигә ике генә бармак тамбур җебе алырга кушсам, орышыр микән?* М. Фәйзи.

Бармак бите — бармак башының тырнакка тискәре, кабарынкы ягы. *Җамал апа тиз-тиз орчык эрли, Төкереп ала бармак битенә.* Н. Баян. **Бармак санаш (санашлы)** — кулдагы бармакларны бөгә барып саналган санамышлы уеннар. *«Бер — бермеш, ике — икемеш...», «бер — бермәк, ике — икемәк...»* яки *«баш бармак әйтә - - -, имән бармак әйтә - - -»* рәвешендә алып барылалар. **Бармак хисабы** — силлабик шигырь үлчәме (унтугыз ижекле юллар). *Безнең төрки телләренең төп хосусияте буенча, бармак хисабы вәзеннәрен тоту белән бергә, Бабичта вәзен туры китерү өчен басымнарны - - - күчерү бөтенләй юк диярлек.* Г. Ибраһимов.

◇ **Бармак арасыннан кысу** — бик чамалап тоту, саранлык күрсәтү. *Сәхап - - - ашлыкны азлап-азлап, бармак арасыннан кысып чыгарып кына - - - тапшыра иде.* С. Рафиков. **(Үз) бармагы аркылы карау** — үзенчә уйлап эш итү, үзе белгәнчә эшләү. *Бөтен нәрсәне үз бармагы аркылы гына карарга өйрәнгән Галимә киңәше Хәлимгә йогармы?* Г. Гали. **Бармак аша карау** — игътибарсыз мөнәсәбәт күрсәтү, игътибарсыз калдыру. *Ул [Шәңгәрәй] эшкә дә хәзер бармак аша карый башлады. Бригадирның сүзен санламады.* М. Җәлил. **Бармак башы** — бармакның иң өске, оч буыны; билгеле бер күләм, зурлык мисалы итеп кулланыла. *Бармак башы кебек борчаклары, Энҗе кебек үскән тарысы.* М. Гафури. *Хәлим - - - ипигә тоз сипте, бармак башы кадәр генәсен сындырып капты.* Г. Гобәй. **Бармак белән санау (санарлык)** — берәмләп санау (санарлык) (аз саилы нәрсәләр турында). *Авыл бәләкәй иде, андагы торак йортлар бармак белән генә санарлык иде.* Н. Фәттах. **Бармак буе (буйлыгы)** — бик кечкенә. *Зыя үзе бармак буе гына булса да, куллары [кубыз уйнарга] бик җиңел килә.* Г. Ибраһимов. **Бармак вату (сындыру)** — бер кул белән икенче кулның бармакларын бөккәләп хәрәкәтләндерү. *Низамов нервланып бармакларын вата.* Ф. Хөсни. **Бармак йөртү (йөрү)** — берәр яшерен йогынты ясау (ясалу). *Соловкига озатырлар дип куркышып торганда, Салахиев кайлардадыр бармак йөртте дә, бай котылып калды.* Г. Ибраһимов. *Бу эшнең нигезендә - - - җылы ояга җыелган кешеләрнең бармаклары йөргәне дә ачык.*

Ф. Сәйфи-Казанлы. **Бармак селкү, бармак янау** — имән бармакны селкеп кисәтү яки куркыту. [*Татар*] *бармагын селкеп, сүгеп: — «Кайтып керерсең өйгә!» — ди.* М. Гафури. *Чжу карт балаларны эшләпәсе белән өркетеп, машинадан куып төшерде, бармак янады.* А. Шамов. **Бармак тешләү** — аптырау, нәрсә эшләргә белми гажиз булу турында. *Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр.* Мәкаль. **Бармак (белән) төртү (төртеп күрсәтү)** — 1) бармакны игътибар ителгән нәрсәгә юнәлдерү. *Мин ул бармак төртеп күрсәткән якка карадым.* Ә. Айдар; 2) *күч.* мыскыллап күрсәтү, берәүнең уңышсызлыгына игътибар юнәлтеп турында.— *Беләм, хәзер бар да бармак төртеп Көлә торгандыр... «Гәрәй — бозау», «Гәрәй — җебегән хатын», Дия торгандыр.* М. Җәлил.— *Инде Фәттахлар, Закирлар миңа бармак белән төртеп күрсәтерләр, рәхәтләнеп авызларын ерырлар...* Ә. Фәйзи. **Бармагы уйнау** — астыртын эш йөртү. *Ул [Янгура] үзе беркайчан да көрәшнең алгы планына чыкмады, әмма һәр җирдә аның бармагы уйнады.* Г. Әпсәләмов. **Бармак чуты** — бармаклар ярдәмендә исәплү ысулы; элементар, кара хисап. *Зур-зур каралтыларны, артезиан коесы кебек катлаулы биналарны бармак чуты һәм күз чамасы белән генә эшләп булмый.* Г. Ахунов. **Бармак шартлату** — 1) бармак буыннарын бөккәләп, характерлы бер аваз чыгару. *Муса --- [биегәндә] бармакларын шартлатып, бөтен түгәрәкне бер мәртәбә әйләнеп чыга.* Ф. Әмирхан; 2) бармакларны шул рәвешле уйнатып, курыкмауны, ис китмәүне, гамьсезлекне белдерү.— *Бу шахтада сикерә-сикерә, бармак шартлатып эшләргә була. Менә җир асты челтәрләнгәч, хәтәргә әйләнә.* М. Гафури. **(Үз) бармагы шикелле белү** — бик якын таныш булу, яхшы белү. *Мин аларны [кулакларны] бармагым шикелле беләм.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Бармагы үзенә таба кәкре** — күбрәк үзе турында гына кайгыртучан. *Менә тагын бер тип — Сибгатуллин. Бармагы үзенә таба кәкре, шәхси интереслар беренче планда.* Г. Иделле. **Бармакка бармак(ны) сукмау** — аз гына да эш эшләмәү. [*Ялкау*] *уңыш көтеп тыныч ятмакта, Бармакны да сукмый бармакка.* Г. Афзал. **Бармакка урарлык та юк (урарга да җитми)** — нәрсәнең дә булса бик аз булуы турында. [*Бикмөхәммәт:*] *Хатыннарның аларның чәчләре генә озын бит, акыллары бармакка урарга да ярамый.* [*Хөппемаһи:*] *Синең үзеңнең бармакка урарлык та акылың юк.* Г. Насрый. **Бармакны авызга кабу** — аптырап яки хәйран калып карап тору турында. *Бу мунчаны күргән һәрбер кеше, гажәпләнүдән нишләргә белмичә, бармакларын авызларына кабып, хәйран булып торырлар иде.* К. Насыйри. **Бармакта биетү (уйнату)** *сөйл.*— үз ихтыярында тота алу. [*Исмәгыйль:*] *Мин Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?* М. Фәйзи. **Бармактан суыру** — уйдырма чыгару, булмаганны бар дип сөйләү яки язу. *Бармактан суырып мәкалә язу.*

БАРМАКЛАНДЫРЫП *ф.* Бармак сыман итеп, тезелгән бармаклар рәвешенә китереп. *Карагалыда тышкы яктан бармакландырып буена сырган, көмеш каптырмалы бишмәт хәзерлиләр.* Ш. Мөхәммәдев.

БАРМАКЛЫ *с.* Бармакка (7 мәгъ.) салынган. *Бармаклы җеп.* □ *Бармаклы мулинене --- кәтүккә урау өчен, башта аны кулга киертеп сүтәләр.* Йорт эшләре.

БАРМАКЧА *и.* 1. Бияләй һәм перчатканың бармакка кидерелә торган өлеше. *Имән бармак өчен, юри шулай иң азакка калдырып, берүзенә аерым бармакча бәйләнә.* Р. Тәхфәтуллин.

2. *сир.* Клавиш, тел, бармак. *Бертөркем яшьләр мәйдан уртасында алка ясаганнар да, сигез бармакчалы гармонь көенә кушылып, вак ташлы җир битен таптыйлар.* Р. Ильяс.

БАРНАГЫЛ, БАРНАУ *и. иск.* Екатерина II заманында Барнагыл (Барнаул) шәһәрендә сугылган бакыр тәңкә һәм шуның кыйммәтендәге акча берәмлеге (Сибер, Урал һәм Урта Азиядә озак вакытлар йөргән). *Эш хакын атлыга өч барнагыл, җәяүлегә ике барнагыл, заводта үз гомеренә эшче булып калучыларга берәр барнагыл артыграк бирәләр.* А. Таһиров. [*Иван Иванович:*] *Әле яңадан бер барнау акча җитми.* Ә. Фәйзи.

БАРО'ГРАФ *и.* Атмосфера басымы үзгәрешен автоматик рәвештә язып бара торган прибор.

БАРО'ККО *и.* XVI—XVIII гасырларда архитектурада, сынлы сәнгатьтә һәм рәсемдә тантаналылык, көчле фантазия һәм динамикалы формалары белән характерлана торган стилистик юнәлеш. *Барокко стилендәге орнаментлар йортка аерым бер горурлык биреп торалар.* Ш. Камал.

БАРО'МЕТР *и.* Атмосфера басымын үлчи торган прибор. *Картадан өстәрәк — барометр. Барометр теле көннәрнең аязга баруын күрсәтә.* М. Әмир. *Әйткән барометр бер заманны: — Мин ясыйм бит, дуслар, һаваны.* Ә. Исхак. // *күч.* Нинди дә булса бер тирәлекнең гомуми хәлен күрсәтә торган предмет турында. *Бу базар --- татар буржуа җәмгатьчелегенең сәяси һавасын алдан белдереп торучы сизгер барометр иде.* К. Тинчурин.

БАРОН *и. тар.* Көнбатыш Европада һәм Балтик буенда король (патша) советы членына бирелә торган дворян титулы һәм шул титулга ия булган кеше (шәхес). *Без аның [Ленинның] сызган юлы белән Тәхетләрне ватып, Таҗларын, корольләрен, Бароннарын утка атып Яндырырбыз.* Һ. Такташ. *Бароннар йорты башына Батраклар байрак кадый.* Х. Туфан.

БАРРИКА'ДА *и.* Шәһәр урамнары аркылы кул астындагы әйберләрдән (бүрәнә, таш һ. б.) корылган хәрби ныгытма. *Халык баррикадаларда кан койган, революция өчен үзенең иң батыр улларын корбан иткән.* И. Гази. *Бик күп йортлар җимерелгән, урамнар баррикадалар белән буылган.* Г. Әпсәләмов.

Баррикаданың каршы ягында — сыйнфый дошман ягында. *Без битараф әдипләрне, бу сыйнфый көрәшкә катнашмаучы «саф» милләтче язучыларны баррикаданың каршы ягында --- рус боярлары белән бер сафта, безгә каршы ак сөңге төзәгән хәлдә күрдек.* Г. Ибраһимов.

БАРС *и. к.* барыс.

БАРСЫ, БАРЫСЫ *а.* Булганның бөтенесе, әйтелгәннең һәммәсе. *Уйлама, күңлем, барсын да, Кайберләре калсын да.* Җыр. [*Насыйрның*] *хатыны, үзе, дүрт баласы — барысы алты җан.* М. Гали.

БАРУ *ф.* 1. Билгеле бер юнәлештә хәрәкәт итү; юнәлешле хәрәкәттә булу. *Алга бару. Поездда бару. Җәяүләп бару.* □ *Туры юлдан бардым ат уйнатып.* М. Гафури. *Яр буйлата бару бик кыенайгач, [солдатлар] аска төшеп, боз өслә бармакчы булдылар.* И. Гази. // Ераклашу, китү; *киресе:* килү. [*Шәйхезаман:*] *Барыгыз моннан!* Т. Гыйззәт.

2. Берәр объектка юнәлү яки шуңа җитү, шуның янына килү. *Калага бару.* □ ***Мәрфуга әби --- тәрәзәгә бара.*** Һ. Такташ. // Кемнең дә булса каршына (катына) килү. *Чикерткә, --- карыны ачкач, күршесе кырмыскага барды.* М. Гафури. — *Нишлисең, чакырган бармый булмый.* Т. Гыйззәт.

3. Нинди дә булса билгеле бер эш башкару максаты белән, берәр якка юнәлү, юлга чыгу яки юл йөрү. *Укырга бару.* □ *Мин хәзер дә барам шул урманга Сандугачлар тавышын тыңларга.* Ә. Ерикәй. // Билгеле бер нәрсәне, мөмкинлекне файдалану максаты белән, шул нәрсәгә бәйләнешле урынга юнәлү. *Кунакка (кунак булырга) бару. Суга (су алырга) бару. Балыкка (балык тотарга) бару.* □ *Бабаң кайткач, --- чикләвеккә барырбыз.* Г. Гобәй.

4. Берәр эшне үтәүне, башкаруны дәвам иттерү. *Николай Степанович Скворцов университетта укуы вакытында бөтен фәннәрдән яхшы барды.* М. Гали.

5. Дәвамлы булу, дәвам итү; үтәлү, башкарылу. *Планетада бүген зур дау бара. Ыгы-зыгы Килеп тора бөтен почмагы.* Һ. Такташ. *Колхоз кырларында һәр килограмм икмәк өчен көрәш барды.* Г. Гобәй.

6. Ярау, килешү; ярарлык яки килешерлек булу. — *Син укытучылык эшен ташла, туган, син аны булдыра да алмыйсыңдыр, аннары бармый да ул сиңа.* Г. Галиев. *Архитектор Сафинның бу полотносы киләчәк берничә ун елларлан соң, дәүләтебезнең экономикасы ныгыганнан соң, барыр да, бәлки.* Ә. Айдар. // *күч.* Билгеле бер ашамлык-эчемлек организм тарафыннан кабул ителү, үтү. *Аш бару.* □ *Ул [Фәрит] бик аз ашады. Аш тамагына бармады.* А. Шамов.

7. Тормышка чыгу. *Иргә бару.* □ *Бармасаң — барасы була, барсаң — баласы була. Баласы булгач, багасы була.* Мәкаль. [*Гали—Зөләйхага:*] *Хәзер генә синең кинәт, минем хатыным булмыйча, икенче кешегә барасыңны ишеттем һәм белдем.* Г. Коләхметов. *Үсә-үсә кызлар зур була, Уз тиңенә бармый хур була.* Г. Сәмитова.

8. Тиешсезне, ярамаганны эшләргә батырчылык итү, тартынмау, кыенсынмау (юклык формасында — кыенсыну, тартыну). — *Ни өчен сез, персонально җаваплы кеше, шундый эшкә бардыгыз? — диде Мөхәммәтҗанов.* А. Расих.

9. *-лык (-лек)* кушымчалы сүзләр белән килгәндә: аерым гадәт, холык, характер галәмәтләре күрсәтү. *Ай, әнем, яшьлегеңә барасың.* М. Фәйзи. *Ферма кызларыннан да берничәсе, чаялыкларына барып, [Хәсәнне] шаяртып каршы алдылар.* М. Шабай.

10. Билгеле бер карашта тору, икърар итү, раслау. — *Димәк, сез Будринны күрмәдем дә, сөйләшмәдем дә дип барасыз инде? — диде прокурор.* А. Гыйләҗев. *Бер як: Ифратка иң каты җәза бирергә кирәк, дип барды, икенче як исә моңа каршы төште.* А. Расих.

11. *боерык ф. форм. кер. сүз мәгъ.* «Шулай ит, шулай эшләп кара» мәгънәсендә. *Бар, кайтып туй яса да, кышка, теләсәгез, парлап килерсез.* Г. Әпсәләмов. // «Һич булдырып булмый» мәгънәсендә.— *Ул юлар хатын кыйбат саттым дип сөенеп йөргән була тагын, алдарсың, бар, Малик карунны.* И. Гази.

12. *хәл ф. форм.* Күчемле яки хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән бәйләнешкә кереп, шул фигыльләрдән аңлашылган эш, хәл, хәрәкәтнең юнәлешле хәрәкәт аркылы башкарылуын, килеп чыгуын белдерә. *Барып алу. Барып килү. Барып килешү.* □ [*Чабышкы ат*] *ычкынып киткән дә улакка салып куйган [салкын] суны барып эчкән.* **М. Гали.**

13. *ярд. ф. функ. Хәл* фигыльләрнең *-ып (-еп), -п* формасы белән бәйләнештә килеп, аларның төп мәгънәсенә түбәндәге төсмерләр өсти: 1) юнәлешле яки нәтиҗәле хәрәкәт төсмере (башлыча хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән). *Чыгып бару. Кереп бару.* □ *Урамнан узып бара, Кашыннан күзе кара.* Җыр; 2) эзлеклелек, дәвамлылык төсмере (күчемле фигыльләр белән). *Габделбасыйр --- үзе сөйләгән нәрсәләрнең һәммәсен хис итеп үткәреп бара.* Ф. Әмирхан. *Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем Була миңа юл күрсәтүче йолдызым.* Г. Тукай; 3) билгеле бер чиккә якынлашу, йөз тоту төсмере.— *Мәхмүзә --- стахановчы булып бара.* Р. Ишморат.. *Кайтып җитә [юлчы] авылга Кояш баеп барган чагында.* Ш. Маннур.

14. *ярд. ф. функ.* Хәл фигыльләрнең *-а (-э)* һәм *-ый (-и)* формасы белән бәйләнештә килеп, аларның төп мәгънәсенә түбәндәге төсмерләр өсти: 1) көчәеп дәвам итү. *Арта бара бүрәнәләр, зурая бара бура.* Ә. Еникәй. *Хәл сәгать саен, минут саен кискенләшә барды.* Г. Гобәй. // *-ганнан... -а, -ый, -гәннән... -ә, -и* парлы формасыннан соң шул ук төсмерне көчәйтеп килә. *Юл начарланганнан-начарлана барып, чиге күренмәгән баткаклыкка әверелде.* К. Нәҗми. *Авылга якынайгаННан-якыная барабыз.* Ф. Хөсни; 2) даими рәвештә кабатланып дәвам итү төсмере. *Дөнья малы — дуңгыз каны, килә бара, китә бара.* Мәкаль. *Һәр ел шулай иген уңа барса, Торырмын мин иркен, байларча.* М. Гафури. *Кар бөртекләре җылы идәнгә төшеп эри бардылар.* Г. Гобәй.

Барып йөрү — махсус атап берәр җиргә бару яки баргалап тору. *Авыл хуҗалыгы машиналарын төзәттерү өчен читкә барып йөрмибез.* М. Гали. **Барып кайту (килү)** — бару һәм кайту (килү). *Туганкаем, Кая барып кайтасың син һәр көн саен?* М. Гафури. **Барып керү** — 1) беркадәр ара үтеп, килеп керү. *Хәят барып кергәндә, Рәхимовларның ялтыратып яктыртылган йорты һәрвакыттагы шикелле шау-шулы, ыгы-зыгылы иде.* Ф. Әмирхан; 2) *күч.* кирәкмәгәнгә яки белмичә йөреп, тик тормау аркасында берәр хәтәргә эләгү. *Имештер, мин бер дә кирәкмәскә әҗәлнең күзенә барып керәм.* Ф. Хөсни. **Барып күренү** — рәсми рәвештә генә, берәүнең үзеңне күрүен үзмаксат итеп, өстән төшерү өчен генә бару. **Барып күрү** — багышлап барып, үз күзең белән күрү, гыйбрәтләнү. *Татарча театрга каршы кешеләр үз кыланышларын шул ук татар театрына барып күрсеннәр.* М. Гали. **Барып чыгу** — 1) берәр урынга юлыгу, тап булу, берәр җиргә җитеп тукталу. *Горький Астраханьга, Каспий буйларына барып чыга.* Г. Нигъмәти; 2) күрешү, хәл белешү, танышу һ. б. максатлар белән берәр җиргә яки берәр кеше янына бару.— *Җиңгәчи, үзегез дә барып чыгыгыз.* Ш. Камал.— *Бер бушрак ара булса, үзем барып чыгармын.* Г. Әпсәләмов; 3) *күч.* уңышлы үтәлү, эшләнү, булдырылу (берәр эш, план, ният һ. б. турында). *Әптери белән Фәтхели б-тотынсын имеш тә, барып чыкмасын имеш.* Г. Гобәй. [*Беркуцкий:*] *Минем композитор булырга хыялым зур иде, тик барып кына чыкмады.* Г. Насрый; 4) *күч.* максатка ирешү, эшне очлап чыгу, булдыру. *Әгәр һаман шулай кызыксынса, моның барып чыга торган малай икәнлеге күренеп тора.* Г. Галиев; 5) *күч.* начарлыкның соң дәрәҗәсенә җитү.— *Ай, энем, энем! Шул әптелмән малаена иярсәң, барып чыгарсың әле.* С. Шакир. **Барып җитү** — 1) билгеле юл, билгеле ара үтеп өлгерү (үтәлү). *Кирәк иде безгә бер сәгатьтән Стансага барып җитәргә.* М. Җәлил; 2) ирешү, билгеләнгән урынга, объектка җитү. *Минем ул хатым барып җиткәндерме, белмим, ләкин мин җавап ала алмадым.* И. Гази; 3) *күч.* өлгерү, атлыгып бару; дәрт-теләк белән барып тотыну. *Кайда мылтык шартласа, ул [Хәйдәр] шунда барып җитә.* Ш. Усманов; 4) *күч.* көчәя барып, билгеле бер ноктага җитү; берәр хәлгә килү. *Фанатик кызганнанкыза барды. Эш таякка барып җиткән иде инде, әле дә ярый, Габдулла тиз генә чыгып өлгерде.* Ә. Фәйзи; 5) *күч.* аңлашылу. *Бу фикер халыкка тиз барып җитте.* Г. Әпсәләмов.

◊ **Барып сугылу** — нәрсәнедер эзләп, аптырап йөргән вакытта, ярдәм өмет итеп һәм очраклы рәвештә генә сайлап, тәвәккәлләп барып керү. *Авыр тойгылар белән мин бу йортның капкасына барып сугылдым.* Ф. Әмирхан. **Барып терәлү** — бер мәгълүм нәрсәгә баглы булып, тоткарланып калу, төп бер мәсьәләгә кайтып калу. *Нәрсә генә эшләргә теләмә, Шул ук атка барып терәлә.* М. Гафури. **Барып тию** — ялгыш берәр кешенең намусына кагылу (әйтелгән сүз, хөкем турында). *Кар, — дисәң, каргага барып тия, тор,— дисәң — торнага.* Мәкаль. **Барып тоташу** — бәйләнешле булу (булып китү). *Татар милли культура тармакларының зур бер өлешенең очы Каюм Насыйригa барып тоташса, икенче зур өлешенең очы, һичшиксез, Галиәсгар Камалга барып тоташа,* М. Гали. **Барып төшү** — бик каты егылу, егылып китү. *Суфьян, атылып, бусагага аркылы барып төште.* Ә. Фәйзи. **Барып эйтү** — барып хәбәр бирү, әләкләү, җиткерү.— *Иртәгә үк волостька барып әйтәм мин бу эшләрне, алай итеп чәчү кампаниясенә аяк чалмасыннар!* М. Гали.

БАРХАН *и.* Чүлләрдә һәм ярымчүлләрдә бик зур дулкын сыман ком өеме. *Барханның җилгә караган — җилгә каршы ягы һәрвакыт сөзәк була.* Физ. геогр. *Яшел киемен кигән дә Постка баскан саксаул, Бархан күчмәсен дигәндәй, Тора гүя сакта ул.* З. Нури.

БА'РХАТ *и. к.* бәрхет.

БА'РЧА *а.* Булган нәрсәнең бөтенесе; әйтелгәннәрнең барысы да. *Әнә Сафин квартирасы. Өр-яңадан барчасы.* Ш. Галиев. *Хайваннарның барчасы да ятып йокыга киткәннәр, ди.* Әкият. // Һәммә, һәркем. *Туй тиешленеке, бәйрәм барчаныкы.* Мәкаль. // Бөтен. *Әрле-бирле тик йөрүдән барча гәүдә сызлана.* М. Гафури.

БАРЧУҚ *и.* 1. *иск. гади с.* Барин яки бай баласы (русларда).

2. *күч. гади с.* Физик эшне сөйми торган бала яки яшь кеше.— *Крестьяннар барчукларны яратмыйлар! — дип кабатлады Әбүзәр абзый.* Г. Әпсәләмов. *Гөлсем апа балаларын япь-яшьтән эшкә күнектерде: «Әйдә, барчук булып үсмәсеннәр әле».* Г. Гобәй.

БА'РЩИНА *и. тар.* Крестьяннарның алпавыт хуҗалыгындагы мәҗбүри һәм түләүсез хезмәте. *Барщина вакытында крестьян атнаның билгеле бер өлешен үзенең җитештерү кораллары белән хуҗа имениесендә, ә атнаның калган көннәрендә үз хуҗалыгында эшләгән.* Политэкономия.

БАРЫ I *а.* Җыелганның бөтенесе һәм булганның барысы да. *Рус юк, яһүд юк, немец юк, татар юк — бары бергә, бары бер юлда.* Г. Ибраһимов. *Кыскасы, авыл тимерчесе нәрсә эшләргә тиеш — барысын да эшлим.* А. Шамов. *Әй, дусларым, җырлыйк әле Барыбыз бергә чакта.* Җыр.

БАРЫ II *терк.* Нибары. *Хәят әле бары уналтынчыда гына булса да, быел кыш ул кинәт үсеп китеп, бүе-сыны белән инде җиткән кызлардан аермасыз булган иде.* Ф. Әмирхан. // Булганның, әйтелгәннең үзе генә. *Җиңү, тик бары җиңү теләге алга ашкындыра мине.* Г. Минский.

Бары тик — ихтимал, мөмкин булганнардан тик берсе генә. *Бары тик иясе читкә күчеп китәсе булганга күрә генә, бу ат бу Түбән авыл кешесенә элэккән, ди.* М. Гали. *Бары тик комиссар Җәгъфәров иптәшне генә онытып бетермиләр.* А. Шамов.

БА'РЫБЕР *рәв.* 1. Каршылыкларга, каршы телэкләргә яки кыенлыкларга карап тукталып калмыйча, ничек тә. *Нихәтле кызгансаң да, барыбер Зөләйха Мостафа хатыны булачак.* Г. Коләхметов. *Әгәр синең яныңа кайталмасам, Барыбер үлмәм, барыбер яшәрмен.* Ә. Ерикәй.

2. Бер дәрәҗәдә, бертөслерәк, бердәй. [*Захаров:*] *Миңа русча ни, татарча ни — барыбер.* С. Рафиков. *Ераклы ни, якында ни — Барыбер сагындыра.* Җыр.

БАРЫМТА *и. тар.* Күчмә төрки кабиләләрдә бер-берсенең көтүләрен әйдәп кайту максаты белән ясалган талау походы. *Барымта карулы, кире кайтарулы.* Мәкаль.

БАРЫНДА *рәв.* Бар чагында, бар чакта; булганда, булган вакытта. *Кайгырма син без барында.* М. Гафури. *Батыр мәйданда ятмас җан барында.* Н. Исәнбәт.

БАРЫ'НЧА *рәв.* Материаль мөмкинлекләрдән чыгып, хәлдән килгәнчә. *Хәлле — хәленчә, барлы — барынча.* Мәкаль.— *Кунакны барынча кадер-хөрмәт итәлсәк, без моңа шатланабыз гына.* Ә. Фәйзи.

БАРЫС *и.* Мәчесыманнар семьялыгыннан урта зурлыктагы ерткыч хайван — Африка һәм Азиядә таралган. *Әйе, бу барыс иде: кара таплар белән сипкелләнгән алмачуар зур ерткыч.* М. Госманов.

Барыс елы — төрки халыкларда һәр елы аерым бер хайван исеме белән аталган борынгы унике еллык циклда өченче ел. *Барыс елны барын чәч, һич булмаса тары чәч.* Мәкаль.

БАРЫШ *и.* 1. Бару, хәрәкәт итү процессы; йөреш, атлау. *Кызның, үзенчә купшы итеп, кәз-кәз басыбрак барышында да күңеллелек сизелгән шикелле булды.* Ф. Әмирхан. // *сир.* Максат белән ясалган сәфәр, чыккан юл.— *Йә, энем, кая барыш, нишләп йөреш?* Н. Исәнбәт.

2. Процесс характеры, башкарылыш. *Тормыш барышы. Эш барышы.* □ *Әңгәмә барышында адреслы һәм адрессыз адресатларга кагылгалап китәм икән, үпкәләштән булмасын.* Г. Галиев. *Биш-алты йөз кешелек отряд, сугышның барышын үзгәртә алмаса да, вокзалны бушатуда зур роль уйнады.* Ш. Усманов.

3. *ярд. ф. функ.* Бару (13 мәгъ.) сүзенең фигыль буларак башкарылу бәйләнешендә торган, ләкин исемләшкән формасы. *Бибинең аттан төшеп чемоданнарын күтәргән килеш өйгә кайтып барышы иде.* К. Басыйров. *Габделгалим — минем танышым. Кырыклардан үтеп барышы.* Г. Латыйп.

БАРЫШ-КӘРЕШ *җыйд. и. сөйл.* Йомыш йомышлап, кайгы-шатлык уртаклашып, бер-беренә кереп йөрү, аралашу. [*Бәдәриянең*] *Бибигөл белән алыш-бирешә, барыш-кәрешә юк.* Ш. Мөдәррис.

БАРЫШЛЫЙ *рәв.* Барганда, барган уңайда. *Кайтып барышлый. Узып барышлый.* □ *Гаяз Гыймади абзый яныннан китеп барды. Барышлый ул бер төркем хатын-кыз янына туктады.* И. Гази. *Чанада барышлый мин бу көтелмәгән хәлем турында уйлап алдым.* Ә. Еники.

БАРЫ'ШНИК *и. сөйл.* Файда калдыру өчен, әйбер алып сату белән шөгыльләнүче, алыпсатар.— *Барышниклар алар, өстәү бирсәң, хатыннарын да алмаштырырлар.* Г. Толымбай. *Һәм ул* [*Хисами*] *нәкъ ат барышниклары кебек шапылдатышу өчен Хәйригә кулын сузды.* Г. Минский.

БАРЫ'ШНИКЛЫК *и. сөйл.* Барышник булу, барышник шөгыле. *Сәлмән карт Сәфәргалине сату-алу һәм барышниклык эшенә җигәргә исәпли иде.* Ф. Хөсни.

БА'РЫШНЯ *и. иск.* 1. Барин кызы, бай кызы (русларда).

2. *гади с.* Җиткән кыз, чибәр кыз, кәләш. *Шамилләрдә вечерда бер генерал кызы — барышня белән белештем.* Ф. Әмирхан. [*Торышым*] *--- барышняларны сәламләп каршылаучы кавалер торышына охшый иде булса кирәк.* К. Басыйров.

БАРЫШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* бару. *Алып барышу.*

2. Бер-береңә кунакка һ. б. йөрешү. *Барышырга, килешергә ят яхшы, Бәла килсә — кардәш булган зат яхшы.* Мәкаль.

БАРЬЕР *и.* 1. Нинди дә булса ныклы комачау: стена, киртә һ. б. *Зур Боз барьеры (Антарктидада).*

2. Арата; бүлмәне бүлеп торган тәбәнәк койма яки рәшәткә. [*Юлчылар*] *дебаркадер барьеры аша һаман әле пароходка сикерәләр.* К. Нәҗми. *Урта бер җиренән такта барьер белән бүленгән бу йортта* [*колхоз идарәсендә*], *барьерның эчке ягында, ачык шкаф алдында хисапчы Вилдан утыра.* Ф. Хөсни.

3. *күч.* Һәртөрле чикли, тоткарлый торган нәрсә. *Гомер озынлыгына биологик барьер йөз ел түгел, бәлки йөз илле-йөз алтмыш ел.* Соц. Тат. // Демократиягә, иҗтимагый аралашуга комачау тудыра торган рәсми законнар, кагыйдәләр. *Ведомство барьерлары. Ценз барьеры.*

БАС *и. муз.* 1. Гадәттә ирләргә хас калын тавыш. *Әнә шул тынлыкта әлеге малахай бүрекле, килешсез зур гәүдәле кешенең бас тавышы яңгырады: — Сөйлә, Касыйм дус!* Ф. Хөсни. // Күп төрле тавышлы музыкаль әсәрдә иң калын тавыш.

2. Бас тавышлы җырчы турында. *Хорның беренче басы.*

3. *махс.* Калын регистрлы музыкаль инструмент яки

музыкаль инструментның калын регистрлы клавишлары. *Гармонь баслары.*

БАСА *и.* 1. Аксыл башлы, нәзек сабаклы киндер (киндернең орлык бирми торганы — ир чәчәклесе). *Баса сүсе.* □ *Ата даны белән кыз китә, баса даны белән сус китә.* Мәкаль. *Киндер арасына кереп --- киндер басаларының бик шәпләрен генә йолыктык та, аларның сусләрен салдырырга тотындык.* Г. Галиев.

2. *диал.* Киндер (үсемлек).— *Җәйгә чыксаң, баса җебетергә, җитен чылатырга тилмереп торасың: су табып булмый...— диде бер ак сакаллы карт.* И. Гази.

БАСАМЫҚ *и. диал.* Баскыч киртләче, басма. *Мавзолейның баскычына аяк кую белән баш киемнәре салынды. Керү белән, сул якка борылып аз гына баргач, берничә басамык аска төшелә.* М. Фәйзи.

БАСҠАҚ *и. тар.* Алтын Урда ханының биләмә өлкәләрдәге урынбасары; ханга ясак җыеп тапшыручы отряд башлыгы. [*Сәхилә — Зөбәржәткә:*] *Ссс! Акылыңдамы син? Кычкыр тагын ныграк! Сине Гыймай баскак килеп тотсын да Җиһангиргә алып китсен.* Н. Исәнбәт.

БАСҠЕТБОЛ *и.* Махсус тупны каршы якның терәк башындагы тактага беркетелгән төпсез кәрзиненә күбрәк ташлау буенча ярышуга корылган командалы спорт уены. *Баскетбол мәйданчыгы. Баскетбол тубы.* □ *Футбол --- инглиз сүзе, «аяк-туп» дигән сүз. Волейбол — «кул-туп», «баскетбол — «кәрзин-туп» була.* Г. Мөхәммәтшин.

БАСҠЕТБОЛЧЫ *и.* Баскетбол уйнаучы спортчы. *Әгәр дә безнең баскетболчыларның буйлары ике метр ярымнан да ким булмаса, аларны беркем дә җиңә алмас иде,— ди Яша.* Ә. Бикчәнтәев.

БАСҠЫН *и. тар.* 1. Тыныч илгә, кабиләгә һ. б. (күбесенчә талау нияте белән) ясалган һөҗүм.— *Өч пәһлеван һәрвакыт Ала малымны тартып. Тагын алар иртәнчәк Баскын ясап китәчәк.* Ш. Маннур. *Һиндстан чит ил баскыннары тарафыннан күп мәртәбә талана.* М. Мәхмүтов.

2. *диал.* Баскынчы. *Ленинград һәм Калинин өлкәләре тулысынча диярлек фашист баскыннардан азат ителде.* Г. Әпсәләмов.

БАСҠЫНЛЫҚ *и.* Изү, кысу, золым. *Моннан соң, билгеле, реакция баскынлыгы, жандарм, урядниклар кысрыклыгы башлана.* Ш. Камал.

БАСҠЫНЧАК *диал. к.* басымчак. *Безне --- бөтенләй баскынчак иттеләр инде.* Э. Касыймов.

БАСҠЫНЧЫ *и.* Талау-басу белән шөгыльләнүче зур масштабтагы бандит, илбасар. *Фашист баскынчылары.* □ *Болгар шәһәре монгол баскынчылары тарафыннан туздырылгач, зур базар озак еллар җыелмаган.* И. Рәмиев.

БАСҠЫНЧЫЛЫҚ *и.* 1. Баскынчы булу, баскынчы шөгыле. *Баскынчылыкта йөрү.*

2. Талау-басу, илбасарлык. *Урам башында быргы унайла. Ат тояклары, кыргый сызгыру, баскынчылык тавышлары якынлаша.* Н. Исәнбәт. // Стихияле кузгалыш, бунт. [*Бакый:*] *Узем кебек егетләр белән байларга каршы баскынчылык итсәм, миңа шул күңелле.* М. Фәйзи.

БАСҠЫЧ *и.* 1. Гадәттә бер пар янәшә терәк бүрәнәгә, тактага яки арканнарга һ. б. ш. беркетеп тезелгән араталардан, басмалардан торган менү-төшү җайланмасы. *Хизбулат, каяндыр баскыч алып килеп, печәнлеккә менеп тә китте.* Г. Ахунов. *Кыяларга менү өчен баудан баскычлар иштек.* И. Гази. *Шмит хисапсыз күп басмалардан торган текә агач баскыч буйлап --- Иделгә таба төшеп китте.* А. Расих. // Менү өчен бер басмалы җайланма. *Газинур бүрәнәләр төяп узып баручы автомашиналарның берсенең кабина баскычына сикерде дә борылышта күздән югалды.* Г. Әпсәләмов.

2. Баскыч басмасы сыман киртләчләнеп торган рельеф; җир киртләче, терраса. // Текә битләүгә менә торган сукмакның киртләчләнгән өлеше. *Миннәхмәт --- язгы көзге тайгакларда киртләп баскычлар ясар иде.* М. Хәсәнов.

3. *күч.* Үсү, күтәрелү дәрәҗәсен билгели торган бүленешнең бер өлеше. *Хәлим укый торган икенче баскыч мәктәп белән Тубал йөри торган беренче баскыч икесе ике бинада.* И. Гази. // Үсеш, күтәрелешнең аерым бер өлеше дип хисапланган вакыйга, чор, стадия. *Кәбир әфәнде «Мәгарифне» инде үтелгән баскыч, шәкертлек мавыгуы дип кенә карый.* Ә. Фәйзи. *Әйе, безнең халыкларның тормышында зур тарихи үзгәрү, яңа баскычка күтәрелү процессы бара.* Соц. Тат. // Катлаулану, кыенлашу дәрәҗәсе. *Икенче баскыч гамәлләрне сулдан уңга таба, язылу тәртибендә эшләү кабул ителгән.* Арифметика.

БАСҠЫЧ-БАСҠЫЧ *с.* Күп киртләчле, күп террасалы. *Исән калсын сусыз-парсыз мунчаң, Баскыч-баскыч коры элүкән.* М. Җәлил. / *рәв. мәгъ. Баскыч-баскыч булып түбәнәя барган тауларның маңгайлары шәрәләнгән.* М. Шәрифуллин.

БАСҠЫЧЛАНУ *ф.* Эре киртләчләр ясалу; эре киртләчле булып тору. *Өч яклап тезелгән таулар, катлау-катлау баскычланып, югары болытларга сузылалар.* Г. Ибраһимов. *Дача турысындагы яр да алангач түгел: ул амфитеатр шикелле баскычланып-баскычланып күтәрелә.* Х. Садрый.

БАСҠЫЧЛАУ *ф.* Киртләчләү яки басмалар ясап тезү, киртләп казу, баскыч сыман итү. *Бер-берсеннән югарырак менгезеп, баскычлап беркетелгән такталар өстендә кешеләр тезелешеп утыралар.* Ә. Фәйзи. *Баскычлап җир астына чокып кергән һәм стеналарын буралап ныгыткан киң генә землянкадан Галләм хаҗиның байтак кына яшергән ашлыгын табып чыгардылар.* Ф. Хөсни.

БАСМА I *и.* 1. Баскычның басып менә торган аратасы яки киртләче. *Бер адәм килде дә шул чакта әйләнderде баскычны. Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.* Г. Тукай. *Бормалы баскычның биш йөз дә егерме җиде басмасы бар икән.* И. Гази.

2. Өйалды баскычы. *Басма астында бала үрдәк, Сибик бодай, симерсен.* Җыр. // Басып яки утырып тору өчен бер генә тактадан торган җайланма. *Көймә басмасы.* □ *Трактор кыр буенча чәчү машиналарын өстери. Орлык тутырылган ящикның артындагы басмада — чәчүчеләр.* И. Салахов.

3. Су кырыеннан эчкәрәк кереп басып торырга (йөрергә) уңайлы булсын өчен махсус ясалган, корылган күперчек. *Пароход тавышын ишетү белән, паром туктый торган зур басма тирәсендә кешеләр чабып йөри башладылар.* М. Гали. *Ак беләкле кызлар* [*Агыйделнең*] *ярларында Басмаларга басып кер уган.* Г. Афзал.

4. Җәяүләләр генә йөрерлек итеп эшләнгән һәм гадәттә озын булмаган тар күпер. *Авыррак сәякле Мисбах басма аркылы чыкканда суга егылып төшә язды.* Г. Әпсәләмов. *Агыйделгә басма салдым, Басма салдым— киң такта, Салмас идем дә киң такта, Сөйгән ярым шул якта.* Җыр.

5. Биналар яки корылмалар, зур кораблар төзегәндә төзүчеләргә басып эшләү өчен ясалган ярдәмче коңылма. *Ул* [*Нуруллин*] *буш вакытларда төзелеш басмаларының иң югары күперенә менәргә, шуннан торып тирә-юньне карарга ярата.* А. Шамов.

6. Клавиш, музыкаль инструмент теле. *Гармоньчы егетнең бармаклары гармонь басмаларында илмәшәп-алмәшәп биештеләр.* Т. Госман.

БАСМА II *и.* 1. Китап һ. б. басу эше яки процессы. *Басмага бирү. Басмадан чыгу* (китап турында). □ *Казанда кулъязмадан басмага күчү уе унсигезенче йөз азагында туа.* И. Рәмиев. *Бәхзит карыйдан җилем басма өйрәнгән идем, беркөн тоттым да --- бикләнеп баса башладым.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Бастырып чыгарылган. *Үзе язган әйбернең басма китап рәвешендә чыгуы Габдуллада «мөхәррирлек» горурлыгы тудырып*

өлгерде. Ә. Фәйзи. *Абыстай кулъязма һәм басма документлар чыгарып салды.* Ф. Әмирхан.

2. Берьюлы бер комплектка кертеп бастырып чыгарылган яки бастырып чыгарырга билгеләнгән текст. *Большевиклар бик күп төрле җыентыклар, арзанлы китапханә басмалары һәм брошюралар бастырып чыгаралар иде.* СССР тарихы. // *сир.* Вакытлы матбугат төрләре. *Еллык басма. Айлык басма.* // Әсәрнең (җыентыкның, җыелманың) бер мәртәбә басылышы. *«Бәхетсез егет»нең беренче басмасы белән икенче басмасы арасындагы кебек, «Өч бәдбәхет» белән «Уйнаш» драмалары арасында да үзгәрешләр бар.* М. Гали. *Әбүзәр абзый --- театр китаплары кибете тәрәзәсендә Шаляпинның яңа басмасын күрә.* Г. Әпсәләмов.

3. Киндергә, бүзгә басып төшерелгән бизәк; шундый бизәкле тукыма. *Басма төшкән бүз.* □ *Ачылыр ла кибет, ачылыр, Бохарларда басма басылыр.* Җыр.

Басма сүз — матбугатта чыккан, матбугат авторитеты белән файдалана торган фикер, хөкем яки хәбәр. *Матбугатта Лев Толстойның вафатына дүрт ел тулу көне билгеләп үтелде һәм ул аерым очракларда сугышка каршы басма сүз әйтеп калу өчен бер җай булды.* Х. Госман. **Басма табак** — китап, газета-журнал бастыруда кулланыла торган стандарт зурлыктагы кәгазь табагы. *Беренче әлифбаның күләме ярты басма табак була.* И. Рәмиев. **Басма хәреф** — язу баса торган, типографиядә, басмада кулланыла торган хәреф. *Шәяхмәт, чираттагы мәкаләнең башын басма хәрефләр белән әйбәтләп язгач, озын эскәмиянең читенә барып утырды.* С. Рафиков.

БАСМА III *и.* Басма (бизәк) төшерү, шулай ук чәч, каш һ. б. ны буяу өчен кулланыла торган махсус буяу. *Фойеда кына һәм басма, ләпес һәм перекись белән буялган чәчләр.* Ш. Хөсәенов.

БАСМА IV *и.* **1.** Ике чөй арасында атлатып чорналган киләп; киләпкә салынган җепне үлчәү берәмлеге (гадәттә җиде карышлы киләп агачына алтмыш бөртек, ун карышлы киләп агачына кырык ике бөртек салынган җеп). *Сал киләпкә, санап рәткә, Тигез сана басмасын. Таралмасын җепнең очы — Нык бәйли күр тасмасын.* З. Байчурова.

2. *иск.* Тукыма үлчәме — буйлыгына нинә басма җеп керүе буенча үлчәнгән киндер һ. б. *Биш басма бүз.*

БАСМАК *и. сир.* Гармун һ. б. музыка коралларының теле, клавиш. *Гармунчы Коля алдына эре ак басмаклы аккордеон китереп куйдылар.* Н. Фәттах.

БАСМАЛАП *рәв.* Басмалар (1 мәгъ.) берәмлегенчә. *Баскычка берәр басмалап менәләр.* Мәкаль.

БАСМАХАНӘ *и. иск. к.* типография. *Бик мөһим сәхнә әсәрләре басмаханәдә нәүбәт көтәләр.* Г. Ибраһимов. *«Шаһмаран» һәм «Сал-сал» исемле дастаннар Казан университеты басмаханәсендә басылып чыга.* И. Салахов.

БАСМАЧА *и.* **1.** Кечкенә, тар гына басма; көймә утыргычы. *Кунаклар, ашханәнең рәшәткәле балконнарына карап, буяулы басмачалардан төштеләр.* М. Шәйми. *Нәҗип, ишкәкләре белән мавыгып, Санияне онытkан иде. Сания, кызларга гына хас бер тыйнаклык белән, күлмәк итәкләрен җыештырып, басмачада утырып килә.* Г. Ахунов.

2. Елга, күл читендә су ала торган басма, күперчек. *Басмачага килеп кереп, Зифа буен бөгелдереп, Көянтәсен сыгылдырып Ак чишмәдән сулар алса — Шундук гашыйк булырсың.* Ш. Маннур.

БАСМАЧЫ *и.* Урта Азиядә Совет властен урнаштыруга каршы контрреволюцион фетнәдә катнашкан баскынчы. *Семиречье фронты өстенә, хәзер Ферганәдә безгә каршы басмачы фронты күтәрелергә тора.* Ш. Усманов.

БАССЕЙН *и.* **1.** Ясалма зур сулык (күл), сусаклагыч. *Бассейнга су тутыру.*

2. Елганың барлык кушылдыкларының яки берәр күлгә, диңгезгә һ. б. агып төшә торган барлык елгаларның су җыю территориясе. *Елганың туенуы елга бассейны мәйданыннан --- җыела торган су хисабына бара.* СССР физ. геогр.

3. Билгеле бер файдалы казылма күп булган географик өлкә. *Донбасс күмер бассейны. Волга — Урал нефть бассейны.*

БАСТИОН *и. хәрби.* Биш почмаклы итеп корылган ныгытма, кечкенә форт. *Иң яхшы хәрби инженерлар тарафыннан салынган немец бастионнары безнең полкларның ярсулы һөҗүмен туктата алмады.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Көрәш мәйданында төп терәк, төп ышаныч. *Барлык континентларның хезмәт ияләре Совет Социалистик Республикалар Союзын кешелек дөньясының маягы һәм авангарды дип, тынычлык һәм прогресс бастионы дип атыйлар.* Соц. Тат.

БАСТРУК *и. иск.* Гадәттә шәһәрдән читтә салынган һәм биек койма белән уратылган төрмә. [*Кызбикә:*] *Бер-бер хәл булып, үземне баструкка ябып куймасыннар тагы.* М. Фәйзи. *Сәхибәнең кара кашы Ай кебек кыйгач матур, Шул кыйгач кашлары өчен Баструкка китте, бахыр.* Бәет.

БАСТЫРМА I *и. диал.* Салам, печән өемнәрен яки салам түбәне басылдырып тора торган агач. *Таш астында кәлтә, кибән астында тычкан, бастырма астында чыпчык* [*үлми*]. Мәкаль.

БАСТЫРМА II *с.* Бастырып, үрә торгызып куела торган. *Бастырма яка.*

БАСТЫРМАЛЫК *и.* Бастырма агачы, бастырма ясауга китә торган агач. *Шәрәфи белән Зәйнулла --- сап-сары саламнар белән кибән өсләре ябалар, әвеннәр куялар, себерке бәйлиләр, бастырмалыклар юналар.* Г. Галиев.

БАСТЫРУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* басу II. *Себермәгән идәнгә бастырмам, өрмәгән җиргә утыртмам.* Әйтем.

2. Басып торган хәлгә китерү. *Егылганны аякка бастыру.* // Озынча яки аяклы берәр нәрсәне вертикаль торышка кую. *Багананы (өстәлне) бастырып кую.* □ *Арбага ике яклап тезелешеп утырган егетләрнең бастырып тоткан чалгылары ара-тирә чагылып киткәли.* Ә. Еники.

3. Җиңел нәрсә таралып яки очып китмәсен өчен, өстенә авыр әйбер салып кую, бастырыклау. [*Габденасыйр*] *умарталарның башларына юан агач кабыгы ябып, аларның кайберләрен ак таш белән --- бастырып чыкты.* М. Гали. // Өстенә авыр әйбер кую. *Ниндидер бер явыз кара таш белән бастырып киткән — орлыкларым вакытында чыга алмый калганнар. --- томаланып черегәннәр.* Г. Ибраһимов.

4. *иск.* Таптату, бөртекле ашлыкны башак яки бәрчәдән төшерү өчен, көлтәләрне таратып җәеп, өстеннән ат яки үгез йөртү. *Без көн буенча басуда тары бастырдык, мин көн буенча ат куладым, салам кагыштым.* М. Гафури. *Ашлыгымны бастырдым, Хәйран уңган ашлыгым.* М. Җәлил.

5. *сөйл.* Үтүкләү, өтеләү. *Шул арада үтүк кыздырып, Хәсәннең күлмәкләрен бастырып алырга да өлгергән иде Сания.* М. Әмир. // Пресс белән кысу.

6. *к.* басу II (24 мәгъ.). *Иң актыкта Солдат торып, болай да якты янмаган лампаны азрак бастырды һәм авыз эченнән нәрсәдер укый-укый иске шинелен башыннан үк ябынып ятты.* Ш. Камал. // *күч.* Эчке кичерешләр, тойгыларны тынычландыру турында. *Агыйделнең --- салкын сулары белән янган йөрәкләремне бастырдым.* Г. Ибраһимов.

7. Көч кулланып берәр каршылыкны җиңү. *Восстание бастыру.* □ *Һәммә карендәш-ыру җыеп, Мине бастырдылар тыеп.* Г. Кандалый. *Родимцев дивизиясе полклары, дошманның каршылыгын бастыра-бастыра, акрынлап Харьковка таба баралар.* Каз. утл.

Бастырып килү — !) таптардай булып ташлану.

Беркөнне ул [*Петя*] *туп-туры Асылгәрәй өстенә бастырып килде.* М. Шабай; 2) арттан куа килү.

БАСТЫРЫК *и.* **1.** Салам, печән кебек йөкләр таралмасын өчен, өстән бастырып куела торган агач. *Бастырык салу.* □ *Бауны тарткан саен, бастырык арба өстендәге көлтәләрне кыса.* З. Бәшири. // Бастырма. *Хәнәфи --- кибән астына барып ауды. Аның өстенә --- бастырыклар, чошлар, салам көлтәләре ишелделәр.* Қ. Нәҗми. *Айдар бабай баскан әнә ферманың түбәсенә, Япкан да алтын саламны, бастырыкларны тезә.* С. Баттал. // Нәрсәне дә булса бастырып тора торган авырлык. *Җир бастырыгы — тау, тау бастырыгы — таш.* Мәкаль.

2. Баш-башы капка яки ишек кыстыргычларына тыгыла торган агач — бикнең бер төре. *Клим, кире кереп, капкага бастырык салды, үзе койма аша сикереп төште.* Г. Гобәй. *Билгеле җирдән кәкре башлы кәшәкә таягын алып, өйалды ишегенең эчтән салынган бастырыгын төшердем.* Ф. Хөсни.

Бастырык бавы — йөк өстенә салынган бастырыкны арба-чанага тарттырып бәйләү өчен кулланыла торган ыргаклы бау. [*Нәби*], *бастырык бавына эләктереп куелган сәнәкне алып, як-яктан төрткәләп куя.* Р. Төхфәтуллин.

БАСТЫРЫҚЛАУ *ф.* **1.** Бастырык (1 мәгъ.) яки башка авыр нәрсә белән бастырып кую. *Хисамук --- салам алып килде, биек иттереп минем арбама өйде, аннан соң: — Моны бастырыкларга кирәк инде,— диде.* З. Бәшири.

2. Ишек яки капкага бастырык (2 мәгъ.) салу. [*Мәрьям*] *капканы нык итеп бастырыклады.* А. Расих.

БАСТЫРЫҚЛЫ *с.* **1.** Бастырыгы булган; бастырыкланган. *Бастырыклы йөк.*

2. Бастырык белән бикләнгән. [*Жандармнар*] *мәктәп капкасының бастырыклы икәненә хәтле белгәннәр.* Г. Гобәй.

БАСТЫРЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* бастыру (2—3 мәгъ.).

2. Саташулы һәм буылулы төш күрү. *Ач — төшендә оча, тук — төшендә бастырыла.* Мәкаль. *Солтангәрәй төне буе рәтләп йоклый алмады, ниндидер куркыныч төшләр күрде, саташты, бастырылды.* Ш. Еникеев.

БАСУ I *и.* Культуралы үсемлекләр үстерелә торган җир мәйданы, иген кыры. *Игеннәре өлгереп килә торган басуны нәрсә белән генә чагыштырырга мөмкин!* Г. Әпсәләмов. *Көн шундый якты, күк йөзе шундый зәңгәр, арыш басуы шундый матур дулкынлана.* И. Гази. // Иген кырының игенчелек культурасы системасында махсус билгеләнгән аерым өлешләре. *Үлән басуы. Пар басуы.* □ *Фәсхи ипташ килгәнче, совхоз, әти-бабайдан калган юл белән барып, өч басудан котыла алмый иде. Хәзер алты басуга күчеп бетәбез инде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

Басу капкасы — авылдан кырга чыгу юлларында корылган капка, кыр капкасы. *Басу капкасын чыккач та, Уңга киткән юл булыр.* Җыр. **Басу каравылчысы** — игенле басуларны янгыннан, мал-туардан, кош-корттан саклау эше йөкләтелгән кеше. *Шулай да басу каравылчысы Фәхри картның абруе белән исәпләшми торган бер оя тинтәк каз бар.* Ф. Хөсни. **Басу киртәсе** — авылны һәм авыл тирәсен иген басуыннан аерып торган һәм ашлыкларны мал-туардан саклау өчен тотылган киртә. *Авыл чите. Уң якта басу киртәсе һәм кыр капкасы күренә.* А. Алиш. **Басу юлы** — басуларга барып йөрү өчен яки басулар аркылы салынган таррак гади юл, кыр юлы. *Көз үзәге җиткәндә аяк аслары кипте, пыяла кебек шома сукмаклар, басу юллары төште.* Г. Галиев.

БАСУ II *ф.* **1.** Аякка калкыну, вертикаль хәлгә килү. *Искәндәр аяк астына төшкән таягын алып бәсте.* Л. Гыйльми. // Аяк өстендә тору. *Казлар бер аякларына гына басып --- ары-бире карангалыйлар да карга утыралар.* Һ. Такташ. *Сарай хадимнәре кайсы утырган, кайсы баскан.* Ф. Бурнаш. // Берәр билгеле урында тукталып, аяк өсте тору. *Закир сәхнәгә менеп басты.* Ш. Қамал.

2. Гадәттә аягүрә торыла торган билгеле бер җирдә (эштә, шөгыльдә һ. б.) урын алу. *Сафка басу. Чиратка басу.* □ *Туган илнең тыныч сулышын тыңлап, Мин постыма тагын нык басам.* Ә. Ерикәй. // *күч.* Берәр йөкләмәне, функцияне үтәүчеләр яки аерым бер группа тәшкил итүчеләр рәтенә керү. *Хезмәт вахтасына басу.* □ *Тырыша-тырмаша торгач, Галиулла урталар рәтенә басты.* И. Гази. *Аңа* [*Дияровка*] *начальство янына әңгәмәгә барырга һәм партия учетына басарга кирәк иде.* Г. Ахунов.

3. Аякны кую, адым ясау. *Бәхетсез ат басмам дигән төшнең уртасына баса.* Мәкаль. *Бер адым алга басам да, әйләнәм мин артыма: Қайда басканнар икән дип, Күз саламын халкыма.* М. Гафури. // Адымлау, атлау. *Бер аяктан басу.* □ *Акрын гына басып, карана-карана сакланып кына Хәлил керә.* М. Фәйзи. *Егетне интектермәде солдат җәфасы гына: — Раз! Два! — санап торалар, шуңа басасы гына.* С. Баттал.

4. Бию адымы ясау; бию. *Матур басып биегәннәр Өзәләр бит күңелне.* Җыр. *Коңгырт чәчле абый уртага сикереп чыкты да бөтерелеп биеп тә китте. Әмма басаг Аякларына күз иярми.* Р. Төхфәтуллин.

5. Ритмик хәрәкәт белән көч салып эш башкару. *Күрек басу.* □ *Өргечне баса кил, зур чүкечне ала кил.* Қ. Нәҗми. *Пожар насосының баш-башына икешәр кеше корсаклары белән ята биреп, тырышып-тырышып баса башладылар.* Ф. Хөсни.

6. Изү, изеп үзле итү, аралаштыру (камыр, балчык шикелле массаларны). *Мөнирә гөлләргә су сипте, бүлмәләрне җыештырды, чумар пешерер өчен, камыр басты.* Г. Әпсәләмов. *Яшьләр --- саман баса башладылар.* И. Салахов.

7. Бастыру (4 мәгъ.). *Басма басу. Көлтә басу.* □ *Җүнәйгә барып ашлык баса башладык.* М. Фәйзи.

8. Махсус ысуллар белән әвәләп, йон массасына яки йон тукымаларга кирәкле форма һәм тыгызлык бирү. *Қайдадыр шунда, Казан шәһәрендәме, киез итек басалар, ди, анда малайлар да эшлиләр, ди.* И. Гази. *Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли Өмәләрдә тула басабыз.* Җыр.

9. Бала чыгару чорында йомыркалар өстендә утыру (кош-корт турында). *Басасы килмәгән казга оя тар.* Мәкаль. *Урдәк йомыркасын тавык басар, бәбкәсе суга качар.* Мәкаль.

10. Берәр яссы нәрсә (мәсәлән, уч) белән каплап тору, каплап кысу. *Зифа, сикереп торып, колагын басып йөгерә.* М. Фәйзи. *Губернатор, бер кулын телефон трубкасына баскан килеш, командующийга сорау бирде.* Қ. Нәҗми. // Берәр нәрсәне яссы ягы белән билгеле бер урынга, төшкә китереп кысу. *Җәрәхәткә мамык басу.* □ *Ул* [*Шәрәфи*] *тиз генә тозга басып икмәк катысын капгы.* Ш. Қамал. *Дошман тәнгә кызу тимер басты.* М. Гаяз.

11. Язуны яки рәсемне кәгазьгә, материягә һәм башка өсйөзләргә махсус җайланмалар (печать, штамп яки басу машинасы) ярдәмендә тиз генә төшерү. *Ике карт тамга салды, староста мөһер басты.* Г. Ибраһимов. *Көн дә кичен эш беткәндә Кесәләргә хәреф тутырдык. Күп чагында Шушы таныш җирдә Өндәмәләр басып утырдык.* М. Крыймов. *Хисмәт Кәримовның рәсемен дә Газет уртасына басканнар.* Ш. Маннур. // *күч. гади с.* Чигү, каю. *Тамбур басам ефәкләргә, Сөйгәнемә дигән сөлгегә.* Җыр.

12. Өсйөзгә, ноктага авырлык яки көч белән тәэсир итү, басым ясау. [*Бикбулат*] *челемен чыгарды, бармагы белән баса-баса аңа тәмәке тутырды.* Г. Бәширов. *Сабитов --- замазканы кулына алды да бармагы белән*

баскалап карады. Г. Ахунов. // Тыгызлау. *Капчыкны басып тутыру.*

13. Авырлык яки көч белән озак вакыт тәэсир итеп гарипләндерү, имгәтү, чиләндерү. *Уникe кадаклы мылтык Басар иң иңнәремне.* Җыр. *Атларның күбесенең муеннарына камыт тигән, җилкәләрен ыңгырчак баскан.* Г. Галиев.

14. Таптап яки өскә егылып, өскә ишелеп имгәтү. *Бүрәнәгә басты бүдәнә, бүдәнәне басты бүрәнә; бүрәнә дә гаепле, бүдәнә дә гаепле.* Мәкаль. *Гомерем булса, таш басмасә, Ташламам, җан кисәгем.* Җыр.

15. Ию, бөгү, түбәнәйтү. *Әтинең бу сүзләрен ишеткәч, башымны түбән бастым.* М. Гафури. // Тәбәнәкләндерү; түбәнрәк төшерү. *Минһаж, колаклар туңмасын дип, бүрекне басты.* Г. Ибраһимов.

16. Үлчәүнең ике ягына салынган нәрсәләрнең бер ягындагысы авыррак тартып, аскарак төшү. *Басып төште герне алтын бодай, Үлчәнгәндә хезмәт көннәре.* Ш. Мөдәррис.

17. Көчлерәк карта белән каплау, ябу (карталы уенда). *Менә крест тугызлысы. Менә сиңа валет, аны баса.* Л. Гумеров.

18. Арттан куа килү, куып җитеп узып китә язу. *Тагын тавыш купты: — Сабир коласы! — Җирән баса! — Түбән авыл юргасы белән кола ярыша!* М. Гали. // Эзәрлекләп килеп җитү, куып килү. *Менә Байдекнең артыннан ук басып килделәр тентү белән.* К. Насыйри.

19. Һөҗүм итеп җиңү, корбанын үтерү (ерткычлар һ. б. турында). *Юлбарыс арысланны басса, тәү башлап басар.* Мәкаль. *Албасты көчсезләрне баса.* Мәкаль.

20. Талау, тар-мар итү ният белән керү, таларга, хакимлек урнаштырырга, буйсындырырга килү. *Дошманнар килә Илне басарга. Тыныч халыкны Дарга асарга.* Э. Ерикәй. // Кереп урлау; һөҗүм итеп талау. *Шул ук төнне детдом складын басалар.* К. Нәҗми.— *Ничек... талады? Өй бастымы ул* [*Гайнетдин*], *юл бастымы?* Н. Исәнбәт.

21. Билгеле бер процесс, күренешне җиңеп, икенче планга калдырып, өстенлек алу, беренче планга чыгу (берәр көчлерәк процесс, күренеш турында). *Дулкын тавышын, урман шаулавын басып, күк күкрәде.* Г. Гобәй. *Зәйнуллин, машина гөрләвен басарга теләп, кычкыра төшеп, МТС хәлләрен сөйләп бара.* Г. Минский. // Зуррак, әһәмиятлерәк булып әверелү (вакыйгаларга карата). *Атна-ун көн дигәндә икенче берәүнең күзе кислотага януы --- Егорка вакыйгасын басып китте.* Г. Гобәй. // *сөйл.* Зуррак булып китү(үсү яшендәге балаларга карата). *Энесе абыйсын басып үсү.*

22. Берәр тәртипсез яки тискәре күренешне туктату, тыю. *Аның* [*дежурныйның*] *шау-шулы, үсеп барган паникаңы басарга теләп --- кычкырганы ишетелә.* А. Шамов. // Тынычландыру, тыю; җиңеләйтү (хисләр һәм кичерешләргә карата). *Урынсыз икән — ачуны баса белергә кирәк.* Н. Арсланов. *Сагынуымны төннәр утырып язган Хатлар гына басар дисеңме?* С. Хәким. *Җыр күңелне дә ача ул, Кайгыны да баса ул.* Җыр.

23. *к.* бастыру (7 мәгъ.). *Хөкүмәт халыкны басар өчен яңа пушкалар, мылтыклар алыр.* Урал.

24. Берәр процессның интенсивлыгын, көчен киметү (ут, ялкын, яктылык турында). *Залдагы утны бастылар (кино башланды).* Ф. Сәйфи-Казанлы. // Акрынайту (тавыш, аваз турында). — *Серебряков янына килдем,— диде ул* [*Васильев*], *тавышын баса төшеп.* И. Газин.

25. *күч.* Басынкыландыру; авыр тәэсир итү. *Ничә сөйләсәң дә, картлык тора-бара баса бит ул.* М. Шабай. // Санга сукмау, кимсетү, җәберләү. *Усал булсаң— асарлар, юаш булсаң — басарлар.* Мәкаль.

26. *күч.* Каплап алу, тоташ каплап китү; җәелеп каплау. *Күкне болыт баскан иде, җил чыгып аларны кайсын кая куып бетерде.* А. Алиш. *Гөлҗимеш куагын кар баскан.* Г. Әпсәләмов. [*Мишә елгасы*] *ярына сыймыйча, читкә җәелә башлады: болыннарны каплады, бакчаларны басты.* Г. Галиев. // Күбәеп, ешаеп, куерып каплау. *Маңгаемны җыерчыклар басты, Пуля эзе калды билемдә.* Ә. Ерикәй. *Бөтен бер басулар кысыр калып, әрем-алабута, төрле чүп үләне басты.* Ф. Хөсни. // Җәберсетү, басымчак итү. *Йомшак агачны корт баса.* Мәкаль.

27. *күч.* Билгеле бер тискәре күренеш яки авыр бер тойгы, хис тәэсире чолгап алу. *Күрку басу.* □ *Тирән тынлык басты. Әхмәдигә --- җавап бирүче булмады.* З. Бигиев. *Күңелне хәвеф басты, --- кайгы артты.* Г. Минский.

28. *сир.* Билгеле бер яшькә керү. *Яшең алтмышка басканда алты яшьлек оныгың булсын.* Мәкаль.

Басып алу — 1) яулау, яулап алу. *Басып алу политикасы.* □ *Япония Кытайны, Һиндстанны, Бирманы, Индонезияне басып алырга омтылды.* Яңа тариx; 2) *к.* басып калу (1 мәгъ.). [*Таҗдар карт — көнлекчегә:*] — *Минеке бит ул* [*чабагач*]. *Моның өчен акчаңны басып алырмын,— диде.* Г. Толымбай. **Басып калу** — 1) көчлелектән файдаланып, бирәчәкне бирмәү, кеше хакына керү.— *Мин үскән Кырлайда, шулай, Хафиз дигән бер бай Җаббар дигән ялчының хакын басып калырга маташкан иде.* Ә. Фәйзи; 2) җинаятьчел рәвештә яшерү, сер саклау, бердермәү. *Салаватны --- юлда үтергәннәр. Менә шушы канлы эзне волостьта эшләүче кулак ияртеннәре басып калдылар.* К. Нәҗми. **Басып керү** — көтмәгәндә көчләп килеп керү, һөҗүм белән керү. *Таң алдыннан өч полицейский, басып кереп, Зөһрә апаның котын алган.* Г. Гобәй. *Дошманны җимер, Дошманны кыйна. Басып керергә Аңа юл куйма.* Ә. Ерикәй. **Басып утыру** — берәр урында озак вакыт утыру яки берәр постны озак вакыт биләп тору. *Фирдәвескә урын эзләп азапланасы юк. Аның күп еллар рәттән басып утырган урыны бар.* М. Хәсәнов. **Басып яткыру** — яшереп тоту; кулланмыйча яки файдаланмыйча саклау. *Менә бусы— Зәһит проекты буенча материаллар. Бу проектны никадәр вакыт басып яткырдылар.* Г. Иделле.

БАСЫК *с.* Киң һәм җәенке. *Кар белән яртылаш күмелгән басык вә тәбәнәк өйләрнең кечкенә тәрәзәләреннән сарғылт шәүләләр урам аркылы сузылып-сузылып киткәннәр иде.* Ш. Камал.

БАСЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* басу II (1, 6, 7, 8, 11, 16, 22, 24 мәгъ.).

2. Тыгызлану, утыру. *Мартның соңнары... Кышкы, басылып өлгән карның үзәгенә үтә торган җил.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. *күч.* Сүрелү, тукталу (ялкынлы, өермәле һ. б. күренешләргә карата). *Буран басылу. Янгын басылу. Сугыш басылу.* □ *Көн буе дәвам иткән каты атышлар басылган, һәм табигать ничектер тынып калган.* А. Шамов. // Әкренәю, тынычлану, тынычлана төшү, кискенлеге яки зыяны һ. б. бетү (бәхәс, дау яки хәрәкәт, ыгы-зыгыга карата). *Безнең Бохара әмире белән конфликтыбыз әле булса басылганы юк.* Ш. Усманов. *Кичтән, кеше аягы басыла төшкәч, безнең хәлфә абый --- караңгы лапас астына кереп чыга имеш.* Ф. Хөсни. // Кимү, бетү (хисләр, тойгылар, кичерешләр яки физиологик күренешләргә карата). *Дәрт басылу.* □ *Бөтен сер ачылды. Ачуларым басылды.* З. Мансур. *Тик бераздан соң гына бу калтыравым басылды.* М. Гафури. *Галәү өйдә хәзер. Мамык түшәк. Акрын-акрын арган басыла.* Ш. Мөдәррис.

4. Боегу, юашлану, басынкылану. *Иртәгә мәктәпкә барам дигән кичне Габдулла шундый күңелсез уйлар белән басылып утыра иде.* Ә. Фәйзи. // Кысылу, җәберләнү; кысынкы хәлдә булу. *Халыкның аңарчы басылып торган --- ижади куәсе тормышның һәр өлкәсендә ургылып, бәреп чыкты.* Каз. утл.

БАСЫМ I *и.* **1.** Аяк басу, адым. *Чынлап та Разиямы? Нечкәлеге аныкы, аякларының йомшак кына басы-*

мы — аныкы. Ф. Әмирхан. *Безнең аяклар басымы тавышында изелгән сыйныфның җиңүе яңгырый.* Г. Толымбай. *Биючеләрнең аяк басымнарыннан идәннәр дер селкенә.* К. Нәҗми.

2. Нәрсәгә дә булса басу II (11, 12 мәгъ.) хәрәкәте яки күренеше. Басу нәтиҗәсендә барлыкка килгән текст яки рәсем. *Кул көче белән йөртелгән агач стан --- сәгатенә бары илле басым (оттиск) бирә алган.* И. Рәмиев. // Басу, басым нәтиҗәсендә барлыкка килгән уем. [*Кызның*] *битләрендә бармак басымы зурлыгында чокырлар хасил булды.* Х. Госман.

3. *физ.* Берәр өсйөзгә юнәлтелгән механик тәэсир (мәсәлән, авырлык) көче. *Атмосфера басымы.* □ *Бораулаучы тормоз рычагы ярдәмендә борауга төшә торган басымны көйли.* Нефть тур. хик. *Әгәр елгага электростанция корырга уйланылса, аны төзүдән элек, һәр квадрат метрга су басымын исәпкә алалар.* Н. Дәүли.

4. Этәреш, кысу. *Арттагы сафлар* [*алдагыларны*] *көчле басым белән шундый нык этәреп җибәрделәр.* К. Нәҗми. // Көчле кысыклау. *Дошман безнең басымга түзә алмады.* Ә. Айдар.

5. *күч.* Көч белән, көчләп тәэсир итү; мәҗбүр итү, көчлек. *Экономик басым. Политик басым.* □ *Крестьяннар ике катлы изелү — беренчедән — морза-алпавытлар, икенчедән — түрәләр басымы астында калалар.* И. Рәмиев.

6. *лингв.* Сүздәге иҗекләрнең яки сөйләмдәге сүзләрнең берсен көчлерәк итеп әйтү. *Сүз басымы. Логик басым. Ритмик басым.* □ *Татар исемнәрендә һәм сүзләрендә басым, кагыйдә буларак, соңгы иҗеккә ясала.* К. Нәҗми.

7. *иск.* Бастырырга таратып җәелгән ашлык, җәем. *Бер басым ашлык.* □ *Әнисә --- ындыр эшләренә бер көн дә калмастан катнашып йөрде. Бергә арыш суктык, басым бастырдык, бәрәңгеләр казыдык.* З. Бәширн. // Басар өчен җәелгән балчык, кизәк һ. б.

Басым ясау — 1) гадәттәгедән артык көч кую; аеруча игътибар юнәлтү. *Химияне үстерүгә басым ясау.* □ *— Юк,— диде Шәвәли, сүзенә басым ясап,— мин фәкыйрьне сазлыкка сөйрәмә инде.* С. Рафиков; 2) янап, үгетләп, үпкәләп яки рәнҗеп, башкаларның фикеренә тәэсир итү. [*Миңниса җиңгинең*] *бу төртмәле сүзләре баягыча көчле басым ясау теләге белән түгел, бәлки үзсүзләнеп әйтелгән көчсез каршылык кына иде.* Ә. Фәйзи.

БАСЫМ II *и.* Гармоньның һәм шуңа охшашлы музыка коралларының клавиатурасы урнашкан өлеше, «колагы». *Гармонеңның басымы алтын, Мехы кытай ефәге.* М. Фәйзи.

БАСЫМ III *с. диал.* Басынкы, тыйнак. — *Үзең тегелә басым гына, дәрвиш кенә дип әйтимме инде.* Ш. Камал.

БАСЫМЛАУ *ф.* Үлчәүле яки башкача үзенчәлекле адым ясау. *Басымлап үлчәү. Басымлап йөренү.*

БАСЫМЛЫ *с.* 1. Басымы булган; үзенә басым төшкән. *Басымлы иҗек.*

2. Кыенлык ясый, авырлык китерә торган. *Патша Россиясендәге бу атмосфера милли өлкәләрдә аерата авыр басымлы булды.* М. Гали.

3. Адымлы, йөрешле. *Фәхри --- бу киң җилкәле, каты басымлы, чандыр йөзле эшче егетнең эшен күзәтеп килә.* Г. Ибраһимов.

БАСЫМЧАК *с.* 1. Юаш, артык басынкы, хурлаукимсетүгә түзеп торучан; мескен. *Бригадир ярдәм эзләп як-ягына каранды һәм --- басымчак кыяфәт белән генә арба тирәли йөренгән олаучыны бер читкәрәк дәште.* А. Гыйләҗев.

2. Тыныч, тыйнак. *Арык кеше — алчак, базык кеше— басымчак.* Мәкаль.

Басымчак итү — мескенгә, юашка санау, санга сукмау.— *Без монда әкият сөйләп утырырга җыйналмадык, басымчак итеп, кереп-чыгып йөрүләр булмаска тиеш.* Ф. Хөсни.

БАСЫМЧАКЛЫК *и.* Үтә тыйнаклык, юашлык. *Пырдымсызланыр вакытларда да Луиза басымчаклык күрсәтеп килде.* А. Гыйләҗев.

БАСЫНКЫ *с.* 1. Юаш, артык тыйнак, мескен. *Мисбах исә басынкы, юаш, оялчан, аз сүзле.* Г. Әпсәләмов. *Ханов, тышкы кыяфәте белән басынкы күренсә дә, мәсьәләне каты куя.* С. Рафиков. // Тыныч, шау-шусыз. *Басынкы тавыш.* □ *Мин басынкы кеше, тиктомалга Рияланып, сикереп чыкмадым.* Ә. Ерикәй. / *рәв. мәгъ. Әле сәхнә буш, залдагы халык, басынкы гына гөжләп, кемнедер көтә.* Г. Бәширов.

2. Күңелсезлек төсмере бирә торган. *Басынкы моң.* □ *Бүген* [*көн*] *тын, басынкы, авыр.* Г. Ибраһимов.

3. *диал.* Тәбәнәк, карсак; салынкы. *Йортларның күбрәге какшак, басынкы, таушалган.* Ш. Камал. *Жандарм офицеры --- басынкы кашлары астыннан бер тапкыр гына күз салды.* Г. Ибраһимов.

БАСЫНКЫЛАНУ *ф.* Басынкы булып китү.— *Борһанны әйтәм әле, ай-һай үзгәргән. Сүз-өне дә басынкыланган.* М. Хәсәнов. // Тынып калу, җитдиләнеп тыну. *Алар* [*Нәфисә бригадасы*] *элеккеге шикелле елашмыйлар, басынкыланганнар.* Г. Бәширов.

БАСЫНКЫЛЫК *и.* 1. Басынкы булу сыйфаты. *Шәрифуллин, --- үзен сабыр тотарга тырышып, баштагы күтәренке тавышын басынкылык белән алмаштырды.* С. Рафиков.

2. Авыр тойгылар, күңелсезлек, боеклык турында. [*Назиповның*] *рухын ниндидер, әйтеп тә биреп булмый торган басынкылык чолгап алган.* Г. Әпсәләмов. *Тотлыгып, тирән басынкылыкта әйтелгән бу сүзләр егеткә тәэсир итте булса кирәк.* Э. Касыймов.

БАТА *и. диал.* Фатиха, изге теләк; бәрәкәт, кот. *Атасыз йорт — батасыз йорт.* Мәкаль.

БАТА-КАЛКА *рәв.* Бер батып, бер калкып, баткалап һәм калыккалап. *Калкавычлар су өстендә бата-калка уйнаклап торалар иде.* Ф. Хөсни.

БАТАЛИСТ *и.* Сугыш картиналары төшерүче рәссам.

БАТАЛЬОН *и.* Берничә ротадан торган гаскәри берәмлек, полктан түбәнрәк баскычта тора. *Батальон командиры.* □ *Егерме көн сугыш һөнәренә өйрәнгәч, батальоннан ике роганы сугышка җибәрделәр.* Ә. Айдар.

БАТАРЕ'Я *и.* 1. Берничә пушка яки минометтан торган артиллерия бүлеге. *Зенит батареясы.* □ *Дошман дотларына җир тетрәтеп Безнең батарея туп атты.* Ә. Ерикәй. // Пушка яки минометлар куелып, махсус ныгытылган позиция. *Кызыл гвардия һәм матрослар --- Дутов юнкерларын җиңеп, аларның Сырт тавына урнашкан батареяларын алу белән шәһәрдәге атаман диктатурасына чик куелды.* Ш. Усманов.

2. Гальваник элементлар яки аккумуляторлар җыелмасы — ток чыганагы. *Электролитның тыгызлыгы белән аккумулятор батареясының корылу дәрәҗәсе арасында билгеле бер бәйләнеш була.* Тракторлар.

3. Аерым секцияләрдән җыеп ясалган һәм пар яки кайнар су белән биналарны, бүлмәләрне җылыта торган җайланма.— *Өебезнең салкынлыгын күрә торгансыңдыр. Бер батареябыз җылы бирми.* Г. Әпсәләмов.

4. *махс.* Йорт кошларын асрау өчен җылытыла торган махсус конструкцияле күп катлы читлек. *Кошчылык фабрикаларында күп этажлы читлекләрдә — батареяларда ун меңнәрчә һәм йөз меңнәрчә тавык асрыйлар.* Зоология.

БАТАТ *и.* Көньяк илләрдә үсә торган бәрәңге сыман тамыразык үсемлеге. *Батат үстерү. Батат плантациясе.*

БАТА-ЧУМА *рәв.* 1. Җир өстендәге таралучан яки сыек массага бата-бата. *Ямщиклар, йөкле чана тирәләрендәге тирән карны ерып, бата-чума алдагы ат тирәсенә җыелалар.* И. Газн.

2. Бата-калка, баткалап, чумгалап. *Күпернең икенче яртысы, бозлар арасында бата-чума, елга уртасыннан агып китте.* С. Рафиков.

БАТИСТ *и.* Чирак катылган җитен яки мамык җептән эшләнә торган ярым үтә күренмәле юка һәм тыгыз тукыма. *Күлмәклек ак батист сатып алу.* // *с. мәгъ.* Батисттан тегелгән (киселгән). *Менә бакчага яшүсмер бер кыз йөгереп килеп керде, өстенә юка гына батист күлмәк, аякларына җиңелчә ак башмаклар кигән.* Г. Лотфи. *Кызыл батист яулыгым Җилферди җилдә генә. Күңелләрем күтәрелә Син булган җирдә генә.* Җыр.

БАТҚАК *с.* 1. Эченә батарлык; былчырак, юеш, сыек балчыклы. *Тирә-як баткак сазлыклар һәм күлләр белән чолганып алынган иде.* Г. Әпсәләмов. *Баткак юлда көпчәкләр күмелә башлагач, кучерлар арбаларын ташлап киттеләр.* Ш. Усманов.

2. *и. мәгъ.* Юеш, пычрак җир өсте, аяк батардай сыек балчыклы урын. *Җиде кат боз астыннан чыгар бака, Баткакларга, балчыкларга бата-бата.* Г. Тукай. *Урамның уртасыннан йөрерлек түгел, баткак, әмма өй буйларында шул баткак эченнән тар сукмак бар.* Г. Ибраһимов. // *диал.* Шундый җирдәге ябышкак балчык. *Тәгәрмәчләргә баткак ябышып калмасын. Аларны кырып торырга кирәк.* М. Гафури.

3. *и. мәгъ. күч. к.* баткаклык (2 мәгъ.). *Кешеләр --- тормыш баткагыннан чыгу юлын бергә эзлиләр.* Һ. Такташ.

БАТҚАКЛАНУ *ф.* Үзләләну, изелү, баткакка әверелү. *Кырысланды һава, Көн-төн яңгыр ява, Каралдылар кырлар, Баткакланды юллар.* Ә. Исхак. *Өстәвенә күл төбе баткакланды, аяклар сумала шикелле сыланучан ләмгә ябыша башладылар.* Г. Әпсәләмов.

БАТҚАКЛЫК *и.* 1. Баткаклы урын. *Яз көннәрендә баткаклыктан бөтенләй үтеп булмый, җәй көне дә әз генә яңгыр яву белән хәзер бата башлый.* Г. Лотфи. *Һич булмаган Бу сазлыкны — баткаклыкны Ерып чыгарлык.* Ә. Исхак.

2. *күч.* Тормышта буталчык һәм озакка сузылган кыенлык, җитешсезлек, комачаулар турында. *Чүпрә Сафа көн үйлады, төн үйлады. Бу баткаклыктан чыгарга юл да, ярдәм дә табалмагач, дәмеллага киңәш сорап барырга булды.* Қ. Тинчурин.

БАТҚАЛАҚ *и.* 1. Елга, күл читләреңдәге бик баткак балчыклы урын. *Бака туе баткалакта.* Мәкаль.

2. Язгы карга казылып, өсте кар кисәкләре белән капланып куела торган алдавыч чокыр. *Гали әнә кар ташый, Энҗе баткалак ясый.* М. Укмасый.

БАТМАЛЫ *с. диал.* Тирән баткаклы, баткалаклы. *Батмалы, мүкле, сазлы Сарс елгасының дамбасы да, күпере дә күп эшләр көткәнлектән, тимер юл төзү участкасының конторы --- читтәге авылда билгеләнде.* Т. Госман.

БАТМАН *и.* 1. Биек һәм тар чиләк; бал тәпәне. *Өй хатыннары --- батманнарын, мичкә, чапчакларын, комганнарын ашыгып-ашыгып су белән тутырырга тотыналар.* Г. Ибраһимов.

2. *иск.* Башлыча сибелүчән-чәчелүчән әйберләр өчен күләм яки авырлык үлчәме — ун-унике кадак, дүрт пот, ун пот (төрле җирдә төрлечә). *Сәмигыл абзыйның арттагы бәрәңге бакчасы да --- өч-дүрт батман бәрәңге чәчәрлек кенә иде.* М. Гали. *Бу кешенең исеме Нары булган, ди, кесә төбе тар булган, ди, тар булса да, бер батман тары сыйган, ди.* Әкият.

БАТМАНЛАП *рәв. күч.* Батман (2 мәгъ.) үлчәме берәмлегенчә; күпләп. *Авыру батманлап керә, мыскаллап чыга.* Мәкаль.

БАТРАК *и.* 1. *тар.* Алпавытка яки кулакка эшли торган ялчы яки көнлекче. *Бу килеп керүче — Хафизулла байның батрагы Әхмәтҗан иде.* Г. Минский.

2. *кыек килешләрдә генә. к.* батраклык. *Матур сүзгә юмарт, ягымлы кешеләр дә очрады. Яшьтән үк батракта яшәгән Хәким абзый Сәйфуллин шундыйларның берсе булды.* И. Туктар.

БАТРАҚЛЫК *и.* Батрак хезмәте, батрак булу хәле. *Бабайның яшь һәм көчле вакытлары авыл байларында батраклыкта үткән.* Г. Гобәй.

БАТРАЧКОМ *и. тар. к.* ярлылар комитеты. *Тимерче Бикбай да партиягә керде. Аны батрачкомга председатель итеп сайладылар.* Ф. Сәйфи-Қазанлы.

БАТУ *ф.* 1. Сыеклыкка куелган очракта, чагыштырма авырлыгы сыеклыкныкыннан зуррак булу сәбәпле, төпкә китү (башлыча сыек булмаган җисемнәр турында). *Суда бату.* □ [*Тишелгән*] *кораб һаман батуында дәвам итә, әкренләп кенә су төбенә китә.* А. Алиш. // Берәр төрле көпшәк яки үзле масса эченә өлешчә яки бөтенләй кереп урнашу. *Баручыларның атлары, корсактан карга бата-бата, юлдан чыктылар.* И. Гази. *Ул арада азгынрак сыерлар, елгага су эчәбез дип барып, сазга төшеп баталар.* М. Гали. // Сыек яки үзле масса эченә кереп үлү. *Галиәкбәргә язган икән су төбенә батарга.* Бәет. // Басканда уелып керү, көпшәк булу, тотмау (юл яки аяк баскан җир турында). *Аяк асты тубыктан бата, кайбер җирләрдә кыска кунычлы итек бөтенләй чумып-чумып китә.* Г. Ибраһимов.

2. Уелып керү, чокырланып тору. *Ялтырый, ялтйолт киләдер [шүрәленең] эчкә баткан күзләре.* Г. Тукай. *Без кызларның яратабыз Бит уртасы батканын.* Җыр.

3. Бик нык чылану яки буялу. *Канга бату. Тиргә бату. Тузанга бату.* □ *Атлар ак күбеккә батсалар баттылар, отряд бер сәгатьтән әҗемнең иске җил тегермәненә якынлашты.* И. Гази. // Бик мул, еш, куе булган берәр нәрсә белән каплану. *Сакалга бату.* □ *Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән дә, саламга баткан йортлар караңгыда калганнар.* Һ. Такташ.

4. *күч.* Берәр (гадәттә кирәкмәгән) нәрсәнең артык күбәюенә дучар булу. *Бурычка бату. Гөнаһка бату.* □ *Хәерчелеккә баткан, күз яшьләренә чыланган, аһзар белән тулган ил елый.* А. Алиш. *Шәмсия кияүгә чыгып күйган, инде балага батарга да өлгергән икән.* Г. Ахунов. // Берәр рухи кичерешкә дучар булу яки шунда бик нык бирелү. *Қайгыга бату. Хыялга бату.* □ *Уйланам, уема батамын, Тормыймын, үзем ятам.* С. Рәмиев.

5. *күч. гади с.* Китеп югалу; китеп, озак кайтмый тору, көттереп зарыктыру. *Вафин, Сәрвәргә бик тиз килеп җитәргә кушып, малай да йөгерткән иде, малае да батты, Сәрвәре дә күренми.* Ф. Хөсни.— *Хәлим кайда соң? — дип сорады ул [Галиулла].— Шырпыга җибәргән идем. Батты.* И. Гази.

6. Офык артына төшеп күмелү, баю (күк җисемнәре турында). *Әле кояш та батмаган, Җәйге көннең тыныч киче.* Г. Латыйп. *Ай янында якты йолдыз, Ай батканчы бат инде!* Җыр.

7. *күч. гади с.* Қабул ителерлек булу, ярау.— *Элекчә, кара халыкка барысы да бата, дип уйламасыннар, кара халык түгел алар хәзер, колхоз халкы.* Ф. Хөсни. // Үзләштерерлек булу, үтү (аш-су турында). *Аш бату.* □ *Безгә ни бирсәң дә бата, талымланып тормыйбыз.* Ә. Еники.

8. *күч. гади с.* Урланып яшерелү, үзләштерелү. *Тирәякта кооперацияне таласалар, андагы мал да Батыршаларда бата имеш, дигән хәбәр тарала иде.* Ф. Сәйфи-Қазанлы.

9. *күч. гади с.* Бәлагә тару, гаепләнеп һәлак булу. — *Бәлагә эләккәч, явыз шайтан миңа вәсвәсә салды. Менә шулай бер баткач, батасың икән ул.* Г. Ибраһимов.

◇ **Баткан аяк чыланган** — «начар эшкә бер керешкәч, кабатлавы кыен түгел» мәгънәсендә әйтелә.

БАТУН *и.* Суганның бер төре, кыяклары өчен үстерелә. *Батун суган — бик тармакланучан, салкыннарга бик чыдам булган күпьеллык үсемлек.* Җиләк-җимеш...

БАТЫК *с. диал. к.* батынкы. [*Мәрьямнең*] *борын уртасы батыграк, иреннәре калын...* Ш. Камал.

БАТЫМ *и.* Батып, батынкыланып торган урын. [*Терлек*] *тимпания белән авырганда бил янындагы ач батым тулып күпереп чыга.* Сөт терлекчелеге...

БАТЫНКЫ *с.* Уемлы, уелып кергән. *Батынкы линза. Батынкы сызык.* □ [*Тимер такганың*] *өске пластинкасы клеткалар белән челтәрләнгән, ә аскы пластинкасына симметрик батынкы тишекләр тишелгән иде.* Ш. Еникеев. *Ияргә охшаган тау: ике башы күтәренке, уртасы батынкы.* Г. Мөхәммәтшин.

БАТЫР *и.* **1.** Курыкмаучанлык, кыюлык, көчлелек, уңганлык сыйфатлары белән танылган шәхес. *Хезмәт батыры. Ил батыры.* □ *Ил каршылый котып батырларын, Чәчәкләргә күмә юлларын.* Ш. Маннур. *Бул син батыр, бул көрәшче СССР илләрендә.* Җыр. // Бәһадир, сугыш мәйданында дан алган кеше. *Батыр — яуда, чәчән дауда беленер.* Мәкаль. *Батыр ярасыз булмас, ярасы дәвасыз булмас.* Мәкаль. // *с. мәгъ.* Курыкмас, кыю, тәвәккәл, көчле. *Батыр сугышчы. Батыр егет.* □ *Татар халкы батыр халык, кыю халык.* А. Шамов. *Бу батыр йөрәкле кеше --- минем командирлык вазифаларым турында тагын бер тапкыр исемә төшерде.* Каз. утл. // *рәв. мәгъ.* Батырларча. *Мин теләдем көрәш давылында Колач җәеп батыр йөзәргә.* М. Җәлил. *Бүлмәгә батыр-батыр басып Әсман карт килеп керде.* М. Әмир.

2. *спорт.* Көрәштә барлык башка көрәшчеләрне җиңеп чыккан кеше. *Бер мәйданда ике батыр булмас.* Мәкаль. *Быелгы сабан туеның үзенчәлеге шунда: ул колхоз батырын район беренчелегенә, район батырын республиканың абсолют чемпионы исемен яулау өчен көрәшкә хәзерләде.* Соц. Тат. // Көчле һәм оста көрәшче, атлет. *Мәйданга янбаш белән ала торган батырлар чыга башладылар.* М. Гали.

Батыр(га) калу — 1) мәйданда барысын да җиңеп, иң көчле булып танылу, батыр булып калу. *Иң соңынан өч кешене --- бер-берсе белән көрәштерделәр дә, батыр калганга зур бер сөлге бирделәр.* М. Гали; 2) *күч.* берәр хезмәт, эш ярышында җиңүче булып калу. *Урды Гали — басуны борып салды. Бу эштә дә бирешми, батыр калды.* М. Сөндекле. **Батыр кычкыру** — мәйданда кем батыр калганлыгын игълан итү. *Мөхәммәдулла абзагыз, таягын һавада уйнатып, Нурулланы батыр кычкырды.* И. Гази.

БАТЫРАЙТУ *ф.* Батыр итү, батырлык бирү. *Байлык батырайта, ярлылык кәкрәйтә.* Мәкаль.

БАТЫРАЮ *ф.* Үз-үзеңне батыррак, кыюрак итеп сизә башлау. *Йөзем суының алтынчы чынаягын эчкәч, Вәли абзый батыраеп китте.* Ә. Фәйзи.— *Минем аркада аның [Хафизның] хурлыкка калачагын белгәч, дөресен сөйләр өчен батыраеп судка килдем.* Г. Камал.

БАТЫРГЫЧ *и.* Суда тирәнрәк батсын өчен, кайбер предметларга (балык аулау коралларына һ. б.) тагыла торган махсус авырлык, йөк. [*Бикмуш бабай белән Илсөяр*] *бауның бер очын кармакка тактылар, батыргыч куйдылар.* Г. Гобәй.

БАТЫРЛАНУ *ф.* **1.** Батырлык күрсәтү, батырчылык итү.— *Әй, бүрекле баш, шушындый куе урманда япаялгызың гына курыкмыйча батырланып ничек йөриссең?* А. Алиш. // Батыраю. *Тора-бара мин дә батырланып киттем...* Г. Мөхәммәтшин.

2. Батыр булып күренү: тышкы батырлык, шәрә батырлык күрсәтү. *Батырланып кырда йөрсәк тә бөз, Юк икән шул, егет, рәтебез!* М. Җәлил. *Артыгын кыланып, батырланып йөрүне ташларга кирәк!* С. Сабиров.

БАТЫРЛА'РЧА *рәв.* Батырлар шикелле, батырларга хас булганча. *Батырларча һәлак булу.* □ *Ул [Октябрь] чакырды безне көрәшләрдә Батырларча чыдам булырга.* Ә. Ерикәй.

БАТЫРЛЫК *и.* **1.** Батыр булу сыйфаты, курыкмаучанлык, кыюлык. *Батырлыкта — матурлык.* Мәкаль. *Авылда үскән балаларның иң беренче батырлыклары ата каздан курыкмау белән башлана иде.* Г. Гобәй. *Халык үзенең газиз улларының батырлыгына куанып: «Батыр егет — яу күркә» дип аңлаткан.* Г. Әпсәләмов.

2. Батырчылык, тәвәккәллек. *Гөлфанысны урлаган ил [кешеләре] яңадан сугыш башларга батырлык кылмадылар.* Г. Ибраһимов.

БАТЫРМА *с.* Батырып куела торган. *Батырма җылым. Батырма насос* (мәсәлән, нефть табу эшендә).

БАТЫРСЫНУ *ф.* Батырчылык итү, йөрәксенү. *Шулай да куштаннар үз фикерләрен ачык әйтергә батырсынмыйлар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БАТЫРУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* бату. *Суга батыру.*

2. Баш киемен күз һәм колакларга төшереп кию. *Үз ишләре тирәсенә якынлаша башлагач, бүрекне ул [Әгъләм] тагын да батырыбрак куйган иде шикелле* Ф. Хөсни.

3. Кадау, кадап кертү. *Көрәкне җиргә батыру.* □ *Кадакны бер сугуда төбенә кадәр батыра аласыңмы?* Г. Әпсәләмов. // Нәрсәнең дә булса эченә кертеп яки төшереп кую, яшерү.— *Син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә.* Г. Камал.

4. *күч.* Интәшлеккә, тугрылыкка хыянәт итеп, башка берәүне бәлагә калдыру, һәлак итү, сату. *Бүтәннәрне батырып, үзеңне коткару — бу инде җинаять.* Г. Әпсәләмов.— *Их, егет, егет, нигә мине батырырга телисең, сиңа ни усаллыгым тиде?!* Һ. Такташ.

Батырып карау — текәп, текәлеп карау.— *Абау, күзләре,— диде Гашия, йөзен читкә борып.— Нигә шулкадәр батырып карыйсың, Хәйрулла абый?* М. Әмир. **Батырып эшләү** — бар көченә тырышып эшләү. *Миңнисә ялан эшләрен батырып эшләде.* Г. Ибраһимов.

БАТЫРЧЫЛЫК *и.* Кыюлык, тәвәккәллек (күбрәк очракта **итү, кылу, җитү** кебек ярдәмче фигыльләр белән килә). [*Урмай:*] *Батырчылык кылып әйтим, ханым! Кулупайга Җикне җиңү читен булыр.* М. Җәлил. *Сезгә бу хәлне сөйләп бирергә батырчылык җитмәгәнгә, хат кына язмакчы идем.* М. Фәйзи.

БАТЫШ *и. сир.* Бату, баю күренеше. *Кояшның чыгыш вә батышында матурлык ниһаясез.* Г. Ибраһимов.

БАУ *и.* **1.** Бәйләү, буу өчен кулланыла торган, ишелеп яки үрелеп ясалган озын предмет. *Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы.* Мәкаль. *Аннан инде миңа бау ишү, сап ышкылау кебек катлаулырак эшләргә дә күнегә башларга кирәк.* Г. Гобәй. // Шуңа охшашлы нәрсәләр: тасма, лента, каеш һ. б. *Минем әти яңа камытларга Баулар көйләп куйды яхшылап.* З. Мансур.

2. *күч.* Бауга яки шнурга һ. б. тезелгән тезем. *Бер бау суган.* □ *Шүрәле, иңенә бер бау крендель асып, капкадан кайтып керә.* Д. Аппакова. // Билгеле бер үлчәмдә бау белән аерып-аерып бәйләнгән утын, печән һ. б. *Ике якта көлтәдәй итеп бауга бәйләнгән печән өемнәре. Өч бавы биш тиен.* Г. Минский.

3. *кыек килешләрдә. к.* бәй I. *Терлекләр абзарында унҗиде сыер бауда тора.* Г. Ахунов.

Бау(ны) салу — элмәк кидерү, уратып бәйләү. *Кәҗәнең мыгезенә бауны салдым да җитәкләп өйгә алып кайттым.* Ш. Камал. **Бау сикереш** — бау аркылы сикереп уйнала торган уен. *Өс киемнәрен койма буена өеп куйган нәни кызлар соры асфальтта бау сикереш уйныйлар.* М. Шәйми. **Бау сикерү** — бау аркылы сикереп уйнау. *Тәрбияче хатын --- оекмы, нәрсәме бәйли, балалар исә, бөтен дөньяларын онытып, дөп-дөп бау сикерәләр.* Г. Бәширов. **Бауга салу** — көлтә бавы белән бәйләп кую. *Ул [ат] тагын әллә кемнең җир өстенә барып, бауга салган тары көлтәләрен ашарга керешкән иде.*

М. Гафури. **Баудан ычкыну** — *к.* бәйдән ычкыну.— *Нигә баудан ычкынган шикелле чабасың?* Л. Гыйльми.

БАУ-БАСКЫЧ *и.* Параллель ике арканга араталар беркетеп ясалган җиңел баскыч (альпинистлар, солдатлар һ. б. йөртә). *Разведчиклар бау-баскычның очын ташка беркеттеләр дә бер-бер артлы төшеп тә киттеләр.* Г. Әпсәләмов. *Ярый әле бау-баскычлар бар: алар булмаса, ничек менәр идең бу таш стенага.* И. Гази.

БАУЛ *и.* Юл йөрү өчен түгәрәк кырыйлы озынча сандык яки таза, нык чемодан. *Төнге вагон. Йокылы керфекләр. Чемоданнар. Киплар, бауллар.* Ә. Еникәй.

БАУЛАП *рәв.* Баулар (2 мәгъ.) санынча. *Бистәнең кәҗә асраучылары баулап печән сатып алалар.* Г. Минский.

БАУЛАУ *ф.* Бауга тезү. [*Йорт салучылар*] *суган баулаган кебек акрын кыймылдыйлар.* А. Гыйләҗев.

БАУЛЫ *с.* 1. Бавы булган. *Баулы чиләк. Баулы камыт.*

2. Бауланган, бауга тезелгән. *Бары да таныш, бары да туган: Мич янында баулы суган, Соры песи, калай комган.* Г. Афзал.

БАУЛЫК *с.* 1. Бауга яраклы, бау ишүгә тотыла торган. *Урак өстендә этием белән әнием миннән бала караталар, көлтәгә баулык тарма йолыктыралар һәм учма җыйдыралар.* С. Кудаш. // Бау ишәргә җитәрлек. *Бер баулык юкә.* // Бауга тезәргә җитәрлек. *Бер баулык суган.*

2. *и. мәгъ.* Көлтә бәйләү өчен бөтереп ясалган салам яки үлән. *Көлтә баулыгы.*

3. *и. мәгъ.* Бау яки каеш беркетелә торган урын — ael, тишек һ. б. *Камытның баулыгы кыек булган, Каерып җигеп булмыйдыр.* Җыр.

БАУ-ШУ *җыйк. и.* Һәртөрле баулар, арканнар.— *Кайбер эшләрне булдыра алам, әгәр эшләтүче булса... Бау-шу ишү, утын кисешү кебек нәрсәләр.* Ш. Еникеев.

БАХ I *аваз. ияр.* Көчле шартлау авазын белдерә. *Кинәт снаряд килеп төшә: бах!* Г. Әпсәләмов.

БАХ II *ы. к.* баһ.

БАХБАЙ *и. сөйл. ирк.* Ат. *Көннәрнең берендә Закир иртә белән үзенең бахбаен конюшнядан чыгарып, кыргычлады, тазартты.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БАХЫР, БАХЫРКАЙ *и. диал. ирк.* Мескенкәй, бичаракай.— *Бу егетне нигә азап чиктерәсез әле сез? Җитмәсә өсте-башы да бик юка бахырның.* И. Туктар.

БАЦИЛЛА *и. биол.* Таякчык формасындагы бактерия. *Туберкулез бацилласы.*

БАШ *и.* 1. Кеше һәм хайван гәүдәсенең авыз, иң әһәмиятле сизү органнары һәм зур ми урнашкан өлеше. *Башың яланбаш икән, Ябын зәңгәр шәлеңне.* Җыр. *Ике тәкә башы бер казанга сыймас — сөзешерләр.* Мәкаль. // Баш киеме. *Башыгызны салыгыз!* // Баштагы чәч. *Баш кырдыру. Баш тарау.* □ *Зәлифәнең кызыл бантлы бөдрә башы, язгы күбәләкне хәтерләтеп, әле бер, әле икенче гөл арасына килеп чыккан.* Г. Ахунов. // Баш мие, ми. *Акыл яшьтә түгел, башта.* Мәкаль. // Баш биеклеге яки баш озынлыгы. *Бер башка алдан килү* (бәйгедәге атлар турында). □ *Җыелыш уртасында Зариф агайның саргылт көрән сакалы чагылды. Ул буйга башкалардан бер баш озынрак иде.* Ш. Усманов.

2. Үсемлекләрнең югарыгы өлеше, өстәге оч ботаклары, шундагы чәчәкләре яки җимешләре. *Агач башы. Җикән башы.* □ *Ал, кызыл, ак, сары чәчкә белән Бизәкләнгән үлән башлары.* М. Гафури. *Җилфер-җилфер җилләр исә, Җитен башларын кисә.* Җыр. // Башак, бәрчә, себеркәч. *Игеннәрнең башларын коеп йөргәч, нигә үтермәсеннәр саранчаны?* А. Алиш.

3. Үсемлекләрнең азык матдәләре җыелган шар сыман сабак яки тамыр бүлтәймәләре. *Кәбестә башы. Суган башы.* □ *Баш та баш, шалкан башы да баш.* Мәкаль.

4. Биеклегенә игътибар итәрлек булган берәр нәрсәнең югарыгы өлеше, өске ягы. *Бағана башы.* □ *Тау башына салынгандыр безнең авыл.* Г. Тукай. *Күзләр Эйфель манарасының башына күтәрелә.* Г. Гали. // Кыек, түбә. *Кырлар үзгәргәннәр, сазлар кипкән. Салам башлы өйләр кимегән.* Ә. Еникәй. *Завод башы иләк шикелле иде... Нишләтте Фәсхи абзаң, ялт иттерде бит!* Ф. Сәйфи-Казанлы.

5. Озынча нәрсәнең ике очының берсе яки оч ягы. *Бау башы. Таяк башы.* □ *Мостафин, карандаш башы белән өстәлне шакылдатып, тынлык урнаштырды.* Ш. Камал. // Озынча предметларның аерым формада юанайтылган яки конусланган, төймә сыман яки шар сыман очлары. *Кадак башы. Шырпы башы. Оек башы. Итек башы. Шешә башы. Өтерге башы. Тукмак башы.* // Авылның, урамның яки озынча зур корылманың билгеле бер очы. *Бик сагындым таныш кырларымны, Урманымны, күпер башымны.* М. Җәлил. *Бөркәүле зур лапас эчендә бер башта --- ясмык ---, икенче башта --- сугу машинасында борчак сугып яталар.* М. Гали. // Зур нәрсәнең күзгә күренеп яки чыгып торган бер кечерәк өлеше, кырые, очы. *Хәзрәт --- кесәсеннән яулык башын күрсәтебрәк куйды да кунаклар ягына чыгарга хәзерләнде.* Ф. Әмирхан. // Махсус эшләнгән оч, очлык, очка куела, беркетелә торган әйбер. *Тастымал башы.*

6. Нинди дә булса бер күренешнең тәүге чоры, башланган дәвере, беренче моменты. *Бервакыт авыл халкы иген ташый, Менә шунда керә инде Көзнең башы.* М. Гафури. // Барлыкка килү, йөз бирү күренеше, башлангыч. *Мал башы — тавык, мая башы — бер күкәй.* Мәкаль. *Начарлыкның башы гына башлансын, аннан соң ул сине ничек хурлыкка төшерергә белер.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Беренче. *Әсәрнең баш өлеше.* □ *Яшь чагымда күңелем китабының Баш битләрен миннән алдылар.* М. Гафури.

7. Әдәби әсәр, мәкалә һ. б. исеме. *Күрәсез, мәкаләнең башы алай котны алырлык түгел, хәтта бик әдәби баш дип әйтергә була.* Ф. Хөсни.

8. Ачыткы. оеткы салынган камыр, сөт, бал һ. б. *Ипигә баш кую.*

9. Оешмада яки коллективта җитәкче роль уйнаучы һәм гадәттә хокуклары буенча да башкалардан өстен торган шәхес, оештыручы. *Баш итеп кую.* □ *Әгәр дә Жиһанша --- командирларны, гаскәр башларын күрсә иде, шунда үк гаскәр башы булуны теләр иде.* З. Һади. / *с. мәгъ. Бригадир Сәетгали кечкенә Юлкотлыда бердәнбер хуҗа һәм баш кеше.* Ә. Еники. // *гади с., ирон.* Башлык, хуҗа, түрә, хөкемдар. *Кабинет ишеге алдына җыелган дүрт-биш кеше --- башның килүенә өметсезләнә башладылар.* Г. Иделле.— *Күрмисеңмени, Имәли абзаң бөтен авылга баш!* М. Әмир. // *с. мәгъ.* Билгеле бер дәрәҗә башлык сыйфатында каралган, өлкән. *Баш агроном. Баш инженер.* □ — *Син, Әхмәтҗан абзый, чынлап та, элек башрак кешеләр белән сөйләшер иең.* Ф. Хөсни.

10. *тарт. һәм кыек килеш форм.* **башында.** Төп җитәкчелек постында. *Эш башында булу.* □ *Бу зур экспедициянең башында академик Отто тора, хәзерге көндә ул экспедициясе өчен белгечләр җыя.* А. Алиш.

11. *күч.* Җан-тән, шәхес.— *Баш исән булсын, бакчаны яңадан үстерербез.* И. Гази. *Кайда гына булмый, ниләр күрми Егет башы белән ат башы.* Җыр.

12. *күч.* Акыл, зиһен, аң. *Хәер, бүген инде соң да, аннары тагын мондый чәбәләнгән мәсьәләләрнең очына чыгарлык баш та калмаган иде.* Ф. Хөсни.— *Бу малайда баш бар, егетләр, моңа күптән разряд бирергә вакыт.* Ш. Бикчурин.

13. Берәмлек, данә (күбрәк очракта башы булган предметлар турында). *Бер баш мал.* □ *Солдат башына яртышар кадак сохари бирделәр.* М. Гали. *Бакчада ике-өч баш умарта күренә.* А. Алиш. // Конус яки шар формасында хәзерләнгән ашамлык (шикәр, сыр). *Бик*

яхшы агартылган мич буена ярты баш шикәр, кадаклы чәйләр, буй-буй сабыннар тезелгән. Г. Ибраһимов. // *сөйл. сир.* Комплект. *Хәтта бер кешенең егерме биш баш киеме була торгандыр, күлмәк-штаннан башка.* К. Насыйри.

14. *рәв. мәгъ.* **баштан, башыннан.** Үзеннән алдагы аергыч аңлаткан халәттә. *Исерек баштан. Кызган баштан. Саф баштан.* ▭ *Ирекле баштан утка кермиләр.* Мәкаль.

15. *-лык, -лек* кушымчалы сүзләр янында: чүп-чар, артык-портык нәрсәләр китереп ташлау өчен билгеләнгән урын. *Көллек башы.* ▭ *Гыйлем, гыйшык шаһлык сөргән илдә Чүплек башы җирләр гөл булыр.* Н. Исәнбәт.

16. *с. мәгъ.* Иң әһәмиятле, төп. *Баш роль.* ▭ *Тормышның баш чыганагы — табигать.* Г. Иделле. *Озакламыйча казакларның баш көчләре белән очрашуны көтәргә кирәк.* Ш. Усманов. // Үзәк урында урнашкан, иң зур, төп. *Баш мәйдан. Баш корылма. Баш магистраль.* ▭ *Музейдан чыккач, Шакир шәһәрнең баш урамын бер кат әйләнмәкче булып, шул тарафка китте.* Ф. Әмирхан. *Баш бинаның кайчандыр якты булган, ә хәзер җилләр уйнап торган залында Наил бер картны очратты.* Г. Әпсәләмов.

Баш бармак — 1) калган дүрт бармактан аерым тора һәм аларга каршы куела торган зур бармак. *Баш бармак башы кадәр эре-эре булып кызарып пешкән җиләкләрне бераз учына җыеп ашаганнан соң, ул* [*Габделкаюм*] *түбәтәенә җыярга кереште.* Г. Гали; 2) *күч. сөйл.* бик булдыклы, бик әйбәт, менә дигән егәрле кеше.— *Көтүчесе кем бит әле, баш бармак иң! Яшь булса да, көтүне кайда күпме вакыт йөртергә кирәклекне бөтенебездән яхшырак белә.* Г. Галиев. // Чагыштыру тәгъбирләре составында. *Бу китапның герое - - - - һәр яктан да баш бармактай солдат.* З. Мансур. **Баш бау** — бастырыкның бер башына бәйләнгән аркан. *Баш бавың үзелмәсен, бастырыгың сынмасын.* Мәкаль. **Баш капкачы** *анат.*— баш түбәсе сөяге. [*Солтан:*] *Баш капкачын эчтән бораулыйлармыни!* С. Рафиков. **Баш исәбе (саны)** — мал-туарның данәләр санына гына игътибар итү, сыйфат ягын икенче планга калдыру күренеше. *Минем нәселле тавыкларым арасына нәселсез чебешләр биреп җибәргәннәр, янәсе, баш исәбе булгач, нәрсә булса да барыбер.* Ф. Хөсни. **Баш киеме** — башка киелә торган кием. [Ул], *баш киемен кулында йомарлап, аягүрә баскан килеш гозерен сөйләде.* И. Гази. **Баш килеш** *лингв.*— махсус кушымчасы булмаган килеш. **Баш күнәк** *диал.* — ат башы яки сыер башы тиресеннән ясалган күнәк, күн савыт. *Җәйләүләргә бардык, бияләр саудык Баш күнәккәйләрне кулга алып.* Җыр. **Баш сөяге** — башның үзара береккән сөякләрдән торган төп өлеше. *Мәхәббәттән аңын җуйган егет... Утерде дә сөйгән ир кардәшен, Баш сөяген кызга китерде.* М. Җәлил. **Баш төрү** — йомарлана башлау (кәбестә башы турында). *Кәҗә бәтиләре - - - яңа гына баш төрә башлаган кәбестә түтәлләренең кирәген биреп чыгалар.* Л. Ихсанова. **Баш хәреф** — җөмлә һәм ялгызлык исемнәр башында, шулай ук кайбер шартлы билгеләрдә һәм кыскартмаларда, аеруча ихтирамны белдергәндә кулланыла торган махсус хәреф. *Китап — иң яхшы дус, турылыклы юлдаш ул. Шуңа күрә дә бу сүзне һәркайчан баш хәрефтән язасы килә.* Соц. Тат. **Баш яулыгы** — башка бәйләнә (бөркәлә, урала) торган гади яулык. *Кызларның башларында шәл урынында зур француз яулык. Баш яулыгы өстеннән ябынып йөриләр.* М. Фәйзи.

◇ **Баш аву** — башның бер ягы авырту (ырымчылар телендә). [*Мәгъри — Айсылу турында:*] *Башы сызлыймы, биле тотамы, ниши? Теге көнне бик миен дә селкеттеләр. Башы ауса да аугандыр. Тастымал салып үлчәргә кирәк.* Н. Исәнбәт. **Баш авыраю** — фикер томаланып, баш авырту. *Миңлениса карчык исерекне тагы бер кат җентекләп карагач, куркудан күз аллары караңгыланып, башы авыраеп китте.* С. Рафиков. **Баш авырттыру** — кирәксез һәм авыр чишелешле мәсьәләкую; тинтерәтү. *Кайберсе кыска кием кию, мыек үстерү, чуксыз кәләпүштән йөрү дөресме дип, кирәкмәгән* [*сораулар*] *илә баш авырттыра.* Ш. Мөхәммәдев. **Баш(ны) алу** —1) баш(ны) кису. [*Җирән — атка:*] *Синең өчен хан тагын минем башымны алсынмы?* Н. Исәнбәт; 2) хөрмәт һәм түбәнчелек күрсәтеп, баш киемен салу. *Батыргали агайга бәгъзы белеш-таныш руслары очрап, баш алсалар да, Батыргали агай бүркен алмаенча, солдатлар кебек, честь бирепкенә үтә иде.* Ш. Мөхәммәдев. **Баш(ны) алып китү (качу, олагу, таю һ. б.)** — араны өзеп китү, качып китү. *Шуннан, ди, ул* [*Хәмит*] *әйтә, олактым, ди, башны алып. Калмаган Әстерхан, Одесса, Семипалат, Ташкент.* К. Нәҗми. **Баш аркылы (аша) егу (ыргыту)** — татарча көрәштә тотрыгын югалткан көрәшчене кулбаш өстеннән алга яки артка аударып егу. *Теге «ектым» дип минем өскә ятарга теләгәндә генә, мин аны баш аркылы ыргытып та җибәрдем. Үзенең дә исе китте.* М. Гали. **Баш арты килү** — йөгерештә баш килгәннән кала икенче булу, икенче приз алу. *Бер йөгерештә катнашып, хәтта баш арты килгәнем бар.* Ф. Булатов. **Баш аша** — турыдантуры арадаш кешеләрне (бигрәк тә җитәкчеләрне) санга сукмыйча. *Чират бозып, баш аша товар алу. Баш аша боерык бирү.* **Баш бала** *диал.*— гаиләдә иң беренче бала, иң өлкән ул, кыз. *Шулай үсте таш кала, Шунда туды баш бала. Аның тәүге адымы, Әлмәт, синнән башлана.* С. Сөләйманова. **Баш белән уйлау** — дикъкать белән фикер йөртү. *Тел белән уйнауга караганда, баш белән уйлау яхшырак.* Мәкаль. **Баш белән җавап бирү** — берәр эш яки шарт үтәлмәгән тәкъдирдә, каты җавапка тартылырга тиеш булу. [*Микитенко:*] *Менә бу кошны губчекага илтеп тапшыр. Яхшы кара, аның өчен без барыбыз да башыбыз белән җавап бирәбез.* Ф. Хөсни. **Баш бетү** — 1) һәлак булу, һәлакәткә очрау. [*Вәлиев:*] *Мин ике аяклап аксаганмын. Әгәр дә сез булмасагыз, баш бетәрлек эшләр булыр иде.* С. Рафиков; 2) авыр хәлдә калу, уңышсызлыкка очрау. [*Төлке:*] *Бетте бит баш йөри торгач Тамак артыннан* А. Алиш. **Баш бирү** — 1) буйсыну, тынлау. *Кара айгыр, малайга баш бирмичә, әллә кая, чит якка таба бәреп алып кереп киткән.* Г. Ибраһимов. *Гобәйдуллинның нинди планнар корып ятуын кем белгән. Горур егет, баш бирә торган түгел.* Г. Ахунов; 2) берәр кимчелек яки кимлек белән килешү. *Тик шулай да баш бирәсе килми, Сындырасы килми күңелне.* Ш. Маннур. **Баш булу** — 1) ия булу, ихтыярлы булу, кулда тота алу. *Барча эшләрдән элек, баш бул, туган, үз иркеңә.* М. Гафури; 2) тыю, инсафка китерү.— *Син инде, Зөләйха килен, шул бер бөртек малаеңа баш була алмадың.* Г. Мөхәммәтшин; 3) биләп алу, басып алу. [*Куян:*] *Кем ул, кем минем ирманыма баш булмакчы була?* А. Алиш. **Баш бәйләнү** *гади с.*— начар кешеләр, җинаятьчел компания яки хәвефле эш белән бәйләнешкә керү. *Башың начарга бәйләнсә, Хур булуың билгеле.* Җыр. **Баш бөгү** — буйсыну; баш ию. [*Иблис*] *тәңрегә, мәгърурланып, баш бөкмәгәч, Диде алла: Ник миңа буйсынмыйсың?* Ш. Бабич. **Баш вату** — бик нык уйлану, кабат-кабат уйлап, берәр мәсьәләне чишәргә тырышу. [*Алсу исемле кыз*] *башын ваткан авыр сорауларга Китабыннан җавап эзләде.* М. Җәлил. **Баш ике булса** яки **ике түгел** *сөйл.*— үлем хәтәреннән кисәтеп яки шуңа сылтап әйтелә. *Кач, Марат, кач, тиз элдер, Башың ике түгелдер.* Ш. Маннур. **Баш ию** — 1) ризалык белдерү яки берәр эшкә, хезмәткә хәзер тору, шулай ук, рәхмәт яки хөрмәт билгесе итеп башны бөгеп алу. *Мин Хохловага берничә кешенең сәламләп баш июен күрдем.* К. Басыйров. *Ул арада Александра Андреевна да, киенеп чыгып, иренә баш иде.* М. Гали; 2) *күч.* ялынып, нәрсәне булса да үтенеп,

берәрсенең каршына бару. *Нишләргә хәзер! Аңарга [Фазылга] барып баш ияргәме: «Синең әшнәләрдән башка эш чыкмый»,— дияргәме?* С. Баттал; 3) күч. буйсыну. *Без, әлбәттә, бомбалардан куркып Баш ияргә хәзер тормыйбыз.* Ә. Ерикәй. *Станоклар да баш ияләр Безнең чибәр кызларга.* А. Алиш. **Баш йөртү** — фикер йөртү, уйлау. **Баш кагу** — ризалык белдереп, җөпләп яки хәбәр биреп, баш хәрәкәте белән ишарәләү. *Фатыйма --- бераз тын торды да гармоньчыга баш какты.* Г. Әпсәләмов. **Баш каеру** — читләшү, тайпылу, ятларга карау. *Килерсеңме бүген, көткән ярым, Әллә син дә баш каердыңмы миннән?* Қ. Тинчурин. **Баш калкыту** — 1) югарыга күтәрелеп үсә башлау, тураю, язылу. *Җир тын алсын пардан арынып, Баш калкытсын чирәм җирләр дә.* М. Җәлил; 2) баш күтәрү, хәрәкәткә килү. *Икенче рәт баш калкытып тора алмастай, Усаллыкның аслы-тамырын кузгатабыз.* М. Гафури. **Баш кату** — озак һәм ныклап уйлаудан уй тоткарлану, баш ару; мәсьәләне уйлап чишә алмас хәлгә килү. *Уй чуалды, катты баш. Нишләргә дә аптыраш.* Ш. Бабич. **Баш(ны) катыру** — кирәкмәгән сораулар, вак мәсьәләләр белән аптырату.— *Андый юк-бар сораулар белән бабаңның башын катырма инде син, улым.* М. Гали. **Баш(ны) кашу** — аптырап, нишләргә белми тору турында. [*Хәкимовлар*] *ирле-хатынлы эндәшми-тынмый гына урамга чыгалар да, аптырашка калып, башларын кашып тораларр.* Ш. Хөсәенов. **Баш кашырга да вакыт юк** — эш бик күп, эш тыгыз. [*Мостафа:*] *Вакыты шундый, туганкай. Баш кашырга да вакыт юк.* Ш. Камал. **Баш килү** — узышлы ярышта, йөгерештә беренче булып килү. *Баш килгән атны якыннан күрү өчен, халык, кычкырышып, аның артыннан йөгерешә башлады.* М. Гали. **Баш китү** — бәлагә тару; һәлак булу; үлемгә яки башка каты җәзага хөкем ителү. *Ни зыян бар: изге юлда Мәңгелеккә китсә баш.* М. Гафури. *Егет өчен егет кеше Баш китәрлек эшләр башкара.* Ә. Фәйзи. **Баш кушу** — берәрсенә уртакка керү, союз ясау. *Сезнең белән инде баш кушабыз Гомер буйларына кирәккә.* Җыр. **Баш(ны) кую** — 1) ял итү яки иркенрәк урнашу өчен урын эзләү. *Кая гына башым куйсам да, Кайгы талый йөрәк итемне.* М. Җәлил; 2) корбан булу, һәлак булу. *Күпләребез вакытсыз баш куйдылар.* Н. Гобәй. **Баш кысу** — башак чыгару. *Арышлар баш кысып, серкәгә утырды.* Г. Ибраһимов. *Менә бу бодайлар нинди шәп үскәннәр, Һәммәсе дә бертигез булып баш кысканнар.* М. Гафури. **Баш күккә (түбәгә) тию (тия язу)** — бик нык шатлану, сөенү, куану. *Мәүлиянең башы түбәгә тия язды. Кайтышлый дәү әниләренә керергә, сөенечен алып чыгарга булды.* И. Гази. **Баш күрсәтү** — үсеп чыга башлау, тишелеп чыгу. *Хәсән яңа гына баш күрсәткән сакалын кырып, мыекларын төзәтеп җибәрде.* Ф. Әмирхан. **Баш күтәрү** — 1) йокыдан тору; 2) үсеп чыгу, баш күрсәтү. *Яз килә ---, җирләр ачыла, язның беренче котлаучылары—умырзаялар баш күтәрәләр.* Г. Әпсәләмов; 3) билгеле бер хөкүмәткә яки иҗтимагый тәртипкә буйсынудан баш тартып, көрәшкә чыгу, восстание ясау; фетнә оештыру. *Әйле хөррият, тагы кузгалыгыз — Баш күтәрмәкче була дошманыгыз!* М. Гафури. **Баш күтәреп чабу** — аеруча җилкенеп, гайрәтләнеп чабу (ат турында). *Алаша бераз юыртып күйгандай итә, ләкин озакка түгел, гел алай баш күтәреп чабып барырга туйга яки Теләче базарына бару түгел лә бу.* Ф. Хөсни. **Баш күтәрми(чә), баш калкытмый(ча)** — ял итмичә, тырышып, бертуктаусыз, тын да алмыйча.— *Җәй, кыш димим, баш күтәрми көч куям, бөтен эшеңне эшлим.* Т. Гыйззәт. **Баш ору** — 1) башны бәргәләү, баш белән сугу (кизәнеп сугу, айкап китереп бәрү). *Җир ярсыды күреп минем канны, Тал-тирәкләр, елап, баш орды.* М. Җәлил; 2) аеруча түбәнчелек һәм хөрмәт билгесе— кешенең аяк турысына бөгелеп баш ию. *Баш органнан муен сынмас.* Мәкаль. *Шул сәгать ул егет, хәрәкәткә килеп, Әбелхарисның аягына баш орып, ишектән чыгып китте.* Қ. Насыйри; 3) түбәнчелек белән үтенү.— *Барыбыз да тамгаларыбызны салып, патшага баш орып язылган үтенеч кәгазен шунда патшаның үз кулына тапшырырга дисеңме?* М. Гали; 4) башны терәү, баш кую. *Шәкертләр, башларын стенага орып, ындыр табагында сугарга әзерләнгән көлтәләр төсле, тезелешеп идәнгә яттылар.* Қ. Тинчурин. **Баш очы** — 1) яткан гәүдәнең баш түбәсе турысы, баш тирәсе. *Хазбулат йоклый, бизәкле зәңгәр халат кигән Разия аның баш очына баскан.* Г. Ахунов; 2) баскан гәүдәнең баш түбәсе турысындагы биеклек, һава; баш өсте. *Баш очыннан берәр чыпчык, карлыгач-фәлән «фырлап» очып китсә, ул [Актырнак], колакларын шомрайтып, яткан җиреннән сикереп торып, кошны куып китә.* М. Гали. **Баш очына болыт җыелу** — хәвеф-хәтәр күбәю, кайгы-хәсрәт, борчулар арту. *Тәзкирә әнисен тыныч ландырырга тырышып караса да, Галимә түтинең баш очына җыелган болытлар алай тиз генә таралмадылар.* Ф. Хөсни. **Баш сабу** — оек, итек, башмак, бияләй кебек киемсалымның тузган башы урынына яңа баш кую. *Мин китәр вакыт җиткәч, Галимә әби оекка баш сабып бирде.* М. Гафури. *Ул [Камали] да иске куныч таба, шундый үк табан сала, баш саба, үкчә утырта.* Г. Ибраһимов. **Баш(ны) салу** — 1) авыру, ару яки кайгыдан башны түбән ию, сүлпәнләнеп, аска салындыру. *Көне-төне басуда йөреп ялыккан, башын салып ялкау гына бара торган ат --- юлдан бер читкә алып кереп китә.* М. Гали; 2) буйсыну, ялынып баш ию, багыну. *«Фәрештә син» дидем, хәлсез булып, алдыңа баш салдым.* М. Гафури; 3) гомерне корбан итү, көрәшеп үлү, баш кую. *Халык бәхете өчен башын салган Ящь коммунист Мулланур.* Г. Афзал. *Кадерле шул ул туган җир! Ай, кадерле... Күпме авылдашлар аның өчен чит җирләрдә башларын салдылар.* А. Гыйләҗев. **Баш та, күз дә** — эшне башкаручы да, күзәтүче дә яки башлык та. *Баш та, күз дә иде ул [Шәйхәттәр бабай] пионерларның кыр эшләрендә.* Г. Гобәй. **Баш та, түш тә** — барысына берүзе генә башлык. *Райсоюз складында асыл малның исәбе-хисабы юк. Анда баш та, түш тә мин.* Б. Камалов. **Баш тарту** — каршы килү; кире кагу, кабул итмәү. *Печән чаптылар, урак урдылар, ашлык суктылар, Фәхри бу эшләрнең берсеннән дә баш тартмады.* Ә. Исхак. **Баш ташлап** — 1) бернигә дә (мәсәлән, материаль кыенлыкларга да) карамыйча. *Хәдичәсе аның [Сәләхинең] яратып, баш ташлап сөйгән.* С. Хәким; 2) киреләнеп, чәпчеп, үҗәтләнеп. *Нәбиебез кинәт кенә баш ташлап, бик яман эчүгә сабыша.* Р. Төхфәтуллин. **Баш ташлау** — башаклар бөгелеп, сынып төшә башлау (башаклы, башлы үсемлек культуралар турында). *Вакытында урылмаганлыктан баш ташлый башлаган игеннәрне күреп йөрәк әрни.* Ф. Хөсни. **Баш тоту** *гади с.* — жирәбә салу, шобага салу. **Баш тубал булу** — баш авыраю, баш ару — ми арудан аңгыралану, миңгерәүләнү. *Көн эчендә кырык кырланам, Башым тубал була уйлардан.* Ш. Маннур. **Баш тыккысыз (тыга алмассың, тыгарлык түгел)** — 1) бик тыгыз, җайсыз. *Баш тыккысыз чират.* □ *Сыеп булмый хәзер иске клубка, нефтьчеләр дә килсә, бөтенләй баш тыга алмассың.* Р. Төхфәтуллин; 2) куе (урман һ. б. турында). *Баш тыккысыз ешлык.* **Баш төзәтү** — күп эчүдән булган баш авыртуын басар өчен, беркадәр вакыттан соң тагын бераз исерткеч эчү. **Баш(ны) төртү** — 1) йокыга яту; бераз ял итеп, йоклап алу. *Хәер, ерак юлдан соң чак кына баш төртеп алу зыян итмәс.* Ә. Еники; 2) *к.* баш калкыту (1 мәгъ.). *Талларда көмеш песәйләр, Үлән баш төртеп ята.* Ш. Маннур; 3) башны берәр якка борып яки иеп күю. *Бия, башын төртеп, көч-хәл белән атлый.* И. Гази. **Баш түбәсе** — 1) кеше башының түбә өлеше. *Гарәфи абзый да, бик үк картаймаса да, шактый олыгайган. Баш түбәсе пеләшләнгән, чигә чәченә чал кунган.* Г. Әп-

сәләмов; 2) баш турысындагы биеклек, һава; зенит. *Һәр көн саен минем баш түбәмнән Очкыч очып китә еракка.* А. Алиш. **Баш түнү** — миңгерәүләнү, баш тубал булу. *Шәйхетдиновның судтан соң атна буе башы түнеп йөрде.* И. Гази. **Баш чатнау** — бик каты баш авырту. *Минем баш чатный, колак шаулый, күз алдым караңгыланып тора, алга барырлык хәл юк иде.* М. Гафури. **Баш чыгару** — башаклану, баш кысу. *Басуларда арыш серкәләнә, Баш чыгара инде солылар.* Г. Афзал. **Баш чыңлау** — к. колак чыңлау. [*Карчык*] *тынгы бирмәде. Яңа вакыйгалар сөйләп, --- баш чыңлавымны көчәйтте генә.* Ф. Кәрим. **Баш чүмече** — башның йөзгә тискәре ягындагы сферик калкулык. *Баш чүмече йомры — сүзе тугры.* Әйтем. **Баш югалу** — гомер киселү, баш бетү; мәгънәсезгә һәлак булу. *Егетләрдән берсе, авыр гына көрсенеп: — Баш югала торган юлга чыктык,—* [*диде*]. К. Нәҗми. **Баш югалту** — баш әйләнү, ни эшләргә белмәү, югалып калу, аптырап калу. *Никах-туй көнендә кызлар башларын югалтучан булалар. Ни кияргә, ничек бизәнергә белми йөдәп бетәләр.* Г. Ибраһимов. **Баш ягалау** *диал.*— (берәр төрле эшне) башлап кую, тотынып карау. *Хәер,* [*Хәкимовлар*] *бер якшәмбе көнне, урамга пычкы-балта күтәреп чыгып, утынны кисә башлау өчен баш ягалап та караганнар иде.* Ш. Хөсәенов. **Баш ярылып, күз чыгу** — бәла-каза килү, бер-бер хәл чыгу. *Бер көннән баш ярылып, күз чыкмас. Килгән-килгән, җиренә җиткереп кайтырсың.* А. Гыйләҗев. *Нәрсә шулкадәр башыңны игән булдың, баш ярылып, күз чыкмаган бит!* М. Хәсәнов. **Баш әйләндерү** — 1) тинтерәтү, аптырату, фикерне чуалту. *Исак, алардан* [*сезонниклардан*] *буш мичкәләр күчертеп, калдык тозларны бер җирдән икенче җиргә ташытып, байтак башларын әйләндерде.* Ш. Камал; 2) масайту. *Бу хисапның* [*үтерелгән фашистларның саны*] *көннән-көн арта баруы Әхтәмовның үз-үзенә ышанычын арттырды, ләкин аның башын әйләндермәде.* М. Максуд; 3) үзенә багындыру, кызыктыру, табындыру, исен китерү. *Утлы кара күзләрнең ягымлы матурлыклары егетнең башын әйләндерде.* Қ. Тинчурин. **Баш әйләнү** — 1) кайбер гадәти булмаган шартларда кешенең үз торышын тоюы тотрыксызлану. *Ул* [*Газинур*] *югары менгәндә баш әйләнмәсен өчен аска карарга ярамаганлыгын белә иде.* Г. Әпсәләмов; 2) төрле хисләргә — шатлык һ. б. бирелү сәбәпле, кешенең үз-үзен белештерү сәләтен зәгыйфьләнү; исерү. [*Шәвәлинең*] *куянудан җиңелчә башы әйләнгәндәй булды.* С. Рафиков. *Күбесенең --- фикерләре бутала, телләре бәйләнә, башлары әйләнә башлады.* А. Алиш; 3) фикер чуалу, аптырашта калу. *Бик озын, бик буталчык тел белән язылган инструкцияне алгач, Фәсхинең чынлап та башы әйләнде.* Ф. Сәйфи-Казанлы; 4) үз хәленне бәяләүдә ялгышу; масаю. *Мактаудан баш әйләнү. Уңышлардан баш әйләнү.* **Баш өсте** — *кер. сүз мәгъ.* хезмәт күрсәтүгә хәзер торуны белдерә. *Шундый шат, шундый ачык йөзле ул* [*Орлова*] *хәзер, ни әйтсәң дә, «баш өсте» дип кенә тора.* Қ. Нәҗми.— *Баш өсте, гөләбем, йөгерәм! — диде Газинур һәм чиләкләр шылтыратып коега чапты.* Г. Әпсәләмов. **Баш өстеннән йөрү** — к. башка менү. *Аттай таза шәкертләр бәләкәй арык хәлфәнең тәмам башы өстеннән йөриләр иде.* Ә. Еники. **Баш өстеннән карау** — башкаларны санга сукмау, үзен зурсыну, һавалану. [*Касыйм*] *бөтен кешегә баш өстеннән карап йөри. Акыллы баш!* Г. Ахунов. **Баш җиту** — аңлый алу, төшенү. *Шәрәфи карт түзмәде, бер сорау бирде: — Барысын да аңладык, Батырша энем! Тик менә бер әйбергә генә башым җитми. Нәрсә ул «Якты сукмак»?* Қ. Нәҗми. **Башка ишәк (ат, тай) тибү** — аңгыраланып калу, юләрләну мәгънәсендә әйтелә.— *Бакча кирәкми дип, бакча зарарлы дип әйттемме икән мин? Алай дип әйтергә минем башыма ишәк типмәгән.* И. Гази. [*Нурый:*] *Кысыр агачларыгыз янында умарта асрарга башыма тай типмәгән бит минем.* Қ. Нәҗми. **Башка йөгерү** — хәмер, аракы яки никотин кебек исерткеч нәрсәләрнең, шулай ук көчле хиснең тәэсире башка, баш миенә таралу турында. *Бал Галәк бабайның башына шактый көчле йөгерде, ахрысы.* Г. Әпсәләмов. **Башка кабу** — башны авырттыру, башка тию (эсселек, ис яки шау-шу, ыгы-зыгы турында). *Агачлар, бу бинаны үзләренең челтәрле күләгәләре белән кояшның башка каба торган эссесеннән саклап, җиңел вә рәхәт салкынлык һәм ял итү урыны ясыйлар иде.* Ф. Әмирхан. *Башка каба эфир, кан исе, әйтә алмый сабый сүзләрен.* Ф. Кәрим. **Башка килү** — берәр уй, фикер туу, ният барлыкка килү. *Бервакыт минем башыма бик кызык бер фантазия килде.* Ф. Әмирхан. *Ундүрт яшькә җиткәч, театрга бару фикере башыма килде.* М. Гали. **Башка китү, башка йөгерү** — исерткеч тәэсире сизелү, исерү. *Азрак эчкәч, башка киткәчтен пирәш,— Кемгәдер ул* [*бай*] *иске серне итте фаш.* Г. Тукай. **Башка менү (менеп атлану, менеп таптау һ. б.)** — артык узыну, чыгырдан чыгу.— *Йомшаклык күрсәтсәң, башыңа, мәсәлән, менеп утыралар.* Ф. Әмирхан. **Башка сугу** — 1) күңелгә бик авыр тәэсир итү. *Бу хәбәр Сәхипнең башына сукты, ул аптырады, ләкин тышка чыгармаска тырышты.* Г. Ибраһимов; 2) катгый рәвештә тәртипкә чакыру, кирәкне бирү.— *Нигә кулакларның башына сукмыйсыз?* Г. Бәширов. **Башка (башына) сыймау (сыешмау, сыйдыра алмау)** — аңлый алмау, аңлап җитмәү. *Сәфәргали Зәйтүнәнең киявгә чыгарга ризалыгын берничек тә башына сыйдыра алмый.* Ф. Хөсни. **Башка төшү** — (бәлагә, кайгы-хәсрәткә һ. б.) дучар булу. *Башыма төшкән хәсрәтне күтәрә алмам шикелле тоелган иде.* М. Максуд. *Кеше хәлен кеше белми Үз башына төшмәсә.* Җыр. **Башка җиту** — 1) берәр начар шөгыль нәтиҗәсендә яки тырышып эзәрлекләү, сагалау соңында һәлак итү (үтерү). *Комсызлык башка җитә.* Мәкаль. *Әхтәмов, яшеренеп, сабырлык белән күзәтеп ятты һәм кичкырын инде теге фрицның башына җитте.* М. Максуд; 2) юкка чыгару, бетерү, жую. *Менә кем икән ул явыз карак, Сөт, каймакның башына җитүче.* Һ. Такташ. **Башны ашау (жую, җыю)** — бетерү; юк итү; бик зур һәлакәткә дучар итү; үтерү. *Шушы авылдан чыкканда Ашадылар башымны.* Бәет. *Кабахәтлекләрнең барсы Иргали кулы белән эшләнә. Ах, без ничек шуның башын җыя алмадык!* Ф. Бурнаш. **Башны кырын салу** — уйга бату, боегу яки үпкәләү. *Тубал, башын кырын салып, бу дөньядан ваз кичкән.* И. Гази. **Башны (нәрсәгә, нәрсәлеккә) салу** — к. салышу. *Башны тилегә салу.* □ [*Шөпшә*] *ярты көн бал җыйса, шунда ук аны ашап бетерә барган. Башын шундый ялкаулыккка салган.* А. Алиш.— *Синең гыйшкың уты белән яну аркасында укуга да күңел бирә алмадым, ахырысында башымны диванага салып, кайтырга мәҗбүр булдым.* Т. Гыйззәт. **Башны ташка бәрү (ору)** — 1) соң дәрәҗәдә ярсып йолкыну.— *Эх-х, адәм көлкеләренә калуым шушыдыр инде,— дип, башын ташка бәрердәй булды Фирдәвес.* М. Хәсәнов; 2) *юкл. форм.* «файдасызга көчәнеп эш чыкмый» мәгънәсендә әйтелә. *Бичара Солтангәрәй моңысы белән дә килешергә мәҗбүр булды. Килешмичә, кая барасың? Башыңны ташка орып булмый ич.* Ш. Еникеев. **Башны түбән салу** — күңел төшенкелегенә бирелү, җебеп төшү турында. *Куркынып башны түбән салу үлемнән сакламас.* М. Гафури. **Баштан ашу** — чиктән тыш күп булу, артык күбәю. *Шомлыгым баштан тәмам ашкан икәндер, белмәдем.* Һ. Салихов. **Баштан кичү (узу, үтү)** — авыр вакыйгаларга дучар булу, очрау, кыенлыклар күрү. *Мин дә ата баласы ич, кешеләр башыннан кичкән михнәтләр минем баштан да кичкән.* Ф. Хөсни. *Каравыл өченең сәндерәсендә Шәфыйк бабайның башыннан узганнарын тыңлап ятканнар искә төшә.* М. Гали. **Баштан сыйпау** — йомшак мөнәсәбәттә булу (күбрәк очракта юклык формасында). *Секретарьның башыннан сыйпамаганнар, әлбәттә. Каты шелтә*

чәпәгәннәр үзенә. Р. Төхфәтуллин. *Башыннан байтак сыйпадык без аның* [*Баязитның*]. [*Инде*] *ныгытып сөйләшербез.* Б. Камалов. **Баштан чыгару** — 1) ниятtән ваз кичү; берәр уй-фикерне онытырга тиеш булу; оныту. *Уен дигән нәрсәне хәзгр бөтенләй башымнан чыгарып ташладым.* М. Гафури; 2) *к.* уйлап чыгару. **Башы белән** *диал.*— 1) бөтенләйгә, тулысынча һәм яңадан кире кайтармаска, бурычка гына түгел. *Бүрегә бирсәң — башы белән!* Мәкаль; 2) (фәлән) кеше булуына карамастан. *— Әй, куй әле, карт башың белән юк-бар артыннан йөрмә.* К. Тинчурин.— *Әнә Гөлҗиһан, тол хатын башы белән нинди өй җиткезде!* Р. Төхфәтуллин. **Башы йомры** — берәр өлкәдә башлы, зиһенле. [*Бәкер:*] *Ничек, этиең кайда эшләгән дип сорадылармы? Сорарлар. Аларның* [*завкомның*] *башы йомры.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Башы (берәр билгеле җирдән) кайтмый торган** — берәр авыр яки мәҗбүри эш урыныннан котыла алмый, һәрвакыт шуңа әләгә торган. *Башы олаудан кайтмый торган ат.* □ [*Миңнәхмәт*] *— шахтадан башы кайтмый торган нәрсә шунда.* Г. Толымбай. **Баш(ы) чыкмау** — берәр бәладән, озакка сузылган кыенлыктан котыла алмау турында. *Тик бервакыт аның* [*Мишаның*] *башы кара тактадан чыкмый башлаган.* Г. Бәширов. **Баш(ы) яшь** — «тәҗрибә яки дәрәҗә җитенкерәми, ул эшкә хакы юк» мәгънәсендә әйтелә. *Карт --- таягы белән идәнгә шалт сукkан да: — Мине имтихан тоттырырга синең башың яшь әле! — дип --- чыгып киткән.* И. Гази. **(Үз) башына** — (үз) һәлакәте юлына басарак, хәтәрле тәвәккәллеккә барып, бәхетсезлегенә каршы. *Башына булгыры.* □ *Ләкин дошман үз башына шаша.* Ә. Ерикәй. **Башына тау төшкән кебек (шикелле)** — бик зур бәла-казага очраган, дучар булган кебек. *Солдат, башына тау төшкән кебек, каты сулап куя.* Г. Ибраһимов. **Башында (башта) җил уйнау** — акыл белән эш итә белмәү, җитди уйлый белмәү.— *Юләр кыз син, синең башыңда җил уйный.* Г. Әпсәләмов.

БАШАГАЧ *и. диал.* Кабер ташы урынына куелган багана. *Каберләрнең күбесе искереп, тузып беткәннәр. Кайсыларының ташлары кыйшайган, кайсыларының башагачлары бөтенләй җиргә ауган.* Г. Иделле.

БАШАК *и.* 1. Кыяклы үсемлекләрнең сабак очында озынча булып укмашып утырган орлыклар теземе. *Башаклар шаулыйлар кырларда, Дулкыннар уйныйлар диңгездә.* Ә. Ерикәй. *Бармак юанлыгы зур башакларын күтәрә алмый башларын җиргә игән озын арышлар, бәбкәләргә, чүмәләләргә әйләнеп, басуны чуарлыйлар.* М. Гали.

2. Кайнар суга башаклы салам турап, он яки көрпә болгатып әзерләнгән мал азыгы. *Хуҗа атына башак болгатып бирә икән, сыеры да ат янына килә, ат ачудан башын чөя, шомырая, авызындагы башакны чәчә, комсызланып ашый.* С. Рафиков.

3. *иск.* Борынгы коралларның үткен тимер очы. *Ук башагы. Сөнге башагы.*

Башакка тулу — башактагы ашлык бөртекләре үсеп тулыша башлау. *«Алка күл» кырларындагы игеннәр башакка тула башладылар.* И. Салахов. **Башакка утыру**— игеннәрдә башак формалашу. [*Ашлык*] *адәм ышанмаслык мәртәбә буйга да үскән, башка да (башакка да) искиткеч дәрәҗәдә утырган иде.* Г. Ибраһимов.

БАШАКЛАНУ *ф.* Баш чыгару, башак кысу. *Җәелә кырда иркен океан сыман Башакланып яткан арышлар.* Ш. Мәдәррис. *Безнең иген хәзер башакланып тора, ә боларныкы әле яңа гына җирдән күтәрелеп бара.* Г. Иделле.

БАШАКЛАП *рәв.* Башак берәмлегенчә санап. [*Ашлык күләмен*] *алай көлтәләп, башаклап ук күрсәтмәсәң ярамыймыни?* И. Гази.

БАШАКЛАУ *ф. иск.* Ашлыкны урмыйча, башакларын өзеп кенә җыю. *Арыш башаклау.*

БАШАКЛЫ *с.* Башагы булган. *Башаклы үсемлекләр.* // *и. мәгъ. күпл.* **башаклылар.** Кыяклылар семьялыгыннан бертөркем үсемлек төрләре (арыш, бодай, арпа һ. б.).

БАШАНТАЙ *и. диал.* Кыскарак оекбаш. *Аякларымда ак йоннан бәйләнгән башантай.* Ф. Кәрим.

БАШАРКАН *рәв. сөйл.* Баш аркылы, баштүбән килеп. *Аглар кешнәп җибәрәләр, чабып барган җирдән пуля тиеп авып калалар, башаркан егылалар.* Сов. әд.

БАШАЯК *рәв.* 1. Бөтенләйгә, тулысынча, тәмам. *Мин башаяк риза булдым.* Г. Ибраһимов. *Әхмәтҗанның бу репликасы Гафине башаяк чыгарыннан чыгарды.* Ф. Хөсни.

2. *кис. функ.* **башаягы.** Нибары, бары тик. *Крестовников, --- хатынга башаягы утыз сум акча биреп, җаваптан котылды.* Ә. Фәйзи.

3. Четерекле эш яки бәлачел кеше турында: «шуннан тизрәк котылырга кирәк» мәгънәсендә әйтелә. *Бәладән башаяк.* □ *Шуннан соң инде, «тавышыннан башаяк!» дип, терлек азыгын иң элек аңа* [*Хәдичәгә*] *китерә торган булдылар.* М. Хәсәнов.

БАШ-АЯК *җый. и.* 1. *сөйл.* Бөтен гәүдә, сан. *Башаягы исән-сау.*

2. Суелган малның башы һәм аяклары (түбән сортлы ит). *Өйдә баш-аяк боткасы пешкән иде инде.* А. Расих.

◇ **Баш-аягы белән** — бөтен барлыгы, җаны-тәне белән. *Һәм егет ялгышмады, - - - кыз аңа башы-аягы белән гашыйк иде.* М. Әмир.

БАШАЯКЛЫЛАР *и.* Моллюскларның иң югарыгы классы, кальмар, каракатица, сигезаяк кебек диңгез хайваннары шул класска керәләр. *Бу моллюскларның башы тирәли кармавычлар үскән, шуңа күрә аларны башаяклылар дип атаганнар.* Үтк. зам. сәяхәт.

БАШБАТА *и. диал.* Язулы кабер ташы. *Мазар зиратына барып башбаталарны укып кара, анда әкәмәт ташлар бар.* Э. Касыймов.

БАШБАШТАК *с.* Гомуми тәртипкә буйсынмаучан, теләсә нәрсә эшләүчән, үзбелдекле. *Башбаштак тәкәгә болын тар.* Мәкаль. / *и. мәгъ. Башбаштакка закон юк.* Әйтем.

БАШБАШТАКЛАНУ *ф.* Үз белдеге белән эш итү, тыйнаксызлану, закон яки тәртипкә буйсынмау. [*Мәрьям Зәйнәпкә:*] *Агаларыңның безне елатканнары җитмәгән иде, син дә башбаштакланып йөреп безне адәм көлкесенә калдыр.* Ф. Әмирхан.

БАШБАШТАКЛЫК *и.* 1. Башбаштак булу сыйфаты. *Революциянең --- мәгънәсе — халыкны аерым шәхесләрнең башбаштаклыгыннан азат итүдә.* А. Расих.

2. Тәртипсезлек, рәтсезлек. *Тәтешнең байлары, офицерлары, караклары, хулиганнары акларга ияреп киткәнлектән, калада һичбер төрле башбаштаклык булмады.* К. Тинчурин.

БАШ-БАШЫ *җый. и.* Озынча предметның ике очы, ике башы (берьюлы күз алдында тотылганда әйтелә). [*Гайнижамал*] *ике тастымалны бергә үреп, баш-башларын әйбәтләп төйнәде.* И. Гази. *Чесноков баш-башы челтәрле озын ак сөлге өстенә куеп күпереп пешкән зур бөтен ипи тоткан; ипи өстендә савыт белән тоз.* Г. Гобәй.

БАШВАТКЫЧ *и.* Фикер күнекмәләре сыйфатында уйлап чыгарылган һәм тапкырлык, зирәклек таләп итә торган төрле табышмаклар, мәсьәләләр, сораулар. *Кайчагында бабай --- безгә дә кечкенә генә эшләр күшып яисә башваткычлар биреп калдыра иде.* Г. Гали. // *күч.* Озак һәм ныклап уйлап кына хәл ителә торган мәсьәлә, проблема, четерекле хәл. *Бераз читкәрәк китеп, акылын башына туплау белән, Вафин өчен беренче башваткыч — кайда тукталу мәсьәләсе килеп басты.* Ф. Хөсни. / *с. мәгъ. Мин бу юлы да аны* [*егетне*] *берәр башваткыч табышмак бирер дип уйлаган идем.* А. Шамов.

БАШИМӘС *с.* Үзсүзле һәм горур, буйсынып эш итәргә яратмый торган, үз дигәнендә нык торучан. *Ирек сөюче, башимәс холыклы --- Кылычбай җырлый иде*

моны. Ш. Маннур. *Бикбулат --- аның* [*кызының*] *үзсүзле башымәс булуын ошатмый иде.* Г. Бәширов.

БАШКА *с.* **1.** Икенче төрле, үзгә, бүтән; бу түгел. *Үз канатым булып очмый торсам, Миңа башка канат кем бирер?* М. Гафури. *Бөкмик башны, түкмик яшьне— Хәзер башка заманнар.* Н. Исәнбәт. / *и. мәгъ. Башкаларга берни түгел, Сиңа бетә хәлләрем.* Жыр.

2. Аермалы, икенче төрле. *Телләребез башка, теләкләр бер, Эчтә кайный көрәш ялкыны.* М. Гаяз. // *рәв. мәгъ.* Аерым, үзе генә. *Эт тапса, башка ашар, егет тапса, бергә ашар.* Мәкаль.

3. *бәйл. функ.* Фигыльдә белдерелгән эш, хәл яки хәрәкәтнең чыгыш килештәге билгеле бер сүз белдергән нәрсәдән аерым үтәлүен белдерә. *Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган.* А. Алиш. *Уйнамыйм да, җырламыйм да Син дускаемнан башка.* Жыр.

Башка чыгу — к. башкалану (2 мәгъ.). *Яшь мишәр дигәнем, әле яңарак кына атасыннан башка чыгып, үзенә аерым тормыш кора башлаган.* Ф. Хөсни.

БАШКА-БАШКА *с.* Аерым-аерым, үзенә аерым, һәркайсы үз башына. *Әбиләр дә безнең башка-башка, Бабайлар да безнең башкадыр.* Х. Туфан.

БАШКАЛА *и.* Дәүләтнең, илнең яки өлкәнең, административ берәмлекнең үзәк шәһәре, башлыча хөкүмәт органнары урнашкан шәһәр; пайтәхет. *Кремльнең зур сәгате башкалада Унике тапкыр санап сукты чаңын.* Қ. Нәҗми. *Казан каласы таш кала, Безнең сөйгән башкала.* Ш. Маннур.

БАШКАЛАНУ *ф. диал.* **1.** Башка төрлегә әверелү. *Бозылган чәчкә исе, башкаланган.* Ш. Бабич.

2. Төп гаиләдән яки хуҗадан аерылып чыгу, аерым яши (эшли) башлау. *Ахыр чиктә Гыйлемдар, үзенә тигән өлешен дә этисеннән тулысынча даулап алып, бөтенләй башкаланды.* М. Шабай. *Гайнулла карт аңа итек ямау өчен кирәкле корал бирде, сумала, җеп бирде, һәм көннәрдән беркөнне Солтангәрәй башкаланып чыкты.* Ш. Еникеев.

БАШКАЛЫК *и.* **1.** Аерымлык; аерма, үзгәлек. *Гайнетдиннең хәрәкәтендә көндәгегә караганда башкалык бар иде.* М. Гафури.

2. *к.* каршылык. *Аннан соң Габделкаюмны укыту турында да семьяда фикер башкалыклары килеп чыкты.* М. Гали.

БАШКАРМА *с.* Берәр эшне, планны, законны даими рәвештә башкарып, үтәп бара, тормышка ашыра торган. *Хезмәт ияләре депутатлары Советының башкарма комитеты.*

БАШКАРУ I *ф.* **1.** Эшләнәсе эшне үтәү, үтәп чыгу. *Кушканны башкару. Хезмәт башкару.* □ *Эх, азмыни соң колхозда кичектермәс эшләр. Берүзенә дә ике-өч кеше эшен башкарырга туры килә.* Ш. Мөдәррис.

2. Тамашачылар өчен уйнау, җырлау, сөйләү, бию һ. б. *Роль башкару.* □ *Мәдинә апа --- «Зөлхиҗә» һәм «Каз канаты» дигән мәшһүр җырларны башкарачак.* Ш. Қамал. *Дуэт — ике кеше бергә башкара торган музыкаль форма.* М. Җәлил.

БАШКАРУ II *ф. диал.* Үзгәрү. *Бу вакытларда авылның куренеше дә --- башкарган иде.* З. Һади. *Тукай үлгәннән соң, аңар мөнәсәбәт бераз башкарды.* Ж. Вәлиди.

БАШКАРУ III *ф. лингв.* Иярүче сүздән билгеле бер грамматик категориядә килүне таләп итү (иярүче сүз турында). *Татар телендә иярүче сүз белән иярүче сүзләрнең үзара бер-берен башкару очраклары да бар.* В. Хангилдин.

БАШКАРЫЛЫШ I *и.* Сыйфат ягыннан үтәлеш. *Программаның башкарылышы. Эшләнгән эшнең башкарылышы.*

БАШКАРЫЛЫШ II *и. лингв.* Башкару бәйләнеше. *Башкарылыш белән бәйләнеп тезелгән тезелмәләрдә җитәкче сүз яки иярүче сүз башкаручы дип, иярүче сүз башкарылучы дип атала.* В. Хангилдин.

БАШКАРЫНУ *ф. сир.* Ярдәм кирәк булса да, берәр эшне үзе генә үтәп чыгу. *Мәрьям абыстай, көндәге гадәте буенча,* [*иренең*] *аякларын салдырырга, киемнәрен чишендерергә «баш өсте» дип каршысына барып басса да, Сафый абзый --- дәшми-нитми үзе генә башкарынды.* Г. Толымбай.

БАШКАТЫРГЫЧ *с.* Башваткыч, четерекле, катлаулы. *Берсенә берсе бәйләнешсез бу башкатыргыч уйлар кайдан килеп болай сарылды соң әле?* Ф. Хөсни.

БАШКА'ЧА *рәв.* Башка рәвештә, бүтәнчә, икенче төрле (итеп). [*Үтәш:*] *Без башкачарак җырлый идек яшь чакта.* Қ. Тинчурин. *Ә менә теге үлчәүләр магазинының хуҗасы Потап Михайлыч бөтенләй башкача уйлый.* Ә. Фәйзи. / *с. мәгъ. Башка төрле. Башкача хәл.* □ *Патша кызларының башкачарак булулары мәгълүм инде.* М. Гафури.

БАШКАЧАЛАНУ *ф. диал. к.* башкару II. [*Галимәнең*] *иреннәре күгәреп, күзләре башкачаланып китте.* М. Гафури.

БАШҚИСӘР *и.* **1.** Кеше үтерүче, юлбасар. *Халык үче дошманнарны куып җитәр; Талаучының, башкисәрнең башын өзеп, Бар дөньясын тетәр, сүтәр, тузан итәр.* Ә. Ерикәй.

2. *күч.* Үтә чая, тәвәккәл, дуамал кеше. *Төрле дезертирлардан, матросның үзе әйтмешли, башкисәрләрдән торган отрядның үз авыллары тирәсеннән китәргә ризалык бирүе дә шикле иде.* И. Гази. / *с. мәгъ. Һади, иң гайрәтле, иң башкисәр егетләрне сайлап алып, доброволец булып киткән.* Э. Қасыймов.

БАШКОДА *и.* Иң башлап белешергә йөргән яучы; яучыларның башлыгы. *Шакиргә башкодалар Габдрахман карт кызы Қәлимәне димләргә тотындылар.* Ш. Әхмәдиев. *Латыйфага күзе төшеп йөри торган Хаттап дигән бер егет бар икән, кызны соратып башкода җибәргән.* Н. Исәнбәт.

БАШҚОРТ *и.* Башлыча Башкортстан АССРда яшәүче төрки халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Бу көрәштә син дә, Татарстан, Туганыбыз бөек рус та, башкорт та бар монда, үзбәк тә бар, Дан яңгырый шанлы сугышта.* Н. Баян. / *с. мәгъ. Башкорт теле. Башкорт әдәбияты.* / *җый. мәгъ. Ул* [*Шаһи*] *җиде-сигез еллар башкорт арасында тегү тегеп йөргән.* М. Гали.

БАШҚО'РТЧА *рәв.* **1.** Башкорт телендә. *Башкортча сөйләү. Башкортча язылган китап.*

2. Башкортларга охшашлы. *Без аның* [*яңа хәлфәнең*] *башкортча кысык кара күзләренә карап тордык.* Г. Гобәй.

БАШҚОРТЧАЛАП *рәв.* Башкорт телендә, башкортча. — *Әссәламегаләйкем, энем, һаумы,— дип тезеп китте башкортчалап Кинҗәбулат.* Ш. Маннур.

БАШҚОРТЧАЛАШТЫРУ *ф.* Башкорт теленә тәрҗемә итү.

БАШҚӨЛЛӘЙ *рәв. диал.* Алдан ук һәм бөтенләйгә. *Шәфинең бөтен татар-башкорт җирен башкөлләй немецка сатып җибәрүе көн кебек ачык.* Ш. Маннур.

БАШ-КҮЗ *җый. и.* Баш һәм күзләр (бергә алганда). *Балык бирсәң, бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир.* Мәкаль. *Бергә эшләп йөргән ипташеңнең* [*атның*] *башкүзенә ничек сугасың?* М. Гафури.

◇ **Баш-күз алу** — аңга килү, айну; үзеңне иркен хис итә башлау, иркенәю. *Әсир Мөхәммәт погромчыларның божрасыннан көч-хәл белән ычкынгач та берникадәр вакыт баш-күз ала алмады.* Қ. Тинчурин. *Хәзер --- адәм баласы баш-күз алды: тырышып эшләгән кешенең тамагы тук.* М. Шабай. **Баш-күз тону** — үз-үзен белештермәү, шашыну. *Шуның артыннан ук, кара яңып, баш-күзе тонган --- Шакир килеп керде.* Ә. Фәйзи.

Баш-күз әйләнү (әйләндерү) — бик нык мавыгу, багыну (багындыру). *Бер тракторчы егет өйләнә, аннан бераздан бер бик начар кыз шушы егетнең башын-күзен әйләндерә башлый.* А. Расих. **Башны-күзне ташлау** — аңга килергә, уйлап карарга тырышмау. *Башта Корбый үзенең каян һәм нәрсә өчен йөргәненә хисап бирми, ул --- башын-күзен ташлап чаба иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БАШКҮКРӘК *и.* Буынтыгаяклылар гәүдәсенең баш һәм күкрәк урнашкан алгы өлеше (ул корсак өлешеннән кискен рәвештә аерымланып тора). *Башкүкрәктә буынтыклы ике пар (озын һәм кыска) мыекча, күзләр, авыз органнары һәм биш пар буынтыклы аяк була.* Зоология.

БАШЛАМ *и.* Әдәби әсәрнең башлангыч өлеше. *Әкият башламы.* □ *Башламдагы бу бер юл шигырьнең эчендә рефрен булып, кабатланып-кабатланып бара да, ниһаять, шигырь шул ук юл белән тәмамлана.* Х. Госман.

БАШЛАНГЫЧ *с.* **1.** Беренче, беренчел, баштагы. *Башлангыч мәгълүматлар. Башлангыч тикшеренү.* □ *Ул башлангыч еллар яңгыр сипкән Болытлардай агып үттеләр.* Ш. Маннур. // Өйрәнчек, күнекмәлек. *Башлангыч адымнар.* □ *Үзенең башлангыч әсәрләрендә үк инде Г. Камал әхлак сатучы булудан бигрәк, тормыш тәнкыйтьчесе булып мәйданга чыга.* М. Гали.

2. Беренче баскычтагы, иң түбәнге. *Башлангыч мәктәп.* □ *Башлангыч классларда уку миңа авыр булмаган иде.* Г. Галиев. // Нинди дә булса оешманың урындагы бүлеге (буыны) булып торучы. *Башлангыч партия оешмасы.*

3. *и. мәгъ.* Башлап җибәрелгән эш яки күренеш; яңалык. *Такташның социалистик башлангычны күрсәтүгә килгәндә ялгышкан чаклары да булгалады.* Х. Госман. *Валентина Гаганова башлангычына Татарстан нефтьчеләре арасында бораулау мастеры, Социалистик Хезмәт Герое М. П. Гринь беренче булып кушылды.* Соц. Тат.

4. *и. мәгъ.* Башланып китүнең төп чыганагы. *Әмма аксымны тереклек башлангычының да башлангычы иткән нәрсә азот икән.* М. Хәсәнов.

Башлангыч ярдәм — яралану, имгәнү, кинәт авырып китү очракларында кичектергесез кирәк булган дәва. *Башлангыч ярдәм күрсәтү.*

БАШЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* башлау (1—3 мәгъ.). *Эш башлану. Башланган пачка. Ясала башлану.*

2. Нәрсәнең дә булса башы, башлангыч, кереш өлеше үтәлү, беленү яки күренү. *Җәйге кызу эш көннәре башланды.* А. Шамов. *Безнең гомер матур урманнарда Май аедай матур башланды.* Һ. Такташ.

БАШЛАНЫШ *и.* Башлану дәвере, башлангыч. *Бу әле тик башланышы гына Без уйлаган гүзәл уйларның.* Ә. Ерикәй.

БАШЛАУ *ф.* **1.** Берәр эш яки шөгыльгә керешү. *Уен башлау. Эш(кә) башлау.* □ *Әминә --- бер нәрсә әйтергә теләп тә, кайдан башларга белми торган шикелле карап торды.* Ф. Әмирхан. *Сорап-нитеп тормый сүз башладым.* Ә. Исхак.

2. Продуктларны һ. б. тотарга, кулланырга керешү. *Бер көн алып кайткан Кузнецов чәен башларсың микән, әллә өченче көн алып кайткан Утәмеш чәен башлап карарбыз микән?* Ф. Әмирхан. *Дустым кайткан башкаладан, Коньягы бар башламаган.* Ш. Галиев.

3. *сир.* Юнәлтү, юнәлдерү; **күрсәтмә бирү, җитәкчелек итү.** *Сайлаек бер баш, ул безне Туғры юлга башласын.* М. Гафури.

4. *бәйл. функ.* **башлап.** Билгеле бер вакыт ноктасыннан соң, билгеле бер урыннан узып, шуннан ары якка. *Шул көннән башлап Габдулла мәдрәсәдә сторожлык хезмәтен үти башлады.* Ә. Фәйзи. // Билгеле бер ноктадан, тәнгәлдән билгеле бер дәвамлы рәттә торган күренеш яки нәрсәләрне санап киткәндә, еш кына, «га кадәр» (чаклы), «гача» кебек формалар белән парлашып килә. *Иртәдән башлап кичкә кадәр. Урманнан башлап авылга чаклы. Балалардан башлап картларгачы.* □ *Беренче батальоннан башлап иң арттагысына кадәр роталар агыла бардылар.* Г. Бәширов.

5. *рәв. мәгъ.* **башлап.** Беренче булып, иң элек. *Талип алдарак иде, шуңа күрә ул капкага башлап керде.* Ә. Фәйзи. // Башта, беренче мәртәбә. *Мәликә башлап бик тузынды, шулай да рөхсәт бирде.* А. Шамов. // Беренчедән, беренче чиратта. *Уңышым белән мин иң башлап Партиягә бурычлы.* М. Җәлил.

6. *ярд. ф. функ.* Эш яки процессның башлану чорында торганлыгын белдерә. *Басуларда матурлыклар бетә башлый. Кошлар кире ерак якка китә башлый.* М. Гафури. *Басмаларны алу өчен, матрослар озатырга төшүче халыкны куа башладылар.* А. Расих. // Эш-хәлнең беренче билгеләре күренү. *Сөйләшә башлау. Уйлана башлау.* □ *Безнең районда колхозларга йөрми торган бер агроном бар иде, шуны газетка язгач, көн-төн колхозларда йөри башлады.* Г. Әпсәләмов.

Башлап алып китү — эшкә, процесска җайлашып керешү. *Габдулла бер язды, бер бозды, башлап алып китә алмыйча, дәфтәр читләрен сырлап, чуарлап бетерде.* Ә. Фәйзи. *Башта булган гади уйлар белән Башлап алып киттем сүземне.* Һ. Такташ. **Башлап китү (җибәрү)** — *к.* башлап алып китү; эшкә тотыну. *Габделбасыйр, сүзне ничек башлап китәргә белмичә, бераз җавапсыз барды.* Ф. Әмирхан. *Без койрыкка тагылырга барыбыз да әзер — башлап җибәрүче юк.* И. Гази.

◇ **Башлап йөрү** — инициатива күрсәтеп, яңа эш яки мәсьәлә кузгатып йөрү; җитәкчелек итү. *Ә икенче көнне безне, башлап йөргән уникә кешене, пашпортларга «шайтан печате» сугып, [эштән] куып чыгардылар.* Ә. Фәйзи.

БАШЛАШ *с.* Җир башы билгеле бер мәйданга яки урынга чиктәш (җир участогы турында). *Габсаттарга [җир] Биби күленә башлаш иң әйбәт урыннан эләкте.* И. Гази. *Акбалчык чирәмлегенә башлаш иген җирләре булган кешеләр кыр эшләре чорында атларны чирәмлеккә тышаулап җибәрәләр.* С. Рафиков.

БАШЛЫ *с.* **1.** *күч.* **сөйл.** Акыллы, зиһенле, зирәк.— *Башлы малай булырга охшый ул, Шәйми малае.* Р. Төхфәтуллин.— *Бу машинаны уйлап табучы кеше бик башлы булган, ул да синең кебек төрлечә уйлаган.* А. Алиш.

2. Күп һәм эре башаклы, уңган. *Арыш үзе буйга озын, үзе бик башлы, эти бик шат.* М. Гафури.

Башлы кәбестә—1) тоташ, туралмаган кәбестә; 2) сабагында баш (3 мәгъ.) үсә торган кәбестә (гади кәбестә) сорты. *Башлы кәбестәнең калын һәм кыскарган сабагы була. Аны күчән дип атыйлар.* Ботаника. **Башлы суган** — суган башы өчен үстерелә торган суган сорты. **Башлы тастымал** — ике башы да (5 мәгъ.) чигүле тастымал. [*Вахит белән Мәхмүт*] *башлы тастымал белән билләрен буып --- кызыл йорт алдына киттеләр.* М. Гафури. **Башлы шикәр** — конус формасында коелган шикәр кисәге. *Сәмигулла абзый беразы ватып алынган башлы шикәрне күтәреп карады.* Ф. Әмирхан.

БАШЛЫК I *и.* Очлы формадагы баш киеме. *Кәрим мәхдүмнең башында җәйге каракүл бүрек өстеннән ука чуклы сары башлык.* Г. Ибраһимов. *Кызның ак башлыгыннан чыгып калган көрәнсу чәчләренә, озын керфекләренә сыкы ябышкан.* М. Хуҗин. // Тышкы киемнәрнең якасына беркетеп куелган һәм баш киеме өстенә киелә торган конус сыман каплама. *Газинур, башкалар кебек үк, ак комбинезонының башлыгын артка ташлаган.* Г. Әпсәләмов.

БАШЛЫК II *и.* **1. Берәр төркем,** оешма һ. б. ш. **башында торучы кеше, җитәкче, баш** кеше. *Делегация башлыгы. Хөкүмәт башлыгы. Яу башлыгы.* □ *Акыллы башлык түгел, акыллы — башлык.* Мәкаль. *Башлыкка баш оралар, үсенсә яки юаш булса, таш оралар.* Мәкаль. *Идәнгә дөп-дөп басып җыелыш өстәле янына ки-*

леп туктаучы кеше батрачком башлыгы Тимер иде. Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. Башчылык, хакимлек. *Халык берләшеп, --- бөтен башлыкны үз кулына алгач кына иркен булачак.* Урал.

Башлык итү (сөрү) — башлык булып тору. *Башчы башлык итәлсә ун көнлек эш бер көндә эшләнер.* Мәкаль. *Тимерләр башлык сөргән вакытта бер яхшы пычкылы станокны амбарга, чүпләр арасына кертеп ыргыткан булганнар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БАШЛЫКЛА'РЧА *рәв.* Башлыкларга, начальникларга хас булганча, баш кешегә охшатып. *«Түрә» булып алгач, Кармак сизелеп үк үзгәрде. Үзен чын-чынлап башлыкларча, җитди тота башлады.* Ш. Еникеев.

БАШЛЫ-КҮЗЛЕ: башлы-күзле булу (итү) — өйләнү, гаиләле булу (өйләндерү).— *Анаң синең башлы-күзле булып торуыңны теләмимени?* А. Шамов. *Галәк бабай тәлинкәсенә өрә-өрә сөйли иде: — Хәзер, әти-әниең исән чагында, үзеңне башлы-күзле иткәндә дә ярар иде, Газинур.* Г. Әпсәләмов.

БАШЛЫЧА *рәв.* Нигездә, күбрәк очракта. *Бу вазифаны [кунаклар каршылауны] башлыча Хөснетдин үтәде.* Ш. Камал. *Татар оригиналь музыкасы бу елларда башлыча җырлар, маршлардан торды.* М. Җәлил.

БАШМА-БАШ *рәв.* Бергә бер, бер данәгә бер данә. [*Хөсәен:*] *Булса — башма-баш, булмаса — кирәкми.* Ф. Бурнаш.

БАШМАК I *и.* Икенче яше белән барган мөгезле эре терлек. *Урамның ике ягыннан да көтүгә сыерлар, башмаклар кушыла торды.* Ш. Еникеев. *Яз көне бозаулаган байтак кына башмакны ай ярымшар чамасы сыерлар исәбеннән йөртмәделәр.* С. Рафиков.

Башмак тана — быел беренче мәртәбә бозаулыйсы яшь сыер. *Җәй җәйләгән, көзге уҗымнарда симергән, инде башмак танага әверелеп килә торган бу бозау шактый көч җыйган.* Ф. Хөсни.

БАШМАК II *и.* Кунычсыз аяк киеме. *Безнең әти,— ди Семен,— кышның озын кичләрендә чабата, башмак тукып, чәй-шикәргә акча эшли.* З. Бәшири. *Агач башмак хутта: тирән эчлесе һәм аяк башына гына эләктереп йөри торганы.* Г. Гобәй.

Башмак чабата — *к.* чабата башмак. *Фәхри бабай яңа башмак чабата ясап бирде.* М. Гафури. **Башмак шәриф** — 1) тәһарәт алганда, мәчеткә барганда киелә торган махсус башмак; 2) пәйгамбәр башмагы төшерелгән шамаил. *Контрлар өендә башмак шәриф булса, безнең өйләрдә Ленин рәсеме булсын.* М. Максуд.

БАШМАКЧЫ *и.* 1. Башмак тегүче, башмак тукучы һөнәрче. — *Миңа корал гына табып аласы, мин үзем башмакчы,— дип көлде ул [Габделвәли].* Ә. Фәйзи. *Навимов башмакчы булып эшли башлаганнан соң да байтак көннәр үтте инде.* Г. Әпсәләмов.

2. *иск.* Мәчеткә килгән кешеләрнең башмакларын саклап, мәчеттән чыгучыларга биреп торучы кеше. *Башыңа төшсә, башмакчы булырсың.* Мәкаль.

БАШМАКЧЫК *и. зоол.* Инфузорияләрнең бер төре. *Инфузорияләр — гади организмнар арасында иң катлаулылары, моңа инфузория-башмакчык мисалында ышанырга мөмкин.* Биология.

БАШМАКЧЫЛЫК *и.* Башмакчы һөнәре.

БА'ШНЯ *и.* 1. Махсус рәвештә биек итеп төзелгән корылма. *Маңгай тире түгеп, сабыйлар көче белән тутырган идек без ул елны силос башнясын.* Г. Галиев. // Архитектурада: манара. *Спас башнясы алдында җыелган халык шау килә.* К. Тинчурин.

2. Танкта, судноларда, су асты көймәләрендә ату кораллары урнаштырылган һәм броня белән капланган калку урын. *Артиллерия башнясы. Ату башнясы.*

БАШСЫЗ *с.* 1. Башлыксыз, командирсыз. *Башсыз калган гаскәр көтүчесез көтү төсле.* М. Җәлил.

2. *күч.* Уйламый эш итүчән.— *Бик башсыз нәрсә, катр китүдән дә курка торган түгел.* Г. Камал. / *рәв. мәгъ. Шәрифҗан, --- Федюшкин шикелле үк үткен дә, кыю да булырга тырышып, кайвакытларны артык башсыз кыланган иде.* И. Гази.

БАШСЫЗЛАНУ *ф.* Башсыз кылану, юләрләнү; урынсызга тәвәккәлләү. *Башсызланып йөрсәң, башсыз калырсың.* Мәкаль.

БАШСЫЗЛЫК *и.* Акылсызлык, ахмаклык; урынсызга тәвәккәллек. *Чуйков шикләнгәнен әйтеп куйды: — Юк, монда нинди дә булса бер сер бар. Безнең ипташлар мондый башсызлык эшләмәсләр.* Х. Садрый.

БАШТА *рәв.* Башланган дәвердә, иң элек, беренче чиратта, әүвәл, әүвәле. *Куянны күргәч тә куа башлама, башта кай якка качасын бел.* Ф. Кәрим. *Узыштыру өчен башта җәяүлеләрне, соңыннан атлыларны Ачасыр юлы белән ерак басуга алып киттеләр.* М. Гали.

БАШТАК *с. диал.* Тәртипсез, әрсез. *Атасы юкта ул баштак, Анасы юкта кыз баштак.* Мәкаль.

БАШТАН *рәв.* 1. *к.* башта. *Баштан без колачны алай зурдан җәймәдек, --- биш-алты колхоз арасында беренчелекне ала алсак, шуңа риза булмакчы булдык.* М. Гали.

2. Яңадан башлап. *Борын-борын заманда булган, ди, бер бәти, ул йөргән, ди, таштан, сөйлимме баштан?* Әкият.

БАШТА'НАЯК *рәв. сөйл.* 1. Бөтен гәүдәсе белән; баштан аякка кадәр. *Штаб начальнигы, --- аның [Газинурның] өс-башын тикшергән кебек, баштанаяк карап алды.* Г. Әпсәләмов. *Тузан --- ат аякларыннан, арба тәгәрмәчләреннән бөркелеп чыга да, сине баштанаяк коендырып --- бара.* М. Гали.

2. Баштан ахырга кадәр, тулысынча. *Әнисе кайткач, [нәни песи] барысын да баштанаяк сөйләп биргән.* А. Алиш.

3. *күч.* Бөтенләй, мөкиббән китеп. *Мирхәйдәр яшәүгә, яшьлеккә, табигатькә, тормышка, туган илгә баштанаяк гашыйк.* Г. Иделле.

Баштанаяк кораллы — сугыш кораллары белән бик нык коралланган. *Өй эченә баштанаяк кораллы, җирән чәчле, иләмсез зур сакал-мыеклы, кызыл кына белән буялган юлбасарлар тулдылар.* К. Нәҗми.

БАШТУК *рәв. сөйл.* Башта үк, иң баштан; беренче чиратта. [*Вәли Галигә:*] *Баштук мине тыңлаган булсаң, бу хәлгә төшмәгән булыр идең.* Г. Коләхметов.— *Хәйлә кылыйк, дуслар, ашыкмагыз, Сарылмагыз баштук кылычка.* Н. Исәнбәт.

БАШТҮБӘН *рәв.* 1. Башы түбәнгә түнтәрелгән торышта. *Рәхим --- лапас астына баштүбән салындырып аскан сарыкны тунап ята.* Ә. Еники. *Алтым тугызга охшады — Алтым баштүбән баскан.* З. Нури.

2. Мәтәлеп, мәтәлчек атып. *Яр башына басасың да, кулларыңны алга сузып, баштүбән суга ташланасың.* Л. Ихсанова. *Асылгәрәй --- кайвакытларда хәтта манарадан баштүбән сикереп төшәрдәй була.* М. Шабай.

Баштүбән килү (китү) — 1) мәтәлү; 2) *күч.* дөмегү, йөзтүбән китү (2 мәгъ.). *Баштүбән килгере дошман.*

БАШЧА I *и.* Әдәби әсәрнең яки әсәр бүлегенең төп атамасыннан соң язылган өстәмә атама. *Газетаның тышкы формасы укучыга тәэсир итәрлек булырга тиеш. Монда баш һәм башчалар (заголовки, подзаголовки), хәреф төрләре ярдәмгә килә.* Ш. Рамазанов.

БАШЧА II *и.* Үсемлекләрдә кечкенә баш (2 мәгъ.). *Тузганакның сары башчасы аерым чәчәк түгел, ә тулы бер чәчәкләр төркеме ул.* Робинзон эзл.

БАШЧЫ *и.* Башлап йөрүче, җитәкче кеше, башлык. *Башчы үрдәк алдан очар.* Мәкаль. *Байрак күтәргән солдат янының берсе, башчы булса кирәк, кулларын бутап бара, ара-тирә төрле командалар бирә.* С. Җәләл.

БАШЧЫЛЫК *и.* Башчы булу; җитәкчелек. *Башчылык итү.* □ [*Сугышчы:*] *Гаскәр көтә синнән башчылык, әйдә, улым, ачык ишектән!* Ф. Бурнаш. *Хәйрулла --- сәнәк фетнәсендә башчылык кылган.* Г. Ибраһимов.

БАШЫ-АКТЫГЫ *с.* Булганы шул, бердәнбер; соңтысы, иң соңгы данә.— *Я, улым, Ташъякның башы-актыгы түгел, тагын килербез, арысланның иң зәһәренә атланып әйләнерсең,— дип юатты әнисе Габдулланы.* Ә. Фәйзи.

БАШЫ-АХЫРЫ *и.* Иң соңгысы, беренче һәм соңгы мәртәбә булганы. *Өйләнүең уң булсын, башы-ахыры шул булсын.* Әйтем.

БАШЫБОЗЫК *и.* 1. Төрек сугышчысы, регуляр армиядә хезмәт итмәгән солдат. *Мансур Салихка карап үртәде: — Менә, чалмалы башыбозык булдың.* Ш. Усманов.

2. *күч.* Тиле батыр, шәрә батыр.

БАШЫННАН-АЯК *рәв. к.* баштанаяк. *Шәрәфетдин башыннан-аяк европача киемдә.* М. Фәйзи.

БАЮ I *ф.* Бату, офык артына китү (күк җисемнәре турында). *Яз җитсә, төн кыскарыр, көн озаер, Кояш та иртә чыгып, бик соң баер.* М. Гафури. *Әнә ничек кызарып байый кояш!* А. Алиш. *Ай урагы баемыйча Таң йолдызы калкырмы?* Жыр.

БАЮ II *ф.* 1. Байлык җыю; бай була бару. *Камилнең атасы --- сәүдә итеп, яхшы ук баеган.* Һ. Такташ. *Колхозлар белән бергә колхозчы агай үзе дә байый иде.* Г. Бәширов.

2. Мәгънәви яктан яки мәгънәви кыйммәте булган нәрсәләр белән тулылану. *Хәятым --- матурайды, баеды, язмыш тагы рәхимләнде.* Г. Ибраһимов. *Бу әсәр татар совет драматургиясендә комедияләр жанрының баеп килүен күрсәтә.* М. Җәлил.

БАЯ *рәв.* Күптән түгел генә, аз гына элегрәк.— *Бая елаган булсаң, хәзер менә җырла инде.* Ф. Бурнаш. *Ул песине бая гына күрдек, мыраулап йөридер иде.* А. Алиш.

БАЯГЫ *с.* Бая (яңа гына, күптән түгел) булган. *Солтанның чыраенда баягы куанычы күренми иде инде.* Г. Бәширов. *Нәкъ баягы җирдә — немецларның дзоты алдында нәкъ баягы кебек үк арлы-бирле атлаган яңа часовой йөренә башлады.* А. Әхмәт.

БАЯ'ГЫНАК *рәв. сөйл. к.* Бая. *Баягынак ул [Мортый], эшкә җибәрүләрен сорап, Хәнәфи абый янына кергән.* Г. Әпсәләмов. *Баягынак кайсыдыр: мәсьәлә ачык, янәсе, безнең өчен хәзер сугыш бетте, дигән иде.* И. Туктар.

БАЯГЫ'ЧА *рәв.* Баягы шикелле. *Аның [Бануның] күзләре тагын баягыча --- шаярулы, сынаулы карадылар.* Қ. Басыйров. *Рахманов инде безнең сүзләрне баягыча тыныч кына тыңлап утырмый иде.* М. Әмир.

БАЯЛЫЧ, БАЯЛЫШ *и. бот. иск.* Ак өянке, ак тал; тал үләне. *Баялычтан ут ал.* Мәкаль.

БАЯН *и.* Клавишлар (телләр) системасы катлаулы булган зур гармонь. *Малайга үзеннән дә зур баян китереп тоттырдылар. Ак төймәле, бака ягында да шундый ук ак төймәләр.* Ф. Хөсни. *Гармоньчы өстәл астыннан бозау буе баянын тартып чыгарды.* А. Шамов.

БАЯНЧЫ *и.* 1. Баянда уйнаучы музыкант. *Баянчылар түгәрәге.* □ *— Дөньяда Инсаф дустымнан да оста баянчыны, яшем шушы яшькә җитеп, күргәнем юк иде.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *сир.* Баян ясаучы мастер.

БАһ *ы.* Ат чакырганда әйтелә. *Андрюша айгырны барыбер тота алмады. Картузына солы уып салып: — Бах! Бах! — дип чакырып та карады.* Қ. Латыйпов.

БАҺАДИР *и.* 1. Пәһлеван, батыр. *Қайда сез, әй, илне саклаучы Баһадирлар! Нигә чыкмыйсыз алтын сарайга Каршы канлы бәйгегә?!* Һ. Такташ. *Сугышта --- ике яктан да асыл ирләр, көчле баһадирлар һәлак булган.* А. Гыйләҗев.

2. *с. мәгъ.* Бик зур һәм нык; бик куәтле. *Күккә таба үрелеп, бер-берсенә нык сыенып, яр өстендә баһадир агачлар утыра.* Н. Фәттах. *Андрей Верещагин киң маңгайлы, баһадир гәүдәле диңгезче иде.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Баһадирдай (баһадирлар йокысы белән) йоклау** — бик каты, тирән йоклау. *Баһадирдай йоклый иптәшләрем, Арып килеп сугыш эшеннән.* Ш. Маннур. *Шаһзадә, гаять арыганлык сәбәпле, баһадирлар йокысы илә гырыл-гырыл йокламакта иде.* Ш. Мөхәммәдев.

БАҺАДИРЛАНУ *ф.* Баһадир булган булу, баһадирларча кыланып карау. *Хатын-кызны әйтмисең дә инде, ир арысланнарның да күбе иртән бик баһадирланып керешсәләр дә, төшкә таба ыңгыраша башладылар.* Г. Ибраһимов.

БАҺАДИРЛА'РЧА *рәв.* Баһадирлар кебек. *Асылгәрәй - - - иңбашларын баһадирларча салмак кына җыергалап куйды.* М. Шабай. *Сержант Шакиров илебез өчен баһадирларча сугышты.* А. Әхмәт.

БАҺАДИРЛЫК *и.* 1. Баһадир булу; баһадир булу сыйфаты. *Куәтнең кадере баһадирлык белән.* Мәкаль. *— Ханлыкка да минем исем китми, миңа шул егетлегем, шул баһадирлыгым җиткән.* Ш. Қамал.

2. Батырлык, геройлык. *Күп заман михнәт вә хурлык Берлә кыйналган халык Октябрьда баш күтәрде Зур баһадирлык белән.* С. Сүнчәләй.

БАҖА *и.* Хатынның апасының яки сеңелесенеңире. *Кәҗә булса да малың булсын, бажа булса да нәселең булсын.* Мәкаль. *Бажалар да кодалар Нәрсә карап торалар? Кунак булып килсеннәр, Өйне котлый күрсеннәр.* Г. Афзал.

БАҖАЙ *и.* Бажа сүзенең махсус атау һәм эндәшү формасы. [Исхак Гыйниятка:] *Син Сафиясын алисың да, сеңелесе — миңа. Син бажай була торган кеше!* Н. Исәнбәт.

БАҖАНАҚ *и. этн.* Көнчыгыш Европаның көньяк өлешендә IX—XI гасырларда яшәгән борынгы төрки кабилә; *рус часы:* печенег. *Бажанак теле. Бажанак ханнары.*

БЕГЕМОТ *и.* Партияклылар отрядыннан Африкада елга-күлләрдә яши торган зур гәүдәле хайван.

БЕГО'НИЯ *и.* Матур чуар яфраклы субтропик үлән, гөл сыйфатында үстерелә. [*Газондагы*] *назлы бегония һәм маргариткалар Заһидны сәламләп каршыладылар.* А. Расих. *Әнә теге бегония --- яфрактан үрчи.* Г. Мөхәммәтшин.

БЕЖГӘК *с. диал.* Сукрануучан, каргануучан. *Бежгәк кеше.*

БЕЖГӘКЛӘҮ *ф.* Сукрану, каргану. *Бежгәкләп йөрү.*

БЕЗ I *и.* Күн, киез, такта һ. б. ш. әйберләрне кечкенә диаметрлы итеп тишеп чыгару өчен кулланыла торган һәм төп өлеше нәзек очлы корыч чыбыктан гыйбарәт булган инструмент. *Без капчыкта ятмый.* Мәкаль. *Скважина бораулау — без белән итек тишү түгел ул.* М. Хәсәнов. // Төрле коралларда: очлы штоклар, тишкечләр. *Хәреф бәйли торган җепләр, верстаклар, безләр аунап ята, ә машина белән касса үз урынында.* Г. Гобәй.

Без борын(лы) — бик очлы борын(лы).— *Синең янга килеп йөри торган без борынлы кешене мин кайдадыр күргән идем.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Без белән кырыну** — бик уңайсыз, примитив коралл белән дә тиешле эшне башкара алу турында. *Солдатмыни — күпне күреп, күпне белеп, Кирәк икән, без белән дә кырынмагач.* Ш. Мәдәррис. **Без белән чәнечкән кебек булу, без булып кадалу** — бик ачы авырттыру, күңелне әрнетү. *Аның [Ефимовның] каравыл астында китүен күру --- солдатларның йөрәкләренә без белән чәнечкән кебек --- булды.* М. Гафури. *Бу хәл Шмидтның егетлек горурлыгына без булып кадалды.* А. Расих.

БЕЗ II *а.* 1. *Беренче зат күплек формасындагы зат алмашлыгы:* сөйләүчене һәм аның белән бергә яки аңа иш булган тагы бер, берничә, күп шәхесне белдерә. *Си-*

нең белән бергә без Туган илгә күлмәккә Нечкә җепләр эрләрбез. Ә. Ерикәй. *Без, искене җимереп, планетада Тигез тормыш, матур, яңаны Төзү уе белән янабыз.* Һ. Такташ. // Үз ишләреңне башкалардан аерып күрсәтү өчен дә кулланыла. *Без, шайтаннар, богауда Гомер иттек бу айда, Қодрәт бавын өзәргә Без шайтанда көч кайда?* Г. Тукай. *Дошман явын юлбарыстай җиңә торган Уллары бар безнең татарның.* Ш. Маннур.

2. Иҗтимагый-политик һәм фәнни-публицистик әсәрләрдә автор сөйләмендә авторның үзен белдерә. *Без бу мәкаләдә аның [М. Гафуриның] иҗат юлына кыскача анализ ясауны бурыч итеп куябыз.* М. Җәлил. // *юг.* Қайбер очракларда сөйләүченең үз дәрәҗәсен, үз абруен белеп сөйләвен белдерә.— *Без, җиде икълимның ханы, боерабыз.* Әкият.

БЕЗ III *аваз иярт.* Чыңлаудан түбәнрәк дулкынлы озын авазны белдерә. *Без-без килү.* □ *Урмәкүч --- ауга килеп эләккән чебеннәрнең без-з-з-з, без-з-з-з итеп тәмам арыганга кадәр безелдәүләрен --- карап тора.* Г. Галиев.

БЕЗГЕЛДӘК *и.* Дүдәк сыман дала кошларының бер төре; *русчасы:* стрепет.

БЕЗЕЛДЕК *с.* Гел безелдәп тора торган. *Безелдек черки.* □ *Безелдек скрипка тавышы тирә-яктан гүләү аркасында бер ишетелә, бер каядыр күмелеп, югалып кала.* А. Расих.

БЕЗЕЛДӘВЕК *с. сир. к.* безелдек. *Безелдәвек чебен.*

БЕЗЕЛДӘҮ *ф.* Без-без итү, без-без итеп тору. *Фермада бик күп сөт җепләренең чиләкләргә тоташып безелдәүләре тышкы якка үк ишетелеп тора.* Р. Төхфәтуллин. *Озынборын --- «Җизни, җизни, күңелем синнән бизми!» — дип безелди-безелди кан эчәргә оча.* А. Алиш.

БЕЗЕЛТЕ *и.* Туктаусыз безелдәү авазы. *Гомәрнең колагында һаман шул ә-ә-ә дигән тавыш --- бер безелте белән чыңламакта иде.* Ш. Қамал.

БЕЗЕРӘҚ, БЕЗРИҚ *с. диал.* Бераз, беркадәр, аз гына күләмдә.— *Барырга да, фәлән абзый, яңа өлгергәнче безерәк он биреп тор, дияргә.* И. Гази.— *Безрик кенә арыш чәчәргә исәп.* Г. Бәширов.

БЕЗКОЙРЫҚ *и.* Нечкә һәм озын койрыклы кыр үрдәге төре; *русчасы:* шилохвостка.

БЕЗЛӘҮ I *ф. к.* безелдәү. *Чаңнар чыңы яуга чакырганда Чебен булып безләр үлем.* З. Нури.

БЕЗЛӘҮ II *ф.* Туры катыру, чәнчү (койрыкны һ. б.). *Чапты үгез койрыгын чәнчеп, безләп.* Г. Афзал.

БЕЗНЕҢЧӘ *рәв.* Без уйлаганча яки без әйткәнчә, без эшләгәнчә.— *Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Безгә иш, без теләгән. *Бүгеннән үк безнең ячейкага Чын безнеңчә кеше табыгыз.* Н. Баян. // Безнең телдә. [*Госман карт:*] *Мадам дигән сүз безнеңчә абыстай дигән сүз була.* Ш. Қамал.

БЕҚАС *и.* Озын томшыклы, чуар арқалы, ак түшле, зур булмаган саз кошы. *Табышым бар — ике бекас үтердем.* М. Максуд.

Бекас ядрәсе — бик вак ядрә. *Аларны [чикерткәләрне] бекас ядрәсе белән корылган мылтыктан атып куркыталар.* Умартачылык.

БЕЛГЕРТҮ *ф.* 1. Сиздерү, белдерү, яшереп калдырмау. *Қатыга бәрелеп, азрак тез башы яңгыраган булса да, белгертмәдем, тиз генә чыгып киттем.* М. Гали.— *Серемне әйтсәм әйтим, дус кеше бит, сиңа белгертим инде.* А. Алиш.

2. *сөйл.* Аңлату, җиткерү. [*Галия Давытка:*] *Ах, ничек итеп мин моны сиңа белгертим!* Г. Қоләхметов.

БЕЛГЕЧ *и.* Фән һәм техниканың берәр өлкәсендә тирән белеме, зур тәҗрибәсе булган кеше. [*Нәфисәнең*] *я агроном, я урман белгече, я бакчачы буласы килә.* Г. Бәширов. *Профессор Әбүзәр Таһиров Казанда йөрәк авырулары буенча иң зур белгечләрдән санала.* Г. Әпсәләмов.

БЕЛГЕЧЛЕҚ *и.* Күп көч куеп озак вакытлар буена үзләштерелгән махсус белем, һөнәр; шундый белем, һөнәр таләп итә торган эшчәнлек өлкәсе. *Мортаза агай төзелеш техникумын тәмамлаган. Тыныч хезмәттә үз белгечлеге белән мәшгуль.* Б. Қамалов.

БЕЛГЕЧЛӘРЧӘ *рәв.* Белгечләргә охшатып, белгечләр сыман. *Хисам, белгечләрчә, йөзенә бер дә артык гаҗәпсенү билгесе чыгармыйча гына, мичне караганнан соң: «Хәзер бәясен әйтергә була»,— диде.* А. Расих.

БЕЛДЕК: белдек сату — минбеләмлек күрсәтү. *Җитмәсә, бая малайлар алдында бик белдек сатып ташладым.* Н. Исәнбәт.

БЕЛДЕҚЛЕ *с.* 1. Күп белүче, киң белемле, күпне күргән. *Солдатта йөреп кайткан белдекле кешеләр әйтеләр: кызылларныкы булырга тиеш бу аэроплан.* И. Гази.

2. Бик белемле булып күренергә теләгән. *Мортаза --- белдекле кыяфәт белән фәлсәфә сата башлады.* М. Хәсәнов. / *рәв. мәгъ.— Үсәсең инде дөнья булгач,— диде малай, белдекле генә кыланып.* Н. Фәттах.

БЕЛДЕҚЛЕЛЕҚ *и.* Белдекле булу сыйфаты.

БЕЛДЕҚЛЕЛӘНҮ *ф.* Белдекле булган булу, үзең белдекле итеп күрсәтергә тырышу, белдекле булып кылану. *Зәмзәмбану бик хәбәрдар кеше сыман белдеклеләнеп тезеп китте.* М. Хәсәнов.

БЕЛДЕКСЕЗ *с.* Белемсез, надан. *Белдеклегә бер әйт, белдексезгә мең әйт.* Мәкаль.

БЕЛДЕРМӘ *и.* Берәр үзгәреш, реформа, фикер һ. б. турында булган махсус белдерү, игълан. *Футуристлардан бер төркем бу белдермәне [аларга каршы белдермәне] ялганга чыгарырга теләде.* Х. Госман.

БЕЛДЕРҮ I *ф.* 1. Сиздерү, белгертү. *Хәзрәт ачуланганын белдермәде, кызмады.* Г. Ибраһимов. *Сөюемне белдерәлми тилмерәм.* М. Җәлил.

2. Игълан итү, әйтү. *Айдар уртага чыкты да, бүгенге җыелышта агротехника кагыйдәләрен бозып эшләүче трактурчы Хәйдәревнең эше тикшереләчәк, дип белдерде.* Ф. Хөсни. *Гафиятулла абзый авыл халкының бер өлеше белән Бөгелмә районына китәргә ризалык белдерде.* Г. Әпсәләмов.

3. Билгеле итү, күрсәтү. *Правление ишек алдына бәйләп куелган, күбеккә баткан, иярле ике ат көтелгән хәбәрчеләрнең дә килеп җиткәнен белдереп тора иде.* Ш. Усманов.

БЕЛДЕРҮ II *и.* Язма игълан. *Белдерүнең ахырында Зиннәтләрнең адресы язылган.* А. Шамов. *Ул [Халикъ], Гали абзый кушуы буенча белдерү язып, аны правление ишегенә ябыштырып куйды.* Г. Әпсәләмов. *Олы юлдагы телеграмм баганаларына зур белдерү такталары һәм күрсәткечләр куелган.* А. Расих.

БЕЛЕҚ *и. иск.* Белем, гыйлем. *Белгән белегенә ышаныр.* Мәкаль. *Күңелебезне белек илән пакьләү кирәк, Фикеребезне, юлыбызны хаклау кирәк.* Г. Қамал.

Белек сату — *к.* белдек. *Шул [фельдшер] миңа, зур белек сатып, бер дару бирде.* Г. Ибраһимов.

БЕЛЕКЛЕ *с.* Белемле, гыйлемле. *Уртадан бер күп белекле карт кеше әйтә: Бу хакта минем фикерем шушы...* Г. Тукай. *Авыл халкы Җиһаншаны күркәм холыклы галим вә белекле бер зат дип белә.* З. Һади. // *шелт.* Артык күп белүче.— *Улың авылның бөтен серләрен шәһәргә белдереп тора, --- бик белекле булган.* Һ. Такташ.

БЕЛЕКСЕЗ *с.* 1. Мәгълүматсыз, аңсыз. *Белексез яу танымас.* Мәкаль.

2. Билгесез, мәгълүм түгел. *Атамны сорасаң — белексез, анамны сорасаң — никахсыз.* Мәкаль.

БЕЛЕМ *и.* 1. Фикерләү алымнарының, фән яки практика белән расланган төп фикер һәм хөкемнәрнең хәтердәге эзлекле җыелмасы. *Кешенең очар канаты белем*

була. Мәкаль. *Газинур, аның [Гали абзыйның] белеменә сокланып, тын да алмыйча тыңлап утырды.* Г. Әпсәләмов. // Мәгълүмат яки мәгълүматлар системасы. *[Гаязның] һәрбер сүзе минем өчен дә яңа белем булып хәтеремә сеңәләр.* М. Әмир. // Билгеле бер фән яки эшчәнлек өлкәсендә мәгълүматлылык, укымышлылык. *Отряд башында сәяси белеме булган кеше торырга тиеш.* Ш. Усманов.

2. Билгеле бер иҗтимагый нормалар буенча укыганлык, тәрбияләнгәнлек, өйрәнгәнлек. *Белем бирү. Белем дәрәҗәсе. Югары белем.* □ *Белем арттыру һәм дөньяга карашны киңәйтү мөмкинлекләре шәһәрдә күбрәк.* Ш. Камал. // Уку, тәрбия алу. *Белем йорты. Белемгә сусау.* □ *Бармы шул егеттә белем дәрте?* Н. Исәнбәт.

3. Фән, гыйлем. *Тел белеме. Табигать белеме.* □ *Безнең Кызыл Армия командирлары, кирәк булгач, сугыш белеменә патша генералларыннан да өйрәнгәннәр.* М. Әмир.

БЕЛЕМЛЕ *с.* 1. Белеме күп булган, белдекле; укымышлы, укыган. *Белемле кеше югалмас.* Мәкаль. / *и. мәгъ. Белемле үлсә, кәгазьдә хаты калыр; оста үлсә, эшләгән заты калыр.* Мәкаль.

2. Билгеле күләмдә белеме (2 мәгъ.), укымышы булган. *Югары белемле кадрлар хәзерләү.* □ *Син дә урта белемле, Мин дә урта белемле.* Г. Афзал.

БЕЛЕН *и.* 1. Әче камырдан юка гына итеп пешерелгән коймак.— *Менә мин мичкә ягам да белен пешерәм. Самовар кайнагач, эссе беленгә уятырмын.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Тыныч, тигез су өстенә берәр нәрсә төшүдән яки сугылудан барлыкка килгән бөжралар. *[Габдулла], ташып килә торган Чаган өстенә ташлар ыргытып, беленнәр ясарга тотынды.* Ә. Фәйзи.

3. *күч.* Бозауларның кояшта кипкән тизәге. *Чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, авылның үз бозаулары салып калдырган беленнәр күпме генә соң ул?* Ә. Еники.

БЕЛЕНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* белү. *Укып белену.* □ *Көйләр яхшы беленгән вә җырлаучылар да тәртипкә салынган.* Ф. Әмирхан.

2. Мәгълүм булу; ачыклану, аныклану. *Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә.* Мәкаль.— *Вәт,— дип уйлыйм мин эчемнән генә,— чын дуслык менә кайда беленә ул!* А. Шамов.

3. Сизелү, төсмерләнү. *Таң белену. Томан аша белену.* □ *[Газизнең] иреннәре беленер-беленмәс кенә тетри.* Ш. Камал. *Ул аксыл сары чәчле, акыллылыгы беленеп торган киң маңгайлы егет иде.* А. Шамов.

БЕЛЕШ *и.* Белгән-күргән, беркадәр таныш кеше. *Түгел алтын, фәкать өч-дүрт көмештән Алган идем бурычка бер белештән.* З. Бәшири. *Кайчандыр бергә укып аерылышкан белешләр шикелле генә сөйләштек.* Б. Камалов. / *с. мәгъ. Хәдичә — Сиражетдиннәргә белеш тол хатын.* Г. Камал.— *Кодамы ул миңа, дусмы? Белеш егет кенә...* А. Гыйләҗев. // *с. мәгъ. сир.* Таныш булган. *Миңсылу абыстай берничә минутлар бу белеш түгел бүлмә(гә) --- аптырашта калып ятты.* Ф. Әмирхан.

БЕЛЕШЛЕК *и.* Танышлык, эшнәлек. *Сәүдәгәр руслар белән белешсәң дә, бу белешлекләрдән миңа кызык булачак түгел.* Ф. Әмирхан.

БЕЛЕШЛӘНҮ *ф. сир.* Үзара белеш булып китү, танышу. *Тарабаров исемле бер бай өстенә-башына бик яхшы киенгән бер кеше белән белешләнгән.* Г. Камал.

БЕЛЕШМӘ *и.* 1. Теге яки бу мәсьәлә буенча махсус белдерелгән мәгълүматлар җыелмасы. *Белешмәләр бюросы.* □ *Иван Иванович райкомда колхозлардан әле генә җыелып беткән ун көнлек белешмә карап утыра иде.* А. Расих. *Газеталардагы кайда нинди кино яки театр бару турында белдерүләр дә белешмәләр дип йөртелә* М. Әмир.

2. Справка, таныклык. *Ул чакта, чыгышын яшереп, ялган белешмәләр ясатып, укырга кереп урнашкан мулла малайлары белән көрәшеп тә баш катып беткән иде.* Ф. Хөсни. *Моннан күп еллар элек миңа әниемнең ничә яшьтә икәнлеге турында метрика белешмәсе артыннан йөрергә туры килде.* Г. Галиев.

3. Белешмәлек, кулланма. *Агитатор белешмәсе.*

БЕЛЕШМӘЛЕК *и.* Билгеле бер эшчәнлек өлкәсе, фән һ. б. буенча белешмәләр, фактлар, мәгълүматлар язылган китап, брошюра, исемлек. *Моңа чаклы бездә татар теле буенча аерым китап рәвешендә чыгарылган мондый белешмәлек бөтенләй юк иде.* Л. Җәләй.

БЕЛЕШ-ТАНЫШ *җый. и. к.* таныш-белеш. *Дус-иш, белеш-таныш, Хөсәеновлар, Гобәйдулла хажилар — һәммәсе мәш киләләр.* Ш. Камал. // *с. мәгъ.* Белеш яки таныш булган. *Галиәкбәр агайга үзенең белеш-таныш руслары туры килеп, моны үзләренең компанияләренә чакырып утырттылар.* Ш. Мөхәммәдев.

БЕЛЕШТЕРҮ *ф.* 1. *сир. к.* таныштыру. *Кешеләрне үзара таныштыру, белештерү.*

2. Тиз генә күп нәрсәне сорашып белеп алу, танышып чыгу.— *Киленем эшкә килгәндә дә үзен сынатмый. Шушы йортта дүрт-биш ел гомер иткән кебек, барын да белештереп, җиренә җиткереп эшли.* Г. Толымбай.

3. *юкл. форм.* **Белештермәү.** Аңсыздан эшләү, үзенә хисап бирмәү. *[Габдулла], үзенең кая барганын белештермәстән, урам буйлап китте.* Ә. Фәйзи.

БЕЛЕШҮ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* белү. *Ләкин егетләр, кызлар барыбер бер-берсен яратышканнар, бер-берсенең мәхәббәтләрен белешкәннәр.* Г. Әпсәләмов.

2. Кирәкле нәрсә турында махсус рәвештә белеп алу, барып яки сорашып белү.— *Түбәгә шифер белешәм, буяулар алып кайтам. Р. Төхфәтуллин.* // Сораштыру, кемнең дә булса хәле белән танышу. *Фәтхине күрдем, ул һәр көн Сәләхинең хәлен белешеп тора.* Ш. Камал.

3. Танышу. *Эчемнән генә --- теге татар белән белешергә карар бирдем.* Ф. Әмирхан. // Хәбәрләшү. *Безгә гел күрешеп, белешеп торырга ышанычлы бер урын кирәк.* Г. Минский.

4. Белеш булып яшәү, танышлык тоту.— *Мин гүр иясе булгач, белешләремне йөреп чык, --- мин ялганчы кешеләр белән белешмәдем.* Г. Бәширов.

5. *к.* белештерү (3 мәгъ). *Җәмил, үзен үзе белешмәс дәрәҗәдә ярсып, --- следовательгә кизәнде.* Г. Гобәй. *Әле генә үз-үзләрен белешмичә очынган атлар шып туктадылар.* Ф. Әмирхан.

БЕЛЛЕТРИСТ *и.* Беллетристик әсәрләр язучы кеше.

БЕЛЛЕТРИ'СТИК *с.* Беллетристикага карый торган, шуңа бәйләнешле. *Беллетристик әдәбият.*

БЕЛЛЕТРИ'СТИКА *җый. и.* Нәфис (матур) әдәбиятның тасвирый төрләре (хикәя, повесть, очерк, роман, сәяхәтнамә һ. б.). // Фәнни-публицистик әдәбияттан һәм классик әсәрләрдән аермалы буларак, мавыктыргыч итеп язылган маҗаралы, фантастик яки фәнни-популяр һ. б. әсәрләр. // Әдәби әсәрне укучыны мавыктырырлык итеп язу ысуллары; мавыктыргыч сюжет яки тасвирлар.

БЕЛЛҮР *и.* Зөбәрҗәт ташының зәңгәрсу төре; берилл аквамарин. *Кыйммәтле ташлар белән эш итә белүче оста үзенең җитез куллары белән вак беллурларны матурлап очлый.* Д. Аппакова.

БЕЛМӘМ *кер. сүз.* Җөмләдә саналган предметларның яки эш-хәрәкәтләрнең әле әйтелеп яки беленеп бетмәгән төрләре дә булуын белдерә. *Крестьяннар бүген алпавытның җирен талый, утарын яндыра, урманын кисә, белмәм, тагы ниләр кыла.* Г. Ибраһимов.

БЕЛМӘМЕШ *и.* Белми, аңламый торган, мәгълүматсыз кеше. *Ялчы белсә дә белмәмеш булып, йөрәге сызланып, тешләре кайралып үз эшендә йөри, ди.* Әкият.

Белмәмешкә салыну — үзеңне белмәгән, аңламаган яки танымый торган итеп күрсәтү. *Искәндәр агарып китте. Белмәмешкә салынды, адымнарын арттыра төште. Мин артыннан киттем.* Г. Газиз. *Хәерниса апа, --- бел-*

мәмешкә салынып, һәр кешенең сүзен яңа хәбәр итеп яратып тыңлый. С. Рафиков.

БЕЛОРУС *и.* Белоруссия ССРда яши торган Көнчыгыш славян халкы һәм шул халыкның бер кешесе.— *Шул белорус кызы булмаса, синең Нәфисәң Белоруссия урманнарында ятып калган булыр иде.* А. Әхмәт. / *с. мәгъ. Белорус теле. Белорус әдәбияты.*

БЕЛОРУ'СЧА *рәв.* Белорус телендә. *Фатыйма русча, украинча, белорусча җырлады.* Г. Әпсәләмов.

БЕЛЬЭТАЖ *и.* 1. Берничә катлы яки күпкатлы өйләрнең астан икенче каты.— *Менә бу бельэтажга менә торган баскыч, менә бусы түгәрәк площадка.* Ә. Фәйзи.

2. Театрда тамаша залының бенуар һәм амфитеатрдан өстәрәк урнашкан ярусы.

БЕЛӘ *бәйл. дисл. к.* белән. *Егет булсаң — егет бул, Арыслан киек кебек бул, Гайрәт белә, көч белә Ташлан дошман өстенә.* Ш. Маннур.

БЕЛӘЗЕК *и.* 1. Беләк белән кул чугы тоташкан буын тирәсе. *Сәфәргали Сәлмән картның сугарга дип кизәнгән кулын беләзек турыннан кысып тотып алды.* Ф. Хөсни. *Хәйдәр аның [Зиннәтнең] гимнастеркасының кыска җиңнәреннән чыгып торган сөяклач һәм тар беләзекләренә кызганып карап торды.* Г. Бәширов.

2. Беләккә кидерелә торган бөжра рәвешендәге бизәнү әйбере. *Кимә беләзегеңне, Уйдырма беләгеңне.* Җыр. // Кул сәгате бавы. *Ферма эшчесе Хәбирәгә беләзеге-ние белән саф алтын сәгать тоттырып куймасынармы!* М. Хәсәнов.

3. *күч.* Бияләй, перчатка кебек киемнәрнең кул чугы белән беләк тоташкан буынны каплый торган өлеше, беләзек турысы. *Сырлап бәйләнгән беләзек.* // Манжет, җиң очы. *Күлмәк беләзеге.*

БЕЛӘК *и.* Кулның кулбаштан беләзеккә кадәрге өлеше. *Беләге юан берне егар, белеме күп меңне егар.* Мәкаль. *Газинур беләге белән йөзен каплап эчкәрәк үтте дә җилгәргечкә ябышты.* Г. Әпсәләмов. *Тал тирбәткәнем юк иде, Талдыра икән беләкне.* Җыр.

БЕЛӘКСӘ *и.* Урак урганда һәм башка кайбер эшләрдә беләкне һәм беләзекне камылга, саламга тырналудан һ. б. саклау өчен киелә торган кием, җиңсә.— *Безнең Сәлимә бик җиңел куллы, ул [ура] башласын,— ди әни, үзе беләгенә беләксә кия.* М. Гафури.

БЕЛӘМӘН *и. сөйл.* Үзен белемлегә санаучы, минбеләмлекле кеше. *Сәлимулла белән сөйләшү колхоз председателенең ачуын кузгатты. Менә шуның ише беләмәннәргә күрә колхоз алга бармый да.* Г. Минский.

БЕЛӘМЛЕК *и. диал. к.* минбеләмлек. *Әмиржанның --- бөтен кешедән күп беләмлек дәгъвасында булуы Хөснуллага ошамый иде.* Ш. Камал.

БЕЛӘН *бәйл.* 1. Бергәлекне, юлдашлыкны белдерә. *Һәр кояшлы иртә үзе белән алып килә безгә яңаны.* Һ. Такташ. *Шулай бервакыт без бер компания белән көймәгә чыктык.* Ф. Әмирхан.

2. Берәр объектка яки үзара мөнәсәбәтне аныклаганда кулланыла. *Дөнья белән танышу. Кеше белән кеше була белү. Дуслар белән сөйләшү.* □ *Безнең балаган озын казарма белән янәшә генә утыра.* И. Туктар.

3. Фигыльдә белдерелгән эш яки хәрәкәтнең нәрсәдән чыгып, нәрсәгә бәйләп, нәрсә нигезендә эшләнүен белдерә. *Туган көн белән тәбрикләү. Эш белән шөгыльләнү.* □ *Вафин --- кайсы бригадага кемне беркетү мәсьәләсе белән баш ватып утыра иде.* Ф. Хөсни. // Сәбәп һәм нәтиҗәне (нәрсә аркасында) белдерә. *Ашыгычлык белән ялгышу.* □ *Чыннан да, сез кызулык белән берәр нәрсә эшләп ташлавыгыз бар.* Т. Гыйззәт. // Иярчен җөмләдә *-ган (-гән), -кан (-кән)* формасындагы сыйфат фигыль белән килеп, баш җөмләдә инкяр ителәчәк (ителгән) нәтиҗәне белдерә. *Асыл буяуга төшкән белән карга каргалыктан чыкмас.* Мәкаль. // Шартны белдерә. *Үсемлекнең тереклеге су белән.* Мәкаль. *Уку белән бик тиз үтәр Бу озын кыш.* М. Гафури. // Эш яки хәрәкәтнең максатлылыгын белдерә. [*Гали:*] *Сезгә бер кечкенә йомыш белән генә килгән идем.* Г. Камал.

4. Эш яки хәрәкәтнең ничек башкарылу рәвешен белдерә. *Саклык белән.* □ *Миләүшә куян җитезлеге белән сикереп торды.* М. Әмир. *Бәйләүдәге колыннар --- кыч җиткәнне түземсезлек белән көтәләр.* Г. Ибраһимов. // Эш яки хәрәкәтнең нинди төсмер, нинди форма аркылы бирелүен белдерә. *Шәйхаттар Таймасов изге Ватаныбызны саклау постында батырлар үлеме белән һәлак булды.* Т. Гыйззәт.

5. Нинди корал ярдәмендә эш башкарганлыкны, хәрәкәтләнгәнлекне белдерә. *Балта белән чабу. Велосипед белән йөрү.* □ *Яз, газиз углым, кара тактаны сыз акбур белән.* Г. Тукай.— *Мин соң инде мылтык белән каравыллый торып та каракларга әйбер бирәм димме?* А. Алиш. // Нәрсә ярдәмендә башкарганлыкны белдерә. *Акыл (киңәш) белән эш итү.* □ *Фабрик-заводлар киләчәк көннәрдә митинглар белән генә идарә ителә алмаячаклар.* Ф. Әмирхан. *Карар инде, карар инде Кара күзләре белән; Өзәр инде үзәгемне Матур сүзләре белән.* Җыр. // Нинди чара, предмет кулланылуын, эшкә куелуын белдерә. *Медаль белән бүләкләнү.* □ *Никрутларны төнге поезд белән озаттылар.* Ш. Усманов. *Җир йөзе тәмам бизәлгән чәчкәләр, гөлләр белән, Төрле агачлар, елгалар һәм чишмәләр, күлләр белән.* М. Гафури. // Нәрсәне хәрәкәт иттергәнлекне белдерә. *Кулың белән бирерсең, аягың белән йөрерсең.* Мәкаль. *Капка баганасына сөялдем дә йөзем белән Зәңгәр чишмәгә әйләндем.* Г. Ибраһимов.

6. Урын төшенчәсен биргән исемнәр белән килеп, нинди юлдан, кай җирләр аркылы хәрәкәт иткәнлекне белдерә. *Сукмак белән бару.* □ *Мин тайгада ачкан юллар белән Килсен ул, әйт, минем яныма.* Ш. Маннур. *Менә инде без атларыбызны әкрен генә атлатып урман юлы белән кайтып барабыз.* Ф. Хөсни.

7. Вакыт төшенчәсен биргән исемнәр янында килеп, вакыт хәле ясый. *Иртә белән. Кич белән.* □ *Утырам мин ялгыз төннәр белән, Тар бер землянканың түрендә.* Ш. Маннур. *Ләкин ничек тә, ничек тә Олы Ширмә авылы иртә таң белән кызыллар кулында булырга тиешле.* Һ. Такташ.

8. *-у (-ү)* формасындагы исем фигыльләр янында килеп, шул фигыльләр белдергән эш-хәрәкәттән соң эшләнгән башка бер эш-хәрәкәтнең шунда ук, бик тиз арада эшләнүен (килеп чыгуын) белдерә. [*Алсу*] *бүлмәсенә керү белән Өске киемен салып ташлады.* Һ. Такташ. *Бурлы кашка --- Дилбегәне чак бер кагу белән Алга таба алып томылды.* Ш. Маннур.

9. Кайсы яктан характеристика бирелгәнлекне, бәяләнгәнлекне белдерә. [*Хөрмәтулла:*] *Георгиевский кавалер булу сыйфатым белән өстәмә урман сорарга кирәк.* Т. Гыйззәт. *Утыз Имәни табигате белән җитез, тиз хәрәкәтчән, үткен телле, һәр эшкә сәләтле кеше булган.* Х. Хисмәтуллин.

10. Төркемне, коллективны белдергән сүзләргә «бөтенесе, барлыгы, һәммәсе, җыйнаулашып» мәгънәсен бирә килә. *Өй эчләре белән. Өере белән. Авылы белән.* // «Төркеменә (төбәгенә, урынына) карап» мәгънәсендә. *Ягы белән шулаймыдыр, әллә Танып буйларында гынамы, быел яңгырлар да вакытында ява.* М. Шабай.

11. *терк. мәгъ.* Бер пар, бер бөтен итеп каралган яки якын мөнәсәбәттә булган предметларны белдергән ике исем арасына куела. *Сөйгән белән сөйгән кочаклашыр, Ана белән бала күрешер, Туган белән туган куанышыр, Хатын белән ир дә килешер.* Ш. Маннур. *Ай белән кояш бер генә, Йолдызын санамадым.* Җыр. // Бер үк дәрәҗәдә һәм уртак мөнәсәбәттә торган сүзләр — тиндәш кисәкләр арасына куела. *Җамали белән*

Камали кат-кат сөйләшеп, икәү тирән уйда, авыр кайгыда утырдылар. Г. Ибраһимов.

...белән бару — яшьнең ничәнчегә киткәнлеген әйткәндә кулланыла. [*Шәрәф*] *өйләнергә яшь әле, унбиш белән бара бугай.* М. Фәйзи. *Карагыз әле, карагыз, Фәрит нинди кечкенә! Без алты белән барабыз, Аңа тула өч кенә.* З. Нури. **...белән бергә** — кечерәк яки ялгыз нәрсәнең (шәхеснең) зуррак яки күбрәк булган объектка ияруен белдергәндә әйтелә. *Колхозчылар белән бергә Гыймазов та икенче бадъян ашны ялт иттереп куйды.* С. Рафиков.

БЕЛӘҮ I *ф. к.* беләүләү. *Утмәсне беләмә, булмасны сөйләмә.* Мәкаль. *Фәхри бабай, беләвенә төкереп, һаман пәкесен беләде дә беләде.* Н. Исәнбәт.

БЕЛӘҮ II *и.* Кечкенә шома кайрак. *Бабай алъяпкыч күкрәкчәсеннән беләү алып, чаж-чож китереп, чалгысын янап җибәрә.* Л. Ихсанова.

Беләүгә сызу — беләү белән үткенләү, янау. *Алтын саплы көмеш пәке — Яшел беләүләргә сызаем.* Җыр.

БЕЛӘҮЛӘНҮ *ф.* Беләү төсенә керү, беләү шикелле шома, тигез булып тору. *Җаекның атаклы язгы пычраклары эченнән беләүләнеп төшкән сукмаклар күп урыннарда озын булып тоташ сузылып китәләр.* Ә. Фәйзи. *Арбаның тимер кыршаулы көпчәкләреннән калган эз беләүләнеп, рельс кебек ялтырап ята.* М. Хәсәнов.

БЕЛӘҮЛӘҮ *ф.* Беләү белән үткенләү, кайрау, беләү.

БЕЛҮ *ф.* **1.** Чынбарлыктагы берәр факт, билге, күренешне хәтердә тоту; хәбәрдар булу. *Разия анасының холкын белә.* Г. Ибраһимов. *Яшәр идем, мең ел яшәр идем, Әгәр белсәм гомер серләрен.* Ш. Маннур. // Берәр махсус өйрәнелә торган нәрсәне: сабакны, фән өлкәсен һ. б. үзләштергән булу. *Татар телен белү.* □ *Мин --- бабай һөнәрен беләм.* Ш. Маннур.

2. Берәр нәрсә яки шәхес турында белешмә, мәгълүмат алу; белем хасил итү. *Җитеннән җеп, җептән киндер ясалганны Зәйнәп үз күзе белән күреп белде.* Дәрдмәнд. *Бабайга ничә яшь булганын сорашып белдек.* Г. Гали. // Аңлап алу, төшенү. *Әле ул* [*Газинур*] *белеп җиткерми торган --- бер сер бар кебек.* Г. Әпсәләмов. *Поездның тиздән кузгалып китәргә тиешлеген перрондагы пассажирларның --- хәрәкәтләренә карап белеп була.* М. Хәсәнов. // Өйрәнү. *Бала егыла-егыла егылмаска белер.* Мәкаль.

3. Таныш булу, күргән булу, тану. *Авылда гына түгел, өязда, хәтта бөтен волостьта аны* [*Гарифулланы*] *белмәгән --- кеше юк.* Г. Минский. // Берәрсенең характеры, холкы һ. б. белән яхшы таныш булу. *Юк, Иван агай, син Нәбиулланы белмисең!* Т. Гыйззәт.

4. *Дип* сүзе белән килгәндә: (... дип) санау, исәпләү. *Үзеңне яхшы дип белсәң, башканы әүлия (фәрештә) дип бел.* Мәкаль. // (... дип) уйлау, (... дип) чамалау. *Гафият, бияләй дип белеп, кесәсеннән мәче баласын тартып чыгарды.* И. Гази.

5. Үз-үзеңне аңлау, үз-үзеңә исәп бирү. *Бала үзен үзе белә башлагач, әйтәләр моңа: «Әбидә син асрау гына».* Әкият. // *к.* белештерү (3 мәгъ.). *Җәмәгать, үзен үзе белми, ватык тәрәзәдән, ишектән качарга ташлана.* Г. Ибраһимов.

6. Берәр нәрсәнең мәгънәсен, асылын тирәнтен аңлау. *Ипи кадерен белү. Эшнең тәмен белү.* □ *Сыер дигәнең бик ахмак нәрсә бит ул, яхшылыкны белми.* Һ. Такташ. // Билгеле бер нәрсәне күргән булу, кичерү, кичереп үткәрү. *Мәхәббәтнең нәрсә икәнен белү. Уенны белми үсү.* // *рәв. мәгъ.* **белеп.** Үз тәҗрибәсендә сынап, күреп, аңлап. *Белеп сөйләү.* □ *Үксез бозау асрасаң, авызың-борының май булыр дип белеп әйткәннәр.* Д. Аппакова.

7. Берәр эш яки шөгыль белән чикләнү, шуның белән генә мәшгуль булу, шуннан читкә тайпылмау. *Үз эшеңне генә белү.* □ *Күбәләк тик ямьгә кавышуны белә, Нә усал уй, нә дә шау-шуны белә.* Ш. Бабич. // *юкл. форм.* Билгеле бер нәрсәне, күренешне үзенең эш яки шөгыль даирәсенә кертмәү, читтә тоту, шуңа якын да килмәү. *Тимеркәй --- уен-көлкедән башканы белми торган бер шаян егет кебек иде.* Г. Ибраһимов. *Эминә һич тынгылык белмәде: мәктәптәге санитария кагыйдәләре белән танышып чыкты...* Г. Минский.

8. *кер. сүз функ.* **белмим.** *к.* белмим шул. *Белмим, әллә гайбәт, әллә чындыр инде* [*бу сүз*]. Һ. Такташ. // **белмәссең.** *к.* белмәссең тагы. [*Утәш:*] *Акбирдин бервакытны миңа: теләсаң, картларны да яшәртә алабыз, дигән иде. Белмәссең, мин әйтәм, кап-кара сакаллы ир уртасы ясар да куяр.* Қ. Тинчурин. // **белсәгез.** Аңларга тиешсез. *Бу зур, ифрат зур мәсьәлә, белсәгез.* С. Рафиков.

9. *ярд. ф. функ. -(ы)рга, -(е)ргә, -маска, -мәскә* кушымчаларына беткән фигыльдән соң шул сүздә белдерелгән эш-шөгыльне бик яхшы, бик шәп итеп булдыра алу төсмерен бирә.— *Мин бандитлар белән ничек көрәшергә белермен.* Т. Гыйззәт.— *Үчемне алырга белермен мин синнән.* Д. Аппакова. // *юкл. форм.* Сорау сүзләре белән бәйләнгән хәлдә килеп, төп фигыльгә аптырап тору, икеләнү төсмерен бирә. *Әхмәт борчылуыннан ни дип әйтергә дә белмәде.* Г. Минский. *Шакир сүзенә ышанырга да, ышанмаска да белмиләр иде.* А. Алиш.

10. *ярд. ф. функ. -а(ый), -ә(и)*гә беткән фигыльдә белдерелгән эш яки шөгыльне яхшы итеп булдыра, эшли алу, шуңа көче, зиһене, осталыгы яки акылы җитү төсмерен бирә. *Теләк ул тели белсәң теләк, тели белмәсәң — имгәк.* Мәкаль. *Йосыфҗан моменттан файдалана белде.* Г. Ибраһимов. // Шелтәләү яки каты таләп кую төсмерен бирә. *Таһир --- бер бүләк тә алып кайтып бирә белмәде.* Ә. Айдар. *Ала белсәң, бирә дә бел.* Мәкаль. // Хуплау, мактау, мактану төсмере биреп килә. [*Яңа мөдәррис*], *мәхәллә кешеләрен тота белер бу! — дигән ышаныч калдырды.* Ә. Фәйзи.

◇ **Бел(егез), белеп тор аны** — әйткәнне онытма, күз алдында тот (кисәтү сүзе). [*Бибкәй Мавиягә:*] *Аягыңны атлап чыгасы булма, бел аны.* М. Фәйзи.— *Сиңа моннан соң ташлама булмаячак, аны белеп тор.* Г. Галиев. **Белмим шул**—берәр нәрсәнең сәбәбен күрсәтүдән, берәр төрле җаваплылыктан читкә тайпылганны яки берәр мәсьәләдә шикләнеп калуны белдерә. [*Байтирәк:*] *Белмим шул, миннән ни генә чыгар икән.* Т. Гыйззәт. **Белмәссең тагы**— бәлки, булып та куюы бар. *Белмәссең тагы, ихтимал, сезнең мондагы үрдәкләр, сызгырып җибәрүгә, аучының кулына килеп куна торганнардыр.* М. Шабай. **Беләмсең (беләмсез) шуны** — беләсеңме (беләсезме) шуны (сезгә билгелеме?). *Әни дисең, ә беләмсең шуны, Әниең сине өзелеп сөя бит.* Ш. Маннур. **Белсәң (белсәгез) иде** — аңламыйсың (аңламыйсыз) шул. *Их, иптәш, минем ни хәлдә икәнемне белсәң иде!* Ф. Әмирхан. **Беләсең (беләсегез) килсә** — шуны да белмисең (белмисез) эле; шуны белергә тиешсең (тиешсез). [*Шәйхулла:*] *Без хәзер, беләсең килсә, авылның падишасы булдык.* Д. Аппакова. — *Беләсегез килсә, патшаның хәрби суды аны* [*М. В. Фрунзены*] *ике тапкыр асарга хөкем иткән.* Г. Бәширов. **Беләсеңме (беләсезме) нәрсә** — игътибар ит(егез) эле. *Беләсеңме нәрсә, Гөлнарый җан, мин өркәбрәк торам.* Ә. Айдар.

БЕНЕФИС *и. иск.* Җыелган акчасы берәр (берничә) артистның файдасына китә торган яки берәр артистка махсус багышланган спектакль. *«Галиябану» Казанда артистка Синаева бенефисына куелганын --- ишетеп куандым.* М. Фәйзи.

Бенефис бирү — үзенең көчен аеруча күрсәтү. *Кыш әле шаяртыр төсле генә. Ул берәр атнага үз дилбегәсен йомшарткан булып күренсә дә, яшеренеп калган суыгын берьюлы чыгарып, соңгы бенефис бирер.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БЕНЗИН *и.* Нефть продуктларын куганда аерылып чыга торган янучан төссез сыеклык. *Аның [Айдарның] бу хәрәкәтеннән әлеге шул бензин катыш автол һәм солидол исе --- һавадан чайкалып үзды.* Ф. Хөсни. *Йосыф бакыр труба буйлап карбюраторга барган керосинны япты, бензинга юл ачты.* Х. Госман.

БЕНЗИНЛЫ *с.* 1. Бензины булган, бензин салынган. *Бензинлы бак.*

2. Бензинга буялган, үзенә бензин сеңгән. *Аэроклуб дию белән үк күз алдыгызга бары бензинлы комбинезоннар, пилоткалар, зур перчаткалар гына китермәгез.* К. Басыйров.

БЕНЗИНЛАП *рәв.* Бензин кулланып, бензин белән. *Махсус эшләнгән автомобильләр бу урамнарны щеткалап, бензинлап юалар.* Г. Гали.

БЕНЗО- Кушма сүзләрнең беренче өлешендә бензинга бәйләнешле дигән мәгънәне белдерә, мәсәлән: **бензобак, бензоколонка.**

БЕНЗОВОЗ *и.* Бензин ташый торган автоцистерна (зур цистерналы яки баклы автомашина). *Бензовоз ыңгырашып, гүләп үргә менде дә яр астына, бензоколонкага төшеп китте.* И. Салахов.

БЕНУАР *и.* Театрның тамаша залында партер белән бер тәңгәлдә як-якта урнашкан ложалар.

БЕР I *сан.* 1 саны һәм цифры. *Бергә берне кушсаң, ике була.* // Шул сан исәбендәге микъдар. *Язның бер көне бер елны туйдыра.* Мәкаль. *Эше торса бер тәңкә, эшне өйрәнүең — мең тәңкә.* Мәкаль. // Парның сыңары. *Бер бияләйне югалту.* □ *Бер аягымны койма дан күтәреп, бер генә аягым белән аның өстендә калдым.* Ф. Әмирхан.

2. Үзе генә, бердәнбер, ялгыз. *Әүвәл анага бер булганга, [Зыя] үзен льгот дип тора. Аның солдатка алынуы һичкемнең башына килми иде.* Г. Ибраһимов. // **бергенәм** *ирк.* Иң кадерлем, иң якыным, бердәнберем.— *Ай, улым, китүең китәрсең анысы, син бит минем бергенәм. Китеп югалсаң, синсез нишләрмен.* Әкият.

3. Фигыль алдыннан килгәндә: бер мәртәбә, бер тапкыр. *Мин әле дә бер үткән урамнардан еш йөрмәскә тырышам.* А. Гыйләҗев. *Мин сине бер ай элек нинди дер үләннәр һәм чәчәкләр җыеп кайтып килгән чагыңда да бер очраткан идем бит.* М. Гали.

4. Берәмлек була ала торган сүзләр алдыннан килеп, җөмләдә белдерелгән юклык төшенчәсен көчәйтә: бөтенләй, аз гына да. *Әхмәдулла абзый чынлап та Габдуллага бер тиен дә бирмәде.* Ә. Фәйзи. *Күңел өчен булсын, бер бөртек кар яумый.* М. Гафури.

5. Арада иң шәбе, тиңдәшсез, бердәнбер.— *Минем Фәрхиҗамалмы? «Якты юл»да бер дисәң дә була аны.* Р. Ишморат.— *Бозавы бик таза, бик көр, көтүдә бер бозау.* К. Тинчурин.

6. Үткән заман фигыльләрдән соң килеп, «барысы да, һәммәсе дә, һәркайсы» мәгънәсен белдерә.— *Бу вакытта акча каян булсын? --- Кергән бер акча бетеп тора!* М. Гафури. *[Кызларның әйберләрен] салганы бере, бүләкләрен алачак кызылармеецларны кырыкмаса-кырык кыяфәттә күз алларына китереп, ящикка карап тордылар.* Г. Гобәй.

7. *с. мәгъ.* Бердәм; бертөрле, бер-берсенә охшаган.— *Күңелләр бер булса, тел белмәү генә киртә түгел.* Г. Әпсәләмов. *Аты бер булса да, заты башка.* Мәкаль. // *рәв. мәгъ.* Тиң, бәрабәр. *Гектарына бер йөз кырык тугыз! Безнең «Чулпан» өчен фронтта берәр полкның шәһәр алуы белән бер бу.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Кебек, нәкъ, (нәрсәгә булса да) тиң, охшаган. *Син үзеңнән аны ким дисеңме? Аның чәче үзе бер болыт.* Н. Исәнбәт.

8. *с. мәгъ.* Уртак. *Дәвам итте һөҗүм гөрелдәп, Атауллы ике большевикны Алга илтте бер көч, бер теләк.* Ш. Маннур.

9. *с. мәгъ.* Бердәм, оешкан (төстә). *Домначылар, тирән дулкынланып, Бер көч белән эшкә тотынды.* Ш. Маннур.

10. *с. мәгъ.* Бөтен бер, тулы бер (әйбер) мәгънәсен белдерә. *Бер басуны бер ялгызы Кыз урамыни җырлап?* Н. Исәнбәт.

11. *рәв. мәгъ.* Кайчан да булса бервакыт. *Диңгез булып җайрап яткан күлләр дә бер корый икән.* Г. Ибраһимов. *Бер китсәң дә ерак, бер кайтырсың Туган илләреңне сагынып.* Ф. Бурнаш.

12. *б-сез а. мәгъ.* Ниндидер (билгесез зат, предмет, эш турында). *Аргы очтан, көянтә башларына юылган керләр салынган кәрзиннәр элеп, бер кыз килә.* Ә. Фәйзи. *Ай йөзә күк гөмбәзендә Тын, бәхетле елмаеп, Күк йөзен күксел көмештәй Бер гажәп нурга манып.* Н. Исәнбәт. // Нинди дә булса, берәр. *Минем бәхетем хәзер сезнең кулда, шуңа күрә мин сездән бер хөкем көтәм.* Ф. Әмирхан. // *и. мәгъ. күпл.* Аерым кеше, шәхес. *Ах, син, илем, Ничек үләргә соң, Сагыныр кешеләр синдә булганда, Ничек үлим, Берләр меңнәр өчен — Меңнәр берләр өчен торганда.* Һ. Такташ.

13. Вакыт берәмлеген белдергән төшем килешендәге сүзләр алдыннан килеп, шул билгеле бер вакыт берәмлекләренең берсендә дигән мәгънәне белдерә. *Бер кичне. Бер мәлне.* □ *Бер төнне атау тирәсендә каравылда тора торган иптәшләребез, бырғылар кычкыртып, бөтен атау халкын йокыдан уятты.* Ф. Әмирхан.

14. Тиңдәш кисәкләр янында кабатланып килгәндә бүлгәләү теркәгече функциясен үти: әле, я. *[Җәмилә] ишектән чыккан вакытта, кая барганын белмичә, бер алга, бер артка атлап, --- ихтыярсыз бара иде.* М. Гафури. *Ялкын бер көчәеп, бер сүрелеп китә.* Г. Әпсәләмов. // Шарт фигыль янында «әгәр» теркәгече мәгънәсендә килә.— *Кызыллар бер килсәләр, беркайчан да китмиләрме инде алар, бабай?* Г. Гобәй.

15. *терк. функ.* Бары, тик, гел. *Кышның карын бар кеше дә ярата! Бер шагыйрьләр генә түгел!* А. Гыйләҗев.— *Бу бер аның гына түгел, барыбызның да авторитетын җимерә.* Г. Бәширов.

16. *кис. функ.* Һич, һич тә. *Гомердә бер киләсең юк, Яндырма йөрәгемне! Җыр.— Мин дә бер шикләнергә урын күрмим.* Г. Камал. // Бернинди, һичнинди, һичбер. *Каршыда җан иясе күренми, башаклар дулкынланыннан чыккан акрын чыжылдаудан башка бер тавыш та ишетелми иде.* Ф. Әмирхан.— *Яңа машина --- белән кырыксаң, мехлар көзге кебек ялтырый торган булачак. Бер браксыз эшли торган машина.* И. Ишморат.

17. *кис. функ.* Җөмләдә бирелгән тойгыны көчәйтә: шатлану, соклану, горурлануны белдерә. *Паровоз фронтка выж итеп барып керсен әле бер.* Г. Гобәй.

18. *кис. функ.* -гач кушымчалы хәл яки шарт фигыль алдыннан килеп, аңа көчәйтү мәгънәсе өсти. *Бер тотынгач. Бер башласа.* □ *[Хәллә] әйткән эшне ялтыратып эшләп куя, бер кулы кызгач, әйтмәгәнен үзе күреп тә эшли иде.* Ф. Хөсни.

Бер ара — 1) кайчандыр бервакыт (узган хәл турында). *[Кәбир] Гәүһәрияне бер ара көндез дә чакыртып алырга уйлаган иде.* А. Гыйләҗев; 2) кайчан да булса, ничек тә булса, киләчәктә бер.— *Булмаса, әнкәй янына иртәгә бер арада кайтып китәрмен әле.* Г. Бәширов. **Бер билгесезле тигезләмә** *мат.*— хәреф белән тамгаланган бер билгесез санны эченә алган тигезләмә. **Бер буйдан** — янәшә, рәттән. *Безнең урам чатыннан борылгач та, чиркәү белән бер буйдан, кечкенә паркны беләсең бит.* Ш. Камал. **Бер (бөтен) булу** — 1) берегү, туплану, бердәм булу. *Балкыды, нурланды туган ил, Бер булып тупланды туган ил.* Ә. Еникәй. *Крестьян кузгалышы — җир һәм ирек өчен булган кузгалу. --- Бу вакытта революцион авыл, бер бөтен булып, алпавытларга каршы көрәшә.* Г. Нигъмәти; 2) *рәв. мәгъ.*

бер кешедәй берләшеп. *Йөрәкле барабыз сугышка, Сакларга Советлар йөрәген! Бер булып бу көчле көрәштә Үләрбез — чикмәбез бер адым!..* М. Җәлил. **Бер елгы** — *к.* бер яшь (яшьлек, яшьтә). **Бер заман** — 1) бервакыт. *Бер заман ачсам күзем, бертөрле япьят кыр күрәм.* Г. Тукай. 2) кайчан да булса бер. *Бер заман терелеп аякка басармын дип һич тә уйламаган иде Назимов.* Г. Әпсәләмов. **Бер итү** — берләштерү, бергә кушу. *Ике колхозны бер итү.* **Бер иш(е)** — 1) кайбер, кайсыбер. *Бер иш кешеләр хыял диңгезендә йөзеп әллә нәрсәләр күз алларына китерәләр.* А. Гыйләҗев. [*Кешеләрнең*] *бер ишесе «яхшы чакта» яр буеннан шылды, байтагы, бер-берсен узып, пароходка таба йөгерә башлады.* Г. Гобәй. **Бер мизгел** — бераз вакыт (вакытның бик кыска өлеше). *Егетләрнең шау-шулары бер мизгелгә тынып калды.* Сов. әд. **Бер очтан** — 1) бер үк материалдан. [*Галиәсгар*] *Галекәй белән икесенә бер очтан камзул белән чалбар, читек белән кәвеш, күлмәк белән кәләпүш тектереп кидерде.* Ә. Фәйзи. 2) *күч. к.* бер уңайдан. *Бер очтан анысын да әйтеп китик: каенана да язмыш белән килешкән.* Г. Гобәй. **Бер(әр) яры** *диал.*— кая булса да, башка бер урынга. *Менә сиңа төн йокларга урын, әгәр дә син шуннан бер яры кузгалсаң, өстеңә дөп итеп тукмак төшәр дә башыңны ярыр.* Н. Исәнбәт. **Бер ярым** — бер бөтен һәм тагын бер ярты. *Бер ярым капчык он. Бер ярым ипи. Измәгә бер ярым өлеш ком кушу.* **Бер яшь (яшьлек, яшьтә)** — бер үк елда туган, яшьтәш. *Бер яшьлек дуслар.* □ — *Әнә Хантимировларның Марат белән бер яшьлек Чыңгызлары анасының рөхсәтеннән башка комлыкка да чыкмый.* Т. Гыйззәт. **Бер өйләр** *бот.*— аерым җенесле чәчәкләре бер үк төптә (сабакта) була торган үсемлекләр. **Бер өлешләр** — яралгыларында бер генә орлык өлеше булган үсемлекләр.

◇ **Бер авыз сүз сөйләшмәү (әйтмәү)** — сөйләшмичә, дәшмичә генә тору. *Кешеләр* [*Мостафинга*] *туры карарга уңайсызландылар, ул үзе беркем белән бер авыз сүз сөйләшмәде.* Ә. Еники. **Бер адым** — бик якын, янәшә. *Мәктәп бездән бер адымда гына булу.* **Бер акча** *иск.*— кыйммәт түгел, арзан. *Астраханьда сыер бер акча, килә-килә мең акча.* Мәкаль. *Тышкы яктан малайлар һаман киреләнделәр: — Жизни! Ишек бавы бер акча, безнең апа мең акча! — дип, тышкы яктан ишек бавын җибәрми тордылар.* Г. Ибраһимов. **Бер алдына, бер артына төшү** — берәүнең ризалыгын, рөхсәтен алу яки аны берәр нәрсәгә күндерү өчен ялагайлану, тирәсендә сырпалану. **Бер алдына, биш артына карап** — бик сак, җитди уйлап. *Җиһан апа, чынлап та, бер алдына, биш артына карап эш итәргә ярата иде.* М. Шабай. **Бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә** *тирг.* — карт яки каты авыру кешегә карата әйтелә.— *Үзеңнең бер аягың җирдә, икенче аягың гүрдә, картайган көнеңдә сиңа мәчет түрендә генә утырырга кирәк иде.* Г. Камал. **Бер (үк) балык башы** — гел бер үк сүз, фикер; күп кабатланган, артык күп сөйләнгән, туйдырып бетергән мәсьәлә.— *Кәгазьләрнең җыенысында бер балык башы иде. Шул инде, һаман бер сүз — сугышу безнең эш түгел, дигән.* К. Тинчурин. **Бер генә (бер), бер генә дә, бер дә генә, бер дә** — 1) бөтенләй, һич(тә), аз гына да (юклык төшенчәсен белдерә). *Очсыз-кырыйсыз дала. Анда бер генә бер агач, бер генә бер куаклык юк.* А. Әхмәт. *Менә, Зөһрә, сине үги кызым дип бер дә генә кимсетмим бит мин.* А. Әхмәт; 2) беркайчан да, һичкайчан да. *Аллага шөкер, егерме биш ел әбилек итәм, бер генә дә ялгышканым юк.* А. Шамов. **Бер дигән** — бик яхшы, иң шәп, менә дигән. *Болар барысы да (эремчек суы, өсте алынган сөт, «гөбе суы») бозаулар, дуңгызлар өчен бер дигән азыклар.* А. Расих. *Ярны сөйсәң, сөй чибәрен, Авылда бер дигәнен.* М. Шабай. **Бер дә бер заман, бер дә бер көнне** — бервакыт, көннәрдән бер көнне. *Бер дә бер заман һавадан кыр казлары очып бара иде.* Э. Касыймов. *Бер дә бер көнне теге кешене идарә председателе итеп сайлап та куйдык.* Ф. Хөсни. **Бер дә харап** — гажәп, искиткеч. *Күмәч шундый тәмле булган, бер дә харап, ашап туйгысыз икән.* Н. Исәнбәт. **Бер дә хәтәр** — *к.* бер дә харап. [*Тирәк агачы*], *бер дә хәтәр эреләнеп, башын тиешеннән артык күккә күтәреп, тотынган, ди, үсәргә, тотынган, ди, үсәргә.* Н. Исәнбәт. **Бер дә юкка (юктан)** — нигезсез, сәбәпсез, һич гаепсез. [*Галимәне*] *бер дә юктан харап иттеләр.* М. Гафури. **Бер итеп** — 1) билгеле бер урынны, мәйданны һ. б. иңләп, аның бер башыннан (почмагыннан) икенче башына (почмагына) кадәр (йөрү, чабу һ. б. ш.). *Авылны бер итеп икәү без, Нурларга коена-коена, Серләшеп, гөрләшеп үтәрбез Урамның буеннан буена.* Ә. Ерикәй. [*Бозау*] *тагын шулай ишек алдын бер итеп чабарга тотынган иде.* Ф. Хөсни; 2) билгеле бер урынның, мәйданның бер төшен дә калдырмыйча, җентекләп (эзләү, актарыну). *Өйне бер итеп китап эзләү.* **Бер калыптан сугылган, бер калыптан яратылган** — *к.* бер чыбыктан сөрелгән (куылган). *Һәммәсе дә бер калыптан яратылган халык, Алда бармасын берсе дә, Башкалар артта калып.* Г. Камал. **Бер кашык су белән йотарлык** — бик чибәр, сылу, сөйкемле (күбрәк кызлар турында). *Кыз чибәр иде, сүз юк. Буе да, сыны да килгән иде. Ул күз дисеңме, ул каш дисеңме... кыскасы, бер кашык су белән йотарлык иде.* А. Шамов. **Бер колактан кереп икенчесеннән чыгу** — 1) игътибарсыз гына, әйтелгәннәрнең мәгънәсенә төшенергә тырышмыйча гына тыңлау. *Гөлбану бу турыдагы сүзләрне тыңлады, ләкин аңламады, бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга тордылар.* Г. Ибраһимов; 2) игътибар итмәү, игътибарсыз калдыру, һаман үзенчә эшләү. *Ник охшатасың аны ожмахка, син «кяфер!» диләр,— Бер колагымнан керә дә, бер колагымнан чыга.* Г. Тукай. **Бер кулга җыю** — бергә туплау. [*Борынгы ыруглык җәмгыятендә*] *сәнгать һәм идеологияне бер кулга җыйган бер җитәкче булган.* Н. Исәнбәт. **Бер кулсыз калу** — 1) ярдәмчесез калу, төп таянычны югалту. [*Камали солдатка алынгач*] *монда анасы белән хатыны бер кулсыз калдылар.* Г. Ибраһимов; 2) иң кирәкле әйбер булмау сәбәпле, гаҗиз хәлдә калу. **Бер көе (көенчә), бер килеш** — уртача, ярыйсы гына.— *Ни хәлләрегез бар соң, кода? — диде* [*хатын*].— *Хәзергә бер көе, кодача,— диде Шәрәфи карт.* Ш. Камал. [*Шырпы фабрикасында*] *эшләп торганда, боларның хәле бер көенчә яхшы барды.* М. Гафури. **Бер күз белән карау (бер күрү)** — һәммәсен тигез күрү.— *Маратның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г. Гобәй. **Бер сүз белән (генә) әйткәндә** — кыскача, гомумирәк итеп, нәтиҗә ясап, җыеп әйткәндә. *Бездән* [*яшелчәдән, җимештән*] *ниләр генә ясап булмый, Нинди генә ашлар ашап булмый. Бер сүз белән генә әйткән чакта — [уңыш] бар чакта, кеше, син кунакта.* Ә. Ерикәй. **Бер сүз юк (булмау, әйтмәү)** — каршы тормау, тулысынча килешү, ризалашу.— *Кызларын Сиражига бирсеннәр, минем бер сүзем дә юк.* Г. Камал. *Урысчаның кирәк кадәрлесендә мин үзем дә бер сүз әйтмәдем.* Ф. Әмирхан. **Бер сүзгә (фикергә) килү** — үзара аңлашу, килешү. **Бер сүздә булу (бару)** — кем белән дә булса тулысынча килешеп, алдан сөйләшеп-киңәшеп эш итү. *Пьесада исә мулла бөтенләй башка: ул хәйләкәр, ул шахта хуҗалары белән бер сүздә бара, хуҗаларның үзенә биргән жалованьесе бушка түгеллеген ул яхшы төшенә.* Г. Нигъмәти. **Бер табактан ашау** — дус, тату яшәү.—*Үзе белән бер табактан диярлек ашап, эчеп, дөнья көтәбез.* Г. Ибраһимов. **Бер тирә** — *к.* бер чама. **Бер (генә) тын** — 1) бераз вакыт. *Бичара арыган сандугач бер генә тынга сайравыннан туктаган.* Н. Исәнбәт; 2) тын да алмыйча, берьюлы. [*Давыт*] *югалып калмады, билен бөгеп башын орды һәм, күзләрен йомып, бер тын белән эчеп тә җибәрде.* А. Гыйләҗев. **Бер уңайдан** — 1) бер үк вакытта. [*Нә-*

фисә] әле бодай җиренә барып, Гөлсемгә теге-бу кирәкмиме, берәр тоткарлык юкмы, дип, аның хәлен белеп килә, шунда бер уңайдан, чи калган урыннар юкмы дип тә искәреп уза. Г. Бәширов; 2) бергә, берьюлы, берьюлап, берьюлатын. *[Гайшәне] ике кат съездга үткәрделәр. --- Баргач, аны съезднең өлкәннәре белән бер уңайдан президиумга сайладылар.* Г. Ибраһимов. **Бер хәер (хәл)** — ярый ла, анысы ярый инде. *Заводның [бер] өлеше генә шундый хәлдә булса, бер хәер иде.* М. Әмир. *Мин бит аның белән саубуллашмый чыгып киттем. Миңниса апа бер хәл, әмма Мирхәйдәр абзыйга ачуланырга хакым бар идеме минем?* Ә. Фәйзи. **Бер чама** — 1) бер үк үлчәүдә, бертигез диярлек; бердәй. *Әлбәттә Илдарга әләккән булыр иде. Көчләре бер чама булса да, --- [ят] малай бик җитез һәм чамасыз кыю иде.* Г. Гобәй; 2) ярыйсы гына, уртача. *Тик менә МТС конторында гына язын да, көзен дә эш бер чамадарак.* Ф. Хөсни. **Бер чыбыктан сөрелгән (куылган)** — бер-берсенә охшаган, араларында аерма юк (гадәттә тискәре мәгънәдә әйтелә). *Шик төште Гәрәй күңеленә: Әллә аның эшчеләре һаман бер чыбыктан сөрелләрме?* А. Гыйләҗев. **Бер юлга** — беренче очракта, бу очракта гына (гафу итү, кичерү һ. б. ш. турында).— *Бер юлга гына ярар. Хатыңа каршы җавап язмыйча булдыра алмадым, йөрәгем түзмәде.* Г. Бәширов. **Бер якка калдыру (кую)** — туктатып тору, игътибардан читтә калдыру. *Ахун, халык авызында үзенә каратып сөйләнгән --- бу эшне бер якка калдырып, сүзне туйлар, никахлар, мәҗлесләр тирәсенә күчерде.* Г. Ибраһимов. **Бер якта (читтә) торсын** — сүз бара торган нәрсә белән чагыштырганда начаррак. *Һава шундый саф, таза, курортларың бер якта торсын.* Р. Төхфәтуллин. *Җир җәннәте торсын бер читтә, Бодай басуына ни җитә.* Г. Афзал. **Бер ялгыз** — япа-ялгыз, үзе генә.— *Ни хәл, иптәш, монда бер ялгызың гына әвене янган кеше шикелле борыныңны салындырып, ни эшләп утырасың?* Г. Камал. **Бер яшьлектә, бер картлыкта** — яшьлектә була торган хәл, вакыйга һ. б. ш. картлыкта да кабатланырга мөмкин дигән мәгънәдә.— *Беләсезме, кызлар, Нәби абыйның кемгә күзе төшеп йөри ди? Рәм-зи-ягә!.. — Кызы кебек ич ул аның. — Бер яшьлектә, бер картлыкта, ди.* Р. Төхфәтуллин. **Бер үк вакытта** — шул ук вакытта, шуның белән бергә. *Сәлим шул турыда уйлап шатланды, ләкин бер үк вакытта борчылды да.* Г. Гобәй. **Бер җан, бер тән булып** — бердәм, нык дус булып. **Бергә бишне кушу, берне биш итү** — алдап, арттырып, күпертеп сөйләү.

БЕР II: бер-беребезне, бер-беренә, бер-берегездән, бер-берсенә, бер-берсеннән һ. б. — үзара берсе икенчесен, берсе икенчесенә, берсе икенчесеннән һ. б.— *Синең белән, җизни, бер-беребезне аңлаша алмабыз.* Ф. Әмирхан. *Мостафа белән Һидият икесе бердән: «Нәрсә икән?» — дип, бер-беренә карадылар.* Ш. Камал. *Сугыш төрле милләтләрне бер-берсенә тагын да якынайтты.* А. Әхмәт.

БЕ'РАВЫЗДАН *рәв.* **1.** Барысы бергә, бердәм рәвештә. *Балалар беравыздан җырлап җибәрделәр.* Г. Гобәй. *Җыелган кошлар беравыздан: — Без һичнәрсә аңлый алмыйбыз — фәлән,— дип --- шаулаша башладылар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Бертавыштан, каршылыксыз. *Бригада членнары [Хәйдәрнең] тәкъдимен беравыздан күтәреп каршы алдылар.* Р. Ишморат.

БЕ'РАВЫК *рәв. сөйл.* Бераз вакыт. *[Хәдичә] беравык уйланып торды.* Г. Бәширов.

БЕРАДӘР *и. иск.* Ир туган, абый яки эне. *Берадәрләр шул рәвешчә үстеләр, гәрчә боларның табигатьләре вә теләкләре бөтенләй башка-башка булса да, бу ике карендәш үз араларында бик дус вә берсе берсенә тәмам бәйланган иделәр.* Г. Тукай.

БЕРАЗ *рәв.* **1.** Аз гына, зур булмаган күләмдә, күп түгел. *Кырга чыгып, бераз китүебез булды, кызлар кай арада чәчәкләр дә җыеп өлгерделәр.* Г. Гали.— *Бераз чыбык-чабык алып кайтыйм дип, бәләкәй арба тартып әрәмәгә киткән идем.* Т. Гыйззәт. // Күпмедер вакыт, озак түгел. *Тордым бераз ишек төбендә мин.* Б. Рәхмәт. *Хәлим төш тәэсиреннән айнып җитә алмыйча, күзләрен зур итеп ачып, бераз хәрәкәтсез ятты.* И. Гази.

2. Билгеле бер дәрәҗәдә, беркадәр, җиңелчә генә, аз-аз гына. *Без, әлбәттә, бераз үсә төштек. Йөрәкләр дә хискә баерак.* Ә. Еникәй.— *Мин үзем дә прокурордан бераз курка төшкән идем.* Һ. Такташ.

БЕРАЗГА *рәв.* Берникадәр вакытка. *Хат укучылар беразга сүзсез калдылар.* А. Әхмәт.

БЕРАЗГА!ЧА *рәв. к.* беразга. *Тулпарның каты тояклларының тавышы, дөп-дөп итеп, беразгача ишетелеп барды.* Г. Ибраһимов.

БЕРАЗДАН *рәв.* Берникадәр вакыт узгач, озакламыйча. *Бераздан өстәл өстенә шаулап торган самовар килде.* А. Шамов. *Бераздан ишек дөбердәткән тавыш ишетелде.* Г. Камал.

Бераздан соң — *к.* бераздан. *Бераздан соң өч ат җиккән зур арба килеп чыкты.* А. Әхмәт.

БЕ'РАЯККА: бераякка атлау (басу) — 1) башкалар белән бер үк вакытта, алар нинди аякка бассалар, шул аякка басу. *[Рәүф белән Гыйльметдин], кулларын бер-беренең иңнәренә салып, сарай артыннан чыгалар да урам буйлап солдатларча бераякка атлап китәләр.* Г. Иделле; 2) *күч.* эш-карашларының кем яки нәрсә белән дә булса ярашкан булуы, берәр мәсьәләдә яки эштә кемнән яки нәрсәдән дә булса калышмау. *Клуб бүгенге тормыш белән бераякка басып яшәргә тиеш.* Соц. Тат.

БЕР-БЕР *с.* **1.** Нинди дә булса, берәр төрле. *Шүрәле фөрьят итәдер, аудан ычкынмак була, һәм дә ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була.* Г. Тукай.

2. *рәв.* Нәкъ (берәр нәрсәгә охшатканда әйтелә). *Айгырым коштай канатлы, яллары бер-бер тарак.* Н. Исәнбәт.

3. *билг. а. функ.* Һәрбер. *[Колхозчыларның] кайсылары бер-бер арбага бишәр-алтышар кеше төялгән, урам буйлап көлешә-көлешә кырдан кайталар.* Ш. Камал.

4. *рәв.* Кайчан да булса (бер).— *Бу арада сораганым да юк, ул Закир дигәннәрен табалармы инде бер-бер, юкмы?* Г. Камал.

5. *рәв.* Һәрберсен аерым-аерым, берәм-берәм, берәмтекләп, җентекләп. *Мин аның алдында чакта бер минут итмим әрәм: һәр эшен, һәрбер төшен бер-бер күземнән үткәрәм.* М. Гафури. *Йөреп бер-бер карап чык һәр каберне, Алып туфракны учка, искә җирне.* Дәрдмәнд.

◇ **Бер-бер артлы** — берсе артыннан икенчесе, эзлекле рәвештә, тәртип белән. *Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә.* Г. Тукай. *Яралыларның кайберләре бер-бер артлы тәрәзәдән төшә башладылар.* А. Шамов.

БЕР-БЕРЕ, БЕР-БЕРСЕ *билг. а. функ.* Берсе-берсе, һәрбере, һәркайсы. *Бер-берсе мең сумлык бар --- бу атларның.* Г. Ибраһимов.

БЕ'РБУЫН *и. мат.* Тапкырлау һәм дәрәҗәгә күтәрү гамәлләрен генә эченә алган алгебраик аңлатма. *Бербуынны дәрәҗәгә күтәрү.*

БЕ'РВАҠЫТ(НЫ) *рәв.* **1.** Кайчандыр бер (узган хәл турында). *Хәйдәр үзе Нәфисәне бервакыт урман буенда күргәннән бирле һаман яна һәм көя.* Г. Бәширов. — *Мин сиңа бервакытны алма белән бәргән идем, исеңдәме?* Ф. Хөсни.

2. Кайчан да булса бер; иртәме, соңмы (киләчәк турында). — *Үзең дә бервакыт бабай булырсың [әле].* Д. Аппакова.— *Бүген без [Хафизны] кыйнасак, икенче бервакытны, вакытын туры китереп, аларның да безне кыйнау ихтималлары бар.* Г. Камал.

БЕ'РВАҚЫТТА *рәв.* 1. *к.* бервакыт(ны). *Бервакытта күреп бер матурны, Кыйлдым ак йөзләрен тамаша.* М. Гафури.

2. Һичкайчан, бернинди очракта (да). *Уңган хатын бервакытта да югалып калмый шул, һәр көтелмәгән кунакка аның сые әзер була.* Г. Әпсәләмов.— *Безнең Баку нефтьчеләре бервакытта --- чигенүне белмиләр.* А. Әхмәт.

БЕРГӘ *рәв.* 1. Кем яки нәрсә белән бергәләп.— *Без, әнкәй, башыбызга килгән кайгыны бергә кичерербез. Никадәр авыр булса да, бергә булгач --- түзәрбез.* Р. Ишморат. *Уйныйк бергә, булыйк бергә. Ямь тулсын яшь күңелгә.* Ш. Маннур.

2. Бер үк вакытта. *Хәзер без, капитализм агачын аудару белән бергә, аның зәһәрле тамырларын да әрчергә тиешбез.* Ш. Камал.

◇ **Бергә булсын** — ашаганда, нәрсә белән булса да шөгыльләнеп торганда, берәрсенең «тәмле булсын», «эшләр уңсын» һ. б. ш. теләкләренә җавап итеп әйтелә. *Шәрәфи карт нәрсәдер юнып ясап маташа иде. Аның турысына җиткәч, Солдат: — Эшләр уңсын, Шәрәфи абзый! — диде.— Шулай, господин унтер, бергә булсын!* Ш. Камал.

БЕРГӘ-БЕР *рәв.* 1. Башма баш. [*Май*] *базда озак торган, каксыган, базарлыклы түгел! Әнә миннән булсын яхшылык, бергә-бер!* Г. Бәширов.

2. Икесе дә бертигез, бертөрле. *Синең төсле берәү юл: бергә-бер сез, Көрәшкәнне җиңалмый ул каберсез.* Г. Тукай.

3. *к.* бермә-бер (1 мәгъ.). *Бергә-бер сугышу.*

БЕРГӘ-БЕРГӘ *рәв.* Бергәләп, җыйнаулашып, коллектив белән. *Күңел көргә бергә-бергә шатлык җырын җырлыйбыз.* Ә. Ерикәй. *Ялның иң яхшысы менә шушында, кеше белән бергә-бергә булу инде аның.* Р. Төхфәтуллин.

БЕРГӘЛЕК *и.* 1. Дуслык, татулык, бердәмлек. *Сирәк-мирәк талашкалап алсалар да, дуслар ич алар! Әнә шул бергәлек көндәлек вак-төякләрдән өстен түгелме әллә?* А. Гыйләҗев. *Һәй, егетләр! --- Кайда безнең бергәлеккә антыбыз?* Н. Исәнбәт.

2. *с. мәгъ.* Бергә булган. *Ике ел бергәлек якты тормыштан соң, Нәфисәнең кияве тиф авыруыннан үлеп китте.* Ш. Камал. // Уртак, күмәк, коллектив. *Атның бергәлек ат булганлыгын Тәки чыгарганмын исемнән.* Һ. Такташ.

БЕРГӘЛӘП, БЕРГӘЛӘШЕП *рәв.* Барысы бергә, күмәк рәвештә, җыйнаулашып. *Кайчак алар дәрестән соң моңлы рус җырларын бергәлап җырлыйлар иде.* Г. Әпсәләмов. *Яшьлек мәхәббәтләренең шәүләләре, һәмәсе бергәләшеп, яңадан бер кат йөрәккә сирпелделәр.* Ф. Әмирхан.

БЕРДА'НКА *и.* XIX йөзнең икенче яртысында рус армиясендә кулланылган бер зарядлы мылтык. *Нургали абзар ишегенә китте, Хисмәт абзый, сүс бау таккан берданкасын бер иңбашыннан икенчесенә күчереп, аның артыннан иярде.* Ә. Еники. // Бер көпшәле ау мылтыгы. *Ярый әле, күзгә-башка тимәде: берданка, атуга ярылып китеп, Илдарның уч төбен чәрдәкләде.* Г. Гобәй.

БЕ'РДӘЙ *рәв.* Бертигез, тәңгәл. *Колхозчының хезмәте стахановчы эшчеләр, доктор һәм инженерлар хезмәте белән бердәй санала.* Р. Ишморат. // Бертөсле, берберсенә охшаган. *Бары да бердәй яшел булып утырган агачларны табигать нинди генә төсләргә бизәмәде!* Г. Гобәй. *Һәркайсыбыз бердәй уйга батып, кабер туфрагын тигезләп күтәрдек.* А. Шамов.

БЕРДӘЙЛЕК *и.* 1. Тәңгәллек, бертигез булу. // Үзара охшашлык, бертөслелек.

2. *мат.* Эчләренә алган хәрефләрнең барлык мөмкин табылган кыйммәтләре өчен дөрес тигезлек. *Ике бердәй аңлатманы тигезлек билгесе белән тоташтырсак, бердәйлек килеп чыга.* Алгебра.

БЕРДӘМ 1. *с.* Үзара килешеп, бергәләп башкарылган. [*Опера театры*] *язучылар белән композиторларның бердәм иҗат эшләре нигезендә эшли.* М. Җәлил. / *рәв. мәгъ. Җиңеп була һәрбер явызлыкны, Бердәм генә кирәк булырга.* З. Мансур. // Уртак, һәркем өчен дә бер булган. *Бердәм теләк белән яшәү.* □ *Бергә берләшеп, бердәм көч белән фронт өчен эшләү үзе кодрәт инде.* Р. Ишморат.

2. *рәв.* Барысы бергә, бер үк вакытта, дәррәү. [*Төгермәннәр*] *бердәм хәрәкәтләнергә тотындылар.* А. Алиш. *Кинәт өч кеше бердәм көлеп җибәрделәр.* А. Әхмәт.

БЕРДӘМЛЕК *и.* Бердәм булу, оешканлык. *Дошман белсен безнең бөек илнең Матур бердәмлеге ныклыгын!* Ә. Ерикәй. // Карашларда, хисләрдә, эштә уртаклык.

БЕРДӘМЛӘШҮ *ф.* Берләшү, бердәм көч булып әверелү.

БЕРДӘН *рәв.* 1. Барысы бергә, бер кешедәй, бер үк вакытта. *Кинәт гайрәтләнеп, барыбыз бердән сикереп тордык, күз ачып йомганчы броневикны сырып алдык.* А. Шамов. *Кызлар, бердән хәрәкәткә килеп, [Гәрәйгә] урын күрсәттеләр.* А. Гыйләҗев. // Кинәт, көтмәгәндә, шунда ук. *Бәгърем минем, багана күк авып, Бердән кочагыма ташланды.* Б. Рәхмәт. *Балконда уйнаган балалайка бердән тынды.* К. Нәҗми.

2. Барысын да, тулаем, берьюлы.— *Син бит, Фәхрелислам абзый, акчасын кирәк саен ала барырсың дигән идең. Ә теге кеше бердән чыгарып бирде.* Ш. Камал.

3. Бер толымга үрелгән чәч турында. [*Әсманың*] *бердән генә үреп салган калын сары чәч толымы гимназия формасы --- өстендә бик ачык бер төс белән ярылып тора иде.* Ф. Әмирхан.

4. *кер. сүз.* Санаганда беренче пунктны күрсәтү өчен кулланыла; беренчедән.— *Бердән, минем карчык акыллы ул, көнләшми. Икенчедән, кызлар күреп тә каш сикертмәгәч, мин нинди Яңа бистә егете, ди?* Р. Ишморат.

БЕРДӘ'НБЕР *с.* Бары берәү генә, башка юк. *Нургали өчен Шәйхи абзый туган атасы урынына калган кеше, ул аны үзен бердәнбер яхшы белүче, аңлаучы һәм яклаучы дип таный.* Ә. Еники. // *и. мәгъ.* Башкалар арасында иң якын, иң газиз кеше турында. *Ана үзенең сырхап киткән бердәнберен ничек караса, Хәлим белән Гөлгенә Шәехтайны шулай карады.* Г. Гобәй. *Шатлыгымны сөйләү өчен Сүз таба алмый телем. Тик син генә куанычым, Син генә бердәнберем.* Ә. Ерикәй.

БЕРЕ *а.* 1. *к.* берсе. *Беребез сары чәчле, беребез кара, Сары чәчлесе ул — мин идем.* Һ. Такташ. *Шәлле хатын барысы белән дә сөйләшә, берен дә җавапсыз калдырмый.* А. Шамов.

2. Айның беренче көне. *Числоның берендә һәм унбишендә, конторадан алып, ике казармада эш хакын ул өләшә иде.* Ш. Камал.

БЕРЕГҮ *ф.* 1. Бер бөтен булып кушылу, ныгу, нығып урнашу, бергә нык тоташу. *Бүрәнә җекләре бер-берсе белән чыелдап үбешә-үбешә урыннарына ныграк берегә барды.* А. Гыйләҗев.

2. Берләшү, оешу.— *Сез кешеләр бит, күз күрмәслек тамчылар түгел. Сез береккәндә нинди көч килеп туачагын күз алдына китерергә тырыш син.* Г. Коләхметов. *Яшәсен Беренче Май көннәре! Эшче-крестьян берексен.* Г. Камал.

3. Туры килү (уй, фикер һ. б.), килешү.— *Патшаларның киңәшләре берексен иде дә, хәере белән тиздән --- балаларыбыз кайтып керсен иде инде.* М. Гали.

4. Бик нык ияләшү, үзләшү. [*Зыя белән Мәрьям*] *бер сүз алышу, бер карашу белән шатлык хис итәләр, бераздан бөтенләй берегеп, бик бәхетле --- гомер итәчәкләр иде.* Г. Ибраһимов.

БЕРЕНЧЕ 1. *Тәрт. саны. к.* бер I (1 мәгъ.). *Беренче этаж.* □ *Менә беренче рәттәге урындыкта, ак ма-*

мык шәлен җилкәсенә салып, мәҗлесне чәчәктәй бизәп, бригадир Хәдичә утыра. А. Шамов. // *рәв. мәгъ.* Барысыннан да алдарак, башта, әүвәл. *Малайларны беренче Якуб абзалары күреп алды.* И. Гази. *Көтмичә бернинди боерыкны, Беренче булып төлке сайлый койрыкны.* А. Алиш.

2. Санап үтелгәннән соң башкалардан алда аталган шәхесне, предметны һ. б. ш. күрсәтү өчен кулланыла. *Әсәрнең икенче басмасында Казан бае Кәрим белән Уфа бае Сәгыйть образлары, нык кына эшләнеп, беренчесе реакцион буржуа, икенчесе либераль буржуа вәкилләре итеп бирелгәннәр.* М. Гали. *Болар икесе дә оятсыз, провокацияле сораулар иде. Бу сорауның беренчесен --- Бакай дигән кеше, икенчесен --- Мөкип Фатих дигән кеше бирде.* Ш. Камал.

3. Башлангыч, башлангыч чордагы. *Язның беренче билгеләре күренә башлау.* □ *Яңа кеше турында беренче тәэсир кайчан шулайрак була бит.* Ә. Еники. // Берәрсенең билгеле бер юнәлештә, өлкәдә күрсәткән башлангыч эше, тәҗрибәсе, уңышы турында. [*Ш. Камалның*] *беренче хикәяләре*[*ндә*] *--- капиталистик эксплуатация тарафыннан гарип ителгән, тормышлары сындырылып ташланган бәхетсезләр бирелә.* М. Җәлил. [*Бу китапларны укып чыгуым*] *зур укучы шәкертләр рәтенә керә башлавымның беренче баскычы иде.* М. Гафури. // Булачак, чираттагы вакыйгаларның, күренешләрнең иң баштагысы, вакыт ягыннан иң якындагысы.— *Мин партиянең, хөкүмәтнең беренче чакыруы белән үк яңадан сугышчылар сафына һич тә икеләнми барып басачакмын.* А. Шамов.— *Мин, беренче мөмкинлек булу белән, бу турыда республика прокурорына хәбәр иттем.* Һ. Такташ. // Бер елда, сезонда, билгеле бер вакыт эчендә иң башта барлыкка килгән, күренгән. *Бүген дөнья беренче кар белән беренче суыкны күрде.* Г. Ибраһимов. *Иң беренче булып калка торган бүтәкә үләне черегән үләннәр астыннан чыгып килә.* Ә. Еники.

4. Моңа кадәр бөтенләй булмаган, яңа барлыкка килгән. *Беренче пар машинасы. Дөньяда беренче социалистик дәүләт.* □ *Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында, беренче милли студия булып, 1934 елда Татар дәүләт опера студиясе төзелде.* М. Җәлил. // Моңа кадәр кичерелмәгән. *Батырларның җиңеп кайтуларын Түземсезлек белән көтәрмен һәм беренче кайнар үбүемне Данлысына бүләк итәрмен.* Ә. Ерикәй. *Беренче мәхәббәтнең ләззәтле пошынуы, шигъри хәсрәт һәм хыялый бәхеттән гыйбарәт беренче сагышы миңа ясмин чәчәкләренең хуш исле дулкыннары өстендә килгән иде.* Ф. Әмирхан.

5. Нинди дә булса бер ягы, сыйфаты белән башкалардан өстен, алдынгы. *Зәйнәпбану үзе болай төскә биткә дә сөйкемсез түгел, эш дигәндә инде бөтен «Чулпан»да беренче кыз.* Г. Бәширов. [*Камалов*] *бөтен фәннәр буенча университетны беренче булып бетерә.* М. Гали. // Төп, иң мөһим.— *Минем беренче бурычым менә боларны кайгырту иде, иптәш командир.* Ш. Усманов. // Иң яхшы, иң югары сыйфатлы, иң югары дәрәҗәгә ия булган. *Беренче дәрәҗә диплом. Беренче дәрәҗә Дан ордены. Пароходның беренче классына билет алу.* □ *— Әйе, Донбасска, беренче премияне алырга, Рөстәмне алмаштырырга* [*барам*]*!* Һ. Такташ.

6. Сайлап алынмаган, кайсы туры килсә, шул; иң башта очраган. [*Нәфисәгә*] *күз атып йөрүче егетләр аз түгел иде. Ул, озак сайламаса да, беренче күзенә юлыккан кешегә чыкмады.* Г. Бәширов. *Ибрай кул астына туры килгән беренче кызны — игезәкләрнең берсен этеп җибәрде.* Г. Гобәй.

7. Иң башта бирелә торган кайнар сыек ашамлык (аш, борщ, щи һ. б. ш.).— *Сез нинди нәрсә телисез, беренчегә суп әйтикме, борщмы?* Г. Камал.

8. *муз.* Баш партияне башкаручы, җитәкче. *Беренче скрипка. Беренче тавыш.*

9. *кер. сүз. функ. сөйл. к.* беренчедән. *Латыйф сыерны* [*платформадан*] *төшерергә рөхсәт сорады.— Беренче, безгә бу станциядә озак торырга туры килми. Аннары, аның үзенең хуҗасы бардыр бит.* Ш. Усманов.

Беренче май, Беренче май бәйрәме — хезмәт ияләренең халыкара бердәмлек бәйрәме. **Беренче ярдәм** — кинәт авырып китүчегә, бәхетсезлеккә очрап яраланучыга врач килгәнгә кадәр күрсәтелә торган медицина ярдәме.

◇ **Беренче адым(нар)** — нәрсәнең дә булса үсешендә башлангыч чор. *Г. Камал Тукайны беренче адымнарыннан ук тәбриклән каршы ала.* М. Гали. **Беренче карлыгач (сандугач)** — нәрсә дә булса барлыкка килүдә яки үсештә беренче билге. *Шахтер җырларын без татар эшчеләре поэзиясенең беренче карлыгачы дип атый алабыз.* И. Надиров. *24 нче елның язында* [*Сарманга*] *авылны* [*караңгылыктан*] *алып чыгачак күп миллионлы отряднең беренче сандугачы — яшь пионер Мөтү килде.* Һ. Такташ. **Беренче кул** — билгеле бер эштә иң яхшы эшләүче, иң шәп, арада иң файдалысы, иң яхшысы (кеше турында). [*Гөлфиянең*] *өлкән трактор чысы итеп МТСта беренче кул трактор чылардан исәпләнүче --- чем-кара күзле егет билгеләнде.* Р. Төхфәтуллин. **Беренче кулдан** — турыдан-туры беренче чыганактан. *Беренче кулдан алынган хәбәрләр.* **Беренче чиратта (нәүбәттә)** — барыннан да элек.— *Син — беренче чиратта пионер, һәм син бу эшең белән чын пионерлыгыңны күрсәттең.* Г. Гобәй.— *Вагонга беренче нәүбәттә иң кирәкле әйберләрне төягез.* Ш. Усманов.

БЕРЕНЧЕДӘН *кер. сүз.* Санап киткәндә беренче пунктны билгеләү өчен кулланыла. *Аерым хуҗалыкта яшәгән хәлдә* [*зур*] *мөмкинлекләрдән файдаланып булмый. Беренчедән, вак-вак хуҗалыкларга машина кертеп булмый; икенчедән, эшне ныклы план белән алып барып булмый.* М. Әмир.

БЕРЕНЧЕЛ *с.* Билгеле бер нәрсәнең үсешендә беренче баскычта торган; башлангыч ноктада булган. [*Корбановча*] *барсак, минем бүген уйлый алуым, сөйлисе сүземне сөйли алуым да беренчел бабаларыма — маймылларга барып тоташа.* Г. Ахунов.

БЕРЕНЧЕЛЕК *и.* Эштә, спортта һ. б. беренче урын; алдынгылык, өстенлек. *Ярышларның берсендә Зиннәт, Идел районында беренчелекне алып, шәһәргә китте.* Г. Бәширов.

БЕРЕТ *и.* Кырпусыз, җиңел, йомшак, түгәрәк баш киеме. *Күлмәге дә, күзләре дә зәңгәр, Зәңгәр берет кигән башына.* Ә. Ерикәй.

БЕ'РИШ *с.* Шундый ук, бер үк төрле, бер үк төстәге, охшаш. *Бериш күлмәкләр.* □ *Томсон моделендә уңай корылган материя тәмам бериш һәм атомның бөтен күләменә тигез таралып урнашкан.* Атомнар дөньясында. // Бер категориядән булган; бер-берсенә иш булырлык (кешеләр турында). *Халык кырда, бар да сабан сөрә, Ә без монда,— моңсу урамда. Җыен бериш, анда-монда сугылып, Уф орабыз атсыз булганга.* Ш. Маннур.

БЕ'РКАВЫМ *рәв. сөйл. к.* беравык. *Зәкия апа беркавым икеләнеп торды.* М. Хәбибуллин. *Тыннарын кысып, кешеләр беркавым су тавышын тыңлап тордылар.* И. Гази.

БЕ'РКАДӘР *рәв.* Зур булмаган күләмдә, бераз. *— Быел иген уңышы начар, --- Бәлки, эш хайваннарыннан башка мал-туарны беркадәр кимәтәргә туры килер.* Ш. Камал. // Билгеле бер дәрәҗәдә, өлешчә. *Рәхимовлар гаиләсе белән катышу Хәятка беркадәр үзгәреш бирми кала алмады.* Ф. Әмирхан.

БЕ'РКАЙДА *рәв.* Бер генә урында да, һичкайда. *Беркайда ут-мазар күренми, кеше дә юк.* Г. Гобәй. *Йөргән урыннарымны тагын бер кат әйләнеп чыктым, тирә-күршеләрдән сораштыргаладым, ләкин бумажнигым беркайда да юк иде.* А. Шамов.

БЕ!РКАЙЧАН *рәв.* һичкайчан, һичбер вакытта да, һичнинди очракта да. *Идият абзыйның --- бите өреп тутырган куыксыманрак түп-түгәрәк тә шоп-шома. Һәм ул биткә карап беркайчан да аның эчендә ни барын сизә алмассың.* Э. Еники. *Бу секундта Хәлимне беркайчан да булмаган курку чолгап алды.* Г. Гобәй.

БЕ!РКАТЛЫ *с.* 1. Тормыш тәҗрибәсе булмаган, хәйләсез, гади, эчкерсез, тиз ышанучан. *Сәрви, беркатлы кызларча һәм бик сөйкемле итеп, абыйсының мастерскойдан хаксызга куылуын сөйләп бирде.* Э. Фәйзи. *Күрмидер, бик беркатлы кеше, күз-колак булырга исенә дә керми торгандыр.* Г. Бәширов.

2. Акылга җиңел. *Беркатлы, сәер кешеләрдән, диваналардан кызык табу, гомумән, көнчыгышта таралган хәл.* Н. Исәнбәт.

3. Җиренә җиткереп эшләнмәгән, үтә гади. *Без, яңа кешене сурәтләгәндә, аның чорга характерлы булган тулай типик сыйфатлары белән аерым кешенең үзенә генә хас, индивидуаль сызыкларын берләштереп бирә алмыйбыз. Шунлыктан [әсәр] беркатлы, схематик булып чыга.* М. Җәлил.

БЕ!РКАТЛЫЛАНУ *ф.* Беркатлы (1, 2 мәгъ.) булу. *Ара-тирә беркатлылана шул минем Миһриҗамал да, тегенең шаяртып, мыскыллап сөйләгәнен белми, аңа чынлап җавап биреп маташа.* М. Гали.

БЕ!РКАТЛЫЛЫК *и.* Беркатлы булу сыйфаты. *Газинурның нәкъ менә шушы балалардай беркатлылыгы, дөньяда хәсрәт уты йотмыйча, җиңел яшәве, төшенкелекне белмәве [Миңнурыйга] ошый иде бит.* Г. Әпсәләмов.

БЕ!РКАЯ *рәв.* 1. Һичкая, бернинди урынга, һичбер җиргә. *Көндез беркая чыгарлык булмаган. Төнлә исә бәләкәй кыз әнисенең ябык тезләре яныннан читкә китәргә курыккан.* А. Гыйләҗев.

2. Берәр җиргә, берәр урынга, кая да булса. *Нәрсә, әллә шул мәтәлчек арбаларда Ташны ярган шарлавыклар аркылы Беркая үтмәк булалармы?* Н. Исәнбәт.

3. *диал.* Беркайда, һичкайда. *Кәҗә тыкрыгына кадәр төштеләр, беркая бер җан әсәре очрамады.* И. Гази.

БЕ!РКЕМ *а.* 1. Бер генә кеше(дә), бер генә җан иясе(дә); һичкем. *Безнең үткән юлыбызны әле беркем шулай үтмәгән.* Ә. Ерикәй. *Киләчәк — синең күз алдыңда әле моңа кадәр беркем дә яшәмәгән, якты, матур, рәхәт, шат булып гәүдәләнә.* Г. Гобәй.

2. Якын дус яки туган тиешле кеше турында. *Кыз бу егетнең беркеме дә юклыкны яхшы белә.* А. Әхмәт.— *Ах, беркемем дә юк шул минем. Тиздән ялым; кая кайтырга?* М. Җәлил.

БЕРКЕТКЕЧ *и.* 1. Аерым предметларны (мәсәлән, кәгазьләрне), нинди дә булса механизмның, корылманың һ. б. ш. аерым өлешләрен бер-берсенә беркетү өчен кулланыла торган җайланма.

2. Фотода: ачыкландырганнан соң беркетү, ныгыту өчен булган химик состав; *к.* фиксаж.

БЕРКЕТМӘ *и.* Утырышның, җыелышның, сорау алуның һ. б. ш. барышы язылган документ.— *Син, Разия, дәфтәр битенә беркетмә язып бир әле.* Г. Минский.

БЕРКЕТҮ *ф.* 1. Нәрсәгә дә булса кадаклап, чәнчеп, эләктереп, кадап, тегеп, бәйләп, ябыштырып, кыстырып, тагып һ. б. ш. юллар белән ныгыту, кузгалмаслык итү, тотрыклы итү. [*Садыйк*] *язу өстәленең түбәнге тартмасыннан бергә беркетелгән кәгазьләр тартып чыгарды.* Г. Ибраһимов. *Илгизәр, тырмалар арасыннан җиңел генә сикергәләп үтте дә, аларны тракторга беркетеп куйды.* Г. Бәширов.

2. Нәрсәне дә булса берәрсе карамагына, файдалануына тапшыру. *Җир колхозга оешкан хезмәт иясе крестьяннарына гомерлеккә беркетелде һәм алар бу җирдә таза тормыш төзиләр.* М. Җәлил.

3. Кемгә дә булса берәр эш йөкләү, шул эш өчен аны җаваплы итү. *Безне, коммунистларны, иң җаваплы участокларга беркеттеләр.* Г. Әпсәләмов. [*Славин*] *берәр җайлы участок сайлап бирсен үзләренә һәм җиллерәк кадровик беркетсен.* Г. Гобәй.

4. Язу, теркәү. [*Паларусов*] *һәммәсе татарча бирелгән җаваплары протоколга рус телендә беркетә барды.* Г. Ибраһимов.

5. Ныгыту, онытылмаслык итү. *Бу кан белән беркетелгән Дуслык гомергә яшәр.* Г. Хуҗи. *Мәлихә абыстай Хәятны бөтенләй икенче юл белән тәрбия итте. --- Хәятның иң соң укыган китабы --- абыстайның бу тәрбиясен бигрәк нык беркетә бара иде.* Ф. Әмирхан.

6. *күч.* Нәтиҗә ясау. *Мостафа кат-кат бу хатынга ачу күзен ташлады: — Тилергәндер, куркудан шашкандыр! — дип беркетте.* Г. Ибраһимов. // Нәрсә дә булса башкарырга ниятләп кую, катгый карарга килү.— *Юк, әни терелгәч тә, хезмәтче ялларга кирәк, һичшиксез ялларга кирәк,— дип беркетеп куйды [Госман].* А. Шамов.

БЕРҖӨН, БЕРҖӨННЕ *рәв.* 1. Берничә көн элек, күптән түгел.— *Беркөн бер солдат үтеп барышлый Гапсаттар абзыйларда кунып чыккан.* И. Гази. *Беркөнне мин Илдусларга барырга дип урамга чыктым.* А. Әхмәт.

2. Қайчан да булса бер, бервакыт, киләчәктә. *Нурланып беркөн күңелле яз кояшы ялтырар.* Н. Исәнбәт.

БЕРКӨНГЕ *с.* Моннан берничә көн элек булган. *Чәйдән соң Илсөяр, Актүшне иертеп, беркөнге давылда Мәрдән абзыйны батыра язган көймәне эзләргә китте.* Г. Гобәй.— *Беркөнге мәкалә фабкомны телгә алмаганнар иде.* Ш. Қамал.

БЕРЛЕ *с.* 1. Бер санын күрсәтә торган. [*Домино уйнаучыларның берсе:*] *Капламадың шул берлене, менә хәзер ала инде ул, син бер дә йөри белмисең.* Г. Қамал.

2. *и.* Биш баллы системада өлгереш турындагы иң түбән билге. «Бик начар» мәгънәсендә. *Берле билгесе.*

БЕРЛЕҚ *и.* 1. Бер сумлык акча. [*Ләйсән*] *йомарланган берлек суздың.* Азат хатын.

2. *лингв.* Сүз бер генә кеше яки бер предмет турында барганда кулланыла торган төрләнү формасы. *Сан категориясенең берлек төре һәрвакыт нуль формада була, берлекнең үзенә аерым формативы юк.* В. Хангилдин.— *Берлек белән күплекне бутадың. Кара аны, егет, укытучы ишетеп, үзеңә казык утыртып куймасын.* Г. Гобәй.

3. Бердәмлек, оешканлык.— *Әгәр колхоз үз ягын гына, завод үз ягын гына каерса, без ерак китә алмабыз. Безгә берлек кирәк.* Г. Әпсәләмов. *Берлек булса, көч нык була.* Э. Ерикәй. // Тыгыз, ныклы бәйләнеш. *Теория белән практика берлеге. Форма белән эчтәлек берлеге.* □ *Безнең идеал: эш белән көч берлеге.* Н. Исәнбәт. // Уртаклык, тулы охшашлык. *Карашлар берлеге. Теләкләр берлеге.*

БЕРЛЕКТӘ *рәв.* Бергәләп. *Авыл, ире, хатыны, баласы-чагасы бары берлектә, дуу килә.* Г. Ибраһимов. [*Майда*] *организм өчен бик кирәкле кайбер матдәләр эри һәм алар май белән берлектә запас буларак саклана алалар.* А. Расих.

БЕРЛӘ *бәйл. иск. к.* белән. *Кайвакыт хәсрәт йозагы берлә күңелем бикләнә.* М. Гафури.

БЕРЛӘН *бәйл. иск. к.* белән. *Менә бер заман, кисәктән, бу яланғач сахра һәйбәт яшел үләннәр, матур-матур чәчәкләр берлән капланып китте.* Г. Тукай.

БЕРЛӘЧ *и. диал.* Ялгыз, бер генә, игез булмаган. *Сарык берләч китерде.*

БЕРЛӘШМӘ *и.* 1. Бер үк төр эш кешеләрен, учреждениеләрне яки предприятиеләрне берләштергән оешма. *Берләшмәнең аеруча тыгызрак формасы — трест.* Политэкономия.

2. Бер үк төрдәге яки төрле-төрле берничә частьтан торган эре гаскәри берәмлек (бригада, дивизия, корпус һ. б. ш.). *Ун меңнәрне эченә алган гаскәр берләшмәләре бер-бер артлы кузгала башладылар.* Г. Бәширов.

БЕРЛӘШҮ *ф.* 1. Бергә кушылу, бер бөтен булу, оешу. *Хәзерге көндә массада да, Үзәк комитетта да берләшү лозунгысы бара. Күп организациядә ике фракция берләште хәзер!* Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* **берләшеп**. Бергә кушылып, уртаклашып, күмәкләшеп. *Байгузиннар, --- берләшеп, бер яшь ат суйдылар.* Ә. Еники. *Яңа гына әле клубка да Радио алган идек берләшеп.* М. Җәлил.

2. Туплану, оешу, бердәм булу. *Хакыңны ал хәр чакта, берләшеп кал форсатта.* Ш. Бабич.— *Коммунист яшьләр союзы тирәсенә җыелып берләшсәк, безне берәү дә куркыта да, җәберли дә алмый.* М. Фәйзи.

БЕРМӘ'-БЕР *рәв.* 1. Бер кешегә каршы бер кеше (көрәшү, ярышу, сугышу һ. б. ш. турында). *Бермә-бергә чакырам! Чык мәйданга!* Н. Исәнбәт.

2. Икеләтә (арту яки кимү турында). *Һәрхәлдә, йортка бәйләнсә,* [*Нәҗиянең*] *эше дә, мәшәкате дә бермә-бер артыр иде.* Ә. Еники. *Әйе, дошманның көче безгә караганда берничә мәртәбә артык. Әгәр алар бермә-бер яисә бераз гына артык булсалар, күрмәгәнен күрсәтәр идек без аларга.* А. Шамов. // Тагын да ныграк. *Фәйрүшиннең чырае бермә-бер җитдиләнде, директорның һәр сүзен йотып алырдай булып тыңлый башлады.* Соц. Тат.

3. Сүзгә-сүз, бик төгәл итеп. *Тәрҗемәче Вахитның бу сүзләрен бермә-бер тәрҗемә итеп бир*[*де*]. М. Гафури.

БЕ'РМӘЛНЕ *рәв. диал.* Бервакытны. *Бермәлне сөяк башына сөяк орынып китте дә, Арсланга электр тогыннан да катырак ток килеп сукты.* Г. Ахунов. *Бермәлне* [*ул*] *кышын-җәен зәңгәр кырпулы студент фуражкасы киеп йөрде.* И. Рәмиев.

БЕ'РНИ *а. к.* һични. *Бу борчуның көчәеп китүенә ирек бирмәс өчен ул, берни дә уйламаска тырышып --- зәңгәрсулана башлаган Идел өстенә, чабылган болыннарга озак-озак карап торды.* Г. Бәширов. *Сәлим берни дә сизмәгән, белмәгән кебек узып китте.* Г. Гобәй.

◇ **Берни эшләп булмый, берни эшләр хәл юк** — теләгәнчә эшләргә мөмкинлек булмаганда әйтелә. *Илдар хәтле Илдар көймәдә круг белән йөрсен әле! Ләкин берни эшләр хәл юк, риза булды.* Г. Гобәй.

БЕ'РНИКАДӘР *рәв.* Бераз, берничә, беркадәр, күп түгел. *Берникадәр иптәшләребезне --- сугыш кораллары алып кайтырга җибәрдек.* Ф. Әмирхан.— *Миңа берникадәр цифрлы мәгълүматлар кирәк иде.* Т. Гыйззәт. // Аз гына, бераз (вакыт). *Гөлзадә берникадәр икеләнеп тора да* [*хатны*] *ача һәм зур эчке кичереш белән укый.* Р. Ишморат. *Камалов, берникадәр вакыттан соң, авылга таба китте.* А. Шамов.

БЕ'РНИНДИ *а. к.* һичнинди. *Хәзер инде мине берниндидошман да җиңә, каушата алмас.* А. Әхмәт.

БЕ'РНИЧАКЛЫ *рәв.* Берникадәр, күп түгел. [*Шәрәфи*] *алгарак үтте, --- берничаклы эшчеләр, крестьяннар, хатыннар кызыл гаскәрләр белән күз алышты.* Г. Ибраһимов.

БЕ'РНИЧЕК *а.* Һичничек, бөтенләй. *Сабыр табигатьле Сания бу турыда бер сүз дә әйтмәде, ләкин бик күңелсезләнде һәм Гөлсем апа берничек тә аның күңелен таба алмады.* Г. Гобәй.

БЕ'РНИЧӘ *рәв.* Бераз (гына), аз (гына) *Ажгырып торган амбразурага берничә адымда Газинур кинәт туктап калды.* Г. Әпсәләмов. *Берничә минуттан авыл әтәч тавышлары белән тулды.* А. Шамов.

БЕ'РНИЧӘЛӘП *рәв. к.* берничә.— *«Әлеппигә» керүче бер ул гына түгел, Фәрихә түти, алар берничәләп бар.* М. Гали.

БЕ'РНӘРСӘ *а.* 1. *к.* һичнәрсә. *Бүген бернәрсәгә дә күңелем бармый.* М. Гафури. *Бернәрсә дә туктата алмас Безнең бөек ил эшен.* Ә. Ерикәй.

2. *и. мәгъ.* Нәрсәдер, ниндидер билгесез әйбер. *Гайнулла кәгазьгә төрелгән бернәрсә чыгарды.* А. Әхмәт. // (Берәр) әйбер, эш, хәл, гадәт һ. б. ш. *Бу хат* [*Габделбасыйрга*] *чынлап та кадерле бернәрсә шикелле тоела.* Ф. Әмирхан. *Бүләкләрне арбага төягәндә Хәдичә тутине тагын бернәрсә куандырды.* Г. Бәширов. // Берәр нәрсә, нәрсә дә булса. *Бернәрсә эшләргә уйласа, үтерсәң дә* [*Таһирны*] *ул эшеннән кайтара алмыйсың.* Т. Гыйззәт. // Бер үк нәрсә. *Һәркем бернәрсә турында уйлый. Киләчәккә зур уйлар йөртә.* Г. Ибраһимов.

3. Берәр кешегә карата кимсетеп яки шаяртып әйткәндә кулланыла. [*Таштүбә Садыйк*] *үзе киез итек биеклеге генә бернәрсә иде, ләкин аның эченә җыйган явызлык, хәйләкәрлек бер дә Бавырсак батырныкыннан ким булмагандыр.* Г. Гали. *Бу кулларыңа караганда мин сине бөтенләй көчсез бернәрсә дип йөри идем.* Ә. Айдар.

БЕ'РРӘТТӘН *рәв.* 1. Янәшә, бер үк рәттә. *Стенада нәзек кенә тимер кыршаулар асылынып тора --- шулар белән беррәттән скрипка эленеп тора.* Ә. Фәйзи. // *күч.* Сыйфаты, әһәмияте һ. б. буенча бердәй, бер дәрәҗәдә.— *Тукайның энҗе шикелле тезелгән матур шигырьләре белән беррәттән куярлык шигырь яза алсаң, шәп булыр иде булуын.* Ш. Камал.

2. Бер-бер артлы, өзлексез рәвештә, рәттән. *Мәрьям* [*Фәхринә*] *арткарак этәрә дә, нәкъ йөрәгенә таба төзәп, беррәттән өч мәртәбә ата.* Г. Ибраһимов. *Бәхетләренә каршы, беррәттән өч-дүрт көн буран булса, шул вакытта алган акча белән фатирларына да түләп куялар.* М. Гафури.

3. Бер уңайдан. *Айсылу, байракны җәеп, аның чукларын төзәткәләде дә, беррәттән Нәфисәнең пальтосын да сыпыргалап куйды.* Г. Бәширов.

4. Кем белән дә булса берәр эшне бертигез дәрәҗәдә, шундый ук күләмдә башкару турында. *Башка халыклар белән беррәттән тынычлык өчен көрәшү.* □ *Эшкә килгәндә* [*Гайния*] *кемне дә үзеннән алда җибәрмичә, ирләр белән беррәттән эшләп, беррәттән дүртбиш җамаяк аш* [*ашый*] *--- булган.* Г. Минский.

5. Бергә, бер үк вакытта. *Совет белән беррәттән буржуазия диктатурасын гәүдәләндергән Вакытлы хөкүмәт килеп чыкты.* КПСС тарихы. *Ләкин* [*уңай яклары*] *белән беррәттән, әсәрнең кимчелекләрен дә әйтми булмый.* М. Җәлил.

БЕРСЕ *а.* 1. Аерым кешене, предметны, күренешне зуррак категориядән, төркемнән, берничәсе арасыннан аеру өчен кулланыла. [*Дускаев*] *күрше районнарның берсендә туып-үскән егет.* Ә. Еники. *Хәят юлларның берсе белән китте дә, койма янына килгәч, бераз туктап торды.* Ф. Әмирхан.

2. Кем дә булса берәү, берәр кеше. [*Адресын*] *белсәм, берсеннән бик оста хат яздырып, бик ныкшелтәлим әле Фазылны!* Г. Ибраһимов.

3. Гадәттә, «очраган, күренгән, чыккан» һ. б. сүзләр белән килгәндә *һәркем, һәркайсы, һәрберсе* мәгънәсен белдерә. *Кешеләр --- кайсы ары, кайсы бире узалар, очраган берсе яңа мөгаллимне ачык кына сәламлиләр иде.* Ш. Камал.

4. Кабатланып яки «башка», «икенче» һ. б. ш. сүзләр белән бергә килеп, бер төркем кеше, предмет, күренешләрне һ. б. ш. санап киткәндә кулланыла. *Вокзал --- Берсе китә, берсе кайта, Башка берәүләре озата.* Ә. Ерикәй.

БЕРСЕ'-БЕР *а.* Һичкем, һичберсе.— *Мин сиңа ике хат яздым --- Шуның берсенә-бер җавап бирмәдең.* А. Шамов. *Шул клубны яхшылап ремонтларга берсенең-бер кулы җитми.* Р. Төхфәтуллин.

БЕРСЕ-БЕРСЕ *а.* Аерым-аерым һәркайсы. [*Алманың*] *берсе-берсе куш йодрык кадәр була аның, үзе, язга кадәр сакласаң да, бакчадан гына өзеп алгандай.* Р. Төхфәтуллин.

БЕРСЕ'КӨН *рәв.* Иртәгенең иртәгесе. *Инде беләсең нәрсә: бөзгә иртәгә үк яисә берсекөннән дә калмыйча, авылда җыелыш үткәрергә кирәк.* Ш. Камал.

БЕРСЕ'КӨНГЕ *с.* Берсекөндә булачак; иртәгәнең иртәгәсенә билгеләнгән. *Берсекөнге концерт бүгенгә күчерелә.*

БЕРСЕ'КӨНГӘ *рәв.* Иртәгәнең иртәгәсенә. *Бүген булмаса иртәгә, ә иртәгә булмый икән, берсекөнгә Бизмән тауның сере ачылыр.* А. Әхмәт.

БЕРСЕННӘ'Н-БЕРСЕ *а.* Бериш зат, предмет яки күренешләрдә нинди дә булса сыйфатның чагыштырмача артыклыгын басым ясап күрсәткәндә кулланыла. [*Агыйделнең сул ягындагы биек таулар*], *Урал тавының тармаклары булып, берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе биек булып күренәләр.* М. Гафури. *Хәлим ашавыннан туктап тыңлый, ә анасы берсеннән-берсе күңелгезрәк сүзләр тезә.* И. Гази.

БЕ'РСҮЗДӘН *рәв.* Каршылыксыз, бертавыштан. *Күрсәтелгән кандидатураны берсүздән үткәрү.* // Барысы бергә, бер булып. *Берсүздән балыкка барырга булу.*

БЕ'РСҮЗСЕЗ *рәв.* **1.** Һичнинди каршылыксыз. *Миңнур карт берсүзсез риза булды, карчыгының уфтануына, киленең кызып китүенә колак салмады.* А. Шамов. // Һичшиксез. *Нәҗипнең күзләренә яшь килде. Больницага керсәң, берсүзсез алып калачаклар.* Г. Гобәй.

2. Бер сүз дә сөйләшмичә. [*Рөстәм*] *озак кына берсүзсез идән буйлап йөри.* Һ. Такташ.

БЕ'РТАВЫШТАН *рәв.* **1.** Бердәм рәвештә, бер үк вакытта. *Кызлар да бертавыштан яңадан кычкырып сабакларын укырга тотындылар.* М. Гали.

2. Тавыш бирүдә катнашучыларның уртак фикере белән, каршы тавышлар булмыйча. *Бертавыштан председатель итеп сайлау.* // Бердәм, уртак фикердә булып. [*Кешеләрнең*] *барысы да бертавыштан шәһәрне саклауны күзаладеләр.* Ш. Усманов.

БЕ'РТИГЕЗ *с.* **1.** Теге яки бу сыйфаты ягыннан тигез, охшаш. [*Укытучы*] *барысы да бертигез, барысы да чем-кара буяуга буялган парталарга утырган укучыларга үткен һәм сынаулы караш белән карый.* А. Әхмәт. // Бертөрле, охшаш. *Революциягә чаклы татар әдәбиятының демократик катлавын тәшкил иткән язучылар барысы да бертигез карашта булмадылар, әлбәттә.* М. Әмир // *хәб. функ.* Бер үк хокукта, бер үк дәрәҗәдә. *Бай, алпавыт яки поп, Аксөякләр хәзер юк, һәммә кеше бертигез.* Г. Камал.

БЕ'РТОТАШТАН *рәв.* Бер дә туктамыйча, туктаусыз, өзлексез рәвештә. *Ул артык кызу темп белән эшләмәсә дә, ләкин армый-талмый бертоташтан озаклап һәм пөхтәләп эшләп утыра ала иде.* М. Гали. *Вак тамчылы һәм бертоташтан ява торган яңгырлар явалар.* Г. Тукай.

БЕ'РТУГАН *с.* **1.** Бер ата-анадан туган; кан кардәш.— *Әнәрнең әнисе әсматтәй минем бертуган апам бит.* Р. Ишморат.

2. *күч.* Бертуганнар кебек тату, үзара якын. *Эшче куллар — бертуган!* Н. Исәнбәт. *Ш. Камалның авыр эш шартларында бер кайгы, бер теләк белән, бертуган булып бер-берсенә үзләшкән эшче геройлары — дөньяга карашлары һәм тойгылары ягыннан яңа тип кешеләр.* М. Җәлил.

БЕ'РТУКТАМЫЙ, БЕ'РТУКТАМЫЙЧА *рәв. к.* бертуктаусыз. *Менә мин, команда мәктәбен бетереп, кызыл командир булып чыктым --- Шуннан соң менә дүрт ел инде бертуктамый эшләп киләм.* Ф. Бурнаш. *Станоклар бертуктамыйча әйләнәләр.* А. Алиш.

БЕ'РТУКТАУСЫЗ *рәв.* Даими, тоташтан, өзлексез рәвештә. *Хәлим бертуктаусыз сөйләнде.* И. Гази. *Бертуктаусыз яуды яңгыр — Тамчылары кургашын.* Ә. Ерикәй.

БЕ'РТУМА *с. диал. к.* бертуган. *Бу Шәләнге авылында Камалиның ата бертума абзасы Ситдыйк бар иде.* Г. Ибраһимов.

БЕ'РТӨРЛЕ *с.* **1.** Аермалы сыйфатлары, үзлекләре булмаган, бер үк характердагы, охшаш. [*Гөлсем*] *бар да бертөрле, шул үк вакытта һәркайсысы үзенчә матур өйләргә, читән коймаларга, капкаларга карады.* Г. Гобәй. *Төзелештәге иң алдынгы бетон бригадасының бригадиры Щербаков* [*Нуруллинга*] *еш кына бертөрле җавап бирә.* А. Шамов. // Тигез, бер үк дәрәҗәдәге. [*Галиәсгар Габдулла белән Галекәйнең*] *икесенә дә бертөрле мөнәсәбәттә булды.* Ә. Фәйзи.

2. Үзенә аерым бер, махсус. *Ул кавем вә җыелышның һәр әгъзасы да эшли, хезмәт итә, ләкин аларның хезмәте аерым-аерым бүленгән: һәрберсе бертөрле эш эшли.* Г. Тукай.

3. Фикергә билгесезлек төсмере өсти: ниндидер. *Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын: «Исле май сөркән икән дөнья!» дидем: бәйрәм бүген!* Г. Тукай. [*Мәрьям*] *артык уйларга, фикер итәргә өлгерә алмады, бертөрле йомшак, ягымлы дулкыннарга чорналып әллә кайларга китте.* Ш. Камал. // *рәв. мәгъ.* Ничектер. *Суы чыкмаса, бармакка бертөрле ябышып торса, шул инде игеннең балавыз хәле була.* Г. Гобәй. *Әллә ничек шуның исеме үк йөрәккә бертөрле якын тоела.* Г. Ибраһимов.

4. *рәв. мәгъ. сөйл.* Ярыйсы гына, бераз. [*Поп*] *патша һәм хөкүмәт тарафыннан бирелгән вазифасын үтәргә теләп, болар кабул итмәгәч, үз вазифасын бертөрле үтәгән --- кебек, тирә-ягындагы начальникларга карап, миннән бурыч төште дигән мәгънәне аңлатты.* М. Гафури. // Беркөе, беркөйгә. *Бертөрле яшәп яту.*

5. *а. функ. тарт. форм.* **бертөрлесе.** Кайберсе. [*Салиха карчык*] *бертөрлесенең нәселен ошатмады, икенчеләренең егете ошамады, кайберләренең туган-тумачасы бик ишле --- дип, үзен бөлдерүдән курыкты.* Г. Бәширов. [*Саф сәнгать теориясен яклаган*] *язучыларның бертөрлесе, ак эмиграциягә китеп, фашизм ялчысына әйләнде, бертөрлесе, совет туфрагында калып, астыртын рәвештә контрреволюцион көрәш алып барды.* М. Җәлил.

БЕ'РТӨРЛЕЛЕК *и.* Бертөрле (1 мәгъ.) хәл, күренеш. *Инде бу кырдагы өч-дүрт төрле шакмакларның, бер-бер артлы тезелешеп, бертөрлелек хасил итүләре бераз ялыктыра башлаганлыктан, мин алда күренә торган урманга тизрәк барып җитүне көтәргә тотындым.* Ф. Әмирхан.

БЕ'РТӨСЛЕ *с.* **1.** Төсләре ягыннан бер үк. *Бертөсле киенү. Бертөсле бизәкләр.* □ [*Төлке куянга:*] *Койрыкның менә дигәнен алып кайтып бүләк итәрмен. Туның белән бертөсле булыр.* А. Алиш.

2. *к.* бертөрле. [*Мохтар*] *каралҗым уйчан күзле кызчыкның язмышы Фатыйманың язмышы белән бертөсле үк булырга мөмкин икәнлеген һич тә күңеленә китергәне юк иде.* Ш. Камал.

БЕ'РТӨСЛЕЛЕК *и.* **1.** Бертөсле (1 мәгъ.) булу сыйфаты.

2. *к.* бертөрлелек. *Классик шигырь строфикасының катып калган калыпларын җимерү ягыннан «Бүзләрем мана алмадым» шигыре бик тә күргәзмәле. Монда Дәрдмәнд строфалар арасындагы симметрик бертөслелекне җимерә.* Х. Госман.

БЕ'РЧАК(НЫ) *рәв.* **1.** *к.* бервакытны. *Александр Сергеевич Пушкин, Берчак бездә кунак идең син — Пугачевның үткән эзләреннән Казан урамында йөрдең*

син. Э. Ерикәй. *Берчакны бер ана каз белән ата каз егерме бер бәбкә үстерә[ләр] икән, ди.* Н. Исәнбәт.

2. Бераз вакыт. [*Шәйхаттар бабай*] *узган кыш урманда артыграк тырышып ташлаган ахрысы, кайткач берчак биленә зарланып ятты.* Г. Гобәй.

БЕ'РЬЕЛЛЫК *с. бот.* Барлык үсеш циклы (орлыктан үсеп чыгып чәчәк атуы, җимеш бирүе һәм бетүе) бер ел эчендә була торган. *Берьеллык үсемлекләр.*

БЕ'РЬЮЛЫ *рәв.* 1. Бер үк вакытта, барысы бергә. *Разиядан берьюлы ике хат килеп төште.* И. Гази. *Зур самолетны көчкә сыйдыра алган ике платформаның тәгәрмәчләре берьюлы тәгәри башладылар.* Г. Гобәй.

2. Шунда ук, шул ук вакытта, бик тиз, кинәт, бөтенләй. *Бу сүзне Габдулла берьюлы төшенде.* Ә. Фәйзи. *Халык җырлары стилен үстереп, шул нигездә, берьюлы халык арасына кереп китәрлек җырлар иҗат итү — опера өчен ят әйбер түгел.* М. Җәлил. *Ләкин сыйнфый көрәшнең иң каты уты эченә килеп керү [Суфияны] берьюлы үзгәртеп җибәрде.* Г. Нигъмәти.

3. Бер уңайдан.— *Шунда [миң торбаларын төзәткәндә] берьюлы мунча мичен дә чыгарып бирерсең.* Т. Гыйззәт. // Бер үк вакытта барысын да, калдырмыйча. *Берьюлы ашап бетерү.* □ *Берьюлы бетсен! — диди, өйнең түбә кыекларын ясадылар.* Г. Ибраһимов.

БЕ'РЬЯКЛЫ *рәв.* 1. Предметның яки күренешнең бер ягын күрсәтеп, нәрсәгә дә булса күбрәк игътибар биреп, башка якларны исәпкә алмыйча. *Мәсьәләгә берьяклы гына килү. / с. мәгъ. Берьяклы караш. Берьяклы гарантия.*

2. Бер сүздә булу.— [*Атасы*] *да тагы, улы белән берьяклы булып, миннән көлгән булып маташа.* Г. Камал.

БЕ'РЬЯКЛЫЛЫК *и.* Нинди дә булса мәсьәләне хәл итүгә берьяклы гына, чикләнгән караш. [*Мәкальләрне социал-тарихи дию*] *белән тагын берьяклылык, схемачылык тудыруларга юл ачылды.* Н. Исәнбәт.

БЕРӘГӘЙЛЕ *с. сөйл.* Шәп, югары сыйфатлы, иң яхшы; берүзе берничәгә торырлык. *Ике булганчы бер булсын да, берәгәйле булсын.* Мәкаль. *Аклардан бер генә генерал калган бит инде дигәнсең диюен дә, беләсең килсә, бер булса да берәгәйлесе калган.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Тиешле дәрәҗәдә итеп, җиренә җиткереп. *Бер эшлә, берәгәйле эшлә.* Әйтем. *Күп сөйләми ул, ләкин бер әйтсә, берәгәйле итеп әйтә.* Г. Ахунов.

БЕРӘМ-БЕРӘМ *рәв.* 1. Берсе артыннан икенчесе, бер-бер артлы, аерым-аерым. [*Агач*] *яфраклары тутлап, куырылып, берәм-берәм бөтерелеп түбәнгә, юл читләрендәге ызаннарга, чокыр-чакырларга төштеләр.* А. Гыйләҗев. [*Пионерлар*] *яттылар һәм берәм-берәм йокыга да китә башладылар.* Г. Гобәй. // *күч.* Җентекләп, тәфсилләп. *Җиһангир булып үткән вакыйгаларны берәм-берәм күз алдыннан кичерде.* Г. Ибраһимов.

2. Берәрләп. [*Ирләр*] *капчыкларны берәм-берәм күтәреп ташыйлар, - - - каравылчы амбар ишеген бикләп кала.* А. Алиш.

БЕРӘМЛЕК *и.* 1. Үзе белән төрдәш, бер типтагы зурлыкларны үлчәү өчен кабул ителгән зурлык. *Авырлык үлчәү берәмлеге. Акча берәмлеге. Озынлык үлчәү берәмлеге.* □ *Хәзер азыкларның туклыклылыгын азык берәмлеге белән үлчиләр.* А. Расих. [*Борын заманнарда*] *товарны товарга алмашканда, акча урынына тиен тиресен берәмлеккә алып, бер тиенлек булды, ике тиенлек булды - - - дип санарга ул бик кулай әйбер булган.* Н. Исәнбәт.

2. *мат.* Күбурынлы саннарның соңгы цифры.

БЕРӘМЛЕКЛӘП *рәв.* Предмет яки күренешне берәм-берәм тәртипкә салып, берсен дә читтә калдырмыйча, күз алдында тотып. *Әсәр берәмлекләп шушы сорауларга җавап картиналарын ача бара.* Г. Нигъмәти. // Аерым бер сыйфатлары буенча җентекләп. *Мансуров, районга килгән көннән башлап, кыйммәтле асылташ кебек берәмлекләп җыйган талантлы яшьләр гвардиясенә тагын бер солдат табылуына чын күңелдән куанды.* Г. Бәширов.

БЕРӘМЛӘП *рәв.* Берәм-берәм, бер-бер артлы. [*Итекче*] *авызын тутырып вак кадаклар каба да чүкеч белән шуларны берәмләп ботинка төбенә кага башлый.* Ә. Еники. *Күп тә тормый, атты әкрен якты таң, Нурлы йолдызлар берәмләп сүнделәр.* Г. Тукай.

БЕРӘМ-СӘРӘМ, БЕРӘН-СӘРӘН *рәв.* Кайбер урынларда гына, бик сирәк, әллә нигә бер. *Түбә кыегыннан берәм-сәрәм кар бөртекләре [оча].* Г. Гобәй. [*Вахта бүлмәсендә*] *башта кешеләр берән-сәрән генә күренәләр, бераздан инде төркем-төркем булып килеп керәләр.* М. Шабай.

БЕРӘМТЕКЛӘП *рәв. сөйл.* 1. *к.* берәмләп.

2. Җентекләп, һәр детальгә игътибар итеп, тәфсилләп. [*Йөзлекәй карчык Арслангалигә*] *Кәлимәтнең салкын сулы чишмәләрен, каен урманнарын, таң атуын, шәфәкъ батуларын күрсәтте. Шуларның хасиятен, серхикмәтләрен берәмтекләп, вәземләп аңлатып йөргән булды.* Г. Ахунов. *Кукурузда - - - нинди матдәләр бар икәнен берәмтекләп тикшерик.* А. Расих.

БЕРӘР 1. *Бүл. саны. к.* бер I (1 мәгъ.). *Валерикны алырга кергән апа барысына да берәр ландрин биреп чыкты.* Г. Гобәй.

2. *б-сез. а.* Нинди дә булса.— *Күңелем бик куркып тора, берәр хәл булмаса ярар иде.* Г. Ибраһимов. *Безне данлы зур сугышка озат, чибәр кыз; Әйт син безгә, акыллы кыз, берәр җылы сүз!* Ә. Ерикәй.

3. Вакыт төшенчәле сүзләр (атна, ай, ел, сәгать) алдыннан килеп, чамалап әйтү мәгънәсен белдерә. *Авария-фәлән булмаса, берәр айдан нефть яткан катлауга барып җитәчәкбез.* А. Әхмәт. [*Мәрьям*] *һәр ике-өч көнгә бер тапкыр керләр алып, тыныч вакытта гына елгага төшә һәм берәр сәгать чамасы вакытта керләр чайкап, юып рәхәтләнеп кайта иде.* Ш. Камал.

Берәр яры — кая да булса; кайда да булса. *Мин берәр яры китеп кенә торыйм булмаса.* Р. Төхфәтуллин. *Ничек уйлыйсыз, Батырхан әфәнде, миңа монда берәр яры урнашырга булырмы икән?* К. Тинчурин.

БЕРӘР-БЕРӘР *рәв. к.* берәм-берәм. *Бәдри - - - әйберләрне берәр-берәр алып, әйләндереп-әйләндереп карап, урыны-урынына рәтләп куйды.* М. Гафури.

БЕРӘРСЕ *б-сез. а.* Кем дә булса, кайсы да булса берсе. *Ай, берәрсе килеп чыкса!* А. Әхмәт. [*Бүре куянга:*] *Барысына да җитәрлек булса, [койрыкларның] берәрсе артып та калса, алып кайтырмын.* А. Алиш.

БЕРӘҮ 1. *Җыю саны. к.* бер I (1 мәгъ.). *Минем йөрәгемне әрнетүче Син генә, берәү генә.* Ә. Ерикәй.— *Тагы сөйлә инде, Мәрдәнша бабай [берәр хикәя]. - - - Бардыр әле.— Берәү калган икән шул,— дип елмайды [бабай].* Г. Гобәй.

2. *б-сез а. функ.* Теләсә кем, һәркем, һәркайсы.— *Киемем энәле булса да, эч сереңне алсам да, мин сиңа начарлык эшләмәм: сак бул, очраган берәүгә сереңне сөйләмә.* А. Алиш.

3. *б-сез. а. функ.* Кемдер, билгесез бер кеше. *Ишеттем мин кичә: берәү җырлый, Чын безнеңчә матур, моңлы көй.* Г. Тукай. // Сөйләүчегә генә билгеле булган бер кеше. *Монда берәүгә кереп чыгарбыз.* Г. Ибраһимов.

4. *б-сез. а. функ.* (Нинди дә булса) бер кеше, кем дә булса. *Сезгә берәү кыңгыкка килә, әсез аны борып җибәрәсез. Нәрсә дигән сүз бу?* Р. Ишморат. *Ул [Сөләйман] башка берәүне сөяме?* Ф. Әмирхан. // *күпл.* **берәүләр.** Кайберләре, кайсыберләре. *Берәүләр кан тирләргә батып эшлиләр, берәүләр бернәрсә дә эшләмиләр.* Г. Тукай. // *эвф.* Киная белән әйтелгәндә кулланыла. *Берәүләрнең йокысы килгән.*

5. *Юкл. а. функ.* «Дә» кисәкчәсе белән килгәндә:

һичкем.— [*Гаγһәрия*] *бит берәү белән дә йөрми.* А. Гыйләҗев.

БЕРӘҮСЕ *а.* **1.** *сөйл.* Кемдер берәү. [*Яралылардан*] *берәүсе солдатларга карап: «--- Сез кемнәргә каршы мылтык күтәреп килеп, кемнәрнең йөрәк каннарын агызуыгызны беләсезме?»* [*диде*]. М. Гафури.

2. *Юкл. а. функ.* «Дә» кисәкчәсе белән килгәндә: берсе дә, һичкем. *Эмма туңа. Аның ачлыктан Күкрәге чатный. Берәүсе дә икмәк китерми, Өйгә дә якмый.* М. Җәлил.

БЕ'РӨЗЛЕКСЕЗ *рәв. к.* бертуктаусыз. *Ике көн берөзлексез вокзал юлында арба тавышы гөрләде.* Ш. Усманов.

БЕ'РҮЗЕ *рәв.* Башкалардан аерым рәвештә, ялгызы, үзе генә. *Биш егет эшләрлек эшне эшләп ташлый берүзе.* Ә. Ерикәй. *Явыз песи берүзе Ялт иттергән ак майны.* М. Җәлил.

БЕРҮК **1.** *модаль сүз. сөйл.* Кисәтеп, борчылу катыш әйтелгән теләкне яки үтенүне белдерә; зинһар.— *Кызым, берүк, су читенә төшмә, ярдан бар.* Г. Гобәй. *Ана ябалак балаларына шушы сүзләрне әйткән: — Уларым, кызларым, берүк, сүземне тыңлагыз. Бер-берегездән аерыласы булмагыз, көндезгә калмагыз.* А. Алиш.

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* Бигрәк. *Эмма тискәре карт икәнсез берүк!* Г. Ибраһимов.

БЕСЕ'ДА *и. сөйл.* Нинди дә булса темага багышлап чыгыш ясау һәм шуның буенча тыңлаучылар белән бергә фикер алышу; әңгәмә. [*Совхозда*] *булган тәҗрибә кырларының уңышлары безгә крестьяннар белән беседа алып барган вакытларда көчле мисал булып хезмәт иттеләр.* М. Әмир.

БЕСЕ'ДКА *и.* Бакчада ял итеп утырыр өчен ясалган түбәсе ябулы җиңел корылма. *Кайчандыр бакчадагы* [*тормышның үзәге*] *булып торган бу беседка бүген инде эченә кералмаслык булып җимерелгән, кычыткannар белән чолганып утыра иде.* Ә. Әмирхан.— *Биредә бөркү бит, нишләп бакчага, беседкага чыгып утырмыйсыз?* Р. Ишморат.

БЕСКОЗЫ'РКА *и.* Козырёксыз, артына кара тасма тагылган фуражка (матрослар баш киеме). [*Малайның*] *башында моряклар кия торган тасмалы бескозырка.* А. Әхмәт.

БЕТ *и.* Кеше һәм хайван тәненә кадалып кан суыра торган канатсыз кечкенә паразит бөҗәк.

Бет уты (үләне) *бот.*— кузаклыклар семьялыгыннан үлән үсемлек; тычкан борчагы; *русчасы:* мышиный горох.

◇ **Бет ачуын туннан алу, беткә ачу итеп тунны утка ягу** — ачуны гаепсез кешедән алу яки, юк-барга хәтер калып, зуррак эшләрне бозып ташлау. **Бете котыру** *гади с.*— яхшы тормыштан яки бик күп күңелле эшләрдән, кәеф-сафадан соң узынып китү.— [*Приказчикларның*] *бетләре бик котырса, кибеттән кайткач, ишек алдына кар көрәргә чыгар.* Ш. Мөхәммәдев. **Бет чәйнәгән** *гади с.*— бик вакчыл (кеше турында).

БЕТЕК *и. иск. к.* язу 11 (1, 2 *мәгъ.*).

БЕТЕМ *и.* **1.** Художество әсәренең тәмамлану өлеше; драматик, э кайвакыт хикәяләү характерындагы әсәрләрдә — эпилог, лирик шигырьләрдә — соңгы юл яки строфа; мәсәлдә — соңгы сүз, мәсәлнең мәгънәсе, мораль өлеше. *Иректе шигырь теориячеләренә килгәндә, алар болай аңлаталар: шагыйрьнең әйтергә теләгән фикерләре, бирергә уйлаган тойгылары вәзен, бетем, строфалар эчендә кысылып калмаска тиешле.* Г. Нигъмәти.

2. *иск.* Кушымча. *Ярдәмлек сүзләрне, хәбәрлек бетемнәре белән төрләнүләренә карап кына, фигыль дип уйларга тагын юл юк.* Г. Алпаров.

БЕТЕП *рәв. диал.* Бик бирелеп, йотылып, бөтен күңелне куеп. [*Ифрат*] *башта иртәнге табигать белән мавыгып, кечкенә кошчыкларның бетеп сайрауларын тыңлады.* А. Расих. *Иванов* [*Вәлинең*] *күзләренә бетеп карады.* Г. Ибраһимов.

БЕТЕРГЕЧ **1.** *с. сир.* Җимергеч, хәлиткеч. *Сугышка, иптәшләр, һәр җирдән, Заводлар, калалар, кырлардан Килегез, ясыйбыз дошманга Җимергеч, бетергеч удар лар.* Ә. Ерикәй.

2. *и.* Язуны ышкып бетерә торган резинка. [*Варис*] *бит кырыйларына карандаш белән язылган искәрмә — курсәтмәләрне бетергеч белән аннан-моннан чистарткалады да --- кире нәшриятка җибәрде.* М. Хәсәнов.

БЕТЕРЕНҮ *ф. к.* бетерешү 2.— *Берәрегез кергәндә, чыкканда аның йөзен күрә алмадымы? Күргән булса, ул кеше минем ябыгуларның, минем бетеренүләрнең төп сәбәбен берьюлы аңлар.* Г. Ибраһимов.— *Әллә бигрәк бетеренеп киткәнсең, әни?* Н. Исәнбәт.

БЕТЕРЕШҮ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* бетерү (1—3,5 мәгъ.). — *Безнең өчен борчылма, аклар бөтенләй бетсеннәр, бергүк муеннары аска килсен, сугышны бетерешеп кайт.* Г. Бәширов. *Ресторанда күп йөреп, Бетердем мин малымны, Бергә бетерешкән дусларым Сорамыйлар да инде хәлемне.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Картаеп яки авырып, ябыгып хәлсезләнү, хәлдән таю, эштән чыгу. *Гариф бу елларда бетереште инде ул, былтыр да Мортаза белән ярыша алмагач, мәйданга җитәр алдыннан, юри егылып калган булды.* М. Гали.

3. *мат.* Вакланмада яки тигезләмәдә билгеле бер саннарның кыскаруы, мәсәлән: 5 *ab* = 3 *ab* яки $\frac{3ab}{5ab}$ да *ab* лар бетерешә.

БЕТЕРҮ *ф.* **1.** Билгеле бер эшне төгәлләү, тәмамлау. *Ялкау киндерәсен ураганчы, тырыш эшен бетерер.* Мәкаль. // Ахырга китереп җиткерү, туктату. *Сугышны бетерү.* □ *Без дә, бүгенге утырышны шуның белән бетереп, өйгә керергә риза булган идек, тик якында гына шакылдавык тавышы ишетелеп бүлдерде.* М. Әмир. // Кайда да булса укуны төгәлләү.— *Консерваторияне бетергәч тә, гастрольгә барабыз.* Р. Ишморат. *Мәктәпне бетереп, --- ул ничек тә булса тагын укү, зуррак белем алу дәрте белән көзен, икенче бер шәһәргә китә.* М. Гали.

2. Юкка чыгару, юк итү. *Урамнарга март җилләре килгәч, Киртләч карлар тавын бетерә.* Ш. Маннур.— *«Халыкларның көрәшеп килгән эше: һичкичекмәстән демократик солых тәкъдим итү, җиргә алпавытчылык милкен бетерү --- тәэмин ителде».* Т. Гыйззәт. // Тоту, сарыф итү (акча, азык-төлек, материал һ. б. ш. турында). // Ябу; яшәүдән, эшләүдән туктату. *Корткычлар заводны бетерү юлында беркадәр эшләп тә өлгерәләр. Мәсәлән: күкерт ачысы эшли торган ике камераның берсен бетереп, аның урынына өч өлеш ким продукция чыгара торган контакт цехы төзиләр.* Ш. Камал.

3. Эшләп өлгертү, җиткерү, салу (йорт, каралты һ. б. ш. турында). [*Гайшә*], *ире сугышларда йөргәндә, илдән урын сорап алды да агай-эненең, күрше-күләннең булышлыгы белән менә шул хәзерге өйне бетереп керә алды.* Г. Ибраһимов.— *Алган бурабыз тора, түбә калае, түшәмлек-сайгаклык барысы да әзер, өй бетерәсебез бар.* Ф. Хөсни.

4. *сөйл.* Өлгереш буенча булган түбән билгедән (берле, икеле, өчле...) соң югары билге (дүртле, бишле) алу. *Гомеремдә беренче тапкыр алган икелене бетерәсе бар.* Р. Төхфәтуллин.

5. *күч. сөйл.* Үтерү; тар-мар итү; җиңү, юк итү. *Эксплуататор сыйныфларны бетерү.* □ *Чех дигәнен бетердек, Корнилов дигәнен бетердек, Дутов дигәннәрен ду китердек.* К. Нәҗми.

6. *күч. сөйл.* Нәрсәгә дә булса кайгырып, сагышланып (үз-үзеңне) авыруга сабыштыру.— *Сабыр ит --- елап үз-үзеңне бетермә, юкка гына үз-үзеңне бетерәсең.* М. Гафури.

7. *рәв. мәгъ. күч. сөйл.* **бетереп.** *к.* бер итеп. *Бүрекне өйне бетереп эзләү. Авылны бетереп йөрү.*

8. *с. рәв. мәгъ.* **бетергесез.** Үзеннән алда килгән хәл фигыль белән берлектә «артык дәрәҗәдә, чамадан тыш, бик күп» кебек мәгънәләрне белдерә. *Ераста, ераста, яр буенда санап бетергесез учаклар күренде.* К. Нәҗми. *Безне беркем дә, беркем дә күрми иде, һәм без беренче мәртәбә икәүдән-икәү генә булуыбыз белән әйтеп бетергесез бәхетле идек.* Ә. Еники.

◇ **Бетереп ташлау** — бик каты итеп тиргәү, ачулану.

БЕТЕШ *и. иск. к.* үсеш 1. *Бетеше яман камышны су эчендә үрт алыр.* Мәкаль.

БЕТЕШҮ *ф. сөйл. к.* бетәшү 2. [*Әниең*] *бик бетешкән иде, улым, күзләре дә начар күрә иде --- Нургалидән хәбәр килү белән, бөтенләй үзгәреп китте.* Т. Гыйззәт.

БЕТКЕСЕЗ *с. сөйл.* санап, үлчәп бетерерлек түгел, иксез-чиксез. *Камышлы күлларнең суына, печән эскертләренең беткесез муллыгына ияләшеп үскән үгезләрне вагонга тутырганнар да Мәскәүгә озатканнар.* К. Нәҗми.

БЕ'ТКӘНЧЕ *рәв.* 1. Ахыр чиккә кадәр, үлгәнче.— *Минем бу сөйләгән сүзләремне син тагы кодагыйларга барып әйтә күрмә, алар усаллыкны беткәнче белә торган явыз, начар кешеләр.* Г. Камал.

2. *күч.* Бик нык, тулысынча, бөтен барлыгы белән. *Укытучылык начар эш буламы соң? Тик аны яратып, җаның-тәнең белән бирелеп эшләргә генә кирәк. Беткәнче бирелергә кирәк ул эшкә.* М. Әмир.

БЕТЛЕ *с.* 1. Бетләгән, бет баскан. *Мәчет картлары Мифтахха авыз ачарга да ирек бирмиләр: — Син, егет, бик масайма әле! Бетле шинелеңә тавык тәпие кадап кайткач та, үзеңне становой дип белдеңме.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Кешегә кимсетеп, хурлап әйтелә торган сүз. *Европаның бетле рыцарьлары Көнчыгышка тәре походы белән килгәндә, андагы культура искиткеч матур булып чәчәк ата торган булган.* Сов. әд.

Бетле баш — *к.* бетле 2.— [*Мәйсәрә*], *бетле баш, остазбикә буласы килгән, корчаңгы.* К. Тинчурин.

БЕТЛӘҮ *ф.* Бет үрчү (башта, киемдә), бет басу. *Яз килгәчтен* [*Фриц*] *язган хатыныма: — Белмим, кайтып булыр микән,— дип,— Бетләп беттем үзем, хәзер инде җәй килгәнен генә көтәм,— дип.* Ә. Ерикәй.

БЕТМӘС *с.* Бетми торган, дәвамлы, озак вакытлар дәвам итә торган.— *Мондый изге таңда нинди бер бетмәс улау бу?!* М. Әмир. *Онытмаслар һич тә һәм аларга Мәңге бетмәс рәхмәт укырлар.* Ә. Исхак. // Чамадан тыш күп. [*Шәриф*] *биш тиененә он алса, ике тиен акча дәхи артып кала, менә бетмәс акча!* М. Гафури. // *күч.* Бик көчле, билгеле бер дәрәҗәгә җиткән, тирән, дәвамлы (уйлар, хисләр һ. б. ш. турында). *Мәңге бетмәс кайгы салдың минем йөрәкләремә.* Җыр.

БЕТМӘС-ТӨКӘНМӘС *с.* Чиктән тыш күп, санап бетергесез (кем яки нәрсәнең саны турында); иге-чиге юк, исәпләп бетererлек түгел. [*Ширинская*] *күңелендә Булатка каршы аз гына җылы, яшерен тоҗы белән бергә бетмәс-төкәнмәс үпкә дә, шелтә дә бар --- иде.* Г. Ибраһимов. *Печән өстенең киң күңелле юмарт кояшы, Идел буе халкының киң тугайлардагы бетмәс-төкәнмәс печәнен киптереп арыганнан соң, баер якка авышкан иде.* Г. Бәширов.

БЕТОН *и.* Цемент массасының ком һәм вакланган таш белән кушылмасы, төзү материалы. *Бетон чәрексез ул, яшь кызлар кебек иркә, назлы. Ул туңа, өши.* А. Гыйләҗев.

БЕТОНЛАҮ *ф.* Бетон салу, бетон коеп нәрсәне дә булса ныгыту, эшләү. *Төзүчеләр яңа гигантларның Бетонлыйлар нигез ташларын.* Г. Хуҗиев.

БЕТОНЧЫ *и.* Бетон коючы. *Бетончылар* [*Нурулинга*] *сөеп, үз итеп, елмаеп карыйлар.* А. Шамов.

БЕТТЕ-КИТТЕ *кер. с.* Җөмлә ахырында килеп, нинди дә булса эшне җиңел генә башкарырга мөмкин икәнлекне белдерә; «шуның белән эш тә бетте; бу турыда башка сөйләшеп тә торасы юк, вәссәлам» мәгънәсендә. *Бертөрлесе ачыктан-ачык әйтте: — Нигә безгә күрәләтә башны таш капчыкка тыгарга? Үзебезгә тигән җирне алырга да бетте-китте.* И. Гази. *Дөресен әйтергә дә бетте-китте иде.* Г. Гобәй.

БЕТЧӘ *и.* Тәнгә чыга торган каты башлы үлекле кабырчык, сыткы.

БЕТЧӘЛЕ *с.* Бетчәләгән, бетчә баскан. [*Кызның*] *бетчәле йөзе каракучкылланып кызарды.* А. Расих.

БЕТЧӘЛӘҮ *ф.* Бетчә басу, бетчәләр чыгу. *Күземне күреп котым чыкты. Бөтенләй бетчәләп беткән.* Г. Лотфи.

БЕТӘШТЕРҮ *ф.* 1. *Йөк. юн. к.* бетәшү (1, 2 мәгъ.).

2. *сөйл.* Ямау, ялгау, төзәтү (кием-салым турында). *Ә култык асты, терсәк кебек артыграк көч килә торган урыннарны Лукьян иске ямаулыклар белән бетәштереп өлгертә алмас булган.* Ш. Камал.

БЕТӘШҮ *ф.* 1. Төзәлеп йомылу, җыерылып кибү (яра, җәрәхәт турында). *Аяк ярасы бетәшү.* // Күзләрнең картаюдан нурсызланып, кечерәеп, күз кабагының җыерчыклар белән чуарланып калуы турында. *Габдулла --- өйнең зур-зур ләгәннәр, комганнар, сөлгеләр, иске туннар белән тулган кара ягында күзләре бетәшкән бик карт бер әби белән бергә яшәде.* Ә. Фәйзи.

2. Картаю, арыкланып, бөрешеп бетү; ябыгып, хәлсезләнеп, кечерәеп калу. *Габдулла бу бетәшеп бетә язган карчыкның җиләк кебек кыз чагы булуын күз алдына китереп бетерә алмады, ишек шыгырдап ачылды.* Ә. Фәйзи. // Авырып яки ачлыктан бетеренү. [*Зәйнәпбанулар*] *инде кияү буласы кеше Зиннәт шикелле бик бетәшеп кайтса, иртәсен-кичен җылы сөт эчерәсе булыр дип әйтеп, узган яз мүкләк кенә булса да бер кәҗә дә алдылар. Г.* Бәширов. // *сөйл.* Искергән, тузган (предмет турында) — *Өй дә суынып китте. Бик бетәшкән шул, җылы тормый.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Саранлану, вакчыллану.— *Биш тиеннән кыйбатрак булыр бит, әй. Бу мал болай да бик бәһа төште безгә,— дип, бетәшеп азаплана купец.* Ф. Хөсни.

БЕТӘҮ: бетәү яра *диал.*— озак вакыт буена төзәлми торган яра.

БЕТҮ I *ф.* 1. Ахырга килеп җитү, төгәлләнү, тәмам булу, тукталу. *Сугыш бетү белән тыныч эшкә Колач җәйде безнең калалар.* Ә. Ерикәй. *Җыр бетеп, биюгә күчкән чагында, Закир уфтанып куйды.* Ш. Камал. // Тотылу, сарыф ителү (акча, азык-төлек, материал һ. б. ш. турында). [*Габдулла*] *Габделвәлигә тәмәке алып кайтып бирде. Ләкин сынатмас өчен аңа акчасы беткәнлекне әйтмәде.* Ә. Фәйзи.

2. Юкка чыгу, юк булу. *Никадәр иртә булса да, көн аяз булганлыктан, чык беткәнче дип, умарта кортлары шул аланлыкны бизәгән матур чәчәкләргә бал алырга, үзләренә кышлык азык хәзерләргә төшкәннәр.* М. Гали.— [*Фәхри*] *хәзер минем якын дустым булды. Нина турындагы шикләрем дә бетте.* Г. Ибраһимов.

3. Нәрсәнең дә булса пространство яки вакыт ягыннан чиге булу, шул чиккә килеп җитү. *Бәрәңге бакчалары бетеп, бераз баруга, текә яр башлана.* Г. Гобәй. *Кар белән бер вакытта бетәдер март, Апрель туса, дөнья була суга юмарт.* М. Гафури.

4. Бик зур бәла-казага дучар булу.— *Алдандым, алдандым, беттем.* Г. Камал.

5. *диал.* Үлү, һәлак булу.— *Бетәм, үләм, чыгарыгыз! Коткарыгыз.* С. Рафиков. *Бер уллары үсеп җитүгә, фин сугышында бетте, икенче уллары --- шушы сугыштан кайтмады.* Р. Төхфәтуллин.

6. Картаеп, ябыгып хәлсезләнү, арыклану, авыр кайгыдан бетеренү.— *Кашки шул бер елны гына күрмәгән булсамчы! Шул бер елда картаюым, шул бер ел эчен-*

дә бетүем. М. Гали. *Син килдең дә нәкъ каршыма тезең чүктең. Тик беткәнсең, сулгансың шул син, бичара.* М. Җәлил. // Искереп, таушалып эшкә ярамас хәлгә килү (предмет турында).— *Ә көймә бик беткәнмени, Гөлбану түтәй?* Г. Гобәй.— *Бигрәк беткән икән синең абзар.* Р. Төхфәтуллин.

7. *ы. функ.* **бетте.** Башка кабатламаска яки дәвам иттермәскә сүз бирү. [*Сафия:*] *Әткәй җаным, килешми лә, карт башың белән.— Бетте, кызым, бетте.* Ш. Камал.

8. *ярд. ф. функ.* Төп фигыль янында килеп, эш яки хәрәкәтнең кабатланып яки көчәя барып, билгеле бер дәрәҗәгә җитү төсмерен бирә. *Куанышып бетә алмый-быз без Тормышыбыз тулы, ямьлегә.* Ә. Ерикәй. [*Габделбасыйр*] *бу фикернең моңар кадәр үз башына килмәвенә гаҗәпләнеп бетә алмый иде.* Ф. Әмирхан.

◇ **Беткән баш беткән** — нинди дә булса эшкә тәвәккәлләп, икеләнүләрне читкә куеп тотынганда әйтелә; ни булса да булыр, барыбер, әллә ни булмас эле.— *Әйдә, Мингулов, безгә хәзер барыбер. Беткән баш беткән, Себергәме, каторгагамы, киткән баш киткән!* Т. Гыйззәт.

БЕТҮ II *ф. диал.* Үсү. *Бәрәңге сабакка бетү.* □ *Тәбәнәк агач ботакка беткән була.* Мәкаль.

БЕФ-СТРО'ГАНОВ *и. кулин.* Сыер итен вак кына турап әзерләнгән, табынга соус һәм гарнир белән бирелә торган ашамлык.

БИ I. Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләрдә юклыкны (сыз-сез кушымчалары мәгънәсен) белдерә торган алкушымча, мәсәлән: **бихисап, биһуш, бигамь, бихәбәр, бичара.**

БИ II *и. иск. тар.* Морза, түрә, князь, хуҗа. *Шагыйрь, бай гаиләдән чыгуына карамастан, бар рухы белән байларга, биләргә, муллаларга — хаксызлыкка, кеше көченнән файда күрергә тырышучыларга каршы чыга.* Каз. утл. *Бирган бигә яраган.* Мәкаль.

БИАГА, БИАГАЙ *и. диал. к.* каенага.

БИАНА, БИАНАЙ *и. диал. к.* каенана. *Килен кеше — ким кеше, Көнлекчегә тиң кеше, Бианай кеше — уллы кеше, Губернаторга тиң кеше.* Мәкаль. [*Килен*] *дә урыныннан торып, өй җыя, биланасына булыша башлаган.* Н. Исәнбәт.

БИАТА, БИАТАЙ *и. диал. к.* каената. — *Килен булып төшкәч тә, җиде ел килен камзулы кидереп, биатай, биланай кебек иң якыннарыбыздан да тел яшерергә киңәш бирдегез!* Т. Гыйззәт.

БИБЕК *и. зоол.* Кыуликлар отрядыннан кечкенә саз кошы; тәкәрлек. *Кайчак ачы елый-елый өстебездән бибеклəр әйләнеп уза.* А. Расих.

БИБЕШ *и.* Каз канаты астында була торган кечкенә каурый (балалар аннан, очлы агачка икешәрләп кадап, ук ясыйлар). *Миндә бибеш булса, бөтен ипташларга ук була.* Г. Лотфи.

БИБИ *и. диал.* Каз яки үрдәк баласы; бәбкә. *Ишек алдын өч-дүрт оя чеби, шыбырдаган үрдәк бибиләре тутырды.* Р. Төхфәтуллин.

БИ-БИИП *аваз. иярт.* Машиналарның сигнал бирү тавышын белдерә.

БИБЛИО'ГРАФ *и.* Библиография белгече. *Идрис Хөрмәтуллин шушы ук китапханәдә библиограф булып эшли иде.* Х. Сарьян.

БИБЛИОГРА'ФИК *с.* Библиографиягә караган. *Библиографик белешмә.*

БИБЛИОГРА'ФИЯ *и.* **1.** Китапларны һәм башка төрле басмаларны берәр билгеләре буенча системага салып санап чыгылган фәнни язма. *Китап басу эше Казанда оешканнан алып Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр чыккан китапларның тулы библиографиясен бирү бурычын куймый автор.* И. Рәмиев. // Билгеле бер авторның әсәрләре исемлеге һәм аның иҗаты турындагы тәнкыйть әсәрләренең библиографик күрсәтмәләре; билгеле бер вакытта чыгарылган яки нинди дә булса берәр мәсьәлә буенча төзелгән әдәбият исемлеге. *Муса Җәлил әсәрләре библиографиясе.* □ *Биредә төрле гыйльми цитаталар, өземтәләр китерелмәүгә --- укучыларым, шаять, гаҗәпләнмәсләр. Аерым санап күрсәтерлек библиография дә юк.* Н. Исәнбәт.

2. Басылып чыккан әсәрләрне политик, фәнни, практик һәм тәрбияви максатларда киң файдалану күзлегеннән карап өйрәнә торган фән.

3. Басылып чыккан китапларга журнал һәм газеталарда рецензияләр урнаштырыла торган бүлек.

БИБЛИОТЕ'КА *и. сөйл. к.* китапханә.

БИ'БЛИЯ *и.* Яһүдиләрнең һәм христианнарның тарихи, көнкүреш һәм дини характердагы борынгы мифлар, легендалар, шулай ук законнар, догалар, гимннар, язылган дини китабы; тәүрат.

БИВАК, БИВУАК *и.* Гаскәрнең ачык һавада куну яки ял итү урыны. *Кем юына, кайсы учакта Аш пешерә, чолгау киптерә. Привалларда, төнге бивакта Шулай, дуслар, тормыш ителә.* Ә. Маликов.

БИГАЙБӘ *кер. сүз.* Гаепләмә, гафу ит.— *Мин сиңа яхшылык белән әйтәм, инде тыңламыйсың икән, ул чагында, бигайбә, кода булып түгел, председатель булып сөйләшергә туры килер.* Г. Бәширов.

БИГА'ЯТЬ *рәв. иск.* Чиксез, чиктән тыш, бик. *Атай кылычны төргән бигаять озын киндерне чишә-чишә тәмам итеп, кылычны кынысыннан чыгарып, бик гайрәт белән чаж итеп селкеп җибәрде.* Г. Газиз.

БИДГАТЬ *и. иск.* **1.** Шәригать законнарын бозучы, динне санламаучы, бозык кеше. *Менә шушы бидгатьләр, мәсәлән, харап иттеләр дөньяны.* Ф. Әмирхан.

2. Традициягә каршы килә торган, гаепләнә торган (эш, хәрәкәт һ. б.). [*Хәмзә бай*], *һәрбер кеше минемчә уйларга, минемчә яшәргә тиеш дип уйлый --- шуннан башка эшнең бөтенесе «бидгать».* М. Гали. / *с. мәгъ. Шул чакта бакчага бер сыер кергән, Бакчада явыз бидгать уен күргән: Бер күбәләк кызыл гөлдә утырганда, Янына умарта корт килеп кунган.* Ш. Бабич.

БИГРӘК *рәв.* **1.** Чиктән тыш, кирәгеннән артык, чамасыз, артык дәрәҗәдә.— *Галия бигрәк тә кыланган була, кыланышы үзенә күрә түгел.* Г. Колəхметов. *Миңа урман бигрәк гүзәл, көмеш ай яктысында бигрәк тә моңлы күренә иде.* М. Җәлил.

2. Барыннан да элек. [*Газинурның*] *бу кыска җавабында, бигрәк тә акыллы күз карашында, теләк тә, кыюлык һәм ниндидер зирәклек тә бар иде.* Г. Әпсәләмов.

3. *кер. сүз функ.* Берәр нәрсә белән килешмәгәндә әйтелә. — *Килешмәгәнне инде, бигрәк.* Ф. Әмирхан.

БИГУДИ *и.* Тукыма, күн, пластмасса, капрон, тимердән һ. б. ш. ясалып, чәчне урап бөдрәләтү өчен кулланыла торган көпшә.

БИДОН *и.* Май, сөт, керосин һ. б. ш. сыекчаларны сала торган, капкачлы металл яки пластмасса савыт. *Сары шинельле ике кеше, зур калай бидонны ике як тоткаларыннан тотып, чанага куйгач, Садыйк картның күз аллары караңгыланды.* Ш. Камал.

БИДРӘ *и. диал. к.* чиләк. *Үз нәүбәтең булса, ашханәгә чыгып, бидрә яки казаннарны өрлеккә тагылган җепләргә асып, аш яки ботка пешерергә керешәсең.* М. Гафури.

БИДӘР *и. иск. диал. к.* бизәк. *Ал бидәрле, гөл бидәрле кайсы байның чанасы; Бөгелә-сыгыла су китерә кайсы егет җанашы.* М. Фәйзи.

БИЕГЭЮ *ф.* Берәр нәрсәнең биеклеге зураю, арту. *Тегендә биек кибәннәр югала торса, монда алардан әллә ничә өлеш зур салам эскертләре баскыч-баскыч булып күккә таба үрмәлиләр, озынаялар, киңәяләр, биегәя баралар.* Г. Ибраһимов. *Төсе уңа төшкән күк көймәсе тагын да биегәйде һәм ачыкланды.* Г. Бәширов.

БИЕК *с.* 1. Астан өскә таба юнәлештә гадәти чамадан, уртачадан зуррак булган, озын. *Биек йорт. Биек тау.* □ *Жил шаяра биек койма белән, Өй түбәсен никтер куптара.* Н. Баян.

2. *рәв.* **биектә, биектән.** Хәрәкәтнең бик югарыда баруын белдерә. [*Казлар*] *биектә-биектә авыл өстеннән утеп китәләр.* А. Гыйләҗев. *Көн җилле, ак читле кабарынкы болытлар язгыча бик биектән ашыгып агалар.* Э. Еники.

БИЕКЛЕК *и.* 1. Биек булу дәрәҗәсе; предметның вертикаль буенча астан өскә таба озынлыгы яки ераклыгы. *Менә болар [Эйфель, Вашингтон манарасы] барысы да үз җирләрендә, үз заманнарында биеклек белән мактанган һәм макталган ноктәлар.* Г. Гали. // *с. мәгъ.* **биеклеге(ндәге).** Бер әйбернең вертикаль озынлыгы икенче бер әйбер белән чагыштырылганда кулланыла: кадәр(ле), озынлыгында(гы). *Борынгы сәүдәгәрләрнең кеше биеклегендәге хәрефләр белән язылган вывескалары урынына продком, артель, комиссия кебек яңалыклар менеп утырдылар.* Қ. Нәҗми.— *Әле кайчан гына --- менә шушы өстәл биеклеге генә идең бит.* А. Әхмәт. // Җир яссылыгындагы нинди дә булса ноктаның океан өсте тигезлегеннән вертикаль сызык буенча югарылыгы. [*Гоби яссы таулыгының*] *биеклеге океан өсте тигезлегеннән 1,5 км га кадәр җитә.* Дөнья кис. геогр.

2. Җирдән күп югарыда булган пространство.— *Очалар,— диде егет, сокланып.— Бабаларының кыр казлары икәнлеген оныта алмыйлар. Канһарында ирекне, бәйсезлекне, биеклекне тою горурлыгы уяна.* А. Гыйләҗев. [*Самолетлар*] *кисеп менеп зәңгәр биеклекне, Ыргылдылар өстән дошманга.* Ш. Маннур.

3. Қалкулык, калку урын, кечкенә тау, кашлак урын. *Безнең подразделение --- элмә, өрәңге һәм башка шундый яфраклы агачлар белән капланган шушы биеклектә туктады.* А. Шамов.

4. *күч.* Дан, шөһрәт. *Бөек җырчы, кыяларга басып, Җирдә торып тавышын бирде ул, Давыл шавын җирдә шаулатты ул, Биеклеккә табан алды юл.* Н. Баян.

5. *мат.* Фигураның түбәсеннән нигезенә төшерелгән перпендикуляр озынлыгы. *Өчпочмакның биеклеген табу.*

БИЕМ *и. диал. к.* каенана. *Ике биемгә бер килен, Көйли алсын кем көен.* Мәкаль.

БИЕНҮ *ф. сөйл.* Үзалдына сикергәләп, биегән шикелле хәрәкәтләр ясап йөрү. *Җамали аяк баскан җирендә, үз алдына селкенеп, биенеп куйды.* Г. Ибраһимов.

БИЕТҮ *ф.* 1. *Йәкл. юн. к.* бию.

2. Биегән шикелле хәрәкәтләр ясатып, сикертү, йөгертү, уйнату. *Батырлыкка гыйшык тоткан кызлар Колоннага якын киләләр, Атын биетеп үткән егетләргә Сокланышып чәчәк сибәләр.* Ф. Қәрим. // Төрлечә җитез хәрәкәтләндерү (иңбашны, аяк, кулларны). [*Киң иякле берсе*] *шул сүзләрне әйткәч, иңбашларын биетеп, китеп тә барды.* И. Гази.

3. Берәр кешене бөтен нәрсәдә үз ихтыярына буйсындыру, үзе теләгәнчә генә йөрергә, эшләргә мәҗбүр итү. *Мосафир кем, җиһанга басты ботны, Биетте ажгырып аны замана.* Дәрдмәнд. *Богауларны киертергә, Теләгәнчә биетергә Уйлаган шаһлар Киде үзләре коршаулар.* Г. Қамал.

4. *күч.* Қемне дә булса берәр ярамаган эше өчен бик каты тиргәү, шелтәләү.— *Аеңны да күктән кубарып алырмын, Әхмәтне дә кызган табага бастырып биетермен.* Д. Аппакова.

5. *гади с.* Сатып җибәрү.— *Теге брошкаларны ике йөз тәңкәгә биеттем.* Г. Қамал.

БИЕШҮ *ф.* Берничә кеше бию (берьюлы яки бер-бер артлы). *Кабыныл китте шатлык ялкыннары, Дулкын булып бәрде гөрләшү, Гөрләшү, кайнашу. Гармоньга биешү.* Ш. Маннур. [*Гыйльман*] *бии башлый, бүтәннәр дә аңар ияреп биешкән булалар.* Г. Қоләхметов.

БИЗ *и. анат.* Қеше яки хайван организмының яшәеше өчен кирәкле булган матдәләр эшләп, аларны канга яки организмга бүлеп чыгара торган орган. *Қалкансыман биз. Май бизе. Төкерек бизе.* □ *Менә әле политругыбызга салкын тиеп, тамак төбе шешкән. Ике яктан да әстерхан чикләвеге хәтле бизләре калкып тора.* К. Нәҗми.

◇ **Биз-биз авырту** — төрле урында авырту.— *Аягым, менә, биз-биз авырта, менә шушы теземнән төшеп китә дә, балтырыма җитеп, яңадан чәнчешеп ботыма менә.* Г. Газиз.

БИЗГӘҚ *и.* Тундырып калтырата торган көчле, йогышлы авыру. *Габдулла бизгәк белән калтыраныл йөрде-йөрде дә, нихаять, урын өстенә егылды.* Ә. Фәйзи. *Бизгәк белән авырып яткан Илсөяр, күзләрен теләр-теләмәс ачып карады да, керүченең Бикмүш бабай икәнен белгәч, тагын йомды.* Г. Гобәй.

◇ **Бизгәк тоту** — бизгәк белән авыру.—*Әнә абыеңны бизгәк тоткан икән ләбаса. Докторлар кирәк.* Д. Аппакова. *Бизгәк тоткан төсле калтырана Куркуыннан кайбер кешеләр.* М. Гафури.

БИЗГӘҚЛЕ *с.* Бизгәк белән авыручы. *Фәтхи бизгәкле кеше шикелле калтыравык тавыш белән [җырлап җибәрде].* Ш. Қамал.

БИЗӘҮ *ф. к.* бизү. // Читләшү, башкалардан аерылу. *Элек тә ялгызлыкны ярата торган Исхак торабара кешеләрдән тагын да бизенде.* А. Гыйләҗев.

БИЗЛЕ: бизле ашказаны *анат.*— кошның аш юлында бүксә белән бүтәкә арасындагы бер урын. *Кошларның бизле ашказаны алдында шактый зур куык — бүксә була, ә ашказаны артында бик итләч бүтәкә була.* А. Расих.

БИЗМӘН *и.* Бер башы чукмарлы, икенче башы үлчәнә торган әйбер әлеп куярлык итеп эшләнгән шкалалы күчәрдән гыйбарәт үлчәү. *Марат белән Шамил бизмәннәрен каланча баганасына элеп куйдылар да корткыч өннәреннән чыккан башакларны үлчи башладылар.* Г. Гобәй.

◇ **Бизмәнгә салып үлчәү** — к. бизмәнләү (2 мәгъ.). — *Ә мин сезгә карашыгызны яңадан бер кат бизмәнгә салып үлчәргә, уйланырга киңәш бирер идем.* А. Расих.

БИЗМӘНЛЕ *с.* 1. *к.* үлчәүле.

2. *күч.* Уйлап, бик үлчәп кенә эш итүче. // Саран; вакчыл.

БИЗМӘНЛӘҮ *ф.* 1. Берәр әйберне бизмәнгә салып үлчәү.

2. Бик уйлап, чамалап эш итү турында. // Саранлану; вакчыллану.

БИЗНЕС *и. сөйл.* Алдашу, хәйлә юлы белән шәхси байлык туплауга нигезләнгән зур табышлы эш.

БИЗНЕСМЕН *и.* Америкада: һәр эштән зур табыш каерырга омтылучы эшкуар. *Маршал белән утырып Бергә план кора, ди, Бизнесмен булып алган да Кризис белән ура, ди.* Н. Исәнбәт.

БИЗОН *и. зоол.* Төньяк Америкада яши торган кыргый үгез.

БИЗЧЕЛ *с.* Бизле, бизләре булган. // Биз сыман, бизгә охшаган. *Бизчел күзәнәкләр.*

БИЗӘҚ *и.* 1. Төрле төстәге җепләр белән чигеп, буяулар белән буяп, ташларны уеп, күп төрле сызыкларны, төсләрне матур берләштереп ясалган рәсем. *Колонналы йорт фасады. Орнамент ясый егет. Таш бизәкләр күренәләр Тере чәчәкләр кебек.* З. Мансур. *Утә күренмәле. юка чынаяк китегенең нәфис бизәкләре өстенә оста куллар, бик килештереп, алтын белән нәрсәдер язган булган, ләкин, заман үтү белән, сүзләре ашалып беткән иде.* Г. Гобәй. // Шундый рәсемне хәтерләткән нәрсәләр турында. [*Габдулла*] *тәрәзә төбенә үк менеп утырган*

да бозның чатлы-чатлы булып пыялага ябышкан искиткеч бизәкләренә карап соклана. Э. Фәйзи.

2. Кемне яки нәрсәне дә булса бизәү, аңа ямь бирү өчен хезмәт итә торган затлы, матур әйбер.— *Кызның колакларына, түшләренә миннән алтын бизәкләр вәгъдә ит.* М. Фәйзи.

3. *күч.* Нәрсәне дә булса белдерә торган, сиздерә торган сызык. *Җитә шундый вакыт, җырчы үз каршында тезелешеп утырган иптәшләренә шаян бер күз сирпи, аның иреннәрендә шуклык бизәкләре уйнаклый.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Нәрсәнең дә булса күрке, яме, мактанычы. *Бөтен тирә-як - - - табынның яме, байрәмнең бизәге булган сайрар кошлары белән табигать күркен — яшел җәйне каршы алырга хәстәрләнә иде.* Г. Бәширов.

Бизәк төшерү — нинди дә булса әйбергә бизәкләр ясау.

БИЗӘКЛЕ *с.* Бизәге булган, бизәкләр төшерелгән. *Кижеле ашъяулык җәйгән өстәлдә, бизәкле поднос өстендә самовар шаулый.* Г. Әпсәләмов.

БИЗӘКЛӘҮ *ф.* 1. Нәрсәгә дә булса бизәкләр төшерү, бизәкле итү. [*Пәке*] *фил сөягеннән көмеш белән бизәкләп эшләнгән бит.* Д. Аппакова.

2. *к.* бизәү. *Ирек мәйданына, бик матур итеп бизәкләп, ёлка ясаганнар.* А. Шамов. *Сибелгән бриллиант төсле — Бизәкли күкне йолдызлар. Бизәклиләр җир өстен — Чәчкәләр төсле матур кызлар.* М. Гафури.

БИЗӘКЧЕ *и.* Бизәкләр ясаучы, бизәкләр төшерүче.

БИЗӘКЧӘ *и.* 1. *кеч. к.* бизәк.

2. *күч. шигъ.* Җырларда, мәкальләрдә төп фикерне әйтү өчен фон итеп китерелгән беренче өлеш. *Мәкальләрнең куш юллы яки күп юллы булганының башында, гадәттә, табигатьтән яки тормыштан алынган бер бизәкчә бирелә дә аннан төп мәгънәне аңлаткан буыны әйтелә.* Н. Исәнбәт.

БИЗӘҮ *ф.* Биткә иннек, кершән сөртеп, күзгә сөрмә тартып, алка, йөзек, беләзек, муенса кебек нәрсәләр тагып, үзенне матурлау. [*Гайни*]*көзге каршына килеп калфагын төзәтә, чәчләрен сыпыра, бизәнә.* Г. Камал. // Матурланү, ямьләнү. *Җир йөзе тәмам бизәнгән Чәчкәләр, гөлләр белән.* М. Гафури.

БИЗӘҮ-ТӨЗӘҮ *ф. к.* бизәнү-ясану.

БИЗӘҮ-ЯСАНУ *ф. җый.* Бизәнү һәм ясану, төрлечә бизәнү, купшылану. *Кыз аулак өйгә барырга бизәнеп-ясанып, киенеп куйган иде.* Г. Ибраһимов.

БИЗӘҮ *ф.* Төрле бизәкләр, бизәкле әйберләр белән кемгә яки нәрсәгә дә булса матурлык, ямь бирү, аны матурлау. *Икенче көнне зифа буйлы чыршы бүлмәнең нәкъ урта бер җиренә килеп басты. Әй, тотындылар аны бизәргә!* Д. Аппакова. // *күч.* Тагын да матуррак, гирән мәгънәлерәк, тәэсирлерәк итү (сөйләм, стиль турында). *Кави курыкмыйча теманы сайлый яки курыкмыйча шуны киңәйтеп, оригиналь, матур тасвирлар белән бизәп яза, сөйләп бирә белә.* Г. Нигъмәти. *Һәрбер халык сүз арасында мәкальләр кыстырырга ярата, үз телен бизи, төзи.* Н. Исәнбәт. // *күч.* Эчтәлеге ягыннан тулырак, баерак итү (тормыш, көнкүреш һ. б. ш. турында). *Хезмәт бизи шулай матур итеп Тормышны һәм кеше язмышын.* Г. Хуҗиев. *Менә шундый хатларны укып, мин семья эчендә тупаслана башлаган хисләремне матур кешеләрнең тойгылары белән бизәргә, Ольгалар өчен дә Кадриямне сөяргә, иркәләргә тырыштым.* Г. Кутуй.

БИЗӘҮЛЕ *с. к.* бизәкле. *Сахтиян читекләү, ай, бизәүле, Болгарныкы икән олтаны шул.* Җыр.

БИЗҮ *ф.* Берәр кешене, күнегелгән берәр нәрсәне яратмый башлау; аңардан тую, гайрәт чигү, ихлас (күңел) кайту. *Солдатның шулкадәр җаны бизгән, ул шундый гарьләнгән, хәтта туган авылына әйләнеп тә карамады.* Г. Бәширов. *Их, Кадрия, эштән бизәргә, эштән качарга ярамый.* Т. Гыйззәт.

БИК I *и.* 1. *иск. кит. к.* бәк.

2. Хәзер кайбер кушма сүзләр составында сакланып калган. Мәсәлән: *Солтанбиков, Ханбиков, Бикбулат. Биктимер* һ. б.

БИК II *и.* 1. Нәрсәне дә булса (ишек, сандык, тәрәзә, тартма кебек әйберләрне) бикләү өчен эшләнгән җайланма; йозак, келә, бикләвеч, эшермә. *Без слесарь чакырттык та бикне ваттырып* [*бүлмәгә*] *кердек.* Г. Ибраһимов. *Әнвәр ишекне үзе генә япмакчы иде дә, элгечне бигенә туры китерә алмыйча, озак кабаланды.* Қ. Нәҗми.

2. *гади с.* Төрмә, зиндан. *Тәүлек узгач, ата-ана, Ак сакаллы картлар килеп, Гозер итеп яшь морзага, Итәкләрен аның үбеп, Қоткарып алган биктән.* Ш. Маннур.

Бик салу — бикләү, йозаклау.

БИК III *рәв.* Гаять, чиктән тыш. *И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә — эш, Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.* Г. Тукай. [*Төньякта*] *булган бик каты салкын җил без кебек чәнчеп-чәнчеп ала.* М. Гафури. // *сөйл.* Җитәрлек яхшы (мәгънә ягыннан үзенә карый торган «әйбәт», «яхшы» сүзләре төшеп калганда). *Үземә-үзем җавап бирә башлыйм: тукта, нәрсәдән куркып торам соң мин, үземне-үзем белмиммени, беләм, бик беләм.* М. Әмир. // *сөйл.* Фикергә катгыйлык төсмере өсти: һичшиксез, әлбәттә. [*Тимеркәй:*] — *Үзең белән бергә аласың бит мине?* [*Батырхан:*]—*Алам, бик алам.* Г. Ибраһимов.— *Мин сезнең белән сөйләшмим. — Бик сөйләр идең дә,— диде аңа солдат,— тыңлаучы юк.* К. Нәҗми. // *сөйл.* Берәр нәрсәгә ис китмичә генә карауны белдерә. *Бик, аның ише. Бик инде, исең киткән. Барам ди бик.*

БИКАСАП *и. иск. кит.* Азия халыклары куллана торган буй-буй ярым ефәк тукыма. // *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Бикасап камзул.* □ *Габдулланың күз алдына тагын хыялындагы әлеге ак бикасап чапанлы - - - зур галим килеп басты.* Э. Фәйзи.

БИҚВАДРАТ *и. мат.* Нинди дә булса санның яки зурлыкның дүртенче дәрәҗәсе.

Биквадрат тигезләмә *мат.*— чишелеше квадрат тигезләмә чишелешенә кайтып кала торган тигезләмәнең аерым очрагы.

БИҚЛЕ *с.* Бикләнгән; йозак салынган.— *Ни булса да, менә бу сандыкның эчендә булыр иде дә, бикле икән шул.* М. Фәйзи. *Капка бикле иде,* [*Камали*] *авыр гәүдәсе белән ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* Қ. Нәҗми.

БИҚЛӘВЕЧ *и. сөйл. к.* бик II.

БИҚЛӘНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* бикләү. *Тоткыннар үзләренең алданганлыкларын сизеп ишеккә килгәндә, тимерле калын ишек бикләнеп өлгергән иде инде.* Г. Гобәй.

2. *Кайт. юн. к.* бикләү. *Тимер ишек өстеннән тагын зур йозак шалтырап бикләнде.* Г. Ибраһимов.

3. Бүлмә эчендә калып, башка кешеләр кермәсен өчен ишекне бикләп кую.— *Көтеп тә машәкатьләнмәгез,* [*Габбас*] *бикләнеп үк йокларга яткан.* Ш. Қамал.— *Батырның тавышы-тыны юк, өенә кереп бикләнде.* А. Алиш. // *күч. рәв. мәгъ.* **бикләнеп.** Үзең генә калып, беркемне дә кабул итмичә. *Кеше йөзе күрмичә бүлмәсендә бикләнеп эшләп утырганлыктан - - -* [*Сөләйманга*] *август һавасы да, кешеләр дә әллә ничек сәер тоелдылар.* Қ. Тинчурин. *Серебряковның кысан каютасына бикләнеп, алар бик озак сөйләшеп утырдылар.* И. Гази.

4. *күч.* Бер урынга яки бер эшкә бәйләнеп, мавыгып, шуннан китә алмау; тар бер эшчәнлек белән чикләнү. *Дәүләтьяров Маликны авылда бикләнеп ятмаска, ә шәһәрдә менә дигән әйбәт магазин ачып, олы сәүдәгә тотынырга өнди иде.* И. Гази.

5. *күч.* Нинди дә булса сәбәпләр аркасында уйларыңны, хисләреңне беркемгә дә чыгармыйча, үзендә генә саклап, үзең генә эчтән кичереп яшәү. *Кайвакыт хәсрәт йозагы берлә күңелем бикләнә.* М. Гафури. // Сер бу-

лып сакланган, берәү дә белми торган.— *Моннан соң дус кына булып йөрү җитмәүне белдереп, күңелемдә бикләнеп яткан серле сәламнәремне язам.* М. Фәйзи.

БИКЛӘҮ *ф.* 1. Ачылып-ябыла торган нәрсәләрне йозак, келә яки башка бикләвечләр белән эләктереп, борып, беркетеп ачылмаслык хәлгә китерү. *Каравылчы амбар ишеген бикләп кала.* А. Алиш. // Берәр нәрсә белән томалау, каплау (юлны, каналны һ. б. ш.). *Тишекне берәү дә бикләмәгән, су бикләгән булып чыкты.* И. Гази.

2. Кемне яки нәрсәне дә булса иреккә чыга алмаслык, яки беркем дә ачып ала алмаслык итеп урнаштыру, бикләнгән нәрсә эчендә калдыру. *Менә бу кәгазьләрне шкафка бикләгә.* Г. Камал. [*Әсирләрне*] *көндез гаскәрләр саклый, кич булгач та, таш зинданга ябып бикли-ләр.* К. Тинчурин. // *күч.* Каян да булса үтеп керергә, алга китәргә мөмкинлек бирмәү. *Ватан юл бикләргә кушканда, Куркак капка ача дошманга.* Ф. Кәрим. [*Сандецкий*] *кайсы төбәккә нинди көчләр беркетеләчәген аңлатты. — Менә бирегә — елга аръягына юнкерларны чыгарам. Прапорщиклар школасы дамбаны бикли.* К. Нәҗми. // *күч.* Берәр сәбәпнең тоткарлавы, комачауларга турында. *Салкын яңгырлар да, аяк астының пычрагы да, җилле яңгырлы болытлар да революция белән ашкынган халыкларны өйләренә бикли алмадылар* Г. Ибраһимов.

3. Яшәвен, эшчәнлеген туктату (учреждение, предприятие һ. б. ш. турында). *Ә биш айдан, ячейканы бикләп, Кузгалдык без туган авылдан.* Ш. Маннур.

4. *күч.* Үзләштерү, үз милкенә әйләндерү турында. *Алпавыт малы синең малың түгел ул, ә халыкныкы! --- Алып кайтып, үз келәтеңә яисә үз абзарыңа бикләргә хакың юк синең.* И. Гази.

5. *күч.* Ятлау (сүз, шигырь, җыр һ. б. ш. турында). *Бу күп тапкырлар әйтелә торган гади сүзләр --- һөҗүм алдындагы сәгатьтә бөтенләй башкача --- яңгырадылар һәм Газинур аларны, яхшы җырны күңеленә бикләгән кебек, ятлап алды.* Г. Әпсәләмов. // Онытылмаслык итеп хәтерләп калу. *Инде карт кешенең биргән киңәшләрен өстән генә укып утмәгез, Күңелегезгә алып бикләгез!* Һ. Такташ.

БИКРӘ: бикрә балык *и. зоол.*— ите һәм уылдыгы белән кыйммәт йөри торган эре ау балыгы; русчасы: осетр.

БИҚӘ *и. иск.* 1. Бай, би(к) хатыны. *Бикә биләнгәнче туй үтә.* Мәкаль. *Урам аркылы гына булса да, җәяү йөрүне бикә яратмый.* Ш. Мөхәммәдев. // Бай һәм морза хатыннарын олылап әйтелгән сүз, мәсәлән: *ханбикә, байбикә* (аларның исемнәренә дә ялганып йөргән: *Фатыймабикә, Әсмабикә, Миңлебикә;* соңыннан бу сүз исемнәргә бөтенләй ялганып киткән: *Артыкбикә* һ. б.).

2. *сөйл. ирк. ирон.* Кушма сүз составында иркәләп әйтүне яки берәр сыйфатка ия булуны ишарәли торган икенче кисәк, мәсәлән: *мияубикә, сөтбикә, иркәбикә.*

БИКӘБАШ *и. бот.* Киндернең орлык бирә торган ана үсемлеге; русчасы: посконник полевой.

БИКӘРГӘ *рәв. иск.* Юкка гына, сәбәпсез, нигезсез.— *Без кечкенәдән бер-беребезне сөеп вәгъдәләр бирештек. Сиңа көндәш булу дигәнне уйлаганым да юк. Син дә безне бикәргә харап итмә.* М. Фәйзи. // Бер дә файдасызга, мәгънәсезгә. *Актык сәгатеңдә ирек бирәм, Сөйлә, сөйлә, егет, бикәргә.* Ф. Бурнаш.

БИҚӘЧ *и.* 1. Қияүгә бирергә сөйләшенгән, димләнгән кыз; кәләш. *Ахыр килеп кызның кияүгә чыгарга ризалык хәбәрен ала. --- Хажи куанычыннан нишләргә белми, яшь бикәчкә мактаулар яудыра.* Г. Нигъмәти.

2. *сөйл.* Яңа гына кияүгә барган яшь хатын. *Кыз идем — солтан идем, Бикәч булдым — хан булдым.* Н. Исәнбәт. [*Нигъмәт, ишектән кереп, юл биреп:*] *Хуш килдегез, рәхим итегез, яшь кияү, яшь бикәч.* Г. Камал.

Бикәч бозау *диал.*— теше бозау. **Бикәч бәрән** — *диал.* теше бәрән. **Бикәчкә керү** — кияүнең беренче кич кыз янына килүе. *Шакир бикәчкә керде һәм аның янында дүрт көн торды.* Ш. Әхмәдиев.

БИҚӘЧЛӘҮ *ф.* Қияүнең, туйдан соң, киленне үз өенә алып кайтканга кадәр кыз янына килеп йөрүе; киявләп йөрү.— *Улем куркынычы борын төбендә торган бер заманда мөселман комитеты президиум әгъзалары бикәчләп яталар.* К. Тинчурин. *Болар бикәчкә бер көнне чыгып китәләр. Бикәчләделәр дә берничә көннән соң кайттылар.* Әкият.

БИЛ *и.* 1. Гәүдәнең күкрәк белән янбаш арасындагы нечкәреп торган өлеше. [*Васильнең*] *биле сыгылып тора, буе-сыны коеп куйган төсле.* Ф. Хөсни.

2. Киемнең бил өлешенә туры килгән урыны, билне кысып торган өлеше. *Күлмәк биле. Пальто биле.* □ [*Бабайның*] *башында картуз, өстендә биле бөргән* [*казаки*]. Г. Ибраһимов.

3. Озынча әйберләрнең нечкәреп торган урта бер җире. *Туфли биле.* □ *Аргамак җаныем, көяз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, шыгыр-шыгыр печән кимереп ята.* К. Тинчурин.

Бил каешы — билне буар өчен каештан эшләнгән билбау. *Гөлзәбәр, вак-вак сипкел төшкән озын бармаклары белән әледән-әле бил каешын рәтләп, Мансуров белән янәшә атлый.* Г. Бәширов.

◇ **Бил алышу** — бил турыннан кочып алып көрәшү. *Синең белән бил алышып карыйк, кем кемне отар!* Г. Ибраһимов. **Бил буу (ныгыту)** — нинди дә булса эшкә ныклап керешергә әзер булу (тору). *Хәзер миндә зур көч бар, көрәшкә бил буып чыктым.* М. Гафури. *Коткарырга Иделне! Ныгыт, туган, билеңне. Шул мәйданда җиңү белән Коткарырсың илеңне.* Г. Камал. **Бил бәйләү** — *к.* бил буу.— *Сабир, билен бәйләп, беләкләрен сызганып, иген эшенә, баерга тотынган.* Г. Ибраһимов. *Төлке, мужикның бу сүзләренә каршылык күрсәтмичә, аның өенә килеп, хезмәткә бил бәйләде.* Г. Тукай. **Бил бөгү** — 1) бик тырышып, барлык көчне куеп эшләү. *Ул, бичара, күп бөксә дә билен, Көн күрмәде бу таң атканчы.* Ш. Маннур; 2) кемгә дә булса физик хезмәт итү. [*Садри*] *моңарчы Хафизуллага бил бөгеп, тир түгеп көн күрде.* Г. Минский; 3) ялыну.— *Әйтик, барырмын мин* [*миччә*] *янына, әмма мәгәр мин аның алдында билемне бөгәсе булмам, башымны да имәм.* А. Шамов. **Билгә сугу** — кыен хәлгә калдыру. [*Паровозны*] *Березниковскийга җибәртеп, билгә суктылар да куйдылар бит.* Ш. Камал. **Билсез калу** *сөйл.*— бил сызлау, янбаш сөякләре бик нык авырту, турая алмау. *Авыр әйберләр ташып, билсез калу.*

БИЛБАУ *и.* Киемне бил турысыннан кысып бәйли торган тар һәм озынча әйбер (каеш, материя, үрелгән бау һ. б. ш.). *Ефәк билбау бил күрке, Матур егет ил күрке!* М. Фәйзи. *Иске чикмәнен чуар билбау белән буган киң җилкәле карт, кое улагы янына басып, күк биягә су эчертә.* К. Нәҗми. // Юбка, чалбар кебек киемнәрнең, кысып торсын өчен, бил турысына беркетелеп тегелә торган озынча тукыма.

БИЛГЕ *и.* 1. Билгеле бер мәгънәне белдереп, берәр нәрсәгә ишарә итә торган предмет, тамга, символ. *Салкын чишмә суын эчкән саен Билге ясап барган талым бар.* Ә. Ерикәй. // Хәбәр итү чарасы, сигнал, символ. *Тора-бара монда байрак күтәрелү бөтен колхозда эш көне башлануның бер билгесе булып китте.* Г. Бәширов. // Нәрсәне дә булса белдерә, хәбәр итә, раслый торган күренеш; галәмәт. *Атлар колакларын шомартып, уткә якынлашып, пошкырып, ашауларыннан туктадылар: — Бу инде якын тирәдә аю булуның билгесе!* М. Гафури. *Яз җитә, бозлар китә, дип бирде инде март хәбәр; Инде яз булганга билге һәр урам, һәр чатта бар.* Г. Тукай. // Нәрсәне яки кемне дә булса танырга ярдәм итә торган характерлы сыйфат, үзлек, үзенчәлек. *Сыйнфый сиз-*

герлеге аяк табанында йөргән Кайбер йомшак башлы түрәләр, Кулак зур корсаклы, коточкыч бер хайван була диеп беләләр --- Шундый билгеләре булган кулакларны авыл буйлап эзләп йөриләр. Һ. Такташ.

2. Берәр хәлдән соң яки нәрсәнең дә булса тәэсире аркасында барлыкка килгән эз. *Эштән кайткач та, [хуҗа] атларның ял асларын, муеннарын тотып карый. Әгәр дә гадәттән тыш тирләгән яки камыт тию билгесе була калса, ул атны йөртүчегә яхшы сүз юк.* М. Гафури.

3. Билгеле бер шартлы мәгънә белдергән тамга. *Тыныш билгесе. Математик билгеләр. Астрономик билгеләр. Нота билгеләре.* □ *Рацияне рота командиры белән сөйләшү өчен җайларга боерык бирдем.— Фридман өйдәме? — дип, морзе билгеләре белән сораша башладым.* Ә. Айдаров. // Келәүмә, тамга. *Фабрика билгесе. Фирма билгесе.*

4. Укучыларның белем һәм тәртип дәрәҗәсен билгели торган бәяләмә (биш баллы система белән күрсәтелә). *Алдагы сафта утыручы озын буйлы малай, бөтен гәүдәсе белән үрелеп, укытучының нинди билге куюын карады.* А. Әхмәт. [*Малай:*] *Менә, бабай, монда бер генә «урта» билгесе дә, хәтта «яхшы» билгесе дә юк, һәммәсе «отлично».* М. Гали.

5. *к.* значок. [*Хәйдәрнең*] *гимнастерка күкрәгендә Кызыл Байрак ордены һәм медальләр белән гвардеец билгесе күренеп калды.* Г. Бәширов.

6. Билгеле бер нәрсәнең тамга булып хезмәт итә торган сурәте, рәсеме. *Йортым ишеген саклап сакчы йөри, җиңнәрендә «сөңге» билгесе.* М. Җәлил.

7. Кемнең дә булса теләгән, боерыгын белдереп, берәр нәрсә турында баш, кул хәрәкәте белән кисәтеп ясалган ишарә. *Вахит үзенең алыну билгесе иттереп кулын гына селкеп, эчке бүлмәгә кереп, скамьяга утырып уйга калды.* М. Гафури.— *Мин тегендә барып торам. Син кычкыра башла --- Миңа карап тор, мин сиңа билге бирермен.* Д. Аппакова.

БИЛГЕЛЕ *с.* **1.** Нинди дә булса билгесе, тамгасы булган.

2. Яхшы таныш, мәгълүм. *Ротмистр боларны туктатырга уйлады, ләкин --- һәммәсе билгеле, таныш байлар булганга, борчылырга сәбәп тапмады.* Г. Ибраһимов. *Аларның йорты каршында гына трамвай туктый. Бик билгеле урында безнең әбиләр йорты.* А. Алиш.

3. Аныкланган, ачык булган, аңлашылы. *Хәятның бүгенге күренеше Михаилда тагын теге тойгыны уятты, һәм бу юлы инде кискенрәк һәм билгелерәк итеп уятты.* Ф. Әмирхан. // Исбатланган, һәркемгә мәгълүм. *Шулай ук мәкальләрнең сәнгать әсәре булулары белән бергә, тормышта да практик роль уйнаулары билгеле мәсьәлә.* Н. Исәнбәт. // Нинди дә булса бер эш эзлекле рәвештә башкарылып килә торган, махсус билгеләнгән (вакыт турында). *Эшчеләрнең акча ала торган бу билгеле көннәрендә завод капка төбе хатыннар белән тулы була иде.* Г. Ибраһимов. *Ел саен җиткән кортлар аерылып, һәр якка таратыла билгеле айда.* Ш. Бабич.

4. Мәгълүм (бер), аерым (бер), ниндидер, беркадәр. *Г. Камал билгеле бер көйгә салып укыла торган революцион әүтәлекле тезмә әсәрләр барлыкка китерде.* М. Гали. [*Организмдагы матдәләр*] *билгеле бер күләмдә һәр көнне таркалып торалар икән, димәк, ризыктагы туклыклы матдәләр күләме дә шул югалтуны каплардлык булсын.* А. Расих.

5. Күренекле, данлыклы, атаклы, танылган, мәшһүр. *Чертежлар бөтен дөньяга билгеле бер хәрби заводныкы була.* Г. Гобәй. *Франция укучыларына гына түгел, бөтен дөнья хезмәт иялэре массасына билгеле булган бу көчле язучы [Анри Барбюс] әдәбиятта шактый катлаулы, бай һәм кызыклы юл үтте.* М. Җәлил.

6. *хәб. функ.* Нәрсәнең дә булса асылы, төп сыйфатлары аның бер билгесеннән, сыйфатыннан беленеп, күренеп, сизелеп тора дигән мәгънәне белдерә. *Май чүлмәге тышыннан билгеле.* Мәкаль.— [*Кызларның*] *матурлыклары тавышларыннан ук билгеле бит.* М. Гафури.

7. *кер. с. функ.* Үзеннән-үзе аңлашыла, һичшиксез, әлбәттә. *Гөл — былбылын, былбыл гөлен Сагынгандыр, билгеле.* М. Фәйзи. *Билгеле, эшли белмәгән кеше унбиш елдан бирле бер ояда гына утыра алмас иде.* Ә. Еники.

Билгеле булганча — *кер. с. функ.* Һәркемнең белүенчә. *Билгеле булганча, [әдәби образларны] иҗади файдалану — лектор, пропагандист, агитатор эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтүдә әһәмиятле шартларның берсе.* Соц. Тат.

БИЛГЕЛЕЛЕК *и.* Билгеле булу хәле. *Мәгълүматларның билгелелеге.*

БИЛГЕЛӘМӘ *и.* **1.** Нәрсәнең дә булса төп характерын, асылын, эчтәлеген ача торган, кыска һәм төгәл итеп әйтелгән тәгъбир. *Җөмләгә билгеләмә бирү. Математик билгеләмәләр.*

2. Билге, тамга. *Бер төрдән булган мәкальләрне сайлап җыярга кирәк булса, --- бөтен китапны укып чыгарга, анда үзеңә билгеләмәләр ясап, --- меңнәрчә юлны күчереп алырга туры килә.* Н. Исәнбәт.

БИЛГЕЛӘНҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к* билгеләү.

2. Билгеле бер фактлардан, хәлләрдән килеп чыгу, шулар белән аңлатылу, ачыклану. *Буржуа реализмы — беркатлы реализм. --- Бу хәл буржуазиянең чикләнгән сыйныф булуы белән билгеләнә.* М. Җәлил. *Язучының амбары, билгеле инде, аның нәшрият, театр һәм редакцияләргә тапшырган һәм алар дөньяга чыгарган әсәрләре белән билгеләнә.* Н. Исәнбәт.

3. Беленү, ачыклану. *Җәләл тыштан тын вә тыныч, хәтта уяулы-йокылы бер халәттә кебек күренсә дә, аның эчендә үзенә дә билгеләнеп бетмәгән бер куәт кайный.* Г. Ибраһимов.

4. Аталу, багышлану. *Уземә билгеләнгән көй белән исемемне халык телләрендә тибрәттерә алса, ул егет минем гомерлек юлдашым булыр.* М. Фәйзи.

БИЛГЕЛӘҮ *ф.* **1.** Билге, тамга салу.— *Мин синең шикелле --- түгел. Син генә ул һәммә шакмакларны билгеләп бетергән.* Г. Камал. *Капитан планшетыннан картасын чыгарды, ләкин коточкыч буранда картада берәр нәрсә билгеләү мөмкин түгел иде.* Г. Әпсәләмов. // Бер билгесе белән хәтердә калдыру. *Беркөнне мин бик яхшы билгеләп кайттым. [Әбиләрнең] йорты каршында гына трамвай туктый.* А. Алиш.

2. Билгеле бер максат белән атап, аерып, бүлеп кую. *Коммуна --- кавын, карбыз һәм бәрәңгелек өчен --- ялпак тауның көньяк итәген һәм өске ачык өлешендәге тигез җирне билгеләгән иде.* Ш. Камал. // Кемнең дә булса карамагына, җаваплылыгына, файдалануына бирү, тапшыру. *Идарә члеңнарга пионерларга Хәлимнәр тәрбияли торган Шәехтайны, Каюмнар тәрбияли торган «Чалкаш»ны, дүрт пионер кушылып тәрбияли торган бер атны билгеләделәр.* Г. Гобәй.

3. Берәр нәрсәнең микъдарын яки вакыт күләмен аныклау, шуны рәсмиләштерү. *Менә алай булса, [мәһәрне] үз белүемчә биш йөз сум билгелим.* Ш. Камал. *Гөләндәм әбигә Совет күп итеп пенсия билгеләде.* Г. Гали. *Ярты ел буе ватылып яткан --- молотилканы төзәтер өчен бары ике көн вакыт билгеләгәнсез.* Р. Ишморат. // Берәр эшнең, хәлнең үтәлү вакытын, урынын, юнәлешен һ. б. ш. алдан ачыклап кую; хәл кылу, чишү. [*Шакир солдат*] *җыелышларның урынын, вакытын үзе билгели торган булды.* Г. Ибраһимов. *Бу пленумда инде язучылар, турыдан-туры конкрет иҗат мәсьәләләре турында сөйләшеп, --- конкрет иҗат бурычлары билгеләделәр.* М. Җәлил.

4. Исәпләү, чамалау, күз алдына китерү (күләм яки ераклык турында). *Даниилның тәҗрибәле күзе бу отрядның бик күп булса бер йөз илле кешелек икәнен*

билгеләде. Ш. Усманов. *Алмагач биеклеге күтәрелгәч тә, зәңгәр өйнең кайдалыгын билгеләде Нечкәбил.* А. Алиш. // Нәрсәне дә булса күрсәтү, раслау, ачыклау. *Бу сорауның җавабы Мохтар алдында Төхфәтнең аң дәрәҗәсен азмы-күпме билгеләргә тиеш иде.* Ш. Камал. // Билгеле бер юнәлеш бирү, максатны, бурычларны ачыклау. *1912 елның 4 апрель вакыйгасы [Галинең] күңелендә гомергә онытылмаслык эз калдырган һәм асылда аның аңлы көрәш юлын билгеләгән.* Г. Әпсәләмов.

5. Нинди дә булса хезмәткә, эшкә, укуга һ. б. ш. урнаштыру, кую, җибәрү.— *Хәзер үзен Тәтеш шәһәренә татар балаларын русча укытырга билгеләгәннәр.* Т. Гыйззәт.— *Җәйге каникулга кайтып балыкка төшәргә дә өлгермәде, комсомол оешмасы аны клубның драмтүгәрәгенә режиссер итеп билгеләде.* Г. Бәширов.

6. *рәв. функ.* **билгеләп.** Ачык итеп, конкрет рәвештә, тәгаен.— *Эш мәсьәләсе шулай үк җиңел чишелә торган әйбер, минемчә. Ләкин ул турыда хәзер мин билгеләп бернәрсә дә әйтә алмыйм.* Ш. Камал.

Билгеләп үтү — мактауга, бүләкләүгә лаек дип табу. *Аның эшен билгеләп үттеләр. Башка коллективларның чыгышларыннан да уңай моментлар китерергә, аерым башкаручыларның осталыкларын билгеләп үтәргә мөмкин булыр иде.* Соц. Тат. // Кемнең дә булса хөрмәтенә яки нәрсәне дә булса искә алып, тантана, тантаналы кичә үткәрү, бәйрәм итү.

БИЛГЕСЕЗ *с.* 1. Билгеле булмаган, таныш булмаган, белмәгән, ят. *Безнең тарафтан ясалган бу һөҗүм дошманның моңа кадәр безгә билгесез ут ноктaларын ачарга мөмкинлек бирде.* Ә. Айдар. *Сәлим азрак каушап торды да --- билгесез кешеләргә таба йөгерде.* Г. Гобәй. // Өйрәнелмәгән, тикшерелмәгән. *Билгесез йолдызлар.* // Ачык булмаган, томанлы. *Билгесез уйлар, хисләр ташкыны.* □ *Күңел ниндидер билгесез, ләкин татлы бер талпыну белән талпынып, илəс-милəсләнеп, очына башлый.* И. Гази / *рәв. мәгъ.* [*Хәятның*] *эче әүвәлгедән дә бигрәк пошына иде. Башта бу пошыну билгесез генә, курку белән катыш башланды.* Ф. Әмирхан.

2. Мәгълүм түгел. *Формасына, знакларына карап, мин [хатынның] военврач икәнлеген белеп алдым, шуннан башкасы билгесез иде һәм шулай билгесез булганга күрә ул миндә берьюлы әллә ничә төрле шайтаный кызыксыну уятты.* Ф. Хөсни. *Тик кем жиңә? — Билгесез. Агыйдел никадәр генә үкереп ташланмасын, барыбер тауны кисеп үтә алмый.* М. Әмир.

3. *мат.* Эзләнелә торган, табылырга тиеш булган зурлык. *Билгесезне билгеле [саннар] аркылы белеп була.* Һ. Такташ.

БИЛГЕСЕЗЛЕК *и.* Ачыкланмаган, билгесез хәл; мәгълүматсызлык. *Инде җитәр, артык түзәр хәлләре калмады, бу билгесезлекнең бер чиге булырга тиештер, ниһаять.* Ә. Еники. // Серле, шомлы хәл. *Ияләшкән тыныч, уңай тормышыңны ташлап, туган-үскән шәһәреңне ташлап, кыз кешегә билгесезлек эченә чыгып китү, әлбәттә, ансат түгел.* И. Гази.

Билгесезлек алмашлыгы — алмашлыкларның предметка, сыйфатка һәм күләмгә гомуми генә, якынча гына ишарә итүне белдергән төре, мәсәлән: **кемдер, нәрсәдер, күпмедер.**

БИЛДӘК *и. диал.* Нәрсәнең дә булса нечкә, тараеп киткән җире, биле; билдәмә.

БИЛДӘМӘ *и.* 1. Түшкәнең бил тирәсе; югары сортлы ит. *Билдәмә бүлү.*

2. *диал.* Киемнең бил турысы. // Билбау.

БИЛЕМЛӘҮ *ф. диал.* Чыгымлау. *Таеңа атлансаң, биясе билемләр.* Мәкаль.

БИЛЕТ *и.* 1. Гадәттә түләп алына торган һәм нәрсәдән дә булса файдалануга хокук бирә торган вакытлы документ. *Кино билеты. Трамвай билеты.* □ [*Баку белән Дербенд арасында*] *бер кечкенә генә станциядә безне поезддан төшерделәр; билетсез килә идек.* Ш. Камал. [*Әхмәт*] *анысын да булдырды: завкомга кереп үзенең кем булуын һәм кичәгә килү телəгән белдергəч, аңар билет та бирделəр.* Г. Минский.

2. Нинди дә булса оешма, партия члены булуны раслый, нинди дә булса вазифага, бурычларга, хезмәткә мөнәсәбәтне күрсәтә торган документ. *Комсомол билеты. Профсоюз билеты. Ак билет. Яшел билет.*

3. Кәгазь акча билгесе. *Кредит билеты. Казна билеты.* □ *Әбинең сандыгында алтын белəзекләре белəн алмаз йөзекләре һəм ике [отыш] билеты бар.* Ш. Мөхəммəдев.

4. Имтихан тапшыручы җавап бирергә тиешле сораулар язылган кәгазь. *Бишенче билет! [Ида] аны белə. Кичəгенəк кенə, обсерватория бакчасында утырганда, шул билет сорауларын кабатлап чыккан иде.* Н. Фəттах.

БИЛЛЕ *с.* Бил турысы тарайтылып, билгә сыланып торырлык итеп тегелгән (кием турында). *Менә [Фатыйма] билле бишмәтен, шәлен салып ыргытты.* И. Гази. *Авылның яшьләре бишбилле казаки ямьсез була дип, Рәхмәтулла карт теккән шикелле билле казакиларны бөтенләй кими башладылар.* М. Гали.

БИЛЛЕК *и.* 1. Киемнең бил тирәсендәге өлеше. *Гадəте буенча, озын итəкле киң күлмəгенең биллеген ыштан бөрмəсенə кыстырган Миңлениса карчык, тəгəрəгəн туп шикелле, идəндə йөрде.* С. Рафиков. // Кысып торсын өчен шинель, пальто һ. б. ш. биленә ике төймәгә каптырып яки тегеп куелган тар гына тукыма кисәге.

2. Шлеяның аркылы каешлары.

БИЛЛИОН *сан.* Рус, француз һәм америка системаларында мең миллионга (яки миллиардка), ә немец һәм инглиз системаларында миллион миллионга (яки мең миллиардка) тигез булган сан.

БИЛЛƏП *рәв.* Билле итеп. *Биллəп тегелгəн күлмəк.*

БИ'ЛЛƏҺИ *ы. сөйл.* Нәрсәнең дә булса чынлыгына, дөреслегенә ышандырып, ант итеп әйтелә. *Биллəһи менə, карчыктан сорагыз, ышанмасагыз.* Ш. Камал.— *Биллəһи дип əйтəм, эшлəр җиңелəйгəч тə, Казанга барып, Сөлəймановаға күчтəнəчкə тегермəн ташы кадəр алма бəлеше илтми хəлем юк инде.* Ф. Бурнаш.

БИЛТЕР *и.* Аяк табанының урта өлеше. // Аяк киеменең шул урынны каплап торган өлеше.

БИЛТƏЛƏҢҮ *ф. диал.* Чуалу. *Өй эчендə көтелмəгəн кунакларны чырае качкан, чəчлəре билтəлəнеп беткəн, яшь, ләкин йончыган бер хатын каршы алды.* А. Расих.

БИ'ЛФАРАЗ *кер. сүз. иск. кит.* Күңелдән берәр нәрсәнең ихтималлыгын, мөмкинлеген уйлау; әйтик, фараз итик.— *Ләкин күңелендə мөселманлык гайрəте булган инсан өчен, --- Каюм яисə яранnары, билфараз, яхшы əйтмəс дип, --- уразаны калдыру һич тə ярый торган эш түгел.* Ш. Камал.

БИ'ЛФИГЫЛЬ *рәв. иск. кит.* Чынлап, чыннан да. *Бу төндə күпшы бишмəт[ле] кыз Габделбасыйрга бигрəк сыланды, сыйпанды. Əхмəткə Диляферүз хакында нилəр сөйлəнгəн булса, күпшы бишмəт Габделбасыйр белəн шул эшлəрне билфигыль эшлəп чыкты.* Ф. Әмирхан.

БИЛЧӘН *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан ашлык арасында үсә торган чәнечкеле, эре, бик әрсез чүп үләне. *Күз алдында менə бер түтəл җир, Билчəн баскан урман шикелле.* Ш. Маннур.

БИЛЧƏЮ *ф. диал.* 1. *к.* бирчәю.

2. Берәр буын урынынан чыгу, кузгалу; таю.

БИЛЬЯРД *и.* 1. Махсус өстәлдә шарлар белән аерым кагыйдәләр буенча уйнала торган уен. [*Байбәтчәләр*], *яше унҗидегә җиткəч, бильярд уйный башлыйлар. Бер-ике йөз сум оттыргач, җилкəсене кашыйлар.* Ш. Мөхəммəдев.

2. Кырыйлары биегәеп килгән, шарлар төшсен өчен дүрт почмагында һәм озын кырыйларының уртасында тишекләре булган, сукно белән капланган өстәл.

БИЛӘВЕЧ *и. к.* биләү III.

БИЛӘМ *и.* Өен ташлап чыгып китеп, бер эшсез, максатсыз кайда да булса йөрү, сөйләшеп утыру. *Заһид аның янына чыкканда, карчык ак ефәк шәлен бөркәнгән, өстенә чесуча пальтосын кигән, чираттагы биләменә чыгарга әзерләнгән иде.* А. Расих. *Биләм бозау имезә.* Мәкаль.

Биләмдә йөрү — өйдән өйгә кереп, бер эшсез, вакытны бушка уздырып йөрү.— *Самоварың җырлап утырмагач, чәйнең тәме буламы? — Тәмләп эчәсең килсә, биләмдә йөрмиләр аны.* Т. Гыйззәт.

БИЛӘМЧЕ *с.* Биләмдә йөрергә яратучы. *Биләмче карчыклар кебек читән артларында --- түгел, менә монда чын күңелдән ачылырга [сөйләшергә] кирәк.* А. Гыйләҗев.

БИЛӘМӘ *и.* 1. Хосусый милекчелек нигезендә кемгә дә булса бирелгән, күчми торган милек (йорт, утар, җир). *Алпавыт биләмәсе.*

2. Аерым ил, өлкә, оешма һ. б. га буйсынган, аңа караган. *Англиянең колониаль биләмәләре.* □ *Новгород биләмәләре төньякка таба бик еракка — Ак күл, Онега аръягына, Төньяк Двина буена һәм Төньяк Уралга кадәр җәелгән.* СССР тарихы.

БИЛӘН *и. иск.* Агач төяп агыза торган яссы төпле, буяуга буялмаган баржа. *Галиулла абзыйны, билән кугында, бүрәнә басып үтерде.* Т. Гыйззәт.

БИЛӘНКЕ *и.* 1. *сөйл.* Биле сызлый торган кеше яки хайван.

2. *күч.* Биләмче.— *Әйт, бәдбәхет, кайда --- йөрдең, әйт тизрәк, тәүфыйксыз, биләнке.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БИЛӘҮ I *ф.* 1. Нәрсәгә дә булса (мәсәлән, җиргә, мөлкәткә) ия булу. [*Бояръларның*] *һәрберсе әллә ничә мең десятина җир биләләр.* М. Гафури.— *Минем юлга аяк бас, бәндә. Ике дөнья дәүләтен биләрсең.* Г. Коләхметов.

2. *күч.* Үзенә җәлеп итү, буйсындыру, чолгап алу (уйлар, хисләр һ. б. ш. турында). *Күңелендә, кара еландай, шик уяна егетнең. Шик үсә: йөрәген, акылын биләп ала.* И. Гази. *Берничә секунд үтмәде, өерелеп, бөтерелеп чыккан калтыманулы курай авазы мине бөтенләй биләп алды.* А. Шамов.

3. Нинди дә булса урынга урнашу, шул урынга хуҗа булу. *Икенче рәт [саф] скамьялардан җидесен Рәхимә абыстай кызлары вә кунаклары белән килеп биләде.* Ф. Әмирхан. // Билгеле бер территорияне алып тору, каплау. *Ишек алдының яртысын диярлек биләп алган бакчада [Газинур] әтисен күрде.* Г. Әпсәләмов.

Биләүле пар — ужымнарга кадәр төрле культуралар чәчелгән пар басуы. *Шулай итеп борчак — игенчелекне интенсивлаштыруда, биләүле пар системасында алыштырғысыз культура.* Соц. Тат.

БИЛӘҮ II *ф.* Баланы биләүгә урап, кысып бәйләү. *Әниең сине тапкач сөя-сөя Ап-ак биләүләргә биләгән.* Б. Рәхмәт.

БИЛӘҮ III *и.* Яшь балаларны төрә торган махсус чүпрәк, җәймә. *Инде син бар. Карап биләвеңнән Берни белми көлеп ятасың.* Ш. Мөдәррис. *Кайвакытларда [баланың] кулларын, аякларын биләүгә чолгап, аны хәрәкәтләнмәскә мәҗбүр иттеләр.* М. Җәлил.

БИЛӘҮСӘ *и.* 1. *к.* биләү III. *«Өлгерерсең, Сания, сиңа да җитәр. Балаңны кара»,— дип, үз уйларына үзе җавап бирде дә, биләүсәләрен кызурак итеп, тырышыбрак уарга тотынды.* М. Әмир.

2. *к.* биләүсә бавы.

Биләүсә бавы — яшь баланы биләүгә төргәч, кысып урап бәйли торган бау.

БИМАЗА *и.* Тынычсызлык, борчу, мәшәкать. *«Алга!» дибез яшәр өчен, Бимаза күрмәс өчен. Имгәнмәс өчен давылда, Көрәштә үлмәс өчен!..* Ә. Ерикәй.

БИМАЗАЛЫ *с.* Борчулы, тынгысыз, тынычлыкны боза торган (уй, эш, хәл турында). *Идел-Урал буйларыннан җир мае эзләү хакындагы бимазалы уй өч гасыр буена кешеләрне борчып килгән.* Г. Ахунов.

БИМАЗАЛАУ *ф.* Кемнең дә булса тынычлыгын алу, борчу. *Мәдрәсә тәрәзәсеннән төшкән кояшның нурлары [Габдулланы] һаман бимазалады, ул алардан качып һаман күләгәгә шуышты.* Ә. Фәйзи. *Өзлексез ишектән кереп-чыгып йөрүчеләр дә [Хафизларны] бимазалыйлар.* К. Тинчурин.

БИМЕТАЛЛ *и. тех.* 1. Берсе өстенә берсе капланган ике төрле металл кушылмасыннан гыйбарәт пластинка, чыбык, ярымфабрикатлар (мәсәлән, телеграф һәм телефон чыбыклары өсте бакыр белән капланган тимердән ясала). *Төрле металлардан, мәсәлән, тимердән һәм җиздән ясалган ике озынча пластинканы заклепкалар белән бер-беренә беркетсәк, биметалл пластинка хасил була.* Физика курсы.

2. *с. мәгъ.* Биметаллизмга бәйләнешле. *Биметалл акча системалары вакытында акча әйләнешенең гомуми эквиваленты һәм нигезе булып бер үк вакытта ике металл — көмеш һәм алтын хезмәт иткән.* Политэкономия.

БИМЕТАЛЛИЗМ *и.* Бер үк вакытта ике төрле металлның (гадәттә алтын һәм көмешнең) әйләнештә йөрүенә нигезләнгән акча системасы.

БИНА *и. кит.* Төрле учреждениеләр, предприятиеләр һ. б. ш. урнаша торган зур йорт, шулай ук күп квартиралы торак йорт, архитектура корылмасы. *Сукно фабрикасы биш катлы бер зур бина булып, шәһәргә бөтенләй башка төрле гүзәллек бирмәктәдер.* Ш. Мөхәммәдев. // Гомумән йорт, өй, корылма. [*Гәрәй байның*] *әллә нинди буяп, чибәрләп салынган зур өйләре — авылның җиргә сеңеп, юк булырга торган кебек, мескен вә аяныч биналары уртасында башларын --- күккә күтәреп утыралар.* Г. Ибраһимов.

БИ'НАМАЗ *с. иск. дини.* Намаз укымый торган, намазсыз (элек гомумән дингә ышанмаучыларны шулай дип атаганнар). [*Баязит*] *намаз укырга яратмый, сәждәгә бөгеләсе килми, аны бинамаз дип мыскыл итәләр.* Г. Ибраһимов.

БИ'НАХАК *рәв. сөйл.* Хаксызга, урынсызга, гаепсезгә. [*Әни:*] — *Үзләренең йөзләре кара булсын. --- Шулай бинахак рәнҗеткән өчен, үзләре бер көн хур булсыннар! — дип сөйләнә иде.* М. Гафури.

БИ'НИҺАЯ *рәв. иск.* Чиксез, очсыз-кырыйсыз, бик күп. *Кояш үзенең бөтен бинихая көченә балкый, су өсләре җем-җем килә.* А. Гыйләҗев. *Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби; Бинихая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.* Г. Тукай.

БИНОКЛЬ *и.* Ерактагы әйберләрне якынайтып, зурайтып күрсәтә торган ике параллель көпшәле оптик прибор. *Театр бинокле. Кыр бинокле.* □ *Диңгез [картасында] бу җирдә һичбер атау күрсәтелмәгәнлектән, без барыбыз да, бу нәрсәдән гаҗәпсенеп, аны бинокльләр аркылы карарга тотындык.* Ф. Әмирхан.

БИНОМ *и. мат.* Ике алгебраик аңлатманың суммасы яки аермасы; ике буын. *Ньютон биномы.* □ *Беренче буынның күрсәткече тапкырлана торган биномнар санына тигез.* Алгебра.

БИНТ *и.* Яраны, шешне һ. б. ш. авырткан урыннарны бәйли торган озын тасма формасындагы марля яки тукыма кисәге. *Илсөяр Өметбаевның белгенә чорналган бинтка эчтән кан тибеп чыкканны күрде.* Г. Гобәй. *Сестра, сумкасыннан бинт алып, Михайловның ярасын бик ашыгып кына бәйләргә тотынды.* А. Шамов.

Бинт салу — *к.* бинтлау.

БИНТЛАУ *и.* Нәрсәне дә булса бинт яки марля белән тыгыз итеп урау, бәйләү.

БИО- кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) бу сүзләрнең тормышка, тормыш процессларына караганлыгын күрсәтә, мәсәлән: **биогенетик, биосфера;** 2) «биологик» сүзе мәгънәсендә кулланыла, мәсәлән: **биофизика, биохимия, биостанция.**

БИО'ГРАФ *и.* Кемнең дә булса биографиясен төзүче. *Пушкин биографы.* □ *Галимнәр, Демосфенның биографлары калдырган язмаларны җентекле өйрәнеп, борынгы Грециянең искиткеч ораторы --- тотлыгудан интеккән, дигән нәтиҗәгә килделәр.* Соц. Тат.

БИОГРА'ФИЯ *и.* Кемнең дә булса тормыш юлы тасвирламасы, тәржемәи хәле. *Драматург Г. Камалның биографиясе.* □ *Кечкенә хикәядә тулы биография, аның тарихына тукталу бик кирәкле дә түгел.* М. Җәлил. // Кемнең дә булса тормышы, тормыш юлы. *Бу якты йөзле гади рус егете [Газинурның] күңеленә мәңгегә онытылмас булып урнашты. Моңа, бәлки, Газинур белән Саша биографиясендәге уртак урыннарның да беркадәр тәэсире булгандыр.* Г. Әпсәләмов.

БИО'ЛОГ *и.* Биология фәнен өйрәнүче, биология белгече. *Тәзкирә апалары — бу тәҗрибәле биолог — балаларга эше һәм киңәшләре белән булышты.* Г. Гобәй.

БИОЛО'ГИК *с.* Биологиягә бәйләнешле; биологиягә караган. *Биологик тикшеренүләр.*

БИОЛО'ГИЯ *и.* Органик дөньяны (тере табигатьне) өйрәнә торган фәннәр комплексы. *Биология кабинеты.* □ *[Дускаев] үзе тарихтан --- ике яшь бала анасы Әминә ханым — биологиядән укытып, Яушырмә колхозы өчен яңа кешеләр булып яши башладылар.* Ә. Еники.

БИОСТА'НЦИЯ *и.* Билгеле бер урындагы хайваннарның һәм үсемлекләрнең биологиясен өйрәнү станциясе.

БИОСФЕ'РА *и. геогр.* Җир өстендә тереклек таралу өлкәсе.

БИОФИ'ЗИК I *и.* Биофизика фәнен өйрәнүче; биофизика белгече.

БИОФИ'ЗИК II *с.* Биофизикага бәйләнешле, биофизикага караган.

БИОФИ'ЗИКА *и.* Биологиянең тере организмнардагы физик закончалыкларны өйрәнә торган бүлеге.

БИОХИ'МИК I *и.* Биохимия фәнен өйрәнүче; биохимия белгече.

БИОХИ'МИК II *с.* Биохимиягә бәйләнешле, биохимиягә караган.

БИОХИ'МИЯ *и.* Тере организмнарның химик составын һәм организмнарда бара торган химик процессларны өйрәнә торган фән.

БИПЛАН *и. авиа.* Аслы-өсле ике канатлы самолет.

БИРГЕ *с.* **1.** Берәр нәрсәнең сөйләүчегә якынрак ягы; *киресе:* аргы. *Тын суны очлы күкрәге белән ерып, бирге яктан аргы якка маһкчы көймәсе йөзеп китте.* Г. Гобәй.

2. Якындагы, сөйләүчегә иң якын урнашкан. *Өйгә кергәч тә Мәдинә, бирге бүлмәдә генә туктап, Гатауллага җебенеп беткән саргылт конверт төртте.* К. Нәҗми.

БИРЕ *рәв.* **1.** Нинди дә булса урыннан, әйбердән якынрак. *Кәнәфидән бире зур көзге һәм түгәрәк өстәл белән гөл.* Г. Колаҳметов.

2. *сөйл. к.* бирегә. *Бәлки бик тиз бире кайтмамын.* Ф. Кәрим.— *Нәфисә, Шәриф, чыгыгыз әле бире.* Ф. Бурнаш.

3. *сөйл.* Бу урын, бу урында; *к.* биредә. *[Газиз:] Мин бире калам. Миңа Ибрайны күрергә кирәк.* Ф. Әмирхан.

4. Бирге, бу ягында. *Себернең бире ягында эшче-крестьян хөкүмәте хөкем сөрә.* **Г. Гали.**

БИРЕГӘ *рәв.* Бу урынга, бу якка, якынрак, монда таба. *Ул арада урман буеннан биргә якынлашып килгән хатын-кызлар төркеме күренде.* Г. Бәширов.

БИРЕДӘ *рәв.* **1.** Бу урында, бу якта, монда.— *Син биредә бул, мин бу иптәшләр белән китәм.* И. Гази. *Эш биредә таң белән башлана, беренче савуны дүрт белән бишарасында уК үткәрәләр.* Ә. Еники. // Нинди дә булса урыннан, предметтан якындарак. *[Бикмүш бабай] шул чакта өстә, будкадан шактый биредә, кычкырып сөйләшкән тавышлар ишетте.* Г. Гобәй.

2. Бу очракта, бу мәсьәләнә (яки эшне) хәл иткәндә.— *Түтинең риза булуы биредә кирәкми, [Хажиһы] безгә генә чакырып алырбыз, сизми дә калыр.* Ш. Камал.

БИРЕДӘН *рәв.* Бу урыннан, моннан.— *[Кыя башына] биредән менү ансатрак, сөзәк.* И. Гази.

БИРЕЛГӘНЛЕК *и.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса турылыклы булу; тугъры булучанлык, тугърылыклылык. *Революция рыцаре Ф. Э. Дзержинскийның коммунизм идеяләренә бирелгәнлеген патша төрмәләре, ялгызлык җәфалары --- сындыра алмадылар.* М. Әмир.

БИРЕЛЕШ *и.* Берәр моментның (теманың, образның һ. б. ш.) билгеле бер яссылыкта чагылышы, гәүдәләнеше, тасвирлануы, сурәтләнүе. *Монологларның бирелеше бер кешенең рәттән сөйләп баруыннан бигрәк, хикәя яки романдагы кебек төрле күренешләрне сурәтләү аша [бара].* М. Гали. *Госман карт белән Мәрьямнең ике әсәрдә дә бирелеше бертөрле.* Г. Нигъмәти.

БИРЕЛҮ *ф.* **1.** *Төш. кайт. юн. к.* бирү.

2. Каршылык күрсәтүне туктату, җиңелү.— *Мин бу эшне эшләвемә үкенәм, гаебемне муеныма алам. Судның туры хөкеменә биреләм.* М. Фәйзи.— *Рус, рус, бирел! — диде миңа немец, Кулым күтәрергә ирендем; Гранатаны маңгаена төрткәч, Немец миңа үзе бирелде.* Ф. Кәрим.

3. Бәхәстә, спорт ярышларында җиңелү турында. *Врач ахыр чиктә бирелде: — Ярый, сезне чынлап та аерып булмас ахры. Ярты сәгать көтсәгез, документларыгыз әзер булыр,— диде.* Ә. Айдар. *Бу ике көчнең соңгысы җиңәчәген күңелем бик ачык сизсә дә, мин сүзсез генә бирелергә теләмәдем.* М. Әмир.

4. Кемнең дә булса йогынтысына буйсынып, аның фикеренә ияреп эш итү, аның ягына чыгу турында. *— Халыкта дини фанатизм бетмәгән әле. Мулла, кулак коткысына бирелеп, җәнҗәл куптарулары ихтимал. Аны да исәпкә алырга кирәк.* Ш. Камал. *[Әсәрдә] бигрәк тә мәсхәрәләнгән, гаепсезгә хур ителгән кыз белән алданган, байлар коткысына бирелгән ата трагедиясе калку итеп күрсәтелә.* М. Җәлил.

5. Нинди дә булса берәр эшкә зур кызыксыну белән, ихлас күңелдән, үз-үзеңне онытып керешү, нәрсә белән дә булса бик ныкмавыгу. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә.* Г. Тукай. *Бик иртә тормыш ыгы-зыгысына бирелеп китүе аны харап итте.* Ә. Еники. // *рәв. мәгъ.* **бирелеп.** Бик ныкызыксынып, бик ныктырышып, мавыгып. *Әтисенең күзе улы Равилгә төште. Әнә бит ул ничек бирелеп тыңлый, күзләре очкынланган.* А. Әхмәт. *Яшьләр --- бөтен күңелләре белән бирелеп җырлыйлар.* А. Шамов.

6. Якын күреп, үз итеп, җан-тән белән яратү, турылыклы булу. *[Ул күзләр] мәхәббәткә каршы шундый ук тирән, саф, намуслы мәхәббәт белән җавап бирергә телә, сиңең күзләреңә сөеп, бирелеп карыйлар.* Ә. Еники.

7. Юнәлеш килешендәге кайбер абстракт исемнәр янында килеп, шул исемнән аңлашылган хәлгә дучар булуны, дәвамлы рәвештә шул хәлдә калуны белдерә. *Паникага бирелү.* □ *Ә Галиулла, ямьсез уйларга бирелеп, тәрәзә каршында утырды да утырды.* И. Гази.

8. Җиңел аңлаешлы булу, тиз үзләштерелү яки башкарылу (уку, эш һ. б. ш. турында). *Уку җиңел бирелү. Эш авыр бирелү.*

БИРЕМ *и.* Алдан уК билгеләнгән эш; тапшырылган, кушылган эш. *Ә коллектив социализм төзүче илнең зур*

биремен үтәп бара. Г. Нигъмәти. // Белемнәрне ныграк үзләштерү, алган күнекмәләрне нығыту өчен тәкъдим ителгән, бирелгән эш, күнегү. *Өйдә эшләргә ике бирем бирелү.*

БИРЕШ: бирешә каты *диал.*— бурычын бик теләмичә генә кайтаручы кеше турында әйтелә.

БИРЕШҮ *ф.* 1. Берәр эштә, уенда, бәхәстә җинелү, өстен чыга алмау. [*Әхми:*] *Әгәр дә безне тешләп җырласалар, яхшы карагыз, бер дә бирешмәгез, бер урынына ун җавап кайтарырга тырышыгыз.* Г. Камал. *Бер укымышлы кырык наданга бирешмәс.* Мәкаль. // Берәр нәрсәдә калышу, ким булу (чагыштырганда әйтелә). [*Кыз:*] *Эт көтүе чаклы егетләребез бар авылда, берсеннән-берсе чибәрләр, Фәтхеттингә бирешә торганнар түгел.* М. Гали.

2. Физик һәм рухи хәлсезләнү, начарлану; каршы торырга көче калмау (авыру, төрле кыенлыклар һ. б. ш. тәэсирләр аркасында). *Карты үлгәннән соң Мәдинә ханым аеруча бирешә, күзләре тагын да начаррак күрә башлады.* А. Гыйләҗев.

3. *күч.* Бер-беренә сугу, кыйнашу, бәргәләшү. *Мондый чакта балалар, сугышган туктап, ну хәзер бирешәләр дип, кызык көтеп торалар. Ләкин* [*Хәлимнәр*] *сугышмыйлар.* И. Гази.

БИ'РЖА *и.* 1. Капиталистик илләрдә — эре сәүдә һәм финанс өлкәсе эшләреңдә акцияләр һәм башка кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-биреш итү турында килешүләр төзү урыны. *Капиталистлар түләү өчен саф акча җитмәүдән интегәләр. Биржалар шартлый башлый — акцияләрнең һәм башка кыйммәтле кәгазьләрнең курслары бик тиз төшә.* Политик экономия.

2. Сәүдә итү мәйданчыгы, базар; эшче көчләр тәкъдим итә һәм яллый торган урын. *Базардагы агай-эне-ләргә --- кибеттәге приказчикларга, биржадагы подрядчикларга күз-колак булырга куштым. Бары да карарбыз диделәр.* Т. Гыйззәт.

БИ'РЖАЧЫ *и.* Капиталистик илләрдә биржа эшләре белән шөгыльләнүче; биржа эшкуары.

БИ'РКА *и. иск.* Авырлыгын, сортын, кая җибәрелүен һ. б. күрсәтү өчен товар төргәкләренә, бәйләмнәренә, капларга тагыла торган номерлы яки язулы такта, калай һ. б. кисәге.

БИРЛЕ *бәйл.* Нинди дә булса эш-хәлнең башлангыч моментын белдерә, вакыт төшенчәсенә дәвамлылык төсмере өсти. *Айсылу аңардан колхоз председателе булып сайланырга ризалык бирүен үтенгәннән бирле, Тимери бу турыда бик күп баш ватты.* Г. Бәширов. [*Малай*] *икенче елдан бирле мәктәптә укый.* Ш. Камал.

БИРНӘ *и. этн.* Кияүгә чыккан кызның үзе белән алып килгән җиһазлары, егеткә һәм егетнең кардәшләренә бирелә торган бүләкләре. *Әсәрдә бөтен вакыйга татар мещанкаларына гына хас булган бирнә күлмәк тирәсенә тупланган. Бирнәнең булу-булмавы яки яхшылыгы-начарлыгы бер кешенең гомерлек тормышын хәл итәргә тиеш.* М. Гали.

БИРТЕЛҮ *ф.* 1. Буында сөякләр нормаль хәрәкәтләнмәслек булып урыныннан кузгалу; таю, каймыгу.

2. Гомумән имгәнү, бетеренү. *Лашманчылар, кайткан да, бик биртелеп кайталар. Кара урманда кар эчендә землянкада яталар.* Бәет. *Эшелон Кавказ тауларында крушениегә очрый һәм Гафиятулла абзый тәмам имгәнеп, биртелеп өенә кайтып егыла.* Г. Әпсәләмов.

БИРТӘК *и. диал.* Теле тотлыга торган кеше.

БИРЧӘЮ *ф.* Күп ышкылудан (эшләгәндә яки йөргәндә) кулда, аякта һ. б. урыннарда тире тупаслану, кытыршылану, сөякләр барлыкка килү.— *Миңниса апай, нигә синең кулларың болай ярганаһып, бирчәеп беткән? — Без кайнаткан сабынның ачысы ашаган аны.* Ә. Фәйзи. [*Зиннәт абзый*] *бирчәйгән бармаклары белән сакалын сыпыргалый.* Г. Ахунов.

БИРӘН *и.* 1. *гади с.* Чамасыз күп һәм ни туры килсә шуны ашаучы кеше. *Бирәнгә биргәнең җитмәс.* Мәкаль. *Бирән бирмәгәнеңнән өмет итәр.* Мәкаль.

2. Йөрәк, бөер һ. б. авыртканда организмдагы төрле куышлыкларга сары су җыелудан эче күпкән, зур корсаклы кеше.

◇ **Бирән корсак** *гади с.* Ашап туймый торган, комсыз кеше турында. **Бирәнгә сабу** *сөйл.*— бирән авыруына дучар булу. *Хода күрсәтмәсен байларның, елкы итен ашап, бирәнгә сабуын.* Ш. Мөхәммәдев.

БИРӘСЕ *и. к.* бурыч 1. [*Алмага*] *миннән дә шул бәя булыр,— диде Малик,— ләкин Галиулланың бирәселәрен шул акчадан тотып калырмын.* И. Гази.

БИРӘЧӘК *и. к.* бурыч 1. [*Сәмигулла:*] *Әйе, шул бирәчәкләрне түләп, тагы бер уникә шыр чәй алырга ният бар иде.* Г. Камал.

БИРҮ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса берәүнең үзенә тапшыру, кулына тоттыру. *Гали абзый дилбегәне Газинурга бирде һәм атлатып кына барырга кушты.* Г. Әпсәләмов. *Нуруллин штабта пакетны комиссарның үзенә бирде.* А. Шамов. // Нәрсәне дә булса берәүнең карамагына, файдалануына тапшыру. *Мостафинга райбашкарма карамагындагы ике катлы агач йорттан зур гына бер бүлмә бирделәр.* Ә. Еники. *Мин* [*китапларны*] *иске татар китаплары музеена бирдем.* Ф. Әмирхан. // Нәрсәне дә булса даими рәвештә сатып яки җибәреп тору. *Магазинда товар бирү. Китапханәдә китап бирү.*

2. Хәбәр итү, белдерү (адрес, телефон һ. б. ш. турында).— [*Китапларны*] *Казаннан алдырырга кирәк. Мин сезгә нәшрләрнең адресын биргән идем шикелле.* Т. Гыйззәт.— *Мин сиңа балалар саны турында --- аларның исемлеген бирергә генә тиеш булам.* Ш. Камал.

3. Тәкъдим итү (урын, юл һ. б. ш. турында). *Канцелярия ишеге төбендә басып торучылар, икегә аерылып, юл бирделәр.* Ә. Еники. [*Вилдан:*] *Гармунчыга чибәррәк урын биреегез, үпкәли башлар.* Ф. Бурнаш.

4. Түләү (хак һ. б. ш. турында). [*Гайшә*] *авылның остасы — Шәмсетдингә, утыз кадак он биреп, мичне дә чыгартты.* Г. Ибраһимов. [*Марат:*] *Кичә колхоз клубына радио куйдым, шуның өчен илле сум бирделәр.* Т. Гыйззәт. // Тәкъдим итү. *Теге кеше башта егерме тиен биреп сатулашса да, соңыннан утыз тиенгә килештеләр.* М. Гали. // Нинди дә булса берәр бәя белән сатып җибәрү. *Итекчеләр --- бер пар итекне 20 аршинга түгел, 15 аршин киндергә дә шатлана-шатлана бирерләр иде.* Г. Тукай.

5. Нәрсә белән дә булса бүләкләү турында. *«Ударник» дип газетларда Аның рәсемен бастылар. Сабан туйда бүләк биреп, Алкышлап кул чаптылар.* М. Җәлил.

6. *күч.* Кайбер абстракт исемнәр белән килеп: шул исемнән аңлашылган сыйфатка, үзлеккә ия итү. *Самолетлар оча киң күгендә, Көч һәм гайрәт биреп йөрәккә.* Ә. Исхак. *Мин укыган кызларыбызга карый-карый гажәпкә калам. Аларның күбесенә, шомлыкка каршы, алла матурлык биргән.* Г. Коләхметов. // Социаль әһәмияте булган берәр сыйфатка ия итү.— *Беркем бирә алмаган иректе минем халкыма большевиклар бирде.* И. Гази. *Сез назлап үбегез гөлләрне, Хуш истән күңелегез ачылсын. Җир бирде сезгә шат көннәрне, Йотып тир, кан һәм яшь тамчысын.* М. Җәлил.

7. *Үгет-нәсихәт, киңәш* һ. б. ш. сүзләр янында килеп, әдәп-тәртипкә, төрле күнекмәләргә һ. б. ш. өйрәтү. *Гали абзый* [*җыелышта*] *ахыргача утырды һәм күп кенә файдалы киңәшләр бирде.* Г. Әпсәләмов.— *Атаманамның биргән үгет-нәсихәтләрен тотсам, мондый бәлаләргә дучар булмаган булыр идем.* Г. Камал.

8. Кемне дә булса берәр эшкә билгеләү, берәр эш башкарырга кушу, эш белән тәэмин итү. *Бүгеннән берәр эш бирүен сорамакчы булып, управляющийның чыккынын көтәргә керештек.* М. Гафури. // Кемгә дә булса

эш йөкләү, тапшыру.— *Мин сезгә җаваплы бер участок бирәм.* Ш. Усманов.

9. Өстәлгә, алга китереп кую (ашау-эчү әйберләре турында). *Кодаларның күчтәнәчләрен күрсәтергә чыгарганда да, мәҗлескә аш-су, шулпа, бәлеш, билдәмә, каз, үрдәк, ширбәт, чәй, коймак, каймак биргәндә дә, һичбер эш Мәрхәбәгә киңәшсез, Мәрхәбәнең ярдәменнән башка үтмәде.* Г. Ибраһимов.— *Чәем булса, ичмасам чәй эчеп бераз ачлыгымны басар идем. Инде ике көн булды, фатирга акча бирмисең дип, самовар да бирмиләр.* Г. Камал.

10. Кая да булса берәр теләк белән язма рәвештә мөрәҗәгать итү турында. *Әгәр тагын бер-ике көн эчендә бумажникның хуҗасы килмәсә, ул, әнисе белән бергә, газета редакциясенә барырга һәм шунда игълан бирергә булган иде.* А. Шамов. *Сафи абзый коммунага керергә гариза бирде. Шуны карарга кирәк.* Ш. Камал. *Крестьяннар, үзләрен хаклы санап, эшне судка биргәннәр.* И. Гази.

11. Рәсми рәвештә берәр җиргә урнаштыру (мәктәпкә, яслегә һ. б. ш. урыннарга). *Балалар йортына бирү.* □ *Яз килүгә әниләре Яслегә аны бирделәр, Үзләре тынычланып Кырда эшләп йөрделәр.* Һ. Такташ.

12. Кияүгә чыгарга рөхсәт итү яки мәҗбүр итү; ярәшү. *Гайнетдин яучыны кадерләп каршы алган булды. Гадәттә була торган сүзләрдән соң, Зәйнәпне бирмәкче булып, яучыны озатып җибәрде.* М. Гафури.

13. *спорт.* Билгеле кагыйдәләр буенча тупны уенга кертү яки партнерга юнәлтү, тапшыру.

14. Тамашачылар алдында чыгыш ясау, концерт, спектакль күрсәтү, кую. [*Туишев*] *ял йортларында, санаторийларда ял итүче, дәваланучы хезмәт ияләренә үзенең дәртләндергеч күңелле, матур концертларын биреп йөрде.* М. Җәлил. [*Сәйяр*] *драмтруппасы артистлары атнага ике тапкыр спектакль биреп килделәр.* И. Рәмиев.

15. Нәрсәне дә булса укыту, өйрәтү. [*Камалов*], *Себердә беренче татар педагогия техникумы оештырып, университетта укыган вакытында шунда төрле фәннәрдән дәресләр биреп килде.* М. Гали.

16. Тасвирлау, сурәтләү, чагылдыру, күрсәтү (әдәбият һәм сәнгать әсәрләре турында). *Әсәрдә кире типларны бирү алымы.* □ *«Тирән тамырлар» әсәре баштан алып ахыргача өч момент, ягъни хуҗалык, сәясәт, шәхси моментларны төрле катлаулы вакыйгалар җебенә чолгандырып, гәүдәләндереп бирә.* Г. Нигъмәти. [*Театрга*] *--- психологик образлар бирүгә күчәргә --- кирәк.* М. Җәлил.

17. Кайбер исемнәр белән янәшә килеп, нинди дә булса эшне башкаруны белдерә. *Залп бирү. Звонок бирү.* □ *Пионерлар сафка тезеләләр, килучеләр ягына карап быргычы каршылау сигналын бирә, ул туктауга җавап итеп, арттан быргы тавышы ишетелә.* А. Алиш. [*Хәлим*] *ни дип тә әйтергә өлгермәде, арттагы вагоннар янында свисток бирделәр.* Г. Гобәй.

18. Кем яки нәрсә өчен дә булса берәрсен яки берәр нәрсәне корбан итү. *Ил каршында тиздән ант итәр ул Халкы өчен утка керергә. Аның өчен канын кызганмаска, Кирәк булса, гомерен бирергә!* Ә. Исхак.

19. Нәрсәгә дә булса багышлау. *Партия сиңа кайда җибәрмәсен, Шул өлкәдә көчен бирде ул: Фабрикалар корды, юллар төзде һәм журналлар басып йөрде ул.* Ш. Маннур.— *Тагын менә нәрсә: җәй көне күбрәк вакытыгызны ял итәргә биреегез.* Г. Гобәй.

20. Җиңелеп, каршы тора алмыйча, нәрсәне дә булса дошманга калдыру.—*Рига өчен буржуазия матбугаты солдатларны гаепли, янәсе, алар дисциплинасыз, приказларны үтәмиләр, төрле комитетлар коткысына ияреләр. Чыныңда, Риганы генераллар бирделәр.* И. Гази. // Хыянәт итеп яки ирексезләп кемнең дә булса карамагына тапшыру (кулга алырга ярдәм итү).— *Мине мецларга бирмәгез,— диде егет һәм, эзләнеп, капшанып, картның кулын тотты.* А. Шамов.

21. Барлыкка китерү, җитештерү, хасил итү. *Күрә җиләк, чия кеби җимеш агачлары үзләренең җимешләрен бирселәр.* Г. Тукай. [*Пионерлар*] *колхоз басуы уртача бирә торганнан ике өлеш — һәр гектардан йөз пот — уңыш алуны үзләренең карарларына язып куйдылар.* Г. Гобәй.

22. *юкл. форм.* Нәрсәне дә булса башкарырга, берәр нәрсәне булдырырга комачаулау.— *Синең шул булыр инде, рәхәтләнеп сөйләшергә дә бирмисең.* Т. Гыйззәт.

23. Нәрсәгә дә булса (белемнең ничек үзләштерелүенә, берәр нәрсә эшли алу сәләтенә) сынау, тикшерү үтү. [*Нәфисә*] *бераз дулкынлана, үзен җиде еллыкны тәмамлар алдыннан имтихан биргәндәге кебегрәк хис итә иде.* Г. Бәширов.

24. Кешеләрне, учреждениене, предприятиене, оешманы һ. б. ш. аерым бер исем белән атау. *Без авылга исем бирербез, Авыл түгел, Колхоз диярбез.* М. Җәлил. *Элекке заманда кызларга Артыкбикә дип кимсетеп исем биргәннәр.* Г. Әпсәләмов.

25. Нинди дә булса уңышлары, эшләре өчен кешене мактаулы исемгә лаеклы итү, дәрәҗәгә күтәрү.— *Яхшы эш үрнәге күрсәткән колхозчыларга Социалистик Хезмәт Герое дигән исем бирү беләсеңме ни дигән сүз?* Р. Ишморат. *Минем кебек яшь малайга аларның бу мөгамәләләре, миңа «дәрәҗә» бирүләре --- тәэсирсез калмады. Бик үк мактанып сөйләнмәсәм дә, әзрәк «эреләнеп киттем».* М. Гафури.

26. Кемгә дә булса берәр нәрсә турында белдерү, хәбәр итү, җиткерү (кеше аркылы, хат, телеграмма белән).— [*Кадыйр байларның*] *уллары Йосыфҗан Истамбулга киткән иде. --- Атаң хәл эчендә дип телеграмм биргәч, кайтты да яңадан китмәде.* Г. Ибраһимов. *Кичә Габдулла Саматовның үзенең һәм Гарифның фронттагы партиягә керүләре турында хәбәр бирүе Мохтарны яхшы үк шатландырды.* Ш. Камал.

27. Тоташтыру (телефон турында).— *Крестовниковны бирегез. Завком белән тоташтырыгыз.* Т. Гыйззәт.

28. Җитештерү, хәзерләү, туплау, ясау. *Гадәттә мондый җыентыкларны төп ике максат белән җыярга мөмкин. Беренчесе — гыйльми тикшеренү һәм гыйльми өйрәнүләргә материал бирү, икенчесе — җырлар өчен ялгыз һәм күмәк җырлаучыларга җырлар бирү.* М. Җәлил.— *Мин соңгы бер ай эчендә бер генә брак та бирмәдем.* Р. Ишморат.

29. Булдыру, тәрбияләп үстерү. *Республикадагы каләмдәшләр, Баш шәһәргә саумы килдегез? Җырчы-шагыйрьләрнең яхшыларын һәм төрлесен күбрәк биregез!* С. Хәким. *Җиһанша бабай сокланып үстергән егетләрен уйлый иде дә: — Мин Сәвиткә ике арыслан бирдем, --- дип күңел эченнән тирән бер хак белән мактана --- иде.* Г. Ибраһимов.

30. Нәрсәне дә булса эшләргә, башкарырга кушу. *Өйгә эш бирү.* // Чишәргә тәкъдим итү. *Менә мин сезгә тагын бер табышмак бирәм, таба алырсызмы?* А. Шамов.

31. Нинди дә булса шәхес яки берәр нәрсә, хәл, күренеш турында берәр максат белән, фактлардан чыгып, фикереңне, бәяңне белдереп телдән сөйләү яки язу (бәяләмә, характеристика, рекомендация, белешмә һ. б. ш. турында). *Мин үземә үзем характеристика, рекомендация бирә алмыйм бит инде.* М. Җәлил. *Кызыл постау белән капланган зур өстәл кырыендагы кафедра артына баскан ак сакаллы, күзлекле бер профессор бетереп чыгучы студентларга кыскача характеристика бирә.* М. Гали.

32. *Күңел, игътибар, әһәмият* һ. б. ш. сүзләр белән килеп, барлык уйларыңны, фикерләреңне нинди дә булса бер объектка, эшкә юнәлтүне белдерә. *Ярты сәгать-*

тән артыкка сузылган бу концертны геологлар күңел биреп тыңладылар. Ә. Айдар. *Әхмәтнең кыланышы [гади], кеше белән игътибар биреп сөйләшә, хатын-кыз белән урынлы-урынсыз шаярып сөйләшергә омтылышы юк.* А. Шамов.

33. Берәр нәрсәгә төрле форма, үзгәреш кертү. *[Лиза] тавышына ясалма риза түгеллек яңгырашы биреп: — Ник ул кадәр каты [әйтәсең?] — диде.* Ф. Әмирхан. *[Классик] музыкаль әсәрләрнең текстлары, зур осталык белән татар теленең үзенчәлекләрен саклап татарчага күчергән вакытта, аңа яңа төс бирәләр.* М. Җәлил.

34. *сөйл.* Чамалап әйтү, билгеләү (яшь турында).— *Хуҗа хатыны Бибилатыйфа белән бер яшьтә без. --- Бер елны диярлек киявгә чыктык. --- Аңа кара да миңа кара. Кем аңа кырык бишне бирер? --- Ә миңа инде алтмышны бирүчеләр бар.* М. Фәйзи.

35. *күч. гади с.* Кыйнау, сугу.— *Икенче кат менә алгы яктан шул ук кендек белән биргәннәр.* Г. Ибраһимов.

36. *ярд. ф.* Үзе янындагы фигыль белдергән эшнең өзлексез, каршылыксыз дәвам ителүен аңлата. *Сөйли бирү. Эшли бирү.* ☐ *Ләкин [егетләр] тыныч гамьсезлекләрен бер генә секундка да җуймадылар һәм утырганы — утырган, ятканы яткан килеш кала бирделәр.* Ә. Еники.

◇ **Бирә-бирә бирән булу (бирәнгә сабышу)** *гади с.*— берәр нәрсәне күп тапкырлар биреп тую яки аптырап бетү турында.— *Хәерчегә ачык чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, диләр. Бирә-бирә бирән булып бетәрсең әле.* А. Шамов.— *Бер тиен бирмим, сүзем сүз! Болай да инде бирә-бирә бирәнгә сабышып беттем.* К. Тинчурин.

БИС *ы.* Артисттан чыгышын яңадан кабатлауны үтенгәндә кычкырып әйтелә. *[Газинур] Фатыйманың һәр җырыннан соң бөтен кешедән көчлерәк кул чапты, бөтен кешедән бигрәк бис кычкырды.* Г. Әпсәләмов.

БИСКВИТ *и.* **1.** Сөткә-майга изеп, йомырка кушып пешерелгән күперенке печенье. *Ванильле бисквит.*

БИСМИЛЛА *и. дини.* **1.** Нинди дә булса берәр эшне башлар алдыннан яки ашарга утырганда әйтелә. *Зифа әби, бисмилласын әйтеп, беренче чынаяк чәйне авызына китергән генә иде, кайдандыр ниндидер тавышлар, кычкырышлар килә башлады.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса башлангычы, чагылышы.— *Я, карышма әле; [бу үбешү өйләнешкән] күңелле көннәрнең бисмилласы булыр.* М. Фәйзи.

◇ **Бисмилласын укыту** — акылга утырту, нинди дә булса эштән тәүбә итәрлек ясау, тәүфыйкъка китерү; җәза бирү.

БИССЕКТРИ'СА *и. мат.* Почмакны ике тигез өлешкә бүлә торган туры сызык.

БИСТӘ *и.* **1.** *тар.* 11—18 гасырларда феодаль Русьтагы бәйсез дәүләт кулында яки шәхси милектә булган җирләргә үзләре теләп килеп утырган крестьяннар, һөнәрчеләр һ. б. яши торган пункт, гадәттә кечерәк шәһәрчек.

2. Шәһәрнең аерымрак урнашкан өлеше, районы. *Яңа бистә.* ☐ *Бистә белән шәһәр арасында трамвай кызулык төште.* И. Гази. *Марат инде Ленинградтан да, Мәскәүдән дә әллә кайда еракта, Казан шәһәрендә, Казанның Ягедни бистәсендә иде.* Г. Гобәй.

БИТ I *и.* **1.** Кеше башының алгы өлеше; йөз. *Табак бит. Озынча бит. Киң бит.* ☐ *Фатыйма, катып калган кебек, тагын бераз басып торды, кинәт яулыгы белән битен каплап, үксеп җибәрде.* И. Гази.

2. Йөзнең яңак өлеше. *Бер бителәй — кояш, бер бите — ай, Ямсн күздән ходаем сакласын.* Г. Тукай. *Каушау килешә икән тагын [Вәсиләгә]: ике бите алма төсле булып кызарды.* Ф. Хөсни.

3. Нәрсәнең дә булса өсте, өске йөзе. *[Садыйкның] чалбар[ы] аяк битенә чаклы тип-тигез булып салына.* Г. Ибраһимов. *Мәрданша бабай, --- чиләктәге бәрәңгенең берсен бармак битләре белән басып, учакка бәрике коры чыбык атты.* Г. Гобәй. // Битлек, циферблат. *[Мансуров], сары битле кесә сәгатенә күз төшереп, аны учына йомарлады.* Г. Бәширов.

4. Тау, калкулыкның һ. б. ш. авыш, сөзәк яны, өслеге. *Моннан бер йөз метрлап уңдарак разведчиклар кыя битендә чытырман куаклык эзләп тапканнар.* И. Гази.

5. *күч. шигъ.* Нәрсәнең дә булса өс йөзе. *Караңгы төн, коеп яңгыр ява, Урам бите сазга күмелгән.* Ш. Маннур. *Кырда салкын буран, җил себерә ялан битләрен.* Ф. Кәрим.

Бит алмасы — яңакның күпереп, калкып торган өлеше. *[Фәйрүзәнең] бит алмалары кызарды, Күзләре янды көлеп.* М. Җәлил. *[Җәмиләнең] ике күзеннән бөртек-бөртек яшьләре тәгәрәп, бит алмасы өстенә төште.* М. Гафури. **Бит очы** *диал.*— *к.* бит алмасы. *Сәгыйть үзенең бит очлары яна башлавын сизде.* Р. Төхфәтуллин. **Бит сабыны** — *к.* исле сабын. **Бит сөлгесе** — бит сөртә торган кечерәк сөлге.

◇ **Бит ерту** — 1) *к.* йөз ерту; 2) үзеңне-үзең түбәнлеккә төшерү, кимсетү. **Бит кызару, биткә кызыллык китерү** — *к.* йөзгә кызыллык китерү. *Район беренче мәртәбә дәүләткә ашлыктан бурычлы булып калды. Моның өчен иң беренче [Мансуровның] бите кызара, колхозлар эшендәге бөтен кыенлыкны иң башлап ул күтәрә иде.* Г. Бәширов.— *Дөрес, биткә кызыллык китерерлек итмәс Исмәгыйль.* М. Фәйзи. **Бит пешү** — *к.* йөз кызару. *Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә — бит пешә.* Мәкаль. **Бит сыптыру** — *к.* бит сыпыру. *Безнең тачкачылар балыкны бик күп тотып та, кырыгар сим акча эшләү хыялларына инде бит сыптырган иделәр.* Ш. Камал. **Бит сыпыру (сыйпау)** — 1) дога кылу. *Тагы икеөч егет [хәер] бирә. [Кыз бикә] битен сыпырып бирмәгәннәргә карап тора.* М. Фәйзи. *Мулла, тавыкны ашап, бер сумга ихлассыз гына бит сыйпап, мәһәр түләнгән дип язып китте.* Г. Ибраһимов; 2) үз исәпләрендә ялгышу, буш калу, мәхрүм калу.— *Без алтыннарның урынын күрсәтәбез икән, аны да рәхәтләнеп төп күтәрә сыпырып алачаклар. Синең белән безгә нәрсә кала: --- бит сыпырудан башка бер әйбер дә калмый.* Ш. Камал. **Битеннән кан таму** — сәламәтлеге ташып тору, таза, тулы канлы булу. **Биткә бәрү, биткә бәреп әйтү** — *к.* йөзгә бәреп әйтү.— *Әле генә бөтен халык алдында хур итеп чыгардылар иң! Битемә бәреп әйттеләр.* Г. Бәширов. *[Якубның] кашлары җыерылды. урычдыгыннан сикереп торып, теленә килгән иң ачы сүзләр белән Дәүләтьяровның битенә бәрәсе килде.* И. Гази. **Биткә кара (корым) ягу** — *к.* йөзгә кызыллык китерү. *Ни генә әйтим инде мин сиңа, Ибраһим,— ди бабасы,— бөтен нәселнең битенә корым яктың бит син моның белән.* Г. Гобәй. **Биткә олтан (ыштыр) каплау** — оятсызлану, намуссызлану.— *Зифа айныган. Шунлыктан, һәммәбез дә, битебезгә олтан каплаган хәлдә, сезне өйгә кабул итми торырга туры килә.* М. Фәйзи. *Әле өенә дә төшләп бирергә туры килә: [Кадриянең] ояты исә, битенә ыштыр каплаган кебек, нихәтле бирсәң, шуны күтәреп кайтып китә.* И. Гази. **Биткә оят (оятлык) китерү** — *к.* йөзгә кызыллык китерү. *Күз генә тия күрмәсен, болай булса әле [Мифрижамал] дус-дошман арасында биткә оят китермәс дим.* М. Гали.— *Карт көнебездә битебезгә оятлык китермә, кызым, үз бәхетеңне киртәләп куйма.* М. Фәйзи. **Биткә төкерү** — кеше алдында оятлы итү, хурлыкка төшерү.— *Инде син чәчкәнеңне урасың, барысы да сиңа каршы баш күтәрде, синең үз балаң үзеңнең битеңә төкереп качты.* Г. Ибраһимов. **Битен юмаган** — оятсыз, намуссыз.

БИТ II *и.* 1. Китаптагы, дәфтәрдәге һ. б. ш. кәгазь табагының бер ягы. *Газета бите. Дәфтәр бите.* □ *Гади формат почта кәгазенең бер битен тутырганчы егерме минутлар вакыт үтте.* Ш. Камал. [*Хәсән*] *алдындагы китабының икенче битен ачып карады.* Ф. Әмирхан. // Китаптагы, дәфтәрдәге һ. б. ш. почмаклап киселгән бер кәгазь табагы.— *Кая, бер бит кәгазь бир әле.* Р. Ишморат. [*Хатын*] *кулындагы блокнотыннан бер битен ертып алды да, тавышсыз атлап, трибунага килде.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса аерым бер чоры, бер өлеше; сәхифә. *Карт тарихның меңләгән Бите төсле мүкләнгән ... Карт чирәмнең карт күкрәген Яра-яра юл сузабыз.* К. Тинчурин. *Күптән көтелгән Татар опера театры төзелеп эшкә кереште. Татар совет операсы туу тарихының беренче битләре ачылды.* М. Җәлил.

Биткә салу — китап, журнал һ. б. ш. басып чыгарганда жыелган гранкаларны битләргә аерып салу; битләү.

БИТ III *кис.* Җөмләдә белдерелгән фикергә аеруча басым ясап, ышандырып әйткәндә кулланыла. *Бу кәгазьләр мачта ярыгына кыстырылып озак торганга шулай сарғайганнар бит.* Г. Бәширов.— *Дошманыңның дусты синең дошманың булу бик табигый әйбер бит.* Ш. Камал. // Сорау җөмләләрдә фикерне тыңлаучыдан раслату өчен кулланыла. *Артыкбикә сискәнеп китте. Җәһәт кенә миңа борылды: — Безгә пәрдәне ачарга вакыт җитәдер бит?* М. Әмир.— *Сез Сәмигулла агай тугелсездер бит? — дип сорады, ниһаять, үзенең авылдашын танып алган Саматов.* Г. Минский. // Экспрессив әйтелешне өстәмә көчәйтү чарасы булып килә (аеруча рәвешләр, хәбәрлекләр һ. б. белән килгәндә).— *Итек алып биргәнең юк бит әле, бушка йөрергә.* К. Тинчурин.— *Менә бит ул, каениш, синең белән утырганда уртак теле дә, җае да табыла.* Т. Гыйззәт.

БИТАРАФ *с.* Ике якның берсенә дә кушылмый яки карамый торган, нейтраль. *Битараф дәүләт. Битараф кеше* □ *Көннәрнең берендә немец ягын капшарга барган безнең разведчиклар битараф мәйданда бер немец лейтенантының үле гәүдәсенә тап булдылар.* Ш. Маннур. // Үзеннән башкаларның хәленә гамьсез караучы. *Моңарчы битараф бер чырай белән тыңлап утырган Идият абзый кузгалып куйды...* Ә. Еники. *Без берсенә дә битараф түгел, барысы да безгә кагыла: я борчый, я куандыра.* Г. Әпсәләмов. / *рәв. мәгъ. Габдулла Тукай милләтчелекнең мондый ... түбәнлегенә һич тә битараф карый алмады.* Г. Халит.

БИТАРАФЛАШТЫРУ *ф.* Битараф итү, битараф хәлгә кую. *Урта хәлле крестьянны битарафлаштыру һич тә аны революциядән читкә этәрү дигән сүз түгел иде.* КПСС тарихы.

БИТАРАФЛАШУ *ф.* Битараф хәлгә килү (кайту).

БИТАРАФЛЫК *и.* Бер якка да катнашмаучылык, нейтральлек; нейтралитет. *Битарафлык политикасын үткәрү* □ *Әхмәт Тангатаров ... аклар камчысының тәмен татыды. Бу аңа битарафлыкның юклыгын аңлау өчен яхшы сабак булды.* Г. Ибраһимов турында истәлекләр.

БИТЛЕК I *и.* 1. Битне умарта кортлары чагуыннан саклау өчен киелә торган кыл яки нечкә тимерчыбыктан үрелгән япма. *Әйттем бит мин сиңа, көз көне бал кортлары ачулы булалар, дидем, ә син битлек кимәдең, карыштың.* А. Алиш. // Борын заманда җәрәхәтләнүдән битне саклау өчен сугышчылар, рыцарьлар кия торган бит каплавычы.

2. Берәр кеше яки җәнлек йөзе итеп ясалган, кеше танымасын өчен битне каплап кия торган каплавыч. *Бу битлек, ком гарәбе төсле кап-кара итеп ясалган, иреннәре кып-кызыл, тешләре, күз алмалары ап-ак иде.* Ак юл. [*Малай*] *битлеген битеннән алып, дүрткә бөкләп, картузы эченә тыгып куйды.* Г. Гобәй.

3. Сәгатьнең һ. б. ш. үлчәү приборларының цифр, язу яки башка төрле билгеләр төшерелгән пластинкасы; циферблат.

◇ **Битлек артына (астына) яшерену** — үзенең чынбарлыгын, чынбарлыктагы хәлен, карашларын, фикерләрен, тойгыларын яшерү. *Демократик дигән хөкүмәтләр Яшеренеп битлек артына, Яклаганда дошманны күмәклән,— Чын туганлык кулын без суздык.* Ә. Исхак. **(Йөзен) битлек белән каплау, (йөзенә) битлек кию** — *к.* битлек артына (астына) яшеренү. *Матур күзләрдәге бу сахтә (ясалма, ялган) ялтырашны ... Шакир чын тойгыларны битлек (маска) белән капларга тырышу галәмәте дип аңлый иде.* Ф. Әмирхан. *Безнең бәхетсез мәдрәсәләребез һаман шул укытучы битлеген киеп мәдрәсәгә туктап, бераз хәл җыйгач чыгып китә торган мөдәррисләр кул астыннан һәмишә чыкмагандыр.* Г. Тукай. **Битлеген ерту (ачу, алып ташлау)** — фаш итү. *Мин сезнең битлегегезне тиз ертырмын.* Р. Ишморат. *Дөньяви фәннәр укыту идеясен башлап кем күтәреп чыкты? Һәм «Бохараи Шәриф»нең битлеген кем ертты? — Мәрҗани!* М. Госманов.

БИТЛЕК II *с.* (Күпмедер) биттән торган, күләмә (күпмедер) бит булган. *Ул китапларның егерме, егерме биш битлек кенә кечерәге ... Сәгыйть Хәлфиннең ... татарча-русча әлифбасы иде.* М. Гали.

БИТЛӘП *рәв.* Һәр битен аерым-аерым, берәмлекләп, бит саен. *Китапны битләп актару, битләп карап чыгу. Кулъязманы битләп санау.*

БИТЛӘҮ *и.* Тау бите, сөзәклек, авышлык. *Тауның көндезге кояшка караган сөзәк битләвендә Бикъяр (шәһәр) ... утыра.* Г. Ибраһимов. *Исламов ... чокыр битләвендәге яшел чирәм өстенә утырды.* Ф. Кәрим.

БИТСЕЗ *с. гади с.* Оятсыз, намуссыз. *Җиһаншаның чыдавы артыкка бара алмады — Фатыйма, битсез, кит аның яныннан! — дип акырды.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Аш пешеруче Мәчене вәгазьләргә башлап: «И оятсыз! Битсез! Син бу эшне эшләргә кешеләрдән генә түгел, хәтта стеналардан оялырга кирәк иде.* Г. Тукай.

БИТСЕЗЛӘНҮ *ф. гади с.* Оятсызлану, намуссызлану.

БИТУМ *җыйм. и.* Углеводороды табигый һәм ясалма сумала матдәләренең гомуми атамасы: асфальт, нефть, гудрон һ. б. ш. *Битум заводлары.* □ [*Нефтьче*] *җирләрдә күбрәк битум һәм известняк була.* А. Әхмәт. *Укымышлы агай-эне әйткән: өч йөз илле метр тирәнлегендәге коедан, дигән, куе кара битум табылган икән, бу инде, димәк ки, нефтьнең барлыкка килгән урыны дигән сүз.* Г. Ахунов.

БИТУМЛЫ *с.* Составында битум булган, битумнан торган (тау токымы һ. б. турында). [*Иванов:*] — *Менә Бизмән тауда табылган битумлы комлы таш, известняк.* А. Әхмәт.

БИТӘР I *рәв.* Бигрәк, ныграк; артыграк. *Кунакта яхшы, өйдә биш битәр.* Мәкаль. — *Кешеләребез, шөкер, әйбәтләр, фермаңыкы дип тормыйлар, әйе, үз терлекләреннән битәр карыйлар.* Ә. Еники. *Мондый ялган хәбәрләрне таратучылардан битәр, шул ялганнарга ышанучыларга Сөләйманның ачуы килде.* К. Тинчурин.

БИТӘР II *и.* Шелтә, ризасызлык. *Әр—битәр, әрдән дә бигрәк наз — битәр.* Мәкаль.

БИТӘРЛӘҮ *ф.* (Яхшылык кадерен белмәгән, ярамаган эш эшләгән һ. б. ш. өчен) оялтып шелтәләү, кабат-кабат әйтеп оялту. [*Мин сәүдә эшенә керешергә исәбе барлыгын белдергән абзыйны:*] *Совет власте сине җирле итте. Ә син кеше талаучы булырга хыялланасың,— дип битәрләмәкче идем.* М. Әмир. *Үзләре чакырып алдырган ятимне ашавы белән битәрләүнең ... гаделсезлек икәнен үзләре дә сизделәр булса кирәк, һәммәсе эчләреннән тындылар.* Ә. Фәйзи.

БИФШТЕКС *и. махс.* Ваклап турап яки суккалап йомшартып кыздырылган сыер ите кисәге.

БИХИСАП 1. *рәв. иск.* Хисапсыз, исәпсез, чиксез күп. *Көнбатыш Себердә һәм иксез-чиксез тундраның көньяк чикләрендә кеше йөри алмаслык сазларның бихисап күп икәнлеге билгеле.* М. Госманов. *Иң яхшы болыннар, шундагы җәнлекләр, кыр казлары, бихисап кыр үрдәкләре — һәммәсе аныкы* [*алпавытныкы*] *иде.* М. Шабай.

2. Артык, гаять, бик. *Һади --- ифрат дәрәҗәдә авыр, бихисап катлаулы кичерешләр эчендә яши.* И. Туктар.

БИХӘБӘР *рәв. иск.* Хәбәрсез, хәбәрдар булмаган, мәгълүматсыз; хәбәрдар түгел. *Бу баланы --- югалтып, кайда икәнлегеннән бихәбәр идек; менә хәзер таптык.* Г. Тукай. *Педагогиядән вә язачак мәүзугыннан бихәбәр хәлфәләр мәктәп китабы яздылар.* Г. Ибраһимов.

БИЧАРА *с.* Мескен, кызганыч, ярдәмчесез. *Фәхерниса бичара төн йокыларын йоклый алмыйча һаман аны* [*ирен*] *көтеп утыра...* Г. Камал. *Бичара ач халыкны һич тә сатмам.* М. Гафури. / *и. мәгъ.* (гадәттә күрсәтү алмашлыклары белән кулланыла.) *Немец самолетлары шәһәрдән качып котылырга тырышкан бу бичараларны* [*хатын-кызлар һәм балаларны*] *пулеметтан кырып йөргән икән.* Э. Еники. *Теге бичара палаткага дүрт аяклаңып кына бара.* А. Алиш.

БИЧАРАЛЫК *и.* Мескенлек, көчсезлек. *Шуларның бичаралыкларын, кызганычлыкларын битләренә бәргән, шуларның ваклыклары өстеннән югарыдан торып хихылдап көләргә миңа ул хәбәр ярдәм итте.* Г. Ибраһимов.

БИЧУРА *и. миф.* Йорт иясе, йорт пәрие. *Кечкенә генә бичура Билен буып утыра.* Табышмак. *Карчык, йөткеренә-йөткеренә:— Күптән өйнең ул ягында кеше тормый. Анда бичура ияләнгән,— диде.* Ф. Әмирхан.

БИЧӘ *и. диал.* Хатын. *Байлар, байлар бәтчәсе, Бакчасында мунчасы, Мунчасына су ташыйдыр Нечкә билле бичәсе.* Табышмак.— *Беләсезме, алар мине ничек мыскыл иттеләр, алар минем кулымнан бичәмне тартып алдылар* [*диде Әлимгул*]. М. Әмир.

БИШ *сан.* 1. Унарлы санау системасында 5 санын, микъдарын һәм цифрын белдерә торган сүз. *Бишмәтеңдә биш төймә, Алтынчысы каптырма.* Җыр. *Ул кичкә кадәр биш көлтә урып, дүрт көлтәне җиргә утыртып, бишенчесен башы белән өскә каплап бәбкә ясап, үзенә бер өем куйды.* М. Гали.

2. *и. мәгъ. күч.* Күл.— *Чынлап сөйләсәгез, Урал абый, биregез бишне. Зөфәр аңа күл сузды.* Ә. Бикчәнтәева.

3 *и. мәгъ. к.* бишле (3 мәгъ.). *--- Әдәби укудан синең гел биш икән, я әле, Зөмәрә, берәр шигырь сөйләп бир әле.* А. Әхмәт.

4. *Чама саны* **бишләр.** Вакытның чама белән сәгать биш тирәсе: 4 белән 5 яки 5 белән 6 сәгать арасы. *Кечерәк кыз сүз арасында үзләренең иртәгә сәгать бишләрдә үз урманнарына йөрергә чыгачакларын да аңлатты.* Ф. Әмирхан.

◇ **Бише белән кайтару** — берәүнең яхшылыгы яки яманлыгына каршы күп мәртәбә арттырып яхшылык яки яманлык эшләү. *Ат --- ашарга бир дип сорый белми ул. Ә син үзең бел, туйдыр аны, сыйла. Ат сиңа бише белән кайтарыр.* Р. Ишморат.

БИШАВЫЗ *и. зоол.* Гадәттә хайваннарның борын куышлыгында яки эчке органнарында яши торган суалчансыман паразит; *русчасы:* пятиустка.

БИШБАРМАК *и.* 1. *кулин.* Башкорт халкының милли ашы: ваклап туралган ит һәм шакмаклап киселгән токмачны пешереп, суган һәм борычлы шулпа сибеп бирелә торган ашамлык.

2. Перчатка. *Ары баскан аягыңны Бире бассаң ни булган. Бишбармагым калган диеп, Килеп китсәң ни булган.* Җыр.

3. Башкорт хатын-кызлар биюе.

БИШБИЛЛЕ *с. иск.* Билгә сыланып торырлык тар итеп, итәккә таба киңәйтеп-чабулап тегелгән бишмәт, казаки һ. б. *Авылның яшьләре бишбилле казаки ямьсез була дип, Рәхмәтулла карт теккән шикелле билле казакиларны бөтенләй кими башладылар.* М. Гали. *Бу милләтче --- бишбилле бишмәтле карт бер татар баеның --- коньяк эчеп утырганын күрде.* Г. Тукай.

БИШБИЛЛӘП *рәв. иск.* Бишбилле итеп, бишбилле формасында. *Болар икесенеке бертөсле кызгылт «шведский» материядән бишбиллән, шома гына тегелгән бишмәтләрен берсе аркасына гына салып, берсе киеп чыкканнар иде.* Ш. Камал.

БИШБЫЛТЫР *рәв. сөйл.* Бик күптән, әллә кайчан. *Минем хәзер булганга бишбылтыр инде, Гарәфи абый,— дип, бер дә тоткарлыксыз җавап бирде Газинур.* Г. Әпсәләмов. *Сыерчыкларның ояларыннан чыгып китүенә бишбылтыр инде.* Э. Касыймов.

БИШЕК *и.* 1. Яшь баланы тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланып эшләнгән асма ятак яки йоклау урыны. *Бишектә йоклаган баланың ара-тирә көрсенеп ыңгырашулары гына ишетелгәли иде.* Ш. Камал. *Ай өстендә алтын бишек.* Табышмак.

2. *күч.* Берәр нәрсәнең барлыкка килгән урыны, туган җире, ватаны. *Революция бишеге — Ленинградның камалышта калуы бөтен совет халкын тирән хафага төшерде.* Г. Гобәй.

Бишек сиртмәсе. *иск.*— бишек элә торган нечкә озын сыгылмалы колга.

◇ **Бишектән бирле (алып)** — бик яшьтән, кечкенәдән үк. *Мин аны бишектән бирле яратам, бала чагымнан бирле сөям.* Г. Ибраһимов. **Бишек җыры (көе)** — бишектәге баланы тирбәтеп йоклатканда, юатканда җырлана торган җыр (көй). *Мин яшәрмен әкиятләрдә, Аналарның бишек җырында.* Ә. Ерикәй.

БИШЕНЧЕ *тәрт. саны к.* биш (1 мәгъ.). *Ул үзе бишенче разрядлы слесарь иде.* А. Алиш. *Бишенче елдан соң реакция еллары килә.* Г. Нигъмәти. / *и. мәгъ. Ул Хәлимҗан белән бер класста, бишенчедә укый.* А. Әхмәт.

БИШКУЛЛАП *рәв.* Бик шатланып, чын күңелдән, рәхәтләнеп (каршы алу яки риза булу турында).

БИШЛЕ *с.* 1. Өс һәм аяк киеме, кайбер көнкүреш әйберләре, эш коралларының шул санча зурлык үлчәмен **белдергәндә әйтелә.** *Бишле галош.* ▭ ***Бишле лампа ягып мич алдында Батрак ана бүген йон эрли*** С. Җәләл.

2. *и.* «Биш» санын белдерә торган цифрның исеме.

3. *и.* Биш баллы системада иң югары билге: «бик яхшы» билгесе. *Бер эшче, аны* [*шигырьне*] *укыгач, астына бишле билгесе дә куйган иде.* Н. Исәнбәт. / *и. мәгъ. Бишледән башка билгене белмәгән Ильич.* З. Мансур.

БИШЛЕК *и.* Биш сумлык кәгазь акча. *Чәй эчкәч тә Хәйрулла белән Андрей, --- бишлекне тотып станциягә киттеләр.* Ш. Камал. *Иртәгесен* [*Нурислам бабайның*] *карчыгы чемодан төбеннән шытырдап торган бишлек алып картына сузды.* Ф. Яруллин.

БИШИНӘ *и.* Төрле әйберләр (оек, биялә, оекбаш, шәл һ. б.) бәйләү өчен биш данә металл чыбык. *Оекны бишинә белән бәйләү.*

БИШЛӘП I *Чама саны.* Бишкә якын, дүрт-биш яки биш-алты. [*Мәдрәсәдә*] *дүрт яки бишләп урысча укып торган балалар бар иде.* К. Насыйри.

БИШЛӘП II *рәв.* Биштән, бишкә аерып, бишкә бүлеп. *Сибелә чәчем, сибелә чәчем, Сибелә бишләп үрмәсәм.* Ә. Ерикәй.

БИШМӘТ *и. иск.* Татар һәм кайбер башка төркы халыкларда мамык белән сырып тегелгән кышкы өс киеме. *Аның башында каракүлле озынча нечкә бүрек, өстендә нечкә билле, күкрәге, якасы укалы бишмәт иде.* Г. Ибраһимов. *Янгын сараеннан өстенә кыска көрән*

бишмәт кигән бер кеше чыкты һәм, кулларын артына куеп, ат абзарына таба килә башлады. Г. Әпсәләмов.

БИШМӘТЛЕК *с.* Бишмәт тегү өчен билгеләнгән. *Вәли миңа --- биш-ун аршин күлмәклек, бишмәтлек кызыл мал бирде.* Г. Ибраһимов. // Бер бишмәт тегәргә җитәрлек. *Бу постаудан бер бишмәтлек материал калды.*

БИШНИ *с. диал. к.* шәмәхә. [*Китап сатучы*] *чана төбенә капчык җәйгән дә зәңгәр, яшел, бишни төсле матур тышлы китапларын --- тезеп салган.* Г. Бәширов.

БИШПОЧМАК *и. мат.* Йомык сыник сызыклар белән чикләнгән биш почмаклы геометрик фигура; күппочмак.

БИШТАШ *и.* Биш кисәк вак ташны җиңелчә чөеп уйный торган уен исеме. *Әйе,— мин әйтәм,— турыгызда бишташ уйнап утырганда, узган саен мине үртәп кала идегез.* Ш. Мөдәррис.

БИШТӘР *и.* Бауларын култык асларыннан җилкәгә алдырып, аркага асыла торган юл капчыгы; *рус часы:* котомка. *Юлга чыксаң, башың иеп чыкма, Юл буена күңлең җырласын; Юл биштәрең авыр булса булсын, Кайгың гына авыр булмасын.* Ә. Ерикәй. *Биштәрен асып, чатаклап бераз киткәч, ул* [*Хәйрүш*] *артына борылып карады...* М. Хәсәнов. / *с. мәгъ. Мусаның да биленда пистолет, җилкәсендә автомат белән кыр сумкасы, бөятләп аскан шинеле, аркасында биштәр капчыгы — бар «хуҗалыгы» үзе белән йөри.* Ш. Маннур.

БИШТӘРЛӘҮ *ф.* Аркага биштәр итеп асу, биштәр формасына китерү, аркага асарлык итеп эзерләү. *Менә бер заман бу солдат --- Биштәрләгән букча белән Авылына кайтып килгән.* Н. Исәнбәт. *Мансур аркасындагы биштәрләп тагылган капчыгын рәтләде.* А. Расих.

БИШУРЫНЛЫ *с. махс.* Биш берәмлек белән белдерелгән. *Бишурынлы сан.* □ *Төгәлрәк исәпләргә кирәк булганда, бишурынлы таблицалар кулланыла.* Алгебра.

БИШЬЕЛЛЫК *с.* Биш елга исәпләнгән, биш елда башкарылырга тиешле. *Без --- бишьеллык планны срогыннан алда үтәү өчен вакыттан алда баруны үзебезгә бурыч итеп куйдык.* Г. Минский. // *и. мәгъ.* Халык хуҗалыгы үсешенең бишьеллык планы. *Бишьеллыкның бөек гигантлары һаман үсә, һаман күккә таба үрелә.* Һ. Такташ.

БИШӘМ *и.* Биш көлтәдән ясалган чүмәлә, бәпкә, сослан.

БИШӘР *Бул. саны, к.* биш. *Биш тапкыр бишәр тиеннән егерме биш тиен (була).* Г. Камал.

БИШӘРЛЕ *с.* Һәр рәтендә, буынында бишәр берәмлек булган. *Бишәрле санау системасы. Бишәрле чикләвек кәшәнкәсе.*

БИШӘРЛЕК *и. к.* бишлек.

БИШӘРЛӘП *рәв.* Бишәр-бишәр төркемнәргә аерып, бүлеп. *Бишәрләп санау.* □ *Һәр җирдә крестьяннар алпавытларны талыйлар, имениеләрен яндыралар, шуның өчен крестьяннарны бишәрләп-унарлап асалар, йөзәрләп Себергә, каторгаларга озатып торалар.* М. Гали.

БИШӘҮ *Җыю саны, к.* биш.

БИШӘҮЛӘП *рәв.* Бишесе бергә, берьюлы; бишәү булып, бишесе дә. *Әниләре чәй әзерләде. Бишәүләп өстәл янына утырдылар.* Г. Мөхәммәтшин.

БИШӘҮЛӘШЕП *рәв. к.* бишәүләп.

БИЮ 1. *ф.* Кичә, уен, концерт-чыгышларда махсус көйләргә кул-аяк, гәүдәнең матур, нәфис хәрәкәтләре аркылы җанлы тормыштан алынган берәр күренешне (гадәттә хезмәт процессы, ял итү, күңел ачу һ. б.) гәүдәләндерү. *Тыпыр-тыпыр биергә Тимер идәннәр кирәк.* Җыр. [*Мәрхәбә*] *матур башкорт җырларын моңланып-моңланып җырлады, кыска, җиңел шат көйләргә таклаклап биеде.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Уйнаклау, сикерәләү. *Пароход әнә нинди була икән ул! Утлары нихәтле! Шәүләләре су өстендә биеп килә.* И. Гази. *Ул --- чуар күбәләкләрнең иртәнге биюләрен һәм куаклыктагы пәрәвезләрдә, --- энҗе бөртекләре кебек, чык тамчыларының ялтыравын аермачык күрә.* К. Нәҗми.

2. *и.* Буй-сын һәм кул-аякларның тормыштан алынган берәр күренешне гәүдәләндерә торган матур, нәфис хәрәкәтләре; танец. *Бию кыза.* Н. Исәнбәт. // *с. мәгъ.* Биюгә караган, биюгә кагылышлы. *Бию хәрәкәте. Бию такмагы. Бию сюитасы.* □ *Гармоньчы --- бию көен басарга кереште.* М. Гафури.

БИЮЧЕ *и.* Бию башкаручы, бию һөнәре остасы. *Театрның составына даими эшчеләр булып кереп эшләүчеләр арасында күп санда рус һәм башка милләт җырчыларын, биючеләрен, режиссерларын, художникларын, музыкантларын очратабыз.* М. Җәлил.

БИЯ *и.* Ана җенестәге ат. *Колынлы биядән су артмый.* Мәкаль. *Авылны чыгуга, ул атның авызын тартып җибәрде дә, кечкенә чаптар бия томырылып юырта башлады.* М. Гали.

БИЯЛӘЙ *и.* Баш бармакка аерым, калган бармакларга исә тоташ бәйләнгән яки тегелгән күл кием. *Фронтовикларга дип атап, кем оекбаш, кем җылы бияләй бәйли.* Г. Әпсәләмов. *Мостафа маңгай тирләрен киндер биялләренең аркасы белән сыпырып җибәрде.* Ш. Камал.

◇ **Бияләй эченнән йодрык күрсәтү** — сиздермичә генә янау, гайрәт чәчү, гайрәт ору. **Бияләй эчендә бармак кыймылдатканны да сизү** — сизгер булу. *Һәй, хәйләкәр дә була бу картлар! Бияләй эчендә бармак кыймылдатканны да сизәләр.* Г. Әпсәләмов.

БИҺУШ *с. иск.* Һушсыз. [*Мәче сандугачка*] *Синең сайравың һәртөрле музыкалардан матур булганлыктан, урмандагы көтүчеләр, ат ашатучылар һәммәсе биһуш булганнар, имеш.* Г. Тукай.

БЛАНМАНЖЕ *и. махс.* Сөт, какао яки җиләк-җимеш суларына шикәр, желатин кушып әзерләнгән һәм аш артыннан бирелә торган ашамлык. *Бланманжены суыту. Сөт бланманжесы.*

БЛАНК *и.* Басма тексты өлешчә генә булып, анкета, отчет һ. б. рәсми язулар өчен билгеләнгән стандарт формадагы кәгазь бите. [*Паларусов*] *Тиз-тиз кәгазьләрен, бланкларын өстәлгә чыгарып куйды.* Г. Ибраһимов.

БЛИНДАЖ *и. хәрби.* Сугышчыларны, шулай ук сугыш кирәк-яракларын артиллерия һәм миномет утыннан саклау өчен ясалган хәрби корылма, яшеренү урыны. *Блиндаж эче чиста, җыйнак һәм фронт шартлары өчен шактый комфортлы.* И. Гази.

БЛОК I *и. физ.* Бау, чылбыр һ. б. шудырып йөртү өчен тирәсе улак сыман итеп эшләнгән, бер күчәрдә әйләнә торган тәгәрмәчтән гыйбарәт иң гади йөк күтәрү һәм көч юнәлешен үзгәртү җайланмасы; чыгыр. *Күпме көч түксәк тә, блогыгызны эшләдек бит, Артем Михайлович.* Г. Әпсәләмов.

БЛОК II *и. полит.* 1. Дәүләтләр, политик партияләр, төрле социаль төркемнәрнең теге яки бу максатка ирешү өчен төзелгән берләшмәсе, килешүе. *Коммунистлар һәм партиясезләр блогы.*

2. *махс.* Берәр төрле корылманың берничә элементтан яки детальдән торган өлеше; секция. *Тәрәзә блоклары.*

3. *махс.* Бетон катнашмасыннан зур күләмле кирпеч рәвешендә әзерләнгән ясалма төзү материалы. *Шлак-бетон блоклар.* □ *Эре блокларны һаваға күтәргән мәһабәт кранлар салмак кына борылалар.* Г. Әпсәләмов.

БЛОКА'ДА *и.* 1. Билгеле шартларга күндерү яки бирелергә мәҗбүр итү өчен берәр ил, шәһәр, крепостьның дошман гаскәрләре тарафыннан камалуы, тышкы бәйләнештән мәхрүм ителүе. *Ленинградта хатыным белән балам блокада вакытында һәлак булдылар.* Г. Гобәй. *Бөлгенлеккә төшкән буржуа иле Теләсә генә ничек*

итсә дә, Безгә блокадалар ясау түгел, Борны белән чәнчелеп китсә дә, Без җиңәрбез! Һ. Такташ.

2. Политик басым ясау максаты белән берәр дәүләтне политик яки экономик яктан изоляцияләүгә юнәлдерелгән чаралар системасы. *Политик блокада. Экономик блокада. Финанс блокадасы.*

БЛОКНОТ *и.* Битләре ертып, өзеп алына торган, кечкенә күләмле язу дәфтәре. [*Эшче хатын*] *кулындагы блокнотыннан бер бит ертып алды да, тавышсыз атлап, трибунага килде.* Г. Ибраһимов.

БЛУ'ЗА *и.* 1. Ирләрнең билбаусыз киң күлмәк формасында тегелгән эш киеме. *Сөләйман ашыга-ашыга кәсәеннән* [*билетын*] *чыгарып, өстенә майланган блуза кигән кешегә сузды.* Қ. Тинчурин.

2. *иск.* Хатын-кызларның иркен кофтасы. *Нәгыймә алдында кыска күк юбка, күк блуза кигән --- бер хатын шаркылдап көлеп җибәрде.* Г. Ибраһимов.

БЛЮ'МИНГ *и. тех.* Авыр эшләнмәләрне кыса торган зур прокат станы.

БЛЯ'ХА *и.* Мебельне, сбруйларны бизәү өчен кулланыла яки эләктергеч, каптырма булып хезмәт итә торган металл пластинка. [*Солдатка алынган егетләргә*] *кызыл погонлы соры шинельләр кигезделәр һәм билләренә зур җиз бляхалы киң каешлар бәйләделәр.* М. Гали.

БО'БРИҚ *и.* 1. Төкләре тырпаеп тора торган сукно. *Әүхәдигә биш айга ун сум илле тиен көмеш саф акчалата һәм шул фабрикада эшләнгән бобриктан бер чикмәнлек кисеп бирделәр.* Қ. Тинчурин. // *с. мәгъ.* Шундый материалдан тегелгән. *Күренеп тора: егет купшыланыбрак килгән, өстендә кыска чабулы бобрик пальто.* Г. Минский.

2. *рәв. мәгъ. сир. Рәвешле, итеп, белән* сүзләре яшында: ирләрнең чәчен ал якта гына тырпаеп торырлык итеп алу турында. *Михаил бобрик белән кыскартылган чәчләрен киргә сыпырып куйды.* Ф. Әмирхан.

БОГАУ *и.* 1. Революциягә кадәрге Россиядә һәм капиталистик илләрдә тоткыннарның кул-аякларына кидерү өчен чылбыр белән тоташтырылган тимер божралар. *Ләкин менә Декабристлар аягында чылдыр-чылдыр Богау чыңлап торганда да, аккош килгән, Сандугачлар шулай кылдан оя үргән.* З. Мансур. *Катакомбаларның, төрмәләрнең канлы диварлары эчендә богау тавышлары шалтырый.* Һ. Такташ.

2. *күч.* Бәйлелек, ирексезлек. *Романовлар тәхете зирзәвәр китерелү аркасында, татар милләте дә --- коллык богауларыннан котылды.* Ш. Камал.

◇ **Богау салу** — *к.* богаулау. *Богау салды дошман кулларыма һәм хурлыклы юлдан атлатты.* М. Җәлил. *Әсирләрне, аяк-кулларына тимер богаулар салып, хайван көтүе кебек куалап кайтып, янәдән шәһәрдәге караңгы таш зинданнарга бикләделәр.* Ш. Мөхәммәдев.

БОГАУЛАУ *ф.* 1. Қул-аякларга богау кидерү, богау салу. *Унбишен, тимер богаулар белән богаулап, җәяүләп, гомерлеккә ерак Себергә озатырга.* М. Гали.

2. *күч.* Ирексезләү, кешенең тойгыларын, теләкләрен, омтылышларын һ. б. чикләү, тыю. *Богаулама хыялыңны, җәйсен канатын!* Ф. Кәрим. *Алдылар үч, көр фикерләрне богаулап, җан кыеп.* Н. Исәнбәт.

БОГАУЛЫ *с.* 1. Богауланган, богау салынган, богавы булган. *Әле бит кеше дигәнең аларны богаулы кулларыбелән ясаган.* И. Гази.

2. *күч.* Ирексез, бәйле. *Мәңгелек төрмәгә ябылган Богаулы тоткыннар идек без.* М. Җәлил.

БОГАУЛЫЛЫҚ *и.* Богаулы булу, богауланган булу хәле.

БОГДАЙ *и. иск. к.* бодай. *Кеше богдай чәчеп арпа алалмас, Яман эшдин дәхи файда табалмас.* Ә. Фәйзи. [*Аю белән бабай*] *икенче ел шулай уқ бергә-бергә чәчтеләр богдай.* М. Гафури.

БОГЫЛ *и.* Конус рәвешендәге печән кибәне. *Эскерт күйганда да, богыл салганда да, каралты түбәләрен япканда да, ул һәрвакыт өстә эшләргә тырыша.* Г. Әпсәләмов. *Буаз сыер богылда, кысыр сыер саламда.* Мәкаль.

БОДАЙ *и.* 1. Бөртекләре ак он хәзерләүгә китә торган кыяклы ашлык үсемлеге. *Көзге бодай.* □ *Печән артына ялганып уқ арыш, арпа да кибә һәм бодайлар да саргая башладылар.* Ш. Камал.

2. Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. *Төшләремдә генә күрәм Бодай тараткандымны.* Ш. Маннур. *Менә Хәлим төбенә бодай салынган капчыкны лап иттереп сәкегә куйды.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Бодай бөртегеннән яки онынннан эзерләнгән. *Бодай боткасы.* □ *Бу вакытта ул бер ялгызы мичтән яңа гына чыккан бодай кабартмасы белән чәйләп утыра иде.* Г. Гобәй. *Менә дигән көр иттән пешергән аш, токмачы да илләгән бодай онынннан.* А. Шамов.

БОЕГУ *ф.* Моңаю, күңелсезләну. *Вокзалда хатыннар, --- ирләрен озатып, өч-дүрт баласын кочаклаган килеш боегып калдылар.* Ә.Фәйзи. *Боекма сиң, егет, яраңа Қилешмәсә безнең дәвалар, Җирдән өздек сиңа чәчәкләр, Эзләгәнең юкмы арада?* Н. Исәнбәт.

БОЕҚ *с.* Моңсу, сагышлы, күңелсез, төшенке күңелле. *Боек, сүлпән, омтылышсыз була Хыялсыз көн иткән һәр кеше.* Ф. Кәрим. *Хәзер күңелем боек чагы, Син кайткач чәчәк атар.* Җыр.

БОЕҚЛЫҚ *и.* Боек булу, боек булу хәле; төшенкелек. *Аның күңеле боек хәзер, елмаймый да, көлми дә. Нигә күңеле боеклыгын кешегә белдерми дә.* М. Җәлил.

БОЕЛЫҚ: боелыгын тотмау, тота алмау — сидеген тота алмау авыруы.

БОЕНДЫРЫҚ *и.* 1. Үгез камыты. *Үгез боендырыкка муенын үзе бирер.* Мәкаль.

2. *күч.* Тартым һәм урын-вакыт килеш формасында: кемнең дә булса кул астында, карамагында, җаваплылыгында дигән мәгънәне белдерә. *Губернатор үз боендырыгындагы чиновникларны үгетләргә ярата иде.* Қ. Нәҗми.

БОЕПРИПАС *и. сөйл.* Сугыш кирәк-яраклары: снарядлар, патроннар һ. б. ш. *Траншея буйлап корал ташылды, боеприпас ташылды, саллар ясау өчен бүрәнәләр ташылды.* И. Гази.

БОЕРУ *ф.* Боерык бирү, әмер бирү, катгый кушу. *Карчык тагын бая Габдуллага кычкырган тавыш белән тизрәк ишекне ябарга боерды.* Ә. Фәйзи.

БОЕРЫҚ *и.* Катгый әмер, приказ. *Сиңа бу зур үтенечем, боерык дип уйлама.* А. Алиш. *Мондый көтелмәгән боерыктан --- Сажидә апа аптырый калды.* Ә. Еники.

БОЕРЫҚЛАУ *ф. сир. к.* боеру. *Андый итагатьсезләргә безнең бер тиенебез дә әрәм! — дип, шулай бер үгетләп, бер боерыклап, сүзен бетерер-бетермәс кузгалган Қадыйр бай ике адым да атлый алмады.* Г. Ибраһимов.

БОЖАН *и.* Шөпшәләр төреннән чага торган бөжәк, *русчасы:* шершень.

БОЗ *и.* 1. Түбән температурада каты хәлгә килгән, каткан су, туңган су. *Юллар, урам ташлары ялтырап торган бозга әйләнделәр.* Д. Аппакова. *Карап торам, шаулап бозлар ага, ярга сыймый Идел ташкыны.* Ф. Кәрим.

2. Шугалак, шуу өчен су сиптереп махсус әзерләнгән мәйданчык; каток. *Бозны күптән түгел генә себереп чыгарганнар һәм аңа су сипкәннәр булса кирәк. Ул көзге төсле ялтырап ята.* А. Шамов. *Егет белән кызлар йөри шаркылдашып, Боз өстендә тимераяк белән шуып.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Бозлы, тоташ боздан торган. *Төньяк боз диңгезе.* □ *Җиһанның бар казылган базларын, боз тауларын үттем.* Н. Исәнбәт. *Берничә минут үтәр-үтмәс, боз диңгезе мотор җырына күмелде.* А. Алиш.

3. Үтә күренмәле түгәрәк боз бөртекләре булып ява торган атмосфера явым-төшеме. *Бернәрсә дә күренми, тик яңгыр вә боз ява.* Ш. Камал.

4. *күч.* Салкынлык (мөнәсәбәтләр турында), читләшү, хәтер калу. *Тик соңгы вакытта бүләкләр дә арадагы бозны эретә алмый башладылар.* Ә. Маликов.

Боз кискеч, боз чапкыч — боз вата торган корал. [*Альпинистларның*] *кулларында боз чапкычлар, аякларында табаннарына очлы тешләр кагылган аяк киемнәре, аркаларында --- җылы капчыклар.* Физ. геогр. **Боз китү** — елгаларда язгы ташу вакытында боз агу. *Бозлар киткәч, елгада кызыл канат белән чабак чиртә башл*[*ый*]. Г. Гобәй. **Боз кузгалу** — 1) елгаларны каплап алган тоташ бозның яз көне вакланып ага башлавы турында; 2) *күч.* берәр эш яки хәрәкәт башлану. *Тулуы җитте ачу диңгезенең, Боз кузгалыр, дилəр, тиз көннән.* Г. Хуҗиев. **Боз сугу (игенне)** — боз явып игенне һәлак итүе. *Урман боз суккан бодай кыры кебек: бер генə сəламəт агач та юк...* Г. Әпсәләмов.— *Тик* [*ашлыкны*] *исән-сау җыеп алырга насыйп булсын, боз сугып, корт төшеп әрəм итмəсен.* Г. Ибраһимов.

◇ **Боз йөрәк** — мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, хисләргә ярлы кеше турында. *Сөю ул шундый серле, тылсымлы, Боз йөрəкне үбеп эретə.* М. Җәлил. **Боз салкыны** — ваемсызлык, бернәрсәгә дә искитмәүчәнлек турында. *Зиннəт хəзер бернəрсəгə дə куанмый да, кайгырмый да, бөтенесенә күзләрендәге боз салкыны аша гамьсез карый.* Г. Бәширов. **Бозга таяну (таяндыру)** — алдану (алдау).— *Шул мəдрəсə өчен ялган договор төзеп, патша хөкүмəтен бозга таяндырган.* Х. Кәрим. **Бозга язган**—реаль тормышта булмаган, булуы мөмкин түгел. [*Батырҗан*] — --- *Ул синең белəн минем хисап түгел.* [*Ярулла*] — *Бозга язган хисапмы? Таяныпкара əле син аңа.* Ф. Бурнаш.

БОЗАУ *и.* 1. Сыер, болан, поши баласы. *Болан бозавы.* □ *Ул ишек алды тулы терлекләрне эчерə, сыерларны сава, бозауларны ябып куя һəм кичке аш урынары хəзерли.* А. Шамов.

2. *күч. гади с.* Бик ихтыярсыз, үтә йомшак холыклы, җебегән, булдыксыз кеше. [*Җəлəш мулла улларына:*] *Укыту əрəм, йөрүең əрəм, акчаң əрəм сез бозаулар өчен.* Г. Ибраһимов.

◇ **Бозау сыйрагы** — юан итеп кулдан гына төрелгән тәмәке. *Икəүлəп «бозау сыйракларын» төреп эчкелт тəмəкене иркенлəп суыра-суыра гəп сата башладык.* Ә. Айдар.

БОЗАУЛАУ *ф.* 1. Бозау тудыру (сыер, болан, поши турында). *Көтүдə йөргəндə берəр сыер бозауласа, --- Мөхəммəтҗан бабай үзенең җилкəсенə күтəреп алып кайта.* М. Гали.

2. *күч. гади с.* Озаклау, әкрен кыймылдау, әкрен маташу, мыштырдау.

БОЗВАТКЫЧ *и.* Бозлар арасында йөзү һәм башка суднолларга юл салып үтү өчен җиһазландырылган куəтле судно. *Атом энергиясенə нигезлəнгəн «Ленин» бозваткычы.*

БОЗГЫЧ *и.* Язуларны боза, бетерә торган резина кисәге, бетергеч.

БОЗДЫРГЫЧ *и. иск.* Сихер. / *с. мәгъ. Шул ук фатирда һəртөрле сөйдергеч имнəре, боздыргыч тасмалары табарга мөмкин.* Г. Тукай.

БОЗЛАВЫК *и.* Яңгыр яки юеш кардан соң кинәт суыту нәтиҗәсендә тоташ боз кабыгы белән капланган җир өсте, тайгалак, тайгаклык. *Аяк асты тəмам бозлавык булган.* Г. Әпсәләмов. *Бозлавыклар очраганда* [*малай*] *йөгереп килеп шуып китə.* М. Хәсәнов. *Ишек алдың бозлавык — Таеп егылган тавык.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Бозланган, боз кабыгы белән капланган. *Мулла, таяк очы белəн бозлавык җиргə ныккына бəреп-бəреп, урам аркылы чыгып бара иде.* Ш. Камал.

БОЗЛАНУ *ф.* Боз белән, боз катлавы белән каплану, боз кату. *Тəгəрмəч эзлəрендə җыелып торган яңгыр суларының өсләре бозланган.* Г. Гобәй. *Куакның барлык ботаклары бозланып, пыяла шарлар шикелле чукланып-чукланып катып калганнар.* Д. Аппакова.

БОЗЛЫ 1. *с.* Боз катнаш, боз белән аралаш. *Кичə --- туктаусыз карлы, бозлы яңгыр ява иде.* Г. Ибраһимов. // Бозланган, боз аккан. *Салкыннарда бозлы елгаларны Чирканмыйча ярсып йөздем мин.* Ә. Ерикәй. // *күч.* Боз кебек салкын. *Хəл җыярга туктап, ирлəр күлəгə астында бозлы əйрəн эчкəндə, Галимə апа үзенең ике иптəш кызы белəн əрəмə арасына китте.* М. Гафури.

2. Боз каткан, боз каплаган, бозланган. *Язгы көннәрнең берендә ялтыраган бозлы урамнан дөп-дөп ат сикертеп, каравыл өе янына --- бер мылтыклы килеп туктады.* Г. Бәширов. *Ул бозлы тəрəзəгə күз салды.* А. Алиш.

3. *күч.* Бик салкын, гаять салкын. *Чылдыр-чылдыр... Белмим, чишмə тавышы? Нинди чишмə бозлы Себердə!* М. Җәлил. *Бураннарны, бозлы тайгаларны Йөрәк уты белəн җылытып, Җимергəннəр үлем полкларын, Үлем барлыгын да онытып.* Ш. Маннур.

БОЗЛЫК *и.* Таулы яки поляр өлкәләрдә хәрәкәт итә торган тоташ боз массасы. *Европаның бөтен төньяк ягының ике километр калынлыкка җиткəн --- бозлык каплап алган.* Бор. зам. тар. *Безнең илдə бозлыклар 0,3% чамасы мəйданны били... СССРда барлыгы берничə мең зур һəм кечкенə бозлык бар.* Физ. геогр.

Бозлык дəвере (бозлык чоры) *геол.*— Җир тарихында көчле салкынаю һәм гаять киң мәйданнарда тоташ боз катлавы барлыкка килү белән характерлы чор. *Бозлык дəверендə Көнчыгыш Европа тигезлегенең төньяк ягының шактый өлеше гигант бозлык белəн капланган булган.* СССР физ. геогр.

БОЗУ *ф.* 1. Яраксыз итү, начарландыру. [*Ярдəмче повар*] *берничə тапкыр ашны бозды.* Г. Гобәй. *Май ботканы бозмый.* Мәкаль.

2. Вату, җимерү, яраксыз хәлгә китерү. *Машина бозу. Юл бозу.* □ — *Малайлар радионы бозганнар, шуны төзəтергə йөри идем.* Т. Гыйззәт.

3. Башкачарак итеп яңадан тегү, кору, ясау өчен сүтү, җимерү.— *Синең искеңнән бозып теккəн камзулга сыймый башладым.* Ф. Хөсни. *Мин итекне ялтыратып, мыекларны бөтереп, шинельдән бозып тектергəн пальтоны иңбашка гына салып йөрим.* М. Гали.

4. Сызып ташлау, бетерү, юкка чыгару (язу-сызу турында). *Бер өем дəфтəрнең берсен калдырмый кызыл карандаш белəн «төзəтеп» чыктылар: сыздылар, бозды-лар, яңаны язган булдылар.* Г. Гобәй. *Фəрит, бу исемне бозып, үз фамилиясен язып куярга да уйлаган иде.* А. Шамов.

5. Бөтен, башланмаган әйберне башлау, бүлгәләү. *Ипи бозу. Каз бозу.* □ — *Əллə инде* [*Нəсимə*] *өчен участок бозарлар!* Ш. Камал.

6. Ялгыш итеп үзгәртү. *Телне бозу. Көйне бозу.* □ [*Камил əфəнде*] *«Кара урман»ны җырлады һəм нинди-дер бер хəерле илһам белəн аны бозмады, ватмады, европалаштырмады.* Ф. Әмирхан. *Бары партия юлына ышанмаган язучы гына чынлыкны бозып, буяп күрсəтəчəк.* М. Җәлил.

7. Үтәмәү (килешенгән, алдан кабул ителгән тәртип, закон, кагыйдәне һ. б. ш.). *Ант бозу. Закон бозу.* □ ***Полк командирын ул, хəрби кагыйдəлəрне бозып, этисе исеме белəн олылап атап йөртə иде.*** А. Шамов. *Башыңа таш явып торса да, вəгъдəңне бозма.* Д. Аппакова. // Үзү, туктату, гамәлдән чыгару. *Договорны бозу. Килешүне бозу.*

8. Тормыш агышының, мөнәсәбәтләрнең, эшнең һ. б. ның урнашкан тәртибен, билгеле бер чиген үзгәртү, чуалту, таркату. *Семья бозу. Араны бозу. Эшне бозу.*

□ *Морозов инде илебез чиген бозып кергән дошманнарга каршы сугыша башлаган булган.* Г. Әпсәләмов. *Стенадагы сәгать маятнигы гына үзенең ритмын бозмыйча тип-тигез тикелдәп тора иде.* Ш. Камал. *Чиләбеләр, --- дошман [сафларын] бозып, шәһәр эченә --- керә башладылар.* Ш. Усманов.

9. *күч.* Җыеру, сыту, чыту (йөзгә, чырайга кәефсезлек, ачу, ризасызлык билгеләре чыгару турында). *Бикмулла карт түзмәде, төсен бозып тагын сыкранып куйды.* Г. Бәширов. *Галиябану (борылып, Исмәгыйльне күргәч, чыраен бозып):— Рәхмәт,— [диде].* М. Фәйзи.

10. Иске Россиядә: солдат хезмәтеннән котылып калу максаты белән берәр эгъзаны (колак, күз, аяк, кул һ. б. ш.) имгәтү, гарипләндерү. *Гыйззәт ---, аяк бозып, солдаттан калды.* Г. Ибраһимов.— *Син миңа да әйтмәстән юрамалый күзеңне бозды.* Ш. Камал.

11. Борчу, тынычсызлау. *Йөрәк бозу. Кәеф бозу.* □ *Зәйнәпнең үзен-үзе күрәсе килми торган бервакытында бу хәлнең булуы аның күңелен дәхи бозды.* М. Гафури. *Син, энем, алай каныңны бозма!* Һ. Такташ.

12. Кешенең дөньяга карашында, үз-үзен тотышында начар якка үзгәреш тудыру, холкын начарландыру. *Гәрәй бик дөрес әйтә: Мәхмүт Гыйльметдинов кебек мошенниклар халыкны бозып бетерәләр.* Ш. Камал. *— Әле сөйләп туктаган бабай безне кешеләрне бозуда, диннән яздыруда гаепли.* М. Әмир.

13. Баланы дөрес тәрбияләмәү. *Әнкәй, Рөстәмне үз тәрбияңә алырсың, --- бабайларга җибәрмә, иркәләп бозарлар.* Т. Гыйззәт.

14. Ямьсезләтү. *Ул, --- шушы сихри матурлыкны бозудан --- сакланып, пышылдап кына әйтте.* Г. Гобәй. *Нурга чумган матур табигатьне --- бозып тора ул [иске авыл].* М. Гафури.

15. *иск.* Сихерләү.

БОЗЫК *с.* **1.** Бозылган, яраксыз, черек. *Бозык йомырка.*

2. Ватык, җимерек, эшкә яраксыз. *Бозык машина. Бозык сәгать.* □ *Аларның --- гармоньнары бозык иде.* А. Шамов.

3. Дөрес булмаган, тиешле нормада булмаган. *[Гали] шул бозык гырылдавыклы тавыш белән бертуктаусыз акырына.* Г. Ибраһимов. *[Закир] хәзрәтнең бик бозык русча белән --- сораганын ишет(те).* Ф. Әмирхан.

4. Чытык, караңгы (чырай турында). *Шулай да булса, бүген Галиәкбәр агайның чырае бозык күренә.* Ш. Мөхәммәдев.

5. Явым-төшемле (һава торышы турында), юеш, пычрак (юл һ. б. турында). *Ерак җирләргә йөрүче юлчылар --- язга таба яки кышын олы юл бозык вакытларда гына Шырдан аша әйләнеп йөриләр.* М. Гали.

6. Әхлаксыз, тотнаксыз, тәүфыйксыз. *Бу поэмада Г. Тукай надан, тискәре, бозык, реакцион хаҗилар, муллалар, сәүдәгәрләр, ялкау, әрәмтамак шәкертләрдән көлә.* М. Җәлил. *Кемнәрдер безне халык алдында бозык кешеләр итеп күрсәтергә телиләр.* Р. Ишморат. // *и. мәгъ.* Әхлаксыз кеше. *Җыен эшлексезне, җыен бозыкны, нәсел черетеп, син җыеп ятасың.* Г. Бәширов.

◇ **Бозык юл** — әхлак нормаларына сыймаган гадәтләр, ярамаган, тыелган эшләр. *Шайтан куәтле: Галиәкбәр агайны аздырып, янә бозык юлга салды.* Ш. Мөхәммәдев.

БОЗЫКЛЫК *и.* Бозык (6 мәгъ.) булу хәле. *Г. Камалның күп әсәрләре буржуа-мещан семья тормышындагы бозыклыкларны ачып салуга багышланган.* М. Гали. *Укымак --- сафлыкның бозыклыкны җиңүләреңә үткен коралдыр.* Г. Тукай.

БОЗЫЛУ *ф.* **1.** Яраксыз хәлгә килү, начарлану. *Силос бозылу.* □ *Вакытында өзмәсәң, кура җилгә дә бозыла башлый.* Г. Ибраһимов.— *Бөртекне ындыр эченә ташып өлгермәсәң, тышка өйгән ашлыкның яңгырда чыланып, сыйфаты бозылуы мөмкин иде.* Г. Бәширов.

2. Ватылу, җимерелү. *Машина бозылу. Телефон бозылу.* □ *Менә шундый салкын көннәрнең берендә Миңнур картның миче бозылды.* А. Шамов.

3. Бетү, юкка чыгу. *Тынычлык бозылу.* □ *Баратора стеналардагы плюс билгеләре бозыла.* Г. Гобәй.

4. Үтәлмәү, дөрес булмаган якка үзгәртелү (закон, кагыйдә һ. б. турында). *Декретлар турында халыкның белмәве, аларның «көчлеләр» тарафыннан бозылуы төп бәлаләрнең берсе булып тора.* М. Әмир. // Нәрсәнең дә булса формасы, эчтәлеге, рәвеше үзгәрү. *Бераздан бу этюд бозылды, утыра торгач, менә шушы әйбер килеп туды.* Г. Бәширов.

5. Йөзгә, төскә, чырайга ачу, ризасызлык һ. б. ш. билгеләре чыгару турында. *Сәгыйтьҗанның чырае тәмам бозылган иде.* Ә. Фәйзи.

6. Зарарлану, гарипләнү, җәрәхәтләнү. *Аяк бозылу. Ашказаны бозылу.* □ *Доктор әйтә: «Йөрәгең бозылган», ди.* Ә. Ерикәй. *Габделкаюмның кызамыктан бозылып калган сул күзе еш кына авырткалап борчый башлады.* М. Гали.

7. *Кәеф, күңел, йөрәк, нерв* сүзләреннән соң: борчылу, тынычсызлану. *Зәйнәпне күргәндә күңеле бозылганга күрә, моннан соң [аны] күрмәскә тырышырга карар бирде.* М. Гафури.

8. Әхлаксызлану, бозык юлга керү. *Закирның бозылуына --- шул типларны тудырган капиталистик төзелеш --- гаепле.* М. Гали.

9. Начар гадәтләр үзләштерү турында. *Холык бозылу.* □ *Баланы никадәр иркәләсәң, шулкадәр бозыла гына.* Т. Гыйззәт.

10. Чуалу, таркалу, рәте китү. *Дөньялар бозылу. Заманалар бозылу. Эшләр бозылу.* □ *Аксак Низамый да үзенең җәдитлеккә чыгуы дөньясы, мәгыйшәте бозылганлыктан икәнлеген икърар итә.* Г. Тукай.

11. Болытлау, явым-төшемле булу. *Маневрга --- чыгу белән, һавалар да бозылып киттеләр.* Һ. Такташ. *Көн җиләсләнеп, болытлап, бозылырга торган төсле иде.* М. Гали. // Пычрану, баткаклану, йөрерлек булмау. *Юллар бозылып өлгергәнче, иптәшләр, безгә бу сазлыклардан, әрәмәлекләрдән чыгарга кирәк.* Г. Әпсәләмов. *Ләкин Яуширмә җирләренә килеп җиткәндә, юл тәмам бозылып өлгерде.* Ә. Еники.

БОЗЫЛЫШУ *ф.* Дуслык китү, мөнәсәбәтләр, ара бозылу. *[Сәлим] ничә еллар атасы белән бозылышып йөргән иде.* Г. Ибраһимов. *Җәмилә җиңеш белән дә Борһан әллә ничек кенә бозылышып киткән иде шул.* М. Хәсәнов.

БОЗЫШТЫРУ *ф.* Дошманлаштыру, котырту, мөнәсәбәтләрне, кешеләр арасын бозу. *Фәсхи, --- Мөхәммәтша милләтче дип, ялган сүз тарата һәм Ипай белән Гөлгенә арасын бозыштырмакчы була.* М. Җәлил. *Кияү белән араны бозыштырып, әллә нишләп беткән иде, мәлгунь.* Ш. Камал.

БОЙКОТ *и.* Аерым дәүләт, оешма, учреждение яки аерым кеше белән һәртөрле мөнәсәбәтләрне өзеп, аны тулысынча читкә кагудан, игътибарсыз калдырудан торган политик һәм экономик көрәш ысулы. *Бойкот игълан итү. Бойкот белдерү.* □ *Ашлык уңмаган. Семья зур. Шәһәрдә дә эш юк, бойкот!* Г. Тукай. **Бойкот ясау** — бойкотка дучар итү, протест белдерү. *Өзделәр өметләрен һәм киттеләр бойкот ясап.* М. Гафури. *Баязит карыйга җеназа җаиз дәгел диешеп, дини бойкот ясаганнар.* Г. Ибраһимов.

БОЙНИЦА *и. хәрби.* Берәр ныгытманың стенасында яки оборона корылмасында пушкалар, пулеметлардан ату өчен ясалган тишек: амбразура. *[Солдатлар], тузан-туфрак арасыннан мылтыкларын алып, үзләренең бойницаларына барып басканнар иде.* Ф. Хөсни.

БО'ЙНЯ *и.* Хайваннар сую һәм түшкәләрне беренче эшкәртү өчен махсус предприятие. *Тәбәнәк кенә таш бойня янындагы кешеләр [Габделбәрне] шаулатып каршылаʔылар.* А. Расих.

БОКАЛ *и.* Эчемлек өчен рюмка рәвешендәге, ләкин аннан зуррак савыт. *Жиңүчеләр хөрмәтенә Күтәрик бокалларны.* Э. Ерикәй.— *Эчми торган кеше булсам да, туып килгән яңа елны котлап, тагын бер бокал --- күтәрергә хәзер.* А. Шамов.

БОКС I *и.* Спортның бер төре. Аерым кагыйдәләргә нигезләнгән, махсус перчаткалар киеп башкарыла торган йодрык сугышы. *Бокс ярышы.* □ *Мансур бокс ярата иде, [ләкин] беркөнне бер иптәше Мансурны сугып екканнан соң, Гөлшаһидәнең котлары очты, һәм ул егеттән боксны ташлауны үтенә башлады.* Г. Әпсәләмов.

БОКС II *и.* Дәвалау учреждениеләрендә, авыруны башкалардан аерым тоту өчен, бинаның бүлеп алынган өлеше. *Беренче бокстагы авыру.*

БОКС III *и.* Ирләрнең чәчен баш түбәсендә кыска калдырып алу төре, рәвеше.

БОКСЁР *и. спорт.* Бокс белән шөгыльләнүче спортсмен. *[Альбомда] башы-күзе гомеренә күгәрүдән чыкмый торган «сугыш чукмарлары» — боксерлар да --- бар.* Г. Мөхәммәтшин.

БОКСИТ *и.* Составында төп өлеше алюминий гидроокисе булган тау токымы.

БОЛАГАЙ *с. диал.* Тәртипсез, әдәпсез, урынсыз шаяртучан, кыланчык.

БОЛАГАЙЛАНУ *ф. диал.* Кылану, тәртипсезләнү, әдәпсезләнү, урынсыз шаяру. *Кәрим (сузып, сыер мөгрәгән аваз белән болагайланып): — Әби өйдәмәүү?! — [диде].* Г. Камал.

БОЛАЙ *а.* 1. Бу рәвештә, шулай, шушы рәвешле. *Менә Кабан күлендә болай йөзәләр,— дип колачлап йөзмәкче булган иде дә, ерак бара алмады, аяк тибеп кенә йөзеп китте.* М. Гали.

2. *рәв. мәгъ.* Яхшы, яхшырак, артык, артыграк. *Хатын-кызны әйтмисең дә инде. Ирләрдән дә болайрак эшлиләр.* Р. Ишморат. *Исәнбайның Федяга булган дуслык тойгылары ашып китте һәм, кичәгедән болай дәртләнеп, кураен тартып җибәрде.* М. Шабай. / *с. мәгъ.— Тәртә, имеш, тәртә сындырган, тәртәдән болайрак дәүләт бирдем мин аңа [Хафиз байга], сәламәтлегемне бирдем. Менә мин үзем сындым.* Э. Фәйзи. / *и. мәгъ. Карт, --- әгәр Садыйк каты бәйләнә башласа, --- «Көчең белән бик масайма, сәвит синнән болайракларны да бөгеп салды» дип, каршы талашырга исәпләп куйды.* Г. Ибраһимов.

3. *кер. сүз функ.* Беренче карашта, тыштан караганда. *Үзе матур, Үзе сөйкемле, Үзе усал, Үзе болай бер дә Усал түгел кебек шикелле.* Һ. Такташ. *Болай һиммәтчел кеше инде үзе.* Э. Фәйзи. // Гадәттә. *Без сине болай көн саен тыңлыйбыз.* И. Гази.

4. *кис. функ.* Сон.— *Әйе, дим, Тукай булам мин, сез үзегез кем болай?* Н. Исәнбәт.

◇ **Болай гына** — бернинди максатсыз, гадәттәгечә, уйламыйча гына.— *Юк, Харрас, болай гына әйттем, моннан соң телемә дә алмам.* Ә. Айдар. *Карл Федорович бик кәефләнеп: — Дөрестән дә, бу мәҗлестә болай гына утыру килешми икән [диде].* М. Гали. *Әллә мине танып, болай гына Елмаясың үтеп барышлый.* Һ. Такташ. **Болайга китү (борылу)** — эш-хәлнең көтелмәгән якка үзгәрүе турында. *Шулай диде дә, эшнең болайга борылуына гаҗәпләнеп, нидер әйтергә җыенгандай, урыннан кузгала башлаган кунак хатынга борылды.* Г. Бәширов. **Болай да** — аннан башка да. *Аның пульсы болай да бик начар,— диде [Җамали].* М. Гали. *Галәү бабай болай да кечкенә күзләрен кечерәйтә төшеп, озын буылыга карап торды.* Г. Тобәй.

БОЛАК *и. иск.* Инеш. *Якында бер болак бар иде, суы салкын.* Дәрдмәнд. *Алар [елкычылар] малайны күтәреп якындагы болакка алып барып юындырдылар, исенә китерделәр, кымыз эчерделәр.* Каз. утл.

БОЛАМЫК *и.* 1. Онны суга яки сөткә болгатып пешерелгән ярым сыек ашамлык. *Боламыкка май кирәк, һәр нәрсәгә җай кирәк.* Мәкаль. // *диал.* Бәрәңгене суга яки сөткә изеп әзерләнгән ашамлык, бәрәңге измәсе. *Бәрәңге боламыгы.*

2. *күч.* Җебегән, булдыксыз кеше турында.— *Шул инде, ни ир, ни хатын. Бер боламык шунда.* Р. Ишморат.

◇ **Боламыкка әйләнү (әверелү)** — 1) явым-төшемнән соң балчык, туфракның һ. б. ш. үзле бер масса хәленә килүе. *[Бригадир]боламыкка әверелгән урам пычрагын ера-ера колхоз ашханәсенә барып килде.* Каз. утл.; 2) буталу, чуалу, тәртипсезләнү, тәртибе бетү. *Элек мәсьәләнең беренче өлешен чишкәннән соң, икенче өлешен чишү бик күп җиңелгәр дип беләм. Юкса, икенче өлеше дә бергә буталып, боламыкка әйләнүе мөмкин.* Ш. Камал.

БОЛАН *и.* Мөгезе тармакланып торган партояклы имезүче хайван. *Болан асраучылык хуҗалыгы.* □ *Тыныч төнгә күмелеп урман йоклый, ак боланнар, йөгрек куяннар.* Ш. Маннур. // *с. мәгъ.* Болан тиресеннән эшләнгән, тегелгән. *Садыйк карт, юрган кисәге өстенә утырып, болан бияләйләрне өстәл кырыена куйды.* Ш. Камал.

Болан мүге *бот.*— Төньякта боланнар ашый торган аксыл сары мүк — үсемлек.

БОЛАНЧЫЛЫК *и.* Болан асраучылык.

БОЛАР *күрс. а.* Якында булган берничә яки күп кешеләргә, әйберләргә күрсәтеп сөйләгәндә кулланыла («бу» алмашлыгының күплеге). *Ә менә болары эшче абыйларың, эшче апаларың.* А. Алиш. *Болар мине никтер яраталар, күңелемне күтәрергә тырышалар, шаярталар.* Г. Ибраһимов.

БОЛВА'НКА *и. техн.* Чимал буларак әзерләнгән чүен яки корыч коелма, бүкән.

БОЛГАВЫР *с. диал.* Буталчык, болганчык, ыгы-зыгылы. *Болгавыр вакыт. Болгавыр юл.* □ *Ичмаса, замананың да бик болгавыр чагы.* Каз. утл. *Сугыштан соңгы болгавыр чаклар булгангамы, Гәрәй туган авылына бер-ике хат язып салса да, җавап ала алмый.* Г. Мөхәммәтшин.

БОЛГАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* болгау (1 мәгъ.). *Яулык парадларда җилгә каршы бөтерелә торган байракларның берсе шикелле болгана.* А. Алиш.

2. Болганчык хәлгә килү, тоныклану, ком, ләм һ. б. ш. белән катнашу, аралашу. *Болганып каралган [елганың] көмештәй саф суы.* М. Җәлил. *Суга барсаң бар иртәрәк, Соңга калсаң болгана.* Җыр.

3. Тәртипсез аралашу, чуалу, буталу. *Күк йөзен томалап өлгергән каракучкыл болытлар, тау-тау булып, берсе өстенә берсе актарылды, болганып, кайнашырга тотынды.* Г. Бәширов. *Атлар килде ат өстенә, бар да бергә болганды.* Н. Исәнбәт.

4. Арлы-бирле килү, ике арада аптырап йөрү.— *Кайчанга кадәр үзеңә үзең хуҗа була алмый ике уртада болганырсың.* М. Фәйзи.

5. *күч.* Төрле тәртипсезлекләр, ыгы-зыгылар, ризасызлыклар туу, чуалыш барлыкка килү. *Күл болганыр, бер тонар, ил болганыр, бер тынар.* Н. Исәнбәт.

БОЛГАНЧЫК *с.* 1. Ләм, ком һ. б. ш. белән катнашкан, болганган, үтә күренмәлелеген югалткан (сыеклык турында). *Болганчык күл.* □ *Урам буенча болганчык сулар йөгерде.* И. Гази.

2. *күч.* Буталчык, чуалчык, тәртипсез, ыгы-зыгылы. *Болганчык заман. Болганчык чор.* □ *Хәсәнгә булган шул якгы тойгыга заман һәм тормышның иң болганчык шартлары да кер кундыра алмыйлар.* К. Нәҗми.

// и. мәгъ. иск. Ызгыш, бәхәс. *Кайвакытта мәмләкәттә болганчык вә фетнәләр булса, бу татулык сөючән, тирән гакыллы картны хәлифә дә киңәшкә чакыра иде.* Г. Тукай.

◇ **Болганчык суда балык тоту** — болганчык вакыттан, обстановканың билгесезлегеннән шәхси максатлар өчен файдаланып калу.

БОЛГАНЧЫКЛАНУ *ф. к.* болгану 2. *Кайчан да булса, елга болганып, болганчыкланып китәр дип, Исмәгыйль уйлый иде.* Г. Тукай.

БОЛГАНЫШ *и.* Чуалыш, кузгалыш.

БОЛГАНЫШУ *ф.* Буталышу, ыгы-зыгы килү, тәртипсезләнү. *Махночылар бераз исләренә килмичәрәк тордылар да, аннары төркем кинәт чайкалып китте, кайнаша, болганыша, кычкыра башладылар.* Г. Бәширов.

БОЛГАР I *и.* 1. Урта Идел, шул исәптән хәзерге Татарстан территориясендә X гасыр башларында төзелеп, XIII гасыр урталарына кадәр яшәгән дәүләт. *Идел буе Болгар дәүләтенең халкы нигездә игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә.* Татарстан АССР тарихы. // Шул дәүләттә яшәгән һәм төрки телләр группасыннан булган халык. *Бабаларыбыз болгардан һичбер әдәби, гыйльми әсәр безгә ирешмәгән.* Г. Ибраһимов. [*Муса Габидуллинга карап:*] *«Чын болгар тибы икән...» дип уйлады.* Ш. Маннур. // *с. мәгъ.* Шул дәүләткә караган, составына кергән. *Мәгърур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары - - - беттеләр.* Г. Тукай. *Болгар хәрабәләренә карата озын тарихи фәлсәфәләр [бар].* Г. Нигъмәти.

2. Көньяк славяннар группасыннан булган, Болгарыядә яшәүче халык. *Машинада руслар гына түгел, немецлар да, болгарлар да бар иде.* Г. Гобәй.

БОЛГАР II *и.* Элек болгарлар тарафыннан эшкәртелгән кызыл күн. *Аягыңдагы читегең болгар икән олтаны.* Жыр. / *с. мәгъ. Болгар читек, сауры башмак, Синдер кызның солтаны.* Н. Исәнбәт.

БОЛГАРИ *с. иск.* «Болгарныкы» мәгънәсендә.

БОЛГАТКЫЧ *и.* Сыек яки тарала, изелә торган нәрсәләрне аралаштырып болгату коралы, таяк (мәсәлән, терлекләргә башак болгата торган).

БОЛГАТУ *ф.* 1. Сыеклыкны яки чәчелә һәм коела торган башка әйберләрне берәр нәрсә ярдәмендә катнаштыру, туглау. *Башак болгату.* ▭ *Ул [Габдулла] ишек алдын себерде, кош-кортка җим болгатып бирде.* Ә. Фәйзи. // Бер төрдәге әйберләрне аралаштыру. *Саимә мичтәге йомычкаларны болгат[а].* К. Нәжми. // сөйл. Пешерү.— *Хәзер сыер бозауламаган әле — сөт, катык юк. Боламык кына болгатырсың алайса, карчык.* М. Гали.

2. Тәртибен чуалту, аңлаешсыз итү.— *Барыгыз да бердән сөйләп, болгатмагыз.* Г. Коләхметов.— *Эшне үзең болгаттың, үзең очла!* М. Фәйзи.

3. Котырту, тәртипсезлек тудыру, гауга, тавыш чыгару.— *Атаң мәрхүмнең дә шулай, туфрагы җиңел булсын, дөньяны болгатып гомере үткән иде.* Р. Ишморат. *Бөтен авылны шул Якуб зимагур болгатып ята.* И. Гази.

БОЛГАУ *ф.* 1. Берәр нәрсәне һавада әрле-бирле әйләндерү, селкү, айкау, чайкау. *Яулык болгау. Кул болгау.* ▭ *[Генерал] үзе кылыч болгап килсә дә курыкмыйм.* И. Гази. *Әптелбәр гарьсенеп китте, ахры, Габдулланың башыннан кәләпүшен тартып алды да, аны өй түбәсенә ыргытырга җыенып, болгый башлады.* Ә. Фәйзи. [*Төлке*] *көлтәдәй койрыгын болгап тора, елмайган килеш, татлы сүзләрен яудырырга тотына.* А. Алиш.

2. *диал. к.* болгату 1. *Бәдри самовар эченә чыбык тыгып болгый.* М. Гафури.

БОЛДЫР *и. диал.* Өйалды баскычы. *Аяк тавышы баскычлардан басып болдырга күтәрелде, аннары тышкы ишекнең шыгырдап ачылуы ишетелде.* Г. Минский.

БОЛТ *и.* Бер башы эшләпәле, икенче башы гайка борып кертү өчен сырлап ясалган төрле зурлыктагы металл кадак (төрле корылмаларның, машиналарның аерым өлешләрен, детальләрен беркетү өчен хезмәт итә). *Болтның сырлары тузу. Терәкләрне болтлар белән беркетү.*

БОЛЫН *и.* Чабулык яки көтүлек җир. *Идел болыннарының иге дә, чиге дә юк, алар тугайларга сыеша алмыйча, тыгылышып утыралар.* Г. Бәширов. *Болыннарда көтү көткән чакта Уйлар белән бергә йөрдем мин.* Ә. Еникәй.

БОЛЫНЛЫК *и. к.* болын. *Уңдарак үләне чабып алынган болынлыкта көтү йөри.* Г. Әпсәләмов.

БОЛЫНЧЫ *и.* Болында эшләүче, печән чабучы. *Кәҗә салам кисәкләре ябышкан сакалын селкә-селкә ялкау гына урамга — болынчылардан коелып калган печән кыякларын чүпләргә чыгып китте.* И. Гази.

БОЛЫТ I *и.* 1. Атмосфераның югары катлауларында куерган су парларының (яңгыр, кар һәм бозның) тыгыз томан рәвешендәге массасы. *Озак та очмадык, куе томан, яңгыр болытлары безне чолгап ала башлады.* Т. Гыйззәт. *Күктәге болытлар түбәнәя төшеп, бияләйбияләй кар да ява башлаган иде.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Зур күңелсезлек, бәхетсезлек, куркыныч турында. *Бәхетләре елдан-ел үсә барды, ләкин якты көннәрен бер кара болыт каплады: хатынның баласы булмады.* Г. Ибраһимов. *Ленинград күген дәһшәтле үлем болыты каплап алды.* Г. Гобәй.

БОЛЫТ II *и.* 1. Күп күзәнәкләләр семьялыгыннан түбән төзелешле хәрәкәтсез диңгез хайваны. *Диңгезләр төбеннән болыт (губка) һәм матур кабырчыклар чыгарыла.* Физ. геогр. 2. Шул хайванның мунчала итеп файдаланыла торган үле гәүдәсе. // Шуңа охшатып резинадан яки синтетик материалдан эшләнгән, суны үзенә жыя торган мунчала.

БОЛЫТЛАНУ *ф.* 1. *сөйл. к.* болытлау. *Көн болытланып тора.*

2. *күч.* Томанлану, караңгылану.

БОЛЫТЛАУ *ф.* 1. Болыт белән каплану, болыт җыелу (һава торышы турында). *Мәликә тәрәзәдән карый да: — Көннәр дә болытлап тора, бүген бармасаң да ярар, кызым,— ди.* А. Шамов.

2. *күч.* Борчылу.— *Күңел борчыламыни? — дип сорады Гали абый.— Әзрәк болытлап тора шул.* Г. Әпсәләмов.

БОЛЫТЛЫ *с.* 1. Болыт белән капланган, болыт җыелган (күк йөзе, һава торышы турында). *Болытлы көн.* ▭ *Майның әүвәлге ике атнасы болытлы, яңгырлы булды.* Г. Ибраһимов. *Аяк асты нык катырмаган, һава болытлы, җепшек, тәрәзәләрдә утлар сирәкләнгән иде.* Ш. Камал.

2. *күч.* Күңелсез, кәефсез, ачулы. *Көнгә унбиш тапкыр кояшлы син, Көнгә унбиш тапкыр болытлы.* Каз. утл.

БОЛЬНИ'ЦА *и.* Авыруларны савыкканга кадәр үзендә тотып дәвалый торган учреждение. *Район врачы, Тимеринең үпкәсенә бик яман салкын тидеруен әйтеп, шул төнне үк үзе белән больницага алып китте.* Г. Бәширов. *Якуб - - - яралыларны больницага салырга ярдәм итеште.* И. Гази.

БОЛЬШЕВИЗМ *и.* Революцион пролетар хәрәкәтенә һәм капиталистик жәмгыятьне коммунистик жәмгыятькә революцион юл белән үзгәртеп кору турында рус һәм халыкара эшчеләр сыйныфының көрәше тәҗрибәсенә нигезләнеп, Ленин тарафыннан эшләнгән теория һәм тактика. *Большевизм халыкара эшчеләр хәрәкәтендә иң революцион - - - юнәлеш булды.* КПСС тарихы. *Без большевизм юлы белән барабыз, һәм нинди юл белән баруыбызны яшермибез.* М. Гафури.

БОЛЬШЕВИК *и.* Большевиклар партиясе члены (башта 1903 елда Россия социал-демократик эшчеләр партиясенең II съездында В. И. Ленин җитәкчелегендә барлыкка килгән революцион күпчелек члены); большевизм тарафдары, коммунист. *Большевиклар менә шулай алар, Могҗизалар ясый куллары. Шуның өчен алар большевиклар, Шуның өчен — Ленин уллары!* Ш. Маннур. *Йөрәгенең бөтен ялкынын, бөтен сәләтен революция юлына биргән Дзержинский кебек батыр йөрәкле революционерлар, я булмаса үзебезнең Сәрьян абыйлардай ныk большевиклар искә төшә.* Г. Бәширов.

БОЛЬШЕВИКЛАШТЫРУ *ф.* Большевик итү, большевикларча караш тәрбияләү.

БОЛЬШЕВИКЛАШУ *ф.* Большевик булу, большевиклар ягына күчү, большевизм тарафдары булып китү. *Советларның бик тиз большевиклашу процессы башланды.* КПСС тарихы. *Фронттан кайтучы казачийларның бик күбесе большевиклашып кайталар.* Ш. Камал.

БОЛЬШЕВИКЛЫК *и.* Большевик булу хәле.

БОЛЬШЕВИКЧЫЛ *с. к.* большевистик. *Без бу язда сиздек колхозчыда Большевикчыл хиснең кабынуын.* М. Җәлил.

БОЛЬШЕВИ'СТИК *с.* Большевикларга хас булган; большевизм принципларына нигезләнгән, большевизмга караган. *Большевистик тәнкыйть.* □ *Большевистик газеталарда эшләү һәм революция дошманнарына каршы сатирик шигырьләр язу белән бергә, ул татар совет театрын үстерү эшенә дә актив катнашты.* М. Гали.

БО'МБА *и.* Эченә шартлаучан матдәләр тутырылган корыч тышлы снаряд. *Фашистларның хәзер баш очында Бомба булып җырым ярылсын.* М. Җәлил.

Бомбага тоту — *к.* бомбалау. *Олауларга утырып Ладога аша чыгып барганда, (эвакуацияләнүче балаларны) Гитлер козгыннары бомбага тотканнар.* Г. Гобәй.

БОМБАЛАУ *ф.* Бомба ташлап шартлату, җимерү.

БОМБАРДИР *и. иск.* Патша армиясендә һәм флотында артиллерист солдат. [*Серебряков*] *Кара диңгез флотында бомбардир булып хезмәт иткән.* И. Гази.

БОМБАРДИРО'ВЩИК *и. хәрби.* 1. Дошман объектларын бомбага тоту өчен билгеләнгән сугыш самолеты. *Йолдызлы күк йөзе буйлап, бик югарыдан, төнге бомбардировщиклар үтеп китәләр.* Г. Әпсәләмов.

2. Бомбардировщиклар авиациясендә хезмәт итүче очучы. *Ул да очучы, тик истребитель түгел, бомбардировщик.* С. Баттал.

БОМБОВОЗ *и. к.* бомбардировщик. *Биш чакрымнар чамасы биектән алты бомбовоз килә иде... Арттагы бомбовозның койрыгыннан күккә таба кара төтен сузыла башлады.* Ш. Маннур.

БОМБОУБЕ'ЖИЩЕ *и.* Бомба һәм артиллерия снарядларыннан саклану өчен махсус җиһазландырылган корылма. *Укытучы --- балаларга дәресләрнең вакытлыча өзелеп торуы турында белдерде һәм барына да бомбоубежищега төшәргә кушты.* Г. Гобәй.

БО'НА *и. тар.* Гадәттә аерым урыннарда вакытлыча чыгарылган һәртөрле кәгазь акчалар.— *Күпме тора соң ул бона дигәннәре? — Төрлечә була,— ...алтын исәбе белән бер сумлык бонаны бүген 37 сумнан саталар иде.* С. Әдһәмова.

БОР I *и. хим.* Күп кенә минералларның составына керә торган химик элемент. *Туфракта бор җитешмәсә, үсемлекләрнең үсү ноктaлары корый.* Химия.

БОР II *и.* Теш дәвалау эшендә кулланыла торган корыч боргу, кыргыч.

БОРАЙ *и.* 1. Бөртекле ашлык үсемлеге, бодайның бер төре. *Күз алдымда борай дулкыннары, Арыш серкәләре уйныйлар.* Ш. Маннур.

2. Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. *Мин авылга кайтып төшкәндә, солы, борайны чәчеп бетергән, тары, карабодайга яңа чыкканнар гына иде әле.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Борай бөртегеннән эзерләнгән. *Борай өйрәсе. Борай боткасы.* □ [*Ярма яргыч*] *ике бүлектән гыйбарәт булып, бер бүлегендә солы, борай, карабодай ярмалары, икенче бүлегендә тары ярыла икән.* М. Гали. [*Абыстай сәдака китергән кызга:*] *— Әниеңә әйт, моннан соң борчак оны җибәрмәсен. Борай оны яисә акча алып кил, сез бит әүкатьле кешеләр.* Т. Гыйззәт. // *с. мәгъ.* Борай онының эзерләнгән. *Борай күмәче. Борай коймагы.*

БОРАУ *и.* 1. Бер ноктада бора-бора агачка, тимергә һ. б. ш. га тишек ясый торган корал. *Аның [Акмелланың] --- арбасы өч кисәккә бүленгән булып, ул боларның берсенә балта, пычкы, борау кеби кораллар тутырып --- йөри икән.* Ж. Вәлиди.

2. Скважиналар тишкәндә кулланыла торган машина. *Җиргә борауны батырганчы, буровойның үзен төзитөзи дә өч-дүрт ай чиләнергә туры килә безнең якташларга.* Ә. Маликов.

БОРАУЛАУ *ф.* 1. Берәр нәрсәгә борау белән тишек ясау.

2. Тау токымнарында, грунтта тирән тишекләр, скважиналар тишү. *Яңа бригада --- үзе бораулаган беренче нефть скважинасын ташлап китәргә теләмичә, буровой янында бик озак шаулаштылар.* Г. Ахунов.— *Тиздән без җирне бораулый башлаячакбыз.* А. Әхмәт.

3. *и. мәгъ.* Бораулау эше. *Бораулауны дәвам итәргә.* □ [*Газиз:*] *Ул миңа җирне тизләтелгән метод белән бораулау турында киңәшләр бирде.* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Бораулау эшенә караган. *Бораулау конторасы. Бораулау планы.*

4. *күч.* Тынычсызлау, борчу. *Юлда Җамалыйның миен бернәрсә һаман бораулап барды.* Г. Ибраһимов. // Бик нык сынап карау, зур игътибар белән, тикәлеп карау турында. *Күзләре белән бораулау.* □ *Урамында да кеше күзенә күренерлек түгел иде: һәммәсе яндырып, бораулап карый сыман.* Э. Касыймов.

БОРАУЛАУЧЫ *и.* Скважиналар бораулаучы эшче. *Һөнәрем буенча мин бораулаучы [диде Исхак], җир байлыгын ачучы — разведчик.* Ә. Маликов.

БОРГАЛАНА-СЫРГАЛАНА, БОРГАЛАНЫП-СЫРГАЛАНЫП *рәв.* 1. Төрле юнәлештәге, бормалы сызык буенча (хәрәкәт итү турында). [*Ярларга*] *сыенып, боргалана-сыргалана тар гына су ага.* И. Гази. *Көмеш тасма кебек боргаланып-сыргаланып агучы Мүлем елгасының --- гүзәллегенә сокланып, гаҗәп-хәйран буласың.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Гәүдәне төрле якка боргалап, сыгылдырып. *«Тәңкә» өрүеннән туктады һәм боргалана-сыргалана Мәдинә янына килде.* Ш. Камал.

БОРГАЛАНУ *ф.* 1. Әле бер якка, әле икенче якка борылу, борылгалау; төрле якка хәрәкәт итү. *Танк боргаланган арада Бәрә төзәп бензин багына.* Ф. Кәрим. *Әмма яз дәрте белән җиңеләйгән атлар, кызларны санламыйча, боргалана һәм киреләнәләр, тырмалар әрлебирле сикергәли иде.* Г. Бәширов.

2. Гәүдә белән сыгылмалы хәрәкәтләр ясап як-якка борылу. *Боргаланып йөргән булып, Кызлар үзе сөйдерә.* Г. Тукай.

3. *рәв. мәгъ.* Боргаланып, борыла-борыла, бормалы сызык ясап, бормалап. *Карлы таулар буйлап калын состав Боргаланып алга сузылды.* М. Җәлил. *Ул арада --- моржадан күңелле боргаланып ак төтен күтәрелде.* И. Гази.

4. Назлану, иркәләнү, кыланчыклану. *Иркә малай үзенең ятлап алган җавабын берьюлы гына әйтми, боргаланып тора яки кыланып берәр тозсыз җавап кайтара иде.* Ә. Фәйзи.

5. *күч.* Фикерен ачыктан-ачык әйтмәү, хәйләләү. *Корбут чыгып басты трибунага, Тирән итеп ала сулышын, Боргалана, үзе сыргалана, Юха елан кебек кылана.* Н. Баян.— *Боргаланмый гына җавап бирегез: сез үзе-*

гез өчен акларнымы, кызылларнымы файдалы дип уйлыйсыз? Ш. Камал.

БОРГАЛАП-СЫРГАЛАП *рәв.* Боргалап, борма сызыклар ясап (язу турында). *Кара ничек итеп боргалап-сыргалап язган.* Р. Ишморат. // *күч.* Читләтеп, ераклаштырып, киная белән (сөйләү турында). *Боргалап-сыргалап тормыйча, авылча итеп туп-туры гына әйт тә, вәссәлам.* А. Әхмәт.

БОРГАЛАУ *ф.* **1.** Берәр нәрсәне төрле якларга әйләндерү, хәрәкәтләндерү. *Кемдер мандолин колагын боргалый.* Э. Ерикәй. *Полк командиры биноклен күзенә куйды, аны боргаларга тотынды.* А. Шамов.

2. *рәв. мәгъ.* Бормалы итеп, бормалап. *«Имза «М» хәрефе, тагын «А» га башланган ниндидер фамилиядән гыйбарәт булып, танырлык түгел, бик боргалап язылган иде.* Г. Гобәй. *Ал күлмәгеңнең якасын Кем каеган боргалап.* Җыр. // *күч.* Сүзне турыдан-туры әйтмичә, читләтеп, киная белән (сөйләү турында). *Гыйльми карчык, бер яктан, безнең өй кешеләренең күңелләрен табар өчен сүзләрен боргалап сөйләсә, икенче яктан, --- бу турыдагы сүзләрне төрле кешеләр авызыннан мең төрле иттереп күчерә --- иде.* М. Гафури.

БОРГЫ *и. к.* бырсгы. *Җиңү дәрте белән Кычкырттылар көрәш боргысын.* М. Җәлил. *Янгын боргысы* [*кычкырта*] *трат-та-та.* Н. Исәнбәт.

БОРГЫЧ *и.* Нәрсәне дә булса борып, ныгытып куя торган корал, жайланма. *Сабир бабай ишек башына кыстырып куелган боргычны, сузылып алып, Газинурга ташлады.* Г. Әпсәләмов.

Боргыч таягы — туку станында тукылган әйбер чорналган агачны беркетеп тора торган деталь.

БОРГЫЧЛАУ *ф.* **1.** Боргыч белән борып, ныгытып кую.

2. Нәрсәне дә булса (бау, чылбыр һ. б. ш. белән) ычкынмаслык итеп бәйләп, урап яки чорнап кую. [*Газинур*] *ярсыган атны, ниһаять, җиңде һәм аның иренен ныклап итеп боргычлап куйды.* Г. Әпсәләмов. *Ул тегермәнгә якын әрәмәлектә корзинка үрергә дип кискән тал чыбыкларын бәйләп маташканда, берәү --- елан төсле сүс бауны кинәт аның муенына салып, зур көч белән боргычлап кысып алды.* Ш. Камал.

3. *күч.* Кулда ныклы (каты) тоту, үзиреклелеккә, башбаштаклыкка юл куймау, үзенә буйсындыру. *Ә менә* [*безнең байларның*] *--- хатыннары --- ирләренең муеннарына тәмам менеп атланганнар да, ирләрен авызлыклап, боргычлап алганнар.* Г. Камал. // Ныгыту. *Дисциплинаны яман боргычладылар, өйрәнүләр кызганнан-кыза, көне-төне киңәшмә, утырыш.* И. Гази. // Зур таләпләр кую, артык власть күрсәтү. *Әйе! Заманында артыграк боргычлап ташлаган идем шул.* М. Хәсәнов. // Авырттыру. *Чигәсен боргычлап уй артыннан уй туды.* Г. Минский.

БОРГЫЧЛЫ: боргычлы борау. Кул белән әйләндереп тишек тишә торган корал. *Русчасы:* коловорот.

БОРДЮР *и.* Тукыма һәм обой кырыйларындагы юл бизәк, кайма. // Түшәм һәм стена кырыйларына төшерелгән бизәкләр.

БОРЖОМ *и.* Дәвалану максаты белән кулланыла торган минераль су (Грузиядә шул су чыганаклары булган курорт исеменнән).

БОРЛЫГУ *ф.* **1.** *диал.* Борчылу, көенү; тынычсызлану. *Гарьсенәм дә, борлыгам да Керәмен өйгә: Меңенче кат сорау белән Карыйм әтигә.* Ш. Маннур.

2. Быгырдау, быгыр-быгыр итү (килү). [*Пәхри*] *көлеп тә җибәрде, авызына су да борлыгып керде.* Х. Җәмил.

БОРМА *и.* Дугасыман кәкре бөгелеш, борылма. *Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт бер борма ясап, авылның эченә керә язып кала.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Бормалы, борылмалары булган. *Борма елга суын эчеп Су буенда тал үсә.* Ә. Ерикәй. *Хәйретдин --- борма-борма баскычлар менеп киткән биек кенә кызыл таугa* [*күрсәтә*]. М. Гали.

БОРМАЛАНУ *ф.* Борылмалы булу, борма-борма булу, борма формасын алу. *Уңдарак, зәңгәрсу төскә буялган рәшәткәләр артыннан, бормаланып асфальт юл үтә.* Р. Ишморат.

БОРМАЛАУ *ф.* Бормалар ясау, бормалы итү.

БОРМАЛЫ *с.* **1.** Борылмалы; бормалары, борылмалары булган. *Бормалы баскыч.* □ *Машина --- авыл арасыннан бормалы шоссе юлына килеп чыкты.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *күч.* Кинаяле, читләтеп әйтелгән. [*Мостафаның*] *җиңел, уен-көлке һәм нечкә бормалы сүзләр сөйләргә сәләте бик чамалы.* Ш. Камал.

3. Бизәкле, катлаулы.— *Ни дим? Хәй, өйрәт безне бормалырак итеп* [*җырларга*]. М. Фәйзи.

БОРНАЙ *с. диал.* Талымчан, нәзберек, сайлана торган. *Борнай кеше.* □ *Элек тә борнай иде, инде булыр сорнай.* Мәкаль.

БОРНАУ *ф. к.* борынлау (1, 2 мәгъ.). *Каз күкәе борнау. Чебеш борнау.* □ [*Орлыклар*] *бер-бер артлы борнап, Мул игеннәр булып үссеннәр.* Б. Рәхмәт.

БОРОВИ'НКА *и.* Алмагач сорты һәм аның алмасы. *Бераздан --- зур, түгәрәк һәм каты боровинкалар, кара орлыклары үтәли күренеп тора торган ак алмалар, хуш исле саргылт антоновкалар сорты-сорты белән алмагач төпләренә өелде.* И. Гази.

БОРСАЛАНУ *ф. диал.* Тынычсызлану, борчылу. *Сафиулла абзый төн буе йокламый борсаланып чыга.* Ш. Бикчурин.

БОРТ *и.* **1.** Корабль һәм судноларда ян стеналарның югарыгы кырые яки судноның ян яклары. // Корабль һәм судноларда палуба. *Зур хәрәкәт сизелә тыныч барган кораб бортында.* Ә. Исхак. *Аюны корабның бортына алалар.* А. Алиш.

2. Йөк машинасы кузовының, ачык өсле товар вагоннарының ян як стеналары. *Бортлары ачып куелган йөк машинасы китәргә әзер булып тора.* Г. Ахунов.

БОРТАК *с.* Сак тота белүче, хәстәрле. *Бортак хатын йорт тотар.* Мәкаль.

БОРТМЕХА'НИК *и.* Очучылар экипажы члены — самолет, дирижабль моторы, җиһазлары, аппараты һәм приборлары эше өчен җаваплы кеше. *Ә минем эти --- хәзер сугышта әле — бортмеханик.* Г. Гобәй.

БОРУ I *ф.* **1.** Берәр әйберне әйләнә юнәлешендә хәрәкәткә китерү, торышын үзгәртү.— *Тукта әле, нигә син ул гайкаларны борасың?* Т. Гыйззәт. *Гөлсем моторының кай төшендер борды.* Г. Бәширов. // Авырттыру. *Кулын бору. Колагын бору. Койрыгын бору.*

2. Хәрәкәт юнәлешен үзгәртү, икенче юнәлеш белән хәрәкәт иттерү. *Илсөяр көймәне зәңгәр маякка таба борды.* Г. Гобәй. *Аларның берсе атын кырт борды да, шпор белән кызулап, күрше авыл юлына кереп китте.* И. Гази. // *күч.* Ижтимагый үсеш, хәрәкәт һ. б. ш. га икенче юнәлеш бирү, эчтәлеген үзгәртү.— *Никадәр көч куйсагыз да, тарихны бора алмассыз!* Ә. Исхак.

3. Бөтерү (мыекны). [*Купшы егет*], *--- зур мыекларын ике якка борып, хахылдап көлде.* Г. Ибраһимов. // *диал.* Бөтерү, урау, төрү (мәсәлән, тәмәке). *Махра борып икәү сөйли торгач, Колхоз хәбәрләрен сораштым.* Һ. Такташ.

4. Игътибарны читкә юнәлтү өчен сүз яки фикернең темасын үзгәртү, алмаштыру, икенчегә күчерү. *Ахырда ул, сүзне икенчегә борырга телэп, --- Галимулла турында яңадан сорашырга тотынды.* А. Шамов. *Гафият мәсьәләне уенга борырга тырышты.* И. Гази.

БОРУ II *с. сөйл.* Кәкре, борылган, борылмалы. *Берәр сарыкны сатсак инде — шунсыз булмый, улым,— теге бору мөгезлене.* Г. Гобәй.

БОРЧА *и.* **1.** Кан суырып тукланучы вак паразит

бөҗәк.— *Кандалалар белән борчалар үзен үрле-кырлы сикертәләр бугай.* Г. Камал.

2. *күч.* Җитез, артык хәрәкәтчел (кеше турында). — *Ә бу борчалар? Ни эшләп йөриләр? — Кызык күреп йөриләр.* Г. Гобәй.

◇ **Борча ашау, борча керү** — тынычсызлау, борчу. *Башка һичбер кешенең дә җаннарын борча ашамый.* Ш. Камал.

БОРЧАК *и.* **1.** Кырда (яки бакчада) үстерелә торган кузаклы ашлык үсемлеге. *Борчак кузагы. Борчак саламы. Борчак чабу.* □ *Арпабыз баш ташларга тора, борчак та өлгергән - - -.* Г. Бәширов. *Яңа гына чыгып килә торган борчак кебек үсемлекләрнең өшеп юкка чыгу куркынычы бар.* А. Алиш.

2. Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. *Борчак тиз куырылды, кәләпүшләргә тутырып алдык та - - - арбага, яшел печән өстенә атланып утырдык.* Г. Ибраһимов. *Борчак белән солыны бергә кушып чәчәргә кирәк.* Э. Еники. // *с. мәгъ.* Борчак бөртекләреннән әзерләнгән. *Борчак шулпасы.* □ — *Әниеңә әйт, моннан соң борчак оны җибәрмәсен.* Т. Гыйззәт. *Анда боларга - - - киндер мае салган борчак боткасы бирделәр.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Борчак оныннан әзерләнгән. *Борчак коймагы.* □ *Җыелыш бетүгә вожатыйлары, өйләренә алып кайтып, борчак чумары белән сыйлады.* Г. Гобәй.

◇ **Борчак кадәр (хәтле)** — вак, кечкенә. *Утте гомерем, белмәдем мин Бер матур айны; Борчак хәтле шатлык булса, Тау хәтле кайгы...* Ш. Маннур. **Борчак пешмәү** — килешмәү, уртак фикергә килә алмау, тату булмау. *Шәмгун карт - - - яшь егет белән председательнең борчаклары пешеп җитмәгәнен сизеп алды.* А. Шамов. **Борчак сибү, чәчү** — 1) ялганлап, арттырып сөйләү, шапырыну. *Илгиз былтыр үзенең сабан туен кайда, ничек каршылавы турында борчак чәчәргә тотынды.* Н. Фәттах; 2) файдасызга сөйләү (сүзне тыңламау, кабул итмәү турында). *Нәрсә генә сөйләсә дә, стенага борчак сибү белән бер буласын аңлый иде ул.* Ш. Камал. **Борчак җәзасы** *иск.*— мәдрәсәләрдә гаепле кешене борчакка бастырып яки тезләндереп тоту җәзасы. — *Ә сиңа, дин сабагын бозуың өчен, борчак җәзасы бирәм.* Т. Гыйззәт.

БОРЧАК-БОРЧАК *с.* Эре-эре (тир тамчылары турында). *Халыкъның борын очында һәм маңгаенда борчак-борчак тир тамчылары ялтырый иде.* Ш. Камал. // Борчак сыман (бизәк турында). *Борчак-борчак бизәкле кофта.*

БОРЧАЛАУ *ф.* Берәр нәрсәдә күп булып борча үрчү.

БОРЧУ *ф.* Тынычсызлау, тынычлыгын бозу, тынычлык, тынгылык бирмәү. *Вөҗдан газабы борчу.* □ *Мине бик күп сораулар кызыксындыра һәм борчый.* М. Җәлил. *Ләкин йөзе шундый тыныч күренсә дә, аның да күңелен борчыган уйлар булган икән.* М. Әмир. // *и. мәгъ.* Тынычсызлык, хафа, мәшәкать. *Элек аны бер генә ай күрмичә яшәргә дә сабыры җитмәс кебек тоелган йөрәк ничә еллык аерылыш газабын, кайгы һәм борчу тулы ялгызлык елларын кичерде.* К. Нәҗми. *Тагын шундый бер күңелсезлек чыкмаса ярый дигән бер борчу аның йөрәгендә бар иде.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Борчылган, борчулы, тынычсыз, хафалы. *Сез һаман да борчу, кайгылы.* Ф. Бурнаш.

◇ **Борчу салу, борчуга салу (төшерү)** — борчылдыру, борчылырга мәҗбүр итү, тынычсызландыру. *Маратның авыруы хакында әйтүең мине бик нык борчуга төшерде.* М. Җәлил. *Гали абзыйның авыруы бөтен «Красногвардееч»ны борчуга салды.* Г. Әпсәләмов. **Борчуга төшү** — борчылу, тынычсызлану, хафалану, борчу хисләре биләп алу. *Салахиев тирән борчуга төште.* Г. Ибһимов.

БОРЧУЛЫ *с.* Хафалы, борчылган, тынычсыз (хәл, халәт, кәеф турында).— *Кешенең борчулы вакытында һаман-һаман килеп йөреп булмый шул.* Г. Камал. *Борчулы уйлар Гришаның да аяк адымнарын кызулаттылар.* А. Әхмәт. // Борчылу, шомлану, дулкынлану белдерә торган (караш, күз турында). *Губернаторның борчулы күз карашы - - - стенадагы портретка төште.* К. Нәҗми. *Ул килгәндә Фәйрүзәнең йөзе борчулы иде.* М. Җәлил.

БОРЧЫЛУ *ф.* Тынычсызлану, кайгыру, хафалану. *Өйгә кайтканнан соң гына ялгышымны сизеп, төн буе диярлек йоклый алмый борчылып яттым.* Ш. Камал. *Синең өчен борчылып тора идем.* Т. Гыйззәт. // *и. мәгъ.* Тынычсызлык, кайгы-хәсрәт, хафа. *Артык борчылу ярамадымы, Габделбәрнең хәле тагын да начарлана төште.* М. Шабай. *Бу эчкерсез ягымлы сүзләрне ишетүгә, Зиннәт бөтен кимсенүләрен, барлык борчылуларын оныты.* Г. Бәширов.

БОРЩ *и.* Чөгендер, кәбестә һәм төрле тәмләткечләр салып пешерелгән аш. *Өйдән - - - тәмле борщ исе килә.* А. Шамов.

БОРЫЛМА *и. к.* борылыш. *Авылыбызны yртылай әйләндереп алган Агыйдел озынайды, борылмалар ешайды.* М. Әмир. // *с. мәгъ.* Борыла торган.

БОРЫЛМА-БОРЫЛМА *с. к.* борылмалы. *Борылма-борылма баскычтан борылып менәр солдатлар.* Г. Тукай.

БОРЫЛМАЛЫ *с.* **1.** Бормалы, борылмалары булган. [*Алар*] *шул таллар арасыннан бара торган борылмалы һәм сикәлтәле юл буйлап киттеләр.* М. Гали.

2. *күч.* Катлаулы, кыен. *Тормыш юлы борылмалы да сырылмалы, кая илтеп чыгарыр ул — алдан әйтүе кыен.* Э. Еники.

БОРЫЛУ *ф.* **1.** Хәрәкәт юнәлешен киregә яки икенче якка үзгәртү. *Җил борылу.* □ *Менә разведчик тагын бераз менде дә болын ягына борыла башлады.* И. Гази. *Арган булуыбызга карамастан, - - - ерак булса да кайту ягына борылдык.* М. Әмир.

2. Икенче якка әйләнү; (баскан, утырган яки яткан хәлдә) гәүдә торышын үзгәртү. *Көймә үзын киткәч, Аля бөтен гәүдәсе белән миңа таба борылды.* Ф. Әмирхан.

3. *ф. Төш. юн. к.* бору (4 мәгъ.). *Искәндәр сүзнең болай кинәт кенә үзенә борылуын көтмәгән иде.* Г. Мөхәммәтшин.

Борылып кайту — чыккан урынга кире кайту.

БОРЫЛЫШ *и.* **1.** Берәр нәрсәнең икенче якка борылган, авышкан, тайпылган урыны; борма. *Урманнан юл белән килеп чыккан турыда Идел зур борылыш ясап ала.* Г. Ибраһимов. *Поезд юл борылышындагы пакгаузларны үзын киткәч, Юныс Вәлишин сәгатенә карап алды да озатучыларга эндәште.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Берәр нәрсәнең барышында, үсешендә, торышында яңа юнәлеш; үзгәреш, күчеш. [*Җырчының*] *менә-менә сулыгып елап җибәрер кебек артык дәрәҗәдә йөрәк дәрте белән тавыш борылышы ясау аркасында Халыкъның тәннәре чымырдап китте.* Ш. Камал. / *с. мәгъ.* Борылыш моменты.

БОРЫН I *и.* **1.** Кеше һәм хайваннар йөзендә сулыш алу һәм ис сизү органы. *Кылыч[ланып] торган озын һәм матур борын да егетнең йөзенә - - - горурлык биреп тора.* Э. Фәйзи. *Сарыклар, басып тораннары да, ятканнары да, борыннарын җиргә төрткәннәр һәм ешеш сулыйлар.* Г. Әпсәләмов.

2. Томшык (кошларда). *Борыны, каз бәпкәсе борыны төсле, сап-сары булып очлаеп тора.* А. Шамов.

3. Судно, пароход, көймә, самолет һ. б. ның алгы өлеше. *Ул арада, - - - Казан ягыннан үткен борыны белән дулкыннарны кистереп, гаскәр төялгән икенче бер пароход килеп чыкты.* Г. Бәширов. *Маякчы хатын көймәнең борынын зур осталык белән агымга кыйгач тотып ишә башлады.* Г. Гобәй. // Нинди дә булса предметның алгы, гадәттә тар, очлаеп торган кырые. *Борыны китек балта.* □ *Ул соскыч борынына бераз ясмык оны элгән иде.* И. Гази.

4. Су һ. б. ш. сыекча салына торган савыт-сабаларда аларны агызу өчен махсус җайланган өлеше, кран. *Чәйнек борыны. Комган борыны.* □ *Самовар борынын үз карамагына алып, сәке йөзлегенә утырган җиңги сүзгә катнашмый.* М. Әмир.

5. *диал.* Аяк киеменең алгы очы, башы. [*Ана*] *чишенмичә йокыга киткән кызының аягындагы борыннары агара башлаган туфлиләрне күргәч гажәпкә калды.* Г. Минский.

6. *күч. ирон.* Зур борынлы кеше, иң беренче булып борыны күзгә ташлана торган кеше.— *Кара әле, Госман, бу борын нигә синең тирәдә бик күп ышкыла?— дип чәнчебрәк сорады.* Г. Ибраһимов.

Борын куышлыгы — борын эчендәге бушлык, пространство. **Борын канатлары, борын яфраклары** — борын тишекләренең як-яктагы тышкы стеналары. *Аның борын канатлары селкенгәләп китә, күзләре ачулы карыйлар иде.* Г. Бәширов. *Мондый җаваптан соң Маликның күзләре акайды, борын яфраклары уйный башлады.* И. Гази. **Борын тәмәкесе** — насвай, исни торган тәмәке. [*Сакчы*] *борын тәмәкесе тарта.* Ф. Бурнаш. **Борын яулыгы** — *к.* кулъяулык. *Ул кеше, әллә кая Идел аръягына карап, аның сүзләренә илтифат итмичә кесәсеннән борын яулыгы алып, - - - бөрчек-бөрчек тирләр чыккан битен җилпи.* М. Гафури.

◇ **Борын (асты) кипмәгән** *кимс.*— берәр эш яки киңәш бирү өчен тәҗрибәсе булмаган яки җитмәгән яшь кеше турында.— *Марат акыллым, кеше көлдереп йөрмә, син бик яшь әле, турысын әйткәндә, борыныңда кипмәгән.* Т. Гыйззәт. **Борын астыннан китү, борын астыннан шудыру** — кемнең дә булса кулына керергә, аңа булырга торган берәр нәрсәне яшертен алу. *Бер зур нефть җирен, инглизләрнең борын астыннан шудырып, Америка капиталистлары сатып алып өлгерделәр.* Ф. Әмирхан. **Борын астыңны (астындагын) бел (тикшер)** — үз гаебеңне бел, үзеңне тикшер. *Борын астындагын белми, ботак башындагын белә.* Мәкаль.— *Халыкның чәч-мыекларын, чапан-чалмаларын тикшергәнче, үзеңнең борын астыңны гына тикшерсәң, мең мәртәбә артык булыр иде.* Г. Камал. **Борын аша (аркылы, астыннан, эченнән)** — 1) теләртеләмәс кенә, канәгатьсезлек белдереп (сөйләшү). *Галиуллин, күзлеген сөртеп, саргылт сакалын сыйпап, борын аркылы гына җавап кайтарды.* К. Нәҗми. *Бригадирның бу сүзләренә каршы урманчы борын эченнән нидер мыгырдап куйды.* Г. Әпсәләмов; 2) (сөйләгәндә яки жырлаганда) сүзләрне аңлашылыр-аңлашылмас, ишетелер-ишетелмәс итеп кенә әйтү турында. *Украина егете өй алдындагы бүрәнәгә утырды да, ике кулы белән яңакларын терәп, борын астыннан нидидер җыр көйләргә тотынды.* И. Гази. **Борын башына** — кеше башына, һәр кешегә, кеше саен. *Дөресен әйткәндә, без инде кичә аның исәнлегенә Ногман белән борын башына йөз иллешәрне төшереп тә алдык.* Г. Гобәй. **Борын белән сөйләү**— тыңкыш тавыш белән сөйләү, сүзләрне ачык әйтмичә сөйләү. **Борынга ис керү** — 1) үсеп дәрт керү (яшүсмерләр турында); 2) тормыш тәҗрибәсе туплый башлау, дөньяны, тормышны аңлый, аның турында фикер йөртә башлау. [*Кандалый*] *- - - үз мохиты яшьләре арасында заманына, шартларына күрә алдынгысы, борынына ис кергәне, фикере ачыла башлаганы.* Х. Госман. **Борын күтәрү (чөю)** — тәкәбберләнү, масаю, эреләнү. *Менә нәрсә сиңа, Давыт: иптәш буласың килә икән, рәхим ит, арага кер. Борыныңны күтәреп йөрисең икән, үзеңә үпкәлә.* Г. Коләхметов. [*Сиражи Кәриме*] *байлыгына масайган була да, әллә кем булып, борынын чөеп йөри.* Г. Камал. **Борын салу (салындыру, төшерү), борын салыну (төшү)** — 1) чырайда, йөздә канәгатьсезлек билгесе чагылу, кәеф китү, үпкәләү. *Менә инде рәхмәт әйтеп аркамнан сөярләр дип кайтсам, бөтенесе борыннарын салганнар.* Т. Гыйззәт; 2) мескен хәлгә килү, элеккеге тәкәбберлеген югалту. *Бүген күрдем үзен милициядә: Борын төшкән, йөзе сагышлы.* М. Җәлил. **Борын сузу** — өметләнеп, өмет итеп йөрү, кызыгып йөрү. *Кем көчле соң, морзамы? Җиңәм дип борынын сузамы, Сезне җиңү уе белән Бөтен гомере узамы?* Г. Камал. **Борын тартып тору** — кыюсызланып, берәр нәрсә өмет итеп, гаебен сизеп тору. *Малай, борынын тартып, куркакурка нәрсәдер мыгырдый, ләкин җавап бирә алмый.* С. Бакиев. **Борын тыгу (төртү)** — 1) тиешсез эшкә катнашу, кирәкмәгән җиргә тыгылу. *Бала-чагасына кадәр зурлар эшенә борынын тыгып йөри.* А. Алиш; 2) *к.* борын сузу.— *Кемнәр генә борынын тыгып карамаган бу бай, матур илгә!* Г. Бәширов. **Борын төбендә (астында)** — бик якын, янәшәдә генә. *Бусы инде Урал тавы артында түгел, ә Идел буенда, ягъни борын төбендә.* И. Гази. *Алар бездән унбиш-уналты километр ераклыкта торалар, ә безгә килеп борын төбеннән болыныбызны чабып алып китәләр.* А. Шамов. **Борын төртер урын булмау** — басып яки утырып торыр урын булмау. **Борын төртеп чыгу** — 1) борынлау (чеби һәм бәпкәләр турында). *Яңа гына күкәйдән борын төртеп чыккан чеби бик җылы сөючән була.* А. Расих; 2) тишелеп чыгу, шыту, шытып чыгу (үсемлек орлагы турында). *Бөртек азыкларны витаминнарга да баетырга була. Әгәр үсентеләр әле генә борын төрткән булса — бөртек B_2 витаминына байый.* А. Расих; 3) барлыкка килү, туу (яңалык турында). *Яшь шагыйрь С. Рәмиевтә, Дәрдмәндтә, Тукайда борын төрткән яңалыкларны үрчетеп җибәрде, үзеннән күп яңалыклар тудырды.* Х. Госман. **Борын чәйнәшү** — сугышу, тарткалашу, даулашу. *Мал өчен, корсак өчен бер-берсенең борыннарын чәйнәшәләр дә алар.* Һ. Такташ. **Борын чөерү** — *к.* йөз чөерү. **Борын үтә (сөйләү яки көйләү)** — *к.* борын аша. 2) *Хәзрәт, борын үтә генә сөйләп, халыкка хезмәт боерды.* З. Һади. *Тик бу вакытта борын үтә генә көй чыгаргалап йөри иде ул.* Ш. Камал. **Борын җимерү** — авыз-борынны канату (сугып яки бәреп). *Ай әттә генәсе, минем Җәмиләмнең борынын җимермәсәләр ярар иде.* М. Фәйзи. **Борын җыеру** — берәр төрле киңәш, фикер һ. б. белән килешмәүне, риза булмауны белдерә. **Борынга борып тыгарлык** — бик яхшы, югары сыйфатлы. **Борынга киртләп кую** — *к.* колакка киртләп кую. *Я менә хәзер үзеңә гомерлек сабак булсын, борыныңа киртләп куй.* Г. Бәширов. **Борынга сугу (суктыру, чиертү)** — берәр өлкәдә (эштә, бәхәстә, ярышта) өстен чыгу, каршы якны узу, җиңү. *Шунда бер уңайда моңарчы үзе белән исәпләшмичәрәк йөрүче - - - командирның да борынына чиертәсе килә иде.* Г. Бәширов. *(Җәләш мулла) - - - бар көче белән тирә-як муллаларның «борынына сугарлык» киенергә тырыша.* Г. Ибраһимов. **Борынны югары тоту** — *к.* борын күтәрү. **Борын гына утырып калу** — бик нык ябыгу. **Борын белән боз тишү** — бик үткен, чая кешегә карата әйтелә.

БОРЫН II *рәв.* **1.** Элек, үткән заманда. *Борын, ат алырдан элек, йөгәнен әзерләп куярга куша торганнар иде.* Ә. Еники. // Алдан. *Туйга барсаң, борын бар; борын барсаң, урын бар.* Мәкаль. [*Староста әтигә:*] — *Акча табарсың да, әйберләреңне түләп алырсың. Борынрак хәстәрен күрәләр аның,— дип - - - өйгә кереп китте.* М. Гафури.

2. *бәйл. функ. -мас, -мәс* формалы фигыльдән соң килеп, баш җөмләнең хәбәрендәге эшнең иярчен җөмлә хәбәрендәге эштән алда үтәлгәнлеген белдерә. *Таң тургае канат какмас борын, Аккош җырлый иде моң гына.* Ш. Маннур.

Борын заман *сөйл.* — *к.* борынгы заман. *Борын заманда, крестьян халкына алпавытлар баш чагында, Җаек буеннан Пугачау батыр күтәрелгән.* Г. Бәширов. **Борын-борын заманда** *сөйл.* — элекке, бик борынгы заманда, күптән үткән заманда. *Борын-борын заманнардан бирле тәрбия ителеп килгән карт-карт агачлар*

белән чолганган бу бакча минем хәтеремдә әле дә шулай хәятлы булып тора иде. Ф. Әмирхан.

БОРЫН-БОРЫННАН *рәв. сөйл.* Бик борыннан, бик борын заманнан; элек-электән, бик күптәннән. *Һәрхәлдә - - - ишегеңне ачып керүчегә якты чырай күрсәтү борын-борыннан килгән әйбәт бер гадәт инде.* Г. Минский. *Бу еллар тирә-юньдәге әйберләрне, борын-борыннан сакланып килгән гадәтләрне, шулай булырга тиеш дип каралган нык законнарны гына түгел, кешеләрнең үзләрен дә үзгәрттеләр.* К. Нәҗми.

БОРЫНГЫ *с.* 1. Борын замандагы, бик күптәнге. *Мин менә борынгы батырларның дәртле җырларын җырларга яратам.* М. Фәйзи. *Борынгы көйләрне әнием бик яхшы җырлый иде,— диде ул.* А. Шамов. //*и. мәгъ. к.* борынгы заман. *Борынгыдан килә торган гадәт буенча, Тимери йортында язгы чәчүнең беренче көнен быел да бәйрәм шикелле көтеп алдылар.* Г. Бәширов.

2. Элекке, әүвәлге, баштагы. *Борынгы шатлыгың юктыр сүзеңдә, Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә.* Дәрдмәнд. *Гаилә эчендәге кешеләр Вахитның ни өчен борынгы юлыннан аерылып икенче бер юлга кергәнен аңлый башладылар.* М. Гафури.

Борынгы заман — үткән заман, күптән үткән заман, элекке заман, иске заман. *Имеш, бик борынгы заманнарда монда бөтен тирә-як сазлык булган.* Г. Гали. *Хосусан, бу заманны борынгы заманнарга тиңләштерергә туры килми.* Ш. Камал. **Борынгы тарих** — тарихта шартлы рәвештә яңа эраның бишенче гасыры белән чикләнгән чор. **Борынгы теллэр** — латин һәм борынгы грек телләре; классик телләр. **Борынгы татар теле** — милли әдәби тел формалашуга кадәр булган татар халык теле. **Борынгы татар әдәбияты** — татар халкының феодализм һәм капитализм дәверендәге тормышы һәм культурасы җирлегендә туып үскән, шул чор социаль катлауларының дөньяга карашын, идеалларын чагылдырган әдәбият.

БОРЫНГЫЛАР *и.* Ата-бабалар, тормыш тәжрибәсе булган кешеләр. *Кышын кар күп булса, җәен иген уңа, дигән борынгылар.* Г. Ибраһимов. *Беренче көнне Гафият, борынгылар гадәте буенча, йомыркаларны [кырга] пешереп алып барды: янәсе йомырка зурлыгы булып уңсын аның бодае.* И. Гази.

БОРЫНГЫЛЫК *и.* Бик күптән, борынгы заманда ук булган нәрсә; бик күптәннән, борын заманнан килгән нәрсә. *Керсә монда берәү, меңәр еллык Борынгылык белән уралыр.* Ш. Маннур. // Борынгы истәлекләр; борынгы җырлар, сүзләр, йолалар, әйберләр һ. б. ш. *Борынгылык калдыклары.*

БОРЫНГЫЧА *рәв.* Борын замандагыча. *Ханифә ханым - - - башындагы ак батист яулыгын, маңгаена төшереп, борынгыча артка кайтарып бәйләгән.* Ә. Еники. // Элеккечә, искечә. *Дәфтәр битендә борынгыча болгап-болгап язылган ниндидер язмалар, билгеләр күренгәләп калды.* Г. Бәширов.

БОРЫНДЫК *и.* Җирдә өн казып яшәүче, тиенгә охшаган кечерәк гәүдәле кимерүче хайван. *Тиен черт-черт чикләвекләр яра, Күзен алмый аннан борындык.* М. Хөсәен.

БОРЫНЛАУ *ф.* 1. Шытым җибәрү, шыта башлау, үренте чыгару, тишелеп чыгып, жир өстендә күренү. *Уч иткән кебек, Бер чикләвек Борынлый Пал йорты ягында.* З. Мансур.

2. Томшыгы белән күкәй кабыгын тишү (бәбкә, чебеш турында). *Өч атна дигәндә йомыркалар борынладылар, берәм-берәм чебешләр чыга башлады.* А. Алиш.

3. *күч.* Барлыкка килү, туу. *Көннәр үтү белән, - - - күңелләрдә борынлап калган яңа уйлар, яңа сүзләр, төрле сәбәпләр аркылы тамырланып, - - - үсәргә йөз тоттылар.* М. Гафури.

БОРЫНЛЫК *и. к.* борынчык (2 мәгъ.).

БОРЫНМӨГЕЗ *и. к.* кәркәдән.

БОРЫННАН *рәв. сөйл.* Электән, күптәннән. *Борыннан мондый эшне күп күреп, бик күп ишеткәнгә, Батырның бик исе китми.* М. Гали.

БОРЫНТЫК *к.* борынчык 2. - - - *Борынтык агачына бәйлә[гән] сус бавы тартылып, борыны авыртканнәтиҗәләр ямьсез тавыш белән акыргалап җибәрделәр.* М. Галәү.

БОРЫНЧА *бәйл. сөйл.* Саен, буенча (өй, йорт, капка сүзләре белән). *Десятский һәм сотскийлар, - - - кулларына таяк тотып өй борынча йөреп, - - - халыкны таяклап җыенга куа башладылар.* М. Гафури.

БОРЫНЧЫК *и.* 1. Кечкенә борын.

2. Тешләмәсен яисә аналарын иммәсен өчен ерткыч җәнлекләрнең яки йорт хайваннарының борынына кидерелә торган җайланма.

БОРЫНЧЫКЛАУ *ф.* Ерткыч җәнлек һәм йорт хайваннарының авызына борынчык кидерү. [*Буренең өстенә*] *сикереп барып төштем дә - - - каеш белән авызын борынчыклап алдым.* Г. Галиев.

Борынчык салу — борынчыклау. *Авызына борынчык салынганлыктан, [бүренең] тешләү куркынычы бетте.* Г. Галиев.

БОРЫС *и.* Ишек, тәрәзә яңагы һ. б. ш. ясау өчен хәзерләнгән дүрт кырлы озын агач материал. // *диал.* Тәрәзә яңагы. *Ул, тәрәзә борысына яңагын куеп, урамны - - - күзәтте.* Сов. әд.

БОРЫЧ *и.* 1. Тропик үсемлек һәм аның аш тәмләткеч ачы түгәрәк орлыгы. *Кара борыч. Кызыл борыч.* □ *Китереп ач шунда [консерв] заводы — помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме, үстереп өлгертәбез.* М. Әмир.

2. Шул үсемлекнең орлык һәм кузагын төеп ясалган аш тәмләткеч.—*Яше-карты һәммәсе чәйгә салсын,— диде, табакларны, тәлинкә, кашык, пычак, тоз, икмәк, борыч — [барысын да] җыеп алдылар, яңа ашъяулык җәйделәр.* Г. Ибраһимов.

3. *күч. сөйл.* Ачы итеп, төрттереп әйтелгән сүз. *Сүзләре борыч: әйткән бере йөрәкне ачыттыра.*

Борыч савыты — төелгән борычны салып тота торган тишекле савыт. *Газизә, тиз генә торып, борыч савытын табып китерде.* Ш. Камал.

БОРЫЧЛАУ *ф.* Борыч салу, борыч сибү. *Борычлап кыздырылган бәрәңгеле ит исе аның борынын кытыклады.* Г. Гобәй.

БОРЫЧЛЫ *с.* Борыч салынган, борыч сибелгән. *Өстәлгә борычлы тәмле пилмән менде.* Ш. Усманов. [*Борынга*] *борычлы ашның исе бәрелә.* Ф. Кәрим.

БОСОНОҒЖКА *и.* Башлары һәм үкчә артлары ачык булган җәйге туфли. [*Сонының*] *сөрмәсез кашлары, коңгырт күзләре, колаклары, муены, аяклары, хәтта аягына кигән зәңгәр босоножкаларына хәтле Николайга сөйкемле, матур булып күренде.* И. Гази.

БОСТАН *и. иск.* Бакча. *Кич кунамын бостанда ла, Җырлыйм эчем пошканда.* Ф. Бурнаш. *Җәелеп ята колхоз кыры Матур булып, киң булып, Чәчәк, җиләк-җимеш тулы Бостаннарга тиң булып.* Ә. Ерикәй.

БОСТОН I *и.* Бертигез калынлыктагы аркау һәм буй җепләреннән тукылган костюмлык саф йон тукыма. *Дәүләтъяров юп-юка инглиз бостоныннан теккән яңа кителе, яңа галифесы белән - - - иптәшләреннән аерыла иде.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Шул материядән тегелгән. *Йөреше салмак, Иңбашында бостон костюм, Аксыл төшкән юл-юл бар, Караңгыда да танырсың.* Н. Исәнбәт.

БОСТОН II *и.* Салмак йөрешле танецның бер төре. *Вальс-бостонга бию.*

БОТ *и.* Кеше, хайван һәм кош-кортларда аякның тездән алып оча сөягенә кадәр булган өлеше. *Тавык боты. Каз боты.* □ *Бик зур азаплык белән бер сәгать чамасы боттан кар ерып барганнан соң, алар һич кеше керә алмаслык бер куе урман авызына килеп җиттеләр.*

М. Гали. *Тимерче ат дагалаганда, бака ботын кыстыра.* Мәкаль.

◇ **Бот буе** *гади с.*— яшь һәм гәүдәгә кечкенә (гадәттә балалар турында). *Ә кемнән җиңдергәнсең бит әле, ботың буе малайдан бит.* Г. Гобәй. *Урман кисәргә я таш чыгарырга бот буе - - - малайны кем алсын?* Г. Бәширов. **Бот күтәреп яту** *гади с.* — эшсез, эшләмичә яту, эшсез тору, ялкаулыкка бирелү. *Шәриф: «Чыкмый булмас, чыгып карарга кирәк, бот күтәреп көтеп буш ятсаң, ашарга китереп бирмәсләр.* М. Гафури. **Бот чабу, ботка сугу** — көчле эмоция: шатлык, үкенеч, борчу, гаҗәпләнү вакытында ботка сугып алу. *Низами үрсәләнеп ботына сугып куйды.* М. Әмир. *Сафа бабай - - - шатлыгыннан ботларына кулларын чапты.* Г. Ибраһимов. *Тимери, алдан хәзерлек күрелмәве исенә төшеп, үкенүдән хәтта бот чабып куйды.* Г. Бәширов. *Хәйран калып эшче ботын чаба, Үзе куркып дер-дер калтырый.* М. Гафури. **Бот чабып (бот чаба-чаба) көлү** — тыела алмыйча көлү, бик каты көлү. [*Иптәшләре*] *рәхәтләнеп, бот чабып, эчләрдән кату чыкканчы көлештеләр.* М. Галәү. **Ботыннан асып кую** *гади с., шаяр.*— җәза бирү. **Ботыннан тотып селексәң дә булмый (юк)** — кемнең дә булса һичбер нинди белеме, мәгълүматы булмау турында.

БО'ТА *и.* Гадәттә юеш яки салкын һавада туфли яисә ботинка өстеннән киелә торган кунычлы аяк киеме. *Фетр боталар.* □ [*Әминә*] *чемоданындагы боталарын чыгарып аягына киде.* Г. Минский.

БОТАҠ *и.* Агач кәүсәсеннән үсеп чыккан ян үсенте, тармак. *Кай төннәрдә аргы бакчадагы миләш ботаклары җил белән тәрәзәгә килеп бәрелиләр.* А. Шамов. // Кәүсәсеннән аерылган тармак, үсенте. *Ботаклардан коры-сары сындыргалап, самоварга салдылар һәм аны шаулатып җибәрделәр.* Э. Фәйзи. *Шул ук көнне дүрт пионер кечкенә арбаларга урманнан коры ботаклар төяп кайтып карчыкларның лапас асларына кертеп өйделәр.* Г. Гобәй.

Ботак тишеге — ботакны кисеп алганнан соң бүрәнәдә, тактада калган эз, урын. *Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге.* Мәкаль.

БОТАҠЛАНУ *ф.* Ботаклар чыгару, ботаклар җибәреп үсү. *Инде ул мәңге тамыр җәймәс, ботакланмас тагын, икенче кәррә ярмас яфрагын.* Г. Тукай.

БОТАҠЛЫ *с.* Тармаклы, ботагы яки ботаклары булган. *Ибрай читән буендагы ботаклы бүрәнә өстендә утырган җиреннән дәртләнеп сикереп торды.* М. Әмир.

◇ **Ботаклы көенчә (селтәү)** — ничек бар, шулай, булганынча әйтү, күңелгә авыр тоела торган итеп (сөйләү). *Рәхмәт, каенага, шомартып әйтүеңә рәхмәт. Бүтән кеше шомартмый-нитми ботаклы көенчә селтәүчән була.* Ш. Камал.

Ботак-чатак, ботак-чабак. Вак-төяк ботаклар, чыбык-чабык. *Бу ылыслы ботак-чатаклардан, тиешенчә эшкәрткәндә, уксус кислотасы, метил спирты, тагын бик күп файдалы химик әйберләр эшләргә мөмкин.* Г. Әпсәләмов.

БОТА'НИҠ I *и.* Ботаника белгече. *Газинур ботаник түгел, ул бары тик шул кырларда кечкенәдән аунап үскән малай гына.* Г. Әпсәләмов.

БОТА'НИҠ II *с.* Ботаникага караган, ботаникага бәйләнешле, ботаникага мөнәсәбәтле. *Ботаник бакча.* □ *Менә бу пыяла шкафлар эчендә тезелешеп торган китаплар, стеналарга эленгән географик карталар, зоологик, ботаник таблицалар - - - аңарда үзен биредә ят кеше итеп тою хисен тудыра иде.* Ә. Еники.

БОТА'НИКА *и.* Үсемлекләр, аларның төзелеше, үзенчәлекләре һәм функцияләре, Җир шары буенча таралышлары, төркемнәре, үзара бәйләнешләре һәм килеп чыгышлары турындагы фән.

БОТАРЛАУ *ф.* **1.** Санын санга аеру (ит түшкәсе турында). // Төрле кисәкләргә аерып ташлау, рәхимсез тарткалап өзеп сындыру, ерту. *Ул үзенең бодаена җәй буе шулкадәр ияләшкән икән, барабан тешләре башаклы рәхимсез ботарлый башлагач, анда хәтта кызганучы якын бер хис туды.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Ерткычларча кыйнап имгәтү, үтерү. [*Сандецкийны*] *хәзер үк Казаннан алып чыгу мөмкин түгел. Солдатлар ботарлап ташлаячаклар үзен.* Қ. Нәҗми.

БОТАУ *ф. диал.* **1.** Ботакларыннан арындыру, ботакларыннан чистарту. *Яшь каенның ботагын Балта бирсәң, ботаем.* Җыр.

2. Ботарлау, саксыз рәвештә өзгәләү, сындыру. *Шомырт (алма, миләш һ. б.) агачын ботап чыгу.*

БОТИ'НКА *и.* Қыска кунычлы, шнур белән бәйләнә торган аяк киеме. *Қысынкы ботинкалардан юка, саргылт оек эчендәге кечкенә генә нәфис аяклар килеп чыкты.* Ф. Әмирхан. *Ботинкаларны кызганмадык, идән сайгаклары сыгылганчы тыпырдадык.* Г. Мөхәммәтшин.

БОТКА и. **1.** Гадәттә ярмадан суда яки сөттә пешерелгән куе ашамлык. *Бер тарыдан ботка пешми.* Мәкаль. *Эш җае белән, ботка мае белән.* Мәкаль. *Поход кухнялары, урамнарны төтенләтеп, итле аш һәм карабодай боткасы пешерә башладылар.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Буталчыклык, берәр нәрсәнең буталган катнашмасы. *Тәртипсез чуалып беткән тузгыган кәгазьләр боткасы эченнән кирәкле кәгазьләрне табуы бик кыен булды.* Г. Иделле.

◇ **Ботка булу, боткага әйләнү**—буталчыклану, аңлап булмаслык дәрәҗәгә килү (эш, сөйләшү турында). **Ботка пешү** — үзара килешеп, уртак тел табып эшләү турында. *Болай итсәк, миңа да җәбер, сиңа да җәбер булмас, моңар күнсәң, безнең ботка пешәр.* Г. Тукай.

БОТЛЫ-ЧАТЛЫ *с.* Ботаклы, төрле якка тырпайган. *Кул-аягы ботлы-чатлы, Үзе адәм сынлы бу.* Н. Исәнбәт.

БОТФОРТ *и. иск.* Өйгә таба киңәеп киткән озын кунычлы итек (иске армиядә кавалеристлар кигән). [*Петр заманындагы дворяннар*] *башларына пудраланган парик һәм өчпочмаклы эшләпә, аякларына биек ботфорт - - - кигәннәр.* СССР тарихы.

БОХАР *с.* Бохара якларында эшләнгән; Бохара якларыннан килгән. *Мин караганда [Ибраһим Хәлфиннең] башында бохар кәләпүш, өстендә кара казаки иде.* М. Гали.

Бохар кавыны — кавынның бер сорты. *Ул - - - синең бохар кавыннарыннан да йомры башларың!* Г. Тукай. **Бохар кынасы** — чәчәкләре сабак тирәли тыгыз булып урнашкан берьеллык үсемлек, бальзамин (элек аның кызгылт сары суы белән чәч, тырнак, теш буяганнар). *Карчыкның ялагайланып кыставына һәм бохар кынасы буялган кара озын тешләрен күрсәтеп хәйләкәр елмаюына әһәмият бирмәстән, Сәгыйтов сүз ачты.* С. Рафиков. **Бохар миләше** — *к.* аю баланы, карга миләше; *русчасы:* бузина. **Бохар кәләвәсе** — чәчәкнең бер төре. **Бохар мәчесе (песие)** — озын йонлы мәче. *Ишан сүз башлады — бохар песиемени — күз йомылган, муен сузылган.* Х. Кәрим.

БОХАРИ *с. иск.* **1.** Бохара мәдрәсәсендә укыган. *Мәдрәсәнең мөдәррисе, илле биш-алтмыш яшьләрендәге бер бохари хәзрәт иде.* Ф. Әмирхан. /*и. мәгъ.* *Бохарилар мәҗлесенә һич тә бармам, и раббем.* Г. Камал.

2. *к.* бохар. *Бер рәсемдә бер тәвәккәл бүрек, бер зур каракүл бүрек, бер бохари чалма төшерелгән.* Ф. Әмирхан.

БОХАРЧЫЛЫҠ *и.* Дин өйрәтүләреннән читкә чыкмау, шуларны алга сөрү, искелек тәртипләре. *Шулар белән берәттән үк бохарчылык-шәрыкчылык, феодалчылык идеологиясенә каршы — яңару, европалашу, Европа мәдәниятын урнаштыру хәрәкәтләре башланды.* Тат. театры.

БО'ЦМАН *и.* Диңгез флотында: кече команда составыннан судноның хуҗалык эшләре өчен җаваплы кеше.

БОЯР *и. тар.* **1.** Мәскәү Русенда бүләк итеп бирелә

торган югары дәрәҗә; шул дәрәҗәгә ия кеше. *Бояр җирнең хакын бик югары куйган.* М. Гафури.

2. Борынгы Русьта һәм Мәскәү дәүләтендә хаким сыйныфның югары катлау вәкиле, эре җирбиләүче. *Крестьяннар, арзан хакка эш эзләп, боярга инәлергә мәҗбүр булдылар.* Г. Нигъмәти. // *с. мәгъ.* Боярныкы, боярга караган. *Бояр җирләре. Бояр урманы. Бояр имениесе.*

Бояр балалары *тар.*— борынгы Русьта (XIII гасырдан алып) һәм Мәскәү дәүләтендә хәрби яки гражданлык хезмәтен үтәгән вак алпавытлар. *Элек заманда бояр балалары гына офицер була торган иделәр бит!* Ш. Камал.

◇ **Бояр егете кебек** *иск.*— *к.* кияү егете кебек. *Минем Алмачуар исә кунакка барырга ясанган бояр егете кебек чибәр булды.* Г. Ибраһимов.

БОЯ'РЩИНА *и. тар. к.* барщина.

БОЖРА *и.* 1. Тимер чыбыктан яки бүтән нәрсәдән гадәттә түгәрәкләп бөгеп ясалган балдак яки кыршау сыман әйбер. *Чалгы божрасы. Пластмасса божра. Гимнастик божрада күнегүләр ясау.* ▭ [*Газинур*] *айгырның башын югары күтәреп, чылбыр тезгенен юан божрага кертеп бәйләде.* Г. Әпсәләмов.

2. Божрага охшаган, шуның төсле нәрсә. *Су өстендәге майлы тап божралары. Төтен божралары.* ▭ *Аның башы әйләнә, күз алларында божралар уйный.* Г. Бәширов.

3. *с. мәгъ.* Божра формалы, шуңа охшаган. [*Сөләйман*] *тагы тәмәкегә тотынды. Туя алмыйм валлаһи! --- дип сөйләнә-сөйләнә, түгәрәк божра төтеннәр чыгарып, --- тагы үзенең язмышын* [*сөйли башлады*]. Г. Ибраһимов.

4. Чолгап, камап торучылар төркеме. *Конвой командасы, эшелон тирәсенә беркемне дә җибәрмичә,* [*тоткыннарны*] *божра эченә алды.* И. Туктар. *Йорт тирәсендә халык божрасы һаман кысыла бара. Һәркем, алгарак чыгып, ут белән көрәшүчеләрне күрергә тели.* Н. Дәүли. // Чолганыш, камалыш. *Безне төрле яклап чорнадылар. Көннән-көн кыса бардылар. Ахыр чиктә утлы божраны өзеп чыгудин башка чарабыз калмады. --- Күп иптәшләрне корбан итү бәрабәренә чолганыштан котылдык.* Т. Гыйззәт.

БОЖРАЛАНУ *ф.* 1. *Төш юн. к.* божралау.

2. Божра формасын алу. *Алар, аяк астында божраланып яткан тимер йомычкалары, тутыгып беткән машина кисәкләре арасыннан --- үттелар.* К. Нәҗми.

БОЖРАЛАУ *ф.* 1. Божра кую, кидерү, божра белән беркетү. *Чалгыны божралау.*

2. Божра сыман итү. *Сатучы, өстәл өстенә кулын божралап куеп, йомыркаларны тәгәрәтмичә тотып торган.* Әкият.

3. *к.* балдаклау 1.

БОЖРАЛЫ *с.* Божрасы булган, үзенә божра беркетелгән яки кидерелгән. *Чаңгычы үзе алга иелгән, божралы таякларын карга да тидерми.* Г. Әпсәләмов.

БОЖЫР *и.* Көртлекләр семьялыгыннан, чуар каурыйлы урман кошы. *Божыр аты.*

БРАДӘР *и. иск. кит.* 1. Ир туган.

2. *кит.* Мөрәҗәгать сүзе: иптәш, фикердәш; дус, туган.— *Сабыр, брадәрләр, сабыр төбе сары алтын дигәннәр бабайлар.* К. Тинчурин. *Әй, брадәр, үземә яхшы булса, башкаларда эшем юк дип, кешеләрне онытма.* Ф. Халиди.

БРАЗИ'ЛИЯЛЕ *и.* Бразилия кешесе.

БРАК *и.* 1. Начар сыйфатлы, куллану өчен өлешчә яки тулысынча яраксыз итеп эшләп чыгарылган әйбер, продукция. *Сәбәпләрен ачмасам, температураны үзгәртмәсәм, бәлки әле хәзергәчә брак чыгарып килгән булыр идек.* Р. Ишморат.

2. Эшләп чыгарылган әйбернең сыйфатын төшерә яки продукцияне бөтенләй яраксызга чыгара торган кимчелек. [*Мастер:*] *Я берәр урында брак җибәргәнбез, я булмаса буяуны нормадан тыш тотканбыздыр.* Азат хатын.

3. *с. мәгъ.* Бик начар сыйфатлы итеп яки бозып эшләү нәтиҗәсендә файдалану өчен өлешчә яисә тулысынча яраксыз булган (әйбер, продукция турында). *Брак товар. Брак продукция.* ▭ *Торбаның брак түгелме, яньчелмәгәнме икәнен тикшерәбез.* Ж. Тәрҗеманов.

◇ **Брак ясау** — начар сыйфатлы продукция эшләп чыгару, әйберне бозып эшләү. **Бракка чыгару** — брак дип, начар сыйфатлы дип табу.— *Минем ишетүемә караганда, безнең --- мехларыбызны бракка чыгарганнар.* Ш. Камал.

БРАҠОНЬЕР *и.* Браконьерлык белән шөгыльләнүче; корткыч.

БРАҠОНЬЕРЛЫҠ *и.* Тыелган җирдә, тиешсез вакытта яки тыелган ысул белән ау аулау; корткычларча аулау. *Әтисе өстенә җылы свитер, аякларына зур кунычлы резина итекләр кигән иде. Димәк, тагын браконьерлыкка чыгарга әзерләнеп, көтеп торган.* Э. Касыймов.

БРАНДСПОЙТ *и.* Янгын насосы. *Куәтле брандспойтлардан сиптерелгән су ташкыны дәһшәтле ут ялкынын юк итте.* Э. Касыймов.

БРА'УНИНГ *и.* Автомат пистолет. [*Сафин*] *үзенең итек балтырыннан кечкенә генә браунинг тартып ала.* Ш. Камал.

БРЕЗЕНТ *и.* 1. Су үткәрми торган тыгыз, тупас тукыма; парусина. *Брезент туку цехы. Йөк өстенә брезент каплап тору.* // Брезенттан эшләнгән яки тегелгән нәрсә. [*Нефть бораулаучы:*] *Киям брезент, йөрим туннан; --- Кышын тирлим, җәен туңам Эшем өчен, эшем өчен.* Э. Юныс.

2. *с. мәгъ.* Брезенттан эшләнгән, корылган яки тегелгән. *Брезент кожан. Брезент палатка. Брезент капчык.* ▭ *Аларның өсләрендә брезент куртка лар, башларында брезент башлык, аякларында күн итек.* А. Әхмәт.

БРИГ *и.* XVIII—XIX йөзләрдә: ике мачталы, җилкәнле хәрби яки сәүдә корабы. *Җилкәнле бриг.*

БРИГА'ДА *и.* 1. Бергә эшләүчеләрдән оештырылган һәм билгеле бер эш яки тармак өчен җаваплы булган кешеләр төркеме, коллектив. *Колхозның кырчылык бригадалары. Яшьләр бригадасында эшләү. Төзүчеләр бригадасы. Тимер юлчылар бригадасы.*

2. *хәрби.* Берничә батальоннан (дивизионнан) яки полктан һәм махсус гаскәр частьларыннан төзелгән берләшмә. *Кавалерия бригадасы. Танк бригадасы. Артиллерия бригадасы. Сапер бригадасы.* ▭ *Мин Фәхрине күптән беләм. Без башта фронтта татар бригадасында бергә эшләдек.* Г. Ибраһимов. // Флотта: бер үк класс кораблеләренең тактик берләшмәсе.

БРИГАДИР *и.* Бригада (1 мәгъ.) җитәкчесе (гадәттә физик эшләрдә). *Тимери Сәйфине ындыр бригадиры итеп тәкъдим иткән.* Г. Бәширов. *«Яшел алан» колхозы --- өч авылны берләштерә икән. Авыл саен берәр бригадир комплекслы бригадага җитәкчелек итә, ди.* Б. Камалов.

БРИГАДИРЛЫҠ *и.* Бригадир вазифасы, хезмәте. [*Нәфис:*] *Әни, яңадан бригадирлыкны алдым.* А. Әхмәт. *Үткән язда аны күтәргәннәр бригадирлыкка.* М. Җәлил.

БРИЗ *и.* Диңгез һәм зур су буйларындагы йомшак җил (көндез судан җиргә, э төнлә киресенчә исә).

БРИҠЕТ *и.* Пресслап, кирпеч формасында эзерләнгән материал, азык-төлек һ. б. нәрсә. *Торф брикетлары. Концентрат азык брикетлары.*

БРИҠЕТЛАУ *ф.* Берәр нәрсәдән брикетлар ясау, берәр нәрсәне брикетка салу. *Торф брикетлау. Брикетлау цехы.* ▭ *Комбиазыкларны кәгазь капларга салалар я брикетлап чыгаралар.* А. Расих.

БРИЛЛИАНТ *и.* 1. Асылташның бер төре: кырлап һәм шомартып махсус эшкәртелгән алмаз. // Бриллианттан эшләнгән бизәнү әйбере. [*Ире*] *Һаҗәрдән дөньяны*

кызганмады. Аны алтыннар, бриллиантлар белән бизәде, атласлар, ефәкләр эченә күмде. Г. Ибраһимов.

2. *с. мәгъ.* Бриллианттан яки шуны катнаштырып эшләнгән яисә шуның белән бизәлгән. *Бриллиант кашлы йөзек. Бриллиант таҗ.* □ *Алкаларың якты бриллиант иче.* Г. Тукай.

БРИЛЛИАНТЛЫ *с.* Бриллианты булган, бриллиант белән бизәлгән. *Алгы ложалардагы хатын-кызларның энҗеле калфаклары, бриллиантлы алкалары - - - гажәп матур ялтырашалар.* Ш. Камал.

БРИЛЛИАНТЧЫ *и.* Бриллианттан әйберләр эшләү остасы.

БРИТА'НИЯЛЕ *и. иск.* Инглиз.

БРИ'ТВА *и.* Чәч ала, кырына торган корыч пәке. *Бритва кайрау.* □ *Мәҗитов, кырынып бетмәс борын үк, кулындагы бритвасын куйды һәм Бикбулатовның җырын тыңлый башлады.* А. Әхмәт. // Кырыну, чәч алу өчен махсус бритвасы булган аппарат. *Электр бритва.*

БРОМ *и.* **1.** Көчле исле, куе кызыл пар чыгара торган сыекча, химик элемент.

2. *сөйл.* Бром кушып ясаган дару (нервларны тынычландыру өчен эчелә).

БРОМЛЫ *с.* Составында бром булган.

БРОНЕВИК *и. хәрби.* Броня белән капланган (тышланган) кораллы автомобиль. *Автомобильләр, түбәсеннән тәгәрмәченә кадәр корыч белән өретелгән броневиклар, алтышар ат җиккән авыр туплар өзлексез конвейер белән шәһәрдән вокзалга агылды.* Ш. Усманов.

БРОНЕКА'ТЕР *и. хәрби.* Бронялы, кораллы катер. *Дулкыннар өстеннән Идел флотилиясенең бронекатерлары уза.* Г. Әпсәләмов.

БРОНЕМАШИ'НА *и. к.* Броневик.

БРОНЕНО'СЕЦ *и. хәрби.* Бронялы, эре кораллы зур корабль (XIX йөз ахыры һәм XX йөз башларында).

БРОНЕПО'ЕЗД *и.* хәрби. Бронялы, кораллы поезд.

БРОНЕТАНК: бронетанк гаскәре (яки берләшмәләре, частьлары) — нигездә танклар, үзйөрешле артиллерия һәм бронемашиналардан төзелгән гаскәр (берләшмә, часть).

БРОНЕТРАНСПОРТЁР *и. хәрби.* Җәяүле гаскәрне һәм сугыш кирәк-яракларын ташый торган, бронялы автомобиль.

БРО'НЗА *и.* **1.** Бакырга кургаш һ. б. металлар кушып коелган эретмә. *Түрдәге язу өстәлендә Ленинның оста кул белән бронзадан эшләнгән кечерәк кенә бер бюсты күренә.* Г. Бәширов.

2. *с. мәгъ.* Бронзадан эшләнгән. *Бронза медаль. Бронза һәйкәл.* □ *Нур, бүлмәдәге укытучыларны үз янына җыеп, бронза каптырманың серләре турында сөйли башлады.* А. Расих.

◇ **Бронза чоры** *археол.* — кешелек тарихында металл куллана башлауның иң борынгы (кешеләргә тимер билгеле булмаган) чоры.

БРОНЗАЛАУ *ф.* Берәр нәрсәнең өстен бронза катлавы белән каплау; бронза йөгертү.

БРОНХ *и. анат.* Сулыш юлының үпкәдәге зур тармакларыннан берсе.

БРОНХИАЛЬ *с. анат.* Бронхка мөнәсәбәтле. *Бронхиаль биз. Бронхиаль астма.*

БРОНХИТ *и.* Бронхларның лайлалы ярысы ялкынсынуы.

БРОНЬ *и.* Берәр нәрсәдән файдалану хокукы бирә торган махсус рөхсәт; шул хактагы рәсми язу, документ.

БРОНЯ *и.* Корыч яки башка төр нык материалдан эшләнгән саклану тышчасы, калканы (хәрби кораблләрдә, танкта һ. б.). *Күтәренке күңел кешене һәртөрле чирләрдән иң калын броняга караганда да ныграк саклый.* Г. Әпсәләмов.

БРОНЯЛЫ *с.* Бронясы булган, броня белән капланган, тышланган. *Алар бронепоезд янына җитүгә, бронялы платформа өстендә - - - торучылар арасыннан ике офицер, җиргә сикереп төшеп, Сөләйманнарны туктаттылар.* К. Тинчурин. *Вагоннар махсус сугыш өчен эшләнгән, броненосец шикелле, бронялы.* Ш. Мөхәммәдев.

БРО'ШКА *и.* Хатын-кыз бизәнү әйбере (гадәттә күкрәккә яки якага кадап йөртелә). *Кашлы брошка. Алтын брошка.* □ [*Кызның*] *ефәк күлмәге дә, хәтта изүендәге кечкенә генә ак брошкасы да Мансурга таныш.* А. Расих.

БРОШЮ'РА *и.* Гадәттә иҗтимагый-политик, фәнни һ. б. ш. темага караган кечкенә күләмле (өч табактан артмаган) басма әсәр (күбесенчә, төпләмичә генә эшләнгән китапчык). *Политик брошюра. «Белем» җәмгыяте чыгарган брошюралар.*

БРОШЮРАЛАУ *ф.* Басма битләрне брошюра итеп теркәү. // Китапларны, журналларны: төпләргә уңайлап, табак-табак теркәү, әзерләү. *Брошюралау цехы.*

БРУ'СТВЕР *и. хәрби.* Пулядан, снарядтан, дошман күзеннән саклану һ. б. өчен окопның яки траншеяның алгы кырыена өеп ясалган калкучык. *Винтовканы бруствер өстенә куеп ату. Брустверны маскировкалау.*

БРУ'ТТО *и.* Төргән нәрсәсе, савыты белән бергә гомуми авырлыгы (товарның); *киресе:* нетто.

БРУЦЕЛЛЁЗ *и.* Терлекләрдә була торган йогышлы авыру (кешегә дә йога).

БРЫ'НЗА *и.* Сарык сөтеннән ясалган сыр.

БРЮНЕТ *с.* Кара чәчле, кара тутлы ир кеше. [*Гали*] — *озын мыеклы, уртача куе сакаллы, брюнет.* Г. Коләхметов.

БРЮНЕ'ТКА *с. сир.* Брюнет хатын-кыз. *Зәйнәп — Хөсәеннең кызы, брюнетка, йомшак табигатьле уйчан гына кыз.* Ф. Әмирхан.

БУ I *и.* Пар. *Өстәлдә самовар кайнап, булары чыгып тора.* Ш. Камал. *Уртада буы чыгып торган зур ак таш табак, аның эчендә тулы пилмән.* Г. Ибраһимов.

БУ II *күрс. а.* (моның, моңа, моны, моннан, монда; *күпл.* болар; *тартымлы форм.* бусы, болары). **1.** Пространство яки вакытның үзеңә якынрак өлешендә булган нәрсәне яисә кешене күрсәтү өчен кулланыла; *киресе:* теге. *Сагынганда хат язмыйсың, бу саргайсын дисеңме?* Г. Тукай. *Күпер аркылы теге яктан бу якка сыерлар чыгалар.* И. Гази.

2. Әле генә искә алып үтелгән нәрсәгә ишарә ясау өчен кулланыла. *Балавыз хәленә җиткәч, арыш булсын, бодай булсын, үсүдән туктый. Ә бу — уру өчен иң шәп чак.* Г. Гобәй.

БУА *и.* **1.** Суның юлын бүлеп, буып тоту өчен ясалган корылма. *Буа белән бөялгән инеш суларын электростанция өчен эшкә җигәрбез.* К. Нәҗми. *Су җыю өчен кешеләр уңай гына урынга текә буалар торгызалар.* Г. Галиев.

2. Шушы корылма алдында буылып җыелып торган су, сулык. *Буада су коену.*

◇ **Буа бу (буарлык)** — бик күп. *Аңарда китаплар бетәсе түгел, буа бу!* Ш. Камал.

БУАЗ *с.* Карынында баласы булган (хайваннар турында); *киресе:* кысыр. *Буаз сыер. Буаз сарык.* □ [*Бияне*] *буаз дигәч, мин инде аның булачак колының, әлбәттә, алмачуар дип, чабышкы дип башыма да утырткан, бөтен ипташларга дә мактанып беткән идем.* Г. Ибраһимов.

БУАЗЛЫК *и.* Буаз булу хәле.— *Кызыл тана шулай кысыр калды микән инде, буазлыгы беленмиме?* Ш. Маннур.

БУАР: буар елан *зоол.*— башлыча эссе якларда яши, корбанын гадәттә гәүдәсе белән чорнап буа торган, агусыз эре ерткыч елан; *русчасы:* удав.

БУ'БИ *и.* Кызыл ромб рәсеме төшкән уен картасы. *Буби короле. Буби тузы. Бубидан йөрү.*

БУГАЗ *и.* **1.** Муенның алгы өлеше. *Бүре шунда үк бер атның бугазына ябышкан.* А. Алиш. *Акбүз ят кешенең бугазына үткен тешләрен тагы да ныграк батырып идәнгә екты.* Г. Гобәй.

2. Тамак төбе, авыз эченең арткы өлеше. *Яратмаган ризыкның бугаздан үтмәве.* □ — *Әллә ничек бугазларны чеметтереп төшеп киткән шикелле булды* [*эчемлек*]. Г. Камал.

3. Сулыш юлының өске өлеше. *Ул әйтмәкче булды — теле әйләнмәде, бугазыннан өне чыкмады.* М. Әмир.

4. Шешә кебек савытларда: тамак, тар авыз. *Нечкә бугазлы шешә.*

5. *геогр.* Ике диңгезне, күлне һ. б. ш. сулыкны тоташтыра торган тар су мәйданы. *Керчь бугазы. Беринг бугазы.* □ *Босфорның агымы табигатьнең бер кызык парадоксыннан санала: бугаз суының өсте Кара диңгездән Мәрмәр диңгезенә ага, асты — Мәрмәр диңгезеннән Кара диңгезгә.* Сов. әд.

◇ **Бугаз ерту (киерү)** *гади с.*— **бик каты кычкыру,** акыру; шапырыну.— *Киермә сәнә бугазыңны, палач!* Г. Гобәй.— *Камали йөри ди ич, «кемгә — вәйна, кемгә — файда» дип, бугаз ертып.* Қ. Нәҗми. **Бугазга килү (терәлү)** — бик ашыгыч башкаруны таләп итү (эш турында). *Монда эшләр тәмам бугазга терәлгән.* Ш. Камал. **Бугазга ябышу, бугаздан алу** — берәр нәрсәне эшләргә тупас рәвештә мәҗбүр итү; котылгысыз хәл алдында калдыру. *Шушы коточкыч буран[да] - - - ике йөз метрда бер-берсенең бугазына ябышырга әзер торган ике фронт яшеренгән.* Г. Әпсәләмов. *Хәзер эш болай тора: я революция үсәр, киңәер, ул вакыт җир дә булыр, власть та булыр; яисә революциянең бугазыннан алырлар,— ул вакыт җир дә эләкмәс, власть та эләкмәс.* И. Гази. **Бугазга-бугаз килү (ябышу)** — сугышканда яки сугышыр дәрәҗәдә ярсып бәрелешкәндә бер-береңнең бугазына якасына ябышу, якалашу. [*Муса:*] *Урлашып баедың!* [*Габдуллажан:*] *Син үзең күмер карагы! (Бугазга-бугаз киләләр.)* Қ. Тинчурин. // Бик каты, бер-береңне аямыйча сугышу, ызгышу, бәрелешү. *Фронтта дошман белән бугазга-бугаз килү.* □ *Бәхәс бугазга-бугаз килүгә барып җитте.* А. Расих.

БУГАЗЛАУ *ф.* 1. Сую. *Сарык бугазлау.*

2. Бугазны чәйнәп, ертып үтерү (ерткычлар турында). *Бүре сарыкларны бугазлый.* Г. Тукай. // *күч.* Үтерү, юк итү, бетерү. *Эшчеләр сыйныфы революцияне бугазларга юл бирмәс.* И. Гази.

БУГАЙ *кис.* Чамалап кына әйтүне белдерә. *Таң ата бугай, Әтәч кычкыра.* М. Җәлил. *Кил, улым, монда, әтиеңә язарга уңайсызлыйсың бугай анда.* М. Гали.

БУГАЙЛАУ *ф. гади с.* «Бугай» сүзен катнаштырып, икеле-микеле сөйләү.

БУГАЛАҚ *и. диал.* 1. Нечкә тимер чыбыктан яки кылдан ясалган, элмәк сыман тозак (аңа эләккән җәнлек, үз талпынуыннан буылып яки кысылып, эләгеп кала). *Бугалак салу. Куян бугалагы.*

2. Бер очы элмәкле махсус, озын бау, аркан (кыргый яки өйрәтелмәгән атларның һ. б. ш. хайваннарның муеныннан эләктерү өчен хезмәт итә). *Муендагы бугалак аның [айгырның] хәлен бетерде.* Г. Ибраһимов.

БУДДА *и.* Буддачылар карашынча, буддизмга нигез салучы зат.

БУДДАЧЫ *и.* Буддизм динендә торучы.

БУДДИЗМ *и.* Қытай, Япония, Тибет, Һиндстан һ. б. кайбер Көнчыгыш илләрендә таралган дин.

БУДИ'ЛЬНИК *и.* Билгеләп куйган вакытта шалтырый торган сәгать. *Иртән будильник тавышына уянып китү.*

БУ'ДКА *и.* Қаравылчы, часовой һ. б. ш. өчен салынган алачык яки шуңа охшаган корылма, каралты. *Суфлер будкасы. Тимер юл будкасы.* □ [*Әхмәтҗан*] *фабриканың капка төбенә килеп часовой будкасы янында Хамматны көтәргә кереште.* М. Гали. *Дуслар, исләренә килеп, көймәне шактый читтә калган маякчы будкасына таба турыладылар.* Г. Гобәй.

БУДЫРГЫЧ *и.* Оекны, балакны һ. б. будырып куя торган сузылмалы тасма. *Оек будыргычы.*

БУДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* буу (1—6 мәгъ.).

2. Берәр нәрсә белән кысып урау, буып бәйләү (җиңне, балакны һ. б. ш.). *Җиң очларын резин белән будырып кую.*

БУЕ *бәйл.* 1. Буйга таба юнәлештә; буенча, буйлап. *Урак вакыты да җитте; үткән җәй - - - урам буе чабып йөргән мин бер малайны быел Садрыйны тартып йөргәндә ураккада алып чыктылар.* Г. Тукай.

2. Озынлыгы, буйлыгы; биеклеге.— *Игенегез уңсае, минем буе булсае.* И. Гази. *Кояш офыктан сөнге буе гына күтәрелеп тора.* Г. Гобәй.

3. Вакытны белдергән сүзләр янында: барлык шул вакыт дәвамында. *Гомер буе. Көн буе. Гасырлар буе. Җәй буе сайрый торган кош.*

БУЕНА *к.* буенча (1, 2 мәгъ.). *Ул носилкада ята, күзләре йомык, зур куллары хәлсезләнгән гәүдәсе буена сузылганнар.* Г. Әпсәләмов. *Юл буена чикмәнгә төренеп йоклап килгән Зәйнагытдин дә уянып китте.* М. Гали. *Их, дускаем, ел буена һаман җәй булса икән.* З. Мансур.

БУЕНЧА *баш килеш бәйл.* 1. Буйга таба юнәлештә; буйлап. *Урам буенча болганчык сулар йөгерде.* И. Гази. *Юл шарлавык буенча бара.* А. Шамов.

2. Күрсәтелгән барлык вакыт дәвамында; буена. *Гомер буенча. Көн буенча. Бөтен кичә буенча бергә булу.* □ *Бакчабызда шомырт агачлары Җәй буенча сине көттеләр.* С. Хәким. [*Фатыйма*] *юл буенча бүгенге очрашу турында уйлап барды.* Г. Минский.

3. Берәр нәрсәдән, җайланмадан файдаланып, шуның ярдәмендә; белән, аркылы, аша. *Чишмә суын фермага торба буенча җибәрү. Колга буенча үрмәләп мену.* □ *Кемдер кыр телефоны буенча боерыклар тапшыра.* Қ. Нәҗми.

4. Берәр нәрсә нигезендә, шуңа таянып, карап, шуны исәпкә алып. *График буенча эшләү. Исемлек буенча сорау. Традиция буенча үткәрелә торган спорт ярышы. Сигнал буенча кузгалу. Гадәт буенча әйтелә торган сүз.* □ *Йола буенча, читтән кайткан кунак белән беренче чәй күз күргән якын кешесез эчелми инде ул.* Ә. Еники. *Җәмилә, Бәдринең киңәше буенча, эш эзләп шәһәр арасына чыгып китте.* М. Гафури.

5. Максатны белдерә: өчен. *Ул, аеруча әһәмиятле бер участокны өйрәнү буенча, һәр төнне диярлек разведкага йөрде.* И. Гази. [*Пионерлар үз карарларын*] *тормышка ашыру буенча җиң сызганып эшкә керештеләр.* Г. Гобәй.

6. Сәбәпне күрсәтә: аркасында, сәбәпле. *Бу алтын игеннәр табигать мәрхәмәте буенча гына үсмәгән бит, аларны кеше үстергән.* Г. Әпсәләмов.

7. Берәр өлкәдә (эшчәнлек, һөнәр һ. б. ш. сыйфатлар турында). *Үз һөнәрең буенча эшләү.* □ *Мәктәптә дә, өйдә уку буенча да уңышлары зур булды аның.* М. Гали. *Мин химия буенча яңа проблема өстендә эшлим.* Ш. Камал.

БУЙ *и.* 1. *гадәттә кыек форм.* Аркылының киресе булган юнәлеш, озын як. *Нурыйның урамга буе белән салынып, салам белән ябылган алты почмаклы өе икегә бүленә.* Г. Ибраһимов.

2. Озынлык; *киресе:* ин. *Буе ике йөз, аркылысы алтмыш аршынлы яңа сал ясадылар.* Ф. Халиди. // Билгеле бер үлчәм (озынлыкка); оч. *Бу [бүрәнә] бик кыска бит, монда ничә генә буй [киндер] тукмакларлар икән?* Г. Камал. *Язгы ташу вакытында Җилем суы белән бик күп сал агызып төшәләр. Ләкин ул саллар ике буй бүрәнә чамасыннан озын булмыйлар.* М. Гафури.

3. Гәүдә, сын (гадәттә аның озынлыгын-биеклеген күздә тотканда). *Буй үсү. Буйга зифа булу. Буең озын булу.* □ *Яшькә яшь булсам да, буем бар минем.* Ф. Хөсни.

4. **Сузылып киткән җир мәйданы; җир өстендәге ара.** *Тау итәгендәге бүген урылган арышны кичә күреп*

киткән идем, - - - бу башы кичә үк балавыз хәлендә иде. Ә иртәгә бөтен буе шулай булачак. Г. Гобәй. *Арыш кибәне әнә теге буйда.* Г. Бәширов.

5. *кыек форм.* Берәр нәрсәнең янәшә-тирәсе, аңа чиктәш тирәлек; шул яклар. *Стена буе. Чишмә буе. Тау буйлары.* □ *Урман буйлары тигез кар белән капланган иде.* М. Гали. [*Авыру хатынның*] *яңак буйлары һәм күз төпләрендә шактый тирән җыерчыклар сызылган.* Ш. Камал.

6. Берәр нәрсәнең өстендә, берәр җирлектә янәшә сузылып киткән сызыкларның, төсле эзләрнең, бизәк юлларының берсе. *Күлмәклектәге зәңгәр һәм кызыл буйлар.* □ [*Кыйналган картның җилкәсендә*] *ике буй булып камчы эзе каралып ята иде.* Г. Ибраһимов.

7. *махс.* Озатыла торган һәм озатылган җеп; тукыманың буйга (1 мәгъ.) сузылган җепләре; *киресе:* аркау. *Киндернең буена да, аркавына да бер үк төрле җеп тоту.* □ *Ак тулалар тиз керешә, аркау-буе тигез эрләнсә.* Җыр.

8. *с. мәгъ.* Буйга (1 мәгъ.) таба юнәлештә урнашкан. *Буй сызыклар төшкән ситсы. Буй сәке. Өйнең буй бүрәнәләре.* □ [*Егет*] *буй урам белән әкрен генә төшеп китте.* И. Гази.

9. *с. мәгъ.* Сузылып-озынаеп тора торган, озын; буйга (1 мәгъ.) таба үскән (сабаклар, көүсәләр һ. б. ш. турында). *Буй камышлар, буй курайлар, Җиргә бөгелеп сындылар.* Н. Исәнбәт. // Буйга, гәүдәгә үскән, җиткән (яшьләр турында). *Буй кызлар сабынлап керләр уып, Агарталар Иделдә юып.* Г. Сәмитова.

◇ **Буй бирмәү**—буйсынмау, санламау. **Буй буйга җитү** *сир.*— гәүдәгә, буйга үсеп җитү. [*Габбас*] *кече яшьтән үзебезнең фәкыйрьлек аркасында дөньяның рәхәтен күрмәде. Буе буйга җитә башлагач, авыр эшкә чумды.* Ш. Камал. **Буй бөгү** — *к.* бил бөгү. *Пугачау патшаны күрсә идең, Алларыннан буй бөгеп узса идең.* Г. Әпсәләмов. **Буй пычкы** — буйга яра торган пычкы. **Буй тарту** — гәүдәгә, буйга үсеп китү. *Буй тартсансың, тазаргансың, улым, күз генә тимәсен.* Г. Гобәй. **Буй үстерү** — гәүдәгә, буйга үсеп җитеп балигъ булу. — *Бер егетне карата алмый, Буй үстермәм кыз булып.* Г. Ибраһимов. **Буй җитү** — 1) үрелгәндә кул җитәрлек булу. *Габдулла верстак өстенә менеп басты һәм шүрлеккә үрелде. Юк, болай гына буй җитәрлек түгел икән.* Ә. Фәйзи; 2) берәр нәрсәгә, максатка ирешү. *Егет бит бу,— диде начальник, хатынына Сәлимне мактарга тотынды.— Ләкин политбүлек бүләгенә буйлары җитмәде менә.* Г. Гобәй; 3) *к.* буйга җитү. *Арсландай ирләреннән башлап, мыексыз малайларга, буй җиткән кызларга хәтле, - - - әле «Әпипә»гә, әле «Барыня»га басып, бөтен Аланбашны ду китерәләр иде.* Г. Бәширов. **Буйга узу** — йөкле булу. *Бертөрле дә авыруың юк синең. Син бары буйга гына узгансың, кызым, буйга.* А. Шамов. **Буйга җитү** — гәүдәгә, буйга җитеп балигъ булу. *Хәйретдин үсеп буйга җитә, 17—18 яшьлек таза гына егеткә әйләнә.* М. Гали. **Буйдан-буйга** — бөтен буена, бер баштан икенчесенә кадәр. *Сәхнә алды. Буйдан-буйга ак чыбылдык корулы.* Н. Исәнбәт. [*Боз өстендә шуучы малайлар*] *елганың урта бер җиреннән буеннан-буена чабышып йөриләр.* Г. Галиев.

БУЙ-БУЙ *с.* Буй сызыклары, бизәк юллары булган; буйлы (берәр өслек, тукыма һ. б. ш. турында). *Буй-буй күлмәк.* □ [*Кәбир*] *яшелле-кызыллы буй-буй ефәк чапанны җилбәгәй җибәреп киеп алган.* Ә. Фәйзи. *Өстәлләрем буй-буй такта, Гөлләрем урам якта. Якты йолдызларга карыйм Сине сагынган чакта.* Җыр.

БУ'ЙВОЛ *и.* Эре мөгезлеләр семьялыгыннан кыска муенлы, зур башлы, кыска аяклы күшәүче хайван (йорт терлеге буларак үрчетелә).

БУЙДАК *с.* 1. Өйләнмәгән (гадәттә яше узган кешегә карата). *Буйдак ир.*□ — *Мин әле буйдак егет.* К. Нәҗми.

2. *и. мәгъ.* Өйләнмәгән кеше. *Монда семьялы кешеләр генә торалар, сез әнә теге буйдаклар тора торган казармага барыгыз.* М. Гафури.

БУЙДАКЛЫК *и.* Буйдак кеше хәле; семьясыз тормыш. *Яшь килен белән яшь кияүләрнең кайберләре буйдаклык рәхәтен җуйган беренче көннәрендә үзгәреп, аптырап киткәнне күргән дә бар.* Каз. утл.

БУЙЛАП *баш килеш бәйл. к.* буенча (1—3 мәгъ.). *Идел буйлап саллар ага.* Н. Исәнбәт. *Карачгы шахталарда эшләгәндә, мин 8—9 ел буйлап, аны һаман элекке еллардагы кебек дип уйлап, акча җибәреп тордым.* Һ. Такташ. *Песи колга буйлап - - - җиргә төште.* Г. Галиев. // Буеннан, яныннан, кырыеннан, янәшәдән. *Урман буйлап бару.* □ *Уң якта стена буйлап, уң һәм арт як диварга беркетеп, киң сәке ясалган.* Ф. Бурнаш.

БУЙЛАТА, БУЙЛАТЫП *баш килеш бәйл. к.* буенча (1—3 мәгъ). *Без урам буйлата йөгердек.* Ш. Камал. *Юл буйлатып, тиргә батып, Чаптар ат чабып бара.* Ә. Ерикәй. // Буеннан, яныннан, кырыеннан, янәшәдән. *Яр буйлата бару.* □ *Елга буйлатып, яшәрә башлаган тау кырыеннан акрын гына сыер көтүе үтеп бара.* Г. Бәширов. *Бәрәңге кыры буйлата бер егермеутыз адым баргач, Миңсылуларның өе.* Г. Минский.

БУЙЛАУ *ф.* 1. Җирне-урынны, мәйданны буйга үтү, бер башыннан икенчесенә таба бару. *Совет илен буйлаган да, аркылаган да кеше инде ул безнең Садыйк абзый.* А. Алиш. *Нинди бит безнең кырлар!— Аларны пионерлар Яздан бирле буйлыйлар, Һаман күреп туймыйлар.* Ә. Юныс.

2. Төпкә басып, атлап бару (суда). *Сай җирдән, йөзмичә, буйлап кына бару.*

3. *махс.* Әйбернең буй юнәлешендә берәр нәрсә (тасма һ. б. ш.) тоту, тегү. *Тәрәзә төбем роза гөл, Лента белән буйлыймын.* Җыр.

4. Тотучыга буйсынмыйча чабу (ат турында).

БУЙЛЫ *с.* 1. Буй сызыклары-бизәкләре булган; буй-буй. *Буйлы халат.* □ — *Әнә шул буйлы материалдан бер чалбар белән бер пинҗәклек бирергә кирәк аңа.* Ш. Маннур. *Сәмигулла абзый капка төбенә якынаеп килә иде. Буйлы-буйлы ак күлмәген кигән, аягында яңа галош.* М. Шәрифуллин.

2. Озын, таза гәүдәле. *Буйлы егет.* □ *Ул буйлы булса да, кайбер кинәт үсеп киткән кызлар кебек котсыз сузан, юка кыз түгел иде.* А. Гыйләҗев.

БУЙЛЫГЫ *бәйл.* Баш һәм иялек килешендәге сүзләрдән соң килеп, «озынлыгы», «буе», «шуның кадәр» дигәнне белдерә. [*Шүрәленең*] *урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.* Г. Тукай. [*Газинур:*] *Әнисе төпчек малайның буен тегәрҗеп белән үлчәп җибәргән. Менә карагыз, карабин буйлыгы инде.* Г. Әпсәләмов.

БУЙЛЫЙ *бәйл. сөйл. к.* буенча 1. *Алар да Илдар кебек авыл буйлый чабып йөри-йөри әлсерәп беткәннәр.* Г. Гобәй.

БУЙЛЫК *и.* 1. Төзелештә: буйга салына-куела, шуңа китә торган материал (агач һ. б.).

2. Киндер сугуда: буй җебе; *киресе:* аркаулык. *Буйлык эрләү.*

БУЙЛЫ-СЫНЛЫ *с.* Килеш, төз гәүдәле, гадәттә озын буйлы. *Буйлы-сынлы егет.* □ [*Ул кеше*] *үзе сүзгә йомшак, буйлы-сынлы гына картрак сәүдәгәр икән.* М. Гали.

БУЙ-СЫН *җыйд. и.* Гәүдә, аның килеш-килбәте (кешедә). *Буе-сыны килешле кыз.* □ *Фәхринең ни җире килми? Аның кай төше Зыядан ким? Буйга-сынга Зыядан шәп, төскә чибәр.* Г. Ибраһимов.

БУЙСЫНУ *ф.* 1. Политик яктан бәйле хәлгә төшү. // Берәүнең хакимлеге астында булу, аның властена, хөкеменә бәйле булу. *Далай ханга ил буйсынган.* Н. Исәнбәт. // Берәр нәрсәгә бәйле булу яки бәйле хәлгә төшү. *Режимга буйсыну. Йолага бийсыну.* // Берәүгә яки берәр нәрсәгә бәйле буларак эш итү. *Алар-*

ның боерыкларына буйсынмый хәлем булмады. Ф. Әмирхан.

2. Берәүнең, берәр оешманың һ. б. ш. турыдан-туры җитәкчелеге астында булу, рәсми рәвештә аның карамагында тору. *Турыдан-туры үзәккә буйсынучы оешма.* □ *Югары авыл, Сазтамакларның һәрберсендә үз советлары бар иде. Алар сиңа* [*Кариле авыл советына*] *буйсынмый иде.* Э. Касыймов.

3. Берәүнең хөкеменә, ихтыярына, берәр нәрсә иркенә бирелү. *Болытлар, авылдан авылга ява-ява гүя бик арганнар, салкынча җил иркенә буйсынып, әкрен генә урманга таба китеп баралар иде.* Г. Гобәй. *Сәгъди абзый башына төшкән бу хәлгә тәмам буйсынган хәлдә бер сүз дә әйтә алмады.* Ә. Фәйзи. *Ат, тартылып-тартылып та ычкына алмагач, буйсынып, кинәт тынып калды.* А. Шамов.

БУЙЧА *и.* Берәр җирлек, фон өстендә бер үк юнәлештә сызылып киткән кыска сызыкларның, бизәк юлларының берсе; кыска гына буй. *Бәйләгән кофтаның кабарынкы буйчалары.*

БУЙЧАН *с.* Озын (гәүдә турында). *Муса каршына таррак җилкәле, буйчан гәүдәле - - - һәм озынча йөзле бер егет килеп кул бирде.* Ш. Маннур. *Капкада Солтанның буйчан гәүдәсе күренде.* А. Расих. // Озын буйлы. *Кара таудай буйчан Егет булдың син!* М. Җәлил. *Ул Зөфәрне үзенең улына охшата. Аның төсле үк буйчан буласы.* Л. Ихсанова.

БУКЕТ *и.* Чәчәк бәйләме. [*Уку башланган көнне*] *гөрләшеп, кулларына ал-кызыл букетлар тоткан балалар мәктәпләргә агылдылар.* Н. Дәүли.

БУКИНИСТ *и.* Файдалануда булган китаплар белән сату итүче. *Ул кунагын кабинетка чакырды, күптән түгел генә букинистлардан сатып алган сирәк очрый торган китапларын күрсәтте.* Г. Әпсәләмов.

БУКСИР *и.* 1. Үзе йөрми торган судноларны, саллары һ. б. йөзмә корылмаларны (баржа, кран, док, дебаркадер кебекләрне) тагып йөртүче катер яки бүтән үзйөрешле судно. *Коткару хезмәте үти торган буксирлар. Танкерларны этеп бара торган буксир.*

2. *с. мәгъ.* Су транспортын, йөзмә корылмаларны һ. б. ш. тагып йөртә торган (суднолар турында). *Буксир катер.* □ *Дебаркадер янында кузгалып китәргә әзер буксир пароход һәм озын муенлы йөзмә кран тора.* С. Сабиров. // Вакытлыча йөрешен югалткан коры җир транспорты машиналарына ярдәм күрсәтүче, аларны тагып сөйрәүче. *Буксир машина.*

◇ **Буксирга алу** — 1) буксирга (1 мәгъ.) тагу (баржаны, салны, пароходны һ. б.); 2) тагып сөйрәтү (вакытлыча йөрешен югалткан коры җир транспорты машиналарын). *Руле зарарланган автобусны буксирга алып гаражга кайтарып кую;* 3) эштә: артта калучыга ярдәм күрсәтү. [*Ишнияз:*] *Башта безне узып китмәсеннәр дип тырыштык, тырыштык та, инде алар артка калгач, буксирга алабызмы?* Р. Ишморат.

БУКСИРЛАУ *ф.* Йөзмә корылмаларны яки коры җир транспорты машиналарын буксирга тагу. *Баржаны буксирлап озату. Баткан машинаны буксирлап чыгару.*

БУКЧА *и.* Дәфтәр, китап һ. б. нәрсәләр салып йөртә торган киндер яки күн сумка. [*Хат ташучы*] *күн букчасыннан бер бәйләм хатлар чыгарды.* Ә. Еники. *Гайшә апа, эштән кайтып керүгә, өстәлдә Рөстәмнең китаплар букчасын күрде.* Г. Кутуй.

БУЛА *юн. килеш бәйл.* Сәбәпне, максатны белдереп, «аркасында», «өчен» дигән мәгънә аңлата (гадәттә кызыгу-кызыксыну, кирәксенү турында сөйләгәндә кулланыла). *Шушы һөнәренә була шәһәрнең теләсә кайсы клиникасында «Рәхим ит!» дип торуларын күргәч, Шәрәф этисенең чыннан да акыллы киңәш бирең калдыруын тагын бер кат аңлады.* Г. Минский. [*Колхоз председателе:*] *Материалларына була иске идарә йортын сүттереп ташлаткан идем.* Т. Гыйззәт. *Сез яшьлегегезгә була сөйлисез, Айдар.* Б. Камалов.

БУЛАВКА *и.* Нечкә тимер чыбыкны икегә бөгеп, бер очын инә кебек, икенчесен йозак сыман башлы итеп ясаган эләктергеч (тукыма нәрсәләрне кадап эләктереп кую өчен кулланыла). *Изү булавкасы.* □ *Бантик ясап, булавка белән бабасының түшенә кадап куйды* [*Илсөяр*]. Г. Гобәй.

БУЛАНУ *ф.* 1. Үзеннән пар чыгару, бөркү. *Бәрәңгеләр табак тулып, буланып торалар.* Г. Ибраһимов.

2. Парлану, пар тамчыларыннан дымлану. *Тәрәзә пыялалары буланган.* Ш. Камал.

БУЛАТ *и.* 1. Элек: кылыч, хәнҗәр һ. б. ш. салкын корал ясауга тотылган нык корыч.

2. *с. мәгъ.* Шундый корычтан ясалган. *Булат кылыч.*

БУЛАЧАК 1. *киләчәк заман хикәя һәм с. ф. к.* булу (1—21, 25 мәгъ.).

2. *и. мәгъ.* Киләчәк. *Ышанычым арта минем үзүземә, Өмит берлән карый башлыйм булачакка.* Г. Тукай.

БУЛГАН *с.* Эшчән, сәләтле; булдыклы, уңган. *Ялкаулансаң, егет, сөймәм. Кызлар булганны сөя.* Җыр. *Эшкә бик булган малай ул.* М. Гали.

БУЛГАНЛЫК *и.* Булган, булдыклы кешегә хас сыйфатлар.

БУЛДЫК *и. гадәттә тартымлы форм.* Булдыклылык, сәләтлелек. *Бариев, үзенчә, Баязитовның бар булдыгын сөйләп китте.* Б. Камалов.

БУЛДЫКЛЫ *с.* Эшлекле һәм сәләтле. *Шәфикъ карт исә бик булдыклы кеше, кулы нәрсә тотса, шуны белә; аның эшләмәгән эше, ясамаган нәрсәсе юк.* Г. Галиев. // Булдыклылыкны белдереп, күрсәтеп торган. *Эш турында сөйләгәндә,* [*Ибрайның*] *булдыклы кыяфәт күрсәтәсе килә.* М. Әмир.

БУЛДЫКЛЫЛАНУ *ф.* 1. Булдыклы булып кылану, үзенне булдыклы итеп күрсәтергә тырышу.

2. Булдыклы булып китү.

БУЛДЫКЛЫЛЫК *и.* Булдыклы булу, булдыклы кешегә хас сыйфатлар, эшлеклелек. [*Ул*] *Ватаны өчен бөтен көчен, бөтен булдыклылыгын, кирәк икән — җанын да кызганмый бирер.* А. Шамов. *Нәсимәне ул күп кенә яклары белән ярата иде. Бигрәк тә аның кыюлыгы, туры сүзлелеге һәм булдыклылыгы аңар ошый иде.* Ш. Камал.

БУЛДЫКСЫЗ *с.* Булдыра алмый торган, сәләтсез. *Әзергә хәзер үсү баланы булдыксыз, ялкау итә.* Г. Гобәй. *Мин үзем заманында булдыксыз кеше түгел идем. Кулымнан килмәгән эш юктыр.* С. Сабиров.

БУЛДЫРУ *ф.* 1. Барлыкка китерү, ясау, эшләү. *Без дусларча саубуллаштык һәм саубуллашкан чагыбызда моннан ары бернинди сугышларны да булдырмас өчен көрәшергә сүз бирдек.* Г. Минский. // Тормышка ашыру, үтәү (теләкне һ. б. ш.). *Әйткәнемне булдырмый калмам!* Г. Бәширов. *Теләгәнеңне булдырырга тырыш.* Г. Коләхметов.

2. Берәр нәрсәне эшләргә көч-сәләт җитү; эшли алу. *Аның кулыннан бөтен эш килә, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра.* А. Шамов. *Илсөяр тормакчы булып селкенеп куйды, булдыра алмады.* Г. Гобәй.

3. Өлгертү (аш-суны, мунчаны һ. б.). *Аш булдыру. Мунча булдыру.* □ *Ул самоварын тизрәк булдыру өчен ашыгып чыгып китте.* А. Расих.

БУЛКЫ *и. сөйл.* Гадәттә бодай онынан пешерелә торган озынча яки түгәрәк вак күмәч.— *Кәримҗан! Шул икраны бик калын итеп булки өстенә сылап бир әле!* Ф. Әмирхан.

БУЛМАГАН *с.* Булдыксыз, сәләтсез, җебегән. *Абзый! Абзый! Булмаган син, пешмәгән, Корсагың үскән, ә гакылың үсмәгән.* Г. Тукай.

БУЛМАС *с.* Тормышка ашмый торган, уңышлы тәмамлануы ышанычсыз булган; өметсез (эш, ният һ. б. ш.

турында). *Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр* [*көчләделәр*]. Г. Тукай. *Мин шуннан соң, булмас уйларымны «Язмыш» учагына аттым да - - - Тоттым да бер тальян гармун алдым.* Ш. Маннур.

БУЛУ *ф.* **1.** Чынбарлыкта яшәү, вакыт һәм пространство эчендә урын алып тору; бар булу. *Күктә ничә йолдыз булса, Безнең дуслар җирдә шул чаклы.* Ф. Кәрим. [*Рабига:*] *Нигә юкларны сөйлим, булганын да сөйләп бетерергә өлгермәдем әле.* М. Әмир. // Берәүгә мөнәсәбәтле рәвештә яшәү. *Халыкта була торган йолалар. Яныңда иптәшең булу. Берәр нәрсә эшләргә теләгең булу.* □ *Акбүз өчен аның* [*Мәрдәншаның*] *булудан булмавы артык.* Г. Гобәй. *Атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә бераз гаеп юк түгел.* Г. Камал. *Дәрте булса, шарты табыла.* Ш. Мөдәррис. // Милек һ. б. ш. сыйфатында яшәү; берәүнең карамагында, файдалануында тору. *Үз автомобилең булу. Театрга барганда биноклең булу.* □ *Бер әбинең ике әтәче булган.* А. Алиш. *Белгәне юан берне егар, белеме булган меңне егар.* Мәкаль.

2. Очрау, табылу, туры килү, килеп чыгу. *Мөмкинлек булмау.* □ *Ышанган тауда киек булмый.* Мәкаль. *Ул иртә үк торып, эш булмас микән дип, чыгып китте.* М. Гафури. *Син тагын бер-ике көн генә түз инде, Әхмәт иптәш, берәр комачау булгандыр* [*Мәдинәләрнең килә алмый торуына*]. Ш. Камал.

3. Барлыкка килү; ясалу. *Тама-тама күл була.* Мәкаль. *Ә соң он нәрсәдән була?* Г. Гобәй. *Соң, без авылдан киткәч, нинди үзгәрешләр булды?* Һ. Такташ. *Ярлы кешенең аягы тиз бозылмый, бик тиз ревматизм да булмый, дәвасыз-нисез бер-ике көндә үз алдына үзе бетә дә куядыр.* М. Гафури. // Яралу, туу, үсеп чыгу. *Менә зур, куе урман кечкенә генә орлыклардан булган түгелме?* Г. Коләхметов. *Шомырт чәчәкләрен өзәргә ярамый. - - - Өзгәч, шомырты булмый аның.* А. Шамов.

4. Үсү, уңу (иген һ. б. ш. турында). *Узган җәй күп җирдә ашлык булмаган, халык ачыккан.* М. Гали.

5. Әзер хәлгә килү, җитешү, өлгерү (аш-су һ. б. турында). *Мунчаның булганын көтеп томаламый тору.* □ *Хәзер аш була. Аннан киногa билет алып кайттым, анда да барасыбыз бар.* Т. Гыйззәт.— *Кая соң, мичем дә янып бетә, камырым да булган; әллә нишләп йөрим шунда.* Р. Төхфәтуллин. // Өлгереп җитү, җитлегү (ашлык, жиләк-җимеш һ. б. ш. турында). *Җирне карап кайттым; иртә чәчкәнгәдер, ахры, бик булган: берәр көн торганда ксела да башларлык.* М. Гали.

6. Булып узу, килеп чыгу, фактка әйләнү (төрле хәлләр, вакыйгалар, табигать күренешләре һ. б. ш. турында). *Көн саен була торган хәлләр. Күптән булган вакыйга.* □ *Ай арасында явымнар була.* Н. Исәнбәт.

7. Килү, җитү, урнашу (тәүлек, ел вакытлары һ. б. ш. турында). *Әллә соң мин йоклаганда кыш була башлаганмы?* Г. Галиев.

8. Тулу, узу (вакыт, срок һ. б. ш. турында). *Сәгать төгәл уникe булганны көтү.* □ *Син җаныйны күрмәгәнгә Бик күп көннәр булды инде.* Җыр. *Ул арада балага биш яшь ярым була.* Г. Гобәй.

9. Уңышлы тәмамлану, төгәлләнү (эш һ. б. ш. турында). [*Килделе-киттеле сөйләүчеләр*], *монда килеп, булып беткән эшне булмәкчеләр.* Г. Лотфи. [*Сәрбиҗамал — яучыга:*] *Эш була калса, боерган булса, сине читкә какмыйбыз инде, булсын гына инде, аннан соң сине бөтенләй башыңнан малга күмәрбез.* Г. Камал.

10. Үтәлү, тормышка ашу (теләк һ. б. ш. турында). *Менә ди, инде бу — бәхет йөзеге, кашына язылган олы исемне генә укыйсы: һәммә теләгең була! ди.* Ш. Камал.

11. Үткәрелү-оештырылу, үтәлү-башкарылу. *Ел да була торган бәйрәмнәр. Күптән булган бәхәсләр. Клубта концерт булу.* □ [*Минзәләдән*] *кайткач туйлары буласы ди.* Г. Камал. *Без сугышны үзебез теләмибез; Була икән — каршы тору юлын белербез.* Һ. Такташ. // Игълан ителү, ясалу (белдерү һ. б. ш. турында). *Белдерүе булганнан соң озак торып кына куелган кино. Звонок булгач дәрескә керү. Һөҗүмгә приказ булганны көтү.* □ *Чакыру булса, без чабышып, Хәзер китәрбез.* Ф. Кәрим. *Булды гудок. Бетте эш.* Э. Юныс. // Бирелү (рөхсәт һ. б. ш. турында). [*Газиз:*] *Мин инде, әни, әгәр сезнең рөхсәтегез булса, быел - - - өйләнергә дибрәк ниятләнеп йөри идем.* Г. Бәширов.

12. Барып-килеп җитү, ирешү, ишетелү; әйтелү (хатхәбәр, җавап һ. б. ш. турында). *Фронттагы сугышчыдан озак кына хат булмый тору. Докладтан соң сораулар булу.* □ [*Басуда урак уручы Гариф:*] *Башлаган җирне бетереп кайтканда шәп булыр иде дә, ләкин бу* [*сугыш турындагы*] *хәбәр булгач, кул эшкә бармый.* М. Гафури.— *Зоя, ач әле,*— [*дидек*]. *Әмтән җавап булмады.* М. Әмир.

13. Йомыш йомышлау өчен яки бүтән максат белән берәр җиргә бару, берәр кеше янына керү. *Театрда булу. Чит илдә булып кайту. Директорда еш булу.* □ *Докторда булдыгызмы?* Г. Тукай. *Уфа ягында булганың бармы?* И. Гази. // Җыелышта һ. б. ш. катнашу. *Мәҗлестә булу.* □ *Була калсаң сугышларда, Арслан күк бул.* Э. Исхак. *Маслов губком бюросы утырышында булу сәбәпле, Һидият аны барган көнендә күрә алмаган.* Ш. Камал. // Вакытны белдергән сүзләрдән соң: берәр җирдә шуныңча вакыт үткәрү, тору. *Курортта ике атна гына булу.* □ *Без анда озак тормыйбыз, ике, өч, күп булса, дүрт көн булырбыз.* Г. Ибраһимов.

14. *күч. сөйл.* Мораль яктан бозылу. *Малайның булуы җиткән: авызда папирос, башта кепканың тар козыреклысы.* Г. Гобәй.

15. Әзерләнеп бетү; берәр җиргә барырга яки берәр нәрсә эшләргә әзер хәлгә килү. *Я, кызым, булдыңмы?* М. Фәйзи. [*Вәли Гафифәгә:*] *Булдыңмы әле син, аппагым, әйдә алайса киттек инде, былбылым!* Г. Камал.

16. Чагыштыру сүзләреннән соң: тоелу. *Тәрәзәдә ут күренгән шикелле булды, әллә шырпы сыздылар инде.* Г. Гобәй.

17. «Тиз» һ. б. ш. ашыгуны белдергән сүзләрдән соң, эш-хәрәкәт фигыльләрен алмаштырып кулланыла. *Тиз бул әле, тиз бул, Сарык! Капчыктагы бүре башын китер алып.* Г. Тукай. — *Әниләре, җәһәтрәк булсаң икән; кунакларның карыны ачкандыр.* Б. Камалов.

18. Тартымлы исемнән соң: тәэсир итү, йогынты ясау; нәтиҗә бирү; тию (файда, зарар һ. б. ш. турында). *Файдасы булсын өчен, даруны врач киңәше буенча гына* □ *Кызга ишеттерергә кушып, каты-каты сүзләр әйтеп карады* [*кияү*] — *берсенең дә файдасы булмады.* М. Әмир.— *Бар нәрсәсен төяп алып китсен. Соңыннан миңа бәласе булмасын.* Г. Камал.

19. Юн. килешендәге тәмамлыктан соң: берәүнең милкенә әйләнү яки карамагына күчү. *Менә хәзер кызыбыз җиткән, сандык әйбере әзерләр хәл юк. Боларны аңа булыр дип саклап тора идем, диде Гөлгенә түти.* М. Гали. *Өзелеп сөярмен, Үземә булсаң гына.* Җыр.

20. Чыг. килешендәге тәмамлыктан яки иясез җөмләдәге *-п, -рга, -са* форм. соң: «булдыра алу», «көч, сәләт, мөмкинлек җитү», «хәлдән килү» дигәнне белдерә. *Миннән буламы соң... диде ул үзенә үзе һәм уңайсызланып аска карады.* Г. Гобәй. *Бар авырлыкларны да җиңеп була.* А. Алиш. *Мондый батырлар барында Җиңәргә була.* Э. Исхак.

21. Иярчен вакыт җөмләдә тартымлы исем фигыльдән соң: берсе икенчесе артыннан ук килгән эш-хәлләрне атаганда «шунда ук», «хәзер үк», «тиз генә» дигәнне белдерә. *Хафиз абыйларын күрүләре була, балалар уеннарын да оныталар.* Л. Ихсанова. *Гашыйк була башладым бугай диюе булды, Гөлнар җаный - - - дип кочаклап алдым үзен.* Э. Айдар.

22. Иясез җөмләдә: «җитте, җитәр, шулай ярар, бүтән кирәкми» дигәнне белдерә. *Зариф абзый тагын кунакларның чынаякларына үрелде. Ләкин Җиһанша абзый чынаягын учы белән каплады: — Булды, Зариф, рәхмәт.* Ә. Еники.

23. *юкл. форм.* Иясез җөмләдә: «мөмкин түгел, ярамый» дигәнне белдерә. *Кызлар белән егет барда уен-көлкесез булмас.* Г. Тукай.— [*Зыяның комиссиядә*] *караласы бар. Анда да акча тотмый булмас.* Г. Ибраһимов.

24. *-Макчы, -мак, -ачак, -мас, -р, -рдай* форм. соң: ниятләүне, теләүне белдерә. *Аллар алырдай булам, гөлләр алырдай булам.* Җыр. — *Кая бармакчы буласыз?* Ш. Усманов. *Шүрәле фөрьят итәдер, аудан ычкынмак була һәм дә, ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була.* Г. Тукай. *Егет бер күл буена туктаган да шунда яшел чирәм өстенә ятып ял итмәкче булган.* Г. Гали. *Ике көннән кайтачак булып, каядыр киткән иде ул.* Г. Ибраһимов. [*Кыз — егеткә:*] *Алмас булсаң, минем исемне чыгарып йөрер булсаң, мине күрү түгел, хат та язма.* М. Гафури.

25. *-Нда, -да* форм. соң: «дәвам итү» дигәнне белдерә. *Хәмит, авызына су капкандай, һич сүзсез алдына карап утыруында булды.* А. Расих. — *Барыгыз, юлыгызда булыгыз.* Т. Гыйззәт.

26. *-Рга* форм. соң: «карар итү, берәр фикергә килү», «килешенү, сүз куешу» дигәнне белдерә. *Вокзалда җыелырга булу. Кино янында очрашырга булу.* □ *Бу хатны аның аркылы җибәрергә булдым.* М. Җәлил. *Донбасска китәргә булдым.* Һ. Такташ. // «Сүз, вәгъдә бирү», «ышандыру» дигәнне белдерә. *Директор яңа салына торган йорттан бүлмә бирергә булды.* Х. Җәмил.

27. *-Сы* форм. соң: зарурлыкны, кирәклекне белдерә. *Сөйсәң ярның сөй матурын, Сөйгәч аласы була.* Җыр. *Кая, әйтәсе сүзегез булса әйтегез дә, әзерләнәсе булыр* [*спектакльгә*]. Г. Бәширов. // *юклык боерык ф. форм.* Катгый тыюны белдерә. [*Хатыны — иренә:*] *Киявүне тынычлыкта калдыр, күзенә күренеп йөрисе булма!* Ә. Еники.— *Үз ихтыярыңны буасы булма!* Ә. Кәмал.

28. Диалогта, җөмлә формасында килеп, ризалашуны, килешүне белдерә. [*Сидоров:*] *Мин Сезне рус теленә өйрәтермен, ә Сез мине татарчага өйрәтерсез. Булмы?* [*Нәдерша:*] *Була.* И. Туктар. [*Председатель — бригадирга:*] *Ярый, булды, сөйләштек. Эшләгез.* Г. Бәширов.

29. була, булды. «Димәк», «дигән сүз» мәгънәсен белдерә.— *Алмыйм дигәч, алмыйм була. Зинһар юкка бәйләнмәгез.* Г. Колэхметов. [*Әтисе — улы турында:*] *Бер булып китте, өч булып кайтамыни?* [*Сәхибә:*] *Үрчеп кайта була инде.* А. Әхмәт.— *Малик бик гайрәт чәчә икән. «Кызыллар белән китеп олакмаган булсалар, мин аларны, ягъни синең белән мине була инде,— диде Шәрифҗан* [*Якупка*],— *урам чатына асып куйдырткан булыр идем дип әйтә ди».* И. Гази.

30. булдымы. Гадәттә эш-хәлләрне санап күрсәткәндә, «әйеме», «аңлашылдымы», «шулай бит?» дигәнне белдерә. — *Ничек итеп* [*атны тәрбиялиләр*] *дисеңме? Беренче әтәчтә торып, --- яхшы иттереп болгатып бирәсең; икенче әтәчтә чыгып, мин сиңа әйтсәм әйтим, һәйбәтләп сипләп бирәсең. Булдымы? Аннары да күңел тыныч түгел әле синең...* Г. Бәширов.

31. *кер. сүз функ.* **булмаса.** Фигыль янында кулланылып, «шулай итү хәерлерәк булыр» дигәнне белдерә. *Булмаса, кайтыйк, карчык,* [*балык*] *чиртми башлады.* Г. Минский. *Йончырсың бит, бабай, кереп йокла, булмаса.* Г. Гобәй. // Һич югында, һич югы; алайса. *Булмаса, әйт, мәрхәмәтсез, кем син? Исемең кем синең?* Б. Рәхмәт. *Булмаса, синең кем булачагыңны үзем әйтеп бирим.* Г. Ибраһимов. // Яки, яисә. *Кем белә, бәлки, яшь егетнең кич кунарга, булмаса, чәйгә-фәләнгә килүе дә бик ихтимал.* А. Шамов. // Бәлки. [*Камилне, китәргә ашыкма, дип кыстаучы Сөләйман:*] *Син, булмаса, бүген төнге поезд белән китәрсең?* Һ. Такташ.

32. *бәйл. функ.* **буларак.** Баш килештәге исемнән соң кулланылып, «шул сәбәпле, шуның аркасында», «шулай булган өчен» дигәнне белдерә. *Партизаннарның күбесе, тайга аучылары буларак, кырыс тормышта ныгып яшәгән.* И. Туктар. *Без аны белгеч буларак та, кеше буларак та яратабыз.* И. Гази.

33. *бәйл. функ.* **булып.** Исемнәрдән соң: «сыйфатында, рәвешендә» дигәнне белдерә. *Былбыл булып гөлгә кунып Керәсең төшләремә.* Җыр. *Син миңа дус булып, абый булып, күпне күргән кеше булып әйт: нигә ул алай?* А. Расих. // «Хезмәтендә, эшендә» дигәнне белдерә. *Укытучы булып эшләү.* // Исемнәрдән һәм сыйфатлардан соң: «кебек, сыман, шикелле» дигәнне белдерә. *Әйбернең ерактан караганда бәләкәй булып күренүе.* □ *Ул яфраклар шундый вак һәм бөдрәләр, ерактан карагында нәкъ төтен булып күренә.* С. Баттал. // Исемнәрдән һәм алмашлыклардан соң: берәр нәрсәгә яки кешегә охшатырга, шуның кебек күренергә тырышып эшләүне, кылануны **белдерә.** *Театрда сәүдәгәр булып уйнау.* □ *Күрше бүлмәдә кемнәрнеңдер ат булып кешнәүләре, кәжә булып мәэлдәүләре, бака булып бакылдаулары ишетелә иде.* И. Гази.

34. *кис. функ.* **булгач.** Кабатлап әйтелгән сүзләр арасында килеп, көчле басым ясауны белдерә. *Чүп булгач чүп инде. Ул таралып ятса да, тәртипкә салынса да — барыбер чүп.* Г. Тукай.— *Әйдә булгач әйдә!* Г. Бәширов.

35. *кис. функ. каб. форм.* **булсын.** Үзе караган сүзгә басым ясауны белдерә. *Моның игъланын урамда булсын, өйдә булсын, һәркем күргәндер дип уйлыйм.* Г. Тукай. *Балавыз хәленә җиткәч, арыш булсын, бодай булсын, үсүдән туктый.* Г. Гобәй.

36. *кис. функ.* **булып.** Гадәттә кабатлап ике исем арасында кулланылып, «хәтта» мәгънәсен белдерә. [*Сталинградта*] *һәммәсе янды, көйде, кара күмергә әйләнде. Тимер булып тимер бөгелде, корыч булып корыч тетелде. Әмма безнең совет сугышчысы анда да бирешмәде.* Г. Бәширов. *Мәдинә булып Мәдинә --- Борһанны мыскыл иткәндәй кәпрәеп торган була бит.* М. Хәсәнов.

37. *кис. функ.* **булыр.** Исемнән, алмашлыктан һәм хәзерге заман хикәя фигыльдән соң: чамалауны, фараз итүне белдереп, «-дыр» кисәкчәсен алмаштыра. [*Җинаятьчене Садыйктыр дип уйлаучы:*] *Бүтән беркем дә булмас — шул булыр. Шул Садыйк булыр.* Г. Ибраһимов. *Уйлый булыр бәлки, ул да Яшьлек көннәрен.* Н. Баян.

38. *ярд. ф. функ.* Кушма хәбәр составында: 1) әверелү, әйләнү. *Бу тычкан шул кадәр йөзгән, куерган сөт тә булган май.* Г. Тукай. *Бәпкәләр тәмам үрдәк булдылар.* А. Алиш. *Бара торгач, моңа бер тычкан очрый. Бу тычкан бер генә мәртәбә селкенә дә кеше була.* Әкият; 2) кушма исем-хәбәр ясау өчен генә кулланыла. *Кайда барсаң да тырыш бул, Тырыш егет хур булмас.* Җыр. *Бу егет абзаң булыр бу, Бик белеп тор син, энем.* Г. Тукай; 3) *-ган форм. соң:* «юри генә эшләү, кылану», «шулай күренү» дигәнне белдерә. *Йоклаган булып ятыу.* □ *Булат уйнап куган булды, Кочаклап алган булды, Фәйрүзәсе көлгән булды, Битен каплаган булды.* М. Җәлил. // Ниятне, эшне үтәргә тырышып та, өлешчә генә, башкалардан калышып кына башкару. *Һаман төйиләр. Хәлим дә селкенеп йөргән була. Ул инде арды, көчкә кыймылдый.* И. Гази. *Әтәч чебешләр --- канат кагалар, киерелеп-киерелеп кычкыралар, үзләренчә күңел ачкан булалар.* А. Алиш. // *җиңелчә ирония белән.* Нәтиҗәсезгә тырышу, кылану, маташу. [*Нәни Сәмига*] *өстәл башында иреннәрен бө-*

рештерә-бөрештерә сиңа хат язган була. Г. Әпсәләмов. *Була бит шундый кешеләр: үзләрен тотып селкесәң дә берни төшми, мәгәр чалбар туздырып, көн-төн* [*фән өстендә*] *җтырган булалар.* А. Расих.

39. *ярд. ф. функ.* Фигыльнең тезмә формаларын ясау өчен генә кулланыла. *Сине белмәгән булсам, хәзер онытуга караганда нинди яхшы булган булыр иде, диләр.* А. Шамов. *Бер популяр китап чыкты. Анда җирнең һәм бүтән планеталарның бөтерелеп торган кайнар газдан яралган булуы турында әйтелә.* И. Гази. *Мәдинә хәзерлек эшләрен тәмамлаган булса, эшкә хәзер үк керешәбез, диде Рәхим.* А. Расих. *Җыентыкка чын халык җырлары җыелган булырга тиеш.* М. Җәлил.

◇ **Була ул** *диалогта* — ярый, яхшы, әйткәнегез үтәлер. [*Мостафа:*] *Оештыру эшен син алып барырсың.* [*Сәләхи:*] *Була ул.* Ш. Камал. **Булмаса булган икән** — тәвәккәлләп. **Булса (булырга) кирәк** — ихтимал, мөгаен. *Яңа килгән булырга кирәк, бүген монда яшь, матур бер студент күренә.* Ф. Әмирхан. *Күрәсеңме, машинага нинди гажәпләнеп карап торалар, беренче тапкыр күрәләр булса кирәк.* А. Шамов. **Булсын дип эшләү (тырышу), булсынга йөрү** — яхшы эшләү, чын күңелдән тырышу. [*Колхозчылар*] *көчләрен кызганмадылар, һәйбәт эшләделәр. Булсын дип тырыштылар.* Г. Бәширов. [*Ибрай*] *бер дә булсынга йөргән кебек түгел.* Г. Гобәй.

БУЛЫШ *и. сөйл. кыек килешләрдә. к.* булышлык, ярдәм. *Гөлйөзем, әйдә булышка!* М. Фәйзи. *Кирәк булса, үзебез дә булышка килеп җитәрбез.* Г. Әпсәләмов.

БУЛЫШЛЫК *и.* Ярдәм. *Әгәр безгә булышлык килеп өлгергәнче патроннарыбыз бетсә?* К. Нәҗми. *Ул һәрвакыт кулыннан килгән булышлыкны күрсәтә.* Г. Садрый.

БУЛЫШЛЫКЛЫ *с. сир.* Булышлык итәргә әзер торучы, ярдәмчел. *Булышлыклы кеше.*

БУЛЫШУ I *ф.* Ярдәм итү. *Наиләгә чанадан торырга булыштым.* Ә. Еники. *Ялкынлы сүз, дәртле җыр дошманны җиңәргә бик каты булышты.* И. Гази.

БУЛЫШУ II *ф.* **1.** Берәр нәрсә яки кеше белән мавыгып китеп, шуның белән озак мәшгуль булу. *Бер кунак белән булышып, икенчесен белми дә калганмын.* М. Фәйзи. *Ул шундый уйлар белән булышканда, аның янына --- бер кечкенә генә кеше килеп утырды.* А. Расих.

2. Берәр кешегә бәйләнү, аны борчу. [*Шәмсия:*] *Кирәкмәс иде, карт. Гомереңә шул кеше белән булышуыңны ташламыйсың.* Т. Гыйззәт. [*Хуҗа Ахунга:*] *Моннан соң, минем эшемә тыгылып, минем белән булышмассыңмы?* Н. Исәнбәт.

БУЛЫШЧЫ *и.* Булышлык күрсәтүче, булышучы; ярдәмче.— *Минем эш кечкенә, мин булышчы гына.* Ә. Камал. *Цехта егерме биш көн генә булышчы эшче булып эшләгәннән соң, Фәнүзә зур осталык һәм тәҗрибә таләп итә торган эшкә күчерелде.* М. Максуд.

БУЛЫШЧЫЛЫК *и.* Булышчы вазифасы, хезмәте; ярдәмчелек. *Рәмиевнең үтенүе буенча, вакытча аңа булышчылыкны кабул иттем.* М. Фәйзи. [*Ишанның*] *ялшы хатыны Кәримә ирен тентешүгә булышчылык кылып йөри.* Г. Нигъмәти.

БУЛЬВАР *и.* Шәһәр урамындагы киң аллея. *Ул бульвар рәшәткәсе янында аз гына тукталып торды да түбән елга буенча төшеп китте.* Ш. Камал. *Саф-саф агачлы, мул чәчәкле бульвар. Бульварда бала-чага.* Р. Төхфәтуллин.

БУЛЬДОГ *и.* Зур гәүдәле, киң күкрәкле, юан кыска аяклы һәм эре казналыклы, тупикъ борынлы махсус токым эте.

БУЛЬДО'ЗЕР *и.* Тракторга һ. б. ш. асылма киң көрәк сыман җайланма беркетелгән үзйөрешле машина (юллар, каналлар төзү-төзәтү кебек эшләрдә җир казу, тигезләү, туфрак катламын күчерү һ. б. ш. өчен файдаланыла). *Юлларга бульдозерлар чыгып китә; дистәләгән километр юлны кардан арчып, юлның ике ягына кар тауларын өеп баралар.* Г. Ахунов. *Бульдозер тирес катламнарын актарып бер җиргә уңай гына өя барды, ә өч-дүрт машина әлеге ашламаларны басуга өзлексез ташый торды.* М. Шабай.

БУЛЬДО'ЗЕРЧЫ *и.* Бульдозер йөртүче.

БУМА *и.* **1.** Кинәт буыла башлау, тән җыерылу-калтырану һәм һуш китү кебек өянәкләр рәвешендә була торган чир; эпилепсия. *Бума зәхмәтенә дучар булган Габдрахман хәлфәнең бумасы тотып, маңгаена пуля кергән кеше төсле авып китте дә авызыннан күбекләр чыгарырга кереште.* К. Тинчурин. [*Мөнәвәрә*] *ах-вах итте дә идәнгә сузылып ятты. Мин әйтәм, бетте баш, моның бумасы килде инде дим.* А. Расих.

2. *с. мәгъ.* Буылдыра, сулышны буа торган (ютәл турында). *Коридор ишеге ачылып, бума ютәлле берәү күрше бүлмәгә кереп китте.* К. Нәҗми.

БУМА'ҖНИК *и.* Документ, акча-мазар салып кесәдә йөртә торган кечкенә букча. *Яраланыр алдыннан Назимовның кесәсендә - - - бумажнигы, бумажнигында хатыны белән кызының рәсеме, Кадриянең соңгы хаты бар иде.* Г. Әпсәләмов.

БУМАЗИ *и.* **1.** Бер ягы йомшак төкле киҗе-мамык тукыма.

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Шакмаклы бумази күлмәк.* ▭ *Ул башына малахай бүреген, өстенә бумази бишмәтен кигән иде.* А. Алиш.

БУМАЛЫ *с.* Бума авырулы. *Бумалы кеше.*

БУМЕРАНГ *и.* Оста җибәргәндә, билгеләнгән җиргә тиеп кире кайта торган, бөгелгән таяк сыман ау коралы (элек Көньяк Азия, Австралия, Африка халыкларында киң таралган булган). *Тугайларында йөргән, әрәмәләрендә җиләк-җимешләрен авыз иткән, суында коенган --- кеше Ык буйларын оныта аламы? Сөйләп туя аламы соң? Ул анда бумеранг шикелле әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта.* М. Шабаев.

БУ'НДЕСВЕР *и.* Германия Федератив Республикасында: армия, кораллы көчләр.

БУ'НДЕСТАГ *и.* Германия Федератив Республикасында: федераль парламент (вәкиллекле иң югары орган).

БУ'НКЕР *и.* Бөртекле, кисәкле, кантарлы һ. б. ш. (ашлык, бәрәңге, ком, цемент, ташкүмер, руда кебек) чәчелә-коела торган йөкне ташу яки вакытлы саклау өчен булган, үзе бушатыла торган махсус зур савыт-җайланма. *Комбайн бункеры.* ▭ [*Фермада*] *азык транспортерлар белән өскә бирелә. Тамыразыклар бункерга элеккәнче юылалар.* М. Хәсәнов. // Судноларда: каты ягулык саклый торган бүлем.

БУНТ *и. сөйл.* Стихияле баш күтәрү, властька каршы чыгу; фетнә.— *Әй, староста, бу бунтны башлап кемнәр чыгарды? Исемнәрен әйт.* Г. Тукай.

БУНТА'РЬ *с. кит.* Һәрвакыт ризасызлык белдереп, көрәшкә ашкынып-атлыгып торучы. *Эшнең төбен бунтарь, баш бирмәс табигатьле Хәбиптән күрделәр, кызыл фикердә аны гаепләделәр.* Г. Ибраһимов. *Бунтарь йөрәк кача тынлыктан.* Һ. Такташ. // Бунтарь кешегә хас (сүз һ. б. турында). *Габделбәкер абыйның бунтарь сүзләре тагын кайберәүләрнең телен ачты.* Г. Гобәй.

БУНТАРЬЛАНУ *ф. сөйл.* Киреләнеп, ризасызлык күрсәтеп тәртипсезләнү. *Ул чакта мин әле сыйфый көрәшне бөтен яклап аңламый идем, бунтарьлана гына идем.* Г. Әпсәләмов. *Бераз башына киткән булса, азрак бунтарьланып та куя* [*әти*]. Г. Гобәй.

БУНТАРЬЛЫК *и.* Бунтарь кешегә хас сыйфатлар. *Яңа, совет тормышының нигезе салынган елларда инде бунтарьлык түгел, бәлки аңлы революционерлык кирәк иде.* М. Максуд.

БУНТЧЫ *и.* Бунт оештыручы яки шунда катнашучы, фетнәче.

БУНЧУК *и. тар.* Казак атаманы, гетман һәм төрек солтанының власть билгесе: бер башына ат койрыгы бәйләнгән таяк сап.

БУП-БУШ *с., рәв. Артык дәр. к.* буш. *Буп-буш казанын дыңгырдатып, ишек алдына поход кухнясы килеп керде.* Г. Бәширов. [*Гәрәшә*] *ябыгып бетте инде. Кулмак якалары хәзер буп-буш.* Г. Толымбай.

БУР I *и. сөйл.* Йомшак ак известьташ. *Бур җитеп бетмәгәнгә квартир ремонтын кичектереп тору.*

БУР II *и.* Карак. *Бурны йөккә җибәрмә, мулланы йортка җибәрмә.* Мәкаль. *Бәйдәге эттән бурлар курыкмый.* Д. Аппакова.

БУР III *и. махс.* Җир токымнарын тишә торган махсус борау. *Ул, кул бурын алып,* [*шартлаткыч салу урынын*] *тишү эшенә кереште. Әмма бур эчкә керергә теләми. Ниндидер каты токым бурны киргә этәрә, бәреп чыгарырга теләгәндәй сиртмәләндерә.* Ә. Айдар.

-БУР- Кушма сүзләрнең состав өлеше сыйфатында җир токымнарын борауларга мөнәсәбәтле дигән мәгънә белдерә, мәсәлән: **бурмастер, турбобур, электробур, Әлмәтбурнефть** һ. б. ш.

БУРА I *и.* 1. Өй, мунча, кое һ. б. өчен бүрәнәдән, таштан дүрт почмаклап эшләнгән корылма. *Өй бурасы. Чишмә бурасы. Нарат бура.* □ [*Сөләйман*] *бер кулы белән баз авызының бурасына ябышты.* К. Тинчурин. *Кайсы гына коега карама, аның бурасы Ташлы тау ташлары белән буралган.* Г. Галиев.

2. Келәттә, амбарда ашлык салу өчен эшләнгән урыннарның, бүлемнәрнең берсе. *Бураларым шыгрым тулды, ди ул, Быел алган яңа ашлыктан.* С. Урайский. *Комиссиянең җитәкчесе, бура төбенә куллары белән тыгылып, орлык солысын учлап алды.* Г. Бәширов.

◇ **Бура батыру** — чишмәнең, коеның эчен бура белән ныгыту. *Чишмәләрне әрчетергә, бура батырырга кирәк дип уйлады ул.* И. Гази.

БУРА II *и. диал.* Уен (уйнаучылар ике төркемгә бүленеп, кыска таяк шакмакларны куелган җирләренә тәпәч ыргытып бәреп чыгаралар); *русчасы:* городки. *Бура уйнау.*

БУРАЗНА *и.* 1. Җир өстен сука яки сабан белән эшкәртүдән ясалган канаучык сыман чокыр; сай һәм тар гына ерым булып сузылган сөрү эзе. *Сабан артыннан кара беләү шикелле тигез, шома буразналар сызылып калды.* Г. Гобәй. *Жеп белән тигезләп сызылгандай туп-туры сузылып яткан бәрәңге буразналарына, андасанда күренеп калган карбыз җирләренә карый-карый барабыз.* А. Шамов // **Буразна!** Сабанга җигелгән атка буразнадан барырга кушып эндәшү сүзе. *На, на, хайван, буразна! дип, Син сукалап йөргән җирме ул?* З. Бәшири.

2. *күч.* Сөрүченең һәм гомумән игенченең эш урыны турында. *Без буразнага килгәндә Чулпан калыкмаган иде әле.* М. Җәлил. *Буразнада туган, буразнада үскән, җирне хөрмәтләгән, җирдән хөрмәтләнгән агайлар икмәк тәмен белгәләр.* М. Рафиков.

3. Буразнага охшап, җир өстен ермаклап торган сай чокыр. // Гомумән, берәр нәрсәнең өслеген ермаклап торган озынча эре сыр, буй җыерчык. *Ми кабыгындагы буразналар.* □ [*Сивашгагы*] *күбек буразнасы полкның барасы юлын кисеп тә чыкты, суегышчыларның аягына су бәрелә башлады.* Г. Бәширов. *Буразналар салды биткә еллар.* М. Хәсәен.

БУРАЗНАЛАУ *ф.* 1. Сука яки сабан белән буразна яру, буразна сызу.

2. Буразна сыман чокырлар ясап, җир өстен һ. б. ергалау-ермаклау. *Тау битләрен яңгыр сулары һәм язгы гөрләвекләр буразналап бетергән.* М. Хәсәнов.

БУРАЛАУ *ф.* 1. Бура кую, бура белән әйләндереп алу [коены һ. б. ш.]. *Чишмәне буралап кую.* □ *Юлдан бераз эчтәрәк, имән куаклары арасында, читән уреп буралаган бу кое ташландык бер хәлдә иде.* С. Рафиков.

2. Әченә буралар (1, 2 мәгъ.) ясау (келәтнең һ. б.).

3. *к.* бурау I. *Бер атна эчендә осталар бу өйне буралап, түбәсен ябып куйдылар.* Ә. Еники.

БУРАЛЫ *с.* Бура (1) белән әйләндереп алынган, бура куелган, буралап ясалган (кое, чишмә һ. б. ш. турында). *Елгадан ерак та түгел тыкрык турында буралы чишмә бар.* А. Гыйләҗев. *Ярты юлда буралы кое очраргa тиеш.* И. Гази.

БУРАН *и.* 1. Җилләп кар яву; кар өермәсе. *Буран чыгу. Март бураны.* □ *Кичкә таба гына әзрәк җил күтәрелде, кечкенә кисәкле йомшак ак мамыклар кебек кар ява башлады, аннан буран күтәрелде, хәзер инде каты җил бертуктаусыз кар белән уйный, аны туздыра, өйләргә, абзарларга, кибәннәргә китереп сылый, өя башлады.* Г. Ибраһимов. // *гадәттә тартымлы форм.* Җил белән күтәрелеп, бөтерелеп йөргән ком, тузан һ. б. ш. *Бичара яшь Агачны Кояш яндыра, я бозлы яңгыр кәефен ала, Я ком, туфрак бураны килеп, җиргә чаклы бөгеп, иелдереп китә.* Г. Тукай.

2. *күч., сөйл.* Гадәттә өй эчендә, бер үк коллектив кешеләре арасында була торган көчле гауга, ызгыш. *Китте тавыш, кузгалды буран, чыдап кына тор.* Ф. Хөсни.

3. *с. мәгъ.* Буранлы (көн, һава турында). *Бу ел кышлар бик буран, Жаныем, шәлеңне уран.* Г. Тукай. *Без таш өйдек шушы стенага Салкын буран, давыл көннәрне.* Н. Баян.

БУРАНЛАТУ *ф.* 1. *к.* буранлау. *Иртә белән буранлаткан иде.* Ш. Камал.

2. Кар, ком ише нәрсәләрне һавада тузгытып очырып тарату. *Ишек алдын буранлатып кар көрәү.*

БУРАНЛАУ *ф.* Буранлы булу (көн, һава турында). *Буранлап торган февраль иртәсе килде.* А. Расих. [*Кыш*] *кинәт кенә болыты белән ишелгәндәй бураннарга тотынды.* Соц. Тат. // Буран рәвешендә исү, яву, тузу (кар һ. б. турында). *Карның буранлап явуы.* □ [*Киселгән нарат*] *ак кар өстенә ауды. Йомшак, тапталмаган кар, буранлап, югары күтәрелде дә әкрен генә нарат өстенә яуды.* Г. Гобәй. // *з-сыз.* Көннең буранлы булуы турында. *Төнлә азрак буранлаган, юлга бераз себергән иде.* М. Гали. *Әле генә буранлап тора иде, шундук чалт аязып та китте.* Ф. Хөсни.

БУРАНЛЫ *с.* 1. Бураны булган, буранлап торган (көн һ. б. нәрсә турында). *Буранлы көн.* □ *Буранлы, авыр юлдан соң, Әхмәдулла бу өйдә үзен аеруча рәхәт һәм тыныч сизә.* А. Шамов. // Буран белән бергә була торган (җил һ. б. ш. турында). *Солдат төннәр буе үзәккә үтеп сызгырган буранлы җилдә --- сакта тора.* Ф. Кәрим. *Буранлы давыл кузгалды.* А. Алиш.

2. *күч.* Гаугалы, ызгышлы (җыелыш һ. б. ш. турында). *Юлда арып-талып килгән Мөслимованы шау-шулы, буранлы җыелыш тагын да ныграк арыткан иде.* Г. Ибраһим.

БУРАУ I *ф.* Бура итеп эшләү. *Бура бурау.* □ *Аска имән, өскә нарат куеп бурагач, бура бик таза була.* Г. Толымбай. *Авылның атаклы балта осталары Тимбикка йорт бурады, миччеләр мич чыгарды.* Г. Ахунов. // Бура итеп тезү, урнаштыру, беркетү (төзү материалын). *Безнең яшь гомеребез әй үтәдер Таш пулатларга таш бурап.* Бәет.

БУРАУ II *ф.* Бик көчле булу (буран турында). *Укереп бураган буран тәрәзәгә көрт өйгән.* Г. Минский. *Урамнары да караңгы, җитмәсә буран бурый башлады.* Г. Әпсәләмов. // *гадәттә хәл фигыль форм.* Бик нык буранлау (кар, җил һ. б. ш. турында). [*Кар*] *әйләнә-тирәне томалап, бурап яварга тотынды.* К. Нәҗми. *Бурап-бурап яуган ярмалы кар асфальт урамнарга калын түшәк булып ятты.* Б. Камалов. *Бурый-бурый Урамнарда Карлар ява.* Г. Латыйп.

БУРАЧЫ *и.* Бура бураучы; шул эшнең остасы. [*Кәбир*] *ишек алды ягына керде һәм бурачыларны карарга булды.* А. Гыйләҗев.

БУРГОМИСТР *и.* Кайбер Европа илләрендә һәм элекке Россиядә: шәһәр идарәсе башлыгы.

БУРГОМИ'СТРЛЫК *и.* Бургомистр хезмәте һәм вазифалары.

БУРҖУА *и.* 1. Буржуазия сыйныфы вәкиле. *Искәндәр бай эшчеләр файдасыннан бигрәк, үзенең генә корсагын үстереп, кесәсен юанайтырга яратучы буржуалардан булганлыктан, --- уналты сәгать хезмәт иттереп, сигез генә сәгать эштән бушата торган иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *җыйн.* Буржуазия. *Буржуа җәмгыяте. Буржуа язучысы.* □ *Буржуа тормышының нигезе җимерелде.* Г. Ибраһимов. *Буржуа кулыннан властьны алмый торып, сугышның тиз генә тукталуын көтәргә ярамый.* Ш. Камал.

БУРҖУАЗ *с.* 1. Буржуазиягә хас. *Буржуаз семья.* □ *Кара реакция аңарда [язучыда] --- тирә-як буржуаз мөнәсәбәтләргә, буржуа җәмгыяте әхлакларына нәфрәт уятты.* М. Җәлил.

2. Буржуазия хакимлеген чагылдыра яки беркетә торган; аның интересларын яклый, тормышка ашыра торган. *Буржуаз революция. Буржуаз республика. Буржуаз демократия. Буржуаз матбугат. Буржуаз реформа. Буржуаз закон.*

БУРҖУАЗИ'Я *и.* Капиталистик җәмгыятьтә төп җитештерү коралларының һәм средстволарының хуҗасы булып, яллы хезмәтне эксплуатацияләү хисабына яшәүче хаким сыйныф. *Эре буржуазия. Либераль буржуазия. Сәүдә буржуазиясе.* □ *Буржуазия еллар, гасырлар буенча кешеләр миенә «хосусый милек изге» диген идеяне тукып килде.* М. Җәлил.

БУРҖУАЗЛАШУ *ф.* Буржуазиягә хас сыйфатларны алу; буржуазия сыйныфына күчү, шуның вәкиленә әйләнү. // Буржуазия тарафдарына әйләнү.

БУРҖУАЛАШУ *ф.* Буржуага әйләнү, буржуа булу.

БУРҖУАЛЫК *и.* Буржуа идеологиясе һәм карашлары; буржуага хас сыйфатлар.

БУРҖУАЧЫЛ *с. сир. к.* буржуаз. *Сәйдәшнең вак буржуачыл [эчтәлекле] музыкадан пролетариат музыкасына булган юлы — музыка үсешебездә характерлы юл иде.* М. Җәлил.

БУРҖУАЧЫЛЫК *и.* Буржуазия идеологиясе һәм карашлары; буржуага хас сыйфатлар. *Бу вакыт капитализм үзен бөтен халык исеменнән феодализмга каршы куйды. Бу заманның идеологиясендә, гыйлемендә, әдәбиятында, гәрчә ул буржуачылык нигезендә булса да, --- алга баручылык роле бар иде.* Г. Ибраһимов. // Буржуазия яклы булу. *Күп иптәшләр сине мактап сөйләделәр. Кайберләре сине буржуачылыкта гаепләделәр.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

БУРҖУЙ *и. гади с. к.* буржуа. *Буржуйларны тармар китердек.* Н. Баян. *Безнең өйдә элек буржуй торган.* Х. Туфан.

БУРЗАЙ *и.* Нечкә озын аяклы, очлаеп килгән озынча башлы ау эте. *Көз көннәрендә, аларның бурзай этләрен ияртеп, уҗым басуына куянга чыгуларны --- гомердә онытасым юк.* Г. Галиев. // *сөйл.* Гомумән, ау эте яки теләсә нинди зур гәүдәле, мәһабәт кыяфәтле эт. *Гыйльметдин койма аркылы төшмәкче булды. Бозау кадәре бурзай Гыйльметдиннең аякларына килеп ябышты.* И. Гази.

БУ'РКА I *и.* Кавказлыларда: җиңсез, плащ сыман киез кием. *Черкес буркасы.* □ *Йонлач бурка бөркәнгән, сөңге тоткан ике атлы урам буенча чабып узды.* И. Гази.

БУ'РКА II *и.* Тукымадан сырып тегелгән яки киез кунычлы, күн табанлы аяк киемс. *Ул Тукайны ялан баш, --- өстенә казакымы, җөппәмә кигән, аягында иске кара бурка булган хәлдә очратканын яза.* М. Гали.

БУРЛАК *и.* 1. Элек: елгаларда аркан белән пароход, баржа тартучылар артелендә эшләүче. *Элек Иделдә баржаларны бурлаклар тартып йөрткән.* С. Сабиров. // *иск. диал.* Хезмәтче, батрак; кара халык. *Таң аткан чакта Кузгала йокыдан бурлаклар, Күп үтми, ялтырап төрле якта, Сөйләшә башлыйлар ураклар. --- Урырга ябыша бурлаклар.* Н. Думави.

2. *иск. сөйл.* кыек килешләрдә. Бурлаклык. *Бурлакка китү. Бурлакта йөреп кайту.* □ *Гомере буе башы бурлактан кайтмаган Гаделшаның.* Г. Толымбай. *Кыш көне егетләр һәммәсе бурлакта.* Ф. Бурнаш.

БУРЛАКЛЫК *и.* Бурлаклар эше, шул кәсеп. *Ул зимагурлык, бурлаклык тормышы белән мәңгегә бәхилләшергә уйлый.* М. Гали.

БУРЛАНУ *ф.* Бурлы яки шуңа якын төскә керү; көрәнсу кызылга яки кызгылтка әйләнү. *Кулымдагы кулъяулыгым яңгыр тигәч бурлана.* Бәет. *Аның хәзер озак йөрүдән бите бурланып, сипкелләре югалып беткән.* Н. Исәнбәт. *Рәшә шушы дүрт-биш көн эчендә арышларны агартты, карабодайларны кызартты, солыларны бурландырды. --- Бу — уракка төшү алды көннәре иде.* Г. Галиев.

БУРЛАТ *и.* 1. Куе кызыл төс.

2. Куе кызыл төстәге тукыма.

3. *с. мәгъ.* Бурлаттан тегелгән, шуннан эшләнгән. *Бурлат күлмәк. Бурлат билбау.* □ *Бурлат чаршау шәүләсе [кызның] битенә төшә.* К. Нәҗми.

БУРЛАУ *ф. диал.* Бур белән агарту (стенаны һ. б.). *Тәтештәге казарманы Акбур белән бурлаган.* Бәет.

БУРЛЫ *с.* Кара яки кызыл өстендә бөртек-бөртек ак йоннары булган (гадәттә ат турында). *Бурлы бия.* □ *Туры бурлы булып туган кайбер колыннарның сабыйлык йоны бераздан соң тәңкә-тәңкә булып чуарлана башлый икән.* Г. Ибраһимов. *Ур куяны җәен бурлы төстәрәк була.* Н. Исәнбәт.

БУРЛЫК *и. сөйл.* Караклык. [*Биктимер:*] *Кешенең инәсенә дә тигәнем юк. Аны син дә, авыл халкы да белә.* [*Басарый:*] *Анысы шулай, ләкин менә бу капчык бурлыкны, караклыкны раслый түгелме?* Т. Гыйззәт.

БУРМИСТР *и. тар.* Крепостнойлык заманында: алпавыт хуҗалыгын идарә итүче яки крестьяннардан билгеләнгән староста.

БУРМИ'СТРЛЫК *и. тар.* Бурмистр вазифасы һәм хезмәте.

БУРОВОЙ *с.* 1. Җир токымнарын бораулау эшенә мөнәсәбәтле. *Буровой мастерның эше җирне бораулау түгелме соң?* А. Әхмәт.

2. *и. мәгъ. сөйл.* Скважина янындагы ярдәмче корылмалар (каланча һәм будка). *Төп игътибарны буровойны җиһазлау мәсьәләсенә юнәлтергә. Буровой телә-сә нинди тирәнлектәге скважиналар бораулаганда чыдарлык [булсын].* М. Хәсәнов.

БУРОВОЙЧЫ *и.* Җир токымнарын бораулауда яки шуңа мөнәсәбәтле башка эшләрдә эшләүче. *Бу бульдозерчы һәм буровойчы егетләрнең идеаллары бер.* К. Латыйпов.

БУРСАЛАНУ *ф. диал.* Борчылу, пошыну. *Картның соңгы сүзләрен шуңа [Сөләйманның качып йөрүенә] киная дип уйлап, ул бурсаланды.* К. Тинчурин.

БУРСУ *ф.* 1. Җиңелчә бозыла, күгәрә башлап исләнү, сөрсү (азык-төлек турында). *Җылырак җирдә озак торган майның бурсый башлавы.*

2. Дымланып күгәрү, бозылып чери башлау. *Биек, бурсыган такталы койма артыннан --- үбешү тавышы гына яңгырады.* А. Гыйләҗев.

3. Дым, төрле начар исләр катнашудан ник бөркүләнеп, сулау өчен авыраю (бүлмә, төрлек торагы һ. б. ш. һавасы турында). *Мәдинә, бөтенчә йөз ксшенең тирә-*

веннән бурсып киткән һаваны җилләтү өчен, --- тәрәзәне ачты. К. Нәҗми.

4. *күч.* Тирләп-кызышып тору, борчылу. *Гафиятулланың күзен йокы алмады. Әле бер ягына, әле икенчесенә әйләнеп, озак кына бурсып ятканнан соң, йоклап булмаслыгына тәмам ышанып, кинәт сикереп торды.* Ф. Хөсни.

БУРСЫК *и.* Сусарлар семьялыгына керүче, очлаеп килгән башлы, шыксыз гәүдәле, озын тупас куе йонлы ерткыч җәнлек. *Алачыкта бурсык ите ашап тик ятабыз.* Э. Айдар.

БУРТ *и. махс.* Суыктан-яңгырдан саклау өчен салам ише нәрсә белән ябып, озын итеп салынган бәрәңге-яшелчә өеме. *Колхоз бәрәңгесен буртларга салып кую.*

БУРЫЧ *и.* **1.** Түләп кайтару шарты белән бирелә-алына торган яки бирелгән-алынган нәрсә; бирәчәк яки алачак. [*Хафиз Хәкимгә:*] *Ике атна элек Рәшиттән егерме сум акча алып торган идем. Син, зинһар, минем шул бурычымны тапшырчы, менә. (Акча бирә.)* Р. Ишморат. *Ул безнең кебек ярлы шәкертләргә бирми, тик аталары бай булган ышанычлы шәкертләргә генә бурыч бирә.* М. Гафури. // Дәүләт йөкләмәсе буенча бирәчәк. *«Чулпан», үз гомерендә беренче мәртәбә, дәүләткә бурычын биреп бетерә алмыйча, бөтен район каршында оятка калды.* Г. Бәширов.

2. Берәү тарафыннан зарурый рәвештә үтәлергә тиешле эш. *Яшь чагында дөнья күрү ир егетнең бурычы диләр иде борынгы картлар.* Г. Әпсәләмов. *Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү — бөтен халык бурычы.* Соц. Тат. // Алда торган һәм үтәлергә тиеш булган конкрет бер эш, йөкләмә. *Безгә җаваплы бер бурыч тапшырыла.* М. Җәлил. *Разведка үзенең бурычын үтәде.* Ф. Хөсни. // Анык билгеләнгән максат. [*Автор үзенең алдына*] *драматик поэма тудыруны бурыч итеп куйган.* М. Җәлил. // Вазифа. *Рәис гадәт буенча аңа шәхеслек бурычларын аңлатты.* Г. Ибраһимов. *Шырпы белән уйнау минем бурычка керми керүен дә, шулай да якындарак торсын әле.* Ф. Хөсни.

◇ **Бурычка керү** — бурыч алу. *Мин сиңа бурычка болай чамасыз керергә киңәш бирмим.* Ф. Әмирхан.

БУРЫЧЛАНУ *ф.* Бурычка алу (керү), бурычлы булу. *Әсфәндияр байтак кына бурычланды.* Ш. Камал. *Кечкенә бала көннәремдә, һичбер эшкә ярамасам да, атам-анам мине киендереп, асрап үстерделәр. Аларга бурычландым, тәкъсир. Инде алар картайды, бер эшкә дә ярамыйлар. Ашатып, эчереп бурычымны түлим.* Дәрдмәнд.

БУРЫЧЛЫ *с.* **1.** Бурычы, бирәчәге булган. *Бурычлы Ярул кырыс күршегә, Гаепле Ярул аның каршында.* Ә. Юныс. *Бурычлы (кеше) үлмәс, чирле үләр.* Мәкаль.

2. *гадәттә хәб. функ.* Яхшылыкка каршы яхшылык эшләргә тиешле. *Мин мине кеше иткән, укыткан илемә, халкыма, партиямә бурычлы.* Ә. Камал. *Син мине коткарсаң, сиңа гомер буе бурычлы булырмын.* Әкият. // *Кушма хәбәр составында -рга форм. килгәндә:* тиешле, тиеш. *Сабыйларны без якларга бурычлыбыз.* З. Мансур. *Син аны, әлбәттә, эзләп табарга бурычлысың.* Н. Исәнбәт.

БУРЫЧЛЫЛЫК *и.* Бурычлы булу хәле.

БУРЫЧЧЫ *и. сир.* Бурыч бирүче; башкаларда алачагы булган кеше. *Эшчеләрнең акча ала торган бу билгеле көннәрендә завод капка төбе хатыннар белән тулы була иде. Болар башлыча икегә бүленәләр. Бер төрлесе — бурыччылар: квартир хуҗасы, кибетче, яшерен аракы сатучы кебекләр.* Г. Ибраһимов.

БУРЯТ *и.* Бурят АССРда яшәүче төп милләт вәкиле.

БУРЯ'ТЧА *рәв.* Бурят телендә. *Бурятча сөйләшү.* // *с. мәгъ.* Бурят телендәге. *Бурятча китап.*

БУСАГА *и.* **1.** Ишекнең яки тәрәзәнең аскы, яткырып салган борысы. *Ишек бусагасын атлап керү. Кәләт бусагасына утыру.* □ *Тәрәзәңнең бусагасы Бик киң микән, тар микән. Синең кебек матур ярлар Бу дөньяда бар микән.* Җыр.

2. *күч. кит.* Берәр нәрсәнең башланыр алды. [*Әсәрдә*] *тормышка яңа гына аяк басып килә торган, семья кору бусагасында әле үзара мәхәббәт тотып кына йөргән Коля, Нурулла, Соня, Гаделия бар.* Г. Иделле.

3. Су төбендә ташлардан барлыкка килгән, пароходлар һ. б. ш. йөрүгә комачаулый торган калкулык. *Днепр бусагалары.* □ *Бусагаларны үтүгә, Ангара, тараеп, актарыла-бөтерелә, ике биек яр уртасына килеп керә.* М. Хөсәен.

◇ **Бусага атлау** — өйгә һ. б. ш. керү. *Мәктәп бусагасын атлау. Завод бусагасын атлау.* **Бусага таптау** — берәр җиргә, берәүнең йортына үтенеч белән бик еш кереп йөрү.— *Кеше бусагасы таптап, җил куып йөрүнең мәгънәсе юк.* Ш. Камал. **Бусагага бару (килү)** — берәр җиргә, берәүнең йортына үтенеч белән керү. *Минем улларым бервакытта да андый үтенеч белән кеше бусагасына бармаслар.* А. Шамов.— *Синең бусагаңа килеп тезләнүчеләр күп булыр.* Г. Камал.

БУСАРЫНУ *ф. диал.* Пошынып газапланы, күңел борчылу. *Бу хәл Шәвәли картның янә көнчелек хисен котыртып җибәрде. --- Шул уйлары белән бусарынып йөргән чакта, кешеләр Шәвәли картны ашка чакырып алдылар.* Г. Ахунов.

БУССОЛЬ *и.* Магнит меридианы белән берәр юнәлеш арасындагы горизонталь почмакларны үлчи торган геодезик корал. *Тартмалы яки көзгеле буссоль. Асма буссоль.*

БУТ: бут ташы — төзелешкә (гадәттә фундамент салуга) китә торган таш. *Камай һәм Коркачы авыллары арасындагы бут ташы чыганагы.* □ [*Эшче — бригадирга:*] *Фундаментка җитәрлек бут ташын бүген китереп бетер инде.* Б. Камалов.

БУТАВЫЧ *и. к.* бутагыч.

БУТАГЫЧ *и.* Бутый, болгата торган җайланма яки корал; болгаткыч. *Илсөя, бер кулына май канаты, икенче кулына күкәй бутагыч тоткан килеш ишектән башын сузып, Шәмсигә ымлады.* Г. Мөхәммәтшин. *Экскаваторларның, бетон бутагычларның, туктаусыз килеп-китеп торган йөк автомобильләренең тавышлары, барысы бергә кушылып, тәртипсез шау-шу булып һавага күтәрелә.* А. Шамов.

БУТАЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* бутау I (1—4, 6 мәгъ.).

2. Чорналып, уралып хәрәкәткә комачаулау (итәкчабу һ. б. ш. турында). *Хәлим, буталып барган чалбар кесәләрен тотып, кызу-кызу атлый.* И. Гази. // Аякка яки гәүдәгә уралган, чорналган, эләккән берәр нәрсә (уңайсыз кием, үлән сабаклары һ. б.) аркасында хәрәкәт тоткарлану. *Мәгъсүмә талпынды, алга атлады, аяклары толып чабуларына буталды.* И. Гази.

3. Тирәдә, янда әрле-бирле тулганып йөрү. *Малайшалай гел Вәгыйзь тирәсендә бутала.* Э. Касыймов. [*Эт*] *ашарлык берәр нәрсә таммасмы дип янымда әрле-бирле буталып йөрергә тотынды.* С. Җәләл.

4. Бергә кушылып, тәртипсез аралашып бетү (кешеләр төркеме һ. б. турында). *Дүрт пар кунак, бер егет, бер апай, өч бала, шуның өстенә хуҗалар үзләре, аларның өч баласы бергә буталгач, йорт алды бер мәлгә ярминкәгә охшап калды.* Ә. Еники. // *шелт.* Берәү белән бәйләну, бәйләнешкә керү. [*Апасы — Сәлимәгә:*] *Бер кеше белән буталмадың, сабый бала кебек үстең.* Ш. Әхмәдиев.

5. Бәйләнеш, эзлеклелек югалу; чуалу (сүз, фикер һ. б. турында); ялгышу (эштә һ. б.). *Илгизәрнең сулышы кысыла, ул ашыга, аның сүзләре бутала иде.* Г. Бәширов. *Башында чуалып йөргән уйлары берәм-берәм бутала башлады.* Һ. Такташ. // Адашу. *Самолет ун*

минутлар чамасы томан эчендә буталып йөргәннән соң, кинәт, эчне кытыклап, югары күтәрелде. Г. Ахунов. *Штабны эзләп, шактый буталып йөрдем.* А. Шамов.

БУТАЛЧЫК *с.* 1. Буталып, тәртипсез хәлгә килгән; чуалган. *Буталчык төргәк.* // Тәртипсез, оештырылмаган (тормыш, режим һ. б. турында). *Мәдрәсә тормышы, андагы шәкертләрнең буталчык хәятлары* [*тормышы*] *һаман бер көе дәвам итте.* М. Гафури. *Бүгенге җыелыш болай да бик буталчык булды.* К. Нәҗми.

2. Бәйләнешсез, каршылыклы, аныҡ түгел, аңлау өчен кыен яки аңлаешсыз (сүз, хәбәр һ. б. ш. турында). *Буталчык җавап. Буталчык язма.* ▭ *Әле генә укып чыккан нәрсәләре аның башында томанлы һәм буталчык булып торалар иде.* Ф. Әмирхан. *Галимулла буталчык төш күрде.* К. Нәҗми.

3. Тынычсыз, борчулы (чор турында). *Буталчык заман.* ▭ [*Патша тарафдары:*] *Монархыбызның законнары ачык булса да, --- шушындый буталчык көннәрдә аларны тулысы белән кулланырга ярамый.* Т. Гыйззәт.

4. *и. мәгъ.* Ыгы-зыгылы тәртипсезлек, буталыш. *Семьялылар казармасындагы җанлылык бүген бөтенләй башкача. --- Нәрсәнедер ашыгып көткән вакытта гына була торган ашыгыч бер төрле буталчык күзгә ташлана.* М. Гафури. // Фикер буталчыклыгы. *Бу мәсьәлә бит авыл агайларының башына коточкыч буталчык кертәчәк.* И. Гази.

БУТАЛЧЫҠЛЫҠ *и.* Буталчык хәл; тәртипсезлек, ыгы-зыгы (хәрәкәттә, эштә һ. б. ш.); буталыш.

БУТАЛЫШ *и.* 1. Тәртипсез хәрәкәт, ыгы-зыгы (ишле төркемдә). *Кунаклар сафында буталыш башланды.* А. Алиш.

2. Ризасызлык белдереп ясалган гомуми чыгыш, чуалыш, баш күтәрү. *Мироныч әйтә: зур шәһәрләрдә тагын буталышлар бара ди.* Т. Гыйззәт.

БУТАЛЫШУ *ф.* Тәртипсез аралашу; ныҡ чуалып ыгы-зыгы килү (ишле төркем турында). *Кешеләр үзара буталышкан арада, мин тиз генә таеп өлгердем.* Ф. Хөсни.

БУТАУ I *ф.* 1. Төрле төрдән булган нәрсәләрне бер-берсенә кушып аралаштыру, болгату (гадәттә түгелә, чәчелә, изелә торган әйберләр турында). *Сыерларга башак бутап бирү.* ▭ *Кәлимуллин кисәүләрне бутаган таягын янып торган учакка ыргытты.* Г. Иделле.

2. Предметларның үзара урнашуындагы тәртипне бозу; чуалту. *Алдан, тантаналы атлап, рота командиры Акчурин, аның артыннан, сафларын бутап, бер-берсе белән сөйләшеп, --- илле-алтмыш кеше бара иде.* Ш. Усманов. // Ҡатлауландырып, аңлау-төшенү өчен кыенлаштыру, чуалту (мәсьәләне, эшне һ. б.). *Исәп-хисап эшләрен бутау.* ▭ [*Сәйфи*] *юри озын итеп, юри бутап биргән берәр хәйләкәр соравы белән бөтен халыкның башын әйләндерә.* Г. Бәширов. *Син бутама, карчык, эшне моннан болай, яме?* Ә. Фәйзи.

3. Кушарга-катнаштырырга, янәшә куярга тиеш булмаган нәрсәләрне ялгыш кушу, аралаштыру, бер рәткә кую. *Бу әсәрдә Нәҗминең төрле вакыйгаларны* [*әһәмиятләре төрле дәрәҗәдә булуына карамастан*] *бутап, аралаштырып йөртүе дә әллә ничек кенә урынсыз кебек тоела.* Г. Нигъмәти. // Ҡатнаштыру, тарту (исемне, кешене берәр күңелсез эшкә һ. б.).— *Зинһар дип әйтәм, Сафиулла абый, бутама син мине бу эшләргә!* Г. Иделле.

4. Берәр нәрсәне яки кешене икенче нәрсә яки кеше дип ялгышу, аларны аера алмау. *Балаларның исемнәрен бутап аптырау.* ▭ *Мине берәр кеше белән бутыйлар, күрәсең.* Г. Ҡутуй. *Тормышны сөю белән тормыш өчен калтырап торуны, тормыштан җиңел табыла торган бәхет эзләүне бергә бутамагыз!* К. Нәҗми.

5. *күч.* Ялгыш фикер тудыру, ялгыштыру. *Сорау алганда ул сораулар белән уйнарга, капма-каршы сораулар куеп кешене тәмам бутарга, каушатырга ярата иде.* Г. Әпсәләмов. // Кешеләр арасын, мөнәсәбәтләрен бозу. [*Хәмит:*] *Инде безне бутарга тотындыңмы?* [*Мәхмүзә:*] *Абау, нишләп мин бутыйм сезне... мин Мөршидә азып китмәсен дип кенә...* Р. Ишморат. [*Һәдия*] *ялган таратып ара бутап йөри икән, Нургали абыйдан үзебез сорап фермадан кудырырбыз.* Ә. Еники.

6. *сөйл.* Болгау; изәү (кул, баш һ. б. турында). *Хәйри әлеге кешеләр янында кулларын бутап-бутап нәрсәдер сөйли.* Ш. Камал. *Ҡойрыгын бутый-бутый хәйләкәр төлке килеп керә.* А. Әхмәт.

БУТАУ II *и.* Бутап, болгатып бирелгән терлек азыгы. *Бия зур улакта бутау ашый иде.* Г. Ибраһимов.

БУТАФОР *и.* Бутафория белән эш итүче театр хезмәткәре. *Сәхнә эшчеләре, бутафорлар да нык тырыштылар.* А. Гыйләҗев.

БУТАФО'РИЯ *и.* Сәхнәдә файдаланылып яки кибет витринасына куелып чын әйберләрне алмаштыра торган нәрсәләр. *Спектакль өчен грим, бутафория, киемсалым сатып алырга да туры килә иде.* Ф. Хөсни.

БУТЕРБРОД *и. сөйл.* Өстенә май, колбаса һ. б. ш. нәрсәләр куелган ипи, күмәч төлеме. *Эш дигәндә бөтен дөньясын оныта ул. Кайчакта төшке ашын да бутерброд кимерү белән генә чикли.* М. Хөсәен.

БУТКА *и. к. ботка. Тары буткасы. Дөге буткасы. Бәрәңге буткасы.* ▭ *Балага манный буткасы пешергән идем.* Т. Гыйззәт. *Утыралар аяк бөкләп каршы утка, Болар инде тәмләп кенә ашый буткасын.* Г. Тукай. *Бер тарыдан бутка булмый.* Мәкаль. // *күч.* Буткага охшаган төрле ярым сыек яки артык йомшап киткән каты нәрсә турында.

БУТҠАЛАНУ *ф. сөйл.* Артык куеру (аш турында). // Җебеп пычранып, ярым сыек, быкырдык хәлгә килү (аяк асты турында). *Базар урамында яңгырлы көнне аяк астының буткаланып бетүе.*

БУТЫ'ШНИҠ *и. тар. сөйл.* Октябрьга кадәрге Россиядә: будкасы янында торып, каравыл хезмәте башкаручы полицейский. *Кара сакаллы бутышниҡ та сыбызгысы белән бергә* [*полк артыннан*] *ирәрде.* Ҡ. Тинчурин.

БУУ *ф.* 1. Берәр нәрсәне тотып, бәйләп яки башкача кысу. *Кан тамырын буу.* ▭ *Тозак выжжт* [*куянның*] *муенынан буып та ала.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Берәр нәрсә белән кысып урау, бәйләү (билне һ. б.). *Гәрәй күлмәк өстеннән билен каеш белән буган.* М. Фәйзи.

3. Берәр нәрсәне кысып чорнау, урап бәйләү (билгә һ. б.). *Билгә пута буу.* ▭ *Егетләр билләренә кызыл билбаулар буганнар.* М. Гафури.

4. Сулыш алу мөмкинлеген киметү яки бетерү. *Бик тынчу һаваның сулышны бууы.* ▭ *Ник бугаздан буа бу һава, Нигә колак чыңлый окопта?* Ф. Кәрим. *Сәгадәт апа бер көнне Авырып ята өйдә, Башы сызлый, ютәл буа.* Н. Гайсин.

5. Сулыш юлын кысып үтерү. // Бугаздан тешләптәлап, яралап үтерү (ерткычлар турында). *Бүре безнең сарыклар абзарына төшкән иде. Биш баш сарыкны буды, мур кыргыры.* Н. Дәүли. [*Төлке*] *үрдәкне буып балаларына бүлеп тә биргән.* А. Алиш. // *күч.* Юк итү, һәлак итү. *Буржуазия революцияне буып ташларга дип җиң сызганган иде.* Ш. Усманов.

6. Махсус корылма белән суның юлын каплау; буа ясау. [*Малайлар*] *гөрләвек суларын буып уйнап йөриләр.* И. Гази. *Колхозчылар елганы будылар да суны күтәрттеләр.* Ф. Хөсни. // *күч.* Юлда тоткарлыклар тудыру, киртәләү. *Солдатларның чылбыр булып юлны буып торулары баягы шикләрне көчәйтте.* Ҡ. Тинчурин. *Ҡызыл гаскәргә ярдәм бирәп, Явызларның юлын будык без.* М. Фәйзи.

7. Изү; кысу; үсәргә, яшәргә мөмкинлек бирмәү. *Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды.* М. Җәлил. *Без ирек куймабыз Кешелек бәхетен буарга.* М. Хөсәен.

8. *күч. сөйл.* Берәр нәрсә сорап, таләп итеп яки берәр нәрсә эшләргә, берәр җиргә барырга кыстап-өндәп бик нык ирексезләү, йөдәтү.— *Соң, эти, буып сорадылар бит! Бик каршы торган идем дә...* М. Шәрифуллин.

БУ'ФЕР *и.* 1. Бәрелешү көчен киметә торган җайланма (паровоз, вагон, автомобильләрдә һ. б.). [*Кинәт туктаган поезд*] *вагоннарының буферлары бер-берсенә бик зур көч белән килеп бәрелделәр.* К. Нәҗми.

2. *с. мәгъ. кит.* Ике каршы якның бәрелешүен кисәтүгә яки йомшартуга хезмәт итүче; арадаш, арадашчы (оешмалар, илләр һ. б. турында). *Буфер дәүләт. Буфер группа. Буфер зона.*

БУФЕ'Т *и.* 1. Ашамлык-эчемлек сату өчен җайланган махсус өстәл яки эчемлекләре дә булган кечкенә чәйханә. *Вагонда буфет та бар иде.* Г. Тукай. *Кызлар буфеттан икесенә ике зур гына алма алган булдылар да чыгып киттеләр.* Ф. Әмирхан.

2. Савыт-саба, ашамлык-эчемлек һ. б. ш. саклау шкафы. *Ана, иртәгә кызыма нәрсә алып барыйм икән дип, буфет тартмаларын ачып-ачып карады.* Н. Дәүли. [*Шәһгали*] *өендә бер буфет дару тота.* Г. Мөхәммәтшин.

БУФЕТЧЫ *и.* 1. Буфетта эшләүче, сатучы. *Йомры гәүдәле, ак алъяпкычлы буфетчы кыздан ул ашамлыкларның әле анысын сораштырды, әле монысының бәясен белеште.* С. Рафиков.

2. *иск.* Буфет (1 мәгъ.) тотучы, буфет хуҗасы.

БУХ *аваз. изл.* бах *сүзе белән бергә дә әйтелә.* 1. Төрле шартлау, бәрелү вакытында ишетелгән көчле, кискен тавышларны, ухылдауны хәтерләткән авазларны белдерә. [*Малай*] *безгә каршы «сугыш ачты». Үзе команда бирде, --- үзе туп атты: — Бух, бах!* Г. Гобәй.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* яки бах *сүзе белән бергә.* «Бух» сыман тавышлар чыгарып. *Бух та бах ату.* ▭ [*Пароход*] *үзенең морҗасыннан куе кара төтен чыгарып бух-бух суларга тотынды.* Г. Гали.

3. *хәб. функ.* Шундый тавышлар чыгарган эшнехәрәкәтне белдерә. *Бер интәшемнән хат килде. Немец очучысын Селигер күленә батырган. Атып түгел, алдап. Патроны булмаган, тегене үз өстенә юнәлдергән, күлгә төшеп җиткәндә генә читкә тайпылып калган, ә немец күлгә — бух!* С. Баттал.

БУХА'НҠА *и. сөйл.* Зур, гадәттә формага салып пешергән ипи.

БУХА'НҠАЛЫ *с.* Буханка формасындагы. *Буханкалы ипи.*

БУХГА'ЛТЕР *и.* Бухгалтерия белгече; хисапчы. *Өлкән бухгалтер булып эшләү.* ▭ *Ул бухгалтерлар курсына укырга керәчәк.* Э. Касыймов.

БУХГАЛТЕ'РИЯ *и.* 1. Исәп-хисап алып бару эше һәм шуның теориясе; хисапчылык.— *Сиңа русчаны, немеччәне яхшы белергә дә, аннан соң бухгалтерия курсын үтеп, миңа ярдәмче булырга.* Ф. Әмирхан.

2. Предприятие яки учрежденинең бухгалтерлык эшен алып баручы бүлеге.— *Директор мең сум акча белән бүләкләгән иде, бухгалтериядә шул приказның копиясен сорыйлар.* Т. Гыйззәт. *Бухгалтерия җәйге сезонга алынган ярдәмче эшчеләр белән исәп-хисап алып бара.* Ә. Айдар.

БУХГА'ЛТЕРЛЫК *и. к.* бухгалтерия 1. *Отчет мәгълүматларының дөреслеген тикшерү пропагандисттан бухгалтерлык --- өлкәсендә махсус белемле булуны таләп итә.* Тат. ком. // Бухгалтер һөнәре һәм хезмәте. *Кәбирнең --- бер апасы яследә балалар карый, икенчесе колхозда бухгалтерлык эшен алып бара.* Г. Галиев.

БУХЛАУ *ф. к.* бухылдау. *Каядыр бухлады зур снаряд.* К. Нәҗми. *Сугышларда бухлаган пушкалар астында йөреп өйрәнгән кызылармеец Павел бу тынлыкны бер дә яратмый.* Л. Гумеров.

БУ'ХТА *и.* Диңгез судноларын давылдан, дулкыннан саклардай култык. *Гаганрог бухтасында торган Азов диңгезе флотилиясенә --- безнең гаскәрләрне акларның диңгез флотилиясе һөҗүменнән саклауны тәэмин итәргә кушылды.* Г. Бәширов.

БУХЫЛДАТУ *ф. сөйл.* 1. *Йөкл. юн. к.* бухылдау. 2. *күч.* Ату (мылтыктан һ. б.).

БУХЫЛДАУ *ф.* «Бух» сыман тавыш чыгарып яңгырау; ухылдау. [*Паровоз*] *бухылдап әрле-бирле йөрергә кереште.* М. Гафури.

БУШ *с.* 1. Өстенә яки эченә бер нәрсә дә салынмаган, куелмаган (савыт-саба, әйбер салу-саклау урыны һ. б. ш. турында). *Буш капчык. Буш баз. Буш мичкә.* ▭ *Ишектән, көянтәсен култык астына кыстырып, кулына буш чиләкләр тоткан бер рус хатыны килеп чыкты.* Ә. Фәйзи.

2. Бер нәрсә белән дә яки беркем тарафыннан да биләнмәгән, алынмаган (урын һ. б. ш. турында). *Анда тик ике-өч өстәлдә генә утыралар, калган өстәлләр буш иде.* М. Гали. // Берәүнеке дә түгел, берәү тарафыннан да алынмаган-биләнмәгән; кешесез, вакантлы (штат берәмлеге, хезмәт урыны турында). *Ул Бохарадан яшел чапан киеп, зур чалма чалып кайтса да, --- якын арада гына зур калаларда буш мәхәллә барлыгы күренмәде.* Г. Ибраһимов. // Торучысы-караучысы булмаган, ялгыз (йорт, торак, каралты-кура һ. б. ш. турында). *Буш сарай. Буш дача.* ▭ [*Хәлил*] *буш казармалар арасында йөренә.* Ш. Камал. // Кеше яшәми, йөрми торган. *Буш урам.* ▭ *Элек буш дала иде* [*шәһәр читендә*]. *Ә хәзер биек йортлар, гигант заводлар!* Р. Ишморат. *Шулай ук бу буш утрауда озак торырга туры килер микәнни?* Әкият. // Сусыз (кое һ. б. ш. турында). *Бер тамчы да суы юк. Буш кое ул.* Каз. утл. // Корылмаган яки ядрәсез генә корылган (патрон һ. б. ш. турында). *Буш патрон белән ату.*

3. Шушы вакытта бер нәрсә белән мәшгуль булмаган (кеше турында). *Хезмәттән буш булган сестралар, санитарлар, врачлар аларны озатырга чыкканнар.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Азат, ирекле, арынган (уйлардан, борчулардан һ. б.). [*Мостафинның*] *башы уйлардан буш, күңеле, йокыга талгандай, тыныч.* Ә. Еники. *Кичке тойгылардан буш калган күңел.* М. Җәлил.

4. Шушы вакытта файдалануда, эштә булмаган (төрле корал, транспорт һ. б. турында). *Буш корал.* ▭ *Станцидә эшелоннарны үткәрү өчен ике буш юл калдырылырга тиеш.* Ш. Усманов.

5. Бер нәрсә өчен дә билгеләнмәгән яки файдаланылмаган (вакыт турында). *Буш арада китап уку.* ▭ *Бүген гәзитә чыкмый, кичем буш.* И. Гази. *Рәхим, шундый уйлар белән дәртләнеп, һәрбер буш минутын эшенә бирде.* А. Расих.

6. Ирекле тора торган, беркетелмәгән, хәрәкәт иреге чикләнмәгән (кул һ. б. турында). *Кунак алдына аш куй, ике кулын буш куй.* Мәкаль. *Һавалардан очкан ике кош, Берсе дә генә бәйле, берсе буш.* Җыр. *Арканны шушы буш башыннан җитәрлек көч белән тарткан да, шап юкары күтәрелә барырга тиеш иде.* Ш. Камал.

7. Кысан булмаган, кысып яки буып тормый торган; иркен (кием һ. б. турында); *киресе:* тыгыз. *Озын мыеклы абзый баскыч буйлап ашыкмый гына төшә, аның буш галошы --- бөтен өйалдын яңгырата.* А. Шамов.

8. Тиешенчә тартылып киерелмәгән, салынып тора торган, сулпән (бау, бәй, уен коралының кылы, мускул һ. б. турында).

9. Орлыксыз, җимешсез-төшсез. *Буш башак. Буш чикләвек.* // Кирәкле казылмалары булмаган (җир катламы һ. б. ш. турында). *Алмаз бөртекләрен бик күп эзләнүләр, күп көч түгүләрдән соң гына ачарга мөмкин, ә күп кенә очракта ул катламнарның бөтенләй буш булып чыгуы да бик ихтимал.* Ш. Маннур.

10. *махс.* Файдалы эшкә тотылмаган, файдалы эш коэффициенты булмаган. *Буш йөреш. Маховикның буш әйләнеше.*

11. *күч.* Сүзгә, мактанырга һ. б. ш. оста, ләкин эшкә сәләтсез, булдыксыз. *Буш кеше.* □ *Син дә, дус кеше, бик үк бушлардан түгел — механик ич.* А. Әхмәт.

12. Тормышка ашмастай, чынбарлыкта нигезе булмаган (ният һ. б. ш. турында). *Аның бу өмете буш булып чыкты.* А. Шамов.— *Синең проектың — фантазия ул. Буш фантазия.* Г. Иделле. *Сиңа буш хыяллар шатлык бирмәс.* З. Бәширн. *Ул буш вәгъдәләр бирергә яратмый.* Б. Камалов. // Чынбарлыкны төгәл чагылдырмый торган, эчтәлексез, нигезсез, мәгънәсез (сүз һ. б. ш. турында).— *Ай-һай, егет, бик шалтыравык, буш сүзләр әйтмәдеңме икән син?!* Г. Минский. // Әһәмиятсез, вак (эш һ. б. ш. турында). *Үзенең шул кадәр вакыт бөтенләй буш, юк нәрсәләр турында уйлануларын аңлау аны ачындырырга --- тиеш иде.* Г. Әпсәләмов. // Нәтиҗәсез, файдасыз (эш һ. б. ш. турында). *Бөтен тирә-якны ду китереп эзләүләр бар да буш булып, аның [картның] кая киткәнен, ничек югалганын бер төрле дә белә алмадылар.* Г. Ибраһимов.

13. *хим.* Кушылмага кермәгән. *Буш атом.*

14. Түләүсез. [*Тегүче*], *малае белән хуҗадан ашап, әзер җылыда, буш фатирда торып --- шул кайры тукны өч көндә өлгертеп бирә.* М. Гали. // *күч.* Бик аз зан. *Җәй көне утынны буш бәягә алу.*

◇ **Буш баш** — акылсыз, аңгыра кеше турында.— *И карчык, буш башлар күк син дә инде һаман киленне кыерсытасың.* А. Әхмәт. **Буш бугаз** — күп сөйләргә, кычкырып мактанырга, шапырынырга яратучан, эшлексез кеше турында. *Халык арасында аның турында «төпле егет», «дөнья күргән егет», «буш бугаз түгел», «сүзен җилгә очырмас» --- кебек сүзләр дә әйри башлады.* Ә. Еники. **Буш итмәү (калдырмау, куймау)** — бурычлы булып калмау.— *Менә, эшләр генә бетсен, әби, аннан соң мин сине буш итмәм.* Г. Камал. *Милләтчеләр үзләре күтәрткән кешене буш куймаска бөтен көчләре белән тырышалар.* Ф. Әмирхан. **Буш кул белән** — 1) үзең белән бер нәрсә дә алмыйча, кулга бер әйбер дә тотмыйча. *Аптырап калган карчык әле почмакка, әле чоланга чыгып, әрле-бирле йөгерде дә буш кул белән тагын сәке янына килеп басты.* А. Шамов; // бер нәрсә дә тапмыйча, ала алмыйча, табышсыз, нәтиҗәсез (берәр нәрсәгә дип барган җирдән кайту турында). *Ауга йөргәндә мин ни туры килсә шуны атмый идем. Бер-ике үрдәк булса, шул җиткән. Әлбәттә, буш кул белән кайткан чаклар да булгалый иде.* Г. Әпсәләмов; 2) коралсыз, аны кулланмыйча (тоту, алу, җиңү, төзү һ. б. ш. турында). *Буш кул белән бер нәрсә дә эшләп булмас бит.* Ш. Камал. *Кызыл гаскәрне буш кул белән алырга өметләнүчеләр --- бу көч каршында аптырап калдылар.* Ш. Усманов. **Буш куык** — шапырынырга яратучан булдыксыз кеше турында. [*Гафур Мирсәеткә:*] *Кит. Шалтыравык, буш куык.* Р. Ишморат. **Буш куык очыру** — корыга мактану, ялганлау. *Буш куык очырудан гыйбарәт булган бу «вәгъдәләр»* [*эшне тоткарлады*]. М. Җәлил.

БУШАНУ *ф.* 1. Бераз бушау, арыну (әйберләрдән, кешеләрдән, эштән һ. б.). *Укудан бушанган арада вакытяк эшләрне карап алу.* □ *Кич җитте; мәдрәсә, ахшам чәеннән бушанып, үкү тавышы белән көрли башлады.* Ф. Әмирхан. *Казарма эче кешеләрдән бушана төште.* И. Туктар.

2. Котылу, арыну (хисләрдән һ. б.). *Андый хәсрәтле чакта, онытылып бер сөйләшеп утырсаң да, бушанып каласың.* Ф. Хөсни.

3. *эвф.* Табигый ихтыяҗны үтәү. [*Шәкертләр*] *абзарга йөгерделәр, акрынлап-акрынлап, кунак атларны карый-карый бушандылар да аш өенә керделәр.* Г. Ибраһимов.

4. *махс.* Электрик корылмадан арыну.

БУШАТКЫЧ *и.* Йөк бушату эшендә кулланыла торган механизм, җайланма һ. б. ш. *Завод вак таш бушаткычларны моннан ике ел элек үк кайтарткан иде.* Чаян.

БУШАТУ *ф.* 1. Өстендәге яки эчендәге нәрсәдән арындыру, азат итү (савыт-сабаны, әйбер салу-саклау урынын һ. б. ш. нәрсәне), буш (1 мәгъ.) калдыру. *Капчыкны бушату. Арбаны бушату.* □ *Бакалтайда баржа бушаталар.* М. Әмир.

2. Берәр нәрсә өстендәге яки эчендәге әйберне аннан алу, икенче җиргә урнаштыру. *Вагоннан товар бушату. Ындырга көлтә бушату. Йөк бушату. Машинадагы ашлыкны амбарга бушату.* □ *Пароход тикмәгә генә туктамагандыр, бушатасы я төйисе нәрсәсе бардыр.* И. Гази.

3. *сөйл.* Торак һ. б. ш. урыннан китү, аны калдырып чыгу. *Шушы көннәрдә әхмәтҗаннар гаиләсе йортны бушатачак.* Г. Иделле. [*Тәһир:*] *Кара әле, Искәндәр, малайларга урын кирәк, син бүлмәне бушатасыңмы, юкмы?* Т. Гыйззәт.

4. *сөйл.* Чыгару, азат итү (эштән). *Журналистлык эшендә файдам тиде булса кирәк, мине [хәрби хезмәттән] 1935 елның февралендә генә бушаттылар.* Ф. Хөсни.

5. *сөйл. сир.* Азат итү. *Отряд вокзалны бушатуда зур роль уйнады.* Ш. Усманов. *Орскины бушату бик кызу бара иде. Унҗидесендә аклар шәһәрне ташлап чыктылар.* М. Фәйзи.

6. *күч., гади с.* Эчү. [*Хисами Хәйригә:*] *Менә, әлгәре берәрне бушатыйк, аннары йомышын башларбыз.* Г. Минский. *Хәйдәр мулла, авыр сулап, чәйне чынаяк артыннан чынаяклап бушата торды.* С. Рафиков.

БУШАУ *ф.* 1. Өстендәге яки эчендәге нәрсәдән арыну, азат ителү (савыт-саба, әйбер салу-саклау урыны турында). *Сөттән бушаган шешә.* □ *Чиләккә бал ага, кәрәз күзәнәкләре бушап кала.* А. Алиш.

2. Биләүчесе-торучысы, йөрүчесе-керүчесе калмау (урын, мәйдан һ. б. ш. турында). *Поезд киткәч, бераз бушап калган зал яңадан халык белән тула башлады.* А. Шамов. [*Юл*] *олаулардан бер дә бушамый.* И. Туктар. // Вакантлы, кешесез, буш булып калу (штат берәмлеге, хезмәт урыны турында). *Мөфти урыны буша-ды.* Ф. Әмирхан.

3. Мәшгуль булудан туктау (кеше турында). *Эштән бушау.* □ *Сөйгән ярым хат ташучы, Хат язарга бушамый.* М. Җәлил. // *күч.* Азат, имин булып калу; арыну (уйлардан, борчулардан һ. б.). *Күңелең кайгылардан бушасын.* Ф. Кәрим.

4. Файдалануда, эштә булудан туктау (төрле корал, транспорт һ. б. турында). *Әйдә, Мәрьям апай, үтүк хәзер бушады.* Ш. Камал.

5. Хәрәкәтләнә алыр, ирекле хәлгә килү (кул һ. б. турында). *Кул бушау. Бауның бер очы бушау.*

6. Тыгыз, кысан булудан, кысып яки буып торудан туктау, иркенәю, бушаю. *Шөреп бушау.* □ [*Егет өстендәге*] *гимнастерка хәзер бөтенләй бушап, астыннан киезе алынган камытка охшап калды.* К. Нәҗми. *Арбаның шалтырап тавыш чыгарырлык бушаган-какшаган урыннарын әйбәтләп ныгыттылар.* Г. Минский.

7. Тартылып, киерелеп торудан туктау; салыну, сүлпәнләнү (бау, бәй, уен коралының кылы, мускул һ. б. турында). *Пружина бушау.* □ *Айгыр аз гына дилбегә бушау белән яңадан алга ыргылды.* М. Хәсәнов.

БУШАЮ *ф. к.* бушау (6, 7 мәгъ.). *Тезләрем бушаеп бөгелергә тора вә калтырый иде.* Ш. Камал.

БУ'ШЕЛЬ *и.* Англия һәм АҚШта: коела-түгелә торган җисемнәрнең күләм үлчәве берәмлеге (35 *л* чамасы).

БУШКА *рәв.* **1.** Нәтиҗәсез, файдасызга (эшләү, **тырышу** һ. б. ш. турында). *Уку белән бик тиз үтәр бу озын кыш, Уйнап-көлеп бушка йөрмә, балам, тырыш.* М. Гафури. *Арғамакны тирләтеп ул җәйләүгә бару бушка булмасмы?* Г. Ибраһимов. // Кулланмыйча, файдалы эш коэффициенты алмыйча.— *Нигә монда эшче, ат көчләрен бушка тотарга?* Т. Гыйззәт.

2. Сәбәпсезгә.— *Ул егетләрне сыйлауның нинди дә булса берәр төрле мәгънәсе булырга кирәк, ул [бай егет] аларны бушка гына сыйламый торгандыр, аңладыгызмы, иптәшләр?* Г. Камал.

3. *күч.* Бик арзан бәягә. *Май сатучылар, [алучының] комсызлыгына ачуланып, сүгенделәр. - - - Кара син аны, бушка җыеп китмәкче! Тот капчыгыңны!* Г. Бәширов. [*Маклер Фәтхырахман], шәһәргә мал китергән казахларны алдап, малларын бушка алып кала һәм шуның белән «көн күрә».* М. Гали. // Бушлай, түләүсез.— *Бу бит сезнең хезмәтчегез, ни дип аның көченнән бушка файдаланасыз?* Қ. Әмири.— *Без кешене бушка эшләтмибез.* Г. Гобәй.

◇ **Бушка китү (чыгу)** — нәтиҗәсез калу, файдасыз булу. *Тир түгүләребез бушка китмәде.* А. Алиш. *Димәк, зур чыдам белән тырышулар бушка чыкмаган.* Ш. Камал.

БУШЛАЙ *рәв.* Түләүсез, хак түләмичә яки алмыйча. *Совет килеп чыгып бушлай укыта башлады.* Г. Толымбай.— *Иртәгә үк тәрәзәне үзем куеп бирәм, пыяла гына тапсыннар. - - - Бушлай куеп бирәм.* Э. Қасыймов.

БУШЛАТ *и.* Якасына кадәр сәдәпләнә торган тышкы кыска сукно кием; матрос курткасы. *Диңгезче бушлаты.* □ *Өстенә кыек кесәле бушлат кигән авыл советы председателе Сөләйманов күренде.* Э. Еники.

БУШЛАТА *рәв. сөйл. к.* бушлай. [*Китап бастыручы — авторга:*] *Китабың басылгач, биш-ун данәсен үзеңә бушлата бирербез.* И. Рәмиев.

БУШЛЫЙ *рәв. сөйл. к.* бушлай. *Һава белән суны һичкем тырышып, көч белән тапмаган, бәлки аларны табигать үзе биргәнлектән, алар кешеләргә бушлый килгәннәр.* Г. Тукай.

БУШЛЫҚ *и.* **1.** Буш булу хәле.

2. Эчендә бер әйбер дә булмаган буш пространство, урын. *Ракеталарга утырып, күкнең зәңгәр бушлыгына очасым килә.* Г. Бәширов. [*Җир асты сулары*] *җирнең эчке катын юалар, шуңа күрә ул урыннарда бик зур бушлыклар хасил була.* Ф. Әмирхан.

3. Бер нәрсә белән дә яки беркем тарафыннан да биләнмәгән яки тереклек билгеләре булмаган урын, жир мәйданы. *Берничә минуттан инде без авыл читендәге бушлыкта, ялгыз үсеп торган бер каен төбендә басып тора идек.* А. Шамов.

4. Рухи ихтыяҗлар, омтылыш-дәрт булмау халәте турында. *Габделбасыйр үзенең йөрәгендә шундый бер бушлык, эч пошыргыч бер бушлык тойды ки, бу бушлыктан аның җаны сыкранды.* Ф. Әмирхан.

5. Өстенә бөрчек-күзчек билгеләре төшерелмәгән домино шакмагы.

БУЫЛУ *ф.* **1.** *Кайт. юн. к.* буу (1, 4, 5 мәгъ); *төш. юн. к.* буу (1—7 мәгъ.).

2. Бума чире кузгалу, шуның өянәге килү. *Буылып егылу.*

3. *сөйл.* Алга үтә алмыйча, тоткарланып, тыгылып тору. *Күпер алдына килеп буылган ташу бозларын ваткалап җибәреп тору. Урамдагы халыкның чатта буылып, алга уза алмый торуы.*

БУЫН *и.* **1.** Кеше яки хайван организмында: сөякләр-сеңерләр тоташкан, хәрәкәтчән, бөгелә торган урын. *Буыннар яхшы эшләү.* □ *Җәяүләү җиңелчә киенгән яшьләр өчен авыр булмаса да, авылга кайтып җитү белән, буыннарыбызда арганлык сизелде.* М. Әмир. *Эшли торгач, буыннар языла, күңелләр көрәп китә.* Г. Ахунов. // Тиренең буын турысындагы өлеше. [*Бабай*] *бармак буыны белән күз төпләрен сыпыргалап алды.* Г. Әпсәләмов.

2. Организмда бер-берсеннән хәрәкәтчел урыннар белән аерымланып торган өлешләрнең берсе. *Бармакта сыну-фәлән юк. Тик аның төп буыны, бармак кирегә каерылу аркасында, эзеннән чыккан булган. - - - Ә инде хәзер буын үзенең урынына төшерелгәч, ул озакламыйча төзәлергә тиеш.* Ш. Камал.

3. *бот.* Сабакның, кәүсәнең яфрак яки ботак чыккан җирендә юанаеп-бүлтәеп торган урыны.

4. Бер-берсеннән буын (3 мәгъ.) белән аерымланып торган өлешләрнең берсе (сабакта, кәүсәдә).

5. Үзара чылбыр эзлеклелеге белән бәйләнгән теләсә нинди кисәкләрнең, детальләрнең һ. б. ш. бер иш нәрсәләрнең тоташкан урыны. // Шул рәвешчә тоташкан кисәкләрнең берсе. *Чылбырны кыскарту өчен аның бер-ничә буынын аерып алу.*

6. Бер-бер артлы туып, барлыкка килеп яшәгән токымнарның, нәселләрнең, төрләрнең кайсы булса да берсе. *Ул тумыштан балыкчы, нәсел-нәсәбе дә җиде буыннан бирле балыкчы булган.* М. Шабаев. *Мәләкәстән кайткан бу асыл сөяк сыерның нәселе, ни хикмәттер, безнең Яушырмәдә мантый алмый, икенче, өченче буыннан үк акрынлап ваклана башлый.* Э. Еники. *Табигатьтә бит кеше кулы катышмыйча да токымнарның кушылуы һәм шуның нәтиҗәсендә яңа буын үсемлекләрнең тууы мөмкин.* Г. Кутуй. // Уртак бабага карата бер үк дәрәҗә кардәшлектә торучы нәсел, токым яки төр вәкилләренең барысы да. *Миңлехәят әби үз каныннан килгән дүртенче буын белән бергә яши.* С. Рафиков. // *җыйд. күч.* Яшь аермалары зур булмаган, бер чорда яшәгән кешеләр. *Өлкән буын. Яшь буын.* □ *Безнең буын көрәшү, җиңү өчен туган!* Г. Гобәй. *Уйлап карагыз: бер буын гомере эчендә шундый могҗиза!* Г. Әпсәләмов.

7. Берәр нәрсәнең, системаның состав өлешләреннән берсе, кисәге. *Шигырь буыннары. Пропорциянең кырый һәм урта буыннары.* □ *Иң мөһиме - - - күп санлы мәсьәләләр арасыннан аеруча әһәмиятле, хәлиткеч буыннарны тотып ала белү.* Соц. Тат.

◇ **Буын бетү** — буын мускуллары йомшап хәлсезләнү. *Әйтергә дә җиңел түгел инде. Ишеткәч, буыннарым бетеп китте. Шәрәфетдиннән хат бар.* М. Фәйзи. **Буынга сикерү** — буынлану. *Игеннәр кыяклана-кыяклана буынга сикерде.* Г. Галиев. **Буыннан буынга** — бер буыннан икенчесенә эзлекле рәвештә (күчеп). *«Кара урман». Бу көй буыннардан буыннарга лаек күчәргә.* Ш. Маннур.

БУЫН-БУЫННАН *рәв.* Элекке буыннардан алып ук, элек-электән.— *Үзем шундый Нужа булып буын-буыннан, Нишләп йөрим әле мин, ди, Кәҗә юлыннан?* Н. Исәнбәт.

БУЫНЛАНУ *ф.* Буын яки буыннар барлыкка килү (сабакта, кәүсәдә һ. б. ш.).

БУЫНЛАУ *ф.* **1.** Тирәли киртләү (агачны); буынлы, буынтыклы итү.

2. Буыннарга, кисәкләргә аеру, кискәләү. *Пычкы тагын хәрәкәткә килә. Күз ачып йомганчы әлеге агачны буынлап та өлгерәләр.* Соц. Тат.

БУЫНСЫЗ *с.* **1.** Буыны яки буынтыгы булмаган; буыннарга аерылмаган, тоташ.

2. Буын мускуллары үтә йомшак яки бөтенләй хәлсез; бик сыек гәүдәле. [*Яралының*] *аяк-кулы, буынсызга әйләнеп, изрәп төшкән.* Каз. утл. // *күч.* Мөстәкыйльлеге булмаган, ихтыярсыз, аумакай. *Шундый зур эшләрне торгызып яталар Арслановлар. Бер буынсызы булса,*

райком секретареның хатын алгач, «Әгәр китсәм, бөтен эшләрем чуала», --- дип лыгырдар иде. Г. Толымбай.

БУЫНСЫЗЛАНУ *ф.* Буын мускуллары бик йомшап, хәлсезләнү. *Монах куркуыннан төртенә, калтырый, буынсызлана барды.* Л. Гумеров.

БУЫНТЫГАЯКЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Тәннәре буынтыклардан торган югары төзелешле умырткасыз хайваннар классы.

БУЫНТЫК *и.* **1.** Умырткасыз хайваннарда, бөҗәкләрдә: тәннең өлешләре тоташкан, хәрәкәтчән, бөгелә торган урын, буын (1 мәгъ.).

2. Умырткасыз хайван яки бөҗәк тәнендә: хәрәкәтчел урыннар белән аерылып торган өлешләрнең берсе, буын (2 мәгъ.).

3. Тирәли юанаеп яки батып торган урын, божра сыман сыр (аяк-кулда, сабакта, кәүсәдә, түбән төзелешле умырткасыз хайваннарда, бөҗәкләрдә һ. б. ш.). *Сыер мөгезендәге буынтыклар.* □ *Кишернең чуғын өзеп ташлап тешләремне бер буынтыгына батырдым.* Г. Гобәй.

БУЫНТЫКЛАНУ *ф.* Буынтык яки буынтыклар барлыкка килү.

БУЫНТЫКЛЫ *с.* Буынтыгы яки буынтыклары булган; буынтыклардан торган. *Миңа калса, минем йөрәгем йомшак ит кисәге түгел, ә буынтыклы каты йодрык.* Г. Әпсәләмов. *Миләүшә инде уянган, буынтыклы ак куллары белән киерелеп ята иде.* Г. Ахунов.

БУЯГЫЧ *и.* Буяу сөртү-ышку өчен кулланыла торган корал яки берәр механизмда шундый җайланма.

БУЯНУ *ф.* **1.** *Кайт. юн. к.* буяу I (1 мәгъ.).

2. (Крем, иннек һ. б. ш. нәрсәләр сөртенеп) бизәнү. *Кыз, бер дә буянмаган булса да, мәхәббәтле генә булып күренде.* Ф. Әмирхан.

БУЯУ I *ф.* **1.** Махсус матдә (буяу) сөртеп, сендереп һ. б. ш. (манудан башка) юл белән әйберне бүтән төскә кертү. *Тәрәзә борысын буяу. Яшелгә буяу.* □ *Ул зәңгәргә буяган артсыз урындыкка утырды.* Г. Әпсәләмов. // Буяп, ягып матурларга тырышу (иренне һ. б.). [*Хуҗа хатын*] *киенгән, ясанган, чәчен бөдрәләткән, кашын-күзен буяган, иреннәре кып-кызыл яналар.* Г. Ибраһимов. *Культуралы булу --- тырнак чистартып, ирен буяудан гына тормый.* Т. Гыйззәт. // *күч.* Матур итеп тасвирлап, күпертеп күрсәтү. *Мин сезнең алга бер дә арттырмыйча, буямый гына киләчәк көрәшләрдән берсен китереп бастырдым.* Ш. Усманов.

2. Буяу һ. б. ш. нәрсәне әйбергә сөртү, ягу, йоктыру. *Яшел буяуны буяп бетерү. Лакны юка гына итеп буяу.*

3. Берәр нәрсә йоктырып пычрату. *Тузанга буяу. Пычракка буяу.* □ *Кит көпчәк яныннан, күлмәгеңне буярсың.* И. Гази. *Кара савыты авып китте дә бөтен өстәлне, эскәтерне буяды.* Г. Иделле.

4. *күч.* Берәүгә гаеп ташлау, аны начарлык эшләүдә катнашкан итеп күрсәтү яки оятка калдыру. *Коллективны буяу.* □ *— Мөбәрәкшаны буярлык кәгазьләрнең барысын да шыпырт кына бирегә ташысын.* К. Нәҗми. // Хурлыкка калдыру, тап төшерү. *Ярамас эше белән ата-анасының исемен буяучы егет.* □ *— Күземнән югал, атаңның фамилиясен буяучы кыз!* М. Фәйзи.

БУЯУ II *и.* **1.** Әйберләргә сөртеп, сендереп һ. б. ш. юл белән аларга тиешле төс бирү, ману өчен кулланыла торган матдә. *Химик буяу. Майлы буяу.* □ *Бу йорт коймалары, капкалары белән бер төскә куе яшел буяу белән, тәрәзә, ишек, капка читләре ак буяу белән күпшы итеп буялган иде.* Ә. Фәйзи. // Берәр әйбер өслегендәге шундый матдә катлавы. [*Автобусның*] *озак йөрүдән буявы кубып беткән.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Төс. *Көн тагын да яктыра төште. Көнчыгыш ягы алсуланды, күк кырые матур буялар белән бизәлде.* Г. Бәширов. *Афишаларның урта бер җирендә ике буяу, салават күпере төсләре шикелле, бергә кушылып киткән иде.* Ш. Камал. // *күч. кит.* Тышкы бизәк, ясалмалылык турында.— *Аларның һәммәсе ялган, һәммәсе буяу.* Ш. Әхмәдиев. // *күч.* Сәнгатьләү чарасы (сөйләмдә, музыкада һ. б.). *Кайчандыр әдәбиятта андый өйләр --- кызыктырырлык итеп экзотик буяуларда тасвирлана торган иде.* Г. Минский. *Ул гади вакытта матур сөйли белми, тасвир буяулары сыек чыга.* Г. Ибраһимов.

БУЯУЛАУ *ф. сир.* Буяу катламы белән каплау. *Булатов матрицаны валикка беркетеп, буяулап алды да* [*басу станогын*] *--- әйләндерә башлады.* Ш. Маннур.

БУЯУЛЫ *с.* **1.** Берәр төскә буялган; өстенә буяу йоктырылган, буяу катламы белән капланган. *Буяулы сары идәндә чүп әсәре күрмәссең.* М. Максуд.

2. Составында берәр төрле буяу булган, буяу катнаштырылган (матдәләр турында).

БУЯУСЫЗ *с.* **1.** Буялмаган, буямыйча эшләнгән. *Буяусыз парта.* □ [*Тикшерүче*] *түргә атлап, сәке янындагы зур, буяусыз агач өстәлгә калын портфелен ташлады.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Сәнгатьләү-бизәкләү сүзләре катнаштырылмаган, артык күпертелмәгән; ясалма түгел, табигый, нейтраль (сөйләм, тасвирлама һ. б. ш. турында). *Бу сабый бала кузгаткан хис кешенең тормышка булган бәйләнешен, мәхәббәтен иң садә, иң буяусыз рәвештә һәм шул ук вакытта аның никадәр тирән, көчле икәнен күрсәткән хисләрнең берсе иде.* Ә. Еники.

БУЯУХАНӘ *и. иск.* Әйберләрне ману, буяу мастерское. [*Хуҗа*] *үзенең буяуханәсенә, аның ишегенә карап утырырга гадәтләнеп китә.* Әкият.

БУЯУЧЫ *и.* **1.** Буяу, ману һөнәре остасы; шул эштә эшләүче. *Буяучылар бригадасы.* □ *Аның бөтен йортын төзәттерергә, --- буятырга уйлаганлыгы, шуның өчен әллә кайдан тимерләр, бүрәнәләр, осталар, буяучылар сөйләшеп йөргәнлеге ишетелде.* Г. Ибраһимов.

2. Буяулар белән сәүдә итүче. *Ак та була, күк тә була Буяучының буявы.* Җыр.

БУЯУЧЫЛЫК *и.* Буяучы һөнәре яки кәсебе.

БЫГЫР *аваз. ияр.* **1.** Берәр сыеклык кайнаганда яки, гомумән, аннан һава куыкчыклары нык бүленеп чыкканда ишетелгән һ. б. ш. авазларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Быгыр» сыман тавышлар чыгарып. *Бабай учак өстендә быгыр-быгыр кайнаган балык шулпасын тәмләп азаплана иде.* Г. Мөхәммәтшин.

◇ **Быгыр итү, быгыр-быгыр итү (килү)** — быгырдау. [*Урдәкләр*] *су читендә быгыр-быгыр килеп сөйләшеп йөриләр.* М. Гафури.

БЫГЫРДАУ *ф.* **1.** «Быгыр» авазлары сыман тавышлар чыгарып шаулау. *Өйрәнең куерып быгырдый башлавы.* □ [*Сазлык суын кичкән вакытта*] *үтеп киткән эзләрдә су төбеннән быгырдап куыклар күтәрелә.* Ф. Кәрим.

2. Башкаларга ишетелер-ишетелмәс кенә үз алдыңа сөйләнү, мыгырдау, быдырдау.

3. *күч.* Лыгырдау, такылдау.

БЫГЫРТ *аваз ияр.* **1.** Кинәт быгырдап куюны белдерә.

2. *хәб. функ.* Кинәт быгырдау тавышлары чыгарган эшне-хәрәкәтне белдерә.

БЫДЫР *аваз. ияр. гадәттә каб. форм.* **1.** Сүзләре ачык әйтелеп яки ишетелеп җитмәгән сөйләмне белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* Сүзләрне ачык итеп, ишетелерлек итеп әйтмичә (сөйләү турында). *Үз алдыңа быдыр-быдыр сөйләнеп йөрү.* □ *Эчтән быдыр-быдыр сөйләшкән тавышлар килде.* А. Гыйләҗев.

БЫДЫРДАУ *ф.* Сүзләрне ачык әйтеп бетермичә яки ишетелер-ишетелмәс сөйләү, сөйләнү.

БЫДЫРДЫК *с.* Өзлексез сөйләнеп, быдырдап торучы; лыгырдык. *Класста апа Хисап чыгарта. Бу быдырдыклар Гел ләчтит сата.* Ш. Маннур.

БЫЕЛ *рәв.* 1. Бу, шушы елда. *Быел план былтыргыга караганда бермә-бер артык.* Г. Әпсәләмов.

2. *и. мәгъ. кыек форм.* Бу, шушы ел. *Без Хөршит белән быелга кадәр очрашмаган идек.* Ф. Әмирхан. *— Председатель алдына кабыргасы белән куярга: быелдан калмый фермада водопровод, автопоилка булсын.* Ә. Еники.

БЫЕЛГЫ *с.* Бу елдагы, шушы елгы. *Һәркем быелгы иген белән үзенең тереклеген төзәтеп калырга өмет итә.* Г. Ибраһимов.— *Безнең заводның быелгы эшләп чыгару программасы былтыргыга караганда иң кимендә егерме биш процент артык булырга тиеш.* Ш. Камал.

БЫЖ *аваз.ияр.* 1. «Ыж» сыман тавыш чыгарып гүләүне белдерә.

2. *рәв. функ. каб. форм.* Шундый авазлар чыгарып. *Пуляларның быж-быж очуы.*

БЫЖАН *и. зоол.* Шөпшәләр төреннән, ләкин алардан эрерәк, элпә канатлы бөҗәк; *русчасы:* шершень. *Быжан ачулы кыяфәт белән килеп чыкты да тагын быжылдап очып китте.* И. Гази.

БЫЖГАК *с. сөйл.* 1. Быжлый, быжлап шаулый, хәрәкәт итә, оча торган (бөҗәкләр һ. б. турында).

2. *күч.* Әһәмиятсез яки кечкенә гаеп өчен дә туктаусыз шелтәләп, сөйләнеп яки зарланып торучы. *Быжгак, усал кеше! Чамасыз... Бәйләнмәгән чагы гел юк, көзге чебен кебек.* А. Гыйләҗев.

БЫЖГАКЛАНУ *ф. сөйл.* 1. Быжгак кешегә әйләнү.

2. Быжгу, шелтәләү, тузыну.

БЫЖГУ *ф.* 1. *диал. к.* быжгыру.

2. *к.* быжлау.

БЫЖГЫРУ *ф.* Ыжылдап-сызгырып исү, хәрәкәт итү (җил һ. б. ш. турында); ыжгыру. *Быжгырып искән --- суык җил колакларны тондыра.* Ш. Маннур.

БЫЖГЫТУ *ф. сөйл.* 1. *з-сыз.* Салкын җилнең ыжылдап исеп торуы турында. *Көне буе быжгытып тора.* // Тундыру (салкын җил һ. б. ш. турында). *Өстеңә калын кимәсәң, юлда җил быжгытуы мөмкин.*

2. *күч.* Шелтәләп-ашыктырып иркесәләү. *Укырга беренче тапкыр килүчеләр, кулларыгызны күтәрегез! — диде [хәлфә]. Габдулла белән Галекәйне яннарында утыручы иптәшләре быжгыта башладылар: — Күтәрегез! Күтәрегез!* Ә. Фәйзи.

БЫЖЛАВЫК *с. к.* быжгак.

БЫЖЛАУ *ф.* 1. «Быж» сыман тавыш белән шаулау, яңгырау. *Орчык быжлау.* □ *Пулялар быжлый башлагач, палачлар артка чигенделәр.* Л. Гумеров.

2. Шелтәле тон белән, ләкин тавышны күтәрмичә туктаусыз сөйләнү, ачулану.

БЫЖЫК *с. сөйл. к.* быжгак 2. *Ул аны тиктомалга каныга торган, үчегүчән, быжык, кырыс холыклы итеп күз алдына китерә иде.* К. Нәҗми.

БЫЖЫЛДАВЫК *с. к.* быжгак. *Быжылдавык җил.* □ [*Хәлим:*] *Ярар, бер кисәк камырын да кызгана... — Мә, быжылдавык!.. Фатыйма камыр чеметеп бирде.* И. Гази.

БЫЖЫЛДАУ *ф. к.* быжлау. *Самовар быжылдап утыра иде.* Г. Ибраһимов.— *Узгаргансең, төсең киткән ич, дип атлаган саен быжылдап торсалар, сәламәт йөргән җиреңнән дә чирли башларсың.* Г. Кутуй.

БЫЗ *аваз.ияр.* 1. «Ыз» сыман тавыш чыгарып бөҗәкләр очканда ишетелгән һ. б. ш. калын авазларны яки шелтәле хис белән өзлексез сөйләнеп торуны белдерә.— *И бызылдыйм, и бызылдыйм! Петр Ильич кулын селкә, ә мин китмим, бөтереләм. Быз-з-з! Кызык!.. Шундый матур төш иде; уянып киткәч, хәтта елый яздым.* Г. Әпсәләмов.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* Бызылдап.

◇ **Быз итү, быз-быз итү (килү)** — бызылдау. *Бал кортлары, быз-быз итеп, Бал җыюдан туймыйлар.* Ә. Бикчәнтәева.

БЫЗГУ *ф.* 1. Ызылдап сызгырып исү, хәрәкәт итү (җил һ. б. турында).

2. Шелтәле тон белән, ләкин тавышны күтәрмичә туктаусыз сөйләнү, ачулану, быжгу.— *Өйдәгеләргә җиткерә күрмәгез тагы. Хатын-кыз дигән халык бик бызгучан була бит ул, өйдә Сафура бураны куптарулары бар!* Г. Бакиров.

БЫЗЛАВЫК 1. *и.* Бызылдап оча торган элпә канатсыз коңгыз.

2. *с. к.* бызылдавык.

БЫЗЛАУ *ф.* 1. «Быз» сыман тавыш белән шаулау, хәрәкәт итү. *Өйдә бер генә чебен дә бызламый.* М. Максуд. [*Бал корты*] *бызлап очып кырга китә.* М. Гафури.

2. Шелтәле тон белән, ләкин тавышны күтәрмичә туктаусыз сөйләнү, ачулану; быжлау. [*Ул*] *күй, бызлап торма дигән шикелле кулын селтәде дә Газинурның сүзләренә бөтенләй җавап бирми башлады.* Г. Әпсәләмов.

БЫЗЫЛДАВЫК *с.* Бызылдый, бызылдап шаулый, хәрәкәт итә торган. *Берничә мәртәбә колак яныннан бызылдап пуля үтсә дә, мине дә, башкаларны да бызылдавык пулялар гына туктата алмадылар.* Р. Ильяс.

БЫЗЫЛДАУ *ф. к.* бызлау. *Пуля бызылдау.* □ *Тәрәзә пыяласында бәргәләнә торган шөпшәнең ярсый-ярсый бызылдавы да ул тынлыкны бозмый.* Ә. Фәйзи. *Орчыкның өзлексез бызылдавы өйдәге моңсулыкны арттыра.* И. Гази.

БЫК *аваз.ияр.* Үрдәк бакылдавын хәтерләткән һ. б. ш. тавышларны белдерә. // Теле ачылып җитмәгән бала яки гомумән сүзләрен аерып аңлап булмый торган кеше сөйләмен белдерә. *Исерекнең теленә бик мәгънәле бер сүз килгән. Авызы шуны әйтәм дисә, бык-бык дигән.* Н. Исәнбәт.

БЫКЫЛДАУ *ф.* 1. *к.* бакылдау 1. *Суның теге як читендә, сайлыкта, өч сары үрдәк быкылдаша иде.* Э. Касыймов.

2. *сөйл.* Сүзләрне аерып аңлап булмаслык ровештә сөйләү (нәниләр һ. б. турында).

3. *күч. гади с.* Такылдау, лыгырдау, лыкылдау.

БЫКЫР *аваз.ияр.* 1. Катырак һәм саңгыраурак «быгыр» тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Быкыр» сыман тавыш чыгарып. *Куера башлаган токмачның быкыр-быкыр кайнавы.* □ *Казанда быкыр-быкыр бутка пешә.* Г. Гобәй.

Быкыр-быкыр итү (килү) — быкырдау. [*Өйрәтүче абзый*] *малайларның ботларыннан тотып, акырта-бакырта суга ыргыта. Тегеләр быкыр-быкыр киләләр, «туйганчы» су эчәләр, --- [йөзәргә] өйрәнәләр.* И. Гази.

БЫКЫРДАУ *ф.* 1. «Быкыр» сыман тавыш белән шаулау. *Мичкә чүен белән су куелган. Су элек салкын иде, беркадәр вакыт үткәннән соң Рәүфнең күз алдында күбекләнә, быкырдап кайный башлады.* Г. Иделле. *Күлнең суын су дисәң су түгел, ниндидер сасы сыекча быкырдап тора шунда.* Г. Әпсәләмов.

2. Суда яки сазда туенып шаулашып яту (каз-үрдәк турында). // Сай урында су коенып уйнап, чыланып-пычранып бетү (бала-чага турында). *Хәлим малайларны таныды: алар, бая Хәлимнәр бу якка чыкканда, су читендә быкырдап яталар һәм кайсысы бу бишенче керү дип, кайсысы алтынчы инде, дип үзара бәхәсләшәләр иде.* Г. Гобәй. // Чыланып, пычранып, сазга һ. б. ш. нәрсәгә буялып бетү. [*Сазда*] *сыерлар да, корсакка тикле батып, дуңгызлар шикелле быкырдап бетәләр.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. Нык юешләнүдән жебеп, баткакка әйләнү, сазлану (туфрак, аяк асты турында). *Кук ат, башын чай-*

кый-чайкый, кичәге яңгырдан соң быкырдаган кызыл балчыклы --- юл белән аларны шәһәргә алып менә башлады. И. Гази.

БЫҚЫРДЫК *с.* 1. Быкырдый, быкырдап тора торган. *Алар, быкырдык сулы баткак эченнән көч-хәл белән атлый-атлый, ике йөз метрлар чамасы алга уздылар.* Ш. Маннур. // Нык юешләнүдән җебеп, баткакка әйләнгән, сазланган (туфрак, аяк асты турында). *Быкырдык юл.* □ *Яңгырлар башланса, бәләкәй түмгәкләр белән капланган бу үзән бака ефәгенә киенгән быкырдык сазлыкка әйләнә иде.* А. Гыйләҗев.

2. *и. мәгъ.* Шундый сазламык җир. *Яңгыр ява, аяк асты адәм үтә алмаслык пычрак. Кая ул мондый ботылар белән йөрү. Моны быкырдык шунда ук суырып алып кала.* А. Расих.

БЫҚЫРДЫКЛАНУ *ф.* Быкырдыкка әйләнү, баткаклану, сазлану.

БЫҚЫРТ *аваз. ияр.* 1. Кинәт быкырдап куюны белдерә.

2. *хәб. функ.* «Быкырт» сыман тавышлар чыгарган хәрәкәтне белдерә.

БЫЛБЫЛ *и. шигъ.* Сандугач. *Әрәмәлектә өздереп-өздереп сандугачлар сайрый иде. И сайрыйлар да инде былбылкайлар! Берсеннән-берсе моңлырак, --- дәртлерәк сыздыралар.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* **былбылым.** Кешегә сөю һәм иркәләү хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Аларның әтисе, аркаларыннан сөеп, --- чәчләреннән сыйпады да: — Былбылларым, шулай балчык арасында йөрергә ярыймыни? --- диде.* М. Гафури. [*Вәли Гафифәгә:*] *Булдыңмы әле син, аппагым, әйдә алайса киттек инде, былбылым!* Г. Камал.

Былбыл кош — *к.* былбыл. *Былбыл кошым, сандугачым, Ник сайрамыйсың?* М. Җәлил.

БЫЛҚЫЛДАУ *ф.* 1. «Былык-былык» сыман тавыш белән бүлкелдәү.

2. *күч.* Артык симерү турында. *Сарыкны былкылдаганчы симертү.* □ *Галимҗан абыйның йорт эшләрен шактый олы яшьтәге, былкылдап торган тулы гәүдәле бер украин карчыгы башкара иде.* С. Әдһәмова.

БЫЛТ *аваз. ияр.* Калын тавышлы кискен «бүлт»не белдерә.

БЫЛТЫР *рәв.* Узган ел. *И юләр! Кысканга былтыр кычкыралармы быел!* Г. Тукай. *Былтыр көздән чибәр генә хәстәрләнде бит бу җир.* Г. Бәширов.

БЫЛТЫРГЫ *с.* Узган елдагы, узган елгы. *Заводның быелгы эшләп чыгару программасы былтыргыга караганда иң кимендә егерме биш процентка артык булырга тиеш.* Ш. Камал. *Чәчелгән җирләрдә уҗым яшәрә, чәчелмәгән җирләрдә былтыргы үлән саргаеп ята.* А. Расих.

БЫЛЫК-БЫЛЫҚ *аваз. ияр.* Калын «бүлт» сыман тавышны белдерә.

Былык-былык итү (килү) — шундый авазлар чыгарып бүлкелдәү, былкылдау. *Самоварда су бетә, тамчы гына тама — пелт-пелт килә. Безнең эчләр тула, үпкәдән уза, кузгалып йөри башласаң, былык-былык килә.* М. Әмир.

БЫР I *аваз. ияр.* 1. *гадәттә сузыбрак яки кабатлап.* Берәр нәрсәнең кызу әйләнеп-бөтерелеп яки калтырап торуын һәм шунда ишетелгән калтыраулы тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Быр» сыман тавышлар чыгарып. *Бөтерчекнең быр-быр бөтерелүе. Маховикның быр-быр әйләнүе.* // Сүзләре ачык әйтелеп яки ишетелеп җитмәгән сөйләм турында. *Ерак та түгел быр-быр сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады.* М. Гали.

БЫР II *аваз. ияр. гадәттә сузыбрак.* Салкынлык тою, чиркәнү, җирәнү, курку һ. б. ш. тойгыларны белдерә. *Салкын су Байгышны куырып алды булырга кирәк. Тоныкъ судан ярты тәнен күтәреп,... быррр... тәнен дә уа башлады.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Әгәр бу кар катламы җимерелеп төшсә, Идрис Харисович?.. Быр...— дип, туңгандай калтыранып китте* [*кыз*]. Ә. Айдар.

БЫРГЫ *и.* 1. Җәенке башлы металл (элек мөгездән дә ясалган) көпшә рәвешендәге тынлы музыка яки сигнал коралы (гадәттә төрлечә бөгеп эшләнгән була). *Оркестрдагы җиз быргылар.* □ *Мәйданнарда җиңү маршын Уйный бүген көмеш быргылар.* К. Нәҗми. *Шәмсетдин басу капкасы төбенә барып баса да быргысын гына уйната. Байтирәк сыерлары, шушы тавышны ишетүгә, мөгри-мөгри үзләре җыелалар.* Г. Бәширов.

2. *сир.* Быргы кычкыртып бирелгән сигнал. [*Зәбих — Мусага:*] *Өченче быргыда сез һәлак булачаксыз.* Н. Исәнбәт.

3. *сөйл.* Рупор. *Буксир пароходлар --- баржаларны өстериләр, өсләрендәге кызыл йөзле капитаннары, тагы да кызара төшеп, быргылар аркылы әллә нәрсәләр кычкырыналар.* Ф. Әмирхан.

БЫРГЫЧЫ *и.* Быргы уйнаучы; быргы белән сигнал бирүче; сигналчы. *Быргычы матрос.* □ *Пионерлар сафка тезеләләр, килүчеләр ягына карап быргычы каршылау сигналын бирә.* А. Алиш.

БЫРҚЫЛДАУ *ф.* «Бырык» сыман тавыш чыгару, шундый тавыш белән шаулау; бырык-бырык килү. *Быркылдый-быркылдый йөзәргә өйрәнү.*

БЫРЛАУ *ф.* «Быр» сыман тавыш чыгарып яңгырау, калтырау. *Чыраның бырлап януы. Мотор бырлау.*

БЫРЫҚ *аваз. ияр.* 1. Суда өзек-өзек сулыш алып батар-батмас хәрәкәтләнгәндә яки тончыкканда ишетелгән тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* Шундый тавышлар чыгарып. *Суда бырык-бырык йөзеп маташу.*

БЫРЫЛДАУ *ф. к.* бырлау. *Янган чыра бырылдаса, татар буран көтә.* К. Насыйри.

БЫТ *аваз. ияр. гадәттә каб. форм.* 1. Бытбылдык кычкырганда (сайраганда), кечкенәрәк двигательләр эшләгәндә ишетелгән һ. б. ш. тавышны белдерә.

2. Теле ачылып җитмәгән бала яки сүзләрен аерып аңлап булмый торган кеше сөйләмен белдерә. // Бик кызу яки күп сөйләүче, такылдык һәм лыгырдык кеше сөйләмен белдерә.

3. *рәв. мәгъ. каб. форм.* Шундый тавышлар белән (берәр нәрсәнең хәрәкәт итүе, сөйләү һ. б. ш. турында). *Ә бытбылдык бытылдык Такмаклый янда быт-быт.* Ш. Маннур.

Быт-быт итү (килү) — 1) шундый авазларны хәтерләтеп яңгырау, шаулау. *Ык ягыннан быт-быт итеп моторлы көймә гөрләве ишетелә.* Г. Мөхәммәтшин; 2) *к.* бытылдау.

БЫТБЫЛДАУ *ф.* 1. Сайрау, кычкыру (бытбылдык турында). *Арба тәгәрмәчләре тавышына пырхылдап кошлар атылып чыга. Бытбылдык бытбылдый.* К. Латыйпов. // Бытбылдык сайраган, кычкырган сыман тавышлар чыгару. *Еракта, урман артында, нәрсәдер бытбылдады.* К. Нәҗми.

2. *күч. сөйл.* Бытылдау, такылдау.

БЫТБЫЛДЫҚ *и.* 1. Кыр тавыгының бер төре: очлаеп килгән озын канатлы, бик кыска койрыклы басу кошы; *русчасы:* перепел, перепелка. *Якындагы болынлыктан бытбылдыкларның өзек-өзек тавышлары яңгырый.* С. Сабиров.

2. *күч. сөйл.* Тиз һәм күп сөйләүче такылдык һәм лыгырдык кеше турында.— *Миннән нинди разведчик чыксын инде, болай күп бытылдаучы бытбылдыктан.* Ф. Хөсни.

БЫТҚЫЧ *с. сөйл.* Вакчыл һәм бәйләнчек (кеше турында).

БЫТҚЫЧЛАНУ *ф. сөйл.* Вак нәрсәләргә дә бәйләнеп борчу.

БЫТЫЛДАУ *ф. сөйл.* 1. Сүзләрне ачык итеп әйтә алмыйча яки бозып сөйләү (теле ачылып җитмәгән бала яки телендә, сөйләмендә берәр кимчелек булган

һ. б. ш. берәү турында). [*Марат*] *бераз сакау тел белән шундый мәзәк, шул ук вакытта шундый җитди итеп бытылдый.* Г. Гобәй. [*Карт*] *аз-маз казакъча бытылдый икән.* Г. Ибраһимов.— *Ах, Тилгән әфәнде! — дип бытылдаган Күке, куркынып.— Мин һич тә сезне ачуландырырга теләмәгән идем.* Әкият.

2. Ашыгып яки күп сөйләү. [*Закирә*] *үзен-үзе тота алмыйча бытылдарга тотынды.* Г. Иделле. *Я, я, абыйны бүлдермәгез әле, бытылдамагыз, малайлар!* А. Расих.

БЫТЫЛДЫК *и. сөйл. к.* бытбылдык 2.

БЫТЫРДАУ *ф.* 1. *сир. к.* бытылдау.

2. *сөйл.* Такылдау, күп сөйләү. *Бер көн бер урысны керттеләр, сөйләшәм дисәң, сөйләшеп булмый, ул үзенчә бытырдый, мин үземчә. --- Ул әйткәнне мин аңламыйм, мин әйткәнне ул аңламый.* И. Гази.

БЫҖЫР-БЫҖЫР *аваз. иярт.* 1. Нечкәрәк тавыш белән җиңелчә быгырдауны белдерә. [*Суфи:*] *Гайрәте ничегрәк икән? Туйда балның гайрәтлесе күркәм була.* [*Айтуган:*] *Суфи абзый, быҗыр-быҗыр булып тора.* Қ. Тинчурин.

2. *рәв. мәгъ.* «Быҗыр» сыман тавыш чыгарып. [*Сазлыктан барганда*] *түмгәгендә озаграк торсаң, күз алдында ул югала, быҗыр-быҗыр күбекләнеп чыккан җирән су итек кунычын кумә башлый.* Ш. Маннур.

БЫҖЫРДАУ *ф.* 1. «Быҗыр» сыман тавыш чыгару. *Сазлык суының быҗырдавы. Эч быҗырдау.*

2. Бик сыек пычрак хәленә килү (аяк асты турында). *Яңгырдан соң үзәнлектәге юлның быҗырдап бетуе.*

БЮДЖЕТ *и.* Дәүләтнең, предприятие яки учреждениенең билгеле бер срокка каралган керем-чыгым сметасы (исәп-хисабы). *Дәүләт бюджеты.* ☐ [*Җәмәгать каралтыларын һәм корылмаларын ремонтлау*] *авыл советы бюджетында каралган булырга тиеш.* Ф. Хөсни. // *күч. кит.* Берәүнең тереклеген, тормышын тәэмин итә торган сума, аның шәхси керем-чыгымнары. *Балалар киемнәренә яңа прейскурант кертү күп ата-аналарны шатландырачак. Ул семья бюджетына экономия ясаячак.* Соц. Тат.

БЮЛЛЕТЕНЬ *и.* 1. Иҗтимагый әһәмиятле берәр вакыйга яки мәсьәлә турында кыскача рәсми белдерү, хәбәр. *Ильичның сәламәтлеге турында көн дә өч тапкыр чыгарылган информация бюллетене алынган сәгатьләрдә вагонны тутырып җыела, бюллетеньнең кыска сүзләрен күңелгә сеңдереп, үз иптәшләребез янына ашыга идек.* Ш. Усманов.

2. Берәр учреждениенең, җәмгыятьнең һ. б. ш. вакытлы басмасы. *Һәр көн иртәле-кичле әре хәрефләр белән басылып таратыла торган «Сугыш хәбәрләре» дигән бюллетеньнәр ике көннән бирле таратылудан туктадылы.* М. Гафури.

3. Сайлауда яшерен тавыш бирү кәгазе. *Сайлаучыларга бюллетень биреп тору.* ☐ *Күтәрепме кулны, Салыпмы бюллетень, --- Ничек сайласак та, Тавышын бәтен ил Икеләнми бирде Шул ук властьны яклап.* Э. Исхак.

4. *сөйл.* Авырганда хезмәткә яраксызлык турында бирелә торган врач язуы. *Чирләгән көннәр өчен бюллетень буенча акча алу.* ☐ *Мин сиңа бюллетень язам, Газинур. Син берничә көн өйдә генә утыр, диде* [*врач*]. Г. Әпсәләмов.

◇ **Бюллетеньдә булу (йөрү)** — бюллетень (4 мәгъ.) буенча эштән азат ителгән булу.

БЮ'РГЕР *и.* Шәһәр кешесе, мещан (Германия һ. б. кайбер Көнбатыш илләрендә).

БЮРЕ'ТКА *и.* Сызыклар белән бүлемләнгән пыяла көпшәчек (сыеклык микъдарын үлчәгәндә кулланыла). *Бюреткага кислота эремәсе салу.*

БЮРО *и.* 1. Җитәкчелек итүче яки боерык бирүче үзәк (берәр оешмада, органда һ. б. ш.). [*Рәхим*] *икенче катка, институтның партия бюросы урнашкан бүлмәгә менеп китте.* А. Расих. // Шушы үзәкнең утырышы. *Бюро башланырга шактый вакыт бар әле.* Г. Әпсәләмов. *Райкомда бүген бюро бара.* Н. Баян.

2. Кайбер учреждениеләрнең, алардагы кайбер бүлекләрнең һ. б. ш. исеме. *Адреслар бюросы.* ☐ *Сез әллә элек метеорология бюросында эшләдегезме? Һавалар торышын һәрвакыт алдан әйтеп бирә беләсез.* Г. Әпсәләмов. *Казан аэропортының белешмәләр бюросы аркылы сине пассажирлар залыннан эзләтеп карадык.* Б. Камалов.

БЮРОКРАТ *и.* 1. *иск.* Буржуаз дәүләтләрдә: бюрократик идарә системасындагы зур дәрәҗәле түрә. *Дума таратылгач, бюрократлар куәт алды, Хөррият тарафларны төрмәгә салды.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Төп игътибарны рәсми кәгазьләргә, эшнең формаль ягына биреп, эшнең асылына зарар китерүче хезмәткәр (гадәттә җитәкче). *Үзе чакырган булды. Үзе тагын урынында юк. Бу секретарь бюрократ булып чыгар, ахрысы.* Г. Иделле.

БЮРОКРАТИЗМ *и.* Бюрократлык, бюрократия. *Ленинның шундый кисәтүе бар: әгәр безне бетерсә шул бюрократизм гына бетерә ала, ди.* А. Расих.

БЮРОКРА'ТИК *с.* Бюрократиягә, бюрократларга хас; шуларга мәнәсәбәтле. *Бюрократик строй. Эшкә бюрократик караш.* ☐ *Планлаштыруның яңа системасы авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүдәге бюрократик бозуларны бетерүгә булышлык итте һәм колхозларның иҗади инициативасына юл ачты.* КПСС тарихы.

БЮРОКРА'ТИЯ *и.* 1. Буржуаз дәүләтләрдә идарә итү системасы: халыктан аерылган һәм хаким сыйныф файдасына эшләүче түрәләрдән торган идарә аппараты. *Бюрократия үзенең эшләрен халык вәкилләренә белдертәсе килми.* Урал.

2. *күч.* Төп игътибарны эшнең асылына, эчтәлегенә бирмичә, рәсми-формаль ягына (инструкцияләргә, күрсәтмәләргә туры килүенә, тиешенчә язып теркәлүенә, документлаштырылуына һ. б. ш.) юнәлтеп идарә итү системасы.

БЮРОКРАТЛАНУ *ф.* 1. Бюрократларча эш итү.— *Сез нигә бюрократланып утырасыз анда, Курамшин? Спектакль куяр өчен нигә мәктәпкә сәхнә бирмисез?* Р. Ишморат.

2. Бюрократ, формалист кешегә әйләнү (аерым кешеләр турында).— *Әллә бюрократланып киттең инде, димме. Килмисең. Чакырганны көтәсең.* Г. Минский.

БЮРОКРАТЛАШУ *ф.* 1. Буржуаз дәүләтләрдә: идарә итү эшендә бюрократия (1 мәгъ.) системасы урнашу. *Идарә системасының бюрократлашуы.*

2. Бюрократка әйләнү, бюрократлану.

БЮРОКРАТЛЫК *и.* Бюрократ (2 мәгъ.) булу хәле, бюрократка хас сыйфатлар. *Бюрократлык — җанлы эшнең дошманы.* Чаян.— *Бюрократлык бу, кәгазь волокитасы.* Ф. Хөсни.

БЮСТ *и. махс.* Гәүдәнең билдән яки күкрәктән югары өлешенең яисә башның скульптур сурәте. *Бронза яки мрамор бюстлар.* ☐ *Язу өстәлендә Ленинның --- кечерәк кенә бер бюсты күренә.* Г. Бәширов.

БЮСТГА'ЛЬТЕР *и. кит.* Хатын-кызның күкрәген (имиен) генә каплап-җыйнап тора торган махсус эчке кием.

БӘ *аваз. иярт. гадәттә сузып* (бә-ә *дип*) *яки һәмәбелән* (бәә *дип*) әйтелә. Сарык, бәрән кычкырганда ишетелгән тавышны белдерә. *Сарыклар борыннарын җиргә төртеп, үзләре бертуктаусыз бә-ә-әү дип кычкыра-кычкыра, кырт-кырт үлән йолкалар.* М. Гали. *Бәтиләр бә! диләр.* Ә. Бикчәнтәева.

БӘБИ *и.* 1. Яңа туган бала, имчәк баласы. *Тиздән бәби туасын көтеп йөргән Сәмигулла хатыны, картлар киткәч, олы якка чыкты.* С. Рафиков. *Йокла, нәни, йок-*

ла, бәби, әлли-бәлли, бәлли-бәү! М. Җәлил. // *күч.* Кечкенә балалар кебек беркатлы һәм тәжрибәсез кеше турында. *Гыйльметдин абыйсы аны үрти: — Әнкәсен сагынган, күсәк хәтле малай әнисез тора алмый, бәби!* И. Гази.

2. *гадәттә балалар теләндә.* Курчак.

3. *диал.* Бәпкә. *Каз-үрдәкләр майның беренче яртысында бәбиләр чыгардылар.* Г. Галиев.

БӘБИЛӘНҮ *ф.* Бәбиләр, нәниләр кебек кылану.

БӘБИЛӘҮ *ф.* Бәби, бала тудыру. *Заводта эшләүче әҗәм кешесенең хатыны бәбиләгән.* И. Гази.

БӘБӘК I *и.* 1. Күзнең карасы (кешесе); *русчасы:* зрачок.

2. *гади с.* Күз. *Бәдринең үткен яшел бәбәкләре күршедәге алма бакчасын шәйләп алды.* И. Гази.

БӘБӘК II *и.* 1. Яңа чыккан яшь ботак, сабак. *Язгы чәчәкләр аткан, Яшел бәбәкләр чыккан, Кичләр матур, төн тыныч, Иртән матур язгы таң.* М. Укмаси.

2. Чәчәк бөресе (бигрәк тә үләннәрдә). *Бастамов, бер ата чәчәкне алып, бәбәкләрен үзеп ташлады.* Г. Галиев. *Энҗе чәчәк — ямьле май чәчәге, Бәбәгендә язның рәсеме бар.* Ә. Ерикәй.

БӘВЕЛ *и. иск. кит.* Сидек. *Аллә кайчангы иске күн исләре, суны күп сибүдән чери башлаган гөл кисмәге исләре, аллә кайсы почмактан гына чыгып борынны яра торган күсе бәвеле исләре, һәммәсе бергә бутальп, Мусаның башын томалый шикелле тоелды.* Ш. Маннур.

БӘГЪЗЕ *а. иск.* Кайбер. *Бәгъзе кешеләр бу китапны бигрәк урам теләндә чыгарган икән дип көләрләр.* Г. Камал.

БӘГЫРЬ *и. шигъ.* Йөрәк; кешенең барлык хисләре, кичерешләре бергә тупланган-төенләнгән орган символы. *Җырладым, чәнчеп каләмне Бай, палачлар бәгыренә.* З. Бәширн. *Тышка чыксам, ташка басам, Ташның салкыннарына, Кулларымны куеп елыйм Бәгырем ялкыннарына.* Т. Гыйззәт. // *тартымлы форм.* Бик яраткан, сөйгән кеше турында.— *Әй, Алмасым, төпчек улым, бәгыремне мәңге күрә алмаммыни инде!?* А. Эхмәт. // **бәгырем.** Сөю хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Белсә идең, бәгырем, нинди көчле Ялкын белән сине яратам.* М. Җәлил.

◇ **Бәгырь кисәгем, бәгырем кисәге** — бик яраткан, сөйгән кеше яки шуна әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. **Бәгырьне кисү (парә-парә китерү, үзү һ. б.)** —рухи газаплау. *Кисмә минем бәгыремне, кызым, кисмә!* Р. Ишморат. *Гөлсем апа үз мисалында әти-әнием юк дип йөрүнең никадәр бәгырьне үзгәнен сөйләде.* Г. Гобәй.

БӘГЫРЬСЕЗ *с.* Кешелек хисләре аз булган, кешелексез; бик каты күңелле. *Кара, тагын Шакир абый кирәк булган моңа [Гөлчәһрәгә], бәгырьсезгә.* Г. Әпсәләмов.

БӘДБӘХЕТ *с. гади с. тирг.* Явыз. *Бәдбәхет усаллардан кач зинһар.* М. Гафури. *Күп ерткычлыклар эшләдең, бәдбәхет, кадал!* А. Алиш.

БӘДДОГА *и. иск.* Каргау, каһәрләү догасы; каргыш. [*Җиһанша хәзрәт*] *файданы китерер өчен хәердога, зарарны китерер өчен бәддога коралы кулланыр иде.* З. Һади. [*Мөтәвәлли*] *хәлфә абый исеменә каргыш сүзләр әйтә-әйтә, кул аркасын йөзенә каратып тотып, бәддога кылырга кереште.* Г. Гобәй.

БӘДРӘФ *и.* Махсус тәрәт урыны яки бүлмәсе. *Башка заман булса,— диде,— Миңзифа - - - синең бу чүпчарыңны бәдрәф чүпрәгенә тотарлар иде.* Г. Ибраһимов.

БӘДӘВИ *и.* Күчмә тормышлы чүл гарәбе. *Заманасында Гарәбстан бәдәвиләренә тәэсир иткән бу мөһергә швейцарның әз генә дә исе китмәде.* С. Җәләл.

БӘДӘЛ *и. иск.* 1. Кеше өчен ялланып хажга бару. *Моңарчы Шәпеш кебек карт пешкадәмнәр кәсебе булып килгән бәдәлнең яшь хәлфәләрне кызыктыруы Габдуллага сәер тоелды.* Ә. Фәйзи.

2. Шунда барган өчен бирелә торган акча. *Гомәр хәлфә, Мамышевлардан бәдәл алып, хаҗга китеп барды.* Ә. Фәйзи.

БӘДӘЛЧЕ *и. иск.* Икенче бер кеше урынына ялланып хаҗга баручы. *Беләсеңме, бәдәлче кем ул, Зөһрә ханым? Үзе өчен түгел, кеше өчен ялланып хаҗга баручы!* Н. Исәнбәт. *Бәдәлчеләр-мәккәчеләр йөри Казан шаулатып; Бер сөяккә унлап эт бар, чәйнәшәләр даулашып.* Г. Тукай.

БӘДӘН *и. иск. кит.* Тән, гәүдә. *Урман кисү эшеннән кайтып, арган бәдәнне сәкегә — төнге ялга ташлаган гына идек, авыл өстендә шау-шу купты.* З. Бәширн.

БӘДӘНЛЕ *с. иск.* Гәүдәле, таза тәнле. *Безнең әти бәдәнле булса да, өшән, тиз аручан.* Г. Гобәй.

БӘЕТ *и.* 1. Халык авыз иҗаты әсәре: берәр кешегә яки вакыйгага багышланып, гадәттә шаярту яки кызгану хисләре белән сугарылган шигырь. *Сак-сок бәете. Ышна бәете. Бәет әйтү. Бәет көе.* □ *Гата хартны сүгеп, кызны кызганып, авылда бик зур бәет чыкты.* Г. Ибраһимов.

2. *иск. әд.* Шигырьнең мәгънә һәм интонация ягыннан аерымланып торган бер кисәге, өзеге. *Көйләү тибындагы лирика дигәннән вәзен, кафияләргә салынган, бәетләргә бүленгән шигырьләрне генә алырга ярамый.* Г. Нигъмәти.

БӘЕТЧЕ *и.* Бәет чыгару яки бәет әйтү остасы. *Габдулла, бәетченең яныннан киткәч тә һаман каерылакаерыла, аңа карап барды.* Ә. Фәйзи.

БӘЗ *и.* 1. Тыгыз киже-мамык тукыма. *Эче кара бәздән, уртасына мамык куйдырып, бишмәт тектердек.* М. Гафури. *Миләүшәнең ак безгә чигелгән зәңгәр кыңгырау чәчәкләренә сокланып карап тордым.* Ә. Бикчәнтәева.

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Бәз күлмәк. Бәз ыштан. Бишмәткә бәз эчлек алу.*

БӘЙ I *и.* Берәр нәрсәне кая да булса бәйләп яки хайванны арканлап куя торган бау, киндерә, чылбыр һ. б. ш. нәрсә. *Бәйне үзү. Эт бәе.* □ *Пароход бәйләреннән ычкынды да яр буеннан шым гына кузгалып китте.* И. Гази. // Бәйләвеч (1 мәгъ.). *Алъяпкыч бәе. Бүрек бәе.* □ [*Старшина*] *гимнастерка-чалбарларыбызны, итекләребезнең ничек куелышын тикшереп йөргән һәм шунда минем балак очымдагы бәйләрне чишмичә йоклаганымны күреп алган.* Ф. Хөсни. // *Кыек килешләрдә.* Бәйләп, арканлап тоту-тотылу, асрау-асралу хәле. [*Салихҗан*] *ияреннән төште дә атын яңадан бәйгә куйды.* Г. Галиев. *Чылбырын үзде дә йөгерде хуҗамның бәйдәге зур филе.* Ә. Исхак.

◇ **Бәйдән ычкыну** — бик тәртипсезләнеп, узынып, бозылып: тыя-тыела алмас хәлгә килү.

БӘЙ II *тар.* 1. Мөселман динле феодаль Кавказ ханлыкларында: берәр райондагы яки шәһәрдәге идарә итүче. *Бу көйләр ханнар, бәйләрнең сарайларында әсирә черкес җарияләрнең көйләре дә түгел.* Г. Газиз.

2. Ирләр исеменнән соң әйтелгәндә, «әфәнде» мәгънәсен дә аңлаткан. *Мин үзем Кәмал бәйнең - - - бәетен генә әйтер идем.* Г. Тукай.

БӘЙ III *ы.* Кабатлап яки «әлли-бәлли» һ. б. сүзләр белән аралаш: бәбинә йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә торган сүз.

◇ **Бәй итү** — 1) шул сүзләр белән көйләп тирбәтү; 2) йоклау (көйләп тирбәтелүче бәби турында). *Җырлый-җырлый кыз бала Энекәшен йоклата. - - - Әлли-бәлли, бәй итә, Энем йокыга китә.* М. Мазунов. *Бүген йоклыйк әле... Бәй-бәй итик... иртәгә, әнкәй, иртәгә!..* А. Гыйләҗев.

БӘЙ IV *ы.* Кинәт килеп туган көчле гажәпләнүне белдерә. *Бәй-й! Мәдинә ахирәт!.. Син түгелме соң? Син ич!* М. Хәсәнов. *Бәй, синең белән сөйләшә торгач, эшемне оныттым ич мин.* Р. Ишморат. *Хатынның моңа*

хәтере калды: — Бәй, бәй... ничек сөйләнеп торган була бит. Г. Гобәй.

БӘЙГЕ *и.* **1.** Ат чабышы. *Революция җилләре исә башлаганнан соң, батрак Сибай, язгы бәйгеләрне сизеп җирсенгән чабышкыдай, кая барып бәрелергә белмичә җилкенеп йөрде дә күздән югалды.* Г. Бәширов.

2. Ат чабышлары үткәрелә торган мәйдан.

3. *күч.* Көрәш, көч сынаш, ярыш. *Кайда сез, әй, илне саклаучы баһадирлар! — Нигә чыкмыйсыз алтын сарайга Каршы канлы бәйгегә.* Һ. Такташ. *Җәмилә гел җиңә бәйгедә, Җәмилә гел кызыл тактада.* М. Җәлил.

4. Ат чабышканда һәм көрәштә җиңүчегә бирелә торган бүләк.— [*Егет*] *бәйгене бүтәннәрдән алдырса, Хәмдиясенә үпкәләмәс.* М. Фәйзи.

БӘЙЛЕ *с.* **1.** Бәйләнгән, бәйләп куелган. *Күз бәйле булу. Бәйле кул. Бәйле ат.*

2. Мөстәкыйльлеге булмаган; буйсынган. *Бәйле илләр. Бәйле дәүләтләр.* □ *Приказчик булып, кешегә бәйле булып торырга теләмим мин, диде Габделнасыйр.* М. Гали.

3. Берәр нәрсәгә карата сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә торган, шуңа бәйләнешле. *Үзеңә бәйле булганның барысын да эшләү. Уңышның ашлама кертүгә бәйле булуы.* □ *Аның күңел күтәренкелеге күп очракта шул балаларының хәл-әхвәленә бәйле була иде.* А. Расих.

4. Берәр нәрсәгә яки кешегә мөнәсәбәтле, бәйләнешле, шуңа караган. *Марат, әнисе үлгәнгә ел ярым дигәндә, аңар бәйле хатирәләрне тәмам онытып бетерде.* Г. Гобәй. *Яңа урамнарга яңарак исемнәр, әйтик, шушы якларның үзенә бәйлерәк исемнәр куясы иде бит.* Р. Төхфәтуллин.

БӘЙЛӘК *и. лингв.* **1.** Барлык төр исем һәм шул функциядәге сүзләрнең башка сүзләргә синтаксик мөнәсәбәтен белдерүче ярдәмлек сүз. *Баш килеш бәйләкләре. Юнәлеш, чыгыш килеше бәйләкләре.*

2. *с. мәгъ.* Бәйлек функциясендәге. *Бәйлек сүз.*

БӘЙЛЕЛЕК *и.* **1.** Бәйле булу хәле.

2. Мөстәкыйльсезлек, буйсынганлык. *Экономик бәйлелек. Политик бәйлелек. Крепостной бәйлелек.*

БӘЙЛӘВЕЧ *и.* **1.** Изүне, бүрек колакчыннарын, балак очларын һ. б. җыеп бәйләү өчен кара-каршы китереп тагылган бәйләрнең берсе. *Күгәвәй дә күлмәк, бурлат кештәк, Ак укадан үргән бәйләвеч.* Ә. Фәйзи.

2. Җәрәхәтләнгән, шешкән урынны каплау, саклау өчен урап бәйли торган бинт яки башка әйбер. *Ситдыйк абзый маңгаендагы бәйләвечен өскәрәк тибәрде.* Қ. Нәҗми. *Икенче көнне үк профессор, операциясенең нәтиҗәсен белү өчен, ассистентыннан Абдулланың күз бәйләвечен чиштерде.* Э. Қасыймов.

БӘЙЛӘВЕЧЛЕ *с.* **1.** Бәйләвече (1 мәгъ.) булган, бәйләвеч белән бәйләнә, тоташтырыла торган (изү, бүрек колакчыны һ. б. турында). [*Шәрәфи*] *күлмәгенең бәйләвечле изүен чиште.* Г. Галиев.

2. Бәйләвеч (2 мәгъ.) белән бәйләнгән. [*Бабай*] *минем бәйләвечле кулымны, өзелгән балак-җиңнәремне күрде.* Н. Исәнбәт.

БӘЙЛӘГЕЧ *с.* **1.** Бәйләү, теркәү, тоташтыру өчен кулланыла яки хезмәт итә торган. *Сварка аппаратының бәйләгеч муфтасын яңача конструкцияләргә тәкъдим иттеләр.* Соц. Тат.

2. *и. мәгъ. к.* бәйләвеч.

БӘЙЛӘМ *и.* **1.** Җыеп, төреп яки чорнап, бер кисәк, төргәк итеп бәйләнгән бер иш әйберләр. *Ачкыч бәйләме. Китап бәйләме.* □ *Алып куйдым өстәлләргә Төрле чәчәк бәйләмен.* Җыр. *Сержант гранаталар бәйләмен кулына* [*тоткан*]. А. Расих.

2. *сир.* Җәрәхәт, шеш өстендәге бәйләвеч. [*Яралы солдат*], *башын тотып, ыңгырашырга тотынды; маңгаендагы ак бәйләм кызара башлады.* Ш. Усманов.

3. Бәйләү, кул эше. *Бәйләм бәйләп утыручы карчыклар.*

4. *с. мәгъ. диал.* Бәйләнгән, бәйләп эшләнгән. *Бәйләм бүрек.* □ *Мин инде өстә бәйләм күлмәк белән генә басып тора идем.* Н. Исәнбәт.

БӘЙЛӘМЛЕ *с.* Бәйләм-бәйләм итеп төрелгән; бәйләмнәргә аерылган. *Бәйләмле чәчәк.*

БӘЙЛӘМЛӘҮ *ф.* Бәйләм-бәйләм итеп төрү; бәйләмнәргә аеру. *Салам бәйләмләү. Мал себеркесен бәйләмләү.*

БӘЙЛӘНЕШ *и.* **1.** *к.* бәйләнү (1—6 мәгъ.). *Кайберәүләр аңа бәйләнеп тә алдылар. Ләкин бу бәйләнеш озакка бармый басылды.* М. Гафури.

2. Үзара бәйлелек, шартлылык мөнәсәбәте. *Теориянең практика белән бәйләнеше.* □ *Табигый бәйләнешнең, табигать күренешләре бәйләнешенең объектив рәвештә бар булуы ап-ачык.* В. И. Ленин. [*Галимә*] *бер-берсенә һичбер бәйләнеше булмаган сүзләр сөйли.* М. Гафури.

3. Турыдан-туры аралашу; якын һәм тыгыз элемтә, мөнәсәбәт. *Мәктәпнең тормыш белән бәйләнеше. Бәйләнешне өзү. Авыл белән бәйләнеш тоту.* □ *Шушы вакыттан алып инде безнең арадагы дуслык-бәйләнеш даими бер төскә керде.* Э. Еники. *Драматургия белән театр арасында бик тыгыз бәйләнеш тудырырга кирәк.* М. Җәлил. // Рәсмиләштерелмәгән мәхәббәт мөнәсәбәте, яшерен якынлык. *Ул чакта мин сиңа Фатихның Зөләйха белән әле һаман бәйләнештә торганлыгын сиздермәгән идем.* Э. Қасыймов.

4. Хәбәрләшү, элемтә. *Полк командиры бәйләнеш өчен тагын ике кавалерист җибәрде.* А. Шамов.— *Алдагы күзәтү пункты белән бәйләнеш ничек? — дип сорады ул.— Бәйләнеш яхшы, иптәш подполковник!* [*диде телефончы*]. Г. Әпсәләмов.

БӘЙЛӘНЕШЛЕ *с.* **1.** Берәр нәрсәгә яки кешегә мөнәсәбәтле, кагылышлы, бәйле (4 мәгъ.). *Истәлекләр белән бәйләнешле уйлар.* □ *Бу ике вакыйга бер-берсенә бәйләнешле түгелме икән.* Г. Минский.

2. *махс.* Логик һәм грамматик яктан дөрес төзелгән, эзлекле текст рәвешендәге (сөйләм, язу турында). *Салих* [*кызның*] *чая икәнен бик күптән белсә дә, болай килешле итеп, укытучылар шикелле бәйләнешле итеп сөйләвен беренче тапкыр ишетә иде.* Г. Мөхәммәтшин.

БӘЙЛӘНЕШЛЕЛЕК *и.* Бәйләнешле булу хәле.

БӘЙЛӘНЕШСЕЗ *с.* **1.** Берәр нәрсәгә бәйләнеше, мөнәсәбәте булмаган.

2. Буталчык, логикасыз, эзлексез, аңлаешсыз (сөйләм һәм андагы сүзләр турында). *Шәмсия карчык йоклы арасында Вафинның соравын аңышмый калды булса кирәк, бәйләнешсез бер-ике сүз мыгырданды да янә тынды.* Ф. Хөсни. *Фарит, сагынып көткән анасын үбәкоча, балаларча бәйләнешсез итеп, күргән-белгәннәрен сөйләргә тотынды.* Г. Минский.

БӘЙЛӘНЕШСЕЗЛЕК *и.* Буталчыклык, логикасызлык, аңлаешсызлык (сөйләм турында). *Хәзер минем уйларым таркау. Мин аларны бер үзәккә җыйный алмыйча газапланам. Шуңа күрә сүзләремдә дә беркадәр таркаулык һәм бәйләнешсезлек килеп чыга бугай.* Ш. Камал.

БӘЙЛӘНЧЕК *с.* **1.** Әһәмиятсез яки юк кимчелекләрне һ. б. сылтау итеп бәйләнергә яратучан. *Килен булып төшкәндә аның аяк астына келәм җәеп каршы алган сөйкемле әнкәсенең хәзер әнә шулай вак сүзле, кырыс чырайлы, көнче һәм бәйләнчек каенанага әверелә баруы бик аяныч иде.* Г. Бәширов. [*Егет*] *бүтәннәрдән көлүдә, бүтәннәрне мыскыллауда үзенә ниндидер канәгатьләнү, ниндидер ләззәт табучы бер бәйләнчек кеше иде бугай.* Н. Фәттах. // Төпченүчән, артык еш мөрәҗәгать итеп борчучан. *Атлылар әйтергә теләмәсәләр дә, бәйләнчек ишан аларны дөресен сөйләргә мәҗбүр иткән.* Э. Қасыймов. // Бәйләнчеклекне күрсәтеп, белдереп тора торган (сүз һ. б. ш. турында). *Бәйләнчек сорау. Бәйләнчек сүз.* // Һәркемгә ташланып, та-

ларга, тешләргә торучы, усал (хайваннар, кошлар турында). *Малай кулындагы чыбыгы белән бер бәйләнчек казны куа.* Г. Гобәй.

2. Ихтыярсыздан күңелгә килеп туйдырып бетерә, тынгысызлый торган (уй һ. б. турында). *Бу бәйләнчек уйлардан тизрәк котылырга теләгәндәй, өстенә кыска бишмәтен киеп, ашыгып тышка чыкты Гайния.* Ф. Хөсни. *Тел очында һаман шул бәйләнчек такмак әйләнде.* Г. Әпсәләмов.

БӘЙЛӘНЧЕКЛЕК *и.* Бәйләнчек кешегә һ. б. хас сыйфатлар. *Көлүче — бәйләнчеклеге өчен Черки кушаматы алган Ибраһим исемле малай иде.* Г. Гобәй.

БӘЙЛӘНЧЕКЛӘНҮ *ф.* **1.** Бәйләнчек булып китү, бәйләнчеккә әйләнү.

2. Бәйләнчек булып кылану; бәйләнү. [*Егетнең*] *куанычы сүрелде. Ул гадәттәгечә бәйләнчекләнә, ризасызлык күрсәтә башлады.* А. Расих.

БӘЙЛӘҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* бәйләү.

2. *сир.* Элемтә урнаштырып, бәйләнешкә керү, хәбәрләшү. *Штурмчылар полкы командиры майор Линник белән бәйләндем һәм алардан фронттагы хәлләр турында безгә хәбәр итеп торуны үтендем.* Каз. утл.

3. *шелт.* Берәү белән якын, тыгыз мөнәсәбәткә керү. // Өйләнү, иргә чыгу. *Фәхри кебек бер өтеккә бәйләнмәсәң, сиңа үз тиңең табылмас дип белдеңме? — дип шелтәләделәр [Гайшәне].* Г. Ибраһимов. [*Мөнирә Назимга:*] *Сиңа күз атучылар азмыни? Ник тол хатынга бәйләнәсең?* Э. Касыймов. // Рәсмиләштерелмәгән бәйләнешкә керү. *Ни өчен бәйләнеп китте соң ул Асия белән? --- Гөлҗамалны яратмауданмы, Асиягә мәхәббәт тотуданмы?* Г. Иделле.

4. Рухи якынлык тою; якын, үз итә башлау. *Казан халкы Габдулла әфәндегә бик нык бәйләнгән. Шуның өчен дә аның яңадан сәхнәгә керә алмавы казанлыларга аерым күңелсез тәэсир итәчәк.* Ш. Әхмәдиев. *Гөлгенә бу дусларына инде йөрәге белән бәйләнде.* Н. Дәүли.

5. Керешү, алыну, башлау (гадәттә күңелгә ошап житмәгән берәр эшкә). // Берәр эшкә бик нык бирелеп, аннан арынып тора, китә алмас дәрәҗәдә мавыгу. [*Зәки:*] *Абыйның матур хыялы бар иде. Без аның белән бөтен тирә-юньне агач белән әйләндереп алмакчы идек. Шулай бит, Алсу?* [*Алсу:*] *Син үзең ич шул трактторга бәйләнеп киттең.* Р. Ишморат.

6. Башланып китү, уңышлы бару (сүз турында). *Беребезгә беребез сораулар бирсәк тә, сүз әле бәйләнми, --- гомуми сүзләрдән ары китеп булмый иде.* С. Баттал.— *Таныш булып чыктыгыз бит, сүзегез бәйләнер инде.* Н. Исәнбәт.

7. Вак, әһәмиятсез яки формаль кимчелек-житешсезлекләрне сылтау итеп, урынсызга шелтәләү, ачулану. [*Хәдичә*], *юк кына нәрсәләргә бәйләнеп, кешеләрнең ачуын китереп бетерде.* М. Хәсәнов. *Мәликә, барып керүе белән үк, бәйләнергә һәм аны бик каты хурларга тотынды.* А. Шамов. // Артык еш мөрәҗәгать итеп яки төпченүле сүзләр белән борчу. [*Малайның*] *кечкенәсе велосипедны күргән саен бәйләнә: әти, утыртып йөрт әле ди.* И. Гази. *Мин хәзер аңа тик тор дип түгел, сөйлә дип бәйләнәм.* Ф. Хөсни. // Таларга, тешләргә чамалап, эзәрлекләү (усал хайван, кош-корт турында).

8. *гадәттә* **бәйләнгән** *форм.* Берәр нәрсәгә карата сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә булу; гомумән, аңа мөнәсәбәтле булу. *Кешенең картаюы аның үзәк нерв системасының какшавына нык бәйләнгән.* Азат хатын. *Опера язуда бик күп нәрсә композиторның инициативасына бәйләнгән.* М. Җәлил.

БӘЙЛӘҮ I *ф.* **1.** Җеп, киндерә, бау, тасма кебек нәрсәләрнең очларын төен белән бер-берсенә яки бүтән әйбергә тоташтыру. *Илгизәр, арбасыннан төшеп, йөгән тезгенен капка баганасындагы бозрага бәйләде.* Г. Бәширов.

2. Бау һ. б. ш. нәрсә белән берәр җиргә тагып, эләктереп кую; арканлау. *Көймәне баржага бәйләп кую. Атны капка төбенә бәйләү.* ☐ *Ал бәйлиләр, гөл бәйлиләр Талган беләкләремә. Сабыр итәргә кушалар, Түзмим йөрәкләремә.* Җыр.

3. Бау, җеп ише нәрсәләр белән кысып урап төрү; төйнәү. *Бүләкне төреп кызыл тасма белән бәйләү.* ☐ *Аннан-моннан капкалап, өс-башка киендем дә кичтән үк бәйләп куйган төенчекне кулыма алдым.* Э. Касыймов. // Билбау, пута, эзәр ише нәрсә белән кысып уратып алу, буу (билне һ. б.). *Кызыл башлы тастымал белән билемне бәйләдем.* М. Гафури. [*Хәмзә бай*] *кыска җиңле камзул кигән, чалбар балагын ак тасма белән бәйләгән.* Г. Камал. // Урап-чорнап төрү (җәрәхәтле яки шешкән җирне һ. б.). *Җәрәхәтне бәйләү.* ☐ *Габденнасыйр, яшь алмагачларны бәйләп, төпләренә тирес өеп һәм умарталарны карап, кышка хәзерләргә кереште.* М. Гали. // Авызын, ачык башын ябып-томалап, бәй белән уратып төенләп кую (капчыкны, тар авызлы савыт-сабаны һ. б.). *Янчыкны бәйләп кесәгә салу.* ☐ *Бал кортлары кереп беткәч бабай тубалның авызын бәйләп куя.* А. Алиш. *Күлмәк җиңнәрен бәйләп маймыч сөзү дә калмый [малайлардан].* М. Шәбаев. // Берәр нәрсә урап-чорнап каплау (күзне, авызны һ. б.). *Балаларның күз бәйләп уйнаулары.* ☐ *Акырмасын өчен бәрәннең авызын бәйләде [малай].* Ф. Кәрим.

4. Башка бөркәнеп, очларын, почмакларын каракаршы китереп төйнәү (яулыкны, шәлне һ. б.). *Косынка бәйләү. Яулыкны чөеп бәйләү.* // Очларын яки бәйләвечләрен кара-каршы тоташтырып кию, тагу. *Ак алъяпкыч бәйләгән кызлар.* ☐ [*Уракчылар*] *беләкләренә җиңсә бәйләгәннәр.* Г. Бәширов. [*Фәрит*], *яңа киемнәрен киеп, кызыл галстугын бәйләп, Пионер клубына китте.* А. Шамов. // Буу, тагу (каешны һ. б.). *Җиңгә тасма бәйләү.* ☐ *Кара күлмәк өстеннән билгә каеш бәйләгән хуҗа егет килеп чыкты.* Г. Ибраһимов. *Камзул киеп, билләренә кызыл пута бәйләгән, чабата-оекълы батыр көрәшчеләр дә килеп җиттеләр.* М. Гали.

5. Бау һ. б. ш. нәрсә белән чолгап, өлешчә яки тулысынча хәрәкәт ирегеннән мәхрүм итү (кулны, аякны, кешене һ. б.). *Суясы әтәчнең аягын бәйләү.* ☐ *Разведчиклар бик тиз генә аның [часовойның] кулларын бәйләп капчыкка салдылар да куаклыкка кереп югалдылар.* А. Әхмәт.

6. *махс.* Оештырып төреп һәм бәйләп ясау (себерке, көлтә һ. б. ш. турында); җыеп оештырып беркетү (сал һ. б. ш. турында). *Көлтә бәйләү. Сал бәйләүдә эшләү.* ☐ *Май аенда җыеп бәйләгән каен себеркесе белән мунча чабынырга ашыга ул.* Ә. Еники.— *Кызлар, кызлар, әйдәгез, йөгерешегез, эзләгез; Алма, хөрмәләр өзеп, Бәйләм-бәйләм бәйләгез.* Ф. Бурнаш.

7. Махсус инә һ. б. ш. нәрсә белән үрү, үреп эшләү. *Шәл бәйләү. Челтәр бәйләү. Ятьмә бәйләү.* ☐ *Фронттовикларга дип атап, кем оекбаш, кем җылы бияләй бәйли.* Г. Әпсәләмов.

8. Тоташтыру, элемтә чарасы булу. *Асфальт җәелгән һәм төзекләндерелгән бу юл шәһәр белән авылларны бәйли.* Соц. Тат.

9. Якын, тыгыз мөнәсәбәт, турыдан-туры элемтә урнаштыру. *Теорияне практика белән бәйләү.* ☐ *Сөюне, семья төзүне дә көрәш белән бәйләү кирәген аңлый алдык.* М. Җәлил. *Мин бүгеннән алып тормышымны Институт белән бәйләдем.* М. Хөсәен. // Нәтиҗәне сәбәпкә бәйле дип тану яки күрсәтү. *Мул уңыш алуны ашлама кертүгә бәйләү. Эшнең сыйфатын эшләүчеләрнең сәләтенә бәйләү.* ☐ *Безнең монда күчүне дә шушы вакыйга белән бәйләргә азапланучылар бардыр.* Ш. Камал.

10. Берәр җирдә даими булырга, торырга яки берәр эшкә урнашырга, алынырга мәҗбүр итү.— *Тукта әле, абый, андый баш китәрлек эшкә нигә мине бәйлисең?*

Т. Гыйззәт.— *Бүген күрәчәкне күз алдыма китерсәм, ач үлсәм дә атымны бу эшкә бәйләмәгән булыр идем.* Ф. Бурнаш. // Үзенә нык җәлеп итү, тарту (кеше, эш һ. б. турында). *Бу кызчык белән ни эшләргә инде? Аны ни белән шөгыльләндерергә һәм ничек аны үземә бәйләргә?* Г. Тукай. *Күңелле эш бит ул уртак хуҗалыкның шулай иегелеген күрү, ныграк бәйли бит ул безне үзенә.* Ә. Еники.

11. Якын, тыгыз мөнәсәбәт урнаштыру, рухи берләштерү. *Бу вакыйга Габдулланы Әптелбәргә тагын да ныграк бәйләде.* Ә. Фәйзи. *Бәйләде аларны Ялкынлы саф сөю.* М. Җәлил.

12. *лингв.* Синтаксик мөнәсәбәтне күрсәтү, белдерү (ярдәмлек сүзләр һ. б. чаралар турында). *Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла торган чаралар. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен бәйли торган интонация.* □ *Бәйлекләр җөмләнең аерым сүздән һәм сүз тезмәләреннән торган кисәкләрен бүтән сүзгә бәйлиләр.* В. Хангилдин.

БӘЙЛӘҮ II *и.* 1. *гадәттә кыек форм.* Бәйләп, арканлап куя торган бәй.

2. *гадәттә кыек килешләрдә.* Бәйләп, арканлап тоту-тотылу, асрау-асралу. *Бәйләүдәге эт.* □ *Бүре бәйләүгә күнмәс, дуңгыз әйдәүгә килмәс.* Н. Исәнбәт. *Без ак каен төбенә бәйләүгә куелган җигүле атыбыз янына килдек.* Г. Галиев.

3. Бәйләп, үреп эшләнә торган яки эшләнгән әйбер, кул эше. *Бияләй бәйлим, сугышчым, Җылытсын кулларыңны; Бәйләү җепләреңә куштым йөрәк җылыларымны.* Ә. Кәмал. *Бәйләү бәйләп утыручы бер карчык эшеннән туктамыйча гына сөйли.* И. Гази.

4. *к.* бәйләвеч 2. *Бәйләү салу.* □ *Айгырның аягы ни хәлдә икән? Аның вакытында бәйләвен алыштырып, ярасын дәвалап торганнар микән?* А. Расих.

БӘЙЛӘҮЛЕ *с.* Бәйләгән (1, 2 мәгъ.), бәйләүгә куелган; бәйдәге. *Бәйләүле ат, бу хатынны күреп, бераз куркынып бер якка тартылды.* Г. Ибраһимов. // Бәйләгән (3, 5 мәгъ.), бәйләп куелган. *Бәйләүле кулны муенга асып йөрү.* □ *— Аңыма килгәндә, кул-аягым бәйләүле хәлдә немецлар арасында ята идем, шул көенчә мине лагерьга озаттылар.* Т. Гыйззәт.

БӘЙНӘ-БӘЙНӘ *рәв. сөйл.* Җентекләп һәм аңлаешлы итеп (сөйләү, язу һ. б. ш. турында). *Миңа бәйнә-бәйнә язып хәбәр биреп тор.* Г. Тукай. *Солдат Кәримнәрнең әби йортында ниләр кыланганнарын, ниләр сөйләгәннәрен һәммәсен дә бәйнә-бәйнә ачты да салды.* Г. Кәмал.

БӘЙНӘЛМИЛӘЛ *и. иск. к.* Интернационал. *Салют биреп, Бәйнәлмиләл җырлап узабыз.* М. Крыймов.

БӘЙРӘМ *и.* 1. Йола буенча үткәрелә торган күңел ачып ял итү көне яки көннәре. *Сабан туе бәйрәме.* // Берәр зур, данлыклы вакыйга хөрмәтенә яки истәлегенә багышланган шундый тантана көне яки көннәре. *Октябрь бәйрәме. Май бәйрәме. Җиңү бәйрәме.* // Гомумән, берәр вакыйга уңае белән үткәрелә торган шундый күңел ачу йоласы, көне. [*Алмас:*] *Әни, минем туган көн бәйрәме чәчәксез буламыни?* А. Әхмәт.

2. *күч.* Зур шатлык, куаныч, тантана. *Мәдинәгә тик эш кенә булсын, эш — аның куанычы, шатлыгы, бәйрәме.* М. Хәсәнов. *Бу көн безнең тормыш бәйрәмгә әйләнә.* М. Гафури.

3. *с. мәгъ.* Күңел ачып ял итүгә багышланган; берәр вакыйга хөрмәтенә яки истәлегенә билгеләнгән, тантаналы (көн һ. б. турында). *Бәйрәм кич.* □ *— Бәйрәм көн итеп, тәбриклә килдек, Гайшә апа.* Ф. Бурнаш.

◇ **Бәйрәм итү** — 1) бәйрәм (1 мәгъ.) ясау, шунда катнашу. *Беренче майны бәйрәм итү.* □ *Бүген чын халык бәйрәме! Һәм аның шунда бар яме: ит бәйрәмеңне бергәләп.* Г. Кәмал; 2) *күч.* Шатлану, куану, тантана итү.— *Әхми иптәш, әйдә рәхим ит, моннан элек Хафизга яла яккан чакларда Кәримнәр бәйрәм иткән булсалар, хәзер инде без бәйрәм итәбез.* Г. Кәмал.

БӘЙРӘМЛЕК *с.* 1. Бәйрәмдә тоту, файдалану өчен булган (акча, азык-төлек һ. б. ш. турында). [*Нәҗми агай*] *үзенең таныш бер приказчигы аркылы Низами байдан бәйрәмлек акча сорапты.* С. Рәмиев.

2. Бәйрәмдә кия торган (кием турында). *Бу ни, кызым, бәйрәмлек күлмәкләр белән эшкә йөрисең?* Һ. Такташ.

БӘЙРӘМЛӘҮ *ф. сир. сөйл.* Бәйрәм итү. [*Полковник*] *алтмыш яшен бәйрәмләргә хәзерләнгән карт кебек түгел, егерме сигез яшьлек фронтчы офицер чагындагы кебек җитез егетлек белән яңадан атка сикереп менде.* Г. Ибраһимов. *Бүген колхоз үзенең героен бәйрәмләп каршы ала.* М. Җәлил.

БӘЙРӘМЧЕ *и. сир.* Бәйрәм итүче, бәйрәмдә катнашучы. [*Бригадир*] *шоферга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н. Фәттах.

БӘЙРӘМЧӘ *рәв.* Бәйрәмдәге кебек (киенү, бизәнү һ. б. турында). *Бәйрәмчә киенгән кунаклар.* □ *— Әйдә, бәйрәм икән, бәйрәмчә булсын, җыелышка чаклы вальс әйләнәбез.* Р. Ишморат. *Шәһәр урамнарында бәйрәмчә күңелле җанлылык.* Г. Минский.

БӘЙСЕЗ *с.* 1. Мөстәкыйль, ирекле, буйсынмаган. *Бәйсез кеше. Бәйсез дәүләт. Бәйсез политика.* □ *Безнең аңыбызга бәйсез, безнең тойгыбызга бәйсез рәвештә, бездән тышта әйберләр бар.* В. И. Ленин. // *рәв. мәгъ.* Мөстәкыйль, ирекле рәвештә; буйсынмыйча. *Эченнән генә ул үзен Андреевтан бәйсез тотарга, үзенчәрәк яшәп, үзе белгәнчә эшләргә булды.* Ә. Еники. *Барлык халыкларның ирекле һәм бәйсез яшәргә, үзләренә тормыш үрнәге һәм җәмгыять строе сайлап алырга мөмкинлеге булырга тиеш.* Соц. Тат.

2. Бәйсезлекне сиздереп-белдереп, күрсәтеп торган (кыяфәт һ. б. ш. турында). *Кулындагы портфелен урынсыз бутап, бәйсез кыяфәт белән ишеккә йөгерде* [*Энҗе*]. Г. Тавлин.

БӘЙСЕЗЛЕК *и.* Бәйсез булу хәле. *Экономик бәйсезлек. Туган илнең бәйсезлеген яклау. Политик бәйсезлек.* □ *Аның киеме, кыяфәте, үзен тотуында, сөйләшүендәге бәйсезлеге - - - әллә нихәтле ялгучылар тудырып өлгерде.* Ә. Фәйзи. *Без бәйсезлек өчен кан түктек.* Ә. Ерикәй.

БӘК *и. тар.* 1. Урта Азиянең феодаль ханлыкларында: берәр районда яки шәһәрдә идарә итүче. *Ханнар, бәкләр, морзалар үзара берәзлексез сугышып, талашып, үтерешеп торганнар.* Г. Бәширов.

2. Ирләр исеменнән соң әйтелгәндә, «әфәнде» мәгънәсен дә аңлаткан. *Хөршит бәк үзенең туганнары һәм дуслары белән сыйлана.* М. Әмир.

БӘКЕ *и.* Су алу һ. б. өчен бозны тишеп ясалган уем (елгада, күлдә һ. б.). *Бәкедә кер чайкау. Бәкедән су китерү. Авылның бәке ачучысы.* □ *— Унлап бәке тишеп карадым — тик бер генә балык та тота алганым юк.* Соц. Тат.

БӘКӘЙ *и. диал.* Бәрән.

БӘКӘЙЛӘҮ *ф. диал.* Бәрәнләү.

БӘКӘЛ *и.* 1. Тояклы хайваннарның аякларында, арт якта, тояктан өстәрәк чокырланып кергән урын; аякның шул турыдагы буынтыгы. *Ак бәкәл.* □ *Аласа ашап бетергәнче, [Хәбир] улак янының китмәде. Аның маңгай чәченә ябышкан сырланнарны чүпләде, бәкәл йоннарына каткан балчыкларны алып ташлады.* Г. Галиев. *Ул бәкәлләренең озынлыгын күрсәгезме [колының], шаклар катарсыз!* М. Хәсәнов.

2. *диал.* Кешедә: балтыр һәм табан сөякләре тоташкан җирдәге кабарып бүлтәеп торган урын; тубык. *Бәкәл кызышып, сызлап тору.* □ *Егылып та киттем, уң аякның бәкәл тирәсе чырт итеп чыртлап та китте.*

Г. Мөхәммәтшин. *Яңгырлар явалар да явалар. Бәкәлдән генә булган пычрак тезгә җитә инде.* Г. Толымбай.

БӘЛА *и.* 1. Бәхетсезлек, күңелсезлек һ. б. ш. хәл. *Бу серне ачу юлында, әллә нинди бәлагә очрыйсың дисәләр дә, Хәлимнең туктаячагы юк иде.* Г. Гобәй.— *Тагын соңга калдым, менә бәла!* М. Фәйзи. // Зарар, зыян; каза. // Холыктагы, үз-үзеңне тотудагы йомшак як, кимчелек һ. б. ш. *Бөтен бәлам дә шунда: мин эшне уйлап эшли алмыйм.* Ф. Хөсни. // *тартымлы форм.* Берәр нәрсәнең аяныч, күңелсез нәтиҗәсе. *Тәҗрибәсезлек бәласе. Сугыш бәласе. Ашыгучанлык бәласе.* □ — *Әнвәр иптәш, синең хыялларың — Болар бары да яшьлек бәласе!* Ш. Мөдәррис.

2. *хәб. функ.* Хәл итүе авыр эш, кыен мәсьәлә. *Эшкә чумган кеше өчен вакыт җитмәве зур бәла.* Г. Кутуй.

3. Яла, нигезсез гаепләү. *Яманга юлдаш булсаң — бәла йогар, Еланга ярдәм итсәң — кулны чагар.* М. Гафури.

4. Мәшәкать, бәла тудыручы; имгәк.— *Безнең әлеге кодача дигән нәрсә бәла булды тагын!* Ш. Камал. [*Шәех — Җәмиләгә:*] *Син минем башыма бәла генә булдың!* М. Гафури.

◇ **Бәладән баш-аяк** — берәр нәрсә яки кеше белән бәйләнмәгәнең хәерле; кирәге, хажәте юк. *Эшне бераз җыйгач, ул* [*кулак*], *ялчының исәп-хисабын өзеп, чыгарып җибәрде.— Бәладән баш-аяк,— диде ул үз-үзенә.* А. Шамов.

БӘЛА-КАЗА *җый. и.* Төрле бәхетсезлек, каза һ. б. ш. бәлаләр. *Мине карап, төрле бәла-казалардан саклап үстерүче, тәрбия итеп аякка бастыручы* [*апам*] *булган.* М. Гафури.

БӘЛА-КАЗАЛЫ *с.* Бәла-каза китереп чыгара торган; хәвефле. *Бәла-казалы эшкә тап булу.*

БӘЛАЛЕ *с.* 1. Начар нәтиҗәгә китерә, бәлагә сәбәп була торган.— *Шулай үк мин бәлале эшкә уралдыммы?* Н. Исәнбәт. *Ул бик зур бәлале мәшәкатьләрдән котылган кеше кебек уф! дип тыныч ланды.* Г. Әпсәләмов.

2. Бәлаләргә яратучы, бәлаче, бәлачел.

БӘЛАЛӘҮ *ф.* Әһәмиятсез генә нәрсә өчен дә үзеңне кимсетелгән санап бәла, гауга чыгару.

БӘЛАЧЕ *с.* Әһәмиятсез генә нәрсә өчен дә үзен кимсетелгән санап бәла, гауга чыгарырга әзер торучы.

БӘЛАЧЕЛ *с. к.* бәлаче.

БӘЛЕШ I *и.* Камыр тыш эченә бер яки берничә төрле ашамлык салып мичтә пешерелгән кунак ашы. *Ит бәлеше. Балан бәлеше. Алма бәлеше. Кабак бәлеше. Вак бәлеш.* □ *Җиләкне күп итеп җый, кызым, кайткач, бик тәмле итеп җиләк бәлеше пешереп ашатырмын.* А. Әхмәт.

БӘ'ЛЕШ II *ы.* Кинәт барлыкка килгән ризасызлык, борчылу һ. б. ш. төсмер катнаш гаҗәпләнүне белдерә.— *Бәлеш, бәлеш, бәле-еш! Бу ни әкәмәт тагын!?* Ф. Әмирхан. [*Гөлбикә Бибкәйне күреп:*] — *Бәлеш! Кызым кайткан иң!* Н. Исәнбәт.

БӘЛЕШЛӘНҮ *ф. гади с.* Ямьсез булып җәелү яки җыерылу, чалышаю (авыз, ирен һ. б. турында). [*Нәсимәнең*] *нечкә ирennәре бәлешләнебрәк тора, ләкин ямьсез түгел.* Ш. Камал.

БӘЛЕШӘЮ, БӘЛШӘЮ *ф. туп. к.* бәлешләнү. *Елак баланың авызы бәлешәю.* □ *Әкми чыга. Иске, бәлшәйгән кырма бүректән.* Н. Исәнбәт. [*Үпкәсе көчәйгән*] *Луизаның турсайган иреннәре бәлшәйде.* А. Гыйләҗев.

БӘЛЗӘМ *и.* Кайбер үсемлекләрдә була торган хуш исле куе сыекча (аерым төрләре техника һәм медицинада кулланыла). *Яралы мең күкрәккә бәлзәм дә син.* М. Максуд.

БӘЛЗӘМЛӘҮ *ф.* Черүдән саклый торган махсус матдәләр сендерү (мәеткә). *Бәлзәмлә мине сары гөлләр белән.* М. Максуд.

БӘ'ЛКЕМ *кер. сүз. сөйл. к.* бәлки. 2. *Бәлкем, аның әйткәннәре бөтенләй үк нигезсез түгелдер.* Ә. Еники. *Шәһәрнең тормышы күңелемә ошап куйса, бәлкем, кышны да монда үткәрермен.* З. Бәшири.

БӘ'ЛКЕ 1. *терк.* Капма-каршы мәгънәле тиңдәш кисәкләрне яки шундый үк эчтәлекле җөмләләрне теркәү өчен кулланыла: ә, ләкин. *Гаилә мәсьәләсен кайнар тойгылар кушуыннан чыгып кына түгел, бәлки уйлап, акыл белән хәл кылырга кирәк.* Р. Ишморат.

2. *кер. сүз* Чамалап-фаразлап, ихтимал дип карауны белдерә. *Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр, Иң дәһшәтле утка керәмен.* Ф. Кәрим.

БӘЛЛӢ *ы.* 1. Кабатлап яки «әлли», «бәү» һ. б. ш. сүзләр белән аралаш: бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. *Шаян кызым син минем, Таң йолдызым син минем, Йоклыйк әле без икәү, Әлли-бәлли, бәлли-бәү.* Н. Исәнбәт. *Йокла, балам, йокла син, Бәлли-бәү, бәлли-бәү.* Т. Гыйззәт.

2. *и. мәгъ.* Балалар телендә: бишек.

◇ **Бәлли итү** — 1) «бәлли-бәлли» дип, көйләп тирбәтү. *Әлли итеп ал үскән, Бәлли итеп гөл үскән.* Н. Исәнбәт; 2) йоклау (көйләп тирбәтелүче бәби турында). *Әлли-бәлли итәр бу, Бохарага китәр бу.* Г. Тукай. *Вагон тәгәрмәчләре дә, үч иткәндәй, бәлли-бәлли итәр бу дигән сыман тирбәлдереп баралар, башны түбән идерәләр.* Г. Кутуй.

БӘЛЛИЛӘҮ *ф. сир.* «Бәлли» һ. б. ш. сүзләрне әйтеп көйләп тирбәтү (бәбине). *Бай, бай, бай... дип сузып бәллили иде* [*ана*]. Ә. Айдар.

БӘЛЛҮ *ы.* 1. Кабатлап яки *«әллү»*, *«бәү»* һ. б. ш. сүзләр белән аралаш: бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. [*Әниең*], *Син еларга башласаң, чү-чү, балам, чү-чү дигән; Тирбәтеп, көйләп кенә, Әллү дигән, бәллү дигән.* М. Гафури.

2. *и. мәгъ.* Бишек. *Бала елый иде бәллүдә.* Н. Баян. *Мин энеләремне, сеңелләремне бәллүдә тирбәтеп, әниемнең авыз эченнән генә нәрсәдер көйләп утырганын беркайчан да оныта алмыйм.* Г. Галиев.

БӘЛЛҮКИ *ы. к. бәллү* 1. Бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә.— *Әлли-бәлли, бәпкәм, бәллүки; Көйлим икән сиңа нинди көй?* М. Җәлил.

БӘЛЛҮЛӘҮ *ф. диал.* «Бәллү» һ. б. ш. сүзләр белән көйләп тирбәтү.

БӘЛЛҮР *и.* 1. Яктылыкны нык сындырып, үзенә бер төрле ялтырый һәм яңгырый торган югары сорт пыяла; *русчасы:* хрусталь. *Бер караганда, ул* [*съезд сарае*] *һавадан җиңел сыман, икенче караганда бәллүрдән үтә күренмәле.* Г. Әпсәләмов.

2. *с. мәгъ.* Бәллүрдән эшләнгән, ясалган. [*Өстәлдә*] *эчемлекләр салынган кечкенә-кечкенә графиннар, алмалар тутырылган алсу-зәңгәр бәллүр вазалар.* Г. Әпсәләмов.

БӘЛТЕРӘҮ *ф.* 1. Искереп тузганлыктан, таралырга тору. // Селкенеп-калтыранып тору. *Күпер дигәннәренең күпер димәсәң хәтере калыр, су өстенә резинка мендәр тезеп чыкканнар, бәлтерәп кенә тора.* М. Әмир.

2. *күч.* Картаеп, хәлсезләнеп бетү. *Ак сакаллы Шәймәрдән бабамның* [*карчыгы да*] *--- үзе кебек үк бәлтерәп беткән.* А. Расих.

БӘЛФАРАЗ *кер. сүз. иск.* Мәсәлән.— *Табылмаган алтын белән нишлисең? — Юк, бәлфараз, табылса?* М. Гафури.— *Бәлфараз, бу хәзрәт безне ни өчен чакыртты икән?* Т. Гыйззәт.

БӘЛӘҢ *и.* Гадәттә бераз кәкрерәк булган җиңел, яссы агач тукмакчык (керне чайкаганда тукмаклау һәм кипкәч йомшату өчен кулланыла). [*Бану белән Рәүфә*] *чиләктәге керләрен чыгарып, үзара эндәшкәләп ала-ала, җитез-җитез чайкарга һәм, су буен яңгыратып, бәләк белән чабарга тотындылар.* А. Шамов. *Миңнурый өвтәлдә сырлы бәләк белән кер тәгәрәтә иде.* Г. Әпсәләмов.

БӘЛӘҠЛӘҮ *ф.* Бәләк белән тукмаклау (чайкала торган керне) яки йомшарту (кипкән керне). *Аның инеш буена кер бәләкләргә төшкәнен сагалап, ат эчерергә бара* [*егет*]. Г. Ахунов. [*Хәкимә*] *әле яңа гына сабын суына басып кибәргә куйган мамык перчаткасын бәләкләп алды.* Г. Галиев.

БӘЛӘҠӘЙ *с.* **1.** Кечкенә. *Болын буйлап бәләкәй таулар тезелгәннәр.* М. Фәйзи. *Бүлмә бәләкәйрәк.* Ш. Камал.

2. Яшь (балалар турында). *Үзем бәләкәйрәк чакта кош кебек атылган текә таулардан хәзер мин түбән карарга да шикләнәм.* М. Шабаев. // Яшь ягыннан кечерәк. *Быел көз минем бәләкәй абзый солдат хезмәтенә алынды.* М. Гафури. *Гөлсәрия - - - Нәсимнән төгәл өч яшькә бәләкәй.* Г. Мөхәммәтшин.

3. Әз. *Эше бәләкәй моның, иптәш председатель,— диде Хәлим.* Г. Гобәй.— *Атлар бәләкәй генә хәл алсыннар әле.* А. Гыйләҗев.

4. *рәв. мәгъ.* **бәләкәйдән.** Яшьтән, яшь вакыттан. *Бәләкәйдән үк авыр эшкә җигелү, һәрнәрсәнең кыен ягын, авыр ягын гына күреп үсү тойгыларымны тупасландырган булган, күрәсең.* М. Әмир.

БӘЛӘКӘЙЛӘНҮ *ф.* Кечерәю. *Аңа үзләренең аты да, арбалары да бәләкәйләнгән төсле булып күренде.* М. Гафури. *Гайфетдинов җыела төшәргә, бәләкәйләнергә тырышты һәм үзенә таба атлап килүче укытучыга күз кабагы астыннан гына карап алды.* А. Әхмәт.

БӘЛӘҠӘЙСЕТҮ *ф.* Бәләкәйгә, кечкенәгә санау, яшь дип карау. *Аны бәләкәйсетеп каршы алган Гыймади хәзер инде, эшен бер якка куеп, Габдулланы үзенең тиңдәше сыман итеп сөйләшеп алып китте.* Ә. Фәйзи.

БӘЛӘҠӘҶ *с. диал.* Бәләкәй. *Бәләкәч кенә учак.*

БӘЛҖЕРӘҮ *ф. сөйл.* **1.** Нык җебүдән үтә йомшакланып яки җәелеп-таралып китү (төрле әйберләр турында). *Аяк асты бәлҗерәү. Аяк киеме бәлҗерәү.* □ *Варис, тәмам бәлҗерәгән пычракны кирза итекләре белән як-якка чәчрәтеп, партком яныннан китеп барды.* М. Хәсәнов.

2. *гади с.* Гәүдәне, әгъзаларны тота, буыннарны эшләтә алмас дәрәҗәдә хәлсезләнү; мәлҗерәү. [*Ис тиюдән*] *бәлҗерәп төшкән булсак та, ишеккә сыеша алмыйча тышка ташландык* [*остабикә укуны калдырып китәргә дигәч*]. Ш. Маннур. // Ямьсез булып җәелү, чалышаю (авыз, ирен һ. б. ш. турында). [*Асия*] *бөтен авыл җыенында авызын бәлҗерәтеп елаган була.* Г. Иделле. // Үтә булдыксызлану, рухи таркалу, ваемсызлану.— *Йөрисең шунда бәлҗерәп. Бар, хәзер Гөлнурны алып кайт!* К. Нәҗми.

БӘН *а. иск.* (бәнем, бәңа, бәне). Мин. *Бән әйткәндә сән дә тыңла.* Г. Тукай.

БӘНДӘ *и.* **1.** *кимс.* Начар, явыз яки булдыксыз, ихтыярсыз кеше. [*Гыйльманов — Мостафага:*] *Танымаган, кемлеген белмәгән кешене бәндә дип мыскыллы сүз белән атау, сезнеңчә, тупаслык түгелдер шул.* Ш. Камал. *Кеше малын, кеше җирен тартып алыр өчен сугышырга теләүче берәү табылса, аны хәтәр бәндә дип, бер көн тотмый юлярлар йортына илтеп ябарлар.* Г. Әпсәләмов. *Өйрәтте ул* [*халык*] *безне кыюлыкка, Бәндә түгел, кеше булырга.* Х. Туфан. // *иск.* Буйсынган кеше, хезмәтче. [*Гали Бибкәйгә:*] *Мин бер бәндәң, гыйшкың әсире.* Н. Исәнбәт.

2. *иск.* Кайбер сүзләр янында яки махсус контекстта: кеше. *Минем исемемә көй чыгарган рәхмәтле бәндә кем бу?* М. Фәйзи. *Менә бит, ниндидер яхшы бәндә, аның эчәсе киләчәген алдан үк белеп, су кертеп куйган.* Г. Бәширов.

БӘНДӘЧӘЛЕҠ *и. иск.* Кешедәге кимчелекле сыйфатлар турында. [*Мәрфуга:*] *Шулай итеп гөнаһлы да булып бетәм.* [*Сыйдыкый:*] *Бәндәчелек инде.* М. Фәйзи.— *Бәндәчелек инде, андый эшләр генә була ул.* Г. Камал.

БӘПҠӘ I *и.* **1.** Каз, үрдәк кебек су кошы баласы. *Су буенда гына яшел каз бәпкәләре йөри.* Ф. Хөсни. *Рәүфә көтүдән соң тавык-чебешләрне, үрдәк-казларны, бәпкәләрне ашата да өй тирәсен җыештырырга керешә.* А. Шамов.

2. *с. мәгъ.* Бер яше тулып җитмәгән, яшь (каз, үрдәк һ. б. ш. су кошлары турында). *Бәпкә каз.*

3. бәпкәм. Картларның яшьләргә, бигрәк тә нәниләргә иркәләп мөрәҗәгать итә торган сүзе. [*Улы*] *каршында басып торса, ул бары бер сүз — «бәпкәм» дип үрелеп, аның маңгаеннан үбәр иде.* Ә. Еники. *Син үсәрсең, чәчәк кебек, Бәпкәм, бу җирдә, Без кан түгеп, сугышып алган Ирекле илдә.* Ә. Исхак.

Бәпкә үләне, бәпкә чиләме — урамда, каралты тирәләрендә үсә торган вак яфраклы үлән; *русчасы:* травка-муравка, птичья гречиха. *Мирвәли урамга чыкты... Юллар тузанлы, машиналар үтеп-сүтеп йөри. Бәпкә үләннәре койма ышыкларында гына.* А. Гыйләҗев.

БӘПҠӘ II *и. к.* бәбәк II. *Яңгырдан соң ачылалар Яшь бәпкәләр.* Ә. Ерикәй. *Агачларның бәпкәләрен чүпләр имди* [*кәҗә*]. Г. Кандалый.

БӘПҠӘ III *и. махс.* Астагылары утыртылган, өстәгесе аларга каплап куелган көлтә өеме. *Бәпкә кую. Җитен бәпкәсе.* □ *Абыйсыннан көлдермәс өчен бик тырышып эшләп, ул, кичкә кадәр биш көлтә урып, дүрт көлтәне җиргә утыртып, бишенчесен башы белән өскә каплап, бәпкә ясап, бер өем куйды.* М. Гали. *Солыны болар өч көн бәпкәдә җилләтәләр.* Әкият.

БӘПҠӘ IV *и. махс. к.* кайчы 2. [*Фронт тирәсендә*] *ярым җимерек каралтыларның ялангач бәпкәләре күренә иде.* Ә. Еники.

БӘПЛӘҮ *ф. сөйл.* Баланы йоклатканда бәү-бәү дип көйләп, аркасыннан кагып тору. *Бәплә-әрләп тел белән Кеше иткән анабыз.* Сов. әд.

БӘПЧЕК *и.* Бәбәк яки бөре яралгысы. *Кыш көне агроном боларны укытканда үк әйткән иде: кояшта җылыткачыннан бодайның бәпчеге уяна икән дә тишелмәстәй орлык та тишелә торган була икән.* Г. Бәширов. *Су буендагы тал бәпчекләренең баллы исләре* [*картның*] *борынын кытыклагандай тоелды.* Г. Бәширов.

БӘРАБӘР *рәв. кит.* **1.** Бердәй, бер-берсенә тиң, торырлык, лаек. *Алар да Гайшәне үз балалары белән бәрабәр күрәләр.* З. Һади. *Тырышлык күрсәтәсез, шуңа бәрабәр күп санлы кешеләрнең ихтирамын казанасыз.* Соц. Тат.

2. *бәйл. функ.* **бәрабәренә, хакына, өчен.**— *Кыйммәтле бүләкләр бәрабәренә бер хезмәт ит.* М. Фәйзи. *Буйсыну бәрабәренә алынган бәхет кирәк түгел!* М. Максуд.

БӘР-БӘР *ы.* **1.** Сарык чакыру сүзе.

2. *и. мәгъ.* Балалар телендә: сарык.

БӘРГӘЛӘНҮ *ф.* **1.** *Каб. дәр., төш. юн. к.* бәрү (1, 2 мәгъ.).

2. Гәүдәне, әгъзаларны бәрә-бәрә нык тыпырчыну, ярсу, өзгәләнү. *Бәргәләнә-бәргәләнә елау.* □ *Тәрәзә пыяласында бәргәләнә торган шөпшә ярсый-ярсый бызылдый.* Ә. Фәйзи. [*Хуҗасыннан көчләп аерып калдырылган эт*] *бәргәләнә-бәргәләнә улый башлады.* Һ. Такташ.

БӘРГӘЛӘШ *и. сөйл.* Җиңелчә йодрык сугышы, кыйнаш. *Мин дә читтә кала алмадым, шул бәргәләшнең эченә кереп уңга-сулга яңаклый башладым. - - - Ул арада зурлар катнашып, безне аердылар.* Г. Ибраһимов.

БӘРГӘЛӘШҮ *ф.* **1.** *Уртак. юн. к.* бергәләү.

2. *сөйл.* Йодрык белән бәрешү, җиңелчә төрткәләшү. *Торып сикергәләп, үзара бәргәләшеп тә карадылар, ләкин эчкә салкын үткәнлектән һәм аяк-куллар бик яман туңганлыктан, ул аларга бертөрле дә ярдәм итмәде.* М. Гали. // Йодрык белән сугышу. *Кайбер вакыт*

юк-бар өчен талашып китәбез. Бәргәләшеп алган чаклар да була. Г. Ибраһимов.

БӘРГӘЛӘҮ *ф.* **1.** *Кабат. дәр. к.* бәрү (1—10, 13 мәгъ.).

2. *күч.* Йодрык белән (җиңелчә) кыйнап алу. *Күзләрен кан баскан берничә* [*фетнәче*] *мужик әбине бәргәләп ташладылар.* Г. Ибраһимов.

БӘРЕЛЕШ *и.* **1.** Сугыш (бер мәртәбә сугышып алу). *Бик каты бәрелештән соң акларның исән калганы плен алынды.* Г. Бәширов. *Бер тапкыр ул штык бәрелешендә катнаша.* И. Гази.

2. Талаш, ызгыш; каты бәхәс. *Гөлбану карчык исә кызы кайтуы шатлыгыннан Рәүф семьясындагы бәрелешләрдән, вакытлыча булса да, читкә китә.* Г. Нигъмәти.

3. Көрәш. *Сыйнфый бәрелешләр.* □ *Соңгы бәрелеш тора чиратта.* М. Җәлил. *Ш. Камал әсәрләрендә яратып бирелгән коллизияләрнең берсе — хыял белән хакыйкатьнең бәрелеше.* Г. Нигъмәти.

БӘРЕЛЕШҮ *ф.* **1.** *Уртак юн. к.* бәрелү 1.

2. Бераз кыйнашып алу; сугышу. *Әгәр дә иртәгә эшчеләр белән бәрелешергә туры килсә,* [*Вахит*] *аларга төзәп атмауны үйлап куйды.* М. Гафури. *Әгәр дошман белән бу урында бәрелешә калсак, полкны шунда җәеп җибәрергә дип приказда да күрсәткән идем.* Каз. утл.

3. Ызгышып, тиргәшеп алу. *Бу хәл икенче бәрелешүгә, талашуга сәбәп булды.* Г. Кутуй.

БӘРЕЛӘ-СУГЫЛА *рәв.* Кат-кат бәрелеп, орынып. *Халык бер-берсе белән бәрелә-сугыла ашыгып, мәгарәдән чыкты.* К. Насыйри. *Зур канатлы яшел чебен тәрәзә пыяласына бәрелә-сугыла гөжли.* Қ. Нәҗми.

БӘРЕЛҮ *ф.* **1.** Кискен һәм нык орыну. *Кинәт бер боз килеп бәрелде дә көймәбез әйләнеп китте.* А. Әхмәт. *Ул театрның тышкы ишеген атлаганда, сул яктан аңа кемдер килеп бәрелде.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Ачуланып каты сүз әйтү, орышу, тәнкыйтьләү. *Газинур башта үк аңа* [*эштән китүчегә*] *турыдан-туры бәрелергә батырчылык итмәде.* Г. Әпсәләмов.

2. Сизү органнарына кискен һәм нык тәэсир итү (ис һ. б. турында). *Борынга хуш ис бәрелде.* Г. Кутуй. // *күч.* Хискә нык тәэсир итү. *Мин аны* [*ул сүзне*] *үйлап-нитеп тормый гына әйттем дә җибәрдем. Апага барып бәреләсе хәтеремә дә килмәде.* Ф. Әмирхан. *Шаяру тоны белән сөйләсә дә, Галимовның соңгы сүзе аңа бәрелде.* Ш. Камал.

БӘРЕМ *и. кит.* Көчле кискен этәреш, көчле бәрү-бәрелү. *Җир асты бәремнәре Көнчыгыш Себер тауларында* [*булгалый*]. СССР физик географиясе. // *күч.* Һөҗүм. *Революциягә патша хөкүмәте бәрем ясау белән, аларда* [*эсерларда*] *таркалу туды.* Г. Нигъмәти.

БӘРМӘ *с.* Көч белән бәрә-бәрелә торган, кискен хәрәкәтле. *Бәрмә дулкын.* // Һөҗүм итә торган, һөҗүмдә төп рольне уйный торган. *Алдан билгеләнгән план буенча --- бәрмә көч туплый башладык.* Ф. Хөсни.

БӘРТӘС *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан булган, төче суларда яшәүче балык (тәңкәсе ак, йөзгечләренең очы гадәттә кызыл була); *русчасы:* язь.

БӘРХЕТ *и.* **1.** Өс ягы кыска калдырып кыркылган куе йомшак төкле, өлешчә яки бөтенләй ефәктән эшләнгән тыгыз тукыма; хәтфә. [*Егетнең*] *өстендә якасына кара бәрхет тоткан язгы-көзге пальто.* Г. Гобәй. // Бәрхеттән тегелгән әйбер. *Бәрхет кию.*

2. *с. мәгъ.* Бәрхеттән яки шуны кушып эшләгән, теккән. *Бәрхет яка. Театрдагы бәрхет пәрдә.* □ *Мандолина уйнап җибәрде ул, Утырып йомшак бәрхет диванга.* М. Гаяз. *Бәрхет түбәтәен җайлап Куйган ул кырын итеп.* Г. Латыйп.

3. *күч. сир.* Йомшак, ягымлы (тавыш турында). *Латыйповның тавышы көчле булмаса да, колакны тирбәтә торган бәрхет тавыш, җанга ягымлы моң --- тамашачыда матур истәлек калдырды.* И. Рәмиев.

◇ **Бәрхет агачы** — Ерак Көнчыгышта үсә торган, кайрысы калын бөке катламлы агач. *Уссури тайгасының төньягындагы Иман елгасында гадәти булмаган сал агызу башланды: алар бүрәнәләрдән түгел, бәлки кыйммәтле бәрхет агачы кабыгының зур-зур тюкларыннан бәйләнгән саллар.* Соц. Тат.

БӘРӘКАЛЛА *ы. иск. дини.* Гаҗәпләнү катнаш сокланулы, мактауны һ. б. ш. белдерә. [*Хаҗи:*] *Төпле егет икәнсең, энем, бәрәкалла, машалла.* Ш. Камал.— *Бәрәкалла, хуш килдең.* М. Гафури.

БӘРӘКӘТ I *и.* Бетмәс-төкәнмәс муллык, барлык; тормыш-көнкүрештәге материаль иркенлек, рәхәтлек; шуларның чыганагы. *Биябез йортка җиңел аягы белән килде һәм үзе белән безнең йортка бәрәкәт китерде.* Г. Ибраһимов. *Авылда бер бәрәкәт булса, шәһәрдә кырык бәрәкәт.* М. Гафури. *Быел җәй бәрәкәте белән килгән, игеннәр бик уңган.* М. Шабай. *Эшләргә, иренми эшләргә генә кирәк! Хезмәттә бәрәкәт!* Г. Әпсәләмов. // Файда, уңыш, табыш; файдалылык, нәтиҗәлелек. *Вак эшкә караганда,* [*тулаем*] *алган зур эштә бәрәкәт бар инде анда.* М. Гали. *Кешеләрнең хезмәтен җиңеләйткән һәм хезмәтнең бәрәкәтен арттырган электр көче бөтен эш тармагына үтеп керсен.* Ә. Еники. // Кадер, кадерлелек. *Өстәлдә бәрәңге суынды, бәрәкәте китте.* Ш. Бикчурин.

БӘРӘКӘТ II *ы.* Кинәт килеп туган нык гаҗәпләнү хисен белдерә [*Хәсән:*] *Бәрәкәт! Закир, синме бу? Кайчан кайттың?* М. Максуд.

БӘРӘКӘТЛЕ *с.* **1.** Мул, тиз бетми торган (ризык һ. б. ш. турында). *Бәрәкәтле ризык.* □ *Печән, ару азык саламнары көтелмәгән дәрәҗәдә бәрәкәтле булып чыкты.* Ф. Хөсни.

2. Муллык чыганагы булган, файда китерә торган. *Идел буе — бәрәкәтле җир.* Н. Исәнбәт. *Җәелеп киткән киң басулар шундый бәрәкәтлеләр ки, вакытында җылы яңгырлар яуса, кояшлы аяз көннәр булса, бу яланнарның - - - куе кара туфраклары ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр.* Г. Ибраһимов. // Нәтиҗәле, файдалы, уңай. *Мин аның бәрәкәтле эшчәнлегенә сокланам идем.* Ә. Еники. *Авылның бәрәкәтле тәэсире турында сөйлим.* Р. Ишморат.

3. *рәв. мәгъ.* Бик саклап, тота белеп, кадерен белеп (ризыктан һ. б. ш. файдалану турында). *Азыкны бәрәкәтле тоту.*

БӘРӘКӘЧ *ы. диал. к.* бәрәкәт II. *Күтәрелеп карасам, күрше малае Гасыйм капка баганаларына сөялеп тора икән.— Бәрәкәч, мин сине күрмәдем дә бит, малай! — дидем куркып.* Ш. Маннур.

БӘРӘН *и.* **1.** Сарык яки кәҗә баласы. *Аналарыннан адашып калган кайбер сарык, кәҗә бәрәннәре, --- нечкә әче тавыш белән өзлексез кычкырып, аналарын эзлиләр.* М. Гали.

2. *с. мәгъ.* Бер яше тулып җитмәгән, яшь (сарык турында). *Бәрән сарык.*

3. *с. мәгъ.* Бәрән тиресеннән тегелгән яки бәрән йоныннан бәйләнгән. *Бәрән тун. Бәрән толып. Кара бәрән якалы бишмәт. Бәрән бүрек.* □ *Кызның ак бәрән шәле читеннән чыккан чәчләрен карчык үзенең хәлсез куллары белән сыйпады.* А. Алиш.

БӘРӘНЛӘҮ *ф.* Бәрән тудыру (сарык, кәҗә турында). *Узган ел да син кәҗәне кысыр дип йөрдең. Карт мал шулай соңга калып бәрәнләүчән була ул.* С. Рафиков.

БӘРӘЧ I *ы.* Сарык чакыру сүзе.

БӘРӘЧ II *ы. сөйл.* Көтелмәгән хәлдән нык гаҗәпләнүне белдерә. *Бәрәч, кеше бар икән.* Т. Гыйззәт. *Һаҗәр эш киемнәрен салырга да өлгермәде, --- янында әнисе дә күренде.— Бәрәч! — диде Камәр түти, --- егет булгансың лабаса, кызым!* М. Хәсәнов.

БӘРӘҢГЕ *и.* **1.** Крахмалга бай эре бүлбеле яшелчә. *Бәрәңге утырту. Бәрәңге төбен өю.*

2. Шул яшелчәнең бүлбеләре яки бүлбесе. *Кыздырылган бәрәңге.* □ *Мин өйгә кайтканда, әни салам ягып, мичкә бәрәңге тәгәрәтеп маташа иде.* М. Гали.

◇ **Бәрәңге ашау белән бер** — бик җиңел (берәр эшне һ. б. башкару турында). **Бәрәңге корсак** *гади сөйл.*— бәрәңге ашарга яратучы кеше турында. **Бәрәңге суы** — үтә сыек һәм туклыксыз бәрәңге шулпасы турында. *— Их, иптәшләр, азмы чиселдек, инде монда тагы изәләр — мәдрәсә тыгыз, сасы, юеш, мөгаллим надан. Ашарга юк, булса, бәрәңге суы белән чи арыш икмәге!* Г. Ибраһимов.

БӘРӘҢГЕЛЕ *с.* Бәрәңге салып, бәрәңге белән пешерелгән; бәрәңге катнаштырып хәзерләнгән. *Ашка бардык. Аш бәрәңгеле ит, каз, пилмәннән гыйбарәт иде.* М. Фәйзи.

БӘРӘҢГЕЛӘНҮ *ф.* Бәрәңге бүлбесе яки бүлбеләре үсә башлау, яралу (үсемлектә). *Бәрәңгенең чәчәк атар алдыннан бәрәңгеләнә башлавы.*

БӘРҮ *ф.* 1. Кискен һәм каты орындыру (берәр нәрсәне). *Тимербулат үзенең стройга күнекмәгән аякларын берсен-берсенә бәрмәкче иде дә, бик көлке чыкты.* Қ. Нәҗми. *Гөлчәчәк урындыкка басып тәти алам дигәндә егылган икән, әрәк тез башын бәргән.* Г. Әпсәләмов.

2. Сугу, берәр нәрсә белән кискен ору. *Эткә таяк белән бәрү. Қадакны бер бәрүдә кертеп бетерү.* □ *Ишеккә ниндидер авыр әйбер белән бәргән, стеналарны дөбердәткән тавыш ишетелә.* Г. Гобәй.

3. Ыргыту, ыргытып ташлау. *Миңнәхмәткә үтерү белән яный башлыйлар. Бер төнне тәрәзәсенә кирпеч бәрәләр.* Г. Толымбай. // *сөйл.* Ату. *Бер бик матур кояшлы көнне иртә белән, ике урман тавыгы бәреп алганнан соң, мин урман авызына чыктым.* А. Шамов. *Ишетәсезме, егетләр?! Безнекеләр якынлашалар түгелме? Авыр туплардан бәрәләр.* И. Туктар. // *гади с.* Ташлау, ташлап калдыру. *Искиткеч эссе. Яндым, пештем. Җилкәдә френч иде, ташлап калдырдым. Котомканы бәрмәкче булган идем, эчендә китаплар бар иде, кызгандым.* М. Максуд.

4. Кискен һәм каты орыну (җил, явым һ. б. ш. турында). *Бәрә йөзгә ачы буран.* Г. Хуҗиев. *Қыек бәреп, салкын яңгыр ява башлый.* А. Шамов. // Кискен һәм нык кагып-этәреп җибәрү. *Ухылдап торып килгән дулкыннар бер бәреп көймәне югары сикертә, кире кайтып комга утыртып куя, тагын бәрә дә тагын сикертеп җибәрә.* Ш. Қамал.

5. Нык бөркелү (пар, ялкын һ. б. ш. турында). *Ялкын бәрү.* □ *Казан кырыеннан пар бәрә башлый.* И. Гази. *Плитәдән --- ыргылып кызу бәрә.* Г. Гобәй. // Бик көчле аңку, нык тоелу (төрле ис һ. б. ш. турында). *Лабораториядә борынга эфир исе бәрү.* // *күч.* Бик сизелеп, беленеп тору (көч-дәрт һ. б. ш. турында). *Аның тулы гәүдәсеннән карусыз көч бәреп тора.* Г. Бәширов.

6. *сөйл.* Организмга зарар китерерлек рәвештә көчле тәэсир итү (ис, эсселек-салкынлык, шау-шу һ. б. ш. турында). *Электр тогы бәрүдән саклану.* □ *— Буяулы идәндә аягыма суык бәрә, туңа башлыйм.* С. Җәләл

7. Көчле агым булып яки фонтан рәвешендә агып чыгу. *Скважинадан «кара алтын» бәрә башлады.* М. Хәсәнов. *Вак ташларны уйнаклатып, чишмә бәреп тора.* Қ. Нәҗми. // Саркып үтеп керү яки чыгу (сыеклык, тир һ. б. ш. турында). *Дым бәрү. Кисмәк төбеннән су бәрү.* □ *Секретарьның маңгаена тир бәрде.* Ф. Хөсни.

8. *күч. сөйл.* Һөҗүм итү. *Ләкин чыдап торсын алар [илебезгә басып керүчеләр] Безнең кызыллар бәргәндә.* Г. Қамал.— *Батальоныңны күтәр, турыдан казармаларга бәр.* Г. Әпсәләмов.

9. Гадәттә «ачыктан-ачык», «турыдан», «турыдан-туры» сүзләре янында: сүзне-фикерне кыю һәм икеләнмичә, кимчелекләрне дә читләтеп үтмичә әйтү, сөйләү турында. *Мондый [үземә ошамаган] мәсьәләдә минем дуслык-танышлык юк. Мин турыдан бәрәм.* А. Шамов. *[Җаббар] Сабирдан тартыныбрак торса да, моның һәр турыда ачыктан-ачык бәргәнен күргәч, --- сөйли башлады.* Г. Ибраһимов.

10. *гади с.* Уйнау (төрле спорт, өстәл уеннарын һ. б. ш.).—*Әйдә менә, теләсәң, карта бәреп алабыз.* Ф. Әмирхан.

11. Әзлекле яки параллель булган, үткән, башкарылган эш-хәлләрне, хәрәкәтләрне атый торган сүзтезмә башында килгәндә: бик каты һәм кискен этү-этәрүне, төртү-кагуны белдерә. *Ишекне бәреп ачу.* □ *Шул арада казарма ишеген бәреп Насрый чыкты.* Ш. Қамал. *Ишектән дулап яңадан өйгә керүче Шакир аларны бәреп ега язды.* А. Алиш. // Шундый ук сүзтезмә башында килеп, гомумән, көч кулланып эш-хәрәкәт итүне белдерә.— *Илебезнең туфрагыннан соңгы дошманны бәреп чыгарганчы кулымнан корал төшмәс!* Қ. Нәҗми.— *Бабам бөек рус армиясенең беренче колоннасында Берлинны үткән, беренче колоннада Парижга бәреп.кергән.* А. Шамов. // Шундый ук сүзтезмә башында килеп, эш-хәлнең, халәтнең, хәрәкәтнең көчлелеген, интенсивлыгын, кискенлеген белдерә. *Йөзгә шатлык бәреп чыгу.* □ *Бу кеше, ишек ачылу белән тыштан бәреп кергән суыкның басылганын көтеп, бераз бер урында басып торды да табын тирәсендә утыручыларга карап сәлам бирде.* М. Гали.

12. Әзлекле яки параллель булган, үткән хәлләрне-хәрәкәтләрне атый торган сүзтезмәдә, гадәттә «тору», «чыгу» фигыльләре алдыннан килгәндә, беленер-күренер дәрәҗәдә кабару-бүлтәюне, төртеп чыгуны белдерә. *Берет астыннан бәреп чыккан чәч.* □ *Ботларындагы бераз тышка бәреп торган калын, каты итләр белән киң күкрәк, маңгайдан авызгача боргаланып төшкән кара кашка айгырның нечкә сылу гәүдәсенә аерым бер --- төс бирә.* Г. Ибраһимов.

13. «Ату», «ыргыту» һ. б. кайбер фигыльдән соң килгәндә эшнең-хәрәкәтнең көчлелеген, интенсивлыгын, кискенлеген белдерә. *Ул ачулы, күл астына элаккан әйберләрне атып-атып бәрә.* Р. Ишморат. *Җиһангир эшен, уенын ыргытып бәрә дә [иптәшләре белән] бергә оча.* Г. Ибраһимов.

◇ **Бәреп егу** — күп өстен булу. *Авылда икмәк кенә түгел, һавасы да дуслыкны [исле майларны] бәреп ега!* Н. Дәүли.— *Әле хәзер дә ул [җырга оста карчык] кайбер артистларны бәреп ега.* Ш. Хөсәенов.

БӘС I *и.* 1. Әйберләр суынган вакытта аларның үз парыннан өсләренә утыра торган юка гына кар сыман катлам (кыраудан башка); көчле сыкы. *Телефон чыбыгын ак бәс сару. Тирләгән атның өсте бәс белән капланы.* □ *Тал ботакларыннан бәслар коела.* Ф. Хөсни. *[Тәрәзә] язгы кояш белән бәсен салган.* А. Шамов.

2. Һавада җиңелчә томан булып күренә торган сыкы бөртекләре. *Авыл моржаларыннан чыккан төтен, һавага күтәрелә алмыйча, бәс белән аралашып җиргә ята.* М. Гали. *Җемелдәп төнге тынлыкта, Энҗедәй бәслар оча.* Ә. Исхак. *Күктә йөзәдер Бәс белән томан.* Дәрдмәнд.

БӘС II *и. сөйл. к.* бәз. [*Тимери*], *көзен Идел туңганнан соң, киндер чалбар белән бәс бишмәтен салып та тормастан, лашман ягына китте.* Г. Бәширов.

БӘС III *кер. сүз. иск.* Димәк, шулай булгач. [*Чыпчык — Байга:*] *Бер күкәй хәтле бөтен гәүдәм дә юк, Бәс, синең хәтле юлар адәм дә юк!* Г. Тукай.— *Ул безнең сүзне тыңламый. Бәс, шулай булгач, үзегез чарасын күрегез.* Т. Гыйззәт.

БӘСЛЕ *с.* 1. Өстенә бәс I (1 мәгъ.) утырган, бәс сарган. *Бәсле агач.* □ *Сафия абыстай --- түр тәрәзәсенә йөгерде, пәрдәнең бер читен күтәреп, йөзе белән бәсле пыялага капланды.* А. Шамов.

2. Бәс 1 (2 мәгъ.) катнашкан, шуның белән аралашкан (һава һ. б. турында). *Бәсле томан.* □ *Бу көннәрдә булып узган бәсле суыклар артыннан хәзер инде һава йомшап килә.* С. Рафиков. *Яратам мин туган якларымның Бәсле таңын, Җепшек буранын.* С. Урайский.

БӘСЛӘҢҮ *ф.* **1.** Бәс (1 мәгъ.) белән каплану, өстен бәс сару. *Ботаклар бәсләнү.* □ *Ат тотучының сакалмыеклары бәсләнгән.* Ф. Әмирхан. [*Рәхим*] *суыктан бәсләнеп беткән трамвайдан төште.* А. Расих.

2. *сир.* Бәскә әйләнү (пар һ. б. ш. турында). [*Подвал*] *салкыны, үч иткәндәй, сөяк җелекләренә үтеп керә, ә дымы бәсләнеп өскә-башка куна.* М. Шабай.

БӘСӘРҮ I *ф. к.* бәсләнү. *Агачлар бәсәрү.* □ *Салкыннан авызы бәсәреп, борынына тамчы-тамчы боз каткан ат, килеп туктауга, пошкырып куйды.* М. Гали. *Иван Кузьмичның соры тышлы туны, - - - сакал-мыеклары, хәтта керфекләре дә бәсәреп агарган, һәм ул үзе дә - - - кыш бабайга охшап калган.* С. Сабиров.

2. *күч.* Агару, чалару (чәч-сакал турында). *Шомырт кебек кара сакал иде, хәзер бәсәрде.* Г. Толымбай.

БӘСӘРҮ II *ф.* Искереп нык юкару, сүсәреп тузу (тукыма һ. б. ш. турында). *Җилән урынына бәсәргән соры шинель, савырлы читек урынына тупас итек кия-чәгән уйлап,* [*Вахитның*] *йөрәге калтыранып китте.* М. Гафури. *Бер кат бәсәргән шпагат белән аннан-моннан типчелгән кыска куныслы бу итек аларның һәркайсына бик яхшы таныш.* К. Нәҗми.

БӘТИ *и. диал. к.* бәрән 1. *Сарык бәтие.* □ *Идәндә, койрыгын чәнчеп, ишекле-түрле бозау белән кәҗә бәтиләре чабып йөри.* Г. Бәширов.

БӘТИЛӘҮ *ф. диал. к.* бәрәнләү. *Бүген төнлә безнең сарык бәтиләде.* Ф. Әмирхан.

БӘТӘҪ *ы. гади с. к.* бәрәч II. *Гайнияҗамал кычкырып җибәрде: — Бәтәч! Бер бәлешне урлаганнар.* И. Гази.

БӘХЕТ *и.* **1.** Тулы канәгатьләнү халәте һәм хисе. *Бәхет — көрәш ул.* К. Маркс. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә.* Г. Тукай. *Бер минутлык күрешү бәхете белән Инде язмыш мине бүләкләл* М. Җәлил.

2. Уңыш (эштә, тормышта һ. б.). *Ләкин безнең эштән бәхет булмады.* М. Гафури. // Уңышлы очраклылык, яхшы язмыш.— *Егетләр, бәхетегез бар икән. Мин бер дә табылыр дип уйламаган идем, сез сораганнарның барысы да табылды.* Г. Камал. // *кер. сүз. функ. тартымлы форм.* Берәүнең очраклы уңышы турында.— *Күрсәткән булыр иде, бәхетең әле, әтисенә әйтмәгән.* Г. Гобәй. [*Әтисе кызына:*] *Бәхетең, әнә егет карап тора... Юкса, мин сине менә шушы каеш белән...* Г. Минский. // **бәхеткә, бәхеттән.** Бәхетле очраклык аркасында, бәхеткә каршы. *Ләкин мин харап булмадым: каяндыр, минем бәхеткә, коткаручы килеп чыкты.* А. Шамов. *Ярый, бәхетегезгә, урманда адашып калмагансыз әле.* С. Җәләл.

3. Бәхет чыганагы, бәхет китерүче. *Юк! Габдулла Җаекта калырга тиеш һәм, бөтен көчен куеп, бердәнбер бәхетен — Сәрвине сакларга тиеш!* Ә. Фәйзи. *Бәхетем син минем, шатлыгым син.* Ф. Кәрим.

◇ **Бәхет басу (җиңү)** — очраклы рәвештә бәхеткә, уңышка ирешү. *Минем бәхет басты: укытучы абый хәзер үз өебездә тора.* Ф. Хөсни. *Минем бәхет җиңде: көн-төн карау аркасында, бер атна дигәндә, минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды.* Г. Ибраһимов. **Бәхет ишеге (капкасы) ачылу** — уңышка очрау, уңыш килү (эштә, тормышта һ. б.). *Аның алдында тагын дөньяның бәхет ишекләре ачылды.* Г. Ибраһимов. **Бәхет йолдызы (кояшы)** *шигъ.* — бәхет чыганагы. *Иректәләр, үксез һәм ачларның Балкып чыкты бәхет кояшы.* М. Җәлил. **Бәхет кошы** *шигъ.* — бәхет чыганагы һәм бәхет билгесе, символы. *Бүген путевканы алгач, Мәликә апа аны, бәхет кошыдай кадерләп, кесәсенә салып кайтты.* Ә. Бикчәнтәева. **Бәхет сынау** — уңыш өмет итеп тәвәккәлләү. *Бәлки, көрәштә дә бәхетне сынап карарга булыр.* А. Әхмәт. *Гарәфи берничә тапкыр читкә дә чыгып бәхет сынап карады.* Г. Әпсәләмов. **Бәхет эзләү** — бәхет өмет итеп чит җирләргә барып йөрү. *Элекке заманда без бәхет эзләп Донбасска шахтага китә идек.* А. Әхмәт.

БӘХЕТЛЕ *с.* **1.** Бәхет хисләрен кичерүче, бәхеткә ия булучы. *Бәхетсезләргә ярдәм итү, аларга кул бирү — бәхетле булуның бер шарты бит.* М. Максуд. *Бөтен илнең тормышы яхшырганда гына без бәхетле була алабыз икән.* Ф. Бурнаш. // Бәхет билгесе булган, бәхетлелекне күрсәтеп торган. *Бәхетле йөз.* □ *Бәхетле, шат җырдан Бөтен кыр яңгырар.* М. Җәлил. *Сестра Хәлимнең кулыннан алды, аңа якын үк сыенып, бәхетле, шат тавыш белән пышылдады.* А. Шамов. / *рәв. мәгъ. Миңнурый, бәхетле елмаеп, аның артыннан карап торды.* Г. Әпсәләмов.

2. Бәхет бирә, бәхетле итә торган. *Бәхетле заман. Бәхетле минут. Бәхетле очраклык.* □ *— Мин бәхетле таң, Бөек Октябрь таңында тудым.* Р. Ишморат.

БӘХЕТЛЕЛЕК *и.* Бәхетле булу хәле. *Син җибәргән кадерле бүләк — ефәк яулык белән күз яшьләремне сөртү миңа чиксез ләззәт, очсыз-кырыйсыз бәхетлелек тойгысы бирде.* Ш. Камал. [*Элек*] *берәүләрнең бәхетлелеге икенчеләрне бәхетсез иткән, берәүләрнең азатлыгы икенчеләрне бәйле иткән, богаулы иткән.* И. Гази.

БӘХЕТСЕЗ *с.* **1.** Бәхете булмаган, бәхеттән мәхрүм; бәхетсезлек кичерүче. *Бәхетсез гомеремнең актык чигенә ирештем дигән кебек булды* [*Җәмилә*]. М. Гафури.

2. Бәхетсезлек китерә торган. *Без бәхетсезрәк заманда туып калган, ә безнең сеңелләр, энеләр бәхетлерәк заманга эләккәннәр.* Ф. Әмирхан.

БӘХЕТСЕЗЛЕК *и.* Бәхетсез булу хәле. *Сугыш Тамарага иң авыр бәхетсезлек — ялгызлык бәхетсезлеген китерде.* Ә. Еники. // Аерым бер уңышсызлык (эштә, тормышта һ. б.). *Бу нинди бәхетсезлек. Бер тәүлек эчендә шул эт* [*шымчы*] *өченче тапкыр очрый.* Г. Ибраһимов.

БӘХИЛ *хәб. сүз.* Гафу итү, кичерү, ризалашуны аңлата. [*Фазыл:*] *Ярый, мин китәм. Бәлки бер-ике сәгатьтән соң тагы да килеп чыгармын әле.* [*Хафиз — кызу гына килеп күрешә:*] *Хуш, килмәсәң дә үпкәләмим. Бәхил, мең бәхил!* Р. Ишморат. *Шул вакыйганы янәдән тәфсиллән язмасаң, һич тә бәхил түгел.* Ш. Камал.

◇ **Бәхил бул** — «гафу ит, кичер, ризалаш» дигән мәгънәләрдә кулланыла. *Картның уллары да түзмәделәр: — Әткәй, карт көнемдә ялгызымны калдырдылар дип рәнҗемә, үлсәк, бәхил бул,— диделәр дә үзләре телән кызыл байрак астында фронтка киттеләр.* Г. Ибраһимов. *Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем.* Г. Тукай.

БӘХИЛЛЕК *и.* Ризалык; гафу итү, кичерү. [*Сәхәү*], *атасы үлем түшәгенә яткач кына кайтып, үткән эшләреннән елый-елый тәүбә итеп, картның бәхиллеген алган.* М. Әмир. *Берәр чынаяк чәй эчеп китмәсәң, бәхиллегем юк, кара аны.* Ф. Хөсни.

БӘХИЛЛӘТҮ *ф.* Ризалаштыру, канәгатьләндерү. *Җаныемның хәтере калган, ничек бәхилләтергә.* Г. Тукай. [*Гыймади:*] *Хәзер акчам юк, мин бәхилләтермен.* [*Фәрит.*] *Безгә хәзер үк кирәк.* К. Әмири.

БӘХИЛЛӘШҮ *ф.* **1.** *Уртак юн. к.* бәхилләү.

2. Саубуллашу (бөтенләйгә дип аерылышканда). *Күптән түгел генә синең белән саубуллашкан идем, күптән түгел генә синең белән мәңгегә бәхилләшкән идем.* М. Максуд. *Хәлен белергә килүчеләр белән бәхилләшә, аз сөйләшә башлады* [*Тукай*]. М. Гали. // *күч.* Берәү белән араны, мөнәсәбәтне бөтенләйгә өзү, аның белән аралашудан бөтенләйгә туктау (гадәттә мәҗбүр ителү

аркасында). // *күч.* Берәр нәрсәне яки кешене бөтенләйгә югалту, аннан мәхрүм калу. *Зарипов белән дә бәхилләштек. Ә шулай да авылны алдык.* Ф. Кәрим. [*Кыз*], *бу матурлык, бу рәхәт уздырылган вакыт белән бәхилләшкән шикелле итеп, ике-өч минут тын гына тордылар.* Ф. Әмирхан.

БӘХИЛЛӘҮ *ф.* Гафу итү, кичерү. [*Зәмзәмбану:*] *Әткәй миңа ачу тотмасын. Бичараны бик күп рәнҗеттем. Зинһар бәхилләсен.* Т. Гыйззәт.

БӘХӘС *и.* **1.** Берәр мәсьәләне тикшергәндә һәркемнең үз фикерен, үзенең хаклы булуын яклап сөйләве; сүз көрәштерү. *Каюм укырга тәкъдим иткән китапларны ул* [*Хәйбулла*] *комсызлык белән укый, алар турында Каюм белән фикер алыша, үзенең фикерләрен әйтә, акыллы сораулар бирә, төпле бәхәсләр алып бара.* Ш. Камал. *Сүз байтакка тартылды, бәхәс киткән саен кызды.* М. Гафури. // *күч.* Җиңелчә ызгыш, дау, низаг. *Җир бәхәсе. Милек бәхәсе. Территориаль бәхәсләр.* □ *Поезд кузгалып китүгә бераз вакыт узгач, вагондагы шау-шу тына төште. --- Урын турындагы бәхәс басылганнан басылды.* Г. Минский.

2. Берәр мәсьәләдә кемнең хаклы булуын ачыклаганнан соң, отылучыдан ни дә булса эшләттерү яки түләттерү шарты белән ясалган килешү.— *Менә Камил белән бәхәсләштек әле. Кем шушы агач башына бәйләнеп атына ала, дибез. --- Светланага да кызык булып китте бу бәхәс.* Л. Ихсанова. // *диалогта.* «Әйдә, бәхәсләшик» дигән мәгънәдә кулланыла. [*Хәлиулла:*] *Болар Бизмән тауда нефть таба алмаслар дисең инде. Әйдә, булмаса, кызык өчен генә булса да бәхәсләшәбезме?* [*Фәйзерахман:*] *Бәхәсме, әйдә!* А. Әхмәт. // *рәв. мәгъ.* **бәхәстән.** Бәхәс итеп, бәхәсләшеп. [*Бәдри*] *бәхәстән җиде төн уртасында мәзин мунчасыннан таш алып чыгуын сөйләде.* И. Гази.

БӘХӘСЛЕ *с.* **1.** Бәхәсләр белән үтә торган (әңгәмә, җыелыш һ. б. ш. турында). *Әңгәмә бәхәсле булган саен кызыграк.* Ә. Фәйзи.

2. Бәхәс чыгара торган, ачыкланып бетмәгән, хәл ителмәгән. *Бәхәсле халыкара мәсьәләләрне тыныч юл белән хәл итү.* □ *Бу мәкаләдәге фикерләрнең бәхәсле булуы да бик мөмкин.* Г. Минский. // Кемнеке икәнлеге ачыкланмаган, дәгъвалы (милек һ. б. турында). *Бәхәсле территория.* □ *— Тизрәк чабыгыз,— диде җир бүлеге кешесе,— бәхәсле болын, «Чуртанлы күл» авылы ул печәнлекне үзеневе дип дәгъвалый.* И. Гази.

БӘХӘСЛӘШҮ *ф.* **1.** Үз фикереңне, үзеңнең хаклы булуыңны яклап берәү белән сүз алып бару. *Казаклар: «Минем пуля тиде.— Юк, минеке тиде»,— дип бәхәсләшеп менеп киләләр иде.* Г. Гобәй. // Каршы әйтеп, җиңелчә ызгышу. [*Малайлар*] *бер дә тынышмыйлар, гел бәхәсләшеп, бер-беренә бәйләнешеп кенә торалар.* М. Гали.

2. Берәр мәсьәләдә кемнең хаклы булуын ачыклаганнан соң, отылучыдан ни дә булса эшләтү яки түләтү шарты белән килешү ясау. *Шәйдүк: — Ышанмасагыз, арагыздан кайсыгыз бәхәсләшә? — дигән. Бер зур корсаклы Казан бае килеп чыккан да: — Менә минем атым белән узышып карасын, мин бер меңнән бәхәсләшәм,— дигән.* Ш. Әхмәдиев.

БӘХӘССЕЗ *с.* **1.** Бәхәстән башка, бәхәс катнаштырмыйча гына була, үтә торган. *Бу темага күчкәнче мәҗлесебез шома, матур, бәхәссез барган иде.* А. Шамов.

2. *күч.* Дәлилләүгә мохтаҗ булмаган, дөреслеге шөбһәсез булган. *Бәхәссез хакыйкать.* □ *Бернәрсә бәхәссез: адәм баласы хыялсыз яши алмый.* Г. Минский.

3. *кер. сүз. функ.* Һичшиксез, шөбһәсез. *Тавышыннан таныдым, бу, бәхәссез, Микита иде.* Г. Гобәй.

БӘҮ *аваз. иярт.* 1. *к.* бә.

2. *шаярт.* Балалар телендә «сөзәм» дигән мәгънә бөлдерә.

БӘӘЛДЕК *с.* Күп бәәлди торган (бәрәннәр турында).

БӘӘЛДӘҮ *ф.* «Бә, бәә» сыман тавыш белән кычкыру (бәрәннәр һәм сарыклар турында). *Яңа туган кәҗә, сарык бәрәннәре нечкә тавыш белән бәәлделәр.* М. Гали.

БӘЯ *и.* **1.** Әйберне сатканда яки алганда сорала яки бирелә торган акча сумасы; әйбернең акчалата хакы. *Ваклап сату бәяләре. Бәяләр төшү. Билет бәяләре. Бәя кую.* □ *Алмаса да, Тимербай, хәтта кайбер күңеленә ошардай нәрсәләргә үз бәясен бирепсатулашып та йөрде.* М. Гали. // Әйбернең акчалата тулаем кыйммәте. *Сыйфатсыз эшләнгән җир өчен трактарчыга эш хакы бирелми. Өстәмә эшкәртү өчен тотылган ягулык бәясе дә аннан түләтелә.* Соц. Тат.

2. *сөйл.* Аерым эш төрләре буенча түләү, эш хакы. [*Эшләүчеләр*] *һәммә эш өчен бәяне дә аерым-аерым билгеләп чыктылар.* М. Гали. *Шәрифулла мичне төзәтергә кирәк тапты, шунда ук алар бәясен дә килештеләр.* А. Шамов.

3. Билге (мәктәптә). *Укучының диктантына югары бәя кую.*

4. Берәр нәрсәнең яки кешенең әһәмияте, кыйммәте турындагы фикер, хөкем; бәяләмә. *Танкыйтьченең әдәби әсәргә биргән бәясе. Артистның уйнавына тамашачының югары бәя бирүе.*

5. *күч.* Кадер. *Хәзер син, Газинур, дәрәҗәле кеше,— диде Гарәфи абзый. --- Халык арасында үзеңнең бәяңне төшермә.* Г. Әпсәләмов. *Сез үзегезнең бәягезне белеп эш итегез.* А. Расих.

6. *с. мәгъ. күч. сөйл.* Кыйбат. [*Бәһау кибетчегә:*] *Шакир, синдә әйбәт духи бармы? --- Бүләккә яраррлыгы. Бик бәя дә булмасын иде.* Г. Минский. [*Алучы күкәй сатучы хатын-кызларга:*] *— Әй, нәрсә сезнең? Бәяме?* Г. Бәширов.

◇ **Бәя бирү** — бәяләү. *Син, Нәсимә, яшь кеше булганга, ахры, авыл кешесе эшенең кадерен аңлап бетермисең, колхозчының хезмәтенә бәя бирепжиткермисең.* А. Әхмәт.

БӘЯЛЕ *с.* **1.** Бәясе билгеләнгән, бәя куелган (товарлар турында).

2. *күч. сөйл.* Кыйбат хаклы. [*Кайберәүләргә*] *бәләкәй габаритлы бүлмәләр өчен ясалган гарнитурлар яраамый. Бүлмәләренә күрә затлысы, күләмлесе кирәк, ягъни иң бәялесе.* М. Әмир. // Кыйммәт; кадерле. [*Мамонт*] *сөякләренең нинди кыйммәтле нәрсәләр икәнен һәм, бәлки, үзенең башка малына караганда да бәялерәк икәнен аңларлык тәҗрибәсе дә, гыйлеме дә булгандыр аның.* А. Тимергалин.

БӘЯЛӘМӘ *и. кит.* Берәр эшнең, хезмәтнең гомуми сыйфатын, әһәмиятен, кыйммәтен күрсәтеп, гадәттә язма рәвештә бирелә торган рәсми бәя, фикер. *Диссертациягә бирелгән бәяләмә. Рецензентның бәяләмәсе белән килешү.*

БӘЯЛӘҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* бәяләү.

2. *күч. сөйл.* Кыйбатлану.

БӘЯЛӘҮ *ф.* **1.** Бәя (1, 2 мәгъ.), хак билгеләү. *Ишан, исәпләп карап, бүлмә ясауны биш мең алтынга бәяләгән.* Э. Касыймов.

2. Берәр нәрсәнең (гадәттә хезмәтнең) уңай һәм кире якларын исәпкә алып, аның гомуми сыйфаты, әһәмияте, кыйммәте турында фикер әйтү. *Халык күрә, ил бәяли безнең эшне.* М. Хөсәен. *Марксизм-ленинизм телне кешеләрнең аралашуы өчен иң әһәмиятле корал дип бәяли.* Сов. мәк. // *күч.* Кадерен белү. *Ачыны белмәгән татлыны бәяли алмас диләр.* А. Гыйләҗев.

БӘЯН *и. иск. кит.* Аңлатма. *Ул Габделбасыйргә бәян көткән күзләрен текәде.* Ф. Әмирхан. *Сабирның үз хәяты хакында ачык бәян бирмәве генә борчый иде* [*әнисен*]. Г. Ибраһимов.

Бәян итү — аңлату, сөйләп-язып бирү. *Өйгә кайткач бөтен вакыйганы бәян итәрмен.* Ф. Әмирхан.

БӘЯСЕЗ *с.* 1. Бәясе билгеләнмәгән, бәя куелмаган (товарлар турында).

2. *күч.* Үтә арзан.— *Күпме тора? дип сорый Әбүзәр абзый аучыдан.— Миллион! — ди теге. Ул елларда акчаның бәясез чагы булса да, Әбүзәр абзый уйлый-уйлый да, кыйбатсынып,* [*киекне*] *алмый китә.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Гадәттән тыш кадерле, яхшы, бәя биреп бетергесез.

БӘЯСЕЗЛӘНҮ *ф.* Бәясе, хакы бик төшү, үтә арзанлану.

БӘЯЧЕЛ *с.* Әйбер сатканда, кыйбат сораучан. *Бәячел кеше.*

БӘҮ *ы.* Кабатлап яки «бәүки», «бәлли» һ. б. сүзләр белән аралаш: бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. [*Рәүф*] *нәкъ әнисечә, зурларча гына иттереп, энесенең битеннән бер тапкыр үбеп алды да: — Йокла, йокла, бәү-бәү! Бәү-бәү!.. дип бишекне селкетә, тирбәтә башлады.* Г. Иделле. *Ай син балам, кечкенәм, --- йокла, йокла син тизрәк, әлли, бәлли, бәлли бәү.* М. Әблиев. *Бик нәни кыз әле Диләрә, --- Йоклый ул әлли, бәү дигәнгә.* Ә. Бикчәнтәева.

Бәү итү — 1) шул сүзләр белән көйләп тирбәтү (бәбине); 2) йоклау (көйләп тирбәтелүче бәби турында).— *Бәү-бәү итеп, күз йомып, Изрәп кенә китәр ул.* К. Әмири.

БӘҮКИ *ы. к.* бәү. *Әлли-бәлли, бәүки, җан кисәк! Тыныч йокла тагын бик дзак.* М. Җәлил.

БӘҺА *и. иск.* Бәя (1, 2, 4 мәгъ.). [*Бай — хезмәтчегә:*] *Ярар, мин сине хезмәткә алырмын, көтү көтәрсең һәм, әгәр яхшы хезмәт итсәң, аена алты тәңкә бәһа куярмын.* Г. Тукай.— *Шулай, кыйммәт бәһа белән табылган репутацияне очсыз бәһа белән сату — алдану!* Ф. Әмирхан. *Бу ел мал бәһасе яхшы.* М. Гафури.

БӨГЕЛЕШ *и.* 1. Бөгелгән урын. *Шәйхетдинов Суфиянең алланган матур йөзенә, --- кечкенә генә күкрәкләренә, терсәгенең матур бөгелешенә яратып карап торды.* И. Гази.

2. *диал.* Борылыш, борылма (юлдагы, елгадагы һ. б.). *Ул* [*юл*] *бөгелешендә күздән югалды.* Н. Исәнбәт.

3. *күч. кит.* Артыгын кыланып эшне бозу, дөрес юнәлештән читкә тайпылу (гадәттә политик эшчәнлек турында). *Комедия күмәкләшү вакытында булган кайбер бөгелешләрне җанландыруны үз эченә ала.* Т. Гыйззәт.

БӨГЕЛМӘ *с. диал.* Бөгеп эшләнгән. *Беләзекләрең бөгелмә, Бөгелмәдән килгән түгелме?* Җыр.

БӨГЕЛМӘЛЕ *с.* Бөгелә-бөкләнә, җыела-ябыла торган. *Бөгелмәле пәке.*

БӨГЕЛМӘЛЕ-СЫГЫЛМАЛЫ *с.* 1. Бөгелә-сыгыла хәрәкәтләнә, йөри торган (гадәттә зифа, нәфис гәүдә турында).

2. Берничә урыннан бөгелеп-сыгылып торган яки спиральне хәтерләткән нәрсә турында. *Зинһар бу бөгелмәле-сыгылмалы торбаңны күтәреп йөрисе булма.* Ф. Хөсни.

БӨГЕЛМӘС *с.* 1. Бөгелми торган.

2. *күч. юг.* Буйсынмый торган, көчле ихтыярлы. *Командир гаять кыю, көчле ихтыярлы, бөгелмәс коммунист иде.* И. Туктар.

БӨГЕЛӘ-СЫГЫЛА, БӨГЕЛЕП-СЫГЫЛЫП *рәв.* Нык иелеп, бөгелеп. [*Юлчы*] *ишекне мәшәкать белән ачты да, караңгы чоланнан абына-сөртенә, бөгелә-сыгыла өйгә керде.* Г. Ибраһимов. // Нык иелү, бөгелү хәрәкәтләрен еш кабатлап, гәүдәне уйнаклатып (кояз яки куштан ялагайлар турында). *Бөгелә-сыгыла су китерә кайсы егет җанашы.* М. Фәйзи. *Низами җитез, шома хәрәкәтләр белән бөгелә-сыгыла безне таныштыра башлады.* М. Әмир.

БӨГЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* бөгү (1—5 мәгъ.).

2. Иелү, гәүдәне бөгү. *Разия, бөгелеп, ал, кызыл берничә чәчәк үзде.* Ф. Әмирхан. *Карт канәгатьләнеп хихылдап көлеп җибәрде һәм, мактавыбыз өчен рәхмәтен белдереп, биленә хәтле бөгелде.* А. Шамов.

БӨГЕШТЕРҮ *ф.* 1. Өстән-өстән, игътибарсыз гына бөгү (4 мәгъ.).

2. *күч. гади с.* Ялганлау. — *Баһави, бөгештерәсең инде, малай. Бернинди кимегү булмады.* А. Расих.

БӨГӘЛЧӘН *и. зоол.* Корт чагында хайван (бигрәк тә ат һәм эре мөгезле терлек) тәнендә тереклек итүче, тәненең нечкәреп очлаеп килгән койрык өлеше бөкрәеп торучан ике канатлы бөҗәк; кигәвеннең бер төре.

БӨГӘЛҖӘ *и. диал.* Ябылып-йомылып җитмәгән кечкенә бөҗра яки ярым бөҗра формасындагы әйбер; эләктереп-тоташтырып кую җайланмасы. *Күз алдына килеп тора: бөгәлҗәсе ычкынган алка, кызның бик матур колагы.* Ф. Хөсни.

БӨГӘРЛӘНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* бөгәрләү 1.

2. Ятканда: кул-аякны бөкләп һәм гәүдәне бөгеп, йомарлану. *Йөзлебикә, агач төбендә бөгәрләнеп, йокыга китәргә дә өлгергән иде.* Г. Бәширов. // Тәнне бөгеп йомарлану (сөйрәлүче хайваннар, бөҗәкләр һ. б. турында). *Өйалды астыннан бөгәрләнә-бөгәрләнә бик яссы башлы, чаңгы буе елан үрмәләп килеп чыкты.* Г. Галиев.

БӨГӘРЛӘҮ *ф.* 1. Ямьсез җыерчыкландырып, тигезле-тигезсез бөкләп, йомарлау. *Кулъяулыгын бөгәрләп кесәгә тыгу. Кәгазьне бөгәрләп чүп савытына ташлау.* // Җыерчыкландырып ямьсезләү (киемне һ. б. ш.).

2. Буыннан бөкләү. [*Иптәшем*], *аякларын бөгәрләп, җыерылып ята.* Ш. Усманов.

3. *к.* бөгү 5. [*Галиулла*] *арсландай егет иде. Дөнья дигәнең нинди генә кешеләрне бөгәрләп ташламый.* И. Гази.

БӨГҮ *ф.* 1. Дуга сыман итеп яки почмакландырып кәкрәйтү, очларын бер-берсенә якынайтып сыгылдыру. *Тимер чыбыкны бөгү.* □ *Нәсимнең талдан бөгеп ясаган бик шәп җәясе бар.* Г. Мөхәммәтшин. // *махс.* Бөгеп ясау, эшләү. *Көянтә бөгү. Чаңгыны каеннан бөгү. Дуга бөгү.* □ *Аның артеле туғым һәм чана табаннары бөгә.* Ә. Еники. *Бәйрәмнәрдә кунак чакыру күңелле эш, исәпсез пилмән бөгү дә әллә ни түгел.* М. Максуд.

2. Буыннан өлешчә бөкләү (әгъзаларны). *Муенны бөгү. Билне бөгү.* □ *Ул табышны алдан санап тора, Бармак бөгеп кесә төбендә.* Н. Дәүли.

3. Ию (үсеп утырган агачны, башны һ. б.). *Уҗым яшел, әйе, уҗым сыек,— Кая тели, шунда бөгә җил.* З. Мансур. *Хәмдия чыга; Бакый башын бөгеп чигенә.* М. Фәйзи.

4. Кирегә бөкләп, кайтарып тегү (тукыма әйберләрнең читен). *Яулык читләрен бөгү. Җиң очларын бөгү.* □ [*Мәрьям*] *абзасына берничә яңа күлмәк текте, аяк чолгауларының, тастымалларының башларын бөкте.* М. Гафури. *Ак калфагың чиккән, бөккән, Ука белән чуклаган.* Җыр.

5. *күч.* Буйсынырга мәҗбүр итү; рухи көчсезләндерү. *Мин аның характерын беләм. Аны бөгеп булмый.* А. Шамов. *Тормыш бөкте аларны.* Э. Касыймов.

6. *күч. сөйл.* Артыгын кылану, чамадан узу, артык суллану (берәр эштә). [*Җамалый*], *Әминә белән сөйләшкәндә дә клуб, кино мәсьәләсендә бераз «бөгеп» җибәруен абайлап, эшне төзәтергә теләде.* Г. Минский.

7. *күч. сөйл.* Ашау (җитез, тиз, күп ашау турында). [*Ачыгып кайткач*], *күземә ак-кара күренмәде, каз йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгеләрне, тозлап-тозлап, арыш икмәге белән бөгәргә тотындым.* Г. Ибраһимов. [*Күрше өстәлдәге кеше*], *казакиен салып, күлмәгенең киң җиңнәрен сызганып, өченче тарелканы бөгәргә кереште.* К. Тинчурин.

БӨДРӘ *с.* 1. Божра сыман бөтерелеп-бөтерелеп торган; бөткәле (чәч, йон һ. б. ш. турында). *Кыска буйлы, чандыр гәүдәле, бөдрәрәк җиткән чәчле яшь бер егетне «менә Тукай шул инде» дип читтән төртеп күрсәттеләр.* М. Гали. // Бөдрә чәчле яки бөдрә йонлы. *[Хәйдәр] бөдрә башын артка ташлап, кулын айкый-айкый шигырь укырга тотынды.* Г. Бәширов.— *Маһруй апа, син аңа [Сөнгатькә], бөдрә, бөдрә, бөдрәсең, җаннарымны көйдерәсең дип җырлагансыңдыр әле.* М. Фәйзи.

2. *шигъ.* Бөдрә сыман, күперенке һәм күркәм (ял турында). *Җиз дагалар аның [атның] аягында, Ефәк тасма бөдрә ялында.* М. Җәлил. // Бөдрә сыман булып күренә торган, күркәм (болыт, үсеп утырган агач һ. б. турында). *Бөдрә каен.* □ *Ул яфраклар шундый вак һәм бөдрәләр, ерактан караганда нәкъ төтен булып күренә.* С. Баттал. *Язгы аяз күктә, еракта-еракта бөдрә ак болытлар йөзә иде.* Г. Әпсәләмов.

3. *и. мәгъ.* Чәчтәге, йондагы һ. б. ш. бөтеркә. *Маңгай бөдрәләрем әкрен генә җилдә тирбәлә.* М. Хәсәен. *Миңнегөл зур көзге каршына килде, бөдрәсе бетә башлаган чәчен кузгатып, кабарткалап куйды.* М. Әмир.

БӨДРӘЛӘНҮ *ф.* Бөдрәгә әйләнү, бөдрәле хәлгә килү.— *Кара, чәчләрең нигә бөдрәләнгән синең?* М. Фәйзи. *Өй буенда бөдрәләнеп үскән яшь каен.* Э. Бикчәнтәева. *Кара төтен бөдрәләнә.* А. Шамов.

БӨДРӘЛӘҮ *ф.* Махсус рәвештә бөдрәгә әйләндерү, бөдрәле итү (чәчне, йонны). *Ул [чәчен] үзе бөдрәли булса кирәк.* А. Шамов. *[Комбинат эшчесе сарыкның] тиресен ала да, тарап, йомшартып һәм бөдрәләп, төрле төсләргә кертә.* Чаян.

БӨДӘҮ *ф. иск.* Бирү (садака, хәер, чәйлек һ. б. ш. турында). *[Егет:] Хәзер миңа тагы бераз имәрлек урын чыкты. Әгәр бераз бөдәмәсә, мин аны [байны] бөтен шәһәргә фаш итәрмен.* Г. Камал. *[Байгура ишанга:] Садакасына күрә фатихаңны бөдә.* К. Тинчурин.

БӨЕК *с.* Әһәмияте ягыннан гадәттәге дәрәҗәдән күп өстен тора торган. *Бөек максат.* □ *Совет халкы бөек революцияне үзе ясады.* Г. Бәширов. // Даһи. *Кем көрәшсә ирек, бәхет яулап, Бөек була менә шул кеше.* С. Урайский.

БӨЕКЛЕК *и.* Бөек булу хәле.

БӨЕНТЕ *и.* Су агымы белән килеп, бер җирдә буылып, җыелып торган нәрсәләр. *Җыелып торган бөенте менә кайчан кузгала.* Г. Ахунов.

БӨЕР *и. анат.* 1. Умырткалыларда: сидек бүлеп чыгара торган орган. *Бөер шешү.* □ *[Авыруның] өч көн элек бер бөерен ярып алганнар иде. Шуннан юньләп һушына килә алмады.* Г. Ибраһимов.

2. Тәннең, тиренең бөер урнашкан турысы. *Кулны бөергә кую.* □ *[Ат чабыштырганда] камчыңны бик ныклап кулыңа чалып тот. Килә-җитә ике яклап бөергә кыйна. Казак шикелле, алгарак ятып бар.* М. Гали.

◇ **Бөергә таяну** — 1) гамьсез, эшлексез кыяфәт алу. *Минемчә, кеше хәтфә келәмнәр өстеннән бөренә таянып үзү өчен генә дөньяга килми торгандыр.* Г. Бәширов; 2) һавалы яки горур кыяфәт алу. *[Төхфәт] балтасын идәнгә кадап куйды да ике кулы белән бөренә таянды.— Менә, күрмәсәң күр: элек мәдрәсә иде бу. Ә хәзер клуб!* Э. Касыймов.

БӨЕРӘК *и. диал. к.* бөер 1. *Аксымнарның сеңгән, ләкин үзләштерелмәгән өлеше, таркалгач, бөерәк аша чыгарылып ташлана.* А. Расих. *Бер саран хатын чәй янына бөерәк пешереп алган да шуны ашарга утырган ди.* Н. Исәнбәт.

БӨКЕ *и.* 1. Кайбер агачларның (күбесенчә бөке агачының) калын җиңел кайрысы.

2. Шешә, мичкә ише савытларның авызына, тишегенә тыгып каплый, яба торган әйбер. *Мичкә бөкесе. Кәгазь бөке.* □ *[Көймәдә] карандаш сыярлык тагы бер тишек бар иде. Анысы белән озак маташырга да туры килмәде, Гөлбану түтәй аңа бөке юнып тыкты, шуның белән эше дә бетте.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Берәр нәрсәнең (мәсәлән, юлдагы транспортның, халык төркеменең) хәрәкәткә комачау итәрлек күп туплануы турында. *Юл чатларында «бөкеләр» барлыкка килде — егермешәр-утызар машина, бер борылышка бөялеп, алга да, артка да китә алмыйча азапланып торган булды.* Г. Ахунов.

БӨКЕЛӘҮ *ф.* Бөке тыгу, бөке белән ябып, каплап кую. *[Кымызны] шешәләргә тутыралар, бөкеләләр һәм берникадәр вакыт җылы бинада тоталар.* Соц. Тат.

БӨККӘН *и. сөйл.* Түгәрәкләп җәйгән камыр эченә бәрәңге, ярма яки шулар янына ит һ. б. нәрсәләр салып, аны урталай бөкләп ябыштырып, мичтә пешерә торган ашамлык. *Балык бөккәне.* □ *Гәрәй киткән көн дип, мич ягып, кишер бөккәне пешергән идем.* С. Баттал.

БӨКЛӘМ *и.* Бөгеп куйган урын (гадәттә тукымадан эшләнгән әйберләрдә). *Үземнең бу тикле нык хәзерләнгәнлегемне, аңа [кыз белән очрашуга] шулкадәр зур әһәмият биргәнлегемне сиздерәсем килмәде: яңа апашемның сынып-сынып торган бөкләм эзләре бетсен дип, караватка ятып аунадым.* М. Әмир.

БӨКЛӘҮ *ф.* 1. Кәгазь, калай, тукыма кебек яссы яки тимер чыбык, җепсә кебек нәрсәләрне почмакландырып бөгү яисә шулай бөккән яссы әйберләрнең якларын кара-каршы китереп, ике яки берничә катлы итү. *Китап тышын ялгыш бөкләү.* □ *Ситдикъ абзый кулындагы кәгазьне бер бөклә де, бер ачты. Тагын бөклә де.* Қ. Нәҗми. *[Галимә] шәлен алып рәтләде дә икегә бөклә п киде ябынды.* М. Гафури.

2. Буыннан бөгү (кулны, аякны, бармакны). *Аяк бөклә п утыру.* □ *Балалар, күңелле шаулашып, бармакларын бөкли-бөкли санап киттеләр.* Б. Камалов.

3. *күч. сөйл. к.* бөгү 7. *Аш белән икешәр кадак күмәчне бөклә п ташладык.* Г. Гобәй. *[Ике] өчпочмакны бөклә дем дә репетициягә чаптым.* Г. Мөхәммәтшин.

БӨКРЕ *с.* 1. Бөгелгән, кәкрәйгән; кәкре. *[Карчык:] Я инде, укы. Минем күзне беләсең ич. Әнә, бөкресе нинди хәреф соң?* А. Әхмәт. *Бабайның күзләре --- ялтырыйлар. Ул бөкре бармаклы кулларын кая итәргә урын тапмаган төсле [утыра].* Н. Дәүли.

2. Умырткалыгы зарарланудан арка-күкрәге калкып чыгып торган. *Бөкре кеше.* // Аркасын бераз бөгебрәк тора яки йери торган; *русчасы:* сутулый. // Гадәттәгедән чыгынкырак булып, алгы өлеше киерелеп калкып торган (мәсәлән, борын). *Сәйфулла бабай таза гәүдәле, кызыл чырайлы, бөкрерәк борынлы, яше җитмешләр тирәсендәге бер кеше иде.* Ш. Камал.

3. *и. мәгъ.* Бөкре кешенең аркасындагы калкып чыгып торган җир. *Аның хәзер торышы нык, хәтта бөкресе дә бераз турая төшкән кебек күренә иде.* Г. Бәширов.

◇ **Бөкре чыгару** — үтә авыр эшләрне башкарып яки артык күп эшләп газап чигү. *[Тимери] көнен-төнен белмәде, арыдым, йончыдым димәде, ары чапты, бире сугылды, җәен-көзен бөкресен чыгарып, берүзе өч-дүрт эскерт куеп ташлады, борчак-ясмык чапты, әллә никадәр ашлык суктырды.* Г. Бәширов. **Бөкре чыгу** — 1) аркада бөкре барлыкка килү; бөкрегә әйләнү. *Габдулла алдында бөкресе шактый чыккан, сакал-мыегы агарып беткән бер карт басып тора иде.* Ә. Фәйзи; 2) авыр эштә газап чигү турында.— *Минем җилкә бөкреләрем чыкты әлеге дә баягы шул Сахап картларга эшләп.* С. Рафиков.

БӨКРЕЛЕК *и.* 1. Бөкре әйбернең шул формасы.

2. Бөкре булу хәле (кеше турында).

БӨКРЕЛӘНҮ *ф. к.* бөкрәю (1—3 мәгъ.).

БӨКРӘЮ *ф.* 1. Бөкре форма алу, кәкрәю. *Нәкъ дуга күк бөкрәеп киткән песинең аркасы.* Г. Тукай.

Ничә еллар буе кырда йөреп, Бөкрәеп беткән бер урак. М. Гафури.

2. Бөкрегә (2 мәгъ.) әйләнү. *Кеше бик озак яшәр, ак сакаллы бөкрәйгән карт булыр, әмма - - - солдат чакларын, сугышта күргәннәрен һич онытмас.* Ә. Еники. *Сабир бабай исә шактый бирешкән, сакал-мыеклары тәмам агарган, гәүдәсе дә бөкрәя төшкән.* Г. Әпсәләмов. // Бөгәрләнү (кеше турында). [*Авыру егет*] *сәке өстендә бөкрәйгән көе тик ята.* М. Гафури.

3. *күч. сөйл.* Үтә авыр эшләрне башкарып яки артык күп эшләп газап чигү. *Гомер чалгы белән бөкрәйгән агайлар комбайннарга боерык кына бирәләр.* Соц. Тат.

4. Иелү, бөгелү. *Ул ишек төбендә бөкрәеп, колагын күеп тыңлап торган.* Э. Касыймов. *Илдус аяк астында ялтырап яткан кечкенә генә сәгатьне күрде һәм - - - аны бөкрәеп алды.* Ә. Бикчәнтәева.

БӨКТӘР *и. диал.* Төен, төенчек. [*Батырша*] *сандык төбеннән ниндидер бер бөктәр кәгазь алып, туры мәктәпкә чапты.* Қ. Нәҗми. *Берсе, зур бөктәрне чишеп, аш өстәленә кыйммәтле тун эчлеге китереп җәйде.* С. Җәләл.

БӨҚШӘЮ *ф. диал.* Бөршәю; бөрешү (2—4 мәгъ.). *Чана башында бөкшәеп утырган мескен малай.* Н. Фәттах. *Ул бөкшәйгән күгәрченнәрне кызганып* [*йөри*]. Ф. Хөсни.

БӨЛГЕНЛЕҚ *и.* Бөлү нәтиҗәсендә туган хәл; зур мохтаҗлык хәле. *Бөлгенлектә яшәү.* □ *Сугыш китергән бөлгенлектән чыгу ансат булмады.* Ә. Еники.

БӨЛДЕРГЕЧ *с.* Бөлдерә торган; ярлылыкка, мохтаҗлыкка китерә торган. *Бөлдергеч сугыш. Бөлдергеч аренда бәяләре.* □ *Бизәнеп ире каршысында киерелеп торырга гына белә. Ир бөлдергеч хатын.* Г. Қамал.

БӨЛДЕРМӘ *и. диал.* Кулга кию өчен җайланган элмәк (чыбыркы сабында һ. б. ш.).

БӨЛҮ *ф.* Мал-мөлкәтеннән язып ник ярлылану.— *Бөләр хәлем юк, улымны өйләндерәм дип, бар сумамнан язар хәлем юк.* Г. Қамал. *Чеховның атасы, бөлеп, сәүдәсен яба.* Г. Нигъмәти. // *махс. диал.* Тулысынча оттыру. *Бөлеп уеннан чыгу.*

БӨРЕ *и.* 1. Ботак, яфрак яки чәчәк яралып китә торган төерчә, бәбәк. *Бөре чыгару. Яфрак бөресе.* □ *Килер яз, - - - кечкенә генә бөреләр бүртер, калынаер, яшел яфракка әйләнер.* И. Гази. *Гөлләрнең күбесе әле яңа ачылып килә, бәгъзылары бөре хәлендә генә.* Ф. Әмирхан. // Өлгереп житмәгән, яралгы хәлендәге җиләк-җимеш. *Җиләкне бөре килеш һич кенә дә әрәм итмәм дип мәңгегә ант иттем.* Г. Галиев.

2. *с. мәгъ.* Ачылып (чәчәк, яфрак һ. б. ш. турында) яки елгереп (җиләк-җимеш турында) житмәгән, яралгы хәлендәге. *Бөре чәчәк. Бөре җиләк.*

БӨРЕЛЕ *с.* Бөресе яки бөреләре булган; бөре чыгарган. *Бөреле агач ботаклары гына бер-берсе белән чәбәләшеп шаяралар.* А. Алиш.

БӨРЕЛӘНҮ *ф.* Бөре чыгару, үстерү (агачлар, үсемлекләр турында). *Тугайларны су баскан, анда-санда яшәреп бөреләнә башлаган тал очлары гына күренгәли.* С. Сабиров. *Гөлләр чәчәккә бөреләнде.* И. Гази. // *күч.* Барлыкка килү (хис-дәрт, теләк-омтылыш һ. б. ш. турында). *Рәхим, бөреләнеп кенә килә торган яңа тойгыхискә, никадәр ирония белән карамасын, буйсынды, биреште.* А. Расих.

БӨРЕШ I *и.* Бөрелгән урын, җыерчык.

БӨРЕШ II *и.* Кечерәк, очлы лом. [*Балыкчы*] *кулындагы боз вата торган бөреше белән бүренең маңгаена бер-ике мәртәбә суккан.* Әкият.

БӨРЕШЛЕ *с.* Бөреп эшләнгән, бөрешләре (I) булган. *Ап-ак өй эче аслы-өсле кызыл башлы сөлгеләр белән бизәлгән, бер як стенага ак бөрешле ашъяулык элеп куелган.* Г. Әпсәләмов.

БӨРЕШТЕРҮ *ф.* 1. Бөрү (2 мәгъ.), түгәрәкләп кысу (иреннәрне). *Лида, үпкәләгәндәй, йөзен чытып, иреннәрен бөрештерде.* Ә. Айдар.

2. *сөйл.* Тиз-тиз һәм өстән-өстән генә типчеп яки ямьсез итеп тегеп, ямап кую. [*Әсхәпҗамал*], *читтегенең тишекләрен җеп белән генә бөрештереп, корым сөртте.* Қ. Нәҗми.

БӨРЕШҮ *ф.* 1. *Уртак юн. к.* бөрү 1.

2. Бөрелү, түгәрәкләнеп кысылу (ирен турында). *Қызның иреннәре бик кызык бөрешеп «о» хәрефенә охшап калды.* Г. Мөхәммәтшин.

3. Ник бөрелеп җыелу, җыерылып-йомарланып бетү (төрле әйберләр турында). *Яфракларның кыраудан бөрешүе.* □ [*Шаярышып утыручы кызлар*] *сикереп торып ыгы-зыгы килергә, бөрешкән кровать япмаларын, өсбашларын тәртипкә китерергә керештеләр.* Г. Гобәй. *Бите бөрешеп кипкән картның.* Э. Қасыймов.

4. Қуырылып-җыерылып бөкрәя һәм кечерәя төшү (тунудан, картлыктан һ. б.). *Хәдичә, аркасы туңып киткәндәй булып, бөрешеп куйды.* Г. Бәширов. [*Яңгыр башлангач*], *тавык-чебеш лапаска кереп бөрешә.* Г. Газиз.

5. Авыз эчен берәр нәрсә куырып-җыерып, ябыша торган итеп тоткан кебек тою (кайбер җимешләрне ашаганнан соң). *Шомырт ашагач авыз бөрешү.*

БӨРҚЕГЕЧ *и.* Сыекчаларны бөркү, чәчрәтеп сибү өчен кулланыла торган җайланма.

БӨРКЕТ *и.* 1. Лачыннар семьялыгыннан, эре ерткыч кош (тау яки дала җирләрдә яши). *Өй алдына бөркет килгән, Қуркытадыр казларны.* Ә. Фәйзи. *Урман өстендә, биектә-биектә, берничә бөркет, канатларын җәеп, зәңгәр һавада асылынып тора.* И. Гази.

2. *күч.* Қыю, батыр һәм горур кеше турында. *Қанын кызганмый сугышкан Ватанның бөркетләре.* Ф. Қәрим.

БӨРҚЕТЧЕ *и.* Бөркет белән ауга йөрүче, шул эшнең остасы.

БӨРҚӘВЕЧ *и.* Бөркәп куя торган япма; каплавыч. *Мендәрләрне дебет белән нәфис чәчәкләр чигелгән ал бөркәвеч каплап тора.* Г. Бәширов.

БӨРҚӘВЕЧЛЕ *с.* Бөркәвече, бөркәве булган, шулар белән бөркәп куела торган; бөркәүле. *Бөркәвечле машина.* □ *Әниләр безне үзләре белән арыш басуына уракка алып киткәннәр. Без шунда Мөҗәй белән чүмәлә төбендә, бөркәвечле кечкенә кабык арбада, имезлек кабып тын гына ята торган булганбыз.* Г. Галиев.

БӨРҚӘГЕЧ *и. к.* бөркәвеч.

БӨРҚӘНЧЕК *и.* 1. Элек хатын-кызлар, йөз яшерү өчен, кием өстеннән бөркәнеп йөргән махсус җинсез ябынча. *Ак яулыгы өстеннән бөрканчек элгән, артыш таягын шак-шок китереп, алпан-тилпән килүче Зөлхиҗә күренде.* И. Туктар. *Мәрҗәнә үз бүлмәсенә йөгереп керә дә чигеп эшләнгән бөркәнчегенә төренә.* Мең дә бер кичә.

2. *күч.* Тышкы, ясалма кыяфәт. *Илнең эчендә, теге яки бу бөркәнчек астында качып калган контрреволюцион буржуазия - - - үзенең зарарларын сала килде.* Ф. Хөсни.

БӨРҚӘНЧЕҚЛЕ *с.* Бөркәнчеге булган; шуны бөркәнгән.— *Ул гадәт сезнең өчен түгел, чапанлы, бөркәнчекле абыстайлар өчен генә.* М. Гали.

БӨРҚӘҢҮ *ф.* Башны, өсне бөтенләй каплап алырлык итеп берәр нәрсә ябыну. *Картаны таш өстенә җәеп салабыз да, плащ-палатка бөркәнеп, кесә фонарен кабызабыз.* И. Гази. *Авырыйм дигән булып, ишек катындагы сәкегә башымнан ук бөркәнеп яттым.* А. Шамов. // Йөзне генә ачык калдырып ябыну (шәлне, яулыкны). *Башына мамык шәл бөркәнгән Галимә апа һәм Әлфия өйдән чыктылар.* Г. Әпсәләмов.

БӨРҚӘҮ I *ф.* Ян-яктан ук томалап ябу, каплау. *Габдулланы баштанаяк киендереп чыгардылар да - - - башыннан ук олылар толыбы белән бөркәделәр.* Ә. Фәй-

зи. *Салам чаклы да яктылык күренмәслек итеп тәрәзәләрне бөркәделәр.* Ф. Хөсни.

БӨРКӘУ II *и.* Бөркәвеч, каплавыч, япма. *Көшел бөркәвенең бер читен ачып ашлык төяу.* □ *Аның күзләре өстендә бөркәү булып асылынып торган калын кашлары әледән-әле селкенгәләп куя, ул шат күренә иде.* Г. Бәширов.

БӨРКӘҮЛЕ *с.* **1.** Бөркәве булган, өстән һәм ян-яклардан бөркәп шыкланган, томаланган; өсте ябулы. *Бөркәүле ындыр.* □ *Алачыкта җиде-сигез колхозчы яныпөшеп авыл хуҗалыгы машиналарын төзәтеп һәм арбалар тимерләп яталар. Шунда ук бөркәүле бер урында агач кыра торган машина да куелган.* М. Гали. *Ишек алдына бөркәүле кара машиналар кереп тулды.* Г. Гобәй.

2. Бөркәү астындагы, бөркәп куелган (төрле әйберләр турында). *Бөркәүле көшел.*

БӨРКҮ I *ф.* Чәчрәтеп яки тузанландырып сибү (сыекчаларны). *Су бөркеп, идәнне себерү. Һуштан язучыны битенә салкын су бөркеп аңына китерү.* □ *Бик күп бакчаларда җимеш агачларына үзенә бер төрле дару бөркеп, аларның бөреләре ачылуны көчле кыраулар үтеп киткәнгә кадәр тоткарлап тору ысулын кулланалар.* Г. Галиев. // Куәт белән һәм мул итеп чыгарып тарату (газ, төтен, пар, нур һ. б. ш.). *Самоварның пар бөркеп кайнап чыгуы. Гранатаның ут бөркеп ярылуы. Умарта караганда кортларга төтен бөркү.* □ *Нурын бөркү аңа язгы кояш.* Ф. Кәрим. *Ярсып, танавыннан кайнар сулыш бөркеп, җиңелчә җигелгән алмачуар айгыр килеп туктады.* М. Хәсәнов.

2. Нык аңкыту (исне һ. б. ш.). *Хуш ис бөркеп чәчәк атты гөлләр.* Ф. Кәрим. *Көндез кояш кыздырган җир, хәзер ягылган мич кебек, рәхәт җылылык бөркү.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Нык сизелеп, беленеп тору (хисләр һ. б. ш. турында). *Йөзеннән шатлык бөркү.* А. Расих.

БӨРКҮ II *с.* Эссе, артык дымлы, тынчу, сулау өчен авыр (һава турында). *Кешеләр, җилсез бөркү һавада кызу эшләгәнгә күрә, шыбыр тиргә баткан иделәр.* Ш. Камал. // Шундый һавалы (бүлмә һ. б. турында). *Бөркү бүлмә.* □ *Көн бүген дә бөркү булачак.* Г. Әпсәләмов.

БӨРКҮЛЕК *и.* Һаваның бөркү булу хәле. *Арслан төнлә бөркүлектән уянды.* Г. Ахунов. *Өебездә бөркүлек бетте, кисәк җил исеп, бөтен әйберләребезне туздырып бетерде.* К. Насыйри.

БӨРКҮЛӘНҮ *ф.* Бөркүгә әйләнү. *Кояш шактый күтәрелде, һава да бөркүләнә төште.* М. Шабай.

БӨРЛЕГӘН *и.* **1.** Урманда, урман буйларында һ. б. ш. үсә торган, кура җиләкләре төреннән булган кып-кызыл җимешле үлән үсемлек; *русчасы:* костяника.

2. Шул үсемлекнең әчкелтем татлы, ашый торган җимеше. *Урман кырыендагы куаклар арасыннан кып-кызыл бөрлегәннәр, зур эшләпәсе белән битен каплап үлән астына поскан гөмбәләр карап кала.* Г. Бәширов.

БӨРЛЕГӘНЛЕК *и.* Бөрлегән (күп) үсә торган урын. *Кәримәгә матур-матур чәчәкләр өзеп тәкъдим итте ул [егет], таллыклар, бөрлегәнлекләр аша үтеп, аны юалыкка алып чыкты.* М. Әмир.

БӨРМӘ *и.* **1.** Бөрелгән, бөреп тегелгән урын (киемдә, янчыкта һ. б.). *Җиң бөрмәсе. Тун бөрмәсе.*

2. *с. мәгъ.* Бөреп тегелгән, бөрмәле. *Бөрмә билле тун.* □ *Аның өстендә бөрмә билле җилән.* З. Бәшири.

БӨРМӘЛЕ *с.* **1.** Бөрмәсе булган, бөрмәләп эшләнгән (кием, капчык һ. б. ш. турында). *Бөрмәле чикмән.* □ *Аның өстендә бөрмәле сатин әрмәк, биленда киң каеш.* Г. Гобәй.

2. Бөрелгән (ирен, авыз турында). *Булатовның да, кызларныкыдай бөрмәле иреннәрен җәя төшеп, янымда басып торуын хәтерлим.* Р. Төхфәтуллин.

БӨРМӘЛӘНДЕРҮ *ф. сөйл.* Түгәрәкләп җыеру, бөрү (ирен, авыз һ. б. турында). *Лида кан сирпеп торган тулы иреннәрен бөрмәләндереп куйды.* Ә. Айдар.

БӨРМӘЛӘҮ *ф.* Бөрмәле итеп тегү, эшләү (киемне, капчыкны һ. б.). *Ул озын, таза; өстендә кара бәрән тиресеннән билен бөрмәләп теккән тун.* Каз. утл.

БӨРТЕК *и.* **1.** Вак-вак кисәкчек-өлешчекләрдән торган чәчелүчән-коелучан нәрсәнең шул кисәкчекләреннән берсе, бер данәсе. *Ярма бөртеге. Ком бөртеге. Тәмәке бөртеге. Тузан бөртеге.* □ *Суы да суы, көмеш бөртеге күк.* М. Гали. *Кара җир өстен ак бөртекләр белән чуарлап, эре, йомшак кар ява башлады.* А. Шамов. // Үтә нечкә һәм озын кисәкчекләрдән торган нәрсәнең шул кисәкчекләреннән берсе. *Йон бөртеге. Җеп бөртеге. Чәч бөртекләре.* □ *Ул, печән бөртеге алып, йөзен сыта-сыта тешен казырга кереште.* М. Шәрифуллин. // Вак тамчыларның берсе. *Яңгыр бөртеге. Яшь бөртеге.* □ *Чык бөртекләре җемелди.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Игелә торган һ. б. үсемлек орлыгының бер данәсе. *Теземнәр күз алдында диярлек җиллəп кибә, башаклардагы тук бөртекләр аның саен җитлегеп авырая бара.* М. Шабай. // *җыл.* Бөртекле ашлык. *Дөньяда нинди генә файдалы үсемлекләр юк! Аларның кайберләре бөртек уңышы бирә, кайберләре кешеләрне һәртөрле җимешләр белән сыйлый.* Г. Галиев. *Тегермәнгә бүген ике тонна бөртек озаттык.* Ә. Еники.

3. Үтә вак яки нечкә озын нәрсәләрне санау берәмлеге; данә. *Өч бөртек җеп.* // *сөйл.* Бик кечерәйтеп яки әзәйтеп сурәтләү образы. *Өч кенә бөртек булсак та, җыелып киңәшик, бер җаен табыйк.* Г. Бәширов. *Көн суык, җилләр каты, эчләрдә юк бөртек җылы.* Антология. *Бөртек тә туңмадым.* Г. Мөхәммәтшин.

4. *с. мәгъ. к.* бөртекле 1. *Бу бөртек чәйгә эченнән куанды да ул.* Г. Минский. *Тавыкка төнгә иң каты азыкны — бөртек азыкны бирәбез.* А. Расих.

БӨРТЕКЛЕ *с.* **1.** Бөртеге (1 мәгъ.) яки бөртекләре булган, бөртекләрдән торган. *Шунда ук яшел төргәктә бөртекле чәй дә бар.* Қ. Нәҗми.

2. *бот.* Бөртек (2 мәгъ.) бирә торган (ашлык һ. б. үсемлекләр турында).— *Без бит әле хәзер бөртекле ашлыкның гектарыннан 12—13 центнер уңыш алсак, шуның белән бик канәгать булабыз, мактанабыз.* М. Әмир.

3. *күч. сөйл.* Бик әз, санаулы гына (санала торган һ. б. ш. нәрсәләр турында).

4. *и. мәгъ.* **бөртеклеләр** *бот.* Орлыклары азыкка китә торган башаклы, кыяклы үсемлекләр.

БӨРТЕКЛӘНҮ *ф. 1. Төш. юн. к.* бөртекләү (1, 2 мәгъ.).

2. Өлгереп җитеп бөртек формасына керү (орлыклар турында).

БӨРТЕКЛӘҮ *ф.* **1.** Берәм-берәм бөртекләргә аеру.

2. *рәв. мәгъ.* **бөртеклəп.** Һәр бөртекне аерым-аерым, берәм-берәм кулдан үткәреп. [*Орлык бодаен*] *колхозчылар кышның кыш буена күз карасыдай күреп, саклап чыгалар. Зур уңыш бирсен дип, бөртеклəп чистарталар.* Г. Гобәй. // Берәмләп, әз-әзләп, ләкин бик күп көч куеп; бик кадерләп (җыю һ. б. ш. турында). [*Латыйфа:*] *Инәмне дә калдырмыйм. Гомерем буена бөртеклəп җыйган әйберләрем белән немеч калдыкларын кинәндерер хәлем юк.* Т. Гыйззәт. // *күч. сөйл.* Бик әзләп-әзләп, кызганып кына (берәр нәрсәне бирү һ. б. ш. турында). // Бик җентекләп, ваклыкларга кадәр игътибар итеп (сөйләү, язу һ. б.). *Бабай, зур шатлыгын уртаклашкандай, тагын да бөртеклəбрәк сөйли башлады.* Г. Мөхәммәтшин.

БӨРТЕКЧӘ *и.* Кечкенә, вак бөртек (1, 2 мәгъ.); бөртекчек.

БӨРЧЕК *и.* **1.** Әйбер өстендәге төерчек, тимгел, әз һ. б. ш., (гадәттә түгәрәк формалы) калкып яки батып тора торган урын. *Яфрактагы кабарынкы кызгылт бөрчекләр.* □ [*Куркудан*] *бөтен тәнемә бөрчекләр чык-*

ты. Ф. Әмирхан. // Берәр нәрсәнең төсендәге-буявындагы төп җирлеккә төшкән вак түгәрәкчек формалы бизәкләрнең берсе. *Эре бөрчекле яулык.* □ *Ул ак өстенә кара бөрчек төшкән күлмәгенең бәйләвечле изүен чиште.* Г. Галиев.

2. Вак-вак тир яки яшь тамчыларының һ. б. ш. берсе. *Хәмитнең битенә, маңгаена тир бөрчекләре тибеп чыкты.* К. Нәҗми.

БӨРЧЕКЛЕ *с.* Бөрчеге (1 мәгъ.) яки бөрчекләре булган; бөрчекләнгән. *Бөрчекле тукыма. Бөрчекле күн.* □ *Күбәләкнең бөрчекле-бөрчекле хәтфә канатлары чит-читләреннән кителгән, чыланган.* А. Гыйләҗев.

БӨРЧЕКЛӘНҮ *ф.* Өстендә бөрчекләр (1 мәгъ.) барлыкка килү. *Су астыннан ул дер-дер калтыранып, каз тиресе шикелле бөрчекләнә башлаган, күгәргән тәнле булып чыга.* Г. Кутуй. [*Ташның*] *өске яғы, умарта башында торганда яңгыр тамчылары тишкәнгә булса кирәк, бераз бөрчекләнгән.* Г. Галиев.

БӨРШӘЙТҮ *ф. диал. к.* бөрештерү 1. *Авызны бөршәйтү. Иренне бөршәйтү.*

БӨРШӘЮ *ф. к.* бөрешү (2—4 мәгъ.). *Суыктан бөршәю. Картайгач яңак бөршәю.* □ *Аяза башлагач, суга төшкән күркә чебиләре шикелле, без* [*яңгырга чыланучылар*], *бөршәеп, юл белән кайтырга чыктык.* М. Гали.

БӨРҮ *ф.* 1. Тигез сырлар, җыерчыклар ясап җыю-тарайту; махсус җыерып эшләү, ясау. *Алъяпкычның иңнәрен бөрү. Капчык авызын бөрү. Бөргән билле тун.* □ *Степан — билен бөргән кара бишмәт, зур кара картуз киеп йөри торган таза гына карт.* Ә. Фәйзи.

2. Түгәрәкләндереп җыерып кысу (иренне) яки йому (авызны). *Ирен бөрү.* □ *Ул авызын бөреберәк, кара күзләрендә очкыннар уйнатып, гел елмаеп сөйләшә.* Г. Ахунов.

3. *күч.* Авыз эчен куырып-җыерып ачыттыру (өлгереп җитмәгән ачы җимеш, борыч һ. б. ш. турында).

4. *күч. сөйл.* Бик ачуланып тиргәп яки тәнкыйтьләп ташлау; куркырга мәҗбүр итеп тору. // Кыйнау. — *Онытма, мин — Әлки сабан туенда көрәшкән Хафиз. (Кулын сызгана башлый). Хәзер моннан чыгып китсәң китәсең; булмаса, бөрәм дә ташлыйм.* Н. Исәнбәт.

БӨРҮЛЕ *с.* Бөрелгән, бөрмәле. *Биле бөрүле, җиң очлары чигүле коңгырт бәрән тун Зәйтүнәнең гәүдәсен тагын да озынрак күрсәтә.* К. Нәҗми.

БӨТЕН *с.* 1. Киметелмәгән, башланмаган. *Бөтен алма. Бөтен кибән.* □ *Сафия абыстай, --- бер бөтен ипине башлап, зур-зур итеп кисеп куйды.* А. Шамов. // Ватылмаган, зарарланмаган; төзек; имин. [*Өй*] *ике генә ел торган. Бүрәнәләре яңалар, корылар. Ишек, тәрәзә, идән, түшәм — бары да бик бөтен.* Г. Ибраһимов.

2. Гадәттә күләмне-үлчәмне, микъдарны белдергән һ. б. ш. сүзләр алдыннан килеп, «тулы», «тулысынча», «тулаем», «барлык» дигәнне аңлата. *Бөтен юл буе сөйләшеп бару. Бөтен халык белән бер адымнан бару. Бөтен илгә атаклы. Бөтен дөнья алдында тора торган проблемалар.* □ *Без аның белән бөтен йортка икәү калдык.* Г. Гобәй.

3. Бар ягы да җитеш, тәэмин ителгән (кием-салым, көнкүреш һ. б. ш. турында). *Өс-баш бөтен булу.* □ *Ул чагында тормышлар тәмам бөтен була: кая барсаң, анда дәүләт, кая барсаң, анда нигъмәт.* С. Җәлил.

4. *мат.* Вакланмасыз (саннар турында). *Бөтен һәм вакланмалы саннар.*

5. *и. мәгъ. кит.* Гадәттә «бер» сүзеннән соң: иҗтимагый, политик һ. б. ш. берәмлек; оешма, система яки бүтән шундый нәрсә. *Партия төзү өчен көрәштә «Искра» бер бөтен булып, бердәм линия белән барды.* КПСС тарихы. *Советлар Союзында --- эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар, халык интеллигенциясе бер бөтен тәшкил итәләр.* Соц. Тат.

6. *и. мәгъ.* Патша заманында: бер сумлык металл акча. *Тәңкә итеп таккан бөтеннәр.*

7. *билг. а.* (бөтенебез, бөтенегез, бөтенесе). Барлык, һәммә. *Бөтен халык бәйрәме. Бөтен гомереңне сәнгатькә бирү.* □ *Бөтенебез кырда кар тоттык.* Ә. Ерикәй. *Бөтенесен дә эшләрбез.* И. Гази.

◇ **Бөтене белән** — бөтен, башланмаган. *Өстәлдә бөтене белән күмәч.* Г. Гобәй.

БӨТЕНЛЕК *и.* 1. Бөтен (1, 3—4 мәгъ.) булу сыйфаты һәм хәле.

2. Һәр ягы, һәр өлеше ярашып торганлык, камиллек, тулы гармониялелек. *Каш-күз, маңгай тирәсендәге бөтенлеккә зыян китерә күрмәсен дип, саклык белән генә эшләнгән төсле кечкенәрәк авыз-борын аны тагын да матуррак итеп күрсәтә.* М. Әмир. [*Ваклыкларны тасвирлау*] *әсәрнең бөтенлеге өчен артык кирәк булмаган.* Г. Нигъмәти.

БӨТЕНЛЕКЛЕ *с. кит.* Өлешләренең, тармакларының эзлекле ярашуына, эчке бердәмлеккә нигезләнгән; бөтен һәм гармонияле булып аңлашыла торган. *Бөтенлекле фәнни караш. Бөтенлекле система.* □ *Сыйныфларның политик көрәшенең иң бөтенлекле, тулы һәм формалашкан гәүдәләнеше — партияләр көрәше.* В. И. Ленин.

БӨТЕНЛӘЙ *рәв.* 1. Тәмам, тулысынча. *Бара-тора җил бөтенләй тынды.* Г. Гобәй. *Сер бөтенләй-бөтенләй ачылды инде.* Ф. Әмирхан.

2. Кабатланмас, кире кайтмас-китмәс рәвештә. *Мин ауга йөрүне бөтенләй ташладым.* А. Шамов. [*Хәмит*] *агач заводына бөтенләй күчеп китте.* Г. Ибраһимов.

3. **бөтенләе.** Барлыгы, бар булганы. *Ах, харап булды. Бөтенләе ике балам иде.* Ф. Әмирхан.

БӨТЕНЛӘЙГӘ *рәв. к.* бөтенләй (1, 2 мәгъ.). *Әле безнең тәннәрдәге яра Бөтенләйгә төзәлеп бетмәгән.* Ә. Ерикәй. *Бөтенләйгә ташлап китмәдем мин авылымны.* З. Мансур.

БӨТЕНЛӘНҮ *ф. сир. к.* бөтенәю. *Без дә күрдек бу көннәрне, Тормышлар бөтенләнде.* М. Фәйзи.

БӨТЕНЛӘТӘ *рәв.* Бөтен, тулы көенчә; башланмаган хәлдә. *Җыйнап алыйк игеннең Бөтенләтә барысын.* М. Җәлил.

БӨТЕНӘЮ *ф.* 1. Бөтенгә, тәмамланып, эшләнеп беткән бер хәлгә килү; тулылану-төгәлләнү. *Җыелудагы сәгать* [*конвейер белән*] *бер эшче турысыннан икенчесе турысына килеп туктый. Секундлар саны тулуга, тагын сигнал була. Һаман бөтенәя барган сәгать үзенең сәфәрендә дәвам итә.* М. Максуд.

2. *сир.* Җитү хәлгә килү, яхшыру, бөтенгә (3 мәгъ.) әйләнү; бөтәю (кием-салым, көнкүреш һ. б. ш. турында). *Өс бөтенәю. Тормышың бөтенәю.*

БӨТЕРГЕЧ *и. к.* бөтерчек 1. *Мидә кырыкмаса-кырык төрле уй утлы бөтергечтәй бөтерелде.* Б. Камалов.

БӨТЕРЕЛЕШ *и.* Судагы, һавадагы һ. б. ш. бөтерелү хәрәкәте. // Суда: бөтерелеп торган урын. *Утраулар арасында кысылган су бик каты көч белән ага. Анда су бөтерелеше барлыкка килә, һәм аннан әле бер корабның да исән чыкканы юк.* М. Гали.

БӨТЕРЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* бөтерү (1—3 мәгъ.).

2. Өермә сыман хәрәкәт итү (очу, исү һ. б.). *Тузан бөтерелү.* □ *Сары яфраклар бөтерелеп җиргә коелды.* Г. Мөхәммәтшин. *Кар бураны --- Бөтерелә койма буенда.* М. Җәлил. *Бөтерелеп кала яр буенда Пароход төтене.* Ф. Кәрим.

3. Әйләнү; әйләнә-әйләнә, бик җитез хәрәкәтләр ясау. *Бөтерелә-бөтерелә бию.* □ *Өстәл өстендәге кечкенә лампа тирәсендә зыр-зыр килеп төн күбәләкләре бөтерелә.* Г. Бәширов.

4. Божра сыман булып, түгәрәкләнеп бөгелү-бөгәрләнү. *Струк тишегеннән чуыжт-чуыжт итеп йомычкалар бөтерелеп чыга.* М. Шәрифуллин. // Бөгәрләнү (2 мәгъ.), йомарлану. *Малай, песи баласы шикелле бөтерелеп,*

әнисенең куенына кереп йоклады. И. Гази. *Йомгак шикелле бөтерелеп зур-зур ике елан ята.* Мең дә бер кичә.

5. *күч.* Куштанланып яки җитезлек, хәрәкәтчәнлек күрсәтеп, тирәдә йөрү. *Әни минем янымда бөтерелеп йөрде. Ничек тә миңа яраргa, күңелемне күтәрергә тырышты.* Г. Мөхәммәтшин. *Актүш [билгесез] кеше янында бөтерелеп йөри, бер аның уң ягына, бер сул ягына чыга иде.* Г. Гобәй.

БӨТЕРКӘ *и.* 1. Түгәрәкләнеп бөгелгән-бөгәрләнгән, бөтерелгән (4 мәгъ.), бөжра сыман булып тора торган нәрсә. *Йон бөтеркәсе. Чәч бөтеркәләре. Хәреф бөтеркәсе.* □ *[Атның] маңгаендагы бөтеркәсе дә өстә, колаклары арасында ук.* М. Хәсәнов. *Аның колак бөтеркәләренә бетон чәчрәп, борынгы зур алкалар кебек ябышып калган.* А. Гыйләҗев.

2. *с. мәгъ.* Бөтеркәле яки бөтеркә сыман формалы; бөдрә. *Бөтеркә мыек.* □ *Бәлки дулкын кебек бөтеркәдер Синең йомшак кына чәчләрең.* Ә. Ерикәй.

БӨТЕРКӘЛЕ *с.* Бөтеркәләре булган; бөдрә. *Бөтеркәле бизәк.* □ *[Тикшерүче] аның һәр җавабын гаять бөтеркәле готик хәрефләр белән, бер дә ашыкмыйча гына язып алды.* Ш. Маннур.

БӨТЕРКӘЛӘНҮ *ф.* Бөтеркәлегә әйләнү, бөтеркә форма алу; бөдрәләнү. *Бөтеркәләнеп тора торган мыек.* □ *Бөтеркәләнеп беткән карама төбе шикелле [бу сер саклаучы картлар]. Чөй сугардай җайлы җәген һичбер таба алмассың!* Ш. Маннур.

БӨТЕРКӘЧ *с. к.* бөтеркә 2. *Бөтеркәч мыеклы ир. Бөтеркәч йонлы бүрек.* □ *Бөтеркәч башлы, каш астыннан карап йөри торган үсмер малай ул.* Г. Ахунов.

БӨТЕРКӘЧЛӘНҮ *ф. к.* бөтеркәләнү. Бәрән йоныны бөтеркәчләнеп торуы.

БӨТЕРЧЕК *и.* 1. Кызу әйләнгәнгә, бөтерелгәнгә (3 мәгъ.) аумый торган күчәрле, түгәрәк яки шар формалы уенчык. *Балаларның чут төймәсеннән бөтерчек ясап уйнавы. Бөтерчекне өстәл өстендә әйләндерү.*

2. *күч.* Бик хәрәкәтчән, җитез балалар, кечерәк буйлы кешеләр яки шундый хайван турында. *Ул үзенең кечкенә улын тез башында тирбәтеп утыра иде.— Бу бөтерчекнең күзләре йомыла башлады, яткызасыңмы әллә?* И. Гази. // *с. мәгъ.* Бик хәрәкәтчән, җитез, тере яки куштан. *Онытып та булмады ул бөтерчек кызны.* Ф. Хөсни.

БӨТЕРЧЕКЛӘНҮ *ф. к.* бөтеркәләнү. [*Укытучы*] *Хәлимне тактага чакырып чыгарды, аның җилкә чокырында бөтерчекләнеп торган чәченә күзлеге өстеннән карап, сөйләнеп куйды.* Г. Гобәй.

БӨТЕРҮ *ф.* 1. Бармаклар арасына алып әрле-бирле тәгәрәтү. *Ал кабаны, эрлә җепне, Орчыгыңны нык бөтер.* З. Байчурина. [*Дәмин*] *папирос кабызды. Шырпысын, янып беткәнче көтеп, кулында бөтерде.* М. Хуҗин.

2. Бер уңайга гына тәгәрәтү хәрәкәте ясап, кату (мунчала һ. б. ш. нәрсәләр турында). *Мунчаланы бөтереп капчык бавы ясау. Җепне ике катлап бөтерү.* // Көпшәчек сыман бөтереп яҫау, төрү (тәмәке кәгазен һ. б. ш.). [*Бари*] *бөтергән кәгазенә учыннан тәмәке тутыра.* М. Фәйзи. // Бөтеркәләр (1 мәгъ.) ясау, бөдрәләндерү. *Чәчне бөтереп кую.*

3. Бөгәрләп йомарлау. *Мин инде барысын да әйттем, иптәш секретарь,— диде Газинур, кулындагы кепкасын бөтереп.* Г. Әпсәләмов. [*Хәлим*] *капчыкны бөтереп кесәсенә тыкты.* И. Гази.

4. *-ып форм.* Эзлекле хәрәкәтләрне белдергән тезмәләрдә җитез һәм көчле хәрәкәт белән берәүне тотуны, күтәрүне, егуны һ. б. ш. белдерә. *Билдән тотуына, ул [көрәшче] малай мине бөтереп алып бер якка ыргытты.* М. Гали. *Солдатның иптәшләре чабышып килеп тә җиттеләр. Миңнулланы бөтереп тә салдылар.* И. Гази.

БӨТИ *и. иск.* Хорафатка ышанучыларның төрле бәхетсезлекләрдән, авырулардан һ. б. «саклану» өчен тагып йөртә торган (чүпрәккә өчпочмаклап яки бүтәнчә бөкләп тегелгән) догалыклары. [*Апам*] *пәри-җеннәрдән, бөтен бәла-казалардан саклый торган бөтиен муеныма такты.* Г. Гобәй. *Хатын бу язуны өчпочмаклы бөти итеп ясаган да чәчүргечена таккан.* Г. Бәширов.

БӨТИЛЕК *и. иск.* Бөтине төреп яки салып йөри торган әйбер.— [*Фатыйма*] *салып куйган җирендә бөтилеген онытып калдырган. Аны Фәхри абзыйның хатыны алып актарып караган. Эчендә бер дә юк нәрсә юк ди: төргәк-төргәк чәчләр, елан мөгезләре, --- һәмәсе дә бар ди.* Г. Камал.

БӨТНЕК *и.* Хуш исле үлән үсемлек (медицина, парфюмерия, кондитер товарлары хәзерләгәндә һәм аш тәмләткеч сыйфатында кулланыла); *русчасы:* мята. *Канау тирәсендә, каз, үрдәк керсә адашырдай булып, кыяк үлән, чаж үләне һәм искиткеч хуш исле бөтнек үләне үсә. Кәлимәт кешеләре бөтнекне чишмәгә суга килгән чакларда яки бозау арканларга чыкканда көлтәсе-көлтәсе белән җыеп алып китәләр, аңардан киптереп, төеп, ашка салу өчен порошок әзерлилəр, авырганда кайнатып эчәләр.* Г. Ахунов.

БӨТӘРЛӘНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* бөтәрләү 1.

2. *сөйл.* Бөгелеп йомарлану, бөгәрләнү. [*Айгырның*] *койрык, көлтәдәй дулкынланып, үзеннән-үзе бөтәрләнеп уйнап тора.* Г. Ибраһимов. *Елан аңа ташланырга әзерләнеп, түгәрәкләнеп бөтәрләнде дә башын күтәрде.* Н. Дәүли.

3. *сөйл.* Бөтерелү (1 мәгъ.), әйләнү. *Зариф башыннан кепкасын алып һавага чөеп җибәрде. --- Кепка һавада бөтәрләнеп әйләнде дә тау кырыена ук барып төште.* Г. Иделле. *Күләгәләр төсле, төтен төсле, Башыңда да синең уйларың Бөтәрләнә һаман бер төсле.* Н. Исәнбәт.

4. *күч. сөйл.* Үтә ялагайлыкны, куштанлыкны һәм яраргa тырышуны күрсәткән хәрәкәтләр ясау. *Бөтәрләнә [немец] Безгә килгәч, нәкъ песи күк, Әй, бөтәрләнә.* М. Җәлил.

БӨТӘРЛӘҮ *ф. сөйл.* Җыерылдырып бөкләү, бөгәрләү, йомарлау. [*Офицер*] *китапны икегә бөтәрләп кесәсенә салды.* М. Гафури. *Ул бер сүз дә әйтмәде.* [*Дәфтәр*] *киптергечен кулында бөтәрли-бөтәрли тик торды.* Г. Мөхәммәтшин.

БӨТӘЮ *ф. к.* бөтенәю 2. *Өс-баш бөтәю.* □ [*Тимери*] *байтак еллар ашыйсын ашамады, йоклыйсын йокламады. Йорт-җир диде, мал-туар дип көенде. --- Менә көйләнер, менә бөтәермен диде.* Г. Бәширов.

БӨЯ *и. диал. к.* буа. *Бөя бер җирендә ярылса, китә бирә дә китә бирә икән!* Г. Ибраһимов.

БӨЯЛҮ *ф. диал. к.* буылу 3. *Аның әйтәсе сүзләре тамак төбендә бөялеп калды.* Ш. Маннур.

БӨЯТ *и.* 1. Камытның ат муенына һәм түшенә тиеп торган аскы өлеше (гадәттә эченә салам һ. б. нәрсә тутырып киез, күн яисә киндер белән тышланган була). [*Мөршидә — Биктимергә:*] *Камытның бөяте тузган, бөят утыртырсың.* Т. Гыйззәт. *Камыт бавын бушатыбрак бәйлә. Бөяте кыса торгандыр.* С. Рафиков.

2. Суга батудан саклау өчен эшләнгән, бөжра сыман махсус җайланма (бөке агачыннан һ. б. ш. җиңел нәрсәдән ясала).

БӨЯТЛЕ *с.* Бөяте булган, бөят беркетелгән. [*Гата*] *камытны бөятле ягы белән келәт алдына кояшка каршы элде.* Г. Галиев.

БӨЯТЛӘҮ *ф.* 1. Бөят кую (камытка), бөятле итү. *Камыт бөятлəү.*

2. Бөят (1 мәгъ.) формасына китереп төрү. [*Мусаның*] *җилкәсенә бөятләп кигән шинеле белән кыр сумкасы, автоматы да биш пот булып тоела.* Ш. Маннур.

БӨЯҮ *ф. диал. к.* буу 6. *Бөя бөяү.*

БӨЖӘК *и.* 1. Умырткасыз, буынтыгаяклы кечкенә җан иясе (чебен, кырмыска, күбәләк, бал корты, кандала һ. б.). *Ачык урынга утыртылган кыярлар җил яки*

бөжәкләр ярдәмендә серкәләнә. Г. Галиев. *Үлән, яфраклар арасында бөжәкләр кыштырдый.* Э. Қасыймов.

2. *күч. гади. с.* Бала яки бик кечкенә дәрәҗәле кеше турында.— *Лыгырдама, бөжәк! — дип акырды Салих.* Чаян.

БҮГЕН *рәв.* **1.** Шушы, сөйләнә торган көндә. *Һавалар яхшы торганда, бүген чапкан печәнне икенче көнне әйләндереп, кичен элек күбәләргә, аннары инде чүмәләләргә салып була.* Г. Галиев. *Бүген төн буе күземә йокы кермәде.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Шушы, сөйләнә торган вакытта; хәзерге заманда. *Тыныслыкны яклап бүген Миллионнар тавыш бирә.* С. Хәким. *Тарих бүген эшче кулы белән Гигант салып куйды далада.* Ә. Ерикәй.

◇ **Бүген булмаса иртәгә** — кайчан да булса бер. [*Галиулла*] *хәзер авырып киткән икән, авыру бит ул казык башыннан йөрми, кеше башыннан йөри: үзеңнең дә бүген булмаса иртәгә егылып ятуың бар.* И. Гази. **Бүген таңда** — бик тиз, шушы көннәрдә үк. *Менә әле юлда Габдулла авылының бер кешесе белән кайттык. - - - Дүрт балам бар ди. Аның өстенә бүген таңда үләргә торган карт анам бар ди.* М. Гафури.

БҮГЕНГЕ *с.* **1.** Шушы, сөйләнә торган көндәге. *Мин кичә кич буе һәм менә бүгенге кичнең шушы вакытына кадәр бер җавап булмасмы дип көттем.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Шушы, сөйләнә торган вакыттагы; хәзерге заманда. *Бүгенге җәмгыять. Бүгенге культура.* ☐ *Ә безнең бүгенге авылны күргәнегез бармы?* Һ. Такташ.

◇ **Бүгенге көн** — агымдагы актуаль мәсьәләләрне эченә алган хәзерге чор. *Моны безнең татар совет драматургиясендә бүгенге көн темасына күңелле комедия тудыруга беренче омтылыш дияргә мөмкин.* М. Җәлил. **Бүгенге көн белән (генә) яшәү** — көндәлек ихтыяҗларны үтәүгә барлык игътибарны биреп, киләчәкне кайгыртмау. *Бөтен бәла дә шунда, Шакиржан абзый, без әле һаман да бүгенге көн белән яшибез. Киләчәк өчен кайгыртмыйбыз.* Т. Гыйззәт.

БҮГЕНГӘЧӘ *рәв.* **1.** Бүгенгә кадәр.

2. Хәзергәчә, шушы вакытка кадәр. *Ул эшләгән завод бүгенгәчә Иң алдынгы завод саналды.* Һ. Тәкташ.

БҮГЕН-ИРТӘГӘ *рәв.* Бик тиз, шушы көннәрдә үк. *Минем бүген-иртәгә колынларга торган бурлы биям Өзән елга буенда йөри.* Г. Ибраһимов. *Аның докторлык диссертациясе өлгереп килә, бүген-иртәгә дигәндәй, аңа профессор исеме дә бирәләр дип көтәләр.* Г. Әпсәләмов.

БҮГЕНЛЕ-ИРТӘГӘЛЕ *рәв. к.* бүген-иртәгә.— *Печән өлгергән. Кайбер колхозлар бүгенле-иртәгәле чыгалар.* Т. Гыйззәт.— *Сыерым бүгенле-иртәгәле бозауларга тора.* Р. Төхфәтуллин.

БҮГЕНЛЕК *с.* Бүгенгә дип билгеләнгән яки бүгенгә җитәрлек булган. *Гүя көлеп мыскыл иткән кеби, - - - бүгенлек ризыгыгыз булса, иртәге өчен кайгырмагыз - - - дип, моңлы-моңлы сызгырмакта иде* [*җил*]. Ш. Мөхәммәдев.

БҮДӘНӘ *и.* **1.** Бытбылдык. *Ике аучы ауга чыкканнар. Икесенә өч үрдәк, бер бүдәнә атканнар.* Г. Бәширов. *Уҗым кырларыннан бүдәнә тавышлары колакка ишетелә.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч. гади. с.* Кечкенә, ләкин тулы, юантыграк гәүдәле кешене хурлау сүзе. [*Хулиган малай*] *Илдарның якасыннан эләктереп тә алды: — Измәңне изәм бит, бүдәнә!* Г. Гобәй.

БҮЗ I *и. иск. к.* бәз. [*Күлмәк*] *юка ак бүздән тегелгән.* Г. Гобәй. *Кулъяулыгың икәү икән, Ефәк белән бүз икән.* Җыр.

БҮЗ II *с. иск.* **1.** Соргылт; аксыл соры төстәге. *Гаҗәпләнәм бүз тургайга, басып сайрый курайга.* Г. Тукай.— *Бүз юргасын юргалатып килсен дә, кочагына алып, теләсә, дөньяның читенә алып китсен.* М. Фәйзи.

2. *иск.* Үсмер, егет. *Бүз бала.* ☐ *Бүз егетләр, сылу кызлар, ат иярләп, юк йомышны бар итеп, җәйләүдән җәйләүгә чаптылар.* Г. Ибраһимов. [*Бакый:*] *Куш йомышыңны, бүз мирза.* М. Фәйзи.

БҮЗӘРҮ *ф. иск.* Агарып төссезләнү. *Бер кызардым, бер бүзәрдем... Ни таныйм?.. таналмадым!* Дәрдмәнд.

БҮК *и.* Тыгыз һәм дымга бик чыдам үзагачлы, шома кайрылы, яфраклы эре агач (паркет, фанер, музыка кораллары, мебель һ. б. ш. ясау өчен файдаланыла).

БҮКИ *и.* Сабыйларны куркыту өчен искә алына торган мифик-фантастик зат. *Баланың, бүки килә дисәң* [*коты чыга*]. Г. Тукай. [*Әнисе — җылаучы малаена:*] *— Бүкигә генә чыгарып бирермен.* Г. Гобәй.

БҮКСӘ *и.* **1.** Қошларда, кайбер хайваннарда һәм бөжәкләрдә: үңәченең киңәеп, юанаеп торган өлеше. *Бал кортының бүксәсе.* ☐ *Қошларның бизле ашказаны алдында шактый зур куык — бүксә була.* А. Расих. *Бүксәсе дә бар аның* [*әрләннең*]. *Ике. Яңакларында. Азыкны шунда тутырып ташый.* Г. Гобәй.

2. *сөйл.* Гәүдәнең аш кайнату органнары урнашкан өлеше, тирәсе. *Малай бүксәсен киереп басып тора.* И. Гази.— *Ну бер сыйлый идем үзегезне! Бүксәләрегез кап булганчы ашата идем.* А. Гыйләҗев. // Цилиндр формалы савытларның бүлтәеп торган яны — йөзе турында. *Менә бусы чи йомырка, диде әби. Һәм аның башын самавыр бүксәсенә бәреп яньчеп ватты.* Г. Галиев.

◇ **Бүксә киерү** *туп.*— масаю, кәпрәю; күкрәк киерү. [*Хисами кызы*] *әллә кем булган булып, бүксәсен киереп утырган була.* Г. Қамал.

БҮКСӘЛЕ *с.* **1.** Зур бүксәле (кош-корт турында).

2. *гади с.* Зур, кабарып торган корсаклы (кеше турында).

БҮКӘН *и.* **1.** Юан агачтан яки бүрәнәдән кисеп алынган оч, бүрәнә башы; шундый агачларны турап ясалган бер кисәк, буын. *Қалдык-постык агачлардан кирәкле озынлыкта бүкәннәр кисеп алдылар. - - - Машина рамын озын күсәкләр белән каерып күтәртеп, - - - әзерләгән бүкәннәр өстенә куйдылар.* М. Шәрифуллин. // Шундый бүкәнне хәтерләткән һәр нәрсә. *Матрос абыйлар чуен бүкәнгә әләктерелгән тимер чыбык арканнарны пароход эченә тартып алдылар.* Г. Мөхәммәтшин. *Газинур урындык итеп куелган бүкән өстенә утырды.* Г. Әпсәләмов.

2. *махс.* Арба тәгәрмәченең уртадагы, күчәргә кидерелә торган өлеше. [*Мастерскойда*] *берничә колхозчы тәгәрмәч бүкәннәрен кырып, тугымнар эшләп, колхоз арбаларына тәгәрмәчләр һәм күчәрләр ясап яталар.* М. Гали. *Юл ул кадәрле үк бозылмаган, тәгәрмәч бүкәне күмелерлек чокырлар да юк иде.* А. Гыйләҗев.

3. *күч. туп.* Қыска буйлы, юан, авыр хәрәкәтле яки булдыксыз, аңгыра кеше турында. *Авылдан килгән бер агай Питербурда матростан, вокзал кайдарак, дип сораган. Матрос, полицейскийны күрсәтеп: — Сора әнә теге бүкәннән,— дигән.* Г. Бәширов.

4. *с. мәгъ.* Бүкән (1 мәгъ.) формасындагы. *Бүкән умарта.* // *күч. туп.* Қыска буйлы, юан, авыр хәрәкәтле яки булдыксыз, аңгыра. *Бүкән Фәхри.*

БҮЛБЕ *и.* Үсемлек тамырының җир астындагы нык юанаеп бүлтәйгән итләч өлеше. [*Дуңгыз балаларына*] *ярты килограммга кадәр печән оны, ике килограммга кадәр төрле бүлбе һәм тамыр азыклар, өсте алынган сөт* [*бирәләр*]. А. Расих.

БҮЛБЕЛӘНҮ *ф.* Үсемлектә: бүлбе яки бүлбеләр яралу, үсү. *Бәрәңгенең бүлбеләнә башлаган чоры.*

БҮЛГЕ *и.* Урталай бүлеп, аерып тора торган нәрсә.

БҮЛГЕЧ *и. махс.* Бүлү, аеру хезмәтен үти торган җайланма һ. б. ш. *Насостагы бүлгеч. Пар бүлгеч.*

БҮЛГӘЛӘҮ *ф.* 1. *Кабат дәр. к.* бүлү (1, 2 мәгъ.).

2. Күп һәм вак өлешләргә, кисәкләргә бүлү. *Мәүлиха тути әле сугылмаган, бер өлеше ындырга да кереп җитмәгән игенне алай алдан-ала бүлгәләп ташлауны ошатмый иде.* Г. Бәширов. [*Хисләремне*] *Төрле-төрле кисәкләргә Бүлгәләп вакламадым.* Ә. Ерикәй.

БҮЛЕК *и.* 1. Бүлем, бүлемтек; кисәк. *Ат белән эшли торган ярма яргычын карадык. Ул ике бүлемнән гыйбарәт булып, аның бер бүлегендә солы, бодай, карабодай ярмалары, икенче бүлегендә тары ярыла икән.* М. Гали. [*Мәдинә*], *музейга кереп, тере хайваннар бүлегендә пыяла ящикка салынган зур еланны күргән иде.* К. Нәҗми.

2. Бер бөтен составында булган, ләкин аерымланып торган өлеш, кисәк (китапта, сәхнәдә һ. б. ш.). *Китап бүлекләре.* □ *Кичә ике бүлектән торачак, беренче бүлектә сорауларга җаваплар, ә икенче бүлегендә - - - спектакль куелачак.* Г. Минский. *Хәмзә җырның әүвәлге бүлеген ялгыз җырлый.* М. Фәйзи.

3. Тармак (предприятиедә, учреждениедә һ. б. ш.). *Филология факультетының татар теле бүлеге. Почтаның посылка бүлеге.* □ *Наил үзенең уку-укыту бүлеге мөдире бүлмәсендә кызаруын оныта алмый.* А. Әхмәт.

4. *иск.* Төркем, даирә (гадәттә кешеләр турында). *Чынлап та Хәятта хатын-кызның бер бүлегендә бик куәтле була торган көнләшү тойгысы аз иде.* Ф. Әмирхан. *Кырыкка якын укучысы бар иде бу классның һәм алар белемнәренә карап өч бүлеккә бүленгәннәр иде.* Ә. Фәйзи.

5. *хәрби.* Зур булмаган гаскәри берләшмә, часть. *Олы Ширмә авылында акларның җәяүле бер бөтен бүлеге ята.* Һ. Такташ.

БҮЛЕКЧӘ *и.* 1. Бүлек эчендәге бүлекләрнең берсе; кечкенә бүлек. *Әгәр ике бүлектән тора. - - - Беренче бүлектәге өч бүлекчә аерым юлларда ике нокта куеп бирелгән «Истә» белән башлана.* М. Максуд. // Кечкенә бүлем. *Биктәһир карт, портмонетын ачып, аның урта бүлекчәсеннән бер сумлык кәгазь акча чыгарды.* И. Гази.

2. Предприятие, учреждение яки хуҗалык оешмасының үзеннән читтә урнашкан бүлеге. *Совхозның өченче бүлекчәсендә сыерлар, дүртенче бүлекчәсендә дуңгызлар абзары төзелде.* Соц. Тат.

БҮЛЕМ *и.* 1. Берәр нәрсәнең бүлеп, аерып куелган бер өлеше. *Урам як тәрәзәнең бер бүлеме чалтыр итеп коелып төште.* И. Гази. // Савыт-саба, төрле әйберләр саклау-йөртү өчен хезмәт итә торган нәрсәләрдә берберсеннән аерылып торган өлешләрнең берсе, бүлекчә. *Бумажникның бер бүлемендә акча йөртү. Портфель бүлемнәре.* □ [*Гаптелмәнев*] *шкафның аскы бүлемендәге шактый зур бер ящикны күрсәтте.* Г. Ахунов.

2. Бина, каралты һ. б. ш. аерымланып торган бер өлеше, секциясе; бүлмә (вагонда һ. б. ш.). *Абзарда терекләр тора торган бүлемнәр.* □ *Күп бүлемле озын таш гараж, машиналар юлга чыгып киткәч, бушап, тынып кала.* М. Шәрифуллин. [*Нуруллин*] *вагон эченә керде. Беренче бүлемне үтте. Ул эзләгән кеше юк. Икенче бүлем ишеген ачты.* А. Шамов.

3. Кечкенә кишәрлек, жир кисәге.

4. *иск.* Бүлек (китапта, сәхнәдә һ. б. ш.). *Кичәнең беренче бүлеме башланды.* Ф. Әмирхан. *Балалар көтелмәгән дәрәҗәдә матур уйнадылар. Әдәбият бүлемендә дә барлык номерны да балалар үтәде.* М. Фәйзи.

5. Махсус сызыклар белән тигез араларга бүленгән үлчәгечләрдә: ике сызык арасы. *Шкала бүлемнәре. Градусник бүлемнәре.* □ *Аның кәеф стрелкасы шкала буенча кисәктән җиде бүлемгә югары күтәрелде.* Ш. Мәдәррис.

6. *иск.* Төркем (кеше, хайван яки әйберләр турында). *Хәзер инде аларны* [*солдатларны*] *тегә тәш кибетләр арасында бүлем-бүлем итеп йөртми, күплэп, рәттән тезеп, каланың читенә дә алып чыга башладылар.* М. Гафури.

◇ **Бүлем саны** *лингв.* — предметларның тигез төркемнәргә бүленүен белдергән сан исеме.

БҮЛЕМЛЕ *с.* Бүлеме (1—5 *мәгъ.*) яки бүлемнәре булган; бүлемләнгән.

БҮЛЕМЛӘҮ *ф.* 1. Бүлемнәргә аеру. *Линейканы бүлемләү.*

2. Бүлем яки бүлемнәр ясау. *Кәләтне бүлемләү.*

БҮЛЕМТЕК *и.* Кечкенә бүлем. *Читлек бүлемтекләре.* □ *Монда булган китаплар ике зур кара шкафта һәм биш бүлемтектән торган, Сәгыйтов үзе әмәллә-тереп куйган киштәдә сакланалар иде.* С. Рафиков. *Өй урыны кадәр генә өчпочмаклы бүлемтектә котырып чүп үләне үскән.* А. Гыйләҗев.

БҮЛЕМТЕКЛЕ *с.* Бүлемтеге яки бүлемтекләре булган; бүлемтекләргә аерылган. *Бүлемтекле бумажник.*

БҮЛЕМТЕКЛӘҮ *ф.* Бүлемтекләргә аеру; бүлемтекләр ясау.

БҮЛЕМТӘ *и. çир.* 1. *к.* бүлемтек. *Нибары ике бүлемтәдән торган бу киң абзарга* [*сыерларны урнаштырдылар*]. С. Рафиков.

2. Бүлмәләрне, бүлемнәрне, бүлемтекләрне бер-берсеннән аерып тора торган юка стена (тактадан, пыяладан һ. б. ш. була). [*Сахап*] *такта бүлемтә артында кешеләрнең сөйләшкәннәрен тыңлап торды.* С. Рафиков.

БҮЛЕНЕШ *и. к.* бүленү 1. // Өлешләргә, кисәкләргә, бүлмәләргә, бүлемнәргә аеру-аерылу рәвеше. *Яңа йорттагы квартирларның бүленеше яңача булу.*

2. Төрләргә, төркемнәргә бүлү-бүленү нәтиҗәсе; төркемләнеш. *Эш көчләренең тигез бүленешен кайгырту. Хезмәт бүленеше. Спектакльдә рольләр бүленеше.*

3. Бүленү нәтиҗәсендә барлыкка килгән берәмлек. *Әлекке административ бүленешләрнең хәзергеләр белән туры килешмәве.*

БҮЛЕНТЕ *и. к.* бүлемтек. *Көзен аның* [*бәрәңге базының*] *бүлентеләренә түбәләмә тутырып бәрәңге салганнар иде.* Э. Касыймов.

БҮЛЕН-ЯРЫН *рәв. сөйл.* 1. Төрле җиргә таралып-чәчелеп, аерылышып (яшәү һ. б. ш. турында). *Бүлен-ярын яшәү.*

2. Берничә мәртәбә бүленеп, өзек-өзек, бүлеп-бүлеп (эшләү һ. б. ш. турында). *Акчаны бүлә-бүлә гына алмыйча, бүлен-ярын алу.*

БҮЛЕНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* бүлү (1—7 мәгъ.).

2. Аерылып чыгу, китү. *Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.* Мәкаль. // Аерылырга мәҗбүр булу, аерылып тоткарланып калу. *Давыллар да безнең бу тирәләргә килеп җиткәндә генә текә таулар артында бүленеп калалар.* Г. Галиев. — *Сафиуллалар немец ягында бүленеп калдылар ди.* Т. Гыйззәт.

Бүленми торган фонд *махс.* — колхозларда: хезмәт көненә бүленмичә, киңәйтелгән кабат җитештерү өчен китә торган акча фонды.

БҮЛЕНҮЧЕ *и. мат.* Икенче бер санга бүленә торган сан; *русчасы:* делимое.

БҮЛЕШ *и. к.* бүлешү 1. *Билгеле, бу* [*Г. Ибраһимов иҗатының үзенчәлекләрен классификацияләүдәге*] *бүлеш әле мәсьәләне кую рәвешендәрәк.* Г. Гали. *Бер китап надан кулына Бүлештә төште өлешкә.* Дәрдмәнд.

БҮЛЕШҮ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* бүлү (1—2, 4, 7 мәгъ.).

2. Уртаклашу. *Ничек тә кешеләргә якынрак килергә, алар белән бергә булырга, кайгы-борчуларыңны алар белән бүлешеп яшәргә кирәк.* Ф. Хөсни. *Без актык сыныкмәгебезне дә аның белән бүлешербез, ач торырбыз, тик аны* [*иптәшебезне*] *ташламабыз.* А. Әхмәт.

БҮЛКЕЛДӘҮ *ф.* Бүленә-бүленә агу сәбәпле өзек-өзек «бүлт», «голт» сыман тавыш чыгару (сыекчалар турында). *Суның графиннан стаканга салганда бүлкелдәве.*

БҮЛМӘ *и.* 1. Өйнең, квартирның һ. б. ш. стена белән яки бүтәнчә аерып эшләнгән өлешләреннән берсе. *Аш бүлмәсе. Йокы бүлмәсе. Алгы бүлмә. Ванна бүлмәсе.* // Торак өчен генә булган махсус шундый бер бүлем. *Бүлмә алып тору.* □ *Бераз сатулашкач, әби бүлмәне алты сумга бирергә риза булды.* Ф. Әмирхан. // Учреждение кебек урыннардагы бүлемнәрнең берсе; кабинет. *Директор бүлмәсе. Укытучылар бүлмәсе.* □ *Вокзалның телеграф бүлмәсендә морзе аппараты янында бер яшь егет утыра.* Ш. Усманов.

2. Бүлмәләрне бер-берсеннән аерып тора торган юка стена (гадәттә тактадан була). *Бүлмә тактасы.* □ *Бүлмә аркылы: — Ни булды сиңа, иптәш, әллә бер-бер төрле авыру әләктеме? — дип сорадым.* Г. Тукай.

◇ **Бүлмә як** — авыл өендә: ашарга әзерләү, юыну, аш-су дирбиясе саклау һ. б. ш. өчен булган кечерәк бүлмә.

БҮЛМӘДӘШ *и.* Бүлмәдә бергә торучы. *Төнге сәгать икедә бүлмәдәшләрем кайтты.* Г. Кутуй.

БҮЛТ *аваз. иярт.* Тар авызлы (мәсәлән, шешә ише) ябык савыттагы сыеклыкны агызып икенче җиргә салганда ишетелгән һ. б. ш. авазларны белдерә.

БҮЛТЕРЕК *с.* 1. Җәйге, соңга калып туган бәрән турында. *Каениш бүлтерек сарык тәкәсе суйды.* С. Рафиков.

2. *и. мәгъ.* Җәйге бәрән. *Маллар һәммәсе далага, яшел үләнгә таралганнар, тик бүген бәрәнләп тә, бүлтерекләре әле ераккә китәрлек нығып җитмәгән дүрт куй гына өй тирәсендә күренәләр.* Г. Ибраһимов.

БҮЛТЕРЕКЛӘҮ *ф.* Җәй бәрәнләү, бүлтерек бәрән китерү.

БҮЛТӘЙМӘ *и.* Бүлтәеп, төенләнеп торган урын, төерчек (организмда һ. б.).

БҮЛТӘЮ *ф.* Килешсез кабарып, нык калкып чыгу. *Бугаз төере бүлтәеп тору. Авыз бүлтәю. Ирсн бүлтәю.* □ [*Хаҗиның*] *кесәләре килешсез генә бүлтәеп тора. Анда һаҗәр биргән бияләйләр.* М. Хәсәнов.

БҮЛӘК *и.* 1. Кешене шатландыру өчен һәм яхшы теләкләрдән чыгып, бушлай бирелә торган нәрсә. *Бәйрәм бүләге. Туган көн бүләге.* □ *Сөйгән ярың чибәр булса, Бүләкләрең җәл буламас.* Г. Тукай. *Күлмәк бәйлим бүләккә, Батыр сугышчы өчен.* Ә. Исхак. // Күчтәнәч. *Мин кайтуны ишеткәч, авыл кешеләре мәҗлес үткәрергә уйлап, кайсы май, ит, күкәй, гөлләр һәм башка бүләкләр алып минем янга җыела башладылар. Каршымдагы өстәлгә тушәмгә чаклы бүләк өелде.* С. Баттал. *Газиз бик яхшы бер чирек кытай чәе алып кайткан, «Әти, сиңа бүләгем шул гына»,— ди.* М. Гафури. // Берәр эш һ. б. ш. өчен җаваи итеп, рәхмәт йөзеннән бирелә торган нәрсә.— *Мин бүләк өчен әйтмәдем,— дип, [яшерен складны күрсәтүче] бүләктән баш тартты.* И. Газн.

2. Хезмәттәге уңышлар, яхшы, мактаулы эшләр өчен котлап бирелә торган нәрсә (премия, орден, медаль, мактаулы исем һ. б. ш.). *Безгә — ударник дип, Мактау белән бүләк бирәләр.* М. Җәлил.

3. Төрле ярышларда җиңеп чыгу билгесе итеп бирелә торган әйбер, приз. *Хафиз — уналты яшьтә чагында сабан туенда батырлар белән көрәшеп --- бүләк алган егет.* Қ. Тинчурин. *Ат юырттырып, бүләккә бер [чәчкеч] алдык.* Г. Галиев.

4. Берәр кешегә, берәр юбилейга һ. б. ш. багышлап, яхшы теләкләр белән эшләнгән эш, яхшылык һ. б. ш. турында. *Бәйрәмне хезмәт бүләкләре белән каршылау.* □ *Әнисенең бу чыдамлыгына бүләк итеп, Госман нәрсә эшләде соң?* А. Шамов. *Совет космонавтларының очышы галимнәрнең, эшчеләрнең, конструкторларның Октябрь бәйрәменә зур бүләгә булды.* Азат хатын.

5. *с. мәгъ.* Бүләк итеп бирелә торган яки бирелгән. *Бүләк йөзек. Бүләк алка.* □ *Бүләк яулыкны, кадерләп кенә төреп, эчке түш кесәмә салып куйдым.* З. Бәшири. [*Сугышчылар*] *без биргән бүләк кисмнәрне Өскә киеп алга китәрләр.* Қ. Нәҗми.

Бүләк итү — берәр әйберне бүләк рәвешендә бирү. — *Минем туган көн дип, [Вәли] бриллиант алка бүләк итте.* Г. Ибраһимов.

БҮЛӘКЛЕК *с.* Бүләк (сатып алу) өчен билгеләнгән; шуңа җитәрлек. *Бүләклек ефәк. Бүләклек акча.*

БҮЛӘКЛӘҮ *ф.* Бүләк (күбесенчә 2, 3 мәгъ.) бирү. *Ярышта җиңгән өчен бүләкләү. Мактау язуы белән бүләкләү.* □ [*Олимпиадада*] *Хәерниса карчыкны бер күлмәклек ефәк, унбиш сум акча белән бүләкләделәр.* Ф. Хөсни.

БҮЛӘК-САНАК *җыйый. и. к.* бүләк-ярак. *Кайткан саен без кардәш-ыруга бүләк-санак төяп кайта торган идек.* Г. Гали.

БҮЛӘК-ЯРАК *җыйый. и.* Бүләк, күчтәнәч кебек нәрсәләр; вак-төяк бүләкләр. [*Солтан:*] *Юлга, вак-төяк бүләк-яракка бер унбиш сум эшлим дә авылга кайтам.* Г. Ибраһимов.

БҮЛҮ *ф.* 1. Кисәкләргә, өлешләргә һ. б. аеру. *Алманы икегә бүлү.* □ *Арыслан, юлбарыс, бүре Тоткаиар ди бик зур ау. Бу ауны бүлү турында Арада чыккан зур дау.* Г. Камал. *Авылны икегә бүлеп аккан инеш ярының читенә килдем.* С. Баттал. // Өләшү. [*Матур чыиаяк ватыкларын*] *ишегалдына алып чыкты да иптәшләренә өләште, барысына да җитмәгәч, ваклап бүлде [Марат].* Г. Гобәй. // Хаслап аеру, атап билгеләү; аерып кую, бирү. *Ат өчен бүлеп куйган он дүрт-биш кенә табак калды.* Г. Гобәй. // Аерым савытка салып бирү (ашны). *Аш бүлә торган чүмеч.* □ *Гайфи, өстәл артына утырып, пилмән бүләргә тотынды.* Ш. Усманов.

2. Төркемләү; төркемнәргә, төрләргә аерып карау. *Кыр утавына кешеләр җибәрү, печән чабуга хәзерлек мәсьәласе һәм, гомумән, эш көчләрен беркадәр яңадан бүлү мәсьәләләрен чишәсе бар.* Ш. Камал. [*Прокурор гаепләнүчеләрне*] *җинаятьләрнең характеры буенча өч төркемгә бүлде.* Г. Ибраһимов. // Төрләргә аерып, хаслап билгеләү (эш һ. б. ш. турында). *Рольләр бүлү.* □ *Эшне бүлгән вакытта һәркем үзе өчен бик кирәкле булган эшне эшли.* Г. Тукай.

3. *мат.* Бер санның икенче санны ничә мәртәбә үз эченә алганлыгын белү; *киресе:* тапкырлау. *Унны икегә бүлү.* □ *Алар чәчү орлыгын исәпкә алалар, шуны чәчү мәйданына бүләләр.* Ф. Хөсни. / *и. мәгъ. махс.* Шул гамәлнең исеме, атамасы. *Бүлү билгесе.* □ *Беренче класста бүлү гамәлен өйрәнәләр.* Г. Бәширов.

4. Ясау, кору (бүлмә, бүлемтек һ. б. ш. турында). *Бүлмә бүлү. Чолан бүлү.* □ [*Председатель*], *канцеляриянең сул яклап такта белән бүлгән кечкенә ягына — «үзенең кабинетына» кереп, тупын, бүрегеи салды.* Э. Еники.

5. Туктатып, өзеп тору (эшне, уйларны һ. б. ш.). *Фикерне бүлү. Җырны бүлү.* □ *Рокыя уенын бүлә дә өстәл янына килеп утыра.* Ф. Әмирхан. *Сугыш безнең тыныч эшне бүлде.* С. Урайский. *Бер-берсен бүлеп, алар бүген ниләр күргәннәрен сөйлиләр.* А. Расих. // Тоткарлау, киртә булу (юлда). *Ташу суы минем юлымны бүлә.* М. Хуҗин.

6. Бирү, сарыф итү (көчне, вакытны һ. б. ш.). *Сиңа эшкә киләбез, сиңа көчне бүләбез. --- Яшәртәбез сине, җир!* М. Җәлил. *Тәҗрибәңне башкалар белән уртаклашырга да вакыт бүлә белергә кирәк.* Соц. Тат.

7. *экон.* Әзер продуктларны, иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән чыгып, җәмгыять членнары арасында урнаштыру, аларга бирү, өләшү. *Уңыш бүлү.* □ [*Колхоз*] *колхозчыларына шактый икмәк бүлеп бирә алды.*

Г. Гобәй. // *сөйл.* Хак бирү (колхозда хезмәт көненә), түләү. *Хезмәт көненә, былтыргы кебек, сигезәр-тугызар килодан бүлик.* Г. Әпсәләмов.

8. *сөйл.* Бүлешү (2 мәгъ.), уртаклашу. *Соңгы телемен бүлде ул Узенең халкы белән.* Н. Дәүли. *Бу зур шатлыгымны Синең белән килә бүләсем.* С. Урайский.

◇ **Бүлеп чыгару** *махс.* — организмнан чыгару. *Организмдагы артык сыеклыкны бүлеп чыгару.*

БҮЛҮЧЕ *и. мат.* Икенче бер санны бүлә торган сан; *русчасы:* делитель.

БҮРЕ *и.* 1. Этләр семьялыгыннан булган имезүче ерткыч хайван.

2. *гади с. күч.* Явыз, усал кеше турында.

3. *с. мәгъ.* Бүре тиресеннән тегелгән, эшләнгән. *Бүре тун.* ▭ *Кыш ул, кая гына барса да, якасы әллә кайдан үк - - - күренеп торырлык зур бүре толып, зуррак җирдә булса, кызыл якалы төлке тамак толып кия.* Г. Ибраһимов.

◇ **Бүресе улау** — кулга байлык-дәүләт керү һ. б. ш. сәбәптән эшләре алга китү, тормышы яхшыру. [*Игеннәр*] *күкрәп үскәннәр бит! Җил-фәлән кагып, боз-фәлән сукмаса, быел крестьянның бүресе улый инде!* З. Бәшири. // Гомумән, теләгең-ниятең үтәлеп, уңышка-бәхеткә ирешү. [*Хәсән — Мавиясе белән кавышучы Самат хакында:*] *Малайның бүресе улады.* М. Фәйзи.

БҮРЕК *и.* 1. Җылы баш киеме. *Колакчынлы бүрек. Камчат бүрек. Мескен бүрек. Тәбәккәл бүрек. Кырпулы бүрек. Кама бүрек. Малахай бүрек.*

2. Кайбер кошларның баш түбәләрендә кабарып торган йон. *Ак күгәрченнәрнең бүрке бар, Күк күгәрченнәрнең күрке бар.* Җыр.

◇ **Бүрек белән киңәшү** — үзең генә уйлап, бер карарга килү. *Бу хакта күп уйладым. Бүрегем белән күп киңәш иттем.* М. Гафури.

БҮРЕКЛЕ *с.* 1. Бүреге булган. *Бүрекле тавык.* ▭ *Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган.* А. Алиш.

2. Бүрек (1 мәгъ.) кигән. [*Сәхнәгә*] *бик франт кына киенгән, бүрекле - - - егет керә.* Ф. Әмирхан.

БҮРЕКЧЕ *и.* 1. Бүрек тегү остасы; шуңа өйрәнүче. *Гыйсмәтне уналты яшеннән Мәскәү татар сәүдәгәренә бүрекче малай итеп җибәрделәр.* Г. Гали.

2. Бүрек белән сәүдә итүче.

БҮРЕКЧЕЛЕК *и.* Бүрекче һөнәре, кәсебе.

БҮРЕЧЕ *и.* Бүре аулаучы.

БҮРТЕНҮ *ф.* 1. *к.* бүртү. *Иске, тузанлы, бераз бүртенгән бер сүс арканны тарттым да ишек алды эчендә шалтыраган кыңгырауның яңгырашын тыңлап тордым.* Ф. Әмирхан. *Кан тамырлары бүртенгән иде аның.* Ф. Кәрим.

2. Артык тулылану, кабарыну.— *Кабахәт!.. Кан эчеп бүртенгән кандаламыны!* М. Хәсәнов.

3. Кан йөгерүдән нык кызару (йөз һ. б. турында). *Бу сүзгә Гали тәмам кызарды, бүртенде.* М. Гафури.

БҮРТМӘ *с.* Бүрткән, бүртенгән. *Саимәнең күзләрендә бүртмә тамырлы кулларга нык кысылып югары күтәрелгән авыр чүкеч күләгәсе чагылды.* Қ. Нәҗми.

БҮРТМӘЧ *с. диал.* Бүртеп-кабарып бүлтәйгән (авыз, ирен һ. б. ш. турында). *Бүртмәч авызлы кыз.*

БҮРТМӘЧЛӘНҮ *ф. диал.* Бүртеп-кабарып бүлтәю (авыз, калын ирен һ. б. турында). *Бер кыз күренде. Битләре нәрсә белəндер янганмы яки пешкәнме шикелле, ямьсез кызыл булып, бүртмәчләнеп тора иде.* Ш. Маннур.

БҮРТТЕРҮ *ф.* 1. Суда тотып, йомшарту һәм дымга туендыру (ярма бөртекләрен һ. б. ш.). *Фәүзия җиңги аңа булышу белән бергә, бәлеш өчен ярма бүрттерү кебек эшләрне эшләргә кереште.* М. Гафури. // Дымлылыгын шытып чыгарга әзер дәрәҗәгә җиткерү (орлык турында). *Кыш буе орлыкларның Сыйфатларын өйрәндем, - - - Аеруча кызыксындым Бүрттереп чәчү белән.* М. Җәлил.

2. *күч. сөйл.* Эшләү, булдыру, уңышка ирешү. [*Зөфәр:*] *Соң... эшләр ничек?* [*Тәһирҗан:*] *Әллә ни бүрттереп булмады әле.* М. Шәрифуллин.

БҮРТӘ *с. диал.* Саргылт яки аксыл таплары булган туры төстәге (ат турында). *Бүртә бия.* ▭ *Мин бүртә алашама печән сала калдым.* Х. Кәрим.

БҮРТҮ *ф.* 1. Дымнан киңәеп калынаю. *Дилбегә бүртү. Ботинка бәе бүртү.* ▭ [*Капка*] *яңгырдан бүртеп авырайган.* Г. Минский. *Лапас түбәсенең саламнары бүрткән.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Қабарып калкып чыгу (тәндәге тамырлар, мускуллар һ. б. ш. турында). *Илдарның муен тамырлары бүртеп чыкты.* Г. Гобәй. *Карчыкның зәңгәр тамырлар бүртеп чыккан куллары калтырап китә.* С. Рафиков.

3. Сусылланып калынаю һәм тулылану: шыту яки яфрак җибәрү алдында тору (орлык, бөре һ. б. ш. турында). *Килер яз, кояшның кайнар нурлары астында алмагачлар терелерләр, кечкенә генә бөрелəр бүртер, калынаер, яшел яфракка әйләнер, һәм язгы матур көннәрнең берендә бөтен тау бите ямь-яшел булыр.* И. Гази.

БҮРӘНҚӘ *и.* Төбенең уртасыннан аска таба нечкә көпшәсе чыгып торган киң авызлы савыт сыман җайланма (тар авызлы савытларга сыеклыкларны салу өчен кулланыла).— [*Габбас*] *төннәр буе үзенең бүлмәсендә шешәләре, бүрәнкәләре арасында бикләнеп ята.* Ш. Қамал.

БҮРӘНҚӘЛӘНҮ *ф.* Бүрәнкә сыман булу, түгәрәкләнеп җыерылу-бөрелү. *Булатовның бөрмә иреннәре бер бүрәнкәләнде, бер җәелде.* Р. Төхфәтуллин.

БҮРӘНӘ *и.* 1. Кисеп аударып боталган, гадәттә башы киселгән зур агач кәүсәсе. *Агач аударучылардан илле метрлар чамасы арттарак ботак чабучылар эшли. - - - Ботак чабучылар үткән урында шәп-шәрә бүрәнәләр һәм чыбык-чабык өемнәре генә кала.* Г. Әпсәләмов. *Моннан җиде ел элек утыртылган Қоргаксай урманы һаман әле бүрәнә бирә алмый.* Қ. Нәҗми.

2. *с. мәгъ.* Бүрәнәдән яки бүрәнәләрдән эшләнгән, ясалган. *Бүрәнә сарай.* ▭ [*Латыйп*] *бүрәнә күпер янына килеп җитте.* А. Расих. [*Кояш нурлары*] *түрдәге бүрәнә стенага, алтын йөзерткәндәй, тоташ сары булып төште.* Ә. Еники.

БҮРӘНӘЛЕК *с.* 1. Бүрәнәгә яраклык, бүрәнә булырлык. *Бак агачлар да юк. Гел зур-зур имән, усак кебек бүрәнәлек агачлар гына калган.* М. Гали.

2. *и. мәгъ.* Шундый агач. *Ул урманнарда нарат, чыршы кебек яхшы агачлар булмаса да, өйгә яраклык усак бүрәнәлекләр* [*бар иде*]. З. Һади.

БҮСЕЛҮ *ф. Төш. юн. к.* бүсү (1 мәгъ.). Таркалып-чәчелеп тузгу, таралу (көлтә, төенчек һ. б. ш. турында). [*Зәки*] *арыш басуында баулары чишелеп, бүселеп ята торган ике көлтәнең һәрберсен аерым-аерым яхшылап бәйләде.* Г. Галиев. // Өлешчә җимерелү, ишелү, тузгу (чүмәлә, кибән һ. б. ш. турында). *Кибән бүселү. Эскертнең бер очы бүселә башлау.* ▭ [*Йортның*] *бүселгән бүрәнәләрен болтлар һәм шөрепләр белән тарттырып куйган.* Г. Ахунов. // Ертылу, тузу һ. б. ш. сәбәптән сүтелеп таркалу (төрле сырган, теккән әйберләр һ. б. ш. турында). *Киез итегенең үкчәләре ничектер артка бүселеп чыккан.* М. Хәсәнов.

БҮСЕР *и.* 1. Авыру: берәр органның (күбесенчә нечкә эчәгенең) эч куышлыгыннан тире катлавы астына керүе. *Аксаби карт яшь чагыннан алып каты бүсер авыруы белән азапланган.* З. Бәшири.

2. Шул рәвешле бүлтәеп чыгып торган орган.

◇ **Бүсер ташы** — сидек капчыгында була торган таш.

БҮСЕРЛЕ *с.* Бүсер авыруы булган. *Бүсерле кеше.*

БҮСӘЮ *ф. диал.* Бүлтәю, калкып чыгу. [*Бала*] *өреп тутырганда бүсәйгән авызын ача алмыйча азапланды.*

Г. Минский. *Гыйльметдин бил каешын чишеп җибәрде дә корсагын бүсәйтеп торган бер пачка кәгазь чыгарды.* Г. Иделле.

БУСУ *ф.* **1.** Таркатып тузгыту, тарату (көлтәне, төенчекне һ. б. ш.). *Көлтәләрне бүсмәскә тырышып, йөкне тәртип белән генә бушату.* // Өлешчә җимерү, ишү, тузгыту (чүмәләне, кибәнне һ. б. ш.).

2. *күч. гади с.* Күп һәм талымсыз ашау. [*Гыйльметдин*] *пулеметы катында икмәк белән бәрәңге «бүсеп» утыра иде.* Г. Гази.

БҮТӘКӘ *и.* **1.** Кошларның ашказаны. *Тавыкка төнгә иң каты азыкны — бөртек азыкны бирәбез. Аның мускуллы ашказанына, безнеңчә әйткәндә, бүтәкәсенә хәзер эш булды.* А. Расих. *Урдәклар, борын очлары белән күл төбен актарып, бүтәкәләренә ком тутыралар.* Қ. Нәҗми.

2. *күч. хур.* Кечкенә гәүдәле кеше турында.— *Менә каһәр суккыры, җир тараканы, бүтәкә башы белән жалунҗә алмакчы була имеш. Тот капчыгыңны!* Қ. Әмири.

БҮТӘН *с.* **1.** Башка, икенче бер. *Өйрән, әй туган, бер башка телне, Бүтән телләр белү яхшы һөнәр.* Дәрдмәнд. *Зарыгып хат көтәм. Кайгы-хәсрәтем дә юк бүтән.* Ә. Ерикәй. // *хәб. функ.* Нык аерылып торган, бөтенләй икенче төрле. *Әллә безме хәзер бүтән инде, әллә синме бүтән инде, күк? Без элек тә сине күзли идек, Бер дә болай түгел идең күк.* Х. Туфан. *Хәзер мәктәпнең килеше үк бүтән.* Г. Гобәй.

2. *рәв. мәгъ.* Моннан ары, тагын да арырак. *Бүтән менмик, моннан да бик яхшы күренә иче.* Э. Қасыймов. // Моннан соң, башка вакытта. *Бүтән болай тилмереп утыру булмас.* Ә. Еники. *Җыр тавышы кинәт өзелде һәм бүтән кабатланмады.* Ф. Хөсни.

3. *чыг. килеш. бәйл. функ.* Икенче берәүдән яки берәр нәрсәдән тыш, башка. *Баязит карыйның Давыт Урмановтан бүтән кардәше юк.* Г. Ибраһимов. *Нәсимәнең күзләренә кайнар яшь тыгылды: — Песием... Йолдызкаем! - - - Инде моннан бүтән һич тә, һич тә алай үпкәләтмәс идем.* Д. Аппакова.

БҮТӘНЛӘНҮ *ф.* Үзгәрү; бүтән сыйфат, үзлекләр алу.

БҮТӘНЧӘ *рәв.* Бүтән рәвештә; башкача. *Һәр яңа көн — бүтәнчә яңа.* Х. Туфан. *Көтелмәгән бер хәл бу ике яшьнең тормышын бөтенләй бүтәнчә борып җибәрде.* Г. Бәширов. *Бу бер офицер кисәге булса кирәк, киеме һәм билгеләре бүтәнчәрәк.* Ә. Еники.

БҮТӘНӘЮ *ф. к.* бүтәнләнү. *Бәйрәм көне кебек иркен монда, Ямьле монда. - - - Тормыш бүтәнәйде.* Х. Туфан.

В

В Татар алфавитында өченче хәреф.

ВА *ы.* Интонациягә карап каты кычкыруны, шатлануны һ. б. ш. ны белдерә. — *Тотасыз да, «а!.. ва!..» — дип акырырга, бакырырга тотынасыз.* Г. Камал.

ВАБА *и.* 1. Коcу, эч китү кебек күренешләр хас булган каты йогышлы авыру; холера. *Ваба чире.* □ — [*Аның*] *ата-аналары вабадан үлгән.* Т. Гыйззәт. *Ул чакларда әле бер, әле икенче авылда ваба үләте башлана торган булган.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч. тирг.* Үлем китерә торган нәрсә, үләт. *Кара үләт кебек шомлы афәт булып, фашист дигән ваба үрмәли.* Г. Бәширов.

ВАБАЛЫ *с.* Ваба авыруы булган; ваба авыруы йоккан.

ВАВИЛОН: Вавилон манарасы — 1) *миф.* Борынгы Вавилонда бик биек манара. *Залда бер-берсенә һич охшамаган дистәләрчә төрле телләр яңгырый. - - - Дин-нәр тарихыннан Вавилон манарасын салырга җыелучылар искә төште. Алар шулай кырыкмаса-кырык телдә сөйләшкәнгә күрә үзара аңлаша алмаганнар бит.* Г. Бәширов; 2) чамасыз ыгы-зыгы, зур шау-шу; буталчыклык.

ВАВИЛОНЛЫ *и. тар.* Хәзерге Гыйрак җирендә яшәгән борынгы халык вәкиле; бабил.

ВАГАЮ *ф.* 1. Вак хәлгә килү, кечерәю, кыскару; *киресе:* эреләнү, озыная. *Карагай һәм наратлар тауның урта тирәсендә нинди эреләр иде, ә хәзер вагайганнан-вагаялар.* М. Кәримов. *Туры ат бик кечкенәләнде, мескенләнде, аның адымнары вагайды.* М. Гафури.

2. *күч.* Әһәмиятен, мөһимлеген кимегү яки югалту. [*Ул*] *заманда сәяси бүлгәләнгән* [*бу халыклар*] *- - - бара-тора* [*үй һәм аң ягыннан*] *вагая башлаганнар.* Ф. Әмирхан.

ВАГОН *и.* 1. Тимер юлда юлчыларны һәм йөкләрне ташу өчен махсус җиһазландырылып, тәгәрмәчләр өстенә утыртылган корылма. *Товар вагоны. Класслы вагон. Трамвай вагоны. Ачык вагон.* □ *Станциягә яшел вагоннар таккан дача поезды килеп туктады.* Г. Минский. *Зур паровоз аның бодае төялгән ничәмә-ничә вагонны, станцияләрдә туктап тормастан, - - -* [*алып*] *чабар.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Шундый корылма ясый торган. *Рига вагон заводы.*

2. Шундый корылмага сыешлы йөкнең, әйбернең микъдар күләме.— [*Сезгә*] *бер вагон да икмәк җибәрелмәс.* Ш. Усманов.

3. *рәв. мәгъ. күч. сөйл.* Саннардан соң килгәндә: хисапсыз күп, бик күп.— *Барысына да бер вагон сәлам.* Ш. Мөхәммәдев. *Бу мидә бардыр* [*наданлык*] *ул вагон, «Минбеләмлек» дәгъвасы — бер мең вагон.* Г. Тукай.

4. Кырда куну өчен җиһазландырылган һәм бер урыннан икенче урынга күчерү өчен тәгәрмәчләр яки чана өстенә утыртылган өйчек. [*Ул*] *тракторчыларның кыр вагонына да бик еш барып йөри башлый.* Р. Төхфәтуллин.

ВАГОН-АРБА *и. к.* вагон (4 мәгъ.). *Балта остаханы трактористларга торырга вагон-арба ясап маташалар.* А. Расих.

ВАГОНДАШ *с.* Бер үк вагонда утырып баручы. *Безнең вагондаш күршеләребез ерак юлга бара торган юлчыларга охшыйлар.* С. Кудаш. // *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Поезд Алатырь урманнарын шаулатып узганда, Кайман вагондашларына үзе турында сөйли иде.* Х. Садрый.

ВАГОНЕ'ТКА *и.* Тар колеялы яки асылма юлларда йөк ташу өчен кулланыла торган ачык өсле кечерәк вагон. *Шахтадан күмер төялгән икешәр яисә дүртәр вагонетка күтәрелә.* Ш. Камал. *Кызыл ком күк руда агылып тора Вагонеткаларга төялеп.* Ш. Маннур.

ВАГОНЛАП *рәв.* 1. Саннардан соң килгәндә: шул кадәр вагонга сыярлык, шул саннлы вагон күләмендә яки чамасында (сан-аергыч белән килә). [*Җылымнан*] *ике вагонлап балык чыккан.* Ш. Камал.

2. *күч.* Бик күп, күпләп; вагоны-вагоны белән.— *Эшләпә дигән товар әгелчән җиреннән вагонлап килә, диләр.* К. Нәҗми. *Сугыш сафларына вагонлап-вагонлап җибәрелгән изге сурәтләр дә - - - дошман гаскәрен чигендерә алмады.* К. Тинчурин.

ВАГОНЛЫ *с.* Саннардан соң килгәндә: шул саннлы вагоннары булган, шул саннлы вагоннардан торган. *Ул илле вагонлы составның йөрешен туктата алмады.* Ш. Усманов. // *иск.* Трамвай йөри торган. *Вагонлы урамга чыккач, Гайнижамал: «Багунга утырып барыйк, Мөхип әби, өч тиен генә алалар»,— - - - ди*[*де*]. Ф. Әмирхан.

ВАГОНЛЫК *с.* Саннардан соң килгәндә: шул саннлы вагоннарга сыярлык (йөк, әйбер турында). *Әллә ничә мең вагонлык күмер тауларыннан - - - эсселек чәчелеп тора.* Ш. Камал.

ВАГОН-РЕСТОРАН *и.* Ресторан урнашкан тимер юл вагоны.

ВАГОНЧЫ *и.* 1. Вагон заводы эшчесе.

2. *иск.* Трамвай йөртүче. *Вагон саен пар ат җиккәннәр дә, тимер юл буенча өстерәтеп киткәннәр. Кулына озын саплы чыбыркы тоткан вагончы - - - җирәнгәй белән көрәнгәйне әйдәп барган.* И. Рәми.

ВАГРА'НКА *и. тех.* Чуен һәм төсле металлар эретү яисә төрле әйберләрне яндырып чыныктыру өчен махсус авызлы мич. [*Сөләйман*] *юан мастерны - - - эчләрендә сыек чуен эремәсе кайнап торган кызу вагранкаларга таба алып та киттс.* Г. Әпсәләмов.

ВАГЫЙЗЬ *и. иск.* Вәгазь сөйләүче, үгет-нәсихәт бирүче; вәгазьче. *Вагыйзь. - - - халыкны үз әйләнәсенә җыеп, һәр изгелекләргә боерып, һәр эшәке эшләрдән тыеп, - - - көйләп-көйләп вәгазь әйтәдер иде.* Г. Тукай.

ВАДИ *и. сир. кит.* 1. Таулар арасындагы уйсу җир, тарлавык, чокыр. *Ул аны җәһәннәмдә — «Баруел» исемле вадидә (чокырда) күр*[*де*]. М. Гафури. *Разведканың инженер-техник эшчеләре таулардан кайтарылган җи-*

һазларның иң кыйммәтлеләрен түбәнгә, вадигә озаталар. Ә. Айдар.

2. Коры үзән, елга үзәне. *Кайчандыр зур елга узган Киң бер вади — коры үзән.* Рәф. Әхмәтҗанов.

ВАЕМ *и.* Берәр нәрсә турында кайгырту, борчылу; тамь. *Мостафа үзен семья асраудан башка бернинди дә ваемы булмаган кеше кебек тотарга тырышты.* К. Нәҗми.— *Бөтен илдә сугыш ваемы. Ә ул монда әнә ниләр кылана.* Г. Бәширов. // Гомумән борчу, кайгы-хәсрәт. *Яшь картайтмый, ваем картайта.* Мәкаль. *Күпме кыен күреп, күпме ваем, Үксеп-үксеп, өзелеп егладың.* Ш. Бабич.

◇ **Ваемга керү** — хәлгә керү, кайгырту, кеше хәлен аңлау. *Мостафа Алексейның --- һәркемнең хәленә, ваемына керә белүен, кайгыртучанлыгын* [*ошатты*]. К. Нәҗми. **Ваем чигү** — берәр нәрсә турында борчылу, кайгыру, хәсрәтләнү. *Алай булгач, өйлән, дус, чикмә ваем.* Г. Тукай.

ВАЕМЛАУ *ф.* Берәр нәрсә турында кайгырту, борчылу, уйлану.

ВАЕМЛЫ *с.* Нәрсә турыңдадыр уйлана, борчыла, кайгырта торган. *Бар иде, дип, бер ваемлы бала, Халкым мине бер яд итәрме?* Н. Арсланов. // Борчылу, кайгы-хәсрәт чагылдыра торган. *Фазлый ваемлы чырай белән килеп керә.* Ш. Камал.

ВАЕМЛЫЛЫК *и.* Ваемлы булу.

ВАЕМСЫЗ *с.* Дөнья мәшәкатьләреннән азат, кайгысыз, гамьсез. *Ваемсыз балачак узган илләргә кайтучының күңеле ничек ашкынмасын!* Г. Минский. *Бик яшь иде ул чагында Гәрәй, наян иде, ваемсыз иде.* А. Гыйләҗев. / *рәв. мәгъ. Ваемсыз көлү.* // Бернәрсә белән дә кызыксынмый, бернәрсәгә дә борчылмый торган, ис китмәүчән, күңел бирмәүчән. *Аның шушы салкын канлы, ваемсыз кешеләрнең --- җаннарын тетрәтәсе --- килә иде.* Г. Бәширов. *Һичнигә ис китмичә, ваемсыз булып күренү аркасында гына ул үзен дошман капризыннан бәйсез тота алачак.* Ә. Еники. // Эшкә салкын карашлы, эш турында уйламаучан, игътибарсыз. *Ваемсыз хезмәткәр.*

ВАЕМСЫЗЛАНУ *ф.* Бернәрсә турында да кайгыртмау, борчылмау, ваемсызлык күрсәтү; гамьсезләнү. *Бу вакыт Асылгәрәйнең шуннан башка бер кайгысы да юк, бөтен дөньясы түгәрәк кебек иде. Һай, шулай ваемсызланмагач булсачы Асылгәрәй!* М. Шабай.

ВАЕМСЫЗЛЫК *и.* Берәр эшкә яки берәр нәрсәгә салкын караш, күңел бирмәү; игътибарсызлык, гамьсезлек. *Ваемсыз гына булмагыз. Кайгы-хәсрәт түгел, ваемсызлык кешенең канатын сындыра.* Г. Әпсәләмов. *Ничек кенә итеп ул үзенең язмышында якты сын булып төсмерләнгән шундый әйбәт йөрәкле хатынны — беренче әлеп-би өйрәткән укытучысын оныта алды соң?! Ничек кенә аңлатып, ни белән генә аклап булыр икән мондый ваемсызлыкны!* Г. Минский.

ВАЗ: ваз кичү — якын кешеләрдән яисә берәр нәрсәдән, эш башкарудан, хокуктан баш тарту, аларны ташлау. *Мирастан ваз кичү.* ▭ *— Император тәхеттән ваз кичкән.* К. Нәҗми.— *Мин бит синең өчен тормышымны корбан итеп, барлык кешелек теләкләреннән ваз кичтем.* Т. Гыйззәт.

ВА'ЗА *и.* Җилəк-җимешләр салу, чәчәкләр утыртып кую яки бүлмәне бизәү һ. б. ш. өчен файдаланыла торган декоратив савыт. *Хрусталь ваза.* ▭ *Өстәл уртасында --- ваза белән аксыл юкә балы тора.* Ә. Еники. *Вазаларда кып-кызыл каен җиләге, җир җиләге, чәчәк бәйләмнәре* [*бар*]. Г. Ахунов.

ВАЗГЫЯТЬ *и. иск. кит.* Торыш, халәт, хәл. *Революция --- нәтиҗәләреннән килеп чыккан* [*халыкара*] *вазгыятьне дикъкатьле* [*күзәтеп бару*] *безнең югарыдагы сөальләребезгә ачык җавап бирәдер.* Ф. Әмирхан.

ВАЗЕЛИН *и.* Нефтьтән табыла һәм медицинада, техникада, гигиенада кулланыла торган май. *Техник вазелин.* ▭ *Нефтьтән бензин, керосин, --- вазелин табыла.* Х. Садрый. [*Фәйрүзә*] *вазелин һәм йомшак чүпрәк әзерли.* Л. Ихсанова.

ВАЗЕЛИНЛАУ *ф.* Вазелин сөртү, вазелин ягу. [*Бригадир*] *битен-кулын бертоташ вазелинлый диярсең, майланып, ялтырап тора.* Б. Камалов.

ВАЗЕЛИНЛЫ *с.* Составында вазелин булган. *Вазелинлы сабын.* // Вазелин сөртелгән, вазелин сыланган. *Вазелинлы кул.*

ВАЗИФА *и. кит.* **1.** Үтәлергә тиешле эш, өскә йөкләнгән бурыч.— *Сезнең отряд өстенә тылны саклау вазифасы йөкләтелде.* Ш. Усманов.— *Шәкертнең вазифасы — укымак, укымак, укымактыр.* Г. Ибраһимов.

2. Үзеннән алдагы исем белдергән әйбер яки кеше функциясен башкару, алар урынына хезмәт итү. *Туфрак Җәмиләне кочагына алып, мәрхәмәт вә шәфкатьле аналар кебек кочып саклаячак, аналар вазифасын күрсәтәчәктер.* М. Гафури. — *Гыйльметдин өйдә туры килмәде: яшьләр вазифасын үземә үтәргә туры килде.* М. Фәйзи.

3. Берәр оешмада, предприятиедә хезмәт, эш һәм шул хезмәткә бәйле бурычлар. *Директорлык вазифасы. Лаборант вазифасын үтәү.* ▭ [*Шәһәретдинов*], *Башгизның җаваплы редакторы булып, матбугат өлкәсендәге* [*эшне*] *бер постта җитәкчелек вазифасын үти.* М. Җәлил.

4. *иск.* Хезмәт хакы. [*Әхмәтнең*] *матди тормышын мөгаллимлектән алган утыз сум вазифасы тәэмин итәдер иде.* Г. Газиз.— *Аларның аена 15—20 тәңкә вазифалары өчен баш ватып, көн уздырып --- утырыр хәлем юк.* Г. Камал.

ВАЙ I *ы.* **1.** Бик каты курыккан, авырткан, аптыраган вакытта әйтелә.— *Һай, харап булдык, балалар, вай, харап булдык.* А. Әхмәт.— *Вай-вай-вай. Күземне чыгардыгыз.* Д. Аппакова. // Шигырьдә иҗек санын тутыру өчен кулланыла. *Ай, Дунай, вай, Дунай! Шәкерт изү бик уңай!* Г. Ибраһимов. *Ай чәчәк, вай чәчәк! Синнән чибәр кызлар юк дип, Исемең илгә чәчеләчәк.* М. Фәйзи.

2. *хәб. функ. к.* аптыраш.— *Булмый дип әйтеп кара! Ләкин бирәм дисәң дә вай. Ике мең пот бит!* Г. Әпсәләмов.— *Дилбегәсе черегән шул, --- каты тотсаң да вай, тотмасаң да вай, барыбер өзелә инде.* К. Нәҗми.

ВАЙ II: **вайга алмау** — теге яки бу эшне, сүзне, фикерне игътибарга алмау, аларга ис китмәү, үзенчә (гадәттә киресен) эшләү; ай-вайга карамау.

ВАЙВАЙЛАУ *ф.* «Вай-вай» тавышлары чыгарып каты кычкыру.

ВАК *с.* **1.** Күләме, зурлыгы ягыннан кечкенә; *киресе:* эре. *Вак бәрәңге. Вак таш.* ▭ [*Якуп*] *йодрык зурлыгында гына вак күмәчләр пешертеп ала.* М. Гафури. *Алмагачтан алма алдым, Эресен түгел, вагын.* М. Фәйзи.

2. *сөйл.* Яшь, кечкенә (балалар турында). *Вак балалар Туктадылар кызык уеннан.* Ф. Кәрим. // *и. мәгъ.* Яшь, кечкенә бала. *Ваклар читтән торып аның авызына карыйлар.* Ш. Камал.

3. Кечкенә күләмле бериш, бертөрле кисәкләрдән торган. *Көзге вак яңгыр акрын, ләкин туктаусыз һаман сибәли.* Г. Ибраһимов. // *и. мәгъ.* Кирпеч, печән, агач кебек нәрсәләрнең вакланган, уалган оны, чүбе, тузаны. *Кайбер маллар өчен генә печән вагы парлыйлар.* Ә. Еники. *Мирхәйдәр абзыйга, --- ике такта арасына пычкы вагы тутырып, өстәмә бүлмә ясарга туры килде.* Ә. Фәйзи. // *и. мәгъ.* Йсни яки тел астына сала торган вак тәмәке тузаны. *Мәгъсүмнең савыты берлә вагы оныгылып калды. Хәят абыстай табып алды да иснәп карады, борыч исе кеби куәтле ачы ис борынына кереп, төчкерде.* З. Һади.— *Безнең мулла --- вагын каба да гакылыннан тая.* М. Фәйзи.

4. Бер-бер артлы еш кабатлана торган; еш. *Бөтен тәнендә аның вак калтырау йөри, үзе уттай яна.* Ә. Еники. // *рәв. мәгъ.* Кыска.— *Абзый кеше, бик озын атлый-сың икән, ваграк атлап булмыймы соң?* Әкият. *Патый әби, өстен чишенеп, карчыкларча вак һәм йомшак кына басып, түргә үзды.* А. Шамов.

5. Аз санлы, зур булмаган. *Вак халыклар.* □ *Гаскәр вак отрядлардан --- полкларга җыелды.* Ш. Усманов. *Урманда финнарның алдагы сугышларда тар-мар ителгән частьларының калдыклары вак-вак төркемнәргә бүленеп йөриләр иде.* Г. Әпсәләмов.

6. *и. мәгъ. к.* вак акча.— *Миндә кәгазь акчалар гына, синдә вак юкмы?* Ш. Әхмәдиев.— *Йөдәтмә әле, хәзергә вак юк, тәнкәлегем дә юк.* Г. Камал.

7. Материаль мөмкинлекләре аз булган; экономик яктан көчсез. *Вак буржуазия. Вак сәүдәгәр. Вак милекче. Вак җитештерүчеләр.* □ *Авылны социалистик нигезгә күчерү өчен хәзерге аерым-аерым вак хуҗалыкларны берләштереп, эре хуҗалыкка әйләндерү кирәк.* М. Әмир. *Шидловский онытып калдырган бик күп вак заводлардан һәм мастерскойлардан комиссиягә кешеләр сайлансын.* РСДРП прокламациясе.

8. *күч.* Эштә һәм җәмгыятьтә дәрәҗәсе түбән, әһәмиятсез урын тоткан, гади эш урынында эшли торган. *Вак хезмәткәр.* □ *Атам — вак чиновник. Мин бала чакта үлгән.* Г. Ибраһимов.

9. *күч.* Зур әһәмияткә ия булмаган; икенче дәрәҗәдәге, әһәмиятсез. *Вак эш артыннан йөрү.* □ *— Выходное пособие дисең. Ансы безнең өчен вак мәсьәлә. Аңардан башка да Мәскәүгә барырлык рәт бар.* Ш. Камал.— *Алары вак эш. Гайнине күрдеңме?* Ф. Әмирхан. // Әһәмиятсез, эчтәлексез; буш. *Башка турыларда нинди нык булган кызның шундый вак ырымнарга ышанып эш итүенә исем китә.* М. Фәйзи. *Юк уй белән гомерең үткәреп, Юлсыз, вак тормышны сөйдең син.* З. Байчурина.

10. *күч.* Җентекләп, зур игътибар белән эшләүне сорый торган (эш турында). *Чәчүлек тары чүплерәк иде,— җилгәрттерде. Җилгәргеч аера алмаган чүп-чарларны кул белән чүпләтте* [*Шәйхаттар бабай*]. *Дөрес, бик вак, бик ялыктыргыч эш булды бу.* Г. Гобәй.

11. *күч. сөйл. к.* вакчыл.— *Каенанам бик вак. Теңкәгә тия.* А. Шамов. — [*Егетне*] *мин бер дә ошатмадым. Вак кеше булырга кирәк.* Т. Гыйззәт.

12. *и. мәгъ. күч. сөйл.* Акыл, зиһен; белем. *Җиһанша староста Габдулла абзыйның аты урлану хәбәрен ишеткән булган икән, кайгысын уртаклашты, башын чайкап торды. Ләкин шуннан да артыкны әллә ни әйтә алмады. Чөнки шуннан да артыкка үзенең дә вагы чамалы иде.* Ф. Хөсни. *Мин урысчаны* [*ярыйсы үк*] *төшенәм икән хәзер, --- шулай да үзем сөйләшкәндә вак җитеп бетми әле, еш төртеләм.* Ш. Маннур.

Вак акча — бер, ике, өч, биш, ун, унбиш, егерме, илле тиенлек металл акча, тиен акча. *Талон алганда вак акчам җитмәгәч, 13 тиен Хикмәттән сорап торам.* Г. Мөхәммәтшин. **Вак бәлеш** *махс.*— эченә ит яки җимеш катыш ярма салынган, тышлыгы әче камырдан басылган түгәрәк кечкенә бәлеш (татар халкының милли таба ашы). *Кемнәрдер дарчин, имбир сата, кемнәрдер, бик каты кычкырып, дөгеле, итле вак бәлеш тәкъдим итә.* А. Расих. *Вак бәлеш дөге, бодай, карабодай ярмаларына ит кушып пешерелә.* Ю. Әхмәтҗанов. **Вак иләк** — еш иләк. **Вак калибрлы** — көпшә куышлыгы кечкенә диаметрлы булган (ату коралы турында).— *Мин вак калибрлыдан яхшы атам.* Г. Гобәй. **Вак товар**— арзан бәяле һәртөрле галантерея әйберләре. [*Вәли*], *урамга чыккач, вак товар белән сату итүче Сафыйга очрап, аның белән сөйләшеп китте.* М. Гафури. **Вак товарчы** — шундый әйберләр сатучы сәүдәгәр; кырык тартмачы. *Вак товарчы Сафый, аз гына баргач та, сүзне хәзер генә үткән җыелышка борды.* М. Гафури.

◇ **Вак балык** *кимс. ирон.*— зур, әһәмиятле эшләр күрсәтмәгән, җәмгыятьтә әһәмияте бик кечкенә булган, икенче дәрәҗәдәге кеше. *Мәкаләнең баш өлешендә бик тәфсилләп Яңгураның медицина өлкәсендә кем булуы, аның кыю фикерле новаторлыгы һәм аңа каршы өерләре белән кызгалган вак балыклар турында язылган иде.* Г. Әпсәләмов. **Вак балыклар арасында йөзгән чабак** *сөйл.*— булдыксыз кеше. *Малайны да, мине дә беләләр, вак балыклар арасында йөзгән чабаклар түгел без.* Ф. Хөсни. **Вак бәрәңге** — *к.* вак пешка. **Вак бөҗәкләрне күреп тә, филне абайламау (абайламый узу)** *ирон. кит.*— бик күренекле, бик әһәмиятле, билгеле нәрсәне күрми үтү, сизмәү. *Ясыйсы нәтиҗәне алдан ук билгеләп кую — фактлар белән үзе теләгәнчә уйнауга, чебенне филне итүгә, яисә, киресенчә, вак бөҗәкләрне күреп тә, филне абайламый узуга китерергә мөмкин.* И. Нуруллин. **Вак иләктән иләү (уздыру, үткәрү)** — берәр эшкә бик җентекләп тикшереп сайлап алу. **Вак пешка** — коллективта, җәмгыятьтә әһәмияте бик кечкенә булган, абруйсыз, дәрәҗәсез кеше турында. *Унлап кешене тоттыруы өчен генә гитлерчылар аның җинаятен гафу итмәячәк. Ул һаман вак пешка булып калачак.* Г. Әпсәләмов. **Вак салу** *иск.*— вак тәмәкене тел астына салу (татар муллаларына Бохарадан кергән гадәт). [*Мәгъсүмнең*] *эче пошар, вак салыр, шуның берлә башын җиңелләндерер, кайгысын таратып, күңелен юатыр иде.* З. Һади. *Моннан соң бик суфый да булачакмын, әфьюн ашау, вак салуны куячакмын.* Г. Камал. **Вак сүзле** — вакчыл, юк-бар кимчелекләр таба торган (кеше турында). *Сөйкемле әнкәсенең хәзер әнә шулай вак сүзле, кырыс чырайлы, көнчел һәм бәйләнчек каенанага әверелә баруы бик аяныч иде.* Г. Бәширов. **Вак сүзлелек**— вак сүзле булу. *Аның Хәбирәсе — качып киткән хатыны — бу өйдә ике нәрсәдән газап чикте: берсе — Сафаның аз сүзлелеге, --- ә икенчесе — Мәликәнең бик күп һәм бик вак сүзлелеге иде.* А. Шамов. **Вак тараканга азык булу** *сөйл.*— бирелгән вәгъдәләр, корылган планнар үтәлмәү, тормышка ашмау. *Әмма ул вәгъдәләр, халык әйтмешли, вак тараканга азык булып кала.* Г. Ахунов. **Вак халык** — җәмгыятьтә әһәмияте бик кечкенә булган, икенче дәрәҗәдәге кеше. **Вак чабак** *кимс.*— *к.* вак балык. *Сәүдә дөньясында Африкан Африканычның исеме билгеле. Ул Исмәт кебек вак чабакларга сәлам дә бирми.* Г. Әпсәләмов. **Вак җанлы** — вөждансыз, әхлаксыз, түбән; вакчыл (кеше турында).— *Мин сине олы йөрәкле, кыю егет дип йөрсәм, син, әнвәр, вак җанлы мещан икәнсең.* Р. Ишморат. **Вак җанлылык** — вөждансызлык, түбәнлек, вакчыллык. *Куркаклыкны, вак җанлылыкны берничек тә аклап булмый.* Ш. Хөсәенов. **Вактан тураy** — 1) нәрсәне дә булса бик ваклау. [*Лоточы:*] *6, 19, 2, 7, 3, 2.* [*Кәрим:*] *Бигрәк вактан турый башладың.* Г. Камал; 2) җентекләү, бөтен нечкәлекләренә кадәр игътибар итү, җиренә җиткерү. [*Биюче*] *Гыйльми түтигә аеруча ошады: «Һай, вактан да турый инде, әй, рәхмәт төшкере!» — [диде ул].* Г. Бәширов.

ВАКАҺНСИЯ *и.* Штатта буш урын.— *Сезнең кафедрада андый-мондый вакансия юктыр? — Юк шул. Ассистентлар штаты тулы.* А. Расих.— *Миңа да берәр вакансия табылыр әле. Эш беткәнмени минем кебеккә.* Ш. Мөдәррис.

ВАКАНТЛЫ *с.* Эштә, уку йортында: штатта каралып та, шул урынга әле хезмәткәр алынмаган, буш. *Вакантлы урыннарга конкурс игълан итү.* □ *Укытучы булыр өчен вакантлы урын* [*кирәк*]. М. Бәдәйли.

ВАҚБАШ *и. бот.* Бер төре — бал, икенчесе дәвалану өчен эфир майлары бирә торган вак чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы:* мелколепестник.

ВАҚҚОРСАҚ *и. зоол.* Кәбестә күбәләге кортлары

белән туклана торган дүрт эллә канатлы вак бөҗәк; *русчасы:* наездник.

ВАКЛАГЫЧ *с.* Қаты нәрсәне вак кисәкләргә бүлгәли, ваклый торган. *Алгы бүлмәдә тамыразыкларны югыч һәм аларны ваклагыч машиналар урнаштырылган.* Сов. әд. // *и. мәгъ. тех.* Қаты нәрсәне вак кисәкләргә бүлгәли, ваклый торган машина; *русчасы:* дробилка.

ВАКЛАНМА *и. мат.* Берәмлекнең бер яки берничә тигез өлешләреннән төзелгән сан. *Гади вакланма. Унарлы вакланмалар. Аралаш вакланма.*

ВАКЛАНМАЛЫ *с. мат.* Вакланмалардан торган. *Вакланмалы саннар. Вакланмалы күрсәткечләр.*

ВАКЛАНУ *ф.* 1. *Кайт. һәм төш. юн. к.* ваклау (1 мәгъ.). [*Акбурның*] *он кебек вакланганын --- карап йөрдек.* Г. Гобәй. *Кварц вакланудан барлыкка килгән ком пыяла ясау өчен китә.* М. Кәримов.

2. Зурлыгы, күләме ягыннан кечерәю. *Терлекләр арасында зыянлаулар күп булды, вакландылар, арыкландылар алар.* Ә. Еники.

3. *күч.* Яшь ягыннан кечерәю, яшәрү.— *Чыныккан кешеләр кирәк. --- Бик кирәк, югыйсә вакланып барабыз. Бала-чага күбәйде.* Г. Ахунов.

4. *күч.* Үзенең дәрәҗәсен төшерердәй юк-бар, вактәяк, әһәмиятсез эшләргә катнашу. [*Фатыйма*] *шәһәр «нәмәрсә»се каршында үзенең бәясен төшермәде, вакланмады, башын югары тотып, горур елмайган хәлдә сөйләште.* А. Расих.

5. *күч.* Вак-төяк, юк-бар, чүп-чар нәрсәләргә чиктән тыш әһәмият бирү; вакчыллану.— *Юк-бар белән вакланып йөрмә!* Г. Ибраһимов.

ВАКЛАП *рәв.* 1. Аз-азлап, бүлгәләп.— *Тиешен дә ваклап, ярым-йорты итеп түлиләр [алар].* Ә. Фәйзи. *Пассаж, ваклап сату белән бергә, зур күләмдә күпләп сату эшен дә алып бара.* Каз. утл.

2. Җентекләп, төпчеп, бөтен нечкәлекләренә кадәр. *Городовой артык ваклап сорашмады.* Ш. Камал. *Сәфәр планымны бик иплә п, ваклап төзедем.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

◇ **Ваклап турау** *сөйл.— к.* вактан турау.— *Эше шулай башны югары тотарга мәҗбүр итә, энекәш. Югыйсә, монда бик алай ваклап турый башласаң, хәтәр.* Ф. Хөсни.

ВАКЛАП-ТӨЯКЛӘП *рәв.* Аз-азлап, берәмләп. *Барлык игенен, ваклап-төяклә п, ярлырак таныш-белешләренә өләшеп куярга уйлады ул.* И. Гази.

ВАКЛАУ *ф.* 1. Вак кисәкләргә вату, бүлгәләү, тураклау. *Тимер тырма --- зур кәсләрне тузан кебек ваклап китә.* М. Гафури. [*Хәлим*] *учак өчен утын ваклый.* И. Гази.

2. Эре акчаны барысы бергә шул ук бәяне тәшкил иткән акчаларга алмаштыру; вату. *«Вакласам — бетә» дип, вакламыйча саклап торган бердәнбер утызлык акчам бар иде.* Ф. Хөсни.

3. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәгә бөтен ваклыкларына кадәр игътибар итү; җентекләү, бөртекләү.— *Карап торам да, [эшне] бик ваклый башлагансың әле син, Нәфисә кодача.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Үз көчен, энергиясен, мөмкинлекләрен, мәхәббәтен, хисләрен, рухи байлыгын әһәмиятсез, юк-бар, вактәяк эшләргә әрәм итү. *Йөргән җирдә мәхәббәтне, Тойгыны таптамадым. Төрле-төрле кисәкләргә Бүлгәләп вакламадым.* Ә. Ерикәй. *Бай табигатьле кыз ул, ләкин бөтен рухани байлыгын ваклап әрәм итә, чәчелә, сибелә.* И. Гази.

ВАКЛАУЧЫ *и. мат. иск.* Вакланмада берәмлекнең ничә тигез өлешкә бүленүен күрсәтә торган сан; бүлүче. *Вакланманың уртак ваклаучысын табу.*

ВАКЛАШУ *ф. сөйл. к.* вакчыллану. *Бу эш гараж һәм складлар каравылчысының вазифасына керми керүен, әмма гомере буена ялкаулыкның нәрсә икәнен белмәгән карт әллә ни ваклашып тормый.* М. Шәрифуллин. *Күрше авылларның бай һәм иген чәчә торган кешеләре печән чабу, урак урдыру өчен алдан акча бирергә сатулашалар, печән чабарга көнлек хакы 40 тиен, урак урырга дисәтинәсенә икә тәңкә акча һәм бер пот арыш оны биреп ваклашалар иде.* М. Гафури.

ВАКЛЫК *и.* 1. Нечкәлек, вак деталь. [*Күчәрбай*] *ничек итеп тауга менүебезне, менгән чакта саескан оясына очравыбызны, шөпшәдән чагылуыбыз кебек бөтен ваклыкларына кадәр тукталып, көлдерә-көлдерә сөйләде.* М. Әмир.

2. Зур әһәмияткә ия булмаган кечкенә вакыйга, күренеш. *Тормыш ваклыклары.* □ [*Г. Камал*] *геройларының тормышны аңлаулары базар, мәчет, ул өйләндерү, кыз бирү, кием-салым һәм ашау-эчү кебек ваклыклардан ерак китми.* М. Гали. // Әһәмиятсезлек, бушлык. *1940 елда ук «Н. Дәүли шигырьләре уңае белән» исемле мәкаләсендә Г. Халит поэзиядәге бертөрлелекне, тема ваклыгын --- тәнкыйть ит[ә].* И. Нуруллин. // Әһәмиятсез, вак-төяк нәрсәләргә зур игътибар итү. *Бәлки, Мәдинә дә үзгәргәндер, ваклыктан һәм мещанлыктан тәм табучы хатынга әйләнгәндер.* Ш. Хөсәенов.

3. *күч.* Түбәнлек, дәрәҗәне, абруйны төшерә торган эш.— *Мин анда кереп җавап бирүне үземә ваклык саныйм!* Г. Ибраһимов. // Әшәкелек, кабахәтлек. *Күр әле: нинди түбәнлек[тә ич] без, изге ак вөҗдан да юк, ваклык һәм җансызлыкта без.* Гыйффәт туташ.

ВАКЛЫ-ТӨЯКЛЕ *с.* 1. *к.* вак-төяк (3, 4 мәгъ.).

2. Җиңелчә булган. // *рәв. мәгъ.* Җиңелчә. *Бикмуш бабай эше алга бармаган чакларда ваклы-төякле сүгенгәләп алырга, тфу, шайтан, дип төкергәләп куярга ярата иде.* Г. Гобәй.

ВА'ҚСА *и.* Туң май белән балавызга корым кушып ясалган һәм күн аяк киемнәрен чистарту өчен кулланыла торган крем. *Мөнир чоланнан алган күн итек, Вакса сылаган аңа күп итеп. Чистарта торгач, Итек ялт иткән.* Ш. Галиев.

ВА'ҚСАЛАУ *ф.* Күн аяк киемен вакса белән чистарту, ялтырату.— *Әй, кызым, минем яңа штиблетларымны ваксалап куй әле.* Ф. Әмирхан.

ВАҚСЫНУ *ф.* 1. Берәр нәрсәне вак, әһәмиятсез, икенче дәрәҗәдәге дип санау. // Үзен түбәнсетү, дәрәҗәсен төшерү. *Шагыйрь. --- Ул Харис абзый кебек балалар укытучы бер хәлфә белән ваксынып маташырмы икән соң?* С. Қудаш. *Зәйнәп аның кем угылы булуын, кайда укыганын һәм бай баласы икәнен белгәнгә күрә, аның [фәкыйрьләр арасында] ваксынып йөрүенә гаҗәпсенә иде.* М. Гафури.

2. Вак-төяк нәрсәләргә игътибар бирү; вакчыллык күрсәтү. [*Мәрҗани*] *юк-бар белән ваксынмый, күбрәк вакытын китап уку белән үткәрә.* Ак юл. *Мин үзем хатын-кыз эшенә тыгылып ваксынырга яратмыйм.* М. Шабай.

ВАҚСЫТУ *ф.* Қимсетү, мыскыллау, хурлау. *Наширлар: «Син бу язганыңны безгә бир, фәлән нашир сиңа аз биргән, ул вөҗдансыз!» —* [*дилә р*]. *Менә шулар мине тәмам ваксыттылар, изделәр...* Г. Тукай. *Мөхип әби бу хәрәкәтләрдә Гайниҗамал тарафыннан сансызлык, кибетче тарафыннан «кеше белән кеше арасын аермыйча ваксыту» хис итте.* Ф. Әмирхан.

ВАҚ-ТӨЯҚ *с.* 1. Күләме, микъдары ягыннан зур булмаган, кечкенә, вак (җанлы һәм җансыз әйберләр хакында). *Карчыга вак-төяк кошларны ашый.* Г. Тукай. [*Нигъмәт*], *вак-төяк такталарны ярып, котелок астына улак эчендә ут якты.* Ф. Кәрим. // *и. мәгъ.* Үз ишләре белән чагыштырганда кечкенәрәк, ваграк булган (җанлы-җансыз нәрсәләр турында). — *Хәзер совхозда, вак-төяген исәпләмәгәндә, аяклы мал йөз башка җитте.* Г. Ибраһимов.— *Бакчамыни бу, --- вагы-төяге белән фәлән пот алма чыгар, аның да яртысы кортлы булыр.* И. Гази. // Зур булмаган, күп көч сорамаган (гадәттә көндәлек эш хакында); аз-маз. *Вак-төяк эшләр дә аны*

бик арыталар. Г. Ибраһимов.— *Амбарларга, сушилкаларга вак-төяк төзәтүләр кирәк.* Т. Гыйззәт.

2. Яше зур булмаган, кечкенә (балалар турында).— *Бала-чага кыйнаган саен усаллана. Шуңа күрә теңкәсе корган карчыклар вак-төяк ыбыр-чыбырны үзләре белән монастырьга өстериләр.* Қ. Нәҗми.

3. Бәясе югары булмаган (гадәттә кечерәк әйберләр турында). *Вак-төяк нәрсәләрне: мәсәлән, савыт-сабаны, кием-салымны, өй җиһазларын һәм шуның кебек бүтән әйберләрне һәр кешенең үзендә калдырырга, --- [ә] сыерларны, атларны, сарыкларны --- җыеп алып, атсыз, сыерсыз кешеләргә бүлеп бирергә* [*кирәк*]. И. Гази.

4. *күч.* Җәмгыятьтә зур урын тотмаган, дәрәҗәсез (кеше турында). [*Мәхмүт*] *үзенең хәзрәт белән вак-төяк кешеләр аңламый торган зур мәсьәләләр хакында сөйләшеп утырганын белдер*[*ә*]. М. Гафури. // Зур әһәмияткә ия булмаган, әһәмиятсез. *Һәр ике* [*оешмада*] *милләт өчен әһәмиятле эшләр урынына әллә нинди вак-төяк хәрәкәтләр белән* [*чикләнәләр*]. Ф. Әмирхан. *Кыш буена бөтен фронт буйлап, вак-төяк атышлардан --- башка, зур сугышлар булмады.* М. Гали. // *и. мәгъ.* Ваклык (2 мәгъ.). *Көнкүреш вак-төяге арасыннан да ул киләчәккә юнәлгән матур уйлар тартып чыгара торган иде.* Г. Бәширов. *Сүзне тормыштагы вак-төякләргә борырга туры килде.* А. Шамов.

5. *и. мәгъ. к.* ваклык (1 мәгъ.). *Ул* [*кызылармеецларның*] *күзенә чалынган барлык вак-төякләрне бик җентекләп сорашып бетергән.* А. Шамов.

ВА'ҚУУМ *и. физ. тех.* Һава үткәрмәүчән приборда яки савытта газның яисә элек калган һаваның сирәкләнгән хәле; гомумән, һавасыз бушлык. *Насослар ярдәмендә трубаларда вакуум (бушлык) булдырыла.* Қаз. утл. *Галәм, әнә, чиксез вакуум ич.* Х. Туфан. // *с. мәгъ.* Шундый бушлык барлыкка китерә торган. *Түрдә --- вакуум насослар* [*күренә*]. М. Хәсәнов.

ВАҚХАНА'ЛИЯ *и.* **1.** Борынгы Римда аракы һәм уен-көлке алласы Вакх (яки Дионис) хөрмәтенә үткәрелә торган бәйрәм.

2. *күч.* Фәхеш белән, бозыклык белән бәйләнгән шаушулы эчү мәҗлесе. *Бай йортларында банкетлар, --- исерек кичәләр, фәхеш, гомумән, вакханалия көннән-көн көчәя барды.* Қ. Тинчурин.

ВАҚЦИ'НА *и. мед.* Йогышлы авырулардан саклану һәм дәвалану өчен кешеләргә, хайваннарга кертелә торган дару (ул шул авыруларны тудыра торган микробларның көчсезләндерелгәннәреннән яки үлеләреннән ясала). *Профессор --- әсиргә тиф вакцинасы* [*ясаган*]. Х. Камалов.

ВАҚЧЫЛ *с.* Вак-төяк, әһәмиятсез нәрсәләргә дә игътибар итүче, юк-бар өчен ачуланучы, тиргәүче. *Ул Мансурның вакчыл түгеллеген, тырнак астыннан кер эзләмәвен, үч сакламавын --- күреп алган иде инде.* Г. Әпсәләмов. [*Ул*] *коточкыч вакчыл һәм үзсүзле картка әверелде.* Р. Төхфәтуллин.

ВАҚЧЫЛЛАНУ *ф.* Вакчыл булу, вакчыл кешегә әйләнү. *Хәдичәнең таләпчәнлеге чамадан ашты, вакчылланууга кадәр барып җитте.* М. Хәсәнов.— *Ярый инде, вакчылланма. Сиңа ни әйтәләр, шуны эшлә.* Т. Гыйззәт.

ВАҚЧЫЛЛЫҚ *и.* Вакчыл булу. [*Надзиратель*] *үзенең үтә вакчыллыгы белән телгә кергән иде. Аңа тоткынның авызыннан актык мундштугын яки кулындагы зажигалкасын тартып алу берни тормый иде.* Г. Әпсәләмов.

ВАҚЫЙГ *и. иск. кит.* **1.** Чынбарлыкта була торган эш яки хәл; чынбарлык. *Кайвакытлада бу* [*сын, пот*] *киләчәктәге эшләрдән дә хәбәр бирепләр, вакыйгага бик тугры китерә.* Г. Тукай. *Бу хыял түгел, бу — вакыйг, бу — тормыш.* Г. Ибраһимов.

2. *рәв. мәгъ. ү.-з. килеше.* **вакыйгда.** Чынлыкта, дөреслектә, чыныңда. *Иске мәхәббәтләребез искә төшеп, «сөеклем» дип яза башладым. Вакыйгда сиңа «хыянәтче, алдакчы бер намуссыз» дип* [*эндәшергә*] *кирәк.* М. Гафури. *Аның хакында --- берәүләр, йорт-җирен сатып, калага күчә, имеш, диләр. --- Вакыйгда исә, хәзратнең бик еш калага иген озатуы белән, атна саен диярлек яхшы ат җиктереп, шәп киенеп, каядыр югалуы гына бар иде.* Г. Ибраһимов.

Вакыйг булу *иск. кит.*— чынбарлыкта килеп чыгу; барлыкка килү, туу. *Бу ел бөтен табигатькә яңа бер хәл вакыйг булган.* Г. Тукай. *Бу уйларның вакыйг булуына ышанырга мөмкин* [*түгелдер*]. Ф. Әмирхан.

ВАҚЫЙГА *и.* **1.** Шәхси яки иҗтимагый тормышта килеп чыккан, булган эш-хәл, күренеш. *Революция вакыйгалары. Лена вакыйгалары. Төнге вакыйгалар.* ☐ *Марат ике вакыйганы: әти-әниләре белән Ленинградта Нева суында йөргәнен һәм Илдарлар белән Аккош күлендә йөргәнен бутый.* Г. Гобәй. *«Қачқын» операсының куелышы — татар совет культурасы тарихында зур вакыйга.* М. Җәлил.

2. *әд.* Әдәби әсәрдә сурәтләнә торган эш-хәлләр. *Бу әсәрдә бөтен вакыйга татар мещанкаларына гына хас булган бирнә күлмәк тирәсенә тупланган.* М. Гали. *Либреттода вакыйгаларның үсеше юк. Күп кенә хәлләр үстерелмәгән, ахырга чаклы җиткерелмәгән.* М. Җәлил.

ВА'ҚЫЙГАН *кер. сүз. иск. кит.* Чынлап та, чыннан да, дөрестән дә.— [*Берсе*] *бик дәртләнеп җырлый. Ә, Зариф старшина угылыдыр. Чана якынайгач, Зыя җырлаучыны тавышыннан таныды, вакыйган, шул старшина угылы Гыйльман икән.* Г. Ибраһимов.

ВАҚЫЙФ *с. иск. кит.* Берәр нәрсәне аңлап белүче, төшенүче, берәр нәрсәдән хәбәрдар. *Толстой әсәрләренең дә хәзер дөньяда бик куәтле бер* [*мәктәп*] *тәрбия иткәнлеге* [*дөнья хәлләреннән*] *вакыйф һәркемгә мәгълумдер.* Ф. Әмирхан.

Вакыйф булу *иск. кит.*— 1) төшенү, аңлау, белү. *Моңарчы хикәяләрдә генә укыган бу як тормышын үзем күрәм, үзем аралашып йөреп күп кенә серләренә вакыйф булам.* М. Фәйзи; 2) берәр хәлгә дучар булу. *Җәлалов, чын вакыйф булдың әсирлек хәленә.* Ш. Бабич.

ВАҚЫТ *и.* **1.** Философиядә: материя яшәешенең объектив формасы. *Урын һәм вакыт — объектив чынбарлыкның төп формалары.* ☐ *Бернинди көч юк дөньяда Тик бер секундка булса да Вакытны туктатырга!* Ә. Исхак. *Вакыт комны ташка, ташны комга әйләндерә.* Мәкаль.

2. Нәрсәнең дә булса секундлар, минутлар, сәгатьләр, еллар, гасырлар һ. б. ш. белән исәпләнә торган яшәеш арасы, дәвамлылыгы. *Вакыт хисабы. Вакыт арасы.* ☐ *Сәгать эчпошыргыч әкрен йөрде, вакыт бик әкрен үтте.* Г. Гобәй. *Газинурлар алгы кырыйга килгәннән соң, ун көнләп вакыт үтте.* Г. Әпсәләмов. // Яшәеш дәвамлылыгын үлчәү берәмлеге. *Җирле вакыт белән. Кояш вакыты.*

3. Төп эштән башка берәр төрле шөгыльгә бирелгән көннәр, сәгатьләр; буш ара. *Вакыт табу. Вакыт уздыру. Вакытны алмау.* ☐ *Ул һәр көн типографиядә сигез сәгатьлек корректура хезмәтеннән калган бөтен вакытын шул дәресләренә бирә.* Г. Ибраһимов. *Кайчан гына килеп карама, Директорның һаман вакыты юк, Аның эше һаман кабалан!* М. Җәлил.

4. Кешелек, халык, дәүләт, җәмгыять яки аерым кеше тормышында: чор, дәвер, чак. *Сугыш вакыты. Бала вакыт.* ☐ *Агайларның күбесе, көннәр корыга китсә, --- мәҗүси вакытыннан калган йола буенча, шыпырт кына яңгыр боткасы пешерә, очраган бер кешегә су сибеп йөри иде.* Г. Бәширов. *Сабый чакларда, егет вакытларда мин аның* [*янында*] *булырга --- өйрәнгәнмен.* Г. Ибраһимов. // Урын-вакыт килешендә килеп, шарт мәгънәсен белдерә. *Оренбург әйтә: «Сөй-*

ләмә, Юк көйләрне көйләмә, Минем «Шура»м бар вакытта, Юл бирелмәс кемгә дә». Г. Камал. // Берәр эшне үтәүгә комачаулаган кире сәбәпне белдергән сүзләрне ул сүзләр караган җөмлә кисәгенә бәйләп килә.— *Мәҗәд карты булып йөрер вакытымда кире дөньяга керешергә туры килә инде.* М. Гафури.

5. Берәр эш, вакыйга барган чак. *Дәрес вакытында алар бик әдәпле утырдылар.* Г. Гобәй. *Каты давыл вакытында --- зур сал тарала.* М. Гали.

6. Елның, көннең билгеле бер өлеше, арасы.— *Иртәнге вакыт. Яңгырлы вакыт. Төш вакыты.* □ *Боз һәм кар эрде, Сулар йөгерде, Еглап елгалар, Яшьләр түгелде. Көннәр озая, Төннәр кыскара, Бу кайсы вакыт, Я, әйтеп кара.* Г. Тукай. *Вакыт кичкә таба, эңгер-меңгер чак.* Т. Гыйззәт. // Тәүлекнең сәгатьләр, минутлар белән үлчәнә торган билгеле бер мизгеле.— *Вакыт иртә әле, бары сәгать туғыз гына.* Ш. Камал.

7. Берәр эш, хезмәт өчен билгеләнгән срок. *Армиядә хезмәт итү вакыты. Эш вакыты.* □ — *Сезгә үн тәүлек вакыт бирәм, һәм шул вакытка таҗ өлгергән булсын.* А. Алиш. *Уткән ай башында үк иске ел планын вакытыннан алда төгәлләгән идем, бер айдан артык инде мин яңа ел хисабына эшлим.* Г. Минский. // Билгеләнгән срокның чиге. *Бертөрлерәк атлылар өчен таңда чыгып, чакырылган вакытка, сәгать җидегә, килеп җитү авыррак.* Г. Ибраһимов.

8. Момент, мизгел, чак. *Ул Нәфисәдән нидер көтә, ниндидер сер әйтәсе бар кебек, җайлы вакыт чамалап йөри.* Г. Бәширов. *Башта миңа бик уңайсыз тоелды. Ләкин шул үк вакытта акылымны башыма тупладым.* Ш. Камал. // Берәр нәрсә эшләр өчен мөмкинлек, уңайлы шарт; форсат, очрак.— *Кара аны, --- вакытны ычкындырма, берәр көн алданрак барып күр.* Г. Минский.— *Бүген без аны кыйнасак, икенче бервакытны, вакытын туры китереп, аларның да безне кыйнау ихтималлары бар.* Г. Камал. // *тарт. форм.* **вакыты.** Билгеле бер эшне башкару өчен кирәкле, уңай дип табылган момент.— *Мин сүгәм дә, вакытын белеп сүгәм.* Ш. Камал. *Һәр эшнең үз вакыты, үз тәртибе бар.* И. Гази.

9. *хәб. функ.* Берәр нәрсә эшләү, үтәү моменты җитүне белдерә.— *Сәгать ике бит, безгә таралырга вакыт!* Г. Ибраһимов.— [*Ул*] *кыргый гадәтләреңне ташларга вакыт, балам.* Т. Гыйззәт.

10. Иген, үсемлек, җиләк-җимешнең җитлегү һәм аларны җыю вакыты; сезон. *Печән вакыты җитте.* Ш. Камал.

11. Хат, шигырь, хикәя һ. б. ш. язылу, иҗат ителү моментын күрсәткән билге; дата. *Җыентыкка кергән җырларның берсенең дә җырлану, күчерелү вакытлары юк.* М. Җәлил.

◇ **Вакыт килер (җитәр)** — берәр нәрсә эшләр өчен мөмкинлек, уңайлы шарт тууга ышаныч белдергәндә әйтелә.— *Килер вакыт, син теләгеңә ирешерсең.* Г. Бәширов. *Вакыт җитәр: без дә гөлбакчага Уратырбыз комлы сахраны!* Ш. Мәдәррис. **Вакыт(ны) оту** — куелган максатка ирешү юлында берәр эшне башкару өчен тиешле вакытка экономия ясау, вакытны уңышлы файдалану. *Валя үлеме турында Кимга хәбәр итмәгәннәр икән, [моны] вакыт отар өчен, ул кайтканчы уйланып, төпләнеп калыр өчен эшләгәннәр.* С. Баттал. **Вакыты белән** — 1) кайчакларда; вакыт-вакыт. *Кайбер вакыты белән үткер сүзләр әйткәлиләр.* Г. Нигъмәти; 2) эшләү, ашау, ял итү, йоклау өчен билгеләнгән ныклы тәртип, режим. [*Хәлим*] *атның корчаңгысын дәвалады. Вакыты белән генә ашатты, бик белеп кенә эчертте.* Г. Гобәй; 3) кирәге чыкканда, кирәк булганда, туры килгәндә. *Аларның --- вакыты белән шаяра да белә, җитди дә була ала торган яхшы күңелле һәм уңган иптәшләре — Әнвәрев юк.* А. Әхмәт; 4) вакыт үтү белән, акрынлап, җай белән.— *Кеше вакыты белән бар нәрсәгә дә күнегә.* Ә. Фәйзи. — *Вакыты белән бары да булыр әле.* Ф. Бурнаш; 5) *к.* вакытында. **Вакыты илә (илән)** *иск.*— *к.* вакыты белән. **Вакыты җитеп** — картаеп, яшен яшәп, картлык көненә җитеп (гадәттә кеше үлгәннән соң әйтелә).— *Ул, бичара, вакыты җитеп --- үлде.* М. Гафури.

ВАҚЫТ-ВАҚЫТ *рәв.* Ара-тирә, әледән-әле; кайчакларда, кайвакыт.— *Вакыт-вакыт бик артык кызып китүләрең өчен мин сине гаепләмим.* Г. Ибраһимов. *Җәйге яңгыр килә төньягыннан, Вакыт-вакыт дымсу җил исә.* Г. Хуҗи.

ВАҚЫТЛЫ *с.* **1.** Беркадәр вакыт эчендә генә бара, хәрәкәт итә, эш итә яки кулланылышта була торган, алмашынучан; *киресе:* даими. *Вакытлы революцион хөкүмәт.* □ — *Бу ярдәм вакытлы гына булмаячак. Безнең промысел сезнең «Уңыш» колхозын даими шефка алды.* А. Әхмәт. *Янар таулар көчле — Җирне тетрәтәләр, Тик вакытлы алар — сүнәчәк. Ә мин менә комсомолда Озак еллар өчен үсәчәк.* Ф. Кәрим.

2. *рәв. мәгъ.* Тиешле, кирәк чакта, нәкъ моментына; соңга калмыйча. *Без үзебезнең бик вакытлы килеп җиткәнебезне белдек.* Ә. Айдар.— *Димәк, Гриша, без бүгенге көн тәртибен дөрес һәм вакытлы куйганбыз.* Т. Гыйззәт. // Билгеле бер вакытта, куелган тәртипне, режимны бозмыйча. *Вакытлы ятып, вакытлы йоклап, вакытлы торганга күрә, ул бүген үзендә --- башка көннәрдәгедән аерым җиңелчә генә бер көч сизә иде.* Ф. Әмирхан.

Вакытлы матбугат — билгеле бер ара саен чыга торган газета һәм журналлар. *Бу истәлекләр вакытлы матбугатта — «Кызыл Татарстан» битләрендә басылганнар иде.* Г. Гали.

ВАҚЫТЛЫ-ВАҚЫТСЫЗ *рәв.* **1.** Гел, кирәксә-кирәкмәсә; теләсә кайчан. [*Әхмәтсафа агай*] *угылы Хәсәншага һәм приказчикларына вакытлы-вакытсыз шәһәргә чыгып, эшсез анда-монда йөрергә рөхсәт бирми торган иде.* Ш. Мөхәммәдев. // *с. мәгъ.* Кирәкмәсә дә гел була торган.— *Хәзер инде вакытлы-вакытсыз явымнарны көт тә тор.* Ш. Камал. // *с. мәгъ.* Урынсыз, кирәксез.— *Ташлагыз әле шул вакытлы-вакытсыз шаяруларыгызны!* И. Гази.

2. Гадәттәгедән бик иртә яки бик соң.— *Алай миңа вакытлы-вакытсыз килеп борчып йөрмә!* Г. Камал.

ВАҚЫТЛЫЛЫҚ *и.* Вакытлы булу.— *Без бит сезнең белән икебез дә вакытлы урынбасарлар... Ә вакытлылыкның кайчан да булса бер чиге булырга тиеш.* Ә. Фәйзи.

ВАҚЫТЛЫ'ЧА *рәв.* Билгеле бер срокка кадәр; *киресе:* даими рәвештә. *Бригадир аларның барысын да --- вакытлыча, кышка кадәр, төрлесен төрле участокка җибәрергә мәҗбүр булганлыгын әйтте.* Г. Әпсәләмов. *Әмма бу эшләр самодержавиенең золымыннан, ачлык вә фәкыйрьлек бәлаләреннән вакытлыча гына коткарыр.* РСДРП прокламациясе.

ВАҚЫТСЫЗ *с.* **1.** Буш вакыты булмаган. *Бакчы, уенын башлаган, күңелен биргән курчагына, Күр бәхетсезлекне, тап килдем вакытсыз чагына.* Дәрдмәнд.

2. Уңайсыз, җайсыз, тиешсез, көтелмәгән, башкаларның кирәге булмаган. *Бик вакытсыз чакта Нургалинең күзенә килеп күренде бу Сөләйманов. Шундый иртә яшь кәләш кочагыннан торып йөрергә ни пычагым калгандыр.* Ә. Еники. // *рәв. мәгъ.* Тиешсез, җайсыз вакытта. *Алар үбешкәндә, Харис килеп керә дә: «Ай, вакытсыз кергәнмен!» — дип, тиз генә чыгып китә.* А. Әхмәт.

3. Бик иртә я бик соң. [*Гайни:*] *Бу вакытсыз вакытта кем йөри икән, дисәм, син икәнсең әле.* [*Закир:*] *Башка вакытларда моннан да соң килә торган идем, бер сүз дә әйтми торган идең бит.* Г. Камал. // *рәв. мәгъ.* Тиешсез вакытта, соңлап.— *Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?* Г. Тукай.

4. Көтелгәннән бик иртә, элек. *Вакытсыз үлем. // рәв. мәгъ.* Бик иртә, элек.— *Гомер буена кирелегең белән җаныма тидең, вакытсыз чәчемне агарттың.* Т. Гыйззәт. *Кайгы кешене вакытсыз картайта.* Мәкаль. *// рәв. мәгъ.* Билгеләнгән, тиешле вакыттан элек.— *Ашыкма, --- вакытсыз чәчәк тә атмый, сәгатең тулгач, ачармын.* Әкият.

ВАҚЫ'ТЧА *рәв. иск. кит. к.* вакытлыча. *Әгәр без, үзебезнең гомеребезнең ачылыкларын вакытча онытып, үзебезне чорнап алган дөньядагы гомерләргә карасак, бу тормышлар әллә нинди гаҗәп күренер.* Г. Тукай. *Зәйнәп инде әүвәлге Зәйнәп түгел, күңеле тәмам сынган, --- вакыт җитеп үлмәгәнгә күрә, вакытча бу дөньяда тора иде.* М. Гафури.

ВАҚЫТЫНДА *рәв.* **1.** *к.* заманында.— *Вакытында бик күп кайгылар да, авырлыклар да кичердек. Ә хәзер, аллага шөкер, баламның рәхәтен күреп бетерә алмыйм.* А. Шамов.

2. Тиешле вакытта. *Анда бик салкын вә Бик эссе түгел, урта һава, Җил дә вакытында исеп, Яңгыр да вакытында ява.* Г. Тукай. *Гакыллылар эшен вакытында эшли.* М. Гафури. // Кирәкле вакытта, моментында (көтелмәгән эш, бәхетсезлек булганчы). *Мисбах басма аркылы чыкканда суга егылып төшә язды. Ярый әле арттан килүче сержант Морозовның көчле куллары аны вакытында тотып калды.* Г. Әпсәләмов.

ВАЛ I *и.* Дошманнан саклану өчен яки хуҗалык максатларыннан чыгып, туфрактан өеп ясалган озын һәм биек ныгытма. *Крепость валы.* ▭ [*Перекопның*] *Кырымга таба ягына ун метр биеклектә балчык өелгән. --- Валның стенасы да тимер чыбык стенасы белән әйләндереп алынган.* Г. Бәширов. *Унбиш, ә урыны-урыны белән утыз-кырык метр биеклегендәге валлар, меңнәрчә километрларга сузылып, бу илләрне диңгез китерүе мөмкин булган һәртөрле афәтләрдән саклап торалар.* Х. Ярми.

ВАЛ II *и. тех.* Төрле механизмнарда: терәкләрдә әйләнеп, механизмның үзе белән тоташкан башка кисәкләрен дә әйләндерә торган металл (яки агач) үзәк. *Бүлү валы. Ишкеч вал. Терсәкле вал.* ▭ *Цилиндр эчендәге туры валның терсәккә тоташкан ягы шактый көкрәйгән.* Ш. Камал. *Ташны йөртә торган вал нинди зыр-зыр әйләнә...* И. Гази.

ВАЛЕНТЛЫ *с. хим.* Бер, ике, өч һ. б. саннар артыннан килеп, үз атомы шул сандагы башка химик элемент атомнары белән кушыла алырга сәләтле (химик элемент турында). *Ике валентлы.*

ВАЛЕНТЛЫҚ *и. хим.* Берәр атомның билгеле бер сандагы башка атомнар белән кушыла алу сәләте. *Даими валентлык.*

ВАЛЕРЬЯ́Н, ВАЛЕРИА́Н(А) *и.* **1.** *биол.* Тамырлары медицинада файдаланыла торган үлән үсемлек; песи үләне.

2. *мед.* Шул үсемлек тамырыннан ясалган дару.— [*Ул*] *больница юлыннан кайтып керми. --- Үзеннән һәрвакыт я валерьян, я йод исе килеп тора.* Г. Мөхәммәтшин. *Ул ашыга-ашыга стаканга валериан тамчысы тамызды да тизрәк эчеп җибәрде. Аннан соң --- йөрәк турысын капшап карады.* Н. Дәүли.

ВАЛЕРЬЯ́НКА, ВАЛЕРИА́НКА *и. сөйл. к.* валерьян. *Голикова, һушыннан язып, әллә ничә шешә валерьянка бетерде.* Қ. Нәҗми.— *Валерианка гына тота идем. Қайчакны тынычлану өчен...* Э. Қасыймов.

ВАЛЕТ *и.* Уен карталарында: егет рәсеме ясалган, **унлык** белән дама арасындагы карта. *Буби валеты. Пики валеты.* ▭ — *Бир валетны, нәрсәгә саклыйсың.* Ш. Камал.

ВАЛИ *и. иск. кит.* Губернатор. *Күп валиләр ярышты, Манифестка карышты.* Г. Камал.

ВАЛИДОЛ *и. мед.* Йөрәкне тынычландыра һәм күңел болгануны туктата торган дару. *Сибгат абый Әхмәт Ерикәйдән валидол сорап алуымны үтенде --- Вечтомовадан бу даруның нинди авырудан икәнлеген сорадым. Ул йөрәгенә күрсәтте.* С. Сөләйманова. *Идрис кергәндә Фаина Наумовна валидолын суырып бетереп килә иде.* А. Гыйләҗев.

ВА'ЛИҚ *и.* **1.** Кечкенә вал II. *Фонограф валигы.* ▭ *Лабораториядә чит илдән китерелгән бер аппаратның валигын сындырдылар.* Г. Әпсәләмов. *Булатов матрицаны валикка беркетеп, буяулап алды да аяк машинасын әйләндерә башлады.* Ш. Маннур.

2. Қиң йомшак диванның, тахтаның ике башына куела торган, тыгыз итеп сүс тутырылган озынча түгәрәк мендәр.

ВА'ЛЛА(Й) *ы. сөйл. к.* валлаһи.— *Җанашым, бәгырькәем. Валла, мин сине ташламам.* А. Расих.— *Билләй, валлай дип әйтәм, артымнан елап иярсә дә, сине аңа алыштырмам.* М. Фәйзи.

ВА'ЛЛАҺ *ы. сөйл. иск. к.* валлаһи. *Үзе бик сөядер, валлаһ.* Г. Қандалый.— *Шул икенең кайсын аласың дисәләр, алтын тавына әйләнеп тә карамас, валлаһ, әйләнеп тә карамас, мөдәррислекне алыр идем.* Г. Ибраһимов.

ВА'ЛЛАҺИ *ы. сөйл.* Сөйләгән сүзенең дөреслеген раслау, кешеләрне ышандыру өчен кулланыла торган ант итү сүзе.— *Әй Сәрби, валлаһи, биллаһи әгәр, икмәкнең бөртеген күрергә мохтаҗ булыйм менә, яратам.* Ф. Бурнаш.— *Ышан, Дәүләтша, валлаһи, бездә булганы юк.* Т. Гыйззәт. // Берәр нәрсә эшләмәскә үтенгәндә ялвару сүзе.— *Җизни, --- валлаһи, әйтмә, мин, әйтсәң, дөнья туздырып елыйм.* Г. Ибраһимов. // *и. мәгъ. күч. мыск.* Ант.— *Эчә торган кешенең валлаһие тишек кесәдә генә йөри ул. Аракы күрде исә, хәзер төшә дә кала.* Қ. Әмири.

◇ **Валлаһи газыйм** *сөйл.*—алла бөек (әйткән сүзенең дөреслегенә яки әйткәнне булдырачагына ышандыру өчен кулланыла торган элекке ант итү сүзе).— *Телисеңме, валлаһи газыйм, хәзер алып китәм үзең.* Г. Кутуй.— *Валлаһи газыйм дип әйтәм, таныймадым.* А. Расих. **Валлаһе әгъләм** *сөйл.*— алла яхшырак, күбрәк белә (тыңлаучыны ышандыру өчен әйтелгән **ант итү** сүзе).— *Валлаһе әгъләм, аның өчен генә бу мажара булмастыр.* Қ. Тинчурин. **Валлаһи әгәр** — *к.* валлаһи.— *Валлаһи әгәр, моннан ары тамчысын да капмыйм.* Р. Төхфәтуллин. [*Сәгыйдулла:*] *Булмас ла...* [*Кәли:*] *Валлаһи әгәр.* М. Әмир.

ВАЛОҚОРДИН *и. мед.* Йөрәк тибешен нормальләштерә, тынычландыра торган дару. *Гөлшаһидә, аптечка янына барып, валокордин алды.* Г. Әпсәләмов. *Андый вакытта мин үземә врачлар язып биргән йөрәк даруларын — валокордин, корвалол* [*эчәм*]. М. Әмир.

ВАЛТО'РНА *и. махс.* Бүрәнкә сыман киңәйгән авызлы, спираль рәвешендә бөгелгән җиз көпшәле, йомшак көр тавыш чыгара торган тынлы музыка коралы.

ВАЛТО'РНАЧЫ *и.* Валторнада уйнаучы музыкант.

ВАЛУН *и.* Зур йомры таш, тау токымы ватыгы. *Бу юлны үтәр өчен --- нихәтле валуннарны шартлатырга яки күтәреп ташларга кирәк.* Г. Әпсәләмов.

ВАЛЧЫҚ *и.* **1.** Берәр нәрсәнең бик вак, бик кечкенә кисәге.— *Икмәкнең валчыгын да әрәм итәргә ярамый.* Э. Камал.— *Гади күз белән караганда, бу таш валчыгының төсен белүе дә кыен, ә микроскоп аша карагач, аның төсе дә, кыяфәте дә, сыйфаты да ачык күренә.* А. Әхмәт. // Берәр нәрсәдән кителгән ватык; кыйпылчык. [*Сөләйманов*] *снаряд валчыкларыннан саклану өчен --- йортларга ышыклана.* И. Гази.

2. *күч.* Аерым җәмгыять, сыйныф, ил яки нәселнең шул җәмгыятькә, сыйныфка, илгә хас сыйфатларын үзендә туплаган бер вәкиле. *Минем бөтен теләгем --- Мәйсәрәне аерып калдырмау иде. Чөнки Мәйсәрәнең әтисе валчыгы булуын, табигате, характеры белән атасына охшаганын да яхшы белә идем.* Ф. Сәйфи-Қазан-

лы. [*Бу кыз*] *кечкенә нәрсәне аңламый. Ни әйтсәң дә, буржуа валчыгы шул.* Г. Ибраһимов. // Берәр нәрсәнең состав өлеше, кисәге. *Кайда коточкыч тирән бер су ага... Шунда мин ташлыйм бәгырьнең валчыгын...* Ф. Бурнаш. *Мин аның туган иленең бер валчыгы бит.* И. Гази. // *ирк.* Кисәкчек, кисәк (кеше турында). *Шугалакка чыкканда, малай инде --- барлык хыял бизгәгеннән арынып, нәкъ шул көн, шул минут белән яшәүче кеше валчыгына әверелгән иде.* Ф. Хөсни.

◇ **Валчыгын да калдырмау** — берәр нәрсәне бөтенләй ашап бетерүне аңлата. *Мәче --- бәхетсез [сандугачны] валчыгын да калдырмыйча тәмамлады.* Г. Тукай. **Валчык та капмау** — бөтенләй ашамау. *Бүген бит ул әле валчык та капканы юк.* И. Гази.

ВАЛЬС *и.* Өч музыкаль тактка нигезләнеп, салмак кына әйләнеп алга барудан гыйбарәт парлы бию һәм шул биюнең музыкасы (көе). *Ераста оркестр вальс уйный.* Ш. Камал. *Өстәлләрне стена кырыена тибәреп, [кунакларның] кайберәүләре вальс әйләнә башладылар.* К. Нәҗми.

ВАЛЬЦО'ВКАЛАУ *ф. тех.* Нинди дә булса әйберне (мәсәлән, тимерне) бер-берләренә тиеп әйләнә торган цилиндрик валлар арасыннан үткәреп җәю.

ВАЛЬЦО'ВКАЧЫ *и.* Вальцовкалаучы эшче.

ВАЛЮ'ТА *и.* **1.** Берәр ил акча системасының нигезе, төп күрсәткече булган акча берәмлеге (мәсәлән, СССР-да — сум, АКШта — доллар).

2. Билгеле бер илнең акча системасы төре (алтын, көмеш, кәгазь һ. б. ш. акча). *Алтын валюта. Көмеш валюта.* □ [*Юныс бай үз*] *малының да зур өлешен, --- валютага әйләндереп, Ирандагы Англия банкысына күчерткән иде.* К. Нәҗми.

3. Чит ил акчалары.

Валюта курсы — төрле валюталарның кыйммәт ягыннан үзара мөнәсәбәте; бер ил акча берәмлегенең башка илләрнең акча берәмлекләре белән чагыштырмасы.

ВАНА'ДИЙ *и. хим.* Химик элемент; югары сортлы корыч коюда кулланыла торган ачык соры төстәге каты металл.

ВАНДАЛ *и.* **1.** Рим империясенең бер өлешен басып алып, Римны тар-мар иткән һәм талаган борынгы герман кабиләсе.

2. *күч.* Культура хәзинәләрен ерткычларча җимерүче кеше; варвар, вәхши. *Безнең һөҗүм дәһшәтенә түзми Көнбатышка качкан вандаллар --- Ак шәһәрне төнге караңгыда Җимергәннәр, утка салганнар.* Ф. Кәрим.

ВАНДАЛЛЫК *и.* Культура һәм сәнгать хәзинәләрен, истәлекләрен, гомумән, кыйммәтле әйберләрне аяусыз җимерү һәм юк итү. *Һәртөрле вандаллыкны төбәтамыры белән корытырга кирәк.* Чаян.

ВАНИЛИН *и.* Ваниль кузакларындагы хуш исле матдә (ясалма юл белән дә табыла). *Тирә-якка татлы ванилин исе генә җәелде.* М. Әмир.

ВАНИЛЬ *и. бот.* **1.** Күке яше семьялыгыннан тропикта үсә торган үрмәле үсемлек.

2. Шул үсемлекнең кулинариядә һәм парфюмериядә кулланыла торган хуш исле киптерелгән җимешләре.

ВАНИЛЬЛЕ *с.* Составында ваниль булган. *Ванильле шоколад.*

ВА'ННА *и.* **1.** Юыну, коену, өчен хезмәт итә торган һәм торба белән канализациягә тоташтырылган озынча тирән тимер савыт. *Эмальләнгән ванна.* // Бала юындыру өчен хезмәт итә торган, тагарак сыман кечерәк кенә савыт. *Колакта йөктән дыңгырдап төшкән чиләк, бала ваннасы тавышлары яңгырап китә.* Ф. Хөсни. // *махс.* Эчендәге сыеклыкка төрле әйберләр салынып эшкәртелә торган төрле зурлыктагы һәм формадагы савыт (мәсәлән, фотографиядә).

2. Шундый савытта дәвалану максатларыннан юыну һәм коену процессы. *Ылыслы ванна.* □ *Әхмәтнең кәефе бик әйбәт. Аңар көн саен нарзан ваннасы бирәчәкләр.* К. Нәҗми. // *сөйл.* Юыну, коену өчен шундый савыт белән җиһазландырылган махсус бүлмә.— *Гөлшат ваннадан чыкканны көтик инде.* Т. Гыйззәт.

3. Тәнне кояш нурлары, һава, су һ. б. ш. ярдәмендә дәвалау, ныгыту. *Мин [Галимҗанны] --- пляжга алып барып, бер сәгать чамасы һава ваннасын кабул иттерә идем.* Г. Мөхәммәдова. *Ял итүчеләр --- кояш ваннасы алалар.* И. Рәмиев.

Ванна керү — ваннада юыну, коену. [*Шәйхеразый*] *яңа квартирада ванна кереп чыгарга уйлады.* Г. Ахунов.

ВА'ННАЛЫ *с.* Ваннасы булган.— *Миңа ванналы квартира биргәннәр.* М. Хәсәнов.

ВАРАН *и. зоол.* Көньякта яши торган зур гәүдәле кәлтә елан. *20 нче елларда Индонезиянең Комодо утравында бик зур, өч метр озынлыктагы кәлтә елан — варан, урындагы кешеләр әйтүенчә, коры җир крокодилы очраган.* А. Фаткуллин.

ВА'РВАР *и.* **1.** *тар.* Борынгы греклар һәм римлыларда: культура үсеше ягыннан үзләреннән түбән баскычта торучы чит ил кешеләренә бирелгән кимсетүле исем; вәхши. // *с. мәгъ.* Культура үсеше ягыннан үзләреннән түбән баскычта торган. *Варвар кабиләләр.*

2. Башкаларга карата рәхимсез, ерткыч кеше. *Туры килмәс явыз варварларга Безнең культураны яндырырга.* Ә. Ерикәй.

ВАРВАРИЗМ *и. лингв.* Чит телдән кергән һәм әдәби тел нормаларын боза торган сүз яки сүз тезмәсе. *Әдәби тел үзенең --- нормаларына сыймый торган диалекталь сүзләрне, варваризмнарны, жаргоннарны, вульгаризмнарны --- кысрыклап чыгара.* К. Сабиров.

ВА'РВАРЛАРЧА *рәв.* Рәхимсез, аяусыз, вәхшиләрчә.— *Җирне --- халык [сезгә] варварларча файдаланыр өчен бирмәде.* А. Расих.

ВА'РВАРЛАШУ *ф.* Вәхшиләнү, варварга әйләнү.

ВА'РВАРЛЫК *и.* **1.** Кешеләргә, культура хәзинәләренә һ. б. надан, тупас, рәхимсез мөнәсәбәт, культурасызлык; вәхшилек. *Нинди сәбәп белән бер карт агачны кисәләр. Мондый варварлыкка Ленин шундый ачулана.* Г. Әпсәләмов.

2. *махс.* Борынгы җәмгыять үсешендәге икенче чорның Л. Морган тарафыннан кертелгән искергән исеме.

ВАРЕ'НЬЕ *и.* Шикәр ширбәтенә, балга салып кайнатылган җимешләр яки җиләкләр. *Варенье кайнату.* □ — *Кунак кызларга чәй эчертә тор, улым, шкафта җиләк вареньесы бар. Алып куй.* К. Нәҗми. *Кура җиләгә вареньесы хуш исләрен чыгарып [тора].* К. Тинчурин.

ВАРЕ'НЬЕЛАП *рәв.* Варенье белән; варенье кабып.— *Мин сезне вареньелап чәй белән сыйлармын.* Г. Кутуй. *Вареньелап чәй эчкәч, [Якуб һәм Фатыйма] олы якка чыктылар.* Э. Касыймов.

ВАРИАНТ *и.* Нинди дә булса эшне башкаруда төп чараларның, юлларның, ысулларның берсе; берәр нәрсәнең төре.— *Чигенергә калса, Урал ягына китү варианты да бар иде, --- ләкин ул вариант безнең өчен кабул ителмәслек булып табылды.* Ш. Усманов.— *Бездә өченче вариант юк. Я безнең тәкъдимне кабул итәсез, яки, чи усак кебек, төрмәдә пыскыйсыз.* Г. Гобәй. // Нинди дә булса әдәби-музыкаль һ. б. ш. әсәрнең бераз үзгәргән, ләкин асылда бер үк булган башка данәсе. *«Качкын»ның унга якын варианты, унлап киңәшмәдә кат-кат тикшерелеп, яралык хәлгә килгәнгә кадәр бик күп, бик җентекләп төзәтелде.* М. Җәлил. // Шахмат уенында: фигураларның билгеле торышында мөмкин булган йөрешләрнең берсе. *Соңгы еллардагы җитди ярышларда Рубинштейн варианты сирәк очрый.* Р. Нәҗметдинов.

ВАРИАНТЛЫЛЫК *и.* Төрле вариантлары булу, төрлелек.

ВАРИАЦИОН *и. к.* вариацияле. *Вариацион форма* (мәс., музыкада). *Вариацион рәт* (мәс., биологиядә).

Вариацион исәплә́у *мат.*— математик анализның иң мөһим тармакларыннан берсе. **Вариацион статистика** *махс.*— табигать һәм җәмгыять күренешләрен өйрәнүдә математик анализ куллану.

ВАРИА'ЦИЯ *и.* **1.** Берәр нәрсәнең нигезе, төп эчтәлеге сакланган хәлдә, икенче дәрәҗәдәге өлешләренә генә кагылышлы үзгәлек, төрлелек. [*Мәкальләрнең*] *төрле вариацияләрдә булуын күрсәтү бик әһәмиятле.* Н. Исәнбәт. // *бот.* Хайваннар яки үсемлекләр төзелешендә төп типтан читкә тайпылыш.

2. Бер үк музыкаль тема яки көй төрле ритм, тональлек, аһәңлелектә кабатланып, үзгәртелеп, эшкәртелеп язылган музыкаль әсәр. [*Ф. Яруллинның*] *әле бик көчле яңгырый, әле йомшара торган, әле кинәт алмашынучан ритмлы вариациясе Зифа кыз-кошның төрлелеген, назлылыгын, ашкынучанлыгын, гамьсез уенчаклыгын сурәтли.* Ч. Бәхтиярова. *Глинканың әлеге җиңел, җилкендергеч «Камаринская» вариацияләрен күңелдән тыңлап барам.* М. Рафиков.

ВАРИА'ЦИЯЛЕ *с.* Төрле вариантлары булган.

ВАРИА'ЦИЯЛӘ́У *ф.* Төрле вариантлар бирү, төрләндерү, төрле үзгәрешләр кертү. *Борынгы классик шигырь, үзендә буын араларын ачык саклаганга, яңадан-яңа строфа калыпларын иҗат итәргә, ритмик буыннарны төрле-төрле рәвешләрдә вариацияләргә мөмкинлек бирә.* Х. Госман.

ВАРИС *и.* **1.** Мирас алган яки мирас алырга хокукы булган кеше.— *Без үлгәннән соң, барлык мөлкәтебез кызыбызга калачак. Безнең бүтән варисыбыз юк.* Г. Бәширов. *Варислар, аталарыннан калган бу йортны сатып, акчасын үзара бүлешергә уйлаганнар.* Ә. Еники.

2. *күч.* Берәр кешенең эшен үз өстенә алып дәвам иттерүче кеше. *Тукай абыйның унөч яшьлек шәкерте һәм варисы кечкенә Муса --- бер-бер артлы ялкынлы шигырьләр урнаштыра башлады.* М. Максуд. *Син — хан кызы Аембикә, үзең тәхет варисы.* Н. Исәнбәт.

ВАРИСЛЫК *и.* Варис булу хокукы, варис булу.— *Атаңның креслосында озак утырасың. Варислыкны бик ныклап алгансың, ахры.* Т. Гыйззәт. [*«Фәраиз»да*] *исламның варислык хокукына карата төп карашлары, кагыйдәләре тасвир ителә.* М. Галәү.

ВАРИСТАШ *и.* Варис булучыларның берсе.

ВАРФОЛОМЕЙ: варфоломей төне — 1) изге Варфоломей көне алдыннан (1572 елның 24 августына каршы төндә) Парижда католикларның ике меңнән артык гугенотларны суеп үтерүе белән атаклы вакыйга. *Давыллар да җирдә, коңлагерь да, Әйтерсең лә берни булмаган; Варфоломей төненнән сыман Битараф ай тыныч, тын һаман.* Х. Туфан; 2) *күч.* масса күләмендә, күпләтә суеш, үтереш. *Варфоломей төне, Үлем төне, Кабатланып тора биредә.* Г. Хуҗиев.

ВАРЬЕТЕ *и.* Комедия жанрындагы эстрада театры.

ВАРЯГ *и. тар.* IX—X гасырларда Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа җирләренә талау һәм сәүдә итү максатларыннан чыгып һөҗүм иткән һәм борынгы Русь, Византия армияләрендә ялланып хезмәт иткән норманнарны борынгы руслар һәм византиялеләр шулай атаганнар. *Олуг бер милләтне әллә кайдан килеп чыккан бер варяг исеме белән атап йөртү асла ярамый!* Г. Ибраһимов.

ВАСИТА *и. иск. кит.* **1.** Берәр эшне булдыру өчен кирәкле чара, әмәл. *Атлар, арбалар, фаэтоннар инсанның хәрәкәтенә васитадыр. Өйләр, киемнәр дә һава үзгәрүдән сакланыр өчен генә васитадыр.* Г. Тукай. // Булышлык, ярдәм. *Абзыйлар васитасы белән алынган хикәяләрне бик яратып укыйм.* М. Фәйзи. *Хәзерге шикытта махсус перископ исемле корал васитасы белән бу атуларны һәрвакыт тәфтиш итеп торырга мөмкиндер.* Ф. Әмирхан.

2. Ике кеше яки оешманың үзара бәйләнешенә ярдәм итүче (кеше); арадашчы, ярдәмче. [*Егет*] *теге татар гаиләсе һәм татар кызлары белән танышасы килгәнлеген сөйләде һәм васита булучылыгын үтенде.* Ф. Әмирхан.

ВАСИТАЛЫК *и.* Васита булу. *Акчалар товарларның кыйммәтен күрсәтәләр, алмашу васиталыгы хезмәтен итәләр.* Г. Тукай.

ВАСИТАЧЫ *и. иск. кит. к.* арадашчы. *Фольклорда кош образы — васитачы, ике арада хәбәр ташучы булса, Муса Җәлил бу образны бик ныклы үстереп ала.* Г. Кашшаф.

ВАСИТАЧЫЛЫК *и. иск. кит. к.* арадашлык.— *Васитачылык өчен сиңа пот башыннан егерме тиен.* К. Нәҗми. *Урта һәм Көньяк Азия белән генә түгел, Һиндстан һәм Кытай белән элемтәдә дә рус сәүдә капиталы татар сәүдәгәрләренең васитачылыгыннан файдаланган.* Қ. Фасиев.

ВАССАЛ *и.* **1.** *тар.* Урта гасыр Көнбатыш Европасында: эре җир биләүче феодалга бәйле булган вак җир биләүче.

2. *күч.* Буйсынган, бәйле кеше яки ил. *Америка капиталы вассаллары.* □ *Аксак Тимер аңа үз вассалы иттереп кенә карый иде.* Н. Исәнбәт. // *с. мәгъ.* Экономик һәм политик яктан бәйле, буйсынган. *Вассал ил.*

ВАССАЛЛЫК *и.* Вассал булу. *Вассаллык хәле.* □ *Чыңгызның гаскәри империя һәм вассаллык системасы заманнар үтү белән үзенең баштагы характерын җуйды.* Н. Исәнбәт.

ВАССА'ЛЧА *рәв.* Вассал сыйфатында, вассал буларак. *Алар Урдага вассалча буйсыналар иде.* Н. Исәнбәт.

ВАСЫЯТЬ *и.* **1.** Берәүнең үлү алдыннан әйтеп калдырган теләге, үтенече. [*Атасы*] *аның алдында васыятьләрен дә әйтте: сыеры белән кәҗәсен ике мәзин белән ике муллага фидия итәргә, --- бер сарыгы белән ике тавыгын — гүр сәдакасына.* Г. Ибраһимов.

2. *юг.* Үзенең юлын дәвам иттерүчеләргә һәм киләчәк буынга әйтеп калдырылган теләк, киңәш, күрсәтмә. *Колхоз тормышын ныгыту — бу Ленин васыяте.* Ф. Бурнаш.— *Сез, Сәлахетдин, медицинаның атасы Гиппократның иң беренче васыятен оныткансыз. Ул, авыруны башта карарга кирәк, дигән.* Г. Әпсәләмов.

Васыять итү (кылу) — үз үлеменнән соң нәрсәнедә булса мирас итеп тапшыру турында әйтеп калдыру.— *Шуннан артык нәрсә әйтә алмыйм, әмма аларны васыять итеп калдырам.* А. Шамов. *Казанда бер бай адәм вафат булып, берничә мең сум акчасын мәҗед вә мәдрәсә файдасына васыять кылып калдырган.* З. Һади.

ВАСЫЯТЬНАМӘ *и. иск.* Васыять язылган кәгазь. *Йортны алу белән бер үк вакытта Таибә абыстай үзенең васыятьнамәсен язып, улы Зөфәрне йортка бердәнбер тулы хуҗа итеп калдырырга тиеш.* Ә. Еники.— *Васыятьнамәмне әле җәен үк яздырган идем. Эш кәгазьләрем янында.* А. Расих.

ВАТАН *и. юг.* Билгеле бер кеше өчен: үзе туган һәм шуның гражданины булган ил; туган ил. *Их, кайчан соң, кайчан кайтырбыз без Туып үскән изге Ватанга!* Ш. Маннур. // Берәр кешенең туган ягы, туган җире. [*Дәрвишләр*] *кире үз ватаннарына, Бохарага кайтып киттеләр.* Ш. Камал. *Ватан — Хөсәен өчен менә шушы басулар, елга буйлары, шушы юллар, исемсез тәбәшәк таулар.* А. Гыйләҗев.

Ватан сугышы — туган илнең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен чит ил илбасарларына каршы гадел сугыш. *1812 елгы Ватан сугышында ул берүзе, ялгыз очрап*

уникe французга каршы сугышкан, уникесен дә кадап үтергән. А. Шамов.— *Бөтен халык сугышы бу, Ватан сугышы. Бу изге сугышта бөтен халык катнашырга тиеш.* Г. Гобәй.

ВАТАН-АНА *и. юг.* Туган ил (туган илнең поэтик символы). *Килеп басты ил өстенә зур куркыныч! Яуга өнди Ватан-ана үз улларын.* Ә. Исхак.

ВАТАНДАР *и. иск.* Ватанчы, патриот. *Олы җанлы ватандарлар булдык һәм җитештек балигъ булып та.* Н. Арсланов.

ВАТАНДАШ *и.* Ватаннары уртак булган, ягъни бер илдә туып үскән кешеләрнең берсе. *Изге җирләребезнең һәр карышы ватандашларыбызның каны белән сугарылды.* М. Шабай.

ВАТАНПӘРВӘР *и. иск. кит.* Ватанчы, патриот. *«Шушма башы» газетасы, бу турыда Батырғали агайны бер атаклы каһарман, ватанпәрвәр кебек мактап, озын-озын [мәкаләләр] язды.* Ш. Мөхәммәдев.

ВАТАНПӘРВӘРЛЕК *и. иск. кит.* Ватанчылык, патриотлык. [*Сенкевич*] *поляк милләтенең мөкатдәс нәрсәләре алдында баш ию белән яза вә әсәрләренең һәрберсендә гаять самими ватанпәрвәрлек --- [күрсәтә] иде.* Ф. Әмирхан.

ВАТАНЧЫ *и.* Үз ватанын сөюче, туган иленә һәм халкына җаны-тәне белән бирелгән кеше; патриот. *Чиксез ватанчы мин — Совет иле булу шарты белән ул Ватан.* М. Гафури.— *Мин ватанчы түгел, синеңчә? Шулаймы?* Н. Исәнбәт.

ВАТАНЧЫЛ *с.* Ватанны сөючән, ватанга җаны-тәне белән бирелгән; патриотик. [*Гәрәй:*] *«Хөр мәмләкәт, хөр Россия!» — дип, үзенең революцион ватанчыл фикерен ипташларына сөйли.* Л. Җәләй.

ВАТАНЧЫЛЫК *и.* Ватанчы булу, патриотлык. *Хезмәт белән тизләт син илеңнең Бу сугышта җиңеп чыгуын, Бөтен эшең фронт өчен булсын, Шунда булыр ватанчылыгың.* М. Җәлил. *Фронтта ватанчылык хисе, дошманнарга нәфрәт, ниһаять, үлсәң, нәрсә намена үлүеңне аңлау куркуны җиңәргә көч бирә иде.* Г. Әпсәләмов.

ВАТА-СЫНДЫРА *рәв.* (Тел законнарын яки көйне) бозып, җимереп (башка телне бик начар белгән кешенең сөйләшүе яки җырлаганда көйне бозуы хакында). *Шәяхмәт үзенең кытыршы теле белән, русчаны вата-сындыра, Фәхринең язмышын сөйләп китте.* Г. Ибраһимов.

ВАТА-СҮТӘ *рәв. к.* вата-сындыра.

ВАТА-ҖИМЕРӘ *рәв. к.* вата-сындыра. *Тел әйткәнне колак ишетмәсә дә, мин аның артыннан вата-җимерә әйтеп бара башладым.* М. Гали. *Капитан дәрәҗәсендәге берсе рус телен вата-җимерә һәм имән бармагын яный-яный әйтте: «Ми вась осьвожжаем пот надзор! Помнить? Пафторяеть — вешайть!»* Ш. Маннур.

ВАТЕРПАС *и. тех.* Агач, җир һәм таш эшләрендә горизонталь тигезлекне күрсәтә торган гади прибор; тигезләгеч.

ВАТЕРПО'ЛО *и. спорт.* Суда ике команда арасында уйнала торган туп уены.

ВАТЕРПО'ЛОЧЫ *и. спорт.* Ватерполо уйнаучы (кеше).

ВАТЕРСЫЗЫК *и. махс.* Пароход һәм көймәләрнең ян стеналарында аларның суда утыру тирәнлегенең кайчанга кадәр нормаль булуын күрсәтә торган сызык. *Алар, бауга асылынган урындыкларга утырып, басып, корабльнең ватерсызыгын, тышын буйый башладылар.* А. Таһиров.

ВАТИН *и.* Киемнең эчлеге һәм тышлыгы арасына җылылык өчен салып калдырыла торган сирәкләнгән йөнтәс трикотаж тукыма.

-ВАТКЫЧ *Бозваткыч, шикәрваткыч* һ. б. ш. кушма сүзләрдә «каты әйберне ваклый, китә торган» мәгънәсендәге икенче кисәк.

ВА'ТМАН *и.* Сызым һәм рәсемнәр өчен кулланыла торган югары сыйфатлы тыгыз кәгазь. [*Абзый*] *безне ак ватманга сыздый-быздый төшереп, шаярып утыручылар итеп кенә карый.* Ф. Хөсни.

Ватман кәгазе — *к.* ватман. *Җәүдәтнең үзенең дә, култык астына папкалар, ватман кәгазьләре кыстырып, --- чыгып киләнен күрдем.* Г. Ахунов.

ВАТТ *и. физ.* Электр тогы егәрлеген үлчәү берәмлеге. *Йөз ватт.*

ВАТТМЕТР *и. тех.* Электр тогы егәрлеген ваттларда үлчи торган прибор.

ВАТТ-СЕКУНД *и. тех.* Электр тогы эшен үлчәү берәмлеге (ул бер ватт егәрлегендәге токның бер секунд эчендә башкарган эшенә тигез).

ВАТТ-СӘГАТЬ *и. тех.* Электр тогы эшен үлчәү берәмлеге (ул бер ватт егәрлегендәге токның бер сәгать эчендә башкарган эшенә тигез).

ВАТТЫРУ *ф.* Машина яки башка шундый әйбер ярдәмендә вату. [*Японнар*] *Порт-Артурны, көлен күккә очырып, бөтенләй ваттырып, харап итеп бетергәннәр.* Ш. Мөхәммәдев.— *Бичара егет, мине таптатмас өчен, машинасын фонарь баганасына бәреп ваттырган.* Т. Гыйззәт.

ВАТТЫРЫШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* ваттыру.

2. *күч. сөйл.* Кем беләндер бәхәсләшү, талашу.

ВАТУ *ф.* 1. Берәр каты әйберне кисәкләргә ваклау, таркату, җимерү. *Мәрьям бәләкәй генә пыяла вазаның төбенә вак-вак кисәкләргә ватып салган шикәрне өстәлгә ку[я].* Ш. Камал. [*Рәхимә белән Иванов*] *таш кисәкләрен, кечкенә чүкеч белән ватып, лупа, микроскоп аша карыйлар.* А. Әхмәт. // Каты әйберне ике яки берничә өлешкә яру. *Чикләвек вату. Утын вату.* // *күч.* Таркату, җимерү. *Дошманнарның кат-кат сафын ватып, дәвам итәм барыр юлымны.* Ш. Маннур.

2. *сөйл.* Зур бәяле акчаны барысы бергә шул ук бәяне тәшкил иткән вак акчаларга алмаштыру; ваклау.

3. Эшләргә яраксыз хәлгә китерү.— *Насосны монда ватканнар.* Ш. Камал.— *Йозакны ватып алырга тиеш идегез.* Ш. Усманов.

4. Юк итү, җимерү, хәрабәгә әйләндерү.— *Ялланам да күчмәләргә, Бу шәһәрне мин ватам.* Н. Исәнбәт.— *Талаучылар бандасы --- юлда бөтен нәрсәне талый, җимерә, вата.* Ш. Усманов.

5. *күч. сөйл.* (Сүзләрне, тел законнарын яки көйне) бозып сөйләү яки бозып җырлау.— *Турысын әйткәндә, русчаны син урман тракторы чыбык-чабыкны ваткан кебек ватасың.* Г. Әпсәләмов. [*Камил әфәнде*] *«Кара урман»ны җырлады һәм ниндидер бер хәерле илһам белән аны бозмады, ватмады, «европалаштырмады».* Ф. Әмирхан.

6. *күч. сөйл.* Сөякләрдә, буыннарда, мускулларда бертуктаусыз авырту сизү.— *Мин каты авырыйм. Миндә коры сызлау... Аяк сөякләрем вата, чыдар хәл юк.* Г. Ибраһимов. // Кешенең сәламәтлеген какшату. *Иртә ватты мине дөнья. --- Мин инде ватылып егылдым.* Г. Ибраһимов. // Бик каты итеп, кешенең яки хайванның сәламәтлеген какшатырлык итеп кыйнау.— *Тотындык без Шәле [егетләрен] кисәргә. Ватабыз үзләрен; аяк белән дә, кул белән дә изәбез үзләрен.* Ф. Сәйфи-Казанлы.— *Шакирны дуңгыз урынына кыйнап, ватып җибәргәннәр.* Әкият. // Авыр эштән яки күп йөрүдән соң арыту, талдыру, йончыту.— *Юл ваткандыр, ял итегез!* К. Нәҗми.

7. *күч.* Рухи газаплау, йончыту, авыру хәлгә китерү, нерв системасын какшату. *Сине кыса, вата хурлыклы тормыш.* М. Гафури.— *Кызым, зинһар, үзеңне ныкотарга тырыш. Бердән, үзеңне ватасың, икенчедән, аны.* М. Фәйзи.

ВАТУ-ҖИМЕРУ *ф.* Җимерү, хәрабәгә әйләндерү, юк итү. *Үн мең дошман гаскәре бу шәһәрне камап алды. --- Инде ватабыз-җимерәбез дип, сугыш кор-*

макчы булалар. Әкият. *Менә һавадан коточкыч зур әйбер гөрселдәп төшәр дә, --- тауларны, ташларны --- челпәрәмә китереп ватар-җимерер төсле тоела.* Г. Гобәй.

ВАТЫК *с.* **1.** Төрле кисәкләргә вакланган. *Егермеләп товар вагоны челпәрәмә килеп, ватык кисәкләре зур бер тау булып өелгән.* Ш. Усманов. // Кителгән, ярылган. *Хафиза балчык эзләп йөри, ватык чүлмәк сыларга.* Г. Камал. *Ватык тәрәзәдән яңгырлы җил керә бүлмәгә.* Ш. Маннур. // *и. мәгъ.* Берәр нәрсәнең сыныгы, китеге, кыйпылчыгы.— *Бишәр катлы таш йортлар күзең йомганчы тузан белән кирпеч ватыгына әйләнә.* Г. Бәширов. *Бомба ватыгы [сугышчының] күкрәгеннәнме, кайдандыр кереп, аркасыннан үтә чыккан.* Г. Ибраһимов.

2. Эшли, файдаланыла алмас хәлгә китерелгән, бозылган, бозык (машина, җайланма һ. б. ш. турында). *Ватык йозак. Ватык күпер.* ▭ — *Водокачканы --- ватык, бөтенләй эшкә ярамый дип әйттеңме соң?* Ш. Камал. *[Игенчеләрнең] кайберләре төзәтергә китерелгән шыксыз көпчәкләр, ватык сабаннар өстенә утырганнар.* А. Шамов. // *күч.* Күп йөрүдән яки башка сәбәпләр белән таушалган, җимерелгән, чокырланган, тигезлеген югалткан (юл турында). *Ватык юллар, янган зур калалар Без килгәнне көтеп яталар.* М. Җәлил.

3. *күч. сөйл.* Тел законнарын бозып әйтелгән; бозык (сөйләү, тел турында). *[Кемдер] бераз ватык, шулай да җиңел русча теле белән сорады.* Г. Ибраһимов.

ВАТЫКЛЫК *и.* Ватык булу. *Лампаларының кечкенәлеге, пыялаларның корымлы һәм пычраклыгы, ул корымлы пыялаларның да күбесенең ватыклыгы аларның яктырту хасиятләрен югалта язган.* Ш. Камал.

ВАТЫК-ПОТЫК *с. сөйл. кимс.* Төрле кисәкләргә вакланган, ватылган, кителгән. // *и. мәгъ.* Вак кисәкләр, кыйпылчыклар, чүп-чар. *Уртага ватык-потыкларын тутырып, сыек бетон белән нык ытсаң, --- йөз мең нән артыграк экономия [аласың].* А. Гыйләҗев.

ВАТЫК-СЫНЫК *җый. и. сөйл.* Ватылган, сынган (төрле әйберләр турында). *Ватык-сыныкларны урамга ташлау.*

ВАТЫК-ЧАТНАК *с. сөйл. кимс.* Ватылган, чатнаган (гадәттә савыт-саба турында). *[Әби], ватык-чатнак булсалар да, чынаякларын да куйган иде.* Г. Толымбай.

ВАТЫК-ҖИМЕРЕК *с.* **1.** Ватылган, җимерелгән. // *и. мәгъ.* Ватык, җимерек әйберләр, берәр нәрсәнең ватык урыннары. *Һәр ел көз укучы балаларның аталары белән мәктәпкә нигез салып, ватык-җимерекләрен төзәтеп --- йөрү Габденнасыйрны туйдырып бетергән иде.* М. Гали.

2. *күч. сөйл.* Тел законнарын бозып әйтелгән; бозык. *Алар әлеге ватык-җимерек немец телендә тагын бер хәтле сөйләшеп алдылар.* Ш. Маннур.

ВАТЫЛУ *ф.* **1.** Кисәкләргә вакланu, таркалу, сыну, җимерелү (каты әйберләр турында). *[Габдулла] тәрәзәнең челпәрәмә килеп ватылуын кызыксынып көтеп торды.* Ә. Фәйзи. *Басуның өсте тоташ казылган, туфраклары тетелеп ватылган.* Дәрдмәнд.

2. Хәрбәгә әйләнү, җимерелү. *Кавдивизиянең йөгерек атлары баскан җирдә дошманның --- ватылган, җимерелгән станцияләре генә калды.* А. Шамов.

3. Эшләргә, файдаланырга яраксыз хәлгә килү. *Броненосец бөтенләй эшкә ярамаслык булып ватылган.* Ш. Мөхәммәдев. *Ике урак машинасының берсе ватылып эштән чыкты.* Г. Бәширов.

4. *күч. сөйл.* Кешенең сәламәтлеге какшау. *Мин дә --- күп яшәдем, бик ватылдым.* М. Җәлил. // Авыр эштән яки йөрүдән соң ару, талу, йончу.— *[Гайнетдин] иртән тугызда чыгып китә, --- ярты төннәрдә арып, ватылып, эштән чыгып кайтып ава.* Г. Ибраһимов. *Әзрәк ял итәргә дип яткач, үземнең көн буенча йөреп арыганымны, ватылганымны белдем...* Ф. Сәйфи-Казанлы.

5. *күч. сөйл.* Тирән рухи кичерешләрдән, кайгы-хәсрәттән, газаплардан йончу, авыру хәлгә килү; нерв системасы какшау. *Тормышның авырлыклары эчендә ватылган, башкаларга самовар куеп йөргән сыныкк үңелле --- шәкертләр генә минем янга кил[әләр].* М. Гафури. *[Мостафин] артык ватылмыйча, тынычрак җан белән эшләүне тансыклый башлады.* Ә. Еники. // *с. мәгъ.* **ватылган.** Газапланган, арып йончыган булуны белдерә торган, кәефсез, төшенке. *[Нәфисә], ишетелеришетелмәс сәер бер ватылган тавыш белән: «Ие...» — диде.* Г. Бәширов.

ВАТЫП-СЫНДЫРЫП *рәв. к.* вата-сындыра. *Тыңкыш тавышлы чандыр студент «Су өсте» көенә ватып-сындырып җырлый да башлады.* Қ. Нәҗми. *Имештер, ул [егет] телен оныты кайткан була... Ата-анасына русчаны ватып-сындырып сүз куша икән дә, тегеләр аңламыйлар.* Г. Толымбай.

ВАТЫП-СҮТЕП *рәв. сөйл. к.* вата-сындыра. *Сүзне Бәк-Бәкич алды. Татарчаны ватып-сүтеп, русчаны сындырга лап биш-алты сүз әйтте.* Х. Кәрим.

ВАТЫП-ҖИМЕРЕП *рәв. к.* вата-сындыра. *[Зәйнуллин] гарәпчә, русча сүзләрне ватып-җимереп нотыклар сөйли.* С. Җәләл. *Теле яңа ачылып килгәнгә күрә, һәрбер сүзне [Зәки] ватып-җимереп сөйләнеп йөри.* Ак юл.

ВАУ I *и.* Гарәп алфавитында егерме бишенче хәреф исеме.— *Элифне таяк дип, ваууны чукмар дип белми икән — минем өчен ул бернәрсә дә түгел.* Г. Ибраһимов. *Вәгъдәнең вавын вак тараканн ашаган.* Мәкаль.

ВАУ II *аваз ияр.* Эт өргәндә чыккан тавышны белдерә. *«Вау!» да «ваау!» да, «һау!» да «һаау!» бертуктамый этләр өрә.* Г. Тукай. *Тынлыкны Актүш бозды: «Вау!» Илсөяр эндәшмәгәч, эт тагын җиңел генә өреп куйды: «Вау!» — Бу Актүшнең ашарга соравы иде.* Г. Гобәй.

ВАУ-ВАУ *аваз ияр.* **1.** Эт өргәндә чыккан тавышны белдерә. *Кинәт: «Вау-вау!»—дип, искәрмәстән җилкәсенә [эт] килеп ябыш[ты].* М. Хәсәнов. *Төнге маэмай [өрә]: «Вау-вау». Кемдә микән әллә бүреләр?* Х. Туфан.

2. *и. мәгъ.* Балалар телендә: эт. *Песи баскан каршына, Вау-вау качкан артына.* М. Саттаров.

Вау-вау итү — шундый тавыш чыгару.— *Курыкма, улым, әнә ишетәсеңме, этләр вау-вау итеп өрәләр.* Н. Дәүли.

ВАФА *и. иск. кит.* Әйткән сүздә тору; тугрылык. *Бу дөньяның һичкемгә вафасы юк бит. «Үлгәнче сине ташламам»,— дигән Маргаритасы да, кесә саекканны белгәч, бик матур һавалы бер көндә, Хәсәншаны аллага тапшырып, сызды.* Ш. Мөхәммәдев.

Вафа итү (кылу) — тугрылык күрсәтү, яхшылык итү, изгелек эшләү.— *Аның өчен вәгъдәгә вафа кылуның кирәге бармыни?* Х. Кәрим. *[Шевченко] тагы малорус телендә тарих, җәгърәфия, риязият язмакчы иде, ләкин гомере вафа итмәде.* Г. Ибраһимов.

ВАФАСЫЗ *с. иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел.— *Мәхәббәтемне аяк астына салып, үземне җәһәннәмгә аткан вафасыз яр, мәңгегә хуш!* М. Фәйзи. // *и. мәгъ.* Тугрылыксыз кеше, хыянәтче.— *Углым! Вафасызлар сөте белән тәрбия кылынмадың. Бөтен хәлең синең өчен генә бетергән, синең өчен генә хәсрәтләнгән ата-анаңны хәтергә ал.* С. Рәмиев.

ВАФАСЫЗЛЫК *и. иск. кит.* Вафасыз булу. *Сугышның мәрхәмәтсез вафасызлыгын үз күзе белән күр[деүл].* Ә. Еники. *Хәят абыстай --- икенче мәх[әббәтеннән] дә аерылды. Дөнья да үзенең вафасызлыгын җиренә китерде.* З. Һади.

ВАФАТ *и. иск. кит.* Үлем. *Байтурәнең вафаты, иртәгә булачак җеназа һәм үлем хәсрәте бу йортның тынычлыгын алган.* Г. Ибраһимов. *[Егет] атасының вафа-*

тыннан соң бик бай мирас алып калган. Г. Тукай. / *хәб. функ. Командир Кәһарманов бүген төнлә вафат.* Г. Кутуй.

Вафат булу — үлү. *Гайнетдин бабагыз авырып вафат булды.* М. Гафури. **Вафат итү** *иск. кит.*— үлү.— *Менә иртәгә, син терелтелгән юл белән, моннан 51 ел әүвәл вафат иткән бер хатынны терелтәбез.* Ф. Әмирхан.

ВА'ФЛЯ *и. махс.* Өслеге кәрәз сыман итеп ясалган юка печенье. *Монда китап төялеп килгән --- ящиклардан кровать ясау вафля пешерү кебек тиз.* Г. Тукай.

ВА'ХМИСТР *и. тар.* Патша Россиясенең атлы гаскәрендә солдатның иң югары дәрәҗәсе (пехотада фельдфебельгә туры килгән). *Запас атлы полк[тагы] --- вахмистр Шеликов шулай үк кичектерелмичә кулга алынырга тиеш.* К. Нәҗми.— *Кавалериядә вахмистр булдым.* Ш. Усманов. // Кайбер чит ил гаскәрләрендә солдатның иң югары дәрәҗәсе. *Карабинын немец вахмистрына биргәндә [Шәрифҗанның] күзләреннән яшь атылып чыкты.* И. Гази.

ВА'ХТА *и.* 1. *махс.* Корабльдә, аның иминлеген тәэмин итү өчен, билгеле бер урында өзлексез дежурлык. *Вахтада тору.* □ *Хәйдәр Ваняның бушлатын салдыра да, --- көч-хәл белән генә рульне тотып торучы иптәшен алмаштырып, вахтага баса.* Г. Әпсәләмов. *Капитан күперчегендә теплоход капитаны Н. И. Миронов, --- машиналар бүлегендә Саша Ефимов, Витя Храмов вахта алып баралар.* Яшь ленинчы. // Өзлексез эшләүне таләп итә торган эшләрдә (мәс., нефть чыгаруда, самолетларда) бер смена дежурлык. *Вахтадан соң арылган, ачыгылган.* Г. Ахунов. *Нефтьче егетләр вахтага, эшкә баралар.* А. Әхмәт.

2. *махс.* Корабль экипажының, нефть чыгару бригадасының дежурлык итә торган бер өлеше. *Вахта членнары.* □ *Яңа вахта эшкә кереште бугай — буровой тирәз генә көрелди.* Г. Ахунов. *Вахтаны вахта алмаштырды.* Ф. Мостафин. // Аерым кеше яки кешеләр вахта хезмәтен башкара торган вакыт; смена.— *Моннан бер атна элек төнге вахтадан кайтып кердек.* Г. Ахунов.

3. *күч.* Берәр вакыйганы билгеләү йөзеннән яки махсус максатлар өчен югары күрсәткечләр белән башкарыла торган эш. *Багышлап зур бәйрәменә Туган илнең, Килеп басты бүген тагын ул вахтага.* Ә. Исхак. *Трибунага берәм-берәм яңа ел вахтасының алдынгылары чыга башладылар.* Г. Минский.

Вахта журналы — вахта вакытында үтәлгән эш яки булган вакыйгаларны хронологик тәртиптә теркәп бару өчен махсус журнал. *Һәр корабның иң мөһим документы — вахта журналы. Анда --- корабның бөтен көндәлек тормышы язылып барыла.* Р. Мостафин. *Будкага кереп, вахта журналына тиешле саннарны да утырттым.* Р. Төхфәтуллин. **Вахта машинасы** — вахтаның вакытында алмашынуын тәэмин итү өчен, вахтага баручы яки аннан кайтучы кешеләрне йөртә торган махсус машина. *Автотранспорт конторасына барыр өчен, вахта машиналары туктый торган җиргә килдем.* Ш. Маннур.— *Нәрсә, иптәш, вахта машинасы көтәбезме?* Г. Ахунов.

ВА'ХТАЧЫ *и.* Вахтада торучы кеше.

ВАХТЁР *и.* Учреждениедә дежур каравылчы; өлкән сакчы. *Капкага чабам. Вахтёр пропуск сорый.* Х. Гарданов. *Пропускымны вахтёрга күрсәтеп, цехтан чыгам.* М. Хәбибуллин.

ВАХТЁРЛЫК *и.* Вахтёр булу. *Вахтёрлык хезмәте.*

ВА'ХТМАН *и.* Немец полициясендә надзиратель. *Вахтманнар, мылтык түтәлләре белән кизәнә-кизәнә, әсирләрне төрткәлиләр.* Н. Дәүли. *Абзар капкасы авызыннан немец вахтманының яшел тавышы яңгырады.* Ш. Маннур.

ВА'ШГЕРД *и. тех.* Алтынга бай комны юу өчен гади җайланма. *Вашгерд — суны кул белән тартып, алтын комын [гади] юл белән юа торган, тимер иләкле, авызы ачык зур ящик кебек бернәрсә. Вашгердта гадәттә өч кеше эшли. Машиналашкан җирләрдә бу ысул бетә бара.* М. Гафури.

ВАҖИБ *с. иск. кит.* Мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле. *Сезгә важибдыр миңа ярдәм кылу.* Г. Тукай.— *Мәрхүмнең үлем алдыннан әйткән васыяте шулай, җеназа намазы укып җирләргә кушкан, әйдәгез, әһле мөселман, сафка басыгыз, важиб эшне башкарыйк.* Ф. Хөсни.

Важиб итү — өскә йөкләү. *Ерак җиргә сәфәр кылу важиб итте Аларның [киресенә] сүз кузгатмак.* М. Гафури.

В-ВШЧ-Ч *аваз изр.* Сызгырганда чыккан тавышны белдерә. *[Галәү], үзалдына «в-вшч-ч» иттереп акрын гына сызгырып куйды.* Г. Ибраһимов.

ВЕ *и.* «В» хәрефенең исеме.— *Юк, Галиуллин түгел, Вәлиуллин. Ве, ве, береңче хәрефе Володя.* Ш. Хөсәенов.

ВЕ-ВЕ-ВЕ *аваз изр.* Аңлаешсыз, бер көйгә генә әйтелгән сүзне белдерә.— *Бытылда шунда, менә болай: «Ве-ве-ве, ве-ве-ве». --- Әлеге Җәмил авызыннан чыккан беренче сүз койрыгына бик күп итеп ве-ве-ве тактым да селкенә-селкенә бытылдарга керештем: «Сөмменбикмен ве-ве-ве, --- сөмменбикмен ве-ве-ве»...* Г. Гобәй.

ВЕГЕТАРИАН *и.* Бары тик яшелчә һәм сөттән хәзерләнгән азыклар белән генә тукланучы кеше, вегетарианлык тарафдары. *Бомбей штатында күбрәк вегетариаңнар яши. Алар, үсемлек маен мул салып, яшелчә, камыр ашлары, сөт, борчак, фасоль ашыйлар.* М. Мәхмүтов.

ВЕГЕТАРИАНЛЫК *и.* Яшелчә һәм сөт азыклары белән генә тукланы, ит ашамау.

ВЕГЕТАРИА'НЧА *рәв.* Вегетарианнарга хас булганча. *Безнең ашау-эчү вегетарианча.* И. Рәмиев.

ВЕГЕТАТИВ *с. биол.* Хайван яки үсемлекләрдә организмның үсүенә, туклануына хезмәт итә торган (әгъзалар турында). *Вегетатив нерв җепселләре.*

Вегетатив нерв системасы *физиол.*— нерв системасының аш кайнату, кан әйләнеше кебек эчке органнарның һәм матдәләр алмашының эшчәнлеген тәртипкә сала торган бер өлеше. **Вегетатив органнар** *бот.*— үсемлекләрнең тукланы һәм үсү өчен хезмәт итә торган органнары (тамыр, сабак, яфрак). **Вегетатив үрчү** *бот.*— үсемлекләрнең җәнси юлдан башка гына, вегетатив органнар ярдәмендә үрчүе.

ВЕГЕТА'ЦИЯ *и. бот.* Үсү, җитлегү (үсемлекләр турында).

Вегетация чоры — ел тәүлегендә үсемлекнең үсү, җитлегү, үрчү чоры. *Азык ногытының үзенчәлеге — вегетация чорының озакка сузылуында. Туфракта дым җитәрлек булганда, ул җәйнең икенче яртысында яңадан чәчәк ата башлый һәм аның көз азагына кадәр дәвам итүе мөмкин.* В. Шәкүров.

ВЕ'ДОМОСТЬ *и.* 1. Нинди дә булса фактик мәгълүматлар (мәс., хезмәт хакы, акча керем-чыгымы һ. б.) исемлеге. *Хезмәт хакын түләү ведомосте.* □ *Колхоз бухгалтеры ведомостьларга кул куйдырырга керде: «Алмалы фермасына хезмәт хакын бүген үк илтеп бирә алам»,— [диде].* Г. Ахунов. *[Заһид] укыту бүлегенә керде, --- секретарьга имтихан ведомостен сузды.* А. Расих.

2. *күпл.* **ведомостьлар.** Кайбер газета-журнал исемнәренең состав өлеше; хәбәрләр. *СССР Верховный Советы ведомостьлары.* □ *Петр патша үз кулы белән редакцияләгән «Гаскәри вә гайри эшләр турындагы ведомостьлар»да: «Идел буенда нефть табылган, Ка-*

заннан хәбәр иттеләр»,— дигән язу саклана. Г. Ахунов.

ВЕ'ДОМСТВО *и.* Дәүләт идарәсенең бер тармагы һәм аңа хезмәт күрсәтә торган учреждениеләр системасы. [*Рифгать*] *өяз хәрби ведомствосы белән сөйләшү алып бара иде.* Ф. Хөсни.— *Министрлык бит безнең ведомство түгел, сезнеке.* Ә. Фәйзи.

ВЕ'ДОМСТВОЛЫ: ведомстволы идарә — ведомстволар аша идарә; ведомстволары булган идарә.

ВЕ'ДОМСТВОЧЫЛЫК *и.* Билгеле бер ведомство файдасы күзлегеннән генә карап эш итү принцибы. *Тар ведомствочылык карашы.* □ *«Алай эшләргә Кировоград заводы безнең министерствога керми бит»,— диде Михаил Михайлович. «Менә бөтен бәла дә шунда шул,— диде Мортазин,— --- дәүләт интересын түгел, ведомствочылык интересы[н] өстен куя[сыз]».* Г. Әпсәләмов.

ВЕЗДЕХОД *и.* Начар юллардан яки юлсыз җирләрдән йөрү өчен махсус автомобиль. *«Татнефть» берләшмәсе --- вәкил[ен] утыртып, вездеходта Кожанов килеп төшә.* Г. Ахунов. *Машиналар, хәтта безнең вездеходлар да, ишек алдында күгәргән быкырдыкта утыралар.* Г. Сафиуллин.

ВЕ'КСЕЛЬ *и.* Бурычка алган акчаны билгеләнгән срокка кире кайтару турында бирелгән язма йөкләмә. *Вексель кәгазе. Вексель хокукы.* □ *Максудовта алачагы бар адәмнәр һәркаюсы, вексель яки распискасы буенча судка биреп, хакын сорый башлады.* Ш. Мөхәммәдев. *Баеннан вексель белән бурычка акча алып, Мостафа [үз] авылында кечкенә бер бакалея кибете ачкан.* Г. Кашшаф.

ВЕ'КТОР *и. мат.* Билгеле торыш һәм юнәлеш алган туры сызыкның бер өлеше.

Вектор исәпләве *мат.*—математиканың вектор өстендә төрле эшләр алып баруны өйрәнә торган бер тармагы.

ВЕЛО- *Велокросс, велокамера, велоспорт, велотрек* кебек кушма сүзләрдә үзенең мәгънәсе белән «велосипед» сүзенә туры килә торган беренче кисәк.

ВЕЛОДРОМ *и.* Велосипед ярышлары өчен махсус юллар ясалган спорт корылмасы.

ВЕЛОРИ'КША *и.* Кайбер Көнчыгыш һәм Көньяк Азия илләрендә кешеләр утыртып йөрү яки йөк ташу өчен җайланган велосипед. *Аллахабадта --- «такси» дигәнең --- ике көпчәкле велорикшалар.* М. Мәхмүтов. *Сәгать бишләрдә инде урамнарны машиналар гөрелтесе, велорикшалар, рикшалар шавы баса.* Каз. утл.

ВЕЛОСИПЕД *и.* Аяклар ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган ике яки өч тәгәрмәчле җиңел машина. *Велосипед ярышы.* □ *Без сикереп велосипедларыбызга атландык та, аякларыбызны кызганып тормастан, бормалы юл буйлап чаптык.* Г. Мөхәммәтшин. [*Аларга*] *көмеш төсле ялтырап торган, ике тәгәрмәче әйләнеп торган велосипедлар биргәннәр.* А. Алиш.

ВЕЛОСИПЕДЧЫ *и.* Велосипедта йөрүче, велосипед спорты белән шөгыльләнүче кеше. *Йөгерешчеләр, велосипедчылар кайтты, --- көрәш әле һаман бара.* Г. Ахунов.

ВЕЛЬБОТ *и. мах.* Кечерәк мачталы һәм җилкәнле, дүрт яки алты ишкәкле, ике башы да очлаеп торган җиңел, тиз йөрешле көймә. *Вельботта җилкән күтәрәләр. Хәйдәрләр утырган көймәне буксирга алалар.* Г. Әпсәләмов.

ВЕЛЬВЕТ *и.* Куе төкләре белән хәтфәгә охшаш киже-мамык тукыма. // *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Вельвет куртка.* □ *Хәбибрахман абзый кара вельвет пиджагын алып киде.* А. Расих.

ВЕЛЬВЕ'ТКА *и. сөйл.* Вельветтан тегелгән куртка. [*Өйдән*] *изүе чылбырлы вельветка [кигән] --- Айрат чыга.* Г. Ахунов. *Институтның беренче курсында вакытта [Ишбулат] --- бумази чалбар, зәңгәр вельветка белән йөргән.* М. Мәһдиев.

ВЕЛЬМО'ЖА *и.* 1. *иск.* Бик югары дәрәҗәле бай түрә. [*Базилио:*] *Юкка ул Фигаро көче җитмәс Кешеләр белән көрәшеп маташа бит! Вельможаларга каршы көрәшү мөмкинме?* М. Җәлил. — *Сезнең канат астында калса, ул да шул урта гасыр вельможаларына гына яраклы бернәрсә булып үсәр.* Г. Гобәй.

2. *күч. ирон.* Үзен зурга санап, масаеп йөрүче кеше турында.— *Кем сөйләшә әле минем белән? — Аллаһияров. Танымый да башладыңмыни, вельможа!!* А. Расих.— *Ничек әле, Дәүләтбаев масая, вельможага әйләнеп бара, дисеңме?* Р. Ишморат.

ВЕЛЮР *и.* Куе, йомшак, бик кыска төкләре аз гына беленерлек итеп махсус эшкәртелгән постау яки иң яхшы сорт юка һәм тыгыз фетр. // *с. мәгъ.* Постаудан яки фетрдан эшләнгән. *Яхшы костюмнарына, фырт кына бераз кырын салынган велюр эшләпәләренә карганда, Кашшаф аларны: «Мәскәү артистлары шушылар икән инде»,— дип уйлаган иде.* Р. Төхфәтуллин.

ВЕ'НА *и.* Әгъзалардан йөрәккә таба кан үткәрә торган тамыр. *Врач Иосиф Галашка әле һаман да аңына килә алмаган полковникның веналарына кан җибәрергә дә өлгергән иде.* Каз. утл. *Малайның веналарындагы үлгән каның агызып, яңа кан җибәрәләр.* Г. Гобәй.

ВЕНГЕ'РКА *и.* 1. Венгр гусарларының формасына охшатып, алдына аркылы ука шнурлар тегелгән куртка. *Николай Иванович, битен сөртергә теләп, венгерка кесәсеннән --- кулъяулыгын алды.* Ж. Тәрҗеманов.

2. Хәрәкәте, көе белән венгр халык биюләренә нигезләнгән бал биюе һәм шул биюгә музыка.

ВЕНГР *и.* Венгриядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер вәкиле; мажар. *Интернациональ үзәк[тә] --- тагын поляклардан, югославлардан, венгрлардан вәкилләр бар иде.* Г. Әпсәләмов. // *с. мәгъ.* Шул халыкка мөнәсәбәтле. *Китә менә яңгырап Назлы венгр теле.* Ш. Мөдәррис.

ВЕ'НГРЧА *рәв.* Венгр телендә. *Өйдә алар татарча, төрекчә һәм венгрча сөйләшәләр.* Х. Гарданов. *Ул мин сөйләгән сүзләрнең һәммәсен дә татарча, русча һәм венгрча язып утырды.* З. Бәшири.

ВЕНЕ'РИК *и. сөйл.* Сифилис, шанкр, гонорея кебек авырулар белән авыручы кеше. [*Лазареттагы*] *авыруларның күп өлеше венериклар һәм аресттa булганнар.* А. Таһиров.

Венерик авыру *мед.*— 1) күбесенчә җенси әгъзалар аркылы тарала торган йогышлы авыру: сифилис, гонорея, шанкр. *Җамалетдинов венерик авыру элэктереп кайта.* Р. Мостафин; 2) венерик авыруларга дучар булган кеше.

ВЕНЕРО'ЛОГ *и.* Венерик авырулар буенча белгеч-врач.

ВЕНЕРОЛО'ГИЯ *и.* Медицинаның венерик авыруларны өйрәнә торган бүлеге.

ВЕ'НЗЕЛЬ *и.* Исем-фамилиянең яки ике исемнең бер-беренә матур итеп чорналып язылган баш хәрефләре. *Шинель погоннарында сары буяу белән Германия императорларының вензеле төшерелгән иде: Вильһельм икенче, Калуга полкының шефы, имеш.* Ш. Камал.

ВЕНОЗ *с. анат.* Венадан ага торган, венага бәйле. *Веноз кан.*

ВЕНОК *и.* Түгәрәкләп үрелгән чәчәкләр яки ботаклар бәйләме. *Лавр веногы.* □ *Кадерле балаларын югалткан аналар иң беренче венокларны фрау Якоп кибетеннән алганнар.* Н. Дәүли. *Табутның тирә-ягы төрле-төрле оешмаларның венокларының, кайгы тасмалары һәм гөлләр белән әйләндерелеп алынган.* М. Әмир, Ф. Кәрим.

ВЕ'НСКИЙ: венский урындык — агачтан бөгеп ясалган җиңел һәм нык урындык. *Уртада ак эскәтер япкан озын өстәл, аның тирәсендә җиңел венский урындыклар* [*тезелгән*]. Ә. Еники.

ВЕ'НТИЛЬ *и.* **1.** *тех.* Сыекча, пар, газ һ. б. ш. агымын ачу, киметү яки туктату хезмәтен үти торган клапан.

2. *муз.* Тынлы музыка коралларында тавышны калынайта яки нечкәртә торган җайланма.

ВЕНТИЛЯ'ТОР *и.* Ябык бинаны яки машинаны җилләткәндә һава агымын көчәйтү өчен хезмәт итә торган җайланма. *Электр вентиляторы.* □ *Югарыда, түбә астында, вентиляторның җиңелчә гүелдәве генә ишетелә.* Э. Касыймов. *Зур вентилятор, хәйран җил чыгарып, пыр-пыр әйләнә.* М. Маликова.

ВЕНТИЛЯЦИОН *с.* Вентиляциягә мөнәсәбәте булган. *Вентиляцион труба. Вентиляцион корылма.*

ВЕНТИЛЯ'ЦИЯ *и.* **1.** Ябык бинаның һавасын җилләтү.

2. Бинаның һавасын җилләтү өчен хезмәт итә торган җайланма яки җайланмалар системасы. *Түшәмнән төшкән такта трубаны күрәсезме? Аның мич калагы кебек капкачы да бар. Һава йөрсен өчен вентиляция ул.* А. Расих.— *Вентиляциягез эшләми, газны начар куасыз.* Т. Гыйззәт.

ВЕПС *и.* РСФСРның Ленинград, Вологда өлкәләрендә һәм Карел АССРда яшәүче халык һәм шул халыкның бер вәкиле.

ВЕРА'НДА *и.* Өй тирәләп яки өйнең бер стенасы буенча эшләнгән ябык балкон. *Өйнең бакча ягында буйдан-буйга шактый иркен веранда да эшләнгән.* Р. Төхфәтуллин. *Веранда тирәли тезелеп баскан карлыган куаклары --- оеп утыралар.* Г. Мөхәммәтшин.

ВЕРБАЛЬ: вербаль нота *кит.*— дипломатиядә: кул куелмаган, шуңа күрә телдән әйтелгән белдерү белән бер дәрәҗәдә йөри торган язма белдерү.

ВЕРБО'ВКА *и. сөйл.* Кешеләрне берәр эшкә, оешмага тарту, яллау. *Вербовка пункты.* □ [*Ул*] *баштарак, Ширъязданны ташлап, нинди дә булса шахтага я төзелешкә вербовка буенча китмәкче булды.* А. Расих. *Моннан уналты ел элек, Маһруй апа вербовка белән эшкә килгәндә, бу шәһәрдә бер генә таш йорт та юк иде әле.* Г. Әпсәләмов.

ВЕРБО'ВКАЛАУЧЫ *и.* Вербовка белән шөгыльләнүче кеше.

ВЕРМАХТ *и. тар.* 1941—1945 елгы Бөек Ватан сугышында Совет Армиясе тарафыннан тар-мар ителгән фашист Германиясенең кораллы көчләре (армиясе). *1942 елның җәендә Кальварий лагерена вермахт капитаны килеп төште.* Каз. утл. *Вермахтның үткән сугыштан соң суд карары белән асылмый калган реваншист генераллары җинаятьле кулларын Көнчыгышка таба сузалар.* Ш. Мөдәррис.

ВЕРМИШЕЛЬ *и.* Фабрикада әзерләнгән түгәрәк нечкә токмач. [*Кадрия*] *ашка вермишель сала башлады.* А. Расих. // *с. мәгъ.* Шундый токмач салып пешерелгән. *Вермишель ашы.*

ВЕ'РМУТ *и.* Виноград аракысына кайбер үлән төнәтмәләре кушып ясалган исерткеч эчемлек.

ВЕРНИСАЖ *и. сәнг.* Сәнгать күргәзмәсен иң башта белгечләр генә карау; шундый күргәзмәнең ачылу көне.

ВЕРОНАЛ *и. мед.* Кристаллик порошок рәвешендәге йокы даруы.— *Мин бүген тагын йоклый алмыйм инде. Кайтышлый веронал алып кайтмый булмас.* Ә. Фәйзи.

ВЕРСАЛЬЧЕ *и. тар.* 1871 елны Франциянең Версаль шәһәренә тупланган контрреволюцион буржуазия вәкиле.— *Пер-Лашез зиратында версальчеләр соңгы коммунарларны атканнар.* Э. Касыймов.

ВЕ'РСИЯ *и.* Берәр факт яки вакыйга турында бер-береннән аермалы булган төрле аңлатмаларның берсе. *Соңгы версия. Беренче версия.* □ *Метрика кенәгәләренең күрсәтүе буенча, «көз көне туган» дигән версия бөтенләй күккә очты, мин — чирләшкә малай — кышкы суыкта, январь азагында туганмын, имеш.* Ф. Хөсни. *Чыннан да, хәл бик катлаулы иде. Бер-бер артлы берничә версия җимерелде.* А. Расих.

ВЕРСТАК *и.* Агач яки металл әйберләрне кул белән эшкәрткәндә шул әйберләрне ныгыту өчен җайланмалары булган эш өстәле. [*Сәмигулла абзый*] *тактаны яңадан верстакка салып шомарта башлады.* М. Шәрифуллин. [*Әти*], *верстагы янында көне буе кисеп, юнып, ышкылап, әллә никадәр эш эшләгән.* Г. Бәширов.

ВЕРСТА'ТКА *и.* Хәрефләрне кул белән җыйганда кулланыла торган типография җиһазы.

ВЁРСТКА *и.* **1.** *сөйл. к.* вёрсткалау. *Иртәгә чыгачак газетага вёрстка башлана. Материалларны биткә салалар.* Г. Минский.

2. Типографиядә биткә салынган набор. *Вёрстка уку.*

ВЁРСТКАЛАУ *ф. махс.* Наборны биткә салу. *Газета вёрсткалауга, оригиналь информацияләр табуга --- [Кәтиевтән] дә уңган кешенең булганын белмим.* Ф. Хөсни.

ВЁРСТКАЛАУЧЫ *и. махс.* Наборны биткә салучы типография эшчесе.

ВЕРТИКАЛЬ *с.* **1.** Горизонтка карата перпендикуляр, астан өскә 90° ка күтәрелгән яки өстән аска 90° ка төшкән; асылма, асма. *Вертикаль сызык. Вертикаль скважина.* □ [*Манара*] *вертикаль күчәреннән бер метр да 68 сантиметрга көньяк-көнчыгышка авышкан.* Г. Шамуков. *Самолет, моторларын бөтен көченә үкертеп, күккә таба вертикаль курс алды.* З. Әхмәтҗанов. // *рәв. мәгъ.* Горизонтка карата перпендикуляр рәвештә. *Вертикаль күтәрелү.*

2. *и. мәгъ.* Асма белән бер юнәлештәге туры; вертикаль сызык. *Гатауллин башта машинасын вертикаль буенча өскә алып менә.* З. Әхмәтҗанов.

ВЕРТОЛЁТ *и.* Вертикаль рәвештә һавага күтәрелә, бер урында асылынып тора һәм шул ук рәвештә төшә ала торган очкыч. *Вертолёт, винт канатларын җилпи-җилпи, шәһәр өстенә күтәрелде, аз гына авыша төшеп, көньякка борылды.* Ш. Бикчурин.— *Ул да синең белән вертолётта очтымы?* Г. Әпсәләмов.

ВЕРТОЛЁТЧЫ *и.* Вертолёт белән идарә итүче; вертолёт спорты белән шөгыльләнүче кеше.

ВЕРФЬ *и.* Суднолар төзи һәм ремонтлый торган предприятие. *Петр I тикмәгә генә Үсиядә суднолар төзү өчен верфьләр кордырып җибәрмәгән.* Ж. Тәрҗеманов.

ВЕРХО'ВНЫЙ: Верховный Совет — бөтен илдә яки аерым республикада законнар чыгара торган иң югары дәүләт органы. *Верховный Совет Президиумы Председателе.* □ *Академик Бах...— Верховный Совет депутаты ул.* М. Җәлил. **Верховный суд** — бөтен ил яки аерым республиканың иң югары суд органы.

ВЕРХОВОЙ *и. махс.* Бораулау вышкасының өске өлешендә эшләүче кеше. [*Лотфины*] *верховой итеп вышка түбәсенә менгереп җибәрделәр.* Г. Ахунов. [*Әхәткә*] *верховой урынына — вышка башына менәргә насыйп булмый.* Ш. Бикчурин.

ВЕРХОЛАЗ *и.* Төрле корылмаларның өске өлешендә эшләүче махсус эшче, белгеч. *Зур төзелешләрдә Эшли минем сөйгәнем. Кыю верхолаз булганга, «Карлыгачым» дигәнем.* Ш. Галиев.

ВЕРШОК *и.* Русларда метрик система кергәнче кулланылган һәм чама белән 4,4 сантиметрга туры килгән озынлык үлчәве. *Хәйретдин, картның кушуы буенча, биш вершок юанлыктагы озын бүрәнәдән ясалган шпильне берүзе, күкрәге белән бик нык терәп, уңга да, сулга да әйләндерә башлый.* М. Гали.

ВЕСТИБУЛЯР: вестибуляр аппарат *махс.*— кешеләрдә яки умырткалы хайваннарда: баш һәм гәүдә

торышы үзгәрүен, гәүдәнең хәрәкәт итү юнәлешен билгели торган һәм эчке колакка урнашкан сизү органы.

ВЕСТИБЮЛЬ *и.* Урам ягыннан кергәндә бинаның алгы бүлмәсе (күбесенчә җәмәгать урыннарында). *Театр вестибюле.* □ [*Сыртланов*] *театрга керде, вестибюльдә басып, кунакларны көтә башлады.* Ш. Хөсәенов. *Вестибюльдәге күңелле тавышлар, ачык ишектән бер көчәеп, бер ерагаеп ишетелгән музыка аны туктатты, эчкә үзарга ирек бирмәде.* Г. Ахунов.

ВЕСТОВОЙ *и. хәрби, сөйл.* Офицерның хезмәткә бәйләнешле йомышларын үтәү өчен билгеләнгән солдат; йомышчы солдат. [*Комиссар*] *вестовойга штаб начальнигын чакырырга кушты.* А. Шамов.— *Биккул, тизрәк бул, командир вестовое сине эзләп йөри, командир чакыра, ди.* А. Таһиров.

ВЕТ- Кушма сүзләрдә үзенең мәгънәсе белән «ветеринария» сүзенә туры килә торган беренче кисәк, мәсәлән: *ветбаклаборатория, ветврач, ветпункт* һ. б. ш.

ВЕТВРАЧ *и.* Ветеринария врачы.— *Әткәй, сез ул бозауны ветврачка күрсәттегезме?* Р. Төхфәтуллин.

ВЕТВРАЧЛЫК *и.* Ветврач булу, ветврач хезмәте, ветврач вазифасы.— [*Ул*] *ике факультет бетергән. Агрономлыкка, ветврачлыкка дипломнары бар.* Т. Гыйззәт.

ВЕТЕРАН *и.* **1.** Күп хезмәт иткән тәҗрибәле сугышчы; күп сугышларда катнашкан кеше. *Бөек Ватан сугышы ветераны.* □ *Полк ветераны И. П. Звонов чын күңелдән чыккан җылы сүзләре белән хезмәт елларын, сугыш кырларында кулга-кул тотышып җитәкчелек итү вакытларын искә алып узды.* Ф. Булатов.

2. Берәр өлкәдә озак һәм күп хезмәт күрсәткән кеше. *Сәхнә ветераны.* □ — *Әйдә, үзара иркенләп сөйләшсеннәр инде бу әдәбият ветераннары!* С. Кудаш. *Яңа тормышның киң мәйданына, революция ветераннары белән бергә, ил төзүчеләрнең иң беренче яшь отряды булып, ул килеп басты.* Г. Бәширов.

ВЕТЕРИНАР *и.* Ветеринария буенча белгеч. *Аның әтисе авылда ветеринар булып эшли.* М. Мәһдиев.

ВЕТЕРИНА'РИЯ *и.* Хайваннардагы авырулар һәм аларны дәвалау турындагы фән. *Ветеринария врачы. Ветеринария институты.* □ — *Мин, әткәй, маллар врачы.* --- *Хәзер ветеринария поликлиникасында эшлим.* Г. Насрый. [*Әтием*] *ветеринария фельдшерын чакырып,* [*кәҗәнең*] *тояклары, тез башларын каратты.* Г. Галиев.

ВЕ'ТО *и.* Тыю, юкка чыгару: а) (бер) дәүләт күләмендәге хокукта — бер дәүләт органының икенче орган карарын бөтенләйгә яки шартлы рәвештә тыюы; б) халыкара хокукта — теге яки бу мәсьәлә бары тик бертавыштан хәл ителә торган халыкара коллегиаль органнарда шул органның берәр членының каршы тавыш бирүе. // Гомумән берәр нәрсәне эшләүдән тыю.— *Уйлап табучының яңа ижат эшенә вето салдым.* А. Тимергалин.

ВЕТСАНИТАР *и.* Ветеринария санитары. [*Зоотехник*], *ветсанитар Әпсәләм белән бергә, бозауның башына тимер чыбыктан ясалган борынчак кидертеп маташа.* А. Расих. *Ветсанитарны ияртеп бөтен терлекләрне шулай күздән кичереп чыгу — аның өчен --- һәр тумыш көн кабатлана торган бер эш.* Ә. Еники.

ВЕТФЕ'ЛЬДШЕР *и.* Ветеринария фельдшеры. *Газинур, атның аягын яңадан җиргә бастырып: --- «Нигә ветфельдшерга күрсәтмәдең, Сабир бабай?» — диде.* Г. Әпсәләмов.

ВЕТЧИНА *и.* Тозлап ысланган дуңгыз боты. [*Өстәлдә*] *сыр, май, пешкән йомырка, казылык, ветчина да бар.* Г. Әпсәләмов.

ВЕ'ЧЕ *и. тар.* Борынгы Русьның кайбер шәһәрләрендә һәм хәзерге Югославиядә югары власть органы булган халык җыелышы. *Новгород вечесы.*

ВЕ'ШАЛКА *и. сөйл.* Кием эләр өчен элгечләре, кадаклары булган җайланма; кием элгеч. *Ишек төбендәге вешалкада ниндидер бер чит кеше пальтосы эленеп тора.* С. Кудаш.// Кием элә торган махсус бүлмә, урын. [*Җиһангир*], *вестибюльгә чыгып, вешалкадан шинеле белән бүреген сорап алды.* Г. Гобәй.

ВҖЖТ *аваз ияр.* Берәр нәрсәнең бик кызу хәрәкәт итүеннән барлыкка килгән тавышны белдерә. // *хәб. функ.* Берәр кешенең яки нәрсәнең бик тиз хәрәкәт итүе яки иткән булуы, бик тиз югалуы турында.— *Вжжт, җилләр исә тегендә, эрегән! Яулык күптән Исмәгыйльнең кесәсендә ята инде.* М. Фәйзи.

ВЗВОД I *и.* Җәяүле гаскәрләрдә — ротаның, кавалериядә — эскадронның, артиллериядә — батареяның һ. б. ш. зур булмаган бүлекчәсе. *Танк взводы. Автоматчылар взводы. Пулемет взводы.* □ — *Отделениесе нык булган взвод, взводы нык булган рота, ротасы нык булган батальон гына җиңүгә ирешә ала.* Г. Әпсәләмов. *Беренче ротаның командиры --- үзенең солдатларын җыйды да, аларны икегә аерганнан соң, бер взводы белән үзе уң якка таба китте, икенче взвод сул якка таба юл тотты.* С. Җәләл.

ВЗВОД II *и. махс.* Ату коралында затворның яки йозакның бәрмә механизмын атуга әзер хәлдә тота торган бер деталь. *Без, стена буена сырышып, автоматларны --- взводка куйган килеш, тын да алмыйча, Поповның хәрәкәтен көтә башладык.* Ә. Айдар.

ВЗНОС *и.* Берәр нәрсә өчен түләнелгән яки түләнеләсе акча. *Членлык взносы. Берәр оешмага керү взносы. Взнос түләү.*

ВИАДУК *и.* Тирән чокыр, тарлавык яки юл өстенә салынган күпер. *Тимер юл виадугы астыннан чыгуга, Татарстан урамына килеп керерсез.* Г. Бәширов.

ВИБРА'ТОР *и. тех.* Һәртөрле тибрәнү, калтырау, электр дулкыннары һ. б. ш. тирбәлешләр барлыкка китерә торган прибор, механизм (детальләрне сынау, көпшәк нәрсәләрне тыгызлау, субай сугу һ. б. ш. эшләрдә кулланыла). *Вибратор белән җитәкчелек итә белмәсәң, --- блок өсте тулы куык була. Димәк, бетон киргәнчә тыгызланмаган.* М. Хөсәен. [*Гөлзадә*] *бетонны тыгызлавын белде. Башкалар шикелле аның кулында да вибратор күндәм йөри башлады.* С. Рафиков.

ВИБРАЦИОН *с.* Вибрациягә бәйләнгән, вибрациягә нигезләнгән, вибрация белән булдырыла, эшләнелә торган.

ВИБРА'ЦИЯ *и. физ.* Тыгыз яки сыгылмалы җисемнең тибрәнүле хәрәкәте, калтыравы.— *Вибрация инде. --- Я станок калтырый, я* [*кискеч*]. *Я деталь белән* [*кискеч*] *икесе бергә калтырый.* Г. Әпсәләмов.

ВИБРА'ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Вибрациягә дучар булу, калтырау, дерелдәү. *Деталь вибрацияләнү.*

ВИБРА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Вибрациягә дучар итү, калтырату, дерелдәтү.

ВИБРИОН *и. биол.* Бөгелгән таякчык яки өтер рәвешендәге бактерия. *Ваба вибрионы.*

ВИБРОСКОП *и. тех.* Механик тибрәнешләрне билгели, үлчи торган прибор. [*Кискечләр*] *гүя суппортка түгел, аның йөргенә ныгытылганнар иде: ул, виброскоп шикелле, аларның һәр тибрәнүен сизеп торды.* Г. Әпсәләмов.

ВИВА'РИЙ, ВИВА'РИУМ *и. махс.* Төрле хайваннарны өйрәнү, алар өстендә тәҗрибәләр ясау өчен махсус җиһазландырылган бина.— *Сез бит сыерлар, сарыклар белән эш итмәкче буласыз. --- Бу — безгә кафедра өчен махсус виварium салдырырга кирәк дигән сүз.* А. Расих.

ВИГОНЬ *и.* Коньяк Америкада яши торган, нечкә, йомшак йонлы дөя сыман имезүче хайван (ламаның бер төре). // *с. мәгъ.* Шул хайван йоныннан бәйләнгән. *Вигонь кофта.*

ВИДЕОТЕЛЕФОН *и.* Экранда бер-береңне күреп сөйләшергә мөмкинлек бирә торган телефон. *Казан шәһәрара видеотелефон пункты.*

ВИ'ЗА *и.* 1. Берәр дәүләткә керү, аннан китү яки аның территориясе аркылы үтү өчен хөкүмәт тарафыннан кемнең дә булса паспортына языла торган махсус рөхсәт. *Франциягә керергә рөхсәт, бу — төп виза. Аннан соң бетмәс-төкәнмәс транзит визаларын гына аласы кала.* Г. Гали.— *Әгәр мин чит илләрне күреп кайтыйм дисәм, миңа теләгән вакытымда рөхсәт итәчәкләр. - - - — Алай булгач, нигә виза сорамыйсың?* Г. Мөхәммәдова.

2. Документта: аның дәүләт хезмәткәре тарафыннан төп кенәгәгә кертелүен, тикшерелүен раслый торган билге. *Виза салу.* □ *Кайбер шәһәрдә җирле начальство Казан цензурасы биргән рөхсәт визасын таныймый.* И. Рәми. // *күч.* Берәр нәрсә эшләргә рөхсәт. *Такташны күмеп кайткан көннең кичендә үк, берәү дә кушмыйча һәм берәүдән дә виза алмыйча, ничектер стихиячел бер төстә үзебездән-үзебез җыелып, - - - Такташка багышлап кичә уздырдык.* Ф. Хөсни.

ВИЗАНТИ'ЯЛЕ *и.* Византиядә туып үскән яки шунда яшәүче кеше.

ВИЗИР *и.* 1. *махс.* Фотоаппаратта яки киноаппаратта рәсемгә төшерелә торган җанлы һәм җансыз әйберләрнең торышын карау өчен билгеләнгән махсус җайланма.

2. *хәрби.* Артиллериядә: тупларның прицел җайланмаларында карау өчен тар ярыгы булган махсус пластинка.

3. *геогр., астр., авиа.* Оптик приборны яки почмак үлчәү приборын билгеле бер ноктага төбәү өчен махсус җайланма.

ВИЗИРЛАУ *ф.* Оптик яки почмак үлчәү приборын берәр ноктага төбәү.

ВИЗИТ *и.* Берәр кеше янына кыска вакытка кереп чыгу (гадәттә рәсми рәвештә). *Аның еш кына безнең конструкторлар бюросына ясаган әлеге визитлары безгә аңлашылмый.* Ф. Хөсни.

Визит карточкасы *иск.*— берәр кешенең исем-фамилиясе, атасының исеме, профессиясе, шулай ук адресы язылган кечерәк калын кәгазь (ул берәр кеше янына барганда яки танышканда калдырыла). *Николай Иваныч Рәхимә абыстай янына килде һәм: «Менә шушы карточка иясе, студент, сезнең белән танышырга тели»,—дип, аңар бер визит карточка[сы] тоттырды. - - - Анда русча: «Гали Мөхәммәт углы Арсланов, Москва университеты студенты»,— дигән сүзләр язылган иде.* Ф. Әмирхан. [*Малай*] *Каюм ага кулына ике визит карточкасын тоттырды. Карточкаларның берсенә латин хәрефләре белән «Җәүдәт бәй» дип, икенчесенә «Гөлнар ханым» дип язылган иде.* М. Галәү.

ВИЗУАЛЬ *с.* Гади күз яки оптик прибор ярдәмендә күренә торган, тикшерелә торган.

ВИ'КА *и.* Кузаклы азык үсемлеге. *Аксымга иң байлары — кузаклылар. Мәсәлән, борчак, вика, ногыт борчагы.* А. Расих. *Як-якта шау кузак сырып алган вика [үсә].* Г. Галиев.

ВИ'КИНГ *и. тар.* Борынгы Скандинавиядә дингез сугышчысы. *Норман викинглары.*

ВИКТОРИ'НА *и.* Фән-гыйлемнең төрле өлкәләренә караган сорауларга телдән яки язма рәвештә җавап бирү уены. *Әдәби-музыкаль викторина.* □ *Викторина «Сез Польша Халык Республикасын беләсезме?» дигән темага иде.* Каз. утл.

ВИКТО'РИЯ *и.* 1. Бакчада үстерелә торган каен җиләгенең эре сорты. *Мәрвәрит апа аларга бакчадан үзеп кып-кызыл эре виктория җиләкләре ашатты.* А. Расих. *Алар, бакчадан бакчага йөреп, виктория җиләгә чүпләгәннәр.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Таба сыман гаять зур яфраклары су өстендә йөзеп йөри торган, эре чәчәкле тропик су үсемлеге. *Виктория-регия Сухуми бакчасында үсә.*

ВИЛАЯТЬ *и. иск. кит.* 1. Илдә эре административ-территориаль берәмлек; өлкә, губерния. *Былтыр Магулстан исемле олуг вилаять, Кытайдан аерылып, үзенә аерым падишаһлык булды.* Г. Тукай. *Иранда ачлык соң чигенә җиткән. Аның көньяк вилаятьләрендә чуалышлар башланган.* Ә. Фәйзи.

2. Ил, дәүләт. [*Фабрикантлар*] *үзләре дә вилаятькә баш булырга чакыруны сорыйлар, алар башлыкны патша берлән үзара бүлешергә телиләр.* РСДРП прокламациясе.

ВИЛДАН *и. иск. кит.* Дини ышанулар буенча: ожмахта хезмәт күрсәтүче егет; җәннәт хезмәтчесе. *Үземне гүяки ожмахта күрдем. - - - Пичәтләнгән шәраплар алга килгән, Официантлар бары вилдан вә гыйльман.* Г. Тукай. *Вилдан, гыйльманнар, - - - ожмахка кергән кешеләр хур кызлары белән гыйш-гашрәт сөргәндә, ак алъяпкычлар бәйләп, аларга хезмәт итеп йөр[иләр].* М. Гафури. // *күч.* Яшь егет. *Сайла да син, ал матурлардан-матур җир вилданын.* Ф. Бурнаш.

ВИ'ЛКА *и.* 1. *тех.* Сәнәк сыман ике ябе чыгып торган төрле детальләр исеме. *Электр шнуры вилкасы.*

2. *хәрби.* Артиллериядә: цельдән ары һәм бирерәк төшкән снарядлар арасындагы ераклык. *Немецларның тубы ата башлады. Снарядлар бер ераграк, бер якынрак ярыла. Вилкага алалар.* Г. Әпсәләмов.

3. Шахмат уенында: бер фигураның бер үк вакытта ике яки берничә фигурага куркыныч тудырып торышы. *Картның ладьясы вилкага эләгеп, карт оттырды.* И. Гази.

ВИ'ЛЛА *и.* Гадәттә аерым бакча эченә салынган йорт яки дача. *Шеф Френцельнең вилласы ябык лагерьдан читтәрәк бер бакча эчендә иде.* Ш. Маннур.

ВИНЕГРЕТ *и.* Ваклап туралган берничә төр яшелчәгә үсемлек мае һ. б. аш тәмләткечләр салынган салкын ашамлык. [*Мәдинә*], *үзенең бар осталыгын җигеп, винегрет әзерләде.* Ш. Хөсәенов. *Винегрет ясау өчен уртача зурлыкта 3—5 пешкән бәрәңге, 1—2 пешкән кишер, 1—2 пешкән чөгендер, 1—2 тозлы кыяр, 100—150 грамм тозлы кәбестә, 1—2 баш суган, кирәк кадәр яшел суган, укроп һәм тәмләткечләр алына.* Ю. Әхмәтҗанов.

ВИНОГРАД *и. сөйл. к.* йөзем. *Тәлгәшләрен күр син виноградның: Куакларын сыгып төшкәннәр.* Г. Хуҗи.— *Көзен Кырымда виноград ашыйбыз.* И. Гази.

ВИНОГРАДЧЫЛЫК *и.* Йөзем үстерү эше, авыл хуҗалыгының йөзем үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы.

ВИНТ I *и.* 1. *сөйл. к.* шөреп.— *Машинасы бозылган яисә куәтле берәр винты какшаган дисәң, анысы бер хәер.* Ш. Камал. *Балкага винт урыны тишелде.* Ф. Кәрим.

2. Корабльне яки самолетны хәрәкәт иттерүче механизмда: үз күчәрендә әйләнә торган валга беркетелгән калаклар. *Винт (пропеллер) янында үк авиатехник тора икән.* С. Баттал. *Пароход винты кузгаткан дулкыннарның ярга бәрелеп йомшак кына чупылдавы ишетелә.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Винты какшаган** (яки **бушаган**) *сөйл.*— аңгыра, ни акыллы, ни юләр (кеше турында).— *Насрый исерекбаш бит ул. Төш күреп саташып йөри. - - - Саташкан ул, винтлары какшаган.* Ш. Камал.

ВИНТ II *и.* Карта уенының бер төре.

ВИНТО'ВКА *и.* Көпшәсенең эче әйләнмә сырлы мылтык.— *Винтовкадан атарга өйрәт үзләрен.* И. Гази. *Винтовкалар бик төрле һәм иске системадагылар иде, анда рус берданкалары да, француз гралары да, немец винтовкалары да бар иде.* А. Шамов.

ВИНЧЕ'СТЕР *и.* Ау мылтыкларының бер төре.

Бүген дә инглиз системасындагы ике зарядлы иң яхшы винчестерлар китерелде. Ә. Айдар.

ВИНЬЕ'ТКА *и.* Кытапның беренче битендә яки бүлек башында, я ахырында, шулай ук альбомнарда һ. б. ш. рәсем сыман кечерәк бизәк.

ВИОЛОНЧЕЛИСТ *и.* Виолончельдә уйнаучы музыкант. *1937 елда скрипачлар һәм виолончелистларның Бөтенсоюз конкурсы уздырылды.* Ә. Бакиров. *Виолончелистлар уен коралларын үзләре белән өстерәп йөртүчән.* М. Маликова.

ВИОЛОНЧЕЛЬ *и. муз.* Смычок белән уйный торган, бас-тенор диапазонлы, дүрт кыллы, скрипка рәвешендә эшләнгән зур музыка коралы. *Инструментның бархат төсле йомшак, кеше авазына охшаш матур авазы бик ошыймы, ничек кенә булгандыр, Фәрит ныклы бер карарга килә: виолончель классына!* Ч. Бәхтиярова.

ВИ'РА *ы. сөйл.* Грузчиклар, диңгезчеләр, бораулаучылар телендә, йөк күтәргәндә яки бушатканда, «күтәр!», «югарыга!» дигән мәгънәдә йөри торган боерык. [*Кәрим*] *кара торбаның башына корыч арканнан элмәк кидертте дә: «Вира!» дип, кулын күтәрде. --- Торба, элмәкле башын буровой күпереннән алып, әкрен генә күтәрелә, турая башлады.* Г. Ахунов.

ВИРАЖ I *и.* **1.** Самолет, автомобиль, велосипед һәм мотоциклның әйләнә буенча борылышы. *Әле генә шундый гайрәтле күренгән егетнең истребителе корсагын кояшта ялтыратып кырын ятты да ниндидер үле вираж белән түбәнгә томырылды.* Ш. Маннур. [*Очучы*], *төрле виражлар ясап, дошманның һаман арт ягына төшә, аларның өсләренә менә.* Г. Кашшаф.

2. Автомобиль, велосипед, мотоцикл кинәт борылганда аумасын өчен, юлның эчке якка авышрак итеп салынган бер өлеше.

ВИРАЖ II *и. махс.* Фоторәсемгә билгеле бер төс бирә торган химик эремә. *Шәмәхә төс бирүче --- виражда эшкәртү өчен фоторәсем бромлы кәгазьдә булырга тиеш.* Ф. Акчурин.

ВИРАЖЛАУ *ф. махс.* Фоторәсемне билгеле бер төскә кертү. *Виражлау ике стадиядән тора: башта фоторәсемне агарталар, соңыннан аңа төс бирәләр.* Ф. Акчурин.

ВИРД *и. дини.* Билгеле бер вакытта укылырга тиешле дога, аять.— *Аннан соң тәһарәт алып, вирдләремне укырмын.* Г. Камал. *Һәр намаз соңында* [*ул*] *вирд җөмләсенә берничә сүз дә куша.* Г. Ибраһимов.

ВИРТУОЗ *и.* Үз эшен гаять оста башкара торган кеше. [*Ш. Бабич*] *декламация сөйләүдә, мандолина уйнауда оста гына түгел, безнең аңлауда виртуоз иде.* М. Бөдәйли.

ВИРТУОЗЛЫК *и.* Берәр эштә гаять дәрәҗәдә осталык. *Таңгатаров бу дәрәҗәдә виртуозлыкка җитә алмый. --- Менә Гриша башкарак. Ул Кропоткин дәрәҗәсендә оста булса кирәк.* Г. Ибраһимов. *Виртуозлык, осталык күрсәтеп, матур һәм төгәл ясалган әйбернең кадерен дә, бәясен дә* [*токарьлар*] *бик яхшы беләләр.* Г. Әпсәләмов.

ВИ'РУС *и. биол.* Оптик (гади) микроскоп аша бик начар күренә яки бөтенләй күренми торган, гадәттә йогышлы авырулар тудыручы бик вак микроорганизм. *Абдулла озак чирләмәде чирләвен, аның җәен-көзен Ишкәйнең салкын суында коеныл чыныктырылган организмы вирусларны бик тиз җиңде.* Э. Касыймов.

ВИ'РУСЛЫ *с.* Вируслар булган. *Вируслы эмульсия.* // Вирус китереп чыгарган, вирус тудырган. *Вируслы авыру.* □ *Ул көзне бөтен илдә, хәтта бөтен дөньяда вируслы гриппа авыруы таралды.* Н. Фәттах.

ВИРУСОЛО'ГИЯ *и.* Вирусларны өйрәнә торган фән.

ВИ'СКИ *и.* Англиядә һәм АКШта кин таралган махсус аракы. [*Ага*] *ташып шешәләрдән вискилар.* Ш. Мөдәррис.

ВИСКО'ЗА *и.* Целлюлозаны махсус эшкәртү юлы белән табыла һәм ясалма җепселләр, ясалма ефәк, целлофан ясау өчен кулланыла торган матдә. // *с. мәгъ.* Шундый матдәдән эшләнгән, шундый матдәдән ясалган. *Вискоза ефәк.*

ВИ'СМУТ *и. хим.* Көмеш сыман кызылсу уалучан металл, химик элемент.

ВИТАЛИЗМ *и.* Биологиядә: материаль сәбәпләрне инкяр итеп, тереклекне, яшәү процессын тереклек иялә рендә табигатьтән өстен «тормыш көче» булу белән генә аңлата торган реакцион, идеалистик караш.

ВИТАЛИСТ *и.* Витализм тарафдары.

ВИТАЛИ'СТИК *с.* Витализмга караган, асылы витализм булган. *Виталистик тәгълимат.*

ВИТАМИН *и.* Кеше һәм хайваннар тукланулы, матдәләр алмашыну һәм организмның тереклек эшчәнлеге өчен аз микъдарда зарури булган төрле химик составтагы органик матдә. *«А» витамины җитмәү --- бөтен нерв системасының тәртибен боза, --- матдә алмашынуүзенең җаен югалта. Үрчем алу мөмкинлеге югала.* А. Расих. *Кызлар, шулай, тере организм өчен нинди матдәләрнең кирәклеге, кайсы азыкта нинди витаминның күбрәк булуы --- кебек «гыйлем» сүзләр сөйләшеп утырган*[*нар*]. Ә. Еники.

ВИТАМИНЛАШТЫРУ *ф.* Витаминнар кушу, витамин белән туендыру.

ВИТАМИНЛЫ *с.* Составында витаминнар булган. *Тамыразыклар, кәбестә — витаминлы азыклар.* А. Расих.— *Тавык күкәе алмый калмагыз, бик эре, витаминлы.* Г. Мөхәммәтшин.

ВИТАМИНЛЫЛЫК *и.* Витаминлы булу. *Мал-туар азыкларының витаминлылыгын арттыру.*

ВИТРАЖ *и.* Тәрәзә, ишек һ. б. ш. әйберләрдә төсле пыялалардан ясалган рәсем яки бизәк.

ВИТРИ'НА *и.* **1.** Кибеттә төрле товарларны күрсәтү өчен махсус җиһазландырылган тәрәзә. *Марат үзеннән әз генә калку бер кыз белән магазин витриналарындагы әйберләрне, уенчыкларны карап йөри.* Г. Гобәй. *Бу косынканы алырга бик кызыгып, витринадан озак кына карап торганым бар иде.* Р. Төхфәтуллин.

2. Музей әйберләрен, газеталарны һ. б. ш. күрсәтер өчен пыяла тартма яки шкаф. *Әхмәт витринадан Рамазановаңың еллык планын үтәү күрсәткечен блокнотына күчереп алды.* Г. Минский. *Иртә тордым да редакциянең ишек төбендәге витринадагы газетадан үземнең шигыремне укып кайттым.* С. Кудаш.

ВИ'ЦЕ- *Вице-губернатор, вице-президент, вице-консул* кебек кушма сүзләрдә «урынбасар», «ярдәмче» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк.

ВИ'ЦЕ-АДМИРАЛ *и.* Контр-адмирал һәм адмирал арасындагы хәрби дәрәҗә.

ВИ'ЦЕ-ГУБЕРНА'ТОР *и.* Патша Россиясендә һәм кайбер капиталистик илләрдә: губернатор урынбасары. [*Ферганә өлкәсендә*] *вице-губернатор булып торган кеше Ташкенттан күчеп килгән кешеләрдән сайланган.* Урал.

ВИ'ЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ *и.* Президент урынбасары яки ярдәмчесе. *АКШ вице-президенты.*

ВИЦМУНДИР *и.* Революциягә кадәрге Россиядә чиновникларның формалы фрагы. *Зәңгәр вицмундир.* □ *Беренче рәтләргә --- вицмундирлар кигән кунаклар — шәһәр думасы членнары* [*утырган*]. Ж. Тәрҗеманов.

ВКЛАД *и.* Саклык кассасына яки дәүләт банкысына сакларга салынган акча. *Отышлы вклад.*

ВКЛАДЧЫ *и.* Саклык кассасына акча салучы кеше.

ВКЛА'ДЫШ *и.* **1.** Китап яки газета эченә салынган өстәмә бит.

2. *тех.* Механизм яки башка деталь эченә куела торган деталь.

ВКЛЮЧА'ТЕЛЬ *и.* Электр тогын тоташтыру яки өзү җайланмасы; тоташтыргыч. *Мондый шатлыклы минутларда Шакир, бар җирдә дә ут януын телэп, стенадагы включательне борды, лэкин ут кабынмады.* Г. Минский. [*Галимә*] *ишек төбендәге включательгә басты. Бүлмәгә яктылык сибелде.* Л. Ихсанова.

ВКП(б) *и.* Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясе (русча *Всесоюзная Коммунистическая партия (большевиков)* тезмәсенең кыскартмасы. КПСС 1925—1952 елларда шулай аталган). *ВКП(б)ның унҗиденче съезды.*

ВЛАСТЬ *и.* **1.** Дәүләт белән идарә итү хокукы, политик хакимлек. *Совет власте. Властька килү.* □ *— Эшчеләр сыйныфы властьны үз кулына алырга тиеш.* Ш. Камал. *Октябрьдагы канлы көрәшләрдән соң, бөтен власть Советлар кулына күчте.* М. Гафури.

2. Дәүләт идарәсе органнары, хөкүмәт.— *Сез властегызга эш белән дә, сүз белән дә ярдәм күрсәтегез.* И. Гази. // *күпл.* **властьлар.** Дәүләт хезмәтендәге кешеләр; администрация; түрәләр.— *Ә ник элегрәк властьларга хәбәр бирмәдең?* Ш. Камал. *Республика властьлары килеп, Катерлардан корабка ук менеп, Юлчыларның санын саныйлар, Паспортларын алып карыйлар.* Э. Исхак.

3. Кешеләр өстеннән хакимлек итәргә, боерыклар бирергә хокук һәм мөмкинлек.— *Минем кулымда власть булса, мин ул контр этләрнең җыенысын таш капчыкка тутыртыр идем.* К. Тинчурин. *Минем кечкенә генә булса да властем бар, бүтәннәргә куша, боера алам.* Э. Еники.

Власть иясе — дәүләт органында эшләүче кеше. *Идеяләр алар, ил чикләрен үткәндә, власть ияләреннән рөхсәт сорап тормыйлар.* М. Максуд. **Власть тоту** — хакимлек итү. *Көчле милләтнең көчсезләр өстендә сәяси власть тотуы да җимерелде.* Ф. Әмирхан. **Властька кайту** — властьны үз кулына яңадан алу.

ВЛАСТЬЛЫ *с.* Власть (3 мәгъ.) көченә ия булган. [*Председатель*] *үзен киң кырда хуҗа итеп, властьлы итеп күрергә тырыша.* Г. Толымбай. *Властьлы сезнең брат, Нишләгәнен хәтта тоймаган. Шахмат пешкасы итеп кешене, Күп язмышлар белән уйнаган.* Х. Камалов.

ВЛАСТЬЛЫК: властьлык итү (кылу) *сөйл.*— хакимлек итү. *Начальстволар --- үзләренең көчләре зур, властьлык итүләре нык икәнлегең күрсәтмәкчеләр иде.* М. Гафури. *Беренче самодур булып сәхнәгә акча белән властьлык кылучы --- Дикой чыга.* Г. Кутуй.

ВЛАСТЬЛЫЛЫК *и.* Властька ия булу хәле. *Ялгыз властьлылык.*

ВЛКСМ *и.* Бөтенсоюз Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы (русча *Всесоюзный Ленинский Коммунистический Союз Молодежи* тезмәсенең кыскартмасы). *ВЛКСМ Үзәк Комитеты карары.*

ВО'БЛА *и.* Гадәттә ысланып һәм һавада киптерелеп ашала торган диңгез балыгы. *Өченче лабаз тирәсендә балык өләшү башланды. Күпләрнең кулларында кибеп-корып беткән вак вобла, тәрәшке тезгешләре күренде.* Г. Минский.

ВОДЕВИЛЬ *и.* Диалоглары шаян җырлар белән чиратлашып килгән һәм күбесенчә бер-ике пәрдәдән торган комедия. *Буш уен-көлкегә корылган чит ил водевильләреннән әллә ни ераккa китмәгән рус театрына Гоголь ачы хакыйкать һәм усал көлү алып килде.* Ф. Хөсни. *«Новый клуб» залында «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан --- «Дача» [исемле] бер водевиль тамашага куелача[к].* Г. Камал.

ВОДОКА'ЧКА *и.* Су суырта торган насослар өчен махсус бина.— *Яшелчә бакчабыз да үсә, водокачкабыз да шаулаттырып су җибәрә.* Ш. Камал.— *Водокачкада паровозлар өчен кирәк кадәр су запасы булсын!* Ш. Усманов.

ВОДОЛАЗ *и.* Су үткәрми торган махсус кием киеп, су асты эшләре башкаручы кеше. *Водолазлар тели Океан төбендәге Җиңүләрен аңа сөйләргә.* Ф. Кәрим. [*Малай*], *водолаз булам дип, аягына гер бәйләгән килеш күл төбенә чумган.* Г. Бәширов.

ВОДОПРОВОД *и.* Халыкны, промышленность объектларын су белән тәэмин итә торган инженерлык корылмалары (трубалар, һава насослары, фильтрлар) системасы. *Водопровод та тукталачак икән дип, өй хатыннары --- батманнарын, мичкә, чапчакларын, комганнарын ашыгып-ашыгып су белән тутырырга тотыналар.* Г. Ибраһимов. *Йортның водопроводы эшләми, өйдә --- су юк.* Ш. Камал.

ВОДОПРОВОДЧЫ *и.* Водопроводны көйләүче, ремонтлаучы эшче.

ВОДОРОД *и.* Кислород белән кушылып су барлыкка китерә торган җиңел газ, химик элемент. *Эченнән әллә никадәр булып янып тора торган бу водород кояшның өстеннән гаҗәп бер* [*тизлек*] *белән бик биек күтәреләдер.* Ф. Әмирхан. // *с. мәгъ.* Шундый газ хәзерли торган.— *Водород цехыннан дидегез бит* [*үзегезне*]*? — Әйе, водород цехыннан.* И. Гази.

Водород бомбасы — водородның атом төше энергиясен файдаланган нигезләнгән һәм гаять зур шартлау көченә ия булган атом бомбасының бер төре. *Бу дошман атом, водород бомбалары һәм кеше аңы сыйдыра алмый торган башка коточкыч кораллар белән коралланмаган.* Ә. Давыдов. *Американың котырынган сугыш чукмарлары --- водород бомбасы белән яныйлар.* Ш. Мөдәррис.

ВОДЯ'НКА *и. мед.* Йөрәк, бөер авырулары вакытында тукымаларга һәм төрле куышлыкларга сары су җыелу.

ВОЕВО'ДА *и.* **1.** *тар.* Борынгы Русьта гаскәр башлыгы, ә XVI—XVIII гасырларда шәһәр яки өлкә башлыгы. *Безнең территориядәге барлык төзү осталарын Мәскәүгә озату турында Казан воеводасына патшаның 1666 елда җибәргән боерыгы бар.* Г. Шамуков.

2. Польшада воеводалык башлыгы.

ВОЕВО'ДАЛЫК *и.* Польшада административ-территориаль берәмлек, өлкә. *Безнең кадерле Кутуебыз Лодзь воеводалыгына керә торган Згеж шәһәрендәге борынгы хәрби зиратка күмелгән.* Г. Галиев.

ВОЖА'ТЫЙ *и.* Мәктәптә, балалар йортында пионер отряды яки дружинасы житәкчесе. *Мине язу машиналары эшли торган заводның Вахитов исемендәге пионерлар отрядына вожатый итеп күчерделәр.* А. Алиш. *Пионер вожатыеның муеныгызга үзегез шикелле пакь, керсез, матур, нәфис кызыл галстук таккан чакта --- тәнегез буенча бик җылы, бик рәхәт дулкын үтеп киткәнен хәтерләгез!* Г. Гобәй.

ВОКАЛИЗМ *и. лингв.* Бер телнең сузык авазлар системасы.

ВОКАЛИСТ *и.* **1.** Вокаль сәнгате белгече, җырчының тавышын тәртипкә салучы, үстерүче белгеч.

2. Үз тавышының мөмкинлекләреннән бик оста файдалана белүче җырчы. *Вокалистларның М. П. Мусоргский исемендәге Бөтенсоюз конкурсы.*

ВОКАЛЬ *с. муз.* Җырлау өчен билгеләнгән, җырга, җырлауга бәйле. *Вокаль сәнгате. Вокаль әсәр.* □ *Музыка белән әдәбият бердәмлегеннән җырлау өчен вокаль музыка туган.* Ж. Фәйзи. *Бу дәреслəр башлыча* [*җырчы*]*ларның тавышларын дөрес үстерү, вокаль мөмкинлекләрен тулырак ачу һәм тәрбияләү --- хезмәтен үтәделәр.* М. Җәлил.

ВОКЗАЛ *и.* Тимер юл станциясендә яки пристаньда пассажирлар өчен билгеләнгән бина. *Вокзалга, шәһәр тирәсендә йөри торган поезд белән китәр өчен, халык җыела башлады.* А. Шамов. *Бу вокзал, чиксез зур итеп*

көймәләп эшләнеп, башын пыяла белән япкан лабазга охшый. Г. Гали.

ВОЛ- Кушма сүзләрдә үзенең мәгънәсе белән «волость» сүзенә туры килә торган беренче кисәк, мәсәлән: *волбашкарма, волком, волкомол, волмилиция. Без [дезертирларны] исән-сау килеш волбашкармага илтеп тапшырыйк.* Ф. Әсгать. *Без дә хәзер комсомол эшенә --- волком тарафыннан ячейканың үзенә беркетелгән тулы хокуклы членнар булып катнаша башладык.* М. Әмир. *[Вафинны] волкомол секретаре итеп җибәрделәр.* Ф. Хөсни.

ВОЛЕЙБОЛ *и.* Тупны ятьмә аша бер команда икенче командага кул белән чөюдән гыйбарәт спорт уены. *[Үсмерләр] баганадан баганага ятьмә тарттырдылар да волейбол уйнарга керештеләр.* Г. Гобәй. *Волейбол тубы чөеп уйнаган чакта, ак трусик кигән Гәрәй исемле бер егет гел Ләйлә тирәсендә чуалды.* И. Гази.

ВОЛЕЙБОЛЧЫ *и.* Волейбол уйнаучы кеше. *Волейболчылар ярышы.*

ВОЛОКИ'ТА *и.* Суд яки административ эшләрне, берәр мәсьәлә чишүне, артык формальлеккә бирелеп, юри озакка сузу.— *Сез кергән саен без үзебездәге кәгазь «ботка»сын, волокитаны ачыграк аңлый идек һәм кешеләрнең кечкенә генә йомышларын да тиз генә үти алмаганыбыз өчен эчебездән эрни идек.* Г. Галиев. *Мартта башланган волокитаның очын июльдә генә тап[тык].* Г. Гали.

ВОЛОКИ'ТАЛЫ *с.* Волокита белән, төрле формаль нәрсәләр белән бәйләнгән, мәшәкатьле.

ВОЛОКИ'ТАЧЫ *и.* Бирелгән эшне юри акрын башкаручы, бутаучы, волокита тудыручы кеше. *Волокитачының җавабы бер: иртәгә мин юкта килерсең.* Мәкаль.

ВОЛОСТНОЙ *и. сәйл. тар.* Элекке патша Россиясендә волость башлыгы, старшина. *[Иван:] Син киткәч, волостной кем булыр икән? [Ислам:] Чукмарлыдан Сәйфулла байны куярга телибез. [Иван:] Китегез, кит. Аның ише неграмотный кешене старшина итеп куярга ярыймы соң!* Т. Гыйззәт. *Мәмсәнең Әхмәтҗан хәзрәткә газета килгән икән, дигән хәбәрне волостной да сөйләп кайтарды.* Г. Газиз.

ВО'ЛОСТЬ *и. тар.* **1.** Патша Россиясендә һәм СССРда 1929—1930 елларга кадәр: өяз составына кергән кечерәк административ-территориаль берәмлек.— *Волостьтагы алпавыт, чиркәү, монастырь җирләрен бүгеннән бөтен халыкныкы дип игълан итәбез.* Т. Гыйззәт. *Меньшевиклар, эсерлар, --- волостьтагы иң бай авылларны сайлап алып, бөтен агитация эшен шул авылларда гына алып бара башладылар.* И. Гази.

2. Шул идарә урнашкан авыл; волость үзәге.— *Бүген барыбер авыл советыннан волостька баручы кеше булмаячак.* Ш. Камал.

ВӨЛЬЕР *и.* Хайваннар һәм кошларны ачык һавада асрау өчен киртәләп алынган урын.

ВОЛЬТ *и.* Электр тогы көчәнешен үлчәү берәмлеге. *Яшен яшьнәгән вакытта атмосферадагы электр кырының көчәнеше 100 әр млн. вольтка җитә.* М. Зиннәтов. *Көнкүрешебезгә электр килеп керү сәбәпле, «вольт» сүзе еш кулланыла башлады.* И. Гази.

ВО'ЛЬТА: вольта баганасы *физ.*— бер-бер артлы тоташтырылган гальваник элементлардан гыйбарәт батарея. **Вольта дугасы** *физ. иск.*— *к.* электр дугасы.

ВОЛЬТ-АМПЕР *и. тех.* Алмаш электр тогы егәрлеген үлчәү берәмлеге.

ВОЛЬТЛЫ *с.* Үзеннән алда килгән сандагы вольт белән исәпләнә торган. *Менә безнең комсо-йөрәк миллион вольтлы токтан көчлерәк.* М. Җәлил. // «Югары», «түбән» сүзләреннән соң килгәндә: зур яки кечкенә көчәнешле. *Тимер чыбыкларга югары вольтлы электр тогы тоташтырылган.* Г. Әпсәләмов.

ВОЛЬТМЕТР *и. тех.* Электр чылбырының ике ноктасы арасындагы ток көчәнешен үлчи торган прибор.

ВОЛЬФРАМ *и. хим.* Көмеш сыман ак төстәге авыр эрүчән металл, химик элемент.

ВОЛЬФРАМИТ *и.* Каты корычның махсус сортларын койганда кулланыла торган минерал.

ВОЛЮНТАРИЗМ *и.* **1.** *филос.* Табигатьтә, җәмгыятьтә объектив закончалыкны һәм зарурилыкны инкяр итеп, дөнья үсешендә хәлиткеч рольне ихтыяр уйный дип санаган реакцион идеалистик караш.

2. *психол.* Психик тормышның хәлиткеч факторы итеп акылны түгел, бәлки ихтыярны санау.

ВОЛЮНТАРИСТ *и. филос.* Волюнтаризм (1 мәгъ.) тарафдары.

ВОЛЮНТАРИ'СТИК *с.* Волюнтаризмга нигезләнгән, волюнтаристларга хас.

ВОССТА'НИЕ *и.* Үз сыйнфый яки милли интересларын яклап, шулай ук иске иҗтимагый төзелешне бәреп төшерү һәм яңа иҗтимагый төзелеш урнаштыру өчен, халыкның хаким сыйныфларга каршы масса күләмендәге кораллы чыгышы. *Партия эшчеләр сыйныфын кораллы восстаниегә хәзерли.* И. Гази.— *Хәрби иптәшләр үзләренең төп эшләре, ягъни подразделениеләрне оештыру, сугыш белеменә өйрәтү һәм восстаниене хәзерләү белән шөгыльләнергә тиеш.* Г. Әпсәләмов.

ВОССТА'НИЕЧЕ *и.* Восстаниедә катнашучы кеше. *Восстаниечеләр Казанга өч яктан һөҗүм иткәләр.* Г. Ахунов.

ВО'ТУМ *и.* Буржуаз илләрдә тавыш бирү юлы белән чыгарылган карар.

ВО'ТЧИНА *и.* XII—XVIII гасыр Русенда эре җир биләүченең мирас булып килгән җире, утары.

ВОТЯК *и. иск. к.* удмурт. *Сикертән авылының кешеләре баштанаяк дип әйтерлек вотякларга охшаган.* Г. Камал.

ВОЯЖЁР *и. иск.* Сәяхәтче, илгизәр. *Иптәш белән Троицкида вәгъдә куешкан тройкалы ике немец вояжёры безне урманда туктап көтәләр икән.* Г. Тукай. *Бу кеше үзе эре сәүдәгәр, шуның өстенә, алып-сатар да, антиквар да, вояжёр да.* К. Тинчурин.

ВОһ *ы.* Берәр әйберне бик мактаганда иң зур мактау сүзе булып кулланыла.— *Вох! — диде ул, болар янына килеп җитүгә уң кулының баш бармагын күрсәтеп.— Сембер ярминкәсендә дә сирәк очрый андый чабышкылар.* М. Гали.

ВРАЧ *и.* Югары медицина белеме алган кеше. *Балалар врачы. Санитар врач. Баш врач.* □ *Ул инде биш-алты елдан бирле: «Йөрәгем чәнчә, сулыш алырга бирми»,— дип зарлангалап йөри, ләкин врачка --- күренгәне юк.* Ф. Хөсни. *Район врачы, Тимеринең үпкәсенә бик яман салкын тидерүен әйтеп, шул төнне үк үзе белән больницага алып китте.* Г. Бәширов.

ВРАЧЛЫК *и.* **1.** Врач булу һөнәре. *Ничек инде ул медицинаны яратмасын?! Яратмаслык булса, [Мәдинә] врачлыкка укып йөрмәс иде.* Ш. Хөсәенов. // *с. мәгъ.* Врач хезмәте белән бәйләнгән. *[Таһиров] врачлык гомерендә ун меңнән артык операция ясады.* Г. Әпсәләмов. *Бу беренче бәладән мине врачлык сизгерлегем коткарды: авыруны коендырырга, юеш простыня белән төреп тотарга куштым.* Г. Кутуй.

2. Дәвалау эше.— *Үзе болай врачлыкка бик оста.* Р. Төхфәтуллин.

Врачлык итү — врач булып эшләү, врач хезмәтен башкару.— *Утыз ел врачлык иттем. Утыз ел кешеләрнең йөрәк тибешен тыңладым.* А. Шамов.

ВРРР *аваз ияр.* Берәр нәрсә (гадәттә машина винты) бик кызу әйләнгәндә барлыкка килә торган тавышны белдерә. *[Суккыч] «Зз... вз... врр...» — дип сызылдап-выжылдап әйләнеп тора, көлтәне бер яктан йота бара.* Г. Ибраһимов.

ВРРХ *аваз ияр.* Берәр нәрсә (гадәттә машина винты) бик кызу әйләнеп кинәт туктаганда чыга торган тавышны белдерә. *Малай, самолет булып, кулларын киң җәеп, әйләнеп йөрде дә (янәсе, ул истребитель, таран ясый) башы белән Илдарның күкрәгенә китереп төртте: «Врррх!»* Г. Гобәй.

ВТУЗ *и.* Югары техник уку йорты.— *Сез үткән яз гына втузны бетергәнсез, иптәш Галин.* Ш. Камал.

ВТУ'ЛКА *и. тех.* Машина яки җайланмада: эченә икенче бер детальне кертеп утырту өчен тишеге булган цилиндрик деталь. *Чугин втулканың эченә үтәли чыккан паз ясый.* А. Расих.

ВУАЛЬ *и.* 1. Хатын-кыз эшләпәсенә беркетелеп, гадәттә битне каплап торган юка, үтә күренмәле тукыма яки челтәр. *Кызлар, аны күреп, вуаль белән йөзләрен каплыйлар.* Т. Гыйззәт. [*Туташ*] *киң читле эшләпәсенә беркетелгән вуальне бер якка таба ачып җибәрде.* Г. Ибраһимов.

2. Үтә күренмәле җиңел тукыма.

ВУЗ *и. сөйл.* Югары уку йорты. *Зур улым быел Казанда вуз тәмамлады. --- Узебезнең районга агроном булып эшкә кайта.* Г. Минский.— *Сиңа да, миңа да әле укырга кирәк. Вуз тәмамларга...* Р. Ишморат.

ВУЗДАШ *и.* Бер вузда укучы кешеләрнең берсе. *Кызым вуздашларым кушкан Йолдыз исемен алды.* М. Хөсәен.

ВУЛКАН *и.* Түбәсендәге кратерыннан вакыт-вакыт эрегән кайнар лава, газ, тау токымнары һәм көл атылып чыга торган конус сыман тау; янар тау. *Җирдән бәреп чыккан вулкан белән таулар шаулап умырыла...* М. Гафури. *1883 елгы вулкан атылу вакытында аның авызыннан бәреп чыккан ташлар 2500 чакрым ераклыкка очканнар.* Р. Мостафин.

ВУЛКАНИЗА'ТОР *и.* Вулканлаштыру эшен башкаручы белгеч.

ВУЛКАНИЗМ *и. геол.* Җир шары эченнән вулкан рәвешендә өскә күтәрелә яки җир кабыгы эчендә ката торган кайнар массаның хәрәкәте белән бәйләнгән күренешләр җыелмасы. *Вулканизм эшчәнлеге.*

ВУЛКА'НИК *с.* Вулканга бәйләнешле. *Вулканик токым. Вулканик матдә.*

ВУЛКАНЛАШТЫРУ *и. тех.* Каучукны, аңа ныклык, тыгызлык сыйфатлары бирү өчен, югары температурада күкерт яки башка матдә белән эшкәртү. *Каучукны вулканлаштыру ысулы.*

ВУЛКАНО'ЛОГ *и.* Вулканология белгече.

ВУЛКАНОЛО'ГИК *с.* Вулканологиягә бәйләнешле. *Вулканологик тикшеренүләр.*

ВУЛКАНОЛО'ГИЯ *и.* Геология һәм физик географиянең вулканик күренешләрне өйрәнә торган бүлеге.

ВУЛЬГАР *с. кит.* 1. Оятсыз, әдәпсез, тупас.

2. Мәгънәсе бозылырлык, үзгәрерлек дәрәҗәдә, чиктән тыш (яки тупас рәвештә) гадиләштерелгән. *Вульгар материализм.* □ *Г. Халит әдәбиятка килгәндә, егерменче еллар ахырында һәм утызынчы еллар башында кабарынкы төс алган вульгар социологизмга каршы көрәш башланып килә иде.* И. Нуруллин.

ВУЛЬГАРИЗА'ТОР *и.* Берәр нәрсәне вульгарлаштыручы кеше. *Кыйммәтле иске мирасны танымаучы төрле вульгаризаторлар тарафыннан 20 нче елларның беренче яртысында Г. Камалның «Банкрот», Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» шикелле тирән эчтәлекле классик комедияләре һ. б. репертуарга кертелмәде.* Б. Гыйззәт.

ВУЛЬГАРИЗМ *и. лингв.* Әдәби телдә кулланылган тупас, әдәпсез сүз яки әйтелмә. *Әдәби тел үзенең нормаларына сыймый торган --- вульгаризмны --- кыскырыклап чыгара.* Қ. Сабиров.

ВУЛЬГАРЛАШТЫРУ *ф.* Берәр нәрсәнең эчтәлеген, мәгънәсен бозарлык итеп тупас рәвештә гадиләштерү. [*Зөбәржәт:*] *Минем өчен хәзергә, үзең әйтмешли, мираж булып күренгән иң зур бәхет — синең белән бик матур тормыш корып җибәрү һәм --- матур гына, нәкъ менә сиңа охшаган бер бәби табу. ---* [*Зәһид:*] *Күрәсеңме, син ничек вульгарлаштырасың мәсьәләне!* А. Расих.

ВУЛЬГАРЛЫК *и.* Тупаслык, әдәпсезлек. *Петефи бу шигырьне реакцион тәнкыйтьчеләрнең, дворян язучыларының аны вульгарлыкта, дорфалыкта гаепләүләренә каршы җавап итеп яза.* Сов. әд.

ВУЛЬГАРЧЫЛЫҚ *и. к.* вульгарлаштыру. *Тәнкыйтьтәге формализмның, вульгарчылыкның совет әдәбияты үсешенә зарар китерүен Такташ тагын да кискенрәк ачып сала.* Х. Хәйри.

ВУУ *аваз ияр.* Улауга охшаш тавышны белдерә.

Вуу итү — шундый тавыш чыгару.

ВШТ *ы. к.* выжт.— *Вшт моннан, мөртәт...* Қ. Нәҗми.

ВЫ'БОРЩИҚ *и. иск.* Сайлау турыдан-туры булмаганда сайлаучылар тарафыннан депутат сайлау өчен вәкил итеп җибәрелгән кеше. *Думага выборщик сайлау түгрысында да җитәрлек эшләр эшләдегез.* Ш. Мөхәммәдев. *Менә, туганнар, мондый сатлык выборщикларны сайларга ярамый шул.* РСДРП прокламациясе.

ВЫ'ВЕСКА *и.* Предприятие, учреждение, оешманың исемен яки эш төрен күрсәткән язулы такта, фанер, калай. *Ишек төбендә «Кече Илшат идарәсе» дигән ак калай вывеска ялтырый.* Г. Гобәй. [*Инспектор*] *балалар йортында бер җитешсезлек тә таба алмаган, ди. Шуңа күрә тиздән капка башына «Урнәк балалар йорты» дип вывеска куячаклар имеш, ди.* Қ. Нәҗми. // *күч.* Ялган исем, пәрдә, битлек. [*Татар буржуазиясе*] *«Милли мәдәни мохтарият» вывескасы астында Идел-Урал штатын игълан итәргә маташа.* Т. Гыйззәт.

ВЫЖ, ВЫЖ-ВЫЖ 1. *аваз ияр.* Һава агымы бик зур тизлек белән хәрәкәт иткәндә яки һаваны бик зур тизлек белән кисеп, ярып барганда туган кискен, ачы тавышны белдерә. *Бер чакны күз алдымда җилләр уйный выж да выж.* С. Рафиков.— *Их, сеңелкәй! Таңгы белән карны җырлатып йөрүе үзе ни тора! Выжжж!* Д. Аппакова.

2. *хәб. функ. сөйл.* Берәр кая бик зур тизлек белән хәрәкәт итү, китү турында.— *Сакчының күзе миндә булыр, ә син шул вакыт выжж... кер дә пос.* И. Гази.— *Әти иртәнге намазга бармый калмас. Мин шул арада тагын выж!* Г. Гобәй. // Берәр кая капыл гына, кисәк кенә китүне белдерә.— *Син барын да белешеп кайт та, көннәрдән беркөнне без выж чирәм җирләргә!* А. Расих.

3. *хәб. функ. гади с.* «Хәзер үк моннан кит» мәгънәсен белдерә.— *Выж-ж-ж-ж, әйдә, карчык, табаныңны ялтырат!* М. Фәйзи.

Выж (выж-выж) итеп (килеп) — 1) выжылдап. *Самолет астыннан бер нәмәрсә аерылып, выж-выж килеп, фырылдап һәм сызгырып түбән төшә башлады.* Ш. Маннур; 2) бик тиз, бик зур тизлек белән. *Атлаган саен Алмаевның колак төбеннән выж-выж килеп йөк машиналары үтеп китә.* И. Гази. *Менә җиргә кадала, менә җиргә бәрелеп бетә дигәндә генә, козгын тагын выж итеп өскә үргыла.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Выж галләм (выж, Галләм)** *гади с.*— эшләгән эштән чыгарылу яки берәр кая китү.— *Алайса озакламый Ифрат «выж галләм» икән,— дип уйлады Бәһави.— Мине персидәтель итеп билгеләүләре дә бар.* А. Расих.

ВЫЖ-ВЫЖАҚ *и.* Түгәрәкләнеп идәнгә утырган балаларның, кулларын артка яшереп, кулдан кулга ишелгән сөлге йөртүләреннән, уртадагы «тәкә» дип исемләнгән уенчыга, ул күрмәгәндә, бик тиз сугып алудан һәм сөлгене кабат яшереп йөртүдән гыйбарәт уен («тәкә» сөлгене кем кулыннан алса, шул уртага чыга, «тәкә»гә әйләнә).

ВЫЖГЫЙЛАУ *ф. сир.* 1. Бик тиз хәрәкәт итү нәтиҗәсендә канатлар, снаряд, пуля, машина һ. б. ш. нәрсәләр «выж-выж»га охшаш тавыш чыгару.

2. *рәв. мәгъ.* **выжгыйлап.** «Выж-выж»га охшаш тавыш чыгарып. *Пуля выжгыйлап барып керә маңгайга яисә иякка.* Н. Думави.

ВЫЖГЫЛДАУ *ф. к.* выжылдау (1—2 мәгъ.). *Алар безнең өскә олы вә салкын күсәкләрен ыргыталар һәм уклар аталар иде. Ул күсәкләр һәм уклар, выжгылдап, безнең баш очларыбызда очып йөриләр, килеп эләккән иптәшләребезне аякларыннан ега вә җәрәхәтлиләр иде.* Ф. Әмирхан.

ВЫЖГЫРТУ *ф. гади с.* Бик тиз куу, куып чыгару.

ВЫЖГЫТУ *ф. гади с. к.* выжгырту.— *Эшеннән выжгыталар инде [Шаминны] болай булгач, Зәйдән куалар...* А. Гыйләжев.

ВЫЖЛАВЫК *и. к.* бызлавык. *Выжлавык дигән коңгызлар --- һәммәсе дә алтышар аяклы. --- Ялтырап торган канат өлекләре булса да, оча алмыйлар. Ник дигәндә: элпә канатлары юк.* Г. Хәсәнов.

ВЫЖЛАТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* выжлау.

2. *рәв. мәгъ.* **выжлатып.** Берәр нәрсәне бик зур тизлек белән (хәрәкәт иттереп). *Атның сыртына шарт-шорт төшкән чыбыркы тарантас тәгәрмәчен выжлатып әйләндерә.* Ф. Кәрим. *Менгән атың айгыр булса, Выжлатып чап, кайгырма!..* И. Туктар.

3. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне яки кешене куып чыгару, куу. *Башка вакытларда капка астында күренүләренә выжлатып чыгара торган ят этләрне дә кумады ул.* Г. Гобәй.

ВЫЖЛАУ *ф.* 1. Зур тизлек белән очканда, хәрәкәт иткәндә һ. б. ш. очракларда һавада выж иткән тавыш чыгару. *Колак төбендә тыгыз, каты җил выжлады.* Н. Фәттах.

2. *рәв. мәгъ. күч.* **выжлап.** Бик тиз, бик зур тизлек белән (хәрәкәт итү турында). *Машиналар выжлап киләләр дә, сәлам бирергә дә өлгерә алмыйча, узып китәләр.* И. Юзеев.

ВЫЖТ, ВЫЖТ-ВЫЖТ 1. *аваз ияр.* Зур тизлек белән һава ярып үткәндә чыга торган тавышны белдерә. *Юлдан выжт та гөжт автомобильләр үтеп тора-лар.* Дин тур. халык.

2. *к.* выж (2 мәгъ.). *Кыш көне чаңгы шуарга әйбәт. Абзар капкасын ачып куясың да — выжт!..* Г. Мөхәммәтшин.

3. *хәб. функ. сөйл.* Берәр нәрсәне бик тиз эшләү, башкару турында.— *Безнең заводларда һәр минут саен бер машина — выжт! — ясалып кына тора бит!* Р. Төхфәтуллин.

4. *хәб. функ. сөйл. күч.* Акча яки кыйммәтле әйбернең бик тиз тотылуы, сарыф ителүе турында. *Әле номерга кереп җитмәгән, ике сум егерме биш тиен выжжт!* Г. Тукай.

5. *хәб. функ. гади с.* Берәр урыннан яки эштән куып чыгару. *Сугышырга ирек бирмәделәр. Выжт Минапны цехның тышына.* Х. Туфан.

Выжт итеп (килеп) — *к.* выж итеп. *Башка авыллар-да машиналар яңгырлы көннәрдә дә выжт итеп кенә үтеп китәләр. Ә безнең Курайлы елга басуларыннан алай тиз генә, ансат кына үтә алмыйсың.* Г. Галиев.

ВЫЖТУ *ф. гади с. гадәттә боерык ф. күплек формасында, килә:* **выжтыгыз.** Берәр урыннан хәзер үк китәргә боерык белдерә. *Габделмән, ачуланып, --- һәмә баланы куа: «Әйдә, выжтыгыз моннан».* М. Фәйзи.

ВЫЖУ *ф. гади с.* Берәр урыннан бик тиз китү, чыгу. *Артымнан теге дуңгызлар чыга күрмәсен тагы дип, тиз генә выждым [ул].* Г. Толымбай.

ВЫЖЫЛДАВЫК *и.* Бер урында бик кызу бөтерелеп выжылдый торган балалар уенчыгы; бөтерчек. *Без таш өйнең караңгырак почмагында --- выжылдавык уйнатып, «Без-без-без идек, без уникe кыз идек» көенә әкрен генә такмаклап, күңел ачып утыра идек.* Ф. Хөсни.

ВЫЖЫЛДАТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* выжылдау. *Велосипедын выжылдатып яныбызга Нияз килеп туктады.* Э. Ибраһимова.

2. *рәв. мәгъ.* **выжылдатып.** Бик тизлек белән, выжт итеп.— *Их, кайчан мин дә шулай выжылдатып мотоциклда эштән кайтырмын?* А. Әхмәт. *Балык выжылдатып җепне үзенә таба ала да башлады...* М. Хәсәнов.

ВЫЖЫЛДАУ *ф.* 1. Бик тиз хәрәкәт итү нәтиҗәсендә, канатлар, снаряд, пуля, машина һ. б. ш. нәрсәләр «выж»га охшаган тавыш чыгару. *Кечкенә генә зәңгәр күбәләкләр оча, төклетуралар выжылдый.* И. Гази.

2. *рәв. мәгъ.* **выжылдап.** Бик зур тизлек белән хәрәкәт иткәндә «выж-выж»га охшаш тавыш чыгарып. *Снаряд, мина ярчыклары безнең тирәдә выжылдап очып кына торалар.* Р. Ишморат. *Грузовиклар фронтларга чаба выжылдап.* Ш. Маннур.

ВЫКЛЮЧА'ТЕЛЬ *и.* Электр тогын тоташтыра яки өзә торган җайланма. [*Шәүкәт*], *стенадан выключательне табып, утны яндырды.* Э. Касыймов. [*Карчык*] *выключательне аска таба басты. Өй эче караңгы һәм тын булып калды.* Г. Галиев.

ВЫ'МПЕЛ *и.* 1. Хәрби диңгез кораблендә аның кайсы илнеке икәнен күрсәтә торган, очы ерык, озынча тар флаг. // Гомумән тар, озынча яки өчпочмак формасындагы кечкенә флаг. *Аның мачтасында социалистик ярышта җиңүченең вымпелы җилферди.* Г. Әпсәләмов. *Безнең теплоходка күчмә вымпел тапшырачаклар.* С. Сабиров.

2. Бер башына төсле озын тасма беркетелеп, эченә хатлар, газета-журналлар, посылка һ. б. ш. нәрсәләр салып, самолеттан җиргә ыргытыла торган тартма яки төргәк. *Самолеттан ак төргәк аерылып җиргә төшеп китте: «Вымпел! Вымпел ташлады!»* Г. Мөхәммәтшин.

3. Өстенә рәсем ясалып яки язу язылып, берәр кая җибәрелә, ыргытыла торган төрле формадагы металл кисәге.— *Хәзер Айда да «Советлар Союзы» дип язылган вымпел бар инде.* Г. Бакиров.

ВЫР-ВЫР *аваз ияр.* Мотор һ. б. ш. нәрсәләрнең бертөрле әйләнүеннән чыккан тавышны белдерә.

Выр-выр килү — вырылдау. *Озын төннәргә, өй эчендәге эчпошыргыч сүрән тормышка, выр-выр килеп әйләнгән орчык тавышына бу озын көй бик пар булып төшә.* К. Нәҗми.

ВЫРТ-ВЫРТ *аваз ияр.* Сыек нәрсә эченнән һава куыкчыкларын чыкканда була торган тавышны белдерә.

Вырт-вырт итү — шундый тавыш чыгару.

ВЫРТЛАВЫЧ *и.* Бер башына төбе тишкәләнгән кечерәк савыт куелган таяк (ятьмә белән балык тоткан-да балык куркытыр өчен кулланыла: аны суга батырсаң, һава вырт-вырт итеп чыга). *Балыкчылар ау салдылар, ахры, выртлавыч белән вырт-вырт итеп балык тота [башла]дылар.* Г. Мөхәммәтшин.

ВЫРЫЛДАУ *ф.* «Выр-выр» авазларына охшаш тавыш чыгару. *Килә бу кош. Әй вырылдый үзе. Тәпиләре тәгәрмәч сыман.* Ф. Кәрим.

ВЫ'ШКА *и.* Бораулау, күзәтү, саклау һ. б. ш. максатлар өчен салынган тар, биек корылма яки биек багана башына ясалган мәйданчык. *Нефть вышкасы.* □ *Алда коточкыч дәү булып, башыңны күтәрсәң, бүрегең төшеп китәрдәй биек булып корыч вышка күренде.* Г. Ахунов. *Өч метр саен өчәр катлы вышкалар. Вышкалар башында пулеметлар, автоматлар белән коралланган сакчылар.* Г. Әпсәләмов.

ВЫ'ШКАЧЫ *и.* Вышкалар сүтүче, коручы оста. *Вышкачы кыр сумкасыннан кәгазьләр тартып чыгарды.* Р. Төхфәтуллин. *Никулин бригадасы буровой төзегәнне көтеп ята — вышкачылар килә алмыйлар.* Ш. Бикчурин.

ВЬЕТНАМЛЫ *и.* Вьетнам халкының бер вәкиле. *Ә тегендә бомбовозлар Үлем сибә вьетнамлы йортына.* Ә. Давыдов.

ВӘ *терк. иск. кит. к.* һәм. *Бу авыл үзе зур вә киң яланнарның уртасында булган бер үргә утырган.* Г. Ибраһимов. *Минем көчле рухымнан Җир вә күкләр калтырар.* һ. Такташ.

Вә гайре (әлех) *иск. кит.*— һәм башкалар. *Японнарның аз дигәндә ике айлык сугышка җитәрлек снарядлары, дарылары вә гайре сугыш кирәкләре бар.* Ш. Мөхәммәдев. *Татарча газета вә журналлар чыга башлагач, мин әүвәл бер журналда язышучы булып, аннан соң бер газетада баш мөхәррир булып тордым вә әлех, вә әлех...* Ф. Әмирхан.

ВӘ-ВӘ *аваз ияр.* Бала елаганда чыга торган тавышны белдерә. *Гайшә, Вәлине үчекләп, авызын бозып: «Вә-вә-вә!» — дип куя.* К. Әмири. *Урманның әллә кай җирләренә кечкенә Фатыйманың елавы [ишетелә]: «Вә-вә-вә!!!»* Х. Садрый.

ВӘГАЗЬ *и. иск.* **1.** Үгет, нәсихәт, яхшылыкка өндәү.— *Ул кадәр егет арасында шыркылдашып йөрергә килешәмени? — ди-ди [эти] вәгазь сөй[ли].* Ф. Әмирхан.

2. *дини.* Мәчеттә, гыйбрәтләр китереп, дини нәсихәт бирү төсендәге чыгыш. *[Вәгыйзь мәчеттә], халыкны үз әйләнәсенә җыеп, һәр изгелекләргә боерып, һәр әшәке эшләрдән тыеп --- вәгазь әйтәдер иде.* Г. Тукай.

Вәгазь итү (кылу) — *к.* үгетләү.— *Намазларыгызны калдырмаска тырышыгыз... Ятлаган догаларыгызны күңелегездән чыгармагыз. Һәрвакыт тәкрарлап торыгыз...— дип вәгазь иткәннән соң, --- [хәзрәт] шәкертләрен озатып, яңа тормышка чыгарып җибәрде.* М. Гафури. *Имам-мулла, вәгазь кылма, ходайдан бар афәтләр, дип.* Н. Исәнбәт.

ВӘГАЗЬЛӘҮ *ф. иск. кит.* Үгет-нәсихәт бирү, үгетләү. *Аш пешерүче, --- мәчене вәгазьләргә башлап: «И оятсыз! Оятсыз! Сиңа бу эшне эшләргә кешеләрдән генә түгел, хәтта стеналардан оялырга кирәк иде»,— дип сөйләнә иде.* Г. Тукай. *Атасы: «Хатыңны еш яз, укуыңны тизрәк бетереп кайт»,— дип вәгазьли.* Г. Ибраһимов.

ВӘГАЗЬ-НӘСИХӘТ *җый. и. иск. к.* үгет-нәсихәт.— *Бу вәгазь-нәсихәтеңне мин дә бик күп мәртәбәләр ишеттем. Кирәкми миңа синең фәлсәфәләреңә!* А. Шамов.

Вәгазь-нәсихәт кылу — үгетләү, вәгазьләү. *Вәлид хәзрәт үзенчә халыкны бик вәгазь-нәсихәт кыла.* З. һади.

ВӘГАЗЬЧЕ *и.* **1.** Вәгазь сөйләүче, үгет-нәсихәт белән шөгыльләнүче, үгет-нәсихәт бирергә яратучы кеше.

2. *с. мәгъ.* Берәр фикер, караш таратучы, пропагандалаучы (кеше турында). *Г. Камал вәгазьче, әхлакчы язучы түгел. Ул үз заманында татар әдәбиятында хөкем сөргән артта калганлык, наданлык, иске фикерлелек турында фәлсәфә сатмый.* М. Гали. // *и. мәгъ.* Шундый кеше.

ВӘГАЗЬЧЕЛЕК *и.* Вәгазьче булу. *Кайбер тәнкыйтьчеләр --- Тукайның [бу] шигыр[ьләр]ендә артык вәгазьчелек, әхлакчылык күрәләр.* Җ. Вәлиди.

ВӘГАЛӘЙКЕМӘССӘЛАМ *ы. мәгъ. иск.* Сезгә дә тынычлык телим (ирләрнең ирләр сәламенә каршы җавап сүзе). *[Ир] туңган тавыш, өшеган авыз белән: «Әссәламегаләйкем! Әткәй, исәнлекме?» — дип, калын җиң эченнән ике кулын сузды. Карт: «Вәгаләйкемәссәлам»,— дип, сәлам кайтарды.* Г. Ибраһимов.

ВӘГЪДӘ *и.* **1.** Берәр нәрсәне эшләргә, башкарырга дип, үз ризалыгы белән алынган йөкләмә. *Аның белән яңадан очрашырга, аның күңелен борчыган күп нәрсәләр турында ныклап сөйләшергә, киңәшергә вәгъдә биреп, Агыйделгә төштек.* М. Әмир. *Катяга ул һәр дәрескә бер җыр ятлап килергә сүз бирде һәм вәгъдәсен бик төгәл үтәде.* Г. Әпсәләмов.

2. Ант.— *Вәгъдә булсын. Шәһәрнең иң серле күренешләре дә минем авыл баласылыгым каршында тоз кебек эреләр. Авылым мине ташламаса, мин аны ташламам!* М. Фәйзи.

3. Берәр нәрсә эшләргә яки эшләмәскә үзара килешү, алдан сүз беркетү. *Вәгъдә буенча, бүген киң бу күпер өстенә Аля киләчәк иде.* Ф. Әмирхан.— *Бу — беренче кисәк — миңа, вәгъдәбез буенча.* Г. Тукай. // Егет белән кызның гомергә бергә булырга сүз куешуы. *Сажидә белән Илдарның Вәгъдәләре бар икән, Үзләре дә бик пар килгән, Уйлары да пар икән.* М. Җәлил. *Татар егете, рус кызы Бер-берен сөештеләр; Аламын, дип, барамын, дип, Вәгъдәләр бирештеләр.* Бәет.

4. *иск.* Алдан килешенгән срок. *Әтисе, бер йортта ике-өч көн торып, вәгъдәсенә өлгертим дип, кызуланып-кызуланып кайры түн тегеп маташа.* М. Гали.— *Туйны хәзер кылмагыз, бер ел да бер көн куеп, шул вәгъдә үткәч кылырсыз.* Әкият. // *иск.* Билгеләнгән вакыт.— *Белмәссең, бәлки, ходадан вәгъдә җитсә, терелеп тә китәр.* Г. Камал.

Вәгъдә алу *этн.*— өйләнешү алдыннан икенче яктан ризалык алу. *Егетнең анасы --- үзе белгән, яраткан бай кызына сүз салдыра. Вәгъдә ала, ике арада бүләкләр йөрешә башлый.* Г. Ибраһимов.— *Алар эшне башларга торалар. Сездән вәгъдә алуга гына эшләре терәлеп тора.* Г. Камал. **Вәгъдә бирнәсе** *этн.*— башкода килеп сөйләшкәндә, кыз ягыннан, ризалык билгесе итеп, егет ягына бирелә торган бүләк.— *Вәгъдә бирнәләрен дә бик һәйбәт итәчәкләр, сиңа күлмәклек җон, кияүгә...* Г. Камал. **Вәгъдә бирү (кую)** — 1) берәр нәрсә эшләргә яки эшләмәскә сүз бирү, ант итү.— *Мин сезнең сафыгызга — үз туганнарым янына чыгам һәм соңгы тамчы каныма кадәр көрәшергә вәгъдә бирәм.* һ. Такташ. *Гомер буе аерылмаска вәгъдә куйдылар [алар].* Г. Тукай; 2) ышандыру.— *Ул көн син үзең көтеп торам дип вәгъдә куйдың, ә үзең әллә кайда югалгансың.* Г. Камал; 3) сөйләшеп килешү, сүз беркетү. *Ахырында Батырғали агай илә икәү бергә дусишләргә сиздермичә генә сугышка китәргә вәгъдә кушештылар.* Ш. Мөхәммәдев; 4) егет белән кызны өйләндерергә сүз беркетү, килешү.— *Ходага тәвәккәлләп, Гаптерәшиткә вәгъдә бирикме әллә, кызым?* М. Фәйзи.— *Мәрьямне мин кайтмый торып Мәхмүткә бирергә вәгъдә куймагыз.* М. Гафури. **Вәгъдә бүләге** *этн.*— кыз белән егетне өйләндерү турында беренче килешү булгач ике яктан да бирелә торган бүләк.— *Риза, риза, иртәгә алардан вәгъдә бүләге китерерсең, бер-ике көннән үк изгъабе кабул итәрбез.* Г. Камал.— *Кияү булачак кеше [бу башмак]ларны вәгъдә бүләге итеп җибәргән.* Т. Гыйззәт. **Вәгъдә итү (кылу)** — 1) берәр нәрсә эшләргә сүз бирү, үз өстенә йөкләмә алу. *Бер тапкыр вәгъдә кылгач, аны сүзеннән кайтару бик җиңел түгел.* Ш. Әхмәдиев; 2) берәр нәрсә бирергә ышандыру. *Бөек хикмәтләр вәгъдә иткән --- атаклы Парижның беренче вокзалы менә шушы инде.* Г. Гали.— *Хаҗи әфәнде вәгъдә иткән егерме биш сумны бирер, аннан гына тормас.* Ш. Камал; 3) үз эшендә яки берәр өлкәдә уңышларга ирешәчәгенә өметләр тудыру. *Ул бердәнбер эшче театры һәм күп нәрсәләр вәгъдә итә торган театр.* М. Җәлил. **Вәгъдәдә тору** — биргән вәгъдәсен үтәү. *Юлларыбыз аерыла башлагач, кызчык вәгъдәсендә торды. Күкрәгендәге чәчәген алып, минем [арбага] ыргытты.* Ф. Әмирхан.— *Вәгъдәсендә тормады, ялганчы малай икән.* И. Гази.

◇ **Вәгъдә — иман** — әйткән сүзендә нык торачагына ышандыру өчен әйтелә.— *Вәгъдә — иман! Балык тотарга килермен.* А. Гыйләҗев.

ВӘГЪДӘЛЕ *с.* **1.** Вәгъдә (1 мәгъ.) белдергән, ризалык белдергән. *Әгәр кумаса, әгәр иреннәреннән бер*

үптереп кенә яки берәр вәгъдәле җылы сүз пышылдап кына кире җибәрсә дә, ул барысын да аңлар иде. Ә. Еники.

2. *этн.* Вәгъдәләшкән, өйләнергә яисә кияүгә чыгарга килешенгән, сүз куешкан.— *Кызыбызның кечкенәдән каланың Әхтәм бай улы Гәптерәшиткә ничек вәгъдәле булуын беләсең инде.* М. Фәйзи. *Рәхмәт синең матур сүзләреңә; Мин — вәгъдәле. Кабат [вәгъдә] бирәлмим.* Ш. Маннур.

3. Алдан билгеләп куелган (көн, сәгать, срок һ. б. ш. турында). [*Зыя*] *каралырга өч кенә көн калгач кайтачак иде. Аның вәгъдәле көннән кичегүе Зөләйха абыстайда әллә нинди караш, хиссият уятты.* Г. Ибраһимов.

4. Биргән сүзендә тора торган.— *Вәгъдәле кешеләр синең акча соравыңны көтмиләр, бурычларын үзләре җибәрәләр.* Г. Галиев. *Яңа начальник вәгъдәле кеше икән, бер-ике көннән соң ул чыннан да «Терәк» колхозына килеп чыкты.* Ә. Еники.

ВӘГЪДӘЛӘШҮ *ф.* 1. Вәгъдә куешу, килешү, сүз беркетү. *Ул кемнең кая барасын сорашып, аларның әйберләрен урнаштырырга вәгъдәләшеп куя.* М. Гали.— *Әйдәгез, болай вәгъдәләшик хәзергә: мин кушкан даруларны эчәсез, тәмәкене ташлыйсыз, көн саен саф һавада йөрисез.* Г. Әпсәләмов.

2. *этн.* Өйләнешергә сүз куешу.— *Минем колагымны тешләтеп, вәгъдәләшеп куярга аларның ни хакы бар? Колагымны тешләгән дип кенә, яратмаган кешемә ничек барыйм мин?* М. Фәйзи.— *Вәгъдәләшү котлы мөбарәк булсын, шатлык, бәхет эчендә яшь кәләш белән бергә-бергә гомер итегез.* Ш. Камал.

ВӘГЪДӘЛӘҮ *ф. сир.* Берәр нәрсәне бирергә яки башкарырга ышандыру, вәгъдә итү.— *Кайчан кайта соң инде ул? Һаман вәгъдәлисез дә вәгъдәлисез.* А. Шамов.

ВӘГЪДӘСЕЗ *с.* Сүзендә тормаучы.— *Мин Суфия апага вәгъдә бирдем. Мин вәгъдәсез була алмыйм.* Н. Исәнбәт.

ВӘГЪДӘСЕЗЛЕК *и.* Вәгъдәсез булу.— *Монда бер кешегә бирәсе бар, бирми калсаң, вәгъдәсезлек була, яхшы түгел.* Г. Камал.— *Ничек инде сез болай, вәгъдәсезлек күрсәтәсез, егетләр?* Ф. Хөсни.

ВӘГЪДӘЧЕЛ *с.* 1. Вәгъдәсендә торучы, биргән сүзен үтәүче. *Вәгъдәчел кеше.*

2. Вәгъдә (1 мәгъ.) бирергә яратучан, вәгъдәгә юмарт.

ВӘГЪДӘЧЕЛЛЕК *и.* Вәгъдәчел булу.

ВӘЗЕМЛӘҮ *ф.* Берәр нәрсәне җентекләп, ваклыкларына кадәр, тәфсиллəп сөйләү. *Аңа Әнвәрнең хәле турында шомартып-түгәрәкләп кенә язган идем мин, инде күзгә-күз карап сөйләшкәндә барысын да вәземләргә туры килде.* Э. Касыймов. // *рәв. мәгъ.* **вәземләп.** Җентекләп, тәфсилләп, аңлатып (сөйләү турында). *Шуларның хасиятен, сер-хикмәтләрен берәмтекләп, вәземләп аңлатып йөргән булды [ул].* Г. Ахунов. [*Тимери агай*] *үз кордашлары белән иген-тару, явым-чәчем, Испаниядәге сугышлар, фашистларның кансыз ерткычлыгы, Кытайдагы хәллəр турында картларча вәземләп аңгәмә корырга ярата.* Г. Бәширов.

ВӘЗЕН *и. әд. иск.* Шигырь үлчәве; ритм. *Гаруз вәзене.* □ *Вәзен дип [стопаларның] бер үлчәүдә килүенә әйтелә. --- [Көйле тезмәләрне] үлчи торган өч төрле вәзен бар: 1) иҗекләр санынча (силлабик), 2) басымнар санынча (тоник), 3) мадләр санынча (метрик).* Г. Ибраһимов. *Безнең шигырьләребез татар вәзеннәре белән генә үлчәнергә тиешле.* С. Рәмиев.

ВӘЗЕНДӘШ *с. әд. иск.* Бер үлчәмдәге; ритмдаш. *Бу персиян ---, шигырьдән кишмиш үлчәве кадәр генә хәбәре булса, «якыйн» вә «ашәфтә хуп» сүзләренең вәзендәш түгеллекләрен сизәр иде.* Г. Тукай.

ВӘЗЕНДӘШЛЕК *и. әд. иск.* Бер үлчәүдә, бер вәзендә булу.

ВӘЗЕНЧӘЛЕК *и. әд. иск. к.* ритмика. *Без Йосыф китабы үлчәвен, халкыбызның үз вәзенчәлеге нигезенә корылган, дип язып киләбез.* Н. Исәнбәт.

ВӘЗИР *и. тар.* Урта гасыр Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә: патша яки ханның дәүләт эшләрен башкаручы иң зур дәрәҗәле вәкиле.— *Мин ханзадә хатыны булам, сезне дә үз сараема вәзир итеп алам.* Д. Аппакова. *Сакчы бер якка, хан үз вәзире белән икенче якка юнәлəләр.* Н. Исәнбәт.

ВӘЗИР-ВОЗӘРА *җыйм. и. иск.* Вәзирләр һәм аларның якыннары, ярдәмчеләре. [*Егет*], *падишаһчык, вәзир-возәра илә исәнләшеп, поездга утырып китте.* Г. Тукай.

ВӘЗИРЛЕК *и.* Вәзир хезмәте, вәзир вазифасы; вәзир булу. *Вәзир дә бер дә аптырамыйча: «Мин Иранда тудым, хезмәтем вәзирлек иде»,— [ди].* Г. Тукай.

ВӘЙРАН *с. иск.* 1. Ватык, жимерек, хәрабә хәленә килгән. *Газет язган: «Яраплан очырабыз»,— дип, «Казанны вәйран хәлгә төшерәбез»,— дип, халыклар да каушаганнар «күченәбез» дип.* Г. Камал.

2. *күч.* Гаять аптыраган, гажəплəнгән. *Хисап итеп караса, калды хәйран, Үзенең кылдыгый малына вәйран.* Ә. Фәйзи.

3. *күч, рәв.* Зая, әрәм. *Алар сүзенә карап, яшь башың белән гомереңне вәйран үткәр, имеш!..* Г. Рәхим.

Вәйран булу — 1) жимерелү, ватылу, хәрабә хәленә килү; тар-мар ителү, юкка чыгу. *Пуля һәм снаряд белми аяуны. --- Шәһәр була вәйран, кабер.* Қ. Нәҗми; 2) *күч.* харап булу, һәлак булу, бәлагә очрау. *Хәйран башлар вәйран була кызның кашычен.* Г. Тукай.— *Үзе, малы белән халыкка никадәр хезмәт күрсәтә ала торган бер егет вәйран булып китсенме?* М. Фәйзи. **Вәйран итү** — 1) жимерү, ватү; юк итү.— *Минем шәһәремне вәйран итеп, малларымны алып китмәкче иде дошманнар.* Әкият; 2) *күч.* харап итү, һәлак итү. *Базарлардин кайтканда Вәйран иттем башымны.* Бәет. *Милләт [не] вәйран [итүче] ишан икәндер, белмәдем.* Г. Тукай. **Вәйран калу** — 1) бушау, бушап калу. *Төшсез чиклəвек шикелле, кешесез вәйран калган таш пулатлар, биек сарайлар --- чын сур илə җаваплашалар.* Г. Тукай; 2) *күч.* аптырау, гажəплəнү.

◇ **Вәйран башын хәйранга калдыру** — болай да авыр хәлдә булган кешене тагын да начаррак хәлгә кую.— *Әллә, ходаем, болай да вәйран башымны хәйранга калдырып, берәр урынга куймакчы булалармы?* Ф. Хөсни.

ВӘЙРАНЛЫК *и.* Хәрабәлек, жимереклек. *Безнең илебезгә фашист мордарлар китергән жимерүләрне, вәйранлыкларны төзәтүгә күпме еллар кирәк булыр икән?..* М. Максуд.

ВӘКАЛӘТ *и. кит.* 1. Берәр кешегә оешма яки жәмәгать тарафыннан теге яисә бу эшне эшләргә бирелгән хокук.— *Без үз фикеребезне --- волость крестьян съездында әйтербез. Хәзергә минем андый вәкаләтем юк.* Т. Гыйззәт.— *Сез биредә ниндидер гражданканы туктатуны сорыйсыз? Тимер юл эшчеләренең, гомумән, моңа вәкаләте юк.* Ш. Хөсәенов.

2. Вәкиллек, вәкил булып тору, вәкил булып саналу. *1965 елның мартында бу чакырылыш җирле советларның вәкаләт срогы тул [ды].* Г. Әпсәләмов.

Вәкаләт кәгазе — берәр нәрсә эшләргә хокук бирә торган кәгазь; мандат.

ВӘКАЛӘТЛЕ *с.* Нинди дә булса эшне үтәргә вәкаләте, хокукы булган. *Ул, кушылып сикәлтәле юлда Көрәшләрнең көчле давылына, Тулы вәкаләтле илче булган Чабаталы татар авылыннан.* Ә. Рәшитов.

ВӘКАЛӘТЛЕЛЕК *и.* Вәкаләтле булу, вәкаләткә ия булу.

ВӘҠАЛӘТНАМӘ *и. иск. кит. к.* вәкаләт кәгазе. *Әкрәм кари исеменә вәкаләтнамә язылып, аңар Фәйзулла староста --- мөһер басты.* М. Галәү.

ВӘҠАРЬ *и. кит.* Олысымаклык, мәһабәтлек, горурлык, җитдилек. *Шәһәр бакчасында өстенә җөббә, башына фәс, күзгә күзлек, аякка ботинка* [*киеп*], *авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкертне туктатып, юри, «вәкарь вә мәһабәтен» бозар өчен: «Син курай уйный белгәсеңме?» — дип сорыйсым килде.* Г. Тукай. *Ул үзенең дәрәҗәсен нинди генә хәлләрдә дә онытмый, вәкарь саклый.* А. Расих.

Вәкарь белән — олысымак кыяфәт белән, җитди, үз дәрәҗәсен (бәясен) белеп. [*Абыстай*] *бик йомшак тел белән, вәкарь белән генә сөйләш*[*ә*]. Қ. Нәҗми. *Вәкарь белән атлап, салкын караш белән байбичә килеп керде.* Г. Ибраһимов.

ВӘҠАРЬЛЕ *с. кит.* Үз дәрәҗәсен белгән, олысымак, эре, мәһабәт, мәгърур. *Ул бик әкрен һәм бик вәкарьле рәвештә, һичкемгә карамый, ике якка тезелгән кешеләр уртасыннан үтеп, михрабка каршы барып утырды.* М. Гафури. *Узенең дәрәҗәсен аңлаган вәкарьле кешеләр, ялкынлы йөрәкле геройлар башларын күтәрәләр.* С. Җәләл. // *рәв. мәгъ.* Эре, мәгърур рәвештә. *Разия, фигурасын туры гына тотып, киберле вә вәкарьле генә алдына карап бара.* Ф. Әмирхан. // *рәв. мәгъ. күч.* Салмак, эре. *Өстән акрын гына, вәкарьле генә, иренеп кенә сирәк-сирәк кар төшә.* Ф. Әмирхан.

ВӘҠАРЬЛЕҠ *и. кит.* Олысымаклык, мәһабәтлек, горурлык. *Сакаллы хәлфәләр, мыеклы пишкадәмнәр кибет, ашханә, тәһарәтханә арасында аеруча көязләнеп, вәкарьлек күрсәтеп йөреп торалар.* Қ. Тинчурин.

ВӘҠАРЬЛЕЛЕҠ *и.* Вәкарьле булу. *Узенең вәкарьлелеге вә җитди торышы белән минем дикъкатемне җәлеп иткән ак сакаллы бер карт иптәшемә таба борылды.* Ш. Камал.

ВӘҠИЛ *и.* 1. Берәр кеше яки оешма кушуы буенча аларның интересларын күзәтүче, яклаучы, алар исеменнән эш йөртүче, ышанычлы кеше. *Министрлык вәкиле. Колхоз вәкиле. Съездга вәкилләр җибәрү.* □ *Вәкилләр сайландылар, һәр сыйныфның вәкилләре шул сыйныфның файдасын химая итәргә вә шулар фикерендәге нәрсәләрне сөйләргә башладылар.* Ф. Әмирхан.— *Без бүген, бүләк һәм теләкләребезне яңа хөкүмәткә тапшыру өчен, үзебезнең вәкилләрне --- озату шәрәфенә ирештек.* Қ. Нәҗми. // Берәр ил интересларын яклаучы дәүләт хезмәткәре. *Франция вәкиле Лайх моңар каршы: «Бу тугрыда Франция хөкүмәте Англия хөкүмәте белән аерылыша»,*— [*дигән*]. Ф. Әмирхан.

2. Теге яки бу катламга, төркемгә, иҗтимагый хәрәкәткә караган һәм аларга хас сыйфатларны үзендә берләштергән кеше. [*М. Гафури*] *татар әдәбиятында реализм мәктәбенең күренекле вәкилләреннән иде.* М. Җәлил. *Айсылу — авыл советларында һәм колхоз идараләрендә эшләүче меңләгән хатын-кызлар вәкиленнән берсе.* Г. Бәширов.

ВӘҠИЛЛЕК *и.* 1. Вәкил булу, вәкил булып тору, вәкил булып саналу. *Бетсен тигезсезлек, бетсен ялган сайлаулар, бетсен ялган вәкиллек!* РСДРП прокламациясе.

2. Икенче берәр ил яки оешма тарафыннан нәрсәне дә булса эшләргә бирелгән хокук; вәкаләт. *Киң вәкиллек бирү.*

3. Берәр оешмага җибәрелгән вәкилләр. *Парламенттагы вәкиллекнең бердәмлеген саклау.*

4. Теге яки бу ил, оешма интересларын күзәтә торган учреждение. *Дипломатик вәкиллек.* □ *Корабта Сингапурдагы Совет сәүдә вәкиллеге хезмәткәре булды.* Р. Мостафин.

Вәкиллек итү — берәр кеше яки оешма интересларын яклаучы хезмәтен үтәү.

ВӘҠИЛЛЕҠЛЕ *с.* 1. *к.* вәкаләтле.

2. Сайланып куелган вәкилләрдән торган. *Вәкиллекле учреждение.*

3. Қатнашучылар саны күп булган. *Вәкиллекле очрашу.*

ВӘҠЫФ *и. иск. кит.* Шәригать буенча: берәр кеше яки җәмәгать тарафыннан уку-укыту, ярлыларга ярдәм итү өчен бүләк итеп бирелә торган акча яки мал. *Әхмәт байның вәкыфыннан мәдрәсәгә күпме өлеш чыккан?* Қ. Нәҗми. *Г. Буби, гадәттәгечә, мәдрәсә файдасына татар байларыннан вәкыф җыю өчен, Минзәлә ярминкәсенә килә.* М. Мәһдиев. // *с. мәгъ.* Берәр кеше яки җәмәгать тарафыннан уку-укыту, ярлыларга ярдәм итү өчен бүләк итеп бирелә торган. *Мәдрәсә хәзрәтнеке түгел, ул вәкыф йорт.* Г. Ибраһимов. [*Хәзрәт*] *бернигадәр вәкыф акчаны исраф кылды.* З. Һади.

Вәкыф итү — мәдрәсә, мәчет тоту өчен (акча яки мал) бүләк итү. [*Әхтәм морза*] *үз милкендәге җирләрне, урманнарны, болыннарны Казанда яңа мәчет белән мәдрәсә асрау өчен вәкыф итеп бирәчәк, имеш.* Қ. Нәҗми. *Бәхтияров үз кулындагы бөтен* [*байлыгын*] *укуукыту юлына вәкыф итеп калдыра.* Ф. Әмирхан.

◇ **Вәкыф козгыны** *иск. тирг. кимс.*— вәкыфны үзләштерүче кеше (гадәттә мулла).— *Вәкыф козгыны Вәли мулла моңа риза булмады.* Ф. Әмирхан.

ВӘҠЫФНАМӘ *и. иск. кит.* Вәкыф бирелү турында рәсми кәгазь.

ВӘЛИ *и. иск.* 1. Хуҗа, ия, башлык.

2. Яклаучы, опекун.

3. *дини.* Изге. *Инде* [*хаҗи*] *булган вәлиләрдән: бохарча чалмасы.* М. Укмасый.

Вәли вәкил *этн.*— никахка кадәр булган килешү (иҗабе кабул) вакытында кыз яки егет исеменнән эш йөртүче кеше. *Қызның вәли вәкиле дигәне атасы Нурмөхәммәт иде.* Г. Ибраһимов.— *Син кем, Җәләлетдин Мифтахетдин кызын --- хәлял җефетлеккә, вәли вәкил булып, бирдеңме?* Ш. Камал. **Вәли нигъмәт** *иск.*— ашамлык-эчемлек иясе, туйдыручы кеше. [*Ул*] *үзен мал табучы һәм ата, аларга баш, вәли нигъмәт төсле --- [күреп] ләззәтләнә.* М. Гафури.— *Сез безнең тәрбиябездән чыккан дип хисап ителеп, шул хакта вәли нигъмәтләрегезгә хәбәр күндерәчәкбез.* Қ. Тинчурин.

ВӘЛИЛЕҠ *и. иск.* Вәли булу.— *Сез бит беренче суфилык, хәтта вәлилек дәгъвасы кылган кеше.* Г. Тукай.

ВӘЛӘ'ҠИН *карш. терк. иск. кит.* Ләкин, әмма, тик. *Ябып бер бик матур читлеккә, әлде бер биек җиргә: Вәләкин сандугач читлек эчендә сайрамый бер дә.* М. Гафури.

ВӘЛҮҠ *и. сөйл.* Ике-өч атны арбага, чанага яки сабанга җиккәндә мичәү баулары бәйләнә торган агач, мичәү агачы.— *Атларны вәлүктән ычкындырды да китте бу.* Ф. Хөсни.

ВӘС, ВӘС-ВӘС *ы.* Сарык чакырганда әйтелә. [*Гапсаттар*] *ризасызланып, чыбыркысын шартлатып кычкыра: «Һәйт, вәс!»* Ю. Әминов.

ВӘСВӘСӘ *и.* 1. Қоткы, берәр нәрсә эшләргә котырту; котырык.— *Ялгыш юлдан* [*кире*] *кайтыгыз. --- Шайтан вәсвәсәсенә бирелмәгез.* Қ. Нәҗми.

2. Шик, шөбһә, шикләнү.— *Син Якты кул җәйләвеннән безнең көтүгә ат яндырып, тирләп килеп чыккач, күңелемә вәсвәсә төште: байның шикләнүе рас икән, бу адәм сарманнардан найманнарга сер ташый икән, дип уйладым.* Г. Ибраһимов. *Намаз укыганда да аның күңеле төрле вәсвәсәләрдән чыга алмады.* М. Гафури. // Шом.

◇ **Вәсвәсә бирү** — котырту, коткы салу.— *Син, имеш, минем киленнәремә вәсвәсә бирергә килдең!* Ш. Камал. **Вәсвәсәгә килү** — күңел шикләнү, шик-шөбһәгә бирелү. [*Шәвәли абзый*], *уйлары белән вәсвәсәгә килеп ята*

торгач, түзмәде, хатынына дәште. Г. Ахунов. **Вәсвәсә салу** — күңелгә шик салу, шикләндерү, котырту.— *Синең, кызым, кеше күңеленә вәсвәсә салып йөрүдән башка эшең юк, ахры.* Р. Ишморат. *Явыз шайтан миңа вәсвәсә салды. Мин уңаен сагалап тордым-тордым да кеше күрмәгән арада шул кендекне җиң эченә тыгып сыздым.* Г. Ибраһимов.

ВӘСВӘСӘЛӘ *с.* 1. Күңелне котырта, аздыра торган. [*Рәшидә*], *тәмле-тансык хатын булуын сиздереп, назлап сөясе килүне котыртып, гел үзенә тартып тора иде. Зөфәр бу вәсвәсәле тойгыны берничек тә җиңә алмыйча, гел янып, дулкынланып утырды.* Ә. Еники.

2. Шик, шөбһә тудыра торган, шикләндерә торган. *Бу вәсвәсәле шомның кара афәте иң беренче булып шушы өйгә бәреп керә.* Р. Төхфәтуллин.

3. *к.* вәсвәсәчел. *Укучылар медицина белешмәләре укуның вәсвәсәле кешеләр өчен ни белән бетүен күз алларына китерәләрдер.* Ш. Хөсәенов.— *Син теләсә нәрсә әйт, хәерлегә түгел бу йөрү,— дип куйды беркөнне Зәйтүнәнең түтәе. Ул нәрсәдәндер шикләнгән кебек вәсвәсәле иде.* Ф. Хөсни.

ВӘСВӘСӘЛӘНҮ *ф.* Шөбһәләнү, шикләнү. *Ул, каушап, үз эченнән вәсвәсәләнеп калды: «Бу нинди бәхетсезлек. Бер тәүлек эчендә шул эт миңа өченче тапкыр очрый. Бу мине күзәтәме? Әллә язмышның берәр бәласе миңа таба якынлап киләме?»* Г. Ибраһимов. *Мәгыйшә түти, Йөзлекәй карчыкның яңа йортта ни өчен төшкә керүен аңлый алмыйча, төрле гөманнар эчендә вәсвәсәләнеп ята торгач, таң алдыннан тагын йоклап китте.* Г. Ахунов.

ВӘСВӘСӘЛӘНҮЧӘН *с.* Вәсвәсәгә бирелүчән, шөбһәләнүчән. *Әллә барын да минем шикләнүчән, вәсвәсәләнүчән хыялым гына уйлап чыгарамы?* Г. Ибраһимов.

ВӘСВӘСӘЧЕ *с.* 1. Котыртучы, күңел аздыручы.

2. Шик, шөбһә таратучы.

ВӘСВӘСӘЧЕЛ *с.* Һәрнәрсәдән шикләнүчән, һәркемгә шикләнеп караучан. *Гайниянең болай таң тишегеннән көрәк тотып су буеннан менүен күреп, вәсвәсәчел хатын бераз шикләнебрәк калды.* Ф. Хөсни.

ВӘССӘЛАМ *ы. сөйл.* Берәр эшне тизлек белән тәмамлауны белдерә; бетте-китте, шушының белән бетте.— *Яратышсак, тотам да ярты дәүләтемне аның исеменә яздырам, бетте-китте, вәссәлам.* Ш. Камал.— *Телим икән — Миңсылу минеке һәм вәссәлам!* Г. Минский.

ВӘСЫФ *и. иск. кит.* Сыйфатлау, тасвирлау. *Берәр нәрсә, күренеш яки табигатьнең сыйфатларын тасвир итү төсендәге вәсыф (сыйфатлау) жанрына иң беренче чиратта «Бу көндә бер сарай ачты әһәли» дип башлана торган шигырь керә.* Ә. Исхак.

Вәсыф кату — сыйфатлау, тасвирлау. *Ул матурны мактамак булдым әле такмак белән, Ямьле әйберләргә охшатмак, вәсыф катмак белән.* Ш. Бабич.

ВӘ'ХАЛӘНКИ *рәв. иск. кит.* Чынлыкта, чынбарлыкта. *«Җәүһәр җирдә ятмый», дигән булалар, вәхаләнки ул үзе җирдән чыга.* Г. Тукай. *Мортазин килеп: «Шәп бит, бу юлы азрак кушкаладым шул»,— дигән була. Вәхаләнки үзе репетициядә булмады да. Бүген арткан, кушкан нәрсәләр минеке генә булды.* М. Фәйзи.

ВӘХИ *и. дини.* Берәр фикерне алла тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салу; хәбәр. [*Алла*] *фәрештәсен Вәкил итеп вәхи җибәрә.* М. Гафури. *Ишетелде колагына һатифтән серле тавыш. Пәйгамбәргә вәхи булып Килгән тавыш ул,— таныш.* С. Баттал.

ВӘХШИ *с.* 1. Кеше кулына ияләшмәгән; кыргый (хайваннар турында). *Славян жирендәге урманнарда һәртөрле вәхши хайваннар бик күп булган, һәм чит мәмләкәт сәүдәгәрләре дә шул хайваннарның тиреләрен, мехларын бик яратып алганнар.* Г. Тукай. // *и. мәгъ.* Кыргый хайван. *Мәхәббәт булмагач, тормышта нинди бер кызык бар соң? Болай булгач, кешенең вәхшидән аермасы нәрсә?* М. Гафури. // Кеше кулы тимәгән, кеше яшәмәгән.

2. Культура үсешенең иң түбән баскычында торган (кешеләр турында). *Вәхши кешеләрнең безнең кебек тора торган өйләре юк. Алар җир казып, җир эчендә торалар.* Г. Колэхметов. *Миклухо-Маклай вәхши кабиләләрнең биюләрендә дуслык тойгыларын күргән.* Ж. Фәйзи. // *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Әгәр бу вәхшиләр берләшмичә, ялгыз-ялгыз торсалар, бичараларның һичберсе кәҗә итен күрмәс иде.* Г. Тукай.

3. *күч. тирг.* Явыз, рәхимсез, варвар, культурасыз (кеше турында). *Вәхши немец үтте синең көлэч Кырларыңны таптап, яндырып, Хатын-кызларыңны мыскыл итеп, Улларыңны үксез калдырып.* М. Җәлил. *Мәктүбне берничә кат укыгач та иң элек хәтеремә килгән нәрсә — туп-туры барып --- ул кара мыеклы шайтанны иң вәхши сурәттә буып, газаплап үтерү иде.* Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Явыз, рәхимсез, культурасыз кеше; варвар. *Безнең нәкъ уртабызга ул — Көнбатыштан килгән ерткыч вәхши авыр бомба ташлады.* Ә. Еники. *Урта гасыр вәхшиләре анда Культураны утка ягалар.* Г. Кутуй.

ВӘХШИАНӘ *рәв. иск. кит. к.* вәхшиләрчә. *Әллә сезнең үз кулыгыз берлә Койган сөнгеләр, Чәнчелеп саф бәгъреггезгә, Вәхшианә көлделәр?!* Һ. Такташ. // *с. мәгъ.* Рәхимсез, явыз. *Аны моннан өч ел элек --- сазлыкка алып кереп, вәхшианә рәвештә җәзалап, буып үтерделәр.* М. Парсин.

ВӘХШИЛЕК *и.* Вәхши (3 мәгъ.) булу. *Рәшиткә яндырылган, туздырылган авылларны, хәрабәләр өземенә әверелдерелгән шәһәрләрне, бигрәк тә ерткычларча үтерелгән бала-чагаларны күрү шулкадәр табигатькә каршы бернәрсә булып тәэсир итте, --- бу кадәр вәхшилекне, бу кадәр мәгънәсез вату-сындыруны аның сәламәт акылы сыйдыра алмый иде.* Г. Әпсәләмов. *Нинди ерткычлык, нинди вәхшилек! Ачылып килгән лалә гөле кебек гаепсез, гөнаһсыз саф нарасыйларны газаплап, яндырып үтерсеннәрче!* Ә. Айдар.

ВӘХШИЛӘНҮ *ф.* 1. Кыргыйлану. [*Робинзон*], *ялгыз атауга барып урнашып, вәхшиләнгән.* Г. Газиз.

2. *күч.* Ерткычлану, рәхимсезләнү. *Кызып, вәхшиләнеп киткән кешеләрнең йодрыгыннан чак кыйналмый, кайсыбыз аннан, кайсыбыз моннан качып, өйләргә кайттык.* М. Фәйзи.

ВӘХШИЛӘ'РЧӘ *рәв.* Ерткычларча, рәхимсез рәвештә.

ВӘХШИЛӘШҮ *ф. к.* вәхшиләнү. *Ачу белән исергән, вәхшиләшкән, Котырган эт шикелле анда дошман.* Б. Рәхмәт.

ВӘХШӘТ *и. кит. к.* вәхшилек. *Сугыш белән килдең безнең җиргә, Вәхшәт, золым безгә китердең, Илебезнең тыныч өйләренә Комсыз ерткыч булып сикердең.* М. Җәлил. [*Иске*] *татар тормышының шушы вәхшәтләре аннан бөтен кешелек сыйфатларын сыгып чыгарып, ерткыч ясап калдырганнар.* Ф. Эмирхан.

ВӘХШӘТЛЕ *с. кит.* Ерткычлык, кыргыйлык, рәхимсезлек китерә торган.

ВӘХШӘТЛЕК *и.* Ерткычлык, рәхимсезлек. *Казаклар да, карательләрнең вәхшәтлегенә түзә алмыйча, атка атланып, кулларына корал алдылар.* И. Салахов.

ВӘӘ *аваз ияр.* Кечкенә балалар елаган тавышны белдерә. *Ир бала дөньяга килгәнлекне аңладык. Озаклламады, бу яңа кеше үзе дә тавыш бирде: «Вәә!»* Г. Галиев.

ВӨҖДАН *и.* Үз эшләрең, үз-үзеңне тотышың өчен эхлакый җавап хисе; намус. *Ничек кенә вөҗданы алдында акланып маташмасын, эмма намусы аңа: «Ах, начар эшләдең син, хата эшләдең»,— дия иде.* Ә. Еники. *Туган иленең чын сугышчысы булып, солдат үлеме*

белән үлүе өчен [Хәйдәрнең] вөҗданы чын мәгънәсендә тыныч иде. Г. Бәширов.

Вөждан иреге — гражданнарның берәр динне тотарга яки тотмаска хокукы. **Вөждан иркенлеге** *иск.— к.* вөждан иреге. *Халыкка барча сәяси иркенлекләр (җыелу иркенлеге, сөйләү, язу, дин, вөҗдан иркенлекләре) бер дә кысмаенча бирелсен.* РСДРП проклама-циясе.

◇ **Вөждан газабы** — үзеңне гаепле хис итү нәтиҗәсендә җәфалану, борчылу, тынычсызлану халәте.— *Мин, шул ярты алманың иясе каршындагы бурычы[мны] түләп, вөҗдан газабыннан терелергә телим.* М. Фәйзи. *Шатлыгымны минем эчтән, ерактан кабынып килгән вөҗдан газабы әкрен генә кимерә иде инде. Мин, кызга сөю хисем үскән, аңа гашыйк була барган саен, үземне әшәкерәк, алдакчырак итеп сизә бардым.* А. Шамов.

ВӨЖДАНЛЫ *с.* Намуслы, гадел, вөждан белән эш итә торган (кеше турында). *Эзлимен шунда олуг җанлы кеше, Бар кешеләрдән дә вөҗданлы кеше.* М. Гафури. *Алар нечкә күңелле, саф вөҗданлы кешеләр булганлыктан, йөрәкләрендәге бу олы мәхәббәтне вак-вак өлешләргә бүлгәләп, әрәм-шәрәм итеп җилгә очырмаганнар.* Г. Әпсәләмов.

ВӨЖДАНЛЫЛЫК *и.* Вөжданлы булу. *Нурулла — әсәрдәге төп герой өчен вөҗданлылыкның һәм гаделлекнең тере символы.* Р. Мостафин.

ВӨЖДАНСЫЗ *с.* Намуссыз, оятсыз.— *Фәлән нәшир сиңа [гонорарны] аз биргән, ул вөҗдансыз!* Г. Тукай.— *Вөҗдансыз ул. Үзенең шәхси даны өчен фабрикаңы да, мине дә, безнең барыбызны да алдарга әзер икән.* Р. Ишморат. // *и. мәгъ.* Шуңдый кеше.— *Болар бит шәкертләрнең өйләренә язган хатлары. Сез аларны җибәртмичә тотып каласыз? Оялмыйсызмы вөҗданыгыздан? Вөҗдансызлар!* С. Рәмиев.

ВӨЖДАНСЫЗЛАНУ *ф.* Намуссызлану, оятсызлану.

ВӨЖДАНСЫЗЛЫК *и.* Намуссызлык, оятсызлык.— *Исламгәрәй әфәнде, бу нинди вөҗдансызлык? Сәгыйть хаҗи белән ат җиктереп тора идек, солдатлар килеп керделәр дә, арбабыздан төшереп, атыбызны алып киттеләр.* Т. Гыйззәт.

ВӨҖҮД *и. иск. кит.* **1.** Яшәеш, тормыш, барлык. *Ул ничаклы оныгырга, ул хатынның вөҗүден күңеленнән чыгарып ташларга теләсә дә, чыгара алмый йончый иде.* М. Гафури. *Элеккедәй пакьләп вөҗүдемне, Кояш, нурыңны чәч!* Н. Арсланов.

2. Күңел, рух; рухи халәт. *Бу ачы-ачы уйлар Шакирны шулкадәр изделәр ки, ул үзенең бөтен вөҗүдендә бер сыкрану сизде.* Ф. Әмирхан.— *Максатым --- сез галиҗәнапка бөтен вөҗүдем белән тугрылыклы булып калуда гына.* Ә. Еники.

◇ **Вөҗүдкә ашыру** *иск. кит.— к.* тормышка ашыру. *Сезнең зур эшләрегезне вөҗүдкә ашыруда кечкенә генә ярдәмче һәм дустыгыз була алсам, үземне гомерем буена бәхетле ләрдән санар идем.* Ә. Камал. **Вөҗүдкә килү** — барлыкка килү, туу. *Безнең көйләребезнең, безнең музыкабызның андый булуы иттифакый гына вөҗүдкә килгән бер эш түгел, аны тарих агымы тудырган.* Г. Ибраһимов. *Ишанлык мәсьәләсе татар матбугатында күптән бирле язылып килсә дә, ул тугрыда мондый мөкәммәл әсәр вөҗүдкә килгәне хәзергә кадәр юк иде.* Ф. Әмирхан. **Вөҗүдкә чыгу** — тормышка ашу.— *Бу эш вөҗүдкә чыкса, ифрат яхшы булыр иде.* М. Фәйзи. *Чарасына керешкәч, вөҗүдкә чыкмый калмый инде. Мансур белән Юматша телләрен салындырганчы чапсалар чаптылар, әмма кирәк әйберләрне булдырдылар.* Г. Әпсәләмов.

Г

Г Татар алфавитында дүртенче хәреф.

ГАБАРДИН *и. махс.* Пальто яки костюм тышлыгы өчен йон материянең бер төре. *Аның, «Нәҗия иптәш, сезгә габардин кирәк түгелме?..» дип әйтүләрен ишетәсе килә.* Ә. Еники. // *с. мәгъ.* Шундый материядән тегелгән. *Габардин пальто.*

ГАБАРИТ *и. махс.* **1.** Машина яки корылмаларның тышкы чик сызыгы; аның зурлыгы, күләме. *Төп магистральләрдәге тимер юлларның киңлеген өч тапкырга, ягъни мәсәлән, дүрт метр ярымга җиткерү күздә тотыла икән. Димәк, вагоннарның габариты өч тапкырга артачак.* М. Хәсәнов. // Гомумән нәрсәнең дә булса зурлыгы, күләме.— *Ичмаса Андрюша киеп йөргән нәрсәләрне бирер идегез. Безнең габаритлар бертигез бит дим.* С. Таһиров.

2. Тимер юлдан поездлар орынмыйча иркен үтсен өчен, корылмалар төзергә яки әйберләр куярга рөхсәт ителми торган аралык, урын.

3. Әйбернең үз зурлыгындагы моделе.

Габарит капка *махс.*— ачык товар вагоннарына төялгән йөкнең тышкы күләмен үлчи торган махсус капка, рама.

ГАБАРИТЛЫ *с.* Күләмне белдергән сүз янында: габариты шундый булган. *Квартира гадәттәге соңгы елларда салына торган өйләргә хас кече габаритлы иде.* А. Расих.

ГАБИ *с. иск. кит.* Аңгыра, аңсыз, акылсыз. *Габи ат, бәлки, кайда булса да адашып калыр, кайта алмас иде.* Г. Ибраһимов.

ГАБИД *и. иск. кит.* Диндар, аллага табынучы, гыйбадәт кылучы. // Баш иеп яшәүче; буйсынучы; кол. *Шәкертләрне үзләренә габид ясамакны теләмәгән байлар --- ожмахка --- баралар.* Г. Тукай. [*Аларча*] *хатыннар кол — «габид» булсын, ир ни теләсә дә кылсын.* М. Укмаси.

ГАВАЙ: гавай гитарасы — махсус пластинка-плектр белән чиртеп уйнала торган 6 кыллы гитара. [*Егетнең*] *гавай гитарасында уйнавына Лена чын-чынлап гашыйк иде.* Г. Әпсәләмов.

ГАВАМ *и. иск.* Халык, халык массасы. [*Давыт*] *гавам өчен көрәшкә чакырган «Кызыл фикер» артыннан китә.* Г. Нигъмәти. *Әнә теге, йөзләре ябык, күзләре сүнгән, куллары богаулы гавам нигә көлми?* Г. Коләхметов. // Укымаган, надан халык, түбән катлау кешеләре. *Бик тупас, гавам зәүкына гына үлчәнгән такмаклар белән сине ул рәнҗетә.* Ф. Әмирхан.

ГАВАМИ *с.* Халыкныкы, халыкка, массага караган. *Минем телем — --- Гавами ул, Бик гади ул.* Р. Фәйзуллин.

ГА'ВАНЬ *и.* Диңгез, океан яки елга буенда судно һәм көймәләр килеп туктау өчен, көчле җилдән, дулкыннан ышыкланган урын. *Кораб алга бара һаман да, Туктамыйча һичбер гаваньга.* Ә. Исхак.

ГА!ГА *и. зоол.* Кыйммәтле, нәфис һәм йомшак мамыклы поляр диңгез үрдәге. *Вак-вак кара бөрчекле, җирән-көрән ана гага оясында утыра, ата гага аның янына баскан.* Г. Әпсәләмов.

ГА-ГА-ГА *аваз ияр.* Каз гаңгылдавына иярткән ясалган сүз.— [*Ата каз*] *ана казым янында «га-га-га» дип биеп кенә йөри.* Г. Бәширов.

ГАГА'РА *и. зоол.* Коры җирдә бик авырлык белән хәрәкәт итә торган, зур гәүдәле төньяк су кошы.

ГАГА'РКА *и. зоол.* Гәүдәсе гади үрдәк зурлыгындагы Төньяк поляр диңгезе кошы.

ГАГАУЗ *и.* Украина, Молдавия, Болгария һәм Румыния территорияләрендә яши, төрки телләрнең берсендә сөйләшә торган халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Гагаузлар елый куанычтан, күпме газап, михнәт күргәннәр.* С. Хәким. // *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Гагауз теле. Гагауз культурасы.*

ГАГЫЛДАШУ *ф. к.* гайгылдашу. [*Әтәч кычкырганын*] *ишетеп, казлар гагылдашты, үрдәкләр бакылдашты.* Ак юл.

ГАДЕЛ *с.* **1.** Дөреслекне яклый торган, хак. *Эшчәннәрнең гадел суды алдында Тезләнгәннәр кара еланнар.* М. Гафури. *Азатлык һәм хаклык өчен булган иң гадел һәм изге сугыш бу!* Ә. Исхак.

2. Хыянәтсез, тугрылыклы, намуслы (кеше). *Һәрвакытта гадел булып, баланың яңлышының нидән икәнен, сәбәбен тикшерергә кирәк.* Г. Тукай. *Чал сакаллы гадел карт бабайлар, Ничек кертик илгә коллыкны?* Ф. Кәрим. // *рәв. мәгъ.* Дөрес, төгәл итеп, алдаусыз. *Соңгы килүендә күчтәнәч итеп алып килгән балан бәлешен дә, бик гадел итеп, балаларның өчесенә дә бүлеп бирде.* Г. Гобәй. *Аны йөкләмәләрен гадел үтәп бара, диләр.* Ә. Еники.

ГАДЕЛЛЕК *и.* **1.** Дөреслек, хаклык; хакыйкать. *Мөхсинов --- һәр эштә иң элек гаделлекне табарга тырышыр.* М. Әмир. *Кайчан син, бу җансыз малның куәтен бетереп, бөтен дөньяга гаделлек чәчәрсең икән?* Г. Коләхметов.

2. Гадел булу, тугрылыклы булу. *Кызга бик ошады егетнең мондый гаделлеге, һәм ул хәзер инде үзе «катырак бәрелмәдем микән?» дип уйлап борчылды.* Г. Минский.

ГАДИ *с.* **1.** Башкалардан бер ягы белән дә аерылып тормаган, өстенлеге булмаган. *Ә мин нәрсә? Авылдагы гади бер хат ташучы.* М. Җәлил. // Һәрвакыт очрый торган, игътибарны үзенә тартмый, җәлеп итми торган. *Болынлыкта үсәр гади генә, иссез чәчәк.* Г. Тукай. // Нормаль, гадәттәге. [*Күлгә*] *дию зурлыгыннан гади кеше зурлыгына төште.* Ш. Камал. // Һәрвакыт була торган, гадәттәге, гадәти, көндәлек. [*Солдатларга*] *сугыш көндәлек гади бер хезмәткә әйләнеп калган.* И. Гази.

2. Төзелеше, составы буенча катлаулы булмаган, элементар. *Бу кешенең нәхүнең бик гади урыннарында да хата мәгънә бирүләре --- ике араны боза башлады.* М. Гафури. // Примитив эшләнгән. *Гади кул станогы белән йон тетүчеләр, --- җеп саручылар эшлиләр иде.* М. Гали. // *махс.* Бер составлы; составы буенча элементар; *киресе:* кушма. *Гади вакланма (мат.). Гади сан (мат.). Гади җөмлә (лингв.). Гади хәбәр (лингв.).*

3. Эшләнеше, сыйфаты ягыннан уртача. *Ләкин бу нәрсә бит чын сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә менеп җитмәгән, бары гади бер панорама гына.* Г. Бәширов.

4. Башкаруы, аңлавы кыен булмаган. *Гади сүзләр белән Алсу өчен яңа-яңа серләр ачты ул.* М. Җәлил. *Бер караганда бик гади кебек: унҗиденче елның бөек революция көннәре килде дә тормышның бөтен катлауларын астын өскә китерде.* Г. Нигъмәти.

5. Хәйләсез, эчкерсез; кыланусыз, тыйнак. *Шундый назлы гади күз карашын Шагыйрь йөрәгеме аңламас?* М. Җәлил.

6. *иск.* Түбән катлау арасыннан, халык арасыннан чыккан, югары катлауга карамаган. [*Фрунзеның*] *иң гади халыктан чыккан фельдшер малае булуы белән дә --- мактанмыйча түзә алмый* [*Исмаев*]. Г. Бәширов.

7. Хәрби хезмәттә чины булмаган, рядовой. *Хәзер гади солдатлар да үзләрен ни өчен хәзерләнеп торырга кушуларын аңладылар.* М. Гафури.

◇ **Гади күз белән (карау)** — 1) оптик приборлар ярдәменнән башка. *Гади күз белән караганда, бу таш валчыгының төсен белүе дә кыен.* А. Әхмәт; 2) ис китмичә, гадәти нәрсә дип санап. *Ул башка авырлыкларга да гади күз белән карый башлаган иде.* Г. Ибраһимов.

ГАДИЛЕК *и.* 1. Катлаулы булмау, җиңел аңлаешлы булу. [*Г. Тукайның*] *балалар әдәбияты буенча биргән күп тәрҗемәләре дә үзләренең гадилеге һәм шул ук вакыт сәнгатьчә эшләнгәнлекләре белән аерылып тора.* Г. Нигъмәти. *Гадилектә — дәһилык.* Мәкаль.

2. Төзелеше, составы буенча элементар, гади булу.

3. Кешеләр белән мөнәсәбәтендә ачык, эчкерсез булу. *Аны гадилеге, иптәшләрчә яхшы мөнәсәбәте һәм оста дәвалавы өчен яраталар иде.* А. Шамов. // Үз-үзен тотышындагы табигыйлек; *киресе:* ясалмалык. *Шул ук гадилек (ясалмалыктан качу) талантлы яшь артистка З. Басыйрова уенында да бар.* М. Җәлил.

ГАДИЛӘНҮ *ф. к.* гадиләшү.

ГАДИЛӘШТЕРҮ *ф.* Артык гади, примитив хәлгә китерү. *Алексей Петрович гади итеп, ләкин гадиләштермичә сөйли, турап салмый.* Г. Әпсәләмов. *Искиткеч матур итеп эшләнгән әйберне «куыш» дип атау бик гадиләштерү сыман тоела иде.* М. Әмир.

ГАДИЛӘШҮ *ф.* Уңай, җиңел, гади нәрсәгә, хәлгә әверелү. *Атасы белән сөйләшкән кичтән соң, бу нәрсә* [*ярлы кызы Рәүфәгә өйләнү мәсьәләсе*] *аның карашында ничектер гадиләшеп, җиңеләеп китте.* А. Шамов. // Кешеләр белән мөнәсәбәтендә ачык, эчкерсез булып китү, үзен гади һәм иркен тота башлау. *Гөлниса бераз гадиләшә төште. Шаярыбрак сөйләшүгә күчте.* М. Әмир. // Гадәти хәлгә әйләнү. *Элегрәк очраклы күренгән танышлыклары үскәннән-үсә барды һәм үскән саен гадиләште.* Г. Минский.

ГАДӘЛӘТ *и. иск.* Гаделлек, гадел булу. *Тип-тигез салган була, гүя гадәләт күрсәтә.* Г. Тукай. *Тигезлекнең, гадәләтнең сүзе бер: кем ач, кем эшли — җир шуныкы.* Г. Ибраһимов.

ГАДӘЛӘТЛЕ *с. иск.* Гадел. *Бабайны --- гадәләтле табигате өчен яраталар.* Г. Тукай.

ГАДӘЛӘТПӘРВӘР *с. иск.* Гаделлек сөюче, гадел (кеше). *Бу зат* [*В. Г. Короленко*] *гадәләтпәрвәр мөхәррирләрдәндер.* Ф. Әмирхан.

ГАДӘЛӘ'ТЧӘ *рәв. иск.* Гаделлек нигезендә, дөрес, гадел итеп; чынбарлык кушканча. *Гадәләтчә, китапча уйлаганда, туп-туры, эшчән, тырышучан вә икътисатлы кеше рәхәт тора --- дип әйтергә тиеш шикелле күренә.* Г. Тукай.

ГАДӘТ *и.* 1. Кемгә дә булса хас, нык урнашкан характер үзенчәлекләре. *Чир китәр, гадәт китмас.* Мәкаль. *Гомумән, байларда кызык бер гадәт бар: ышанырга теләмәгән нәрсәнең дөреслеге көн кебек ачык күренеп торса да ышанмый ул.* Ш. Камал. // *күч.* Җансыз предметларга карата. *Тойгыларыңны музыкага ышанып тапшырсаң, аның сер сакламый торган гадәте бар.* Г. Бәширов.

2. Билгеле бер чорда аерым халык яки җәмгыятьнең традициясенә кереп урнашкан, шул чор, шул халык, җәмгыять өчен хас үзенчәлекләр. *Шул заманның гадәте буенча, миңа бәхет теләп, дога кылырга утырдылар.* М. Гафури. *Бездә, Җаекта, мосафирларны хөрмәт күрсәтми җибәрү гадәте юк.* Ә. Фәйзи. // Традициягә кергән, һәркем үтәргә тиешле кагыйдә, закон. *Һәлакәт булганда экспедиция башлыгы иң соңгы булып котыла, бу — гадәт, закон булып тотыла.* А. Алиш. // Йола, гореф-гадәт. *Игеннәрнең уңуына юрап, чәчүгә чыгасы көнне йомырка пешерү гадәте Хәдичә түтидә хәзергәчә саклана бирде.* Г. Бәширов.

3. Еш, системалы рәвештә кабатланудан ихтыяҗга әверелгән үз-үзен тотыш, сыйфат. *Менә синең дә шулай уянгач аунап ятуың гадәт булып китмәсен.* А. Әхмәт.

ГАДӘТЕ'НЧӘ *рәв.* Гадәт, йола буенча. *Татар гадәтенчә, чынаяк чокырын тәлинкәсенә каплап, өстенә калган шикәрен куйды.* М. Гали. // Һәрвакыттагы кебек. *Шәриф --- гадәтенчә балтасын тотып чыгып китте.* М. Гафури.

ГАДӘТИ *с.* 1. Көн дә, һәрвакыт була торган, кабатланып тора торган, гадәткә кереп киткән, гадәттәге. *— Җыелышта нәрсәләр булсын, гадәти эшләр.* Ш. Камал.

2. Башкаларыннан аерылып тормаган; *к.* гади (1 мәгъ.). *Гадәти көн.*

3. Еш кабатлана, әйтелә торган, аерым эмоцияләр белән бәйләнмәгән (сүз яки тәгъбир). *Утыручыларга бу гадәти сүз бик табигый, бик тыныч әйтелгән күк тоелды.* Г. Әпсәләмов.

4. Күләме, сыйфаты яки дәрәҗәсе ягыннан нормаль исәпләнгән, гадәттә була торган. [*Бу йортның*] *тәрәзәләре, гадәти авыл өйләреннән зуррак булса да, --- килешсез вә кызганыч рәвештә күренә иде.* Ш. Камал.

ГАДӘТИЛЕК *и.* Гадәти булу. *Хикәя үтә гадәти вакыйгага корыла алмый. Хикәя нигезенә салынган вакыйга гадәтилектән чак-чак кына күтәрелебрәк, чыгыбрак торырга тиеш.* Ф. Хөсни.

ГАДӘТ-ЙОЛА *җыйм. и.* Гадәтләр һәм йолалар; гореф-гадәт. *Үз халкының ямьнәренә, гадәт-йолаларына хөрмәт һәм мәхәббәт нык аларда* [*авыл халкында*]. М. Фәйзи.

ГАДӘТЛЕ *с.* 1. Теге яки бу гадәте булган. *Яхшы гадәтле. Яман гадәтле.* □ [*Кызлар үзләре дә*] ***теге гажәп гадәтле егетләрнең йөзләренә*** *атып бәрделәр.* Ф. Әмирхан.

2. Тәрбияле, тәртипле, үзен әдәпле тота торган; *киресе:* гадәтсез. *Балаларны гадәтле итеп үстерү. Гадәтле бала.*

ГАДӘТЛЕЛЕК *и.* Яхшы гадәтләргә ия булу, тәрбиялелек, әдәплелек. *Балаларда гадәтлелек тәрбияләү.*

ГАДӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* Нинди дә булса бер эшкә, гадәткә күнектерү, өйрәтү. *Кызны, өстәлгә ни килсә, шуны ашарга гадәтләндер.* Г. Тукай.

ГАДӘТЛӘНҮ *ф.* Күнегеп, өйрәнеп китү, гадәткә керү. *Дару эчәргә гадәтләнмәгән, яратмыйм мин аны.* Ш. Камал. *Менә безнең муллалар шул законсыз, шәригатьсез теләнеп ашарга хәзер бөтенләй үк гадәтләнеп киттеләр.* Г. Тукай.

ГАДӘТСЕЗ *с. сөйл.* Тәртипсез; әдәпсез, тәрбияҫез. *Гадәтсез бала. / рәв. мәгъ. Гадәтсез кылану. Үзен гадәтсез тоту.*

ГАДӘТСЕЗЛЕК *и.* Тәртипсез булу; әдәпсез, тәрбиясез булу. *Чын татарча киенгән бай малайларында була торган әдәпсезлекләр, гадәтсезлекләр бу егеттә канәгать хасил итмеш.* Ф. Әмирхан.

ГАДӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* Үзен әдәпсез тоту, тәрбиясезлек күрсәтү.

ГАДӘТТӘ *рәв.* 1. Һәрвакыт. *Гадәттә була торган сүзләрдән соң, Зәйнәпне бирмәкче булып, [атасы] яучыны озатып җибәрде.* М. Гафури.

2. Кагыйдә буларак. *Драма әсәрләренә килсәк, аларда табигать күренешләре гадәттә бик аз урын ала.* Г. Нигъмәти. */ кер. сүз. Гадәттә, күп уйларга яратмый иде ул.* А. Әхмәт.

ГАДӘТТӘГЕ *с.* 1. Һәрвакыттагы, һәрвакытта була торган. *Алгы кырыйда гадәттәге атышлар бара.* Г. Әпсәләмов. *Бу юлы полицейскийның йөзендә гадәттәге тынычлык юк иде.* Ә. Фәйзи.

2. Гадәти, гади. *Толпар — яратылышта үк гадәттәге атлардан аерым хасиятләр белән яратылган шәп ат.* М. Гафури.

ГАДӘТТӘГЕЧӘ *рәв.* Һәрвакыттагы кебек. *Механика цехы гадәттәгечә гөрли.* А. Әхмәт. */ кер. сүз. Хәтта Хәмидә аны, гадәттәгечә, җиңги дип түгел, ничектер якын итеп, туганым апа дип йөртә башлады.* А. Шамов.

ГАДӘТТӘН: гадәттән тыш — 1) гадәттә булмый, сирәк очрый торган. *Беренче мәртәбә невод салган көннең иртәдән үк промыслода гадәттән тыш хәрәкәт, кайнашу башланды.* Ш. Камал; 2) күренеше, чагылышы, тәэсире буенча көчле. *Икенче актта аңа ариоза бирелсә, картина көчәя төшәр иде, һәм бу вакыйга гадәттән тыш бер нәрсәгә әйләнер иде.* М. Җәлил. *Бала-чага, хатын-кыз акырып елап җибәрәләр, гадәттән тыш тавыш, елаш күтәрелә.* Г. Ибраһимов; 3) сыйфат һәм рәвеш янында: бик, артык, гаять, чиксез. *Һава гадәттән тыш юеш иде.* Г. Ибраһимов; 4) планнан яки кабул ителгән кагыйдәләрдән читкә чыгып, махсус рәвештә башкарыла торган; ашыгыч. *Гадәттән тыш чаралар.*

ГАДӘТ-ХОЛЫК *җыйм. и.* Табигать, үз-үзеңне тотыш, характер. *Алар бер-берсенең гадәт-холкына берьюлы күнегеп җитә алмыйча да интектеләр.* Г. Минский.

ГАДӘТЧӘ *рәв.* 1. Кабул ителгән гадәт, урнашкан тәртип буенча, элеккегечә. *Ул хатларны җыйнады да Сумкасына тутырды һәм гадәтчә хат тарату Хезмәтенә тотынды.* М. Җәлил.

2. Гореф-гадәт буенча. *Мосафир, ишек төбендә туктап, гадәтчә сәлам бирде.* Г. Тукай.

3. Гадәти, уртача. *Бүлмәнең җылылыгы гадәтчә иде.* Ш. Камал.

ГАЕП *и.* 1. Халык, җәмгыять тарафыннан яки традиция, гореф-гадәт буенча тыелган булуга карамастан эшләнгән эш; ярамаган эш; *русчасы:* проступок. *Бу гаебең намус белән хезмәт итми торып оныгылмас.* Ф. Кәрим. // *с. мәгъ.* Тыелган, ярамый торган. *Андый мөнәсәбәттә булуны бер дә гаеп эшкә исәпләмәү монда да артыгы белән бар иде.* М. Гафури. // *дини.* Дин тарафыннан тыелган булуга карамастан эшләнгән эш, гөнаһ. *Сал үзең син тугры юлга, ярлыка гаебең, рәхим!* Һ. Такташ.

2. Шундый ярамаган эш өчен җаваплылык; *русчасы:* вина. *Гаепне үз өстеңә алу.* □ *Гаеп сиңа ауса, җәзаңны күрәсең.* М. Гафури. // *юр.* Җинаять. *Еллар үткәннән соң Сафия аша Лутовның гаебе фаш ителеп, корткычлар кулга алыналар.* Г. Нигъмәти.

3. Кимчелек, җитешмәгән як. *Гаепсез дус эзләмә, ялгыз калырсың.* Мәкаль.

4. Оят, гарьлек. *Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп.* Мәкаль.

5. Сылтау, сәбәп. *Иртәдән бирле тавыш чыгарырга гаеп эзләп йөргән Мәликәгә бу җитә калды.* А. Шамов.

◇ **Гаеп итмәгез (итмәссез)** — гафу үтенүне белдерә. *Хәзергә күпләрегезгә идәнгә утырырга туры килә, гаеп итмәссез.* Ш. Камал. **Гаеп итү (ташлау)** — *к.* гаепләү.— *Бер генә нигезләре дә юк гаеп итәргә мине.* С. Баттал.— *Алай урынсызга гаеп ташлама син.* Р. Ишморат.

ГАЕПЛЕ *с.* 1. Гаеп эш эшләгән, ярамаган, тыелган эш эшләгән, гаебе булган.— *Шулай инде,— дип куйды ул, гаепле кеше төсле, туры карамыйча гына.* М. Гали. */ рәв. мәгъ. Габдулла үзенең ярамаган эш эшләвен яңа гына сизеп алды һәм гаепле генә кызарып: «Әйе»,— диде.* Ә. Фәйзи.

2. *юр.* Җинаять эшләгән, җинаять эшләүдә гаепләнгән. *Гаепсезне гаепле итеп чыгаручы хакимнәрдән безне сакла үзең, ходай.* М. Гафури. / *и. мәгъ. Фәхринең үтерелүендә гаеплеләрне эзәрләү төбене әнә шулай башланып китә.* Г. Нигъмәти.

3. *хәб. функ.* Нинди дә булса ярамаган эш өчен җаваплы. *Аларның гыйбрәткә сусаган күңелләрен сугара белмәүчеләр, менә без гаепле бу эштә.* Ә. Фәйзи.

4. *хәб. функ.* Сәбәпче. *Әллә сукыр лампа яктысының зәгыйфьлеге гаепле булдымы?!* И. Гази.

◇ **Гаеплеләр урындыгында утыру — судка тартылу.** *Ивановның бу җинаятьчеләр белән гаеплеләр урындыгында утыруы зур хаксызлык.* Г. Ибраһимов.

ГАЕПЛЕЛЕК *и.* Гаепле булу. *Гаеплелекне тану.*

ГАЕПЛӘҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* гаепләү (1, 3 *мәгъ.*). *Ул мәсьәлә [өйләнергә җыену] белән үземнең аерата кызыксынган булуым турында гаепләүдән куркып, бер сүз дә әйтмәскә тиеш табам.* Ш. Камал.

2. *юр.* Җинаятьче дип табылу, юридик җавапка тартылу. *Патшага хыянәт итүдә, фронтка революция фикере таратуда гаепләнгән түбән чин Егорыч белән Гыйльмановны уникә сәгать эчендә асып үтерергә дигән хөкем карары игълан ителде.* М. Гали.

◇ **Гаепләү урындыгында утыру** — *к.* гаеплеләр урындыгында утыру. *Миңа абый тиешле Сөләйман Тангатаров та атам Габдулла Тангатаров белән бер үк гаепләнү урындыгында утырырга тиешле.* Һ. Такташ.

ГАЕПЛӘНҮЧЕ *и. юр.* Җинаять эшләүдә гаепле дип табылган кеше. *Судьялар киңәшергә чыкканнар, гаепләнүчеләр дә күренмиләр иде.* К. Нәҗми.

ГАЕПЛӘШҮ *ф. сөйл.* Бер-береңә гаеп ташлау; бер-береңнең гаебен, начар якларын күрсәтү. *Алар: — Ах, спекулянт, контр! — Ах, буржуй! — дип, берсен-берсе контрлыкта гаепләштеләр.* Һ. Такташ.

◇ **Гаепләштән булмасын** — *к.* гаеп итмәгез.— *Киттек, алайсам... Тик, ни, гаепләштән булмасын, өйдә минем сыем бик тә такырдан булыр,— дип кисәтте Рабига.* Э. Касыймов.

ГАЕПЛӘҮ *ф.* 1. Гаепле дип карау, гаеп эш эшләгән дип санау. *Сез мине хәзер аскетлыкта гаеплисез.* А. Шамов. *Мостафаның бу турыда мине гаепләве нигезсез.* Г. Камал. / *с. мәгъ. Каным белән язган соңгы җырым, Бул гаепләү акты фашистка.* М. Җәлил.

2. *юр.* Гаеплелекне судта тикшереп раслау.— *Сине иске хөкүмәткә каршы эшләүдә гаеплә, ун елга каторгага хөкем иткәннәр иде.* М. Гафури.

3. Гаеп итеп сөйләү, яманлау.— *Ә абыстай — абзыйны гаеплә утырды.* Г. Камал. // Шелтәләү, әрләү.— *Хәят! Сез мине болай ачыктан-ачык үз тойгыларымны язган өчен гаепләмәгез!* Ф. Әмирхан. *Башка хатын-кызлар җебеп төшкәннәр бит, ничек инде шулар кебек булмаганы өчен гаеплисең.* М. Гафури.

ГАЕПЛӘҮЧЕ *и. юр.* Суд органнарында җинаять эшләүдә гаепләп чыгучы (кеше). *Рәснең килмәгән икенче шаһит турында әйтеп, бу хакта гаепләүче белән яклаучыларның фикерләрен соравына каршы, Арҗанов күтәрелде.* Г. Ибраһимов.

ГАЕПСЕЗГӘ *рәв.* Хаксызга; нахакка, урынсыз(га); хаксыз рәвештә. [*Әсәрдә*] *мәсхәрәләнгән, гаепсезгә хур ителгән кыз белән, алданган, байлар коткысына бирелгән ата трагедиясе калку итеп күрсәтелә.* М. Җәлил.— *Бернинди гаепсезгә кешене батырып үтер, икенче берәүне тотып камчыла имеш.* Г. Гобәй.

ГАЕПЧӘН *с.* Гаеп итәргә яратучан, гаеп итү гадәте булган. [*Гарифә кодагый*] *бик үпкәчән, бик гаепчән кеше.* Г. Камал.

ГАЕТ *и. иск.* Дини бәйрәм. *Рамазан гаете. Корбан гаете.* □ *Ураза гаетенең өченче көнендә дәрес бүлмәсендә, чаршаулар корып, урындыклар тезеп, театр уйнау булды.* Ә. Фәйзи.

Гает намазы — гает көнне мәчеттә укыла торган намаз. *Гает намазыннан кайту белән* [*хуҗаң*] *Пычак кайрый сине* [*кәҗәне*] *суярга.* М. Гафури. **Гает уку** — гает намазын уку. *Кешеләр ачык һавада рәхәтләнеп күлмәкчән гает укыдылар.* Ш. Камал. **Гает ясау (итү)** — бәйрәм итү. *Инде динне ташлыйлар, Уразада ашыйлар, Оялмыйча алладан, Ничек гает ясыйлар!* Г. Тукай. *Йөрмәсен инде фәкыйрьләр, әлсерәп, хәлдән таеп! Бертигез тотсын «руза» һәм бертигез итсен «гает»!* Ш. Бабич.

ГАЗ I *и.* 1. *хим.* Аерым кисәкчекләре үзара тыгыз бәйләнмәү сәбәпле һавага, бушлыкка тиз һәм җиңел тарала торган физик җисем. *Серле камера эчендә Газ саркып югала, «В» билгесе янына клапан куйсаң, Газ куерып мичкә юл ала.* Ф. Кәрим. // Ягу, яктырту өчен кулланыла торган газ яки пар хәлендәге матдә. *Табигый газлар. Нефть газы.* □ [*Яңа шәһәрдә*] *газ биреп торачаклар, өйләрне газ җылытачак, ашны газ пешерәчәк.* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Газ энергиясе ярдәмендә эшли торган. *Газ лампасы. Газ плитасы.* □ *Баскын караңгылык эчендә яктылык чәчрәтеп торган газ фонарьлары тонык күңелләрне моңландыра.* Ш. Камал.

2. Ашалган азык таркалудан ашказаны һәм эчәкләрдә барлыкка килә торган газ сыман бүлендек.

Газ бирү *техн.* — газны өстәү юлы белән автомобиль, мотоцикл һ. б. ш. машиналарны хәрәкәткә китерү яки аларның хәрәкәт тизлеген арттыру. *Шофер егет баш иеп кенә сәлам алды, ишек ябылыр-ябылмас газ бирде.* И. Салахов. **Газга кую** *техн.* — *к.* газ бирү. **Газ гангренасы** *мед.* — җәрәхәтнең анаэроб бактерияләре белән зарарлануыннан гыйбарәт булган каты авыру.

ГАЗ II *и. махс.* Үтә күренмәле ефәк тукыма. // *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Ул киенгән газ итәкләр җил-һавада ялтырый.* Н. Исәнбәт.

ГАЗАВАТ *и. иск. дини.* Корьәндә язылган буенча: мөселманнар ислам динен тарату флагы астында яңа җирләр биләү максаты белән алып барган «изге сугыш».

ГАЗАЗИЛ *и. миф.* Дини мифологиядә: Иблиснең фәрештә вакыттагы исеме. *Инде аны мәңгегә Иблис диләр, Газазил дип эндәшергә кушмыйлар.* Ш. Бабич. // *күч. сөйл.* Котыртучы, яман эшкә эйдәүче.

ГАЗАМӘТ *и. иск.* 1. Бәеклек; мәһабәтлек. *Тимер юл станциясенең килешсез кызгылт биналары табигатьнең газамәте каршында --- кечкенә, кызганыч булып күренә иделәр.* Ш. Камал.

2. Үзен эре тоту, тәкәбберлек. *Килдегез сез кулларымны бәйләп алырга минем, Күктәге шәүкәт, газамәт алласына ялланып!..* Һ. Такташ.

ГАЗАМӘТЛЕ *с. иск.* 1. Бөек, мәһабәт. *Мусыйль шәһәрендә дә моңарчы күренмәгән бер газамәтле вә тантаналы гает булды.* Г. Тукай. *Менә бер ягы сары алтын төсенә манылган зур күл. Әнә шул зур күлнең аргы ягына батып барган газамәтле кояш.* Г. Ибраһимов.

2. Эре кыяфәтле, тәкәббер. [*Зөһрә*] *хәзер элекке мәгърур, газамәтле патша кыяфәтендә түгел.* Ш. Камал.

ГАЗАП *и.* 1. Физик интектерү, җәза. *Синең бәхетең өчен җир өстендә Тәмуг газаплары алучы, Ул кем иде!* Һ. Такташ.

2. Җәбер, золым; җәфа. *Дошман белән бергә алпавытлар кайта, иске власть, иске михнәт, иске газап кайта.* И. Гази.

3. Бик авыр эчке кичерешләр, рухи интегүләр. *Вөҗдан газабы.* □ *Ул — авыр уйлар, әрнүле йөрәк газаплары урынына алмашка килгән шатлык иде.* А. Шамов.

4. Азап, авырлык, кыенлык, мәшәкать. [*Мөгаллимә Камәр*] *ярлы гаиләдән чыгып, мең газап белән белем алган һәм соңыннан партиягә кергән.* Г. Нигъмәти.

Газап кылу *иск.* — *к.* газаплау. *Болай да бик мәрхәмәтле, бик үк инсаниятле вә йомшак күңелле булмаган төрекмән ханы үзенең дошманнарын, үзснең әсирләрен үзе теләгәнчә газап кыла иде.* Ш. Мөхәммәдев. **Газап чигү (күрү)** — *к.* газаплану. *Аның моңарчы чын кайгыны татып карамаган бала күңеле, тозакка эләккән кош кебек, тетрәнә, газап чигә.* Г. Бәширов.

ГАЗАПЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* газаплау (1 *мәгъ.*).

2. Җәфалану, интегү. *Халык шулкадәр фәкыйрьлектә газапланып тора.* Г. Коләхметов. *Кояш баюга якынлашкач, көндәге гадәт буенча, газапланып, арып беткән әсирләрне --- таш зинданнарга бикләделәр.* Ш. Мөхәммәдев. // Авыртудан интегү, сызлану, җәфалану. *Фатыйма аның газаплануын күреп: — Тагын авыртамы? — дип сорады.* И. Гази. // Тырышу. *Газаплана торгач, Бикмуш бабай, Илсөярен күтәреп, көч-хәл белән су читенә чыгып басты.* Г. Гобәй.

3. Рухи тетрәнү, вөҗдан газабы кичерү. *Әле тупасланып бетмәгән яшь вөҗданы газапланды аның.* К. Тинчурин.

ГАЗАПЛАУ *ф.* 1. Җәзалау, физик интектерү. *Минем әтиемне үтергәннәр, Явыз куллар газаплаганнар.* Ә. Ерикәй.

2. Интектерү, җәфалау. [*Врач:*] *Бу кайәр төшкән тын кысылу мине газапламаса, бәлки мин дә сезнең белән бер сафта була алыр идем.* А. Шамов.

3. Рухи кичерешләргә, вөҗдан газабына дучар итү.— *Нигә әйтмисез, нигә болай газаплыйсыз?* Г. Бәширов.

ГАЗАПЛЫ *с.* Газаплый торган, авыр, интектергеч. *Нинди яра, нинди газаплы чир, ямен алдың матур саулыкның!* М. Җәлил. // Интегү, газап билгеләре чагылган.— *Шул үрмәкүчләр инде безнең канны суырдылар,— диде карт, әкрен, газаплы тавыш белән.* Г. Әпсәләмов.

ГАЗАПЛЫЛЫК *и.* Газаплы булу. *Узган гомер миңа да, үзенең авырлыгына, газаплылыгына карамастан, шулай бик тиз үткән кебек тоела иде.* А. Шамов.

ГАЗГОЛЬДЕР *и. техн.* Газны җыя һәм саклый торган урын, корылма (резервуар). *Саф ацетиленны газгольдерларга җыю.*

ГАЗЕЛ: газел кылу *иск. кит.*— (урыннан) төшерү, (эштән) чыгару, куу, мәхрүм итү. *Бара торгач, үзенең ахмаклыгы сәбәпле, ишан исеменнән газел кылынып, ишан булып калды.* К. Насыйри.

ГАЗЕЛЬ *и. зоол.* Антилопалар токымыннан матур сынлы, йөгерек кыргый тау кәҗәсе.

ГАЗЕТ *и. сөйл. к.* газета.

ГАЗЕТА *и.* Җәмгыять тормышындагы яңалыкларны, агымдагы вакыйгаларны яктыртып бару максаты белән системалы рәвештә зур табаклы кәгазьдә чыгарыла торган вакытлы матбугат басмасы. *Газинур, кулына газета тотып, җыелган халыкка кычкырып укучы Миңнурыйга күтәрелеп карап ала.* Г. Әпсәләмов.

ГАЗЕТАЧА *рәв. сөйл.* Публицистик стильдә, коры, хиссез. *Ничектер, сүзләрем газетача гына яңгырады.* Р. Төхфәтуллин.

ГАЗЕ'ТАЧЫ 1. *и. иск.* Газета чыгаручы, газета редакциясе хезмәткәре. *Әллә нинди газетачылар чыгып яза башладылар.* Г. Тукай.

2. *с.* Газета сатучы. *Кәяндыр, яшен уты шикелле атылып, газетачы малайлар килеп керделәр.* А. Шамов.

ГАЗЕ'ТАЧЫЛЫК *и.* 1. Газета чыгару белән шөгыльләнү. *Соңыннан [Г. Камал], газетачылык эшеннән китеп, пенсиягә чыга.* М. Гали.

2. Әдәби әсәр телендә газета стиленә охшашлык — хис һәм образга ярлылык. *[Театрга] «җанлы газетачылык», «курчак уены» методыннан арыныл, психологик образлар бирүгә күчәргә --- кирәк.* М. Җәлил.

ГАЗИ *и. иск. дини.* Ислам динен яклап сугышучы, сугышчы; *к.* газават. *Ул Сәет-Баттал газинең киерелгән җәясе кеби авыз ерып көлешләреңә!..* Г. Тукай.

ГАЗИЗ 1. *с.* Кадерле, иң якын; бердәнбер. *Куй, елама, газиз ана!* М. Җәлил. *Минут саен газиз гомер үтеп бара.* М. Гафури. *Мондый вакыт газиз җаныннан бизеп кем йөрсен.* А. Шамов. // *рәв. мәгъ.* Олылап, кадерләп; якын, үз итеп. *Мусыйль халкы бабайның сүзен шулкадәр газиз тоталар ки, хәтта даулашкан вә тартышкан вакытларында --- бабайга киләләр иде.* Г. Тукай.

2. *и. күпл. дини.* **газизләр.** Изгеләр; пәйгамбәрләр. *Нәзерем булсын: җиде атнада җиде газизләр рухына җиде ясыйн укып бағышлармын.* Г. Камал.

ГАЗИРО'ВКА *и. сөйл.* Эчү өчен махсус әзерләнгән, газландырылган су.

ГАЗИФИКА'ТОР *и.* Промышленность предприятиеләренә һәм торак йортларга газ үткәрү, газ кертү белгече; газ үткәрүче, газ кертүче.

ГАЗЛАНДЫРУ *ф. махс.* Газ белән туендыру (сыекчаны), газлы ясау, газ кушу. *Ышанмасаң барып кара: Бездән икенче чатта Хөсни нәни арба белән Газландырган су сата!* Э. Исхак.

ГАЗЛАУ *ф. махс. к.* газландыру.

ГАЗЛЫ *с.* Газы булган, газга бай. *Ә без менә газлы төтен ярып, Сыек, утлы шлак ташыйбыз.* Ш. Маннур. // Газ белән тәэмин ителгән, газ кертелгән (йорт, квартира). *Салынып бетүгә, сиңа икенче каттан дүрт бүлмәле, ванналы, газлы, менә дигән квартира.* И. Гази.

ГАЗОГЕНЕРА'ТОР *и. техн.* Каты яки сыек ягулыкны газга әйләндерә торган махсус аппарат.— *Имеш, еллар буе төгәл эшләп килгән газогенератор атна-ун көнгә түзми, сафтан чыга.* Р. Ишморат.

ГАЗОЛИН *и. хим.* Табигый нефтьне куу ярдәмендә алына һәм эчке ягулы двигательләр өчен ягулык итеп кулланыла торган газлы бензин.

ГАЗО'МЕТР *и. махс.* Газны җыю, саклау һәм күләмен үлчәү өчен лабораторияләрдә кулланыла торган прибор.

ГАЗОН *и.* Парк, бакча, скверларда чәчеп һәм тигез итеп өстен кыркып үстерелә торган үлән яки чәчәкләр түтәле. *Үреләләр өскә яшь тирәкләр, Ал-гөл чәчәк ата газоннар.* Э. Давыдов.

ГАЗОСВА'РКА *и. техн.* Тимерне газ ярдәмендә эретеп ябыштыру. // Тимерне газ ярдәмендә эретеп ябыштыра торган аппарат.

ГАЗОСВА'РЩИК *и.* Газосварка белән шөгыльләнүче, тимерне газ ярдәмендә эретеп ябыштыру остасы.

ГАЗОУБЕ'ЖИЩЕ *и.* Сугыш шартларында газ куркынычы вакытында саклану өчен махсус төзелгән корылма.

ГАЗОХОД *и.* Каты ягулыкны (күмер, утын, торф һ. б.) газга әйләндереп эшли торган двигательле елга судносы. *[Әнвәр], беренче җай чыгу белән үк, сайда йөрешле газоходка утырып, билетсыз-нисез кайтыр юлга чыккан.* Э. Касыймов.

ГАЗРАИЛ *и.* Дини мифологиядә: җан алучы фәрештә. *Мал малга җиткәнче, Газраил җанга җитә.* Мәкаль. // *сөйл.* Артык усал, явыз кешеләргә карата әйтелә. *[Төткыннар] эшкә баргандә-кайтканда колоннаның башында һәм ахырында шул ике газраил [немец] була.* Ш. Маннур.

ГАЗСАКЛАГЫЧ *и.* Газ саклый торган урын, резервуар.

ГАЗСЫЗЛАНДЫРУ *ф.* Урынны, кием һ. б. ш. нәрсәләрне агулы газлардан арындыру, дегазация ясау.

ГАЗЧЫ *и.* 1. Газ промышленносте эшчесе.

2. *к.* газификатор.

ГАЗӘЛ I *и. иск. филол.* Поэзиядә шигырь төзелешенең бер төре: шигырьнең беренче ике юлы рифмалашып, бу рифма ике юллы һәр куплетның азагында дәвам итә. *Шигъри формалардан рөбагый һәм газәл Тукайда очраклы рәвештә диярлек кенә күренәләр.* Г. Нигъмәти.

ГАЗӘЛ II *и. к.* газель. *Бара торгач, газәлләр бик күп була торган җиргә килеп җиткәннәр.* Мең дә бер кичә.

ГАЗҮЛЧӘГЕЧ *и. техн.* Газ трубалары аша үтә торган газның күләмен үлчәү приборы.

ГАЗҮТКӘРГЕЧ *и. техн.* 1. Газ үткәрә торган труба.

2. *с. мәгъ.* Үзе аша газны үткәрә торган, газны тотып калмый торган; *русчасы:* газопроницаемый.

ГАИБАНӘ *рәв. иск.* Күрмичә, үзе юкта; күрмәс борын («гаип» сүзеннән). *«Интикад» нам әсәреңезне гаибанә тәбрик идәрем.* Г. Тукай. *Бу өч бүлек тагы: сагынып җырлау, гаибанә мактау, күз алдында мактау, үгетләр, киңәшләр, фәләннәргә бүленә.* М. Фәйзи.

ГАИЛӘ *и.* 1. Бергә яшәүче ир, хатын, балалар һәм якын туганнардан торган кешеләр төркеме; семья. *Газиз үлү белән хәр һәм күңелле гаилә тормышы турындагы матур хыяллар берьюлы җимерелеп төште.* Г. Бәширов. // Бер гаилә членнары. *Бу гаилә бернәрсәдән хәбәрсез, тыныч кына утырган чакта, --- Гайнетдинне мыскыллап үтәләр.* Г. Тукай.

2. *күч. сөйл.* Бергә эшләүче, максат һәм интереслары бер булган кешеләр коллективы. // Җәмгыять. *Иске тормыш! Синең кырларыңда зәңгәр күзле уйчан яшь егет — ул юк инде... Гаиләң тар синең аның өчен...* Һ. Такташ.

Гаилә кешесе — гаиләсе, семьясы булган, хатынлы яки ирле кеше. *Аларның --- күбесе — гаилә кешесе, әни булган, әти булган кешеләр.* Г. Кашшаф.

ГАИЛӘЛЕ *с.* Гаиләсе, семьясы булган (кеше).

ГАИЛӘЧЕЛ *с.* Гаиләсен ярата торган, гаилә җанлы (кеше); гаилә тормышын яхшы алып бару өчен тырыша торган (кеше).

ГАИП *с. иск.* 1. Яшерен, билгесез, берәүгә дә билгеле булмаган. *Мәшәехләр, әүлиялар хөрмәтенә гаип хәзинәләрен насыйп итсен.* Т. Гыйззәт.

2. *с. күч.* Көтелмәгән. *Гаип кунак.*

Гаип алмашлык *лингв. иск.*— сөйләү процессында катнашмаган затка карата кулланыла торган алмашлык — өченче зат алмашлыгы: ул, алар. *[Әсәрдә] «ата», «ана» тормышы хикәя ителеп, аларга карата гаип алмашлык кулланыла.* Г. Нигъмәти. **Гаип булу** — югалу, юк булу, юкка чыгу; күздән югалу. *Кичә чыгып киткән Шәех, шул көенчә, гаип булды.* М. Гафури. **Гаип зат** *лингв. иск.*— өченче зат. **Гаип итү** — югалту. *Чөнки алар үзләренең ана телләрен көннән-көн гаип итеп тормактадырлар.* З. Бәшири.

◇ **Гаиптән хәбәр** — борынгы ышанулар буенча, алладан иңгән яки төрле кораулар нигезендә беленгән, алдагы киләчәк турындагы хәбәр. *Дүрт куллап театрны кабул итәчәкләре хосусында, пәйгамбәрлек итеп, гаиптән хәбәр бирергә дә мөмкиндер.* Г. Тукай.— *Имеш, гаиптән хәбәр алам диген дә, фалнамә ач...* Р. Ишморат.

ГАИТ, ГАИД *бәйл. иск.* Нәрсәгә яки кемгә дә булса кагылышлы, бәйләнешле. *[Җәләш мулланың] иң зур дәрт белән караган нәрсәсе — ат, сбруй тирәсенә гаит*

булып, ул һәрвакыт кучер белән йөри... Г. Ибраһимов. *Авылның иң усал кешеләре дә Хәсби әбигә гаит әйбергә зарар итүдән сакланалар.* М. Гафури.

ГАЙБӘТ *и.* Уйдырма фактларга нигезләнгән сүз, хәбәр.— *Нургали абыйны фермадан алу турында сүз дә буласы юк, гайбәт ул сүз, ышанмагыз ул гайбәткә.* Ә. Еники. // Берәүнең кимчелекле ягын гаеп итеп сөйләнгән сүз. *Кайсыдыр аның [Нәфисәнең] артыннан тырышып-тырышып гайбәт җыеп йөри.* Г. Бәширов.

◇ **Гайбәт итү** — гаепләү, гаеплəп сөйләү. *Куәт байлар ягында булганга күрә, Гарифны гайбәт итүдән Зәйнәпне гайбәт итәләр.* М. Гафури. **Гайбәт сату (чәйнәү, ашау)** — яманатын сату, яманлап сөйләү, гайбәт сөйләү. *Хатын-кызлар, гомумән, Мәдинәне яратмыйлар, --- аның гайбәтен сата иделәр.* Ш. Камал. *Безем татар хатыннары өч-дүртәү бергә җыелып булсын, мәҗлесләрдә булсын, гайбәт ашап, юк-бар хикәяләр сөйләү белән вакыт уздыралар.* З. Бәширн.

ГАЙБӘТЛЕ *с.* Гайбәткә, ялганга нигезләнгән, гаепләп сөйләнгән. *Гайбәтле хат.* □ *Туган агалары кызның бу гайбәтле романына бер бәхетсезлек, бер хурлык итеп карыйлар.* Г. Ибраһимов.

ГАЙБӘТЛӘҮ *ф.* Гайбәт тарату, гаепләп, яманлап сөйләү. *Апасы Фатиха романын тәмләп, гайбәтләп чәйнәргә тотынды.* Г. Ибраһимов. *Әфьюн ашау, вак салуны куячакмын, Җәдитләрне гайбәтләүдән туячакмын.* Г. Камал.

ГАЙБӘТЧЕ *с.* Гайбәт сөйләүче, таратучы, яла ягучы. *Болар --- гайбәтче мещан хатыннарның классик образлары булып торалар.* М. Гафури. / *и. мәгъ. Ялагай һәм гайбәтчеләрнең --- эткә ташлар идем теллəрен.* Ф. Кәрим.

ГАЙБӘТЧЕЛ *с.* Гаеп итәргә, яла ягарга, гайбәт сөйләргә яратучан. *Бикьярлар --- бик көяз, бик гайбәтчел халык.* Г. Ибраһимов.

ГАЙБӘТЧЕЛЕК *и.* Гайбәтче булу сыйфаты. *Бу сатлык җан Гайнулланы --- ришвәтчелеге, гайбәтчелеге һәм байлар тәлинкәсе яларга яратканлыгы өчен Хөсәеннең жене сөйми.* А. Расих.

ГАЙБӘТЧӘН *с. к.* гайбәтчел.

ГАЙГЫЛДАУ *ф.* 1. Калын көр тавыш белән кычкыру (казлар турында).

2. *күч.* Калын тавыш белән кычкырып, ихахайлап көлү.

ГАЙГЫЛДАШУ *ф.* 1. Казларның калын көр тавыш белән кычкырулары. *Күл буендагы казлар уяндылар да үзара гайгылдаша башладылар.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Кешеләрнең ихахайлап кычкырып көлешүләре. [*Хәлим*] *сискәнеп, күзләрен ачып җибәргәндә, бүлмә тулы малай гайгылдашып көлешеп тора иде.* И. Гази.

ГАЙДАМАК *и. тар.* 1. XVII—XVIII йөзләрдә Польша паннарына каршы көрәшкә күтәрелгән украин казагы. *Гайдамак кылычы.*

2. Чит ил интервенциясе һәм гражданнар сугышы чорында Украина Үзәк радасы тарафыннан оештырылган махсус атлы гаскәр, шулай ук Петлюра һ. б. ларның контрреволюцион отрядлары сугышчысы.

ГАЙДУК *и. тар.* Көньяк славян илләрендә төрек хакимлегенә каршы сугышкан партизан. *Искә төшереп батып гайдукларны, Сөйли «дойна» ...* С. Хәким.

ГАЙКА *и. техн.* Винт яки болт кебек спираль сырлы нәрсәләргә борып кертелә торган төрле формадагы деталь; шөрепнең алынмалы башы.— *Нигә янгын сүндерү машинасының гайкаларын борып аласың?* Т. Гыйззәт.

◇ **Гайкасы йомшак** *сөйл.*— Нәрсәне дә булса эшләрлек, башкарып чыгарлык түгел, йомшак характерлы, көчсез (кеше). *Гайкасы йомшак минем ул малайның. Үзем дә аптырыйм, бу Уразмәт кавеменә кайдан шундый чирләшкә килеп эләккән икән?* Г. Әпсәләмов. **Гайкасын бору** *сөйл.*— ачулану, тиргәү, шелтәләү; ныграк, җыйнаграк, эштә җитдирәк булуны таләп итү.— *Бик тәкәббер кыз ул, райстат инспекторы, гайкаларын борырмын мин аның.* Каз. утл.

ГАЙМОРИТ *и. мед.* Өске теш казналыгындагы борын яны куышлыгының ялкынсынуы.

ГАЙРЕ *с. иск.* 1. Башка, бүтән. *Ул балта, пычак вә гайре тимер кораллары юклыктан зәхмәт чигәдер.* Г. Тукай. / *и. мәгъ. Без генә идек без, гайреләр ят иде.* Дәрдмәнд. *Инде, җанаш, үпкәләмә: гайриләргә сер салдым.* Җыр.

2. *кис. функ.* Үзеннән соңгы сүзгә карата инкярлау кисәкчәсе булып килә: ...булмаган, түгел. *Гайре ихтыяри.* □ *Асрау — татар байларының гайре рәсми кече хатыннары.* Г. Тукай. *Бу либреттода халыкның ханнар золымына каршы күтәрелеше кебек җитди [эчтәлек] --- гайре табигыйлек белән чишелгән.* М. Җәлил.

ГАЙРӘТ *и.* 1. Көч, куәт. *Күкрәк сукты Чүкеч гайрәт белән, Китте бөтен җирләр калтырап.* М. Гафури. // Батырлык, кыюлык, каһарманлык белән бәйләнгән көч, дәрт. *Куеп башын сезнең күкрәкләргә, Гайрәт биреп янган йөрәкләргә, Сөйгән ярлар калдылар...* Ә. Исхак.

2. *сөйл.* Хәл, егәр; үз вазифасын үтәү сәләте. *Аякларның гайрәте китү.* □ *Картайдым, гайрәтем юк эш эшләргә.* М. Гафури. // Көч, сәләт. *Күз гайрәтең кайттымыни.* Н. Исәнбәт.

3. *күч.* Нәрсәгә дә булса чын күңелдән бирелгәнлек хисе. *Күңелендә мөселманлык гайрәте булган инсан өчен --- ураза ны калдыру һич тә ярый торган эш түгел.* Ш. Камал. // *сөйл.* Исерткеч эчемлекнең куәте турында. *Җимеш суына коймак гайрәт кертеп җибәрә.*

◇ **Гайрәт керү** — исерү, башка китү.— *Кил, оялма, гайрәт тә кергән икән үзеңә, кил.* М. Әмир. **Гайрәт ору (итү, күрсәтү, чәчү)** — 1) батырлык күрсәтү. [*Пугачев явында*] *башкортлар бигрәк тә зур гайрәт күрсәткәннәр.* М. Галәү. *Үзебезнең кирәкләрне ятка бирмик, гайрәт итик...* Г. Камал. *Әйдә алга, курыкма, алда сугыш, Гайрәтеңне чәч, йөр сугышта.* М. Җәлил; 2) *күч.* урынсыз шапырыну, үзен батыр итеп күрсәтү.— *Кем булса да, кызганма, башын чап та өз, жавапка үзем барырмын, дип гайрәт орды.* Г. Ибраһимов.— *Син нәрсә бик гайрәт чәчәсең,— диде ул Егорычка карап.* М. Гали; 3) кычкырып ачулану, җикеренү.— *Әти бүген кайсыбыз өстенә гайрәт чәчә инде?* Ф. Әмирхан; **Гайрәт чигү (сүнү, кайту)** — теләк бетү, дәрт сүну. *Алга барудан бөтенләй гайрәтем чикте.* М. Әмир. *Гайрәте сүнде, кызык эшне күреп.* Г. Тукай. *Ләкин әле бу дошманның шәһәрләр шәһәрен басып алудан гайрәте кайткан дигән сүз түгел иде.* Г. Гобәй.

ГАЙРӘТЛЕ *с.* 1. Көчле; батыр, кыю. [*Бу дөнья*] *гайрәтле арысландай егетләрне иң начар адәмнәргә илтеп кушар.* М. Гафури. // Дәртле, ялкынлы. *Атасына охшаган булса, моңысы да гайрәтледер.* Ф. Хөсни. *Яз килгән саен йөрәк дәртлерәк, гайрәтлерәк, Язны ярсып һәм ашкынып көтмәгән йөрәк сирәк.* Ә. Ерикәй.

2. *күч. сөйл.* Градуслы, градусы көчле булган. *Балавызның каны бар, гайрәтле дигән даны бар.* Г. Бәширов.

ГАЙРӘТЛЕЛЕК *и.* Кыюлык, батырлык. *Александр Матросовның бөек батырлыгы Кызыл Армиянең барлык сугышчылары өчен гайрәтлелек һәм геройлык үрнәге булырга тиеш.* Г. Әпсәләмов.

ГАЙРӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* Көч бирү, гайрәт кертү. *Бу эш --- безне тергезеп һәм гайрәтләндереп җибәрде.* Ф. Әмирхан. // Дәртләндерү. [*Елкин*] *һаман басып, гел алга атылып, башкаларны гайрәтләндереп торды.* Ш. Усманов.

ГАЙРӘТЛӘҮ *ф.* Көч., гайрәт (1 мәгъ.) керү; батыраеп, дәртләнеп китү. *Кинәт гайрәтләнеп, барыбыз бердән сикереп тордык.* А. Шамов. *Шәкерт, халыкның кычкыргачына гайрәтләнеп, тегене күтәреп алмакчы булган иде, икесе берьюлы егылдылар.* М. Гали. // *к.*

гайрәт орү (итү, күрсәтү, чәчү). *Ул себерке белән, гайрәтләнеп, баскычны тукылдатып куйды.* Г. Бәширов. *Гайрәтләнеп, көяз башкисәр каты ябып керде ишекне.* М. Җәлил.

ГАҠЕС *и. иск.* Киресе, капма-каршысы. *Зәйнәп бу вәгъдәләрнең җиренә җиткерелүенә шул дәрәҗә ышанган вә иман китергән иде, аны моның гаксенә ышандыру мөмкинлек дәрәҗәсеннән узган иде.* М. Гафури.

ГАҠСЕ'НЧӘ *рәв. иск. к.* киресенчә. *Бәгъзысы хан кызыны зиндандагы әсир алып качкан, бәгъзылары моның гаксенчә, ягъни хан кызы әсирне алып качкан диләр иде.* Ш. Мөхәммәдев.

ГАҠЫЙБӘТ *и. иск.* Нәтиҗә; нинди дә булса эшхәлнең соңы, нәтиҗәсе. *Һәр катылыкның гакыйбәте шатлыктыр.* Қ. Насыйри. // *кер. сүз функ.* Ахырда, ахыр чиктә. *Тагы киңәш, тагы мәслихәт ясадылар, гакыйбәт, үлем җәзасын гомерлек хибескә алмаштырырга карар бирделәр.* Г. Тукай.

ГАҠЫЙКА *и. иск.* Баланың тугандагы чәче, беренче чәч.

Гакыйка корбаны *иск.*— бала туу уңае белән чалына торган корбан (гадәттә, тууның җиденче көнендә суялар).

ГАҠЫЛ *и. кит. к.* акыл. *Мин сүзем, гакылым белән генә түгел, үземнең инстинктым белән үк авыл ягына карыйм.* Г. Ибраһимов. *Салкын гакылың Үзеңә булсын, Тимә күңелемә!..* Ш. Бабич. *Үземнең башка мондый зур гакыл килеп төшүенә --- бик шатландым.* М. Гафури.

ГАЛА'ҠТИҠ *с.* Галактикага мөнәсәбәтле.— [*Син*] *кеше булып фикер йөртәсең. Адәм логикасы белән галактик табышмакларны да чишмәкчесең.* А. Гыйләҗев.

ГАЛА'ҠТИҠА *и. астр.* Бердәм йолдызлар системасы.

ГАЛАН: галан бәрәңге — бәрәңгенең кызгылт кабыклы эре бер сорты. **Галан тавык (этәч)** — гадәттә ак төстәге эре тавык токымы. *Элек барган ишан хәзрәткә, Нәзер итеп галан этәчен.* М. Крыймов.

ГАЛА'НҠА *и. сөйл.* Җыйнак формада салынган мич. *Уникә яшьлек Рабига галанкага салам тыккан, шырпы сызып маташа иде.* Ш. Қамал.

Галанка мич — *к.* галанка. *Кызлар бер почмактарак, ягылмаган галанка мич тирәсенә бөрешеп утырганнар.* Ә. Еники.

ГАЛАНТ *с. сөйл.* Артык нәзакәтле, үзен тәкәллефле, әдәпле тота торган. [*Рәүф:*] *Зәйтүнә! Тукта, аның янында кем? Ниндидер бик галант егет.* Ә. Фәйзи.

ГАЛАНТЕРЕЙЧЫ *и.* Галантерея товарлары белән сату итүче. *Кайдан килеп тагылган бу колак ишетмәгән әкәмәт өстәмә [«әйттем-бетте» кушаматы] безнең галантерейчы егеткә?!* Ә. Еники.

ГАЛАНТЕРЕ'Я *и.* Сатудагы челтәр, тасма, тарак, брошка, энә, җеп, хушбуй, сабын һ. б. ш. әйберләрнең гомуми атамасы. *Аз-маз яшергән кызыл малларын, кечкечә-кечкенә кызыл тартмалы галантерея калдыкларын --- күтәрәләр дә мәйданга рәт-рәт тезелиләр.* Г. Ибраһимов. / *с. мәгъ. Кооперативның галантерея кибете ябык, бакалея кибете әле ябылмаган.* Ш. Қамал.

ГАЛЕ'РА *и. тар.* Агачтан эшләнгән, күп ишкәкле хәрби көймә.

ГАЛЕРЕ'Я *и. махс.* **1.** Бинаның аерым өлешләрен тоташтырган яки фасад буенча үткән түбәле озын тар коридор. *Әлеге шул галереяларга бетон салучы Сафин да үзенең эш көнен --- уздырды.* С. Рафиков.

2. Театр, цирк һ. б. залларында өске ярус; *к.* галёрка.

3. Хәрби корылмаларда, тау яки җир асты эшләрендә һ. б. ларда җир асты юлы.

4. Нәфис, сынлы сәнгать әсәрләреннән төзелгән музей. *Третьяков галереясы. Дрезден галереясы.* ▭ *Художник музейдан яисә галереядан күреп түгел, тормыштан күреп эшкә өйрәнсен.* Г. Гали.

5. *күч.* Матур әдәбиятта бертөрлерәк образлар, типлар төркеме. [*Шапырай карт*] *әдәбиятта бик күп тапкырлар яктыртылган мәзәк картлар галереясына керә.* Ф. Мусин.

ГАЛЁРҠА *и. сөйл.* Театр, цирк залларында иң өске ярус. *Бер студенттан: «Ник син һәрвакыт театрда галёркада утырасың?»— дип сорыйлар.* Мәзәк. // Галёркадагы халык, тамашачылар. *Партер көчләрәк итеп кул чапты, галёрка исә дөньяны күтәрде.* Ш. Қамал.

ГАЛЕ'ТА *и. махс.* Чүпрә, шикәр һәм химик күперткеч кушып әзерләнгән, төче камырдан пешереп киптерелгән ашамлык; эре печенье. *Өстәл янына килеп утыргач,* [*Бакый*] *үз каршында язу һәм ашамлыклар: берничә галета, чикләвек һәм ипи кисәге күрде.* Г. Әпсәләмов.

ГАЛИ *с. кит.* **1.** Бөек, олы. *Гали хис.* ▭ *Бар синең дустың, бар ул, Ул гали, ул ак күңел.* Һ. Такташ. [*Театр*] *мөкатдәс ул, бөек ул, гали зат ул.* Г. Тукай.

2. Дәрәҗәсе, сыйфаты белән өстен. *Хәзрәтнең икенче әсәре моңысыннан да гали һәм шулай булуы табигый дә.* Ф. Әмирхан. // Югары. *Гали курслар.* ▭ *Ниһаять, ул гали мәктәпне тәмам итеп чыккач, врач булып эшкә кереште.* Ш. Қамал.

ГАЛИБАНӘ *рәв. иск.* Җиңүче булып, җиңеп, җиңү белән. *Сугышлардан галибанә ерып чыкканлыгын икърар итте.* Ф. Әмирхан. // Җиңүче сыман; җиңүче кыяфәте белән. *Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата.* Г. Тукай. // Эреләнеп, тәкәббер генә, үзен югары тотып. *«Әҗәл җитте бу кызга!» — дип тәңре хөкемен Укыды ул галибанә бар дөньяга.* Һ. Такташ.

ГАЛИЛЕК *и.* Гали булу, бөеклек, олылык. *Ул үзендә галилек, зурлык эзли.* Г. Нигъмәти.

ГАЛИМ **1.** *с.* Аерым бер фән өлкәсендә югары квалификациясе булган. *Галим математик. Галим кешеләр.* ▭ *Бөек галим Ломоносовның сүзләрен искә төшерегез.* А. Әхмәт. // Мәгълүматлы, укымышлы. *Озынча битле сарғылт мишәр һәммәсеннән картрак вә, үз ченча, һәммәсеннән гакыллы һәм галимрәк иде.* Ф. Әмирхан.

2. *и.* Аерым фән буенча белгеч, белеме рәсми танылган (дипломлы) кеше. *Күренекле галим.* ▭ *Чит илләрдән дә атаклы химия галимнәре килгәннәр.* М. Гали.

3. *и.* Профессиясе буенча фән кешесе, фәнни эзләнүләр алып баручы кеше. *Бу яшь буын эченнән яңа илнең политик җитәкчеләре, беренче инженерлары һәм галимнәре --- күтәрелеп чыкты.* Г. Бәширов.

ГАЛИМ-ГОЛӘМА *җыйд. и.* **1.** Гыйлем ияләре, галимнәр, фән кешеләре.

2. *мыск.* Дин кешеләре, муллалар дөньясы. *Газетачылар галим-голәманы хурлыйлар.* Г. Тукай.

ГАЛИМЛЕҠ *и.* Галим булу.

ГАЛИМНӘ'РЧӘ *рәв.* Галим кешеләр кебек. *Үзен галимнәрчә тоту.* // *с. мәгъ.* Галимнәргә хас булган. *Галимнәрчә җитдилек.*

ГАЛИП *и. иск.* **1.** Җиңүче, җиңеп чыгучы. *Вәисев фиркасы кай тарафта булса, --- шул тараф галип булыр, диләр.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Өстен, башкалардан югары. *Галип булгач яманлык яхшылыкка, чыга һәр яхшылык бушка вә юкка.* М. Гафури.

ГАЛИФЕ *и.* Балагы тар булып, тездән югары өлеше киңәйтеп тегелгән чалбар. [*Газиз*] *күлмәкчән, итек, галифедан аптыраган кыяфәттә йөренә.* А. Әхмәт. // *с. мәгъ.* Шундый өлгедә (фасонда) тегелгән. *Йортның икенче катыннан күн пиджак, галифе чалбар кигән тузма чәчле бер кеше сикереп төште.* Г. Гобәй.

ГАЛИҖӘНАП *и. иск.* **1.** Олы күңелле, олы хисле, мәрхәмәтле, шәфкатьле кеше.— *Сез үзегезнең галиҗәнап икәнегезне күрсәттегез.* М. Фәйзи.

2. Түрәләрне, зур дәрәҗәле кешеләрне атау һәм шуларга мөрәҗәгать итү сүзе. [*Сусанна:*] *Ах, граф, минем бурычым — сез галиҗәнапларның теләкләрен үтәү.* М. Җәлил.

ГАЛИҖӘНАПЛЫК *и.* 1. Олы күңеллелек, олы хискә ия булу, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек. *Кардәш кайгысына иштирак итү, кардәш хәсрәтен җиңеләйтү кебек галиҗәнаплыклар аңарда* [*агабызда*] *юк иде, ахрысы.* Ш. Камал.

2. Галиҗәнап (2 мәгъ.) булу, түрә булу.

Галиҗәнаплык итү — зур дәрәҗәгә ия булганлыгын күрсәтү; үзеңнең бөеклегеңне, галилегеңне, кешелеклегеңне күрсәтү.— *Мин синең кәефең өчен дә, атаң кәефе өчен дә социалист була алмыйм шул, гафу итәрсез; урам халкына чыгып: «Малымны алыгыз!» — дип галиҗәнаплык итә алмам.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ГАЛЛ *и. тар.* 1. Хәзерге Франция, Бельгия территорияләрендә яшәгән борынгы кельт кабиләләре кешесе. *Афина һәм Римның утлары да һәм галларның очлы уклары да --- Бар да синең өскә ташландылар.* Ә. Исхак.

2. *иск.* Француз.

ГА'ЛЛИЙ *и. хим.* Сирәк очрый торган ак төстәге металл.

ГАЛЛИЦИЗМ *и. лингв.* Француз теленнән алынган сүз яки тәгъбир. *Л. Н. Толстой үзенең әсәрләрендә --- аристократия вәкилләренең теленә французча тулы җөмләләр һәм галлицизмнар кертә.* Н. Гыйззәтуллин.

ГАЛЛОМАН *и. иск.* Француз телен, гореф-гадәтләрен, культурасын һ. б. яратучы, шуның белән мавыгучы кеше.

ГАЛЛОФОБ *и. иск.* Француз теленә, гореф-гадәтләренә, культурасына һ. б. нәфрәт белән караучы кеше.

ГАЛЛЮЦИНА'ЦИЯ *и. мед.* Баш миенең аерым урыннары зарарлану сәбәпле сизү органнарының ялгышуы: юкны бар итеп күрү, ишетү, тою. *Чын тавыш идеме бу, әллә галлюцинация генә идеме — анда хәзер аның әше юк иде.* Н. Фәттах.

ГАЛОГЕН *и. хим.* Менделеевның периодик системасында VII группа химик элемент (фтор, хлор, бром, йод).

ГАЛО'ИД *и. хим. к.* галоген.

ГАЛО'Ш *и.* Күн яки киез аяк киемнәрен юешләнүдән саклау өчен кия торган резин аяк киеме. *Чабатаны ташлап матур гына галош алдым.* М. Гафури.

◇ **Галошка утырту** *гади с.*— алдау. *Тагын да ныграк итеп галошка утыртмавыгызга нинди гарантия бар?* Ш. Камал.

ГАЛОШЛЫ *с.* Галош кидерелгән, галошы булган. *Аягына галошлы киез итек кигән бер чибәрне Нарспи диделәр.* Г. Бәширов.

ГА'ЛСТУК *и.* 1. Алгы яктан бант формасында төенләп муенга киелә торган тасма. *Ул үзенең коңгырт озын чәчен артка җибәргән, ак якадан, галстуктан, яхшы костюмнан.* М. Гали.

2. Ике очын түбән төшереп, алдан махсус төенләп бәйләнә торган өчпочмаклы кызыл (яки ал) муен яулыгы — пионер формасының бер өлеше, пионерлык билгесе; *к.* кызыл галстук. *Малае-кызы бер-берсенә тотынышып баскан, галстуклары җәйге кояшта ялкын телләредәй балкып җилферди.* Г. Гобәй.

ГА'ЛСТУКЛЫ *с.* Галстук таккан. *Иген уртасында, җиңнәрен сызганып, беләкләренә бик зур бодай көлтәсе салган, эшләпәле, галстуклы бер кеше басып тора.* Г. Бәширов. *Бу эзләрдә — галстуклы яшь буынның Чикләнмәган дәрте, алга ашкынуы.* М. Җәлил.

ГАЛУ'ШКИ *и. махс.* Сөт яки шулпада пешерелгән кисәкле камыр (чумар) — украиннарның милли ашы. *Бер киявем — Полтавада, Кил, күңел ачарсың, ди,— Тансыкка син ап-ак оннан Галушки ашарсың, ди.* М. Хөсәен.

ГАЛЬВАНИЗА'ЦИЯ *и. мед., тех.* Даими электр тогын техник яки дәвалау максатлары өчен файдалану.

ГАЛЬВАНИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. *тех.* Электролиз ярдәмендә әйбернең өстенә металл йөгертү.

2. *мед.* Билгеле күләмдә тәнгә электр тогы җибәрү; электр белән дәвалау.

ГАЛЬВА'НИК *с.* 1. *физ., хим.* Химик реакция ярдәмендә барлыкка килә торган. *Гальваник ток.* // Химик реакция юлы белән электр тогы барлыкка китерә торган. *Гальваник батарея.*

2. *тех., мед.* Гальванизация эшенә караган; электр тогы белән дәвалый торган. *Гальваник дәвалау.*

ГАЛЬВАНО'МЕТР *и. физ.* Аз көчле электр токларын үлчәү приборы. *Термик гальванометр. Вибрацион гальванометр. Универсаль гальванометр.*

ГАЛЬВАНОПЛА'СТИКА *и. хим., тех.* Нинди дә булса әйбернең төгәл металл копиясен алу өчен, электр тогы тәэсирендә металлны аның тозлары эремәсеннән аерып, шул предмет өстенә утырту ысулы.

ГАЛЬВАНОСКОП *и. физ.* Электр чылбырындагы даими токны табу һәм аның юнәлешен билгеләү приборы.

ГАЛЬВАНОТЕ'ХНИКА *и. тех.* Электрохимиянең металлны аның катнашмаларыннан электр тогы ярдәмендә аерып алу мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган бүлеге.

ГАЛӘ: нур галә нур *иск. кит.*— нур өстенә нур, ягъни берәр нәрсәнең, күренешнең һ. б. кыйммәтен, дәрәҗәсен тагы да югарырак күтәрә торган икенче бер нәрсә, күренеш, эш һ. б. *Яшь абыстайны да бергә алып килсәгез, ул тагы нур галә нур була инде.* Ф. Әмирхан.

ГАЛӘБӘ *и. кит. иск.* 1. Җиңү; өстен чыгу, өстенлек казану. *Хәзрәт үз гомерендә сүзгә, бәхәс вә моназараларга бик зур әһәмият бирә торган адәмнәрдән. Ул үзе гомер буенча шуңа тырышты, галәбәне шунда дип белде.* Г. Ибраһимов.

2. Өстенлек; бөеклек, олылык.

Галәбә итү *иск. кит.*— җиңү, өстен чыгу, өстенлек казану.

ГАЛӘБӘЛЕ *с. кит. иск.* Җиңүле; тантаналы, өстенлекне чагылдырган. // Өстен, югары. *Хәзер шигырь мәйданында иң --- галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный.* Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* Җиңүле; җиңү белән, җиңеп. [*Бу нәсер*], *гражданнар сугышын галәбәле тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә багышлана.* Ф. Әмирхан.

ГАЛӘБӘЛЕК *и. кит. иск.* 1. Җиңү тантанасы. *Җитмәсә аның* [*Уфа шәһәренең*] *«авыллыгы» --- шау-шу яратучылыгымны, галәбәлек, көрәш сөючелегемне үчекләгән кеби булды.* Г. Тукай.

2. Ыгы-зыгы, шау-шу. *Андагы* [*вокзалдагы*] *галәбәлекләр, бер-берсенә мөнәсәбәте булмаган күренешләр --- Хәмидәнең күзе алдыннан үтәләр иде.* М. Гафури. *Бу галәбәлек арасында --- кыскарак буйлы кызга һәркемнең күзе төшә иде.* Ф. Әмирхан.

ГАЛӘҖА *и. иск. кит.* Бәйләнеш, мөнәсәбәт. *Аның үзе белән дә, мәдрәсәсе белән дә минем хәзер һичбер төрле галәкам калмады.* Г. Ибраһимов.

ГАЛӘМ *и.* 1. Материянең бер бөтен тәшкил иткән барлык формалары: планеталар, йолдыз һәм йолдызлыклар; космос. *Ул китәр башка галәмгә, җир йөзе айсыз калыр.* М. Гафури. *Ә Совет кешесе --- айкап йөри әнә Галәм киңлеген.* Ә. Исхак.

2. Җир йөзе, барлык терек һәм терек булмаган **табигать; дөнья.** *Бар галәмнең җан чишмәсе — кояш.* Ш. Маннур. *Тынып калды гүя бөтен галәм --- Кешелекнең дәһше сөйләгәндә.* Ә. Исхак. // Кешелек җәмгыяте; җирдә яшәүче барлык кешеләр. *Җиңү тели бөтен галәм батырларга.* Ә. Ерикәй. // Халык, кешеләр. *Кит*

тем ходайның гарышенә, Унсигез мең галәме Артымда калды барсы да. Ш. Бабич. // Нинди дә булса төркем, тараф һ. б. халкы, кешеләре, әһелләре. [*Хәмитне*] *шәһәрнең бөтен сәүдә галәме белә.* Ә. Еники.

3. *иск.* Чынбарлыкның аерым өлкәсе — күренеш яки предметларның билгеле бер җыелмасы яки кешенең психик кичерешләре даирәсе; аның дөньясы. *Ул бала бу вакытта адәм түгел, хикәяләр галәменнән килгән бер пәри кызы иде.* Ш. Камал.

4. Тормыш, яшәү рәвеше; халәт. *Боларда чит, билгесез галәмгә, «тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән» яшәргә омтылыш та бар.* Г. Нигъмәти. *Әмма Җәмилә бичара, яңа гына кызлык галәменнән чыгып, хатын булган.* М. Гафури.

5. *рәв. сөйл.* Бик, артык. *Галәм күп. Галәм эш эшләгән.*

ГАЛӘМЧЕ *и.* Космонавт; галәмгә, космоска очучы. *Галәмче без барчабыз — Ил өстендә яңа күкләр, Яңа юллар ачабыз.* З. Нури.

ГАЛӘМӘТ 1. *и.* Нәрсәне дә булса күрсәтә, белдерә яки алдан сиздерә, искә төшерә, хәбәр итә торган әз, билге. *Болар барысы да яз башының беренче галәмәтләре.* Ф. Хөсни. *Бу сүзләрне әйткәндә, аның төсенә бик нык курку галәмәте чыкты.* М. Гафури. // Тамга, билге. *«Йолдыз» идарәсе шигырьдәге «әүлиялар» дигән сүзгә махсус галәмәт куеп, газетаның итәгенә: 1) «Дуслар» мәгънәсендә аңларга тиеш» дигән бер шәрех төшерде.* Г. Тукай.

2. *с.* Искиткеч, гаҗәпләнерлек. *Мирхәйдәр абзый Габдуллага үзенең галәмәт бер машина уйлап табу хыялын, әлеге сызыкларга күрсәтеп, сөйләде.* Ә. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* Бик, артык; искитәрлек. [*Җаббаров*] *үзе тагын галәмәт чибәр, ягымлы кеше иде.* М. Әмир. *Тын гына ага торган елга быел бер дә галәмәт җәелгән.* Г. Әпсәләмов.

3. *и.* Гаҗәп хәл; табигый булмаган, сирәк очрый торган хәл. *Менә бервакытны, җәй көннәрендә, көнчыгыш ягында кич белән күктә кызыллыклар, койрыклы йолдызлар, башка төрле галәмәтләр күренә башлады.* Ш. Мөхәммәдев. // Могҗиза. *Цыкса мәгъриптән кояш, шунда заманның ахыры; Бу — китапларда язылган күп галәмәтнең бере.* Г. Тукай.

ГАЛӘМӘТЛӘНҮ *ф. сөйл.* Төрле кызык, әкәмәтләр кору, мәзәк эшләр эшләп ташлау. // Кызык булу, көлкегә калу, уңайсыз хәлдә калу.— *Балалары иколда суғыша, аталары урамда талаша торган иде. Ул җитмәсә, аналары кунакта тиргәшә. Йа-а галәмәтләнеп бетә торганнар иде.* М. Фәйзи.

ГАМ *иск.* 1. *с.* Гомуми, һәркем өчен дә бер. *Су һавага караганда авыр, --- Истамбул шәһәре Төркиянең пайтәхете дигән хакыйкатьләр — бөтен милләтләргә гам нәрсәләр.* Ф. Әмирхан.

2. *и.* Гади халык, түбән катлау кешеләр, масса, гавам.

ГАМАК *и.* Ачык һавада ял итү, йоклау өчен баудан үрелеп махсус эшләнгән асылмалы көйка. *Йке карт агачның урталарына гамак бәйләп куелган.* Ф. Әмирхан.

ГАМАШ *и.* Җылы оек кунычы.

ГАМБИ'Т *и. шахм.* Шахмат уенында һөҗүмгә тизрәк күчү өчен берәр фигураны яки пешканы оттыруга корылган уен башы, башлангычы. *Ферзь гамбиты.*

ГАМБӘР *и. иск.* 1. Кит балыгының бер төре, кашалот.

2. Гамбәр балыгыннан алына һәм парфюмер әйберләр эшләүгә китә торган хуш исле матдә. // Хушбуй. *Мисек гамбәр исе аңкый, Гамбәр, синдә.* Ш. Бабич.

ГАМИ *с. иск.* Надан. *Әхмәтҗан абзый шикелле гамиләргә карт булса да гакыл керми әле.* Г. Тукай.

ГАМИЛ *и. иск. кит.* 1. Төп көч, фигура. *Хезмәт халкын баш гамил (төп фигура) ясау --- беренче шарт буладыр.* Ф. Әмирхан.

2. Нигез фактор, сәбәп. *Тукаевның үзеннән соң да кыйммәте бетмәүгә сәбәп булган гамилләрнең тагын да берсе — аның халык әдәбиятыннан --- файдаланулы булды.* С. Сүнчәләй.

ГА'ММА *и.* 1. *муз.* Октаваларда эзлекле рәвештә күтәрелә яки төшә барган тавыш рәтләренең тоны. *Күршеләрдә пианинода уйныйлар. Бала уйный ахрысы, гел бер гаммаңы кабатлый.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Бер-береннән артык аерылып тормаган күренешләрнең эзлекле урнашуы. *Буяулар гаммасы.*

Гамма нурлар *физ.*— кайбер үтә күренми торган предметлар аша да үтәргә сәләтле, рентген нурларына охшаш нурлар.

ГАММӘ *и. иск. кит.* 1. Халык, масса; гади халык. *Бу кәгазь акчалар гаммәнең иттифакы илә алмашу васитасы булып йөридер.* Г. Тукай. *Килде ачлык --- гаммәләрнең Ачтан интеккәннәрен һәм балаларның соранып канлы яшь түккәннәрен Күргән адәм һич онытмас.* С. Сүнчәләй.

2. Җәмгыятьтәге билгеле бер катлау, халык катлавы. *Демократия гаммәсе. Хезмәт гаммәсе.* □ *Үзебезнең зыялылар гаммәсенең дә мещанлык идеологиясеннән югары --- икәнлегенә ышанабыз.* Ф. Әмирхан.

ГАМЬ *и.* 1. Кайгы, хәсрәт; көенеч, сагыш. *Кешене эш картайтмый, гамь картайта.* Мәкаль. *Ургылып кайнап чыга күкрәк төбемнән утлы гамь.* Ш. Бабич.

2. Нинди дә булса эш, әйбер, хәл турында кайгырту, шул эш кайгысы, хәстәре. *Киресенчә, ныграк күмелерсең ямь эчендә яшәү гаменә.* Ә. Ерикәй. // Игътибар, күңел кую. *Сәет үзенең барлык вакытын, барлык гамен укуга бирде.* И. Салахов.

◇ **Гаме(ндә) дә юк** — уйламый да, исе дә китми; игътибар да итми. *Кыз инде бөтенләй диярлек ишми, Маратның да койрыкта гаме юк иде.* Г. Гобәй. *Кешеләр изге бәйрәм көтә, аның гамендә генә булса иде.* Ш. Камал. **Гамь чигү** — кайгыру, хәсрәтләнү, көенү. *Син дә Зөләйха булма, гамь чикмә.* М. Гафури.

ГАМЬЛЕ *с.* 1. Кайгылы, хәсрәтле. *Гурстандай гамьле авылларда кыбырдаша җанлы мәетләр.* Ш. Бабич. *Сиздермичә килгән төн төсле килә мәллә гамьле елларың?* Н. Исәнбәт.

2. Кайгыртучан. *Шәмсетдин, гамьле кыяфәт белән башын чайкап, телен чартлатып куя.* Г. Бәширов.

ГАМЬСЕЗ *с.* Ваемсыз, бернәрсә турында да уйламаучы, кайгыртмаучы, һәрнәрсәгә өстән-өстән генә, игътибарсыз караучы.— *Мин җырлыймын сагынып, ә син [кош] — гамьсез, Читлегеңдә ярма ярасың.* Ш. Бабич. / *рәв. мәгъ. Зиннәт --- бөтенесенә күзләрендәге боз салкыны аша гамьсез карый.* Г. Бәширов.

ГАМЬСЕЗЛЕК *и.* Гамьсез булу. *Аларның кайберләре Газизовны гамьсезлектә, сизгерлеген югалтуда --- гаеплиләр.* А. Шамов.

ГАМЬСЕЗЛӘНҮ *ф.* Гамьсез булу, гамьсезлек күрсәтү.

ГАМӘЛ *и.* 1. Эш; хәрәкәт. *Заман вә табигать тәэсиреннәндерме, атаның әмәле [идеал, максаты] белән балаларның гамәле кара-каршы килеп бәрелешкәннәр.* Г. Ибраһимов. // Практика. *Гамәлсез гыйлем — җансыз тән.* Мәкаль. // Эш, эшнең торышы; хәл. *Гамәлләре бик үк шәп булмаган ферма мөдирләре бу сары тышлы дәфтәрне агент кулында күрергә бер дә яратмыйлар иде.* Ә. Еники.

2. *мат.* Математик хисаплауның төп ысулы, төре. *Арифметиканың дүрт гамәле: алу, кушу, тапкырлау, бүлү.* □ *Беренче елны ук укырга-язарга, дүрт гамәлдән кайсы саннарга кадәрдер хисап эшләргә өйрәнә башладык.* Г. Бәширов.

3. *дини.* Намаз; шәригать буенча мәҗбүри үтәлергә тиеш булган эш. *Ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, --- ишаннар — тәрәкъкыйгә дошманнар.* Г. Тукай.

4. Чара, мөмкинлек; ысул, әмәл. *Бу тылсымны кырырга бер дога бармы, гамәл бармы?* М. Гафури.

Гамәл итү (кылу) — 1) шөгыльләнү. *Үземне һәрвакыт мулла баласынча тотарга вә укылган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем.* Г. Тукай; 2) гыйбадәт кылу. *Җәһәннәмнән куркып, оҗмахыңа кызыгып, гамәл кылып йөриләр.* М. Гафури. **Гамәлгә ашу** — үтәлү, тормышка ашу.— *Була шундый бригадирлар, шундый колхоз җитәкчеләре, ул колхозчыларына әллә ниләр вәгъдә итә. --- Карыйсың: бер генә сүзе дә гамәлгә ашмаган.* Г. Бәширов. **Гамәлгә кую** — куллану, тормышка ашыра башлау. *Герасимов кайбер вакытта Зубатов методын гамәлгә куючан.* Г. Ибраһимов. **Гамәлдә калу** — көчендә калу, закон хәлендә, яшәештә, кулланышта калу, яшәвен дәвам иттерү. *Идрис яңа командующийның патша уставларын тулы килеш гамәлдә калдыруын --- әйткәч, Юныс Вәлишин малайларча кеткелдәп көлде.* Қ. Нәҗми. **Гамәлдән чыгу** — кулланудан чыгу, тыелу, закон төсен югалту, яшәештән төшеп калу.

◇ **Гамәл дәфтәре** *дини* — 1) дини өйрәтүләрдә: кешенең уң һәм сул ягындагы ике фәрештә тарафыннан аның яхшы һәм яман эшләре язылып барыла торган дәфтәр. *«Гамәл дәфтәре»ңә язылып барган һәр ел саен чалган корбаның.* М. Гафури. [*Карт*] *Газраил җаныммы җиңеллек белән генә алса икән; гамәл дәфтәрем уң кулларыма бирелеп, рәсүлнең шәфәгатеннән мәхрүм булмасам икән, илаһем, ди.* Г. Ибраһимов; 2) *шаяр.* алу-бирүләр, эш барышы язылган блокнот, кесә дәфтәре. *Шәйдуллин* [*ул дәфтәрне*] *«гамәл дәфтәре» дип кенә атап йөртә.* Ә. Еники.

ГАМӘЛДӘ *рәв.* Чынлыкта; чынбарлыкта, тормышта. *Эш ташлаулар --- эшчеләр җиңү белән беткән кебек иде. Ләкин гамәлдә башкача барып чыкты.* Г. Ибраһимов. *Шул ук кешенең киңәшен гамәлдә эшләп карау чарасына керешәләр иде.* М. Гафури.

ГАМӘЛДӘГЕ *с.* Кулланышта булган, практик кулланыштагы. *Гамәлдәге алымнар. Гамәлдәге чаралар.*

ГАМӘЛИ *с. иск. кит.* Тормышка нигезләнгән, практик. *Сүзләремнең ялган түгеллегенә гамәли булган дәлилләрем ышанырлык иде.* М. Фәйзи.

ГАМӘЛЛЕ *с.* 1. Ничәдер гамәлдән торган. *Күзләрен бер ноктага терәгән, гүя хисаптагы дүрт гамәлле мәсьәләне күңелдән* [*чишә*]. Г. Тукай.

2. Гамәле, шөгыле, эше булган. *Гамәлле һәрвакыт әмәлле.* Мәкаль.

ГАМӘЛӘ *и. иск. кит.* Эшче, эшчеләр сыйныфы вәкиле. *Анда һәртөрле гамәлә вә крестьяннар арасына кереп, --- папиросын кабызып җибәрде.* Г. Тукай.

ГАНГАНӘ *и. иск. к.* традиция. [*Төрки халыклар*] *милли гадәт, милли ганганә буенча да бер-береннән ераклашалар.* Г. Ибраһимов. *Көрәш, татар көрәше булуга карамастан, ул үзе дә аның ганганә белән эшләнеп чыккан кагыйдәләре турысында катгый бер фикер әйтә алмый.* Ф. Әмирхан.

ГАНГРЕ'НА *и. мед.* Кан йөреше бозылу нәтиҗәсендә күзәнәкләрнең үлүе, тәннең нинди дә булса бер өлешенең черүе.

ГА'НГСТЕР *и. кит.* Америкада монополистлар тарафыннан оештырыла торган җинаятьчел эшләрдә ялланып хезмәт итүче бандит. *Ути Пентагонның гаскәрләре Банкир, гангстерлар иреген.* Ә. Давыдов.

ГАНДӘЛИБ *и. иск. кит.* Сандугач, былбыл. *Очмак өчендер мәхәббәт багына ул гандәлиб.* Дәрдмәнд.

ГАНИМӘТ *и.* 1. Сугышта кулга төшкән байлык, трофей. *Канлы сугыш ганимәтен мактый-мактый, Йөзләрчә кул чыныяклар болгый һаман.* Ф. Бурнаш. / *с. мәгъ. Көрәшмәк куркыныч, күп хәлләре бар, вәли* [*ләкин*] *җиңгәч, ганимәт маллары бар.* Г. Тукай.

2. *күч.* Табыш, казаныш, уңыш.— *Дөрес карар өчен көрәшсәң, ул бит икебез өчен дә ганимәт.* А. Расих.

◇ **Ганимәт белү** — берәр нәрсәдән, очрактан файдалану; уңай очрак, форсат дип санау. *Кала халкы, бу минутларны ганимәт белеп, киенде, ясанды да, зур урамнарга, өлкән бакчаларга агылды.* Г. Ибраһимов.

ГАНКА *и. миф.* Каф тау артында яши дип саналган фантастик кош. // *күч.* Ахмаклык, аңгыралык символы буларак кулланыла. [*Ишан:*] *Койма аркылы? Галәви, ишеттеңме? Син нәрсә карап тордың, ганка?* Қ. Тинчурин.

ГАНТЕЛЬ *и. спорт.* Ике башын да чукмарлап кыска таякчык формасында тимер яки чуеннан коелган гимнастика снаряды. *Гантель, теннис һәм бадминтон — Өендә бар — таный ул.* Ш. Галиев.

ГАОЛЯН *и.* Тарыга охшаш, озын сабаклы, корылыкка чыдам берьеллык игүле үсемлек; кытай тарысы. *Бәрәңгеләр, гаоляннар, чумизалар шаулап үсеп торган уйсулыкка барып төштек.* А. Шамов.

ГАРАЖ *и.* Автомобиль, мотоциклларны ремонтлау һәм саклау өчен төзелгән махсус бина, корылма. *Ул, гажәпләнеп, китә гараж буйлап.* Н. Баян.

ГАРАНТ *и.* Гарантия бирүче.

ГАРАНТИЯ *и.* 1. Нәрсәне дә булса үз җаваплылыгына алу, нинди дә булса эшне башкаруга ышандыру. [*Зиннур:*] *Мин үзем анда юк чагында, сынаулар бозыла дип, һич борчылырлык булмасын.* [*Солтан:*] *Монысына да гарантия бирә алам.* А. Расих.

2. Сатылган яки ремонтлап бирелгән нәрсәнең билгеле бер вакытка кадәр төгәл, нормаль эшләвенә ышандыру, ватылган очракта түләүсез төзәтеп бирүне үз өстенә алу. *Гарантия бирү. Гарантия вакыты чыгу.*

Гарантия паспорты (язуы) — гарантия (2 *мәгъ.*) документы. *Билгеле, бу алмаш-тилмәшлек итү закон нигезендә алып барыла, төрле гарантия язулары языла, вәгъдәләр бирелә.* И. Гази.

ГАРА'НТИЯЛЕ *с.* Гарантияләнгән, ышанычлы. *Инде, линкорны бомба ташлап шартлатырга йөз процент гарантияле мөмкинлек килеп чыккач, таранга баруның кирәге юк.* С. Баттал.

ГАРА'НТИЯЛӘҮ *ф.* Нинди дә булса эшкә гарантия (1 *мәгъ.*) бирү, шуны үтәүне тәэмин итү. *Өлкән офицерларның салкын коралларын үзләрендә калдыруны гарантияләргә.* Каз. утл.

ГАРАСАТ *и. иск.* 1. Көчле давыл. *Ул — әллә нинди кар-бураннар күргән, яшеннән һәм гарасаттан — өермәдән исән калган нарат.* Н. Фәттах. / *күч. Бу сугыштан, көн саен меңнәрчә адәм балаларын йотып торган бу гарасаттан котылып калган кеше, һичшиксез, бәхетле булачак.* Ә. Еники.

2. *дини.* Ахирәттә алланың кеше жанын оҗмахка яки тәмугка хөкем итүе.

◇ **Гарасат мәйданы** *дини.*— ахирәттә кеше җаннарының алла хөкеменә җыйналу урыны — соңгы хөкем бара торган мәйдан.— *И үлекләрнең рухлары! --- Әүвәлге тәннәрегез илә гарасат мәйданына килегез!* Г. Тукай.

ГАРБИ *с. иск.* Көнбатышка караган, көнбатыштагы. *Мондый галим булмас Гарби Европада.* М. Гафури.

ГАРГАРӘ *и. иск. кит.* Үлгән минутларда гырылдау, соңгы сулыш. // *күч.* Үләр вакыт, үтә картлык. *Тешләрегез коелып бетеп, гаргарәгә килсәгез дә, әгәр башыгызга өйләнү уе төшсә, Яңа бистәдәге туган апагыз сезгә ярдәм итәр.* Ш. Хөсәенов.

ГАРДЕМАРИН *и. иск.* Революциягә кадәр диңгез кадетлар корпусының югары класс укучыларына бирелә торган исем. // Шул чордагы рус флотында мичманнан түбәнге чин.

ГАРДЕРОБ *и.* 1. Кием шкафы. *Һәфисә, гадәте буенча, портфелен тиз генә гардероб янына идәнгә ташлады да радио тыңлаучылар янына килә башлады.* А. Әхмәт.

2. Күп кешеләр җыйнала торган зур биналарда (клуб, мәктәп һ. б.) чишенү бүлмәсе. *Миргали --- вестибюльгә узды. Гардероб янында чишенгәндә үк инде ул, биек пыяла ишекләр аша, көчле музыкага бию ече парларны күрде.* М. Хәсәнов.

3. *җый.* Аерым бер кешенең барлык киемнәре. *Җәйге гардероб.* □ *Оригинал әсәрләр уйнаганда кием табу кайгысы артистның үз өстендә. Артистлардан кайберсенең гардеробында ул-бу табыла.* И. Рәмиев. // *театр.* Сәхнәгә киеп чыга торган киемнәр (костюмнар) жыелмасы.— [*Бу киемнәрнең*] *бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк.* Э. Еники.

ГАРДЕРОБЧЫ *и.* Гардеробта (2 *мәгъ.*) эшләүче. *Гардеробчы лакей урынына куркынган кыяфәт белән килеп кергән --- [кеше] бөтен залны чыжылдаган тавышлар белән тутырды.* К. Нәҗми.

ГАРДИН *и.* Гардинаны элү өчен махсус ясалган таяк, пәрдә элгече. *Тәрәзәгә пластмасса гардин белән вак кына матур бозҗараларга элактереп нәфис челтәр (тюль) кордылар.* Азат хатын.

ГАРДИ'НА *и.* Тәрәзә пәрдәсе.

ГАРЕМ *и.* Күпхатынлылык хөкем сөргән көнчыгыш мөселман халыкларында хатыннар ягы, хатыннар бүлмәсе. // Бай мөселманнарның кәнизәк һәм җарияләр яши торган сарайлары. *Мөселман кәефләнеп көн уздырган гаремнарда.* М. Җәлил.

ГАРЕП *и. иск.* Көнбатыш, көнбатыш як. *Йокысын калдырып, ашын, җәмәгатен ташлап, шәрыктан гарепкә, җәнүптән шимальгә чапкан.* Г. Ибраһимов.

ГАРЕШ *и. иск.* Дини ышану буенча алла тәхете урнашкан иң югары кат; күк. [*Вахит*], *кесәсенә тегеп куйган догалыкларын алып, күзләрен гарешкә терәп укый торган иде.* М. Гафури.

Гарше көрси, гарше әгъля *дини* — иң югары, бөек урын, алла тәхете. *И тумыштан гарше әгъзаларга җилкенгән күңел!* Г. Тукай. *Мулла --- күзләрен гарше көрсигә төба күтәрде.* И. Гази.

ГАРИЗА *и.* Нәрсә дә булса сорап язылган үтенеч язуы.— *Син, Халикъ абзый, гаризаңны бик кыска язгансың.* Ш. Камал.

ГАРИЗИ *с. иск. кит.* Очраклы. *Вакытлы вә гаризи булган нәрсәгә игътибар юк, диләр.* Г. Тукай.

ГАРИП I *с.* Бирәр җире имгәнгән, зәгыйфь, эшләү, үсү сәләтен югалткан (күплектә: гораба). *Шундый матур итеп, бәгырьләреңә үткәреп уйный белә торган нечкә бармаклары шулай үк гарип булып калды микәнни?* Г. Бәширов. // Зәгыйфь, хәлсез, көчсез. *Унбишегерме ел шушы чүплек башында [мәдрәсәдә] черегәннән соң --- тормыш көтәргә сәләхиятсез, дөньяга яраксыз, рухи гарип кешеләр булып чыгабыз.* Т. Гыйззәт.

ГАРИП II *и. иск. кит.* Читтән килгән йортсыз-җирсез кеше; юлчы, мосафир (күплектә: гараип). *Гарипләр шәмчырак [үт] күргәндә юлда, Дисеннәр бер заман бар булган ул да.* Дәрдмәнд. // Ярлы, хәерче кеше. *Жан тыныч ланды димә, булганга монда артыгың. Артык ул, алганга намәгълүм гарипләр актыгын.* Г. Тукай. *Халыкның михнәтен аңлаучы, Гарипнең хәсрәтен агъларучы ---— бәхетле бу җиһанда.* «Шура». // *куч.* Мескен, бичара; кызганыч хәлдәге кеше. *Һәркемне иркәләүчеләр табылган кебек, сакал-мыеклар үсә башлагач, без гарипне дә баштан сыйпаучылар табылды.* Һ. Такташ.

ГАРИП III *с. иск. кит.* Сирәк очрый торган, серле; гажәеп. *Җәгъфәр бала вакытларыннан бирле, шөһрәт казанмак, халык арасында гади булмаган, гарип һөнәрләр күрсәтү кебиләрне уйлый иде.* Г. Тукай. *Ерак диңгездә ул кышлар кичергән, Чит илләрдән гарип моңнар китергән.* Дәрдмәнд.

ГАРИП-ГОРАБА *җый. и.* Гарип кешеләр. *Менә бөкрәеп беткән карт-корылар, гарип-горабалар бер-бер артлы тезелешеп комиссия өстәленә таба агыла башладылар.* Г. Әпсәләмов.

ГАРИПЛЕК *и.* Гарип (I) булу, имгәнгәнлек. *Кешеләрне үлем кочагыннан, Гариплектән каерып алып, Сафка бастырасың тагын да* [*врач турында*]. Ф. Кәрим.

ГАРИПЛӘНҮ *ф.* Гарип (I) хәлгә килү; имгәнү. *Бәлки аның куллары бернигә яраксыз булып гарипләнгәндер дә, ул кеше ярдәменә мохтаҗдыр.* Г. Бәширов.

ГАРИПЛӘҮ *ф.* Гарип (I) хәлгә китерү, имгәтү, зәгыйфьләү.

ГАРИФ *и. иск. кит.* Акыл иясе, тирән фикерле кеше. *Бер файдаң: фикер иткән һәр гарифкә Дәлил булдың бу көндәге мәгарифкә.* М. Гафури.

ГАРМО'НИК *с.* Гармониягә нигезләнгән. *Гармоник тирбәнү (муз.). Тоннарның гармоник тезмәсе (муз.). Гармоник үсеш (биол.).*

ГАРМО'НИЯ *и.* 1. Музыкада аһәңлелек, төзек һәм ягымлы яңгырау. *Ничек сыйган аларның күкрәкләренә бу чаклы моң һәм гармония.* Г. Гали. // Билгеле бер авазларның үзара ярашуы, төзек яңгыравы. *Сузыклар гармониясе (лингв.).*

2. Үзара ярашу, туры килү (аерым предмет, күренеш яки сыйфатлар турында). *Характерлар гармониясе. Табигать гармониясе.* □ *Табигать байлыгы белән кеше тормышы арасындагы без омтыла торган гармонияне дә художник дөрес биргән.* Г. Бәширов.

3. Музыка теориясенең бер бүлеге: музыка әсәрләрендә аккордлар төзелешен һәм алар арасындагы бәйләнешне өйрәнә. *Хәбир гармониядән аксый, контрапунктны аңламый, кыскасы, композитор белергә тиешле бик күп нәрсәләрне белеп җиткермәгән булып чыкты.* Ш. Хөсәенов.

ГАРМО'НИЯЛЕ *с.* 1. Аһәңле.

2. Гармониягә буйсынган; үзара ярашкан, төзек. *Аның яшьлек гомеренең чәчәк аткан --- гармонияле чакларына инде унбиш еллап үтеп киткән иде.* Г. Газиз.

ГАРМО'НИЯЛЕЛЕК *и.* Гармонияле булу.

ГАРМО'НИЯЛӘШТЕРҮ *ф. муз.* Көйне гармония кагыйдәләре нигезендә күптавышлы итеп төзү. // Аерым бер көй нигезендә музыкаль әсәр тудыру, шул көйне камилләштерү. [*Композиторлар*] *сәхнә әсәрләрен музыкалаштыру, халык җырларын гармонияләштерү, шагыйрьләрнең текстларына җырлар язу буенча --- эшләп килделәр.* М. Җәлил.

ГАРМО'НИЯЛӘШҮ *ф.* Гармония хасил итү, үзара ярашу.

ГАРМОНЬ *и.* 1. Металл телләр яныннан күрек ярдәмендә өрдерелгән һава агымы үткәндә көй чыгара торган музыка коралы. *Тальян гармонь. Саратов гармоне.* □ *Ерактан сузып-сузып уйнаган гармонь тавышы ишетелә.* А. Әхмәт.

2. *с. сөйл.* Гармонь күрегенең сыры кебек итеп ясалган, гармонь күреге сыман.— *Эни, гармонь итәкле күлмәк тектерик!* Г. Камал.

ГАРМОНЬЛАНДЫРУ *ф. сөйл.* Гармонь күрегенә охшату, параллель сырлар ясау. *Ул --- хром итегенең кунычын гармоньландырып аска сыерган, кунычөстенә чалбар балакларын яртылаш кайтарып салган.* М. Хәсәнов.

ГАРМОНЬЛЫ *с.* 1. Гармонь тоткан, гармоне булган. *Гармоньлы егет.* □ *Менә алар [ике кыз], гармоньлы төркем белән очрашып, читкә тайпылдылар.* С. Баттал. // Гармонь белән башкарыла торган, гармоньга кушылып җырлана торган (жыр). *Сине дәртләндерер гармоньлы җыр бу.* Г. Тукай.

2. *сөйл.* Гармонь күрегенә охшатып тегелгән. *Гармоньлы итәк.*

ГАРМОНЬЧЫ *с.* 1. Гармонь ясау остасы, гармонь ясаучы.

2. Гармоньда уйнаучы, гармоньда оста уйнаучы. *Абыстай да түбән очның гармоньчы Фәхригә ябышып чыга.* Г. Ибраһимов.

ГАРМОНЬЧЫЛЫК *и.* 1. Гармонь ясау һөнәре.

2. Гармоньчы булу, гармоньда оста уйнаучы булу; гармоньда уйнау һөнәре. *Урамнарда ду күчереп йөрдем, Давыл булып, дөнья кубарып, Тирә-якта тиңсез гармоньчылык, Удалойлык даның чыгарып.* Ш. Маннур.

ГАРМУН *и. к.* гармонь.

ГАРНИЗОН *и.* Аерым бер урын, төбәк яки крепостьта билгеле бер вакытка урнашкан хәрби бүлекләр, гаскәр. *Гарнизонда бары картрак казачийларны гына калдырып, «ышанычсыз» яшьрәк составны --- станицаларга җибәрәләр.* Ш. Камал.

ГАРНИР *и. махс.* Ит яки балык белән бирелә торган ашамлык; гадәттә, яшелчә, ярма яки макароннан әзерләнә. *Гарнир янына кыярны телемләп, ә помидорны урталай ярып куялар.* Тат. хал. ашлары.

ГАРНИРЛАУ *ф. махс.* Гарнир салу, гарнир кую. *Бәрәңге белән гарнирланган тавык ите.* // Ашамлыкка төрле тәм керткеч әйберләр салу, аны төрле аш тәмләткечләр, яшелчәләр белән бизәү.

ГАРНИТУР *и.* Бер максатка хезмәт итә торган әйберләрнең (мебель яки киемнәрнең) тулы комплекты. [*Өйдә*] *чиклəвек гарнитур: кием шкафы, сервант, карават, өстәл, тумбочка, көзге һәм креслолар.* Ш. Хөсәенов.

ГАРПИЯ *и. зоол.* Көньяк Америкада яши торган иң зур лачын. // Һиндстанда һәм Малайя архипелагында ярканатның бер төре.

ГАРПУН *и. махс.* Диңгездә яшәүче эре хайваннарны (кит, кашалот һ. б.) аулаганда махсус туп ярдәмендә атыла торган, озын корыч аркан бәйләгән ыргаклы сөнге. *Күпер өстендәге фонарьлар кит тәненә кадалган гарпуннарны хәтерләтә иде.* Каз. утл.

ГАРПУНЧЫ *и. махс.* Гарпун атучы.

ГАРТ *и. полигр.* Типография шрифтлары кою өчен кулланыла торган каты кургаш, аккургаш һәм сөрмә эретмәсе.

ГАРУЗ *и. иск. әд.* Гарәпләрдә шигырь үлчәве һәм шуның турындагы теория. *Татарлар шигырь төзелешен гарәпләрнең гарузыннан күчереп алганнар дигән, электән үк килгән бер караш бар.* Х. Госман.

ГАРЫЗ *и. иск. кит.* 1. Берәр эш яки хәл турында аңлату, белдерү, сөйләп бирү. *Гарзы халь.* М. Гафури. // Зар; үтенеч. [*Хуҗа:*] *Башка ни гарзыгыз бар тагын?* Н. Исәнбәт.

2. Тәкъдим. *Сул кадетларның гарызларын --- мөнһәзәм иттеләр* [*кире кактылар*]. Ф. Әмирхан.

Гарыз итү (кылу, әйләү) — 1) аңлату, белдерү, сөйләп бирү. *Ихтыяҗ, гарыз итеп килсә телəнче капкаңа, Каты сүзләр берлə инсаниятен син таптама.* Г. Тукай.— [*Хəлләребезне*] *гарыз кылыйм дип мөфтигə килүем иде.* Н. Исәнбәт; 2) зарлану, зарын сөйләү. [*Бүре*] *«Тик йөргəндə, Үгез мине кыйнады»,— дип, Аюга гарыз кыйлды.* М. Гафури; 3) тәкъдим итү. *Телəсəгез, бүлмə бирергə мөмкин, дип хезмәт гарыз кылды.* Г. Ибраһимов. *Аннан соң ул боларның һәр икесенə атлас тартмалардан конфетлар гарыз итте.* Ф. Әмирхан.

ГАРЫК: гарык булганчы — 1) туйганчы.— *Яхшы тәрбияля, сөтне жəлләмə, гарык булганчы эчсеннəр.* Э. Еники; 2) чамадан тыш күп, кирәгеннән артык.— *Әйе, мин күз буяучы да, алдакчы да, гарык булганчы аракы күлендə йөзүче дə.* С. Рафиков. **Гарык булу** — 1) бату, чуму (суга); суга батып үлү. *Авызыңа-борыныңа су тулып, шунда гарык булырсың.* Шомбай әкияте; 2) күмелү, каплану. *Кайберләре Казанның комга гарык булырга тора торган Устьесын яңадан бер кат әйләнеп килергə чыгып китə.* Ф. Әмирхан; 3) *күч.* хисләрдән күңел тулып, ташып тору. *Мин дə мəхəббəткə гарык... Сөямен халкым сине.* С. Баттал; 4) тук, җитәрлек булу.— *Минем өйгə барсаң, майга, иткə гарык булырсың, симерерсең!* Г. Тукай. **Гарык итү (кылу)** — батыру. *Бөтен кешеләрне, җанварларны суга гарык итеп үтергəн.* М. Гафури.

ГАРЫС *и.* 1. Чигү яки бәйләү өчен махсус катып эзерләнгән йомшак йон җепнең бер төре. *Гашыкабану --- кыйммәтле гарыс җебе белəн үзе чиккəн поднос яулыгына төрелеп саклана торган хатлар төргəген --- картына бирде.* Ф. Хөсни. // Шундый җептән эшләнгән тукыма. *Гарыс шарф.*

2. Йонга охшаш киҗе-мамык тукыма. *Җаныемның шарыфы киҗе-мамык гарысы.* Җыр.

ГАРЫСЛАУ *ф.* Гарыс кушу, гарыс белән сугу. *Моңа түбəндəгe нəрсəлəр керə* [*сүз урта хəлле кешенең кызы турында бара*]: *кунак өен бизəр өчен киң кылычта гарыслап суккан озын кашага, чүпләм сөлгеләр...* С. Сүнчәләй.

ГАРЬ *и.* 1. Оят, хурлык, мәсхәрәлек. *Надан булу гарь, татар.* Г. Тукай.

2. Гарьләнә белү хисе, горурлык, әдәп, намус. *Кызның намусы бар, гаре бар.* Н. Исәнбәт.

ГАРЬЛЕ *с.* Хурланучан, гарьләнә белүчән. *Ярлы башым — гарьле башым.* Әйтем.

ГАРЬЛЕК *и.* 1. Оят, хурлык. *Кызым китте, мин дə шул гарьлектəн--- аптекага киттем агуга.* М. Җәлил.

2. Кемгә яки нәрсәгә карата гаделсезлек, нахакка рәнҗетү аркасында туган ризасызлык хисе, хәтер калу, үпкәләү. *Нахак килеш кəҗəдəн колак кагу гарьлеге аны ярсыта.* Ш. Камал.

ГАРЬЛӘНДЕРҮ *ф.* Гарьлек хисе тудыру, намусына тию. *Үзеңнəн яшь кешегə зарыңны сөйлəргə бару бераз гарьлəндерə кебек.* Ә. Еники.

ГАРЬЛӘНҮ *ф.* 1. Оялу, уңайсызлану, оят санау. *Алар минем өчен кызарып, гарьләнеп йөриләр бугай.* Г. Ибраһимов.

2. Хурлану, гарьлек санау. *Бу кушаматка ул бик каты гарьлəнə.* М. Әмир. // Үпкәләү. [*Солтан*] *шундый гарьлəнгəн, хəтта туган авылына əйлəнеп тə карамады.* Г. Бәширов.

ГАРЬСЕНҮ *ф. к.* гарьләнү (1 *мәгъ.*). [*Фәрит:*] *Бездə эштəн гарьсенмиләр. Бездə эш белəн макталалар һəм хөрмəтлəнəләр.* Ә. Фәйзи.

ГАРЬЧЕЛ *с.* Тиз гарьләнә торган, юкка да гарьләнү гадәте булган.— *Әтисе бик кызу, бик гарьчел кеше, кайгысыннан бүген чəй дə эчмəде.* М. Гафури.

ГАРЬЧЕЛЛЕК *и.* Гарьчел булу. *Өйрəнчекләр арасында күбесе бала-чага булуы Фәрдәнәне башта бераз гарьләндергән иде дə, узды. Шул үк гарьчеллеге үзе ярдəм итте.* М. Әмир.

ГАРЬЧӘН *с. к.* гарьчел.— *Бик гарьчəн кеше мин, бик хурланучан мин.* Ф. Әмирхан.

ГАРӘБИ *с. иск. кит.* Гарәпчә; гарәп теленә караган. *Аңлашылуы җиңел --- гарəби сүзләр дə аз гына булырга ярый.* Г. Ибраһимов.

ГАРӘБИЯТ *и. иск. кит.* Гарәп телен, гарәпчәне белү. *Әллə аның гарəбияте Мусадан кимме?!* Г. Тукай. // Гарәп филологиясе (әдәбияты һәм теле). [*Гали хəзрəт мəдрəсəлəрдə*] *хəдис, гарəбият өстенə табигать, татар теле, рус теле дəреслəрен арттырды.* Г. Ибраһимов.

ГАРӘП *и.* Алгы Азия һәм Төньяк Африкада яшәүче, семит телләреннең берсендә сөйләшүче халыкның гомуми атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. [*Ярминкәдə*] *французлардан, немецлардан, төрекләрдəн, гарəплəрдəн, əлхасил, һəр милләттəн адəмнəр бардыр.* Ш. Мөхәммәдев. // *с. мәгъ.* Гарәп халкына караган,

шул халыкка мөнәсәбәтле. *Гарәп теле. Гарәп культурасы.*

Гарәп аты — йөгерек атлардан иң яхшы токымлы атларның берсе. **Гарәп графикасы (язуы, шрифты)** — татарларга мөселман дине белән кереп, латин графикасына кадәр яшәгән графика, язу системасы. *Әгәр сиңа авыр булмаса, минем папкаларымны һәм күлъязма дәфтәремне (гарәп шрифты белән язылган күлъязмаларымны) алып кил.* М. Җәлил. **Гарәп цифрлары** — урта гасырларда гарәпләрдән алынып, киң таралган, хәзер дә күпчелек халыкларда кулланышта булган цифрлар, сан тамгалары. **Гарәп ясмине** *бот.*— ак, хуш исле катмар яки гади чәчәк ата торган мәңге яшел куак, зур гөл. Чәчәк атуның азагында чәчәкләренә кызгылт төс керә. **Гарәп әкиятләре** — «Мең дә бер кичә» җыентыгына кергән әкиятләр.

ГАРӘПЧЕ *и.* 1. Гарәп теле, гарәп культурасы белгече, гарәп теле һәм культурасын өйрәнүче, шул фән белән шөгыльләнүче.

2. Егерменче гасырның 20 нче елларында, татарларга латин графикасын кертүгә каршы чыгып, гарәп графикасын калдыруны яклаучы

ГАРӘПЧЕЛЕК *и.* Гарәпче (2 *мәгъ.*) булу.

ГАРӘПЧӘ *рәв.* Гарәп телендә. *Саңгырау хәрефләр гарәпчәдә булмаганга күрә үзгәртелмәде.* Г. Тукай. // *и. мәгъ.* Гарәп теле. *Насыйри гарәпчә вә русча яхшы белгән.* Ф. Әмирхан. / *с. мәгъ. Ярым гарәпчә, ярым истамбулча сүзләр белән бутап, Гайфулла киңәш бирә.* Г. Ибраһимов.

ГАРӘФӘ *и. иск.* Гает алды көне. *Мин гарәфә көнне әнигә кеше аркылы бүләкләр җибәргән идем.* Г. Тукай. // *күч.* Гомумән нәрсәнең дә булса алды. [*Шәрәфетдин:*] *Кияүлекнең гарәфәсендә генә әле ул.* М. Фәйзи.

ГАСАБ *и. иск. кит.* Нерв.

ГАСАБИ *с. кит.* Нервлы; борчулы. *Гасаби калтырану Шакирны бер скамьяга ташланырга мәҗбүр итте.* Ф. Әмирхан.

ГАСАБИЛАНУ *ф. кит.* Нервлану; ярсу, кызып китү. *Ул гасабиланып кулыннан чүлмәкне төшереп җибәрә.* Һ. Такташ.

ГАСАБИЛАШТЫРУ *ф. кит.* Нервландыру, ярсыту; борчу. *Яшьләрнең бу эшкә илтифат итмичә уйнап-көлеп йөрүләре — һәммәсе аны борчый, гасабилаштыра иде.* Ш. Камал.

ГАСАБИЛЫ *с. кит.* Нервлы, нерв авырулы; ярсучан. *Артык гасабилы булуына* [*Золотухин*] *үзе дә үкенә иде.* Г. Ахунов.

ГАСАБИЛЫК *и. кит.* Нервлар киреңке хәлдә булу, нервлар ярсыган булу; ник борчылу. *Кызның гасабилык күрсәтә торган йөзе, --- матур авызы Галигә таныш шикелле иде.* Ф. Әмирхан.

ГАСАБИ'ЧА *рәв. кит.* Борчылган хәлдә, ярсыган кешеләр кебек. *Ул, гасабича атлап, яныма җитүгә, --- кире чигендем.* Г. Ибраһимов.

ГАСКӘР *и.* Дәүләтнең кораллы көчләре, армия. *Фронтта безнең гаскәрларнең контрһөҗүме дәвам итә иде.* Г. Әпсәләмов. // Кораллы көчләрнең аерым бер төре, бүлеге. *Атлы гаскәр. Җәяүле гаскәр. Чик буе гаскәрләре.* // *күч.* Нинди дә булса бер мөһим эшне башкаруга тупланган төркем. *Гөлзәбәр --- аңа бөтен «гаскәрен» санап күрсәтте: — Гаскәремме? Үндүрт комсомолым бар минем — бу бер. Алар янына бөтен авыл яшьләре, бу булды ике.* Г. Бәширов.

ГАСКӘРИ *с.* Гаскәргә мөнәсәбәтле. *Фетнәне басарга чыккан гаскәри бүлек тиздән килеп җитәргә тиеш иде.* Г. Ибраһимов. *Гаскәри мулла Гайфетдин әфәнде Ижбулдин гүзәл мәкам белән җомга намазын укытты.* Қ. Нәҗми. // *Хәрби. Бу гаскәри киемне кию белән син әле, Алмас, кызылармеец булдың дигән сүз түгел.* А. Әхмәт. // *и. мәгъ.* Хәрби хезмәткәр. *Революциянең --- көчле дулкыннары гаскәриләрнең йөрәкләренә бәреп керде.* М. Гафури.

ГАСКӘРИЛӘ'РЧӘ *рәв.* Хәрбиләрчә, хәрби кешеләргә хас рәвештә. *Барысы да ишек төбендә гаскәриләрчә төз басып торучы әкбәревкә карадылар.* А. Әхмәт.

ГАСКӘРЛЕК 1. *с.* Гаскәр өчен; гаскәргә җитәрлек.

2. *и. иск.* Гаскәри булу, гаскәри хезмәттә булу. *Ул, иске гадәтенчә, ике мәртәбә зур акча белән гаскәрлектән котыла.* Г. Ибраһимов. *Ислам голәмасыннан, ягъни, запасной солдат имам булса, гаскәрлеккә алмаска.* Ш. Мөхәммәдев.

ГАСТРИТ *и. мед.* Ашказанындагы лайлалы катлауның ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. [*Мамайкин:*] *Ну, аңарда хроник гастрит.* Ә. Фәйзи.

ГАСТРОЛЁР *и.* 1. Гастрольгә килгән артист.

2. *күч. сөйл.* Очраклы рәвештә генә урнашкан, вакытлыча гына эшли торган кеше яки пассив күзәтүче булып кына килгән кеше.— *Мин сезгә гастролер булып килүче түгел.* А. Расих.

ГАСТРОЛЁРЛЫК *и.* Гастрольдә йөрү, гастролёр булу. [*Янудин Атласовка:*] *Ә сез ни өчен анда? Гастролёрлык итү өченме?* С. Рафиков.

ГАСТРОЛЬ *и.* Читтән килгән артистларның яки театр труппасының чыгышлары. *Менә без труппа белән гастрольгә йөргән вакытта Бохарага --- барган идек.* Ш. Камал.

ГАСТРОЛЬЛЕК *и.* Гастрольгә чыгу, гастрольдә йөрү. *Гастрольлек итү. Гастрольлек эше.*

ГАСТРОНОМ *и.* 1. Ашамлыкларга карата нечкә зәвыклы кеше.

2. Гастрономия (2 *мәгъ.*) товарлары сату кибете. [*Кыз*] *Казан гастрономнарында сату сатамыни?* Н. Фәттах.

ГАСТРОНО'МИЯ *и.* 1. Ашамлык әйберләре әзерләүдә зур осталык, нечкә зәвыклылык.

2. Югары сыйфатлы итеп әзерләнгән азык товарларының гомуми атамасы. [*Хафиз:*] *Гыйлемдар алып кайткан гастрономия әйберләрен сүтеп, кич сәгать 7 гә өстәл хәзерләп куегыз!* Ә. Фәйзи.

ГАСТРОПТОЗ *и. мед.* Артык ябыгудан корсак мускуллары зәгыйфьләнү нәтиҗәсендә ашказаны төшү авыруы.

ГАСТРОСКОП *и. мед.* Ашказаны авыруларына дөрес диагноз кую өчен авыздан ашказанына төшерелә торган инструмент.

ГАСТРОСКОПИЯ *и. мед.* Гастроскоп ярдәмендә ашказанын **тикшерү.**

ГАСЫЙ *и. иск.* Алладан баш тарткан, диннән язган; бунтарь; *к.* гыйсъянчы. *Гасый булган Иблистән дә яман күреп, бичарага таш атабыз.* М. Гафури. // Алла каршында гөнаһлы.— *Мин гасый бәндәңне ярлыка, бер ходам!* А. Шамов. *Беләсеңдер: бар да тигез булмый Җир йөзендә гасый бәндәләр.* М. Җәлил.

ГАСЫР *и.* Йөз елны эченә алган вакыт, йөз. *Хатын доктор XX гасыр татар хатыннарын үзе күреп белә иде.* Ф. Әмирхан. // Берәр нәрсә белән характерлы булган чор, билгеле бер вакыт арасы. *Кан түгеш, коллык, золым гасры үтә!* С. Сүнчәләй.

ГАСЫРЛА'РЧА *рәв.* Берничә гасыр буена; озак елар буена. *Гасырларча миллиард йөрәкләрне чертеп **килгән диннәр төрмәсен** яндырабыз! Тупка тотабыз!* Һ. Такташ.

ГАСЫРЛЫК *с.* Гасырны эченә алган, гасыр дәвамына сузылган. *Казан яшь-җилбәзәкләренең дүрт-биш гасырлык тарихи гадәтләре буенча, быел да үткән сишәмбедән бирле һәр көнне көндезге сәхәр җыелышлары була башлаган иде.* Ф. Әмирхан.

ГАСЫРЧЫЛЫК *и.* Билгеле бер гасырга, чорга хас булган күренеш, гадәт. *Урта гасырчылыкка каршы көрәш.*

ГАТАЛӘТ *и. иск. кит.* Ялкаулык. *Гомер итмәк — тырышмактыр, ялыкмый, һич тә ял итми, Гаталәт хурлыгын асла үзеңә ихтыяр итми.* Г. Тукай.

ГАТЫРША *и. иск.* Ислемай, хушбуй. *Миргалинең кесәсендә бадъян белән гатырша.* Бәет.

Гатырша гөле — *к.* исле гөл. *Гатырша гөленең дә исләре борынга килеп бәрелде.* Г. Газиз.

ГАТЬ *и.* Сазлык җирләрдә бүрәнәләр яки чыбык-чабык түшәп эшләнгән күпер-юл. *Гать җаю.* □ *Сазлыкка агач түшәп ясалган гать иде бу.* Каз. утл.

ГАҖУБИЦА *и. хәрби.* Җир өстендәге объектларга текә траектория белән ата торган, көпшәсе пушканыкыннан кыскарак артиллерия коралы. *Уррра, дуслар! Безнең гаубицадан Күтәрелде һөҗүм кояшы.* Ә. Юныс.

ГАУВАС *и. иск. кит.* Су төбенә оста чумучы, водолаз. *Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гауваслары.* Г. Тукай.

ГАУВАСЛЫҚ *и. иск. кит.* Водолаз булу, су төбенә чуму эше. *Болар, уйлары буенча, гауваслык (диңгезгә чуммак) гыйлеменә бик яхшы үгрәнеп һәр өчесе диңгезгә чума башладылар.* **Г. Тукай.**

ГАУГА *и.* Ыгы-зыгы, шау-шу, аңлаешсыз тавышлар, тәртипсез кычкырулар. *Мәдрәсә эче тагы тавыш, гауга белән тулы.* М. Гафури. // Даулаш, нәрсәне дә булса даулап кычкырышу; җәнҗәл. *Ике якның берсе, яу булып килеп, авылны басар, кызны яңадан алып китәргә гауга чыгарыр дип көтәләр иде.* Г. Ибраһимов.

Гауга барабаны *иск.* — тревога күтәрү, халыкны аякка бастыру, җыю өчен кулланыла торган барабан. *[Гыймай команда бирә:] Каравыл башы! Анда эленгән барабан тора. Ор, бәр, гауга барабанын!* Н. Исәнбәт.

ГАУГАЛАНУ *ф.* Гауга, җәнҗәл күтәрү, кычкырышу. *Чит кешеләрдә яшәп ятканда, гауганаһып, кашыккаяк шалтыраткан минутлар да булмады түгел.* **А. Гыйләҗев.**

ГАУГАЛАУ *ф.* Даулашу, дәгъва итү, нәрсә дә булса таләп итеп җәнҗәл куптару. *Балалар кычкырышакычкырыша --- нидер гаугалыйлар.* **Р. Батуллин.**

ГАУГАЛЫ *с.* Тавышлы, шау-шулы; җәнҗәллы. *Жыелыш бик зур гаугалы булды. Җәмгыять һәр ике мәдрәсәдән чыккан шәкертләрнең таләпләрен хаклы тапты.* Г. Ибраһимов.

ГАУГАЧАН *с.* Тавышланучан, кычкырышларны ярата торган, дәгъвачыл. *Искиткеч гаугачан малай Фәрит!* Г. Ахунов.

ГАУГАЧЫ *с.* Җәнҗәлчы. *Гаугачыга гел камчы.* Мәкаль.

ГАУГАЧЫЛ *к.* гаугачан.— *Менә бусы --- чая, гаугачыл һәм оят дигән нәрсә белән дә бик үк санашмый торган Кәүсәрия.* Каз. утл.

ГАУГАЧЫЛЛЫҚ *и.* Гаугачыл булу.

ГАУПТВАҺТА *и.* Гаепле хәрби кешеләрне ябып куя торган урын. *Ефимовның шул китап өчен генә гауптвахтага ябылуы берәм-берәм* [*Вахитның*] *күңеленнән кичте.* М. Гафури.

ГАУРӘТ *и. иск.* 1. Оят җир; женси орган. // Хатын-кыз тәненең шәригать буенча ирләрдән яшерергә тиешле урыннары.— *Сезнең муеннарыгыз, чәчләрегез, бигрәк тә колакларыгыз һәммәсе гаурәт була.* Ф. Әмирхан. // Гомумән хатын-кыз. *Әхмәтҗан абзый бәндә ләбаса: ихтимал, ул чит гаурәт йөзенә бакканды.* Г. Газиз.

2. *күч.* Мәгълүм булмаган, яшерен нәрсә; мәсьәләнең караңгы ягы. *Безгә татарның феодализм чорындагы әдәби-гыйльми эшләре, буржуазия мәйдан алгач туган яңалыклары һәммәсе үзләренең сыйнфый гаурәтләре белән ачыла барыр.* Г. Ибраһимов.

ГАФИЛ 1. *с.* Ваемсыз; гамьсез; саксыз; игътибарсыз; пассив (кеше).— *Һай, һай, аңламыйбыз шул без гафил адәмнәр.* Ә. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* Кайгыртусыз, берни белән дә кызыксынмыйча, гамьсез рәвештә. [*Безгә*] *искечә, йоклап, гафил ятарга ярамый, үз чарабызны үзебез кайгырту тиеш буладыр.* **Ш. Мөхәммәдев.**

2. *рәв.* Белмичә, хәбәрсез. *Гафил калу.* □ *Гафил булмагыз, кунак килеп җитте.* Г. Гобәй. // *хәб. функ.* Хәбәрсез булу, белмәү.— *Адәм баласы ул эшләрдән гафил, энекәем.* Ш. Камал.

ГАФИЛЛЕК *и.* Гафил булу. *Бичаралар шул гафиллекләре илә --- җан бирделәр.* Г. Тукай.

ГАФИФ *с. иск. кит.* Гыйффәтле, намуслы, саф. — *Әйт, гафиф кыз! Нигә миңа килгән идең?* Һ. Такташ.

ГАФИФАНӘ *рәв. иск. кит.* Саф, эчкерсез рәвештә. *Исемдә --- гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар.* Г. Тукай.

ГАФЛӘТ *и. иск. кит.* 1. Гафил булу; игътибарсызлык, ваемсызлык. *Сандугачлар гафләт илә утырганда, карчыга тотар өчен салды тырнак.* М. Гафури.

2. Наданлык, аңсызлык. *И авыл, син бик матурсың, зур шәһәрдән башкасың, Аһ, тәэссеф шунсы, син бит йоклыйсың, гафләттәсең.* Н. Исәнбәт.

ГАФУ *и.* Гаепне кичерү, начарлыкны җәзасыз калдыру. *Әмма рәнҗеш, гафу алай тышкы нәрсәләр түгел, болар җан әйберләре.* Г. Ибраһимов. *Хәлим гафу үтенде һәм үзенең колакларына кадәр кызарганын тойды.* А. Шамов.

Гафу итү (кылу) — 1) кичерү; гаебен җәзасыз калдыру.— *Хәмдиягә әйт, атакаең сине гафу итә, диген.* М. Фәйзи; 2) *кер. сүз.* **гафу ит (-егез, -әсез)** — борчыган һ. б. ш. өчен гафу сораганда яки әңгәмәдәш фикере белән килешмәгән очракларда кулланыла. [*Нәсимә:*] *Гафу итегез, Кәримов абый, аңламаган кешегә кайвакыт кабатламый да булмый икән.* А. Әхмәт. *Туган апагыз белән аңлаша алмау, гафу итегез, бу егетлек түгел.* Р. Ишморат.

ГАФУР *и. иск. кит.* Гафу итүче.— *Аллаһе тәгалә гафур рәхим, гөнаһлы бәндәсен ярлыкаса кирәк.* Ш. Камал.

ГАФФАР *и. иск. кит. к.* гафур. *Әле гаффар булып, әле каһһар... Холыкландым тәңрем холкыдай.* Ш. Бабич.

ГАШЕҢТА, ГАШЕҢТКА *и.* Ату коралында корылган курокны ычкындырып җибәрә торган ыргак. *Аэродром өстеннән очып үткәндә, бөтен гашеткаларга басып, пулеметлардан атып салют бирдем.* С. Баттал.

ГАШИР *и. иск.* Гошер алучы. *Яз, ни язсаң да, синең бар язганыңның нашире, Ашлыгың үстисә, бир, тайярдыр [әзер] аның гашире.* Г. Тукай.

ГАШИШ *и.* Һинд киндере сумаласыннан алына торган наркотик матдә.

ГАШЫЙК *и.* Мәхәббәт, сөю хисе белән янучы; кемне (яки нәрсәне) дә булса сөюче, яратучы. *Хәр йөрәкле Гейне гашыйгына хуҗаң тимер богау кигезде.* М. Җәлил.

Гашыйк булу — мәхәббәт төшү, ярата, сөя башлау.— *Мин, әллә тагын безнең Нәгыймәгә берәр бай улы гашыйк булып хат җибәрде микән, дип торам.* Г. Камал. **Гашыйк итү** — яраттыру. *Мин сәламәт, көчле, шул килеш тә бик күпләрне гашыйк итәрлек.* Һ. Такташ. *Һәр урында яңа бер күренеш Гашыйк итә мине үзенә.* З. Мансур.

ГАШЫЙҚЛЫК *и.* Гашыйк булу, ярату, сөю (хисе). *Аның [Власовның] үз-үзенә гашыйклыгы тәмам башын әйләндерде.* Ш. Маннур.

ГАШЫЙҚ-МӘГЪШУҚ *җый. и.* Бер-берсен яратучылар, бер-берсенә гашыйк булган кешеләр. *Минем эшем шул инде: дәртле күңелләргә дәрман табу, бу гашыйк-мәгъшукларны кавыштыру.* Ш. Камал.

ГАШҮРӘ: гашүрә көн, гашүрә бәйрәме — мөселман ел исәбе буенча камәр (ай) календаренда мөхәррәм аеның унынчы көнендә уздырыла торган дини бәйрәм. *Шул көннәрдә ниндидер мәүлетме, гашүрәме бәйрәме*

килеп җиткән икән. Ш. Маннур. *Гашүрә көн байлар бәйрәм итә, безгә бәйрәм көннәр бар микән?* Бәет.

ГАЯ *и. иск. кит.* 1. Чик, ахыргы нокта; ахыры, соңы. *Һәрбер нәрсәнең гаясе бардыр.* Қ. Насыйри. // Нәрсәдән дә булса көтелгән нәтиҗә. *Боларның [ярлыларның] максутларының гаясе шушы салкында эш табып, 20—30 тиен акча алып кайтмак.* М. Гафури. // Чиклелек, чикләнгәнлек. *Милләткә вагаерга, милли гаяләрдән ераклашырга ирек бирмәү Сенкевич хиссасына төште.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Максат, теләк. *Әмма ник үлдең --- мөкатдәс гаяләргә җитмичә.* С. Сүнчәләй. *Шул тарихи зәмендә бер әдәбият туа. Узенә күрә мәсьәләләре, әмәл һәм гаяләре мәйдан ала.* Г. Ибраһимов.

ГАЯН *с. иск.* Ачык; билгеле; мәгълүм. *Сүз рәте килгәч, итәм азрак бәян, Таки яшерен күл төбе булсын гаян.* Г. Тукай.

Гаян итү (кылу) — ачу, ачып салу, күрсәтү; белдерү. *Қаләм! Қальбеңдә ни сер бар, гаян ит!* Дәрдмәнд. [*Егет:*] *И хәким философ! Бу эшнең асылын бәян һәм бу хыялның фаслын [төп серен] гаян кыл!* Қ. Насыйри.

ГАЯРЬ *с.* Гайрәтле, батыр.— *Бу Қузьмич дигәннәре бик гаярь кеше булды бит, әкият.* Т. Гыйззәт. *Моратай исә заманында бик гаярь, бик дан кеше булган имеш, дигән риваять йөри.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Батырларча, гайрәт белән. *Сугышканнар алар шулай гаярь, Күп калалар, җирләр алганнар.* Ш. Маннур.

ГАЯРЬЛЕК *и.* Гайрәтле, батыр булу.

ГАЯРЬЛӘНҮ *ф.* Гайрәтләнү, батыраю. *Сугыш вакытында башын исәрлеккә салып йөргән кеше [Давыт] еллар үткән саен гаярьләнә бара.* А. Гыйләҗев.

ГАЯТЬ *кис.* Бик, артык, үтә. [*Илкә батыр*] *йозаклангән гаять зур бер ишек янына барып җитте.* М. Гафури. *Қеше белән мөгамәләсе гаять яхшы.* Ш. Қамал.

ГАҖАИП *и. иск. кит.* Гажәп хәл, искитәрлек, кызык хәл; сәер хәл. *Агып, күздән югалып, була гаип, гажәп, кая китә соң бу, гажаип?* Г. Тукай. // *күпл.* **гажаибат.** Гажәп хәлләр. *Башы кызып, хыялында теге төштә күргән гажаибаты, томан эчендәге гәүдәләр шикелле, буталып йөзәләр.* Г. Ибраһимов.

ГАҖӘЗ *и. иск. кит.* Гаҗизлек; көчсезлек. *Мәзкүр шагыйрьләр үз гаҗезләрен икърар итеп, --- каләмнәрен чүплеккә ташларлар иде.* Г. Тукай.

ГАҖИЗ *с.* 1. Аптырап калган, аптыраулы; кыен хәлдә калган. *Гаҗиз башым. / хәб. функ. Ул социаль проблемаларны чишүдән гаҗиз.* Г. Нигъмәти.

2. Көчсез; хәлсез; зәгыйфь. *Без кичә яр буйларыннан көчкә-көчкә атлаган, Бер ташыңны кузгатырлык кулда дәрман тапмаган Бер гаҗиз җир корты булсак, Күр менә: без бүген килдек җыйнау...* Н. Исәнбәт. / *и. мәгъ.* [*Аны*] *фәкыйрьләргә, гаҗизләргә ярдәмле дип хыял кылсалар, [хата] булыр.* Ш. Мөхәммәдев.

Гаҗиз булу (калу) — аптырау, аптырашта калу, ни эшләргә белмәү. *Гаҗиз булдым, эчем, тышым туңганга мин.* Г. Тукай. *Әтәчкә җавап тапмый гаҗиз калды сандугач.* М. Гафури. **Гаҗиз итү** — аптырату, аптыраштa, кыен хәлдә калдыру. [*Хатын*] *минем, ди, монда, ди, урак урып, салам көлтәләп, мичкә салам ягып йөрер хәлем юк, әйдә киттек калага,— ди, гаҗиз итә бит.* М. Гали.

ГАҖИЗАНӘ *рәв. иск. кит.* Аптыраулы хәлдә, гаҗиз булып. // *с. мәгъ.* Түбәнчелекле. *Гаҗизанә шагыйрең булмакка бардыр ниятем.* Г. Тукай.

ГАҖИЗЛЕК *и.* 1. Аптыраганлык, гаҗиз, аптыраган булу. *Һәркемнең күзендә, тирән кайгы белән бергә, бу эш алдында гаҗизлек галәмәте күренә.* М. Гафури.

2. Көчсезлек, зәгыйфьлек. *Күңел вә каләм ягыннан гаҗизлекләре сәбәпле, --- кулга алырлык бераз әсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме?* **Г. Тукай.**

ГАҖӘЕП *с.* 1. Искиткеч (яхшы, матур), сокланырлык. *Айга каршы ялтырап яткан елгалар, ул гаҗәеп йолдызлар һәммәсе бергә кушылып җырлыйлар.* Ш. Қамал. *Гөлзәбәр секретарьның --- гаҗәеп бер эчкерсезлек белән балкып тора торган ачык зәңгәр күзләренә хөрмәт белән карый.* Г. Бәширов.

2. Сәер; кызыклы. *Беркөнне [Дәүләтшинның] башына гаҗәеп бер фикер килә.* И. Гази.— *Бик гаҗәеп рәсем бу.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Искиткеч. *Төрле кошлар сайрашып, атауның бөтен тирәсен гаҗәеп матур бер музыка белән яңгырататалар иде.* Г. Ибраһимов.

ГАҖӘЕПЛЕК *и.* Гаҗәеп, сокланырлык булу; искиткеч яхшы булу. *Ф. Халиди зурлыкта вә гаҗәеплектә әллә ничә «Әбүгалисина» кадәр булган «Әлфе Ләйлә вә Ләйлә»не тәрҗемә иткән.* Ж. Вәлиди.

ГАҖӘП *с.* 1. Аптырарлык, аптырашта калдырырлык. *Гаҗәп хәл: бер кул яңа гына терсәктән түбән киселгән, канаган.* Г. Гали. *Гаҗәп сезнең халык! Бигрәк канәгатьсез вә бик консыз.* М. Гафури. // *и. мәгъ.* Искиткеч, аптырашта калырлык хәл. *Тугызынчы елда бер гаҗәп булгай: наданнарны мөфти ахун итеп куйгай.* Г. Қамал. // *күпл.* **гаҗәбә.** Гажәплә нерлек, искитәрлек хәлләр. *Гаҗәбә, мәҗүс замандагы җырлар, бөтенләй онытылып бетте микәнни?* Г. Тукай.

2. *к.* гаҗәеп. *Туры килдек гаҗәп бер чорга без, Туры килдек гаҗәп елларга.* Ә. Исхак. *Берсеннән-берсе гаҗәбрәк хәбәрләр явып тора башлады.* И. Гази. *Моңарчы талашудан бушамаган ике кыз гаҗәп тиз дуслашып китәләр.* Г. Ибраһимов.

Гаҗәпкә калу — гажәпләнү, хәйран калу. *Махночылар, көтелмәгән бу кыюлыктан гаҗәпкә калып, кинәт туктадылар.* Г. Бәширов. **Гаҗәпкә каршы** *кер. сүз* — һич көтмәгәндә, уйламаганда. *Аязгулов, Гаязны калдырып, миңа борылды һәм, гаҗәпкә каршы, турыдан-туры исемем белән дәште.* М. Әмир.

ГАҖӘПЛЕ *с. сир. к.* гаҗәп (1 *мәгъ.*). *Ул гаҗәпле мәсьәләне уйлый-уйлый баш арып, Калды ул инде тынычлыкка вә рәхәткә талып.* Г. Тукай. *«Сәмруг кош» искиткеч гаҗәпле бернәрсә булса да, аның тышкы күренеше простой гына шәкелдә иде.* Ш. Қамал.

ГАҖӘПЛӘНДЕРҮ *ф.* 1. Гажәп бернәрсә булуы белән хәйран калдыру яки кызыксыну уяту. *Бу урам мине гаҗәпләндерә дә, куркыта да иде.* Г. Тукай.

2. Аптырашта калдыру. *Аны теге мәдрәсә белән бу мәдрәсә арасында әллә ни юклыгы гаҗәпләндерде.* Ә. Фәйзи.

ГАҖӘПЛӘНҮ *ф.* 1. Ис китү, шаккату; хәйран калу. *Шулкадәр җитезлегенә, кайчагында бер үк көндә аның берничә урынга өлгерүенә гаҗәпләнәләр иде.* А. Шамов.

2. Аптырау, аптырап калу. *Нәфисә бу сүзләргә бик гаҗәпләнеп һәм рәнҗеп, Сәйфинең күзләренә карады.* Г. Бәширов.

ГАҖӘПСЕНҮ *ф.* Гажәпләнү; гажәп санау. *Тик ул һаман шуңа гаҗәпсенә: «Тапкан малым кая китә?»* — *ди.* М. Гафури.

ГАҢ *аваз ияр.* Қаз яки башка кошларның көр аваз белән (бигрәк тә яз һәм көз) кычкыру тавышын белдерә. *Озын муенлы ак ата каз гына башын югары күтәреп, «гаң-гаң» дип сөйләнә-сөйләнә, ашамыйча басып тора.* И. Гази.

Гаң итү — *к.* гаңгылдау. *Аккош китә гаң итеп, Исәнләшеп, моң итеп.* М. Укмасый.

ГАҢГЫЛДАУ *ф.* Гаң-гаң килү, гайгылдау.

ГАҢГЫЛДАШУ *ф. к.* гайгылдашу. *Николайдан өркеп, казлар як-якка сибелделәр дә гаңгылдашып калдылар.* **И. Гази.**

ГАҢГЫЛДЫК *с.* Сөйләгәндә гаңгылдап чыккан ин түбән тавыш турында әйтелә. *Гаңгылдык тавыш белән сөйләү.*

ГАһЕТ *и. иск. кит.* Ант. *Шул минуттан башлап «һич кешене сөймәм» дигән гаһетем бозылды.* М. Гафури. // Килешү, вәгъдә; ант белән беркетелгән вәгъдә. *Гыйшык шул көннән соңгы ике ел эчендә Шакир белән Әсманың һәр икесе өчен бер-берсенә бирелгән мөкатдәс бер гаһет шикелле булып дәвам иткән иде.* Ф. Әмирхан.

ГВАРДЕ'ЕЦ *и. сөйл. к.* гвардияче. *Коткардылар безнең гвардеецлар зур авылны немец кулыннан.* Ш. Маннур.

ГВАРДИН *и. сөйл. к.* гвардияче. [*Ящик*] *акларга каршы киткән кызыл гвардиннарның арбасыннан төшеп калгандыр.* К. Нәҗми. / *күч.* Сугышның иң кыен вакытында безнең колхозда гвардиннар бригадасы туды. Г. Бәширов.

ГВАРДИННА'РЧА *рәв.* Гвардиячеләр кебек. [*Бюро*] *Нәфисә бригадасының фронттагы гвардиннарча көрәшүләре өчен шушы кызыл байракны тапшырырга карар итте.* Г. Бәширов.

ГВА'РДИЯ *и.* Сугышта зур батырлык күрсәткән, иң алдынгы хәрби частьлар. *Бу участокны башта рота командиры гвардия өлкән лейтенанты Камалов таныды.* А. Шамов. // *күч.* Нинди дә булса өлкәдә зур сынау үтеп танылган эшлеклеләр, үз эшләренә бирелгән көрәшчеләр. *Мансуров --- кыйммәтле асылташ кебек берәмлекләп җыйган талантлы яшьләр гвардиясенә тагын бер солдат табылуына чын күңелдән куанды.* Г. Бәширов.

ГВА'РДИЯЧЕ *и.* Гвардия хәрби хезмәткәре. / *с. мәгъ.* Гвардиягә мөнәсәбәтле. *Гвардияче солдат.*

ГВАЮ'ЛА *и. бот.* Сары оешма чәчәкле мәңге яшел күпьеллык куак-үсемлек (ул Урта Азия һәм Закавказьеда каучук алу өчен үстерелә).

ГЕБРАЙ'СТИКА *и. кит.* Борынгы еврей теле, язуы, культурасы һәм тарихы турындагы фән.

ГЕ'ГЕЛЬЧЕ *и. филос.* Гегельчелек тарафдары.

ГЕ'ГЕЛЬЧЕЛЕК *и. филос.* Философиядә Гегель карашларына нигезләнгән реакцион идеалистик агым.

ГЕГЕМОН *и. полит.* 1. Җитәкче, юлбашчы; политик көрәштә җитәкләүче, алдынгы сыйныф. [*Эшчеләр сыйныфы*] *табигый рәвештә капитализмга каршы көрәшүче барлык көчләрнең гегемоны була.* КПСС программасы. // Җитәкче көч, юл күрсәтүче. *Пролетар әдәбиятка гегемон булырга маташкан формализмның да заман чире, тарих чүбе булып калуы шиксез.* Г. Халит.

2. Өстен, хаким сыйныф, баш. Алар [*немецлар*] *кинәергә, үзләренең чиксез югары куелган техникаларына таянып, дөньяга гегемон булырга, шул җөмләдән Россияне икътисади яктан да, башка җәһәттән дә үзләренә бәйләп тотарга телиләр.* М. Гафури.

ГЕГЕМО'НИЯ *и. полит. к.* гегемонлык. [*Кораллы восстаниедә*] *иң энергияле катнашудан гегемония килеп чыкмый әле.* В. И. Ленин.

ГЕГЕМОНЛЫК *и. полит.* 1. Җитәкчелек; җитәкчелек итү, алдынгы булу. *В. И. Ленин меньшевикларның революциядә либераль буржуазиянең гегемонлыгына һәм революцияне вак реформалар белән алыштыруга исәпләнгән оппортунистик установкаларын җимергеч рәвештә тәнкыйть итте.* КПСС тарихы.

2. Өстенлек, хакимлек, бүтәннәргә баш булу. [*Гимлер:*] *Дөньяда фәкать немец халкы гына яшәргә, башка халыклар безгә кол булырга, безнең гегемонлыгыбыз өчен хезмәт итәргә тиешләр.* Т. Гыйззәт.

ГЕДОНИЗМ *и. филос.* Безнең эрага кадәр IV йөздә борынгы Грециядә барлыкка килеп, колбиләүче аристократия идеологиясен чагылдырган, кеше тормышында иң югары бәхет, максат — хозурлану, рәхәт яшәү дип раслый торган идеалистик юнәлеш.

ГЕ'ЙЗЕР *и. кит.* Вакыт-вакыт фонтан формасында су һәм пар атып чыгара торган кайнар чишмә (вулкан атылуга бәйләнешле рәвештә барлыкка килә). *Син гейзерларга — кайнар чишмәләргә гашыйк.* Каз. утл.

ГЕКЗА'МЕТР *и. әд.* Дактиль һәм хорейның аралашып килүе тәртибендәге алты буынлы шигырь төзелеше. // Антик шигырь төзелешендәге алты буынлы дактиль.

ГЕКСАХЛОРАН *и. хим.* Бензолны яктылыкта хлорлау юлы белән алына торган органик матдә (корткыч бөҗәкләргә каршы көрәштә агу итеп файдаланыла).

ГЕКСА'ЭДР *и. мат.* Алты кырлы геометрик җисем.

ГЕКТАР *и.* Метрик системада 100 арга, ягъни 10 000 квадрат метрга тигез җир үлчәү берәмлеге. *Инде утыз мең гектар чирәм күтәрдек.* А. Әхмәт.

ГЕКТАРЛЫК *с.* Күпмедер гектардан торган. *Ул һәр көн 0,17 гектарлык нормаңы 0,19—0,20 гектарга тутырып урып килгән булган.* М. Гали. // Күпмедер гектарга җитәрлек. *Бер гектарлык чәчү орлыгы.*

ГЕКТОВАТТ *и. физ.* Йөз ватт.

ГЕКТО'ГРАФ *и. махс.* Язма яки басма текстның күп санлы копиясен алу җайланмасы. *Бу әйбер типография юлы белән чыга алмады, аның русчасын да гектографта тараттылар.* Г. Ибраһимов.

ГЕКТОЛИТР *и.* Йөз литр.

ГЕКТОМЕТР *и.* Йөз метр.

ГЕЛ *рәв.* 1. Һәрвакыт, һәрчак, еш кына. *Клубка килгәндә дә, мин гел сине уйлый идем.* М. Җәлил. *Сине монда гел телгә алып сөйлиләр.* Ш. Камал. // Өзлексез, туктаусыз. [*Күзгә*] *гел яшь килә дә тора.* М. Фәйзи.

2. Бөтенләй, тулысынча. *Кара инде, гел хатын-кызлар кулына охшаган.* Т. Гыйззәт. // Барысы да, бөтенесе дә. *Монда гел читләр, читләр, читләр!* Г. Ибраһимов.

ГЕЛЕ'РТЕР *и. кит. ирон.* Кыю белемле, ләкин белемен практикада куллана алмаучы, тормыштан аерылган галим; хәрефкә табынучы, хәрефкә ябышып ятучы.

ГЕ'ЛИЙ *и. хим.* Төссез һәм иссез, водородтан кала иң җиңел инертлы газ, химик элемент (һава шарлары тутыру һ. б. максатларда файдаланыла).

ГЕЛИКОН *и. муз.* Божралап бөгелгән зур җиз труба формасындагы, контрабас группасына керә торган тынлы музыка коралы.

ГЕЛИКОПТЕР *и. авиа.* Горизонталь урнаштырылган пропеллер ярдәмендә югарыга туры күтәрелә ала торган вертолет төре.

ГЕЛИО- Кояшка, кояш нурларына бәйләнешле кушма сүзләрнең беренче кисәге: **гелиофизика, гелиохимия, гелиотехника** һ. б.

ГЕЛИО'ГРАФ *и.* 1. *астр.* Кояшны рәсемгә төшерә алу өчен фотоаппарат куелган телескоп.

2. *метеор., физ.* Кояш балкышының дәвамлылыгын автомат рәвештә теркәп бара торган прибор.

3. *хәрби.* Яктылык сигналлары ярдәмендә хәбәрләшү өчен хезмәт итә торган прибор.

ГЕЛИОГРА'ФИЯ *и.* Астрономиянең Кояшны тикшерү һәм тасвирлау белән шөгыльләнә торган бүлеге.

ГЕЛИОСКОП *и. астр.* Кояшны күзәтү өчен кулланыла торган җайланма.

ГЕЛИОСТАТ *и. астр.* Кояш нурларын бер якка җыйнап юнәлтә торган оптик прибор.

ГЕЛИОТЕРАПИЯ *и. мед.* Кояш нурлары белән дәвалау.

ГЕЛИОТРОПИЗМ *и. иск. биол.* Үсемлекләрнең кояшка, кояш нурларына йөзләрен бору үзенчәлеге (мәсәлән, көнбагыш).

ГЕЛИОЦЕНТРИЗМ *и. филос.* Кояш үзәктә булып, планеталар аның тирәсендә хәрәкәт итәләр дип раслый торган тәгълимат.

ГЕЛИОЦЕ'НТРИК: гелиоцентрик система. *к.* гелиоцентризм. **Гелиоцентрик орбита** — үзәгендә Кояш булган орбита.

ГЕЛЬМИНТО'ЛОГ *и. мед.* Гельминтология белгече.

ГЕЛЬМИНТОЛО'ГИЯ *и. мед.* Паразит суалчаннар һәм шулар тудыра торган авырулар турындагы фән.

ГЕЛӘН *рәв. диал. к.* гел (1. *мәгъ.*). *Гелән үзе хакында гына сүз барганлыктан, [Галимә] өчен бу сүзләр дә авыр булачагы мәгълүм иде.* М. Гафури. *Мин аны гелән сөймидер идем.* Г. Ибраһимов.

ГЕМАТОГЕН *и. мед.* Кан азлыктан дәвалану өчен, каннан әзерләнгән препарат.

ГЕМАТОЛО'ГИЯ *и. мед.* Каннның составын һәм үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән.

ГЕМАТУ'РИЯ *и. мед.* Канлы сидек килү авыруы.

ГЕМОГЛОБИ'Н *и.* мед. Кызыл кан шарчыкларындагы кызыл төс бирә һәм организмны кислород белән тәэмин итә, углекислый газдан арындыра торган матдә, каннның состав өлеше.

ГЕМОТЕРАПИЯ *и. мед.* Кан күчерү юлы белән дәвалау.

ГЕМОФИЛИЯ *и. мед.* Каннның оешу сәләте кимү аркасында, күп кан югалтуга китерә торган авыру.

ГЕМПШИР *и. а. х.* Кыска йонлы, ит өчен асрала торган сарык токымы.

ГЕН *и. биол.* Күзәнәкнең хромосом составындагы, организмның аерым үзенчәлекләрен нәселдән нәселгә күчерә торган элемент.

ГЕНЕАЛОГ *и. кит.* Генеалогия белән шөгыльләнүче.

ГЕНЕАЛО'ГИК *с. кит.* Генеалогиягә мөнәсәбәтле. *Телләрне генеалогик классификацияләү.*

ГЕНЕАЛО'ГИЯ *и.* 1. Тарихның аерым нәсел һәм ыруларны тикшерә торган бүлеге; нәсел тарихы, шәҗәрә.

2. *биол.* Хайван һәм үсемлекләрнең килеп чыгу тарихы; аларда төр һәм ырулар тарихы турындагы мәгълүмат.

ГЕ'НЕЗИС *и.* Килеп чыгу, барлыкка килү. // Чыгыш, нәсел.

ГЕНЕРАЛ *и.* Командирларга бирелә торган югары хәрби дәрәҗә. // Шул дәрәҗәгә ия булган кеше: **генерал-майор, генерал-лейтенант, армия генералы.** *Элекке генераллар алтын ялтыравыгы белән күзне камаштыра, таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабарынган кыяфәте белән тыныңны кыра иде.* Г. Бәширов.

ГЕНЕРАЛИ'ССИМУС *и.* Иң югары хәрби дәрәҗә. // Шул дәрәҗәгә ия булган кеше.

ГЕНЕРАЛИТЕТ *и. хәрби.* Армиянең югары командирлары составы, генераллар.

ГЕНЕРАЛЛА'РЧА *рәв.* Генераллар кебек.

ГЕНЕРАЛЛЫК *и.* Генерал исеме; генерал дәрәҗәсе.

ГЕНЕРАЛЬ *с.* Төп; баш җитәкче, җитәкләүче. *Партия һәм хөкүмәтнең илне индустрияләштерү буенча генераль планы.* □ *Менә бу көн төндә --- Фәсхигә каршы ыргытылуның генераль сызыгы сызылырга тиеш иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. // Соңгы; хәлиткеч. *Бүген соңгы репетиция. Генераль репетиция.* Н. Фәттах.

ГЕНЕРАТИВ *с. биол.* Җенси. *Генератив күзәнәкләр.*

ГЕНЕРА'ТОР *и. физ.* Механик энергияне электр энергиясенә әверелдерә торган машина.— *Ярый әле Тарасов сизеп алып, газ клапаннарын ябып, генератор бугазын ача алган.* Р. Ишморат.

Генератор газы — махсус мичтә — газогенераторда каты ягулыктан алына торган газ.

ГЕНЕ'ТИК *с.* 1. *биол.* Генетикага мөнәсәбәтле.

2. *лингв.* Генезиска, килеп чыгышка мөнәсәбәтле. *Телләрнең генетик кардәшлеге. Чагыштырма генетик метод.*

ГЕНЕ'ТИКА *и. кит.* Биологиянең организмда нәсел-дәнлек һәм үзгәрүчәнлек мәсьәләләрен өйрәнә торган бүлеге. *Аның ин яратмаганы --- ун-уникә яшьтән үк интегралларны, генетиканы... капшый башлаган өлгер һәм тырыш үсмерләр иде.* А. Гыйләҗев.

ГЕНОЦИД *и. полит.* Теге яки бу милләтне, халыкны үтереп бетерү политикасы; мәс., гитлерчыларның еврей, поляк, чех һ. б. халыкларны кыру политикасы.

ГЕНӘ *кис. к.* гына.

ГЕО- Җиргә бәйләнешле кушма сүзләрнең беренче кисәге: **геофизика, геохимия, геоботаника** һ. б.

ГЕОБОТА'НИК I *и.* Геоботаника белән шөгыльләнүче; геоботаника белгече.

ГЕОБОТА'НИК II *с.* Геоботаникага мөнәсәбәтле. *Геоботаник тикшеренүләр.*

ГЕОБОТА'НИКА *и.* Ботаника фәненең Җир шарындагы үсемлекләрнең таралышын һәм бүленешен климат, туфрак һ. б. үзенчәлекләренә бәйләп өйрәнә торган бүлеге.

ГЕО'ГРАФ *и.* География белгече. *Училищеда география фәненә сабыйларча гашыйк ирле-хатынлы географлар бар иде.* М. Мәһдиев.

ГЕОГРА'ФИК *с.* Географиягә бәйләнешле. *Стеналарга эленгән географик карталар, зоологик, ботаник таблицалар --- аңарда үзен биредә ят кеше итеп тою хисен тудыра иде.* Ә. Еники.

ГЕОГРА'ФИЯ *и.* 1. Кешелек җәмгыяте яши торган табигый шартларны, җитештерүнең төрле илләрдә һәм өлкәләрдә ничек урнашу һәм үсеш үзенчәлекләрен, үсү шартларын өйрәнә торган фән. *Географияне укымаса да, Батыргали агай французлар җирен, шәһәрләрен бик яхшы беләдер.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Җир шарында яки аерым бер урында нәрсәнең дә булса таралу рәвешен өйрәнү. *Хайваннар географиясе. Лингвистик география.*

ГЕОДЕ'ЗИК *с.* Геодезиягә мөнәсәбәтле. *Геодезик приборлар. Геодезик күзәтүләр.*

ГЕОДЕЗИ'СТ *и.* Геодезия белгече. *Геодезистлар кагып киткән билгене генә табасы бар. Аны кар баскан.* Г. Әпсәләмов.

ГЕОДЕ'ЗИЯ *и. кит.* Җирнең һәм җир өстенең аерым мәйданнарын үлчәп, аларның планын, картасын төшерә торган фән.

ГЕО'ЛОГ *и.* Геология белгече. *Юл кожаныннан, авыр күн итекләрдән хуҗаларча нык басып, беренче геолог узуын күргән кешеләр яңа төзелешләргә совет кешесенең никадәр көче кергәнен бик яхшы аңлыйлар.* Г. Ахунов.

ГЕОЛО'ГИК *с.* Геологиягә мөнәсәбәтле. *Озын буйлы абыйның --- геологик разведка кешесе икәнен --- сизенергә бер дә әллә ни зирәклек кирәкмидер.* Р. Төхфәтуллин.

ГЕОЛО'ГИЯ *и.* Җирнең составын, җир кабыгының төзелешен һәм үсешен, җирдәге органик тормышның тарихын, шулай ук файдалы казылмаларны өйрәнә торган фән.— *Иптәш Иванов, миңа геология буенча китаплар табып бирсәң иде.* А. Әхмәт. // *с. функ. Стенада районның геология картасы.* А. Әхмәт.

ГЕОЛОГОРАЗВЕ'ДКА *и.* Файдалы казылмаларны эзләп табуны максат итеп куйган геологик тикшеренүләр. // Шундый тикшеренүчеләр группасы.

ГЕОЛОГОРАЗВЕ'ДКАЧЫ, ГЕОЛОГОРАЗВЕ'ДЧИК *и.* Геологик разведка белән шөгыльләнүче.

ГЕО'МЕТР *и.* Геометрия белгече.

ГЕОМЕ'ТРИК *с.* Геометриягә мөнәсәбәтле. *Геометрик фигура. Геометрик прогрессия.*

ГЕОМЕ'ТРИЯ *и.* Математиканың пространствоны зурлыкларның үзенчәлеген һәм җисемнәрнең формасын, күләмен, бер-берена мөнәсәбәтен өйрәнә торган бүлеге.

ГЕОМОРФОЛО'ГИЯ *и. кит.* Физик географиянең җир өсте рельефын һәм аның үсеш, үзгәреш тарихын өйрәнә торган бүлеге.

ГЕОРАЗВЕ'ДКА *и. кит. к.* геологоразведка. [*Идрис Лиданың*] *береңче мәртәбә георазведкага килеп --- гариза биргән вакытын күз алдына китерде.* Ә. Айдар.

ГЕОРГИН *и. бот.* Төрле ачык төстә (ак, кызыл, чуар) матур эре чәчәк ата торган бүлбеле гөл; *к.* дәлия. *Бетте череп соңгы георгиннар, Йомылдылар бакчи гөлләре.* Ш. Мөдәррис.

ГЕОФИ'ЗИК I *и.* Геофизика белгече.— *Хәзер мин --- геофизиклар күзлегеннән чыгып бер-ике сүз әйтеп үзмакчы булам.* М. Хәсәнов.

ГЕОФИ'ЗИК II *с.* Геофизикага мөнәсәбәтле.

ГЕОФИ'ЗИКА *и.* Җирнең физик үзенчәлекләре һәм анда бара торган физик процесслар турындагы фән.

ГЕОХИ'МИК I *и.* Геохимия белгече.

ГЕОХИ'МИК II *с.* Геохимиягә мөнәсәбәтле.

ГЕОХИ'МИЯ *и.* Җирнең химик составын, җирдә химик элементларның урнашу, таралу тәртибе һәм бер-берсенә мөнәсәбәте, ярашулары законын өйрәнә торган фән.

ГЕОЦЕНТРИЗМ *и. астр., филос.* Җир галәмнең үзәгендә тора һәм башка җисемнәр җир тирәсендә әйләнә дигән, фән тарафыннан юкка чыгарылган тәгълимат.

ГЕОЦЕ'НТРИК: геоцентрик система — *к.* геоцентризм.

ГЕПАТИТ *и. мед.* Бавыр ялкынсынуы авыруы.

ГЕР *и.* 1. Металлдан эшләнеп, әйбернең массасын, микъдарын үлчәү өчен кулланыла торган төрле авырлыклар. *Алай-болай булса дип, кесәмә биш кадаклы гер тыккан идем, кирәкмәс йөк кенә булды.* Ф. Хөсни. // *спорт.* Авыр атлетика гимнастик күнегүләре ясау өчен кулланыла торган махсус спорт снаряды. *Спорт залына үздылар. Кулларына акбур ышкып, идәндәге герләрне күтәреп карадылар.* И. Гази.

2. Каршы авырлык бирү яки механизмны хәрәкәткә китерү өчен файдаланыла торган асылма йөк. *Дәү мич, геренә иске йозак асылган сәгать --- шул килеш сакланалар.* Г. Ахунов.

ГЕРА'ЛЬДИК I *и. кит.* Геральдика белән шөгыльләнүче, геральдика белгече.

ГЕРА'ЛЬДИК II *с. кит.* Геральдикага мөнәсәбәтле. *Геральдик атлас.*

ГЕРА'ЛЬДИКА *и. кит.* Тарих фәненең гербларны тарихын өйрәнү бүлеге.

ГЕРБ *и.* Аерым бер дәүләтнең, өлкә яки шәһәрнең һ. б. ның байракларына, акча һәм печатьләренә ясалган тамгасы, дәүләт билгесе, махсус эмблемасы. *СССР гербы. РСФСР гербы. УССР гербы.* ☐ *Минем кулда урак. Безнең дәүләт гербының бер элементы. Хезмәт ярату символы.* Ә. Баянов.

ГЕРБА'РИЙ *и.* Җыеп киптерелгән төрле үсемлекләр коллекциясе. — *Әйдә, Илдус, бергәләп үзебезнең мәктәп өчен табигать дәресенә гербарий әзерлибез.* Ә. Бикчәнтәева.

ГЕРБИЦИД *и. хим.* Чүп үләннәргә каршы көрәштә кулланыла торган химик препарат.

ГЕ'РБЛЫ *с.* Герб рәсеме төшерелгән; гербы булган. *Герблы марка.* ☐ *Почта залының бер почмагында торган сары гербле озынча ящик --- зәңгәр конверт [ны] эченә алды.* Э. Касыймов.

ГЕРЕШ *и. диал.* Суда чылатылган киндернең әзер булуы, сүсенең кабыгыннан, талкышыннан тәмам аерылуы. *Киндернең гереше җиткән. Гереш аткан.*

ГЕРКУЛЕС *и.* 1. Бик зур физик көчкә ия булган һәм матур, таза гәүдәле кеше (борынгы грек мифологиясендәге гадәттән тыш көчле Гераклның латинча исеменнән алынган). [*Һәйкәл булып*] *кайтканнар геркулес кебекләр.* Х. Туфан.

2. Яньчеп юкартылган солы ярмасы. *Геркулес боткасы.*

3. *астр.* Төньяк ярымшарда йолдызлар төркеме.

ГЕРКУЛЕС-КОҢГЫЗ *и. зоол.* Озынлыгы 15 сантиметрга җитә торган зур коңгыз (Үзәк һәм Көньяк Америкада очрый).

ГЕРЛЕ *с.* Гер белән эшли торган, гере булган. *Герле үлчәү. Герле физик күнегүләр.*

ГЕРМАН *и. сөйл.* 1. Германия кешесе; немец. *Әгәр герман русны татарга, татарны руска каршы куярга маташа икән, бу эше барып чыкмый аның.* Г. Галиев.

2. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш Европада яшәгән һәм үзара якын телдә сөйләшкән борынгы кабиләләрнең гомуми атамасы. *Герман телләре.*

ГЕРМАНИ'СТ *и. кит.* Германистика белгече.

ГЕРМАНИ'СТИКА *и. кит.* Герман халыкларының телен, әдәбиятын һәм культурасын өйрәнгән фәннәр җыелмасы.

ГЕРМА'НИЯЛЕ *и.* Германия кешесе.

ГЕРМАНОФИЛ *и. кит.* Немец культурасын, тормышын һәм әйберләрен яратучы һәм шулар белән мавыгучы, аңа ис китеп караучы кеше.

ГЕРМАНОФОБ *и. кит.* Немец культурасын, тормышын, әйберләрен яратмаучы, аңа нәфрәт белән караучы кеше.

ГЕРМАФРОДИТ *и. к.* хәнса. *Мастер Пальчиков --- семья корырга сәләтсез, гермафродит.* А. Расих.

ГЕРМЕТИЗА'ЦИЯ *и. техн.* Производство биналарын һәм җиһазларын зарарлы яки шартлау куркынычы булган матдәләр үткәрми торган итеп төзү.

ГЕРМЕ'ТИК *с.* Һава, су һ. б. үткәрмәслек итеп бик нык ябыла торган. *Герметик мич.* ☐ *Әллә нинди герметик капкачлар белән биклəп бетергән чуен казаннан атылып чыгарга торучы пар шикелле ярсый ул үч.* Ш. Маннур. / *рәв. мәгъ. Тәрәзәләр герметик ябыла.* А. Гыйләҗев.

ГЕРМЕ'ТИКЛАШТЫРУ *ф.* Герметик итеп, һава үткәрми торган итеп төзү. *Герметиклаштыру материаллары.*

ГЕРОИЗМ *и. к.* геройлык.

ГЕРО'ИК *с.* 1. Геройларга, батырларга хас, геройларча башкарылган. *Героик эш.* ☐ *КПСС үзенең героик көрәшенең бөтен тарихы буена --- «Коммунистлар манифесты»ның: «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән өндәмәсен кулланып килде.* КПСС тарихы. // Батырлык, геройлык күрсәтүче (күрсәткән), батырларча көрәшүче. *Тыл кешеләрендә Ленин шәһәрен саклаучыларны, аның героик халкын ач үлемнән йолып калу теләге чиксез көчле иде.* Г. Гобәй. // Батырлыкларга бай, геройларча көрәшләр белән данлыклы. *Героик чорда яшәү.*

2. *әд.* Геройлар һәм аларның батырлыкларын сурәтли торган. *Героик поэма. Героик эпос.* ☐ *Җикнең халыкны ханга каршы көрәшкә туплавы бу эпоска халыкның үзелүгә каршы көрәшен чагылдырган героик эпос төсен бирә.* М. Җәлил.

ГЕРО'ИКА *и.* Нәрсәнең дә булса героик ягы, героик эчтәлеге; геройлык. *Ул киң полотнода безнең тормышның героикасын сурәтли башлый.* Г. Нигъмәти.

ГЕРОИ'НЯ *и.* 1. Герой хатын-кыз.

2. Әдәби әсәрдәге хатын-кызлардан төп персонаж. [*Камилә*] *романнарда очрый торган героиняләр шикелле башын ике кулы белән кыса да ачы тавыш белән кычкырып җибәрә.* М. Әмир.

ГЕРОЙ *и.* 1. Батырлык күрсәткән, батырлык белән дан алган кеше. *Батырлык белән геройлар кайта, Җиңү бәйрәме илне балкыта.* Т. Гыйззәт. // Дошманга каршы көрәштә яки хезмәттә аерата тырышлык, батырлык күрсәткән өчен бирелгән исем. *Социалистик Хезмәт Герое.* ☐ *— Советлар Союзы Герое исеме белән,—диде майор һәм Шакировка газетаны сузды.* А. Әхмәт. // Җиңүче. *Бүген халык — герой, Халык — батыр, Хәзер һәркем оратор да агитатор, Бар да — трибун.* Н. Исәнбәт.

2. Билгеле бер чорның төп характерлы билгеләрен үзендә туплаган, шул чор кешесе. *Язучыларыбыз чорыбызның геройларын җанлы итеп бирү алга басканын беләләр.* М. Җәлил.

3. Кайсы яктан да булса үзен күрсәткән, халыкның игътибарын үзенә тарткан кеше. [*Фәтхи:*] *Зәйтүнә монда көннең герое --- Менә кемнең кулын кысарга кирәк.* Ә. Фәйзи.

4. Әдәби әсәрләрдәге төп персонаж. *Әсәрдә азрак урын тотуына да карамастан, Закир әсәрнең төп герое итеп алына.* **М. Гали.**

5. *күч. сөйл. ирон.* Сугыш чукмары, этәчләнергә яратучан кеше. // Куркак, куркаклык күрсәткән кеше.

Герой ана — 10 һәм аннан да артык бала тудырып үстергән аналарга бирелә торган мактаулы исем; моңа лаек булган аналарга бирелә торган орден исеме. *Мин нишләп ялгыз булыйм ди, үстереп унбер бала, Мин нишләп хәлсез булыйм ди, Мин булып герой-ана.* Н. Исәнбәт.

ГЕРОЙЛАНУ *ф. гади с.* Ясалма геройлык күрсәтү, куркыныч юк вакытта батыраю; этәчләнү.

ГЕРОЙЛА'РЧА *рәв.* Геройлар кебек, батырларча, батыр рәвештә. *Син терелерсең, Тагын геройларча Үч алырсың явыз дошманнан.* Ә. Ерикәй.

ГЕРОЙЛЫК *и.* Батырлыклар эшләргә сәләтле булу, куркусызлык, ныклык, үз-үзеңне аямаучылык. *Александр Матросовның бөек батырлыгы Кызыл Армиянең барлык сугышчылары өчен гайрәтлелек һәм геройлык үрнәге булырга тиеш.* Г. Әпсәләмов.

ГЕРОНТОЛО'ГИЯ *и. мед.* Медицинаның картлыкка каршы көрәш чараларын өйрәнү бүлеге.

ГЕРЦ *и. физ.* Тирбәнеш ешлыгы берәмлеге: бер секундта бер тирбәнеш ясалса, ешлык бер герц була.

ГЕ'РЦОГ *и. тар.* Кайбер көнбатыш Европа илләрендә югары дворяннарга һәм күп җир биләүче князьләргә бирелә торган титул һәм шул титулга ия булган кеше.

ГЕРЦОГИ'НЯ *и.* Герцог хатыны яки кызы.

ГЕ'РЦОГЛЫК *и.* 1. Герцог булу, герцог титулы.

2. Герцог биләмәсе, аерым бер герцог кул астында булган феодаль дәүләт.

ГЕСТА'ПО *и.* Германиядә фашизмга каршы кешеләрне ерткычларча кыруы белән танылган яшерен полиция.— *Гестапо эшкә кереште. Коммунистларны эзлиләр.* Н. Дәүли.

ГЕСТА'ПОЧЫ *и.* Гестапода хезмәт итүче фашист. *Таза гестапочы зур каты йодрыгы белән Мусаның чигәсенә суга.* Ә. Давыдов.

ГЕ'ТА *и.* Япониядә эшләнә торган агач башмак.

ГЕТЕРО'ЗИС *и. кит.* Бер-берсеннән нык аерыла торган ике төр үсемлек яки хайванны кушудан барлыкка килгән гибридларда үсү, ныклык, продуктивлылык һ. б. сыйфатларның кушылган төрләрдәгедән шактый көчле булуы.

ГЕ'ТМАН *и. тар.* 1. XVI—XVII йөзләрдә Украина казакларының сайлап куелган начальнигы; XVII—XVIII йөзләрдә Украина идарәчесе. *Шундый матур кыз, гетманга бирсәң дә оят түгел.* М. Җәлил.

2. Польша-Литва дәүләтендә XVI—XVIII йөзләрдә гаскәр белән идарә итүче.

ГЕ'ТМАНЛЫК *и. тар.* 1. Гетман дәрәҗәсе, вазифасы.

2. Гетман хакимлеге, гетман идарәсе.

ГЕ'ТМАНЧЫЛЫК *и. тар.* 1. Украинада гетманнар көчем сөргән чор.

2. 1918 елда Украинада герман империалистлары тарафыннан гетман итеп куелган Скоропадский урнаштырган контрреволюцион хәрби диктатура.

ГЕТР *и.* Күн, сукно яки мехтан тегелгән һәм ботинка өстеннән киелә торган төрле озынлыктагы җылы куныч. *Күптән кызыгып йөргән күн куртка, --- йон гетр алып кидем.* Ф. Хөсни.

ГЕ'ТТО *и.* Урта гасырда Европада һәм хәзерге капиталистик илләрдә түбән раса дип каралган кешеләр яши торган квартал. *Негърлар геттосы. Варшава геттосы.*

ГИББОН *и.* Көньяк-көнчыгыш Азиядә яши торган кешесыман маймылларның бер төре.

ГИБРИД *и. биол.* Төрле токым хайваннарның яисә төрле сорт үсемлекләрнең табигый яки ясалма кушылуларыннан килеп чыккан хайван, үсемлек. *Без көнбагыш-топинамбур гибриды үрчетмәкче булабыз.* А. Расих.

ГИБРИДЛАШТЫРУ *ф. биол.* Төрле токым яки сортларны кушу юлы белән яңа сыйфатлы гибрид алу.

ГИГАНТ *и.* Гадәттән тыш зур төзелеш, индустрия. *Бишьеллыкның бөек гигантлары һаман үсә, һаман күккә таба үрелә.* Һ. Такташ. *Салыштың син, димәк, Менә шушы гигантларның нигез ташларын.* З. Мансур. // *с. мәгъ.* Гадәттән тыш зур (күләмле). *Күктәрәк — гигант кран, ыржаеп күренә корычтан тешләре.* Н. Исәнбәт. *Кара урман, гигант имәннәрнең Төпләрендә — идеаль чисталык.* Ш. Маннур.

ГИГИЕ'НА *и. кит.* Сәламәтлекне саклау, авыруларны булдырмау чаралары турындагы фән. *Коммуналь гигиена. Шәхси гигиена.*

ГИГРО'МЕТР *и. физ.* Һава дымлылыгын үлчи торган прибор.

ГИГРОСКОП *и. физ.* Һавадагы дымлылыкның үзгәрүен күрсәтә торган прибор.

ГИГРОСКО'ПИК *с.* Дымлылыкны үзенә җиңел сеңдерә ала торган, дым җыя торган. *Гигроскопик мамык. Гигроскопик кислота* [*күкерт кислотасы*].

ГИГРОСКО'ПИКЛЫК *и.* Дым сеңдерү, һавадагы дымны үзенә җыю сәләте. *Туфракның гигроскопиклыгы.*

ГИД *и.* Туристларга шәһәрнең яки берәр төбәкнең истәлекле урыннарын күрсәтеп, аңлатып йөрүче профессиональ экскурсовод.

ГИДАЙ *и. иск.* Ярлы, фәкыйрь. *Байның күп вакыт борычы, тозы — мескен гидайлар яшьләре.* Г. Тукай. *— Акылга утырырга вакыт: аксөякне мактап, гидайны хурлап гомер итәсең.* Г. Ибраһимов. / *с. мәгъ. Тук ел булса, гидай казах та моңа куй табып бирер* [*иде*]. Ә. Фәйзи. // Төрле урыннарда йөреп гомерен уздыра торган йортсыз, семьясыз кеше. *Заманында батрак Сибай дигән гидай бер егет бар иде.* Г. Бәширов.

ГИ'ДРА *и.* Эчәккуышлылар семьялыгыннан иң гади төзелешле, бүленү юлы белән тиз үрчи торган умыртказсыз хайван (төче суларда яши). / *күч. Вәсвәсә — гидра, вак-вак кисәкчекләргә тырасаң да, үлми, һәр кисәкчегеннән яңа гидра, яңа вәсвәсә үсеп чыга.* Ш. Хөсәенов.

ГИДРА'ВЛИК *с.* 1. Гидравликага караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Гидравлик тикшеренүләр.*

2. Сыеклыкка басым ясау ярдәмендә хәрәкәткә китерелә яки барлыкка килә торган. *Гидравлик таран. Гидравлик электростанция.*

ГИДРА'ВЛИКА *и.* Сыеклыкларның хәрәкәте, тигезлекләрен саклау законы һәм аны практикада куллану турындагы фән.

ГИДРАНТ *и.* Урамга су сибү яки янгын сүндерү максаты белән куелган колонка яки кран.

ГИДРАТ *и. хим.* Металл окисеның су белән химик кушылмасы.

ГИДРИД *и. хим.* Водородның башка элементлар белән химик кушылмасы.

ГИДРО- Суга мөнәсәбәтле кушма сүзләрнең беренче кисәге: **гидроавиация, гидроакустика, гидробиология, гидрогеология** һ. б.

ГИДРОАЭРОПЛАН *и. к.* гидроплан.

ГИДРОГЕНЕРА'ТОР *и. физ.* Су хәрәкәте энергиясен электр энергиясенә әверелдерә торган махсус электр генераторы.

ГИДРО'ГРАФ *и.* Гидрография белгече.

ГИДРОГРА'ФИЯ *и. геогр.* Географиянең җир өсте суларын өйрәнә торган бүлеге.

ГИДРОДИНА'МИКА *и.* Гидромеханиканың сыекча хәрәкәтен һәм шул процесста каты әйберләр белән бер-берсенә тәэсирен өйрәнә торган бүлеге.

ГИДРОИНКУБА'ТОР *и.* Кайнар су ярдәмендә җылытыла торган инкубатор.

ГИДРО'ЛИЗ *и. хим.* Катлаулы матдәләрнең су тәэсирендә таркалуы.

ГИДРО'ЛИЗЛАШУ *ф. хим.* Су тәэсирендә химик таркалу. *Крахмалның гидролизлашуы.*

ГИДРО'ЛОГ *и.* Гидрология белгече. *Тәҗрибәле гидролог [су] эчендә кайнаган «ачуны» ачык сизә.* Г. Әпсәләмов.

ГИДРОЛО'ГИК *с.* Гидрологиягә мөнәсәбәтле. *Гидрологик тикшеренүләр.*

ГИДРОЛО'ГИЯ *и.* Җир шарындагы барлык сулыкларны һәм табигатьтә суның әйләнешен тикшерә торган фән.

ГИДРОЛОКА'ЦИЯ *и.* Тавыш сигналлары ярдәмендә диңгез һәм океаннарда су эчендәге әйбернең урынын билгеләү.

ГИДРОМЕТЕОРОЛО'ГИК *с.* Гидрометеорологиягә мөнәсәбәтле. *Гидрометеорологик күзәтүләр.*

ГИДРОМЕТЕОРОЛО'ГИЯ *и.* Атмосферадагы суның әйләнешен өйрәнә торган фән.

ГИДРОМЕ'ТРИК *с.* Гидрометриягә мөнәсәбәтле.

Гидрометрик станция — елгаларда суның тирәнлеген, агым тизлеген, күләмен, күпме су тотылуын һ. б. үлчи һәм исәпли торган пункт.

ГИДРОМЕ'ТРИЯ *и.* Гидрологиянең агым суларның агу тизлеген, тирәнлеген, су тотылу күләмен һ. б. үлчәү, исәпләү эшләре белән шөгыльләнә һәм шуның методикасын өйрәнә торган бүлеге.

ГИДРОМЕХАНИЗА'ТОР *и.* Гидромеханизация белгече.

ГИДРОМЕХАНИЗА'ЦИЯ *и.* Тау промышленностенда һәм җир казу эшләрендә грунтны һәм җир, тау асты токымнарын көчле басымлы су агынтысы ярдәмендә ваттыра торган механизмнардан файдалану ысулы.

ГИДРОМЕХА'НИКА *и.* Механиканың сыеклыкның тигезлек саклау һәм хәрәкәт законын, сыеклык белән каты матдәләрнең бер-берсенә тәэсир итүчәнлеген өйрәнә торган бүлеге.

ГИДРОМОНИТОР *и.* Тау токымнарын һәм грунтны көчле су агынтысы ярдәмендә юдырып эшкәртү өчен хезмәт итә торган җайланма.

ГИДРОПЛАН *и.* Судан күтәрелү һәм су өстенә төшү өчен җайланган самолет. *Су төсле кечерәк кенә гидроплан нәкъ райком бинасы турысында сөзәклән Идел өстенә төшеп килә иде.* Г. Бәширов.

ГИДРОПУЛЬТ *и.* Ут сүндерү, сиптереп стеналарны буяу, дезинфекция ясау, үсемлекләргә сыекча бөркү һ. б. ш. максатларда кулланыла торган кечкенә насослы чиләк.

ГИДРОСАМОЛЁТ *и. к.* гидроплан. *Туплар, пулеметлар туктаусыз хәрәкәткә килде, берничә гидросамолет һавага күтәрелде.* Х. Садрый.

ГИДРОСТА'НЦИЯ *и. к.* гидроэлектростанция. *Гидростанция буасының ярына тезелешеп үскән [тирәкләр] --- яр буен караңгылап торалар.* Ә. Еники.

ГИДРОСФЕ'РА *и.* Җир өстендәге барлык сулыклар: океаннар, диңгезләр, күлләр, елгалар.

ГИДРОТЕРАПИ'Я *и. мед.* Су белән дәвалау.

ГИДРОТЕ'ХНИК I *и.* Гидротехника белгече.

ГИДРОТЕ'ХНИК II *с.* Гидротехникага бәйләнешле. *Гидротехник корылмалар.*

ГИДРОТЕ'ХНИКА *и.* Махсус корылмалар ярдәмендә су көченнән халык хуҗалыгында файдалану һәм су белән бәйләнгән стихиягә каршы көрәш турындагы фән.

ГИДРОТОРФ *и.* Торф ятмаларын көчле су агынтысы ярдәмендә юдырып алынган торф.

ГИДРОТУРБИ'НА *и.* Су көче ярдәмендә әйләнә торган двигатель.

ГИДРОТӨЗЕЛЕШ *и.* Су корылмалары, су белән эш итү өчен махсус корылмалар.

ГИДРОТӨЗҮЧЕ *и.* Гидротөзелешләрдә катнашучы гидротехник корылмалар төзүче.

ГИДРОУ'ЗЕЛ *и.* Төрле гидротехник корылмалар җыелмасы (станция, канал, шлюз һ. б.)

ГИДРОФОН *и.* Су эчендә тарала торган тавыш дулкыннарын тоту җайланмасы.

ГИДРОХИ'МИЯ *и.* Җир өсте суларының химик составы һәм аны өйрәнү методлары турындагы фән.

ГИДРОЭЛЕКТРОСТА'НЦИЯ *и.* Су көчен электр энергиясенә әверелдерә торган электростанция. *Менә шул хәл Кандырда кечкенә генә алты-җиде йөз ат көчле гидроэлектростанция ачарга мөмкинлек бирә.* К. Тинчурин.

ГИДРОЭНЕРГЕ'ТИК *с.* Су энергиясенә мөнәсәбәтле. *Илнең гидроэнергетик мөмкинлекләре.*

ГИДРОЭНЕРГЕ'ТИКА *и.* Электр энергиясе алуда су көченнән файдалану белән шөгыльләнүче фән һәм техника тармагы.

ГИДРОЭНЕ'РГИЯ *и.* Су энергиясе, судан алына торган энергия.

ГИЗӘРГӘ *и. иск. к.* гизүче. *Сәгатен алып, теге ярлы картка бирсәм, юргасына менеп, гизәргә булып китсәм, язык булырмыни?* М. Фәйзи.

ГИЗҮ *ф.* Чагыштырмача зур араны, урынны йөреп чыгу, төрле урыннарында булу. *Муса ил гизеп өлгергән егет иде.* Ә. Еники. *Эх, ил өстеннән шул ак болытлар кебек гизеп йөрсәң иде!* Г. Әпсәләмов.

ГИЗҮЧЕ: ил гизүче — *к.* сәяхәтче. *Ил гизүчеләр белән хәйлә сөючеләр.* А. Алиш.— *Сәйях була безнеңчә,— дип аңлатты Габдулла,— ил гизүче.* Ә. Фәйзи. **Гизүче бөер** *мед.*— үз урыныннан күчкән һәм әледән-әле урынын алмаштырып тора торган бөер. **Гизүче йолдыз** *астр.*— билгеле бер юнәлештә хәрәкәт итмәү сәбәпле төрле урында күренә торган йолдыз. **Гизүче нерв** *анат.*— йөрәктә, үпкәләрдә, бавырда, ашказанында һ. б. эчке органнарда тармаклана торган, баш кабыгындагы иң зур нерв.

ГИ'ЛЬДИЯ *и. тар.* **1.** Урта гасырларда Көнбатыш Европада купецлар һәм һөнәрчеләр берләшмәсе.

2. Революциягә кадәрге Россиядә: купецларның капитал күләменә карап бүленгән өч разрядының берсе. *Беренче гильдия купец.*

ГИ'ЛЬЗА *и.* **1.** *хәрби.* Бер башы ябык, икенче башына пуля яки снаряд кую өчен җайлаштырылган, эченә дары салынган цилиндр труба. *Аяк астында буш гильзалар, атылмаган патроннар, ак саплы гранаталар ауный.* И. Гази.

2. *техн.* Көпшә, шүре формасындагы төрле детальләр атамасы. *Инженер Назиров, ике кулын пальто кесәсенә тыгып, гильзаларны эшкәртүче расточный станокларга карап уйланып басып тора иде.* Г. Әпсәләмов.

ГИЛЬОТИ'НА *и.* Кеше башын кисә торган җәзалау машинасы. [*Фашист тоткынлыгында*] *Гильотинмы кисәр газиз башны, Искәрмәстән яки атарлар, Ачлык белән буып үтерерләр Яки биек дарга асарлар.* А. Алиш.

ГИМН *и.* **1.** Дәүләт яки аерым сыйныфның бердәмлеге символы итеп кабул ителгән тантаналы җыр. *«Интернационал» гимны яңгырагач, «Сандугачлар монастыре»ндагылар ниндидер бер үзгәрешнең якынаюын сизделәр.* К. Нәҗми.

2. Мактау җыры; мәдхия. [*М. Җәлилнең*] *1928 елда язган «Истә» исемле бер шигыре бар. Саф мәхәббәткә һәм табигатьнең язгы җанлануына багышланган көчле бер гимн.* М. Максуд.

◇ **Гимн җырлау** — кемне яки нәрсәне дә булса артык мактау.

ГИМНАЗИ́СТ *и.* Гимназиядә укучы. *Аңа юлда ертык тезле гимназист, сипкел Тангатаров очрады.* Г. Ибраһимов.

ГИМНАЗИ́СТКА *и.* Гимназиядә укучы хатын-кыз. *Әнә тәрәзә алдыннан бик күп яшь-яшь гимназистлар вә гимназисткалар укырга баралар.* Ф. Әмирхан.

ГИМНА́ЗИЯ *и.* Революциягә кадәрге Россиядә һәм кайбер чит илләрдә гомуми урта белем бирә торган уку йорты. *Димәк, гимназиядә укымасаң да, тарихтан бөтенләй үк хәбәрсез түгел үзең.* Ш. Камал.

ГИМНАСТ *и.* Гимнастика остасы; гимнастика белән профессиональ шөгыльләнүче кеше. *Гимнастлар чыгышы.*

ГИМНАСТЁРКА *и.* Тыгыз материядән туры якалы итеп тегелгән (хәрби форма дип кабул ителгән) ирләр күлмәге. [*Газинур*] *көзге кисәген күкрәк кесәсенә тыгып, бил каешын, гимнастеркасын рәтләп алды.* Г. Әпсәләмов.

ГИМНА́СТИК *с.* Гимнастикага мөнәсәбәтле. *Гимнастик күнегүләр.*

ГИМНА́СТИКА *и.* Сәламәтлекне ныгытуга, организмны чыныктыруга һәм эш сәләтен күтәрүгә ярдәм итә торган физик күнегүләр системасы. *Бала өчен суда йөзү, --- велосипедта йөрү, гимнастика бик файдалыдыр.* Г. Тукай.

Гимнастика ясау — гимнастик күнегүләр, гимнастик хәрәкәтләр ясау. *Тора, юл уңаенда гына гимнастика ясый һәм --- йөзен юа башлый.* Һ. Такташ.

ГИНЕКО́ЛОГ *и. мед.* Гинекология белгече, хатын-кыз авырулары буенча врач.

ГИНЕКОЛО́ГИК *с. мед.* Гинекологиягә мөнәсәбәтле. *Гинекологик операция.*

ГИНЕКОЛО́ГИЯ *и. мед.* Хатын-кыз организмы үзенчәлекләрен һәм женес органнары авыруларын, аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган фән. // *с. мәгъ.* к. гинекологик. *Гинекология больницасы.*

ГИПЕ́РБОЛА I *и. мат.* Конусны аның ике төзүчесенә параллель яссылык белән кистергәндә барлыкка килгән кәкре сызык.

ГИПЕРБОЛА II *и. әд.* Сурәтләнә торган күренешнең тәэсир көчен арттыру максаты белән, аның күләмен яки әһәмиятен чиктән тыш арттырып күрсәтү алымы. *Хәзерге заманга якынайган саен, тормышның турыдан-туры үзеннән (символик образга әйләнмәстән, гиперболасыз) килеп керүче реализм элементы* [*әсәрләрдә*] *көчәя бар*[*а*]. Г. Бәширов. // Гомумән, чиктән тыш күпертү, арттыру. *Гипербола кулланып сөйләү.*

ГИПЕРБОЛИ́К I *с. мат.* Гиперболага (I) мөнәсәбәтле. *Гиперболик кисем.*

ГИПЕ́РБОЛИК II *с.* Гиперболага (II) мөнәсәбәтле. *Гиперболик чагыштыру.* □ *Реакция --- [М. Гафури-да] караш һәм тойгыларын төрле гиперболик формаларда әйтергә теләү омтылышы тудырды.* М. Җәлил.

ГИПЕРЕМИ́Я *и. мед.* Тәннең аерым бер урынына яки нинди дә булса әгъзага кан саву (авыру). *Патолого-анатомик картина шундый: ашказаны ертылган, --- бөердә гиперемия.* А. Расих.

ГИПЕРТО́НИК I *и. мед.* Гипертония белән авырый торган кеше.— *Эчкечеләрнең барысы да гипертоник та невростеник.* Н. Фәттах.

ГИПЕРТО́НИК II *с. мед.* Гипертониягә мөнәсәбәтле.

ГИПЕРТОНИ́Я *и. мед.* 1. Кан басымының артык күтәрелүе.

2. Кан басымы күтәрелүгә бәйләнешле авыру. *Ул гипертония миндә дә бар. Җитмәсә склероз.* А. Расих.

ГИПЕРТРО́ФИК *с. мед.* Гипертрофиягә мөнәсәбәтле. *Гипертрофик күренеш.*

ГИПЕРТРОФИ́Я *и. мед.* Авыру яки киеренке эш аркасында аерым әгъзаларның гадәттән тыш үсеп китүе (авыру).

ГИ́ПНОЗ *и.* Үз ихтыярына тулысынча буйсындыру юлы белән икенче бер кешедә ясалма рәвештә барлыкка китерелгән йокы яки ярым йокы хәле. *Ә бераздан* [*аудитория*] *Заһидның лекциясе белән, гипнозга эләккән кешедәй, бөтенләй мавыгып китә.* А. Расих. // Шундый ясалма йокы хәленә китерү, шулай ук ясалма йокыдагы кешенең ихтыярына тәэсир итү (бу, гадәттә, дәвалау максаты белән эшләнә). *Кем нинди хәлдә булса, гипноз белән йоклатылган шикелле, шул хәлендә катып калган.* М. Әмир.

ГИПНОЗЛАУ *ф.* Гипноз белән йоклату, гипноз хәленә китерү. *Илдарның исә үз кызыгы кызык, ул, гипнозланган песи баласы кебек, комбайнердан күзен ала алмады.* Г. Гобәй. // *күч.* Әкренләп үз ихтыярына буйсындыру; теге яки бу фикергә ышандыру. *Председательнең олы гына --- авызы нәрсә беләндер буйсындыра, гипнозлый ахрысы — шундый мәхәббәт белән карап тора аңа Тимербикә апа.* Ә. Баянов.

ГИПНОЗЛЫ *с.* Зур тәэсир итү, йогынты ясау көченә ия. *Гипнозлы күз. | рәв. мәгъ. Галимәнең күзләре --- безнең егетебезгә бөтен залның күл чабуыннан да гипнозлырак тәэсир итте.* И. Гази.

ГИПНОЗЧЫ *и.* Гипноз көченә ия булган кеше. // Гипноз белән дәвалаучы врач.

ГИПНОПЕ́ДИЯ *и.* Гипноз, йокы ярдәмендә укыту, укыганны үзләштерү, хәтердә калдыру методы (бигрәк тә чит телне өйрәнгәндә кулланыла).

ГИПНОТИЗМ *и.* Гипноз күренешләре турында тәгълимат.

ГИПНО́ТИК *с.* Гипнозга мөнәсәбәтле.

ГИПО́ТЕЗА *и.* Нинди дә булса күренешне аңлату өчен китерелгән, ләкин әле дөреслеге тәжрибә нигезендә исбатланмаган, фән нигезендә булуы мөмкин дип кенә табылган фараз, гөман. [*Иван Ильич*] *бик оста дәлиллән, үзенең дә кайчандыр теге профессор кебек үк уйлаганлыгын, ләкин сынаулар ясый башлагач, гипотезасының бөтенләй җимерелүен сөйләде.* А. Расих. *А. М. Горький халык әкиятләрен фантастик гипотеза дип атый.* Г. Бәширов.

ГИПОТЕНУ́ЗА *и. мат.* Турыпочмаклы өчпочмакта туры почмакка каршы як.

ГИПОТЕРМИ́Я *и. мед.* Кеше яки хайваннарның тәнен яисә аерым әгъзасын вакытлыча суыту юлы белән нерв сизгечлеген кимәтү.

ГИПОТО́НИК I *и. мед.* Гипотония белән авырый торган кеше.

ГИПОТО́НИК II *с. мед.* Гипотониягә мөнәсәбәтле.

ГИПОТОНИ́Я *и. мед.* Кан басымының гадәттәгедән түбәнәюе (авыру).

ГИ́ПОФИЗ *и. анат.* Кеше организмының үсешенә тәэсир итә торган эчке секреция бизе; ул баш миенең аскы ягында була.

ГИППОПОТАМ *и. к.* бегемот.

ГИПС *и.* 1. Сары яки ак төстәге известьле минерал. *Әнә тегендә, яр астында гипс чыгаралар.* А. Расих.

2. Яндыру юлы белән сусызландырылган, порошок хәлендәге минерал, ул хирургия, скульптура эшләрендә һәм төзелештә төзү материалы буларак кулланыла.

3. *махс.* Шундый минералдан сын, скульптура әсәре.

4. *мед.* Сынган сөякне ялгаганда яки тайган урынны утыртканда селкенмәсен өчен гипстан катырып ясалган каты хирургик бәйләвеч. [*Илдар*] *яңа гына гипстан чыккан кулын сәламәт кулы белән тоткан хәлдә --- басып торды.* Г. Гобәй.

ГИ́ПСЛАУ *ф. мед.* Гипска (4 *мәгъ.*) салу. *Алты ай гипслап тоткаңнан соң, терсәк сөяге ялгана.* С. Сабиров.

ГИ'ПСЛЫ *с.* 1. Гипс (1 *мәгъ.*) табыла торган, гипска бай. *Гипслы урыннар.*

2. Гипс (4 *мәгъ.*) сыланган, гипсланган. [*Сәгыйдә*] *Арсланның аягына катырган гипслы марляны --- кисә башлады.* Г. Ахунов.

ГИПЮР *и.* Күпертеп эшләнгән челтәр. *Хаҗи аның гипюр кофтасының киң җиңнәре аша беленеп торган йомры беләкләренә карап алды.* М. Хәсәнов.

ГИРЛЯ'НДА *и.* Чәчәкләрдән, яфрак һәм ботаклардан чылбыр сыман итеп үреп ясалган тезмә, бәйләм. // *архит.* Шундый формада эшләнгән орнамент.

ГИРОКО'МПАС *и. к.* гироскопик компас.

ГИРОСКО'П *и. тех.* Төрле авышлыкта да үз турылыгын саклый торган әйләнмә күчәрле прибор.

ГИРОСКО'ПИК *с. тех.* Гироскопка мөнәсәбәтле. *Гироскопик приборлар.*

Гироскопик компас — магнит угы хезмәтен гироскоп башкара торган компас.

ГИСТО'ЛОГ *и.* Гистология белгече.

ГИСТОЛО'ГИК *с.* Гистологиягә мөнәсәбәтле. *Гистологик тикшеренүләр.*

ГИСТОЛО'ГИЯ *и.* Кеше һәм хайван организмы тукымаларының төзелешен өйрәнә торган фән.

ГИТА'РА *и.* Озын грифлы, сигезле цифрына охшаш корпус-резонаторы булган кыллы музыка коралы.— *Их, яратам да шул гитара тавышын!..* Т. Гыйззәт.

ГИТА'РАЧЫ *и.* Гитарада уйнаучы кеше. *Сизов экипаждагы барлык гитарачыларны күз алдыннан үткәрде.* Г. Әпсәләмов.

ГИТЛЕРИЗМ *и. тар.* Германиядә: башында Гитлер торган фашистик диктатура (1933—1945) һәм шул диктатураның идеологиясе.

ГИ'ТЛЕРЧЫ *и.* Гитлеризм тарафдары; немец фашисты. *Гитлерчылар аның гәүдәсен кырга чыгарып ташлаганнар.* А. Шамов.

ГЛАДИА'ТОР *и. тар.* Борынгы Римда: циркта ерткыч хайваннар яки икенче бер кеше белән сугышу өчен коллар яисә хәрби әсирләр арасыннан махсус өйрәтелгән көрәшче.

ГЛАДИО'ЛУС *и. бот.* Бер өлешләре классына керә торган, төрле төстәге матур чәчәкле, кыяксыман яфраклы декоратив гөл — суганчалы күпьеллык үсемлек.

ГЛАЗУРЬ *и.* Балчык яки фаянс савытларның өстенә йөгертелә торган ялтыравыклы эретмә.

ГЛАЗУРЬЛАУ *ф.* Өстенә глазурь йөгертү, глазурь белән каплау.

ГЛАЗУРЬЛЫ *с.* Глазурьланган, ялтыратылган.

ГЛА'НДА *и. анат.* Йоткылыктагы миндальсыман биз.

ГЛА'СНЫЙ *и. тар.* Революциягә кадәрге Россиядә: шәһәр думасы яки берәр жирле идарә системасы члены. *Шәһәр думасына гласный булудан башлап, --- мөфти булуга кадәр булган урыннарга тамгы итүче бездә кирәгенә караганда йөз мәртәбә артыктыр.* Ф. Әмирхан.

ГЛА'СНЫЙЛЫК *и.* Гласный булу. [*Сәйдәшев:*] *Гласныйлык хезмәте бик авыр һәм расходлы. Шуның мәшәкатенә, расходына чыдый торган кешене генә сайлыйк.* Г. Тукай.

ГЛАУКО'МА *и. мед.* Күз алмасы эчендәге басымның артуы сәбәпле сукырлыкка китерә торган авыру; карасу авыруы. *Академик А. Е. Арбузов уйлап тапкан дарулардан берсе глаукома белән авырып сукыраючыларны күзле итә.* Г. Бәширов.

ГЛЕ'ТЧЕР *и. геогр.* Тау башларыннан түбән таба шуышып хәрәкәт итә торган бозлык.

ГЛИКОГЕН *и. анат.* Кандагы шикәрдән бавырда һәм мускулларда барлыкка килә торган крахмал.

ГЛИ'ССЕР *и.* Яссы төбе белән су өстеннән җиңел шуа торган тиз йөрешле, пропеллерлы көймә.— *Әнә! Мотор гөре кисте су өстен! Диңгез ярып үтте глиссер.* Н. Исәнбәт.

ГЛИСТ *и. зоол.* Кеше яки хайван эчендә яши торган паразит суалчан. *Йомры глист. Тасма глист.*

ГЛИЦЕРИ'Н *и.* Майдан химик юл белән алына торган үтә күренмәле төчкелтем куе сыекча, техникада һәм медицинада кулланыла.

ГЛИЦЕРИНЛЫ *с.* Глицерин катнашкан.

ГЛИЦИ'НИЯ *и. бот.* Аксыл шәмәхә төстәге хуш исле тәлгәш чәчәк ата торган декоратив куак.

ГЛО'БУС *и. геогр.* Жир шарының яки күк сферасының үз күчәре тирәсендә әйләнерлек итеп вертикаль аскуймага урнаштырылган моделе. *Әйтерсең, минем алдымда глобус түгел, ә Жир шары үзе басып тора: таулар, сулар...* А. Әхмәт.

ГЛОКСИ'НИЯ *и. бот.* Бәрхет сыман йомшак эре яфраклы, ак, алсу яки аксыл шәмәхә төстә кыңгыраусыман чәчәкле, бүлбеләрдән үрчи торган бүлмә гөле.

ГЛУБИ'НКА *и. сәйл.* Тимер юл һәм пристаньнардан ерак урнашкан ашлык кабул итү һәм вакытлыча саклау пункты. *Глубинкага дигән алтын ашлык Көнен-төнен агыла улактан.* Ш. Мәдәррис.

ГЛЮКО'ЗА *и.* Үсемлекләрдә, жимешләрдә барлыкка килә торган татлы матдә — углевод; виноград шикәре.

ГНОСЕОЛО'ГИК *с.* Гносеологиягә мөнәсәбәтле. *Теге яки бу философик карашның сыйнфый тамырыннан башка тагын гносеологик нигезе дә бар.* М. Абдрахманов.

ГНОСЕОЛО'ГИЯ *и. филос.* Танып белү теориясе — танып белү процесслары, аның чыганаклары, формалары, чынлыгы турындагы философик тәгълимат.

ГНОСТИЦИЗМ *и. филос.* Христиан диненең беренче чорында барлыкка килгән дөнья яратылышы турындагы дини-философик агым.

ГОБЕЛЕН *и.* Бизәкләп тукылган яки кулдан эшләнгән стена коверы. [*Солтан*] *безнең делегацияне фабриканың үзендә эшләнгән, Ленин портреты төшерелгән гобелен бүләк итте.* Г. Ахунов. // Декоратив тукыма.

ГОБОЙ *и.* Кларнетка охшаш, тавыш югарылыгы буенча кларнет белән флейта арасында тора торган тынлы музыка коралы.

ГОБОЙЧЫ *и.* Гобойда уйнаучы музыкант.

ГОГЫЛДАУ *ф.* Тамак төбе белән басынкы көлү (кайын тавышлы ирләргә карата әйтелә). *Сәфәргали үзе дә кешеләргә кушылып гогылдап алды: «ho-ho-ho!..»* Г. Мөхәммәтшин.

ГОЗЕР *и.* 1. Үтенеч; ялыныч; йомыш.— *Һәркемнең моң-зарын тыңлыйсың, һәркемнең гозерен үтисең.* Х. Вахит. // Гафу. *Син аңардан барып, гозер үтен, аягына егыл, ул сине кичерер.* Қ. Насыйри.

2. Сәбәп, сылтау. *Газизә абыстай кызының: «Мин, әни, мәсихемне бозган идем шул»,— дигән гозерен дә колагына алмады.* Ф. Әмирхан. *Ахшамнан чыккач, гозерсез намаздан калганнарны тикшерү --- башлана.* М. Гафури.

Гозер итү (кылу) — гозерләнү, ялынып, ялварып сорау. *Ак сакаллы картлар килеп, Гозер итеп яшь морзага, Итәкләрен аның үбеп, Коткарып калган [Бибкәйне] биктән.* Ш. Маннур.

ГОЗЕРЛЕ *с.* Үтенечле, үтенече булган, ялварулы, ялынычлы. *Гозерле караш ташлау.* // Йомышлы, йомышы булган. *Гозерле кеше.*

ГОЗЕРЛӘНҮ *ф.* Үтенү, ялынып-ялварып сорау. *Жәяү барсам да, тышта, иркендә барам,— дип гозерләнсәм дә, --- мине чыгармыйлар иде.* Г. Тукай.

ГОЗЕРЛӘҮ *ф. к.* гозерләнү. *Әнисе дебаркадердан торып миңа --- гозерләгән тавыш белән сүз куштым.* Ф. Хөсни. [*Асия апа*], *күрше-күләннән әҗәткә карточка гозерләп, итен, маен, чәй-шикәрен алып кайтты.* Г. Гобәй.

ГӨЗЕРХАһ *и. иск. кит.* Гозерләнүче, үтенеп сораучы.

ГОЛ *и. спорт.* 1. Футбол, хоккей һ. б. ш. уеннарда туп кертү өчен эшләнгән махсус капка.

2. Тупны каршы команданың капкасына кертеп откан очко. [*Диктор*] *бөтен үпкәсен киереп акырды: Гол!..* Ғ. Мөхәммәтшин.

ГОЛДЫРАУ *ф. к.* голдырдау. [*Кунак абый*] *күркә голдыравы сыман мәзәк тавыш белән кычкырып көлде.* Ә. Фәйзи.

ГОЛДЫР-ГОЛДЫР *аваз изр.* 1. Күркәләрнең голдырау тавышын белдерә. *Лапас тирәсендә голдыр-голдыр килеп --- бер урында биегән ата күркәдән башка җан изсе күренмәде.* С. Рафиков.

2. *рәв. мәгъ.* Тамак төбеннән эчке яки тышкы якка сыеклыкны голт-голт итеп үткәрүне белдерә. *Батырғали агай --- бер ашаганда үнбиш кадак елкы ите ашап, ике чирек кымыз эчеп, җомга намазларында голдыр-голдыр кикерә иде.* Ш. Мөхәммәдев.

3. *күч.* Күркә тавышына охшатып сөйләүне белдерә. *Голдыр-голдыр килеп сөйләү.*

ГОЛДЫРДАУ *ф.* 1. Күркәләрнең голдыр-голдыр итеп кычкыруы турында.

2. *күч.* Кешенең калын тавыш белән сөйләве турында.

ГОЛҚЫЛДАТУ *ф.* Голт-голт итеп йоту, эчү. *Сабый, иреннәренә каксо тигәч, --- кинәт очынып, голкылдатырға тотынды.* Г. Гобәй.

ГОЛЛАНД *и.* Голландиядә яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. / *с. мәгъ. Голланд теле.*

ГОЛЛА'НДИЯЛЕ, ГОЛЛАНДЛЫ *и. к.* голланд. *Французлар, немецлар, голландлылар, бельгиялеләр, чехлар төркеме, һәрберсе үз телләрендә сөйләшә-сөйләшә, алар яныннан үз почмакларына үтә бирделәр.* Ғ. Әпсәләмов.

ГОЛТ-ГОЛТ *аваз изр.* Сыеклыкны зур йотымнар белән бүлеп-бүлеп эчү, йотуны белдерә. *Ул күпме эчелгәнне чамалый-чамалый голт-голт йотты.* Г. Ибраһимов.

ГОЛЬФ *и.* Тезгә кадәр җитә торган оек. [*Малайның*] *йөгергәндә гольф аша балтыр итләре былкылдап торалар.* Ә. Давыдов.

ГОЛӘМА *җыйм. и. иск.* 1. Галимнәр, укымышлылар. *Хәзер бөтен педагогия голәмасы коры вәгазь-нәсихәт һәм кушу белән шәкертләрне бер мәсләктә тәрбия итүдә һичбер төрле дөньяга нәзар бирә алуны мөмкин тапмыйлар.* Ф. Әмирхан.

2. Дини кануннарны, шәригатьне белүче кешеләр, дин башлыклары. *Гасырлар буенча голәма-голәма дип тордык, һәр эшне мулладан көттек.* Г. Ибраһимов.

ГОМЕОПАТ *и. мед.* Гомеопатия ысулы белән дәвалаучы врач.

ГОМЕОПА'ТИК *с. мед.* Гомеопатиягә мөнәсәбәтле.

ГОМЕОПА'ТИЯ *и. мед.* Зур доза биргәндә организмда авыру китереп чыгара торган препаратны бик аз дозада куллану юлы белән шул ук авыруларны дәвалау методы.

ГОМЕР *и.* 1. Барлык тереклек иясенең туу моментыннан алып үлгәнгә кадәр булган физиологик хәле, яшәү вакыты. *Бар бит шундый кешеләр ай-һай лабаса, үз йорт-җирем, үз малым дими, бөтен гомерен ил хезмәтендә уздыра.* Г. Бәширов. *Гомер түгелдер күпер: чыгып китәргә генә түгел, барын да күрәсең.* Мәкаль. // Берәр нәрсәнең барлыкка килүдән бетүенә, юкка чыгуына кадәрге яшәү вакыты, ягъни кулланыштагы вакыты. *Сине гөлчәчәккә тиңләр идем — Чәчәкләрнең гомере аз гына.* Җыр. // *күч.* Тормыш, яшәү ләззәте. *Бер күрүең — бер гомер.* Мәкаль. // *күч.* Җан; тормыш. *Бар җырымны илгә багышладым, Гомеремне дә бирәм хилкыма.* М. Җәлил.

2. Кешенең гомерендә була торган билгеле бер чор. ***Яшь гомер. Кызлык гомере. Картлык гомере.*** □ *Ул да килен гомерен уздырды.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Вакыт, вакытның бер өлеше. *Менә итле шулпа капмаганга да әллә ни гомер.* И. Гази.

4. *рәв. мәгъ. күч.* Юклык формасындагы фигыль янында: беркайчан да, бервакытта да. [*Рокыя:*] *Мин сорасам, әти гомер дә җибәрми.* Ф. Әмирхан.— *Кара әле син аны, гомер булмаган хәл бит!* Г. Гобәй.

5. *рәв. мәгъ. күч.* **гомергә.** Мәңге, мәңгегә, гомер буена, бик озак вакытка. *Вакыт инде гүрне кайгыртырга, мин килмәгән җиргә гомергә.* М. Җәлил. *Ат калдырдык бергә, туган илгә сагынып яд итәргә гомергә.* Ф. Бурнаш. // Мәңгегә, бөтенләйгә; кайтмаска, яңадан кабатланмаска. *Җырланган җыр кебек яшьлек таңым шаулап үтте инде гомергә!* һ. Такташ.

Гомер итү (сөрү) — 1) яшәү, тору. *Нишлисең, үз сөйгәне белән гомер итү бәхете аны читләтеп узды күрәсең.* Г. Бәширов. *Бу дөньяда байтак еллар гомер сөрдем.* М. Гафури; 2) тормыш көтү, тормышны алып бару. *Минем әнием --- үз кул көче белән эшләп гомер итүче.* һ. Такташ. *Ау ауласак, урманнарда бергә йөрик, Рәхәтләнеп яшәп, бергә гомер сөрик.* Ак юл. **Гомер үткәрү (уздыру, кичерү)** — 1) *к.* гомер итү. *Сине уйлап, син-син диеп Гомер кичерер идем.* Җыр; 2) бушка вакыт уздыру. *Сүз боткасы белән гомер үткәрергә ярамый.* Г. Ибраһимов. *Ул педагоглык эшенә балалар белән чыр-чу килеп гомер уздыру дип кенә карый.* Р. Ишморат.

◇ **Гомер (җебе) киселү (өзелү)** — үлү, һәлак булу. *Өзелеп төшкән яшел яфрак кебек, синең якты гомерең өзелде.* Ә. Ерикәй. **Гомерен бирү** — үлү, билгеле бер эш, максат өчен үзен корбан итү. *Гомерең бирә алган якты көнне Мин саклармын, Ятка бирмәмен.* Ш. Маннур. **Гомерен кисү (өзү, чикләү)** — үтерү, юк итү, һәлак итү. *Дошман уты аның гомерен кискән; Ал кан белән юган яңагын.* М. Җәлил. **Гомернең таңы (язы)** *шигъ.*— яшьлек. *Ни гамь бөлсәм, әгәр үлсәм, --- гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.* Дәрдмәнд. *Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин, И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.* Г. Тукай. **Гомернең көзе (соңы, актыгы)** *шигъ.*— картлык. *Гомеренең таңы томан булса, аяз булган аның актыгы.* М. Җәлил. *Үз законы табигатьнең, Ул — хуҗа үзе, Берәүне дә үтми читләп Гомернең көзе.* Г. Хуҗиев.

ГОМЕР-ГОМЕРГӘ *рәв.* Бөтен гомере буена, һәрвакыт. *Дөресен әйтсә, сабыйның рухы гомер-гомергә төшенке, күңеле китек булачак, гомер-гомергә ятимлеге турында уйлап әрнячәк.* Г. Гобәй. *Элеккерәк елларда исә бу ике авыл гомер-гомергә ызгышып яшәгәннәр.* Г. Бәширов.

ГОМЕРЕ'НЧӘ *рәв.* Гомер буена. *Гомеренчә [байда] эшләп тә, ахырда урамга ташланган картлар, --- без сездән җавап көтәбез.* Г. Ибраһимов.

ГОМЕРЛЕ *с.* Озак яши торган, озакка бара, чыдый торган. *Гомерле булырсың.* □ *Дөрләп янган мәхәббәт яна да бетә, көлгә әйләнә, ә җылыта торган мәхәббәт озын гомерле була.* Р. Ишморат. // Мәңгелек; исеме, эше мәнге онытылмый торган. *Насыйп икән ут эчендә Янып исән калырга һәм шулай булган өчен дә Гомерле саналырга.* Ә. Ерикәй.

ГОМЕРЛЕК *с.* 1. Бер гомергә җитәрлек; гомер буена дәвам итәрлек. *Гомерлек истәлек. Гомерлек кайгы.* □ — *Йорт бит ул — гомерлек нәрсә.* Ә. Еники. *Гомерлек дустыңа онытылмас сүз әйтмә.* Мәкаль. // Үлгәнгә кадәр. *Гомерлек пенсия.* □ *Нурый карак --- гомерлек каторгагамы, Себергәме озатылган.* Г. Ибраһимов.

2. Мәңгелек. *Корыч төрәннәр, гомерлек ызаннарны җимереп ташлап, бәрәкәтле кара туфракны гайрәт белән*

әйләндереп салганда, күңелләрдә шатлык өермәсе кузгалды. Г. Ахунов.

3. *рәв. мәгъ.* **гомерлеккә.** Мәңгегә, бөтенләйгә. *Гомерлеккә иде бу аерылу.* С. Хәким. *Гомерлеккә истә кала моңлы җырың.* З. Мансур.

ГОМЕРЛЕЛЕК *и.* Гомерле булу. *Озын гомерлелек. Кыска гомерлелек.*

ГОМИНДАН *и. тар.* 1949 елгы Кытай халык революциясенә кадәр Кытайда власть башында торган, буржуазия һәм эре помещиклар мәнфәгатен яклаган контрреволюцион партия. *Гоминдан хөкүмәте.*

ГОМИНДАНЧЫ *и. тар.* Гоминдан тарафдары, гоминдан партиясен һәм гоминдан хөкүмәтен яклаучы.— *Гоминданчыларны үзегез беләсез, аркага пычак кадарга гына торалар.* А. Шамов.

ГОМОГЕН *с. физ., хим.* Үзенең составы,. үзлекләре һәм барлыкка килүе буенча бертөрле. *Гомоген система. Гомоген тигезлек.* // *лингв.* Бер сүздән барлыкка килгән, чыганагы уртак булган. *Гомоген омонимнар.*

ГОМУМ *и. иск.* Халык, халык массасы. *Бу шартны гомумне үзенә җәлеп итә алмаячаклыгы мәгълүм иде.* Ф. Әмирхан. *Чын татар йөрәгеннән чыгып, гомум тарафыннан сөеп, үз итеп кабул кылына алырлык көйләр — тик шулай гына булырга мөмкиндер дә.* Г. Ибраһимов.

ГОМУМ- 1. Уртак; барысы, бөтенесе өчен дә бер. *Гомумдәүләт милке.* □ *Дөньяда өр-яңа аваз... Гомумтавыш гармониясенә кушылды.* Р. Фәйзуллин.

2. Барысы өчен дә характерлы, барысына да кагылышлы. *Гомумаңлаешлы мәсьәлә.*

3. Иң әһәмиятлесен эченә алган, махсус түгел. *Гомумтеоретик мәсьәләләр.*

ГОМУМИ *с.* 1. Һәркемгә, һәрнәрсәгә караган; барысын да эченә алган. *Гомуми кимчелек.* □ *Мостафа төзәүнең гомуми кагыйдәләре белән таныштыра.* Ш. Камал. // Һәркем, һәркайсы өчен уртак, бердәм. *Бер ярты сәгатьтән соң инде ана бу палатадагы яралыларның гомуми аналары кебек якын булып китте.* А. Шамов. *Гомуми юнәлеш, иптәшләр, бер — Берлин.* Г. Әпсәләмов.

2. Кем белән дә булса бергәләп башкарыла торган, күмәк эшләнә торган. *Гомуми эшкә комачаулау.* □ *Һиммәтсезләр, сәүдәләренә бикләнәләр дә, гомуми эшләрнең һәммәсеннән качалар.* Ф. Әмирхан.

3. Иң төп, асыл билгеләргә генә караган, детальләргә кермәгән. [*Сажидә апа*] *«фәлән итәбез», «төгән итәбез» дип гомуми рәвештә әйтелгән сүзләргә җавап бирә белми иде.* Ә. Еники. // Аерым фактларга нигезләнеп гомумиләштерелгән. *Чехов иҗатына гомуми бер бәя бирү юлында М. Горький сүзләрен --- китерү бик урынлы булачак.* Г. Нигъмәти. / *рәв. мәгъ. Без монда мәсьәләгә хосусый итеп алмыйбыз, гомуми алабыз.* Ш. Камал.

4. Берләштерелгән; аерым кисәкләрне, группаларны үз эченә алган.— *Безнең гомуми отрядта хәзер өч йөзгә якын кеше бар.* Ш. Камал. // Бербөтен, тулы; бөтен, барлык. *Бу эш әле гомуми Россия микъдарында алганда да тиз вакытта гына кирәгенчә куелып җитә алмаячактыр.* Ф. Әмирхан. // Барлыгы, бөтенесе. *Гомуми саны.*

5. Уртача, чагыштырмача алынган. *Суның гомуми катылыгы. Гомуми табыш нормасы.*

6. Зур масштабтагы, тоталь. *Хәзергә миңа повестка юк һәм гомуми мобилизация дә юк.* М. Җәлил. *Татарда бу төркем исә гомуми реакция дулкыны сәбәпле төшенкелеккә бирелгән --- вак буржуа төркеме иде.* Г. Нигъмәти.

Гомуми белем мәктәбе — махсус профессия яки белем бирүне максат итеп куймаган, күпьяклы белем һәм тәрбия бирү мәктәбе. **Гомуми җыелыш** — аерым оешма яки коллективның барлык членнары катнашындагы җыелыш.— *Гомуми җыелышта колхоз җитәкчесенең отчетын тыңлыйк.* Г. Бәширов.

ГОМУМИЛЕК *и.* Гомуми булу. *«Нәшре мәгариф» җәмгыяте, уставының киңлеге вә максат итеп куйган нәрсәсенең гомумилеге белән, яшьләр өчен --- бик уңайлы организация булачактыр.* Ф. Әмирхан.

ГОМУМИЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. Һәркем өчен дә гомуми, уртак итү. *«Кызыл таң» колхозында сыер, сарыкларга чаклы гомумиләштергән булганнар.* С. Рафиков.

2. Аерым предметлар, күренешләр яки фактлардан, аларның төп, уртак сыйфатларыннан чыгып, гомуми нәтиҗә ясау. *Алдынгылар тәҗрибәсен гомумиләштерү.*

3. *әд.* Типиклаштыру. *«Шик» пьесасы Ш. Камалның тирәнтен гомумиләштерүне эченә алган синтетик сурәтләр бирү юлында җитди эшчәнлеген күрсәтә.* Г. Нигъмәти. // Аерым шәхесне түгел, ә гомумирәк характердагы кешеләрне бирү. *Тукай үзенең «Яңа Кисекбаш»ында Печән базарын гомумиләштереброк алса, Г. Камал --- ул почмакның иң данлыклы кешеләреннән хисапланган Мөхәммәтҗан хафизны ала.* М. Гали.

ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ: гомумиләштерүче сүз *лингв.*— җөмләнең тиңдәш кисәкләрен гомумиләштереп, алардан алда яки соң әйтелгән сүз.

ГОМУМИЛӘШҮ, ГОМУМЛӘШҮ *ф.* Уртак булу, уртак булып китү. // Гомуми кулланышка керү, халык арасында нык таралу, урнашу. *Халык теленда солдатка керүне аңлатканда «сикермә, малай, кызыл өйдән үтәсең бар әле!» дип әйтү дә гомумиләшеп бара.* Г. Ибраһимов.

ГОМУ'МЧӘ *рәв.* 1. Гомум, гади халык кебек, халыкча. *Гомумчә яшәү. Гомумчә кылану.*

2. Гади халык карашынча, халык фикеренчә. *Гомумчә бик кызыклы, бик шау-шулы вакыйгалар да аның тарафыннан һичбер илтифатсыз үтә алалар.* Г. Ибраһимов.

ГОМУ'МӘН *рәв.* 1. Тулаем алганда, аерым шәхес, индивид яки детальләргә кагылмыйча. *Бу китапта Габдулла өчен ачылып бетмәгән мәгънәләр, мифологик һәм классик мәгънәләр бар иде. Әмма алар аңа Пушкинны гомумән төшенергә комачауламадылар.* Ә. Фәйзи.

2. Һәрвакытта да, гел. *Ул гомумән шулай шат.*

3. *кер. сүз.* Нәтиҗә ясау алдыннан гомумиләштерү өчен китерелә: җыйнап әйткәндә. [*Идият*] *сүзне чамалап кына сөйли, күбрәк тыңларга ярата, гомумән, уяу, сак кеше булырга тиеш.* Ә. Еники.

4. *кер. сүз.* Нигездә. *Татар студиясе консерватория каршындагы милли студияләр арасында беренче булып үз эшен төгәлләде һәм ул эшенә, гомумән, югары бәя алды.* М. Җәлил.

ГОНГ *и.* 1. *муз.* Кырыйлары бөгеп эшләнгән металл тәлинкә (диск) һәм шуңа сугу өчен хезмәт итә торган агач тукмакчыктан гыйбарәт музыка коралы.

2. Элеп куелган рельс кисәге сыман тимергә яки металл тәлинкәгә сугу юлы белән бирелгән сигнал. *Лагерьда гонг яңгырый... Берничә минуттан барлык тоткыннарны сафларга тезәләр.* Г. Әпсәләмов.

ГОНДО'ЛА *и.* 1. Венециядә яссы төпле, каюталы бер ишкәкле көймә.

2. *авиа.* Дирижабльдә, аэростатта, стратостатта кешеләр утыру һәм механизмнарны, приборларны урнаштыру өчен җайланган урын.

3. *махс.* Түбәсе ябылмаган үзбушаткыч вагон.

ГОНОРАР *и.* Әдәбият, сәнгать яки журналистика белән шөгыльләнүчеләргә хезмәтләре өчен договор нигезендә бирелә торган акчалата түләү. *Яшел күзле машһүр шадра шагыйрь Бездә яза бөтен шигырен, Гонорары белән шул шигырьнең Каплый бара сыра чыгымын.* М. Җәлил.

ГОНҖӘ *и. иск.* Чәчәк бөресе; ачылып бетмәгән чәчәк. *Усә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.* Г. Тукай.

ГОПАК *и.* Украин халык биюе һәм шул бию көе

музыкасы. *Самат Мавияне чыгара. Бергәләп гопакка бииләр.* М. Фәйзи.

ГОРБУ'ША *и. зоол.* Сөләйман балыгы семьялыгыннан Ерак Көнчыгыш диңгезләрендә яши торган балык.

ГОРБӘТ *и. иск.* Ил гизеп, туган җирдән ераклашып, читтә каңгырып йөрү. *Ике ел буена горбәттә җәфалар, куркынычлар арасында каңгырып йөргән Төхфәт өчен бәләкәй өйнең --- почмагына килеп сыену күңеленә рәхәт бирә.* Ш. Камал.

ГОР-ГОР *аваз ияр.* Күләме зур булган су актарылып-актарылып кайнаганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Күлгә ширбәтне җибәргәч ыргытып, Башлады кайнарга күл гор-гор итеп.* Ш. Бабич.

ГОРГЫЛДАУ *ф. к.* голдырдау. *Сәгать «тек-тек» итеп һаман сөйли бирде, --- «Ай-яй!» дип горгылдап куйды әтәч.* Г. Галиев.

ГОРГЫЛДЫК *с.* Горгылдап торган, голдырдау тавышына охшаган. *Жаденко эре, тигез тешләрен күрсәтеп елмайды, горгылдык көчле тавыш белән көлеп куйды.* А. Гыйләҗев.

ГОРЕ'ЛКА *и.* Сыек ягулык яки газны кирәгенчә генә яндырып тору өчен махсус җайланган прибор.

ГОРЕФ *и.* Үз-үзеңне тотуда традицион ныгыган тәртип. *Һәрбер җан үз җенесенә тартып туар, һәрберсе үзе күргән горефен куар.* М. Гафури.

ГОРЕФ-ГАДӘТ *җыйм. и.* 1. Билгеле бер халыкның тарихи үсеш традициясе белән килә торган, көнкүрешкә караган яки дини йолалар. *Татар халкының этнографиясе, гореф-гадәтләре һәм йолалары белән кызыксынып йөри торган бу кызыклы профессор белән Габденнасыйр --- Ибраһим Хәлфин өендә танышкан иде.* М. Гали.

2. Гадәт, тәртип. *Сөләйман бу «кафе»дә еш кына булганлыктан, аңа мондагы барлык гореф-гадәт таныш иде.* К. Тинчурин.

ГОРЖЕ'Т(КА) *и.* Яка урынына муенга салып йөртә торган мех. *Көя төшкән төлке горжетлы, ябык, котсыз шул --- хатынны Җәгъфәр терсәге белән авырттырырлык итеп этеп җибәрде.* А. Расих.

ГОРИЗОНТ *и.* 1. Күз күреме кадәр җир, ераклык, күзәтүчегә күк гөмбәзенең җир белән тоташкан булып күренгән сызыгына кадәрге аралык. *Бераздан соң горизонттагы атлылар яңадан күздән югалдылар.* А. Шамов. *Диңгез өсте зәңгәр киндер төсле, горизонты күктә тоташкан.* Ә. Ерикәй.

2. Күк гөмбәзенең түбәнге, җиргә якын өлеше. *Горизонттан кояш күренә башлау белән алар тагын матурланачаклар әле.* М. Гали.

3. *күч. кит.* Киңлек, зур күләмлелек, киң колачлылык. *Үзендәге кечкенә көзге ватыкларын да тиз һәм җиңел рәвештә йөртә белеп, шуларның һәркайсында тормышның яңа бер ягын ачык итеп чагылдыра, шул кечкенә парчаларда ераккка сузылган тормыш горизонтларын ул күрсәтә ала иде.* Г. Нигъмәти. // Фикерләү, белем, дөньяга караш киңлеге. *Үй горизонтын үстерү.* // Мөмкинлекләр, эш итә алу киңлеге. *Авиаторлар, ичмасам, канатлы кешеләр, ди. Аларның горизонтлары да, колачлары да киң.* Г. Әпсәләмов.

4. *махс.* Елга, сусаклагыч яки күлләрдә су өстенең биеклеге. *Горизонтның күтәрелүе. Шартлы горизонт.*

5. *геол.* Билгеле бер тирәнлектә файдалы казылмалар рәтен кисеп үтә торган җир асты катлавы, горизонталь катлау. *Бу якның горизонтлары, иптәш Хәйров, --- төрле районда төрле тирәнлектә булуы мөмкин.* А. Әхмәт.

Горизонт сызыгы — күк гөмбәзенең җир яки су өсте белән тоташкан кебек булып тора торган сызыгы; офык сызыгы. [*Даланың*] *көнбатыш ягында, горизонт сызыгында, Оренбургның корпуслары, биек өйләре, чиркәүләре күренә.* Ш. Усманов.

ГОРИЗОНТАЛЬ 1. *с.* Горизонтка параллель урнашкан, ятма; *киресе:* вертикаль. *Горизонталь хәлдә калу.*

2. *и.* Горизонт яссылыгына параллель түры сызык. *Горизонталь үткәрү.*

3. *и. геод.* Картада бердәй биеклектәге урыннарны күрсәткән ноктaларны тоташтыра торган кәкре сызык.

ГОРИЗОНТАЛЬЛЕК *и.* Горизонталь (1 *мәгъ.*) булу.

ГОРИ'ЛЛА *и. зоол.* Көнбатыш Африкада яши торган зур гәүдәле, кешесыман маймыл.

ГОРКОМ (городской комитет) *и.* Шәһәр комитеты. *КПСС горкомы секретаре.* □ *Горком бюросына эзләнү* [*Гөлшаһидәнең*] *бөтен вакытын алды.* Г. Әпсәләмов.

ГОРМОН *и. физиол.* Эчке секреция бизләре бүлеп чыгара һәм теге яки бу органның эшчәнлеген көчәйтеп җибәрә торган матдә. *Үсү гормоны.*

ГОРМОНАЛЬ *с.* Гормонлы, үзендә гормоны булган. *Гормональ препарат. Гормональ матдә.* // Гормонга бәйләнешле. *Димәк, карындагы микробларның эшчәнлеге калкансыман бизләрнең гормональ функциясенә бәйләнгән.* А. Расих.

ГО'РНА *и* 1. Тимерче учагы.

2. Домна миченең аскы өлеше. *Тик тимерләр, горна дәһшәтеннән, Әйләнәләр йомшак камырга.* М. Крыймов.

ГОРНОВОЙ *и. махс.* Горна (2 *мәгъ.*) эшчесе, горна янында эшләүче эшче. [*Сөнгатулла бабай*] *Урал якларында горновой булып эшләп йөргән.* М. Шабай.

ГОРНЯК *и.* Тау промышленностенда эшләүче. *Горняклар шәһәрчеге.*

ГОРОДНИ'ЧИЙ *и. тар.* Россиядә XIX йөз урталарына кадәр: шәһәр башлыгы. *Кариев* [*Хәмзә бай*] *ролен «Ревизор»дагы городничийны хәтерләтерлек итеп күрсәтә.* И. Рәмиев.

ГОРОДОВОЙ *и. тар.* Патша Россиясендә: шәһәр полициясенең түбән чины. *Күзләрен кан баскан городовойлар Безнең өйгә кереп тулалар.* М. Җәлил.

ГОРСОВЕТ (городской совет) *и.* Хезмәтияләре депутатларының шәһәр Советы. *Икенче көн Әхмәт иртүк тагын горсоветка барды.* Ш. Камал.

ГОРТЕ'НЗИЯ *и.* Төрле төсләрдәге эре сеңшма чәчәкле декоратив үлән үсемлек.

ГОРУР 1. *с.* Үз дәрәҗәсен белеп эш итә торган, дәрәҗәсенә кимчелек китерми торган. *Ара-тирә йөзенә җәелә торган тыныч һәм горур бер салкынлыкка күзләр төшеп,* [*Нәфисә*] *Хәйдарнең ул вакытта башыннан ниләр узуын --- күз алдына китерде.* Г. Бәширов. // Мәһабәт, мәгърур (үзен тотышында, тышкы кыяфәтендә). [*Мостафинда хәзер*] *таза көчле иргә хас элекке мәһабәт сын, горур килбәт юк инде.* Ә. Еники.

2. *с.* Батыр, кыю; батырларча. *Ни булса да, горур үлем бит ул Европаның урта өлешендә.* А. Алиш. / *рәв. мәгъ. Кайчандыр бу тауларда горур атлап Пугачев йөргән.* А. Әхмәт. // Мәгърур, баш имәс. *Шуңар синең горур йөрәгеңдә Сөенү дәрте ярсып ташкандыр.* М. Җәлил.

3. *с.* Тәкәббер; мактанулы, масаюлы, һавалы. *«Менә хаты»,— дип өстәде Гайнулла шатлыклы һәм горур тавыш белән.* А. Әхмәт. / *рәв. мәгъ. Ул, алдан ук, бу сүз көрәштерүдә үзенең җиңеп чыгасын сизгән кебек, симез казахка горур гына карап куйды.* Ә. Фәйзи.

4. *и. к.* горурлык (1 *мәгъ.*). *Син кайвакыт үзеңнең урынсыз кибер вә горурың белән мине рәнҗеткәли идең.* Ф. Әмирхан. // Горурланырлык нәрсә. *Юк бит бер нәрсәң дә: горурың да, милләтең дә, халкың, Ватан да!* Н. Исәнбәт.

5. *и. к.* горурлык (2 *мәгъ.*). [*Жиһаншаның*] *бу вакытка кадәр ни уйлаганы була килде, шул сәбәпле горуры артты.* З. Һади.

ГОРУРАНӘ *рәв. иск.* Горур рәвештә. *Эшчеләр --- сөнгеләрен горуранә югары күтәреп, социализм һәм ком-*

мунизм дөньясына юл ачарга ашкыналар. Ф. Сәйфи-Казанлы.

ГОРУРЛАНУ *ф.* 1. Горурлык хисен, башкалардан ким булмавын тою, үз дәрәҗәсен белү. *Хәзер инде Шәрифулла үзенең осталыгы белән масаймый, ә хаклы рәвештә горурлана гына.* А. Шамов. // (Кем, нәрсә белән) хаклы рәвештә мактану. *Емельянов: «Менә,— диде,— Безнең ударнигыбыз, Шулар белән горурлана Безнең туган илебез».* М. Җәлил. // Уңышлардан канәгатьлек хис итү. [*Яңа авыл кешеләре*], *эш беткәч, горурланып кайтып китте Авылдагы мәктәп белән клубына.* М. Гафури.

2. Тәкәбберләнү; масаю, һавалану. *Бу үз һөнәре белән горурланырга яраткан картны чиксез ачуландырды һәм җәберсетте.* Г. Әпсәләмов. *Көчлелегең белән горурланма, кешелегең белән горурлан!* М. Җәлил.

ГОРУРЛЫ *с. к.* горур (1—3 *мәгъ.*). *Безнең чын иманлы, горурлы иптәшләребезнең берсе сатлык иман колларының меңен каушата ала.* М. Фәйзи. *Карт кәҗә --- горурлы мактану белән дөньяга карый, тик масаеп сакалын гына сыйпап куймый.* Ә. Еники.

ГОРУРЛЫК *и.* 1. Горурлану хисе, үзеңә хөрмәт хисе, үз дәрәҗәңне тою.— *Миндә, аз гына булса да, хатын-кыз горурлыгы булырга тиеш бит, ахрысы!* Р. Ишморат. // Хаклы рәвештә мактану, канәгатьлек хисе. [*М. Гафури*] *«Чит ил кунаклары» дигән шигырендә, СССРга килүче эшче делегатларга карап, горурлык белән, Совет иле уңышларын сөйли.* М. Җәлил.

2. Үзен башкалардан өстен тою хисе, масаю, һавалану хисе, тәкәбберлек. *Дүрт ел мәдрәсәдә укып, мин күпне беләм инде, дип йөргән Габдулланың горурлыгына китереп сукты бу.* Ә. Фәйзи.

3. *сөйл.* Мактаныч. *Ул бит безнең колхозның горурлыгы.*

ГОРЧИ'ЦА *и.* 1. *бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан кузаклы үлән үсемлек. *Җемелдәшеп калды... Горчицаның сары киңлекләре, люцернаның калын юрганы.* Ш. Мөдәррис. // Шул үсемлекнең орлыгы. // *с. мәгъ.* Шуннан эшләнгән. *Горчица мае.*

2. Горчица орлыгын төеп ясалган порошок һәм шул порошоктан әзерләнгән аштәмләткеч.— *Син бит кайсы вакытта, керән,* [*горчица*] *шикелле әче булып, бөтенләй күзләремнән яшьләр китерә торган идең.* Г. Камал.

ГОРЧИ'ЦАЛАУ *ф.* Горчица (2 *мәгъ.*) белән тәмләтү, горчица салу.— *Китерергә Астраханьнан бик күп балык, Ашарга горчицалап һәм дә суйлап (соуслап).* Г. Камал.

ГОРЧИ'ЧНИК *и. мед.* Бер ягына горчица (2 *мәгъ.*) ягылган материя яки кәгазь; медицинада кан йөрешен көчәйтү өчен тәнгә ябып дәвалау чарасы итеп куллана.

ГОРЫЛДАУ *ф. к.* голдырау. *Әхмәт сүз арасында тамак кырып, күркә төсле горылдап куя.* М. Гафури.

ГОС- Дәүләт төшенчәсе белән бәйләнгән кушма сүзләрнең беренче кисәге.

ГОСБАНК *и.* Дәүләт банкысы. *Кассир Гыймай кичә бездә булды, Госбанктан кайтып барышлый.* М. Җәлил.

ГОСЕЛ: госел бүлмәсе — *к.* госелханә. [*Кәрим*] *госел бүлмәсендә тәһарәт яңартам.* Т. Гыйззәт; **Госел коену** *иск.*— чистарыну, юыну, бөтен тәнне юу — ритуаль коену.— *Ышанмыйсың икән, мәсәлән, күз алдыңда госел коенып ант итәрмен.* Ф. Әмирхан.— *Басуга чыгып, госелләр коенып, намазлар укып, тәүбәләр итеп --- яңгыр боткасы пешереп карадык, ди.* М. Гали.

ГОСЕЛХАНӘ *и. иск.* Госел коену бүлмәсе, тәһарәт бүлмәсе. *Алар, комганнар, кәвешләр тулган госелханәне үзып, арткы юлдан ишек алдына чыктылар.* А. Расих. *Ике почмакта тактадан ясалган ике госелханә бар.* Г. Ибраһимов.

ГОСКОНТРОЛЬ *и.* Дәүләт контроле. *Һич көтмәгән җирдән госконтроль кешеләре килеп, ОРСның бөтен системасында зур ревизия үткәрергә керештеләр.* Ә. Еники.

ГОСМАНЛЫ *и. тар.* Төрек халкының элеккеге исеме. *Анатолиядә госманлылар, Кавказның җәнүбендә әзербәйҗаннар --- үзләренең башкалардан аерым тормышларын төзеделәр.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Госманлы халкына караган, аңа мөнәсәбәтле. *Г. Тукай да әле үзенең беренче шигырьләрен гарәп, фарсы сүзләре белән чуарланган ярым госманлы телендә язды.* М. Гали.

ГО'СПИТАЛЬ *и.* Хәрбиләр өчен больница. *Берничә сәгатьтән соң госпиталь яңа яралыларны кабул итәргә тотынды.* Г. Әпсәләмов. *Батыржан* [*яраланып*] *госпитальгә кергән икән.* Ә. Еники. *Госпитальгә керүенең дүртенче көнендә авыруым аңын югалтты.* Г. Кутуй.

ГОСТИ'НИЦА *и.* Читтән килүчеләргә вакытлыча тору өчен махсус җиһазландырылган бүлмәләре булган йорт. *Аларны шәһәрнең иң яхшы гостиницасына урнаштырдылар.* Г. Әпсәләмов.

ГОСТИ'НЫЙ: гостиный двор *тар.*— шәһәрдә шәхси сәүдә кибетләре рәте. *Хәлил Галиевнең гостиный дворда кызыл мал кибете бар.* Ф. Әмирхан.

ГО'ТИК *с.* Готикага мөнәсәбәтле. *Боларның уң якларысы Византия стиленә тартым, куполлап эшләнгән, сул яктагысы тешләк башнялары белән готик стильне дәгъвалап маташа иде.* Ш. Камал.

Готик шрифт (хәреф) — хәрефләрне почмаклап, сындырып-сындырып язу формасы. [*Тикшерүче Мусаның*] *һәр җавабын гаять бөтеркәле готик хәрефләр белән бер дә ашыкмый гына язып чыкты.* Ш. Маннур.

ГО'ТИКА *и. архит.* Европада XII—XV гасырларда очлы гөмбәзләр, аркалар һәм төрле орнаментларга бай булган архитектура стиле. *Готика сәнгате.* // *с. мәгъ.* Готик стильдә эшләнгән. *Төрмәгә охшаулы авыр, салмак, караңгы роман чиркәүләре готика чиркәүләренә алмаша барганнар.* Г. Гали.

ГОТОВА'ЛЬНЯ *и.* Футлярга урнаштырылган сызым инструментлары җыелмасы. [*Карповның*] *кул астында готовальнясы, өчпочмак, лекало кебек сызым приборлары --- ята иде.* М. Әмир.

ГОФР, ГОФРЕ *и.* Тукыма, калай, кәгазь кебек нәрсәләргә ясалган бөкләмле дулкын сыман тигез параллель сырлар.

ГОФРЕЛАУ *ф.* Гофре ясау, сырлау. *Гофрелап тегелгән күлмәк.*

ГОФРЕЛЫ *с.* Гофреланган, сырлы.

ГОШЕР *и. иск. дини.* Керемнең, уңышның уннан бер өлеше: мулла яки мәчет файдасына җыйнала торган җыем.— *Гошер түлә, ураза тот, Гөнаһларыңны ипләү.* М. Җәлил.— *Бу көнгә чаклы биргән гошерләремә дә үкенәм.* М. Гафури.

ГРАВЁР *и.* Граверлау эше белән шөгыльләнүче, граверлау остасы.

ГРАВЁРЛАУ *ф.* Металлга, сөяккә яки агачка чокып рәсем ясау, бизәкләү.

ГРАВЁРЛЫК *и.* Граверлау эше. / *с. мәгъ. Граверлык сәнгате.*

ГРА'ВИЙ *и.* Төзү һәм юл эшләрендә кулланыла торган вак таш. [*Юллар*], *тигезләп, грейдер белән юнып алынып, вак таш һәм гравий җәелеп ныгытылган.* М. Хәсәнов.

ГРАВИТА'ЦИЯ *и.* Бөтендөнья тартылышы; җисемнәрнең, материянең үзара тартылу үзлеге.

ГРАВЮ'РА *и.* 1. Нинди дә булса каты әйбернең (металл, агач, пыяла һ. б.) шома өсйөзенә чокып ясалган рәсем.

2. *полигр.* Кәгазьгә рәсем төшерү өчен чокып ясалган клише һәм шундый клишедан төшерелгән рәсем.

ГРАДА'ЦИЯ *и. кит.* Предмет яки күренешләрдә бер хәлдән икенчесенә күчкәндә үсә яки кими бару тәртибендәге эзлеклелек. *Градацияләр, гомумән, төрле фигуралар монда юк диярлек дәрәҗәдә аз.* Г. Нигъмәти.

ГРАДИ'РНЯ *и.* Пар корылмаларында кайнар суны суыту җайланмасы. *Еракта, әллә кайларда булып күренгән газ-бензин заводының градирнясыннан аксыл пар күтәрелә.* Г. Ахунов.

ГРАДУИРЛАУ *ф.* Градусларга бүлү; градуслы шкала ясау, кую. *Градуирланган көпшә.*

ГРА'ДУС *и.* **1.** Почмак һәм дугаларны үлчәү берәмлеге: түгәрәкнең яки ноктa тирәлегенең 360 тан бер өлеше. *Корткыч [йомран] тишек авызыннан 15—20 градус сөзәк юл ясап, бер метр чамасы аска төшкән.* Г. Гобәй. // *геогр.* Җир шарының меридиан һәм параллельләренең 360 тан бер өлеше.

2. Температураны үлчәү берәмлеге. *Борчак участогына барып төшкәндә, термометр нәкъ өч градус күрсәтә иде.* А. Алиш.

3. Исерткеч эчемлекнең исертү көчен яки сыекчаның тыгызлыгын үлчәү берәмлеге. *[Гыймади эчемлекле стаканны сузып:] Градусы кимегәнче тотыйк әле. Туй хөрмәтенә!* Ю. Әминов //*күч.* Эчемлекнең гайрәте, исертү көче. *Безнең газиз башларга сеңгән банкет градуслары төрлесе төрле якка очып таралды.* В. Монасыйпов.

ГРА'ДУСЛЫ *с.* **1.** Күпмедер градуска ия булган. *45 градуслы почмак. 40 градуслы коньяк.* □ *Кызыл гвардия январь аеның утызар градуслы салкын көннәрендә Дутов юнкерларын җиңде.* Ш. Усманов.

2. *сөйл.* Югары градуска ия булган, куәтле (эчемлек турында). *Исән калсын --- таш моржалы, градуслы сыра заводың.* М. Җәлил.

ГРА'ДУСНИК *и.* Температураны үлчәү приборы. *[Палата докторы] кулымны карады, култык астына градусник куйды.* Г. Ибраһимов.

ГРА'ЖДАН *и.* Билгеле бер дәүләтнең законнары белән тәэмин ителгән хокукларыннан файдаланучы һәм законда каралган бурычларын үтәүче, шул дәүләттә даими яшәүче кеше. *Советлар Союзы гражданы.*

Гражданнар сугышы — бер дәүләтнең үз эчендә сыйныфлар арасында барган кораллы көрәш, сугыш. *Гражданнар сугышы елында Урта Азиядә Тянь-Шань таулары арасында булдым.* Т. Гыйззәт.

ГРАЖДАНИН *и.* 1. Граждан (ир кеше). *И Россия, үстем синдә туып, Чит күрмәдең газиз улыңны; Гражданиның һәм солдатың булып Уздым бөтен гомер юлымны.* Г. Хуҗиев.

2. Ир-атка мөрәҗәгать итү сүзе. *[Парикмахерлар:] Пожалуйста, гражданин! — дип сөеп каршы алдылар.* Һ. Такташ.

ГРАЖДА'НКА *и.* **1.** Граждан (хатын-кыз). *Һәрбер илдәге, мәмләкәтләрдәге хатыннар тигез хокуклы гражданка булсалар, --- ни өчен татар хатыннары гражданка була алмыйлар?* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. Хатын-кызга мөрәҗәгать итү сүзе.— *Хәерле юл сезгә, хөрмәтле гражданка!* Г. Гобәй.

ГРАЖДАНЛЫК *и.* **1.** Граждан булу. *[Мөхсинов] үзендә гражданлык, патриотлык, гомумән кешелек тойгыларының ташып баруын тойды.* М. Әмир. *Һәркем изге гражданлык бурычын үтәргә тиеш.* Т. Гыйззәт.

2. Нинди дә булса бер дәүләт кешесе булу, шуның гражданы булу хокукы. *Гражданлык кабул итү.*

3. Хәрби булмаган, гадәти тормыш. *Фронт тирәсендәге чын тормыш алай ук уңайлы түгел. Без аны гражданлык шартларында икенче төрлерәк күз алдына китерәбез.* М. Җәлил.

Гражданлык итү (сөрү) — гамәлдә булу, актив кулланышта булу. *Алар арасында гади кием гражданлык сөрүе күзгә ташлана.* Г. Гали. **Гражданлык хәле актларын язу бюросы, гражданлык бүлеге** — башкарма комитетның туу, үлү, өйләнешү, аерылу фактларын теркәү бүлеге; *к. загс. 17 сентябрьләрдә гражданлык бүлегенә килеп, бер-берсе белән иптәшлек бәйләнешенә ризалык бирделәр һәм таныклык кәгазьләре алдылар.* Ф. Бурнаш.

ГРАЖДА'НСКИЙ *с.* Гражданнарга хас, хәрби булмаган, хәрби түгел. *Залдагы өстәлләр тирәсендә кайсы гражданский кием, кайсы эсэчылар формасы кигән исерекләр утыра.* Ә. Исхак.

ГРАЖДАНЧЫЛЫК *и.* Үз иленең яки сыйныфының гражданы, патриоты булу. *Тукай поэзиясенең халыкчанлыгы — аның намуслы гражданчылыгында, кеше сөючелегендә, социаль пафосында, халык тормышы белән шагыйрьнең бергә яшәвендә.* Г. Халит.

ГРАММ *и.* Метрик системада бер куб сантиметр суның авырлыгына тигез үлчәү берәмлеге. *Капчыгыннан ул йөз грамм яхшы чәй белән бер кило чамасы шикәр чыгарды.* А. Шамов.

ГРАММА'ТИК I *и.* Грамматика белгече; грамматика дәреслекләре язучы.

ГРАММА'ТИК II *с.* Грамматикага мөнәсәбәтле. *Грамматик хаталар.*

ГРАММА'ТИКА *и.* **1.** Тел гыйлеменең сүз һәм җөмлә төзелешен өйрәнә торган тармагы: морфология һәм синтаксис бүлекләреннән тора. *Чагыштырма грамматика. Тарихи грамматика.*

2. Аерым телнең сүз һәм җөмлә төзелешенә караган кагыйдәләр җыелмасы. *Хәзерге татар теле грамматикасы.* □ *Костя аңа рус теленең грамматикасын, имля кагыйдәләрен өйрәтте.* Г. Әпсәләмов. // Шундый кагыйдәләр тупланган китап, дәреслек. *«Менә шушы китапны язган кеше кебек буласым килә минем»,— диде Габделкаюм, Ибраһим Хәлфиннең грамматикасын тотып күрсәтеп.* М. Гали.

ГРАММЛАП *рәв.* **1.** Граммнар белән. *Сайлап кына салган эре бөртекле сигез мең орлык. Моннан соң әле боларны граммлап кына үлчисе бар.* Г. Бәширов.

2. Аз-азлап, бик азлап. *Потлап таратсаң, граммлап җыярсың.* Мәкаль.

ГРАММЛЫ *с.* **1.** Граммнар белән үлчәнә, исәпләнә торган. *Граммлы әйберләр.*

2. Саннан соң килгәндә: шулкадәр грамм авырлыгындагы. *Йөз граммлы гер.*

ГРАММОФОН *и.* Махсус пластинкага элек язылган тавышны (музыка әсәрен яки речьләрне) кабат тыңлауны тәэмин итә торган рупорлы музыкаль аппарат. *Ара-тирә ерактан граммофон тавышлары ишетелә.* Г. Камал.

ГРА'МОТА *и.* **1.** Укый һәм дөрес яза белү. *Габденасыйр шунда өч кыш укып, яхшы гына русча сөйләшергә һәм русча грамотага өйрәнде.* М. Гали. // Мәгълүмат; башлангыч гомуми белем.— *Грамотаң чамалы синең, политический грамотаң чамалы.* Р. Ишморат.

2. Яхшы эш яки уңышлар өчен бүләкләү билгесе **итеп бирелгән документ.** *Мактау грамотасы.* □ *Берәвенә әле үткән көз генә район выставкасыннан грамота бирделәр.* К. Нәҗми.

ГРА'МОТАЛЫ *с.* **1.** Укый-яза белә торган. *Грамоталы кеше.* // Дөрес язылган яки эшләнгән; яхшы сыйфатлы. *Музыкаль яктан грамоталы итеп эшләнмәгән булулары [бу әсәрләрне] татар балалар музыкасын тудыруда [җитди] адымнар итеп карарга мөмкинлек бирми.* М. Җәлил. // Теге яки бу өлкәдә мәгълүматы, тәҗрибәсе, белеме булган.— *Бригадир әле җитмәсә --- грамоталы бригадир.* Ф. Бурнаш.

2. Грамотасы (2 *мәгъ.*) булган, грамота алган.

ГРА'МОТАЛЫЛЫК *и.* Грамоталы булу, укый-яза белүчелек.

ГРАН *и. мед.* Метрик система кабул ителгәнгә кадәр кергән аптека үлчәве берәмлеге: 0,062 граммга тигез.

ГРАНАТ *и.* I *бот. к.* анар. *Җылы якка карап кошлар оча --- Анда яңа пеште гранат.* М. Җәлил.

ГРАНАТ II *и. махс.* Асылташның бер төре: коңгырт кызыл, куе кызыл төстә, бик үк затлылардан саналмый. *Гранат муенса.*

ГРАНА'ТА *и. хәрби.* Шартлап ярыла торган артиллерия снаряды. *Менә саргылт ут бөркеп, бик каты шартлап, граната ярылды.* А. Шамов. // Кул белән ыргытыла торган зур булмаган шартлагыч снаряд; кул гранатасы. *Атарга патроны, ыргытырга гранатасы калмагач кына, яраларыннан хәлсезләнеп егылгач кына, дошманнар аның янына килә алганнар.* Г. Әпсәләмов.

ГРАНАТОМЁТ *и. хәрби.* Артык зур булмаган арага гранаталар ата торган сугыш коралы. *Автомат, гранатомёт кебек яңа корал алган яшь сугышчылар аеруча тырышалар.* Каз. утл.

ГРАНАТОМЁТЧЫ *и. хәрби.* Гранатомёттан атучы.

ГРАНД *и.* 1931 елга кадәр Испаниядә югары дәрәҗә дворян титулы. // *күч.* Гомумән аристократ, аксояк.

ГРАНД- Кушма сүзләрдә беренче урында килеп, югары дәрәҗәле яки зур дигән мәгънәләрне бирә. *Гранд-опера.*

ГРАНДИОЗ *с.* Үзенең күләме, көче, әһәмияте буенча гаять зур. *Грандиоз корылмалар.* □ *КПСС Үзәк Комитеты Пленумнары турында, аларның халык алдында грандиоз планнар билгеләве турында сөйли Яруллин.* М. Хәсәнов.

ГРАНДИОЗЛЫК *и.* Грандиоз булу. *Социалистик төзелешнең грандиозлыгы.*

ГРАНИТ *и.* Составында кварц, кыр шпаты, слюда булган иң каты тау токымы. *Җимереп үткән Аркылы яткан гранит тауларын, Җырларында: «Мин ирекле, Миндә көч»,— дип җырлаган, Җырларын таулар Дерелдәп тыңлаган.* Н. Исәнбәт. // *күч.* Көч, ныклык символы. *Москва гранит! Дошман, теше белән бергә, шунда Муеның сындырды.* Ә. Ерикәй.

ГРАНИТЛЫ *с.* Граниттан торган; граниттан ясалган; гранитка мөнәсәбәтле. *Анда яңа шлюзлар юлы казыла — күксел гранитлы ярларда.* Ш. Маннур.

ГРА'НКА *и. полигр.* Типографиядә җыелып, әле битләргә салынмаган набор. // Шул наборның кәгаздәге күчерелмәсе. *Безнең мыдыр-мыдыр гранка укуыбыз [күршеләргә] аермачык ишетелеп тора иде.* Ф. Хөсни.

ГРАНОЗАН *и. а.-х.* Чәчүлек орлыкларны эшкәртү, кайбер авыру тудыручы микробларны агулау өчен кулланыла торган препарат. *Гранозан һәм гексахлоран сибелгән, яхшылап калибрланган орлыклар 6—7 см тирәнлеккә күмдерелә.* М. Хәсәнов.

ГРАН-ПРИ *и.* Ярышта беренчелек; җиңүчегә бирелә торган иң зур бүләк. *Җыр буенча ярыш уздырылса Җир шарында барлык кошларга, Булыр иде сиңа гран-при Кошлараra конкурсларда.* Р. Әхмәтҗанов.— *Әгәр телләр выставкасы булып, анда иң авыр телләргә хосусый [бүләкләр] бирелә торган булса, минемчә, рус теле гран-при алыр иде.* Ф. Әмирхан.

ГРА'НУЛА *и. махс.* Оерша, төерсыман хәлендәге тыгыз вак бөртекләр.

ГРАНУЛАЛАУ *ф. махс.* Оерша, төерчексыман хәлгә китерү.

ГРАНУЛАЛАШТЫРУ *ф. к.* гранулалау. *Утыз тонна черемгә ике центнер аммоний сульфаты, хлорлы калий һәм бер центнер чамасы гранулалаштырылган суперфосфат кертелә.* М. Хәсәнов.

ГРАНУЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. *к.* гранулалау.

2. Кояш өслегенең бөртексыман, төерчекләнеп күренүе.

3. *мед.* Яра төзәлеп, аның урынына яңа ит үсү. *Беренче операцияне [кәҗә] әйбәт уздырган иде... Грануляция тиз арада булды, хайван нормага тиз кайтты.* А. Расих.

ГРАФ *и.* Революциягә кадәрге Россиядә һәм хәзер дә Көнбатыш Европада дәрәҗәсе буенча князь белән барон арасындагы дворянлык титулы. // Шул титулга ия булган кеше. *Әйдә, граф хакына Җырлагыз шат җырлар.* М. Җәлил. *Ставканы шартлатып, фюрерны дөмектерергә теләүче кеше граф фон Штауфенберг дигән берәү булган.* Н. Дәүли.

ГРАФА *и.* Таблицаларда, эш кәгазьләрендә яки контора кенәгәләрендә: ике вертикаль сызык арасындагы багана яки полоса. *Кенәгәдәге графаларга саннарны көчкә-көчкә генә куеп өлгерә.* Ф. Хөсни. *Атасы кем дигән графадан ялгызак дигән сүз ярылып ята.* Г. Гобәй.

ГРАФАЛАУ *ф.* Графалар сызу, графаларга бүлү, аеру. *Уткән елдан калган недоимкалар бик әйбәтләп, графалап язып куелган иде.* Ә. Еники.

ГРАФАЛЫ *и.* Графаларга бүленгән, аерылган. *Графалы кәгазь.*

ГРА'ФИК I *и.* 1. Төрле процессларның сан бәйләнешләрен кәкре сызыклар ярдәмендә күрсәтә торган диаграмма, сызым. *Һава температурасы үзгәреше графигы (метеор.). Тигезләмә графигы (мат.).*

2. Күләме һәм үтәлү вакыты анык күрсәтелгән эш планы. *Бригадаларда сәгатьле график белән эшләүне кертү турында --- сүз булды.* Ф. Хөсни.

ГРА'ФИК II *и.* Графика (1 *мәгъ.*) өлкәсендә эшләүче рәссам.

ГРА'ФИК III *с.* Графикага (2 *мәгъ.*) мөнәсәбәтле. [*Орфографиядә*] *әдәби телдә ишетелгәнчә язу төп кагыйдә итеп алына. Шуның өстенә, кирәк урыннарда, морфологик, тарихи-традицион һәм график принциплар да кире кагылмый.* Х. Курбатов.

ГРА'ФИКА *и.* 1. *сәнг.* Буяусыз, сызыклар һәм штрихлар белән генә рәсем ясау сәнгате. // *җый.* Шундый сәнгать әсәрләре.

2. *лингв.* Язу, хәрефләрнең язылу рәвеше. *Рус графикасы белән язу. Латин графикасы. Рус графикасы нигезендәге яңа алфавит.*

ГРАФИН *и.* Су яки эчемлек салып тоту өчен кулланыла торган тар муенлы пыяла яки хрусталь савыт. *Ул Маратка графиннан су --- салып эчерде һәм, тәмәке төтенен куа-куа, тагын форточка янына килде.* Г. Гобәй.

ГРАФИ'НЯ *и.* Графның хатыны яки кызы. [*Разия*] *графинялар кебек башын арткарак салып утырган.* Г. Ибраһимов.

ГРАФИТ *и.* Кара яки коңгырт төстәге минерал, кара таш; электротехник әйберләр, уткә чыдам футляр, карандаш үзәге һ. б. ясау өчен кулланыла. // *с. функ.* Шушы минералдан эшләнгән. *Шырт иттереп сындырды графит карандашны.* А. Гыйләҗев.

ГРАФЛЫК *и.* 1. Граф булу.

2. Граф кул астындагы җирләр, граф биләмәләре.

ГРАФО'ЛОГ *и.* Графология белән шөгыльләнүче кеше. [*Немец тикшерүчесе*] *каллиграф һәм графологлар тапты, --- үз консультациясендә шушы документны әзерләтте.* Ш. Маннур.

ГРАФОЛО'ГИК *с.* Графологиягә мөнәсәбәтле. *Графологик метод.*

ГРАФОЛО'ГИЯ *и.* Кешенең характеры белән язу рәвеше (почеркы) арасындагы бәйләнешне өйрәнү эше, шулай ук язу рәвешеннән чыгып, кешенең характерын, сәләтен билгеләргә мөмкин дип раслый торган ялган теория.— *Графология белән соңрак мавыгырсың. Уйлыйк.* А. Гыйләҗев.

ГРАЦИОЗ *с. юг.* Грацияле, нәзакәтле. [*Салават*] *әйтерсең грациоз бер бию башкара, әйтерсең гомер буе чаңгыда йөрергә дип яратылган зат.* Г. Ахунов.

ГРА'ЦИЯ *и. юг.* Хәрәкәт һәм кыяфәтнең, гәүдә төзелеше һәм торышының гүзәллеге, нәзакәтлеге.

ГРА'ЦИЯЛЕ *с. юг.* Гүзәл, матур, нәзакәтле. *Комбинезонлы яшь илаһлар, алиһәләр, Җирдән күккә йөртеп*

грацияле кулларын, Ак оҗмах сала пыяладан, кирпечтән. Ә. Давыдов.

ГРЕ'ЙДЕР *и.* Грунт юлларны тигезли һәм канаулар казый торган тагылма машина. *Кукуруз [кыры] янында грейдер озынча тирән чокыр казыды.* Н. Фәттах. *Каршы якtан, юлны тигезләп, грейдер таккан трактор шаулап килә.* Г. Әпсәләмов.

ГРЕК *и.* Грециянең төп халкы һәм шул халык вәкиле, кешесе. *Борынгы бер грек ораторының, диңгез буена барып, [речен] дулкыннарга сөйләп өйрәнүен Хәлим тарихтан укып белә иде.* И. Гази. / *с. мәгъ. [Лувр музеенда] грек [сәнгате] белән чынлап танышырга була.* Г. Гали.

ГРЕ'ЛКА *и. мед.* Эченә кайнар су салып, тәннең аерым өлешен җылыту өчен кулланыла торган махсус резин савыт; җылыткыч. *Әле су җылытып грелка бир аңа, әле ястыгын икенче якка әйләндереп кабартып бир.* Р. Төхфәтуллин.

ГРЕ'НА *и. махс.* Ефәк күбәләге йомыркалары.

ГРЕНАДЕР *и.* Патша Россиясендә һәм кайбер чит ил армияләрендә: буе һәм тазалыгы буенча сайлап алынган кешеләрдән генә торган махсус җәяүле яки атлы гаскәри бүлекнең солдаты яисә офицеры (элек: граната ыргытырга махсус өйрәтелгән озын буйлы солдат). *Гафиятулла бабайның элеккеге гренадер солдат сыны хәзер бик нык бирешкән.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Бик озын буйлы, таза. *Ул безгә гренадер шикелле тимерче табып китергән.* Т. Гыйззәт.

ГРЕНАДИН: гренадин канәфере *бот.*— икееллык декоратив бакча гөле.

ГРИЛЬЯЖ *и.* Чикләвек төшен шикәр комында кыздырып әзерләнгән конфет.

ГРИМ *и. театр.* 1. Актер йөзенә буяу, сакал-мыек һ. б. ярдәмендә ул башкарырга тиешле роль таләп иткәнчә бирелгән ясалма төс, кыяфәт, чырай.— *Беркөнне Соловьевның гостиница сәхнәсенә грим белән карт кеше кыяфәтендә чыктым.* М. Гали. // Гомумән ясалма кыяфәт, ясалма чырай. *Кайда синең дөрес кыяфәтең — Йөзең «грим», чәчең парикта.* М. Җәлил.

2. Грим итеп салына, йөзгә сөртелә торган махсус майлы буяу.— *Менә, гримымны да сөртмәдем, монда йөгердем.* Т. Гыйззәт.

ГРИМА'СА *и.* Юри (яки ирексездән) чырайны төрле рәвешкә кертү, чырай сыту, кыланыш.

ГРИМЁР *и.* Грим салучы, артистларны гримлаучы. *Сәхнә арты дөньясына да күз салыйк: кайберләре киенә, грим сала. Шунда гримёр, парикмахер.* И. Рәмиев.

ГРИМЛАНУ *ф.* Үзеңә-үзең грим салу. *Ул ашыга-ашыга Хәлил булып киенергә, гримланырга тотынды.* М. Әмир.

ГРИМЛАУ *ф.* Грим салу ярдәмендә йөзгә берәр төрле кыяфәт бирү. *Старшиналар [мәктәпкә] килеп кергәндә, Заһидә киенеп, битләрен гримлап ята иде.* Х. Садрый.

ГРИМЛЫ *с.* Гримланган, грим яккан. *Гримлы хәлдә.*

ГРИПП *и.* Сулыш юлларының ялкынсынуы һәм тән температурасының кинәт үзгәрүе характерында була торган йогышлы авыру.— *Кайәр төшкән гриппны үткәрдек дип уйлагыз.* А. Шамов.

ГРИППЛАУ *ф. сөйл.* Грипп белән авыру. *Баһави да килде. Ул әле грипплап йөри икән.* А. Расих.

ГРИФ I *и.* 1. *зоол.* Кыяларда, текә ярларда, биек ялгыз агачларда оялый һәм үләксәләр белән туена торган зур ерткыч кош.

2. *миф.* Борынгы мифологиядә арслан гәүдәле, бөркет башлы, канатлы коточкыч җанвар.

ГРИФ II *и.* 1. *муз.* Кыллы музыка коралларында кылларны басып тавыш югарылыгын үзгәртү өчен хезмәт итә торган агач яки пластмасса планка.

2. *спорт.* Штанганың дисклар яки шарлар кидерелә һәм күтәргәндә кул белән тотыла торган күчәре.

ГРИФ III *и.* Имзалы, исем язылган печать, мөһер. // Китапның тышына яки титул битенә языла торган, җаваплы учреждение исеме. *Университет грифы белән чыккан китап.* // Документка махсус печать белән төшерелгән яки язылган сүз.

ГРИ'ФЕЛЬ *и.* Аспид тактага язу өчен аспид ташыннан ясалган таякчык, таш карандаш. / *с. мәгъ. Хәлфә абзый --- кечкенә кара такталарны, грифель карандашларны әзерләргә куша.* Г. Бәширов.

ГРИФТАР: грифтар булу *иск.*— 1) очрау, юлыгу, тап булу; дучар булу. *Мәхәббәт бер бәладер кем, грифтар булмаган белмәс.* Мәкаль; 2) ирексез булу, кемнең дә булса кулына төшү. *Сез ки патша кулында грифтар булып торучы угълымыз Котбетдингә --- күп дога вә сәлам.* М. Гали. **Грифтар итү (кылу)** *иск.*— 1) дучар итү. *Илаһи, җәдит фетнәсенә грифтар итмә, дип уйландым.* Ф. Әмирхан. *Бай әйтте: «Җәмәгать,— диде,— һәр каюгыз беләсез, дошманнарым нахак бәлагә грифтар кылдылар».* Г. Ибраһимов; 2) кемнең дә булса кулына төшерү, ирексездән шул кешегә бәйле итү. [*Галиябану:*] *Ходай башымны шул кансызга [Исмәгыйльгә] грифтар итмәсен.* М. Фәйзи.

ГРОССМЕ'ЙСТЕР *и. спорт.* Шахмат яки спорт буенча иң югары дәрәҗә. // Шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Беренче «СССР гроссмейстеры» — М. М. Ботвинник.*

ГРОТЕСК *и.* Әдәбиятта һәм сәнгатьтә вакыйгаларны артык күпертүгә һәм көтелмәгән, кискен каршылыкларга корылган алым, шушы алымны куллана торган әдәбият һәм сәнгать әсәре.

ГРУЗИН *и.* Грузия ССРда яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Бер ананың балалары кебек, Бездә һәркем тигез, һәркем дус: Якын туган безгә таҗик һәм рус, Украинец, грузин, белорус.* Ә. Ерикәй. // *с. мәгъ.* Грузин халкына караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Грузин теле. Грузин культурасы.*

ГРУЗИ'НЧА *рәв.* Грузиннарга хас, грузиннар кебек. *Ярым грузинча, ярым Казан татарыча киенеп йөргән --- эшче егетнең эшләрен күзәтеп килә.* Г. Ибраһимов. // Грузин телендә. *Грузинча язылган хат.*

ГРУЗОВИК *и. сөйл.* Йөк автомобиле. *Грузовикта икмәк... Ул совхозның Бөек илгә җанлы бүләге.* М. Җәлил.

ГРУ'ЗЧИК *и.* Йөк төяү һәм бушату эшен башкаручы. *Ул, яңадан үз шәһәренә кайтып, пристаньда ирекле грузчик кына булып эшли башлый.* Г. Гали.

ГРУНТ *и.* 1. Җир, балчык, туфрак. *Рассаданы чыныктырырга, аны ачык грунтка утырту өчен хәзерләргә кирәк.* Җиләк-җимеш...

2. Буялачак әйбергә (агач яки киндергә) беренче кат буялган буяу, җирлек.

Грунт юл — таш яки асфальт җәеп махсус эшләнмәгән, күп йөрүдән такыраеп кына барлыкка килгән машина юлы. [*Варис*] *газигын тигез киң асфальттан төшерде дә машиналар салган такыр грунт юлдан алып китте.* М. Хәсәнов.

ГРУНТЛАУ *ф.* Буялачак әйберне беренче кат тигезләп буяп чыгу, грунт белән каплау.

ГРУ'ППА *и.* 1. Эш, профессия, дөньяга караш, максат һ. б. буенча берләшкән кешеләр төркеме.— *Гафиятуллин, сез — «тел»не алу группасында, Билалетдинов — каплау группасында.* Г. Әпсәләмов. // Мәктәп, уку йортларында бергәләп уку, аерым занятиеләр үткәрү өчен берничә кешедән торган, класс яки курс эчендә бүленгән төркем. [*Мусин белән*] *алар рабфакта бергә, бер группада укыганнар иде.* А. Шамов. // *иск.* Класс. *Без бу беренче җыентыгыбызны эшләгән вакытта башлап мәктәпкә кадәр һәм мәктәпнең беренче группаларында укучы балаларны күздә тоттык.* М. Җәлил.

2. *биол.* Нинди дә булса гомуми сыйфатлары, үзлекләре белән берләшкән әйберләр, предметлар, күренешләр җыелмасы.— *Каныгыз беренче группа булганга күрә, сезнең өчен яраклы канлы кешене табуы да читенрәк булды.* Э. Айдар.

ГРУППАДАШ *с.* Кем белән дә булса бер группада булган (кеше). *Узе турында, Гөлнур турында, группадаш иптәшләре турында --- уйлады.* Г. Ахунов. / *и. мәгъ. Кайчан туй буласын группадашлары инде күптән белеп торалар.* Н. Фәттах.

ГРУППАЛАУ *ф.* Төркемләү, группаларга (төркемнәргә) бүлү, аеру. *Һәр көнне группалап фронтка яки Көнчыгышка җибәрәләр.* М. Җәлил.

ГРУППАЛАШУ *ф.* Группалар хасил итү, аерым группаларга берләшү, төркемләшү.

ГРУППАЛЫ *с.* 1. Группа итеп берләштерелгән; берничә группадан торган. *Группалы уеннар (пед.).*

2. Тере яки бу группага (2 *мәгъ.*), категориягә караган. [*Дарья:*] *I А группалы каныбыз да юк.* Ю. Әминов.

ГРУППАЧЫЛЫК *и. полит.* Нинди дә булса бер коллективның эшчәнлегендә бердәмлек булмау, таркаулык, төрле максат яки интересларны яклау өчен аерым группаларга бүлену. *Группачылыкка каршы көрәш.*

ГРУППИРО'ВКА *и.* Төркем, берләшмә, группа (1 *мәгъ.*). *Советлар иленең ерак районнарында немецларның Идел буендагы группировкасын чолгап алып тар-мар итәргә тиеш булган яңа армияләр әзерләнде.* Г. Әпсәләмов.

ГРУ'ША *и.* 1. Роза чәчәкләләр семьялыгыннан, сабак төбеннән очлаебрак киткән шар сыман итләч җимеш бирә торган агач. [*Төргәкнең*] *эчендә груша агачыннан ышкып, сырлап ясалган, бик матур биш почмаклы бер йолдыз яга иде.* А. Шамов.

2. Шул агачның җимеше. [*Илсөяр*] *тәмле грушалар ашады.* Г. Гобәй. // Шул җимештән әзерләнгән. *Груша компоты.*

ГРУШО'ВКА *и.* 1. Август башында ук уртача зурлыктагы сусыл, хуш исле алмалар бирә торган алмагач сорты.

2. Шул агачның алмасы.

ГРУҺ *и. иск.* Төркем, өер. *Күптәнге тәҗрибәсе белән бүген ул бу груһның котырачагын, котырырлык чамалары барлыгын сизенде.* Г. Ибраһимов. *Берничә көннән соң бер груһ адәм илә Саба патшасы килеп җитте.* К. Насыйри.

ГРУҺЛАНУ *ф.* Төркемләну, төркем-төркем булып өелу. *Хулиганнар груһлана казенкага* [*аракы кибетенә*], *суык, чөнки, сызлый арка һәм җилкә дә.* Г. Тукай.

ГУАШЬ *и.* Акварель буяуның бер төре: суда җилем һәм акбур катнаштырып изелгән, үтә күренми торган куе буяу. // Шул буяу белән ясалган рәсем, картина.

ГУАҺ *и. иск.* Шаһит, танык. *Хәзрәтнең шушы сүзләреннән соң теге гуаһларның берничәсе шиккә калган сымак булдылар.* М. Гафури.— *Ике йөзне* [*акча*] *җыям! Мәргәннең кабер ташы моңа гуаһ булсын!* Г. Ибраһимов. *Ялганчының гуаһы әзер.* Мәкаль.

ГУАҺЛАНДЫРУ *ф.* Күргән, белгән кешеләрдән дөресләтү, раслату, аларны шаһит итү. [*Штигер:*] *Бу зимагурның нәрсә сөйләгәнен ишеттегезме? — дип, шунда ук гуаһландырып та алды.* М. Гафури. // Раслату, дөрес булуына рәсми шаһитлык алу. *Бу протоколдан Камали агай копия алдырып, нотариуста гуаһландырып, хәзрәткә җибәргән, диләр.* Ш. Мөхәммәдев. // Белдерү, алдан әйтеп кую; нәрсәне дә булса эшләргә сүз бирүенә шаһит ясау. *Гөлҗиһан ---, анасына карап: «Менә боларны чәй белән кушып эчәрмен»,— дип гуаһландырып куйды.* М. Гафури.

ГУАҺЛАУ *ф.* Шаһитлык бирү, раслау. *Фәйзулла Җамалетдин углы, гуаһлап, кулым куйдым вә таныклап --- мөһер бастым.* М. Галәү.

ГУАҺЛЫК *и. иск.* Шаһитлык; шаһит булу. *Менә берәм-берәм кешеләр очрый башладылар. Алар һәммәсе дә бик яхшы, бик саф, бик гөнаһсыз булырга кирәк: аларның күзләре, шулай дип, гуаһлык биреп торалар.* Ф. Әмирхан. // Таныклык, раслау, дөресләү өчен дәлил. *Бу әҗәл авылы бик күптән бардыр. Моңа гуаһлык бирәдер: әҗәл зираты бер таш бар, язылганына 400 елдан артык.* К. Насыйри.

ГУБ- Губернага бәйләнешле кушма сүзләрнең беренче кисәге: **губисполком, губком** һ. б. *Кичә губисполком җыелышында* [*чигенергә*] *карар бирелде.* Ш. Усманов.

ГУБЕ'РНА *и.* Элек Россиядә һәм районнар бүленешенә кадәр СССРда административ-территориаль берәмлек. *Шул вакыт Уфа губернасы Эстәрле Тамак өязенең Югары Күл атлы бер авылына яхшы тарантаска өч ат җиккән, кыңгырау таккан бер түрә килеп төшә.* Г. Ибраһимов.

ГУБЕРНА'ТОР *и.* Губерна башлыгы. *Губернатор канцеляриясендә халык бик күп булып, кайсы прошение бирергә, кайсы башка йомыш илә килгән иде.* Ш. Мөхәммәдев.

ГУБЕРНА'ТОРЛЫК *и.* Губернатор булу. *Губернаторлык хезмәте.*

ГУ'БКА *и. к.* болыт. II.

ГУВЕРНА'НТКА *и. тар.* Буржуаз семьяда балага тәрбия һәм башлангыч белем бирүче (гадәттә чит илдән китерелгән) хатын-кыз, тәрбияче. *Электә аларда гувернантка булып торган хатын хәзер Казанда тора икән. Шуңа кунакка килгән.* К. Тинчурин.

ГУДОК *и.* Механик юл белән бирелә торган сузынкы сигнал тавышы. *Һавада беренче тревога гудоклары үкерә башлау белән бөтен халык аякка баса.* Ш. Усманов.

ГУДРОН *и.* Нефть кудырганда барлыкка килә торган куе кара масса (юл төзелеше эшләрендә түбә һәм изоляция материаллары әзерләүдә кулланыла). *Гудрон юллар.* □ *Гомерем узды, ну шул старостаны гудрон казанына ташламавыма үкенеп туя алмыйм,— ди Әндри.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ГУДРОНЛАУ *ф.* 1. Гудрон сөндерү.

2. Гудрон җәю (мәсәлән, юлга).

ГУЛЯШ *и. махс.* Вак итеп туралган иткә гарнир һәм соус кушып, икенче блюдо итеп бирелә торган ашамлык.

ГУМАНИЗМ *и.* 1. XIV—XVI йөзләрдә — Яңарыш чорында Көнбатыш Европада феодализм-чиркәү идеологиясенә каршы көрәштә барлыкка килгән, шәхес иркен һәм хокукларын яклауга нигезләнгән ижтимагый әдәби хәрәкәт.

2. Кешелеклелек, кешеләргә һәм аның эшенә яратып, үз итеп карау; кеше сөючелек. *Мин гуманист, сөям дөньяны, Акмасын дим, җирдә кеше каны, Гуманизм — минем байрагым.* Ф. Кәрим.

ГУМАНИСТ *с.* 1. Гуманизм (1 *мәгъ.*) яклы кеше, гуманизм тарафдары, гуманизм идеяләрен яклаучы, шуны алга сөрүче. [*М. Гафури*] *гуманист демократик шагыйрь буларак, --- коточкыч эксплуатациягә протест белдерде.* М. Җәлил.

2. *к.* гуманлы. [*Муса:*] *Алар — үз туган илләрен чиксез сөюче, тау хәтле алтын бәрабәренә дә җан сатмаучы, изге күңелле, гуманист рухлы сокланғыч егетләр.* Ш. Маннур.

ГУМАНИ'СТИК *с.* Гуманизмга мөнәсәбәтле. *Гуманистик караш. Гуманистик идеяләр.* □ *Безнең яшь геройларыбызга --- гуманистик әңгәмә алып барырга бернәрсә дә комачаулык итми.* М. Максуд.

ГУМАНИСТЛЫК *и.* 1. Гуманист булу.

2. *к.* гуманизм (2 *мәгъ.*). *Гуманистлык идеяләре.*

ГУМАНИГА'Р *с. кит.* Җәмгыятьнең тарихын һәм

культурасын өйрәнә торган. *Гуманитар фәннәр: тарих, философия, филология һ. б.*

ГУМАНЛЫ *с.* Кешелекле, кешеләргә карата игътибарлы һәм ихтирамлы, кеше сөюче. *Семьяда туган, үскән һәм ныгыган иң гуманлы, күркәм мөнәсәбәтләр --- көнкүрешнең коммунистик нигезләрен ныгыта.* Қ. Фасеев.

ГУМАНЛЫҚ *и. к.* гуманизм (2 *мәгъ*). *Баланы үлемнән коткарып калу — бик зур гуманлык.* Г. Әпсәләмов.

ГУММИАРА'БИҚ *и.* Көньякта үскән кайбер акация агачларыннан алына торган үтә күренмәле сумала (текстиль промышленностенда һәм типографиядә җилем итеп файдаланыла).

ГУ'МУС *и. махс.* Черемә-туфрак, җир өстенең черемәгә бай өлеше, өске катлавы. *Туфрак уртача гумуслы. Ул еш кына җил эрозиясенә бирелеп җимерелә.* И. Салахов.

ГУРТ *и. сөйл.* Сатарга яки суярга куып алып барыла торган мал-туар көтүе. *Себерләрдән качып килгән чакта очрадым мин сарык гуртына.* Бәет.

ГУРТЧЫ *и.* Гурт куучы, мал-туарны көтүе белән куып алып баручы.

ГУСАР *и. тар.* Патша Россиясендә һәм хәзер дә кайбер илләрдә җиңел кавалерия частьларында хезмәт итүче. *Гусарлар урам-урам йөреп, Пугачау [иярченнәрен] кырып йөргәннәр икән.* Қ. Насыйри. // *с. мәгъ.* Гусардан торган. *Гусар полкы.*

ГУТ *и. бот.* Хуш исле тропик агач. *Разия гут агачы яндырып, урын-җирне төтәсләп йөри.* М. Фәйзи.

ГУТАЛИН *и.* Күн аяк киемен чистарта торган май.

ГУТТАПЕ'РЧА *и.* Қайбер үсемлекләрдән алына торган резин яки каучук сыман сыгылмалы үзле масса (техникада һәм медицинада кулланыла). // *с. мәгъ.* Шул матдәдән ясалган. *Гуттаперча ченчык.*

ГУУ *аваз иәр.* Нәрсә дә булса һава ярып үткәндә чыга торган тавышны белдерә. *Анда, мылтыклар, пуляләр вә туплы арбалар!..— Трр... Трр... трр Гуу!.. Гуу!..* М. Гафури.

ГУЦУЛ *и.* Карпат тауларында яшәүче украинлы. *Гуцул биюе.*

ГУҖ *и.* **1.** *миф.* Дини мифологиядә: ахырзаманда Җир өстенә чыгып барлык азыкны ашап, суларны эчеп бетерергә тиешле, кеше кыяфәтендәге зур җан иясе. [*Миңсылуның*] *башына бу «адәм»нең Гуҗ бине Гоньк булучылыгы, тиз көннән дөньяларның суларын эчеп бетерәчәклеге, бөтен шәһәрнең тәгамен ашап бетерәчәклеге килде.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Күп ашаучы, туймас тамак, бирән. *Бер гуҗы вагонга кереп утыруы белән тотынды тавык итен ашарга.* Ф. Хөсни. // Қарун, комсыз кеше. *Бүгенге әдәбиятның төп геройлары — урлап байлык җыя торган гуҗ да түгел, бер төрәнле сабанга ябышып йөри торган адәм актыгы да түгел.* Г. Галиев. / *с. мәгъ. Теге каз ул ярлыныкы түгел икән, бер гуҗ мулланыкы икән.* Э. Қасыймов.

ГУҢГЫЙҚ *и. диал.* Тирес коңгызы. *Бик матур яшел «броняга» киенгән гуңгыйкның юлда мәтәлчек атып уйнавы мине бераз аптырашта калдырды.* И. Гази.

ГЫГЫЛДАУ *ф.* **1.** Яшь баланың беренче «гы, ыгы» авазлары чыгарып «сөйләшүе». *Гыгылдап яту.*

2. Тамак төбе белән «гы-гыгы» авазларына охшаш тавыш чыгарып көлү. / *рәв. мәгъ. Җамалый агай тамак төбе белән гыгылдап көлде.* Г. Минский.

ГЫЖ-ГЫЖ *аваз иәр.* Һаваның тоткарланып, өзек-өзек үтүе аркасында барлыкка килгән тавышны белдерә. [*Шәкерт*] *приемга килер алдыннан көнгә икешәр кат кислота иснәп, гыж-гыж йөткереп, кан төкерә торган иде.* М. Гали.

ГЫЖЛАВЫҚ *с.* Гыжлап чыга торган, гыжлап торган. *Гыжлавык тавыш.* □ *Аралык артындагы гыжлавык сәгать дүртне сукты.* А. Гыйләҗев.

ГЫЖЛАУ *ф.* Гыж-гыж иткән тавыш чыгару. *Этисе бик авыр итеп гыжлап тын ала, аның күкрәгендә ниләрдер гырылдый һәм сызгыра.* Г. Бәширов. [*Черкасовның*] *тамагыннан сүзе чыкмый, чыкса гыжлап кына чыга.* Г. Әпсәләмов.

ГЫЖНАУ *ф. к.* гыжлау. *Өй эчендә Шәрифнең гыжнавы белән Җәмиләнең ыңгырашуыннан --- башка тавыш юк иде.* М. Гафури.

ГЫЖЫЛДАВЫҚ *и. к.* гыжлавык. *Авызыннан нинди-дидер гыжылдавык сүз кисәкләре атыла.* Г. Ахунов.

ГЫЖЫЛДАУ *ф. к.* гыжлау.— [*Нокта Вәлинең*] *тирән-тирән гыжылдап сулыш алганын үз колагым белән ишетеп тордым.* Ш. Қамал.

ГЫЙ *аваз иәр.* Акчарлаклар һ. б. кошларның кычкыру тавышын белдерә. *Гый-гый килеп акчарлаклар оча.*

ГЫЙБАД, ГЫЙБДИ *с. иск. кимс.* Надан (кеше); томана, белемсез, тупас (кеше).— *Чү, дим, гыйбди! Ипләп кенә сөйлә, нәрсә бар?* Т. Гыйззәт.— *Авыл гыйбадлары шул сез, авыл гыйбадлары!* А. Расих.

ГЫЙБАДЛЫҚ *и. иск.* Гыйбад булу. *Кыз --- Тәкәнеш якларыннан иәртеп килгән, пединститутта кырыпюып бетерә алмаган «гыйбадлыгы» күзгә бәрелеп торган Хәлилгә чәчәк йөрәген ачты да куйды.* Ә. Еники.

ГЫЙБАДӘТ *и.* Аллага табыну, сыгыну, аңа гозерләнү, ялвару, аны олылау, мәдех әйтү белән бәйләнгән дини йола.— *Минем дингә караш болай: гыйбадәтләр-фәләннәрне мин таныымыйм, ләкин һәммә нәрсәдән көчле бер әйбер барлыкка ышанам.* Ш. Қамал. // Намаз. *Ул намазны яңадан башлап, гыйбадәтен бүлдерүенә рәнҗи-рәнҗи, күңелен яңадан изге уйларга юнәлдерә.* Г. Бәширов.

Гыйбадәт йорты — *к.* гыйбадәтханә. *Инди ачкычлар кулыңда шалтырый ул, карт монах? Монда хакимнәр киләләр, ач гыйбадәт йортларын!* Н. Исәнбәт. **Гыйбадәт кылу (итү)** — гыйбадәт йоласын башкару. *Икенде-ахшам вакыты булганга, анда хәзер әһле иман гыйбадәт кылалар.* Г. Ибраһимов.— *Мин гыйбадәтләр итәрмен, мәңге елап, ялварып.* Һ. Такташ.

ГЫЙБАДӘТХАНӘ *и.* Гыйбадәт кылу йорты (чиркәү, мәчет, храм, костел, синагога һ. б. ш.). *Шәһәр халкы кырык мең чамасында булып, егерме ике чиркәү, бер немсә, бер яһуди гыйбадәтханәсе [бардыр].* Ш. Мөхәммәдев.

ГЫЙБАДӘТЧЕЛ *с.* Диндар, һәрвакыт гыйбадәт кылып торучы, гыйбадәт кылучан. *Ул бик гыйбадәтчел кеше.* Ә. Фәйзи.

ГЫЙБАРӘ *и. иск.* Текстан өзек, өземтә. *Мулла Сабиржан Әлхөсәйни дә урыныннан яртылай торып: — Бу гыйбарә хәдистә юк! — диде.* Ф. Әмирхан. // Сүз тезмәсе, әйтелмә, тәгъбир. *М. Гафури чын халык теле белән, киң массага аңлаешлы, җиңел һәм гади итеп язды. Киң халык гыйбарәләрен, мәкаль, җыр һәм әйтемнәрен файдаланды.* М. Җәлил. // Сүз. *Һәркем беләдер ки, «ярты алма» китабындагы «тидия» гыйбарәсе «тиди» (әйтте) мәгънәсендәдер.* Г. Тукай.

ГЫЙБАРӘЛЕ *с.* Гыйбарәләрдән торган; гыйбарәләрен эченә алган. *Китапның башына аңлавы җиңел, саф гыйбарәле шигырьләр вә кыйтгалар куелды* Г. Тукай.

ГЫЙБАРӘТ *хәб.* Исемле кушма хәбәр составында килеп, (нәрсәдән) тору, (нәрсәне) аңлату, белдерү, эченә алу, (нәрсә) булу мәгънәләрен бирә.— *Тормыш ашауэчүдән генә гыйбарәт түгел лә.* Р. Ишморат. *Соң боларның тәмам берләшүенә каршылык салган мәсьәлә нидән гыйбарәт?* Г. Нигъмәти.

ГЫЙБРӘТ *и.* **1.** Сабак; сабак булырлык, уйланырга мәҗбүр итә торган эш, хәл. *Искене сөйләсәң — әкият, Яңаны сөйләсәң — хикәят, Уйлаганга — гыйбрәт. Уйламаганга ник кирәк?!.* Н. Исәнбәт. [*Закир белән Галимә вакыйгасы*] *тирә-як авылларда да гыйбрәт булып сөйләнә, җырлана башлады.* М. Гафури. // Үрнәк булыр-

лык, иярерлек, уңай мисал булырлык яхшы эш. *Театрның киряклеген тормыш үзе талап итә. Халык гыйбрәт эзли. Театр аркылы аларга гыйбрәт күрсәтергә кирәк.* Ә. Фәйзи.

2. *сөйл.* Шаяртып ачулану сүзе: юньсез.— *Бу Бикмулланың авызына җен төкергәндер, каян таба, гыйбрәт.* Ә. Еники. [*Мәрфуга:*] *И, гыйбрәт! Нәрсә сөйләп утыра бит!* Ә. Фәйзи.

◇ **Гыйбрәт алу** — 1) сабак алу, нинди дә булса эшнең яхшы яки яманлыгын төшенү, шул турыда бер фикергә килү.— *Башкалар әйткәнгә дә колак сал, ул сүзләрдән гыйбрәт ал.* А. Алиш; 2) үрнәк алу, яхшы эшкә иярү.— *Әнә каерылып уңган иген кырына, кешеләрнең дәртләнеп эшләүләренә карап гыйбрәт ал, ичмасам.* Р. Ишморат. **Гыйбрәт белән** — уйлап, тикшереп, яман яки яхшыны аерып. *Карасак гыйбрәт белән бу дөньяга, кай җирдә көчле белән көчсез тигез!* М. Гафури.

ГЫЙБРӘТЛЕ *с.* Сабак алырдай, уйланырга мәҗбүр итәрдәй, акылга өйрәтердәй (эш, сүз, вакыйга һ. б.). *Гыйбрәтле сүзнең бер файдасы тимәсә, бер тия.* Ш. Камал. // Үрнәк алырлык; яхшылыкка өнди торган. *Күптән түгел генә иптәш Дускаев та безгә Украинадагы бер колхозның терлекчелек фермасы турында нинди гыйбрәтле сүзләр сөйләгән иде.* Ә. Еники. *Тукайның бик күп кенә көчле шигырьләре, гыйбрәтле, үткер сүзләре либреттода уңышлы һәм матур файдаланылганнар.* М. Җәлил.

ГЫЙБРӘТЛӘНҮ *ф.* Гыйбрәт алу, сабак алу.

ГЫЙГЫЛДАУ *ф.* Гый-гый килеп кычкыру (акчарлаклар турында), [*Акчарлаклар*] *елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап-гыйгылдап кычкыралар.* Ш. Камал.

ГЫЙДДӘТ *и. иск.* Ирсез калган хатынның икенче иргә бармый торырга тиешле булган вакыты. *Гыйддәт айлары. Гыйддәт саклау.* □ *Нурылгаян абыстай тол калгач, гыйддәте тулар-тулмас, якын авылдагы муллалардан үзенә яшь хатынлыкка сораучылар күп булды.* З. Һади.

Гыйддәт нәфәкасе — аергач, ир хатынга 4 ай буена туенып тору өчен бирергә тиешле акча яки азык. [*Хәзрәт:*] *Мәһәре бирелгәнме? Гыйддәт нәфәкаләре бирелгәнме?* Г. Камал.

ГЫЙЗЗӘТ *и. иск.* **1.** Дәрәҗә, шөһрәт, дан; горурлык. *Ләкин бу гозер Җәләш мулланың изелгән гыйззәтен кайтармый.* Г. Ибраһимов.

2. Хөрмәт, ихтирам; кадер. *Бер заманнар чалмалыга кадер, гыйззәт бар иде.* Г. Тукай.

ГЫЙЗЗӘТЛЕ *с. иск. кит.* Ихтирамга лаеклы, хөрмәтле, кадерле. *Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү улып торгучы әткәем хәзрәтләренә...* М. Гафури.

ГЫЙЗЗӘТЛЕЛЕК *и. иск. кит.* Гыйззәтле булу.

ГЫЙЗЗӘТЛӘҮ *ф.* Ихтирам итү. *Гыйззәтләү тойгысы.*

ГЫЙҚЫЛДАУ *ф.* **1.** *к.* гыйгылдау.

2. *күч.* Күп сөйләү, кирәкмәгән урында лыгырдау.— *Җитте инде, карт, гыйкылдама, синнән акыллырак кешеләр бар монда.* Г. Әпсәләмов.

ГЫЙЛЕМ *и.* **1.** Белем. *Гыйлемнең урысныкы, татарныкы дигәне юк аның.* Ф. Әмирхан. *Гыйлем китапның эчендә дә, тышында да.* Мәкаль. // Тормыш тәҗрибәсе. *Ата-бабаның Еллар буе көч түгеп Тапкан гыйлеменнән Безгә син белгерт.* Н. Исәнбәт.

2. Фән. *Бу егет һәндәсә гыйлемендә бик маһир булырга кирәк.* Г. Тукай.

3. Галим. *Хәйран булды әнкәсе, гыйлем булгач бәбкәсе.* Г. Тукай. / *с. мәгъ. Авылда аны* [*Каюм әбисен*] *мулладан да зуррак укыган, аннан да гыйлемрәк диләр.* М. Гали.

Гыйлем алу — уку, өйрәнү, белем алу.— *Баланың файдалы гыйлем алып чыгуына дога кылыйк.* М. Гафури. **Гыйлем иясе, гыйлем кеше** — *к.* галим.— *Сезнең кебек гыйлем иясеннән сабак аласыбыз килде.* Т. Гыйззәт. **Гыйлем йорты** — уку йорты. *Дворян, буржуа балалары гына кереп укырга мөмкин булган бу югары гыйлем йортларыннан без бүген чын хезмәт массасы арасыннан --- яңа кадрлар хәзерләп чыгарабыз.* М. Гали.

ГЫЙЛЕМЛЕ *с.* Гыйлеме, белеме булган. *Боларның һәммәсе --- гыйлемле, гакыллы, гайрәтле эшсөяр бер мөфтинең эш башына килүен көтеп торалар.* Ф. Әмирхан. // Мәгърифәтле, укымышлы. *Син гыйлемле вә мәдәниятле тормышның зәһәре белән бер мәртәбә агулангансың.* Г. Ибраһимов.

ГЫЙЛЕМЛЕК *и.* Гыйлем, белем.— *Акча бирикме, гыйлемлек өйрәтикме, кайсы кирәк?* Әкият. *Ике ел җыйган гыйлемлек — бар да китте эчемдә.* Бәет. // *күч.* Тормыш белеме, тормыш тәҗрибәсе, эш күнекмәсе. *Бу абзый 1923 елдан бирле нефть эшендә эшләп, җир бораулау буенча байтак кына гыйлемлек җыйган иде.* Г. Ахунов.

ГЫЙЛЕМ-МӘГЪРИФӘТ *җый. и.* Гыйлем һәм мәгърифәт, һәртөрле белем. *Тырышыйк без, тырмашыйк, Укуга чынлап керешик, Гыйлем-мәгърифәт аркасында морадыбызга ирешик.* Ш. Мөхәммәдев.

ГЫЙЛЕМХАНӘ *и. иск.* Уку йорты, белем бирү йорты, мәктәп. *Бердәнбер милли гыйлемханәләребез мәдрәсәи руханиләрдән гыйбарәт булып --- көннән-көн бәһасы төшә бар*[*а*]. Ф. Әмирхан.

ГЫЙЛЬӘТ *и. иск. кит.* Кимчелек, җитешсезлек; сыйфатсызлык. *Кыйммәт булса — хикмәте бар, арзан булса — гыйльләте бар.* Мәкаль.

ГЫЙЛЬМАН *и. иск. кит.* Ожмах егете. *Җиргә Иблисне сөрү булды кызык: Хур вә гыйльманнар йөриләр пыр тузып.* Ш. Бабич. *Берең гыйльман, берең хурдай, мең яшәгез, Зөһрә җан.* Ф. Бурнаш.

ГЫЙЛЬМИ *с.* Фәнни; гыйлем, фәнгә мөнәсәбәтле. *Гыйльми язмалар. Гыйльми Совет.* □ *Гыйльми атамаларга, фән, китап исемнәре кебек авыр мәсьәләгә килгәч, аның теле көрмәкләнә, күз алды караңгыланып китә.* Г. Ибраһимов.

ГЫЙНВАР *и.* Календарь елда беренче ай; январь. *Гыйнвар башы. Гыйнвар суыклары.* □ *Төнге гыйнвар. Җил дә Кыш.* Һ. Такташ.

ГЫЙРФАН *и. иск. кит.* Аң-белем. *Бу халыкның әүвәл башлап кыйлган эше: гыйлем, һөнәр, тәрбия һәм гыйрфан, әдәп.* М. Гафури.

ГЫЙСМӘТ *и. иск. кит.* Саф күңеллелек; мораль сафлык, гөнаһсызлык, гыйффәтлелек. *Кил, фәрештәм, килче, гыйсмәттән яралган сөмбелем; Килче, килче, бер үбимче, соңра уйнарсың, гөлем.* Ш. Бабич.

ГЫЙСЪЯН *и. иск. кит.* Баш күтәрү, фетнә. *Гыйсъян явы әкрен генә Канлы кырлардан басып җырлап килә.* Һ. Такташ. *Дурт ягым гыйсъян уты, сүнмәс һич, ул сүндермәсә.* Г. Тукай.

ГЫЙСЪЯНЧЫ *и. иск. кит.* Баш күтәрүче, буйсынмаучы; бунтарь. *Мин гыйсъянчы, менә уңыңда карап торам.* Һ. Такташ.

ГЫЙСЪЯНЧЫЛЫК *и.* XX йөз башында иске тормышка каршы юнәлдерелгән, аны тулысынча инкяр итү, билгесез яңа тормышка омтылу белән характерлы әдәби агым. *Гыйсъянчылык, барысыннан да элек, татар әдәбиятының билгеле бер традицияләренә, аның милли җирлегенә нык тоташкан.* Г. Халит.

ГЫЙТАП *и. иск. кит.* Шелтә. *Бир халәленнән хисап, шөбһәле маллар өчен гыйтап, хәрам өчен газап!..* М. Гафури.

ГЫЙФРИТ *и. миф.* Зур гәүдәле, көчле, куркыныч, диюнең бер төре дип уйланылган җан иясе. *Кап-кара урманда ерткычлар улый, һәм дә җир астында гыйфритләр дулый.* Ш. Бабич. // Артык усал, явыз, рәхимсез

кешеләргә карата әйтелә. *Ул да башка каенанилар кебек гыйфрит булмас.* Г. Ибраһимов.

ГЫЙФРИТЛӘНҮ *ф.* Усаллану, явызлану; гыйфрит кебек усал, куркыныч төскә керү. // Гайрәт ору, акырыну. *Зәһәрләнә, төсе зәңгәрләнә, Гыйфритләнә килеп өстенә.* М. Укмасый.

ГЫЙФФӘТ *и.* Кызлык, намуслылык, **җенси сафлык.** *Шул вакыт Әбугалисина, егеткә кызның гыйффәтенә кагылырлык һичбер нәрсә эшләмәүне шарт итеп, аларның икәвесен бер бүлмәдә калдырып чыгып китте.* К. Насыйри.

ГЫЙФФӘТЛЕ *с.* Кызлык намусы булган, саф. *Гыйффәтле Зәйнәп инде урамга чыгарга ояла.* М. Гафури. // *күч.* Гомумән саф, пычранмаган, пакь; намуслы. *Таң чыгыдай саф, беренче тау чәчәгедәй гыйффәтле мәхәббәтебезне бер-беребезгә ачарга тели идек.* Ә. Еники. *Судта хөкем иткән чакларда ата-анамның вә башка кешеләрнең гыйффәтле, абруйлы йөзләренә ничек итеп оялмыйча карар[мын]?* Г. Камал.

ГЫЙФФӘТЛЕЛЕК *и.* Гыйффәтле булу.

ГЫЙШ-ГАШРӘТ *и. иск.* Күңел ачу, кәеф-сафа. *Бер сәгать соң зур сарайда Шат гыйш-гашрәт иде.* М. Гафури.

Гыйш-гашрәт кылу (сөрү) — кәеф-сафа сөрү, вакытны гыйшык-мәхәббәттә үткәрү. *Булган, ди, бер патша, бик усал булган, ди, үзе алтын сарайларда көне-төне гыйш-гашрәт кылган, ди.* Һ. Такташ.

ГЫЙШЫК *и.* Мәхәббәт, ярату хисе. *Дөнья, сине Ләйлә төсле күреп, Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым.* М. Җәлил. *Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка булган көчле гыйшкы турында.* Һ. Такташ.

Гыйшык тоту — ярату, сөю, мәхәббәт тоту. *Ул чагында аңа гыйшык тотып йөрүче егетләр дә аз түгел иде.* А. Шамов. *Тик шулкадәресе бар, без бит гыйшык тотарга түгел, укырга килдек.* Т. Гыйззәт.

ГЫЙШЫК-МӘХӘББӘТ *җый. и.* Гыйшык һәм мәхәббәт. *Ничә буын авыл яшьләренең гыйшык-мәхәббәтенә җансыз шаһит булып килгән инеш буендагы карт өянкеләр урынына --- парк ясаганнар.* Г. Бәширов.

ГЫЙШЫКЛЫК *и.* Гыйшык тоту; гашыйк булу. *Татьяна әле генә өйдән, Онегиннан гыйшыклык куркуы дигән курку белән качып, чыгып утырган.* Г. Тукай.

Гыйшыклык тоту — *к.* гыйшык тоту. *Буй кызлар, гыйшыклык сез тотмагыз Җаныгыз теләмәгән ярларга ла.* Җыр.

ГЫЙШЫКЧАН *с.* Гыйшык тотарга һәвәс, бик тиз гашыйк булучан. *Шәкертләр бик гыйшыкчан булалар.* Н. Исәнбәт.

ГЫК *аваз иярт.* Бик тиз арада ишетелеп киткән саңгырау тавышны белдерә. *Шул вакыт Акморат «гык» дигән тавыш чыгарды да җиргә кырын әйләнеп төште.* Ф. Кәрим.

ГЫЛДЫР-ГЫЛДЫР *аваз иярт. к.* голдыр-голдыр (2 *мәгъ.*). *Елкы итен күп ашаган булса, «гылдыр-гылдыр» кикерә.* Ш. Мөхәммәдев.

ГЫНА (генә, кына, кенә) *кис.* 1. *чикл. кис.* 1) ике яки берничә предмет, эш яки хәлнең берсе генә булу-булмауны аңлата: бары, тик, бары тик, фәкать. *Җыр гына, фәкать ул гына кузгатып җибәрә ала торган, чәчәк тажыдай нәфис һәм нечкә тойгылар уяна.* Г. Бәширов. *Бар теләгем җиңү генә, Уйлаганым син генә.* Ә. Ерикәй. // Ике яки берничә эшнең берсе генә үтәлүгә басым ясый. *Укыдым гына, язарга өлгермәдем;* 2) урынны белдергән сүз янында килеп, шул урынны чикли, шуннан ары, ерак булмауны белдерә. *Су да яныбызда гына.* Ә. Еники. *Ул бакчада гына.* А. Әхмәт; 3) төп сан янында килеп, предметның саны шуннан артык булмауны, барлыгы шулкадәр генә булуны аңлата. *Аңар әле уналты гына яшь.* Ш. Камал. *Аның тик бер генә иптәше булган — Шул кара айгыр.* М. Гафури; 4) вакыт рәвеше янында килеп, шул вакытны аныклый, чикли төшә, аның күптән түгел, чагыштырмача хәзерге вакытка якын булуын белдерә. [*Кәрим:*] *Базардан әле күптән түгел, яңарак кына кайтты.* Г. Камал. *Әле генә кайда идем, хәзер менә нинди ямьле тау битендә утырам.* Г. Бәширов; 5) шарт фигыль янында килеп: бары тик шул очракта, бары тик шул шарт (эш) үтәлгәндә, фәкать шул вакытта... кебек мәгънәләрне аңлата.— *Юлар булсаң гына, шушындый егеткә бармассың! — диде* [*берсе Газизәгә*]. Ш. Камал; 6) берәр эшнең үтәлү яки үтәлмәвенең сәбәбен белдергән сүзләр янында килгәндә, сәбәпнең шул бер генә булуына, башка сәбәпләрнең юклыгына басым ясый. *Тик ташлап китәргә килештермәгәнгә генә көчләнеп утыра иде.* Г. Ибраһимов; 7) рәвеш функциясендәге **-ып-еп** формалы хәл фигыль янында килеп, төп эш яки хәлнең шул рәвештә генә башкарылуын күрсәтә. *Шул чак песи посып кына өй кыегы буйлап тәрәзә башына таба үрмәләде.* А. Алиш.

2. көч. *кис.* 1) гел, бөтенләй; тулысынча. *Аяк асты су гына. Өй эче төтен генә. Актан гына киенгән;* 2) сыйфат яки рәвеш янында: байтак, шактый. *Өй эче чрыйсы гына зур.* Ш. Камал. *Матур гына, сөйкемле генә бер кыз.* Г. Тукай; 3) фигыль янында килеп, фигыль белдергән эшнең көчле, интенсив булуына яки еш кабатлануына басым ясый. *Лотфуллаң кычыткан белән кирәгемне бирә генә бит.* Ә. Айдар. // тезмә фигыль компонентлары арасында. [*Газинур:*] *Соңгы вакытта --- бәла артыннан бәла явып кына тора.* Г. Әпсәләмов; 4) боерык фигыльләр янында килеп, фикергә янау, кисәтү мәгънәсе өсти. *Тукта, кайтсын гына әле.* А. Әхмәт; 5) инкярләү формасындагы раслау җөмләләрдә **кем, нәрсә, кайда, кая, ничек, нинди...** алмашлыклары янында килеп, алмашлык белән бирелгән төшенчәне көчәйтә яки сан-сыйфаты ягыннан арттыра. *Анда кемнәр генә җырламас!* М. Гафури. *Бу яулыкларда колхоз кызларының нинди генә нечкә тойгылары чигелмәгән!* Г. Бәширов; 6) теләк, хис, тойгыны... көчәйтә. *Каян гына килеп бу җиргә кердем?* М. Гафури. *Хәерле сәфәр генә булса ярар иде.* Р. Ишморат.

3. көч.-чикл. кис. 1) бер эш яки хәлнең икенче бер эш яки хәл башкарылгач та, шуннан соң ук үтәлүен белдерә. *Кәҗә батие авызын түбән таба сузган гына иде, шул вакыт моны ерактан күргән этләр, Бүре дип белеп, аяктан да ектылар.* Г. Тукай.— *Чыгып китәргә торганда гына сез килеп кердегез.* Ш. Камал; 2) каршы куючы теркәгеч составында килә: ... гына түгел, (хәтта, бәлки) ... да. *Болар арыган гына түгел, берсенең хәстә икәнлеге дә күренеп тора иде.* Ш. Камал. *Затлы мех өчен генә түгел, затлы йөрәк өчен дә көрәшә ул.* Р. Ишморат; 3) мөнәсәбәтле сүзләрнең иярчен җөмләдәгесе янында килә. *Нәрсә генә эшләргә теләмә, Шул ук атка барып терәлә.* М. Гафури. *Җаным, Газизәбануым, кем генә хат язса да, син аңар илтифат итмәссең бит?* Ф. Әмирхан.

4. Иркәләү кисәкчәләре **-кай, -кәй** мәгънәсендә йөри. *Мескеннең йон гынасы калды ике бөртек.* Дәрдмәнд. *Аю да бит үзенең баласына чибәр генәм, аппак кынам, ә керпе йомры гынам, йомшак кынам ди икән.* Ш. Камал.

5. Борынгы озын көйле җырларда ритмны саклау, иҗек санын тутыру өчен кулланыла. *Ап-ак та гына җиләк, ай чәчкәсе ятадыр да җиргә бәйләнеп.* Җыр. *Төннәр уртасында үкереп елый Буйга гына җиткән кыз бала.* Ш. Камал.

ГЫРГЫЛДЫК *с. к.* гырылдык.

ГЫР-ГЫР 1. *аваз иярт.* Сулыш юлыннан килә торган һаваның кече телне калтыратып үтүеннән барлыкка килгән калын тавышны белдерә. *Һәм тамакның төпләре гыр-гыр килә, Болгана куллар, авыз мыр-мыр килә.* Ш. Бабич. *Милләтебез йоклый һаман безнең гырр! гырр! Йөткерә чахотка күк һаман кырр! кырр!* Г. Камал.

2. *и. мәгъ.* Бугаз төене. *Бугазымнан тотып алып мунча идәненә сузып салды да гыр-гырымнан буа башлады.* Т. Гыйззәт.

ГЫРЛАУ *ф.* Гыр-гыр иткән тавыш чыгару. [*Пароход*], *тамагы карлыккан кеше шикелле, гырлаган тавыш белән бик каты кычкыртып җибәрде дә, борылып, Зөя елгасына керә башлады.* М. Гали. // Йоклаганда гыр-гыр иткән тавыш чыгару. *Ике яшьлек бала мәңге тынды... Немец гырлап йоклый башлады.* Ш. Маннур.

ГЫРЫЛ-ГЫРЫЛ *авазияр. к.* гыр-гыр. *Шаһзадә, гаять арыганлык сәбәпле, баһадирлар йокысы илә гырыл-гырыл йокламакта иде.* Ш. Мөхәммәдев.

ГЫРЫЛДАВЫК 1. *с.* Гырылдап торган, гырылдап чыккан. *Гырылдавык тавыш.*

2. *и. к.* бугаз (1 *мәгъ.*).

◇ **Гырылдавыгын өзү** — үтерү, юк итү.— *Хәзер гитлерчыларны үкертеп кыйный торган чак. Гырылдавыгын тот та өз.* Г. Әпсәләмов.

ГЫРЫЛДАУ *ф.* Гырлау, гыр-гыр иткән тавыш чыгару. *Кысылган бугаз тагы берничә ыңгырашты, тереклек актык тапкыр тагы бер гырылдап селкенеп карады да сүнде.* Г. Ибраһимов. // Йоклаганда гырлау. *Кичтән үк йокыга киткән егетләрнең мышнаулары, гырылдаулары ишетелеп торды.* И. Гази.

ГЫРЫЛДЫК *и. диал.* 1. Бугаз төбе; гомумән бугаз. *Гырылдыгына ябышу (буу). Гырылдыктагы шартлау (лингв.).*

2. Гырылдау тавышы. *Гырылдык чыгару.*

Гырылдык авазлар *лингв.*— бугаз төбендә ясала торган авазлар (къ, гъ).

ГЮРЗА[1] *и.* Медицина максатлары белән агуы алына торган елан.

ГӘП *и.* Әңгәмә, сөйләшү. *Сорашу китте, гәп куерды.* А. Әхмәт. [*Мансуров:*] *Я, ни турыда гәп?* [*Хәйдәр:*] *Менә шушы панорама турында.* Г. Бәширов.

◇ **Гәп сугу (ору, сату)** — сүз алып бару, сөйләшү. — *Борынын җыя алмаган нәрсә, олылар белән зур булып, гәп сугып тора бит.* А. Алиш. *Егет алар: фасон шәп, Төрле фәннән ора гәп.* Г. Камал. *Әчкелт тәмәкене иркенләп, тәмләп суыра-суыра гәп сата башлады.* Ә. Айдар.

ГӘПЛӘШҮ *ф.* Үзара сөйләшү, әңгәмә кору. *Анда чертләтеп чикләвек ашыйлар, өчәү-дүртәү бергә җыелып, үзара гәпләшеп утыралар.* Г. Бәширов. *Башта Гали абзый алар белән Казан хәлләре турында гына гәпләшергә уйлаган иде.* Г. Әпсәләмов.

ГӘПЛӘҮ *ф. сир.* Сөйләү, әйтү. *Мин кергәч тә, хәлфә, иптәшемә карап: «Бу кяфергә минем кем икәнлекне гәпләмә инде син, мәхдүм...» — диде.* Ф. Әмирхан.

ГӘПТӘШ *с.* Әңгәмәдәш, бергә сөйләшүче, әңгәмәдә катнашучы (кеше).

ГӘП-ӘҢГӘМӘ *җый. и.* Әңгәмә, үзара сөйләшү. *Сүзнең, гәп-әңгәмәнең исәбе күренми, агылып киләләр дә хәйран калып сорашалар.* Г. Ибраһимов.

ГӘРДАП *и. иск. кит.* Упкын, тирән чокыр. *Мине ниһаяте булмаган гәрдап эчендә калдырып киттегез.* М. Гафури.

ГӘРӘЗ *и. сөйл. к.* гарыс. *Әминәнең сөлгесе, Читтән килгән өлгесе; Гәрезләре базардан, Чигешләре Казаннан.* Ә. Фәйзи.

ГӘРНИЧ *и. сөйл.* Тегермәндә ярма ярдырган, он тарттырган яки сөт аерткан өчен натуралата бирелә торган түләү; *русчасы:* гарнец — 3,28 литрга тигез үлчәү берәмлеге. [*Нәбиуллин:*] *Сез пот башына күпме гәрнич аласыз әле?* Р. Ишморат.

ГӘ'РЧӘ *терк.* Иярчен кире җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем...* Г. Тукай. *Тышта кунып булмый бит, Булса да гәрчә йөз ак.* М. Җәлил.

ГӘРӘБӘ *и.* Саф нарат сагызы аерым шартларда күп гасырлар буена ятудан барлыкка килгән сары яки кызгылт сары төстәге үтә күренмәле матдә; асылташ сыйфатында кулланыла. *Безнең турда салкын чишмә — Гәрәбә эри торган.* Җыр. // *с. мәгъ.* Гәрәбәдән эшләнгән. *Сары гәрәбә муенсасы һәм кызыл тамчы төсле тамып торган алкасы --- бу сылу хатынның пөхтә һәм җыйнаклык сөюен күрсәтәләр.* Г. Бәширов.

ГӘРӘНКӘ *и. бот.* Әвернәчәчәкләләр семьялыгыннан, беренче елында эре шалкан формасында яшелчә, икенче елында сары чәчәк атып, кузаклы орлык бирә торган үсемлек; *русчасы:* брюква. *Гәрәнкә гарниры.* □ *Киң яфраклары белән җирне сыйпап утырган гәрәнкә, ап-ак чәчәк белән чуарланган бәрәңге[ләр] --- үсәләр, имеш.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

Гәрәнкә күбәләге *зоол.*— әвернәчәчәкле яшелчәләргә зарар китерә торган күбәләк.

ГӘҮДӘ *и.* 1. Кеше яки хайванның аяк-кул һәм башыннан башка тәне. *Бигрәк тә кулларының гәүдәсенә караганда озынрак булулары белән* [*Сафа*] *беркадәр анасына охшый төшә иде.* А. Шамов.

2. Кешенең гомумән тәне; буй-сыны. *Аның күзенә Миңнулланың озын, ябык гәүдәсе чалынып калды.* И. Гази.

3. Мәет, үлек (үлгән кеше турында). *Фәхринең гәүдәсе табылгач та, волбашкармага хәбәр җибәрделәр.* Г. Ибраһимов. // Үләксә (хайван турында). *Кырда ат гәүдәләре сибелеп ята.* Ш. Усманов.

4. *диал.* Күлмәкнең өске өлеше, кофтасы; кыса.

ГӘҮДӘЛЕ *с.* Гәүдәгә озын, буйчан. *Безнең әти гәүдәле булса да, өшән, тиз аручан.* Г. Гобәй.

ГӘҮДӘЛӘНДЕРҮ *ф.* 1. Әдәби образлар аша бирү, чагылдыру. *«Көзгыннар оясында» — киң социаль тормышны гәүдәләндергән тарихи сюжеттагы пьеса.* Г. Нигъмәти. // Аерым образны бирү, сурәтләү, тасвирлау. *Язучы әсәрдә сыйфый дошманны ачыктан-ачык советка каршы коткы таратучы дип гәүдәләндерми.* М. Җәлил. // Сәхнәдә берәр персонаж ролен уйнау, шуның образын тудыру. [*Хәйдәр Нәфисәгә:*] *Сиңа Галиябануның көчле, саф мәхәббәтен гәүдәләндереп бирергә кирәк булачак.* Г. Бәширов.

2. Аерым сыйфат, фикер, хис һ. б. ны үзендә чагылдыру. *Утыра солдат Ленин каршында, Гәүдәләндереп халкы намусын.* С. Хәким.

ГӘҮДӘЛӘНЕШ *и.* Чагылыш. *Асылда Галия сурәте Рәүф өчен дә баштан ук аның ниндидер бәхетсез ялгышуларының гәүдәләнеше булып тоела.* Г. Нигъмәти.

ГӘҮДӘЛӘҢҮ *ф.* 1. (Чынбарлыкның) әдәби әсәрләрдә чагылуы, бирелүе. [*Большевик җитәкчеләр*] *кулакның һәрбер каршылыгын сындыруны тулысынча тәэмин итәләр. Бу момент әсәрдә Бикташев сурәте аркылы гәүдәләнә.* М. Җәлил. // (Аерым образларның, картиналарның һ. б.) рольдә бирелүе, сәхнәдә чагылуы. *Шәехзаман образы атказанган артист Х. Уразиков уйнавында оригиналь образ булып гәүдәләнде.* М. Җәлил.

2. Билгеле бер образда яки предметта туплану, чагылыш табу (чынбарлык, чынбарлыктагы вакыйгалар яки хисләр турында). *Бу карашта гәүдәләнде Дуслык, якын туганлык.* М. Җәлил. *Олы юлда көрәшергә сүзе калды, Җиңү юлын күзәтергә күзе калды — Партиядә гәүдәләнеп* [*Ленин*] *үзе калды.* Ф. Бурнаш. // Чагылу, пәйда булу (анда, хыялда). *Илсөярнең күз алдында әтисе, дулкыннарга каршы тора алмыйча, батып барган хәлдә гәүдәләнде.* Г. Гобәй.

ГӘҮҺӘР *и. к.* җәүһәр. *Гәүһәр кечкенә дә, бәясе зур.* Әйтем. *Тәхтең нәфис, бәллүр синең, Гәүһәр синең сарайларың.* Н. Исәнбәт.

ГӨБЕ *и.* Каймак туглап, май язу өчен кулланыла торган тар, тирән кисмәк. *Гөлләр җиз кыршаулы гөбедә тырышып-тырышып май яза иде.* Г. Әпсәләмов.

Гөбе атлау — гөбедә май язу, каймакны май һәм әйрәнгә аеру. *Урак урмак — уйнамак, гөбе атламак — җан чыкмак.* Мәкаль. **Гөбе мае** — атланмай, ак май. **Гөбе таягы** — *к.* атлавыч; **Гөбе әйрәне** — май язганнан калган

сыекча. *Каймак диеп алып чыккан гөбе әйрәне ачыдыр.* Бәет.

ГӨБЕР-ГӨБЕР *аваз иәр.* Аш кайнау яки сыеклыкка механик тәэсир ясау нәтиҗәсендә барлыкка килә торган тавышны белдерә. *Гөлҗамал абыстасы гөбер-гөбер сыер савып утыра иде.* И. Гази. *Казанда акрын гына гөбер-гөбер кайнаган итнең өйгә таралган буы --- борынны кытыклап җибәрә.* Ә. Еники.

ГӨБЕРДӘТҮ *ф.* **1.** Гөбер-гөбер китерү, шундый тавыш чыгару. *Гөбердәтеп май язу.* □ [*Фатыйма*] *кызыл сыерының эре имчәкләрен учлап тоткан хәлдә, гөбердәтеп саварга кереште.* А. Расих.

2. *диал.* Кабарту, күпертү, мамыкландыру. *Фәйрүзә кәҗә мамыгыннан гөбердәтеп бәйләгән соры мамык шәл бөркән[гән].* Г. Ахунов.

ГӨБЕРДӘҮ *ф.* **1.** Гөбер-гөбер килү. *Торбадан гөбердәп су килә башлады.* □ *Самовар кайнап чыкты, казанда шулпа гөбердәп тавыш бирде, бүлмәгә ит исе таралды.* А. Гыйләҗев.

2. Күперү, кабару. *Гөбердәп торган ак туннар, кызлар киеп йөри торган нәфис кофталар — барысы газдан.* Г. Ахунов.

3. Калын тавышның кабатланып ишетелүе, кими бару тәртибендә кабатлануы. *Здравья желаю ваше ... — дигән сүзләр --- — Дра-ра-ра-ра! — дигән кебек гөбердәгән, мәгънәсе булмаган бер тавышка әйләнеп, тирә-якка таралды.* М. Гафури.

ГӨБЕРЛЕ: гөберле бака — тәне лайлалы сөялләр белән капланган, койрыксыз җир-су хайваны — җир бакасы, сасы бака.

ГӨБЕРТ *аваз иәр.* Нәрсә дә булса ишелеп төшкәндә барлыкка килә торган тавышны белдерә. [*Тәртә*] *бер якка кыйшалды, сәнәкләр таеп төштеләр, бөтен күләнкә берьюлы аш, табын һәм кешеләр өстенә гөберт итеп җимерелде.* Г. Ибраһимов.

ГӨБЛӘ *и. зоол.* Үсемлек суы белән тукланучы вак корткыч бөҗәк, үсемлек бете.

ГӨБӘДИЯ *и.* Дөге, ит, пешкән йомырка, корт, җимештән әзерләнә торган бәлеш.— *Кына такталарында чәкчәк турыйлар, гөбәдия камырын нәрсәгә җәябез?* Ә. Фәйзи.

ГӨҖ *аваз иәр.* Бик күп жан ияләренең тавышлары кушылмасыннан яки гомумән гүләү, жулау кебек төрле авазлар кушылмасыннан барлыкка килгән шау-шуны белдерә. *Тимерчелек цехында чак-чак чүкеч тавышы, трансмиссияләр гөже.* Ф. Хөсни. *Аның колагына урам буйлап баганадан баганага сузылып киткән телеграф чыбыгының «гөжжж... гөж-ж» дип шаулавы ишетелде.* Ә. Еники.

Гөж килү (итү) — шаулау, шау-шу килү; кешеләр яки хайваннар һ. б. ш. күп җыелган урынның шаулап торуы. *Чиксез зур куркыныч көткән кебек, Шәһәр шаулый, Халык гөж килә.* М. Гафури. *«Хөкем килә! Торыгыз!» — дигән каты тавыш белән бөтен зал «гөж-ж» итеп, аякка басты.* Г. Ибраһимов. *Колаклар гөж килеп чыңлыйлар.* Ә. Фәйзи.

ГӨҖГЕЛӘҮ *ф.* Труба яки шуның кебек эче куыш урынны чистарту, андагы әйберләрне өс яки ас якка чыгару өчен нәрсә дә булса тыгып бутау, тиз-тиз хәрәкәт белән яки һава өрдереп себертү (мәсәлән, пумала белән төнлек чистарту). *Шул арада «убыр» бер почмактагы тишектән нигезгә төште дә китте. Тишекне гөжгеләп карасалар да, «убыр» чыкмады.* С. Кудаш.

ГӨҖЕЛДӘТҮ *ф. к.* гөбердәтү.

ГӨҖЕЛДӘҮ *ф.* Гөжләү, гөж килеп тору. *Борынгыдан урман гөжелдәвен Якын иптәш иткән Рус иле.* Ш. Мөдәррис.

ГӨҖЛӘТҮ *ф. сөйл.* **1.** Гөжләргә, шауларга ирек кую. *Гөжләтмә әле шул балаларны.*

2. Шаулату (самоварны), кайнатып чыгару.— *Чәй эчеп китәрсез, хәзер самовар гөжләтәм,— дип, Марзия кече якка чыгып китте.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *рәв. мәгъ.* **гөжләтеп.** Шәп, яхшы итеп. *Минем машиналарым тирә-як авылларда гөжләтеп эшләп йөриләр.* Г. Ибраһимов.

ГӨҖЛӘШҮ *ф.* Шаулашу, шау-гөр килү. *Тоткыннар ишек төбендә бераз гөжләшеп тордылар да, тын гына килеп, Бикмүш бабайны әйләндереп алдылар.* Г. Гобәй.

ГӨҖЛӘҮ *ф.* **1.** Гөж килү, шау-шу килү. *Халык умарта корты кебек гөжли башлады.* Г. Бәширов. *Бакча төрле кошлар тавышы белән гөжләп тора иде.* Г. Гобәй.

2. Эш процессында мотор, машиналарның тигез тавыш чыгарып торулары турында. *Тигез гөжләү белән әйләнеп торган дизельләр янында эшләүче җитди монтерлар --- Газинурның йөрәгенә бик нык кереп урнашканнар.* Г. Әпсәләмов. // Тирә-якның машина тавышыннан шау-гөр килеп торуы турында. *Кайдандыр су тегермәненең салмак кына гөжләве ишетелеп тора.* Ф. Хөсни.

3. Дөрләп янган утка һава өрдерүдән тавыш чыгу. *Авыл артындагы язгы ермакларда язгы суның үкерүе --- тимерче алачыгында ут гөжләгән кебек тоела иде.* И. Гази. *Чиксез кызулыкны эченә җыйган Гөжләп торган мартен мичләре...* М. Гафури. // Самовардагы суның шаулап кайнавы турында. *Самовары --- гөжләп утыра читтә, почмакта.* М. Җәлил.

ГӨЖТ *аваз иәр.* Кызулатып үтеп киткәндә ишетелеп калган тавышны белдерә. *Юлдан выжт та гөжт автомобильләр үтеп тора.* Дин тур. халык.

◇ **Гөжт итеп** — бик тиз. *Һади контора алдына кадәр гөжт иттереп машинада утырып килде.* А. Гыйләҗев.

ГӨЛ *и.* **1.** Бүлмәдә яки бакчада матурлык өчен үстерелә торган үлән-үсемлек. *Вакыт җитми чәчәк атмый Бакчадагы гөлләр дә.* Җыр. // Гомумән, чәчәк ата торган үлән яки куак-үсемлек. *Безнең кырда зәңгәр гөлләр күкрәп үсәрләр.* Һ. Такташ. *Батырларның юлында Гөлләр чәчәк атсыннар.* М. Җәлил. // Шул үсемлекләрнең чәчәк өлеше. *Урамнарга сирень гөленнән исләр аңкып тора.* Һ. Такташ.

2. *с. мәгъ. күч.* Чәчәк кебек, гөл кебек балкып торган матур. *Борынгы шатлыгың юктыр сүзеңдә. Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә.* Дәрдмәнд. *Гөл битеннән бер генә Үпсәм кызу ирнем белән...* М. Гафури.

3. Роза. *Хәер, мин моны болай гына әйтәм: гөл чәчәге бик матур да, сабы бик чәнечкеле бит.* Ф. Әмирхан. // **Гөлем, гөлкәем** — иркәләп әйтелгән мөрәҗәгать сүзе. *Сине шундый сагындым, гөлкәем, язасы сүзләрем шул тикле күп...* Г. Бәширов.— *Йокла, гөлкәем,— диде Өметбаев,— йокла.* Г. Гобәй.

ГӨЛБАБА *и. бот.* Оешмачәчәкләр семьялыгыннан үентыклы озын яфраклы, озын сабакчыкларга урнашкан йонлач сары корзинка чәчәкле үсемлек (гадәттә, болынларда һәм басуда, юл буйларында үсә); *русчасы:* кульбаба.

ГӨЛБАДРАН *и. бот.* Оешмачәчәкләр семьялыгыннан формасы белән абагага охшаш яфраклы, көпшәсыман сары чәчәкле, чәчәк корзинкалары зонд кебек урнашкан үсемлек (гадәттә, юл, канау буйларында үсә; жәрәхәтләрне дәвалау, эч китүне туктату һәм глистларны кудыру өчен дару итеп кулланыла); *русчасы:* пижма. *Имбир һәм дарчынны алмаштыручы үсемлек итеп оешмачәчәкләр семьялыгыннан булган гөлбадранны файдаланалар.* Робинзон эзләреннән.

ГӨЛБАКЧА *и.* Гөлләр үстерелә торган матур бакча. *Үсә таш калалар, Гүзәл гөлбакчалар, Зур сарайлар калка күкләргә.* Ш. Маннур.

ГӨЛБОСТАН *и. иск. к.* гөлбакча. *Гөрлиләр заводларың, Татарстан, Бәхетле синең барган юлларың, Кырларың, болыннарың — гөлбостан.* Ә. Ерикәй.

ГӨЛБӘЧ *и. диал.* Мич арты, мич аралыгы. *Мөнәвәрә Сөнгатьне күргәч, каушап, тиз генә гөлбәчкә йөгерде.* Г. Ахунов. *Көн җилле-мазар булганда, әнисе самовары өйгә гөлбәчкә куя.* А. Гыйләҗев. // *күч.* Өйнең кухня ягы, казан тирәсе.— *Әллә син теге, анаңны гөлбәчтән чыгармас идеңме?* А. Расих.

ГӨЛДЕР *авазияр.* 1. Күк күкрәгәндәге кебек зур көч белән башланып, кимү тәртибендә таралып ишетелә торган тавышны белдерә. *Кара болыт киләдер гөлдер-гөлдер күкерәп.* Бәет. *Ерактан гөлдер-гөлдер арба килә.* Ш. Бабич.

2. Күгәрченнәрнең гөрләү тавышын белдерә. *Эч, кадерле күгәрченем, Балдай татлы суыбыз, «Гөлдер-гөлдер-гөлдергү»,— дип, Бездә кунак булыгыз!* Ә. Бикчәнтәева.

ГӨЛДЕРДӘШҮ *ф.* 1. Күгәрченнәрнең гөрләшүе. *Гөлдердәшүләр читлектә Мысыр күгәрченнәре.* С. Баттал.

2. Гөлдердәшкән күгәрченнәр кебек тату һәм матур итеп сөйләшү. *Берәүдән дә курыкмыйча, бөтен дөньяга «күрегез, без нинди бәхетле» дигән сыман гөлдердәшеп бакчага киләләр.* Г. Ибраһимов.

ГӨЛДЕРДӘҮ *ф. к.* гөлдерәү. *Ерактан кыр тавыгы гөлдердәгән тавыш килде.* А. Гыйләҗев.

ГӨЛДЕРЕК *с.* Гөлдерәп торган. *Гөлдерек тавыш.*

ГӨЛДЕРӘШҮ *ф. к.* гөлдердәшү.

ГӨЛДЕРӘҮ *ф.* 1. Күкрәү, гөлдер иткән тавыш чыгару. *Ул да түгел, ерактан яшен яшенләп, күк гөлдерәп куйды.* И. Гази. *Шул минутта, күк гөлдерәгән кебек, әллә нинди куркынычлы тавышлар ишетелде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Гөрләү (күгәрчен гөрләве). *Алдыбызда ап-ак бер күгәрчен җим җыеп гөлдерәп йөри, имеш.* Қ. Тинчурин. // Күгәрчен гөрләве кебек матур итеп сөйләү. *Ул көлми, гүя күгәрчен кебек гөлдери иде.* Г. Әпсәләмов. // *рәв. мәгъ.* **гөлдерәп.** Шәп, тату, матур итеп (яшәү турында). [*Сәмигулла:*] *Икәүдән икәү гөлдерәп кенә яшәрбез.* Ш. Хөсәенов.

3. *күч.* Шау-гөр килеп сөйләшү, гөрләшү (кешеләр турында). *Авыл урамында хатын-кызларның кинәт үзара гөлдерәп алулары ишетелеп кала.* Ф. Хөсни.

ГӨЛЗАР *и. иск. к.* гөлбакча.

ГӨЛЛЕК 1. *и.* Гөлләр үсә торган урын, гөлләмә, гөлзар.

2. *с.* Гөлгә хас; хуш исле. *Ал вә кызыл ул чәчкәләр --- дәва исләре белән авырайган һаваны үзләренең гөллек исләре белән җиңеләйткәннәр, хәятландырганнар.* Ф. Әмирхан.

ГӨЛЛӘМӘ *и.* Чәчәклек; гөлләр, чәчәкләр үсә торган урын, чәчәк газоны.

ГӨЛЛӘНҮ *ф. сир.* Чәчәк ату, чәчәк бөреләре ачылу. // *күч.* Чәчәк ату, югары үсештә булу. *Син теләгән чын мәхәббәт гөлләнә безнең илдә.* Ә. Исхак. // *күч.* Кызару, алсу кызыл төскә керү. *Ут кабынды кинәт күзләренә, Яңаклары кинәт гөлләнде.* М. Җәлил.

ГӨЛСИРИН *и. сөйл. к.* глицерин. *Уфаларга барулары-рым Гөлсирин өчен генә, Януларым, көюләрем Гел синең өчен генә.* Җыр.

ГӨЛСТАН *и.* Чәчәк иле, гөрләп яши торган бәхет иле. *Бабай үлгән, ләкин кырында Гөрләп үскән безнең Гөлстан.* Ф. Бурнаш.

ГӨЛТ, ГӨЛТ-ГӨЛТ *авазияр.* 1. Тиз һәм кинәт кабынып сүнү рәвешендәге ритмик тавышны белдерә. *Электростанциянең движогы гөлт-гөлт итеп эшли.* А. Расих. // *к.* дәп (2 *мәгъ.*). *Аның тавышы үзгәргән, йөрәге гөлт-гөлт тибә иде.* И. Гази.

2. Тизлекне, кинәтлекне белдерә торган образлы миртем. *Әбугалисина урынында гөлт итеп ут күтәрелә, ә ул үзе юк була.* Н. Исәнбәт.

Гөлт итү, гөлт итеп тору — яп-якты булып, ялтырап тору. *Күкрәк ут ялкыннарыннан тын ала, Гөлт итеп торган учак төсле яна.* Н. Исәнбәт.

ГӨЛЧӘЧӘК *и.* Роза. // Чәчәк ата торган матур гөлләр, гомумән чәчәкле үсемлекләр. *Аллы-гөлле гөлчәчәкләр бакчабызны ямьләде.* М. Җәлил.

ГӨЛӘНДӘМ *с. иск.* Гөл кебек нәфис гәүдәле, зифа буйлы. *Ишек төбендәге стена буена алсу ак йөзле, гөләндәм буйлы керәшен кызлары тезелеп баскан.* Х. Сарьян.

ГӨЛӘП *и. к.* гөлҗимеш. [*Миңнурыйның*] *карашы гүя: «Мин гөләп чәчәге, ләкин синең өчен минем инәләрем юк»,— дип әйтә иде.* Г. Әпсәләмов. [*Әби*] *мунчадан чыккач, гөләп җимеше кайнатып эчерергә әйтте.* Х. Садрый.

ГӨЛҖИМЕШ *и.* Розачәчәкләр семьялыгына керә торган чәнечкеле куак үсемлек; җимеше итләч тартмачык эченә тулган орлыклардан тора. С витаминына бик бай була. *Җәй айлары үтте, Гөлҗимешләр изелеп пешеләр...* М. Җәлил.

ГӨЛҖИМЕШЛЕК *и.* Гөлҗимеш күп үсә торган урын.

ГӨМАН *и. кит. иск.* Уй, фикер; фараз; юрау. *Минем гөманымча. Аның гөманынча. Теоретик гөман.*

Гөман итү (кылу) — ... дип уйлау, фараз итү, күз алдына китерү. *Кечкенә икән әле, мин аны шактый дәү шәкерт дип гөман кылган идем, дип мыгырданып алды кода абый.* Ә. Фәйзи.

ГӨМБЕР *и. сөйл.* Балыкларны билгеле бер якка куркытып куу өчен су болгатып тавыш чыгара торган балык тоту җиһазы; дөмбе.

ГӨМБЕР-ГӨМБЕР *авазияр.* Әйберләрнең бер-берсенә бәрелүеннән чыккан салмак калын тавышны белдерә. *Шахтерлар, егетләр, гөмбер-гөмбер вагоннарны Тәгәрәтеп йөрибез.* Ш. Қамал.

ГӨМБЕРДӘТҮ *ф.* Гөмбер-гөмбер китерү, гөбердәү тавышы чыгару. *Фуат Булатов аеруча рәхәтләнеп, ничектер буш сыман тоелган авыз эчен гөмбердәтеп көлде.* Ш. Маннур.

ГӨМБЕРДӘҮ *ф.* Гөмбер иткән тавыш чыгару. *Газизә йокысыннан уянганда һәрвакытта ишетелеп, колаклар күнегеп беткән калын һәм тонык аваз, ишек алдында әйләндереп куйган таз өстенә су тамчылары төшкән шикелле, гөмбердәп тора иде.* Ш. Қамал.

ГӨМБЕРЛӘҮ *ф. к.* гөлдерәү. *Болыт үтте. Гөмберли күк ераклarda.* Дәрдмәнд.

ГӨМБЕРТ *авазияр.* 1. Қинәт китереп бәргәндә яисә җиргә биектән берәр әйбер кинәт төшкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. [*Хәлимнәр*] *йокыга ятуга, ишеккә гөмберт иттереп бәрделәр.* И. Гази.

2. *хәб. функ.* «Гөмберт» авазларына охшаш тавыш чыгарган эш-хәрәкәтне белдерә. *Утыз ел казыган баз бик тирән шул: менә инде Хәмитең шунда гөмберт!* Г. Тукай.

ГӨМБӘ *и.* 1. Чәчәге, яфрагы булмаган, споралар яр-дәмендә генә үрчи торган түбән төзелешле үсемлек. *Ашарга яраклы гөмбә. Агулы гөмбә. Черек гөмбәсе.* □ *Урман кырыендагы куаклар арасыннан аңа кып-кызыл бөрлегәннәр, зур эшләпәсе белән битен каплап үлән астына поскан гөмбәләр карап тора.* Г. Бәширов. *Ауган агач чери, Ябыша аңар сасы гөмбәләр.* Һ. Такташ.

2. Ашлыкларда була торган авыру, кисәү гөмбәсе. // Гомумән, үсемлекләрдә була торган авыру.

3. Қаты гөмбә, агач гөмбәсе. *Әнә аның сабый вакытлары, иртәдән кичкә кадәр йөгерә-йөгерә уйнап йөрүләре... Кайткач, әнисенең «мәәмә» итүләре, гөмбә белән төсләүләре...* М. Максуд.

4. *мед.* Эшь балаларның авыз эче бозылу (тел өстендә ак эренле катлау барлыкка килә); сөт авыруы.

5. *күч.* Янгырдан яки кызу кояш нурларыннан саклану өчен гөмбә сыман итеп ясалган ышык урын. *«Гөм-*

бәләр» астына баскан дневальныйларның --- тавышлары яңгырый иде. Г. Әпсәләмов.

6. *күч.* Фикер йөртүдә яки эштә җитезлеге булмаган, җебегән кешегә карата әйтелә торган мыскыллау сүзе. [*Киребикә хезмәтчеләргә:*] *Гөмбәләр! Качырмагыз, тотыгыз! Тот!* **Ф. Хөсни.**

◇ **Гөмбә яңгыры** — гадәттә, көзге кояшлы көндә ява торган җылы вак яңгыр.— *Гөмбә яңгыры, утырып явар, ахрысы.* Э. Касыймов.

ГӨМБӘЗ *и.* **1.** *махс.* Кабарынкы формада ярымшарсыман итеп эшләнгән түбә; купол. [*Мортаза бай*] *салынып ята торган собор чиркәвенең зур гөмбәзен үз акчасына алтын белән каплаттырды.* Ә. Фәйзи. *Болдыр баганалары нечкә биллән, гөмбәз чыгарып эшләнгән.* Э. Еники.

2. Шул гөмбәз формасындагы әйбер яки әйбернең шуңа охшаш өлеше. *Кар бөртекләре, ап-ак парашют гөмбәзе шикелле, бераздан яңадан җиргә төшә башлый.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Билгеле бер урыннан караганда күк йөзенең офык белән чикләнгән күренмә ярымшары. *Ай йөзә күк гөмбәзендә.* Н. Исәнбәт.

ГӨМБӘЗЛЕ *с.* Гөмбәзләп эшләнгән, гөмбәзе булган. *Биек гөмбәзле собор.* □ *Башлы суганга охшаган сары гөмбәзле озын чиркәү аңа шәһәрдән «йодрык яный» шикелле.* И. Гази.

ГӨМБӘЗЛӘНЕП *рәв.* Гөмбәз сыман булып, гөмбәз, ярымшар формасын алып. *Гөмбәзләнеп күренү.* □ *Александров исемендәге типография --- калын стеналы, түшәмнәре гөмбәзләнеп килгән, берсеннән икенчесе аркалар белән генә аерылып торган зур-зур галереяларга урнашкан иде.* Ф. Хөсни.

ГӨМБӘЛЕ *с.* **1.** Гөмбәдән (1 *мәгъ.*) **хәзерләнгән,** гөмбә катнаштырылган. *Гөмбәле аш.*

2. Гөмбә (2 *мәгъ.*), кисәү белән зарарланган. *Гөмбәле ашлык.*

3. Гөмбә (1 *мәгъ.*) күп үсә торган. *Минем ул тирәләрдә булганым бар — гөмбәле урыннар.* Г. Әпсәләмов.

ГӨМБӘЛЕК *и.* Гөмбәгә (1 *мәгъ.*) бай, гөмбә күп үсә торган урын. *Гөмбәлеккә юлыгу.*

Гөмбәлек җебе — гөмбәнең (1 *мәгъ.*) вак җепселләрдән торган вегетатив үрчү тамыры.

ГӨМБӘЛӘНҮ *ф.* **1.** Гөмбә (2 *мәгъ.*) белән зарарлану.

2. Гөмбә (1 *мәгъ.*) белән каплану. [*Өйнең*] *почмаклары ап-ак булып гөмбәләнгән, гөмбәләр тирәсендә кырыгаяклар мыж итеп торалар.* Х. Садрый.

ГӨМБӘЧЕ *и.* Гөмбә (1 *мәгъ.*) җыючы.

ГӨНАҺ *и.* **1.** *дини.* Дини кануннардан читкә китү, дин, шәригать законнарын бозу, үтәмәү сәбәпле алла каршындагы гаеп, язык.— *Улем алдыннан гөнаһларының кичерелүен сора.* Г. Ибраһимов. *Иң зур гөнаһ — ыруг бетермәк.* М. Җәлил.

2. Әдәп-әхлак кагыйдәләрен бозу; гаеп эш. *Үз гөнаһын башкалар өстенә аудару иң мордар, иң әшәке кешенең эше.* Дәрдмәнд. // Ялгышлык, кимчелек. [*Сабит:*] *Гөнаһым зур: мин аның* [*алманың*] *артысын аладым.* М. Фәйзи.

3. *хәб. функ.* Яхшы түгел; гаеп санала. *Ул чәчләр шундый матурлар, алардан тую — гөнаһ.* Ф. Әмирхан.

4. *кер. сүз функ.* **гөнаһтыр.** Каргану, ант итү сүзе: биллаһи, валлаһи. *Үзем, гөнаһтыр, колхозларына барып чыкканым юк әле.* Һ. Такташ.

◇ **Гөнаһ шомлыгы** — 1) бәхетсезлек; бәла.— *Инде васыятькә калган, ахирәтем биргән чүлмәкне дә ваткач, тагын әллә нинди гөнаһ шомлыклары китерер.* А. Шамов.— *Нинди гөнаһ шомлыгы булды соң бу?* Р. Ишморат; 2) *кер. сүз. к.* гөнаһ шомлыгына каршы.— *Гөнаһ шомлыгы, былтыр бит аның кышы да нинди рәхимсез булды.* Г. Бәширов; 3) кешегә карата җиңелчә генә ачулануны, орышуны, канәгатьсезлекне, ризасызлыкны, берникадәр рәнҗүне белдерә. [*Хәмзә Бибигә:*] *Бар тизрәк! Гөнаһ шомлыгы.* Г. Камал. *Ай, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры да бик тын тагын...* Г. Тукай. **Гөнаһ шомлыгына каршы** *кер. сүз* — бәхетсезлеккә каршы. *Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, капка бикле иде.* Г. Гобәй.

ГӨНАҺЛАНУ *ф.* Гөнаһ эш эшләү; гөнаһлы, гаепле булу. [*Салих:*] *Гөнаһланма! Укыган намазыңны юкка югалтасың ич!* Һ. Такташ.

ГӨНАҺЛЫ *с. дини.* Гөнаһы булган, гөнаһ эш эшләгән. *Янәсе, урыс кулы белән ясалган хәрам әчемлекне әчеп алла каршында гөнаһлы буласы килми.* И. Гази. // Гаепле, гаеп эш эшләгән. *Гөнаһлы малайларның агалары боларга каршы чыктылар.* М. Гафури.

ГӨНАҺЛЫК *и.* Гөнаһ, гөнаһ эш. *Гөнаһлык эшләү.*

ГӨНАҺЛЫЛЫК *и.* Гөнаһлы булу. *Гөнаһлылыгы көн кебек ачык.*

ГӨНҖӘЛӘ *и.* **1.** Эрләгәндә кабага бәйләү өчен әзерләнгән бер төргәк йон яки сүс; *к.* көнҗәлә. *Әни* [*Клаваны күргәч:*] *«Бу нинди гөнҗәлә тагын?» — дип кенә сорап куйды. Чыннан да Клаваның чәчләре --- сүс төсле аксыл-сары.* М. Хәсәнов.

2. *диал.* Өермә үләне, дуңгәләк; *русчасы:* перекати-поле. [*Зәйтүнә*] *дала гөнҗәләседәй, басу өсләтеп каядыр — Мәтәскә урманнары ягына таба абына-сөртенә атлап китте.* Ф. Хөсни.

Гөнҗәлә бавы — гөнҗәләне кабага бәйли торган бау. **Гөнҗәлә таягы** — кабаның гөнҗәләне бәйли торган өлеше.

ГӨП, ГӨП-ГӨП *авазияр.* Бер әйбер белән икенчесенә бәргәндә барлыкка килгән саңгырау тавышны белдерә. *Гыйльметдиннең аяк астында баскыч такталары гөп-гөп итеп калды.* И. Гази. // *рәв. мәгъ. к.* дәп (2 *мәгъ.*). *Гарәфи:* [*Сиражетдиннең «таланган булуын»*] *күргәч тә, минем йөрәкләрем «гөп!» итеп китте.* Г. Камал.

Гөп итү — гөп иткән тавыш чыгару, гөпелдәү. *Аю сикереп торды да, бу су иясен күтәреп, «гөп» иттереп җиргә салды.* К. Насыйри.

ГӨПЕЛДӘТҮ *ф.* **1.** Гөп иткән тавыш чыгару. *Борһан гөпелдәтеп дәү чүкечен китереп төшерде.* М. Шәрифуллин. // *күч.* Егу, аудару (кешене яки хайванны).

2. *күч.* Кыйнау, гөп-гөп сугу. // Үтерү.— *Ул кулакны --- тот та яр астына алып төшеп гөпелдәт!* И. Гази.

ГӨПЕЛДӘҮ, ГӨПЛӘҮ *ф.* Гөп иткән тавыш чыгу. *Гөпелдәгән тавышны ишетеп калулары ихтимал иде.* М. Шәрифуллин. *Сугыша торган кул тавышлары гына гөпли.* А. Таһиров.

ГӨПКОРСАК *и. гади с.* Капкорсак (зур корсаклы, туймас кеше).— *Бер әйбер калыр хәл юк, ач керне балаларына кертә дә тыгындыра, кертә дә тыгындыра, синең гөпкорсак балаларың туймас!..* М. Гафури.

ГӨПӘШ *с. сөйл.* Базык, кыска юан (гәүдәле). [*Әсирләрнең*] *берсе — зуррак чинлы һәм гөпәш гәүдәлесе — аеруча куркынган, дер калтырап тора иде.* Каз. утл.

ГӨР *авазияр.* **1.** Ритмик рәвештә кабатлана торган түбән калын тавышлар җыелмасыннан гыйбарәт шауны белдерә. *Туплар гөре кинәт тынып калгач, Онтыла бит, бар да онтыла.* Ш. Маннур.

2. *и. мәгъ.* Күгәрченнәрнең гөрләү авазын белдерә. *Кайда калган ул туган йорт, Тын күгәрченнәр гөре?!* Н. Исәнбәт.

◇ **Гөр килеп (итеп)** — шәп, яхшы, дус (яшәү, тору, үсү). *Гөр килеп, шатланып яшибез.* Ә. Ерикәй. **Гөр килү (итү)** — шау-гөр килү. *Указ турында ишеткәч тә әле барлык яшьләр гөр килде.* Р. Ишморат. *Ындыр көндәгечә шаулый, гөр килә.* М. Җәлил.

ГӨРБИЯН *с. сөйл.* Тәкәббер, башкаларга кимсетеп караучан һәм дорфа, каты бәрелүчән кеше, тупас телле; *русчасы:* грубиян. *Гөрбияннарга гөрбиян, баш исәләр — баш иям.* Җыр. *Хәсән гөрбиян, тупас, ләкин шул тупас-*

лык артында Илшатның йөрәген көчлерәк тибәргә мәҗбүр итә торган тагын нәрсәдер бар бит. Г. Әпсәләмов.

ГӨРБИЯНЛАНУ *ф. сөйл.* Үзен гөрбиян, тәкәббер һәм дорфа тоту, башкалар белән санашмау.

ГӨРБИЯНЛЫК *и. сөйл.* Гөрбиян булу, тәкәббер һәм дорфа булу.

ГӨРГЕЛӘҮ *ф. диал. к.* гөжгеләү.

ГӨРГЕЧ *и. сөйл.* Агачны каезлау яки тирене кыру өчен кулланыла торган, ике яктан тоткалы кәкре пычак; *русчасы:* скобель.

ГӨР-ГӨР *аваз ияр.* **1.** Күгәрченнәрнең гөрләү авазын белдерә. *Гөрлидер күгәрчен, Шатлык зур, күрәсең; гү-гү-гү... гөр-гөр-гөр...* М. Максуд.

2. Күгәрченнәрне чакыру авазы.

3. Балаларның качыш уены («әби» булган бала, күзләрен каплап, гөр-гөр дип торганда, башкалары кача, шуннан соң «әби» аларны эзләп табарга тиеш була). *Гөр-гөр уйнау. Гөр-гөр уены.*

ГӨРЕЛДЕК *с. сөйл.* Калын, гөрелдәп чыккан (тавыш турында). *Гөрелдек тавышлы.*

ГӨРЕЛДӘВЕК(ЛЕ) *с. к.* гөрелдек.

ГӨРЕЛДӘШҮ *ф.* Шаулашу, күп предметларның берьюлы гөрелдәве, шау-гөр килүе. *Трамвайлар утә гөрелдәшеп, Юлчыларны төяп тыгызлап.* Ш. Маннур.

ГӨРЕЛДӘҮ *ф.* **1.** Өзлексез калын яңгыравыклы тавыш чыгарып тору. *Басуда көн-төн трактор гөрелдәде.* Г. Гобәй. // *күч.* Гөрелдек, яңгыравыклы, көр калын тавыш чыгарып сөйләү. *Хисмәт абзый үзенең көр тавышы белән салмак кына гөрелдәп, Нургалигә төнлә күргән-белгәннәрен сөйли.* Ә. Еники. *Тимери, кулындагы салам учмасын күрсәтә-күрсәтә, гөрелдәп чыккан калын тавыш белән* [*сөйли*]. Г. Бәширов.

2. Кинәт-кинәт барлыкка килә торган көчле шартлаулы яңгырау турында. *Туплар гөрелдәү.*

3. Шаулау, шау-гөр килү. *Зал берничә минут гөрелдәп торды.* М. Гафури. *Җиде литр керешле яңа ак самовар гөрелдәп җырларга тотына.* Н. Фәттах.

4. *күч. к.* гөрләү (1 *мәгъ.*).—*Әйтерең бармы? Хикмәт чүлмәгенең үзе инде,— дип күгәрчен кебек гөрелдәде карчык.* Г. Әпсәләмов.

5. *рәв. мәгъ.* **гөрелдәп.** Су яки канның мул булып, гөрләвектәй бәреп чыгуы. *Гөрелдәп кан ага башлады.*

ГӨРЕЛТЕ *и.* **1.** Гөрелдәп чыккан тавыш. *Моторлар гөрелтесе әкренәя төште.* Ф. Хөсни. *Түшәм буенда, тимер шар тәгәрәп йөргән шикелле, тонык кына гөрелте ишетелә башлады: күк күкри иде.* Ш. Камал. // Төрле авазлар, тавышлар кушылмасы, шау-гөр. *Гөрләвекләр гөрелтесе җыр булып агып китте.* Г. Хуҗиев.

2. Янгын вакытында яки бомба, снаряд ярылудан барлыкка килгән саңгырау шартлау тавышы. *Бер иртәдә аны сугыш гөрелтесе уята.* Г. Гобәй.

ГӨ'РЕС *аваз ияр к.* гөрс. *Күмүчеләр кырык адым киткәч, кабергә мөнкир-нәнкир килеп кермәсенме? --- Гөрзи белән гөрес!..* Г. Гобәй.

ГӨРЕҖДӘ *и. бот.* Наратлыкта үсә торган киң аксыл-саргылт эшләпәле гөмбә; нарат гөмбәсе; *русчасы:* грузди. *Арыш камчылый башлагач, беренче ак томаннар ачылганда шушы куак төпләрендә аксыл-сары итләч гөреҗдәләр үсә.* А. Гыйләҗев.

ГӨРЗИ *и. тар.* **1.** Борынгы сугыш коралы: чәнечкеле авыр чукмар башлы таяк. *Берничә кеше Кулупайның гөрзисен, берничә кеше аның калканын чак күтәреп чыгарып мәйданга куялар.* М. Җәлил.

2. *дини миф.* Дини китапларда язылганча, кеше үлгәч, аны җәзалау өчен кулланыла торган утлы чукмар. *Бу сурәтнең тирәсендә җәһәннәмнәр, гөрзиләрен күтәргән зобанилар йөри башладылар.* Ф. Әмирхан.

ГӨРЛЕ: гөрле уйнау — гөр-гөр (3 *мәгъ.*) уйнау. *Бергә-бергә уйныйсы килә, салам эскертләрендә ауныйсы килә, гөрле, качышлы чабышасы килә.* А. Гыйләҗев.

ГӨРЛӘВЕК *и.* **1.** Көчле яңгырдан яки язын кар эрүдән барлыкка килеп, жир өстеннән аккан су. *Тау битләреннән беренче гөрләвекләр шаулап чокырларга төшәләр.* Ә. Еники.

2. Гөрләү, гөр килү тавышы. *Тәрәзәдән кайчак тонык кына кала гөрләвеге ишетелә.* М. Җәлил. // *с. мәгъ.* Шаулап, гөрләп торган. *Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә --- шып итеп туктады.* Ш. Камал.

ГӨРЛӘВЕКЛЕ *с.* Гөрелдәүле; гөрелдәвек тавышлы. *Сюитадагы төп мелодия --- бу бүлектә акрын һәм көчсез ишетелә. Аны гөрләвекле, дулкынлы яңа музыка баса.* М. Җәлил.

ГӨРЛӘТҮ 1. *ф.* Шаулату (самоварны), кайнатып чыгару.— *Хәзер самовар гөрләтеп җибәргән булыр идек.* А. Шамов.

2. *к.* **гөбердәтү (1** *мәгъ.*). *Сыерны саудым гөрләтеп, Үрчеттем кортын-кошын.* Г. Хуҗиев.

3. Януын көчәйтү. [*Бу*] *сүзләрне ишетү аның йөрәгендә сүнеп бетмәгән хәвефле ут-ялкынны тагын да зәһәрәк гөрләтеп җибәрде.* С. Рафиков.

4. *рәв. мәгъ.* **гөрләтеп.** Шаулап, шау-гөр килеп, тавышланып. *«Яу!» дигән чакта яварсың гөрләтеп һәм шаулатып.* М. Гафури. // Яхшы, шәп итеп, күңелле итеп. *Гөрләтеп спектакльләр куярбыз.* Ш. Камал.

ГӨРЛӘШҮ *ф.* **1.** Үзара гөр-гөр килү (мәсәлән, күгәрченнәр). *Урман якын, болын янәшә, Чишмә чылтырый, кошлар гөрләшә.* Җыр.

2. *күч.* Үзара тату, йомшак, ягымлы итеп сөйләшү турында. *Нәкъ күгәрченнәр төсле гөрләшәләр.* Ш. Камал. *Серләшәләр, гөрләшәләр егет белән кыз.* Ә. Ерикәй. // Кешеләрнең үзара тату яшәүләре турында. *Без яшибез иркен җиребездә, Бертуганнар кебек гөрләшеп.* Ә. Исхак.

3. Шау-гөр килү, шаулашу. *Очрашкан чакта гөрләшеп күрешәләр дә, әлбәттә, яз турында сүз кузгатып җибәрәләр.* И. Гази. // **Шаулау.** *Җәйге кичтә учаклар гөрләшеп яналар, Күмәк эштә кешеләр зур бәхет табалар.* Ә. Ерикәй.

4. *рәв. мәгъ.* **гөрләшеп.** Яхшы, **шәп** (үсү, яшәү, тору). — *Бер матур кыз алырмын да, гөрләшеп торырбыз.* М. Фәйзи.

ГӨРЛӘҮ *ф.* **1.** Күгәрченнәрнең гөр-гөр килүе. *Күгәрченнәр гөрли гөр килеп.* Н. Дәүли. // *күч.* Салмак, ягымлы, йомшак тавыш белән сөйләү. *Наҗия* [*иренең*] *муенына сарылып гөрләргә тотына.* Ә. Еники.

2. Шау-гөр килү, салмак, бер-берсенә кушылып барган ритмик тавышлар чыгып тору. *Палата яңадан гөрли башлады.* А. Шамов. // Шау-шу, җыр, көлү, шатлыктан гөр килеп тору. *Бигрәк җанлы хәзер безнең тирә, Гөрләп тора җырдан, тавыштан.* М. Җәлил.

3. Гөрелдәүле тавышлар чыгарып тору. *Әйләнерләр орчыклар, машиналар гөрләрләр.* Ә. Ерикәй. // *рәв. мәгъ.* **гөрләп.** *к.* гөрелдәү (5 *мәгъ.*— гөрелдәп). *Кызның муеныннан гөрләп кан ага башлады.* Р. Ишморатова. // Шаулау, гөжләү (самоварның кайный башлавы).

4. «Гөр-гөр» уенында «әби»нең гөр-гөр дип торуы. *Берли, икели, өчли, дүртли, Асия кача, Бану гөрли* (санамыш).

5. *күч.* Бик яхшы бару (эш һ. б. ш. турында). *Әбинең эшләре гөрләп иде шул.* М. Фәйзи. // Даны таралу, киң танылу, берәр өлкәдә зур уңышка ирешү. *Ул елларны Фатыйма Ильскаяның гөрләгән чагы иде.* Ф. Хөсни. // *рәв. мәгъ.* **гөрләп.** Шәп, яхшы (үсү, яшәү, тору турында).— *Тукучылар да бар, очучылар да бар, гөрләп яши безнең Татарстан.* Ә. Ерикәй.

ГӨРЛӘҮЧЕ *и.* «Гөр-гөр» уенында «әби», уенны алып баручы (куучы яки эзләүче). *Ул һәрбер гөрләүченең аркасына шап иттереп суга.* М. Галәү.

ГӨРС, ГӨРС-ГӨРС *аваз ияр.* **1.** Авыр әйбернең көчле бәрелүеннән туган саңгырау тавышны белдерә. [*Сол-*

датлар], мостовой ташларына гөрс-гөрс басып, --- Кремльгә таба узып киттеләр. И. Гази.

2. *к.* дөп. *Йөрәге гөрс-гөрс тибә, дулкынланудан авызы кибә иде.* И. Гази.

Гөрс итү — кинәт бөтен гәүдә белән егылганда, нәрсә дә булса ауганда, төшкәндә гөрселдәгән тавыш чыгару. *Аның артыннан гөрс итеп ишекме, нәрсәдер ауды.* Ә. Фәйзи.

ГӨРСЕЛДӘТҮ *ф.* 1. Гөрс иткән тавыш чыгару. *Забой эчендә гөрселдәтеп күмер кискән тавышлар ишетелде.* Ш. Камал. // Гөрелдәтү, гөрелдәү тавышлары чыгару. *Тау-таш җимерелгәндәй гөрселдәтеп, күк күкрәп үтте.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Ату, атып җибәрү; атып үтерү. *Тагын берне гөрселдәтимме икән, дип патронын кызгана төшебрәк уйланып торганда, караңгылыктан иңгәндәй итеп, ике кеше пәйда булды.* Г. Минский.

ГӨРСЕЛДӘҮ *ф.* Гөрс итү, гөрс итеп шартлау (мәс. бомба, туп ярылу). *Дон буйларын яңгыратып, Гөрселдәп ярыла туплар.* Ә. Ерикәй. *Кинәт бөтен урман эчен дәһшәтле гөрселдәү каплап алды.* Ә. Еники. // Гөрелдәү, гөрелдәп күк күкрәү. *Кырлар өстендә ялт-йолт эшен яшьнәде, гөрселдәп күк күкрәде дә, шаулатып коярга да тотынды.* Г. Бәширов. // Әйберләр бер-берсенә бәрелгәндә гөрс иткән тавыш чыгару. *Җир гөрселди тигез басудан.* Ф. Кәрим.

Гөрселдәп егылу (аву, килеп төшү) — *к.* гөрс итү. *Монысына [сугуга] инде ул чыдый алмады, баскан урынында гөрселдәп егылып китте дә ике-өч минут хәлсезләнеп ятты.* Ф. Әмирхан. *Сөләйманов бөтен авырлыгы белән гөрселдәп барып төште.* И. Гази.

ГӨРСТ *авазияр. к.* гөрс. *Гөрст-гөрст итеп утлы бомба ява.* Г. Кутуй.

ГӨРТ, ГӨРТ-ГӨРТ *авазияр.* Кинәт кабынып сүнү рәвешендәге ритмлы саңгырау тавышны белдерә. *Гөрт итеп мотор кабынды.* Г. Ахунов.

ГӨРТЛӘҮ *ф.* Гөрт итү, гөрт иткән тавыш чыгару.

Гөртләп кабыну — 1) гөлт итеп кабыну, кинәт һәм көчле янып китү; 2) кызып китү, кинәт кенә ачуланып ташлау. *Син күпмедер вакытка бик сабыр булсаң да, бер кызсаң, гөртләп кабынасың.* Б. Камалов.

ГӨРӘНКӘ *и. иск.* Авырлык үлчәү берәмлеге: бер кадак.— *Дә, өч гөрәнкә он үлчәтеп ал.* Ә. Фәйзи.

◇ **Гөрәнкәсе җиңел** — акылга сайрак, акылы тулы булмаган, юләррәк (кеше).

ГӨРҖӘ *и. к.* гюрза.

ГӨСЛӘ *и.* Бармаклар белән чиертеп уйный торган күпкыллы музыка коралы. *Әйдә, тотып гөсләләрне, Бераз җырлап алыйк.* Ә. Исхак.

ГӨСЛӘЧЕ *и.* Гөсләдә уйнаучы, гөсләдә уйнау остасы.

ГҮ, ГҮ-ГҮ *авазияр.* 1. Механик приборлардан яки мотор, машинадан чыккан сузынкы түбән тавышны белдерә. *Өй эченнән «гүү-гүү» итеп тоник кына шаулаган сепаратор тавышы һәм шуңа аралашып хатын-кызларның сөйләшкән, көлешкән тавышлары ишетелеп тора.* Ә. Еники.

2. Күгәрченнең гөрләү тавышын белдерә. *Тиз килер шул көннәр, Күгәрчен шат гөрләр: гү-гү-гү... Гөр-гөр-гөр...* М. Максуд.

3. Ябышлы баланың беренче авазлар чыгарып сөйләшүен белдерә. *Нәни улым көлсен, гү-гү килсен...* М. Максуд.

ГҮБӘН *с. диал.* Базык; юан, калын (кеше турында).

◇ **Гүбән чәч** — чыкканда ук ак булып чыккан юан ак чәч.

ГҮЕЛДЕК *с.* Гүелдәп торган. *Гүелдек тавыш.* // *и. мәгъ. Тирә-якта колак тондыргыч бер гүелдек яңгырап тора.* Н. Фәттах.

ГҮЕЛДӘҮ *ф.* Машина яки гомумән моторның ритмик сузынкы түбән тавыш чыгарып торуы, гү-ү итеп эшләве. *Машина, әле очып барган самолеттай гүелдәп, үргә менә, әле --- түбәнгә ыргыла.* Г. Иделле.

ГҮЗӘЛ *с.* 1. Чибәр, күркәм, матур (төсе). *Көтмәгәндә, гүзәл бу чәчәккә Китереп басты аның итеге.* Ә. Исхак. // *и. мәгъ.* **гүзәлем.** Иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе. *Вакыт җитми, кавышып булмый — Сабыр итик, гүзәлем.* Җыр.

2. Яхшы, бик яхшы (сыйфаты, эчтәлеге һ. б.). *Җир йөзендә иң гүзәл, иң мәһабәт нәрсәләр кеше башы белән уйлап табылган, кеше кулы белән ясалган.* И. Гази.

ГҮЗӘЛЛЕК *и.* Матурлык, ямь. *Бүгенгебез гүзәллегеннән дә гүзәл булсын безнең киләчәк.* Ш. Маннур. // Яхшылык, камиллек, әйбәт булу сыйфаты. *Әллә ачык елмаюы аның, Әллә кыю сүзе, белмәдем, Кешедәге эчке матурлыкны, Гүзәллекне миңа сөйләде.* З. Мансур.

ГҮЗӘЛЛӘНҮ *ф.* Матурлану, матур, гүзәл булу. *Ничек гүзәлләнеп таң әйләнә! Матурлыктан күзләр бәйләнә.* Ф. Бурнаш.

ГҮЗӘЛЛӘҮ *ф.* Матурлау, матур итеп күрсәтү. *Хәзер менә нәни куакчыклар Гүзәллиләр йөзен даланың.* Ш. Мөдәррис.

ГҮЛӘТҮ *ф.* Гөрләтү, гөжләтү. *Бик шәп, гүләтеп ут [костер] ягылды.* М. Гафури.

ГҮЛӘШҮ *ф.* Шаулашу, шау-гөр килү, гүләү. *Утырыштагылар гүләшә башладылар.* А. Расих.

ГҮЛӘҮ *ф.* 1. Шау-гөр килү, күп төрле тавышлардан гөр килеп тору. *Бөтен тирә-як мең төрле нечкә авазлар белән үзалдына гүләп тора.* Г. Бәширов. *Анда умарта корты кебек гүлиләр иде.* Г. Ибраһимов.

2. Гүелдәү, машиналарның тавышланып эшләве. [*Бомбардировщикларның*] *басынкы гүләүләре дулкындулкын булып килә һәм кайдадыр еракта — көнбатышта югалалар.* Г. Әпсәләмов. // Гүләп, гөрелдәп чыгу (тавыш турында).

ГҮП *авазияр. к.* гөп. *Сикерә алмассыз инде күп, Егылырсыз итеп «гүп!».* Г. Камал.

ГҮПЕ *с. к.* копы. *Урам уртасына бер казак килеп туктады, аның башында алама гүпе.* А. Таһиров.

ГҮР *и.* 1. Кабер, каберне эчке өлеше. *Менә гаҗәп, үзе төшкән үзе казыган гүренә.* Н. Исәнбәт.

2. *күч.* Үлем. *Вакыт инде гүрне кайгыртырга, Мин килмәгән җиргә гомергә.* М. Җәлил.

Гүргә индерү — үлгән кешене кабергә төшерү. **Гүр сәдакасы** *дини.*— үлгән кешенең гөнаһларын йолдыру өчен, мәет өстендә әйтеп, аның өчесе узганчы бирелә торган аяклы мал. *Гүр сәдакасы өчен фәкыйрь кешеләрнең актык сарыгын алганда, бер дә безнең янга килми бит ул.* А. Шамов.

◇ **Гүргә керү, гүр иясе булу** — үлү.— *Калага алдырып, абыйның кайдалыгын әйттерер өчен кыйнаганнар иде, шуннан соң, хәленә килә алмыйча, гүр иясе булды.* К. Тинчурин. **Гүр тынлыгы** — тулы тынлык. *Гүр тынлыгы басу.*

ГҮРГӘ'ЧӘ *рәв.* Үлгәнче, гүргә кергәнче, гүргә кергәнгә чаклы. *Аерылмабыз, дустым, гүргәчә!* Ф. Бурнаш.

ГҮРЛЕК *и. к.* каберлек. *Алда, артта шаулый туплар, Уйный уклар шәүләсе. Баскан әз гүрлек — каберлек, Канлы илнең гәүдәсе.* Һ. Такташ.

ГҮРЛӘҮ *ф. сир.* Гүргә керү, үлү, гүр иясе булу. *Күп каһарман гүрләгәндә, син аяк чалдың гына.* Шура. // Җирләү, күмү.

ГҮРНИЧӘ *и. диал.* Ак өй, кунаклар кабул итә торган чиста, якты, зур итеп эшләнгән өй; *русчасы:* горница. *Безнең Тархан байларында кара-каршы гүрничә.* Бәет. *Өстәлләрен алмас идем, Гүрничәмнең күрке юк...* Бәет.

ГҮРСТАН *и. иск. к.* каберлек.

ГҮ'Я *терк.* Предметларны, күренешләрне чагыштыру, охшату өчен кулланыла: әйтерсең лә. *Су өсте тын булды, Ул гүя туктаган.* Н. Исәнбәт. *Күге зәңгәр гүя йолдызлары Ак кар булып җиргә коела...* Һ. Такташ. // *бәйл. функ. к.* кебек. *Я җанвардай үкерәдер, я егълый гүя бала.* Дәрдмәнд.

ГҮ'ЯКИ *терк. к.* гүя. *Сүзең үтмәс урыннарда әмер итмәк — Гүяки багананы ташка какмак.* М. Гафури. *Өзгәләнә бала, кулын суза, Гүяки ул безне чакыра.* Ә. Ерикәй.

Д

Д Татар алфавитында бишенче хәреф.

ДА (дә, та, тә) *кис., терк.* **1.** *кис.* Үзе карагән сүзгә басым ясауны белдерә. *Бик тә салкын хушлашты ул.* Ш. Бикчурин. *Безнең халыкта дуслык көчле. Менә шуңа күрә дошманны җиңәбез дә шул без.* Ә. Айдар. // Үзе караган сүзгә басым ясап, чикләүне, аерып күрсәтүне белдерә. *Аңа балык булсын. Балыкның да ниндие генә әле: Ык патшасы җәен!* М. Шабаев. // Соклану хисен белдергән тезмәдә, кабатлап әйтелгән исемнәр арасында килеп, басымны куәтли.— *Ну аты да аты! Биеп кенә тора.* Г. Гобәй.

2. *кис.* «Хәтта» мәгънәсен белдерә. *Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә әз.* Мәкаль. *Уйлый күңел үлем каршында да Баш имәгән дуслар турында!* З. Мансур.

3. *кис.* «Нәкъ» мәгънәсен белдерә. [*Ябалак*] *канатларын ботакларга бәреп бетергән һәм җиргә килеп төшкән. Ә хәйләкәр төлкегә шул гына кирәк тә булган, ул аны байтактан бирле сагалап йөри икән.* А. Алиш.

4. *кис.* «Шулай ук» дигәнне белдерә. *Иртәгә дә көн безнеке бит.* Г. Ибраһимов. *Хәзер патша үлде, аның законнары да үлде.* И. Гази. *Журналны без әдипләрнең иҗат тәҗрибәсен --- пропагандалый торган бер үзәк дип тә беләбез.* З. Нури.

5. *кис.* Кайбер алмашлыклардан һәм «көн», «ел» сүзләреннән соң: «һәр», «саен» мәгънәсен белдерә. *Кем дә үти алырлык эш.* □ *Көн дә иртән Казан ягына Ак пароход үтә Иделдән.* Ф. Кәрим.

6. *кис.* Фигыльләрдән соң: эш-хәлнең тиз үтүен белдерә. *Мине ничек кыерсытуыңны оныттың дамыни?* Мең дә бер кичә.

7. *кис.* Иярчен урын җөмлә хәбәреннән соң: якынлыкны белдереп, «шуннан соң ук» дигәнне аңлата. *Баскычтан менгәч тә безнеке беренче ишек.* Э. Касыймов.

8. *кис.* Озын көйле халык җырларында: иҗек санын тутырып, ритм саклау өчен кулланыла (гадәттә «ла» кисәкчәсен алмаштыра). *Кызыл да гына төлке, урман күрке, урманнарга кереп лә югала. Батыр да гына егет, һай, күкрәге хәнҗәр әзе белән лә дан ала.* Җыр.

9. *терк.* Эзлекле эш-хәлләрне белдергән гади һәм тезмә кушма җөмләләрдә тиңдәш фигыль-хәбәрләрне яки гади җөмләләрне теркәп, «аннан соң» мәгънәсендә килә.— *Атларыңны тугар да кереп чәй эч.* Г. Ибраһимов. *Кояш бата да кич була.* Г. Насрый. // Сан исемнәрен, санны, микъдарны, яшьне һ. б. ш. белдерә торган сүзләрне терки. *Унбер яшь тә Тугыз ай дигәндә Сирай ятим калды.* Н. Баян. *Өч тә өч алты була.* Сөйләмнән. // Күп урынлы санның (бигрәк тә аның берәр урта буыны нуль булса) янәшә буын исемнәрен терки. *Синекеке, минекеке, өч йөз бер кешегә алты йөз дә икебула ул.* Г. Гобәй. [*Мәдрәсәгә язылганда*] *мин үземнең кырык беренче түгел, бәлки йөз дә әллә ничәнче шәкерт икәнемне белдем.* М. Гафури. // Хәлнең-хәрәкәтнең тиз булуын, эшнең җитез үтәлүен белдергән фигыль тезмәләрдәге сүзләрне терки.— *Кырын эшкә юл куялар икән, өсләреннән язам да бирәм.* А. Расих.— *Санап торганчы, тотам да үлчим.* Мең дә бер кичә.

10. *терк., кис.* Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен теркәп, чикләүне белдерә. *Бу арада бөтен егетләрнең Теллә рендә кук тә йолдызлар.* Ә. Юныс.

11. *терк., кис.* Фигыльне кабатлап ясаган тезмәдә кулланылып, озаклыкны белдерә. *Әтәчләре дә бүген дөмекте, кычкырмый да кычкырмый.* Т. Гыйззәт.

12. *терк., кис.* Беренче сүзе логик басымлы тезмәдә кабатлап әйтелгән фигыльләрне теркәп, шөбһәсезлекне белдерә.— *Сәлим абзый тегеләйрәк җыелышлардан да калмый, моңа бара да бара инде ул.* Ш. Камал.

13. *терк., кис.* Кабатлап әйтелгән ымлыкларны һәм аваз ияртемнәрен теркәп, тизлек-җитезлекне, эш-хәлнең активлыгын белдерә. *Тимер ваклый чүкеч: Доң да доң!* М. Җәлил. *Ишекләр шалт та шалт ачылды, ябылды.* И. Гази.

14. *терк., кис.* Каршы кую бәйләнешендәге җөмлә кисәкләрен яки җөмләләрне теркәп, «ләкин», «карамастан» дигәнне белдерә. *Минем хатын һаман сезгә үпкәли. --- Вәгъдә иттегез дә килмәдегез.* И. Гази. *Арабыздан Ленин югалса да уе яши безнең арада.* Н. Баян.

15. *терк., кис.* Һәр тиңдәш кисәктән соң кабатланып, аларга басым ясый. *Муса да, мин дә бик дус яши идек.* М. Максуд. *Тыныч та да, сугышта да Куллар тотышып барабыз.* Ә. Ерикәй.

ДАВЫЛ *и.* **1.** Гадәттә явым алдыннан яки явым вакытында була торган җимергеч көчле җил. *Давыл чыгу. Давыл күтәрелү.* □ *Җил кинәт көчәйгәннән-көчәя барды. Берничә минуттан соң инде ул көчле давылга әверелде.* Г. Галиев. // *күч.* Зур куәт һәм дәһшәт белән үтә торган эш-хәл, процесс, күренеш. [*Сугыш кырындагы*] *бу котырынган ут һәм тимер өермәсенә кемнең дә булса җитәкчелек итүе, бу коточкыч давылның кемнеңдер ихтыярына буйсынуы акылга сыймаслык бер нәрсә кебек тоела.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Иҗтимагый хәрәкәттәге, җәмгыять тормышындагы дәһшәтле вакыйгалар, бәрелешләр турында. *Сыйнфый көрәш давыллары. Гражданнар сугышы давылы.* □ *Революция иске дөньяны җимерүче давыл гына түгел, революция — яшьлек ул!* Ш. Маннур. // *сөйл.* Гауга, зур ызгыш. *Шәмгун карт аның* [*хатыныны*] *тиз генә туктамаячагын сизеп алды да чыгып китте. Аның давылыннан бары шулай гына котылырга мөмкин иде.* А. Шамов.

3. *күч.* Көчле хисләрнең ташуы турында. [*Габдулла*] *яңа хисләр, яңа кичерешләр давылы эчендә бөтерелде, бер көлде, бер елады, бер шатланды, бер моңайды.* Ә. Фәйзи.

4. *с. мәгъ.* Давыллы (көн турында). *Без таш өйдек шушы стенага Салкын буран, давыл көннәрне.* Н. Баян.

◇ **Давыл кошы** *зоол.*— ыргак сыман томшыклы, тар һәм озын канатлы диңгез кошы; *русчасы:* буревестник.

Давыл чәчәге *бот.*— гадәттә сары чәчәк ата торган үлән; *русчасы:* лютик едкий.— *Менә бу сары чәчәкне давыл чәчәге диләр. Өзәргә ярамый; өзсәң, давыл чыга.* Г. Әпсәләмов.

ДАВЫЛЛАНУ *ф.* 1. Давыл чыгарып хәрәкәт итү. *Яшенле яңгыр алдыннан һаваның бик давылланулы. Давылланып болыт килү.* □ *Давылланып көчле җилләр исәр.* М. Җәлил. // Давыл тәэсиренә бирелеп, көчле хәрәкәткә килү. *Ярларыннан чыгып, ярсып-ярсып Давыллана, диләр, чал диңгез.* Ш. Маннур.

2. *күч.* Көчле хисләрне тышка чыгару (ачулану, талашу һ. б. ш.); ярсу. [*Наилә*] *кече яктан давылланып чыкты да, Хәлләнең ашап бетергәнен дә көтмичә, чатыр чабып табынны җыярга да тотынды.* Ф. Хөсни. *Җанда яхшы хисләр яңарды. Йокладылар кыргый омтылышлар, Давыллану-ярсу калмады.* М. Максуд. // Үтә көчле дәрт, бик зур куәт белән хәрәкәт итү, эшләү һ. б. ш. турында. *Давылланып барган егет алда, Ә иптәше, байрак тотып,— янда.* Ә Исхак. [*Шагыйрь*] *давылланып яшәргә омтыла.* Г. Хужиев.

ДАВЫЛЛАУ *ф.* Давыллы булу (көн һ. б. турында). *Көн давыллап торганда ерак юлга чыкмый калу.* // *сөйл. к.* давыллану. *Диңгезнең дә була төрле чагы, Бер давыллап ала, бер тына.* Ш. Галиев. *Тормыш бит ул шаулы диңгез, Бер давыллый, бер тына.* Соц. Тат. // *з-сыз.* Көннең давыллы булуы турында. *Бүген дә җилли, давыллый, һавада циклон бугай.* Х. Туфан.

ДАВЫЛЛЫ *с.* 1. Давылы (1 *мәгъ.*) булган; давыл белән бергә була торган. *Давыллы көн.* □ *Төн давыллы, Кар туза.* Һ. Такташ. *Йөзләрчә арбалар күпердән узгандай тоташ дөбердәп, давыллы яңгыр килеп тә җитте.* Ә. Еники. // Давыл тәэсиренә бирелеп, хәрәкәтләнеп тора торган. *Давыллы елганы кичтек.* И. Гази.

2. *күч.* Дәһшәтле, шау-шулы иҗтимагый һәм шәхси бәрелешләргә бай булган (чор, вакыйгалар һ. б. ш. турында). *Гражданнар сугышының давыллы еллары шаулап уздылар.* Г. Нигъмәти. *Ике атна буе барды бу давыллы җыелышлар.* И. Гази.

3. *күч.* Көчле, ташып торган (хисләр һ. б. ш. турында). *Давыллы хисләрнең ташуын --- Җырлыйм мин.* Һ. Такташ.

ДАГА *и.* 1. Таюдан һәм зарарланудан саклау өчен ат тоягына кадаклап беркетелә торган, тояк формасына китереп бөгелгән яссы металл җайланма. *Атның дагасы төшү. Дага кадагы.* □ — ***Какшаган дагаларны өч көндә алыштырып бетерерсез.*** Ә. Еники.

2. Тузудан саклау өчен күн аяк киеме табанының алгы өлешенә һәм үкчәсенә кадаклап беркетелә торган юка металл җайланма (дуга сыманрак итеп коелган була). *Ботинканың дагасы кубу.* □ *Ут яктысында Мәрдән абзыйның итек үкчәсендәге шомарган дагасы --- күренеп калды.* Г. Гобәй.

ДАГАЛАУ *ф.* 1. Дага беркетү (ат тоягына). *Дагалау станы.* □ ***Мөнип абый аны*** [*стандагы атның аягын*] *күн алъяпкыч ябылган тез араларына кыстыра да эшкә тотына. Уткен пычак белән тоягыннан юка алсу телем кисеп ала. Аннары дагалау башлана. Көйгән тире исе, йон исе тарала.* М. Шабаев.

2. *күч. гади с.* Берәр өлкәдә эшләү өчен җитәрлек белем, теоретик хәзерлек бирү (гадәттә политик яктан). *Кыска сроклы курс ачыла. Без сине шунда җибәрергә булдык. Бераз дагалап кайтарсыннар үзеңне.* А. Расих.

3. *күч. гади с.* Алдау. *Тукта, мин сизмәгәндә генә, теге явыз мине дагаламыймы икән дип хәвефләнеп торасы юк, бергәләп табалар, бергәләп кабалар иде* [*грузчиклар*]. Ф. Хөсни.

ДАГАЛЫ *с.* Дагасы булган; дагаланган. *Дагалы итек.* □ *Атымның тояклары дагалы.* И. Гази.

ДАГАН *и.* 1. Атынып уйнау өчен ясалган җайланма (гадәттә асылма утыргыч рәвешендә була). *Кечкенә кызның әнисе Илсөярга сөтле, шикәрле салкын әйбер ашатты һәм аның белән кара-каршы басып дагана атынды.* Г. Гобәй.

2. *диал. к.* таган. [*Бәдретдин*] *даганга чиләк элгән дә учак янында йоклар-йокламас калыгып утыра.* Г. Бәширов.

ДАИМ *рәв. иск. кит.* Һәрвакыт, гел. *Чыга идем даим юлга, Тота идем китап кулга.* Г. Кандалый.

ДАИМИ *с.* 1. Һәрвакыттагы, гадәти, үзгәрешсез, үзгәрми торган (сыйфат һ. б. турында). *Даими теләк. Даими омтылыш.* □ [*Акча*] — *кыйммәте даими һәм ышанычлы булган товар.* Г. Тукай.

2. Вакытлы булмаган, озак сроклы. *Даими семинар. Авыл Советының даими комиссияләре.* □ [*Докладчы*] *урман эшен механикалаштыру, аңа даими кадрлар булдыру турында --- сөйләде.* Г. Әпсәләмов.

ДАИМИЛЕК *и.* Даими булу хәле һәм сыйфаты. *Үсешнең даимилегенә ирешү. Үзлекнең даимилеге.*

ДАИМӘН *рәв. иск. кит.* Гел, өзлексез, һаман. *«Йолдыз» газеты уникә ай даимән Садрый әфәндене мактап яза.* Ф. Әмирхан.

ДАИР *юн. килеш бәйл. иск. кит.* Берәр нәрсәгә яки кешегә кагылышлы, мөнәсәбәтле; шуңа караган, шуның хакында булган. *Шәкертләргә даир мәкалә. Әхлакка даир хикәяләр.* □ *Көтепханәдә егерменче гасыр башына даир никадәр китаплар бар.* Ф. Әмирхан.

ДАИРӘ *и. кит.* 1. *иск.* Түгәрәк. *Безнең көймә бер даирә эчендә мәркәз ноктасында торган төсле.* Ш. Әхмәдиев.

2. Тирә-юнь, чолганыш, мохит. *Шатлык бизәкләгән бәхет илен. Нур балкыта бөтен даирәне.* Ә. Ерикәй.

3. Эшләре, профессияләре, карашлары уртак булган кешеләр төркеме. *Киң даирә. Тар даирә. Идарәче даирәләр. Бер даирә кешеләре. Промышленность даирәләре. Хөкүмәт даирәләре.* □ *Тукайның шәхесе белән таныш даирәләрдә йөргән кешеләрнең ишеткәннәре бардыр, ул хатын-кыздан кача иде.* Ф. Әмирхан.

4. Берләштереп карала торган мәсьәләләр, темалар һ. б. ш. төркеме, шуларны эченә алган берәр өлкә, цикл. *Идеяләр даирәсе. Хәл итәсе мәсьәләләр даирәсе.* □ *Шигырьләребезнең даирәсе бик кечкенә, төре бик аз.* Г. Ибраһимов. // Норма, кагыйдә, тиешле чик (үзүзенне тотуда). *Әдәп даирәсе.* □ [*Кайбер артист*] *хәрәкәт һәм кыланышларында даирәсеннән чыга.* Ш. Әхмәдиев.

ДАК *аваз изәр., гадәттә* «док» *сүзе белән бергә.* 1. Түбән тонлы көчле саңгырау шакылдау тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «док» *сүзе белән бергә.* «Дак», «док» сыман тавышлар чыгарып. *Дак-док басып йөрү.*

ДА'КТИЛЬ *и. әд.* Силлабо-тоник шигырьдә (мәс., рус, немец, инглиз телләрендә): беренче иҗегенә басым төшкән өч иҗекле ритмик буын (стопа).

ДАЛА *и.* 1. Күбесенчә үлән белән генә капланган, зур мәйдан алып тора торган тигез җир (гадәттә корырак якларда). *Очсыз-кырыйсыз дала. Анда бер генә агач, бер генә куаклык та юк. Ул кыган үләне белән капланган.* А. Әхмәт. // Гомумән, киң кыр, еракка сузылган тигез җир. *Калкынып Зәй даласыннан, Кыймыйгына елмайды ай.* Ә. Юныс.

2. *с. мәгъ.* Дала рәвешендәге; далалы. [*Асылгәрәй*] *күзен ачып җибәрсә, инде үрне узганнар да. Алда тагын шул ук шыксыз дала җирләр.* М. Шабай.

ДАЛА'Й-ЛА'МА *и.* Тибетта баш рухани, чиркәү оешмасы башлыгы (1951 елга чаклы бер үк вакытта Тибет дәүләтенең дә башлыгы).

ДАЛАЛЫ *с.* Даласы яки далалары булган; даладан яки далалардан торган. *Далалы якларга күчү. Украинаның далалы районнары.*

ДАЛЬТОНИЗМ *и.* Күз авыруы: кайбер төсләрне аера алмау.

ДА'МА *и.* 1. *иск.* Гадәттә хәлле катлаудан, шәһәр интеллигенциясеннән булган хатын, ханым. *Кыланчык аристократия дамалары арасында мигрень авыруы үз алдына бертөрле --- модный авыру хисаплана.* Ш. Камал. // Гомумән, хатын кеше. [*Курортта*] *чишмә янында халык өелеп тора: һәркайсы --- я таныш дамалары белән сөйләшеп тора, ә яшьрәкләр кызлары белән очрашу урынын шушында билгеләгәннәр.* И. Гази.

2. Танцыда: кавалер белән бии торган хатын-кыз. [*Офицер Кривоносов*], *дамалар сайлаганда, сары чәчлесен сайларга* [*тырыша иде*]. М. Гали.

3. Хатын-кыз сурәте төшерелгән уен картасы. *Дамадан йөрү. Уен дамасы.*

ДА'МБА *и.* Күбесенчә балчыктан өелгән һәм су басудан саклау, сулыкларны буып тору һ. б. ш. өчен хезмәт итә торган, өсте гадәттә юл итеп файдаланыла торган гидротехник корылма. *Тимер юл дамбасы. Күл буендагы дамба. Асфальтлы дамба. Таш җәелгән дамба.* □ *Шәһәрне судан саклау дамбалары Яңа бистә ягыннан башланып, вокзал, Кремль буйларыннан үтә.* С. Сабиров.

ДАМЕЛЛА *и. иск.* Мәдрәсә тотып, дәрес бирүче мулла. *Дамеллага фәтва сорарга бару.* □ *Бер дә шиксез, минем әнем Буага мөдәррис вә дамелла булыр.* Г. Тукай.

ДА'МКА *и.* Шашка уенында: каршы як шакмакларының соңгы рәтенә җитеп, алга да, артка да теләсә ничә шакмакка йөрү хокукы алган шашка.— *Без инде аннан соң берьюлы аның* [*каршы якның*] *өч шашкасын алабыз да дамкага чыгып утырабыз.* М. Гали.

ДАН *и.* 1. Бирәүнең яки берәр нәрсәнең уңай сыйфатлары турында киң таралган сүз; мактаулы исем; шөһрәт. *Гармунчы дигән даны бар, Сөеп туймас яры бар.* Җыр. *Безнең Советлар илендә исә һәрбер намуслы хезмәт кешегә дан китерә.* Г. Кутуй. / *юг.* Күтәренке хис белән, хөрмәтләп әйтелә торган тантаналы мактау сүзе. *Дан аларга! Бөек кешелекнең Батыр улларына дан бездән! Дан аларга шанлы чорыбыздан! Дан аларга безнең барыбыздан!* Ә. Исхак. // Гомумән, нинди дә булса бер эш, бер сыйфат белән танылганлык. *Бу җыр кичәләренең даны бүтән мәдрәсәләргә барып җитте.* Ә. Фәйзи. *Яман дан дегет табы кебек бит, тиз ябыша.* Г. Әпсәләмов.

2. *гадәттә тартымлы форм.* Үзенең хезмәтләре, батырлыклары, уңай сыйфатлары белән берәр кешенең, коллективның, илнең исемен данлыклы иткән, аңа мактау китергән кеше һ. б. ш. турында. *Биек йортлар, гигант заводлар! Илебезнең байлыгы, даны, күәте алар.* Р. Ишморат. *Җиңгән егет илгә дан!* Н. Исәнбәт.

3. *с. мәгъ.* Данлыклы, атаклы (кешеләр турында); бик мактап сөйләнә торган (төрле нәрсәләр турында). *Моратай исә заманында бик гайяр, бик дан кеше булган.* Г. Бәширов. [*Кызның*] *чибәрлеге дә дан түгел, гәүдәгә дә чандыр гына.* Ф. Хөсни. *Сөте ягыннан әллә ни дан булмаса да, юашлыгы белән көтүдә тиңдәше булмаган* [*бу сыерның*]. М. Хәсәнов.

◇ **Дан алу** — 1) мактаулы булып танылу, исем таралу. *Үлсәң дә, егет, Ул син дан алып.* Ф. Кәрим; 2) гомумән, нинди дә булса берәр эшең, сыйфатың белән халык теленә керү; билгеле булу. [*Сәмигулла*] *аз сүзле булуы белән дан алган.* А. Шамов. *Бәрәңге ул дан алган, Бөтен җиргә таралган.* Ә. Ерикәй. **Дан сату** — начар исем белән телгә кертү, начар исем күтәртү: начар эш эшләп, исемен пычрату.— *Бөтен районда алдан барырлык булмагач, «Чулпан»ның* [*колхозның*] *даныя сатып, тавыш күтәреп йөрмим дә мин.* Г. Бәширов. **Дан тоту** — данлыклы булу. *Безнең егетләр җырда да, Хезмәттә дә дан тота.* Х. Вахит. **Дан эше** *юг.*— мактаулы, дан китерә торган эш. *Хезмәт бездә дан эше, кайда гына эшләсәгез дә, хезмәт бездә мактау эше.* А. Алиш. **Дан җырлау** *юг.*— берәр кешене, берәр нәрсәне бик нык мактап язу, сөйләү. *Яшьлек үсә Совет җирендә, --- Дан җырлыйк Яшьлек иленә!* Г. Кутуй.

ДА'НИЯЛЕ и. Дания халкы вәкиле.

ДАНЛАУ *ф.* Данлыклау. *Халкымның көчен, батырлыгын, Горурлыгын данлый* [*җыр*]. Ш. Маннур.

ДАНЛЫ *с.* Даны булган; данлыклы, атаклы. *Данлы гаскәр. Данлы бәйрәм. Данлы чор.* □ *Атаң мәрхүм дә синең бөтен тирә-юньдә данлы аучы иде.* А. Шамов. *И данлы ил, и шанлы ил, Син минем туган илем.* Г. Кутуй. // Дан китерә торган, мактаулы. *Сине саклап, туган җирем, Мин ирләрчә үләр идем Данлы сугыш кырында.* М. Җәлил. *Чигенеп хурлыкка калганчы, данлы үлем белән үлү яхшырак!* Каз. утл.

ДАНЛЫК *и. сөйл., сир.* Дан (1 *мәгъ.*); мактаулы исем. *Сугыш беткән, дошман җиңелгән. Данлык белән гаскәр күмелгән.* Ф. Бурнаш. *Үлгәннәргә данлык! Тереклә ргә иркенлек!* Г. Коләхметов.

ДАНЛЫКЛАУ *ф.* Берәр кешенең яки берәр нәрсәнең исемен атаклы итү, данын (1 *мәгъ.*) танып телгә алу, халык арасында тарату. *Данлыклагыз үлмәс батырлыгын Большевикның, бөек кешенең!* Ә. Исхак. *Совет фәне Октябрь Ватаның бөтен дөньяга данлыклады.* Соц. Тат.

ДАНЛЫКЛЫ *с.* Атаклы, мәшһүр; исеме, даны киң таралган, танылган. *Иң зур сабан туйларында да ул* [*Хафиз*] *әллә кайлардан килгән данлыклы көрәшчеләрне шаяртып кына чөеп ташлый торган булган.* Г. Ибраһимов. *Бу сорт* [*алма*] *үзенең тәмлелеге һәм көзге салкыннарга чыдамлыгы белән данлыклы.* Г. Галиев. // Мактауга, данлыклауга лаек булган. *Җәмгыятькә файдалы һәм данлыклы эш беткәнме?* М. Җәлил.

ДАНӘ *и.* Саннар һәм микъдарны белдергән сүзләр янында: бер төрдән булган әйберләрнең берсе; берәмлек. *Мәктәп өчен хәзер үк бер мең данә кирпеч кирәк.* Г. Галиев. *Вәли рәсемен мин берничә данә итеп эшләдем.* Г. Кутуй.

ДАР *и.* Асып үтерү юлы белән җәзалау җайланмасы: бер яки ике багананың башына аркылы агач беркетеп ясалган **корылма**. *Дарга асу.* □ [*Шәрифне*] *җилтерәтеп дар астына илтеп, муенына элмәк салалар.* Н. Исәнбәт.

палачлары; Урам саен тезелеп киткән Дар агачлары.

◇ **Дар агачы** *к.* дар. *Котырынган бу авылда Фриц* Ф. Кәрим.

ДАРВИНИЗМ *и.* Терек табигатьнең үсеш законнары — хайван һәм үсемлек төрләренең табигый сайланыш нәтиҗәсендә барлыкка килүе һәм үсүе турындагы тәгълимат.

ДАРВИНИСТ *и.* Дарвинизм тарафдары.

ДАРВИНИ'СТИК *с.* Дарвинизмга нигезләнгән; шуңа мөнәсәбәтле. *Дарвинистик караш.*

ДАРДАР *и. диал. к.* элмә.

ДАРЕЛФӨНҮН *и. иск.* Университет. *Петербургның дарелфөнүн* [*врачын*] *--- минем номерыма китерттек.* **Г. Тукай.**

ДАРУ *и.* 1. Чирне яки авыртуны бетерү яисә киметү өчен кулланыла торган, сыекча яки порошок хәлендәге матдә. *Ютәл даруы. Баш даруы. Йөрәк даруы.* □ *Аның битенә салкын су бөркеп, дару иснәтеп көч-хәл белән аңына китерделәр.* М. Гали. // Җәрәхәтне, авыртканжирне турыдан-туры эшкәртә торган шундый матдә. *Пешкән җирне дару сөртеп бәйләү. Күзгә, колакка дару салу.*

2. Бөҗәкләрне бетерү һ. б. ш. өчен булган агу. *Таракан даруы. Дару сибү.*

3. *күч.* Күңелсезлекне һ. б. ш. борчуны җиңел кичерергә, аннан арынырга ярдәм итә торган чара. *Интектерде мине айлар буе Эчем пошуы, йөрәк ануы. Кирәк иде миңа тәннән бигрәк Җан даруы, күңел даруы.*

М. Җәлил. *Дару таптым көрәш кочагында Иске көннән килгән ярага.* М. Крыймов.

Дару итү *сөйл.*— авыру кешене яки аның чирен дәвалау. *Мәзинне дару итә торган ханәгә җибәргәннәр.* Әкият.

ДАРУЛАУ *ф.* 1. *к.* дәвалау **1.** *Рәхим яраларны юып дарулады.* А. Расих.

2. *сөйл.* Дару белән эшкәртеп агулау. *Бөҗәкләр туплана торган урынны дарулау.*

ДАРУЛЫ *с.* **1.** Даруы булган, эченә дару салынган. *Дарулы шешә. Дарулы ампула.* // Дару исе сеңгән, таралган яки дару йоккан. *Дарулы бүлмә.* // Дару белән эшкәртелгән, даруланган. *Дарулы колакны җайлап яту.*

2. Дару бирә, дару ясау өчен китә торган. *Дарулы үлән.*

ДАРЧИН *и.* Тропик лаврлар семьялыгыннан булган бер төр агачның киптерелгән кайрысы (тәмләткеч булараk һәм азык промышленностенда кулланыла); *русчасы:* корица.

ДАРЫ *и.* Ату коралларында кулланыла торган шартлагыч матдә. *Төтенсез дары. Дары савыты.*

◇ **Дары исен иснәү** — сугышта катнашу.— *Бабам Севастополь оборонасы герое. --- Әтием — гвардейский солдат. Аллага шөкер, үзем дә дары исен иснәдем, кешедән калышмадым.* А. Шамов.

ДАСТАН *и. әд.* **1.** Тормышта булган хәлләр, вакыйгалар турында буыннан буынга сөйләнеп килә торган хикәя. *Борынгы әкиятләрдә, дастаннарда «яу» сүзе «дошман» мәгънәсендә йөртелә.* М. Җәлил.

2. Әһәмиятле тарихи вакыйгалар хакында язылган күләмле әдәби әсәр; эпопея. *Классик дастаннар, дөньяның зур вакыйгалары турында хикәя итеп язылган шигъри әсәрләр, гадәттә, әнә шундый төр лирика белән [сугарылган] булалар.* Г. Нигъмәти.

ДАСТАНЧЫ *и. әд.* Дастаннар сөйләүче яки язучы.

ДАҐТА *и.* Берәр вакыйганың календарь вакыты. *Тарихи даталар. Истәлекле дата.* ☐ [*Г. Камал*] *тәрҗемәләренең дата һәм тарихларын да белү читен.* М. Гали. // Документ, хат, төрле әсәрләр һ. б. ш. язылу-эшләнү вакытын (елын яки елы белән аен һәм көнен) күрсәткән билге, язма. *Әдәби әсәрнең язылу датасы ахырда күрсәтелгән булу.* ☐ *Ул, комсомолга кабул итүләрен сорап, әллә кайчан язып куелган гаризасына датасын куйды: 20 февраль, 1933 ел.* Г. Гобәй.

ДАУ *и.* **1.** Берәр нәрсә таләп итеп күтәрелгән көчле дәгъва (1, 2 *мәгъ.*). *Дау кузгату.* ☐ *Җир давы шулай кызып киткән.* К. Нәҗми. // Ызгыш, талаш, гауга. *Дау чыгару.* ☐ *Мәрзия, тынычланып җитмәсә дә, Каюмга сүз үткәрә алмаячагын аңлаганга күрә, артык дау күтәреп маташудан туктады.* Ш. Камал. *Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер.* Мәкаль.

2. *күч.* Көрәш, сугыш. *Без яңа җир, Яңа кеше өчен Җирдә зур дау алып барабыз!* Һ. Такташ. *Изге дауда көч сынауның сәгате килде безгә.* М. Максуд.

ДАУЛАУ *ф.* **1.** Берәр нәрсә таләп итеп, дау күтәрү. *Хокук даулау.* ☐ [*Мортый*] *армиядә булдым, ранен булдым дип кукраеп йөри башлады. --- Колхоздан тегесен-монысын даулый.* Г. Әпсәләмов.

2. Рәсми төстә яки суд аркылы таләп итү. [*Шәйхел:*] *Ачуланма, әткәй, мал дауларга кайтмадым.* Г. Ибраһимов. [*Зәмзәмбану:*] *Яхшылыкта бирмәсәгез, суд аркылы даулап алырмын.* Т. Гыйззәт.

3. *күч.* Берәр нәрсәне яклап көрәшү, сугышу, аңа ирешергә омтылу. *Ирек даулау.* ☐ [*Егетнең*] *бәхеткә һәм мәхәббәткә хакы бар, ул аны --- каны белән даулап алды.* Ә. **Еники.**

ДАУЛАШ *и. сир.* Дау, даулашу. *Күк булып күкрәр һавада хәр яшәү даулашлары.* Г. Тукай.

ДАУЛАШУ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* даулау.

2. Берәр нәрсә даулау; даулап сатулашу, ызгыш куптару. [*Вәлигә*] *каршы әйтсәң, даулашсаң, ялкау дип, эш белми дип куа да чыгара.* Г. Ибраһимов. *Шәкертләр, даулашып, мәдрәсәгә яңа программа керттергәннәр.* Ә. Фәйзи.

ДАУЛЫ *с.* Давы булган, дау белән барган, дау белән тәмамланган (эш, мәҗлес, вакыйга һ. б. ш. турында). *Даулы эш.* ☐ [*Галәк бабай:*] *Туйларның зурысын да, кечкенәсен дә, күңеллесен дә, даулысын да күп күрдем.* Г. Әпсәләмов. // Дауга, дау чыгаруга сәбәп булган; низаглы, бәхәсле. *Даулы территория.* ☐ *Куптәрасыз даулы мәсьәләләр, Кампаниягә артык бирелеп.* Ш. Мөдәррис. // *күч.* Гаугалы, ызгышлы вакыйгаларга бай булган, тынычсыз (тормыш, көрәш күренешләре, чор турында). *Даулы көннәр.* // Зур, тарихи көрәшләргә бай (чор һ. б. ш. турында). *Авырлыкны җиңгән кеше генә Матур яши даулы заманда.* Р. Гәрәй.

ДАУЧАН *с.* Дау кузгатырга, даулашырга яратучан; дәгъвачыл. *Даучан кеше.* // Дау-көрәшкә сәләтле, сугышчан табигатьле, кыю, батыр. *Салават нинди пәһлеван? Даучан, яучан пәһлеван! Җиңелмәүчән пәһлеван!* Ш. Бабич.

ДАҐФНИЯ *и. зоол.* Төче суда яши торган су борчасының бер төре (маймычларга һәм кайбер балыкларга азык булып хезмәт итә).

ДАҐЧА *и.* Шәһәрдә яшәүченең, күбесенчә җәй көне ял итү өчен, шәһәрдән читтә салган йорты. *Җәй көне эшкә дачадан гына йөрү. Кышкы дача.* // Дача яки дачалар урнашкан урын; дачалык. *Казандагы бер заводның дачасы. --- Күл янына гына унлап өй салганнар. Өйләр тирәсен җиләк-җимеш, чәчәк-гөл түтәлләре белән тутырганнар. Шулай итеп урман уртасында менә дигән ял урыны үзерләгәннәр.* Г. Мөхәммәтшин.

ДАҐЧАЛЫК *и.* Дачалар урнашкан урын. *«Роща» дигән дачалыклар шәһәргә тоташ диярлек, тик шәһәр белән «роща» арасын Урал елгасы гына аера.* Ш. Камал.

ДАҐЧНИК *и. сөйл.* Дачада торучы. *Якшәмбе булганлыктан, бүген дачникларның һәммәсенә кунаклар килде.* Ф. Әмирхан.

ДАШНАК *и. тар.* XIX йөз ахырында төзелгән милли-буржуаз әрмән контрреволюцион партиясе члены.

ДАЯ [дайә] *и. иск. кит.* Икенче кеше баласына сөтен имезеп үстерүче хатын. *Баланың атасы, анасы, агасы, даясе — һәммәсе дә аның ни белән һәм ничек үйнаганын дикъкатьлечә тикшерәләр.* Г. Тукай. // Баланы карап-тәрбияләп үстерүче хезмәтче хатын-кыз. [*Гөлрөх*] *үзенең иң якын даясенә исә бу серне һичкемгә сөйләмәскә кушты.* К. Насыйри.

ДАҢ *аваз изәр.* **1.** Зур кыңгырауны какканда, авыр металл әйберләргә бәргәндә ишетелгән һ. б. ш. түбән тондагы көчле тоник тавышларны белдерә. *Мөнәвәрәнең уйларын тузгытып сәгать сукты: Даңң-ңң!* Г. Ахунов. *Даң-даң-даң! Эшчеләргә эштән туктарга вакыт икәнен белдереп, [кыңгырау] кагылды.* М. Гафури.

2. *рәв. мәгъ., кабатлаулы яки* «доң» *сүзе белән аралаш форм.* «Даң»ны хәтерләткән тавышлар чыгарып. *Фәрит даң-доң барабан кага.* Э. Касыймов.

ДАҢГЫЛДАУ *ф.* «Даң» авазларын хәтерләтеп, өзек-өзек яңгырау. *Цехта эшләүчеләр коелган металл кисәкләре өстендә --- даңгылдыйлар.* Г. Нигъмәти.

ДАҢГЫЛДЫК *с.* Даңгылдый торган.

ДАҢГЫР *аваз изәр., гадәттә* «доңгыр» *сүзе белән аралаш кулланыла.* **1.** Дөбердәүле-калтыраулы «даң» авазларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., кабатлаулы форм.* яки «доңгыр» *сүзе белән аралаш.* «Даңгыр» сыман тавышлар чыгарып. *Буш чиләкнең баскычтан даңгыр-даңгыр төгәрәп төшүе.* ☐ *Даңгыр-доңгыр трамвай килә.* Г. Гобәй. // Даңгырдык яки сикәлтәле юлда (арбага һ. б. ш.) утырып баргандагы селкенү турында. *Илле километр җирне йөк өстендә даңгыр-даңгыр баруны да рәхәт дип булмый.* Соц. Тат.

ДАҢГЫРДАУ *ф.* 1. «Даңгыр» сыман тавышлар чыгару; дөбердәү катнаш даңгылдау. *Буш мичкә даңгырдау.*

2. Даңгырдык яки сикәлтәле юлда арбага һ. б. ш. утырып барганда селкенү.

ДАҢГЫРДЫК *с.* 1. Даңгырдый торган.

2. Даңгырдатып селкетә торган (юл һ. б. ш. турында). *Даңгырдык юл.*

ДАҢГЫРТ *аваз иәр., гадәттә* «доңгырт» *сүзе белән аралаш.* Кискен даңгырдап куюны белдерә.

ДАҺИ *с.* 1. Иң югары иҗади сәләткә ия булган, гадәттән тыш талантлы. *Даһи галим.* □ *Кешеләрнең акылы нинди даһи! Ниләр бүләк итми дөньяга!* Ш. Маннур. // Бөек, данлыклы, мактаулы. *Кара төннәрне яктыртты Аның [Ленинның] Даһи исеме, югалмас даны.* С. Урайский.

2. *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия булган кеше; гадәттән тыш талант иясе. [*Казан университетында*] *кешелекнең иң бөек даһие Ленин укыган.* Ф. Хөсни.

3. Иң югары иҗади сәләт, даһилык җимеше булган (иҗат әсәрләре һ. б. ш. турында). *Даһи эш.* □ [*Низаминың*] *даһи әсәрләре безнең чорыбызда да үзләренең кыйммәтләрен югалтмадылар.* М. Максуд.

ДАҺИЛЫК *и.* Даһи кешегә хас сыйфатлар; даһи булу хәле. *Марксның бөтен даһилыгы нәкъ шуннан гыйбарәт ки, ул кешелек дөньясының алдынгы фикере тарафыннан инде куелган сорауларга җаваплар бирде.* В. И. Ленин.

ДВИ'ГАТЕЛЬ *и. тех.* Берәр төрле энергияне механик энергиягә әверелдереп, нинди дә булса механизмны хәрәкәткә китерә торган машина. *Эчке янулы двигатель. Реактив двигатель.* □ *Эшләп торган двигатель гөжләве генә ишетелә иде.* Ф. Хөсни.

ДВИЖОК *и. тех.* Күчереп йөртелә торган кечкенә двигатель. *Колхозда түгәрәк пычкы! Әллә үзләре такта да яралармы? Ул пычкыны нәрсә белән әйләндерәләр, әллә движоклары да бармы?* Г. Әпсәләмов.

ДВОР *и. сөйл.* Революциягә кадәрге Россиядә: җәяүле һәм атлы юлчылар кереп куна торган йорт. *Әби — авылда двор тотучы карчык.* Г. Камал. *Уникә кеше Камали дворының бер бүлмәсенә кереп урнашты.* К. Тинчурин.

ДВОРЕЦ *и. сөйл. к.* сарай II (*1 мәгъ.*). *Бу дворец Безнең җилкә белән салынды.* Н. Баян.

ДВО'РНИК *и.* Ишек алды һәм йорт тирәсен карап, чистартып торучы эшче. *Рәүф бай дворнигы, капкасын япкач, урамга чыкты да кулындагы себеркесе белән тротуарны себергәләде.* Ф. Әмирхан. *Ак алъяпкычлы дворник бабай кар көри.* Г. Әпсәләмов.

ДВО'РНИКЛЫК *и.* Дворник хезмәте, вазифасы. [*Кочегар Ситдыйк*] *җәй көннәрен дворниклык бурычы үти.* К. Тинчурин.

ДВОРО'ВЫЙ *и. иск.* Алпавыт йортындагы крепостной хезмәтче.— *Сәлим мирзада дворовый булган улымны күрергә кердем.* М. Фәйзи.

ДВОРЯН *и.* Феодаль һәм капиталистик җәмгыятьләрдә: алпавытлардан һәм дәрәҗәле түрәләрдән торган привилегияле хаким катлауның, эксплуатацияләүче сыйныфның вәкиле. *Вак дворяннар.* □ — [*Кригерның*] *дүртенче бабалары Пугачев явын бастыруда эш күрсәткән икән, шуннан әби патша боларның бабаларын дворян ясап, безнең бабайларның җирләренә утырткан.* Т. Гыйззәт.

ДВОРЯНЛЫК *и.* 1. Дворян титулы. *Дворянлыкка күтәрелү.*

2. Дворяннар вәкиленә хас сыйфатлар.

ДЕ- *кит.* Сүзгә кире мәгънә биреп, түбәндәгеләрне белдерә торган алкушымча: 1) бетерү-туктату, тарату-таркату һ. б. ш., мәсәлән: **дегазация, демобилизация, демилитаризация;** 2) түбән дәрәҗәгә төшерү, бозу һ. б. ш., мәсәлән: **деградация, девальвация, деформация.**

ДЕБАРКА'ДЕР *и.* Суднолар туктала торган урындагы махсус йөзмә корылма (суднолар килеп туктау, пассажирларга хезмәт күрсәтү һ. б. ш. өчен махсус җиһазланган була). *Дебаркадерны ярга чылбырлар белән тарттырып кую.* □ *Дебаркадердагылар алгарак барып басу, пароходка алданрак кереп, алданрак урын алу өчен --- [ашыга] башладылар. Дебаркадерны ярга тоташтырган басма кырыенда тезелеп тора торган сөт, җиләк, пирожки сатучы хатын-кызлар да --- дебаркадерга үк килеп җиттеләр.* М. Гали.

ДЕБАТ *и. кит. гадәттә күпл. форм.* Парламент утырышында һ. б. ш. җыелышта фикер алышу тәртибендә ясалган чыгышлар, алып барылган бәхәс. *Парламент дебатлары.* □ *Зал тына. Кайнар дебат, җиңел сулыш алып, Яңа фикер көтә.* Х. Туфан.

ДЕБЕТ *и.* 1. Хайван яки кош-корт мамыгы. [*Кызлар*] *җеп эрлиләр йомшак дебеттән.* К. Нәҗми.

2. Йоннан яки мамыктан катып эшләгән чигү җебе. *Яшькелт дебет. Дебет белән яулык чигү.* □ — *Кемдә бар аныкы шикелле кызыл дебет белән чигелгән бик әйбәт кара чуар итек?* Ш. Маннур.

3. *с. мәгъ.* Дебеттән эшләнгән. *Ул күк дебет шәл кырыеннан тузгып маңгайга төшкән сары чәчен колак артына сыпырып куйды.* К. Нәҗми.

ДЕ'БЕТ *и. махс.* Бухгалтер кенәгәсендә: счетның барлык керемнәрне, бирәчәкләрне һәм тотылачак чыгымнарны терки торган ягы; *киресе:* кре́дит.

ДЕБИ́Т *и. махс.* Коедан, скважинадан һ. б. ш. чыганактан алына торган сыеклыкның (суның, нефтьнең һ. б.) яки газның мәгълүм вакыт берәмлегенә туры килгән микъдары, күләме; чыганакның шул микъдарны бирү мөмкинлеге, куәтлелеге. *Дебиты түбән булган нефть скважинасының куәтен арттыру.* □ ***Далада тагын бер скважина ике мең 600 метр тирәнлектән газ бирә башлады. Аның дебиты тәүлеккә 270 мең кубометр.*** Соц. Тат.

ДЕБИТОР *и. махс.* Бирәчәге булган, бурычлы як (кеше яки учреждение).

ДЕБЮТ *и. кит.* 1. Сәхнәдә яки гомумән берәр өлкәдә беренче тапкыр ясаган чыгыш. *Яшь артист дебюты. Дебют уңышлы үтү.* □ *Менә ичмасам дебют! Бер репетициядән — сәхнәгә!* Г. Әпсәләмов.

2. Шахмат-шашкада: уенның баш өлеше, мәгълүм йөрешләрдән торган башланыш. *Дебют теориясе. Дебютларны яхшы белү. Ачык һәм ябык дебютлар. Дебютта фигураларны тизрәк активлаштырып, үзәктә өстенлек алырга омтылу.*

ДЕБЮТАНТ *и. кит.* Сәхнәдә, спорт ярышында яки бүтән иҗтимагый эшчәнлек (гадәттә сәнгать) өлкәсендә беренче чыгышын ясаучы. *Концертта дебютант буларак катнашу. Хоккей дебютантлары.*

ДЕВАЛЬВА'ЦИЯ *и. махс.* Девальвацияләү яки девальвацияләнү эше, акты. *Сугыштан соңгы чорда Көнбатышта үткәрелгән девальвацияләр. Франк девальвациясе. Өлешчә девальвация.*

ДЕВАЛЬВА'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Акча берәмлекләренең кыйммәтен рәсми төшерү. *Стерлингны девальвацияләргә мәҗбүр иткән финанс-экономика шартлары.* □ *Долларны яки башка валютаны девальвацияләү нәрсәне аңлата соң? Долларның халыкара кыйммәте барлык башка валюталарга карата күпмегә кимегән — сүз шул хакта бара.* Соц. Тат.

ДЕВИА'ЦИЯ *и. махс.* 1. Төрле тәэсир нәтиҗәсендә компас угының читкә тайпылуы (җирнең магнит полюсын ялгыш күрсәтә башлавы).

2. Төрле тәэсир нәтиҗәсендә снаряд һ. б. ш. нәрсәнең тиешле юнәлештән читкә тайпылуы.

3. Юлындагы әйберләр нурланышының тәэсире белән радиодулкынның үз юнәлешеннән тайпылуы.

ДЕВИЗ *и.* 1. Эшнең, ниятнең һ. б. ш. төп идеясен, максатын, программасын чагылдыра торган өндәмә-ло-

зунг тибындагы сүз яки кыска тәгъбир. *Көрәш девизы. Юлбашчы сүзләрен эштә девиз итеп алу.*

2. Шартлы имза (ябык конкурска бирелгән әсәрдә, проектта һ. б.). *Тәрҗемәчеләр конкурсына җибәрелгән кулъязмага девизыңны кую.*

ДЕВОН *и. геол.* 1. Җирнең геологик тарихында палеозой эрасының дүртенче дәвере.

2. Җир кабыгының шул дәвергә туры килә торган катламнар системасы. *Нефть фонтаннары күтәрелә, Тишеп төшсәң девон катлавын.* Н. Гайсин.

ДЕГАЗА'ТОР *и.* 1. Дегазацияләү аппараты.

2. Дегазацияләүче; дегазацияләү эшләре белгече.

3. Дегазацияләү өчен кулланыла торган зарарсызландыргыч матдә.

ДЕГАЗА'ЦИЯ *и.* Агулаучы матдәләрдән зарарланган нәрсәләрне (участокны, әйберләрне һ. б.) зарарсызландыру, агусызландыру эше.

ДЕГАЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Дегазация юлы белән эшкәртү.

ДЕГЕНЕРАТ *и. кит.* Нәселдән килгән уңай биологик һәм психик сыйфатларын югалткан яки югалта баручы кеше.

ДЕГЕНЕРАТИВ *с.* Дегенерациягә мөнәсәбәтле. *Хайваннарның йөрәгендәге һәм кан тамырларындагы дегенератив үзгәрешләр.*

ДЕГЕНЕРА'ЦИЯ *и.* 1. *биол.* Терек организмнарда күзәнәкләрнең һәм органнарның (әгъзаларның) таркалуы.

2. Организмдагы биологик һәм психик сыйфатларның начарлануы; уңай сыйфатларның бетүгә йөз тотуы яки бетүе; нәсел кору.

ДЕГЕТ *и.* Агачны, торфны яки ташкүмерне корылай куу юлы белән табыла торган исле куе кара сыекча. *Агач дегете. Дегет чыгару. Дегет мичкәсе. Дегет пумаласы. Кулга дегет исе сеңү.* □ [*Урманда*] *күмер яндыралар, дегет кайнаталар иде.* Г. Гобәй.

◇ **Дегет чиләге (лагуны)** *шелт.*— башкаларга гына ияреп-тагылып йөри торган, инициативасыз, ихтыярсыз кеше турында.

ДЕГЕТЛЕ *с.* 1. Дегет салынган яки катнашкан, составында дегет булган. *Дегетле чиләк. Дегетле су. Дегетле сабын.*

2. Махсус дегетләгән, дегет белән майлаган; дегет сөртелгән яки сеңдерелгән. *Дегетле арба. Дегетле шпал. Дегетле чыбыркы. Дегетле такта. Дегетле күчәр.* □ *Хатын куркып китте. Аның күз алдына теге дегетле капка килде.* Г. Ибраһимов. // Дегеткә буялган, пычранган, дегет сеңгән. *Һәммәсе берәм-берәм килеп Кашшафны тәбрик итәләр, аның дегетле кулларын кысалар.* Г. Гали.

ДЕГЕТЛӘҮ *ф.* Дегет сөртү, дегет белән майлау; дегеткә буяу. *Шпал дегетләү. Чыбыркының төенен дегетләп катыру.* □ [*Мөхәммәтша*] *арба күчәрләрен дегетли.* К. Тинчурин.

ДЕГЕТЧЕ *и.* Дегет чыгару, куу эше белән яки дегет сәүдәсе белән шөгыльләнүче. [*Хәнифә*] *үзен шәһәрнең бер дегетче малаена бирергә теләүләрен, риза булмавын сөйләде.* Г. Гали.

ДЕГЕТЧЕЛЕК *и.* Дегетче һөнәре яки кәсебе.

ДЕГЕШКИ-ДЕГЕШКИ, ДЕГӘ-ДЕГӘ, ДЕГӘШКИ-ДЕГӘШКИ *ы.* Каз-үрдәк чакыру сүзе.

ДЕГРАДА'ЦИЯ *и. кит.* Кыйммәтле үзлекләрне, әһәмиятле сыйфатларны югалта барып, әкренләп төшенкелеккә килү, начарлану-бозылу күренеше. *Буржуаз моральнең деградациясе.*

ДЕГРАДА'ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Деградациягә дучар булу, шуны кичерү. *Буржуаз сәнгатьнең деградацияләнүенә китергән сәбәпләр.*

ДЕГУСТА'ТОР *и.* Дегустация белгече; дегустацияләүче. *Чәй фабрикасында яки эчемлек заводында дегустатор булып эшләү.*

ДЕГУСТА'ЦИЯ *и.* Дегустацияләү яки дегустацияләнү. *Дегустациядән соң чәйнең сортларын билгеләү.*

ДЕГУСТА'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Тәме, исе, шулай ук төсе һ. б. кайбер тышкы билгеләре буенча эчемлек, тәмәке, чәй кебек продуктларның сыйфатын билгеләү. *Виноград аракыларын дегустацияләү.*

ДЕДУКТИВ *с.* Дедукциягә мөнәсәбәтле. *Дедуктив метод.* // Дедукциягә нигезләнгән. *Дедуктив нәтиҗәләр.*

ДЕДУ'КЦИЯ *и. лог.* Гомуми фикердән хосусыйга күчеп фикерләү һәм исбатлау ысулы; гомуми фикердән логик юл белән исбатлап хосусый нәтиҗә чыгару; *киресе:* индукция.

ДЕЖУР *с. сөйл.* 1. *к.* дежурный. *Дежур кибет. Дежур санитар. Дежур солдат.* □ *Идарәдә ялгыз дежур әби генә --- бәйләү бәйләп утыра иде.* Г. Гобәй.

2. *кыек килешләрдә.* Дежурлык; дежурный вазифасы һәм хезмәте. *Дежурга билгеләнү. Дежурда булу.* □ *Землянка янында дежурдан буш калган бер төркем сугышчы җыелган.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Дежур тору** — дежурный хезмәтен башкару, шул вазифаны үтәү. *Төннәр, көннәр буе койкам янында дежур тора иделәр һәм шул дежур торучыларның берсе белән мин аеруча якынлаштым.* Г. Минский.

ДЕЖУРЛЫК *и.* Дежурный хезмәте һәм вазифасы. *Нәгыймә үз дежурлыгының соңгы минутына кадәр уяу.* Азат хатын. *Ул дежурлыгын тапшырган, диспетчер бүлмәсендә Якупны көтеп утыра иде.* И. Гази.

ДЕЖУ'РНЫЙ *с.* 1. Җәмәгать эшен һ. б. ш. вазифаны чират тәртибендә башкаручы. *Дежурный укучы. Дежурный класс.*

2. Гомуми расписаниедән тыш, гадәти тәртиптән үзгә вакытта, бүтәннәр эшләмәгәндә эшләүче. *Дежурный врач. Дежурный магазин. Дежурный трамвай.*

ДЕЗ- *кит.* Берәр нәрсәнең туктатылуын, юкка чыгарылуын яки булмавын белдергән алкушымча, мәсәлән: **дезинфекция, дезорганизация, дезинсекция, дезинтегратор.**

ДЕЗАКТИВА'ЦИЯ *и.* Атом һөҗүме нәтиҗәсендә радиоактив матдәләр белән зарарланган нәрсәләрне (мәйдан, каралты, кием, азык һ. б.) чистарту, алар өстендәге радиоактив утырмаларны бетерү эше.

ДЕЗЕРТИР *и.* Дезертирлык итүче кеше. *Документлар тикшергән вакытта Кәримнең дезертир икәнлеге беленгәнлектән, аны дезертирларны яба торган төрмәгә алып киттеләр.* Г. Камал.

ДЕЗЕРТИРЛЫК *и.* Хәрби хезмәттән качу, баш тарту. // *күч.* Үз вазифаларыңны, дәүләт яки җәмгыять алдындагы бурычларыңны үтәүдән баш тарту, качу.

ДЕЗИНСЕКТАЛЬ *и.* Торак йортлардагы бөҗәкләрне бетерү өчен кулланыла торган агулы сыекча (дуст порошогын керосинда эретеп ясала).

ДЕЗИНСЕ'КЦИЯ *и.* Зарарлы, паразит бөҗәкләрне махсус дарулар белән юк итү эше; шуның алымнары һәм чаралары. *Профилактик дезинсекция. Азык-төлекне зарарлый торган бөҗәкләргә каршы дезинсекция үткәрү.*

ДЕЗИНФЕКЦИОН *с.* Дезинфекциягә мөнәсәбәтле. *Дезинфекцион камера. Дезинфекцион отряд.*

ДЕЗИНФЕ'КЦИЯ *и.* Авыру таратучы микробларны махсус дарулар ярдәмендә юк итү яки йогышсызландыру эше.

ДЕЗИНФЕ'КЦИЯЛӘҮ *ф.* Дезинфекция үткәрү, дезинфекция ясау. [*Фельдшер — ат караучыларга:*] *Һич кичекмәстән дезинфекцияләү чарасына керешергә кирәк. Бөтен көчне сәламәт атларны саклауга юнәлтегез!* Г. Әпсәләмов.

ДЕЗИНФОРМА'ЦИЯ *и. кит.* Ялгыш фикер тудыру максаты белән бирелә, таратыла торган төгәлсез яки ялган информация. *Буржуаз пропаганданың дезинформациядән файдалануы.*

ДЕЗИНФОРМА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Берәүдә ялгыш фикер тудыру, аны ялгыштыру, бутау максаты белән төгәлсез яки ялган информация бирү. *Күрәсең, аны дезинформацияләгәннәрдер. Юкны бар итеп күрсәткәннәрдер.* А. Расих.

ДЕЗОРИЕНТА'ЦИЯ *и. кит.* Дөрес ориентациядән мәхрүм булу, фикер буталчыгы туу.

ДЕЗОРИЕНТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Дөрес ориентациядән мәхрүм итү, фикер буталчыклыгы тудыру.

ДЕИЗМ *и. махс.* Алла дөньяны яраткан, ләкин аның үсешенә һәм вакыйгаларның закончалыклы барышына катнашмый дип раслаучы дини-философик тәгълимат (Яңарыш чорында таралган булган).

ДЕИСТ *и.* Деизм тарафдары.

ДЕ'КА *и. махс.* Кыллы уен коралында: корпусның аваз яңгырашын көчәйтә торган өлеше. *Гитараның өске декасы. Пианино декасы.*

ДЕКА- Кушма сүзләрнең беренче өлешендә килеп, «ун» дигәнне белдерә, мәсәлән: **декалитр, декатонна.**

ДЕКАБРИСТ *и. тар.* Крепостнойлыкка һәм самодержавиегә каршы көрәшеп, 1825 елның декабрендә кораллы баш күтәрү оештырган рус дворян революционерлары вәкиле. *Җырлый-җырлый үтәм Уралны, Европаны Азиягә илткән, Декабристлар йөргән юлларны.* Х. Туфан.

ДЕКАБРЬ *и.* Календарь елының утыз бер көнлек, соңгы, уникенче ае.

ДЕКА'ДА *и.* 1. Ун көнлек вакыт. *Айның беренче декадасы.*

2. Берәр кампаниягә багышланган махсус ункөнлек. *СССР халыкларының Мәскәүдәге әдәбият һәм сәнгать декадалары. Кино сәнгате декадасы.*

ДЕКА'ДАЛЫК *с.* Бер декада өчен булган, шуңа дип билгеләнгән. *Декадалык план.* □ *Фәйзуллина декадалык нормасын 145 процент итеп үти.* Ф. Кәрим.

ДЕКАДЕНТ *и.* 1. Буржуаз әдәбиятта һәм сәнгатьтә: декадентлык вәкиле. *Муса Җәлил иҗатында декадентлар йогынтысы бик кыска гомерле бер эпизод булып кына калды.* М. Максуд.

2. *с. мәгъ.* Декадентлыкка нигезләнгән, шуның белән сугарылган; декадентчыл. *Декадент сәнгать.*

ДЕКАДЕНТЛЫК *и. кит.* XIX йөз ахыры — XX йөз башындагы буржуаз гуманитар культурага хас кризис күренешләренең (төшенкелек, гаҗизлек, тормыштан бизү, индивидуализм һ. б. ш.) гомуми атамасы. *Символизм, декадентлык үтәдән-үтә эгоистик индивидуализм, дини мистика белән сугарылган.* Х. Госман.

ДЕКАДЕНТЧЫЛ *с. кит.* Декадентлыкка нигезләнгән, шуның белән сугарылган. *Тукай декадентчыл әдәбиятка һәм декадентчыл теорияләргә, реализмга чит булган барлык әдәби алымнарга каршы көрәштә --- әдәби пародия жанрына зур әһәмият бирә.* Сов. әд.

ДЕКАЛИТР *и.* Ун литр. // Шуңа тигез сыеклык үлчәве берәмлеге.

ДЕКАН *и.* Югары уку йортында факультет җитәкчесе. *Филология факультеты деканы.* □ *Профессор Филиппов бер үк вакытта ветеринария факультетының деканы булып та эшли.* А. Расих.

ДЕКАНАТ *и.* 1. Факультетның укыту-административ эшләрен алып бара торган декан җитәкчелегендәге идарә. *Кайбер кафедра һәм деканатлар кичке һәм читтән торып уку проблемаларына багышланган фәнни-методик тикшеренүләр үткәрәләр.* Соц. Тат.

2. Югары уку йортының шушы идарә урнашкан бүлмәсе. *Утырышны деканатта үткәрү.*

ДЕКАНЛЫК *и.* Декан вазифасы һәм хезмәте.

ДЕКАТО'ННА *и.* Ун тонна. // Шуңа тигез авырлык үлчәве берәмлеге.

ДЕКА'ЭДР *и. мат.* Ун яссылык белән чикләнгән геометрик җисем.

ДЕКВАЛИФИКА'ЦИЯ *и. кит.* Квалификацияне, берәр һөнәр буенча белгечлекне, берәр эштәге тәжрибәне һәм күнекмәләрне югалту; квалификациясезләнү.

ДЕКЛАМА'ТОР *и.* Декламация (2 *мәгъ.*) сөйләүче. *Җырларга теләүчеләр дә, биючеләр дә, декламаторлар да табылды.* Ф. Хөсни.

ДЕКЛАМА'ЦИЯ *и.* 1. Матур әдәбият әсәрен халык алдында яттан уку сәнгате.

2. Халык алдында сәнгатьчә яттан уку өчен билгеләнгән әсәр (гадәттә шигырь). *Декламация сөйләү.* □ [*Г. Камал*] *эшче клубларында уку өчен шигырь һәм декламацияләр яза.* М. Гали.

3. *күч. кит.* Артык күперенке сүзләр.— *Яхшы гына сөйләп килгән җиреңнән тотасың да кинәт коры пафоска, декламациягә биреләсең.* Н. Исәнбәт.

ДЕКЛАМА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Матур әдәбият әсәрләрен сәнгатьчә яттан уку. *Декламацияләү-сөйләү өчен уңайлы булган шигырьләрне әдәбиятыбыз тарихында, XIX йөзнең соңгы чирегендә, Я. Емельянов бирә башлаган иде.* М. Гайнуллин.

ДЕКЛАРАТИВ *с. кит.* 1. Декларация (1 мәгъ.) формасындагы, рәвешендәге; рәсми, тантаналы. *Декларатив белдерү.*

2. *күч.* Артык гомуми сүзләрдән торган һәм коры вәгазьләү, акыл сату рәвешендәге. *Декларатив карар.,* □ [*Тикшерелгән драмада*] *күп кенә персонажларның теле коры, декларатив.* М. Җәлил.

ДЕКЛАРАЦИОН *с.* Декларациягә бәйләнешле; декларация характерындагы; декларатив. *Декларацион документ.*

ДЕКЛАРА'ЦИЯ *и.* 1. Төп принциплар турында рәсми, гадәттә тантаналы белдерү (дәүләтләр, партияләр, халыкара оешмалар һ. б. ш. тарафыннан ясала). *Бәйсезлек декларациясе. Россия халыкларының хокуклары декларациясе. Тынычлык мәсьәләсе буенча халыкара конференциянең декларация кабул итүе.* // Аерым кешенең яки оешманың шундый белдерү, игълан белән чыгыш ясавы.

2. *махс.* Кирәкле мәгълүматларны бирә торган кайбер рәсми документларның исеме. *Сәүдә декларациясе.*

ДЕКОЛОНИЗА'ЦИЯ *и. кит.* Деколонизацияләү яки деколонизацияләнү эше, чаралары һәм хәле.

ДЕКОЛОНИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Колония хәленнән чыгарып, азат итү. *Африка континентын деколонизацияләү.*

ДЕКОЛЬТЕ' *и.* 1. Хатын-кыз күлмәгендә: муенны, иңнәрне һәм арка-күкрәкнең өске өлешен ачык калдырырлык итеп уелган киң изү.

2. *с. мәгъ.* Декольте ясап тегелгән; декольтелы.

ДЕКОРАТИВ *с.* 1. Бизәү, матурлау өчен хезмәт итә торган. *Декоратив үсемлек. Декоратив бизәк.* □ *Бакчада төрле-төрле җиләк-җимеш агачы. Сирень, шомырт ише декоратив агачлар да бар.* И. Рәмиев. // Декорациягә (2 *мәгъ.*) мөнәсәбәтле. *Декоратив сәнгать.*

2. *күч.* Тыштан гына матур, ялтыравыклы булган, ясалма. [*Шагыйрь*] *шәһәр тормышының күбесенчә «декоратив» күренешен* [*ала*]. Г. Нигъмәти.

ДЕКОРА'ТОР *и.* 1. Декорация рәсемнәре һәм күренешләре ясаучы. // Декорация җиһазларын урнаштыручы сәхнә эшчесе. [*Шәрык клубының*] *сәхнә арты дөньясына да күз салыйк. --- Тарлык, ярлылык күзгә ташлана. Шунда декорация, бутафория; декоратор сәхнә куя, артистларның кайберләре аңа булыша, кайберләре киенә.* И. Рәмиев.

2. *махс.* Йортларны, тракларны һ. б. ш. бизәү сәнгате остасы, шул өлкәдәге белгеч.

ДЕКОРА'ЦИЯ *и.* 1. Куела торган пьеса эчтәлегенә туры китереп эшләнгән сәхнә күренеше һәм бизәүләр. *Өченче звонок булды. Утлар сүнде, шау-шу басылды. Пәрдә күтәрелеп, матур урам декорациясе ачылды.* Ш. Камал. *Көнчыгыш стиленда башкарылган декорация*

спектакльгә әкияткә хас нечкәлек, җиңеллек һәм гадилек биреп тора. М. Җәлил. // Шул күренешнең җиһазлары.— *Нишләргә белмичә, сәхнә артына чыгып, үзем тудырган җыр тәэсиреннән исереп, декорацияләр арасына кереп качтым.* Г. Кутуй.

2. *күч.* Җитешсезлек, кимчелекләрне каплау өчен хезмәт итә торган тышкы бизәк, матур тышча. *Дача ишек алдында хәзер инде берничә нарат кына үсеп утыра. Аларны декорация өчен генә калдырганнар шикелле.* М. Максуд. *Дума — декорация генә, Думаның эше алдау һәм икейөзлелек.* В. И. Ленин.

ДЕКРЕТ *и.* 1. Үзәк власть органнарының закон көчендәге карары; указ; закон. *Җир турындагы декрет.* □ *Советлар дәүләте В. И. Ленин имзасы белән биргән беренче декретында ук барлык халыкларга солых тәкъдим иткән иде.* Г. Иделле. *Бу көнне без Татарстан республикасын оештыру турындагы декретка күл куючы Ленинны да тирән ихтирам белән искә алабыз.* Г. Бәширов.

2. *сөйл., гадәттә кыек форм. к.* декрет ялы. *Декретка чыгу.* □ — *Бара алмадык [туйга]. Мин декретта идем.* Э. Касыймов.

◇ **Декрет ялы** — хатыннарга бала тудыру алдыннан һәм тудырганнан соң бирелә торган махсус озын ял.

ДЕКРЕТЛАШТЫРУ *ф.* Декрет белән урнаштыру, кертү (хокукны һ. б. ш.); декрет чыгару юлы белән башкару (оешма, җәмгыять төзүне һ. б. ш.).

ДЕКСТРИН *и.* Промышленностьның төрле тармакларында җилем сыйфатында кулланыла торган матдә (крахмал продукты).

ДЕЛЕГАТ *и.* Берәр коллективтан, оешмадан яки дәүләттән сайланган яисә билгеләнгән һәм киңәшмәдә, съездда һ. б. ш. катнашырга вәкаләте булган кеше. *Конференция делегаты.* □ *Хафизулла картны районга картлар киңәшмәсенә делегат итеп җибәрделәр.* Ф. Хәсни.

ДЕЛЕГАТЛЫК *и.* Делегат вәкаләте һәм вазифасы. *Делегатлык мандаты.*

ДЕЛЕГА'ЦИЯ *җый. и.* Берәр оешманың, коллективның, дәүләтнең һ. б. ш. вәкиле булган делегатлар төркеме. *Чит ил делегацияләре. Яшьләр делегациясе. Сәүдә делегациясе.* □ *Ике районның делегациясе, кичегеп, әле яңа гына килеп төшкәннәр [конференциягә].* Г. Ибраһимов.

ДЕЛИКАТЕС *и. кит.* Нәзакәтле сый булып санала торган затлы ризык. *Кыздырылган кысла итен ярата сызмы? --- Ул элек-электән дөнья күләмендә деликатес санала.* М. Шабаев.

ДЕЛИКАТЛЫ *с. сөйл.* Яхшы мөгамәләле; нәзакәтле. *Деликатлы кеше.*

ДЕЛИКАТЛЫК *и.* Деликатлы кешегә хас сыйфатлар. *Оста деликатлык һәм сокланғыч джентльменлык белән Каратаегин беренче көннәрне үк Катяның ышанычын казанып өлгерде.* И. Гази.

ДЕ'ЛО *и. махс.* 1. Эш кәгазьләрен һ. б. ш. документларны, язмаларны салып теркәп бара торган папка. *Дело ачу. Эш планнарын терки торган дело. Рәсми кәгазьләрне делога салып кую.*

2. Махсус папкага салып теркәлгән төрле эш кәгазьләре һ. б. ш. документлар. *Шәхси дело.* 1□ *Низамов сумкасыннан икегә бөкләп салган делоны алып Орловка суза.* Ф. Кәрим. *Прокурор алдында яткан чуар тышлы «дело»ның үзенеке икәнен белгәч, аның [Гәрәйнең] кызуы шактый сүрелде.* А. Гыйләҗев.

ДЕ'ЛЬТА I *и.* Елга тамагында утырмалардан барлыкка килгән һәм күп санлы су тармаклары белән ергаланып беткән урын; елганың күп тармаклы тамагы. *Волга дельтасы.*

ДЕ'ЛЬТА II *и.* Грек алфавитындагы дүртенче хәрефнең исеме.

◇ **Дельта нурлар** *физ.*— корылган атом кисәкчекләре матдә аша үткәндә атомнардан бәреп чыгарыла торган электроннар.

ДЕЛЬФИН *и. зоол.* Тешле китлар төреннән булган имезүче диңгез хайваны. *Сикереп йөзә уйнак дельфиннар.* Ш. Маннур.

ДЕМАГОГ *и.* Демагогия алымнарын кулланучы. *[Меньшевикларның] җитәкчеләрен демагоглар дип, ялган вәгъдә өләшүчеләр дип атадылар.* И. Гази.

ДЕМАГО'ГИК *с. к.* демагогияле. *Демагогик вәгъдә.*

ДЕМАГО'ГИЯ *и. шелт.* Максатка ирешү өчен ялган вәгъдәләр бирү, юмалау, халыкның хисләренә йогынты ясау, аңы түбәнәкләрнең зәвыкларына җайлашу, фактларны бозып аңлату һ. б. ш. белән җәмәгатьчелек ышанычын, яклавын казану алымы һәм чаралары. *Политик демагогия.* □ *Политикадан бөтенләй хәбәрләре булмаган кешеләрне генә мондый демагогия белән алдарга мөмкин.* И. Гази.

ДЕМАГО'ГИЯЛЕ *с.* Демагогиягә нигезләнгән яки демагогия катнаштырылган. *Демагогияле өндәмә. Демагогияле речь.*

ДЕМАГОГЛЫК *и.* Демагогка хас сыйфатлар. *Ул бишенче елларда социалист булып --- йөргән, демагоглыгы белән шөһрәт тапкан.* К. Тинчурин.

ДЕМАРКАЦИОН *с.* Демаркациягә мөнәсәбәтле; демаркацияләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Демаркацион зона.*

ДЕМАРКА'ЦИЯ *и.* Демаркацияләү яки демаркацияләнү эше. *Демаркация үткәрү. Демаркация документлары.*

ДЕМАРКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Күрше дәүләтләр арасындагы җирдә: чик сызыгы үткәреп, аны махсус билгеләр белән күрсәтү. *Вакытлы чикне демаркацияләү.*

ДЕМАРШ *и. махс.* Дипломатик чыгыш, чара (нота, үтенеч, протест һ. б. ш.). *Политик демарш.* □ *Бүләкләр король кулына күчкәч, ул Америка дипломаты белән очрашырга риза икәнлеген әйткән. Бу демаршка кадәр, бик тырышып карасалар да, король дипломатны кабул итмәгән.* Сов. эд.

ДЕМИЛИТАРИЗА'ЦИЯ *и.* Демилитаризацияләү яки демилитаризацияләнү эше, шуның нәтиҗәсе. *Тулы яки өлешчә демилитаризация. Демилитаризация үткәрү.*

ДЕМИЛИТАРИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Берәр илдә хәрби промышленностьны, ныгытмаларны һ. б. ш. бетерү, кораллы көч тотуны тыю; коралсызландыру, хәрби булмаган хәлгә кайтару. *Чик буе зонасын демилитаризацияләү. Промышленностьны демилитаризацияләү. Германияне демилитаризацияләү.*

ДЕМИСЕЗОН *с. сөйл.* Яз-көз кию өчен билгеләнгән яки шуңа яраклы булган (кием турында). *Демисезон кием.* □ *Гыйльфанның Ташкент һавасына карап тегелгән кечкенә демисезон пальтосы бер эшкә дә ярамады: егетем поездда --- суыкка ләгънәт әйтеп килде.* Ш. Усманов.

ДЕМОБИЛИЗА'ЦИЯ *и.* Демобилизацияләү яки демобилизацияләнү эше. *Демобилизация игълан итү.* □ *Хезмәте кайчан тула соң Сәфәрнең? Әллә демобилизациягә элгәрәк микән?* М. Рафиков.

ДЕМОБИЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Армиянең тынычлык хәленә күчүеннән соң яки хезмәт итүченең срогы тулганнан соң аны хәрби хезмәттән азат итү, җибәрү. *Солдат һәм офицерларны демобилизацияләү.* □ *Унсигезенче ел январеннан алып Совет хөкүмәте искә армияне акрынлап демобилизацияләү эшенә керешә.* КПСС тарихы.

2. Кораллы көчләрне һәм халык хуҗалыгын хәрби хәлдән тынычлык хәленә күчерү.

ДЕМО'ГРАФ *и.* Демография белгече. *Халык санының үсешен тикшерүче демографлар.*

ДЕМОГРА'ФИК *с.* Демографиягә мөнәсәбәтле. *Демографик статистика.*

ДЕМОГРА'ФИЯ *и. махс.* Статистика фәненең халык санын, аның составын, үсеш-үзгәрешен һ. б. ш. тикшерә торган тармагы. *Демография мәгълүматлары.*

ДЕМОКРАТ *и.* 1. Демократия яклы кеше, демократия тарафдары.

2. Буржуаз демократик партия члены.

3. *с. мәгъ.* Демократия яклы яки демократик партия члены булган. *Демократ табигатьле кеше.* □ *Алдынгы, демократ язучыларыбыз әдәби телне халыкка якынайту юлында зур хезмәт күрсәттеләр.* М. Максуд.

ДЕМОКРАТИЗМ *и. кит.* Демократия (1, 2 *мәгъ.*) принципларына нигезләнгәнлек; демократияне тануанлык һәм тормышка ашыручанлык. *Эшчеләр демократизмы. Социалистик демократизм.* □ *Дәүләтнең иң эзлекле демократизмы шартларында барлык милләт эшчеләренең бердәмлеге — безнең лозунгыбыз.* В. И. Ленин.

ДЕМОКРА'ТИК *с.* 1. Демократия принципларына нигезләнгән. *Демократик оешма. Демократик дәүләт.* // Демократия принципларын эшкә ашыра торган. *Демократик хөкүмәт. Демократик лозунг. Революциянең демократик һәм социалистик этаплары.* □ *Демократик хәрәкәтнең үсүе тыелгысыз.* В. И. Ленин. // Гомумән, демократиягә мөнәсәбәтле, бәйләнешле, шуңа караган. *Демократик әдәбият. Милли культураның демократик һәм социалистик элементлары.*

2. Демократия яклы булган. *Демократик көчләр.* □ [*Г. Камал*] *сәхнә аша үзенең демократик карашларын чагылдырды.* М. Гали. *Татар халкының демократик укымышлылары, демократик язучылары --- әдәби телнең, әдәбиятның киң массаларга аңлаешлы булырга тиешлеген күтәреп чыктылар.* Ш. Рамазанов.

ДЕМОКРА'ТИЯ *и.* 1. Югары властька халык ия булган политик строй; *киресе:* монархия. *Халык демократиясе. Совет демократиясе.* □ *Халык яңа тормышка һәм кешенең элементар хокуклары өчен, демократия өчен көрәшкә уянды.* В. И. Ленин.

2. Бөтен коллективның катнашы белән тормышка ашырыла торган җитәкчелек формасы. *Партия эчендә демократия һәм үзара тәнкыйть тормышка ашырылганда гына партия ныгый.* КПСС тарихы. [*Председатель*], *бакчаны яклап сөйләүчеләргә дә, яманлап сөйләүчеләргә дә вакытны бертигез биреп, җыелышны демократиягә хыянәт итмичә алып барырга тырыша.* И. Гази.

3. *җый.* Демократлар һәм демократия яклы кешеләр; халыкның алдынгы катлавы. *Демократия көчләре. Демократия лагере. Демократия хокукларын яклау.* □ [*М. Вахитов*] *бик тиз Казан демократиясенең иң сөекле революционеры булып китте.* Ш. Әхмәдиев.

ДЕМОКРА'ТИЯЛЕ *с. к.* демократик. *Пролетар демократия теләсә генә нинди буржуаз демократиягә караганда миллион тапкыр демократиялерәк; Совет власте иң демократик буржуаз республикага караганда да миллион тапкыр демократиялерәк.* В. И. Ленин.

ДЕМОКРА'ТИЯЛӘШТЕРҮ *ф.* Демократик нигездә үзгәртеп кору. *Сайлау системасын демократияләштерү. Армияне демократияләштерү. Идарә системасын демократияләштерү.* □ *Илне тулы демократияләштерү өчен көрәшергә* [*кирәк*]. В. И. Ленин.

ДЕМОКРА'ТИЯЛӘШҮ *ф.* Демократик нигездә үзгәртеп корылу; демократик характер алу. *Совет строе тагын да демократияләште.* КПСС тарихы.

ДЕМОНСТРАНТ *и. к.* демонстрацияче. *Демонстрантларның байракларына большевистик лозунглар язылган иде.* И. Гази.

ДЕМОНСТРАТИВ *с. кит.* 1. Кылешмәү, ошатмау, яратмау кебек хисләрне ачыктан-ачык, ачу китерерлек итеп белдерә торган (хәрәкәт, чыгыш һ. б. ш. турында). [*Стачка*] *күп очракларда кыска вакытлы, демонстратив чыгыш булды.* В. И. Ленин. [*Заһитов — өмәгә чыкмаучыларга:*] *Сез монда демонстратив рәвештә карта сугасыз.* А. Расих.

2. Демонстрация (2 *мәгъ.*) рәвешендәге, характерындагы. [*Дошман*], *совет гаскәренең һөҗүмен өзәр өчен, төрле участокларда демонстратив «һөҗүмнәр»* [*хәзерләде*]. Г. Әпсәләмов. *Дошман үзе көтмәгән вакытта, кинәттән, көндез демонстратив һөҗүм башлады.* Ә. Айдар.

ДЕМОНСТРАЦИОН *с.* 1. Күрсәтү өчен билгеләнгән, демонстрацияләү вакытында кулланыла торган. *Залда йөзләрчә тамашачылар. Алар, уенчының* [*шахматчының*] *йөреше стенадагы демонстрацион такталарга күчерелгәч, кинәт хәрәкәткә киләләр.* Г. Кашшаф.

2. Демонстрация (2 *мәгъ.*) рәвешендәге, характерындагы; шуңа мөнәсәбәтле. *Армиянең демонстрацион хәрәкәтләре.*

ДЕМОНСТРА'ЦИЯ *и.* 1. Иҗтимагый-политик бердәмлекне, гомуми теләкләрне, таләпләрне оешкан төстә белдерү өчен ясала торган гомуми чыгыш (колонналарга тезелеп урамнардан үтү һ. б. ш.). *Беренче май демонстрациясе.* □ *Шәһәрдә эшчеләрнең сугышка каршы демонстрациясе булды.* Т. Гыйззәт. *В. И. Ленин пролетариатның политик һәм экономик забастовкалар, демонстрацияләр кебек массовый чыгышларының зур әһәмияте барлыгын аңлатып бирде.* КПСС тарихы.

2. *хәрби.* Һөҗүмнең төп юнәлешен яки вакытын сиздермәскә теләп, каршы якның сизгерлеген алдау һәм дикъкатен читкә юнәлтү максаты белән эшләнә торган чара, хәрәкәт, маневр. *Монда алар* [*дошманнар*] *һөҗүм итәбез дип демонстрация генә ясаганнар. Шуның белән совет командованиесен бутарга теләгәннәр.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч. кит.* Хисләрне, теләк-омтылышларны ачыктан-ачык белдергән күренеш; мөнәсәбәтнең күрсәткече. *Конференция тынычлык файдасына бик зур демонстрация булды.* В. И. Ленин.

ДЕМОНСТРА'ЦИЯЧЕ *и.* Демонстрациядә катнашучы. *Демонстрациячеләр колоннасы.* □ *Атлы казаклар килеп чыкканнар да демонстрациячеләрне камчылар белән кыйнарга керешкәннәр.* Г. Әпсәләмов.

ДЕМОНТАЖ *и. тех.* Төзеп, корып, көйләп куйган, урынына урнаштырылган нәрсәне (машина, аппарат, корылма, җиһаз-мазарларны) кире сүтү, урыныннан алу, күчерү эше.

ДЕМОРАЛИЗА'ЦИЯ *кит.* 1. Мораль яктан түбән төшү, бозыклыкка бирелеп таркалу.

2. Төшенкелеккә, таркаулыкка бирелү, рух төшү. *Көрәш авыр формалар ала, ул ызгышка, талашка әйләнә, нәтиҗәдә --- бик зур деморализация.* В. И. Ленин.

ДЕ'МОС *и. кит.* Сыйнфый җәмгыятьтә: өстенлекле хокуклары булмаган сыйныф, халык массасы, түбән катлау, гади халык.

ДЕ'МПИНГ *и. махс.* Товарларны тышкы базарда эчке базардагыдан һәм дөнья базарыныкыннан түбән (еш кына җитештерү чыгымнарыннан да кимрәк) бәягә сату (тышкы базардан конкурентларны кысрыклап чыгаруның бер чарасы). *Демпинг бәяләре. Демпинг политикасы. Демпинг куллану.*

ДЕН *и. диал. к.* дин. [*Карчык*] *каргый-каргый теләде: — Денеңнән яз, явыз,* [*диде*]. Һ. Такташ. [*Баһави — хәзрәткә:*] *Хәзрәт кешесең, ден юлында йөрисең.* Н. Исәнбәт.

ДЕНАТУРАТ *и.* Техникада куллану өчен хәзерләнеп, эчәргә яраксызландырылган спирт.

ДЕНАТУРЛАШТЫРУ *ф.* Агулы, тәмсез яки начар исле матдәләр кушып, (спиртны) эчәргә яраксыз хәлгә китерү.

ДЕНАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯ *и. кит.* Национализацияләгән милекне хосусый милекчеләргә бирү.

ДЕНАЦИФИКА'ЦИЯ *и. кит.* Германиянең дәүләт, иҗтимагый-политик һәм экономик тормышын фашизм (нацизм) хакимлеге нәтиҗәләреннән, йогынтысыннан арындыру чаралары.

ДЕНДРА'РИЙ *и.* Фәнни тәжрибәләр ясау максаты белән төрле куаклы үсемлекләр һәм агачлар үстерелә торган **махсус** бакча **яки** бакчадагы шундый махсус бүлем. *Хат җибәрүче кеше үзенең исемен дә, кайдан икәнлеген дә язмаган иде. Дендрарий рәсеменә карап кына, Сочидан килгән дип булмый, әлбәттә.* М. Әмир.

ДЕНДРОЛО'ГИЯ *и.* Ботаниканың агачларны һәм куаклы үсемлекләрне тикшерүгә багышланган тармагы.

ДЕНСЕЗ *с. диал. к.* динсез.— *Әй, денсез тәмәкечеләр. Сезнең эш начар.* М. Максуд. [*Сәрби — муллага:*] *Син кереп бутадың безнең араны, - - - денсез!* Н. Исәнбәт.

ДЕНЩИК *и.* Патша армиясендә һәм флотында: офицерның яки түрәнең шәхси йомышларын, эшләрен башкарып торган хезмәтче солдат. *Офицерда денщик булып, борынгы кара коллар кебек хезмәт иткән ул.* М. Гафури.

ДЕПАРТА'МЕНТ *и.* 1. Патша Россиясендә һәм күп кенә буржуаз дәүләтләрдә: министрлыктагы яки башка берәр югары дәүләт учреждениесендәге бүлек. *Полиция департаментының яшерен эшләр бүлеге альбомында Заһит исемле бер егетнең фоторәсемен күргәннәр.* Г. Минский.

2. Министрлык (АКШта һәм Швейцариядә). *Дәүләт департаменты* (АКШның тышкы эшләр министрлыгы).

3. Иң эре административ-территориаль берәмлек (Франция һ. б. кайбер дәүләтләрдә).

ДЕПЕ'ША *и. дипл., хәрби.* Ашыгыч хәбәр, телеграмма һ. б. ш.— *Сезнең борчылуыгыз юкка булмаган икән... Яшерен депеша китерделәр. Петроградта революция.* Қ. Нәҗми.

ДЕПО *и.* 1. Паровозлар, вагоннар тора торган һәм аларны карау-төзәтү өчен махсус җиһазландырылган бина, каралты. *Паровоз депосы. Трамвай-троллейбус депосы.* ▭ [*Фәтхи*] *Ташкент тимер юлы депосында өйрәнчек слесарь булып эшләде.* Ш. Қамал.

2. Янгын машиналары тора торган бина, каралты. *Янгын депосы.*

ДЕПОЗИТ *и. фин.* Кредит яки дәүләт учреждениесенә (банкка, саклык кассасына, нотариаль конторага) билгеле бер максат белән яки сакка салына, кертелә торган акча, кыйммәтле кәгазь яки документлар.

ДЕПОРТА'ЦИЯ *и. кит.* Илдән сөрү, чыгарып җибәрү.

ДЕПОЧЫ *и.* Депода эшләүче; депо эшчесе. *Демонстрациягә Якуп кайчандыр үзе хезмәт иткән депо эшчеләренә кушылып чыккан иде. Балык рәтендә депочыларның сафлары буталды.* И. Гази.

ДЕПРЕССИВ *с.* Депрессия хәлендәге. *Экономикадагы депрессив күренешләр.*

ДЕПРЕ'ССИЯ *и. кит.* 1. Рухи төшенкелек. [*Сөләйманов образының*] *эчке кичерешләрен тасвирлауда аны ниндидер рухи депрессиягә кадәр илтеп җиткерү бездә канәгатьсезлек тудыра.* Г. Иделле.

2. Җәмгыять тормышында, экономикада: гадәттә төшенкелектән соң урнаша торган торгынлык. *Экономик депрессия. Капиталистик җитештерүнең 1933 нче елдан соңгы депрессия чоры.*

ДЕПУТАТ *и.* 1. Закон чыгаручы һ. б. ш. вәкиллекле органга сайланган кеше. *Депутат сайлау.* ▭ [*Айсылу*] *авыл һәм район Советларының депутаты иде.* Г. Бәширов.

2. Гомумән, берәр җәмәгать эшен, йомышын башкару өчен коллектив тарафыннан махсус сайланган кеше, вәкил. *Эшчеләрдән депутат булып бару.*

ДЕПУТАТЛЫК *и.* Депутат вәкаләтләре һәм вазифалары. *Сайлау алды җыелышына барган идек. Шунда минем әтине депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр.* Г. Галиев. *Депутатлык бурычларын үтәү аның күп кенә вакытын ала, ләкин шуның белән бергә аның күңелен күтәрә.* М. Максуд.

ДЕПУТА'ЦИЯ *җый. и.* Берәр коллектив тарафыннан сайланган яки билгеләнгән депутатлар (2 мәгъ.) төркеме. *Депутация җибәрү.* ▭ *Романов юбилее мөнәсәбәте белән, падишаһ хәзрәтләренә депутация барган иде.* Г. Тукай.

ДЕР *аваз ияр., еш кына сузып (дерр) яки кабатлап әйтелә.* Әйберләрнең төрле дулкыннар тәэсире белән калтыравыннан барлыкка килгән нечкә тавышларны белдерә.

◇ **Дер итү (килү)** — дерелдәү, калтырау. [*Сабир*] *бизгәк тоткандагы шикелле дер-дер итә.* Э. Қасыймов. *Шәһәр дер килде, кешеләр сискәнеп уянды.* И. Туктар. **Дер калтырау** — нык дерелдәү, калтырау. *Суык үзәккә үтеп, тәннәр дер-дер калтырый.* Г. Ибраһимов. *Мастер яман усал кеше иде. Аның янына кергән чакта - - - дер калтырап керәләр иде.* И. Гази. **Дер кубу** — шау-гөр килү, көчле ыгы-зыгы ясау. [*Икенче мәдрәсә шәкертләре*] *Фәттахның мужикларга ошавын ишетү белән дер куптылар.* Э. Фәйзи. **Дер селкенү** — нык дерелдәү; дерелдәп селкенү. *Бомбалар шартлаудан анабыз җир дер селкенгән.* И. Гази. **Дер селкетү** — 1) тирә-юньне һәм бигрәк тә һаваны нык калтыраткан көчле авазлар, тавышлар чыгару; тетрәтү. [*Солдатлар*], *урамнан барганда, дер селкетеп атлыйлар.* М. Гафури; 2) *күч.* көчле тәэсир калдыру; шау-шулы вакыйгаларга сәбәпче булып дан тарату. [*Шайбәк*] *галим дә, бай да - - - булган. Заманында бөтен тирә-якны дер селкеткән.* Г. Ибраһимов. **Дер тетрәтү** *сир.— к.* дер селкетү. *Сугышса, дер дә дер тетрәткән ул* [*Мәмәт*] *бу фани дөньяны.* Г. Тукай. *Көчле һава дулкыны корабльне дер-дер тетрәтте.* Қ. Латыйпов.

ДЕРЕЛДЕК *с. к.* дерелдәвек. *Инженер, һичнәрсәгә игътибар итмәстән, дерелдек шәм ялкынына текәлгән килеш, нидер уйлый иде.* А. Тимергалин.

ДЕРЕЛДӘВЕК 1. *с.* Дерелдәп, калтырап тора торган. [*Карт*] *дерелдәвек кулы белән ни өчендер телефон тартмасына тотынды.* Қ. Нәҗми. *Мич авызыннан төшкән дерелдәвек яктылык аның йөзен яктырткан.* Г. Әпсәләмов.

2. *и. мәгъ. сөйл. к. койка́. Сыер аякларыннан әзерләнгән дерелдек.*

ДЕРЕЛДӘҮ *ф.* 1. Еш һәм кыска тирбәнеш хәрәкәтләре ясап селкенү. *Кул дерелдәү.* ▭ *Бакчадагы яфраклар әкрен генә дерелди.* Г. Газиз. // Қалтырау (тавыш, буыннар һ. б. турында). *Тез буыннары дерелдәү. Самолет тавышына тәрәзә пыялалары дерелдәү.* ▭ [*Апасы*] *бер карау белән кызның күзендәге, дерелдәгән тавышындагы куркуын сизде.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Куркуга бирелү. *Әйдә күрсеннәр усаллар, тетрәсеннәр аптырап; Күзләреннән яшь тә түксеннәр дерелдәп-калтырап.* М. Җәлил.

ДЕРЖА'ВА *и. юг.* Мөстәкыйль, бәйсез, куәтле, гадәттә эре дәүләт. *Партия властьны үз кулына алганда халыкка хәерче һәм көчсез илне куәтле социалистик держава итәргә вәгъдә бирде.* КПСС тарихы.

ДЕРИВАТ *и. махс.* 1. Берәр нәрсәдән килеп чыккан, ясалган әйбер, продукт. *Крахмал дериватлары.*

2. *с. мәгъ.* Ясалма, икенчел. *Дериват матдә.*

ДЕРИВА'ЦИЯ *и. махс.* Елга, күл кебек сулыклардан канал һ. б. буенча аерып су җибәрү эше һәм шундагы гидротехник корылмалар.

ДЕРЛӘҮ *ф. к.* дерелдәү 1. *Абзыкаем! Сыныкъ... бер телем! дип, Тезен чүгә дерләп, кул сузып* [*теләнче*]. Н. Исәнбәт.

ДЕРМАТИН *и.* 1. Тукымадан эшләнгән ясалма күн (китапларны, мебельләрне һ. б. ш. тышлауга китә). *Кара дерматин белән тышланган ишекне ачып - - - Гаяз керде.* И. Гази.

2. *с. мәгъ.* Дерматиннан яки шуны катнаштырып эшләнгән, тышланган һ. б. ш. *Дерматин бумажник. Дерматин тышлы диван.* ▭ *Фәттах стена кырыендагы ба-*

ганага элгән дерматин сумкадан взводның исемлеген ала. Ф. Кәрим.

ДЕРМАТИТ *и. мед.* Тире ялкынсыну авыруы.

ДЕРМАТО'ЛОГ *и. мед.* Тире авырулары белгече, врач.

ДЕРМАТОЛО'ГИЯ *и.* Медицинаның тире авыруларын өйрәнә торган тармагы.

ДЕРТ *аваз изәр.* 1. *кабатлап та әйтелә.* Җиңелчә калтырап кую, дерелдәп алу вакытында ишетелгән тавышларны белдерә. // Кинәт дерелдәп куюны белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Дерт» сыман тавышлар чыгарып. *Керосины чиста булмаганда лампаның дерт-дерт януы. Кош йөрәгенең дерт-дерт тибүе.* ▭ *Аның чигәсендәге зәңгәр кан тамырлары дерт-дерт тибә.* Каз. утл. // *гадәттә каб. форм.* Кинәт дерелдәп. *Кинәт ул [Әнисә], йокысыннан куркып уянган кешедәй, дерт селкенеп китте.* З. Бәширн. *Аның салынып төшкән сул як мыегы дерт-дерт селкенеп куйгалый.* Ә. Еники.

ДЕРТЛӘҮ *ф.* «Дерт» сыман тавышлар чыгару. *Янып торган чыраның дертләве. Лампа утының дертләве.* // Кинәт дерелдәп-калтырап кую; сискәнеп китү. [*Галимә*] *капыл гына дертләп, сискәнеп китә.* М. Гафури.

ДЕСАНТ *и.* Сугыш алып бару өчен, дошман карамагындагы җиргә төшерелгән яки төшерелә торган гаскәр. *Һава десанты. Диңгездән төшерелгән десант. Танк десанты.* ▭ *Төнлә белән дошманның десант төшерергә матавыы мөмкин.* И. Гази.

ДЕСАНТЧЫ *и.* Десант гаскәре сугышчысы яки офицеры. *Немецның иң курыкканы десантчы белән партизан булып китте.* Ш. Маннур.

ДЕСЕРТ *и.* Табын ахырында бирелә торган татлы ашамлык-эчемлек. *Десертка җимеш суы эчү.* ▭ *— Син бүген безне нинди десерт белән сыйларсың икән?* Н. Исәнбәт.

ДЕ'СПОТ *и.* 1. *тар.* Борынгы Көнчыгышның колбиләүчелек дәүләтләрендә: чикләнмәгән властьтан файдаланып, үз хөкеме белән идарә итүче монарх.

2. *күч.* Башкаларны тупас рәвештә үз ихтыярына буйсынырга мәҗбүр итүче, аларның иреге һәм теләге белән исәпләшмичә эш итүче, изүче.— [*Төзелеш башлыгы*] *түзеп тормаслык деспот! --- Прораблар бер атна да чыдый алмыйлар үзендә.* А. Гыйләҗев.

ДЕСПОТИЗМ *и. к.* деспотлык.

ДЕ'СПОТЛЫК *и.* 1. *тар.* Деспотның *(1 мәгъ.)* идарә итү системасы, режимы.

2. *күч.* Башкаларны изеп торучы явыз кешегә хас сыйфатлар. *Фатыйма бикәдә аз гына булса да деспотлык, үзсүзлелек күренә.* Г. Нигъмәти.

ДЕСТРУ'КЦИЯ *и. кит.* Берәр нәрсәнең структурасы таркалу-җимерелү күренеше. *Полимерлар деструкциясе.*

ДЕСЯ'ТСКИЙ *и. к.* дисәтник (2, 3 мәгъ.). *Менә сиңа авыл советы секретаре налог язуы биргән иде,— диде десятский һәм --- чикмәненең эчке кесәсен актара башлады.* А. Шамов. *Куркуыннан ни эшләргә белмәгән староста шунда ук халыкларны десятскийлар белән кудырып, пристав кушкан эшләрне җиренә җиткерергә җибәрде.* М. Гафури.

ДЕТАЛЬ *и.* 1. *тех.* Машинаның, механизмның һ. б. ш. аппаратның иң вак элементларыннан, тагын да ваграк өлешләргә аерып-сүтеп (бозмыйча таркатып) булмый торган кисәкләреннән берсе. *Сәгать детальләре.* ▭ *Станокта яшь кыз деталь кыра.* С. Урайский.

2. Эштәге, мәсьәләдәге бер аерым момент, ваклык, вак өлеш; вак-төяк. *Рабига беренче очрашуның барлык вак детальләренә кадәр хәтерли.* А. Шамов. *Студент халкы тарихи шәхесләрнең кызыклы тормыш детальләрен тыңларга ярата.* А. Расих.

3. *с. мәгъ.* Бик җентекләп, ваклыкларга кадәр исәпкә алып эшләнгән, уйланган. *Полюс аша очу катлаулырак. Чөнки әлегә полюсны тикшергән деталь карталар юк.* С. Баттал.

ДЕТЕКТИВ *и.* 1. Җинаятьчене эзләү белән шөгыльләнүче полиция агенты, шымчы (капиталистик илләрдә). *Детективны чакырту.*

2. Детективлар, шымчылар белән булган хәлләрне, җинаять эшләрен һ. б. ш. мәҗараларны тасвирлап язылган, иҗат ителгән әсәр (роман, фильм һ. б. ш.). *Детективлар белән мавыгу.*

3. *с. мәгъ.* Детективка мөнәсәбәтле. *Детектив әдәбият. Детектив фильм.*

ДЕТЕ'КТОР *и. махс.* Радиоалгычта югары ешлыктагы тирбәнешләрне колак белән ишетерлек түбән ешлыкка күчерә торган махсус җайланма.

ДЕТЕ'КТОРЛЫ *с.* Детекторы булган, детектор ярдәмендә эшли торган. *Детекторлы радиоалгыч* (лампочкасыз кристаллик детекторы булган иң гади радиоалгыч).

ДЕТЕРМИНИЗМ *и. филос.* Материаль һәм рухи дөнья күренешләренең үзара объектив закончалыклы һәм сәбәпле бәйләнештә булуы турындагы тәгълимат.

ДЕТЕРМИНИСТ *и. филос.* Детерминизм тарафдары.

ДЕТЕРМИНИ'СТИК *с.* Детерминизмга нигезләнгән. *Детерминистик караш.*

ДЕТОНА'ТОР *и.* Детонация китереп чыгара торган шартлаучан матдә яки җайланма; шартлаткыч.

ДЕТОНА'ЦИЯ *и.* 1. Шартлаучан матдәнең бүтән бер матдә шартлавы яки бәрелүе нәтиҗәсендә бик тиз ялкынланып китүе. *Каты һәм сыек матдәләр детонациясе. Бәрелү детонациясе.*

2. *тех.* Двигатель цилиндрында ягулыкның нормаль янмавы.

ДЕ-ФА'КТО *рәв. кит.* Фактта, чыплыкта, асылда; *киресе:* де-юре.

ДЕФЕКТ *и. кит.* Кимчелек, җитешсезлек.

ДЕФЕКТОЛО'ГИК *с.* Дефектологиягә мөнәсәбәтле. *Дефектологик мәктәп. Дефектологик сүзлек.*

ДЕФЕКТОЛО'ГИЯ *и.* Физик һәм психик кимчелекле балаларның үсеш үзенчәлекләрен өйрәнеп, аларны укыту-тәрбияләү мәсьәләләрен тикшерә торган фән тармагы.

ДЕФЕКТОСКОП *и.* Металлик һ. б. эшләнмәләрнең эчке кимчелекләрен тикшереп (эшләнмәне зарарламый торган нурлар, радиодулкыннар үткәреп һ. б. ш.) табу һәм билгеләү коралы, аппараты.

ДЕФИС *и. грам. к.* сызыкча 2.

ДЕФИЦИТ *и.* 1. *махс.* Чыгымның керемнән артык булуы; шуның нәтиҗәсендә килгән зыян. *Бюджет дефициты. Баланс дефициты.*

2. *кит.* Берәр нәрсәнең җитәрлек булмавы, җитмәүчелеге. *Сульфат кислотасы дефицитын бетерү.*

3. *с. мәгъ. к.* дефицитлы 2. *Дефицит материал.* ▭ *Сабын хәзер дефицит товар түгел.* Г. Кашшаф.

ДЕФИЦИТЛЫ *с.* 1. Дефицит (1 *мәгъ.*) тудыра торган, экономик яктан зыянлы.

2. Җитешми торган, ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә җитәрлек булмаган. *Дефицитлы товар. Дефицитлы металлар.* ▭ *Дефицитлы химикатларны, буяуларны башкалар белән алыштыру буенча бик күп тәкъдимнәр кертелде.* М. Максуд.

ДЕФОРМА'ЦИЯ *и.* Форманың бозылуыннан (бер үк вакытта күләм дә үзгәрергә мөмкин) гыйбарәт үзгәреш (җисем кисәкчекләренең урын күчүе нәтиҗәсендәге үзара нисби торышлары үзгәрү). *Сузылу деформациясе. Умырткалык кәкрәю кебек деформацияләрне булдырмас өчен зарядка ясау.* // Гомумән, берәр нәрсәнең формасына кертелгән үзгәреш. *Тукай шигырьләре нәкъ менә татар халык җырларыннан файдалану, алар ритмына билгеле деформация кертү нигезендә үсте дә.* Г. Нигъмәти.

ДЕФОРМА|ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Деформациягә дучар булу. *Каты җисемнәрнең деформацияләнүе. Баш сөяге деформацияләнү.*

ДЕЦИ- Үлчәү берәмлеге атамасы булган кушма сүзнең беренче өлеше сыйфатында «уннан бер» дигәнне белдерә, мәсәлән: **дециграмм, децилитр** һ. б.

ДЕЦИМЕТР *и.* Метрның уннан беренә тигез озынлык үлчәве берәмлеге.

ДЕЦИМЕ|ТРЛЫ *ф.* 1. Бер дециметр озынлыктагы. *Дециметрлы таякчык. Дециметрлы радиодулкын.*

2. Дециметрларга бүленгән. *Дециметрлы линейка.*

ДЕ-Ю|РЕ *рәв. кит.* Юридик тәртиптә, закон буенча; *киресе:* де-факто. // Формаль яктан гына карап, фактларга таянмыйча.

ДЕҢ *аваз ияр.* Вак металл әйберләр агачка (һ. б. үзеннән йомшаграк нәрсәгә) бәрелеп яңгыраганда ишетелгән һ. б. ш. урта тондагы тавышларны белдерә; тонык «чең».

ДЕҢГЕЛДЕК, ДЕҢГЕЛДӘВЕК *с.* Деңгелди торган.

ДЕҢГЕЛДӘҮ *ф.* «Дең» авазларын хәтерләтеп өзек-өзек яңгырау. *Җил улаган тавышлар ишетелгән кебек булды, аннары түбә калайлары деңгелдәде.* С. Баттал.

ДЕҢГЕР *аваз ияр.* Җиңелчә дөбердәү, калтырау катнаш «дең» авазларын белдерә.

ДЕҢГЕРДЕК *с.* 1. Деңгерди, деңгердәп тора торган.

2. *к.* дыңгырдык (2, 3 *мәгъ.*).

ДЕҢГЕРДӘВЕК *с. к.* деңгердек.

ДЕҢГЕРДӘҮ *ф.* 1. «Деңгер» авазларын хәтерләтеп яңгырау; келтерәү һәм җиңелчә дөбердәү катнаш деңгелдәү. *Дугадагы алканың деңгердәве аермачык булып ишетелә.* И. Гази. *Түбә калаеның деңгердәве һәм җил сызгыруына охшашлы тавышлар ишетелә.* С. Баттал.

2. Тигезсез, каты юлдан барганда селкенеп җиңелчә дөбердәү (арба, автомобиль һ. б. ш. турында).

ДЕҢГЕРТ *аваз ияр.* Кискен деңгердәп куюны белдерә.

ДЕҢК *аваз ияр.* Кискен деңгелдәп куюны белдерә.

ДЕҢЛӘҮ *ф. к.* деңгелдәү.

ДЖАЗ *и.* 1. Төрле музыка коралларыннан, бигрәк тә тынлы һәм бәрмә уен коралларыннан төзелгән оркестр.

2. Шундый оркестр өчен язылган (күбесенчә танцы өчен булган) җиңел музыка. *Джаз тыңлау.* ▭ [*Зөмәрәнең*] *ипташ кызлары джаз көйләре язган тәлинкәләр күтәреп килделәр.* Б. Камалов.

ДЖЕМ *и.* Җилэк-җимешне шикәр белән кайнатып ясаган, кесәл сыман куе татлы ашамлык; вареньеның бер төре.

ДЖЕ|МПЕР *и.* Баштан киелә торган йон, ефәк һ. б. ш. җептән якасыз итеп бәйләнгән кофта, фуфайка. [*Хәдичә*], *туңуын басарга теләпме, күлмәге өстеннән джемперын да киеп алды.* М. Хәсәнов.

ДЖЕ|НТЛЬМЕН *и. кит.* Англиядә: буржуаз-аристократик җәмгыятьтә кабул ителгән мораль-әдәп нормаларын һәм кагыйдәләрен бөтен нечкәлекләре белән үтәүче әфәнде.

ДЖЕ|НТЛЬМЕНЛЫК *и. кит.* Джентльменга хас сыйфатлар. *Оста деликатлык һәм сокланғыч джентльменлык белән Каратагин беренче көннәрне үк Катяның ышанычын казанып өлгерде.* И. Гази.

ДЖО|УЛЬ *и. физ.* Энергия үлчәү берәмлеге.

ДЖУ|НГЛИ *и.* Лианалар чорналып үскән куе, ерып үткесез тропик урман һәм куаклык. *Һиндстан һәм Африка джунглилары.*

ДЖУТ *и.* 1. Сүсе тупас тукыма эшләүгә һәм аркан ишүгә китә торган көньяк үсемлеге; һинд сүсе.

2. *с. мәгъ.* Джуттан яки шуның җебеннән эшләнгән. *Джут капчык. Джут аркан.*

ДЗОТ *и. хәрби.* Сугыш кырындагы саклану-оборона корылмасы; агач белән балчыктан эшләнеп, ут ноктасы белән ныгытылган була (*русча:* дерево-земляная огневая точка). *Дошман дзотын тупка тотып актартып ташлау.* ▭ *Калын дзотта, тыштагы үкерүгә колак салып, пулеметчылар утыра иде. Җир әкрен генә селкенә, калтырана. Дзотның түшәме, стеналары --- урыннарыннан кузгалгандай булалар.* Г. Әпсәләмов.

ДЗЮДО *и. спорт.* Япончарның милли көрәше (егу, аяк чалу, кысу-буу, сугу-тибү алымнарын эченә ала).

ДИ- «Ике», «икеле» дигәнне белдерә торган алкушымча, мәсәлән: **дилогия, дилемма.**

ДИАБАЗ *и. махс.* 1. Каты тау токымнарының бер төре (башлыча юлга түшәү материалы сыйфатында кулланыла).

2. Диабаздан торган яки составында диабаз булган (тау, кыя һ. б. ш. турында). *Кара кучкылланып диабаз кыялар, ә аста --- бусагалар күренә.* М. Хөсәен. // Диабаздан эшләнгән.

ДИАБЕТ *и. мед.* Бик сусау һәм күп сидек бүлеп чыгару белән үтә торган хроник чир.

ДИА|ГНОЗ *и. мед.* Авыруның чире һәм хәле турындагы врач билгеләмәсе (гамәлдәге терминология белән бирелә). *Иң курыкканым — авыруны белә алмау, дөрес диагноз куймыйча ялгышу иде.* Г. Кутуй.

ДИАГНО|СТИК *с.* Диагностикага мөнәсәбәтле. *Диагностик тикшеренү.*

ДИАГНО|СТИКА *и.* Медицинада: чирләрнең билгеләре, диагноз кую ысуллары һәм принциплары турындагы тармак. *Диагностика кафедрасы.* ▭ *Рентген диагностикасы методларын үзләштергән невропатолог — алтын кадр бит ул.* Каз. утл. // Диагноз кую эше. *Менә дигән яңа аппаратлар бар чагында диагностиканы һаман иске методлар белән алып бару мөмкин түгел.* Г. Әпсәләмов.

ДИАГОНАЛЬ *и.* 1. *геом.* Күппочмакта: янәшә булмаган ике почмакның түбәләрен тоташтыра торган туры сызык; күпкырлыкта: бер үк яссылыкта ятмаган ике почмакның түбәләрен тоташтыра торган туры сызык.

2. Кыйгач сырлы тыгыз тукыма. *Костюмлык диагональ сатып алу.*

3. *с. мәгъ.* Диагональ (1 мәгъ.) рәвешендәге (сызык, юнәлеш һ. б. ш. турында). *Сөрү уңаена аркылы китереп һәм диагональ юнәлешләрдә тырмалау. Диагональ сызык.*

4. *с. мәгъ.* Диагональдән (2 мәгъ.) тегелгән. *Диагональ чалбар.* ▭ [*Бикләмишев*] *күк диагональ мундирын рәтләп куйды.* Қ. Нәҗми.

ДИАГРА|ММА *и.* Төрле зурлыкларның үзара чагыштырмасын күрсәтмәле итеп, кисемтәләр яки геометрик фигуралар ярдәмендә сурәтли торган сызым. *Баганалы һәм секторлы диаграммалар. Чәчәк төзелешен күрсәтә тореган диаграмма. Хезмәт җитештерүчәнлеге үсешен диаграммалар белән күрсәтү.* ▭ *Театр алды кызыл флаглар, лозунглар, диаграммалар белән бизәлгән.* А. Шамов.

ДИАДЕ|МА *и. тар.* Көнбатышта. 1. Патшалык билгесе булган таҗ яки асыл ташлар белән эшләнгән, башка урый торган махсус тасма (борынгы патшаларның, иң югары дин башлыкларының власть һәм дәрәҗә билгесе).

2. Хатын-кызларның ачык таҗ рәвешендәге кыйммәтле бизәнү әйбере. [*Валерия*] *кулбашына төшкән кара бөдрә чәчләрен маңгаеннан алтын диадема белән каптырган.* Н. Исәнбәт. *Мәзәкче үзенең гәүдәсен балчыкка буяп, башына диадема кия дә муенына елан тиресеннән ясалган бизәү әйберләре тага.* Әкият.

ДИАКРИ|ТИК: диакритик билге *лингв.*— хәрефнең өстенә яки астына куелып, аның укылышын (мәгънәсен) аныклау яки үзгәртү өчен кулланыла торган (мәсәлән. **й, ң** хәрефләрендәге кебек) график билге.

ДИАЛЕКТ *и. лингв.* Телнең җирле формасы: гомумхалык теленнән аермалы булган бер төркем сөйләшләр-

не берләштерә. *Урта диалект. Мишәр диалекты. Көнчыгыш диалект.* □ *Барлык диалектларны туплау аңлатмалы сүзлек бурычы түгел.* М. Максуд. // Гомумхалык теленең аерым бер социаль катламга, төркемгә хас булган формасы. *Социаль һәм территориаль диалектлар.* □ *Эшчеләр буржуазия диалектыннан башка булган диалектта сөйлиләр.* Г. Гали.

ДИАЛЕКТАЛЬ *с. лингв.* Берәр диалектта кулланыла торган, диалектка хас булган (сүзләр, авазлар, формалар һ. б. ш. турында). *Диалекталь сүз. Диалекталь күренеш.*

ДИАЛЕКТИЗМ *и. лингв.* Әдәби сөйләмдә кулланылган диалекталь сүз, фраза яки форма. *Язучы телендәге диалектизмнар.* □ *Укучыларның сөйләм телләрендә һәм язма эшләрендә фонетик, морфологик, синтаксик һәм лексик-фразеологик диалектизмнар еш кына очрый.* Сов. мәк.

ДИАЛЕ'КТИК I *и.* Диалектика һәм диалектик философия тарафдары.

ДИАЛЕ'КТИК II *с.* **1.** Диалектика (1 мәгъ.) законнары нигезендә бара, була торган (процесслар, күренешләр, вакыйгалар һ. б. ш. турында). *Диалектик процесс.* □ *Язучы булу өчен, барыннан да элек, - - - вакыйгаларны, иҗтимагый көрәшне диалектик каршылыкларында күрә һәм күрсәтә белүче фәнни төгәллек* [кирәк]. Ф. Хөсни.

2. Диалектикага (2 мәгъ.) нигезләнгән; шуңа мөнәсәбәтле. *Диалектик метод. Диалектик караш. Диалектик материализм.*

ДИАЛЕ'КТИКА *и.* **1.** Табигатьнең, җәмгыятьнең һәм фикерләүнең хәрәкәт-үсеш процессы. *Миллә тләр бер-берсенә якыная баралар. Тормышның объектив үсеше, диалектика шуңа алып бара.* Сов. әд.

2. Барлыкка килүнең һәм үсешнең иң гомуми закончалыклары турындагы тәгълимат (боларның чыганагы булып капма-каршылыклар бердәмлеге һәм көрәше тора). *Материалистик диалектика.* □ *Кыскача, диалектиканы капма-каршылыклар бердәмлеге турындагы тәгълимат дип билгеләргә мөмкин. Моның белән диалектиканың төше тотып алынган булыр, ләкин бу — аңлатмалар бирүне һәм җәелдерүне таләп итә.* В. И. Ленин.

ДИАЛЕКТО'ЛОГ *и.* Диалектология белгече.

ДИАЛЕКТОЛО'ГИК *с.* Диалектологиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Диалектологик карта. Диалектологик сүзлек. Диалектологик экспедиция.*

ДИАЛЕКТОЛО'ГИЯ *и.* Тел фәненең диалектларны тикшерә торган тармагы.

ДИАЛОГ *и.* **1.** *кит.* Ике яки берничә кешенең каракаршы сөйләшүе. *Малай белән безнең арада әледәнәле булып алган бер диалогны китерәм.* Ф. Хөсни.

2. Әдәби әсәрдә: ике кешенең сөйләшүен биргән өлеш. *Романдагы диалогларны киметү. Пьесадагы диалоглар.* // Әңгәмә формасында язылган әдәби әсәр.

ДИАЛО'ГИК *с.* **1.** Диалог (1 мәгъ.) рәвешендәге. *Диалогик сөйләм.*

2. Диалог (2 мәгъ.) төзү өчен булган; диалогка хас. *Диалогик алымнар.*

ДИАМАТ *и. сөйл.* Диалектик материализм (фән буларак укытыла торган курс турында). *Диаматтан экзамен бирү.*

ДИА'МЕТР *и. мат.* Әйләнәнең үзәгеннән үтеп, аның ике ноктасын тоташтыра торган туры сызык; әйләнә үзәгеннән үтә торган хорда.

ДИАМЕТРАЛЬ *с.* **1.** *мат.* Диаметр сызыгыннан урталай булә торган. *Диаметраль яссылык.*

2. *кит.* «Каршы», «каршылык» һ. б. ш. сүзләр алдында килеп, «бөтенләй», «тулысынча» дигәнне белдерә. *Диаметраль каршы фикерләр.* □ *Эшчәнлекнең ике төрле, диаметраль капма-каршы ике юнәлештә булуы мөмкин.* В. И. Ленин.

ДИАПАЗОН *и.* **1.** *муз.* Бер кешенең яки бер музыка коралының барлык югарылыктагы авазларны чыгару мөмкинлеге; бер тавыш иясе яки бер уен коралы чыгара ала торган барлык шундый авазлар. *Җырчының тавыш диапазоны.* // *махс.* Җисемнең, физик күренешнең хәрәкәт-тәэсир зонасы. *Радиотапшыруларның кыска диапазоннар буенча бирелә торган программасы. Радиоалгычның урта диапазон шкаласы.*

2. *күч. кит.* Эшчәнлекнең, кызыксынучанлыкның колачы. *Шагыйрьнең тематик диапазоны. Кызыксыну диапазоның киңәю.*

ДИАПОЗИТИВ *и.* Үтә күренмәле җирлеккә төшерелгән, яктыга куеп карала яки экранда күрсәтелә торган фоторәсем (гадәттә текстлы була). *Леон Небенцаль Муса Җәлилнең тормышы һәм көрәшенә багышланган диапозитивлар эшли.* Г. Кашшаф.

ДИАСКОП *и.* Үтә күренмәле җирлектәге рәсемнәрне (мәсәлән, диапозитивларны, диафильмнарны), текстларны зурайтып экранга һ. б. ш. төшерә торган оптик-механик аппарат.

ДИАФИЛЬМ *и.* Тематик бәйләнешле позитив фоторәсемнәрдән (мәсәлән, диапозитивлардан) төзелеп, диаскоп, фильмоскоп кебек аппаратлар ярдәмендә карала-күрсәтелә торган кыска фильм.

ДИАФРА'ГМА *и.* **1.** *анат.* Күкрәк һәм корсак куышлыкларын аерып тора торган юка мускул катлавы, яры, пәрдә.

2. *махс.* Оптик аппаратта (мәсәлән, фотоаппаратта) яктылык нурларының үтү юлын киңәйтү яки тарайту өчен күелган жайланма.

ДИАХРО'НИК *с. лингв.* Диахрониягә карәган, шуңа мөнәсәбәтле. *Диахроник күренеш.*

ДИАХРО'НИЯ *и. лингв.* Тел күренешләренең үсешендә тарихи эзлеклелек.

ДИВАН I *и.* Утыру-яту өчен билгеләнгән артлы һәм янлы йомшак мебель. *Якупов, ашап бетергәч, дивангa кырын ятты да газета укырга тотынды.* Г. Гобәй.

ДИВАН II *и. иск. кит.* Урта һәм Якын Көнчыгыш халыклары әдәбиятында: лирик шигырьләр җыентыгы, хрестоматия. *Шигырьләр диваны.* □ *Һичбер дивannың басылу сәне икедән артмаган булса да, алар шактый һәм хәтта күп таралган.* Г. Тукай.

ДИВАН III *и. иск.* Төркия солтаны каршында: югары дәрәҗәле кешеләрдән, вәзирләрдән төзелеп, киңәш хокукы булган совет, мәҗлес. *Барча халык, патша һәм диван халкы һаман да бу эшкә хәйран калалар.* Қ. Насыйри. *Мин диванга кердем һәм диван беткәнче шунда булдым.* Мең дә бер кичә. // Шушы советның кешеләре, члennары утырышып, җыелышып киңәшә торган зал; диванханә. *Диван бара-бара әмирләр, вәзирләр, чуар җилән кигән атаклы кешеләр белән тула. Диван чәчәкле бакчага охшап кала.* Мең дә бер кичә.

ДИВАНА *с.* Акылдан язган, юләр. *Бу хәсрәттән булмам микән дивана?* Г. Кандалый. *Ничә еллар буена дивана саналып та, ничектер акылына кайтып төшкән Гыймади карт - - - бакча каравылларга яллана.* Қ. Нәҗми. // *күч.* Аңгыра, ахмак, булдыксыз кеше турында. *Карагыз бу бичараны, Карагыз бу дивананы! Әллә чын да Килупайны Жиңәрмен дип юанамы?* М. Җәлил.

ДИВАНАЛАНУ *ф.* **1.** Акылдан язу, юләрләнү.

2. *күч.* Аңгыра, юләр булып кылану.

ДИВАНАЛЫК *и.* Дивана кешегә хас сыйфатлар. *Хуҗа ирыны белән кирәксез җиңеллек, диваналык күрсәтә.* М. Җәлил.

ДИВАНХАНӘ *и. иск.* Диван (III) сарае, йорты.

ДИВАР *и. кит. юг.* Стена. *Зыя, яткан җиреннән баш калкытып, дивардагы сәгатькә карады.* Г. Ибраһимов. *Юмартлык — җанны саклар бер дивар ул.* М. Максуд.

ДИВЕРСАНТ *и. к.* диверсияче. *Ул шикле кеше, ипташлар, бер чит илнең безгә җибәргән террористы, диверсанты булып чыкты.* А. Әхмәт.

ДИВЕРСИОН *с.* Диверсия ясый торган, диверсия ясау өчен билгеләнгән; диверсиягә китерә торган. *Диверсион отряд. Диверсион эш.*

ДИВЕ'РСИЯ *и.* 1. Дошманның сизгерлеген алдау һәм аның көчләрен һөҗүмнең төп юнәлешеннән читкә тарту максаты белән ясалган хәрби маневр (сугыш хәрәкәтләре).

2. Дошман тылында хәрби һ. б. әһәмиятле дәүләт объектларын зарарлау, җимерү, сафтан чыгару эшләре; берәр илдә чит дәүләт агентлары тарафыннан алып барыла торган һәртөрле җимерү, корткычлык эшләре. *Партизаннарның дошман тылындагы диверсияләре.* □ *Мондый кара урман эчендәге гаскәр йөрми торган юлларда дошманның һавадан ташланган вак диверсия группалары хәрәкәт итүе бик мөмкин.* Г. Әпсәләмов.

ДИВЕ'РСИЯЧЕ *и.* Диверсия ясаучы кеше.

ДИВИДЕНД *и. махс.* Акционерлар җәмгыятендә: табышның акция ияләре арасында ел саен бүленә торган өлеше.

ДИВИЗИОН *и. хәрби.* 1. Төрле ил армияләренең ракета гаскәрендә һәм артиллериясендә, сирәгрәк бронетанк гаскәрендә һәм кавалериядә: төп сугышчан берәмлек (подразделение). *Артиллерия дивизионы. Атлы дивизион.*

2. Флотта: бер үк типтагы берничә корабтан төзелгән берләшмә. *Көннәрдән беркөнне дивизионга диңгездә дошман су асты көймәсенең күренүен хәбәр итәләр.* Сов. әд.

ДИВИ'ЗИЯ *и.* Төрле илләрнең коры җир гаскәрендә, хәрби-һава көчләрендә һәм хәрби-диңгез флотында: эре тактик берләшмә (составы төрле дәүләттә һәм төрле чорда төрлечә). *Пехота дивизиясе* (берничә укчы һ. б. полктан тора). *Хәрби-диңгез флоты дивизиясе* (бер үк класс корабларының иң эре берләшмәсе). *Десант дивизиясе. Авиация дивизиясе* (берничә авиация полкыннан тора). *Танк дивизиясе.*

ДИДАКТ *и. сир. к.* дидактик 1.

ДИДАКТИЗМ *и. кит.* Турыдан-туры киңәшләр белән үгетләүдән генә гыйбарәт, үгет-нәсихәт бирүне генә максат итеп куйган алым; коры дидактика; вәгазьчелек. *Ул дидактизмга, вак-төяк фәлсәфә сатуга каршы көрәш белән кирәгеннән артык мавыга.* М. Хәсәнов.

ДИДА'КТИК I *и.* Дидактика белгече.

ДИДА'КТИК II *с.* 1. Дидактикага мөнәсәбәтле, бәйле; дидактикага караган. *Дидактик карашлар.* □ *Әлифбага кадәр һәм әлифба чорында төрле-төрле дидактик материаллар кулланырга, эш алымнарын әледән-әле төрләндереп торырга кирәк.* Сов. мәк.

2. Үгет-нәсихәт бирү, вәгазьләү формасындагы. *Дидактик әдәбият.* □ *Дидактик поэзия иҗтимагый тормышның торгын хәлдә булган чорлары өчен хас.* Х. Госман.

ДИДА'КТИКА *и.* 1. Педагогика фәнендә: укытуның гомуми методлары турындагы тармак.

2. *к.* дидактизм.

ДИЕ'ТА *и.* Тукланудың махсус режимы. *Диета саклау.* □ *Мин диета кешесе, сездә миңа яраклы ашамлык юктыр.* А. Расих.

ДИЕ'ТИК *с.* Диета режимына җайлаштырылган, диета таләпләренә җавап бирердәй. *Диетик азык. Диетик ашханә.* □ *Бүген диетик көн.* Г. Әпсәләмов.

ДИЕТОЛО'ГИЯ, ДИЕТЕ'ТИКА *и.* Дөрес тукланы турындагы фән.

ДИЗ- «ДИС»- алкушымчасының яңгыраулар алдыннан килгәндә кулланыла торган варианты, мәсәлән: **диз-ассоциация.**

ДИ'ЗЕЛЬ *и.* Кысылудан ялкынланып эшли торган эчке янулы двигатель. *Дизель ягулыгы.* □ *Катерның дизельләре кызып җиткән иде.* Г. Минский.

ДИ'ЗЕЛЬЛЕ *с.* Дизеле булган, дизель белән эшли торган. *Дизельле трактор. Дизельле электрокран.*

ДИ'ЗЕЛЬЧЕ *и.* Дизель моторлы машинада эшләүче. [*Наил*] *дизельче булып эшкә керде.* Г. Ахунов.

ДИЗЕНТЕРИ'Я *и.* Канлы эч китү рәвешендәге йогышлы каты чир. *Бактериаль дизентерия. Хайваннар дизентериясе.*

ДИКОБРАЗ *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан; аркасы, яннары һәм койрык очлары инәле, буе 40—70 *см* булган имезүче хайван.

ДИКТАНТ *и.* Дөрес язарга өйрәтү яки дөрес язу күнекмәләрен тикшерү өчен, укытучы тарафыннан әйтеп яздырыла торган язма эш. *Диктант дәфтәре. Диктант җыентыгы. Диктант дәресе. Диктант тикшерү.* □ *Бүген Стариков диктант өчен икенче бер әйбер хәзерләп куйган иде.* Г. Әпсәләмов.

ДИКТАТ *и. кит.* Көчле як тарафыннан көчсез якка куелган, сүзсез үтәлергә тиешле таләп; көчләп тагылган күрсәтмә. *Диктат политикасы.*

ДИКТА'ТОР *и.* Чикләнмәгән властьтан файдаланып дәүләт белән идарә итүче кеше, дәүләт башлыгы.

ДИКТАТУ'РА *и.* 1. Хаким сыйныф көченә турыдантуры таяна торган дәүләт власте һәм шуңа нигезләнгән идарә итү системасы. *Буржуаз диктатура.* □ *Ленинга, эшчеләр диктатурасын торгызучы бөтен ипташларга - - - хөрмәтем артты.* М. Фәйзи.

2. Диктаторның идарә итү системасы, диктаторлык режимы. *Хәрбиләр диктатурасы.*

ДИ'КТОР *и.* Радио яки телевидение аркылы тапшырулар текстын микрофон алдында укучы. *Репродуктордан Мәскәү дикторының көчле, шома тавышы яңгырый.* Э. Касыймов.

ДИ'КТОРЛЫК *и.* Диктор һөнәре; диктор вазифаларын үтәү эше.

ДИКТОФОН *и.* Сөйләгән сүзне язып алып, кирәк булганда кабат сөйләтә торган аппарат.

ДИ'КЦИЯ *и.* Сөйләгәндә яки җырлаганда сүзләрнең, иҗекләрнең һәм аерым авазларның ачык әйтелеш дәрәҗәсе, әйтелеш төгәллеге. *А. Измайлованың җыры һәм дикциясе яхшы.* М. Җәлил.

ДИКЪКАТЬ *и.* 1. Тыңлау сәләтенең, күз карашының, фикернең бер нәрсәгә, бер ноктага төбәлүе; игътибар. *Дикъкатьне тарту. Дикъкать белән карау.* □ *Безнең бөтен дикъкатебез җитешсезлекләрне бетерү, уңышларны ныгытуга юнәлдерелергә тиеш.* Ш. Камал.

2. *өндәү форм.* Игътибарны тупларга яки көчәйтергә кушып үтенгәндә яки боерганда кулланыла торган мөрәҗәгать сүзе. *Дикъкать, иптәшләр! Яңа гына районнан шалтыраттылар, - - - Советлар Союзы Герое Сабир Әкбәров авылга кайтырга чыккан. - - - Каршы алырга хәзер булыйк.* Ә. Камал.

ДИКЪКАТЬЛЕ *с.* Дикъкате көчле булган; игътибарлы, игътибар итүчән; күзәтүчән, күңел салучан. *Дикъкатьле укучы.* □ *Әминәнең озак һәм дикъкатьле карашында ошатканлык сизелә иде.* Ф. Әмирхан. *Хатыннар — мөлаем һәм дикъкатьле җаннар.* Г. Ибраһимов.

ДИКЪКАТЬЛЕЛЕК *и.* Дикъкатьле булу; дикъкатьле кешегә хас сыйфатлар. *Иң күп авария әнә шундый идеаль юлларда килеп чыга. - - - Бу юлның куркынычсызлыгы турында рефлекс барлыкка килә, ягъни шофер дикъкатьлелеген югалта, йокымсырый һәм машинаны һәлакәткә алып бара.* Г. Ахунов.

ДИКЪКАТЬЛӘП *рәв.* Дикъкать белән. *Әхмәт бу [рәсемдәге] кешеләрнең йөзләренә бик дикъкатьләп карап торды.* Ф. Әмирхан. *Камилә ишекне бик дикъкатьләп яба.* Г. Камал.

ДИЛБЕГӘ *и.* 1. Җиккән атны идарә итә торган озын нечкә бау, каеш яки брезент тасма (йөгәнгә

тоташтырыла). *Каеш дилбегә. Сүс дилбегә.* □ *Ат, өркеп, читкә тайпылды, ләкин Гали абзый дилбегәне нык тоткан иде.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч. гадәттә кыек форм.* Җитәкче роль, власть; җитәкчелек. [*Тимери*] *сугыш алдыннан бервакыт дилбегәне бөтенләй балалар кулына тапшырырга да уйлаган иде.* Г. Бәширов. *Власть үзебезнең кулга күчте.* --- [*Якуп*] *әйтә, дилбегә хәзер эшче белән крестьян кулына күчте, ди.* И. Гази.

◇ **Дилбегә кагу** — җиккән атны (яки башка хайванны) әйдәү. *Зариф абзый дилбегәне кагуга, җирән алаша элеп алып китте.* Г. Гобәй. **Дилбегә тарту** — 1) җиккән атка туктарга кушу. *Абзый кеше дилбегәсен тартып, атын туктатты.* И. Гази; 2) *к.* дилбегә кагу. [*Әхмәди*] *дилбегәсен тартты. Ат кузгалды.* Г. Галиев.

ДИЛЕ'ММА *и.* 1. *лог.* Бер-берсен инкяр итә торган ике нәрсәнең берсен сайлап алырга кирәклек турындагы фикер; шул фикерне эченә алган хөкем.

2. *кит.* Бер үк дәрәҗәдә күңелсез ике мөмкинлекнең берсен сайларга мәҗбүр булу хәле. *Картны рәнҗетү, әлбәттә, Заһитча, намуссызлык булыр иде. Шул үк вакытта бу тынгысыз лаборантка карата күрәләтә начарлык эшләү дә егетлек түгел иде. Нишләргә, дип уйланды Заһит.— Менә сиңа дилемма!* А. Расих.

ДИЛЕТАНТ *и.* Махсус хәзерлеге булмауга, предметны өстән-өстән генә белүенә карамастан, фән яки сәнгать белән шөгыльләнүче.

ДИЛЕТАНТЛЫК *и.* Дилетантка хас сыйфатлар.

ДИЛИЖАНС *и. иск.* Пассажирлар һәм почта йөртү өчен хезмәт иткән ябык карета (тимер юл һәм автомобиль транспорты үсеш алган чорга кадәр).

ДИЛО'ГИЯ *и.* Бер үк автор тарафыннан язылып бер идеягә буйсындырылган, ләкин мөстәкыйль булган ике зур әдәби яки музыкаль әсәр. *Мирсәй Әмир дилогиясе.*

ДИЛӘ'НКЕ *и.* Агач, печән хәзерләү һ. б. ш. өчен билгеләнгән урман, болын кишәрлеге, бүлеме. *Урманнан дилянке алу. Дилянке чистарту.* □ *Дилянке кисеп туң юлдан урман ташулар --- үтеп китте.* Ш. Маннур.— *Берәр дилянке печән сорап карыйсың мәллә?* Г. Ахунов.

ДИМ I *и. сир.* Өндәү, үгет. *Күтәрелер Англиянең эшче халкы да, Туктата алмаслар аларны дим белән.* Г. Камал.

ДИМ II *и. диал. к. зим. Октябрьның икенче ярты-сында Иделдә дим ага башлады.* Каз. утл.

ДИМЛӘҮ *ф.* Өндәү-чакыру, үгетләү. *Ул ирен гомер буенча калага күчәргә димләде.* Г. Ибраһимов. [*Яшьләрне*] *яңа тормышка чакырып, яңа эшләргә димләп байтак сөйләдем.* М. Фәйзи. // Өйләнергә, кияүгә чыгарга өндәү, үгетләү. *Димләгез кызның чибәрен, Егет үзе сөйгәнен.* Җыр.

ДИМЧЕ *и.* Өйләнергә, кияүгә чыгарга димләүче; шул эш белән кәсеп итүче.— *Мин димчесез генә өйләнергә булдым.* А. Шамов.

ДИМЧЕЛЕК *и.* Димче кәсебе, димләү эше. *Димчелекне кәсеп иткән мәкерле Мөгълифә карчыкның психологик төгәл һәм ышандырырлык образын иҗат итте ул.* Каз. утл.

ДИМЧЕЛӘҮ *ф. сөйл.* 1. Димче аркылы тәкъдим ясау (өйләнешү һ. б. турында).

2. *к.* димләү.

ДИМӘК I *ф. иск. к.* дию I. *Кил димәк бар, кит димәк юк.* Мәкаль.

ДИМӘК II *кер. сүз.* Соңрак әйтелгән сүзнең, фикернең башта әйтелгәнгә карата йомгаклау яки нәтиҗә мәнәсәбәтендә торганлыгын белдереп, «шуңа күрә», «шулай булгач» дигән мәгънәдә кулланыла. *Бернинди шартлар да, әгәр кеше үзе пассив икән, аны бәхетле итә алмый! Димәк, безнең бәхетле булуыбыз үзебездән тора.* А. Расих. *Эш бар икән, димәк, шатлык бар, дуслар бар, күңел көрлеге бар.* Ф. Хөсни.

ДИН *и.* 1. Табигатьтән өстен торып аны идарә итә торган көчләрнең (мәсәлән, аллаларның, рухларның, фәрештәләрнең һ. б. ш.) булуына ышану; *русчасы:* вера. // Шундый ышануга нигезләнгән һәм фәнгә каршы килә торган карашлар, күзаллаулар системасы; *русчасы:* религия. [*Кулаклар*] *дин белән халыкны бик нык агулыйлар.* Г. Толымбай.

2. Теге яки бу диндәге руханиларның һәм дин тотучыларның дини оешмасы. *Динне дәүләттән һәм мәктәпне диннән аеру.*

Дин башлыгы (башы) — рухани (мулла, мөфти һ. б.). *Кабила, ыру башлыклары, дин башлыклары, патша түрәләре казах халкын чиксез изәләр.* М. Максуд. *Мулла булып йөргән Хөснетдин карт дөнья куйгач, дүртбишләп агайның дин башы булу өчен барган дәгъвасына Карибулла да катнаша.* Э. Касыймов.

◇ **Дин дошманы** *иск.*— башка диндәге кеше. *Мулла русны дошман күрергә өндәгән. --- Үз чиратында, чиркәүдә поп татарның руска дин дошманы булуы турында сөйли, һәм патша хөкүмәте моны бик хуп күрә иде.* Г. Гобәй. **Дин кардәше** *иск.*— бер үк диндәге кеше, диндәш. [*Вәли бай:*] *Читләр түгел, үзебезнең дин кардәше мөселман авыллары тоттылар да минем җиргә басып керделәр.* Г. Ибраһимов. **Дин тоту** — дингә ышану; дини йолаларны үтәү. [*Чурагол*] *бер төрле динне дә тотмады, бер төрле динне дә хөрмәт итмәде. Шулай үк бер төрле динне дә сүкмәде, хурламады.* З. Бәшири. **Диннән язу** — динне югалту, диннән ваз кичү. *Диннән язу өчен бик күп, бик күп нәрсә белү кирәк.* Г. Гобәй.

ДИ'НА *и.* Механикада: бер грамм массага секундына бер *см* тизләнеш бирүче көч берәмлеге.

ДИНА'МИК I *и.* Электродинамик репродуктор.

ДИНА'МИК II *с.* 1. Динамикага (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле, шуңа нигезләнгән. *Динамик геология. Динамик теория.*

2. *кит.* Хәрәкәтләргә, күчешләргә, үзгәрешләргә бай булган; динамикалы. [*Тормыш*] *— туктаусыз үзгәреп, алмашынып торган бер диңгез. Шуңа күрә пролетариат әдәбиятында статиктан бигрәк динамик моментлар зур урын алалар.* Г. Ибраһимов.

ДИНА'МИКА *и.* 1. Механикада: җисемгә тәэсир итүче көчләргә бәйләп аның хәрәкәт законнарын тикшерә торган тармак. *Квант динамикасы. Машиналар һәм механизмнар динамикасы.*

2. Берәр җисемнең, күренешнең үсеш, үзгәреш юлы. *Җир асты сулары динамикасы. Иҗтимагый хәрәкәт динамикасы. Тормыш динамикасы.* // *күч.* Үсеш, хәрәкәт, җанлылык. *Буржуа реалисты чынлыкны бөтен каршылыгы һәм динамикасы белән ала алмый.* М. Җәлил. *Кечкенә, терекөмеш кебек тере бу кеше спектакльгә динамика һәм комик төсмер кертә.* Соц. Тат.

ДИНА'МИКАЛЫ *с. к.* динамик II (2 мәгъ.). *Бу редакциядә хикәянең барышы динамикалырак (хәрәкәтлерәк) төскә керә.* Қ. Нәҗми.

ДИНАМИТ *и.* Көчле шартлагыч матдә. *Бозны динамит белән шартлату.* □ *Динамитлар шартлап бер-бер артлы, Күк күкрәвен искә төшерә.* С. Урайский.

ДИНАМИТЧЫ *и.* Динамит белән шартлату остасы; шул эшнең белгече. *Динамитчы тауны актара.* С. Урайский.

ДИНА'МО *и.* к. динамомашина. [*Якуп*] *үзләренең электр станцияләренә динамомашина табып кайтырга тиеш! --- Якупның динамосыз кайтып керергә хакы юк.* И. Гази.

ДИНАМО- Физикада: кушма терминнарның беренче өлеше сыйфатында «көч», «көчкә мөнәсәбәтле» дигәнне белдерә, мәсәлән: **динамограмма, динамокардиография** һ. б. ш.

ДИНАМОМАШИ'НА *и. иск.* Электр тогы эшләп чыгарү машинасы, даими ток генераторы.

ДИНАМОМЕТР *и. физ.* Көч зурлыгын үлчәү коралы, көч үлчәгеч. *Пружиналы динамометр.*

ДИНАР *и.* Кайбер гарәп илләрендә һәм Югославиядә: акча берәмлеге һәм шул бәйдәге вак акча.

ДИНА'СТИЯ *и.* **1.** Бер үк нәселдән булып, бер-бер артлы идарә итүче монархлар (императорлар, короллләр, шаһлар һ. б. ш.). *Династиягә нигез салучы. Романовлар династиясе.* □ *Өч йөз еллык династияне, патша монархиясен җимерү өчен революция җиленең бер исүе җитте.* К. Нәҗми.

2. *күч. сөйл.* Бер үк эшне, һөнәрне дәвам итүчеләр нәселе. *Эшчеләр династиясе.* □ *Юлбасар да, илбасар да түгел, Безнең нәсел — хезмәт иясе: Безнең нәсел — ун гасырдан бирле Игенчеләр династиясе.* Х. Туфан.

ДИ'НГО *и. зоол.* Австралиядә яши торган, кыргыйлашкан эт.

ДИНДАР *с. к.* динле. *Мулла киңәшеннән башка аяк та атламый торган бер диндар кеше мулладан киңәш сорады.* Г. Бәширов. *Бу кеше чикылдаган надан һәм, һәрбер надан кешегә хас булганча, кара диндар булып чыкты.* Ф. Хөсни.

ДИНДАРЛАНУ *ф.* Диндар булып китү, диндарга әйләнү. // Диндар булып кылану, суфилану.

ДИНДАРЛЫК *и.* Диндар кешегә хас сыйфатлар, карашлар. [*Әхсән бай*] *диндарлыкка бирелеп, гади «мөселман» кыяфәтендә йөрүдән ниндидер тәм таба башлаган.* И. Нуруллин.

ДИНДӘШ *и.* Икенче берәү белән бер үк диндә торучы.

ДИНИ *с.* **1.** Дингә ышануга нигезләнгән; дин белән сугарылган. *Дини хорафатлар. Дини уйдырма.* □ *Политик һәм дини карашлары төрле булган бу кешеләр конгресста уртак тел таптылар.* М. Максуд. // Дингә мөнәсәбәтле, дингә караган; дин исеменнән эшләнгән. *Дини йола. Дини бәйрәм. Дини реформа. Дини китап. Дини мәдрәсә. Дини оешма.*

2. Дингә ышанучы, дин тотучы; динле. *Дини кеше.* □ *«Фани дөньядан ваз кичкән» дини карчык та, хатын-кыз бәхетсезлегенә җаны әрнеп, алласына үпкәли.* М. Максуд.

ДИНЛЕ *с.* Дингә ышанучы, дин тотучы. *Чеп-чи надан, кара халык үзләренчә бик динлеләр, мулла ни әйтсә, шуңа ышаналар сыман иде.* Г. Иделле. *Ул динле семьяда үсмәде, шуңа күрә динле кешеләрне күрү аңа сәеррәк иде.* Г. Әпсәләмов.

ДИНОЗАВР *и.* Мезозой эрасында яшәгән зур гәүдәле сөйрәлүче хайван.

ДИНСЕЗ *с.* Дингә ышанмаучы, дин тотмаучы. *Минем атам --- Байлар өчен алтын чүпләгән. Авыр көннәр аны Динсез иткән, Теләк теләп Тезен чүкмәгән.* М. Крыймов.

ДИНСЕЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Дингә ышанмас булу, динсезгә әйләнү. *Хәзерге нык динсезләнгән, сәясәттән күзем ачылган заманымда алар [иске язмалар] бик ачуымны китерәләр.* М. Фәйзи.

2. *күч. гади с.* Явыз, эшәке кешегә әйләнү; бозылу. [*Көсәен:*] *Газиз, сүз шул сиңа. Синең картуз киеп, --- студент булып йөрүеңә без риза була алмыйбыз; болай да динсезләнүең чигенә җитте инде.* Ф. Әмирхан.

ДИНЧЕ *и.* **1.** Дини оешмаларның берсендә хезмәт итүче; рухани. *Динчеләргә унар тиен сәдака бирделәр.* Г. Ибраһимов. *Дога көченә һәм һәртөрле сихерләргә ышандыру — динчеләрнең иң әһәмиятле коралларыннан санала.* Э. Касыймов.

2. *с. мәгъ.* Динле. *Авылның динче картлары белән куштаннары уенны килеп туздырдылар.* М. Гафури.

ДИНЧЕЛ *с.* Динле, дингә бирелгән, диндар. *Фәтхулла тыштан бик динчел, сифи кеше булып йөри.* Г. Иделле. *Аксаби карт --- бик динчел.* З. Бәшири.

ДИНЧЕЛЕК *и.* Дингә ышанучылык, дини карашлар; динне, дини хорафатларны яклау, алга сөрү һ. б. ш. *Динчелек хисләрен җиңү. Халыкның аңын динчелек сөреме белән агуларга маташучы буржуаз язучылар.*

ДИНЧЕЛЛӘНҮ *ф.* Динчел кешегә әйләнү яки шундый булып кылану.

ДИО'ПТРИЯ *и. физ.* Оптик пыялаларның һ. б. яктылык нурларын сындыру көчен үлчәү берәмлеге.

ДИОРА'МА *и.* Үтә күренмәле җирлекнең (тукыманың, тоник пыяланың һ. б.) ике ягына да ясалып, күләмлелек тәэсире бирү өчен махсус яктыртып күрсәтелә торган рәсем. // Рәсем алдына күләмле нәрсәләр, мәсәлән макетлар, урнаштырып эшләнгән сынлы сәнгать әсәре. *«Кышкы сарайны штурмлау» дигән диорамаы аеруча зур кызыксыну белән карыйлар. Алгы планда — Сарай мәйданы һәм Сарай; алар артында — «Аврора» крейсеры, --- солдатлар һәм матрослар төрле яктан сарайны штурмлыйлар.* Соц. Тат. // Гомумән, махсус яктыртуга исәп тотып эшләнгән сынлы сәнгать әсәре.

ДИПЛОМ *и.* **1.** Югары яки махсус урта мәктәпне тәмамлау, берәр исем яки дәрәҗә бирелү турындагы рәсми документ, таныклык. *Укытучы дипломы. Инженер дипломы.* □ *Ул әле --- яңа гына кулына диплом алган яшь врач иде.* Н. Дәүли.

2. Берәр кешенең, оешманың һ. б. ш. теге яки бу эшкә (мәсәлән, сәүдәгә) хокукын раслый торган рәсми документ.

3. Конкурста, ярышта, күргәзмәдә һ. б. ш. яулаган уңышлар, ирешкән күрсәткечләр өчен бүләк, приз рәвешендә бирелә торган таныклык. *Халык хуҗалыгы күргәзмәсендә беренче дәрәҗә диплом алу. Чемпион дипломы.*

4. *сөйл.* Уку йортын тәмамлап таныклык-диплом алыр алдыннан эшләнә торган мөстәкыйль фәнни тикшеренү, техник проект һ. б. ш. махсус хезмәт; диплом эше. *Диплом язу. Диплом яклау.*

ДИПЛОМАНТ *и.* **1.** Диплом (4 мәгъ.) язучы, хәзерләүче; диплом авторы. *Күп кенә институтларда дипломантлар үзләренең биш-алты ел буена зур көч куеп алган белемнәрен --- күрсәтү өчен дәүләт комиссиясе алдында имтихан тотуга, диплом эшләрен яклауга керешеләр.* Соц. Тат.

2. Диплом (3 мәгъ.) белән бүләкләнгән кеше һ. б. *Халыкара конкурс дипломанты.*

ДИПЛОМАТ *и.* **1.** Дипломатия (1 мәгъ.) эше белән шөгыльләнүче; дәүләтнең тышкы, халыкара мөнәсәбәтләре өлкәсендә эшләүче. *Совет дипломатлары.*

2. *күч.* Кешеләр белән үтә нәзакәтле, бик оста мөгамәлә итә белүче кеше турында.— *Кирамов хәтле дипломат кеше моны бер дә юкка сөйләмәс.* Н. Исәнбәт.

ДИПЛОМА'ТИК *с.* Дипломатиягә (1, 2 мәгъ.) караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Дипломатик сөйләшүләр. Дипломатик миссия.* □ [*Империалистлар*] *экономик һәм дипломатик басым ярдәмендә Советлар Россиясенә колониаль режим тагарга уйладылар.* КПСС тарихы.

ДИПЛОМА'ТИЯ *и.* **1.** Дәүләтнең тышкы политикасын тормышка ашыру буенча хөкүмәт тарафыннан алып барыла торган эш, эшчәнлек. *Дипломатия вәкиллеге. Дипломатия күзәтүчесе. Дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштыру.* // *җый.* Дипломатия өлкәсендә эшләүчеләр; дипломатлар (1 мәгъ.). *Яңа хәлләр рус дипломатиясенә үз дигәнендә ныграк торырга тулы мөмкинлек бирделәр.* В. И. Ленин.

2. *к.* дипломатлык. *Кызмача башлы Сәүбәннең дип-*

ломатиясе шуннан [*ягымлы сүз башлаудан*] *да артыкка җитмәде.* Ф. Хөсни.

ДИПЛОМАТЛАНУ *ф.* Дипломат (2 мәгъ.) кебек эш итү.— *Гыймади Шакирович, син әле дипломат та икәнсең! --- Сугыш вакытында бер дә болай дипломатланып тормый идең, туп-туры бәрә идең, ни булды сиңа?* И. Гази.

ДИПЛОМАТЛЫК *и.* 1. Дипломат (1 мәгъ.) вазифалары.

2. Дипломатка (2 мәгъ.) хас сыйфатлар. *Мин үзем Харисның дипломатлыгына ышанам. Ул бик зур кыенлыклардан чыкканы бар.* Ш. Усманов. *Син сүз өчен кесәгә керә торган адәм түгел. Дипломатлыгың да җитәрлек.* Г. Ахунов.

ДИПЛОМЛЫ *с.* Дипломы (1—3 мәгъ.) булган, диплом алган. *Дипломлы врач.* □ *Без — дипломлы яшь белгечләр, Яңа ил төзүчебез.* М. Хөсәен.

ДИРБИЯ *и.* 1. Йорт-җир һәм хуҗалык җиһазлары, көнкүреш кирәк-яраклары, эш әсбаплары һ. б. ш. *Табын дирбиясы. Ат җигү дирбиялары.* □ *Бурыч вакытында түләнмәгәч, әлеге күпец шушы казна фабрикасын барлык эшчеләре, җиһаз-дирбиялары белән бергә үз исеменә яздырган.* К. Нәҗми. [*Шәмсегаян*] *чиста ашъяулык өстенә аш дирбиялары китереп тезде.* А. Гыйләҗев. // Сугыш кирәк-яраклары һ. б. ш. *Елгаларны бик тиз кичү әмәлләрен өйрәнәбез* [*фронтта*]. *Үзебез генә түгел, пушкаларыбызны, тагын дөнья хәтле сугыш дирбияларын да бик тиз алып чыга белергә кирәк.* Р. Төхфәтуллин.

2. Аш-су хәзерләү өчен кирәк булган азык-төлек һәм төрле тәмләткечләр (тоз, суган, борыч һ. б.); малларны, кош-кортны тәрбияләү өчен кирәк булган азык һ. б. *Дирбиясы гына булсын аның! Дирбиясы булса, ничек пешерергә икәнен үзебез дә карар идек әле!* Э. Исхак.

ДИРЕКТИВ *с.* 1. Директива рәвешендәге, директива характерындагы. *Директив хат.*

2. Директивалар бирә торган. *Директив органнар.*

ДИРЕКТИ'ВА *и.* Югары органнар тарафыннан бирелгән һәм үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмә. *Директивалар бирү. Бишьеллык план буенча директивалар. Партия һәм хөкүмәт директиваларының үтәлешенә җәмәгать контроле булдыру.*

ДИРЕ'КТОР *и.* Предприятие, учреждение яки кайбер уку йорты җитәкчесе, башлыгы. *Мәктәп директоры. Совхоз директоры.*

ДИРЕ'КТОРЛЫК *и.* Директор хезмәте, вазифалары; шул хезмәт урыны. [*Җамалый агай*] *бу җаваплы эшкә балалар йорты директорлыгыннан күчерелгән.* Г. Минский.

ДИРЕ'КЦИЯ *и.* 1. Берәр предприятиенең, учреждениенең яки уку йортының директор җитәкчелегендәге идарә органы. *Завод дирекциясендә эшләү. Театр дирекциясе белән сөйләшүләр алып бару. Дирекция исеменнән чыгыш ясау.*

2. Шушы идарә урнашкан бина яки бүлмә.

ДИРИЖАБЛЬ *и.* Һавадан җиңелрәк булган, рульле һәм моторлы озынча очкыч-аппарат.

ДИРИЖЁР *и.* Оркестрга, хорга һ. б. җитәкчелек итүче. *Баш дирижер.* □ *Музыка, бик каты яңгырап, кырт өзелә. Халык күл чаба башлый. Дирижер борылып башын ия.* И. Гази. *Баку циркында Фәйзулла хоркапелланың дирижеры булды.* Ф. Хөсни.

ДИРИЖЕРЛЫК *и.* Дирижер хезмәте, вазифасы яки аның һөнәре.

ДИРһӘМ *и.* 1. Кайбер гарәп дәүләтләрендә: акча берәмлеге һәм шул бәядәге вак акча.

2. Мисырда һәм Суданда: кыйммәтле металларны үлчәү берәмлеге (3,12 *г*).

ДИС- Сүзгә кире мәгънә бирә яки таркату-җимерүне, бетерү-бозуны, аеру-бүлүне, начарлату-кыенлаштыруны белдерә торган алкушымча, мәсәлән: **дисгармония, дискредитация, дискрет** һ. б. ш.

ДИСБЕ *и. к.* тәсбих 2. *Килеп кердем бер йортка, дип сөйли ди Әхмәтша хәлфә, карты-яше, ире-хатыны дисбеләр тотып, тәсбих укып каршы алдылар мине, дип әйтә ди.* Э. Фәйзи.

ДИСГАРМО'НИЯ *и. кит.* Гармония бозылу, бозылганлык күренеше; гармониясезлек, үзара ярашмаучанлык; аһәңсезлек. *Музыкаль авазлар дисгармониясе.*

ДИСК *и. махс.* 1. Яссы түгәрәк рәвешендәге әйбер, деталь, җайланма, тәлинкә. *Чәчкеч машиналарының калай дисклары зыңгылдый, өере белән каргалар сикерешә.* Г. Мөхәммәтшин. *Магнитофон дискы үзенә бертөрле җиңелчә шау чыгарып әйләнә башлады.* Э. Касыймов. // *спорт.* Шундый формалы, ыргыту өчен хезмәт итә торган гимнастик әсбап. *Диск ыргытучы.*

2. Кул пулеметының һәм автомат винтовканың патроннар салына торган магазины (тартмачыгы). *Автомат дискларына Патрон тутырасыңмы, Күргәнен берен дошманның Син бәреп торасыңмы?* Ф. Кәрим.

ДИ'СКАНТ *и. махс.* Малайларга хас нечкә (югары) тавыш. *Дискант белән җырлау.* // Шундый тавышлы җырчы. *Хордагы дискантлар.*

ДИСКВАЛИФИКА'ЦИЯ *и.* Дисквалификацияләү яки дисквалификацияләнү эше-хәле.

ДИСКВАЛИФИКА'ЦИЯЛӘНҮ *ф. кит.* 1. *Төш. юн. к.* дисквалификацияләү.

2. Квалификацияне, берәр һөнәр буенча белгечлекне, берәр эштәге күнекмәләрне югалту; квалификациясезләнү.

ДИСКВАЛИФИКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ярышның техник кагыйдәләрен бозган спортчыны (яки спорт командасын) квалификация исемлегеннән төшерү (ирешкән күрсәткечләрен, яулаган урынын танымау, исәпкә алмау һ. б. ш.). // Мораль-этика нормаларын бозган спортчыны (яки спорт командасын) ярышка катнашу хокукыннан мәхрүм итеп тору.

ДИСКЛАУ *ф. а.-х.* Дисклы корал (тырма һ. б.) белән эшкәртү. *Арыш чәчү алдыннан җирне аркылыга-буйга дисклау. Люцерна дисклау.*

ДИСКРИМИНАЦИОН *с. кит.* Дискриминациягә мөнәсәбәтле; дискриминация рухы белән сугарылган; дискриминацияне тормышка ашыра торган. *Дискриминацион карар. Дискриминацион чаралар.*

ДИСКРИМИНА'ЦИЯ *и.* Дискриминацияләү эше һәм чаралары, шулай ук дискриминацияләнү хәле. *Раса дискриминациясе. Дискриминация политикасы.*

ДИСКРИМИНА'ЦИЯЛЕ *с. кит.* Дискриминацияләү рухы белән сугарылган яки аны тормышка ашыра торган; дискриминацион. *Дискриминацияле шартлар кую. Дискриминацияле таләпләр. Колонизаторларның дискриминацияле политикасы.*

ДИСКРИМИНА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Расасы, милләте, женесе, политик яки дини карашлары һ. б. ш. бүтән булган кешеләрнең теге яки бу хокукларын чикләү яки хокукларыннан мәхрүм итү. *Америкада негрларны дискриминацияләү. Азчылык милләт вәкилләрен дискриминацияләү. Буржуаз җәмгыятьтә алдынгы фикер ияләрен дискриминацияләү.* // Халыкара мөнәсәбәтләрдә: теге яки бу дәүләтнең вәкилләренә, оешмаларына һәм гражданнарына башка дәүләтнекеләргә караганда кимрәк хокуклар бирү.

ДИСКРИМИНА'ЦИЯЧЕ *и.* Дискриминация кулланучы; дискриминация политикасын яклаучы һәм алга сөрүче. *Дискриминацияче плантатор.*

ДИСКУССИОН *с.* Дискуссия китереп чыгара торган, бәхәсле яки дискуссия юлы белән ачыкланыга мохтаж булган. *Дискуссион проблема. Дискуссион караш.*

// Дискуссия тәртибендә, дискуссия вакытында ясалган (булган). *Дискуссион чыгыш.*

ДИСКУ'ССИЯ *и.* Берәр мәсьәлә буенча җыелышта, матбугатта яки үзара әңгәмәдә фикер алышу тәртибендә алып барылган бәхәс. *Ачык дискуссия.* □ *Бәхәсләр, әңгәмәләр, дискуссияләр юлы белән бу мәсьәләне тулысынча ачыкларга тырышыгыз.* В. И. Ленин. *Клубта яңа тормыш турында дискуссия уздырабыз.* Ф. Хөсни. // Бәхәс, сүз көрәштерү. *Дискуссиягә керү.* □ *Ягез, дискуссиягезне куегыз әле.* Ш. Усманов.

ДИСЛОКАЦИОН *с.* Дислокациягә мөнәсәбәтле. *Дислокацион карта. Дислокацион план.*

ДИСЛОКА'ЦИЯ *и. хәрби.* Кораллы көчләрне һәм аңа караган учреждениеләрне тиешле урыннарда урнаштыру. *Дошман позицияләре безнекеләрдән өстәрәк иде. Аларга безнең батальонның дислокациясе ап-ачык күренеп тора.* Г. Әпсәләмов.

ДИСПАНСЕР *и.* Махсус дәвалау һәм авыруларны булдырмау чаралары үткәрә торган медицина учреждениесе. *Тире авырулары диспансеры. Трахома диспансеры. Туберкулез диспансеры.*

ДИСПЕПСИ'Я *и. махс.* Ашказаны һәм эчәкләрнең нормаль эшчәнлеге бозылу чире. *Кайчак бозаулар бик зәгыйфь туа. Алар, тугач, беренче атнада ук диспепсия белән җәфаланалар.* А. Расих.

ДИСПЕ'ТЧЕР *и.* Үзәк пункттан гадәттә төрле элемтә чаралары ярдәмендә транспорт хәрәкәтен, предприятиедә эш барышын график нигезендә оештырып һәм күзәтеп торучы. *Автопаркта диспетчер булып эшләү. Үзәк телефон станциясенең диспетчеры.* □ [*Серебряков*] *диспетчер ярдәмчесе булып эшли.* И. Гази.

ДИСПЕ'ТЧЕРЛАШТЫРУ *ф.* Идарәне һәм контрольне техник-оештыру ягыннан үзәкләштереп, диспетчерлар ярдәмендә идарә-контрольлек итү системасына күчерү. *Нефть чыгару процессларын диспетчерлаштыру.*

ДИСПЕ'ТЧЕРЛЫК *и.* Диспетчер хезмәте, вазифалары яки аның һөнәре. *Диспетчерлык пункты.*

ДИСПОЗИ'ЦИЯ *и. хәрби иск.* Гаскәрләрне сугышка кертү өчен хәзерлек хәленә китерү-урнаштыру тәртибе, планы. [*Командующий*] *адъютанты Зубрицкийга алдагы һөҗүмнең диспозициясен яздыра.* Ш. Усманов. // Корабларның туктап торгандагы (рейдта, гаваньда яки дингездә якорьда) урнашу тәртибе.

ДИСПРОПО'РЦИЯ *и.* Бер бөтен өлешләренең яки үзара мөнәсәбәтле нәрсәләрнең нормаль чагыштырмасы югалу, күләм-микъдар ягыннан ярашучанлыгы бозылу күренеше; пропорциональ нисбәт бозылу; пропорциясезлек, тигезсезлек. *Төрле тармак фәнни кадрларын хәзерләүдәге диспропорция. Авыл хуҗалыгы белән промышленностьны үстерүдә диспропорциягә юл куймау.* □ *Урыны-урыны белән бер үк җыр эчендә ижек ягыннан зур гына диспропорцияләр күренә.* Г. Гали.

ДИ'СПУТ *и.* Җәмәгатьчелек алдында фәнни, иҗтимагый-политик, әдәби һ. б. әһәмиятле темага алып барылган бәхәс. *Клубта дуслык темасына диспут үткәрү.* □ [*Футуристлар*], *Такташ иҗатына каршы көрәшкә масса формасы бирергә исәпләп, әдәби судлар, диспутлар оештырдылар.* Х. Госман.

ДИССЕРТАНТ *и.* Диссертация яклаучы.

ДИССЕРТАЦИОН *с.* Диссертациягә мөнәсәбәтле.— *Рәхимнең гыйльми хезмәте белән танышканнан соң, аның эшен бик актуаль, кирәкле дип табам. Мин аны диссертацион тема булырга лаеклы дигән фикердә торам.* А. Расих. // Диссертация итеп язылган. *Диссертацион эш.*

ДИССЕРТА'ЦИЯ *и.* Фәнни учреждениенең гыйльми советында яклап гыйльми дәрәҗә алу өчен язылган фәнни хезмәт. *Диссертация язу. Кандидатлык диссертациясе.* □ *Мөнирә үзе аспирантурага керәчәк, диссертация яклаячак.* Г. Әпсәләмов.

ДИССИМИЛЯТИВ *с. кит.* Диссимиляция рәвешендәге, характерындагы. *Диссимилятив үзгәреш. Диссимилятив күренеш.*

ДИССИМИЛЯ'ЦИЯ *и. лингв.* Фонетик охшашлыкны бетерә торган үзгәреш (мәсәлән, «коридор» урынына «колидор» дип, «шушы» урынына «тушы» дип сөйләү һ. б.).

ДИССИМИЛЯЦИЯЛӘНҮ *ф. лингв.* Үзгәреш нәтиҗәсендә фонетик охшашлык бетү, охшашсызлану (авазлар турында). *Авазлар диссимиляцияләнү.*

ДИССОНАНС *и.* 1. Шигырьдә: ким рифманың бер төре (тартыкларның гына туры килешүеннән ясалган аваздашлык).

2. Музыкаль тоннарның бер-берсе белән «кушылмыйча» яңгырашы; *киресе:* консонанс.

3. *күч. кит.* Берәр нәрсәнең нормаль, көйле барышына туры килми торган хәл килеп чыгу, тәртипне, халәтне боза торган күренеш һ. б. ш. турында. *Шул тигез агыш эченә бер генә ят тавыш килеп керсен, бер генә ялгыш нота яңгырасын — шунда ук бөтен симфония җимерелә, ямьсез диссонанс башлана!* Ш. Маннур.

ДИССОЦИА'ЦИЯ *и. физ. хим.* Молекулаларның состав өлешләргә таркалышы. *Термик диссоциация. Электролитик диссоциация. Газ диссоциациясе.*

ДИСТА'НЦИЯ *и.* 1. Аралык, ераклык, ара. [*Бокс чы*] *Җоржның кечкенә бер бәрелештә үзенең бөтен серен ачып бетермәвен Андрей сизә иде. Шуңа күрә ул көрәш башлану белән аның кайсы дистанциядә — якынындамы, ерагындамы көчлерәк сугышуын ачыкларга һәм шуннан чыгып хәрәкәт итәргә булды.* Г. Әпсәләмов. // *спорт.* Старт белән финиш арасы. *Кыска дистанция. Озын дистанция.* □ *Якшәмбе көнне меңләгән спортчылар кросс дистанцияләренә чыктылар.* Соц. Тат.

2. *махс.* Шоссе, су, тимер юлында административ-техник бүленеш арасы. *Дистанция башлыгы.* □ *Халкым илһам биреп тора Ераклларга юллар сузарга; Ул дәрт бирә, дистанцияне түгел, Вакытны да хәтта узарга.* С. Урайский.

ДИСТИЛЛЯ'ТОР *и.* Дистилляция аппараты, җайланмасы.

ДИСТИЛЛЯЦИОН *с.* Дистилляция өчен билгеләнгән; дистилляциягә мөнәсәбәтле. *Дистилляцион көпшә.*

ДИСТИЛЛЯ'ЦИЯ *и.* Куу (кайнатып парга әйләндерү) юлы белән чистарту.

ДИСТРО'ФИК I *и. мед.* Дистрофия белән авыручы.

ДИСТРО'ФИК II *с.* Дистрофиягә бәйләнешле, мөнәсәбәтле. *Тукымалардагы дистрофик үзгәрешләр.*

ДИСТРОФИ'Я *и. мед.* Организмда тукымаларның һәм аерым органнарның тукланышы бозылу хәле. *Йөрәк дистрофиясе. Ачлыктан дистрофия башлану. Аксым дистрофиясе. Балалар дистрофиясе.*

ДИСТӘ *и.* 1. Ун берәмлек; ун данә; уңга тигез санау-хисаплау берәмлеге. *Бер дистә күкәй.* □ *Советлар илендә генә әллә ничә дистә тел бар.* И. Гази. *Быел безнең авылдан бер дистәдән артык егет солдатка алынды.* М. Гафури. // *сөйл.* Ун яшь. [*Газимәгә*] *инде дүртенче дистә китте.* Н. Фәттах.

2. Унарлы санау системасында: күп урынлы санның ахырдан икенче цифр исеме.

ДИСТӘЛӘГӘН *с.* Бер дистә чамасы, дистәдән артыграк. *Дистәләгән күзләр биюче егетнең җитез йөргән аякларына текәлде.* М. Гафури. *Һәр көн юлдан дистәләгән Юлчы уза, тузан туза.* М. Җәлил.

ДИСТӘЛӘП *рәв.* Дистәгә якын, бер дистә чамасы. *Багана янында дистәләп кеше --- приказлар, хитапнамәләрне* [*өндәмәләрне*] *укырга тырышалар.* Ш. Камал.

ДИСТӘЛӘРЧӘ *с.* Күп: берничә яки күп дистә. *Елга тамаклары гадәттә тармакланып-тармакланып, дистәләрчә култыклар-куеннар ясап, җәелеп-киңәеп ятучан була.* М. Шабаев.

ДИСТӘЛӘҮ *ф.* Дистәләргә аеру. *Дистәләп санау.* □ *Ул бер кочак әйберне [фронтка дигән бүләкләрне] алып, икенче өстәлдә аларны дистәләп бәйләп торучы Хәдичә тутыгә илтеп аударды.* Г. Бәширов.

ДИСЦИПЛИ'НА *и.* Коллективтагы һәр кеше мәҗбүри буйсынырга тиеш булган кагыйдәләр; тәртип. *Аңлы дисциплина. Хезмәт дисциплинасы. Хәрби дисциплина. Дәүләт дисциплинасы. Дисциплинага буйсыну.* □ *[Фәритнең] табелендә дә бары бишләр белән дүртләр генә. Дисциплинасы бервакытта да биштән төшкәне юк.* А. Шамов. // Режим (технологиядә, финанс эшендә һ. б.). *Финанс дисциплинасы. Технология дисциплинасы.*

ДИСЦИПЛИ'НАЛЫ *с.* Дисциплинага күнеккән, аңа буйсынучан; тәртипле. *Дисциплиналы коллектив.* □ *[Командир:] Отрядның өчтән берсен татарлар тәшкил итәләр. Алар шундый аңлы, дисциплиналы, тәртип сөючәннәр.* Ш. Усманов. *Хәрбиләр — дисциплиналы халык.* Г. Ахунов.

ДИСЦИПЛИ'НАЛЫЛЫК *и.* Дисциплиналы кешегә, коллективка хас сыйфатлар. *Эштә дисциплиналылык күрсәтү.*

ДИСЦИПЛИНАР *с. кит.* Дисциплинага мөнәсәбәтле. *Дисциплинар устав.* // Дисциплинаны бозу эшләренә мөнәсәбәтле; төзәтү характерындагы. *Дисциплинар җәза. Дисциплинар батальон. Дисциплинар җаваплылык.* □ *Айлык сәяси һәм дисциплинар карантин --- узган иде инде.* Ш. Маннур.

ДИСӘНӘ *кис.* Күңелле, шаян җыр юлларына өстәп, ритм яки рифма максатларында кулланыла. *Батыр егет печән чаба дисәнә; Утми аның чалгысы дисәнә. Утәр иде чалгысы дисәнә, Анда кызлар кайгысы дисәнә.* Җыр. *Яңа Бистә чын-чын яңа, күрсәнә, күрсәнә. Анда үсә яңа кеше дисәнә, дисәнә.* Р. Ишморат.

ДИСӘТИНӘ *и.* Россиядә метрик системага кадәр: 2400 квадрат сажинга яки 1,09 гектарга тигез җир үлчәү берәмлеге. *Әткәй Гыйрфан байдан бер дисәтинә урак белән ике дисәтинә печән чабарга алган.* Г. Ибраһимов.

ДИСӘ'ТНИК *и.* 1. Төзелештә һ. б. эшләрдә: эшчеләр төркеменең башлыгы, өлкән эшче. *Төзелештә дисәтник булып эшләү.*

2. *сөйл.* Авыл советында дежур тору һәм йомышюлга йөрү өчен билгеле бер вакытка чират тәртибендә билгеләнә торган кеше, дежурный. *Дисәтник аркылы авыл советы утырышына чакыру.* □ *Бөтен авылны берьюлы дисәтникләр аша нардомга [чакырдык].* Ф. Хөсни.

3. *сөйл.* Элек авылда полицейский хезмәтләрен башкару өчен ун йорттан «сайлап» куелган крестьян. *Сәхәби абзый, күптәнге солдат кеше, без белә-белгәннән бирле дисәтник булып, халыкка артык катылыгы да, артык йомшаклыгы да тимәгән --- бала күңеллерәк кеше, [кызыл] комачны югары күтәреп горур гына атлый.* Ш. Маннур.

ДИФРА'КЦИЯ *и. физ.* Дулкыннарның, каршылыкны әйләнеп үтеп, юнәлешләрен үзгәртү күренеше. *Радиодулкыннар дифракциясе. Яктылык дифракциясе.*

ДИФТЕРИТ, ДИФТЕРИ'Я *и. мед.* Күбесенчә балаларда булып, организмның гомуми агулануына китерә торган йогышлы һәм каты авыру (тышкы билгеләреннән берсе: тукыманың ялкынсынган җире, бигрәк тә авыз-борын эче яки йоткылык, тыгыз булып шешенкерәп тора). *Тамак дифтериты. Борын дифтериты.*

ДИФТОНГ *и. лингв.* Бер иҗектә янәшә килгән ике сузык авазның кушылмасы.

ДИФТО'НГЛАШУ *ф. лингв.* Дифтонгка әверелү (гадәти сузык аваз яки авазлар турында).

ДИФФЕРЕНЦИАЛ *и.* 1. Математикада: функция үсемтәсенең төп сызыкча өлеше.

2. *тех.* Автомобиль, трактор, танк кебек машиналарның йөртүче тәгәрмәчләренә борылышларда төрле тизлек белән әйләнергә мөмкинлек бирә торган механизм.

ДИФФЕРЕНЦИАЛЬ *с.* 1. Дифференциалга (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Дифференциаль геометрия. Дифференциаль тигезләмә.*

2. *кит.* Төрле шартлар һәм очраклар өчен бердәй булмаган; аермалы. *Дифференциаль метод. Дифференциаль диагноз.*

ДИФФЕРЕНЦИА'ЦИЯ *и.* Дифференцияләү эше, алымнары һәм дифференцияләнү хәле. *Дифференциация ясау. Социаль дифференциация.*

ДИФФЕРЕ'НЦИЯЛЕ *с. к.* дифференциаль (2 мәгъ.). *Мәсьәләгә дифференцияле якын килү. Дифференцияле чәчү сроклары. Дифференцияле эш нормалары.*

ДИФФЕРЕНЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Һәр конкрет шартның һәм очракның үзенчәлегенә мөнәсәбәтле рәвештә аерымлау, аерып карау. *Билгеләмәләрне дифференцияләү. Йөкләмәләрне дифференцияләү. План төзегәндә хуҗалык зоналарын дифференцияләү. Халык доходларын дифференцияләү. Сатып алу бәяләрен дифференцияләү.*

ДИФФУ'ЗИЯ *и.* махс. Орынышып торган матдәләрнең кисәкчекләре һәм молекулалары бер-берсенә үтеп керү, аралашу, үзара катнашу процессы һәм күренеше. *Сыеклыклар диффузиясе. Каты җисемнәрдәге диффузия. Нейтроннар диффузиясе.*

ДИФФУ'ЗИЯЛӘНҮ *ф. махс.* Диффузиягә дучар булу, үзара катнашу, кушылу. *Газларның тиз диффузияләнүе. Ионнарның диффузияләнү тизлеге.*

ДИЭЛЕ'КТРИК I *и. физ.* Электр үткәрми яки бик әз үткәрә торган матдә (мәсәлән, күкерт, пыяла, сыеклык һ. б.).

ДИЭЛЕ'КТРИК II *с.* Электр үткәрми яки бик әз үткәрә торган. *Диэлектрик җисем. Диэлектрик антенна.*

ДИЮ I *ф.* Туры һәм кыек сөйләмне контекстка бәйләп, автор сүзе сыйфатында яки автор сүзләре составында түбәндәге мәгънәләрдә грамматик хәбәр булып кулланыла. 1. Сөйләү, әйтү, хәбәр итү.— *Юлны яхшы беләсездер бит? — диде Мостафа.* Ш. Камал. *Малай әйтә, мин ди, Мәскәүдә торганда ди, Ленинны үз күзем белән күрдем, сөйләгәнен дә ишеттем ди.* Г. Толымбай. *Гармуныңны уйнап җибәр, Кызлар җырлыйбыз диләр.* Н. Арсланов. *Ленин бабай балаларга Тырышып укырга дигән.* Җыр.

2. Үзеннән алда килгән сүзгә мөнәсәбәтле рәвештә «(шулай) атау, исемләү», «(шулай) карау» дигәнне белдерә. *Безне карт дияргә кемнең хакы бар?* Р. Ишморат. *[Колынның] төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк тә дип булмый.* Г. Ибраһимов. // «(Шулай) дип уйлау, фараз итү, чамалау» дигәнне белдерә. *Ат типмәс димә, эт капмас димә.* Мәкаль. *Ак күян дип аткан идем, Булды тауның катлавы.* Җыр. *Нигъми белән без бакча каравылларга барган икәнбез дим төшемдә.* Г. Лотфи. *Уракны мин эш тә димим.* Ш. Маннур. // «Теләү», «ниятләнү» дигәнне белдерә. *Яхшы торам дисәң, бергә торырга кирәк.* Һ. Такташ. *Тиз генә әйләнеп өйгә Кайтырмын дигән идем.* С. Хәким.— *Ялгыз бер кызыбыз, без аның теләгенә каршы килеп йөрмәбез инде, үзе дигәнен эшләрбез.* М. Фәйзи.

3. *юкл. форм.* Үзеннән алда килгән сүзгә мөнәсәбәтле рәвештә, «аңа игътибар итмәү», «аның белән исәпләшмәү» дигәнне белдерә. *Рекрут яшьләр, пычрак димиләр, Тальян белән урам иңлиләр.* Н. Баян. *Авыл арасы еракмы-якынмы, көн дими, төн дими, аяз дими,*

яңгыр дими, сулышлары бетеп кайтып керә ул. Э. Касыймов.

4. *кер. сүзтезмә яки җөмлә составында* **дигәннән, димәктән.** Сүзне, фикерне, башта әйтелгән бер сүзгә ялгап, икенчегә борып җибәргәндә (темасын алыштырганда) кулланыла. *Янгын сарае да шунда гына. Янгын сарае дигәннән, иллә дә күңелле җир инде үзе.* М. Шабай. [*Зәйнәп:*] *Менә укыйм...* [*Рокыя:*] *Укыйм димәктән, әле Гыйззәтулла абзыйлар да Хәсбикамалны укытырга маржа яллаганнар икән.* Ф. Әмирхан.

5. *кер. сүз функ. кушма хәбәр составында* **ди.** Әйтелгән фикернең үзеннеке түгеллеген күрсәтеп, «имеш» мәгънәсен белдерә. *Булган ди бер патша, бик усал булган ди үзе.* Һ. Такташ. *Мәче, буе җитмәгәч, итне сөрсегән дип әйтә ди.* Мәкаль. // «Сөйләүләргә яки мәгълүматларга караганда», «дип әйтәләр» мәгънәсен белдерә. *Төнлә бүлмәгә магнолия чәчкәсе тутырып ишекләрне, тәрәзәләрне япсаң, аның исеннән үләргә мөмкин ди.* М. Максуд. // «Шулай дип фараз итсәк», «шулай булган очракта» дигәнне белдерә. *Сыерның ите сигез пот булды ди. Потын җиде сумнан саттык ди. --- Җиде сумнан сигез пот иткә күпме акча тия?* М. Гафури. [*Арслангали*] *бер юл хат та язып салмады. Ярар, әти-әнисенә язмасын да ди, алар аның хәтерен калдырганнар. Нигә дип ул әбисенә язмый?* Г. Ахунов.

6. *рәв. мәгъ.* **диярлек.** Үзе караган сүздә белдерелгән эш-хәлнең, сыйфатның, микъдарның күләме кимрәк икәнне аңлата. *Бөтен Казанны диярлек әйләндем, ләкин армадым.* Р. Ишморат. [*Колхозда*] *ел саен диярлек бал бүлешмичә калганыбыз юк.* Ә. Еники.

7. *бәйл. функ.* **дигән.** 1) баш килештәге сүзне аерылмышка бәйләп, «исемле», «шулай дип атала торган» мәгънәсен белдерә.— *Иркутск дигән шәһәрдән бер кеше кайткан.* Т. Гыйззәт. *Авылыбызда Әхмәт дигән бер батыр егет бар.* Д. Аппакова. *Көт син мине, ил кызы, Җиңү дигән бакчада!* Ә. Юныс; 2) юн. килештәге исемне яки алмашлыкны аерылмышка бәйләп, «берәүгә хаслап аталган, багышланган», «берәр максат өчен билгеләнгән» мәгънәсен белдерә. *Кәрзин тулы — Әнкәйләргә дигән бүләгем.* Ш. Маннур.— *Ярлыларга дигән бер келәт икмәк бар әле анда.* М. Гали.

8. *бәйл. функ.* **дигәндә.** 1) «берәр нәрсә мәсьәләсендә, шуның буенча, шул яктан караганда» дигәнне белдерә. *Җыр дигәндә инде Газинурның капчыгы тишек түгел.* Г. Әпсәләмов.— *Хәйлә дигәндә төлкене көлкегә калдырырлык сәләтем бар.* Д. Аппакова. *Ис сизәргә дигәндә аннан да җәһәт кеше юк инде.* Ф. Хөсни; 2) «берәр нәрсә яки кеше өчен, шуның хакына» дигәнне белдерә. *Мәдрәсәнең бөтен яшь-җилкенчәге, барлык көрәшче демократиясе Җиһангир дигәндә үлеп тоталар.* Г. Ибраһимов. *Үзен һич айый белми торган, эш дигәндә беткәнче яна торган бер кеше иде ул.* Ә. Еники; 3) «күрсәтелгән срок килеп җиткәндә, тулып килгәндә», «шул вакыт эчендә» дигәнне белдерә. *Көн-төн карау аркасында, бер атна дигәндә минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды.* Г. Ибраһимов. *Алтынчымы, җиденчеме көн дигәндә, хат инде аның кулына килеп керә.* И. Гази; // «берәр эш-хәл булыр алдыннан гына, нәкъ шул вакытта» дигәнне белдерә. *Баскычка меним дигәндә, Рәхим Камилне күрә.* Һ. Такташ. *Менә җиргә бәрелеп бетә дигәндә генә, козгын тагын выж итеп өскә ыргыла.* Г. Әпсәләмов.

9. *бәйл. функ.* **дип.** 1) баш килештәге сүздән соң килеп, «өчен», «хакына» дигәнне белдерә. *Разия дип мин үләргә хәзер тордым.* И. Гази. *Нәрсә дип инде юк хыял артыннан чаба ул?* Г. Ибраһимов; 2) юн. килештәге сүздән соң килеп, «өчен», «шуңа атап» дигәнне белдерә.— *Сиңа дип аш калдырган идем.* Г. Камал. *Чылтырап аккан чишмәгә Суга дип килгән идем.* С. Хәким.

10. *терк. функ.* **дигән.** Баш җөмлә белән иярчен аергыч җөмләне терки. *Сөйгәне өчен корбан булудан яшь егет баш тартырмы дигән сүзне мин уйнап кына әйтмәдем.* М. Фәйзи. *Иртәгә мәктәпкә барам дигән кичне Габдулла шундый күңелсез уйлар белән басылып утырды.* Ә. Фәйзи.

11. *терк. функ.* **дигәндәй.** Мәкаль-әйтемнәрне, еш кабатлана торган тәгъбирләрне (сүзләрне яки җөмләләрне) сөйләмгә кертеп, ялгап җибәрү чарасы буларак кулланыла. *Юл кешесенең юлда булуы яхшы дигәндәй, эштә булуыбыз хәерлерәк.* А. Алиш. *Кышын, таң ата да кич була дигәндәй, көннең узганын сизми дә каласың.* М. Шабай. *Хәзер ичмасам, рәхәтләнеп эшлим дигәндәй, эшем дә бар, ашым да бар.* Р. Ишморат.

12. *терк. функ.* **дип.** 1) гадәттә кыек сөйләм формасындагы тәмамлык җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла.— *Сафиулла абый турында хәбәр бар дип ишеттек.* Т. Гыйззәт. *Шул егетне яратам дип әйт, Зөләйха, әнкәң.* Җыр. // Максат җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Разия ишетсен дип, юри кычкырып әйтәм.* И. Гази. // Сәбәп җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Соңга калдым дип, ашыга-ашыга киләм.* Ф. Бурнаш; 2) *гадәттә диалогта.* Әңгәмәдәшнең сүзләрен өлешчә яки тулысынча кабатлап төзелгән һәм кереш сүзтезмә яки җөмлә буларак кулланылган тәгъбир составында килеп, аны әйтеләчәк сүзгә ялгау чарасы булып тора. [*Гөлсем:*] *Син уңышны елдагыча һәйбәт алгансың.* [*Ярулла:*] *Һәйбәт дип, моржадан төтен чыгарсак, --- яңага җитеп егылсак, без шуңа риза инде.* Ф. Бурнаш. [*Басарый:*] *Каян килгән сезгә ул капчык?* [*Биктимер:*] *Каян дип, кем инде аларны хәтерли. Алар минем күптәнге капчыклар.* Т. Гыйззәт.

13. *кис. функ.* **ди.** Кайбер риторик сораулы җөмләләрдә инкяр итүне куәтли. *Укымыйча ничек белемле буласың ди?* Г. Мөхәммәтшин. // Ирония ле җөмләләрдә инкяр итүне куәтли. *Батучы, синең чишенгәнеңне көтеп, батмыйча тора ди.* А. Әхмәт.

14. *кис. функ.* **дигәч.** Кабатлап әйтелгән сүзләр арасында килеп, катгыйлык төсмере белдерә.— *Кайтмыйм дигәч кайтмыйм. Миңа монда да бик әйбәт.* Э. Касыймов.

15. *кис. функ.* **дисеңме.** *каб. форм.* Үзе караган сүзгә басым ясап, «да» мәгънәсен белдерә. *Җырга дисеңме, биюгә дисеңме,— барысына да оста ул.* Сөйләмнән. *Үз илебезнең төрле почмакларында дисеңме, төрле чит илләрдә дисеңме, аның* [*М. Горькийның*] *бик якын, кадерле дуслары азмыни?* Г. Иделле.

16. *көч. кис. функ.* **дисәң.** Кабатлап әйтелгән сүзләр арасында килеп, басым ясауны белдерә. *Менә кыз дисәң дә кыз, чәчрәп тора.* М. Фәйзи.

◇ **...дигән сүз** — кушма хәбәр составында килеп, нәтиҗә ясауны белдерә һәм «шуңа тиң», «шуның белән бердәй» дигән мәгънә аңлата. *Ленин юлы — халыклар дуслыгы дигән сүз.* М. Максуд.

ДИЮ II *и.* Бик зур, ямьсез, куркыныч гәүдәле, бер яки күп башлы, төрле кыяфәткә керә ала торган, мәкерле, кеше ашаучы итеп тасвирланган мифик зат. *Әй дулый мәлгунь Дию, әй тартыла! Акыра ямьсез каты — җир селкенә!* Г. Тукай.— *Ай, адәм заты, --- син бу тирәгә ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, дию патша кайтып керсә тотып ашар үзеңне.* Әкият.

Дию пәрие *к.* дию II. *Ул өч ай барганнан соң дию пәриенең шәһәренә барып җитә.* Әкият.

ДИҢ *аваз изл.* **1.** Вак металл әйберләргә бәргәндә яки алар бер-берсенә бәрелгәндә ишетелә торган һ. б. ш. югары тонлы (нечкә) яңгырау тавышларны белдерә. *Ишектә звонок шалтырады: диң-диң.* Ә. Маликов. *Диң-диң-диң-доң, диң-диң-диң-доң. --- Чиркәү чаңына уянып киттем.* Г. Гобәй.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Диң» сыман тавышлар чыгарып. *Сәгать җырлый «диң, диң»!* М. Җәлил.

ДИҢГЕЗ *и.* 1. Океанның коры җир белән теге яки бу дәрәҗәдә чолгап алынган бер өлеше — тозлы әчкелтем сулы зур мәйдан. *Кара диңгез. Урта диңгез. Балтик диңгезе.* // Зур ясалма сулык; зур су мәйданы. *Казан порты яннарында Чайкала диңгез.* М. Хөсәен. *Әнә тагын яңа диңгез туды, әнә тагын — Яңа бер шәһәр.* Х. Туфан.

2. *күч. гадәттә тартымлы форм.* Берәр нәрсәнең күп булуы, зур мәйдан алып торуы турында. *Гыйлем диңгезе. Кар диңгезе. Хисләр оңгезе.* □ *Чыгып киттек шуннан без болынга, Гизеп йөрдек чәчәк диңгезен.* М. Җәлил.

Диңгез авыруы — тирбәлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән авырулык халәте: күңел болгану, баш авырту һ. б. ш. **Диңгез арсланы** — колаклы тюленьнәр семьялыгыннан булган диңгез хайваны. **Диңгез йолдызы** — инәтирелеләр тибыннан булган умырткасыз диңгез хайваны (тәненең үзәгеннән як-якка чыгып торган очлыклары белән бераз йолдызны хәтерләтә). **Диңгез керпесе** — инәтирелеләр тибындагы умырткасыз диңгез хайваны (гәүдәсенең тышкы формасы белән керпене хәтерләтә). **Диңгез климаты** — температурасы кискен үзгәрми торган дымлы климат (диңгезгә якын тирәләр өчен хас); *киресе:* континенталь климат. **Диңгез козгыны** — зур гәүдәле, кара каурыйлы, кыска канатлы, каты озын койрыклы су кошы; бакланның бер төре. **Диңгез кәбестәсе** — ашауга һәм дару ясауга китә торган диңгез суусемнәренең бер төре. **Диңгез мәчесе** — кыйммәтле мехы булган, ишкәгаяклы, зур гәүдәле имезүче диңгез хайваны; *русчасы:* котик. **Диңгез филе** — ишкәгаяклылар отрядыннан булган имезүче су хайваннарының бер төре.

ДИҢГЕЗЧЕ *и.* Диңгез флотында хезмәт итүче. *Мин үзем дә диңгезче, алты ел Кара диңгез флотында хезмәт иттем.* Т. Гыйззәт.

ДИҢГЕЗЧЕЛЕК *и.* Диңгездә йөрү эше, һөнәре, осталыгы һәм сәнгате.

ДИҢКҮ *ф. диал.* Төрле борчулардан арып, фикерләү сәләте кимегән кебек булу (баш турында). *Бүген өенә кайтканда, аның [Габдулланың] башы, әллә ничек диңкеп, авыртырга тотынды.* Ә. Фәйзи.

ДИҢКАН *и.* Урта Азиядә: игенче. *Тимер юлга Гаҗәпләнеп торды диһканнар.* Ә. Ерикәй.

ДНЕВА'ЛЬНЫЙ *и.* Хәрби бүлектә тәртип саклау, торакны һәм милекне күзәтү һ. б. өчен бер тәүлеккә билгеләп куела торган солдат, дежурный ярдәмчесе. [*Газинурны*] *дневальный итеп билгеләделәр. Солдатлар яткач, ул, су сибеп, вагон идәнен әйбәтләп себереп чыкты.* Г. Әпсәләмов.

ДО *и.* Музыкаль авазлар системасында баштагы, беренче тон; шушы авазны белдерә торган нота.

ДОВЕ'РЕННЫЙ *и.* 1. *иск.* Берәүнең исеменнән эш йөртү өчен вәкаләте булган кеше; аның ышанычлысы. *Шәвәлиев бер байда доверенный булып эшли.* З. Бәшири. *Ул зур бер фирмада доверенный булып хезмәт итә.* Г. Газиз.

2. Верховный һәм җирле Советларга сайлау кампаниясе вакытында сайлаучыларны депутатлыкка кандидат белән таныштыру өчен хезмәт ияләре тарафыннан сайлап куела торган кеше. *Доверенный сайлау.*

ДОГА *и. дини.* 1. Дин тотучыларның аллага, изгеләргә ялварып, теләкләр теләп мөрәҗәгать итүе. [*Бабай*], *яман күздән, эт-бүредән ходай сакласын дип, догалар укый-укый, минем айгырымның муенына шул кызыл тасма белән кыңгырауны такты.* Г. Ибраһимов. *Ничек җитәр догаң күккә?* Г. Кандалый. // Аллага, изгеләргә мөрәҗәгать иткәндә әйтелә торган һәм сүзләре алдан билгеле булган текст; гыйбадәт сүзләре; доганың тексты. *Нинди дога язарга инде ул бөтигә?* И. Гази. *Намаз ниятләрен белсәң, кирәкле догаларны ятласаң, шул җиткән сезгә [кызларга], ди торган иде карт абыстай.* М. Гали.

2. Фатиха. *Дога бирү.* □ [*Мәрьям — кызына:*] *Безнең сүзне тыңла — ата-ана догасын ал.* Ф. Әмирхан. *Туганымны күрер булсаң, Дога диген ки безләрдән.* Г. Кандалый. *Сиңа миннән дога.* Г. Тукай.

ДОГАЛЫК *и.* 1. Дога тексты. [*Нурыйга*] *намазлар, догалыклар, аятьләр өйрәтәләр.* Г. Ибраһимов.

2. Догалар язылган кәгазь (китап һ. б. ш.); догалар җыентыгы. *Минем чәчәгемне бер гүзәл куплы ханымның догалыгы арасына салып куйдылар.* Ф. Әмирхан. [*Вахит*] *күкрәк кесәсенә тегеп куелган догалыкларны алып, күзләрен [күккә] терәп укый торган иде.* М. Гафури.

ДОГАЧЫ *и.* Мәрхүмгә багышлап дога кылучы яки кылырга тиешле кеше. *Эти дә бит мине үстергәндә: Догачы бул, улым, дия иде.* М. Крыймов. *Әхмәтҗан абзый картаеп, -- - теге дөньяга китте. Аның догачысы булып Сәхипҗамал әби [калды].* Ф. Хөсни.

ДО'ГМА *и. кит.* Барлык заманнар һәм тарихи шартлар өчен дә дөрес, үзгәрешсез дип танылырга, бәхәссез кабул ителергә тиешле караш, теория. *В. И. Ленин марксизм теориясен китапча, абстракт үзләштерүне чит күрде. Аның өчен марксизм догма түгел, бәлки һәрвакыт революцион хәрәкәттә җанлы кулланма иде.* КПСС тарихы.

ДО'ГМАЛАШТЫРУ *ф. кит.* Берәр теорияне, тәгълиматны, карашны догмага әйләндерү; аңа сукырларча ияру.

ДОГМАТ *и. кит.* Һич тәнкыйтьсез, сукырларча ышанып каралырга тиешле дини тәгълимат яки шуның бер кануны (югары дини инстанцияләр тарафыннан расланып, бәхәссез хакыйкать дип танылган нәрсә). *Католик чиркәү догматлары. Дөньяны алла яраткан дигән догмат. Кайбер догматларны диңчеләрнең үзләренең шик астына алуы.*

ДОГМАТИЗМ *и. кит.* Догмаларга таянып, мәгълүм нәтиҗәләргә һәм теорияләргә тәнкыйтьсез карап фикерләү ысулы. *Догматизм һәр эштә зыянлы.* Г. Әпсәләмов.

ДОГМА'ТИК I *и. кит.* Догмаларга таянып эш һәм фикер итүче. *Сектантлар һәм догматиклар, марксизм-ленинизмны тормыштан аерып, аңа хәреф ятлаучыларча карыйлар. Догматиклар марксизмның үсешен тоткарларга тырышалар, искергән --- формулаларны яклыйлар.* Соц. Тат.

ДОГМА'ТИК II *с. кит.* Догмаларга нигезләнгән, шулар белән сугарылган. *Догматик караш.*

ДОГОВО'Р *и. к.* килешү I.— *Ташчылар белән договор төзелде, --- иртәдән үк җир казу, фундамент салу эшләренә керешәбез.* Т. Гыйззәт. *Директор һаман да әле алдында яткан договорны күздән үткәреп бетерә алмаган.* М. Хәсәнов.

ДО'ЗА *и. махс.* Даруның бер тапкыр кабул итү өчен билгеләнгән микъдары. [*Зәһит*] *бер ярым доза йокы даруы эчеп урынына ятты.* А. Расих. // *күч.* Берәр нәрсәнең берникадәр микъдары. *Тәҗрибә өчен аерып алынган дуңгызларга ашатыла торган азыкка көн саен тиешле дозада биомицин кушып бирәләр.* Г. Галиев.

ДО'ЗАЛАУ *ф.* Дозаларга бүлү. *Даруны дозалау.*

ДОЗИМЕТР *и. физ.* Радиоактивлык дозасын яки радиоактив нурланыш тәэсиренең дозасын үлчәү коралы.

ДОЗИМЕ'ТРИЯ *и. физ.* Радиоактивлык дозасын яки радиоактив нурланыш тәэсиренең дозасын үлчәү.

ДОЗОР *и. хәрби.* 1. Саклык чаралары күрү һәм күзәтчелек, разведка эшләре алып бару өчен билгеләнгән кечкенә отряд (сугышчылар отряды, машиналар яки корабльләр төркеме). [*Разведкага барганда*] *өч төр-*

кемгә бүлендек. Алда — дүрт кешедән торган дозор, уртада — хәрәкәт итүче группа. Ә. Айдар. *Атлы дозор, чик буен яңа нарядка тапшырып, инде заставага таба [борылды].* К. Нәҗми. // *сөйл. к.* дозорчы. *Сугышчыларның күпчелеге йоклый. --- Бары тик часовойлар, алдагы дозорлар, секретлар гына төннәрне йокысыз үткәрәләр.* Г. Иделле.

2. *гадәттә кыек килешләрдә.* Саклык чараларын күрү һәм күзәтчелек, разведка алып бару эше. *Дозорга бару. Дозорда тору.* □ *Бу беренче тапкыр дозорга чыгуым иде әле. Мин бу дозорны изге бурыч итеп каршыладым. Дозорда очравы мөмкин булган хәлләрне күз алдыма китерергә тырыштым.* Г. Кашшаф.

ДОЗОРЧЫ *и.* Дозорда постта торучы.

ДОК *аваз ияр.* 1. Түбән тонлы тоник шакылдау-шапылдау тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Док»ны хәтерләткәч тавышлар чыгарып. *Комбайнер, күперчекнең такта идәненә агач аягы белән док-док басып, артка, баскыч төбенә килде.* Г. Гобәй.

3. *хәбәр функ.* «Док» сыман тавышлар чыгарган эшхәрәкәтне белдерә.

ДОК *и.* Портта суднолар ремонтлау корылмасы. *Йөзмә док. Коры док.* □ *Безнең пароход докта ремонтта тора.* С. Сабиров.

ДО'КЕР *и.* Англиядә һ. б. кайбер илләрдә: порт эшчесе. *Докерлар забастовкасы.* □ *Искә төшә Тулон докерлары.* Г. Хуҗиев.

ДОКЛАД *и.* 1. Берәр теманы киң яктыртып, җәмәгатьчелек алдында ясала торган хәбәр, белдерү. *Фәнни доклад.* □ *Клубта доклад һәм спектакль булачак.* М. Гали. *Доклад өчен Мостафа иптәшкә сүз бирелә, диде Шихрай.* Ш. Камал. // Шундый белдерү (доклад) өчен хәзерләнгән язма текст.

2. Җитәкчегә эш турында телдән яки язма рәвештә ясала (яки тапшырыла) торган рәсми белдерү, хәбәр итү. *Доклад белән керү.* □ [*Заһит — директорга:*] *Эшнең барышы турында мин сезгә доклад ясаган идем инде бүген.* Г. Иделле.

ДОКЛАДНОЙ *и. сөйл.* Доклад (2 мәгъ.) язылган рәсми кәгазь. *Мин штабка докладной язачакмын.* Г. Гобәй. [*Миргалинең*] *борау сорап язган яңа докладное Галкинны каты борчуга төшерде.* М. Хәсәнов.

ДОКЛАДЧЫ *и.* Доклад (1 мәгъ.) ясаучы кеше. *Докладчыга сүз бирү.* □ *Пленумда, докладчылар булсын, доклад буенча сүз алучылар булсын, барысы да ачык фактлар белән безнең әдәбиятның зур үсүгә ия булганын әйттеләр.* М. Җәлил.

ДО'КТОР *и.* 1. *сөйл.* Врач. *Докторлар егетнең чирен миеннән таптылар.* А. Расих.

2. Иң югары гыйльми дәрәҗә. // **Шул дәрәҗәне** алган кеше.

ДОКТОРАНТ *и.* Докторлык диссертациясе хәзерләү өчен фәнни учреждениегә беркетелгән галим.

ДОКТОРАНТУ'РА *и.* СССР Фәннәр академиясенең фәнни-тикшеренү институтлары каршында фән хезмәткәрләре (докторлар) хәзерләү системасы.

ДО'КТОРЛЫК *и.* 1. *сөйл.* Доктор (1 мәгъ.) һөнәре һәм вазифалары; врачлык. *Гөлшатыбыз докторлыкка укып бетерде.* Т. Гыйззәт.

2. Доктор (2 мәгъ.) дәрәҗәсе; фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗә.

ДОКТРИ'НА *и. кит.* Тәгълимат; фәнни яки философик теория; карашлар системасы. *Планнар төзи, ярыша, ашыга халык, Бәхетлерәк көнгә җитәргә, Тегеләрнең һәр доктринасын, Системасын җиңеп үтәргә.* Х. Туфан.

ДОКТРИНЁР *и. кит.* Тормыштан аерылган доктринага, догмага ябышып ятучы, шуның буенча эш һәм фикер итүче.

ДОКТРИНЁРЛЫК *и.* Доктринерга хас сыйфатлар һәм шуның хәле.

ДОКУМЕНТ *и.* 1. Берәр фактны раслый яки берәр нәрсәгә хокук бирә торган һ. б. ш. эш кәгазе. *Техник документлар.* □ *Сестра кереп кызның курорт документларын алып чыкты.* И. Гази.

2. Шәхесне раслый торган язма таныклык (паспорт; партия, комсомол, профсоюз билеты һ. б.). [*Гөлсем апа*] *Искәндәрне Маратның әтисе дип түгел, аның документы белән йөрүче, --- егетне үзенә дауларга килгән кеше дип белде.* Г. Гобәй.

3. Берәр вакыйганы чагылдырган һәм закон көченә ия булган, тарихи күрсәтмә характерындагы язма белдерү, хәбәр, акт һ. б. ш. *Партия съездының документлары.* □ *Безнең программабыз --- шундый документ булыр ки, шуның нигезендә эшчеләр: биредә безнең иптәшләр, безнең туганнар, биредә безнең уртак эшебез эшләнә, диярләр.* В. И. Ленин.

4. *кит.* Үткәндәге берәр вакыйга, борынгы берәр нәрсә турында таныклык, истәлек сыйфатындагы язу, рәсем, әдәби әсәр һ. б. ш. турында. *Истәлекле документлар.* □ *Күп илләрдә Муса Җәлил шигырьләрен --- шагыйрьнең якты идеаллар өчен ничек көрәшүен күрсәтә торган документ дип каршы алдылар.* М. Максуд. *Минкинның үткән йөзнең азакларында бастырып тараткан игъланы шактый кызыклы документ булып тора.* И. Рәмиев.

ДОКУМЕНТАЛЬ *с.* Документларга, фактларга нигезләнгән. *Документаль фильм. Документаль әсәр.* □ *«Газинур» — нигезендә, биографик, документаль роман. Анда күрсәтелгән төп образлар, вакыйгалар --- бар да реаль.* Г. Иделле. // Документ буенча гына, документларга таянып кына эшләнгән. *Документаль ревизия.*

ДОКУМЕНТА'ЦИЯ *и.* 1. *җый.* Документлар (1 мәгъ.). *Фәнни ачыш ясалганнан соң аңа документация хәзерләү.*

2. Документлаштыру эше һәм алымнары. *Документация эшен вакытында кайгырту.*

ДОКУМЕНТЛАШТЫРУ *ф.* Документлар (1 мәгъ.) белән нигезләү, раслау.

ДОКЫЛДАУ [докылдау] ф. «Док» авазларын хәтерләтеп яңгырау, тоник шакылдау, шапылдау.

ДО'ЛЛАР *и.* АКШта һ. б. кайбер илләрдә: акча берәмлеге.

ДОЛОМИТ *и.* Составында кальций һәм магнезия булган минерал (утка чыдам төзү материалы сыйфатында кулланыла).

ДОМИНАНТ *с. кит.* Доминанта сыйфатындагы; төп. *Доминант сүз.*

ДОМИНА'НТА *и. кит.* 1. Берәр нәрсәнең иң әһәмиятле өлеше, төп билгесе; төп идея.

2. *лингв.* Синонимнар рәтендә: төп берәмлек (стилистик яктан нейтральрәк һәм кулланыш ягыннан активрак сүз, тәгъбир һ. б. ш.). *Синоним сүзләрнең доминантасын билгеләү.*

ДОМИНИОН *и.* Британия империясе составына керә торган, эчке һәм тышкы политикасында аңа бәйле булган үзидарәле дәүләт (элекке колония).

ДОМИНО *и.* Өсләренә бөрчек-күзчек билгеләре төшерелгән озынча яссы 28 (берсе генә бөрчексез) шакмакчык белән уйнала торган өстәл уены. // Шул комплект шакмакчыкларының берсе.

ДОМИНОЧЫ *и.* Домино уйнаучы; шул уенны ратучы. *Доминочылар өстәле.*

ДОМКРАТ *и. тех.* Авыр нәрсәләрне бераз күтәртеп куя торган җайланма, винтлы механизм (гадәттә ремонт-монтаж эшләрендә кулланыла). *Ремонттагы машинаның күчәрен домкрат белән күтәртеп кую.*

ДО'МНА *и.* Тимер рудасыннан чуен коя торган махсус мич. *Бездә янган домналарның Бергә кушсак аккан чуенын, Кара диңгез өчен көндәш булыр.* Ф. Кәрим.

ДО'МНАЧЫ *и.* Домна эшчесе. *Домначылар тирән дулкынланып, Бер көч белән эшкә тотынды.* Ш. Маннур.

ДОНЖУАН *и. кит. шелт.* Мәхәббәт маҗараларын яратучы, хатын-кызлар артыннан күп йөрүче кеше. *Фәрит Әхмеровны мин күптән беләм. Күршем ул минем. Азгын да түгел, донжуан да түгел. Сез аңа яла якмагыз!* И. Нуруллин.

ДОНКИХОТ *и. кит.* Үз хыялында гына булган дошманнарга, киртәләргә каршы чыгып, тормыштан аерылган идеаллар хакына файдасызга көрәшеп йөрүче. [*Кадермәт:*] *Нәрсә без алдык та, нәрсә без бирдек, донкихотлар! Киләчәктә кешеләр көләрләр бездән яки акылсызга санарлар.* Н. Исәнбәт.

ДО'НОР *и.* Яралыларга яки авыруларга җибәрү өчен үзенең канын бирүче кеше.

ДОНОС *и. шелт.* Берәүне нәрсә өчен булса да гаепле санап, аның өстеннән власть вәкилләренә яки башлыкларга җиткерелгән яшертен хәбәр, әләк. *Донос ясау. Ялган донос.* ▭ *Хәзрәтнең доносы белән мәктәп ябылды, мөгаллим куылды.* Г. Ибраһимов. *Донос кем тарафыннан һәм кем өстеннән булса да,* [*түбәнлек*] *һәм кабахәтлек икәнен һичбер вакытта да онытырга ярамый.* Ф. Әмирхан.

ДОНОСЧЫ *и.* Донос ясаучы, язучы.

ДОП *аваз ияр.* Калын тавыш белән яңгыраган дәпелдәп куюны белдерә.

ДОПРИЗЫ'ВНИК *и. махс.* Хәрби хезмәткә чакырылу алдыннан хәрби өйрәнүләр үтүче.

ДОПРОС *и. сөйл.* **1.** Гаепләнүчедән, шаһиттан сорау алу (берәр эш, җинаять һ. б. ш. хакында). *Допрос алу.* ▭ *Инде кабат допросның кирәге дә юк: эш беткән, җинаятьче үз гаебен өстенә алган.* Г. Минский. *Плен алганнар. Аңыма килгәндә, аклар лазаретында идем. --- Әз генә яткырдылар да допроска алып киттеләр.* Г. Гобәй.

2. *күч. сөйл. шелт.* Таләпчән тон белән яки артык төпченеп сорашу.

ДОПЫЛДАУ *ф.* «Доп» сыман тавышлар чыгару. *Көлтә допылдаган, салам чытырдаган авазлар --- авылның ерак урамнарына кадәр китеп яңгырыйлар.* М. Гали.

ДОРФА *с.* Тупас (кеше, аның мөгамәләсе, кайбер сыйфатлары һ. б. ш. турында). *Дорфа үсмерләр. Дорфа кыланыш. Дорфа тавыш.* ▭ *— Әллә нинди дорфа сүзләр сөйлисең.* Н. Исәнбәт.

ДОРФАЛАНУ *ф.* Дорфалык күрсәтү. *Тәрбиясез үсмерләрнең җәмәгать урыннарында дорфаланулары.* // Дорфага әйләнү.

ДОРФАЛЫК *и.* Дорфа булу сыйфаты, тупаслык.

ДОСААФ *и. спорт.* Армиягә, авиациягә һәм флотка ирекле ярдәм итү җәмгыяте (*русча:* Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту).

ДОТ *и. хәрби.* Сугыш кырында озак оборонага исәпләнеп төзелгән корылма; таш, кирпеч, бетон, броня һ. б. кулланып эшләнгән һәм туплар, миномётлар, пулеметлар белән ныгытылган була (*русча:* долговременная огневая точка). *Артиллеристлар яндыргыч снарядлар белән фашистларны дзотлардан һәм дотлардан куып чыгардылар.* Каз. утл.

ДОТА'ЦИЯ *и. махс.* Планда каралган зыян-зарарны каплау өчен дәүләт-хуҗалык оешмаларына һәм учреждениеләргә, шулай ук материаль байлык җитештермәүче сфераның аерым оешмаларына (мәсәлән, театрга) җибәрелә торган бюджет ассигнованиесе. *Дәүләттән дотация алу. Дотация белән эшләүче театр. Фәнни тикшеренүләр өчен дотация сорау. Продукциясен планда каралган үзкыйммәтеннән түбәнрәк бәягә сатучы заводларның дотация соравы. Авыр промышленность үсешен тизләтү максаты белән дотация куллану.* ▭ *Дүрт совхозга тиешле дотацияне «Хезмәт» бергә йоткан.* Г. Ибраһимов.

ДОХА *и.* **1.** Эче-тышы мехлы тун. *Мөнәвәрә, кулларын җылы дохасы эченә яшереп, сүзсез калды.* Г. Ахунов.

2. *с. мәгъ.* Эче-тышы мехлы итеп эшләнгән (кышкы кием турында). *Доха тун.* ▭ [*Профессор*], *киң якалы, озын җиңле доха толыбын киеп, Иван Никитичның --- чанасына чыгып утырды.* М. Гали.

ДОХОД *и. сөйл.* Керем, табыш, төшем, килер. [*Бабайлар*] *җәй көннәрендә курыс төшереп, күмер яндырып, шулардан килгән доход белән тамак ялгый торган булганнар.* М. Әмир. *Колхоз киндерчелектән ел саен миллион сум чамасы доход ала.* Г. Галиев.

ДОХОДЛЫ *с. сөйл.* **1.** Доход китерә (бирә) торган; экономик яктан нык, бай, доходы күп булган. *Доходлы колхоз.*

2. Табышлы, төшемле, файдалы; керем-табыш чыганагы булган. *Доходлы һөнәр. Доходлы сезон.* ▭ *Бу эш,— куелып җиткәндә, бик доходлы, файдалы эш.* Ф. Әмирхан. *Алма — бик доходлы нәрсә.* И. Гази.

ДОХОДЛЫЛЫК *и.* Доходлы (2 мәгъ.) булу; төшемлелек. *Ясмык игүнең доходлылыгы.*

ДОЦЕНТ *и.* Югары уку йортында укытучының гыйльми исеме (профессордан түбән, ассистенттан югары). *Рәхим Заһитның үзләренә беренче тапкыр лекция укуын хәтерләде. Заһитка әле яңа гына доцент исеме бирелгән чак иде.* А. Расих. // Шул исемне алган кеше. *Хатын-кыз доцент.*

ДОЦЕНТЛЫК *и.* Доцент дәрәҗәсе. *Доцентлык алу.*

ДОШМАН *и.* **1.** Берәүне яратмаучы, күрә алмаучы, аңа нәфрәт хисе саклаучы; *киресе:* дус. *Сыйнфый дошман.* ▭ *Дошман күп дип курыкмыйбыз, Дошманнардан дуслар күп.* М. Гафури. *Дошман дустан ярала.* Мәкаль.

2. Сугышта: каршы як. *Разведчиклар дикъкать белән дошман ягын күзәтә башладылар.* А. Расих. *Сугыш беткән, дошман җиңелгән.* Ф. Бурнаш.

3. Берәр нәрсәгә каршы булучы, килешмәүчәнлек күрсәтүче кеше һ. б. *Мин үзем — сугыш дошманы.* Г. Кутуй. *Вәли бабай,— беләм, бик усал карт, Түбән сыйфат — аның дошманы.* М. Җәлил. // Зыян, зарар китерә торган нәрсә турында. *Телем — дошманым.* Мәкаль. *Дәһшәтле дошман — корылык Мәңгегә беткән булыр.* Ә. Исхак.

4. *с. мәгъ.* Дошман булган, дошманлык хисе саклаган. *Дошман сыйныфка каршы көрәш бетмәгән.* Г. Нигъмәти. *Без балага дошман кешеләрне Җинаятьче итеп карыйбыз.* Н. Баян. // Дошманлык хисләре белән сугарылган. *Дошман карашларга каршы кискен көрәш ачу--- тәнкыйть өстенә йөкләтелгән бурыч.* Г. Гали.

5. *рәв. мәгъ.* Дошман кебек, дошманнарча. *Кызның* [*безгә*] *карашында әллә нинди бер ултифатсызлык һәм хәтта бераз дошман тоту сымак нәрсә сизелә.* Ф. Әмирхан.

ДОШМАНЛАШУ *ф.* Бер-береңә дошман (1 мәгъ.) булып китү. [*Хәлил:*] *Син яратмыйсың дип, Зөһрә, мин иң якын иптәшләрем белән дошманлаша алмыйм инде.* Ш. Усманов.

ДОШМАНЛЫК *и.* Берәүне яратмауга, күралмауга нигезләнгән мөнәсәбәт. *Бай белән безнең эти арасында, ниндидер бер җир талашы сәбәбеннән, әллә кайчаннан бирле дошманлык бара иде.* Г. Ибраһимов.

ДОҢ *аваз ияр., гадәттә* «даң» *сүзе белән аралаш кулланыла.* **1.** «Дың»нан көчлерәк һәм ачыграк тавышларны белдерә. [*Заводта*] *төн буена Тимер ваклый чүкеч: Доң да доң!* М. Җәлил.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Доң»ны хәтерләткән тавышлар чыгарып.

ДОҢГЫЛДАУ *ф.* «Доң» авазларын хәтерләтеп, өзек-өзек яңгырау.

ДОҢГЫР *аваз изл., гадәттә* «даңгыр» *сүзе белән аралаш кулланыла.* 1. Дөбердәү-калтырау катнаш «доң» тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Доңгыр»ны хәтерләткән тавышлар чыгарып.

ДОҢГЫРДАУ *ф.* «Доңгыр» авазларын хәтерләтеп, өзек-өзек яңгырау. *Араны самолет шактый озак уздыр. Гәрәй --- тәгәрмәчләрнең доңгырдап җиргә тиюенә сискәнеп уянды.* А. Гыйләҗев. *Вагон колакларны тондырып доңгырдый иде.* А. Расих.

ДОҢГЫРДЫК *с.* 1. Доңгырдый торган.

2. Доңгырдатып селкетә торган (юл һ. б. ш. турында). *Доңгырдык юл. // и. мәгъ.* Юлдагы балчык түмгәкләр, вак кантарлар; шулардан торган тигезсез һәм каты җир. *Доңгырдыктан бару.*

ДОҢГЫРТ *аваз изл.* Кискен доңгырдап куюны белдерә.

ДОҢК *аваз изл., сир.* Шапылдап, кискен доңгылдап куюны белдерә. *Барабан һаман тынмый: Доңк! Доңк! Доңк!* Ш. Маннур.

ДРАГОМАН *и.* Европа дәүләтләренең Көнчыгыштагы илчелекләрендә яки консуллыкларында эшләүче тәрҗемәче, тылмач. [*Жандарм*] *Мөбарәкшаны, «патшага турылыклы хезмәте өчен», Көнчыгыштагы берәр илгә консул тылмачы — драгоман итеп билгеләргә вәгъдә бирә.* К. Нәҗми.

ДРАГУН *и.* Патша армиясендә һәм кайбер чит ил гаскәрләрендә: махсус кавалериядә хезмәт итүче (башта бу частьлар җәяүле строй белән дә хәрәкәт итәргә тиеш булган). *Гриша кече яшьтән патша гаскәренең драгун полкында тәрбияләнеп үскән.* Ш. Усманов.

ДРА'МА *и.* 1. Әдәби әсәрнең бер төре: диалог формасында төзелгән сәхнә әсәре. *Һәрбер хикәя, роман, драма тибындагы --- әсәр гадәттә нинди дә булса вакыйга яки вакыйгалар турында сөйли.* Г. Нигъмәти.

2. Шундый төрдәге, ләкин комедиядән һәм трагедиядән аермалы буларак, җитди эчтәлекле әсәр. *Трагедия дә, комедия дә, драма да безгә хезмәт итәргә тиеш.* М. Җәлил.

3. *күч. кит.* Авыр рухи газапка дучар итә торган, кайгылы вакыйга; газаплы кичерешләр. *Тормыш драмасы.* ▭ *Азмы кешенең башыннан һәртөрле драмалар үтә! Биргәк дә мондый* [*сугыш*] *вакытта.* Г. Бәширов.

ДРА'МАЛАШТЫРУ *ф. кит.* 1. Драмага (1 мәгъ.), сәхнә әсәренә әйләндерү. *М. Гафуриның «Кара йөзләр» повестен драмалаштыру.*

2. Драмага (3 мәгъ.) әйләндерү; киеренке, борчулы хәл китереп чыгару.

ДРАМАТИЗМ *и.* 1. Драма (2 мәгъ.) әсәренә хас булган киеренкелек. [*Поэмада*] *вакыйгаларны сурәтләүдә драматизм бик көчле.* М. Максуд.

2. *күч. кит.* Кайгылы, газаплы кичерешләр; драматик (2 мәгъ.) хәл. *Кирәмәтнең йөрәгендәге авыр яраларны уйлап моңайган күренешләрендә көчле драматизм, моңсулык, тирән аһәң яңгырый.* М. Җәлил. *Г. Кутуйның тормышы драматизм белән тулы.* Г. Кашшаф.

ДРАМА'ТИК *с.* 1. Драма (1, 2 мәгъ.) формасындагы, сәхнә өчен язылган. *Драматик әсәр. Драматик образ. //* Драмага (1, 2 мәгъ.) бәйләнешле, шуңа мөнәсәбәтле; драмага хас. *Драматик роль башкару.* ▭ *«Беренче чәчәкләр» драмасында хәрәкәт тудыручы, аны алга әйдәүче төп драматик конфликт нәрсәдә соң?* Г. Гали.

2. *күч. кит.* Газаплы кичерешләр белән бәйләнгән яки шуңа китерә торган. *Драматик вакыйга. Драматик көрәш. Драматик хәл.* ▭ — *Җиһангәрәй белән Хөббениса арасында булган драматик мәхәббәткә багышлап бәетләр чыгардым.* Т. Гыйззәт.

ДРАМАТУРГ *и.* Сәхнә әсәрләре иҗат итүче, язучы. *Оста драматург.* ▭ *«Бәхетсез егет» белән «Өч бәдбәхет» драматик эшләнеш ягыннан югары тормыйлар, алар яшь драматургның беренче тәҗрибәсе генә.* М. Гали.

ДРАМАТУ'РГИК *с.* Драматургиягә бәйләнешле, шуңа мөнәсәбәтле. *Язучының драматургик эшчәнлеге. Спектакльнең драматургик эшләнеше. Драматургик алымнар. Драматургик осталык.* ▭ [*Шәриф Камал*] *башлыча эшчеләр темасын яктыртуны максат итеп алды һәм аның драматургик көче дә шушы темада чагылды.* Г. Кашшаф.

ДРАМАТУРГИ'Я *и.* 1. Драма (1 мәгъ.) язу сәнгате; сәхнә әсәрләре иҗат итү теориясе. *Драматургия белән театр арасында бик тыгыз бәйләнеш тудырырга кирәк.* М. Җәлил.

2. *җый.* Сәхнә әсәрләре. *Татар драматургиясенең беренче классик әсәрләрен ул* [*Г. Камал*] *бирде.* М. Гали. *Совет драматургиясе соңгы елларда зур уңышларга иреште. Бу уңышларның иң күренеклесе һәм әһәмиятлесе итеп рус драматургиясендә бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин образының чагылуын күрсәтергә кирәк.* М. Җәлил.

ДРАМАТУ'РГЛЫК *и.* Драматург һөнәре. *Г. Камалның хезмәте драматурглык белән генә чикләнми, ул башка әдәби жанрларда да яза.* М. Гали.

ДРА'МАЧЫ *и. иск.* Драматург.

ДРАМТҮГӘРӘК *и.* Драма (1 мәгъ.) түгәрәге. [*Ибрайның*] *сәхнә белән мавыкканын сизеп алып, драмтүгәрәккә тарталар.* Г. Гобәй.

ДРАНЧА *и.* 1. Штукатура астына кадаклый торган озын юка планкалар яки шуларның берсе. // Түбә ябуга һ. б. ш. китә торган юка, махсус агач тактачыклар яки шуларның берсе. *Гөлбакча эргәсендә түбәсе дранча белән ябылган матур нарат өй бар иде.* М. Әмир.

2. *с. мәгъ.* Дранча рәвешендәге. *Дранча такта. //* Дранчадан торган, дранчадан эшләнгән; дранча белән ябылган. *Дранча түбә.* ▭ *Өй түбәсе дранча, Дранчасын җил ача.* Г. Тукай.

ДРАНЧАЛАУ *ф.* Дранчага әйләндерү, дранча итеп телү, яру (агачны).

ДРАП *и.* 1. Өске киемлеккә китә торган калын һәм тыгыз йон тукыма. *Ул бостон кебек кыйммәтле материяне, пальтолык яхшы драпны--- сагалап кына йөри.* Э. Еники.

2. *с. мәгъ.* Драптан (1 мәгъ.) булган. *Пальтога драп тышлык сатып алу. //* Драптан (1 мәгъ.) тегелгән, тышлыгына драп куелган. [*Мөрсәлим*] *каракүл якалы драп пальтодан.* Г. Галиев.

ДРА'ХМА *и.* Грециянең акча берәмлеге.

ДРЕДНО'УТ *и.* Зур броненосец, хәзерге линкорның элгәрге төре.

ДРЕЗИ'НА *и.* Тимер юлда якын араларга кеше яки йөк ташу өчен хезмәт итә торган транспорт машинасы (элегрәк кул көче белән дә йөртелгән). *Тимер юл ремонтлаучыларның дрезина белән йөрүе.*

ДРЕЙФ *и. махс.* Бозның, корабның һ. б. ш. нәрсәнең җил яки агым тәэсирендәге хәрәкәте, ирексез агуы. *Зарарланган корабның дрейфка ятуы.*

ДРЕНАЖ *и.* 1. Махсус каналлар, торбалар системасы һ. б. ш. ярдәмендә сазлы җирләрне, туфракны киптерү эше, чаралары. *Туфрак дренажы. //* Корылмаларны, аларның фундаментларын су үтеп керүдән, дымланудан саклау чаралары һәм системасы. *Фундамент дренажы. Горизонталь һәм вертикаль дренаж.*

2. *мед.* Шештәге, тәндәге үлекне, сыекчаны махсус көпшә яки марля тасмасы ярдәмендә агызып-суырып чыгару эше һәм чаралары.

ДРЕНАЖЛАУ *ф.* Дренаж юлы белән эшкәртү. *Авыл хуҗалыгы җирләрен дренажлау.*

ДРУЖИ'НА *и.* 1. Борынгы рус князьләренең гаскәре. *Князь дружинасы.*

2. Берәр максат белән төзелгән ирекле берләшмә, отряд. *Пионер дружинасы. Янгынчылар дружинасы. Район дружина штабы.* □ [*Буржуйларның*] *янауларына җавап итеп, бистә эшчеләре кораллы дружиналарга язылдылар.* Қ. Нәҗми.

ДРУЖИ'НАЧЫ *и.* Дружина члены. *Җәмәгать урынларында тәртипне күзәтүче дружиначылар.* □ *Түбәләрдә, урам чатларында курку белмәс ПВХО дружиначылары шәһәрне ут-күздән саклый* [*фронт шәһәрендә*]. Г. Гобәй.

ДУ *аваз иярт.* 1. Гадәттә сузынкырак «ду-у-у» сыман тавышны, калын гүләүне белдерә (җил исүе, уен кораллары тавышы һ. б. турында).

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Ду» сыман тавышлар чыгарып. *Автомобиль гудогын ду-ду кычкыртып тору.*

3. *хәб. функ.* «Ду» сыман тавышлар чыгара торган эшне-хәрәкәтне белдерә. *Фәрит дан-доң барабан кага, ә мин быргыда ду-ду...* Э. Қасыймов.

◇ **Ду итү** — 1) *к.* дуылдау 1. *Ярканат поскан урынныннан чыгып бер ду итеп очып ала, ай калкуга тагын чормага кереп югала.* Н. Исәнбәт; 2) *к.* ду килү 1. *Сиңа әле өйләнеп, яңадан ду итеп, яшәгән кадәр яшәргә кирәк.* Э. Қамал. *Шауладык без, шуу! иттек, кузгалдык без, дуу иттек.* Г. Тукай. **Ду килү (кубу, күтәрү, күчерү, тузу** һ. б.) — 1) көчле шау-гөр күтәрү, шау-шулы хәрәкәтләр ясау, ыгы-зыгы куптару һ. б. *Өстәлләрне читкә этеп куйганнар да ду килеп биешеп яталар* [*яшьләр*]. Г. Сабитов. *Морза йорты ду купты. Бибкәй бит качкан икән.* Ш. Маннур. *Бөтен колхоз ду күтәреп бәйрәмгә хәзерләнә.* Г. Галиев. *Кешеләрдә кайгы, өметсезлек күренми. Уйнап-көлеп, чыр-чу килеп, ду күчерәләр.* Ш. Қамал; 2) *к.* дулау 3. *Әле генә, эшсез утырабыз дип ду килә идең, инде эш биргәч тә ярамады.* Г. Ахунов.— *Петербургта ирек биреп Манифест чыккан, янәсе, Бездән яшереп тотасыз дип, Ду күчәләр һәммәсе* [*крестьяннар*]. Т. Гыйззәт.

ДУАДАҚ *с. диал.* 1. Бала чыгармаган, ялгыз (кошкорт турында). *Мәймунә түтәй өендә, дуадак каз кебек, берүзе генә була.* Э. Қасыймов.

2. Буйдак (ир кеше турында). *Ул заманда дуадак булып йөргән Гарифлар да хәзер биш җанга җир чәчәләр инде.* Г. Толымбай.

ДУАЛИЗМ *и. филос.* Дөньяның нигезендә бер-берсенә бәйсез ике башлангыч (материя һәм рух) ята дип раслый торган идеалистик философик тәгълимат; *киресе:* монизм.

ДУАЛИСТ *и.* Дуализм тарафдары.

ДУАЛИ'СТИК *с.* Дуализмга мөнәсәбәтле, дуализмга нигезләнгән. *Дуалистик философия. Дөньяга дуалистик караш.*

ДУАМАЛ *с.* 1. Уйлап җиткермичә, ашыгып һәм тупас эш итүчән; артык кызу канлы; тотрыксыз холыклы. *Ул яшьрәк чакта мәгәр зерә дә усал, зерә дә дуамал кеше иде.* Г. Насрый. *Бик дуамал ул* [*Андрей*]. *Ачуланса, акны-караны күрми.* А. Шамов.

2. Үз-үзеңә хисап биреп бетермичә, тупас эшләнгән; артык тәвәккәл (эш, хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Бу минутта ул* [*малай*] *теләсә кемнең кулын тешләргә, күзен тырнарга, акыл сыйдырмаслык әллә нинди кыргый, дуамал адым ясарга хәзер иде.* Қ. Нәҗми. *Әнисенең дуамал сүзләрен тыңлап утырырга Борһанның да түземе җитмәде.* С. Рафиков. // *рәв. мәгъ.* Қинәт һәм кискен, тупас рәвештә; ахырын уйлап тормыйча, үз-үзеңә хисап биреп бетермичә. [*Бәкер — кызларга:*] *Жибәрегез әле, болай уңайсыз. Сез бигрәк дуамал ябыштыгыз.* М. Фәйзи.

3. *рәв. мәгъ. диал.* Чиктән тыш, гадәттән тыш (берәр сыйфат турында). *Әле генә дуамал тере, тапкыр сүзле һәм гамьсез күренгән Булатов та, --- ничектер, сыгылып төште.* Ш. Маннур. *Дуамал каты эшлиләр иде алар.* Э. Қасыймов.

ДУАМАЛГА *рәв.* Дуамаллык белән; тиктомалга, сәбәпсез. *Без дуамалга тавыш чыгарып сөйләнүебез белән зур ялгышлык иттек.* Г. Қамал. *Бер дә юкка, дуамалга кыйнады да китте.* Ш. Усманов.

ДУАМАЛЛАНУ *ф.* Дуамал рәвештә эш итү, артык кызу канлылану, холыксызлану, дулау. *Үзенең бу тойгысын ул бервакытта да тышка чыгармады, дуамалланмады, үзен дә, ирен дә кимсетерлек шау-шу күтәрмәде.* Г. Әпсәләмов. *Көйсез табигатьнең я бик саранланып, я бик дуамалланып бирә торган яңгырлары* [*да була*]. М. Әмир.

ДУАМАЛЛЫҚ *и.* Дуамал кешегә хас сыйфатлар; акылсыз тәвәккәллек; акылсызлык, башсызлык. *Эх дуамаллык, эх ахмаклык, ди ул* [*Нургали*] *ачынып һәм үзенең бала вакытта артык шуклыгы, ваемсызлыгы аркасында биш классны бетерер-бетермәс укуны ташлавын искә төшерә.* Ә. Еники.

ДУБЛЁР *и.* 1. Бер үк эшне параллель рәвештә үтәүче. *Андриян һәм аның дублеры, скафандрлар киеп, старт мәйданына юл тоттылар.* Қ. Латыйпов.

2. Төп артистның алмашчысы. *Спектакльдә дублер булып катнашу.*

ДУБЛЕТ *и. кит.* Берәр әйбернең икенче данәсе; бер төрдәге ике нәрсәнең берсе. *Китерелгән мисаллар татар телендәге җанлы сүзләрнең коры дублетлары гына булып, телебезгә яңа бер мәгънә өстәмиләр.* Ш. Рамазанов.

ДУБЛИҚАТ *и.* Төп нөсхә белән тигез хокукта булган икенче экземпляр, тигез хокуклы күчермә (төрле документ турында).

ДУБЛЯЖ *и.* 1. Тавышлы кинофильмның, вакытлы матбугат басмасының һ. б. ш. сүзләрен икенче телгә тәрҗемә итеп чыгару эше.

2. Шул рәвешчә эшләнгән хезмәт (кинофильм, вакытлы басма һ. б. ш.). *Қинофильм дубляжы.*

ДУГА *и.* 1. Ат җигү әйбере: тәртәне камытка беркетү өчен ике очы ике як камыт бавына кертелә торган, ярым әйләнә рәвешендә агачтан бөгеп ясалган җиһаз. *Дуга бөгү. Қыңгыраулы дуга.* □ *Бер агайның аты дулаган да дугасы сынган.* Г. Бәширов.

2. Дуга сыман бөгелгән һәр нәрсә. *Электр дугасы.* □ *Қайчак трамвай дугасыннан кабынган яшькелт чаткының яктысы, палатага кереп, шәрә стеналарда тибрәнеп ала.* Г. Әпсәләмов.

3. *мат.* Әйләнәнең яки кәкре сызыкның нинди дә булса ике нокта арасындагы өлеше.

4. *с. мәгъ.* Дугага охшатып бөгелгән. *Дуга биллеяр.* □ [*Ат*] *киң күкрәкле, дуга муенлы.* Н. Баян.

ДУГАЙЛАНУ *ф. к.* дугалану. *Елганың дугайлануы. Юлның урман кырыеннан дугайланып үтүе.* □ *Нечкә булып сузылган су җепләре гөлләр өстенә югартын әйләнеп, дугайланып килеп төшәләр.* Г. Бәширов.

ДУГАЙЛЫ *с.* Дугайланган, бормалы. *Дугайлы-дугайлы елга үзәннәре. Дугайлы тырма теше.* □ *Олы юлдан камыл ярып киң басу эченә кереп киткән дугайлы юллар күргәнегез бармы?* Р. Төхфәтуллин.

ДУГАЛАНУ *ф.* Ярым әйләнә рәвешен алу; дугага охшап бөгелеп килү. *Инешнең дугаланып эчкә кереп торуы.* □ *Қызның гажәпләнүдән кашлары дугаланды.* Ялкын.

ДУГАЛЫҚ *и.* 1. Дуга бөгү өчен билгеләнгән яки шуңа яраклы материал. *Урманнан дугалык эзләү.* □ — *Пешекләргә куйган дугалыкларым бар иде.* Т. Гыйззәт.

2. *с. мәгъ.* Дуга бөгү өчен дигән, шуңа яраклы. *Дугалык агач.*

ДУГАЧЫ *и.* Дуга бөгүче, шул эшнең остасы; дуга белән сату-кәсеп итүче.

ДУЕН I *и.* Агым суның төбендәге яки яры буендагы утырма. *Ярчыкланып калды тирән эзләр Катып яткан соры дуенда.* Ш. Мөдәррис. // *диал.* Юшкын.

ДУЕН II *и. диал. гадәттә* **дуены** *форм.; күбесенчә* «уен» *сүзеннән соң яки шуңа каршы куеп кулланыла.* Берәр эшнең, тамашаның иң кызган чагы, өлеше; эшнең-бурычның иң хәтәр, иң авыр өлеше һ. б. ш. *Мәҗлескә кичегеп, аның дуенына өлгерми калу. Уен кебек кенә җиңел эштән соң дуены булу.*

ДУКАТ *и.* Элек кайбер Көнбатыш Европа илләрендә: көмеш яки (соңыннан) алтын акча.

ДУЛАТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* дулау.

2. *сөйл. к.* дуылдату 2. *Менә шулай итеп безнең эти хәзер дулатып сельсоветта эшләп ята.* Г. Лотфи.

ДУЛАУ *ф.* **1.** Бик зур көч белән һәм тоник гүләү авазлары чыгарып хәрәкәт итү (табигать көчләре һ. б. ш. турында). *Тышта җил, буран дөньяның астын өскә китерерлек булып кузгалган, дулый.* Ш. Камал. *Самоварның өстәл өстендә дулап утыруын яратам.* К. Нәҗми. *Көчле җил... Диңгез дулый.* М. Максуд.

2. Буйсынмый башлап, чыгымлау (хайваннар турында). *Шәвәлигә бүре очрый да аты дулап китә.* С. Рафиков.

3. Ачулану, ризасызлык кебек хисләрне үтә шаушулы төстә (талашып яки сугышып) белдерү; холыксызлану. [*Мансур Рәхимгә:*] *Җитешсез якларыңны тәнкыйть итсәләр — дулыйсың, зур белгеч, янәсе заводның тоткасы.* Р. Ишморат. *Шәрәфи хәзер баягы шикелле дуламый, һәрбер сүзен инсаф белән юаш кына сөйли иде.* К. Нәҗми. // Бик нык тәртипсезләнеп, талашып йөрү. [*Солтан*] *кичә исереп дулаган Әхмәтҗанны очратты.* А. Расих.

ДУЛКЫН *и.* **1.** Җил тәэсиреннән тирбәнү нәтиҗәсендә су өстендә барлыкка килә торган озынча калкучыкларның берсе. *Җил көчәйгән саен дулкын арта.* Ф. Кәрим. // *күч.* Гомумән, тигез өлектә барлыкка килгән дулкын сыман нәрсә. *Арыш басуы буйлап яшел дулкыннар чапты.* И. Гази.

2. Физик мохиттәге тирбәнешле хәрәкәт. *Һава дулкыны. Рәшә дулкыны. Электромагнитик дулкыннар.* □ *Көчле шартлау дулкыны аны* [*түбәдә сакта торучыны*] *җиргә бәреп төшергән.* Т. Гыйззәт.

3. Бер-бер артлы хәрәкәт итүче ишле төркемнәр һ. б. ш. турында. // Ишле халык төркеменең үтә җанлы, шау-шулы һәм ыгы-зыгылы хәрәкәте турында. *Мәктәптә ул* [*Солтан*] *балалар дулкынын ерып, озын коридор буйлап укытучылар бүлмәсенә узды.* Г. Кутуй.

4. *күч.* Иҗтимагый тормыштагы, хәрәкәттәге көчле гомуми күтәрелеш, талпыныш һ. б. ш. күренешләр турында. *Социалистик ярыш дулкыны. Стачкалар дулкыны.* □ *Дүрт еллык революция дулкыннары халыкның күз алдыннан шаулап үтте.* Г. Ибраһимов.

5. *күч.* Хисләр ташкыны. *Шатлык дулкыны.* □ *Ачу, нәфрәт дулкынының көче астында тыела алмый каласың.* Ф. Кәрим.

6. *с. мәгъ. сир.* Дулкынлы, дулкынланып тора торган. *Әле дә күз алдымда дулкын чәчең.* Ш. Маннур.

ДУЛКЫНЛАНДЫРГЫЧ *с.* Дулкынлану (2 мәгъ.) тудыра, хисләргә нык тәэсир итә торган. *Дулкынландыргыч китап. Дулкынландыргыч минутлар.* □ *Моның кебек гади, табигый, шул ук вакытта ихлас күңелдән барган җылы, дулкынландыргыч җыелышны мин үзем хәтерләмим.* Ә. Еники.

ДУЛКЫНЛАНУ *ф.* **1.** Дулкын (1, 2 мәгъ.) барлыкка китереп хәрәкәтләнү, тирбәнү. *Җил улый, сызгыра, диңгез һаман дулкынлана, дулый бара иде.* Ш. Камал. *Өлгереп килгән игеннәр әкрен генә дулкынлана.* Г. Әпсәләмов. // **дулкынланып.** Дулкын сыман булып. [*Кызның*] *чәч толымы Дулкынланып төшә иңенә.* М. Җәлил.

2. *күч.* Төрле эчке кичерешләрдән, көчле хисләрдән нервлар киеренкеләнү, нык борчылу. *Әсәрне укып дулкынлану.* □ *Җырны тирән бер ләззәт һәм дулкынлану белән җырлыйм.* З. Бәширн. *Муса ачуланган иде. Ачуыннан күзләре акайган, йөзе ут шикелле яна, дулкынлануыннан сүзен әйтә алмый иде.* Ш. Камал.

3. Ризасызлык хисләре белдерү. *Фронт дулкынлана башлады.* М. Гафури. *Ачу белән җыелыш дулкынланды.* Н. Баян.

ДУЛКЫНЛЫ *с.* **1.** Дулкынланып торган. *Дулкынлы хәрәкәт.* □ *Уенчык кебек ат ул. --- Киң күкрәк, дулкынлы ял, кабарып торган кыска куе койрык.* Г. Кашшаф.

2. Дулкын хәрәкәте, дулкын сызыгы рәвешендәге, шуңа охшаган. *Дулкынлы сызык. Дулкынлы ком барханнары.*

3. *күч.* Көчле кичерешләр белән сугарылган (сүз, жыр, халәт һ. б. ш. турында). *Дулкынлы музыка. Дулкынлы җыр.* □ *Без аны* [*абыйны*] *дулкынлы сабырсызлык белән көтеп алдык.* З. Бәширн.

ДУ'МА *и. тар.* Патша Россиясендә һәм Мәскәү Русенда: идарә учреждениеләрнең исеме. *Дәүләт думасы* (1905—07 еллардагы революция барышында төзелгән вәкиллекле, формаль яктан закон чыгару функцияләре булган учреждение). *Шәһәр думасы* (патша Россиясендә сайлап куела торган шәһәр идарәсе органы). *Бояр думасы* (Мәскәү Русенда боярлар советы). □ *Думага сайлау көннәре алдында бөтен Россия бер төрле сабырсызлык белән сайлау нәтиҗәсен көтә.* Ф. Әмирхан. // Дума урнашкан бина. *Шәһәр думасының ишекләре киңенчә ачык, кешеләр кырмыска шикелле кайнаша.* Ш. Камал.

ДУ'МАЧЫ *и. тар.* Дума члены. *Думачы трудовиклар һәммәсе берәм-берәм эре буржуазиянең сафына күчәләр.* Г. Ибраһимов.

ДУМБРА *и.* Казахларда: чирттереп уйнала торган ике кыллы, өчпочмак яки ярымтүгәрәк формасындагы корпусы халык уен коралы. [*Егет*], *думбрасының кылларын бераз рәтләгәннән соң, күзләрен югарыга күтәрә төшеп, думбра чиртә башлады.* М. Гафури.

ДУМБРАЧЫ *и.* Думбра уйнаучы, шул һөнәрнең остасы. *Кызны үз иркенә куйсаң, думбрачыга барыр ди.* Н. Исәнбәт.

ДУС *и.* **1.** Берәүгә дуслык мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән кеше; якын иптәш. *Аңа дуслары да, дус булмыйча коры таныш булган кешеләре дә үзләренең сер дип уйлаган нәрсәләрен сөйлиләр.* Ф. Әмирхан. *Әйт дусыңны — әйтермен кемлегеңне.* Мәкаль. // *күч.* Якын күргән, яраткан нәрсә яки шул нәрсәне яратучы үзе. *Гармун бит ул — минем иске дустым.* М. Крыймов. *Шундый егет безнең Мәлик — Бакчалар, гөлләр дусы.* Ш. Маннур. // Теләктәшлек итүче кеше, тарафдар, яклаучы. *Миллионнарча минем дусларым Дан эше дип таныш хезмәтне.* М. Җәлил. *Безнең дуслар — һәркайда! — Барлык илләрдә дә алар көннән-көн арта баралар!* Э. Исхак. // *с. мәгъ.* Дуслык мөнәсәбәте белән бәйләнгән, якын иптәш булган. *Дус егет. Дус коллектив.* □ *Дус халыклар семьясында, башкалар белән кулга кул тотынып коммунизм төзибез.* Ф. Хөсни. // *күч. кушма хәбәр составында.* Берәр нәрсә белән (артык) мавыгучы, аны яратучы. *Габдулла әфәнде табигать белән бик дус түгел.* Г. Ибраһимов. *Без яз белән дус.* М. Максуд. // *рәв. мәгъ.* Дуслар кебек, дусларча. *Халыклар дус яшәргә тиешләр.* Г. Әпсәләмов.

2. Мөрәҗәгать сүзе (гадәттә, якын күргән, теләктәш-фикердәш булган кешеләргә юнәлтелә). *Алга кара! Алда, дуслар, Коммунизм язы инде яктыра.* К. Нәҗми. *Бик яхшы, бик яхшы, дустым. Температурагыз төшә.* А. Шамов. *Уйна, дустым, гармуныңны, Син*

матур уйнатасың. Җыр / аныклагыч функ. Эндәш сүзләрдән соң кулланыла. *Җырла берне, Вәли дус!* Н. Баян.

◊ **Дус кеше — мөрәҗәгать сүзе.—** ***Син дә, дус*** *кеше, бик үк бушлардан түгел — механик ич.* А. Әхмәт.

ДУС-ИШ *җый. и.* Дуслар, якын танышлар. *Күңел күтәренке, тик кайбер дус-ишләрнең үзебезнең янда булмавы гына җанны борчый.* И. Гази. *Дус-иш барда ирләр хур булмас.* Җыр. // *с. мәгъ.* Дус-ишләрдән, якын танышлардан булган. *Дус-иш малайлардан уздырмый идем уздыруын, шулай да бер кыздырырлык кына тота идем* [*балыкны*]. Э. Касыймов.

ДУСЛАНУ *ф. к.* дуслашу. *Сәгъди әфәнде белән дусландым.* Ф. Әмирхан.

ДУСЛА'РЧА *рәв.* Дус кебек; дуслык хисе белән. *Разин миңа дусларча бик җылы хат язган иде.* М. Җәлил. *Камил дусларча аның* [*Зөһрәнең*] *кулын кыса.* Һ. Такташ. // *с. мәгъ.* Дусларга хас булган. *Дусларча мөгамәлә. Дусларча ярдәм.*

ДУСЛАШУ *ф.* Берәр кеше, берәр җәмгыять һ. б. ш. белән дуслык мөнәсәбәте урнаштыру, дус булып китү. *Гөлфая кемнәр белән дуслашуын бездән бервакытта да яшермәде.* Г. Әпсәләмов. Ике колхоз, елдан-ел дуслаша барып, берсен-берсе алга әйдиләр. Г. Бәширов. // *күч.* Берәр нәрсә белән (артык) мавыгып китү, аны ярата башлау. *Спорт белән дуслашу. Китап белән дуслашу.*

ДУСЛЫК *и.* Ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгына, үзара рухи якынлык, бер-береңне ихтирам итү һ. б. ш. хисләргә нигезләнгән мөнәсәбәт. *Халыклар дуслыгы. Иҗади дуслык.* □ *Бу ике балыкчының бер-берсенә ияләшүләре соңгы бер-ике елда зур дуслыкка әйләнде.* Г. Минский. [*Хәйдәр:*] *Әйт әле, дуслык нәрсә, синеңчә?* [*Наилә:*] *Минемчә, кешеләр арасындагы иң якты, иң югары хис ул. Дуслар бер-берсе өчен бөтен нәрсәне эшләргә тиешләр.* Р. Ишморат. //*күч.* Берәр нәрсә белән (артык) мавыгу, аны ярату хисе. *Нургали абыйның китап белән дуслыгы сизелми.* Ә. Еники. *Кече яшемнән мәчет белән дуслыгым булмады.* Ф. Хөсни.

ДУСТ *и.* Зарарлы бөҗәкләрне бетерү өчен кулланыла торган агулы порошок. *Гексахлоран дусты.*

ДУСТАНӘ *рәв. кит. иск.* Дусларча. *Әхмәт дустанә бер йомшаклык белән сүз башлады.* Ф. Әмирхан.

ДУТАР *и.* Таҗик, төркмән, үзбәк һәм кытайларда: чирттереп уйнала торган, ике кыллы, груша сыман корпуслы халык уен коралы. *Паласта үзбәк музыкантлары һәртөрле дутар, тамбур, саз, думбра шикелле --- музыка кораллары тотып утыралар.* Н. Исәнбәт.

ДУТАРЧЫ *и.* Дутар уйнаучы, шул һөнәрнең остасы.

ДУХО'ВКА *и.* Плитә эчендә: ашамлыклар куеп пешерә торган, тимер тартма сыман бүлем. *Газ духовкасы.*

ДУЧАР: дучар булу — тару, юлыгу, туры килү (авыр хәлгә). *Бәхетсезлеккә дучар булу.* □ *Ил ачуына дучар булган кеше — үлемгә дучар булган кеше ул.* Р. Ишморат. — *Арсланбайның сөргенгә дучар булуын хаксыз күрәбез.* Г. Ибраһимов.

ДУЧМАК *и.* Түгәрәкләп җәйгән камыр өстенә изгән бәрәңге, әремчек һ. б. нәрсә ягып пешерелгән таба ашы. *Орлык дучмагы. Ачы дучмак.* □ *Без суыктан туңып кайтып керүгә, ниндидер бәхеткә каршы, --- әнинең самовары кайнап тора һәм бәрәңге дучмагы мичтән чыгып кына килә иде.* Ш. Маннур.

ДУШ *и.* 1. Суны басым белән бөркеп сиптерә торган коену-юыну җайланмасы, аппараты. *Җәйлеккә душны бакчага урнаштыру. Душны салкын һәм кайнар су тигез килә торган итеп ачу. Ванна бүлмәсендәге душны ремонтлау.* // Шундый җайланма урнашкан бүлмә. *Душ бикле чакка туры килү.*

2. Юыну-коену өчен душтан (1 мәгъ.) бөркелеп-сиптереп агызыла торган су. *Салкын душ астында коеныл рәхәтләндем.* Г. Минский. // Душта юыну-коену; шул гигиеник ихтыяҗны үтәү процессы. *Душтан соң тән җиңелләп китү. Җәй көне салкын душны ярату.*

ДУЫЛДАТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к* дуылдау.

2. *күч.* Берәр эшне үтә өлгер һәм җитез башкару.

ДУЫЛДАУ *ф.* 1. «У-у-у» сыманрак тавыш чыгару, калын тавыш белән гүләү (табигать көчләре һ. б. ш. турында). *Җилнең дуылдап исүе. Буран дуылдау. Гудок дуылдавы.* // Шундый тавыш тәэсире белән яңгырау, шаулау. *Урманнар, тыкрык башлары көчле музыка астында дуылдыйлар.* Л. Гумеров. // Гомумән, каты *шаулау. Ярларын кимереп, дуылдап аккан* [*су елга*]. Қ. Нәҗми.

2. Үтә җанланып, шау-шу килеп эш-хәрәкәт итү. [*Кошлар ярканатка:*] *Ни өчен хайваннар җиңгәндә, без җиңдек! дип, алар арасында дуылдап йөрдең?* Н. Исәнбәт. // Ачулану, ризасызлык кебек хисләрне үтә шаушулы төстә (әрләшеп-талашып яки сугышып) белдерү; дулау, холыксызлану. *Ялганлап ышандыра алмассыз безне --- дип дуылдап, әхмәтнең китаплар бүлмәсенә кереп китте* [*Фәтхулла хәзрәт*]. Ф. Әмирхан.

ДУЫЛДЫК *с.* Дуылдый (2 мәгъ.) торган; тиз кызып китүчән. *Дуылдык кеше.*

ДУЭЛЬ *и. кит.* Дворян-буржуаз җәмгыятьтә: дошманлашкан ике кешенең, мәгълүм кагыйдәләр буенча, корал кулланып сугышуы. *Дуэльгә чакыру.* □ *Патша хөкүмәте --- Пушкинны, Лермонтовларны дуэльдә аттырып үтергән.* С. Баттал. // *күч. кит.* Каршы, дошман якларның каты көрәше, тартышы, сугышы. *Безнекеләр алар пароходына ата, аларныкы — безнекенә. Менә шул дуэль була инде.* И. Гази.

ДУЭТ *и. махс.* 1. Ике башкаручыдан (җырчылар яки музыкантлардан) торган ансамбль.

2. Ике корал яки ике тавыш өчен язылып, аларның һәр икесе тарафыннан мөстәкыйль (ләкин бер үк вакытта) башкарыла торган әсәр.

ДУҢГЫЗ *и.* 1. Партояклылар семьялыгыннан, кыл белән капланган чагыштырмача зур гәүдәле, кыска аяклы, имезүче хайван (ите, мае һәм кылы өчен асрала). *Дуңгыз асрау. Дуңгыз ите.*

2. *күч. гади. с.* Үзен шапшак, пычрак йөртүче, җыйнаксыз кеше турында. // Культура-рухи ихтыяҗлары түбән булган кеше турында. // *тирг.* Әдәпсез, әшәке һ. б. ш. кеше турында.

ДУҢГЫЗЛАНУ *ф. гади с.* Әдәпсез, әшәке, түбән кешегә әйләнү яки әдәпсезлек, әшәкелек күрсәтү.

ДУҢГЫЗЛЫК *и. гади с.* Үзен шапшак йөртүче, җыйнаксыз кешегә хас сыйфатлар. // Әдәпсез, әшәке, түбән җанлы кешегә хас сыйфатлар. *Бу егет үзенең русча грамотасы аркасында совет аппаратында икмәк ашады. Ләкин һаман да үзенең дуңгызлыгын итте.* И. Гази.

ДУҢГЫЗЧЫ *и.* Дуңгыз асрап, дуңгыз белән сәүдә итүче. [*Сәлахетдин*] *киптерергә дип тезеп куйган ипи сыныкларын түбәдән сыпырып төшерә дә дуңгызчы Гаврилга илтеп сата.* Г. Гобәй.

ДУҢГЫЗЧЫЛЫК *и.* Авыл хуҗалыгының дуңгыз асраучылык белән шөгыльләнә торган тармагы. *Дуңгызчылык бригадасы.* □ *— Бәрәңге булмаса, дуңгызчылык белән шөгыльләнеп булыр идеме соң?* А. Расих.

ДЫҚ *аваз изәр.* 1. Авыр нәрсәнең шапылдап орынубәрелүе вакытында ишетелгән тонык тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Дык» сыман тавышлар чыгарып. *Ул, күн итек өстеннән резин галош киеп, Тобол урамнарындагы такта тротуардан дык-дык басып кына окружкомга килә.* Ш. Маннур.

ДЫҚЫЛДАУ *ф.* «Дык» авазларын хәтерләтеп шапылдау, шакылдау.

ДЫМ *и.* Әйбернең составында бераз гына булган яки аңа сеңгән су, сыекча; юешлек. *Һавадан әле төн дымы да китеп бетмәгән.* Ф. Хөсни. *Талгын җил урам арасына күл исен, яңгыр дымын алып килә иде.* Г. Мөхәммәтшин.

◇ **Дым каплау** *махс.*— дымын саклап калу өчен туфракны эшкәртү. **Дым тарту** — 1) *к.* дымлану 1. *Салкын стенаның дым тартуы.* □ *Салам дым тартканы.* А. Расих; 2) җиңелчә тирләү. *Атның дым тартуы.*

ДЫМЛАНУ *ф.* **1.** Дым сеңү (әйберләр, һава һ. б. турында); җиңелчә чылану, юешләнү. *Патроннар җирдә күмелеп ята-ята дымланган иделәр.* Г. Гобәй. *Кич кырын дымланырга өлгергән яфраклар --- кыштырдамыйлар иде инде.* М. Хәсәнов.

2. *күч.* Җиңелчә яшь белән каплану, яшь белән юешләнү (күз турында). *Айсылу дулкынланудан дымланган күзләрен* [*сөртте*]. Г. Бәширов.

ДЫМЛЫ *с.* **1.** Дымланган, җиңелчә чыланган, юешләнгән. *Дымлы җил. Тузанны дымлы чүпрәк белән сөртеп алу. Кар базының дымлы стеналары.*

2. *күч.* Бераз яшьләнгән (күз турында). *Сәйфулла абзыйның дымлы күзләрендә шатлык балкый.* С. Сабиров.

ДЫМЛЫЛЫК *и.* Дымлы булу сыйфаты һәм хәле; сеңгән дым микъдары. *Орлыкның дымлылыгын тикшерү. Һаваның дымлылыгы.* □ *Урман куера барган саен, һавасы да үзгәрә, дымлылык арта.* М. Хәсәнов.

ДЫМСУ I *с.* **1.** Бераз дымлы; җиңелчә дымланган. *Дымсу һава. Дымсу чүпрәк.* □ *Җир дымсу. Ул аяк баскан урында аз гына иңеп керә.* Г. Бәширов. *Акрын гына дымсу җилләр исте.* С. Урайский.

2. *күч. сир.* Бераз яшьләнгән (күз турында). *Ул Гәүһәриянең дымсу күзләренә тутырып карады.* А. Гыйләҗев.

ДЫМСУ II *ф. сир. к.* дымсулану. *Су китереп ташлаган чыбык-чабыклар аша дымсыган урман эченә кереп киттеләр алар.* А. Расих.

ДЫМСУЛАНУ *ф.* Җиңелчә генә дымлану, бераз дымлыга әйләнү. *Чык төшеп яфракларның дымсулануы. Тоз дымсулану.*

ДЫМЫГУ *ф.* Дымсулану, җиңелчә генә дымлану. *Мылтык атылмаган: --- әллә дары дымыккан, әллә пистон бозылган, әллә чакма чакмаган.* Ш. Маннур.

ДЫМЫК *с.* Бик әз генә дымлы; сизелер-сизелмәс кенә дымланган. *Дымык чүпрәк.* // Тыныч, җилсез, салынкы һәм дымлы (һава, көн һ. б. ш. турында). *Туман бераздан вак яңгырга әйләнеп ява да башлады. Мондый дымык, пычрак көндә печән турында уйларга да ярамый иде.* А. Гыйләҗев. *Алар диңгезнең дымлы һәм дымык һавасын рәхәтләнеп суладылар.* И. Туктаров.

ДЫМЫКЛАНУ *ф.* Дымык булып китү, дымыкка әйләнү. *Төн буенча буран уйнаганнан соң, җил басылган, көн дымыкланып, тынычланып калган.* Ф. Хөсни.

ДЫР *аваз изл.* **1.** Берәр нәрсәнең кызу әйләнеп, бөтерелеп яки калтырап торуын яисә шунда ишетелгән калтыраулы тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ.* «Дыр»ны хәтерләткән авазлар чыгарып. *Тирә-ягындагы нәрсәләр чуарланып, туктаусыз дыр-дыр селкенгән кебек күренделәр* [*Актырнакка*]. М. Гафури.

-ДЫР [-дер, -тыр, -тер] *кис.* **1.** Үзе ялгана торган кайбер сүзләргә чамалау, фаразлау төсмере өсти. *Пароход һәрвакыт юлда. Күрмәгән-белмәгән кешегә анда эшләүчеләрнең тормышы күңелсездер, бер төрледер, гел юлда булу ялыктырадыр; алар --- берни күрмиләрдер, белмиләрдер шикелле.* С. Сабиров.

2. Сорау сүзләре кулланылган яки сораулы интонациягә корылган контекстларда үзе ялгана торган сүзгә билгесезлек төсмере бирә. *Нинди уеннар башлап ташлаганбыздыр, анысын ачык хәтерләмим.* Г. Ибраһимов. *Орлов (төргәкне кулына алып үлчәп карый): Яхшы, салмак кына нәрсә, эчендә нинди байлыклар бардыр инде.* Ф. Кәрим.

3. Сорау алмашлыкларыннан билгесезлек алмашлыклары ясый, мәсәлән: **кемдер, нәрсәдер, ниндидер, кайсыдыр, кайдадыр, кайчандыр, ничектер** һ. б.

4. *сөйл.* Көчле хис белдергән җөмләнең алда килгән баш кисәгенә ялганып, көчәйтү, берәр сыйфатны ассызымлау төсмерен белдерә. *Хәлим ниндидер таш бина каршына килеп җитте. Үзедер зур, үзедер биек.* И. Гази. // Ант итеп сөйләгәндә, сүзне куәтләү өчен кулланыла. *Кайберәүләр, фәлән икән, төгән икән дип кенә түгел, үзләре ишетеп торган кешеләрдәй, чындыр, ихластыр менә дип, тәмам ышандырып сөйлилләр.* М. Шабай.— *Төпкә абынмаган булсам, кояштыр, куып җитә идем* [*кыр күркәсен*]. А. Гыйләҗев.

5. Санаганда кулланылган исемнәргә ялганып, «кебек нәрсәләр» дигән мәгънә белдерә. *Келәтнең бөтен почмаклары ондыр, ярмадыр, борчактыр тутырып куйган капчыклар белән тулган.* Ә. Фәйзи.

6. *и. мәгъ., сөйл.* **дыр, дер.** Нигезсез, дәлилсез мәгълүмат-хәбәр; имеш-мимеш. *Бу гайбәтнең «дер»е бик тиз кисеп ташланды.* Г. Гобәй. *Дыр-мырга ышанмыйлар шул аны.* А. Әхмәт.

ДЫРҚЫЛДАУ *ф.* **1.** «Дырык» сыман тавышлар чыгару, шундый авазлар белән шапылдау-шакылдау.

2. Сикертмәле юлда арбага, машинага һ. б. ш. утырып барганда: каты селкенү. *Һәр буразнаны эчәк-бавырың белән тоеп, басу башындагы җыйгыч комбайнга кадәр шактый дыркылдап үтәргә кирәк* [*машинада баручыга*]. Р. Төхфәтуллин.

ДЫРЛАУ *ф. к.* дырылдау 1.

ДЫРТ *аваз изл.* **1.** Кинәт ишетелгән «дырт» сыман авазларны һәм кискен дырлап-дырылдап куюны белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Дырт» сыман авазлар чыгарып.

ДЫРЫК *аваз изл.* **1.** Дөбердәүле тонык шапылдау тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Дырык» сыман тавышлар чыгарып. *Арбада дырык-дырык селкенеп бару.* □ [*Гармунны остарып җитми уйнаганда*] *бармаклар да шома гына йөрми, телдән телгә дырык-дырык сикерә.* Ш. Маннур.

ДЫРЫЛДАВЫК *с.* **1.** Дырлый, дырылдый торган. *Хәзерге яшьләр өчен дырылдавык торбалы фордзон тракторлары түгел, алтмыш ат көчле чылбырлы тракторлар да гади бер нәрсәгә әйләнде.* Г. Ахунов.

2. Дырылдата торган; дөбердәүле калтырау-селкенү барлыкка китерә торган. *Дырылдавык юл.*

ДЫРЫЛДАУ *ф.* **1.** «Дыр» сыман тавышлар чыгарып шаулау-калтырау. *Трактор дырылдавы.* □ *Туң җир өстендә арба тәгәрмәче дырылдый.* Ф. Хөсни.

2. Дырылдавык, каты юлда (арбага һ. б. ш. нәрсәгә) утырып барганда селкенү. *Буш арбада дырылдый-дырылдый авылга кайтабыз.* Фәтхи-Балыкчы.

ДЫҢ *аваз изл.* **1.** Тоныграк яңгыраган «доң» тавышларын белдерә. *Алачыктан тавыш ерактан ук ишетелде.— Дың-дың-дың!* Каз. утл. // Башның сулкылдап авыртуын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Дың» сыман тавышлар чыгарып. *Аяк асты катырган иде, барабан тавышына дың-дың басабыз.* Э. Касыймов. *Кызым пианинода дың-дың бәреп Бетховенны уйный.* М. Мәһдиев. // Сулкылдап (баш шаулау турында). *Баш дың-дың шаулау.*

3. *хәб. функ.* «Дың» сыман тавышлар чыгарган эшне-хәрәкәтне, шулай ук башның сулкылдап авыртуын белдерә. *Җитмәсә, чиркәве чәнчелде: бертуктамый*

диң-диң-доң!.. Дың-дың-дың! Г. Гобәй. [*Тимерче*] *көнозын туктаусыз дың да дың...* Каз. утл.

ДЫҢГЫЛДАУ *ф.* «Дың» авазларын хәтерләтеп, өзек-өзек яңгырау. [*Чиркәү кыңгыраулары*] *котырынып дыңгылдыйлар, чаңгылдыйлар.* К. Тинчурин.

ДЫҢГЫР *аваз изл.* 1. Дөбердәү-калтырау катнаш «дың» тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ., каб. форм.* «Дыңгыр» сыман тавышлар чыгарып. *Чаналарына икешәр буш тимер мичкә салган олаучылар дыңгыр-дыңгыр юыртып узалар.* Э. Еники.

ДЫҢГЫРДАВЫК *с.* 1. Дыңгырдый торган. [*Нигъмәтҗан*] *төтеннән карайган дыңгырдавык чиләкле озын арбада ишле семьясы белән бергә утырып бара.* К. Нәҗми.

2. Дыңгырдатып селкетә торган (юл һ. б. ш. турында). *Мансур механизмны машинага салганда да, дыңгырдавык юлдан сикерә-сикерә машина кузовында барганда да шул турыда уйланды.* А. Расих.

3. *и. мәгъ.* Дыңгырдый яки дыңгырдата торган нәрсә; дыңгырдык (3 мәгъ.) *Юлдагы дыңгырдавыкларга сөртенү.*

ДЫҢГЫРДАВЫКЛЫ *с.* Дыңгырдатып селкетә торган, дыңгырдык. *Дыңгырдавыклы юл.*

ДЫҢГЫРДАУ *ф.* «Дыңгыр» авазларын чыгарып яңгырау. [*Чиләк*] *йөктән дыңгырдап төште.* Ф. Хөсни. *Тигезсез урам ташлары өстендә дыңгырдаган арба тавышлары ишетелә башлады.* М. Әмир. *Күршедәге мәҗлес кызганнан-кыза барды. Биергә дә керештеләр, ахрысы. --- Тәрәзә пыялалары җиңелчә генә дыңгырдап куйгалый иде.* М. Хәсәнов. // Дыңгырдык юлда (арбага һ. б. ш. нәрсәгә) утырып барганда селкенү. *Юлларның рәте китте микән? Казылмалардан дыңгырдап кайтып җиткәнче кич булыр.* Г. Ахунов. *Муса шундый сәер һәм ачы уйлар белән олау арбасында дыңгырдап барды.* Ш. Маннур.

ДЫҢГЫРДЫК *с.* 1. Дыңгырдый торган. *Ике тәгәрмәчле дыңгырдык арбаларны сөйрәп, пошкыра-пошкыра атлар чаптылар.* К. Нәҗми.

2. Дыңгырдатып селкетә торган (юл һ. б. ш. турында). *Дыңгырдык юл.*

3. *и. мәгъ.* Юлдагы, аяк астындагы каткан балчык түмгәкләр, вак кантарлар, шулардан торган тигезсез һәм каты җир. *Дыңгырдыктан бару. Дыңгырдыкны әйләнеп үтү.*

ДЫҢГЫРТ *аваз изл.* Кискен дыңгырдап куюны белдерә.

ДЫҢГЫЧЛАУ *ф.* Төя-төя тыгызлау (төрле капларга, савытларга сыек булмаган нәрсәләрне тутырганда һ. б.). *Капчыкны дыңгычлап тутыру.* □ *Силослау өчен, яшел массаны тураклыйлар да чокырга салып дыңгычлыйлар.* А. Расих.

ДЫҢЛАУ *ф.* «Дың» авазларын чыгарып яңгырау; тонык чыңлау.

ДЬЯК *и.* Борынгы Русьта: XIV йөзгә кадәр — князьнең язу-сызу, секретарьлык эшләрен алып баручы; XIV—XVII йөзләрдә — дәүләт учреждениесендә җаваплы урыннарда эшләүче хезмәткәр, түрә.

ДЬЯ'КОН *и.* Православие чиркәвендә: иң түбән рухани дәрәҗә.

ДЬЯЧОК Православие чиркәвендә: руханига ярдәм итүче хезмәтче.

ДЮ'ЖИНА *и.* Унике данәгә тигез булган санау, хисаплау берәмлеге. *Ике дүжина шырпы.* □ — *Әфәнде, миңа бер ярты дүжина ак яка кирәк иде.* Г. Камал.

ДЮЙМ *и.* Футның $^1/_{12}$ өлешенә яки 2,54 сантиметрга тигез озынлык үлчәве берәмлеге.

ДЮ'НА *и.* Җил китереп өйгән күчмә ком калкулыгы. *Ком дюналары. Материк дюналары. Диңгез дюналары. Елга дюналары.*

ДЮРАЛЬ, ДЮРАЛЮМИ'НИЙ *и.* 1. Ныклыгын арттыру өчен бакыр, магний һ. б. элементлар кушып коелган алюминий.

2. *с. мәгъ.* Дюральдән эшләнгән, ясалган. *Теплоходның дюраль корпусы. Дюраль торба. Дюраль чыбык.*

ДӘ *кис. к. да.*

ДӘВА *и.* 1. Дару. *Тәрәзә төбендә дәва шешәләре күренә.* Ш. Камал. [*Врач*] *нервларны тынычландырырга дәва бирде.* М. Фәйзи. // Гомумән, дарулану, дәваланы чарасы. *Шаһбаз көлә.— Сиңа, Гали, ди, байлар авыруы йоккан... Моның бердәнбер дәвасы: һәр көн ун сәгать эшләү, катыга ятып йоклау, арыш икмәге белән бәрәңгедән башканы ашамау, ди.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Төрле бәхетсезлекләрне кичерергә, күңелсезлекләрне онытырга ярдәм итә торган һ. б. ш. чара турында. *Дәрткә дәва табу.* □ *Доктор тапмый, аптек сатмый Сагынганга дәваны.* Җыр. *Аның моңлы да, шатлыклы да тавышы күпләргә көч бирде, күпләрнең* [*сугыш чорындагы*] *сынык күңелләрен төзәтте, дәва булды.* Э. Касыймов.

ДӘВАЛАУ *ф.* 1. Чирне, дарулар һ. б. ш. ярдәмендә бетерү чаралары күрү. *Ревматизмны дәвалау. Үпкә чирен дәвалау. Ютәлне кайнар сөт эчеп дәвалау.*

2. Чирле кешене яки авырткан җирне, махсус режимга куеп, шифалы шартларга-мохиткә күчереп, кирәк очракта дарулар да кулланып савыктыру чаралары күрү. *Күзне дәвалау. Рентген нурлары белән дәвалау.* □ [*Үпкә авыруы белән курортта ятучы шагыйрь:*] *Мине элекке тормыш черетте, хәзер Совет хөкүмәте дәвалый.* М. Гафури. *Бу кечкенә курорт Әлмәттән әллә ни ерак түгел. Шөгер тирәсендә генә. Анда ләм белән дәвалыйлар.* Ю. Әминов.

3. *күч.* Күңелсезлекне һ. б. ш. борчуны җиңел кичерергә, аннан арынырга ярдәм итү. *Хатыным, үзе дә белмичә, --- мине үзенең табигате, холкы, мөгамәләсе белән дәвалады.* Г. Ибраһимов. *Социал-демократлар үзләренең партиясен туры һәм кыю тәнкыйть белән дәвалый беләләр.* В. И. Ленин.

ДӘВАЛЫ *с.* Савыгуга ярдәм итә, дәвалый торган; шифалы. *Дәвалы климат. Дәвалы үләннәр.*

ДӘВАМ *и.* 1. *күбесенчә тартымлы форм.* Пространстводагы, җирдәге яки берәр өлектәге нәрсәнең нинди дә булса бер чиктән узып арырак сузылган өлеше, кисәге, очы. *Әрәмәнең елга аръягындагы дәвамы. Трамвай юлының дәвамын салу. Юлның дәвамы урманга кергәч сукмакка әйләнү.* // Эш-хәлнең, әсәрнең һ. б. ш. нәрсәнең бүленеп өзелеп торганнан соңгы өлеше, кисәге. *Журналда басыла торган романның дәвамын уку. Берничә серияле киноның дәвамын көтү. Колониаль режимның икенче формадагы дәвамы. Мәҗлеснең тәнәфестән соңгы дәвамы. Элекке дәрестә узыла башлаган теманың дәвамын аңлату. Бәхәснең дәвамын икенче вакытка калдыру.* □ *Ленинизм — марксизмның дәвамы һәм иҗади үсеше ул.* КПСС тарихы.

2. *к.* дәвамчы. [*Шагыйрь:*] *Яңа буыннарның башы да мин, Үткән буыннарга дәвам да.* Каз. утл. *Өзелмәде ләкин безнең юл: Төркем-төркем дәвамнар килә.* Х. Туфан.

3. *бәйл. функ.* **дәвамында.** Вакытны белдергән сүзләрдән соң: **«шул вакыт эчендә»** дигәнне аңлата. *Бер-ике минут дәвамында ул бүлмә эченнән күз йөртеп чыкты.* Э. Еники. // Эш-хәлне, хәрәкәтне белдергән сүздән соң: «шуның барышында, шул процесс вакытында» дигәнне аңлата. *Җыелыш дәвамында кузгатылган мәсьәләләр.* □ *Сугыш дәвамында дүрт мәртәбә яраланган ул.* А. Расих. *Куплетлар җыр дәвамында үзләреннән-үзләре туа бардылар.* Г. Әпсәләмов.

Дәвам итү — 1) арырак сузылу, тагын да булу (пространство, җир, андагы нәрсәләр турында). *Тролейбус маршрутының бистәгә тикле дәвам итүе.* // Тә-

мамланмый-бетми тору, һаман бару, сузылу (эш-хәл, хәрәкәт, халәт, уйлар һ. б. ш. турында). *Журналның яңа исем белән дәвам итүе.* □ *Сүзләр бер өзелеп, бер ялганып дәвам итте.* Ф. Әмирхан. *Синең гомер, Ильич, дәвам итә, Илтә-илтә безне җиңешкә.* Х. Туфан. *Тормыш юлы нинди матур булып Дәвам итә бездә кешенең.* С. Хәким. // Вакытны белдергән сүзләрдән соң: шул вакыт эчендә булу, узу (эш-хәл, хәрәкәт, халәт, уйлар һ. б. ш. турында). *Җыелышның бер сәгать дәвам итүе.* □ *Бу киеренке минутлар озак дәвам итмәде.* Г. Минский. *Безнең сәяхәт бары ике көн дәвам итте.* Ә. Еники. // Урын-вакыт килешендәге сүздән соң: шул эштә-хәлдә калу, булу, шуны өзми-туктатмый алып бару. *Сөләйман сөйләвендә дәвам итә.* Һ. Такташ. *Киләчәккә күкрәп баруында Дәвам итсен безнең туган ил!* Ш. Маннур; 2) эшне-хәрәкәтне: туктатмау, бетермәү. *Уенны дәвам итү. Сәяхәтне дәвам итү. Мәҗлесне дәвам итү. Элгәрләрнең эшен дәвам итү.* □ *Син кинәт кына ярсыныр Юлыңны дәвам иттең.* Ә. Ерикәй. [*Галия:*] *Хатымны дәвам итәм.* Г. Кутуй. *Урдәк һаман туктамаган Хуҗасын эзләүне һаман дәвам иткән.* А. Алиш. // Бетерми саклап бару. *Традицияләрне дәвам итү.*

ДӘВАМЛЫ *с.* Дәвам итә торган; бер тапкыр булу белән генә бетми-тукталмый, озаккарак сузыла торган. *Дәвамлы авыру. Дәвамлы очыш. Дәвамлы күренеш.* □ [*Табигатьнең*] ***матурлыгы сизелми дә*** [*егеткә*]. *Чөнки дәвамлы эш табып булмый, тормыш авыр, шуның өстенә полиция эзәрлекли.* Г. Садрый.

ДӘВАМЧАН *с. кит.* Эзлеклелек саклап дәвам итә торган. *Дәвамчан тышкы политика. Дәвамчан эзлеклелек.*

ДӘВАМЧАНЛЫК *и. кит.* Дәвамчан булу хәле, күренеше. *Традицияләрнең дәвамчанлыгы. Житәкчелектә дәвамчанлык саклау. Дәреслекләр төзүдәге дәвамчанлык.*

ДӘВАМЧЫ *и. кит.* Берәр эшчәнлек өлкәсендәге элгәрләр юлыннан барып, аларның эшен дәвам итүче; рухи варис.

ДӘВАЧЫ *и. иск.* Дәвалаучы. *Син — минем дәвачым.* Ф. Халиди.

ДӘВЕР I *и.* Чор; заман. *Узган дәвер.* □ *Безнең җырда дәверебезнең бөек төзелешләре яңгырасын!* Н. Баян. // Вакыт. *Фронт редакциясендә эшләү дәверендә мин йөзләрчә татар егетләре белән очраштым.* Г. Насрый. // *сир.* Берәр процессның үсешендәге бер баскыч, стадия. *Комиссиягә кердем... Үпкә туберкулезының икенче дәвере...* М. Фәйзи.

ДӘВЕР II *и. иск. дини.* Үлгән кешенең гөнаһларын кичерү йоласы: бер варис тарафыннан бирелгән сәдаканың кире «бүләк ителеп», фидияне бирүче белән алучы арасында шулай кат-кат (мәрхүмнең 12 яшьтән соң яшәгән еллары санынча) әйләнеп йөрүе. *Муллаларның дәвере исемә төште.* Г. Тукай. *Һәрбер казакъ, «дәвердән калмасын» дип, үзенең мулласын дәвергә кертергә эзләп йөгерде.* Г. Ибраһимов. *Мәрхүмнең васыяте гүр сәдакасына ике бәрәнле бер сарык, дәвере өчен тышлы яңа туны иде, диде* [*мулла*]. А. Шамов.

ДӘВЕРЧЕ *и. иск. дини.* Дәвер (II) йоласын башкаручы. *Мәетнең сул ягы буйлап, ишектән түргәчә ике рәт булып, дин әһеле — дәверчеләр, фидиячеләр сафланганнар.* Г. Ибраһимов.

ДӘВӘЮ *ф. диал.* 1. Зураю. [*Тәслимәнең*] *сипкелләре дәвәеп-дәвәеп киткән.* Р. Төхфәтуллин.

2. Үсү. *Бу бала, шөбһәсез, дәвәйгәч, --- мөхәррир булыр.* Г. Тукай.

ДӘГЪВА *и.* 1. Берәр нәрсәгә хокукын булу турындагы белдерү, талән; берәр нәрсәгә омтылыш. *Дәгъва белдерү.* □ *Берәү дә бу* [*үзенең яхшылык эшләве турындагы*] *сүзләрне нинди дә булса дәгъва белән әйтми.* Г. Әпсәләмов.

2. Бәхәсле эшне хәл итү турында судка һ. б. ш. органнарга ясалган мөрәҗәгать. [*Гәүһәрия — прокурорга:*] *Бу — кешеләр өстеннән дәгъва белән килгән, аларга җәза сорый дип уйламагыз.* А. Гыйләҗев. *Мөгаллимнәрне гаепле ясаса, ул* [*газет*] *дәгъвасын исбат итәргә дә тиеш.* Ф. Әмирхан.

3. Канәгатьсезлек, ризасызлык, зар. [*Гайниянең*] *үзен болай яшьтән үк тол итеп калдырган рәхимсез язмышына карата үпкәле дәгъвасы да бар.* Ф. Хөсни.— *Колхоз яшьләренең «артист җитми, декорация юк, сәхнә кечкенә» дигән дәгъваларына берәрегез колак салсагыз иде.* Г. Насрый.

4. Һавалы, мин-минлекле, ләкин нигезсез омтылыш, теләк. *Сез үзегезнең бик матур күзләрегезнең җазибәләренә ышанган шикелле, мин дә үземнең мәхәббәтле егет булучылыгымның көченә ышанам --- дидем вә көлдем. Кызлар да минем бу дәгъвамнан көлделәр.* Ф. Әмирхан.

◇ **Дәгъва итү** — дәгъвалау, дәгъва белдерү. *Балаларыбыз, телибезме-теләмибезме, бездән узып китәчәкләр, безгә остазлыкны дәгъва итәчәкләр.* Б. Камалов.

ДӘГЪВАЛАШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* дәгъвалау.

2. Даулашу, талашу, низаглашу. *Шушындый тар методик мәсьәлә буенча дәгъвалашып югары инстанцияләргә барып йөрергә киңәш бирмәс идем.* А. Расих.

ДӘГЪВАЛАУ *ф.* Берәр нәрсәгә хокукың булу турында белдерү, берәр нәрсәне таләп итү; берәр нәрсәгә омтылып эш итү. *Спорт мастеры исемен дәгъвалаучылар.* □ *«Чуртанлы күл» авылы ул печәнлекне үзенеке дип дәгъвалый.* И. Гази.

ДӘГЪВАЛЫ *с.* 1. Низаглы, талашлы, даулы; тынычсыз. *Дәгъвалы эш.* □ ***Әтисе белән әнисе арасында килеп чыккан җәнҗал, әнә шул чакны бу дәгъвалы йортны ташлап, Казанга китеп барырга мәҗбүр итте Арсланны.*** Г. Ахунов.

2. Бераз гына мин-минлекле, һавалы. [*Хөсәен*] — *дәгъвалы гына --- сәүдәгәр.* Ф. Әмирхан.

ДӘГЪВАТНАМӘ *и. иск.* Чакыру язуы (мәҗлескә, кунакка һ. б. ш. җиргә). *Бер студент килеп, Сафа әфәндедән миңа дәгъватнамә тапшыра. Дәгъватнамәдә адресы бар.* Г. Тукай. *Никах мәҗлесенә ашыгып дәгъватнамәләр таратылды.* Ш. Әхмәдиев.

ДӘГЪВАЧЫ *и.* 1. Дәгъва (1, 2 мәгъ.) белдерүче.

2. *күч.* Гауга, ызгыш, низаг чыгаручы.

ДӘГЪВАЧЫЛ *и.* Дәгъвалашырга яратучан, күп дәгъваларда катнашучы.

ДӘДӘ, ДӘДӘЙ *и. диал.* 1. Әтисенең абыйсы яки әнесе. *Мин, бик яшьли үксез калып, ундүрт яшемә кадәр мәрхүм дәдәм өендә тәрбияләндем.* Ш. Камал.

2. Үзеңнән шактый өлкән, ләкин карт булмаган кеше; агай (гадәттә, русларга һәм керәшеннәргә карата кулланыла). *Бүген төшемдә Иван дәдәйне күрдем.* Г. Бәширов.

ДӘҚЫЙҚА [дәқиқә] *и. иск. кит.* Бик кыска вакыт, мизгел, минут. *Биш-ун дәкыйка.* □ *Әхмәт әфәндегә офицерның ике-өч дәкыйка бер мөтдәт эчендә карап торуы бер ел кебек озын тоелды.* Г. Газиз.

ДӘЛАЛӘТ *и. иск.* Эшкә һ. б. берәр җиргә урнашуда берәүгә ярдәм күрсәтеп, аның өчен жаваплылыкны үз өстенә алу; рекомендация. *Партиягә Костомаров дәлаләте белән Шевченко да керде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Дәлаләт итү (кылу)** *юн. килешеннән соң.*— 1) берәр нәрсәне белдерү, күрсәтү, чагылдыру. [*Күз яшьләре*] *ачлык белән хәерчелеккә дәлаләт кыла.* М. Гафури. *Бу көй бер киявнең үзенең балдызына гашыйк булуыннан чыга. --- [Мисалга китерелгән] җырулар шушыңар дәлаләт итә.* Г. Тукай; 2) берәр нәрсәне дәлил итеп китерү. *Газет укучылар гыйлем һәм мәгарифкә дәлаләт кылалар, укырга кушалар.* З. Һади.

ДӘЛИЛ *и.* Берәр нәрсәне раслау, исбатлау өчен китерелгән фикер, нигез. *Ораторның дәлилләр китереп сөйләве.* □ *Зиннәт Хәйдарнең шундый үтемле сүзләре һәм көчле дәлилләре белән үзен җиңә башлавын тойды.* Г. Бәширов. // Раслый, исбатлый торган факт. *Кешенең сафлыгына дәлил булыр — һәрвакыт хаклык белән кылган эше.* М. Гафури. *Кырым конференциясе төрле иҗтимагый стройдагы дәүләтләрнең хезмәттәшлек итү мөмкинлеген күрсәткән яңа дәлил булды.* КПСС тарихы.

ДӘЛИЛЛЕ *с.* Дәлиле булган, дәлил белән исбат ителгән. *Дәлилле фикер.* | *Кавиның дәлилле чыгышы Рәхимгә карата җыелышның карашын үзгәртте.* А. Расих.

ДӘЛИЛЛӘҮ *ф.* Сүзне, карашны һ. б. дәлил белән беркетү, фикерне раслау өчен дәлил китерү; берәр фактны раслау, исбатлау. *Сүзне дәлиллә.* □ [*Сөйләүче үз фикерләрен*] *практикасында булган мисаллар белән дәлилләде.* Ф. Хөсни.

ДӘЛИЯ *и. диал. бот. к.* георгин.

ДӘЛЛӘТЧЕ *и. иск.* Эшкә һ. б. берәр җиргә урнашуда берәүгә ярдәм күрсәтеп, аның өчен җаваплылыкны үз өстенә алучы. [*Сөләйман:*] *Мин бик тырышып хезмәт итәр идем, бай абзый.* [*Бай:*] *Дәлләтчең бармы дим мин сиңа? --- Сине миңа кем җибәрде? Сине шәһәрдә кем белә?* К. Тинчурин.

ДӘРВИШ *и.* Тормыш ләззәтләреннән ваз кичеп, гомерен ислам диненә хезмәткә багышлаган, ярым теләнче хәлендә ил яки дөнья гизеп йөрүче кеше. *Фәлән җирдә, фәлән урманның артында тау тишегендә бер дәрвиш булыр.* Ш. Камал. *Хәзерге көндә исә ул шагыйрьләрнең* [*кайчандыр данлыклы булган Иран шагыйрьләренең*] *каберләре тирәсендә --- адәмнәрдән сәдака теләнеп дәрвишләр генә йөриләр.* Г. Ибраһимов.

ДӘРВИШЛЕК *и.* Дәрвишкә хас сыйфатлар, дәрвиш булу хәле. *Шагыйрь, туган иленнән аерылып нинди генә кыен хәлләргә төшсә дә, дәрвишлеккә бирелми, дөньявилыгын саклап кала.* Каз. утл. // Дәрвиш тормышы.

ДӘРВИШЛӘНҮ *ф.* Дәрвиш булып кылану.

ДӘРГАһ: дәргаһтан сөрелгән (куылган) *иск. гади с.*— тиргәү сүзе (динчеләр, динлеләр телендә).

ДӘРЕС *и.* 1. Аерым бер фәнгә багышланган укуукыту сәгате һәм шул вакыттагы уку-укыту. *Җыр дәресе. Дәрес башлану. Дәресне игътибар белән тыңлау. Ачык дәрес. Дәрескә керү.* □ *Хәмитнең дәрескә барасы бар.* А. Әхмәт.— *Без сиңа Яруллина группасында дәрес алып баруны тапшырырга уйлыйбыз.* Р. Ишморат.

2. Мәктәптә, урта махсус уку йортларында укытыла-укыла торган фән.— *Нинди дәресләр укыдыгыз?* Т. Гыйззәт.

3. Укучыга эшләргә, үтәргә кушылган эш, сабак. *Өйгә бирелгән дәресне яхшы хәзерләү.* □ [*Бала:*] *Уйнасам, дәресем кала.* Г. Тукай.

4. *күч. иск.* Акыл-тәҗрибә бирердәй файдалы нәтиҗә, гыйбрәт, сабак. *Һәр нәрсәдән гыйбрәт дәресе алмак кирәк.* М. Гафури. *Халикъ өчен бу* [*күңелсез хәл*] *яхшы дәрес булды.* Ш. Камал.

ДӘРЕСЛЕК *и.* Уку-укыту эшендә махсус кулланма булып хезмәт итә торган китап. *Әдәбият дәреслеге. Ботаника дәреслеге. Дәреслектән укып килү.*

ДӘРЕСХАНӘ *и. иск.* Дәрес алып бару бүлмәсе, класс. *Ак түшәмле дәресханәнең яшел стенасына асылган --- сәгать унны сукты.* К. Тинчурин.

ДӘРМАН *и.* 1. Рухи һәм физик мөмкинлекләр; көч, хәл. *Суынмадык: Бездә әле дәрман, Бездә әле җегәр җитәрлек.* Х. Туфан. *Байның эше фәрман белән, ярлының дәрман белән.* Мәкаль. // *күч.* Материаль мөмкинлек, хәл. *Керосин алырлык та дәрманы булмаганлыктан,* [*Хафиз*] *дәресләрен читтә, сандыклар өстендә караңгыда хәзерли.* К. Тинчурин. [*Сугыш елларында бригадир булып эшләүче:*] *Минем дәрман җитенкерәми, оланнар. Ат кисә муенны, ат! --- Нибарысы үнбер ат бар.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Күңелсезлекне һ. б. ш. борчуны җиңел кичерергә, аннан арынырга ярдәм итә торган яки рухи канәгатьләнү китерә торган нәрсә турында.— *Минем эшем шул инде: дәртле күңелләргә дәрман табу, гашыйк-мәгъшукаларны кавыштыру.* Ш. Камал. *Елмаеп каравың — Дәртемнең дәрманы.* М. Максуд.

ДӘРМАНА *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан булган күпьеллык дару үсемлеге, ярымкуак; *рус часы:* цитварная полынь. // Шуның киптерелгән чәчәге (эчәктәге селәүчәннәрне куу өчен дару сыйфатында файдаланыла).

ДӘРРӘҮ *рәв.* Күмәк, бердәм һәм бик җитез рәвештә. *Каләмдәшебезнең бу чыгышын котлап-яклап, зал дәррәү күл чаба башлады.* Г. Иделле. *Чыпчык өере кебек, дәррәү күтәрелеп, малайлар авылга таба очтылар.* И. Гази. // Кинәт, бик тиз, шул секундта ук. *Көтүченең иң якын ярдәмчесе — эт. Ул чабанның күзләренә генә карап тора һәм ни әйтсә шуны дәррәү башкара.* А. Расих. *Абыйсы елмаеп карагач,* [*Сәлимәнең*] *үпкәләве дәррәү бетеп китте.* Г. Гобәй.

ДӘРТ *и.* 1. Ашкыну һәм рухи күтәренкелек, омтылыш; рухи көч. *Иҗади дәрт. Дәрт сүрелү. Җиңү дәрте. Хезмәт дәрте. Яшьлек дәрте.* □ *Бу көй --- күңелләргә әллә нинди гайрәт, хәзер кузгалып китәрлек дәрт бирә иде.* М. Гафури. *Яшьлек — Дәртнең ташыган чоры!* Ф. Кәрим. // Теләк. *Эчәргә дәртем юк, диде* [*егет*]. К. Тинчурин. *Мин, һаваның яхшылыгын, Идел өстендәге төннең матурлыгын сөйләп, Разияга чыгып йөрергә гарыз иткән идем, аның да дәрте бар иде.* Ф. Әмирхан.

2. Ярату, мәхәббәт хисе. □ *Шаһзадәнең гыйшык уты көннән-көн көчәя барды. Ул, дәртенә чыдый алмастан, авыруга сабышты.* К. Насыйри. *Җамалый картның бирергә исәбе юк түгел, кызы Фәхернисаның да миндә дәрте бар икән.* Г. Ибраһимов. // Икенче җенескә тартылу хисе яки тойгысы. *Женси дәрт.* □ *Тегермән буасында, эри башлаган яшел боз өстендә, дәрт кергән ана казлар гаҗылдаша.* И. Гази.

3. *с. мәгъ.* Дәртле, ашкынучан, берәр нәрсәгә омтылучан. *Балыкка дәрт кеше.* □ *Сүзгә караганда эшкә дәртрәк, уракны да әтигә карагандa ике өлеш артыграк ура* [*әни*]. Р. Ишморат.

◇ **Дәрт бирү** — 1) берәр нәрсәгә күңел бирү, ошату, ярату. *Укуга дәрт бирү.* □ *Мин икра белән балыкка ныграк дәрт биреп ашый башладым.* Ш. Усманов; 2) берәүне өндәп-җилкендереп, аңа рухи көч бирү, куәт бирү. *Бүлмәдәгеләр, нәкъ сабан туендагы кебек, көрәшчеләргә дәрт, көч бирәләр.* А. Әхмәт. **Дәрт итү** — берәр нәрсәне теләү, аңа омтылу. *Сазлык кибә, гөлләр үсә, Эшче батыр дәрт итсә.* М. Максуд. **Дәрт почмаклану** — теләк үтәлеп, күңел булу; канәгатьләнү.— *Әйдә инде, дәртең почмаклансын, бер казаки тегеп бирермен.* Г. Гобәй.

ДӘРТЛЕ *с.* 1. Дәрте (1 мәгъ.) булган; ашкынулы, омтылучан. *Дәртле йөрәк. Дәртле яшьлек.* □ *Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.* Г. Тукай. [*Нуруллин*] *үзен дә чал керә башлаган чәчле, ләкин һаман да шулай дәртле, ашкынулы инженер итеп тоя.* А. Шамов.

2. Женси хискә, тойгыга тиз бирелүчән, темпераментлы. *Дәртле кеше.* □ *Мостафин өчен ул* [*Нәҗия*] *һаман дәртле, кайнар хатын.* Ә. Еники.

3. Дәрт (1 мәгъ.), илһам бирә торган; рухландыргыч. *Оркестрлар, уйнагыз дәртле көйләрне.* М. Крымов. *Безнең бабаларыбыз да, язны билгеләп, дәртле сабан туйлары үткәргәннәр.* М. Максуд.

ДӘРТЛЕЛЕК *и.* Дәртле булу сыйфаты. [*Кызлардан*] *тазалык, ныклык аңкый, дәртлелек ташып тора.* А. Шамов. *Аның рәсеме дә батыр егетнең ихтыяр көченә бай булуын, ныклыгын, дәртлелеген сөйли.* Г. Кашшаф.

ДӘРТЛӘНДЕРГЕЧ *с.* Дәрт бирә торган; рухландыргыч. *Дәртләндергеч сүз.* □ [*Фәйзулла*] *хезмәт ияләренә үзенең дәртләндергеч, күңелле, матур концертларын биреп йөрде.* М. Җәлил.

ДӘРТЛӘНҮ *ф.* Дәрт керү, дәрт тою, ашкыну, рухлану. *Каюм да* [*көрәшкә*] *чыгарга дәртләнгән иде дә, аның яшендәге малайларны чыгармадылар.* М. Гали. [*Биюче*] *дәртләнә төште, аның аяклары тагын да җиңелрәк --- тыпырдый башлады.* А. Шамов.

ДӘРТСЕНҮ *ф.* Дәртләнү. *Шәфи, килү белән үк дәртсенеп, лекциягә тотынды.* Ш. Маннур.

ДӘРХӘЛ, ДӘРХАЛЬ *рәв. иск.* Тиз генә, шунда ук. *Кечкенә чагымда миңа бервакыт утыз тиен кадәр бакыр акча бирделәр. Бу кадәр байлыкка куанып мин дәрхәл уенчыклар сатыла торган кибеткә йөгердем.* Г. Тукай.

ДӘРЬЯ *и. шигъ.* **1.** Елга; зур су. *Кичәбез киң дәрьяларны, Урман, тауларны.* Ф. Кәрим.

2. *күч.* Берәр нәрсәнең зур микъдары, күплеге турында. *Шушы зур һәм матур бинага көн саен халык дәрьясы агыла.* М. Максуд.

ДӘРӘҖӘ *и.* **1.** Берәр нәрсәнең чагыштырмача микъдары, үлчәме, чамасы. *Дәресләремне урта дәрәҗәдә генә алып барам.* М. Фәйзи. *Карт үзенең әнисәсен чиксез дәрәҗәдә ярата.* З. Бәшири. // Кабат, тапкыр, мәртәбә. [*Телескоп*] *нәрсәне үз зурлыгыннан ничә дәрәҗәләр зурайтып күрсәтә.* Ф. Әмирхан.

2. Үсештәге бер баскыч, ирешелгән нокта; чик. *Аң-белем дәрәҗәсе. Профессор дәрәҗәсенә күтәрелү.* □ [*Габбас*] *үзенең тырышлыгы аркасында буяу цехын үрнәк булу дәрәҗәсенә күйды.* Ш. Камал.

3. Рәсми һ. б. ш. бүленештә яки бүленеш системасында: бер баскыч, урын, тәртип. *Зыя* [*мәдрәсәдә*] *Кәримнән берничә дәрәҗә* [*сыйныф*] *алда булып, аның һәммә сабакларын өйрәтә, төрле низагларда үз итә, яклаша иде.* Г. Ибраһимов. *Рәхимов өченче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнде.* А. Шамов. // Стадия, баскыч (төрле авыруларда һ. б.). *Пешүне дәрәҗәләргә бүлеп йөртәләр. Беренче дәрәҗә пешү булганда, тире кызара һәм бераз шешә.* Соц. Тат.

4. Югары дәүләт һәм хөкүмәт посты, рәсми эш урыны; җәмгыятьтә тоткан урын. *Кыз да чарлактан тамаша итә: кайсы кияү дәрәҗәдә түгел, кайсы дәрәҗәдә дә,— медале аз; берсенең кашы куерак, икенчесенең борыны киңрәк, өченчесенең дәрәҗәсе дә бар, ләкин кесәсендә акчасы юк.* Г. Тукай.

5. Рәсми бирелә һәм эш-хезмәт баскычын күрсәтә торган исем. *Фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә. Профессор дәрәҗәсе алу.* □ *Шәрип ялгызы калды* [*мәхәллә*], *тиздән мөфти аңа ахунлык дәрәҗәсе дә бирдерде.* Г. Ибраһимов. *Колоннаны алып килүче хәрби киемле, ләкин бернинди дә дәрәҗә билгеләре такмаган командир колоннаны тараттыда --- өйгә кереп китте.* А. Расих.

6. Авторитет, абруй. *Халык алдында дәрәҗә казанһ* □ *Дәртләнеп эшләвә дә колхозчылар каршында аның* [*Нәфисәнең*] *дәрәҗәсен торган саен күтәрә бардылар.* Г. Бәширов. // Кешелек горурлыгы, кадер, үз-үзенә биргән бәя. *Кешелек дәрәҗәсен югары тоту.* □ *Әнисә үзенең дәрәҗәсен-бәясен яхшы аңлап, үзен пакь, чиста тотуы белән дә башка кызлардан аерылып тора.* З. Бәшири. *Фәкыйрь булдың, әмма тез чүкмәдең, Дәрәҗәңне белдең, әй Сина.* Н. Исәнбәт. // Әһәмиятлелек, кыйммәтлелек, кадерлелек. *Әйтер сүзенең дәрәҗәсен күтәрергә теләгәндәй, беравык эндәшми торды* [*мастер*]. Г. Ахунов.

7. *мат.* Санны үз-үзенә тапкырлап табылган тапкырчыгыш. *Дәрәҗәгә күтәрү. Дәрәҗә күрсәткече.*

8. *лингв.* Сыйфатларда һәм рәвешләрдә: билгенең сыйфатның микъдари дәрәҗәсен белдерә торган форма (сыйфатларда: гади дәрәҗә, чагыштыру, артыклык һәм кимлек дәрәҗәләре; рәвешләрдә: төп дәрәҗә, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләре). // Фигыльләрдә: эш-хәлнең яки процессның дәвамлылык яки кабатлаулылык, тизлек яки кинәтлек, тулылык яки кимлек төсмерләрен белдерә торган форма. *Азайту дәрәҗәсе. Кабатлау дәрәҗәсе.*

ДӘРӘҖӘЛЕ *с.* **1.** Югары дәрәҗәгә (4, 5 мәгъ.) ия булган, югары дәүләт яки хөкүмәт хезмәтендә торучы. *Хәзер син, Газинур, дәрәҗәле кеше,— диде Гарәфи абзый. --- Халык арасында үзеңнең бәяңне төшермә.* Г. Әпсәләмов.

2. Җәмгыятьтә югары урын тотып, авторитетка, хөрмәткә ия булган. *Идият абзый утыз елдан бирле --- белгеч исеме белән төпле, дәрәҗәле бер кеше булып яшәп килә.* Ә. Еники.

3. Мактаулы, хөрмәтле (эш һ. б. ш. турында). *Дәрәҗәле эш.*

ДӘФГА *и. иск. кит.* Мәртәбә, тапкыр. *Мәдрәсәләребез хакында беренче дәфга язылган бу әсәр.* Ф. Әмирхан. *Утызынчы апрель дүшәмбе көн Оренбургта --- икенче дәфга татарча театр уйналды.* Ш. Мөхәммәдев.

ДӘФГАТӘН *рәв. иск. кит.* Кинәт; көтмәгәндә, искәрмәстән. *Агар сулар дәфгатән бозландылар.* Г. Тукай. *Дәфгатән яктырды һәм балкыды нур.* Ш. Бабич.

ДӘФЕН *и. иск.* Мәетне җирләү, күмү йоласы. [*Азымбай*], *мәрхүмнең энесе Якуп белән бергә дәфен, җеназа артыннан йөрде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Дәфен итү** — дәфенләү, күмү. *Кадерле якының дәфен итеп кайтучы кешедә — авыр тойгылар.* Ф. Әмирхан.

ДӘФЕНЛӘҮ *ф. иск.* Йоласын үтәп җирләү; күмү. [*Галимә*] *бәкегә төшеп, шунда вафат булган. Ике көн үткәч кенә табып алдылар. Өч көннән соң гына дәфенләп күмдек.* М. Гафури.

ДӘФТӘР *и.* Кәгазь битләрен бер тыш эчендә (яки тышсыз гына) теркәп яисә төпләп ясаган язу-сызу әсбабы. *Шакмаклы дәфтәр. Рәсем дәфтәре. Укытучының дәфтәр тикшерүе.* □ *Хат бер дәфтәр битенә ачык кына итеп карандаш белән язылган.* Ш. Камал.

ДӘХЕЛ *и. сөйл.* Берәр эш-хәлгә мөнәсәбәт.— *Үзара сугышуларның сиңа ни дәхеле бар?* Ш. Әхмәдиев. *Атта* [*аны яшерүдә*] *үзенең дә дәхеле булуын җиңгәсенең исенә төшерде ул.* Ф. Хөсни.

ДӘХИ *рәв. иск. кит.* Тагын бер тапкыр, янә; яңадан. *Туй мәҗлесләре тәмам булгач, кияү кыз катына бармас борын кыз өендә дәхи хатыннар мәҗлесе була. Моны бүләк багу мәҗлесе* [*диләр*]. К. Насыйри. *Вәлинең* [*сәхнәдә*] *әйтә торган такмагы бөтен комедиягә дә дәхи бер кат зиннәт бирә.* Ф. Әмирхан. // Да; шулай ук. *Гадәт ал: егет булсаң — алданмаска! Үзең дәхи башкаларны алдамаска.* М. Гафури. *Кеше бодай чәчеп арпа ала алмас, Яман эштән дәхи файда таба алмас.* Ә. Фәйзи.

ДӘШҮ *ф. к.* эндәшү. *Чәчәктән чәчәккә күчкәндә, баллы сулар эчкәндә, Нечкәбилгә тагын кемдер эндәшә, үзе янына дәшә.* А. Алиш.

ДӘҮ *с.* **1.** Зур. *Тимерчелектә дәү һәм бәләкәй чүкеч белән сандал суккан тавышлар чыңлый.* Г. Әпсәләмов.

2. Үсеп җиткән, зур гәүдәле. *Егетләр, ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп дигәндәй, бик тиз вакыт эчендә дәү булып җиткәннәр.* Әкият.

3. Өлкән яшьтәге, олы. *Иң дәү, иң карт, иң сизгер Колхозчыбыз син безнең.* М. Җәлил.

4. Дәрәҗәле, авторитетлы, ихтирамга лаек. [*Габдулла*] *гыйлем алып дәү кеше булу турында хыяллана.* Ә. Фәйзи.

ДӘҮКӘДИ *и. диал.* Зур гәүдәле кеше. *Ишектән танытмас өчен битләренә кара яулыклар бәйләгән билгесез ике дәүкәди кереп, егетнең кулларын каерып алалар.* Ф. Хөсни.

ДӘҮЛӘТ *и.* 1. Илдәге тәртипне саклау һәм каршы сыйныфларны бастыру өчен, хаким сыйныф тарафыннан төзелгән, башында хөкүмәт һәм аның органнары торган политик оешма; шундый политик оешмасы булган ил. *Дәүләт власте. Дәүләт башлыгы. Дәүләт органнары. Дәүләт чиге. Дәүләт милке.* □ *Өй салырга теләгән һәр колхозчыга идарә дәүләттән ссуда алырга ярдәм итә.* Р. Ишморат.

2. Мал-мөлкәт, байлык.— *Дәүләтем юк, бәхетем ким, дип зарлык кылма.* Г. Ибраһимов. *Дворяннар, үз кулларыннан дәүләтләре китү сәбәпле, тормыш кызыгын югалтканнар.* Г. Нигъмәти.

◇ **Дәүләт департаменты — тышкы эшләр министрлыгы** (АҚШ һ. б. кайбер дәүләтләрдә). **Дәүләт секретаре** — тышкы эшләр министры (АҚШ һ. б. кайбер дәүләтләрдә).

ДӘҮЛӘТАРА *с.* Ике яки берничә дәүләт өчен уртак булган. *Социалистик илләрнең дәүләтара оешмалары.* // Ике яки берничә дәүләтнең үзара мөнәсәбәтенә караган. *Дәүләтара килешү. Дәүләтара сөйләшүләр. Дәүләтара каршылыклар.*

ДӘҮЛӘ'ТКҮЛӘМ *с.* Дәүләт масштабындагы, тулаем дәүләт өчен әһәмиятле. *Дәүләткүләм проблема. Эшнең дәүләткүләм әһәмияте булуы.*

ДӘҮЛӘТЛЕ *с.* Дәүләте (2 мәгъ.) булган, бай. *Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар.* Г. Тукай. [*Гариф*] *— дәүләтле генә кеше улы.* М. Гафури.

ДӘҮЛӘТЛӘШТЕРҮ *ф.* Дәүләт милке итү; национализацияләү. *Завод-фабрикаларны дәүләтләштерү.* // Дәүләт карамагына күчерү, тапшыру.

ДӘҮЛӘТСЕЗ *с.* 1. Дәүләте (1 мәгъ.) булмаган, дәүләт булып оешмаган. *Җәмгыять үсешенең дәүләтсез чоры. Дәүләтсез халыклар.*

2. Зур дәүләте (2 мәгъ.) булмаган, бай түгел; малмөлкәтсез, ярлы. *Дәүләтсез кеше.*

ДӘҮЛӘТЧЕЛ *с.* Дәүләт (1 мәгъ.) булып оешкан; дәүләтчелеге булган.

ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК *и.* Дәүләт оешмасы, строе. *Дәүләтчелеккә ирешү. Артта калган Россия халыкларының Октябрь революциясеннән соң дәүләтчелек алуы.* □ *Социалистик демократияне һәрьяклап җәелдерү һәм камилләштерү, барлык граждannарның дәүләтне идарә итүдә, хуҗалык һәм культура төзелешенә җитәкчелек итүдә актив катнашуы, дәүләт аппаратының эшен яхшырту һәм аның эшенә халыкның контролен көчәйту — коммунизм төзү чорында социалистик дәүләтчелек үсешенең төп юнәлеше әнә шундый.* КПСС программасы.

ДӘҮЛӘ'ТЧӘ *рәв.* Дәүләт интересларын күздә тотып, аларны беренче урынга куеп. *Без әйберләрнең үз исемен әйтеп сөйләшик. --- Менә ул булыр — дәүләтчә сөйләшү.* Г. Ахунов.

ДӘҖҖӘЛ *и.* Динчеләр фаразынча, кыямәт булыр алдыннан чыгачак бер алдакчы зат.

ДӘҺРИ *с. иск.* 1. Динсез, алласыз; дингә ышанмаучы; дин тотмаучы. *Шәкертләр арасында аны дәһри Садыйк дип йөртәләр иде.* Г. Ибраһимов.

2. Дәһрилек, динсезлек белән сугарылган, шуңа өнди торган.— *Мин инде, хәлфә абый, аның дәһри сүзләре турында уйламаска тырыша идем.* Г. Гобәй.

ДӘҺРИЛЕК *и.* Дәһри кешегә хас сыйфатлар, динсезлек; дәһриләр карашы. [*Мулла:*] *Ярый, кызым, андый затлар турында сорашма, зур гөнаһ, дәһрилек була, ди китап.* Т. Гыйззәт.

ДӘҺРИЛӘНҮ *ф.* 1. Дәһри булып, динсез булып китү; дингә, аллага ышанмый башлау.

2. Дәһри булып кылану, дәһри булып күренергә тырышу.

ДӘҺШӘТ *и.* 1. Курку сала торган зур көч, җимергеч куәт. *Революция дәһшәте.* □ *Безнең гаскәр бара дәһшәт булып, Дошман явын таптап.* Ш. Маннур. *Снарядлар үкеруенең дәһшәтенә түзә алмыйча, җир үзе тетрәде.* Г. Бәширов. *Дуслар безнең үз көчләрен бергә туплар. Ул бергәлек Дәһшәт булыр тәхетләргә.* М. Ногман. // Гомумән, зур көч, куәт, көчле энергия. *Әйдә җырлыйк шундый җырларны без, Дәһшәтеннән җирләр яңгырасын.* М. Гафури.

2. Зур, хәтәр куркыныч; афәт. *Сугыш дәһшәте.* □ *Урамда шатыр-шотыр атышу дәһшәтеннән төн буе йоклamый чыктык.* М. Фәйзи.— *Баланы ач үлем дәһшәтеннән йолып калгансыз.* Г. Гобәй.

ДӘҺШӘТЛЕ *с.* Зур бәла-каза китерә торган; бәлаказалы, афәтле. *Дәһшәтле сугыш.* □ *Егерме беренче елгы дәһшәтле ачлык бу театрны яшәтергә мөмкинлек бирмәде.* Т. Гыйззәт. // Бик куркынычлы, хәтәр. *Сөйгән кешеңә һәм туган иленә мәхәббәтең никадәр көчлерәк булса, дошманга булган нәфрәтең шулкадәр дәһшәтлерәк икән.* А. Шамов. *Иң алдынгы, Иң дәһшәтле сафта йөрдем мин.* Ә. Ерикәй. // Мәһабәтлек, зур куәтлелек кебек сыйфатлары белән күңелдә курку, шом һ. б. ш. хис кузгата торган. *Кинәт бөтен урман эчен дәһшәтле гөрселдәү каплап алды.* Ә. Еники. *Якупның киң җилкәләре, зур йодрыклары, гомумән бөтен кыяфәте бу минутта шактый дәһшәтле иде.* И. Гази. // Гомумән, гадәттән тыш көчле тәэсир ясый, күңелне тетрәтә торган. *Дәһшәтле үлем. Дәһшәтле пирамидалар. Дәһшәтле җиңү.* □ *Моңарчы һичкайда күрмәгән, ишетмәгән дәһшәтле гүзәллекне татудан туган хис иде бу.* Г. Кутуй.

ДӘҺШӘТЛӘНҮ *ф.* Дәһшәтлегә әйләнү. *Җил ыжгыра тышта дәһшәтләнеп.* Ш. Маннур.

ДӨБЕР *аваз.ияр.* 1. Гөрелдәп яки шалтырап дөпелдәүне һ. б. ш. тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дөбер» сыман тавышлар чыгарып. *Дөбер-дөбер күк күкрәү. Балаларның идәндә дөбер-дөбер йөгерешүе. Поездның дөбер-дөбер үтеп китүе.* □ *Урамга таш җәелгән иде. Арба дөбер-дөбер ташлар өстеннән бара.* И. Гази.

ДӨБЕРДӘТҮ *ф.* 1. Дөбердәү тавышы чыгарып шаку, кагу, шапылдату. *Давылның түбә калаен дөбердәтүе. Капка дөбердәтү. Урынныннан күчергәндә урындыкларны дөбердәтү.* □ *Ишек дөбердәткән тавыш ишетелде.* Г. Камал. *Тәрәзәләрне яңгыр тамчылары дөбердәтә.* Ш. Камал. *Казарма ишеге ачылып, бозлы итек үкчәләрен дөбердәтеп бер төркем солдатлар кайтты.* Қ. Нәҗми.

2. *рәв. мәгъ. күч. сөйл.* **дөбердәтеп.** Үтә җанлы, актив һәм уңышлы төстә башкару, эшләү, оештыру һ. б. турында. *Дөбердәтеп туй ясау. Дөбердәтеп эшләү.* □ *— Кодагый ни хәл соң? — Дөбердәтеп яши.* Н. Дәүли.

ДӨБЕРДӘҮ *ф.* 1. «Дөбер» сыман тавышлар чыгару; шатырдап дөпелдәү. *Ауган өстәлнең дөбердәве. Трамвай дөбердәү. Өйгән утынның дөбердәп ишелеп төшүе.* □ *Күпердән атлар, сабаннар белән колхозчылар басуга чыкканда, күк күкрәгәндәй дөбердәү ишетелеп торды.* С. Рафиков.

2. *рәв. мәгъ. күч. сөйл.* **дөбердәп.** Үтә җанлы һәм актив, уңышлы төстә бару, башкарылу, эшләнү турында.— *Сәүдәләр дөбердәп бара.* Г. Иделле. *Дөбердәп йөри торган карчыкны да нинди хәлгә китерде бу сугыш.* Ә. Қамал.

ДӨБЕРТ *аваз.ияр.* Кинәт, кискен дөбердәп-дөбердәтеп алуны белдерә. *Дөберт! Арслангали сискәнеп күзләрен ачты: кулыннан тормоз рычагы ычкынган икән!* Г. Ахунов.

ДӨ'БЕР-ШАТЫР *аваз иляр.* **1.** Кәты дөбердәү тавышларын белдерә. [*Аулак өйдә шаяруларын сөйләүче егет:*] *Шулай итеп, тартыша торгач, бервакыт дөбер-шатыр! Гәрәем казанга баткан!* М. Фәйзи.

2. *рәв. мәгъ.* «Дөбер-шатыр» сыман тавышлар чыгарып, кәты дөбердәп. *Дөбер-шатыр таш бушату. Балаларның дөбер-шатыр шаярулары. Машинаның дөбер-шатыр чабуы.* □ [*Илгиз*] *бидоннарын дөбер-шатыр төяде дә атына чыбык белән суга-суга чапты.* Г. Мөхәммәтшин. *Дөбер-шатыр бишләр.* Б. Рәхмәт. *Дөбер-шатыр чаптырып атлы кунаклар килә.* М. Фәйзи. // *күч.* Берәр нәрсә эшләү турында: бик җитез, актив һәм җанлы рәвештә.— *Иртән китсәм, кичкырын дөбер-шатыр анда барып җитәм.* Ш. Камал.— *Атна көн дөбер-шатыр туй уйныйбыз.* Ш. Камал.

ДӨГЕ *и.* **1.** Кыяклылар семьялыгыннан җылы якларда сугарып игелә торган озынчарак ак орлыклы үсемлек. *Дөге сугару.*

2. *җый.* Шушы үсемлекнең орлыклары. *Дөге ярмасы. Дөге бәлеше.*

ДӨГӘ-ДӨГӘ *ы. к.* дегә-дегә. *Дөгә-дөгә, лил-лил-лил! Килегез, казлар, кил, кил, кил!* Ш. Маннур.

ДӨК *аваз иляр.* **1.** Бәрелгәндә ишетелә торган нечкә тонык тавышны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. гадәттә каб. форм.* «Дөк» сыман тавышлар чыгарып. *Бәрәннәрнең дөк-дөк басып йөрүе.* □ *Сүзләр, Муса колагына килеп җиткән саен, ниндидер автомат чүкеч шикелле дөк-дөк бәреп куялар.* Ш. Маннур.

ДӨЛДЕЛ *и. миф.* Канатлы ат. *Аның кечкенә генә аты хыялый дөлдел шикелле канатлы ат булудан бик ерак иде.* И. Гази.

ДӨМ *кис.* **1.** Кайбер сыйфатлардан артыклык дәрәҗәсе ясый, мәсәлән: дөм караңгы, дөм сукыр, дөм ят.— *Бер нәрсә дә ишетмим, колакларым дөм чукрак минем.* А. Расих.

2. *рәв. мәгъ.* Кайбер сүзләр янында гына килеп, «бөтенләй, тәмам, тулысынча» дигәнне белдерә. *Күзне дөм йомып яту.* □ — *Җитәр инде, дөм бушка килмешәкләр тотар хәлем юк.* Ш. Камал. *Бу семья өчен өйгә дөм исереп кайту гадәттән тыш, гомердә булмаган, башка сыймый торган бер хәл иде.* Г. Әпсәләмов.

3. *и. мәгъ.* Көчле караңгылык. [*Көндәш белән торучы бай хатыны:*] *Хатын көне дөм кебек, кап-караңгы төн кебек.* Т. Гыйззәт. *Бу дөмдә нәрсә күреп булсын соң?* Сөйл.

ДӨМБЕ *и.* Вак һәм сай суларда балык сөзгәндә суга төртә-төртә балыкны куып китерә торган чүкмар башлы колга яки таяк. *Балакларын бот тиңентен сызганган сипкелле малайлар агач дөмбе белән комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып --- бәләкәй җәтмәләр белән балык сөзәләр.* А. Гыйләҗев.

ДӨМБЕЛӘУ *ф.* Суга дөмбе белән төртә-төртә балыкны җәтмәгә таба куып китерү.

ДӨМБЕР *аваз иляр.* **1.** Яңыраурак һәм сузынкырак дөбердәү тавышын белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дөмбер» сыман тавышлар чыгарып. *Дөмбер-дөмбер барабан кагу. Чиләкнең баскычтан дөмбер-дөмбер тәгәрәп төшүе.*

ДӨМБЕРДӘУ *ф.* «Дөмбер» сыман тавышлар чыгару. *Буш бидоннар төягән машинаның дөмбердәве. Барабан белән уйнаучы бала-чаганың дөмбердәве. Арбадагы буш мичкә дөмбердәү.*

ДӨМБЕРТ *аваз иляр.* **1.** Кинәт ишетелгән, кискен дөмбердәү тавышларын белдерә.— *Егетләр, шәкерт салмасы белән сыйлыйк! Дөмберт! (Киштәдән мендәр алып һөҗүм итәләр.)* Т. Гыйззәт.

2. *хәб. функ.* Кискен дөмбердәү тавышлары чыгарган эшне-хәрәкәтне белдерә.

ДӨМБӘСКӘ *и. диал.* Үлән яки мүк үскән балчык кантары, түмгәк.

ДӨМБӘСКӘЛЕК *и. диал.* Дөмбәскәләр (күп) булган җир. *Урмандагы дөмбәскәлек.*

ДӨМБӘСЛӘУ *ф.* Кәты-кәты итеп сугып тору, кыйнау. *Бүрәнәгә атланып, салам тутырылган капчык белән бер-берсен дөмбәсләүләр дисеңме, --- әкәмәт инде* [*сабан туе мәйданында*]. Г. Насрый. [*Байбикә:*] *Ялкаулланмагыз, дөмбәсләрмен үзегезне!* Д. Аппакова. // *күч. сөйл.* Фронтта, сугышта: көчле һөҗүм ясау, җиңелүгә дучар итү. *Кутузовның ничек итеп Наполеонны дөмбәсләве турында сөйләделәр.* Г. Әпсәләмов.

ДӨМЕГҮ *ф. гади с.* Үлү, һәлак булу.— *Дөмегеп кенә китсеннәр иде бу сугышны башлап җибәрүчеләр!* К. Нәҗми. [*Атасыннан зарланучы Шәйхел:*] *Бу комсыз карт дөмекми торып, безгә якты көн булмас бугай.* Г. Ибраһимов. // Харап булу, начар тормышка юлыгу. [*Артта калган мәдрәсәдә укучылар:*] *Ятабыз икән монда дөмегеп! --- «Мөхәммәдия» шәкертләре даулашып мәдрәсәгә яңа программа керттергәннәр.* Ә. Фәйзи. // Югалу, юкка чыгу. [*Бай:*] *Галимә, Галимә дим! Кая дөмеккәнсең?* Ш. Камал.

ДӨНЬЯ *и.* **1.** Материянең бер бөтен тәшкил иткән барлык формалары; галәм. *Кояш бөтен дөнья пространствосына чиксез күп энергия тарата.* Соц. Тат.

2. Галәмнең бер өлеше. [*Ерак йолдызлар*] *анда да, миллион еллар буе безгә текәлеп торган чиксезлектә дә, ниндидер тормышлар, ниндидер яңа дөньялар бар икәнен хәбәр итәләр.* Каз. утл.

3. Җир шары; Җир планетасындагы терек һәм терек булмаган нәрсәләрнең барысы. *Әйләнер дөнья һаман да, Булмас аңа берни дә!* Н. Исәнбәт.

4. Безне чолгап тора торган барлык табигать, мохит. *Яз көне дөнья яшәрү.* □ [*Чәчәк*] *хуш исләрен дөньяга чәчә.* Г. Газиз. *Таңнар ата, дөнья яктыра.* С. Урайский.

5. Мохитның, табигатьнең, тереклекнең аерым бер өлкәсе. *Хайваннар дөньясы. Үсемлекләр дөньясы. Су асты дөньясы. Минераллар дөньясы.* □ *Җир асты дөньясын үзләренең --- казармалары кебек күреп, анда йөрергә, эшләргә өйрәнеп беткән эшчеләр.* М. Гафури.

6. Җирдә яшәүче һәм яшәгән барлык кешеләр; кешелек җәмгыяте. *Совет фәненең дөньяны хәйран итүе. Октябрь революциясенең дөньяда беренче социалистик җәмгыять төзү өчен юл ачуы.* □ *Синең ат тануың дөньяга мәгълүм инде.* Г. Ибраһимов. *Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай.* Ш. Бабич.

7. Җәмгыять тормышы; иҗтимагый төзелеш системасы. *Социалистик дөнья.* □ *Эшчеләрнең көчле протестлары Капиталистлар дөньясын.* М. Гафури. *Дөньяны көрәшсез төзү мөмкин түгел.* М. Җәлил. // Тормыш, яшәеш, көнкүреш. [*Иген уңган елны*] *һәркем шулай үзенең дөньясын рәтләп калырга уйлый.* Г. Ибраһимов.— *Кыен инде, кыен дөньяны берүзеңә алып барырга.* Ә. Фәйзи.

8. Җәмгыять тормышының, иҗтимагый чынбарлыкның бер өлкәсе. *Әдәбият дөньясы.* □ *Авыр яралыларның дөньясы гадәттә палата эче белән чикләнә.* Сов. әд. *Мин каләмемне куеп иректән музыка дөньясына чумам һәм күзләремне йомам.* М. Мәһдиев. // Аерым бер иҗтимагый төркем, кешеләр даирәсе. *Күзгә, уян, ләгънәт ителгән Коллар һәм ачлар дөньясы!* Һ. Такташ.

9. Психик тормышның (хисләр, күзаллауларның) бер өлкәсе. *Матурлык дөньясы. Хыял дөньясы. Рухи дөнья.* □ *Бер төрле уйлар дөньясыннан икенче төрле уйлар дөньясына, күктән җиргә сикергән шикелле сикерергә туры килгәндә, кемнең генә күңеле дулкынланмас икән!* И. Гази.

10. *иск.* Дөньяви тормыш, дөньялык; *киресе:* ахирәт. *Татар кызлары арасында элек бер-берсе белән «ахирәтлек» (ягъни дөньяда гына түгел, ахирәттә дә) дус булышу гадәте бар иде.* М. Җәлил.

11. *с. мәгъ. күч. сөйл.* Бик күп, зур. *Чәйләп чыкканчы, дөнья вакыт узды.* Г. Гобәй. *Акча әрәм итеп, нигә әйбер алып йөрисең? Безнең үзебездә дә дөнья бит алар.* Т. Гыйззәт.

◇ **Дөнья бәясе** — бик кыйммәт, бик кадерле. *Дөнья бәясе кеше иде. Асыл кеше иде* [*Сәрьян*]. Г. Бәширов. **Дөнья йөзе** — к. жир йөзе.— *Мондый кеше дөнья йөзендә тагы бар микән?* Г. Колаҳметов. **Дөнья куу** *сөйл.*— тормыш алып бару, мал табу өчен тырышу. *Дөнья куып, бәгърем, йөри-йөри, Тәбриләргә сине кичектем.* Һ. Такташ. **Дөнья кую** — к. дөньядан китү. *Икебез дә бу дөньяны куйсак, улыбыз Габдулла кем кулында калыр дип бик куркабыз.* Ә. Фәйзи. **Дөнья көтү** — тормыш итү, тормыш алып бару. *Мәгъсүм, яшь булса да, дөнья көтүнең рәтен белә.* М. Гали. **Дөнья күрү** — 1) тормыш белән, аның уңай яклары һәм каршылыклары белән үз практиканда танышу. *Яшь чагында дөнья күрү ир-егетнең бурычы, диләр иде борынгы картлар.* Г. Әпсәләмов; 2) басылып чыгу (китап һ. б. ш. турында). *Бу китап 1960 елны дөнья күрде.* Н. Фәттах. **Дөнья тигезләнү (төгәлләнү, түгәрәкләнү)**—тормыш-көнкүреш ихтыяҗлары үтәлеп, борчу-мәшәкатьләрең бетеп, тынычланып калу. [*Эшеңдәге уңыштан соң*] *инде син үзеңдә көч барлыкны сизәсең, менә шунда инде син һавага күтәреләсең, менә шунда инде синең бөтен дөньяң тигезләнә.* Г. Галиев. *Инде конституция булды! Дөнья төгәлләнде! — дип уйларга мөмкин түгел. --- Сыйнфый көрәшләрне бер минут та күз алдыннан җибәрергә ярамый.* Г. Ибраһимов. [*Камәр:*] *Әй карт, карт! Син дә кайттың бит. Инде дөньябыз түгәрәкләнде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Дөньяга килү** — туу. *Без үзебез кеби кешенең кулы астында кол булып торырга дөньяга килгәнбезмени?* Г. Колаҳметов. **Дөньяга чыгу** — 1) тормыш белән практикада таныша башлау, аның берәр өлкәсендә турыдан-туры катнашып китү. *Ул әле дөньяга чыкмаган, бары укып кына йөргән.* М. Гафури; 2) басылу (китап һ. б. ш. турында). *Егерме биш елдан «Хыялмы, хакыйкатьме?»нең дөньяга чыгуына юбилей ясалды.* Ф. Әмирхан. **Дөньядан китү (үтү, кичү, күчү** һ. б.) — үлү, вафат булу.— *Мин инде шулай һәлак булып дөньядан китәрмен микәнни!* Г. Камал. *Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәтеп карап, бер атнага якын ыңгырашып ятты да җомга көн, иртә белән сәгать унда дөньядан үтте.* Г. Ибраһимов.

ДӨНЬЯВИ *с.* Дингә, руханиларга мөнәсәбәте булмаган; чын, реаль күренешләргә һәм фактларга мөнәсәбәтле. *Дөньяви эшләр. Дөньяви проблемалар.* ▭ *Хәзрәт, коръән укып, дога кылып беткәннән соң, - - - сүзен дөньяви тормышка борып җибәрде.* М. Гафури.

ДӨНЬЯВИЛЫК *и.* Дөньяви булу сыйфаты. *Карашларның, хыялларның дөньявилыгы. Сүзләрнең дөньявилыгы. Әсәрләрнең дөньявилыгы.* // Дөньяви эшләрне, мәсьәләләрне яклаучыга хас сыйфатлар. *Шагыйрь, туган иленнән аерылып нинди генә кыен хәлләргә төшсә дә, дәрвишлеккә бирелми, дөньявилыгын саклап кала.* Каз. утл.

ДӨНЬЯ'КҮЛӘМ *с.* Бөтен дөнья җәмгыяте өчен әһәмиятле, барлык илләргә һәм халыкларга карый торган. *Дөньякүләм бурыч.* ▭ *Илебездә дөньякүләм әһәмияткә ия булган зур тарихи эшләр башкарыла.* М. Әмир.

ДӨНЬЯЛЫК *и.* Дөньядагы, чын тормыш; җәмгыять тормышы; *киресе:* ахирәт. [*Кешеләрнең*] *сабыр итүләре аркасында шул авырлыклардан --- чыгуларын, дөньялыкта чыга алмыйлар икән, ахирәттә рәхәт күрәчәкләрен күп мисаллар китереп сөйләделәр* [*муллалар*]. М. Гафури.

ДӨП *авазияр.* 1. Авыр әйбер бәрелгәндә, шапылдап куйганда һ. б. ш. ишетелгән тонык тавышларны белдерә. *Ильяс, артта дөп-дөп аяк тавышы ишетеп, башын калкытып карады.* Р. Төхфәтуллин.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дөп» сыман тавышлар чыгарып. *Таш идәнгә дөп-дөп басып йөрү.* ▭ [*Балалар*] *дөп-дөп бау сикерәләр.* Г. Бәширов. *Ул имәндәй ирләр рәтендә торып --- көн буе дөп-дөп ындыр суга.* Ш. Маннур. *Дөп-дөп тибә йөрәк.* Б. Рәхмәт.

3. *хәб. функ.* «Дөп» сыман тавышлар чыгара торган эшне-хәрәкәтне белдерә. *Тып-тын эшлим. Йөрәк кенә дөп тә дөп.* Ә. Юныс.

ДӨП-ДӨРЕС *с. Артык. дәр. к.* дөрес (1—8 мәгъ.). *Дөп-дөрес хәбәр. Дөп-дөрес җөмлә. Дөп-дөрес җавап.* ▭ *Теге кызылармеец дөп-дөрес әйткән шул.* И. Гази.

ДӨПЕЛДӘҮ *ф.* «Дөп» сыман тавышлар чыгару. *Мотор дөпелдәү. Дагалы итекнең ташка басканда дөпелдәве. Бала-чага дөпелдәү.* ▭ *Саңгырау гына дөпелдәп агач ауды.* А. Гыйләҗев.

ДӨПЕЛТ *авазияр.* Кинәт дөпелдәп куюны белдерә.

ДӨР *авазияр.* 1. Ишле төркем кинәт хәрәкәткә килгәндә, ут кабынганда һ. б. ш. калтыраулы тонык тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дөр» сыман тавышлар чыгарып. *Коры утынның дөр-дөр януы.*

ДӨРЕС *с.* 1. Чынбарлыкны төгәл чагылдыра, фактларга туры килә торган. *Дөрес теория. Дөрес мәгълүмат. Дөрес җавап. Мәсьәләнең чишелеше дөрес булу.* ▭ *Шулай дөрес тә ул: үзеңнән югары белән алыш, аннан да узып кит син. Менә булырсың егет.* Г. Бәширов. // Хак, туры (сүз, юл һ. б. ш. турында). *Дөрес сүзле кеше.* ▭ [*Әдәбиятны*] *дөрес, ышанычлы юлдан яздырырга теләүчеләр дә булды.* А. Шамов. // Урынлы (кисәтү, сүз һ. б. ш. турында).— *Кеше гайрәте таулар кисә диләр. Коммунистлар турында бу сүз бигрәк тә дөрес булырга тиеш.* Ш. Камал. // Оригиналны төгәл чагылдыра һәм бирә торган (тәрҗемә турында). *«Интернационал»ның дөрес, бик дөрес тәрҗемәсен бирүгә конкурс игълан ителде.* М. Җәлил. // *рәв. мәгъ.* Чынбарлыкны төгәл чагылдырырлык рәвештә, фактларга туры килерлек итеп. *Уткәнне, хәзергене, киләчәкне дөрес аңлап һәм дөрес аңлатып тәрбия кылырга кирәк.* М. Максуд.

2. Законга туры килә торган, законлы.— *Мин коммунист башым белән андый дөрес булмаган нәрсәләргә күз йома алмыйм.* Г. Ахунов. // Мораль, әхлак кагыйдәләренә, йолаларга каршы килми торган.— *Сыйрагы сынганга гына чалдың бит син ул кәҗәне, наян; корбаның дөрес түгел синең.* Г. Гобәй.

3. Куелган таләпләргә җавап бирердәй; максатка ярашлы, тиешле. *Иҗатыңда дөрес юнәлеш алу.* ▭ *Сәйфулланы башыннан сыйпап үстергән, укыткан, аңа мөмкин кадәр дөрес, яхшы тәрбия бирергә тырышкан кеше Сабир булды.* Ә. Еники. // Кагыйдәләргә, нормаларга туры килә, җавап бирә торган. *Дөрес чәчү әйләнеше кертү.* ▭ [*Закир*] *Әпипә көен уйный башлый. Ләкин көйне дөрес тавышлардан уйнамый.* Х. Җәмил. // *рәв. мәгъ.* Кагыйдәләргә, нормаларга, таләпләргә җавап бирерлек, туры килерлек итеп. *Дөрес уку. Дөрес тәрбияләү. Исемеңне дөрес язу. Хәрәмләшмичә, дөрес көрәшү.* ▭ *Чалгыны дөрес чүкү, аның йөзен юка итеп чыгару өчен зур осталык кирәк.* Г. Галиев.

4. Төгәл, аныклык. *Дусың дус булсын, исәбең дөрес булсын.* Мәкаль. // *рәв. мәгъ.* Вакытны төгәл күрсәтеп. *Сәгатең дөрес йөрү.*

5. Сәламәт, нормаль, чын; гадәттәгечә (акыл, хәтер, кыяфәт һ. б. турында). [*Габдрахманның*] *үләр вакытына кадәрле исе дөрес булып, үләр алдыннан да сөйләшеп, үзенең васыятен әйтеп, --- бәхилләшеп вафат булды.* М. Гафури. *Кайда синең* [*мещанканың*] *дө-*

рес кыяфәтең? Йөзең — грим, Чәчең парикта. Эчең-тышың белән төренгәнсең, Әкәм-төкәм төсле, кабыкка. М. Җәлил.

6. Намуслы, гадел. [*Айсылу*] *Сәйфинең дөрес кеше булуына чын күңелдән ышанмый иде.* Г. Бәширов.— *Эшем дөрес, Вәли иптәш, ул товарны мин саф акча түләп алдым.* К. Әмири.

7. *и. мәгъ. гадәттә кыек килештә.* Дөреслек, хакыйкать. [*Хәлимнең*] *ялганларга теле бармады, дөресен сөйләп бирде.* Г. Гобәй. *Дөресне язу өчен тирә-як чынлыкны тирәнрәк белергә, аның катлаулы процессларын төшенергә кирәк.* М. Җәлил.

8. *хәб. функ.* Диалогик сөйләмдә, сөйләүченең сүзләрен раслау өчен кулланылып, «әйе», «шулай шул», «чыннан да шулай», «хак» дигән мәгънә белдерә. *Үзең тоткан балыкның тәме дә бөтенләй башка була бит аның, дөресме? — Бик дөрес!* Ә. Еники. *Алтынны бик авыр диләр иде, дөрес икән.* Г. Бәширов.

9. *кер. сүз функ.* Әйтелгән фикергә басым ясауны белдерә. *Дөрес, кеше вакыты белән бар нәрсәгә дә күнегә. Ләкин Габдулла өчен бу мәктәпкә ияләшү авыр булды.* Ә. Фәйзи. *Матурлык ул, дөрес, әйбәт нәрсә, Тик алдый шул, каһәр суккыры.* М. Хөсәен.

10. *кер. сүз. функ.* **Дөресе, дөресрәге, дөресендә** *форм.* Аныграк, төгәлрәк итеп әйткәндә. [*Миңнурның*] *бервакытта да халык алдына чыгып сөйләгәне юк иде, дөресе, аңа сөйләргә туры килгәне юк иде.* А. Шамов. *Беренче көнне Катя артык тынычсызланмады, дөресрәге — тынычсызланмаска тырышты.* И. Гази. *Эшли башладым. Дөресендә, эшләгән булып йөрим.* Ш. Усманов.

◇ **Дөрес килү (чыгу); дөрескә килү (чыгу)** — дөрес булып чыгу, раслану (алдан әйтелгән сүз, фараз һ. б. ш. турында). *Тиз күрешеп булмас дигән идем, Дөрес килде минем юраВым.* К. Нәҗми. *Тормышымның ахыргы өлеше турында әнинең күрәзәчелеге дөрес чыкмады.* М. Гали. *Безнең уйлар дөрескә килер, ахры.* А. Әхмәт. *Бу имеш-мимешләре дөрескә чыкты, ахры?* И. Гази. **Дөресен әйтергә кирәк, дөресен әйтик.** *кер. сүз. функ.*— әйтелгән фикернең дөреслегенә, хак булуына басым ясауны белдерә. [*Нуретдин*] *терлекләрнең нәселләрен яхшырту мәсьәләсен кузгатты һәм, дөресен әйтергә кирәк, шактый катлаулы мәсьәләне гаҗәп бер гадилек белән, һәркем аңларлык итеп әйтеп бирә алды.* Ә. Еники. *Гражданнар сугышыннан кайткач, ауга берничә мәртәбә чыгып карадым. Ләкин, дөресен әйтим, ләззәт таба алмадым.* А. Шамов. **Дөресен әйткәндә** *кер. сүз функ.*— төгәлрәк, аныграк итеп әйткәндә. **Дөрестән дә** — чыннан да. *Үземне мондый иркендә күрү дөрестән дә минем өчен зур бәхет иде.* М. Гали. *Кабартма дөрестән дә тәмле иде.* Г. Гобәй.

ДӨРЕСЛЕК *и.* 1. Дөрес (1—7 мәгъ.) булу хәле. [*Айтуган карт*] *үлчәүнең дөреслеген күзәтеп тора.* Г. Бәширов.

2. Хакыйкать, хаклык. *Үзара сөйләшеп кенә кешеләр дөреслекне табалар.* Ә. Еники. [*Миңнур карт*] *күз алдында хаклыкның, дөреслекнең, турылыкның күмелеп калуына әрни.* А. Шамов.

ДӨРЕСЛЕКТӘ *кер. сүз.* Асылда, чынлыкта.

ДӨРЕСЛӘҮ *ф.* 1. Сүздәге, язудагы һ. б. ш. ялгышны төзәтү. *Мин игъланда ялгыш язылган* [*сүзне*] *дөреслә, төзәтеп куйдым.* Ф. Әмирхан. // Дөрес (4 мәгъ.), төгәл итеп кую, җибәрү. *Рәхим, стенадагы сәгатькә карап, сәгатен дөреслә куйды.* А. Расих.

2. Берәр нәрсәнең дөрес булуын, дөреслеген дәлил белән раслау. *Иптәше аның сүзләрен дөреслә гән рәвештә баш ишарәсе генә ясаштырып утыра.* Ш. Камал. // Дөрес дип табу. *Абзый күп вакытта өйдә тормаганга күрә, өйдә торса да һәрбер эштә җиңги сүзен дөреслә гәнгә, без җиңгинең зәһәрле күз карашы астында изелергә - - - мәҗбүр идек.* М. Гафури. // Раслау, дөрес дип тану, күрсәтү. [*Хат язучы:*] *Шуның белән хәбәр итмәк булдык үзебезнең исән-сау торуыбызны. Һәм дә дөреслим синең хатыңны алганлыгымны.* Ш. Мөдәррис.

ДӨРЛӘҮ *ф.* «Дөр» сыман тавышлар чыгару (ут, ялкын һ. б. турында). Коры утынның дөрләп яну. // Ныграк гөжләп, катырак гөрләп яна башлау; көчәю (ут-ялкын һ. б. турында). *Керосин сипкәч учакның дөрләп китүе.* □ *Шырпы уты түзә алмый җилгә, Күмер уты җилдә дөрли генә.* Г. Хуҗиев. // Керосин лампасы, аның уты турында: ялкыны артык сузылып һәм бик сөремләнеп яна башлау. *Мөршидә дөрләргә якынлашкан лампаның фитилен кысты.* К. Тинчурин.

ДӨРС *аваз ияр. сир. к.* гөрс. [*Зәки*] *авыр гәүдәсе белән дөрс итеп идәнгә егылды.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Аларны шулай дөрс-дөрс атлатып алып бара торгач - - - бер йортның алдына туктаттылар.* М. Гафури.

ДӨРСЕЛДӘҮ *ф.* «Дөрс» сыман тавышлар чыгару; гөрселдәү. *Завод цехындагы дөрселдәп тора торган механизмнар. Кискән агачның дөрселдәп авуы. Тулы капчыкның машинадан җиргә дөрселдәп килеп төшүе.* // Җиңелчә дөпелдәү. *Авыру күкрәктә тибә Дөрселдәп әле яшь йөрәк.* Б. Рәхмәт.

ДӨРТ *аваз ияр.* Ишле төркем кинәт хәрәкәткә килгәндә, мотор, ут кабынганда барлыкка килә торган һ. б. ш. гөрелдәүле кискен тавышны белдерә.

ДӨЯ *и.* Бер яки ике өркәчле, эре гәүдәле күшәүче хайван (чүлдә яки ярым чүлдә яши). *Чүлне дөягә атланып кичү. Дөя асрау.* □ *Кәрванны әйләнеп, әле яңа дөядән төшкән анасы янына килде* [*кыз*]. Г. Ибраһимов.

ДӨЯЧЕ *и.* Дөя караучы яки юлда аларны йөртүче.

ДӨҢ *аваз ияр.* 1. «Дың» сыман, ләкин нечкәрәк яңгырый торган тавышларны белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дөң» сыман тавышлар чыгарып. [*Базардагы*] *әйләнчек эчендә берәү бик кыландырып гармун уйный, икенчесе мичкә кебек зур бер нәрсәне дөң-дөң суга.* Ә. Фәйзи.

ДӨҢГЕЛДЕК *с.* Дөңгелди торган.

ДӨҢГЕЛДӘҮ *ф.* «Дөң» сыман тавышлар чыгарып дөпелдәү. *Бер генә очередь җибәрәсе* [*атасы*] *иде үзләренә* [*илбасарларга*]*! Туң бүрәнәләр кебек дөңгелдәп аварлар иде.* Ф. Кәрим. [*Өмәгә*] *чыккач, сынатып буламыни? Алты чабагыш бит ул. Көлтәләр дөңгелдәп, биеп кенә йөри* [*сукканда*]. Ш. Маннур.

ДӨҢГЕР *аваз ияр.* 1. Дөбердәү катнаш «дөң» тавышларын белдерә.

2. *рәв. мәгъ. каб. форм.* «Дөңгер» сыман тавышлар чыгарып. *Бәрәңгеләрнең колашадан дөңгер-дөңгер төгәрәп төшүе. Балаларның уенчык машиналарын идәндә дөңгер-дөңгер йөртүе.*

ДӨҢГЕРДЕК *с.* Дөңгерди торган. *Шәһәрләр үсеше тарихында берничә дистә еллар буена урамнарга эре ташлар түшәлде. Арбага утырып йөрер өчен дөңгердек булса да, ул инде яңгырда изрәми торган ныК, чиста урам иде.* С. Баттал.

ДӨҢГЕРДӘҮ *ф.* «Дөңгер» сыман тавышлар чыгару; нечкәрәк яңгырап дыңгырдау. *Яңгыр тамчыларыннан түбә калае дөңгердәү.* □ *Ватык вагон тәгәрмәчләре дөңгердәп бара.* Ф. Кәрим.

ДӨҢГЕРТ *аваз ияр.* Кискен дөңгердәп куюны белдерә.

ДӨҢГЕЧЛӘҮ *ф.* 1. *к.* дыңгычлау. *Китаплар белән дөңгечләп тутырылган кара чемодан җилкәне шактый баса башлаган иде.* З. Нури.

2. Сугып, бәреп, шакып тору. [*Машинадагылар*] *кабинаның түбәсен дөңгечләргә тотындылар.* Г. Ахунов. *Дүнгән дип башын җеп белән үлчәделәр һәм аны урынына утыртыр өчен дөңгечләп карадылар.* Ә. Фәйзи. // *күч. сөйл.* Кат-кат сугу, кыйнау. [*Суд ясаучылар*] *Мусаның авызын үзләре дөңгечләрдәй булып утырдылар.* Ш. Маннур.

ДӨҢК *аваз иәр.* Шапылдап, кискен дөңгелдәп куюны белдерә. *Ә Миңгали сәкедән Егыл да кит йөзтүбән! Берне бирим дигәндә, Динкәй башын игән дә, Кизәнүе буш киткән, Үзе идәнгә дөңк иткән!* Н. Исәнбәт.

ДҮДӘК *и.* Тиз йөгерүче, озын муенлы, зур гәүдәле дала кошы; *русчасы:* дрофа. *Яз килеп җитте --- Елгачыклар, күлләр дүдәк, торналар белән тулды.* А. Расих.

ДҮЛӘНӘ *и. бот.* Агач яки куак төрләренең берсеннән булган чәнечкеле үсемлек (койма рәвешендә яки матурлыкка үстерелә); *русчасы:* боярышник.

ДҮНҮ *ф.* **1.** *иск.* Бер нәрсәдән икенче нәрсәгә, бер төрдән икенче төргә әверелү. *Сагынып еласы булсам, гомергә Эчем янып дүнәр кара күмергә.* Г. Кандалый.

2. Аумакайлык күрсәтү, икенче якка күчү. *И падишаһ, мин сине бик иләс-миләс күрдем. Бер сүздә бер дә тормыйсың, гяһ вәзирләр ягына дүнәсең, гяһ минем якка.* К. Насыйри. // Фикердән, караштан һ. б. ш. кайту, баш тарту. *Карарыбыздан дүнмибез.* К. Насыйри. // Диннән ваз кичү, икенче дингә күчү турында.

3. *диал.* Караңгы чырайлы булу (ачудан, үпкәләүдән һ. б. ш.). [*Әти*] *миңа һәм сеңелләремә артык катылык та күрсәтми, фәкать күбесенчә йөз бирми, дүнеп тора иде.* Ш. Камал.

ДҮРТ *сан.* **1.** Өчтән соң килеп, 4 санын, микъдарын белдергән сүз.

2. *и. мәгъ. к.* дүртле 3. *Безнең дуслар дүрткә, бишкә укый.* Ж. Тәрҗеманов.

◇ **Дүрт аякланып (аяклап) йөрү** — үрмәләү, мүкәләү. *Һай, гомер дигәнең, җил шикелле исеп кенә тора, әле кайчан гына дүрт аяклап, мүкәләп йөргән бала иде, ә бүген үнөч яшь тула үзенә.* А. Әхмәт. **Дүрт күз белән көтү**—бик көтү. *Уенны дүрт күз белән көтәм.* М. Фәйзи. *Халыкның дүрт күз белән көткән өметләре вакытча киселде.* Ш. Мөхәммәдев. **Дүрт стена эчендә (арасында) яту** — өй эчендә, семья эчендә генә бикләнеп яшәү, җәмәгать тормышыннан читләшкән булу турында. *Дүрт стена эчендә ятып әле берәүнең дә яхшы ана да, яхшы гражданка да була алганы юк.* И. Гази. **Дүрт ягың кыйбла** — теләсең кая барырга ирекле. [*Кәширов*] *хәзер һавадагы кош дәрәҗәсендә ирекле, дүрт ягы кыйбла, кая китсә дә, ни кылса да, иреге бар.* Г. Ибраһимов.

ДҮРТЕНЧЕ *Тәртип саны. к.* дүрт 1.

ДҮРТЕНЧЕЛ *с.* Дүртенче (үсеш-үзгәреш буыннарының эзлеклелегендәге шул баскыч, тәртип, дәрәҗә, стадия турында). *Дүртенчел чор.*

ДҮРТКЕЛ *с.* **1.** Дүрт кырлы яки дүрт яклы, квадрат яисә куб формасындагы. *Зурлыгы белән бусы [бүлмә] иске фатирдан әллә ни аерылмый, әмма тегесе озынчарак, бусы дүрткел иде.* Ә. Фәйзи.

2. *и. мәгъ.* Квадрат яки куб формалы нәрсә. *Магистральгә тигез дүрткел итеп кискән гранит таш җәелгән.* Ш. Маннур.

ДҮРТКЕЛЛЕ *с.* Дүрткел формалы.

ДҮРТКЕЛЛӘҮ *ф.* **1.** Дүрткел формасын бирү. *Чыгарган ташны дүрткелләп өеп кую.* □ *Мәйданның сул ягында — дүрткелләп эшләнгән һәйкәл.* С. Шакир.

2. *диал.* Дүрт катлап бөкләү. *Җәймәне дүрткелләп төрү.*

ДҮРТЛЕ *и.* **1.** 4 цифрының исеме. *Тактадагы дүртлене күчереп ала алмыйча җан тирләре чыга Бәкернең.* Г. Гобәй.

2. *с. мәгъ.* Куллану әйберләренең (кием-салым, төрле җиһаз һ. б.) тиешле размерын, зурлык үлчәмен белдерә торган сүз. *Дүртле галош.*

3. Мәктәптә: «яхшы» билгесе (биш баллы системада иң югары билгедән түбәнрәге). *Аның табелендә бер генә дүртле билгесе.* А. Әхмәт.

ДҮРТЛЕК *с.* **1.** Дүрткә бүләргә җитәрлек.

2. Дүртле билгесенә торырлык, җавап бирерлек.

3. *и. мәгъ.* Махсус бурыч башкару өчен төзелгән дүрт кешелек төркем, орган. *Батальоннарда [яшерен] өешма дүртлек тәртибендә төзелде.* Ш. Маннур.

ДҮРТЛӘП I *Чама саны. к.* дүрт 1.

ДҮРТЛӘП II *рәв.* Дүрткә аерып (үрү-ишү һ. б. ш. турында), дүрт буйдан. *Чыбыркыны дүртләп ишү.* □ *Кара бөдрә чәчләремне Дүртләп үрәсем килә.* Җыр.

ДҮРТЛӘТЕЛГӘН *с. мат.* Дүрткә тапкырланган.

ДҮРТЛӘТӘ *рәв.* Дүрт тапкырга. *Дүртләтә арттырып үтәү.*

ДҮРТӘР *Бүлем саны. к.* дүрт 1.

ДҮРТӘРЛЕ *с.* Һәр рәтендә, төркемендә, буынында дүртәр берәмлек булган. *Дүртәрле саф.*

ДҮРТӘРЛӘҮ *ф.* **1.** Дүртәрле төркемнәргә аеру, бүлү (сафка тезгәндә һ. б.).

2. *рәв. мәгъ.* **дүртәрләп.** Дүртәр-дүртәр итеп. *Балаларны сафка дүртәрләп тезү.*

ДҮРТӘҮ 1. *Җыю саны. к.* дүрт 1. *Бездәге агым сулар арасында иң зурлары һәм мәшһүрләре — дүртәү.* Г. Бәширов.

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* Дүртәүләшеп, дүртәү бергә. — *Дүртәү сугыштык.* Г. Тукай.

ДҮРТӘҮЛӘП *рәв.* Дүртәү булып, дүртәү бергә. *Дүртәүләп пароходка утырып Ялтага киттек.* С. Әдһәмова.

ДҮРТӘҮЛӘШЕП *рәв.* Дүртәү бергә, дүртесе дә. *Бик зур хаҗи кайткан, имеш; әйдә йөгер Дүртәүләшеп дүрт әт төсле, дөбер! дөбер!* Г. Тукай.

ДҮШӘМБЕ *и.* Календарь атнаның беренче көне. *Ял көне эшләгәнлектән, дүшәмбедә Гөлшаһидә больницага төштән соң гына килде.* Г. Әпсәләмов.

ДҮҢГӘЛӘК *и.* Дала һәм чүлдә үсә торган ярым куак яки үлән үсемлек (орлыгы өлгереп җиткәч, тамырыннан аерылып җил уңаена тәгәрәп йөри); *русчасы:* перекати-поле. *Салкын көз килеп җитте. Яңавыл урамнарында хәзер ком өермәләре уйный. Урамнар буйлап йомарланып чәнечкеле дүңгәләкләр тәгәри.* А. Расих.

Е

Е Татар алфавитында алтынчы хәреф.

ЕВРЕЙ *и.* Б. э. к. I—II йөзләрдә Палестинада яшәгән халыктан килеп чыгып, соңыннан төрлә илләргә таралган, ләкин уртак милли үзенчәлекләрен, өлешчә дин уртаклыкларын саклаган халык (нигездә үзләре яшәгән илдәге төп халык телендә сөйләшәләр). // Шул халыкның бер вәкиле. *Шәрәфи агай байтак еллардан бирле промыслочы еврейләрдә хезмәт итә иде.* Ш. Камал,

ЕВРЕ'ЙЧӘ *рәв.* Еврей телендә. *Рита үзе еврей кызы. [Ләкин] еврейчә сөйләшә белми.* Р. Ильяс.

ЕВРО'ПАЛАШТЫРУ *ф.* Европа үрнәгенә, гадәтләренә яраштырып үзгәртү. *Гаспринский һәм аның фикердәшләренең [милләт өчен «тырышулары»] борынгы дини мәдрәсәләрне реформалау, милләтне европалаштыру, яңача укуны яклаудан ерак китмәде.* М. Җәлил.

ЕВРО'ПАЛАШУ *ф.* Европа үрнәгенә, гадәтләренә иярү. *[Абыйзов] ничек кенә европалашмасын, эше бөтенләй татар байларынча килеп чыккан.* Г. Ибраһимов.

ЕВРО'ПАЛЫ *и.* Европада яшәүче яки чыгышы белән шуннан булган кеше. *Галата — Истамбулның иң зур өлеше, европалылар яши торган район.* Ш. Камал. //с. *мәгъ.* Европада яшәүче яки чыгышы белән шуннан булган. *Европалы колонизаторлар.* □ *Беэгә — шәрык хатын-кызына европалы хатын-кыз дәрәҗәсенә җитәргә бик ерак бит әле.* К. Тинчурин.

ЕВРО'ПАЛЫЛЫК *и. сир.* Европага хас булган тәртип, гадәтләргә мәхәббәт, шуңа ияруҗәнлек. *[Уфа шәһәренең] «авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем --- европалылыгымны, шау-шу яратучанлыгымны --- үчекләгән кебек булды.* Г. Тукай.

ЕВРО'ПАЧА *рәв.* Европа илләрендә кабул ителгәнчә, Европа илләрендәге кебек. *Европача киену.* □ *Ислам байның европача җиһазландырылган кунак бүлмәсе.* Т. Гыйззәт.

ЕГЕРМЕ *Төп сан.* 20 санын һәм микъдарын белдерә торган сүз. *Егерме уннан ике мәртәбә зур. Егерме километр. Егерме яшькә җитү.*

◇ **Егерме бер** — комарлы карта уенының бер төре; очко. *Бер карчык үзенең карта уйнап эштән чыгып беткән улына: «Их улым, улым, «шул егерме бер» харап итте инде сине»,— ди икән.* М. Гали.

ЕГЕРМЕБИШМЕҢЧЕ *и. тар.* 1930 елда, партия чакыруы буенча, промышленность үзәкләреннән оештыру эшләре өчен колхозларга җибәрелгән 25 мең алдынгы эшченең берсе. *Егермебишмеҥче иптәшләрнең Берсе булып килгән иде ул.* Х. Туфан.

ЕГЕРМЕЛЕК *и. сөйл.* Егерме сумлык кәгазь акча. *[Әгъләм:] Әнә әби патша акчалары. --- Астагы саргылты кәгазьлеләре егермелеге.* С. Рафиков.

ЕГЕРМЕЛӘП *Чама саны. к.* егерме. *Бер комсомол егет егермелəп фашист өстенә берүзе ташланды.* Г. Бәширов.

ЕГЕРМЕНЧЕ *Тәрт. саны. к.* егерме. *Егерменче гасыр. Егерменче әйләнеш.*

ЕГЕРМЕШӘР *Бүл. саны. к.* егерме. *Валда --- егермешәр, утызар кеше чиратлашып эшләгәнгә, күп халык арасында аның авыры боларга [тачкачыларга] тими дә иде.* Ш. Камал.

Е'ГЕРЬ *и.* 1. Профессиональ аучы.

2. *хәрби.* Кайбер армияләрдә (атлы яки җәяүле) махсус укчылар полкында хезмәт итүче солдат. *Атлы егерь. Таулы егерь дивизиясе.* □ *Кара кителле исерек егерьләр --- атака артыннан атакага күтәрелделәр.* Г. Әпсәләмов.

ЕГЕТ *и.* 1. Яшүсмерлектән өлгергәнлек чорына күчкән, буйга җиткән яшь ир кеше. *Малай чак белән егет чак чиген сизми дә калдык.* А. Гыйләҗев. *Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.* Мәкаль. // Өйләнмәгән, буйдак ир кеше (төрле яшьтәге). *Яшьтән сөйгән үз танышың егет башы белән шулай өзелеп тора икән, әйдә, кире какма, андыйлар хәзер бик исәпле.* Г. Бәширов. // Гомумән ир кеше.— *Бүген менә таныш егет [Газизәнең ире Төхфәт] үлгән, шуның кайгысы белән йөрибез.* Ш. Камал.— *Без, Идел буеның егетләре, --- тарих битенә яңа батырлыклар сызарбыз.* К. Нәҗми. // *тарт. форм.* «Сөйгән яр» мәгънәсендә. *[Гайния:] Сүз биргән егетем бар, аны көтәм.* Г. Ибраһимов. *Алсуланып, матур булып җәйге таң ата. Бер чибәр кыз зур сугышка егетен озата.* Э. Ерикәй. // *энд. сүз мәгъ. күпл.* «Иптәшләр, дуслар» мәгънәсендә. *[Мәхмүт:] Забастовка игълан итәбез, егетләр!* Ш. Камал. *Дан казанып кайтыгыз илебезгә, егетләр!* М. Җәлил.

2. *күч.* Уңганлык, тәвәккәллек, кыюлык, батырлык, намуслылыкны белдерә торган мактау сүзе буларак кулланыла. *[Тимери:] Үзеңнән югары белән алыш, аннан да үзың кит син. Менә булырсың егет. Мактыйм мин Аланбашны, егет алар.* Г. Бәширов. *Егет булып яшәгән кеше егет булып китә дә белергә тиеш.* Г. Әпсәләмов.

ЕГЕТЛЕК *и.* 1. Яшьлек, егет чак, егет булу чоры. *Егетлек кадерен картлар белер.* Мәкаль.

2. Кыюлык, батырлык, тәвәккәллек. *Байлык — бер айлык, егетлек — гомерлек.* Мәкаль. *[Моратай] Идел кичеп, ил гизеп, --- бик озак сугышып йөргән. Егетлеге белән дан алган.* Г. Бәширов. // Көч, гайрәт.*[Николай белән Шәрәфи картның көрәшкәнен карап торучылар:] Бирешмә, Шәрәфи абзый!— Бәр таза гына! Күрсәт егетлегеңне!* Ш. Камал. // Күркәм, мактала торган эш. *[Зыя:] Гали бабай! Барыбер сер ачылды инде, мин сиңнән егетлек сорыйм, син минем юлыма койма булма!* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Егетләргә хас. *Сәрвинең көнләп соравы [Габдулланың] егетлек горурлыгын китерде.* Ә. Фәйзи.

3. Сафлык, гыйффәт. *Мин биш ел солдат булып йөрдем, әмма ләкин үземнең егетлегемне сакладым.* А. Расих.

ЕГЕТЛӘНДЕРҮ *ф. сир.* Батырайту, кыюландыру, үз көченә ышана торган итү. *Кешене егетләндерә торган нәрсә — фәннәр.* К. Насыйри.

ЕГЕТЛӘНҮ *ф. ирон.* 1. Егет (1 *мәгъ.*) булып күренергә тырышу (яшүсмерләр турында); батыраю, кыюлану. *Фирдәвес, егетләнеп, бер дә исе китмәгән кебек, кызга кулын сузды.* М. Хәсәнов.

2. Егетләрчә (1 *мәгъ.*) кылану. *Ул Мәрвәр тирәсендә яратучы булып, ягъни яратам дип үзен ышандырырга тырышып, башта бик егетләнеп, бөтерелеп йөрде.* Ә. Еники.

ЕГЕ'ТЧӘ, ЕГЕТЛӘ'РЧӘ *рәв.* 1. Егетләргә, яшьләргә хас булганча (йөреш-торышта, үз-үзен тотуда һ. б.). [*Нәгыйльмнең*] *егетчә кыйланышлары да табигый түгел, көчләнеп, тәкәллефләнеп кыйланган төсле күренә.* Ш. Камал. *Сөләйман абзый егетләрчә җәһәт сикереп аякка басты.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Батырларча, кыю, куркусыз. [*Нуруллин*] *гражданнар сугышы елларында үз бурычын егетләрчә үтәгән.* А. Шамов. *Егет үлеме егетчә булырга тиеш.* Ш. Маннур.

ЕГЕТ-ҖИЛӘН *җый. и.* Егетләр һәм яшүсмерләр. *Авылның бөтен халкы диярлек — ире-хатыны, карты-карчыгы, баласы-чагасы, килене-кызы, егет-җиләне — һәммәсе Гыйрфан байның йорты эченә тулган иде.* Г. Ибраһимов.

ЕГИ'ПЕТЛЫ *и.* Египетта (Мисырда) яшәүче төп халык вәкиле.

ЕГИПТО'ЛОГ *и.* Борынгы Египетны (Мисырны) өйрәнүче белгеч.

ЕГИПТОЛО'ГИЯ *и.* Борынгы Египетның (Мисырның) тарихын, экономикасын, телен, сәнгатен һ. б. өйрәнә торган фәннәрнең җыйма атамасы.

ЕГУ *ф.* 1. Көч белән (сугып, бәреп, этеп, тартып һ. б.) аудару, аварга мәҗбүр итү. *Федорны, өстәл арасыннан чыгарып, җиргә екканнар, ике кеше берьюлы кыйныйлар.* Ш. Камал. *Габдулла берьюлы дүрт ашыкны бәреп екты.* Ә. Фәйзи. // Үсеп утырган агачны, игенне һ. б. кисеп яки чабып аудару. *Кайсын егарга соң бу асыл агачларның?* И. Гази. [*Комбайнчылар*] *беренче гектарларны тезмәләргә егып кайттылар.* Р. Төхфәтуллин. // Атып үтереп яки җәрәхәтләп аудару. *Яуга чыксаң — атылып чык, Дошман күрсәң — атып ек.* Ш. Маннур. *Җиңү таңын яулаганда, Ядрә екты ахры егетне.* М. Җәлил. // Югарыдан җиргә аударып төшерү. *Биби, кәттән тартып җибәреп, Хәмзәне* [*урындыктан*] *егып төшерә.* Г. Камал.

2. Җиргә ию, сөрлектерү (игенне).

3. *спорт.* Җиңү, аркасы белән җиргә салу (көрәшкәндә). *Көрәшне малайлар башлап җибәрде. Габделхәй дә чыгып, бер малайны егып, икенчесеннән үзе егылып, ике йомырка алып керде.* М. Гали. *Мәйданда екканбатырдан яуда еккан батыр олы.* Мәкаль.

4. *күч.* Каршы тора алмаслык итү, җиңү.— *Көрәш законы каты бит: я сине ега, я син егасың.* Р. Ишморат. *Бу сөйләшү Рифатны тәмам екты. Хәзер ни әйтсәм дә минем сүземнең төпле булуына малайларда нык ышаныч туды.* Н. Исәнбәт.

5. *күч. сөйл.* Төшерү, куу (эш башыннан). *Бөтен Путилов заводы эшчеләре керенщинаны бүген дисә бәреп егарга торалар.* Ш. Камал.

6. *күч. сөйл.* Кыру, һәлак итү. *Балаларны тиф егу.* □ *Бүре - - - малларыбызны ега.* М. Әмир.

7. *күч. сөйл.* Каты тәнкыйтьләү, юкка чыгару. [*Громов:*] *Шушы кешеләр горкомда отчетымны ектылар, шушы кешеләр монда графикны өзделәр.* Н. Исәнбәт. // *сөйл.* Имтихан алганда начар билге кую.

8. *күч.* Ихтирам итмәү, (кемнең дә булса исеменә, намусына һ. б.) тап төшерү. [*Бабасы Габдуллага:*] *Атаң мәрхүм дә галим кеше иде синең. Менә, исемен екма инде атаңның.* Ә. Фәйзи. // Игътибарсыз калдыру, тыңламау (сүзне). *Бу сүзләрдән соң мин, аларның сүзен екмас өчен, - - - түбәндәге бәетләрне борчак кеби тездем.* Г. Тукай.

◇ **Егып салу** — өстенрәк, яхшырак, көчлерәк булу. [*Сергей Яковлевичның коллоквиум дигәне*] *үзенең катылыгы белән кайберәүләрнең зачетларын егып сала.* Э. Касыймов.

ЕГЫЛА-ТОРА *рәв.* 1. Бер егылып, бер торып; бик авырлык белән. // *күч.* Акрын гына (зур каршылыклар аша барган иҗтимагый үсеш, прогресс турында). *Мәдәният мәйданында урын алыйк, Егыла-тора алга таба атлыйк.* Г. Тукай.

2. Бик ашыгып, кабаланып. *Егыла-тора йөгерү.*

Е'ГЫЛГАНЧЫ *рәв.* Арып хәлдән тайганчы. *Егылганчы көлү. Егылганчы эшләү.*

ЕГЫЛУ *ф.* 1. Тигезлекне югалтып (җиргә) аву, югарыдан түбәнгә мәтәлеп килеп төшү. *Мәйданга килеп кердек дигәндә генә, күзләрем тонып китеп, әллә нәрсәгә сөртенеп, мин шап итеп җиргә егылдым.* М. Гали.— *Бүген атка печән салганда, утлыкка егылып, кулбашымны имгәттем.* Т. Гыйззәт. // Аяк өстендә басып тора алмыйча җиргә аву (арып, хәлсезләнеп, яраланып һ. б.). *Узенә пуля тиеп егылгач та... [ул] сугыш кырын ташламады.* Ш. Усманов. *Хәлим, тәмам хәле бетеп, карга егылды.* Г. Гобәй. // Җиргә иелү, сөрлегү (җил, яңгыр, боз һ. б. көче белән). *Бодай, артык котырып уңганлыктан, җил-давылда егылгалаган егылуын.* М. Шабай.

2. *күч.* Каты авырып китү, каты авырып яту. *Эти мескен, мин мәдрәсәгә кергән көзне авырый башлап, декабрь числоларында түшәккә егылды.* М. Гафури. // Һәлак булу, үлү. *Син корал тот һәм ал әткәң үчен,— Мин сугышта әгәр егылсам.* Ш. Маннур.

3. *и. мәгъ. күч.* **егылган.** Гадәттә кыек килеш формаларында: кыерсытылган, авыр хәлдә калган кеше. *Егылганны түбәләмиләр.* Әйтем. *Бәхетле шул баладыр, - - - Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга юл бирсә.* Г. Тукай.

4. *күч. сөйл.* Зур үтенеч белән мөрәҗәгать итү, ялыну, ялвару.— *Йомыш төшкән саен аңа* [*Маликка*] *барып егылырга туры килә.* И. Гази.

5. *күч. сөйл.* Җиңелү, җимерелү, таркалу (хөкүмәт, аның башында утыручы реакцион көчләр һ. б. турында). *Без - - - Керенский егылганын көтмәдек, күрше бояр-ларның җирләрен җәйдән үк сөреп чәчтек, йортларын тартып алдык.* Г. Ибраһимов.

6. *күч.* Авыр, уңайсыз хәлгә калу; уңышсызлыкка очрау. *Иптәшләрем күңелсезләнергә бирмәсәләр, башкалар матди егылудан саклап калдылар.* Г. Кутуй.— [*Галиябану роленә*] *белеп тотын, кызый! Егылсак, синең аркаңда гына егылырбыз.* Г. Бәширов. // *сөйл.* Начар билгесе алу. [*Җиһангир*] *ике тапкыр имтиханда егылды.* Г. Ибраһимов.

7. *рәв. мәгъ. күч.* **егылып.** Бик каты, бик нык. *Игеннәр егылып уңу.* □ [*Хәзрәтнең биюеннән*] *бөтен йорт халкы егылып көлделәр.* Ф. Әмирхан.

Егылып китү — кинәт, искәрмәстән егылу турында. *Менә ул капыл гына җиргә егылып китте.* М. Гафури. **Егылып төшү** — 1) югарыдан түбәнгә мәтәлеп килеп төшү. [*Авыл*] *янына аэроплан егылып төште.* И. Гази. *Кара карганың баласы караңгы төндә оядан ялгыш егылып төшкән.* А. Алиш; 2) *күч.* уңышсызлыкка очрау, кыен хәлгә калу.— *Егылып төшәргә туры килсә, кара, ул вакыт аяк астында минем җилкәм булмас.* Ф. Бурнаш. **Егылып яту** — 1) *к.* егылып китү. *Тигез җирдә егылып яту;* 2) егылып, тора алмау. — *Атларыгыз,* [*тышаулары*] *агач төбенә эләгеп, егылып ятмасыннар.* М. Гафури; 3) *күч.* дәвамлы каты авыру турында.— *Менә егылып ятам бит. - - - Ярый ла, ятып-ятып, яңадан аякка баса алсаң.* Ә. Фәйзи.

◇ **Егылып үлү** — 1) кинәт үлү турында. *Кешеләр юлда егылып үлә башладылар.* А. Шамов; 2) *шаярт.* Кем яки нәрсә өчен үз-үзен корбан итәргә хәзер булу. *Килгән кодаларның хакы өчен җырлау түгел, егылып үләрмен.* Җыр.

ЕГЫЛЫШУ *ф.* 1. Күпләрнең бер-бер артлы егылулары турында. — *Малайлар егылышып-егылышып калалар, ә мин бер дә егылмадым.* И. Гази.

2. *рәв. мәгъ. күч.* **егылышып.** Бик каты, бик нык. *Өй эче шау-гөр килә, бөтенесе егылышып көләләр, кулларын чәбәкиләр.* Г. Бәширов.

ЕГӘР *и.* Физик көч, куәт.— *Сукса тимер өзәрлек егәре булган кеше [абзар көрәп йөримени]. Заводка баралар аны.* Ф. Сәйфи-Казанлы. // Эшчәнлек көче, энергия.— *Егерме минут эчендә [никадәр] егәрне урладыгыз!— диде Гәрәй, әрнеп.* А. Гыйләҗев.

Егәре китү (бетү) — 1) көчсезләнү, хәлсезләнү; 2) егәрлеге, эшли алу, энергия бирү мөмкинлеге кимү.— *Бер дә кирәкмәскә суны буып куйдыгыз. Сезнең аркада безнең станциянең егәре китә башлады.* Ф. Хөсни.

ЕГӘРЛЕ *с.* Көчле, куәтле, таза. *Ябык чак — егәрле чак.* Әйтем. *Дилбегәне кагып җибәрү белән, егәрле мал йөрешен кызулатты.* С. Рафиков.

ЕГӘРЛЕК *и.* 1. *физ. тех.* Вакыт берәмлеге эчендә башкарылган эш микъдары белән исәпләнә торган зурлык. *Эшче егәрлек. Алмаш ток егәрлеге. Тракторның тарту егәрлеге.*

2. Нәрсәнең дә булса көч-куәт, файда бирү, җитештерү мөмкинлеге. *Автохуҗалык паркын тулы егәрлегенә файдалану.*

ЕГӘРЛЕЛЕК *и.* Егәрле булу сыйфаты. *Эксперименталь станокны егәрлелеккә сынау.*

ЕГӘРЛӘНҮ *ф.* Егәрлелеккә ия булу, хәлләнү, көч җыю (кешегә карата). *Мин шактый егәрләнә төштем.* М. Шабай.— *Мин моңарчы авыруның, егәрләнеп китеп, аякка басуына ышана идем әле.* Ш. Маннур.

ЕЛ *и.* 1. Җирнең Кояш тирәсендә бер кат әйләнеп чыгуына тигез вакыт үлчәү берәмлеге (1 январьдан исәпләнеп, 12 календарь айны эченә ала). *Узган ел. Бер мең тугыз йөз алтмыш дүртенче ел. Ел вакытларының алмашынуы.* □ *Егерме дүртенче елның язын Сарман авылы бик күп яңалыклар белән каршылады.* Һ. Такташ. // Нинди дә булса көннән исәпләнгән 12 ай вакыт арасы. *Бу өч елның миңа һәр сәгате, һәр көне елдай озын булып тоелды.* А. Шамов.

2. Вакыт, срок; яшь. *Зыяның солдатка каралыр елы якынаеп килә.* Г. Ибраһимов.

3. Нинди дә булса эшләр, занятиеләр циклы башкарыла торган вакыт арасы, чор. *Авыл хуҗалыгы елы.* □ *Җәй узды. Тагын уку елы башланды.* Н. Дәүли.

4. *күпл.* **еллар.** Берничә елны эченә алган вакыт арасы, чор. *Революция еллары. Яшьлек еллары. Авыл хуҗалыгын коллективлаштыру еллары.* □ *Алар сүзне икенче темага күчерделәр, студентлык елларын хәтерләделәр.* А. Расих.

5. *күпл.* **еллар.** Дистә тәртип саннары белән килгәндә ун ел эчендәге вакыт арасын белдерә. *Егерменче елларның беренче яртысында инде татар әдәби көчләренең күпчелеге Казанда эш алып бара башлады.* Г. Халит.

Ел ашы *иск. дини.— к.* елын уздыру. *Нуретдиннең «кырык кичәсе» дә үтте, «ел ашы» да үтеп китте.* Ш. Камал. **Ел исәбе** — шартлы рәвештә алынган нинди дә булса тарихи бер моментка мөнәсәбәттә вакытны еллар белән күрсәтү системасы. *Һиҗри ел исәбе. Милади ел исәбе.* **Ел(ы) тулу** — алдан каралган, билгеләнгән эш, хезмәтнең һ. б. үтәлү срогы, вакыты җитү. *Бу рус Усман белән бергә солдатка алынганнар. Бергә хезмәт иткәннәр. Ел тулып котылыр вакыт җиткәч, бергә-бергә кайтырга дип йөргәндә, тегене тотып ябалар.* Г. Ибраһимов. **Ел тәүлеге** — *к.* ел әйләнәсе. *Ел тәүлеге уникә ай, бик сагынган чак була.* Җыр. **Ел әйләнәсе** — бер ел эчендәге вакыт арасы. *Ел әйләнәсенә барлыгы биш-ун хат аласың, шунда да боларны язучылар, әйтерсең лә, кешене күңеллеләндерерлек һичнәрсә язмаска сүз куешканнар.* Ш. Камал.

◇ **Ел озынлыгы** — бик озын. *Ел озынлыгы кышкы төн үзенекен иткән — әти тәмам арыган да, бераз ял итеп алырга дип, кар өстенә утырган.* В. Нуруллин. **Елның ел буена** — бөтен ел дәвамында. [*Сыерларны*] *елның ел буена сусыл яшел азык белән тәэмин итеп торырга кирәк.* Сов. әд. **Елның елында** — һәр елны, ел саен.— *Былтыр да бит без эш көненә өчәр килодан бүлдек. Колхоз өшканнан бирле елның елында шулай.* Г. Бәширов. **Елы белән, елы-елы белән** — кайбер елларда (ел саен бер үк дәрәҗәдә кабатланмый торган күренешләр турында). *Елы белән бездә чикләвек бик шәп була.* **Елы (туры) килү** — 1) уңай һава шартлары булу.— *Елы гына килсен, - - - [Нәфисә] колхозны оятка калдырмас.* Г. Бәширов; 2) яше туры килү, тиешле яшькә җитү. *Халитов белән Масловның да [солдатка каралырга] елы туры килде.* Х. Садрый. **Елын тутыру** — *к.* елы тулу. [*Дәүләй Миркәйгә:*] *Елыңны тутырмадың, ашаганыңны түләтмәбез, йорт урыныңны безгә калдырып кит.* Н. Исәнбәт. **Елын уздыру** *иск. дини* — йола буенча, якын кешенең үлүенә бер ел тулу уңае белән (коръән укып) искә алу мәҗлесе үткәрү. *Мәрхәбә - - -, мәэзин бабайны гына чакырып булса да, аш-чәй ясап, [әнисенең] елын уздырырмын дип уйлады.* Г. Ибраһимов.

ЕЛАВЫК *с. диал. к.* елак. *Елавык булса да, балаң булсын; Бакырдавык булса да, кәҗәң булсын.* Мәкаль.

ЕЛАК *с.* 1. Бик еш елаучан. [*Гайшә Мостафага:*] *Бик мазаң китте, ахры; балабыз елаграк шул...* Ш. Камал. *Елак-мылак утыра читтә елап, чөнки аңарга, Син елак дип, билет бирмәгәннәр елка карарга.* З. Мансур.

2. Еламсыраган, кызганыч (аваз, тавыш турында). *Елак тавыш белән сөйләү.*

3. *күч.* Һәрвакыт ризасызлык күрсәтүче, зарланучан; пессимистик рухлы. *Елак булма, Фатыйма, батыр бул.* М. Әмир.

4. *күч.* Яңгырлы. *Елак көз иген-таруны бердәм генә җыеп алырга ирек бирми.* А. Гыйләҗев. *Быелгы күк елак булып чыкты; күз яше коя да коя.* Ф. Хөсни.

◇ **Елак капчыгын чишү** *гади с.* — елау, елый башлау. *Таш атып уйнаганда, [Зиннәт] сары малайның аягын авырттырды. Сары малай шунда үк елак капчыгын чишеп җибәрде.* А. Шамов. **Елак җыю** *гади с.*— еларга җыену.

ЕЛАКЛЫК *и.* Елак булу сыйфаты.— *Безнең нәселгә елаклык, гомумән, чит нәрсә.* Г. Минский.

ЕЛАМСЫР *с.* Ботаклары озын һәм куе булып салынып торган. *Еламсыр талларга тия-тия астан инеш ыңгыраша.* А. Гыйләҗев. *Каршыда - - - еламсыр каеннар моңаеп торалар.* М. Әмир.

ЕЛАМСЫРАУ *ф.* Елаган сыман булу, елаган тавышлар чыгару. *Яшь бала еламсырарга тотынды.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* **еламсырап.** Елагандай булып; елак тавыш белән. *Еламсырап сөйләү.*

ЕЛАН *и.* 1. Боргалана торган озын, нечкә гәүдәле, аяксыз, кайберләрендә агулы тешләре булган сөйрәлүче хайван. *Күзлекле елан. Агулы елан. Елан угы.* □ *Елан агуы тешендә, адәмнеке теләндә.* Мәкаль. *Еланның койрыгы өзелсә дә, үзе үлми.* Мәкаль.

2. *күч.* Мәкерле, астыртын явыз кеше турында. — *Елан син, Гайшә, чагарга гына беләсең.* Г. Кутуй. [*Сәрби Галимҗанга:*] *Явыз елан! - - - Инде мине харап итәргә уйлыйсың?* Ф. Бурнаш. // Явыз дошман турында. *Бу чокыр - - - немец, фин еланнарына котылмас кабер булыр.* Ф. Кәрим. // Бик үткен, булдыклы кеше турында.

Елан балыгы *зоол.*— *к.* еланбалык. *Шамил шуышып китте. - - - Үләннәр арасыннан гәүдәсе түгел, башы да күренми, шундый кызу йөзә, нәкъ елан балыгы.* Г. Әпсәләмов. **Елан елы** — һәр елы бер хайван исеме белән атала торган борынгы 12 еллык циклда алтынчы ел. *Тычкан һәм елан елларында бал күп була, дип сөйлиләр.* Сов. әд. **Елан көпшәсе** *бот.*— зонт чәчәклеләр семья-

лыгыннан булган үсемлек (әрәмәлекләрдә, дымлы урыннарда үсә); *русчасы:* бутень. **Елан тамыры** *бот.*— иренчәчәклеләр семьялыгыңнан хуш исле эре чәчәкле, тоташ яфраклы дару үләне; *русчасы:* шалфей. **Елан теле** *бот.*— күрәнгеләр семьялыгыннан кыска, нечкә һәм үткен кыяклы үлән үсемлек; *русчасы:* ужавник. **Елан үләне** *бот.*— кызгылт күк чәчәкле баллы үсемлек; *русчасы:* синяк.

◇ **Елан аягын кискән** — үткен, бай тәҗрибәле, күпне күргән.— *Елан аягын гына кискән нәрсә икән. Кыз гына түгел, ут икән.* Н. Исәнбәт. **Елан булып йөрү** — астыртын явызлык эшләп йөрү. *Арабыздан алып ташлый белдек Елан булып йөргән кешене.* Ф. Кәрим. **Елан мөгезе генә юк** — барысы да бар; ни кирәк, шул бар. [*Әхмәди Шәмсигә:*] *Синең капчыгыңда елан мөгезе генә юктыр.* Г. Бәширов. **Елан кабыгын салу** — явызлыкны яшерү, икейөзлеләнү. [*Мәйсәрә*], *елан кабыгын салып, беркатлылык күрсәтмәкче булды.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЕЛАНБАЛЫК *и. зоол.* Елан сыман гәүдәле балык; *русчасы:* угорь.

ЕЛАНБАЛЫКЧАЛАР *и. зоол.* Елан сыман гәүдәле балыклар отряды.

ЕЛАНБАШ 1. *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан күгелҗем-шәмәхә яки ак чәчәкле, эфир мае бирүче берьеллык үсемлек (баллы чәчәк дип тә йөртәләр); *русчасы:* змееголов.

2. *зоол.* Башы еланныкына охшашлы, атмосфера һавасын сулау өчен махсус органы булган балык; *русчасы:* змееголов.

ЕЛАНЛЫК *и. күч.* Мәкерлелек, астыртын явызлык. [*Александра Сигизмундовна*] *үзенең яшь хатынлыгы, - - - еланлыгы белән минем башымны әйләндерергә тырышты.* Г. Ибраһимов.

ЕЛАН-ЧАЯН *җый. и.* Чага торган төрле сөйрәлүче хайваннар.

ЕЛАП-СЫКРАП *рәв.* Газапланып, күз яше эчендә. *Ул елны елап-сыкрап төннәр уздыручы аналар белән - - - җир өсте капланган иде.* А. Алиш. // *күч.* Зарланып, теләмичә генә. *Елап-сыкрап эшләү.*

ЕЛАТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* елау. *Сары малайны инде ул әллә ничә мәртәбә елатты, хәтта бер мәртәбә аягын да аксатты.* А. Шамов.

2. *күч.* Бик нык кимсетү, кыерсыту, рәнҗетү; җәберләү. *Мескен адәм баласын кемнәр соң елатмаган?* М. Гафури.

ЕЛАУ *ф.* 1. Яшь агызу, күзләрне яшьләндерү (авыртудан, кайгыдан, көтелмәгән фаҗигале хәлдән һ. б.). *Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга.* Мәкаль. *Төннәр уртасында үкереп елый Буйга гына җиткән кыз бала.* Җыр.

2. *күч.* Сузынкы эчпошыргыч яки моңлы тавышлар чыгару (җансыз әйберләр турында). *Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый.* Г. Тукай. [*Хәйдәр Зиннәткә:*] *Синең кулыңда гармонь кеше шикелле күз яше белән елый.* Г. Бәширов. // Кеше кычкырып елаганга охшашлы тавыш чыгару. *Кайдадыр тартар кычкыра, ябалак елый.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч. сөйл.* Зарлану. *Председательне управада туры китерүе бик читен, ә туры китерсәң, вакыт юк дип, елый башлый.* И. Гази.

ЕЛАУЛЫ *с. сир.* 1. Елау билгеләре булган, елаган; яшьле, елап кызарган (күзләр турында). *Елаулы тавыш. Елаулы күзләр.*

2. *күч.* Моңсу, ямансу, эчпошыргыч (җыр, музыка турында). *Елаулы көй.*

ЕЛАШ *и. сөйл. к.* елау 1.— *Башланып китте бер заман герман сугышы! Урамнарда елаш, басуда елаш.* Г. Бәширов.

ЕЛАШ-КЫЧКЫРЫШ *җый. и.* Бер үк вакытта булган елау һәм кычкыру яки елау һәм тиргәшү тавышлары.

ЕЛАШ-СЫКРАШ *җый. и. сөйл.* Бер үк вакытта булган елау һәм кычкырып зарлану тавышлары. *Елаш-сыкраш, ызгыш-талаш инде басыла дигәндә, яңадан шау-шу күтәрелә.* И. Туктар.

ЕЛАШУ *ф.* Берничә яки күп кешенең бергәләп, берьюлы елаулары турында. *Балалар елашып уяндылар.* Ә. Фәйзи. *Хатыннар күңелсез генә чыш-пыш елашалар.* Ш. Камал.

ЕЛБЫР *с. к.* елтыр II (1 *мәгъ.*). *Ул барган уңайга елбыр чәчләрен тарады.* А. Гыйләҗев.

ЕЛГА *и.* 1. Башланган урыннан койган җиренә чаклы үзе салган үзәнлек буенча табигый рәвештә туктаусыз агып торган су. *Елга тамагы. Елга башы. Тау елгасы.* □ *Безнең авылның буеннан аккан бу елга Өршәккә, Өршәк Димгә, Дим Агыйделгә коя.* Г. Ибраһимов. *Елгаларда язгы су ташый.* Ф. Кәрим. //*с. мәгъ.* Елгада йөзүгә, елгада эшләүгә бәйләнешле. *Елга флоты. Елга вокзалы.*

2. *күч. гадәттә тартымлы формада.* Сыеклык һәм бөртекле әйберләрнең чиктән тыш күп булуын белдерү өчен кулланыла. *Сөт елгасы.* □ *Җамалыйның башыннан кан елгалары йөзенә агып төште.* Һ. Такташ.

Елга коңгызы *зоол.*— төклеканатлылар отрядыннан кортлары һәм курчаклары суда, ә үзе корыда яши торган бөҗәк (бик кызу йөгерә, начар оча); *русчасы:* ручейник. **Елга үләне** *бот.*— озын сабаклы, яфраклары өлешчә су астында, өлешчә су өстендә йөзеп торган чәчәкле су үсемлеге; *русчасы:* рдест.

ЕЛГАЛАП *рәв. күч.* Бик күп.— *Юк! Меңнәрчә-меңнәрчә яхшы кешеләребезнең тормышларын биреп, елгалап каныбызны агызу бәрабәренә яулап алынган азатлыкны бернинди дошманга да бирмәбез!* М. Әмир.

ЕЛГАЛЫК *и. сир.* Елга үзәне, коры үзәнлек. *Без шулчаклы тиз чабабыз инде, безгә дөньяда һичбер нәрсә күренми: әллә юлдан, әллә җир өстеннән, әллә тигезлектән, әллә елгалыктан барабыз шунда.* М. Гали.

ЕЛГАЧЫ *и.* Елга транспортында эшләүче. *Елгачылар киңәшмәсе.* □ *Вокзал мәйданында ыгы-зыгы йөреп торган халык арасыннан бер елгачы Зәйтүнәгә ничектер таныш кебек күренә.* С. Сабиров.

ЕЛГЫ *с.* (Ничәнчедер) елда булган, хәзерләнгән, туган һ. б. *Мең туғыз йөз бишенче елгы революция киң халык массасын самодержавиегә каршы көрәшкә күтәрде.* М. Җәлил. // *и. мәгъ. күпл.* (Кайсыдыр) елда туган кеше. *Мин [армиядә] унберенче елгылар белән, үз елгыларымнан өч ел соңга калып хезмәт иттем.* Ф. Хөсни.

ЕЛГЫР *с.* 1. *к.* елдам 1. *Елгыр балык. Елгыр күзле.* □ *Бүренең нинди елгыры да гомерен ядрә белән, капкын белән чикли.* Г. Гобәй. / *рәв. мәгъ. Чыннан да, теләсә генә нинди серне саклый алырлык көч, түземлек бар иде бу бик елгыр хәрәкәт итә торган кечкенә гәүдәле малайда.* Г. Галиев.

2. Үткен, булдыклы, сәләтле. *Малай җитез, елгыр булып чыкты: ни тотса, шул кулына ябышып торды.* С. Рафиков. // Хәйләкәр, мут. *Күпме алпавытлар, үз имениеләрен елгыр купецларга сатып, бөлгән боярга әверелделәр.* К. Нәҗми.

ЕЛГЫРЛЫК *и.* Елгыр булу сыйфаты. *Сүзгә елгырлык.* □ [*Ординарецның*] *батырлыгы, елгырлыгы хакында Резчиков миңа берничә мәртәбә сөйләгән иде.* Каз. утл.

ЕЛГЫСЫЗЛАНУ *ф. диал.* Аяк яки кулларның вакытлыча тою сәләтен югалтуы, хәлсезләнүе, егәре китү (авыру, курку һ. б. ш. сәбәпләр аркасында, ләкин физик арудан түгел). *Хәтта җиләкләкләргә барсаң да, шушы [землемер] баганаларын күргәч, синең кулыңнан савытлар төшеп китә, - - - кулларың елгысызлана.* Г. Галиев.

ЕЛДАГЫ *с.* Ел саен була торган. *Елдагы гадәт буенча, быел да май башларында авылга кайттым.* З. Бәшири. *Каспий диңгезе буендагы балык промыслоларында елдагы рәвешчә хәрәкәт башланган.* Ш. Камал.

ЕЛДАГЫЧА *рәв.* Үткән еллардагы кебек, ел саен булып килгәнчә, гадәттәгечә. *Шаулы гөрләвекләре, җылы ләйсән яңгырлары белән елдагыча кояшлы яз килә.* Р. Төхфәтуллин. *Ноябрь ае керде. Ләкин Россия кояшы бүтән еллардагыча нурын киметми, - - - салкынлык бирергә ашыкмый.* Г. Тукай.

ЕЛДАМ *с.* **1.** Җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Күз ачып йомганчы төенчек Бәдринең елдам кулларына килеп керде.* И. Гази. *Алабай бик елдам кыяфәттә, эзне иснәп, алдан бара.* Н. Исәнбәт. /*рәв. мәгъ. Малайлар, елдам кузгалып, ярыша-ярыша чаба башладылар.* М. Шабай.

2. Үткен, булдыклы. *Ир уңган булса, хатын елдам була.* Мәкаль. *Берсе уңган, берсе елдам, Берсе алдынгылардан.* Җыр.

ЕЛДАМЛАНУ *ф. сир.* Елдам хәлгә килү, җитезләнү, тизлекне арттыру. *Кайтыр юлга чыккач, ат та елдамлана.* Мәкаль.

ЕЛДАМЛЫК *и.* Елдам булу сыйфаты. *Халык бәйрәм иткән. Ир егетнең елдамлыгын, көчен зурлаган.* М. Максуд. *Зиннәт, үзе дә сизмәстән, гүя аларның елдамлыгын, җитезлеген сынап карагандай, уң кулының бармакларын кыймылдатып ала.* Г. Бәширов.

ЕЛДА'Н-ЕЛ *рәв.* Ел саен, һәр елны; еллар үткән саен. *Ильясның байлыгы елдан-ел кими бара иде.* Г. Тукай.

ЕЛДАШ *и. сөйл. к.* яшьтәш. *Без аның белән елдашлар.*

ЕЛДЫРУ *ф. сөйл.* Нәрсәгә дә булса төбәп ыргыту, шудырып җибәрү. *Хәлим, бик каты кизәнеп, бер таш кисәген кыекка таба елдырды.* И. Гази.

ЕЛДЫРЫМ *и.* **1.** Төнлә яки кичен офык читендә ялтйолт итә торган яктылык чаткысы (ераста яшен яшьнәү чагылышы); ажаган. *Офык буена җәелгән зәңгәрсу кара болытларны ярып, уңга да, сулга да елдырым камчысы селтәнә.* Г. Бәширов.

2. *диал.* Яшен. *Яңгыр бетмәс, болыт һаман күбәймәктә, Шау-шу арта, елдырымнар уйнамакта.* Ак юл.

3. *с. мәгъ. күч.* Үткен, өлгер; хәйләкәр. [*Габделбәр:*] *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем.* [*Гарифҗан:*] *Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н. Исәнбәт.

ЕЛКА *и.* **1.** Яңа ел бәйрәмендә бүлмәгә, залга, ачык мәйданга бизәп куела торган чыршы. *Ирек мәйданына, бик матур итеп бизәклән, елка ясаганнар.* А. Шамов.

2. Бизәлгән чыршы тирәсендә җыр, бию, уеннар белән үткәрелә торган Яңа ел бәйрәме. *Елка билеты.* □ [*Мәрьям*] *кардәшләре белән елкаларга, балалар спектакльләренә - - - бара.* Г. Ибраһимов.

ЕЛКЫ *и. иск.* **1.** Ат. *Елкы колыннан үсә.* Мәкаль.

2. Эшкә җигелмичә, иркендә, көтүдә йөрүче ат. *Безнең бабайлар бу якка күп атлар, елкылар алып килгәннәр.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Биек тауның башларында елкы йөри көтүсез.* Җыр. // Сую өчен симертелгән ат; сугым аты. *Елкы мае.*

ЕЛКЫЛДАВЫК *с.* Елык-елык итеп торган. [*Егет*] *майга буялган елкылдавык беләкләрен, муенын - - - ныгытып-ныгытып сабынлап ышкый башлады.* Н. Фәттах. *Шофер елкылдавык утны бер кабызып, бер сүндергәләп торды.* Б. Камалов.

ЕЛКЫЛДАУ *ф.* **1.** Яктылык нурларын кире чагылдырып ялтырау, җемелдәү. *Кояшның су өстендә куе шәүләләр ясап елкылдавы - - - Габдулланы тибрәтә башлады.* Ә. Фәйзи. *Гөлҗиһанның елкылдап торган куе маңгай чәчләре өстендә генә энҗеле хәтфә калфак.* А. Расих.

2. Эре малларның симезлеген, көрлеген белдерү өчен әйтелә.

3. *күч. сөйл.* Киемнең яңа, яхшы булуы белән күзгә ныкташлануы турында. *Өс-баш елкылдап тору.*

ЕЛКЫЧЫ *и.* Елкылар көтүен караучы, елкылар көтүче. *Елкычы* [*Бөркетбайның*] *куышына атлы бер юлчы килеп туктады.* И. Салахов.

ЕЛЛАГАН *с.* **1.** Яше тулган, бер яшьлек. *Бу йөз илле сум бурычны - - - түләү өчен бер ат, йөз пот бодай, елларган чуар үгез кереп китте.* Г. Ибраһимов.

2. Җыеп алынганнан яки хәзерләнгәннән соң бер ел яки берничә еллар буена сакланган. *Еллаган әчемлекләр.* □ [*Сәхип байның ындырында*] *еллаган кибәннәр каралып - - - утыралар.* С. Рафиков.

ЕЛЛАП *рәв.* **1.** Ел исәбе белән; ел саен, ел үткән саен. *Еллап түгел, айлап-көнләп алга бара бит хәзер тормышыбыз.* Р. Төхфәтуллин.

2. *сир. к.* еллыклап. [*Шаһибәк*] *юаш, акыллы күренгәнгә, аны* [*Байморзалар*] *кайтармыйлар, еллап хезмәткә яллыйлар.* Г. Ибраһимов.

3. Янында килгән сан белдерергә тиешле чама төшенчәсен үзенә ала һәм ... «елга якын», ... «ел чамасы» дигән мәгънә аңлата. *Утыз еллап Бохара, Каргалыда торганыбыз бардыр.* Г. Тукай.

4. Ел буена, еллар буена. *Еллап күренми йөрү.* // *күч.* Бик озак. [*Шәмсия ирене:*] *Бар алайса, еллап йөрмә, мин хәзер мичкә ягам.* Т. Гыйззәт.

5. *гадәттә кабатлаулы формада.* Һәр елныкын аерым җыеп, туплап. *Шүрлекләргә еллап-еллап куелган журналлар - - - әлек юк иде.* Г. Әпсәләмов.

ЕЛЛА'РЧА *рәв.* Еллар буенча, күп еллар дәвамында. *Елларча җыйналган нәфрәтне һәм дәртне мин хәзер чыгарам.* М. Җәлил. *Елларча тау тишегендә ятып чыккан кыяфәттәге бу кешеләрне күреп, Габделкаюм бик нык гажәпләнде.* М. Гали. // Берничә ел үткән шикелле, бик озак. *Шушы берничә айга кыска гына аерылу аңа* [*Сажидәгә*] *елларча озак тоелды.* С. Рафиков.

ЕЛЛАТУ *ф.* Ел буенча саклау, карау. *Елкы еллату.* □ *Әнә саклыгым да бар, өч кибән еллатам.* Г. Ибраһимов.

ЕЛЛАУ *ф. сир.* Ел буе тору, сакланы. *Елларга калдырылган арыш кибәннәре.*

ЕЛЛЫК *с.* **1.** Тулы бер елга караган, бер елга исәпләнгән; *Еллык табыш. Еллык план.* □ *Әдәбиятыбызга еллык йомгак ясаганда, балалар әдәбияты турында аерым бер доклад билгеләү бик кирәк иде.* Л. Ихсанова. [*Гыймазов*] *«Игенче» журналының еллык текмәсен дә бүлмәсенә алып кайтты.* С. Рафиков. // Бер ел эчендә булган. *Еллык үзгәрешләр.* □ [*Чарасын күрмәсәң, ефәк кортларының*] *алмагачны эштән чыгарасын көт тә тор! Чәчәксез, яфраксыз кала, еллык үсешен үк югалта.* Г. Хәсәнов.

2. Елга бер тапкыр чыга торган. *Еллык журнал.*

3. Саннар янында шул сан күрсәткәнчә елга исәпләнгән, җитәрлек, шул кадәр ел эчендә башкарылган яки башкарыла торган дигән мәгънәләрне белдерә. *Җидееллык мәктәп. Бишьеллык план. 50 еллык иҗат эшчәнлеге юбилее.* □ [*Гариф:*] *Безнең өле - - - бер еллык иген бар.* М. Гафури. // (Ничәдер) яшьлек, (ничәдер) ел үскән. *Кайчандыр Казан тирәсендә йөзәр еллык имәннәр шаулап үскән.* Г. Әпсәләмов.

4. Саннар янында «яшәрү, картаю» фигыльләре белән килгәндә, «шулкадәр елга, шулкадәр яшькә тиң булырлык» мәгънәсен белдерә. *Василий Петрович бер көндә ун-егерме еллык яшәрде.* Г. Ибраһимов. [*Әхмәтҗан:*] *Синең хатыңны алгач, хафамнан өч көн эчендә ун еллык картайдым.* Г. Камал.

5. Нинди дә булса күренекле вакыйгага (ничәдер) ел тулу көнен билгеләп үтә торган календарь дата. *Бөек Октябрьның 50 еллыгы.* □ *Яшь Әхмәт үз гомерендә бер тапкыр булса да Тукайны күрә. Аннан аны күмгәнне*

хәтерли, үлгәннән соң үткәрелгән еллыгын хәтерли. С. Хәким.

6. *и. мәгъ. тарт. форм.* **еллыгы.** Ел исәбе белән түләнә торган хезмәт хакы. *Имеш* [*Сабир*], - - - *авылга кайтып, еллыгы егерме сум торган ялчылар белән берәттән сабан сөреп йөрсен!* Г. Ибраһимов.

Еллык божралар *бот.* — үзагачтагы божралы катлаулар (шуларны санап агачның яшен билгеләргә була).

ЕЛЛЫКЛАП *рәв.* Ел исәбеннән түләү тәртибендә. *Еллыклап эшләүче.* □ *Фәтхетдинов миңа үзенең байда еллыклап хезмәт итүе* [*турында*] *сөйли.* А. Таһиров.

ЕЛМАГАЙ *с. диал.* Елмаючан. *Ялагай сүс елмагай.* Әйтем.

ЕЛМАЕШУ *ф.* Берничә яки күп кешенең бергәләп, берьюлы елмаюлары турында. *Корбанов, - - - әллә нигә бер Гаязга таба янтаеп, аның колагына нәрсәдер әйтә дә, алар икесе дә елмаешалар.* И. Гази.

ЕЛМАЮ *ф.* **1.** Көлүгә тартымлы йөз (ирен, күз) хәрәкәтләре белән төрле хисләр белдерү; җиңелчә генә тавышсыз көлү, көлемсерәү. *Өй эчендәгеләр кайсы көлешеп, кайсы елмаеп куйдылар.* Ә. Фәйзи.

2. *күч.* Көткәнчә, теләгәнчә булу, уңай килү. *Миңа әле бәхет елмаер икән.* М. Хәсәнов.

3. *шигъ. күч.* Ай, кояш, йолдыз һ. б. ның балкып, нур сибеп торулары турында. *Безгә карап матур ай елмая.* Ә. Ерикәй. *Вакыт-вакыт күк йөзе ачылып китә дә кояш елмаеп куя.* Г. Галиев.

ЕЛМАЮЛЫ *с.* Ягымлы, мөлаем. *Елмаюлы караш.* □ *Елмаюлы йөзләреңне бер күрергә зар иттең.* Җыр.

ЕЛНЫКЫ: елнык елга җитү (ялгану, бетү) — бер елда булган керемнең, хәзерләнгән азыкның мул булмавы, шул елга гына җитүе турында. *Җиңги — елнык елга гына ялганып килә торган урта тормышлы бер семьяда - - - үскән кыз.* Г. Гали.

ЕЛТ *рәв.* **1.** *сөйл.* Бик тиз, бик кыска вакыт эчендә.— *Көтеп кенә торыгыз. Бик елт әйләнермен.* Ю. Әминов. // *каб. форм.* **елт-елт.** Бер-бер артлы, бик тиз. *Әхмәт ышанмады. Миңа, күзен елт-елт йомып, сәер итеп карады.* Г. Бәширов. // Кинәт кенә, кискен хәрәкәт белән. *Елт кына борылып китү.* □ *Нигъмәт елт кына башын күтәрде.* Қ. Нәҗми.

2. *хәб. функ. сөйл.* Кинәт кенә, сиздермичә кая да булса китү, юкка чыгу.— [*Балыкны*] *ачык калдырсаң, сикерә-сикерә, сикерә дә — елт!* Ш. Камал.

Елт-елт итү (килү) — 1) елтырау, елык-елык килү. *Лампа* [*уты*] *елт-елт килә.* Ә. Фәйзи; 2) хәрәкәт вакытында бик тиз генә бер-бер артлы күзгә чалынып калу. *Ак күлмәкле яшел каеннар машинаның яныннан елт-елт итеп торалар.* И. Гази.

◇ **Елт итеп** — бик тиз генә. *Елт итеп үтеп китү. Елт итеп килеп керү.* □ [*Фатыйма апа*] *елт итеп Габделкадыйр байлар капкасына борылды.* Х. Садрый.

ЕЛТЫР I *и. диал. к. өре.*

ЕЛТЫР II *с.* **1.** Елтыравыклы, җем-җем итеп ялтырап торган. [*Фуражка*] *бигрәк матур шул: өсте яшел, әйләнәсе кызыл, козырёгы елтыр кара.* Г. Гобәй. *Күлнең өсте бүген дә шома, тигез, елтыр, көләч иде.* А. Әхмәт.

2. *күч.* Ялтырап, уйнаклап торган, бик хәрәкәтчән (күзләргә карата). [*Әхмәтшаның*] *елтыр кара күзләре, сиңа хезмәт күрсәтергә мин һәрвакыт әзер дигәндәй, майланып, ягылып торалар.* М. Әмир.

Елтыр-елтыр итү (килү) — *к.* елтырау. *Галиулла җанланды: аның ябык күзләре елтыр-елтыр итә башлады.* И. Гази. *Кызларның җитез бармаклары бөгелеп тә сыгылып уйнаклап тора, көмеш балдаклары белән энәләре елтыр-елтыр килә.* Г. Бәширов.

ЕЛТЫРАВЫК *с. к.* елтыравыклы. [*Габдрахманның*], *күпшы юртак җигеп, елтыравык пролеткада кәефләнеп йөрергә яратуы кеше күзендә билгеләнми калмасы.* Ә. Фәйзи.

ЕЛТЫРАВЫКЛЫ *с.* Елтырап торган. *Елтыравыклы пыялалар.* □ *Бик матур елтыравыклы бер йолдыз атылды.* Ш. Әхмәдиев.

ЕЛТЫРАТУ *ф.* Ниндидер хисләр, кичерешләр белдереп очкынландыру, уйнакландыру (күзләр турында). *Башкорт, - - - кара күзләрен тагын ныграк елтыратып, үзенең хәлен сөйләп бирә.* Г. Ибраһимов.

ЕЛТЫРАУ *ф.* **1.** Яктылык биреп нурлану, җемелдәү. *Алда, әле ерак күренә торган авылда, берән-сәрән алынган утлар елтырый башладылар.* Ф. Әмирхан. *Күк күкрәгән тавыш хәзер ачыграк ишетелә, яшен яктырак елтырый башлаган иде.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Ниндидер хисләр, кичерешләр белдереп очкынлану, уйнаклау (күзләр турында). [*Кешеләрнең*] *күз карашларында мутлык һәм хәйләкәрлек елтырый.* И. Гази.

3. *күч.* Исерү, исереклек билгесе күзгә, йөзгә чыгу турында. *Безнең Сәфәргали шактый ук елтырап өлгергән иде инде.* Ф. Хөсни.

ЕЛТЫРГЫЧ *и.* Кармак беркетелгән елтыравыклы кечкенә металл пластинкадан гыйбарәт балык тоту алдавычы. *Нинди елтыргычларым бар, һәммәсен* [*кармакка*] *куеп карадым.* Ә. Исхак.

ЕЛЪЯЗМА *и.* **1.** Илдә, шәһәрдә, аерым урыннарда булган тарихи вакыйгаларны үзе күргән кеше тарафыннан язып барылган еллык язма; шундый язмалардан торган китап. *Бөек Ватан сугышы елъязмасы.* □ *Рус елъязмаларыннан күренгәнчә, - - - Владимир-Суздаль җирендә ачлык куркынычы тугач, болгарлар русларга ашлык сатканнар.* Каз. утл. // *с. мәгъ.* Шундый язмаларга мөнәсәбәтле, шуларга караган. *Архивның елъязмалар бүлеге. Елъязма мәгълүматлары.*

2. Нинди дә булса вакыйгалар, нәрсәнең дә булса тарихы турында еллар тәртибе белән даими рәвештә алып барылган язма. *«Сиваш» — көньязма да, елъязма да, истәлек тә түгел, бәлки сәнгать кануннары буенча язылган әсәр.* Г. Бәширов. *Тарих туктаусыз үзенең елъязмаларын яза бара.* Г. Әпсәләмов.

3. Илдә, союздаш яки автономияле республикаларда басылып чыккан яңа китаплар турында белешмә бирә бара торган (атналык, кварталлык, еллык) библиографик журнал. *Татарстан китап елъязмасы.*

ЕЛЪЯЗМАЧЫ *и.* Елъязмалар язучы.

ЕЛЫК-ЕЛЫК: елык-елык итү (килү)—*к.* елкылдау. *Күл төбе елык-елык итеп китә: көмеш тәңкә сипкәнмени.* Г. Ахунов. *Елык-елык килеп торган брошка алдым да - - - Гөлнарыма бирдем.* Ә. Айдар.

ЕЛЫНДА *рәв.* Бер ел вакыт арасында. *Ат аенда, ир елында таныльр.* Мәкаль. *Елында берничә мәртәбә* [*Фатыйма бикәгә аның кардәшләре, якыннары*] *килә.* Г. Ибраһимов.

ЕЛЫ'Н-ЕЛ *рәв. сөйл.* Ел саен, һәр елны. *Тау белән елга арасында яткан тар гына бер мәйдан булганлыктан, ул* [*җир*] *елын-ел да буш кала.* Ә. Еники.

ЕЛЫШТЫРУ *ф.* Кемгә яки нәрсәгә якынайту, якынайтып урнаштыру. *Озын кеше - - - урындыгын Гыйльманов өстәленә якын үк елыштырып китерде.* Ш. Камал. *Мич* [*кырыена*] *үк елыштырылган өстәл янына Газинур бүген дә иң алдан килеп утырды.* Г. Әпсәләмов.

ЕЛЫШУ *ф.* **1.** Кемгә яки нәрсәгә таба әкрен-әкрен хәрәкәт итү, якынаю. *Камил, бер позициядән икенче позициягә күчә-күчә, чокыр кырыйлап һаман күлгә таба елышты.* М. Әмир. *Бик акрын гына елышам мин Бу матур кыз янына.* М. Җәлил. // *рәв. мәгъ. күч.* **елышып.** Әкрен генә, посып кына. *Ул килә кошка таба елышып кына, Алдалап тотмаммы дип, тырышып кына.* Г. Тукай.

2. Шуышу; үрмәләү. [*Дала*] *өстеннән, борылып-борылып, елышып барган көмеш елан төсле, Сакмар елгасы ага.* Ш. Камал. [*Мәче*] *корсагына яткан да, муенын сузып, кыектагы күгәрченнәргә таба елыша.* И. Гази.

3. Кемнең яки нәрсәнең дә булса янына **якынрак** килү, күчеп утыру, якынаеп урнашу. *Бабай якты чырай биргәч, [балалар] якынрак елыштылар.* Г. Гобәй.— *Әйберләрегезне почмакка куегыз, ә үзегез ут янынарак елышыгыз.* А. Расих. // *күч.* Якынлык, яхшы мөгамәлә күрсәтү. *Соңгы вакытта, әйткәнемчә, ул үзе үк миңа елыша башлады.* Ә. Еники.

4. Берәр җиргә яшеренү, посу, ышыклану. *Фәттах блиндаж түбәсендә - - - ишек өстендә генә елышып ята.* Ф. Кәрим. *Төлке куркуыннан чинап җибәрде һәм җиргә елышты.* Г. Мөхәммәтшин.

5. Яклау эзләп яки иркәләнеп, кемнең дә булса янына килү, аңа сыену (аны кочаклау, кочагына керү). *Нәфисә, сабый күңеле белән нинди дер коточкыч хәл булуын сизенеп, нишләргә белмичә, абыйсының күкрәгенә елышты.* Г. Бәширов. *Син йончыган, арган гәүдәң белән Минем кочагыма елыштың.* М. Җәлил.

6. Ярдәм итәрдәй, аркаланырдай берәр кеше янына, иминлек тәэмин итәрдәй берәр җиргә урнашу; сыену. *Җылы җиргә елышу. Җитәкче канаты астына елышу.* □ *Ул яңа дуслары Марс Абуздырин белән Рәшит Сәлмәнов тирәсенә елышты.* Э. Касыймов.

ЕНО'Т. *и.* Имезүчеләр токымыннан кыйммәтле мех бирә торган кечкенә гәүдәле, куе сары йонлы ерткыч җәнлек. // *с. мәгъ.* Шул җәнлекнең мехыннан эшләнгән. *Енот яка. Енот тун.*

ЕПИ'СКОП *и.* Христиан чиркәвендә югары дәрәҗәле рухани. *Рим папалары, кардиналлары, Епископлар торган урыннар — Тиздән эшчәннәргә ял йортлары, Клуб, театрлар булырлар!* М. Гафури.

ЕРАГАЙТУ *ф. к.* ераклаштыру. *Әйберне күздән ерагайтып карау. Күңелсез очрашуны ерагайтырга тырышу.* □ *Озакларга аерылышу ерагайта араны.* Җыр.

ЕРАГАЮ *ф. к.* ераклашу. *Ай нуры коендырган киң урам уртасында гармоньчының ак күлмәге күренә, ул һаман ерагая.* Г. Бәширов. *Яһудинның бу әйткәннәре белән дә килешмәде Ханов. Сөйләшкән саен аралары ерагая барды.* С. Рафиков.

ЕРАК *рәв.* **1.** Зур аралык турында; *киресе:* якын. *Әбиләр бездән ерак торалар.* А. Алиш. *Җитәсе җирләр ерак, Очарга кирәк озак.* З. Мансур. // *с. мәгъ.* Зур ара белән аерылган, ерактагы. *Авыл җирендә җәй көне малайлар, егетләр ат белән ерак тугайга куна йөриләр* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Зур аралыклы, озакка сузылган.— *Хәерле юл сезгә! Ерак юлларыгызны җиңел үтегез!* Ә. Еники.

2. Озак, озак вакыт белән аерылган (киләчәктә булачак эш, хәл турында). *Ул арада таң атарга да ерак калмаган иде.* М. Гали.— *Шатлык ерак әле, шатланмыйм мин.* Г. Коләхметов. // *с. мәгъ.* Күптән үткән, моннан күп вакыт элек булган. *Ерак яшьлек еллары.* □ [*Галәк бабай балаларга*] *ерак үткәннәр турында — Ямәлкә патша турында сөйли.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Югалмаслык итеп, ышанычлы урынга. *Полк командиры [Нуруллинга] - - - бер-ике генә сүз язылган кәгазьне бик ерак яшерергә кушты.* А. Шамов.

4. *рәв., с. мәгъ. күч.* Берәр нәрсәгә бөтенләй мөнәсәбәте яки бәйләнеше булмау турында. *Фән дөньясыннан ерак кеше.* □ *Мостафа, сәүдә дөньясыннан ерак булу сәбәпле, Габдуллага урын табу мәсьәләсендә ярдәмләшә алмады.* Ш. Камал. // *хәб. функ.* Нәрсә дә булса эшләргә бөтенләй уйламау, исәп тотмау турында. *Хәким дә немецларны бик җентекләп күзәтеп бара, ләкин Василий шикелле үк ашыгып нәтиҗә ясаудан ерак иде.* Ә. Еники.

5. *күч.* Күп нәрсә җитми (кем-нәрсә кәбек булырга). *Садыйков кебекләргә ерак әле Шәрифуллин белән куышырга.* С. Рафиков.

6. *с. мәгъ.* Өченче буыннан да якын булмаган уртак бабага кайтып калучы (чыбык очы кардәш турында). *Ерак кардәштән тату күрше якшы.* Н. Исәнбәт. [*Шаһбаз*] *бер ерак агасында гына тора.* Г. Ибраһимов.

Ерак баба — 1) ата яки ана ягыннан гаиләгә, ырыгка, кабиләгә нигез салучы, башлап җибәрүче. *Габдулла үзенең шәҗәрәсе белән кызыксынды. Әхмәдулла абзый аны ерак бабаларга китеп белмәсә дә, белгән хәтлесен санап бирде.* Ә. Фәйзи; 2) *күпл.* моннан бик күп еллар элек яшәгән буын. *Борынгы заманнардан үк безнең ерак бабаларыбызны караңгы төн куркуга салган кебек, хәзерге заман кешесен дә караңгылык шөбһәгә сала.* Каз. утл. **Ерак бабай** *диал.*— әнисенең атасы. *Безнең ерак бабай күреп белгән аны, Петрны.* Г. Гобәй.

◇ **Ерак бара (китә) алмау** — 1) теләккә, максаткә, уңышлыкларга ирешә алмау. *Кеше акылы белән ерак бара алмассың.* Мәкаль; 2) чыгыш килешендәге исем фигыльдән соң: ... башка берни дә эшли алмау. *Буржуаз язучылар — ялгыз бунтарьлыктан яхут өметсез ачынып елаудан ерак китә алмадылар.* М. Җәлил; 3) теге яки бу ашамлыкның туклыклылыгы аз булуга ишарә йөзеннән әйтелә.— *Әйдә, [нәрәмәч] белән сыйлыйм үзеңне. - - - Балык белән ерак бара алмассың.* Ш. Камал. **Ерак итү (кылу)** — нәрсәдән дә булса мәхрүм итү. *Рәхмәтемнән сине ерак иттем, Син калырсың мәңге хур булып.* М. Гафури. [*Зөләйха:*] *Алла иң усал бәндәсен дә мондый җәфалардан ерак кыйлсын!* Г. Коләхметов. **Ерак йөрү (тору)** — 1) читләшү, катнашмау, аралашмау. *Бүреләр белән байлардан ерак йөргәнең яхшы.* И. Газин. *Кайбер хәлләрдә кешеләрнең бер-берләреннән ераграк торулары хәерле.* Ә. Еники; 2) эләкмәү, нәрсәгә дә булса ия була алмау. [*Безгә*] *яхшысы эләкмәсә дә, яманы ерак йөрмәс.* Ф. Хөсни. **Ерак киная** — бик читләтеп әйтелгән сүз, фикер. [*Бирем әкә*], *ерак киная белән китерep, - - - йортны ак патшага кол итүдә булышлык иткән бабаларына да күләгә ташлады.* Г. Ибраһимов. **Ерак китү** — үсү, уңышка ирешү. *Хуҗамның кәефе килде. «Молодец, йозак остасы булырсың, бу юлда ерак китәрсең», - - - дип, мине канатландырып куйды.* Ш. Усманов. **Ерак күрү** — *к.* ерактан күрү. *Ерак күргән ул! Көрәшләрдә дусны дошманнардан Даһиларча аера белгән ул.* Х. Камалов. **Ерак тору (булу)** — катнашмау (начар эшкә), аралашмау (начар кешеләр белән).— *Бәладән ераграк булганың яхшы.* Р. Ишморат.

ЕРАККА *рәв.* Ерак урынга, ерак тирә-якка, әллә кая. *Еракка куйсаң, якыннан алырсың.* Мәкаль. *Җыр тавышлары еракка китеп яңгырыйлар.* М. Җәлил. // *қаб. форм.* Бик еракка. *Володяның - - - көләч күзләре, чак кына кысыла төшеп, каядыр еракка-еракка карыйлар иде.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Еракка бармый(ча)** — читкә чыкмыйча, үзебезнең арадан (мисал, факт китергәндә).— *Менә, еракка бармый, Галигә генә карыйк.* Г. Коләхметов.

ЕРАҚЛАНУ *ф. сөйл. к.* ераклашу (1. 3 *мәгъ.*). *Кош дигәнем аэроплан булып чыкты. Ул югалды — ераклануы безнең ара.* М. Гафури. [*Зыя*] *авыл халкыннан аерылган, еракланган иде.* Г. Ибраһимов.

ЕРАҚЛАП *рәв.* Ерактан, якын килмичә генә. *Қайбер вакыт ялгыз бүрене аучылар ераклап әйләндереп алалар.* Г. Ибраһимов.

ЕРАҚЛАТУ *ф. сир. к.* ераклаштыру. *Қуркынычлар юлны ераклатыр төсле.* М. Җәлил.

ЕРАҚЛАШТЫРУ *ф.* **1.** Ераграк арага күчерү. *Фронт сызыгын ун километрга ераклаштыру. Зур производство төзелешләрен шәһәр үзгеннән ераклаштыру.*

2. Соңлату, берәр эш-хәлнең үтәлү срогын кичектерү. [*Әсәрдәге*] *менә шул хәлләр, һәммәсе бергә килеп, конфликт чишелешен ераклаштыра төшәләр.* Г. Нигъмәти.

3. *күч.* Кемнән яки нәрсәдән читләштерү, аралашудан туктату. *Григорийның бу аңлатмасы - - - Дилбәр-*

не азрак көнләштерү, ничек тә булса Фәсхидән ераклаштыру уе белән әйтелгән чәнечкеле сүз иде. Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЕРАҚЛАШУ *ф.* **1.** Ераграк урынга, арага күчү, ара ераклыгы арта бару. *Халык төркеме бездән ераклашты.* М. Гали. *Фонарь яктысы ераклаша, сыегая торгач күренмәс булды.* Г. Минский. // *күч.* Вакыт үтү белән, берәр зур вакыйганың онытыла баруы, ерак тарихка әйләнүе турында. *Һаман-һаман ераклаша бара Өермәле сугыш еллары.* Ә. Ерикәй.

2. *күч.* Соңлау, берәр эш-хәлнең үтәлү срогы кичектерелү, озак вакытлардан соң булу. *Сугыш никадәр озакка сузылса, [колхоз авылының матур киләчәге] шулкадәр ераклашуы мөмкин.* Г. Бәширов. // *сир.* Артта калу (тормыш, заман таләпләреннән). *Мәктәп-мәдрәсәләребез белән бергә [тормышыбыз да], заманнан шул кадәр ераклаша вә тараеп, үзебезне кыса барган.* Ф. Әмирхан.

3. *күч.* Аралашудан, очрашудан туктау, мөнәсәбәтләр бозылу. [*Рәшит Гөлзадәгә:*] *Хафиз белән сезнең ераклашуыгызга мин сәбәпче түгелмендер дип уйлыйм.* Р. Ишморат. *Без ераклаштык, ишет: син — син хәзер, мин — мин хәзер.* Г. **Тукай.** // Читкә китү, читләшү (темадан, төп мәсьәләдән һ. б.). *Темадан ераклашу.* □ *Шәйхи, үзе дә сизмәстән, шул заманның теге-бу политик партияләренең асылына төшенүдән ераклашып, сирәк-мирәк күренгәләгән газеталарны бөтенләй укымас булды.* И. Туктар.

ЕРАҚЛЫҚ *и.* **1.** Ерак ара. *Әмма туганлык хисләрен ераклыклар гына киметә аламыни!* Каз. утл. *Син ерак миннән ерагын, Ераклыкка карамый, Яраласа мине дошман, Ул сине дә яралый.* Ф. Кәрим. // *күч. сир.* Вакыт арасы. *Кисеп еллар ераклыгын, җырың яңрап Барсын иде килер буыннарны каулап.* Ш. Маннур.

2. Ике пунктны, ике предметны аерып торган ара, шундый ара озынлыгы. *Йөз метр ераклыкта гына яткан буадан мичкә белән су ташу бер дә кызык түгел.* Ә. Еники. [*Шәкертләр*], *бу шәһәрләрнең исемнәрен беренче рәт кенә ишеткәнгә күрә, кайда икәнлеген дә, ераклыгын да белми, аптырашта калдылар.* М. Гафури. *Менә немецлар белән ике ара мылтык атарлык ераклыкта гына калды.* А. Шамов. // Билгеле ике нокта арасы (мәсәлән, снарядның атылып чыгу ноктасыннан барып төшү ноктасына кадәр булган ара). *Мылтыкныңату ераклыгы. Снарядның очыш ераклыгы. Йөк ташуның уртача ераклыгы.*

3. Күз күреме иңли алырлык ерак аралык, бушлык; киңлек. *Карчык таңның саргылт көмеш нурлары белән яктырган зәңгәр ераклыкка тагын бер мәртәбә күзен төшерде.* А. Алиш.

4. *күч.* Аерма, үзгәлек. *Ветеринария белән медицинаның әллә ни ераклыгы юк бит.* А. Расих.

Ераклык үлчәгеч *физ.*— күзәтүчедән ерактагы предметка кадәр булган араны урыннан торып билгели торган прибор. *Акустик ераклык үлчәгеч. Оптик ераклык үлчәгеч.*

ЕРАҚЛЫ-ЯҚЫНЛЫ *с.* Төрле ераклыкта булган, урнашкан. [*Болынлыклар*] *арасында ераклы-якынлы, зурлы-кечкенәле --- матур күлләр ялтырап ята.* Ш. Камал.

ЕРАКТА *рәв.* Ерак урында, ерак җирдә; әллә кайда. *И туган ил, и матур ил, Калдың бездән еракта.* Г. Кутуй. *Еракта ялгыз ут җемелдәде.* А. Алиш. // *каб. форм.* Бик еракта. *Еракта-еракта, зәңгәр тасма булып, су күренде.* И. Гази.

◇ **Еракта йөрү** — *к.* ерак йөрү (тору). *Саҗидә апа тирәсеннән ул, фән дигәнебез, ерактарак йөри шул.* Ә. Ениқи.

ЕРАКТАН *рәв.* **1.** Ерак урыннан, ерак җирдән, әллә кайдан. *Ерактан күзәтү. Ерактан ату.* □ *Ерактан, әллә кайдан, ишетелә күк күкрәгән аваз.* Г. Тукай. *— Каланың барлык түрәсе - - - миңа ерактан кул кушырып торалар.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Читләтеп, кинаяләп. [*Хәбибулла абзый*], *сөйләшүнең уңышлы чыкмасын аңлап алып, сүзне ерактан башлады.* Г. Кашшаф.

Ерактан күрү — алда, киләчәктә булачакны дөрес аңлап, чамалап эш итү. *Күрәм күңел күзем белән Ерактан-ераккарак.* Г. Хуҗиев. **Ерактан суктыру** — кинаяләп сөйләү. **Ерактан уйлау** — нәрсәнеңдер ничек буласын, нәтиҗәсен алдан белү, сиземләү.— [*Салават*] *ерактан уйлап эш итә ул.* А. Шамов. **Ерактан уратып**— бик читләтеп, зур киная белән. [*Сабир*] *сүзләрен бөгә ерактан уратып, киная белән сөйләде.* Г. Әпсәләмов.

ЕРГАЛАУ *ф.* **1.** Еру, буразналар салу. *Җирне ергалау.* // Берәр нәрсә өстендә буразна сыман эзләр калдыру, ясау. *Ара-тирә җил җилпенеп үтә дә, тын күлләрнең битен ергалый.* Х. Госман.

2. *күч.* Төрле юнәлештә кисешеп үтү; телгәләү, ермачлау. *Йөзне җыерчыклар ергалау. Яр буен ерганаклар ергалау.*

ЕРГАНАҚ *и.* **1.** Ташкын яки яңгыр суы белән юылып, ашалып ясалган тирән булмаган сулы яки сусыз озын чокыр. *Бөтен ерганаклардан, кырлар өстен тоныҡ гөрләтеп, шарлавыклар йөгерде.* Ә. Ениқи. *Ерганакның текә борылышында бер буа ялтырап ята.* Г. Гобәй.

2. Шундый урыннан ага торган язгы ташкын яки көчле яңгыр суы. *Нурын сибә кояш, тама тамчы, Ерганаклар ага, әнкәем.* Ф. Кәрим.

ЕРГЫЧ *и.* **1.** Итчеләр пычагының бер төре.

2. *диал.* Рамга ырмау ясый торган корал.

ЕРГЫЧЛАУ *ф. сөйл. к.* ергалау 2. *Чаларган сакал, бит-маңгайны аркылыга-буйга ергычлаган тирән җыерчыклар — болар һәммәсе дә Сафаның ил гизеп йөрүләре бик үк татлы булмаганлыгын күрсәтеп торалар иде.* М. Галәү.

Е'РЕСЬ *и.* Өстенлек итеп килгән диннең кануннарына каршы булган дини тәгълимат.

ЕРЕТИК *и.* Ересь яклы кеше, ересь тарафдары. *Руханиларның еретикларга каршы көрәше.*

ЕРМА *и.* Су ташкыны ерып үткән урын. *Ерма аша басма салу.*

ЕРМАҚ *и.* Артык киң һәм тирән булмаган озын чокыр; ерганак.— [*Ат өстендә*], *казак шикелле, алгарак ятып бар, ермаклар аркылы сикергәндә, ялга ныграк ябыш.* М. Гали. // Елганың, күлнең тар гына булып ярдан эчкә таба кереп торган урыны; култыкчык. *Ак күлнең югары башындагы кереп торган ермагы миңа тагы да гүзәл һәм матур күренде.* М. Җәлил. *Без пароход йөртеп уйнаган ермак авызында пристань була.* Г. Гобәй.

ЕРМАҚЛАУ *ф.* Ермаклар ясап телгәләү, ергалау. *Тау битләрен ермаклау.*

ЕРМАҚЛАНУ *ф.* Тармаклану, ермаклар барлыкка килү. *Түбәләрдән ашыгып-ашыгып тамчылар тама, труба асларына сулар җыела, алар, ермакланып, күгелҗем карны ашап, тауга түбән ашкыналар.* А. Шамов. *Мохтарның хыялында төрле уйлар, ермакланып җәелгән ташкын шикелле, әрле-бирле авып тордылар.* Ш. Камал.

ЕРМАЛАУ *ф. к.* ермачлау 2. [*Харис:*] *Һи, телеграмма ич бу, кая, карчык, икәүләп ермалыйк әле.* А. Әхмәт.

ЕРМАЧЛАНУ *ф.* Ерганак һәм ерымнар белән ергалану, телгәләнү. *Ермачланып беткән борынгы тау битләре хәзер җимеш бакчаларына әверелгән иде.* Г. Бәширов.

ЕРМАЧЛАУ *ф.* **1.** Төрле юнәлештә кисешеп үткән чокырлы-чакырлы эзләр, ерынтылар ясау. *Агачны корт ермачлау.* □ *Нефтьчеләр болыннарны, басу өсләрен ермачлап бетергәннәр.* Г. Ахунов. // *күч.* Төрле юнә-

лештә кисеп үтү. *Врач җыерчыклар ермачлаган маңгаен имән бармагы белән ышкып алды.* Каз. утл.

2. *күч.* Нинди дә булса эшне зур кыенлык белән башкару турында. *Малай башта аввыррак ермачлый, соңга таба «шома гына, төртелмичә генә укый» башлый.* Ф. Хөсни. *Язгы чәчүне вакытында ермачлап чыктык.* Э. Касыймов.

ЕРТКАЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* ерткалау.

2. Күп урыннан ертылу; тузу, сәләмәләнү. *Егетнең --- бишмәте ерткаланып беткән иде.* Г. Әпсәләмов.

ЕРТКАЛАУ *ф.* **1.** Ертып вак-вак кисәкләргә аеру. *Арадан бер хатны Хәят, яңадан укып чыкмыйча, ерткалап тәрәзәдән ыргытты.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Җирне начар сөрү турында. *Аннан-моннан ерткалап, әйтерсең, исерек кул белән чәчелгән, шундый тигезсез чыккан дүрт дисәтинә арыш аламасы ята.* Г. Ибраһимов.

ЕРТКЫЧ *и.* **1.** Башка хайваннар белән тукланучы җәнлек. *Ерткыч төсле ташлану. Ерткыч тырнагыннан котылу.* ☐ *Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар, Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Башка хайваннар белән тукланучы. *Ерткыч хайваннар. Ерткыч кошлар.*

2. *күч.* Чиктән тыш явыз, рәхимсез, аяусыз, кансыз кеше турында.— *Нинди ерткыч бу Иргали!* Ф. Бурнаш. *Вакыт килер: безгә үлем, хәсрәт алып килгән фашист ерткычларны җир йөзеннән себереп түгәрбез.* Р. Ишморат.

ЕРТКЫЧЛАНУ *ф.* Кешелек сыйфатларын югалту, артык явызлану, аяусызлык, хаксызлык күрсәтү. *Унтерофицер, ротныйлардан башлап һәммәсенең дә төсләре качкан, --- [алар] башка көннәргә караганда, әллә ничә тапкыр усалланганнар, ерткычланганнар.* М. Гафури. *Ә сез менә, мулла, кулак — Эшчеләрнең дошманы, Колхозларга ут ачасыз, Котырып, ерткычланып.* М. Җәлил.

ЕРТКЫЧЛА'РЧА *рәв.* **1.** Явызларча, үтә рәхимсез, аяусыз рәвештә. *Ерткычларча бомбага тоту.* ☐ *Шушы туганнар каберендә интервентлар тарафыннан ерткычларча үтерелгән кешеләр --- ята.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Юкка чыгаруга, кырып бетерүгә алып килә торган зарарлы нәтиҗәсе турында уйламыйча, бүген, тиз арада булачак файдага гына исәп тотып. *Ерткычларча хуҗалык итү.*

ЕРТКЫЧЛЫК *и.* **1.** Чиктән тыш явызлык, рәхимсезлек; талау, үтерү. *Кулаклардан оештырылган бу банда үзенең ерткычлыгын әле һаман дәвам иттерә.* А. Шамов. *Хәзерге фашист палачларының җирәнгеч ерткычлыклары, күләм һәм куркынычлык ягыннан кешелек тарихында булып үткән иң кабахәт ерткычлыкларны да бик күп артта калдыра.* Ш. Камал.

2. Хуҗалыкны ерткычларча (2 *мәгъ.*) алып бару, нәрсәдән дә булса ерткычларча файдалану.

ЕРТЛАЧ I *с.* Куе, ямьсез эре чокырлы (шадра турында). *Варяның ертлач-ертлач шадрасы портретта бөтенләй беленми.* Ф. Әмирхан.

ЕРТЛАЧ II *с. сөйл.* Чиктән тыш комсыз, оятсыз. *Сафа, абыйсы шикелле ертлач бер кеше булмаганлыктан, бу йорттагы кешеләрнең гаепләреннән файдаланырга уйламады.* М. Галәү. [*Яникә Тынгысызга:*] *Сараф шул чаклы ертлач булмаса, син гомердә дә аңа өйләнә алмаган булыр идең!* Н. Исәнбәт. // Бик эрсез, оялуны, уңайсызлануны белми торган. *Юаш адәм оялчан булыр, ертлач адәм соранчак булыр.* Әйтем. — *Зур төзелешкә андый ертлач эшкуарны ансат кына озатып җибәрергә хакыбыз бармы әле безнең?* Э. Касыймов.

ЕРТЛАЧЛАНУ *ф. сөйл.* Ертлачка (II) әйләнү.— *Кыю булам дип, ертлачланып та китмисеңме, Хәйдәр?* Р. Төхфәтуллин.

ЕРТЛАЧЛЫК *и. сөйл.* Ертлач (II) булу сыйфаты. [*Чагин*] *шомарган бәндә — тәмам әт каешы инде. Әмма ертлачлыгы да көчле үзенең.* Э. Касыймов.

ЕРТУ *ф.* **1.** Кисәкләргә бүлү, аеру; бөтеннән бер кисәк аеру, өзү (кәгазь, тукыма һ. б. ш. әйберләр турында). *Кәгазьне урталай ерту.* ☐ *Җиңен ертып бәйләде ул Комиссарның ярасын.* Ә. Ерикәй. // *рәв. мәгъ. күч.* **ертып.** Ярып, аерып. *Ак болытлар, җирне каплап тормагыз, --- Мин барыбер сезне ертып үтәрмен.* М. Җәлил. *Вакыт-вакыт, төнге караңгылык чаршавын ертып, ак ракеталар күккә күтәрелде.* Г. Әпсәләмов.

2. *сөйл.* Сөрү. *Әхмәт, Нәгыйм һәм Халикъ өчесе бер бүлектә атлар белән сөрәләр. Кара Хәсән, Мортаза һәм Җаббар үгезләр белән икенче бүлекне ерталар.* Ш. Камал.

3. Нинди дә булса үткен, очлы әйбер белән ерып, тырнап эз калдыру. *Яра зур түгел, пуля сөяккә тимәгән, ә итне генә ертып узган иде.* А. Шамов. *Тракторларга тагылган сабаннарның җәенке төрәннәре күтәреп куелган булсалар да, алар калкурак урыннарда җирне ертып үзалар.* С. Рафиков.

4. *күч.* Ислемай, төтен, агулаучы газ, хлор һ. б. ш. нәрсәләр исенең сизү органнарына, күзгә көчле тәэсир итүе турында. *Аның борынына одеколон исе ертып керде.* С. Рафиков.

ЕРТЫК *с.* **1.** Ертылган; тузып тишелгән (кием-салымга карата). *Ертык күлмәкне никадәр җөйләсәң дә эзе кала.* Мәкаль. *Бүген әле, тиздән кыш килә дип, Ямап куйдым ертык бүрекне.* Һ. Такташ. // Сәләмә, начар. *Өс-баш ертык, тамак ач.* Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Ертылган, тишелгән урын. *Ертыгына күрә ямавы.* Мәкаль. *Киеменең ертыкларыннан ачы җил, салкын үтә.* М. Гафури.

ЕРТЫК-ПЫРТЫК *с. сөйл.* Бик сәләмә, теткәләнеп, тишелеп беткән. *Өс киеме аның ертык-пыртык, Кырык җирдән ямау салынган.* М. Җәлил.

ЕРТЫК-СҮТЕК *с. сөйл. к.* ертык-тишек. *Тормышның авырлыгын күбрәк ул [Зөһрә] күтәрә, тегү тегеп булса да, тормышның ертык-сүтекләрен каплый.* З. Бәширi.

ЕРТЫК-ТИШЕК *с. сөйл.* **1.** Ертылган, тузып тишелгән; ертылып, тишелеп беткән. // *и. мәгъ.* Ертылган, тишелгән урын. [*Гарәфи абзый*], *читтә йөргәндә хатын янда булмый дип, барлык ертык-тишекләрен яматтты, өзелгән төймәләрен тактырды.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Җитешмәгән, кирәкле. *Алманың акчасы кесәгә дә йокмады; ертык-тишек урын күп булгач, акчаны күрми дә калдылар.* И. Гази. // *и. мәгъ.* Кирәк-ярак, ихтыяҗ. [*Хәйретдин*] *тормышның авырлыгыннан, көнтөн эшләп тә кечкенә генә тормышның ертык-тишекләрен дә ямап булмаудан зарлана.* М. Гали.

Е'РТЫЛГАНЧЫ *рәв. гади с.* **1.** Озак һәм бик каты, бөтен көчкә. *Ертылганчы кычкыру.*

2. Туйганчы; чамадан тыш күп. [*Бохари хәлфә*] *көн дә ертылганчы ашарлык үпкә-бавыр, баш-аяк алып китә, бирән!* А. Расих.

ЕРТЫЛУ *ф.* **1.** *Төш., кайт. юн. к.* ерту 1. *Минем бармаклар канап, тез сөякләрем бәрелеп, киемнәрем ертылып бетә.* И. Гази.

2. *күч. гади с.* Каты кычкыру, акыру.— *Кая шул тикле ертыласың? Янамы? — диде Зөлхәбирә [Кәшфразыйга], онытылып китүен акларга теләп.* Б. Камалов. // Бик нык кәефсезләнү, соңгы чиккә җитеп ачулану турында. *Кызның аты-чабы чыкты. Ата, боларны ишеткәч, хурлыгыннан ертыла язды.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Кирәклек, ихтыяҗ; җитешмәгән яклар. *Җиңү чорларында ертылып та хәзер дә ямалмаган, ямала алмаган ертыклар күп әле.* Г. Гобәй.

ЕРТЫШ I *и. зоол.* Йөзгечләре эре чәнечкеле, ите кылчыклы зур булмаган елга балыгы. [*Аквариумнарның*] *һәркайсында төрле-төрле балык. Алтын балыклар, чабак, ертыш, чуртаннар.* Г. Мөхәммәтшин.

ЕРТЫШ II *и. диал. этн.* Кычкырышып-шаярышып туй бүләге итеп бирелгән материяне ерту йоласы. *Агай-эненең тартышы — Туй бүләге ертышы.* Мәкаль.

ЕРУ *ф.* **1.** Су ташкыны белән юлдагы нәрсәләрне юып, җимереп үтү. *И яуды, и яуды* [*яңгыр*], *күперләрне агызды, буаларны ерды.* А. Гыйләҗев. // Сулыкны тотып тора торган ныгытманы җимерү, суга юл ачу.— *Алла сакласын, ул* [*Миркәй*] *авылга ут салыр, тегермәнне ерыр.* Н. Исәнбәт.

2. Җирне озынлыкка казып нәрсә дә булса эшләү, үткәрү. *Безнең куллар канал ерырлар Идел кебек итеп, киң итеп.* Ә. Ерикәй.— [*Бакчага*] *күлдән су ерып кертәм.* И. Гази.

3. Кар, пычрак, су эченнән бару; шундый карлы яки пычрак юлдан кыенлык белән үтү турында. *Картлар, урам буенча йомшак кар ерып, дәшми-тынмый гына өйләренә кайталар.* Ш. Камал. *Искәндәрев, кара төн уртасында пычрак ерып, тикмәгә генә килмәгәндер иче!* Ә. Еники. // Ике якка этәрү, аеру. *Шатыр-шотыр куаклар ерып, урман эченнән Бикмулла карт килеп чыкты.* Г. Бәширов. [*Нәгыйлмә*], *кешеләрне ерып, тыгызлана-тыгызлана барып, үз урындыгына җитте.* Г. Ибраһимов.

4. *сөйл.* Киң итеп ачу. [*Мортыйның*] *күлмәк якасы күкрәгенә кадәр ерып җибәрелгән.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Ерып чыгу** — 1) ахырынача башкару, үтәү.— *Эшне әйтәм әле, баштарак бер дә ерып чыга алырбыз төсле түгел иде.* М. Хәсәнов; 2) кыенлыкларны җиңү, җиңеп чыгу. *Мәсьәлә анда түгел, мәсьәлә әнә шул аерым бәхетсезлекләрне ерып чыга алуда, шуларны ерып чыга алырлык көч, ихтыяр булдыруда.* Ф. Хөсни.

ЕРШАЮ *ф. диал.* Кыйшаю (авыз турында). [*Бәли карт*] *еламаска тырыша иде, ләкин, ихтыярсыз, авызы ершаеп китте.* Ш. Камал.

ЕРЫК *и.* **1.** Кием итәгендә яки чабуында җәй буенча махсус тегеп җиткерелмичә калдырылган урын. *Шинель ерыгы.* // *с. мәгъ.* Ерыгы булган, ерыклы. *Ерык чабулы пальто. Ерык итәкле юбка.*

2. Эчкә таба батып яки ярык булып торган тартына уем. *Өч-дүрт атналык яралгы инде балыкка охшый: аңарда саңак ерыклары күренә.* А. Тимергалин. // *с. мәгъ.* Шундый уентысы булган. *Кайтканда юл буе бер авыз сүз сөйләшмәделәр. Тик Василий Степанычның ерык ирене генә селкенеп торды.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Ерык авыз** *гади с.* — 1) сәбәпсез көләргә яратучы.— *Көлә дә көлә, явыз. Иллә ерык авызлар бар да соң бу дөньяда!* Г. Мөхәммәтшин; 2) урынлы-урынсыз теләсә нәрсә сөйләүче, күп сөйләргә яратучы. [*Мәүлиха Әпипәгә:*] *Һи, тел бистәсе, һи, ерык авыз! Телеңә салынып утырган буласың.* Г. Бәширов.

ЕРЫКЛЫ *с.* Ерыгы булган. *Арты ерыклы пальто.*

ЕРЫЛУ *ф.* Су ташкыны басымы астында җимерелү, ачылу (буа һ. б. ш. турында). *Тегермән буасы бер ерылса, туктатып булмый бит аны.* Ә. Касыймов.

◇ **Ерылып көлү** *гади с.*— киң итеп елмаеп көлү. *Шулай ук Зәйтүнә дә Сәфәргалигә - - - ерылып көлеп тора иде.* Ф. Хөсни.

ЕРЫМ *и.* **1.** Яңгыр һәм язгы кар сулары белән юылып, ашалып ясалган киң һәм тирән озын чокыр. *Каранғы почмакка, ерымнарның берсенә, посып өлгергән* [*җинаятьче*] *Алмазга төзәп аткан.* Б. Камалов.

2. Махсус ерып, казып ясалган зур, озын канау. *Кабанның әле Болак дигән ерымы да бар.* Ә. Еники.

ЕРЫНКЫ *с. сир.* Зур (авыз турында). *Габделбасыйрның йөзе матурлык белән аерырлык түгел иде: төссез генә соры күзләр, - - - шактый ерынкы гына авыз, таррак кына маңгай.* Ф. Әмирхан.

ЕРЫНТЫ *и. к.* ерым. *Ерынтылар, уйсу җирләр белән телгәләнгән, бүлгәләнгән басулар һәм болыннар урыны-урыны белән кардан арынып чуарланганнар.* А. Расих. *Бозлы юлны урталай кисеп, ерынты ерып җибәргәч тә, сул яктагы су тиз арада хәрәкәткә килде.* Н. Фәттах.

ЕСАУЛ *и.* Патша армиясенең атлы казак гаскәрләрендә офицер чины, җәяүле гаскәрләрдәге капитан дәрәҗәсенә тигез; шул чиндагы хәрби кеше. *Есаулның әйтүе дә булды, бер эскадрон казаклар, кылычларын болгый-кизи, халык өстенә ташланды.* И. Туктар.

ЕФРЕЙТОР *и.* Рядовой солдатка бирелә торган беренче хәрби чин; шул чиндагы кеше. *Аларны казарма алдындагы мәйданга өйрәтергә алып барган солдат үзен «господин ефрейтор» дип атарга кушты.* М. Гали.

ЕФӘК *и.* **1.** Ефәк кузысыннан эшкәртелгән җеп. *Кулымдагы кулъяулыгым ефәк белән чигелгән.* Җыр. [*Карт врач*], *яралының корсак җөвен тегеп бетереп, ефәген кисеп маташа.* Ш. Маннур.

2. Шундый җепләрдән, шулай ук ясалма, синтетик сүстән эшләнгән тукыма. *Быел язын иркәмә ефәк алдым күлмәккә.* Җыр.

3. *с. мәгъ.* Шундый җепләрдән бәйләнгән, үрелгән; шундый тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Ефәк оек. Ефәк шарф. Ефәк билбау. Ефәк тасма. Ефәк күлмәк.* □ *Газинур - - - сөйгәненең иңнәренә аллы-гөлле ефәк яулык салды.* Г. Әпсәләмов. // Ефәк эшкәртә торган, ефәк тукымалар эшли торган. *Ефәк фабрикасы.*

4. *с. мәгъ. күч.* Йомшаклыгы, нәфислеге, елтыравы белән шундый җепләрне, тукымаларны хәтерләткән. *Кояш көлә ефәк нурлар сибеп.* Ә. Ерикәй. *Ефәк чәчен үргән ефәк тартып.* Ш. Бабич.

Ефәк корты — ефәк күбәләгенең курчаклану стадиясенә кадәр булган тереклек хәле. *Ефәк корты кузыларын җыю.* **Ефәк кузысы** — ефәк кортының курчаклык стадиясенә күчү чорында үзеннән чыгарган бик нечкә, нәфис җепселләргә чорналуыннан барлыкка килгән йомгакчык. [*Сүн*] *ефәк кузыларын күп итеп алып кайта да алардан, җепләр эрләп, тукымалар тукый.* З. Бәшири. **Ефәк күбәләге** — кортлары (гусеницалары) ефәк кузылары үрә торган күбәләк.

◇ **Ефәктә генә йөртү** — затлы, асыл, ефәк киемнәр генә кидерү. *Мин сине шундый кадерләрмен, ефәктә генә йөртермен үзеңне.* Г. Кутуй.

ЕФӘКЛӘНҮ *ф. сир.* Ефәк сыман нәфис, елтыравыклы булу. *Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык ефәкләнеп, дулкынланып тора.* Г. Ибраһимов.

ЕФӘКЧЕ I *и.* Ефәк күбәләге. *Имән ефәкчесе. Тут ефәкчесе.* □ [*Күкеләр, выжлавыклар*] — *ефәкчеләр дошманы.* Г. Хәсәнов.

ЕФӘКЧЕ II *и.* Ефәкчелек эшендә эшләүче; шул өлкәдә эшләүче белгеч. *Колхоз ефәкчеләре.* □ *Төядән: — Һөнәрең ни? — дип сораганнар икән: — Ефәкче,— дип җавап биргән ди.* Н. Исәнбәт.

ЕФӘКЧЕЛЕК *и.* Хуҗалыкның ефәк үрчетү һәм эшкәртү тармагы. [*Сүн*] *сарай ефәкчелегендә булган бөтен ефәк кузыларын карап, тикшереп чыга.* З. Бәшири.

ЕХИ'ДНА *и. зоол.* **1.** Австралиядә һәм Тын океан утрауларында яши торган керпе сыман хайван.

2. Австралиядә яши торган агулы елан.

ЕШ *рәв.* (кабатлаулы формада да кулланыла). **1.** Тыгыз, куе; *киресе:* сирәк. *Агачларны еш утырту.* □ *Күршеңне дус тот, читәненең еш тот.* Мәкаль. / *с. мәгъ. Еш иләк.* // Бер-берсенә бик якын. [*Казармада*] *рәттән аслы-өсле, еш итеп тактадан тезелгән сәке сымак урыннар - - - башта Гарифка бик күңелсез булып күренде.* М. Гафури.

2. Бер-бер артлы тиз кабатланып (бердәй хәрәкәт, тавыш, күренеш һ. б. турында). *Ат әйдәгән тавышлар, кыңгырау тавышлары бик еш ишетелә башлады.* Г. Ибраһимов. [*Сабира*], *һава җитмәгән сыман, авыр һәм еш-еш интегеп сулый иде.* Ә. Фәйзи. // *сөйл.* Кызу,

тиз.— *Әйдә, Сөләйман абзый, [уйна скрипкаңны], элек сирәк, аннан ешрак.* Ф. Бурнаш.

3. Бераз вакыт үткән саен, әледән-әле (кыска вакыт арасында кабатланып торган эш-хәл турында). *Еш очрашу. Еш ялау. Еш чакыру.* □ *Һәр көн димәсәм дә, бик еш буран.* Г. Тукай. *Еш-еш кына синнән хатлар алдым.* Б. Рәхмәт. // «Кына» кисәкчәсе белән килгән кайбер очракларда «күп вакытта, күпчелек очракта» дигән мәгънәне белдерә. *Газинур җырны кешедән отып алганча гына җырламый, еш кына ул аны, кәфенә карап, үзгәртә дә торган иде.* Г. Әпсәләмов. *Еш кына көнозын вак яңгыр сибәләп тора.* А. Шамов.

ЕШАЙТУ *ф.* 1. Бер-берсенә якын китерү, тыгызлау.

2. Тизләтү, хәрәкәт темпын арттыру. *Адымнарны ешайту.*

3. Нинди дә булса эшне ешрак кабатлау. [*Нәгыйм*], *барган саен, Вахитларга килүен ешайтты.* М. Гафури.

ЕШАЮ *ф.* 1. Нәрсәнең дә булса тизлеге, ешлыгы арту. *Газинурның кара күзләре уйнаклый башлады, сулышы ешайды.* Г. Әпсәләмов.

2. Еш булу, еш кабатлану. *Бу хәл соңгы вакытларда ешая башлаган иде.* С. Рафиков. // Күбәю, ешрак очрау. *Авылыбызны яртылай әйләндереп алган Агыйдел озынайды, борылышлар ешайды.* М. Әмир. *Лагерь тирәсендә сакчылар күбәйде, постлар ешайды.* Н. Дәүли. // Көчәю. *Яңгыр --- ешая төште.* М. Шабай. *Ату тавышлары тагы ешайды.* А. Расих.

ЕШҚЫНЛЫҚ *и. диал. к.* ешлык 3. *Ешкынлыкларда күпереп торган йонлы койрыклар күренеп кала, агач башларында, бик сәер тавышлар биреп, озын канатлы кошлар җилпенә.* Г. Галиев. *Җәнлекләрнең исән калганнары урман ешкынлыкларына, саз буйларына качканнар.* Г. Мөхәммәтшин.

ЕШЛАНУ *ф. к.* ешаю. *Җиңү хәбәрләре килгән саен йөрәгемнең тибүе ешлана.* М. Ногман. *Күләгәләр һаман ешлана, шавылты көчәя.* Ш. Камал.

ЕШЛАТУ *ф. к.* ешайту (2, 3 *мәгъ.*). *Балыкка йөрүне ешлату.* □ *Вагон тәгәрмәчләре рельс ялгаулары өстеннән тигез тавыш белән сугылып үтүләрен ешлата баралар.* Ә. Еники.

ЕШЛАУ *ф. сөйл.* 1. *к.* ешайту 1. *Идән такталарын ешлау.*

2. Еш барып, килеп йөрү (кем янына, кая). [*Мидхәт*] *хәзер калага бик еш бара, тик болай ешлавының сәбәпләрен өйдәгеләргә белгертми иде.* Ф. Хөсни. *Карт кирәгеннән артык ешлады: көн саен диярлек тау башындагы өйгә килеп китә.* М. Шабай.

ЕШЛЫҚ *и.* 1. Нәрсәләрнең дә булса бер тирәгә күп һәм бер-беренә бик якын, тыгыз урнашуы. *Һәркем --- арышның саламга озынлыгын, башакка туклыгын, көлтәнең күп чыгуын, чүмәләләрнең ешлыгын, зурлыгын күреп --- [куана].* Г. Ибраһимов. *Күплекләре һәм ешлыклары белән шаулап утырган --- биек вышкалар арасында «Челекөн» тавы, горурланып, күкрәген калкыткан.* Р. Ильяс.

2. Нәрсәнең дә булса еш кабатлану дәрәҗәсе. *Сүзнең кулланыш ешлыгы. // махс.* Билгеле бер вакыт эчендәге хәрәкәтнең, тирбәнешнең саны, зурлыгы. *Тавыш ешлыгы. Ток ешлыгы. Маятникның тирбәнеш ешлыгы. Югары ешлык.*

3. Урманның агачлар бик куе үскән урыны; чытырманлык, куелык. *Ешлыкларны [чистарту] урманга файда гына ул: калган хәтлесенә иркенәеп үсәргә җай.* Э. Касыймов. *Көмештән коеп ясалгандай матур урман ешлыгы.* А. Расих.

ЕШУ *ф. диал.* Ышкылау. *Бакырны күпме ешсаң да алтын булмас.* Мәкаль. *Йомрыдыр тыштан, Эчке ягы ешкан, Осталар шулай кушкан.* Табышмак.

ЕШЫНУ *ф. диал. к.* елышу (3, 4 *мәгъ.*). *Мөзәкир рәхмәт әйтеп табыннан купты да почмактагы китап шкафы янына ешынды.* А. Гыйләҗев. *Тирә-якка карана-карана без шушы өй янына барып җиттек тә арт як стенасына ешындык.* Ф. Кәрим.

Ж

Ж Татар алфавитында җиденче хәреф.

ЖАКЕТ *и.* Хатын-кызларның бәйләгән кыска өске киеме. *Өстенә кыска жакет --- кигән Миңнурый [чыкты].* Г. Әпсәләмов.

ЖАКТ *и.* Җирле Советлар карамагындагы торак йортларны үзенең пайчыларына билгеле бер хакка вакытлыча файдалануга биреп тору белән 1937 елга кадәр шөгыльләнгән кооператив берләшмә.— *Жакт фатирында гына рәхәтләнеп яшисе иде инде!* А. Расих. *Мин бүлмә өчен, гомуми тәртиптә, метр исәбеннән жактка түләргә [булдым].* Ф. Хөсни.

ЖА'ЛОБА *и. сөйл.* Берәр кеше, учреждение яки оешманың ялгыш, законсыз, начар эшләрен яки гаебен күрсәтеп язган рәсми гариза; шикаять.— *Мин начальникка жалоба белән барам.* Г. Ибраһимов.

Жалоба бирү — берәр кеше яки оешма өстеннән зарлану. *[Мәхдүм] атасына: «Әти, әнә тегендә Гариф мәзиннең күзлекле угылы --- рамазан шәрифтә көпә-көндез сабын ашап утыра», --- дип жалоба бирә.* Г. Тукай. **Жалоба итү** *сир.— к.* жалоба бирү.— *[Ул] минем өстән жалоба итәргә килә.* Н. Исәнбәт.

ЖАЛЮЗИ *и.* Һава агымын һәм яктылыкны тигезләү өчен файдаланыла торган махсус тәрәзә капкачы яки, төрле әйберләрдән ясалып, бер-беренә беркетелгән пәрдә.

ЖАНДАРМ *и.* Жандармериядә хезмәт итүче кеше.— *Жандармнар выборныйларны, берәм-берәм корпустан өстерәп алып чыгып, кул-аякларын богаулыйлар!* М. Гали. *Жандармнар аны кулга алдылар.* Г. Әпсәләмов.

ЖАНДАРМЕ'РИЯ *и.* Патша Россиясендә һәм кайбер буржуаз илләрдә революцион хәрәкәткә каршы көрәш алып бару, революционерларны эзәрлекләү өчен махсус оештырылган полиция гаскәре. *Александр патша һәм аның жандармериясе азатлыкка табан булган кечкенә генә омтылышны да буа.* К. Нәҗми. *Казан алпавытларының агентлары аның «коткы тарата торган» речен шундук жандармериягә җиткергәннәр.* Г. Ахунов. // Шул гаскәр оешмасы урнашкан бина. *[Тангатаровны] туры жандармериягә — охранкага алып бардылар.* Г. Ибраһимов.

ЖАНДА'РМЛЫК *и.* Жандарм хезмәте.— *Коридорда «Марсельеза» җырлауга каршы бәйләнеп йөрү сез [мәгаллимнең] эше түгел, бу — жандармлык.* Г. Ибраһимов.

ЖАНР *и.* **1.** Нинди дә булса әдәбият яки сәнгать әсәрләренең үзенә генә хас сюжет һәм стилистик билгеләре белән аерылып торган төре. *Эпик жанр. Лирик жанр. Драма жанры.* □ *[Г. Камал], төрле жанрларда язып, үзенең каләмен сынап карый. Ул шигырь, --- хикәя сыман әйберләр, --- сәхнә әсәрләре иҗат итү тәҗрибәләрен дә ясый.* М. Гали. *Студия дәвере --- татар музыкасының күп тавышлы хор, сюита, соната, квартет, симфония һәм опера кебек катлаулы жанрларга баюы белән характерлы.* М. Җәлил.

2. *иск.* Көнкүреш, көндәлек тормыш күренешләре. *Г. Ибраһимов әсәрләрендә жанр сурәтләре зур урын ала. Авыл, аның эше, крестьяннарның ашау-эчү, тору-киюләре, йөрешләре, гадәтләре киң итеп күрсәтелә.* Г. Нигъмәти.

ЖАРГОН *и.* Берәр социаль яки профессиональ төркемнең үзенә генә хас, үзенчәлекле, әдәби нормаларга сыймый торган сүз һәм әйтелмәләре. *[Г. Камал] Печән базары татарлары арасында таралган жаргоннарны әдәбиятка кертми.* М. Гали. // Билгеле бер мохитта, төркемдә генә аңлашылы шартлы сөйләм; арго. *Караклар жаргоны.* □ *Әлеге сүзчән хатын саф солдат жаргоны белән, нәкъ солдатча итеп [әйтеп] калды.* Ф. Хөсни. // Башка тел сүзләре белән чуарланган тел; бозык тел. *Сөйләп китте Әшрәп, русча түгел, Татарча да түгел, жаргонда: --- «Ә, революция, аны үткән вакта Больше практиковали французлар».* Н. Исәнбәт. // *с. мәгъ.* Башка тел сүзләре белән чуарланган, бозык. *Беренче карашта вак булып тоелган бозулар нәтиҗәсендә --- жаргон тел барлыкка килә.* И. Гази.

ЖАРГОНЧЫЛЫК *и.* Жаргон белән мавыгу, сөйләмгә урынсызга чит, ят сүзләр кертеп, тел бозу. *Туып, формалашып барган дворян аристократиясенең телгә мөнәсәбәтен ачык күрсәтеп торган жаргончылык та XIII—XIV йөз болгар-татар әдәби теленда инде сизелә төс алган.* Л. Җәләй.

ЖГУТ *и.* **1.** *мед.* Кан китүне вакытлыча туктату өчен кул яки аякны кысып бәйли торган сузылмалы резин көпшә яисә бинт. *Жгут салу.* □ *Парашют белән һавадан медикаментлар төшә, Сынган кул-аяклар өчен Жгут, кабыклар төшә.* С. Баттал.

2. *зоол.* Иң гади организмнарның тәннәрендә хәрәкәт итү әгъзасы хезмәтен үти торган җепсел сыман хәрәкәтчән төерчек.

ЖГУТЛЫЛАР *и. зоол.* Жгутлар (2 мәгъ.) хәрәкәт әгъзалары булып хезмәт иткән иң гади организмнар семьялыгының исеме.

ЖЕ *и.* «Ж» хәрефенең исеме.

ЖЕЗЛ *и.* **1.** Берәр дәрәҗә яки түрәлек билгесе булып хезмәт иткән махсус таяк. *Маршал жезлы.*

2. *махс.* Бер колеялы тимер юлда машинистка юлын дәвам итү хокукы бирә торган тимер таяк. *Кызыл фуражкалы дежурный, кулына жезл тотып, инде поездны каршыларга чыккан.* И. Гази.

ЖЕЛАТИН *и. тех.* Хайван сөяге яки тиресеннән ясалып, техникада, фотографиядә, кулинариядә, медицинада кулланыла торган койкә сыман аксым матдә; коллоид.

ЖЕЛЕ *и.* Җиләк-җимеш суларыннан, кызыл аракы, сөт һ. б. продуктлардан желатин ярдәмендә хәзерләнә торган койкә сыман татлы ашамлык. *Мүк җиләге желесы.*

ЖЕНЬ-ШЕНЬ *и.* Ерак Көнчыгышта үсә һәм тамырыннан дару ясала торган куак. *Кешенең үткән яшьлеген, бөтен көчен кабаттан кайтара, авыруларны сәламәтләндерә торган гаҗәеп жень-шень --- куагы. Сабагы билдән югары түгел, нәкъ түбәсендә җәеп җибәргән күл бармаклары кебек жиде яфрагы һәм алсу төстә вак кына чәчәкләре бар. Жень-шеньның бөтен хикмәте — аның тамырында.* Г. Әпсәләмов.

ЖЕТОН *и.* **1.** Берәр җәмгыять члены булуны күрсәтү өчен, шулай ук берәр вакыйга яки шәхси җиңү хөрмәтенә бирелә торган калай значок (яки медальнең бер төре). *Өчесенә дә көмешчедән монограмма яздырып,*

алтынланган жетон бүләк итәргә карар чыгардык. Сов. эд.

2. Берәр нәрсәгә хокук бирә торган металл кисәге.— *Кая, этегезне күрсәтегез әле? Жетоны бармы?* В. Монасыйпов.

Ж-Ж-Ж *аваз ияр.* Бөҗәкләр очканда яки механизмнар зур тизлек белән хәрәкәт иткәндә чыккан тавышны белдерә. *Йөк машинасы: --- «Жжж-жый...»* [*дип буксовать итә*]. Н. Исәнбәт.

ЖИКЕТ *и. сөйл. к.* жакет. [*Хатыннарының*] *бере яңа жикет даулый.* Г. Камал. [*Киленнәр*] *яшел я зәңгәр плүштән жикет тектерергә бик һәвәс иделәр. Биле нечкә, жиң очлары тар булсын, иңбашлары бөрмәләнеп, күпереп торсын...* Г. Бәширов.

ЖИЛЕТ *и.* Ирләр пиджак астыннан кия торган жиңсез, якасыз кыска кием. *Хисами, жилет кесәсеннән чыгарып, бәрәңге зурлыгы көмеш сәгатенә карады.* Г. Минский.

ЖИЛЕ'ТКА *и. к.* жилет. *Кызыл сатин күлмәк өстеннән яшел хәтфә жилетка --- кигән мишәрләр --- солдатларга дәртле кычкыр*[*алар*]. К. Нәжми. *Укытучы пиджагын сала, жилеткадан гына кала.* М. Мәһдиев.

ЖИРАФ *и. зоол.* Африкада яши торган бик озын муенлы, озын аяклы, ала-кола төстәге хайван.

ЖИРӘБӘ *и.* **1.** *к.* шобага. *Жирәбә салу.* □ *Безнең урамнан бәхетле жирәбә студент егет Коляга эләкте.* Р. Төхфәтуллин. *Сугышчан разведка ясау бурычы, бүректә бөтереп салган кәгазь жирәбә буенча, Булатка чыкты.* Г. Ахунов.

2. *иск. сөйл.* Язмыш, тәкъдир. *Без тартасы йөкне беркем тартмас. Безнең өлеш—безнең жирәбә.* Р. Рәхимов.

ЖОКЕЙ *и.* Ат чабышларында ат өстендә яки ат жигелгән жиңел арбада йөрү белән шөгыльләнүче кеше. [*Җәгъфәрнең*] *аягында елтыр итек, кулында кыска гына жокейлар чыбыгы иде.* А. Расих.

ЖОНГЛЁР *и.* Берничә әйберне берьюлы ыргытып һәм тотып алып уйный торган цирк артисты. *Син циркта дистәләгән шарлар, алкалар, дөрләп янган факеллар чөеп уйнаучы виртуоз жонглёрның өлгер кулларына карап шаклар да каттың.* Р. Төхфәтуллин. *Сәхи — гимнаст, жонглёр, төрле кәмит күрсәтә.* Н. Фәттах.

ЖОНГЛЁРЛЫК *и.* Жонглёр һөнәре яки сәнгате. // *күч.* Сүзләр, фактлар белән оста һәм үзе теләгәнчә эш итүчәнлек.

Жонглёрлык итү — үз файдасына сүзләр, фактлар белән оста һәм теләсә ничек эш итү.

ЖРЕЦ *и.* Мәҗүсиләрдә дин башлыгы. *Әүвәлге Мисыр жрецлары шикелле, ялгыз зыялылар сыйныфын тәшкил иткән руханиларыбыз* [*бар*]. Ф. Әмирхан.

ЖУ *аваз ияр.* Бөҗәкләр очуыннан, кешеләр һ. б. шаулавыннан яки механизмнарның зур тизлек белән хәрәкәт итүеннән барлыкка килә торган тавышны белдерә. *«Нәрсә бу?» — дип китте гөжләү, жу да жу!..* Ш. Бабич.

Жу итү — жулау, «жу» авазын чыгару. *Жир асты — мәгарәдә урын табып, жу итеп тора* [*бал кортлары*], *эшләр бара.* Ш. Бабич. *Жуу итеп килеп тә чыга бер машина.* Н. Исәнбәт.

ЖУЛАУ *ф.* **1.** Очканда канатлар белән «ж-ж-ж» га охшаш бертөрле аваз чыгару (бөҗәкләр һ. б. турында); жу итү. *Кинәт ниндидер коңгыз жулый башлый.* Г. Әпсәләмов. *Тубал эчендә жулау башлангач, яртысыннан артык ил тубалга тупланган, бал кортлары үзләре үк тубалга керә башлыйлар.* А. Алиш. // Зур тизлек белән очканда, хәрәкәт иткәндә шуңа охшаш аваз барлыкка килү. *Пуля жулавы. Снаряд жулавы.* □ *Таш яшен тизлеге белән жулап дошман ягына барып һәлакәт ясый.* М. Гафури. *Оча туплар, жулап, кара күктә.* М. Җәлил.

2. *күч. сөйл.* Бер үк нәрсәне кабатлап теңкәгә тию, бәйләнү, эч пошыру.

ЖУ'ЛИК *и. сөйл.* Вак карак, кесә карагы. — *Ә мин сине жулик дисәм? --- Ягъни мәсәлән, угры, карак дисәм, ни әйтерсең?* К. Тинчурин. // Алдакчы, хәйләкәр. *Чыгымчы, айгырын «Бик шәп хайван!» дип ялганлап сатучы бер карт жуликка каршы чыккан идем.* Ф. Хөсни.

ЖУ'ЛИКЛЫК *и.* **1.** Жулик булу.

2. Алдакчылык, хәйләкәрлек. *Шәһәр мещаннары --- жуликлык һәм аферистлык юллары белән төрле махинацияләр коралар, халыкны алдыйлар.* Х. Хәйри. [*Г. Камал*] *Сираҗетдин Туктагаев образы аша ул чорда татар сәүдә буржуазиясе арасында массалашкан шундый жуликлыкны ачып сала.* М. Гали.

ЖУМБА *и. зоол. к.* шамбы. *Елгада --- авыл теле буенча жумба дип йөртелә торган кечкенәрәк сом балыклары гына була торган иде.* Г. Камал. *Хәтерләдем үзебезнең завхозны мин, Карап торгач бер көн жумба балыгына. Икесе дә нәкъ бертөсле — тотып булмый, Кулдан шуып чыгалар бик шома гына.* Ә. Исхак.

ЖУРНАЛ *и.* **1.** Китап формасында чыга торган, гадәттә кәгазь тышлы вакытлы басма. *Айлык журнал. Әдәби журнал. Модалар журналы.* □ *1908 нче елда* [*Г. Камал*], *--- Г. Тукай белән бергәләп, «Яшен» исемле көлке журнал чыгара башлый.* М. Гали. *Бу поэма «Аң» журналының 1916 нчы елгы 19—20 нче санында басылган.* Н. Исәнбәт.

2. Төрле вакыйгаларны, эшләрне һәрвакыт теркәп, язып бару өчен тотылган зур форматлы калын дәфтәр. *Вахта журналы.* □ [*Зиннәтнең*] *дәфтәрләрендә генә түгел, класс журналында, хәтта табелендә дә бары бишләр белән дүртләр генә.* А. Шамов.

ЖУРНАЛИСТ *и.* Журналистика белән шөгыльләнүче профессиональ хезмәткәр. *Ә мин, --- журналист, --- аларның батыр эшләре турында бер сүз дә* [*язмаганмын*]. М. Җәлил.

ЖУРНАЛИ'СТИКА *и.* **1.** *к.* журналистлык. *Журналистика белән шөгыльләнү. Журналистика кафедрасы.* □ *Публицистика һәм журналистика өлкәсендә Г. Камалның хезмәтләре аерата зур. Ул 1905 нче елдан башлап --- газета, журнал редакцияләрендә өзлексез эшләп килә.* М. Гали.

2. *җый.* Барлык вакытлы матбугат. *Татар демократик журналистикасы.*

ЖУРНАЛИСТЛЫК *и.* Газета-журналларда әдәби-публицистик эшчәнлек. [*Г. Камал*] *үзенең тормышын бөтенләе белән журналистлыкка бәйләде.* З. Бәширн. // Журналист булу. *Журналистлык хезмәтен* [*М. Җәлил*] *чын күңеленнән яратып башкара иде.* М. Максуд.

ЖУЫЛДАУ *ф. к.* жулау. *Зур бер коңгыз, жуылдап очып килеп, эскәтергә төште.* Г. Газиз. [*Килен*] *көнетөне иренең колак төбендә жуылдар. Синең анаң фәлән, синең анаң төгән дип әләкләр.* Ш. Хөсәенов.

ЖЮРИ *и.* **1.** Ярышларда, конкурсларда, күргәзмәләрдә жиңүчене билгеләүче һәм аңа нинди бүләк бирү мәсьәләсен хәл итүче белгечләр. *Бу трагедия --- жюри тарафыннан бүләкләнде.* Н. Исәнбәт. *Хәзер конкурс жюрисына шактый гына* [*җыр*] *текстлары җыйналды.* М. Җәлил.

2. *иск.* Спорт ярышларында судья. *Көрәшәләр, егалар, егылалар, --- теләгән кеше телгәнчә мөхакәмә итә. --- Ә жюри, жюри соң нишли? --- Аның халык арасында һичбер авторитеты юк.* Ф. Әмирхан.

ЖӘЛ *с. рәв. сөйл. к.* кызганыч. *Аның өчен башың да жәл түгел.* Г. Әпсәләмов. *Кара көннәр аның --- маңгаена тирән эләр салган, аркасын бөккән, күзендәге нурны сүндергән иде. Бу вакыт ул миңа әйтеп бетерә алмаслык жәл тоелды.* С. Җәләл.

ЖӘЛЛӘҮ *ф. сөйл. к.* кызгану. *Туктамый кояш та яндыруын, Жәлләми аз гына атларны.* Н. Думави. *Бу беркөнне хатынын, балаларын искә төшереп елый. Ак елан моны жәлли.* Әкият.

З

З Татар алфавитында сигезенче хәреф.

ЗАБАСТО'ВКА *и.* Нинди дә булса экономик яки политик таләпләрне үтәргә мәҗбүр итү өчен, эшчеләрнең оешкан төстә эш ташлавы.— *Казан округындагы бунтлар, Алафузовтагы забастовка, тимер юлчыларның беркөнге номерлары — барысы да алар эше.* К. Нәҗми.— *Әнә Сидоров әйтә: һәммәбез бер сүздә булып эш ташларга, забастовка ясарга кирәк, ди.* Ш. Камал.

ЗАБАСТО'ВКАЧЫ *и.* Забастовкада катнашучы, эш ташлаучы эшче. *Габидулла, забастовкачылар белән булып алган сүз көрәштерүдән җенләнеп, кабинетына кергәч тә тиз генә басыла алмады.* Г. Минский. [*Оля:*] *Ул чакта сезнең барыгызны да забастовкачы дип куып чыгарачаклар.* Р. Ишморат.

ЗАБОЙ *и.* Шахтада күмер яки руда казу, чабу урыны. *Забойларга төшәм синең белән, Бергәләшеп күмер казышам.* З. Мансур.— *Забое да, кабер кебек, кечкенә генә бит аның.* И. Гази.

Забой чабу (кисү) — күмер казу, руда казу, чабу. *Забой чапкан чакта җырлар өчен Яңа җырлар кирәк аларга.* Һ. Такташ.

ЗАБОЙЧЫ *и.* Забойда эшләүче, күмер яки руда казучы. [*Хөснулла абый*] *забойчылар ятып чапкан тәбәнәк, тар «мич»тән күмерне шул чанага тутыра да, җилкәсенә ләмкә киеп, үрмәли-үрмәли тартып чыгара.* Ш. Маннур.

ЗАБОЙЧЫЛЫК *и.* Забойчы булу, забойчы һөнәре.

ЗАВКОМ *и.* Профсоюз оешмасының завод комитеты.— *Ул халыкка [ялкауларга, прогулчыларга] каршы завком гомуми чараларны гына җитәрлек тапмый.* Ш. Камал. // Завком җитәкчесе, завком башлыгы. *Ләкин янда завком басып тора: «Син,— ди,— ял ит бер кат елында!»* Ш. Маннур.

ЗАВОД *и.* **1.** Эре промысел яки промышленность предприятиесе. *Трактор заводы. Шикәр заводы. Сабын заводы.* □ *Үзебез хуҗа хәзер һәммәсенә: җиргә, суга, нурга, һавага, Урманнарга, шәһәр-авылларга, заводларга, фабрикаларга.* Ә. Исхак.

2. Яхшы токымлы, нәселле хайваннар (ат, балык) үрчетү һәм үстерү хуҗалыгы. *Ат заводы. Балык үрчетү заводы.*

ЗАВОДЧЫ *и. иск.* Завод хуҗасы. *Россиядә никадәр фабрикант вә никадәр заводчы бар.* Ш. Мөхәммәдев. *Заводчы Габидулла Башкинның өйләре шәһәрнең берничә җирендә иде.* Г. Минский.

ЗА'ВУЧ *и.* Мәктәптә уку-укыту бүлеге мөдире. *Наил дә үзенең завуч бүлмәсендә башын иеп, кызарып басып торган вакытын исенә төшерә.* А. Әхмәт.

ЗА'ВУЧЛЫК *и.* Завуч булу, завуч вазифасы, хезмәте.

ЗАВХОЗ *и.* Учреждение яки предприятиенең хуҗалык бүлеге мөдире. *Берсен, тәҗрибәсе дә бар дигән булып, завхоз ителәр, икенчесен директор итеп куйдылар.* Г. Гобәй.

ЗАВХОЗЛЫК *и.* Завхоз булу, завхоз вазифасы, хезмәте. *Легионның завхозлыгына австрияле еврей Бавер, аның ярдәмчесе итеп Сафин куелды.* Ш. Усманов.

ЗА'ГОВОР *и.* Билгеле бер (гадәттә политик) максатка ирешү өчен бергәләп эш итү турында берничә кешенең яшерен килешүе. — *Сак булыгыз, кара көчләр революциягә каршы заговор коралар.* И. Гази.

ЗА'ГОВОРЧЫ *и.* Заговорда катнашучы кеше. *Дошман армиясе Мәскәүгә килеп җиткәч тә, заговорчылар фетнә күтәрергә җыендылар.* ҚПСС тарихы.— *Әй Вакытлы хөкүмәт? — дип сорады Серебряков, башын газетадан күтәреп.— Ул кем яклы? Заговорчылар яклымы әлле?..* И. Гази.

ЗА'ГОВОРЧЫЛЫК *с.* Заговорчыларга хас; яшерен. *Заговорчылык алымнары.* □ *1818 елда «Бәхетле тормыш союзы» дигән яңа союз төзелгән. Бу союз инде беренчесе шикелле тар заговорчылык оешмасы булмаган.* СССР тарихы.

ЗАГОТ- Кыскартылган кушма сүзләрдә беренче урында килеп, «заготовительный» сүзеннән, дәүләткә сату өчен авыл хуҗалыгы продуктларын әзерләү мәгънәсен аңлата, мәсәлән: **заготзерно, заготпункт.**

ЗАГОТО'ВКАЧЫ *и.* Дәүләт өчен авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алу эшен оештыручы, шул эштә эшләүче кеше, заготпункт эшчесе.

ЗАГС *и.* Башкарма комитетның туу, үлү, өйләнү, аерылу кебек гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге *(рус.ча:* запись актов гражданского состояния). *Мәхәббәт тә — нәфис, матур чәчәк, Ләкин үзе гажәп гомерсез, Кайчак загс белән соңы бетә, Ә кайчакта... Яхшык күңелсез.* Һ. Такташ.

ЗАДӘ *и. иск.* Ир бала, (кемнең дә булса) улы.— *Синең кыяфәтең, синең сөйләшүең бер асыл задә икәнлегеңә дәлаләт кыладыр.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗАЁМ *и.* Кире кайтару шарты белән дәүләт бюджетына башка илдән яки халыктан бурычка акча туплау формасы. *Заём тарату. Заёмга язылу.* □ *Америка финанс магнатлары, һөҗүмгә күчүне шарт итеп, Вакытлы хөкүмәткә зур сумада заёмнар бирделәр.* Т. Гыйззәт.

ЗАИГЪ *рәв. иск.* Әрәмгә, бушка, файдасызга; *к.* зая. *Күктә йолдыз ничәдер, Ничә баксаң, күчәдер; Ничә айлар, ничә еллар Гомерләрем заигъ кичәдер.* Җыр.

Заигъ булу — югалу, юкка чыгу. **Заигъ итү** — әрәм итү. *Гомереңне заигъ итеп, шундый һич файдасыз нәрсәләрне укып утырасың.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗАКАЗ *и.* Берәр төрле әйберне ясау, ремонтлау яки берәр эшне башкару турында сорап, телдән яки язма рәвештә махсус мөрәҗәгать. *Телефоннар аша заказ яуган, Сорау яуган төрле сортларга.* С. Хәким. *Безнең инженерлар, конструкторлар бөтен Союзга атаклы заводларның заказларын үти башладылар.* А. Гыйләҗев. // *сөйл.* Махсус сорау буенча эшләнгән әйбер. *Заказыңны килеп ал.*

ЗАКАЗНОЙ *с.* Адресатка тапшыру җаваплылыгын көчәйтү максаты белән, почта расходлары артыграк түләнеп җибәрелә торган (хат, бандероль). *[Галәви:] Әманәт [хат] бар, --- үз кулына тапшырырга кушылган. Заказной.* Г. Әпсәләмов. *Бу хатны заказной итеп җибәрәм.* Т. Гыйззәт.

ЗАКАЗЧЫ *и.* Нинди дә булса эшне эшләргә заказ бирүче.

ЗАКЛАД *и.* Бурычка акча яки берәр нәрсә алганда яисә бәхәсләшкәндә салына торган әйбер. *Билеңдәге актык каеш зинарыңны кибетчегә ике кадак арыш икмәге өчен закладка саласың.* Г. Ибраһимов.— *Карале, көтәргә он-фәлән сорап килүче булса, закладсыз бер кашык та бирәсе булма.* И. Гази.

ЗАКЛАДЧЫ *и.* Закладка салып торучы, закладка әйбер бирүче.

ЗАКЛЁПКА *и. тех.* Бер башы эшләпәле, икенче башын чүкеп җәю юлы белән ике металл кисәген беркетү өчен кулланыла торган очсыз металл кадак. *Заклёпка ярдәмендә беркетү.* □ — *Узем бармасам инде бер якын арада, заклёпкалар, шайбалар да кирәк.* М. Фәйзи.

ЗАКОН *и.* **1.** Югары дәүләт власте тарафыннан чыгарылган, үтәлүе һәркем өчен мәҗбүри булган кагыйдә, карар; канун. *Хөкем бара. Совет законнары суд залында һава ярып яңгырап китәләр.* Һ. Такташ. *Бер ягымнан закон, бер ягымнан Дин, шәригать белән кыстылар.* М. Гафури.

2. Үтәлүе мәҗбүри булган боерык яки эш.— *Минем теләк һәм мин әйткән сүз — закон.* М. Җәлил.— *Бик матур алманың бик матур иясен ризалату хәзер бөтенләй закон булып әверелде.* М. Фәйзи.

3. Җәмгыятьтәге аерым кешеләр арасында, коллективта гомум кабул ителгән гадәт, традиция. *Бу еллар тирә-юньдәге әйберләрне, борын-борыннан сакланып килгән гадәтләрне, шулай булырга тиеш дип каралган ныклы законнарны гына түгел, кешеләрнең үзләрен дә үзгарткән.* Қ. Нәҗми. *Разведчикларның ниндидер язылмаган законнары, традицияләре бар иде.* Г. Әпсәләмов. *Һәлакәт булганда экспедиция башлыгы иң соңгы булып котыла, бу — гадәт, закон булып тотыла.* А. Алиш.

4. Предмет яки күренешләр арасында аларның үз табигатьләренә нигезләнгән зарури бәйләнеш. *Диалектика законы.* □ *Барысы да шулай, тормыш кушканча, табигать законнары кушканча бара торгандыр.* Г. Минский. *Кара әйберләргә, физика законнары буенча, кояш нурлары күбрәк, тизрәк үтә.* Г. Гобәй.

ЗАКОНЛАШТЫРУ *ф.* Закон нигезендә раслау, рәсмиләштерү; закон көче бирү. *Авыл урамнарының, рәсми законлаштырылмаса да, исемнәре була.* А. Гыйләҗев. // Гадәткә, традициягә кертү. *Печать басылган кәгазь күңел сизгерлегеннән көчлерәк санала. Үзебез шуны законлаштырганбыз.* М. Әмир. // Загс бүлегендә язылу, никахлану. *Җәй башында мин Мәрфуганы тормыш иптәшем итеп законлаштырып, шәһәргә килен итеп төшердем.* Ф. Хөсни. *[Гайфи Айсылуга:] Икебезнең араба «алдым-бирдем» булды инде — загс белән законлаштырасы гына калды.* Қ. Әмири.

ЗАКОНЛАШУ *ф.* Закон көчен алу, рәсмиләшү. // Гадәт булып китү, ныклы урнашу. *Аня аны Геннадий дип йөртә, һәм бу исем ничектер үзеннән-үзе законлашып кала.* Ә. Ерикәй.

ЗАКОНЛЫ *с.* **1.** Законга туры килә торган, законга нигезләнгән. *Законлы документ. Законлы эш.*

2. *күч.* Гадел, дөрес, нигезле, урынлы. *Татар буржуа һәм вак буржуа журналистлары «Яшь йөрәкләр»не татарда беренче зур роман һәм шул заманда татар әдәбиятында законлы урын алырга тиешле стильнең бер үрнәге итеп карадылар.* Г. Нигъмәти.

3. Законы гамәлдә йөргән (урын), үз законы булган (урын). *Законлы җир.*

4. *сөйл.* Загс бүлегендә рәсмиләштерелгән (хатын-ир яки семьяда туган бала). *«Ул — минем законлы хатыным»,— дидем мин аңа коры гына итеп.* А. Шамов.

ЗАКОНЛЫЛЫК *и.* **1.** Законлы (1 мәгъ.) булу. *Документның законлылыгы.*

2. Иҗтимагый тормыш һәм эшчәнлекнең тиешле законнар белән тәэмин ителү хәле. *Социалистик законлылыкны ныгыту.*

ЗАКОНСЫЗЛЫК *и.* Законны бозу, законга каршы килү, закон таләпләрен сакламау. *Өч семьяның, шәһәрдә яшәүләренә карамастан, шушы көнгә чаклы каралты җирләреннән өзлексез файдаланып килгәнлекләре билгеле булды. Идарә членнары --- озак вакыт бу законсызлыкның яшәвенә һәм аны күрмәүләренә гена гаҗәпләнделәр.* А. Шамов.

ЗАКОНЧА *рәв.* Законга туры китереп, закон таләпләре нигезендә. *Законча эш итү.*

ЗАКОНЧАЛЫК *и.* Объектив законнарга бәйләнгән булу; законга (4 мәгъ.) нигезләнгән булу. *Табигый сайланыш закончалыгы.* □ *[Этләр] өстендәге тәҗрибәләр терлекчелек өчен бик артык киң, бик артык гомум закончалыкларны гына ача.* А. Расих. *Үзенең какшамас закончалыклары буенча, колхоз тормышы элеккеге ялчыны өлешле, мул тормышлы иткән.* М. Максуд.

ЗАКОНЧАЛЫКЛЫ *с.* Закончалыкка, объектив законнарга нигезләнгән. *Кешелек дөньясының капитализмнан социализмга таба --- дөньякүләм-тарихи борылышы — җәмгыять үсешенең закончалыклы нәтиҗәсе.* КПСС Программасы.

ЗАКОНЧЫ *и.* **1.** Законны (1 мәгъ.) яхшы белүче, закон кагыйдәләре белән таныш кеше.— *Ә ул электәлектән Казан [мещаннары] арасында дипломсыз адвокат, закончы булып килгән.* З. Бәширн.

2. Законга таянып эш итүче, закон күрсәтмәләренең ныклап сакларга тырышучы.

ЗАКОНЧЫЛ *с. к.* закончалыклы. *Закончыл үсеш.*

ЗАКУ'СКА *и. сөйл.* Аппетитны ачу яки эчемлек артыннан капкалау өчен әзерләнгән салкын ашамлык. *Төрле ашлар, закускалар тезеп, өстәл хәзерләнгән.* М. Фәйзи. *[Гадәттә] закускага тозлы кәбестә, тозлы кыяр, торма, балык — шундый нәрсәләр генә китерәләр.* Г. Камал.

ЗАЛ *и.* **1.** Җыелыш, лекция, концерт, спорт уеннары һ. б. уздыру өчен күп кешеләр сыярлык итеп эшләнгән зур бүлмә. *Концерт залы. Спорт залы. Хөкем залы.* □ *Ул зал ишегеннән килеп кергәндә, концерт инде башланган иде.* И. Гази.

2. Өйнең кунаклар кабул итү өчен махсус җыештырылып тотыла торган зуррак бүлмәсе; кунак бүлмәсе. *Уртача тормышлы татар сәүдәгәре йортының залы.* Ф. Әмирхан. *Сәрвәрев квартирасында зал. Ул яхшы җиһазланган.* Р. Ишморат.

ЗАЛИМ *с.* Изүче, җәберләүче, явыз. *Ахырда бер көн Китте өстән кара төн, Залим патша тәхетләре Янып булдылар төтен.* Г. Камал. *«Карчыга» журналы залим байларга каршы каләм йөртәчәк.* Г. Тукай. // *и. мәгъ.* Мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, каты күңелле кеше. *Тәэсир итмәс ул залимгә күз яшь илә бакканың.* М. Гафури.

ЗАЛИМАНӘ *рәв. иск.* Залимнәр кебек, залимнәрчә. *Мәңге хәсрәткә салып, Язмышым белән нигәдер Заманә уйный ул.* Һ. Такташ.

ЗАЛИМЛЕК *и.* Залим булу. *Арыслан, әлбәттә, Бүренең кан эчкүче залимлеген күп ишеткән булырга кирәк.* Г. Тукай. // Явызлык, мәрхәмәтсезлек. *Байның малы арткан саен, явызлыгы, залимлеге, мәлгуньлеге бетмәде, һәмишә арта барды.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗАЛИМӘ *и.* Залим хатын-кыз.

ЗАЛОГ *и.* **1.** Өскә алынган бурыч яки ссуданың ышанычлылыгын тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт.

[*Җамали:*] *Ул ни дигән сүз? Аның йорты залог. Кибетендә малы юк, акчасы урланган.* Г. Камал.

2. *иск.* Тоткындагы кешене бирелә торган акча. *Бу ике егетне бер әр айга гына булса да 600 сум залог илә порукага алыр өчен* [*ул*] *Мәхмүт байга мөрәҗәгать итте.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗАЛО'ЖНИК *и.* Берәр дәүләт яки оешманың үз дошманына куелган талән яисә йөкләмәсе үтәлгәнгә кадәр үзендә тоткан дошман як кешесе.— *Илсөярне алып чыгарга мөмкин. Ләкин безнең янда ике өлкән надзирательне заложник итеп калдырасыз.* Г. Гобәй. *Баш күтәрүчеләрне эзәрлеклиләр, аларның туганнарын, хатыннарын, кулга алып, заложник итәләр, төрмәгә ябалар.* И. Салахов.

ЗАЛП *и. хәрби.* Берничә мылтыктан яки туптан берьюлы ату. *Бераздан соң бер автоматтан, ике винтовкадан залп бирдек.* А. Шамов. *Ерак ишетелсен залп тавышы, Яңгырасын таулар, урманнар.* Ф. Кәрим.

ЗА'ЛПЛАП *рәв. хәрби.* Залп белән. [*Австриялеләр*] *тау кабыргасына залплап атылган шрапнельләр яудыра башладылар.* А. Таһиров.

ЗАМА'ЗКА *и.* Ярык яки җәкләрне томалау яки ике кисәкне бер-беренә ябыштыру өчен, тиз сыланучан һәм каты хәлгә килүчән сутлы матдә (акбур, он яки көлне үсемлек маена изеп ясала). [*Монда*] *ватылгач яңадан җыеп замазка белән ябыштырылган чынаяклар, чәйнекләр куелган булыр иде.* М. Гали. *Ташка төшеп уалган вазаны замазка белән ямагач ямьсез була.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЗАМА'ЗКАЛАУ *ф.* Замазка белән сылау яки замазка ярдәмендә ябыштыру. *Берничә көннән соң ул аңа рамалар буярга һәм тәрәзә замазкаларга да бирә башлады.* М. Гали.

ЗАМАН *и.* **1.** Җәмгыять яшәвенең билгеле бер вакыты, чоры. *Үзең алга кит, арттагыларга ярдәм ит, гомуми күтәрелешкә иреш — заман девизы шундый.* Соц. Тат.— *Кадерен белмиләр диюем шуннан, хәзерге солдаткалар Николай заманында без күргән азапны төшләрендә дә күрмиләр.* Г. Бәширов.

2. Вакыт. *Көннәр үтә, айлар үтә; Көз дә җитәр бер заман.* З. Мансур. *Аның күп заманнардан бирле тик үзендә генә саклап йөртә торган мәхәббәт романтикасы бар икән.* Ф. Хөсни.

3. *лингв.* Фигыльдә эш яки хәлнең сөйләү моментына карата вакыт мөнәсәбәтен белдерә торган форма. *Хәзерге заман хикәя фигыль. Үткән заман сыйфат фигыль.*

◇ **Заман ахыры** *дини.*— кешелек җәмгыяте яшәешнең ахыры, дөнья бетү алды. — *Хосусан, заман ахырларында, китап әйтүе буенча, адәм балаларының гомерләре кыскара барыр, дигән риваятьләр бар.* Ш. Камал.

ЗАМАНА *и.* Хәзерге чор, вакыт. *Минем карашымда мондый йокымсыраган, салмак кеше озак яши алмас, хәрәкәт яраткан заманабыз андый кешеләрне онытыр дигән фикер туган иде.* Г. Кутуй.— *Заманалар авыр чагында бер-беребезгә булышыйк, фронтка икмәкне күбрәк бирик.* Г. Бәширов.

ЗАМАНАЛАШТЫРУ *ф.* Заманага яраклаштыру, хәзерге заман таләпләренә туры китерү. [*М. Җәлилнең беренче шигырьләрендә*] *Тукай аһәңе аермачык сизелеп тора иде, кайберләрендә хәтта Тукайны «заманалаштыру», - - - Тукай җырын 19 нчы ел шартларына яраклаштыру күренә иде.* М. Максуд.

ЗАМАНАСЫНДА *рәв. к.* заманында. *Шибай карт, заманасында кантон булып, башкортны күп талаган.* Г. Нигъмәти.

ЗАМАНА'ЧА *рәв. к.* заманча. *Банктыр кыйблалары, заманачадыр киемнәре.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗАМАНДАШ *и.* Кем яки нәрсә белән дә булса бер чорда, бер вакытта яшәгән яки яшәүче, чордаш. *Я, кайда син, Тыйнак, басынкы дус, Замандашы бөек сынауның?* С. Хәким. *Замандашлары аның яшь чактагы мәзәкләрен искә төшереп көләләр.* И. Гази.

ЗАМА'НЧА *рәв.* Үз заманы өчен кабул ителгәнчә.— *Алар әллә нәрсә сорамыйлар: эче-тышы әйләнәсе белән камзуллык чатма, аннан соң, хәзерге заманча булсын дип, бер озын сак.* Г. Камал. [*Гайнулла хаҗи*] *заманча киенгән кешене бик дошман күрәдер.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗАМАНЧАЛЫК *и.* Заманча булу, хәзерге заман таләпләренә буйсыну. *Заманчалык рухы тормыштагы яңалыкны күрсәтә белү белән билгеләнә.* Каз. утл.

ЗАМАНЫНДА *рәв.* Элек, кайчандыр, бер вакытта (элек булган билгесез бер вакытны белдерә); үз вакытында.— *Заманында техникум бетерә язган кеше ич мин.* Р. Ишморат. *Заманында батрак Сибай дигән гидай бер егет бар иде.* Г. Бәширов.

ЗА'МАТ *рәв. диал.* Тиз, бик тиз, күз ачып йомганчы.— *Давай, эти, замат яздырып алып кайтам.* С. Җәләл.

ЗАМЕ'ТКА *и.* Газетага бирелә торган кечкенә мәкалә.

ЗА'МОК *и.* Урта гасырларда феодалның крепость сыман торак йорты. *Тау башларында урта гасырлардан калган замоклар.* Г. Гали.

ЗАМШ *и.* Болан, поши, сарык һ. б. хайван тиреләреннән өске ягы бәрхет сыман итеп эшләнгән йомшак күн. [*Юлчы*], *кечкенә замш кисәге чыгарып, парланган күзлеген сөртте.* М. Хәсәнов. // *с. мәгъ.* Шул күннән эшләнгән. *Нечкә кара ефәк оеклар белән ыспай замш туфлилләр аның аяклары белән бергә үскән төсле килешеп, ягышып торалар.* К. Тинчурин. *Разия белгәнә көмеш ридикюль аскан, үзе кулындагы озын замш перчаткасын каптыра-каптыра азапланып бара.* Г. Ибраһимов.

ЗАНЯ'ТИЕ *и.* Уку, нәрсәгә дә булса өйрәтү дәресе. [*Солдатлар*] *иртәнге занятиегә, үзләренә билгеләнгән эшләрне җиренә җиткерергә китәргә әзерләнәләр иде.* М. Гафури. *Занятие бетәргә өч сәгатьләр вакыт калган.* Ш. Камал.

ЗАПАЛ *и. хәрби.* Шартлаучан матдәләргә ут биреп шартлата торган кабызгыч җайланма. *Гранаталар билдә, капчык иңдә, Анда патрон, анда запаллар.* Ф. Кәрим. *Абушахман --- гранаталарына запаллар куйды.* Г. Әпсәләмов.

ЗАПАС *и.* **1.** Киләчәктә куллану, файдалану өчен билгеле бер күләмдә алдан әзерләп куелган азык, әйбер, материал. *Беренче көннән барлык запас чамалап кына тотылган булса, атны дүрт айга, ягъни сабан өстенә кадәр үтермичә саклап чыгып була.* Г. Гобәй. *Кортлар --- хәзер инде үзләренә кышлык запас хәзерләделәр.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Кирәк булу ихтималы өчен хәзерләнгән, калдырылган; запас итеп сакланган. *Запас кием.* ▭ — *Дус, мә, син дә балык каптыр, дип, запас кармакны аңа бирдем.* А. Әхмәт. *Кинода запас ишеккә, кешегә күренеп торсын өчен, кызыл ут белән язып куялар.* Г. Гобәй.

2. Кирәк кадәр күләмнән артыгы. *Азыкны запас белән алу.* // Киемне теккәндә, кирәк чакта зурайту максаты белән, тукыманың җәй астында калдырылган өлеше. *Запас белән тегелгән күлмәк. Итәк запасын җибәрү.*

3. Байлык, җир асты байлыгы, эшкәртелүгә кермәгән чимал. *Нефть запасы. Күмер запасы.* // Аерым кеше, коллектив яки дәүләт карамагындагы билгеле күләм әйбер, байлык. *Икмәк запасы.* ▭ *Республиканың алтын запасы дошман кулына эләгүе хакында радио хәбәре алынган.* Ш. Усманов. // *күч. сөйл.* Кешедәге белем, сүз байлыгы, хис һ. б. ш. күләме. *Газинурның сүз запасы шактый бай, җөмләләр төзергә дә осталыгы бар, әмма басымнарны, родларны ул бик бутый иде.* Г. Әпсәләмов.

4. *хәрби.* Сугыш вакытында хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле, хәрби учетта тора торган гражданнар. *Мин запаста торган яшь командир, Уйларымның белми тынгысын, Әзерләнеп һәр көн әмер көтәм...* С. Хәким. // *с. мәгъ.* Запаста торган, запастагы.— *Кырык яшькә кадәр булган запас солдатларга исемлек төзерсең.* Т. Гыйззәт.

5. *с. мәгъ. хәрби.* Сугыш вакытында алгы фронттан ераграк торган, резервтагы хәрби бүлек турында. *Шулай итеп, мин запас полкларның берсенә эләктем.* Ә. Айдар.

ЗАПАСЛЫ *с. сөйл.* Запасы (1 мәгъ.) булган, запас тотучан, җыючан. *Запаслы Вася, Степанычны дусларча шелтәли-шелтәли, каяндыр ямаулык алып килеп бирде.* А. Шамов.

ЗАПАСЛЫЛЫК *и. сөйл.* Запаслы булу.

ЗАПА'ШНИК *и. а.-х.* Сай сөрә торган сабанның бер төре, рәт араларын йомшарту өчен дә кулланыла.

ЗАПЕКА'НКА *и. махс.* Йомырка һәм сөткә изелгән бәрәңге янсә ярма боткасын, билгеле бер формада, мич яки духовкага куеп, өсте кызарганчы пешереп әзерләнгән ашамлык. *Ботка, запеканка һәм пудинглар өчен соуслар: җиләк соусы, абрикос соусы, ванильле соус.* Йорт эшләре.

ЗАПИ'СКА *и. сөйл.* Берәр төрле хәбәрне яки үтенечне белдереп язылган язу. *Зәңгәр эчле ак конверттан шома ак кәгазьгә яшел кара белән язылган кечкенә записка чыкты.* М. Әмир.— *Әллә берәр җирдән парлы кунакка чакырып записка килде микән?* Г. Камал.

ЗАПОВЕ'ДНИК *и.* Сирәк очрый торган кыргый үсемлек яки җәнлекләрне саклау һәм үрчетү урыны; тыюлык. *Машина капотындагы сөзәргә җыенгандай башын игән, очлы мөгезле көмеш үгезләр (Беловежский заповеднигы буйволлары) башка машиналарныкына караганда зәһәррәк тә, ерткычрак та күренәләр.* М. Хәсәнов.

ЗА'ПОНКА *и.* Җиңне яки яканы каптыру өчен кулланыла торган пар төймә яки галстукны күлмәккә беркетү өчен пластинкалы каптырма. *Поручик --- манжетларының запонкаларын ычкындырырга кереште.* К. Тинчурин. *Шәмсия комодтан күлмәк һәм галстук алып бирә.* [*Хафиз:*] *Ә запонкалары?* Р. Ишморат.

ЗАПРА'ВКА *и. сөйл.* Машиналарга ягулык, май һәм су салу. *Автомашиналарга заправка ясау.* □ *Беренче трактор кайтып җитү белән, ул шундук заправка урынына чыкты.* Н. Фәттах.

ЗАПРОС *и.* Нинди дә булса мәгълүматлар яки аңлатма бирүне таләп итеп, депутатлар (элек: Дума делегатлары) тарафыннан дәүләт органына ясалган рәсми сорау. *Әлеге делегатларның барысы да диярлек кулга алынды. Бу уңай белән Думадагы* [*демократик*] *фракция кичекмәстән запрос ясады.* КПСС тарихы.

ЗАПЧАСТЬ *и.* Машиналар өчен запас часть. *Машиналарга запчастьләр дә алып кайтырга кирәк булыр.* А. Расих.

ЗАР *и.* Нәрсәдән дә булса риза булмауны белдергән сүзләр; ризасызлык, канәгатьсезлек. *Көне буена бик күп хәлләр белән танышып, бик күп зарлар ишетеп өлгергән идек инде без.* М. Әмир.— *Минем зарларым акча ягыннан түгел дим ич.* Ш. Камал. // Кайгы-хәсрәт, моң-зар. *Ул урындык читенә утырды һәм, үзенең кемлеген дә әйтеп тормыйча, зары турында кызып-кызып сөйләргә кереште.* Г. Әпсәләмов. *Бәдри карчык мең дә беренче мәртәбә үзенең зарын, хәсрәтен сөйли.* Г. Ибраһимов. // Мохтаҗлык, нәрсәнең дә булса җитешмәве. *Йомык төнбоеклар кыры. Бездә юк аһ, бездә юк зар, Күңелең ачарбыз без.* Н. Исәнбәт.

◇ **Зар булу** — 1) мохтаҗ булу.— *Бер сынык икмәккә зар булып йөрерсең, мин сине шул көнгә калдырырмын.* Ә. Фәйзи; 2) зарыгу, тилмерү. *Бик сагынып, бик саргаеп, бер күрергә зар булып бик күп сәлам.* Г. Камал. **Зар елау** — 1) әче күз яшьләре белән елау. *Кол итеп унлап халыкны, зар елаттырган идең.* Ә. Исхак; 2) ачынып зарлану. *Кибетчеләр зар елыйлар: кассадан акчаны ала да, чыга да китә...— диләр.* Г. Камал. **Зар калу** — мәхрүм калу, мохтаҗ булу.— *Мин дә күп вакыт арыш икмәгенә зар калган күп егетләрдән беремен.* Г. Ибраһимов.

ЗАРАР *и.* **1.** Предмет яки күренешкә, аның яшәешенә, үсүенә комачаулый, аны боза яки өлешчә җимерә торган нәрсә; *киресе:* файда. *Кешегә файдалы эшне зарар дип уйлаганнар күп.* М. Гафури. *Ул отрядларның ярдәмгә караганда зарарлары күбрәк күренә.* Ш. Усманов.

2. Каза, зыян; материаль югалту. *Мондый вакытта ул* [*яңгыр*] *чамалап кына яумый, бик каты явып, мал-туарны агызып китеп, илгә зур зарар китерүе бар.* М. Гали. *Шәриф байның башы каткан, Яңа ярминкәдән кайткан, Малын зарар итеп саткан, Итә алмаган тиен файда.* Г. Камал.

Зарар итү — кемгә дә булса зыян китерү; югалтуларга дучар итү.— *Мин бит кешегә зарар итә торган бер ерткыч түгел.* Ф. Әмирхан.

◇ **Зарар итмәс, зарар булмас** — яхшы булыр, файдага гына булыр. *Эйфель манарасын музейлар белән берәттән сөйләү урынлы булмас, шулай да азрак тукталып китү зарар итмәс.* Г. Гали.— *Шулай чәчсенме, әллә бераз киметкәндә дә зарар итмәсме?* Г. Бәширов. **Зарар күрү** — 1) зыянга, казага дучар булу. *Боларнайманнан җәберләнгән, яхшы җәйләүләре алынган, юк-бар сәбәп белән зарар күргән --- кабиләләрнең башлыклары — байлары иде.* Г. Ибраһимов; 2) икенче бер предмет яки күренешнең начар тәэсиренә эләгү, шуннан интегү. *Бу «пофф»лардан ул артык зарар күрми, хәтта, киресенчә, алар аның тизрәк йоклап китүенә ярдәмләшәләр.* Ш. Камал. **Зарар салу** — начарлык, явызлык эшләү, зыян китерү. *Узенең тазалыгы белән масаеп, кем әләкте, шуңа зарарын салып йөри торган Зәйдүкне бервакыт әләктереп алып, башын ярдылар.* Г. Толымбай. **Зарар юк** *кер. сүз.*— ис китмәүне яки игътибар итәргә кирәк түгеллекне искәртү өчен кулланыла. [*Гомәр:*] *Зарар юк, мин соңыннан да өлгерермен.* Ф. Әмирхан.

ЗАРАРЛАНУ *ф.* Зарар күрү, зарар килү, кимчелек килү, үзенең бөтенлеген, сыйфатын, саулыгын яки дәрәҗәсен югалту. [*Сәләхинең*] *мие зарарланган булыргакирәк, диләр.* Ш. Камал. *Бу дулкыннар кубарса да шау-шу, гауга, һөҗүм итеп килсәләр дә, охшап яуга, Шунда үсеп тора торган олуг таш-тау Зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау.* Г. Тукай.

ЗАРАРЛАУ *ф.* Зарар (1 мәгъ.) итү, зарар китерү. *Зарарлау көче. Зарарлау дәрәҗәсе.*

ЗАРАРЛАТУ *ф.* Кемнән яки нәрсәдән дә булса зарар күрү. *Яралыларның күбесе - - - башын-битен зарарлатканнар иде.* Ш. Усманов.

ЗАРАРЛЫ *с.* Зыян, зарар китерә торган. [*«Сарык ашап йөргән» Куян кебек, буржуаз җәмгыятьтә*] *Зарарлы бәндә булып күренерсең, Башкаларга кыйлмасаң да һичбер зыян.* М. Гафури. // Зарарлый, боза торган, корткыч. *Чүп-чарда агач өчен бик зарарлы булган кортлар, бөжәкләр үрчи.* Г. Әпсәләмов. *Сезнең бодайга әкбәрдән дә зарарлырак корткыч кул сузган.* Г. Гобәй.

ЗАРАРЛЫЛЫК *и.* Зарарлы булу. *Чүп үләннәренең зарарлылыгы. Зарарлылык дәрәҗәсе. Аракының зарарлылыгы турында әңгәмә.*

ЗАРАРСЫЗ *рәв.* Ярыйсы гына, канәгатьләнерлек; шактый әйбәт. [*Мәдинә*] *төскә-башка хәзер дә әле зарарсыз.* Ш. Камал. *Әсәрегезне зарарсыз таптык.* Г. Ибраһимов. // Куркыныч түгел; түзәрлек (авырту, күргән зарар, зыян һ. б. турында).— *Җәрәхәтең ачылган бит,*

Җомагыл абый.— Зарарсыз,— диде Өметбаев, һаман да сызланып. Г. Гобәй.

ЗАРАРСЫЗЛАНДЫРУ, ЗАРАРСЫЗЛАУ *ф.* Зарар итү тәэсирен бетерү, зарар китерү мөмкинлеген бетерү. *Мина зарарсызландыру юлларын үзлегеннән өйрәнеп, --- беренче булып юл салучы да шушы Николай булган.* Р. Мостафин. / *куч.* [*Буржуаз интеллигенциянең*] *бер өлешен пролетариат казанында кайнатып зарарсызландыру бурычы бөтен күләме белән килеп басты.* Г. Нигъмәти.

ЗАРИ, ЗАРЫЙ: зари кылу, зарый кылу *иск.— к.* зарлану. *Дулкыннарның гайрәтенә карап, халык аллага зарый кыла башлады.* Г. Коләхметов.

ЗАР-ИНТИЗАР: зар-интизар булу — түземсезлек белән көтү, тилмерү, зарыгу. [*Хажи:*] *Мин былтырдан бирле, җанкәем, ашым аш түгел, суым су түгел, фаразан, сиңа гыйшык тотып, зар-интизар булып йөрим, җаным.* Ш. Камал.

ЗАРЛАНУ *ф.* Ризасызлык белдереп сөйләү, зарын сөйләү. *Киленчәк үз язмышыннан зарланды: «Иткәнем коллык, күргәнем хурлык!»* Г. Ибраһимов. *Кайсы үзенең начар йоклавыннан, кайберсе ярасы авыртуыннан зарлана башлады.* Э. Айдар. // Кешенең кимчелекле яки начар яклары турында сөйләү. *Кайсысы улын орыша, кайсысы киленен сүгә, кайсысы киявеннән зарлана.* А. Шамов.

ЗАРЛАНЫРЛЫК *с.* Кимчелекле; начар, җитми, килешми һ. б. дип сөйләрлек. *Атасыз үсүләреннән башка, зарланырлык нәрсәләре юк.* Г. Кутуй.— *Зарланырлык җиребез юк, җан кисәгем.* Ш. Камал.

ЗАРЛАНЫШУ *ф.* Бер-берсенә зарларын сөйләү. *Хатын-кызлар бергә җыелып, үзара зарланышалар да, бер үк сүзләрне кычкырып, төрле якка йөгерешәләр.* Қ. Нәҗми. [*Галиулла:*] *Зарланышканнар, сукранышканнар да таралышканнар. Безнең крестьянның гадәте шул инде.* И. Гази.

ЗАРЛЫ *с.* Зарга дучар ителгән, зары булган. *Кайда ярлы, кайда зарлы, Кайда моңлы күп була, Мин шулар янында булам — Алар белән килешеп була.* М. Гафури. *Ярлы кеше — зарлы кеше.* Мәкаль. // Зар белән тулы. *Зарлы җырлар инде юк бездә.* З. Нури. *Зарлы иде сезнең көннәрегез, Мәрхәмәтсез иде төнегез.* Э. Ерикәй.

ЗАРЛЫК: зарлык кылу. *иск.— к.* зарлану. — *Дәүләтем юк, бәхетем ким, дип зарлык кылма.* Г. Ибраһимов.

ЗАРЛЫЛЫК *и.* Зарлы булу.

ЗАР-МОҢ *и. к.* моң-зар. *Алар, киресенчә, «тәкъдир»дән, «бәхет юклык»тан, «адәмгә адәм тиң түгел»лектән зарлана, сыкраналар, зар-моң белән «хода»ларына йөзләрен юнәлдерәләр.* Г. Нигъмәти. [*Ярлылар*] *зар-моңнарын бергәләп уртаклашырга керештеләр.* М. Гафури.

ЗАРУР *с.* **1.** Бик кирәкле, бик әһәмиятле, бик мөһим. [*Хуҗа*] *ике мәртәбә конторага кереп, бик зарур кәгазьләргә кул куеп чыгадыр.* Ш. Мөхәммәдев. *Бераүлар, сәламәтлекләре өчен зарур булган йокыларыннан аерылып, революцияне контрлар белән караклардан төннәр буенча саклап торалар.* Қ. Тинчурин.

2. Шуннан башка булмый торган, котылгысыз; мәҗбүри. [*Гөлсем апа*] *хезмәткә мохтаҗлыктан гына эшләнә торган эш итеп түгел, кешене чын кеше итү өчен иң зарур нәрсә итеп карый иде.* Г. Гобәй.

ЗАРУРАТ *и.* Чарасызлык, мәҗбүрилек. [*Шәриф*] *менә, зарурат буенча беренче мәртәбә буларак, балаларына һәм хатынына садакадан алган кисәкләрне ашатты.* М. Гафури.

ЗАРУРИ *с.* **1.** *к.* зарур. *Тукайның сатира язуы очраклы хәл түгел, ә Тукай иҗатының идеологик юнәлешенең табигый җирлегендә килеп туган зарури бер хәл.* Г. Халит.

2. *филос.* **Очраклы гына түгел, закончалыклы,** әйбернең үз табигатеннән чыгып барлыкка килә торган. ***Колбиләүчелек строе кешелек җәмгыятенең үсешендә зарури этап булган.*** Политэкономия.

ЗАРУРИЯТ *и. к.* зарурлык. *Бөтен уй-фикерләремне бары аңа гына сөйлисем килеп тору минем күңел ихтыяҗына, ниндидер бер зарурияткa әйләнде.* Э. Еники. [*Партия карарлары*] *тарихи чынбарлыкның үз зарурияты на җавап булып туалар, зарурияткa аңлы юнәлеш ачалар.* Х. Госман.

ЗАРУРЛЫК *и.* **1.** Кирәклек, кирәк булу; мөһимлек, әһәмиятлелек.

2. *филос.* Әйберләрнең яки күренеш, вакыйгаларның эчке бәйләнешләреннән, асылларыннан килеп чыга торган котылгысыз, закончалыклы хәл. *Диалектик материализм зарурлык һәм очраклылык категорияләренең бердәмлеген иң элек аларның объектив булуларыннан күрә.* М. Абдрахманов.

ЗАРЫГУ *ф.* **1.** Көтә-көтә ару, талчыгу. *Сагынып көткән идек, Зарыгып беткән идек.* М. Җәлил. *Матур кыз, һаман тәрәзә янында утырып, инде зарыга башлагандыр шикелле тоела иде.* Ф. Әмирхан.

2. Көтүдән яки нинди дә булса эшкә атлыгып торудан туеп бетү, түземсезләнә башлау турында. *Хат язганда җентекләп яз, йөрәгең зарыкса да.* Э. Ерикәй.

3. Ачыну, үрсәләнү, өзгәләнү кебек хис кичерү. *Ник хәзер дә алар арасында Алдан барган егет мин түгел! Шуңа зарыгып сыкрый бу күңел.* Ф. Кәрим.

ЗАРЫГЫШУ *ф. к.* зарыгу 1. *Күңелләр зарыгыша. / рәв. мәгъ. Тик озак та үтми, берсен берсе зарыгышып көткән ике яшь күңел яңадан очраша.* Г. Бәширов.

ЗАРЫКТЫРУ *ф.* Көттереп арыту, тилмертү. *Якын иткән кеше зарыктырмый озак көттереп.* Г. Хуҗиев.— *Шәрифҗан,— диде Якуб кинәт,— ат зарыктырып торганчы, бар, син кайт.* И. Гази.

ЗАРЫКТЫРГЫЧ *с.* Арыта торган, алҗыта торган; ялыктыргыч. *Унсигез көнлек уңайсыз, зарыктыргыч юлдан соң бай өйдә, йомшак түшәк өстенә тук әрләп кебек йомарланып ятудан да рәхәтрәк нәрсә бар?* Э. Фәйзи.

ЗАРЯД *и.* **1.** *хәрби.* Снаряд гильзасында яки патронда тиз кабынып китүчән шартлагыч матдә. *Патрон гильза, капсуль, заряд һәм пулядан тора.* // Ату өчен хәзерләнгән снаряд, патрон. *Ә якында япон офицеры һәм зарядсыз калган наганы.* Ш. Маннур.

2. *физ.* Электр корылмасы. *Аккумулятор заряды.*

ЗАРЯ'ДКА *и. спорт.* Организмның эш һәм яшәү сәләтен күтәрү максаты белән ясала торган физик күнегүләр, гимнастика. *Иртәнге зарядка. Зарядка ясау.* □ — *Әйдә, тизрәк, зарядкага соңга калабыз.* Э. Бикчәнтәева.

ЗАСА'ДА *и. хәрби.* **1.** Яшерен урыннан дошманга көтмәгәндә һөҗүм итү ысулы. *Дошманга засада оештыру.* □ *Уземнең мавыгыбрак китүемне хәзер генә, немец засадасы тозагына килеп капканнан соң гына сизендем.* Ф. Хөсни.

2. Шундый һөҗүм өчен әзер торган отряд, төркем. *Бу битараф җирдә [дошманның] засадалары булуы мөмкин.* Г. Әпсәләмов.

3. Засада отряды урнашкан урын. *Күзәтүче группабыз, ике көн буена засадада утырган килеш, дошманның хәрәкәтен тикшерде.* Э. Айдар.

ЗАСЛОН *и. хәрби.* Сугыш операциясен алып барганда, дошманның төп көчен үзенә юнәлдереп, шул операцияне уңышлы башкаруга ярдәм итә торган сугышчан отряд. [*Дошман*] *мондый ерткычлыкларны эшләү өчен үзенең башкисәрләреннән заслоннар --- калдырып китә.* Э. Айдар. *Беркөнне, каты сугышлардан соң, безнең подразделениеләр Истра елгасы аръягына чигенде, анда фәкать заслоннар гына калды.* Г. Әпсәләмов.

ЗАСТА'ВА *и. хәрби.* **1.** Дәүләт чиген саклый торган хәрби подразделение. *Күтәрелде безнең заставалар, Килеп җитте төнге дозорлар, Телгә килде яшерен пулеметлар, Винтовкалар, җитез маузерлар.* Ш. Маннур.— *Туган көнен котлап, безнең застава пионер Алмас Сафинны бүләкләргә булды.* А. Әхмәт. // Шул подразделение урнашкан урын. *Заставадан ата башладылар.* Ш. Усманов. *Ул сугышка чаклы хезмәт иткән Заставага таба борылды.* С. Хәким.

2. Нәрсәне дә булса саклау, каравыллау өчен куелган хәрби подразделение, каравыл отряды.

ЗАСТА'ВКА *и. махс.* Китапта текст, бүлек башланган битнең өске өлешендәге бизәк, орнамент. *Татар халык әкиятләре матур заставкалар белән чыгарылган.*

ЗАТ *и.* **1.** Төп билгеләре гомуми булган предметлар төркеме. *Адәм заты. Хайван заты.* □ *Таш өстендә таш калмады, агач затыннан агач калмады, куаклар калмады, бернәрсә дә калмады — һәммәсе янды, көйде, кара күмергә әйләнде.* Г. Бәширов. *Аңа тәрәзә-фәлән куелмаган, һичбер җиренә такта заты кермәгән, гел бүрәнә белән чыршы ботакларыннан гына эшләнгән.* М. Гали. // Җенес. *Безнең өйдә хатын-кыз затыннан бер кеше дә булмаганга күрә, әйберләр тырым-тырагай ята башладылар.* М. Гафури.

2. *ирон.* Кеше, шәхес. *Казанлылар эчендә мөселман эшләрен яхшы йөртә белүче затлар табылса иде.* Ф. Әмирхан. *Минем намусым саф булганга, Мин ташландык зат түгел.* Ә. Ерикәй.

3. Әйбер, нәрсә. *Күбәләкнең бер дә чик юк һәр матурга гыйшкына, Тиз генә ул барды да кунды матур зат өстенә.* Г. Тукай.

4. Чыгыш, нәсел, токым (кеше яки хайван турында). *Безнең затыбыз куркаклардан түгел.* Д. Аппакова. — *Аһ, син әйтче, Сылу, кай дөньядан? Фирештәме затың, тумышың?* Н. Исәнбәт. [*Үгез*] *картаеп, бәлтерәп беткән бернәрсә, үзе җитмәсә яхшы заттан да түгел.* Ә. Айдар.

5. Әйбернең сыйфаты; югары сыйфатлылыгы. [*Боларның*] *асылы бер — заты башка.* Әйтем. // *с. мәгъ. к.* затлы. *Сатингамы, бер затрак нәрсәгә чиктерсәкме дип тә торам әле мин.* М. Фәйзи. [*Карт*] *--- фарфор, хрусталь кебек зат әйберләрнең чын сыйфатын - - - әйтә дә бирә.* Ә. Еники.

6. *лингв.* Эш-хәрәкәтнең сөйләүчегә мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категория.

ЗАТВОР *и. хәрби.* Ату коралында көпшәнең түбән башын ачу яки ябу өчен махсус эшләнгән механизм. *Һаваларда ком бураны уйный, ком авызга, борынга, колакларга тула, винтовкалар атмый, автоматларның затворлары ябылмый.* И. Гази. *Мостафа иң әлек аларны винтовка һәм затворның кисәкләре белән кыскача таныштырды.* Ш. Камал.

ЗАТЛАНДЫРУ *ф.* Затлы, яхшы сыйфатлы итү. *Ул мех эшкәртүнең һәм мехны затландыруның фәнни методларын тикшерә, эзләнә, яңа юллар ача.* М. Максуд.

ЗАТЛАНЫШЛЫ *с. лингв.* Зат белән төрләнә торган.

ЗАТЛАНЫШСЫЗ *с. лингв.* Зат белән төрләнми торган. *Затланышсыз фигыльләр.*

ЗАТЛЫ *с.* **1.** Асыл зат нәселеннән булган, чыгышы морза һ. б. ш. нәселеннән килә торган; яхшы нәселдән дип саналган. *Кияүне кышкы челләдә салкын келәткә ябарга ошатмады, нәселле, затлы кешенең баласы бит, дип, менә шул Хәмиттән калган өйне тиз генә төзәттерде.* Г. Ибраһимов. // Яхшы тәрбия алган, тәрбияле, эчке культуралы. *Бай булсалар да инде, бер дә затлы кешеләр түгел.* Г. Камал.

2. Яхшы токымлы, нәселле (хайваннар, кошлар турында). *Безнең янда көчсез канатларын җилпи-җилпи яшь бөркетләр ята. Исабәк, аларга карап, тыныч кына әйтеп куя: «Затлы кош булырлар, боерган булса, Корыч Тырнагым да шушы оядан иде бит».* М. Госманов. // *күч.* Кыйммәтле, кадерле. *Моңарчы минем өчен бернәрсә дә тормаган әлеге койрыксыз куян кинәт кенә искиткеч кызыклы, затлы бернәрсәгә әйләнде дә куйды.* Н. Исәнбәт.

3. Кыйммәтле, асыл.— *Бу бит байның затлы сәгате.* Д. Аппакова. *Кодагыйга бирергә дә бер затлырак нәрсә салмый килешмәс.* М. Фәйзи. *Менә сезгә энҗе калфак, Менә асыл ашъяулык, Менә затлы ефәк шәлләр, Менә көмеш кулбаулык.* Т. Гыйззәт. // Югары сыйфатлы, сыйфаты һәм материалы яхшы булган. *Затлы нәрсә — хаклы нәрсә.* Мәкаль. // *рәв. мәгъ.* Матур, яхшы итеп. *Ямьсез ситсыларны алучы сала маржәлары акчасына менә әле син затлы киенеп, гимназиягә акча түләп, ач-яланғач булмыйча торасың.* Ф. Әмирхан.

Затлы агачлар — күбесенчә көньякта үсә һәм гадәттә мебель ясауга китә торган кыйммәтле агач (мәсәлән, кызыл агач). *Бу — затлы агачтан матур итеп сырлап, чын сәдәпләр белән бизәкләп эшләнгән бик нәфис язу өстәле иде.* Г. Гобәй. **Затлы металлар** — һавада тутыкмый торган кыйммәтле металлар (алтын, көмеш, ак алтын).

ЗАТЛЫЛЫК *и.* Затлы булу. *Әмма аларның килешле һәм яхшы өс-башларыннан алып аяк атлауларына, сөйләшүләренә, елмаюларына кадәр үзенә бертөрле гакыллы олылык, яхшы күңеллелек, үзенә бертөрле затлылык сизелеп тора.* Г. Бәширов.

ЗАТОН *и.* Елгаларда пароходлар кышлый торган урын. *Валентин судноға килгәндә, земснаряд кышкы затонда тора иде әле.* Г. Әпсәләмов.

ЗАТСЫЗ *с.* **1.** Түбән сыйфатлы, начар эшләнгән. *Затсыз тукыма әйберләре.* // *рәв. мәгъ.* Сыйфатсыз, начар итеп. *Бу мәкаль, икенчеләй миңа эш кушмасыннар, дигән кебек, формаль һәм затсыз эшләүгә мисал ителә.* Н. Исәнбәт.

2. Нәселе, чыгышы белән данлы булмаган, нәселсез.— *Бичаракаем, әле кичә генә диярлек затсыз гына бер мальчишка иде ләбаса.* Ш. Камал.

3. *сөйл.* Әдәпсез, тәртипсез. *Бигрәк затсыз бала икән. // рәв. мәгъ. Затсыз кылану.*

ЗАТСЫЗЛАНУ *ф. сөйл.* Әдәпсез кылану, үзен әдәпсез тоту, оятсызлану. *Шул [Нурсама] бит инде, затсызланып, яңагына миң ясап йөри, сул яңактагы миң егетләргә мәхәббәтле күрсәтә, дип сөйләнә, ди.* Ш. Хәсәенов.

ЗАТСЫЗЛЫК *и. сөйл.* Әдәпсезлек, әдәп кагыйдәләреннән читкә китү, тәртипсезлек. [*Мәүлиха түти*] *Әпипәнең шәрә балтырларына ачуланып карап алды: «Яратмыйм лабаса шушы затсызлыгыңны, кем, Гафифә!»— диде.* Г. Бәширов.

ЗАЧЁТ *и.* Югары яки махсус урта мәктәпләрдә укучыларның практик белемнәрен тикшерә торган имтихан төре.— *Син шул, кызый, Үзең зачётыңны Бик соң әзерләргә башлыйсың. Үзең бездән алда биреп ташлыйсың.* Һ. Такташ. *Зачётлар бетү белән, акка-карага карамый, өйгә ашкындым.* Ш. Камал. // *сөйл.* Шундый имтихан үтүне раслый торган билге.

Зачёт книжкасы — студент кулына аның өлгерешен исәпкә алып бару өчен бирелгән документ. *Бу эшнең нәтиҗәсе зачёт книжкасындагы билге булып түгел, ә халкның башкарган бөек, иҗади хезмәтнең бер өлеше булып гәүдәләнәчәк.* Г. Әпсәләмов.

ЗАЯ: зая(га) китү — әрәм булу, бушка, кирәкмәгәнгә тотылу. **Зая(га) үтү** — бушка, әрәмгә, мәгънәсезгә үтү. *Бер карыймын байга, бер фәкыйрьгә, фәкыйрь гомере үтә заяга,— ди.* Г. Ибраһимов. *Үтсә дә гомере заяга, Ул да көлә, шаяра.* М. Җәлил.

ЗАЯ'ВКА *и.* Нәрсәгә дә булса рәсми рәвештә җибәрелгән сорау, таләп. *Безнең заявка буенча нәселле үгезләр бирәләр.* Ә. Айдар. *Цемент агрегаты җибәрерләр. Заявка бирелде.* М. Хәсәнов.

ЗАЯВЛЕ'НИЕ *и. сөйл. к.* гариза.— *Батырҗан заявлениесен карап, аны колхозга алу турында карар чыгардык.* Ф. Бурнаш.

ЗАҢ *и. иск. кит.* Гадәт; әхлак кагыйдәләре. *Заманына күрә заңы.* Әйтем. *Сөйлә, [курай], тарихыннан, яуларыннан, Сөйлә канлы башкорт боласын [чуалыш], Сөйлә олы атайлар хәлләреннән Йөреш-торыш, заңын, йоласын.* Ш. Бабич.

ЗАҢГЫЛДАУ *ф.* Заң-зоң иткән тавыш чыгару.

ЗАҢ-ЗОҢ *аваз изр.* Тимернең тимергә өзек-өзек ритмик бәрелүе нәтиҗәсендә яки чаң сукканда чыккан тавышларны белдерә. *Назимовның колаклары чаң кебек заң-зоң шаулый, башы әйләнә, күңеле болгана.* Г. Әпсәләмов.

ЗАҺИД *и. иск. кит.* Суфый, тәкъва, динчел кеше. *Таза бер мужик чаклы эш эшли — урак ура, печән чаба, урман кисә, чын бер заһид кадәрле динен, гыйбадәтен үти иде.* Г. Ибраһимов.

ЗАҺИР *с. иск. кит.* **1.** Тышкы, күренеп тора торган. *Бу адәмне, заһир сыйфатына карап, бәлки, аралашмаган, бәгъзы беркатлы, ак эчле кешеләр: инсафлы, игәнәтле, шәфкатьле, фәкыйрьләргә, гаҗизләргә ярдәмледер, дип хыял кылсалар да, бер мәртәбә үзен күргән кеше, үзенең хата фикергә, яңлыш юлга сапканын аңлап, тәүбә итәр иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *рәв. мәгъ.* Аермачык, ачык. *Ләкин ул хисапның ялгыш чыкканын һәркем бик тиз аңлады: Толстой гасырына кайтарырга теләүчеләр бар икәнчелеге бик заһир күренде.* Ф. Әмирхан.

3. *рәв. мәгъ.* **заһирда, заһирдан.** Тыштан, тышыннан, тышкы яктан караганда, асылына төшенмичә, өстән генә караганда. *Сираҗетдин Туктагаев — заһирда бик суфый күренә торган сәүдәгәр.* Г. Камал. *[Җәмилә] заһирдан караганда шөйлә хәсрәтсез күренсә дә, эчендә бәйләнеп зур кисәк бернәрсә яткан кебек хәсрәте кузгалып, сирәк-сирәк «Уф!» дия авызыннан чыга иде.* М. Гафури.

Заһир булу — барлыкка килү, күзгә күренү. *Кояштагы бу таплар вакытлы нәрсәләр булалар: бер заһир булалар, бер бөтенләй бетәләр.* Ф. Әмирхан. *Сәхнә яктырып, болытлар өстендә фәрештәләр заһир булалар.* Һ. Такташ.

ЗАҺИРИ *с. иск. кит.* Тышкы. *Икенче бер куәт аны заһири мөгамәләдә суыклык, хәтта мәңге өзелгәнлек сурәте бирергә мәҗбүр итә иде.* Г. Ибраһимов.

ЗАҺИРӘН *рәв. иск. кит.* Тыштан, тышкы яктан караганда. *[Эченнән] хәвеф итсен дә, заһирән белгертмәсен.* Г. Тукай.

ЗВА'НИЕ *и. хәрби.* Махсус хәзерлегенә һәм күрсәткән хезмәтенә карап бирелгән дәрәҗә исеме; чин. *[Нургали], фронтта күрсәткән батырлыклары белән бергә дәрәҗәсе дә үсә барып, старшина званиесен алгач, --- кара мыек үстереп җибәрде.* Ә. Еники. *Шакиров исемен әйткәч, майор аның атасының исемен һәм, белсә дә, ни өчендер, званиесен дә сорады.* А. Әхмәт.

ЗВЕНО *и.* Нинди дә булса берләшмә яки төркемдә зур булмаган бүлек. *[Биктимер] безнең төнге бомбардировщикларның звено командиры булган.* С. Баттал. // Пионер отряды яки дружинасының 8—10 пионерны берләштергән бер бүлеге. *Сәлим звеносы һәркайчан, һәр эштә үзенең исеменә — пионер исеменә тап төшермәде, өстенә төшкән бурычын һәркайчан намус белән үтәп барды.* Г. Гобәй. *Звено сборының беткән вакыты.* А. Алиш. // *иск.* Колхозларда бригаданың бер бүлеге. *Югары уңыш звеносы. Яшьләр звеносы.* □ *Эшнең кызу вакыты булуына карамастан, колхоз правлениесе карт-корылардан бер звено төзеп ярдәмгә бирде.* Ә. Айдар.

ЗВОНОК *и.* **1.** Тавыш сигналлары бирү өчен махсус җайланган прибор яки зур булмаган кыңгырау. *Доклад вакытында звонок хезмәтен Мостафаның карандаш башы үтәгән булса да, концерт өчен --- колын муенына таға торган зур гына кыңгырау табып алып килделәр.* Ш. Камал. *Үтеп барам шулай урам буйлап, Парадныйда күрәм бер бала, Звонокка үрелә, буе җитми. Аптырагач, карап уйлана.* М. Җәлил.

2. Кыңгырау яки башка берәр нәрсә ярдәмендә бирелгән тавыш сигналы. *Звонок, озын коридорны яңгыратып, укучыларны класска өндәде.* А. Әхмәт. *Беренче звоноктан соң халык платформага агылып чыга башлады.* А. Шамов.

ЗЕ!БРА *и. зоол.* Ат токымыннан Африкада яшәүче, буй-буй аклы-сарылы төстәге кыргый хайван.

ЗЕ'БУ *и. зоол.* Африкада һәм Көньяк Азиядә яши торган өркәчле, эре мөгезле терлек.

ЗЕКЕР: зекер кылу *иск. кит.*— искә алу, искә төшереп әйтү, әйтеп үтү. *[Шәриф] югарыда зекер кылган ярлылар тора торган урынга барып торды.* М. Гафури. *[Мулла] байгурадан, бер мәртәбә исемен менбәрдә зекер кылган өчен, кырык куйны [ала].* Г. Ибраһимов. **Зекер әйтү** *иск. кит. дини.*— алланы зурлап һәм мактап укыла торган доганың бер төре: тәсбих тарту. *Кайбер кеше кыйблага каршы утырып зекер әйтә, ягъни тәсбих тарта.* М. Гафури.

ЗЕЛПЕ *и. бот.* Парлап урнашкан вак яфраклы, хуш исле алсу һәм ак чәчәк ата, кара коңгырт төстәге жимеш бирә торган куак үсемлек; *русчасы:* жимолость. *Гаяз ал чәчәккә күмелеп утырган зур зелпе агачын төбеннән үк сындырып алып, Артыкбикәгә тәкъдим итте.* М. Әмир. *Безнең җәй көннәре башак, дару үләннәре җыеп, зелпе тамыры төшереп, ашлык утап --- үтә иде.* Г. Мөхәммәтшин.

ЗЕЛПЕЛЕК *и.* Зелпе күп үскән урын.

ЗЕМЛЕМЕР *и. иск.* Җир бүлү һәм җирдән файдалануны тәртипкә салу эшләре белгече. *Көннәрнең берендә алпавыт, шәһәрдән землемер китертеп, крестьяннарның Ышна җирен үзенә кистереп алган.* И. Гази.

ЗЕМЛЯ'НКА *и.* Җиргә казып эшләнгән торак урыны. *Башка өйләрнең барысы да балчыктан эшләнгән яки бөтенләй җирне казып ясалган, бик кечкенә --- кызганыч землянкалар, җимерек алачыклар иде.* Г. Ибраһимов. *Җылы землянкада, үз отделениесенең солдатлары арасында, Газинур тәмәке тартып утыра.* Г. Әпсәләмов. // Кыш өчен җирне казып эшләнгән җылы мал абзары. *Городовой чакырып, моның кем икәнен тикшерсәләр, бозаулар белән бер землянкада ачлы-туклы ятучы әюповның бер приказчигы икән.* Ш. Мөхәммәдев. *Кара турының землянка ишеге начаррак.* Г. Толымбай.

ЗЕ'МСКИЙ 1. *с. иск. тар.* Земствога караган, земство карамагындагы. *Земский мәктәпләр.* □ *Крестьяннар помещик һәм земский управаларга каршы күтәрелделәр.* М. Җәлил. *[Гөлшаһидә:] Әткай, тройкада йөргән өчен өлкән земский врач сезгә ни әйтте?* Г. Әпсәләмов.

2. *и. мәгъ. к.* **земский начальник.**— *Русча укып йөрде, әйе, форма киеп, земскийдәй, җиз төймәсен ялтыратып.* Н. Исәнбәт.

Земский начальник — авылларда администрация һәм суд эшен башкаручы өяз чиновнигы.— *Әле генә миннән алган кәгазьне Намажанга бир дә, аның белән икәү --- теге элекке земский начальник Митрий Степанычка барыгыз.* Г. Ибраһимов.

ЗЕМСНАРЯД *и. тех.* Гидротехник эшләр башкару өчен билгеләнгән судно; су асты грунтыннан балчык суыра торган снаряд. *Хәзер --- каналлар төзүдә җир казу эшләренең төп өлеше земснарядлар ярдәмендә башкарыла.* СССР экон. геогр.

ЗЕМСНАРЯДЧЫ *и.* Земснарядта эшләүче. *Кайчакта корыч тросларның өзелеп китә. Аларны ялгый-ялгый земснарядчылар мең газап чигәләр.* Г. Әпсәләмов.

ЗЕ'МСТВО *и. тар.* Революциягә чаклы Россиянең үзәк губерналарында җирле үзидарә. *Аның атасы үз гомерен земствода чиновник булып үткәрде.* Г. Ибраһимов.

ЗЕМФИ'РА *и.* Бер генә төн яши торган төн күбәләге.— *Яшәү үлемнән көчлерәк! — дидем.— Рас! — диде миңа төнге земфира.* Г. Рәхим.

ЗЕНИТ *и.* 1. *астр.* Күк гөмбәзенең җир өстендәге күзәтүчегә карата иң югары ноктасы. *22 нче декабрьда Кояш көньяктагы 23°27′ параллельдә яткан урыннарның зенитында була.* Астрономия.

2. *сөйл. к.* зенит артиллериясе (пулеметы, тубы). *Пароходның пулеметлары, зенитлары ата башладылар.* Х. Садрый.

Зенит артиллериясе (пулеметы, тубы) — һавадагы дошман самолетларына ата торган артиллерия (пулемет, туп). *Паровоздагы зенит пулеметы бер самолетны мушкага алган.* Ә. Айдар. *Бу чибәр кызның --- зенит тубыннан атып торуын күз алдына китерә алмый Дәүләтшин.* И. Гази.

ЗЕНИ'ТКА *и. сөйл. к.* зенит артиллериясе (пулеметы, тубы). *Зениткалар шулкадәр еш һәм күп аттылар, алар Хәлимнең тавышын томаладылар.* Г. Гобәй.

ЗЕНИ'ТЧИК *и. сөйл. к.* зенитчы. *Каныкты безнең лачынга Кипкән йөзле, бүре күзле Дошман зенитчиклары.* Ф. Кәрим.

ЗЕНИТЧЫ *и.* Зениткадан атучы артиллерист. *Безне озатучы истребительләр --- зенитчыларның утларын басар өчен түбән төшеп киттеләр.* С. Баттал.

ЗЕРЕЛДӘҮ *ф. к.* зырылдау.

ЗЕР-ЗЕР *аваз изл. к.* зыр-зыр.

ЗЕРНОПУЛЬТ *и. а.-х.* Ашлыкны киптерү, чистарту, сортларга аеру һәм төяү-бушату эшләрен башкара торган машина. [*Ындыр табагында*] *биш электр моторы, ике зернопульт, ике сортировка --- эшләп тора.* Г. Галиев.

ЗЕРӘ! *рәв. сөйл.* Юкка, сәбәпсез, нигезсез; тик торганда.— *Син алай дисең дияен дә, Баһави абзый, эшнең җае бар бит аның, --- беләсең, аңа зерә генә тотынып булмый бит.* М. Гали. *Рәхим бабайның аты бер заманны, урактан кайткач, зерәдән генә үлде дә китте.* Г. Толымбай. // Бушка, юкка, максатсыз. *Алты ай буена мин үз башыма гыйлемне зерәгә генә төямәдем.* Ә. Айдар.

ЗЕ'РӘ *рәв. сөйл.* Бик, артык.— *Шулай да мин үземнең Чуртанны* [*Халикъны*] *зерә яратам.* Ш. Камал.— *Көйсез икән сезнең эшләр, зерә дә көйсез икән.* Г. Бәширов.— *Ишеттеңме? Зерә тиз өлгертерләр инде.* Ф. Бурнаш.

ЗЕФИР I *и. иск. шигъ.* Әкрен искән йомшак җил; саба жиле. *Туган җирдә тузган тузаннар да Ник соң болай зефир төслеләр?* Ш. Маннур.

ЗЕФИР II *и. махс.* Киже-мамык тукыманың бик юка төре. / *с. мәгъ. күч. Вак-вак кына кара бөрчекле зефир күлмәк кигән яшь каеннарның исәбе-хисабы юк.* Г. Галиев.

ЗЕФИР III *и. махс.* Җиләк-жимештән әзерләнгән пастиланың күбек сыман күпертеп эшләнгән сорты.

ЗЕҢ *аваз. изл.* Юка металл, пыяла, хрусталь һ. б. ш. нәрсәләр бер-беренә җиңелчә орынганда туган калтыраулы нәфис тавышны белдерә. *Өстәлгә шапылдап ак башлы шешә утырды... Зең итеп стаканнар чәкелдәде.* Т. Миңнуллин.

ЗЕҢГЕЛДӘТҮ *ф.* Зеңгелдәү тавышы чыгару. *Тирәяк тын, бары кое янындагы качырлар гына пошкырышып, йөгәннәрен зеңгелдәтеп торалар.* Мең дә бер кичә.

ЗЕҢГЕЛДӘҮ *ф.* Зең иткән, зеңгел иткән тавыш чыгу. *Шпораларның күңелле зеңгелдәүләрен әллә сокланып, әллә көнләшеп тыңлап торды да, йөгереп килеп, таганга әлгән казан астына ягып җибәрде.* Г. Гобәй. *Җәйге коры һава чыңлап, зеңгелдәп тора.* А. Гыйләҗев.

ЗЕ'ҢГЕЛ-ЗЕ'ҢГЕЛ *аваз изл.* Қалтырап тарала һәм бәрелеп кабатлана торган зең авазына охшаш нәфис тавышны белдерә. *Күз алдымнан Кама буе, --- зәңгәр һавага зеңгел-зеңгел сайрап менгән тургайлары үтте.* Э. Қасыймов.

ЗИГЗАГ *и.* 1. Сынык сызык. // Қинәт әле бер, әле икенче якка борылган юнәлеш. *Зигзаг ясап йөгерү.* □ *Профессор җәмгыять үсешенең туры сызык белән генә бармыйча, үз юлында төрле әйләнмәле борылышлар, зигзаглар ясаганлыгын исбат итә.* Ф. Хөсни.

2. Тешләре зигзаг тәртибендә аралаштырып урнаштырылган тырма. *Авылга, әлбәттә, яңа маркалы, киң алымлы сабаннар, зигзаг дип йөртелгән тимер тырмалар, һәртөрле машиналар һаман саен күбрәк кайта башлады.* Г. Галиев.

ЗИГО'ТА *и. биол.* Үсемлек яки хайваннарда аталанган күкәй күзәнәк. *Яңа организм, кагыйдә буларак, --- зиготадан үсә.* Биология.

ЗИЛЗИЛӘ *и.* 1. Көчле җир селкенү, җир тетрәү. *Кинәттән зилзилә купкан төсле булды, бүлмә эче селкенеп китте.* Қ. Насыйри. // *күч.* Тетрәү, давыллану. *Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә.* Г. Қутуй.

2. *күч.* Җәмгыять тормышындагы хәлиткеч, давыллы күренешләр. *Советлар Союзы җире өстеннән узган гражданнар сугышы зилзиләсен бер генә, ун гына түгел, йөз еллар язсак та, аннан җиңгән класс туячак түгел.* Ф. Сәйфи-Қазанлы.

ЗИЛЗИЛӘЛӘҮ *ф. сөйл.* Үзен давыл кебек тоту, давыллану. *Ә Төхфәт синең өскә куркыныч төшкәндә генә посып яткан икән. - - - Шаукым үткач, әүвәлгечә зилзиләләп йөри торган булды.* Э. Қасыймов.

ЗИЛЛӘТ *и. иск. кит.* Хурлык, мәсхәрә. *Ни хурлыклар, Ни зилләтләр Күрмәдек без.* Г. Тукай. *Һәр зилләтнең каһре бар, һәр хөрмәтнең кадре бар.* Мәкаль.

ЗИМ *и.* Көз көне яки язын елга өстен тутырып ага торган вак көпшәк боз; сил.

ЗИМАГОР *и. иск. сөйл.* Төрле промыселларга китеп эш эзләп йөрүче крестьян, даими эше булмаган сезонлы эшче. *Зимагорның чалбары, буй-буй аның аллары; Кайда эшләсә, шунда кала зимагорның маллары.* Җыр. *Шахталарга китеп, бәхет куып йөрүчеләрне җене сөймәде* [*Гафиятнең*], *андый кешеләрне ул «зимагорлар» дип атый иде.* И. Гази.

ЗИМАГОРЛЫҚ *и. иск.* Зимагор булу, сезонлы эшче булу. *Араларында --- гомер буена бурлаклыкта, зимагорлыкта, көтүчелектә йөргән Чатан Шаһи, Кушавыз Гыймади шикелле авылның ярлылары, батраклары да бар.* М. Гали. *Табылмаган бәхетне эзләп илдән илгә каңгырып йөри торгач, кайберәүләре бөтен дөньясына төкергән дә зимагорлыкка чыккан.* Г. Бәширов.

ЗИНА *и.* Фәхешлек, женси бозыклык, уйнаш. *Хәлимәне дә бит ире зинадан бала табуда гаепли торган булган.* Ш. Камал.

ЗИНАР *и.* Нечкә билбау. *Котлы булсын туегыз дип, зинар чишкән биленнән.* Бәет. — *Синең картуз киеп, биленә зинар бағлап, студент булып йөрүеңә без риза була алмыйбыз.* Ф. Әмирхан.

ЗИНАХУР *и. к.* зиначы. [*Җамали:*] *Гайфулла абзый, менә шушында тотылдылар. Зинахурлар!* [*Беренче егет:*] *Уйнашчылар! Менә шунда!* М. Максуд.

ЗИНАЧЫ *с.* Зина кылучы, женси бозыклык юлына баскан (кеше).— *Яп ул изүләреңне... Атаң алдында зиначы хатыннар күк басып торасың.* Г. Ахунов. / *и. мәгъ. Карак карганыр, зиначы елар.* Мәкаль.

ЗИНАЧЫЛЫК *и.* Уйнаш итү, зина.

ЗИНДАН *и. к.* төрмә. *Гаҗәбе шул булды: Қачкыны, гадәт буенча, зинданга алып китмәделәр, кире*

баягы участокның сасы пычрак камерасына китереп бикләделәр. Г. Ибраһимов. *Без кол идек бай кулында, Богау, зынҗырлар муенда, Зинданнарда чери идек Хак сүз, тугрылык юлында.* Г. Камал. // *күч.* Кысанлык, кысынкылык; тар, кысан урын. *Ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә, тәмам унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып кердек.* Г. Тукай.

ЗИНДИҚЪ *с. иск. дини.* Иманы дөрес булмаган, бозык; динсез, диненә хыянәт иткән. *Хәзрәт, караңгыда калгач, бик курыкты да, бар көче белән сарай ишеген дөбердәтеп: «Ачыгыз, кяфер-мәлгуньнәр, ачыгыз, зиндикълар!»* [*диде*]. Ф. Әмирхан. *Әгәр ул ялгыш* [*ышану*] *белән зиндикъ булган булса?..* Г. Газиз.

ЗИННӘТ *и.* 1. Затлы, кыйммәтле әйбер; алтын, көмеш, ука һ. б. ш. кебек затлы әйберләр яки шулардан эшләнгән әйберләр. *Башкортларның гадәт вә әхлакларын язып һәм кием вә зиннәтләрен музей өчен тикшереп яталар икән.* Г. Тукай. // *күч.* Байлык, муллык. *Ул, мәдәни тормыштан, каланың баштанаяк зиннәт вә мода эченә күмелгән ялтыравыклы хәятыннан гомергә күл селтәп, --- караңгы авылга китеп югалырга карар бирде.* Г. Ибраһимов.

2. Ямь, күркәмлек, матурлык, нәфислек. *Өстәлемә генә түгел, бөтен хәятыма зиннәт биреп торган бер альбомым бар.* Г. Ибраһимов. *Кар беткән урыннарга зиннәт бирер, Вак-вак кына төрле-төрле үлән үсеп.* М. Гафури.

ЗИННӘТЛЕ *с.* 1. Кыйммәтле, затлы. *Россиягә исә зиннәтле әйберләр һәм ил эчендә эшләнми торган товарлар кертелгән.* СССР тарихы. // Затлы нәрсәләр, зиннәт әйберләре белән бизәлгән. *Фронт штабының зиннәтле салон-вагонында Сангурский кич күн диванга җәелеп утырган.* Ш. Усманов. *Зиннәтле бүлмәләрдә йомшак түшәкләр өстендә сузылып яткан промысло хуҗалары шул ук балык хисабына кырыгар мең сум төшерү хыялы белән ләззәтләнә* [*иделәр*]. Ш. Камал.

2. Матур, нәфис; бизәкле. *Ишек алдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны күреп, бигрәк тә сокландым.* Г. Тукай.

ЗИННӘТЛЕЛЕК *и.* Зиннәтле булу; зиннәтләнгән булу.

ЗИННӘТЛӘҮ *ф.* Зиннәтле әйберләр белән бизәү, җиһазлау. *Болар шулай ашыгыч рәвештә кияү бүлмәсен зиннәтләп бетереп барганда, теге ябык яшүсмер ялчы Мифтах килеп керде.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Бизәү, ямь бирү; матурлау, матур итеп күрсәтү. *Көйләр яхшы беленгән вә җырлаучылар да бер таякка карарлык тәртипкә салынган булганлыктан, кичәне зиннәтли иде.* Ф. Әмирхан. [*Хикәянең*] *эчтәлеген чуашларның тормыш, гадәтләрен күрсәтү белән дә зиннәтли алсаң, ул татар әдәбияты өчен яңа, кыйммәтле бер бүләк булыр иде.* З. Бәшири.

ЗИНЬ-ЗИНЬ *аваз иәр.* Тартылган кыл яки нечкә тимерчыбык калтыраудан барлыкка килә торган нәфис тавышны белдерә. *Сары түшле елдам песнәкләр, скрипка кылы гына чыгара ала торган нәфис тавышлары белән зинь-зинь килеп, ботактан ботакка сикерешәләр.* И. Гази.

ЗИННЬАР *кер. сүз.* Үтенүне, ялваруны белдерә.— *Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр.* Г. Тукай.— *Зинһар, Шәмгун абзый, кадак ярым май белән ун йомырка биреп тор әле.* А. Шамов. / Кереш сүз тезмәсе составында.— *Зинһар дип үтенәм синнән, калдыр бу бәндәне, жаның теләгән малны бирәм мин сиңа.* Г. Колэхметов. — *Тик, зинһар өчен дип әйтәм, эшне тизлэтергә кирәк.* Ш. Камал.

ЗИННЬАРЛАП *рәв.* Бик ялынып-ялварып. *Пристань дебаркадерында басып калган ябык, моңлы хатын зинһарлап үтенде: кызыма күз-колак була күрегез, диде.* Ф. Хөсни. — *Валентинны мин яратам. - - - Шуңа күрә зинһарлап сорыйм, аны герой ясый күрмәгез. Яшь әле ул.* Г. Әпсәләмов.

ЗИР *и. иск. кит.* Алтын. *Гөл кадерен былбыл белер, зир кадерен зирәкләр белер.* Мәкаль.

ЗИРАТ *и.* Үлгәннәрне күмү урыны, каберлек. *Карт аны, бөтен халыкның гажәпләнүенә карамастан, зиратка түгел, ә бакчага, алмагачлар янындагы түтәл буена күмде.* А. Шамов.

ЗИРАТЛЫҚ *и. сөйл.* Зират, каберлек. *Март уртасы җитүгә карамастан, зиратлык өстендә кар күп иде.* М. Гафури.

ЗИРАТЧЫ *и.* Зиратта күмү-күмдерү эшләрен алып баручы, зират эше буенча җаваплы кеше.

ЗИРЕК *и.* Каеннар семьялыгыннан үзагачы бераз кызгылт төсле, тиз сынучан, иртә чәчәк ата торган агач (дымлы урыннарда, яр буйларында үсә). *Ике аккош очып китте су буенда зиректән.* Г. Тукай.

ЗИРЕҖЛЕК *и.* Зирек күп үскән урын. *Алда ерак түгел елга чокыры буйлап сузылган зиреклек күренеп тора иде.* М. Әмир.

ЗИР-ЗӘБӘР, ЗИР-ЗӨБӘР: зир-зәбәр килү — җимерелү, актарылу, асты өскә килү. *Чыксалар дошман яулар, зир-зәбәр килер таулар.* Ә. Ерикәй. *Туплар төшми калган цехларда да машиналар зир-зәбәр килде.* Г. Әпсәләмов. *Чиркәүләре белән бергә иске Тормышлары килер зир-зәбәр!* М. Гафури.

ЗИРӘК *с.* 1. Белем алуга сәләтле, тиз аңлаучан, төшенүчән, зиһенле. *Фәһме үткен, ул зирәк, андый балалар сирәк.* Г. Тукай. *Бер елда ижек танып, сүрә белгәч, «Бу бала зирәк!» — диде авыл халкым.* М. Гафури. *Алар каршында укытучы абыйлары табигатьнең бөтен серләрен һәм бөтен тереклекнең телен белә торган ниндидер кодрәтле, зирәк кеше булып гәүдәләнә.* Г. Бәширов. // Акыл белән, һәр ягын уйлап эш итә торган, үткен акыллы. *Вафин Харис — «Ялкын» колхозының Тырыш, җитез, зирәк хуҗасы.* Ш. Маннур.

2. Үткен, өлгер, елдам.— *Нураеваны өлкән оператор итеп күтәрдек. Бик зирәк кыз булып чыкты ул.* А. Әхмәт. // Сизгер, уяу, игътибарлы. *Ярый әле, килене — бик зирәк нәрсә. Хәдичә түти иснәнә башлауга, ялт итеп торды да нәрсәнедер минут эчендә сүндереп тә куйды.* Г. Бәширов.

ЗИРӘҚЛЕК *и.* Зирәк булу. *Узенең зирәклеге һәм укырга япьтәшлеге аркасында, ул шул өч кышта мәктәптә укылырга тиешле бөтен китапларны артыгы белән укып бетерде.* М. Гали. *Ул уйлый бары дошманны Жиңәргә кирәклеген, Шуңа туплый бар сәләтен, Акылын, зирәклеген.* Ә. Исхак.

ЗИФА *с.* Сылу, төз, ыспай гәүдәле; матур, нәфис төзелешле. *Сузылып үскән зифа кипарислар Чолганалар куе томанга.* Ә. Ерикәй.— *Синең кебек таза, зифа буйлы сылу егетне* [*солдатка*] *алмый калдырачак түгеллэр.* А. Шамов.

ЗИФАЛАНУ *ф.* Сылулану, матурлану. *Менә алар, яңадан яз көне кабарынган күгәрченнәр, аталары янында купшыланып сыйпаланган, зифаланган ана күгәрченнәр кук, яңадан гайрәтләнерләр.* Г. Газиз. *Лалә --- матур киенгән, буе зифаланган.* М. Фәйзи.

ЗИФАЛЫҚ *и.* Зифа булу. *Маркс иптәшенең матурлыгы, күркәмлеге, зифалыгы белән мактанган.* Г. Кутуй. *Мин сүрәтли алмам зифалыгын, Нечкәлеген сезгә биленең.* М. Җәлил.

ЗИ'ЯДӘ *рәв. иск. кит.* Артык, артык дәрәҗәдә, бик. *Бик озын мәктүбең илә эчендә юлламыш рәсемеңне алып, зиядә* [*канәгать булдым*]. Ш. Мөхәммәдев. *Бер* [*билгеле*] *дәрәҗәдән зиядә суык булса, җир эчендә булган сулар --- бозга әйләнәдер.* Қ. Насыйри.

ЗИЯРАТ *и. к.* зират. *Шәкертебезне Куянаяк исемле мөселман зияратына илтеп күмдек.* Ш. Камал.

ЗИЯРӘТ: зиярәт итү (кылу). *иск.*— 1) үлгән кешенең кабере янына барып гыйбадәт кылу, үлгәннәр рухына багышлап дога кылу. *Атаң-анаң барда хөрмәт ит, үлсәләр, зиярәт ит.* Мәкаль. *Мәрхүмә хатыныи искә төшерде. --- Әллә кайчаннан бирле кабере дә зиярәт ителми.* Ш. Камал; 2) *күч.* кемнең дә булса янына керү, күрешергә яки хәл белергә килү. *Мәкаржәгә барышлый безне зиярәт итәрсең дип, апай берлә икебез дә Гурьев тарафына дүрт күз берлә карамактабыз.* Г. Тукай; 3) кая да булса барып карау, тамаша кылу. *Галиәкбәр агай, шәһәрнең астын-өстенә китереп, беренче класс ресторанның башлап түбән дәрәҗәдәге кабакка кадәр һичбер зиярәт итмәгән җирне калдырмады.* Ш. Мөхәммәдев. [*Эйфель манарасы*] — *Парижга читтән баручыларның сөеп зиярәт итә торган җирләреннән берсе.* Г. Гали.

ЗИЯРӘТЧЕ *и. иск.* Зиярәт итү эшен башкаручы, зиярәт итүче. *Әсма ул вакытта, зиярәтчеләр кабул ителә торган вакытның иң башыннан кереп, иң ахыргы минуты узганчы утырган иде.* Ф. Әмирхан.

ЗИЯФӘТ *и. иск. кит. к.* банкет I. *Патша аларга бик зур зиафәт ясады.* К. Насыйри.— *Банкетны да белмәскә, оят бит. Безнеңчә зияфәт, Европача банкет дип бер кешенең шәрәфенә багышлап ясалган мәҗлескә әйтәләр.* К. Тинчурин.

ЗИҢ-ЗИҢ *аваз изр.* Тимерне тимергә җиңелчә генә бәрүдән яки тартылган кыл калтыраудан туган йомшак тавышны белдерә. *Сәгать җырлый: диң-диң! --- Мин бит туктый белмим, Моннан ары зиң-зиң! Миңа карап йөр син.* М. Җәлил. *Колын, колын, колынкай, Аяклары озынкай, Өсте җирән мамыклы, Зиң-зиң алтын тавышлы.* Табышмак.

ЗИҢКҮ *ф. диал.* Баш түнү, миңгерәүләнү. *Гөлдәр икеме-өчме сәгать ятып алды да, отыры зиңкеп кенә торып, беренче яртыда дәресенә китте.* Х. Сарьян.

ЗИһЕН *и.* 1. Акыл, аң. *Теге яки бу һөҗүмнең уңышлы булуы --- разведчикларның зиһен белән, акыл белән хәрәкәт итүләренә бәйләнгән.* Г. Галиев. *Зураерсың, зиһенең арта барыр.* С. Хәким.

2. Уй, фикер. *Аның башы авырта, зиһене чуалган, күңеле бернигә дә утыра алмый иде.* Г. Бәширов. *Артыкбикә турындагы көтелмәгән хәбәр минем зиһенемне читкә борып җибәрде.* М. Әмир.

3. *к.* хәтер. *Бер сәгать чамасы сузылган йөрү вакытында шул беренче тәрәзә Габделбасыйрның зиһененнән бер генә минутка да чыгып тормады.* Ф. Әмирхан. *Мәнә хәзер Нокта Вәлинең яньчелеп беткән башын күргәч, Миңсылуның зиһененә --- әлеге балта килеп утырды һәм бөтен юл буенча аның зиһененнән китмәде.* Ш. Камал.

ЗИһЕНЛЕ *с.* 1. Зиһене (1 мәгъ.) яхшы булган; акыллы, зирәк.— *Минем улым аз сүзле булса да, аның каравы, үткер зиһенле, тирәнтен уйлый торган бала ул.* Ш. Камал.

2. Яхшы хәтерле, хәтере яхшы булган.

ЗИһЕНЛӘҮ *ф.* Уйлау, фикер йөртү. *Кинәт* [*Муса*] *күңеленнән яшен утыдай куркыныч уйлар чагылып үзды, ул аларны хәтта ачык аң белән зиһенләргә дә курыкты.* Ш. Маннур.

ЗИһЕНСЕЗ *с.* 1. Зиһене булмаган, фикер йөртү сәләте начар булган, башсыз. [*Вәзир:*] *Мәрхәмәтсез кайгы көнемдә зиһенсезмен, ханым, үзем дә.* Ф. Бурнаш.

2. Хәтерсез, начар хәтерле. [*Кеше:*] *Тфү, нинди зиһенсез! Мин әйттем бит инде сиңа, мин сәяси сөрелгән кеше дип.* Г. Тукай.— *Туктале, самоварлары кайда соң аларның... Әй, зиһенсез!* И. Гази.

ЗИһЕНСЕЗЛЕК *и.* Зиһенсез булу. [*Мәхүп:*] *Кодагый, зинһар, гаеп итә күрмәсен, үземнең зиһенсезлегем белән бик зур оятлы булдым, кодагый, зинһар, үпкәли күрмәсен,— дигән.* Г. Камал.

ЗНАЧОК *и.* Кешенең белемен, кайсы оешмага караван яки берәр төрле күрсәткән хезмәтен, уңышын һ. б. белдереп, күкрәккә кадап йөртелә торган, гадәттә металлдан бизәкләп ясалган билге. *Комсомол значогы.* □ *Яшь морякның күкрәгендәге значоклары хәрби эштә осталыгын, политик белемдә алдынгылыгын күрсәтеп тоталар.* А. Әхмәт. — *Без, фермадагы бөтен хатын-кызлар, санитарный оборона значогына норма тапшырдык.* А. Шамов.

ЗОБ *и. мед.* Эчке секреция системасындагы калкансыман бизнең эшчәнлеге бозылу нәтиҗәсендә килеп чыккан авыру.

ЗОБАНИ *и.* 1. *дини, миф.* Җәһәннәмдә гөнаһлыларны җәзалаучы. *Бу сурәтнең тирәсендә җәһәннәмнәр, гөрзиләрен күтәргән зобанилар йөри башладылар.* Ф. Әмирхан. *Имеш, зобанилар тәмугларда Утлы чукмар тотып эшлиләр.* М. Гафури.

2. *күч.* Явыз, кансыз, рәхимсез кеше, палач. *Бераз гына хәл җыярга, ял итәргә утыргач, хәзер --- зинданнан сакчылары — зобанилар камчы илә кыйныйлар.* Ш. Мөхәммәдев.— *Ишеттеңме әле, теге ни, безнекеләр зобаниларны шәп дөмбәслиләр икән анда, ---* [*фашистлар*] *бөтен җирдә чигенә, ди.* Г. Әпсәләмов.

ЗОБАНИЛЫК *и.* Зобани булу; явызлык.

ЗОДИАК *и. астр.* Эклиптика буенча урнашкан 12 **йолдызлык җыелмасы** (Кояшның еллык күренмә хәрәкәте шул йолдызлыклар аша үтә һәм бу юл зодиак — хайваннар түгәрәге дип атала). *Зодиак йолдызчаларын исеменә корылган язма календарьда ай исемнәре түбәндәгечә:* 1. *Дәлү (чиләк) — январь;* 2. *Хут (балык) — февраль;* 3. *Хәмәл (кузы) — март;* 4. *Сәвәр (үгез) — апрель...* Н. Исәнбәт.

ЗОДИАҠАЛЬ *с. астр.* Зодиакка мөнәсәбәтле. *Зодиакаль йолдызлыклар.*

ЗОЛОТНИК *и. тех.* Гидравлик, пневматик яки җылыту машиналарында пар, газ яисә сыеклык йөрешен автомат рәвештә идарә итә торган җайланма, механизм.— *Пар машинасын ходка җибәрә алмый бер-икесәгать азапланган, эшнең серенә төшендем. Гаеп золотникта гына булган икән.* Х. Садрый.

ЗОЛЫМ *и.* Җәбер, изү. *М. Гафури бу вакыттагы Россиядә миллионнарча ярлыларның күз яшьләре түгелүе турында, байларның ярлыларга күрсәткән золымнары, вәхшәтләре турында язды.* М. Җәлил.

Золым итү (кылу) — җәберләү, изү. *Кан түгеп, золым кыйлып торганнары Түкмәделәр ошбу көндә бер тамчы кан.* М. Гафури.

ЗОЛЫМЛЫ *с.* Золымга нигезләнгән, золым, изү хөкем сөргән.

ЗОЛЫМЛЫК *и. к.* золым. *Ярлы вакытта эшли алмый торган золымлыкларын малы күбәйгәч эшли башлады.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗОЛЫМЛЫЛЫК *и.* Явызлык.— *Ничек тәкәбберлектән һәм масаюдан, гаделсезлектән һәм золымлыктан соң шундый ялваруга, түбәнчелеккә, хурлыкка, буйсынуга барып җиттең?* Мәзәк.

ЗОЛЬМӘТ *и. иск. к.* караңгылык. *Килеп чыкты хәзер фикрем кояшы зольмәт артыннан.* Г. Тукай. *Күктә сызылып таң атып, Нурланып чыксын кояш, Бу төнге зольмәтне ватып.* Һ. Такташ.

ЗОЛЬМӘТЛЕ *с. иск. к.* караңгы. *Аның янында кичкән котлы көндә --- Ачылды күк капу зольмәтле төндә.* Дәрдмәнд.

ЗОНА *и.* 1. Нинди дә булса гомуми бер билге белән характерлана торган билгеле бер төбәк, район. *Чик буе зонасы. Шәһәр тирәсе зонасы.*

2. Җир шарының аерым табигый шартлары белән характерлана торган территория, полоса. *Кара туфраклы далалар зонасы. Чүллар зонасы.*

ЗОНАЛАП *рәв.* Зоналар буенча, зоналарга бүлеп. *Зоналап тикшерү.*

ЗО'НАЛЫК *и.* Зоналарга бүленеш. *Туфрактагы зоналык.*

ЗОНАЛЬ *с.* Нинди дә булса зонага караган, аерым зона өчен характерлы. *Зональ киңәшмә. Зональ күренеш.*

ЗОНД *и.* 1. *мед.* Авыруга диагноз кую яки дәвалау максаты белән берәр органга (мәсәлән, ашказанына) кертелә торган көпшә сыман яки башка төрле медицина коралы.— *Менә йөрәкнең зонд ярдәме белән алынган рентген [рәсеме].* Г. Әпсәләмов.

2. *геол.* Җир асты катлауларын тикшерә торган борау яки көпшә сыман корал.

3. *махс.* Метеорологик күзәтүләр алып бару өчен автомат язу приборы урнаштырылган һава шары.

ЗОНТ *и. к.* зонтик. *Яңгыр инде бер-ике көннән бирле шулай тоташ ява иде. Шунда да зонт алырга онытканмын.* Ш. Камал.

ЗО'НТИК *и.* 1. Махсус металл чыбыклар ярдәмендә материя кисәген гөмбә формасында корып, кирәкмәгәндә таяк тирәсенә җыйдырып була торган, кояш нуры яки яңгырдан ышыклану җайланмасы. *Баш өстендә алтын зонтик күләгәли.* Г. Тукай. *Әй, сез!.. Ак сөяктән туган вак сөякләр! Агач күләгәсен зонтик итеп Кояш нурларыннан качмагыз!..* М. Крыймов.

2. *бот.* Чәчәкләре бер яссылыкта урнашып зонтик формасын алган оешма чәчәк. *Һәвруз һәм чия чәчәкләре гади зонтик дип йөртелә торган чәчәк төркеме булып утыралар.* Ботаника.

ЗООВЕТЕРИНАР *и.* Зооветеринария белгече.

ЗООВЕТЕРИНА'РИЯ *и.* Хайваннарның яшәү шартларын һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнү. [*Ферма да*] *зооветеринария эшләре көннән-көн яхшыра.* М. Хәсәнов.

ЗОО'ЛОГ *и.* Зоология белгече. *Зоологлар конференциясе.*

ЗООЛО'ГИК *с.* Зоологиягә мөнәсәбәтле. *Зоологик карта.* // *күч.* Хайваннарга мөнәсәбәтле. *Унбер илнең галимнәре, бергәләп, бу кыйммәтле зоологик төрне (Пржевальский атларын) ничек саклау һәм үрчетү турында уйландылар.* Соц. Тат.

ЗООЛО'ГИЯ *и.* Хайваннар дөньясын, аларның төзелешен һәм тереклеген өйрәнә торган фән.— *Әллә берегез дә зоология укымадымы?* Ж. Тәрҗеманов. // *с. мәгъ.* Төрле кыргый һәм йорт хайваннары асрый торган. *Зоология паркы. Берлинның зоология бакчасын карарга туры килде.* Г. Гали.

ЗООПАРК *и.* Зоология паркы. [*Тигр*] *үзе шундый матур, ә үзе коточкыч усал. Бөтенләй зоопарктагыга охшамаган.* Ш. Хөсәенов.

ЗООТЕ'ХНИК *и.* Терлекчелек (терлекләрне тәрбияләү) белгече. *Комбайнны мехчы кызлар йөртми, Зоотехник коймый корычны.* З. Мансур.

ЗООТЕ'ХНИКА *и.* Терлекләрне дөрес асрау, үрчетү һәм файдалану турындагы фән. *Зоотехника яңалыклары.*

ЗУБИ'ЛО *и. махс.* Металл кисү, таш чокып эшкәртү һ. б. максатлар өчен кулланыла торган өтерге сыман инструмент. *Композитор булсам, заводларның Жырланмаган бөек җырына Зубил белән нота язар идем Станокның корыч сырына.* М. Крыймов. *Төрле игәүләр, зубило - - - минут саен кирәк була.* Соц. Тат.

ЗУБР *и.* 1. Кыргый үгез (хәзер бик аз санда калган). *XX гасыр башларында Россиядә сакланып калган зубрларның саны 2000 нән артмаган.* Биология.

2. *күч. кит.* Үзенең иске карашларына ябышып ята торган, үтә реакционер кеше турында.— *Әй, байлар, карагыз инде бу шәкертләрне, әй, мөхтәрәм татар зубрлары, рәхим итеп, авызларын җимерегез инде шул әдәпсезләрнең.* Ф. Әмирхан.

ЗУБРО'ВКА *и.* 1. *бот.* Кыяклылар семьялыгыннан булган хуш исле үлән үсемлек.

2. Шул үсемлекне салып төнәтелгән аракы.

ЗУР *с.* 1. Күләме, микъдары буенча гадәтидән олы, артык; *киресе:* кечкенә. *Берсе зур калын гәүдәле, икенчесе аның янында бала кебек кенә.* Ә. Айдар. *Алда сигез-тугыз чакрымда зур тимер юл күпере ватылган.* Ш. Усманов. // Сан ягыннан гадәтидән артык, күп. *Зур акчалар бирми ни чара бар?* Г. Тукай. // Ишле, күп кешесе булган. *Зур коллектив.* □ *Атасының семьясы зур иде.* И. Гази.

2. Көче, барышы яки тәэсире буенча гадәтидән артык, көчле.— *Көтмәгәндә бик зур яңгыр, ташкын булса, куркыныч бөтенләй юк түгел.* Қ. Тинчурин. *Ул зур дәрт һәм ышаныч белән Казанга килде.* Ф. Әмирхан. // Киң колачлы, масштаблы. *Нишлисең, зур көрәшләр корбансыз булмаган кебек, зур сугышлар да үлемсез булмыйлар.* Т. Гыйззәт. *Бу устав буенча әллә нинди зур эшләр кылырга мөмкин.* Г. Камал. // Тирән, ныклы нигезле. *Белеме зур булмаса, үзенә каршы чыккан генералларны алай барысын да бер кунычка тыга алмас иде.* Г. Бәширов. *Мин бу хатта Зур фикерләр алга куймадым.* Һ. Такташ.

3. Әһәмияте, нәтиҗәлелеге, файдалылыгы ягыннан аерылып торган. *Дисциплина рамкасыннан чыкмаган биш-алты йөз кешелек отряд - - - вокзалны бушатуда зур роль уйнады.* Ш. Усманов.

4. Мөһим, җитди.— *Ә мин сиңа зур гына киңәш белән килдем.* Ш. Камал. *Зур сынауны кирәк узарга.* Г. Хуҗиев.

5. Дәрәҗәсе, чины белән югары; дәрәҗәле, зур урындагы (кеше).— *Гаяз,— дим мин,— син, һичшиксез, бик зур кеше булырсың, зур җитәкче булырсың син.* М. Әмир.

6. Яшь ягыннан олы, өлкән.— *Минем зур улым быел Казанда вуз тәмамлады.* Г. Минский. *Барырсыз сез зур абзыйларыгыз салган матур эздән.* М. Гафури. // *и. мәгъ. күпл.* **зурлар.** Олы кешеләр, өлкәннәр. *Авыл картларына, зурлар кебек, сәлам биреп кенә китәм мин.* Һ. Такташ.— *Ул аны зурлар авызыннан ишетеп сөйли торгандыр әле.* Г. Камал.

Зур юл — машиналар күп йөри, гадәттә промышленность үзәкләрен яки зур шәһәрләрне тоташтыра торган магистраль юл. *Авыл зур юл өстендә.* Ш. Камал. *Донбасс эченә алып керә торган зур юл нәкъ шушы Николаево аркылы үтә.* И. Гази. **Зур як** — өйнең, квартираның кунак бүлмәсе, залы. *Зур якта байтак кешеләр: Зөләйха абыстай, Сабир, Фатыйма бикә, Бәдри карчык, белмәм, тагы әллә нинди затлар бар иде.* Г. Ибраһимов. **Зурлар мәктәбе** — егерменче, утызынчы елларда зурлар арасында грамотасызлыкны бетерү мәктәбе; кичке мәктәп.— *Мин киткәч тә, зурлар мәктәбенә - - - йөреп, белемегезне арттырырга тырышыгыз.* Һ. Такташ.

◇ **Зурга китү** — (эш, мәсьәлә, шау-шу һ. б.) катлаулылану, җитди төс алу.— *Эш зурга китеп юридик төс алмасын өчен, директорга шушы аңлатманы бирсәң, барысы да ачыклана, минемчә.* Р. Ишморат. *Менә бер заман тавыш зурга китте.* Қ. Нәҗми. **Зурга җибәрү** — (эш, мәсьәлә һ. б.) катлаулыландыру, җитди төс кертү.— *Абый, зинһар, әни белән карулашып, тавышны зурга җибәрә күрмәгез инде.* Ф. Әмирхан. **Зурдан кубу (күтәрелү)** — нинди дә булса эш, вакыйгага артык зур әһәмият бирү, арттырып җибәрү; зур байлык яки шау-шу белән үткәрү.— *Мин, ул кадәр зурдан кубып, күп акчалар чыгарырга риза түгел.* Г. Камал.— *Нәрсә син, Солтан, берьюлы зурдан күтәреләсең?* Г. Ибраһимов.

ЗУРАЙТКЫЧ *с. махс.* Зурайта торган, зур итеп күрсәтә торган. *Зурайткыч пыяла.* // *и. мәгъ.* Фоторәсемнәрне зурайтып төшерү приборы.

ЗУРАЙТУ *ф.* 1. Зур итү, күләмен, микъдарын арттыру, үстерү.— *Язга чыгу белән, заводымны ике өлеш*

зурайтып салдырып җибәрәм,— дип әйтә, ди. Ә. Фәйзи.— *Зурайтыгыз ферма коесын!* Ш. Мөдәррис.

2. Колачын, әһәмиятен, дәрәҗәсен һ. б. арттыру, көчәйтү, киңәйтү. *Әхмәтсафа бай да, нәфсенә булышып, эшне зурайтам дип. Мәскәү малына бик тирән чумды.* Ш. Мөхәммәдев. // *к.* зурга җибәрү.— *Эшне зурайтмагыз. Барыбер барачаксыз.* Г. Коләхметов.

ЗУРАТ *и.* Басуда ашлык көлтәләреннән ясалган озынча зур өем. *Кырга чыкса, юк урак, куя белмидер зурат.* Бәет. *Урдык урак, күйдык зурат, Колхоз кырын матурлап.* Ә. Ерикәй.

ЗУРАЮ *ф.* **1.** Зур булу, зур хәлгә килү, үсү. *Картлары яшәрде, бала-чагалары кинәт үсеп, зураеп киттеләр.* Р. Ишморат. [*Агыйдел*], *барган юлында очраган кечкенә-кечкенә елгаларны үзенә ияртеп, зурая бара.* М. Әмир.

2. Катлаулылану, җитди төс алу, зурга китү (эш, хәл, мәсьәлә һ. б.). *Эш бу рюмкалар вату белән генә калса, бәлки ул кадәр зураймаган булыр иде.* Ш. Мөхәммәдев.

3. *к.* зурлану. *Нинди эш кушсаң, шул эшне Шул минутта эшләүчеләр Ник сиңа буйсынмыйлар соң? Ник зурайганнар алар?..* М. Гафури. // *рәв. мәгъ.* **зураеп.** Эреләнеп, масаеп, үзен эре, тәкәббер тотып. *Бүре, беркөнге зураеп сөйләшкәненә йөзе кара булып, --- тагын хода хозурына китте, ди.* Әкият.

ЗУРЛАНУ *ф.* Эреләнү, масаю; баш имәү, үзен зур, югары тоту. *Теге Чебен, эреланеп моңа карап, Зурланып, тамак кырып бирде җавап.* М. Гафури. *Үз хатыны әллә баш булганга, Бераз зурланып, Сүз әйтмәс дип барыбер, Әллә инде аннан хурланып, Ул эшкә дә хәзер бармак аша Карый башлады.* М. Җәлил.

ЗУРЛА'РЧА *рәв.* Зурлар, олылар, өлкән кешеләр кебек.— *Мин аны зурларча рәхмәт әйтеп алдым.* М. Гали. *Ул зурларча, иң гүзәл кешеләрчә хөкем итә.* А. Шамов.

ЗУРЛАУ *ф.* Олылау, хөрмәт күрсәтү, ихтирам итү. *Ихлас куеп дәресләрдә калмак кирәк, Күңелебезне гыйлем белән нурлау кирәк, Укыган адәмнәрне зурлау кирәк.* Г. Камал.— *Безне зурлап килгән кунаклар алдында булмастай нәрсә сөйләсәм, ояты үземә булыр, миннән көләрсез.* Г. Бәширов.

ЗУРЛЫК *и.* **1.** Зур булу, башкалардан күләме артык булу. *Бу өй авылдагы башка өйләрдән үзенең зурлыгы белән аерылып тора иде.* Ә. Айдар. *Газинурны шәһәрнең зурлыгы гаҗәпләндерде.* Г. Әпсәләмов. *Буйга зурлыгы өчен аны Озын Хафиз дип йөртәләр.* Г. Ибраһимов.

2. Күләм; әйбернең инә, буе, биеклеге яки диаметры белән үлчәнгән күләме. *Һәркемгә мәгълүм: ерактан [әйбер] үз зурлыгына карагында кечкенә күренә.* Ф. Әмирхан. *Этаж саннары белән 7-8 гә үрләп, киңлек, зурлык исәбе белән бөтен кварталлар өстен каплаган бу магазиннар чынлап та башны әйләндерәләр.* Г. Гали.

3. *мат., физ.* Үлчәнә һәм исәпләнә ала торган нәрсә. *Билгесез зурлык. Даими зурлык. Чикле зурлык.* □ *Берәр зурлыкны үлчәү — аны берәмлек итеп кабул ителгән шул ук төрдәге зурлык белән чагыштырып карау дигән сүз.* Физика.

4. Бөеклек, өстенлек, башкалардан сыйфат, дәрәҗә һ. б. яктан артыграк булу. *Ничек җырда илгә күрсәтергә Чорыбызның бөтен зурлыгын.* М. Җәлил. *Ватан булсын бәхет, муллык йорты, Тиңсез куәт, көч һәм зурлык йорты.* Ә. Исхак.

5. Дәрәҗә, югары чин. *Ничегрәк булырсың икән, Ирешсәм зурлыкларга.* Ш. Галиев. // Авторитет, абруй. *Ялкаулык — хурлык, тырышлык — зурлык.* Мәкаль. *Шибай карт заманында зурлык, байлык белән гомер итте.* Г. Ибраһимов.

6. *бәйл. функ., тарт. форм.* **зурлыгы, зурлыгында.** Бер әйберне икенчесе белән чагыштырганда: чаклы, кадәр, күләмендә. *Кыр зурлыгы номерда япа-ялгыз утырырга күңелсез.* Г. Тукай. *Беренче көнне Гафият, борынгылар гадәте буенча, йомыркалар пешереп барды. Янәсе, йомырка зурлыгы булып уңсын аның бодае.* И. Гази.

ЗУРЛЫ-КЕЧКЕНӘЛЕ *с.* Төрле зурлыкта, зурысы да, кечкенәсе дә булган. *Читтә зурлы-кечкенәле мичкәләр белән арбалар тезелгәннәр.* Г. Ибраһимов. *Идәндә зурлы-кечкенәле биш-алты кисәк төен вә чемоданнар ята.* Ш. Камал.

ЗУРЛЫКЛАНУ *ф. сир. к.* зурлану. *Куе ботаклы, зурлыкланып, башларын югары күтәреп тора торган агачлар --- җиңел вә рәхәт салкынлык, ял итү урыны ясыйлар иде.* Ф. Әмирхан.

ЗЫЙТ, ЗЫЙД *и. мәгъ. иск. кит.* Кире, каршы. *Үзең галим түгел, үзең белəм дисең, галим булмагач, галимнең зыйдде — җаһилдер.* Г. Тукай. *Гыйлем вә мәслəк җəһəтеннəн бер-берсенə тəмам зыйт булган аерым икə табигатьтəгə кешеларнең арасында [бəйлəнеш тууга] --- һичбер төрле гакылым ирешмидер.* М. Гали. // *с. мәгъ. диал.* Кире, тискәре, үҗәт (кеше турында).

ЗЫҚ: зык кубу — шаулашу, шау-гөр килү. *Өйдə мондый зык кубудан бик аптырап калган икə җан иясе булса, аның берсе, әлбəттə, Зəйтүнə иде.* Сов. эд. **Зык куптару** — шау-шу күтәрү.— *Бу ни дигəн сүз? — дип, зык куптарып, кызышып, теге егетнең өстенə һөҗүм итə башладылар.* М. Гафури.

ЗЫҚЫ *и.* **1.** Кыш көнендә була торган дымлы салкын һава, томан (мондый көннәрдә агач ботаклары, бау яки тимерчыбыклар, калай түбәләр һ. б. предметларның өсте кристалл хәлендәге кар сыман бәс белән каплана). *Иртәләрен [тоткыннарның] казарма эче ап-ак зыкы белән каплана. Солдат шинеле төсле соры күктән көннәр буе чәнечкеле, ярма сыман кар ява.* Каз. утл. // *с. мәгъ.* Томанлы, кырыс һава турында. *Чатнап тора кышкы зыкы салкын, күз ачкысыз була бураны.* Г. Хуҗиев.

2. *күч. сөйл.* Зур көч түгеп эшләгәндә тәннән күтәрелә торган бу, пар; кара тир. *Эшләтеп зыкысын чыгару.* □ — *Су ташый-ташый зыкыларым чыкты.* Атака.

ЗЫҚЫЛЫ *с.* Томанлы салкын (һава), дымлы салкын (һава), сыкы барлыкка китерә торган. *Салкын иде, зыкылы салкын... Кешеларнең бүрекләре, иңбашлары кар гына.* Г. Гобәй.

ЗЫҚЫМ *и. диал.* Тәэсир, шаукым, начар йогынты. *Шаяруларның зыкымы кайчак минем кебек [мәдрәсәгә] яңа кергәннәргә генә түгел, хәзрәтләргә дә барып тия иде.* Г. Гобәй.

ЗЫНҖЫР *и. иск. кит.* **1.** Нәрсәне дә булса тоту, беркетү һ. б. максатлар өчен кулланыла торган чылбыр. *Белем-тауга --- һәркем тезен чүгеп керсен өчен, ишегенә зынҗыр салынган.* Н. Исәнбәт.— *Сезнең эш — кое чыгырына зынҗыр бәйләп, чиләк тагасыз.* Э. Касыймов.

2. Коллар яки кулга алынган кешеләр — арестантларның, эшләгәндә качмасын өчен, кул яки аякларына салынган богау. [*Закир:*] *Мескен кулларым! --- Аякларым! Авыр зынҗырлар салып җирләр казыткан вакытларда ничек сез чыдарсыз?* Г. Камал. // *күч. к.* богау. *Улган илләр яңадан терелер, Коллык зынҗырлары өзелер.* М. Гафури.

ЗЫНҖЫРЛАУ *ф. иск.* Богау, зынҗыр салу, иректән мәхрүм итү. *Бəһадир Җəгъфəрнең артыннан аяк вə куллары зынҗырланган вə һəр ягы гаскəрләр берлə чолганган əсирләр килə иде.* Г. Тукай. / *күч.— Хезмəт үзенең табигатенə туры килмəгəн, аны буып, богаулап, зынҗырлап торган бу --- хəлгə озак түзеп тормас.* Г. Әпсәләмов.

ЗЫНҖЫРЛЫ *с. иск.* Богаулы, богауланган, зынҗыр салынган.

ЗЫР, ЗЫР-ЗЫР *аваз ияр.* Әйбер бөтерелгәндә яки тиз-тиз хәрәкәт иткәндә, очканда һавага ышкылудан барлыкка килгән тавышны белдерә. *Карчыкның кулында зыр-р әйләнә орчык батыр-р...* Н. Исәнбәт. *Өстәл өстендәге кечкенә лампа тирәсендә зыр-зыр килеп төн күбәләкләре бөтерелә.* Г. Бәширов. [*Трактор*], *мин сиңа әйтим, зыр-р-р, зыр-р-р китереп, бөтен дөньясын актара.* Ш. Камал.

Зыр-зыр әйләнү, зыр-зыр килү — бик кызу, шәп әйләнү, бөтерелү. *Ташны йөртә торган вал нинди зыр-зыр әйләнә.* И. Гази. *Әй төшә иблис, төшә зыр-зыр килеп, койрыгы ялт-йолт килә яшен кебек.* Ш. Бабич.

ЗЫРЛАУ *ф.* Зырылдау, зыр-зыр иткән тавыш чыгару. *Станоклар шаулап, зырлап, гөрләп, Бу егетнең сүзен кистеләр.* С. Урайский. *Зырлый кыргыч — цех яңрата, Кызлар фетр шомарта.* Ш. Маннур. // *рәв. мәгъ.* **зырлап.** Зыр-зыр иткән **тавыш** чыгарып, бик кызу (әйләнү). *Бертуктамый зырлап әйләнеп торган пропеллер кинәт тынды.* А. Алиш. *Монда зык куптарып, Машиналар зырлап әйләнә.* М. Гафури.

ЗЫРЫЛДАВЫК 1. *с.* Зырылдап әйләнеп торган яки зырылдау тавышы чыгарып торган. *Зырылдавык уенчык.*

2. *и.* Җилдә җитез әйләнерлек итеп, таяк белән каралты башына урнаштырылган әвернә сыман яссы калаклардан гыйбарәт әйбер; ул җил юнәлешен һәм, зырылдап, җил көчен күрсәтә. *Җил чыктымы — зырылдавык әйләнергә, зырылдарга тотына.* М. Галәү.

ЗЫРЫЛДАТУ *ф.* 1. Зыр-зыр иткән тавыш чыгару, зыр-зыр китерү.— *Зырылдатма әле шуны* [*уенчыкны*]. // Яңгырату, шаулату. *Алар артыннан ташларны зырылдатып авыр туплар иярде.* Қ. Нәҗми.

2. *рәв. мәгъ. күч.* **зырылдатып.** Шәп, җитез генә. *Тауның яртысына да менеп җитмәдем, Фәрит, «һәйт!» дип зырылдатып, янымнан үзып та китте.* Д. Аппакова. // Җилтерәтеп, кызу гына (кешене тиз генә алып китү яки хәрәкәткә китерү турында). *Зырылдатып китереп җиткерү.* □ *Озын буйлы, юан, мәһабәт карчыкның ике иңбашыннан электереп алып, әйләнәсендә алты мәртәбә сикердем һәм аны зырылдатып әйләндердем.* Ф. Әмирхан.

ЗЫРЫЛДАУ *ф.* Зыр-зыр иткән тавыш чыгару, калтыраулы тавыш чыгарып тору. *Кинәт тәрәзә пыялалары зырылдый башладылар.* Ф. Хөсни. / *и. мәгъ. Кайдадыр такта яралар ахрысы, түгәрәк пычкы зырылдавы ишетелә.* Г. Әпсәләмов.

ЗЫЯ *и. иск. кит.* Яктылык, нур. *Зәгыйфь лампам зыясында Язам хәсрәтләрем һәр кич.* С. Сүнчәләй. // *күч.* Белем, мәгърифәт. [*Муллалар*] *халыкны мөмкин кадәр зыядан тыеп торырга да шул васита белән үзләре надан халыкны кимереп ятарга тырышалар.* Ф. Әмирхан.

ЗЫЯЛАНУ *ф. иск. кит.* Белемле булу, культуралашу, агару. *Безнең дә әдәбият галәмебездә дә зыялану вә нурлануны шул таулар кадәр матбуг рисаләләр өлүдән гыйбарәт дип белү - - - бардыр.* Г. Тукай.

ЗЫЯЛЫ *и. иск. кит.* Интеллигент. *Әдәбият ахшамы үзебезнең мотивларыбызны үзебезнең яшь зыялыларыбыз авызыннан ишеттерәчәктер.* Г. Тукай.— *Мин дә сезнең кебек үз кул көчем белән яши торган бер зыялы.* Г. Ибраһимов.

ЗЫЯЛЫЙ *с. иск. кит.* Зыялы, укымышлы. *«Һәр кешенең хакы тигез булсын!» диеп Кычкырдылар зыялый һәм ач кешеләр.* М. Гафури.

ЗЫЯЛЫЛАШУ *ф.* Интеллигентлашу; укымышлы булу. *Рус җәмагасы арасына катышып үсеп, рәтләп укымыйча гына зыялылашкан бу туташ, бай ата-ананың кызы булганлыктан, зур приданлы кызлардан санала иде.* Ф. Әмирхан.

ЗЫЯН *и.* 1. Материаль югалту, каза; чыгым. *Фәкыйрьләргә зәкят бирмиләр, бу да* [*зәкят бирү дә байларга*] *бик зур зыяндыр.* Ш. Мөхәммәдев. // Сату яки җитештерүдә чыгымның керемгә караганда артыклыгы; *киресе:* файда. *Кайберәүләре, без андый өяз фельетончысының язмаларын бастырып зыян күрер хәлебез юк, дип тә җибәрәләр.* Г. Нигъмәти. *Әгәр дә хезмәт хакы үсеше хезмәт җитештерүчәнлеге үсешеннән алда барса, ул предприятие зыянга эшли булып чыга.* М. Хәсәнов.

2. *к.* зарар 1.— *Шофер булуның зыяны юк аның, кайчан булса да бер кирәк була ул.* Т. Гыйззәт.— *Сиңа бер-бер зыяннары тимәдеме, Мавия?* М. Фәйзи.

Зыян итү — *к.* зарар итү. [*Бу тәкә*] *монда килеп зыян итте, көзге ватты.* М. Гафури.

◇ **Зыян итмәс** — *к.* зарар итмәс. *Зыян итмәс фашист этне үз теле белән кыйнау.* М. Җәлил.

ЗЫЯНДАШ *и. сөйл.* Вакыт-вакыт аң югалту һәм көзән җыеру рәвешендә өянәкләре була торган нерв авыруы; үзбума чир, үзауру. *Бизгәктән котылган, зыяндашка тотылган.* Мәкаль. / *с. мәгъ. Гомерендә бер, фаразан, зыяндаш авыруы күрмәде.* Ф. Әмирхан.

Зыяндаш тоту — зыяндаш авыруының өянәге башлану. [*Мәгъри:*] *Зыяндаш тотамы? Бизгәге бармы? Нишли?* Н. Исәнбәт.

ЗЫЯНДАШЛЫ *с. сөйл.* Зыяндаш авыруы булган, үзчирле. *Карчык һаман саен: — Кузгатмагыз, узар... Зыяндашлы бала ул... һәр ел шулай була торган иде,— ди.* Г. Кутуй. *Урамга - - - хәтта бик сирәк күренә торган зыяндашлы Коттыбай да чыккан.* Ф. Хөсни.

ЗЫЯН-ЗӘВЕР, ЗЫЯН-ЗӘҮРӘТ *җый. и. иск.* Зыян һәм зарар. *Ниһаять, вышка зыян-зәверсез яңа урынга күчте.* Каз. утл. *«Вредитель син...» ди иде ул үзенең гамьсезлеге белән колхозга берәр зыян-зәүрәт китергән колхозчыга.* Г. Гобәй.

ЗЫЯНЛАУ *ф. диал.* (Мал) үлү. *Сыерыбыз зыянлады.* □ *Терлекләр арасында зыянлаулар күп булды.* Ә. Еники.

ЗЫЯНЛЫ *с.* 1. *к.* **зарарлы.**— *Бу яраларың бик зыянлы түгелме, балам?* Г. Ибраһимов. // Қазалы, зыян, каза белән бәйләнгән.— *Бик зур зыянлы булдык бит әле без, Айсылу җаным.* Г. Бәширов.

2. Начар, яман (кеше). *Юк, зыянлы кеше түгел ул, эштә — таян, юлда — аерылма!* С. Хәким.

ЗЫЯНСЫЗ *с.* 1. Зыян-зарар китерми торган. *Ә хәзер һәр колхоз өстендә дөньядагы бу иң гүзәл, иң затлы, иң зыянсыз кошлар* [*күгәрченнәр*] *төркем-төркем очалар.* Г. Әпсәләмов.

2. *рәв. мәгъ. к.* зарарсыз.— *Исәнлек дип, ул яктан зарарсыз. - - - Кул да зыянсыз, ярыйсы...* Г. Бәширов.— *Игеннәр ничегрәк соң? — Зыянсыз. - - - Баштарак, яңгырларның рәте булмагач, бераз борчыла төшкән идек. Хәзер алай түгел.* Ш. Камал.

ЗЫЯНЧЫ *с. сир.* Зыян, зарар китерүчән. *Зыянчы песи күзен елтыратыр.* Мәкаль.

ЗЫҢ *аваз ияр.* Җиңелчә вибрация (калтырау) бирердәй нәрсәләргә орынганда барлыкка килгән калтыраулы йомшак тавышны белдерә. *Дугалап эшләнгән тимер ырнау эчендәге җиз тел* [*кубызда*], *уенчының бармак тибрәтүе белән, әллә нинди сер сөйләгән сыман, акрын гына зыңлый башлады: зың! зың! зың! зың!* Ә. Фәйзи. // *и. мәгъ.* Зыңлау тавышы. [*Хафиз*] *Алтайкның белә һәр зыңлавын, Шул зыңына куша җырларын.* Н. Исәнбәт.

ЗЫҢГЫЛДАТУ *ф.* Зыңгылдаган тавыш чыгару. *Зыңгылдатып кую.* □ *Мәһабәт һәм матур гәүдәлесе шпорларын зыңгылдатып килде дә:— Командир! — дип кычкырып җибәрде.* Г. Бәширов.

ЗЫҢГЫЛДАУ *ф.* Калтыраулы калын зың яки зыңк иткән тавыш чыгару, зыңлау. *Балта түтәсе белән сугып карады, гәрәбә төсле сап-сары нарат скрипка кылыдай зыңгылдап куйды.* И. Гази.

ЗЫҢГЫРАУ *ф. к.* зыңгылдау. *Аһ, кинәт бер туп атылды! Китте таулар зыңгырап!* Н. Исәнбәт.

ЗЫҢГЫРДАТУ *ф. к.* зыңгылдату. *Тәрәзә пыялаларын зыңгырдатып, бөтен көченә ишек ябылды.* Г. Ахунов.

ЗЫҢГЫРДАУ *ф. к.* зыңгылдау.

ЗЫҢК *аваз изр.* Бер генә тапкыр нык һәм кинәт бәрелүдән чыккан калтыраулы калын «зың» тавышын белдерә.— *Әйе, кайтып төшәсе иде дә әни каршысына зыңк иттереп килеп басасы иде.* Г. Бәширов.

ЗЫҢКУ *ф.* Зыңк итеп килеп төшү, егылу.— *Аталыуллы икесе дә зыңкыдылар.* Х. Җәмил.

ЗЫҢКЫТУ *ф.* 1. *к.* зыңлату.

2. *күч.* Күтәреп җиргә бәрү.

ЗЫҢЛАТУ *ф.* Зың-зың иттерү; чыңлату. *Бу тавыш колакларны зыңлата.*

ЗЫҢЛАУ *ф.* Зың-зың иткән тавыш чыгару. *Рация --- кирәкле дулкынны эләктереп алды булса кирәк, тыныч кына зыңларга кереште.* Ә. Айдар. / *рәв. мәгъ. Аннары вокзал колоколының икене бәргән тавышы зыңлап яңгырады.* Г. Минский.

ЗЫҢЛЫ *с.* Зың-зың иткән, зыңлап торган. [*Тургай*] *канаткайларын җилпи-җилпи өскәрәк күтәрелә дә --- көмеш зыңлы җырын сибә.* Р. Төхфәтуллин.

ЗӘБҮР *и. иск. дини.* Христиан динендә: догалар җыентыгы.

ЗӘВАЛ *и. иск. кит.* 1. Бетү, югалу. *Күрмәсәң дә син һичбер зәвал да, югалгандыр шунда күп атсыз.* М. Җәлил. // *күч.* Үлем. *Илчегә зәвал юк.* Мәкаль.

2. Чик, кульминацион нокта, үсү яки кимүнең максимум чиге. *Һәр кәмальнең бер зәвалы бар.* Мәкаль.

ЗӘВЫК *и.* 1. Матурлыкны, гүзәллекне тоя белү, әйбер яки күренешләргә эстетик бәя бирә белү сәләте. *Йомшак урындыклар, кәзгеләр, язу, туалет өстәлләре, алтын тышлы китаплар белән тулы кызыл агач шкафлар нечкә бер зәвык белән тезелгәннәр.* Г. Ибраһимов. *Гомумән, монда яхшы тәрбия алган, сәнгать әсәрләреннән тәм табучы һәвәскәр зәвыгы сизелә иде.* Г. Бәширов. // Исем янында «зәүкында» формасында: манера, алым, мода. *Башкалар бар да авыл зәүкында киенгәннәр.* М. Фәйзи. *Ярым татар, ярым Европа зәүкында тегелгән күлмәктән һаҗәр керә.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. Ләззәт, рухи рәхәтлек, кәеф, хозур. *Мин шуны әйтергә телим: минем белүемчә, моңа кадәр берәүнең дә үз файдасы, үз зәвыгы өчен генә музыкант яисә артист булганы юк әле.* Г. Бәширов. *Мин яшендәй гайрәтемне Корбан итмим зәүкыма.* Ә. Ерикәй. // *сөйл.* Кызык. [*Ибрай сабан сөрүгә*] *файдалы эш итеп түгел, бер зәвык итеп кенә карый.* Г. Гобәй.

3. Кызыксыну, мавыгу. *Габдулла китапны кулына алды һәм, һәрвакыттагыча, кулына төшкән яңа китапка ничек ташланса, моны да аеруча зәвык белән йотылып карый һәм укый башлады.* Ә. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* Оста, һәвәс (сүзгә). *Егет сүзгә бик зәвык, чая булып чыкты.* А. Шамов.

ЗӘВЫКЛАНУ *ф.* Зәвык, ләззәт, тәм табу, кызык табу, рухи рәхәтлек кичерү. *Бу кыз берлә көлеп-уйнап, тәмам атна кадәр торгач, Күңел ачкач, зәвыкланган вә күп рәхәт, сафа сөргәч, Мәмәт хан кайта инде яшь бикә берлә Һиратына.* Г. Тукай. *Бу уй белән никадәр зәвыкланганымны бүтән йөрәкләр аңламас.* М. Фәйзи.

ЗӘВЫКЛЫ *с.* 1. Зәвык (1 *мәгъ.*) белән эшләнгән, матур. [*Фәттах әфәнденең*] *көйләр вә җырлар сайлавы да Камил әфәнденекенә караганда күп зәвыклырак.* Ф. Әмирхан. / *рәв. мәгъ. Бүлмәләр генә түгел, хәтта кухня да күзләреңне иркәләп, җанга рәхәт бирә торган итеп зәвыклы җыештырылган.* М. Максуд.

2. *рәв. мәгъ.* Зәвык *(2 мәгъ.)* белән, рәхәтләнеп, тәм табып. *Җәмил, мәзәкчел малайларга хас булганча, аеруча зәвыклы итеп көлде.* Г. Гобәй.

ЗӘВЫКЛЫЛЫК *и.* Зәвыклы булу, зәвык белән эшләнгәнлек, матурлык.

ЗӘВЫК-САФА *и.* Хозур, ләззәт, рәхәтлек. *Намуслы фамилияләр үз йортларында --- әдәп берлә зәвык-сафа кылалар.* Ш. Мөхәммәдев.

ЗӘГЪФРАН *и.* 1. Шәмәхә чәчәк ата торган, чәчәк авызчыклары хуш исле сары буяу матдәсенә бай булган суганчалы көньяк үсемлеге.

2. Шул үсемлектән ясалган буяу. *Мөхетдин суфыйдан өшкертеп, зәгъфран суы белән тәлинкә яздырып алып кайттылар һәм аны чайкап эчерделәр.* Ә. Фәйзи. *Кыз ятканда кулына зәгъфран буяп ятсын ---, диделәр.* Қ. Насыйри.

3. Қызгылт сары төс — зәгъфраннан ясалган буяу төсе. *Сарғайдым, зәгъфраннан сары мин.* Г. Тукай. / *с. мәгъ. Өй түрендәге биек карт усак, сирәкләнеп калган зәгъфран яфраклары белән лепелдәп, нәрсәдер сөйли иде.* Р. Төхфәтуллин.

ЗӘГЫЙФЬ *с.* 1. Сау-сәламәт булмаган, физик яктан кимчелекле, гарип.— *Мин зәгыйфь, имгәк кешеме әллә!* Ш. Қамал.— *Хәзер инде мин бервакытта да трактор йөртә алмамын. Чөнки мин аяксыз... Бер кулым зәгыйфь...* Р. Ишморат.

2. Көчсез, хәлсез, нинди дә булса эшне башкаруга яки үзен яклауга сәләтсез. *Зәгыйфь кырмыскамын мин, юлда яткан; Түгел бал корты мин, чагып елаткан.* Дәрдмәнд.— *Эт булса да кызгана белә, --- бер өер ерткыч тарафыннан җәберләнүче зәгыйфь кызчыкны ничек яклый!* Г. Гобәй.

3. Начар үскән, үсеп, өлгереп җитмәгән. *Береннән бере кечкенә бу ятимнәр, әле канат та ярмаган зәгыйфь кош баласыдай, үзләреннән аз гына калкурак булган апаларына күзләрен тутырып карыйлар, аңа сыеналар иде.* Г. Бәширов. [*Шахтадан чыгучыларны күргәч*], *зәгыйфь һәм нечкә булып үскән үсемлекләр күз алдыма килде.* М. Гафури.

4. Көчсез, аз гына сизелерлек (ишетелерлек, күренерлек) булган. *Яралының зәгыйфь сулышы Бәрелде бүренең борынына.* М. Җәлил. *Бер-ике секундтан эт зәгыйфь тавыш белән бер тапкыр гына «ырр» дип куйды һәм тынды.* Ә. Фәйзи. / *рәв. мәгъ. Лампа бик зәгыйфь яна.* Г. Ибраһимов. *Қаяндыр әкрен генә, зәгыйфь кенә булып скрипка тавышы ишетелә иде.* А. Шамов. / *хәб. функ.— Безнең арада сыйнфый аерымлык билгесе бик зәгыйфь.* Қ. Нәҗми.

5. *рәв. мәгъ.* Начар, түбән. *Русча укып аңлавы зәгыйфьрәк булса да, ул үзенең тырышлыгы белән русча газет-журналлар һәм китаплар укый.* М. Гали. [*Әсәрдә*] *сурәтләү чаралары зәгыйфь.* Г. Нигъмәти.

ЗӘГЫЙФЬ-ЗОГАФА *җыйд. и.* Һәртөрле гарип-гораба. *Нуретдин --- һәртөрле зәгыйфь-зогафага дарулар белән ярдәм итүне, бигрәк тә үз кулы белән дару сөртүләрне бик ярата иде.* Г. Тукай.

ЗӘГЫЙФЬЛЕК *и.* 1. Зәгыйфь булу. *Баланың зәгыйфьлеге өчен ананың борчылуы яхшы.* Ш. Қамал. *Әллә сукыр лампа яктысының зәгыйфьлеге гаепле булдымы?* И. Гази.

2. Қимчелек.— *Аның гакылына зәгыйфьлек килгән булыр.* М. Фәйзи. / *күч. Хәрәкәт, вакыйгаларның үсеше зәгыйфь булуы, бертөрлелек — менә болар әсәрнең художество әсәре булып сиземләнүенә зәгыйфьлек китерәләр.* Г. Нигъмәти.

ЗӘГЫЙФЬЛӘНДЕРҮ *ф.* 1. Зәгыйфь хәлгә китерү, имгәтү, гарипләү. *Фигурасының бик күп татар хатыннарыныкы шикелле зәгыйфьләндерелгән булмавы --- миндә яхшы хис калдырды.* Ф. Әмирхан.

2. Көчсезләндерү, көчен киметү яки бетерү. *Дошманның көчен зәгыйфьләндерү.*

ЗӘГЫЙФЬЛӘНҮ *ф.* 1. Зәгыйфь хәлгә килү, имгәнү, гарипләнү. *Сул кулы зәгыйфьләнгән бер карт килеп утырды.* М. Гафури.

2. Көчсезләнү, хәлсезләнү. *Күп көннәр буена кыршау эчендә булып зәгыйфьләнгән гаскәрнең һөҗүм итүен*

дошман көтмәгән ахры. Ә. Айдар. *Мин монда торганда чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.* Г. Тукай. // Көче, интенсивлыгы кимү, көчсезләнү. *Җир астындагы пар бер куәтләнсә, бер зәгыйфьләнсә, ул вакытта җир бер күтәрелә вә бер төшә дә, зилзилә хасил була.* Ф. Әмирхан.

ЗӘЙТҮН *и.* 1. Вак кына ак чәчәкле, җимешендә май күп булган мәңге яшел көньяк агачы. *Зәйтүн плантацияләре.* □ *Зәйтүн кырларыннан Җилбер-җилбер искән Җилдә минем уем.* М. Җәлил. [*Сүриянең*] *күгелҗем зәйтүн урманнары өстендә кабарынкы болытлар күренә.* Р. Мостафин.

2. *к.* зәйтүн гөле. *Тәрәзә төпләрендә гөл савытлары, аларда кыналар, зәйтүннәр чәчәк атып утыра.* Ә. Бикчәнтәева.

Зәйтүн гөле — төптән үк чыккан кыяк сыман эре киң яфраклы, сабак башында башак сыман формада урнашкан эре саргылт кызыл, кып-кызыл яки куе сары чәчәкле декоратив үсемлек; *русчасы:* олеандр. *Роза гөлләр арасында Зәйтүн гөлләрем куе.* Җыр. **Зәйтүн мае** — зәйтүн җимешен беренче кат сыгудан алынган югары сортлы май. *Көнгә зәйтүн маенда кыздырылган, чикләвек кадәр генә берәр бадәм җимеше ашап, ел буена тау тишегендә укып яткан Әбүгалисина белән Әбелхарис аның [Габделкаюмның] исенә төште.* М. Гали.

ЗӘКЪКУМ *и. иск.* 1. *дини.* Җәһәннәмдә үсә дип уйланылган агулы агач.

2. *күч.* Көчле агу, зәһәр.— *Эчтегезме сез зәкъкум?.. Нигә сез эндәшмисез?!* Һ. Такташ.

ЗӘКЪКУМЛЕ *с. иск. кит.* 1. Агулы, агу салган.

2. *күч.* Зәһәр, ачы. *Нишлием соң? Зәкъкумле хәсрәтләр белән күңелем яна.* Ш. Бабич.

ЗӘҚЯТ *и.* 1. *иск. дини.* Шәригать кушуы буенча, байлыкның ярлыларга һәм дин файдасына бирелергә тиешле кырыктан бер өлеше.— *Мин үзем дә бик яхшы беләмен зәкят бирү, хаҗга бару сәвап икәнен.* Ш. Мөхәммәдев. [*Юныс бай:*] *Зәкят өлешеннән милләт өчен бер мәчет, бер мәдрәсә һәм мөселманнар өчен бер шифаханә ачтык.* Қ. Нәҗми.

2. *тар.* Ханлыклар чорында: хан тарафыннан буйсындырылган халыкка салына торган салым.

ЗӘҚЯТЧЫ *и. тар.* Зәкят (2 *мәгъ.*) җыючы. [*Күзләре*] *моннан утыз еллар элек Кинәсары ханның зәкятчылары камчысыннан сүнгән.* И. Салахов.

ЗӘМ *и. иск. кит.* Хурлау, яманлау. [*Хәзрәт:*] *Казанда --- русча укырга тотынып, руслашкан кешеләр бар икән дип ишетә идек, хәзер үз күзебез белән күрдек,— дип, мәдех белән зәм арасында бер сүз әйтеп куйды.* Ф. Әмирхан.

Зәм кылу — хурлау, гаепләп, яманлап сөйләү. *Фәкыйрь бәһадир икән, аны --- йөрәксез дип зәм кылырлар.* Қ. Насыйри.

ЗӘМЗӘМ *и.* 1. Мәккәнең кәгъбә янындагы изге дип саналган чишмә исеме. *Эшләре шул: болгасыннар, әйдә, зәмзәм чишмәсен!* Г. Тукай. // *дини.* Шушы чишмәнең хаҗга баручылар эчеп яки алып кайта торган суы. *Кари әфәнде әүвәлге догадан соң ук өйдәгеләрнең һәммәсенә үз кулы белән салып зәмзәм эчерергә тотынды.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Исерткеч эчемлек, хәмер, аракы. *Зәмзәм харап итте аны.* Г. Иделле. *Стаканнарым тирән, зәмзәм тутырып бирәм.* Җыр.

ЗӘМИН *и. иск. кит.* 1. Җир. *Бирмә ут син, [Кояш], миндә ут бар, Бирмә якты, якты мин; Ут кирәк булса, аны Миннән генә алсын зәмин.* М. Гафури. *Шул вакытта мәгърип зәминеннән ике сихерче килеп чыгып, аларның явызлыкларыннан халык гаҗиз булганнар иде.* Қ. Насыйри.

2. *күч.* Җирлек, нигез; мөмкинлек. *Авыл зур, үзенә күрә аңлы: эшләргә зәмин бар.* М. Фәйзи. *Татар пролетар артистларына үзләренең көчләрен, хезмәтләрен үстерергә яхшы зәмин ачыла.* Г. Ибраһимов. *Бу киренкелек астында өметсезлек, --- ятып калганчы атып калыйк дигән зәминсез тәвәккәллек түгел, бәлки тирән ышаныч яңгырый иде.* Г. Әпсәләмов.

ЗӘМҺӘРИР *и. иск. кит.* Қышкы ачы салкыннар. *Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар.* Г. Тукай. / *с. мәгъ. Кай елны Казанда декабрь аенда җәпшек була, ә кай елны зәмһәрир суыклары башлана.* А. Расих.

ЗӘНБИЛ *и. иск. кит.* Қамыш сумка. *Хәлвәфруш, яхшы киемнәр киеп, зәнбилгә хәлвә тутырып, урамнарда, базарларда сатып йөрде.* Қ. Насыйри.

ЗӘНҚИ *с. диал.* Қара чырайлы, явыз, усал (кеше). [*Хаҗия Сафурага:*] *Һе, зәнки карчык!.. Күргәнең-күрмәгәнең шул булсын (акчалар бирә).* Т. Гыйззәт. / *и. мәгъ.— Гайнижәмал, керт, ул зәнкигә карама.* И. Гази.

ЗӘНҚИЛӘНҮ *ф. диал.* Явызлану, **усаллану, ярсу.** *Муллагали аның якасыннан эләктереп алгач та, ул [Мөрем], зәнкиләнеп, тырнашырга кереште.* А. Расих. // *рәв. мәгъ.* Явыз, усал итеп. *Түр як бүлмәдән зәнкиләнеп кычкырган яшь кенә тавыш ишетелде: «Шушыны бер! Әйтә торам, барасым бар дип!..»* Р. Төхфәтуллин.

ЗӘНҖИ *и. иск. кит.* Негр, кара тәнле кеше. *Каршыдан бик зур гәүдәле --- бер зәнҗи килеп чыкты.* Қ. Насыйри.

ЗӘП *и. сөйл.* Туңга сөрү, яз сабан ашлыгын чәчәр өчен җирне көзен сөреп калдыру.— *Вакытлы килдегез. Урнашкач, бергәләп зәпнең сыйфатын тикшерергә чыгарбыз.* Г. Минский.

Зәп(кә) сөрү *сөйл.*— туңга сөрү. *Ул хәзер зәпкә сөрү эше белән җитәкчелек итә.* Р. Ишморат.

ЗӘП-ЗӘҢГӘР *с. Артык. дәр. к.* зәңгәр. *Тирә-ягы тулы чәчәкләр: ап-аклар, сап-сарылар, зәп-зәңгәрләр, кып-кызыллар.* А. Алиш. *Күзләреңә синең күк кебек: Апачык һәм зәп-зәңгәр.* Ә. Ерикәй.

ЗӘРДӘ *и. к.* сәрдә.— *Балтырган белән зәрдәдән пешергән аш шундый тәмле була ул! — ди [Әнисә].* З. Бәширн. *Безнең буа буенда үсә микән ак зәрдә?* Җыр.

ЗӘРРӘ *и.* 1. *иск. кит.* Башка бүленә алмый торган иң вак кисәкчә; атом. *Бер тылсым да юк, Алла бәндәсе, Бел: һәрнәрсәдә Атом зәррәсе.* Н. Исәнбәт.

2. Иң вак кисәкчә, бөртек, тузан. *Синең бу күргән хикмәтләреңдиңгездән бер катрә, кояштан бер зәррә генә кебектер.* Қ. Насыйри. *Өйдә зәррә кадәр --- җим дә юк.* М. Гафури. *Мин инде тигезлек дөньясына чыктым, монда икебезнең арада зәррә кадәр дә аерма юк.* М. Җәлил.

ЗӘХМӘТ *и.* 1. Михнәт, газап. [*Әбүгалисина—егеткә:*] *Безнең теләгебез — сезне бу зәхмәт һәм мәшәкатьтән коткарып, башка төрле җиңел бер һөнәр өйрәтү иде.* Қ. Насыйри. *Һич йокысыз юл зәхмәте хан кызы илә шаһзадәне тәмам хәлдән тайдырып арыткан иде.* Ш. Мөхәммәдев. // Авыр эш, мәшәкать. *Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа.* Г. Тукай.

2. Зарар, начар тәэсир. *Көзге салкын яңгырның зәхмәтен онытып та өлгерә алмаган үләннәрне таптап, изеп, бер атлы арба каберлеккә таба бара.* Г. Иделле. // *с. мәгъ.* Зәһәр, явыз.— *Әгәр дә мин әйткәнлекне белсәләр, минем күземне дә ачырмаслар, бөтен зәхмәт уклярын миңа кадый башлярлар.* Г. Камал.

3. *миф.* Мифологик көчләр тудыра дип каралган чир, авыру. *Саташа башлагач, әллә зыяндаш зәхмәте микән дип, мәдрәсәдән җиде шәкерт чакырып җиде азан да кычкырттык.* М. Гали. *Имеш, алар нәселендә бума зәхмәте бар икән.* А. Шамов.

4. *сөйл.* Ачулану, мәсхәрәләү сүзе: имгәк.— *Карагыз әле, нигә бу зәхмәтләр безгә катнашмыйлар?* Т. Гыйззәт. *Карчык та чыгымлый, кәҗәнең дә сөте юк,*

зәхмәтнең. Ф. Бурнаш.— *Әй, Әхмәт түгел, зәхмәт булдың әле син!* М. Хәсәнов.

◇ **Зәхмәт кагылу (сугу, тию)** — 1) элек: халыкның ышанулары буенча, явыз җеннәрдән чир кагылу, төзәлми торган чиргә, авыруга дучар булу. *Култык асты шешкән вакытларда, зәхмәт кагылгандыр дип, --- [әни] күлмәк итәгеннән бармак бите кадәр генә ситсы ертып алып, аны агызып җибәрә.* Г. Галиев. *Аяк-куллары да, йөз әгъзалары да үз ихтыярыннан тыш килешсез хәрәкәтләр ясап, аны кararга имәнеч бер кыяфәткә кертәләр. Андый кешене халык телендә зәхмәт суккан дип йөртәләр.* М. Әмир; 2) берәр нәрсә белән бик нык мавыгу турында.— *Сиңа, минем үемча, калкавыч зәхмәте тигән булыр.* Ш. Камал. **Зәхмәт чигү** — интегү, газаплану, җәфа чигү.— *Бу кадәр көннәр мәгарәдә зәхмәт чигеп гыйлем хасил итүдән максат мондый кирәк урында башыбызны бәладән коткармак өчендер.* К. Насыйри.

ЗӘХМӘТЛЕ *с.* 1. Зәхмәте, михнәте булган, михнәтле, газаплы. *Син, [сабый], өлкән кешеләр кебек, уянсаң — зәхмәтле эшләр, йокласаң — имәнеч төшләр күрмисең.* Дәрдмәнд.

2. Зәхмәте, авыруы, чире булган, зәхмәт кагылган. *Зәхмәтле кеше.*

3. *сөйл.* Зәхмәт, чир китерә, йоктыра торган; сихерле. *Без аны «Мунчала күле» дип йөртәбез, тирә-як «Зәхмәтле күл» я «Бизгәкле күл» дип йөртә.* Ә. Фәйзи.

ЗӘХМӘТЛӘНҮ *ф. иск.* Интегү, хезмәт кую, азаплану. [*Бала, режимга һәм үз эшен үзе башкаруга өйрәнгәч], бу эшләр инде аның гадәте шикелле булып китеп, син бер дә зәхмәтләнмәссең.* Г. Тукай.

ЗӘҮҖӘ *и. иск. кит.* Хатын, ир хатыны. *Я ходай! Нишлим, әгәр күрсәм кешенең зәүҗәсен, --- Көнләшәм...* Г. Тукай.

ЗӘҢГЕЛӘ *и.* «С» витамины җитмәүдән була торган урт шешү авыруы; *русчасы:* цинга.— *Яшелчә ашагач, балаларың зәңгелә белән авырмаслар.* С. Рафиков. *Зәңгелә тән җимерә, дошманлык өй җимерә.* Мәкаль.

ЗӘҢГӘР *с.* Спектрдагы төп төсләрнең берсе — яшел белән күк арасындагы төс; күк йөзенең бик аяз көндәге ачык төсен аңлата. *Әй, ямьле бүген болыннар, күк йөзе якты зәңгәр.* Ә. Ерикәй. *Аның сыек зәңгәр күзләре туп-туры һәм якын итеп карыйлар.* Г. Бәширов. // *и. мәгъ.* Зәңгәр төс, зәңгәр буяу. *Аклы ситсы күлмәгемнең Зәңгәре күллар кебек.* Җыр. / *и. мәгъ. к.* зәңгәрлек 2. *Ник [кешегә], күкләр зәңгәреннән әнә күздәй генә күренгән кыя бөркетләре сыман, баш әйләнеч биекләрне айкау мөмкин түгел?!* Ш. Маннур.

Зәңгәр билет — революциягә кадәр икенче разряд хәрби учеттагы кешеләргә бирелә торган билет. *Үзебезнең авылда 18 яшь арасындагы бөтен ирләрне сугышка алып бетерделәр, шул яшьтәге ак билетлылар да, кызыл билетлылар да, зәңгәр билетлылар да китеп беттеләр.* М. Гали. **Зәңгәргә калдыру** — зәңгәр билет бирү, тыныч чорда хәрби хезмәттән азат итү. **Зәңгәр күз, зәңгәр чәчкә** *бот.*— гадәттә арыш басуында үсә торган ачык зәңгәр чәчәкле чүп үлән; *русчасы:* василёк. *Ул чакта да арыш арасында зәңгәр күзләр чәчәк аттылар.* С. Урайский. *Зәңгәр чәчкә тирбәлә ямьле арыш эчендә.* С. Сүнчәләй. **Зәңгәр төлке** — төлкенең соргылт зәңгәр, ягъни төтен сыман төстәге төре. *Тынып йоклый зәңгәр төлкеләр.* Д. Фәтхи.

◇ **Зәңгәр күзлек аша карау** — тормышны, кешене яки нәрсәне дә булса идеаллаштыру, аның кимчелекләрен, кыенлыкларын күрмәү. *Дөньяга яшьлекнең зәңгәр күзлеге аша караган, мәхәббәтләрен әзли генә башлаган яки таба алмаган бүгенге көн геройларына безне, әлбәттә, аңларга кирәк.* Ә. Баянов. **Зәңгәр сөт** — өсте җыеп алынган сыек сөт.— [*Бай*] *иртә белән малларга бирә торган каткан, күгәргән икмәк сыныклары белән өстен алган зәңгәр сөт я сыек әйран эчереп җибәрә.* М. Гали.

Зәңгәр таң — таң ату алдыннан була торган вакыт, төн белән таң арасы. *Зәңгәр таңнар белән торам да --- Җирән аткаемның йомшак ялын Сыйпый-сыйпый сөеп тарыймын.* Ш. Маннур. **Зәңгәр хыял** — чынбарлык белән бәйләнмәгән, тормышка ашмастай хыял. *Әнә шул кешеләр аңа тыныч ланып калырга, зәңгәр хыялларга батарга --- вакыт калдырмыйлар.* Г. Ахунов.

ЗӘҢГӘРЛЕ *с.* 1. Зәңгәр бизәкләре булган, зәңгәр төс катнашкан. *Аклы күлмәк кем кимәс, зәңгәрлесен кем сөймәс.* Г. Тукай. *Тирә-ягында, әллә нинди зәңгәрле, сорылы киемнәр киенеп, медальле күкрәкләрен киереп, --- бик мәһабәт түгыз кеше утыра.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. к.* зәңгәрле-яшелле 2. — *Әйтәм! — диде [Нургали], зәңгәрле тавыш белән яман кычкырып.* Ә. Еники.

ЗӘҢГӘРЛЕК *и.* 1. Зәңгәр төс. *Мин сокланып карыйм күзләренә, Күзләрендә куе зәңгәрлек.* М. Җәлил. *Тирә-як җылымса, йомшак зәңгәрлеккә чумган.* Г. Әпсәләмов. *Идел үзе, зәңгәрлеккә өртелә барган арагы яктан алып бирге якның тәбәнәк ярына кадәр, --- һаман ага.* Г. Бәширов.

2. Зәңгәр бушлык, зәңгәр фон. *Йокыга күзен йомган зур корпуслар куе зәңгәрлеккә уралган.* М. Җәлил. *Югарыда, күк зәңгәрлегендә, җил юк бугай.* Г. Ахунов. *Ерактагы куе зәңгәрлектән Ак болытлар инде күренә.* Ш. Маннур.

ЗӘҢГӘРЛЕ-ҚЫЗЫЛЛЫ *с.* Зәңгәр һәм кызыл төсләре, сызык яки бизәкләре булган. *Күзләре зәңгәрле-кызыллы томан аркылы чак-чак күрә иделәр.* Ш. Камал.

ЗӘҢГӘРЛЕ-ЯШЕЛЛЕ *с.* 1. Зәңгәр һәм яшел төсләре, сызык һәм бизәкләре булган. *Күз алдымда зәңгәрле-яшелле очкыннар чәчелде.* Ә. Айдар. *Ул кечкенә өйнең --- тәрәзәләренә элгән зәңгәрле-яшелле шарлары үк кызыктырып чакырып тора.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Колакка ятышсыз, чәрелдек (тавыш турында).

ЗӘҢГӘРЛӘНҮ *ф.* 1. Зәңгәр, күк төскә керү; күгәрү. *Газинур --- үзәкләре зәңгәрләнә башлаган үзагачлар турында сөйләп китте.* Г. Әпсәләмов. // Зәңгәр булып күренү. *Таң сызыла башлады. Тәрәзә пыялалары зәңгәрләнде.* А. Шамов. [*Нәфисә*] *Иделнең түбән ягында зәңгәрләнеп торган калын болытларга күз салды.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Ачулану, ярсу, ачудан агарыну, күгәренү.— *Күрдеңме балаларыңны? Я, тагы зәңгәрләнә, «син» диген, «үзең» диген.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЗӘҢГӘРЛӘТҮ *ф.* Зәңгәр төскә кертү, зәңгәрләндерү. *Зәңгәр күзкәйләрен зәңгәрләтеп, гүзәл карый минем фәрештәм.* Ш. Бабич. // Зәңгәр итеп күрсәтү. *Зәңгәр һава, зәңгәр һава, Гөлзадә, Зәңгәрләтә диңгезне, диңгезне.* Р. Ишморат.— *Инеш буйларын кәбестә шулай зәңгәрләтә торгандыр, әйе бит, Хәйдәр абый?!* Г. Бәширов.

ЗӘҢГӘРЛӘҮ *ф. сир.* Зәңгәргә буяу. *Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр, Ничек зәңгәрләгәннәр.* Җыр.

ЗӘҢГӘРСУ *с.* Сыек зәңгәр. *Кыз зур итеп ачылган зәңгәрсу күзләре белән аңа текәлгән иде.* А. Шамов. *Умырзаялар, йонлач кызыл сабакларына таянып, зәңгәрсу кыңгырауларын матур итеп асып куйганнар.* И. Гази. // Зәңгәргә тартым, зәңгәр төсмере булган (башка төс билгесе). *Зәңгәрсу кызыл шәфәкъ күкне яндырды.* Ш. Усманов. *Зур ишек алдының бер ягы зәңгәрсу кара бронза рәшәткәләр белән киртәләнеп, матур бакча эшләнгән.* Ш. Камал.

ЗӘҢГӘРСУЛАНУ *ф.* Зәңгәрсу төскә керү. [*Нәфисә*] *кояш яңа гына күздән югалган якка, сарғылт кызыл тау башларына, зәңгәрсулана башлаган Идел өстенә, чабылган болыннарга озак-озак карап барды.* Г. Бәширов.

ЗӘҢГӘРӘЮ *ф. к.* зәңгәрләнү 1. *Кайдадыр ераклараклара әлегә бик үк зәңгәрәергә өлгермәгән күксел офык диңгез белән тоташкан.* Ф. Хөсни.

ЗӘҺӘР 1. *и.* Агу. *Мин дидем: «Су!», эчмәдем су, сондылар — эчтем — зәһәр.* С. Сүнчәләй. // *с. мәгъ.* Агулы; агу яки газ катнашкан. *Ачы зәһәр төтен җиргә сылана, тамакларны, борыннарны ачыттыра, күзләрне ашый иде.* Каз. утл.

2. *и. күч.* Явызлык, усаллык; ачу. *Явыз кеше гел шулай була бит ул. Эче тулы зәһәргә чыдый алмыйча, гел ябыга, гел кибә.* Ш. Хөсәенов. *Соңгы айларда башын, йөрәген кайнаткан зәһәрләр, тагын аның бөтен тәненә таралып, көйдерә башлады.* Г. Ибраһимов. *Карт солдатның йөзенә чыкты зәһәре.* Н. Исәнбәт. // *с. мәгъ.* Явыз, усал, ачулы. *Карчыгының яшел тавышы бөтен өйне тутырды, зәһәр сүзләре яшен ташы шикелле атыла башлады.* А. Шамов. *Нидән шундый шәфкатьле, яхшы күңелле хатын ун ел эчендә шундый зәһәр, холыксыз хатын булып киткән?* Ф. Әмирхан. / *рәв. мәгъ. Аның кан баса башлаган күзләре зәһәр елтырап китте.* Г. Иделле.

3. *с. күч.* Бик каты, көчле, үзәккә үтә торган (салкын, эссе, җил һ. б. турында). *Тагын көндәгедәй эчпошыргыч зәһәр эсселек.* Ш. Маннур. *Кышның зәһәр суыклары һәм бураннары үтте.* Ә. Фәйзи. // Бик суык.— *Әйе, мондый зәһәр көннәрнең күптән булганы юк иде. Җелеккә үтә, каһәр суккыры!* Т. Миңнуллин.

4. *с. күч.* Куәтле, градусы зур булган (эчемлек турында).— *Ай-яй, зәһәр дә нәрсә икән, әкият!.. Авызны яндыра.* Ф. Әсгать. *Варис, тамакларны көйдереп төшеп киткән зәһәр эчемлекнең нәрсә икәнлеген белү өчен, иректән шешәгә күз салды.* М. Хәсәнов.

5. *с. күч. сөйл.* Шәп, бик яхшы, менә дигән. *Камчының бик зәһәрен әзерләделәр.* Г. Ибраһимов. *Болар күрше бояр хатынының кызлары, аларның бу атлары зәһәр инде, уздырмыйм дисәләр, безне уздырмыйлар инде алар.* Ф. Әмирхан. / *рәв. мәгъ. Күрше квартал командасы, аерата бер-ике малай бик җитез, бик зәһәр уйный иде.* Э. Касыймов.

Зәһәр елан — 1) агулы, чага торган елан; 2) *күч.* бик усал, явыз кеше турында. **Зәһәр кислота** — пыяланы ашый торган агулы кислота — фторлы водородның судагы эремәсе.

ЗӘҺӘРЛЕ *с.* 1. Агулы, агулый, чага торган. [*Елан*], *зәһәрле телен чыгарып, агуын чәчеп карады, кырмыскаларны чагарга уйлады.* А. Алиш. *Авызы көлсә дә, күзләре, әллә нинди зәһәрле елан күзләре кебек, мәгънәле, мәкерле рәвештә уйный.* Ш. Камал.

2. *күч.* Явыз, усал; ачулы. *Аның тавышында нинди-дер явыз тантана, зәһәрле мыскыл һәм шуның белән бергә шатлык та бар иде.* А. Шамов. *Фатыйманың йөзенә зәһәрле ачу бәреп чыкты.* И. Гази. *Гайшә --- бераз зәһәрле, әрнүле тавыш белән сүз башлады.* Г. Ибраһимов. // Усал, ачы. *Чехов әсәрләрендә тормыш каршылыкларын зәһәрле көлү аша ачып салган.* Г. Нигъмәти.

3. *күч.* Бик каты, көчле (суык яки эссе). *Кайда сөеклем, алтыным Уздыра бу куркыныч Төннең зәһәрле салкынын.* Һ. Такташ. // Кискен, ачы (җил турында).

ЗӘҺӘРЛЕК *и.* 1. Зәһәрле (2 мәгъ.) булу, явызлык, усаллык. [*Килен*] *Сафаның анасы Мәликә карчыкка, аның зәһәрлегенә түзә алмады.* А. Шамов. *Хаҗи, кемнедер мыскыллаган төсле, зәһәрлек белән елмайган килеш җавап бирде.* Ш. Камал.

2. Бик каты салкын яки эссе булу. *Сугышчылар бу кышның зәһәрлеген беләләр.* Г. Әпсәләмов.

3. *сөйл.* Күрү көче, җетелеге.— *Күзнең зәһәрлеге бетте.* М. Хәсәнов.

ЗӘҺӘРЛӘНҮ *ф.* 1. Агулану. *Кара инде бу бакчага, әйтерсең лә чума белән зәһәрләнгән.* Қ. Тинчурин.

2. *күч.* Бик нык ачулану, күңелдәге усаллык, явызлыктан ни эшләргә белмәү. *Ләкин дошман күпме чуалмасын, Зәһәрләнеп аяк астында, Яши Ватан...* С. Хәким. *«Мин моны оныта алмыйм! Гомер булса, бер аның исенә төшерермен! Төшерермен дигәч, төшерермен!» — дип зәһәрләнде* [*Мостафа*]. Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* **зәһәрләнеп.** Ачу белән, явызланып, усал итеп. *Губернатор күн утыргычны зәһәрләнеп кырыйга этәрде.* К. Нәҗми. [*Бәһави*] *бер зәһәрләнеп чәрелдәгән хатынга, бер үзенең көрәктәй йөнтәч, сипкелле кулына карап алды.* А. Расих.

3. *күч.* Усаллану, усал, явыз кешегә әйләнү. *Элек мин бөтенләй башка кеше идем. Күңелем йомшак иде минем. Хәзер зәһәрләндем.* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Көчәю, арту. *Безнең ачу моңа каршы тагын да зәһәрләнде.* Г. Минский.

5. *күч.* Көчәю, тагы да көчлерәккә, зәһәррәккә әйләнү (җил, буран турында). *Кайбер көннәрне* [*җил*] *зәһәрләнеп, үкереп, күз ачкысыз буран кузгатты.* Каз. утл. // Куәтләнү, гайрәте, градусы арту (эчемлек турында). *Колмак күбрәк салынган ахры, ачы бал зәһәрләнгән.*

ЗӘҺӘРЛӘҮ *ф.* 1. Агулау. / *күч. Тормышыбызны зәһәрләгән бу үзәк өзгеч уңайсызлыкка да артык бирешмичә генә чыдап килә идек.* Ш. Камал. *Ул — капиталистик тормышта семьяны агулап, зәһәрләп торучы бер пычрак җан.* М. Гали.

2. Зәһәрен, ачуын китерү, үртәү. *Хәтта тәнкыйтьчеләр дә аны* [*Г. Тукайны*] *урынсызга зәһәрләп тордылар.* С. Сүнчәләй. *Агулады шәүләң бу атаны, зәһәрләде исемең ананы.* Ф. Бурнаш.

ЗӨБӘ: зөбә кабыргалары — 7 пар чын кабыргадан соң урнашкан һәм түш сөягенә түгел, ә үз янындагы кабыргаларга мускул ярдәмендә тоташкан 3 пар ялган кабырга. [*Становойның*] *чигә тамырларын карышлаганнармы, зөбә кабыргаларын санаганнармы — аларын мин күрә алмадым.* Х. Қәрим.

ЗӨБӘРҖӘТ *и.* Затлылыгы белән беренче класска керә торган, зәңгәрсу яшел яки үлән төсендәге үтә күренмәле асылташ; *русчасы:* изумруд. *Тау башында төрле-төрле кыйммәтле ташлар: зөбәрҗәтләр, якутлар, ахаклар һәм башка эре-эре матур ташлар бик күп икән.* А. Алиш. *Қирәкми, бер якта торсын зөбәрҗәт, алтыннарың.* С. Хәким. // *тарт. форм.* **зөбәрҗәтем.** *Иркәләп, назлап әйтә торган мөрәҗәгать сүзе.— Кил яныма, кил, чибәрем, Кил алтын, зөбәрҗәтем.* Ә. Ерикәй.

ЗӨЛКАГДӘ *и. иск.* Мөселманнарның ел исәбе буенча, ай календаренда унберенче ай исеме. *Безнең башымыз мәрхүм булды зөлкагдә ае эчендә.* Бәет.

ЗӨЛФӨҚАР *и. иск.* Дини әкиятләрдә: бик үткен кылыч. [*Фәтхулла хәзрәт*], *кулын зөлфөкарга охшатыбрак тотып, яңа схоластика тарафдары әфәнде ролен уйнаган артистның өстенә атылды.* Ф. Әмирхан. / *күч. Чыгар кынның калам — тел зөлфөкарын.* Дәрдмәнд.

ЗӨЛХИҖҖӘ *и. иск. кит.* Мөселманнарның ел исәбе буенча, ай календаренда уникенче ай исеме.

ЗӨМРӘ *и. иск. кит.* Төркем. *Безнең Шәриф шул көннән башлап хәерчеләр зөмрәсенә — ярлылыкның иң түбән дәрәҗәсенә керде.* М. Гафури. *Җәлаләддин хәзрәт тә, бабасы мөнәсәбәте белән катышып, мәдәрриснең якын дуслары зөмрәсенә кертелгән.* Г. Ибраһимов.

ЗӨФАФ *и.* Өйләнешкән егет белән кызның беренче төне. *Кавышкач, зөфафның беренче көненнән үк бөтен йөрәге белән аңар бирелде, аны яратып, сөеп китте.* Г. Ибраһимов.— *Әйе, хәзрәт, беренче этәч кычкыргач та, мин сине зөфаф кичәсенә кертермен.* Т. Гыйззәт.

И

И I Татар алфавитында унынчы хәреф.

И II *ы.* **1.** (Гадәттә эндәш сүзләр янында.) Сүзнең кемгә төбәлүен белдерү, объектның игътибарын үзенә тарту өчен кулланыла.— *И, егетләр, тизрәк булыгыз. Без бит озак йоклаган икәнбез.* Әкият. *Ерактанрак кычкырган тавыш* [*ишетелә*]: *«И-и-и! Мине көтегез!»* М. Фәйзи. // Шундый ук кулланышта, контекстка карап, төрле хисләр һәм кичерешләрне дә белдерә. *И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!* Г. **Тукай.** *И иптәш, ул кансыз* [*ак офицерларга*] *ничек итеп ачуланмыйсың?* Ш. Усманов.

2. Контекстка карап, интонация ярдәмендә ярату, иркәләү, ис китү, гаҗәпләнү, искә төшерү, аптырау, кызгану, шелтәләү, ризасызлык һ. б. төрле хисләрне һәм кичерешләрне көчәйтә (бу хисләрнең көчлелеге, сүзнең сузылып әйтелүе язуда ике яки берничә **и** хәрефе белән бирелергә мөмкин).— *И-и-и, хәтеремнән дә чыккан бит!* Г. Мөхәммәтшин.— *И-и, килешми тагы, күчтәнәчнең ни гаебе бар?* М. Әмир.— *И-и. Бу кадәр матур булырлар икән!* Р. Ишморат.

3. *аваз. ияр.* Физик яки мораль газапланып ынгырашканда, елаганда чыккан тавышны белдерә.— *Ии... Билләрем сызлап тора. Җил-яңгыр булыр, ахры.* Қ. Әмири. *Ишетәм! Чынлап та: «И-и-и»,— дип, бик нечкә генә сузып, әкрен генә елаган тавыш!.. Бала елавына охшаган.* Ә. Еники.

4. *көч. кис.* Гадәттә стиль өчен кабатлап әйтелә торган һәр сүз янында килеп, тәэсирлелекне көчәйтү өчен кулланыла. *Су анасыннан котылгачтын, тыныч лангач, әни и орышты, и орышты, и орышты соң мине.* Г. Тукай.— *И яуды, и яуды* [*яңгыр*], *күперләрне агызды, буаларны ерды.* А. Гыйләҗев.

5. *кис. сир.* Шигырьдә иҗек саны тутыру, җырны сузып җырлау өчен кертелә. *Быел кискән и утыным, Бар да ярый и казыкка.* Бәет.

И III: и булу — җайлы, кулай булу. *Суга тире и булмас.* Мәкаль. **Игә кертү** — 1) *к.* игә китерү (1 мәгъ.).— *Күрше авыллардан яхшы түгел, бөтен колхозлары белән бер юньсезне дә игә кертә алмадылар, диерләр.* Г. Сәгыйдуллин; 2) көйләү, төзәтү. *Камера шартлаган. --- Әгәр җилем булса, бер-ике сәгать эчендә игә кертеп булыр иде.* А. Шамов. **Игә килү** — 1) кешеләрнең үгет-нәсихәтен, киңәшен кабул итеп, үз холык-фигылен яхшырту, җайлану, тыңлаучанга әйләнү. *Игелексез игә килмәс, юньсез юньгә кермәс.* Мәкаль.— *Тагын бер сөйләшеп карыйм да, аннан соң да игә килмәсә, белмим, нишлисе булыр инде аның белән?* Г. Бәширов; 2) рәткә килү, әйбәтләнү. **Игә китерү** — 1) кемнең дә булса холык-фигылен яхшырту, җайлау, тәртипкә кертү.— *Мондыйларны сүгенеп кенә дә игә китерә алмассың, каеш камчы белән ярырга кирәк.* А. Гыйләҗев; 2) берәр нәрсәне төзәтү, рәткә китерү, әйбәтләү.— *Алабута карабодайны баскан әле анда. --- Аны шыгырдап кына игә китерә алмассың.* Ф. Бурнаш. **Игә-чөйгә китерү** — *к.* игә килү (1 мәгъ.). **Игә-чөйгә китерү** — *к.* игә китерү (1 мәгъ.).— *Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә-чөйгә китерер хәл юк. Һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр.* Г. Қамал. **Игә-юньгә килү** — яхшы холык-фигыльле, юньле булып йөрү.— *Шул бәдбәхет Шөҗәкә катнашканнан бирле --- [Әхмәтнең] һичбер игә-юньгә килгәне юк.* Г. Қамал. **Ие килү** — җае туры килү, җайлану, рәтләнү. *Ие килсә, көе килмш.* Әйтем. **Иен бирү** *диал.*— *к.* кирәген бирү.

И IV Борынгы телдә **ир-** формасында булып, хәзер *иде, икән, имеш, исә* ярдәмче фигыльләре һәм сүзләре составында калган тамыр кисәк. *«Иде», «икән» --- икесе дә «и» кисәгеннән торган фигыль тамырга нигезләнгән.* В. Хангилдин.

И-А (И-А-А-АА) *аваз. ияр.* Ишәк кычкырган тавышны белдерә. *Мөбәрәкша каядыр якында гына үкергән ишәк тавышына уянып китте. Әйтерсең, --- тактадан кадак суыралар, әйтерсең лә, бикле капканы каералар: «И-а... И-а-и-ааа...»* Қ. Нәҗми.

ИБЕ-ЯБЕ: ибе-ябе булмау *сөйл.*—*к.* ибе-җебе күренмәү.

ИБЕ-ҖЕБЕ: ибе-җебе булмау (күренмәү) *сөйл.*— (эшнең) рәте, уңай нәтиҗәсе булмау.— *Үзегез бүген кайтам дисез, ә үзегезнең бер генә эшегезнең ибе-җебе күренми.* Қ. Тинчурин.

ИБЛИС *и.* **1.** *дини.* Аллага буйсынмавы өчен каһәрләнеп, күктән җиргә сөрелгән һәм кешеләрне аздыру белән шөгыльләнүче коточкыч кыяфәтле мифик зат, шайтаннар башлыгы; элеккеге исеме — Газазил. *Шунда тәңре: «Кит, сиңа ләгънәт!.. Күгемнән кит!— диде.— Бар, хәзер шайтанга баш бул, --- Ал бөтен нәрсәңне, кит, иблис!»— диде.* Ш. Бабич. *Хәйлә дигәндә иблиснең үзен төп башына утыртыр ул Йосыф.* Г. Гобәй.

2. *күч. тирг.* Башкаларны кызыктырып, котыртып бозыклыкка өндәүче, аздыручы, юлдан яздыручы хәйләкәр, явыз кеше. [*Мөстәкыйм Айдарга:*] *Бунт чыгарып йөрүең өчен аркаңнан сөяргә кушар идеңме, карт иблис!* Т. Гыйззәт. *Көнчелектән бозылган хыялы Гайнияне ничаклы гына ирләр аздыручы иблис итеп сурәтләмәсен, Маһибәдәр әле --- Гайниянең алай ялынып йөри торган кеше булмаганлыгын белә иде.* Ф. Хөсни. // Җансыз нәрсәләргә карата; мәсәлән: акча, алтын, байлык. *Булмасын хуҗа акча, Булсын җир йөзе бакча. Булса дуслык һәм тигезлек, Ул иблис аннан кача.* Г. Қамал.

◇ **Иблис көчеге** *гади с.*— кешеләрне юлдан яздыручы азгын яшь кешегә (һәм, гомумән, яшьләргә) карата тиргәп әйтелә. [*Әхмәт:*] *Кайда ул иблис көчеге?* [*Гөлшаян:*] *Әнә, сандыкта.* М. Әмир. **Иблис ләгыйнь** *сөйл. иск.*— каргалган, ләгънәтләнгән иблис (тиргәү сүзе).— *Иблис ләгыйнь берәр нәрсә болгата торгандыр, тагын* [*фалнамәне*] *ачыйм әле бер.* Р. Ишморат. **Иблис токымы** — 1) иблис нәселеннән булган зат, шайтан. *Мәүлиха түти,* [*Әпипәнең*] *елтырап тора торган көләч күзләренә*

карап, башын чайкап куйды да: «Тфу! Адәми зат түгелсең лә син, иблис токымыннандыр син»,— [*диде*]. Г. Бәширов.— *Хатын-кыз гына түгелдерсең син: иблис токымыннандыр! Ир-атны түгел, фәрештәңне дә юлдан яздырырсың.* М. Хәсәнов; 2) явыз, хәйләкәр кешеләрне, сирәк очракта хайваннарны тиргәү өчен кулланыла. *Галиулла, кәҗәнең мөгезеннән тотып алгач, усал итеп пышылдады: «Әһә, элэктеңме, иблис токымы».* И. Гази.— *Сезне хәйләгә өйрәтәсе юк инде, иблис токымы бит сез.* Э. Фәйзи. **Иблис төкереге** *гади с.*— усал, шаян балага ачуланып әйтелә.— *Син, иблис төкереге, чәнчелеп төшмичә, нишләп анда койма өстендә утырасың?— диде мулла.* Ф. Хөсни. **Иблис ялчысы** *тирг. иск.* — кешеләрнең арасын болгатып, гел җәнҗәл чыгарып йөрүче кеше.— *Каферләр, шайтан арбалары, иблис ялчылары, рәхәтләнеп йокларга да бирмиләр.* К. Тинчурин. **Иблис өмәсе** *мыск. иск.*— җәнҗәл, ыгы-зыгы, зур тәртипсезлек. [*Шәйхезаман:*] *Бу нинди шайтан туе? Бу нинди иблис өмәсе?* [*Байтирәк:*] *Менә, хәзәрткәем, күр: эчеп кайтканнар.* Т. Гыйззәт. **Иблис өшкергән нәрсә** *гади с. тирг.*— ачы, усал телле кеше; гомумән усал кеше.— *Тукта! Тукта дим, иблис өшкергән нәрсә!* Э. Касыймов. **Иблисне иманга өндәү** — бозык, начар кешенең эхлагын яхшыртырга теләүнең файдасыз икәнлегенә ишарә итеп әйтелә.— *Әгәр үтенеп карасаң? - - - Иблисне иманга өндәү? Кертерсең иблискә иман!..* Ш. Маннур.

ИБЛИСЛЕК *и.* Иблискә хас булган явызлык, хәйләкәрлек, кара эчлелек, икейөзлелек. *Аякларың инде җиргә тими, Көн ягына таба атларга. «Горур» көчең, «Дан»ың, иблислегең Танк асларында таптала.* Х. Мәҗәй.

ИБЛИ'СЧӘ *рәв.* 1. Иблискә (2 мәгъ.) хас булганча. 2. *күч.* Хәйләкәр, мутланып (карау, сөйләү турында). *«Шулай да без Газизә белән икәү кайтабыз!..» Гариф бу сүзләрне әйткәндә Газизәгә туп-туры һәм дә «иблисчә»рәк карый иде. Газизә, кызарып, куллары белән йөзен каплады.* Ш. Камал.

ИБНЕ *и. иск. кит.* Ул, ир бала. [*Бу*—] *Мөхәммәт Фатих ибне мелла Зариф Әльәмирханның юл истәлеге.* Ф. Әмирхан. // Гомумән бала. *Шигырь язды Габдельмәҗит ибне татар.* М. Гафури. *Ибне адәм кисә торыр — урман халкы үсә торыр.* Мәкаль.

ИБТИДА *и. иск. кит.* 1. Башланып китеш, башланыш. *Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы* [*шушыдыр*]. К. Насыйри. 2. *с. мәгъ.* Беренче, элекке, әүвәлге. *Безнең - - - бер*[*еб*]*езгә иң ибтида уларак нинди әсәрләребезне укымак кирәк?* Г. Тукай.

Ибтида кылу — башлау, башлап җибәрү. *Ибтида кыламын әүвәл Бу хәсрәтнең бәласындан.* Г. Сәмитова.

ИБТИДАИ *с. иск.* Башлангыч. *Шәкертләргә рус теленнән дә ибтидаи мәгълүмат бирелә торган булды.* Ф. Әмирхан. *Ул яше белән шактый олы булса да, рөшдигә күчә алмыйча, һаман безнең арада, ибтидаи сыйныфта утыра иде.* Э. Еники.

Ибтидаи мәктәп — революциягә кадәр: беренче баскыч (башлангыч) мәктәп. *Тукаев шигырьләрен ибтидаи мәктәп балалары рәхәтләнеп укыйлар.* Г. Рәхим.

ИГАНӘ *и. иск.* 1. Ярдәм, булышлык. *Күп мәшәкатьләр вә тарихның да иганәсе белән табылган бу репутацияне* [*югалту*] *җиңнәять.* Ф. Әмирхан.

2. Халыктан акчалата ярдәм, булышлык.— *Менә монда бер шәкерт укырга дип иганә сорый.* Г. Камал. *Фәкыйрьләргә дип ярдәм җәмгыятьләреннән вак-төяк иганәләр бирелә.* Ш. Әхмәдиев. // Гомумән материаль ярдәм. *Хәдичә дип исем куеп, Җамалетдингә килгән, Сигез яулык вә дүрт күлмәк Кызлар иганә биргән.* Бәет.

Иганә итү (кылу) — ярдәм күрсәтү, булышу. *Бөтен яшьләр, мөгаллимнәр, шәкертләрне кулларыннан килгән кадәр матди вә мәгънәви иганә итешергә чакырабыз!* Ф. Әмирхан. *Оренбургның байбәтчәләре һәр көн Беловкада, Топольдә җыручы кызларга милләт өчен йөзәр сумлап иганә кылалар.* Ш. Мөхәммәдев. **Иганә кертү** — материаль ярдәм күрсәтү.— *Яңа салынып ята торган соборга бераз гына иганә кертсәң, ул синең малайны гаскәрдән азат итү генә түгел, синең исемне изгеләр санына кертеп, чиркәүдә дога кылдырыр...* Э. Фәйзи. **Иганә җәмгыяте** *иск.*— ярлыларга ярдәм итү өчен төзелгән җәмәгать тәртибендәге оешма; җәмгыяте хәйрия.

ИГАНӘЧЕ *и. иск.* Иганә бирүче кеше.

ИГЕ I *с. бор.* Яхшы. *Атадан ул туса иге, ата юлын куса иге, биленә садак буса иге, битенә килер оятны үзе белеп юса иге; шушыларны кылмаса, барыннан да югы иге.* Мәкаль.

ИГЕ II: **иге дә юк, чиге дә юк** — *к.* иге-чиге булмау. *Идел болыннарының иге дә, чиге дә юк.* Г. Бәширов. *Шаулый арыш, алтын бодай гөрли, Иге дә юк аның, чиге дә.* Э. Ерикәй.

ИГЕЗ *с.* 1. Бер анадан бер үк вакытта туган. *Игез бозау.* □ [*Кәнҗебикә:*] *Бу кайсы була соң, игезнең сыңарымы?* [*Шәмсия:*] *Түгел. Игезләр Гөлшат белән Шәүкәт ул. Бу — Морат, - - - төпчегем.* Т. Гыйззәт. *Гарифәбикә берьюлы игез бала тапкан.* Қ. Тинчурин.

2. *күч.* Тигез, бертөрле. [*Электрик фонарь*] *якты бирдең, һәр кешене игез күреп, Бай, фәкыйрьне Үги күрми, тигез күреп.* М. Гафури. *Бөтен дөнья бертигез булсын, корылсын нигез; Ирек, кардәшлек юлында һәр кеше булсын игез.* Г. Камал.

ИГЕЗӘК *и.* 1. Бер анадан бер үк вакытта туган балаларның берсе.— *Шушы Гафур абыйның игезәкләре белән башларым гына әйләнеп бетә. Кайсыгыз Рәхимә, кайсыгыз Рәхилә икәнен һич хәтердә тотып булмый.* И. Абдулов. [*Хатынның*] *өч баласы бар икән. Соңгы икесе игезәкләр— өчәр яшьлек кыз балалар.* М. Хәсәнов.

2. *бор.* Зодиак йолдызчалары исеменә корылган элекке Болгар-Казан календаре буенча май ае. *Зодиак йолдызчалары исеменә корылган язма календарьда ай исемнәре түбәндәгечә:* 1. *Дәлү (чиләк) — январь;* - - - 5. *Жәүза (игезәк) — май.* Н. Исәнбәт.

ИГЕЛЕК *и.* 1. Яхшылык, кыйн күңеллелек.— *Заманында бик күп кешегә яхшылыгы тиде инде синең бабаңның. Иткән игелекләре өчен генә булса да, әҗәл бер юлга тими торсын үзенә.* И. Гази.— *Габдулла дус белән бәрәр хәл булганын ишетсәм, - - - миннән игелек көтмә. Кайтып синең тешеңне сындыру белән генә калмам, муеныңны өзәрмен!* Э. Фәйзи. // Яхшылыкка җавап итеп кайтарыла торган яхшылык.— *Гаҗиз булдык инде без, тәмам аптырадык. Ходай безгә бала игелеге (изгелеге) күрергә язмады инде.* Ф. Әмирхан. *Әле бит аның төпчеге бар — Әбүзәре. Аның игелеген күрә әле ул. Ләкин аңа Әбүзәренең дә игелеген бик озак күрергә насыйп булмаган икән: Ватан сугышына китеп хәбәрсез югалды егет.* Г. Ахунов.

2. *күч.* Файда, табыш.— *Кәһәремнең кәһәрләре,* [*чебеннәр*] *бигрәк каты тешлиләр ләбаса, әйтерсең лә корт чагамыны! Корт, ичмасам, балы белән рәхәтләндерә, ә болардан нинди игелек көтәргә. Пычагым гына да файда юк бит болардан!* Ш. Камал. *Менә умарта асрыйбыз, үзегез беләсез, ел саен диярлек бал бүлешмичә калганыбыз юк. Күңелле эш бит ул уртак хуҗалыкның шулай игелееген күрү.* Э. Еники.//Рәхәт тормыш, рәхәтлек.— [*Яшь хатын*] *да игелек күрә алмас. Кырмыска түмгәгенә төшкән елан шикелле үрле-кырлы сикерер.* Г. Камал.— *Болай булсан, син ата-анаңа да игелек күрсәтмәссең, кешегә дә файдаң тимәс.* А. Әхмәт.

◇ **Игелек кайтару** — яхшылыкка каршы яхшылык эшләү.— *Сез мине үз итәсез, сезнең игелегегезне кайтарырга кулымнан килмәгәнлектән, мин оялам.* Ш. Камал. **Игелек күргере** — 1) «яхшы, рәхәт тормышта тор» мәгънәсендә рәхмәт сүзе булып йөри; 2) кешегә яки хайваннарга яратып эндәшкәндә әйтелә («рәхмәт

төшкерә» кебек). [*Крестьян — атка:*] *Әйдә, әйдә, рәхмәт төшкерә!.. Һәйт, бәрәкәт. Тарт инде, игелек күргере.* К. Тинчурин. **Игелек күрсәтү** — 1) яхшылык итү, рәхәт тормышта тоту.— *Бала чагыннан бирле кадерләп, тәрбияләп үстергән җизнәсенә шундый явызлык эшләгәнне, туган апасына да ул игелек күрсәтмәс.* Р. Ишморат; 2) файда китерү.— *Син, энем, эт булсаң да хуҗаңа игелек күрсәтмәс идең. Бүреләр белән дуслашкан булып, үзеңне дә бүреләрдән ашатыр идең, хуҗаңның маллары да талатыр идең.* К. Нәҗми. [*Бодайларның*] *кайсы яньчелгән, кайсы сынган, кайсы-берсе бик чирләшкә. Андыйларның күбесе тишелсә дә игелек күрсәтмәс иде.* Г. Бәширов.

ИГЕЛЕКЛЕ *с.* Игелек китерә торган, ярдәмчел, яхшы, киң күңелле. *Игелекле бала. Игелекле хезмәт күрсәтү комбинаты.* // Яхшы, изге, файдалы. *Игелекле эшнең иртә-кичә юк.* Мәкаль. *Ай-һай, бу елга! Аш та ул бирә, су да эчерә, Тәнгә саулык та, Җанга шатлык та — барын җиткерә: Бик игелекле безнең авылга.* Х. Кәрим. // Бәрәкәтле. *Көзге-кышкы яңгырлар башлану белән, Украинаның игелекле җире дә үзенең матурлыгын югалта.* Ә. Айдар.

ИГЕЛЕКЛЕК *и.* Файда.— *Бик арык нәрсә икән ләбаса бу, - - - Сәбәбы өчен генә алмасаң, бүтән игелеклеге юк моның.* М. Шабай.

ИГЕЛЕКЛЕЛЕК *и.* Игелекле булу сыйфаты.

ИГЕЛЕКЛӘҮ *ф.* 1. Файдалану, файда күрү.— *Мин ул җирне саруттан арындыра алмыйча өч сука калагы сындырдым.* [*Аптул*] *игелекләнсен дип сындырдыммыни мин ул калакларны?* Ф. Хөсни.

2. Рәхәтләнү, рәхәт күрү. *Гомере буе ат җигеп игелекләнмәгәнгә, ул тайның тиздән тәртә арасына керерлек булуын уйлап куана.* С. Рафиков.

ИГЕЛЕКСЕЗ *с.* 1. Яхшылыкка каршы яхшылык итмәүче.— *Бәлки, балалары игелексездер, дип уйлар идең, - - - алар аның өчен үлеп торалар.* М. Шабай. // Яхшылык, рәхәт күрсәтми торган.— *Ялкау кыз икән бу, карчык кешенең идәнен генә дә себереп бирмәде, һай, игелексез нәрсә.* А. Әхмәт.

2. Булдыксыз, юньсез. *Игелексез ике бозауга кибәк аерып бирә алмаган, ди.* Мәкаль. — *Игелексез кеше син, Борһан. Кешеләр әнә тиздән уянып эшкә тотыныр лар, ә син адәм җанын үртәп яшәвеңне генә беләсең.* М. Шабай.

3. Игелек китерми торган, файдасыз, бәрәкәтсез. *Игелексез эш. Игелексез мал.* □ *Тик былтыр нигәдер игелексез ел булды.* Г. Бәширов.

ИГЕН *и.* 1. Орлыкларыннан он яки ярма хәзерләнелә торган бөртекле, кузаклы яки техник культура. *Сабан игене. Иген үрү. Иген басуы. Иген игү.* □ *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булган.* Г. Бәширов. *Күрәм, гүя, серкә очыруын Дүртилемдә үскән игеннең.* З. Мансур. *Шулай эшләп, матур яз көнендә* [*игенче*] *Чәчкән төрле-төрле игеннәр: Тары, карабодай, солы, борчак һәм дә Ясмык белән җитеннәр.* М. Гафури. // Шул үсемлекнең орлыгы: ашлык. *Иген амбарлары игеннәр белән тулы.* А. Шамов. *Яңа ашлыкның җитәрлеген чамалап калдырып, артык игенне саттык.* Г. Ибраһимов.

2. Шундый культура үсеп утыра торган басу. *Иген уртасында җиңнәрен сызганып, беләкләренә бик зур бодай көлтәләре салган - - - бер зур кеше басып тора.* Г. Бәширов.— [*Атларны*] *ераккарак куып җибәр инде. Игенгә төшә күрмәсеннәр тагы.* М. Фәйзи.

3. Иген эше, игенчелек. *Ул бит ничә еллардан бирле бөтен районда беренчелекне алып килгән иген остасы.* Г. Бәширов.— *Сезнең машиналарыгыз төзәтелмәгән, иген коралларыгыз каралмаган.* Т. Гыйззәт.

Иген бае — иген белән сату итүче авыл бае, кулак. *Ниндидер бер чуваш авылында булган, ди, бер чуваш бае. Үзе кибет тотып сатучы булмаган, ди, ул тик иген бае булган, ди.* З. Бәширн. **Иген гөмбәсе** *а.-х.*— ашлык бөртекләрен кара тузанга яки каты орыга әйләндерә торган гөмбә авыруы, корымбаш, кисәү; *русчасы:* головня. **Иген киптергеч** *а.-х.*—1) ашлык киптерү өчен махсус җиһазланган бина; 2) ашлык киптерү өчен механик җайланма. **Иген корымы** *а.-х.*— *к.* иген гөмбәсе. **Иген коңгызы** *а.-х.*— икмәк культураларына зыян китерә торган корткыч коңгыз; *русчасы:* кузька. **Иген сугу** — *к.* ашлык сугу. *Иген сукканда да Хәлимсез бер адым да атланылмый: ул чүмәләдән көлтә китерешә, ул әнисенә көлтә тезешә, бер кат тәпәчләп чыккач, көлтәләрне әйләндерергә булыша.* И. Гази. **Иген тараканы** *а.-х.*— *к.* иген коңгызы.

◇ **Иген төбе** — ашлык җыеп беткән вакыт, уңыш. *Иген төбе кинәнеч.* Мәкаль. **Иген чүмәләсе** *гади с. шелт.* — бернинди идеяләр яки әдәбият-сәнгать белән кызыксынмаган, мәгърифәтсез, культурасыз кеше.— *Безнең сеңелләр дә, энеләр дә бар. Аларны да карарга кирәк. Ә картларга гына калдырсаң, алар үзләре кебек иген чүмәләсе итеп үстерәләр дә, бетте.* Ф. Бурнаш.

ИГЕН-АШЛЫК *җый. и.* Ашлык, икмәк. *Габдулла агаең, Сәлмәннекеләрдән тире, иген-ашлык төяп, егерме мәртәбә калага барырга тиеш.* Ф. Хөсни. *Мин иген-ашлык сукканда көлтәләр ярсып сикерәләр.* З. Бәширн.

ИГЕН-ИКМӘК *җый. и. к.* иген-тару.

ИГЕНЛЕ *с.* Игене булган, игенгә бай; икмәкле. *Игенле байның исе бар, игенсез байның нисе бар?* Мәкаль. // Игеннәр яхшы үсә, уңа торган. *Актаныш — игенле як.* Н. Дәүли.

ИГЕНЛЕК *и.* Иген чәчелгән яки чәчелә торган җир. *Юлда бер игенлеккә очрадылар, богдайларның барысы да башакларын җиргә карап игәннәр.* Дәрдмәнд. *Бу ата-анасыз балаларга игенлекләрдән, кырлардан берике бөртек орлык булса да китереп бир.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Иген чәчелгән яки чәчелә торган. [*Аның*] *өч йөз дисәтинәгә якын игенлек кырлары бар.* Г. Ибраһимов.

ИГЕНЛЕКЛЕ *с. сир. к.* игүле. *Су кырыйларындагы игенлекле җирләрдән аерыл*[*дык*]. Г. Сәгъди.

ИГЕНЛӘТӘ *рәв.* Иген белән. *Игенлятә түләү.*

ИГЕН-ТАРУ *җый. и.* Игеп үстерелә торган һәртөрле культуралар, өлгергән ашлык.— [*Безнең*] *иген-тару да бар, тамак та тук.* Ф. Бурнаш. *Елак көз иген-таруны бердәм генә җыеп алырга ирек бирми.* А. Гыйләҗев.

ИГЕНЧЕ *и.* Иген игү белән шөгыльләнүче кеше. *Тургай сайрый мактый-мактый җырында Игенченең сабан сөргән чакларын.* Ә. Ерикәй. *Игенчеләр игеннәрне дә урган.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Иген игү белән шөгыльләнүче. *Якты теләк белән эшкә тотынган игенче ирләр, игенче егетләр зур хезмәт, күп көч түгеп, каты җирне йомшарталар, йомшарган туфракка алгы көннәрнең рәхәте өчен саф орлык чәчәләр.* Г. Ибраһимов.

ИГЕНЧЕЛЕК *и.* 1. Авыл хуҗалыгының җир эшкәртеп, иген игү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Бер колхозчы игенчелек тирәсында тиңе булмаган гажәп бертөрле бодай үстергән.* Г. Бәширов. *Игенчелекне фән һәм алдынгы тәҗрибә нигезендә алып барырга тиешбез.* А. Расих.

2. Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм алардан югары уңыш алу турындагы фән. *Игенчелек нигезләре.*

ИГЕН-ЧӘЧЕМ *җый. и.* Чәчелгән игеннәр (1 мәгъ.).— *Тары чәчегез быел. - - - Башка иген-чәчем, белмим, уңмастыр.* Р. Төхфәтуллин.

ИГЕН-ҮЛӘН *җый. и.* Игүле культуралар һәм үләннәр. *Иген-үлән көйгән кытлык елларда тамак ялгарлык урын эзләп шәһәргә килгән - - - сала кызларының хәле тагы да авыррак* [*булган*]. К. Нәҗми.

ИГЕ-ЧИГЕ: иге-чиге булмау — 1) гаять киң, озын, очсыз-кырыйсыз, чиксез булу. *Биналар, ташлар - - - урынында иге-чиге булмаган бакча хасил булды.* Г. Ибраһимов. *Менә алда - - - иге-чиге булмаган озын һәм карлы юл.* Ф. Хөсни; 2) *күч.* гаять күп булу; *синонимы:* исәпләп бетергесез.— *Бер елдан соң җиләк-җимешнең иге-чиге булмаячак бездә.* И. Гази. **Иге-чиге күренмәү** — очы-кырые булмау. *Монда зур диңгез, иге-чиге күренмәгән ак кар диңгезе иде.* Г. Ибраһимов.

И'ГРЕК *и.* 1. Латин алфавитында ахырдан икенче хәрефнең («у»ның) исеме. *Әлбәттә, без борынгы [латин] хәрефләренең шактыен танып белә идек инде: эпсилон, игрек...* Э. Касыймов.

2. *мат.* Билгесез зурлыкның шартлы билгесе. *[Сәгыйдә:] Шул икслар белән төн буе сөйләшеп утырдыңмы? [Камил:] Юк. Игреклары белән дә ара-тирә сүз көрәштердем. Ә беләсең, уку авыр әйбер.* Һ. Такташ.

ИГУА'НА *и. зоол.* Җылы якларда яши торган һәм ите ашарга яраклы озын кәлтә елан. *Игуана ите.*

ИГУ'МЕН *и.* Ирләр монастыреның башлыгы. *Һичбер [кеше] ул күлләрдән игумен (монастырь башлыгының) рөхсәтеннән башка балык тота алмый.* К. Нәжми.

ИГЪДАДИ *с. иск. пед.* Революциягә кадәрге чорда татар мәдрәсәләрендә: урта белем алган шәкертләрне югары уку йортына (галиягә) әзерли торган (класс. сыйныф турында); уртадан югары. *[З. Бәшири] 1908 нче елның язында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең игъдади сыйныфын тәмам ит[ә].* М. Гайнуллин. *Ул вакытта беркадәр реформалашкан мәдрәсәләрдә класска бүлү тәртибе менә шулай була торган иде: өч класс ибтидаи (башлангыч), дүрт класс рөшди (урта), өч класс уртадан югары — игъдади.* З. Бәшири.

ИГЪЛАН *и.* Берәр нәрсә турында газета-журналга урнаштырылган яки стенага элеп куелган белдерү.— *Авыл советы, мәктәп һәм көтепханә ишекләренә бәләкәй игъланнар ябыштырырга тәкъдим итәм. Игъланнарны башлыча яшьләргә төбәп язарга кирәк.* Ш. Камал. *Бумажникның хуҗасы килмәсә, [Зиннәт] - - - газета редакциясенә барырга һәм шунда игълан бирергә булган иде.* А. Шамов. // Афиша. *Күземә татарча язылган зур бер игълан (афиша) күренгәч, мин аны, алдына туктап, укыпга тотындым.* Ф. Әмирхан.

Игълан итү (кылу) — 1) хәбәр итү, белдерү.— *Юк, егет! Ул сиңа - - - тиң булмаган икән, ни өчен башлап мәхәббәт игълан кылдыгыз?!* М. Гафури; 2) рәсми рәвештә белдерү. *Шихрай җыелышны ачык дип игълан итте.* Ш. Камал.— *Ярты сәгатьтән хөкем карары игълан ителер.* М. Гали; 3) дөньяга чыгару, бастыру. *Аның бу шигыре «Тормыш» газетасында игълан ителә.* С. Кудаш.

ИГЪЛАННАМӘ *и. иск.* Белдерү кәгазе. *Иртәгә каланың уртасына халык җыйдырып асарбыз дип, халыкка игъланнамә тараткаиннар.* Әкият. *Бер кабак өстендә фатир алып һәм капка өстенә игъланнамә күеп, алты-жиде, бәлки, унлап бала җыелды.* К. Насыйри.

ИГЪЛАНЧЫ *и.* 1. *тар.* Борынгы заманнарда: берәр вакыйганың булачагын яки берәр югары дәрәҗәдәге кешенең килүен алдан хәбәр итеп йөрүче кеше. *Быргы тавышлары. Игъланчы керә: «Эрчелегез юлдан, квиритлар! Бөек диктатор Сулла хатыны — Валерия Мессала килә!»* Н. Исәнбәт.

2. Игъланнар, афишалар бастырып таратучы кеше. *Матбугат дөньясы вәкилләреннән игъланчы, календарьчы Шәрәфетдин Шәһидуллин беренче була.* И. Рәмиев. // Игъланнар, афишалар ясаучы яки язучы кеше. *Г. Тукай, Казанга килгәч, - - - игъланчы булып та эшли.* Н. Исәнбәт.

ИГЪТИБАР *и.* 1. Фикерләү, күрү һәм ишетү сәләтенең берәр нәрсәгә, берәр ноктага төбәлгән булуы; дикъкать. *Дүртенче, бишенче тәрәзәләргә Габделбасыйр инде бик игътибар белән карады.* Ф. Әмирхан. *Йөз яшәр Галәк бабай да, - - - уң кулын колагына куеп, Гөлләрнең һәр сүзен игътибар белән тыңларга әзер тора.* Г. Әпсәләмов.

2. Ихтирамлы мөнәсәбәт, хөрмәт, илтифат. *Сезнең тарафтан миңа шундый тирән игътибар һәм сизгер кайгыртучанлык күрсәтүгә мин чиксез нык шатланам.* М. Җәлил. *Нуруллин, аның игътибарыннан, аның җылы, йомшак мөгамәләсеннән - - - ничектер тынычланып, авыруын, сызлануын онытып ята.* А. Шамов.

3. Абруй, авторитет, дәрәҗә. *Минем балалар арасында игътибар артты. Мин сабак өйрәткән балаларның ата-аналары - - - мине өйләренә чакырып кунак иткәли башладылар.* М. Гафури. *Башка казармаларның халыклары арасында боларның игътибары юк. Һәммәсе «ташландыклар» дип хисапланалар.* Ш. Камал.

Игътибар бирү — 1) илтифат итү.— *Беттеме? Бик озак сүзасың бит?— диде Һидият. Нәгыйм Һидиятнең сүзенә игътибар бирмичә дәвам итте.* Ш. Камал.— *Ә сез ул кисәтүгә аз гына да игътибар бирмәгәнсез икән.* Р. Ишморат; 2) хөрмәтләү, ихтирамлы мөнәсәбәт, кайгыртучанлык күрсәтү.— *Аңа да күбрәк игътибар бир. - - - Ул үзен читкә этәрелгән кеше итеп хис итмәсен.* Р. Ишморат. **Игътибар итү (кылу)** — 1) күрү, сизү, дикъкать итү. *Ул, Зөбәйдә игътибар итсен өчен, - - - энесе белән кычкырып сөйләште.* Г. Гобәй; 2) әһәмият бирү, кирәкле санау. *Әгәр Татар опера студиясе операның иҗат көчләрен тәрбияләүгә игътибар итмәгән булса, опера театрын [оештыру] өчен иң мөһим шартларның берсе үтәлмәгән - - - булыр иде.* М. Җәлил. **Игътибар иясе** — дәрәҗәле, авторитетлы, хөрмәт ителүче, гомумән хөрмәткә лаек кеше. **Игътибар казану** — илтифатка, дикъкатькә ия булу. *Ләкин әгәр дә чынлап та игътибар казанырлык берәр эш кузгала калса, Фәхси, мәһабәт сынын күрсәтеп, калкып килеп чыга.* Ф. Хөсни. **Игътибар күрсәтү** — *к.* игътибар бирү.— *Колхоз председателе - - - мәктәп бинасын яктырту мәсьәләсенә җитәрлек игътибар күрсәтми.* Р. Ишморат. *Сөләйманны редакциядә ачык йөз белән каршы алдылар. Редактор аеруча аңа игътибар күрсәтте.* Қ. Тинчурин. **Игътибарга алу** — 1) әһәмият бирү, илтифат итү, кабул итү. *Ул минем сәламемне игътибарга алмады; хәтта, минем сәламемне күргәч, яңлыш кына, илтифатсыз гына миңа караган күзләрен ашыгып-ашыгып - - - карчык өстенә күчерде.* Ф. Әмирхан.— *Гөлсинә сүзен игътибарга алмыйм, ул әле балаларча фикер йөртә.* Р. Ишморат; 2) исәпкә алу, истә тоту. *Бу ике товарны эшләп чыгарырга киткән тип-тигез вакыт игътибарга алынды.* Г. Тукай.— *Сез, безнең әлекке иң актив членыбыз булуны игътибарга алып, безнең соравыбызны кире какмассыз дип ышанабыз.* Ш. Камал.

◇ **Игътибар үзәгендә (булу)** — әһәмиятле саналу, гомуми кызыксыну тудыру. *Ленинның игътибар үзәгендә һәрвакыт кеше иде.* Г. Әпсәләмов. *Балалар китабының жанрларын [төрләндерү] игътибар үзәгендә булырга тиеш.* М. Җәлил.

ИГЪТИБАРЛЫ *с.* 1. Дикъкать итүчән, игътибар белән карый торган, кызыксынучан. *Ул яшь натуралистларга юлда очраган һәммә нәрсәгә игътибарлы булырга куша иде.* М. Кәримов.

2. Кеше турында кайгыртучан, кеше хәлен аңлаучан, ярдәмчел, кешене хөрмәт итүчән. *Кешеләргә бик тә игътибарлы, кеше җанлы председательгә тап булгач, без бик тә сөенеп, кая кушсалар, шунда йөгерергә әзер идек.* Ф. Хөсни. *Бу кичне син гаҗәп игътибарлы идең. Сүзләрең җылы, тавышың йомшак иде.* Г. Кутуй.

3. Әһәмиятле, игътибарга лаек. *[Хәбибулла:] [Иптәшең] мөселманча йөри, мәсҗедкә бара, җомгаларда күренә. Син дә шулай булсаң, рас, аңардан бик күп артык булыр идең. [Сөләйман, тегенең сүзен игътибарлы тапмыйча:] Чәй эчәмсең, Хәбибулла абзый, чәй алдырыймммы?* С. Рәмиев.

4. Абруйлы, хөрмәтле, ихтирам ителүче. *Авылның иң игътибарлы кешесе булганга, зур мәсьәләләрне хәл иткәндә халык һәркайчан аның киңәше белән хисаплашканга, хөрмәт йөзеннән олысы-кечесе аны Акбабай дип йөргән.* Г. Гобәй. *Ул авылның игътибарлы һәм хөрмәтле карты* [*иде*]. А. Шамов.

ИГЪТИБАРЛЫЛАНУ *ф.* Игътибарлыга әйләнү. *Аның каш аралары җыерылмады җыерылуын, - - - ә күзләре, йөзе игътибарлыланды.* К. Басыйров.

ИГЪТИБАРЛЫЛЫК *и.* Игътибарлы (1, 2, 4 мәгъ.) булу сыйфаты. *Игътибарлылык тәрбияләү.* □ *Шәп кешене начар кешедән аера белү байтак көч, игътибарлылык сорый иде.* А. Расих. *Сөббухның мондый игътибарлылыгына чын күңелемнән куанып утырдым.* Г. Галиев.

ИГЪТИБАРСЫЗ *с.* 1. Күңел бирми торган, дикъкатьсез, таркау. *Игътибарсыз кеше.* □ *Бүген ул аларны аңа карата ничектер игътибарсыз, гамьсез итеп тапты.* А. Шамов. // *рәв. мәгъ. Укытучы үзенең алдынгы укучысының дәрестә болай игътибарсыз утыруына аптырады.* А. Әхмәт. // *рәв. мәгъ.* Гамьсез, игътибар бирмичә. *Патша һәм министрлар бу коточкыч һәлакәт турындагы хәбәрне бик игътибарсыз гына тыңлыйлар.* А. Алиш. *Без ялкау гына, игътибарсыз гына* [*әйләнәтирәбезгә*] *каранып гомер үздырдык.* Ф. Әмирхан.

2. *рәв. мәгъ.* Әһәмият, илтифат итмичә. *Акчаның өстендәге язуына гына игътибар итәләр, ә ул нәрсәдән ясалган, анысы игътибарсыз каладыр.* Г. Тукай. *Сәлмән карт йортка буй бирмәс бу «малай актыгы»ның мондый сүзләрен башта колак яныннан игътибарсыз уздырырга тырышып йөрде.* Ф. Хөсни. // Хөрмәт итмичә, кадерен белмичә, саксыз. *Кеше хезмәтенә игътибарсыз карау.*

Игътибарсыз калдыру — 1) әһәмият бирмәү, дикъкать итмәү, игътибар итмәү. *Ул Сания белән бик якын танышларча исәнләште. - - - Сөләйман белән дә күрешеп алды. Хәсәнне дә игътибарсыз калдырмады.* М. Әмир; 2) илтифат итмәү, үзенең бернинди мөнәсәбәтен белдермәү. *«Әткәй, әткәй, тиз кайт, без сине көтәбез!» Ләкин «этисе» бу тавышны игътибарсыз калдырды. Бәлки, ишетмәгәндер ул, ишетсә дә, ничек итеп инде ул бу тансык сүзне аңа кычкыралар дип үйлый алсын?* Г. Минский; 3) үтенечне читкә кагу, канәгатьләндермәү. *Мөхип әби Гайнижамалның бу хаклы дәгъвасын игътибарсыз калдырмады.* Ф. Әмирхан. *Ачык сәбәпләрен дә китергәч, аның бу үтенечен игътибарсыз калдырмадылар.* Ф. Хөсни.

ИГЪТИБАРСЫЗЛАНУ *ф.* Игътибарсыз булып китү, игътибарсызлык күрсәтү, кайгыртмау. *Игътибарсызланды дип сукранып йөргән улы да: «Әни, син авырмыйсыңдыр бит? Бер дә төсең юк»,— дип куйды.* Ш. Хөсәенов.

ИГЪТИБАРСЫЗЛЫК *и.* Игътибарсыз булу сыйфаты. *Корректорның игътибарсызлыгы аркасында, афишада зур хата киткән:* [*гади*] *студентлар диясе урында мәшһүр студентлар диелгән.* Ш. Камал. *Үзенең шигыренә мондый салкынлык, мондый игътибарсызлык Хәлимнең кәефен җибәрде.* И. Гази.

Игътибарсызлык күрсәтү — 1) әһәмият бирмәү, дикъкать итмәү, гамьсез булу. *Чак кына ялгыштың, чак кына игътибарсызлык күрсәттең исә, күрше скважинаны һәлак итәсең.* Ф. Мостафин; 2) кайгыртучанлык күрсәтмәү, ярдәм итмәү. *Театрга якын килергә омтылган сирәк кадрларга карата да игътибарсызлык күрсәтү фактлары очрый.* М. Җәлил; 3) хөрмәт итмәү, санга алмау. *Ул кисәк кенә Баһавига арты белән борылды, көтелмәгән игътибарсызлык күрсәтеп, кунакка сүз дәшмәстән, башта лампаның филтәсен чеметеп тазартты.* А. Расих.

ИГЪТИБАРӘН *рәв. иск. кит.* 1. Башлап, шуннан башлап. *Менә шул вакыттан игътибарән безнең тормышыбызда бертөрле үзгәрү сизелә башлады.* Ш. Камал. [*Бу әсәрләр*] *бүгеннән игътибарән һичбер җирдә, һичбер сәхнәдә уйналырга, укылырга, төзәтелергә, йөртелергә тиеш түгелдер.* М. Җәлил.

2. Истә тотып, искә алып, игътибар итеп; хөрмәтләп. *Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибарән, миңа, башка малайларга биргән кеби, конфет, бер-ике перәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде.* Г. Тукай.

ИГЪТИЗАР *и. иск. кит.* Үтенеч. *Бу кадәр моңлы зар белән, Бу кадәр игътизар белән - - - сорыйм сез*[*дән*]. Г. Кандалый.

Игътизар итү (кылу) — үтенү; гафу үтенү. *«Бу вакыйганы кешегә сөйләмә»,— дип,* [*ул*] *игътизар кылды.* К. Насыйри.

ИГЪТИКАТ *и. иск. кит.* Ышаныч, ышану. *Бу сүзләрне ул чын игътикаты белән сөйли; бу сүзләргә бөтен күңеле белән ышанган.* Ф. Әмирхан. *Аның игътикатынча, Һиндстан кыйтгасы Боз диңгезе буенда, Бомбей шәһәре Амур суы янында, Сахалин атавы Африкада, имеш.* Ш. Мөхәммәдев. // Берәр нәрсәгә инану; тоткан юл, мәсләк. *Минем алдымда игътикатлары белән, дингә, дөньяга карашлары белән - - - төн белән көн кебек капма-каршы булган ике кеше тора иде.* Х. Кәрим.

Игътикат итү (кылу) — ышану. *Авыру авыруга кардәш дип игътикат иткәнгә күрә: «Күптәнме бу хәлдә сез?»— дип сорарга җөрьәт итәм.* Ф. Әмирхан. *Без үзебез шулай уйлыйбыз, шулай игътикат кылабыз.* Ш. Камал.

ИГЪТИРАЗ *и. иск. кит.* Бер фикер яки карарга каршы төшү, бәхәс. *Шәрәфи картның бу игътиразына канәгатьләндерерлек җавап бирү читен түгел иде.* Ш. Камал.

Игътираз итү (кылу) — каршы төшү, бәхәсләшү. *Бикә моңа каршы елап игътиразлар кылса да, - - - ирексез җиңелә һәм туктый иде.* Г. Ибраһимов. *Бу карарга каршы без катгый сүрәттә игътираз итәбез һәм моның эшкә куелуына катгый сүрәттә каршы торабыз.* Ф. Әмирхан.

ИГЪТИРАФ *и. иск. кит.* Тану, икърар. *Шәкертнең күңелендә үзенең чынлап та шәм һәм дә халыкны яктырту өчен булган шәм икәнлеген игътираф, аңлау туа.* Г. Тукай.

Игътираф итү (кылу) — үзенең гаебен тану, яшермичә әйтеп бирү, икърар итү.— *Игътираф кыл инде, газизем. Аның өчен генә борчылдың, еладың бит син.* Ш. Әхмәдиев. *Караны яз кара дип һәм игътираф ит акны ак.* Г. Тукай.

ИГӘЛҮ *ф. Кайт. юн.* Борчылу, интегү, йөдәү. *Вафин ул төнне, - - - каршылыклы уйлардан игәлвп, бик озак йоклый алмыйча ятты.* Ф. Хөсни.

ИГӘР *и. диал.* 1. Ау эте.

2. *күч.* Ялкау кеше.

ИГӘРЕШҮ *ф. диал.* Талашу, сүзгә килү. *Яман белән игәрешкәнче, яхшы белән киңәш.* Мәкаль.

ИГӘРЧЕ *и. диал.* Күәс чиләген кырып җыйган камырдан ясалган кечкенә генә икмәк; кырындык. *Арыш икмәге пешергәндә, икмәкләрне әвәләп бетергәч, күәс чиләгенең төбендә, кырыйларында ябышып калган камырларны җыештырып, оештырып бер кечкенә икмәк ясыйлар. Шул кечкенә икмәк «игәрче» аталадыр.* Г. Сәгъди.

ИГӘРЧЕЛЕК *с. диал.* Игәрче пешерү өчен калган, бер игәрчегә җитәрлек. *Игәчем өченә барганчы, игәрчелек он тартырмын.* Мәкаль. *Аз гына булган арыш камырын «игәрчелек кенә» дип сөйләшәләр.* Г. Сәгъди.

ИГӘЧ *и. диал.* 1. Кыз туган. *Раббани Кара байның өченче кызы иде. Игәчләре арасында ул иң зәһәре, иң астыртыны булып үсте.* Г. Әпсәләмов. // Бертуган сеңел.

2. *күпл.* **игәчләр.** Апалы-сеңелле(ләр).

ИГӘҮ I *и.* Металл, мөгез яки агачның өске катлавын кырып шомарту, үткерләү яисә кисеп чыгару өчен

тешәлгән, сырлы корыч кисәге, корал. *Өч кырлы игәү. Яссы игәү. Түгәрәк игәү.* □ [*Егет*] *игәүне кулга алгач та сакланып кына богау бикләрен кисәргә кереште.* К. Нәҗми. *Бер кеше байның кибетен басарга килгән дә йозагын игәү белән игәп утыра икән.* Г. Бәширов.

Игәү борын *зоол.* — үрдәкләр семьялыгыннан озын, нечкә, өске ягы игәүгә охшаган һәм аска таба кәкрәйгән томшыклы, кечкенә гәүдәле су кошы; *русчасы:* грохаль. **Игәү койрык** *диал.*— *к.* күсе.

ИГӘҮ II *ф. сир. к.* игәүләү. *Ул, бөтен дөньясын онытып, иске Мәкәрҗә урагының үтмәсләнгән тешләрен иги иде.* К. Нәҗми. *Ул бичара үзенең шик-шөбһәләре, - - - һәрвакыт үзен үзе игәп торучан эчке каршылыклары - - - белән ялгыз башы пыскып яши.* Ф. Хөсни.

ИГӘҮЛӘҮ *ф.* 1. Игәү I белән ышкып, металлны, резинаны, агачны шомарту, үткерләү, кайрау, тигезләү. *Мохтар өйдән чыгып барганда, Гыйльмулла кухня ягында иске әчкечләр игәүләп утыра иде.* Ш. Камал. [*Кеше*] *протезны үзе сүтеп, кирәгеннән артык югары куелган үкчә урынын игәүләп тигезли.* Р. Мостафин.

2. *күч. сөйл.* Кемне дә булса туктаусыз битәрләп, шелтәләп тору. *Тотындылар әкәмне игәүләргә! Мөгезсез сыер шикелле ник анда барып кердең? Алма ашыйсың килдә? Э безнең килмиме?* И. Гази. *Аннары* [*әни*] *тагы мине игәүли. Имеш, өенең яме юк, имеш, өстәл арты буш.* Г. Әпсәләмов. // (Күңелне, йөрәкне) борчу, тынгылык бирмәү.

ИГҮ *ф.* Бөртекле культураларны чәчеп үстерү. *Алар сөенә-сөенә ул җирләрдә иген игәләр.* А. Алиш. *Игә белгән иген ашар.* Мәкаль. //*күч.* Үсемлек булмаган әйберләр турында: үстерү, булдыру. *Киттек әйдә, кырлар буйлап, киләчәк көннәрнең шатлыгын игәргә!* К. Нәҗми.

ИГҮЛЕ *с.* Игелә торган. *Игүле җир. Игүле үсемлек.*

ИГҮЛЕК *и.* Игелә торган җир.

ИГҮЧЕЛЕК *и.* Игү эше. *Тәмәке игучелек.*

ИДАРӘ *и.* 1. Хакимлек, җитәкчелек, власть. *Политик идарә. Дәүләт идарәсе.* □ *Кадет вә аларга якыннар - - - мәмләкәт идарәсендә иң зур роль аларга тиеш икәнчелеген - - - дәгъва итәләр.* Ф. Әмирхан.

2. Кешеләрнең эшләренә, хәрәкәтләренә җитәкчелек. *Безнең контрартиллерия хәзерлегебез аларның бөгек исәпләрен бутап ташлаган, идарә бозылган.* Г. Сафиуллин. // Үз хәрәкәтләреңә җитәкче булу, хуҗа булу. [*Мостафа*], *нервлар шаярмасын, идарә көче йомшармасын дип, һәр көн иртә-кич бозлы су белән тәнен ышкыды.* Г. Ибраһимов.

3. Берәр оешма яки учреждение эшләре белән җитәкчелек итү өчен сайланып куелган яисә билгеләнгән административ орган. *Завод идарәсе. Тимер юл идарәсе.* □ *Колхоз идарәсенең секретаре белән хисапчысы, бригадирларның рапортларын тыңлап, шул көнге эшкә йомгак ясый башлаганнар иде.* М. Гали. *Йорт идарәсе ремонтны язга чыккач кына ясарга уйлый.* М. Җәлил. // Шундый органда эшләүче кешеләр, администрация. *Көз көне, үзебезнең мәдрәсә идарәсенең димләве белән, Себер ягында бер шәһәргә мөгаллимлеккә киттем.* Ш. Камал. // Шул оешма, учреждение урнашкан бина яки бүлмә. *Анасы, Нәфисәне җитәкләп, - - - колхоз идарәсенә йөгерде. Идарәнең эче тулы халык иде, болар килеп кергәч, ике якка тайпылып, юл бирделәр.* Г. Бәширов. *Идарә дигәннәре яландай иркен бер бүлмә иде.* А. Расих. // Шул органның җыелышы.— *Идарәнең карары шундый: бүгенгесе көннән син монда ындыр бригадиры буласың.* Г. Бәширов. *Бүген идарәдә бик мөһим мәсьәлә караланга, ул сөйләүчеләрнең, аеруча председательнең, бер сүзен дә ычкындырмыйча ишетеп калырга тырыша.* А. Шамов.

4. Хәрәкәт итә торган машиналарны, приборларны, экипажны һ. б. ш. йөртү, тотып бару. *Үзәктән идарә.* // Машина, механизм һ. б. конструкцияләрнең эшләре белән җитәкчелек итү өчен кирәкле приборлар җыелмасы. *Руль идарәсе.* □ *Мосолов, идарә рычагын борып, двигательнең тизлеген киметте.* Каз. утл. *Гафият, тормоз рычагын күтәреп, - - - идарә пультларына кагылып алды.* Г. Ахунов.

5. *иск.* (Газета-журнал) редакциясе. *Казаннан киткәнеңә икенче ай инде, бер нәрсә дә язмыйсың, идарәгә бер мәкалә дә җибәрмисең.* Г. Тукай. *Һәркемдә язуга һәвәс артып китте. - - - Газета идарәләренә шигырь* [*дип*] *төрле әсәрләр язып җибәрә башладылар.* Г. Камал.

Идарә итү (кылу) — 1) идарә (1, 3 мәгъ.) эшен алып бару, җитәкчелек итү. *Хөкүмәтне идарә итү тәртибе алмашыну турындагы хәбәрләр - - - бөтен Россияне зык куптарды.* М. Гафури. *Фабрик-заводлар киләчәк көннәрдә митинглар белән генә идарә ителә алмаячаклар, гыйлем һәм тәҗрибә белән идарә ителәчәкләр.* Ф. Әмирхан; 2) прибор, рычаг, руль һ. б. ярдәмендә машиналар, механизмнар һәм хайваннар йөрешенә, эшенә юнәлеш бирү; эшләтү, йөртү. *Зур Чыршылы кешеләре беренче тапкыр шундый машина белән идарә итүче авылдашлары белән сөенеп исәнләштеләр.* С. Рафиков. *Ат, бәлки, кайда булса да адашып калыр, кайта алмас иде. Чөнки мулла нә юл белерлек, нә дилбегә тотып, атны идарә кылырлык* [*түгел*] *иде!* Г. Ибраһимов; 3) сүзне, эшне билгеле юнәлештә алып бару. *Исмаев әңгәмә белән тагын да кыюрак идарә итә башлады.* Г. Бәширов; 4) үзе теләгәнчә эш йөртү, үзе теләгәнчә файдалану. *Аның кулында миллионнар иде һәм ул шушы миллионнар белән исәпләнә торган дәүләт акчасын үзе теләгәнчә, үзе файдалы тапканча тота ала иде. - - - Ул миллионнар белән идарә итүдән тәм һәм рухи азык таба иде.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Идарә дилбегәсе (җебе)** — баш булу, власть. *Эти, картаеп, кулдан идарә дилбегәсе ычкынганнан соң да,— ахры, элекке хакимдар чакларын сагынып булса кирәк,— зур тавыш күтәрде.* Ф. Хөсни.

ИДАРӘХАНӘ *и. иск.* 1. Административ учреждение урнашкан бина. *Волостьның идарәханәсе дә шул мәйданга салынган. Идарәханә — иңе киң, буе озын, түбәсе карсак, тәрәзәләре зур вә караңгы күренгән бер бина булып, моның һәммә җире кызылга буялган.* Г. Ибраһимов.

2. Китап яки газета-журнал чыгару, аны редакцияләү белән шөгыльләнү өчен сайланган яки билгеләнгән орган, редакция урнашкан йорт яки бүлмә. *Калды уң якта «Китаплар ханәсе», Сулда — «Әльислах» идарәханәсе.* Г. Тукай. *Мирзаханов фатирын типография һәм идарәханә итеп, - - - бер номер журнал чыгардык.* М. Фәйзи.

ИДАРӘЧЕ *с.* Дәүләт, ил, өлкә белән җитәкчелек итүче, хакимлек итүче. *Капиталистик дәүләтләрнең идарәче сыйныфлары. // и. мәгъ.* Шундый кеше. *Германия идарәчеләре.*

◇ **Идарәче даирәләр** — власть башында торучылар, дәүләт идарәсенең төп вәкилләре.

ИДЕ *ярд. ф.* 1. Исем, сыйфат, сан, алмашлык һәм хәбәрлек сүз булып килә торган мөнәсәбәтлекләр белән бергә тезмә хәбәр ясый, аларның үткәнгә караганлыгын белдерә. *Үз-үзеңә кара: Кем идең, кем булдың?* Г. Тукай. *Син адаштың, Ләкин син яхшы идең, Синең яхшы иде күңелең.* Һ. Такташ.— *Шушы яшемә җитеп, мондый бодайны күргәнем юк иде әле минем.* Р. Ишморат.

2. Хикәя һәм ният фигыльләрнең аналитик үткән заман формаларын ясауда кулланыла: 1) тәмамланмаган үткән заман формасын ясый. *Әле таң атып, зәңгәрсуланып, яктырып кына килә иде.* А. Шамов. *Аның улы Газиз дә нәкъ менә шулай — укыр иде дә язып куяр иде, укыр иде дә кәгазенә сызып куяр иде.* Г. Бәширов. *Әлфиянең кинаяле сүзләреннән соң* [*Газинур*] *шунда ук Миңнурый янына кермәкче иде дә, имеш-мимешләргә юл куймас өчен, үзен тыйды.* Г. Әпсәләмов;

2) күптән үткән заман формасын ясый. *Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем, Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.* Г. Тукай; 3) киләчәк-үткән заман хикәя фигыль ясауда катнаша. *Солдат һаман ерагая бара, хәзер аны куып җитү кыен булачак иде.* Г. Бәширов.— *Моны кем генә күрсә дә, совет солдатларының батырлыкларына сокланыр иде.* Н. Дәүли.

3. Теләк фигыль ясауда кулланыла. *Сиңа атап язган бу җырым Барып җитсен иде хат булып.* Ф. Кәрим. *Баскан әзем җирнең күкрәгендә Югалмаслык уелып калса иде, Җырлаган җырларым һаваларга Утлар белән язылып барса иде.* Һ. Такташ. *Менәргә иде Урал тауларына, Карарга иде текә кыядан.* Җыр. // *-Гай, -гәй* кушымчалы теләк фигыльнең юклык формасын ясауда катнаша. *Бу хәтле баю шомлыкка булмагай иде.* Ш. Камал.

4. *-Асы, -әсе* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыль белән килеп, тиешлек мәгънәсен белдерүдә катнаша.— *Бу* [*февральдәге*] *революциядән әллә нилләр көткән идек: янәсе сугыш та бетәсе иде, эш сәгате дә кимисе иде, крестьянга җир дә биреләсе иде.* И. Гази.

5. Кабатлаулы эш-хәрәкәтне белдерә. *Күп вакытта безнең бүлмәбездә Собраниеләр булып үтә иде, Качып йөргән бик күп большевиклар Кайчак шунда кунып китә иде.* Һ. Такташ. *Эш арасында ул еш кына: «Әнә шулай»,— дияргә ярата торган иде.* Р. Төхфәтуллин.

6. Контекстта икенче бер фигыль белдергән процесс өчен фон булып килә. *Бервакыт кырда урак ура идек. Кинәт яңгыр яварга тотынды.* Г. Гали. *Зәйтүнә өенә кайтканда, картлар кичке ашны ашап утыралар иде.* Ф. Хөсни.

7. Хәзерге заман хикәя фигыльнең күплек санында килеп, реаль мөмкинлек була торып та эш-хәрәкәтнең үтәлмәвенә ризасызлык белдерү өчен кулланыла. *Эшлиләр иде аны.*

8. Үткән заман сыйфат фигыль белән килеп, икенче бер эш-хәрәкәт белән кинәттән бүлдерелгән, өзелгән, каршы куелган эш-хәрәкәтне белдерә. *Мохтаров, урыныннан торып, шүрәле башлы мундштугына сигарет киертә башлаган иде, Сарымсаков аны туктатты.* Г. Ахунов. *Ул Газинурга тагын нидер әйтергә җыенган иде, аныгыч рәвештә полк штабына чакырдылар.* Г. Әпсәләмов.

ИДЕАЛ *и.* 1. Җәмгыять яки аерым шәхеснең алга куйган, шуңа омтылган иң югары максаты; кеше омтылышының, теләк һәм максатының иң югары ноктасы. *Халыкка нур чәчеп, ак юлга атлау. Минем бит иң олуг идеалларым ул!* М. Җәлил.— *Идеалыгыз ни соң сезнең, Әнисә?— Кешеләр рәхмәт әйтерлек итеп эшләү. Уку, өйрәнү!* Г. Мөхәммәтшин.

2. Кемгә дә булса яхшы якларның, яхшы сыйфатларның иң югары гәүдәләнеше, иң камил үрнәге булып күренгән кеше турында.— *Бәлки, мин ялгыша торганмындыр. Бәлки, минем хыялым гына аны гаҗәп бер идеал итеп күрсәтә торгандыр.* Р. Ишморат. *Мин Гәрәйдә коры идеал гына түгел, реаль таяныч таптым.* Н. Исәнбәт.

ИДЕАЛИЗМ *и.* 1. Рухны, аңны, идеяне — бөтен барлыкның нигезе һәм беренчел, ә материяне икенчел, шулардан чыгарылма дип саный торган, фәнгә каршы булган реакцион философик юнәлеш. *Идеализмның асылы шунда ки, беренче чыгыш пункты итеп психик нәрсә алына; шуннан табигать китерелеп чыгарыла һәм шуннан соң инде табигатьтән гади кеше аңы китереп чыгарыла.* В. И. Ленин. *Субъектив идеализм бердәнбер нигез итеп «субъектның» (кешенең) аңын ала.* М. Абдрахманов.

2. *сөйл.* Үз-үзен аямыйча, үз интересларын күзәтмичә, тиеш яки бу эшкә хезмәт итүгә омтылыш, һәвәслек.

3. *сөйл.* Чынбарлыкны матур итеп, идеаллаштырып күрсәтергә ярату.

ИДЕАЛИСТ *и.* 1. Идеалистик философияне яклаучы, шуның тарафдары. *Без - - - идеалистлар түгел, без — материалистлар.* Ә. Фәйзи.

2. Теге яки бу эшкә үз-үзен аямый, үз интересларын, үз файдасын күзәтми хезмәт итүче кеше. *Бу егетнең* [*эчке, рухи сыйфаты*] *миңа һәрвакыт рус идеалистлары арасында «народник» (халыкчы)* [*исеме*] *белән мәгъруф 60—70 еллар зыялыларының хөрмәтле* [*рухи сыйфатларын*] *хәтерләтә.* Ф. Әмирхан.

3. *сөйл.* Чынбарлыкны идеаллаштырып, матурлап күрсәтергә яратучы кеше; хыялый, фантазёр.— *Идеалистмы, гуманистмы дип әйтим мин аны, - - - Кузнецов ул хәзерге моменттагы эшләп чыгару интересына тиешенчә бәя бирә алмый. Ул вак әйберләр белән хыяллана.* Ш. Камал.— *Идеалист булмагыз, егетләр, һәр нәрсәнең тамырына карый өйрәнегез. «Абда-как» абыегызның безнең бюрога кереп сәгатьләр буена утыруының тамырында тик бер нәрсә ята: үз урынында утырса, аны шундук күреп алып, йөгертәләр.* Ф. Хөсни.

ИДЕАЛИ'СТИК *с.* Идеализмга (1 мәгъ.) хас. *Идеалистик философия исә һаман артка чигенә, таяныч югалта, җиңелә.* М. Абдрахманов.

ИДЕАЛИСТЛЫК *и.* Идеализм белән сугарылганлык.— *Ильбековның идеалистлык, ялган новаторлык - - - тайпылышларын фаш итеп ачып сала торган фактлар менә бу папкада...* Ә. Фәйзи.

ИДЕАЛЛАШТЫРУ *ф.* Кемне яки нәрсәне дә булса чынбарлыктагыга караганда яхшырак, югарырак итеп, идеаль (2 мәгъ.) сыйфатлар белән күрсәтү, сурәтләү. [*Г. Камал*] *үзенең әсәрләре аша татарның бурҗуамещан тормышын, һичбер ялган буяуларга буямый, идеаллаштырмый, чын төсе белән күрсәтте.* М. Гали. *Алар киләчәкне дә искиткеч матур итеп, - - - идеаллаштырып күз алларына китерәләр.* М. Хәсәнов.

ИДЕАЛЛЫ *с.* Идеал (1 мәгъ.) белән сугарылган.— *Изге тормышка! Идеаллы тормышка* [*атлыйк*]*!* М. Фәйзи.

ИДЕА'ЛЧА *рәв.* Идеалдагы кебек.— *Бу соңгы рюмканы мин сезнең өчен күтәрәм, сезнең гади тормышта идеалча матур итеп, бәхетле итеп яши белүегез өчен!* Н. Исәнбәт.

ИДЕАЛЬ *с.* 1. Хыялда гына яши торган; абстракт; *киресе:* чын, реаль, хакыйкый. *Фатих Әмирхан, «Фәтхулла хәзрәт» сурәтен биреп, искелекне тәнкыйть*[*ләп*] *кенә калмый, буржуа яңа тормышының идеаль үрнәге турында да хыял итә.* Г. Нигъмәти.

2. *сөйл.* Камил үрнәк булырлык, бик яхшы. *Идеаль чисталык. Идеаль герой.* □ *Мин үземне, Рәүфә ханым, бер дә идеаль кеше итеп күрсәтәсем килми. Менә мин бөтен тормышым, килешем, бөтен кимчелекләрем белән сезнең алда.* Ә. Фәйзи.— *Безнең авиа*[*шәһәрчектә*] *бердәнбер фәрештә диярлек идеаль хатын, гөнаһсызлыкның үрнәге булган Валентина Николаевна турында шундый сүз йөри бит!* С. Баттал.

Идеаль газ *физ.* — молекулалары бары бер-беренә бәрелеп кенә үзара бәйләнешкә керә торган хыялдагы газ. **Идеаль сыеклык** *физ.* — гадәти сыеклык кебек сыланучанлык, ябышучанлык үзлеге булмаган хыялдагы сыеклык.

ИДЕЛ *и. иск. сир.* 1. Зур елга. *Сүн суы, Бәләбәй өязеннән чыгып, Минзәлә өязен үтеп, Кама иделенә күшыл*[*а*]. З. Һади. *Пароходта без барабыз Вятка иделе буйлап.* Бәет.

2. Көнчыгыш Европада Каспий диңгезенә коя һәм Татарстан территориясе аркылы үтә торган зур елга исеме (борынгы исеме — Итил); *русчасы:* Волга.

Идел күбәләге *зоол.* — бер генә көн яши һәм күбрәк су өстендә очып йөри торган бөжәк, бер көнлек күбәләк.

◇ **Идел уртасында калу** — *к.* ике ут арасында.

ИДЕЛ-ЙОРТ *җый. и. фольк.* Идел буена урнашкан борынгы Болгар һәм Кыпчак дәүләтләре. *Элекке Болгар-*

һәм соңыннан Кыпчак йортын фольклорда - - - Идел-йорт дип йөртү еш очрый. Н. Исәнбәт.

ИДЕОГРА'ММА *и. лингв.* Нинди дә булса бер төшенчәне белдерә торган язма шартлы билге (мәсәлән, саннар, тапкырлау, кушу, алу билгеләре). *Идеограммалар системасы.*

ИДЕОГРА'ФИК *с. лингв.* Идеографиягә мөнәсәбәтле. *Рәсем - - - билгеле бер фикернең, идеянең шартлы билгесе була, [нәтиҗәдә] идеографик язу барлыкка килә.* Х. Курбатов.

ИДЕОГРА'ФИЯ *и. лингв.* Идеограммалар ярдәмендә язу; рәсемнәр ярдәмендә язу.

ИДЕО'ЛОГ *и.* Теге яки бу сыйныфның, иҗтимагый-политик стройның һәм аның идеологиясенең яисә берәр юнәлешенең тарафдары, яклаучысы. *«Солых теләсәң, сугышка хәзер бул!» Бу сүзне буржуазиянең идеологлары һәрчакта кычкыралар иде.* Ф. Әмирхан. [*Г. Камал*] *«Безнең шәһәрнең серләре»ндә Печән базарының кадимче идеологларыннан рәхимсез көлә.* Г. Нигъмәти.

ИДЕОЛО'ГИК *с.* Идеологиягә бәйле, идеологияне чагылдырган. *Идеологик көрәш. Идеологик мөнәсәбәтләр.* □ [*Империализм*] *безгә каршы иң кабахәт төстә идеологик диверсия алып бара.* Г. Әпсәләмов.

ИДЕОЛО'ГИЯ *и.* Билгеле бер җәмгыять, сыйныф яки политик партия интересларын гәүдәләндерә торган политик, философик карашлар, идеяләр җыелмасы, аларның иҗтимагый аңы, дөньяга карашы һәм фикерләр системасы. *Пролетариат идеологиясе.* □ *Дөньяда ике идеология бар: социалистик идеология һәм буржуаз идеология.* Г. Әпсәләмов. *Революциягә кадәрге татар әдәбиятының реакцион катлавын тәшкил иткән язучылар өчен - - - капиталистик хосусый милекне саклау идеологиясе характерлы.* М. Җәлил.

ИДЕ'Я *и.* 1. Кеше аңында чынбарлыкны чагылдыра, шул чынбарлыкка аның мөнәсәбәтен белдерә торган төшенчә, күзаллау. *Социализм — хәзер ул коры идея генә түгел, ә ул — факт.* М. Җәлил.

2. Кешенең дөньяга карашында нигез принцип булган төп фикер; инанган нәрсә. *Алдынгы идеяләр. Политик идеяләр. Идея коралы. Идея дошманнары.* □ *Г. Камал белән Г. Тукай икәвесе дә — демократ язучылар. Алар икәвесе дә демократлык идеяләре белән яналар һәм шуның өчен көрәшәләр.* М. Гали. *Большевиклар, кайда гына булмасыннар, Мәскәүдәме, Оренбургтамы, Ташкенттамы, бер идеягә хезмәт итәләр.* Ш. Усманов.

3. Сәнгать әсәренең эчтәлегенә салынган төп фикер. *Әсәрнең идеясе. Идея эчтәлеге. Идея тирәнлеге.* □ *Зур идеяләрне җиңел итеп әйтә белү - - - шагыйрьнең әсәре өстендә бик нык эшләвен сорый, чөнки зур бер фикерне массага аңларлык бер телдә әйтә алу ул бик җиңел эйбер түгел.* Һ. Такташ. *Авторның төп идеясе — колхозчыларның бәхетле тормышын һәм халыклар арасындагы интернациональ дуслыкны күрсәтү.* М. Җәлил.

4. Фикер, уй.— *Миңа бер идея килде. Беләсезме нәрсә, ханым. Алып китегез сез бу баланы үзегез белән.* Г. Гобәй. // Теләк, ният. *Пароход капитаны булырга теләү коры бер җилкенү булып кына калмады, бу идеяне мин байтакка кадәр үземдә саклап, җайлы форсат чыкканны көтеп йөрдем.* Ф. Хөсни.

ИДЕ'Я-*Идея-теоретик, идея-тематик, идея-политик* кебек кушма сүзләрдә *идея* сүзенең мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк.

ИДЕ'ЯЛЕ *с.* 1. Идеясе, фикере булган, нинди дә булса бер идея белән сугарылган. *Идеяле сәнгать.* □ *Образлы, матур тел белән язылган, ачык идеяле кыска хикәя ул бер стакан куе ширбәт белән бер.* Г. Галиев. // Алдынгы фикер белән сугарылган.

2. *сөйл.* Шәхси интересларны күздә тотмаган; идеягә чын күңеленнән бирелгән.

ИДЕ'ЯЛЕЛЕК *и.* Идеяле булу сыйфаты. *Югары идеялелек.* □ *Татар хатынының образы үзенең идеялелеге, иҗтимагый көрәштәге активлыгы белән тулылана, байый.* Г. Кашшаф.

ИДЕ'ЯСЕЗЛЕК *и.* Идеясе булмау, тирән, эчтәлекле фикерләре булмау; принципсызлык. *Бу идеясезлек бүгенге тормыш куйган тематикадан читкә китүдә генә түгел, бәлки бүгенге тематиканы алып та, аны тирәнәйтми бирүдә, «пафослы» терминнар белән генә канәгатьләнеп өстән йөзүдә, укучы массага бер яңа фикер дә бирмәүдә.* Һ. Такташ.

ИДЕ'ЯЧЕЛ *с.* Берәр идеягә (2 мәгъ.) чын күңеленнән бирелгән. [*Г. Ибраһимовның*] *иң идеячел һәм, әдипчә, үзен үзе онытып революция эшенә чумган дип бирелгән революционерлары да көрәшә, сөя, иҗтимагый эш рәтеннән тагын шәхес тормышы белән дә яши белә.* Г. Нигъмәти.

ИДИ'ЛЛИК *с.* 1. Идиллиягә (1 мәгъ.) караган. *Идиллик шигырьләр.* □ *Яңа, азат хезмәт эстетикасына каршы бер күренеш буларак, мещанлык поэзиясе, идиллик романтика дөньяга чыкты.* Г. Халит.

2. Тыныч, гаугасыз, борчылусыз. *Идиллик тормыш.*

ИДИ'ЛЛИЯ *и.* 1. Табигать кочагындагы тыныч, борчылусыз, гамьсез тормышны сурәтләгән поэтик әсәр. *Идиллия жанры.* □ *XVII һәм XVIII йөзләрдә француз шагыйрьләре, Россиядә Сумароков, Херасков һәм башкалар «көтүчеләр» турында идиллияләр иҗат иткәннәр.* Н. Гыйззәтуллин. *Г. Газиз исә үзенең кечкенә күләмле бу - - - әсәрен, аның төче бер лирик характерда булуы һәм вакыйганың бакчада, алмагачлар чәчәк аткан җирдә—«табигать кочагында» баруыннан чыгып, «идиллия» дип атаган.* Р. Гайнанов.

2. *күч. ирон.* Табигатькә якын, тыныч, идеаль тормыш. [*Муса*] *элекке көтүченең хурлыклы, ач-яланғач тормышыннан идиллия эзләми иде.* М. Максуд. *Бөтен барлыгым белән авыл идиллиясенә бирелгәнмен.* Ф. Хөсни. // Тыныч, гамьсез тормыш картинасы турында. *Ул килгән саен карчык, аны сөйләтеп утырыр өчен, самовар куеп чәй эчерми торып җибәрми икән. Бу идиллиягә суфый шулкадәр өйрәнеп, ияләшеп киткән, - - - тоткан да, читләтебрәк, үзенең өйләнергә теләге барлыгын әйтеп салган.* Ә. Фәйзи. *Дүртенче һәм бишенче курста укыган еллар Хәбир белән Мәдинә өчен мәхәббәт идиллиясе белән тулы булды.* Ш. Хөсәенов.

ИДИ'ЛЛИЯЛЕ *с.* Гамьсез, тыныч, борчылусыз. *Вафинның моннан бер сәгать-сәгать ярым элек кенә кичергән идиллияле рухи халәте яңадан шик-шөбһәләр, җавабы табылмаган - - - сораулар белән алышынды.* Ф. Хөсни.

ИДИО'МА *и. лингв.* Составындагы сүзләренең мәгънәләренә бөтенләй туры килмәгән яңа мәгънә алган һәм билгеле бер телгә генә хас булган әйтелмә, тотрыклы сүз тезмәсе. *Идиомаларда аерым сүзләрнең урынарын алмаштырып яки - - - берәр компонентын төшереп һәм өстәп булмый диярлек.* Ш. Рамазанов.

ИДИОМА'ТИК *с. лингв.* Идиоматикага бәйле, идиоматикага хас. *Идиоматик берәмлек.* □ *Тукай иҗатында фразеологиянең татар халык сөйләвенә генә хас булган, башка телгә тәрҗемә ителми торган идиоматик төрләре дә күп. - - - «Авызыма җаным килә» — әнә шундый идиоматик әйтелмәләрнең берсе.* Ә. Исхак.

ИДИОМА'ТИКА *и. лингв.* 1. Билгеле бер телдәге идиомалар җыелмасы. *Татар идиоматикасы.*

2. Идиомалар турындагы фән. *Идиоматика белән шөгыльләнү.* □ *Бүгенге көн өчен - - - идиоматиканың лексикологиягә параллель фән тармагы икәнлеге ачыкланды.* Г. Ахунҗанов.

ИДИОТ *и. сөйл.* 1. Акылга зәгыйфь, ни акыллы, ни юләр кеше. [*Врачлар*] *аның - - - тумыштан яки контузия-фәләннән идиот булмавын да расладылар.* Ш. Маннур.

2. *тирг.* Аңгыра, ахмак (кеше турында).— *Нинди еланны мин үз канат астыма сыендырганмын. --- Мин сукыр булганмын, гамьсез идиот.* Р. Ишморат.

ИДИОТЛЫК *и.* 1. Идиот булу, акылга зәгыйфь булу.— *Башыңны идиотлыкка салып торма. Исеңә төшер, Чистополь шәһәрендә, базарный площадьта кул болгый-болгый кычкырып, политика сатучы кеше син булгансың ич?!* Ф. Хөсни.

2. *күч.* Ахмаклык, аңгыралык; мәгънәсезлек.

ИДӘН *и.* Теләсә нинди корылманың йөрер өчен тактадан, таштан түшәлгән түбәнге өлеше. *Җир идән. Паркет идән. Идән асты. Идән тактасы.* □ *Мин байлар йорт эченең матурлыгын, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен* [*күрдем*]. Г. Тукай. *Блюхер, вагон идәненә куйган ияр өстенә утырып, каршындагы иптәше белән сөйләшә иде.* Ш. Усманов. *Чиста итеп юылган такта идәнгә сары төстә иске киез җәелгән.* Ш. Камал.

Идән балавызы — идәнне ялтырату өчен балавыз һәм буяу кушылмасыннан торган сыекча; *русчасы:* мастика.

◇ **Идән асты** — бик яшерен, бик нык конспирация шартларында властьларга, хакимлек итүчеләргә каршы алып барыла торган эшчәнлек, көрәш; властьларга каршы көрәш алып баручының конспирация шартларындагы тормышы. *«Интернационал» --- [Э. Потье] тарафыннан идән астында (яшерен көрәштә чакта) язылган.* М. Җәлил.— *Син әле яшеренеп яшәү хикмәтләрен белеп бетермисең. Ә мин яртылаш идән астында инде. Айдан артык фатирга кайтканым юк.* Қ. Нәҗми. **Идән астына китү** — эшне легаль булмаган, яшертен хәлдә алып бара башлау. *Ни өчен ул чын ирек сөюченең хыялы булган профессиональ революционерга әверелеп идән астына китмәгән?* А. Расих. *Бишенче елның декабрь күтәрелеше бастырылып, Россия буйлап җәза отрядлары чаба башлаган заман иде. Революцияче партияләр идән астына киттеләр.* Г. Нигъмәти. **Идән астыннан** — яшертен. [*Рәхимҗанның*] *яңарак вафат булган бер хәзрәтнең егерме яшьлек матур хатыны белән мөнәсәбәт саклавы хакында бөтен шәһәрдә идән астыннан бер хәбәр йөри башлады.* Г. Ибраһимов. **Идән астыннан чыгу** — легаль хәлгә кайту. **Идән түпрәге** *мыск.*— ихтыярсыз, булдыксыз кеше турында. [*Малай*] *кемгә карап идән түпрәге булсын, --- әтисеннән түрәләр дерелди* [*ич аның*]. Г. Әпсәләмов.

ИДӘНЛЕК *с.* Идәнгә җәю өчен махсус хәзерләнгән. *Авылда идәнлек такталар бар.* Р. Төхфәтуллин.

ИЕ I *кис. сөйл. к.* әйе. [*Вахит:*] *Бу Хафиз түгелме соң?* [*Сиби:*] *Ие, ие, шул икән, шул.* Г. Камал.— *Галиябану колхоз кызы булса, менә дигән кеше булыр иде, иеме, Миңнурый? — Ие.* Г. Әпсәләмов.

ИЕ II *ф. сөйл. к.* иде.— *Әни әйткән ие, ни дип әйткән ие, оеткылыкка катык дип әйткән ие.* Ф. Хөсни.— *Әнине каршы алырга килгән иек.* Г. Гобәй.

ИЕЗУИТ *и. дини.* 1. XVI гасырда барлыкка килеп, Рим папасының һәм реакциянең терәге булган католик монахлар ордены (сугышчан дини оешма) члены. *Иезуитлар монастыре.* □ *Иезуит Саккери (1667—1733) --- геометриядәге «караңгы тапны» яктыртырга тырышкан.* Җ. Тәрҗеманов.

2. *күч.* Икейөзле, мәкерле, явыз кеше.

ИЕЗУИТЛЫК *и. кит.* Икейөзлелек, явызлык, мәкерлелек.

ИЕК, ИЕКК *аваз яр.* Укшыганда, очкылык тоткында чыга торган тавышны белдерә.— *Эчегез, Шакир ага... И-иекк... Пажалыста... Миңа ярамый... Иекк... Бөерем... И-иекк... Җәфалый, иек!!!* Г. Мөхәммәтшин.

ИЕЛЕНКЕРӘҮ *ф. сир.* Гәүдәнең өске өлешен бераз гына бөгә, ия төшү. [*Аның*] *гәүдәсе дә борынгы кебек бик үк туры түгел, бәлки, эче яки биле авырткан кеше кебек. алга таба иеленкерәп йөри.* М. Гафури.

ИЕЛӘ-БӨГЕЛӘ *рәв.* Бер иелеп, бер тураеп. *Нәфисә, сүзне тизрәк очларга теләп, иелә-бөгелә үләннәр йолкыштыргандай итте.* Г. Бәширов. *Без траншея эчләп иелә-бөгелә үзебезгә кайтабыз.* И. Гази.

ИЕЛӘ-СЫГЫЛА *рәв.* Гәүдә белән сыгылмалы хәрәкәтләр ясап, гәүдәне сыгылмаландырып ия-ия. *Алар, иелә-сыгыла, камыш эчләп китеп бардылар.* И. Гази. // Шул ук: үсемлек, агачлар турында. *Ә яшь таллар Җилләр дулкынында Иелә-сыгыла җиргә авалар.* Х. Туфан. *Өянке агачлары сизелер-сизелмәс кенә иелә-сыгыла күлгәләр бирә.* Ш. Камал.

ИЕЛӘ-ТОРА *рәв.* Гәүдәне бер иеп, бер торайтып. *Үз окопларыннан иелә-тора немец окоплары ягына китеп баручы ике шәүләне күреп, Сәфәргали Арнаутовка эндәште.* Ф. Хөсни.

ИЕЛҮ *ф.* 1. Басып торган хәлдә гәүдәнең билдән югары өлешен аска таба бөгү. *Шуларны түйдырамын дип, тирең түк, Иел җиргә, дуга төсле, билең бөк.* Г. Тукай. *Ул иелеп йөгерергә киреклеген белсә дә, уклау йоткан кебек, туп-туры йөгерә башлады.* Г. Әпсәләмов. // Җиргә таба салыну, бөгелү (үсеп торган агач яки үсемлек турында). *Помидорлар пешеп кызарды һәм җиргә иелде.* М. Җәлил. *Тал иелә, тал иелә, Нигә иелә икән?* Җыр.

2. Яктаю, куйшаю, авышу. *Әнә шул* [*элекке*] *авылның баштанаяк иске вә черегән, саламга күмелгән, мескеннәрчә иелеп, җиргә сеңгән аяныч биналары!* Г. Ибраһимов. *Иске дә иске, һай, түбәсе, Еллар үтеп, кыеклар иелгән.* Н. Исәнбәт.

ИЕ'НА *и.* Япониядә акча берәмлеге.

ИЕНКЕ I *с.* 1. Иелгән, иелеп торган. [*Вульфның*] *иенке гәүдәсе, күтәренке җилкәләре миндә тирән нәфрәт уятканнар иде инде.* А. Расих.

2. *күч.* Буйсынган. *Бу җил, бу туфанны каршы алыр капитан Иенке баш, бөгелгән бил белән.* Г. Камал.

3. *күч. сөйл.* Сүз тыңлый торган, күндәм. *Бик иенке бала.*

ИЕНКЕ II *и. сир.* Уйсу җир.

ИЕРАРХ *и. дини. кит.* Епископның чиркәүдәге рәсми исеме. *Рим иерархы.*

ИЕРА'РХИК *с. кит.* Иерархиягә бәйләнешле, эзлекле. *Иерархик баскыч. Иерархик система.*

ИЕРА'РХИЯ *и. кит.* Хәле, хезмәте, чины буенча түбән дәрәҗәле кешеләрнең яки учреждениеләрнең югары дәрәҗәдәге кешеләргә яки учреждениеләргә эзлекле буйсыну тәртибе. *Феодаль дәрәҗәләр баскычы (иерархиясе) кагыйдәләре белән бәйләп алып карағанда,* [*«Син һәм мин»*] *шигыренең шулай язылуына гаҗәпләнмисең дә.* Х. Госман. *Алтын Урдада бу иерархиянең ничек торышын ярлыкларда күрергә мөмкин.* Н. Исәнбәт. // Эзлеклелек, теземлелек.— *Сез түбәндә, пычракта болганып ятасыз, ә без югарыга күтәрелеп иркен яшибез, басмалар иерархиясен табигать үзе шулай куйган.* Г. Нигъмәти.

ИЕРО'ГЛИФ *и. лингв.* Кытай, япон, корея кебек кайбер халыкларның язу системасында шартлы рәвештә тулы бер төшенчәне, ижек яки аерым авазны белдерә торган рәсемгә охшаш билге. *Кытай иероглифлары япон, корея һәм маньчжур телләрендә дә файдаланыла. Ләкин бу телләрдә иероглиф бөтен сүзне түгел, бәлки ижекне белдерә.* Х. Курбатов.

ИЕРО'ГЛИФИК *с. лингв.* Иероглифларга бәйләнешле, иероглифларга нигезләнгән. *Иероглифик язу.*

ИЕРОМОНАХ *и. дини.* Рухани дәрәҗәсендәге монах. *1912 елда Аксак Низамый җәдитлек һәм иеромонах Ильядор яңүтлек кабул иттеләр.* Г. Тукай.

ИЗА *и.* Җәфа, газап. *Курорттан кайтышка тагын дүрт-биш көн иза: тегендә тынлыкка өйрәнгән газиз башкаең янәдән хатынның --- музыкасына ипләшергә тиеш.* Ф. Хөсни.

Иза чигү — газаплану, җәфалану, интегү.— *Гөбәнәйгә эшләп, иза чигәсебез бар икән быел!* Ш. Маннур. *Прокурор байтактан бирле Давыт белән иза чигг. Күзмә-күз алдашып утырган бу бәндә белән ул чиләнеп бетте.* А. Гыйләҗев.

ИЗАЛАНУ *ф.* Җәфалану, газаплану, интегү.— *Изаланасыбыз бар әле бу Саша белән: --- егет үзенең гаебен бөтенләй оныткан.* Г. Әпсәләмов. *Хәлимә билгесезлектән изаланды.* Ш. Хөсәенов.

ИЗАЛАУ *ф.* Җәфалау, газаплау, интектерү.— *Пычагыма кирәкмени буранда халык изалап, ат азаплап йөрергә!* А. Расих.

ИЗАЛЫ *с.* Интектергеч, җәфалы, газаплы.

ИЗАР *и.* 1. Билгә бәйли торган алъяпкыч (гадәттә мунчада бәйләнә). *Быел яз көне ул хатыныннан --- бер изар [тектерде].* Г. Газиз. *[Мунчада кунакларның] икесен ике хезмәтче чишендерде. Үзләренә дә, кунакларга да изар бәйләделәр.* М. Галәү.

2. Скульптурада ялангач кеше сынларының җенес әгъзаларын каплап торган яфрак сурәте; фига яфрагы.

ИЗАФӘ, ИЗАФӘТ *и. лингв.* Аергыч һәм аерылмыш мөнәсәбәтендә торган исемле сүз тезмәләрендә предметның билгеле бер затка яки предметка нисбәт ителүен белдергән **грамматик кат**егория.

ИЗАХ *и. иск. кит.* Аңлатма, ачыклама. *Кулланган ишарәтләрем хакында изах биреп китүне тиешсенәм.* М. Фәйзи.— *Мәсьәләгә изах кертеп, аңлатып бирсәгез икән?* К. Тинчурин.

Изах итү (кылу) — аңлату, төшендерү, ачыклау. *[Моңарчы] байлык ходай биргәннән, «казна тапкан»нан, очраклы рәвештә байлыкка юлыгудан кебек җаваплар белән изах ител[гән була].* Г. Нигъмәти. *Әдәбиятның да матди тормышка багланган бер тармак икәнен башта изах кылып үтү кирәк.* Г. Ибраһимов.

И'ЗВЕСТЬ *и.* Известьташларны яндырып табыла торган ак минераль матдә. *Сүндерелгән известь.* □ *Ак буяу юк иде, известь белән буядылар.* Г. Гобәй.— *Коры елга буеның туфрагы ачы. Ул известькә мохтаҗ.* Г. Галиев.

Известь сөте *хим.*— сүндерелгән известь белән туендырылган эремә. **Известь сүндерү** *хим.*— төзелештә кулланыла торган известь массасын ясау өчен зәһәр кальцийны (сүндерелмәгән известьне) су белән кушу. **Известь шпаты** *махс.*— к. кальций.

И'ЗВЕСТЬЛЕ *с.* Составында известь булган, известь катнаштырылган. *Известьле су.* □ *Известьле ашламалардан еш кулланыла торганнары — известьле туфрак, доломит оны, известьташлар, акбур.* Х. Байчурова.

И'ЗВЕСТЬЛӘНҮ *ф.* Известькә әйләнү, известь утыру. *Йөткергән вакытта Галимҗанның үпкәсендәге күптән известьләнеп каткан туберкулез учагындагы кан тамыры ярылган.* Г. Мөхәммәдова.

И'ЗВЕСТЬЛӘҮ *ф.* Әчелеген киметү өчен туфракны известь белән ашлау.— *Сезгә, ничек кенә булса да, бу урынны быел яз известьләргә кирәк.* Г. Галиев. // Берәр нәрсәгә известь сеңдерү, известь катнаштыру. *Менә известьләү ысулының бер төре. Башта туралган саламны әле генә сүндерелгән известьнең бер процентлы эремәсендә манчыйлар.* А. Расих.

ИЗВЕСТЬТАШ *и.* Составында известь (кальцит) булган утырма тау токымы (мәсәлән, доломит, акбур, мрамор).— *Известьташ [бу],— ди ул, аксыл ташны карап.* М. Кәримов.

ИЗВЕСТЬТАШЛЫ *с.* Составында известьташ булган, известьташ катнашкан. *Известьташлы көньяк тау битләрендә --- кылган үләннәре зур урын алганнар.* А. Фаткуллин.

ИЗВО'ЗЧИК *и. тар. сөйл.* 1. Ялланган экипажның, олауның, көймәле арба яки чананың кучеры. *Ат янында дилбегә тотып барган извозчик --- вакыт-вакыт арт якка әйләнеп карап ала иде.* Ш. Камал. *Извозчик Шәяхмәт бүген башка көндәге кебек атына сукмый, тургәнми, атының ялкау адымына риза булган хәлдә, кузласында изрәп бара.* Ә. Фәйзи.

2. Кучеры белән берлектә ялланган экипаж. *Монда трамвай юк. Извозчикта эч кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде.* Г. Тукай.— *[Закир], бер бәдбәхет, эштән чыккан нәрсә белән извозчикка утырып, поезд китәр алдыннан вокзалга таба киткән.* Г. Камал.

ИЗВО'ЗЧИҖЛЫК *и.* Извозчик (1 мәгъ.) булу. *Шул мәктәптән хәзер дә җиде татар, өч кыргыз имтихан кылынып, ломовой извозчиклыкка шәһадәтнамә алып чыктылар.* Ш. Мөхәммәдев. *Гомерен извозчиклыкта үткәргән атаның исеме арбага яки чекушкага бәйле булуы гаҗәп түгел.* Қ. Басыйров.

ИЗГЕ *с.* 1. *дини.* Бөтен гомерен аллага багышлаган һәм үзе үлгәннән соң дингә ышанучыларның яклаучысы дип игълан ителгән, аллага якын (зат, әүлия, пәйгамбәр турында). *Мин йөрим ялгыз калып, Изге Йосыфтай ташланып.* Ф. Бурнаш. *[Марко] Катяга изге Варвара йөзеген алып кайткан.* М. Җәлил. / *и. мәгъ. [Хаҗи:] Бер-беребезгә догада булыйк, фаразан, пәйгамбәребез шулай итәргә кушкан. [Хөснетдин:] Шулай, хаҗи әфәнде, шулайдыр. Изгеләр белми әйтмәсләр.* Ш. Камал. // Бик диңле, диндар, тәкъва; суфый.— *Патша сараенда бер изге, аллаяр карт торган.* Т. Гыйззәт.

2. *дини.* Табигатьтән өстен көчкә ия булган, илаһи.— *Төхфәт ул өшкергән изге суларның файдасын сизәме соң?* Ш. Камал. *Минем дә тизрәк шулар янына тезләнеп, шул изге, тылсымлы сүзләрне ятлый-ятлый селкенәсем килде.* Г. Гобәй. // Дини гыйбадәтләр, табынулар белән бәйләнгән (гадәттә дини табыну урыннары һәм әсбаплары алдында даими эпитет булып килә). *Бел дә тор син, изге корбан бәйрәме җиткән бүген.* Г. Тукай.— *Мин сүксәм, вакытын белеп сүгәм. Ә изге гает алдыннан ул сүгәсе булмасын!* Ш. Камал.

3. Башкаларга һәрвакыт яхшылык итә торган, яхшы күнелле (кеше турында). *Бу изге картны ул бераз зурая төшкәч үк эзли башлады. Татарстан иленда аңа охшаган яхшы күңелле картлар бик күп булып чыкты.* Г. Бәширов.— *Артык изге булдык... Дошманны кешегә санадык.* М. Әмир. // Яхшы күңелдән эшләнгән, башкаларга яхшылык китерә торган. *Яхшылыкка эреп китәм — балавыз мин, Мактап сөйлим изге эшне — бал авыз мин.* Г. Тукай.

4. Тормышта, үз-үзен тотышында тел тидермәслек, югары әхлаклы, чиста, саф күнелле.— *Фәрештә кебек изге балада шундый бозыклык буламы соң?* Р. Ишморат. *Анамны хәтерли алмыйм, --- ул, белмим, бик матур, белмим, бик изге булган, ни дә булса бар, аны һәммә кеше яхшы исем белән яд итә.* Г. Ибраһимов.

5. *күч.* Бөек, гүзәл, саф. *Халык изге ул, туган, халык зур көч ул! Кыен чагында синең атаң да була ул, анаң да!* Г. Бәширов. *Баланың анага булган чиксез зур, кадерле, изге мәхәббәте аларның күңелләрендә сакланып калган.* Г. Әпсәләмов. // Газиз, жанга якын, хөрмәтле, кадерле.— *Хезмәт көне ул бил бөгеп, маңгай тире агызып эшләгәндә генә хезмәт көне! Шул чагында гына ул изге һәм кадерле.* А. Шамов. *Безнең татар халкы гомер-гомергә икмәкне изге нәрсә дип санаган.* Н. Дәүли.

6. *күч.* Гаделлек, азатлык өчен алып барыла торган (сугыш, көрәш турында); гадел. *Багышлармын калган гомерне Ирек өчен изге көрәшкә.* М. Җәлил. *Бөтенесен сиңа, сиңа бирәм, Ватанымның изге сугышы!* Ф. Кәрим.

7. *күч.* Күл сузарга ярамый торган, кагылгысыз, мөкатдәс.— *Колхоз милке ул — җәмәгать милке, изге милек, аны әрәм-шәрәм итү һич тә ярамый.* А. Шамов.

Изге ай *дини* — ислам дине буенча: рамазан һәм мәүлет айлары.— *Уразада гошер бирмәү зур гөнаһ*

бит, көфер бит! Шундый изге айларда да имамнарны оныткач,— [*ди мулла*]. М. Җәлил. **Изге ата** *дини* — христиан динендә руханиның исеме. *Череп кипкән Исус Христосның «Җир вәкиле» — Рим папасы, Сөрсеп беткән чиркәү әһленең Күз терәгән «изге атасы».* М. Гафури. **Изге рух** *дини* — пәйгамбәр. *Түбәнлек бу, кабул итмәс үзенә изге рух аны!* Г. Тукай.

◇ **Изге киселү** — суфый, тәкъва, яхшы күңелле булып кылану. *Ачыктан-ачык фәхешханә тотып та,* [*Мифри җиңгинең*] *изге киселеп утыруына ачу килеп китте.* Ә. Фәйзи. **Изге сәгать** — күптән көтелгән, бөек, мөкатдәс мизгел, вакыт. *Сукты безнең изге сәгать, Бөек җиңү сәгате.* Ә. Ерикәй. **Изге сәгате белән (изге сәгатьтә)** — берәр эш алдыннан уңыш теләп әйтелә; хәерле сәгатьтә.— *Берсекөннәргә --- бәхетне сыныйк әле. Изге сәгате белән булсын.* Ш. Камал.— *Изге сәгатьләрдә, төкле аягың белән, бәхетең, тәүфыйгың белән!* Г. Бәширов. **Изгедән явыз туган (нәрсә)** *сөйл. тирг.*— *к.* яхшыдан яман туган.

ИЗГЕЛЕК *и.* **1.** Изге (1, 2 мәгъ.) булу. *Мине ишан дигәннәр һәрберсе синдәй ишәк, Минем изгелегемә һичберсе китермә шәк.* Г. Тукай. // Изге эш. *Мәчеткә барып изгелек эшләгән кеше шул ук көндә, күбесенчә кичкә таба, берәр җиргә барып исереп кайта һәм өйнең астын өскә китерә торган иде.* Ш. Камал.

2. *к.* игелек (1 мәгъ.). *Кешедә явызлык түгел, изгелек өстенлек итә.* И. Нуруллин. *Изгелек җирдә ятмас.* Мәкаль. *Василий үзе дә офицердан бернинди изгелек көтми иде.* Ә. Еники.

3. Саф күңеллелек, югары әхлаклылык. *Хәзер инде Шүрәле безнең егеткә ялына, Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына.* Г. Тукай.

4. *күч.* Кагылгысызлык, кул сузарга ярамау. *Буржуазия хосусый милек «изгелеген» халык миенә сеңдерү өчен --- бөтен юлларны файдаланды.* М. Җәлил.

Изгелек итү (кылу) — 1) динлелек, тәкъвалык күрсәтү. *Ул, бичара, вакыты җитеп, гыйбадәтен кылып, намазлыгы өстендә үлде дип әйтерлек, һаман изгелек кылып үлде.* М. Гафури; 2) яхшылык эшләү. *Әмиров исеменә җибәрелгән ун сум акчагызны* [*алдым*]. *--- Бу изгелегеңезгә каршы изгелек кылп алырмын дип --- өмитем бардыр.* Г. Тукай.

ИЗГЕЛЕКЛЕ *с.* Игелекле, яхшы күңелле, шәфкатьле. *Аларның балалары берсе артыннан икенчесе үлеп торганга күрә, бала үстереп, аның кызыгын күрүдән, кеше төсле, изгелекле балаларның хезмәтләреннән мәхрүм булганнар.* М. Гафури. *Низами аны юатты: «Елама, әби, исән-сау калага керә алсак, мин сиңа үзем бишь кадак* [*он*] *бирермен!» — диде. Карчык дөньяда әле дә шундый изгелекле адәмнәр барлыгына хәйран калды.* Г. Ибраһимов.

ИЗГЕЛӘНҮ *ф.* Изгегә әйләнү. // Изге булып күренергә тырышу.

ИЗГЕЧ *с.* **1.** Нәрсәне дә булса изә, сыта торган.

2. *күч. сир.* Рухи яктан газаплый, рухи авырлык китерә торган. *Зур өмит баглаган --- угылы Сабирның югалуы хакындагы хәбәрне алгач, Җәләл хәрәт --- авыр вә изгеч булган бер --- вәҗүткә килгәнен тойды.* Г. Ибраһимов. [*Шакир*] *гаять авыр вә җан изгеч оныгылуга чумды.* Ф. Әмирхан.

ИЗЕЛДЕК *с. сөйл. шелт.* Бик йомшак, акрын кыймылдаучы, мәлҗерек (кеше турында).

ИЗЕЛҮ *ф.* **1.** *Кайт., төш. юн. к.* изү (2—6 мәгъ.). *Иптәш алты потлык сабын кисәген күтәреп илткән җиреннән сөртенеп егылды да сабын астында калып изелде.* Ә. Фәйзи. *Бичара апа --- бала хәсрәте белән дә изелә, газаплана иде.* Ш. Камал. *Изелгән милләт халкын чын-чыннан азат итү, милли кысынкылык һәм хокуксызлыкларны бетерү бары самодержавиегә һәм эксплуататорларга каршы күтәрелгән эшче-крестьян революцион хәрәкәтенең җиңүе белән генә мөмкин иде.* М. Җәлил.

2. Су, дым яки җылылык тәэсире белән йомшару, жебү, изрәү. *Шул көннәрдә генә яуган йомшак кар эреп, аяк асты пешмәгән боламыкка әйләнде, юл тәмам изелде.* Ф. Хөсни.— *Аш пеште, токмач изелеп бетә.* Г. Ибраһимов. // Төзелештә су, ком һ. б. материаллар кушу нәтиҗәсендә йомшару (балчык, бетон турында); үзләнү.— *Бу яңа изелгән кызыл балчык нигә биредә?* Г. Гобәй. // *рәв. мәгъ.* **изелеп.** Гомумән йомшарып. *Гөлҗимешләр изелеп пештеләр.* М. Җәлил.

3. *күч. сөйл.* Эсселектән, исерткеч эчемлектән яки бик нык арганлыктан хәлсезләнеп, организм йомшау; мәлҗерәү. [*Сиражетдин*] *урындыкка егылып, изелеп төшә.* Г. Камал. / *и. мәгъ. Мулла артык исереклегеннән үз аягы белән керә алмады, аны абыстай күтәреп алып диярлек кертте. Аның изелүе актык чиккә җиткән иде.* Г. Ибраһимов.

4. *рәв. мәгъ.* **изелеп.** Бик каты, изрәп (йоклау турында). *Өй эче тәмам тыныч ланды... Барысы да изелеп йокыга китте.* Ф. Агеев. // Рәхәтләнеп, бик нык мавыгып, онытылып. *Көтүче дә сулышын көчкә генә алып, сандугач тавышын эреп, изелеп тыңлый иде.* Г. Тукай.— *Кәрим абзагыз ул бик сүз ярата торган кеше. Сүзгә керешеп киткәндер дә тик изелеп утыра торгандыр.* Г. Камал.

5. *гади с.* Каты курку, каушау.— *Турысын әйтергә кирәк,* [*Нәфисә*] *изелеп төшмәде, үзенекен итте.* Г. Бәширов. *«Каптым» дип уйлады ул һәм тәмам изелеп төште, тик шунда гына үзен кулга алып, күз ачып йомганчы дошманына ташланды.* Г. Гобәй.

6. *күч. сөйл.* Бер үк сүз кат-кат сөйләнү, кабатлану, чәйнәлү.

Изелеп китү — каты йокыга талу, изрәп йоклау. *Ул гадәттә мендәренә башын төртүгә изелеп китә иде, бүген исә гел борчылып ятты.* Г. Гобәй.

◇ **Изелгән арыш боламыгы** *гади с. тирг.*— *к.* арыш боламыгы.— *Исмәгыйльнең аласы кызы --- да шул бер изелгән арыш боламыгыдыр әле.* Г. Камал.

ИЗЕН *и. кит. иск.* Рөхсәт, фатиха, ризалык. *Карт әйтте: --- «Әгәр изен булса, сөйлим»,— диде. Патша әйтте: «Сөйлә».* Әкият. *Габбас июнь ахырында атасыннан Мәкәржәгә кәсепкә барырга дип рөхсәт вә паспорт сорап хат язгач, атасы изен бирде һәм паспорт та җибәрде.* З. Һади.

Изен ясау — рөхсәт бирү. *Шаһмара бер еланга куште: «Бар, чыгар моны»,— ди, койрыгы белән изен ясый үзенә.* Әкият.

ИЗЛОЖЕ'НИЕ *и. к.* инша.

ИЗМӘ *и.* Төзелештә: цемент, алебастр, гипс, известь һ. б. ш. матдәләрне суга изүдән барлыкка килгән камыр сыман катнашма. *Цемент измәсе.* □ [*Алар*] *балчык измәсе белән тагын забой стеналарын сыладылар.* Г. Ахунов. *Панельләр тигез булгач, түшәмнәрне инде элеккечә калын итеп штукатурламаска, измә белән юка гына итеп ышкып, шомартып чыгарга* [*мөмкин*]. М. Садри.

◇ **Измәсен изү** *гади с.*— бик каты, аякта тормаслык итеп, имгәтеп кыйнау.— *Хәзер аяк-кулыңны сындырып, измәңне изеп, әнә тегендә, ишекнең теге ягына кертеп ташлыйбыз.* М. Әмир. [*Малай*] *Илдарның якасыннан элэктереп тә алды: «Измәңне изәм бит, бүдәнә!»* Г. Гобәй.

ИЗМӘЧЕ *и.* Измә ясаучы эшче.— [*Исәнмесез*], *бетончы һәм измәче дуслар!* З. Нури.

ИЗНИГАМ *и. иск. кит.* Ирек, рөхсәт.— *Бездән изнигам! Әнә, үзегезгә кирәк фәннәрне урамнарда коты-рынып йөргән бозык зимагурлардан, сукбайлардан* [*әйрәнерсез*]*!* К. Тинчурин. *Калган вакытларда — бакчага төшеп «яшелчә урлаучылар» өчен, Миңлебикә остабикә әйтмешли, изнигам!* З. Бәширн.

ИЗО- *Изобата, изотерма, изоглосса* кебек кушма сүзләрнең «бертигез, бертөрле, бер үк, охшаш» мәгънәсендәге беренче өлеше.

ИЗОБА'РА *и. геогр.* География картада атмосфера басымы бер үк дәрәҗәдә булган урыннарны тоташтыра торган сызык.

ИЗОБА'РИК *с. геогр.* Изобарага бәйләнешле. *Изобарик метод.*

Изобарик процесс *физ.*—даими басым астында бара торган процесс (мәсәлән, химик реакцияләр, эчке ягулы двигательләрдә ягулыкның яныу һ. б.).

ИЗОБА'ТА *геогр.* География картада диңгез төбенең бер үк тирәнлектә булган урыннарын тоташтыра торган сызык.

ИЗОБУТАН *и. хим.* Составы белән бутанга якын булган углеводород кушылмасы.

ИЗОГЛО'ССА *и. лингв.* Диалектологик картада бер үк тел күренешләре булган урыннарны тоташтыра торган сызык.

ИЗОЛЯ'ТОР *и.* 1. Электр тогы үткәрми торган матдә (мәсәлән, гәрәбә, эбонит һ. б.).

2. Электр чыбыкларын изоляцияләү, беркетү өчен кулланыла һәм, күбесенчә, фарфордан яки пыяладан ясала торган әйбер. *Югары вольтлы электр үткәргечнең челтәрле корыч тәрәкләре[нда]* --- *ак чынаяк изоляторлар ялтырый.* Г. Әпсәләмов.

3. *кит.* Җылылыкны аз үткәрә торган әйбер. *Һава катламы — яхшы изолятор.*

4. Йогышлы авыру белән авыручыларны, акылдан шашканнарны, кулга алынганнарны һ. б. ш. әйләнә-тирәдәгеләрдән аерым тоту өчен махсус бина яки бүлмә. *Кайсы хәерсезедер ящур белән чирләү сәбәпле изоляторга алынган сыерларны ишек алдына куып чыгарган.* М. Хәсәнов.— [*Ул*] *әгәр тагын акырса, изоляторга чыгарып ябыгыз.* Г. Әпсәләмов.

ИЗОЛЯЦИОН *с.* Изоляциягә (1 мәгъ.) бәйләнешле. // Изоляция өчен файдаланыла торган. *Изоляцион лента.*

ИЗОЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. Токны яисә җылылыкны үткәрми яки аз үткәрә торган материал. *Сания тырнаклары белән ток чыбыгының изоляциясен әрчи.* Ш. Маннур.

2. Кемне дә булса тирә-юньдәге кешеләрдән, берәр илне, сыйныфны икенче илләр, сыйныфлар белән бәйләнештән, аралашудан аеру, бүлеп алу. *Сүрия акрынлап политик изоляциядән чыга башлаган иде.* М. Мәхмүтов.

ИЗОЛЯ'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Изоляцион материал белән каплау, чорнау.

2. Тирә-юнь белән бәйләнештән, аралашудан мәхрүм итү. *Авырулар булган тәкъдирдә, шунда үк изоляцияләргә кушып, дивизия врачы М. Е. Ястребевны Занбега җибәрдем.* Ф. Булатов. *Рыкалов безне алдаган.* --- *Аны бер минут тотмый изоляцияләргә киләк.* Г. Әпсәләмов.

ИЗОМЕР *и. хим.* Химик составы һәм молекуляр авырлыгы ягыннан бер үк булып та, молекула төзелеше төрле булган кушылмаларның берсе.

ИЗОМЕРИ'Я *и. хим.* Составы һәм молекуляр авырлыгы бер үк булган химик кушылмаларның физик һәм химик сыйфатлары, төзелешләре белән аерылу күренеше.

ИЗОМОРФ *с. хим.* Кристалларының формалары һәм үзлекләре бердәй булган, изоморфизмга ия булган.

ИЗОМОРФИЗМ *и. хим.* Бердәй химик составлы ике яки берничә матдәнең катнаш составлы кристалларга әйләнә алу сәләте.

ИЗОПРЕН *и. хим.* Ике иярмә бәйләгече булган туендырылмаган углеводород (синтетик матдәләр эшләгәндә кулланыла).

ИЗОТЕ'РМА *и.* 1. *геогр.* География картада сызгеле бер вакыт аралыгында уртача бердәй температура булган урыннарны тоташтыра торган сызык.

2. *физ.* Җылылык процессы диаграммасында бер үк температураны күрсәткән ноктaларны тоташтырган сызык.

ИЗОТЕ'РМИК *с.* 1. *геогр.* Изотермага (1 мәгъ.) бәйләнешле.

2. *физ.* Бертөрле яки даими температуралы. *Изотермик процесс. Изотермик вагон.*

ИЗОТОП *и. хим.* Бер үк химик элементның атомнары арасында үзенең авырлыгы ягыннан аерылып торган атом. *Хәтерем ялгышмаса, ул су кислородындагы изотопларның нидән гыйбарәт булуын тикшерә.* Каз. утл.

ИЗОТРОП *с. махс.* Төп физик үзлекләре һәр яктан да бертөрле булган. *Изотроп мохит. Изотроп тирәлек.*

ИЗОХРОМА'ТИК *с. физ.* Барлык төсләрне бертөрле күрсәтә, бирә торган. *Изохроматик негатив материалларга күренә торган төсләр барысы да тәэсир итә. Шуңа күрә аларны караңгыда гына эшкәртергә ярый.* Ф. Акчурин.

ИЗОХРОН *с. махс.* Бер үк дәвамлылыктагы. *Тавыш дулкыннарының изохрон тирбәнүләре.*

ИЗОХРОНЛЫК *и. махс.* Теге яки бу процесс, күренеш бер үк дәвамлылыкта булу. *Маятник тирбәнүенең изохронлыгы.*

ИЗРӘТҮ *ф.* 1. Берәр каты нәрсәне йомшарту, җебетү. [*Ул*] *бер дә кирәкмәгәнгә сабын изрәтә.* М. Галәү. / *з-сыз. Юлны изрәткән. Аяк атлавы авыр.* Э. Касыймов.

2. Рәхәтлеккә талдыру. [*Ул*] *суга төшеп битен дә юа, ләкин файдасы аз, йокы һаман изрәтә.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч. диал.* Изү, сыту.— *Карагыз, кара, Хава анабыз, аю анасы бара... Аяк астына эләгә күрмәгез,* --- *изрәтеп ташлар.* Ш. Камал.

ИЗРӘҮ *ф.* 1. Су, дым яки җылылык тәэсирендә йомшару, җебү, сыегаю. [*Ат*] *тыпырчынган саен, пычрак тагын изри төштә.* Г. Бәширов. *Минһаҗетдин, һәр көнне шушы бүгенге төсле изрәп апарага әйләнә язган токмачны ашап, бу көнгә кадәр яшәде.* К. Тинчурин.

2. *диал.* Тузу, җепләре юкарып, искереп өзелә башлау (тукыма турында).— *Күлмәкләрең изрәп беткән, җеп тотарлык җирләре дә калмаган!* М. Гафури.— *Ыкмык итәсең дә, әллә нихәтле машина мае сеңдергән чалбарыңның күпне күрүдән изри башлаган тез күзенә карыйсың.* Г. Мөхәммәтшин.

3. *күч.* Тән рәхәтлеккә талу, рәхәт ою. *Йокы рәхәтендә изрәгән сабый куллары белән муенымны кочып ала да* --- *мышный-мышный йоклый.* Г. Минский. // Йокы басу, йокымсырау. *Без, Шиһап бабайның әкиятләрен тыңлап пинкә тетә-тетә, изрәп утырабыз, кайчакта шулай йоклап та китәлә.* Г. Гобәй. // Тәмле, татлы, тыныч һәм каты йокыга талу. *Батыр төрлечә уйлар берлә ут янына килеп ятты. Җылы ут каршысында изрәде, күп тормады яткач, кара ат кешнәп җибәргәч тә уянды.* М. Гафури. *Илгизәр, елап арыгач, кровать кырыена башын төрткән килеш, изрәп китте.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Бик курку, каушау, артык юашлану, җебү.— *Бирдек малайга кирәген.* --- *Малаең изрәп төште: үтермәгез, абзыкайларым, моннан соң якын бармам, башыахыры шул булыр, дип елый-елый тәүбәгә килде.* Г. Ибраһимов. *Ә ул, куян йөрәк, шул сүздән изрәп төшә.* К. Нәҗми.

◇ **Изрәгән арыш боламыгы** *гади с. тирг.*— *к.* арыш боламыгы. **Изрәгән кабак бәлеше** *гади с. мыск.*— мәлҗерәгән, җебегән кешегә карата әйтелә. [*Гөлҗамал:*] *Ә без чәчрәп торган физкультурный комсомолка булган булыр идек.* [*Локман:*] *Ай, изрәгән кабак бәлеше!* Ш. Камал.

ИЗЮБР *и. зоол.* Көнчыгыш Себердә яши торган эре болан; маралның бер төре.

ИЗӘҮ *ф.* (Чакыруны яки, киресенчә, саубуллашуны һ. б. ш. ны белдереп) кулны беркадәр күтәреп, нинди дә булса ишарә ясап селтәү, болгау. *Мисбах алар арасында Газинурны шәйләде һәм үзе дә сизмәстән, кул изәде. Янәсе, монда кил, мин яраландым.* Г. Әпсәләмов. [*Кыз*], *нәфис кулын җиңелчә изәп, ишектән чыгып күздән югалды.* К. Тинчурин. // Кул селтәп яки башны хәрәкәтләндереп кемгә яки нәрсәгә дә булса күрсәтү; берәр әйбергә карарга, игътибар итәргә чакыру. [*Ул*] *башы белән түргә таба изәде.* И. Гази. *Барый да чыбыркы сабы белән изәп имәнгә ишарәли, күрдеңме, янәсе.* А. Гыйләҗев.

ИЗҮ I *ф.* **1.** Каты яки порошок сыман нәрсәне су кушып болгату, йомшак, сыек яки боламык хәленә китерү.— *Бар, кызым, син юынганчы, мин камыр изеп җибәрим.* Т. Гыйззәт. [*Ул*], *балакларын тездән сызганып, иртәдән кичкә кадәр аягы белән кызыл балчык изә.* Г. Гобәй. *Александра Андреевна --- изгән бәрәңге белән котлет, ак күмәч --- китереп куйды.* М. Гали.

2. Берәр әйберне зур авырлык астында калдырып басу, яньчү, сыту, таптау, формасын бозу. *Таш ава, Баязитның өстенә таба ишерелеп килә. Менә, менә хәзер таптап, изеп китәчәк.* Г. Ибраһимов. *Чәчәкләрне шыгырдатып изеп, Чыгып китте авыр машина.* Ш. Маннур.

3. *күч. гади с.* Бик каты кыйнау, кыйнап хәлдән тайдыру. — *Аз гына нәрсә белән тотылып эләктең исә, чистый изеп бетергәнче кыйныйлар.* Г. Камал. *Теге малайны канга батырып, үтергәнче кыйнаган төсле, аны да изеп ташласалар, ни эшләрсең?* К. Тинчурин. // Кырып бетерү, үтерү, юк итү. *Ватанны сөйгән кеше дошманны изеп бетермичә үзенең йортына кайтмаска тиеш.* Ш. Камал.

4. *күч.* Йөрәккә авыр булып, борчып, җәфалап, газаплап тору. *Күңелсез, эч поша, шунысы изә.* Г. Тукай. *Бу ачы-ачы уйлар Шакирны шулкадәр изделәр ки, ул үзенең вөҗүдендә бер сыкрану сизде.* Ф. Әмирхан.

5. *күч.* Төрле авырлыклар, дөнья мәшәкатьләре басу, азап чиктерү; хәлдән тайдыру, эштән чыгару. *Караңгылык, коллык, ярлылыклар безнең бабайларны изгәннәр.* И. Хәйруллин.— *Картайдым инде, киям, юклык изде.* Һ. Такташ. // Физик, психик яктан организм таушалу.— *Мин нервлы кеше, фронтлар мине изде.* Ш. Камал.

6. Экономик, политик һәм рухи яктан кысынкылыкта тоту, җәберләү. *Капитал дөньясы изде, Кол итәргә тели безне.* Г. Камал. [*Безне*] *изеп килгән әфәнделәр власть башыннан куып төшерелде.* И. Гази. / *и. мәгъ. Октябрь революциясенә кадәр* [*Казан губерниясе*] *халыклар төрмәсенең иң типик бер почмагы булып килде, монда хезмәт ияләре ике катлы изү астында — Россия самодержавиесе һәм үз милли буржуазиясе изүе астында — яшиләр иде.* К. Нәҗми. // *күч.* Үз властена һәм йогынтысына бөтенләй буйсындыру. *Сафи — муен, Фатыйма апай — баш иде. Сафи абзыйны изәр* [*иде*], *көрпә кеби.* Г. Тукай. // Эксплуатацияләү.— *Ул революция дигәннәре, --- Шәйхи бай шикелле, безнең кеби ярлыларның каннарын сыгып эчүче мәлгуньнәрдән элеккечә безне издермәү, безне кол итмәү өчен ярлылар файдасына чыгарылган бернәрсә икән.* М. Гали. // *и. мәгъ.* Эксплуатация. *Хезмәт ияләрен аяусыз изүгә — эксплуатациягә нигезләнгән капиталистик система эшчеләр һәм ярлылар сыйныфыннан исәпсез күп корбаннар чыгарып ташлый.* М. Җәлил.

7. *гади с.* Бер үк сүзне кат-кат сөйләү, кабатлау; бер үк мәсьәләне кирәгеннән артык тикшерү.— *Сез зирәк егет, сездән зур кеше чыга... Халкыгызга зур хезмәт күрсәтә алырсыз...*— *дип,* [*ул*] *картларча озак изеп килә.* Г. Ибраһимов.

8. *күч. гади с.* Урынсызга, зарарга берәр эш эшләү, җайланган эшне бозу. *Менә Хәйдәрнең үзенә дә сәхнәгә чыгар вакыт җитте. Ул үзе өчен түгел, һаман да Нәфисә өчен борчыла иде: «Изеп кенә ташламаса ярар иде бу нәрсә!»* Г. Бәширов.— *Теге тишек авызлар изгәннәр бит эшне.* Г. Гобәй. // Танымаслык, аңлашылмаслык хәлгә китереп бозу. *Ахун бу коръән аятьләрен шулкадәр сындыра, шулкадәр изә иде.* Г. Тукай. *Һәммәсе* [*килешле*] *уйнадылар, тик чегән хатыны — Алмазова гына изде: татар сүзен дә* [*әйтә*] *алмагач, сәхнәгә аяк басмау кирәк иде.* Ш. Әхмәдиев.

ИЗҮ II *и.* **1.** Киемдә муен турысыннан күкрәк ягына таба уелган ерык һәм шул ерыкның һәр ике ягы. *Күлмәк изүе. Изү ычкындыру. Изү еру.* □ [*Фәсхи*] *гимнастерка изүен чишеп җибәргән, ачык изү аша көчле муены һәм төк баскан күкрәге күренеп тора.* Ф. Хөсни. *Кыз эшеннән туктады, җебен теше белән өзеп, инәсен изүенә чәнчеде.* А. Шамов.

2. *этн.* Революциягә кадәр татар хатын-кызларының, төрле төстәге ленталарны изү (1 мәгъ.) тирәли тегеп, аларны укалар белән чигеп, тәңкәләр һ. б. зиннәтләр белән бизәп эшләгән, күлмәк якасыннан алып билгә кадәр бөтен күкрәкне каплый һәм бизәү өчен күлмәк өстеннән кия торган күкрәкчәсе. *Борын-борын заманнарда хәзерге картларның бабалары --- Аланбашның хәситәләр белән уралган, түшләренә көмеш тәңкәдән изүләр аскан көяз кызларын күзләргә барган*[*нар*]. Г. Бәширов.

ИЗҮЛӘШҮ *ф. сөйл.* Сугышу, изүдән II (1 мәгъ.) тотып кыйнашу. *Җыелыш кайнап торган казанга әйләнде. Кемнәрдер изүләшеп алдылар. Кемнәрдер бер-берсенең нәсел-нәсәбен тикшереп алды.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ИЗҮЧЕ *и.* Политик, экономик һ. б. өлкәләрдә кысучы, җәберләүче; эксплуататор. *Барлык милләт хезмәт ияләре үзләрен изүчеләргә каршы күтәрелделәр.* К. Нәҗми. *Бу илдә инде эшче канын имүче сөлекләр дә, сука артыннан бил бөгүчеләрне изүчеләр дә бөтенләй калмадылар.* А. Алиш.

ИЗҮЧӘ *и. диал.* **1.** *к.* күкрәкчә.

2. Кием өстеннән киелә торган күкрәкчә сыман җиңсез камзул.

ИЗһАР: изһар итү (кылу) *иск. кит.*— теге яки бу нәрсәне, хәбәрне, уйны кешеләргә ачып бирү, белдерү, сөйләү. *Ул миңа һәрвакытта җылы йөз күрсәтә, күңелендә булган аналык мәхәббәтен изһар итә.* М. Гафури. *Мин ачык, көләч йөз белән аңа үз шатлыгымны изһар кылырга тырышам.* Ш. Әхмәдиев.

ИКЕ *сан.* **1.** Бердән соң килә торган бөтен сан, аның исеме һәм бу санны күрсәткән цифр. *Бер, ике, өч. Җыелып зур көч, Дошман башына Төшер зур чүкеч!* Г. Камал.— *Икегә икене кушсаң, нәкъ дүрт була ул, кордаш.* Р. Төхфәтуллин. // 2 санының микъдары. *Нәҗип Җиһанов студия елларында клавирда ике опера («Качкын» һәм «Ирек») язып бетерде.* М. Җәлил. *Әлфия ике эш алып бара: хисапчы да, звеновод та.* Г. Әпсәләмов.

2. *к.* икеле (3 мәгъ.). *Начар малайга, билгеле, «ике»не куялар. Юк, Зиннәтнең бер дә «ике» билгесен аласы килми.* А. Шамов.

Ике авызлы *зоол.*— кеше яки хайван тәнендә паразит булып яши һәм ике имгечләләр отрядына керә торган яссы суалчан. **Ике басулы** *а.-х.*— бер яки ике төрле культура һәм пар чиратлашулы. *Ике басулы игенчелек системасы.* **Ике башлы мускул** *анат.*— ике өскесеңер белән калак сөягенә, э аскы сеңер белән беләк сөягенә тоташып, кыскарганда беләкне кулбашына тарта һәм кулны терсәктән бөгә торган мускул; бицепс. **Ике буын** *мат.*— ике бербуын суммасы яки аермасыннан торган алгебраик аңлатма; бином (мәсәлән, a + b). *Ике буынлы тигезләмәләр.* **Ике властьлылык** — илдә, шәһәрдә, оешмада һ. б. ш. бер-береннән кискен аермалы ике

властьның бер үк вакытта яшәве. *Февральдән соң Россиядә ике властьлылык барлыкка килә: бер үк вакытта пролетариатның һәм крестьяннарның революцион-демократик диктатурасы органы сыйфатында эшче һәм солдат депутатлары Советлары да, буржуазия органы булган Вакытлы хөкүмәт тә яши.* М. Хәсәнов. **Ике канатлылар** *зоол.*— бер пар канатлары булган бөҗәкләр отряды (аңа чебен, черки, кигәвен һ. б. керә). **Ике капкачлы клапан** *анат.*— канның йөрәктәге сул колакчыкка кире агып керүен тоткарлый торган һәм йөрәкнең сул карынчыгында урнашкан клапан. **Ике капкачлылар** *зоол.*— ике капкачлы кабырчык (яки бака кашыклары) эчендә яшәүче умырткасыз йомшак тәнле, җәенке саңаклы моллюскләр классы. **Ике капкачлы җимеш** *бот.*— өлгереп җиткәндә каты кабыгы икегә аерылып китә торган җимеш. **Ике кардәш каны** *бот.*— 1) оешма чәчәкләләр семьялыгына караган һәм тажларыннан май, буяу ясала торган үсемлек; ялган зәгъфран; *русчасы:* сафлор красильный; 2) шул үсемлекнең чәчәкләреннән ясала торган кызыл һәм сары буяу; 3) шул үсемлекнең орлыкларыннан ясалган һәм азык өчен яки техник максатларда кулланыла торган эфир мае. **Ике кырлы почмак** *мат.*— ике яссылык кисешүеннән барлыкка килгән почмак. **Ике көчлеләр** *бот.*— дүрт данә аталык эгъзасының икесе озынрак булган үсемлекләр. **Ике мөгезле кәркәдән** *зоол.*— кечкенәрәк икенче мөгезе булган Африка кәркәдәне (**мөгезборыны**). **Ике нокта** *лингв.*— аслы-есле ике ноктадан гыйбарәт тыныш билгесе. [*К. Насыйри*] *90 нчы еллардан соң басылган әсәрләрендә --- сызык (—) һәм ике нокта (:) куллануга күчә.* Л. Җәләй. *Малай бик матур хәрефләр белән тактага: «Ленин сказал»,— дип язып куйды һәм, акбурын борабора, ике нокта төртте... Ике ноктадан соң, хәрефләрен куерак итеп: «Учиться»,— дип язып куйды.* Г. Гобәй. **Ике оксидлы** *хим.*— теге яки бу элемент атомының кислородның ике атомы белән кушылмасы. **Ике орлыклы** *бот.*— берьюлы ике орлыгы булган. **Ике саңаклылар** *зоол.*— баш һәм авызлары янында капшавычлары булган моллюскләр классына кергән диңгез хайваннары (каракатица, спрут). **Ике составлы** *лингв.*— ия, хәбәр һәм аларга караган иярчен кисәкләре булган. *Ике составлы җөмләдә барлык кисәкләр дә ике үзәккә — ия һәм хәбәр янына* [*тупла*]*налар.* М. Зәкиев. **Ике стопалы** *әд.*— ике стопадан (буыннан) торган. *Г. Тукайның «Кичке азан», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырьләре ике стопалы ямблар белән язылганнар.* Г. Нигъмәти. **Ике тактлы** *тех.*— пешкәкнең ике йөреше бер тулы цикл ясый торган. *Ике тактлы двигатель.* **Ике телле** *лингв.*— бер тел сүзе икенче тел сүзе белән тәрҗемә ителеп бирелгән. *Ике телле сүзлек.* **Ике тереклекле** *зоол. иск.*— суда да, корыда да яши торган; җир-су (хайваны). **Ике төркемлеләр** *бот.*— аталык эгъзалары ике чук булып үскән үсемлекләр классы. **Ике төртке** *лингв. иск.*— *к.* ике нокта. *Язуда мондый җөмләләрдә санау, озынлау алдыннан ике төртке (:) куела.* Г. Алпаров. **Ике юл** *әд.*— *к.* ике юллык. *Чулпанлы тагын икешәр юллы берничә шигырь әйтте, Габдулла да аңа шундый үк ике юллар белән җавап кайтара барды.* Ә. Фәйзи. **Ике юллык** *әд.* — билгеле бер мәгънә бердәмлеге тәшкил иткән һәм үзара рифмалашкан ике шигырь юлыннан торган строфа яки бер бөтен шигырь; дистих. *Касыйдәнең һәр ике юлы үзара рифмалаша торган мәснәвиләр (ике юллыклар) белән язылган төре дә Тукайда бар.* Ә. Исхак. *Ш. Галиевнең дә үткен итеп язылган ике юллыклары, дүрт юллыклары байтак.* Н. Юзиев. **Ике өйлеләр** *бот.*—ата һәм ана чәчәкләре төрле төптә булган үсемлекләр. [*Артыш*] *май аенда --- яшькелт һәм саргылт чәчәкләр — ата һәм ана чәчәкләр* [*ата, чөнки*] *ул ике өйле.* Г. Хәсәнов. **Ике өлешлеләр** *бот.*— орлык яралгылары ике аерым төштән торган һәм орлыгы тышча белән капланган үсемлекләр (мәсәлән, **имән, каен, чия, кәбестә**). **Ике җенесле** — 1) *анат.* аталык һәм аналык органнары булган кеше; кызтәкә, хонса; 2) *зоол.* шундый хайван; 3) *бот.* аталык һәм аналык эгъзалары бер чәчәктә булган үсемлек.

◇ **Ике авыз сүз** *сөйл.*— берничә сүз, кыска гына җөмлә. **Ике авыз сүз белмәү** *сөйл.*— берәр телдә бөтенләй сөйләшә алмау. *Аның әтисе русча ике авыз сүз белми.* И. Гази. **Ике авыз сүз кайтарып әйтә алмау** *сөйл.*— каршы сүз әйтә алмаучы бик юаш, куркак кешегә карата әйтелә. *Гадәттә ике авыз сүз дә кайтарып әйтә алмый торган мескен, йомыкый кешенең кинәт кенә кабынып китүенә, әллә нинди аңлаешсыз, бәйләнешсез сүзләр сөйләп ташлавына Садыйк абзый чын-чынлап гаҗәпкә калды.* Н. Фәттах. **Ике авыз сүз (җөмлә) оештыра (җыеп әйтә, сөйли) алмау (белмәү)** — 1) психик, физик зәгыйфьлек яки исереклек нәтиҗәсендә тел бәйләнү, тел көрмәкләнү; рәтләп сөйләшерлек хәлдә булмау. *Мидхәт үзе ике авыз сүзне дә оештырып әйтә алмаслык исерек иде.* Ф. Хөсни; 2) кеше белән рәтләп сөйләшергә өйрәнмәгән, тел культурасы түбән булган яки надан кешегә карата әйтелә. *Әгәр безнең мәдрәсәләребез һаман шул көе ике җөмлә дә оештыра алмый торган шәкертләр чыгаруында дәвам итсәләр, --- һичбер вакытта бездә үз әдәбиятыбыз булыр, яхшы да булыр дип өмит итәргә юл юктыр.* Ф. Әмирхан; 3) *к.* ике авыз сүз белмәү. **Ике агач арасында адашу** — бик гади мәсьәләләрне дә хәл итә алмыйча аптырап калу. **Ике адым да атлый (китә) алмау (өлгермәү)** — берәр эшвакыйганың бик тиз башланып китүе турында әйтелә. *Кадыйр бай ике адым да атлый алмады, Җиһангир якындагы урындыкка сикереп менде.* Г. Ибраһимов. *Почта ящигыннан ике адым да китеп өлгерми, ялт итеп аның башына яңа уй килә.* И. Гази. **Ике адым ераста**— бик якын. *Хәзер «Пыяный шап» Болак елгасыннан ике генә адым ераста булганга, --- Болакка җимерелеп төшеп, алдыбыздагы кышта шунда ятачак.* Г. Тукай. **Ике адымлык җир** — бик якын(да).— *Аның ни мәшәкате бар? Ике адымлык җир ул.* Г. Ибраһимов. **Ике адымны бер итү** — кая да булса бик ашыгып, бик тиз бару (йөгерү). **Ике адымның берендә** — *к.* ике сүзнең берендә. *Хатыны Фатыйма беренче тапкыр балага узгач, икесе дә сөенештеләр. Галиулла ике адымның берендә: «Кара аны, Фатыйма, авыр күтәреп, өзлегә күрмә»,— дип, гел хатыны тирәсендә бөтерелеп йөрде.* И. Гази. **Ике азан әйтмәү** *иск.*— бер мәҗлестә бернәрсә хакында ике мәртәбә сөйләмәү. **Ике ара** — үзара мөнәсәбәт, бәйләнеш. *Нәфисәнең яхшылыгы хакына* [*аның*] *ике араны бозасы килми иде.* Г. Бәширов. *Менә шушы усал карчык Бутап йөри ике араны.* С. Хәким. **Ике арага кара мәче керү** — үзара яхшы, якын мөнәсәбәтләр бозылу.— *Атаң карт сиңа ни өчен бик салкын? Әллә ике арагызга кара мәче кердеме?* Г. Ибраһимов. **Ике арага керү (төшү)** — берәр максат белән ике кешенең үзара мөнәсәбәтләренә катнашу. *Галләм абзый, ике арага төшеп: «Көчләмәгез инде, хәзер Вахит ничек кирәк икәнен үзе белә торгандыр, ул бит сабый бала түгел»,— дип көлеп куйды.* М. Гафури. **Ике арада, бер турыда (йөрү)** — бер рәтле эш эшләмичә буталып (йөрү). **Ике арада, бер турыда (калу)** — кая да барырга мөмкинлек булмау, уңайсыз хәлдә калу. *Алда боз ватылган. Артка карадым: анда боз ага үк башлаган. Ике арада, бер турыда калдым.* Ж. Вәлиди. **Ике арада бетү (калу)** — сөйләшенгән, эшләнгән эшләр ике кеше яки ике төркем кешеләр арасында гына билгеле булып, башкаларга мәгълүм булмау, сер итеп саклану. *Туганым җиңги белән шәп-шәп кенә әйткәләшеп алабыз, ләкин җиңгинең бер ягы бик яхшы, абыйга әләкләми, булган сүз ике арада бетә иде.* Ф. Хөсни.— *Безнең сөйләшүләр ике арада гына калыр.* К. Нәҗми. **Ике арада йөрү** — 1) теге яки бу якка кушылмыйча буталып йөрү; 2) хужа-

лыкта вак эшләр эшләү. — *Көн буе ике арада йөреп, арымаган кая инде.* Ф. Бурнаш. **Ике арада калу** — капма-каршы ике фикер яки ике төркем кешеләрнең кайсысына кушылырга белми икеләнү, аптырау. *Моннан соң аның күңеле [шикләнә, икеләнә] башлап, ни эшләргә белми, ике арада кала башлады.* М. Гафури. *Әле моңа кадәр кузгалышка кушылмыйча, икеләнеп, ике арада калган казакълар да, карательләрнең вәхшәтлегенә түзә алмыйча, - - - кулларына корал алдылар.* И. Салахов. **Ике арада киләп сару** — ике арада бер эшсез йөрү. **Ике арадан буш калу** — ни тегеләй, ни болай, ике якка да карамау. *Чалпы авыл дисәң — зур, поселок дисәң—кечкенәрәк, кыскасы, ике арадан буш калган бер авыл иде.* Соц. Тат. **Ике араны шомарту** — ике арада күп йөрү.— *Аларга ныгытып әйткәли тормасаң, менә көт тә тор, кызу эш вакытларында алар, төрле сылтаулар табып, авылдан шәһәргә, шәһәрдән авылга ике араны шомартачаклар.* Ш. Камал. **Ике ат — бер тиен** — бары да бер, ничек тә ярый. *Безнең кечкенә малай чак, безгә пешкән дә көйгән, ике ат — бер тиен, диңгез тубыктан — без яңгыр яумауны да, игеннәр, үләннәр көюне дә, ачлыкны да белмибез.* М. Гали. **Ике атлам җир** — *к.* ике адымлык җир.— *Кирәкми, Вәли абый, ике атлам җирне болай да кайтып җитәрмен.* С. Рафиков. [*Варламов:*] *Барып җитә алдыгызмы соң сез?* [*Рабига:*] *Җитмәскә әллә, ике атлам җиргә.* Р. Ишморат. **Ике аягын (ботын) бер кунычка (итеккә) тыгу** *сөйл.*— 1) теге яки бу гаеп өчен җәзалау, үч алу; акылга утырту.— *Кыз белән егетне алай йөртергә закон юк, хәзрәтнең указын алдырам, Зәмир Дәүлиенең ике аягын бер кунычка тыгам мин аның.* Н. Исәнбәт.— *Мин аныңы, мин әйтәм, - - - тетмәсен тетәрмен, ике ботын бер кунычка тыгармын.* Э. Айдар; 2) үз ихтыярына буйсындыру.— *Килен бик үткен минем — иренең ике аягын бер кунычка тыга ала торган.* Г. Ахунов; 3) берәр эшкә бик кыстап гаять дәрәҗәдә аптырату.— *Ике аякны бер итеккә тыкмагыз әле, иптәш доктор. Кырыкка ярылырга җиткән чакта...* Г. Әпсәләмов. **Ике аягына бастыру** — хуҗалыкны, эшне һ. б. ш. тәмам торгызу, рәткә салу. *Бөлгенлек белән тәмам йончыган авылны ике аягына да бастыру бик авыр иде.* Г. Галиев. **Ике аяк идәндә** *сөйл.*— йомыш, эш үтәү өчен һәрвакыт әзер булып торуны аңлата. *Киңәш дигәндә шәкертнең ике аягы идәндә.* Г. Әпсәләмов. **Ике аякка (берьюлы) аксау** — эш һәрьяклап артка китү, начарлану турында. *Саттар Хәбирәсе, кем әйтмешли, ике аягына берьюлы аксый башлады. Кулыннан эш төште. Савымы бермә-бер кимеде.* М. Хәсәнов. **Ике аяклы, ике куллы** *сөйл.*— башкалар кебек үк, нормаль.— *Э мин кешедән киммени? Бүтәннәр кебек ике аяклы, ике куллы кеше. Бүтәннәр эшләгәнне эшләрмен.* Ф. Хөсни. **Ике аяклы бүре (елан, күсе, хайван, эт)** *гади с. тирг.*— шул хайваннарга хас кире сыйфатларны үзенә туплаган начар, эшәке кеше.— *Ике аяклы елан ул: күзләре белән синең йөрәгеңне бораулый.* И. Туктар. *«Райпотребсоюз складына ике аяклы күсе оялаган»,— дип, явыз кешеләр өстемнән яздылар.* М. Кәримов. *Фашистлар кеше түгелләр! Алар ике аяклы ертыкчылар, кеше ашаучылар.* Р. Ишморат. **Ике аяклы хәсрәт (бәла, афәт)** *гади с. мыск.* — таяныч булырга яраксыз кеше турында. [*Ул*] *Ибраһимны исә бөтенләй яратмый. Аны: булмаганны бар дип язып йөрүче ике аяклы хәсрәт, дип кенә атый.* Г. Әпсәләмов.— *Стражникларны әйтеп тә тормыйбыз инде. Алар хәзер ике аяклы бәлаләр генә.* Х. Кәрим. **Ике аякның бер(с)ен дә атламау** —берәр җиргә барудан, берәр эшне эшләүдән катгый рәвештә баш тарту.— *Әгәр инде ялгыш мине җибәрмәкче булалар икән, сиңнән башка мин ике аягымның берен дә атламыйм.* Г. Бәширов.— *Китәсең килә икән, әйдә, бар, ә мин ике аягымның берсен дә атламыйм!..* Т. Гыйззәт. **Ике бармак арасына ит үсмәү** — ике туган, ике дус арасын бозып булмау. *Ике бармак арасына ит үсми, ике агай-эне без болай да шәт аңлашырбыз.* Ф. Хөсни. **Ике бармак арасыннан чыгару** — бик аз бирү, саранлану. **Ике бармакта тоту** — үзенә буйсындыру, үз сүзен тыңлату.— *Мин бөтен авылны ике бармагымда тоткан кеше.* С. Шәкүров. **Ике башлы кара кош** *тар.*— Патша Россиясенең дәүләт гербында ике башлы сәмруг кош геральдик рәсеме һәм герб үзе (монархия символы). *Паспортның ике башлы кара кош төшерелгән җирендә полиция түрәсенең әллә ниләр кыландырып куйган имзасы* [*бар*]. Ә. Фәйзи. **Ике бозауга башак (кибәк) аера алмау (белмәү)** *мыск.*— бик гади нәрсәне дә аңлый алмау, эшнең рәтен белмәү, булдыксызлык.— *Ике бозауга кибәк аера белмәгән малай белән сөйләшмисең, Идрисов, кая баскач нинди тайпылыш булачагын сиңнән яхшырак беләбез.* Ф Хөсни.— *Унике ел староста булып берничә медаль алган кешене [төшертте дә Сабир] ике бозауга кибәк аера белмәгән кешене староста итеп куйдырды.* Т. Гыйззәт. **Ике бәрән башы бер казанга сыймау** — *к.* ике тәкә башы бер казанга сыймау. *Ике бәрән башы бер казанга сыймый, ди безнең вожатый.* К. Нәҗми. **Ике бәя (бәһа, хак)** — бик кыйммәт, икеләтә бәя. *Байлар бу ат, сыерларны [ярлыларга] ике бәһасенә күеп бирәләр.* Шура. [*Ул*] *ртылай тирескә әйләнгән саламын, - - - тагын шуның шикелле җыен чүп-чарын җыеп, бергә ике бәя күеп бирә.* М. Гали. **Ике дигәнче** — *к.* эһ дигәнче. *Гани абзый исә кайсы әйбернең кайда саклануын, җиде төн уртасында йокысыннан уятып сорасыннар, эһ тә итми әйтеп бирә, күзләрен бәйләп җибәрсеннәр — ике дигәнче таба.* Ш. Рәкыйпов. **Ике дога, бер җыр** — ваемсыз кешегә карата әйтелә. **Ике (дә) уйламау** — бик кыю эш итү, икеләнеп тормау, тиз генә бер карарга килү. *Башка эштә ике дә уйламый торган җанкыяр Нурислам карт бу очракта уйламыйча гына атка кызыл камыт кидерергә ашыкмаган.* Ф. Хөсни. *Ике уйлап тормыйча, тоттым да язылдым.* К. Нәҗми. **Ике дә өч** *жарг.*— татар сәүдәгәрләре телендә: ике порция чәй, өч чыныяк, алты пәрәмәч. [*Бер мөрит:*] *Әйдә, Ибраһим, чәйгә керәбез.* [*Шкафчы:*] *Барыгыз, бар, ике дә өчне әйтә торыгыз, мин хәзер кереп җитәм.* Г. Камал. *Базар әһелләренең (чәйханәдә) дә үз жаргоны. - - - Кереп утыра да: «Ике дә өч, алты»,— ди. - - - Бу сүзләрне кеше теленә күчереп әйтсәк, - - - ике порция чәй-шикәр, өч стакан, алты пәрәмәч, дигән сүз була.* И. Рәми. **Ике дөнья — бер кыяр (моржа, уртасы камыр, тиен)** — гамьсез, ис китмәүчән кешегә карата әйтелә. *Ике дөнья — бер моржа, төтене кайтмаса, ярый.* Әйтем.— *Акчаның кадерен бик беләбез, тиенен тиенгә чутлап торабыз. Ирләргә нәрсә аларга, ике дөнья бер, уртасы камыр.* Г. Зәйнашева. *Хәлил булмаса, аңа ике дөнья — бер тиен! Аның өчен Галиябану, утка дисә, утка керә, суга дисә, суга ташлана!* Г. Бәширов. **Ике дөньядан буш калган** *сөйл.*— акылга сайрак, бераз аңгырарак, гамьсезрәк кеше турында әйтелә. **Ике инә бер җептә, ике имән бер төптә (булу)** — бик якын дуслар (булу). **Ике исәп — бер исәп (хисап)** — тегеләй дә, болай да ярый, барыбер.— *Әйдә, бушат! Ике исәп — бер исәп.* Г. Бәширов. — *Барыбер лә инде, ике исәп — бер хисап. - - - Хәтта [тәкъдимнәрнең] тегесе мәслихәтрәк, минемчә.* Ш. Камал. **Ике кабып, бер йоту** — бик тиз, күз ачып йомганчы (ашап бетерү яки эшләп ташлау).— *Мин аны ике кабам, бер йотам.* М. Хәсәнов. **Ике каен арасында адаштыру** *кит.*— аптырату, баш әйләндерү (гадәттә ясалма рәвештә). *Автор үз героен ике каен арасында адаштырып йөртә башлый, коялшы көнне яшен суктыра. Мондый әсәрләрдә чынбарлык уйдырма вакыйгалар белән конфликтка керә.* Л. Ихсанова. **Ике карбыз бер култыкка сыймау** — *к.* ике үгез башы бер култыкка сыймау. **Ике килмәү** — кабатланмау, кире кайтмау.— *Ашык, дустым, яшьлек ике килми.* Г. Әпсәләмов.

Ике колагың үзенә булсын — сөенчегә бернәрсә дә бирмәүне белдерә. **Ике колагыңны дүрт җирдән тыгу** — берәр нәрсәне озак тыңлаудан туеп бетү, гаҗиз булу.— *Минем җитмәгән җирләрне, минем кирәгемне санап китсәң, ипташкәем, ике колагыңны дүрт җирдән тыгарсың.* М. Әмир. **Ике кул белән** — *к.* ике куллап.— *Урыс байлары ике кул белән ярдәм биреп торганда, без мөселманнарга читтә калу һич килешмәс.* И. Гази. **Ике кул белән җил аулаучы** *шелт.*— үзен эшчән итеп күрсәтергә тырышса да, бернинди эше дә булмаган, эшсез кешегә карата әйтелә. *Ике кулы белән җил аулаучы, бөтен шәһәрләр буенча шарлатанлык итүче --- әфәнде хәзрәтләре белән Шаляпин лакееның дуэле булды.* Г. Тукай. **Ике кулга бер эш** — нинди дә булса билгеле бер шөгыль. *Ике кулга бер эш булыр дип көтү алган идем.* Г. Бәширов. *Тимер шикелле таза куллы эшчеләр, ике кулына бер эш таба алмыйча йөрүчеләр белән авыл тулган була иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Ике кулга дүрт эш** — эшнең күплеге турында.— *Крестьян хуҗалыгында ике кулына дүрт эш булыр, котырып йөрергә вакыт калмас.* И. Гази. **Ике кулга шәм тотып эзләү** — бик сирәк була торган кешеләр һәм предметлар турында әйтелә.— *Андый яхшы белгечне мин ике кулыма шәм тотып эзләсәм дә таба алмый идем.* Т. Гыйззәт. *Дошманга каршы позиция тотар өчен моннан да уңайлы урынны ике кулыңа шәмнәр тотып эзләсәң дә таба алмассың.* Ш. Камал. **Ике куллап** — бик теләп, бик шатланып.— *Әгәр мөмкин булса, Минҗамалны мин --- ике куллап алыр идем, хәтта авылдагы бер кызга да алыштырмас идем.* А. Шамов.— *Ник теләмәскә? Ике куллап риза мин бу эшкә!* С. Рафиков. **Ике кулны баглау (бәйләү)** — 1) бернәрсә дә эшләмичә тик тору; 2) *к.* ике кулсыз итү (1 мәгъ.). **Ике кулны да кую** — тулысынча, хәтта шатланып риза булу.— *Монысына ике кулымны да куям, авылга йөз белән, димәк? Әйдә, күчә бир, күчә.* Г. Гобәй. **Ике кулсыз итү** — 1) эшләү, хәрәкәт итү мөмкинлегеннән мәхрүм итү. [*Ул*] *шундый вакытта больницада ятуына көенә һәм үкенә башлады: «Менә син, ике кулсыз итте ләбаса бу дошман!»* Г. Бәширов; 2) уңайсыз хәлдә калдыру, аптырашта калдыру.— *Оныткан булсаң, мине ике кулсыз итәсең, әни!* Ф. Әмирхан. **Ике кулсыз калу (булу, утыру)** *сөйл.*— берни эшли алмау.—*Синнән башка мин монда ике кулсыз калам.* Р. Төхфәтуллин.—*Цемент вакытында булырмы, --- иң кирәк чагында ике кулсыз утырмабызмы?* Ф. Мостафин.— *Син ярдәмчем минем, син булмасаң, ике кулсыз булыр идем.* Х. Вахит. **Ике куян артыннан куу** — берьюлы берничә эш башкарып, ике максатка ирешергә ниятләү.— *Ике куян артыннан куып, берсеннән коры калма.* Ш. Хөсәенов. **Ике куянны бер атуда егу** — *к.* ике куянны берьюлы ату.— *Әткәй белән дә күрешербез, укырга да кереп кайтырмын. Ике куянны бер атуда егарбыз.* Э. Касыймов. **Ике куянны берьюлы ату (куу, тоту)** — бер эш башкару белән ике максатка ирешү.— *Ике куянны берьюлы тотмакчы булган идем мин. Синнән үч тә алмакчы идем, кызда да өмет юк түгел.* Ф. Хөсни.— *Сине китертеп, ике куянны берьюлы аттык: җыр да жырладың, күзле дә булдың.* Э. Касыймов. **Ике көймәнең (куянның) койрыгын берьюлы тоту** — *к.* ике куянны берьюлы ату.— *Ике көймәнең койрыгын тотарга теләдең: Суфия артыннан да, минем артымнан да йөрдең.* Т. Гыйззәт. **Ике күзе дүрт булу** — гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнү, аптырау. *Югалган улын күргәч, әнкәсенең ике күзе дүрт булыр инде.* И. Гази. **Ике күзе кебек** — бик кадерле, бик көткән, теләгән. *Ике күзем кебек ике улым сизгер саклар илнең постларын!* А. Алиш. *Мостафинның ике күз кебек телә-гән нәрсәсе — бала.* Ә. Еники. **Ике күзем (карасы, нуры)** — кемгә дә булса сөеп, иркәләп әйтү сүзе (*«бәгырем»* мәгънәсенә туры килә).— *Сине дә күрү көннәрем бар икән! Һай, балам! Ике күзем!* Н. Исәнбәт. *Кайтмадың инде, газизем, Ике күзем карасы.* Бәет. *И бала! Әнкәң сине Ярата, сөя: бәбкәм бу, ди; И ике күзем нуры, Җаным бу, ди, чәчкәм бу, ди.* М. Гафури. **Ике күзем чәчрәп чыксын** — берәр нәрсәгә ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе.— *Ялган булса, ике күзем чәчрәп чыксын, дөньялардан имансызлар үтим!* Г. Бәширов.— *Чын сүз бу, икмәктер, кояштыр, ике күзем чәчрәп чыксын!* Г. Зәйнашева. **Ике күзе төсле** — иң кадерле нәрсә төсле (саклау, саклап тоту турында). *Өзелеп сорыйм — ике күзең төсле, Спартакны сакла, аппагым.* М. Җәлил. **Ике күзе ут булу** — 1) гайрәтле, йөрәкле, энергияле булу.— *Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын, ә моның ишедән ала да, кола да туа торган түгел, бигрәк җебегән нәрсә бит.* М. Шабай; 2) бик нык кызыксыну; берәр нәрсәгә зур теләк уяну, йөрәк җилкенү. *Гармуныңны тартып уйна, Җырлаучыга ход булсын, Җыр тыңлаучы яшь кызларның Ике күзе ут булсын.* Н. Исәнбәт. **Ике күзен дүрт итеп** — 1) зур дикъкать белән, бик яхшылап (карау, уку һ. б. ш. турында). *Григорьян разведчикларга ике күзләрен дүрт итеп карап барырга кушты.* Г. Әпсәләмов; 2) зарыгып, түземсезләнеп (көтү турында). *Алар, ике күзен дүрт итеп, һаман көтә булган: берәр якташ килеп чыкмасмы, Идел буеннан игеннәр уңуы, тормышның азрак җиңеләюе турында җылы хәбәр ишетелмәсме?* Г. Бәширов. **Ике күзен дүрт итү** — бик нык гажәпкә калдыру. *Авыл кызының саф күңелдән әйтелгән бу сүзләре Сөләйманның ике күзен дүрт итте.* К. Тинчурин. **Ике мәгънәле** — ике төрле аңларлык, кинаяле. *Кайсы шаярып Лалягә ике мәгънәле сүзләр әйткәли.* М. Фәйзи. **Ике сарылы** — шикле, икеле (эш турында). **Ике сыңар — бер кием**—бер үк, охшаш, икесе дә бер.— *Ник ат белән чыгармыйсыз? — Һәй-й, ике сынар — бер кием дигәндәй, ат белән чыгарсаң, төяү генә түгел, бушатасы да бар.* М. Хәсәнов.— *Муллакаев белән син ике сыңар — бер кием түгел идегез шул. Җир белән күк арасы...* Э. Касыймов. **Ике сөйләмәү (сөйләп тормау, сөйләшмәү)** *сөйл.*— 1) әйткәнчә эшләү; сүзендә тору. *Шаһи бабай: «Ир ике сөйләмәс»,— дигән иде, сүзендә торды.* Г. Ибраһимов.— *Иртәгә була, өлгертәм. Ике сөйләү юк бездә хәзер.* К. Тинчурин; 2) бер әйтү белән чикләнү, кабатламау. *Бибиҗамал апа ике сөйләшергә теләмәде. «Кайтам булгач, кайтам. Яхшылык белән чыгармасагыз, качып китәм»,— дип кырт кисте.* Ш. Хөсәенов.— *Ул ике сөйләп тормады, тотты да бирде, корыгын да, башкаларын да...* Р. Ишморат. **Ике сөяксандырак** *шелт.*— *к.* Ишәй белән Кушай. *Агеев кебекләр, [дуслар] турында сүз чыккан чагында: «Ике сөяк-сандырак!» — дип кенә куя торганнар иде.* З. Бәшири. **Ике сүз** — берничә сүз; кыскача. *Шпрее елгасы буе турында ике сүз: бу елга буе кечкенә пристаньнар, пароходлар, баржалар белән тулы.* Г. Гали.— *Миңа справка өчен ике генә сүз бир әле, Мостафа,— диде Шихрай.— Ярар, бик кыска гына итеп әйт,— диде Мостафа.* Ш. Камал. **Ике сүз арасында** — әңгәмә вакытында; сүз уңаенда, сүз җае килгәндә. *Шунда. ике сүз арасында, аның күңеленнән бу юлы сүзне әйткән саен исенә төшә торган бер вакыйга сирпелеп үзе.* Г. Бәширов. **Ике сүз булмау** — башкача фикер, ике төрле фикер яки бәхәс булмау, булырга ярамау (мөмкин түгел). *«Димәк, син риза, алайса, бир кулыңны!» Туташ урынынан торды: «Ул турыда ике сүз булырга ярамый!» — дип, кулларын Фазыйлга сузды.* Г. Ибраһимов. **Ике сүзгә урын калдырмау** — каршы фикергә, бәхәскә юл калдырмау, өзеп, кистереп әйтү. *Мин ике сүзгә урын калдырмаслык итеп әйтәм: «Миңа фатиха бирегез, мин бүген үк китәм».* Г. Ибраһимов. **Ике сүздә, ике сүз белән** — кыскача гына. *Фазыйл ике сүздә моны әйтеп бирде. Өйләнү ихтималы юк.* Г. Ибраһимов.— *Ике сүз белән генә әйткәндә, иптәш Никонов белән безнең арада [каршылык] эшләп чыгару продукциясенең*

күләме турында. Ш. Камал. **Ике сүзле** — 1) ике төрле, бер урында бер төрле, икенче урында икенче төрле (капма-каршысын) сөйләүче (кеше); 2) әйткән сүзендә тормаучы (кеше).— *Әйткән сүз — каккан казык! Мин аның канын багышладым. Мине ике сүзле ясыйсың, атам!* Н. Исәнбәт. **Ике сүзне кушып бер җөмлә тәртип итә белмәү** *иск. кит.*— *к.* ике авыз сүз оештыра алмау. *Бездә ике сүзне кушып бер җөмлә тәртип итә белмәгән кешеләр --- газета чыгаралар.* Г. Тукай. **Ике сүзнең бере(ндә)** — сүз саен, бик еш. [*Сөләймановның*] *ике сүзнең берендә «Нургали абый» дип дәшүе аны, нинаять, ярсытып җибәрде.* Ә. Еники. **Ике сүз сөйләү** — бер вакытны (бер урында) бер, икенче вакытны (икенче урында) икенче төрле сөйләү; төрлечә сөйләү. **Ике сүз әйттермәү** — күп сөйләтмәү. *Алтынчәч бу эшләрне ирennән дә нечкәрәк аңлый иде. Ике сүз әйттермәде: «Бер секөнгә каланың базар көне гуй — Җылкычы атаны чакырыйк».* Г. Ибраһимов. **Ике тамчы су кебек (шикелле)** — тулы охшашлык турында.— *Бирәхмәт хәзер сездә трактор йөртүче Шәяхмәтнең туган агасы була... Алар ике тамчы су кебек бер-берсенә охшыйлар. Бер-береннән аера алмассың!* Г. Ибраһимов. **Ике тиен — бер акча** — бернигә дә тормый, әһәмиятсез, берни түгел.— *Күрделәр дә кебек, өйрәнделәр дә. Ә нәтиҗәсе, ни әйткәндәй, ике тиен — бер акча.* Р. Ишморат.— *Аларга көзең дә, салкын дулкыннарың да, җепшек карлы җилләрең дә — ике тиен — бер акча.* Қ. Нәҗми. **Ике тиен тормас(лык)** *мыск.*— яраксыз, әһәмиятсез. [*Нәгыймә:*] *Әле кичә генә диярлек затсыз гына бер мальчишка иде ләбаса. Габбасны әйтәм.* [*Локман:*] *Әйтмә инде, читтән караганда ике тиен тормаслык йолкыш малай иде.* Ш. Камал. **Ике тиенгә исәпләнмәү** — кирәксез, әһәмиятсез саналу; бер тиенгә дә тормау. *Аның өчен матәм тотучылар Йөзләр, меңнәр белән чикләнә, Ләкин дөнья эшчәннәре өчен Исәпләнми ике тиенгә дә.* М. Гафури. **Ике тиенлек** — 1) аз гына да, бөтенләй.— *Без* [*кәҗәне*] *ике ел асрадык. Ике тиенлек тә хәерен күрмәдек. Беренче елында ул бөтенләй кысыр калды. Икенче елны --- үле бәтиләр тудырды.* Ш. Камал.— *Сүземдә ике тиенлек тә хыянәт юк. Ышанмыйсың икән, --- ант итәрмен.* Ф. Әмирхан; 2) бернигә дә ярамаган, юк-бар.— *Сез үзегезнең ике тиенлек тормышыгыз өчен вәжданыгызны сатасыз.* Ф. Сәйфи-Қазанлы. *Исемемне сата яздым ике тиенлек яр өчен.* Җыр. **Ике тирәк бер төптә, ике төймә бер җептә (булу)** — бик якын дуслар (булу). **Ике тәйле** *диал.*— икеле; ә була, я юк. *Хәзер патша туй ясый, кызлар, кием булгач, бармакчы булалар булуын, шулай да бару әле ике тәйлерәк.* Әкият. **Ике тәкә башы бер казанга сыймау** — тыныша, килешә алмау (бер семья, коллектив кешеләре, җитәкчеләр һ. б. турында). [*Җиңги*] *мине йорттан җибәрергә, эти үлгәннән соң, нигездә үзе генә хуҗа булып калырга теләп булса кирәк, --- котырта. Ике тәкә башының бер казанга сыймаслыгын сизенәм.* Ф. Хөсни. **Ике тәләйле** *диал.*— икеле, билгесез, ике яклы. *Дөрес, истикъбаль ул ике тәләйле, Аңар бакмыйм вә булмыйм әйле-шәйле.* Г. Харис. **Ике төрле сөйләү** — *к.* ике сүз сөйләү. *Бу кеше ике төрле сөйләргә яратмый — агын — акка, карасын карага аерып кына куя иде.* Г. Ахунов. **Ике уйлап тормау** — *к.* ике дә уйламау.— *Ике уйлап та торасы юк монда, --- утырдык та киттек.* Р. Төхфәтуллин. **Ике уртада (тору)** — 1) яхшы да, начар да түгел, уртача гына булу.— *Хатыннар арасында иң нык тырышып эшләүче — Мәдинә, ә иң ялкавы — Миңсылу, башкалары ике уртада.* Ш. Камал; 2) ике фикер, ике төркем кешеләр фикере арасында кайсы якка кушылырга белми икеләнү, урталыкта калу.— *Кайчанга кадәр үзеңә үзең хуҗа була алмый ике уртада болганырсың?* М. Фәйзи. *Бу ике төркем арасында икеләнүче, ике уртада торучы, күп төрле каршылыклы язучылар бар.* М. Җәлил. **Ике ут арасында (эчендә)** — капма-каршы ике якның кайсысына кушылырга белмәүдән туган куркынычлы хәлдә. *Егетнең күз алды караңгыланып китте: бер яктан наймаллар белән талашу бара; икенче яктан бу көрәштә иң нык таяныч, юлбашчы булган Сарсымбай һәм Қалтай атасы Сарыбайлар белән ара бозылачак. Бу ике ут эчендә ул нинди юл тотарга тиеш?* Г. Ибраһимов. **Ике ут белән уйнау (шаяру)** — ике хәтәр нәрсә белән берьюлы эш итү.— *Миңнурый, мин беләм, син Газинурны көтәсең! --- Ике ут белән шаярасың. --- Ә ике ут кара-каршы бәрелгәндә хәтәр була.— Бик беләсең килсә, Сәлимҗан абый, мин ике ут белән генә уйнамыйм. Синең кебек хәсрәт утларым минем унлап бар!* Г. Әпсәләмов. **Ике чабата — бер кием** *сөйл.*— 1) барыбер, ничек булса да ярый, ис китми.— *Әмма миңа калса, кечкенә йорт хуҗасы булдың ни, зурныкы булдың ни — барыбер, мужик әйтмешли, ике чабата — бер кием.* Ә. Еники; 2) бер иш, бертөсле, бер-беренә охшаган. — *Мулла белән кулак дус булса да булыр, ике чабата — бер кием инде.* Г. Толымбай. **Ике шалкан — бер тиен**— икесе дә бер, барыбер. *Татар бае газет сөйми. Ике чабата — бер кием, ике шалкан — бер тиен.* Г. Тукай. **Ике юл уртасы (чаты)** — кеше яки җәмгыять тормышында берәр эшне, карарны үтәү, юлны билгеләү алдыннан хәлиткеч момент. *Ул кичне мин ике юл чатына баскан идем. Гарәфи-лотошникның сөйләгәннәре минем алдагы язмышны теге яки бу юлдан җибәрергә тиеш иде.* Э. Қасыймов. **Ике якка да кушылмау** — битараф булу. *Алар ике якка да кушылмый торырга мөмкин түгеллеген сизәләр, яңаралар. Шунлыктан алар сыйнфый дошманга артык аңсыз корал булмыйлар, киресенчә, кулакны фаш итү юлы белән китәләр.* М. Җәлил. **Ике якка да юк** — юньсез, бер эш тә булдыра алмый. **Ике яклы** — 1) киләчәге, нәтиҗәсе ничек буласы билгесез; томанлы, ачык түгел. *Эшләр әле ике яклы;* 2) икейөзле. **Ике яклы (йөзле) пычак (пәке)** *тирг.*— *к.* икейөзле.— *Дөньяда беренче ялагай, --- арка сөяксез бәндә бит ул! Тегеләй дә ярый, болай да. Ике яклы пычак.* А. Гыйләҗев. *Авылның куштаны Сибәт тә, кулаклар янына барса, Гыйбайны мактап, ярлылар, урта хәллеләр тирәсенә барса, Гыйбайны яманлап—ике йөзле пычак булып, арып бетте.* Г. Толымбай. **Ике яклы уен уйнау** — ике якны да алдау, ике як белән дә тыштан бер, эчтән капма-каршы эш алып бару. **Ике яклылык** — турылыксызлык, икейөзлелек. **Ике ятып бер төшкә кермәү (уйламау)** — уйлап та карамау, ис китмәү. *Инде без иртәгә бөтенләйгә китәбез. --- Ә минем, ичмасам, һич кенә дә исем китми, ике ятып бер төшемә дә керми.* Ф. Хөсни. **Ике әйттермәү** — кушкач ук эшләү. *Күндәм ике әйттермәс.* Мәкаль. **Ике әйтү — кабатлау.** *Краюшкинга ике әйтеп торуның кирәге юк, ул командирның боерыгын күз карашыннан ук аңлап ала иде.* Қаз. утл. **Ике үгез башы бер култыкка сыймау** — ике эшне берьюлы эшли алмау (мөмкин булмаслык эш турында). *Бер култыкка ике үгез башы сыймавы, бер көймәче ике көймәнең койрыгын тота алмаганы һәркемгә мәгълүм була торып, бер муллага --- 20 төрле эш биргәннәр.* Г. Тукай. **Ике җирдә ике(ң) — дүрт** — бик гади, аңлавы җиңел булган нәрсәләр турында әйтелә.— *Ике җирдә ике — дүрт икәнлеген дә белмәгән работникларның безгә кирәге шул чаклы гына.* М. Хәсәнов.— *Ышаныч кына түгел, шөбһәсез, ике җирдә ике — дүрт төсле хакыйкать.* Ф. Сәйфи-Қазанлы. **Икенең берсе** — 1) ике юлның, ике мөмкинлекнең берсен сайларга кирәклекне аңлатканда әйтелә; я теге, я бу; я берсе, я икенчесе. *Бер аулакта мин аңа кырт кисеп куйдым: «Чыгасыңмы, Нәфисә, юкмы? Туп-туры әйт, икенең берсе»,— дидем.* А. Шамов; 2) «ике ихтималның, мөмкинлекнең берсе булмый калмый» дигән мәгънәдә кулланыла. *Монда хәзер икенең берсе: я хәзер* [*бүре*] *безгә ябыша, я без аны бетерәбез!..* Н. Исәнбәт. **Икесе дә бер багана төбен таптау** — 1) бер үк сүз сөйләү.— *Сабиров аңа каршы*

бер генә сүз әйтмәде дисәм дә, хата булмастыр. Алар икесе бер багана төбен таптыйлар. С. Рафиков; 2) бер тирәдә йөрү. **Икесе дә бер очтан кискән** — бер-беренә иш, бертөсле, бер характерлы. **Икесе — ике нәрсә** — төрле, бер-беренә бәйләнешләре булмаган нәрсәләр турында.— *Ул «берләшү» белән Разия туташ кузгаткан «берләшү» икесе — ике нәрсә ич.* Г. Ибраһимов. **Икесе кешенеке, өчесе күршенеке** *сөйл.*— ярлылыкны аңлата торган сүз жилеме.— *Алты пар чынаягыбыз бар, кунаклар,— диде ул.— Гаеп итмәгез инде. Аның да икесе кешенеке, өчесе күршенеке дигәндәй, өч пары гына үзенеке.* М. Әмир.

ИКЕ- *Икеатналык, икееллык, икеурынлы* кебек кушма сүзләрдә (вакыт, озынлык, күләм, урын ягыннан) «ике өлеш» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәк.

ИКЕАТНАЛЫК *и.* 1. Ике атнага бер чыга торган вакытлы басма.

2. Билгеле бер иҗтимагый-политик, хуҗалык кампаниясенә багышланган ике атна вакыт.

ИКЕЕЛЛЫК *с.* 1. Ике ел буена дәвам итә, эшләнә торган.

2. *бот.* Үсеше ике вегетацион чорга сузыла торган (үсемлекләр турында). *Икееллык үсемлекләр.* // *и. мәгъ. күпл. бот.* **икееллыклар.** Икееллык үсемлекләр классы (мәсәлән, кишер, шалкан, чөгендер һ. б.).

ИКЕЙӨЗЛЕ *с.* Тыштан яхшы булып күренеп, асылда начарлык эшләүче, берәү алдында бер төрле, икенче кеше алдында икенче төрле сөйләүче; мөнафикъ, хәйләкәр. *Ул — икейөзле, хәйләкәр, ягъни «яхшы» булып күренергә тырышучы усал алпавыт.* Г. Кутуй. *Ләгънәт сезгә, ялган демократлар, Икейөзле куркак бандитлар!* Ә. Исхак.

◇ **Икейөзле янус** *кит.*— икейөзле кешеләр турында: (бер як йөзе яшь, капма-каршы йөзе карт итеп сурәтләнгән борынгы Рим алласы исеменнән барлыкка килгән икейөзлелек символы).— *Кабахәтләр, башта сәламәтлекне тикшерергә булып, соңыннан пулеметтан кырмакчылар. Икейөзле януслар!* Г. Әпсәләмов.

ИКЕЙӨЗЛЕЛЕК *и.* Икейөзле кешегә хас сыйфат, икейөзле булу. *Самодержавиене һәм буржуаз стройны яклаган хәлдә, «милли азатлык» өчен көрәшү — икейөзлелек һәм халыкны алдаудан башка нәрсә түгел иде.* М. Жәлил.

ИКЕЙӨЗЛЕЛӘНҮ *ф.* Икейөзле кешеләрчә эш итү. *— Икейөзләләнергә? --- Алайса мине икейөзлелектә гаепләвең дөрес?!* Г. Минский.

ИКЕЛЕ *с.* 1. Ике компоненты булган. // *хим.* Икеләтә. *Углерод атомнарының икеле бәйләнеше.*

2. *и. мәгъ.* Ике цифры. *Сәгать теле икеле өстеннән узган булса да, кем дә күренми әле.* Қ. Нәжми.

3. *и. мәгъ.* Укучыларның өлгерешен бәяләү өчен кертелгән биш баллы системада «начар» мәгънәсен аңлата торган билге. *Кечкенә Наил бик начар укыган. Ул көн саен я «икеле», я «өчле» генә алып кайта икән.* Г. Бәширов.

4. Ике төрле, еш кына бер-беренә капма-каршы булган. / *рәв. мәгъ. Фома тибы икеле күрсәтелгән: бер яктан, ул күпец дөньясыннан эшкә яраксызланып ташланган төзәлмәс эчкече булса, икенче яктан, сүзләре, фәлсәфә сатулары белән ул әдипнең беренче әдәби дәверендәге бераз идеаллаштырган босякларын хәтерләтә.* Г. Нигъмәти. // Ике төрле аңларга мөмкин булган. *Сораганда, икеле сүз белән җавап кайтара: тәнем сау, җаным авырта, ди.* Г. Ибраһимов.

5. Шикле, шөбһәле, ачык билгеле түгел. / *рәв. мәгъ.*— *Солтанны былтыр көз - чолганышта калган дип сөйлиләр иде, --- исән чыгуы икеле булыр дип әйткәннәр иде.* Г. Бәширов.— *Болай булса, таңга кадәр барып җитү икеле булыр.* И. Гази.

ИКЕЛЕК *и.* 1. Ике берәмлекне эченә алган. *Икелек цифр.*

2. *с. мәгъ.* Икегә җитәрлек. *Тиз арада Әхмәди каяндыр икелек тәмәке әләктереп килде.* Г. Бәширов.

3. *иск.* Ике тиенлек яки ике сумлык акча. *Биргәнне яхшылап саклыем дип, Янчыкка икелек салдым.* Я. Емельянов.

Икелек саны *лингв.*— кайбер телләрдә (борынгы рус, гарәп, грек һ. б.) ике предмет яки ике зат турында сөйләгәндә кулланыла торган төрләнеш формасы.

ИКЕЛЕКЛЕ *с.* 1. *сир.* Ике төрле аңлашыла торган. *«Туктаусыз», «чалыш кына» һәм «басып» сүзләре* [әсәрдә] *--- үз урыннарына куелмаганнар һәм шуның аркасында буталчык, икелекле мәгънәдә чыкканнар.* Л. Җәләй.

2. Икеләнүчән, аумакай. *Татар буржуасы гомумән һәрбер мәсьәләдә эзлексез һәм икелекле булып килде.* Г. Нигъмәти.

ИКЕЛЕКЛЕЛЕК *и. сир.* Икелекле булу; аумакайлык. *Аның аңында икеләклелек, ныгып утырып бетмәгәнлек тә үзен нык сиздерә.* Л. Җәләй.

ИКЕЛЕ-МИКЕЛЕ *с.* Ачык булмаган, хәл ителмәгән, томанлы.— *Икеле-микеле түгелме уйларың?* Р. Ишморат. [*Илсөя*] *икеле-микеле җавабын ачыклап бирде.* Г. Мөхәммәтшин. // Икеләнүчән, аумакай.— *Мәгънәсез кеше лә ул Хәлил. Куркак бит ул, икеле-микеле.* Ш. Камал.

ИКЕЛӘ'НМӘСТӘН *рәв.* Шикләнмичә, һич уйланып тормыйча, ике төрле уйлап тормастан. *Бөек Октябрь социалистик революциясе булу белән, Г. Камал, һичбер икеләнмәстән, революция өчен хезмәт итәргә кереште.* М. Гали.

ИКЕЛӘНҮ *ф.* 1. Икегә әйләнү, икегә бүленү.

2. Ачык бер карарга килә алмыйча тору. *Озак икеләнде Мостафа. Морза каршына басып ялынырга аның үзенең дә күңеле тартмый. Шул ук вакытта әнисенең ачтан үлеп баруын карап торырга да жәаны түзми иде.* Қ. Нәжми. *Газинурның каушавы тагын да арта төште. Ул икеләнеп калды: утырыргамы, юкмы?* Г. Әпсәләмов.

ИКЕЛӘНҮЛЕ *с.* Қайсын эшләргә, кайсы якка карарга, берәр мәсьәләне ничек хәл итәргә белмәгән, аптыраулы. *Икеләнүле хәл.* □ *Һәртөрле икеләнүле уйлардан бөтенләй диярлек арының --- килеп кергәндә, --- өй ишегенең өске борысына* [*аның*] *башы бәрелде.* Ф. Хөсни. [*Надежда*] *йокысыз үткән бәхәсле, икеләнүле, борчылулы төннәрне хәтерләде.* Г. Әпсәләмов.

ИКЕЛӘНҮСЕЗ *рәв. к.* икеләнмәстән. *Ул, авылга кергәч, йөрешен кызулатты. Билгеле бер барып керә торган жире бар шикелле, бер дә икеләнүсез эре-эре атлап бара.* Ш. Камал.

ИКЕЛӘНҮЧӘН *с.* Қайсы якка карарга белми, ачык фикергә килә алмый торган, аумакай. *Икеләнүчән кеше.*

ИКЕЛӘНҮЧӘНЛЕК *и.* Икеләнүчән булу.

ИКЕЛӘТӘ *рәв.* Ике өлеш, ике тапкыр (мәртәбә), ике кат. *Икеләтә изү.* □ *— Без аңардан икеләтә артык соряачакбыз.* Р. Ишморат. *Макаров тегермән тик торганда югалткан акчасын икеләтә кайтарып алды.* Ә. Фәйзи.

Икеләтә шах — шахмат короленә дошман фигуралары берьюлы һөжүм итү.

ИКЕЛӘТӘ-ӨЧЛӘТӘ *рәв.* Ике-өч мәртәбә, ике-өч өлеш. *Кешедә булган гамь анда да, әлбәттә, бар, хәтта анда икеләтә-өчләтә көчлерәк.* Ф. Хөсни.

ИКЕЛӘТҮ *ф.* Ике (куш) итү. *Икеләтелгән җеп. Икеләтелган тапкырчыгыш. Икеләтелган синус.*

ИКЕЛӘЧ *с. диал. к.* игез.— *Бу* [*хатында*] *икеләч бала булырга кирәк.* Г. Толымбай.

ИКЕНДЕ *и. иск.* 1. Төштән соң һәрнәрсәнең күләгәсе үзе озынлыгы кадәр ике өлеш булган вакыттан алып кояш батканга кадәр ара. *Икенде аллары, көн караңгыланып килә.* М. Гали. *Икенде вакыты җитеп, кояш баюга якынлашкач, --- [әсирләрне] таш зинданнарга биклиделәр.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *дини.* Биш вакыт намазның өченчесе (икенде вакытында үтәлә). *Икендегә азан әйткән тавышны ишеткәч, болар, сүздән тукталып, тәһарәт алып, намаз укырга керештеләр.* М. Гафури. [*Сара:*] *Әле кояш батмаганмыни?* [*Нәҗип:*] *Батмаса бит, икендеңне укы.* С. Баттал.

◇ **Икенде күләгәсе** *гади с. мыск.*— бик озын кешегә карата әйтелә.

ИКЕНДЕ-АХШАМ *и. иск. дини.* **1.** Икеңдә белән ахшам арасы (кояш баер алды һәм баю арасындагы эңгер-меңгер чак). *Мәчет нәкъ менә караңгы төшкән чакта гына (ягъни икенде-ахшам арасында) елап ала, имеш.* Ә. Еники. *Капка төбендә кечерәк кенә гәүдәсе белән кичке эңгердә ничектер бик зур күренеп, Сәлман карт басып тора иде: «Дөнья куып, икенде-ахшам намазына да соңга калдым»,*— [*ди*]. Ф. Хөсни.

2. Икенде (өченче) һәм ахшам (дүртенче) намазлары (вакыт аралары бик кыска булганга күрә, икесен бергә кушып, беренчесенең фарызын, икенчесен тулысынча бергә кушып укыйлар).— *Кая, тәһарәт алып икенде-ахшам укырга кирәк.* Ш. Камал. *Мин, эти икенде-ахшамга китү белән, минут тормый, - - - Тарас янына йөгердем.* Г. Гобәй.

ИКЕНЧЕ 1. *Тәрт. саны. к.* ике. [*Ул*] *тегермәннең икенче, өченче, дүртенче катына йөгереп менеп китте.* И. Гази.— *Мин әле һаман беренче класста, син быел гына укый башласаң да, миннән алга киттең, икенче класска күчтең.* М. Гали.

2. *с. мәгъ.* Моннан соңгы, киләсе (вакыт турында). *Талип ул көнне дә, икенче көнне дә кайтмады.* Ә. Фәйзи. // *Бер — икенче, берсе — икенчесе, берәүләр — икенчеләр* кебек тезмәләрдә каршы куюны, санап китүне белдергәндә кулланыла. *Алоа я бер машина, я икенче машина туктый.* А. Шамов. *Берәүләре парикмахерга, икенчеләре мунчага ашыга.* Г. Минский.

3. *рәв. мәгъ.* Тагын, яңадан, кабат.— ***Мин икенче болай булмыйм, бабай, бик каты тырышып эшлим.*** Г. Гобәй. *Икенче бәйләнсә, мин аңа бик каты итеп җавап бирәчәкмен.* Г. Әпсәләмов.

4. *кер. сүз функ.* Нәрсәне дә булса санап киткәндә беренчедән соң килгән пунктны билгеләү өчен кулланыла. *Бердән, атларын ял иттерү, икенче, үзләре дә бераз хәл алып, тамаклану ният илә, [алар] кечерәк бер елга янына туктадылар.* Ш. Мөхәммәдев. *Сиңа, минемчә, элекке мәктәбеңә укырга алуларын үтенеп гариза җибәрергә кирәк. Бу — бер. Икенче — мәктәбеңә киткәнче, үзебезнең уку өендә булса да, эшли тор.* Г. Бәширов.

5. *с. мәгъ.* Беренчене, чынын алмаштырган. *Ул минем икенче әнием.* // Кемгә дә булса бик охшаган булуны белдерә; нәкъ, бөтенләй. *Яшьтән үк «Сәет Баттал», «Салсал» вә башка сугыш китапларын укып үскән Батыргали агай, - - - политикага ихлас куеп, тәмам икенче Бисмарк булган иде.* Ш. Мөхәммәдев.

6. *с. мәгъ.* Әһәмияте ягыннан беренчесеннән ким яки әһәмиятсез, ярдәмче. *Икенче чиратта.* □ *Чехов — беренче нәүбәттә, вак хикәяче. Икенче нәүбәттә — драматург.* Г. Нигъмәти. *Гадәттә операларның сәхнәгә куелышы икенче дәрәҗәдәге эш булып тора, шунлыктан алар, җыр һәм музыкадан гына гыйбарәт булып, начар уйналалар иде.* М. Җәлил. // *муз.* Ярдәмче партияне башкаручы. *Икенче скрипка. Икенче тавыш.* // Сыйфаты ягыннан беренчесеннән калыша торган. *Икенче сорт.* □ *Пароходның беренче, икенче классларында урын булмады.* Н. Фәттах.

7. *и. мәгъ.* Беренчедән (аштан) соң бирелә торган ризык; аш арты ашы.— *Миңа бер порция [аш] китер, тавыктан булсын, икенчегә бер порция розбив китер.* Г. Камал.— *Иртән җитен маена манып бәрәңге ашап килгән ием. Шуңа күрә икенчене генә алдым инде.* Г. Мөхәммәтшин.

8. *с. мәгъ.* Башка, бүтән.— *Һөҗүм безнең районда түгел, бөтенләй икенче урында башланачак.* И. Гази.— *Корылмымы, корымсызмы, анысы икенче эш.* К. Тинчурин. // Башка төрле, бүтән, элеккесенә охшамаган. *Кичә күк йөзе кара, караңгы һәм ачулы — авыр болытлы булып, туктаусыз карлы-бозлы яңгыр ява иде, - - - ә бүген бөтенләй икенче дөнья. - - - Көн аяз, матур, күк йөзе ачык.* Г. Ибраһимов. *Имәли безнең күз алдында ук икенче кешегә әверелде.* М. Әмир.

9. *с. мәгъ.* Каршы, аргы. *Атауның икенче башында да дошман көймәләре бик каты ут астында калдырылып, дошманнан бик күпләре үтерелгән.* Ф. Әмирхан.

Икенче бер — 1) башка, бүтән.— *Кемнең дә булса икенче бер кешенең ярдәменә Рәхим мохтаҗ булмас дип ышанам.* Р. Ишморат; 2) башка вакытта, кайчан да булса бер.— *Икенче бер, уңае туры килгәч, барырсың, хәзергә ял ит.* К. Нәҗми. **Икенче кат (мәртәбә, тапкыр)** — кабат, башка вакытта, тагы.— *Бер юлга кичерәм, икенче кат эшләсәң, - - - мәдрәсәдән куармын.* Т. Гыйззәт.— *Сине икенче тапкыр чыкмаслык итәргә кирәк.* К. Нәҗми. **Икенче төрле (төстә)** — башкача.— *Китапта бер төрле язылган, ә ул аны икенче төрле аңлатып бирә.* Ә. Фәйзи. *Ә өйгә кайткач, үзенең яшь кәләше Гөлкәйгә [ул] - - - мәсьәләне бөтенләй икенче төстә аңлатты.* Ш. Камал. **Икенче эшелон** *хәрби* — хәрби берләшмәләрнең дошман белән турыдан-туры сугыш алып баручы алгы позициясе артында торып, аны азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары, резерв көч белән тәэмин итә торган, санитария һ. б. ш. бүлекләр урнашкан өлеше. *Һөҗүм итеп баручы частьларыбызның икенче эшелонына, аларның транспортлары арасына барып кергәнгә, шактый акрын барырга туры килде.* А. Шамов.— *Дивизиянең ике полкын, бик зур югалтулар булганлыктан, икенче эшелонга чыгардым. Алгы сызыкта көчләр сыеграк калды.* Г. Сафиуллин.

◇ **Икенче кулдан (белү, ишетү)** — беренче чыганактан түгел, ә берәр кеше аркылы ишеткәндә, белгәндә әйтелә. **Икенче күз белән** — башкача, элеккегедән үзгә буларак (карау, мөнәсәбәттә булу). *Шул вакыйгадан соң әти «тар балаклар» язган китапларга икенче күз белән рәк карый башлады.* Г. Гобәй. **Икенче сүз белән (төрле) әйткәндә** *кер. сүз* — шул ук фикерне башкача формада, башкача сүзләр белән белдергәндә. *Ул бичараны ачка үлмәсен, атасының бәддогасы төшмәсен өчен мулла ясага[ннар], икенче сүз белән әйткәндә, бер дә кирәге булмый торып, кирәкле хис итми торып, мулла ясага[ннар].* Ф. Әмирхан. *Боларның сүзләренә колак салмаска, икенче төрле әйткәндә, сер бирмәскә тырышып, үземнең урыныма барып, - - - сабакларымны кулыма алып утырдым.* М. Гафури. **Икенче этәч** — тәнге сәгать берләр. *Шулай көтә-көтә ярты төн үтте. - - - Беренче этәч кычкырды — һаман килмәде, икенче этәч кычкырды — һаман килмәде.* Г. Ибраһимов. *Ала икенче этәчкә кадәр сөйләшеп утырдылар.* Г. Әпсәләмов.

ИКЕНЧЕДӘН *кер. сүз.* Нәрсәне дә булса санаганда тәртип, эзлеклелек ягыннан икенче урында торуны белдерә.— *Бердән, сез авыруны терелтә аласыз, икенчедән, миңа бик зур шөһрәт була.* Г. Камал.— *Бердән, мин эшче, икенчедән, мин синең атаң.* Т. Гыйззәт.

ИКЕНЧЕЛ *с.* Башлангыч булмаган, нәрсәнең дә булса нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән яки үсештә икенче баскычта торган. *Икенчел фосфат. Икенчел чимал.* □ *Материализм табигатьне — беренчел, рухны икенчел итеп ала.* В. И. Ленин.

ИКЕНЧЕЛИ, ИКЕНЧЕЛӘЙ *рәв.* **1.** Икенче мәртәбә, кабат.— *Шундый итеп бирегез, - - - икенчели Мәкаржәгә якын да килә алмаслык булып китсеннәр.* Н. Исәнбәт. *Андый малайларны Ибрай вак кычыткан белән чәбәкли, акыртып-бакыртып: «Икенчеләй бакчага кермәм,*

кермәм, кермәм!» — дип ант иттереп җибәрә торган иде. М. Әмир.

2. *кер. сүз функ. сөйл. к.* икенчедән.— *Икенчеләй, кайдан керәсең, ничек керәсең белмим.* Г. Камал.

ИКЕНЧЕЛӘНҮ *ф.* Үзгәрү, башка төскә, хәрәкәтләргә күчү. *Бүген Зөһрә --- бөтенләй икенчеләнеп калган. Тагын да нечкәргән, җыйнаклангән.* Н. Фәттах. [*Ул*] *үзгәрде, бөтенләй икенчеләнде.* Р. Төхфәтуллин.

ИКЕНЧЕЛӘП *рәв. диал. к.* икенчеләй (1 мәгъ.). *Ул, бер караганда, бик биек вә зур, икенчеләп — бик кечкенә, чак кына күзгә чагылырлык була.* Ш. Камал. *Йосып китте сәяхәткә; Рәшит икенчеләп китте.* Г. Тукай.

ИКЕТЕЛЛЕЛЕК *и.* Берьюлы ике телне яхшы белү һәм ике телдә яхшы сөйләшү. // Бер үк халыкның берьюлы ике телдән дә файдалану күренеше.

ИКЕУРЫНЛЫ *с.* Ике урыны булган. *Икеурынлы самолет.*

Икеурынлы сан *мат.*— 10 һәм 99 арасындагы теләсә нинди сан (мәсәлән, 23).

ИКЕШӘР *Бул. саны* **1.** *к.* ике. *Болар икесе дә икешәр кармак таягы тоткан.* Г. Гобәй. *Алар безгә икешәр мең сум акча бирергә дә әйттеләр.* Г. Ибраһимов.

2. Аерым басым һәм интонация белән әйтелеп, «ике» мәгънәсен көчәйтеп бирә. *Ул хәзер сабан туенда, башка атларны икешәр чакрым артта калдырып, гел беренче килерлек булган бер чабышкы ат тотуны сөя.* Г. Нигъмәти.

ИКЕШӘР-ИКЕШӘР *Бүл. саны.* Һәрберсенә ике, һәр якка пар. [*Ул*] *икешәр-икешәр дүрт казны көянтә башына элеп алып төшә.* Ә. Еники. [*Сираҗеттин*] *төргәкләрне, икешәр-икешәр итеп, балтырларының ике ягына куеп, аякчу белән чорный башлый.* Г. Камал.

ИКЕШӘРЛЕ *с.* Һәркайсында яки һәрберсендә ике булган.— *Әнә Гыйльми дә өч бүлмәлегә күчкән, Саниялар дә, Федькалар да икешәрлене алдылар.* Г. Мөхәммәтшин. *Саннар башта --- икешәрле, дүртәрле, бишәрле, унарлы нәрсәләрне (күз, кул, аяк, бармакларны) берьюлы атап әйтүдән туып чыкканнар.* Г. Алпаров.

ИКЕШӘРЛӘП *рәв.* Икешәр-икешәр булып (итеп), парлап. *Көрәк, кәйләләр күтәргән эшчеләр берәмләп, икешәрләп казармага кайтып керә башладылар.* М. Гафури. *Фельдфебель бөтен ротаны икешәрләп тезеп, --- юлсыз җирләрдән алып китте.* М. Гали.

ИКЕ-ӨЧ *Чама саны.* Ике яки өч, берничә. *Чокырда ике-өч күләгә кыймылдый.* И. Гази. [*Аның*] *хаты ике-өч көн саен килеп торды.* Г. Гобәй.

◇ **Ике-өч авыз сүз** — берничә, бик аз гына (сүз әйтү яки язу турында). *Ул бары ике-өч авыз сүз генә әйтә алды: «Ташларга... мәҗбүр иттеләр... Югыйсә ташлар идемме соң?!»* М. Хәсәнов. *Гыйльмениса тоз төргән кәгазь почмагына ике-өч авыз сүз тырнап җибәрә.* Ф. Хөсни. **Ике-өч сүз (белән)** — берәр нәрсә турында бик кыскача гына сөйләп бирү яки язу турында. [*Ул*] *ике-өч сүз белән генә чәчү орлыгын ничек хәзерләвен, агроном белән киңәшүен, үз бригадасында игенне ничек тәрбияләргә, эшне ничек оештырырга уйлавын әйтеп бирде.* Г. Бәширов.

ИКМӘК *и.* **1.** Ачы камырдан мичтә пешерелгән азык; ипи. *Ак икмәк. Бодай икмәге. Кара икмәк. Икмәк салу.* □ [*Карчык*] *бер телем икмәк тотып чыкты.* И. Гази. *Бер капчыкка өч зур кирпеч, ике зур бөтен икмәк салып, капчыкны Җамалиның аркасына астылар.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Шундый ашамлык пешерә торган.— *Әйдә, минем белән бергә икмәк заводына йөр.* Г. Галиев.

2. Ашлык. *Икмәк тапшыру.* □ *Алар фронт өчен үз куллары белән икмәк үстереп бирергә булдылар.* Г. Гобәй. // Үсеп утырган иген. *Икмәк уңган, мул үскән совхоз басуларында.* М. Җәлил. *Синең аккан маңгай тирләреңнән Кырлар тулып икмәк, бал үсәр.* Н. Думави.

3. *күч.* Гомумән ашамлык, азык.— *Апам сезнең икмәгегезне ашап, сезнең кул астыгызда кабер күрде... Үзем дә менә --- бар гомеремне сезнең икмәгегез белән үткәрдем.* Г. Ибраһимов.

4. *күч. сөйл.* Яшәү, көн күрү чарасы; хезмәт хакы. [*Парижда ак*] *генераллар, кухня янында торып, бөрәңге пюресы пешерүләре, полковникларның иске автомобильләрдә шофер булып йөрүләре берсе дә тамак туйдырырлык икмәк бирмиләр.* Г. Гали. [*Идел*] *халыкларга эш биргән, икмәк биргән, барыр юлларын кыскарткан.* Г. Бәширов.

5. *күч. сөйл.* Тормышның, йорттагы хуҗалыкның бергә яки аерым булуы турында. *Торулары бергә, ләкин икмәк аерым булу. Әти белән бер икмәктә булу* (ягъни бүленеп чыкмау).

6. *диал.* Кәрәздәге чаршын.

Икмәк агачы *бот.*— крахмалга бай җимешләре пешерелеп, кыздырылып ашала торган тропик агач. **Икмәк башы** — ачыткы. **Икмәк миче** — *к.* рус миче. *Зур икмәк миче[нә] --- көлтәләп салам ягып --- утыручылар да эшләреннән туктадылар.* М. Гали. [*Ул*] *үзенә дә яхшы кызыл кирпечтән икмәк миче чыгарды.* Г. Толымбай. **Икмәк чыртлакасы** *зоол.*— авыл хуҗалыгы культураларына зыян китерә торган нечкә, цилиндрик формадагы корт.

◇ **Икмәк бүсере** *гади с.*— эшләмичә, әзерне бушка ашап ятучы. **Икмәк йөзен (төсен, чыраен) күрмим** — *к.* икмәктер.— *Сүзебезнең инә очы кадәрлесе генә ялган булса да, икмәк төсе күрмик.* А. Шамов.— *Алдасам, икмәк чыраен күрмим! Баскан урынымда яшен сугып үтерсен...* И. Гази. **Икмәк кызавы** *диал. шелт.*— булдыксыз, уңмаган кеше. **Икмәк көясе** *миф.*— икмәкне әрәм-шәрәм итүдән килгән начар нәтиҗә; икмәк каргышы. **Икмәк суы** — аракы. *Икмәк суын эчкән өчен Жанкай мине ташлады.* Жыр. **Икмәк тегермәне** *мыск.*— авыз. *Инде икмәк тегермәненнән [түрәләр] кызыл су агызалар дип торабыз.* Х. Кәрим. **Икмәк тотып сөйләү, икмәк өстендә әйтү** *карг.*— *к.* икмәктер.— *Үзенең каениш тиешле кешесе минем үземә икмәк тотып сөйләде.* Ш. Камал.— *Әгәр шунда бүре патроннары барлыгы исемә төшкән булса, икмәк өстендә әйтәм, бер генә секундка да икеләнеп тормаган булыр идем.* А. Шамов. **Икмәк убыры** *гади с.*— 1) *к.* икмәк бүсере.— *Быелдан болай шул икмәк убырларыңны асрыйсы булма.* Т. Гыйззәт; 2) бик күп ашаучы. **Икмәк черетү** *сөйл.*— бушка азык әрәм итү, дөньяда мәгънәсезгә яшәү. *Алар бик җиңел җавап биргәч, ул: «Рәхмәт, балалар, икмәк черетеп кенә ятмыйсыз икән. Шулай тырышып укыгыз инде!» — дип куйды.* М. Гали. **Икмәк шүрлеге** *гади с.*— авыз.— *Сиңа, чатан туганый, картлар алдында икмәк шүрлегеңне бераз ябып торасы иде. --- Бераз уйлап кычкырырга кирәк.* А. Шамов. **Икмәк шүрлегенә менеп төшү** *гади с.*— авызга сугып җибәрү.— *Хурлама мине алай... Югыйсә икмәк шүрлегенә менеп төшәргә дә күп алмам.* Р. Ишморат.

ИКМӘКЛЕ *с.* **1.** Икмәккә (2 мәгъ.) бай. *Буа ягы — безнең икмәкле як, Буалылар гаҗәп уңганнар, Һәм быел да дәүләт амбарлары Алтын көшел белән тулганнар.* Г. Хуҗиев, Ш. Галиев.

2. *күч.* Бай, киң тормышлы кешегә карата әйтелә.

3. *күч.* Хезмәт хакы булган, яшәргә средствосы булган.— *Энекәшне үземнең группага алырга уйладым. Биш маркадан алса да, ичмасам, икмәкле булыр.* Ш. Камал. // Табышлы, төшемле. *Икмәкле эш. Икмәкле урын.*

ИКМӘКЛЕК *и.* **1.** Икмәк булу, азык булу сыйфаты. *Бу нәрсәнең икмәклеге шулкадәр генә, ләкин тамак алдарга ярап тора.* Н. Дәүли.

2. *с. мәгъ.* Икмәк өчен хәзерләнгән (он, камыр). *Икмәклек он.*

3. *с. мәгъ. күч.* Азык алырлык, туенырлык. *Икмәклек акча да табылып тора.* С. Кудаш.

ИКМӘКЛЕК-ТОЗЛЫК *рәв.* 1. Ашарга-эчәргә җитәрлек. *Получка саен кесәдә икмәклек-тозлык, чәйлек-шикәрлек калдырам да, калганын әйбәтләп кенә төреп, бүрек түбәсенә, эчкә теккән барам.* Ф. Хөсни.

2. *күч.* Аз-маз аңлашырлык, ашарга сорап алырлык, туенырлык кына, аз гына (телне белү турында).— *Руса беләсеңме? --- — Икмәклек-тозлык кына бар инде шунда.* Г. Бәширов.

ИКМӘКЛЕ-ТОЗЛЫ *с.* 1. Азыкка мул, хәлле, бай (кеше турында). *Икмәкле-тозлы кеше.*

2. *күч.* Яхшы доход китерә торган, җайлы.

ИКМӘКЛӘП *рәв.* Икмәк белән бергә. *Аның җыйган җиләген икмәкләп сөт белән ашадылар.* М. Гали.

ИКМӘКЛӘТӘ *рәв.* Икмәк белән, икмәк хәлендә. [*Аклар*] *халыкның --- өчен сарыгын сарыклата, икмәген икмәкләтә алганнар.* С. Җәләл. *Хезмәт көненә хәзер икмәкләтә дә, акчалата да мул гына түли башлаганнар.* Э. Касыймов.

ИКМӘКСЕЗЛЕК *и.* Икмәк булмау. *Кулаклар, икмәк яшереп һәм икмәк белән спекуляция ясап, илдә, аеруча үзәктә, икмәксезлек кыенлыгын көчәйтәләр.* М. Җәлил.

ИКМӘК-СУ: икмәк-су белән яшәү — ашау ягы начар булу турында. [*Җиһангирның*] *тамак ягы начар, күп вакыт икмәк-су белән яши иде.* Г. Ибраһимов. **Икмәк-суга утырту (ябу)** *сөйл.*— ашарына икмәк һәм судан башка бернәрсә дә бирмәү. *Егетне өч көнгә икмәк-суга, караңгы юеш карцерга ябалар.* Г. Ибраһимов.

ИКМӘ'КТЕР *ы.* Сүзнең дөреслегенә, вәгъдәсенең үтәләчәгенә ышандыру өчен ант итеп әйткәндә кулланыла; кояштыр, валлаһи.— *Икмәктер, кояштыр, шулай булмаса, иманым кяфер китсен!* Г. Тукай. [*Маһи:*] *Юк, җаным, бу юлы биллаһи алдамам.* [*Сәет:*] *Икмәктер диген.* [*Маһи:*] *Икмәктер.* Т. Гыйззәт.

◇ **Икмәктер газим** *карг.*— «изге, олуг икмәк белән ант итәм» мәгънәсендә кулланыла.— *Икмәктер газим, мин алай түгел!* К. Әмири.

ИКМӘК-ТОЗ *җыйм. и.* 1. Икмәк һәм тоз. *Чигүле сөлге өстенә салып икмәк-тоз китергән Хәбра картны гына кибиткә янына җибәрделәр.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Азык-төлек; сый-хөрмәт. *Бу — Галим муллаңың авылдашы булып, яшь вакытында анда укыганда, ятимлеге сәбәпле, икмәк-тозыннан да файдаланган икән.* Г. Ибраһимов. *Бакырчы авылы — зур авыл, Икмәк-тозга бай авыл.* Бәет.

◇ **Икмәк-тоз белән (каршылау)** — хөрмәтләп, якты йөз белән, ягымлы каршылау.— *Безне икмәк-тоз белән каршы алырсыз, малай.* М. Фәйзи.

ИКМӘК-ТОЗЛЫК *рәв. к.* икмәклек-тозлык. *Электән икмәк-тозлык та русча белмәгән --- крестьян балалары өчен бу нәрсәне аңлау, белү чиксез авыр булды.* М. Гафури.

ИКМӘКЧЕ *и.* Икмәк белән алыш-бireш итүче кеше. *Мин [юкка] икмәкче булмаганмын: икмәк — бик үтә торган товар.* Г. Тукай. // Икмәк пешерү остасы.— *Тегүче тегү хәлен сөйләгәндә, икмәкче бүген салган нанын сөйләр.* М. Гафури.

ИКО'НА *и. дини.* Христианнарда: алланың һәм изгеләрнең тактага, материягә, калайга ясалган һәм табыну өчен кулланылган сурәте. *Гыйбадәт почмагы. Анда әллә никадәрле эреле-ваклы әүлияларның, пәйгамбәрләрнең путаллы рәсемнәре — иконалары эленгән.* К. Нәҗми. *Ул иң элек почмактагы икона тактасы алдына туктап, Мәрьям-ана сурәтенә бер-ике мәртәбә башын орды.* Ф. Хөсни.

ИКОНОГРА'ФИЯ *и. махс.* 1. Сынлы сәнгатьтә, фотографиядә һ. б. билгеле бер кеше, вакыйга яки урынның төрлечә төшерелгән рәсемнәрен (сурәтләрен) тасвирлау һәм өйрәнү.

2. Дини сюжетларны яки изгеләрне сурәтләүгә чиркәү тарафыннан кертелгән кагыйдәләр. *Натураны артык җентекләп тормыйча, шартлы рәвештә генә сурәтләү — рус иконографиясе өчен типик күренеш икәнлеге мәгълүм нәрсә.* Г. Шамуков.

ИКОНОСКО'П *и. физ.* Телевизион сурәтләрне тапшыру өчен махсус электрон-нур трубкасы.

ИКОСАЭДР *и. мат.* 20 кыры, 12 түбәсе һәм 30 кабыргасы булган төзек күпкырлык.

ИКРА *и. сөйл.* 1. Балыкның ашамлык итеп хәзерләнгән уылдыклары. *Закускага балык, икра, колбаса китерделәр.* Ш. Мөхәммәдев. *Кәрим булки өстенә икра да сылап бирә.* Ф. Әмирхан.

2. Бик ваклап туралган гөмбәләрдән яки яшелчәләрдән ясалган ашамлык. *Баклажан икрасы.* □ *Киен гөмбәсенең икрасы --- тәмле дә [инде]!* Г. Хәсәнов.

ИКС *и.* 1. Латин алфавитында егерме беренче хәреф (х) исеме.

2. *мат.* Билгесез санның шартлы билгесе.

3. *күч.* Билгесез кеше турында әйтелә. *Аның чын исемен бик беләсе иде дә бит, ләкин ничек? Шуңа күрә мин аны гражданин икс дип кенә атадым.* Н. Дәүли.— *Мин, Сәгыйдә, сиңнән соң, --- ике икснең артына ияреп, квартираларына кадәр бардым.* Һ. Такташ.

ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ *с.* 1. Гаять дәрәҗәдә зур, киң, озын, чикләре күренмәгән яки булмаган, очсыз-кырыйсыз. *Иксез-чиксез хыялларга чумып, Уйлап чыгам кара төнемне.* Ш. Маннур. *Иксез-чиксез җир үттек без Дошман каннарын түгеп.* Ә. Ерикәй.

2. *күч.* Гаять күп, әйтеп, санап бетергесез. *Күктә иксез-чиксез йолдызлар көтүе җемелди.* К. Нәҗми. *Агыйдел буе табигатенең --- күңелләрне күтәрү, сәламәтлекне нығыту өчен кирәк булган барлык даруларга иксез-чиксез дәрәҗәдә бай табигать икәнлеген [сиздем].* М. Әмир.

ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗЛЕК *и.* Иксез-чиксез булу.

ИКСЕЛМӘС *с. бор.* Киемәс. *Белсәң, Хания, икселмәс дәүләт иде бу.* Сов. әд.

ИКС-НУРЛАР *и. күпл. иск.* Рентген нурларының элекке атамасы.

ИК-ЧИК *җыйм. и. к.* иге-чиге. *Шәрәфи агайның көтүенә ик-чик юк иде.* Г. Газиз. *Площадкага төшү белән сез игенә-чигенә күз җитмәслек бөек төзелеш алдына килеп басасыз.* К. Нәҗми.

ИКЪРАР *и. кит.* Берәр фактның булганлыгын тану, әйтү; *киресе:* инкяр.— *Сез минем [гади] икърарымны гаеп итмәгез.* М. Фәйзи.

Икърар итү (кылу) — берәр фактның булганлыгын, кирәклеген телдән тану, яшермәү.— *Икърар итәргә кирәк, безнең илебезнең беркайчан да эле мондый ныклы һәм оешкан тылы булганы юк иде.* Г. Бәширов. *Гаепләнүчеләр бик кыска рәвештә үзләренең гаепләрен икърар кылалар.* Г. Айдарский.

ИКЪТИБАС *и. иск. кит.* Берәр язучының әсәреннән файдалану яки берәр кешенең әйткән сүзләренә иярү. [*Г. Тукайның*] *Пушкин вә Лермонтовтан тәрҗемә вә икътибаслары да --- гүзәл чыкканнар.* Ф. Әмирхан. *Кайвакыт Тукай икътибаслары оригиналларын хәтергә китермәслек дәрәҗәдә үзгә әһәмияткә ия булалар.* Г. Нигъмәти.

Икътибас итү — файдалану, файдаланып язу; иярү. *Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов ггәр булса кояш, Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән бу баш.* Г. Тукай.

ИКЪТИСАДИ *с. иск. кит. к.* экономик. *Әгәр дә Россиянең мәдәни һәм икътисади үсеше хәзерге кызулык белән барса, өч-дүрт елдан соң безнең алдыбызда иске Россиягә бер дә охшамаган Россия — төзек, бай Россия булачак.* Г. Гали. *Күп кенә жалованье һәм паеклар алуга да карамастан, аның тормышы икътиса-*

ди яктан һаман начарланганнан-начарлана барды. С. Җәләл.

ИКЪТИСАТ *и. иск. кит.* **1. к.** экономика. *Октябрь революциясе --- Советлар иленда искедән килгән дәүләт, сәясәт, икътисат, мәдәният нигезләрен җимер[де].* К. Нәҗми.

2. Малны аз-азлап кына тоту, экономия. *Икътисат бу халыкта бик начар куелган. Көз көнендә мең сум табып кайткан плантацияче кыш буена бу акчаны бетерә.* Шура.

ИКЪТИСАТЛЫ *с. иск. кит.* Экономияле, малын саклап тотучы. *Эшчән, тырышучан вә икътисатлы кеше рәхәт тора.* Г. Тукай. *Чехов хикәя язганда да гаять икътисатлы һәм конкрет булырга киңәш итә.* Г. Нигъмәти.

ИКЪТИСАТЛЫК *и. иск. кит. к.* экономиялелек. *[Аның], үзенең тырышлыгы вә икътисатлыгы белән бер әр, шулай һаман «кечкенә» булып калуында да --- йомшак табигатьле булуының катнашмасы юк түгелдер.* Ш. Камал.

ИКЪТИСАТСЫЗЛЫК *и. иск. кит.* Икътисатсыз булу; экономиясезлек. *Бер тәңкә кирәк, ди. Ни эшлим? Бирдем. --- «Икътисат» мөхәррирена барганда шундый икътисатсызлык эшләдем бит! Соңыннан таксаның 25 тиен генә икәнен белдем.* Г. Тукай.

ИКЫ-ЧИКЫ: икы-чикы килү *сөйл.*— көлә-көлә сөйләшү; чикылдашу. *Син, мөгаен, анда да шулай күңел ачудан читтә утыргансыңдыр, э иптәш кызларың икы-чикы килеп утырганнардыр.* М. Мәһдиев.

ИКӘМ *сан, сир.* **1.** (Санамышта гына кулланыла.) *к.* икәү.— *Берәм, берәм, Икәм, икәм. Өчәм, өчәм, Авыр балтам кая китте?* Р. Ишморат.

2. *и. мәгъ. сөйл.* Биш таш уйнаганда уенның беренче баскычы (янәшә куелган ике ташны сыптырып алу). *Мин икәмдә генә, син дүртәмгә җиттең.*

ИКӘН *ярд. ф.* **1.** Фигыльдән башка сүзләр янында килеп, аларга фигыль төсмере кертә.— *Әй, егет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең.* Г. Тукай.

2. Хәбәр составында килеп, фикерне раслау, ачыклау төсмере кертә. *Боларның җирләре урман буенда икән.* Әкият.

3. Сорау җөмләдәге билгесезлек төшенчәсен көчәйтеп килә. *Дивизия бу кыенлыктан ничек котылыр икән?* Г. Бәширов.

4. Шарт җөмләне баш җөмләгә бәйләү функциясен үти.— *Безне хөкүмәт милкен сакларга куйганнар икән, без синең аягың авырту белән хисаплашмыйбыз.* А. Алиш. *Яратасың икән, укып бак.* Б. Рәхмәт.

ИКӘН-МИКӘН *и. сөйл. к.* имеш-мимеш.

ИКӘҮ **1.** *сөйл. к.* ике.— *Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү. Тәрәзәләрнең очына чыга алмассың.* А. Алиш.

2. *җый. сан.* Икәүләп, икесе бергә. *Без икәү: әткә куян, әнкә куян.* Г. Тукай. *Без аналы-кызлы, Кадрия белән икәү, Шубертны тыңлыйбыз.* Г. Кутуй.

3. *тарт. форм.* **икәве, икәвесе.** Тегесе дә, монысы да; икесе. *Алар икәве дә алай зарланырлык кеше түгелләр.* К. Нәҗми.— *Җәмәгать! Полковник белән мәзин абзыйны икәвесен бер кабергә күмәбез, шаһит булыгыз!* Ш. Камал.

ИКӘҮДӘН-ИКӘҮ *рәв.* Икәү генә, бары тик икәү. *Гата картның карчыгыннан башка бүтән беркеме дә юк иде, алар бары икәүдән-икәү генә яшиләр иде.* Н. Фәттах. *Хәлим белән сестра икәүдән-икәү генә калдылар.* А. Шамов. // *к.* күзгә-күз.— *Теләсәгез, икәүдән-икәү генә сөйләшербез.* Р. Ишморат.

ИКӘҮЛЕК *и.* Икәү булу. *Без икәүлектән, ул безнең янга килергә баэмаган.* Ш. Камал.

ИКӘҮЛӘП *рәв.* Икәү бергә, парлап. *Бәдрия белән Гайшә, аналы-кызлы икәүләп, --- өч сәгать чәй эчтеләр.* Г. Ибраһимов. // Икәү берьюлы. *Алай икәүләп сөйләмәгез, арагыздан берегез генә сөйләгез!* М. Гафури.

ИКӘҮЛӘШЕП *рәв.* Икесе бергә, икесе дә. *Корбангали карт белән Фәхри карчык Сәхипне икәүләшеп бик нык кыздырганнар.* Ш. Камал. *Ирле-хатынлы икәүләшеп тагын --- Мостафа турында киңәш сорадылар.* К. Нәҗми.

ИЛ I *и.* **1.** Билгеле бер хөкүмәте булган дәүләт, мәмләкәт. *Туган ил. Совет иле. Ил саклау.* □ *Берсе уйлый китәргә чит илләргә: Германия, Австрия, Сицилиягә.* Г. Камал. *Дөньяда илләр күп, җирләр күп, Тик безнең ил генә бер генә.* Ә. Ерикәй. // Республика, край, өлкә. *Уяна, бөек эшләргә дәртләнеп, Бәхет һәм дуслык иле — Татарстан.* Ә. Исхак. // Як, җир.— *Чит илләрдән абыем кайтты туйга дип.* К. Тинчурин.

2. Туып-үскән җир, ватан. *Ил димен мин, ил дигәнем — Ул туып-үскән җирем.* Ә. Ерикәй.— *Туйган җирдән туган җир артык шул. Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул, дип белми әйтмәгәннәр шул.* Г. Ибраһимов. // *диал.* Туган як.

3. *диал.* Авыл. *Чуваш иле. Мулла иле.* □ *Бай малайлары үзләренең илләренә — авылларына кайтып киттеләр.* М. Гафури. *Уралдан, Алатаудан үз илләре Караюргага кайтып җиткәнче, юл буенча Мәрхәбә белән Шәйхел киңәш корып килделәр.* Г. Ибраһимов.

4. Халык, коллектив.— *Ил сүзеннән чыкмагыз, ил күзеннән качмагыз.* К. Тинчурин.— *Ил сөйли дип, муллабызның гөнаһына кермим...* Ә. Фәйзи.

5. *күч. сир.* Дуслык, татулык. *Каршы очраган сугышчылардан гаскәр башлыгы: «Илме, яумы?» — дип сорый. Ягъни: «Дусмы, дошманмы?»* М. Җәлил.

Ил гизү — сәяхәт итү, чит җирләрдә йөрү. *Мәдрәсәнең тынчу мохиты тәмам биздерде, ил гизеп, бер дөнья күреп кайтыйм, дидем...* Ә. Фәйзи. **Илгә чыгу** — 1) ил буенча сәяхәт итү. *Малайлар илгә чыгарга исәплән йөриләр.* Әкият; 2) халык арасына чыгу. *Ризык эзләп әнкәй илгә чыкты.* З. Байчурина.

◇ **Ил авызы** — халык теле. *Кайсыдыр бер тапкыр аңарга «Куян солдат» дигән кушаматны бирә дә, шул ил авызына кереп китә.* Г. Толымбай. *Ил авызында йөргән бу сүзләрнең күпмесе чын, күпмесе ялган булгандыр, әйтүе кыен.* И. Гази. **Ил авызын тыгу (иләк белән ябу)** — халыкка сөйләргә, үз фикерен әйтергә мөмкинлек бирмәү.— *Этләрнең өрүләре бетәр, ил авызын тыгып булмас.* М. Гафури. **Ил агасы (карты)** *иск.*— авылның, ыругның өлкән, хөрмәтле кешесе; аксакал. *[Асылҗегет] акылы, [характеры] белән ил агасы була торган яхшы бер адәм иде.* Г. Ибраһимов. *[Ул] чал сакаллы ил карты икәненне искә алмас, нигә төнлә борчып йөрисең дип, каты гына сүгеп тә ташлар.* А. Шамов. **Ил аралау — ил буенча** сәяхәт итү, төрле кешеләр белән аралашу. *Оренбургта эшләгән чорда Муса Җәлил еш кына авылларда йөри, үзе әйтмешли, «ил аралый», тормышның эчендә кайный иде.* Каз. утл. *Ун ел элек, узгынчы булып, ил аралап йөргәндә, бер йомыш илән Краснояр каласына бар[дым].* Шура. **Ил арасына керү** — халыкка үзен теге яки бу яктан күрсәтү; танылу. *Ул бу көндә ил арасына керә башлаган, халык арасында сүзе дә үтә башлаган бер кеше.* М. Гафури. **Илдә бер (кеше)** — тирә-якта иң хөрмәтле (кеше).— *Монда сорап торучылар кемнәр? — Илдә бер кешеләр.* Ф. Хөсни. **Ил дәресенчә** *иск.*— халыкта булганча; гореф-гадәтне җиренә җиткереп. **Ил кеше(се)** — халыкка хезмәт итә һәм халык тарафыннан хөрмәт ителә торган кеше.— *Мин әйтәм, врач — ил кешесе, Казанга барып җитсәм, ничек тә табармын әле.* Г. Әпсәләмов. **Ил козгыны** *тирг.*— *к.* ил корткыч.— *Ил козгыннарыннан йолкып алырбыз җирне!* Р. Төхфәтуллин. **Ил корткыч** *тирг.*— халыкны талаучы, хәерчелеккә, бөлгенлеккә төшерүче (кеше.— *Кайда ул, ил корткыч, карак баш?!.* К. Тинчурин.— *Ах, кулак койрыгы, ил корткыч!* Г. Гобәй. **Ил корыту** — халыкны талау, хәерчелеккә төшерү.— *Бу байлык, әкренләп, Малик кебек ил*

корытучыларның төпсез кесәсенә кереп тулмасмы? И. Гази. **Ил кыдыру** *диал.*— авылдан авылга, өйдән өйгә йөрү. *Кыз урлану хәбәре, ил кыдырып, кымыз эчеп, кызык эзләп, кыз күзләп йөргән бүз балалар --- аркылы бөтен далага шул көн эчендә таралып өлгерде.* Г. Ибраһимов. **Ил уртасында тору (булу)** — халык арасында, кешеләр арасында булу.— *Сезгә, ил уртасында торгач, күренә торгандыр.* А. Расих. **Ил фетнәсе** *тирг.*— халык арасына коткы салучы, җәнҗалчы кеше.— *Кара син аларны, ил фетнәләрен, э! --- Монда, минем үз өемә килеп, көпә-көндез [талашалар].* Ф. Бурнаш. **Ил өстендә илэмән йомыркасы** — илнең кадерлесе.— *Такканнар икән, аны сиңнән ала да белерләр, ил өстендә илэмән йомыркасы бер син генә түгел.* Ф. Хөсни.

ИЛ II *и.* Умарта кортларының аерым семьясы; күч. *Алмагач ботагына беренче булып ана корт куна. Шул урынга үк эшче кортлар да куналар, бары да бергә җыйналалар, күп булалар. Йон мамыгы төсле булып, корт иле алмагач ботагын сара.* А. Алиш. *Кортның анасын эләктер, иле тубалга үзе керер.* Мәкаль.

Ил аеру — корт анасы белән эшче кортларның бер өлеше аерылып яңа күч төзү.— *Корт анасы ил аерыр көнне иртә үк: «Тию, тию, тию»,— дип җырларга керешә.* Т. Гыйззәт. **Ил очыру** — *к.* ил аеру.— *Бабай, ерак умартаны карарга кирәк. Ил очырмадымы икән?* К. Тинчурин. **Ил тоту** — яңа илне (күчне) читкә җибәрмичә, тубалга җыеп урнаштыру. *Умартаны карарга кирәк. --- Әйдә, егет, ил тотканны күрәсең киләме?* К. Тинчурин.

◇ **Ил булып** — бик күп булып, төркем-төркем булып. *Аккош очар ил булып, Шаулап искән җил булып.* Э. Фәйзи.

ИЛ-АНА *җый. и. шигъ.* Туган ил. *Алар барысы да корал кардәшләре, бер үк ил-ананың, Совет Ватанының уллары.* К. Нәҗми. *Ил-ананың нәни портретын танып, күңел рәхәт тетрәнә.* Э. Давыдов.

ИЛ-АТ *җый. и. сир.* Халык, ил. *Ул хуҗа хатыннан аның ничек көн күрүен, ил-атның ничек торуын сорашты-рып, сөйләшеп утырды.* Ф. Хөсни. [*Без*] *бар белекемезне онытып, ил-ат көлкесе булдык.* Шура.

ИЛАУ: илау салу — *к.* илаулау.— *Иртән көлгән бала кичен илау сала.* Ш. Маннур.

ИЛАУЛАУ *ф.* Бик каты кычкырып, илереп елау. *Бер төрек, дөясенең муеныннан кочаклап, илаулый-илаулый елый икән: «Әй, дөям, үркәчкәем! Синсез ни-ләр генә эшләрмен!»* Чаян.

ИЛАһ *и. иск. дини.* **1.** Алла, тәнре. *Гарәп халкы кабул итмәстән әүвәл дине исламны, Илаһ урынында тотканнар агач, таш төсле [балбалны].* Г. Тукай.

2. *тарт. форм. энд. сүз.* **илаһем, илаһым.** Аллам, тәнрем. [*Жамали:*] *Хода безгә дә шулай ярдәм бирә иде.* [*Камали:*] *Илаһем, үзең ярдәм бир!* Г. Камал. *Карандагы катлау мөселман агай-эне: «Ходаем, тагы нинди афәт-ләрең бар икән? Үзең сакла, илаһым!» — дип, тәңрегә ялваралар.* Г. Ибраһимов. // *ы. мәгъ.* Берәр нәрсәдән гажәпләнгәндә, ачынганда, аптыраганда, аны яратмаганда, каргангандa һ. б. очракларда кулланыла.— *Аю чыкты. Илаһым, нинди зур.* К. Тинчурин.— *Әй, йөргән була, илаһем, күкрәген киереп!* А. Расих.

3. *күч.* Үрнәк булырлык кеше. *Гайшәләр белән бәхетле булдым. Ул миңа — илаһ иде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Илаһ булу** — баш булу. *Халык мескен уенчак; Кем көчле, шул булды илаһ.* М. Гафури.

ИЛАһИ *с. иск. дини.* **1.** Аллага хас, аллага мөнәсәбәтле, алланыкы. *Илаһи көч.* □ *Ахырына күйган ходай үз имзасын, Имзасын, ягъни илаһи тамгасын!* Ш. Бабич. [*Карт хәзрәт*] *иман шартымны идәнгә ачып салды да --- изге, илаһи сүзләрне тезеп китте: «Әлеппи тисси җимхи ыхы ыгы дал-зәл...»* Г. Гобәй. // Алла тарафыннан барлыкка китерелгән; рухи.— *Күңелнең илаһи бернәрсә түгеллеге, бәлки реаль физиологик күренеш булуы --- һәрберебезгә билгеле.* Г. Әпсәләмов.

2. *и. мәгъ. дини.* Алла, тәнре, ходай. *Карчык: «Илаһи инде тәүфыйклы гомер бирсен!» — дип, һаман бәбигә дога кыла иде.* Ш. Камал. *Әллә кемнәр вәгазе, фәләннәр хәйләсе түгел, илаһиның үз эшләре дә минем йөрәгемне тыңлата алмас иде...* Г. Ибраһимов.

3. *энд. сүз. к.* илаһ (2 мәгъ.). *Хәят, одеялы белән кагыныл: «Әстәгъфирулла, илаһи, үзең сакла»,— дип, тагы аллага сыенды.* Ф. Әмирхан.

4. *күч.* Табигатьтән өстен; серле, тылсымлы. *Уйнавы да бик шәп, бик оста күренә. Шулай да нәрсәдер җитми, ниндидер яшерен вә илаһи булган, ләкин музыканың тәэсирендә, бернәрсәнең рухи мәртәбәсендә зур урын тоткан бер хасыять аңарда юк кебек.* Г. Ибраһимов. [*Бу*] *бер илаһи вакыйга, могҗиза вә серле эш иде.* Г. Тукай.

5. *күч. юг.* Сокландыргыч, гажәеп, искиткеч, тиңдәшсез. *Килер бакчачылар, --- Гүрләр өстен бизәп гөлләр белән, Илаһи бер бакча итәрләр.* **һ. Такташ.**— [*Камилә туташ*], *аяк астыгызда туфрак булыйм. Мин сезнең илаһи матурлыгыгызга җанымны бирергә әзер.* Ш. Камал.

6. *ы. мәгъ.* Берәр нәрсәдән гажәпләнгәндә, ачынганда, аптыраганда, аны яратмаганда, каргангандa һ. б. әйтелә.— *Районнан хәзер гөнә музыкантлар килделәр. Иә, илаһи! Җиз моржалардан кычкыртуларын ишетсәң, күк җимерелеп төшә диярсең.* Қ. Нәҗми. [*Сылу:*] *Син мал бирмәүләренә карамыйсыңмы?* [*Зифа:*] *Үзләренә булсын, илаһи.* М. Фәйзи.

Илаһи бәет *иск.*— дөньяви мотивлар белән сугарылган җыр яки шигырь. *Шагыйрьләр тарафыннан дөньяви мотивлар белән сугарылган җырлар, шигырьләр, шул заман термины белән әйтсәк, илаһи бәетләр иҗат ителә килгән.* З. Максудова.

◇ **Илаһи мәгәр** — *к.* илла.— *Кызлар, басыгыз шуларның үкчәләренә! — дип кычкыруым да булды, илаһи мәгәр, китте эш, китте эш.* Г. Минский. **Илаһи уптым** — *к.* уптым илаһи.— *Илаһи уптым килеп чыкмагандыр бит? Башта кем дә булса берәү үйлагандыр?* Г. Насрый.

ИЛАһИЛЫК *и.* Илаһи булу. *Коръәннең бөтен илаһилыгы, бөтен «изгелеге» безнең халык белмәгән телдә булуында бит аның.* Г. Гобәй. *Легендар каланың илаһилыгы, кешеләрнең эшлекле һәм кече күңелле булулары аны сөендерде.* Г. Ахунов.

ИЛАһИЯТ *и. иск. дини.* **1.** *к.* илаһилык.

2. Дини фәлсәфә гыйлеме. *Безнең хәлфә бик галимдер, --- Сабыйларга илаһият Дәресләрен [өйрәтәдер].* Н. **Думави.**

3. *күч. юг.* Гүзәллек, соклану, гажәпләнү. *Бәхетле адәм --- Мәрьямнең йөзенә, сер, илаһият, нур вә ялкын илә тулган зур һәм кара күзләренә тик бер генә мәртәбә карасын, ант итәм, ул даһи ихтыярын югалтыр, дөньясын онытыр.* Г. Ибраһимов.

ИЛАһЭ *и. иск. кит.* Хатын алла. *Венера — борынгы галәмнең матурлык илаһәсе.* Ф. Әмирхан. *Без мәхәббәт илаһәсенә самими гыйбадәтебезне вакытында --- үтәдек.* Г. Ибраһимов.

ИЛБАСАР *и.* Башка илне корал көче белән басып алучы кеше. [*Диктор*] *Гомельнең фашист илбасарларыннан азат ителүе турында Верховный Баш командующий приказын укый.* Ф. Булатов.— *Илбасарларга Казанны бирмәс өчен бервакыт, Батырларча жаның бирде монда Муллануp Вахит.* Н. Исәнбәт. / *с. мәгъ.*— *Илбасар империалистларга каршы көрәшкә әзерләүче партиянең кешесе мин!* К. Нәҗми. *Илбасар дәүләтләр һөҗүменнән имин булу кирәк.* Г. Гобәй.

ИЛБАСАРЛЫК *и.* Илбасар булу. *Мөхәммәтнең бу илбасарлыгын да мулла абзыйлар, изге эш күреп, авыз суларын корытып сөйлиләр.* Г. Гобәй.

ИЛБАСҚЫН *и. сир. к.* илбасар. *Чылтырап аккан салкын чишмә өстенә Илбаскыннар зиндан кормасын!* М. Хөсәен.

ИЛГИЗӘР *и.* Сәяхәтче. *Татарлар арасыннан чыккан илгизәрләрнең исемлеген, XVIII гасырда Мәскәү хөкүмәте тарафыннан Һиндстанга җибәрелгән --- Исмәгыйль ага[дан] башлап, --- очсыз-кырыйсыз сузарга мөмкин.* Қ. Нәҗми. *Ил гизеп йөргән җиде мужик --- Матрена Тимофеевна янына киләләр. Тимофеевна илгизәрләргә үзенең кимсетелү һәм нужа тулы тормышын сөйләп бирә.* М. Максуд.

ИЛГӘЗӘҚ *с.* Ачык йөзле, киң күңелле, ягымлы, түбәнчелекле, кечелекле.— *Серафима ахирәт белән безгә дигәне плитәдә тагын бар әле аның,— диде Тәүфика җиңги, илгәзәк бер юмартлык белән.* Г. Ахунов. *Иренчәк кеше чигенчәк, илгәзәк кеше күңелчәк.* Мәкаль. // *ирон.* Чамадан тыш ачык, киң күңелле булырга тырышучы, юма телле. *Илгә барса — илгәзәк, өенә барсаң — бик мәзәк.* Мәкаль.

ИЛГӘЗӘҚЛЕҚ *и.* Илгәзәк булу.

ИЛГӘЗӘҚЛӘНҮ *ф.* Үзен илгәзәк тоту. // *күч.* Чамадан тыш мутлану, кылану. // Уйнаклау. *Иртән ара-тирә япа-ялгыз очып килгән кар бөртекләренең инде мулланып, илгәзәкләнеп, төрле яктан бөтерелгәләүләре дә кешеләрнең кәефен тырный алмый.* А. Гыйләҗев.

ИЛГӘСӘР *и. диал.* Ил күләмендә тилеләрнең тилесе; илнең тилесе. *Әллә шуңа хәтере калдымы икән илгәсәрнең?* Г. Әпсәләмов.

ИЛДӘТНӘ *и. диал.* Өйдән өйгә кереп йөрергә яратучы биләмче хатын. [*Оекбаш*] *башын су итеп, Авыл арасын ду итеп, Ул йөрер юртаклап, Илдән кайтмас илдәтнә.* Мәкаль.

ИЛДӘШ *и.* 1. Кем белән дә булса ватаннары бер булган кеше; ватандаш. *Урман, урман, миңа чиксез авыр Бу хурлыклы түбән әсирлек! Әйт син миңа, илдәш дусларымны Кайсы почмагыңа яшердең?* М. Җәлил.

2. Якташ. *Аксубайдан шундый ерак җирдә, Кавказ сырты киртләчләрендә, Кем уйлаган, шундый биеклектә Очрармын дип илдәшләремә.* Х. Туфан.

ИЛЕ *с. диал.* Җайлы, рәтле.— *Әле синдә мужик тупаслыгы, Тыңла, яшьтәш, бераз иле бул. Булса булыр, булмаса юк, дию — Колхоз өчен кул сүз түгел ул.* Ф. Қәрим.

ИЛЕГҮ *ф. диал.* Берәр мохитка ияләнү, үзләшү. *Кеше баласы кештәккә тыксаң да илекмәс, Бүре баласын бүреккә салсаң да илекмәс.* Мәкаль.

ИЛЕК *и. диал.* Кыр кәҗәсе, урман кәҗәсе. [*Ир*] *бүген дә алып кайткан бер илекнең — урман кәҗәсенең итен ботарлап мәш килә.* М. Госманов.

ИЛЕРҮ *ф.* Ямьсез ачы, хәвефле тавыш белән бик каты кычкыру, акыру. [*Ул*] *үз тавышыннан үзе куркып: «Әнкәем!» — дип илерде.* Ш. Қамал. *Профессор аның әченә кагылуга, Чибәркәева илереп җибәрде.* [*Профессор:*] *«Нигә кычкырасыз, авыртмый ич».* Г. Әпсәләмов. // *рәв. мәгъ.* **илереп.** Үз-үзен белештермичә, үкереп (елау). *Кемдер илереп үкси башлады.* Қ. Нәҗми. *Минем җырларымны җырлаганда Туганнарым илереп елыйлар.* Бәет.

ИЛ-ЙОРТ *җый. и.* 1. Туган як, туган авыл, йорт-җир.— *Юньле кеше илен-йортын ташлап Колчак --- артыннан да тагылып китми ул!* Н. Исәнбәт.

2. Туган як халкы; халык. *Ил-йортның күпчелеге шулай карагач, инде акыллы усал бай-түрә Мирзаның калдыкларын* [*яклап*] *казакъ баласы тавыш бирмәс.* Г. Ибраһимов.

ИЛ-КӨН *җый. и.* 1. Ил һәм аның халкы. *Һәр илбасар — сугыш чукмары Сукыраеп һәлак булган, ди, һәм ил-көнгә бәйрәм туган, ди...* Г. Хуҗи. *Дөньяда бер зур теләгем бар иде: кызым яхшы кешеләргә иш булсачы, кем баласы, аның баласы дигәндә, ил-көн арасында, яхшыдан яхшы туган, дип телгә алсаларчы.* Г. Бәширов.

2. Тормыш, хуҗалык (семья рамкасында). *Егет шул акча белән* [*генә*] *илен-көнен рәткә сала алмаган, эш эзләп, Каспий буйларына, промыселларга килгән.* Г. Нигъмәти. *Халык, арба басып киткән түмгәкне яңадан өярга керешкән кырмыска күчедәй, мәш килеп, үзенең илен-көнен торгызырга, рәткә кертергә тотынды.* Ә. Еники.

ИЛ-ҚҮЗ *җый. и.* Халык, авыл халкы. *Мин Гайниярне еш күрәм. Ил-күз тынгач, карт-коры йоклагач, урам як бакчалары аша аңа барам.* Г. Ибраһимов.— *Укымаган балаларның --- ата-анага күпме зыян китерүләре, ил-күз алдында аларны рисвайлыкка төшерүләре һәркайсыбызга мәгълүм.* Х. Қәрим.

ИЛҚҮЛӘМ *с.* Бөтен ил өчен гомуми, әһәмиятле. *Шушындый зур, шушындый киң, илкүләм бай иҗатның бары тик кайберләре генә язылып калганнар.* Н. Исәнбәт.

ИЛ-ҚҮРШЕ *җый. и.* Күрше-тирә халкы, туган авыл халкы. [*Тимери*] *киләчәктә Акбит нәселенең генә түгел, бөтен тирә-якның данын, намусын иң беренче булып ил-күрше алдында күтәреп чыгучы кеше аның улы — Газиз булырга тиеш дип уйлый иде.* Г. Бәширов.

ИЛЛӘ *көч. кис.* 1. *к.* иллә (1 мәгъ.).— *Илла шул арттырып, күпертеп сөйләүләрегезне яратмыйм.* Р. Ишморат. *Илла шәп таш пулат та соң безнең йорт!* Г. Әпсәләмов.

2. *карш. терк. к.* иллә (2 мәгъ.). *Алай-болай курыксагыз, үзем җавап бирәмен, илла алар акчаны алдан бирә барырлар, дидем.* С. Рәмиев.

ИЛЛАЛЛА *рәв. сөйл.* Қөчкә, көч-хәл белән, ах-вах килеп. *Алай-болай итеп көчкә, иллалла үзебезнең авыл урманына чыгып котылдык.* М. Гали.— *Миңе товар белән яптылар. Қөчкә, иллалла судка кадәр генә дип чыгардылар.* Т. Гыйззәт.

◇ **Иллалла, кырык мулла белән** — көчкә, көч-хәл белән; ах-вах килеп. *«Иллалла, кырык мулла белән» дигәндәй, аңардан зәгъфран суы алып кайттым.* З. Бәшири.— *Әле генә иллалла, кырык мулла белән хан казнасына биш йөз алтын салым китертеп салдым.* Н. Исәнбәт.

ИЛЛЕ I *сан.* 50 саны.— *Миңа ике илле тулды инде, йөз дә бер белән барам, беләсең килсә.* Г. Минский. // Шул санның микъдары.— *Егерме биш сумны ике ел бирми йөрткән өчен процент унбиш сум, барлыгы кырык сум. --- Сеңелкәштән гашыйк-мәгъшүк сәламе китергән өчен ун сум. Шулай итеп, барлыгы төп-төгәл илле сум булып чыга.* Ш. Қамал.

◇ **Илле батман Идел суы** *сөйл.*— тәмсез, сыек аш турында.— *Бу ни бу, илле батман Идел суы? Кеше төсле рәтләп аш та пешерә белмисең.* Т. Гыйззәт. **Илле иләктән уздыру** — бик нык, берничә мәртәбә тикшерү. [*Әсирләрнең*] *һәркайсын илле иләктән уздыр*[*ганнар*]. Ш. Маннур.

ИЛЛЕ II *и.* Бармак киңлегенә тигез үлчәү берәмлеге (6 арпа киңлегенә, ягъни 18 *мм* га туры килә). [*Карт*] *уртасы бер илле генә калган чалгысын түндәк башына сабы белән кадады.* Г. Ибраһимов.— *Итнең өстендә бер илле мае бар.* Ф. Сәйфи-Қазанлы.

ИЛЛЕЛЕҚ I *и.* Илле сумлык кәгазь акча. *Ул букчасыннан изелеп, майланып беткән бер төргәк иллелекләр, йөзлекләр тартып чыгарды.* А. Гыйләҗев. *Яңа унлык, яңа иллелекләр Қыштырдасын әле кулларда.* З. Мансур.

ИЛЛЕЛЕҚ II *и.* (Бармак) киңлеге. *Муса белән Андре камерада шул капкачларның уртасына ике бармак иллелеге ырмау ясарга тиешләр.* Ш. Маннур. *Бу юлы коньякны Вәсилә салды. Аз гына, бармак иллелеге генә итеп салды.* М. Хәсәнов.

ИЛЛЕЛӘП *Чама саны. к.* илле I. *Барлыгы иллелəп савым бия бар иде.* Г. Ибраһимов.

ИЛЛЕНЧЕ *Тәрт.* саны. *к.* илле I.

ИЛЛЕШӘР *Бүл. саны. к.* илле I. *Ике китап язып, иллешəр тəңкəдəн 100 тəңкə акча алган идем.* Г. Тукай. *Спектакльдə катнашкан өчен безгə иллешəр тиен акча бирделəр.* Х. Сəлимҗанов.

ИЛЛЕШӘРЛЕК *и. к.* иллелек I.

ИЛЛЕШӘРЛӘП *Бүл. саны.* Иллешəр-иллешəр итеп.

ИЛЛЮЗИОНИЗМ *и. филос.* Тышкы дөньяны күз буяу, тойгыларны алдау дип кенə саный торган идеалистик философия агымы.

ИЛЛЮЗИОНИСТ *и.* Күптөрле һəм катлаулы җайланмалар ярдəмендə фокуслар күрсəтүче цирк артисты. *Русларның үзләренең яраткан артистлары бар иде. --- Акробат Саша маленький, иллюзионист Андрей Федоров --- исемнəре тоткыннар теленнəн төшми иде.* Г. Əпсəлəмов.

ИЛЛЮ'ЗИЯ *и. кит.* 1. Тойгыларның алдавы нигезендə чынбарлыкны бозык, хата күз алдына китерү; чынлыкта булмаган, уйдырма нəрсəне чынбарлык итеп кабул итү. [*Шигырьдə*] *сүзләрнең тиз алмашынуы, картиналарның бер-бер артлы үзгəрүләре чынлап та поезд белəн баргандагы иллюзияне тудыра.* Ф. Хөсни. *Авыз-шигырь иҗатының фантастик геройлары --- гаҗəеп иллюзияләр рəвешендə шагыйрь күз алдына килеп басалар: кышкы кырның салкын бураны шагыйрь күз алдына табигать иркəсе — шүрəлене китереп чыгара.* Г. Нигъмəти. // Берəр нəрсə турында ялгыш караш; тормышка ашмаслык хыял, булмаслык эш. *Капиталист министрлар хөкүмəтенең бу җинаяте барлык элекке иллюзияләрне юкка чыгарды.* К. Нəҗми.— *Моннан качып китү — иллюзия.* Ш. Маннур.

2. Фокус ясаучы, иллюзионист номеры.

ИЛЛЮ'ЗИЯЛЕ *с.* Хыялый, ялган, иллюзия тудырган.

ИЛЛЮ'ЗИЯЛЕЛЕК *и.* Иллюзияле булу, иллюзиягə бирелү. *Кайбер эшлəрдə артык төчелек, иллюзиялелек һəм рəсем сəнгатенең начар үрнəкләренə ияру тенденциясе сизелə.* Х. Якупов.

ИЛЛЮЗОР *с.* Иллюзиягə нигезлəнгəн; тормышка ашмый, хыялда гына була торган, реаль тормыш белəн бəйлəнеше булмаган.

ИЛЛЮЗОРЛЫК *и.* Иллюзор булу.

ИЛЛЮМИНА'ТОР I *и.* Корабльдə калын пыялалы түгəрəк тəрəзə. *Мин кулым белəн иллюминаторны сыпырып алдым, ләкин пыяла барыбер чистармады.* Р. Мостафин. *Гəрəй түгəрəк иллюминатордан тышка карады.* Г. Ахунов.

ИЛЛЮМИНА'ТОР II *и.* Иллюминацияләр ясаучы белгеч; пиротехник.

ИЛЛЮМИНА'ЦИЯ *и.* Берəр тантана, бəйрəм уңае белəн урамнарны, йортларны төрле төстəге утлар, утлы язулар белəн яктырту. *Сəхнə төрле төстəге электр утлары иллюминациясенə бизəлə.* Г. Минский.

ИЛЛЮМИНА'ЦИЯЛƏҮ *ф.* Төрле төстəге фонарьлар, утлар белəн бизəү; иллюминация ясау.

ИЛЛЮСТРАТИВ *с.* Берəр нəрсəгə иллюстрация булып хезмəт иткəн; күрсəтмəле. *Хезмəтнең иллюстратив материалга бай булуы аның фəнни һəм практик əһəмиятен тагын да күтəрə.* Л. Җəлəй. *Безгə урта кул, иллюстратив эсəрләр белəн дə əшнəлекне бетерергə вакыт җиткəндер.* И. Нуруллин.

ИЛЛЮСТРА'ТОР *и. махс.* 1. Текстның эчтəлегенə ярашлы рəсемнəр ясаучы художник. *Шундыйлар рəтенə китап һəм газета-журнал иллюстраторлары М. Галиев белəн Г. Гумеров керə.* Ф. Ибраһимов.

2. Сəхнəдə уйналган берəр күренешкə музыка белəн кушылып уйнаучы кеше; аккомпаниатор. *Ул вакытта кинолар тавышсыз була, һəм фильм барышында иллюстраторлар пианинода уйнап торалар.* Ч. Бəхтиярова.

ИЛЛЮСТРА'ТОРЛЫК *и. махс.* Иллюстратор профессиясе, эше.

ИЛЛЮСТРА'ЦИЯ *и.* 1. Китапта, газета-журналда эчтəлекне аңлату, ачыклау өчен бирелгəн рəсем. [*Сəнгать*] *турындагы хəзергəчə чыккан бик күп китапларның битлəрен актарып, иллюстрацияләренə күз ташлау белəн, «бу əсəр Лувр музеенда саклана» дигəн имзалар бик күп очрыйлар.* Г. Гали.— *Кукурузның уңганлыгын бу кадəр оста чагылдырган мондый иллюстрацияне мин таба алмаган булыр идем, əле яхшы, җəй көне син моны төшереп ала белгəнсең.* Г. Галиев.

2. Берəр фикерне, сүзне ачык итеп күз алдына китерə торган мисал. *Аның күз алдына Карип Ишбулдин яңадан килеп басты. Шəфи Алмаз сөйләгəннəрнең җанлы иллюстрациясе кебек тора иде ул.* Ш. Маннур.

3. *əд.* Кешенең эчке рухи халəтен, вакыйгаларның асылын җанлы образлар аша ачу урынына эсəрдə берəр вакыйганы, хəлне өстəн-өстəн генə сурəтлəү. *Əдəби əсəрне барыннан да элек һəм бары тик теге яки бу иҗтимагый-политик хəлнең иллюстрациясе итеп кенə аңлату --- мəктəп практикасында əле тулып ята.* Ф. Хөсни. // Берəр эсəргə музыкаль кушмалык. *«Качкын» операсы — чын мəгънəсе белəн опера. Ул — музыкаль иллюстрация ролен генə үти торган музыкалы пьеса түгел.* М. Җəлил.

ИЛЛЮСТРА'ЦИЯЛЕ *с.* Иллюстрацияләре (1 мəгъ.) булган; рəсемле. *Аның ике терсəге арасында иллюстрацияле ниндидер журнал җəелеп ята, битлəрендə зур-зур портретлар.* Ш. Маннур.

ИЛЛЮСТРА'ЦИЯЛƏҮ *ф.* 1. Эчтəлекне аңлату, ачыклау өчен, текстка рəсемнəр бирү. *Художниклар --- [Тукай] шигырьлəрен иллюстрацялилəр.* Сов. əд.

2. Билгеле бер фикерне һ. б. ш. күз алдына китерү өчен мисаллар куллану. *Г. Галиевнең бу хикəяләре совет шартларында авылның, авыл кешеләренең тормышы һəм психологиясе, дөньяга карашы ничек үзгəрə баруын реалистик стиль белəн, җанлы фактлар белəн иллюстрацияләгəн кечкенə күләмле проза үрнəкләре иде.* Г. Халит. // Берəр əсəргə музыка белəн кушмалык итү. *Кинофильмда геройларның күңел үзгəрешләрен һəм драматик бəрелешләрне [музыкант] музыка теле белəн иллюстрацияли.* Ж. Фəйзи.

ИЛЛЮСТРА'ЦИЯЧЕЛЕК *и.* Иллюстрация (3 мəгъ.) белəн мавыгучанлык. *Зуррак темаларга алына башласак, безнең əсəрләрдə иллюстрациячелек, схематизм көчəя.* Х. Вахит. *Безнең шигырьләрдə иллюстрациячелек һəм риторика элементлары да əлегə аз түгел.* Э. Исхак.

И'ЛЛƏ 1. *көч. кис.* Берəр төрле тойгыны белдерү чарасы буларак кулланыла; бик тə, бигрəк тə.— *Иллə дə тынгысыз күршеләр булып чыктыгыз соң, минем йөрəккə дə гел борчу салып торасыз.* М. Шабай.— *Иллə карарсыз да инде син, Мавия.* М. Фəйзи.

2. *карш. терк. сөйл.* Əмма, тик, ләкин.— [*Флагны*] *тапшыру тантанасына бармый калу үзе зур гөнаһ булыр. Кырык эшең кырылып калсын, иллə барырга кирəк!* Ш. Камал. [*Ул*] *нидер əйтмəкче булды, иреннəре кыймыл да кыймыл, иллə сүзен əвəлəп чыгара алмады.* Ф. Хөсни.

Иллə мəгəр *сөйл.*— 1) бик тə, бигрəк тə.— *И карчык, --- бəлеш ашадым, иллə мəгəр тəмле дə соң!* Г. Бəширов; 2) əмма ләкин (көчəйтү төсмере белəн ачуланып яки чын йөрəктən ышандырып əйтелə).— *Телəсəгез ни əйтегез, иллə мəгəр моның кебек зур эшне болай коры гына калдырырга ярамый.* Э. Еники.

ИЛЛƏРАРА *с.* Илləр арасында яшəп килə, гамəлдə була, эшлəнелə торган. *Безнең эш илləрара экономик бəйлəнеш, илləрара сəүдə һəм тынычлык өчен кирəк.* Сов. əд.

ИЛСАТАР *и. сир.* Ватанына хыянәт итүче, ватанын сатучы кеше. *Илсатарлар кулында [үлгәнче], Алар белән сугышып үлү мең кат артык!* Н. Исәнбәт.

ИЛ-СУ *җыл. и. сөйл.* 1. Туган авыл, туган як; йорт-җир. *Гәрәй үзенә үзе бик кызганыч, иленнән-суыннан аерылган кеше сыман күренә башлый.* Г. Мөхәммәтшин.— *Илегез-суыгыздан аерылып, кая бармакчы итәсез соң?* М. Шабай.

2. Халык, авыл халкы. *Ул, дөрестән дә, кызын әнә шундый баерак кешегә бирәп, байлар белән аралашып, картайган көнендә, улыннан булмаса, кызының игелеген күреп, ил-су алдында дәрәҗәгә менеп калырга омтыла иде.* Ф. Хөсни.

ИЛСӨЯР *с.* 1. Туган иленә, туган халкына мәхәббәт һәм бирелгәнлек белән сугарылган; патриотик. *Туган җир! Нигә син шул хәтле кадерле, кочаклап үбәрлек якын икән? Бездәге иң бөек тойгы, илсөяр тойгы, ата-бабаларыбыз дөнья көткән, дөнья калдырган менә шушы кечкенә йорттан башлана бит.* Х. Сарьян. // Туган илгә мәхәббәт һәм бирелгәнлек белдергән, туган илгә мәхәббәт һәм бирелгәнлек белән сугарылган. *Илсөяр шигырьләр.*

2. *и. мәгъ.* Үз ватанын, үз халкын яратучы, үз ватанына, үз халкына бирелгән кеше; патриот.

ИЛСӨЯРЛЕК *и.* Туган илгә, туган халкына мәхәббәт, бирелгәнлек.

ИЛТЕР *и.* Бөдрә йонлы бәрән тиресе. *Кулына бер дистә илтер тотып --- йөрүче Касыйм маклерлары да килде.* Ш. Мөхәммәдев. // Шундый тирене махсус эшкәртеп ясалган мех (каракүлнең бер төре). // *с. мәгъ.* Шундый тиредән тегелгән. [*Сөләйман*] *янында басып торган илтер бүрекле борылып: «Бу нинди хәл?» — дип карады.* К. Тинчурин.

ИЛТИМАС *и. иск. кит.* Үтенеч. *Сездән янә бер илтимасым бар: Сез --- хат язганда, мәгълум итегез.* Г. Тукай. *Илтимасым ошбу саба җиленә: Бер хатым бар, илтсә Борнай иленә.* Г. Кандалый.

Илтимас итү (кылу) — үтенү. *Дус-ишләр шул матур вә мөкатдәс хезмәтне хосусый миннән илтимас иткәнгә, --- ушбу «Мәктәптә милли әдәбият дәреслә ре» китабыны тәртип иттем.* Г. Тукай.

ИЛТИФАТ *и.* 1. Ягымлылык, ихтирамлы игътибар. *Күрешергә теләсәм дә, ул артык илтифат күрсәтмәде. Тик кулын бирәп, күзе белән карамый, әллә кем белән сөйләшкәне хәлдә үтеп китте.* М. Гафури.

2. Кадер-хөрмәт, олылау. *Мәҗлес аның мөнәсәбәтен үзәрткән — якын вә дус кебек ясаган иде. Шул тәэсир белән ул бүген Зарифка аерым илтифат күрсәтмәкче, кунак кылмакчы иде.* Г. Ибраһимов.— *Күрче, нинди күркәм табын! Рәхмәт сезгә, рәхмәт, ханым, Илтифат өчен.* Г. Насрый.

Илтифат итү (кылу, бирү) — 1) игътибар итү, дикъкать итү. *Тышкы күренеше белән хәерче сыман бу картка башта ул илтифат итмәде.* Ш. Камал; 2) игътибарга алу, ихтирамга алу, әһәмият бирү. [*Зәйнәп*] *боларның бу сүзләрен әһәмияткә алмый, халык сүзенә илтифат итми.* М. Гафури. *Надан дигән үзен белмәс, Сүзеңә илтифат кылмас.* Г. Кандалый; 3) хөрмәтләү, илтифат белән карау, ачык йөз күрсәтү.— [*Ул*] *бик ачык йөзле, кешегә бик илтифат итүчән, мәҗлесе бик хозур кеше икән.* Г. Камал. **Илтифат ясау** — кадер-хөрмәт күрсәтү, хөрмәтләү, олылау. [*Көтүче*] *кунакка илтифат ясады.* Г. Ибраһимов. **Илтифатка алмау** — игътибарга, исәпкәсанга алмау, әһәмият бирмәү. *Ләкин аның бу зарлануын егетләр аз гына да илтифатка алмадылар.* Ш. Камал. *Мин сөйләгәндә сызгырсалар да, һич илтифатка алмадым.* Ш. Мөхәммәдев.

ИЛТИФАТЛЫ *с.* 1. Хөрмәт итүчән, ихтирамлы. *Минем дуслар саф йөрәкле, илтифатлы, хөрмәтле.* Ә. Еникәй. *Кешегә илтифатлы булу, аңа хөрмәт белән карауның төрләре чиксез.* Азат хатын.

2. Игътибарлы, дикъкать итүчән. *Шагыйрьне үз эшенә тагын да тирәнрәк игътибар бирәп карарга, язуда илтифатлы булырга --- чакырабыз.* Г. Кутуй.

ИЛТИФАТЛЫЛЫК *и.* Илтифатлы булу, илтифатлы булу сыйфаты. [*Шагыйрьдән*] *шигырь кануннарына илтифатлылык сорала.* Н. Юзиев.

ИЛТИФАТСЫЗ *с.* 1. Игътибарсыз, игътибар итмәүчән, әһәмият бирмәүчән.— *Менә сез үзегез ифрат --- илтифатсыз [кеше]. Мин сезне якын күреп сөйләшәм, ә сез рәтләп тыңламыйсыз.* Ш. Камал. // *рәв. мәгъ.* Игътибар итмичә, әһәмият бирмичә, **игътибарсыз**. *Хәлфә минем сүзне илтифатсыз калдырмады, җавап бирәп китте.* М. Гафури. [*Гомәр*] *тыштан илтифатсыз гына торган кеби, әмма эченнән бөтен дикъкатен бер ноктага җыеп, күзләрен астан гына шул якка юнәлдерә.* Г. Ибраһимов.

2. Ихтирамсыз, хөрмәт итмәүчән. [*Аның*] *аптыраганы да --- анасыннан гафу сорамавы, һаман аңар илтифатсыз һәм салкын мөгамәләсе өчен иде.* Ш. Камал.

3. *рәв. мәгъ.* Ис китмичә. *Җәллад бугазына киерткәндә дә богауны, Егет каушамый, илтифатсыз каршы ала аны.* Г. Камал. *«Ни күрсәк тә --- күрербез»,— дип, илтифатсыз йөрсәк, тиз заманда --- һәлак булачакмыз.* Ш. Мөхәммәдев. // *с.* Ис китмәүчәнлекне белдергән. *Ул илтифатсыз, бераз караңгы йөз белән синең язмаларыңны алып кала.* Г. Ибраһимов.

ИЛТИФАТСЫЗЛЫК *и.* Илтифатсыз булу. *Без кайвакыт билгесезлектәнме, илтифатсызлыктанмы — тарихи кыйммәте булган халык сәнгате әсәрләрен игътибарсыз калдырабыз.* Б. Урманче. *Мостафа, аны бөтенләй күрмәмешкә салынып, урамның икенче ягына чыкты. Бу илтифатсызлык Гыйльметдингә бигрәк тә ошамады.* К. Нәҗми.

ИЛТӘБИР *и. бор. к.* вассал.— [*Алмыш хан*] — *Хазар йортның, изге каганның колы... илтәбире.* Н. Фәттах.

ИЛТҮ *ф.* 1. Җитәкләп, күтәреп я утыртып кая да булса алып бару. *Илтеп ташлау. Илтә китү.* □ *Ул тимер көрәген почмакка илтеп сөяде.* Г. Әпсәләмов. *Их машина, машина, Кая болай ашыга. Калаларга икмәк илтә, Ул ашыга бит шуңа.* М. Җәлил. *Җил ихтыярсызлап әллә кайларга сөреп илтә.* Ш. Камал.

2. Нәрсәгә булса да алып бару. *Маркс-Ленин юлы адәмнәрне чын азатлыкка, яктылыкка илтәчәк.* Г. Ибраһимов. *Актүбәдән Оренбургка илтә торган тимер юл буйлап сузылган таулар өстенә менеп карасаң, --- Яйсан станциясе күренә.* Ш. Усманов.

3. *күч.* Көрәштә, эштә җитәкче булып алып бару, әйдәү. *Батыр егет! --- Илт син безнең егетләрне яугa!* М. Җәлил. *Партия! --- Илт Ленинның сукмагыннан, Социализм юлларыннан; Илт батыр миллионнарын, Эшче сыйныфның җиңелмәс Соңгы көрәш сафларын!* Ф. Бурнаш.

4. Берәр нәрсәгә сәбәп булу, шуңа китерү. *Каты җилләр һәм давыл, бозның ачлыкка илтәчәген* [*игенче*] *яхшы белә.* Г. Нигъмәти. [*Мондый*] *уңышсыз сүзләр --- телне бозу, әсәрне укучыдан ераклаштыруга илтәләр.* М. Җәлил.

◇ **Илтеп җиткерү** — 1) нәрсәгә булса да ирешү, берәр эшне башкарып чыгу, теләкне тормышка ашыру. *Ул бу әһәмәне ни өчен башлавын нык исендә тотып, сүзне уенга бормыйча, ничек тә төп мәсьәләгә илтеп җиткерергә тели иде.* Ә. Еники. *Ул мең төрле план төзеде, мең төрле хәйлә корды, ләкин һичбере теләккә илтеп җиткерерлек булып чыкмады.* Г. Ибраһимов; 2) берәр кеше турында кемгә дә булса барып әйтү, әләкләү. *Кайсыдыр кәһәре аларга минем урларга теләвемне илтеп җиткергән.* А. Шамов.

ИЛХАН *и. бор.* Патша; илнең ханы, башлыгы. *Илхан булырга теләүче Пугачевны --- генерал Михель-*

сон Казаннан тотып кайткан, имеш. Борынгы татар әдәбияты.

ИЛЧЕ *и.* 1. Берәр мөһим йомыш белән, берәр эш буенча арадашлык итү өчен кая да булса, кемгә дә булса җибәрелгән кеше.— *Илчегә үлем юк, Фәхри абзый, без ахун хәзрәт кушканга килдек. Безнең белән бармасаң да, барыбер икенче кешеләр үзеңне алып китәрләр.* М. Гафури. [*Мидхәт*], *Сибгатулла бабайны үзләренә баш итеп чакыру өчен, өч пионерны илче итеп җибәрде. Илчеләр бик тиз Сибгатулла бабайның ризалыгын алып кайттылар.* Г. Гобәй. // Ике арада йөрүче, йомышчы; курьер.— *Яшь күңелләрнең сәламен ташу өчен лаек бер илче... Ал, илче, бу хатны! Ал да, яшь мирзага илтеп, ахак кашлы көмеш иярен сора.* М. Фәйзи. *Еш кына редакция белән типография арасындагы илче дә (гади тел белән әйтсәк, курьер да) үзем.* М. Максуд.

2. Дошман якларның берсе тарафыннан икенчесенә сөйләшүләр өчен җибәрелгән вәкил; парламентёр.— *Күрәмсең син, синең каршыга Далай ханнан килде илчеләр.* Н. Исәнбәт. *Илне канга батырачак бер эштән болай котылуларына шатланып, --- илче кунаклар Сарыбай җәйләвенә килешү булганлыкны хәбәр итәргә юнәлделәр.* Г. Ибраһимов.

3. Югары рангтагы дипломатик вәкил. *СССРның Франциядәге илчесе.* □ *Әй, сез, лордлар, ерткыч юлбасарлар! --- Яки безгә үлем, яки сезгә, Ишетегез! Илчебезнең канын даулыйбыз!!* Һ. Такташ.

4. *күч.* Билгеле бер кешеләр төркеменнән яки кешеләр эшчәнлегенең берәр тармагыннан вәкил. *Татар сәнгатенең илчесе булып Мөнирә Булатова да килгән иде.* М. Максуд.— *Мин ачы юллы хакыйкатьнең илчесе, мине чакырган идең, килдем.* Г. Коләхметов.

5. *күч.* Алдан хәбәр китерүче, хәбәрче. *Илчем — җил аркылы сәлам сөйлим Сезгә: Чәчәкләргә, гөлләргә, Нәфис лаләләргә, сөмбелләргә.* Һ. Такташ. *Зур хәбәр, сөенеч бирергә халкына, Китте алдан илче Каф-тау артына.* Ш. Бабич.

6. *иск. кит.* Пәйгамбәр, рәсүл. [*Аның*] *бозау абзарында пычракта аунап яткан җансыз гәүдәсе алланың барлык илчеләрен --- җавапка чакыра иде.* Г. Ибраһимов.

ИЛЧЕБАШЫ *и. бор.* Илчелек (2—3 мәгъ.) җитәкчесе.

ИЛЧЕЛЕК *и.* 1. Илче вазифасы. *Укчысына рөхсәт ителсен Илчелеген илнең үтәргә, Җәнабына хәбәр итәргә.* Ф. Бурнаш. *Ике арада илчелекне үтәүче килен авылның иң читендәге фәкыйрь тирмәдә иде.* Г. Ибраһимов.

2. Бер дәүләтнең икенче дәүләттә илче (3 мәгъ.) җитәкчелегендәге дипломатик вәкиллеге. *Илчелекнең ялтырап торган кара, зур «Зил»ларына утырып, аэродромнан шәһәргә юнәлдек.* М. Мәхмүтов. // Шул вәкиллек урнашкан бина. *«Әйдә, тиз!» — дип, [ул] илчелектән чыкты.* Ә. Исхак.

3. Билгеле бер максат белән җибәрелгән вәкилләр төркеме. *Багдадта болгарларга илчелек җибәрергә карар бирәләр.* Каз. утл. *Олеарий Шлезвиг-Гольштейн илчелеге сафында Мәскәүгә килә.* Г. Шамуков.

ИЛЧЕХАНӘ *и. иск. к.* илчелек (2 мәгъ.). *Рус патшалыгы илчеханәсе чит илләр белән бары тик рус, латин һәм татар телләрендә генә языша.* И. Рәмиев.

ИЛЬЯС: Ильяс камчысы *иск. мифол.*— дини мифология буенча: имеш, Ильяс пәйгамбәр үзенең камчысын селеккәннән соң карлар эри башлый, яз башлана.

ИЛӘ *бәйл. иск. кит. к.* белән. *Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә, Яд итәрләр, кем белә? рәхмәт илә.* Г. Тукай. *Бер бала боларның янындагы өстәлгә ике пар чәй илә бер пәрәмәч китереп куйды.* Ш. Мөхәммәдев.

ИЛӘК I *и.* 1. Он яки ярманы үзенә катышкан эре кисәкләрдән аеру, иләү өчен түгәрәк агач кысага кидерелгән челтәрдән гыйбарәт җайланма. *Җиз иләк. Кыл иләк.* □ [*Онны*] *эре иләктән — ярма иләгеннән генә үздырганмын, --- мин иләгән онны әни яңадан бер кат нечкә иләктән иләргә мәҗбүр булды.* Ф. Хөсни. *Бичара ана, хәзинәсендә ни нәрсә булса, һәммәсен төягән: ике тәлинкә, алты чаган кашык, бер агач табак, юкә иләк, еш тимер иләк, куна такта...* Г. Ибраһимов.

2. Орлык чистарту, җилгәрү, суыру машиналарында иләү өчен челтәр җайланма. *Сафа, суыру машинасының иләкләрен рәтләргә дип, ындырда берүзе калды.* А. Шамов. // Балчык, ком кебек нәрсәләрне үткәрү, иләү, сөзү өчен зур җайланма. *Аларның машиналашкан куллары --- таш катнаш балчыкларны тимер иләкнең бер ягыннан икенче ягына йөгерт[әләр].* М. Гафури.

Иләк йолдыз *астр.*— йолдызлар төркеменнән берсенең халык телендәге исеме; *русчасы:* стожары. *Андасанда Иләк йолдызлар тоныкланып, Өелешеп-өелешеп торган бу йолдызларны нинди шагыйрь иләккә охшаткандыр!* Г. Әпсәләмов. **Иләк өсте** — ашлык иләгәндә иләк челтәре өстендә кала торган башак, кибәк һ. б. ш. гыйбарәт эре чүпләр.

◇ **Иләк авыз** *гади с. тирг.*— 1) түгеп-чәчеп ашаучы кеше; 2) зур авыз.— *Их, иләк авыз, иләк авыз... Юкка гына мин уймак авыз дип җырлап йөргәнмен икән!* Ф. Бурнаш. [*Ул*] *ямьсез тешләрен күрсәтеп, иләк авызын җәеп җибәрде.* Ф. Сәйфи-Казанлы; 3) сер тотмас (кеше).— *Монда сөйләшкән монда калсын. Иләк авыз булма.* Г. Мөхәммәтшин. **Иләк асты** — 1) иләгәндә аска коелган чүп-чар; 2) эшкә ярамаган, яраксызга чыккан нәрсәләр, кешеләр. **Иләк аша үткәрү** — җентекләп, төрле яктан тикшерү, тикшереп, бик нык сайлап алу. **Иләк баш** *гади с. тирг.*— 1) тиз онытучан кешегә карата әйтелә; 2) аңгыра, надан кешегә карата әйтелә. **Иләк белән кояш (су) ташу** — кирәксез, файдасыз, максатсыз эшләр белән шөгыльләнү.— *Ишморат, нәрсә эшлисең? — дип сорагач: «Көндез иләк белән кояш ташыйм, кичен комнан аркан ишәм»,— ди торган иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Тилегә акыл бирү — иләк белән су ташу.* Мәкаль. **Иләк бит** *гади с. тирг.*— шадра битле кеше турында әйтелә. *Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит, Синең кебек иләк битләр сирәк бит.* Г. Тукай. **Иләк булу** — сизрәү, тишкәләнү (әйбер турында). [*Ат*] *бөтенләй тишкәләнеп иләк булган, --- төз аткаларын, --- тишкәләп бетергәннәр.* Ш. Усманов. **Иләкнекен чиләккә бушату (авыштыру)** — 1) мәгънәсез, нәтиҗәсез бер эш белән шөгыльләнү.— *Кәҗәң кайтмаган, утының ярмаган, самоварыңның борынын сыламаган, ... йөрисең шунда иләкнекен чиләккә бушатып, сакалыңны сәлперәйтеп.* Ф. Бурнаш. *«Кыямәт хак, Мәкәрҗә дә ялган түгел, хак»,— дип, иләктән чиләккә авыштырып, Мәскәү малы илә бай булып йөрүче абзыйлар да [ярминкәгә] килерләр.* Ш. Мөхәммәдев; 2) гайбәт сөйләп йөрү. *Бу турыда --- Галимә карчыкка да сөйләп карамакчы булган иде дә, Галимәнең сүз йөртүче, иләкнекен чиләккә авыштырырга яратучы бер карчык булуын уйлап, ул фикереннән кире кайтты.* Ф. Хөсни. **Иләктән уздыру (үткәрү, үткәзү, сөзү)** — *к.* иләк аша үткәрү.— *Сезнең белән бергә ясаган ул экспериментны безгә бер утырып тәнкыйть иләгеннән уздырырга кирәк. Шуннан соң нәрсә булса да өзеп әйтә алырбыз.* А. Расих. *Исемлек башта зур гына булды, бергәләп тикшереп-сайлап иләктән үткәрә торгач, күп кенә исемнәр --- төшеп калды.* Г. Минский.

ИЛӘК II *и. сөйл.* Металл акчаның бәһасен күрсәткән цифрлы ягы; *киресе:* күн.— *Бер заман [Сарымсаков] акча чөя. --- Янәсе, күн төшсә — отлично, иләк төшсә — үзеңә үпкәлә.* Г. Ахунов. *Акча күн ягы белән килә, иләк ягы белән китә.* Мәкаль.

ИЛӘКЛӘНҮ *ф. сөйл.* Тузып, тишкәләнеп бетү (кием турында). *Очкын тиеп иләкләнгән кием-салымнарыннан ыс исе, төтен исе килә иде.* А. Гыйләҗев.

ИЛӘҠЛӘП-ЧИЛӘҠЛӘП *рәв.* Бик көчле, күп итеп (яңгыр яву турында). *Көтмәгәндә иләкләп-чиләкләп яңгыр коя башлады.* М. Хөсәен.

ИЛӘҠЛӘҮ *ф. сөйл.* Тишкәләү. *Вагоннарның түшәмидәннәрен пулеметлардан иләкләп узганнар.* М. Рафиков.

ИЛӘҠЧЕ *и.* Иләк ясау остасы, иләк ясаучы кеше. *Иләкченең иләге, чиләкченең чиләге булмас.* Мәкаль.

ИЛӘК-ЧИЛӘК, ИЛӘК-ЧҮМЕЧ *җыйд. и.* Йорт хуҗалыгында һәртөрле савыт-саба. *Хатын алсаң, иләк-чүмеч кирәк бит.* Г. Тукай.— *Башта иләк-чиләкләрне зур сандыкка тутырыйк.* Т. Гыйззәт.

ИЛӘМ *и. диал.* Ямь, матурлык. *Исән йөреп сау кайтсак, Иләм кертер идек авылга.* Җыр.

ИЛӘМЛЕ *с. диал.* Матур, ямьле. *Иләмле икән иләгең, күксеми микән чиләгең!* Н. Исәнбәт. *Карыйсыңмы, әнвәр, зелпе белән кочаклашып үскән имәнне? Тегендәрәк булыр. Искитәргеч — Әллә ничек, матур, иләмле.* Ш. Мөдәррис.

ИЛӘМСЕЗ *с. диал.* 1. *к.* ямьсез. [*Зәйтүнә*] *йөгереп килеп кызу мичкә сузылды, анда юеш пумала белән озак кына маташканнан соң, биленнән корымга маныльп, шактый ук иләмсез бер кыяфәттә әйләнеп чыкты.* Ф. Хөсни.— *Сакалыңны кырып ташласаң да зыян итмәс. Бигрәк иләмсез күренәсең болай.* Қ. Нәҗми.

2. *көч. кис.* Гаять, бик, гадәттән тыш.— *Бәрәңгедәй иләмсез олы борын белән генә мактанмаса, ул да әллә кем түгел...* М. Шабай. *Миче, бүлмәнең үзенә ятышсыз рәвештә, иләмсез зур.* М. Максуд.

ИЛӘМСЕЗЛЕҠ *и. диал. к.* ямьсезлек. *Көн үзенең бөтен иләмсезлеге, ачлыгы, талаш-сугышлары белән Габдулланы ашыкмый гына үтерә торган зур аждаһага әверелде.* Ә. Фәйзи. *Кандалый, тарихи сәбәбенә күз салмастан, мужикны аның көнкүрешендәге иләмсезлекләре, тупаслыклары өчен яманл[ый].* Х. Госман.

ИЛӘМТЕК *и.* Иләк төбендә калган чүп-чар.

ИЛӘМӘН *и.* Ил башлыгы, ил хуҗасы. *Үстергән аны Иделем, Иләмән иткән илем, Иделгә, илгә аваздаш Исемгә ия Ленин.* М. Шабаев. *Ил иле иләмән белән булганда, иләмән үзе белән була.* Мәкаль. // Гомумән хуҗа. *Илдә иләмән, кырда Сөләйман.* Мәкаль.

ИЛӘН *бәйл. иск. кит. к.* белән. *Сезне бу олуг көн иләң чын күңелебездән тәбрик итәбез.* Г. Тукай.

ИЛӘҢҮ *ф.* 1. *Төщ. юн. к.* иләү I (1 мәгъ.).— *Килеп җитте бит бу яз дигәннәре, ә минем әле чәчүлегем дә иләнмәгән.* И. Гази.

2. *күч.* Берәр эш, мәсьәлә яки кешеләр кат-кат, төрле яклап, җентекләп тикшерелү һәм яраклысы сайлап алыну. *Бу революция безнең ипташларебезгә имтихан булды. Революционерлар иләнделәр. Без хәзер кем безнең дус, кем дошман икәнлеген ачык аңладык.* Ш. Әхмәдиев. [*Аның*] *әсәрләре кыенлык белән, бик күп тәнкыйть аша иләнеп үтә.* М. Әмир.

3. *күч. сөйл.* Күп файдалануда булып таушалу. *Безнең машина исә, киресенчә, һич тә инәдән-җептән чыккан гына машина түгел иде, ул инде, кимендә, бер-ике ел иләнгән машина иде.* Н. Фәттах.

ИЛӘС *с.* 1. Җилкенүчән, бик тиз талпынып китүчән, шашкын (йөрәк, күңел турында). *Әй сез, бунтлар, җилтуфанлы көннәр, Өермәләр, утлар, вулканнар! Яраттым мин сезне Малай чакта, Әллә романтикка, Әллә йөрәк иләс булганга?..* Х. Туфан. // Җилкенүчән, шашкын күңелле. *Укымыйча гына «летчик булырга» хыялланучы иләс малай, сумкасын кая җитте шунда ыргытып, үенга чапкан.* Ф. Хөсни.

2. Җиңел акыллы. [*Ул*] *юри бераз иләсрәк булып кылана иде.* Г. Әпсәләмов.

ИЛӘСЛЕК *и.* Иләс булу. *Әллә ни тирәннән үйлап түгел, исерек бер иләслеккә бирелеп, шул ук вакытта --- мактанырга яратудан туган бу мәгънәсез сорау шулай да Галләм хаҗи өчен шактый мәгънәле булып чыкты.* Ф. Хөсни.

ИЛӘСЛӘНҮ *ф.* 1. Дулкынлану, җилкенү, талпыну (йөрәк, күңел турында). *Үз гомеремдә пароходка утырганым да, аны күргәнем дә юк иде, җизнинең бу тәкъдименнән күңелем тагын иләсләнде.* Ф. Хөсни.— *Андыймондый җирләргә йөртергә, күңелен иләсләндерергә, аздырырга кара.* М. Фәйзи.

2. Юләрләнү, дуамаллану.

3. Аңгыралану, миңгерәүләнү. *Авыр йокыдан иләсләнгәч, теләр-теләмәс уянып, [алар] тагын эшкә китәләр.* И. Туктар.

ИЛӘС-МИЛӘС *с.* 1. Җилкенүчән, шашкын (күңел турында).— *Картаясың килми торгандыр, дускай... Иңнәреңдә алтмыш елның йөге, ә күңелең һаман хыялый, һаман иләс-миләс.* Г. Әпсәләмов.

2. Акылга утырып җитмәгән, җиңел акыллы. [*Хәсби:*] *Сорашмадыңмы, нишләп алай алданган?* [*Тимай:*] *Иләс-миләс чагы бит. Хатынлыкка алам дигән тасма теленә ышанган.* Т. Гыйззәт. // Акылсыз, тилемсә. *Зиннәткә дә: «Шундый чакта иләс-миләс сүзләрем белән кешенең хәтерен калдырмыйм микән?» дип, бер уйлап карарга кирәк иде.* Г. Бәширов. // *рәв. мәгъ.* Ярым тиле, юләр сыман кыяфәттә. *«Дару»ларның, имтомнарның һичбер файдасы тими, ул һаман --- иләс-миләс тора. Куркынып, сискәнеп китә, я булмаса, шатлык күрсәтеп, әллә нәрсә сөйләп ташлый.* М. Гафури.

3. Аңгы-миңге, ярым исерек.— *Елама, бәгърем, йокыдан уянуга, иләс-миләс баштан, пәри-җен дип торам...* Г. Рәхим. // *рәв. мәгъ.* Ярым исерек кебек, үзүзен онытып, үз-үзен белештермичә. *Үзен үзе онытып, иләс-миләстәй йөрүче бер кеше йомырка пешермәкче булган.* Мәзәк.

Иләс-миләс килү — 1) (күңел) җилкенү, талпыну, дулкынлану; күңел урынынан кубу. *Бәлки, бүген аның урынына башка берәү килгәндер? Менә яхшы булыр иде! Стрельцовның йөрәге болай сикермәс, күңеле болай иләс-миләс килмәс иде.* И. Гази; 2) аңгы-миңге булу, ярым исерек кебек булу. *Үзем, йокылы кучер төсле, Иләс-миләс килеп утырдым.* М. Җәлил; 3) аңгыралану. *Иләс-миләс килә башым, Әллә гомерем аз микән?* Җыр.

ИЛӘС-МИЛӘСЛӘНҮ *ф. к.* иләс-миләс килү. *Күңел ниндидер билгесез, ләкин татлы бер талпыну белән талпынып, иләс-миләсләнеп, очына башлый.* И. Гази.

ИЛӘШЕНҮ *ф. диал.* Ияләшү, ияләнү.— *Бусы иләшенгән урын.* М. Әмир.

ИЛӘШТЕРҮ *ф. лингв.* «Өй, ой» дифтонгларын «и» гә охшатып әйтү (мәс., *сөйләү — силәү*).

ИЛӘШҮ *ф. диал. к.* ияләшү. *Бу — алтын-көмешкә җен иләшкән җир.* М. Гафури. [*Күңелгә*] *авыр югалтуның очкыннары кереп иләште.* Қ. Нәҗми.

ИЛӘҮ I *ф.* 1. Онны көрпәдән аерып алу өчен иләк аркылы үткәрү. *Он иләү.* □ *Ул капчыктан бер чеметем он алды да Миңнулла янына килде: «Менә нинди вагын состым. Кара әле, иләп торасы да юк бит. --- Из дә пешер».* А. Шамов. // Бөртекле ашлык, вак таш яки комны кирәкмәс нәрсәләрдән, чүп-чардан арындыру өчен иләк яки иләкләр аркылы үткәрү.— *Машина өчен орлыкны аеруча нык иләргә кирәк.* М. Җәлил.

2. *күч. сөйл.* Берәр эшне, мәсьәләне, кешене кат-кат, төрле яклап, җентекләп тикшерү. *Алар, үзләренең «виза» исемле иләкләреннән иләп, «коммунизм агитаторларының» үз илләренә аяк басуларыннан котылмакчы булалар.* Г. Гали.

3. *күч. сөйл.* Күп киеп таушалдыру, эштән чыгару. *Кием иләү.* □ *Хәчтерүшкә ни кирәк, йөри чабата иләп.* Ф. Хөсни.

4. *күч. гади с.* Кыйнау. *Теге егет шактый таза булып чыкты, берүзе өч егетне күз ачып йомганчы илəп ташлады.* М. Мəһдиев. // Бик каты **ачулану**, əрлəү. *Ничек кенə хатын илəмəде, Тормыш та нык кына сугарды.* Х. Камалов. // Талау, бөлгенлеккə **төшерү**.— *Без сезгə ышанып харап була яздык. Илəдегез инде, Нигъмəт əфəнде, илəдегез. Алла хəерле кылсын инде.* К. Тинчурин.

ИЛƏҮ II *ф.* Тиренең йонсыз ягын эчегән камыр яки имəн кайрысы суына салып (яки буяп) йомшарту, иетү һəм соңыннан чиста итеп кыру. *Илəми күн булмас, тиресез тун булмас.* Мəкаль. *Əхмəдинең этисе сарык тиресе или иде.* Г. Мөхəммəтшин.

ИЛƏҮ III *и. к.* кырмыска илəве. *Алар ашханəдəн чыкканда, халык кырмыска илəве кебек булып мыжлап тора иде.* Ф. Кəрим. *Ə кырмыска халкы бердəм: Чакырылмаган бу кунакны күрү белəн, Кайный башлый бөтен илəү, зур казандай.* Г. Шамуков.

ИЛҮ: илүдə йөрү *диал.*— үз эшен карамыйча, өйдəн өйгə эшсез, йомышсыз йөрү; биләмдə йөрү.

ИЛҮМƏ: илүмə килү *сөйл.*— үзара аралашып, шаулашып мəш килеп йөрү. *Хəзер мөселман егетлəренең эте-бете — һəммəсе* [*алар*] *белəн илүмə киләлəр.* Ф. Əмирхан.

ИЛ-ҖИР *җый. и.* Төрле илләр, җирләр. *Кеше, --- озак уйлап тормастан, ил-җир күреп, «дөнья гизеп» кайтырга дип, Сахалинның яки Камчатканың үзенə үк барып төшə.* Г. Бəширов.

ИЛһАМ *и.* 1. Гадəттən тыш дəрт, рухланыш, күңел күтəренкелеге. *Ул шушыларны зур илһам белəн Əмиржанга сөйлəгəн.* Ш. Камал. *Сулый саф, матур яз, Күңелləрдə илһам тудырып.* Ш. Мөдəррис.

2. Дəрт, рух чыганагы. *Син аңа илһам булырсың. Аның каламеннəн тагы да матуррак гөлləр түгелер.* М. Фəйзи.

Илһам бирү — илһамландыру, рухландыру. *Тукайга Кырлай урманнары илһам биргəн.* М. Максуд. **Илһам итү** — берəр эшкə рухландыру, илһамландыру. [*Рөкыя:*] *Мин ул хикəягезне, Сөләйман абзый, шулкадəр яраттым, шулкадəр яраттым...* [*Сөләйман:*] *Яраттыңмы? Син үзең илһам иткəн хикəя ул, Рөкыя. Аны миңа синең күзləреңнең бер иркə елмаюлары илһам итте.* Ф. Əмирхан.

◇ **Илһам чишмəсе** *шигъ. кит.*— дəрт, рух бирə торган чыганак. *Муса өчен Мəскəү шəһəре --- илһам чишмəсе дə булды.* М. Максуд.

ИЛһАМЛАНУ *ф.* Илһам алу, рухлану. *Ни өчен аннан шагыйрь илһамлана? Шигыренə ник мəңгелек рух — җан ала?* Ш. Бабич. *Рəсемең генə минем янымда. Аның белəн утка кердем мин, Аның белəн илһамландым мин.* Б. Рəхмəт. // *рəв. мəгъ.* **илһамланып**. Рухланып, дəртлəнеп, күтəренке күңел белəн.— *Сез чүп үлəннəре турында шундый илһамланып сөйлисез.* И. Юзеев. *Гөлнур чын күңеле белəн, илһамланып уйнады.* Г. Əпсəлəмов.

ИЛһАМЛЫ *с.* Илһам белəн сугарылган; рухлы, дəртле. *Бу вакытта карт командирның йөзе ифрат күркəм һəм илһамлы иде.* Г. Əпсəлəмов. [*Шагыйрь*] *аңа илһамлы юлларын багышлый.* Х. Хəйри.

ИЛһАМЧЫ *и.* Илһам бирүче, илһам кертүче. *Чынын əйткəндə, ул миңа килеп тə хатыным булмаячак, бəлки илһамчым булачак... Мин аның тəэсирендə бөтенлəй икенче төрлегə əвереləм.* Г. Ибраһимов. *Нурлы йолдыз, мин сусыз Монда кибəм, син тамчы бул, Тиз тамып хəлсез йөрəккə Җыр тудыр, илһамчы бул.* Б. Рəхмəт.

ИМ *и.* 1. Ырым, им-том. [*Мостафа*] *чирлəп егылды. Һичбер төрле им килешмəде аңа. Ишнияз суфыйны чакыртып, тəлинкə яздырып эчереп, өшкертеп карадылар. Шифасы тимəде.* К. Нəҗми. [*Алар*] *сары төшкəнгə каршы ителə торган имнəрнең берсен дə калдырмадылар.* Г. Рəхим. // Дəва, шифа. *Син минем җан сердəшем, җан моңдашымсың, мандолин! Сергə беткəн, моңга беткəн зарлы тавышың җанга им.* Ш. Бабич. *Ялкауның име — тырышлык.* Мəкаль.

2. *күч.* Əмəл, чара. *Йөрəгемə үк тиде. Үк тимəде, ут тиде,— сүндерергə име юк.* К. Нəҗми.

3. *күч.* Кирəкле, зарури, мəҗбүри нəрсə.— *Чын йөрəктəн сөяр өчен Бай, сəүдəгəр им түгел.* Т. Гыйззəт. *Русча һəм татарча текстларда сүзлəр санын һəрвакыт тигез бирү им түгел.* К. Сабиров.

4. *күч.* **Им өчен, имгə эзлəсəң дə, имгə дə** һ. б. ш. **тезмəлəр** белəн килгəндə: бик аз гына да, бөтенлəй, **бернинди дə, бернигə** дə. *Имгə яраксыз.* □ *Кызга һичкем яучы җибəрми, теге яучы карчыкларны имгə эзлəсəң дə таба алмассың.* Г. Тукай. *Аңа 86 гына яшь əле. Лəкин бер бəласе — авыз эчендə им өчен генə дə бер теш калмаган.* М. Мəһдиев.

Им имлəү — авыруга каршы берəр ырым эшлəү. **Им итү** — халык дарулары яки ырымнар белəн дəвалау.

◇ **Имен бирү** *сөйл. сир.*— *к.* кирəген бирү.— *Мин ул юньсезлəрнең имен бирим əле, менə битсезлəр.* М. Фəйзи.

ИМАҖИНИЗМ *и.* Егерменче гасыр башларында барлыкка килгəн һəм ижатта идеясезлекне, үзара билгеле бер фикер белəн бəйлəнмəгəн чуар сүз образларын күтəреп чыккан формалистик əдəби агым. *Кави Нəҗми, «имажинизм» бетерелүе турындагы манифестына карамастан, хəзердə дə əле башка татар язучыларына караганда сурəтлəргə күбрəк иркенчелек бирə, күп җирдə аның тасвирлары бөтерелеп, чуалып китə.* Г. Нигъмəти. *Бу имажинизм дигəн алымның марксизм тəгълиматы белəн һичбер төрле алыш-бireше юк.* Г. Ибраһимов.

ИМАҖИНИСТ *и.* Имажинизм тарафдары. *Имажинистлар беренче нəүбəттə тышкы тасвирга əһəмият бирəлəр, шуның белəн бергə, алар: сурəтлəр бер тəртипкə, законга баш имəсен, əсəр баштан укыганда да, азактан укыганда да бер үк ләззəт белəн укылырлык булсын, сурəтлəр өермəлəр кебек бөтерелсен, диләр.* Г. Нигъмəти.— *Син əйтəсе фикерləреңне ачык итеп, башкалар аңларлык итеп əйтергə тиешле. Имажинизм дип, модага ияреп, үз талантыңны үзең бозып йөрү килешми сиңа. Үзеңнең өстеңдə шинель, ə үзең имажинист.* Г. Мөхəммəдова.

ИМАҖИНИСТИК *с.* Имажинизмга хас, имажинизм рухында язылган. *Гадел Кутуйның, Кави Нəҗминең һ. б. ның «гаять нечкə аһəңле, гали гармонияле ирекле шигырь» дип тəкъдим ителгəн имажинистик яки футуристик «тəҗрибə»ləрендə демократик əдəбиятның һəм совет əдəбиятының реалистик стиленə бөтенлəй ят күренешлəр тулып ятты.* Г. Халит.

ИМАҖИНИСТЛЫК *и.* 1. *к.* имажинизм. *Моның шулай икəнлеге имажинистлык образлары белəн күмелгəн шигырьləремнең дə кайберləреннəн ачык күренеп тора.* Қ. Нəҗми.

2. Имажинист булу.

ИМАМ *и. иск.* 1. Кешеләрне үзенə ияртеп намаз укытучы мəхəллə башлыгы, өлкəн мулла. *Беренче сорау — мəдрəсəнең рəсми башлыгы, мəхəлləнең имамы Гали хəзрəттən булды.* Г. Ибраһимов.— *Бөтен мəхəллə халкы, атаң хөрмəтенə сине үзləренə имам итү телəге белəн, мəдрəсə тəмам иткəнеңне дүрт күз белəн көтə.* Т. Гыйззəт.

2. Берəр гыйльми карашны, мəсləкне нигезләүче, берəр дини төркемнең, мəзһəпнең башында торучы кеше. *Билгеле, ожмахта торды ул* [*Газазил*] *элек, Бар мəлəкләргə имам булган булып.* Ш. Бабич. // Ислам дəүлəтендə дөньяви һəм дини властьны үз кулында тоткан хөкүмəт башлыгы. *1948 елны алдынгы офицерлар имамга каршы баш күтəрəлəр* [*Мисырда*]. Сов. əд.

◇ **Имам тору** — имам булып, башкаларны үзенә иярткән намаз укыту. *Мулла имам торган. Аның артында өч-дүрт рәт халык --- һәммәсе сәҗдәгә киткән.* Һ. Такташ. *Бер мулла биш вакыт намазда, җомгаларда, гаетләрдә имам тора.* Г. Тукай. **Имам хатип** — җомга, гает намазларын укыту (хөтбә) хокукына ия мулла (икенче дәрәҗәдәге мулла). *Бу көндә иң бай бер авылга имам хатип, хәтта мөдәррис булган булыр идең.* М. Гафури. **Имам хатип мөгаллим** — мәдрәсәдә шәкертләр укыту хокукы алган мулла (урта дәрәҗәдәге мулла). **Имам хатип мөдәррис** — күп санлы шәкертләрне мәдрәсәдә укыту хокукына (өлкән укытучылык дәрәҗәсенә) ия мулла (иң югары дәрәҗәдәге мулла). *Биек мәчетнең карт имамы имам хатип мөдәррис Фәхретдин хәзрәт --- мәдрәсәдә авыл балаларыны вә башка авыллардан килгән мулла балаларыны да укыта иде.* З. Һади. **Имамга ою** *дини* — намазның бер өлешен башны иеп, кулларны кушырып уку. *Безгә гаеттән кайтып килүче картлар очрады. Имамга оеган кебек итеп, бөкреләрен ныграк чыгарганнар, кулларын җиң очларына тыкканнар иде алар.* М. Әмир.

ИМАМЛЫК *и.* Имам (1 мәгъ.) булу. *Карт хәзрәтнең: «Бу эшегезгә фатиха бирә алмыйм, имамлыктан ваз кичәм»,— диюенә карамастан, мәктәпкә җәдит кертергә мәҗбүр итәләр.* Г. Гобәй. *Анда шул ук Шәмсетдин мулла имамлыгында көненә әллә ничә тапкыр намаз укыла.* Э. Касыймов.

Имамлык итү — имам вазифаларын башкару. *Зәйнетдин мулла сизгер`кеше иде. Күп еллар имамлык итү тәҗрибәсендә кеше күңеленә үтеп керү юлын өйрәнде ул.* Г. Минский.

ИМАН *и. иск.* 1. *дини.* Ислам динендә: аллага, пәйгамбәргә, диннең төп нигезләренә ышану. *Ислам динендәге иман, барыннан да элек, аллага, аның пәйгамбәренә, алла «җибәргән» китапларга, фәрештәләр һәм шайтаннар барлыгына, кыямәт көненә һәм тәкъдиргә ышанудан тора.* Ф. Мөсәгыйть.

2. *күч.* Ышаныч, ышану, инану. *Ышана егет яшәвенә, төндә күргән татлы төшенә. Нурлана күзе, шатлана йөзе, арта яшәүгә иманы.* Г. Камал. *Ахыр чиктә, кешенең язмышы үз кулында. Шундый иман, шундый ышаныч белән Зөфәр җиң сызганып эшкә тотынды.* Э. Еники.

3. Мөселман булуга дәлил итеп укыла торган дога сүзләре. *Кыска иман. Озын иман. Иман әйтү.* □ *Әҗәлем шул икән, үләм икән,— дип, Зифа әби иманын укырга тотынды: «Ходаем, үзең ярлыкагыл! Ләиләһи иллаллаһ...»* Г. Ибраһимов. *Кемдер шунда әкрен генә иман кәлимәләрен укырга кереште. Абзый ясин укуын шәбәйтә төште.* М. Гафури.

Иман итү — бик нык ышану. *Докторлар никадәр син таза дисәләр дә, үзенә ютәл зәхмәте булганына иман иткән, шуңа күрә --- ул көн саен дүрт чи йомырка эчми калмый.* Г. Газиз. **Иман шарты** — кадимчелекне яклаган дини мәдрәсәләрдә иң беренче уку китабы. *Ападан калган букча эчендә өебездәге бердәнбер китап заты — матчада кыстырылып ята-ята, матча белән бергә сарганган иман шарты.* Г. Гобәй. *Әнкәйне елатып, иман шартын Тәмәкегә тарткан идем мин.* Һ. Такташ.

◇ **Иман заты көтмәү** — *к.* иман көтмәү.— *Алайболай мин әйтте дип әйтә калсаң, иман заты көтмә, бүгенге шикелле генә итмәм, бер бирүдә тынсыз ясармын.* В. Нуруллин. **Иманга зәгыйфь** — аллага, пәйгамбәргә, дингә ышанычы аз.— *Бу нинди диниятсезлек! Күрдегезме, Хуҗагыз иманга зәгыйфь.* Н. Исәнбәт. **Иман качу (качыру)** — диннән язу. *Әбиләр-бабайлардан калган гадәт буенча, кәккүк кычкыра башламыйча су коенырга ярамый. «Су салкын була, иманың кача»,— дип куркыталар алар балаларны.* Ф. Кәрим.— *Кытыклама, иманымны качырырсың! Кытыклама дим, мәллгүнь!* Т. Гыйззәт. **Иман китерү (иманга килү)** — 1) ышану, инану. *Кызның уңганлыгына тагын бер кат иман китердем — очынып кына тора.* Ф. Хөсни; 2) **мөселманлыкка чыгу, мөселман** динен кабул итү. *Уйлана күз: «Ул да мәхлук, ул да җан, Аллага ул да китергәндер иман».* Ш. Бабич. *Таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, --- Әбүҗәһел иманга килер. Әмма [Әлемгол бай] --- бу данлыклы бияне карынындагы колыны белән тиктән-тик Хафизга китереп бирмәс.* Г. Ибраһимов; 3) *к.* иман яңарту; 4) ышанмыйча йөргән нәрсәгә ышану, тәүбәгә килү. [*Хаҗи:*] *Ничек илле сум? Саташтыңмы әллә син? Тәүбә диген. Иман китер, хода бәндәсе.* [*Хөснетдин:*] *Саташмадым һәм иман да китермим. Ә сез илле сум бирергә тиешсез.* Ш. Камал. **Иман көтмәү** — берәр кешедән яхшылык, изгелек, гадел мөнәсәбәт өмет итмәү.— *Бер авызын турсайтса, тиз генә иман көтмә инде син аңардан. Кара коелып йөри.* Р. Төхфәтуллин. **Иман нуры** *дини* — динле кешеләр фикеренчә: аллага иман китергән, динле кешеләрдә генә була торган мөлаемлылык, чырай, йөз күркәмлеге. *Алар әүвәлдә бик матур булганнар да, чукынгач, йөзләреннән иман нуры китеп, зәңгәрсу акланып калганнар.* Ф. Әмирхан.— *Ул юлдашыгызның йөзендә иман нуры юк. Күзләре: «Бер чиләк су белән йотам»,— дип тора.* И. Юзеев. **Иман сату** — 1) үзенең әлек ышанган нәрсәсенә, фикеренә, әлекке мәсләгенә хыянәт итү, башкача уйлый яки эшли башлау. *Тор дөньяда: иманың сат, вөҗданың сат; Шулай торсаң, гомрең үтәр бигрәк ансат.* Г. Тукай. *Реакция керү белән эсер Разия, Фәхри, Йосыфҗан, социализмны, революцияне ачыктан-ачык таптап, «иманнарын сатып», капитализм сафына күчәләр.* Г. Ибраһимов; 2) хыянәткә бару, намус югалту.— *Акча ул бакчада үсми. Без аңа байтак иман сатабыз!* М. Галәү. **Иман укыту** *сөйл.*— тиешле җәза бирү; акылга утырту.— *Бүре чабагачлары белән кистәннәр булса, бер погромны түгел, ун погромның әбисенә иман укытачакбыз.* К. Тинчурин. **Иман яңарту** — иманга, аллага ышануга кимчелек китерерлек эш эшләгәннән соң тәүбә итү, яңадан иман китерү. [*Егет:*] *Без алла биргәнне көтеп, дөньяда да, ахирәттә дә рәхәттән колак кагып калмабыз микән соң?* [*Кеше, каһәрле рәвештә:*] *Чү! Иман яңарт!.. Алланың кодрәтенә шик тотма, юньсез.* М. Фәйзи. *Сурәтләрне күрмәс өчен күзләремне чытырдатып йомдым һәм иманымны яңартырга керештем: «Сөаль: каферме сән, мөселманмы сән? Җавап: «Әлхәмделилла, мөселман бән».* Г. Гобәй. **Иман(ым) камил** — үз эшенә, максатына бик нык ышануны белдергәндә әйтелә. *Ул үзен бәхетсезгә хасап итеп, кем туры килсә, шуңа барырга да күнде. Үзенең бәхетсезлегенә иманы камил булганга күрә, бу эшләрнең һәрберсенә сабыр итте, түзде.* М. Гафури. *Иманым камил. --- Җанымны да аямыйча хезмәт итә торган кеше мин.* Н. Фәттах. **Иманым кафер булсын (китсен)** — каргану сүзләре (*укмәктер, җир йотсын* кебек). *Авыл Гайнетдине белән бәхәс итеп буламыни? Ул: «Икмәктер, кояштыр, шулай булмаса, иманым кафер китсен!» — ди дә авызыңны капый.* Г. Тукай. [*Ниязов:*] *Боларны син казыдыңмы?* [*Хаҗи:*] *Иманым кафер булсын, мин түгел.* К. Нәҗми.

ИМАНА *и. тар.* 1. Элекке авылда хисап вакытында билгеле күләмдә җир алырга хокукы булган ирләр җенесендәге кеше, җан исәбе.— *Минем җирем юк бит. Соңрак туып, иманага керми калганмын.* Г. Бәширов.— *Теге вакытта минем абзый алган акчаны миннән кире кайтарып ал да, миңа безнең өч иманага тигән җиребезне кайтарып бир.* Ф. Хөсни.

2. Җир бүлгәндә җан башына тигән җир участогы. *Нурый хаҗи әткәй иманасын ун елдан бирле чәчсә дә, аның безгә бер тиенлек тә файда иткәне юк.* Г. Толымбай.— *Сабан игене иманасын да алар чәчеп-урып алдылар.* А. Шамов.

3. Җан башына бирелгән җир өчен казнага түләнә торган салым; җир рентасы. *Имана түлим дисәң, бөтенләй ач-ялангач калырга туры килә.* К. Нәҗми.— *Имана түләмәгән өчен, кичә Бикбулат картның самоварын алып чыкканнар.* Х. Җәмил.

ИМАНАЛЫК *с.* Бер иманага (1 мәгъ.) тиярлек. *Кыз тапса, минем өлешкә тигән сыңар иманалык җирне дә тартып алырлар.* К. Нәҗми.

ИМАНЛЫ *с.* 1. *дини.* Дингә ышанучы, динле.— *Мулла, иманлы авыздан кара йөрәк вә мордарлар турында син ни әйтерсең икән?* К. Тинчурин.

2. Билгеле бер нәрсәгә нык ышанган; ышанган фикерендә нык торган. [*Мәргубә:*] *Мин шуңа ышандым.* [*Сабит — читкә:*] *Ах, никадәр нык иманлы кыз.* М. Фәйзи. *Чын иманлы ир егетләр какшамас һәм каушамас.* М. Гафури.

Иманлы бүрек — тирәсенә кама тоткан бүрек.

ИМАНСЫЗ *с.* 1. Аллага ышанмаучы, динсез.— *Динсез, имансыз --- кеше дим мин сине... «Тәмуглык кеше» дип, кызганып та алабыз.* Ш. Камал. // *и. мәгъ.* Тиргәү сүзе булып кулланыла.— *Ләхәүлә диегез, имансызлар! Аллага шулай тел тидерергә ярыймыни! Яшен сугып үтерер үзегезне!..* А. Шамов. *Безнең иске мулларыбыз аңар бик дошман булганнар, аны кафер, имансыз дип һәр җирдә сүккәннәр.* Ак юл.

2. Һичбер нәрсәгә ышанмый һәм һичбер изге нәрсәне танымый торган; рәхимсез, кешелексез.— *Имансыз икән... Чәй белән сыйлап маташкан иде, инде шуны да безнең өскә саныйсызмы?* Т. Гыйззәт.

3. Ышанычсыз, вәгъдәсез.— *Үз арабызда да шәп түгел, куркаклар, шкурниклар, имансызлар бар.* Г. Ибраһимов.

◇ **Имансыз китү (үтү)** *дини.*— иман (3 мәгъ.) сүзләрен әйтә алмыйча үлү.— *Ялган булса, ике күзем чәчрәп чыксын, дөньялардан имансызлар үтим!* Г. Бәширов.— *Нигә бөтен яшьләр, хәтта бөтен халык имансыз китүдән, тәмугта янудан курыкмый?* А. Шамов.

ИМАНСЫЗЛЫК *и.* 1. Аллага ышанмау, динсезлек.

2. Вәгъдәсезлек.— *«Була ул» Урал эшчеләренең үзләрендә дә җитәрлектер ---,— дип,* [*Солтан*] *тагын үзенең имансызлыгын күрсәтте.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ИМБИР *и.* 1. Тамырлары эфир майларына бай булган үлән сыман тропик үсемлек.

2. Шул үсемлекнең тамырларыннан ясалган аш тәмләткеч. *Кемнәрдер дарчин, имбир сата.* А. Расих. // *с. мәгъ.* Шул аш тәмләткеч кушып эшләнгән. *Грей, трактирга кереп, --- имбир сырасы китерергә боера.* Азат хатын.

ИМГЕЧ I *и.* Үләннәрдә һәм кайбер тере организмнарда тәннән, үсемлектән туклыклы матдәләр суырыр өчен махсус әгъза. *Чукмарбашлар, төркем-төркем булып, имгечләре белән сүүсемнәргә ябышып торалар.* Г. Хәсәнов.

Имгеч суалчан *зоол.*— балыкларның тиреләрендә һәм саңакларында, кеше һәм хайваннарның эчке әгъзаларында паразит булып яшәүче яссы суалчан; *русчасы:* сосальщик.

ИМГЕЧ II *и. бот.* Сары яки шәмәхә чәчәкле чүп үләне яки декоратив үсемлек; баллы чәчәк; *русчасы:* льнянка.

ИМГӘК *и.* 1. Бәла, михнәт, мәшәкать.— *Бу кешене фатирга кертеп тә өстемә имгәк алдым. Бар белгәне кыңгырау да сыбызгы...* Ф. Бурнаш. *Артык байлык — башка имгәк.* Мәкаль. // *иск.* Эш, мәшәкатьле эш. *Актардылар, эзләделәр — хәзинә юк! Басуның өсте тоташ казылган, тупраклары тетелеп ватылган иде. Ике кардәш, бу кадәр имгәкләре бушка калмасын өчен, богдай чәчтеләр.* Дәрдмәнд. // *тирг.* Булдыксыз, бәлале, мәшәкатьле кеше турында. *Динсез идем, Шуның өчен дә бит әткәй мескен кулын ташлады,— Бу имгәктән кеше чыкмас, диде, Иблис булыр,— дия башлады.* Һ. Такташ. *Монда бу имгәк сүз тапкан, имеш, аның «сөйгән егете бар».* Ф. Хөсни.

2. Нинди дә булса әгъзасы яки әгъзалары имгәнгән, сынган, гарипләнгән кеше.— *Син элек минем яныпторган күзләремне, таза күкрәгем, көчле кулларымны --- ярата идең. Ә хәзер аларның берсе дә миндә юк инде... Я, әйт, минем кебек имгәк белән сиңа нинди бәхетле, матур тормыш булсын?* Р. Ишморат. // *с. мәгъ.* Гарип, зәгыйфь.— *Мин зәгыйфь, имгәк кешеме әллә?* Ш. Камал.

3. *сөйл. тирг.* Кеше җилкәсендә йөк булып бушка ашап ятучы кеше.— *Теге имгәкләрне* [*кияүгә*] *бирергә булгач, буш кул белән җибәрү ярамас.* Т. Гыйззәт.

◇ **Имгәк тарту** — күп бәлаләр, михнәтләр, кыенлыклар күрү, күп эшләү.

ИМГӘКЛЕ *с.* 1. Бәлале, мәшәкатьле. *Уен төбе имгәкле.* Мәкаль.

2. Булдыксыз, эшнең рәтен белмәүче. *Ир егет — игез, имгәкле ир — ялгыз.* Мәкаль.

ИМГӘКЛЕК *и.* Имгәк булу. *Имгә калган имгәклек.* Әйтем.

ИМГӘНҮ *ф.* 1. Берәр әгъза яки әгъзалар каерылып, бертелеп гарипләнү. *Герасим аның тәнен тоткалап караганнан соң, күкрәге яньчелгән, берничә кабыргасы имгәнгән, я сынган, дигән фикергә килде.* А. Шамов. *Эшелон Кавказ тауларында крушениегә очрый, һәм Гафиятулла абзый тәмам имгәнеп, бертелеп өенә кайтып егыла.* Г. Әпсәләмов. // Шул ук — үсемлекләргә, җансыз әйберләргә карата. *Бодайның тамыры имгәнмәде, басылып калган кыяклары да яңадан торып бастылар.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Рухи халәткә зәгыйфьлек килү.— *Минем тәнем генә түгел, акылым да, хисләрем дә имгәнгән хәзер.* Р. Ишморат.

3. Күп эшләп зәгыйфьләнү, гарипләнү, куәт һәм сәламәтлек югалу. *Яшьтән эшләп имгәнү.*

4. *күч.* Экономик яктан хәлсезләнү, фәкыйрьләнү.— *Дөрес, безнең тормыш авыр хәзер, имгәнде, аксады ул. Ләкин җимерелмәде.* Р. Ишморат.

5. *күч. бор.* Зур тырышлык куеп эшләү, мәшәкатьләр күрү. *Яз имгәнсең, көз кинәнерсең.* Мәкаль.

ИМГӘТКЕЧ *с.* Имгәтә, гарипләндерә торган. *Хаким сыйныфлар тарафыннан алга сөрелгән имгәткеч законнар[ны] --- Гоголь нәкъ үз төсендә күрсәтте.* Ф. Хөсни.

ИМГӘТҮ *ф.* 1. Берәр әгъзаны гарипләндерү, зәгыйфьләтү.— *Үлсәм үләрмен, әмма үз кулым белән үземне гарип ясап, имгәтеп маташыр хәлем юк.* Г. Ибраһимов. *Газинур, бүрәнә төшереп, аягын имгәтте.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Рухи яктан зарар, кимчелек китерү. *Нәсимә бу тойгыны барлык өермәләр, яшенле күкрәүләр уртасыннан имгәтмичә үткәрде.* К. Нәҗми. *Сабыйның чыныгып җитмәгән яшь табигатен сугыш җиреннән килгән үлем хәбәрләре вакытсыз имгәтмәсен.* Г. Бәширов.

ИМДЕ, ИМДИ *кис. иск. кит.* 1. *к.* инде (1 мәгъ.). *Имди инспектор хезмәтенә тотынырга вакыт җитте.* К. Насыйри. *Бәс, имде әдәбият кирәкмидер.* Ф. Әмирхан.

2. Иске шагыйрьләрнең 11—12 шәр иҗекле, дүртәр юллык шигырьләреннең ахырында иҗек санын тутыру өчен бернинди мәгънәсез кулланыла (соңгы чор шагыйрьләрдә стильләштерү өчен алына). *Бу көнгәчә без байларга күп эшләдек, Аларга пулат салдык, тун тышладык, Үзебез бишмәт берлән кыш кышладык, Инде безгә дә тун кияр вакыт имде.* Ш. Мөхәммәдев. *Язлар җитте, карлар эри башладылар, Толыплылар толыпларын ташладылар, Киемсезләр иркен йөри башладылар, Тунсызларга иркен көннәр килде имди.* Г. Тукай.

ИМЕГҮ *ф. сир.* Имәсе, ашыйсы килү (имчәк бала турында). *Әлли-бәлли бишеге, Бал ялаган кашыгы, Имеккәндә имезе, Сусаганда кымызы.* Такмак.

ИМЕЗЛЕК *и.* 1. Элек (гадәттә шикәр кушып) чәйнәп хәзерләнгән һәм, имчәк балага каптыру өчен, чүпрәк яки марляга салынган ипи йомшагы. *Түтәе аңа, иске чүпрәккә төреп, әче арыш икмәгеннән зур итеп имезлек каптыра.* Ф. Хөсни. *Арыш ипиенә шикәр салып чәйнәлгән имезлеген чат-чат суырып, яшь ярымлык Рәхилә йоклый.* Ш. Рәкыйпов. // Шундый ашамлык төрелгән чүпрәк. *Имезлек — киндердән иде.* С. Баттал. *Ул анда бәләкәй энекәшен караштыра, --- ипи йомшагы төйнәлгән юеш имезлекне дәррәү аның тешсез авызына тыга.* К. Нәҗми.

2. Имчәк формасында итеп эче буш резиннан эшләнгән һәм балага, бозауларга һ. б. суырырга бирелә торган әйбер; *русчасы:* соска. *Сөтне ашыгып, комсызланып эчмәсеннәр өчен, без бозауны резин имезлекләрдән ашатабыз. Менә алар,— диде Мәрфуга апа һәм укучыларга авызына имезлек беркетелгән тоткалы зур пыяла банкалар бирде.* А. Расих. *Тугачтан ук, белмим ничек, Сынаргамы теләп, Мин сөт сорап Үксегәндә каптыргансың Имезлек дип исемләнгән Буш резинка — ялган имчәк...* Ә. Баянов.

3. Имчәк башы.

4. *күч.* Кирәкле, зарур нәрсә урынына юаныч итеп бирелгән алдавыч әйбер, вак ташлама.— *Татарны Россиянең кече баласы дисез, бөтен татарларга имезлек сорыйсыз, имезлек каптырганда бармагың белән кулыңны тешләп өзәрлек татар агайлар бездә юкмыни?* Й. Гази.

ИМЕЗӘК *с.* Сауган чорда да бозавын яки бәтиен имезүдән аермаган. *Имезәк сарык. Имезәк сыер.*

ИМЕЗҮ *ф.* Имчәктән, җиленнән ирен, тел ярдәмендә сөт суырту. *Хәмидә, кечкенә имчәк баласын кулына алып, --- изүләрен ычкындырып, баласын имезә башлады.* М. Гафури.

ИМЕЗҮЧЕЛӘР *и. күпл. зоол.* Балаларын үз сөтләре белән имезеп туендыручы югары төзелешле хайваннар классы.

ИМЕШ *кис.* 1. Теге яки бу хәбәрнең берәр кешедән ишетелгәнлеген һәм аның дөресме, түгелме икәнлеген сөйләүче кистереп әйтә алмавын аңлату өчен кулланыла. [*Аны*], *бер килүендә Артыкбикәгә күзе төшеп, үзенең тол малаена бичә итеп алырга уйлаган имеш, дип сөйли башладылар.* М. Әмир. *Пахомов әлек патша офицеры булган имеш, дип сөйлиләр.* Г. Бәширов.

2. «Белми дә торам» мәгънәсендә кулланыла. *Сәгать 12 тулган имеш!*

3. *и. мәгъ.* Төрле хәбәр, кеше сүзе, гайбәт. *Үз имешен сөйләгән ахмак — бер ахмак, башкалар имешен сөйләгән — йөз ахмак.* Мәкаль. *Заман алмашынып тора, --- булган эшләр әкиятка, имешкә әйләнеп кала.* Н. Исәнбәт. // *с. мәгъ.* Дөреслеге ачыкланмаган. *Авыл шундый имеш хәбәрләр белән күмелде.* Х. Кәрим.

4. *кер. сүз мәгъ.* Кеше сүзен, кеше эшен яратмаганда ирония белән әйтелә.— *Кеше, акчага, юк-бар нәрсәгә комсызланып, үзенең алтыннан кадерле булган тормышына, дөньяда яшәү хокукына хыянәт итсен, имеш!* Т. Гыйззәт.

5. *кер. сүз мәгъ.* Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү өчен кулланыла. *Имеш, монда русча белмәгән кеше юк бит, һәммәгез дә беләсез.* Ш. Камал. *Имеш, мин терәүләрне дөрес салмаганмын.* Ф. Хөсни.

ИМЕШ-ДИМЕШ *җыйл. и. сөйл. к.* имеш-мимеш. [*Ул*] *һәрбер урында --- тәҗрибә илә эш күргән, бар нәрсәне имеш-димешләргә карап түгел, балки тугрыдан-тугры үзе тикшергән.* Ж. Вәлиди. *Имеш-димеш хәбәрләргә караганда, Петербургта бу әфәнделәргә сый-хөрмәт бик шәп имеш.* Ф. Әмирхан.

ИМЕШ-МАНИШ *җыйл. и. сөйл. к.* имеш-мимеш. *Мин аларның тарихларын шәкерт чагымда ук яза башлаган идем, мәгәр күбрәк имеш-маништан иде.* «Шура»ның тел ярышы.

ИМЕШ-МИМЕШ *җыйл. и.* Колактан колакка йөри торган, дөреслеге ачыкланмаган хәбәрләр. *Иртә белән төрле имеш-мимешләр күпертелеп, өсте-өстенә өелеп, шомлы хәбәрләр булып өйдән өйгә таралдылар.* М. Шабай. *Җинаятьнең җепләре Салахиев белән Ивановка да барып тоташа икән, болар да кулга алыналар икән, алынганнар икән, зиндандалар икән дигән гайбәтләр байтактан бирле телләрдә йөрсәләр дә, болар шул имеш-мимеш чамасыннан үтә алмаганнар иде.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Һәртөрле юрауга нигезләнгән, дөреслеге ачыкланмаган. *Мондый имеш-мимеш хәбәрләрдә дөреслек тары бөртеге чаклы булса, арттырылганы — тау чаклы була.* Ф. Хөсни.

ИМЕ'ШТЕР *кер. сүз.* 1. Теге яки бу хәбәрнең кешедән ишетелгәнлеген, аның дөресме, түгелме икәнлеген сөйләүче кистереп әйтә алмаганлыгын аңлату өчен кулланыла; имеш (1 мәгъ.). *Колактан колакка төрле хәбәрләр йөри башлады: имештер, шушы арада һөҗүм башланачак икән, дошман фронты нәкъ безнең участокта өзелачәк икән.* И. Гази.

2. Нинди дә булса берәр эшнең, күренешнең чынбарлыкта түгел, бәлки хыялда, төштә генә булуын күрсәтү өчен кулланыла. *Менә малайның хыялы эшли башлады: имештер, менә ул, алма сатып, шәһәрдән кайтып керде: кесәсе тулы акча, кесәсе тулы кызыл билле пәннек.* И. Гази.— *Мин бүген гаҗәеп бер төш күрдем. Имештер, минем сул кулымның сау чагы, имештер, мин скрипкамда ниндидер бер... әлеге, үтә нечкә шундый, гаять тә нәфис бер көй уйныйм.* Г. Бәширов.

3. Кыек сөйләмдә: әйтелгән сүзләр икенче кешенеке булуын күрсәтү өчен кулланыла. *Җае килгән саен чыпчык мактана бирде, әй мактады чыпчыкларны, әй мактады — күкләргә чөверде. Имештер, дөньяда алардан батыррак бар микән, имештер, хәтта сандугач та аларның җырларына хәйран кала, имештер, аларның өйләрен берәү дә җимерә алачак түгел.* А. Алиш.

ИМЗА *и.* 1. Нинди дә булса текст, рәсем, картина астына авторның үз кулы белән язылган фамилиясе (гадәттә чорнап, боргалап, кыскартып языла). *Конвертны ертып, имзасына күз салдым; гәрчә: «Дустыгыз Батыргали Шалканов»,— дип кул куйган булса да, кулы безнең Батыргали агайның кулына бик охшамаган иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Кеше, трубка кабызырга дип сызган шырпысын рәсемгә якын тотып имзага карап торгач, тагы да әсәрләнә төште. Имза, «М» хәрефе, тагын «А»га башланган ниндидер фамилиядән гыйбарәт булып, танырлык түгел, бик боргалап языган иде.* Г. Гобәй.

2. Әдәби, музыкаль, сәнгать әсәрләренең авторын күрсәткән уйланма исем; псевдоним. *Еллар үткәннән соң гына «Дәрдмәнд» имзасы белән язылган шигырьләрнең иясе Закир әфәнде Рәмиев булып, аның шул ук приискаларның хуҗасы икәнен белдем.* М. Гафури. *Г. Камалның «Саип» имзасы белән язган беренче оригиналь мәкаләләре 1905 елда «Казан мөхбире» газетасында ук күренә башлыйлар.* М. Гали.

3. Нәрсәнең дә булса астына язылган язу, искәрмә. [*Сәнгать*] *турындагы хәзергәчә чыккан --- китапларның битләрен актарып, иллюстрацияләренә күз ташлау белән, «бу әсәр Лувр музеенда саклана» дигән имзалар бик күп очрыйлар.* Г. Гали.

Имза итү *иск. кит.*— кул кую, исем-фамилиясен берәр текст, рәсем астына язу. *Фельетонга «Дареләдәп»тән чыккан биш мөгаллим имза иткәннәр.* Ф. Әмирхан. **Имза кую** — *к.* кул кую. *Кулда — каләм. Ә күңелдә — минем Туган җирнең урман, сулары. Мин шуларны яклап килдем, дуслар, Имза куям, яклап шуларны.* З. Мансур.

ИМЗАСЫЗ *с.* Кем язганы билгесез, автор кулы куелмаган. *Гөлгенә Хәлим өстенә берәр куркыныч кил-*

гәнне күрсә, --- имзасыз язу язып, үзе күрмәгәндә сумкасына салды. Г. Гобәй.

ИМИ *и. сөйл. к.* имчәк (бигрәк тә балалар телендә кулланыла). *Тәнемне этинең бер иске күлмәге белән төреп, авызыма ими каптырган, туктадым.* Ф. Әмирхан. [*Колын*], *шомыраеп, иркәләп торган әнкәсенең күпергән имиләренә йомшак борынын төртә.* А. Гыйләҗев.

ИМИЛЕК *и. к.* лифчик. *Карачәч керә. Шаровар белән имилек кенә кигән. Күлмәген салып утынына ураган.* Н. Исәнбәт.

ИМИН *с.* 1. Куркынычсыз, тыныч, сугышсыз, кан коешсыз. *Илгә тыныч имин көннәр телә, аның өчен тавыш бирәмен!* Ш. Маннур. *Тынычлык — миллионнар сүзе, Ил имин дигән сүз ул.* З. Мансур.

2. *рәв. мәгъ.* Исән-сау, зыянсыз, хәвеф-хәтәрсез, сәламәт. [*Гайнавал:*] *Исән генә йөреп кайттыгызмы?* [*Биктимер:*] *Аллага шөкер, Гайнавал. Үзегез нихәл соң, имин генә тордыгызмы?* Т. Гыйззәт.

3. Куркынычтан, зыяннан, башка күңелсезлекләр булудан азат, гарантияләнгән. *Бу хәрәкәтнең төбендә зур контрреволюцион серләр ятуы мөмкинлегеннән без имин түгелбез.* Қ. Тинчурин. *Юк күңел кырылыр дигән уй, ул җәһәттән мин имин.* М. Гафури.

ИМИНЛЕК *и.* 1. Тынычлык, куркынычсызлык. *Иминлек көчләре. Дәүләт иминлеге.* □ *Дошманны җиңгәч — иминлек кайткач, балда-майда йөзәрбез әле.* Ә. Еники. *Ил кайгысы бөтенесеннән дә көчле, илнең иминлеге барыннан да газизрәк.* Г. Бәширов.

2. Исәнлек, сәламәтлек, хәвеф-хәтәрсезлек. *Бу нәкъ этиләрчә, үз баласын сөйгән, баласының иминлеге өчен борчылып көйгән этиләрчә итеп ярсу иде.* Г. Минский.— *Я, үзегез исән-саулармы? Иминлекме? Улем-җитемнәр юкмы?* Г. Мөхәммәтшин.

3. Қагылгысызлык, гарантия. *Дипломатик иминлек. Шәхси иминлек.* □ [*Тамгалар*], *гүя, иминлек билгесе булып, күкрәп үсеп утырган бодайны хәвеф-хәтәрдән саклап торалар шикелле.* М. Шабай.

ИМИНЛӘНҮ *ф.* Тынычлану, хәвеф-хәтәрсез хәлгә килү.— *Хәзер генә дөньялар иминләнгәч тә! Әллә нинди вакытлар бар иде.* М. Шабай.

ИМИНЛӘҮ *ф.* Төрле куркынычлардан саклау. *Сул флангны көтелмәгән хәлләрдән иминләү өчен, ашыгыч рәвештә күрше шәһәргә атлы батальон җибәрелгән иде.* И. Гази.

ИМИНЧЕЛЕК *и. к.* иминлек.— *Нихәл, Зыя? --- Йөргән җирләреңдә иминчелекме?* Г. Ибраһимов. *Колхозыбызда --- әлегәчә иминчелек. Чәчүебезне вакытында башкардык.* Г. Бәширов.

ИМИТА'ТОР *и.* Кемне яки нәрсәне дә булса имитацияләүче кеше. // *театр.* Имитация белән шөгыльләнүче профессиональ артист.

ИМИТА'ТОРЛЫК *и.* Имитатор эше һәм сәнгате.

ИМИТА'ЦИЯ *и.* 1. Берәр кеше, хайван, кош яки җансыз нәрсәләр тавышына охшаш аваз чыгару, кычкыру, сөйләү. *Кариевның чыгышынна бу «милләт аталары» тавышлы кинодагыча аллы-артлы күздән кичәләр. Имитация тамашачының өзлексез көлеше астында дәвам итә.* И. Рәми.

2. Ясалма охшашлык турында. *Алтын медаль имитациясе һәм университетка керер өчен бирелгән характеристика Владимир Ульяновның Сембер чорын --- гәүдәләндерәләр.* Фәтхи-Балыкчы.

3. *муз.* Берәр музыкаль теманы, көйне калынрак яки нечкәрәк тавыш белән кабатлау.

ИМИТА'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Имитация (1—3 мәгъ.) ясау. *Кариевтан «Казан шәһәренең мөселман җәмгыяте хәйрияче» (байлар, муллалар җәмгыяте) утырышын имитацияләп күрсәтүен сорыйлар.* И. Рәми.

ИМКЯН *и иск. кит.* Мөмкинлек. *Тугайдагы печәнең белән урмандагы утыныңны ташырга да имкян юк. --- Кар-буран исә һәммәсен туктата.* Г. Ибраһимов. *— Кыр госпитале шартларында аларны булдырырга имкянебез юк.* Т. Гыйззәт.

ИМЛА *и. лингв. иск.* Сүзләрне дөрес язуда кабул ителгән тәртип; орфография. *Костя аңа рус теленең грамматикасын, имла кагыйдәләрен өйрәтте, диктант яздырды.* Г. Әпсәләмов. *Без имлада идеал итеп һәр авазга бер хәреф табуны зиһенебезгә салып куябыз.* Г. Ибраһимов.

Имла итү — тыңлаучыларга кычкырып әйтеп торып яздыру.

ИМЛАЧЫ *и. иск.* Имла мәсьәләсе белән шөгыльләнүче кеше. *Татар телендә ун (яки тугыз) сузык аваз бар диючеләрнең иң зур күпчелеге һәр сузык өчен дә аерым-аерым хәрефләр алырга тәкъдим итә. Татар язуы тарихында болар унчылар яки яңа имлачылар дип йөртелә.* Х. Курбатов.— *Имлачы әфәнде, сез инде коньякны хәзер ничек итеп язасыз? — Авыздан ишетелгәнчә.* Қ. Тинчурин.

ИМЛӘВЕЧ *и. этн.* Им-том өчен файдаланыла торган әйбер (чык, чәч, тырнак һ. б.).

ИМЛӘҮ *ф.* 1. Хорафатлар буенча: төрле сүз һәм әфсеннәр әйтеп, чәч, кара мәче сөяге, кара сыер сөте һ. б. белән кешене савыктырырга, даруларга маташу яки, киресенчә, бозу, өшкерү; ырымлау.— *Бу баланың очасы калыккан, шуны имлим. Ай кайтсын, көн кайтсын. Әфсүн-төфсүн, зәхмәт тидергән җеннең эче күпсен, бүсере типсен. Минем кулым түгел, Әйшә батман кулы, тфү, тфү.* Қ. Нәҗми. *Бибигөлгә, имләп, җыен чүп-чар ашаталар, төрле ырымлы сулар эчерәләр, әфсүннәр укыйлар, тәлинкә язалар.* Ш. Мөдәррис.

2. Гомумән дарулау. *Өч ай авырдым. Имләмәгән им калмады, алмаган дару калмады.* Г. Толымбай.

ИММАНЕНТ *с. филос.* Теге яки бу күренешнең эчке табигатенә хас, шул табигатьтән килеп чыга торган. *Имманент закон.*

ИММИГРАНТ *и.* Даими тору өчен берәр илгә килеп урнашкан чит ил кешесе. *Европадан һәм Америкадан иммигрантлар кил*[*ә*]. М. Мәхмүтов.

ИММИГРА'ЦИЯ *и.* Даими рәвештә тору өчен берәр илгә күчү.

ИММУНИЗА'ЦИЯ *и. мед.* Агуга, авыруга бирешмәүчәнлек.

ИММУНИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф. мед.* Организмда иммунитет (1 мәгъ.) булдыру.

ИММУНИТЕТ *и.* 1. *мед.* Организмның теге яки бу авыруга бирешмәүчәнлеге.

2. *махс.* Аерым кешеләргә, бигрәк тә дипломатларга һәм депутатларга карата кайбер чикләү законнарын кулланмау; иминлек.

ИММУНОЛО'ГИЯ *и.* Кешеләрнең һәм хайваннарның йогышлы авыруларга бирешмәүчәнлеген тикшерә торган фән.

ИМНӘҮ *ф. диал. к.* имләү.— *Угы күренмиме? Уһу... Бик усал корт икән... (Имнәргә керешә.) Өшкертен, төшкертен, калма качып яшертен. Азмасын, тузмасын, үз турыннан узмасын.* Т. Гыйззәт.

ИМПЕРАТИВ *и. лингв.* 1. Боерык фигыль.

2. *с. мәгъ.* Боеруны, кушуны белдерә торган. *Императив ымлыклар --- кешенең ихтыярын, теләген белдерәләр. Аларга боеру, тыю, чакыру, эндәшү, әйдәү, таләп итү кебек мәгънәләр белдерү хас.* Д. Тумашева.

ИМПЕРА'ТОР *и.* 1. Монархистик дәүләт башлыгының иң югары титулы һәм шул титулга ия булган кеше (монарх). *Германия императоры, Германия империясенең төп законнары --- биргән хокук берлән файдаланып, рейхстагны тараттты.* Урал. *Император Александр I гаять каты реакция политикасы үткәрә.* Ж. Тәрҗеманов.

2. *тар.* Борынгы Римда: зур чинлы, зур дәрәҗәле гаскәр башлыгы.

ИМПЕРА'ТОРЛЫҚ *и.* Император дәрәҗәсе, император булып тору.

ИМПЕРАТРИ'ЦА *и.* 1. Император хатыны. *Безнең Николайның хатыны, императрица, бала тапкан.* Ә. Фәйзи.

2. Хатын-кыз император. *Императрица Екатерина II.*

ИМПЕРИАЛ *и. тар.* Россиядә — 1755 елдан алып 10 сумлык, 1897 елдан алып 15 сумлык алтын тәңкә. *Иске вакытта [аның] елга бер өч тапкыр кәгазь екатеринкаларны алтын империалларга әйләндерү өчен станицага илткәнлеге хутор кешеләренә ачык билгеле иде.* Ш. Камал.

ИМПЕРИАЛИЗМ *и.* Капитализмның иң югары һәм соңгы стадиясе; ул эре монополияләрнең хакимлек итүе, эре капиталистик илләрнең чимал чыганаклары өчен, товар урнаштыру базарлары өчен, чит территорияләрне яулап алып, чит халыкларны эксплуатацияләү өчен ерткычларча көрәшүләре, ә моның бүленеп беткән дөньяны яңадан бүлү сугышларына китерүе белән характерлана. *Империализм тарих тарафыннан бетәргә хөкем ителгән.* Г. Әпсәләмов. // Капитализмның шушы стадиясендәге капиталистик илләр турында. [*Гафури*] *Европа империализмы тарафыннан таланучы көнчыгыш колония халыкларының хәлләрен сурәтли.* М. Җәлил.

ИМПЕРИАЛИСТ *и.* Империализм политикасын алып баручы эре капиталист. *Советлар власте гына --- мазлум милләтләрне, изелгән эшчеләрне капитал тырнагыннан, империалистлар коллыгыннан азат итәчәк!* М. Гафури. *Империалистлар Совет властен бәреп төшерү өчен әллә ничә мәртәбәләр корал көче кулландылар.* Г. Әпсәләмов.

ИМПЕРИАЛИ'СТИК *с.* Империализм сыйфатларына ия булган, империализмга хас. *Империалистик ил.* □ *Халыкка кан кою, илгә хәерчелек, бөлгенлек китерә торган мондый империалистик сугышны долой!* М. Гали.

ИМПЕ'РИЯ *и.* 1. Башында император торган монархистик дәүләт. *Хәдичәнең ире Россия империясендә --- яңа тәртипләр урнаштырырга йөрүче революционер социал-демократ булып чыкты.* А. Расих. *Моннан ике йөз ел элек империяне дер селкеткән Пугач явы Казанны алмага барышлый бу җирләрдән яңгырап үткән.* Х. Сарьян.

2. Эре империалистик колониаль дәүләт. *Британ империясе.*

И'МПОРТ *и.* Чит илдән товар кертү эше. // *с. мәгъ.* Чит илдән кертелгән.— *Карачы, Заһид, кибетләргә бик әйбәт импорт винолар килгән, ди.* А. Расих. *Импорт итек киген кызлар [килә].* М. Әмир.

И'МПОРТЧЫ *и.* Чит илләрдән товар кертүче (ил, оешма).

ИМПОТЕНТ *и. мед.* Җенси көчсезлек белән авыручы кеше. // *с. мәгъ.* Җенси көчсезлек белән авырый торган.

ИМПОТЕ'НЦИЯ *и.* Җенси көчсезлек. [*Җансатаров:*] *Көтүгә барып «Холмогор»ны карадыгызмы?* [*Малтабаров:*] *Карадым. Һичшиксез, аңарда импотенция. --- Ягъни җенси көчсезлек.* Т. Гыйззәт.

ИМПРЕССА'РИО *и.* Буржуаз илләрдә: театр, цирк тотучы яки концертлар, гастрольләр оештыручы, барлык хуҗалык-финанс эшләрен алып баручы җитәкче яки агент.

ИМПРЕССИОНИЗМ *и. сәнг.* Буржуаз сәнгатьтә XIX йөзнең икенче яртысында барлыкка килгән һәм художникның иң нечкә субъектив тойгыларын, хисләрен, вакытлы настроениесен чынбарлыктан, иҗтимагый тормыштан аерып күрсәтергә омтылган агым. [*Люксембург музеенда*] *импрессионизм агымында башлап картиналар язучы Монс картиналарын [күрдем].* Г. Гали.

ИМПРЕССИОНИСТ *и.* Импрессионизм тарафдары. [*Венцлова*] *художникларның — француз импрессионистларының --- үзенә көчле тәэсир итүләрен ачыктаначык әйтә.* Н. Юзиев. *Художник нинди дә булса әйбернең нинди булуына түгел, бәлки ул әйбернең ничек күзгә бәрелеп, нинди тәэсир калдыруына әһәмият биргә, шул күзлектән карап картина эшләргә тиеш. Импрессионистлар әнә шул фикер тирәсендә әйләнәләр.* Г. Гали.

ИМПРЕССИОНИ'СТИК *с.* Импрессионизмга хас. *Минем Юрий Олеша, Исаак Бабель белән кирәгеннән артык мавыга башлавым да, гомумән, импрессионистик агымнар алдында --- авызымны ачып калуым да нәкъ әнә шул елларга туры килә.* Ф. Хөсни. *Композиторның музыкаль теленда --- кешеләрнең тирән эчке кичерешләрен реаль тасвирлап бирү бик уңышлы итеп романтик дулкынлану, саф күңеллелек һәм импрессионистик матурлык белән бергә алып барыла.* Ч. Бәхтиярова.

ИМПРОВИЗА'ТОР *и.* Импровизация ясаучы, импровизациягә сәләтле кеше. *Уйгур һәм казах телләрен яхшы белгән Рәхим, импровизатор буларак, казах яшьләре арасындагы җыр ярышларына катнашып, фольклорны яхшы үзләштергән.* Х. Туфан. *Гармунның һәм гомумән музыканың чын осталары көйне башкаручы гына түгелләр, бәлки импровизаторлар да, хәтта композиторлар да алар.* М. Рафиков.

ИМПРОВИЗА'ТОРЛЫҚ *и.* Импровизация ясарга сәләтлек һәм импровизация ясаучылык. *Кариев бик оста пародияче һәм импровизаторлык талантына ия иде.* И. Рәми.

ИМПРОВИЗА'ЦИЯ *и.* 1. Тамашачылар алдында алдан хәзерлексез яңа көй чыгару, яңа шигырь уку. *Музыкаль фольклорны яхшы белүе һәм импровизация сәләтенә ия булуы [Ф. Яруллинга] бик нык ярдәм итте.* Ч. Бәхтиярова. *Чулпани яшь шагыйрь белән импровизациядә ярыша.* Сов. әд.

2. Тамашачылар алдында иҗат ителгән шигырь, көй кебек сәнгать әсәре.

ИМПРОВИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Тамашачылар алдында алдан хәзерлексез яңа көй чыгару, яңа шигырь уку. [*М. Максуд*] *шагыйрь [М. Җәлилне] гаҗәп бай натуралы, тере --- һәм ачы телле итеп импровизацияли ала торган күңелле кеше сыйфатында сурәтли.* Г. Кашшаф. // Башка ни килә, шуны сөйләү, уйлап чыгару. *Әкият импровизацияләү.*

2. *күч. сөйл.* Нәрсәне дә булса алдан хәзерлексез оештыру.

И'МПУЛЬС *и.* 1. Нерв уяткычларының эшчәнлеге аркасында нинди дә булса эшкә этәрә торган эчке теләк, омтылыш. *Билгесез бер импульс тәэсиренә буйсынып, [Сабир] ишегалдына атлады.* Ш. Хөсәенов.

2. *физ.* Җисем массасын аның тизлегенә тапкырлаудан килеп чыккан санга бәрабәр хәрәкәт микъдары.

3. *физ. к.* электр импульсы. *Мин мускул очларына электр импульслары белән тәэсир иттем.* А. Тимергалин.

ИМПУЛЬСИВ *с.* Кинәттән туган теләк һәм импульслар тәэсире астында эш итәргә һәвәс. *Импульсив кеше.*

И'МПУЛЬСЛЫ *с. махс.* Электр импульслары белән бәйләнгән. *Импульслы генератор.*

ИМРА *и. миф.* Кешеләргә яхшылык эшләүче, мәрхәмәтле булган мифик зат; *русчасы:* **эльф.** *Әй имра, имра, Имра сөяк кимерә; Казаклар җыйган казларны Галим каты кимерә.* Бәет.

ИМРӘТҮ *ф. диал.* 1. Бераз куркыту, шикләндерү.

2. Йотлыгып тыңларга мәҗбүр итү, берәр тәэсиргә дучар итү.

3. Йокымсырату, йоклату, оету.

4. *күч.* Йомшарту, нечкәртү (күңел турында). *Җирән бияне алырга тотылган егерме биш сум турында ләммим сүз катмавы Ишмайны тагын шатландырды,*

аның күңелен имрәтеп җибәрде. Ш. Камал. *Адәмнең татлы сүзләре төяне бөтенләй имрәттеләр. Төя эшне озакка сузарга теләмәде, тизрәк адәм алдында бөтен серләрне ачып бирергә булды.* Ф. Агиев.

ИМРӘҮ *ф. диал.* 1. Бераз куркып, шикләнеп китү.

2. Йотлыгып тыңлау, тәэсиргә бирелү.

3. Йокымсырау, йоклап алу яки йокыга ою. *Тик бераздан [Илдус] изрәп китә — Калгып китә, имрәп китә.* Рәф. Әхмәтҗанов.

4. *күч.* Йомшау, нечкәрү (күңел турында). *Бу сайрауга иң каты күңелләр имрәгәннәр, Элеккеләр моңайганнар, изрәгәннәр.* Г. Нугайбәк.

ИМСЕЗ *с.* Дәвалап, савыктырып булмый торган.

ИМТЕКЛӘҮ *ф.* 1. Бозау яки бәрәннең имчәккә борынын төртә-төртә бик аз гына имүе. / *и. мәгъ.* [*Хәерниса*] *сыерга чыккач, ничек бозау имтекләвен тәрәзә аркылы җентекләде.* Г. Ибраһимов.

2. Сөт төшсен өчен саву алдыннан сыерның, кәҗәнең имчәк башын өзек-өзек тарткалау.

ИМТИХАН *и.* 1. Нинди дә булса уку фәне буенча үткәрелә торган сынау (гадәттә класстан класска, курстан курска күчү өчен үткәрелә). *Гали үзе дә укуга бик ихлас куеп иҗтиһат кылды: гимназиядә һәр ел имтихан вакытларында [укытучыларыннан мактау] ала торган иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Тиздән имтиханнар! Жиденчегә күчәбез!* Г. Гобәй. // Тиешле рәсми хокуклар алыр өчен үткәрелә торган сынау. *Өлгергәнлеккә имтихан. Керү имтиханнары. Кабул итү имтиханы.* ▭ *Мөгаллимлектән алган акчам белән, бер ел хәзерләнеп, институтка керү өчен имтихан башладым.* Г. Ибраһимов. *Мужик баласы дигәнебез, белем байлыгы һәм кыю фикерләре белән имтихан алучыларны таң калдырып, институтка уза.* Г. Ахунов.

2. *күч.* Тормышка яки нәрсәгә дә булса яраклылыкны, сыйфатларны сынау. *Бу сүзләрнең «чынын» һәм «ялганын» Октябрь аерып бирде. Аңарчы революционер күренгән күп-күп зыялылар бу бөек имтихан көнендә кинәт контрреволюция ягына чыкканнарын сизми дә калдылар.* Г. Ибраһимов.

Имтихан бирү (тапшыру, тоту) — 1) билгеләнгән фәннәр буенча укытучы яки комиссия куйган таләпләргә канәгатьләндерерлек җаваплар бирү, сынау үтү. *Гөлсем апа, имтиханнарны биреп бетереп дүртенче курска күчүгә, Наркомпроска китте.* Г. Гобәй. *Исхакларны класслары белән район үзәгенә имтихан тапшырырга җибәрделәр.* А. Гыйләҗев; 2) *күч.* үзенең эше, сыйфатлары белән нәрсәгә дә булса яраклылыкка сынау үтү, билгеле югарылыкта тору. *Ул бүген үз чорының алдынгы кешесе икәнен күрсәтте һәм шуңа беренче имтихан тотты.* Ә. Фәйзи. *Совет очучылары бөтен дөнья алдында беренчелеккә имтихан тоттылар.* А. Алиш. **Имтихан итү (кылу)** *иск.*— берәр фән буенча белемнәрне тикшерү, сынау үткәрү. *Комиссия безне, белгән нәрсәләребездән имтихан итеп, һөнәрләребезгә карап, урыннарга [билгеләде].* Ф. Әмирхан.— *Угылың укыган икән. --- Күпме еллар имтихан кылып, аның кебеккә очраганым юк иде. --- Сорап бетмисең, ул ут кебек чәчрәтеп әллә кайчан җавабын аткан була.* Г. Ибраһимов.

ИМТИХАНЛАУ *ф. сир.* Имтихан алу, сынау.— *Син мине сынасаң, мин дә сине имтиханлап карыйм әле!* З. Бәшири.

ИМТИЯЗ *и. иск. кит.* 1. Өстенлек, өстен хокук, привилегия. *Народниклар --- җир биләүчелектәге бөтен имтиязларны бетерергә омтылалар.* Г. Нигъмәти. *Патша хөкүмәте рус булмаган милләтләрнең иң югары сыйныфларына — мирзаларына, байларына, зур руханиларына, мөфтиләренә төрле имтиязлар бирде.* Г. Ибраһимов.

2. Мактау кәгазе. *Тырышты бу бала, чын ләззәт алды инде [укудан], --- Балаларның арасында үзенә «имтияз» алды.* Г. Тукай.

3. Рөхсәт. *Россия хөкүмәте --- Сибирия тимер юлыны Манчжурия кыйтгасыннан үткәрмәк өчен Чин (Кытай) хөкүмәтеннән туксан тугыз елга имтияз (рөхсәт) ал[ды].* Ш. Мөхәммәдев.

Имтияз казану — танылу, билгеле булу. *Иске юл белән хөкүмәтне идарә итү[дә] [Германия] дөньядагы бөтен дәүләтләр арасында имтияз казанган.* С. Җәләл.

ИМТИЯЗЛЫ *с. иск. кит.* Мактаулы, өстен. [*Хәзрәт*] *мөдәррислекнең имтиязлы мәртәбәсенә, үз каршында дөньяда аңардан зур дәрәҗә юклыгына* [*карата*] *сөйли башлый.* Г. Ибраһимов.

ИМ-ТОМ *җыйм. и.* Авыруга каршы төрле имнәр, ырымнар. *Аның янында һәрвакыт әзер тоткан им-том бар иде: бер чеметем тоз, кечкенә кисәк икмәк катысы, иске чүпрәк.* Г. Ибраһимов. *Сафура дигән карчык им-том өчен туфрак алырга кергән икән.* К. Нәҗми. // Дару, дәва. *Имгә-томга тозлы кәбестә кирәккән чагында кешеләр, Васильевнага барып, күкәйгә алмашып алып кайта торган иделәр.* Ш. Камал.

Им-том итү — имләү, им-томлау, дәвалау.— *Бераз им-том итеп карамадыңмы соң? — диде Шәмгун карт, яңадан сүзне авыруга борып.* А. Шамов. *Үзен әллә ничә тапкыр төрле-төрле нәрсәләр белән им-том итеп карасалар да, терелүгә табан [бармый ул].* З. Бәшири.

◇ **Имгә-томга да очратмау** — бөтенләй булмау.— *Шәһәрдә бу нигъмәтләрне имгә-томга да очрата алмыйсың...* Ш. Камал.

ИМ-ТОМЧЫ *и. к.* имче. *Доктор-мазар сүзе түгел, им-томчы карчыклар әйткән.* Г. Гобәй.

ИМ-ТОМЧЫЛЫК *и.* Им-том итү шөгыле. [*Ул*] *«Медицинадагы соңгы яңалыклар, дин һәм им-томчылык» дигән темага мәкалә язарга утырды.* Г. Әпсәләмов.

ИМЧЕ *и.* Төрле ырымнар, өшкерүләр белән хорафатларга ышанучы кешеләрне дәвалыйм дип алдап йөрүче кеше; им-том итүче. *Хәзер имче — газаплап кеше үтерүче кабахәт карчыклар тырнагыннан котылып, таза, фән нигезендә сәламәтлекне саклый торган больницаларга барыйк без.* Ф. Кәрим. *Бабай дөрес әйтә шул: имче дә, имгәтүче дә син.* К. Нәҗми.

ИМЧЕЛЕК *и.* Имче булу, имче кәсебе.

Имчелек итү — им-том белән көн күрү.

ИМЧЕ-ТОМЧЫ *и. к.* имче. [*Г. Камал*] *хәйләкәр, ара бозгыч имче-томчы карчыклар, бай хатыннары һәм асрауларның типларын аерым бер табигыйлек һәм осталык белән бирә ала.* Г. Сәгъди.

ИМЧӘК *и.* 1. Хатын-кыз күкрәгенең өске өлешендә түгәрәкләнеп калкып торган сөт бизе. *Сөтсез имчәкләрен суыра-суыра Елый аның сабый баласы.* Ә. Ерикәй. *Ул тыңлый тынып, Беренче кат имчәк капкан төсле сусап, йотылып.* М. Җәлил.

2. Хайваннар җиленендәге сөт чыга торган чөмәк. *Колын --- әнкәсенең сөт белән тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.* Г. Ибраһимов. *Сыерның имчәге тәмам бушады, шәлперәйде, тамчы да сөт чыкмас булды.* М. Хәсәнов.

Имчәк асты *диал.*— имчәк имү дәверендәге, бер яшь тулмаган тай, колын. **Имчәк баласы** — имү дәверендәге бала. *Хәмидә кечкенә имчәк баласын кулына алып --- имезә башлады.* М. Гафури. **Имчәк башы** — хатын-кызларда сөт бизенең уртасыннан сөт чыга торган чөмәк. **Имчәк тай** *диал.*— колын. **Имчәктән аеру (ташлату)** — баланы имезүдән бөтенләйгә туктату. *Балаларым да бер-ике көнгә генә имми дә торырлар. Аларны бөтенләй имчәк ташлатыр вакыт та җитеп килә.* М. Гафури. **Имчәк төбе** — 1) сөтнең иң соңыннан савыла торган куе өлеше. *Карт бия дә, угылының ярганын [сизеп], --- кыргыз абыстай килеп сауганда, урлап*

имчәк төбен алып кала иде. Шура; 2) *күч.* тәмәкенең бераз тартылганнан калган өлеше; тәмәке төпчеге. **Имчәк шешү** — сөт бизләре авыру; *русчасы:* фруз.

ИМЧӘКТӘШ *и.* 1. Бер ана балаларының берсе.— *Туганнарым — имчәктәшләрем янына барам.* К. Насыйри.

2. Бер хатын имчәгеннән имгән төрле ана балаларының берсе.

ИМӘЗӘ *и. диал.* Әңгер-меңгер чак. *Кичке имәзә.*

ИМӘН *и.* Яфраклары челтәр кырыйлы, каты үзагачлы зур юан агач (аның ачы чикләвекләре була). *Юеш яфракларын салындырып, мәһабәт имәннәр тынып утыра.* Г. Бәширов. [*Өермә*] *ничә йөз еллык зур карт имәнне тирән тамырлары белән йолкып --- ташлады.* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Шундый агачтан ясалган. *Имән казык.* □ [*Ул*], *калын гына имән таякка таянган хәлдә, аксабрак килеп керде.* Ә. Фәйзи.

Имән алмасы *бот.*— имән яфрагында аклы-кызыллы кечкенә алма сыман түгәрәк шар, паразит үсенте. **Имән бармак** — баш һәм урта бармаклар арасындагы бармак; ишарә бармак. [*Кеше*], *уң кулын әкрен генә кесәсенә шудырып, имән бармагын пистолет курогына тыкты һәм пистолетын чыгарып Акбүзгә төзәде.* Г. Гобәй. *Сауганда имчәкне баш һәм имән бармаклар белән мөмкин кадәр өстәнрәк тотарга кирәк.* М. Хәсәнов. **Имән борын** *зоол.*— тау чыпчыклары семьялыгыннан конус сыман зур томшыгы белән чия, шомырт төшләрен ватып ашаучы кечкенә урман кошы; *русчасы:* дубонос. **Имән гөмбәсе** *бот.*— кызылсу-сары яки саргылт-көрән эшләпәле, ашарга яраклы гөмбә. **Имән чикләвеге** *бот.*— имәннең ачы тәмле, озынча, кабыклы җимеше. *Ачлык елны --- алабута, имән чикләвеге оны белән кушылып пешерелгән җитәр-җитмәс азыклардан әкренләп өзелә килгәнлектән булса кирәк, минем әни үлде.* Ф. Хөсни. [*Малай*] *урманда имән чикләвеге җыя.* И. Гази. **Имән чыпчыгы** *зоол.*— солы чыпчыклары семьялыгыннан кызгылт-сары төстәге кечерәк күчмә кош; *русчасы:* дубровник.

◇ **Имәндә икән чикләвек** — гажәпләнүне, аптырауны белдерә. *Уйнар өчен дә, карар өчен дә кызыклы берәр пьеса алырга онытканбыз. Имәндә икән чикләвек, хәзер нишләргә инде безгә?* Ф. Хөсни.

ИМӘНГЕЧ *с. диал. к.* имәнеч. *Бу нинди нәрсә бу... Койрыгы да бар, мөгезе дә бар. Тфү! Үзе шәп-шәрә тагы, имәнгеч.* Д. Аппакова. *Булышырга килүчеләрдән берсе, сузылып, атның имәнгеч булып тырпаеп калган борынын тотып карады.* Г. Бәширов.

ИМӘНДЕРГЕЧ *с. к.* имәнеч. *Кызыл борынлы исерек урядниклар аларның яшьлек истәлегендә имәндергеч шомлы карачкы булып гәүдәләнеп калган.* Г. Бәширов.

ИМӘНЕЧ *с.* 1. Куркыныч, куркытырлык. *Син, өлкән адәмнәр кебек, уянсаң — зәхмәтле эшләр, йоклысаң — имәнеч төшләр күрмисең.* Дәрдмәнд. *Гаяз башына сугылган кулак балтасыннан чыккан имәнеч саңгырау тавыш Тәкъва Сәхәү бүлмәсендә генә калмады, безнең активлык белән көчәйтелеп, ераклерга яңгырады.* М. Әмир.

2. Җирәнгеч, чирканыч.

3. *кис. мәгъ. диал.* Сыйфатлар һәм рәвешләр алдында артыклык дәрәҗәсен бирә. *Имәнеч күп.*

ИМӘНЛЕК *и.* Имәннәрдән гыйбарәт урман, имәннәр күп үсә торган урын; имәнсәр. *Ул, көнтәлек агач эзләп йөри торгач, моңар хәтле таныш булмаган имәнлеккә килеп чыкты.* К. Нәҗми. [*Сөләйман*] *туп-туры имәнлеккә таба юл тотты.* К. Тинчурин.

Имәнлек җилдәге *бот.*— к. умырзая.

ИМӘНСӘР *и. диал. к.* имәнлек. *Әйди, имәнсәр, имәнсәр, Имәнсәр башларын җил кисәр.* Җыр.

ИМӘҢ *ф.* Курку, куркудан тетрәнү, сискәнү. *Каркыны як көзгедә үзенең берьюлы суырылып өлгергән сынын күреп,* [*ул*] *имәнеп калды. Бигрәк тә аны моңындагы яра эзләре тетрәтте.* Ф. Хөсни. *Шундый хәлләр искә төшкән саен, куркыныч төш күргәндәй, имәнеп китәсең.* Г. Бәширов.

ИМӘС *кис. диал.* Түгел.— [*Андый*] *хатын белән тору яхшы имәс.* Г. Газиз. *Дүрт аяклы мал күп имәс.* Г. Бәширов.

ИМҮ *ф.* 1. Иренне, телне эчкә таба хәрәкәтләндереп, имчәктән сөт суыру. [*Алар*] *икесе дә бер күкрәктән сөт имгәннәр.* Н. Исәнбәт. [*Болан*] *нәрсәдер тыңлый, ә баласы --- анасына үрелә, имәргә тели, --- аның бары имәсе, суырасы гына килә.* А. Шамов.

2. Кешедәге яки берәр әйбердәге сыеклыкны үзенә җыю, суыру (бөжәкләр һәм үсемлекләр турында).— *Әгәр* [*кандалалар*] *төрле яктан сарып имә башласалар, чыдап кына тор.* Г. Коләхметов. *Үсемлек иң элек, үзенең кабыгы белән, җирнең түйдыра торган матдәсен имәдер. --- Күбәләк һәм умарта корты* [*исә*] *чәчәкләрдән бал имәләр.* Г. Тукай.

3. *диал.* Каты нәрсәне авызга кабып, төкерек белән чылатып суыру. *Бармак имү.* // Тел һәм иреннәрне эчкә таба хәрәкәтләндереп, шикәр, конфет кебек нәрсәләрне жебетеп ашау.

4. *гади с.* Хәйлә юлы белән кеше акчасыннан, байлыгыннан (гадәттә яшертен) файдалану.— [*Исмәгыйльне*] *кулыңа төшкәндә имеп кал, --- өйләнгәч, атасыннан чиерткән акчаларын сиңа бик яудырмас.* Г. Камал.— *Кайберәүләр Сабировны: --- ышанычлы кеше түгел, диләр, ОРСны имеп ята, диләр. Билгеле, үз кулында булгач, имә дә торгандыр.* Ә. Еники. // Кеше хезмәтеннән файдалану, кеше исәбенә баю. *Кеше көчен имеп симергән кулакларга үлем китергәнен Ситдыйк абзый бик яхшы аңлый.* К. Нәҗми.— *Эре җир арендаторы. Бик күп ярлыларны имеп килгән кеше* [*ул*]. Г. Толымбай.

ИНАБӘТ *и. иск. кит.* Ышаныч; вәгъдәсендә торучанлык. *Син мине үзеңнең сандыгың янына каравылга куясың икән, рәхмәт инабәтеңә.* Г. Тукай. [*Шәкертләрнең*] *хәлфәләргә инабәтләре беткән, аларны бер йөз ерткыч аюлар дип кенә беләләр.* С. Рәмиев.

Инабәт итү — ышану, ышаныч күрсәтү. *Чит мәмләкәттә безнең кәгазьләргә бик күп инабәт итмиләр.* Г. Тукай.

ИНАБӘТЛЕ *с. иск. кит.* Ышанычлы, вәгъдәсендә торучан.— *Әгәр бер инабәтле һәм безне алдамаслык бер кеше табылса, без бу алтыннарны* [*сатабыз*]. Г. Камал.

ИНАНУ *ф.* Берәр нәрсәнең дөреслегенә, раслыгына чын күңелдән ышану. *Аның әйләнә-тирәсендә дә, кайчан да булса хәзинә табуга ышанып, төшкә, ырымга инанып яшәүчеләр бар.* К. Нәҗми. *Ул үзенең бары тик аның белән генә дөньяда яши алачагына тәмам инанган, --- башка төрле инануның булуы мөмкин дип уйлый да алмый иде.* Ф. Хөсни.

ИНВАЛИД *и.* Авыру яки имгәнү сәбәпле, хезмәткә яраклылыкны өлешчә яки тулысынча югалткан кеше. *Аяклар юк! Аларны кайчан кискәннәр дә, кайчан чыгарып ташлаганнар? Менә шунда гына инде элеккеге солдат Артур үзенең инвалид икәнен белеп алды.* Н. Дәүли.

ИНВАЛИДЛЫК *и.* Хезмәткә өлешчә яки тулысынча яраксызлык, инвалид булу хәле. [*Аның*] *анасы ревматизм белән авырып китте һәм, өч айдан артык больницада ятканнан соң, инвалидлыкка чыкты.* Ш. Хөсәенов.

ИНВЕНТАРИЗА'ЦИЯ *и.* Милекнең ничек торышын, ничек саклануын исемлек нигезендә тикшереп барлау, исәпкә алу эше.— *Кичә цехта инвентаризация үткәрүгә верстак астыннан әлеге калайларны табып алдылар.* Т. Гыйззәт. *Галләмнәрдән калган әйберләрне барлап, инвентаризация үткәреп йөриләр иде булса кирәк* [*алар*]. Ф. Хөсни. // Инвентарь дәфтәренә, инвен-

тарь кенәгәсенә кертү эше. // *с. мәгъ.* Шул эш белән шөгыльләнә торган.— *Инвентаризация комиссиясе шул микроскоп аркасында үзенең эшен тәмам итә алмый.* Г. Галиев.

ИНВЕНТАРЬ *и.* 1. Берәр оешманың эш кораллары, эш көчләре, җиһазлары, гомумән, җитештерү средстволары. *Җанлы инвентарь. Җансыз инвентарь.* □ *Ремонтланган инвентарьларны яңадан барлап, тикшереп чыгарга [кирәк].* М. Шабай. *Бу сарайда колхозның кышкы инвентарьлары һәм --- яңа җилгәргеч тора.* Г. Әпсәләмов.

2. Милектә булган әйберләрнең — җиһаз, корал һ. б. исемлеге.— *Инвентарь дәфтәрләрен Көчтер агай алган.* Т. Гыйззәт.

ИНВЕНТАРЬЛАУ *ф.* Инвентаризация ясау, инвентаризация үткәрү.

ИНВЕ'РСИЯ *и. лингв.* Берәр сүзнең мәгънәсенә басым ясау яки бөтен фразага билгеле бер стилистик төсмер бирү өчен, җөмләдә сүзләрнең гадәти тәртибен үзгәртү. *Инверсия[гә] — җөмләдәге кайбер сүзләрне кире тәртип белән урнаштыру[га] — мисал: «Бәләкәй иде ул чагында Сәубан».* Л. Җәләй. *[Шагыйрь] фразадагы сүзләрнең урыннарын алмаштырып куярга — инверсия ясарга мәҗбүр була.* Х. Госман.

ИНВЕ'РСИЯЛЕ *с.* Сүз тәртибе үзгәртелгән. *[Бу язучы] иптәштә артык дәрәҗәдә инверсияле сөйләмнәр күп очрыйлар.* З. Искужин.

ИНВЕ'РСИЯЛӘҮ *ф.* Инверсия ясау. *«Мин торам кырларда, Болында, урманда; Уйныймын, очамын, Якты көн булганда»,— дип, Г. Тукай урын хәлләрен матур итеп инверсияли.* Л. Җәләй.

ИНВЕ'РТОР *и. физ.* Даими электр тогын алмаш токка күчерә торган җайланма.

ИНВЕСТИ'ТОР *и. экон.* Озак срокка капитал салучы кеше.

ИНВЕСТИ'ЦИЯ *и. экон.* Табыш алу өчен предприятиеләргә капитал салу.

ИНГАЛЯ'ТОР *и. тех.* Сыек даруны көчле һава яки пар агымы белән (мәсәлән, тамакка яки борынга) сиптерә торган прибор.

ИНГАЛЯ'ЦИЯ *и. мед.* Сулыш органнарын газ яки бик вак сыеклык парлары хәлендәге дару сиптереп дәвалау.

ИНГЛИЗ *и.* Англиянең төп халкы һәм шул халыкның бер кешесе. *Француслар, немец, инглизләр, эшче-социалистлар, коммунистлар --- [Испаниягә] иреклеләр булып килгәннәр.* Э. Исхак. *Кабинетта француз һәм инглизләрдән берничә журналист [бар].* Г. Гобәй. // *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Инглиз культурасы.* □ *Мәшһүр инглиз шагыйре лорд Байронның исемен ишетмәгән кеше аздыр дип уйлыйм.* Г. Тукай. *[Солтан] Шекспир, Байрон шикелле бөек талантларны тиздән үз ана телләрендә, инглиз телендә, укый алачагына куанды.* Г. Кутуй.

Инглиз авыруы *иск.— к.* рахит. **Инглиз йозагы** — ишеккә уеп куела һәм үзеннән-үзе бикләнә торган йозак (аның бер ягы сырлы, яссы ачкычы була). *Инглиз йозагы челт итеп бикләнеп калды.* М. Маликова. **Инглиз тозы** *мед.*— эч йомшарту өчен кулланыла торган дару; магний оксиды.

ИНГЛИ'ЗЧӘ *рәв.* 1. Инглиз телендә. *[Китапханәдә] французча, немецча, инглизчә, эсперанточа язылган китаплар күп.* Ф. Әмирхан. *Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте инде сугышка кадәрле үк французча, немецча, инглизчәгә тәрҗемә ителгән иде.* Г. Ахунов.

2. *с. мәгъ.* Инглизләргә хас. *Хабуш — офицер, инглизчә мыеклы.* Н. Исәнбәт.

ИНГУШ *и.* Чечен-Ингуш АССРда яшәүче төп халыкларның берсе һәм шул халыкның бер кешесе. // *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Ингуш теле. Ингуш әдәбияты.* // *с. мәгъ.* Шул халык кешеләреннән оештырылган. *Ингуш полкы, дрогуннар эскадроны Казанга күчерелде.* К. Нәҗми.

ИНДЕ *кис.* 1. Төрле сүз төркемнәре янында килеп, эшнең тәмамлануына ишарә итә. *Мин аннан бер узган идем инде.* Г. Бәширов. *Хәзер теге шәһәр дә ерак түгел инде.* Әкият.

2. Боерык фигыльләрдән соң килеп, аңа үтенү яки сабырсызлану, түземсезләнү төсмере кертә.— *Ычкындырмагыз инде үзен!* Г. Бәширов.— *Бие инде, Йолдыз, бие!* А. Алиш.

3. *рәв. мәгъ.* Берәр эш эшләргә вакытның килеп җитүен, эшнең башланып китүен белдерә; хәзер.— *Инде кайтырга ярый.* М. Фәйзи. *Күп буйсындык, инде аны буйсындырыйк безнең теләккә.* Ф. Кәрим.

4. *рәв. мәгъ. диал.* Күптән түгел генә.— *Әле ул чакта чәй дигән нәрсә юк иде, --- инде генә чыкты.* М. Галәү.

5. *и. мәгъ. диал.* Бүгенге, хәзерге көн, хәзерге мизгел. *Фәридә алар киткән көнне --- күңелендә әллә нинди бер авырлык хис итә. Индедән соң яныбызда аз сүзле, акыллы күзле, һәрвакыт йомшак мөгамәләле Рөстәм абый булмый бит, дигән уй аңар, никтер, авыр тоела.* С. Җәләл.

6. *терк. мәгъ. сөйл.* Берәр эшнең шартын белдергәндә, шарт җөмләләрне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла; әгәр. *Әгәр сөюе чын икән, ул аның артыннан районга барыр, әллә кайларга барыр. Инде бармый икән, ул чагында...* Г. Бәширов.

7. *сөйл.* Әңгәмәдәш әйткән сүзне яратмау, дөреслегенә ышанмауны аңлата.— *Я, бәлкем, [ул] китаплар кеше үтерергә котырталардыр? — Инде, инде! Андамыни эш?* Г. Бәширов. *[Рөстәм:] Кара әле, бәлки, сине алар чәй дә эчерми куганнардыр, ә? Ха-ха-ха!..* *[Сәгыйдә:] Инде, абый!* Һ. Такташ.

◇ **И'нде дә** — сокланууны, таң калуны, гаҗәпләнүне белдергәндә кулланыла; шулкадәр.— *Их, егетләр, күрсәгез кызларын фатир хуҗасының! Инде дә сылу, инде дә гүзәл булса булыр икән!* Ш. Бикчурин. **Инде килеп** *диал.*— тагын, өстәвенә. *Камилнең колхоздан рөхсәт-нисез нефть эшенә китеп баруы, инде килеп армиядән калуы яңадан Галләмнең йөрәген тырнап узды.* Ш. Бикчурин.

ИНДЕГЕ *с. бор.* Хәзерге. *Борынгының бере юк, Индегенең коны юк,— [дип сөйләгәннәр].* Н. Исәнбәт.

ИНДЕ'ЕЦЛАР *җыйг. и. күпл.* Америка континентының хәзер кайбер урыннарында гына яши торган борынгы төп кабиләләрнең, халыкларның гомуми исеме. *Төньяк Америка индеецларының чокып ясалган көймәсен элек [каноэ] дип йөрткәннәр.* Г. Мөхәммәтшин. *Америка җиренә исә [кукурузны] бик борынгы заманда индеецларның бабалары үзләре белән бергә алып барганнардыр, дип уйлыйлар.* А. Шамов. // *берл.* **индеец**. Шул кабиләләрнең бер кешесе.

И'НДЕКС *и.* 1. Берәр нәрсәнең исемлеге, берәр нәрсә турында белешмә. *Китаплар индексы.*

2. Исемлектә цифрлы күрсәткеч. *Почта индексы.* □ *«Казан утлары» --- Бөтенсоюз журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән кертелгән.* В. Нуруллин.

3. *экон.* Нинди дә булса экономик күренешнең эзлекле рәвештә үзгәрә баруын процентларда чагылдыра торган цифрлы күрсәткеч. *Бәяләр индексы. Хезмәт хакы индексы.*

4. *мат.* Математик аңлатма составындагы хәрефнең аскы уң ягына куела торган хәреф яки цифрлы күрсәткеч; мәсәлән: a_3, y_n.

5. *махс.* Китапханә классификациясендә китапның кайсы бүлеккә караганлыгын һәм алфавит тәртибе буенча кайсы урында торуын билгели торган, цифрлар яки хәрефләрдән гыйбарәт шартлы билге.

ИНДЕТЕРМИНИЗМ *и. филос.* Табигать һәм җәмгыять күренешләре арасында сәбәп бәйләнешләре һәм гомуми закончалык барлыгын инкяр итә, дөньяда очраклылык, башбаштаклык хөкем сөрә дип саный торган идеалистик юнәлеш.

ИНДЕТЕРМИНИСТ *и. филос.* Индетерминизм тарафдары.

ИНДЕТЕРМИНИ'СТИК *с. филос.* Индетерминизмга хас, шуңа бәйләнешле.

ИНДИВИД *и. кит. к.* индивидуум. *Акыл шәхеснең үз-үзен тикшерә, үзен индивид буларак анализлый.* Н. Юзиев.

ИНДИВИДУАЛИЗА'ЦИЯ *и.* Характеры, үзенә генә хас сыйфатлары ягыннан аерымлап күрсәтү, сурәтләү. *Образларда һәм ситуацияләрдә дә бер-берсенә охшашлык, индивидуализациянең җитәрлек булмавы күзгә ташлана.* Б. Гыйззәт.

ИНДИВИДУАЛИЗМ *и.* **1.** *филос.* Барысын да шәхес интересларына буйсындыруны яклап чыккан буржуаз караш һәм ижтимагый юнәлеш.

2. Үзенең шәхесен, бөтен коллективка каршы куеп, күтәрергә тырышу. *Без сөймибез «мин» дип сөйләшүне, индивидуализм чире ул! Ә. Фәйзи. Индивидуализм гадәттә чит ил язучыларына әйтелә торган бәя. --- Үзен чолгап алган мохит белән, җәмгыять белән алыш-биреше булмыйча, үз эчендә генә казынучыларга карата әйтелә бит бу сүз.* Г. Ахунов.

ИНДИВИДУАЛИСТ *и.* Эштә дә, фикер йөртүдә дә үз шәхесен коллективтан өстен куючы кеше. *Я булмаса, шагыйрь үзен коллективтан өстен куючы бер индивидуалистмы?* М. Максуд.— [*Рәүф*], *үзенең хосусый интересларын алга куеп, үз туган-тумачасына хөкүмәт хисабыннан фатир өләшеп ята торган чеп-чи бер индивидуалист булып чыкты!* Ә. Фәйзи.

ИНДИВИДУАЛИ'СТИК *и.* Индивидуализмга хас. [*Г. Рәхим*] *шагыйрьнең индивидуалистик рухтагы ялгышуларын, эзләнү дәверендәге каршылыкларын югары күтәреп мактады.* Г. Халит. [*Реакция елларында*] *Казан рус театрына индивидуалистик хисләргә һәм буржуаз идеяләргә корылган әсәрләр дә үтеп кергәләделәр.* Сов. эд.

ИНДИВИДУАЛИСТЛЫК *и.* Индивидуалистларга хас сыйфат. *Ш. Фидаиның «Мин» шигыренең башыннан ахырынача «мин» күкрәп тора. Бу шигырьне романтик индивидуалистлыкның иң күперенке бер үрнәге дип әйтергә мөмкиндер төсле.* М. Максуд. *Такташның 1924—1928 елларда язылган шигырьләрендә, чыннан да, шәхес интересы белән җәмгыять интереслары мөнәсәбәте мәсьәләсе, эчтәге шикелле индивидуалистлык карашыннан килеп куелмыйча, киресенчә, ижтимагый интереслар өстенлеген яклау формасында куела.* Г. Нигъмәти.

ИНДИВИДУАЛЬ *с.* **1.** Бары тик бер шәхескә генә хас һәм аны башкалардан аера торган. *Индивидуаль үзенчәлекләр.* □ *Без, яңа кешене сурәтләгәндә, аның чорга характерлы булган тулай типик сыйфатлары белән аерым кешенең үзенә генә хас, индивидуаль сызыкларын берләштереп бирә алмыйбыз* [*әле*]. М. Җәлил. *Әсәрдә* [*«Ящь йөрәкләр»дә*] *үзәк урын тоткан шәхесләр --- индивидуаль эчке сыйфатларга ия булган, һәрберсе берәр хирескә бирелгән (мәхәббәт, үзүзен сөючәнлек, җәмгыятьтән бизү һ. б.) кешеләр итеп биреләләр.* Г. Нигъмәти.

2. Бер генә кеше карамагында, биләвендә булган, ялгыз; *киресе:* гомуми. *Индивидуаль хуҗалык. Индивидуаль милек.*

3. Аерым кешеләр тарафыннан башкарыла торган. *Индивидуаль җитештерү.*

4. Һәркемгә аерым бәйләнешле, һәр кешегә, һәр очракта аерым. *Индивидуаль план. Индивидуаль мөнәсәбәт.* □ [*Биредә*] *кулаклар бөтенләй индивидуаль налогка тартылмаганнар.* Г. Толымбай. *Менә мондый индивидуаль беседа үткәргәнлегемне яхшы хәтерлим.* Р. Төхфәтуллин. // *рәв. мәгъ.* Һәр очракта, һәр кеше белән аерым. *Композиторлар союзы татар композиторларының --- һәркайсы белән индивидуаль шөгыльләнеп, дөрес юнәлеш бирергә тиеш.* М. Җәлил.

5. Аерым, ялгыз. *Индивидуаль очрак.* □ *Вәли байлар --- индивидуаль террор ясауларга хәтле барып җитәләр.* Г. Нигъмәти. *Коллектив өчен көрәшкәндә индивидуаль таләпне дә читкә кагарга ярамый.* Ә. Фәйзи.

Индивидуаль пакет *мед.*— кемнең дә булса шәхси файдалануындагы яра бәйләвеч материаллар җыелмасы.— *Менә сезгә индивидуаль пакетлар, ярасын кысыбрак төшеп бәйләрсез.* Г. Минский. [*Абдул*] *индивидуаль пакетын алып тиз генә сүтә дә картның кулын бәйли.* Ә. Фәйзи.

ИНДИВИДУАЛЬЛЕК *и.* Бер шәхесне яки күренешне башкалардан аера торган сыйфатлар җыелмасы. *Малай мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтыла, ләкин бу теләк күмәклеккә һич тә дошман түгел иде. Әгәр шундый индивидуальлек булмаса, кешеләр бер калыптан чыккан таш курчаклар кебек булыр иде.* А. Тимергалин. *Образларның телен җирле сөйләм үзенчәлекләре белән чуарлап кына индивидуальлеккә ирешеп булмый.* М. Җәләлиева.

ИНДИВИДУАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Үзенә генә хас, үзенә генә характерлы, индивидуаль сыйфатлар буенча аерымлап бирү. *Кешеләр әсәрдә индивидуальләштерелеп, бер-беренән ачык аерылып бирелгәннәр.* Г. Нигъмәти.

ИНДИВИДУАЛЬЧЕ *и. к.* индивидуалист. *Буржуа әдәбияты әнә шул милек иясе — эксплуататор катлауларның геройларын, индивидуальче геройларны җырлады.* К. Нәжми.

ИНДИВИ'ДУУМ *и. кит.* Мөстәкыйль тереклек итә торган зат, организм. // Аерым кеше, шәхес. *Кеше, индивидуум, никадәр генә көчкә ия шәхес булса да, җәмгыятьтән башка яши дә, бернәрсә эшли дә алмый.* М. Хәсәнов. *Бу мәсьәлә --- коллектив белән индивидуум проблемасына бәйләнгән.* Ә. Фәйзи.

И'НДИЙ *и.* Көмеш сыман ак төстәге сирәк табыла торган металл, химик элемент.

ИНДИКА'ТОР *и.* **1.** *тех.* Басым, авырлык һ. б. ш. физик зурлыкларны үлчи торган приборларның исеме. [*Алмаев*] *индикатор каршына чүгәләде, түгәрәк диаграмманың чатлы-ботлы сызыкларын укый башлады.* И. Гази. [*Закир*] *буровой коймасына беркетелгән сәгать төсле түгәрәк прибор — индикатор янына китте.* Г. Ахунов.

2. *хим.* Тикшерелә торган эремәдә химик процесс бару-бармавын төс үзгәртү белән билгели торган матдә. *Алар карыннан алынган пробаларны --- индикатор салып селте белән титрладылар.* А. Расих.

3. Гомумән күрсәткеч. *Үсемлекләр — файдалы казылмаларның индикаторлары.*

4. *махс.* Китапханәдә китапның кемгә бирелүен күрсәтә торган картотека.

ИНДОНЕ'ЗИЯЛЕ *и.* Индонезия иле кешесе.

ИНДУИЗМ *и.* Брахманизм һәм буддизм нигезендә барлыкка килеп, Һиндстанда хакимлек итә торган дини системаның исеме.

ИНДУКТИВ *с.* **1.** *лог.* Индукциягә (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Индуктив метод. Индуктив фикер йөртү.*

2. Индукция (2 мәгъ.) барлыкка китерә торган. *Индуктив каршылык.*

ИНДУКТИВЛЫК *и.* **1.** *лог.* Фикер йөртүдә индукция (1 *мәгъ.*) методын өстен кую. *Исбатлауның индуктивлыгы.*

2. *физ.* Индуктив (2 мәгъ.) булу. *Электр чылбырының индуктивлыгы.*

ИНДУ'КТОР *и. тех.* 1. Алмаш ток алу өчен кул белән әйләндерелә торган электр машинасы. *Индуктор аппаратына куелган кечкенә звонок шалтырый.* Х. Садрый.

2. Динамомашинада магнит кыры, индукцион токлар тудыра торган магнит.

ИНДУКЦИОН *с. физ.* Индукция (2 мәгъ.) нәтиҗәсендә барлыкка килгән яки индукциягә нигезләнгән. *Индукцион ток. Индукцион мич.* □ [*Прибор*] *эченда көпчәкләр, индукцион катушкалар* [*күренә*]. А. Тимергалин.

ИНДУ'КЦИЯ *и.* 1. *лог.* Аерым, очраклы фактлардан һәм положениеләрдән гомуми нәтиҗәләр чыгару методы; *киресе:* дедукция.

2. *физ.* Үткәргечне магнит кырында хәрәкәт иттергәндә яки магнит кырын үзгәрткәндә шул үткәргечтә барлыкка килә торган электр тогы. *Электромагнитик индукция күренеше.*

ИНДУС *и.* 1. *иск.* Һиндстанда яшәүче төп җирле халыкның исеме һәм шул халыкның бер кешесе; һинд. *Индусларның күпчелеге бер Буддага табына.* Г. Гобәй. *Рус, кытай, француз, Негр һәм индус... Барлык халыклар Булсыннар чын дус.* Н. Арсланов.

2. Индуизм тарафдары.

ИНДУСТРИАЛЬ *с.* Промышленносте булган; индустриягә бәйләнешле. *Индустриаль ил. Индустриаль методлар.* □ *Инде үсте бар Казан, Ул машиналар илһәре, Индустриаль Казан.* Н. Исәнбәт. *Аның заманнары гәүдәләндерә белүе индустриаль пейзажлар белән генә чикләнми.* Х. Якупов.

ИНДУ'СТРИЯ *и.* Машина техникасы булган фабрика-завод промышленносте. *Авыр индустрия. Җиңел индустрия.* □ *Бөек Рәсәйнең әрем баскан кыргый далаларында иң башлап индустрия гигантлары төзүче дә шул буын иде.* Г. Бәширов.

ИНДУ'СТРИЯЛӘШТЕРҮ *ф.* Халык хуҗалыгын индустриаль машина техникасы нигезенә күчерү. / *и. мәгъ. Илебезне индустрияләштерү --- нигезендә яңабаштан кору эшендә химия промышленносте чиксез зур урын тота.* Ш. Камал.

ИНДУ'СТРИЯЛӘШҮ *ф.* Халык хуҗалыгы индустриаль машина техникасы нигезенә күчү. / *и. мәгъ. Илебезнең индустрияләшү һәм авыл хуҗалыгының кумәкләшү уңышлары нигезендә без данлы Кызыл Армиябезнең көчен өзлексез ныгытабыз.* К. Нәҗми.

ИНЕРТ *с. махс.* Башка матдәләр белән кушылмый торган. *Инерт газлар.*

Инерт материаллар *тех.*— измә, бетон һ. б. ш. составына керә торган ком, вак таш, гравий; төзелеш материалы.

ИНЕРЦИОН *с. физ.* Инерциягә нигезләнгән, инерциядән файдалана торган. *Инерцион этәрешләр.* □ — *Чагыштырмалык теориясе күзлегеннән караганда, --- без инерцион системада калмадык.* А. Тимергалин.

ИНЕ'РЦИЯ *и. физ.* Җисемнәрнең баштагы тынычлык хәлен яки хәрәкәт юнәлешен һәм тигезлеген саклау үзлеге. *Безнең винтовкалардан чыккан пуляларның көче инерция законы буенча сигез чакрымлык аралыкта кешене --- үтерә ала.* К. Тинчурин. [*Һавага*] *күтәрелгән вакыттан алып берничә минут үтә, ә тәгәрмәчләр инерция белән һаман әйләнүләрендә дәвам итәләр.* С. Баттал.

◇ **Инерция буенча** — гадәт буенча, аңламастан, белештермичә, механик рәвештә. *Көтмәгәндә авызы йомылган Рәшит телсез-өнсез калды, як-ягына каранды, тик шулай да, инерция буенча гына, барыбер елмаюынан туктамады.* Н. Фәттах. *Тагын бер адым — һәм ул упкынга очачак. Инерция буенча ул шуңа бара да, үткәндәге үз хаталары һәм бүтәннәрнең хаталары аркасында аның өстенә өелгән авыр йөк хәзер аны рәхимсез рәвештә базга тарта.* Г. Әпсәләмов.

ИНЕЧ *и.* Киемнең яки башка нәрсәнең эчке ягына тегелгән тукыма. [*Зөһрә*] *күлмәкнең инеченә кош теледәй генә хат язган да Гафурига җибәргән. --- Ләкин Гафуриның күзләре инечкә язылган бу хатка бары тик берничә көннән соң, күлмәкне салган чакта, аның тискәре ягы әйләнеп киткәч кенә төшкән.* С. Кудаш. *Илдар антны --- портфель инеченә тегеп куйды.* Г. Гобәй.

ИНЕЧЛӘҮ *ф.* Инеч салу, инеч белән тегү. *Инечләп тегү.*

ИНЕШ *и.* Кечкенә, сай һәм тар елгачык. *Урман арасын кисеп бик сай сулы тар гына инеш ага.* Г. Гобәй. *Габделкаюмның үзләренең авыл кырыендагы сай гына кыр инешеннән башка суда коенганы юк иде.* М. Гали.

ИНЖЕНЕР *и.* Фән-техниканың берәр тармагы буенча югары белем алган белгеч. *Инженер-конструктор. Тау инженеры. Баш инженер.* □ — ***«Катюша» дигәне безнең совет инженерлары уйлап чыгарган шундый яңа корал ич ул!*** Г. Бәширов. *Инженер! Бу исемне ишетү белән, зур-зур заводларда, меңләгән эшче катнашкан төзелешләрдә эшләүче, производствоның тирән серләрен белүче югары белемле кеше күз алдына килә.* Г. Ахунов.

ИНЖЕНЕРЛЫК *и.* Инженер профессиясе; инженер һөнәре. *Минем малаем да --- инженерлык алыр үзенә.* Ш. Маннур. *Инженерлыкка әзерләнәм, сынау бирәсем бар.* Г. Мөхәммәтшин. // *с. мәгъ.* Инженерлар эшчәнлегенә бәйләнгән. *Инженерлык корылмасы.* □ *Викторның әтисе инженерлык гаскәрләрендә сугышкан.* Р. Төхфәтуллин. *Төп юнәлешләрдә аларга инженерлык киртәләре белән томаланган траншеялар, аралашу юллары өстәлә.* Г. Сафиуллин.

ИНИЦИАЛ *и.* 1. Исем-фамилиянең яки исем һәм атасы исеменең баш хәрефләре. *Бу бинокльнең күненә нәкъ минем инициалга туры килә торган «С. Т.» хәрефләре язылган иде.* С. Тажетдинов. *Вил ул — Владимир Ильич Ленинның инициалларыннан ясалган исем.* Э. Касыймов.

2. *махс.* Китапның, бүлекнең яки кызыл юлның башында зурайтылган һәм гадәттә бизәкләнгән хәрефләр.

ИНИЦИАТИ'ВА *и.* 1. Башлап йөрү, берәр эшне башлап җибәрергә этәреш бирү.— *Андый эшләр минем инициатива белән эшләнми.* А. Расих. [*Тукайның*] *бу көчле поэмасын либретто итеп эшләү идеясе — бик дөрес һәм яхшы идея. Ж. Фәйзинең бу инициативасын котлап каршы алырга кирәк.* М. Җәлил. // Берәр эштә җитәкче роль. *Сугышта инициативаны кулга алу.* □ [*Җәмгыяте хәйрияне*] *башлап җибәрү җәдитчеләр кулында булса да, инициатива кадимчеләргә күчкәнлеге күренеп тора.* М. Гали.

2. Мөстәкыйль эш йөртүгә сәләт, булдыклылык, эшлеклелек.— *Консилиумнарны еш җыю белән без врачларны үзалларына фикер йөртүдән, мөстәкыйль карар кабул итүдән, инициатива күрсәтүдән биздерәбез.* Г. Әпсәләмов.

ИНИЦИАТИ'ВАЛЫ *с.* Мөстәкыйль эш йөртүгә сәләтле, булдыклы; эшлекле. *Такташның яңа кешесе ул — --- ирекле, дәртле, кайнар йөрәкле, инициативалы совет кешесе.* Б. Гыйззәт.— [*Халисә*] *нинди зур эш алып бара. Тәки үзен күрсәтте бит. Инициативалы кыз. Үсә.* С. Рафиков.

ИНИЦИА'ТОР *и.* Яңа эшне башлап җибәруче, иң элек кузгатучы кеше. *Дөнья фашизмына каршы көрәшнең инициаторы Анри Барбюска 60 яшь тулды.* М. Җәлил. [*Җиһангир*] *шундый мактаулы эшнең инициаторы булып алды.* Г. Гобәй.

ИНИЦИА'ТОРЛЫК *и.* Инициатор булу.

ИНК *и.* Хәзерге Перу дәүләте территориясендә яшәгән югары культуралы борынгы халык вәкиле. *Франсиско үзенең туганына инклар империясеннән көнчы-*

гышта ята торган җирләрне басып алырга бөера. Азат хатын.

ИНКАССА'ТОР *и.* Акча һ. б. төрле байлыкларны, күбесенчә, төрле урыннарга йөреп кабул итүче яки өләшүче кассир.— *Язу-сызу белән маташ, акча сана. - - - Хәзер инкассатор килә.* Г. Гобәй. *Ул, инкассатор килгәнне көтеп, тагын күңелсез генә иске гәзитләрне укып утыра.* М. Мәһдиев.

Инкассатор пункты — түләнергә тиешле документлар буенча акча кабул итү эше белән шөгыльләнә торган банк бүлеге.

ИНКВИЗИ'ТОР *и.* 1. *тар.* Инквизиция (1 мәгъ.) судьясы. *Инквизиторлар тарафыннан тәмам эштән чыгарылып, аяк-кулларына кадәр сындырылып Неаполь төрмәсенә ташланган Кампанелла - - - турында да сөйләде ул.* М. Хәсәнов. *1540 елда - - - котырынган инквизиторлар* [*Вязалий дигән*] *галимне асып үтерергә хөкем итәләр.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Газаплаучы, җәфалаучы, залим, кансыз кеше. *Үтердең дә тыныч ландың бугай, Яшереп «эзне» Төрмән төбенә?! Бүрегең яна, бүрегең, инквизитор, Нахак каннар яна бүрегеңдә!* Х. Туфан. *Инквизитор Мисыр Фатих яралы шәкертләрнең яраларын тикшерә.* Қ. Тинчурин.

ИНКВИЗИ'ТОРЛЫҚ *и.* Чиктән тыш рәхимсезлек, кансызлык, залимлек.

ИНКВИЗИ'ЦИЯ *и.* 1. *тар.* Еретикларга каршы көрәшү өчен католиклар чиркәве тарафыннан XIII гасырда оештырылган һәм үзенең аяусызлыгы, рәхимсезлеге белән танылган суд-полиция оешмасы. *Урта гасырлар Парижын өйрәнү өчен, Клюни музеенда - - - гөнаһлы кешеләрнең җәза бүлмәләрен шул килеш калдырганнар. Анда авыр богаулар һәм башка җәза кораллары - - - инквизицияне күз алдына китереп басгыралар.* Г. Гали. *Фашистлар, урта гасырлардагы инквизиция гадәтләрен терелтеп, зур революционерларның әсәрләре белән бергә, романтика короле* [*Гейненың*] *шигырьләрен дә мәйданнарда өеп, ут төртеп яндырдылар.* М. Максуд.

2. *күч.* Газаплау, ерткычларча җәзалау.

ИНКРУСТА'ЦИЯ 1. *и.* Берәр әйбергә уеп урнаштырыла торган сөяк, металл, перламутр бизәкләр, рәсемнәр. *Бу кеше портретның үзенә карамый, ә аның бай инкрустация белән эшләнгән рамындагы алтын бизәкләрен өйрәнә иде.* Ш. Маннур. [*Мылтыкның*] *казна өлеше инкрустация - - - белән* [*бизәлгән*]. А. Тимергалин.

2. Шундый рәсемнәр, бизәкләр ясау эше.

ИНКРУСТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Берәр әйбернең тышын уеп, төрле асылташлар, сөяк, металл, перламутр рәсемнәр белән бизәкләү. *Нефертити бюстының - - - күзләре зәңгәр кварциттан, күз алмасы, кашлары кара таштан инкрустацияләп ясалган.* Каз. утл.

ИНКУБА'ТОР *и.* Ясалма җылылык һәм дымлылык ярдәмендә йомыркалардан күпләп чебеш чыгару аппараты.— *Бумы? — Бу — инкубатор. Көне-төне, бертуктаусыз, Җылыда гына тотып, Чеби чыгаралар монда, Күкәйләрне җылытып.* Ш. Галиев. *Инкубатордан яңадан алты йөз баш чебеш килде.* Қ. Тинчурин. // *с. мәгъ.* Ясалма җылылык һәм дымлылык ярдәмендә йомыркалардан күпләп чебеш чыгара торган. *Инкубатор станциясе.* // *с. мәгъ.* Шундый аппарат ярдәмендә чыгарылган. *Инкубатор чебеше әрсез булыр.* Н. Исәнбәт.

ИНКУБАЦИОН *с. мед.* Йоккан вакытыннан алып беренче билгеләре күренә башлаганчыга кадәр булган, яшерен барган. *Йогышлы авыруларның да инкубацион чоры (тыштан билгеле булмаган вакыты), мәгълүм булганча, шактый озакка сузыла.* С. Тажетдинов.

ИНКУБА'ЦИЯ *и.* 1. *а.-х.* Инкубаторда чебеш чыгару. *Инкубация чорында йомырка эчендә барган процессны ул үзенең биш бармагы кебек белә. Каз. утл.*

2. *мед.* Йогышлы авыруның йоккан вакытыннан алып беренче билгеләре күренә башлаганга кадәр булган чор. *Дизентериянең инкубациясе 2 көннән 7 көнгә кадәр сузылу.*

ИНКУНА'БУЛА *и. махс.* Көнбатыш Европада XV гасырга кадәр типография хәрефләре белән җыелып басылган иң беренче китапларның берсе.

ИНҚЫЙЛАБИ *с. иск. кит. к.* революцион. [*Без*] *«Интернационал» һәм башка инкыйлаби җырлар җырлыйбыз.* М. Максуд. *Без, Казандагы инкыйлаби әдипшагыйрьләр, - - - «Октябрь» исемендәге гомуми* [*коллектив*] *оештырырга карар бирдек.* Қ. Нәҗми.

ИНҚЫЙЛАП *и. иск. кит.* 1. *к.* революция. *Шунысын әз генә хәтерлим: «ихтилал», «инкыйлап» сүзләрен корректорга әйтеп «революция» сузе белән алмаштырттым бугай.* Г. Ибраһимов.— *Илебездә инкыйлап булды, бөтен* [*чаралар*] *халыкка* [*файдалы булырга*] *тиеш.* Т. Гыйззәт.

2. *күч.* Үзгәреш. [*Пьесаның*] *исемен дә «Галиябану»га алыштырдым. Иң элек көенең тарихы итеп бетерсәм дә, соңынтын, чын тарихына җинаять булыр дип, үзгәрт*[*тем*]. *Бу инкыйлап пьесага бер гайре табигыйлек биргән.* М. Фәйзи.

ИНҚЫЙЛАПЧЫ *и. иск. кит. к.* революционер. *Колчак килде Уралга Хезмәт халкын тунарга, Инкыйлапчы татар халкы Ничек түзсен шуңарга?* Н. Исәнбәт.— [*Таһирнең*] *үлемен патша дошманнары — инкыйлапчылар эше дип әйтергә кирәк.* Г. Минский.

ИНҚЯР: инкяр итү (кылу) *кит.*— берәр нәрсәне юкка чыгару, берәр нәрсәнең юклыгын раслау. *Тереклек — бер тарихи хакыйкать, аны берәү дә инкяр итә алмый.* Ф. Әмирхан. *Аның иҗатында көчле генә чагылган демократик мотивларны һич тә инкяр итәргә ярамый.* Г. Халит. **Инкярны инкяр итү** *филос.*— диалектикада: табигать, җәмгыять һәм фикерләүнең диалектик үсеше процессында тарихи күчешне һәм яңалык тууда бердәмлекне чагылдыра торган төп закон. *Инкярны инкяр итү законы күренешләргә хас капмакаршылыкларның ничек тууын, үсүен һәм хәрәкәтләнүен ачып сала.* М. Абдрахманов.

ИНҚЯРЛАУ *ф. к.* инкяр итү.

ИННЕК I *и.* Битне алсуландыру өчен кулланыла торган алсу, алсу-кызыл төстәге косметик буяу. [*Ул*] *иннек чыгарып, иренен буярга кереште.* Ә. Ибраһимова. *Йөзгә кершән сөртелде, иреннәргә, бит алмаларына чамасын белеп кенә иннек тә ягылды.* А. Расих.

ИННЕК II *и. диал.* 1. Қиртә. *Иннеген төшереп, ишек алдына үзсам, аның лапас почмагындагы баз чоланында маташуы күземә чалынды.* Ш. Маннур. // *с. мәгъ.* Буйга сузылган киртәләрдән эшләнгән. *Ул өйнең - - - кергәндә-чыкканда арасыннан ятып яки киртәсен алып керә торган иннек капкасыннан башка бернәрсәсе дә юк.* М. Гали.

2. Берсе өстенә берсе куелган киртәләрдән эшләнгән капка (аны кергәндә-чыкканда алып куялар). [*Матрослар*] *басмаларны тартып алдылар, - - - иннек ябылды, һәм канатлы тәгәрмәчләр, суга шап-шоп бәреп, - - - әйләнә башладылар.* Н. Фәттах.— *Төшемдә синең белән икәү йортта - - -* [*утыра идек*]. *Иннектән Хөзер галәйһиссәлам чыкты.* Қ. Тинчурин.

3. Хайваннарны туплау өчен киртәләр белән уратып алынган урын.— *Мин бозаулар иннегендә булырмын.* Т. Гыйззәт.

ИНСАН *и. иск. кит. к.* кеше. *Ник болай бу? Ярлылар да Бай кебек инсандыр ич?* Ш. Бабич. [*Фәйзелкәбир:*] *Без барыбыз да инсан.* [*Гөлшаян:*] *Аны үзебезчә генә әйтсәгезче, мәхдүм!* [*Фәйзелкәбир:*] *Без барыбыз да иң элек кеше димәкче булам.* М. Әмир.

ИНСАНИЯТ *и. иск. кит.* 1. Кешелек дөньясы, кешеләр. *Мең туғыз йөз унҗиденче Елның октябрь таңы — Инсаният тарихының Иң мөкатдәс бер таңы!* С. Сүнчәләй. *Инсаният дөньясы шат, Ул көлә... уйный ... бүген.* Ш. Фидаи.

2. Кешелек сыйфаты, кешелек намусы. *Ихтыяҗын гарыз итеп килсә теләнче капканда, Каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама.* Г. Тукай. *Һәрбер* [*грамоталы һәм грамотасыз*] *әфәнделәр --- берәр* [*гыйльми нәрсә*] *язуны үзләренең инсаният вазифалары дип белгән*[*нәр*]. Ф. Әмирхан.

3. *күч.* Кешелеклелек, кеше сөючәнлек, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек.— *Залим ире хатынының актык тамчы каның эчеп бетереп гүргә керткәнчегә кадәр бара. Я, әйт инде, --- шушы булдымы инсаният?* Г. Камал.

ИНСАНИЯТЛЕ *с. иск. кит.* Кешелекле, мәрхәмәтле, шәфкатьле. *Болай да бик мәрхәмәтле, бик үк инсаниятле вә йомшак күңелле булмаган төрекмән ханы үзенең дошманнарыны, үзенең әсирләрене --- газап кыла.* Ш. Мөхәммәдев.

ИНСАНИЯТЛЕК *и. иск. кит. к.* кешелеклелек. *Әсирләрне бу дәрәҗәдә җәбер кылып, орып-сугып, ачлы-туклы хезмәт иттерү — һич инсаниятлек түгелдер* Ш. Мөхәммәдев.

ИНСАНИЯТЧЕ *и.* Кешелеклелек идеясен алга сөрүче. [*Ул*] *үзен инсаниятче дип уйлый.* Ф. Әмирхан.

ИНСАНИЯТЧЕЛЕК *и.* Кешелеклелек идеясен алга сөрү. [*Сәлим*], *динчелектән милләтчелеккә, милләтчелектән инсаниятчелеккә чыгу кебек, бер идеядән икенче идеягә күчеп йөргән.* Г. Ибраһимов.

ИНСАНЛЫК *и. иск. кит.* 1. Кеше булу. *Һәр инсан инсанлык йөзеннән карал*[*сын*]. Шура. *Хайванлык* [*теләге*] *күп булса да, Инсанлык* [*таләбе*] *Аны баскан.* Н. Думави.

2. *к.* инсаният (3 мәгъ.). ***Улмәде, үлсәң дә, күңелемдә сәнең дәртең*** [*һаман*], ***Дуслыгың, инсанлыгың*** [*күңелемдә*] ***калдырдың*** [*һаман*]. Г. Тукай.

ИНСАФ *и.* Әдәп, тыйнаклык, тәүфыйклылык, тәрбиялелек.— *Ике тиен сәдака биргән идем, тагын килгән: һич оят та юк, инсаф та юк.* Ш. Мөхәммәдев. *Шәрәфи хәзер баягы шикелле дуламый, һәрбер сүзен инсаф белән юаш кына сөйли иде.* **К. Нәжми.**

Инсаф итү (кылу) *иск.*— инсафлану. *Җитәр, инсаф итең, --- [оятсызлар]!* Г. Тукай. [*Күңелемдә*] *ялгыз синең сурәтең бар, Шуның өчен мине кызган, кыйлгыл инсаф!* М. Гафури. **Инсафка килү (кайту)** — инсафлану. *Бер* [*кат*] *инсафка кайтып, яхшылап уйлап карыйк: ике йөз мең адәм төрмәдә ятсын!* Ш. Мөхәммәдев.— ***Аңа биргән үгетне бер эткә бирсәң, ул да бераз инсафка килер иде.*** Г. Камал.

ИНСАФЛАНУ *ф.* Тыйнаклану, әдәплелӛну, тәүфыйклану. *Туктаусыз борчый торган хыял да бераз инсафланды шикелле.* Г. Ибраһимов. *Хәкимҗан агай соңгы вакытларда бик инсафланып киткән, хәтта челем тартуын да ташлаган.* Э. Касыймов.

ИНСАФЛЫ *с.* Әдәпле, тыйнак, тәүфыйклы, тәрбияле. *Сасык кымыз эчмәгез, Егылышып җиргә төшмәгез, Акчаны юкка түкмәгез, Инсафлы булыгыз.* Ш. Мөхәммәдев.— *Бик инсафлы, бик әдәпле кыз бит ул.* К. Тинчурин.

ИНСАФЛЫК *и.* Инсафлы булу. *Судья янына, зур инсафлык күрсәтеп, --- бер карчык килеп керде.* Сов. әд.

ИНСАФСЫЗ *с.* Әдәпсез, тәүфыйксыз, тәрбиясез. [*Ул*] *абзаларының инсафсыз мөгамәлә вә тәрбиясезлекләренә ачулан*[*а*]. Ш. Камал.— *Инсафсыз кыз бала. Нәселнең муенын сындырган кыз.* М. Фәйзи.

ИНСАФСЫЗЛАНУ *ф.* Әдәпсезләнү, тәүфыйксызлану.

ИНСАФСЫЗЛЫК *и.* Әдәпсезлек, тәүфыйксызлык. *Көз көннәрендә никрутларның урам буенда төрле-төрле инсафсызлыклар кылып йөрмәкләре Вәлид хәзрәтнең башын әйләндермәктә иде.* З. Һади.— *Олуг дәрәҗәле хайваннардан үзып, безнең кебек зәгыйфь суркаларга сүз сөйләү инсафсызлык бул*[*а*]. Ш. Мөхәммәдев.

ИНСЕКТИСИД *и. хим.* Корткыч бөҗәкләрне бетерү өчен махсус химик матдә, агу.

ИНСПЕ'КТОР *и.* 1. Үз карамагындагы оешмаларның, учреждениеләрнең һәм кешеләрнең эшне дөрес, алып баруын, закон тәртипләрен дөрес үтәвен тикшереп, күзәтеп тора торган дәүләт хезмәтендәге кеше. *Финанс инспекторы. Районо инспекторы.* □ *Инспектор Хәмитов дәрескә кергәч, --- Минҗамал шул баладан сөйләтте.* М. Мәһдиев. [*Яныбызга*] *фабричный инспектор килде.* Ә. Фәйзи.

2. *тар.* Революциягә кадәр ирләр уку йортларында директорның тәрбия һәм уку-укыту буенча ярдәмчесе. *Имтиханга кердем. Инспектор мине күргәч кул гына селекте. Сине инде, ди, имтихан кылмыйча да беләбез, ди.* Ф. Әмирхан.

ИНСПЕ'КТОРЛЫК *и.* 1. Инспектор хезмәте, инспектор вазифасы.— *Егет болай матур-матурын, әмма ләкин инспекторлыкка яраксыз.* Ю. Әминов.

2. *с. мәгъ.* Инспекцияләүне максат иткән. *Кышкы инспекторлык тикшерүләре вакытында безнең рота ярыйсы гына күрсәткечләр биргәч, --- увольнениеләр дә ешрак әләгә башлады.* Ф. Хөсни.

ИНСПЕ'КЦИЯ *и.* 1. Кемнең дә булса эшләренең дөрес барышын күзәтү һәм тикшерү. *Хәрби-политик үзәк сугышчан хәзерлекне тикшерү өчен Агач һәм Таш бригадаларда махсус инспекция үткәрү турында карар кабул итте.* Г. Әпсәләмов. *Сентябрьдә Төркстан фронты командующие бригадага инспекция ясады.* Каз. утл.

2. Инспекторлык эшләрен алып бара торган оешма, учреждение.— *Янгын инспекциясенә инспектор итеп алыгыз.* Ю. Әминов.— *Балык саклау инспекциясенә әләксәң, арт сабагыңны укыта белерләр анда.* Э. Касыймов. // Инспекторлык эшләре өчен махсус оештырылган кешеләр төркеме. *Икенче көнне җиде кешедән төзелгән сыйфат инспекциясе килде.* М. Әмир

ИНСТА'НЦИЯ *и.* Бер-беренә буйсынган партия, профсоюз, суд, дәүләт идарә итү органнары системасының аерым баскычы. *Ә фатир мәсьәләсендә, беләсең килсә, иң югары инстанция — шул шәһәр советы инде.* Ә. Исхак. *Проект барлык инстанцияләр буенча расланып, төзүчеләр кулына бирелгәч, --- Кара елга мәсьәләсе куба.* Г. Әпсәләмов.

ИНСТИНКТ *и.* 1. *биол.* Тере организмның, эчке яки тышкы мохиттагы үзгәрешкә карап, кирәкле, яшәү өчен әһәмиятле эш-хәрәкәтне аңсыз рәвештә башкаруга тумыштан килгән сәләте. *Куллары да аның бер максат белән түгел, тик инстинкт белән генә үзләреннән-үзләре хәрәкәтләнеп, тыгыз гәүдәсен су өстендә тоталар.* М. Әмир. *Автомат тавышларын ул ишетмәде, фәкать үз-үзен саклау инстинкты гына аны артка чигенергә мәҗбүр итте.* Г. Әпсәләмов.

2. Аңсыз рәвештә, белештермичә берәр нәрсәгә омтылыш, хис. *Ниндидер бер инстинкт, ул аңламаган, аңа таныш булмаган, шул үк вакытта аңа буйсынмаучы, аның өстеннән хакимлек итүче көч аны тагын һәм тагын шул кызга карарга мәҗбүр итте.* Ш. Хөсәенов *Барысы да инстинкт буенча, ныклап урнашкан бер гадәт буенча эшләнде.* Н. Фәттах.

3. Эчке сизем, табигый сизү. *Акылы белән булудан бигрәк, инстинкт белән танып алды. --- Шул үзе. --- Нәҗия үзе иде.* Ф. Хөсни. *Шушы авырлыктан котылыр өчен, акылны читкә куеп, коры йөрәк көче, инстинкт белән генә юл эзләве тагы да авыррак.* К. Тинчурин.

ИНСТИНКТИВ *с.* 1. *биол.* Инстинктка бәйле. [*Бу*] — *инстинктив хәтер. Эчкәрәге хәтер!* А. Тимергалин.

2. Аңсыз, белештермичә, ихтыярсыз, үзе дә сизмәстән. [*Лида*], *үзенең хатын-кыз киемендә икәнен онытып, инстинктив рәвештә күкрәк кесәсен капшый.* С. Баттал. *Һәрбер провинциядән чыккан татар әдибе үзе белән күп вакытны, моны үзе дә сизмәстән,*

инстинктив рәвештә, татар әдәбиятына яңадан-яңа байлыклар алып килә. С. Җәләл.

ИНСТИТУТ *и.* 1. Кайбер югары уку йортларының һәм фәнни учреждениеләрнең исеме. *Педагогия институты. Тел, әдәбият һәм тарих институты. Казан микробиология фәнни-тикшеренү институты.* ▭ *Быел Казанга агрономнар чыгара торган институтка укырга китте*[*м*]. Г. Мөхәммәтшин. *Институтта укыганда ук гыйльми хезмәткә, тикшеренү-төпченүгә һәвәс булды* [*ул*]. А. Расих.

2. *тар.* Революциягә кадәр югары катлау кызлары өчен ябык типтагы урта уку йорты. *Смольный институты.*

3. *махс.* Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең берәр өлкәсендә билгеләнгән хокуклар нормасының җыелмасы яки җәмгыять төзелешенең билгеле формасы. *Милек институты. Никах институты.* ▭ *Буржуа чиркәү,* [*хосусый*] *хуҗалык институтлары аркылы халыкны бозык тәрбия кыла.* Ш. Әхмәдиев.

4. Җәмгыять органының билгеле формасы. *Армиядә хәрби комиссарлар институты.* ▭ *Нацистлар партиясе җитәкчеләренең гаскәрдә «тәрбияче национал-социалист офицерлар институты» булдыруы да тикмәгә генә түгел.* Г. Сафиуллин.

ИНСТИТУ́ТТАШ *и.* Бер институтта (1 мәгъ.) укучы яки укыган. [*Салих*] *институтташ дусы хакына бер дә иренмичә шундук телефон трубкасына ябышты.* Ф. Хөсни.

ИНСТРУКТАЖ *и.* 1. Җитәкче күрсәтмәләр, инструкцияләр. *Инструктаж алу.* ▭ *Врачка тулы инструктаж бирелде.* А. Тимергалин.

2. Инструкцияләр бирү. *Инструктаж тәмамланды. Взвод --- шәһәргә чыгып китте.* Г. Минский. *Командирларны җыярга, инструктаж үткәрергә һәм полкларга* [*кире*] *җибәрергә туры килде.* Г. Сафиуллин.

ИНСТРУКТИВ *с.* Җитәкче күрсәтмәләре булган; инструктажга хас, инструктаж кебек. *Инструктив әңгәмә. Инструктив күрсәтмә. Инструктив хат.* ▭ [*Партком*] *инструктив киңәшмәләр, семинарлар үткәрде.* М. Хәсәнов.

ИНСТРУ́КТОР *и.* 1. Совет, дәүләт, кооператив яки җәмәгать оешмасының үзенә буйсынган кешеләрнең һәм оешмаларның эшләрен тикшерүче һәм күрсәтмәләр бирүче хезмәткәре. *Райком инструкторы.* ▭ *Көн тәртибендә --- волость башкармасы янындагы мәгариф инструкторының доклады.* Ф. Бурнаш. [*Мөстәкыймов*] *шәһәр комитетының инструкторы булып эшләде.* Г. Ахунов.

2. Берәр белгечлеккә яки һөнәргә өйрәтүче кеше. *Физкультура инструкторы.* ▭ [*Ул*] *парашют белән сикерү инструкторы булып хезмәт итә.* М. Җәлил. *Инструкторлар аларны ашыгыч рәвештә өйрәтәләр.* И. Гази.

ИНСТРУ́КТОРЛЫК *и.* Инструктор вазифасы, эше. *Мин комсомолдан Инструкторлык йомышы өчен киләм.* М. Җәлил. [*Ә. Синяева*] *сәхнә сәнгате юлындагы кайбер инструкторлык эшләре белән --- Зуевский шәһәренә китте.* С. Айдаров.

ИНСТРУ́КЦИЯ *и.* Берәр эшне үтәү юлларын һәм тәртибен билгели торган кагыйдәләр, җитәкче күрсәтмәләр җыелмасы.— *Инструкциядә бит һәрбер грамотный граждани аңлардай тел белән: «Кеше башына бер поттан артык он йөртү --- ярамый!» — дигәннәр.* К. Нәҗми. *Сәрби карчык --- Закирның бу йортта эшләре нәрсәдән тору турысында беренче инструкцияләрне бирә иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ИНСТРУМЕНТ *и.* 1. Берәр эш башкару өчен корал. *Хирургия инструменты.* ▭ *Инструментлар шкафында --- пинцетлар* [*бар*]. Г. Минский.— *Тукта, игезләрне кырасың бит, ничә кабат әйттем мин сиңа: «Минем инструментларга кагылма»,— дип!* С. Баттал.

2. Музыкаль аваз чыгара торган корал. *Ул пианино улының киләчәге иде. --- Ана тормышының бөтен максатлары шул инструментка барып тоташа иде.* Ш. Хөсәенов. *Кыз, артык ялындырмастан, инструмент янына килде. Рояль капкачын ачып ноталарын барлады.* А. Расих.

ИНСТРУМЕНТАЛЬ *с. муз.* Музыка коралында уйнала торган. *Бу жанрлар арасында, сюита, соната, квартет һәм симфония кебек инструменталь әсәрләр булган шикелле, җыр, романс, кантата, опера кебек текстка бәйләнгән әсәрләр дә күп.* М. Җәлил. *Узган ел мин күп кенә романслар һәм җырлар, инструменталь пьесалар яздым.* Р. Яхин.

ИНСТРУМЕНТЧЫ *и.* Инструментлар (1 мәгъ.) ясаучы белгеч. [*Рифгать*] *инструментчы булып эшләргә кереште.* С. Рафиков. *Инструментчылар бригадасы бригадиры --- Первухинны баш инженер янына чакырдылар.* Ш. Рәкыйпов.

ИНСУЛИН *и. мед.* Ашказаны асты бизләреннән организмда углевод алмашуын тәртипкә салуда катнаша торган гормоны.

ИНСУЛЬТ *и. мед.* Баш миендә кан йөрешенең кинәттән бозылуы (ул шул ук вакытта аң югалтуга һәм параличка китерә).

ИНСЦЕНИРО́ВКА *и.* 1. *әд.* Театрда яки кинода күрсәтерлек итеп үзгәртелгән әдәби әсәр. *Ул елларда әле мин Галимҗан абый әсәре буенча инсценировка эшләрмен дип күз алдыма да китермидем.* Х. Сәлимҗанов. [*Г. Камал*] *инсценировкаларыннан бары тик «Күзсез мастерлар» дигән әсәр генә басылган.* М. Гали.

2. *күч.* Кешеләрне ялгыш юлга төшерү, алдау өчен берәр күренешкә, эшкә охшаган нәрсә оештыру. *Тупас инсценировка.* ▭ *— Шушы хыянәтче кабахәт, коралы өч кеше белән бергә төрмә больницасына барып, тегене чекага допроска илтәбез дип алып чыккан, һәм шуннан юк булганнар. --- Оешулы инсценировка ясалган.* Ш. Камал.

ИНТЕГРАЛ *и. мат.* Чиксез кечкенә саннар суммасы булып каралган бөтен зурлык.— *Нәрсә, интегралларга тотыныргамы?— Әйе, Георгий, укырга кирәк.* Каз. утл. [*Лобачевский*] *күп кенә интегралларның кыйммәтен таба.* Ж. Тәрҗеманов.

ИНТЕГРА́ЛЬ *с. мат.* Интегралга бәйләнешле, табигате белән интеграл булган. *Интеграль тигезләмә.* ▭ *Лобачевский студентларга --- дифференциаль һәм интеграль исәпләүләр буенча лекцияләр укый.* Ж. Тәрҗеманов.

ИНТЕГРА́ЦИЯ *и.* 1. *мат.* Алмаш зурлык интегралын табу.

2. *кит.* Берәр нәрсәнең өлешләрен бер бөтенгә җыю. // Гомумән берләшү. *Социалистик илләрнең экономик интеграциясе.*

ИНТЕГРА́ЦИЯЛӘҮ *ф.* Интеграция ясау. *Экономиканы интеграцияләү.*

ИНТЕГҮ *ф.* 1. Рухи һәм физик газаплар кичерү, газапланы. *Ачлыктан, чамасыз газаплардан интеккән --- бик ябык, хәлсез кешеләр --- ирекле чыктылар.* А. Шамов. *Беребез көтте кайгы-сагышларда Төннәр йокламыйча интегеп.* Ә. Ерикәй. // Нәрсәне дә булса эшли, үти алмыйча йөдәп бетү; аптырау. [*Алар бу эшнең*] *хикмәтенә төшенә алмый интегеп беттеләр.* Г. Ибраһимов. *Старостаның тавышын чанага бәйләп салынган әлеге теге кәҗә тавышыннан аера алмый интекте*[*к*]. Ф. Хөсни. // Мәшәкатьләнү, көч түгү, газапланы.

2. Зарыгу, тилмерү. [*Ул*] *килә кайчан тәрәзәгә зарыгып, интегеп.* М. Җәлил. *Ялгыз торучылар --- җәйне җиткерә алмыйча интегәләр.* М. Галәү.

3. Нәрсәгә дә булса мохтаҗ булу, зар булу.— *Һәрвакыт акчага интегеп тор*[*ам*]. Ш. Камал.

ИНТЕГҮЛЕ *с.* Рухи яки физик газаплану чагылдыра торган. *Интегүле караш.*

ИНТЕКТЕРГЕЧ *с.* Газаплый, җәфалый торган. [*Ул*] *суык йөрәкле икенче берәү белән интектергеч михнәткә тарыр дип шомлана иде.* К. Нәҗми.

ИНТЕЛЛЕКТ *и.* Кешенең фикерләү, акыл сәләте; акыл үсеше дәрәҗәсе. *Бармы Гомәрдә көчле интеллект, киң караш?* И. Нуруллин. *Гади хезмәт кешесенең интеллекты үткән чорлар белән чагыштырганда нык үсүе --- язучының шәхес буларак интеллектуаль югарылыгын, киң карашлы һәм культуралы булуын сорый.* Н. Юзиев.

ИНТЕЛЛЕКТУАЛИЗМ *и. филос.* Кешенең психик кичерешләрендә ихтыярның катнашы юк, бары тик акыл гына роль уйный дигән идеалистик караш.

ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ *с. кит.* Акыл ягыннан, рухи. *Интеллектуаль сәләт. Интеллектуаль тормыш.* □ *Халыкның экономик хәлен, интеллектуаль мөмкинлекләрен бик нык белергә кирәк.* Г. Кашшаф. *Минем, --- бик тә катлаулы интеллектуаль мәсьәләләрне кузгатып, институт тәэсирләрен үзәккә салып язган хикәяләр җыентыгым басылып чыккан иде.* Ф. Хөсни.

ИНТЕЛЛИГЕНТ *и.* Интеллигенция вәкиле. *Шәһәребезнең яшь интеллигентлары Уральскида --- әдәбият ахшамы ясарга ният иткәннәр.* Г. Тукай. [*Сөләйман*] *үзен чын советчыл интеллигент дип исәплән йөри иде.* К. Тинчурин. // *с. мәгъ.* Интеллигентларга хас. *Аксыл, бик интеллигент йөзле, --- рәсми реалист киемле --- бер егет --- килеп керә.* Г. Ибраһимов. *Митрофанов — зифа буйлы, сөйкемле йөзле, интеллигент кыяфәтле бер кеше.* С. Тажетдинов.

ИНТЕЛЛИГЕНТЛАНУ *ф.* Культуралы, тәрбияле булу; интеллигент кыяфәтле булу. *Аның шушы эше белән сүзләре бер Нугайбәкне генә түгел, коры манжетлар, ак якалар белән интеллигентланып йөргән башка берәүләрне дә шактый кызартты.* З. Бәшири.

ИНТЕЛЛИГЕНТЛЫК *и.* 1. Интеллигент булу.

2. Укымышлылык, культуралылык, тәрбиялелек. [*Тамара*] *чын, яхшы мәгънәдә, ягъни тышкы калыбы белән генә түгел, эчке җаны белән дә интеллигент кеше иде. Мин әйтер идем хәтта, бу интеллигентлык аңардан ничектер менә --- аңкып тора кебек иде.* Ә. Еники.

3. *кимс.* Интеллигентларга хас сыйфатлар (йомшаклык, икеләнүчәнлек). *Моңа ул үзенең арка сөяксез интеллигентлыгы уңайсызлый дип уйлый.* К. Тинчурин.

ИНТЕЛЛИГЕ'НТЧА *с.* Интеллигентларга хас. *Соңыннан, торакка кайтып койкасына яткач, бу интеллигентча йомшаклыгы, сентиментальлеге өчен* [*ул*] *үзен үзе тиргәп ятты.* Г. Ахунов.

ИНТЕЛЛИГЕ'НЦИЯ *и.* 1. Фән, техника һәм культураның төрле өлкәсе буенча белем алган һәм шул өлкәдә даими рәвештә акыл хезмәте белән көн күрүче кешеләрдән торган социаль катлау. *Галинең әүвәлге татар интеллигенциясенә --- үпкәләрен бик урынлы, бик хаклы табам.* Ф. Әмирхан. *Реакция --- вак буржуа интеллигенциясе арасында өметсезлек тудырды.* М. Җәлил.

2. Шул социаль катлау кешеләре; интеллигентлар.— *Монда югары мәктәп тәмам иткән кешеләр азмы әллә? Әнә врач, прокурор, әнә агроном. Һи... Э Рәйхан апа? --- Утызлап укытучы гына җыйды бит. Бер дигәннәрен. Хәзер безнең авылның үз интеллигенциясе бар.* Н. Исәнбәт. *Укытучылар, китапханә, медпункт эшчеләре — гомумән авыл интеллигенциясе — халык иҗатын --- җыешуда зур булышлык күрсәтә торган иде.* Э. Касыймов.

ИНТЕНДАНТ *и.* Хәрби хуҗалыкны алып баручы һәм армияне кирәк-ярак белән тәэмин итүче хәрби хезмәткәр. *Алтынга, җәүһәргә күмелгән интендантлар, сугыштан файда күрүче байлар идән буйлап бию тавышына әйләнәләр.* К. Нәҗми. // Хәрби хуҗалыкны алып бару һәм армияне кирәк-ярак белән тәэмин итү эше; интендантлык хезмәте.— *Интендант командиры Арыслан Алыпкулов! Азык-төлек обозларын урманга тарттыр.* Ш. Маннур. [*Сидоров*] *капитан иде, ләкин интендант хезмәте буенча, ягъни хәрби тәэминат кешесе.* Ә. Еники.

ИНТЕНДАНТЛЫК *и.* Армияне барлык кирәк-ярак белән тәэмин итә һәм хәрби хуҗалыкны алып бара торган хәрби оешма. *Немецларның алгы кырыйдан качкан солдат ташкыны һәм бөтен интендантлык эшелоны шушы юлдан ашыгыч рәвештә Минскига таба агылган.* Ш. Маннур.

Интендантлык хезмәте — кораллы көчләрне барлык төр кирәк-ярак белән тәэмин итә торган оешмалар һәм учреждениеләр системасы. *Полкның интендантлык хезмәтенә Ватаннарын онытмаган җыен күсе җаннар оялап алып, солдат казанын ай-һай сыегайттылар.* Р. Төхфәтуллин.

ИНТЕНСИВ *с. кит.* Көчле, киеренке. *Дивизиядә һәр көн дип әйтерлек бик интенсив рәвештә сугыш хәрәкәтләренә --- өйрәнү эшләре алып барылды.* Ф. Булатов. / *рәв. мәгъ. Бу хәл, беренчедән, Кәрим Тинчуринның гаҗәеп интенсив эшләвен дәлилли.* Х. Сәлимҗанов. // Күп җитештерүчән, файдалы. *Интенсив метод.*

ИНТЕНСИВЛАШТЫРУ *ф.* Интенсив итү, интенсивлыгын арттыру. *Авыл хуҗалыгын химияләштермичә һәм интенсивлаштырмыйча иген уңышын да, терлекчелекне дә үстереп булмый.* Каз. утл.

ИНТЕНСИВЛЫК *и.* Киеренкелек, киеренке эшчәнлек, куәтлелек, көчлелек. *Эшнең интенсивлыгы. Җитештерүнең интенсивлыгын күтәрү. Космик нурларның интенсивлыгы.*

ИНТЕРВАЛ *и.* 1. Ике әйбер арасындагы ераклык. [*Корабльләр*] *тиешле интервал — аралык ясап янәшәләштеләр, --- строй белән бара башладылар.* А. Таһиров.

2. Ике эш арасындагы вакыт, ара, тәнәфес. *Батарея тигез интервал белән тыныч һәм ышанычлы җавап кайтара иде.* А. Шамов. *Ә немец ата, төгәл бер интервал аша ата да ата.* Ә. Еники.

3. *махс.* Бер үк вакытта яки бер-бер артлы чыккан ике тавышның калынлык-нечкәлегендәге аерма. *Мелодик интерваллар.* □ *Интервалларның төрлечә чиратлашуы нәтиҗәсендә яңа көйләр барлыкка килгән.* Ә. Бакиров.

ИНТЕРВЕНТ *и.* Интервенциядә катнашучы кеше. *Эчке дошманнарга каршы да, чит ил интервентларына каршы да күкрәк киереп сугышырга туры килде.* Г. Әпсәләмов. *Партизан отрядлары Агыйдел буеннан интервентларны, ак банданы кысрыклап куып киләләр.* Г. Гобәй.

ИНТЕРВЕ'НЦИЯ *и.* Революцион яки милли азатлык хәрәкәтен бастыру, яңа җирләр басып алу максатын күздә тотып, бер яки берничә дәүләтнең, кораллы көч кулланып, икенче дәүләтнең эчке эшләренә катнашуы. *Чит ил капиталистлары Россиядә кабынган революция ялкынын сүндерү, Россияне үзара бүлгәләп алу һәм аның халкын кол итү теләге белән советларга каршы интервенция алып баралар.* М. Җәлил. *Черчилль оештырган ул интервенция халыкның күңеленә ун мең нәрчә революция солдатының кайнар каны белән язылган!* Г. Бәширов.

ИНТЕРВЕ'НЦИЯЧЕ *с.* Интервенция ясаучы. *Интервенцияче гаскәрләр.*

ИНТЕРВИ'ДЕНИЕ *и.* СССР һәм Европадагы социалистик илләрнең берләшкән телевидение оешмасы.

ИНТЕРВОКАЛЬ *с. лингв.* Ике сузык арасындагы. *Интервокаль тартыклар.*

ИНТЕРВЬЮ *и. кит.* Матбугат хәбәрчесенең берәр атаклы кеше белән гомуми кызыксыну тудыра торган берәр темага матбугатта игълан итү өчен махсус әңгәмәсе. *Интервью алу.* □ *Кәримгә үзәк газеталарның хәбәрчеләреннән интервьюлар бирергә туры килде.* Г. Ахунов. *Радиокомитеттан --- съезд алдыннан нилләр уйла-*

нулары турында радио тыңлаучыларга берничә сүз әйтүен үтенделәр. Гөлшаһидә интервьюлар бирергә күнеккән кешемени, аптырап калды. Г. Әпсәләмов. // Шул әңгәмәнең эчтәлеген чагылдырган газета мәкаләсе.— *Баягынак язган интервьюларымны укып чыгыйм үзегезгә...* С. Баттал.

ИНТЕРДЕНТАЛЬ: интерденталь тартык *лингв.*—тел аскы һәм өске тешләр арасына куелып ясала торган тартык аваз; теш арасы тартыгы (мәсәлән, диалектальз). *Башка урындагы с авазы --- интерденталь (сакау) ç авазына алмашынып әйтелә.* Г. Алпаров.

ИНТЕРЕС *и.* 1. Аерым кеше яки җәмгыять һ. б. файдасын, ихтыяҗын канәгатьләндерүне күздә тоту; мәнфәгать. *Сыйнфый интереслар.* □ [*Ул*] *халкыбыз интересларын үзләренең интересларыннан өстен куйган ялкынлы патриотларыбызның соклангыч киеренке хезмәт нәтиҗәләре турында уйлый.* М. Садри.— *Эш интересы һәрнәрсәдән алда торырга тиеш.* Ш. Камал.

2. Файда, табыш.— *Бары тик капиталистлар интересы өчен генә башланган бу канлы сугышның тизрәк бетүе кирәк.* М. Гали. // *тар. экон.* Бурычка бирелгән акча өчен процент. [*Хиссәт*] *ике ел микъдам бер кешегә мең ике йөз тәңкә акча биргән икән, шул кеше акчаны интереслары илән бергә китергән.* Г. Фаикъ.

3. *сөйл.* Берәр кешенең бөтен уй-фикерен, тормышын биләгән, аның тормыш эчтәлеге булган нәрсә. [*Гафифә*] *үзенең бик вак: күлмәк-күнчек, кершән-иннек интереслары белән --- көлке халәттә күрсәтелә.* Ф. Әмирхан.

ИНТЕРМЕ!ДИЯ *и. әд.* Драма яки опера спектакленең пәрдәләре арасындагы паузада уйнала торган көлкеле пьеса.

ИНТЕРМЕ'ЦЦО *и. муз.* Ирекле формадагы кечерәк инструменталь пьеса.

ИНТЕРНАТ *и.* Укучылар өчен тулай торак. *Мәктәп каршында, авылдан килеп укучылар өчен, интернат та ачылырга тиеш иде.* Ф. Хөсни. // Интернат-мәктәп. *Балаларны интернатка, атналык мәктәпкә урнаштырырга кирәк.* А. Расих.— *Апагызның балаларын --- интернатка бирергә йөриләр [алар].* Г. Әпсәләмов. // Балалар ел тәүлеге буена тора һәм шунда тәрбияләнә торган урын, учреждение.— *Их, бу сабый интернатта булса, нинди тәрбияле булыр иде.* Г. Ахунов. [*Әбҗәлилов*] *эвакуацияләнеп килгән Мәскәү артистлары балаларын интернатларга урнаштыруда зур эш күрсәтә.* Х. Кумысников.

ИНТЕРНАТ-МӘКТӘП *и.* Укучылар торып укый торган мәктәп. *Интернат-мәктәп янында промыселлар җибәргән уннарча автобуслар делегатларны көтеп тора иде инде.* Ж. Тәрҗеманов.

ИНТЕРНАЦИОНАЛ *и.* 1. Халыкара берләшмә. *Коммунистик Интернационал.* □ *Маркс-Энгельсның турыдан-туры җитәкчелеге астында эшләгән беренче Интернационал --- безгә гыйбрәт булырга тиеш.* Г. Ибраһимов. [*Тарасов*], *отрядта дүрт татар, бер украинец, тагын кемнәрнеңдер барлыгын белеп, ягымлы гына елмайды: «Безнең отряд чынлап та пролетарский интернационал икән».* Қ. Нәҗми.

2. Халыкара пролетариатның һәм Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең гимны. *«Коммунист» редакциясе, --- Эжен Потье тарафыннан язылып, --- бөтен дөнья пролетариатының көрәш гимнына әйләнгән «Интернационал»ның дөрес, бик дөрес тәрҗемәсен бирүгә конкурс игълан итте.* М. Җәлил. *Фронт бу алмашуны «Интернационал» җырлап каршы алды.* М. Гафури.

ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМ *и.* Капиталистик стройны бәреп төшерү һәм коммунизм төзү, барлык халыкларның иреклелеге һәм тигез хокуклылыгы, дуслыгы һәм хезмәттәшлеге өчен көрәштә, шулай ук милләтчелеккә һәм шовинизмга каршы көрәштә халыкара пролетариатның бердәмлеге һәм теләктәшлеге. *Халыкларның арала-шуы һәм аларны пролетар интернационализм рухында тәрбияләү сокланғыч нәтиҗәләр бирә.* Г. Бәширов. [*Г. Камалның*] *бу чордагы иҗат тематикасы татар халкы эчендә генә чикләнеп калмады, ул интернационализм нигезендә халыкара темага язуга күчте.* М. Гали.

ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТ *и. к.* интернационалчы. *Идел ярларында фашист танкларына каршы күтәрелгән совет солдаты ул бит Қытай халкының азатлыгы өчен дә сугышты. Ул бөек интернационалист иде.* Г. Әпсәләмов. *Тельман, менә интернационалист булдым дип, үз милләтен дошман күрүче буш бугазларга нинди шәп отпор бирә.* Н. Исәнбәт.

ИНТЕРНАЦИОНАЛИ'СТИК *с.* Интернационализм белән сугарылган. *Интернационалистик программа.* □ *Шагыйрь халыкларның интернационалистик рухтагы уртак теләкләрен алга сөрә.* Х. Хисмәтуллин.

ИНТЕРНАЦИОНАЛЧЫ *и.* Интернационализм тарафдары. *Горькийны без халыклар дуслыгының авазы салучысы, төрле халыкларның үзара мөнәсәбәтендәге бу изге юнәлешне революциягә кадәр үк фидакарьләрчә тырышлык белән алга сөрүче интернационалчы буларак та ихтирам итәбез.* Г. Бәширов.

ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ *с.* 1. Халыкара. *Интернациональ гимн. Интернациональ элемтә. Интернациональ бердәмлек.* □ *Интернациональ үзәкнең членнары: немец Вальтер, чех Квет, австрияле Густав, француз Марсель.* Г. Әпсәләмов. *Бу кораллы кешеләрнең интернациональ коммунистлар отряды икәнлеген --- белгәч, аның күңеле бераз тыныч лангандай булды.* Қ. Тинчурин. // Барлык милләтләр өчен гомуми. *Көндәлек тормыш музыкаларының кайберәүләре, милли чикләрдән чыгып, бар милләтләр өчен гомуми — интернациональ булып киттеләр.* Ж. Фәйзи. *Һәр милли культураның тулысынча чәчәк атуыннан башка дөньядагы интернациональ культура да үсә алмый.* Р. Мостафин.

2. Интернационализм принципларына нигезләнгән, шуңа рухы белән туры килгән. *Интернациональ тәрбия.* □ *Без үзебезнең интернациональ [эчтәлекле], пролетариатның сыйнфый теләкләре белән сугарылган --- пролетариат әдәби стиле тудыруда зур адымнар атладык.* Һ. Такташ.

ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛЕК *и.* 1. Барлык милләтләр өчен гомуми булу. *Чын милли сәнгать аша интернациональлеккә барырга мөмкин.* Ж. Фәйзи.

2. Интернационализм фикерләре белән сугарылганлык, аңа нигезләнгәнлек.

ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛӘШҮ *ф.* Асылы белән интернациональ, халыкара булу.

ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЧЕ *и. к.* интернационалист.

ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЧЕЛЕК *и. к.* интернационализм.

ИНТЕРПОЛЯ'ЦИЯ *и. мат.* Янәшә торучы ике сан буенча шулар арасындагы санны табу.

ИНТЕРПРЕТА'ТОР *и. кит.* Интерпретация ясаучы. *Дирижер бик күп башкарылган әсәргә үзенчә яңа мәгънә бирә ала, аның интерпретаторына әйләнә.* Ж. Фәйзи.

ИНТЕРПРЕТА'ЦИЯ *и. кит.* Берәр нәрсәне аңлату, аның эчтәлеген, асылын ачу. // Музыка әсәрен яки образын башкаручы тарафыннан иҗади рәвештә ачу.

ИНТЕРФЕРЕ'НЦИЯ *и. физ.* Тавыш, яктылык яки электр дулкыннары кушылганда я берсе өстенә берсе туры килгәндә, аларның үзара көчәюе яки кимүе. *Интерференция күренеше.*

ИНТЕРЬЕР *и.* 1. *махс.* Бинаның архитектура һәм сәнгать чаралары белән бизәлгән эчке өлеше. *Метро станциясе интерьеры. Театр интерьеры.* □ *«Шәфәкъ» ресторанының Шәехзадин проекты буенча эшләнгән интерьеры яңа стильгә пародия булып чыкты: аның кара түшәмен аркылы-торкылы итеп беркеткән тимер аратәлар башка төшәр кебек, анда-санда тоныкъ кына янган лампочкалар күңелгә шом сала.* М. Маликова.

2. *сәнг.* Бинаның эчке күренешен сурәтләгән рәсем, картина.

ИНТИЗАМ *и. иск. кит.* Тәртип. *Бозылсын интизам. --- Әй, кояш! Син төнгә кал да, әйдә көндез, ай, калык!!* Ш. Бабич.— *Безнең тәртип-низам, интизамнарыбызга риза булмаганнарны мәдрәсәбездә калдыра алмабыз.* К. Тинчурин.

ИНТИЗАР *и. иск. кит.* Зарыгу, зарыгып көтү. *Минем өчен сиңнән шәфкать булырмы дип, бөтен гаскәр тын да алмый интизарда...* Г. Тукай. // *хәб. функ. к.* интизар булу. *Иркәләр илнең матур наз кызлары үз йолдызын, Бер үбәргә интизар ил егетенең ал-гөл йөзен.* М. Фәйзи.

Интизар булу — зарыгу, зарыгып көтү. *Сезнең нурлы йөзләрегезне күрергә зар вә интизар булып йөзләрем саргайды.* Г. Камал. *Күптән күрергә интизар булып йөргән шагыйрем Мәҗит Гафурины яхшылап кабарга тырыштым.* С. Кудаш. **Интизар итү** — зарыгу, зарыгып көтү. *Тиз килерме, ди-ди интизар иттем.* Г. Кандалый.

ИНТИМ *с. кит.* 1. Үтә шәхси, яшерен. *Интим темага сөйләшү.* □ *Бу хатның матбугат өчен язылмаган булуын истән чыгармаска кирәк; ул — интим хат.* Г. Кашшаф. *Безнең интим — шәхси тормышыбыз да группа белән нык бәйле иде.* М. Хөсәен.

2. Мәхәббәт, хис белән бәйле. *Кешенең сөйгәне, интим тормышта аралашканы бер генә булырга тиеш!* А. Расих. *Узеннән шундый зур корбан таләп иткән егет белән гөнаһсыз үбешеп йөрүләрен исәпләмәсәң, аның әле бер ир белән дә интим мөнәсәбәттә булганы юк.* Ш. Хөсәенов.

ИНТОНАЦИОН *с.* Интонациягә хас, интонациягә бәйләнешле. *Интонацион чара.* □ *Шагыйрь, аңлы рәвештә, беренче игътибарын шигырьнең мәгънәсенә, интонацион яңгырашына юнәлдерә.* М. Гайнуллин. *Гарәп-фарсы метрикасына корылган көйләп укыла торган шигырьләр урынына интонацион сөйләүгә нигезләнгән шигырьләр --- барлыкка килә.* Ә. Исхак.

ИНТОНА'ЦИЯ *и.* 1. *кит.* Сөйләүченең объектка яки тыңлаучыга мөнәсәбәтенә, аның хисләренә, рухи халәтенә карап үзгәрә торган сөйләү гадәте, тоны. *Без ул әйтәчәк фикерләрне, аның сүзләреннән генә түгел, аның интонациясеннән --- аңлап алдык.* А. Шамов. *Беренче карашта бераз салкынрак тоелган, ләкин асылда үз итүчән бер интонация белән дәшеп, Шмит кулын сузды.* А. Расих.

2. *лингв.* Сөйләмнең тонны күтәрүгә һәм төшерүгә **бәйләнгән ритмик-мелодик төзелеше.** *Тавышы да аның күп сөйләүгә кулай тавыш, төрле интонацияләргә бай һәм тыңлаучыларны ялыктырмый.* Қ. Нәҗми. *Кешеләрнең сөйләмендә музыкага якын авазлар төзелешен, тавышының төрле югарылыкларын — интонацияләрне ишетергә була.* Ж. Фәйзи.

3. *муз.* Җырлаганда яки музыка коралында уйнаганда тавышның, тонның күтәрелү-төшү ягыннан дөреслеге, сафлыгы, төгәллеге. *[Сәйдәшев] — халык музыкасының интонациясен тирән үзләштергән искиткеч талантлы --- композитор.* М. Җәлил. *Дөрес интонация белән җырлаганда, тавыш нык һәм көчле ишетелә.* Ә. Бакиров.

ИНТРИ'ГА *и.* 1. Берәр максатка ирешү өчен астыртын алып барылган мәкерле эш. *Интрига кору.* □ — *Бронепоездны мин чыгарышкан! Бу нинди интрига бу? Кем тарата, кем сөйли моны?* Н. Исәнбәт.— *Син мине эшемнән алып, дустың Шәймәрдәневне куярга телисең. --- Мин сезнең бу интригагызга юл куймам.* Р. Ишморат.

2. *әд.* Әдәби әсәрдә эш-хәрәкәтнең киренкелеге һәм бик буталчыклыгы белән аерылып торган сюжет сызыгы. *Сюжет хәрәкәтсез, интригасыз, шуның нәтиҗәсендә автор үзе куйган матур идеяләрне ача алмый.* М. Җәлил. *[Әсәр] миңа бик эчтәлекле, интригасы бик бай, кызыклы, яхшы язылган кебек күренде.* Г. Мөхәммәдова.

ИНТРИГАН *с.* Интрига (1 мәгъ.) белән шөгыльләнүче, мәкерле, астыртын (кеше турында).— *[Чамаев] тынгысыз, гаять интриган --- кеше! Бик сак булырга кирәк.* Ә. Фәйзи. *Ул гаять мәгънәсез, логикасыз алама политикалы, тупас бәхәсче, вак интриган кеше иде.* И. Рәми. // *и. мәгъ.* Шундый кеше.

ИНТРИ'ГАЧЫ *и. к.* интриган.

ИНТУИТИВ *с.* Интуициягә (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Тәҗрибәле остазлар интуитив рәвештә тойган, Хәбирнең үзенә дә чынлап билгеле булмаган бу талант кына --- аз түгелме?* Ш. Хөсәенов. *Иҗат процессында интуитив башланғыч өстенлек итми.* Қ. Гыйззәтов. // *рәв. мәгъ.* Интуициягә нигезләнеп. *[Җәлил кебек] катлаулы шагыйрьләр үзләренең алгы язмышларын мәгълүм бер дәрәҗәдә интуитив сиземи алып, киләчәк адымнарына билгеле бер юнәлеш бирә белсәләр — бу гаҗәп түгел.* Ш. Маннур.

ИНТУИ'ЦИЯ *и.* 1. Элекке тәҗрибәгә таянып, дөрес фикер тудыра торган сиземләү. *Монда сөйләнгәннәр — музыканың белгече булып сөйләү түгел, ә бәлки аны гади бер тыңлаучы, яратучы, аның язмышы турында уйланучы буларак, күбесе, ихтимал, интуиция буенча әйтелгән фикерләр булыр.* Ф. Хөсни. *Шамильский эчке интуициягә никадәр бай булса да, башлыча, акыл белән уйлап иҗат итүче артист иде. Ул образ өчен кирәкне дөрес сизү белән генә чикләнмичә, акылы белән эзләп табарга тырыша [иде].* Ә. Еники.

2. *филос.* Идеалистик философия өйрәтүенчә: «хакыйкатьне» фәнни анализ, фикри нәтиҗә ярдәменнән башка «турыдан-туры» төшенү.

ИНТУИ'ЦИЯЛЕ *с.* Берәр нәрсәне дөрес сиземләүче. *Без Шамильскийны тирән интуицияле артист дидек.* Ә. Еники.

ИНФАНТИЛИЗМ *и. мед.* Организм физик һәм психик яктан җитлекмәгән булу; балалык яшендәге физик яки психик сыйфатлар олыгайгач та саклану. *Җиңел формадагы инфантилизм дөрес дәвалаганда бетәргә һәм барлык функцияләр нормальләшергә мөмкин.* Азат хатын.

ИНФАРКТ *и. мед.* Қеше органнарында кан тамырларының тыгылу яки кысылуы нәтиҗәсендә тамыр очларына кан килмәү сәбәпле үлгән учак. *Инфаркт мине көтмәгәндә, уйламаганда, кайнар эш өстендә аяктан бәреп екты.* Г. Әпсәләмов. *Иван Ильич быел кышын --- лекция укыган җирендә егылып үлде. Икенче тапкыр инфаркт булган.* А. Расих.

ИНФЕКЦИОН *с. мед. к.* йогышлы. *Инфекцион авыру.* // Инфекция керү нәтиҗәсендә булган, инфекциягә бәйле.— *Фермада сөт планы тулмый, --- сыерларда инфекцион аборт.* Т. Гыйззәт.

ИНФЕ'КЦИЯ *и. мед.* Организмга авыру йоктыручы микроорганизмнар керү. // Йогышлы микроблар, йогыш.— *Чишәргә ярамый. [Ярага] инфекция керүе мөмкин.* Н. Дәүли. *Былтыр Куштирәктә скарлатина инфекциясе таралган булган икән. Скарлатина авылдагы барлык балаларга диярлек йоккан.* Н. Фәттах. // *с. мәгъ.* Йогышлы авыруларны дәвалый торган. *Хәзер инде терапия бүлеге, --- инфекция бүлеге аерым.* Г. Әпсәләмов.

ИНФИЛЬТРАТ *и. биол., мед.* Ялкынсыну продуктлары, шеш күзәнәкләре һ. б. саркып, организм тукымасының билгеле бер өлеше тыгызлану һәм киңәю. *Авыруның сәламәтләнә башлавына карамастан, 1928 елның ноябренда тамакта туберкулез инфильтраты башлана.* Г. Кутуй.

ИНФИЛЬТРА'ЦИЯ *и. биол., мед.* Организм тукымаларына ялкынсыну продуктлары, шеш күзәнәкләре сарку.

ИНФИНИТИВ *и. лингв.* Зат, сан һәм заман белән төрләнми торган фигыль формасы. *Татар телендә ул (инфинитив) -ырга // -ергә, -рга // -ргә кушымчалары ярдәмендә ясала.* Д. Тумашева. *К. Насыйрилар чорында инфинитив («-ырга» лы исем фигыль) формасы бик аз кулланыла.* Л. Җәләй.

ИНФЛЮЭ'НЦА *и. мед. иск. к.* грипп. *Куркынычлы әйбер юк, [ул] салкын тидергән, инфлюэнца.* М. Гали.

ИНФЛЯ'ЦИЯ *и. экон.* Товар әйләнеше ихтыяҗларыннан артык итеп чыгару нәтиҗәсендә кәгазь акчаларның бәясе төшү.

ИНФОРМА'ТОР *и.* Информация ясаучы, хәбәр итүче кеше. *Ул нибары күзәтүче — информатор гына.* Э. Касыймов.

ИНФОРМАЦИОН *с.* Информация биреп тора торган. *Информацион бюллетень. Информацион бюро.* □ *Сугыш елларындагы ашыгычлык, газетаның үзенчәлеге, урын тарлыгы безне күп очракта информацион характерда язарга мәҗбүр итә иде.* Г. Әпсәләмов.

ИНФОРМА'ЦИЯ *и.* Берәр өлкәдәге эшләрнең торышы, берәр кеше яки нәрсәнең эшчәнлеге турында хәбәр, белдерү; берәр нәрсә турында мәгълүматлар. *Информация бирү. Информация ясау.* □ *Шәйхи һәрбер эшелонда диярлек үзенә якташлар очратып, алардан сугыш эшләре, авыл хәлләре турында информация алып тора иде.* Ш. Усманов. *[Шиһаби] умарта караучылар, тимерчеләр, --- ат караучылар һәм башкаларның да көндәлек эш турындагы кыскача информацияләрен тыңла[ды].* М. Гали.

ИНФОРМБЮРО *и.* Информацион бюро. *[Шәмсетдин] Совет информбюросының белдерүен тыңлап китә.* Г. Бәширов. *[Агитатор] информбюро сводкасына анализ ясый.* Г. Гобәй.

ИНФРАКЫЗЫЛ: инфракызыл нурлар *физ.*— спектрның күзгә күренә торган кызыл очыннан башлап сузылган күзгә күренмәс нурлар.

ИНФУЗО'РИЯ *и. зоол.* Суда яши торган бер күзәнәкле иң гади тереклек иясе. *Хайваннар дөньясының иң беренче баскычында торучы организмнар — --- инфузияләр — клетчатканы физик таркатуны үз өзләренә алганнар.* А. Расих. *Яңа планетада --- сай күлләрдәге беренчел инфузияләр генә табылган.* А. Тимергалин.

ИНЦИДЕНТ *и.* Күңелсез, хәвефле вакыйга, бәрелеш. *Чик буе инцидентлары.* □ *— Хәзер генә вокзалдан хәбәр иттеләр, анда зур инцидент булган: --- пычак-кинжаллар белән коралланган кешеләр шайкасы безнең охранага ташланган.* Т. Гыйззәт.

ИНЧЕ *и.* 1. *иск. этн.* Хатынның үз ата-анасыннан бирелгән һәм гомер буе үз милкендә исәпләнгән аяклы малы.

2. *бор.* Нәсел башы итеп калдырылган аяклы мал. *[Сарсымбай] картка йөз сум алтын бирде: җылкыдан үзең барып сайларсың, дөядән, сыердан яхшы инче алырсың, диде.* Г. Ибраһимов. *Малчының инчесе булыр, патшаның илчесе булыр.* Мәкаль.

ИНЧЕК *с. бор. к.* инче (2 мәгъ.). *Ирләр менгән инчек бүз ир менәргә туп булсын.* Мәкаль.

ИНША *и. иск.* 1. Берәр вакыйганы, фикерне үз сүзләрең белән сөйләү, хикәяләү стиле. *Ул хатларда [кайбер бәйләнешсезлекләр] дә булыр, ләкин минем аларны төзәтергә хакым булмаганга, шул көйләренчә күчердем. Әмма имла, инша мәсьәләләрендә төзәтергә мәҗбүр буламын.* Ш. Әхмәдиев.

2. *пед.* Укылган текстны үз сүзләрең белән кабат язу; изложение. // Берәр мәсьәләне, фикерне үз сүзләрең белән язу; сочинение. *Өйдә язып килергә тиешле иншаның темасы — «Безнең гаилә».* Р. Төхфәтуллин.— *Кулаклар, аларның ияртеннәре тәмам котырды бит хәзер. --- Костёр янында сөйләр нәрсә менә кайда ул! Мәктәптә инша язганда да теманың менә дигәне.* Г. Гобәй.

Инша итү (кылу) — 1) берәр мәсьәлә турында язу, берәр вакыйганы үз сүзләрең белән хикәяләп язу. *Менә бу — шигырь. --- Ләкин кем моны инша иткән? Һич билгеле түгел.* Г. Тукай; 2) төзү, салу; төзәтү, салдыру. *[Мөхәммәтвәли] күп мәдрәсәләр, мәктәпләр --- инша итте.* Г. Ибраһимов.

ИНШАЛАУ *ф. к.* инша итү.

ИНШАЛЛА *кер. сүз.* 1. *дини.* Алла теләсә, алла кушса, алла боерса (берәр нәрсәнең үтәлүенә ышаныч белән әйтелә).— *Җәйгә бер кайтып китәргә тырышырмын, шул чагында, иншалла, күреп сөйләшербез.* С. Җәләл.— *Озаклатмабыз, иншалла, шушы арада туй итәрбез.* С. Рәмиев.

2. Бәлки, мөгаен, минем уемча.— *Азрак шаярдык та. Аңысын, иншалла, гафу итәрсең.* М. Фәйзи.— *Кечкенә мәхдүмәне, иншалла, гимназиягә биргәнсездер бит?* Ф. Әмирхан.

ИНЪЕ'КЦИЯ *и. мед.* Тире астына дару җибәрү.

ИНӘ *и.* 1. Бер башы очлы, икенче башына җеп тагу өчен тишек (күз) ясалып, тегү эшендә кулланыла торган бик кыска, шома, нәзек корыч чыбык. *Камыт инәсе.* □ *Зөбәйдәнең әние күлмәк тегә, чәнчеп-чәнчеп ала инәсен.* Һ. Такташ. *[Ул] инәгә бик озын җеп саплап ала, төймәнең сукыр күзеннән бер генә кат үткәзә, төенләп, җепне өзә.* Г. Ибраһимов. // Бәйләү өчен файдаланыла торган, ике башы да очлы, кыска, шома, нәзек корыч чыбык. *Ул Фәйрүзәнең бармаклары арасында бияләй инәләренең нервлы җемелдәшүен күзәтеп утырды.* Г. Ахунов.

2. Махсус кулланыла торган һәм гадәттә бер башы очлы булган күп төрдәге кыска, нәзек корыч чыбык. *Патефон инәсе белән саксыз кылану аркасында булса кирәк, пластинкалар бик тиз туза башлаганнар.* Г. Галиев. *Мөдир, санобработка язуын алып, чукмар башлы инә белән Маратның документлары янына теркәп ку[я].* Г. Гобәй.

3. Ылыс. *Нарат инәсе.* □ *Нарат төпләрендә өелеп ят[а] сары инәләр.* Ш. Маннур. // Кайбер үсемлекләрдә очлы вак кына чәнечке. *Гөлҗимеш инәсе.* □ *Гөл кипте, Сабагында --- бер бөртек инә калды.* Дәрдмәнд.— *Мин гөләп чәчәге, ләкин сынең өчен минем инәләрем юк.* Г. Әпсәләмов.

4. Кайбер хайваннарның тәннәрендә чәнечкеле, каты кыска кыл. *Керпе инәсе. Дикобраз инәсе.*

5. *күч.* Киная белән төртереп әйтелгән зәһәрле сүз. *Хатын: «Туйганчы яндырырлык керосин булырмы икән бер вакыт»,— дип, [кибеткә] инәсен кадап та куя.* Г. Толымбай. *Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар, Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.* Дәрдмәнд.

6. *күч.* Очлы нәзек кристалл. *Боз инәсе.* □ *Кышкы суык бураның рәхимсез инәләре битләрне чәнечте.* Ш. Мөдәррис.

7. *күч.* Очлы нәзек әйбер турында. *Адмиралтейство инәсе.*

Инә букчасы — инә кадап куяр өчен чүпрәктән тегелгән капчык. **Инә күзе** — инәнең җеп үткәрелә торган тишеге. **Инә саплау** — инә күзенә җеп кертү. *Ичмасам, күзләремнең дә рәте юк, утырсам, инә саплый алмыйм.* Ф. Хөсни. **Инә ташы** *иск.*— магнит.

◇ **Инә белән кое казу** — бик үрчемсез, озак эшләнә һәм искиткеч түземлелек сорый торган вак, авыр эш. *Гыйлем алу — инә белән кое казу.* Мәкаль. **Инә буе җир китү** — бик акрын кыймылдау, бик аз юл үтү. *Көн киттеләр, төн киттеләр, ай киттеләр, ел киттеләр, инә буе җир киттеләр.* А. Алиш. **Инә дә бүләк, дөя дә бүләк** — бүләкнең теләсә ниндиен дә зур итеп кабул итәргә, канәгать булырга кирәк; тегесе дә, монысы да бер үк бәядә. *Инә дә бүләк, дөя дә бүләк дигәндәй, бүлган кадәре дә Якуп Сәйфине сөендерергә җитәрлек иде.* Э. Касыймов.— *Бүләкнең төре күп аның. --- Инә дә*

бүләк, дөя дә бүләк. Күңелегездә булганны алып кайтырсыз М. Гали. **Инә йоткан** — бик ябык, нәзек озын (кеше). **Инә күзе хәтле (чаклы, шае, шикелле)** — бик кечкенә; аз гына да.— [*Мин*] *бу көнгә чаклы бер инә күзе хәтле ялгышлык эшләми килдем.* Г. Коләхметов. [*Аның*] *сул күзе күбрәк ачылган, уңы да, инә күзе шае гына булса да ачылып, --- безгә карап тора.* Г. Гобәй. **Инә күзеннән дөя күрү** — юк нәрсәдән зур нәрсә чыгару, арттыру, күпертү. *Аның карты — шулай ук инә күзеннән дөя күрергә рәхәт торган кеше. Әллә нәрсәләр дип күпертеп бетерер.* Ф. Хөсни. **Инә күзеннән тамызу** — бик аз гына бирү; саранлану.— *Цилиндр головкаларын да инә күзеннән генә тамызып торасыз.* Г. Әпсәләмов. **Инә күзеннән үткәрү (кичерү)** — бик нечкәләп, җентекләп тикшерү.— *Тентергә! Һәммә нәрсәне инә күзеннән үткәрергә.* Г. Гобәй. *Ул бөтен эш кәгазьләрен тагын бер кат барлап, инә күзеннән үткәреп кую өчен үз бүлмәсендә утырып калды.* Г. Мөхәммәтшин. **Инә очы кадәр (хәтле)** — бик кечкенә; бик аз гына да. *Газинур, үзенең күңелендә бүтәннәргә карата инә очы хәтле дә кер булмаганга, башкаларның да күңеле шундый ук сафтыр дип йөри иде.* Г. Әпсәләмов.— *Инә очы кадәр дә гаебем юк.* А. Шамов. **Инә төртерлек (чәнчерлек) урын булмау** — гадәттән тыш тыгызлык турында. *Беренче класс залында инә төртерлек тә урын юк, тыгызлык иде.* С. Җәләл. *Спектакльгә, «Чулпан» колхозының үз кешеләреннән тыш, күрше авыллардан да килүчеләр күп иде. Уен башланыр алдыннан залда инә чәнчерлек тә урын калмады.* Г. Бәширов. **Инә тыгарлык түгел** — гадәттән тыш тыгызлык турында.— *Хәзер тимер юлда да, паровозларда да халык, инә тыгарлык түгел.* Э. Касыймов. **Инә түгел** — кечкенә әйбер түгел, югалса да табылыр.— *Кичәге бодай табылмаган бит әле! — Анысына пошынма. Табылыр, инә түгел.* Г. Бәширов. **Инә эзләп табарлык итеп** — бик ныклап эзләү. *Мең шәмле электр лампалары --- чуерташтан түшәлгән урыннарны инә эзләп табарлык итеп яктырталар.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Инәдә утырту** — кемне дә булса үзен уңайсыз хис итәргә, борчылырга мәҗбүр итү. *Секретарь көлемсерәгәндә бу турыда түгел, Каюмны инәдә утырткан вакыйга турында уйлады һәм шуны малайларның исләренә төшерде.* Г. Гобәй. **Инәдә утыру** — үз-үзеңне уңайсыз хис итү, борчылу. **Инәдән дөя ясау** — юк кына гаепне яки юк-бар нәрсәне зур итеп күрсәтү, күпертү, зурга җибәрү.— *Анда, егеткәем, инәдән дөя ясаучы осталар утыра.* А. Гыйләҗев. [*Хәсәнша:*] *Ишек алдына түгәргә ярамый.* [*Гөлҗиһан:*] *Ярый инде, инәдән дөя ясама.* Т. Гыйззәт. **Инәдән куркып лом йоту** — кечкенә генә ялгыш җибәрүдән куркып, зуррак ялгыш эшләү.— *И бичаралар, инәдән куркып лом йоткан халыклар!* Г. Камал. **Инәдән (генә) чыккан** — өр-яңа, бөтенләй киелмәгән, әле генә тегелгән (кием). *Минем өстемдә инәдән чыккан яңа костюм.* Ш. Әхмәдиев. **Инәдән җепкә киендерү** — баштанаяк гел яңадан киендерү. *Солдатлар арасында тегүчеләр табыла һәм алар бер көн эчендә Җиһангирне инәдән җепкә киендерәләр.* Г. Әпсәләмов. **Инәне бүрәнә итү** — юк кына нәрсәне күпертү, зурга җибәрү.— *Син инәне бүрәнә итәсең, ул тикле куркыныч түгел, син юкка безне өркетәсең!* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Инәсе белән кинәсе тел очында булган** — бик үткен, ачы телле (кеше турында). *Редакциядә шаян табигатьле, тапкыр сүзле, инәсе белән кинәсе тел очында булган бер егет күренә башлады.* И. Рәми. **Инәсеннән жебенә кадәр (хәтле, чаклы)** — җентекләп, бернәрсә дә калдырмыйча, берәмтекләп. *Ул башта Миңсылудан вакыйганы инәсеннән жебенә кадәр сорашып алды.* К. Тинчурин.— *Вәҗданыгыз кушканча, инәсеннән жебенә хәтле тикшереп хәл итүегезне үтенәм.* К. Нәҗми. *Мәһи әби аңа бу хәлне инәсеннән жебенә чаклы сөйләп бирде.* Ф. Хөсни. **Инәсенә дә тимәү** — кешенең бер генә әйберен дә сораусыз алмау.— *Үз гомеремдә кешенең инәсенә дә тигәнем юк.* Т. Гыйззәт.

ИНӘКӘ *и. диал.* 1. Әби, дәү әни. *Балаларны караучы инәкә өйдә юк иде.* Н. Фәттах.

2. Үги ана. *Минем кулым түгел, Әйшә-Батманың кулы; Минем телем түгел, Идел кичкән инәкәләр теле.* Такмак.

ИНӘЛГЕЧ *с. диал.* Ялынулы, ялварулы. [*Тәкәрлекнең*] *тавышы шундый зарлы, шундый инәлгеч булып ишетелә, әйтерсең ул: «Зинһар, таптый күрмәгез!» --- дип кычкыра.* Ш. Маннур.

ИНӘЛЕ *с.* 1. Инәсе булган.

2. *күч.* Кеше күңеленә тия торган, чәнечкеле, ачы (телле).

ИНӘЛӘҢҮ *ф.* Инә рәвешенә керү, инә кебек тырпаю; инәләр белән каплану. *Мәче ябыккан, кабыргалары ерактан ук беленә, йоннары кыл кебек инәләнеп тора.* Н. Дәүли.

ИНӘЛҮ *ф. диал.* Түбәнчелек белән бик үтенү, ялыну, ялвару. *Көйрәп яткан чатырлар янында су сорап инәлгән тавышлар ишет*[*елә*]. А. Гыйләҗев. *Малик көчле, Малик бай, берни булса, аңа барып инәлергә туры килә.* И. Гази.

ИНӘЛҮЛЕ *с. диал. к.* инәлгеч.— [*Аның*] *сыңар күзе генә --- инәлүле тирән моңсулык белән карый.* Р. Төхфәтуллин.

ИНӘТИРЕЛЕЛӘР *и. күпл. зоол.* Тиреләре известь инәләр, чәнечкеләр белән капланган умырткасыз диңгез хайваннары (мәсәлән, диңгез йолдызлары).

ИНӘҮ *ф. диал.* Хайваннарга яки кош-кортларга тамга салу.

ИНҮ *ф. иск. к.* иңү. [*Ул*], *атыннан инеп, һушсыз яткан әсирне --- зуррак куакның күләнкәсенә яткырды.* Ш. Мөхәммәдев. *Белгән филгә менәр, белмәгән гүргә инәр.* Мәкаль. *Сабир хаҗи туры Хикмәтулла агай йортына инеп, берничә көн кунак булды.* Г. Камал.

ИНҖИЛ *и.* Гайса пәйгамбәрнең тормышы һәм тәгълиматы турында легендар хикәяләрдән торган һәм христиан дине өйрәтмәләренең нигезен тәшкил иткән дини китап, библиянең бер өлеше; евангелие. *Инҗилдә: --- «Алла кешене үзенә охшашлы итеп ясады»,— диелгән.* Г. Гобәй. *Коръән, инҗил үбеп* [*ант*] *биргән солдатлар* [*тезелгән*]. М. Гафури.

ИНҖИР *и.* 1. Каты, кытыршы эре яфраклары кышын коела торган, сусыл, татлы жимешле көньяк агачы. *Аның нәкъ баш турысында гына пешкән һәм өлгергән инҗир жимешләре асылынып торалар.* Ш. Әхмәдиев.

2. Шул агачның гадәттә киптереп хәзерләнә торган татлы жимеше; салма жимеше.— *Бераз инҗир --- дә бирим.* Т. Гыйззәт.

ИОН *и. физ.* Нейтраль кисәкчектән бер яки берничә электроны артык я ким булу белән аерылып торган, электр корылмалы атом яки атомнар төркеме. *Анод һәм катод арасындагы ионнар хәрәкәте турында Рушат татарча* [*сөйләде*]. М. Мәһдиев.

ИОНЛАШТЫРУ *ф. физ.* Ионнар барлыкка китерү.

ИОНЛАШУ *ф. физ.* Ионнар хасил булу. *Әгәр дә каналда башланғыч ионлашу аз булса, лидерның үсү процессы өзек-өзек рәвештә бара.* М. Зиннәтов.

ИОНЛЫ *с. физ.* Составында ион булган. *Ионлы берләшмә. Ионлы кушылма.*

ИОНОСФЕ'РА *и. физ.* Атмосфераның ионнар һәм ирекле электроннар бик күп булган югарыгы өлеше. *800 км биеклектә әле иносферaның чиге сизелми.* А. Фаткуллин.

ИП *и.* 1. Җай, уңай, көй. *Ипкә салу.* □ *Тел ясалмас, [әгәр] туган сүз ятмаса үз ибенә!* Дәрдмәнд. *Ип белән сөйләгәннең ирене авыртмый.* Мәкаль. *Юксыллыкны җиңә алмагач, күп талашып,* [*ул*] *ни кылырга ибен тапмый шашып кала.* Шура.

2. *рәв. мәгъ.* Җай белән, уңайлап. *«Бишек» менә һавага Талгын гына, ип кенә...* Ә. Маликов.

3. Як, тараф, юнәлеш. *Алдан әби йөгерә, Арттан Сәми җилдерә, Җәгъфәр, Әкмәй, Миңгали — Бар да больнис ибенә.* Н. Исәнбәт. *Идел каргасы Идел ибенә, Җаек каргасы Җаек җаена очар.* Мәкаль.

4. Берәр нәрсә эшләү уе, исәп, теләк, шул теләкне тормышка ашыру юлындагы эш. *Красноярдагы ошбу дүрт-биш татар-төрек баласы үзләренең алдагы көннәрен яхшырту ибенә кереш[әләр].* Шура.

◇ **Ипкә килү (керү)—1) җайлану, юлга салыну, рәтләнү,** көйләнү.— [*Комбайн*], *техник ярдәм чакырып төзәттермичә, ипкә килә торган түгел.* Ә. Камал.— *Эшләр бер дә ипкә килми.* М. Фәйзи; 2) (кешенең) характеры уңай якка үзгәрү, җайлану, рәтләнү.— *Башына тай типмәгән булса, өйләнгәч ипкә керер әле.* Ә. Камал; 3) сүз тыңлау, берәр нәрсәгә күну. *Коммуна төзү мәсьәләсенә килгәч, Хәйбулла кирелә́нде дә китте. Һич ипкә килми. Артель ди, вәссәлам!* Ш. Камал. [*Асрауларның*] *ипкә килә тороннарын табармын.* К. Әмири.

ИПИ *и. сөйл. к.* икмәк. *Сандугач моңа бер бөтен ипи китереп бирә.* Әкият. *Алар ипине акыл белән үстерелә́р, машина белән эшлә́рлә́р.* Г. Бәширов.— *Совет һәрвакыт ипине тир түгеп ашаучылар ягында ул.* Р. Төхфәтуллин.

Ипи чәчәге *бот.— к.* тукранбаш. *Кабинасында бер кочак кыр чәчәкләре булырга тиеш иде аның: ромашкалар, ипи чәчәкләре, күк күзләр, күзлутлар...* А. Гыйләҗев.

◇ **Ипи орып үтерсен** — *к.* икмәк йөзен күрмим.— *Ипи орып үтерсен, әгәр алмыйча китсәм.* Ф. Хөсни. **Ипи салган көнне ачтан үлгән** — бик саран, хәтта үзеннән дә кызгана торган кешегә карата әйтелә. **Ипи черетеп яту** — вакытны, акчаны әрәм-шәрәм итү.— *Юкка ипи черетеп ятасыз сез, егетләр.* Ф. Кәрим. **Ипи шүрлеге** *гади с.*— авыз. *Теге, Сәфәргалине күргә, йодрыгын туп-туры аның ипи шүрлегенә турылап килә башлаган иде.* Ф. Хөсни. **Ипи шүрлеген җимерү (талкан ясау)** *гади с.*— авызын, авыз тирәсен сугып җәрәхәтләү.— *Бик ныклап, уңлап-суллап тамызырга, яки ипи шүрлеген җимерергә исәп бар иде.* А. Шамов.— *Тотыгыз мине! Югыйсә, мин аның ипи шүрлеген талкан ясыйм!* К. Нәҗми. **Ипи шүрлегенә менеп төшү (тамызу)** *гади с.*— авызга сугу.— *Син үлчәп сөйләш, агай-эне... Юкса, мин ипи шүрлегеңә менеп төшәргә дә күп алмам (йодрыгын төйнәп килә).* К. Әмири.— *Ипи шүрлегенә тамызып җибәр!.. Башына сук! Башына...* К. Нәҗми.

ИПИ'ДЕР, ИПИЕ'МДЕР *кер. сүз. сөйл. к.* икмәктер.— *Егетләр, оттым, менә, ипидер, оттым!* А. Расих.— *Алай шыр җибәрсәгез, берүзем тотам. Биллә́һи тотам. Ипидер әгәр.* Ш. Рәкыйпов.

ИПИЛЕК *с.* 1. Ипи өчен хәзерләнгән. *Бер ипилек он.*

2. Ипи алыр өчен җитәрлек (гадәттә акча турында).— *Ул исән чагында ике-өч тиен ипилек килеп тора иде.* К. Тинчурин. *Әллә монысы да шул көннәрнең авырлыгына бирешмичә, бер-ике кадак ипилек кенә булса да вак-төяк эш эзләп йөрүче забастовкачыларның берсе микән?* Г. Минский.

ИПИЛЕК-ТОЗЛЫК *с. к.* икмәк-тозлык. [*Аның*] *татарчасы ипилек-тозлык кына калган.* Г. Бәширов.

◇ **Ипилек-тозлык белү** — телне бик начар белү. *Малайлардан сораштырасы килә дә, русча ипилек-тозлык та белмим.* Г. Әпсәләмов.

ИПИ-ТОЗ *җыйм. сөйл. к.* икмәк-тоз. *Җәлүк бабай кунакларны, ипи-тоз, якты йөз дигәндәй, җылы гына каршылады.* Э. Касыймов.

◇ **Ипи-тоз белән (каршылау)** — *к.* икмәк-тоз белән (каршылау).— *Марфуша, кунак бар. Ипи-тоз белән каршы ал.* К. Тинчурин.

ИПИ-ТОЗЛЫ *с.* 1. Ипие-тозы булган, хәлле. *Ипи-тозлы кеше.*

2. *күч.* Юмарт, сыйларга яратучан (кеше турында).

ИПИ-ТОЗЛЫК *с. сөйл. к.* икмәк-тозлык.

◇ **Ипи-тозлык белү** *сөйл.— к.* ипилек-тозлык белү. *Мин аларның телен, үземә күрә, ипи-тозлык белә идем инде.* Г. Мөхәммәтшин.

ИПЛЕ *с.* 1. Файдаланырга җайлы, уңайлы. *Ипле сәнәк, яхшы тырмаларны кулга тотып: --- «Иллә шәп икән соң»,— [диләр алар].* М. Гафури. *Ул кайтарып бирде яңадан --- Ташчыларның ипле чүкечен.* М. Сөндекле. // *рәв. мәгъ.* Җайлы итеп, уңайлы итеп. *Гәрәй кашыгын бик ипле тота.* М. Җәлил. [*Нарат*] *ипле генә авып төшә.* Г. Әпсәләмов.

2. Кулай, уңайлы, җайлы. *Шушыннан да ипле урын булмас Безнең ише --- егет[кә].* М. Җәлил.

3. Әйбәт, яхшы (хоҗыклы), җайлы, күндәм.— *Сирайның ярлылыгын әйтмәсәң, болай ипле егет күренә.* К. Нәҗми. *Белмәгәнмен күршемне, Ул шундый ипле икән; Бакчамны саклый алмадым, Үзем гаепле икән.* М. Җәлил. // *рәв. мәгъ.* Җайлап, яхшылап.— *Шакиржан бабай белән ипле генә сөйләш. Авыр сүз әйтеп, хәтерен калдыра күрмә.* Г. Насрый. [*Әлбинә*] *тәмам тынычланып калды һәм --- дәресне ипле генә дәвам иттерде.* Э. Касыймов.

4. *күч.* Уңган, һөнәрле. *Эш иплене ярата.* Мәкаль. *Ипле кеше иленнән китми.* Мәкаль.

5. *рәв. мәгъ. күч.* Җайлап, уңайлы урынын чамалап, ныклап итеп (сугу турында). [*Матрос*] *надзирательнең кабыргасына шундый ипле итеп утыртты, теге тынын да ала алмыйча, бөгәрләнеп, коридор идәненә ауды.* Г. Гобәй.

ИПЛЕЛЕК *и.* Ипле (1—4 мәгъ.) булу. *Хафиз, шәкертнең иплелегенә хәйран калып, барлык күңеле белән аңа ышанды.* К. Тинчурин. *Әдәп белән иплелекне базарда сатып алмассың.* Мәкаль.

ИПЛӘМӘ *и.* Эшләгәндә коралны, детальне уңайлырак тотар өчен җайланма. [*Аның*] *балта тотарга да ипләмәсе бар.* Г. Бәширов.

ИПЛӘНҮ *ф.* 1. Файдаланырга җайлы, көйле булу, уңайлану. *Урын ипләнү.*

2. Характер ягыннан төзәлү, әйбәтләнү.— *Балабыз да көпә-көндез илдән качып читләрдә себерелеп йөрми. Отыры ипләнеп, акыллыланып кына китте.* М. Фәйзи.

3. Берәр нәрсәгә күнегү, җайлашу, яраклашу. [*Нәҗия*], *кемгәдер ошарга тырышып, тормышка ипләнергә азаплан[мый].* Ф. Хөсни.

4. *Кайт. һәм төш. юн. к.* ипләү. *Кыр эшенә киясе киемнәр төзәтелде, ипләнде.* Г. Бәширов. [*Батырхан*] *киенә, ипләнә башлый.* Г. Ибраһимов.

ИПЛӘП *рәв.* 1. Кулланырга, эшләргә җиңел, җайлы булырлык итеп. *Учларына төкереп, чалгысын ипләп тотты да китте, китте ул чабып!* И. Гази. [*Мужик*], *кулына балтасын ипләп тотып, аз гына вакыт эчендә теге карт агачларның һәммәсен кисеп аударды.* Г. Тукай. // Тәнгә рәхәт булырлык итеп җайлап, уңайлап. *Ул астындагы ылысларын кызу костёр янына якынрак күчереп, ипләбрәк ятты.* Г. Гобәй.

2. Берәр эшне җайлап, рәтләп, тиешенчә итеп башкару турында. *Чәчен үзең тара, үзең ипләп үр, чулпыларын үзең ипләп так.* Г. Ибраһимов. *Мин тегәрмен ипләп, иренмичә, һәрбер җөвен җөйгә китереп.* Ә. Ерикәй. // Сак кына.— *Ипләбрәк,* [*урындыкларның*] *аякларын сындырасыз.* Т. Гыйззәт.— *Кыярны аны, синең кебек, тамыры белән йолкып чыгармыйлар, менә шулай ипләп кенә өзәләр.* М. Әмир. // Берәр нәрсәне иркенләп, ашыкмыйча эшләү турында.— *Иртәгә ипләбрәк сөйләшербез әле. Бүген әллә ничегрәк булды.* Г. Әпсәләмов.

3. Җайлап, сүз җаен туры китереп; илтифат белән. *«Яхшырагы юкмы тагын?» — дип, Ипләп кенә сорау бирәм мин.* З. Мансур.— ***Ипләп сөйләш, улым, ип-***

ләп!.. Син безне [юкка] ургәмәкче буласың. Ш. Камал. // Аңлаешлы итеп, рәтләп.— *Син ипләп сөйлә: кайда, ничек булды?* Г. Ибраһимов.

4. Игътибар белән, яхшылабрак, бөтен дикъкатьне туплап. [*Ул*] *ипләбрәк караса, әнисе уянган имеш.* Г. Бәширов.

5. *күч. сөйл.* Ныклап, *каты итеп. Ипләп сугу.* □ — *Алырга дип килсә, бик ипләп кенә ярырга үзен.* Ш. Камал.

ИПЛӘП-СИПЛӘП *рәв.* Акрын гына, җайлап кына, сиздермичә. *Бер заман апаң мине җайлап-майлап кына сөйләтергә тотына, ипләп-сипләп кенә сораштыра башлый.* М. Хөсәен.

ИПЛӘП-ЧАКЛАП *рәв. сир.* Җайлап, уйлап, тәртип белән. *Ипләп-чаклап, үлчәп-кисеп кенә сөйлим.* З. Бәшири.

ИПЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. Бер әйберне икенчесенә туры килерлек итеп билгеле бер үлчәүгә, калыпка яраклаштыру, җайлау. [*Габдулла*] *шакмакка ипләштереп кертелгән кубызын урынынан чыгарып, авызына китерде.* Ә. Фәйзи.

2. Куллану яки өйрәнү өчен билгеле бер төркем зәвыгына, аң дәрәҗәсенә яраклаштыру. *Җыентык, «Сайланма әсәрләр» дип аталып, үзенең төзелеш тәртибе һәм материалларның эшкәртелеше ягыннан киң катлау укучылар массасына ипләштерелгән* (т ө ш. ю н.). Л. Җәләй.

ИПЛӘШҮ *ф.* 1. Бер әйбер яки кеше икенче әйбер яки кешеләр янына тигез, җайлы итеп урнашу. *Барысы да, Хәйдарне уртага алып ипләшеп утыргач, тынып калдылар.* Г. Минский.

2. Берәр нәрсәгә, мохиткa җайлашу, яраклашу. *Буржуазиянең «милли хәрәкәте» самодержавие политикасына ипләшеп, эшчеләр һәм крестьяннар хәрәкәтен бууга хезмәт итте.* М. Җәлил. / *и. мәгъ.* [*Бу*] *шаяру да, ипләшү дә, коры тәкәбберлек тә түгел.* Ф. Хөсни.

ИПЛӘҮ *ф.* 1. Кулланырга, тотарга, киергә һ. б. эшләргә уңай булырлык хәлгә китерү, уңайлы ясау, рәтләү. *Урынны ипләү.* □ *Зыя толыбының якасын күтәреп ипли.* Г. Ибраһимов. [*Малай*] *үз сумкасын ипләде.* А. Алиш.

2. Урыныннан күчкән яки тәртипсезләнгән нәрсәне кире урынына яткыру, төзәтү. [*Кыз*] *сары чәчләрен --- тарак белән ипли-ипли безнең белән исәнләште.* М. Әмир. // Бозылган, ватылган нәрсәне төзәтү, көйләү, эшләрлек хәлгә китерү. *Арт тәгәрмәчнең чыгып китүен һәм аны ипләп байтак кына вакыт уздыруны исәпкә алмаганда, Тирәкле авылына нәкъ вакытында --- килеп җитте*[*к*]. Ф. Хөсни.

3. Берәр нәрсәгә, үлчәүгә, калыпка яраклаштыру.

4. *күч. сөйл.* Берәр эшне, нәрсәне юлга салу, рәтләү. *Кунаклар озак юл килә-килә бик ачыкканнар. --- Шуңа күрә дә алар чәй янына утыруга бигрәк тә тамак ягын ипләргә керештеләр.* С. Җәләл.

5. *күч. сөйл.* Берәр кешене үз ягына карату; җайлау. *Нишлисең бит сүзең үтмәгәч, Йөз баш сарык белән нәпман чәйләп ипләгәч!* М. Җәлил.

ИПОХО'НДРИК *с. мед.* Ипохондриягә хас. // *и. мәгъ. сөйл.* Ипсхондриягә бирелгән кеше.— *Чибгркәева — ипохондрик. --- Буллмаган авыруны бардыр дип уйлап, авыруга сабышкан кеше.* Г. Әпсәләмов.

ИПОХО'НДРИЯ *и. мед.* Юк-бардан шикләнү, борчылу авыруы; боегу, эч пошу.

ИППОДРОМ *и.* Ат чабышлары үткәрә торган урын. *Ипподромда* [*кунакларга*] *юртаклар чапканын да күрсәттек.* Б. Камалов.

ИПРИТ *и. хим.* Тәндә шеш, җәрәхәт барлыкка китерә торган агулы газ (сугыш максатлары өчен кулланыла).

ИПСЕЗ *с.* 1. Җайсыз, уңайсыз. [*Ул*] *баланы кулына алды һәм ипсез рәвештә бер-ике тапкыр «үчтеки» иттерде.* Ә. Камал. *Иркен, якты һәм бай залда үткәргән шатлыклы сәгатьләрдән соң, үзеңнең кысан, күңелсез һәм ипсез бүлмәңә кайткач, бу ияләшкән торагың ошамый башлый.* Р. Төхфәтуллин.

2. Эшнең рәтен белми торган, булдыксыз. *Соң, билгеле, үзең ипсез булсаң, Кулың тешләп өзәр аю да.* Н. Исәнбәт. *Ипсез кеше үзенә тиң бер иптәш тә табалмас.* Шура.

ИПСЕЗЛӘНҮ *ф.* Ипсез хәлгә килү; җайсызлану, көйсезләну.

ИПСЕЗЛӘҮ *ф.* Ипсез хәлгә китерү; җайсызлау, көйсезләү.

ИПТӘШ *и.* 1. Эштә, тормышта, дөньяга карашта һ. б. ш. уртак сыйфат булудан якынайган, дуслашкан кеше. *Элек «иптәш» сүзе күбрәк теге яки бу һөнәр ияләренә генә кагылган. Балта остасы, такта яручы, тимерче, сунарчы, итек басучы, тегүче үзенә лаек иптәш белән генә эшкә йөргән.* Ш. Мөдәррис. *Әгәр иптәшләре иптәш булмаса, Корбангали абзый быел тегүгә, ихтимал, бөтенләй икенче бер малай иартеп чыгарга мәҗбүр булган булыр иде.* Ф. Хөсни. / *с. мәгъ. Ул үзенең иптәш малайлары белән* [*уйный*]. Ш. Камал. *Патша кызы, --- үз янына бер-ике иптәш кызын утыртып, урамга чыга.* Әкият.

2. Революцион партия, эшчеләр коллективы члены. *Яшерен революцион оешмаларда --- «иптәш» сүзе берберсен күреп-танып белмәгән, әмма бөек революцион эш белән уртак язмыш кичергән батыр көрәшчеләр өчен ышанычлы пароль булып яңгыраган.* Ш. Мөдәррис.— *Үзебезнең коммунист иптәшләр алдында турысын әйтергә кирәк.* Г. Бәширов. // Шул ук мәгънәдә эндәш сүз булып йөри.— *Революциянең язмышын сез хәл итәсез, иптәшләр!* И. Гази.

3. Совет җәмгыяте члены, граждане. *Самараны аклар алганнар. Алар «иптәш» дип эндәшкән өчен дә үтергәнче суктыралар икән.* Қ. Нәҗми.— *Совет председателе нишләп әфәнде булсын! Иптәш диген!* И. Гази. // Шундый кешенең исем-фамилиясе, профессиясе, дәрәҗәсе алдыннан шул ук мәгънәдә килә.— *Сез миңамы, иптәш Гыйбаев?* Г. Ибраһимов.— *Иптәш полковник, сугышка җибәрегез мине.* Ә. Айдар.

4. *иск.* Ярдәмче, урынбасар. [*Фәхретдин*] *Җиһанша хәзрәткә иптәш мулла булды.* З. Һади. *«Кармак»ның иптәш нашире З. Дәминов дигән егет тә килде.* Ш. Бабич.

5. *юн. кил. форм.* **иптәшкә**. Бергә эшләү, бергә булу өчен башка кешегә иш, компаньон. *Кайчакны, иптәшкә дип, Гали дә барғалаган.* Э. Қасыймов. // Иш, пар. *Ул өстенә --- керләнеп беткән сары майка һәм аңа иптәшкә ике балагының да тез күзләре тишек иске чалбар кигән.* Г. Мөхәммәтшин.

6. *сөйл.* Семьяда ир яки хатын. *Еллар үтү белән минем иптәш Үзе шулай малай тудырыр.* Һ. Такташ.— *Минем элекке иптәшем Алпамша кайткан, мин әле яңа иптәш белән кушылмаган да, кушылмыйм да, минем Алпамшадан бер малаем да бар.* Әкият.

Иптәшләр суды — дәүләт судыннан аермалы буларак, аерым кешеләр арасындагы вак бәхәсләрне, вак низагларны тикшерә һәм җәмәгать шелтәсе бирә торган суд.— *Тәртипсез егет булып чыкты* [*бу шофёр*]. *Инде ике мәртәбә иптәшләр судында тикшергәннәр.* Г. Ахунов.— *Бүген Миргатаны тикшерәсез. Ну, анысына мин дә кул куям. Иптәшләр суды — әйбәт нәрсә.* Г. Мөхәммәтшин.

ИПТӘШЛЕК *и.* 1. Иптәш булу мөнәсәбәте. *Торабара бу иптәшлек кенә, гади дуслык кына булып калмады, ул кыз минем йөрәк түренә менеп утырды.* Ә. Айдар.— *Мин сине гади хатын итәргә генә хәзерләнмим. Миңа гомерлек иптәш кирәк. Мин иптәшлекка синнән дә якынрак кеше таба алмыйм.* М. Әмир.

2. *юн. кил. форм.* **иптәшлеккә.** *к.* иптәш (5 мәгъ.).— *Кызларга иптәшлеккә әби кушып җибәргән кебек, безгә әә иптәшкә бер бабай кушып җибәрсәләр* [*иде*]. М. Фәйзи.

Иптәшлеккә алу — өйләнү.— *Әгәр мин сине шушыннан коткарсам, син мине иптәшлеккә алырсыңмы? — ди кыз.* Әкият. **Иптәшлеккә килү** — кияүгә чыгу. *Кыз да бер дә оялып тормый: «Мин Җиһангәрәйгә иптәшлеккә килдем. Сез хәзер миңа да әти, әни буласыз»,— ди.* Г. Толымбай.

ИПТӘШЛЕКЛЕ *с.* 1. Үз иптәшләренә ярдәмчел, тугры; иптәшчән.

2. Кешеләр белән бик тиз аралашучан, тиз дуслашучан; компаниячел. *Ул бик иптәшлекле кеше булып чыкты. Политрукның әңгәмәсе башланганда, алар инде дуслашып та өлгергәннәр иде.* Г. Бәширов.

ИПТӘШЛӘНҮ *ф. сөйл.* Өйләнү. *Җиһангәрәй шул тәкәрлек Билал кызы белән көпә-көндез кайтып кермәсенме?! — Әти, әни! Менә инде мин иптәшләндем. Сез моңар минем иптәшем дип карагыз,— ди Җиһангәрәй.* Г. Толымбай.

ИПТӘШЛӘ!РЧӘ *рәв.* Иптәш итеп, иптәшлек хисе белән, үз итеп, якын итеп.— *Ул бит синең кайбер кимчелекләреңнән иптәшләрчә көлә.* И. Юзеев. // *с. мәгъ.* Иптәш кешеләргә хас. *Аны гадилеге, иптәшләрчә яхшы мөнәсәбәте һәм оста дәвалавы өчен яраталар иде.* А. Шамов.

ИПТӘ!ШЧӘ *рәв. иск. к.* иптәшләрчә. *Ул тачкачылар белән эре кыланса да, Шәрәфи карт белән иптәшчәрәк маташа.* Ш. Камал. *Ул керә-керүгә --- иптәшчә дәште.* Г. Ибраһимов.

ИПТӘШЧӘН *с.* Иптәшлек, дуслык хисе көчле булган.

ИПТӘШЧӘНЛЕК *и.* Иптәшчән булу. *Революцион эшкә ахырынача бирелгәнлек, --- иптәшчәнлек, алдан күрә белү --- менә шундый сыйфатлар чын революционер Вәлине характерлыйлар.* Б. Гыйззәт.

ИР *и.* 1. Хатын-кызга капма-каршы женестәге кеше. *Автобуста Фәездән, Янбай агайдан --- башка ир заты юк иде. Калган урыннарның барысына да --- хатыннар утырган иде.* Г. Мөхәммәтшин.— *Ирләрнең бугазларында төерләре була, хатын-кызларда ул булмый.* Т. Гыйззәт. // *с. мәгъ.* Хатын-кызга капма-каршы женестәге. [*Аның*] *4 баласы булып, ике өлкәне кыз, соңгы икесе ир бала.* Ш. Камал.

2. *с. мәгъ. күпл.* **ирләр.** Ирләр (1 мәгъ.) өчен билгеләнгән. *Ирләр мәктәбе. Ирләр кие ме. Ирләр эше.* ☐ *Зәйнәп дигәнем --- аягына ирләр итеге, өстенә куртка кигән.* Қ. Нәҗми. *Ирләр бүлегендә профессор иң элек Исмәгыйль Хәйретдинов янына узды.* Г. Әпсәләмов. // **Ирләргә (1 мәгъ.) хас; ирләрдәге кебек.** *Ирләр тавышы.* ☐ *Бу хат ирләр язуына охшатып язылган булса да, кызлар язуы икәнен белгертеп тора.* Ф. Әмирхан. *Җолкынбай боларга ирләр көче кирәк булачак урыннарда, авыррак нәрсәләрне күтәрү кебек эшләрдә ярдәмче иде.* Г. Ибраһимов.

3. Малайлык, егетлек чорын үткән, олыгайган кеше. *Бу инде, элекке кебек, --- җиңел холыклы, ярым малай, ярым егет түгел, хәзер Мансуров каршында канлы сугыш юлларын --- үткән егерме дүрт яшьлек ир кеше — фронт офицеры утыра иде.* Г. Бәширов. *Син кем үзең, белмимен мин: Хатын-кыз яки ирме, Яшь егетме, карт кешеме, Әллә бер пионермы?* Ә. Исхак.

4. *с. мәгъ. күч.* Батыр, йөрәкле, булдыклы. *Киң беләкле, ир йөрәкле Безнең Идел кызлары.* Ш. Маннур. *Идәне — җир, ишеге җил булсын, әмма егете ир булсын.* Мәкаль.

5. Хатынның бергә тормыш итә торган иптәше. *Егет белән кыз, хәзер инде ир белән хатын, култыклашып, Арыслан байның ак тирмәсенә керделәр.* Г. Ибраһимов. *Ун көн элек кенә өйләнешкән яшь семья бу: яшь ир, яшь хатын.* Ш. Маннур.

6. *у.-в. кил.* **ирдә.** Кияүгә чыккан, ирле (хатыннар турында).— *Мине сөяргә ярамый, Рәшат! Мин ирле; мин кыз кеше түгел, мин ирдә.* Ф. Әмирхан.

Ир тамыры *бот.*— ак тамыры даруга китә торган кылыч сыман озын яфраклы саз үләне; кылыч үләне; *русчасы:* аир. **Иргә чыгу (бару)** — хатын-кызның берәр ир кеше белән уртак гаилә төзүе; кияүгә чыгу. *Матур иде, яшьлә иргә чыкты, Хәзер инде алты баласы.* Һ. Такташ.— *Аны ташлап, ничек икенче иргә барасың?* М. Гафури. **Ирләр рифмасы** *әд.*— шигырьдә басымлы иҗеккә тәмамлана торган рифма. *Татар шигырьләрендә ирләр рифмасы өстенлек алып тора.* А. Сайганов.

◇ **Ир егет** — батыр, булдыклы, кыю кеше. *Сөнге, чукмар тотып атка менгән ир егетләр үзләренең яралы тәннәрен дошман гәүдәләре белән күмгәннәр.* А. Гыйләҗев. *Кыюлык — ир егетнең юлдашы.* Г. Әпсәләмов. **Ир егетчә** — ир егетләргә хас. *Әнә аның салмак, төз йөреше, Ир егетчә басып килеше.* Н. Исәнбәт. **Ир уртасы** — утыз биш-илле яшь тирәләрендәге ир. *Аңа бит хәзер нибары кырык яшь булыр иде. Ир уртасы кеше.* Г. Әпсәләмов. *Ул кырык бишләр тирәсендәге ир уртасы кеше икән.* Қ. Нәҗми. **Ир хатыны** — 1) ире (5 мәгъ.) булган, ир белән тора торган хатын.— *Кыз чакта бер хәл. Ә хәзер син ир хатыны.* М. Әмир. *Бәлки, бу аның өчен бердәнбер мөмкинлектер, әйе, ир хатыны, семья кешесе булыр өчен бердәнбер, кабатланмас мөмкинлектер?* Ә. Еники; 2) бөтен максаты, шөгыле ирен кайгырту белән генә чикләнгән, җәмгыятьтә башка урыны булмаган хатын.— *Минем бары тик ир хатыны гына булып каласым килми, шуны яхшы бел син, Хафиз.* Р. Ишморат. **Ирләр тастымалы** *гади с. хур.*— төрле ирләр белән женси мөнәсәбәткә керергә яратучы хатын.— *Менә хәзер ирләр тастымалы Гөлсемне алып кайтып куярсың.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ИРАВЫЛ *и. бор.* Алдан бара торган гаскәр; авангард. *Алмыш хан үзе иравыл белән иде.* Н. Фәттах. *Әзгәрләр суккан әтрәч аша Иравыллар булып бу якка Килгән алар Кайбыч тирәсеннән.* Ә. Рәшитов.

ИРАН *с.* 1. Иранлылар эшләгән, иранлылар ижат иткән. *Байлар ачулы күзләре белән иран паласы өстендәге «ат башыдай алтын»га карап алдылар.* М. Гафури. [*Тукай*] *ачда булган борынгы иран һәм гарәп анекдотларын укып ләззәтләнә.* В. Бахтияров.

2. *к.* иранлы. [*Малай*], *әрмән, француз, гарәп, немец, төрек, англичан, иран сәүдәгәрләренең йөзләренә, өс-башларына хәйран булып карап тора торгач, --- адашып калды.* Қ. Тинчурин.

Иран тукранбашы *бот.*— канәфер чәчәге төсле чәчәкләре баллы сыекчага бай булган, кыска көпшәле берьеллык үсемлек; *русчасы:* шабдар.

ИРАНАЙ *с. диал. к.* ирдәүкә.

ИРАНАЙЛЫК *и. диал.* Иранай булу. *Шук күңелле иде бүген Гайния һәм, шуның өстәвенә тагын, беләкләрендә көче ташып торганын сизә иде ул. Хәер, киенүендә, килеше-килбәтендә үк ниндидер бер иранайлык бар иде.* Ф. Хөсни.

ИРАНИСТ *и.* Иран телләре, әдәбияты һәм культурасы буенча белгеч.

ИРАНИ!СТИКА *и.* Иран группасына кергән халыкларның телен, әдәбиятын һәм культурасын өйрәнә торган фәннәр җыелмасы.

ИРАНЛЫ *и.* Иранда яши торган төп халык вәкиле. *Сөекле шагыйребезнең бу әсәре русларның Пушкиннары, --- иранлыларның Сәгъдиләре, Фирдәүсиләре заманында чыккан булса иде.* Г. Тукай. *Әгәр дә миңа бирәр гарәп, төрек яки иранлы очраган булса, мин алар белән рәхәтләнеп сөйләшер идем.* С. Кудаш.

ИР-АТ *җыйи.* Ирләр. *Кибеттә ир-ат юк. Ике хатын гына.* Қ. Тинчурин. *Күбесе ир-аттан торган бу төркем арасында анда-санда гына хатын-кызлар да күренгәли.* Ф. Хөсни.

ИРАУЛАУ *ф. сир.* Қаты кычкыру, ай-вайлау.— *Юләр, шулкадәр ираулап еларга ярыймыни?* Ф. Әмирхан.

ИРГӘЛӘШҮ *ф. диал.* Сүз көрәштерү, карулашу.

ИРГӘСӘР *с.* Ирләр белән чуалырга яратучы, азгын (хатын-кыз турында). *Зур бәхетсезлеккә төшкән ялгыз анага бу иргәсәр хатын нинди җылы сүз әйтсен, нинди кешелек мөнәсәбәте күрсәтсен?!* Г. Әпсәләмов.

ИРДЕ *ф. бор. к.* иде.— *Аулар ирдем мин балыкларны бу болганчык судан.* Г. Тукай. [*Ул*] *эш итәр ирде ничәмә ил белән.* Ә. Исхак.

ИРДӘҮҚӘ *и. шелт.* 1. Үзен ирләрчә тотарга, ирләр арасыңда кайнашырга яратучы, ир табигатьле хатын. *Андый хатыннар, заманга иярүне ялгыш аңлап, башларына кепка, аякларына итек киеп, тәмәке тартып, ирдәүкә булырга тырышалар.* Г. Кутуй.— *Кыз түгел, егет ул Сажидә! Чын ирдәүкә!* М. Галәү. // *с. мәгъ.* Үзен ирләрчә тотарга, ирләр арасында кайнашырга яратучы, ир табигатьле. *Акыл җитмәс дәрәҗәдә дорфалык, күздән яшь китерердәй нечкә күңеллелек бу үзсүзле ирдәүкә кызның канына сеңгән иде.* Г. Ахунов.

2. *к.* иргәсәр. *Хатын-кызлар --- Мәдинәне яратмыйлар: «Шадра шайтан, ирдәүкә, кыланчык, ир-ат күңелен аздырып кайнаша...» — дип, аның гайбәтен сата иделәр.* Ш. Қамал.

ИРДӘҮҚӘЛӘНҮ *ф.* Үз-үзен ирләрчә тота башлау; тупаслану.

ИРЕГҮ *ф.* 1. Гел бернәрсә эшләүдән, бертөрле торудан, бертөрлелектән яки эшсезлектән тую, бизү, ару. [*Гәрәфие*] *көндез колхозның бухгалтериясендә --- гел утырып эшләүдән иреген кайта да, аякларын тыеп тора алмагандай, тизрәк чыгып китү ягын карый.* Ф. Хөсни. *Байбәтчә бер ел шулкадәр кысынкы сүрәттә кибеттә һәм атасы янында торгач, әлбәттә, иреккәндер.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Иренү, ялкаулану. *Мин сөямен ирекне, ирекне, Хезмәт итәм ирекми, ирекми.* Г. Қамал.

3. *диал.* Сагыну.— *Һе, дускай, иректеңмени? --- Хәзер үзеңә әпәй кисеп бирәмен.* Э. Қасыймов.

ИРЕК *и.* 1. Шәхси азатлык, бәйсезлек.— *Мин, ирек теләп, атам йортын тарсынып чыгып киткән кыз.* **М. Фәйзи.** *Белдем микән ирек кадерен Хәр чагында, дуслар, элек мин?* М. Җәлил.

2. Сак астында, ябылуда, тоткынлыкта булмау. *Иреккә чыгу.* □ [*Айсылу:*] *Мирвәли абыең иректә.* [*Гөлчирә:*] *Иректә?.. Чыгареганнармы?* Т. Гыйззәт. [*Милләтчеләрне*] *«татар диванаханәсе»нә ябарга кирәк. Ул исә... бездә юк. Ни эшлисең? Иректә йөри шул!* Г. Тукай.

3. Дәүләттә, илдә шәхескә бирелгән хокук. *Политик ирек. Сүз иреге. Иҗат иреге. Демократик ирекләр.* □ *Бу революциядә --- яулап алган матбугат иреге аркасында татар телендә газета, журналлар чыга башлый].* М. Гали.— *Сезгә монда юк ирек, Солтан җиренә кит, диләр.* Г. Тукай.

4. Билгеле бер сыйныф яки җәмгыятьнең иҗтимагый-политик тормышында политик һәм экономик изелү, чикләүләр булмау; бәйсезлек, хөрлек. *Гафури бу революцияне башлыча үзенең изелгән милләте өчен ирек, хокук һәм тигезлек даулау мотивлары белән кабул ылады.* М. Җәлил. *Қол булырга теләмәгән, Ирек сөйгән халык Күтәрелгән, сәнәкләрен, Балталарын алып.* Ә. Исхак.

5. *тар.* Крепостное праводан һәм коллыктан азатлык. *Антон, халык каршына чыгып, патшадан аяк терәп җир һәм ирек сорарга, барщина һәм оброк йөкләмәләрен үтәүне туктатырга чакыра.* К. Нәҗми. *Җирсез ирек нәрсәгә ул, Хаҗәтемә кирәкме? Тагын боюр өчен эшләп, Тагын газап чигикме?* Т. Гыйззәт.

6. Иркенлек, иркен тормыш. *Ирек иркендә үскән яшь каракош Тәрәзәм алдына килде дә кунды.* Г. Тукай. *Кыр төлкене! Ирек булсын үрдәк-казга!* Ш. Бабич.

7. *күч.* Саф һава, ачык җир. *Бозаулар иректә йөрү.* □ — *Малларны абзарда җыеп асрап булмый инде, иреккә чыксыннар.* И. Гази.

8. Теләгән нәрсәне эшләргә мөмкинлек.— *Берсенә, беркөнне «ирек нәрсә ул?» дип сорагач, үзең теләгәнчә тору, дип ычкындырган идем.* Һ. Такташ.— *Тормышта Бикмурзиннар белән Крестовниковларга элек тә теләсә нишләсәләр дә тулы ирек иде, хәзер дә ирек.* И. Гази. // Гомумән, берәр нәрсә эшләргә мөмкинлек. *Башкаларга йокларга ирек тә булмады.* М. Гали. *Еш кына көнозын вак яңгыр сибәләп тора, кырдан игеннәрне җыеп бетерергә ирек бирми.* А. Шамов.

9. Теләк.— *Ханнар ханы олуг ул хан! Аның иркен үтәү өчен Бүген монда мин хан булам!* Н. Исәнбәт. *Иркем белән бу эшкә кергәнче, шул зимагорларга иректсез корбан булганым артык.* М. Фәйзи.

10. *к.* ихтыяр (1 мәгъ.). *Мортый эчә, Тормышында шушы аның иң зур өзеклек. Ул табалмый шуңар йөрәгендә Қаршы торыр корыч ирекне.* М. Җәлил.

11. *тарт. форм.* **иркегез, иркен.** *к.* ихтыяр (3 мәгъ.).— *Шушы бер кыз алдында җимерә торган булсагыз, иркегез.* М. Фәйзи.

12. Власть.— *Сандугач минем иркемдә түгел.* Әкият. *Аның иркендә булса, ул Якубын да, Миңнулласын да, бүтәннәрен дә бүген үк бәреп үтерер иде.* И. Гази.

◇ **Ирек алу** — 1) бәйлелектән, буйсынудан котылу. *Мин дәү кеше булдым вә мәктәптә түгел инде. Ачылды юл, ирек алдым. --- Шаярырмын, теләсә нишләрмен, уйнар, көләрмен.* Г. Тукай; 2) иркенләү, рәхәтләнү. *Болар качкач, кәҗә белән безнең сарык Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып. Утыралар аяк бөкләп каршы утка, Болар инде тәмләп кенә ашый бутка.* Г. Тукай; 3) ял итү.— *Балакаем, инде кавырсының яңа гына ката башлаган икән, тагы берничә айлар ирек алсаң, үзеңә бераз көч керер.* Әкият; 4) артык иркенләп китү, берәү белән дә, һичбер нәрсә белән дә хисаплашмыйча теләсә ни эшләү; узыну. **Ирек ачу** — күңел ачу, ял итү, иреккә чыгып бер хозурлану, рәхәтләнү.— *Йөрегез, балаларым, тормыштан --- ләззәт алыгыз, ирек ачыгыз.* С. Җәләл. *Яланга ирек ачар өчен чыккандай итеп кенә хис кылды кызый үзен.* М. Шабай. **Ирек бирү (кую)** — берәр нәрсә эшләргә мөмкинлек бирү, рөхсәт итү, юл кую, берәр эш эшләүдән тыймау.— *Без сиңа бернинди башбаштаклык эшләргә дә ирек куймабыз.* М. Хәсәнов.— *Барыбер туңарга ирек бирмәбез!* Г. Бәширов. **Иреккә чыгару** — тоткынлыктан азат итү. *Суд аны, «аклап», иреккә чыгарды.* Ш. Қамал. **Иреккә чыгу** — тоткынлыктан азат ителү.— *Әллә иреккә чыгып, охранкага материал биреп килгәнме [ул]?* Г. Ибраһимов. **Иректән мәхрүм итү**— берәр төрле җинаять өчен төрмәгә ябу, сак астына алу.

ИРЕКЛЕ *с.* 1. Беркемгә дә буйсынмаган, үз ихтыяры белән яши торган. // Ни теләсә, шуны эшләргә мөмкинлеге яки хокукы булган; бәйсез.— *Ул ирекле кыз ла! --- Кемдә күңеле булса, шуңа барыр.* Р. Ишморат. *Очар идем, ирекле кош булсам.* К. Тинчурин.

2. (Берәр эшкә) үз теләге, үз ихтыяры белән тотынучы яки алынучы. *Пар күгәрченнәрне кавыштыру юлында йөрүче бик күп ирекле яучылар да табылды.* Р. Төхфәтуллин. // *и. мәгъ.* Сугыш вакытында гаскәргә үз теләге белән язылган кеше. *Фронтка китүче иреклеләр белән аны рәсемгә төшерделәр.* Г. Ахунов. *Чит илләрдән килгән иреклеләр, Аерым частьлар булып берләшеп, Халык белән бергә йөри алар, Фашистларга каршы көрәшеп.* Ә. Исхак. // *чыг. кил. форм. рәв. мәгъ.*

ирекледән. Үз теләге, үз ихтыяры белән.— *Кемнең соң ирекледән башын тоткынлыкка саласы килсен?* М. Әмир.

3. Аерым кешеләрнең үз теләкләре, үз ихтыярлары **белән** оештырыла торган яки оештырылган. *Ирекле халык дружиналары.* □ *Мәдрәсәдә укулар башланып китү белән үк, шәкертләрнең төрле ирекле түгәрәкләре эшкә башлый.* С. Кудаш.

4. Һәртөрле изүдән, коллыктан азат. *Ирекле кеше. Ирекле хезмәт.* □ *Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син, Ләкин илең ирексез калсын, дип, Әйтер идем: мине зинданга сал, Фәкать илем ирекле булсын, дип.* А. Алиш. *Тез чүкмәдек, тез чүкмәбез, Без ирекле гражданнар!* Н. Исәнбәт.

5. *тар.* Крепостной булмаган, крепостнойлыктан азат ителгән.

6. Әсирлек яки тоткынлык хәлендә булмаган; азат.— *Ач булсак та, ирекле без хәзер! Ирекле, Актүшкәй!* — *диде Илсөяр.* Г. Гобәй. // *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Аларның барагы да башта төрмә өчен дип салынган булган. Ләкин нишләптер анда иреклеләрне китереп тутырдылар.* Н. Фәттах.

7. Чикләнмәгән, закон тарафыннан һәртөрле тоткарлыклар куелмаган (эш-хәрәкәт турында). *Ирекле конкуренция. Ирекле сайлаулар.* □ *Ирекле сәүдәгә юл куелгач, [Сәхәү] тагын да иркенрәк тын ала башлаган.* М. Әмир. // Билгеле кагыйдәләр, калыплар, нормалар белән чикләнмәгән. *Ирекле стиль.*

8. Бернинди чикләүләрне, киртәләрне белмәгән, кешенең үз иркенә нигезләнгән.— *Ә син кайда, ата булыр кеше? Шулмы булды синең сөюең, Шулмы инде синең: Ирекле сөю, Яңа тормыш диеп йөрүең?..* Һ. Такташ. *Син дә бит: мәхәббәт ирекле булырга, семьяга бәйләнмәгән булырга тиеш, ди идең...* Р. Ишморат.

9. Мөстәкыйль, хөр (караш турында). *Кафелар --- тарихның мәгълум бер вакыт[ында] ирекле фикер учагы булып яшәгәннәр, --- монархизмга каршы либерал-бурҗуа фикерләре шул тирәдә үскән.* Г. Гали.

10. Теләсә ничек. *Аның ирекле рәвештә тузгып дулыкынланган чәчләре чем-кара.* М. Әмир. / *рәв. мәгъ. Тезмәләр эчендәге басымнарның күпчелеге ирекле килә.* Г. Нигъмәти.

11. *рәв. мәгъ. сир. к.* иркен (6 мәгъ.). [*Ул*] *бу кечкенә шәһәрнең клубында үз-үзләрен рус кызлары кадәр үк ирекле тота ала торган калфаклы татар кызларын күрде.* Ф. Әмирхан.

12. *хим.* Икенче бер элемент белән химик кушылмага кермәгән. *Ирекле водород. Ирекле углерод.*

Ирекле диктант *пед.*— диктантның укытучы укып чыккан тулы текстны хәтердә калганча язудан гыйбарәт төре. *Ирекле диктант текстны укыганнан соң хәтердә калган җөмләләрне язу юлы белән эшләнә.* М. Вәлидова. **Ирекле сүз тезмәсе** *лингв.*— сүзләрнең лексик берәмлек тәшкил итмәгән бәйләнеш төре (мәсәлән, *кояшлы көн, урманга бару*). **Ирекле тыңлаучы** — югары уку йортында лекцияләр тыңларга һәм практик дәресләрдә катнашырга рөхсәт алып та, студентлар исемлегенә кертелмәгән һәм аларның хокукларына ия булмаган кеше. [*Бәһапов*] *ирекле тыңлаучы сыйфатында табигать факультетында лекцияләргә* [*йөри*]. И. Рәми. **Ирекле тәрҗемә** — төп нөсхә белән төгәл туры килми торган, якынча тәрҗемә. **Ирекле хәрәкәтләр** *спорт.*— спорт коралларын кулланмый эшләнә торган гимнастик күнегүләр. **Ирекле шигырь** *әд.* — басымлы һәм басымсыз иҗек саннары төрле юлда төрлечә булган шигырь. *Ирекле шигырь теориячеләре, --- шагыйрьнең әйтергә теләгән фикерләре, бирергә уйлаган тойгылары вәзен, ритм, строфалар эчендә кысылып калмаска тиешле, диләр.* Г. Нигъмәти. *Мин ирекле шигырьләрне дә, рифмалы шигырьләрне дә (әгәр аларда чын поэзия булса) яратам. --- Яңа поэзияне рифмасыз ирекле шигырьдә генә күрү дөрес булмас иде.* Р. Әхмәтҗанов.

Ирекле шәһәр — мөстәкыйль дәүләт хокукы алган шәһәр. **Ирекле электроннар** *физ.*— үз атомнарыннан аерылып, атомара пространствода хәрәкәт итә торган электроннар.

◇ **Ирекле баштан (көннән)** — үз иреген, үз теләгең белән, кеше мәҗбүр итмичә.— *Ирекле баштан нигә каенана кулында торам соң?* Г. Бәширов.— *Мин әле әбине орышып киләм. Ирекле көннән, үз ихтыяры белән үз башына авыру алган.* Ш. Камал. **Ирекле казак** — беркемгә дә буйсынмаган, бернәрсә белән дә бәйләнмәгән, бәйсез кеше турында.— *Хәзер сез ирекле казак, теләсә нишли аласыз.* Г. Әпсәләмов.— *Менә безнең кебек --- семьялы кешегә ярамый ул* [*әш*]. *Ә сиңа нәрсә? Син бит ирекле казак!* А. Расих. **Ирекле кую** — *к.* ирек кую. *Мин аны да ике тәүлек буенча шәһәрдә теләгәненчә йөрергә ирекле куйдым.* Г. Ибраһимов.

ИРЕКЛЕ-ИРЕКСЕЗ *рәв.* **1.** *к.* ихтыярсыздан. *Үзем инде шатлыктан нишләргә белмим. Авыз читләрем ирекле-ирексез колакка таба сузылалар.* К. Нәҗми. *Нидидер билгесез көч ирекле-ирексез аның артыннан иярергә, ул ни кушса, шуны тыңларга мәҗбүр итте мине.* М. Әмир.

2. Теләсә, теләмәсә дә; мәҗбүрилектән. *Зәйтүнәнең чанасы чалулап, йөгә бер якка авып төште. Ирекле-ирексез тукталырга туры килде аңа.* Ф. Хөсни. [*Кыскартуга*] *эләгеп, мин кучерлыктан да ычкындым. Ирекле-ирексез тагы авылга кайтып, бөтенләй шунда төпләнергә туры килде.* М. Гали.

ИРЕКЛЕК *и. к.* азатлык. *Мактаган ул бөек иреклекне, ләгънәт укып богау-чылбырга.* А. Алиш.— *Шәхес иреклеген, демократия хокукларын чикләвегезгә каршы мин, --- протест белдерәм!* Т. Гыйззәт.

ИРЕКЛЕЛЕК *и. кит.* **1.** Эшне бары тик үз теләге белән эшләргә мөмкинлек. *Колхозлашуны иреклелек нигезләрендә үткәрү.*

2. Гомуми кагыйдәләрдән, күрсәтмәләрдән, төп нөсхәдән читкә тайпылыш, аларга буйсынмаучанлык. *Иреклелек принцибы матур әдәбият һәм указ, инструкция, договор, директива, нота кебек --- документлар өчен бердәй була алмый.* К. Сабиров. *Мин тәрҗемәдә иреклелек яклы.* Г. Гобәй.

3. Нәрсә теләсә, шуны эшләргә мөмкинлек.— *Мин, шушы минуттагы иреклелектән файдаланып, иркенчә, сиңа әйтәчәк серләремне яшермичә, барын чишәсем килә.* Ан.

4. *филос.* Табигать һәм җәмгыятьнең үсеш законнарын танып белү нигезендә кешенең үз теләкләрен һәм максатларын тормышка ашыра алу мөмкинлеге. *Чын иреклелек ул — танып беленгән зарурлык.* М. Абдрахманов.

Иреклелек һәм зарурлык *филос.*— табигать һәм җәмгыятьнең объектив законнары белән кешеләрнең эшчәнлеге арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә торган философик категорияләр. *Иреклелек һәм зарурлык нисбәтен беренче тапкыр дөрес итеп күрсәтүче кеше Гегель булды. Аның өчен иреклелек зарурлыкны танып белү ул.* Ф. Энгельс.

ИРЕКСЕЗ *с.* **1.** Тормышы, эшчәнлеге берәр кешегә яки берәр илгә бәйле, буйсынган. *Изелгән, хурланган, кагылган, ирексез бер коллар идек без.* М. Җәлил. // *рәв. мәгъ.* Бәйле, буйсынган хәлдә. *Татар, башкорт хатын-кызларының борынгы ирексез яшәүләрен --- язып үтүне тиешле күрдем.* М. Гафури.

2. Мәҗбүр. [*Алар*] *яңадан бурыч ясарга ирексез булырлар.* Урал. *Хатыннар бер тарафка, ирләр икенче тарафка сафландылар. Хәзрәтебез дә, хайваннлыгын җиңеп, ирләр ягындагы сафка керергә ирексез иде.* Ф. Әмирхан. // *рәв. мәгъ.* Теләмәсә дә, мәҗбүри рәвештә. [*Ул*] *бу караңгы авылга кайтуны бер дә эстәми. Ләкин җәмәгать тели, бөтен агай-эне ялына, --- ни эшләсен — ирексез — мулла була.* Г. Ибраһимов.

Кайтып торырлык урыным да юк. - - - Шуңа күрә ирексез төнге унбергә кадәр вокзалда калырга булдым. А. Шамов.

3. *рәв. мәгъ.* Нәрсә эшләвен үзе дә сизмичә, ансыз рәвештә; үзе дә теләмичә, ихтыярсыздан. *Сүз бу тугрыга килсә, аның күзләреннән ирексез яшь коела башлап, ул үзен үзе оныткан хәлдә каһәрләргә керешә.* Г. Ибраһимов. *Ул үзендә ниндидер бер билгесез уйның, гажәп дәртләндергеч канның йөгереп үткәнен сизде һәм кызга ирексез күтәрелеп карады.* А. Шамов.

Ирексез итү — ирексезләү, мәҗбүр итү. *Газизә [ул] абыстайны - - - рөхсәт бирергә ирексез итте.* Ф. Әмирхан. *Россиянең һәр җирендә безнең эш ташлавыбызның куәтле дулкыны, самодержавие правительствосын куркытып, эшчеләрнең сораганнарының кайберләрен ирексез итте.* РСДРП прокламациясе.

ИРЕКСЕЗДӘН *рәв. к.* ирексез (2, 3 мәгъ.). *Ул белмәде кемгә дә сөйләргә - - - Үзенең канлы һөҗүмнәргә Ирексездән генә барганын.* Ә. Исхак. *Ирексездән килгән күз яшьләремне, иптәшләремә күрсәтмәскә теләп, йоттым.* А. Шамов.

ИРЕКСЕЗЛЕК *и.* Ирексез (1 мәгъ.) булу; бәйлелек, хокуксызлык. *Бәеттә революциягә кадәр татар хатын-кызларының ирексезлеге - - - [турында] сөйләнә.* М. Җәлил.

ИРЕКСЕЗЛӘҮ *ф.* Үз ихтыярына куймау; көчләү, мәҗбүр итү.— *Ирексезләү әйбәт эш булмас ул, иптәшләр. Әгәсе килми икән, әчмәсен.* Г. Ахунов.— *Үзең күнмәгән булсаң, сине ирексезләмиләр иде бит.* М. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* **ирексезләп.** Мәҗбүри рәвештә, мәҗбүр итеп, көчләп. [*Ул:*] *«Аша, аша!» — дип ирексезләп ашатты.* Әкият.

ИРЕН *и.* Авыз ачыклыгы тирәсендәге хәрәкәтчән, итләч мускуллы тукыманың һәрберсе. *Нечкә иреннәр. Калын иреннәр. Өскеирен.* □ *Аның иреннәре кыймылдыйлар, ул нәрсәдер әйтә шикелле.* Э. Еники. [*Егет*] *Сылуның тулы канлы, карасу кызгылт иреннәреннән үпте.* Г. Ибраһимов.

Ирен авазлары *лингв.*— иреннәр катнашы белән әйтелә торган авазлар (б, п, в, ф, о, ө, ү, у). *Тел һәм ирен авазлары арасындагы аерымлыклар - - - әйтелү рәвешендәге төрлелектән дә килә.* Г. Алпаров. **Ирен чәчәклеләр** *бот.*— ике иренле тажчыклары булган бөтнек, шалфей кебек үсемлекләр семьялыгының гомуми атамасы.

◇ **Ирен дә кыймылдатмау** — бернәрсә дә әйтмәү, эндәшмәү. **Ирен тешләү** — 1) дәшмәү, бер сүз дә әйтмәү, сүзсез калу. *Ул, китап телендәгечә, «дәшми, сүзсез калды», дип әйтәсе урында, «иренен тешләде», дип сурәтли.* Ә. Исхак; 2) үз гаебе белән берәр нәрсәдән мәхрүм калганда әйтелә. *Эшләмәгән иренен тешләгән.* Мәкаль. *Болар исраф итә нишләп? Кала бер көн ирнен тешләп.* Г. Тукай. **Ирен турсайту** — үпкәләү, ачулану; ризасызлык һәм үпкә белдереп йөз чыту. *Зөһрә хәрәкәт һәм ачу аша Вәлигә күз ташлап иренен турсайта.* Г. Ибраһимов. [*Матильда*], *бик җәберсенгән рәвештә иреннәрен турсайтып, читкә китеп барды.* Ш. Маннур. **Ирен чылату** — бераз гына эчемлек эчү, эчемлек эчеп күнел ачу. *Бөтен гомере буена — очрашу вакытларында, бергә утырып ирен чылаткан чакларда, - - - һәрвакыт, һәр урында, очынып, дөньяның катлаулылыгына хәйран калып яши белә иде ул.* Ф. Хөсни. **Иренгә сөртерлек** — бик аз, җитәрлек түгел. *Өч көн ташыдылар инде алар тиресне, ә ул якын барып карамасаң, күренерлек тә булмады. Чынлап та, җирнең иренә сөртерлек кенә булды бит әле бу!* Г. Гобәй. **Иренендә (ирененнән) сөте кипмәгән** *кимс.*— яшь һәм тәҗрибәсез кеше турында.— *Каян ул кияү булсын ди, бала гына ич әле, иренендә сөте дә кипмәгән!* М. Хөсәен.

ИРЕНДЕРГЕЧ *с.* Ирендерә, ялыктыра торган. *Ирендергеч эш.*

ИРЕНДЕРҮ *ф.* Эштән күнелне кайтару, эшкә теләкне бетерү. *Хәзер мин юлдамын — һичтөрле арганлык ирендермәс.* Н. Исәнбәт. / *з.-сыз. Ирендерә дә киерелдерә, иснәтә дә йоклата.* Мәкаль.

ИРЕНЛӘШҮ *ф. лингв.* Кайбер авазларны әйткәндә иреннәр алга таба сузылып бөрешү. *Сузык авазлар иренләшү.*

ИРЕНЧӘК *с.* Эшкә ихлассыз, ялкау. *Ул да минем кебек сүзгә бай түгел һәм иренчәк кеше.* Ш. Камал. / *и. мәгъ. Иренчәк: иртәгә эшлим, дияр.* Мәкаль. *Тешләре тешкә бәрелә, Иренчәккә нишләргә? Чыдамады, аптырагач, Мәҗбүр булды эшләргә!* Ш. Галиев. // Иренү билгесе сизелеп торган, ихлассыз. *Шәриф абый иренчәк кара күзләрен зур итеп ачып, бер тутырып ачуланып карады.* Г. Газиз. [*Ул*] *иренчәк тавыш белән: «Нишләп инде ятмыйсың?» — диде.* Ш. Камал.

ИРЕНЧӘКЛЕК *и.* Иренчәк булу, ялкаулык. *Эш — төзәтер, иренчәклек — бозар.* Мәкаль.— *Син иренчәклегең аркасында үзеңне бер бәлагә салган икәнсең.* Г. Тукай.

ИРЕНҮ *ф.* 1. Берәр нәрсә эшләргә теләмәү, эшкә ихлас куймау; ялкалану.— *Бар, дисәгез, мин тегеләрнең нишләгәннәрен карап кайтырга да иренмим.* Х. Кәрим. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә, Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.* Г. Тукай.

2. *и. мәгъ.* **иренгән.** Ялкау, иренчәк кеше. *Иренгән ике эшләр, пычрак бармагын тешләр.* Мәкаль.

3. *рәв. мәгъ.* **иренеп.** Акрын, салмак, ялкау, теләр-теләмәс (хәрәкәтләнү, сөйләү һ. б. ш. турында). *Иренеп кенә язгы җил исә.* Ф. Кәрим. *Авылның төрле урыннарында сирәк-мирәк кенә, иренеп кенә этләр өргәләп ала.* А. Шамов.

ИРЕНҮЛЕ *с.* Иренү сизелгән, ялкау, теләр-теләмәс. *Иренүле тавыш.* □ *Кемдер иренүле, ярым ачулы аваз белән русча: «Кем бар инде? Керегез!» — диде.* Г. Ибраһимов.

ИРЕШТЕРҮ I *ф.* 1. Берәр нәрсәгә алып килү, берәр нәрсәгә китерү. / *и. мәгъ. Юлыгызның яктылыкка, бәхеткә, иреккә ирештермәвен тәҗрибәдә күреп, яңа юллар эзләргә кушмыйсызмы?* Г. Ибраһимов.

2. Берәр хәбәрне, сүзне килеп әйтү, тапшыру, җиткерү.— *Кирәк хәбәрне сиңа ирештерербез, син тиешле җиренә ирештерерсең.* Г. Толымбай. *Нәрсәгә соң Миңнурый бу кадәр ярсыган? Мөгаен, сүз ирештергәннәрдер.* Г. Әпсәләмов.

3. Берәр нәрсәгә ия итү, берәр нәрсәне (теләкләрне, уйларны һ. б. ш.) тормышка ашыру, теләгән, уйлаган нәрсәсенә китерү. *Эштә максат куеп эшләү моратка ирештерә.* Н. Исәнбәт. *Мөкатдәс яшь, мөкатдәс кан!.. Китәрләрме болар юкка?.. Я булмаса ирештерерме безне мәңге шатлыкка?* М. Гафури. // *сөйл.* Берәр нәрсә белән тәэмин итү, берәр нәрсәгә ия итү. *Ул җәйне безне, ниһаять, фатирга ирештерделәр.* Э. Касыймов. // Берәр эштә, өлкәдә билгеле бер югарылыкка күтәрү (осталык, камиллек һ. б. ш. турында). *Картның бик зур мәшәкать белән камиллеккә ирештергән зур, бай, матур бакчасы - - - гына да аны башка һәммә адәмнән әллә ничаклы аера.* Г. Ибраһимов. [*Яңгыр*], *навадагы кызулыкны җиңелчә язгы җылылык белән алмаштырып, көнне ямьлелекнең чигенә ирештергән иде.* Ф. Әмирхан.

4. *иск.* Берәр нәрсәгә дучар итү. [*Алар*], *Харбинга да килеп, бер каза ирештермәсәләр ярар иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Хәзрәт бу сүзгә ышанмаса да, Әхмәтнең гыйльме симия белән берәр афәт ирештерүеннән куркып, ышанмаганлыгын белдермәде.* Ф. Әмирхан.

ИРЕШТЕРҮ II *ф. диал.* Үчекләү, үртәү, котырту.— *Әйт әле Саимәгә, ирештермәсен иде шул Шәрәфине. Эт оясында көчле, үчегеп-нитеп китүе бар.* К. Нәҗми. *Нә-*

симә чынлап кыза, Халикъ аны юри ирештереп маташа иде. Ш. Камал.

ИРЕШҮ *ф.* **1.** Берәр урынга яки билгеле чиккә килеп җитү. *Шул бүре илә сугыша-сугыша Ирештем мин илемә.* Бәет. *Кайдадыр яктылык бар, кайчан да булса без шуңа ирешербез.* Г. Ибраһимов. // Билгеләнгән урынга барып җитү, тапшырылу (хат, посылка һ. б. ш. турында). *Бу хат сезгә барып ирешкәнче, --- Безнең колонналар Соңгы крепостьны алачак!..* Һ. Такташ.

2. Хәбәр, сүз, гайбәт кемгә дә булса билгеле булу, ишетелү. *Бу хәбәр отрядтан отрядка яшен тизлеге белән ирешүе.* К. Нәҗми.

3. *күч.* Үзе теләгән нәрсәне зур тырышлык белән булдыру, куелган максатына ия булу. *Зур уңышларга ирешү. Тулы җиңүгә ирешү.* □ [*Ул*], *егерме өч яшенә кадәр шулай үзен үзе белештермичә эшли торгач, үзенең максатына ирешкән кебек булды: ат алды, өйләнде, --- җыйнак кына йорт торгызды.* И. Гази. *Җиңеп барлык чүл, комлыкны, Кайнар җил һәм корылыкны, Ирешербез тиңсез муллыкка!* Ә. Исхак. // Берәр эштә, өлкәдә билгеле бер югарылыкка, дәрәҗәгә күтәрелү, аңа ия булу.— *Синең энең безнең шәһәрне аждаһадан коткарды, шуның белән* [*бу*] *дәрәҗәгә иреште.* Әкият.— *Шигырь бит ул бик күп көч куеп, озак вакытлар эшләү нәтиҗәсендә генә чын сәнгать үрнәге булу дәрәҗәсенә ирешә ала.* Т. Гыйззәт.

4. *күч.* Берәр нәрсәнең мәгънәсен, эчке табигатен, эчтәлеген аңлар хәлгә җитү, аңлау, төшенү.— *Теләгән кеше белә ала. Кеше акылы ирешә алмый торган бер нәрсә дә юк.* Г. Әпсәләмов. *Һич сәбәпсез бу эшнең киредә китүенә* [*аның*] *гакылы ирешмәде.* М. Гафури.

5. Берәр яшькә кадәр яшәү, җитү. *Бу угыллар үсеп җитәр вакытларда Мөхәммәтгали бабай зур-зур яшьләргә ирешкән вә башы кар төсле агарган* [*иде*]. Г. Тукай.

6. *иск. күч.* Бәла, каза һ. б. ш. килү. *Аңсыздан я бер авыру, яки башка бер бәла-каза ирешеп, адәмнең хәятен әллә ничәгә бүгә вә сындырадыр.* Г. Тукай. *Болар шунда яхшы гына эшләп йөргән вакытта, шыпты фабрикасына да каза ирешеп, ут чыгып, баганаларына кадәр янып бетте.* М. Гафури.

И'РИС *и. бот.* Кылыч сыман эре кыяклы һәм шәмәхә, күк яки сары төстәге эре чәчәкле күпьеллык үлән; күк сусын. *Ирис чәчәк ату.*

ИРИ'С *и.* Шикәр һәм бәрәңге балын сөттә изеп, шакмак формасында хәзерләнә торган кызгылт-көрән конфет. *Авызының тәме юк иде, гастрономга кереп ирис алды, шуны суырды.* А. Гыйләҗев.

ИРКӘН *с.* **1.** Кысынкы булмаган, киң (урын турында). *Иркен бүлмә.* □ — *Өебез артык иркен түгел түгелен дә, күңел киң булса, сыярбыз әле.* Г. Әпсәләмов. *Секретарьның кабинеты якты һәм иркен иде.* Г. Бәширов. // Кысып тормаган (өс һәм аяк киеме турында). *Иркен күлмәк.* □ [*Аның*] *өстенә кигән шинеле --- гәүдәсенә караганда иркенрәк булганга, иңбашлары бераз төшенке булып, итәкләре бераз салпырак булып тора иде.* М. Гафури.— *Кайдан таптың бу бишмәтне? Бик тар. Иркен кием кирәк мондый җирдә.* Г. Гобәй.

2. Киң, җәелгән (урын, кыр һ. б. ш. турында). *Иркен дала.* □ *Диңгез кебек иркен, киң болында Кызык та соң сабан туенда.* Н. Исәнбәт. *Нинди татлы яшәү, көчле сөю. Нинди якты, иркен җир йөзе!* М. Җәлил.

3. *и. мәгъ.* Ачыклык, ачык һава. *Бу һава, бу яз галәмәте кешеләрне өйләреннән урамнарга тарта, кысыктан иркенгә өстери.* Ф. Әмирхан. *Мине, чыпталы чананың өстен каплап, алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һичбер яктан сулыш алырга бирмәделәр. Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә иркенгә чыгаралар иде.* Г. Тукай.

4. Азат, бәйсез, хөр. [*Халык*] *бөтен башлыкны үз кулына алгач кына иркен булачак.* Урал. *Миңа бүген унсигез яшь инде, --- иркен илнең граждане булып өлгердем.* Ш. Маннур. // *рәв. мәгъ.* Бәйсез, хөр. *Иркен яшәү өчен хокук алды Безнең илнең мәгърур кешесе.* Ә. Ерикәй. *Азмы-күпме иркенрәк уйлый алган* [*кешеләр бирегә*] *туплана.* Г. Гали.

5. *и. мәгъ.* Азатлык, бәйсезлек; ирек (2, 4, 5 мәгъ.). — *Кол булып тору белән иркендә торуның аермасы бик зур бит.* Г. Коләхметов.

6. *рәв. мәгъ.* Җиңел, ансат, кыенсынмыйча. *Русча иркен сөйләшү.* □ *Гомере шундый катлау тирәсендә үткәнгә, аның иркен укый-яза белүендә шик тотмыйлар.* Г. Ибраһимов.— *Мин аларның беразын бик иркен эшләп ташлый алам.* Ш. Камал.

7. *рәв. мәгъ.* Тартынмыйча, уңайсызланмыйча, табигый рәвештә (сөйләшү яки үзен үзе тоту турында). *Кунаклар, бик тиз ияләшеп китеп, үзләрен* [*өйләрендәге*] *кебек иркен тоттылар.* Г. Гобәй. [*Килен*], *әйтерсең, шул авылда, шул йортта туып, шунда үскән — шул дәрәҗәдә иркен кылана. Юньләп качмый, өлкәннәр бар дими, үз дигәнен кылып, юк-бар сүз белән көлдереп, шаярып йөри.* Г. Ибраһимов. // Берәр нәрсәне бушайтып, киренке итмичә (тоту, кую турында). *Гәүдәне иркен тоту. Тезгенне иркен кую.* □ *Тарасов стройдагыларга --- иркен торырга рөхсәт бирде.* К. Нәҗми.

8. *рәв. мәгъ.* Комачаусыз, чикләүсез, тоткарлыксыз. *Мин үземнең әдәби иҗат көчләремнең иркен үсеп китә алу*[*ын*] *тик Бөек Октябрь революциясе аркасында гына дип табам.* Г. Ибраһимов.

9. *күч.* Бертөрле дә материаль кыенлыклар кичермичә торган, бай, хәлле, мул. *Җәләш мулла угылларын да зур мәртәбә иясе, бай, иркен тормышлы --- итеп күрәсе килә.* Г. Нигъмәти. // *рәв. мәгъ.* Материаль кыенлыклар кичермичә. *Һәр ел шулай иген уңа барса, Торырмын мин иркен, байларча.* М. Гафури.

10. *рәв. мәгъ. күч.* Җитәрлек, мул, күп.— *Сума күп түгел минем, Сөләйман әфәнде. Әгәр акча иркен булса* [*иде*], *--- бик зур эш итеп булыр иде.* Ф. Әмирхан.

11. *рәв. мәгъ. күч.* Берәр эшнең билгеле бер вакыт эчендә һичшиксез үтәлү мөмкинлеге барлыгын белдергәндә кулланыла.— *Яңа вокзал бездән ун чакрым. Бер сәгатьтә иркен барып җитәбез...* Г. Ибраһимов.— *Әле кояш баерга ике сәгать вакыт бар, «Лапашты» моннан уникә чакрым. Без анда караңгы төшүгә иркен җитәбез.* М. Гафури.

12. *күч.* Кичектергесез эшләр белән мәшгуль булмаган, буш (вакыт турында).— *Әгәр дә иркен вакыт булса, мин сезнең белән отрядларны берләштерү турында сөйләшер идем. Кызганычка каршы, без берничә минут эчендә алга кузгалырга тиешбез.* Ш. Усманов.— *Ярый, улым, иркенрәк вакытта килеп чыгармын әле шулай, сөйләшеп утырырбыз.* Р. Ишморат.

Иркен һава — тыш һавасы, ачык һава. *Париж* [*халкы*] *өйдә, квартирада, ял итә белми. Ул, ничек булса да, иркенрәк һавада утырырга тели.* Г. Гали. *Иркен һавада тын алулар җип-җиңел.* М. Гафури.

◇ **Иркен куллы** — байлыгы җитеш, хәлле (кеше турында). **Иркен күңелле** — *к.* киң күңелле. *Киленнең болай иркен күңелле, ачык чырайлы булып, ачу сакламавы --- Хәдичәнең дә күңелен йомшарткалый иде.* Г. Бәширов. [*Бабай*] *бик юаш,* [*кечелекле*], *иркен күңелле иде.* Г. Тукай. **Иркен сулау, иркен сулу (сулыш, тын) алу** — 1) бөтен күкрәк белән, тирән итеп сулыш алу. *Киттек, иркәм, ап-ак йолдызларны Көнләштереп чаңгы шуарбыз... Җилбәзәкле карда эзләр сызып, Саф һавада иркен сулармыз.* Ә. Ерикәй. [*Авыруга*] *җан кергән шикелле булды. Аннан ары инде, иркен тын алып, үзе сөт сорап эчте.* Г. Ибраһимов; 2) төрле мәшәкатьләрдән, куркынычтан котылып, җиңеләеп, тыныч-лаңып китү (калу). *Габдулла җавап бирә алырмы...*

бирсә, нәрсә әйтер, дип тынгысызланып утырган шәкертләр һәм яшь хәлфәләр: «Һай, яхшы әйттең!» — дип, иркен сулап куйдылар. Э. Фәйзи. *Бу уңайсыз хәл авыр иде минем өчен. Тизрәк котылырга, тизрәк иркен тын алырга телән, Гаязны ашыктырдым.* М. Әмир; 3) экономик, политик һәм рухи яктан җиңеллекләр сизү. *Әле берничә генә ай элек капитализм богавыннан котылып иркен сулу ала башлаган Агыйдел крестьяннарының яңадан тыннары кысылды. --- Алпавыт богаулары, казак камчылары күренде.* Г. Гобәй. *Халык иҗатының реакция, дин, капитал белән буылып торган бай чишмәсе --- Бөек Октябрь революциясеннән соң гына иркен сулыш алып, киң тармакланып, җәелеп агарга мөмкинлек тапты.* М. Җәлил.

ИРКЕНЛЕК *и.* 1. Иркен булу хәле.— *Мин менә бу сахраларны, иркенлекне анам кебек күреп сөюче бер баламын.* М. Фәйзи. [*Сагынамын*] *далаларның шаулы иркенлеген, Сыерчыкның моңсу тавышын.* Ш. Мөдәррис.

2. Ирек, азатлык, хөрлек.— *Ә монда жандарм Герасимов --- һәрбер сүздә ораторның телен кисә. Бу — манифестмы? Иркенлек шулмы?* Г. Ибраһимов. *Патша безгә җыен вә сүз иркенлеген бирми.* РСДРП прокламациясе.

ИРКЕНЛӘҮ *ф.* 1. Ашыкмау, акрын кыймылдау, үз җае белән генә эш итү. // *рәв. мәгъ.* **иркенләп.** Ашыкмыйча, җай белән, үз уңаена, озаклап.— *Бик иркенләп утыра алмабыз инде, кодагый абыстай, тизрәк хәзерләнеп бетсәгез, китәрбез, анда көтәләрдер.* М. Гали. *Мин тынычлап, иркенләп ашый-эчә алмыйм, ашыгам, ашыкынам.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Вакытны бушка, әрәмгә, тиккә уздыру.— *Кибетчеләр, «абзый өйдә юк» дип, иркенләп йөрмәсеннәр. Вакытында кайтып, вакытында кибеткә чыксыннар.* Г. Камал.— *Нәгыймә аулак өй дип бик иркенләп утырмасын, сугуларын суксын.* М. Гали.

3. *рәв. мәгъ.* **иркенләп.** Иркен һәм уңай булырлык итеп, җайлап. [*Шәймәрдән*] *тарантаска иркенләп, җәелеп утырды.* Қ. Нәҗми.

4. Үзе теләгәнчә яшәү, эшләү, иркенлек алу. *Йомшак урынга чишендереп яткырган бала, бераз шулай иркенләгәч тә, яңадан йокыга китә.* Г. Минский. *Ут иркенләде, ботактан ботакка йөгерә башлап, минуттан минутка кыза һәм ялкынлана бара иде.* Г. Тукай. // *рәв. мәгъ.* **иркенләп.** Үзе теләгәнчә, ничек кирәк шулай, рәхәтләнеп. *Октябрьдан соң --- масса күләмендәге халык әдәбиятына да, масса иҗатына да иркенләп тармакланып үсәргә юл ачылды.* М. Җәлил. *Бары безнең Хәят бу урамнарда иркенләп бара алмады: еш-еш очраган татарлардан ул йөзен качыра барырга тиеш иде.* Ф. Әмирхан.

5. Кысынкылык, газап, авырлык һәм мәшәкатьләрдән котылып, җиңеллек сизү. *Ми үзен баскан нидидер авырлыктан котылган сымак бер иркенләде.* Ф. Әмирхан. *Аңар бирдем азатлык мин, Үзем дә шул вакыт күрдем: Тынычлап калды, никтер, Һәм тәмам иркенләде күңлем.* Г. Тукай.

◇ **Иркенләп сулыш (сулу, тын) алу** — *к.* иркен сулау. *Ул шулай дигәч, Каюм белән Әхмәт иркенләп сулыш алдылар.* Ш. Камал. *Аның мине яклап чыгуы минем өчен бик зур җиңеллек булып төште, иркенләп тын алдым.* М. Гафури.

ИРКЕНЧЕЛЕК *и.* 1. Теләгәнчә эш итәргә мөмкинлек. *Габдуллага үз чаршавы эчендә урын ягыннан да, вакыт ягыннан да иркенчелек туды, һәм ул хикәя язарга утырды.* Ә. Фәйзи.

2. *иск. к.* ирек (3—5 мәгъ.). *Үзләренә иркенчелек сораган Питербург рабочийларын ни өчен ул патша аттырды, үтертте?* РСДРП прокламациясе. *Революцион көрәш нәтиҗәсендә азмы-күпме әдәбият һәм матбугат иркенчелегенә ирешелде.* М. Гали.

3. *күч.* Муллык, җитенкелек (ашау-эчүгә, кием-салымга карата). [*Ачлык елларда*] *Сәмәрканд белән Ташкент ягында ашауга иркенчелек* [*булган*], *ди.* И. Гази.

ИРКЕНӘЮ *ф.* 1. Киңәю, күләм ягыннан зураю. *Кырга җәелеп, иркенәеп, Бер кинәнеп су ташый.* М. Җәлил. [*Парикмахерскаяга*] *кергәндә бүрегем баш очында гына тора иде, чыкканда күзләремә чаклы батты, --- бүрек эче иркенәеп калды.* Ф. Хөсни.

2. Җиңеләю (сулыш, тын турында). *Иркенәеп китә авыр сулышлар да, күкрәк бушап кала, түзмәс йөрәк тына.* Ш. Маннур.

3. *күч.* Үзе теләгәнчә яши башлау; иркенлек алу. *Алар үзләре генә калгач, тагын да иркенәебрәк киттеләр.* Ш. Камал. [*Игумен*] *булмагач, монахлар тагын да иркенәйделәр. Эш аз. Теләсәң җиде көн, җиде төн буенча бер тоташтан йокла.* К. Нәҗми.

4. *күч.* Рухи яки физик авырлыктан соң җиңеләю, рәхәтлек сизү. *Бу тетрәткеч тойгылар узгач, аның күңеле, яңгырдан соң саф һава бөркелгәндәй, иркенәеп, рәхәтләнеп кала иде.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Политик, экономик кысынкылыктан котылу, рәхәт яши башлау.— [*Сез*] *коммуна булгач кына иркенәйдегез.* М. Фәйзи. *Дөньялар иркенәеп* [*бер*] *җиелсак, бу көннәрнең истәлеге итеп күрсәтерсең үзләренә.* Қ. Нәҗми.

6. *күч.* (Эш) кимү, (эштән) бушану. *Урып-җыю эшләре бераз иркенәя төшкәч тә, аларның туйлары булды.* Г. Әпсәләмов.

ИРКӘ *с.* 1. Сөелүне, назлауны, иркәләүне ярата торган. *Иркә күгәрченем, я, хуш инде, күзләреңнән үбим тагын бер...* Ш. Маннур. *Ул бик иркә кыз, мин язуны карый башлагач, йөгереп килде дә алдыма сикереп менеп утырды.* М. Гали. // Сөелә торган, кадерле. *Өстендәге ак челтәр иңсәле бәрхәт бишмәте, песи бүрege, аякларындагы җылы йон оегы белән йомшак сары башмаклары аның --- эти-әнисе өчен үтә кадерле, үтә иркә бала икәнен әйтеп торалар.* Г. Гобәй. *Бер соры куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән.* А. Алиш.

2. Артык иркәләүдән узынган, көйсез; назлы. *Иркә бала, кагыйдә буларак, ялкау була.* Г. Гобәй. *Иркә малай үзенең ятлап алган җавабын берьюлы гына әйтми, боргаланып, назланып тора яки кыланып берәр тозсыз сүз белән җавап кайтара иде.* Э. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* Артык иркәләнеп, наз күреп, назланып. *Малай бик иркә үсте. --- Аңа җил-буран тидермәделәр. Хәлим ни сораса, шуны алып бирергә тырыштылар. Ни теләсә, шуңа ирек куйдылар.* И. Гази.

3. *и. мәгъ.* **Сөекле, яраткан кеше (гадәттә кыз).** *Тик ярата белгән кеше генә Сагына шулай үзенең иркәсен.* С. Хәким. *Рәхмәт сезгә, илнең иркәләре, Көләч йөзле, кыйгач кашлылар.* М. Җәлил.

4. Ягымлы, назлаучан, йомшак (сүз, караш, җил һ. б. ш.). *Иркә сүзләр сөйләр идем Көтә белгән иркәмә.* Ә. Еникәй. [*Ул игеннәр*] *иркә җилләр белән дулкынланып, Тау итәкләп сузылып киткәннәр.* Ш. Маннур. // Назлы, назланучан.— *Сиңа кем кирәк соң? — диде хатын шаян иркә тавыш белән.* М. Әмир. // *рәв. мәгъ.* Ягымлы итеп, назлы итеп. *Ул да, сөеклем, бәгырем дип, минем исемемне бик иркә, бик йомшак кына кабатлый иде.* А. Шамов. *Нажия аңа сарылып, гадәтенчә иркә еламсырап, --- ялварып та карады.* Ә. Еники.

5. *и. мәгъ.* Иркәләү, яратып карау, наз. *Аның бала вакыты ата-ана иркәсендә бик кызык һәм бәхетле булып үтте.* Ш. Әхмәдиев. *Гөлбикә егетнең куенына кереп югалды, иркәгә, сөюгә сусап кипкән иреннәр бер-беренә юлыгып дөньяны оныттылар...* Г. Ибраһимов.

◇ **Иркә тай** — яратуны көтеп, сырпаланып йөри торган кеше. [*Айбала*] *әле һаман юрганнар эчен-*

дә иренеп яткан дустын шаяртып шелтәләде: «Иркә таем, син ни кылып һаман ята бирәсең? Кузгалсаңчы!» Г. Ибраһимов.

ИРКӘК *с. иск.* 1. Ата женесендәге.— *Гавам баласы, кирәк иркәк, кирәк кыз бала булсын, --- [бераз] өйрәнсә, шул җитә.* Г. Камал. *Тәңреләр аңар бер кыз гына багышладылар, --- бәлки [әле] иркәк бала да багышлардар.* Ш. Әхмәдиев. // *и. мәгъ.* Шул женестәге кош яки хайван.— *Торналарның иркәге генә кычкыра, мин исә ана торна, мин кычкыра белмим.* Ак юл. // Ирләргә хас, ирләрнеке кебек. *Сабир хәзрәт --- иркәк йөзле, киң иңсәле, сәламәт адәмдер.* Г. Камал.

2. *и. мәгъ.* Ир женесендәге кеше, ир.— [*Алла*], *Һаваны ясаган кебек, кабырга шәрифеннән бер иркәк тә ясап бирмәде.* Г. Гобәй. [*Хатын*] *элекке ирен сагынып елады: «Ясаган иямә үпкәм зур, чичә! Күрек бирмәсә дә, акыллы бер иркәк биргән иде...»* Г. Ибраһимов.

ИРКӘЛЕ *с.* Иркә, сөю белдерә торган, ягымлы. *Мин алар белән исәнләшергә, сөеклем, бәгырем, кадерлем дип иркәле, йомшак сүзләр әйтергә күңелемнән атналар буенча хәзерләнгән идем.* А. Шамов. *Бу сүзләрне әйткәндә, Нәсимәнең күзләрендә ачулы караш беткән, хәтта, киресенчә, алар көлемсерәүгә тартым иркәле караш белән карый иделәр.* Ш. Камал.

ИРКӘЛЕК *и.* 1. Иркә (1—2 мәгъ.) булу, назлану, иркәләнү. [*Бу зарда*], *арка-җилкә сызлавыннан да бигрәк, бераз картлык иркәлеге дә* [*бар иде*]. Г. Бәширов.

2. Иркәләү, назлау, сөю.— *Минем уемча,* [*аның*] *йөрәгендә Ирочкага карата да җылы мәхәббәт һәм иркәлек табылыр.* Г. Кутуй. [*Ул*] *баласының --- моңа кадәр анасына гына биргән йөрәк җылысын, иркәлеген һәм назын һич кызганмый шул кызга бирүен* [*теләмәде*]. Ш. Хөсәенов.

ИРКӘЛӘНҮЛЕ *с.* Иркәлек, иркәләнү хисе белдергән. *Хатын-кызларга гына хас назланулы, иркәләнүле йомшак тавыш белән Халисә сүз куштым.* С. Рафиков.

ИРКӘЛӘҮ *ф.* 1. Үбеп, җиңелчә кочып, сыйпап ярату, сөю хисе белдерү; назлау. *Мин аз беләм анам иркәләвен, Алдына алып, үбеп сөюен.* Ш. Маннур. *Бу минутта Шаяхмәтнең Шәфикасын күрәсе һәм аның башыннан сыйпап иркәлисе, кочаклап аласы --- килеп китте.* А. Әхмәт. // Кешегә яки берәр нәрсәгә күз карашы, җиңелчә хәрәкәт, сүз һ. б. ш. белән рәхәтлек, рухи ләззәт бирү. *Иркәли һәм сөя Кояшның яктысы.* Г. Тукай. *Хәйдәрнең ягымлы тавышы колакны иркәли.* Г. Бәширов.

2. Кирәгеннән артык җиңел тормыш шартлары тудырып, тулы рәхәттә яшәтеп, теләсә нәрсә эшләргә юл куеп бозу (гадәттә балалар хакында әйтелә). [*Кадрия:*] *Шаулыйлар ич, бу тавышка бала ничек йоклысын, шуның өстенә, көн эссе.* [*Таһир:*] *Иркәлисең, килен, иркәлисең, баланы алай тәрбияләргә ярамый. --- Баланы никадәр иркәләсәң, шулкадәр бозыла гына.* Т. Гыйззәт.— *Төпчек кызым, бәхетле кызым дип, үзем иркәләп бетердем, үзем...* Ф. Бурнаш.

ИРКӘЛӘҮЛЕ *с.* Иркәләү, назлау хисе белдергән. *Иркәләүле караш.*

ИРКӘЛӘҮЧӘН *с.* 1. Ярату, сөю, наз белдергән, ягымлы, рухи канәгатьлек бирә торган. *Гәрчә инде мин балалык яшеннән күптән чыккан булсам да, сезнең иркәләүчән сүзләрегезне ишетәсем килә.* Қ. Нәҗми. *Муса ягымлы, иркәләүчән, йомшак тавышы белән бәхәскә катнаша иде.* М. Максуд.

2. Рәхәтлек бирә торган. *Иртәнге кояшның иркәләүчән җылылыгында һәрнәрсәдән иренчәк пар күтәрелә.* Ә. Камал.

ИРКӘМ *и.* Сөеп, иркәләп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Күмелгәнсең ак мамык мендәргә, Толымнарың җәеп син, иркәм. Сине өзелеп сагынып, сөю белән янып, Тәрәзәңне чиртәм мин иртән.* Х. Вахит.— *Мин сине иркәм диярмен, ярыймы? Әбием дә мине, иркәм, ди, яратканкешегә шулай дип әйтәләр, ди. Мин дә сине яратам бит.* М. Фәйзи.

ИРКӘЧ *и. диал.* Үзен сөйгәнне, иркәләгәнне яратканкеше; иркә (1 мәгъ.). *Һи-һи икән бикәчем, кая китте иркәчем?* Мәкаль.

ИРЛАНД: ирланд теле (әдәбияты) — Ирландиядә яшәүче төп халык теле (әдәбияты).

ИРЛА'НДИЯЛЕ *и.* Ирландиядә яшәүче төп халыкның бер кешесе. // Чыгышы белән Ирландиядән булган, шуннан күчеп килгән. // *күпл. җыйг. и.* **ирландиялеләр.** Ирландиянең төп халкы. *Инглиз теле британлылар теле генә түгел, бәлки ирландиялеләр, австралиялеләр теле* [*дә*]. В. Хаков.

ИРЛЕ *с.* Ирдәге, кияүгә чыккан. *Мәдинәдән авылдагы байтак кына ирле хатыннар көнләшкән.* К. Нәҗми. [*Мөгълифә*], *Сәрбиҗамалга ясаган тормыш трагедияләрен --- башка ирле хатыннарга да ясап, бик күп семьяларның тормышларын боз*[*а*]. М. Гали.

ИРЛЕК *и.* 1. Ир (1 мәгъ.) булу. [*Әхмәтҗан*] *Җаббар Гайниясе алдында сакалын сәлперәйтеп сөйләшеп торуны үзенең ирлек дәрәҗәсен түбәнәйту дип карый иде.* Ф. Хөсни. *Егет чыннан да үзен Тамара Сергеевна яныңда бары ирлек вазифасын үтәп торучы итеп кенә таный иде шикелле.* Ә. Еники.

2. *күч.* Батырлык, ныклык, кыюлык. *Кыенлыкта күренә кыюлык, Ил батырны сыный батканда. Ирлек сорый көрәш егеттән, Иреше өчен бөек өмиткә.* М. Җәлил. *Бу дошманнар белән көрәшергә көчле гайрәт, зур ирлек кирәк.* М. Гафури. // Егетлек.— *Хатын-кызга кул күтәрү ирлек түгел.* Н. Исәнбәт. *Балалар белән сугышу да ирлек булдымы инде?* А. Алиш.

ИРЛЕКЛЕ *с.* Ирлек (1—2 мәгъ.) сыйфатына ия булган. *Сабир бөтен табигате белән ир, чын мәгънәсе белән ирлекле булса, Зыяның йөрәгендә, җан вә яратылышында анасы Зөләйхадан, гомумән хатынлыктан бераз өлеш бар кебек.* Г. Ибраһимов. *Ир булу гына җитми, ирекле һәм ирлекле ир булырга кирәк.* Н. Исәнбәт.

ИРЛЕ-ХАТЫНЛЫ *с.* Ир белән хатын мөнәсәбәтендәге, өйләнешкән. *Өйнең аскы катында торучы ирле-хатынлы хезмәтчеләр — Гыймади һәм Гайниямал белән ул аеруча кызыксынды.* Ә. Фәйзи. // *рәв. мәгъ.* Ир белән хатын бергә; парлап.— *Бер көн ирле-хатынлы икәү генә чәй эчеп утырабыз.* Ш. Камал. *Сырның бозаулар вакыты җиткәч,* [*алар*], *төннәр буе йокламыйча, ирле-хатынлы алмаш-тилмәш саклап утырдылар.* И. Гази.

Ирле-хатынлы булу — өйләнешү. *Ул инде бу кеше белән ирле-хатынлы булып гомер итәргә --- дип күңеленә беркетеп тә куйган.* Ф. Хөсни. *Бу кыз белән* [*егет*] *ирле-хатынлы булып тора башлаганнар.* Әкият.

ИРЛӘ'РЧӘ *рәв.* Ирләр кебек, ирләргә хас. *Нәфисә үзенең беләгендә аның ирләрчә ныкулын* [*тоя*]. Г. Бәширов. *Кылычым булса кынымда, Карабиным кулымда, Сине саклап, туган җирем, Мин ирләрчә үләр идем Данлы сугыш кырында.* М. Җәлил.

ИРМӘК I *ярд. ф. иск. кит. к.* булу. *Бал-шикәр тик датлу ирер сүзләрең.* Г. Кандалый. *Гәүдәсе юк, бер гөҗәеп баш ирер, Шаһит ирер, ике күзе яшь ирер.* Г. Тукай.

ИРМӘК II *и. диал.* Кызык, юаныч. *Уку һәм язу белән ирмәк табам.* М. Фәйзи.— *Һәй, мондый давыл ирмәк кенә ул* [*диңгезче*] *өчен.* Р. Ишморат.

ИРМӘКЛӘНҮ *ф. диал.* Кызык табу, юаныч табу, юану. *Атлар, юргалар белән дә ирмәкләнмим. Аучылык та кызыктырмый.* М. Фәйзи.

ИРНӘҮ *и.* Чүлмәк, чиләк, кисмәк кебек савытның авыз тирәсендәге калынаеп, кайтарылып торган кырые, чите. *Шешә ирнәве.* □ *Зыр-зыр әйләнгән такта өстендәге әлеге балчык кисәге түгәрәк форма ала, тагы*

бераз әйләнгәч, чүлмәкнең ирнәүләре дә үсеп чыга. М. Госманов.

ИРНӘҮЛЕ *с.* Ирнәве булган, ирнәве бар. *Виктория-региянең ирнәүле яфрагы.*

ИРНӘҮЛӘҮ *ф.* Ирнәү ясау.

ИРО'НИК *с. к.* иронияле. *Монда «кем белә?» фразасы гына бераз ироник төс алган.* Л. Җәләй.

ИРО'НИЯ *и.* 1. Читләтеп, мыскыллап, астыртын көлү. *Сәфәргалинең тавышындагы, сүзләрендәге ирониянә шунда ук тотып алган Фәсхи, --- егетнең болай һавалы сөйләнүен ошатып җиткермичә, әйтеп куйды.* Ф. Хөсни. *Газиз көлеп, ирония белән: «Менә һәйбәт кыз инде ул. Барасы киявенә аяк чолгаулары чигеп ята торгандыр»,—* [*диде*]. Ф. Әмирхан.

2. *әд.* Берәр кешене яки әйберне мактаган булып, алардан яшертен көлүдән гыйбарәт стилистик әйләнмә яки сүз. *Мактаган булып мыскыллауның, ягъни ирониянең иң көчле үрнәге* [*Г. Тукайның*] *«Мөнтәкыйть» («Тәнкыйтьче») шигырендә бирелгән.* Ә. Исхак.

ИРО'НИЯЛЕ *с.* Ирония белән сугарылган, ирония белдергән. *Ирониялә тавыш.* □ *Дунаев,* [*Әхмәтнең*] *сүзен бүлдереп: «Ә безгә чәчәкләр дә, бакчалар да кирәкмәс, дип уйлыйсыңмыни?» — диде һәм ирониялә тон белән өстәде: «Гафу итә күр, пожалуйста, пролетариат өчен чәчәкләр дә, бакчалар да һич тә зарарлы әйберләр түгел...»* Ш. Камал. [*Әти*] *йөзенә ирониялә елмаю чыга.* Ә. Камал.

ИРРАЦИОНАЛИЗМ *и. филос.* Идеалистик философиядә иң реакцион юнәлеш; ул, чынбарлык закончалыкларга нигезләнмәгән һәм шуңа күрә аны танып белүгә кеше акылы ирешә алмый, дип раслый, фәнни логик танып белүне инкяр итә.

ИРРАЦИОНАЛЬ *с.* 1. *филос.* Законча лыклары булмаган һәм шуңа күрә кеше акылы белән танып беленә алмый торган, логик төшенчә белән аңлатып бирү мөмкин булмый торган.

2. *мат.* Берәмлек белән үлчәнми, шуңа күрә бөтен һәм вакланмалы сан белән төгәл бирелми торган. *Иррациональ саннар.* // Арифметиканың дүрт төп гамәленнән башка тамыр алуны да күздә тоткан. *Иррациональ тигезләмә.*

ИРРИГА'ТОР *и.* Ирригация буенча белгеч.

ИРРИГА'ЦИЯ *и.* Коры яки дым аз булган җирләрне ясалма рәвештә сугару. *Ирригация челтәре. Ирригация эшләре. Ирригация системасы. Караком каналы — зур ирригация корылмасы.*

ИРРР *авазияр.* Гөберле бака кычкырганда чыккан нечкә тавышны белдерә. *Яшел гөберле бакалар --- нечкә тавышлы: «Иррр... иррр... иррр...» Шушы калтыраулы тавышлары аларның кавышу җырлары инде.* Г. Хәсәнов.

ИРСЕТҮ *ф. диал.* Узындыру, кәпрәйтү.— *Юк, юк, дүрт мәртәбә пәрдә ачтырып чыгарырга сез... Нишләтәсез туташны? Аннан соң публикацияны да ул чаклы ирсетергә ярамый.* Н. Исәнбәт. // Ярсыту.

ИРСӘК *с. сөйл. шелт.* Ирләрне ярата торган, ирләр артыннан йөри торган (хатын-кыз турында). *Ирсәк кыз иргә китмәс, Ашыккан өенә җитмәс.* Мәкаль.

ИРСӘКЛЕК *и.* Ирсәк булу сыйфаты.

ИРСӘҮ *ф.* Ирләргә чамадан тыш омтылу (хатыннар турында).

ИРСҮ *ф. диал.* Масаю, кәпрәю, узыну.— *Ирләргә ул сүзне бик әйтергә ярамый, ирсеп китәр. «Сагындым»ны башта ул әйтсен.* Н. Исәнбәт. // Ярсу.

ИРТӘ *и.* 1. Тәүлекнең бер өлеше, көннең беренче сәгатьләре, көннең башы. *Иртә. Дөнья җанлана, Мәшрикъ ягы аллана, Кояш чыгып, нурлары Төшеп җиргә ялгана.* Г. Тукай. *Иртә бик аяз һәм тын иде. Алар Мәскәү турына җиткәндә, тәмам якты иде.* М. Гали.

2. *күч. шигъ.* Берәр нәрсәнең башлангыч чоры, башы. ***Син түгелме сөю нурың белән кабызучы гомрем иртәсен?*** М. Җәлил. *Пролетариат язучысы --- бүгенге социалистик экономиканың иртәсе алып килгән җиңүләрне айнык рәвештә алдан күрергә* [*тиеш*]. Һ. Такташ.

3. *рәв. мәгъ.* Иртә белән, иртән, иртәнге сәгатьләрдә. *Урманда кар агач башыннан. Бүген иртә юл салынган булса, төштә аны кар басып китә.* Г. Ибраһимов. *Иртә исемдә, кич төшемдә, яныңа бармасам да.* Җыр. // *с. мәгъ. иск.* Иртәнге, иртә белән. *Аю яки арысланнар, ичмаса, иртә чәйгә бер кыр кәҗәсе яки бер үгез хәзерлиләр.* Г. Тукай. *Иртә сәгать уннарда --- [палубага] чыктым.* Ф. Әмирхан.

4. *к.* иртәлек (2 мәгъ.). *Пионер иртәсе.*

5. *рәв. мәгъ.* Гадәти, билгеләнгән вакытка кадәр; вакытыннан элек. *Иртә яту. Иртә үлү.* □ *Аның мондый нәтиҗәгә килүе, минемчә, иртәрәк тоелды: «Көрәш башланды гына әле, дус,— дидем мин,— нәтиҗә чыгарырга ашыгырга ярамый».* М. Әмир. *Быел иген бик уңган иде. Ләкин көз бик иртә килде.* Г. Ибраһимов. // Алдан. *Иртә кычкырган күкенең башы авырта.* Мәкаль. *Яшь балалы хатыннар эштән иртәрәк кайта.* Г. Гобәй.

6. *с. мәгъ.* Башкалардан алда күренә яки өлгерә торган. *Бәрәңгенең һәм яшелчәнең иртә өлгерешле сортлары.* □ *Кар бетү белән диярлек Ибрайның иртә шалканнары өлгерә.* М. Әмир.

7. *хәб. функ.* Билгеләнгән, тиешле вакытның килеп җитмәве турында. *Иртә әле безгә картаерга, Илебез өчен бик аз эшләдек.* Г. Хуҗи.— *Күй, балам, су керергә иртә әле.* М. Гафури.

8. *рәв. к.* иртәгә (1 мәгъ.). *Бүген берәү, иртә тагын — артып тора гел ише.* Г. Камал. *Уракка чыгарга вакыт җиткән бит, иртәдән калырга ярамас.* М. Гали.

Иртә белән — иртән, көннең башында. *Матур кояш иртә белән кызарып күк йөзенә күтәрелде.* Дәрдмәнд. *Һәр көн иртә белән, кояш чыкканчы ук, Мөхәммәтҗан бабай безне килеп уята.* М. Гали. **Иртә буаз** *а.-х.*— кыш башында яки январь, февраль айларында бала китерергә тиеш булган (хайваннар турында). **Иртә намаз(ы)** *дини*— таң яктылыгы җәелгәннән башлап, кояш чыга башлаганчы укыла торган намаз; биш вакыт намазның беренчесе. *Таң алдыннан, иртә намазыннан элек, шәкертләрнең һичберсе калмыйча урыннарыннан торырга мәҗбүрләр.* М. Гафури.— *Иртәгә иртә намазына таң атканчы ук җыйналырга* [*булдык*]. Ф. Хөсни. **Иртә пар** *а.-х.*— яздан эшкәртелеп, көзгә кадәр бернәрсә дә чәчелми торган җир.— [*Алар*] *иртә парларын сөрергә, печәнгә чыгарга эшче көчләре сорап миңа килгәннәр иде.* Т. Гыйззәт. **Иртәдән соң** — берсекөнгә.— *Мин ике генә көнгә кайттым. Иртәдән соң китәм...* Г. Ибраһимов.

◇ **Иртә таңнан** — бик иртә, иртүк. *Иртәгә мин иртә таңнан шәһәргә китәм.* Ш. Камал. [*Алар*] *иртә таңнан ук --- уйнарга тотынганнар.* К. Нәҗми. **Иртә таңнан кара төнгә кадәр (хәтле, чаклы)** — *к.* иртәдән кичкә кадәр. *Тимерчелектә чек-чек чүкеч тавышлары иртә таңнан кара төнгә кадәр ишетелеп тора.* Г. Гобәй. **Иртә туып кич калган** — бик акрын кыймылдаучы, юнсез кеше турында. **Иртә юк, кич юк** — вакытсыз, кешеләрне борчып.— *Иртә юк, кич юк, туктаусыз лыгырдаталар да йөрилә р.* Г. Ибраһимов. **Иртәдән кичкә кадәр (хәтле, чаклы)** — көнозын, көне буе. *Олылар иртәдән кичкә кадәр кырда кар тота.* Г. Әпсәләмов. *Иртәдән кичкә хәтле бер локма аш капмадым.* Ш. Камал.

ИРТӘГЕ *с.* 1. Бүгенге көн артыннан киләчәк, алдагы, чираттагы, туачак (көн турында).— *Миңа иртәге көн өчен пыялалар кисеп куярга кирәк.* Д. Аппакова. // *и. мәгъ.* Шундый көн. *Сагындыра мине Ул көннәрнең матур тезмәсе, Ә шулай да бүген үтәр-үтмәс, Иртәгене килә күрәсе.* Ш. Маннур.— *Опера театрына иртәгә өчен дүрт билет* [*алдым*]. Р. Ишморат // Киләсе көндә булачак, **иртәгәге.** *Өстәл янында бер сабый Ян тәрәзә каршысында иртәге дәресен карый.* Г. Тукай — *Миңа га-*

зетаның иртәге номерына --- материал оештырырга кирәк. А. Әхмәт.

2. *иск. к.* иртәнге.— *Әгәр баланың иртәге аш берлә көндезге аш арасында --- ашыйсы килсә, син аңар бер стакан сөт [бир].* **Г. Тукай.** *[Малай] иртәге чәйгә коймак ашарга чакырган.* Ш. Мөхәммәдев.

Иртәге имәзә *иск.*— якын-тирәдәге нәрсәләр күренер-күренмәс кенә булып таң сызылып килгән вакыт. **Иртәгәдән соң** *диал.*— берсекөнгә.

◇ **Иртәге көн** — *к.* иртәгәге көн. *Бүгенге көн [буржуазия] өчен канәгатьләнерлек булса да, иртәге көн инде аның өчен үлем хәзерли.* М. Җәлил.

ИРТӘГЕДӘН *рәв.* Иртәге көннән (башлап).— *Иртәгедән Рөстәмне үз тәрбияңә алырсың.* **Т. Гыйззәт.**— *Безгә иртәгедән калмыйча фронт гаскәрләренә кушылырга приказ бирелгән.* Ш. Усманов.

ИРТӘГЕСЕ *с. к.* иртәге (1 мәгъ.). *Иртәгесе көнгә каршы төндә Без утырып байрак тегәбез.* Һ. Такташ. *Бабай иртәгесе көнне дә, аннан соң да кайтмады.* Г. Гали. // *и. мәгъ.* Бүгенге көн артыннан киләчәк көн; алдагы, чираттагы көн. *Хәлим гармонен сузып җибәрде. Иртәгесен дә сузды. Аның иртәгесендә дә...* Г. Гобәй.

ИРТӘГЕСЕН *рәв.* Икенче көнне, бер көн узгач. *Якуб, ул төнне Васильевта кунып, иртәгесен авылларга чыгып китте.* И. Гази. *Иртәгесен иртә белән бөтен авыл аякка басты.* А. Шамов.

ИРТӘГӘ *рәв.* 1. Бүгенге артыннан ук килгән көнгә; икенче көнгә.— *[Ул] бүген булмаса, иртәгә кайтып җитәр, бер көннән ни була?* Ә. Еники. *Иртәгә дә яши алыр өчен, Бирешмәскә кирәк бүген дә.* Х. Туфан. *Бүгенге эшеңне иртәгә калдырма.* Мәкаль.

2. *и. мәгъ. күч.* Киләчәк. *Мин үземне сүгәм, үкенеп түгел, Иртәгәмне сөеп...* Ә. Фәйзи.

ИРТӘГӘ-БЕРСЕКӨНГӘ *рәв.* Якын көннәрдә, тиздән.— *Ифрат! Мине иртәгә-берсекөннәргә Казанга озатасың инде.* А. Расих.— *Иртәгә-берсекөнгә һөҗүм башлыйбыз.* Ф. Кәрим.

ИРТӘГӘГЕ *с.* Бүгенге артыннан ук килгән, алдагы. *Бүген җыеп алыр игеннәрне Иртәгәге көнгә [калдырма].* Ф. Кәрим. // Бүгенге артыннан ук килгән көнге, алдагы көнге. *Иртәгәге эшеңне бүген эшлә.* Мәкаль.

◇ **Иртәгәге көн** — якын киләчәк. *Электростанцияләр — --- алар өчен тормыш мәсьәләсе, ул аларның иртәгәге көне.* Г. Әпсәләмов.

ИРТӘГӘДӘН *рәв.* Иртәгесе көннән, иртәгә.— *Уземә тапшырылган эшкә мин иртәгәдән үк тотыначакмын.* Р. Ишморат.— *Иртәгәдән калмый кайт, балам!* М. Гафури.

ИРТӘГӘЛЕ-БҮГЕНЛЕ *рәв.* Я иртәгә, я бүген; шушы көннәрдә, тиздән.

ИРТӘГӘЛӘК *рәв.* Иртәгәге көнгә җитәрлек.— *[Өйдә] шикәр иртәгәлек кенә калды.* Ә. Фәйзи.— *Күмер беткәнне правлениедә беләләрме? Монда иртәгәлек тә юк бит, әйткәнең бармы аларга?* Г. Галиев.

ИРТӘГӘСЕ *с. к.* иртәгесе. *Иренмәгән — иртәгәсе эшен бүген бетергән.* Мәкаль.

ИРТӘГӘСЕН *рәв. к.* иртәгесен.— *Бу сезнең бары бүгенге көн белән генә мавыгып йөрүегезне, киләчәк турында уйламавыгызны, --- бүген көн үтсә ярар, иртәгәсен ишәк кайгыртсын, дип яшәвегезне күрсәтмиме соң?* Ә. Еники. *Иртәгәсен мин трактор гөрләвен ишетеп уяндым.* М. Әмир.

ИРТӘГӘЧ *рәв. диал.* Икенче көнне иртән. *Иртәгәч шул хәлне көтүчеләр үзләре кайтып әйттеләр.* Г. Толымбай

ИРТӘ-КИЧ *рәв.* Иртә дә, кич тә, иртән һәм кичен. *Аны ел буе берәзлексез һәр иртә-кич су керә дип сөйлилар.* Г. Кутуй. *Һәр көн иртә-кич --- эшче халык диңгез буена тарала.* Ш. Камал. // Көнозын. *Без күптән инде көтелгән, иртә-кич телдән төшми килгән Павлодар шәһәренә килеп җиттек.* Н. Фәттах. *Гарәфи абзый биленнән иртә-кич төшми торган алъяпкычын алып, аны хатынына бирде.* Г. Әпсәләмов.

ИРТӘКЧЕ *и. бор.* Әкият сөйләүче кеше. *[Җыенда] иртәкчеләр (әкият сөйләүчеләр), әйтүчеләр (җырчылар), уенчылар ярышкан.* И. Рәмиев.

ИРТӘЛЕК *и.* 1. Иртә булу.— *Вакыт буенча иртә иртәлеген. Әмма җир кибү сәбәпле, иртәгәдән калу яра-мый.* Ш. Камал. *Былтыр Габдулла русча укырга йөрүне үзе сораган иде. «Сиңа иртәрәк әле!» — дип, аның соравын кире кактылар. Иртәлектә түгел иде хикмәт.* Ә. Фәйзи.

2. Иртән (күбесенчә балалар өчен) үткәрелә торган спектакль, тамаша; *русчасы:* утренник. *Мәктәптә дингә каршы иртәлек. Бибигөл рухланып хорда җырлый.* Ш. Мөдәррис.

ИРТӘЛЕ-КИЧЛЕ *рәв. к.* иртә-кич. *Ул кайдадыр эшкә йөридер иде, ахрысы, иртәле-кичле безнең капка алдыннан үтә иде.* Ш. Камал. *Һәр көн иртәле-кичле эре хәрефләр белән басылып таратыла торган «Сугыш хәбәрләре» дигән бюллетеньнәр ике көннән бирле таратылудан туктады.* М. Гафури.

ИРТӘЛӘЙ *рәв. диал.* Вакытыннан элек, иртә. *Йөрәк чире әнине бик иртәләй гүргә алып киткән.* Э. Касыймов.

ИРТӘЛӘРЕН *рәв.* Һәр көн иртән. *Иртәләрен ап-ак булып кырау төшә.* Г. Бәширов.

ИРТӘЛӘҮ *ф.* 1. Иртән иртүк берәр кая кузгалу (килү, бару, эшләү һ. б. ш.).— *Иртәләгәнсез, тутиләр! --- — Җиребез бик ерак! Шуңа күрә кузгалдык.* И. Гази.

2. Берәр эшне вакытыннан элек эшләү. *[Илдар:] Дания, син бүген иртәләгәнсең. [Дания:] Нишләп иртәлим? Мин көндәгечә. Менә син үзең бүген соңладың?* Т. Гыйззәт. *Алар ашап бетерергә дә өлгермәделәр, пароход килеп тә җитте. Иртәләде бүген.* И. Гази.

ИРТӘ!МЕ-СО!ҢМЫ *рәв.* Киләчәктә, кайчан да бер (берәр нәрсәнең һичшиксез булачагы турында). *Хатынның күңелендә кискен бер карар туды: «Иртәме-соңмы, теләпме-куылыпмы,— һәрхәлдә ул моннан китәчәк».* Г. Ибраһимов. — *Барыбер аңа да, иртәме-соңмы, йортлы булырга кирәк.* Ә. Еники.

ИРТӘН *рәв.* 1. **Иртә белән, иртәнге вакытта.** *Иртән торып таңнар илә көтү куа көтүче.* Г. Тукай. *Иртән кызылланып --- Кояш чыга... Күктә таң ата...* М. Җәлил. // *и. мәгъ. к.* иртә (1 мәгъ.). *Ни өчендер бик сөям мин җәйге көннең иртәнен.* М. Гафури. *Иртәнгә таба җил басылды.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *сир.* Икенче көнне; иртәгә. *Бүген бездә баш күтәрсә, иртән сездә, Һәр җирдә дә кузгалыр, калмас көзгә.* Г. Камал.

ИРТӘНГЕ *с.* Иртә белән. — *Миңа иртәнге алтыда торырга кирәк.* Г. Ибраһимов. // Иртән була торган. *Иртәнге кырау.* □ *Иртәнге тынлыкны моңсуландырып этәчләр кычкыра башлады.* Г. Бәширов. *Иртәнге салкын чык малайның аякларын өтеп алды.* И. Гази. // Иртән эшләнә, иртән була, иртә чыга торган. *Иртәнге газета. Иртәнге гимнастика.* □ *[Аларны] иртәнге чәйгә чакырдылар.* М. Гафури. *Ифрат игътибар белән сыерларны карап чыкты, иртәнге савым белән кызыксынды.* А. Расих.

Иртәнге аш — 1) иртә белән ашау-эчү. *Иртәнге аштан соң картлар --- кырга киттеләр.* М. Җәлил; 2) иртә белән ашар өчен хәзерләнгән азык. *Иртәнге аш өлгергәндә, гимнастерка ямалып беткән иде инде.* А. Шамов. *Алар, инде өлгергән, парлары чыгып торган иртәнге ашлары турында онытып, балаларның эшләгәннәрен --- карап тордылар.* Г. Гобәй. **Иртәнге күлем (кавым)** *диал.* — иртәнге аштан төшке ашка чаклы булган вакыт. **Иртәнге намаз** — *к.* иртә намазы. *Ул Печән базары мәчетеннән иртәнге намазларын укып чыккан*

тук кибетчеләргә бәйләнүдән чак кына тыелып калды. К. Нәҗми.

ИРТӘНГЕЛЕК *и. диал.* Иртәнге аш. *Сахраның салкынча таңында --- иртәнгелекне капкалап алгач, [студентлар] сәгать алтыдан ук казу мәйданына китәләр.* М. Госманов.

ИРТӘНГЕСЕН *рәв. к.* иртәгесен. *Иртәнгесен төш уртасында Уфага да барып кердек.* М. Гафури. *Иртәнгесен [шаһзадә] канатны әткәсенә кертеп бирде.* Х. Кәрим.

ИРТӘНГЕ'ЧӘ *рәв.* Иртәнге кебек. *Ул, иртәнгечә, үзенең бөтен тарихын сөйләп бирде.* Г. Ибраһимов.

ИРТӘНГӘ'ЧӘ *рәв.* Иртәнгә кадәр. *Өч сарык бәрәнләгән, яңа бәрәннәрнең берсе иртәнгәчә туңып үлгән.* Г. Ибраһимов.

ИРТӘН-КИЧЕН *рәв. к.* иртә-кич. *Иртән-кичен гигант агачларның Күлгә ята тыныч шәүләсе.* Ш. Мәдәррис.

ИРТӘНЧӘК *рәв. диал.* Иртән, иртә белән. *Иртәнчәк көн ифрат суык булып, төштән соң аз гына йомшартып җибәрде.* Ш. Камал. *Иртәнчәк бераз салкынча иде, --- ә көн урталарына таба шундый кыздыра башлады.* Г. Әпсәләмов.

ИРТӘСЕН *рәв.* **1.** *к.* иртәгесен. *Мин дә кызыгып шундый бер тун алдым, Ә иртәсен ямый-ямый яңа тунымны, --- Җәрәхәтләп беттем кулымны!* Һ. Такташ. *Бүген тәмам каплап яңгыр яуса, Ә иртәсен — йомшак кар баса.* Ш. Маннур.

2. Иртә белән, иртән. *Хәлимә чәчәкләрне бик ярата торган булган: иртәсен дә, кичен дә шунда чуала икән.* Д. Аппакова. *Кызарып кояш туганда, Кызлар көтү куганда, Киленнәр каз бәбкәсен Туйдырганда иртәсен, Бу хәбәр тиз таралды.* Ш. Маннур.

ИРТӘСЕН-КИЧЕН *рәв. к.* иртә-кич. *Иңбашларына сөлге салып, [алар] иртәсен-кичен күлгә коенырга төшәләр.* И. Рәмиев.

ИРТӘСЕНҮ *ф.* Берәр нәрсә эшләү вакытын бик иртә санау, әле вакыт җитмәгән дип карау.

ИРТӘЧЕЛ *с.* Иртән торуны гадәт итеп алган. // Эшне вакытыннан алда үти торган. — *Иртәчел безнең кешеләр, бөтен хикмәт шунда! --- Көзге чәчүне иртә чәчтек. Туңга сөрүне беренчеләрдән бетердек.* С. Рафиков.

ИРТӘЧЕЛЛЕК *и.* Иртәчел булу сыйфаты. *Иртәчеллек үзе бер бәхет ул.* С. Рафиков.

ИРТҮК *рәв. сөйл.* Бик иртән; иртән үк. *Иртә белән иртүк торып, таң аткач үк --- Тагын болар урман буйлап сәфәр китте.* Г. Тукай. *Сайлауларга, иртүк торып, Таң белән килдем бүген.* **Ә. Ерикәй.**

ИР-УЛАК *җый. и.* Ирләр (1 мәгъ.). *Унсигез яшьлек малайдан башлап кырык биш яшьлек көрәк сакаллыларга тикле бөтен ир-улакны үзенең төпсез упкынына суырып алган патша армиясе өчен бер әйбер дә төткәзеп булмый.* К. Нәҗми.

ИР-ХАТЫН *җый. и.* Ир һәм хатын. *Гаилә дә уен өчен түгел, Ир-хатынның берсе-берсенә Ярдәме өчен, Җәмгатькә бирү хезмәтләрен. Юлга кую өчен төзелә.* Һ. Такташ. // *тарт. форм.* **ире-хатыны.** Ирләр һәм хатыннар. — *Ире-хатыны, олысы-кечесе бары тик шул турыда гына уйлады.* Г. Гобәй. *Зур-зур тәрәзәле кызыл йорт янында ире-хатыны бик күп кеше кайнашып тора иде.* Ф. Хөсни.

◇ **Ир-хатын булу** — өйләнешү. *Ир-хатын булгач, байтак еллар кемдә туры килсә, шунда өйдәш торып гомер иттеләр [алар].* Г. Ибраһимов.

ИР-ШАҺБАЗ *җый. и. иск. кит.* Үткен, кыю, батыр егет; ир-егет. *Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы, Назы белән аулап ала ир-шаһбазны.* Ш. Бабич.

ИРӘБӘ *с. диал.* Эре сөякле, зур (кеше турында).

ИРӘГЕШҮ *ф.* Сүз көрәштерү, каршы сүз әйтү. [*Ул*] *әлифне таяк дип белмәсә дә, «мин ысул кадим» дип ирәгешә.* Ш. Мөхәммәдев. *Аңдышкан авыл булмас, ирәгешкән ил булмас.* Мәкаль.

ИРӘК *и. бор.* Кремль. *Бу ике тамга урманын ил агалары белән бергә ирәктә (кремльдә) яңадан аларга бүләк иттек.* Каз. утл.

ИРӘМ: Ирәм багы *иск. кит. дини.* — гарәп мифологиясе буенча: борынгы бер падишаһның җәннәт кебек эшләнгән, табигатькә бай бакчасы. *Ирәм багындамы үстең? Йөрәгем бәгърене кистең.* Г. Кандалый.

ИРӘМСҮ *с. диал.* Тәкәббер, эре. *Ирәмсү кеше.*

ИРӘН *и. иск.* **1.** *дини.* Аллага якын, изге кеше. — *Изге ирәннәрнең сөякләре өстендә кәҗә йөртү һичбер килешә торган эш түгел.* К. Нәҗми. // Күзгә вакыт-вакыт күренеп бәхетсезлектә ярдәм итә торган изге кеше. — *Юлы уңсын инде, илаһи, гаип ирәннәр ярдәм күрсәтсен үзенә.* С. Баттал.

2. *күч.* Ил башлыгы. *Әгәр тели икән — килсен Чемберлен да, Якын дусты Черчилль яки Бриан белән, Европаның «мәшһүр олуг» ирәннәре Җыелсыннар да килсеннәр бары бергә.* М. Гафури. *Туры әйткән ил алдында ирән булган.* Мәкаль.

ИРӘЮ *ф. диал.* **1.** Зур булып үсү. *Ирәеп адәм булганда, ияккә сакал чыкканда Менәреңә атың да булмасынчы!* Н. Исәнбәт.

2. Эреләнү, үзен үзе зурга кую, масаю. *Гасыйм минем белән сөйләшеп тә тормас инде, борын чөяр дип уйлаган идем мин, алай булып чыкмады, --- ирәйгәнлеге сизелми.* Ш. Маннур. *Ташказар ишекне ачуга, батыраеп, ирәеп килеп керә бер кәрлә.* Әкият.

ИРҮ *и. бор.* Ял итү өчен тукталыш; *русчасы:* привал.

ИРҮЛЕ *с. бор.* Ял итәр өчен туктаган. / *и. мәгъ. Ирүлегә — карулы.* Мәкаль.

ИРҖӘНКӘ *и. диал. к.* ирдәүкә. [*Галимә*] *артык үткер, артык булдыклы инде, һич аны-моны карап тормый, Фәхри абзыйның ярты эшен алып бара бит; ул шулай артык үткер булганга күрә, аны күрәлмаучылар, «ирҗәнкә» дип әйтүчеләр дә бар инде.* М. Гафури.

ИС I *и.* **1. Җисемнәрнең, әйберләрнең борын белән** сизелә торган үзлеге. *Һавадан кара туфрак исе, яңа киселгән нарат агачы исе, черегән яфрак исе аңкый.* И. Гази. *Аның борынына, юкә, сирень чәчәкләренең нечкә хуш исе белән бергә, ак әремнең ямьсез ачы исе килеп бәрелә, аннары мәтрүшкә исе көчәеп киткәндәй була.* Г. Әпсәләмов. // Сасы ис. *Нинди ис? Һәрбер кеше борынын кысып тоткан бүген?* Г. Тукай.

2. Нәрсә дә булса янганда һава азлыктан барлыкка килә торган тончыктыргыч агулы газ. — *Әйдә, Ваня, үә бүлмәбездә ис бетте.* Т. Гыйззәт.

3. *күч.* Берәр нәрсәнең булу билгесе, галәмәте, әсәре. *Акча барда бар да дус шул, бар да яр; Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!* Г. Тукай. *Нәгыймнең бу сүзләреннән дә мыскыллау исе аңкый иде.* Ш. Камал. // *сөйл.* Берәр нәрсәнең тиздән, якын арада булу ихтималы билгесе. — *Бу начар хәл. Монда суд исе аңкый.* Ш. Камал.

Ис газы *хим.* — углеродның өлешчә генә окисьланыныннан туган төссез агулы газ; углерод окисе. **Ис тию** — 1) сөрем белән, ис (2 мәгъ.) белән агулану. — *Ис тидеме әллә, ходаем? Бик кыздырып яккан идем шул.* К. Нәҗми. *Болар икесе бер төндә ис тиюдән һәлак булдылар.* Г. Ибраһимов; 2) *күч.* исерү (1 мәгъ.). *Тик фәкать беркөнне «башка ис тигач», Азрак эчкәч, башка киткәчтән «пирәш», — Кемгәдер ул иске серне итте фаш.* Г. Тукай.

◇ **Исе дә калмау** — кемнең яки нәрсәнең дә булса бөтенләй бетүе, юкка чыгуы турында. *Элек борынын күккә күтәреп йөргән офицерлар хәзер шым булганнар. Элекке кебек аяк тибеп кычкыруларның исе дә калмаган.* Г. Ибраһимов. **Исе дә чыкмау** — бөтенләй булмау, күренмәү, ишетелмәү. — [*Алтыннарның*] *эзенә төшәргә нихәтле генә тырышып карамадык, ни аланда, ни ялан-*

да дигәндәй, һич исе дә чыкмый!.. Я ул нәрсәләр монда бөтенләй килмәгәннәр, яисә шундый оста итеп яшергәннәр. Ш. Камал. **Исе дә юк** — берәр нәрсәнең бөтенләй булмавы, табылмавы турында. *Кайтмый бүре, эзе дә юк, исе дә юк.* Г. Тукай. *Әмма бу матур утрауда карлыган дигән затлы нәрсәнең исе дә юк иде.* Э. Касыймов. **Исе керү** — берәр нәрсә бик аз гына кушылган булу. **Исе килү** — берәр нәрсәнең билгеләре сизелү.— *Бу сүзләрдән 1905 ел исе килә.* Ф. Әмирхан. **Исен иснәү** — берәр нәрсә белән беркадәр таныш, аннан хәбәрдар булу. *Хәзер ул, Габдулла, ни әйтсәң дә, гыйлем исе иснәгән, күп китаплар укыган шәкерт.* Э. Фәйзи. *«Ристан Хабул» инде элекке «суык аяк» Хабулдан башкарак, ул төрмә ачыларын татыган, бераз сәяси исне дә иснәгән.* Г. Нигъмәти.

ИС II *и.* **1.** Элекке тәэсирләрне башта саклый һәм яңарта алу сәләте; хәтер. *Исенә төшү. Истә калу.* □ *— Исеңдәме, былтыр без бервакытны кырдан тоташ чәчәкләргә чорналып кайткан идек.* М. Фәйзи. *Иртән истә, кичен төштә, һич чыкмыйсың күңелдән.* Җыр. // *тарт. форм. у.-в. кил.* **исемдә.** Ядәч аерганда: уенда катнашучыларның берсе икенчесенең кулыннан әйберне алганда уенны хәтердә тотуын, онытмавын белдереп әйтелә торган сүз. [*Әхмәт, ядәчнең үзендә калган җәбен Гөлшаянга сузып:*] *Мә, гөлем, икесен бергә җыеп куй.* [*Гөлшаян:*] *Исемдә. (Ядәчне ала).* М. Әмир.

2. *диал.* Акыл, зиһен.— *Бичараның үләр вакытына кадәре исе дөрес булып, үләр алдыннан да сөйләшеп, үзенең васыятен әйтеп --- вафат булды.* М. Гафури. *Үлгәндә дә исең дөрес булсын.* М. Җәлил.

◇ **Ис аву** — 1) һуштан язу, аңын югалту; 2) берәр кеше яки нәрсә искиткеч, һуштан язарлык әйбәт булганда әйтелә.— *Мәрьям* [*матур*]. --- [*Аңа*] *туры карап булмый, ис ава...* Ш. Камал. **Ис алу** — 1) һушка килү, аңга килү, акылны җыю; 2) һуштан яздыру, аңны югалту. *Кара киемле кеше каравылчы солдатның йөзенә бер яулык каплады. Шул минутта ук солдатның һушы китеп «гөп!» итеп җиргә егылды. Чөнки ул яулык адәмнең исен ала торган нәрсә илә даруланган иде.* Ш. Мөхәммәдев.— *Ул кычкыра башлаган иде, Таһир аның башына сугып исен алды.* М. Әмир; 3) *диал.* физик зәгыйфьлектән яки материаль кысынкылыктан соң хәл керү; хәл алу. *Мал-туар бер атна арасында ис алды, хәтта сөт тә артты.* Б. Камалов; 4) *диал.* тәжрибә туплау, чынбарлыкны тирәнтен аңлау. **Ис итмәстән (итмәгәндә)** — көтмәгәндә, уйламаганда. *Ис итмәстән хәбәр килде Сугышларга китәргә.* Бәет. *Авылга отряд көпә-көндез яисә төнлә белән ис итмәгәндә, кинәт барып керә.* Ш. Камал. **Ис керү** — 1) ачы тәҗрибәдән соң аңлы, уяу булу, нәрсәнең ни өчен икәнлеген аңлый башлау; 2) үсү, өлгерү, дәрт керә башлау (яшүсмер егет яки кыз турында). **Ис китәрү** — 1) бик нык гаҗәпләндерү, гаҗәпкә калдыру. *Моның бер генә дә түгел, ике үрдәк белән өйгә кайтышы өйдәгеләрнең тәмам исен китәрде.* Ш. Камал; 2) сокландыру, таң калдыру. *Исмәгыйль Һилалов мандолина уйнавы белән исемне китәрде. Рустан да, татардан да аны алай уйнаучыны күргәнем юк иде.* М. Фәйзи. *Сахраларда кешеләрнең исләрен китәрә торган матур вә хуш исле чәчәкләрне бизәү --- Кояш хезмәтедер.* Г. Тукай. **Ис китү** — 1) бик нык гаҗәпләнү.— *Тора торып исем китә: шундый җебеган малайга нинди кызның күзе төште икән!* Г. Камал. *— Карап торам да исләрем китә: нигә һаман шулай уйчан син?!* Г. Бәширов; 2) таң калу, таңга калу, сокланү.— *Без әле шундый тормыш корып җибәрербез, бөтенесенең исләре китәр.* Р. Ишморат.— *Яшь бала башың белән синең шулхәтле тырышлыгыңа, синең чыдамлыгыңа бөтен отрядның исе китә иде.* Ш. Камал; 3) артык игътибар итү, әһәмият бирү.— *Исе китте инде шул Әхмәткә, белмим, аның кай җиренә кызыга торгандыр?* Г. Камал.— *Орышсалар тагы, бик исем китә!* Г. Тукай. **Ис югалту (җую)** — һуштан язу; аң югалту. [*Арслан*] *тормакчы була, ләкин егыла да яңадан исен югалта.* М. Җәлил. **Ис җибәрү** — гаҗәпләндерү, шаккатыру. *Сакмар күпере төбендәге сугышта да ул күпер дамбасына басып, пуля астында шаярып торуы, җидесигез кеше җәрәхәт алган урында бер сәгатькә якын һич зарарсыз басып торуы белән бөтенесенең исләрен җибәрде.* Ш. Усманов. **Ис җыю** — 1) хәл җыю. *Кара канлы тереклек диңгезендә Исен җыйды батыр ауган җирендә.* Н. Исәнбәт; 2) зиһенне, уй-фикерне бер ноктага туплау, берәр нәрсәне аңларлык хәлгә килү. *Ис җыеп йөрдем бераз бүлмәмне буйлап уйланып, Сайрашып кызлар белән йөргәннәремне уйга алып.* Ш. Бабич. *Шундук аны капка артыннан кемдер зур кулларын сузып эләктереп алды. Габдулла исен җыеп өлгермәде, капка артында --- Шәпеш күренде.* Э. Фәйзи. **Исендә дә юк** — 1) бөтенләй онытылган.— *Тартмыйм ич мин... — Әй, истә дә юк.* Г. Бәширов; 2) берәр кеше яки нәрсә турында бөтенләй уйламау, ис китмәү турында.— *Атасы монда карт башы белән дөнья көтеп йөри. Ә аның һичбер исендә дә юк.* Г. Камал.— *Урам тулы халык йөри, аларның исләрендә дә юк, иха-хай да миха-хай киләләр.* Т. Гыйззәт. **Исең киткән иске чикмәнгә** — берәр кеше яки берәр нәрсә белән бик соклану яки гаҗәпләнүнең, куркыту, янауның нигезсез икәнлеге турында әйтелә. [*Зөләйха:*] *Белеп тор! Костырырмын әле бу сүзләреңне!..* [*Фәкия:*] *Һе-һе, исебез китте иске чикмәнгә...* Э. Касыймов. **Исеңә дә кертәсе булма** — берәр нәрсә эшләмәскә, эшләргә җыенмаска кисәтеп әйтелә.— *Ничек инде ул төкерергә? Исеңә дә кертәсе булма, сердәшем. Сора, бирмиләр икән, судка бир.* А. Шамов. **Искә алу** — 1) нәрсәне дә булса игътибарга алу, истә тоту, исәпкә алу. *Юлдан тузан туздырып килүче әллә кайдагы атлыларны искә алмаганда, якын-тирәдә бер җан иясе дә, үзгынчы-фәлән дә юк иде.* Г. Бәширов.— *Рәхимҗан абзый, синең күрсәтмәләреңне бик яхшы, без аның ныклап искә алырбыз.* Р. Ишморат; 2) *гадәттә юкл. форм.* санлау. *Сәлим башта* [*каргаларны*] *чыбык-чабык ыргытыкалап кына куркытмакчы булган иде. Кая ул!.. Исләренә дә алмыйлар.* С. Сабиров; 3) хәтергә төшерү, **хәтердә, күңелдә яңарту.** *Сагынып искә алырга һәрберәүнең була үткәне.* Ф. Кәрим; 4) хәтергә төшереп сөйләү. [*Алар*] *сугыштагы улларын, ирләрен, кияүләрен --- җылы сүзләр белән искә алалар.* Г. Бәширов; 5) берәр кешене яки нәрсәне атау, исемен әйтү. *Нәгыйм үзенең гаризасын Фәтхи сораганнан соң гына бирергә дип уйлап куйган иде. Ләкин аны искә алучы да булмады.* Ш. Камал; 6) үз чыгышында берәр нәрсәне яки кешене билгеләп үтү.— *Аннан соң син бабай яратмаган --- тагын бер нәрсәне искә алмагансың: бабай саранлыкны, ач күзле, комсыз булуны бер дә яратмый иде.* Г. Гали. *Болар арасында Татар дәүләт опера театрының художество җитәкчесе һәм баш дирижеры С. С. Берггольцны аерым искә алып үтәргә кирәк.* М. Җәлил; 7) берәр кеше яки нәрсә хөрмәтенә бәйрәм, тантана үткәрү. *Аның калдырган хезмәтләре югалмыйлар һәм алар югалмаячаклар. Моны Г. Камалның тууына 60 ел тулу уңае белән 1939 елда ясалган искә алу ачык күрсәтте.* М. Гали. **Искә кереп чыкмау** — берәр кеше яки нәрсә турында бөтенләй уйламау, хәтердә тотмау.— *Менә аның исенә дә кереп чыкмый, өч ятып, бер төшенә дә керми ичмасам!* М. Гафури.— *Казанда торганда йортым исемә дә кереп чыкмады, бары сезне генә сагындым.* Ф. Әмирхан. **Искә кертеп (чыгармау)** — 1) берәр нәрсә турында бөтенләй уйламау.— [*Кызым*] *ул-бу булмагае дип исенә дә кертеп чыгармый.* К. Нәҗми; 2) теге яки бу эшне эшләргә җыенмау. *Кош халкы чигенүне исенә дә кертмәде.* Г. Хәсәнов. **Искә керү** — *к.* искә төшү (1 мәгъ.). *Кай заманда, кайсы телдә булса да мәзкүр Казан, Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл — Кабан.* Г. Тукай. **Искә килү** — 1) *к.* искә төшү

(1 мәгъ.).— *Нигә син моны Паларусов тикшерәндә әйтмәдең? - - - — Онытканмын, азактан гына исемә килде.* Г. Ибраһимов. *Шул матур кыз искә килсә, Әрни җаным, һуш ава.* Н. Исәнбәт; 2) һушка килү, һушсызлык хәленнән чыгу, аңга килү. *Ул берничә секундка аңын җуйды. Исенә килгәч, читкә ташланды.* Г. Мөхәммәтшин; 3) үз-үзен оныту дәрәҗәсендә тирән уйга чумудан, тәэсиргә бирелүдән айну.— *Мәрткә киткән изге төсле, баскан җирдә катып калганмын. - - - Азан тавышыннан гына исемә килгәнмен.* Т. Гыйззәт. *Ак пароходның кисәтеп кычкыртканын ишеткәч кенә, иске дуслар, исләренә килеп, көймәне - - - турыладылар.* Г. Гобәй; 4) аңлап алу, төшенү, абайлау. *Махоҗылар көтелмәгән бу кыюлыктан гаҗәпкә калып кинәт туктадылар, - - - бераз исләренә килмичәрәк тордылар.* Г. Бәширов; 5) үз-үзен тотышы, карашлары, теләкләре ялгыш булуын аңлап, алардан баш тарту, акылга керү, үз карашларын, холык-фигылен үзгәртү. [*Андреев*] *Мостафинга моңарчы бик ышануын, ихтимал,* [*Мостафин*] *үзе үк кая таба баруын сизәр, исенә килер, чигенер дип өметләнеп торуын әйтте.* Ә. Еники. **Искә китерү** — 1) берәр нәрсә турында уйлау, хәтергә алу. [*Алар*] *кешеләрнең моңда аларны көтеп торганын исләренә дә китермиләр.* Ш. Камал; 2) һушка китерү. *Әни: «Галимә балам, саташасың, торып утыр...» — дип, аны уятырга, исенә китерергә тырыша.* М. Гафури; 3) үз-үзен тотышын, холык-фигылен үзгәртергә, төзәтергә мәҗбүр итү. **Искә төшерү** — 1) элек күргән яки белгән нәрсәләрне, кешеләрне хәтердә, күңелдә яңарту. [*Газинур*] *шушы соңгы сулышында үзе өчен иң кадерле, иң якын булган балаларын, хатынын, карт әтисен, җаннан артык күргән дусларын, сөекле һәм газиз Ватанын исенә төшерде.* Г. Әпсәләмов. [*Ул*] *Нәфисәнең аны Идел буена озату килүен, анда бик озак аерылыша алмый торуларын, мәктәпкә барып урнашканнан соң, аңардан атна саен хат килеп торуларын бик ансат исенә төшерде.* Г. Бәширов; 2) элек күргән-белгәннәрне хәтердә яңартып сөйләү. *Сүзгә сүз ялганып, Гыйлажи белән Бикмулла Ватан сугышында күргәннәрен исләренә төшерә башладылар.* Ә. Еники; 3) берәр нәрсә, вакыйга яки кеше турында онытмаска, хәтердә тотарга кирәклек турында кисәтү ясау. *Мине һаман немецларның әлеге ут ноктaлары борчый. Бу турыда мин Дәүләтшинның исенә төшерәм.* И. Гази; 4) *сөйл.* үзенә карата начарлык эшләгән кешедән үч алачагы турында кисәтеп әйтелә.— *Мин моны оныта алмам! Гомер булса, бер аның исенә төшерермен!* Г. Ибраһимов.— *Әмма бер кайтмасак, бер кайтырбыз. Кайберәүләрнең исләренә төшерербез әле без моны!* Ә. Фәйзи; 5) берәр нәрсә яки кеше булып күренү, берәр нәрсәне яки кешене хәтерләтү. *Көйләп утырган самовар тавышына Бәдри белән Җәмиләнең тавышлары кушылып, бик хәсрәтле генә иске тормышны искә төшерә.* М. Гафури.— *Беләсезме, бу көй - - - тау араларыннан чылтырап аккан чишмәләр тавышын хәтерләтә, кошлар сайравын искә төшерә.* А. Әхмәт. **Искә төшү** — 1) элек күргән-белгән нәрсәләр, кешеләр, сүзләр һ. б. ш. хәтергә килү, аларны хәтердә яңарту. *Кырлардагы учак кырында Искә төшә баштан кичкәннәр...* Х. Туфан.— *Ә мин сине онытмадым, туганкай, гел искә төшәсең.* Г. Гобәй; 2) берәр нәрсә эшләү фикере туу.— *Синең шул булыр инде. Бернәрсә исеңә төшсә, тынгы бирмәссең.* Т. Гыйззәт; 3) эшләгән эшенең ялгышлыгын аңлап, шуның өчен үкенү.— *Соңыннан исенә төшәр әле төшүен, әмма ул чагында кайгыруның файдасы булмас.* Г. Камал. **Истә тоту** — 1) онытмау, хәтерләү. *Рабига беренче очрашуның барлык вак детальләренә кадәр хәтерли һәм ул нәрсәләрне Нуруллинның да исендә тотуына бик гаҗәпләнә иде.* А. Шамов. *Монысын инде ул язмыйча да исендә тота алачак иде.* Г. Бәширов; 2) теге яки бу эшне башкарганда берәр нәрсәне исәпкә, игътибарга алу. *Бөтен уем кинәт шул тавышка таба тартылса да, кунак икәнлегемне истә тотып, ишетмәмешкә салыштым.* М. Әмир. *«Алтынчәч» либреттосы, менә шул тәҗрибәләрне истә тотып, халык әкиятләре нигезендә яңа әсәр иҗат итү тәртибендә эшләнде.* М. Җәлил. **Истән аву** — к. ис аву. *Хәйрулла, икенче мәртәбә исеннән авып, Лиданың йомшак кулына егылды.* К. Нәҗми. **Истән салу** *диал.*— к. истән чыгару. *Җаным — син, алтын алмам ла, Исемдин бер дә салмам ла!..* Г. Кандалый. **Истән тайдыру** — һуштан язарлык, акылны югалтырлык итеп бик нык әсәрләндерү. *Ник мине бу хәтле истән Тайдыра тик бер кеше? Күңелемне кол, дөньяны гел Гөл итә, көлсә теше.* С. Рәмиев. **Истән чыгару** — оныту, **хәтердән чыгару.** *Мин ул кызны күпме истән Чыгарырга теләдем. Юк, булмады... Һаман аңа ашкына яшь йөрәгем.* М. Җәлил. *Орск өязендә алтын разведкасында бергә йөргән бу иптәшләремне әле дә исемнән чыгара алмыйм.* М. Гафури. **Истән чыгу (китү)** — онытылу, хәтердә калмау. *Истән чыкмый монда минем күргәннәрем, Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем.* Г. Тукай. *Күзәнәкле йомшак ипигә ягып биргән алтын төсле балның хуш исе гомердә дә истән китмәслек.* Г. Бәширов. **Истән язу (таю)** — 1) **аңны югалту, һушын югалту.** *Бу вакытта инде Шәфикъ кычкырмый, тыпырчынмый: ул әллә кайчан исеннән язган иде.* М. Галәү. *Кайсы шәкертләр, сугыштан бушап, истән тайган шәкертләрне мәдрәсә очына күтәреп ташый башладылар.* К. Тинчурин; 2) һуштан язарлык, акылны югалтырлык итеп бик нык әсәрләнү, тәэсиргә бирелү; шаккату. *Шул гүзәлне уйлый-уйлый истән таеп, Ничә көннәр ашап-эчми йөргән чаклар* [*бар иде*]. Ш. Бабич. *Утырган дусларымнан җилләр искән, Кесәмгә кулны салсам, тайдым истән.* Г. Тукай. **Истән җибәрү** — һуштан яздыру, аңын югалттыру.— *Беренче сугуым белән* [*аны*] *истән җибәрсәм, икенчесе белән аяктан ектым.* Т. Гыйззәт.

ИСАГУҖИ: исагуҗи хан *иск.*— иске мәдрәсәнең икенче баскычында укучы шәкерт. *Бу хәл аның исагуҗи хан заманында «тәүзыйх» мәсьәләләренә катнашып көлкегә калуларына да сәбәп була иде.* Г. Ибраһимов.

ИС-АКЫЛ: ис-акылны алу (исен дә, акылын да алу) — бик нык гаҗәпләндерү, хәйран калдыру, сокландыру. *Яртылаш каеш, яртылаш ефәктән үрелеп эшләнгән дилбегәләр, көзге төсле ялтырап торган көмешле камытлар, матур кызларның кыйгач кашлары төсле киез ыңгырчаклар Сөләйманның исен дә, акылын да алдылар.* К. Тинчурин. **Ис-акыл бетү** — бик нык курку, аптырау нәтиҗәсендә ни эшләгәнен аңлый алмау хәленә килү.— *Сукмак аркылы бер кеше сузылып ята, карыйм — Фәхри! - - - Тәне бөтенләй суынган. Исем-акылым бетте. Эх, мин әйтәм, баш китте, харап булдык.* Г. Ибраһимов. **Ис-акыл китмәле (ис тә, акыл да китмәле)** *диал.*— гаҗәпкә калырлык, хәйран калырлык. *Колхоз ишегалдыннан чыгып киткән атларны карап торсаң да, ис-акыл китмәле: алар урамда уйнап, я чирәм йолкыган булып йөриләр, йөриләр дә - - - колхоз абзары ишегалдына кайтып керәләр.* Г. Толымбай *Ис тә, акыл да китмәле! Ничек чыдый бу ир-ат?* К. Нәҗми. **Ис-акыл китәрү (җибәрү)** — бик нык гаҗәпләндерү, хәйран калдыру. *Дошманның исен-акылын китәргән көчле штурм башланды.* Г. Әпсәләмов.— *Баһадирлыгың белән исне-акылны җибәргән идең.* М. Кәримов. **Ис-акыл китү** — гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнү, хәйран калу. *Нәфисәгә әле хәзер дә исем-акылым китә: каян белгән!* А. Шамов.— *Шундый матур иде инде. Күрсәң, исең-акылың да китәр иде.* С. Җәләл. **Ис-акылны югалту (җую)** — гадәти психик халәтне югалту, ни эшләгәненне аңлый алмау, ни эшләгәненә хисап бирә алмау хәленә килү. *Александрова начальникның тупаслыгыннан исен-акылын җуйган иде. Моның нәтиҗәсе дә булмый калмады. Резервуарның бер ягын үлчәгәндә ул тиешле киңлектән таррак үлчәү бирде, брак китте.* А. Гыйләҗев. **Ис-акылны**

җыю — *к.* ис җыю (2 мәгъ.). *Бу минутта Зөфәр тәмам айнып, исен-акылын җыеп өлгергән иде инде.* Ә. Еники. *Мин, сихерләнгән кебек, шундый искиткеч тәэсирдән тиз генә исемне-акылымны җыя алмыйча, бертуктаусыз һаман шул әкият тауларына карап бардым.* Н. Фәттах. **Искә-акылга килмәгән** — бөтенләй булмаган, уйламаган. *Авырган, сәламәт чакта искә-акылга килми торган нәрсәләр турында уйлыйсың.* Г. Әпсәләмов. **Искә-акылга килү** — *к.* искә килү (3 мәгъ.). *Ул, муеннан бәхет-куанычка чумып, әле һаман исенә-акылына килә алмыйча, тын гына утыруында булды.* Н. Фәттах.

ИС-АҢ: искә-аңга килү — аңлап алу, төшенү, абайлау. *Габдулла исенә-аңына килгәнче, әнисе аны юрганга төреп, - - - Саснага алып китте.* Ә. Фәйзи. **Истә-аңда булмау** — (берәр нәрсә) хәтердә бөтенләй булмау, ул турыда бөтенләй уйламау. **Истә-аңда юк** — бөтенләй хәтердә булмаган, бөтенләй уйламаган кеше яки җанлы-җансыз нәрсә турында әйтелә.— *Кара син аны, юньсезне, гомерендә исендә-аңында юкны. Каян бер бүген генә уена килде икән?* М. Шабай.

ИСБАТ *и. иск.* Берәр нәрсәнең дөреслеген, реальлеген, булганлыгын фактлар белән раслау өчен китерелгән **дәлил.— *Дөрес әйтте Нәни абый, исбат* [*кирәк*].** Ә. Фәйзи.

Исбат итү (кылу) — берәр нәрсәнең, күренешнең, эшнең дөреслеген, булганлыгын фактлар белән дәлилләү, раслау. *Башка дәлил кирәк түгел, баланы даулаучының нәкъ Марат әтисе икәнен шушы рәсем үзе генә дә исбат итә ала иде.* Г. Гобәй. [*Бинаров*], *Ивановның бу җинаятьчеләр белән гаеплеләр урындыгында утыруы зур хаксызлык, тирән бер аңлашылмау, дип исбат кыла башлады.* Г. Ибраһимов.

ИСБАТЛАУ *ф. к.* исбат итү. *Хөсаен ишкәр ителмәслек фактларны тезеп исбатлый башлагач, зал иректән тыныч калды.* А. Расих.

ИС-ДӘРТ: исем-дәртем Искәндәр *сөйл.*— бары тик үз уе белән генә мәшгуль булып яшәү яки берәр кешене **генә уйлау** турында әйтелә.

ИСЕМ *и.* **1.** Кешегә тугач та бирелә торган шәхси атама; ат II. *Төрле якта малайның исемен кычкырдылар: Илдус, Илдус!* Г. Бәширов. *Исемнәр күп бит. Дөнья тулы малайлар, дөнья тулы исем. Шулай булса да, берсе дә ялгышмый, бугалышып бетми. Хәбир дисәң, Хәбирне «ә» ди, Җәмиле тик тора, Җәмил дисәң, аныны «җә» ди, Хәбирне тик тора.* Г. Мөхәммәтшин. // *сир.* Кешенең шәхси атамасы һәм фамилиясе.— *Менә ул шәкертләрнең исемнәре: Йосыф Уразаев һәм Габдулла Тукаев.* Ә. Фәйзи. *Аның татарча исеме — Биктимер Вилданов.* Г. Ибраһимов.

2. Кеше яки хайван кушаматы. [*Рөстәм*] *чебен тими чер итә торган булып чыкты. Кайберәүләр аңа Елак, Чыелдык дигән исем дә биреп карааннар иде, ләкин ул исемнәр шунда ук онытылды. Аның исеме бары «Сары малай» булып кына калды.* А. Шамов. *Атның паспортында исеме «Маймыл» дип язылган иде.* Г. Әпсәләмов. // Әйберләр, күренешләр, төшенчәләр һ. б. атамасы. *Гөләндәм әби генә: «Бусы энҗе чәчәк, бусы канәфер чәчәк, бусы күгәрчен күзе, бусы казаягы чәчәге...» — дип, чәчәкләрнең барысының да исемнәрен санап чыкты.* Г. Гали. *Г. Ибраһимов башлап 1907 елда «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемендә хикәя язып чыкты.* Г. Нигъмәти. *Юк, планета! Моңдый вәхшилеккә Акыл җитми исем табарга.* Ш. Маннур.

3. *күч.* Шөһрәт, дан, танылганлык. *Сиңнән чибәр кызлар юк дип, Исемең илгә чәчеләчәк.* М. Фәйзи.— *Шушы тавышың илә дөньяга исемең таралдымы?* Г. Тукай. // Берәр нәрсә яки кешенең яхшы яки начар сыйфатлары турында туган гомуми **фикер**; дан.— *Кая безнең элекке яхшы исемебез? «Чулпан»ның бу көнгә төшкәнен кем күргән?* Г. Бәширов.— *Саран дигән исемеңне чыгартмас өчен, кеше алдында хур булмаслык яшим дип, үземә күбрәк тота башлыйсың...* Г. Ибраһимов. // Абруй, авторитет.— *Авыл егетләренең исемен кала егетенең аяк астына таптатмам...* М. Фәйзи.

4. *күч.* Берәр төркемгә яки оешмага карауны күрсәтә торган атама. *Коммунист исеме.*

5. Күрсәткән хезмәт өчен бирелә торган мактаулы атама, дәрәҗә. *Татарстан АССРның атказанган укытучысы исемен алу.* □ *— Шатлык, Шәмсия, безнең Маратка Советлар Союзы Герое исеме бирелгән.* Т. Гыйззәт. // Кешенең берәр өлкәдә квалификациясен яки хезмәттә тоткан урынын рәсми рәвештә билгели торган атама; **дәрәҗә**. *Лейтенант исеме. Инженер исеме.* □ *Екатерина Павловна Газинурны сержант исеме белән тәбрикләде.* Г. Әпсәләмов. *Күрәсең, Сарымсаков, җилкәсендә докторлык исемен сизгәч, Талибәдән барлык үчләрен кайтарырга уйлаган.* Г. Ахунов. // Теге яки бу эшчәнлек белән танылган кеше турында.— *Мин Петр Великийның, Наполеонның тарихта зур исем алган кеше икәнлекләрен беләм.* М. Әмир.

6. *юн. кил.* **исеменә.** Берәр кешегә адресланган, билгеләнгән, юнәлтелгән. *Директор исеменә гариза язу.* □ *Чәчәкләр яуды батырлар өстенә, Мактаулар яуды алар исеменә.* А. Алиш. *Шәйхетдинов исеменә бер хат килде.* А. Шамов.

7. *чыг. кил.* **исеменнән.** Берәр кеше, оешма яки коллектив кушуы, әйтүе, теләге, соравы, үтенече буенча; вәкил буларак. *Халык исеменнән.* □ *Партия губкомы исеменнән Коростылев сөйләгәч, бөтен халык бер карарга килде.* Ш. Усманов. *Тагын берничә бала бүләкләнгәч, бүләкләнүчеләр исеменнән сүз Сәлимгә бирелде.* Г. Гобәй. // Берәр кешегә яки оешмага, коллективка бирелгән властька таянып, нигезләнеп.— *Революцион закон исеменнән үзләрен хөкем итегез.* Т. Гыйззәт.

8. *лингв.* Предметлыкны белдерә һәм килеш, тартым, сан белән төрләнә торган сүз төркеме. *Исемнәр җөмләдә ия, хәбәр һәм иярчен кисәк булып киләләр.* Ш. Сайкин. *Исемнәр, нигездә, предмет төшенчәсен таләп итә торган җөмлә кисәкләрен белдерә*[*ләр*]. В. Хангилдин.

Исем бирү — 1) *к.* исем кушу. [*Мулла*] *берсенә Мифтах, икенчесенә Нәҗип дип исем бирде.* Һ. Такташ. [*Элек*] *кызларга Артыкбикә дип кимсетеп исем биргәннәр.* Г. Әпсәләмов; 2) берәр нәрсәне яки кешене атау. *Кешеләр* [*ул кошка*], *бик белеп,* [*чебенче*] *дип исем биргәннәр.* Г. Гобәй. *Моннан соң җәмгыятькә исем бирү мәсьәләсе кузгалды.* Ф. Әмирхан; 3) кушамат кушу. *Шушы эшләрем өчен авыл халкы Разбойник дип исем бирде.* Һ. Такташ. **Исем йөртү** — аталу.— *Яшь гвардия исемен йөртәч, сез инде сынатырга тормагыз.* Р. Ишморат. **Исем кушу** — 1) кеше тугач, аңа билгеле бер шәхси атама беркетеп кую. *Малайга Гәрәй дип исем куштылар.* Қ. Нәҗми; 2) кушамат бирү, **кушамат** тагу. **Исем кую** — *к.* исем кушу (1 мәгъ.). *Кем дип башлыйм, Кем дип исемең куйыйм, Кем дип атап сиңа эндәшим?* Һ. Такташ. *Хәдичә дип исем куеп,* [*ул*] *Җаматедингә килгән.* Бәет. **Исем туе** — исем кушу мәҗлесе.— *Лира, әйдә, иртәгә исем туе ясыйбыз.* М. Әмир. **Исем фигыль** *лингв.*— эш яки хәлнең исемен белдерә торган фигыль төркемчәсе. *Исем фигыль боерык фигыльгә -у, -ү, -ю кушымчалары ялганып ясала.* Д. Тумашева. *Исем фигыль формаларының күпчелеге исемнәр өчен характерлы булган грамматик категорияләрне дә (килеш, тартым кебек) үзләрендә еш чагылдыра.* В. Хангилдин. **Исем шәриф(ләр)** *иск.*— кадерле, хөрмәтле, мөгътәбәр исем.— *Минем җан сөйгәнемнең дә исем шәрифләре Сәрби иде.* И. Гази. **Исем этисе** — христианнарда: баланы чукындырып, исем кушканда рәсми шаһит буларак катнашкан ир кеше. **Исемендә булу** — теге яки бу әйбер кемнең дә булса милкендә булу. *Монда бәләкәйрәк фирмалар мәзин исемендә булалар.* Г. Тукай. **Исеменә күчерү (яздыру)** — теге яки бу әйбергә, милеккә икенче кешене хуҗа итү.— *Йорт-җиреңне дә*

хатының ***исеменә*** *күчертергә кирәк.* Ш. Мөхәммәдев.— *Яратышсак, тотам да ярты дәүләтемне аның исеменә яздырам.* **Ш.** Камал.

◇ **Исем алу** — теге яки бу эшләре, холкы белән уңай яки тискәре яктан билгеле булу; ат казану.— *Син бит үзең «зирәк»* ***исеме алган,*** *Үзең эшнең төбен белми калган.* Н. Исәнбәт. **Исем буяу (пычрату)** — *к.* исем сату. [*Тәһир*] *судка тартылган, комсомолның исемен пычраткан.* Ә. Айдар. **Исем казану** — *к.* исем алу. [*Шәймәрдәнов*] *гади механы асыл мехка әйләндерүчеләрнең берсе булып зур исем казанды.* Р. Ишморат. *Исем казанган хаттатлардан Рәхмәт Әмирхан, Мостафа Әлдермеши --- кебекләрне күрсәтергә мөмкин.* И. Рәмиев. **Исем күтәрү** *сөйл.*— тиешсезгә, хаксызга берәр дәрәҗәгә ирешү яки кимсетелү, **җәберләнү** турында. *Бер байбәтчә --- өч-дүрт ел Истамбулда торып, укыган исеме күтәреп йөреп, бер авыз сүз төрекчә дә сөйләшә белми кайт*[*ты*]. Ф. Әмирхан. **Исем сату** — 1) абруй төшерү, яхшы исемгә тап төшерү.— *Каланың, кала егетенең исемен сатмыйм дисәң, көрәшергә тиешсең.* М. Фәйзи.— *Җәдит булган, имеш! Адәм мәсхәрәсе булып, --- атаңның исемен сатуың җитмәгән, өстәвенә хатын-кыз артыннан өстерәләсең!* М. Әмир; 2) кеше турында гайбәт сөйләп, аның **яман** атын чыгару.— *Кыз баланың исемен сатарга ояламадылар инде* [*алар*]. Н. Исәнбәт. **Исем тагу** — берәр кеше яки нәрсәне начар исем белән яки начар яктан хурлап атау. *Ул әниемне минем тартып алды, Ул чуалтты минем юлларны. «Үксез» дигән исем такты миңа һәм урамга куып чыгарды.* М. Җәлил. *Шулай бөгәрләнеп утырулары өчен аңа «чирләшкә» дип исем тактылар бит.* Г. Әпсәләмов. **Исем чыгару** — 1) берәр кеше турында яхшы яки яман хәбәр тарату. *Әгәр икесе дә йөзәр сум тамызган булмасалар, чынлап та кеше арасына исемнәрен чыгарачак идем.* Г. Камал; 2) берәр нәрсә белән үзен таныту, билгеле, атаклы **итү**. *Вәликәй — авылда атларының яхшылыгы белән исем чыгарган кеше.* Г. Ибраһимов. **Исем чәчү** — *к.* исем сату (2 мәгъ.).— *Эчерми булмый, беркөн ул мине тегендә күргән иде, эчертмәсәң, ул аннары бөтен дөньяга исемеңне чәчеп йөри.* Г. Камал. **Исем җәю** — шөһрәт казану. *Шәкертләр, Җиһанша хәзрәт мәдрәсәсенә килеп, еллар үтеп, хәлфә булып, исем җәйделәр.* З. Һади. **Исемгә чыгу** — уңай яки тискәре яктан билгеле булу.— *Шул җырлаудан исемгә чыгып,* [*Гөлбикәне*] *шәһәргә алдырганнар, хәзер монда театр уйный.* Г. Ибраһимов. **Исемдә генә** — 1) сүздә берне әйтеп, чынбарлыкта шуның киресен эшләү, икейөзлеләнү турында. *Меньшевиклар белән эсерлар --- үзләренең чын йөзләрен ачтылар, --- исемдә генә эшчеләр партиясендә йөргәнлекләрен күрсәттеләр!* М. Гафури; 2) *к.* исеме генә калу. **Исеме белән атау** — хакыйкатьне турыдан-туры әйтү. **Исеме генә калу (булу)** — элеккечә аталып та, үзенең элеккеге төп сыйфатларын югалткан әйберләр, күренешләр һ. б. ш. турында. *Россия өстендәге кара болытлар көннән-көн куера, --- хәррият союзлар тәмам бетте, хәррият матбугатның да исеме генә калып бара.* Ш. Мөхәммәдев. **Исеме дә ишетелмәү** — бөтенләй булмау, күренмәү. [*Картлар*] *бар вакытта --- руза калдыру дигән нәрсәнең исеме дә ишетелмәгән.* М. Гафури. **Исеме дә юк** — бөтенләй юк. *Урам буена ике казык кагылган. Иптәшем: «Менә бу — капка* ***булыр»,*** *— диде. Читән, киртә дигәннең исеме дә юк. Капкадан керәбезмени, дип көлә-көлә, юри шул ике* ***казык*** *уртасыннан үттек.* Г. Ибраһимов. **Исеме (дә) калмау** — бөтенләй бетү, югалту, бөтенләй онытылу. *Шул золымнар тәмам бетеп,* [*Реакциянең*] *исеме калмас җир йөзендә.* М. Гафури. **Исеме китү** — дан таралу. *Исеме киткән аның Зәй буена...* С. Хәким. **Исемем (фәлән) булмасын** — берәр нәрсәнең һичшиксез эшләнәчәге турында ант итеп әйтелә торган сүз.— *Айбикәне барып алмасам, исемем Яхъя булмасын.* Қ. Нәҗми.— *Үз гомеремдә әгәр аны хур итмәсәм, исемем Шөҗаг булмасын!* Г. Камал. **(Фәлән) исеме харам булсын** — *к.* исемем (фәлән) булмасын.— *Әгәр шушы Хәлилнең кулыннан Галиябануны тартып ала алмасам, Исмәгыйль исеме миңа харам булсын!* М. Фәйзи. **Исеме чыгу** — яхшы яки яман яктан даны таралу, танылу. [*Аның*] *иптәшләре арасында «комсыз Галиулла» дигән* ***исеме*** *чыкты.* И. Гази. *Явызлыгы, усал теллелеге белән исеме чыккан Мәликә кул астында килен булуны --- ул гомер юлының иң авыр һәм куркыныч бер баскычы булыр дип уйлаган иде.* А. Шамов.

ИСЕМДӘШ *и.* Бер үк исем белән аталучыларның берсе; адаш. *Ул заманның шәһәрен, хәзерге исемдәшләре белән чагыштырганда, --- «зур авыл» дип атасаң, дөресрәк булыр иде.* Г. Бәширов. // *с. мәгъ.* Бер үк исемле, бер үк исемдәге. *Чуваш* [**авылларының**] ***исемнәре*** *күбесе үз якынларында булган мөселман* **авыллары** *илә исемдәш буладыр.* З. Бәшири.

ИСЕМДӘШЛЕК *и.* Исемдәш булу. *Шәйләнәләр саны-сыз йөзләр — Исемдәшлектә игезләр: Йонас,* ***Йон,*** *Джон, Иван.* Рәф. Әхмәтҗанов.

ИСЕМЕНДӘГЕ *с.* Берәр кеше яки берәр вакыйга хөрмәтенә аталган. *Г. Тукай исемендәге* **клуб.** *Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.* ☐ *Бу вакыйга Казан шәһәренең Максим Горький исемендәге культура-ял паркында башланды.* Г. Гобәй.

ИСЕМЛЕ *с.* **1.** Нинди дә булса **исеме** булган, нинди дә булса исем белән аталган. *Бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди* **исемле** *бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән.* Г. Тукай. *Шулай сайлап булмаслыклар Кемнәр алар, дисеңме? Берсе — Газиз, берсе — Батыр, Берсе — Камил исемле.* Ә. Исхак.

2. Исеме киң таралган, атаклы, данлыклы.— *Сүз, ниһаять,* ***исемле,*** *дәрәҗәле,* **олы** *яшьтәге кеше турында бара.* Ә. Еники. *Зәйнең картага да төшмәве* [*Шаминнының*] *кәефен кырды. Аның данлырак,* ***исемлерәк*** *урынга барасы килә иде.* А. Гыйләҗев.

3. Берәр кеше исеменә атап бирелгән; хуҗасының исеме куелган, язылган. *Исемле* **корал.** ☐ «[*Совет Армиясе*] *маршы» өчен маршал Ворошилов композитор* [*С. Сәйдәшевкә*] *исемле көмеш сәгать бүләк иткән.* Г. Ахунов. *Бу яулык кызның исемле яулыгы була.* **Экият.**

4. Берәр кеше исеме белән бәйләнгән, аталган; махсус, гадәттәгедән югарырак.— *Яхшы укырга кирәк, Шәйхи дус. Исемле стипендия бирәп куймаслармы.* Г. Мөхәммәтшин.

ИСЕМЛЕК *и.* **1.** Җанлы яки җансыз нәрсәләрне исемләп тезеп, тәртип белән санап чыккан язу. *Сайлаучылар исемлеге.* ☐ *Шинельле кеше Хәлимне исемлеккә өченче кеше итеп язып куйды.* Г. Гобәй. *Волков китүчеләрнең исемлеген төзеп бирде.* Ш. Усманов.

2. Исем (8 мәгъ.) булу. *Татар телендә кулланылган һәм* **кулланыла** *торган* **андый** *исем фигыльләрнең дә* ***исемлек дәрәҗәсе*** *бердәй үк түгел.* В. Хангилдин.

ИСЕМЛӘШҮ *и. лингв.* Башка сүз төркемнәренең исем төркеменә күчүе, исемгә әверелүе; субстантивлашу. *Сыйфатларның* ***исемләшүе.*** ☐ [*Чама саннарында*] ***исемләшү*** *(субстантивация) --- күренеше юк.* В. Хангилдин.

ИСЕМЛӘҮ *ф.* **1.** Берәр кешегә яки нәрсәгә исем бирү; атау, исем кушу. *Закир Һади --- үзенең хикәясен «Яңа әсхабе кәһаф» дип исемли.* М. Гайнуллин. *Ауда мәрәнлеге өчен, Яуда алдынгылыгы өчен Халык аны Мәргән батыр Дип исемләде.* М. Җәлил.

2. *рәв. мәгъ.* исемләп. Үз исеме белән атап. *Утыз егетне исемләп чакырды да писарь: «Хәзергә җитте!» — дип, эчкә кереп китте.* Г. Ибраһимов.

ИСЕМСЕЗ *с.* **1.** Исеме билгесез. *Уннарча куллар исемсез геройның гәүдәсен учак өстеннән алып, сак кына, яңа яуган кар өстенә салдылар.* Г. Әпсәләмов.

2. *к.* имзасыз. *«Шәкертләрнең чын ислах сорау вакыты килде» дигән, зур таләпләр куеп язылган исемсез мәкаләсе чыкты.* Ә. Фәйзи. *Хат исемсез иде.* Г. Газиз.

3. Әлегә кадәр билгеле булмаган, әле танылмаган.— *Сезне, бөтенләй тәҗрибәсез һәм исемсез бер, гафу итегез, мальчишканы, сәләтлерәк врачлар бар чагында, үземә ассистент итеп билгеләдем.* Г. Әпсәләмов.

Исемсез бармак — кулда урта һәм чәнчә бармаклар арасындагы бармак; атсыз бармак. [*Миңсылу*] *исемсез --- бармагын чынаякның сабына кертеп уйный башлады.* К. Тинчурин.

ИСЕМСЕЗЛЕК *и.* Кешеләр арасында билгеле булмау, атаклы булмау, танылмау. [*Ул*] *исемсезлек кайгысы белән яна, көенә.* Ә. Фәйзи.

ИСЕМ-ЧАП *җыйд. и. к.* исем (3 мәгъ.).— *Чичән кыз дигән исемем-чабым аңа да ишетелгән.* Н. Исәнбәт.

◇ **Исеме-чабы таралу (чыгу)** — яхшы яки начар яктан даны чыгу, танылу. *Икенчесе — бик данлыклы, бөтен дөньяга исем-чабы таралган мөхәррир — китап язучы.* Г. Тукай.— *Бу арада Газиз үзе генә эшне изеп ташлады әле.* [*Кафер*] *кызы белән йөри дип, исеме-чабы чыгып тора.* Ф. Әмирхан.

ИСЕ'МЧӘ *рәв. лингв.* Исем (8 мәгъ.) кебек; исемгә (8 мәгъ.) охшаш. *Бу очракта алар исемчә төрләнәләр.* В. Ханғилдин.

ИСЕРГӘҮ *ф. бор.* 1. Яклау, саклау, канат астына алу. *И яхшы вә яманнарны исергәүче! Без*[*не*] *үзең исергә!* Шура.

2. (Кемне дә булса) кызгану, хәленә керү. *Бәнем кеби* [*ярдәмчесез фәкыйрьне*] *Исергәп, дәр*[*темә*] *кыйлгыл дәва.* Г. Сәмитова.

ИСЕРЕК *с.* 1. Исерткеч эчемлек эчү тәэсире астындагы. *Исерек кеше.* □ *Мулла үзе исә шул дәрәҗәдә исерек иде ки, теле көрмәклəнгән — бер сүз сөйләргә хәле калмаган, аягына басарлык куәте дә беткән иде.* Г. Ибраһимов.— *Син әле исерек икән, бераздан — айныгач килерсең.* Г. Камал. // *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Исерекне айнытып чыгару пунктына озаттылар.* Г. Минский.

2. Исергән яки кызмача хәлендә булган кешеләргә хас. *Агачлар арасыннан исерек тавыш белән сузып кына җырл*[*ыйлар*]. Ф. Әмирхан.

3. *күч.* Шатлык, мәхәббәт һ. б. ш. тәэсире астында әсәрләнгән, башы әйләнгән. *Мин бүген болай да исерек: һаваның сафлыгы, табигатьнең матурлыгы, дөньяның гүзәллеге, яшәүнең күңеллелеге исертте мине.* А. Шамов. *Ул шулай көлсә, хуш исләр бөркелә, Күзләреннән серле нурлар сирпелә. Шул ике нәрсә белән исерек булам, Зур гаепле бәндә төсле тотлыгам.* М. Гафури.

4. *и. мәгъ.* Исереклек. [*Ул*] *йокы исерегеннән һаман айный алмаганга күрә генә нәрсәдер абайлап җиткермиме?* М. Шабай.

Исерек баштан — исерек хәлдә, исереклек белән.— *Тегеләр, исерек баштан мактанышып, үзләренең нәрсәләр эшләгәнлекләрен һәммәсен дә сөйләгәннәр.* Г. Камал.— *Исерек баштан тузга язмаганны сөйләп йөри бит.* Г. Насрый.

ИСЕРЕКБАШ *и.* Һәрвакыт исерек кеше. *Вафин бу авыл кешеләренең хәзергә барысын да танымаса да, мәгълүмрәк исерекбашларны таный башлаган.* Ф. Хөсни. *Һәр җирдә бу ялкау исерекбаштан тизрәк котылырга ашыктылар.* Ш. Хөсәенов.

ИСЕРЕКЛЕК *и.* 1. Исерек (1 мәгъ.) булу. *Мулла артык исереклегеннән үз аягы белән керә алмады, аны абыстай күтәреп алып диярлек кертте.* Г. Ибраһимов.— *Бу көнгә кадәр мин синең исереклегеңә, синең эчеп йөрүеңә бик күп түздем.* Г. Камал.

2. *күч.* Айныклык фикер белән эш итә алмау хәле, аңгыминҗелек, йокылы-уяулы булу хәле. *Туп тавышларынамы, чатырын җил алып ташлаугамы шомланып уянган, ләкин йокы исереклеге белән башы түнәп, аптырап торган Өметбаев чокырыннан атылып чыкты.* Г. Гобәй.

3. *күч.* (Шатлыктан, мәхәббәттән һ. б. ш.) үз-үзен онытырлык булып тәэсирләнү, әсәрләнү хәле. *Берничә минут каушау катыш шундый зур шатлык исереклеге белән солдатлар тирә-якны тәмам оныттылар.* М. Гали.

ИСЕРТКЕЧ *с.* 1. Составында спирт булып, исертә торган. *Исерткеч эчемлекләр турында ишетелгән сүзләр --- котымны алалар.* М. Әмир. // *и. мәгъ.* Шундый эчемлек. *Исерткеч* [*эчми*] *торган Шакирга бу өч рюмка инде гаҗәеп тиз тәэсир итте.* Ф. Әмирхан.— *Зинһар, андый нәстә белән булышма, исерткеч эчүеңә риза түгелмен.* М. Әмир.

2. *күч.* Үз-үзен онытырлык дәрәҗәдә тәэсирләндерә, әсәрләндерә торган. *Алар, сүзсез калып, тынып, бер-берләренең йөрәк тибешен тоеп, озак утырдылар. Бу рәхәт, исерткеч тынлыкны бозасы килми иде аларның.* А. Шамов. *Кызның йөзе алсуланып яна, калын чәчләреннән исерткеч татлы исләр аңкый иде.* А. Гыйләҗев.

ИСЕРҮ *ф.* 1. Аракы һ. б. ш. исерткеч эчеп, вакытлыча айныклык фикер йөртү һәм нормаль хәрәкәт итү сәләтен югалту. *Катып үлүдән куркып, ул спирт эчә, исерә, йоклый.* И. Гази. [*Ул*], *лаякыл исереп, идәнгә ауган да шул килеш йоклаган.* Г. Бәширов.

2. Агулану (гадәттә газ белән).— *Мичне бик кызу томалагансың ахры, исерерсез бит монда.* М. Гали.

3. *күч.* Берәр нәрсә тәэсирендә баш миңгерәүләнү, аңгы-миңгә хәлгә килү. *Йокысызлыктан исергән хаҗи йокыга да китте.* Г. Тукай. *Бары елап исергәч, тәрәзәгә таң яктысы төшкән чакта гына, ул йоклап китте.* Ш. Камал.

4. *күч.* Шатлык, яхшы мөгамәлә, табигать матурлыгы һ. б. ш. тәэсирендә әсәрләнү, үз-үзен онытыр хәлгә килү. *Кошлар тавышыннан, һаваның сафлыгыннан, аның хуш ислелегеннән, дөньяның матурлыгыннан, яшәүнең ләззәтлелегеннән исергән идем мин.* А. Шамов. *Мин исердем күзләреннән, балдан татлы сүзләреннән.* Ә. Еникәй. // Берәр нәрсә тәэсиренә бик нык бирелү.— *Кичә мода, тәкълит афәте белән исергән яшьләребез бүген үз аналарының кочакларына яңадан кайталар.* Г. Ибраһимов.

ИСЕШ *и. сир. к.* исү. *Җилнең исеше әкрен-әкрен җылы якган салкын якка борыла!* Ә. Еники.

ИСЕ-ҖИЛЕ: исе-җиле калмаган (юк) — юкка чыккан, бөтенләй калмаган, беткән.

ИСКЕ *с.* 1. Озак вакытлар буена куллану нәтиҗәсендә искергән; кулланышка яраксыз хәлгә килгән, тузган, таушалган. *Иске күлмәк. Иске кое.* □ *Шулар яныңда ук тышсыз ак тун, түбәсе ертылган иске бүрек, оек, чабата киеп, бу егетләрнең агалары йөри.* Г. Ибраһимов. [*Каршыда*] — *стеналары каралып, сылаган балчыклары коелып, бүрәнәләре күренгәләп торган иске кыйшык-мыйшык өй.* М. Фәйзи. // *и. мәгъ.* Күп куллану-лыпты тузган, таушалган әйбер. *Иске яңаны саклар.* Мәкаль. *Искегә тимә, исең китәр, диләр. Ремонтка җиңел кулдан гына тотынгач, шаккаттылар: стеналарны, түшәмнәрне өр-яңадан диярлек штукатурларга, тәрәзә төпләрен алмаштырырга кирәк булды.* Г. Әпсәләмов.

2. *и. мәгъ.* Яшь балаларның астына салына торган чүпрәк. *Авырлы чагында ул туачак балага --- искеләр, күлмәкләр, юрганнар әзерләп куйган иде.* Г. Ибраһимов. *Хәмидә, баласын имезеп туйдыргач, искесен җәйде дә баласын шунда утырт*[*ты*]. М. Гафури.

3. Хәзерге таләпләргә җавап бирми торган, хәзерге вакыт өчен яраксыз. *Эшнең иске алымнары. Иске мода. Идарәнең иске структурасы.* □ *Винтовкалар бик төрле һәм иске системадагылар иде.* А. Шамов. // *и. мәгъ.* Тормышта элекке заманга хас, хәзерге вакыт өчен яраксыз, искергән нәрсә, күренеш. *Без искене җимереп, Планетада Тигез тормыш, Матур, Яңаны Төзү уе белән янабыз!* һ. Такташ.

4. *и. мәгъ.* Элекке заманга хас, хәзерге вакыт өчен яраксыз **фикерләр** иясе; консерватор. *Искеләр: «[Борынгылар] юлы мөкатдәс, алар эзеннән генә барабыз; хатын-кызлар — - - - **ирләр курчагы»**,— дип, дөнья куптаралар иде.* Ш. Әхмәдиев. *Яңа фикерләләр белән иске фикерләләр арасындагы беренче **очрашуларда** искеләр җиңгән төсле булса да, бу хәл яңа фикерләләрдә киләчәктәге тартышларга ышаныч тудырды.* Қ. Тинчурин.

5. Үткән иҗтимагый төзелешкә караган. *Иске дәүләт аппараты.* ▭ *Хезмәт иттем иске армиядә, Эт урынына тотып ярдылар, Патша өчен сугышып кан коярга, Дуска каршы алып бардылар.* М. Җәлил.

6. Күптәннән бирле яшәп килгән; күптәнге. *Иске дус.* ▭ *Анасының бер тәүлектән бирле тәкрар **иткән** шушы **«килмәделәрме» сөальләре** аның күңеленде әллә нинди **тирән** һәм иске җәрәхәтләрен яңадан ача иде.* Ш. Қамал. *Син кем, белмим, Әллә күптән инде Онытылган бер иске танышмы?* Һ. Такташ. // Күптән үткән, элекке.— *Шуларны күргәч, кире иске тормышыма кайтасым килми.* М. Гафури. // Күптәннән билгеле. *Иске җыр. Иске мәзәк.* ▭ [*Әгъзам:*] *Әнвәр сменасын мактап газетага язганнар. Менә...* [*Тәнзилә:*] *Бик иске хәбәр.* Р. Ишморат. *Аңа бу сүзләр бик иске, аның ипташларе бары да мондый фажигаләрне үткәргәннәр.* Г. Ибраһимов.

7. Бик күптәнге. *Иске, күчмә заманнардан калган адәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик* [*һәвәсле*] *халык.* Г. Тукай. *Алар иске стильдә салынган зур таш йортның **подъездына** керделәр.* Г. Әпсәләмов. // *и. мәгъ.* Элеккеге, борынгы чор. *Искедән калган язулар, **китаплар** дигәч, Карл Фёдоровичның колагы торды.* М. Гали.

8. Былтыргы, узган.— *Үткән ай башында ук иске ел планын вакытыннан алда төгәлләгән идем, бер айдан артык инде яңа ел хисабына эшлим.* Г. Минский. // Былтыргы ел уңышыннан калган. *Иске бәрәңге.*

9. Моңарчы булган, элекке. *Елганың иске эзе. Иске адрес.* ▭ *Нинаять, ул акрынлап терелә башлады, акрынлап иске хәленә кайткан кебек булды.* Э. Еники. *Бу җыелышта иске бюро* [*урынына*] *яңа бюро һәм яңа секретарь сайланды.* М. Әмир.

10. Срогы чыккан, яраксыз. *Иске билет. Иске таныклык.*

Иске дөнья — Европа, Азия һәм Африка. *Кукурузның бик файдалы культура **икәнен** Иске дөньяда бик тиз сизеп алалар. Берничә ун ел эчендә ул Испаниягә, Италиягә, Балканга һәм **Төркиягә** тарала.* А. Шамов. **Иске керәшеннәр** *этн.*— XVI—XVII гасырларда ук чукындырылган татарлар. **Иске стиль** — патша Россиясендә хәзерге вакыттагы ел исәбеннән 13 көнгә соңарып йөргән ел исәбе. [*1918 ел апрельнең*] *икесендә (иске стиль) Габдулла Тукайның вафатына биш ел тулды.* Ф. Әмирхан. **Иске елга күле** — елганың элекке юлы; *русчасы:* старица. **Иске җир** — күп игелгән, ундырышлылыгы начарланган җир.

◇ **Иске авыздан яңа сүз** — берәр кешедән көтелмәгән, урынсыз яки дөрес булмаган сүз ишеткәндә әйтелә.— *Менә иске авыздан яңа сүз! Сиңа кеше зурлап бүләк китергән, ә син «яратмыйм», имеш.* Ф. Сәйфи-Казанлы. [*Сәрбиҗамал:*] *Син... алай булгач... белә торып мине... харап... иттең...* [*Мөгълифә, явыз карау белән карап:*] *Ие, менә тагын иске авыздан яңа сүз, мин ни эшләп сине харап итим?* Г. Қамал. **Иске бер тиен** *кимс.*— 1) шомарган, әрсез кеше турында әйтелә; **2) кыйммәте, файдасы** юк дәрәҗәдә аз булган нәрсә турында. **Иске бер тиен кебек (төсле)** — кайтуы яки сөйләве кирәксез булып та, кайткан яки сүз сөйләгән кеше турында. *Озак та тормас, иске бер тиен төсле ялт итеп кайтып керер әле* [*ул*]. И. Гази. **Иске бистә асравы** *кимс.*— 1) үз-үзенә шаккатып, эшләмичә йөргән кеше турында әйтелә; 2) жыйнаксыз кеше турында. **Иске бишмәтне (тунны) кузгату** — күптән булган-үткән эшне яңадан искә алу, тикшерү.— *Я, ярый, иске бишмәтне кузгатмыйк — тузаны чыкмасын. Үткән-беткән, өстенә үлән **үскән**.* Г. Мөхәммәтшин. [*Ул*] ***бала-чагасы** турында сөйли, авыл турында, туган-тумача **турында** сөйли, ә Вәсилә турында ник кенә тешен агартсын. Иске тунны кузгатмыйм, тузаны чыгар, ди ахрысы.* Ф. Хөсни. **Иске искедән** — бик күптәннән. **Иске колакчын кидерү** — бөлдерү, авыр хәлгә калдыру. **Иске корсак — яңа аш** — борынгы ышанулар буенча: күчтәнәч ашамлык алып авыз иткәндә әйтелә. [*Бибкәй:*] *Менә күчтәнәч.* [*Гөлбикә:*] *Я, иртәдән бирле иренем кычыта иде, иске корсак — яңа аш!* Н. Исәнбәт. **Иске күз** — электән таныш булган кеше, борынгы дус. **Иске мунча, иске таз (таш)** — берәр үзгәреш яки яңа нәрсә булмау турында. *Иске мунча, иске таш, һаман безгә алар баш.* **Т. Гыйзәт.**— *Дөрес, матбугат вә әдәбият дөньясында кузгә күренерлек уңышларыбыз да юк түгел. Ләкин уку-укыту тәртипләренә, педагогия мәсьәләләренә килгәндә, бездә әле һаман шул иске мунча, иске таш!..* З. Бәширн. **Иске мунча фәрештәсе** *кимс.*— *к.* иске чабата олтаны. *Анда Вәли мулла һәм Ф. Сәймани кебек иске мунча фәрештәләре адәмиләрнең көфер вә иманын язарга вә печать басып торырга* [*боерылганнардыр*]. Г. Тукай. **Иске чабата** *эвф.*— 1) бизгәк, малярия; 2) *миф. хур.*— жен, пәри. *Юкка ышанучы крестьяннар элек «жен» дигән күзгә күренми торган нәрсә бар дип, шул жене хурлау өчен «иске чабата», «сыңар тәрәзә» дип исемлиләр иде.* Х. Қәрим. **Иске чабата белән куу** — хурлап, мәсхәрәләп куу.— *Син, Фәсхи абзый, үзең дә йомшаграк. Мин синең урыныңда булсам,* [*аны*] ***иске чабата** белән совхоздан куар идем.* Ф. Сәйфи-Қазанлы. **Иске чабата (читек) олтаны** — ямьсез яки кирәксез кешегә карата мыскыллап әйтелә.— *Шул чепи күзле нәрсә гүзәлләр солтаны буласы имеш. «Иске чабата олтаны» дисә, бер хәер иде.* Г. Қамал. **Иске җыр** — бик күп мәртәбә ишетелгән, сөйләнгән, еш кабатланып туйдырган нәрсә турында.— *Һаман шул иске җыр: яңәсе, большевиклар начар, ә без — эсерлар белән **меньшевиклар** — бик тәти кешеләр.* И. Гази.

ИСКӘДӘН *рәв.* Борын-борыннан; күптәннән, элек-электән. *Искедән бирле **аш-су** күреп килгән дус-ишләр бөтенләй үк хәтерләреннән чыгарып бетермиләр әле.* Г. Қамал.

ИСКЕЛЕК *и.* **1.** Тормыш-көнкүрештә элеккеге, ата-бабалар вакытындагы тәртип, гореф-гадәт, зәвык. *Искелек калдыклары.* ▭ *Безнең шикелле **искелек** эчендә күп яшәгән вә ялыккан милләткә бу яңалык, яңа халәтләр бигрәк тансык.* Ф. Әмирхан.— *Күңелеңә авыр алма, белеп җиткермисең син, карчык, искелегеңә тартасың!* Г. Бәширов.

2. Һәртөрле яңалыкка каршы булу; фикер торгынлыгы. [*Хәмзә бай*] *бөтен **искелекне, кирелекне**, үзсүзлекне, **минбеләмлекне** үзендә гәүдәләндерган.* М. Гали.

ИСКЕ-МОСКЫ *с.* Күп һәм еш кулланылудан **таушалган**, тузган, яраксыз хәлгә килгән. *Иске-москы **бишмәтләремне, тишек киез каталарымны** кидереп, күп тә үтми, мине арбага **чыгарып** утырттылар.* Г. Тукай. *Дошманның күп **сандагы** пулеметларына, броневикларына каршы куярга полкта төрле җиргә сибелгән иске-москы берничә «максим»нан **башка** юньле корал да юк.* Г. Бәширов. // *и. мәгъ.* Қиелеп тузган әйберләр. *Йөрде* [*ул*] *иске-москы белән, Рәтле күлмәк кимәде.* Н. Думави. *Әни дә ямау сыргап чуар **күлмәген** әллә кайчан искемоскылар җыючы Қиек **Шәрипкә** биреп җибәргән.* А. Гыйләҗев.

ИСКЕ-МОСКЫЧЫ *и.* Иске, киелгән, тотылган, тузган әйберләрне җыючы һәм алар белән сату итүче кеше; искече (1 мәгъ.). *Болак артының бу иске бистә-*

сендә күбесенчә һөнәрчеләр, читек-кәвешчеләр, --- иске-москычылар, хәерчеләр [*яшәгән*]. Ә. Камал.

ИСКЕ-ПОСКЫ *с. сир. к.* иске-москы.— *Ул миңа иске-поскы калдыкларын биргәндер.* Г. Ибраһимов. *Сукбай үзенең иске-поскы киемнәрен ки*[*де*]. Ак юл.

ИСКЕРҮ *ф.* 1. Вакыт үтү белән яки күп кулланудан таушалу, тузу, яраксыз хәлгә килү. *Зонт бераз искерә төшкән. --- Бер ягы өстән азрак ертылган һәм дә ике чыбыгы беркетелгән җиреннән, нишләптер, ычкынган.* Ш. Камал. *Өе дә искергән: йоклап яткanda өстеңә төрселдәп ишелеп төшсә, нишләрсең?* И. Гази.

2. *с. фиг. форм.* **искергән.** Элекке заманга хас.— *Табигать ярату комсомолецлык түгел, имеш. Бик искергән караш.* М. Әмир. // Хәзерге заман таләпләренә җавап бирми торган, яраксыз. *Без, бу китаптагы ысулны искергән санаганлыгыбыздан, мөгаллимнәргә* [*тәкъдим*] *итәргә җөрьәт итмибез.* Ф. Әмирхан. // Бүгенге әһәмиятен, кирәклеген югалту. *Бу эшләр бераз онытыла төшкән, мәсьәлә искергән иде.* М. Гафури. *Мәгълүматлар инде бераз искергән, шунлыктан мин аларга ышанып та бетмим.* И. Гази.

3. Куәте кимү яки бөтенләй бетү. *Сыра искерү.*

4. Яңалыгын, йомшаклыгын югалту; кибү, кату (икмәк-күмәч турында).— *Күмәчләр алып килгән идем. Күп булгач, искереп китәр инде.* М. Фәйзи.

ИСКЕЧЕ *и.* 1. Тотылган, тузган, искергән әйберләр белән сату итүче кеше; иске-москычы. *Кечкенә вә бик иске бер өйнең бер бүлмәсендә --- искече карт* [*тора*]. Ш. Камал.

2. Консерватив, реакцион карашлы кеше. *Ул бишенче елга хәтле дәверендә мөмкин булган чаклы искечеләр белән конфликттан качу --- юлын тоткан.* Г. Нигъмәти. *Коткарылды Оренбург, Искечеләр булды хур.* Г. Камал.

ИСКЕЧЕЛЕК *и.* 1. Искече (1 мәгъ.) булу, искече кәсебе.

2. Фикердә, тормышта консерватывлык, реакционлык. *Фатих Әмирхан, «Фәтхулла хәзрәт» сурәтен биреп, искечелекне тәнкыйть итү белән генә калмый.* Г. Нигъмәти.

ИСКЕ!ЧӘ *рәв.* 1. Иске рәвештә, иске заманга, иске карашларга туры китереп. [*Ул*] *киемне искечә тектерә, өйне искечә салдыра: түр як та почмак як, түшәмә тәбәнәк, тәрәзәләре кечкенә, эчке яктан мүкләр асылынып тора.* Г. Бәширов. *Искечә укыту тәртипләре дә бик начар.* М. Гали.

2. Үзгәрешсез, элеккечә.— *Үзгәреш юк, гел искечә.* Ш. Камал. [*Бәхтияр:*] *Я сөйлә, ничек торасың?* [*Бибкәй:*] *Сорама инде, бабай, һаман искечә.* Т. Гыйззәт.

И!СКИТКЕЧ *с.* Гаҗәеп, сокландыргыч, хәйран калдырырлык. *Идел ярына чыгу белән, аларның алдында искиткеч бер картина ачылды: алда диңгез шикелле җәелгән киң Идел, уң якта ераккa сузылып киткән һәм куе агачлар белән капланган таулар.* М. Гали. *Пожар сүндергәндә бабай искиткеч батырлык эшләгән.* Г. Гали. // *рәв. мәгъ.* Гаҗәеп, чиктән тыш. *Ашлык искиткеч уңган иде.* Г. Ибраһимов.— *Минем үземә ул искиткеч ошый.* Ә. Фәйзи.

И!СКИТМӘЛЕ *с. диал. к.* искиткеч. *Хыял канатларының җитезлеге искитмәле бит. Күз ачып йомган арада алар сине әллә кайларга, әллә кайчангы заманнарга илтеп ташлыйлар.* Г. Әпсәләмов.— [*Кешеләр*] *нинди искитмәле, хәйран эшләр эшлиләр. --- Галәмнең дә серен ача башладылар бит.* М. Хәсәнов.

ИСКИТМӘҮЧӘН *с.* Бернәрсәгә дә гаҗәпләнмәүчән, борчылмаучан, бернәрсә белән дә кызыксынмаучан. *Кабинага чәчби генә бер кыз утырган, кыяфәте — искитмәүчән, чыраенда сизелер-сизелмәс көлемсерәү бар иде.* Г. Ахунов.

ИСКИТМӘҮЧӘНЛЕК *и.* Искитмәүчән, гаҗәпләнмәүчән булу. *Бөтен эрелеге, бөтен искитмәүчәнлеге кинәт каядыр югалган* [*аның*]. Н. Фәттах.

И!СКИТӘРГЕЧ *с. сөйл. к.* искиткеч. [*Ул*] *бүген хәзрәт алдында «Китабел-җиһат»та язылган искитәргеч «сугыш коралларын һәм сугыш белемнәрен» укып утырган.* М. Гафури. *Монда куәт, монда искитәргеч Мәһабәтлек белән тантана.* Ш. Мөдәррис.

И!СКИТӘРЛЕК *с. к.* искиткеч. *Кешене әсәрләндергән рәсем — рәсем буларак — бер дә искитәрлек түгел иде: көймә, бер кеше ишкәк ишә, күк ленталы бер кыз койрык тота.* Г. Гобәй.

ИС-ҚОН: исе-коны(сы) да юк — 1) исе, төтене һ. б. ш. булмау, сизелмәү; 2) берәр кеше яки берәр нәрсәнең бөтенләй булмавы яки югалуы турында. *Ул елларда Дегтярка руднигының исе-конысы да юк иде әле.* С. Әдһәмова.— *Нәсимә качкан. --- Исе дә, коны да юк киленнең.* Қ. Нәҗми. **Исе-конысы килмәү** — ис, төтен һ. б. ш. сизелмәү. *Алар, мал-туар ята торган җирнең исе-конысы килеп тормасын дип, юри шулай читкәрәк утырганнар.* С. Әдһәмова.

ИС-ҚОС *җыйм. и.* Һәртөрле исләр.— *Капкын бик чиста, анда бернинди дә ис-кос булмаска тиеш. Әгәр капкыннан кеше исе килсә, җәнлек аны бик тиз тоеп ала.* Г. Галиев.

И!СҚРАЧЫ *и.* 1900 елда В. И. Ленин тарафыннан нигез салынган «Искра» газетасы тирәсенә тупланган революционерларның берсе.

ИСҚӘН: искән җил *шигъ.* — *к.* исәр җил. *Аклы ситсы күлмәгемне Қисәм, каралыр микән, Искән җилгә сәлам әйтсәм, Алып баралыр микән?* Җыр. *Искән җилгә ярышып барган поезд Үтә чиксез басулар аша.* М. Гафури.

ИСҚӘНҮ *ф. диал. к.* иснәнү. [*Маһибәдәр*] *ап-ак кулы белән авызын каплый төшеп, күзләрен бөтенләй йомып бетереп, башта озак итеп искәнде.* Г. Бәширов. *Бүген иртәдән алып бу урамда, бу йорт тирәсендә филерлар туктаусыз искән*[*әр*]*ләр.* Г. Ибраһимов.

ИСҚӘРМӘ *и.* Текстка (мәсәлән, берәр кагыйдәгә, закон пунктларына һәм аларның кайбер сүзләренә) карата бирелгән аңлатма, ачыклама. *Дәреслекләрдә, төп текстны яхшырак аңлату теләге белән, махсус искәрмәләр һәм өстәмәләр бирелгән.* Ж. Тәрҗеманов. [*Ул*] *шигырь тексты астына шундый искәрмә өсти.* Г. Нигъмәти. // Теге яки бу нәрсәгә карата әйтелгән фикер. *Мыекны борып куя да Искәрмә кертә Минап! «Тукай ул көйләп сөйли бит, Э бит бу көйсез китап!»* Х. Туфан. // Фәнни характердагы тәнкыйть фикере.

ИСҚӘ!РМӘГӘНДӘ *рәв. к.* искәртмәстән. *Ул җитмәсә искәрмәгәндә, көтмәгән чакта* [*булды*]. Г. Тукай.

ИСҚӘРМӘС *с.* 1. Көтелмәгән. *Сирәк булса да, шәп кенә исемнәр тапкалыйм. Һәм мондый искәрмәс табышлар булганда куанычымнан сикерәм.* Г. Галиев.

2. Күренмәгән, сизелмәгән, көтелмәгән. *Искәрмәс түмгәк чана аудара.* Мәкаль. *Қурайлы елга буеның искәрмәс байлыкларыннан файдаланырбыз.* Г. Галиев.

3. *күч.* Астыртын. *Искәрмәс эт каты тешли.* Мәкаль.

ИСҚӘ!РМӘСТӘН *рәв. к.* искәртмәстән. *Боларның берсе, һөҗүмнең кинәт, искәрмәстән ясалуы аркасында, үлем дәрәҗәсендә бик каты яралана.* Ш. Камал. *Бәреп керүләре дә искәрмәстән, без һич уйламаганда булды.* Э. Қасыймов.

ИСҚӘРТКЕЧ *и. сир.* Ядкарь (язма).

ИСҚӘ!РТМИ *рәв. сир.* Сиздермичә, белдермичә, алдан киңәтмичә. *Тел кирәк дошман планын Яхшырак ачар өчен; Искәртми барып, фашистның Олсын басар өчен!* М. Җәлил.

ИСҚӘРТМӘ *и. к.* искәрмә. *Китапны туры сиңа гына җибәртәм инде. Мин үземнең искәртмәләрем булган урыннарга карандаш белән сызып яки «?» куеп киттем.* М. Җәлил.

ИСКӘРТМӘЛЕ: искәртмәле ишетмә диктант *пед.*— кирәкле орфограммалары алдан аңлатылган текст буенча языла торган диктант. *Искәртмәле ишетмә диктантта текстлар укучыларга язып күрсәтелми. Алар текстны ишетеп кенә үзләштерәләр.* М. Вәлидова. **Искәртмәле күрмә диктант** *пед.*— кирәкле сүзләре бергәләп тикшерелгәннән соң тексты тактадан сөртелеп, әйтеп яздырыла торган диктант. *Искәртмәле күрмә диктантлар өчен «Диктантлар җыентыгы»нда аерым җөмләләр һәм бәйләнешле текстлар бирелде.* М. Вәлидова.

ИСКӘ'РТМӘСТӘН *рәв.* Көтмәгәндә, уйламаганда, кинәттән; искәртү ясамыйча. *Ярым хәрби киемдәге берәү, искәртмәстән генә килеп, аның җиңеннән тотты.* Ф. Хөсни. *Университет янында исерек казачийлар һичбер искәртмәстән ут ачтылар.* К. Нәҗми.

ИСКӘРТҮ *ф.* 1. Искә төшерү, хәтердә яңарту. *Чыланган тал һәм миләш агачларыннан үлән һәм кайры тәмнәрен искәртә торган сизелер-сизелмәс кенә әчкелтем, күңелле исләр аңкый.* Ш. Камал. *Елмаюың белән әллә ничек Искәрттең син яшьлек җанымны.* Һ. Такташ.

2. Алдан хәбәр итү, алдан әйтеп кую, кисәтеп кую. *Бирәселәрен алдан искәртсәләр, --- бер зыян да булмас иде.* Г. Гобәй. / *и. мәгъ.* [*Обер-лейтенант*] *ике бармагын күтәреп, искәртү командасы бирде.* Ш. Маннур. *1 август шартлавы беренче искәртү генә иде әле.* К. Нәҗми. // Нәрсәне дә булса эшләргә тиеш булып та эшләмәгәндә кисәтү ясау.— *Мин искәрттем, абайла!* Р. Ишморат. *Уяу дустым, Искәрт байларыңа: Бу сөякләр бер көн үлчәнер.* М. Җәлил. // *и. мәгъ.* Шундый кисәтү. *«Беләсеңме нәрсә борчый мине? Синең бригадаңда хезмәт дисциплинасы». Нәфисә бик уңайсызланды. Бу беренче искәртү иде әле.* Г. Бәширов.

3. *әд.* Текстка карата кыскача аңлатма, искәрмә ясау. *Әсәрнең матбугатта басылып чыккан өзекләре дә ««Гарнизон» романыннан» дип искәртеләләр иде.* Н. Гыйззәтуллин. // *и. мәгъ.* Кыскача аңлатма, искәрмә. *Шигырьнең ахырына «Бу шигырь стена газетасыннан күчереп басыла» дигән искәртү басылган иде.* М. Җәлил.

4. Күрсәтү, юнәлеш бирү. *Чабудан да тарта социализм, Иң хак юлны миңа искәртә.* Х. Туфан.

Искәртү ясау — искә төшерү. *Аның әсәрдә катнашы һәрвакыт Рәүфкә искәртү ясап, аны үз хәрәкәтендә сак булырга өндәп торудан гыйбарәт.* Г. Нигъмәти.

ИСКӘРТҮЛЕ *с. к.* кисәтүле. *Искәртүле караш.*

ИСКӘРҮ *ф.* 1. Искә төшерү, хәтерләү. [*Ул*] *тиз үк бу сөйкемле егетне искәреп алды: моннан дүрт ел элек алар Воронеждагы лазаретта бер палатада яткан иделәр.* Ш. Камал. *Солдат, нәрсәдер искәрәндәй булып, Сәгыйтовка карап торды да: «Бу шул түгелме икән?..» дигән уйга калып, сөйләүченең янына барды.* М. Гафури. // Кисәтү, исенә төшерү.— *Син инде «Йолкын»ны бик үк күздән югалтма. Кемгә генә бирсәләр дә, искәрә тор.* А. Шамов.

2. Күрү, абайлау, сизү. *Сизгер ана кече улының чырае караңгы булуын шунда үк искәреп алды.* Г. Бәширов. *Гомер дигәнең — искән җил. Узганын искәрмисең дә.* Б. Камалов. // Игътибар итү. *Богдайларның барысы да башакларын җиргә карап игәннәр, --- Хөсәен бу хәлне искәрде. Әтисенә әйтте: «Әти! Карачы бу богдайларны: мескеннәр! Ничек муеннары бөгелгән!» Дәрдмәнд.— Син искәрдеңме? Әпипә беренче көннә үк никадәр соңга калып килде.* Г. Бәширов.

ИСКӘРҮЛЕ *с.* Игътибарлы. *Искәрүле караш.*

ИСКӘ-САНГА: искә-санга алу (сугу, кату) *сөйл.*— зурлау, хөрмәтләү, исәпкә алу, санлау.— *Ул, алай булгач, мине дә, сине дә, Габдуллажанны да искә-санга алмас.* Г. Камал.

ИСКӘҮ *ф. диал.* 1. Иснәү. [*Ул*] *бик матур бер кыз сурәте төшерелгән исле сабынны --- искәде.* М. Гафури. *Комагай авылның бу башыннан торып искәсә, тегә башында ни пешкәнне белер, ди.* Әйтем.

2. *күч.* Берәр нәрсәне, эшне сизү, аңлау. *Ни эшләгәнне тиз искәү.*

ИС-КӨЧ: ис-көч җыю — хәл җыю, югалган көчне яңадан кайтару. *Дошманлыгы канына сеңгән дошманны яхшылык белән генә игә китереп булмый, вакыты җитү, исен-көчен җыю белән тагын үз юлына баса.* Н. Исәнбәт.

ИС-КҮЗ: истә-күздә тоту — онытмау, һәрвакыт игътибар үзәгендә тоту. *Истә-күздә тотылмаган, игътибар ителмәгән нәрсәдән бәла килеп чыга.* Н. Исәнбәт.

ИСЛАМ *и.* Мөхәммәт пәйгамбәр тарафыннан тудырылган дин; мөселман дине. *«Азгын хан кулында һәлак була Ислам кебек туры, хак бер дин, Коткарырга кирәк, җәмгать!» — дип, Вәгазь сөйли мулла Чемберлен.* Һ. Такташ. *Карәхмәт дин өчен, ислам өчен дию белән сугышып йөри.* М. Җәлил. // *с. мәгъ.* Ислам динен тоткан. *Безнең ислам халкы күпме сәүдә илә мәгыйшәт итеп көн кичерде.* Ш. Мөхәммәдев.

Ислам дине — мөселман дине.— *Ата-бабайлар ислам динендә булганнар.* Г. Ибраһимов. *Ислам дине исә хатын-кызларның хокуксызлыгын алла исеменнән мәңгеләштерә.* М. Максуд.

ИСЛАМИЯТ *и. иск. кит.* Ислам дине, мөселман дине. [*Исмәгыйль абзый*] *ике мулланың --- капитал өчен исламиятне, инсаниятне бер якка ташлауларын күр[ми].* Г. Тукай.— *Минем углым Ходаяр, дингә ислах кертеп, исламиятне үз җиребездә ныгытырга тырыша* [*ди мулла*]. Т. Гыйззәт.

ИСЛА'МЧА *рәв.* Ислам диненә хас булганча. *Гарәпләрчә вә гомум исламча* [*кабул ителгән*] *«Касыйдәи бөридә»не дә теләсә нинди татар көе белән җырлап буладыр.* Г. Тукай.

ИСЛАМЧЫ *и. тар.* Исламчылык идеяләрен алга сөрүче кеше; панисламист. *Үзе исламчы, төрекче булганга,* [*Кәрим Гайфи*] *Төркиядә калып хезмәт итүне мәсләгенә каршы тапмый иде: татармы, гарәп яки фарсылымы,— аерып карамый, мөселман булгач, бары да бер.* Г. Ибраһимов.

ИСЛАМЧЫЛЫК *и. тар.* Ислам динен тоткан барлык халыкларны бер дәүләткә берләштерүне күтәреп чыккан реакцион дини-политик агым; панисламизм. *Давыт кебекләр кадимчелектән исламчылыкка, аннан милләтчелеккә үсә.* Г. Нигъмәти.

ИСЛАНД *и.* Исландиядә яшәүче төп халыкның атамасы. // *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Исланд теле.* // *с. мәгъ.* Исландиядә үсә яки табыла торган. *Исланд мүге. Исланд шпаты.*

ИСЛА'НДИЯЛЕ *и.* Исландиядә яшәүче төп халыкның бер кешесе. // *с. мәгъ.* Исландиядә яшәүче яки чыгышы белән шуннан булган.

ИСЛАХ *и. иск. кит.* 1. Төзәтү, үзгәртү; төзәтмә, үзгәреш. [*Алар*] *дөньяны ислах өчен тырышканнар, Төрлесе төрле якка бүленгәннәр.* М. Гафури.

2. Иҗтимагый тормышта яки аның бер өлкәсендә яңалыкка таба үзгәреш; реформа.— *Интәшләр, без ислах сорадык. Мәдрәсәләргә яңа программа сорадык. Җавап урынында безнең ислах хәрәкәтенең башында торучы ишаннарне мәдрәсәдән куарга хәзерләнәләр.* Г. Ибраһимов. *Сүз хөрриять бирелмәсен. Чөнки шәкертләр ислах сорый башлыйлар,* [*имеш*]. Г. Тукай.

Ислах итү (кылу) — 1) төзәтү, төзәтмәләр кертү. *Рисаләмне ислах итәргә керештем.* Г. Камал. *Мондый җыелуыбызның сәбәбе --- сөйләшеп бер фикер алмак, үзебездә булган кимчелекләрне тәфтиш кылып, халебезне ислах кылырга юл эзләмәк.* Ш. Мөхәммәдев; 2) яңалык кертү, реформалар ясау, үзгәрешләр кертү. *Курсави, Мәржани, Насыйри мәдрәсәләрне ислах итәргә, рус телен укытырга чакыралар.* Г. Ибраһимов. *Мәк-*

тәп-мәдрәсәләр ислах кылынып, укулар көйләнсә иде. Ш. Мөхәммәдев.

ИСЛАХЧЫ *и. иск.* 1. Билгеле бер өлкәдә үзгәрешләр кертү тарафдары; реформатор. *Мәгълүмдәр, күптән бирле ислахчы сез, Ислах өчен чын күңелдән ихласлы сез.* Г. Тукай.

2. *тар.* Татар мәдрәсәләренә реформалар кертү тарафдары. *Егет ислахчылар арасында, яңача укыту өчен, мәдрәсәләрдә Европа мәктәпләрендәгечә укыту булсын дип көрәшеп йөрде.* А. Расих. *1905—06 елларда, беренче рус революциясе йогынтысы астында, ислахчы шәкертләр хәрәкәте тагын да киңрәк колач ала.* Сов. эд. // *тар.* 1905—1907 елларда татар мәдрәсәләренә реформа кертү мәсьәләсен күтәреп, шул юлда эшләгән «Әльислах» газетасын чыгаручыларның берсе. *Г. Камалның «Бүләк өчен» исемле комедиясен --- карар өчен ислахчылар Тукайны да алып баралар.* В. Бәхтияров.

ИСЛАХЧЫЛЫК *и. иск. кит.* Теге яки бу өлкәдә яңартулар, үзгәрешләр кертүне күтәреп чыккан агым. // *с. мәгъ.* Шул агымга бәйләнешле. *Бу әсәрдә бердәнбер үзен йолган хәрәкәт — шәкертләрнең ислахчылык хәрәкәте.* Г. Нигъмәти. *Ул хикәядә шәкертләр арасындагы ислахчылык хәрәкәтен (мәктәп-мәдрәсәләргә реформа кертү өчен көрәшне) --- бирергә тел[и].* Г. Халит.

ИСЛЕ I *с.* 1. Нинди дә булса (хуш, сасы һ. б.) ис аңкытып торган. *Бал исле йомшак юкәләр, --- шомырт агачлары — һәммәсе: яз, ди.* Г. Ибраһимов. *Ул төенчеген чишеп, хуш исле кипкән мәтрүшкә чыгарды.* И. Гази. // Хуш исле. *Исле чәчәк өзелсә дә, Исе кала болында.* Җыр. *Без мәк чәчәкләре, гөлчәчәкләр, исле сиреньнәр --- [иснәдек].* Ә. Еники.

2. Ис тидерә торган. *Исле бүлмә.* □ *Имән күмере исле булыр.* Мәкаль.

Исле борчак *бот.*— кузаклылар семьялыгыннан нәзек сабаклы, хуш исле чәчәкле берьеллык декоратив үсемлек; *русчасы:* душистый горошек. **Исле гөл** *бот.*— 1) ирен чәчәкләр семьялыгыннан вак яфраклы, бик хуш исле үсемлек; *русчасы:* тимьян. *Исле гөл исле була, Гел яран төсле була.* Җыр. *Тәрәзә төбем исле гөл, Яфраклары киң түгел.* Җыр; 2) *диал. к.* мәтрүшкә. **Исле май** *бот.*— *к.* исле үлән. **Исле сабын** — бит-кул юу өчен файдаланыла торган хуш исле сабын; бит сабыны. *Исле сабын үзенең ак, йомшак күбекләре белән Солтанның битләрен, муеннарын, шалкан чәчәрлек булып каткан колак эчләрен иркәләп юа.* Г. Ибраһимов. **Исле яран** *бот.*— *к.* яран. **Исле әрем** *бот.*— *к.* куян талы. **Исле үлән**,— 1) тау битләрендә өем-өем булып үсә торган, сыек канәфер төсендәге вак чәчәкле, исле, тәбәнәк үлән үсемлек; чабыр, чамбыр; *русчасы:* чабрец, чабер. *Тау башында исле үлән, Син дускайны исемә төшерсәм, Бер тереләм, бер үләм.* Җыр.— *Нигә мине күрмәмешкә салынып үтәсез? — дип үпкәләде бик вак яфраклы исле үлән.* Г. Галиев; 2) оешма чәчәкләр семьялыгыннан ак чәчәкле дару үләне, исле ромашка; *русчасы:* ромашка пахучая.

ИСЛЕ II *с. диал.* 1. Аңлы, акыллы. *Ике кеше сүзгә килсә, исле кеше читкә тартылыр.* Мәкаль. *Исле кеше уйламый эш итмәс.* Мәкаль.

2. Балалыктан чыккан, балигъ булган (яшүсмер турында).

ИСЛЕКӘЙ *и. бот. диал.* Зонт чәчәкләр семьялыгыннан икееллык агулы үлән.

ИСЛЕЛЕК *и.* Исле I булу. [*Һаваның*] *хуш исленнән, дөньяның матурлыгыннан --- исергән идем мин.* А. Шамов.

ИСЛЕМАЙ *и.* Хуш исле матдәләрнең парфюмерия әйбере буларак кулланыла торган спиртлагы эремәсе. *Кыздан аңкып калган бик куәтле ислемай исе --- Хәсәннең борынына керде дә аны тагы да исертә төште.* Ф. Әмирхан. [*Аның*] *борынына хуш ис килеп бәрелде. Мондый ислемайны бары тик яшь кияүләр генә сөртергә тиеш.* А. Шамов.

ИСЛӘНҮ *ф.* 1. Хуш ис белән аңку, ислеләнү. *Һава да хуш җофар, сирень, каләнфер исләре берлә исләнеп китте.* Г. Тукай. *Тәрәзә төбем исле гөл, Исләнәмен исенә.* Җыр.

2. *диал.* Ислемай сөртенү.

3. Органик матдәнең, ашамлыкның, чери башлап, сасы ис чыгаруы турында. *Исләнгән ит.* □ — *Кичә Кәлҗәмановларда исләнгән бавыр ашаган идек, шуның исе килә булыр.* Х. Вахит.— *Ашаганнары яңа суелган симез сыер ите. Тегеләре дә өйрәнеп беткәннәр, исләнә башлаганны ашамыйлар.* Г. Гобәй.

ИСЛӘҮ *ф. диал.* Искә төшерү, хәтерләү. *Бик каты бер нәрсәгә барып бәрелдем, аның аръягын исли алмыйм.* Ж. Вәлиди. *Чәй янында егетнең туктаусыз сөйләве аз гына хәтерендә калды. Аңа елмаерга тырышуын да бик аз гына исләде.* Г. Ибраһимов.

ИСНӘК *и. диал.* Йокы; иснәү. *Иснәү иснәк китерер.* Мәкаль.

ИСНӘНҮ *ф.* 1. Үзалдына иснәп йөрү; бер нәрсәнең исен сизәргә, иснәп карарга тырышу. *Бүре кинәт туктаган, тын калган, борыныи күтәреп иснәнергә тотынган.* А. Алиш. *Ярый әле, килене бик зирәк нәрсә, Хәдичә түти иснәнә башлауга, ялт итеп торды да, нәрсәнедер минут эчендә сүндереп тә куйды.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Яшерен күзәтеп, берәр нәрсәнең эзенә, серенә, асылына төшенергә тырышу, сагалап йөрү.— *Волостьтан килеп, иснәнеп йөри башласалар, барың да бер сүздә торырга [кирәк].* И. Гази.— *Эшчеләр тирәсендә берәр нәрсә юкмы икән дип, бәлки, иснәнеп йөри торгансың?* Ф. Сәйфи-Казанлы. // Берәр нәрсәне көтеп, сагалап йөрү.— *Әллә каян иснәнеп сизәсең дә, бәйрәм көннәрендә киләсең дә чыгасың.* Т. Гыйззәт.

3. *к.* иснәү (4 мәгъ.). *Кадермәтев йокламаган, күрәсең, иснәнеп киерелде.* К. Нәҗми.

ИСНӘТҮ *ф.* 1. Иснәргә бирү, борынга ис җибәрү. *Безгә килеп борычлар да өшкертәләр, Шуны иснәтеп байларны төчкертәләр.* Г. Камал. *Алар, аның битенә салкын су бөркеп, дару иснәтеп, көч-хәл белән аңына китерделәр.* М. Гали.

2. *күч. сөйл.* Махсус дару бирепп, авыртуны сизмәс хәлгә китерү. *Минем бер иптәшкә доктор иснәтми авыр бер операция ясаган иде.* Һ. Такташ.

3. *з.- сыз. ф. к.* иснәү (4 мәгъ.). *Йокы килә: иснәтә.* Ф. Бурнаш. *Ирендерә, иснәтә башлады.* Г. Ибраһимов.

ИСНӘҮ *ф.* 1. Борын аркылы һава сулап ис сизү. *Күбек сыман ак нәрсәне икесе дә иснәп карадылар: аңардан чын сабын исе килә иде.* И. Гази. *Тәрәзә төбем исле гөл, Иснә, дустым — исле ул.* Җыр.

2. *күч.* Бер эшне сизеп алу, асылына төшенү. [*Хәзинә*] *кәгазь акчаларны --- [булган алтыннан] әллә ничә кат артык җибәргән. Заграницада да бу эшне иснәп белгәннәр.* Г. Тукай.

3. *күч.* Берәр нәрсәне тотып, күреп, татып, баштан кичереп белү. [*Ул*] *гыйлем вә мәдәният дигәннең төсен дә күрмәгән, уку вә китап дигәннең исен дә иснәмәгән.* Г. Ибраһимов. *Хабул бераз сәяси исне дә иснәгән.* Г. Нигъмәти.

4. Иренү, ялыгу, йокы килү кебек хәлләрдә, ирексездән авызны киң ачып, тирән сулыш алу һәм аны шунда ук кире чыгару. *Хәят, йокысы килгән кеше шикелле, бик еш исни.* Ф. Әмирхан. [*Берәү*] *каты итеп киерелде, авызын зур ачып иснәде.* М. Әмир.

ИС-ОС: исе-осы юк — бертөрле дә хәбәр ишетелмәү, һаман билгесез булу турында. *Вакыйгаларның барышы һаман үзгәреп тора, әмма җирнең исе-осы да юк иде.* М. Шабай. **Искә-оска кермәү** — башка, уйга килмәү, билгесез булу. *Җиңгиләр, апалар --- көне буе аш-чәй әзерләп, идән-кер юып, бала ашатып, бала киендереп, ирләрнең исенә-осына да кереп чыкмый торган тагын*

әллә никадәр вак-төяк эшләр эшләп җик булганнар. Г. Мөхәммәтшин. **Истә-оста булмаган** — уйга, башка килмәгән, уйламаган; бөтенләй билгесез. *Алексей Петрович верстагында моңарчы истә-оста булмаган, Кызыл Армиягә дошманны җиңәргә булыша торган яңа бер корал килеп туды.* Г. Бәширов. **Истә-оста юк** — 1) искә дә килмәгән, башка да килмәгән.— *Аракы дигән җен исемдә-осымда да юк иде. Шул Рахмай — кыска аяк кына ашады башымны.* Г. Мөхәммәтшин; 2) **уйламаган**, булуы көтелмәгән. *Хуҗаның үзен көткәндә, һич истә-оста юк кеше — аш өе ишегендә баштанаяк киенгән Нәҗия күренде.* Ф. Хөсни. **Истә-оста юк чагында (югында)** — көтмәгәндә, уйламаганда. *Һәм кинәт, ... истә-оста юк чагында, тегеләрнең икесенә берьюлы сорау бирәм.* Ф. Хөсни.— *Ә, кайттыңмыни, якташ! Бәй, ничек болай истә-оста юк чагында? --- Ничек алай бик тиз?!* Г. Бәширов.

ИСПАН *и.* Испаниянең төп халкы һәм шул халыкның бер кешесе. *Көнбатыш Европадан куып китерелгән французлар, испаннар, бельгиялеләр, итальяннар [лагерьдагы] кар-яңгырлардан каты газап чигәләр.* Г. Әпсәләмов. *Бирелергә ләкин уйламыйлар Илен сөйгән батыр испаннар.* Ә. Исхак. // *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Испан әдәбияты. Испан теле.* □ *Яңа дивизияләр Ташланганнар ярсып бары да Испан җирен басып алырга.* Ә. Исхак. // *с. мәгъ.* Испан милләтеннән булган. *Бераста ике кулы белән йөзен каплап бер испан карты утыра.* Г. Әпсәләмов.

ИСПА'НИЯЛЕ *и.* Испаниядә яшәүче яки чыгышы белән шуннан булган кеше. *Син русмы, итальянмы, төрекме, испаниялеме — телгә аптырамассың.* Г. Гали.— *Куышта яшибез! Испаниялеләр өчен Испачиядә яшәр урын бетте.* А. Әхмәт.

ИСПА'НКА *и.* 1. Гриппның беренче мәртәбә Испаниядә күренгән һәм 1918—19 елларда дөньяның күп илләренә таралган бик авыр формасы.

2. Озынча дүртпочмак итеп тегелгән балалар баш киеме (пионер формасы). *Кара пиджак, кара чалбар, кара испанка яшәүсмерне кечкенә генә солдатка охшатып җибәрде.* Н. Дәүли. *Хафиз үзен тирги, бетерә. Испанкасын салды башыннан, Аның ефәк чүгын бөтерә.* А. Сәләхетдинов.

ИСПАНЛЫ *и.* Испан халкының бер вәкиле. *Яшь испанлы ашыга фронтка, Култыгында — аучы мылтыгы.* М. Җәлил. [*Отто*] *испанлы Ренатоның иртән өченче тәрәзәгә чакырылачагын әйтте.* Г. Әпсәләмов.

ИСПОЛИН: исполин көнгерәсе *зоол.*— сумкалылар семьялыгында үзенең озын буе белән аерылып торган көнгерә.

ИСПОЛНИ'ТЕЛЬНЫЙ: исполнительный лист — суд карарын үтәү турында боерык кәгазе. *Судебный пристав киләдер исполнительный лист берләп.* Ш. Мөхәммәдев.

ИСПО'ЛЬЩИК *и. тар.* Җир хакын хуҗага уңышның ярты сы белән түләүче арендатор.— *Байлар өчен тырлап, испольщик булып, мәңге шулай газап чигеп, бер генә дә якты көн күрмәбез микәнни?* И. Туктар.

ИСПО'ЛЬЩИНА *и. тар.* Җир хакын хуҗага уңышның ярты сы белән түләүдән гыйбарәт булган аренда төре; уртакка эшләү.

ИСПРА'ВНИК *и. тар.* Революциягә кадәрге Россиядә өяз полициясе начальнигы. *Исправник Белявский, халыкны куркыту өчен, беренче залпны һавага атарга боера.* Г. Ахунов. *Исправник белән куштаннар Закирны алып китәргә килгәндә, халык үзенең соңгы сүзен әйтергә тиеш.* М. Җәлил.

ИСПӘРӘК *и. бот.* Казаяклылар семьялыгыннан зәңгәр һәм алсу чәчәкле кыргый яки бакча үсемлеге; зәңгәр чәчәк; *русчасы:* живокость.

ИСРАИЛ *и. иск.* Якуп пәйгамбәрнең икенче исеме һәм аннан таралган еврейләр нәселе; еврей. *Израил алласы.* □ *Исраил кызына да, күзләремне елмайтып, үземнең [хөрмәтләвемне] белдердем.* Ф. Әмирхан.

ИСРАИЛИЯТ *и. иск.* Еврей халкы, аның пәйгамбәрләре, изгеләре хакындагы әкиятләр; еврей **мифологиясе**.

ИСРАФ *и. иск. кит.* Малны кирәксезгә тоту, **юкка**, урынсызга бетерү, әрәм-шәрәм итү. *Бик бай мирас алып калган бер яшь егет, артык дәрәҗәдә мутлык вә исрафка керешеп, берничә көн эчендә мал-мөлекнең барысын урнаштырып, өстендә бер искерәк туннан башка нәрсәсе калмады.* Г. Тукай. [*Алар*], *һәрнәрсә үз кулларында булса да, чиктән тыш --- исрафны [яратмыйлар].* З. Бәшири.

Исраф булу — әрәм-шәрәм ителү. *Исраф булды юкка малың.* Бәет.— *Икмәк валчыклары җиргә төшеп исраф булмасын.* Ю. Әминов. **Исраф итү (кылу)** — әрәм-шәрәм итү, әрәм итү, юкка тоту; сарыф итү. [*Миңлебай*] *атасының тырышып тапкан малын бозык урынларга исраф кыла башлады.* Ш. Мөхәммәдев. *Исраф итмә, кызым, күз яшеңне.* Бәет.

ИСРАФИЛ *и. дини.* Ислам диненчә: кыямәт көнендә сур (бырсы) өреп үлекләрне тергезүче фәрештә (дүрт зур фәрештәнең берсе). *Кыямәт көнендә Исрафил сурын өргәч, адәмнәр терелеп, кабер өстендә җитмеш ел хәйран булып утырган кебек, «Аркадия» бакчасында --- эскәмияләрдә эшсез хәйран булып утыручылар бу ел да күп иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Исрафилме «сурын» өргән? Әллә «мәхшәр» көн килә?* Н. Исәнбәт.

ИСРАФЧАН *с. иск.* Артык юмарт, әрәм-шәрәм итүчән, юкка-барга тотучан, сарыф итүчән. *Исрафчан бай ярлы булыр.* Мәкаль.

ИСРАФЧЫ *и. сир.* Әрәм-шәрәм итүче, сарыф итүче кеше. *Саранның чыгымы исрафчыныкы белән бер.* Мәкаль.

ИСРАФЧЫЛ *с. иск.* Акчасын, малын юкка-барга тотучан; теге яки бу нәрсәне әрәм-шәрәм итүчән.

ИСРАФЧЫЛЛЫК *и. иск.* Исрафчыл булу. *Мәгърифәт кешене --- ялкаулыктан, исрафчыллыктан, бозыклыктан сакларга [тиеш].* И. Нуруллин. *Адәм баласына нинди генә исем кушмасыннар — элек-электән аны кыскарта килгәннәр. Бу, бәлки, халыкның үзенә күрә исрафчыллыкка каршы көрәшедер?* М. Мәһдиев.

ИСРӘЮ *ф.* Аңгыраланү, миңгерәүләнү. *Башың исрәйгән, аркаң бөкрәйгән.* Д. Гобәйди.

ИССЕЗ I *с.* Исе I булмаган. *Болынлыкта ускән гади генә иссез чәчәк яңлыш исле чәчәкләр бәйләменә бергә бәйләнгән.* Г. Тукай.

Иссез эрем *бот.*— эремнең бер төре; кара чагыр; *русчасы:* нехворощь белая.

ИССЕЗ II *с. диал.* Ансыз, һушсыз, һуштан язган. // *рәв. мәгъ.* Һушсыз хәлдә, аңын югалтып. *Бала үр астында иссез ята иде. Ул ташка сугылган, авызы, борыны канаган.* И. Салахов. *Яраланган, азрак иссез яттым бугай!..* М. Галәү. // Миңгерәү. *Иссез булып, баш авыртып күп утырдык. Бу утыру инде җитәр, инде җитәр!* М. Гафури. *Гали һаман иссез кеше кебек тора.* М. Фәйзи.

Иссез калу — 1) һуштан язу; 2) кинәттән бик әсәрләнеп, ни әйтергә белми тору. *Егет аңа, өнемме бу, төшемме дип, иссез калып карап торды да, исенә килгәч, куанычыннан елмай[ды].* Г. Мөхәммәтшин.

ИССЕЗЛӘНҮ *ф. диал.* Аңгыраланү, миңгерәүләнү. *Бу күренеш ачлыктан йончыган Гөлҗамалга начар тәэсир итә, ул артта иссезләнеп тора да, тавышсызнисез, жиңелчә генә урынына авып төшә.* Н. Исәнбәт.

ИССЕЗ-ТЫНСЫЗ *с.* Һушсыз, сулый алмаслык хәлдә. *Ята Морат. Иссез-тынсыз ул.* Н. Исәнбәт.

ИСТЕ'РИК I *с.* Истериягә дучар булган, истерияле. [*Мидхәт*], *Зәйтүнәнең күкрәгенә кинәт йөзе белән капланып, истерик бер үксү белән елап җибәрде.* Ф. Хөсни. *Суфия истерик тавыш белән көл[де].* К. Нәжми.

ИСТЕ'РИК II *и. сөйл.* Истерия белән авыручы кеше.

ИСТЕ'РИКА *и.* Истерия өянәге. *Ул урынынан кузгалды да, «ах-ух» килеп, еламсырап истерикага ташланды.* Ш. Маннур. [*Зәлифә*] *бер үк кеше белән көлә дә, елый да, чәчен-башын туздырып кычкырыша да ала. --- Көн саен кабатланып торган* [*мондый*] *истерикадан соң ул* [*ни эшләргә*] *тиеш?* Г. Ахунов.

ИСТЕ'РИКЛЫК *и.* Истерик II булу, үзен истерия белән авыручы кешеләрчә тоту, истерикага бирелү хәле.

ИСТЕРИ'Я *и.* Юк-бар нәрсәдән үзен үзе белештермәслек рәвештә кычкырып елау, көлү яки бик нык әсәрләнү белән үзенчәлекле нерв авыруы. // *күч.* Берәр өлкәдә ярсулы, кызу эшчәнлек; берәр нәрсәгә шашынулы омтылыш. *Империалистларның сугыш истериясе кабызуы.* □ *Көнбатыштан искән җилләр белән хәзер яңадан сугыш истериясе төтене килә.* Ш. Мөдәррис.

ИСТЕРИ'ЯЛЕ *с.* Истериягә дучар булган.

ИСТИБДАТ *и. иск. кит.* Бер кешенең баш булуына һәм кәфенә корылган идарә, һичбер законга буйсынмаган, чикләнмәгән хакимлек; деспотлык. *Үз истибдатын саклап, халык акчасына төркем-төркем җәрияләр асрау, хәрәмнәр тоту өчен фидаилар канына сусаган Иран бюрократиясе йөзен чыткан.* Ф. Әмирхан. // Реакция, изүчелек. *Хөкүмәтнең истибдаты аркасында* [*изелдек*]. М. Гафури. *Яңадан истибдат (реакция) кире кайтты, аның канлы тырнаклары астында шомлы сыкрану таралды.* М. Максуд.

ИСТИГАРӘ *и. әд. иск. кит. к.* метафора. *«Таш йөрәк», «тимер кул» дисәк, истигарә була.* Г. Ибраһимов.

ИСТИГЪМАЛЬ *и. иск. кит.* Кулланылыш, кулланыш. *Һичбер кем --- [дәреслекләр] урынына торачак вә аларны истигъмальдан төшерәчәк бер китап язмады.* Ж. Вәлиди.

Истигъмаль итү (кылу) — 1) файдалану, куллану. *Фәкыйрь халык күбрәк истигъмаль кыла торган нәрсәләрдән налог бөтенләй алынмасын.* Урал. *Бу коралны аларның кальгаләрен (крепостьлары була) ваттыру кебек эшләргә истигъмаль итәләр.* М. Гафури; 2) эчү, ашау, эчкә кабул итү. *Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм.* Г. Тукай. *Аның хәтеренә үзе исән вакытта истигъмаль итә торган мәгъҗүн исемле исерткечнең юклыгы күлеп төште.* Ф. Әмирхан.

ИСТИГЪФАР *и. дини.* Алладан гөнаһларның кичерелүен, ярлыкауны ялварып сорау; «әстәгъфирулла» дию. [*Ул:*] *«Әстәгъфирулла, я раббем, әстәгъфирулла»,— дип уйлады, бу истигъфар астында көфердән вә көферне сөюдән алланың кодрәтенә сыену яшеренә иде.* Ф. Әмирхан.

Истигъфар кылу — тәүбә итү, алладан гөнаһларны кичерүне сорау.— *Тәүбә, истигъфар кылың.* К. Нәҗми.

ИСТИҚАМӘТ *и. иск. кит.* Тугрылык, дөреслек, намуслылык. *Күрсә ул мактар сине: «Һәйбәт кеше Әхмәт»,— дияр; «Тәүфыйгында, истикаматтә, менә рәхмәт!» — дияр.* Г. Тукай.— *Тәүфыйк, истикамәт белән йөреп кайту насыйп булсын!* М. Фәйзи.

ИСТИҚАМӘТЛЕ *с. иск. кит.* Тугрылыклы, намуслы.— [*Ул*] *бик тәүфыйклы, бик истикамәтле шәкерт иде.* Ә. Фәйзи. *Бәдретдингә дә, ул замандагы тел белән әйтсәк, истикамәтле вә ижтиһатлы шәкерт булганга күрә, байлар иганәсеннән ара-тирә ярдәм тия иде.* Ә. Еники.

ИСТИҚЪБАЛЬ *и. иск. кит.* Қиләчәк. *Истикъбаленнән* [*егет*] *өмет кискән, «Ник тудым,— дип егълый,— анадан».* М. Укмасый. *«Яшьләр» дим, чөнки мин бөтен истикъбальнең алар кулында икәненә чыннан ышанам.* Ф. Әмирхан.

ИСТИЛАХ *и. иск. кит.* Атама, термин. *Һәр фәннең үзенә махсус истилахы бар.* К. Насыйри. *Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилах.* Г. Тукай.

ИСТИРАХӘТ *и. иск. кит.* Ял, рәхәт. *Бәйрәмнәрне истирахәт ясау сезнең үзегездән килә.* Ф. Әмирхан. *Һәр елны ике атна истирахәт өчен вакыт бирелсен.* РСДРП прокламациясе.

Истирахәт итү (кылу) — ял итү, рәхәтлек сизү. *Гадәттә хәзрәт --- сәгать тугызларга кадәр истирахәт итә.* Г. Қамал. *Сезнең менә бу бакчагызны яратып киләм бирегә. --- Мин монда чын мәгънәсе белән истирахәт итәм.* Ә. Фәйзи.

ИСТИСКА *и. дини.* Яңгыр теләү. // Яңгыр теләү намазы. *Моңарчы ихлас күңелдән яңгыр намазы — «истиска» укып йөргән картлар да дөнья кайгысыннан ваз кичтеләр.* Қ. Нәҗми.

Истиска намазы *дини* — кырга чыгып, яңгыр теләп укыла торган намаз. *Яңгыр теләп, истиска намазына чыгып карасак та, яңгыр булмады.* М. Гафури.

ИСТИСНА *и. иск. кит.* Чыгарма; аерып алу. *Баланы ата-анадан беренә яисә икенчесенә дә охшату гадәт хөкеменә кергән. --- Ләкин Җәләл хәзрәт һәм Зөләйха абыстай илә ике зур угылы арасында бу хакта истисна кебек бер хәл булды. ---* [*Сабир*] *һичбер сыйфаты, нә җаны, нә кыяфәт вә табигате белән атасына да, анасына да охшамады.* Г. Ибраһимов. *Орфографиядә чыгармалар (истисналар) күп була. Бу хәл язуны читенләштерә.* Х. Курбатов.

ИСТИФАДӘ: истифадә итү (кылу) — файдалану, куллану, файда күрү. *Бөтен табигатьтә никадәр гүзәллек! --- Фәкать адәмләр үзләре генә моннан истифадә итә белмиләр.* Ф. Әмирхан. *Габбас бу базардан күп нәрсәләр истифадә кылды.* З. Һади.

ИСТИХАРӘ *и. иск. кит. дини.* Берәр эшнең яхшы яки начар булачагын алдан төштә күреп белү өчен кичтән махсус догалар укып, шуна ниятләп йокыга яту. // Шундый догалар укып яткач күрелгән төш. *Истихарәләренең һәркайсы яхшы чыкты. Хәзрәт төшендә бик шәп бакчалар, бик һәйбәт ялтырап аккан чишмәләр күрде.* Г. Қамал.

Истихарә кылу — төшлек салу, төш юрау. [*Ул*] *Ишми хәзрәтне яңадан күрә алачакмы икәнчелеген тәмамән белеп җитү өчен бүген төнлә истихарә кылып карарга уйлаган иде.* Ф. Әмирхан. [*Ул*] *бу эшнең хәерле булып-булмавын* [*күрәзәлек итеп*] *карау өчен хәзрәттән истихарә кылып карарга үтенде.* Г. Қамал.

Истихарә намазы — йокларга ятыр алдыннан, күреләчәк төшнең хәерле булуын теләп укыла торган намаз. [*Хәзрәт*] *истихарә намазын, хәзер генә юып алып чыккан чалбарын җәеп, аның өстендә укыды.* Ф. Әмирхан.— *Улларыңның котылып кайтуларын теләп, истихарә намазыннан соң дога кылырмын.* Т. Гыйззәт.

ИСТИХАРӘЛЕ *с. иск. дини.* Алдагы эшнең хәерле булу-булмавын белү өчен махсус (төш турында).— *Аһ, шайтан, килеп, тәһарәтемне боздырып чыгып китте бит, нәгъләт! Истихарәле төш күрермен дигән идем.* М. Әмир.

ИСТИһЗА *и. иск. кит.* Мыскыл, мәсхәрә. *Ул, күзләрен югарырактан йөртеп, илтифатсыз гына, хәтта истиһза беләнрәк көлемсерәп тора.* Ш. Қамал. *Батырхан, тагы пычрак истиһза белән елмаеп: «Әллә шуны ярып та бирәсезме?» — [диде].* Г. Ибраһимов.

Истиһза итү (кылу) — мыскыллау, мәсхәрәләү, ачы көлү. *Мөгълифә, һаман да истиһза итеп: «Кем белә, бәлки, алыр да, синең өчен, бәлки, хатыннарын да аерыр»,— [ди].* Г. Қамал.

ИСТИһЗАЛЫ *с. иск. кит.* Мәсхәрәле. *Батырханның йөзендә истиһзалы елмаю сизелә.* Г. Ибраһимов.

ИСТОРИО'ГРАФ *и. махс.* Историография белгече.

ИСТОРИОГРА'ФИК *с.* Историографиягә караган. *Историографик тикшеренү. Историографик әдәбият.*

ИСТОРИОГРА'ФИЯ *и. махс.* **1.** Билгеле бер чорга яки мәсьәләгә караган тарихи хезмәтләр җыелмасы. *Болгар чоры историографиясе.*

2. Тарих фәненең үсеше һәм тарихи чыганаклар турындагы гыйлем. *Идел һәм Урал буе тарихы буенча --- чыганакларны өйрәнү һәм историография канәгатьләнерлек түгел.* Ш. Мөхәммәдьяров.

ИСТРЕБИ'ТЕЛЬ *и. хәрби.* 1. Һава сугышларында дошман самолетларын юк итү өчен файдаланыла торган җиңел, тиз йөрешле һәм яхшы коралланган сугыш самолеты. *Атылган ук шикелле, күз иярмәс тизлек белән, безнең штурмовиклар, истребительләр һәм бомбардировщиклар үтеп китәләр.* Г. Әпсәләмов. *Җитез истребительләребез дошман бомбардировщигын кире борылырга мәҗбүр иттеләр.* Г. Гобәй.

2. *с. мәгъ.* Кораллы көчләрне (мәсәлән, танк, туп һәм башкаларны) юк итү өчен хезмәт итә торган.— *Танкка каршы аерым истребитель дивизионы* [*килде*]. Ф. Булатов. *Күңелнең иң эчкәрege почмагында истребитель авиациясенә күчү теләге гел яшәп килде.* Г. Ахунов.

ИСТЫЙРАП *и. иск. кит.* Борчылу, аптырау. *Рухны бөтенләй ниндидер бер коры сызлау, ниндидер бер зәһәрле әрнү, ачы бер истыйрап (борчылу) каплый.* Г. Ибраһимов. *Бер-берсенә багланышсыз, хәтта бер-берсенә капма-каршы тойгылар --- минем теңкәмә тиделәр, мине бер истыйрапта тоттылар.* Ф. Әмирхан.

Истыйрапка төшү — борчылу, борчуга төшү. *Мин, алдан ук икенче класста бер урын яздырып куйганлыгымнан, бик истыйрапка төшми утыруымда дәвам итә идем.* Ф. Әмирхан.

ИСТЫЙРАПЛЫ *с. иск. кит.* Борчулы. *Һәммә нәрсә үзенең кара ягы, ямьсез, мәгънәсез йөзе белән әйләнгән истыйраплы минутларда бу* [*нәрсә*] *минем каршымда --- әһәмиятен югалта.* Г. Ибраһимов.

ИСТӘК *и. иск. к.* хантый.— *Харап итмә Болгарны, Қашан белән суарны, Башкорт, мишәр, чувашы, --- Истәк, мари, удмуртны.* Н. Исәнбәт.

ИСТӘЛЕК *и.* 1. Истә, хәтердә сакланган вакыйга, күренеш. *Улы белән икәүләп иртән --- урманлыкка таба чыгып китүләре, --- өч яшьлек баланың* [*сорашып баруы*] *--- --- йөрәкне бер үк вакытта әрнетә дә, рәхәтләндерә дә торган шушы татлы истәлекләр Сөләймановның күңеленә тәмам хуҗа булып алдылар.* И. Гази. *Күпме истәлекләр — яхшысы, яманы, кызыгы, кызганычы — сөйләп бетергесез.* Ә. Еники.

2. Үлгән кешенең хатирәсе, ядкаре. [*Шигырь*] *Мулланур Вахитов истәлегенә багышланган.* М. Гафури. *Матросовның үлемен куркаклар үлеме белән янәшә кую батырның якты истәлеген мәсхәрә итү булыр иде.* Г. Әпсәләмов.

3. Берәр кеше яки нәрсә турында искә төшерерлек әйбер, ядкарь.— *Бәләкәй генә бүләк — баш яулыгы җибәрәм. Мине чит күрмәсәң, истәлек итеп бәйләрсең.* Ш. Қамал. *Ничә әйтсәң дә, бу бүрек аның ике ярым еллык Қырлай тормышының истәлеге иде бит.* Э. Фәйзи.

4. Борынгы заманнардан сакланып калган корылма яки сәнгать әсәре; язма әсәр. *Шундый канлы фажигаләр вакытында нинди әдәби, гыйльми әсәрләр, тарихи истәлекләр, кыйммәтле һәйкәлләр һәлак булмагандыр!* Г. Бәширов. [*Киев*] — *уникенче йөзләр истәлеге, Тутыкмыйча килгән алтыны.* С. Хәким.

5. Үткән хәлләр турында язма хикәя; мемуар. *С. Рәмиев Тукай турындагы истәлегендә аның, гаруз гыйльмен белү өстенә, гаруздан башка үлчәүләрдә дә татар шигыре язылганлыкны белүе турында сөйли.* Г. Нигъмәти. [*Г. Тукай*] *турында әле тулысынча истәлекләр — мемуарлар да чыкканы юк* [*иде*]. Г. Қутуй.

Истәлек дәфтәре — хәтер дәфтәре. *Шул ук юкәгач таяк аның истәлек дәфтәре, бухгалтерия дәфтәре урынына йөри.* М. Гали. *Минем истәлек дәфтәрем немецча язылган.* Г. Гали. **Истәлек язуы** — берәр кешенең яки вакыйганың истәлеген мәңгеләштерү өчен язылган язу; мемориаль такта. *Казанга килгән кеше гадәттә бу йорткa күз салмыйча, аның стенасындагы истәлек язуын укымыйча узып китә алмый.* Г. Бәширов.

ИСТӘЛЕҚЛЕ *с.* 1. Теге яки бу яклары белән хәтердә яхшы сакланган, саклана торган; онытылмас. *Артка әйләнеп караганда, игътибарны азмы-күпме тотып торырлык кайбер истәлекле сәхифәләр бар.* Ф. Хөсни. *Ул еллар минем өчен «Ике буйдак» исемле романымның дөньяга чыгуы белән истәлекле.* А. Расих. // Тормыштагы билгеле бер вакыйгалар, истәлекләр белән бәйләнгән. *Һәр авылның үзе генә белгән истәлекле урыны була. Бер авылда ул — чишмә, икенче авылда — урман аланы, өченчесендә — ялгыз ак каен.* Г. Ахунов. [*Гәрәй*] *кесәсендә һәрвакыт ике чуерташ йөртте. Искә урыннан күчеп киткәндә аларны кая да булса истәлекле урынга ыргытып калдыр*[*а*] *--- торган булды.* А. Гыйләҗев.

2. Берәр әһәмиятле вакыйганы яки атаклы кешеләрне искә алуга багышланган. *Хәзерге Үзәк лекторийда --- очрашулар оештырыла, истәлекле кичәләр үткәрелә.* М. Максуд. // Берәр кеше яки вакыйга истәлегенә бирелгән, чыгарылган, куелган. [*Миңа*] *чиктән тыш хөрмәт күрсәттеләр, күп истәлекле бүләкләр бирделәр.* Қаз. утл.

ИСТӘЛЕҚЧЕ *и. сир. к.* мемуарчы. *Икенче бер тип мемуарчы — истәлекчеләр «җиңел» юл тоталар.* Г. Ибраһимов.

ИС-ТӨШ: истә-төштә юк (булмау) — бөтенләй көтмәгән, уйламаган. *Қинәт, истә-төштә юк чагында, кемдер иңбашыма кулын китереп салмасынмы!* Г. Шәрәфетдинов.

ИСӘ *ф.* 1. *бор. И-IV* (борынгырак формасы *ир-*) тамырыннан ясалган ярдәмче фигыль, хәзерге телдә: *булса.— Ялгыш исә, гафу ителсен.* Г. Қамал. [*Без*] *өч йөз ел нә хәлдә исәк, әле дә* [*1907 елда*] *шул хәлдәбез.* Ш. Мөхәммәдев. // Төп формада *алай исә (алайса), юк исә (югыйсә), я исә (яисә), әйттем исә кайттым* тезмәләрендә генә состав өлеш булып сакланган.— *Ярый, алай исә, бишне арттырам.* Ф. Бурнаш.— *Әллә юк исә мин саташаммы?* Г. Қамал.— *Үзең беләсең тагын, әйттем исә кайттым.* Қ. Әмири.

2. Үткән заман хикәя фигыльгә кушылып шарт фигыль ясый һәм баш җөмләдә белдерелгән эшнең иярчен җөмләдә белдерелгән эштән соң ук, бик тиз арада башкарылуын аңлата. *Ул бетмәскә тиеш, эш бетте исә, тормыш бетә дигән сүз.* Ш. Қамал. *Сәгать кичке алты булды исә, бакчада музыка башлана.* Г. Ибраһимов.

3. *диал.* Үз сүзенең яки фикеренең дөреслегенә үзедә ышанып җитмәвен, чамалап кына әйтүен белдерә.— *Безнең килен бригадасында эшли иде дә, әле бүген өйдә күренде. Берәр йомыш белән кайтканмыдыр исә...* Г. Бәширов. *Сәләхи абзыйның Мөбәрәкшасын югалттык, бер дә кая киткәнен белмибез, үлгәндерме исә дип әйткән, ди... дөресмедер исә, юкмыдыр, ансын мин аермачык белмим.* М. Гали.

4. *терк. функ.* Әйтелә торган сүзләрне алдагы фикергә каршы кую өчен кулланыла. *Ә менә хәзер ноябрьның беренче атнасы инде, көннәр исә һаман да коры әле.* Г. Бәширов. *Төннәрен исә аларның ике кечкенә тәрәзәсендә бик озак ут яна.* Ә. Еники.

ИСӘВӘН *с. диал.* Онытучан, тиз онытучан. *Исәвән кеше.*

ИСӘҚӘЙ *и. этн.* Каз өмәләре вакытында егет һәм кызларның төрле кыяфәттә киенеп, биеп-уйнап су буена төшү гадәте.

ИСӘН *с.* 1. Тере; *киресе:* үлгән. *Үлгән кебек түгел, миңа Ленин, Ул һаман да исән төследер.* М. Гафури. *Атасы исән чагында да, шулай ук атасы үлгәч тә, аның аларга килгәне бар.* А. Шамов. // *рәв. мәгъ.* Тере килеш, тере.— *Сезне үлеп беткәннәрдер диеп, бик ашыгып кайттым, ярый, исән калгансыз икән әле.* Әкият. // *и. мәгъ. диал.* Тереклек иткән чак, дөньяда яшәгән

чак.— *Бердәнбер баламны үз исәнемдә күзле-башлы итеп калдырасым килә.* Г. Бәширов.

2. *рәв. мәгъ. күч.* Гамәлдә, яшәештә, имин, иминлектә (җансыз әйберләргә карата). *Совет исән булса, аты да булыр, сыеры да булыр.* М. Гали.

3. Сәламәт, таза; авыру булмаган.— *Үзе булса, бик яхшы аңлар иде дә, хәзер исән түгел, гакылдан шашкан.* Г. Камал. / *рәв. мәгъ. Өскә алдым туган ил каршында Аның исән, таза үсүен.* М. Җәлил.

4. Югалмаган, юкка чыкмаган, үз урынында калган. *Документларым барысы да исән, тик бумажнигым белән акчамны гына алганнар.* А. Шамов. // Зарарланмаган, җимерелмәгән.— *Тез капкачы да исән, примочка ябып, урап куегыз,— диде врач.* Ш. Камал. // *рәв. мәгъ.* Зарарланмыйча, җимерелмичә. [*Сугыш үткән авылда*] *җимерелми, яндырылмый калган йортларны тапмассың, авылның уртасындагы чиркәү генә исән калган.* Ф. Булатов.

5. **Исәнме(сез), исәннәрмесез.** Очрашканда, исәнләшкәндә, исәнлек-саулык сорашканда әйтелә. [*Мәдинә*] *егеткә җитез генә кулын суздыр: «Исәнме, Сәйфулла, исән-сау кайттыңмы?»* Ә. Еники.— *Ә, кунак та бар икән... Исәнмесез, Гөлнур туташ!* Ф. Бурнаш. *Ишектән керүче шул Чатан Шәрифулла булды: «Исәннәрмесез!» — диде ул, тавышы белән бөтен өйне яңгыратып.* А. Шамов.

6. *ы. мәгъ. сөйл.* **исәнме(сез)** *к.* исәнгенә торасыңмы.

◇ **Исән бул(ыгыз) (калыгыз)** — саубуллашканда, эчемлек эчәр алдыннан чәкешкәндә яисә бер әрсе төчкергәндә сәламәтлек теләү.— *Хушыгыз, иптәшләр... Исән булыгыз.* Г. Әпсәләмов. *Тын яланнар, бөдрә таллар, Исән калыгыз!* М. Җәлил. [*Вилдан:*] *Исән булыгыз!* [*Бары да:*] *Сау бул! (Эчәләр.)* Ф. Бурнаш. **Исән генә торасыңмы** *сөйл.*— гаять гажәпләнүне, нәрсәгә булса да ризасызлыкны һ. б. ш. хисләрне белдерә.— *Безне каравыл өенә чакырдылар. Исән генә торасыңмы! Усман урядник, староста, Мөхәммәтша Тукран, таҗын берничә кеше шунда күзләрен чекерәйтеп утыралар.* А. Шамов. *Камышев, гажәпләнгәннән-гажәпләнә барып, үзалдына башын чайкап куйды. Менә сиңа кешеләрне беләм дип уйлап йөр! Җыелышларда колакка ягылырлык фикерләр сөйли, политикадан да бөтенләй төшеп калган егет түгел, ә бүген, исән генә торасыңмы, тыныч эшләүне ярата торган кеше булып чыкты.* И. Гази.

ИСӘНГЕРӘҮ *ф.* Аңгыралану, миңгерәүләнү, зиһенен җыя алмаслык хәлгә килү, аптырап калу. [*Ул*] *бик нык кыйналып, имгәтелеп, һушсыз ташланып та, соңра яңарак һушына килеп, исәнгереп утырган кеше сымак* [*күренә*]. М. Гафури. *Нәсимә аны ишетми дә, аңламый да. Аркасы белән ташка сөялгән хәлдә исәнгерәп тик тора.* Г. Ахунов.

ИСӘН-ИМИН *рәв.* 1. Тере, сау-сәламәт килеш. *Сәфәргали сугыш утлары белән җәрәхәтләнгән җирне аркылыга-буйга таптап исән-имин чыг*[*а*]. Ф. Хөсни.— *Без дә, шөкер, бер көе исән-имин генә йөрибез әле.* Э. Еники.

2. Зарарламыйча, зарарланмыйча, зарарланмаган хәлдә, бөтен хәлендә. *Кыйммәтле хәзинә тутырылган тартманы мәктәпнең хезмәт бүлмәсенә исән-имин кайтарып җиткерәсе генә калды.* Г. Мөхәммәтшин.

ИСӘНКЕРӘҮ *ф. диал. к.* исәнгерәү. *Яңа гына йокыларыннан уянган солдатлар исәнкерәгән кебек бар*[*алар*]. М. Гафури. / *и. мәгъ.*—[*Фәттах*] *авыр автомат дискысы белән чык итеп берне тондырды да, исәнкерәүдән тавыш-тынсыз, телсез калып, бүрәнә кебек җиргә ава башлаган немецның өстенә үк ыргып төште.* Ф. Кәрим.

ИСӘНЛЕК *и.* 1. Исән (1—4 мәгъ.) булу. *Туган ил өстенә шундый куркыныч ябырылган бер вакытта үз башымның исәнлеге, үз бәхетем турында гына уйларга минем хакым юк.* Г. Бәширов. *Малай бу нәрсәгә карап тора, белми исәнлеген, белми үлгән икәнлеген.* Әкият. *Озын мыеклы абый, бумажнигы эчендәге әйберләренең исәнлеген күргәч, кинәт дулкынланып, әнисенең кулын кысты.* А. Шамов.

2. **Исәнлекме.** *к.* исән (5 мәгъ.). *Сафа белән әнвәр керәләр: «Исәнлекме, Җамали абзый?»* А. Әхмәт.

3. *У.-в. кил. рәв. мәгъ.* **исәнлектә.** Исән (1 мәгъ.) чакта, исән (1 мәгъ.) вакытта.— *Исәнлектә күрешергә насыйп итсен!* Ә. Айдар.

4. *юнәл. кил. тарт. форм.* **исәнлегенә, исәнлегеңә.** Эчемлекнең берәр кешенең сау-сәламәт булуына теләк йөзеннән эчеләчәге турында әйтелә.— *Әйдәгез, бу рюмкаларны безнең мәҗлестә катнашмаган хатын-кызлар исәнлегенә күтәрәбез.* Г. Минский. *Күтәрәм бүген бокал мин Яшәү исәнлегенә. Һәм күтәрмичә кала алмыйм Дуслар исәнлегенә.* Ә. Ерикәй. // *юнәл. кил.* **исәнлеккә.** Эчемлек эчкәндә бер-береңә сәламәтлек теләп әйтелә торган сүз. [*Габдерүш:*] *Чынлап та, яле, күршеләр, исәнлеккә! (Эчәләр.)* Ф. Бурнаш.

ИСӘН(ЛЕК)-САУЛЫК *җыйм. и.* 1. Сәламәтлек, тазалык; авыру булмау.— *Я, нихәл соң? Исәнлек-саулык?..— Исәнлек дип, ул якын зарарсыз.* Г. Бәширов.— *Бәхетсез бала булды* [*ул*], *ахрысы. Исән-саулыгы чамалы, күрәсең. Ашының рәте юк, йокысының рәте юк.* Ш. Камал. // Исәнләшү, сәлам бирү. [*Илдус керә:*] *Менә, нәкъ син дигәнчә булды.* [*Айдар:*] *Улым, исәнлек-саулык кайда? - - -* [*Илдус:*] *Исәнме, бабай!* Д. Аппакова. // Иминлек, гомер, тереклек. *Ул сугышта чакта аңа исәнлек-саулык теләдек, - - - ә ул безнең бәхетебезне көнли.* Р. Ишморат.

2. **Исән-саулыкмы.** *к.* исән (5 мәгъ.). [*Мөгаллим:*] *Әссәламегаләйкем, хаҗи әфәнде. Исән-саулыкмы?* [*Хаҗи:*] *Вәгаләйкемәссәлам.* Ш. Камал.— *О, Иштуган кайткан! - - - Исән-саулыкмы? Кайчан кайттың?* Г. Әпсәләмов.

3. *юнәл. кил.* **исәнлеккә-саулыкка.** Эчемлек эчкәндә бер-беренә сәламәтлек теләп әйтелә. [*Локман:*] *Әйдә, исәнлеккә-саулыкка!* [*Кулаев:*] *Әйе, шулай булсын, кода. (Эчә.)* Ш. Камал.

Исәнлек-саулык сорашу — исәнләшү, сәлам бирү.— *Исәнме, кызым Җәмилә? Ачуымнан исәнлек-саулык сорашырга да онытканмын.* Г. Камал.

ИСӘНЛӘШҮ *ф.* 1. Очрашканда бер-берең белән сәламләшү, күрешү. *Нәфисә, аңа кулын сузып: «Шулай да, иң элек исәнләшик әле, Гөлсем, сау гына килеп җиттеңме?» — диде.* Г. Бәширов. *Керүгә ул Низами абзый белән ике куллап күреште һәм, Гөлгенә түти белән болай гына исәнләшеп, өстен чишенде.* М. Гали.

2. Саубуллашу. *Байтак сөйләшеп утыргач, Гайнулла - - - исәнләшеп кайтып китте.* Ш. Мөхәммәдев.— *Бүген кич поезд белән Бакуга китәм,— дип,* [*ул*] *танышларына исәнләшергә барды.* Г. Ибраһимов.

ИСӘН-САУ *с. к.* исән (1—5 мәгъ.). *Егетнең зыянзәрәте юк, аяк-кулы исән-сау.* А. Шамов. *Безнең бүлмә һәм мебель исән-сау.* М. Җәлил.— *Исән-сау гынамы, Хәмит энем?* Р. Ишморат.

ИСӘН-ӘМАН *рәв. к.* исән-имин. *Бер картка боз аккында көймә белән Идел аша чыгарга туры килгән. Картка бу бик куркыныч тоелган һәм ул, исән-әман чыксa, бер сум хәер бирергә адарынган.* Мәзәк. *Хәерелбанатлар Нурулла янына исән-әман барып та җитә алмаганнар. Юлда үк алар утырган поездга немец самолетлары бомба ташлаган. Сания шунда һәлак булган.* А. Гыйләҗев.

ИСӘН-ӘМАНЛЫК *и.* Исән-әман булу хәле. *Килеп керде, - - - миңа сәлам бирде, Исән-әманлыкны сорады: «Кәеф начар мәллә, абзыем?» — ди.* «[*Әйе*],— *мин әйтәм,— сырхап торамын».* Ш. Маннур.

ИСӘП I *и.* 1. Бериш нәрсәләрнең гомуми саны, микъдары.— *Кош-кортның инде аның исәбен хатын-кыз*

белсә белә торгандыр. И. Гази.— *Сахау абыйларның, Фәсхи бабайларның, Камилә әбиләрнең өйләрен йорт исәбенә кертергәме, юкмы? Аларның бит мукча кебек җир өйләреннән башка бернәрсәләре дә юк.* Г. Гали.

2. Билгеле сандагы нәрсәләр арасында, составында (арасыннан, составыннан) булуны белдерә. *Пассажирлар, шул исәптән носилкалардагы яралылар да, аның --- әдәп белән ашап утырганына сокланып карап торалар.* Г. Гобәй. *Ключарев байтак кына җырлар язды. Болар исәбендә «Әй, иптәшләр», «Җырламыймы?»-[ны] --- күрсәтергә мөмкин.* М. Җәлил.

3. Нәрсәнең дә булса санын, микъдарын билгеләү нәтиҗәсе.— *Минем исәпкә караганда, яхшы уңыш алу өчен, гектарына йөз җитмеш биш килодан да ким чәчәргә ярамый.* Г. Бәширов. // Спорт уеннары нәтиҗәләре турында. *1 : 0 исәбе белән оту.* □ *Казанлылар, исәпне тигезләргә телән, тырыша-тырыша тупны каршы як капкасына алып килгәләделәр.* А. Гыйләҗев.

4. Берәр нәрсәне игътибарга алып билгеләнгән сан, норма. *Пионерлар сыекчаны, һәр гектарга 20 центнер исәбеннән, тарыга сибеп чыктылар.* Г. Гобәй.

5. *У.-в. кил. күч.* **исәптә.** (Яхшы яки начар) булып исәпләнү, саналу турында. *Безне әле яхшы исәптә йөртәләр, дип тынычланып яшәвен ул менә хәзер аңлады.* Ә. Еники.— *Мин анда начар исәптә түгел.* С. Рафиков.

6. Вәгъдә, договор буенча эшнең ахырында түләнә торган хезмәт хакы; расчёт. *Иртән алырга уйланган исәпне кичкырын гына алдылар. Исәптән вак-төяк әйбер һәм акчалата алганнары чигерелеп, һәммәсенә йөз ун сумлап акча бирелде.* Ш. Камал.

7. *күч.* Эшләгән эш өчен җавап, хисап, отчет.— *Санап ал да расписка яз! Иптәшләргә исәбен бирергә туры киләчәк.* К. Нәҗми.

8. *юнәл. кил.* **исәпкә.** Кемнең дә булса акчасына, средствосына.— *Минем исәпкә яхшылап киендерегез үзен.* К. Нәҗми. *Мал хуҗаларының артык кәефе кырылган да, күп киңәшеп-нитеп тормыйча, безнең исәпкә яллап, икенче берәүне көтүгә чыгарганнар.* Г. Ибраһимов.

9. *юнәл. кил.* **исәбенә.** Берәр әйбер урынына, бәрабәренә (алу, файдалану турында). [*Әсәрне*] *кыскарту Печән базарындагы күп кенә артык эпизодлар, юк-бар сөйләшүләр исәбенә булырга мөмкин.* М. Җәлил. *Десятниклар, урядниклар мужикның соңгы кәҗәссн, ястык-мендәрләрен, эти-бабадан калган борынгы самоварын оброк исәбенә, недоимка исәбенә тартып алалар.* К. Нәҗми.

10. Алдан ясалган хисап, экономия. [*Мостафин*] *бабасының исәп белән тора белүенә чын-чынлап гаҗәпләнә. Ә бабасы, --- кулына счет алып, аңа аяклы мал симертеп суюның базардан ит сатып алуга караганда никадәр арзанга төшүен исәпләп күрсәтә.* Ә. Еники.

11. *У.-в. кил.* **исәптә.** *к.* исәпле I.— *Ипекәй ифрат кадерле. Һәр мыскалы исәптә аның.* С. Рафиков. *Егетнең кесә ягы да исәптә. Леспромхозда «көрәп алган» акча инде тагын бетеп килә.* Ф. Хөсни.

12. *рәв. мәгъ. диал.* Күп, артык. *Бер тәлинкә аш дәү кешегә исәпмени ул.* □ — *Инде бишәү булдык, кашык саны ишәйде. Иреңатың яныңда булмагач, аныңсы да исәп.* Г. Бәширов.

Исәп алу — хезмәт хакы түләнеп, эштән азат ителү; расчет алу. *Тачкачылар иртән үк исәп алып, төш вакытларына станциядә булырга дип киттән үк чамалаган[нар].* Ш. Камал. **Исәп бирү** — хезмәт хакын түләп эштән чыгару. *Артык эш юк дип, безгә исәп бирделәр.* Ш. Камал. **Исәпкә алу (кертү)** — 1) билгеле бер санга, исемлеккә кертү, санау.— *Мал-туарларны, барлык җиһазларны исәпкә алыгыз, бер генә шырпысын да әрәм-шәрәм итәргә ирек бирмәгез.* Т. Гыйззәт; 2) игътибарга алу, истә тоту.— *Мулла, кулак коткысына бирелеп, җәнҗәл куптарулары ихтимал. Аны да исәпкә алырга кирәк.* Ш. Камал. **Исәптә тору** — *к.* учетта тору.— *Аларга барыбер түгелмени, исәптә торгач, кешеме — кеше.* И. Гази.

◇ **Исәп тулмаганга яралган** *шелт.*— *к.* исәпкә бар, санга юк. **Исәп юк** — *к.* исәбе юк. *Һич исәп юк, бездә бик мул аш та су.* Г. Тукай. *Боярның җиренә исәп юк.* Г. Ибраһимов. **Исәпкә бар, санга юк** *шелт.*— булдыксыз, эшкә яраксыз кеше турында.— *Адәм рәтлесе мине алмый, исәпкә бар, санга юк ишесенә чыгасым килми.* Б. Камалов.— *Аны бар дидең ни дә, юк дидең ни, Григорий Иванович. Исәпкә бар, санга юк безнең ветфельдшер.* Г. Әпсәләмов. **Исәпкә сан тутырыр өчен** — билгеле бер төркемгә, категориягә кертелеп тә, үз сыйфатлары белән шул төркемгә керергә лаек булмаган кеше яки нәрсә турында.— *Бик мокыт нәрсә иде ләбаса. Ничек итеп теге юлбасарлар үзләренең шайкаларына керткәннәр? --- Исәпкә сан тутырыр өчен, минемчә.* Ш. Камал. **Исәпне ачу** — спорт уенында: үз файдасына беренче очко алу. *Беренче таймда ук исәпне ачу.* **Исәпне хисапка китерү (чыгару)** — материаль мөмкинлекләрне исәпкә алып эш итү турында. [*Җәләл:*] *Чапанны, дим, яңартырга исәплисең бугай?* [*Нәсимә:*] *Исәпнең хисапка туры килүе кирәк, бәбкәм. Әйбер яңарту җиңел генә була торган эш түгел ул.* Ш. Камал. *Болай да әле очын очка ялгап, исәпне хисапка чыгарып булмый.* А. Әхмәт. **Исәпне өзү (бетерү)** — 1) үтәлгән эш өчен тиешле хакын түләп бетерү. [*Мулла*] *акчасын түләми, дога укып кына исәпне өзәргә чамалый.* К. Нәҗми; 2) үч алу, үч кайтару.— *Мин фашистлар белән исәпне өзәргә китәм.* К. Нәҗми.— *Ул ат карагы белән исәпне бетереп китәргә кирәк.* К. Тинчурин. **Исәптән төшеп калган** *мыск.*— булдыксыз, йомшак кеше турында әйтелә. **Исәптән чыгарып ташлау** — игътибарсыз калдыру, бар дип тә белмәү. *Без көндәлек тормышыбызда --- һәртөрле эгоистлык, мещанлык, хезмәткә җиңел карау элементларын да, әлбәттә, исәптән чыгарып ташлый алмыйбыз.* Ф. Хөсни. **Исәбе (дә), хисабы(да) юк** — бик күп, төгәл санын алырлык түгел: исәпсез-хисапсыз. [*Байтирәк:*] *Халык бармы?* [*Исәнбай:*] *Исәбе дә, хисабы да юк. Күрше авылларлан да килгәннәр.* Т. Гыйззәт. **Исәбе күренмәү** — гаять күп булу, бик озын булу, исәпсез-хисапсыз булу. *Сүзнең, гәп-әңгәмәнең исәбе күренми, ачылып китәләр дә хәйран калып сорашалар.* Г. Ибраһимов. **Исәбе (дә) юк** — *к.* исәбе дә, хисабы да юк.— *Әле без сине кызганып торабыз. Югыйсә, ул урынга керүченең исәбе юк.* М. Гафури.— *Патроннар күп, снарядның исәбе дә юк.* Г. Бәширов. **Исәбен югалту** — төрле затларның, әйберләрнең бик күплеге турында. **Исәбенә чыга алмау** — затларның, әйберләрнең бик күп булуы турында. *Аның салдыран мәчетләренең исәбенә чыга алмассың бит!* Г. Ибраһимов.

ИСӘП II *и.* **1.** Уй, фикер. *Гыймазов үз эченнән шулай уйлаганда, Сәйдә җиңги аның бу исәпләрен бүлеп, әйтелгән сүзенә ялгап җибәрде.* С. Рафиков. *Кыз инде: «Бу солдат исерде»,— дип уйлады, шулай да үзенең исәбенә ышанып җитмәде.* Әкият. // Ният, план. *Василийның башында бер исәп тә туып өлгерде: менә шулай өркетмичә генә немецларга якынлашып, кинәт кенә автоматларын тартып алып булмасмы?* Ә. Еники. *Исәбе бик гади Маликның: барлык игенен, ваклап-төяклап, ярлырак таныш-белешләренә өләшеп куярга уйлады ул.* И. Гази.

2. Сагышлы, кайгы-хәсрәтле уй.— *Карап торган арышыңны боз суксын, бердәнбер кәҗәңне яшен суксын. --- Шул исәпләр бары да ялгыз башыңа җыйналгач, кая барасың инде.* Ф. Бурнаш. *Хәсрәтләрдән соңра рәхәт булгач, ул исәпләр бар да бетәдер.* Г. Тукай.

◇ **Исәп белән** — берәр төрле файданы күздә тотып. *Бәк Бәкич өйләнгәндә хатынны исәп белән алган.*

Х. Кәрим. **Исәп итү (йөртү)** — 1) *к.* исәпләү II (1, 3 мәгъ.). *Хатын юл буенча исәп йөрткәндә бу турыда да уйлады.* Г. Ибраһимов. *Латыйп исә, --- Галләм хажи белән күзне күзгә терәшеп, элек ныклап бер сөйләшергә исәп итә.* Ф. Хәсни; 2) өмет баглау, **өмет итү**. *Бала [тормышны] авыз ачып һава сулау кебек ансат күреп үссә, тормыш үз башына калгач та шуларга исәп итә торган була.* Г. Гобәй. **Исәп кору** — *к.* исәпләү II (3 мәгъ.). *Фәхри исән чагында зур улын фабрика-завод өйрәнчекләренең мәктәбенә бирергә исәп корып йөргәнен сөйләде.* Г. Ибраһимов. **Исәп тоту** — 1) берәр нәрсә эшләргә ниятләнү, җыену. *Күренеп тора, карт гөмбәләре белән бик мактанырга исәп тота.* А. Расих. *Ирен үз кубызына гына биетергә исәп тотамы бу килен?* М. Шабай; 2) өмет баглау, өмет итү. *Без, магазинга барып җиткәнче, гармоньчы сөйләгән хәбәрнең ялганга чыгуына исәп тоткан идек.* С. Кудаш. **Исәп төшү** — башка уй, фикер килү. *Башына бу кешенең төште исәп. Шәһәргә барып кайту уе белән Чыгып китте Ишәгенә нәрсә төяп.* М. Гафури. **Исәпкә бату** — каты уйлану. *Бервакыт ул авыз эченнән генә көйли, моңая башлады. Бу аның исәпкә баткан чагы иде.* Г. Галиев. **Исәпкә калу — берәр нәрсә турында уйлану**. *Беркөнне Газинур аның сандыгында ат башы хәтле яңа йозак күргәч, исәпкә калды: нинди кеше бу Сәлим?* Г. Әпсәләмов. **Исәбе күренмәү** — (кемнең дә булса) нияте, уе сизелмәү. *Егетнең кире чигенергә исәбе күренми, мәгәр сүзендә, йөзендә, гадәт буенча, бераз үзен гаепле күргәнлек төсе бар иде.* Г. **Ибраһимов.**

ИСӘПЛЕ I *с.* Исәпләнгән, санаулы. *Ишегалды тар гына, кечкенә генә. --- Ләкин барысы да исәпле, бер квадрат метр җире дә исраф ителмәгән, барысы да сыйган.* А. Расих. *Исәпле көн тиз үтә.* Мәкаль. // Чикле, аз; кадерле.— *Вакытында чыгарып өлгерергә кирәк, безнең сәгате генә түгел, минуты да исәпле! Әле дә әзрәк кичектек!* Г. Ибраһимов.— *Яшьтән сөйгән үз танышың егет башы белән шулай өзелеп тора икән, әйдә, кире какма, андыйлар хәзер бик исәпле.* Г. Бәширов.

ИСӘПЛЕ II *с.* Кайгылы, хәсрәтле, сагышлы.

ИСӘПЛӘШҮ *ф.* **1.** Тиешле акчаны, малны тулысынча түләп, үзара исәп-хисапны өзү; ике араны өзү.— *Илле тәңкә акча да алып килгән идем. Җитмәслек булса, тагы үз янымнан бераз кушып булса да алып кайта күрсен. Кайткач исәпләшербез.* Г. Камал.

2. *күч. сөйл.* Үч кайтару.— *Хәзергә баш ияргә туры килә. Бервакыт безнең очта да түй булыр, шул вакытта без дә исәпләшербез!* М. Гафури.

3. *күч.* Берәр кешене яки берәр нәрсәне игътибарга алу, шулар белән хисаплашу. *Хәзер җиңел яра белән генә исәпләшә торган чак түгел.* Р. Ишморат. *Балалары байның шахтасы җимерелү белән дә, эшсезлек мәсьәләсе белән дә исәпләшеп тормыйлар. Аларга бүген табып, бүген ашатырга кирәк.* М. Гафури.

ИСӘПЛӘҮ I *ф.* **1.** Нәрсәнең дә булса исәбен, санын билгеләү, исәпкә алу; хисаплау, санау. *Без аның белән бөтен йортка икәү калдык. Сабыйны кушып исәпләсәк — өчәү.* Г. Гобәй. *Бер санаганда 14 йорт килеп чыга, икенче исәпләгәндә 13 була.* Г. Гали. // Нинди дә булса санаулар, хисаплаулар ясау. [*Бодайның*] *барысын, бөртеген бөртегенә китереп, исәпләп чыгарганнан соң гына бер гектар җиргә күпме орлык кирәге билгеле буласы.* Г. Бәширов.

2. Саннар белән арифметик гамәлләр башкару. *Син аны укырга, язарга, исәпләргә өйрәтерсең.* Г. Тукай.

3. Нәрсәне дә булса күздә тоту, нәрсәне дә булса күздә тотып, игътибарга алып эшләү. *Берәр нәрсәгә исәпләп башкарылган эш.*

4. Кеше турында билгеле бер фикердә булу, аңа билгеле бер бәя бирү; кем-нәрсә дип карау, санау.— *Хәзер мине кешегә исәпләүчеләр дә калмады. Аш-су күргән дус-ишләрем бары да миннән качып беттеләр.* Г. Камал.— *Сез мине үлгәнгә исәпләдегез.* Г. Гобәй.

ИСӘПЛӘҮ II *ф.* **1.** Уйлау, фикер йөртү.— *Андый-мондый хәл була калса, үзең исәпләп кара, аларны җиңәргә ничаклы көч кирәк.* К. Нәҗми. *Кара, шәкерт әйләнеп, аны-моны исәпләми, икенче шәкертне салып екты.* Ә. Фәйзи.

2. Кайгыру; кайгырулы уйлау. *Туган йортларымнан егълап чыктым. Төрле исәпләрне исәпләп.* Бәет. *Үз язмышын каргый-каргый Елый ул, исәпли ул.* М. Җәлил.

3. Берәр эш эшләргә ниятләү, җыену.— *Әллә син аны шушы кабахәтлеге өчен болай гына калдырырга исәплисеңме?* М. Әмир. *Күптән мин бу секретарьлыкны ташлап, пулемётчик булырга исәпләп йөри идем.* Ш. Усманов.

ИСӘП-САН *җый. и.* Төрле исәпләүләр, саннар. [*Без*] *беравык исәпләр-саннар, чагыштырмалар теле белән сөйләшеп алыйк.* Г. Бәширов.

◇ **Исәбе-саны булмау** — *к.* исәбе-хисабы булмау. *Суелган малның, эчелгән кымызның исәбе-саны булмады.* Г. Ибраһимов. **Исәбе-саны юк** — *к.* исәбе юк. [*Хәлифәгә*] *ачулы кешеләрнең исәбе-саны юк иде.* С. Бикбулат. **Исәбен-санын югалту** — *к.* исәбен югалту.

ИСӘПСЕЗ I *с.* **1.** Исәбе алынмаган, исәпләп бетергесез, бик күп. *Болар, меңләгән елкылары, яхшы нәсел дөяләре, исәпсез куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында --- күчеп йөриләр.* Г. Ибраһимов. *Исәпсез автомобильләр, автобуслар, --- завод-фабрикалар һаваны корым белән, бензин һәм мазут төтене белән тутыралар.* Г. Гали.

2. *кис. функ. күч.* Бик, гаять, ифрат. *Болар да исәпсез күп ич: Габдулла, Миңнулла, Лотфулла, Гайнулла...* Г. Тукай. *Качакларның исәпсез күбәеп китүләре бушлай ярдәм бирү гайрәтен бик тиз сүрелдерде.* К. Нәҗми.

ИСӘПСЕЗ II *с.* Гамьсез, ваемсыз, сансыз.— *Ай, акылсыз, исәпсез!.. Кем кушкан сиңа халыкка вәгазь сөйләргә!* Ш. Камал.

ИСӘПСЕЗ-САНСЫЗ *с. к.* исәпсез-хисапсыз. *Балкып торган исәпсез-сансыз йортлар эчендә --- Казан кешеләре [торалар].* Г. Бәширов. *Төнлә чыксаң, абзар түбәсендә Исәпсез-сансыз йолдыз күрәсең.* Ш. Маннур.

ИСӘПСЕЗ-ХИСАПСЫЗ *с.* Исәбе булмаган, чиксез күп. *Урманнар, сазлар, таулар һәм исәпсез-хисапсыз күлләр, елгалар белән капланган Карелия җире сугыш операцияләре алып бару өчен иң кыен урыннарның берсе санала.* Г. Әпсәләмов. *Зәп-зәңгәр күк гөмбәзе исәпсез-хисапсыз йолдызлар белән бизәлгән.* Г. Гали.

ИСӘП-ХИСАП I *җый. и.* **1.** *тарт. формасында.* **исәбе-хисабы.** Берәр нәрсәнең саны, исәбе, күпмелеге. *Әй [ферма]дагы кош-кортларның күплеге! Аларның исәп-хисабын белсә тик колхоз хисапчысы Гөлшат апа гына белә торгандыр.* А. Әхмәт.

2. Исәпләү, санау эшләре. *Имана җый[ганда] --- ул исәп-хисапны белмәүче, язу танымаучы кешеләрнең Шәмгун өчен нинди файдалы икәнен чын мәгънәсе белән аңлады.* А. Шамов.

3. (Хуҗалыкта, кибеттә һ. б. ш.) сакланган товарларның күпме калганлыгын барлау эше. [*Кибет*] *ябык, исәп-хисап бара.* Г. Мөхәммәтшин. // *с. мәгъ.* Кәремчыгымны санап, барлап алып баруга мөнәсәбәтле. *Корбангалиев дигән егетебезне бик әйбәтләп кенә колхозның исәп-хисап эшләренә утыртып куйдык.* Ф. Хәсни. *Колхоз хисапчысы белән кладовойчының исәп-хисап дәфтәрләре аңа күчте.* Г. Бәширов.

4. Үзара акчалата яки әйберләтә алыш-биреш.— *Интендантлык белән элекке исәп-хисапка 20 процент өстәргә [кирәк].* К. Нәҗми.

5. Эш өчен хезмәт хакын түләү эше. [*Мочтак:*] *Без исәп-хисапны бетерик әле.* [*Сабир:*] *Анысы качмас, соңыннан да алырсың.* Т. Гыйззәт.

6. *күч.* Ике арада булган начар мөнәсәбәт, эш, ачу, үпкә. *Әле бер оппоненты, әле икенчесе, иске исәп-хисап ларны казып чыгара-чыгара, тәгәрмәчкә таяк тыкты* Г. Әпсәләмов. // *сөйл.* Үч алу.— *Ну, Акбирдин, исәп хисап көне бер килер. --- Сөйгән кызымның күңелен суындырдың. --- Бәхилли алмам.* К. Тинчурин.

7. *күч. сөйл.* Файда. [*Галия*] *зур урын тоткан Рәүф белән --- үзенең «мәхәббәтен» тышкы ялган исәп-хисапка кора.* Г. Нигъмәти.

Исәп-хисап итү (кылу) — исәпләү, санау. [*Рәхим*] *үзенең булмәсендә байтак вакыт исәп-хисап кылып утырды.* А. Расих. **Исәп-хисап ясау** — 1) нәрсәне дә булса алдан исәпләү. *Карчык үзенең килене --- белән мәҗлескә нәрсәләр хәзерләү турында исәп-хисап ясарга кереште.* Ш. Камал; 2) эш өчен тиешле хезмәт хакын түләү. *Алук дәдәкәй шәкертләргә исәп-хисап ясап, иртәгә таң белән кире мәдрәсәгә кайтып китәргә фәрман бирде.* К. Тинчурин.

◇ **Исәп-хисапны коры тоту — үзара алыш-бирешне** вакытында, төгәл үтәү һәм үтәтү, бурычны вакытында түләү һәм түләтү. *Бирәчәге булса — түләр, алачагы булса — түләтер. Исәп-хисапны коры тота ул безнең бабай.* К. Нәҗми. **Исәп-хисапны өзү (алу)** — 1) үзара акчалата алыш-бирешне ясау, тиешле хезмәт хакы алу яки түләү. *Алу-сатуны рәсмиләштерү һәм исәп-хисапны өзү кайчан булачак?* Ә. Еники. *Шушы хатны алгач та, эшләгән урының белән исәп-хисапны өз дә тизрәк кайт.* А. Расих; 2) үч кайтару, үч алу. *Сугыш башлангач, миңа немец илбасарлары белән исәп-хисапны өзү мөмкинлеге туды.* А. Шамов.— *Ничек Грибакиннан үч алырга? --- Ни генә булмасын, аңардан мин барысы өчен дә берьюлы исәп-хисап алачакмын.* Р. Ишморат. **Исәбе-хисабы булмау** — санап бетергесез дәрәҗәдә күп булу, бик күп булу. *Яз-җәй айларында монда чәчәк дигәннең исәбе-хисабы булмый.* Г. Гали.— *Анда безнең ише карчыклардан башка яшь-яшь хатын-кызларның да исәбе-хисабы булмый.* Ш. Камал. **Исәбе-хисабы юк** — бик күп. *Болын өстендәге кибәннәрнең исәбе-хисабы юк.* Г. Бәширов. *Котлый килүченең исәбе-хисабы юк.* К. Нәҗми.

ИСӘП-ХИСАП II *җыйм. и.* Уй-фикерләр, ният-планнар. *Командир була торып та, минем исемә килмәгән мондый бик мөһим нәрсәне истә тотуы һәм сүзен сөйләгәндәге сабырлыгы белән ул мине тәмам аптырашка төшерде. Хәтта бер минутка исәбем-хисабымны чуалтып ташлады.* Х. Госман.

◇ **Исәп-хисап йөртү** — исәпләү, уйлау, план кору. *Ул, дивана кебек үзалдына шулай исәп-хисап йөртеп бара-бара, Баязитның үзеннән аерылып --- калганын сизмәде.* Г. Ибраһимов.— *Әле кичә дә, булачак уңыш турында исәп-хисап йөртеп, төн йокысын бирмәдең.* М. Шабай.

ИСӘПЧЕ *и.* Алдан ясалган исәп I (10 мәгъ.) белән яшәргә яратучы кеше. *Исәпчене җот алыр, яурынчыны [күрәзәчене] яу алыр.* Мәкаль.

ИСӘР I *с. диал.* Юләр, дивана, акылсыз, ахмак.— *Мондый ахмаклыкны эшләү өчен шыр тиле, дивана, мәҗнүн, исәр булырга кирәк.* К. Тинчурин. *Исәр буйга үсәр, акылга юк.* Мәкаль.

◇ **Исәр әйтмешли** — кем әйтмешли. *Инде бераз әкренрәк барсаң да була иде, чөнки без, исәр әйтмешли, әллә егерме, әллә утыз машинаны артта калдырган идек.* Н. Фәттах.

ИСӘР II: **исәр җил** *шигъ.*— поэтик образлылык өчен әйтелә торган гыйбарә. *Мине сагынып, тополь агачлары Исәр җилдән хәбәр көтәрләр.* М. Җәлил. *Ялангач калган куакларны исәр җилләр [ара-тирә] --- селеккәлән куялар.* С. Җәләл.

ИСӘРЕНҮ *ф. диал. к.* әсәрләнү (1 мәгъ.). *Икесе дә күрешү кинәтлегеннән исәренеп шактый озак бардылар.* А. Гыйләҗев.

ИСӘРЛЕК *и. диал.* Акылсызлык, юләрлек, ахмаклык, диваналык. *Кайбер исәрлекләрне искә төшереп үземнән үзем оялдым.* Н. Фәттах. *Хисләр нечкәргән, күңелләр дулкынланган хәтәр бер минутта булып алган хәлләр --- яшьлек исәрлеге генә.* Г. Әпсәләмов.

ИСӘРЛӘНҮ *ф. диал.* **1.** Юләрләнү.— *Куй инде, куй!.. Кеше карап торса, Шәрифҗан карт исәрләнә башлаган диярләр.* Ф. Хөсни.— *Бар, исәрләнеп, үрелеп кенә кара, күзләреңнән утлар күренер.* М. Шабай.

2. Миңгерәүләнү, аңгыраланау. *Күземә кеше күренмәс, колагыма аваз ишетелмәс булды. Исәрләндем тәмам...* Э. Касыймов. *Көннәр буе исәрләнеп, җан көеге булып йөргәнче, шулай берьюлы эче бушанса, йорт җанлы хатынның үзе өчен әйбәт иде.* Г. Бәширов.

ИСӘРӘН *с. диал.* Аңгыра, миңгерәү. *Каладан кайтышлый гына кереп ал дип әйтергә онытканмын аны. Исәрән булгач ни...* М. Фәйзи.

ИСӘРҮ *ф. диал.* Берәр нәрсәдән, күренештән бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү. *Аларның башларына кигән кызыл фәсләре татар агайларын тәмам исәртә калды.* М. Галәү.

ИСӘЮ *ф. диал.* Бераз үсеп, ис II, акыл, аң керү (балалар турында). *Безнең дә бәләкәй чакларыбыз артта калды һәм без исәя төштек.* Г. Галиев.— *Берәр ел эшләмим әле. Бала азрак исәйсен.* Б. Камалов.

ИСҮ *ф.* Җил белән һава хәрәкәткә килү; өрү. *Чәчәк башларын селкетеп җил исә.* И. Гази. *Рәхәт салкынча җилнең исүе куәтләнгән шикелле булды.* Ф. Әмирхан.

ИТ *и.* **1.** Ашамлык өчен суелган йорт хайванының түшкәсе яки бер кисәге (эчке әгъзалар, мәсәлән, үпкә-бавыр, эчәкләр гадәттә ит дип саналмыйлар). *Сарык ите. Яшь ит. Йомшак ит. Ак ит. Сум ит. Тавык ите.* □ — *Менә бусы күркә ите, энем Харрас, менә монысы каз ите!* Ә. Айдар. [*Шәрифнең*] *күңеленә өченче фикер төште. Бу фикер ит алмый гына, тояк, эчәк-фәлән алып кайту иде.* М. Гафури. *Ит күрсәтеп үпкә сатып булмый.* Мәкаль.

2. Мускулларның гади телдә йөри торган атамасы. [*Балаларның*] *тәннәрендә ит әсәре калмады. Кара-сары-гылт, җыерчыклы тиреләре кечкенә, нечкә сөякләренә ябышып катты.* Г. Ибраһимов.— *Каешның прәшкә кадагы --- этнең муен тиресен тишкән һәм, бер сантиметр чамасы аның муен итенә батып, эренләндереп шештергән.* Ш. Камал.

3. *с. мәгъ.* Итне (1 мәгъ.) эшкәртү (турау, чабу һ. б.) өчен хезмәт итә торган. *Ит тагарагы.* // Ит (1 мәгъ.) эшкәртү яки сату белән шөгыльләнә торган. [*Камышлының*] *үзенә күрә промышленносте да бар (--- зур элеватор, ит комбинаты* һ. б.). Ә. Еники. *Сатучы хуҗалар үзләренең ит кибетләре алдыннан этләрне [куалар].* К. Тинчурин.

4. *с. мәгъ.* Составында ит (1 мәгъ.) булган. *Ит шулпасын барлык солдат та ашаганына шигем юк.* Ф. Булатов.

5. Яфракның тамырчалары арасындагы өлеше. *Яфрак ите.*

6. Җиләк-жимешнең кабык астындагы йомшак өлеше. *Ул йодрык хәтле бер хорошавканы өзеп алды да алманың кызыл ителә тешләрен батырды.* И. Гази. *Карбызның ите үскән саен кабыгы да үсә, кабыгы үскән саен ите дә үсә.* А. Расих.

Ит машинасы — *к.* ит тарткыч. *Үпкә-бавырны --- ит машинасыннан үткәрәләр.* Ю. Әхмәтҗанов. **Ит тарткыч** — ит тарттыра торган машина. **Ит токымы** — күп ит бирә, сугым өчен үрчетелә торган терлек. **Ит тәлинкәсе** — табынга ит бирү өчен түгәрәк тирән яки озынча сай тәлинкә. **Ит чапкычы** — *к.* тәпке. *Симез сыер ителә --- ит чапкычы белән чабарга да мөмкин.* Ю. Әхмәтҗанов. **Ит шешләү** *диал.*— тозлап киптерелгән итне утта кыздыру.

◇ **Ит арттыру** *ирон.*—симерү, тазару. *Ял вакытларында Муса тән үстерүне, ит арттыруны кешегыртмый шөгыльләнә, ләкин күп җәяү йөри иде.* М. Максуд. **Ит басу** *сөйл.*— чамадан тыш симерү, артык тазару. **Ит бүкәне (кисмәге, мичкәсе, чапчагы)** *гади с. мыск.*— юан, симез кеше.— *Ул ит кисмәгенә бу көнгә чаклы биргән гошерләремә дә үкенәм.* М. Гафури. [*Юныс Латыйфка:*] *Төртмә, төртмә, ит чапчагы, бездә дә кул бар бит.* Д. Аппакова.— *Бу ит бүкәне нишләп йөри икән бездә?* Т. Гыйззәт. **Ит йогу** — *к.* ит куну.— *Син күпме генә ашасаң да мантымыйсың. Сиңа ит йокмый.* Г. Мөхәммәтшин. **Ит кибәне (чүмәләсе)** *гади с. мыск.*— бик зур гәүдәле симез кеше. **Ит корышу** *диал.*— ачу килү. **Ит куну (утыру)** — тазару. *Айсылу аның калкып чыккан яңак сөякләренә, юкарып калган йонлач беләкләренә күз төшереп: «Кара син, әле һаман да тәненә ит кунмый бит»,— дип борчылып алды.* Г. Бәширов. *Үзе эре сөякле хайван иде, әкренләп ит утыргач, өстенә нур кунып, мәһабәтләнеп тә китте.* М. Шабай. **Иткә әйләндерү** — кош-кортны, хайваннарны сую. *Ат-сыер күрсә Арыслан, [аларны] иткә тиз әйләндерә.* Г. Тукай. **Ит күрмәгәнгә (югында) үпкә (дә) тансык** — яхшысы булмаганда начарракка да риза булу, начаррак белән дә канәгатьләнү турында.— *Ит күрмәгәнгә үпкә тансык дигәндәй, актык чиктә алар да ярый.* Ш. Маннур. *Бик үк шома түгел инде түгеллеккә, ит югында үпкә дә тансык дигәндәй, әйдә, аның ул шарын да файдаланырга булдык.* Ф. Хөсни. **Ит тә юк, йон да (сөт тә) юк** *мыск.*— булдыксыз, эш рәтен белми торган, файдасыз кеше турында. *Аннан ит тә юк, йон да юк.* Әйтем.— *Ул кешедән ит тә юк, сөт тә юк, алыштыр син аны, Мохтар абзый.* Ю. Әминов. **Ит урлаган мәче (песи) төсле** — *к.* май урлаган мәче төсле. [*Хәйрулла*], *ит урлаган песи төсле, як-ягына ялт-йолт каранып: «Э командир үзе ничегрәк соң?»— диде.* Қ. Тинчурин. **Ит үсү** — яраланган, киселгән урын төзәлү, яшь ит барлыкка килү. **Ите белән ертып (аерып) алу**— янындагы әйбер (мәсәлән, төймәне үзе тегелгән материя) белән ертып, өзеп алу. **Ите сезгә (сиңа), сөяге безгә (миңа)** *тар.*— ата-аналарның үз балаларын мәдрәсәгә биргәндә хәлфәләргә, муллаларга әйтә торган сүзләре. *Баланы [хәлфә] кулына тапшырган чакта, ата-аналар: «Ите сиңа, сөяге миңа»,— дип тапшыралар. Янәсе, кары сөяккә калдырганчы кыйна үзен, тик белем генә бир.* И. Гази. **Итен ашау** *гади с.*— берәр кешене вак сүз белән тиргәп аптырату, гаҗиз итү.— *Минут саен итемне ашады [ул], әле бер эшем килешми, әле икенчесе.* Х. Садрый. **Итен чәйнәү** *гади с.*— кеше гайбәтен сөйләү. *Ул заманда татар шәкерте берсе-берсенең итен чәйнәү белән, моназара дип, эт урынына сүгеш белән гомер үткәрә иде.* Г. Ибраһимов.

ИТАГАТЬ *и. иск. кит.* Буйсыну.—*Остаз юк, итагать юк, бу нинди адәм хурлыгы?!* Г. Ибраһимов. *Сүз дәшүче юк иде, Мин бер караны ак дисәм, һай гомерләр! Әһле исламда итагать бар иде.* Г. Тукай. // Сүз тыңлау. *Кадерле Хатип! Игътибарың һәм итагатең өчен тагын бер кат рәхмәт әйтәм.* Г. Кутуй.

Итагать итү (кылу) — буйсыну. *Бу чордагы билгеле татар язучыларының зур бер өлеше дин һәм милләт исеменнән халыкны бөек Россия патшасына итагать итәргә чакырдылар.* М. Җәлил. *Йөгермәкче булдым. Ләкин аякларымның сеңерләре миңа итагать кылудан баш тарттылар.* К. Тинчурин. **Итагать күрсәтү** — буйсыну. *Ул хәзер дингә вә Коръәнгә итагать күрсәтә.* Г. Тукай.

ИТАГАТЬЛЕ *с. иск. кит.* Буйсынучан, сүз тыңлаучан. *Рус буржуазиясенең итагатьле коллары Гучков белән Шульгин - - - тәхеттән ваз кичкән патша янына чаптылар.* Ф. Хөсни. *Ишле семьяда үзен бик итагатьле итеп, юаш, сабыр гына тоткан хатын - - - ана поши кебек усалланды да китте.* Ә. Еники.

ИТАГАТЬ(ЛЕ)ЛЕК *и. иск. кит.* Буйсынучанлык, сүз тыңлаучанлык. [*Ул*], *суфиланып, итагатьлек күрсәтеп, хәзрәткә елышырга тырышты.* Ә. Еники. *Ярым хәрби киемле [кеше] - - - армиядә тиешле тәртип урнаштырырга, командованиегә карата итагатьлелек күрсәтергә [чакырды].* Ф. Хөсни.

ИТАГАТЬЧЕЛ *с. к.* итагатьле.— *Падишаһ хәзрәтләренә яхшы хезмәт итегез, аның олуг түрәләренә итагатьчел булыгыз,*— [*диде мулла*]. М. Гафури.

ИТА'ЛИЯЛЕ *и.* Италиядә яшәүче яки чыгышы белән шуннан булган кеше.— *Заманында италиялеләр дә Германиягә кирәк кешеләр иде.* Н. Дәүли.

ИТАЛЬЯН *и.* Италиядә роман телләренең берсендә сөйләшүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. [*Лагерьда*] *поляклар, бельгиялеләр, итальяннар* [*бар*]. Г. Әпсәләмов. // *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Ул итальян җырын русча җырлады.* А. Расих. *Наумова итальян артисткасы ролен үтәде.* М. Фәйзи.

Итальян бухгалтериясе — предприятиеләрдә керемчыгым операцияләрен ике кенәгәдә алып бару методы. **Итальян забастовкасы** — эшкә килеп тә берни эшләми йөрүдән яки эшләгән булып күренүдән гыйбарәт булган забастовка. **Итальян карандашы** — графиклар тарафыннан сызу, буяу өчен кулланыла торган махсус материал. *Мин ярты табак ватман кәгазенә итальян карандашы белән фотодан зурайтып ясадым.* Б. Урманче. **Итальян музыкасы** — XVIII гасыр азагы — XIX йөз башында иҗат иткән итальян композиторлары музыкасы. **Итальян тәрәзәсе** — өч-дүрт өлгеле киң тәрәзә.

ИТАЛЬЯ'НЧА *рәв.* 1. Итальян телендә. *Итальянча сөйләшү.* // *с. мәгъ.* Итальян телендә булган. — *Монда итальянча китаплар да бирәләрмени?* Ш. Маннур.

2. *с. мәгъ.* Итальяннарга хас.

ИТЕК *и.* 1. Озын кунычы күннән, кирзадан, брезенттан тегелгән, каты табанлы күн аяк киеме. *Кирза итек. Итек тегү.* □ [*Рахмановның*] *аягында яхшы хром итек.* М. Әмир. [*Аның*] *аягындагы күн итекләре, бүген генә унбиш километр юл үтүгә карамастан, ялт итеп тораллар.* Ә. Еники.

2. Озын кунычлы, йомшак табанлы, мехы эчкә каратылган күн аяк киеме. *Өстендәге киеменә, аягындагы мех итегенә караганда, очучы булырга тиеш иде ул.* А. Шамов.

3. Йоннан басылган, балтырлы киез аяк киеме; киез итек. *Итек басу.* □ [*Ул*] *аягына озын кунычлы пима (киез итек), өстенә, билен бәйләп, кыска тун* [*кия*]. Г. Ибраһимов. *Аның өстендә кыскача сары тун, аягында яңа чуар киез итекләр иде.* Ш. Камал.

4. *с. мәгъ.* Итек тегү яки басу эшенә мөнәсәбәтле.— *Итек мастерскоенда мастер булып эшлим.* А. Шамов.

Итек басу — йоннан киез аяк киеме хәзерләү. *Итек басу эше зур көч сорагангадырмы, ничектер, бер итекче итек басарга кергәч, хуҗага әйткән: «Коймак пешерсәң, коеп куярмын».* Г. Бәширов.— [*Этиең*] *гомер буе кешеләргә итек баса.* Г. Мөхәммәтшин.

◇ **Итек астында (булу)** — нинди дә булса власть астында изелү, тулы буйсынуга дучар булу. [*Гафури*] *хаклык, тигезлек, кешелек идеяләренең самодержавие итеге астында тапталуы турында язды.* М. Җәлил.

ИТЕКЧЕ *и.* 1. Аяк киемнәре тегүче һәм төзәтүче оста. *Оста итекче бер пар итекне ике көн эчендә тегеп бетерәдер.* Г. Тукай. *Бер кеше итекчедән ботинка төзәттергән.* Г. Бәширов. // Итек басучы оста.

2. *күч. гади с.* Эш рәтен белмәгән, белер-белмәс эшләгән кеше турында.— *Сез кемне итекче дисез? - - - — Кемне булсын, билгеле, кино күрсәтүчене. - - - Күрәсез ич, лентаны өзде. - - - Начар эшләгән кешене шулай итекче диләр инде...* Н. Дәүли.

ИТЕҠЧЕЛЕҠ *и.* Итекче булу. *Базарда итекнең кыйммәте бик түбән төшеп, итекчелек һөнәре иң файдасыз һөнәрләрдән санала.* Г. Тукай.

ИТЕҠ-ЧИТЕК *җый. и. сөйл.* Итекләр һәм читекләр; гомумән озын кунычлы аяк киемнәре.

ИТЕНЕШ *и. диал.* Қыланыш, үз-үзен тотыш. *Сельскийның итенеше булды илгә ошаусыз.* Бәет. *Сакалны кырганда борыла-сарыла бөтәрләнеп йөргән парикмахерның итенешләре безгә бик ошады.* Һ. Такташ.

ИТЕНМЕШ *и. иск. к.* итенеш. *Ашады бит колак итемне... Имеш, итенмешең илдән аерым... Гүргә саклыйсыңмыни хәерчелегеңне, ди.* Ф. Бурнаш.

ИТЕНЧЕК *с. диал.* Қыланчык.

ИТЕНҮ *ф. Қайт. юн.* **1.** *иск. к.* итү (ярдәмче фигыль функциясендә йөри). *Чалбар урынына сырган, бөргән штан киюне мәхәллә әһалиясе гадәт итенгән иде.* Г. Газиз. *Сәмигулла абзый: «Күп салсаң, чәй пешми ул...» — дип кенә химая итенү белән канәгатьләнергә мәҗбүр булды.* Ф. Әмирхан.

2. *диал.* Қылану.— *Кирле-мырлы шул... Менә бит, әле генә ни итенеп чыгып китте.* С. Баттал. [*Ул*], *Арслановның йөрешен, утырышын күрсәткән булып, маймыларча итенә.* И. Гази.

3. *диал.* Берәр нәрсә эшләмәкче булу. *Кошчыклар ава-тунә бүрек төбендә йөренделәр, очып чыгарга итенделәр.* Г. Гобәй. *Тегеләй итенә, болай итенә байтал, малайны бәреп төшермәкче була — төшерә алмый.* Әкият. // Берәр нәрсә эшләгән булып кылану.— *Нәрсә син анда итенеп йөрисең? Кер ашарга!* И. Гази.

ИТКЕЧ *с. Итү* ярдәмче фигыленнән ясалып, кайбер исемнәрдән соң килә һәм шулардан аңлашылган эшне үтәүче мәгънәсендә йөри. *Әсир иткеч гүзәллек монда.* Ш. Маннур. *Моның бер сәбәбе Заһидның таш йөрәклелегенә үпкәләве булса, икенчесе, хәл иткече — әле бая сизенгән нәрсә.* А. Расих.

ИТЛЕ *с.* **1.** Составында ит булган, ит кушып эзерләнгән. *Итле шулпа. Итле гөбәдия.* □ *— Син инде безгә итле аш пешер.* Ә. Еники. [*Безне*] *итле ботка белән сыйладылар.* Ш. Усманов.

2. Ите булган; симез, таза. *Қамчы бераз итлерәк урын эзләп торды да, таба алмагач, калак сөякләре буйлап аска таба сузылды.* Г. Гобәй. *Ул үзенең итле вә калын беләкләре белән мине күкрәгенә кыскан да гәүдәсен гәүдәмә тәмам, тәмам урап алган.* Г. Ибраһимов.

ИТЛЕ-ТӘНЛЕ *с.* Симез, таза, көр.

ИТЛӘНҮ *ф.* Ит куну, тулылану, симерү, тазару.

ИТЛӘЧ *с.* **1.** Симез, ите күп булган. [*Елгада*] *итләч, кылый балыклар тулып ята.* С. Рафиков.

2. *сөйл.* Юан, симез (кеше тәне, тәннең, битнең аерым өлешләре турында). *Итләч борын.* □ [*Аның*] *итләч беләкләре җиңенә көчкә сыеп торалар.* А. Әхмәт. *Картның салынып торган итләч кабаклары астында зәһәр елтыр[ый торган] күзләре - - - Сәфәргалинең ачуын кузгатты.* Ф. Хөсни.

3. Симез йомшаклы (үсемлекләр һәм җиләк-җимешләр турында). *Итләч яфраклы.* □ *Кешеләр помидорның итләч өлешен генә ашыйлар, ә орлыгына кагылмыйлар.* Г. Галиев.

ИТЛӘЧЛӘНҮ *ф.* Симез, калын, итләч булу. [*Миңнисаның*] *кашы юк, тик урыны гына итләчләнеп кабарып тора.* М. Шабай.

ИТЛӘШКӘ *с. сөйл. к.* итләч (2 мәгъ.).

ИТЛӘҮ *ф. махс.* Җепне материалның тышына чыгармыйча гына тегү. *Читек табанын итләү.*

ИТ-МАЙ *җый. и.* Ит һәм май (яхшы азык мәгънәсендә). *Ит-май ашау юк инде ул. - - - Итең, маең сата, ә картасың, бавырларың үзебез ашый* [*идек*]. К. Әмири. *Икмәк тә бар, бодай күмәче дә, Ит-майлар да, Бал да — барысы да!* Ш. Маннур.

Иттә-майда йөзү — таза, мул, бай яшәү. *Шундый вакытта ничек син иттә-майда йөзә аласың, ничек тамагыңнан үтә?* И. Гази.

ИТСЕЛ *с.* Иткә охшаган, ит кебек.

ИТТИФАҠ *и. иск. кит.* **1.** Берлек, берләшү, союз. *Татулашты, килештеләр ахырда Бу көннән сүз көрәштермәскә бер дә, - - - Қояш, Яңгыр әле бу көнгә чаклы Бозып эш кыйлмыйлар бу иттифакны.* Г. Тукай. *Арадагы иттифакны бозмаска дип, тагы бер кат сүз беркетелде.* К. Тинчурин.

2. *күч.* Бер сүздә, бер киңәштә булу. *Ул бу эштә кызының әсир белән бер сүздә, бер иттифакта икәненә бигрәк ышана иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Базарда, гүя иттифак берлә эшләгән төсле, акчаның өстендәге язуына гына игътибар итәләр.* Г. Тукай.

Иттифак итү *иск. кит.* — сүз берләштерү, берләшү. *Сөйләшеп бер фикер алмак - - - бер-беребез илә иттифак итмәк вә фикерләрне берләштермәк өчендер.* Ш. Мөхәммәдев. **Иттифакка килү** *иск. кит.*— килешү, бер сүзгә килү, берләшү. [*Болар*], *иттифакка килә алмый, үзара сугыша яздылар.* М. Гафури.

ИТТИФАҠЛАШУ *ф. иск. кит.* Берләшү, сүз беркетү, килешү, татулашу. *Һич оеша алмыйлар, - - - Галиулла коданың мәслихәт мәҗлесендә эш инде тәмам булып, иттифаклашырлар диеп торганнар иде, каһәр сукканГалиәкбәр агай - - - мәҗлескә килми калган.* Ш. Мөхәммәдев.

ИТТИФАҠЛЫ *с. иск. кит.* Бердәм, тату, берләшкән. *Хор матур, дәртле вә хәятлы бер көйне урта гына вә бик иттифаклы тавыш белән суза иде.* Ф. Әмирхан.

ИТТИФАҠЧЫ *и. тар.* Октябрь революциясенә кадәр: татар буржуазиясе арасында эшәп килгән һәм үзенең төп максаты итеп барлык мөселманнарны берләштерүне күздә тоткан дини-реакцион мөселман иттифакы партиясе тарафдары яки шул партия члены. *Синдә,* [*З. Сәетзадә*], *кызыл таҗчылар да, Кызгылт ислахчылар да, Милләтче иттифакчылар да — Барчасы макталган.* Г. Тукай. [*Сәфәр карт*] *иттифакчыларны чалмалы, кәләпүшле кадет партиясе дип бәйләнүлә[гә] чын күңелдән рәнҗи иде.* Г. Ибраһимов.

ИТТИФАҠЫЙ *рәв. иск. кит.* Очраклы рәвештә, очраклы. *Бервакыт мин Тукаевлар мәдрәсәсенә барган идем, иттифакый аларның мәҗлесләренә туры килдем.* Г. Кариев. *Моның әйләнәсенә, вәгазь тыңлыйбыз дипме, әллә иттифакый шулай туры килдеме, егерме-егерме биш башлап Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан абзыйлар җыелдылар.* Г. Тукай. // *с. мәгъ.* Очраклы.— *Бер көнне шулай икенде намазына барышым, хикмәти хода, иттифакый рәвештә шушы тәрәзәгә күзем төшмәсме.* Т. Гыйззәт.

ИТТИФАҠЫЙЛЫҠ *и. иск. кит.* Очраклылык. *Тарихның тәҗрибәле каты кулы, бу эше, бу кануны белән мәсьәләләрне иттифакыйлыктан коткарып, аларга туры хөкем чыгара.* К. Тинчурин.

ИТЧЕ *и.* **1.** Ит белән сату итүче кеше.— *Итче дә бүген ит бирмичә керткән.* Г. Қамал. *Казанда итчеләр елкы итенә хакны арттыра башладылар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Базарда ит чабып торучы кеше.

ИТЧЕЛ *с. к.* итләч. *Итчел үсенте.*

ИТӘК *и.* **1.** Күлмәк, алъяпкыч, пальто һ. б. ш.ның билдән түбәнге өлеше. *Күлмәк итәге. Алъяпкыч итәге.* □ *Шинель итәкләре авыраеп, аяк арасында лыпыр дап йөдәтте.* Г. Бәширов. *Фәйзерахман итәк чабуы белән күз яшьләрен сөртә.* А. Әхмәт.

2. *диал.* Юбка. *Ул киенгән газ итәкләр Җил-һавада ялтырый.* Н. Исәнбәт.

3. Кешенең кием алды; тез, ал. *Никтер әнине сагынам. Аның итәгенә ятып, озак еглыйсым, дөньяның мине җәберләве турында йөрәгемдә уянган зардан күз яшем белән бушанасым килә.* Г. Ибраһимов. *Син кызыңны алып итәгеңә, Йомшак чәчен сыйпап сөярсең.* Гиз-эль Габид. // *рәв. мәгъ.* Итәкнең алгы өлеше кадәр

(үлчәү берәмлеге булып йөри).— *Сиңа. Менә, бер итәк... кәнфит, пряннек, чикләвек, җимеш... бары да бар.* Ф. Бурнаш.

4. Биек нәрсәнең түбәнгә таба сөзәкләнеп җәелеп киткән аскы кырые, чите. *Кыя итәге. Манара итәге.* □ *Алар тау итәгенә кадәр әкрен генә төштеләр дә, тигез җиргә килеп җиткәч, кинәт чабышырга тотынып, бик тиз якыная башладылар.* И. Гази. *Салам эскертенең итәгендә, һәммәсе бертугандай бер-берсенә сыенышып, - - - бодай сугучылар йоклап ята.* Г. Бәширов.

5. Урман, болыт, күк һ. б. ш. кырые. *Офык итәге.* □ *Юл сузыла урман итәгеннән, Тукта, ямщик, туктат юргаңны!* Ш. Маннур. *Кояш, аксыл болытлар итәгеннән чыгып, саф, зәңгәр, тирән күктә йөзә башлады.* Г. Гобәй. *Зәп-зәңгәр күк итәгенә барып тоташкан, очы-кырые күренмәгән бер кара урман бар.* А. Алиш.

6. Диңгез, елга, океан яры. *Карт Каспийның Сөзәк итәгендә Балыкчылар ләмкә тартканнар.* М. Җәлил. [*Фәтхи*] *инеш итәгенә төшеп китте.* Ш. Камал.

Итәк астары *диал.* — эдеп. **Итәк салу** — күлмәкнең түбәнге өлешенә бериш яки башка тукымадан бала итәк тегү. *Гайниҗамал киң генә итәк салып тегелгән йон күлмәген кидө.* Ф. Әмирхан. **Итәк тоту** — 1) *к.* итәк салу; 2) *күч.* ялагайлану.

◇ **Итәк асты** — яшерен.— [*Хәйдәр*] *атнасына бер көн авылда булмый, Ясәвиләр белән итәк асты сәүдәсенә йөри.* Т. Гыйззәт. **Итәк астыннан** — 1) бик якыннан гына, бер-ике адым җирдән. *Туган илнең өч солдаты, - - - немец часовоеның итәк астыннан шуышып үтеп, чәнечкеле тимер чыбыклар пәрәвезе арасына кереп югалды.* Ф. Кәрим; 2) яшерен рәвештә. *Спекулянтлар, итәк астыннан иген сатып, кесә калынайталар.* И. Гази.— [*Генерал*] *немецларга сатылган. Сугыш серләрен итәк астыннан ярганнарга җибәреп торган.* Т. Гыйззәт. **Итәк астыннан ут йөртү** — астыртын, коткы эш алып бару. *Итәк астыннан утны Гыйбадулла куштан йөртә. Мулланы да ул котырткан.* И. Гази.— *Мәкерле җаннар! Итәк астыннан ут йөрткәннәр.* Ш. Маннур. **Итәк белән җитәк** — һәрвакыт бергә булучы, бер-беренән беркайда да аерылмый йөрүче кешеләр турында.— *Һаман бергә, итәк белән җитәк, Кушмый бит болай йөрергә китап.* Қ. Әмири. **Итәк касмагы** *тирг.*— бәйләнчек (кеше турында).— *Тәмам итәк касмагы булдың син, Минһаҗ агай!* Қ. Тинчурин. **Итәк кисеп җиң ялгау (ямау)** — икенче бер кирәкле як, кирәкле әйбергә зарар китерү хисабына берәр төрле эш башкару.— *Хуҗалыкны киметмибез, килен... Итәк кисеп җиң ямаган күк була бит ул.* Г. Гобәй.— *Ул комбинацияне эшләү - - - итәк кисеп җиң ялгау гына икәнен үзем дә төшендем мин.* М. Хәсәнов. **Итәк кыска** — мөмкинлек, хәл чамалы булу турында.— *Уткән ел техниклар китертеп смета да төзетеп карадык, Нурулла абзый, ә?— Әлеге дә баягы, итәк кыскарак.* Т. Гыйззәт. **Итәк тулы** — бик күп (балалар турында әйтелә). *Сәхи абзыеңны боярның урман каравылчысы атып үтерде... Мескен Әскап җиңгәң итәк тулы баласы белән ятим калды.* М. Гафури. **Итәккә бастырмау** — сер бирмәү. *Мина нәкъ алар җыелышып утырган урынга төшеп ярылды. - - - Ләкин сугышта очкан ядрәне күзләре белән күрергә өйрәнгән егетләр итәкләренә бастырмадылар. Блиндажга барып кергәндә Фәттах кына: «Күгәргән тешләр! - - - Ял итәргә дә ирек бирмәделәр»,— дип тиргәнде.* Ф. Кәрим. **Итәккә басу** — 1) (берәр нәрсә) килеп җитү.— *Өйдә утырырга картайгач та җитешерсең әле. Андый заманнар да итәккә килеп баса ул бер.* С. Рафиков; 2) кешене гаеп өстендә тоту. **Итәккә тагылу (ябышып йөрү)** *шелт.* — 1) берәр кеше артыннан калмау, берәр кешегә гел ияреп йөрү.— *Нигә, шикле кешедәй, минем итәгемә тагылып йөрерсең!* Г. Бәширов.— *Чыкмыйм мин сиңа кияүгә, менә шул! Кырмавык төсле, минем итәгемә ябышып йөрисе булма моннан болай!* Қ. Нәҗми; 2) мөстәкыйль эш, мөстәкыйль тормыш итә алмыйча, өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк, көчлерәк кешеләргә салыну.— *Син зур инде, - - - һаман-һаман әни итәгенә тагылып кына яшәмиләр дөньяда.* Қ. Нәҗми. **Итәккә ут кабу** — читен, куркынычлы хәл алдында калу. *Бусы турында Сәлмән карт үзе кайгырта башлаган: ул итәккә ут кабынганны көтмичә, алдан ук күрәсе кешеләрне күрә, сөйләшәсе кешеләр белән сөйләшә йөри иде.* Ф. Хөсни. *Чехларның итәкләренә ут капкач, башта алар белән сыпыртса да, кире борылып кайтырга башы җитте* [*аның*]. И. Гази. **Итәкне җыештыру (җыйнау, җыю)** *сөйл.*— 1) сак булу, саклык белән эш итү.— *Итәкләреңне җыештыргалап йөрмәсәң, күрерсең күрмәгәнеңне.* И. Гази.— *Шаярудан үзды эшләр, җаным. Итәгеңне җыебрак йөр.* М. Маликова; 2) эшләгән җинаятьне яшерү, сиздермәү.— *Сиңа итәкне җыебрак йөрергә туры килер. - - - [Илдар] колхоз бухгалтериясенә бик җентекләп ревизия ясатачак...* Г. Насрый. **Итәктән тоту** — берәр эштән тыеп калу, берәр нәрсә эшләргә ирек бирмәү. *Итәгеңнән колхоз тотмаса, син, Арыслан дип белеп үзеңне, Айга сикереп, егылып төшкән чакта Кемнәр җыяр иде көлеңне?* Ш. Маннур. **Итәктән төшү** — үсеп җитеп мөстәкыйль тормыш кора алырлык булу (балалар турында). *Моңарчы күңел җылысын улына биреп килгән Фәйрүзәнең улы, итәктән төшеп, шау-шулы урам дөньясына чумгач, күңел ялгызлыгы, үзәкләрне өзеп, өскә калкып чыкты.* Г. Ахунов. **Итәге касмаклы** *сөйл.*— 1) яман, гаебе зур (кеше турында); 2) бәйләнчек (кеше турында).— *Улым, чынлап әйтәм, каенанаң тирәсендә күп чуалма син. Итәкләре касмаклы халык бит алар.* Қ. Нәҗми.

ИТӘҚЛӘНҮ *ф.* Тау, кыя түбәдән тигез җиргә таба сөзәкләнү. *Тау итәкләнгән җирендә Күренә тынган бер авыл.* Н. Исәнбәт.

ИТӘҚЛӘП *рәв.* (Тау, урман, елга) итәге буйлап. *Менә хәзер тиңсез гүзәл төндә Мин барамын урман итәкләп.* Ш. Маннур.

ИТӘҚ-ЧАБУ: итәк-чабуны җыю (җыештыру, җыйнау) *сөйл.*— 1) *к.* итәкне җыештыру.— *Шәпкүлгә шушы арада тикшерүчеләр киләчәк, Морза дус алдын-артын шәйләп, итәк-чабуын җыеп куйсын.* Г. Мөхәммәтшин. *Қычқыр-[ырга] яратучан булса да, Қәшфразый Зөлхәбирә белән сөйләшкәндә итәкне-чабуны җыештырыбрак эш итә. Белә чөнки, бу хатын мәлҗерәп тора торганнардан түгел.* Б. Камалов; 2) эшләнми калган эшләрне төгәллә. *Беренче квартал тәмамлану алдында тора, итәк-чабуны бик нык җыярга кирәк.* Г. Ахунов.

ИТӘК-ҖИҢ *җыйд. и.* Төрле итәкләр. *Ә без итәк-җиңнәрне ычкырга төрдек тә, беләкләрне сызганып, уракларны алдык кулга.* Г. Минский.

◇ **Итәк-җиң тулу** — әйбер бик күп булу. **Итәк-җиңне җыю (җыештыру)** — *к.* итәкне җыештыру. *Болар барысы да безне итәкне-җиңне җыебрак тотарга, саклыкны, уяулыкны югалтмаска мәҗбүр итә.* Ф. Хөсни.— *Аракы заводындагы чатаклыкларны тикшерергә губерна эшче-крестьян депутатлары Советы кеше җибәрә. - - - Өяздән Ишниязов шалтыратты. Итәк-җиңнәрегезне тизрәк җыегыз, ди.* Т. Гыйззәт.

ИТҮ *ф.* **1.** *сөйл.* Эшләү, берәр эш башкару, үтәү.— *Шуларны җибәрәм дип сөйләнәдер иде, каһәр суккыры карчык. Сүзен утми куймас инде.* М. Фәйзи.— *Ничек итсәм итәрмен, аннан үчемне алмыйча, аны эштән чыгармыйча калмам.* Г. Камал.

2. *диал.* Берәр нәрсә эшләмәкче булу, берәр нәрсә эшләргә теләү, ниятләү. *Менә Габбас мулла да кайткан, күлмәк алыштырасы иткән.* Н. Исәнбәт.— *Ахрысы, мине өч ел азапларга итәрләрдер.* Г. Ибраһимов. *Күрәсең, күрше авыл кунаклары Гайниянең өенә керәсе итмәгәннәр.* Ф. Хөсни. // Берәр нәрсә эшләгән булып кылану. *Аны-моны сөйләшми утырганда итәләр болар.* Г. Мөхәммәтшин.

3. *эвф. сөйл.* Табигый йомышны үтәү.— *Тышка чыгып йөрмә, балам, - - - менә бәләкәй ләгәнгә генә утыр шунда. - - - — Минем алай өйдә иткәнем юк шул, тышка чыгамын мин.* Әкият.

4. *ярд. ф.* Төрле сүз төркемнәреннән соң килеп, тезмә фигыльләр ясауда катнаша: 1) исемнәрдән, хәбәрлек сүзләрдән соң килгәндә, шул исемнәр белән бәйләнешле эш-хәрәкәтне башкаруны, үтәүне аңлата.— *Иртәгә үк син безгә кайт, мин сине элек ничек тәрбия иткән булсам, хәзер дә һич авырсынмаенча тәрбия итәчәкмен.* Г. Камал.— [*Хәкимҗан:*] *Нигә райкомга хәбәр итмәдегез?* [*Галәви:*] *Иттек, иттек. Итмәгән кая.* К. Әмири; 2) исем, хәбәрлек сүз, сыйфат һәм рәвештән соң булганда, берәр хәлгә китерү, бер рәвешкә кертү, әверелдерүне аңлата. *«Хезмәт сезне ирекле итәр»,— дип язылган анда.* С. Тажетдинов.— *Син мичне бик кызу итеп як та, безнең кайтуга, бу солдатны куырдык ит.* Әкият; 3) аваз ияртемнәреннән соң килеп, алар белдергән эш-хәрәкәтне аңлата. *Шуып кына киткән иде, «Булт» итте, төште-китте суның төбенә!* Дәрдмәнд. *Аның күзе туганнан ук сөрмәләнгән, Керфекләре җемҗем итә сөрмәсез дә.* Ш. Бабич; 4) теге яки бу кешегә берәр вазифа, хезмәт йөкләү, аны берәр эшкә билгеләү. *Баш итү. Укытучы итү.* □ — *Җиргә аттык без моны мәхрүм итеп, Барча шайтаннарга баш мәлгунь итеп.* Ш. Бабич; 5) исемнәрдән аңлашылган карашта, фикердә, мөгамәләдә булуны белдерә. *Ата итү. Яхшы белгеч итеп карау.* □ — *Бик яхшы, каенатa итеп килгәнсең икән.* Әкият. *Тагы үзе әллә нинди сөйкемле, аны кызлардан да болайрак яратырлык, аны гел яратасы, дус итәсе килерлек.* Г. Ибраһимов.

5. Төрле сүз төркемнәре белән килеп, фразеологик әйтелмәләр ясауда кулланыла.— *Ис итмәгәндә абыйсы белән танышу аңа нихәтле күңелле булгандыр!* Ш. Камал.

6. *диал. к.* илтү. *Бетеп гомерең, итеп күмгәч, үзеңне, Итәрләр* [*җанны саклый торган тылсым*] *күмгән сүзеңне.* Дәрдмәнд.— [*Мин*] *Фәрхи җиңгиләргә әйбер итергә чыктым...* Г. **Ибраһимов.**

ИФАДӘ *и. иск. кит.* 1. Сөйләп аңлату, аңлатма. [*Р. Фәхретдинов*] *гомумән ифадәсе ачык, язу* [*стиле*] *садә вә гүзәл бер язучыдыр.* Г. Тукай.

2. Тәгъбирләү. *Гарәп лөгать вә әдәбияты никадәр бай булса да, яңарган без татарларның яңа әдәбиятында бәгъзы мәгънәләрне ифадә өчен һаман да җитеп бетмидер.* Г. Тукай.

3. Әйләнмә, сүз тезмәсе (сүзләр турында). *Әсәрдә табигать күренешләрен бирә торган урыннары да көчле тойгыны аңлатуга булышлык күрсәткән сүз һәм ифадәләр белән тулылар.* Г. Нигъмәти.

Ифадә итү — 1) сөйләп аңлату. [*Мин ризасызлыгымны*] *ифадә итмеш идем.* Г. Тукай; 2) тәгъбир итү. *Дөньяның зур вакыйгалары турында хикәя итеп язылган шигъри әсәрләр гадәттә әнә шундый төр лирика белән ифадә ителгән булалар.* Г. Нигъмәти; 3) күрсәтү. [*Тукай*] *бу журналга ахыргы минутларына кадәр хезмәт итәчәгенә вәгъдә бирде. Һәм шуны бөтен мәгънәсе белән ифадә итте.* Ә. Урманчиев.

ИФРАТ *рәв. кит.* Чамадан тыш, кирәгеннән артык, гаять, бик тә. *Ифрат күп. Ифрат кызыклы.* □ — *Тирәякка үрнәк булырлык ныклы бер коммуна хуҗалыгы торгыза алсагыз, ифрат зур эш булачак.* Ш. Камал. *Бу бер аның гына түгел, барыбызның да авторитетын җимерә, - - - ифрат та уңайсызлый.* Г. Бәширов. // *и. мәгъ.* Чамадан тыш арттыру. *Боларны* [*сурәтләгән*] *вакытта ифраттан һәм* [*чиктән тыш киметүдән*] *бик вә бик ныклы сакландым.* М. Гафури. [*Кадимче:*] *«Менә бу кадәрлесенең ачык йөрүенең* [*дөреслегенә*] *шәригатьтә юл бар, - - - әмма ифраттан сакланырга кирәк: пәрдә төшерелмәгән бүлмәгә чәчләрне капламый керү ярамас».*— [*Ди*]. Ф. Әмирхан.

Ифрат китү *иск. кит.*— чамадан ашу, чиктән ашу. *Кычкырырга, тавышын мәдрәсәгә ишеттерергә юл бармы — булса җитте. - - - Болар бит аның моназыйрлыкта ифрат китүен генә күрсәтә.* Г. Ибраһимов.

ИФРАТЛЫК *и. кит.* Чамадан тыш булу, кирәгеннән артык булу. *Ул бит үзе дә һәр тугрыда ифратлыкны гына эзли.* Г. Ибраһимов.

ИФТАР *и. дини.* 1. Уразада авыз ачу. [*Әсәрдә*] *ифтарга (рамазанда авыз ачарга) барулар бик көлке тасвир ителә.* Г. Сәгъди.— *Ифтар вакытларында мәчеттә җимеш тотмыйсың.* Т. Гыйззәт.

2. Рамазан аенда авыз ачу вакытына махсус чакырылган кунаклар мәҗлесе. *Йосыф хәзрәт икенче бер байның өендә ифтар — авыз ачу мәҗлесендә Галимҗан хәзрәтне бик ныклы кызартырга* [*уйлый*]. З. Бәширн. *Тукаев башка шәкертләр кебек ифтарларга йөреми иде.* Г. Кариев.

Ифтар итү (кылу) — ураза тоткан көнне, кояш баегач, авыз ачу. *Рамазан шәрифтә бер мөритнең бик ифтар итәсе килде.* Г. Тукай. *Икенде-ахшам укыгач, өйгә кайттым да, ифтар итеп, хөрмә ашадым.* З. Һади.

ИФТИРА *и. иск. кит.* Яла, ялган сүз.— *Ифтира, хәзрәт, ихлас ифтира, мәзин башым белән утын урлап йөримме, алла сакласын.* Т. Гыйззәт. [*Хәзрәт:*] *Алай дип әйтмә син, мулла Әхмәтҗан, бәлки ифтирадыр.* [*Әхмәтҗан:*] *Түгел, хәзрәт, түгел, көн шикелле беләм, ялган түгел.* Г. Камал.

Ифтира итү (кылу) — яла ягу.— *Сез миңа ифтира итәсез, ялганлыйсыз, - - - миңа ифтира итәргә, минем йөземне каралтырга гына килгән икәнсез монда!* Г. Тукай.

ИХ *ы.* Контекстка карап, шатлану, әсәрләнү, дәртләнү, соклану, кайгыру, ачулану, үкенү, мыскыллау һ. б. ш. хисләрнең көчлелеген күрсәтү өчен кулланыла (*и* авазының сузылып әйтелүе бу хисләрнең бигрәк тә көчле булуына ишарә итә). [*Ул*] *шелтәләп: «Их, куян йөрәкләр, куян йөрәкләр!»— дип кабатлый.* А. Шамов.— *И-их, туган! Сөенүемне күрсәң иде.* Г. Мөхәммәтшин.

ИХАТА *и. диал.* 1. Йортны, корылмаларны әйләндереп алган киртә, читән яки койма. *Йорт ихатасы. Завод ихатасы.* □ *Ибәт абызгайның ихатасы читән.* З. Һади. *Борынгы Кремль генә үзенең горур мәһабәтлеген югалтмаган: - - - Туп-патша, Патша-кыңгырау, киртләч башлы кирпеч ихаталар, ихата читләрендәге манаралар.* Г. Гобәй.

2. Киртә, койма яки читән белән әйләндереп алынган урын; ишек алды. *Нургали мәктәпнең рәшәткә белән әйләндереп алган алан кадәр ихатасына килеп кергәндә, бурәнәдән салган ике катлы зур бина тынлык эчендә утыра иде.* Ә. Еники.— *Ат-арба белән мәдрәсә ихатасына керү рөхсәт ителми.* К. Тинчурин.

Ихата итү (кылу) *иск. кит.*— 1) ишек алдын киртәләп, корылма белән әйләндереп алу. *Бикгимер агайның кечкенә салам түбәле ялгыз өенең тирәсе киртә берлә ихата ителеп, - - - кишер вә шалкан* [*утыртылган*]. З. Һади; 2) чолгап алу, уратып алу, ихата хасил итү. *Авылның тирәсе кара урманнар берлә ихата кыйлынган иде.* З. Һади

ИХАТАЛАУ *ф. диал.* Койма, читән яки киртә белән уратып алу. [*Мәктәпнең*] *артка — ихаталап алынган ишек алдына чыгу юлы да бар иде.* Г. Минский. [*Кабернең*] *тирәсен яхшы итеп ихаталаганнар.* З. Бәширн.

ИХАТАЛЫ *с. диал.* Ихатасы булган, ихата белән әйләндереп алынган. *Ихаталы бакчаларда - - - шомырт, чияләр, алмагачлар шау чәчәктә утыра.* Г. Әпсәләмов.

ИХАХА(Й) *ы. сөйл. шелт.* Авыз күтәреп шаркылдап көлүне белдергәндә кулланыла. *Ишек артына кача... Ихаха да михаха... Менә кызык ичмаса!* М. Җәлил. // *и. мәгъ.* Гамьсез, ваемсыз рәвештә шаркылдап көлү.— *Аңа шул ихахай да михахай гына булсын! Эш*

турында уйлап та бирми. Н. Фәттах. // *и. мәгъ.* Дөньяда кайгысы булмаган, гамьсез, шаркылдап көлеп йөрүче кеше.— *Ул ихахайга өйләнеп, ни кырырсың икән?* Ә. Камал.

Ихаха(й) да михаха(й) килү *шелт.* — оялмыйча шаркылдап көлеп чытлыклану. *Урам тулы халык йөри, аларның исләрендә дә юк, ихахай да михахай киләләр.* Т. Гыйззәт. **Ихахай ябалак** — *к.* байгыш. [*Байгыш*] *кеше булып шаркылдый. - - - Аны ихахай ябалак дип юкка атамыйлар.* Г. Хәсәнов.

ИХАХАЙЛАНУ *ф. сөйл. шелт.* Оялмыйча шаркылдап көлеп чытлыклану.— [*Килен*] *ире каршында ихахайлана, ул чыгып китте исә булмәсенә керә дә дөмегә.* Г. Камал.— *Шаяралар тагы. Кызларның гадәте инде ул. Аулактарак туры килгәндә, шулар ук ихахайланып йөри торгандыр әле.* М. Фәйзи.

ИХАХАЙЛАУ *ф. сөйл. шелт.* **1.** Әдәпсез шаяру, шаркылдап көлү. *Джаз илертеп аулак бүлмәләрдә Ихахайлый алар төн ката.* Х. Туфан. *Фәйрүзә егет-җилән тирәсендә ихахайлап йөрми.* Л. Ихсанова.

2. *рәв. мәгъ.* **ихахайлап.** Шаркылдап, кычкырып (көлү турында). *Күрәсең, хуҗа хатынның теләгәне булды, ул, зур эчен тоткан хәлдә, ихахайлап көләргә тотынды.* А. Расих. // Кычкырып, тавышланып. *Мөхәммәтша ага телеграмма-фәлән сугып тормады. Шау-шу куптарып, ихахайлап каршы алуларны бер дә яратмый иде ул.* В. Монасыйпов.

ИХАХАЙЛАУ-МИХАХАЙЛАУ *ф. сөйл. шелт.* Шаркылдап көлү. — *Ашлык сугучы кызларыңа әйт: бәрәңгеләрен [аша]сыннар да, ихахайлап-михахайлап утырмасыннар, өйләренә китсеннәр.* Т. Гыйззәт.

ИХА-ХА-ХА: иха-ха-ха килү *сөйл. шелт.*— 1) берәр нәрсәдән яки кешедән мыскыллы көлү. *Дошман теле иха-ха-ха... килә, Пычрак бер сүз йөри күтәреп.* Һ. Такташ; 2) *к.* ихаха(й) да михаха(й) килү.

ИХИ-ХИ, ИХИ-ХИ-ХИ *ы.* **1.** Акрын гына, шаркылдамыйча, кеткелдәп көлүне аңлатканда кулланыла.— *Тешләп тартсаң да өзелмәслек булсын... Ихи-хи!* Ф. Бурнаш.— *Кечкенә генә фонарь өчен шушындый эш эшлибез диген, ә? Уйлап карагыз үзеңез, ихи-хи-хи-хи!* К. Әмири.

2. Көрсенүне, гажәпләнүне һ. б. ш. белдерү өчен кулланыла.— *Ихи-хи-хи... Кешеләр түгел, ерткычлар [алар].* Т. Гыйззәт.— *Ихи-хи-хи, җырлап та булмый рәхәтләнеп!* К. Тинчурин.

ИХЛАС *и.* **1.** Күңел чынлыгы, сафлыгы, турылык, эчкерсезлек. *Аның чын күңеле белән революция ягында булып бирелеп эшләве солдатларның аңа булган яхшы карашларын, ышанычларын тагын да арттырды. Аның шул ихласына - - - ышанган солдатлар Вахитны - - - съездга вәкил итеп сайладылар.* М. Гафури. *Ихлас белән сөйгән кызлар барын-югын уйламас.* М. Фәйзи.

2. *с. мәгъ.* Саф, эчкерсез, чын күңелдән эшләнә торган. — *Хәзерге үзгәрешең ихлас күңелдәнме, әллә җан саклау өчен[ме]?* Г. Ибраһимов. *Сөям дигән ихлас сүзең белән Ашкындырдың мине бүген дә.* Г. Насрый. // *рәв. мәгъ.* Чын күңелдән, риясыз. *Миңнулланың балалары әтиләрен көтәләр. Газиз әткәбез кайтыр, дип, Ихлас өмет итәләр.* Бәет.

3. Теләк, омтылыш, дәрт. [*Нәҗиянең*] *укырга ихласы юк.* Ә. Еники. *Минем өйгә дә кайтасым килми, малайлар белән уйнарга да артык ихлас юк.* М. Гали. // *с. мәгъ.* Теләге, омтылышы булган, һәвәс. *Кыш һәм көзнең озын кичләрендә безнең өйгә бик еш кына авылның китап тыңларга ихлас кешеләре һәм кайбер күршеләр киләләр.* М. Гафури. // *рәв. мәгъ.* Тырышлык куеп, зур теләк белән.— *Киләсе җомга көн тагы да ихласрак дога кылырмын әле.* М. Фәйзи.

4. Кемне дә булса чын күңелдән ошату; симпатия, мәхәббәт. *Хәзрәтнең бу кешегә булган ихласы тагын да арта төште!* Ф. Әмирхан.— *Ничә мәртәбә Гани бай сиңа бирергә әзер торганлыгын, кызның да синдә ихласы зурлыгын сөйләде.* М. Фәйзи.

5. *кер. сүз мәгъ.* Берәр нәрсәнең дөреслегенә ышандырганда әйтелә; чынлап та, чын-чынлап, дөрестән дә.— *Әгәр теләсәк, ферманың бөтен савым сыерларын шулар кебек итә алабыз. Ихлас, итә алабыз.* Ә. Еники.— *Без барганны көтә ул, Нурия җиңги. Ихлас, шулай.* Г. Гобәй. // Гозерләнеп сораганда, үтенгәндә кулланыла. *Ул, эчкә баткан күзләре белән үтенеп, Айсылуга карады: «Барсана, Айсылу сеңел, Михаил Павлычка тагын бер сүз салып карасана. - - - Ихлас, авырсынмасаң, кереп чыксана, ә!»* Г. Бәширов.

◇ **Ихлас белән** — берәр нәрсәгә бөтен күңелне бирепигътибар белән, бирелеп. *Шундый тын, ихлас белән тыңласаң, пароходның дөп-дөп дөпелдәп баруына хәтле ишетелә.* Г. Гобәй.— *Син бит минем кушканнарымны бик ихлас белән үти торган акыллы малай.* М. Фәйзи. **Ихлас кайту** — теләк бетү, күңел кайту, күңел бизү. *Бер хикәя вә анекдотның әллә ничәшәр мәртәбә тәкрарлануы да безнең ихласны кайтармый, тыңлаган саен тансык тоела иде.* Ш. Камал. *Яңа көй чыктымы, - - - авыл урамнарында егетләр, көз көне никрутлар, яңа көйдән ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар.* Г. Тукай. **Ихлас кую (баглау, салу)** — чын күңелдән кызыксыну, күңел бирү. *Ихлас куеп дәресләрдә калмак кирәк, Күңелебезне гыйлем белән нурлау кирәк.* Г. Камал. *Уенга салмаса ихлас — менә бәхете аның шунда.* Г. Тукай. *Йөргән кырда — иген арасында Ихлас баглап, тәмам дәрт биреп.* М. Гафури. **Ихлас әгәр** — *к.* ихлас (5 мәгъ.). [*Айсылу:*] *Мирвәли качкан.* [*Әкрам:*] *Булмас ла.* [*Айсылу:*] *Ихлас әгәр. Яныннан кайткан кешене күреп сөйләштем.* Т. Гыйззәт.

ИХЛАСЛАНУ *ф.* Берәр нәрсәгә бөтен күңелен бирү, шуның белән мавыгу, шуңа бирелеп китү. [*Ул*] *яңа фикерләр тыңлап кайта вә, боларның нәтиҗәсе булырак, - - - хәдискә көннән-көн ихласлана.* Ф. Әмирхан.— *Монда килгәч, шәһәр кызлары кебек, чәчәккә ихласланды үзе.* Г. Мөхәммәтшин.

ИХЛАСЛЫ *с.* **1.** Чын, эчкерсез, саф. *Шагыйрьнең ихласлы сүзләрен зал йотылып, онытылып тыңлый.* М. Максуд. // *рәв. мәгъ.* Чын күңелдән, җаны-тәне белән. *Моңысын алгач, бик ихласлы сөйсен: хатыным дип, һичбер каты сүз әйтеп хафаларга батырчылык итә алмасын.* Г. Тукай.

2. Күңел бирүчән, мавыгучан.— *Зөбәйдә, син бит яңа китапларга мавыгучан, ихласлы гына идең.* Ш. Камал. *Балалар музыкага ихласлылар.* Ф. Кәрим.

ИХЛАС(ЛЫ)ЛЫК *и.* Саф күңеллелек, эчкерсезлек. [*Бәдри*] *бик ихласлык белән: «Монда Җәмилә аш ашарга керсен, тизрәк бул!»— диде.* М. Гафури.

ИХЛАСТАН *рәв.* Чын күңелдән, бөтен йөрәктән, эчкерсез, риясыз рәвештә. *Башкалар аның сүзен тыштан җөпләгән булып маташсалар да, ихластан түгел, болай хәтер өчен генә икәнлеге әллә кайдан билгеле иде.* Ш. Камал.— *Зөбәрҗәт, син минем сөюемнең ихластан икәнлегенә ышанасыңмы?* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ИХЛА'СТЫР *кер. сүз. к.* ихлас (5 мәгъ.).— *Алай димә әле, карт, ихластыр, берсе килә.* М. Шабай.

ИХМА *ы.* **1.** Рәхәтләнү, кәефләнү тойгысын белдерә (сузып әйтелү бу тойгының көченә ишарә итә).— *Их-х-ма-а! — ди ул, күңелле итеп, һәм үзе уйнап, үзе җырлап җибәрә.* Г. Гобәй.

2. Үкенү, тирән борчылу, көрсенү тойгысын белдерә. *Әгәр берәрсе төшенкелеккә бирелеп, шуның өстенә: «Ихма!»— дип көрсенеп тә куя икән, иллә җен ачулары чыга торган иде Җәүдәтнең.* М. Шабай.

ИХРАМ *и. дини.* **1.** Хаҗга баручыларның Мәккәгә җитәрәк билгеле бер урында, бөтен хәрам эйберләреннән арынып, режимга керүе. // Шул урын үзе.— *Ихрамнан*

чыгасы көндә, уяулы-йокылы чагымда - - - [изге сүз] колагыма керде. Г. Камал.

2. Хаҗга баручылар изге җиргә керер алдыннан өсләренә кия торган япма, өреткеч кием.

ИХСАН *и. иск. кит.* Кешегә эшләгән изгелек, ярдәм, мәрхәмәт; бүләк. *Бабайның бу карт көненә кадәр ярдәме берлә файдаланган гарипләр вә ихсаны аркасында җанланган үлекләрнең исәбе-хисабы юк иде.* Г. Тукай.

Ихсан итү (кылу) — 1) бүләкләү. *Миңа сабый балалар йокысын ихсан ит.* Г. Тукай; 2) ярдәм итү, яхшылык кылу. *Бәдри, үзенчә бик зур ихсан кылган, бер кешенең рәхәт тормышына сәбәп булган кешеләрчә: «Я, Җәмилә, бу көн ирең кая китте?»— диде.* М. Гафури; 3) *күч.* бирү.— *Аңа шушы сыйфатлар ихсан ителгән: аягы юк, кулы юк, телсез, сукыр...* М. Фәйзи.

ИХСАНЛЫ *с. иск. кит.* Изгелекле, мәрхәмәтле, ярдәмчел. *Быел Астраханьнан килгән юмарт хаҗилардан - - - утыз мең сум иганә җыелды. - - - [Шундый] ихсанлы хаҗиларны күбрәк җибәрегез.* Ш. Мөхәммәдев.— *Гарәфи юмарт, ихсанлы [кеше] иде.* Х. Садрый.

ИХСАНЛЫЛЫК *и. иск. кит.* Ихсанлы булу. *[Ул] башкаларның милке илә - - - ихсанлылык [күрсәтә].* Г. Тукай.

ИХСАНЧЫ *и. иск. кит.* Ярдәмчел, изгелекле кеше. *Әйтсәң — әйт: Габделлатиф хаҗины бер ихсанчы дип!* Ш. Бабич.

ИХТИЛАЛ *и. иск. кит.* Революция. *Ул Россиядә тиздән ихтилал — революция булачагы турында сөйли.* З. Бәшири. *Бөек ихтилал хәбәре белән рухланып, җилпенеп киттек. Падишаһ очкан, ди, малай.* М. Фәйзи. // Фетнә, чуалыш. *Февральдә Бакуда бөек ихтилал булып, мөселманнар илә әрмәннәр бер-берен [күп үтерделәр].* Ш. Мөхәммәдев. // Баш күтәрү, революцион хәрәкәт. *Бу протест, бу сугыш — бездә дә менә шундый шәкерт ихтилаллары рәвешендә дөньяга бәреп чыга.* Г. Ибраһимов.

ИХТИЛАЛЧЫ *с. иск. кит.* Революцион, баш күтәрүче. *Ихтилалчы мәмләкәтләр кыйбласыдыр Москва!* С. Сүнчәләй. // *и. мәгъ.* Революционер, баш күтәрүче кеше. *Ихтилалчы - - - булмасам да, - - - күрдем зиндан.* Г. Тукай. *Ихтилалчылар Англия халкына падишаһыбыздан шикаятькә баралар.* Ф. Әмирхан.

ИХТИЛАФ *и. иск. кит.* Фикер башкалыгы, бәхәс, каршылык. *Имла, тел, өслүб турында ихтилафлар булган кебек, монда да, югарыда әйтелгәнчә, көрәшләр — агымнар булыр.* Г. Ибраһимов. *Әхмәдев белән минем арадагы ихтилаф хәл ителгән. Ул, сәхнәгә гел интеллигентлар гына булсын, дип, мин, халык арасыннан талантлар чыгачак, дип тартыша торган идем.* М. Фәйзи.

ИХТИМАЛ 1. *и.* Теге яки бу нәрсәнең, эшнең тормышка ашуына объектив мөмкинлек, фараз (эш яки хәлнең тормышка ашуы икеле, шикле булган очракта әйтелә). *Бүген кинәт үзгәреш. Мохтарның күңеленә ике ихтимал килде: фатир хуҗасы я хак арттырырга уйлаган, яисә ничек тә булса боларны квартирадан чыгарырга карар биргән.* Ш. Камал. // Булуы мөмкин саналган очрак. *Табигать аның я дошман, я дусы булып килеп баса. Һәр ике ихтималда крестьян аны өйрәнергә, төшенергә, аның артыннан күзәтергә тырыша.* Г. Нигъмәти. *Авыл халкы - - - мәсьәләне төрле якка борып карый, төрле ихтималларның берсен дә калдырмый, барысын да күздән кичерә.* С. Җәләл.

2. *хәб. сүз.* Мөмкин.— *Кайда булса да тагын кузгалыш булгандыр, безне шуларны басарга җибәрәләрдер...— Булмагандыр, булуы ихтималдыр.* М. Гафури.— *Бармый калсаң, бер дә ярамый: якын кеше, үпкәләүләре ихтимал.* Г. Камал.

3. *кер. сүз.* Берәр эш-хәлнең булу-булмавы ачык хәл ителмәгәндә, икеләнеп фараз иткәндә, кайсы якны тотарга белми икеләнгәндә һ. б. әйтелә; бәлки, мөгаен.— *Докладка рәхим итегез! — Ихтимал, килермен,— дип, Якуб урыныннан торды.— Ихтимал түгел, әлбәттә киләсез!* И. Гази. *Кем белә, бәлки, атасы кебек калмас, бәлки, безнең кеше булыр, ихтимал, калага да урнашыр.* Г. Ибраһимов.

Ихтимал йөртү — я тегеләй, я болай булырга мөмкин дип уйлау; фараз итү. *Әйберләрнең дә табылмавына карап төрле кеше төрле ихтимал йөртсәләр дә, колакка хуш килердәй сүз сөйләүче юк иде.* Ш. Камал. *Кайбер сүзләрнең мәгънәсе турында шундый ихтималлар йөртергә була.* Н. Исәнбәт. **Ихтимал тоту** — теге яки бу вариантның конкрет монысы булыр дип фараз итү, уйлау. *Болар, бу сукмакның берәр күмер яндыра торган җиргә барып чыгуын ихтимал тотып, күңелне юаталар.* М. Гафури.

ИХТИМАЛЛАНУ *ф.* Берәр эш-хәл мөмкин булыр дип уйлану. *Үндүрт яшьлек кызга никах укыганлыгы өчен указының китүе ихтималланган, ул, дөньясын онытып, - - - әллә нинди түбәнлекләр күтәргән.* Г. Ибраһимов.

ИХТИМАЛЛЫК *и.* Ихтимал булу; мөмкинлек. *Мондый бәхетсез вакыйганың ихтималлыгын Муса яхшы төшенә.* Ш. Маннур.

Ихтималлык теориясе *мат.*— математикада күп сандагы очраклы күренешләрнең үзара бәйләнешләреннә нигезләнгән закончалыкларны өйрәнә торган бүлек.

ИХТИОЗАВР *и.* Казылма хәлендә табыла торган сөйрәлүче зур диңгез хайваны. *Ничәмә миллион еллар бу матурлык, бу гүзәллек әрәм яткан. Ихтиозаврлар матурлыкны аңламаганнар.* И. Гази.

ИХТИОЛ *и.* Казылма балык калдыклары катнашкан тау токымнарын (сланецларны) күкерт кислотасы ярдәмендә эшкәртү юлы белән табыла торган май сыман дару.

ИХТИО'ЛОГ *и.* Ихтиология белгече. *Тәҗрибәле ихтиолог.* □ *Саф сулары пычранган елгалар - - - хакында укымышлы ихтиологлар [сөйлиләр].* Г. Ахунов. *Һавалар үзгәрәчә[ген] балыклар ничек сизәләр? - - - Анысын инде ихтиологлар белсен.* М. Әмир.

ИХТИОЛО'ГИК *с.* Ихтиологиягә мөнәсәбәтле.

ИХТИОЛО'ГИЯ *и.* Зоологиянең балыкларны өйрәнүгә багышланган бүлеге.

ИХТИРАГ *и. иск. кит.* Берәр яңа, моңарчы булмаган нәрсә, фикер, ачыш. *Моны гомеремдә уйлаганым юк иде, Зыя әфәнде әйткәннән соң, тәмам үз ихтирагым шикелле булып китте.* Г. Ибраһимов.

Ихтираг итү (кылу) — уйлап табу, уйлап чыгару. *Тегү машинасы ихтираг иткән Зингерның [газетада] - - - игъланы бар.* Г. Тукай. *Адәмнәр язу дигән нәрсәләрне ихтираг итү вә хәзерге дәрәҗәсенә җиткерү өчен дә бик күп тәҗрибәләргә мохтаж булганнар.* Ф. Әмирхан.

ИХТИРАЗ *и. иск. кит.* Саклану. *Шуның өчен Әхмәтҗан карт хәзердән үк, ихтималдан ихтираз өчен, читеген салган.* Г. Тукай. *Бу дөньяда өч кешедән ихтираз: Бере аксак, бере сукыр, бере таз.* Мәкаль.

ИХТИРАМ *и.* Хөрмәт, зурлау, олылау. *Ихтирам казану. Ихтирамга лаек.* □ *Бик урынлы ихтирамың: хөрмәт итү кирәк, ханым, сәнгать кешесен.* Г. Насрый. *Укытучылар төркеменнән һәркем аңа ихтирам күрсәтергә әзер тора, һәркем үзенчә яхшы дип тапкан урынны аңа тәкъдим итә.* М. Әмир.

Ихтирам итү (кылу) — хөрмәтләү, олылау, зурлау. *Сөләйман эшчәнлеге өчен Сәетзадәне ярата, хәтта ихтирам да итә иде.* К. Тинчурин. *Үзең әйткән авазлар дөньясына шулай гашыйк булуыңны чын күңелдән ихтирам итәм мин.* Г. Бәширов.

ИХТИРАМЛАУ *ф. сир. к.* ихтирам итү. *Энеләрен йөрсен ихтирамлап, Үрнәк булсын апа сеңеленә!* З. Бәшири. *«Алтын чәч» операсын тыңлаганда син, Нәҗип Җиһанов белән берәттән, операның шигъри юллар*

белән либреттосын язган Муса Җәлилне ихтирамлый-сың. Ж. Фәйзи.

ИХТИРАМЛЫ *с.* 1. Хөрмәтле, ихтирамга лаек, ихтирам ителүчән. [*Ул*] *бер үк вакытта амбарчы да, бригадир да булып, авылның ихтирамлы олы кешесе булып яшәде.* Г. Ахунов. *Гомеремнең бу дәверендә инде мин Фәтхулла хәзрәткә вә аның халык арасындагы ихтирамлы урынына кызыкмый башладым.* Ф. Әмирхан.

2. Хөрмәт итүчән, ихтирам күрсәтүчән. [*Алар*] *берберенә карата ихтирамлы да булып киттеләр.* Г. Ахунов.

ИХТИРАМЛЫЛЫК *и.* Ихтирамлы булу, ихтирам күрсәтүчән булу. *Кешелекле, күркәм холыклы, культуралы кешенең гадәтенә кергән, акылына сеңгән сыйфат ул — ихтирамлылык.* Азат хатын.

ИХТИРАМЧЫЛ *с.* Һәрвакыт ихтирам итүчән; хөрмәтчел.— *Иң ихтирамчыл Россия халкының саулыгын* [*телик*]. Т. Гыйззәт.

ИХТЫЯР *и.* 1. Кеше психикасының алга куйган максатны, теләкне тормышка ашыруда чагылган сәләте, аңлы омтылышы, теләккә ирешүдә ныклык. *Җиһангир автоматын төзәде, ләкин актык секундта дустына атар өчен аның ихтыяры җитмәде, ул төзәгән автоматын түбән төшерде.* Г. Әпсәләмов. *Кеше алдында елап җибәрмәс өчен, ул, бөтен ихтыяр көчен җигеп, үз-үзен кулга алырга тырышты һәм еламады.* М. Әмир.

2. Теләк, ирек. [*Һайдель:*] *Кем сине тотып китерде?* [*Шаһбаз:*] *Беркем дә. Үз ихтыярым белән килдем.* Т. Гыйззәт. *Ихтыярымнан башка күзләремнән яшь чыкты.* М. Гафури.

3. Власть, ирек. *Аның ихтыярында булса, тагын йөз ел яшәр иде әле.* И. Гази. *Хәзер бөтенләй синең кулыңда, синең ихтыярыңдамын.* Ш. Мөхәммәдев. // *тарт. форм.* **ихтыярыгыз, ихтыярың.** Ничек телисез, шулай эшли аласыз, сезнең карамакта, сезнең иркегездә. [*Гарифә:*] *Кирәкми, мин бармыйм.* [*Вәли:*] *Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә, көчләмим.* Г. Камал.— *Бүген бездә кунарсың, иртәгә ихтыярың, теләсәң кая бар.* Ф. Хөсни.

4. Берәр нәрсә эшләргә мөмкинлек, мөстәкыйльлек; бәйсезлек.— *Ихтыярың атаңда! Син аның кулында! Ул сине теләсә нишләтсә дә ирекле!* С. Рәмиев.

5. *иск.* Азатлык, политик, экономик ирек. *Безнең правительство эшчеләргә җыелышырга, союзлар ясарга --- ихтыяр, иркенлек бирү --- патша хөкүмәтен җимерергә юл бирү икәнлеген аңлый.* РСДРП прокламациясе. *М. Гафури халыкның иреген, ихтыярын басып торучы әшәке дин-шәригать законнарын фаш итә.* М. Җәлил.

Ихтыяр бирү *иск. кит.— к.* ирек бирү. *Карт абыстай төн буенча --- һич йокларга ихтыяр бирмәгән иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Авыру булу сыйфаты белән Мәдинәгә килү-килмәү турында ихтыяр бирелгән булса да, ул да, таяк тоткан килеш, аксый-туксый акрынлап килде.* Ш. Камал. **Ихтыяр итү (кылу)** *иск. кит.*— ике нәрсәнең, ике якның берсен сайлау, теләү. [*Доктор*] *фронтка ватан каһарманнарын дәваларга баруны ихтыяр иткән.* А. Таһиров. [*Ул*] *ике юлның берен ихтыяр итәчәк иде.* З. Һади. **Ихтыяр(га) кую (салу)** — теләгән нәрсәсен эшләргә ирек, мөмкинлек бирү.— *Яшьлегебез сәбәпле, зөфафыбызны үз ихтыярыбызга салдылар.* З. Һади.— *Без көчләмибез, без сезнең ихтыярыгызга куябыз, --- әгәр каласыз икән, --- рәхим итәсез.* Ә. Еники.

ИХТЫЯРИ *с.* 1. Мәҗбүри түгел, ирекле.— *Халхоз ихтыяри нәрсә ул, --- телим икән — керәм, теләмәсәм — аерым хуҗалык булып калам.* Ф. Хөсни. *Советлар дөньясының үзенә генә махсус гадәтләре туып торадыр. Җөмләдән берсе — ихтыяри өмәләр ясау.* Ш. Әхмәдиев.

2. Ихтыярга (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Ихтыяри карарлар. Ихтыяри күрсәтмә.*

ИХТЫЯРИ-МӘҖБҮРИ *рәв.* Нигездә мәҗбүри булып, үтәлеше аңлы рәвештә кешенең үз ихтыярына куелган эш турында әйтелә. *Врач апасы да башын түбәнрәк иеп атлый шикелле. Ихтыяри-мәҗбүри дигәндәй генә килешеме икән?* Б. Камалов.— *Аңысы ихтыяри-мәҗбүри сыманрак килеп чыкты инде аның, Сәйдәшев агай.* Х. Сарьян.

ИХТЫЯРЛЫ *с.* 1. Ихтыяр көче булган. *Сезне дә мин --- эчегездәге барлык сагышны, борчылуны, хәтта кайгыны да баса ала торган көчле ихтыярлы кеше итеп уйлаган идем.* А. Шамов.— *Син егет чагыңда шактый ихтыярлы, үз иркеңә үзең хуҗа идең.* Ә. Камал.

2. Теләгән нәрсәне, теләгән эшне эшләргә ирекле; тулы хокуклы. *Монда ул --- теләгән китапны я журналны алырга, актарырга, укып чыгарга ихтыярлы. Аштан соң теләгән эшеңне эшләргә ихтыярлы.* М. Гафури. / *рәв. мәгъ.*— *Безнең сүзләребезне, җырларыбызны тыңлау һәркем өчен ихтыярлы. Тыңлаганнан соң аларга ышану-ышанмау да ихтыярлы.* М. Әмир.

ИХТЫЯРЛЫ-ИХТЫЯРСЫЗ *рәв.* Теләккә каршы, теләр-теләмәс.— *Ни эшләмәк кирәк. --- Ихтыярлы-ихтыярсыз алар белән бергә буласың.* Г. Камал. [*Итекчеләрнең*] *эшләп чыгарган итекләрен алырга кеше табылм*[*агач*], *ихтыярлы-ихтыярсыз итекчеләр берсеннән-берсе очсызрак сатарга тырышырлар иде.* Г. Тукай.

ИХТЫЯРЛЫК *и.* Теләгән нәрсәне эшләргә ирекләлек, хокук булу; мөмкинлек. *Һәркемгә тигез иркенлек, ихтыярлык игълан кылынды, теләгәнчә сөйләргә, теләгәнчә язарга рөхсәт булды.* Ш. Мөхәммәдев.

ИХТЫЯРЛЫЛЫК *и.* Ихтыяр көченә ия булу. *Аның көр тавышында зур ихтыярлылык, үз-үзенә бик ныык ышану бар иде.* А. Шамов.

ИХТЫЯРСЫЗ *с.* 1. Ихтыяр көче булмаган. *Абыстай бу колларча ихтыярсыз һәм буйсынучан хатынның аш-суга осталыгын да күргәч, аны аш өендә генә эшләргә калдырды.* Г. Минский.

2. Теләгән нәрсәне, теләгән эшне эшләргә ирексез, хокуксыз. *Үзенең правосын киңәйтү тугрысында дума бер сүз дә кузгатырга ихтыярсыз.* РСДРП прокламациясе. *Ибәт абызагайның* [*ышануында*], *хатыннар — кәнизәк кеби ихтыярсыз (ирексез) затлар.* З. Һади.

3. Берәр нәрсә эшләргә мәҗбүр. *Сез үзенең эшли торган көчең сатарга ихтыярсыз булган эшчегә карагыз.* РСДРП прокламациясе.

4. *рәв. к.* ихтыярсыздан. [*Җиңгәсенең*] *кызык булып җыерылган кашларына күзе төште дә, Нәфисә ихтыярсыз көлеп жибәрде.* Г. Бәширов. *Маңгаема бөртек-бөртек салкын тир бәреп чыкты, йодрыклар ихтыярсыз йомарландылар.* Ә. Айдар.

Ихтыярсыз итү — ирексезләү, мәҗбүр итү. *Халык* [*патшаны*] *яңадан дума җырга ихтыярсыз итә.* Урал.

ИХТЫЯРСЫЗДАН *рәв.* Ихтыярдан тыш, ирексездән (күбесенчә кешенең үз ихтыярына буйсынмаган хисләр турында әйтелә). *Бу карарга ихтыярсыздан гына кушылабыз.* Ш. Усманов. // Үзе дә сизмәстән. *Искереп беткән «Победа»ның ишек тоткасына кулын тидергәндә ул ихтыярсыздан --- озын «ЗИМ»ын исенә төшерде.* Г. Әпсәләмов. *Ихтыярсыздан аның күңелендә укымыйча калуы өчен тирән үкенү уяна.* Ә. Еники.

ИХТЫЯРСЫЗЛАНУ *ф.* Ихтыяр көчен югалту, икенче берәүнең ихтыярына буйсыну. [*Аңа*] *кулларын туп-туры куярга куштылар. --- Ул ихтыярсызланды, алар кушканча торды.* М. Гафури.

ИХТЫЯРСЫЗЛАУ *ф.* Көчләү, мәҗбүр итү, ихтыярга буйсындыру. *Кара инде хәзер ничек итеп җил ихтыярсызлап әллә кайларга сөреп китә.* Ш. Камал.

ИХТЫЯРСЫЗЛЫК *и.* Ихтыярсыз булу сыйфаты.— *Үз эшеңә шикләнеп карау — көчсезлек, ихтыярсызлык ул.* Г. Насрый. *Ул бу сүзне, --- тау астына йөгереп бара торган кеше йөгерүенең ихтыярсызлыгы шикелле, ихтыярсызлык --- белән әйтте.* Ф. Әмирхан.

ИХТЫЯҖ *и.* Тормыш-көнкүреш өчен бик кирәкле, зарур нәрсә. *Культура ихтыяҗлары. Үсемлекләрнең суга ихтыяҗы.* □ *Ашау, йоклау — табигый ихтыяҗ. Кешеләрне сөю, алар белән дус булырга тырышу табигый ихтыяҗ түгелме әллә?.. Шиксез, табигый ихтыяҗ.* А. Гыйләҗев. *Сабый өчен уен — бик табигый ихтыяҗ.* Г. Гобәй. // Ялыныч. *Галиәкбәр агай чарасыз үз исемен һәм фамилиясен куярга үгрәнде. Моннан соң һичкемгә ихтыяҗы калмады: акчасы күп һәм үзе кул куя да беләдер.* Ш. Мөхәммәдев. // Мохтаҗлык. *Монда катык, сөт күп, шулай ук бәрәңгегә дә ихтыяҗ юк иде.* Г. Тукай. *Анда эшчеләргә ихтыяҗ зур икәнен сөйләделәр.* М. Гафури.

ИХ-ХА-ХА *ы.* Шаркылдап көлүне белдерү өчен кулланыла.— *Их-ха-ха, Фатихә! Сыер бии әпипә.* Н. Исәнбәт.

ИХ-ХИ-ХИ *ы. к.* ихи-хи.— *Их-хи-хи-хи, убыр кулында никадәр мал әрәм ята бит?!* Қ. Тинчурин. *Солдат кычкырып җибәрде: «Их-хи! Карагыз, көймәне кая илтеп ташлаган!»* Ш. Қамал.

ИХЫЛДАУ *ф.* «Их» дип кую (көрсенүне белдерә). [*Гамир*], *«Эх-ма!»сын ихылдап, тагын яныма килеп ятты.* Р. Төхфәтуллин.

ИЧ *кис.* Сөйләмнең төп эчтәлегенә раслау төсмере өстәү, хәбәрнең тыңлаучыга мәгълүм булганлыгын яки мәгълүм булырга тиешлеген аңлату, фикерне көчәйтү, куәтләү өчен кулланыла; бит III.— *Әйе, әйе, янәшә төптә үскән бодай ич ул.* Г. Бәширов.— *Андый эш булганы юк ич.* Ш. Қамал.

ИЧМАСА(М) 1. *кер. сүз. (Һич булмаса* тезмәсеннән кыскарган). Ахыр чиктә, бер дә булмаса, бер дә булмаганда, һич булмаса, шунысы гына булса да.— *Ичмаса, атасы табып кайтса да, бераз йөрәгемә ял булыр иде.* Г. Қамал.— *Як-якка колак салам, ичмасам, тычкан гына да чыелдамый.* Г. Бәширов. // Һич югында.— *Әй, җан көярлек кыз булса иде, ичмасам!* Г. Минский.— *Ник, ичмаса, бер генә кеше күренсен!* Г. Бәширов. // Җитмәсә, житмәсә тагы, өстәвенә.— *Обушогы да төшеп калды, ичмаса.* И. Гази.— *Һичбер кеше юк, ичмасам.* Г. Тукай.

2. *кис. функ.* Соклану, гаҗәпләнү тойгысын көчәйтә.— *Менә ичмасам зал дисәң дә зал икән.* Д. Аппакова.— *Менә ичмасам ул оятка калу дисәң дә калу!* А. Шамов.

3. *кис. функ.* Хәтта.— *Мәулиха тутине җибәрмим! Ичмасам тешеңне дә агартма!* Г. Бәширов.— *Юк, юк, Галимҗан абзый, кычкырышу түгел, уйлаганыбыз да юк ичмасам.* Г. Тукай.

ИШ *и.* 1. Материаль, рухи яки башка яктан тиң, пар булырлык кеше, үзе кебек кеше. *Иш булу. Иш итү.* □ *Үз ишеннән алган булса, авылда кызлар беткән идемени? Менә дигән матурын, сандык тулы маллысын тапкан булыр иде. Ялгышты Сафа, ялгышты.* А. Шамов.— *Нишлисең, чиләгенә күрә капкачы шул инде. Сәрвиназына күрә егете. Иш ишен, җил тишеген таба, ди, әйдә, рәхәтләнсеннәр.* М. Фәйзи. // Физик, женси, сыйфат һ. б. яклардан бер төр. *Аларны үз ишләре белән, айгырын айгыр белән, байталын байтал белән - - - араннарга ябалар.* А. Расих. // *с. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса охшаш, шул ук сыйфатка ия.— *Җир йөзендә моңа иш булырлык айгыр һичбер патшада юктыр.* Әкият.

2. *бәйл. функ. тарт. форм.* **ише.** Сорты, төре белән икенчесенә якын әйбергә карата әйтелә.— *Чите каймасыз мамык шәл белән яхшы ише бер ефәк шәл* [*бирәчәкләр*]. Г. Қамал.— *Барыбер һәйбәт ише прәннек аласыбыз бар.* Ф. Әмирхан.

3. Дус, иптәш, әшнә. *И дусларым, ишләрем, аерылгач ни ишләрмен?* Бәет.— *Кәрим инде берничә көннән бирле, кемне күрсә шуны сыйлап, үзенә ишләр дә җыя башлаган, ди.* Г. Қамал.

4. Бер үк материалдан эшләнгән, бер үк сыйфатлы, бер үк төрдәге икенче әйбер. *Бер иш тукыма. Әллә* □ *энҗе, якут, әллә башка?— Тезелеп төшкән тешләр бер иштән!* Ш. Бабич. // Шул ук төр материал (тукыма мех һ. б. ш.). *Аклы ситсы күлмәгемнең Таба алмадым ишләрен.* Җыр.— *Сугышка киткәндә әнкәмнең төсе итеп үзем белән аның күлмәк ишен алган идем мин.* Г. Галиев.

5. *бәйл. функ. тарт. форм.* **ише.** Қебек, шикелле, сыман. *Гомеремдә моның ише осталыкны, хәйләкәрлекне күргәнем дә юк иде.* Г. Минский.— *Синең ише егетләр уллы-кызлы булып беттеләр инде.* Г. Ибраһимов.

Иш итү — 1) тиңләү, тиң итү. [*Туган җирем*] *Көчле иткән мине, эшле иткән, Көрәш ирләренә иш иткән.* Ә. Еникәй; 2) якын итү, үз күрү, үз тиңе итеп карау.— *Кермәдең инде, әʔ Иш итмәвең инде бу синең, кодача, якын итмәвең.* Г. Бәширов. **Иш килү** — 1) бер-беренә охшау, бердәй, тиң булу; 2) *к.* пар килү.

◇ **Иш белән куш** — *к.* Ишәй белән Қушай. **Иш ише белән** — экономик, социаль яки рухи яктан бер-беренә охшаган кешеләрнең бердәм булулары, бер-берен якын күрүләре турында әйтелә. *«Иш ише белән», дигән шикелле, байлар бай белән аралашадыр, абыстай һәм башка бай хатыннары белән танышадыр.* Ш. Мөхәммәдев.— *«Иш ише белән», диләр, бер мулла гына түгел, алар компаниясе белән шулай.* Г. Толымбай. **Иш янына куш** — өстәмә булу, берсе өстенә икенчесе өстәлү турында әйтелә.— *Дөрес, әллә ни зур акча түгел инде ул түгелен, тик шулай да иш янына куш булып торганы яхшы аның.* И. Гази. *Иш янына куш дигәндәй, башка заводлардан куылган мастеровойлар да, - - - эш эзләп, - - - Ягоднаяга килеп ябырылалар.* Қ. Нәҗми. **Ишкә куймау** — санламау, санга сукмау. *Син, Чемберлен агай, карап торам, Безнең ишне ишкә куймыйсың.* Һ. Такташ.

ИШАН *и. дини.* 1. Үз тирәсенә мөритләр җыеп, алар белән рухани житәкчелек иткән диндар, изге саналган кеше. *Мондагы шәкертләрнең бөтенесе ишанга мөрит булып,* [*суфыйлык*] *юлына кереп, тәсбих тартып йөриләр, укудан бигрәк, тизрәк ишан булуны күз алдында тоталар.* М. Гафури.— *Миндә ишан өшкергән тоз бар, шуны изеп эч, йөрәгең басылып китәр.* Г. Қамал.

2. *күч.* Дөнья эше белән кызыксынмаучы, бик тәкъва кеше. *Алар башта мине эчмәгән, тартмаган, карта уйнамаган өчен, бигрәк тә хатын-кызга карамаган өчен «ишан» дип мыскыл итәләр иде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Ишанга кул бирү** — ишанның мөрите булу, аңа рухи яктан иярү. *Гайнулла хажи Қазанда тәкъвалык, суфыйлык илә атаклы булып, - - - Қазан тирәсендәге бер зур ишанга кул да биргән иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Мондагы халыкларның күбесе — ишанга кул биргән мөритләр.* Ә. Қамал. **Ишан таягы** — ишанлык билгесе. **Ишан хилкасы** — мөритләрнең түгәрәкләнеп, ишанны уртага алып үткәрә торган дини мәҗлесе. *Мәдрәсә дип, нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе, Нәкъ эче азган мөрит,* [*акылдан язган*] *ишаннар хилкасы.* Г. Тукай.

ИШАНЛЫҚ *и.* Ишан булу, ишан дәрәҗәсе. *Ишанлык мәсьәләсе татар матбугатында бик күптәннән бирле язылып кил*[*ә*]. Ф. Әмирхан. *Төрле якларга йөри торгач, Бохарга барган ул, Шунда ишанлыкка дипломнар, билетлар алган ул.* Н. Думави.

Ишанлык итү (кылу) — ишан булып тору, мөритләр белән житәкчелек итү. *Монда кайткач инде* [*ул*] *Ишанлык итәргә башлаган.* Н. Думави. [*Аның максаты*] — *мөдәррис булып, ишанлык кылып, байларны кулга алып, барча муллалар вә мөдәррисләргә өстен булып, - - - гомерен рәхәт кичермәк.* З. Һади.

ИШАРӘ *и.* 1. Гадәттә кул, баш, йөз хәрәкәте белән теләкне, әмерне, ризалыкны яки кисәтүне белдерә торган билге, ым. *Бармак ишарәсе.* □ *Биктимернең күз ишарәсе белән бирелгән әмерен үтәп, җанлы курчак кара көч алдында тез чүкте.* Ф. Әмирхан. *Бернәрсә дә әйтмичә, баш ишарәсе белән генә үземнең дә чын ихластан аның сүзенә кул куйганлыгымны аңлаттым бугай.*

Ш. Камал. [*Алар*] *бер-берләре арасында ишарә белән сөйләшәләр.* Г. Колэхметов.

2. *күч.* Ачыктан-ачык, турыдан-туры әйтмичә, читләтеп сиздерү; киная. *Ит табакның төбендә генә калгач, - - - Җылкычы ата: «Булдым, биргәнеңә шөкер»,— дип, майлы кулларын итек кунычларына сөртә башлады. Башкалар да, туйганмы, юкмы, бу ишарәне аңладылар. Азаккы локманы зур, симез итеп йота-йота туктадылар.* Г. Ибраһимов.

3. *иск.* Билге, тамга. *Калынлык ишарәсе.*

Ишарә бармак — баш һәм урта бармаклар арасындагы икенче бармак; имән бармак. [*Күрәзәче*], *ханга телен чыгарып, ишарә бармагын куеп, монда җитди кисәтү барын белдерә.* Н. Исәнбәт.— *Менә!— диде Ифрат, ишарә бармагын күтәреп.* А. Расих. **Ишарә итү (кылу)** — 1) баш, кул хәрәкәте белән берәр нәрсә эшләргә кушу. *Гатау Гәрәйгә калырга ишарә итә.* М. Фәйзи. *Таһир ишарә кыла, шул вакыт гаскәр марш уйный башлый.* Ф. Бурнаш; 2) күрсәтү, ымлау. *Бер кабер ярылды да бер кеше атылып чыкты. - - - [Ул], кулы белән сыер хуҗасына ишарә итеп: «Менә бу кеше мине үтергән иде», - - - диде.* Г. Тукай. *Аның бер кулы күтәрелде дә әүвәл теге мәеткә таба ишарә кылды.* Г. Ибраһимов; 3) *күч.* ачыктан-ачык, турыдан-туры әйтмичә, читләтеп сиздерү. **Ишарә сәламе** — кулны күкрәккә куеп яки башны иеп, яисә бер кулны күтәреп, сүзсез генә сәламләү. *Ожмах хуры кебек өч кыз бала - - - миңа таба күз сала. Шуннан кулымны күкрәгемә куеп ишарә сәламе бирдем.* Т. Гыйззәт.

ИШАРӘЛЕ *с.* Нәрсәгә дә булса ишарә ясаган, кинаяле, читләтеп әйтелгән. *Бер генә булса да ишарәле сүз көткән иде ул...* Ш. Маннур.

ИШАРӘЛӘҮ *ф.* **1.** Гадәттә кулны, башны хәрәкәтләндереп, нәрсәгә дә булса күрсәтү.— *Ә бу иптәшләр,— Низамый бу урында куллары белән ишарәләп Зояның күзләренә карады.— Менә бусы — безнең авыл егете Ильяс, ә бусы — - - - Гаяз иптәш.* М. Әмир. *Ул әле миңа, әле Уфа егетенә карап торгач, кулы белән миңа ишарәләде.* Г. Минский. // Ым белән нәрсә дә булса эшләргә кушу яки ризалык белдерү. [*Хәлим*] *җырламаска ишарәләп кулын күтәрде.* Г. Гобәй. *Ул, бармагы белән ишарәләп, хатынын янына чакырып алды.* Г. Әпсәләмов. // Ымлау, әйтергә теләгәнне ым белән белдерү. *Ишарәләп тоз сорады ул. Тегеләр бик тиз аңладылар.* И. Гази. *Каюм нидер әйтеп, көләргә дип авызын ачкан иде, Хәлим, ишарәләп, аны тыеп калды.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Берәр нәрсә эшләргә кирәклекне турыдан-туры түгел, бәлки читләтеп, кинаяләп әйтү. *Мәхмүт писарьга коры кул белән барырга ярамаганлыкны шактый ачык итеп ишарәләде. Әйе, бирергә кирәклеге ачык, анысын яхшы төшенде Габдулла абзый.* Ф. Хөсни.

ИШАРӘТ *и.* **1.** Ым, мимика. *Ул бу ишарәт белән үзенең максутын аңлатмакчы була иде.* М. Гафури. *Аңлаганга — ишарәт, аңламаганга бишәр әйт.* Мәкаль.

2. Берәр нәрсә эшләнәчәге, эшләнергә тиешлеге турында билге, сигнал.— *Кәккүк тавышы, - - - бу — безгә ишарәт. Таралыштык.* Н. Исәнбәт. *Менә козгын да кычкырды. Бары да — хәерсезлеккә ишарәт.* Г. Тукай.

3. Тамга, билге. *Боларны аеру өчен бу бүлекләрдә миңа озын сызык, кыска сызык, бер нокта кебек ишарәтләр кулланырга туры килде.* М. Фәйзи.

4. *күч.* Эз, галәмәт, әсәр. *Уфага килеп җиткәнче җан ишарәте очратмадык.* С. Кудаш.

5. *күч.* Бер генә дә, аз гына да, бөтенләй. *Бәкедә ишарәт су юк.*

Ишарәт бармагы — *к.* ишарә бармак. *Бер карт, иптәшемә таба борылды да, ишарәт бармагын бутап: «Гайнетдингә әйтергә кирәк»,— диде.* Ш. Камал. **Ишарәт итү (кылу)** — *к.* ишарә итү. *Сафый күзе белән Рокыяга ишарәт итә.* Ф. Әмирхан. *Фәссах кат-кат сораса да, Габдерәкыйп хәзрәт җавап бирмәде, ягъни: «Чыкмасаң чыкма»,— дип ишарәт итте.* Г. Тукай.

◇ **Ишарәтен китерү** — бөтен таләпләрен төгәл үтәү; җиренә җиткерү.— *Усентеләрне шул әйткән чүлмәкләргә утырткан идем... Күрәсең, ишарәтен китереп җиткерә алмаганмын,* [*үлделәр*]. Г. Насрый.

ИШГАЛЬ: ишгаль итү (кылу) *иск. кит.* — 1) кешенең күңелен берәр эш яки күренеш белән, аңгәмә белән биләү, мәшгуль итү. *Бу гаиләдә кешенең зиһен вә фикерен ишгаль итәрлек бернәрсә дә юк иде.* Ш. Камал. *Аның күзе җанлы әйберләр күрә, шулар аз булса да аны ишгаль кылалар.* Г. Ибраһимов; 2) (урын) алу, (урын) биләү. *Ул товар тиз бозылмый да һәм күп урын да ишгаль итми.* Г. Тукай. *Безнең татарыбыз класс тәрәзәсе янында күптән бер урын ишгаль итеп өлгергән.* Ф. Әмирхан.

ИШЕ'ГАЛ *и. сөйл. к.* ишек алды. [*Кешеләр*] *елмаешып капка ачтылар, йөгәненнән тотып атны ишегалга алып керделәр.* Н. Фәттах. [*Сәләхетдин абзый*] *безне ишегалларына - - - алып керә.* Г. Гобәй.

ИШЕ'ГАЛДЫ *и. сөйл. к.* ишек алды. *Күк «Волга»ны - - - ишегалды уртасына, нәкъ юл өстенә китереп куйганнар.* М. Маликова. *Институт ишегалдындагы мәйданда гына арлы-бирле атладык.* И. Салахов.

ИШЕК *и.* **1.** Бина, бүлмә яки башка корылманың стенасына кереп-чыгып йөрер өчен ясалган уем һәм шул уемга беркетелгән ачылмалы-ябылмалы капкач, каплавыч. *Агач ишек. Тимер ишек. Ишек шаку. Ишек дөбердәтү. Ишектән керү (чыгу). Ишек тоткасы (келәсе, элгече). Бүлмә ишеге. Абзар ишеге. Өй ишеге. Ян ишек. Арткы ишек.* □ *Ишек ачылды һәм - - - бер яшь егет килеп керде.* Ә. Еники. *Түрдә ике якка ачылмалы бер ишек — икенче бүлмәгә чыга.* М. Фәйзи. *Газинур чатырның асылма ишеген кайтарып керә.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч. шигъ.* Бәхеткә, азатлыкка, рәхәт тормышка, белемгә һ. б. ш. илтә торган яки эчке серләрне белергә мөмкинлек бирә торган юл, ачкыч. *Ожмах ишеге.* □ *Аның алдында тагын дөньяның бәхет ишекләре ачылды. - - - Садыйктан, аның Садыйккаеннан кечкенә генә хат бар.* Г. Ибраһимов. *Укый-яза белү - - - — Аң-белемгә таба ишек ачып, Яктылыкка барган туры юл.* М. Гафури.— *Нигә син минем йөрәк хәзинәмнең барлык яшерен ишекләрен ачасың?* Р. Ишморат.

Ишек алды — өй янында койма һәм каралты-кура стеналары белән әйләндереп алынган җир, терлекләр, хуҗалык әйберләре өчен буш урын. [*Терлекләр*] *имениенең таш койма белән уратып алынган ишек алдына тупланган иде.* А. Шамов. *Гыйрфан байның зур капкаларын ачтырып, ике ягы яшел түбәле келәтләр, лабазлар, складлар белән әйләндерелгән киң ишек алдына барып кер[дек].* Г. Ибраһимов. **Ишек бавы** — 1) ишекне тартып ачар өчен куелган каеш, агач яки тимер тотка; ишек тоткасы. *Кияү ишек бавын тартып җибәрде.* Г. Ибраһимов. *Хәлим, бишмәтен, бүреген, бияләйләрен киеп, ишек бавына тотынгач, анасы: - - - «Бар, озак йөрмә»,— [диде].* И. Гази; 2) *этн.* кыз куенына керергә килгән кияү тарафыннан кыз бүлмәсенең ишеген ачучыга бирелә торган акча. *Кыз яныңа керәсе кияүне ишек төбендә балалар туктатып акча сорыйлар. Балаларга акча бирмәсәләр, ишек ачылмыйдыр: - - - «Ишек бавы бер алтын, Безнең апай мең алтын; Җылыныйм дисәң, бер алтын Бир, жизни, тыш бик салкын.* Г. Тукай. **Ишек бавын тоту (басу)** *этн.*— кыз куенына керергә килгән кияүдән акча алу өчен, балаларның кыз өе ишеге төбендә саклап басып торулары. *Без, дүрт кияү егете, кияүне алып кердек. Ишек бавын тотучы малайларга акча чәчеп җибәргән идек, ишек саксыз калды. Эчкә кердек.* М. Фәйзи. *Кияү өчен хәзерләнгән кыз бүлмәсенең ишеге төбендә бер-ике бала тора. Бу балалар монда тормакны ишек бавы басмак дип әйтәләр. Кияү булып*

килгән егет ул балаларга акча бирә. К. Насыйри. **Ишек башы** — ишек яңакларын өске яктан тоташтырган агач һәм аның өстенә сугылган юка тар такта. [*Ул*], *ишек башына бәрелүдән курыккандай, кирәгеннән артыграк иелә төшеп, чыгып китте.* М. Хәсәнов. *Сабир бабай ишек башына кыстырып куелган боргычны, сузылып алып, Газинурга тапшырды.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Ишек ачу** — кемгә дә булса керү, якыннан катнашып, аралашып йөрү турында.— *Гайшә инде безнең кебек ялгыз-ябаганың ишеген ачарга теләмәс.* Ф. Бурнаш. **Ишек ачык** — 1) һәрвакыт зур теләк, якты йөз белән кабул итүне аңлатканда әйтелә.— *Мал булса, кая барсаң — ишек ачык.* М. Гафури. — *Син чакырсаң, синдә дә бер төн кунып чыга алам.— Синең өчен ишегем һәрвакыт ачык.* И. Гази; 2) теләсә кая барырга, керергә, теләсә нәрсә эшләргә мөмкинлек, ирек булуны аңлата. *Һәммә җирдә безгә ишек ачык, «Доклад белән» керү үтенелми.* М. Җәлил; 3) кешене көчләп тотмау, теләгә булса, ташлап чыгып китәргә ихтыярлы булуына кинаят.— *Кем дә кем мәдрәсәнең уставына, программына, идарәнең карарына риза түгел икән — ишекләр ачык, үз юлын үзе карасын.* Г. Ибраһимов. **Ишек кагу (шакыу)** — 1) берәр кеше янына йомыш, үтенеч белән килү. *Гали баба бу юлы да иң элек Мәхүбә карчыкның ишеген какты. - - - Читеңсенеп кенә каршы алды Мәхүбә карчык.* Ф. Хөсни; 2) берәр нәрсә белергә теләп мөрәҗәгать итү. *Әдәби образлар ничек туалар? - - -Моңысы инде язучының иҗат лабораториясенең ишеген кагу була.* Г. Әпсәләмов; 3) берәр нәрсә яки күренеш якынлашу, килеп җитү, үзе турында белдерү. *Матур нурлар, язгы җилләр Яз ишеген килеп какты лар.* Ә. Еникәй. *Хисам Камалов, - - -Зәет Мәҗитов иптәшләр үзләренең беренче китаплары белән әдәбият ишеген кыю шакыдылар.* Сов. әд. **Ишек тупсасын төшерү** *сөйл.*— кая да булса еш килеп йөрү. [*Рәмзия*] *аларның ишек тупсаларын төшереп бетерде, әмма бер эш тә чыгара алмады*]. Г. Гобәй. **Ишеккә бару (килү)** — кемгә дә булса берәр төрле йомыш белән мөрәҗәгать итү; йомыш төшү. *Башка кешегә сатар иде, кирәк вакытта аның ишегенә барып булмас дип курка Сәмигыл карт.* М. Гали. [*Сәрбиҗамал:*] *Минем ишеккә кем килсен?* [*Мөгълифә:*] *Һи, синең шикелле чибәр кызлар янына кемнәр килмәс?* Г. Камал. **Ишеккә ишек** — кара-каршы яки янәшә (берберенә кара-каршы яки янәшә ясалган керү-чыгу урыннары турында). **Ишеккә күрсәтү** — кемнең дә булса чыгып китүен таләп итү. **Ишекнең кайсы якка ачылганын белү** *сөйл.*— кемнең дә булса өендә моңарчы да булганлыкны аңлата.— *Ерак юлдан килгән кунакны - - - миңа алып килергә кирәк иде. Аллага шөкер, ишекнең кай якка ачылганын беләсең.* А. Шамов. **Ишекнең кай якка ачылуын оныту** — берәр кешенең өенә йөрми, бармый башлау яки озак бармый тору. *Хәдичә кунакка чыгып китәргә кушты: «Хәзергә, Мисбах дус, минем ишекнең кай якка ачылганын онытып тор».* М. Хәсәнов. **Ишек төбеннән бору** — йомышны үтәми яки кунак итми, өйгә кертми кайтарып җибәрү. [*Карт*] *өч тапкыр бара, ә алар аны, алдалап, ишек төбеннән борып җибәрәләр.* Г. Әпсәләмов. **Ишектән куганда тәрәзәдән (тишектән) керү** — 1) әрсез кеше турында әйтелә; 2) бәла-каза турында.

ИШЕКЛЕ-ТҮРЛЕ *рәв.* Бер ишеккә, бер түргә таба, арлы-бирле. *Әти кеше ни дип әйтергә дә белмичә һәм ачуын баса алмыйча ишекле-түрле йөри башлаган.* Г. Минский. *Ишектән кеше өзелми, салкын бертуктаусыз ишекле-түрле уйнап кына тора.* Ә. Камал.

ИШЕКЧЕ *и. иск.* Швейцар.

ИШЕКЧӘ *и.* **1.** Ике якка ачыла торган ишекнең бер ягы. *Киштәләрнең бер генә як ишекчәсе ачылган чагында - - - анда күп нәрсә күреп булмый.* Ш. Камал.

2. Мич, плитә авызының кечкенә ишеге. *Карт та плитә ишекчәсе каршындагы бүкән өстеннән ашыкмый гына торды.* Ә. Айдар.

ИШЕЛҮ I *ф.* **1.** Оешкан яки корылган нәрсә таркалып җимерелү, аву. *Тау ишелү. Түшәм ишелү. Яр ишелү. Кибән ишелү.* □ *Иптәшләре үлә берәмберәм, Ташлар басып, туфрак ишелеп.* М. Гафури. *Кар ул хәтле җепшек түгел. Өеп бетерүгә яңадан ишелә.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Өстән күп булып таралып төшү (чәч турында). [*Ул*] *кап-кара кашлары өстенә ишелеп торган чемкара һәм куе чәчен бармак очлары белән колак артына сыпыр*[*ган*]. Г. Бәширов.

3. *күч.* Алга таба авышу, янтаю, бөкрәю. *Элек аны атасы бик ачуы килгәндә: «Тасламаган агач, килбәтсез өрәк»,— дип тирги иде. - - - Алга табан ишелеп йөргән гәүдәсе - - - чынлап та шундый кушаматларга урын калдыра иде.* Г. Толымбай.

4. *рәв. мәгъ. күч.* **ишелеп.** Бик яхшы, мул, куе булып. *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булганнар.* Г. Бәширов. *Ишелеп үскән куе үләнне кистереп, саф һавада чалгы тавышы көенә күкрәкләрне киереп, дәртләнеп җырлап йөрү - - - рәхәтлек бирә җанга.* М. Фәйзи. // Бик күп булып, берсе өстенә икенчесе өелеп (гадәттә болытлар, төтен, боз, дулкын турында). *Кар ишелеп ява.* Х. Кәрим. *Ферма алачыгының моржасыннан ишелеп-ишелеп куе төтен чыга.* Ә. Еники.

ИШЕЛҮ II *ф. Төш. юн.* **1.** *к. ишү* II. *Ат куа торган я билгеле бер хезмәткә яраштырып түгел, болай, ишәсе килеп ишелгән чыбыркылар* [*болар*]. Ә. Фәйзи.

2. *күч.* Боргалану. *Кыз, елан төсле ишелеп, аның култык астыннан үтеп: «Ярамый, егет!..»— дип, яшен төсле, ишеккә юнәлде.* К. Тинчурин. *Бер кара елан, авызыннан селәгәйләр агызып, ишелеп-ишелеп* [*кош балаларын*] *ашарга үрмәли.* Аң.

3. *күч.* Сарылу, назланып сыену. *Егет кызга кушылды, ефәк булып ишелде.* М. Фәйзи.

ИШЕМ *и.* Көчле су агымы, көчле су ташкыны.— *Сез текә борылышларны истә тота торгансыздыр. Су ишеме кәрванны ярга бәрсә, буксирның аны сөйрәргә көче җитмәс, дисез.* Г. Әпсәләмов, С. Сабиров. *Агым буйлап йөзгәндә, текә борылышларда агым ишеме баржаларны ярга китереп бәрә.* Г. Иделле.

ИШЕРЕЛҮ *ф. диал.* Күп булып, өем-өем булып, бер-бер артлы, берсе өстенә берсе менеп, бер юнәлешкә авышу, ташкын булып килү. *Ап-ак матур болытлар күгелҗем карага әйләнеп, җил белән Идел өстенә таба ишерелеп-ишерелеп актарылдылар.* Г. Ибраһимов.

ИШЕРӘМ *и. диал.* **1.** Ашлыкны җилгәргәндә аерылган кибәк, башак кисәкләре, кылчык катнаш масса.

2. Саламны, башакны вак итеп турап, кайнар су һәм он белән болгатып бирелә торган хайван азыгы.

ИШЕРҮ *ф. диал. к.* ишү I. *Баздан чыккан да Самат Ярны тибеп ишергән, Җимереп балчык төшергән.* Н. Исәнбәт.

ИШЕТЕЛЕР-ИШЕТЕЛМӘС *рәв.* Чак-чак кына ишетелерлек итеп. [*Захаров*] *ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады: «Атлар - - - уң якта».* А. Шамов. / *с. мәгъ. Апа аңа ишетелер-ишетелмәс басынкы тавыш белән җавап кайтарды.* К. Нәҗми.

ИШЕТЕЛЕШ *и. махс.* Ишетелү дәрәҗәсе, ишетелү ачыклыгы.

ИШЕТЕЛҮ *ф.* **1.** Тавыш дулкыннары килеп җитеп, ишетү органына тәэсир итү. *Шул секундта ук тагын бер «ура» тавышы ишетелде.* А. Шамов.

2. Берәр эш-хәл яки хәбәр кешеләр аркылы башка урында мәгълүм булу. *Бу сүз Йосыфҗан аркылы Фәхригә, аннан Габдерахманга, аңардан Тангатаров, Нигъмәт казыйларга барып ишетелде.* Г. Ибраһимов. *Чып-*

чык, Балавыз урманнарында: --- «Фәлән байны талаганнар»,— дигән хәбәрләр атна саен ишетелә. Г. Тукай.

ИШЕТЕШ *и.* Музыкаль аваазларны дөрес итеп ишетә һәм кабатлый алу сәләте. *Музыкаль ишетеш.*

ИШЕТКӘН-БЕЛГӘН *с.* Ишетеп, күреп белгән, билгеле булган; таныш.— *Нинди Разин? Нинди алты йөз сум ул? Ишеткән-белгән нәрсәм түгел.* Г. Ибраһимов. *Кирәк булмас микән безгә Бер җырлап алырга, Ишеткәнне-белгәннәрне Бер көйгә салырга?* Ә. Исхак.

ИШЕТТЕРҮ *ф.* **1.** *к.* ишетелү 1. [*Ул*] *авылга ишетерлек итеп кычкырып, шаулап сөйләнде.* Г. Ахунов.

2. Кеше аркылы гадәттә начар сүз яки хәбәр җиткерү. *Хатын-кыз аркылы Маликка сүз ишеттерделәр.* И. Гази.

ИШЕТҮ *ф.* **1.** Төрле аваазларны, тавышны колак белән сизү, кабул итү.— *Саңгырау түгел лә* [*мин*], *ишетмәскә.* Ш. Камал. *Алар үз артларында тоташ, каты бер гөрелдәү ишеттеләр.* Ә. Еники.

2. *с. мәгъ.* Тыңлау, тавышны кабул итү өчен хезмәт итә торган. *Ишетү органы.* □ [*Соломон*] *тиз генә ишетү аппараты куелган хикмәтле күзлеген киеп алды.* А. Расих.

3. Берәр хәбәрне икенче бер кеше аркылы белү. [*Мостафа*] *бу тегүченең авырып егылганын ишеткән иде.* Г. Ибраһимов. *Шул ук яралыдан без тагын бер хәбәр ишеттек: безнең бригада бөтенләй башка төбәккә киткән.* К. Нәҗми. // *боер. ф. форм.* **ишет(егез).** *к.* ишетсен колагың.— *Ишетегез аны: сезнең өчен начальство кызарырлык булмасын!* Ә. Исхак.

4. Тыңлау, игътибарга алу.— *Менә ишет әле, Зәки абыең нәрсәләр ди.* Ф. Әмирхан. *Исмәгыйль абзый минем сүзне ишетергә дә теләмәде.* Ф. Хөсни.

◇ **Ишетсен колагың** — берәр нәрсәне эшләгәндә игътибарсыз булмаска, онытмаска кисәтү ясаганда әйтелә.— *Ишетсен колагың, өенә кайтмыйча ачып карыйсы булма.* А. Әхмәт.— *Әгәр начар укып, имтихан бирмәсәң, колхоз ясаган чыгымнарын синең үзеңнән кайтарып алачак, ишетсен шуны колагың!* Ә. Айдар.

И'ШИАС *и. мед.* Утракса нервлары ялкынсыну (авыру).

ИШКЕЧ *с.* Ишә торган. *Ишкеч тәгәрмәчләр. Ишкеч винт.* □ — *Йөзгәләкнең --- ишкеч аякларын төкләр каплаган.* Г. Хәсәнов. // *и. мәгъ.* Машина яки башка берәр нәрсәнең ишә торган өлеше.

ИШ-КҮШ *җыйл. и.* Үз тиңнәре, үз ишләре. *Өченче класстагы сәүдәгәрләр, иш-кушы белән табышып, танышып алгач, беренче эш итереп чәй эчәргә керешәләр.* И. Рәмиев.

ИШҚӘГАЯҚЛЫЛАР *и. зоол.* Очлыклары ишкәккә охшаган имезүче диңгез хайваннары (мәс., тюлень, морж, су арысланы һ. б.) төркеме; *русчасы:* ластоногие. *Ишкәяклылар һәм китсыманнар отрядлары.*

ИШҚӘК *и.* **1.** Бер башы яссы итеп юнылган һәм көймәне хәрәкәткә китерү өчен файдаланыла торган зур калак. [*Мәрдән абзый*] *көймәсен этеп җибәрде дә, сикереп кереп, тиз генә ишкәкләрен киертте һәм шаулап килгән ак башлы дулкыннарга каршы каерып-каерып ишә башлады.* Г. Гобәй. [*Мостафа*], *тәртә кебек йомры саплы ишкәкләрне су төбенә җиткерергә теләгән кебек, текә батырып ишүендә дәвам итә.* К. Нәҗми.

2. *зоол.* Морж, тюлень кебек диңгез хайваннарының йөзгече. *Тюленьнәрнең очлыклары ишкәкләргә әйләнү.*

ИШҚӘКЧЕ *и.* Ишкәкләр ярдәмендә көймәне хәрәкәткә китерүче кеше. *Ишкәкчеләр каерылып селтәнделәр. Көймәләр бөтен тизлекләрендә пароходка таба ыргылдылар.* Г. Әпсәләмов. *Мәдинә әйбәт ишкәкче иде. Хәбир, аның каерылып-каерылып ишкәк ишүдән алсуланган йөзенә карап, бар дөньясын онытты.* Ш. Хөсәенов.

ИШЛЕ *с.* Сан ягыннан күп, зур. *Ишле семья.* □ — *Без бик ишле. Бер очканда йөзәрләп-йөзәрләп, хәтта меңәрләп очабыз.* Г. Галиев.— *Бала-чага ишле, өйләндереп башка чыгарасы тагын дүрт малай бар.* Г. Бәширов.

ИШЛЕЛЕК *и.* Ишле булу. *Күк йөзенә таралышкан йолдызларның ишлелегенә сокланып шактый озак бардылар алар.* А. Гыйләҗев.

ИШЛӘҮ *ф.* Шул ук төрдәге материя кушу. *Ишләп тегү.*

ИШМӘ *и. бор.* Тимер яки бакыр чыбыкка көмеш җепләр урап ясалган беләзек. [*Мишәр*] *кызлары вә хатыннары гомумән кулларына беләзек вә ишмә кияләр.* З. Бәшири.

ИШСЕЗ *с.* Ише булмаган, пары булмаган, сыңар. [*Ул*], *карсак буйлы булганлыктан, стройга тезелгән саен иң кырыйга ишсез номер булып бас*[*а*]. К. Нәҗми.

ИШСЕНҮ *ф.* Якын күрү, иш күрү, иш итү.

ИШТИРАҚ *и. иск. кит.* Катнашу, кушылу, булышу; бергәләп эшләү. *Мусин җәнаплары беркөнне миңа «Сак-сок» бәетен язып китерде. - - - Бу иштиракы өчен - - - Мусин җәнапларына* [*рәхмәт*]. Г. Тукай.

Иштирак итү — 1) катнашу.— [*Җыелышта*] *хатын-кызлар иштирак итә алмыйлар.* С. Кудаш; 2) кушылу, уртаклашу.— *Сезнең кайсыларыгыз Гаптелкаюм фикеренә иштирак итә?* К. Тинчурин. *Кардәш-ырулар безнең кайгыбызга иштирак иттеләр.* М. Гафури.

ИШТИҺА *и. иск. кит.* **1.** Табигый ихтыяҗны үтәү теләге. *Хайваннык иштиһасы күп булса да, Инсанлык* [*кушуы*] *аны баскан.* Н. Думави. [*Ул*] *гомеренең нәфес вә иштиһа илә кайнарлык дәвере булганына карамыйча, үзе суфый вә тәкъва иде.* Г. Ибраһимов.

2. Аппетит, ашау-эчү теләге. *Бүген хәзрәтнең иштиһасы азрак булырга кирәк: берничә тарелка кабартма бушагач һәм самоварның да суы бетеп, --- акмый башлаганны күргәч: --- «Җитәр инде»,—* [*диде*]. Ш. Мөхәммәдев. *Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, бик шәп бер иштиһа илә икмәк белән катыкны ялт иттердем.* Г. Тукай.

ИШТӘ *алм. иск. кит.* Менә. *Иштә шул адәмләр эчендә сез, шәкертләр дә, бар идегез.* РСДРП прокламациясе. *Зыяның ул дөньядан, ул фонарьлы йортлардан җаны вә йөрәге белән чиркануы — иштә башлыча шул табигатенең тәэсиреннән иде.* Г. Ибраһимов.

ИШТӘШ *с.* Бер иштән, бер төрдән булган. *Иштәш тукыма.*

ИШТӘШЛЕК *и.* Иштәш булу хәле. *Ул сүз, үз аваз-ларының көче белән каршы яктагы берничә сүзне дә үз рифмасына буйсындырып, --- аваз ымлыгы иштәшлеге (интонацион симметрия) китереп чыгара.* Н. Исәнбәт.

ИШӘЙ: Ишәй белән Кушай — һәрвакыт бергә булучы, бер-береннән беркайда да аерылмый йөрүче кешеләр турында. *Ике ел эчендә без, аның белән икебез, бер кеше төсле яшәдек. «Ишәй белән Кушай» дип бездән көләләр, берәр җирдә ялгызыбызны гына очратсалар: «Кушаең кайда?» — дип сорамыйча булдыра алмыйлар иде.* М. Әмир. *Берничә хатын, Котдус белән Шәрипнең колхоз дворына ат кууларын күреп: «Ишәй белән Кушай яңа тормышка киттеләр. Болар кая барса — бергә, тач игезәкләр инде»,—* [*диләр*]. С. Рафиков.

ИШӘК *и.* **1.** Атлар токымыннан булган, гадәттә сары төстәге, зур авызлы, озын колаклы, кечерәк гәүдәле, аркасына йөк салып ташу өчен асрала торган хайван. *Колаклары чабата чаклы булыр, бик зур бер ишәк килеп керде.* Г. Тукай. *Шәһәрнең әле бер ягыннан, әле икенче тарафыннан бик ямьсез ачы-ачы бакырган ишәк тавышлары да ара-тирә ишетелә.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *күч. гади с.* Аңгыра, ахмак, булдыксыз кеше турында.— *Без әле, карт ишәкләр, кайда нинди зат нәр-*

сә әрәм булып ятканны белмичә йөргән булыр идек, ә син менә тапкансың. Ф. Хөсни.— *Син егет булсаң, [кызның башын] ничек әйләндерим дип атасыннан сорама. - - - Ишәк!* М. Гафури.

3. *күч. гади с.* Кире, үҗәт, авыр холыклы кеше турында.

Ишәк колагы *бот.— к.* испәрәк. **Ишәк колак** — 1) *бот.* дымлы болыннарда, иңкүлекләрдә, канау-чокырда, яр буйларында үсә торган зур яфраклы һәм чәчәкле көпшә сыман үлән; *русчасы:* окопник; *2) күч. гади с. тирг.* аңгыра, ахмак кеше.— *Их, ишәк колак! Тавык тәпиенең ни кирәге бар?* Ш. Камал. **Ишәк миләүшәсе** *бот.*— оешма чәчәкләләр семьялыгыннан кыска сабаклы, чәчәгенең кырыйлары ак, ал яки кызыл, ә уртасы ак булган бакча үсемлеге; *русчасы:* маргаритка.

◇ **Ишәк сугару** — вакытны заяга уздыру, бер файдасызга, юк-бар белән йөрү.— *Алыпкулов! Кайда ишәк сугара ул?* Ш. Маннур.— *Бозау! Ачуым да килмәгәе, Лаля белән йөридер дип юанып торсам, ул анда ишәк сугарып йөри.* М. Фәйзи. **Ишәк төчкергәндә туу** — бәхетле булып туу турында.— *Безгә алла дәүләтен яудырып кына тора шул. Без, карчык, ишәк төчкергәндә туганбыздыр.* Д. Аппакова.

ИШӘКЛЕК *и.* Кирелек, үҗәтлек. *Ишәк ишәклегенә барыр.* Мәкаль. *Ишәк янына атны бәйләсәң, ишәклеге йогар.* Мәкаль.

Ишәклек итү — киреләнү, үҗәтлек күрсәтү.— *Беләм нахаклыгымны, - - - итәм ишәклегемне.* Г. Тукай.

ИШӘЮ *ф.* Күбәю, үрчү; күләм яки сан ягыннан арту, үсү, зураю.— *Терлек дигән нәрсә ул — җан иясе, һаман үрчүгә, ишәюгә омтыла бит ул.* Ә. Еники. *Семья да бик ишәеп китте.* М. Гали.

ИШҮ I *ф.* **1.** Өелеп, оешып торган яки корылган нәрсәләрне җимерү, аудару.— *Коймабызны җимергәннәр, базны ишкәннәр.* А. Алиш.— *Мичләрен дә иштек, казанын да ваттык.* А. Шамов.

2. *рәв. мәгъ.* **ишеп.** Күп булып, оеш-оеш булып. *Яңгыр ишеп яву.* □ *Төнлә ишеп кар яуган, җир өсте ап-ак иде.* Х. Сарьян.

3. *күч. мыск.* Билгеле бер эшкә тотынып та аны башкарып чыкмау, эшне бозу, юкка чыгару.— *Иштегез, бу юлы, өләшкән булып, җыен дублитны миңа тутыргансыз!* Г. Камал. *Разведчикларның берничәсе берьюлы: «Ишкәнсең инде... кулын тоткан, имеш!» — дип, үзләренең ризасызлыкларын белдереп куйдылар.* А. Әхмәт. // Бернәрсә дә эшли алмау, бернинди эш тә чыгара алмау.— *Теге елларны авылда калсак, ишәр идең инде.* Р. Төхфәтуллин.

4. *күч. гади с.* Кыйнау.— *Эх, шул чакны [имчене] пумала белән генә ишеп чыгарган булсам ла.* Ш. Мәдәррис.

ИШҮ II *ф.* Бауны, җепне яки җеп сыман нәрсәне ныклык өчен берничә катлы итеп үрү. *Аркан ишү.* □ *Вәли бабай ишеп биргән чыбыркымны өстерә[дем].* Г. Толымбай. *Кыяларга менү өчен җеп баскычлар иштек.* И. Гази.

◇ **Ишкәнсең (яки иштең) ишәк чумарын (яки ишек бавын)** *сөйл.* — 1) күп тырышып та рәтле бернәрсә эшли алмау, бернәрсә чыгара алмау. [*Хатыны*] *әйткән: «Урып урмадым, карап тормадым, торып торна санамадым, як-ягыма каранмадым, өчәр көлтәдән өч өем көлтә урдым». Ире моңа әйткән: «Һи, ишкәнсең икән ишәк чумарын!» — дигән.* Мәзәк; 2) эшне аңламый бозу, таркату (булдыксыз кеше турында әйтелә). [*Биби:*] *«Вәли җизниләр киатрга китмәделәр, кодаларга киттеләр»,— диярмен.* [*Вәли, ачуланып:*] *Иштең ишәк чумарын! Ә мин сиңа алай дип әйттеммени?* Г. Камал.— *Әй әти, әти... Ишкәнсең икән ишек бавын. - - - Ул синнән кунып чыгарга өй сораган, ә син аңа, күз ташың чыкканмы әллә, дип җавап биргәнсең.* Н. Исәнбәт.

ИШҮ III *ф.* **1.** Көймәне хәрәкәткә китерү өчен ишкәк белән этәрү. *Көймәче карт, кыска саплы ишкәген бер кулыннан икенче кулына күчергәләп, салмак кына ште дә ште.* Н. Фәттах. *Ул көймәне бору өчен ишкәкләрнең берсен алга, берсен артка шундый оста ште, көймә, зыр әйләнеп, борыны белән сыек томанны ертып китеп тә барды.* Г. Гобәй. // Аяк, тәпи яки берәр яссы нәрсә белән суда гәүдәне хәрәкәткә китерү (гадәттә кошларга карата әйтелә). [*Урдәк балалары*] *кечкенә генә тәпиләре белән ашыгыч ишә-ишә, мамык йонлы канатларын кага-кага чәчәк артыннан ташландылар.* А. Шамов.

2. *күч.* Тормыш агымы кеше теләмәгән якка алып китү. *Шулай, ләкин киребә ишсә язмыш, Үлеп китсә хатын, күп тормый яңлыш.* Г. Тукай.

ИЮ I *ф.* Гәүдәнең, агач кәүсәсенең яки үлән сабагының югары өлешен аска таба салындыру, бөгү (*сыйфат фигыль формасы* — **игән**). [*Сәхип*] *башын түбән иеп, җиргә карап үтте.* Ш. Камал. *Михаил, сының ия төшеп, Хәятка култыгын сонды.* Ф. Әмирхан. *Богдайларның барысы да башакларын җиргә карап игәннәр, арада берничәсе генә башларын югары күтәреп, теп-текә торалар.* Дәрдмәнд.

ИЮ II *ф.* Йомшару (тире яки күнел турында; *сыйфат фигыль формасы* — **иегән**). *Тире ию. Күнел ию.* □ *Студентка череп, иеп беткән - - - бер үләксә туный.* Ф. Әсгать.

ИЮЛЬ *и.* Календарь елының җиденче ае. *Июль [аеның] эсселегеннән һава тузан белән тула.* Г. Коләхметов. *Җәй айлары: июнь, июль, август.* Г. Тукай.

ИЮНЬ *и.* Календарь елының алтынчы ае. *Җиргә елның алтынчы ае — июнь килде.* Г. Галиев. *Июнь урталары якынлашып килгәндә, кояш өстенлек алды — менә дигән җәй кояшы!* М. Әмир.

ИЯ *и.* **1.** Берәр нәрсәнең, милекнең хуҗасы. *Машина иясе. Тавыш иясе. Итек иясе.* □ — *Бүген малаеңны алып киттеләр, иртәгә килеп, атыңа ия чыгар.* Ф. Хөсни. *Талаучылар ия булмас Совет җиренә.* Ә. Ерикәй. // Нәрсәнең дә булса башлыгы. *Власть иясе.* □ — *Бәлки, әле безнең кәрваннарны Дәүләт ияләре белмидер...* Ф. Бурнаш. *Ул үзенең үгылы Зыяны, - - - озакламый мәхәллә иясе булып, мөнбәр өстенә менәргә якын итеп хыяллый башлаган иде.* Г. Ибраһимов.

2. Нинди дә булса сыйфатка, сәләткә, дәрәҗәгә һ. б. ирешкән кеше. *Һөнәр иясе. Гыйлем иясе. Акыл иясе.* □ — *Габдулла әфәнде — чын талант иясе.* Ә. Фәйзи.— *Ул тик тыштан гади күренә, Чиксез галим, хикмәт иясе ул, Ия кеше атом серенә.* Н. Исәнбәт.— *Кешедән дә зиргәрәк, кешедән дә бөегрәк җан иясе юк бит инде дөньяда.* И. Гази. // Нәрсәгә дә булса (мәсәлән: хөрмәткә, игътибарга, әһәмияткә һ. б.) лаек. *Сөйләнгән вакыйгалар безнең революция мәмләкәтенең бөтен җирендә күреп үтелгән - - - күренешләрдән торганлыктан, [«Тирән тамырлар»] әсәре бу яктан интернациональ-революцион әһәмияткә ия.* Г. Нигъмәти.

3. Берәр эш белән шөгыльләнүче, көн күрүче кеше. *Революция җәелгән һәм күтәрелгән саен, эксплуататорлар һәм хезмәт ияләре арасындагы каршылык тирәнрәк ачылды.* М. Җәлил.— *Хөкем ияләре, минем фәкыйрьлегемне, картлыгымны уйлап, берьюлга кичерсәләр [иде]!* Г. Ибраһимов.

4. Уйлап чыгарган, язган яки әйткән кеше; автор. *Кулъязманың иясе аякка басты: «Мин Разия туташның сүзенә каршы»,—* [*диде*]. Г. Ибраһимов. *Сүз иясе белән йөрми.* Мәкаль.

5. Хорафатлар буенча: гүя суда, урманда, йортта, абзарда кешегә күренмичә яши торган һәм шуларның хуҗасы булып саналган мифик зат. *Абзар иясе. Урман иясе.* □ — [*Сыер*] *сөтен төннәрдә шайтаннар, йорт ияләре, шүрәлеләр вә һәм дә төрле-төрле гыйфрит һәм пәриләр савып эчәләр икән.* К. Тинчурин.

Киндерә ишеп торганда, күлдән бер су иясе чыкты. Әкият.

6. *иск. дини.* Тәнре, алла. [*Бирем әкә:*] *«Мин карт инде, ясаган иямнән әҗәл көтәм, миңа ике адымнан артык тупрак кирәкмәс»,—* [*диде*]. Г. Ибраһимов.

7. *лингв.* Җөмләдә бары тик баш килештә килә һәм хәбәр тарафыннан расланган яки аныкланган предметны яки билгене белдерә торган баш кисәк. *Җитмәсә, укытучы* [*җөмләдә*] *кайсы ия, кайсы хәбәр, иярчене кайсы дия башлар...* Г. Гобәй.

Ия җөмлә *лингв.*— баш җөмләдәге алмашлык белән белдерелгән ияне ачыклап килгән яки баш җөмләнең иясе урынына килә торган иярчен җөмлә (мәсәлән: *«Кем эшләми, шул ашамый»*). *Ия җөмлә баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, - - - «ки» теркәгече ярдәмендә бәйләнә.* М. Зәкиев.

ИЯК *и.* **1.** Кеше йөзенең аскы өлешендә аскы теш казналары урнашкан, ашаганда, сөйләгәндә хәрәкәтләнә торган ярымтүгәрәк чыгынты. [*Аның*] *чәче агарган, ияк очында җилбердәп торган сакалына да чал кергән.* Г. Ибраһимов. *Сөт, юл ясап, иреннән ияккә, аннан сизелер-сизелмәс кенә типкән көчсез күкрәккә агып төште.* Г. Гобәй.

2. *диал. к.* яңак II. [*Галләметдин*] *ишек иягендәге чөйгә эленгән ачкычын алып чыгып китте.* Ш. Камал.

◇ **Ияк асты (ияге) тишек** *сөйл. шелт.*— сер сакламас кеше турында әйтелә. **Ияк биетү** *сөйл.*— яхшылап, ныклап ашау.— *Азрак ияк биетеп аласы иде. Син каршы түгелсеңдер бит?* А. Гыйләҗев. [*Алар әнеләрен*] *көттеләр, көттеләр дә, казандагы токмачның шулпасы кайнап бетә язгач, тавышсыз-тынсыз гына ияк биетергә керештеләр.* Ш. Рәкыйпов. **Ияк кагу** — 1) исәнләшү, сәламләшү билгесе. [*Ул*], *ерактан гына ияк кагып, ямщиклар белән исәнләшеп чыкты.* М. Гали; 2) раслау, җөпләү, риза булу билгесе. *Иягемне кагып, «ярар» дигән җавапны аңлатып утырдым.* М. Гафури; 3) ымлау, ымлап берәр нәрсә эшләргә кушу. *«Мулланы чакыртыйк, мәзин килсен!» — дип шаулаша башлагач, староста бер дисәтниккә ияк какты.* М. Галәү.

ИЯЛЕ *с.* **1.** Иясе (1, 5 мәгъ.) бар. *Бу урын ияле. Әйбер ияле булу.*

2. Ире булган, ирле (хатын кеше турында).

3. Иясе (7 мәгъ.) бар. [*Бу җөмләләрнең*] *ияле икәнлекләре исемнәреннән дә аңлашылып тора.* В. Хангилдин.

ИЯЛЕК: иялек килеше *лингв.— кемнең? нәрсәнең?* сорауларына җавап бирә торган килеш. *Иялек килеше - - - -ның, -нең - - - кушымчасы ярдәмендә формалаша.* В. Хангилдин. *Баш һәм иялек килешләрен Вил шартлатып әйтеп бирде.* Э. Касыймов.

ИЯЛӘНҮ *ф.* **1.** *к.* ияләшү. *Бу ике кыз, кечкенә вакыттан ук бергә уйнап үскәнгә күрә, бер-берсенә бик ияләнгәннәр иде.* Ф. Әмирхан. *Бер ияләнсәң, куркыныч та гади нәрсә генә булып кала.* Г. Тукай.

2. Гел яки еш килеп йөрү. *Килә ява, килә ява, Ияләнде бер болыт.* Җыр.

ИЯЛӘШҮ *ф.* **1.** Берәр кешегә, нәрсәгә, эшкә күнегү, өйрәнү, гадәтләнү, үзләшү.— *Мин сиңа шулкадәр ияләшеп беттем, әгәр синең белән сөйләшмәсәм, эчем поша башлый.* Г. Насрый. *Авыл мәктәпләренә ул ияләшкән, шәкертләре һәм хәлфәләре белән үзләшеп беткән иде.* Ә. Фәйзи.

2. Берәр урынга еш килә башлау, шуны гадәткә алу. *Берәр тавык салмый калса, Галиулла, борчуга төшеп: «Күрше-коланга ияләшә күрмәсен, карантырып йөрергә кирәк»,— дия* [*иде*]. И. Гази. *Чоландагы ак майга Ияләшкән күселәр.* М. Җәлил.

3. Кешегә буйсыну, аны тыңлаучанга әйләнү (хайван турында).— *Кеше түгел, аю да кулга ияләшә.* Т. Гыйззәт.

ИЯР *и.* **1.** Ат яки ишәк сыртына атланып утырыр өчен бәйләнә торган махсус җайланма, утыргыч. *Көн буе йомшак иярдә өстәндә тирбәнеп барабыз.* Г. Тукай. *Атлылар иярләреннән сикереп төштеләр дә өйалдына йөгереп менделәр.* И. Гази. // Велосипедта, мотоциклда һ. б. ш. утыргыч. *Бари косилканың ияренә утыра.* М. Фәйзи. [*Мөнир*] *велосипедның ияренә атланып утырды.* Н. Фәттах.

2. *тех.* Утырту, кидерү, саклау яки терәтү өчен кулланыла торган машина детальләре исеме. *Бу җиздән ясалган шуцерларның астында чуеннан ясалган иярләр бар.* Т. Госман-Сулмаш.

3. Қош түшендә сыртланып торган сөяк.

Ияр агачы (яки арчагы, тактасы) — кавалерия аты ияренең агач кысасы. **Ияр аелы (яки бавы)** — ат сыртындагы иярне яки япманы беркетә торган киң каеш. [*Ат*] *ияр бавы тартылганда хуҗасының җиңеннән - - - тешләп-тешләп алгалады.* И. Туктар. **Ияр асты (ястыгы яки җәймәсе)** — атның аркасы суелмасын өчен ияр астына җәелә торган постау яки киез. [*Атлы*] *атыннан төште, - - - бармакларын ияр җәймәсе астына кертте.* Ш. Камал. **Ияр каплавычы (яки канаты)** — иярнең ике ягына өзәңге бавы өстеннән төшеп тора торган күн. **Ияр кашы (яки җәясе)** — иярнең дугаланып торган алгы яки арткы кырые. [*Аучының*] *ат өстендәге ияр кашына кунган кошы күренә.* Н. Исәнбәт. *Әгәр шулай булмаса, бу кадәр куркып, зәңгәрсу күзләрен зур итеп ачып, ияр җәясенә ике кулы белән дә ябышмас иде.* А. Шамов. **Ияр койрыкчасы** — ияр алга таба шуышмасын өчен ат койрыгына кидерелә торган очы бөжралы каеш. **Ияр элмәге** — иягә йөк, төен беркетү өчен махсус элмәк. **Ияр япмасы** — ияр өстеннән җәелә торган келәм, постау яки киез.

◇ **Иярдә тоту** — атларны һәртөрле көтелмәгән хәлгә әзер булсын өчен иярләнгән килеш тоту. *Ике якның берсе, яу булып килеп, авылны басар - - -* [*дип*], *байтак атларны иярдә тоталар.* Г. Ибраһимов.

ИЯРЕШЛЕ *с. махс.* Бер-бере белән бәйләнгән, үзара бәйләнештә булган; *русчасы:* сопряжённый. *Иярешле гиперболалар. Иярешле саннар.*

ИЯРЛЕ *с.* Иярләнгән. *Кешеләр, баганаларга бәйләнгән иярле атларга атланып, каядыр ашыгып китәләр.* К. Тинчурин.

ИЯРЛЕК *и.* Ат сыртының ияр беркетелә торган урыны. *Гали чиләк белән сумала китерә. Атның иярлеген майлыйлар.* Д. Аппакова.

ИЯРЛӘҮ *ф.* **1.** Атның (яки ишәкнең) сыртына ияр беркетү. *Әтисе шунда Ат иярли дә: «Атлан, улым»,— ди.* З. Мансур. *Сандугач акбүз атны алтын иярләр белән иярләргә куша.* Әкият.

2. *күч.* Атлану, атланып утыру.— *Әйдә, җилкәгә иярләп, Аякларыңны җайла.* Ш. Камал.

3. *күч.* Буйсындыру, кулга алу. *Иярләп бер менеп алгач замана, Өйрәтте ул ишәкне кана-кана.* Дәрдмәнд.

4. *күч.* Фәнне, техниканы үзләштерү һәм үз максатларыңа файдалану. *Без, иярләп техниканы, Үттек норма киртәсен.* Г. Кутуй. *Яңа рифманы иярләп алдым дигәндә генә, иске рифма чабудан тарта да төшерә.* Ф. Хөсни.

5. *хәрби.* Елга, юл һ. б. ш. стратегик әһәмиятле урынны кулга төшереп, шуның тирәсеңдә нығу. *Аның взводына - - - зур таш юлны иярләргә, чолганыштан котылырга теләгән дошманны үткәрмәскә кирәк иде.* А. Шамов.— *Синең батальоның менә бу юлны - - - иярли, Харитонов һәм Бобровников батальоннары — менә бу юлны.* Г. Әпсәләмов.

ИЯРМӘ *с. тех.* **1.** Бер-берсенә бәйле булган, үзара бәйләнештә торган. *Иярмә реакцияләр.*

2. Машиналарда: йөртүче деталь тәэсире астында хәрәкәт итә торган. *Иярмә тәгәрмәч.*

ИЯРМӘЛЕ *с.* Нәрсәгә дә булса (мәсәлән, кошлар тавышына) ияреп ясалган. *Сирин өчен, сурәт тудырганда, хәрәкәт итү тавышларына иярмәле чаралар куллану хас.* Х. Госман.

ИЯРТЕМ: аваз иярteме — *к.* аваз иярteме. *Мисалларда без аваз иярtемнәренең һәм җанварларга эндәшү сүзләренең грамматик яктан да ымлыклар белән бер хәлдә үк тормауларын күрәбез.* В. Хангилдин.

ИЯРТҮ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* ияру (1—3 мәгъ.). *Алар үз артларыннан бөтен авылны иярtү эшен дә өсләренә алырга [тиешләр].* М. Әмир.— *Малайлар арасында - - - төрлесе була. Авыру иярtерсең.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Үзе белән алу, үзеннән калдырмау. *Суык иярtеп керү.*

3. *юкл. форм. сөйл.* Артыннан җиткермәү.— *Бер сту[дентны] өч казак ат белән куа, ә ул ичмасам иярtми дә, ди.* Т. Гыйззәт.

4. *этн.* Кызның ата-анасы ризалыгыннан башка өйләнү; ябыштырып чыгару.

ИЯРТҮЛЕ *с. лингв.* Бер җөмлә кисәгенең (яки җөмләнең) икенче җөмлә кисәгенә (яки җөмләгә) буйсынуына, иярүенә (6 мәгъ.) нигезләнгән. *Иярtүле конструкцияләр.* □ *Иярtүле бәйләнеш, сүзләрне бәйләүче чараларның төрләренә, иярtүче сүзнең иярүче сүздән нинди форма талэп итүенә карап, өч типка бүленә.* М. Зәкиев.

ИЯРЧЕН *и.* 1. Кемгә дә булса иярүче, аның юлыннан баручы кеше. *Кара сакаллы бер кеше, үзенең иярченнәренә кул изи-изи, боларны куа башлады.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Куштан, ялагай кеше.— *Кулак һәм кулак иярченнәренең советка каршы дошманлык чыгышы ясау ихтималларын сез һәрвакытта күз алдында тотарга тиешсез.* Ш. Камал.— *Шушы канлы эзне волостьта эшләүче кулак иярченнәре басып калдылар.* Қ. Нәҗми.

3. Мөстәкыйль булмаган, бәйле нәрсәгә яки кешегә карата әйтелә. *Империалистик монополияләрнең колониаль иярченнәре.*

4. Планета яки йолдыз тирәсендә әйләнеп йөри торган күк җисеме. *Җирнең ясалма иярчене. Юпитерның тугызынчы иярчене.* □ [*Ул*] — *күктә очып йөрүче җир иярченнәре белән ракеталарны һавага очыра белүче - - - хәзерге заман кешесе.* Г. Бәширов.

Иярчен бала — анасы икенче иргә чыкканда ияреп килгән бала. **Иярчен кисәк** *лингв.*— җөмләнең ия яки хәбәренә буйсынып, алар белдергән эчтәлекне ачыклап, тулыландырып килгән кисәк. *Җөмләдә иярчен кисәкләрнең санын билгели торган кагыйдә юк.* В. Хангилдин. **Иярчен җөмлә** *лингв.* — кушма җөмләдә баш җөмләгә ияреп, аны ачыклап килгән һәм аңа төрле синтаксик чаралар белән бәйләнгән җөмлә. *Иярчен җөмләдә - - - хәбәрлек булырга тиеш. Шул ягы белән ул иярчен кисәктән аерыла. - - - Иярчен җөмлә һәрвакытта да башка бер җөмләгә ияреп, буйсынып килә.* М. Зәкиев.

ИЯРЧЕНЛЕ *с.* Иярчене булган.

Иярченле кушма җөмлә *лингв.*— компонентлары үзара иярtүле юл белән бәйләнгән кушма җөмлә. *Аерым җөмләләр, үзара тигез хокукта булмыйча, берсен берсе буйсындырсалар, ягъни үзара иярtүле юл белән бәйләнгән булсалар, алар иярченле кушма җөмлә төзиләр.* М. Зәкиев.

ИЯРЧЕНЛЕК *и.* Иярчен булу. *Тагып сиңа иярченлек [түбәнчелеген], Қорал итеп йөрстәләр [наданлыгыңны].* Г. Тукай.

ИЯРҮ *ф.* 1. Берәүнең яки берәр нәрсәнең артыннан калмый бару. *Төләндәм әби [җиләккә] кызлар белән генә бармакчы иде дә, без, малайлар да, аларга иярдек.* Г. Гали. [*Ул*] *Троицк юлы белән, татар сәүдә кәрванына ияреп, Бохарага барды.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр кешегә яки нәрсәгә ябышу, сырышу, тагылу, сылану. *Аның күлмәк-штанына иярган ясмыклар шыбыр-шыбыр идәнгә коелдылар.* И. Гази. *Язның хәбәрчесе кебек килеп, Кар суына ияреп китә ул [чәчәк].* Ә. Ерикәй.

3. Йогу (авыру турында).

4. *күч.* Берәр кешенең сүзенә, фикеренә карап, тәянып эш итү.— *Байморат коткысына ияреп, сине Минзәлә ярминкәсенә алып бармый хәтереңне калдырдым.* Т. Гыйззәт.— *Начар фикерләргә ияреп, алданып, адашып йөрмә, тыңла мине.* Г. Қолэхметов. // Берәр кешене җитәкче дип тану, аңа буйсыну, аның фикеренә кушылу, аның юлыннан бару.— *Авыл ярлылары барысы да Ленинга иярәчәк.* К. Нәҗми.— *Хәзер козырьлар безнең кулда бит, бөтен авыл диярлек безнең арттан иярәчәк.* И. Гази. // Гомумән кушылу. *Повар, Платон агайга ияреп көлә-көлә, тиз генә Хәлим янына килде.* Г. Гобәй.

5. Буйсыну. *Аның кулы әүвәл белгән көйләр рамкасыннан чыга да, аларга иярмичә, үз рухында булган сызлануларның гармониясенә җиңелә башлый.* Г. Ибраһимов. *Мин исә нәфсемә ияреп кабул итмәдем.* Г. Тукай.

6. *лингв.* Синтаксик бәйләнешнең бер төре (ул бер җөмлә яки җөмлә кисәгенең икенче җөмлә яки җөмлә кисәгенә буйсынуыннан гыйбарәт). *Иярtүле бәйләнештә сүзләр һәрвакытта да берсе икенчесенә иярgән, буйсынган булалар.* М. Зәкиев.

7. Берәр кешедән үрнәк алу, аныңча эшләргә тырышу. *«Яшь йөрәкләр» романы - - - Сабирга иярергә, аннан үрнәк алырга кирәклек фикер тойгысын тәрбияли.* Г. Нигъмәти. *Аңа берничә шәкерт ияреп, яланбаш йөри башладылар һәм балакларын чыгарып салдылар.* Ә. Фәйзи.

8. Иҗат эшендә: берәр язучы, художник яки халык иҗатының стилен кабатлау, өлге итеп алу. *Тукайга иярү. Борынгы әсәрләргә иярү.* □ *Сәйдәш, әлбәттә, халык музыкасына сукыр иярмәде, аларны күчерү белән генә шөгыльләнмәде.* М. Җәлил. *Шигырь тулысынча Дәрдмәндкә ияреп язылган.* Ә. Давыдов.

9. Берәр көйгә, тавышка мөмкин кадәр дөресрәк, төгәлрәк охшату. *Бу әсәрдә - - - авылның реалистик картиналарын - - - бирергә омтылу һәм шуның үзенә күрә бер формасы да табылу (орчык тавышына иярү, эвфоник алымнар)* [*сизелә*]. Н. Исәнбәт.

ИЯРҮЧЕ *и.* Берәр кешедән үрнәк алучы, аның юлыннан баручы. *Хәсән Туфанны ал син. Анда ичмасам рифма дисәң дә рифма. - - - Иярүчеләре дә шундук табылды. Газиз Әхметов шундый рифмалар белән яза.* Ф. Хөсни. *Аның киеме, кыяфәте, үзен тотуында, сөйләшүендәге бәйсезлеге берьюлы әллә нихәтле иярүчеләр тудырып өлгерде.* Ә. Фәйзи.

ИЯСЕЗ *с.* 1. Иясе булмаган, беркемнеке дә булмаган, хуҗасыз. *Үзе белән бергә иясез бер ат эйдәгән яшь егет — әлеге - - - Нуруллин иде.* А. Шамов. *Безне сагышлы кырлар, иясез ындырлар - - - каршы алдылар.* Қ. Нәҗми.

2. Иясе (7 мәгъ.) булмаган. *Беренче җөмлә дә иясез.* М. Җәлил.

Иясез җөмлә *лингв.*— иясе күрсәтелмәгән һәм табыла да алмый торган җөмлә (мәсәлән: *«Бүгенге эшне иртәгә калдырма»*). *Иясез җөмләдә ия алдагы җөмләләр ярдәме белән дә беленми, обстановка да аны күрсәтми.* М. Қорбангалиев.

ИЯСЕЗЛЕК *и.* Хезмәткәрнең үзенә тапшырылган эшкә шәхси җаваплылыгы булмау белән характерлы эш тәртибе; хуҗасызлык. *Синең идеяң — иясезлекнең нинди көлке һәм аяныч хәлгә китерүен ачып салу.* Г. Галиев. *Һәр кыз үзенә төшкән өлешен җәй буе үзе карый, үзе үстерә, уңышын да үзе җыеп ала, үзе тапшыра. Болай эшләү һәркемне кызыксындырган, иясезлеккә юл куелмаган.* Фәтхи-Балыкчы.

ИЖАБЕ-КАБУЛ, ИЖАП-КАБУЛ *и. иск. этн.* Кыз ярәшкәндә никахка кадәр булган килешү; алдым-бирдем.— *Риза, иртәгә алардан вәгъдә буләге китерерсең, бер-ике көннән үк ижабе-кабул итәрбез.* Г. Камал.— *Бу әле тегеләй, репетиция сыман, алдым-бирдем генә, --- шәригать теле белән әйтсәк, ижабе-кабул.* Ш. Камал.

ИЖАБИ *с. иск. кит.* Уңай; *киресе:* тискәре. *Эстетика тойгысы ике төрле ул: ижаби (уңай), сәлби (тискәре).* Г. Нигъмәти. [*Әсәрдә*] *бер якта бик әшәке, кире типлар, икенче якта бик ижаби, культур, эшлекле, уңган типлар бирү — трафарет схемасы ныкүзгә бәрелә.* М. Җәлил.

ИЖАДИ *с.* 1. Ижат итү белән бәйләнгән. *Ижади процесс. Ижади эзләнүләр.* ▭ *Бу җыентыкның басылу фактын --- зур ижади адым дип санарга кирәк.* М. Җәлил. // Төзүгә, барлыкка китерүгә, ижат итүгә юнәлдерелгән. *Ижади фикер. Ижади дуслык.* ▭ *Баш әйләндергеч уңышлыкларны күрү безнең ижади көчебезгә туры юл сыз[а].* Һ. Такташ. *Оешканлык, бердәмлек, ижади дәрт, омтылыш --- [аның] ышанычын тагын да нығыта.* М. Җәлил.

2. Үзендә ижат яңалыгы, яңача эшкәртү, ижат итү сыйфаты булган. *Ижади марксизм. Ижади төстә гомумиләштерү.*

Ижади диктант *пед.*— нинди дә булса кагыйдәне үзләштерү өчен махсус сайланган сүзләр нигезендә телдән җөмләләр төзеп, аларны тикшереп һәм соңыннан хәтердә калганча яки укытучы әйтүе буенча язудан гыйбарәт диктант. *Ижади диктант укучыларның сөйләү телен үстерүгә дә ярдәм итә.* М. Вәлидова.

ИЖАДИЯТ *и. кит.* Ижат эшчәнлеге. *Мин үз ижадиятемне нәкъ әнә шул югарыда китерелгән шигырьдән башлап җибәрдем.* Ф. Хөсни. *Мин тик ижадиятемнең нигезенә куелган түбәндәге матдәләрне әйтеп үтәм.* Һ. Такташ.

ИЖАТ *и.* 1. Кешенең рухи, матди байлыклар, культура хәзинәләрен төзүгә юнәлдерелгән мөстәкыйль эшчәнлеге. *Язучылык ижаты.* ▭ *Студиягә тартылган язучылар ижат белән генә түгел, киңәш, тәнкыйть белән дә бик күп ярдәм иттеләр.* М. Җәлил. *Кайбер язучылар исә, киресенчә, ижат иреген дөрес булмаган юнәлештә файдаланырга омтылалар.* М. Әмир. // *с. мәгъ.* Шундый эшчәнлек белән бәйләнгән. *Ижат активлыгы. Ижат командировкасы. Ижат юлы.* ▭ *Бары тушь белән генә эшләнгән, китап бите күләменнән зур булмаган бу рәсемгә художник бөтен ижат көчен, бөтен дәртен, сәләтен салган.* А. Шамов.— *Барыбыз да ижат кешеләре. Беребез — әдәбият, икенчебез — мәгърифәт, өченчебез — сәнгать, дүртенчебез — медицина* [*өлкәсендә*]. Г. Минский.

2. Шул эшчәнлек нәтиҗәсе; берәр кеше яки кешеләр коллективы тарафыннан барлыкка китерелгән хезмәтнең җыелмасы. *Халык ижаты.* ▭ *Рус һәм Көнбатыш Европа классикларының лирик ижатлары белән укучыларны таныштыруда Тукаевның роле зур булды.* Г. Нигъмәти.

Ижат итү (кылу) — матди һәм рухи байлыклар тудыру. [*Г. Камал*] *«Корсын балам»ны яза. Соңрак исә «Хафизалам, иркәм», «Өч тормыш» һәм башкаларны ижат итә.* М. Гали. *З. Солтанов, К. Шамил һәм Һ. Шаһвәлиев --- ижат иткән өч хәлфә тибы оригиналь эшләнгәннәр.* М. Җәлил.

ИЖАТТАШЛЫК *и.* Бергәләшеп ижат итү эшчәнлеге.

ИЖАТЧАН *с.* Ижат итәргә яратучан, ижат итәргә һәвәс. [*Балаларның*] *ижатчан булулары белән оригинальлеккә, яңалыкка омтылулары билгеле.* Н. Исәнбәт.

ИЖАТЧАНЛЫК *и.* Ижатчан булу.

ИЖАТЧЫ *с.* 1. Ижат итүче. *Ижатчы халык.* // *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Әдәбиятның үсүе, баюы, береңче чиратта, аның ижатчылары — язучыларга бәйле.* Н. Юзиев. [*Алдыбызда*] *неэвклид геометриясенең --- гениаль ижатчысы — --- Лобачевскийның бюсты тора.* Ж. Тәрҗеманов.

2. Үз акыл сәләте белән уйлап яңалык кертүче, һәр нәрсәгә ижади караучы. *Секретарь эштә дә, тормышта да стандартны сөймәс, ул кешенең ижатчы булуын, кечкенә генә эшкә дә ни дә булса үзенекен, үз белдеген өстәвен тели.* Г. Бәширов. // *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Бөек кешеләр, бөек ижатчылар рәтенә театр галәмендә үзенең режиссерлыгы белән танылган --- Станиславский да керә.* Г. Кутуй.

ИЖАТЧЫЛ *с.* Ижат итү сыйфатларына ия булган, яңа уй-фикерләр тудыра торган. *Дискуссиянең ижатчыл методы.*

ИЖАТЧЫЛЫК *и.* Ижади эшкә сәләт, омтылыш, ижади эш белән шөгыльләнү. *Баланың [бу эше], --- ирекле һәм күңелле эшләнә торган бер эш булып, баштанаяк ижатчылык белән бәйләнгән.* Н. Исәнбәт.

ИЖЕК *и.* 1. *лингв.* Сүзнең аерым һава этәреше белән әйтелә һәм бер сузыктан яки сузык катнашкан берничә аваздан торган кисәге. *Ачык ижек. Ябык ижек. Сүзне ижекләргә бүлү.* ▭ *Тукай силлабик система эчендә 4 тән башлап 16 га кадәр ижектән торган тезмәләр кулланып яза.* Г. Нигъмәти. [*Хизбулла сүзнең*] *ижекләрен бүлә-бүлә кычкырды: «Җә-мә-гать!»* К. Нәҗми.

2. *пед. иск.* Иске ысул белән укытуда: гарәп сүзләрен ижеккә (1 мәгъ.) аерып, нинди хәрәкә белән булуын әйтеп уку (мәсәлән, *кәп өсте кә, ләм асты ли, мим өсте мә, т гә ике өтер, кәлимәтен* дип уку). *Ул вакытта башлап уку һәм ижек таныпкитү чиксез авыр булып, бик күп балаларның башлары шул ижек танудан чыга алмый аптырый иде.* М. Гафури. *Ижек укучылар --- өченче почмакта: «Әпсен әләмгә сәкен, әлхисөннә, әлхәм мимгә сәкен»,— дип сүзып кычкыр[а] башладылар.* М. Гали.

Ижек язуы *лингв.*— бер билге ярдәмендә бер авазны түгел, бәлки бөтен бер ижекне белдергән язу системасы (мәсәлән, кореялылар язу системасы).

◇ **Ижеген ижеккә китерү** — матурлап, стиль ягыннан шома, дөрес итеп уку, сөйләү, язу.— *Ижеген ижеккә китереп оештырып утырырга минем вакыт бармыни?* Р. Ишморат.

ИЖЕКЛӘҮ *ф.* 1. Ижекләргә бүлү. [*Хатларның*] *кайсын-берсен [ул] үз-үзенә ижеклән укыды.* Ф. Хөсни. *Камали русча ташка басканны кыенлык белән аера иде. Күп ижекли торгач, ул кәгазьләрдән «заградительный отряд» дигәнне генә таный алды.* Г. Ибраһимов. // *рәв. мәгъ.* **ижеклән.** Авырлык белән, сүзләрнең ижекләрен, хәрефләрен берәм-берәм оештырып. *Бер ярлы тәкәббер --- керепкоридордагы ишекләр каршына — әле берсенә, әле икенчесенә — туктала-туктала, ишектәге язуларны ижеклән-ижеклән укып йөрде.* Ф. Хөсни.

2. *иск. пед.* Ижек (2 мәгъ.) белән уку. Кечерәк кызлар: *«Әбсен ә, бигә сәкен, әб...» — дип, ижекләргә керешәләр.* К. Нәҗми.

3. *рәв. күч.* **ижеклән.** Аңлатып, төбенә төшендереп; җентекләп.— *Шулай диген син; савытларыгызны диген. Безнең шикелле наданнарга ижекләбрәк әйтмәсәң, әллә ни калага барып укыган гыйлемлек юк.* М. Фәйзи.

ИЖЕКЧЕ *и. пед.* Ижекләп (2 мәгъ.) укыту тарафдары. *Әлифба укыту мәсьәләсендә Каюм --- ижекче (слоговой метод белән баручы) иде.* Г. Сәгъди.

ИЖТИМАГЫЙ *с.* 1. Җәмгыятькә караган, җәмгыятькә бәйләнешле. *Җәмгыятьнең ижтимагый үсеш законнары. Ижтимагый строй.* ▭ *Пьесадагы вакыйгалар җәмгәгать урыннарында: заводта, сугыш яланында, цехларда, директор кабинетында, клубта, мәйданнарда барган шикелле, кафарманнар да өйдә, гаиләдә түгел, бәлки эштә, ижтимагый урында бирелгәннәр.*

Г. Нигъмәти. [*Фәхрине*] *үтерүчеләргә иҗтимагый саклану чараларының иң югарысы бирелергә тиеш.* Г. Ибраһимов.

2. Бөтен кешелек җәмгыяте катнашында тудырыла, үтәлә, эшләнә торган. *Иҗтимагый җитештерү. Иҗтимагый хәрәкәт.* □ *Кайчандыр, шәхси бәхет иҗтимагый хезмәт белән бергә бара алмый, - - - дигән бул*[*ганнар*]. Г. Нигъмәти. // Бөтен җәмгыятьнеке, барлык кешеләрнеке; күмәк. *Иҗтимагый байлык.*

3. *Зарур, әһәмият* сүзләре белән килгәндә: бөтен җәмгыять өчен. *Иҗтимагый зарур эш вакыты.* □ *«Безнең шәһәрнең серләре» комедиясе яки «Беренче театр» кебек гаять зур иҗтимагый әһәмияте булган классик әсәрләрне семья рамкасына гына бикләнеп калган дип әйтергә берәүнең дә хакы юк.* М. Гали.

4. Җәмгыятьнең политик, культура ихтыяҗларын үтәү белән бәйле. *Ш. Камал үзенең иҗтимагый эшчәнлеген революция белән бәйләде.* М. Җәлил.

5. Кешеләрнең җәмгыятьтә тоткан урыннарын, үзара мөнәсәбәтләрен, сыйныфларга бүленүен чагылдыра торган һәм шуларга бәйле булган; социаль. *Иҗтимагый фәннәр. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр. Иҗтимагый тормыш. Иҗтимагый төркемнәр.* □ [*Горький*] *көрәшчеләрне төрле иҗтимагый катлаудан эзләп карый: босякларда, әлбәттә, бу рольне үтәү ихтималы юк, крестьяннардан да Горький юньле эш көтми, зыялылардан әче рәвештә көлә.* Г. Нигъмәти.

6. Иҗтимагый җитештерү мөнәсәбәтләрен үзгәртүне максат иткән, социаль. *Иҗтимагый борылыш. Иҗтимагый хәрәкәт. Татар бурҗуазиясенең иҗтимагый программасы.* □ *Партия әгъзалары - - - бөек иҗтимагый сугыш утларында кайнап чыны*[*галар*]. Г. Ибраһимов.

ИҖТИҺАТ *и. иск. кит.* Тырышлык. [*Ул*] *күп иҗтиһат белән янә берничә бала җыйды.* Қ. Насыйри.— *Үземнең иҗтиһатым да булмады түгел, булды. Бик күп тырыштым.* Г. Камал.

Иҗтиһат итү (кылу) — тырышу, тырышып эшләү, тырышлык күрсәтү. *Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһат.* Г. Тукай. *Гали үзе дә укуга бик ихлас куеп, иҗтиһат кылды.* Ш. Мөхәммәдев.

ИҖТИҺАТЛЫ *с. иск. кит.* Тырыш. *Мин яңадан ташчы булам, Әүвәлгечә иҗтиһатлы эшче булам.* Г. Тукай. *Без дәресенә тырышкан, иҗтиһатлы шәкертләрне яратабыз.* М. Гафури.

ИҢ I *и.* **1.** Әйбернең киңлеге, аркылысы. *Материя иңе.* □ *Камера. Буе аның биш, иңе — өч, биеклеге ике ярым аршын.* И. Туктар. *Син торасың алачыкта, Буе кыска, иңе тар.* Г. Камал.

2. Арканың калак сөякләре турысындагы киңәеп киткән өлеше (ике кулбаш арасы). *Кичә генә иңгә менгән өр-яңа мундир, аның буй-сынга бер ыспайлык биреп, тәнгә сыланып торуы егетнең кәефен күтәреп җибәргән.* Ф. Хөсни. // *к.* иңбаш. *Хәлим шинелен иңнәренә салды.* Г. Гобәй. *Газинур, башын иңнәренә батырып, - - - артка тайпылды.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Иң бирү** — бер башы яки бер очы белән янәшә урнашкан булу. *Колхоз идарәсе йортына иң биреп торган ашханә янына берничә машина килеп туктады.* Ялкын. **Иңен иңләү** — берәр җирне аркылыга үтү. *Хәйруллә абзый, киң Россиянең буен буйлап, иңен иңләгәннән соң, 1925 еллар тирәсендә - - - шушы шәһәрчеккә тукталган иде.* Г. Әпсәләмов. **Иңеннән буена** — берәр әйбернең бөтен өслеген кертеп (каплау, йөрү һ. б. турында). *Җамали* [*үтүк белән*] *- - - киемнәрнең иңеннән буена тагын бер йөреп чыга.* Г. Ибраһимов. **Иңеннән буена айкау** — берәр нәрсәне барлык ваклыкларына кадәр җентекләп тикшерү. *Каенана белән килен арасындагы бу талашлар һәр икесенең үткән тормышларын иңеннән буена айкап чыгалар.* Г. Ибраһимов. **Иңне иңгә куеп (терәп)** — *к.* иңгә-иң (1 мәгъ.). *Дошманны сытарга ташланган гаскәрләр сафында, бәлки, Илнур белән бу шофер иңне иңгә терәп янәшә атлаганнардыр.* Г. Мөхәммәтшин. *Омтылам мин һәрчак яшьләр белән Иңне иңгә куеп барырга.* Г. Хужи. **Иңнән иңгә** — 1) бер кырыйдан икенче кырыйга кадәр; бөтен киңлегенә. *Урамны иңнән иңгә тутырып килүче тыгыз колонналарның алгы сафында тынлы оркестр булган икән.* Қ. Нәҗми; 2) бер яктан икенче якка һәм киргә (йөреп, йөзеп һ. б. чыгу турында). *Кандыр иңен йөзеп буйлаганда Уртасына басып тын алдым, Иңнән иңгә сине айкаганда, Синең өчен, Кандыр, оялдым.* К. Тинчурин. **Иңнән тау төшү (ташлану)** — *к.* җилкәдән тау төшү. *Көзнең яралы юлларыннан авыр арбалар тартып интеккән бахбайлар җиңел, сылу чаналарга күчкәч, иңнәреннән тау ташлагандай, ялларын җилфердәтеп, йөрәк кагып кына йөриләр.* А. Гыйләҗев. **Иңнәргә күтәрү** — авыр, мәшәкатьле, күп көч һәм сабырлык сорый торган эшләрне үз өстенә алу. *Без, дөньяны якты итәр өчен, яңа бәхет өчен илләргә, Авыр, тирән канлы көрәшләрне күтәрмибезмени иңнәргә?!* Ш. Маннур. *Ул яшь бер коммунистның партиянең бөек эшенә җиң сызганып керешүен, шул данлы эшнең бер өлешен үз иңнәренә иренмичә күтәрергә ашкынуын күрде.* Г. Әпсәләмов.

ИҢ II *кис.* **1.** Асыл сыйфат алдында килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый; үтә, бик. *Иң зур. Иң матур. Иң яшь.* □ *И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә — эш.* Г. Тукай. *Улының иң соңгы рәсеме бит бу.* А. Шамов. // Асыл сыйфатлар өченче зат тартым формасында килгәндә: һәммәсеннән бигрәк, аеруча. *Арада иң түземлесе Фәтхия* [*икән*]. Г. Ибраһимов. *Сайлый торгач, аның иң яратканы җимеш бакчасы булып чыкты.* Г. Бәширов.

2. *сир.* Нәкъ. [*Балыкның*] *өченчесе - - - диңгезнең иң уртасына чумарга* [*исәпләгән*] *иде.* Г. Тукай. *Хәсән иң урта җиргә - - - ачык хат кадап куйды.* Ф. Әмирхан.

Иң зур уртак бүлүче *мат.*— бирелгән саннарның барысын да калдыксыз бүлә торган иң зур сан (мәсәлән, 24 һәм 36 саннарының иң зур уртак бүлүчесе — 12). **Иң кечкенә уртак кабатлы** *мат.*— бирелгән берничә саннның һәрберсенә калдыксыз бүленә торган иң кечкенә сан (мәсәлән, 4 һәм 6 саннарының иң кечкенә уртак кабатлысы — 12).

◇ **Иң аз дигәндә** — *к.* иң азында (кимендә). *Элекке елларда иң аз дигәндә мунча чабыныр өчен илле себерке чыккан бу каеннардан хәзер дүртәве генә калды.* Қ. Нәҗми. **Иң азы (яки киме)** — *к.* иң азында (кимендә).— *Иң киме - - - ун мең сумнар акча кирәк булыр.* Г. Ибраһимов.— [*Ул*] — *иң киме тәрбиясез,— дип хөкем йөртер идем.* Ш. Камал. **Иң азында (кимендә)**— 1) бик аз дип исәпләгәндә.— *Мансур иң азында биш ел* [*хезмәт итәргә*] *җыена.* Ш. Усманов. *Бәхетсезлеккә каршы, анда ике-өч кенә кеше түгел, ә иң кимендә җидесигез кеше булып чыкты.* А. Шамов; 2) *кер. сүз. мәгъ.* ахыр чиктә, бер дә булмаса; һич югында. *Аның бу ямьсез кыяфәтен күргән - - - кеше куркыр, иң азында, соң дәрәҗәдә авыр хәлгә калыр.* М. Гафури. **Иң башлап** — беренче булып. *Иң башлап Миңлегөл сүз ачты.* Ш. Камал. *«Татар телендә язу» лозунгысын иң башлап тормышка ашырырга керешүче - - - язучы, һичшиксез,— Г. Камал.* М. Гали. **Иң күбе(се), иң күбендә** — берәр нәрсә, берәр эш өчен кирәкле әйберләрнең зур саны; күп булса, күп дип санаганда.— *Иң күбе миңа бер ел вакыт бирәсез, мин сезгә, санап, ике йөз сумны менә шул икмәк янына китереп куярмын.* Г. Ибраһимов. [*Тамыр*] *өзелгән булса, бармак тамыр өзелүдән иң күбендә алты сәгатьтән соң җанлылык төсен югалта башларга тиеш иде.* Ш. Камал. **Иң күпкә киткәндә** — *к.* иң күбе(се). *Безне аерачак заман алты, җиде ай булыр. Иң күпкә киткәндә, бер елга сузылыр.* Г. Ибраһимов. **Иң яхшысы** *кер. сүз мәгъ.*— барлык юллардан дөрес-

рәге, кулайрагы, файдалырагы. — *Иң яхшысы, эшне ул дәрәҗәгә җиткермәскә кирәк.* Р. Ишморат.— *Хәзер безгә, иң яхшысы, [һөҗүмгә] барудан баш тарту.* М. Гали.

ИҢБАШ *и.* Гәүдәнең муеннан кулбашына кадәрге өске өлеше. *Иңбашларына көрәкләр күтәргән ишле генә хатын-кыз төркеме кайтып керде.* Г. Бәширов. *Зоя Газяның ике иңбашыннан тотып, күзләренә карады.* М. Әмир.// Киемдә: муеннан кулбашына кадәрге өлеш. *Иңбашлары күпертмәле итеп тегелгән ак алъяпкычы --- бу сылу хатынның җыйнаклык сөюен күрсәтә.* Г. Бәширов.

◇ **Иңбашларын җыеру (яки сикертү, тарту)** — аптырау, ни эшләргә белмәү, берәр нәрсәне төшенмәү һ. б. ш. хисләргә иңбашларын хәрәкәтләндереп ишарә ясауны белдерә.— *Аңлап җитмим,— диде Нургали, иңбашын җыерып.* Ә. Еники. *Садри гаҗәпләнеп иңбашларын тартып чыгып китә.* Ш. Камал. *Зиннәт хәзерге Нәфисә белән ничек сөйләшә башларга белмичә иңбашын сикерткәләде.* Г. Бәширов.

ИҢ-БУЙ *җыл. и.* Берәр әйбернең, җирнең иң һәм буе, барлык күләме. *Иңе-буе метр ярым киңлектә казылган чокырларның берсеннән --- таныш картым күренде.* Қ. Нәҗми. [*Тимери*] *эшлисе җирнең иңенә-буена күз салды, бераз уйланып торды.* Г. Бәширов.

◇ **Иң-буй үлчәү** — кемне дә булса башыннан аягына кадәр карап алу. *Ул яратмыйча гына күтәрелеп карады, икесенең дә иң-буйларын үлчәде.* А. Гыйләҗев. **Иңгә-буйга айкау** — барлык юнәлешләрдә эш итү. *Прожектор нурлары --- һаваны иңгә-буйга кисеп, айкап чыгалар.* Қ. Нәҗми. **Иңе-буе үлчәнгән (үлчәнеп киселгән)** — әзер килеш файдаланыла торган, әзер. *Боларның һәммәсе --- иңе-буе үлчәнеп киселгән бер шаблон буенча язалар.* Г. Ибраһимов. **Иңен-буен тап-тау** — берәр җирнең бар урыннарында да булып чыгу. *Бу тирәләрнең иңен-буен таптаган кешеләр без.* Ә. Ибраһимова. **Иңне-буйны абайлау — барысын да алдан** күреп, тикшереп эш итү.— *Иңне-буйны абайлый торганга охшамый [ул]. Юк, мин болай гына, яманлавым түгел.* Қ. Тинчурин.

ИҢГӘ-ИҢ *рәв.* **1.** Бик якын, янәшә, бер адым да калышмыйча, рәттән (бару турында). *Узең кешеләр белән иңгә-иң барып, бер һаваны сулаганда гына синең сүзеңнең бәясе бермә-бер күтәрелә, ышанычы арта.* А. Гыйләҗев. *Искәндәр иңгә-иң селкенеп килгән Маратны «улым!..» дип кочып алыр [хәлгә] җитте.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Тыгыз бәйләнештә; бергә. *Иңгә-иң эшләү.*

ИҢДЕРҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* иңү (1, 3, 5 мәгъ.). *Салкын авырлык, җиргә иңдерергә теләгәндәй, гел баса барды.* Г. Бәширов. *Мәрхүмәне җиргә иңдерү өчен кабер эченә Шәвәли карт төшмәкче була.* Г. Ахунов.

2. *диал.* Югарыдан башка сугу. *Түбәңә иңдерермен!*

ИҢЕЛӘЙ *рәв. диал.* Бөтен иңенә; тулысынча. *Ул урам яктагы тәрәзәне иңеләй ачып җибәрде.* Н. Фәттах.

ИҢЕЛҮ *ф.* Батып, чокырланып керү.

ИҢЕШ *и. диал.* Батыш. *Кояш иңешендә биек вә калын агачлар арасыннан гына кызыллы-сарылы офык күренә.* Ш. Камал.

ИҢКЕЛ *с., и. к.* иңкү I. *Эти белән әни, «яңгырга китсә, черемгәге» дип, иңкелрәк урыннардагы печәнне калкулыкка ташырга тотындылар.* Г. Бәширов. *Төн эченда Карабаш иңкеленда шактый су җыелып өлгергән.* Ш. Бикчурин.

ИҢКЕЛЛЕК *и. к.* иңкүлек. *Гомумән, бу район тигез урын булып санала, тик аның кайбер урыннарында гына кечкенә иңкеллекләр (подалар) очрый.* А. Фаткуллин.

ИҢКЕ-МИҢКЕ *рәв. к.* аңгы-миңге. *Юл читендә иңке-миңке басып калган Зәйтүнә --- абына-сөртенә атлап китте.* Ф. Хөсни.

ИҢКӘЛ *и. диал.* Ит һәм бәрәңге белән пешерелгән токмач ашына салынган киң камыр кисәкләре.

ИҢКӘЙТҮ *ф.* **1.** Берәр нәрсәне авыштыру. *Мичкәне иңкәйтү.* □ *Ишек төбендә зур самоварны бер колагыннан иңкәйтеп тоткан Һәдия түти басып тора.* Қ. Нәҗми.

2. (Башны) бөгү, салындыру. *Яхшы адәм алтын башын иңкәйтсә, Яман адәм артын туңкайтыр.* Мәкаль.

ИҢКӘЮ *ф.* **1.** Туры хәлдән бераз авыша төшү; аву (җансыз әйберләр турында). [*Өстәл*] *өстендә карчыкның үзе кебек бераз алга иңкәйгән калай самовар утыра.* С. Кудаш.

2. Иелү, бөгелү, салыну (баш турында). *Вәли абзыйның «йөзем суы» йөгергән башы иңкәеп төшкән иде, ул аны кинәт күтәреп куйды.* Ә. Фәйзи. *Чалкайганга чалкай — башың күккә җиткәнче, Иңкәйгәнгә иңкәй — башың җиргә тигәнче.* Мәкаль.

ИҢКҮ I *с.* Әйләнә-тирә җирдән түбәнрәк, батыбрак торган; уйсу. *«Дымык күл»нең бер башында иңкүрәк, сазлыклырак урын бар.* Г. Мөхәммәтшин. *Үргә менгәндә тәпили-тәпили, иңкү җирләрдә аз-маз утырып, Исхак кичкырын гына Чаллыга килеп җитте.* А. Гыйләҗев. // *и. мәгъ.* Шундый урын; иңкүлек. *Якуб иңкү буенча сузылган ак томанга күрсәтте.* И. Гази. *Инеш буендагы иңкүләргә зәңгәрсу сыек томан җәелә.* Г. Бәширов.

ИҢКҮ II *ф.* Аңгыраю, аңгы-миңге килү.— *Телең кутырлап талганчы, башың түмәрләнеп иңкегәнче [сүгенәсең син]!* А. Гыйләҗев.

ИҢКҮЛЕК *и.* **1.** Әйләнә-тирә җирдән чокырланып, батып торган урын, иңкү җир; уйсулык. *Ялгыз нарат яныннан елгага тар гына, сай гына чокыр кебек бер иңкүлек барып кушыла иде. Бу иңкүлек, бу тар гына батынкы җир елганың кайчандыр иске эзе булган.* Н. Фәттах. *Озакламый иңкүлектә кечкенә генә буа хасил булды.* Гәр. Рәхим.

2. *геогр.* Диңгез өсте тигезлегеннән дә түбән торган урын. // Диңгез өсте тигезлегеннән 200 метрдан югары булмаган тигезлек; түбәнлек. *Академик [Губкин] Икенче Баку районнарында — Иделдән алып Уралга хәтле булган гаять зур иңкүлектә — нефть эзли.* Г. Ахунов.

ИҢЛЕ *с.* **1.** Иңе киң булган. *Иңле сатин.*

2. Киң җилкәле. *Унтер-офицер --- бүген, көн яктысында, иңлерәк тә, буйлырак та күренә.* Ф. Хөсни.

3. *күч.* Күпьяклы, киң. [*Әхмәтбәз*] *тормышны тирәнрәк, иңлерәк колачлый.* Ф. Хөсни.

4. *к.* илле II. *Йөрәкне бер иңле мук баскан.* М. Хәсәнов.— *Кулларга ике иңле сөял үстереп әйткән сүз бервакытта да контр булмый ул.* Р. Төхфәтуллин.

ИҢЛЕК *и.* Киңлек.— *Чамаладыгызмы? — Кыскарак әз генә.— Күпме? — Дүрт бармак иңлеге булыр.* Г. Гобәй. [*Тайның*] *аркасыннан бармак иңлеге тасма сузылып киткән.* Г. Бәширов.

ИҢЛӘП-БУЙЛАП *рәв.* **1.** Бөтен киңлеге һәм озынлыгы буенча; иңен-буен каплап, биләп. *Авыл көтте --- Иңләп-буйлап тоташ басуларны, Изү чишеп эшләр чакларны.* Ш. Маннур.

2. Бөтен җирне, урынны аркылыга-буйга (йөрү турында). *Сары тавык --- бөҗәкләр чүпли, бакчаны иңләп-буйлап йөри.* Н. Фәттах.

ИҢЛӘТЕП *рәв. к.* иңләү (2 мәгъ.). [*Малайлар*] *бөтен тыкрыкны иңләтеп --- Иделгә төшеп киттеләр.* М. Әмир.— [*Паласны*] *бөтен түрне иңләтеп җәеп җибәрер идек.* Т. Гыйззәт.

ИҢЛӘҮ *ф.* **1.** Берәр урынны биләү, алып тору. *Сәмигыл абзыйның арттагы бәрәңге бакчасы да башка кешеләрнеке кебек ярты дисәтинә җирне иңләмәгән, --- тик өч-дүрт батман бәрәңге чәчәрлек кенә иде.* М. Гали.

2. *рәв. мәгъ.* **иңләп.** Бөтен киңлеккә каплап алып. *Бөтен елга өстен иңләп, җәяүле буран себерә...* М. Хә-

сәнов. [*Болытлар*] *күкне иңләп каядыр ашыгалар.* Г. Ахунов.

3. *күч. рәв. мәгъ.* **иңләп.** Берәр нәрсәне тулысынча, бөтен күләменә күздән үткәрү турында. *Директорның йөгерек карашлары Иңләп чаба совхоз аланын.* М. Җәлил.

4. *күч.* Кочу, бөтенләй чолгап алу. *Искән җилләр иңләп бетә алмас Бу ил киңлеген.* Ф. Кәрим.

5. Берәр җирне, урынны, илне һ. б. ш. аркылыга-буйга йөреп чыгу. *Алтай сахраларын иңлисең син, Чирәм-далаларда тирлисең.* Г. Афзал. [*Ул*] *башта авыл белән базар арасын таптый, соңрак базар белән шәһәр арасын иңли башлый.* М. Хәсәнов. // *рәв. мәгъ.* **иңләп.** Берәр җирне, илне һ. б. ш. аркылыга-буйга (йөреп чыгу турында). *Дулкыннарны ерып, шул кырны Иңләп йөри безнең Җәмилә.* М. Җәлил. *Кыр казлары бүген баш очымнан Зәңгәр күкне иңләп йөрделәр.* Л. Айтуганов.

6. *рәв. мәгъ.* **иңләп.** Кочак-кочак. *Байлар бирде* [*акларга*] *ярдәмнәрне меңләп-меңләп, Кызыл маллар, ситсыларны иңләп-иңләп.* Г. Камал.

ИҢРӘҮ *ф.* 1. Көчле авыртудан, зур кайгыдан һ. б. ш. йөрәк әрнеткеч, үзәк өзгеч аваз чыгару; шулай ыңгырашу. *Хатыны Бибиәсма үлгәннән соң, Нигъмәтҗан*[*ның*] *--- ыңгырашуы һәм үксүе әледән-әле ишетелеп торды. Бу үзәк өзгеч зарлы иңрәү кешеләргә генә түгел, җанварга да тәэсир итте.* Ә. Фәйзи. *Ул, авыр хәсрәтен күтәрә алмаган кайгылы кешедәй, каты иңрәп: «А-а-һ!» — ди, бераз китә дә, гүя йөрәгенә кабынган ялкынга түзә алмыйча, күз яше белән, тагын төнге урамны тетрәтеп җибәрә: «А-а-һ!..»* Г. Бәширов.

2. Зур кайгыдан, кайгылы хәбәрдән бик нык әрнү, рухи газаплану, тетрәү. *Күңелемә бик якын тоелган ямьле Хәсәннең лазаретта авырудан үлгәнлеген ишетеп иңрәдем.* М. Фәйзи. *Әнә шулай иңрәп тынып калулар, өметсезлекләр, караңгы уйлар астыннан яшерен сөенеч туа.* Ф. Хөсни.

3. *күч.* Берәр кайгылы, ачы яки каты тавышка кайтаваз булып гүелдәү (җансыз әйберләр турында). *Кырларда гизеп, өмет өзеп, Мин җырладым, таулар иңрәде.* М. Фәйзи. *Бөтен яктан аталар. Таулар, мең яңгыраш чыгарып, иңриләр, әйтерсең җир ишелә.* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Тилмереп зар елау, газаплану. *Авыл ярлылары бер телем икмәккә иңрәгәндә дә, Таштүбә Садыйк ындырында тау-тау кибәннәр яшиләр иде.* Г. Гали. *Ул зарыгып, иңрәп безне көтә, Йокламыйча төннәр буена.* Ә. Ерикәй.

ИҢСЕРӘҮ *ф. сир. к.* әлсерәү. *Ул, башка картлар шикелле, иңсерәгән, йөдәгән, сөйкемсез түгел: тулы гәүдәле, тулы битле, кызыл төсле, киң күкрәкле карт иде.* Ак юл.

ИҢСӘ *и.* 1. Арканың иңбаштан һәм җилкәдән торган югары өлеше. [*Мәрфуга*] *еш кына курчактай Нәфисәне дә иңсәсенә асып бара иде.* М. Шабай. // Киемнең шул турыдагы өлеше. *Өстендәге бер генә сәдәпле, ак челтәр иңсәле бәрхет бишмәте --- [аның] әти-әнисе өчен үтә кадерле, үтә иркә бала икәнен әйтеп торалар.* Г. Гобәй.

2. *к.* иңбаш. *Сәлперәйгән* [*аның*] *ике иңсәсе.* Н. Баян.

3. *диал.* Баш арты, баш чүмече.— *Ике көн иңсәләрем чатнап, хәтта намазга да чыга алмадым.* Ш. Камал.

4. Кием элгеч, киерге. *Юеш киемне иңсәгә элеп калдыру.*

◇ **Иңсәләрен җыеру** — *к.* иңбашларын җыеру. *Корякин аңа ярдәм итәсе килсә дә, иңсәләрен генә җыерды.* А. Гыйләҗев.

ИҢСӘЛӘҮ *ф. диал.* 1. Иңсәсеннән (2 мәгъ.) тоту, иңсәсеннән (2 мәгъ.) эләктерү.

2. Баш артына, баш чүмечесенә сугу.— *Төнлә йоклямыйча гулять итеп йөрисез! — дип, шәкертләрне иңсәләп, үз казармаларына хәтле озатып куйдылар.* К. Тинчурин.

ИҢСӘЮ *ф. диал.* Салыну, асылынып төшү. *Балык аулый торган үрмәкүчләр суга иңсәеп төшкән агач ботаклары өстенә урнаш*[*алар*]. Яңалиф.

ИҢСҮ *с. диал. к.* иңкү I.

ИҢСҮЛЕК *и.* Чокырланып, батып торган урын. *Дулкын иңсүлеге.*

ИҢҮ *ф.* 1. Югарыдан түбән таба төшү. *Хуҗага күктән бер янчык алтын иңгән.* Н. Исәнбәт.— *Ишелеп-ишелеп, бер коточкыч Аждаһа күктән иңә.* Һ. Такташ. // *дини, с. ф. форм.* **иңгән.** Күктән боерылган.— *Патша белән бер алладан иңгән хокукларны яклый алмыйсың.* Т. Гыйззәт.

2. *диал.* Бату, баю (кояш турында). *Кояш иңгән, тышта караңгы төшеп килә.* Ш. Камал. *Көн бетеп, кояш иңәр вакытлар.* Һ. Такташ.

3. Җиргә батып керү, сеңү. *Ул арада инде алаша алгы саны белән пычракка иңеп бара иде: «Әй, бата бит!»* Г. Бәширов. *Турай батыр тегене сакалыннан урап алып китереп бәрә, үзе бер карыш, сакалы биш карыш тез тиңентен идәнгә иңә.* Әкият.

4. Чокырланып батып керү. *Алты почмаклы йортның түбәсе, урта бер җиреннән иңеп, дөя өркәченә охшап калды.* Г. Ахунов. // Иңкү урын, сай чокыр сыман урын хасил итү. *Жир иңү.* // Аска таба сеңү, басылу. *Кар таулары кайнар кояш нуры астында шул көнне үк иңеп төште.* И. Гази.

5. Берәр нәрсәнең эченә керү. *Тәрәзәдән иңгән чоланга Моңлы айның нурлары.* Н. Исәнбәт. *Жырларыма иңеп, Уйларыма килеп, Хисләремне тарткан урын бар.* Г. Афзал.

6. Биләп алу. *Байтирәк өстенә яз киченең дымлы йомшак тынлыгы иңә башлады.* Г. Бәширов. *Өй эченә кичке караңгы иңә башлады.* М. Галәү.

7. *рәв. мәгъ. күч. диал.* **иңеп.** Бик тирән (йокы турында). *Башымны кую белән мин иңеп йокыга китәм.* Ш. Әхмәдиев.

8. *диал.* Бер нәрсәдән икенче нәрсәгә йогу (буяу турында). *Күлмәккә буяу иңү.*

9. *күч.* Ишетелү, барып җитү. *Бик каты елашкан халыкның елау тавышы күкләргә иңгән.* А. Гыйләҗев.

ИһА-һА-һАЙ *ы.* Берәр кешене яки хайванны чакыруны, аңа мөрәҗәгать итүне белдергәндә кулланыла. *Ерактанмы, тавыш ишетәмен: «Иһа-һа-һай!» Бу кем мондый төндә? Әллә салчы суга батканмы? Әллә бандит иптәшенә хәбәр итә Үзенең кайда качып ятканын?* Ф. Кәрим.

ИһАһАЙЛАУ *ф. к.* ихахайлау. *Безнең апайлар --- егетләр белән чырык та чырык килеп шаярышып туймыйлар, иһаһайлап көлеп җибәрәләр.* Г. Бәширов. *Кыз җитез тилпенеп, иһаһайлап судан чабып чыгып китте.* Э. Касыймов.

ИһАһАЙ-МИһАһАЙ *и. сөйл. к.* ихахай. *Энекәшләре күргән булса, борып кайтарып җибәрерләр иде. Ә теге иһаһай-миһаһайларга нәрсә?..* Э. Касыймов.

ИһИ *ы.* Ярату, шатлану, гаҗәпләнү, яратмау кебек хисләрне белдерә.— *Иһи! Менә кайда икән рәхәт!* Ш. Камал.— *Иһи, һи, һи, һи! Сәрби миңа үпкәләгән.* Г. Камал.— *Иһи! — диде Поцелуйкин, шатланган булып.* Г. Әпсәләмов.

ИһИҖ *ы.* Көләсе килмичә кыланып көлүне, балаларның капризаланып елавын белдергәндә кулланыла.— *Нинди гаҗәп... Иһиж, иһиж — Йотарсың телләреңне...* Н. Исәнбәт.

ИһИЭ *ы.* Акрын гына, мышкылдап елауны белдерә.— *Әбделбәр... иһиэ, иһиэ... синең... синең... ә... ә... әтиең юк диде миңа! — дип, көчкә генә әйтеп чыга Габдулла, һәм күз яшьләре аны әүвәлгедән дә ныграк буалар.* Ә. Фәйзи.

Й

Й Татар алфавитында унынчы хәреф, кыска «и».

ЙА *ы.* Соклану, гаҗәпсенү һ. б. ш. хисләрне белдерә. *Йа, кайларга кадәр җәелгән икән бу Идел!* Г. Бәширов.

ЙОГ *и.* Һиндстанда: үз эченә бикләнү, үз-үзеңне физик һәм рухи җәфалау юлы белән табигатьтән өстен көчләргә ия булырга мөмкин дигән дини-философик тәгълиматка ияруче. *Йоглар системасы буенча тән тәрбиясе күнегүләре ясау.*

ЙОГАНУ *ф. диал.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса кагылу, тотыну. *Искегә йоганма, исең китәр.* Мәкаль.

ЙОГУ *ф.* 1. Берәүдән икенчегә күчү, эләгү (йогышлы авыру турында). *Бибиҗамал апа --- туберкулезның үзенә йоккан икәнлегенә дә ышана башлаган иде.* Ш. Хөсәенов.

2. Йогынты ясау, тәэсир итү, башкаларга да күчү (хис, кәеф һ. б. турында). *Аның үз-үзен болай тотуы, табигый рәвештә, иптәшләренә дә йогып өлгерде.* Ә. Еники. // Күчү, үзләштерелү (һөнәр, сәнгать үрнәкләре һ. б. турында). *Минһаҗга тимерчелек эше күбрәк йоккан икән.* М. Шәрифуллин. *Яхшыга иярсәң, яхшылыгы йогар; яманга иярсәң, яманлыгы йогар.* Мәкаль. // *күч.* Аңга, күңелгә кереп калу (фәнне, белемне, укыганны һ. б. үзләштерү, хәтердә саклау турында). *Малайга һаман да гыйлем йокмады.* Г. Ибраһимов.— *Менә хәзер мин спектакль карадым, ә күңелемә бернәрсә дә йогып калмады.* И. Гази.

3. Буялып, ягылып калу, сеңү. *Ис йогу.* □ *Казанга якын барсаң — карасы йогар, яманга якын барсаң — бәласе йогар.* Мәкаль. *Кулъяулыгым куе яшел, кулларыңа йокмасын.* Җыр.

4. *күч.* Нинди дә булса төскә керү (кешенең йөзендә, битендә булган үзгәрешләр турында). *Суфия ханым тәмам ябыккан, йөзенә саргылт төс йоккан.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч.* Кемгә-нәрсәгә ияләшү; үзләшү, якынлашу. [*Повестьта*] *кешеләргә бик йокмыйча һәм кешеләр белән уртак тел таба алмыйча* [*йөрүче инженер Шамин образы бирелә*]. Ф. Хөсни.— *Я, Гыйлемдар кода, җиргә-суга тиендеңме? --- Ел саен диярлек, читкә чыгып --- гомер үткәрмәссең, йортка йогарсың.* Ш. Маннур.

6. *күч. гадәттә юк. форм.* Бик кыска, бик кечкенә, җиңел яки бик аз булган әйберләргә карата: эләкмәү, тоелмау (кулга, авызга, телгә). *Кече телгә дә йокмады.* Әйтем. [*Әле*] *басуда терлек авызына йогарлык шытым заты юк.* Ф. Хөсни.

ЙОГЫМ *и. диал.* Тәэсир, йогынты; шаукым. *Сабир абзый каладан кайтканда* [*атын*] *яндыра язган. --- Хәзер дә шуның йогымы бетмәгән әле.* М. Гали.

ЙОГЫМЛЫ *с. диал.* Йогынтылы, тәэсир итәрлек. *Йогымлы сүзләр белән сөйләп аңлату.* □ *Йогымлы иркенлек белән барлык Нәрсәләр шундый хуш тын ала; Күңелгә, фикергә килми тарлык, Җан үсә, шатлана, зурлана.* Н. Думави.

ЙОГЫНТЫ *и.* Кем яки нәрсә тарафыннан кемгә дә яки нәрсәгә дә булса ясала торган тәэсир. *Дошман йогынтысыннан сак булырга кирәк.* Ф. Бурнаш. *Шушы кичерешләр йогынтысы астында мин шактый вакыт оныталып тордым.* М. Әмир.

Йогынты ясау — тәэсир итү. *Художество әсәрләре сурәтләр аша тойгы һәм аңга йогынты ясый.* Г. Нигъмәти.

ЙОГЫНТЫЛЫ *с.* 1. Йогынты ясый алырлык; абруйлы, дәрәҗәле. *Йогынтылы даирәләр.* □ *Кунакка күбесе бай, йогынтылы, культуралы, авылча әйтсәк, затлы киенгән кешеләр җыелачак.* Ә. Баян.

2. Йогынты, эз калдырырлык; көчле. *Бу агитация бик йогынтылы чыкты.* Ф. Хөсни.

ЙОГЫРТ *и. бот.* Вак сары яки ак чәчәкле берьеллык яки күпьеллык үлән үсемлек (кайбер төрләре чүп үләннәр рәтенә керә, мәсәлән: *җитен йогырты*); *русчасы:* подмаренник. *Кызыл буяу йогырт дигән чүп үләне тамырыннан алына.* Робинзон эзл.

ЙОГЫРТЛЫЛАР *и. бот.* Ябык орлыклы үсемлекләр семьялыгы (йогырт, кофе агачы, хина агачы һ. б.).

ЙОГЫШ I *и. мед.* Авыру таратучы микроорганизмнар. *Йогыш чыганагы.*

ЙОГЫШ II: **йогыш килү** — йогышлы II (2 *мәгъ.*) булу. [*Саниянең*] *өстендәге карасу зәңгәр костюмы да, яңа гына үтүк астыннан чыккан нәфис ак якасы да ничектер аның йөз төсенә һәм җыйнак гәүдәсенә бик йогыш килеп, килешеп торалар иде.* М. Әмир. **Йогыш китерү** *диал.*— чамалау, нәрсәгә дә булса юрау.— *Азагын үзең йогыш китереп аңларсың инде.* М. Әмир.

ЙОГЫШЛАНУ *ф.* 1. Йогышлы авыру эләктерү, йогышлы авыруга дучар булу. *Грипп белән балалар бигрәк тиз йогышланалар.* Азат Хатын.

2. *күч. сир.* Нәрсәнең дә булса йогынтысына, тәэсиренә бирелү, шуның белән мавыгу. *Абстракционизм чире белән бездә аерым художниклар гына йогышланды.* Каз. утл.

ЙОГЫШЛЫ I *с.* Йога торган, күчә торган (авырулар турында). *Йогышлы авыру пычрак җир эзли.* Мәкаль.— *Синең улың тиф белән авырый, ә ул йогышлы авыру.* Ш. Камал. // *күч.* Начар, зарарлы тәэсир итүчән, йогынты ясаучан. *Һәрбер начар авыру кебек, начар фикерләр дә йогышлы була.* Г. Ибраһимов. [*Сугышның*] *сөреме алама чир шикелле йогышлы иде.* М. Шабай.

ЙОГЫШЛЫ II *с.* 1. *сир.* Ягымлы, сөйкемле. *Йогышлы караш.* □ *Йогышлы итеп көлә торган Надя белән мин беренче тапкыр әнә шулай очраштым.* Р. Төхфәтуллин.

2. Килешле, таман (кием турында). *Аның төрле-төрле киемнәре булмаса да, өстендәге бер кат киеме һәрвакыт соңгы мода белән тегелгән йогышлы киемнәр булган иде.* Ф. Әмирхан.

ЙОГЫШЛЫЛАНДЫРУ *ф. сир.* Йогышлы II (2 мәгъ.) итү. *Биек ак яка аның озынчарак кына муенына бик килешә, хәтта аның өстендәге гадәтчә пиджагын да әллә ничек матурлатып, --- йогышландырып җибәрә иде.* Ф. Әмирхан.

ЙОГЫШЛЫЛЫК I *и.* Йогышлы I булу сыйфаты. [*Бу авыруларның*] *кайберләрендә йогышлылык юк диярлек.* Ш. Камал.

ЙОГЫШЛЫЛЫК II *и.* Йогышлы II булу сыйфаты. *Елмаеп көлүләренең йогышлылыгы. Киеменең йогышлылыгы күзгә нык ташлану.*

ЙОГЫШСЫЗ *с. сир.* **1.** Йогышлы II нең киресе. *Йогышсыз елмаю. Йогышсыз кием.*

2. Тәртипсез, гадәтсез. *Йогышсыз бала.* □ [*Шәмсинур ирена:*] *Бу нинди йоклламаган бәндә икән... Шушының бетмәс инде, и йогышсыз да инде.* С. Рафиков. // Ошамый торган, кире хис уята торган. *Йогышсыз бәйләнчеклек.* □ *Симез үрдәкне хәтерләткән бу хатында күңелгә йогышсыз нидидер бер нәрсә бар иде.* А. Гыйләҗев.

3. Кылешсез, ятышсыз, гадәтләнмәгән. *Госман --- тупас вә йогышсызрак хәрәкәтләр белән Әсма һәм үзенең икенче ягындагы күршесе кызга хезмәтләр күрсәтергә тырыша.* Ф. Әмирхан.

ЙОГЫШСЫЗЛАНДЫРУ *ф. сир.* Авыру тарата торган микробларны бетерү; дезинфекцияләү.

ЙОГЫШСЫЗЛЫК *и.* Йогышсыз булу сыйфаты. *Фатыймага бирелгән җавабының йогышсызлыгы белән пошынып, Шакир --- бүлмәгә чыкты.* Ф. Әмирхан.

ЙОГЫШУ *ф. диал. к.* йогу 5. [*Зарифның*] *бу халыкка күңеле йогышып җитми бугай.* Ш. Камал.

ЙОД *и.* **1.** Гадәттә диңгез суүсемнәреннән алына торган көрән төстәге химик элемент. *Йод кристаллары.*

2. Медицинада куллану өчен шул элементның спирттагы эремәсе. *Ярага йод сөртү.*

ЙО'ДА *и. сөйл. к.* йод. *Лотфулла абзый --- чуан авызын йода белән майлады, яңа мамык ябып, ак марля белән урады.* Г. Ахунов.

ЙОДЛАУ *ф.* Теге яки бу әйбергә йод кристаллары кушу. *Аш тозын йодлау.*

ЙОДЛЫ *с.* Составында йод булган, йод катнашкан. *Йодлы металлар.* □ *Йодлы океан һавасында озон һәм «һава витамины» — кире ионнар күп.* Р. Мостафин.

ЙОДОФОРМ *и. махс.* Йодтан эшләнгән препарат (дару) — бик көчле исле сары кристаллар (медицинада йогышсызландыру чарасы буларак кулланыла).

ЙОДРЫК *и.* **1.** Бармаклары уч төбенә кысып йомарланган кул очы. *Йодрык зурлыгында.* □ *Марат, күз яшьләрен йодрыгы белән сөртеп, елап тора --- иде.* Г. Гобәй. *Курыккан башлап йодрык күтәрә.* Мәкаль.

2. *күч.* Физик җәза, кыйнау. *Юләргә йодрык кына акыл кертә ала.* Әйтем. *Ул җилкәгә байның йодрыгыннан, Камчысыннан каннар укмашкан.* Н. Баян. // Корал көченә яки физик көчкә таянып буйсындыру, куркыту турында. *Йодрык белән эш итү.* □ *Элек империалистлар колония һәм бәйле илләр халыкларына каршы көрәштә йодрыкка исәп тоткан булсалар, хәзер алар төрле интригалар, --- экономик шантаж методларын һаман ешрак кулланалар.* Соц. Тат.

3. *күч.* Бергә тупланган сугышчан көч. *Көчләр алгы сызыкка тупланып тыгызланды — корыч йодрыкка әверелде.* Х. Госман. *Лагерьда коммунистик йодрык барлыгын фашистлар нык сизделәр.* Н. Дәүли.

◇ **Йодрык ашау (алу)** — кыйналу, җәбер-золым күрү. [*Солдат икенче солдатка:*] *Ефрейтордан бүген ничә тапкыр йодрык алдың?* Т. Гыйззәт. [**Бер**] **йодрык булып** — бердәм көч булып. *Бер йодрык булып оешмаган коллектив, үз хуҗалыгыннан, крестьян психологиясеннән аерылып та бетмәгән эшчеләр --- ялгыш юлга кереп киттеләр.* А. Гыйләҗев. **Йодрык кесәдә** — *к.* йодрыкны кесәгә тыгып йөрү. *Дөрес, Микъдат йомшарды, шулай да --- аның йодрыгы әле кесәсендә.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Йодрык күрсәтү (иснәтү, төю, сугу)** — янау, куркыту. *Бу җавап хаты, --- соңгарак калып булса да, бер йодрык күрсәтү булачак.* Ф. Хөсни.— *Өченче көн* [*Әпрәү*] *Гатау абыйга бәйләнгән була. Гатау абый йодрыгын гына иснәтә.* М. Фәйзи. **Йодрык сугышы** *иск.*— 1) борынгы Грециядә спорт уеныңың бер төре; *к.* бокс I. 2) революциягә кадәрге Россиядә боз өстендә үткәрелә торган бергә-бер кул сугышы (гадәттә кара-каршы сугышучылар төрле милләт вәкилләре булып, ахырда бу сугыш милләтләр арасындагы дошманлык утын көчәйтүгә сәбәпче булган). *Йодрык сугышы Камалига хәтле үк булып килгән кыргый бер гадәт иде.* К. Нәҗми. *Йодрык сугышы бер Казанда гына түгел икән,— дип уйлады Хөсәен.* А. Расих. **Йодрык хокукы**—көчлеләрнең көчсезләр өстеннән иректезләп хакимлек итүе; законсызлык. **Йодрык эчендә тоту, йодрык эченә алу** — буйсындыру, буйсынырга мәҗбүр итү (көч белән). [*Федоров:*] *Әгәр --- бер полк гаскәр булса, без бөтен шәһәрне тимер йодрык эчендә тота алган булыр идек.* Ф. Сәйфи-Казанлы.— *Тукта, малайлар, мин сезне тимер йодрык эченә алырмын. Күрмәгәнегезне күрсәтермен.* Ш. Усманов. [**Бер**] **йодрыкка туплау** — төп максатка юнәлтү өчен көчләрне бер урынга җыю турында.— *Барлык көчебезне бер йодрыкка туплыйк та шуның белән дошманның башына кундырыйк.* Г. Әпсәләмов. **Йодрыкны кесәдә (кесәгә тыгып) йөртү (йөрү)** — үч алырга, һөҗүм итәргә уңайлы момент көтеп йөрү. *Фәттахларның Габдуллага каршы чыгулары --- йодрыкларын кесәгә тыгып йөрүдән ары узмады.* Ә. Фәйзи. **Йодрыкта тоту** — 1) тулысынча буйсындыру; 2) үз-үзеңне нәрсә дә булса эшләүдән тыю. *Габитовның үзенең дә ачуы кабара башлады, ләкин ул үзен «йодрыкта тотып» сөйләргә тырышты.* И. Гази. **Йодрыктан баш чыкмау**— кыйналып, җәберләнеп яшәү.

ЙОДРЫКЛАУ *ф.* **1.** Бармакларны уч төбенә кысып йому, йомарлау. *Малай, тешләрен шыгырдатып, кулларын йодрыклады.* Г. Гобәй. // *рәв. мәгъ.* **йодрыклап.** Йодрык белән. *Подполковник, аягына баскан көйгә, йодрыклап өстәлгә сук*[*ты*]. М. Гали.

2. *сөйл.* Сугу яки кыйнау (йодрык белән). *Мансур, тәкатьсез булып, тәрәзә рамын йодрыкларга кереште.* А. Расих. // *күч. сөйл.* Каты тәнкыйтьләү. [*Сез*] *бу газетаның --- җитешсез якларны шактый йодрыклаганын күреп үттегез.* А. Алиш.

ЙОДРЫКЛАШУ *ф. күч. сөйл.* Кыйнашу, сугышу (үзара). *Эш йодрыклашуга барып җитү. // рәв. мәгъ.* **йодрыклашып.** Йодрык белән һөҗүм итеп. *Мондый вакытта сүз көрәштереп талашырга да, йодрыклашып кыйнашырга да ярамый.* Г. Минский.

ЙОДРЫКЧА *и. тех.* Үзенең чыгынтысы белән этәреп, нинди дә булса машина механизмын хәрәкәткә китерә торган деталь. *Йөрәк сыман йодрыкча. Кабатлы йодрыкча. Бору йодрыкчасы.*

ЙОДРЫКЧАЛЫ *с.* Йодрыкчага бәйләнешле; йодрыкчасы булган. *Йодрыкчалы вал.*

ЙОЗАК *и.* **1.** Нәрсәне дә булса ачкыч белән бикләү өчен эшләнгән җайланма: бик, бикләвеч. *Асма йозак. Богау йозак. Эчке йозак. Йозак теле.* □ *Дачаларның ишекләре йозакларга бикләнде.* К. Тинчурин.

2. Ату коралы затворы. *Пулемет йозагы. Туп йозагы.* □ *Винтовка йозагы шакылдавы ишетелде.* Ш. Усманов.

3. *күч.* Берәр нәрсәнең барлыгы яки булуы өчен ин әһәмиятле шарт. *Ашлыкның йозагы — салам, акчаның йозагы — саран.* Мәкаль.

◇ **Йозак салу** — йозак белән бикләп кую. *Күршеңне гаепләгәнче, ишегеңә йозак сал.* Н. Исәнбәт. **Йозакта тоту** — бик (йозак) астында саклау.

ЙОЗАҚЛАУ *ф. сөйл.* Йозак белән бикләү. *Ишекне йозаклап кую.* □ *Мин, көймәмне йозаклап, ишкәкләрне алып азапланганда, югарыдан ике тавыш ишетелде.* Г. Ибраһимов.

ЙОЗАҚЛЫ *с.* 1. (Йозак белән) бикләнә торган. *Йозаклы портфель.* □ *— Бир йөгәнеңне, әткәй. Теге мин [солдатка] киткәндә калган йозаклы богау хәзер дә бардыр бит, аны да алыйм.* Г. Галиев.

2. Йозак белән бикләнгән, йозакланган. *Җир йөзе шундый киң, Күңелле һәм якты! Тик төрмәм караңгы, Ишеге йозаклы.* М. Җәлил. [*Сәгыйтьне*] *йозаклы ишек каршы алды.* Р. Төхфәтуллин.

◇ **Йозаклы тел белән яшәү** — үз фикерләреңне, карашларыңны ачыктан-ачык әйтү, сөйләү мөмкинлегеннән мәхрүм булу. [*Мусаның*] *шушындый богаулы иректә йозаклы тел белән яшәүгә ачуы килде.* Ш. Маннур.

ЙОЗАҚЧА *и.* Кечкенә йозак.

ЙОЗАҚЧЫ *и.* 1. Йозак ясаучы, йозак эшләре остасы.

2. *хәрби.* Тупны корып торучы. *Менә һаҗәр Степанов расчетының яраланган йозакчысына ярдәм күрсәтә.* Г. Әпсәләмов.

ЙОЗАҚЧЫЛЫҚ *и.* Йозакчы булу. *Минем йозакчылык һөнәрем файдаланылмыйча ята иде.* Ш. Усманов.

ЙОКЛАТҚЫЧ *с.* 1. Йоклата, йокыга талдыра торган (дару, укол турында). *Йоклаткыч дару эчү.* □ [*Әлбинә*] *Гөлсинәдән ике-өч йоклаткыч таблетка сорап алды.* Э. Касыймов.

2. *күч.* Йокы китергеч, эчпошыргыч.

ЙОҚЛАНУ *ф. з-сыз.* Йокы хәле турында. *Бик каты йокланган.* А. Расих.

ЙОҚЛАТУ *ф.* 1. Йокы хәленә китерү.— *Кулен бала йоклата.* Т. Гыйззәт. *Күзләреңнән күз алмыйча, Назлап йоклатыр идем.* Ә. Ерикәй. // Берәр төрле чара белән йокларга мәҗбүр итү. *Наркоз белән йоклату. Гипноз белән йоклату.* □ *— Теге кеше Тарабаровның стаканына йоклата торган дару салып эчерткән.* Г. Камал.

2. *күч. эвф.* Үтерү, агулап үтерү.

ЙОҚЛАУ *ф.* 1. Йокы хәлендә булу, йокыга китү. *Командир һичбер солдатка йокламаска, йоклаганнарны уята торырга әйтте.* М. Гали. // *күч.* Җансызлык, тынлык урнашу, тынып калу. *Авыл йоклаган, утлар сүнгән иде.* А. Шамов. *Кыш урталары, җир йөзе кар юрганына төренгән, йоклый.* С. Җәләл.

2. *күч.* Гамьсезлек, ваемсызлык күрсәтү; акрын кыймылдау. *Пулеметның атмавына башкаларның да эче поша башлады. --- Кайсыдыр сүгенеп тә алды: — Әй, нәрсә йоклыйсың син анда?!* Г. Бәширов. *Булат уйлый... «Чыннан да, ник Мин кешеләргә хат ташыйм, Ә үзем ник хатлар язмыйм, Ник болай йоклап яшим?»* М. Җәлил. // *күч.* Куелган максатка ирешү юлында бернәрсә дә эшләмәү, тик яту. [*Галләм хажи*] *хәзергә мылтыкка үк тотынырлык эш күрми. --- Шул үк вакытта йоклап ятар чак түгеллеген дә сизә.* Ф. Хөсни.— *Җәмәгать, сез дә йокламагыз, бу җирләр безгә тиеш икән, --- бүлә башларга кирәк.* М. Шабай. // Тынычлану. *Йокларга ярамый, әле көрәш бетмәгән.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Үсмәү, алга китмәү, туктап тору. *Уян, милләт, йоклама инде.* Г. Тукай.— *Тарих ул йокламый. Һаман алга бара.* К. Тинчурин.

4. *с. мәгъ. күч. сөйл.* **йоклаган.** Сүлпән, дәртсез. *Йоклаган йөрәкләрне дә уята торган чагың, Бар дөньяны оныттырып уйната торган чагың.* Ш. Галиев. // *и. мәгъ. шелт.* Җебегән, булдыксыз. [*Двор хуҗасы Йосыфка:*] *Әллә башыңны югалттыңмы, йоклаган!* К. Нәҗми.

Йоклаган бөреләр *бот.*— вегетация чорында, шартлар булмау сәбәпле, ачылып үсә алмый калган бөреләр.

◇ **Йоклап калу** — 1) сизгерлек, уяулык күрсәтмәү. *Мылтыгыңны ал, Батыраеп алга! Дошман килмәсен. Син йоклап калма!* Г. Камал; 2) мөмкинлектән файдаланмау, ваемсызлык күрсәтү. *Губземотделга алтмышлап ат килә, диләр. Йоклап калырга ярамый. --- Үзебезгә ышандырган унны алсак, эш рәтләнә дигән сүз.* Ш. Камал. **Йоклап эшләү** — иренеп, җиренә җиткермичә, начар эшләү.— *Малга сукмыйм,— диде Газинур,— әмма йоклап эшләгән күзле бүкәнгә суккан булыр идем.* Г. Әпсәләмов.

ЙОКТЫРУ *ф.* 1. Эләктерү, күчерү (чирне, йогышлы авыруны). *Грипп йоктыру.* □ *Бары билгеле бер шартлар тудырылса гына, [бодай] үзенә гөмбә чирен йоктыра.* А. Расих.

2. Берәр төрле һөнәр, гадәт яки характер сызыгын икенче кешегә күчерү, шундый йогынтыга дучар итү. [*Бозык кешеләр*] *эшәкелекләрен башкаларга йоктырмасыннар.* М. Әмир.

ЙОКЫ *и.* 1. Билгеле бер вакыт арасында кабатланып торган һәм аң эшчәнлегенең тулысынча яки өлешчә тукталып торуы белән бәйләнешле физиологик тынычлык, организмның ял итү хәле. *Йокыдан уяну. Татлы йокы.* □ *Йокы мине үзенең татлы кочагында тирбәтә-тирбәтә бөтен тәнемә татлы рәхәтен сеңдерә, --- иркәләп, үземә дә сиздермичә генә күзләремне йомдыра.* Г. Бәширов. *Шул кичне йокымда --- миңа да төш артыннан төш күренде дә торды.* Г. Тукай.

2. *күч.* Гомуми тынлык, хәрәкәтсезлек. *Җир йөзен баскан тирән йокы, Тынлык урамнарда, базарда.* М. Гафури. *Бөтен авыл йокыда.* М. Әмир.

Йокы авыруы — тропик Африкада һәрвакыт йокы килү, еш баш авырту, бизгәк тоту белән үтә торган йогышлы авыру. **Йокы артериясе** — муенның ике ягына урнашкан зур куш артерия. [*Зиннурның*] *кул пульсының ритмы зәгыйфь, йокы артерияләрен бөтенләй капшап булмый.* Г. Әпсәләмов. **Йокы бүлмәсе** — йоклау өчен билгеләнгән бүлмә. **Йокы капчыгы** — 1) ачык һавада йоклау өчен махсус җайлаштырып тегелгән капчык. *Идрис --- йонлы тиредән тегелгән йокы капчыгының өстенә ташланды.* Ә. Айдар; 2) *күч. гади с.* күп йокларга яратучы.— *Әй, йокы капчыклары! --- Көн уртасында хырылдап ятасыз,— дип,* [*Кәбир*] *шинелен киеп тышка чыкты.* Ш. Усманов.

◇ **Йокы алмау (кермәү)** — йоклый алмыйча яту, йоклый алмау. *Була кайчак авыр, озын төннәр. Йокы алмый, күңел борчыла.* М. Җәлил. *Ятсам йокы кермидер.* Т. Гыйззәт. **Йокы ачылу (таралу)** — уянып, йокы хәленнән тәмам айну.— *Алайса мин сиңа бер сүз әйтим, берьюлы йокың ачылыр.* Ә. Фәйзи. *Күзләрен ачуга,* [*Газинурның*] *бөтен йокысы таралды.* Г. Әпсәләмов. **Йокы аралаш (арасында)** — йокы белән өн арасында, йоклар-йокламас. *Әйдүк йокы аралаш сүзен кайдан башларга белми торганда, урамда Караборын ачы-ачы өрә башлады...* Һ. Такташ. *Кайчагында йокы арасында Ыңгыраша әрнеп кечкенәм!* М. Җәлил. **Йокы базарына китү** — йоклап китү, йокыга талу.— *Юл йөреп арыганнардыр инде, бичаралар, әнә курайчы малай да йокы базарына китеп барды.* М. Шабай. **Йокы басу** — бик каты йоклыйсы килү, ярым йокылы хәлгә җитү. *Нәрсәдәндер күз эленгән, һәм тәмам баскан йокы.* Г. Тукай. **Йокы качу (очу)** — йоклый алмау (тирән кичерешләр, борчылулар һ. б. аркасында). *Сугыш башланганнан соң,* [*Тимеринең*] *бөтенләй йокысы качты.* Г. Бәширов. **Йокы китергеч** — йокымсырата торган; эчпошыргыч, күнелсез. *Кайдадыр шунда, бодай төбендә, йокы китергеч итеп, чикерткә черелдәргә тотынды.* Г. Гобәй. **Йокы симертү (бүсү, сүтү)** *гади с.*— йоклау (гадәттә күп, озак йоклау, вакытлы-вакытсыз йоклау турында). *Икенче якка әйләнеп ятып, тагын да аз гына йокы симертергә исәп бар иде дә, туры килмәде.* Г. Мөхәммәтшин. [*Егетләр*], *рәхәтләнеп, мышный-мышный йокы бүсәләр.* А. Гыйләҗев. *Гажәби карчык сәкедә йокы сүтә иде.* А. Расих. **Йокы чүлмәге** — *к.* йокы капчыгы 2. [*Хәлим*

малайларга:] *Торыгыз, йокы чүлмәкләре! Иртәнге матур сәгатьләрне күрми каласыз.* И. Гази. **Йокыга китү** — йокы хәленә күчү. *Һәркайсы, үз хыялларына, үз уйларына бирелеп, йокыга киттеләр.* А. Шамов. **Йокыга талу (чуму, ою)** — татлы, тыныч йокыга китү. *Кыз иңенә башын куеп, Егет йокыга талды.* М. Җәлил. **Йокыдан калу** — йоклый алмау; йокысызлык белән интегү. [*Мәүлиха түти:*] *Инде монысына көчебез җитмәс --- дип, җаннарың өши, йокыдан каласың.* Г. Бәширов. **Йокыдан уяну** — 1) политик наданлыктан котылу, аңлы көрәшкә күтәрелү. *Вакыт үтә. Изелгәннәр йокыдан уяна башлыйлар.* М. Мәхмүтов; 2) актив эшчәнлек күрсәтү. [*Айрат*] *үз күл астындагы бюро членнарын йокыларыннан уятты.* Г. Ахунов.

ЙОКЫЛЫ *с.* Йокысы туймаган, йокыдан арына алмаган. *Барый, әле һаман йокылы күзләрен ачалмыйча, өстәл башына килеп утырды.* Н. Фәттах. // *күч.* Надан, политик аңсыз, пассив. *Үз түбәсендә кара болытның куерганын, яшен ялкыннары уйнавын күргәч, татарның авыр йокылы катламы да сискәнде.* Г. Ибраһимов.

ЙОКЫЛЫК *и.* 1. Яшь бала башындагы кавык.

2. Кайбер яңа туган балаларның аркасында була торган чәч сыман каты төк.

ЙОКЫЛЫ-УЯУЛЫ *рәв.* Йокы белән өн арасында, йокы аралаш. *Төнне йокылы-уяулы үткәрдек.* Г. Әпсәләмов. *Каты мендәрдә йокылы-уяулы миңгерәп ятса да, матур төш керә Гәрәйгә.* А. Гыйләҗев.

ЙОКЫМСЫРАУ *ф.* 1. Ярым йокылы хәлгә килү, йокы басып изрәү. *Әллә ничек йокымсырап киткәнмен.* Г. Камал. *Ишек алларында сыерлар, бозаулар йокымсырый.* Г. Бәширов. // *күч. шигъ.* Тынып калу, хәрәкәтсез калу. *Бер карасаң, бар табигать йокымсырап утыра.* Э. Ерикәй.

2. *күч.* Ваемсызлану, һичнәрсә белән кызыксынмау. *Салих соңгы вакытларда бернигә борчылмый йокымсырап яши башлады, һәм аның үз дөньясы да Салих белән бергә йокымсырады, тынды.* Г. Мөхәммәтшин.

ЙОКЫМСЫРАТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* йокымсырау.

2. *з-сыз.* Йокы килеп тору, изрәп китү турында. *Бөтен тән оеп, йокымсырата башлау.*

ЙОКЫМСЫРАУЛЫ *с.* Ярым йокылы хәлдә була торган. *Йокымсыраулы тавыш.* ☐ *Мине каты суык һәм йокымсыраулы ят бер тынлык чолгап алды.* Г. Камай.

ЙОКЫСЫЗЛЫК *и.* Аз, начар йоклау яки бөтенләй йокламау хәле. *Яшькә җитте Мария, газапланды Йокысызлык белән кичләрен.* Ш. Мөдәррис. *Ул, йокысызлыктан кызарган күзләрен салонның киң тәрәзәсе аркылы далага текәп, нидер карап тора башлады.* Ш. Усманов. // Дәвамлы, авыруга әйләнгән йоклый алмаучылык хәле. *Бай карчык йокысызлык белән авырый иде.* Г. Тукай.

ЙОКЫЧАН *с.* Йокы яратучан, күп йоклаучан. *Йокычан егеттә дәрт булмас.* Мәкаль. *Иренчәк йокычан булыр.* Мәкаль.

ЙОКЫЧЫ, ЙОКЫЧЫЛ *с. сөйл. к.* йокычан. *Йокычы иснәр, гашыйк киерелер.* Мәкаль.

ЙОЛА *и.* Теге яки бу халыкның яшәешенә борыннан кереп урнашкан тормыш-көнкүреш традицияләрен яки дини кануннарны үтәүгә бәйләнешле тәртип һәм гадәтләр; гореф-гадәт. *Туй йоласы. Дини йолалар.* ☐ [*Карл Федорович:*] *Татар йолаларын белүдә без бик наданнарбыз икән әле, Насыйр Хөсәенович.* М. Гали. *Канга сеңеп калган иске гадәт, Иске караш, иске йолалар Яңа кешенең туып үсүенә Киртә булып чыгып торалар.* Һ. Такташ. //Күпчелек тарафыннан кабул ителеп, гадәткә кереп киткән нинди дә булса күренеш. *Ленин мавзолеена бару — ул инде күптәннән үк бер яхшы гадәт, күңелне пакьләндерә торган изге бер йола булып әверелгән.* Г. Бәширов.— *Хәзер инде кыз ябыштырып чыгару йола булып китте.* Г. Камал. // *с. мәгъ.* Нинди дә булса йолага караган. *Йола җырлары.*

◇ **Йоласын китерү** — теге яки бу вакыйгага караган йолаларны җиренә җиткереп үтәү. *Өйгә яшь килен килү вакыйгасын коры килеш калдыру мөмкин түгел, йоласын китерергә кирәк иде.* Ф. Хөсни.— *Әйдә, дуслар, җырлап бирик, китерик туйның йоласын.* Г. Камал.

ЙОЛАЛАУ *ф. сөйл.* Кабул ителгән йоланы башкару, йола буенча эш итү. *Йолалап йөрү.* ☐ *Никрут булгач, азрак йолаларга кирәк бит. Без дә тиңдәшләр белән, сыралар куеп, кайгыларны урамнарга түгә башладык.* М. Крыймов.

ЙОЛАЛЫК *и. сир. к.* традициялелек. *Уткән әдәби мирас һәм йолалыкның дәвамлы булучанлыгын кайбер көй исемнәре һәм җыр калыпларының саклануларыннан да күрергә була.* Н. Исәнбәт.

ЙОЛА'ЧА *рәв.* Кабул ителгән йола буенча. *Туйны йолача үткәру.*

ЙОЛАЧЫ *и.* Һәртөрле йолаларны төгәл үтәүче, саклаучы. *Ак җайдаклар төркеменең башында, озын саплы ал байрагын күтәреп, ыруның өлкән йолачысы Утташ бара.* Н. Фәттах.

ЙОЛДЫЗ *и.* 1. Үзенең табигате белән кояшка охшашлы, гади күзгә яктырткыч нокта рәвешендә генә күренә торган күк җисеме. *Йолдызлар тупланышы. Йолдызлар нурланышы.* ☐ *Караңгы күк йөзен аксыл җәүһәр кисәкләре төсле балкып торган хисапсыз шаян йолдызлар бизи.* Ш. Камал. [*Мөнирә*] *гомерен яңа йолдызлар табуга багышлаячак.* Г. Әпсәләмов.

2. *тарт. форм. ирк. шигъ.* **йолдызым.** Ярату, иркәләү хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Йокла, углым, йом күзең, Йом-йом күзең, йолдызым.* Г. Тукай.

3. *күч.* Нәрсәгә дә булса юнәлеш, көч, рух биреп торучы чыганак. *Авылда без — Октябрь кабызып җибәргән йолдызлар идек.* Г. Кутуй. *Һәр җырчының илһам йолдызы син, Баемаска туган кояш син.* Э. Ерикәй.

4. Язмыш, өлеш; бәхет. *Мәхәббәт йолдызы.* ☐ [*Гайния Гөлбануга:*] *Бәхетең каралып бара, йолдызыңны болыт каплый.* Г. Ибраһимов. *Тормышта һәркемнең үз йолдызы булырга тиеш.* Б. Камалов.

5. *күч.* Атаклы, күренекле, нәрсә белән булса да дан казанган кеше турында. *Шахмат йолдызы.* ☐ *Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул.* Г. Тукай.— *Минем кызым да, әнкәсе кебек, мәшһүр артистка булсын! Әнисе — йолдыз, кызы — йолдызның йолдызы!* Г. Әпсәләмов. // Нәрсәнең дә булса күрке, яме, горурлыгы, мактанычы.— *Сарай йолдызы олуг ханбикә килә.* Н. Исәнбәт. *Аш җыелуга өстәлләрдән өскә ашъяулыклар алынып, мәҗлеснең йолдызы булган лото уены башланды.* Қ. Тинчурин.

6. Очлы башлы чыгынтылары әйләнә буенча бердәй ераклыкта урнашкан геометрик фигура; шундый фигура формасындагы предмет. *Очкыч, ящел буяуга буялып, гажәп матур итеп эшләнгән иде. Канатларындагы йолдызлар янып, кызарып торалар.* А. Әхмәт. [*Төргәкнең*] *эчендә груша агачыннан ышкып, сырлап ясалган бик матур бишпочмаклы бер йолдыз ята иде.* А. Шамов. // Фуражкага, бүреккә һ. б. беркетеп йөртелә торган шундый формадагы хәрби значок. *Аларның [кызылларның] очлы башлы бүрекләрендә кызыл йолдызлар ялтырый.* Һ. Такташ. // Хәрби дәрәҗәне күрсәтә торган шундый ук формадагы кечкенә билге (гадәттә, погоннарга беркетелә). [*Мөхәммәтнең*] *погоннарында тагын бер йолдыз арта: ул капитан була.* Г. Кутуй. // Шундый формада ясалган орден, батырлык билгесе. *Маршал йолдызы.* ☐ *Ике йолдыз күкрәгендә... Кем карамас туктатып.* Ә. Ерикәй.

Йолдыз атылу — уттай кызган космик җисемнең җир атмосферасында бик кызу хәрәкәт итеп юкка чыгу күренешенә әйтелә. *Баш очларында гына йолдыз атылды: күк чатыры буйлап кадалып төште дә, көмеш эз калдырып,*

чәчелеп юк булды. И. Гази. **Йолдыз елы** *астр.*— кояшның күк сферасы буенча йолдызларга мөнәсәбәттә күренмәле юл үтә торган вакыт арасы. **Йолдыз кашка** — маңгаенда ак тап булган ат. *Йолдыз кашка җирән атымны Көчкә тыеп барам.* Ф. Кәрим. **Йолдыз тәгәрмәч** *тех.*— тешле тәгәрмәч. *Лебедканың йолдыз тәгәрмәче шалт та шолт,— бушап беткән, тешләре чылбырны тотмый.* И. Гази.

◇ **Йолдыз яңгыры** — бик күпләп йолдыз атылу күренеше. **Йолдыз күрсәтү** — уен (бу уенны белмәгән бер кешегә, идәнгә ятып, җиң аша түшәмгә карарга кушалар һәм сиздермичә генә җиң очыннан аның йөзенә су коялар, шул йолдыз күрсәтү була).— *Ә хәзер йолдыз күрсәтик без сиңа. Түшәм аша йолдыз күргәнең юктыр ич әле синең?* Г. Гобәй. **Йолдыз санау**—1) гамьсез яки эшсез йөрү. *Иркәм белән йолдыз санар чакта Танк астында яндым — каралдым.* М. Хөсәен.— *Мин эш кешесе. Йолдыз санарга вакыт юк.* Ю. Әминов; 2) уен (кичәдә, «җәза бирү» тәртибендә, кыз белән егетне тышка, ишек төбенә, аулакка чыгаралар). *Уен вакытында аларның икесен* [*Марат белән Нурияне*] *«йолдыз санарга» чыгардылар.* Г. Әпсәләмов.

ЙОЛДЫЗАК *и. бот.* Канәфер чәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык үсемлек; *русчасы:* звездчатка. *Бу үсемлек һәрвакыт, хәтта һавалар коры торганда да тотып карауга юеш төсле була. Бу үләннең исеме — йолдызак.* Робинзон эзл.

ЙОЛДЫЗАРА *с.* Йолдызлар арасындагы; йолдызлар арасында була торган. *Йолдызара ераклык. Йолдызара пространство.* // Йолдызлар арасында башкарыла торган. *Йолдызара очыш.*

ЙОЛДЫЗЛАНУ *ф.* **1.** Йолдыз формасына килү, керү.

2. *күч.* Балку, нур чәчү (күзләр турында). *Егет сайлаучы Кыз картайды. --- Күзенең йолдызланган нурларын да ирсез үткән гомерләр урлаган.* Г. Тукай.

ЙОЛДЫЗЛАП: йолдызлап тоташтыру *физ.*— өч фазалы ток чылбырында статор кәтүкләренең ахыргы очларын бергә генераторның (яки трансформаторның) нуль ноктасы белән, баш очларын бергә электр челтәре белән тоташтыру.

ЙОЛДЫЗЛЫ *с.* **1.** Йолдызлар (1 мәгъ.) белән капланган, йолдызлар балкып торган. *Мин карыйм күкләргә йолдызлы кичләрдә.* Э. Ерикәй.

2. Йолдыз (6 мәгъ.) беркетелгән. *Йолдызлы шлем.* ▭ *Башларда йолдызлы Өр-яңа фуражка.* Қ. Нәҗми. // Йолдыз сыман бизәк төшерелгән, ясалган, чигелгән; йолдызлар (6 мәгъ.) белән бизәлгән. *Мин дә, --- йолдызлы кызыл кәләпүшемне киеп, тиз генә чәй эчеп, урамга чыктым.* М. Гали.

3. Төрле яктан бер ноктага (пунктка) килә торган. *Йолдызлы эстафета. Йолдызлы йөзеш.*

4. *күч. шигъ.* Якты, бәхетле; уңышлы. *Минем гомерем караңгы төн, кояшым һәм аем тугмас; Шуңар да шөкер итәм мин, бу төнем йолдызлы, йолдызлы.* Г. Тукай.— *Юлларыгыз йолдызлы булсын,— дим мин, Валентина һәм Андриян белән саубуллашып.* Қ. Латыйпов.

◇ **Йолдызлы су** — коньяк. *Мин, гомумән, җае туры килгәндә, йолдызлы сулардан баш тартмыйм.* Г. Әпсәләмов.

ЙОЛДЫЗЛЫК *и. астр.* **1.** Бер исем астына берләштерелгән йолдызлар төркеме. *Зур Җидегән йолдызлыгы.*

2. *күч.* Чибәрлек, күркәмлек.— *Безнең йолдызлык беткән инде, энем. Карт жиңгәләреңне йолдызга тиңләп* [*җырлап*] *юатуыңа рәхмәт.* М. Фәйзи.

ЙОЛДЫЗНАМӘ *и. иск.* Йолдызларга карап күрәзәлек итә, фал ача торган китап. *Йолдызнамә миңа таныш, Тик мин укып йөрмим Язмыш сүзен, йолдыз санап.* Ш. Мөдәррис.

ЙОЛДЫЗНАМӘЧЕ *и. иск. к.* йолдызчы.

ЙОЛДЫЗЧА *и. махс.* Чылбырлы тапшыргычта: тешле тәгәрмәч. [*Тракторның*] *гусеницаны хәрәкәткә китерүче арткы тәгәрмәче, --- ияртүче йолдызча, үз урыныннан ычкынып, читкәрәк күченгән булырга тиеш.* Н. Фәттах.

Йолдызча зурлык *астр.*— йолдызларның яктылык дәрәҗәсен характерлый торган астрономик үлчәү берәмлеге.

ЙОЛДЫЗЧЫ и. **1.** иск. Йолдызларга карап күрәзәлек итүче; астролог. *Бераз йолдызчылар бардыр ки, күктән йолдыз эзлиләр, Түбәнгә күз дә салмыйлар, һаман күкләрне күзлиләр.* Г. Тукай.

2. Йолдызларны өйрәнү белгече; астроном. *Кайчак җир сөрүче буласы килә. Кайчак — галәм белән юанасы йолдызчы галим булып.* Р. Фәйзуллин.

ЙОЛДЫЗЧЫК *и.* **1.** *кеч. к.* йолдыз 6. *Күлмәгендә балкый йолдызчыклар, Балкыгандай Зөһрә йолдызы.* Ж. Тәрҗеманов.

2. *махс.* Китапларда, кулъязмаларда төрле максатлардан чыгып кулланыла торган шартлы билге. *К. Насыйри ноктадан башка билгене кулланмый, һәм әле аның ноктасы да йолдызчыктан --- гыйбарәт.* Л. Җәләй.

ЙОЛКУ *ф.* **1.** Тамырланып үсеп утырган берәр нәрсәне тартып чыгару яки тамыры белән өзеп алу; тартып, өзеп-өзеп алу (җыю яки тазарту өчен). *Борчак йолку. Каз йолку.* ▭ *Алар урак урдылар, җитен йолыктылар.* Ә. Фәйзи. *Шул арада каргалар, чәүкәләр, --- сарыклар, сыерлар өстенә кунып, үзләренә оя ясау өчен, борыннары белән аларның йоннарын йолка башлыйлар.* М. Гали. // Урыныннан тартып, каерып чыгару, кубару. [*Өермә*] *карт имәнне тирән тамырлары белән йолкып --- ташлады.* Г. Ибраһимов. [*Рябков:*] *Шәйдулла, кара әле, малай, фриц капка баганасын йолкый бит.* Г. Бәширов.

2. Кискен хәрәкәт белән тарту, тартып алу. *Бандит, ыңгырашып, ерткыч кебек үкереп, аның* [*Хәлимнең*] *винтовкасын йолкырга тотынды.* А. Шамов. *Хәлил Исмәгыйлькең кулыннан шәлне йолкып ала.* М. Фәйзи. // Беркетелгән яки тегелгән нәрсәне тартып өзү, өзеп чыгару. [*Гайфи Галләмнең*] *ычкынмыйча карышып торган тире төймәләрен бер тарту белән йолкып төшерде.* Ф. Хөсни. // *күч.* Коткару, йолу. *Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине.* Г. Тукай.

3. *күч. сөйл.* Талау; ирексезләп алу. *Йолкырга дип бардым, йолкыныпкайттым.* Мәкаль. *Кемнәр — йолкый, кемнәр — йоклый, Дөнья бу, абзыкаем.* Ш. Галиев.

4. *күч. сөйл.* Төрле сораулар, таләпләр белән бик еш мөрәҗәгать итеп борчу, тынгылык бирмәү.— *Бүген* [*Мансурны*] *газета кешеләре бик йолыктылар, алардан качып йөрмиме икән?* И. Гази.— *Менә инде башланды. Кайтып керергә дә өлгермәдең, анда да, монда да йолкырга керештеләр.* Т. Гыйззәт.

5. *күч.* Юкка чыгару, бетерү. [*Сәлимә:*] *Колхоз тормышы ярлылык-хәерчелекне тамырыннан йолкып ташлады.* Ф. Бурнаш. // Тарату, туздыру. *Саламнарын җил йолкыган түбәләрдә алабута үсеп утыра.* К. Нәҗми. *Җил бу бөдрә төтенне, урап алып, йолкып, тарткалап, бик тиз күздән югалта.* А. Шамов.

6. *күч.* Зур көч куймыйча, җиңелрәк юл белән генә күбрәк файда, табыш, эш хакы алу, алырга тырышу турында. *Юныс бай, --- кайдан ничек табыш йолку мөмкинлеген исәпләп чыккач, Хоканд автономиясенә якын Сәмәркандка юл тотты.* Қ. Нәҗми. // Уйлап тормыйча, ничек туры килсә шулай, тегеннән-моннан нәрсә дә булса (фикер, сүз, әйбер һ. б. ш.) алу, җыештыру.— *Син инде, шәт, кайбер чиле-пешле композиторлар шикелле, көйләрнең башын моннан, ахырын тегеннән йолкып, шуларны гына сипләштереп чыгармассың бит!* Г. Бәширов. *Аннан-моннан йолка торгач, кирәк кадәр өй җиһазы да табылды.* И. Гази.

ЙОЛКЫНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* йолку (1, 2 мәгъ.). *Тау башындагы наратларның кайберләре --- төпләре-төпләре белән йолкынып авып китәләр.* Г. Әпсәләмов.

2. Тартышу, тыпырчыну, ычкынырга тырышу. *Галимә апа шәле белән ныклап каплаган битен һаман ачмый, һаман китәргә тырыша, һаман йолкына.* М. Гафури. *Тибрәнә дә йолкына, бичара гакылыннан шаша.* Г. Тукай. // *күч.* Тынычсызлану, ярсу. *Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син.* Дәрдмәнд. *Зыярат өстендәге халык үз йөрәген үзе тартып алып кабергә салырдай булып йолкынды.* И. Салахов.

3. *күч. сөйл.* Зур чыгымнарга дучар булу; бөлү, мохтаҗлыкка төшү. *Туй вакытында шактый йолкынып калу.* ▭ *Сугыш вакытында бик нык йолкынган идек шул.* Э. Касыймов. // *с. мәгъ.* **йолкынган.** Сәләмә кыяфәтле. *Көрәк һәм казымаларына таянган хәлдә поездны озатып калучы бер төрле йолкынган гына кешеләр күзгә чагылып кала.* Ш. Камал.

4. *күч. сир. шигъ.* Бетү, китү (хис-тойгылар турында). *Йөрәктән сагыш йолкынмый, менә шул ябыктыра.* С. Баттал.

◇ **Йолкынып алына торган** — үтемле, бик тиз сатыла торган. *Бер заман без шәһәргә китәбез. Күкәй төягәнбез, май, бал кебек әйберләр төягәнбез — шәһәргә бару белән йолкынып алына торган әйберләр.* М. Әмир.

ЙОЛКЫШ *с. гади с. кимс.* 1. Ярлы, хәерче; сәләмә киемле. *Без өтеләбез, граф байый бара, Ник ул байый? Ә ник без йолкыш?* Х. Туфан. [*Галимә Хаҗига:*] *Син бит йолкыш шәкерт кисәге, кибетче малае идең.* Ш. Камал.

2. Начар, җимерек, хәрабә хәлгә килгән. *Йолкыш авыл. Йолкыш биналар.* // Начар, хәлсез, йончыган. *Ә тавыклар? Бигрәк йолкышлары бар, бигрәк йонсызлары. Югыйсә, үзләренә азык та бирәләр бит.* С. Рафиков.— *Йолкыш кына атым булса да — аңа мин үзем утырам.* Ф. Бурнаш. // *күч.* Җебегән, булдыксыз. *Теге көнне Рәзинә каршында бик йолкыш, бик кызганыч булып калганмын.* Б. Камалов. / *и. мәгъ.*— *Бу йолкышны* [*Тангатаровны*] *куып чыгар. Яңадан минем йортыма аяк басмасын.* Г. Ибраһимов.

ЙОЛКЫШЛАНУ *ф. гади с.* Ярлылану, бөлгенлеккә төшү; сәләмәләнү.— *Беркөн* [*Бондаренконы*] *урамда күргән идем, бик йолкышланган.* Т. Гыйззәт. *Зәйнулланың һичбер нәрсәсез, --- йолкышланып бу авылга килеп чыгуына әле өч кенә ел.* Г. Иделле. // Җимерек, хәрабә хәлгә килү. *Авыл уртасында каланча тора, ул да йолкышланып, ватылып, кителеп беткән иде.* Х. Госман.

ЙОЛКЫШЛЫК *и.* Ярлылык, сәләмәлек. [*Миңсылу Халикъның*] *йолкышлыгын да, күзләре бака күзләренә охшаганлыгын да, --- берсен дә калдырмады.* Ш. Камал.

ЙОЛТ-ЙОЛТ: йолт-йолт килү — ялтырап, җемелдәп тору. *Өйләрдә, урамнарда гына түгел, сыер абзарларында, күпер башларында электр лампалары йолт-йолт килә(ә)к.* К. Тинчурин.

ЙОЛУ *ф.* 1. Коткару, аралау; саклап калу. *Бу авырлыктан сине кемнәр йолар, кемнәр коткарыр.* М. Гафури. [*Агроном:*] *Кайчагында табигать үзе үк бәладән йолып калгалый.* Г. Бәширов. // Бетерү, юкка чыгару (гаепне, яман атны, гөнаһларны һ. б.). *Минем бурычым, Мөхәммәтҗан, Йолу синең яман атыңны.* Һ. Такташ. *Кеше гаебен кеше йолмый.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Яшерү, дөресен әйтмәү. [*Шәрәфи*] *прокурорның Садыйкны гаепле күрсәтүче әйберләр көчле икәнлеге турындагы сүзен үзе йолып калды, хатынга әйтмәде.* Г. Ибраһимов. *Киндидер техник җитешсезлекләргә таянып, брак продукцияләрнең төп сәбәпләрен йолып калырга тырышучылар да булды.* М. Шабай.

3. *күч.* Әләктереп алу. *Патша кырык аршинлы бер багана утырттыра, элеп куя бер янчык: «Менә шуны кемнең үгы йолып китә, алтын шуныкы».* Әкият.

Йолып алу — 1) аралап тартып алу. [*Хөсәен*], *арбадан төшүгә, беркемгә дә игътибар итмәстән, төркем арасыннан сеңелесен йолып алып кочагына кысты.* А. Расих; 2) тиешле түләү кертеп, кире үз милкеңә кайтару. *Бары тик чирек бәясенә закладка салынган әйберләре, йолып алу срогы үтү аркасында, бөтенләйгә Иманкол кулына күчә башлагач кына,* [*эшчеләр*] *тормыш юлында тагын бер уткен тешле тозак корылганын сизделәр.* К. Нәҗми; 3) *күч.* нәрсәдән дә булса иректезләп мәхрүм итү. *Беренче мәртәбә иркемне миннән ул йолып алды.* М. Гафури.

ЙОЛЫМ. *и.* Алпавытлар тарафыннан җир өчен крестьяннардан алына торган түләү акчасы, салым. *Бервакыт Хизбулла, сүз арасына кыстырып, тимерче Сәүбанның Әхтәм Морзага тиешле җир йолымын үзе түләп торганлыгын --- әйтте.* К. Нәҗми.

ЙОМАРЛАВЫК *и.* Төер, кантар. *Туфрак йомарлавыклары.*

ЙОМАРЛАВЫКЛЫ *с.* Төерле; кантарлы. *Йомарлавыклы туфрак.*

ЙОМАРЛАК *с.* 1. Йомгак сыман булып укмашкан, йомарламлы. [*Ат тояклариннан*] *атылган йомарлак кар, чанага сикереп менеп, Баязитовның тун итәгенә шап-шап килеп төшә иде.* И. Гази. *Җәмилә бер тәлинкә белән --- башланмаган бер йомарлак ак май чыгарып куйды.* М. Әмир. // *и. мәгъ. к.* йомарлам. [*Байдек*], *борчак онын юешләп, өч йомарлак ясады.* К. Насыйри.

2. *бот. к.* дүңгәләк.

ЙОМАРЛАМ *и.* Гадәттә йомшак, таралучан булып, тыгызлану аркасында йомгак сыман формага килгән (яки китерелгән) матдә кисәге. *Май йомарламы. Балчык йомарламы.* ▭ *Малайлар Хәлимне кар йомарламнары белән каршы алдылар.* Г. Гобәй.

ЙОМАРЛАМЛЫ *с.* Йомарланган, йомгак сыман итеп укмаштырылган. *Йомарламлы май.*

ЙОМАРЛАМЧЫКЛЫ *с. к.* йомарлавыклы. *Йомарламчыклы туфрак.*

ЙОМАРЛАНУ *ф.* 1. *Кайт. юн. к.* йомарлау (1, 4, 5 мәгъ.). *Куллар йомарлану.* ▭ ***Кара урманга кар ява, йомарлана, бозлана.*** Җыр. *Кырлар буенча, йомарланып, бүре уты тәгәри.* К. Нәҗми.

2. *Төш. юн. к.* йомарлау (1—3 мәгъ.). *Әйберләр төргәккә йомарлану.*

3. Кул-аякларны бөкләп, җыеп бөгәрләну. *Куак арасына, куян кебек, йомарланып поскан бер кеше.* Ф. Кәрим. *Аю йомарланып капчыкка керә.* Әкият.

4. Чәчәк, яфрак бөреләре яки җимешләр барлыкка килү турында. *Алмагач чәчәккә йомарлана башлау.* // *күч. шигъ.* Нәрсә дә булса эшләргә өлгереп җитү, җитлеккән хәлгә килү. *Чәчәк атарга күңел йомарланды.* М. Гафури. *Йомарланды, чәчкә атмады безнең яшьлек еллары.* Җыр.

ЙОМАРЛАУ *ф.* 1. Әвәләп, уч эченә кысып оештыру, укмаштыру, йомры хәлгә китерү. *Кар йомарлап ату.* ▭ *Егет --- җир өстеннән бер уч туфрак йомарлап алып чыккан иде.* Ф. Хөсни.

2. Төрү, чорнау. [*Егетләр*] *чистарак киемнәр, --- сабын, сөлге эзләделәр, шуларның барысын бер төргәккә йомарладылар.* Н. Фәттах.

3. Бөтәрләү, җыеру. *Рәхилә кәгазьне ахырына кадәр укый алмады, каты итеп сул кулына йомарлады.* **Ә. Еники.** [*Ефәк тукыманы*] *йомарласаң да сынмый, тәпәрләнми.* З. Бәшири.

4. Йодрык хасил итеп, бармакларны уч төбенә кысып йому; йодрыклау (1 мәгъ.). [*Сафа*], *кулларын йомарлап, сугышырга хәзер тора иде.* Ш. Камал. // Нәрсәне дә булса уч төбенә кысып тоту, йому.— *Әй-әй, Гафият,— диде Миңнулла.— Учыңа йомарладың түгелме бер алтын тәңкәне?* И. Гази.

5. *күч.* Җыю, туплау (көчне, ихтыярны һ. б. ш.). [*Колчак*] *гаскәрен өч йодрык итеп йомарлап һөҗүм итә.* И. Гази. *Командир бөтен ихтыярны кулына йомарлаган да эндәшми.* Г. Әпсәләмов.

6. *күч.* Үзләштерү, яшереп саклау. *Кул — кеше хакын йомарлый.* Г. Тукай. [*Габдуллажан:*] *Юк инде, Муса әфәнде, алай үзеңә генә бөтен нәрсәне йомарлап тотмыйлар аны.* Қ. Тинчурин.

ЙОМАРЛЫ *с.* Төерле, йомры кисәк булып укмашкан. *Кемнәрдер ат тояклары астыннан йомарлы карлар чәчрәтеп уздылар.* К. Нәжми.

ЙОМГАҠ *и.* 1. Шар формасындагы җеп чорнамы. *Ак мамыклар эрлим җеп итеп, йомгакларга чорныйм күп итеп.* Ә. Фәйзи. *Әкияттәге серле йомгак булып Тәгәрәде тормыш сукмагым.* М. Җәлил. // Формасы белән шарга охшашлы әйбер турында. *Камил немец самолетын үзен күрә алмады. Бары тик күк йөзендә, төтен йомгаклары ясап, зенитка снарядлары ярылганын күрде.* М. Әмир.

2. *күч.* Нинди дә булса эшнең, хезмәтнең нәтиҗәсе. *Тарихи үсешнең төп йомгаклары. Қонкурс йомгаклары. Йомгак ясау.* □ *Ул үз участогына керә торган колхозларның шул көнге эш йомгакларын тикшерергә чыккан икән.* М. Гали. // Барлыгы, бөтенесе (исәп-хисапта). *Бүген эшнең әхмәди өчен бер дә рәт-чираты булмады. --- Счет салганда да саннар ни өчендер ялгыш китәләр, йомгак дөрес чыкмый.* Г. Иделле.

3. *күч.* Чишәргә, ачыкланырга тиеш булган буталчык нәрсәләр; сер. *Җинаятьләр йомгагы.* □ *Қәгазьдәге сызыклар йомгагы әкренлек белән булса да сүтелә башладылар.* Г. Бәширов. *Баш врач кулга алынгач кына, йомгак чишелде.* Г. Кутуй.

◇ **Йомгак сүтелү — эш кирегә китү, сер ачылу.** [*Сәүбән:*] *Галләм абзый, белергә тиешсең, --- үземнең дә йомгак сүтелергә тора, ишеткәнсеңдер, сизә торгансыңдыр.* Ф. Хөсни. **Йомгакның очы** — мәсьәләнең, эшнең төбе, асылы. [*Фәйзулла:*] *Менә кайда икән ул йомгакның очы.* Ф. Бурнаш. **Йомгакның очы чыгу** — нәрсә дә булса ачыклану. [*Әкмаль:*] *Йомгакның очы чыкты. Тегенең кесәсеннән чыккан кәгазь беләсеңме нәрсә? --- Прокламация.* Х. Җәмил. **Йомгакның очын югалту (яшерү)** — нинди дә булса эшне бутау; ялгыш юлга кертү; әз яшерү. [*Сәлим*], *сүзен саташтырып, йомгакның очын югалткан кебек сөйләп күйды.* М. Гафури.— *Бөркү булып китте әллә нигә. Тәрәзәне ачтым,— дип җавап кайтарды ул, йомгакның очын яшерергә тырышып.* Ф. Хөсни. **Йомгакның очына чыгу (очын тоту)** — эшнең, мәсьәләнең төбен, асылын белү, аңлау. *Бу эштә астыртын дошман кулы уйнаганлыгы турында сүзләр күп була, әмма мәкерле йомгакның очына чыга алмыйлар.* Р. Төхфәтуллин. *Гафиятулла карт йомгакның очын тоттырырга бик үк ашыкмады.* Ф. Хөсни.

ЙОМГАҠЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* йомгаклау 1.

2. Йомгак хәленә килү; йомгак булып оешу. *Йон йомгаклану. Кар йомгаклану.*

3. *күч.* Барлыкка килү, җыйналу, туплану (ниңдә дә булса хис, фикер һ. б. ш.). *Хәлимнең күңелендә юан малайга ачу йомгаклана башлый.* И. Гази.

ЙОМГАҠЛАУ *ф.* 1. Йомгакка чорнау. *Җеп йомгаклау. Йомгаклау цехы.*

2. Йомгак (2 мәгъ.) ясау, нәтиҗә ясау. *Йомгаклау сүзе. Үзешчән сәнгать коллективларының йомгаклау концерты.* □ *Сугышчы: — Бер сүз белән әйткәндә,* [*иптәш Фрунзе*] *революционер инде, аның да иң зурысы,— дип йомгаклап күйды.* Г. Бәширов. // Сөйләп бетерү, тәмамлау. *Әминә докладын йомгаклады.* Г. Минский.

ЙОМГАҠЛЫ *с.* Йомгакка чорналган. *Йомгаклы җеп.*

ЙОМГАҠЧА *и. сир.* Йомгакны хәтерләтә торган кечкенә төер. *Менә бу чөгендер йомгакчасы, икенче төрле әйткәндә, чөгендер орлыгы.* Г. Галиев.

ЙОМГЫЧ: йомгыч мускуллар *зоол.*— бака кабырчыгының капкачларын ябу һәм ачу өчен хезмәт итә торган мускуллар.

ЙОМДЫРГЫЧ: йомдыргыч яры *анат.*— күз кабакларының бер күтәрелеп, бер төшеп торуын тәэмин итә торган юка, сыгылмалы элпә.

ЙОМДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* йому (1, 2 мәгъ.).

2. *күч. гади с.* Үтерү.— *Сакта торган кешене искәрмәстән йомдырырга кирәк.* Ш. Қамал.

ЙОМ-ЙОМРЫ *с. Артык дәр. к.* йомры.

ЙОМ-ЙОМШАҠ *с. Артык дәр. к.* йомшак (1, 2 мәгъ.). *Ул мамык кебек йом-йомшак.* И. Гази.

ЙОМРАН *и. зоол.* Қимерүчеләр отрядыннан җиргә оя ясап яши һәм игеннәргә зур зыян китерә торган вак җәнлек. *Юл чатында йомран сызгыра.* М. Җәлил. // *с. мәгъ.* Шул җәнлекнең тиресеннән эшләнгән. *Нургали --- башыннан йомшак йомран бүреген салып өстәлгә ташлады.* Ә. Еники.

Йомран балчык — кызыл балчык.

ЙОМРЫ I *с.* Түгәрәк, шар сыман; формасы белән шундый булган. *Йомры таш.* □ *Сәхәп карт --- камалы тунының йомры кызыл төймәләрен ычкындырып җибәрде.* С. Рафиков. [*Нәзир*] *бәләкәй генә йомры башлы, шундый үк бәләкәй битле.* Ш. Маннур. // Аркылы кисеме түгәрәк булган озынча әйберләр турында. *Йомры мич.* □ *Урамга йомры агачлар түшәп, җәяүле йөрү өчен, кырыйларына юллар ясалган иде.* М. Гали. // Тулы, симез, юан (кешенең бите, гәүдәсе турында). *Йомры битле, такыр башлы Габдуллажан абзый ишек алдында балаларга --- даган да ясап бирде.* А. Расих. *Без тәбәнәк кенә, йомры гәүдәле, ак сакаллы Сәетша агага ияреп киттек.* Г. Галиев. // *и. мәгъ. тарт. форм.* **йомрысы.** *к.* **йомарлам.** *Такта алдында Хәлимне чалыш еккан, зур кар йомрысы белән битенә бәргән малай --- тора иде.* Г. Гобәй.

Йомры карта — имезүче хайваннар ашказанында беренче иң зур бүлек; шуннан хәзерләнгән ашамлык. *Майпәрвәз ханым* [*өстәлгә*] *--- атның йомры картасы белән бавырын китереп куя.* Ә. Еники. **Йомры чабак** — карплар семьялыгыннан елгаларда һәм саф сулы күлләрдә яши торган зур булмаган балык.

◇ **Йомры баш(лы)** *сөйл. хуп., ирон., шаяр.*— акыллы, үткен; бик елгыр, хәйләкәр. *Кулак шырпысыннан авылларда һәлак булган колхоз йортларын, игеннәрне Теге йомры башлы түрәләр Хулиганнар эше дип күрәләр.* Һ. Такташ. **Йомры сан** — башкарылган яки башкарылырга тиешле эш(ләр)нең күләмен күрсәткән бик зур сан. *Аннары ул, бүгенге эшләр, иртәгәге бурычлар, перспектива турында мисаллар китереп, йом-йомры саннар атады.* М. Хәсәнов. **Йомры сүз** — каты һәм тупасрак итеп әйтелгән сүз. **Йомры тел белән, йомры телне яссы итеп** — ясалма ягымлылык белән, ялагайланып. *Қасыйм --- әле йомры тел белән, әле өркетүгә күчеп, әле бер тирләп, әле бер суынып үгетли торгач, --- [җиңгәсе] телгә килде.* Ф. Хөсни.— *Әйтәм җирле, баядан бирле, йомры телең яссы итеп, күгәрченнәр күк гөрлисең.* Г. Ахунов.

ЙОМРЫ II *и. диал.* Чынаяк чокыры.— *Бәй, ашыкма, берәр йомры чәй эчеп китәрсең, самоварым кайнап утыра.* Г. Гобәй.

ЙОМРЫБАШ *и. зоол.* Қәлтәләр семьялыгыннан башы йомры, яссы-җәлпәк гәүдәле сөйрәлүче хайван; *рус. часы:* круглоголовка. *Колаклы йомрыбаш.*

ЙОМРЫҠ *и. иск. к.* йодрык 1. *Сөйли иблис ут чәчеп, төкрек коеп, Мөгезенә һәм борынына йомрык төеп.* Ш. Бабич.

ЙОМРЫҠЛАНУ *ф. иск.* йодрыклану. [*Хиффәтҗан абзыйның*] *куллары йомрыкланды, тешләре ыржайды, тавышы ачыланды.* Г. Газиз.

ЙОМРЫЛАНУ *ф.* 1. Йомры формага керү. *Зенитка снарядлары, озын, кызыл ут көлтәсе булып, астан (болытларны) тишеп килеп чыгалар да, бераз меңгәч, йомрыланып туктап калалар һәм шунда ук --- як-якка таралып китеп сүнәләр иде.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Тулылану, симерү. *Куян балалары --- көннән-көн кабара, түгәрәкләнә һәм йомрылана барып [үстеләр].* М. Шабай. // *рәв. мәгъ.* Тулы, симез булып. *Атның таза күкрәкләре, ян башлары ерактан ук елтырап, йомрыланып күренә иде.* Н. Фәттах.

ЙОМРЫЛАУ *ф. сөйл.* 1. Йомры хәлгә китерү, йомры итү.

2. *күч. сөйл. ирон.* Бетерү, төгәлләү (нинди дә булса эшне, киңәшмәне һ. б.). *Киңәшмәне йомрылап куйдык.* Э. Касыймов.

ЙОМУ *ф.* 1. Ябу (күз, авыз турында). [*Фәхри абзый*] *мине дәртләндерергә теләп сөйли дә сөйли. Әллә көне буе йомып йөргән авызы сөйләшүне сагынганмы?* А. Гыйләҗев. *Күз ачылмый, көчләп ачсаң, куәтле йокы аны йомып, үзенә алып китеп бара.* Г. Ибраһимов.

2. Нәрсәне дә булса, учка алып, бармаклар астына калдыру, кысу; уч эченә йомарлау. *Бирсә дустың ком, аны оа учыңа йом.* Мәкаль. // (Бармакларны) уч төбенә бөгү. *Хәлфә, ике кулының бармакларын йомып, шулар аркылы числоларның нидән килүен күрсәтергә кереште.* М. Гафури.

3. *күч.* Яшерү, сиздермәү. *Ачуны эчкә йому.* □ *Чын күңелдән, бик ягымлы сөйли, йомып калмый кыен якларны.* Х. Камалов. [*Алар*] *бер-берсенең гаебен йомарга яраталар.* Ә. Еники.

4. *күч.* Яшерен үзләштерү, бирмичә алып калу. *Кеше хакын йому.* □ [*Сария түти*] *кул астына нәрсә туры килде, шуны җыйды, базарга, кибеткә бара-нитә калса, әйберләренең бәясен арттырып күрсәтеп, ярты акчаны «йома» барды.* М. Хәсәнов.

5. *күч. гади с.* Тавышсыз-тынсыз гына юк итү, үтерү. [*Гайнуллин:*] *Башлыкларын йомарга кирәк.* Х. Госман.

ЙОМШАК I *с.* 1. Тотып, капшап карауга каты, тыгыз булмаган, басымга, кысуга җиңел бирелүчән; *киресе:* каты. *Йомшак туфрак.* □ *Коймалар, өй түбәләре һәммәсе яңа яуган йомшак кар белән түшәлгәннәр.* Г. Ибраһимов. // Эшкәртүгә җиңел бирелә торган. *Йомшак металлар.* □ *Йомшак агачны корт баса.* Әйтем. // Яңа пешкән, искермәгән, кипмәгән (икмәк турында). *Йомшак ипи. Йомшак булка.* // Нәфис, тупас түгел; кабарып торган (кул, бит, муен һ. б. турында). *Аппак кына, йомшак кына Җаныемның куллары.* Җыр. // Нечкә, ефәк сыман (чәч, йон һ. б. турында). *Йомшак йонлы.* □ *Мөнәвәрә маңгаена кайтарылып төшкән йомшак чәч бөтеркәләреннән су тамчыларын сыпырып ташлады.* Г. Ахунов. *Җир өстен ефәк кебек йомшак үләнкәйләр үсеп каплады.* Дәрдмәнд. // *и. мәгъ.* **Йомшагым.** Ярату, иркәләү хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Карга да әйтә: «аппагым»,— ди, Керпе дә әйтә: «йомшагым»,— ди.* Әйтем.

2. Сыгылмалы. *Йомшак пружина.* □ [*Директор*] *Шәйхаттар бабайны йомшак диванга утыртты.* Г. Гобәй.

3. Буш, нык тартылмаган, тыгыз уралмаган, нык түгел. [*Әткәй*] *чормадан чалгыны алып төшеп карады да, --- муены йомшак, яңа бөҗра кирәк булыр [диде].* Г. Ибраһимов.

4. Физик көчсезлек белән аерылып торган; сәламәтлеге нык булмаган. [*Солтан*] *элек ел буе чирдән айнымый торган йомшак кына кеше иде, хәзер әнә аркажилкәгә дә киңәеп, күз карашлары да үткенләнгән кебек күренә.* Г. Бәширов. // Зәгыйфь, начар (күрү, ишетү, сизү, хәтер, игътибар турында). [*Кайбер кешеләрнең*] *хәтерләре һәм игътибарлары бик йомшак була.* С. Кудаш. // *күч.* Зәгыйфь, көчсез. *Алда берничә җирдә бик йомшак ут шәүләсе чагылды.* Ш. Камал.

5. *күч.* Ихтыяр көче нык булмаган. *Йомшак характерлы.* □ *Иптәшенең начар, йомшак булуына Габитнең эче поша башлады.* Ф. Кәрим. // Басынкы, тыйнак, юаш, күндәм. *Шундый [Зәйнәп кебек] йомшак кешеләрдә кирәк вакытта әллә никадәр гайрәт булып куя.* Ф. Әмирхан. *Госпитальдә эшләү дәверендә аның йомшак холкы шактый ныгып өлгерде.* Г. Әпсәләмов. // *рәв. мәгъ.* Таләпчәнлек күрсәтмичә, кыюсыз. [*Сәмигуллин*] *гомумән Гыйльманов турында артыграк йомшак, хәтта иркәләгән сыман маташа.* Ш. Камал.

6. Ягымлы, мөлаем. [*Хәмдия Бакыйга:*] *Туташыңның йомшак карашын үзеңә мәхәббәт дип юрадыңмы?* М. Фәйзи. *Зыя исә бөтенләй башка. --- Ул юаш, ул йомшак; --- йомшак сөйли, йомшак мөгамәлә кыла.* Г. Ибраһимов. // Әдәпле, нәзакәтле, каты бәрелми торган. *Көләч йөзе, йомшак сүзе белән керә кешеләрнең эченә.* М. Гафури. // *рәв. мәгъ.* Ягымлылык күрсәтеп, ихтирам белән. [*Ишмурзин*] *фининспекторларны елмаеп кына, йомшак кына каршы ала.* Г. Иделле.

7. Җылы (һава, климат турында). *Су күп булганга, биредә климат та йомшак.* Каз. утл. *Биткә Иделнең йомшак сулышы бәрелә.* Г. Бәширов. *Кыш йомшак килгән иде.* М. Хәсәнов.

8. (Ишетүгә, күрүгә, сиземләүгә) күңелле, ягымлы, нәфис. *Җырның йомшак моңы сине тибрәтеп әллә кайларга, югары уйларга алып китә.* Ф. Хөсни. *Иртәнге кояшның йомшак нурларына иркәләнеп, көлеп уяндым.* М. Әмир.

9. Тиешле оборона яки һөҗүм итү мөмкинлекләре булмаган; начар коралланган, начар ныгытылган. *Тупланган мәгълүматлар дошман оборонасының йомшак урыны — Лодейное Поле районы икәнлеген белергә мөмкинлек бирә.* Г. Әпсәләмов.

10. Тәэсир итү көче, куәте түбән булган. *Йомшак аракы. Йомшак эремә.* □ *Мохтаров егеткә сигарет тәкъдим итте.— Тартмыйм мин аны, йомшак ул,— диде егет.* Г. Ахунов.

11. Тиешле дәрәҗәдә түгел, начар. *Прокурорның рече йомшак булды.* Һ. Такташ. *Каюмда ул як [физика законнарын белү] йомшаграк, хәтта бик йомшак диярлек.* Ш. Камал. // Аз, җитәрлек түгел. *Бу эштә район оешмаларының ярдәме йомшак.* Ф. Кәрим. // Кимчелекле, җитешсез. [*Шәйхи*] *үзенең ферма мөдирен бөтен көчле һәм йомшак яклары белән белә иде.* Ә. Еники. // Экономик яктан начар, хәлсез. *Йомшак хуҗалык.* / *и. мәгъ. Йомшакларны, ярлыларны барлар исәбенә түйдырырга кирәк.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

12. Үз эшен, хезмәтен начар белүче, хәзерлеге җитәрлек булмаган, хәзерлексез. *Йомшак класс. Йомшак укучы.*

13. Составында минераль тозлары аз булган, сабынны яхшы юып ала торган (су турында).

14. *рәв. мәгъ.* Экрен, сүлпән (үсеш, темп турында).— *Ярыш нәтиҗәләрен тикшерү йомшак бара, иптәшләр.* Ш. Камал.

15. *рәв. мәгъ. гадәттә «кына» кисәкчәсе белән килеп.* Җиңелчә генә, сизелер-сизелмәс кенә, әкрен генә. *Эшнең тәмам кызып киткән чагында, Нәфисә үзенең иңбашына кемнеңдер йомшак кына кагылып куюын тойды.* Г. Бәширов. *Биби аягын булдыра алган кадәр йомшак басып йөри иде.* Ф. Әмирхан.

Йомшак аңкау *анат.*— авыз куышлыгының хәрәкәтчән, гөмбәз сыман формадагы югарыгы өлеше. **Йомшак вагон** — йоклау өчен йомшак урыннары булган тимер юл вагоны. *Казан — Мәскәү поездында, йомшак вагон купеларының берсендә, ике юлчы бара.* Г. Әпсәләмов.

◊ **Йомшак авыз** — булдыксыз, җебегән, юньсез.— *Без үзебез дә шул йомшак авыз: [Закирны] күптән тотып өйләндерәсе бар иде.* Г. Камал. **Йомшак алтын** —

кыйммәтле мех. *Казан мех фабрикаларыннан эшләнеп чыккан «йомшак алтын» йөге-йөге белән [мехбазага] килеп керә.* Ә. Еники. **Йомшак баш(лы)** *гади с.*— аңгыра, томана. *Сыйнфый сизгерлеге аяк табанында йөргән Кайбер йомшак башлы түрәләр Кулак зур корсаклы, коточкыч бер Хайван була дип беләләр.* Һ. Такташ. **Йомшак итеп әйткәндә** — каты бәрелү, кискен сүзләр әйтүдән саклануны искәрткәндә кулланыла. **Йомшак куллылык** — таләпчәнсезлек, кылешүчәнлек. *Бәһәвича, Ифрат хезмәт дисциплинасын бозучыларга карата артык йомшак куллылык күрсәтә.* А. Расих. **Йомшак муен** — үз фикерендә, карашында нык тормаучан; жебегән. [*Гәрәй:*] *Бу да йомшак муен шул! Их, кайдан аласың Ризван Вахитов кебек корыч егетләрне!* Г. Ибраһимов. **Йомшак сыйпап каты егу** — *к.* йомшак җәеп катыга утырту. **Йомшак телле (сүзле)** — матур, ягымлы, әдәпле сөйләшүче. **Йомшак як** — 1) кимчелекле, җитешсез як. *Бәйрәмбайның мин ике йомшак ягын сизеп алдым. Беренчесе шул: аның аю кебек каты йоклавы.* Шура; 2) нәрсә белән дә булса артык мавыгу, кызыксыну турында. *Драма — ул минем элек-электән йомшак ягым.* Ф. Хөсни. **Йомшак җир (урын)** — 1) *әвф.* арт сан, утыра торган җир. [***Кемдер***], ***тезе*** *белән Сөләйманның йомшак җиренә бәреп, егетне, солы көлтәсен ыргыткан төсле, читкә бәреп җибәрде.* Қ. Тинчурин; 2) кимчелекле, җитешсез як. [*Зөләйха Зифа артыннан*] *Бөгелерсең әле. Бөгәргә йомшак җиреңне беләм мин синең.* М. Фәйзи.— *Бәла шулай инде ул! Йомшак урынны күзләп йөри.* Ф. Бурнаш. **Йомшак җәеп (тотып, түшәп) катыга утырту (яткыру)** — 1) тыштан ягымлы, яхшы булырга тырышып, асылда киресен эшләү. [*Мостафа:*] *Менә хәзер юаштан юан чыгар. Йомшак түшәп катыга яткырачак бу мине.* Қ. Нәҗми; 2) *гади* генә, ачуланмыйча, каты бәрелмичә сөйләп тә бик үтемле, тиешле нәтиҗә ясарлык итеп әйтү (тәнкыйть сүзләре турында). *Ә Гали абзый бик шәп итте: йомшак тотып, каты җиргә утыртты.* Г. Әпсәләмов.

ЙОМШАК II *и.* **1.** *диал.* Калач, бодай икмәге. *Әни безгә ак күмәч белән зур гына бер борай йомшагы --- биреп җибәргән иде.* З. Бәширн.

2. *тарт. форм.* Кеше яки хайван тәненең итләч, мускуллы урыны. *Акбай да усал булып чыкты, Бот йомшагын өзеп ташлады.* Һ. Такташ.

3. *тарт. форм.* Яшелчәләрнең, җиләк-җимешләрнең тыгыз эченә итләч өлеше.

ЙОМШАКЛАНУ *ф.* **1.** Йомшак I (1, 2 мәгъ.) хәлгә килү; йомшару. *Туфрак йомшаклану. Җиләк-җимешләр йомшаклану. Пружина йомшаклану.*

2. *күч.* Йомшаклык күрсәтү.— *Син дә, Булат, йомшакланасың: --- андыйлар [Акчулпанов кебекләр] аякка мунчала булып кына уралалар.* Г. Ибраһимов.

ЙОМШАКЛЫК *и.* **1.** Йомшак (1—14 мәгъ.) булу сыйфаты, хәле. *Туфракның йомшаклыгы.* ☐ *Мин --- күңелемдә әйтеп бетерә алмаслык рәхәт бер йомшаклык хис иттем.* М. Гафури. [*Тәзкирә*] *моңа кадәр күрсәткән йомшаклыклары өчен, бөтенесе-бөтенесе өчен берьюлы әйтергә теләгәндәй кистереп әйтте.* Ф. Хөсни.

2. *күч.* Төшенкелеккә, хискә бирелүчәнлек; кәефсезлек. *Нәфисә, үзен бик тиз кулга алып, йомшаклыгы өчен гафу үтенгәндәй, көлемсерәп куйды.* Г. Бәширов.

3. Тәжрибә, сәләт житеп бетмәгәнлек. [*Каюм*], *үзенең житәкчелек эшендә йомшаклыгын сәбәп итеп күрсәткән хәлдә, председательлеккә сайланудан баш тартты.* Ш. Камал.

4. Һәвәслек, мавыгучанлык, нәрсәгә дә булса артык бирелү гадәте (еш кына начар, хупланмый торган эшкә). [*Суфия:*] *Без хатын-кызның йомшаклыгы — матур итеп киенү дә — бәлки миңа насыйп булыр.* А. Расих.

ЙОМШАКТӘНЛЕЛӘР *и. зоол.* Йомшак тәнле умырткасыз хайваннар, моллюсклар.

ЙОМШАНУ *ф. сир.* Бушану, киеренке хәлдән чыгу. *Мускулларның йомшануы.* ☐ *Әүвәл аяк вә кулларда рәхәт арганлык сыман бер йомшану башланды, бераздан бу хәл бөтен гәүдәгә җәелде.* Ф. Әмирхан.

ЙОМШАРТҚЫЧ *с.* Нәрсәне дә булса йомшарта, йомшак хәлгә китерә торган. *Туфрак йомшарткыч корал. Йомшарткыч май. Биткә йомшарткыч крем сөртү.*

ЙОМШАРТУ *ф.* **1.** Йомшаграк хәлгә китерү; катылыгын кимәтү. *Сафура --- ятакны рәтләде, ястыкны төзәтте, мендәрләрне, юрганнарны кабартып, йомшартып җәйде.* Г. Ибраһимов. *Киндер йомшартучылар парлы-парлы дүрт кыз булып чыкты.* Г. Бәширов. // Көпшәкләндерү, кабарту (туфракны, балчыкны). *Картлар, карчыклар, ящүсмерләр бәрәңге төбе йомшартырга керешеләр.* Г. Галиев.

2. Язу, сыгылмалырак, хәрәкәтчәнрәк хәлгә китерү. *Пружинаны йомшарту.* ☐ [*Физкультура*], *кан йөрешен көчәйтеп, каткан сеңерләрне йомшарта.* Т. Гыйззәт.

3. Тартып, кысып торуны кимәтү, бушайту, җибәрә төшү. *Егет, [атның] ял асларын карап, аелны бераз йомшартты.* Г. Ибраһимов.— *Ныграк тотыгыз, Гали абзый. Дилбегә йомшартканны яратмый ул [ат].* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Қырыслыгын, ачуын кимәтү; күндәмрәк, юашрак итү. [*Фәтхия әби*] *бу бүләкләр белән картның рәнҗүле күңелен йомшартырга --- теләде.* Г. Ибраһимов.— *Мин инде аны [кире беткән Әхмәтне] йомшартырга бик күптәннән тырышып йөрим.* Г. Камал.

5. Газапсызрак итү, жиңеләйтү, кискенлеген кимәтү. *Авыртуны йомшарту.* ☐ [*Вәзир:*] *Ханым, азрак кына хөкемне йомшарт, Саклан кызып чиктән ашудан.* Ф. Бурнаш. *Фәтхинең фикеренчә, [Халикъ] булган хәлне беркадәр йомшартырга, авыр хәбәрне бераз жиңеләйтергә тели иде.* Ш. Камал.

6. Нәрсәнең дә булса көчен, дәрәҗәсен, киеренкелеген кимәтү. *Уяулыкны йомшарту. Таләпчәнлекне йомшарту.* ☐ [*Миңлекамал:*] *Житәкчелектә тәжрибәсез кешеләр калды. Дисциплинаны йомшартып жибәрделәр.* М. Әмир. // Мөнәсәбәтләрдә киеренкелекне кимәтү турында. *Халыкара киеренкелекне йомшарту.* ☐ *Мостафин --- арадагы ямьсез киеренкелекне бераз йомшартырга теләп булса кирәк, [Андреевка] гадәттәгечә: — Кайтабызмы? — диде.* Ә. Еники. // Тупаслыгын, кискенлеген кимәтү (сүзнең, тәнкыйтьнең, тонның һ. б.), йомшаграк итеп әйтү, сөйләү. [*Хәдичә*] *--- әле генә ычкындырган авыр сүзләрен аз булса да йомшартырга ашыкты.* Г. Бәширов.

7. Қимәтү, акрынайту (нинди дә булса эшнең барышын, темпын). *Мөхетдин карт, [егетләрнең]. --- сугуларын йомшарта башлаганнарын күреп, чабагачын югары күтәрә дә: — Һайт, йомшартма!! Күтәребрәк ал!! — дип кычкырып, көлтәләргә каты-каты бәрә башлый.* М. Гали. *Немецлар, автомат, пулеметтан атуны йомшартып, --- минометтан атуга күчтеләр.* Ф. Кәрим.

8. Физик хәлсезләндерү, арыту. *Кояш эсселәтә, кайберәүләрне йомшарта башлады.* Г. Ибраһимов. *Юлсыз жирләрдән юл салып, шундый биек тау башына менеп төшү безне шактый йомшарткан.* М. Әмир.

9. Салкынлык кимү, жылыту (һава, климат турында).— *Ай-ай суык! Көндезен бераз йомшарта төшкән иде шикелле, кичкә тагын пешереп ала башлады.* Ш. Камал. *Төньягыннан искән жил кире, башка якка таба борылды да һаваны йомшартты.* Ф. Сәйфи-Қазанлы.

10. Йомшак (13 мәгъ.) хәлгә китерү (су турында). *Составында минераль тозлар аз булган сабын белән каты суны йомшарту.*

Йомшартып әйтү — 1) *лингв.* тартык авазларны телнең урта өлешен каты аңкауга таба күтәреп әйтү; палатальләштерү; 2) *күч.* жайлап, киеренке хәл тудырмаслык итеп әйтү, сөйләү.— *Соң син, тутакаеңның ак-*

дый гадәтен белгәч, хәбәрне бераз йомшартыбрак әйтергә кирәк иде. Ә. Фәйзи.

ЙОМШАРУ *ф.* **1.** Йомшаграк хәлгә килү. *Яңгырлар башланса, иске чокырларга су тула, ярлары җеби, йомшара.* А. Гыйләҗев. *Газинур җылы землянкада эргән һәм яңадан йомшарган халатының дымлы җиңе белән маңгай тирен сөртте.* Г. Әпсәләмов. // Изрәп бетү, хәрәкәт итү өчен җайсыз булу (юл турында). *Юл йомшарган дип тормый, Ирек атын куа бирә.* Сов. әд.

2. Язылу, сыгылмалырак, хәрәкәтчәнрәк хәлгә килү. *Тез-буыннар йомшару. Сөяклəр йомшару.* □ *Берникадәр азапланугa, --- пружина йомшарып киткән кебек булды.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Кырыслыгы, таләпчәнлеге кимү; күндәмләнү, юашлану. *Күрәсең, Тимери бик тиз сүрелә торган кеше иде булса кирәк, Хәерниса җайлап әйтүгә, ул бераз йомшарды.* Г. Бәширов. *Йомшарырмы аның [Айдарның] тискәрелеге?* Ф. Хөсни. // Елау дәрәҗәсенә җитү, күңел тулу. *Абыстай артык йомшара да тыела алмыйча елап җибәрә.* Г. Ибраһимов.

4. Җиңелəю, кимү; басыла төшү. *Авырту йомшару.* □ *Киренкелек артыннан йомшару, эш артыннан ял булырга тиеш.* Г. Әпсәләмов.

5. Кимү, акрынаю (нинди дә булса эшнең барышы, темпы). *Көрəш йомшару.* □ *Дошманның һөҗүме ничектер кинәт кенә йомшарып калды.* М. Әмир.

6. Нәрсәнең дә булса көче, эшчәнлек дәрәҗәсе, киренкелеге кимү. *Тәртип йомшару. Нервлар йомшару.* □ *1912 нче елларда реакция бераз йомшарган кебек булса да, 1914 нче ел сугышы белән ул яңадан кайтты.* Г. Нигъмәти. // Мөнәсәбәтләрдәге киренкелек кимү. *Халыкара киренкелек йомшару.* // Тупаслыгы, кырыслыгы кимү (сүзнең, тәнкыйтьнең, тавышның). *Әнинең тавышы тәмам йомшарып китте.* Х. Садрый.

7. Физик хәлсезләнү; ару. *Туташ бик бетеренгән, бик йомшарган иде.* Г. Ибраһимов.

8. Салкынлык кимү, җылыну (һава, җил, климат турында). *Быел яз иртə килердер ахры, февраль азагында ук һава йомшарды.* К. Нәҗми. *Бая гына кар бөртекләре очкалап торган шыксыз салкын көн хəзер шактый йомшарды.* Ә. Еники.

ЙОМШАТУ *ф. к.* йомшарту. *Күпсүзлелек, натурализм күренешләре һəм композицион таркаулык прозабызның мускулын йомшата, тəэсир көчен, сугышчанлыгын шактый киметə эле.* И. Нуруллин.— *Бала күңелне йомшата!* Г. Камал.

ЙОМШАУ *ф. сөйл. к.* йомшару. *Эхмәди бер агарынды, бер кызарды, бер ачуланды, бер йомшады.* Г. Идел-ле. *Суык та иртəнгедəй зəһəр түгел, бит урталарын чеметеп ала алмый, йомшаган.* Ә. Айдар. *Әгәр ун секунд эчендә сакчының дикъкате йомшавына ышансам,— шул җитте миңа.* А. Расих.

ЙОМЫҚ *с.* **1.** Ябык, йомылган. *Йомык бөре. Йомык күз. Йомык иреннəр.* □ *Йомык авыз белəн чебен тотып булмый.* Мəкаль.

2. *күч.* Аралашмаучан, сөйләшмәүчән, артык тыйнак, басынкы. *Асылгәрəй ятимлекнең ачысын татыган йомык кына бер малай иде.* М. Шабай.— *Мин бертөрле басынкырак, йомыграк кеше.* Ш. Маннур. // Аң дәрәҗәсе түбән. *Революциягə кадəрге крестьянны --- йомык һəм тар карашлы итеп сурəтлəргə берникадəр нигез бар иде.* Г. Бәширов. // Аерымланган, башкалар белән бәйләнеше булмаган. *Йомык производство. Йомык оешма. Йомык тормыш белəн яшəү.*

3. Очлары белән тоташкан, ялганган (әйләнә, шуңа охшашлы маршрут һ. б.). *Йомык сыныk сызык. Йомык электр чылбыры. Йомык маршрут буенча хəрəкəт итү.*

4. Чыгар юлы булмаган. *Йомык иңкүлеклəр. Йомык диңгез.* □ *Һəлак булган организмнарның шактый өлеше йомык су бассейннарының төпləрендə --- туплана.* Каз. утл.

5. *лингв.* Үпкәдән килə торган һава тешләрнең яки иреннәрнең тоткарлыгына очрап, шартлау нәтиҗәсендә ясалган. *Йомык тартыклар* (мәс., б, п, д, т авазлары).

ЙОМЫҚЛАНУ *ф.* Йомык (2 мәгъ.) кешегә әйләнү. *Соңгы көннəрдə əллə нишлəп бик йомыкланып китте шул бу кеше.* Г. Минский.

ЙОМЫҚЛЫК *и.* Йомык (1, 2 мәгъ.) булу хәле. ***Җирле йомыклык.*** □ ***Сəрвəрнең --- йомыклыгы*** *соңга таба тагын да көчəя төшкəн кебек иде.* Ф. Хөсни. *Зыя, аталар яклаган йомыклыкка, явызлыкка һəм коллыкка каршы көрəштə мəхəббəт һəм сəнгать иреген корал итеп, шуларда шəхеснең азатлыгын, рухи азатлыгын табарга тели.* Г. Халит.

ЙОМЫҚЫЙ *с.* **1.** *сөйл.* Кеше күзенə ташланмый яшəгəн, аралашмаучан; йомык. *Закир Нургали өчен ни яхшы, ни яман ягы белəн телгə кермəгəн йомыкый гына бер ящүсмер иде.* Ә. Еники. *Бу йомыкый кешенең кинəт кенə кабынып китүенə --- Садыйк абзый чын-чынлап гаҗəпкə калды.* Н. Фəттах. // Үз эченə бикләнгəн, артта калган (аң дəрəҗəсе белəн). [*Мостафа:*] *Сүзем сүз — малайга синең төсле йомыкый булып үсəргə юл куймам.* Қ. Нəҗми.— *Безнең заманда мескен булып, йомыкый булып яшəү дə килешми.* Р. Ишморат.

2. *диал.* Қысынкы (күзләр турында). *Бер күзе зур, берсе йомыкый булган бу йолкыш кыяфəтле кеше күп сөйлəшеп тормады.* Н. Исəнбəт.

ЙОМЫҚЫЙЛАНУ *ф. сөйл.* Йомыкый булу. *Қазарма тормышында тагын да бөрешеп, йомыкыйланып калган Мостафа аптыраган саен Сəфəргали янына йөгереп килə.* Ф. Хөсни.

ЙОМЫҚЫЙЛЫК *и. сөйл.* Йомыкый булу сыйфаты. *Аларның йомыкыйлыгы югала, йөзлəрендə җанлылык һəм рухи күтəренкелек барлыкка килə.* С. Сабиров.— *Син аның йомыкыйлыгы, хиссезлеге каян килə дисең? Барысына да шул ятим үсү гаепле.* А. Гыйләҗев.

ЙОМЫЛУ *ф.* **1.** Ябылу, бер-берсенə тиеп, орынып тору (иреннəр һəм күз кабаклары турында). *Бикбулатның иреннəре ачыла да йомыла, əмма сүзлəре ишетелми.* Г. Бәширов. *Күз йомылгач ихтыярсыз, Йоклыйсың шундук ятып.* Г. Тукай. // Чәчəкләрнең ачылган таҗ яфракчыклары турында: кире бергə тоташу, укмашу. *Давыл чəчəкләренең катлы-катлы нəфис таҗ яфраклары дерелдəп ачыла, йомыла.* Р. Төхфəтуллин.

2. Бетəшү, ябылу, төзəлү (яра турында). *Ташбайның яралары йомылып килə, шулай да, каты хəрəкəт, селкенү аркасында яңадан ачылып, кан агуы мөмкин.* Ә. Айдар.

3. Бөгəрлəнү, йомарлану (гəүдəгə карата). *Эт йомылып сеңде җиргə, Ыгармый тыныn.* Ф. Кəрим. *Күрəсең, пуля шактый якыннан узды — басмачы йомылып ук китте.* А. Расих.

4. *күч. сөйл.* Қачу, яшереңү, посу. *Кешеләр,* [*салкыннан куркып*], *йомраннар кебек, үз өннəренə кереп йомылдылар.* Ә. Фəйзи. *Апай югары өйнең кечкенə ягына кереп йомылды.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Тирə-юньнән читләшү, аралашмыйча яшəү. *Без гомер-гомердəн йомылып кына яшəмəгəнбез, йомылырга уйламыйбыз да.* А. Гыйләҗев. // Басынкылану, сөйләшмәүчәнгə әйләнү. *Хафаза ничектер үзен сəеррəк тота башлады, ничектер йомыла, сагая төшкəн кебек булды.* Ә. Еники. // *рəв. мәгъ.* **йомылып.** Тыныч-ланып, онытылып. *Менə ул* [*карт*] *йомылып кына татлы йокыга китеп бара.* Н. Исəнбəт. *Абзыйлар яңадан бəхəскə кереп тормадылар, йомылып, сүзсез генə тыңладылар.* Каз. утл.

6. *күч.* Үзеннән-үзе хəл ителү, онытылу, бетү.— *Əһə,— диде Баһаветдин агай, беркемнең дə җиде йөз тəңкəне түлəтергə ашыкмавын күреп,— əйттемме мин дигəнчə булыр дип!.. Йомылды лабаса, басылды!* Н. Фəттах.

7. *күч.* Нинди дə булса үсеш баскычында тукталып

калу яки тар бер эшчәнлек белән чикләнү. [*Кайбер халыклар*], *игенчелеккә керешсәләр дә, натураль хуҗалыкта йомылып калганнар.* Х. Госман. [*Хәбирнең әтисе*] *күңеленда якты һәм зур хыяллар тибрәткән, ләкин, музыкаль белеме булмау сәбәпле, чәчәк атмыйча йомылып калган.* Ш. Хөсәенов.

8. *күч. сөйл.* Зур омтылыш белән бар көчкә чабу, йөгерү. *Төлке ялт кына әйләнеп карады да, --- түмгәкләрне сикереп үтеп, урманга таба йомылды.* Г. Ахунов. // *рәв. мәгъ.* **йомылып.** Бик кызу, барлык көчкә. *Йомылып та атың чапкан чакта, Тезгеннәрен тотма, буш җибәр.* Җыр. *Яшел киемле немец солдатлары йомылып, артларына карамыйча чабалар.* А. Расих. // Кинәт ыртылып, бик кызу рәвештә, уктай атылып. *Бу арада* [*ат*] *әллә ничек үзгәреп тора: юк-барга ачулана, якын барсаң, өстеңә йомылып килә.* Г. Ибраһимов. *Нишләргә белми үрсәләнеп әйләнгән ике тилгән, йомылып, ояларыартыннан түбәнгә* [*текә кыя астына*] *ташландылар.* М. Әмир.

◇ **Йомылып тору** — 1) беленмәү, сизелмәү. *Моңа кадәр бу хәл йомылып торды, ә хәзер ачыкланды.* А. Расих; 2) яшерү, сер саклау. *Юк, монда инде артык йомылып торырга мөмкин түгел иде: Зәйтүнә үзенең өйдән нинди ният белән чыгып киткәнлеген әйтеп бирмичә булдыра алмады.* Ф. Хөсни. **Йомылып яту** — 1) тиешенчә файдаланылмау, үстерелмәү, таратылмау (белем, талант, тәҗрибә һ. б. ш. турында).— *Синең талантың йомылып ята, аны үстерергә кирәк, сиңнән зур артист чыгуы мөмкин.* Г. Бәширов.— *Алдынгыларның бай тәҗрибәсе өйрәнелмичә йомылып ята.* И. Гази; 2) пассивлашу, актив эшчәнлектән читләшү турында. *Аңа зур эшләр кирәк иде. Болай да ул* [*Гөлшаһидә*] *шактый йомылып ятты бит.* Г. Әпсәләмов.

ЙОМЫРКА *и.* Кошларда, ташбакаларда һәм йомыркадан бала чыгара торган кайбер хайваннарда озынча түгәрәк формалы төрле төстәге кабык белән тышчаланган күкәй күзәнәк (кайберләре, мәсәлән, тавыкныкы, үрдәкнеке һ. б. ашамлык буларак кулланыла). *Йомырка агы. Йомырка оны.* ▭ *Йомырканың җәве юк.* Мәкаль. *Кыткылдыйлар яшел печәнлектә Ак йомырка салган тавыклар.* Н. Баян.

Йомырка тәбәсе — йомырканы, сарысын агы белән тугламыйча, табада кыздырып әзерләнгән яки, туглап, сөттә пешерелгән ашамлык.

◇ **Йомырка эчендәге сары кебек** — *к.* күкәй эчендәге сары кебек. **Йомыркадан (әле, яңа) гына чыккан** — яшь, тәҗрибәсез кеше турында.

ЙОМЫРКАЛЫ *с.* Йомырка салып, кушып хәзерләнгән, пешерелгән. *Йомыркалы аш. Йомыркалы гөбәдия.*

ЙОМЫРКАЛЫК *и. к.* күкәйлек.

ЙОМЫРКАЧЫ *и. иск.* Йомырка җыючы.— *Кырык биш тиен акчам чыкмый, кайәр суккан йомыркачыдан сдача алырга гына онытмасам ярар иде.* Ә. Фәйзи.

ЙОМЫРЫЛЫП *рәв. диал.* Бик кызу, йомылып.— *Йомырылып, йөз километрдан артык тизлек белән килгән шәпкә карасам, алда күпер шикелле нәрсә.* М. Хәсәнов.

ЙОМЫЧКА *и.* Агачны яки металлны эшкәрткәндә киселеп, юнылып чыккан вак, юка кисәкләр. *Балта чапканда йомычка чәчрәми калмый.* Мәкаль. [*Мостафа белән Гәрәй*] *аяк астында бозраланып яткан тимер йомычкалары, тутыгып беткән машина кисәкләре арасыннан --- учакларга таба үттеләр.* К. Нәҗми.

Йомычка балык — сельдь балыклары семьялыгыннан консервлар хәзерләү өчен тотыла торган вак балык; килька. [*Невод*] *бөтенләй үк буш түгел иде. Бишалты тачка йомычка балык, сельдь, --- эре генә өч сазан чыкты.* Ш. Камал.

◇ **Йомычканы йомыш итеп** — юк нәрсәне, кечкенә генә эшне сәбәп итеп. *Йомычканы йомыш итеп йөри.* Әйтем.

ЙОМЫЧКАЛАУ *ф. сир.* 1. Йомычкага әйләндерү, йомычка итеп ваклау. *Урман кисәләр, вагоннарга бүрәнә төйиләр. Баракны җылытырга үзләре йомычкалап утын ташыйлар.* Н. Фәттах.

2. Йомычка белән чүпләү. *Идәнне йомычкалау.*

ЙОМЫЧКАЛЫ *с.* Йомычка белән тулган, чүпләнгән. *Нарат исе аңкып торган йомычкалы бүлмәдә --- яңа бер корал туды.* Г. Бәширов.

ЙОМЫШ *и.* 1. Кемгә дә булса башкарырга кушылган эш; йөкләмә. *Җаваплы йомыш. Йомышка йөртү.* ▭ *Балага йомыш бирер, артыннан үзең йөгерер.* Мәкаль. *Мәрдән абзыйны шәһәрдә Костин тапшырган яшерен йомышларны үтәп йөргәндә эләктереп алулары мөмкин.* Г. Гобәй. // Үтенеч, сорау. *Җаек казакларының иң ышанычлы һәм игътибарлыларыннан Перфилиев һәм Герасимов халык йомышы белән Петербургка барганнар иде.* М. Галәү. *Төрле йомыш белән кергән күршеләрен* [*Гашия*] *бервакытта да буш чыгармый.* М. Әмир.

2. Эш, хезмәт. *Өстәл төзү, аш китерү йомышларын Фәрхи карчык үзе үтәде.* Ш. Камал.— *Мин сине ярминкәдән ярминкәгә йөрттем, күпме йомыш күрсәттем.* Ә. Фәйзи. [*Николай*], *юк йомышын бар итеп, көн саен лабораториягә йөгерә.* И. Гази.

3. Әйтәсе сүз, киңәш; киңәшләшеп хәл итә торган нинди дә булса эш, мәсьәлә. [*Мәрьям Зәйнәпкә:*] *Әйдә әле, кызым, теге якка, сиңа бер йомышым бар.* Ф. Әмирхан. *Халык таралырга хәзерләнгән вакытта гына ул бүрәнә өстенә менеп басты да:— Җәмәгать, туктагыз әле, бик зур йомыш бар!— диде.* А. Шамов.

4. Вакытлыча файдалану өчен сорап алына яки бирелә торган нәрсә. *Йомыш алу.* ▭ *— Кешегә санап йомыш бирәсең, кадерен белмиләр.* Ә. Юныс.

5. *күч.* Табигый бушануны үтәүгә туган ихтыяж.— *Шоссе юл буйлата чаңгыда финнар килә,—диде йомыш белән читкәрәк киткән Миңлегалиев.* Г. Иделле.

◇ **Йомыш төшү** — кирәклек, ихтыяҗ булу. [*Куян солдат*] *йомышы төшмәгәндә капкасын да ачып чыкмады, тәрәзәсеннән дә башын тыгып карамады.* Г. Толымбай. **Йомышы юк** — нәрсәгә дә булса исе китмәү, борчылмау, кайгыртучанлык күрсәтмәү. [*Әнвәрнең*] *сатуда һичбер йомышы юк.* Г. Камал.

ЙОМЫШЛАУ *ф.* Нинди дә булса эшне, йомышны үтәү, башкару, хәл итү.— *Ишек төбендә генә йомышлый торган эш түгел.* Ф. Хөсни. [*Хәлим*], *башка бер йомыш йомышлаган булып, чыгып китте.* Г. Гобәй.

ЙОМЫШЛЫ *с.* 1. Йомышы булган. *Бу* [*ат турында барган*] *сүзләрне тыңлаучы риялырак адәм яисә хәзрәттә берәр йомышлы кеше булса, керешә салам кыстырырга.* Г. Ибраһимов.

2. *тар. иск.* XV—XVII йөзләрдәге Рус дәүләтендә: дәүләт хезмәтендә эшләргә, гаскәри хезмәт үтәргә тиеш булган. *Князь Долгоруков Бакуга Казаннан тылмачлыкка йомышлы татарлар чакыртып китергән.* К. Нәҗми. *Рус патшаларының татарларны дәүләт хезмәтләренә тартуы «йомышлы татарлар» дигән катламны китерепчыгара.* Х. Госман.

ЙОМЫШЛЫ-ЙОМЫШСЫЗ *рәв.* Кирәксезгә, вакыт уздыру өчен генә; юк эшне бар итеп. *Хәзер инде правление йортында, йомышлы-йомышсыз кереп, ишек төбендә чүгәләп ятыручылар да күренми.* Ф. Хөсни.

ЙОМЫШЧАН *с.* Сорауны, үтенечне кире какмый торган; тыңлаучан, кушкан эшне үтәүчән. *Йомышчан булуы өчен Дилбәрне хатыннар яраталар, үз күрәләр иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЙОМЫШЧАНЛЫК *и.* Йомышчан булу; йомышчан кешегә хас сыйфат. *Әби киленененең йомышчанлыгын мактап бетерә алмый.* Сов. әд.

ЙОМЫШЧЫ *с.* 1. Йомышка йөрүче; кемнең дә булса йомышын (1 мәгъ.) икенче берәүгә житкерү өчен махсус билгеләнгән. *Ул арада Йөзлебикә бригадасыннан йомышчы малай килде.* Г. Бәширов. *Диңгез*

эчендәге «Өч туган» [атавы] янында йомышчы катерлар тыз-быз килә. Ә. Маликов. / *и. мәгъ.— Мин баш, ә син, минем йомышчым булып, әйткәнне эшләп, йөгереп йөрерсең.* А. Расих.

2. *и.* Хәрби хезмәттә офицерларның хезмәт йомышларын (1 мәгъ.) үтәү өчен билгеләнгән солдат. *Полк парторгы Соловьевның йомышчысы килде һәм Газинурны парторг янына чакырды.* Г. Әпсәләмов.

3. Берәр төрле йомыш (1, 3 мәгъ.) белән кая да булса сайлап җибәрелгән кеше. *Күп санлы эшчеләр делегацияләре, крестьян йомышчылары - - - В. И. Ленинга үзләренең мәсьәләләре һәм тәкъдимнәре белән мөрәҗәгать иттәләр иде.* КПСС тарихы.

ЙОМЫШЧЫЛ *с.* Тыңлаучан, кушкан эшне үтәүчән. *Никадәр телсез-тешсез, тугры, җитез, йомышчыл булырга тырышсам да, ул әле бер эшемнән, әле икенче эшемнән гаеп тапты.* Х. Садрый.

ЙОМЫШ-ЮЛ *җый. и.* Төрле йомышлар (1, 2 мәгъ.). *— Минем бу тирә-юньдә йомыш-юлым бар иде.* Әкият. [*Гөлсем апа*] *яралы солдатларга - - - китаплар укый, хатларын язып бирә, йомыш-юлларына йөри.* Г. Гобәй.

ЙОН *и.* 1. Имезүче хайваннарның тәнен тоташ каплап алган чәч сыман куе төкләр. *Туры атның йоннарын сыпырам, ялларын тарыйм.* М. Әмир. *Бүреләрнең, төлкеләрнең йоннары күерды.* Г. Әпсәләмов. // Кеше тәнендәге төкләр. *Төхфәтнең - - - ияк буйларын йон баскан.* Ш. Камал.

2. Эрләү, киез итек басу һ. б. өчен хайваннардан (гадәттә сарыктан, дөядән, кәҗәдән) кыркып яки тарап алына торган чәч сыман йомшак җепселләр. *Йон язу. Йон эрләү.* □ *Хуҗа хатыны сарык йоны кыркый торган зур кара кайчы китереп бирде.* А. Шамов. *Машиналар йон тетәләр, җәяләр, әвәлиләр.* Ш. Маннур. // *с. мәгъ.* Шундый җепселләрне эшкәртә торган. *Йон фабрикасы.* □ [*Шәрифә Илмәтованың*] *ире тегермән, йон машинасы тотты.* Г. Толымбай.

3. Шундый җепселләрдән эрләнгән җеп. *Ана капчык төбеннән бәрән йоныннан бәйләнгән җылы оекбаш чыгарды.* А. Шамов. // *с. мәгъ.* Шундый җептән бәйләнгән. *Йон фуфайка. Йон оек. Йон шарф.* □ [*Шәкертнең*] *кулында нечкә генә йон перчатка иде.* Г. Ибраһимов.

4. Шундый җептән эшләнгән тукыма.— *Абый әйтә: «Без солдатта хезмәт иткән җирдә - - - һәр кеше дә ситсы белән йоннан гына киенәләр»,— ди.* Г. Камал. // *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Йон костюм.* □ *Гайниҗамал киң генә итәк салып тегелгән йон күлмәген киде.* Ф. Әмирхан.

5. Кошларның тәнендә һәм каурыйларындагы мамык үсентеләр. *Тавык йонын йолку. Йон чыгару.* □ *Җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз йоннары куып йөргәнемне - - - бер дә онытмыйм.* Г. Тукай. *Аккош очар — йонын кояр, Аның йонын кем җыяр?* Җыр.

◇ **Йон батыр** — мактанчык, җилкуар, юньсез. [*Хатыннар Галәвигә:*] *Хәерче эт, син тик тор, Каян килгән йон батыр!* К. Тинчурин. **Йон йөрәк** — куркак, өркәк. **Йон да юк, сөт тә юк** — бернинди дә файдасы юк. **Йон кабару** — ачу килү, ачулану.— *Борисовларның шактый йоннары кабарган иде һәм, әйтергә кирәк, алар хаклы иде.* Сов. әд. **Йон куну** — файда булу; эш, тормыш, хуҗалык алга китү.— *Караклар, хулиганнар куып йөреп, кемгә йон кунганы бар.* Г. Мөхәммәтшин. **Йон урынына өреп очыру** — җиңел генә юкка чыгару, кире кагу. *Минем дәлилләрем көчле һәм ышандырыгыч иде. Мин аның барлык гаепләүләрен йон урынына өреп очырдым.* А. Шамов. **Йон уңаена сыпыру (сыйпау), йон ятышына сөйләү** — жаена тору, каршы килмәү.— *Ул кадәресен үзең беләсең инде,— диде карт [Зөфәргә] килешкән сыман; аңа ничек тә йон уңаена сыпырырга кирәк иде.* Ә. Еники.— *Кешеләр тыныч кына йон ятышына сөйләгәндә, сиңа сүз әйтергә ярамый, дөньяны кубара башлыйсың.* Ш. Камал. **Йоннан төрмәгән** — юләр түгел, акылсыз түгел.— *Бай абзыйны да йоннан төрмәгән, [матыларны] сразы үлчәп алмый; элек кояшта тота.* Г. Гобәй. **Йонсыз мендәргә яткыру** — бик җиңел генә алдау.— *Алар [кулга алынган кешеләр] безне йонсыз мендәргә яткырырга уйлаганнар.* Ш. Камал **Йонын киргә сыпыру** — жаена тормау, каршы килү.— *Мин серкәсе су күтәрми торганнардан түгел. Минем йонны киргә сыпырырга да ярый.* Г. Әпсәләмов. **Йонын сыйпаштыру** — юмалау, бүләк һ. б. нәрсәләр биреп алдалау.— *Син энекәем, аны [Нәгыймәне] кулда тотарга тырыш. Йонын сыйпаштырырга, икмәк биргәләргә кирәк.* Ш. Камал. **Йонын тету (туздыру)** — 1) бик каты тиргәү, тәнкыйтьләү.— *Безнең әле кодача дигән нәрсә бәла булды тагын. Килеп-килеп, мин сиңа әйтим, йоннарыбызны тетә.* Ш. Камал; 2) бик каты кыйнау, җиңелеп качарга мәҗбүр итү.— [*Кулда*] *чукмар булса, бер качкын гына түгел, унау чыксалар да йоннарын туздырыр идем.* А. Гыйләҗев.

ЙОНАШАР *и. зоол. к.* мамыкашар.

ЙОНКОЯР *и. зоол.* Кан эчүчеләр семьялыгыннан сарыклар йонында паразитлык итүче канатсыз чебен (бөҗәк); *русчасы:* рунец.

ЙОНЛАНУ *ф.* 1. Йон (1, 5 мәгъ.) чыгу, йон белән капланы. [*Сыерның карынынан*] *яңа гына йонлана башлаган кечкенә генә бозау килеп чыкты.* Г. Иделле.

2. Киемгә яки башка нәрсәгә йон бөртекләре, төкләр ябышу турында.

ЙОНЛАЧ *с.* 1. Йон белән капланган, куе озын йонлы. *Капкадан керүгә аны салпы колаклы, зур, йонлач койрыклы Сарбай каршы алды.* М. Әмир. *Йонлач кара бурка бөркәнгән, сөңге тоткан ике атлы урам буенча чабып узды.* И. Гази // Куе төкләр белән капланган (кешеләргә карата). *Йонлач күкрәкле.* □ *Сары мыеклы, йонлач битле - - - берәү сүгенә-сүгенә эчкә керде.* Г. Бәширов. // Йон сыман куе төкләр белән капланган (үсемлек һәм бөҗәкләргә карата). *Йонлач үсемлекләр.* □ [*Кунаклар*] *яшел яфрак өстендәге йонлач көяне күреп алдылар.* А. Алиш.

2. *и. зоол.* Каурыйларының йоны чәч бөртекләренә охшашлы кош; *русчасы:* шерстопер.

ЙОНЛАЧЛАНУ *ф.* Йонлач хәлгә килү. [*Сугышчыларның*] *сакал-мыек басып йонлачланган битләрендә кызарган күзләре, юкарган борыннары гына күренеп калды.* Г. Бәширов.

ЙОНЛЫ *с.* Йон белән капланган, йонлач. *Йонлы бүрек.* □ [*Аюның*] *йонлы йөзе буенча күз яшьләре тәгәрәп китте.* Г. Тукай. // Тәннәрендә куе төкләре булган, йонлач (кешеләргә карата). *Шул чирәмдә әллә, чатыр корып, Яшәгәнме йонлы адәмнәр?* Н. Дәүли.

Йонлы җимеш *диал.— к.* крыжовник.

ЙОНЛЫБАШ *и. бот. к.* тузганак.

ЙОНМАМЫК *и.* Озын, чәч сыман төкләр арасындагы кыска йомшак һәм нәфис йон (җәнлекләрдә). *Мех бирүче җәнлекләрне, гадәттә, куе йонмамык үсеп җиткәч, кыш көне аулыйлар.* Зоология.

ЙОН-МАМЫК *җый. и.* Йон, мамык һ. б. ш. йомшак нәрсәләр. *Саз эчендә, кыяклы түмгәк өстенә чыбык-чабыклар, йон-мамыклар өеп, үрдәкләр оя ясаганнар.* А. Алиш.

ЙОНТАСЛАНУ *ф. диал.* Сизерәү. *Йонтасланган шинель җиңе белән Борын астын сөртеп алгалый.* Н. Дәүли.

ЙОНТАЧ *с. сөйл. к.* йонлач. *Йонтач калын каш.* □ *Башына зур йонтач малахай кигән Гафур ишекне хуҗаларча киң ачып кайтып керә.* Р. Ишморат.

ЙОНЧА I *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан терлек азыгы үсемлеге; *русчасы:* мятлик. *Болын йончасы. Саз йончасы. Сары йонча.*

ЙОНЧА II *и.* Кайбер тукымаларның уң (өске) ягындагы кыска, тигез, йомшак төкләр; *русчасы:* ворс.

ЙОНЧУ *ф.* 1. Ару, талчыгу, хәлсезләнү. *Гаскәр йончыды, сафлар сирәгәйде, корал, сугыш кирәк-яраклары җитешмәде.* Г. Гобәй. [*Әсирләрнең*] *бер ишеләре ачлыктан йончып егыла.* Ш. Маннур. // Бик нык борчылу, рухи газаплану.— *Син, улым, ятып йокла булмаса, кәефең юк, йончыгансың, күрәм.* Ш. Камал. // *с. мәгъ.* Борчулы, мәшәкатьле. *Көзге йончу көннәр артка калды.* Каз. утл.

2. Җәфалану, интегү (зур мохтаҗлык, физик кимсетүләр һ. б. аркасында). *Авырулар икесе дә төн йокламаганнар, күләгә кебек кенә калганнар, бигрәк тә эче авырта торганы йончыган.* Г. Әпсәләмов. *Минһаж төшенде: ул физик яктан ни дәрәҗәдә арып йончыган булса, дошман тылындагы бу кешеләр мораль яктан шулай йончыганнар.* С. Баттал.

3. *к.* йончыту 2. *Дошман тылына разведка ясап, аны борчып, йончып тордык.* Каз. утл.

4. *с. мәгъ.* Чандыр, ябык, хәлсез; өшән (ат турында). *Бабай гәрчә бик карт һәм йончу булса да, Гаяз кебек ялкау түгел иде.* Г. Галиев. [*Шаһиның*] *атлары бик йончу.* Г. Ибраһимов.

ЙОНЧУЛЫ *с.* Арыган, талчыккан, хәлсез. *Йончулы кыяфәт. Йончулы караш.* // Борчулы, мәшәкатьле. *Йончулы вакыт.*

ЙОНЧЫЛУ *ф. к.* йончу (1, 2 мәгъ). *Зөһрә изелгән, йончылган кебек күренә иде.* Ш. Камал. *Тамчы-тамчы яшьләр тамды Йончылган күзләреннән.* М. Җәлил.

ЙОНЧЫГУ *ф. к.* йончу (1, 2 мәгъ.). *Ай ярымнан бирле клиникада ятып йончыккан, арган Шакир, башка көннәрдәге шикелле, бүген дә сәгать дүртне көтеп алды.* Ф. Әмирхан. *Йокыдан ул йончыгып торды.* М. Мәһдиев.

ЙОНЧЫТКЫЧ *с.* Йончыта торган. *Варис йончыткыч уйлардан арынырга телән карады.* М. Хәсәнов.

ЙОНЧЫТУ *ф.* 1. Арыту, талчыктыру, хәлсезләндерү. *Юл бик йончыткан булган ахрысы, мин бик тиз йокыга киткәнмен.* Х. Садрый. *Бөркү һава Гали абзыйны аеруча нык йончыткан.* Г. Әпсәләмов.

2. Җәфалау, интектерү, бик нык борчу. *Озак вакытлар салкында, буранда, алдынгы линия окопларында ач көйгә яту һәм җылы киемнәрнең җитәрлек булмавы да аларны бик йончыткан иде.* М. Гали. [*Ирем мине*] *көнетөне орыша, суга, чиксез-хисапсыз йончыта.* М. Гафури.

ЙОН-ЯБАГА *җый. и.* Йон һәм ябага. *Бу ел тире-яры, йон-ябага бик кыйммәтләнде.* Ш. Мөхәммәдев. *Төп сәүдәбез тире-яры, йон-ябага, Азия маллары һәм куй алып сату иде.* К. Нәҗми.

ЙОП-ЙОМРЫ *с.* Артык. дәр. к. йомры I. *Рөстәм футбол тубыдай тыгыз тәнле, йоп-йомры бер малай иде.* Л. Ихсанова.

ЙОП-ЙОМШАК *с. к.* йом-йомшак. [*Гәрәйгә*] *йоп-йомшак сары толып кидерделәр.* А. Гыйләҗев.

ЙОП-ЮАН *с. Артык дәр. к.* юан. *Йоп-юан кулак Гәрәйша да, - - - Әхтәм Мирзасы да, Низами да — барысы да шул көнне үк районга озатылдылар.* Г. Толымбай.

ЙОРТ *и.* 1. Тору өчен, төрле учреждениеләр, предприятиеләр өчен билгеләнгән корылма, бина; өй. *Йорт салу. Йорт күтәрү. Таш йорт. Агач йорт. Ун катлы йорт.* □ *Бу йорт Гариф әфәнде тора торган йорт булырга тиеш.* Ф. Әмирхан. // Өй һәм аңа караган каралты. *Йортлар киң кырларга сибелеп утырганнар.* Г. Гали.

2. Бер хуҗалык булып яшәүче кешеләр, семья. *Никадәр тырышып эшләсә дә,* [*Тимери*] *төп йортта озак яши алмады.* Г. Бәширов. *Сәйдә җиңги: «Менә кайтыр, менә кайтыр, йортка бәхет алып кайтыр»,— дип, һәр көн ирен көтә башлады.* С. Рафиков. // Бер йортта яшәүче бер яки берничә семья кешеләре. *Янгын бик тиз куркыныч төскә керде. Бөтен йорт аякка басты.* Ә. Фәйзи. // Аерым семья хуҗалыгы. *Җиде йорт бергә оешып, артель төзергә булдык.* Ш. Камал.

3. Ишек алды. *Һәммәсе дә, йортка чыгып, кунаклар озатып калдылар.* Ә. Фәйзи. *Фетнәчеләр белән урам тулды, йорт тулды, өй тулды.* Г. Ибраһимов.

4. Культура-агарту, фән эшләренә, көнкүреш хезмәтләре күрсәтүгә һ. б. ш. мөнәсәбәтле дәүләт учреждениесе; шул учреждение урнашкан бина. *Ял йорты. Галимнәр йорты. Матбугат йорты. Балалар йорты.* □ *Совет йорты ишеген ачып кергәндә, - - - аның йөзгә бик еш тибә иде.* А. Шамов.

5. Ил, туган җир. [*Хан:*] *Болгар йортының данлы чичәне - - - шушы байгышмы?* Н. Исәнбәт. *Язгы алсу таң белән, Мәңге сүнмәс дан белән Туган йортка кайталар, Безнең батыр лачыннар.* М. Җәлил.

6. *иск.* Династия, нәсел-нәсәп. *Сез Галиҗәнап император хәзрәтләренең һәм сезнең патшалык итүче йортыгызның сәламәтлеге турында - - - иксез-чиксез итагать хисләребезне юнәлдерәбез.* К. Нәҗми.

7. *с. мәгъ.* Йортка, семья тормышына караган. *Йорт эшләре. Йорт җиһазлары.* □ *Мин аз булса да йорт хезмәтләренә ярый башладым.* Г. Тукай. // Кулга, йортка ияләштерелгән. *Йорт кошлары.* □ *Агач араларында коймалары, стеналары яхшы зәңгәр төскә буялган йорт хайваннары каралтылары.* Ф. Кәрим.

Йорт башы (хуҗасы) — семья башлыгы, гадәттә ата; йорттагы хуҗалыкны алып баручы. [*Габдулла*] *соңыннан бу кешенең шушы йорт хуҗасы Ибраһим бай икәнен белде.* Ә. Фәйзи. *Авылда, гадәттә, «кем өе» дип сораганда, йорт башы, ир кеше исеме белән «фәләннәр йорты» дип йөртәләр.* А. Гыйләҗев. **Йорт идарәсе** — торак йортлар мәсьәләсе белән шөгыльләнә торган контора. *Йорт идарәсе* [*квартирага*] *ремонтны язга чыккач кына ясарга уйлый.* М. Җәлил. **Йорт иясе** *миф.*— хорафатларга ышану буенча, һәрбер йортта була торган явыз яки мәрхәмәтле җан, рух. **Йорт кенәгәсе** — йортта торучыларны регистрацияләү китабы (шәһәр йорт идарәсе тарафыннан алып барыла). **Йорт куяны** — куяннар семьялыгыннан тиресе, мамыгы һәм ите өчен махсус үрчетелә торган җәнлек.— *Болар куян түгел, шайтан алгырлары, ә йорт куяннары,— ди ул, көлүеннән бераз айнып.* Г. Гобәй.

◇ **Йорт итү (көтү)**—семья, хуҗалык булдырып яшәү. *Яхшы ага йорт көтсә, йорт кирәген җиткерер.* Мәкаль. *Габдрахман тырышып-тырышып йорт итә башлады инде.* Ф. Әмирхан. **Йорт тумасы** — 1) йортта, үз хуҗалыгында үрчетелгән, карап үстерелгән мал. *Шәмси* [*сугышка*] *китәр алдыннан туып калган йолдыз кашкалы йорт тумасы җирән тай хәзер өч айлык булды дигән сүз!* Г. Бәширов; 2) үз җирлегендә, үз халкы арасында туып, үсеп күтәрелгән кеше турында. [*Зөбәер:*] *Шуны әйтәм әле, Касыйм туган, ничә әйтсәң дә, үзебезнең йорт тумасы шул.* Ф. Хөсни. **Йорт җанлы** — йорт, семья өчен тырышучан, кайгыртучан. *Ихтимал* [*Нажия дә*] *әнисе кебек йорт җанлы хозяйка булыр.* Ә. Еники. **Йортка керү** — өйләнеп, хатын йортында калу. [*Шәмсетдин, Гандәлипкә*] *йортка кереп, бер атна дигәндә йортлы-җирле, башлы-күзле булып алды.* Г. Бәширов.

ЙОРТ-КАРАЛТЫ *җый. и.* Өй һәм аңа караган корылмалар. *Әптелбәр йорт-каралтыны күрсәтеп чыгу белән генә чикләнеп калмады.* Ә. Фәйзи. [*Әхтәм:*] *Йорт-каралтыларымның артканы юк. Шулай да атка тиендем.* Т. Гыйззәт.

ЙОРТЛАШТЫРУ *ф.* Йортка, кулга ияләштерү. *Йортлаштырылган хайваннарда кешенең йогынтысы бигрәк тә нык сизелә.* Зоология.

ЙОРТЛАШУ *ф.* Кулга, йортка ияләшү (хайваннар турында). *Йортлашкан төньяк боланы.*

ЙОРТЛЫКЛЫ *с. к.* йорт җанлы.

ЙОРТТАШ *с.* Бер йортта яшәүче. *Йортташ күршеләр Камилнең уртак бакчага болай чынлап ябышуына баштарак кырын карадылар.* М. Әмир.

ЙОРТТОТМАС *с. сөйл.* Йортка, семьяга күңел бирми торган, йорт җанлы булмаган. *Йорттотмас ауга*

чыкса, артыннан гауга чыгар. Мәкаль. [*Халидә өчен*] *Айдар - - - йорттотмас кеше булып чыкты.* Ф. Хөсни.

ЙОРТТУМА *с.* 1. Йортта, үз хуҗалыгында үрчетелгән, карап үстерелгән. *Йорттума чабышкы.*

2. Үз жирлегендә, үз халкы арасында туып, үсеп күтәрелгән. *Илебездә, халкыбыз эчендә, үзенең һөнәренә хас мәктәп тәрбиясе күрә алмаган, ләкин табигый талант иясе — йорттума оста куллар һаман була килгән.* И. Рәмиев.

ЙОРТ-ҖИР *җыйк. и.* Йорты һәм жире булган шәхси хуҗалык. *Бикмулла - - - йорт-жиргә хуҗа булып калмакчы була.* А. Шамов.

ЙОРТ-ҖИҺАЗ *җыйк. и.* Семья тормышы өчен кирәкле милек, йорт кирәк-яраклары. [*Миргалим*] *йорт-жиһаз арттыруның да чиге барлыгын сизә.* М. Әмир.

ЙОТ *и.* 1. *сир.* Афәт, һәлакәт (кышын, бозлавык вакытта мал-туарның далада, кар тибеп туклана алмавы аркасында, күпләп һәлак булуы, кырылуы турында). *Йот килү.* □ *Итнең төбе бот булыр, Йотның төбе юк булыр.* Мәкаль.

2. *с. мәгъ. диал.* Талымсыз, күп ашаучан, комсыз. *Йот кеше.*

ЙОТКЫЛЫК *и.* Авыз куышлыгын үңәч белән тоташтыра торган канал, ашкайнату системасының бер өлеше. *Йоткылык бизе. Йоткылык өсте.* □ *Ашар — тамак, йотар — йоткылык.* Әйтем.

ЙОТКЫЧ *и.* Дымны, парны һ. б. үзенә сеңдерә, йота ала торган күзәнәкле матдә. *Химик йоткыч.*

ЙОТКЫШ *и. диал.* Туемсыз, комсыз.

ЙОТКЫШЛАНУ *ф. диал.* Туймастай кылану, комсызлану.

ЙОТЛЫГУ *ф.* 1. Бик нык ачыгу һәм сусау. *Йотлыккан йортын мактый.* Мәкаль. *Бер чишмәнең суын эчеп бетерердәй булып йотлыктым, ирен иренгә ябышты.* Х. Садрый. // *рәв. мәгъ* **йотлыгып.** Ашыгып, туймастай булып (ашау, эчү, һава сулау турында). *Өендә ач торган шикелле, анда* [*кунакка*] *баргач, йотлыгып ашап утыру бер дә килешкән эш түгел.* Ф. Әмирхан. *Зөлфия йотлыгып су эчә.* Р. Ишморат. *Чыклы төнге һаваны йотлыгып сулаудан* [*Фәттахның*] *киң, таза күкрәге - - - бер югары калка, бер түбән төшә иде.* Ф. Кәрим.

2. Ашаганда, эчкәндә төелү, чәчәү. *Авыру* [*суны*] *бер-ике йоткач ук йотлыкты, башын бер читкә тартты.* А. Шамов. *Күп чәйнәп аз йотсаң, йотлыкмассың.* Мәкаль.

3. *күч.* Ашыгу, дулкынлану, каушаудан һ. б. тотлыгып сөйләү, уку; сөйләгәндә, укыганда авазларның яки сүзләрнең ахырын ачык әйтеп бетермәү. [*Егетнең*] *балалар кебек йотлыгуы, бер сүзне бетерми икенчесен башлаулары ничектер кызыклы вә күңелле тоела иде.* Ш. Камал. // *рәв. мәгъ. Кыз сулу алды һәм - - - йотлыгып өстәп куйды: — ...Ипташлар... мине калдырмагыз!* А. Шамов. [*Балалар*] *сүзләрен ашыга-ашыга, йотлыга-йотлыга әйттеләр дә җавап та көтми чыгып киттеләр.* Х. Кәрим.

ЙОТЛЫГУЛЫ *с.* Тотлыгулы, өзек-өзек чыккан. *Ул вак йотлыгулы тавыш белән пышылдап утена:— Туганкайлар!.. Туганкайлар, кызганыгыз!* Ш. Камал.

ЙОТЛЫК *и.* Афәт, һәлакәтлек; *к.* йот. *Куй елы — кытлык, Куян елы — йотлык.* Мәкаль. *Батыр — бер уклык, бай — бер йотлык.* Мәкаль. // *с. мәгъ.* Афәтле, һәлакәтле. *Йотлык ел.*

ЙОТМА *и. гади с.* Бугаз. [*Көснетдин:*] *Болар бит, адәм рәтле итеп, «буржуйның муенын кисәргә кирәк» диясе урында «йотмасын өзеп алырга кирәк» диләр.* Ш. Камал.

ЙОТУ *ф.* 1. Тел һәм йоткылык мускулларының хәрәкәте белән азык, эчемлек һ. б.ларны үңәч аша үткәрү. *Дару йоту.* □ *Кабып йотар алдыннан төлке дә тавыкны мактый.* Мәкаль. *Хәлим шикәрне кетердәтеп тешләде, чәй йотты.* И. Гази.

2. Үзенә алу, сеңдерү. [*Химик препарат*] *аркасында яфраклар кояш нурларын үзләренә йоту сәләтләрен югалтканнар.* Г. Галиев. // *күч.* Бик тырышып, мавыгып өйрәнү, үзләштерү турында. *Мәгарәдә укып чыккан, Ничә фәнне йотып чыккан, Әбелхарис аның исеме, Моны белсә белер ул зат!* Н. Исәнбәт. *Баязит сүзләрне беренче хәрефеннән үк аңлап йота бара.* Г. Ибраһимов.

3. Үз эченә суыру, батыру. [*Танк*] *хәзер, бөтенләй кәкрәеп, жиргә сеңеп бара: тиздән сазлык аны бөтенләй йотачак.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Нәрсәнең дә булса эченә кереп юкка чыгу, икенче бер хәлгә килү турында. [*Барабан*] *көлтәне бер яктан йота бара, икенче яктан саламны кагып алга этәрә.* Г. Ибраһимов. // *күч.* Үзе белән чолгап, күренмәслек итү, каплап алу. *Караңгы төн киткән бер сугышчыны упкынына йоткан шикелле йота бара.* Г. Бәширов.

4. Сөйләгәндә сүзләрне, авазларны ачык әйтмәү, әйтеп җиткермәү. *«Р» авазын йотып сөйләү.* □ [*Чибәркәева*] *сүзләрен йота-йота ашыгып сөйли башлады.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч.* Нәрсәне дә булса тотып бетерү, сарыф итү, юкка чыгару. [*Гыйниятулланың*] *бер йомшак ягы бар. Менә шул аның барлык тапканын йотып бетерә.* С. Җәләл.

6. *күч.* Нәрсәне дә булса (вакыт, чыгым, көч һ. б. ш.) үзенә күп таләп итү. *Кич белән укырга йөрү, техник китапларда казыну* [*Николайның*] *бөтен вакытын йотып торды.* И. Гази.

7. *күч.* Тышка чыгармау, яшерү, эчтә саклау. *Ачу йоту. Үч йоту.* □ [*Солтан*], *гайбәт сату була дип, әйтер сүзен йотып, әйтмичә калды.* А. Расих. *Сөләйман - - - көлкесен йотып калырга мәҗбүр булды.* К. Тинчурин.

8. *күч.* Басып алу, көчләп буйсындыру. *Безне дошман йота алмады, Утлы божраларын өздек без.* Ә. Ерикәй. // Бер телнең икенче телне кысрыклавы, аны мөстәкыйль тел булып яшәүдән туктатуы, юкка чыгаруы турында. *Көчлерәк халыкларның телләре көчсезрәк, буйсынган, колониаль халыкларның телләрен кысрыклый, йота.* С. Фәйзуллин. *Бер тиран да йота алмас, И көчле туган телем.* И. Юзеев.

9. *күч. сөйл.* Юкка чыгару, һәлак итү. *Безне дошманнар йотар күк, Йота алмаслар, дуслар күп.* Жыр.— *Кемнәрне генә йотмады бу сугыш.* М. Әмир.

10. *күч. сөйл.* Берәр төрле, гадәттә гадел булмаган юл белән үзләштерү турында. *Мин,— дигән,— базарда зур кибет тотып, Бетерермен вак кибетләрне йотып.* Н. Баян. *Фәлән бай караклар белән казна баскан да, аларның башларына житеп, бөтен малны үзенә йоткан.* Г. Бәширов. // Урлау. *Хафизны* [*коммуна йортындагы балаларга җибәрелгән әйберләрне*] *йотуда гаеплиләр.* Г. Гали.

11. *күч.* Нәрсәгә дә булса дучар булу, шуны баштан кичерү (кайгы, газап һ. б. ш.). [*Мостафин*], *тау кадәр газап йотып, ахыр чиктә үзенең язмышы белән килеште.* Ә. Еники.— *Ах, әни, бу көннәрдә минем - - - нинди кайгылар йотканымны белсәң иде, кызганыр идең.* Ф. Әмирхан.

12. *күч.* Кызыксындыру, мавыктыру, үзенә бик нык җәлеп итү. *Яңалык Ильясны шулкадәр йотты, ул хәтта кызның якташы булуын да онытты.* А. Расих.

13. *күч. гади. с.* Исерткеч эчемлек эчү турында. *Зәки - - - бик аз гына булса да йоткалый.* Г. Толымбай.

◇ **Йотардай (йотып алырдай) булып** — 1) бик усал рәвештә, ачуланып. *Йотардай булып карау;* 2) бик кызыксынып, зур игътибар белән. *Вәлитов, Шәмси янына идәнгә утырып, аның авызыннан чыккан һәр сүзне йотып алырдай булып* [*тыңлый иде*]. Г. Бәширов.

ЙОТЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* йоту.

2. *күч.* Берәр нәрсә белән артык мавыгу, бөтен игътибарны шуңа юнәлтү. *Матур сахра, моңлы тавыш-*

ларга Безнең Эшче тәмам йотылды. М. Гафури. // Кемгә яки нәрсәгә дә булса күзне алмыйча текәлеп карау. *Хатын аңар йөзе белән әйләнде, күз карашы белән егеткә йотылды.* Г. Ибраһимов. *Чем-кара күзләр куксел таулара йотылганнар.* М. Әмир. // *рәв. мәгъ.* **йотылып.** Зур игътибар белән, бик нык бирелеп, кызыксынып. *Йотылып тыңлау.* □ *Сәгыйдә --- [китапны] йотылып укый башлый.* Һ. Такташ. *Шәрифуллинның текәп, йотылып карап торуыннан Халисә, оялыпмы шунда, читенсенепме, аска карады.* С. Рафиков.

3. *күч.* Таралып, ераклашып юкка чыгу. *Гөрселдәгән тавыш урман эченә кереп йотылды.* Г. Гобәй. *Затон ярлары арасында йөрүче паром эзенең көмеш тимгелләре дә озакка бармыйлар, шомаралар, тигез катлау булып, койрык артында йотылалар.* К. Нәҗми.

ЙОТЫМ *и.* 1. Йоту вакытында йоткылык мускулатурасының бер тапкыр хәрәкәте; йоту хәрәкәте: *Вак-вак йотымнар белән эчү.* □ *Ул чәен бер-ике йотымда бушатты.* С. Рафиков.

2. Шундый бер хәрәкәт вакытында эчелгән, йотылган эчемлекнең яки сыек ашамлыкның күләме. *Вәли абзый, чәенең соңгы йотымын озын гына итеп чөмереп алганнан соң, чыныягын өстәлгә куйды.* Ә. Фәйзи. // «Бик аз гына микъдарда» мәгънәсен белдерә («бер», «ике-өч» кебек саннар белән дә кулланыла). *Аз булмады хәтта йотым суны Икәү бүлеп эчкән чагыбыз.* З. Мансур.

ЙОТЫМЛАУ *ф.*. Йотым-йотым итеп эчү. *Минем ашыгыр җирем юк, сыраны әз-мәз генә йотымлап, шуларга карап утырам.* Ә. Еники. // *рәв. мәгъ.* **йотымлап.** Йотым-йотым итеп, йотым саен тукталыш ясап. *Мостафа чәй янында утыра, ясап куйган стаканны иренеп кенә берәр йотымлап эчә.* Ф. Әмирхан.

ЙОТЫНУ *ф.* Ирексездән бик еш йоту хәрәкәтләре ясау. *Мин бакчада берәр әйләнгәч тә, әллә нихәтле җир йөргән төсле, аякларымда бертөрле хәлсезлек сизә башладым, --- бик еш йотынам, иреннәрем кибә иде.* Ш. Камал.

ЙӨГЕНӘ: йөгенә керә алмау — кистереп дөресен генә әйтә алмау, җаваплылыкны өскә ала алмау.— *Исерекләрме, аеклармы, йөгенә керә алмыйм, иллә мәгәр [Фәхри белән Садыйк] котырынган этләр кебек талашып баралар иде.* Г. Ибраһимов.— *Йөгеңә керер хәлем юк, синең кая йөргәнеңне мин каян белим.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЙӨГЕНҮ *ф.* 1. Гәүдәне бераз ию (алга таба). *Бөркет канаты кебек җәелгән кара буркалар, очып барганда алга йөгенгән гәүдәләр --- дәһшәтле ташкын булып үттеләр.* Г. Бәширов.

2. *диал.* Җиңелчә генә тез чүгеп сәлам бирү, исәнләшү.— *Атаң сараена керәсең, йөгенеп ал, кызым.* Н. Исәнбәт.

3. *диал.* Хәлсезләнү, өшәнү. *Карт йөгенгән, туктаусыз гыжлый иде.* А. Гыйләҗев. *Йөгенгәннәрне ныклабрак туйдыру кирәк булган чакта, [аш блогында] үз кешең булуы бик мөһим иде.* Ш. Маннур.

ЙӨГЕРЕК *с.* 1. Кызу, тиз чаба торган; шәп йөгерүче. *Абзый, безгә яхшы ат кирәк: я йөгерек, я юрга.* Г. Тукай. *Бүген сабан туе! --- Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар.* Г. Ибраһимов. // *и. мәгъ.* Чабышкы (ат). *Байлар --- Шәйдукның йөгерегенә агу каптырып үтерергә булганнар.* Ш. Әхмәдиев. *Безнең монда Дон йөгерекләре һәм инглиз атлары гына.* А. Расих. // *күч.* Тирән һәм җентекле булмаган, өстән-өстән генә булган. [*Мәкалә*] *атаклы язучының иҗатына йөгерек күзәтү рәвешендә генә язылган булса да, күп кенә кызыклы фикерләрне әченә ала.* И. Нуруллин.

2. Кызу хәрәкәт итә торган. *Тоннель аша йөгерек поезд үтте, Ак тасмасы калды сүтелеп.* М. Җәлил. // Кызу ага торган (су, елга турында). *Уйсулыкны нинди тар йөгерек елга кисеп үтә.* А. Шамов. // Җитез, өлгер, хәрәкәтчән. *Йөгерек кул.* □ — *Яшь сөяк йомышюлга йөгерек дип, [Нәсимәне] үз яныма алдырткан идем.* К. Нәҗми. *Йөгерек аяк — атка, йөгерек гел — башка.* Мәкаль. // Бик тиз арада булып үтә торган; кыска вакытлы, ашыгыч. *Ул тирә-ягына яшен шикелле йөгерек караш ташлады.* Ш. Усманов. *Бүген дә --- йөгерек бер сөйләшү булып алды.* Г. Әпсәләмов.

3. Тиз, шома, тоткарланмыйча. *Йөгерек уку. Йөгерек исәплә.* // *күч.* Шома, үткен (тел турында). *Хикәя йөгерек, матур тел белән язылган.* Х. Хисмәтуллин.— *Синең тел, агай, шактый озын һәм йөгерек күренә.* К. Тинчурин.

Йөгерек кошлар *зоол.*— комлы далаларда һәм чүлләрдә яши торган, очуга караганда йөгерү сәләте көчлерәк булган озын ботлы кошлар төркеме.

◇ **Йөгерек акыллы** — өстән генә уйлаучы, төптән уйламаучы.— *Аларның [яшьләрнең] бер йөгерек акыллысы хәтта Елизавета Федоровнаны мороженое сатарга чыгарып җибәрмәкче.* Г. Әпсәләмов. **Йөгерек зиһенле** — бик үткен, зирәк. *Габдулла Әлказый иң йөгерек зиһенләләрдән иде.* Г. Ибраһимов.

ЙӨГЕРЕКЛЕК *и.* Йөгерек булу, йөгерек булу сыйфаты. *Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.* Г. Тукай. *[Тәнкыйтьчегә] минем шигырь төзеләшем, телнең йөгереклеге --- ошаган булса кирәк.* Ф. Хөсни.

ЙӨГЕРЕКЛӘНДЕРҮ *ф. сир.* Тизләтү, кызулату. [*Гыйльманов*], --- *каләмен тагын да йөгерекләндерә төшеп, кәгазьне тагын да шәфкатьсезрәк кыштырдатырга кереште.* Ш. Камал.

ЙӨГЕРЕШ *и.* 1. «Йөгерү» фигыленнән ясалган исем. *Бөтен цирк мәйданын ут чыккандагы кебек бер тапталы, кычкырыш, йөгереш капкый.* Г. Ибраһимов.

2. *спорт.* Йөгерү ярышы. *Гайрәтулла малае, көрәштә батыр калуыннан гайрәтләнеп булса кирәк, олыларга ияреп, йөгерешкә дә киткән булып чыкты.* Ф. Хөсни. // *диал.* Бәйге, чабыш. *Халык, йөгерешкә барган атлар турында сөйләшә-сөйләшә, авылга таба агыла башлады.* М. Гали.

ЙӨГЕРЕШЧЕ *и. спорт.* Йөгерү спорты белән шөгыльләнүче; **йөгерү ярышында катнашучы.** *Халыкның күбесе, урынныннан сикереп торып, йөгерешчеләрнең килгән нәрен карый башладылар.* М. Гали.

ЙӨГЕРЕШӘ-КУЫША *рәв.* Йөгереп, бер-берсен куып җитәргә, узарга тырышып. *Без аның белән шундук йөгерешә-куыша су буена төшеп киттек.* Г. Бәширов.

ЙӨГЕРЕШҮ *ф.* Ярышып, узышып йөгерү.— *Өченче ел безнең сабан туенда капчык киеп йөгерешкән идек ич!* Г. Гобәй. *Ташбака белән куян, үзышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар.* Г. Тукай. // Бер-бер артлы яки күмәкләп бер якка таба йөгереп китү. *Балачага, гөж килеп, --- шул кызыкка таба йөгерештеләр.* Г. Ибраһимов. // Ары-бире йөгерү, йөгереп йөрү (күпләр турында). *Йөгерешә, куыша уйнау.* □ *Якуп йөгерешеп йөргән вак кара кырмыскаларны газета битеннән сыпырып төшерде.* И. Гази.

ЙӨГЕРМӘ *и. диал.* Вак-вак, йөгерүгә якын кызу адымнар. *Каршыдан бер җария, йөгермә белән кереп, Яникә алдына чүгә.* Н. Исәнбәт.

ЙӨГЕРТҮ. *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* **йөгерү** (1, 2, 7—9 мәгъ.). [*Солдатларны*], *хәлдән тайганчы йөгертеп, караңгы төшкәнче этлиләр.* М. Гали. *Хатын --- өйдә ирен шактый йөгертә белә.* А. Әхмәт.

2. Кая да булса бик тиз генә барып кайтырга җибәрү. *Мәктәп караучы апаны Сәлимнең тора торган өенә йөгерттеләр.* А. Алиш.

3. Куу, куалау, йөрешен тизләтү (атның).— *И, туташлар, я минем белән сөйләшеп барыгыз, я атыгызны йөгертегез, булмаса, мин эч пошудан үләм.* Ф. Әмирхан. // *диал.* Ат чабышында катнашу, ат чаптыру.— *Теге сабан туен хәтерлисеңме? --- Ат йөгертергә барган идек бит.* Ф. Хөсни.

4. *рәв. мәгъ. күч.* **йөгертеп.** Тиз генә, жентекләп тормыйча, өстән-өстән генә. *Йөгертеп карап чыгу.* ☐ *Мулла --- әлеге кәгазен йөгертеп укып чыкты.* А. Шамов. *Хәдичә түти --- аңа йөгертеп кенә авыл хәлләрен, колхозның ничек эшләвен сөйли.* Г. Бәширов. // Бик тиз, кызу; җиңел генә. *Йөгертеп эшли.* ☐ *Җирән кашка яшь булса да көчле икән: шулчаклы печән белән биш кешене йөгертеп алып кайтты.* Г. Ибраһимов.

ЙӨГЕРТҮ II *ф.* 1. Бер әйбернең өстен юка гына иттереп икенче төрле матдә белән каплату, буяу. *Төргәк эченнән алсу төсле, читләренә алтын буяу йөгертелгән --- тагын бер кәгазь килеп чыкты.* Н. Дәүли.

2. Әйбергә, аны тузаннан, йоннан һ. б. ш. арындыру, пакьләндерү өчен, су бөркү, сибү турында. *Тәрәзә пыяласына су йөгертү.* ☐ *Хәзрәт, бөтен киемнәрен салып, аларга өчәр кат су йөгерт[те].* Ф. Әмирхан.

ЙӨГЕРТҮ III *ф.* Хайваннарда: җенси кушылдыру, каплату.— *Кәҗә буаз. Тәкә йөгерткәнен үз күзем белән күрдем.* С. Рафиков.

ЙӨГЕРӘ-АТЛЫЙ *рәв.* Бер йөгереп, бер адымлап; бик ашыгып. *Алар йөгерә-атлый райком бинасының баскычына менеп киттеләр.* М. Әмир.

ЙӨГЕРҮ *ф.* 1. Аякларны тиз-тиз алыштырып, кискен этәрешле адымнар белән бик кызу хәрәкәт итү. *Башта ашыкмый гына бардык. Аннары йөгерергә тотындык.* Г. Әпсәләмов. *Бандитлар каушап калган арада Җәүдәт, энесен күтәреп, елга буена йөгерде.* Г. Бәширов. // Ашыгыч рәвештә кая да булса бару.— *Берәр йомышың төшсә, яхшымы-яманмы, тагын шул каһәр төшкән Маликка йөгеререгә туры килә́чәк бит.* И. Гази.

2. Зур тизлек белән бару (поезд, машина һ. б. ш. хәрәкәте турында). *Юл буйлап кечкенә генә бер поезд алга йөгерә иде.* Ш. Усманов. // Зур тизлек белән күчү, таралу (төтен, җил, яктылык һ. б. турында). *Ут иркенләде, ботактан ботакка йөгерә башлап, минуттан минутка кыза һәм ялкынлана бара иде.* Г. Тукай. *Авылны урап алган чыбыклар буйлап күз ачып йомганчы ток йөгерде, бөтен авыл ялт итте.* Г. Галиев. // Организмга кинәт таралып, нинди дә булса тәэсир ясау турында. *Эчкә салкын йөгерү.* ☐ *Аракы аларның башларына йөгерде.* Ә. Айдар.

3. *күч.* Җитез хәрәкәт итү (куллар турында). *Җырлый-җырлый Дилбәр күлмәк тегә. --- Кулы йөгерә ефәк сатин буйлап, Тирән сагыш уйчан йөзендә.* М. Җәлил.

4. *күч.* Тиз үтү (вакыт турында). *Вакытның ничек тиз йөгергәне сизелде.* Ш. Усманов.

5. *күч.* Агу, ташып агып китү (сыеклыкларга карата). *Боз һәм кар эреде, Сулар йөгерде.* Г. Тукай.

6. Нинди дә булса бер юнәлештә ераккa сузылу, тартылу (юллар, сукмаклар, телефон чыбыклары һ. б.). *Юл буенда яңа багаиалар. Алга йөгерә телефон чыбыгы.* Ф. Кәрим. *Автобус чаба да чаба. Ирʹән иртүк бульдозерлар көрәп киткән асфальт кара тасма булып артка йөгерә.* Г. Ахунов.

7. *күч.* Кинәт, тиз арада нинди дә булса психик күренеш булып алу (кешедә). *Ананың әрнүле йөзеннән эчке сыкрану билгеләре йөгереп үтте.* А. Шамов. *Фоатның күңеленә шатлык йөгерде.* Г. Әпсәләмов.

8. *күч.* Нинди дә булса төскә керү. *Йөзгә кызыллык йөгерү. Чәчкә ак йөгерү.* ☐ *Офыктан офыкка кадәр җәелеп ярыш кырлары ята. Аларга ак йөгерә башлаган инде.* М. Хәсәнов. *Назлы усакларның зифа буйларына инде яшеллек йөгергән.* А. Расих.

9. *күч.* Нинди дә булса эшне башкарырга, булдырырга тырышып йөрү. [*Бай*] *көне-төне йөгерде мал артыннан.* Г. Камал. // Күп нәрсә башкарырга, эшләргә өлгерү, җитешү турында. *Рәүфә барын да эшли, барысына да йөгерә.* А. Шамов.

ЙӨГӘН *и.* 1. Җигеп, атланып йөрүдә файдалану өчен, хайваннарның, мәсәлән, атның башына кидерә торган, галәттә каештан ясалган авызлыклы тезгенле җайланма — ат җигү җиһазларыннан берсе. *Йөгән балдагы. Йөгән капламасы.* ☐ *Чылдыр-чылдыр чылдырыйдыр ат башында җиз йөгән.* Г. Тукай. *Газинур, атларны чистартып бетереп, йөгәннәрен салдырды.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Нәрсә дә булса эшләргә мөмкинлек бирмичә, иркезләп, тоткарлап тора торган сәбәп, хәл. *Габдрахман үзе — күптән түгел генә баеның йөгәненнән котылган, тегелә́й итеп, болай итеп җыйган акчасы белән тире сәүдәсенә керешкән егет.* Ә. Фәйзи. *Әле хәзердән үк болай җенләнгән анасы, Шибай карт үлеп, йөгәнсез, авызлыксыз калса, --- бәйләүдән ычкынган эткә әйләнер.* Г. Ибраһимов.

Йөгән күзлеге — ат як-якка каранып бармасын өчен, йөгәнгә беркетелгән күз каплагыч; йөгән капламасы.

◇ **Йөгәндә тоту** — тыңлату, буйсындырып яшәтү. **Йөгәнне каты(рак) тоту** (кешегә карата) — ирек бирмәү, узындырмау. **Йөгәнне кулдан ычкындыру** — ирек бирү, үз иркенә кую. **Йөгәннән тотып бару** — җитәкләү, нинди дә булса эшкә юл күрсәтү.— [*Халыкны*] *кемдер йөгәннән тотып барырга тиештер инде?* Г. Бәширов. **Йөгәннән ычкыну** — буйсынмау, үз белдекчә эш итү.— *Нишләп сез ул малайны [Айдарны] йөгәннән ычкындырасыз?* Ф. Хөсни.

ЙӨГӘНЛЕ *с.* Йөгән кидерелгән, йөгәнләнгән. *Кара урманга кереп китте Минем йөгәнле атым.* Җыр.

ЙӨГӘНЛЕКЛӘҮ *ф. сир. к.* йөгәнләү. *Йолдызлар таң калсын ачышка: Йөгәнлеклә кояш йөргән.* М. Хөсәен.

ЙӨГӘНЛӘҮ *ф.* 1. Йөгән кидерү. *Акрынлап айгырны йөгәнләделәр.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Тыю, таләп ителгән тәртипкә буйсындыру, үз иркенә куймау. [*Нәфисә:*] *Мин ул Әпипәне ничек булса да йөгәнләрмен.* Г. Бәширов. *Ветлугин монда да үзенең усаллыгын, дуамаллыгын йөгәнли алмый калды.* М. Хәсәнов. // Үз ихтыярына буйсындыру, билгеле бер максат өчен файдалану. *Ташкын Ангараны йөгәнләү.* ☐ [*Кәбир*] *тракторны тезгенли, комбайнны йөгәнли.* Сов. әд. // *рәв. мәгъ.* **йөгәнләп.** Көчләп, иркезләп. *Йөгәнләп эшләтү.* ☐ [*Фәйрүзә Арсланга:*] *Йөгәнләп алып килмәкче идем сине.* Г. Ахунов.

ЙӨГӘНСЕЗ *с.* 1. Йөгәне юк, йөгән кидерелмәгән. *Йөгәнсез ат.*

2. *күч.* Тотнаксыз, әдәпсез, азгын. *Йөгәнсез характер. Йөгәнсез сүзләр сөйләү.* ☐ [*Фатыйма:*] *Сез үзегезнең йөгәнсез тойгыларыгызга хуҗа була алмыйсыз, Фәрид.* М. Әмир. *Холкы ямьсез адәм йөгәнсез.* М. Хәсәен. // Үзирекле, башбаштак. *Йөгәнсез хөкүмәт беренче һөҗүмне дошман крепостьларына һәм флотларына каршы түгел, бәлки эшче газеталарның редакцияләренә туздырудан башлады.* К. Нәҗми. *Юлбарысның җаны йөгәнсез, Җинаятьсез үтми бер юлдан.* Ф. Кәрим. // *шигъ.* Иректе, бернәрсә белән дә чикләнмәгән. *Йөгәнсез яшьлек.* ☐ *Кинәт блиндаж эчендә йөгәнсез шаян, тыелгысыз ашыккан җиңел көйләр өермәсе бөтерелеп узды.* Г. Бәширов.

ЙӨГӘНСЕЗЛЕК *и.* Артык тотнаксызлык, тыйнаксызлык, әдәпсезлек; азгынлык. *Мораль йөгәнсезлек.* ☐ [*Ногман Хөбәйбәгә:*] *Моңарчы булган йөгәнсезлегеңне ташламасаң, фермадан гына түгел, колхоздан чыгарырга да кыйбат алмаслар.* Т. Гыйззәт. // Үзиреклелек, башбаштаклык. *Меньшевиклар партияне артка, организацион таркаулыкка, йөгәнсезлеккә, түгәрәкчелеккә һәм кустарьчылыкка өстерәделәр.* КПСС тарихы.

ЙӨГӘНСЕЗЛӘНҮ *ф.* Йөгәнсезгә (2 мәгъ.) әйләнү. *Г. Камал әсәрләрендә кеше хакын ашап, симереп котырынган, йөгәнсезләнгән байларны, сәүдәгәрләрне, черек буржуа җәмгыяте тудырган мещаннарны күрәбез.* М. Гали. // *рәв. мәгъ.* **йөгәнсезләнеп.** Иркенләп, тыелгысыз рәвештә. *Буран тәмам йөгәнсезләнеп котыра.* Р. Төхфәтуллин.

ЙӨДӘТҮ *ф.* **1.** Аптырату, әледән-әле борчып тору, тынгылык бирмәү. *Теге - - - шайтан минем сәүдә юлыма аркылы төшеп йөдәтте бит инде.* Ш. Мөхәммәдев. *Алма байлары бик йөдәтәләр.* И. Гази. *Әхмәт бабай - - - бер үк сүзне мең тапкыр кабатлап йөдәтми иде.* Г. Гали.

2. Интектерү, җәфалау (авыру, ачлык һ. б. ш. турында). *Барлык өйрәтә, юклык йөдәтә.* Мәкаль. *Уткән яз мине бер килеп, бер китеп борчыган шул бизгәкме, маляряме быел да яз башыннан бирле йөдәтә.* М. Җәлил.

3. Җәберләү, рәнҗетү, рухи газаплау.— *Шәйхи мәзин - - -ярлыларны талап йөдәтүдән башканы белми иде.* Ш. Камал. [*Галиябану:*] *Исмәгыйль абый, йөдәтмә мине юкка.* М. Фәйзи.

ЙӨДӘҮ I *ф.* **1.** Интегү, җәфалану. *Ачлыктан йөдәгән авыл халкына - - - җир кирәк.* Ш. Мөхәммәдев. *Минем халкым җирсез йөдәгәндә, Җирле итте Бөек Октябрь.* Ә. Ерикәй. // Ару, талчыгу, хәлдән таю.— *Фазлулла авырый башлаганнан бирле бөтен эшне* [*үзем*] *башкарып йөдәп беттем.* М. Фәйзи. *Ябалакны эзли-эзли йөдәп беткәннәр, таң тугач, өйләренә кайтып киткәннәр.* А. Алиш.

2. Берәр нәрсәне хәл итә, башкара алмыйча аптырау, кыен хәлдә калу. *Тавыклар фермасында бервакыт күпләп-күпләп чебиләр югала башлый. Бер атна чамасы вакыт моның сәбәбенә төшенә алмый йөдиләр.* Г. Галиев. *Очрашканда сөйгән егете белән Сүз табалмый йөдәп беткәндер.* Г. Хуҗиев.

3. Газапланы, бик нык борчылу. *Мәрхәбә үзенең туган илен сагынып йөдәдә.* Г. Ибраһимов. *Һәр көн сине көттем, йөдәдем.* Ф. Бурнаш.

ЙӨДӘҮ II *с. диал.* Арык, хәлсез. *Атлары бик йөдәү.*

ЙӨЗ I *сан.* **1.** 100 санын һәм микъдарын белдерүче сүз. *Йөз гектар җир.* □ *Йөз сум акчаң булганчы, йөз дусың булсын.* Мәкаль.— *Язгы чәчүне йөз процентка башкарып чыгарбыз.* Г. Бәширов.

2. Йөз ел эчендәге вакыт арасы; гасыр. *XIX йөз татар әдәбияты. XX йөзнең беренче яртысы.*

3. «Күп, бик күп» мәгънәсендә. *Йөз тапкыр әйтү. Йөз җирдән ялгаулы.* □ *Йөз үлемнән мине тартып алды Синең керсез кайнар сөюең.* М. Җәлил. *Белеп эшләүдә— йөз хикмәт.* Мәкаль.

Йөз башы *тар. иск.*— йөз сугышчыдан торган төркем башлыгы. [*Баһадир:*] *Ул — ун башы, мин — йөз башы.* Н. Исәнбәт.

◇ **Йөз яшә** — озак яшә, озын гомерле бул. *Ил ашасын, йөз яшәсен.* Әйтем. **Йөз яшәгән, йөз яшәр** — озак яшәгән, карт. *Йөз яшәгән имән.* □ *Йөз яшәр Миңлебай картның уйлары әүвәлге белән бүгенгенең контрастлыгын тоярга ярдәм итә.* Г. Ахунов. **Йөзе белән кайтару** — бик күп арттырып бирү яки алу.— *Күңел биреп тотынсаң, җир дигәнең йөзе белән кайтара ул.* Г. Бәширов. **Йөзгә бер тулмаган** — акылы тулы булмаган, беркатлырак, сәеррәк кешегә карата әйтелә.

ЙӨЗ II *и.* **1.** Кеше башының алгы өлеше, бит. *Түгәрәк йөз. Йөз агару.* □ *Кеше күрке — йөз, йөзнең күрке — күз.* Н. Исәнбәт. *Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап.* Г. Тукай. // Чырай. *Көләч йөз.* □ *Элекке иркә, матур йөздә хәзер бик аз җитдилек күренә.* Г. Ибраһимов.

2. Ал, ал як. *Сәхнәдә пәрдәгә махсус эшләнгән байрак, байрак йөзендә Ленин рәсеме.* Г. Әпсәләмов.— *Әнә тегә калкулыкларга көнбатышка йөз белән урнашыгыз,— дидем мин* [*полк командирына*]. Каз. утл. // «Кеше йөзенә, халык йөзенә» кебек тезмәләрдә «каршысына», «алдына» дигән мәгънәне белдерә. *Адәм йөзенә чыгарлыкны калдырмау.* □ — [*Хәзер*] *ничек ипташлар йөзенә күренергә?* А. Алиш.

3. Нәрсәнең дә булса өске ягы, өсте. *Ипи йөзе. Чабата йөзен кайтару.* □ *Тукайның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар - - - иде.* М. Гали. // Гөмбәз. *Вакыт-вакыт нурлы күк йөзен ишелеп аккан болытлар каплап ала.* Ә. Еники.

4. Йөззурлык, мәйдан (кечкенә әйберләргә карата кулланыла). *Бер чөгендернең яфрак йөзе шулкадәр* [*3 мең квадрат сантиметр*] *булгач, бер гектардагы яфракларның йөзе күпмегә җитә?* Г. Галиев.

5. *күч.* Кемнең дә яки нәрсәнең дә булса үзенә генә хас сыйфаты, асылы, характерлы үзенчәлеге. *Язучының иҗат йөзе. Институтның гыйльми йөзе.* □ *Кешенең чын йөзен бары тик хезмәттә, көрәштә генә белергә мөмкин.* Х. Садрый. *Үз йөзе бар һәрбер яңаның, Үз эзе бар һәрбер заманның.* М. Хөсәен. // Нәрсәнең дә булса тышкы күренеше. *Казан бөтенләй йөзен үзгәртте.* Г. Ахунов.

6. *күч.* Дәрәҗә, абруй; намус. *Кешелек йөзен югалту.* □ — *Минем хәзер дус-иш арасына күренерлек йөземне калдырмадыгыз.* Ф. Әмирхан.— *Кит, Зарифулла, - - - бөтен авыл йөзенә кара яктың, бәдбәхет.* Г. Гобәй. ◇ **Йөз ак (якты) булу** — намус саф булу; уңайсыз, оятлы хәлгә калмау. *Әйе,* [*Нәфисәнең*] *хәзер туган иле каршында вөҗданы пакь, йөзе ак булачак.* Г. Бәширов. *Үзем ярлы булсам да, йөзем якты.* Мәкаль. **Йөз аклау** — йөз аклыгын саклау.— *Безгә кияүлеккә лаек булу һәм халык арасында йөзебезне аклау өчен дип,* [*Шәрәфкә*] *Казанга барып ике ел укып кайтуны шарт иттек.* М. Фәйзи. **Йөз аклыгы** — дәрәҗәлелек, горурлык. [*Галимә:*] *Шәбрәк җиһаз белән барса, Галиябануның үзенә дә каениш арасында йөз аклыгы булыр.* М. Фәйзи. **Йөз ачу (күрсәтү)** *иск. дини* — хатын-кызның ирләр алдында йөзен капламыйча йөрүе турында.— *Биләмгә чыккансыңдыр әле! Ир-атка йөзеңне ачкансыңдыр!— дип кычкырды «әти» кеше* [*Габдулланың әнисенә*]. Ә. Фәйзи. **Йөз ачылу (яктыру)** — шатлану, рух күтәрелү кебек хисләрнең йөздә чагылуы турында. *Бабай сүзләреннән соң, Исмәгыйльнең йөзе ачылып китте.* Г. Гали. *Сабыйның бугазына килеп тыгылган төер эреп юк булды, йөзе яктырып китте.* Г. Гобәй. **Йөз белән** — бөтен игътибарны, омтылышны нинди дә булса максатка юнәлтү турында. *Шәкерт дөньясы Көнбатыш белеменә табан йөз белән әйләнде.* И. Рәмиев. *Безнең лозунг — авылга йөз белән!* И. Гази. **Йөз белән җир себерү** — җан-тән белән бирелеп эшләү.— *Хезмәтеңә йөзем белән җир себерергә хәзермен, хуҗа хатын.* Ф. Бурнаш. **Йөз бирү** — 1) үз итү; яхшы, уңай мөнәсәбәт күрсәтү. [*Әткәй*] *миңа һәм сеңелләремә артык катылык та күрсәтми, фәкать күбесенчә йөз бирми, дүнеп тора иде.* Ш. Камал; 2) игътибар итү. *Такташ, күбесенчә, совет авылы кешеләренә, иҗтимагый тормышның үзәк мәйданына социалистик революция чыгарган яшьләр, комсомоллар тормышына йөз бирде.* Х. Госман. **Йөз ерту** — тупас кимсетү, дәрәҗәсен төшерү, хурлау. *Бу урында һичкемнең йөзен ертмыйча гына бер сүз әйтергә мөмкин: бер эшнең очына чыкмыйча, мактану кирәкмәс.* Г. Тукай. **Йөз ертып** — оялмыйча, һич уңайсызланмыйча. *Мөнәвир кыстауны көтмәде, мастерга ияреп культбудкага керде. Йөзеңне ертып килгәч, кире китеп булмый инде.* Ш. Бикчурин. **Йөз каралу (караңгылану, суыну)** — кәеф бозылу хәленең чырайда чагылуы турында. *Укыган саен* [*Зиннәтнең*] *йөзе караңгыланып барды, хаттан аңа берсеннән-берсе ачулырак, үткенрәк сүзләр бәрә башлады.* Г. Бәширов. **Йөз каралыгы (карасы)** — оят, хурлык. [*Искәндәр:*] *Әйе, - - - йөз каралыгыннан котылыр өчен шулай итәбез инде.* М. Фәйзи. **Йөз каралыгы китерү** — оятка, хурлыкка калдыру.— *Балаң шулай* [*Галимә кебек*] *йөз каралыгы китерсә, ни эшләр идең?* М. Гафури. **Йөз кату** — бик нык аптырап калу, куркуга төшү. *Кызның йөзе катты. Күзләренә ниндидер авыр уй чыкты.* Г. Ибраһимов. **Йөз качу** — бик каты курку яки тирән дулкынлануның, яки бик каты авыруның һ. б. ш. чырайга чыгуы. *Поручик*

Ефремовның ачудан бөтенләй йөзе качкан иде. Ф. Хөсни. *Ике көн эчендә авыру ананың йөзе качкан, бөтенләй йөри алмый башлаган, тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыга.* Каз. утл. **Йөз качыру** — 1) *иск. дини к.* йөз яшерү. *Бары безнең Хәят кенә бу урамнарда иркенләп бара алмады: еш-еш очраган татарлардан ул йөзен качыра барырга тиеш иде.* Ф. Әмирхан; 2) кемгә дә булса күренмәскә тырышып, качып йөрү. **Йөз күрсәтү** — *к.* йөз бирү 1. *Бургомистр --- хәзер нигәдер [миңа] йөз күрсәтми.* Н. Дәүли. **Йөз кызару** — оятлы булу, уңайсыз хәлдә калу.— *Сеңел бик үпкәләп яза: «Өзелеп көткән идек. Туган итмәдең. Кеше арасында йөзебез кызарды!»— ди.* Г. Ибраһимов. **Йөз оялу** — уңайсызлану, тартыну. *Җырласам йөзем ояла — кызлар тора каршымда.* Г. Тукай. **Йөз сулу (суырылу, шиңү)** — ябыгу. *Шәйхинең иреннәре кысылды, нечкәрде, йөзе сулды.* И. Туктар. *Ачлыктан ана шешенгән, Гөл күк бала — йөзе шиңгән.* Г. Камал. **Йөз суы** — намус, дәрәҗә. *Булсайде эшләрем Дәверемә торырлык; Үземә — йөз суы, Балама — горурлык.* Ә. Фәйзи. **Йөз суын түгү** — 1) мыскыл итү, кимсетү, түбәнсетү (кемне дә булса яки үз-үзеңне). [*Хуҗа Колыйга:*] *Аш-суымны эчтең, йөз суымны түктең.* Н. Исәнбәт; 2) түбәнчелек күрсәтеп сорау, ялыну. *Намус сатып тезләремне бөкмимен мин, Урынсызга йөз суымны түкмимен мин.* З. Бәшири. **Йөз сөрү** — табыну (чиктән тыш ихтирам күрсәтү турында). [*Шаһтимер:*] *Гыйшкына җиңелеп, --- сөйгәненең бусагасына йөз сөрергә мәҗбүр булган баланы Хәмдия күрә алмаса, аның ни гаебе бар?* М. Фәйзи. **Йөз тоту (төбәү)** — эш-хәлнең нинди юнәлеш алуы, кая таба баруы турында. *Совет балалар әдәбияты үзенә советчыл яңа катлау язучылар кадрын тартты, үсүгә, ныгуга табан йөз тотты.* Ф. Кәрим. *Шиңәргә йөз тота кырда үләннәр, чәчкәләр, гөлләр.* Г. Тукай. **Йөз чыту (җыеру, җимерү)** — 1) ачы нәрсә капканда күзләр йомылып, авыз ершаеп китү, йөздә җыерчыклар барлыкка килү; 2) ризасызлык, канәгатьсезлек, яратмау кебек хисләрнең йөздә чагылуы турында. *Фазыйл, бик күңелсезләнеп, йөзен чытты.* Г. Ибраһимов. *Зиннәт аңа сәрсенеп карап торды да, йөзен җыерып, кулын селтәде.* Г. Бәширов. **Йөз чөерү (бору)** — кемнән-нәрсәдән читләшү, кем белән дә булса мөнәсәбәтне үзү. *Йөз чөермәссеңме икән, Юлыксам хурлыкларга.* Ш. Галиев. *Нургалинең, --- әлеге кешеләрем миннән йөзләрен борырлар дип, йөрәген борчып торган шик менә хәзер урынсыз булып чыкты.* Ә. Еники. **Йөз яшерү** *иск. дини* — хатын-кызларга карата: ирләр алдында йөз каплап йөрү. [*Мәрхәбә*] *яшь ирләр каршында йөз яшерми.* Г. Әпсәләмов. **Йөзгә бәрү (ору), йөзгә бәреп әйтү** — әдәплелек саклап тормыйча, ачыктан-ачык, турыдан-туры каты итеп әйтү, гаепләү, тиргәү. *Хәким малае: «--- Бердәнбер кызыгызны карап тормыйсыз...» дип, йөзебезгә бәрде.* М. Гафури. *Моңа чаклы ул, эчтән үзе ризасызлык күрсәтсә дә, бу хакта Вәлинең йөзенә бәреп әйтергә җаен туры китерә алмады.* С. Рафиков. *Кеше гаебен йөзгә орасыз, белмисез сез инсафны.* Ш. Мөхәммәдев. **Йөзгә кара коелу** — тирән борчылу, зур кайгыга калу хисләренең йөзгә бәреп чыгуы. *Син җаныйны уйлый-уйлый йөземә кара коелды.* Г. Тукай. **Йөзгә кара ягу** — хурлыклы хәлгә төшерү, оятка калдыру. [*Сәлим мирза:*] *Ялчылар белән минем арсма кереп, нәселнең йөзенә кара ягып килгән кыз, бүген бер көтүчегә төшәчәк таякны үзенә йөклән, ак нәселнең тамырын черетте.* М. Фәйзи. **Йөзгә кызыллык (оятлык) китерү** — хурлыкка, оятка калдыру, уңайсыз хәлдә калдыру. [*Маһи:*] *Ябышып чыгарга?.. Кешеләр алдында адәм мәсхәрәсе булырга, әниләрнең йөзенә кызыллык китерергә?* Т. Гыйззәт.— *Минем белән бер үк заводта эшләдең, анда да йөзгә оятлык китермәдең.* Ш. Камал. **Йөзгә ыштыр каплаган (булу)** *гади с.*— чиктән тыш оятсыз (булу).— *Нәрсә аның белән сүз көрәштерәсез әле, егетләр? Әллә күрмисезме, йөзенә ыштыр каплаган ич ул.* М. Шабай. **Йөзгә әйләнеп (борылып) тә карамау** — бөтенләй игътибар итмәү; читләшү, бәйләнешне өзү.— *Әүвәлдә өстәл янында дус булып йөргән кешеләрнең ничберсе дә хәзер йөземә әйләнеп тә карамыйлар.* Г. Камал. **Йөзе алдында** — кемнеңдер каршысында.— *Хәзер син бу җирдә атаңның йөзе алдында торачаксың.* Н. Исәнбәт. **Йөзе кара** — явыз, кабахәт. [*Хан:*] *Ах, син, йөзе кара! Ханга каршы тел озайтасың.* М. Җәлил. **Йөзе килү** — камыр ашының өсте кызару (яхшы пешү билгесе).— *Бәлешебезнең йөзе килсә генә ярар иде.* Ф. Хөсни. **Йөзен дә чытмый(ча)** — исе дә китмичә, уңайсызланмыйча; курыкмыйча.— *Илләү, үзе зәһәр, үткен егет иде!..* [*Жандармнар кулга алганда*] *йөзен дә чытмый аларга каршы сөйләште.* М. Гафури. **Йөзен ачу** — берәрсенең мәкерле эшен, хәйләсен фаш итү. **...Йөзен күрмәү** — кемгә яки нәрсәгә мохтажлык булып та, аннан мәхрүм булу. *Әгәр арабызда сатлык җан табылса, ул мәңгегә дуслар йөзен күрмәсен.* Р. Батуллин. *Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, --- икмәк белән катыкны ялт иттердем.* Г. Тукай. **Йөзен кызарту** — хурлау, кимсетү, оялту. [*Гөлҗамал*] *яңадан Асияне сүгәргә, йөзен кызартырга, эттән алып эткә салырга теләде.* Г. Иделле. **Йөзең белән йөзтүбән каплан** *гади с., карг.*— теләсә нәрсә эшлә, бет, кадал.— *Вәли, менә юл, әнә теге ишек! Чык әйдә! --- Йөзең белән йөзтүбән каплан, җәһәннәмгә хәтле!* Ш. Камал. **Ни (нинди) йөз белән** — ничек итеп оялмыйча.— *Мин ни йөзем белән халык күзенә күренем.* М. Гафури. [*Лаля Шәрәфка:*] *Шулкадәр вәгъдәләр, шулкадәр антларны аягың астына салып таптаганнан соң, нинди йөз белән бире килдең?* М. Фәйзи.

ЙӨЗ III *и.* Кисә, чаба торган әйберләрнең үткен ягы **(өлеше)**. *Кылыч йөзе. Балта йөзе.* □ *Ул, пычакларның алып, аларның һәрберсенең йөзен бармак битенә каптырып карады.* Г. Галиев.

◇ **Йөз салу** — кисә, чаба торган әйберләрнең йөзен ясау, үткенләү. **Йөзен чыгару** — кисә, чаба торган әйберләрне тиешле дәрәҗәгә житкереп үткенләү, кайрау. *Пәкенең йөзен чыгару.* □ *Чалгыны дөрес чүкү, аның йөзен юка итеп чыгару өчен зур осталык кирәк.* Г. Галиев. **Йөзе кайту** — үтмәсләнү, тупаслану. *Чәч арасына утырган ком-тузаннар аның [чәч алучының] пәкесенең йөзен шунда ук кайтаралар, күрәсең. --- Минут саен янап азаплана.* М. Гафури.

ЙӨЗГЕЧ *и.* Балыкларда һәм суда яшәүче умырткалы хайваннарда хәрәкәт итү органы. *Арка йөзгече. Парлы йөзгечләр. Ике аерчалы йөзгеч.* □ [*Голомянка*] *үзе алсу төстә, йөзгечләре кош канаты шикелле зур.* Ә. Малик. // *с. мәгъ.* Йөзү өчен хезмәт итә торган. *Акуланың йөзгеч куыгыннан аш та пешерәләр икән.* Б. Камалов.

ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ *рәв.* Бер-берсенең каршысына бик якын килеп; кара-каршы килеп. *Шәйхигә болай дошман белән йөзгә-йөз килеп сугышырга туры килгәне юк иде.* И. Туктар.— *Йөзгә-йөз бер тиңләшеп карагыз әле, күрим: күктәге ай сылумы, җирдәге Айсылумы?* Н. Исәнбәт.

ЙӨЗГӘЛӘК *и. зоол.* Әкрен ага торган яки торгын суда яшәүче эре коңгыз. *Аерчалы йөзгәләк. Каймалы йөзгәләк. Тимгелле йөзгәләк.*

ЙӨЗГӘ-МЕҢГӘ *рәв.* Бик сирәк. *Йөзгә-меңгә бер генә очрау.*

ЙӨЗДЕРҮ *ф.* Тирән суга кертеп коендыру, юу (ат турында). *Агыйделнең суы кибә: әүвәле ат йөздереп йөргән җирләр хәзер кичү бирә.* М. Әмир.

◇ **Йөздереп чыгу** — тирән һәм киң елганы ат өстендә яки ат койрыгына ябышып кичү. *Моратай, атның койрыгына ябышып, Иделне йөздереп чыккан.* Г. Бәширов.

ЙӨЗЕК *и.* Кыйммәтле таш белән бизәлгән, каш куелган балдак. *Алтын балдак, көмеш йөзек җаныем бармакларында.* Җыр. [*Хәмдия Бакыйга:*] *Сөенеч хәбәр китерсәң, алмаз кашлы алтын йөзегем синеке.* М. Фәйзи.

Йөзек салыш *иск.*— яшьләр уены (уенны алып баручы тезелешеп утыручыларның учларына йөзек тоткан кулын тидереп чыгып, сиздермәстән, аны берсенең учына салып калдыра һәм: «Кемдә йөзек, йөгереп чык!»— дип кычкыра. Учына йөзек салынган кеше тиз генә урынынан торып китәргә, ә ике ягында утыручы иптәшләре аны тотып калырга тиешләр; әгәр тотылса, ул «җәза» ала). *Кызлар, берничә төркемгә бүленеп, йөзек салыш, сукыр тәкә уйнарга керештеләр.* Г. Гобәй. **Йөзек алышу (бирешү)** — кыз белән егетнең, вәгъдәләшү билгесе итеп, бер-беренә йөзек бүләк итүе турында. [*Морат*] *миңа тәкъдим ясады. Мин риза булдым. Ләкин мин аңа шуны шарт итеп куйдым — иң элек икебезгә дә югары мәктәп тәмам итәргә. Шул сүз өстендә йөзекләр дә бирештек.* Н. Исәнбәт.

ЙӨЗЕМ *и.* 1. Җылы якларда уралып үсә торган куак үсемлек; виноград. [*Аксакал:*] *Туган илебездә кояш җылы, туфрак яхшы, анда алма, йөзем үсә.* Г. Ибраһимов.

2. *җый.* Шул үсемлекнең җимешләре. *Төлке йөзем бакчасына кергән. Югарыда бик матур булып пешеп утырган йөземнәрне күргән.* Г. Тукай. // Шул җимешләрнең махсус киптереп әзерләнгән төре. *Ураҡчылар сөт, ипи, йөзем белән чәй эчтеләр.* М. Галәү.

◇ **Йөзем суы** — йөзем җимешеннән төнәтелгән исерткеч эчемлек. *Эчтем йөзем суын, Түктем йөзем суын.* Мәкаль.

ЙӨЗЕМЛЕ *с.* Йөзем кушылган; йөзем кушып әзерләнгән, пешерелгән. *Маһибәдәр кала күчтәнәчләреннән — мәк хәлвәсеннән, йөземле батоннан авыз итте.* А. Гыйләҗев.

ЙӨЗЕМЧЕЛЕҠ *и.* Йөзем үрчетү белән шөгыльләнү. *Йөземчелек совхозы.*

ЙӨЗЕМЛӘП *рәв.* Йөзем белән. *Җомга көн шәкертләр пылаудыр, бавырсактыр пешерәләр, йөземләп чәй эчәләр.* Ә. Фәйзи.

ЙӨЗЕНДӘ *бәйл. кит.* Кемнең дә яки нәрсәнең дә булса эшчәнлегенә, тоткан урынына бәя биргәндә кулланыла: фәлән кебек шәхестә яки нәрсәдә; мисалында, үрнәгендә. *Без бүген иптәш Янбаева йөзендә совет интеллигенциясенең алдынгы вәкилен күрәбез.* А. Алиш.

ЙӨЗЕННӘН *бәйл.* 1. Нинди дә булса максат белән. *Кисәтү йөзеннән. Ярдәм итү йөзеннән.* ☐ *Тәҗрибә йөзеннән хисап фәненнән бер китап басып чыгарган идем.* К. Насыйри. *Зәйтүнә, саклык йөзеннәнме, әллә эчке инстинкт белән нидер сизепме, юлдан читкәрәк кагылды.* Ф. Хөсни. // Нәрсә сыйфатында, нәрсә итеп. *Мисал йөзеннән әйтү.*

2. Нәрсә билгесе итеп, нәрсә хөрмәтенә. *Ихтирам йөзеннән. Дуслык йөзеннән.* ☐ *Егет --- хөрмәт йөзеннән сабыр гына тыңлый.*

ЙӨЗЗУРЛЫҠ *и. к.* мәйдан 4.

ЙӨЗЕНЧЕ *с. Тәр. саны. к.* йөз. *Йөзенче яшькә китү.* // *күч.* Күп тапкыр, бик күп. *Йөзенче тапкыр кабатлау.*

ЙӨЗ-КЫЯФӘТ *җый. и.* Кешенең тышкы күренеше (йөзе, өс-баш киемнәре). [*Борһанның*] *йөз-кыяфәте дә кыйналган кешенеке сыман.* М. Хәсәнов.

ЙӨЗЛЕҠ I *и.* 1. Йөз сум бәясендәге кәгазь акча. *Сиражәтдин бик кечкенә итеп бөкләнгән бишйөзлекне докторның кулына кыстыра.* Г. Камал.

2. *иск.* Революциягә кадәр Россиядә атлы казак гаскәрләрендә гаскәри бүлек (регуляр атлы гаскәрләрдәге эскадронга бәрабәр). *Казачий йөзлеге.*

ЙӨЗЛЕҠ II *и.* Йөзне нәрсәдән дә булса саклау өчен махсус эшләнгән әйбер; битлек. *Землянкалар алдында --- черкиләрдән сакланыр өчен башына йөзлек кигән часовой гына арлы-бирле йөренә.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Йөзлек белән туу** — бәхетле булып туу.— *Бәхетең баса да тора, йөзлек белән тугансыңдыр син.* Х. Вахит.

ЙӨЗЛЕҠ III *и.* 1. Ишек яки тәрәзә уеп куелган урын тирәли беркетелә торган, гадәттә сырлап, бизәкләп эшләнгән юка тар планка (такта). *Тәрәзәләрнең йөзлекләре --- я акка, я зәңгәргә буялган.* Г. Әпсәләмов. // Эчке бикләүле йозакның тишегенә тышкы яктан яраклаштырып куелган металл пластинка. *Йозак йөзлеге.*

2. Сәкенең кырыен тәшкил иткән такта. [*Сания:*] *Бер сәке йөзлегенә аяк салындырып утырып, туйганчы чәй эчәр идем ичмасам!* Н. Исәнбәт. *Әби, кунак кеше буларак, түр башына менеп утырды, мин йөзлек буена урнаштым.* Ш. Маннур.

3. Аяк киеменең аяк йөзен каплап торган өлеше. *Башмакларга йөзлекләр тегү.* ☐ *Җырлашып Өнсә кызлары Чүәккә йөзлек кайый.* С. Хәким.

4. Нәрсәнең дә булса өс йөзе, тигез өслеге. *Такта йөзлеге.* ☐ [*Малайлар*] *юка таш сайлап алалар да су йөзлегенә ыргытып җибәрәләр.* Р. Төхфәтуллин.

ЙӨЗЛЕҠ IV *и.* Мичнең кызуын саклау өчен аның алгы өлешенә өеп калдырылган утлы күмерләр (ипи, гомумән, мич ашы пешергәндә).

ЙӨЗЛӘГӘН *Чама саны. к.* йөзләрчә. *Халык байтак җыелганда иде. Йөзләгән-меңләгән кеше.* Э. Касыймов.

ЙӨЗЛӘП *Чама саны. к.* йөз. I. *Барын хисапласаң, дүрт йөзләп кеше булгандыр.* Ш. Мөхәммәдев.

ЙӨЗЛӘ'РЧӘ *Чама саны.* Йөзләп, берничә йөзгә якын. *Йөзләрчә күл алкыш белән уйный һаман, Биючегә ак яулыклар болгый һаман.* Ф. Бурнаш. *Бу урманнар дистәләрчә, йөзләрчә километрларга сузылган.* Ә. Айдар.

ЙӨЗЛӘТӘ *рәв.* Йөз тапкыр, күп тапкыр, бик күп мәртәбә арттырып.— *Узеңнең бер шигырең белән йөз солдатны сугышка рухландырасың икән,— монысы инде йөзләтә, бәлки меңләтә дошманны юк итү дигән сүз.* Н. Исәнбәт.

ЙӨЗЛӘҮ *ф.* 1. Ныклык, шомалык, матурлык һ. б. өчен нәрсәне дә булса таш, металл, мәрмәр һ. б. ш. катлам белән тышлау яки каплау.

2. Кисә, чаба торган әйберләрне үткенләү. *Балтаны --- йөзләтеп аласы бар.* К. Нәҗми.

3. Әйбергә эчтән ямау салганда ертык урынның әйләнәсен ямаулыкка пөхтәләп тегеп чыгу.

ЙӨЗМӘ *с.* 1. Йөзеп йөри торган, су өстенә корылган. *Йөзмә ял йорты. Йөзмә күпер. Йөзмә ресторан. Йөзмә бозлар.* ☐ *Мине яңа гына төзелгән хәрби судно ga йөзмә госпитальнең комиссары итеп билгеләделәр.* Х. Садрый.

2. *и. мәгъ. хим.* Аерым молекулаларга кадәр вакланмыйча, чагыштырмача зуррак каты кисәкчекләр катнашмасыннан торган болганчык сыеклык яки газ; *русчасы:* взвесь.

ЙӨЗСЕЗ *с. сөйл.* Үтә оятсыз, намуссыз, әдәпсез. *Бу кеше үзенең принципсыз — йөзсез бер кеше булуы белән безнең күңелгә бик ошап [бетми].* М. Әмир. *Үзе йөзсез, сүзе тозсыз.* Әйтем.

ЙӨЗСЕЗЛӘНҮ *ф. сөйл.* Үз-үзен тупас тоту; оятсызлык, намуссызлык күрсәтү.

ЙӨ'ЗТҮБӘН *рәв.* Йөз белән аска таба карап; *кирәсе:* **чалкан.** *Йөзтүбән яту. Йөзтүбән егылу.* ☐ *Шәкир, ике кулы белән йөзен каплап, кровать өстенә йөзтүбән атылды.* Ф. Әмирхан. // Асты өскә әйләнеп (әйберләр турында). *Тимерче алачыгы алдында йөзтүбән капланган арба --- ята.* К. Нәҗми.

◇ **Йөзтүбән килү** — 1) йөз белән төшү, аву. [*Немец солдаты*], *йөзтүбән килеп, Җамали өстенә ауды.* М. Гали; 2) *гади с.* үлү, һәлак булу. **Йөзтүбән китү** — 1) йөз белән капланып егылу; 2) *гади с.* юкка чыгу, һәлак булу. *Укыган морадына җитәр, укымаган йөзтүбән китәр.* Мәкаль. *Байлар йөзтүбән киткәнгә эшче халыклар бик шат.* Г. Камал.

ЙӨЗЧЕ *и. иск. к.* йөз башы.

Йөзьеллык *и.* Йөз ел вакыт арасы; гасыр. *1360—1440 елларны эченә алган йөзьеллык — Көнчыгыш Европа халыклары, шул исәптән болгарлар тарихында зур үзгәрешләр дәвере.* Р. Фәхретдинов. // *с. мәгъ.* Йөз ел буенча дәвам иткән. *Йөзьеллык сугыш.* // *с. мәгъ.* Йөз ел яшәгән. *Йөзьеллык имән.*

Йөзьяфрак *и. бот.* Катмарлы роза чәчәге ата торган вак яфраклы бакча гөле; *русчасы:* столепестка.

Йөзьяшәр *и. бот.* Озынча итләч һәм чәнечкеле яфраклы күпьеллык тропик үлән үсемлек (бездә бүлмә гөлләренең бер төре итеп үстерелә, дару өчен файдаланыла); *русчасы:* столетник. *Йөзьяшәр гөлне беләсең микән син? Аны алоэ гөле дип тә атыйлар.* А. Расих.

Йөзәр *Бүл. саны к.* йөз I. *Йөзәр граммлап үлчәү. Йөзәр яшьлек картлар.* □ *Йөзәр еллык наратларны, имәннәрне шатырдатып егалар.* И. Гази.

Йөзәрле: йөзәрле үлчәү — үлчәнә торган әйберне үзеннән 100 тапкыр җиңелрәк гер белән тигезли ала торган махсус төзелешле үлчәү.

Йөзәрлек *и. к.* йөзлек I (1 мәгъ.). *Вак акчаларны бөтен иске йөзәрлеккә алмаштыр[дым].* Г. Ибраһимов. // *с. мәгъ.* Йөз сумлык, йөз сум бәясендәге. *Өй салырга дип җыйган йөзәрлек акчалар - - - сандык төбендәге шкатулкада яталар.* Ф. Хөсни.

Йөзәрләгән *Чама саны к.* йөзләрчә. *Йөзәрләгән кигәвеннең берьюлы талауларына чыдый алмый, ат тыпырчына, качарга уйлый.* М. Гафури.

Йөзәрләп *Бүл. саны к.* йөзәр. *Йөзәрләп санау. Йөзәрләп аерып кую.* // Бик күпләп. *Дошманны берәмләп кенә түгел, йөзәрләп кырасы килә.* Г. Бәширов. *Хәзер бит безнең гаскәр эченә һәркайдан эшчеләр йөзәрләп, меңәрләп агылалар.* Г. Ибраһимов.

Йөзү *ф.* 1. Су өстендә яки су асты тирәнлегендә: махсус җайланган органнар ярдәмендә хәрәкәт итү (балыклар һәм суда яшәүче хайваннар турында). *Агыйдәлне иңләп-буйлап йөзәрсең, үрдәккәем.* Җыр. *Йөгереп төштем су буена Суда сусар йөзә дип.* Җыр. // Кул-аяклар ярдәмендә хәрәкәт итү (кешеләр, җирдә яшәүче хайваннар турында). *Малай су астыннан бер дә йөзә белми икән.* И. Гази. // Махсус җайланмалар ярдәмендә хәрәкәт итү (суднолар, көймә һ. б. турында). *Елга өстендә җилкәнен киергән көймә йөзә.* А. Алиш.

2. Махсус йөзгеч корылмаларда (суднода, көймәдә һ. б.) су өстеннән кая да булса бару, күчел ачып йөрү. *Без көймәдә йөздек.* Ә. Ерикәй. // Суднода хезмәт итү.— *Без әле аның белән су асты көймәсендә бергә йөзгән кешеләр.* Г. Әпсәләмов.

3. Сыеклык эчендә бүлып, бөтенләй батмыйча, өскә калкып тору. *Кипкән камыштан ясалган калкавычларыбыз су өстендә йөзә башлады.* А. Әхмәт. *Суда йөзә нефть, май таплары.* Х. Камал. // Берәр төрле сыеклык эчендә булу, яту.— *Тугзак егетләре кан эчендә йөзәләр.* М. Җәлил.

4. *күч.* Һавада салмак кына хәрәкәт итү. *Һавада болытлар йөзү.* □ *Авыл өстендә салам төтене йөзә.* К. Нәҗми. Ай, кояш хәрәкәтә турында. *Күктә ай йөзә ялгызы.* С. Хәким. // Очу (кошлар һәм очу аппаратлары, алар белән идарә итүче кешеләр турында). *Һаваларда йөзгән кошларны да Бер ябалар тотып читлеккә.* Ф. Бурнаш. *Канатлы кош кебек күктә йөзә Элек аттан курыккан кызларың.* Ә. Ерикәй. // Салмак, җиңел хәрәкәтләр белән бию турында. *Ак алъяпкыч япкан кызлар, кара казакилы, түбәтәйле, киң чалбарлы егетләр, бүлмәне урап, тавышсыз-тынсыз гына йөзеп киләләр.* Г. Ахунов.

5. *күч.* Нинди дә булса өлкәдә киң мәгълүматлылык, тирән белем, зур осталык күрсәтү. *Сәнгать һәм әдәбият мәсьәләләренә кереп китсә йөзә инде ул.* М. Гали. // Иркенләп эшләү, нәтиҗәле эш күрсәтү. [*Комбайнчы*] *Габделхак абыйның йөзе яктырып китә: — Менә бөтен басу шушылай булса, йөзәр идек без.* Г. Галиев. *Теләр идем илдә мин иректә Иҗат дөньясында йөзәргә.* М. Җәлил.

6. *күч.* Бай, рәхәт тормышта, рәхәтлек-күңеллелеккә чумып яшәү турында. *Ел тәүлегенең май башы — күпләрнең тоташтан шатлык-куаныч диңгезендә айнымый йөзгән чагы.* Э. Касыймов.— *Гомер буе атакаеңның байлыгында йөзмәссең, кызым.* Г. Әпсәләмов.

7. *күч. гади с.* Имтиханда сорауларга начар җавап бирү.

Йөзү ярысы — йөзүче кошларның бармак араларында ишкәк хезмәтен үтәүче юка тире, яры.

Йөзүче *и.* 1. Йөзә белүче, суда йөзеп йөрүче кеше. *Бу чибәр егет нишләп йөзүчеләр арасында булмады бүген? — дип уйлады Камил.* М. Әмир.

2. Йөзү спорты белән шөгыльләнүче. *Йөзүчеләр ярышы.*

Йөзүче кошлар — суда яшәүче, суда йөзәргә җайлашкан кошлар.

Йөк I *и.* 1. Нинди дә булса әйбер төялгән олау (арба, чана, автомобиль һ. б.). *Бервакыт Аккош, Чуртан, Кысла — өчесе бер йөккә җигелеп, аны алга алып бармакчы булдылар.* Г. Тукай. *Йөк артыннан җәяүләп баручылар арасында Халикъ белән Закир да бар иде.* Ш. Камал.

2. Шундый олауга сыешлы әйбернең, авырлыкның микъдары. [*Шәйхел*] *тегермәнгә ике йөк бодай тарттырырга алып барды.* Г. Ибраһимов. *Авылга, өч-дүрт йөк товар төяп, кызыл малчылар килгән.* Г. Бәширов.

3. Авырлык, авыр әйбер. *Йөк күтәргеч кран. Алты тонна йөккә чыдарлык күпер.* □ *Арбаңа карап йөк сал, атыңа карап юлга чык.* Мәкаль. // Бер урыннан икенче урынга күчерелә, җибәрелә торган нинди дә булса күләмле әйбер; товар. *Ул ике аты белән гомер буе шәһәргә авыл байларының йөген ташыды.* Г. Галиев.— *Йөк бик авыр,— диде* [*шофер*] - - - *һәм итек белән машинаның тәгәрмәченә тибеп-тибеп карады.* И. Гази. // *с. мәгъ.* Йөк йөртү, ташу һ. б. өчен билгеләнгән. *Йөк арбасы. Йөк вагоны.* □ *Йөк атларының көч-хәл белән атлауларын күреп, ул туктаусыз мыгырдана иде.* А. Расих.

4. Эш, хезмәт. *Иген игү эшенең иң авыр йөкләре кеше җилкәсеннән машина җилкәсенә салынды.* Ф. Хөсни. // Вазифа, йөкләмә. *Бүген ул мондый йөкне күтәрергә бик үк әзер түгел иде.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч.* Кыенлык, авырлык; нинди дә булса эшнең иң күп көч сорый торган өлеше. *Менә шундый имәндәй таза, яшь ирләр тарта йөкнең иң авырын.* С. Рафиков. // Мәшәкать, борчу, маза. *Гайни белән Гыймади өчен ул үзен һәм иптәшләрен артык йөк итеп тойды.* Ә. Фәйзи. *Дөньяда дус бул, йөк булма.* Н. Исәнбәт. // Төрле газаплы, күңелсез хисләр турында. *Күңелендәге авыр йөктән һаман да котыла алмаган бригадир - - - ерак басуга таба юл тотты.* Э. Касыймов. *Син бастыңмы сафка, кыенлык, Кайгы йөген улең тартканда?* М. Җәлил.

Йөк әйләнеше — билгеле бер вакыт эчендә нинди дә булса транспортта ташылган йөк хисабы. *Моннан утыз ел элек корыч магистральләрнең [еллык] йөк әйләнеше 300 миллиард тонна-километрдан артмый иде.* Соц. Тат.

◇ **Йөге белән** — бик күп. [*Бай шәкертләргә*] *йөге белән азык килә.* Ә. Еники. **Йөге кыйшайган** *гади с.*— исерек. **Йөк аты** — 1) бернинди эштән дә баш тартмаучы, карусыз кеше турында; 2) берәр өлкәдә эшнең зур өлешен, иң авырын башкаручы төп көч. *Проза дигән йөк атыбыз күмәк көшелгә нәрсә төяп китерде?* Г. Ахунов.

Йөк II *и.* Ана карынындагы бала.— [*Гөлчәһрәнең*] *йөге бар, ди.* Т. Гыйззәт.

Йөккә узу (калу) — *к.* балага узу. [*Нуржиһан*], *йөккә узу аркасында, үзен үзе кая куярга белми аптырап йөргән.* Г. Галиев.

ЙӨКЛЕ I *с.* Йөк төялгән. *Йөкле машина.* □ *Мөбәрәкша --- йөкле арбаларның берсенә ышыкланды.* К. Нәҗми. / *и. мәгъ. күпл. Йөклеләр әкренләп-әкренләп алга хәрәкәт итәләр.* С. Рафиков.

ЙӨКЛЕ II *с.* Авырлы, балага узган. *Йөкле хатын --- ишекле-түрле йөренеп тора иде.* Н. Фәттах.

ЙӨКЛЕЛЕК *и.* Йөкле II булу хәле. *Йөклелек буенча ялга чыгу.*

ЙӨКЛӘМӘ *и.* 1. Кемгә дә булса тапшырылган, йөкләтелгән эш; задание. *Бүген полк парторгыннан шундый зур һәм җаваплы йөкләмә алганнан соң, Газинур бары тик Александр Матросов турында гына уйларга тырышты.* Г. Әпсәләмов.

2. Өскә алынган һәм үтәлүе мәҗбүри булган бурыч, вәгъдә. *Социалистик йөкләмә.* □ [*Айсылу:*] *Сез социалистик ярыш байрагын беренче булып күтәрдегез, өстегезгә бик зур йөкләмә алдыгыз.* Г. Бәширов.

3. *тар. иск.* Крестьяннарның алпавыт яки дәүләт файдасы өчен түләүсез мәҗбүри эшләү вазифасы. *Антон, халык каршына чыгып, патшадан аяк терәп җир һәм ирек сорарга, барщина һәм оброк йөкләмәләрен үтәүне туктатырга чакыра.* Қ. Нәҗми.

4. *рәс.* Гражданнарның дәүләт яки урындагы җәмәгатьчелек кирәкләре өчен мәҗбүри тәртиптә эшләнгән эше, хезмәте. *Хәрби хезмәт йөкләмәсе. Хезмәт йөкләмәсе. Юл төзәтү йөкләмәсе.*

5. Нинди дә булса эшкә җәлеп ителү дәрәҗәсе, шул эшнең микъдары. *Укыту йөкләмәсе.*

ЙӨКЛӘП *рәв. к.* йөге белән.— *Әнә кеше* [*колхоздан*] *йөкләп ашлык ала.* А. Алиш.

ЙӨКЛӘТҮ I *ф. Йөкл. юн. к.* йөкләү I. [*Йөз илле шәкерткә*], *--- әйберләрен атларга йөкләтеп, өч катлы таш йортны ташларга гына калган иде.* Г. Ибраһимов. *Атыңны көченә күрә йөкләт.* Мәкаль.

ЙӨКЛӘТҮ II *ф. к.* йөкләү II (1, 2 мәгъ.). [*Баланы*] *гомер буена ата җилкәсенә йөкләтү дә яхшы түгел.* Ш. Камал.— *Сөю дигән нәрсә шундый хәлләрне йөкләтә торган көчле нәрсәмени шулай?* М. Фәйзи.

Йөкләтү юнәлеше *лингв.*— фигыль юнәлешләреның бер төре (грамматик субъектның эшне башка берәүгә яки башка бер нәрсәгә кушуын, йөкләвен белдерә). *Йөкләтү юнәлеше кушымчалары фигыльгә бер генә тапкыр да, өсте-өстенә дә ялгана алалар.* В. Хангильдин.

ЙӨКЛӘҮ I *ф. сир.* Төяү (атка, машинага һ. б.). *Кем үз йортын үз өстенә йөкләп йөртә?* Табышмак. *Князь Абалинский --- Сөембикәне, Утәмеш Гәрәй вә башка иптәшләрен, көймәсенә йөклап, Мәскәүгә алып китте.* Шура. // Берәр төрле авыр нәрсәне күтәрү, аркага асу (кая да булса алып бару өчен). *Хәзер инде* [*разведчиклар*]*а, --- автоматларны алып, шартлаткыч әйберләрне аркага йөкләп, тәвәккәлләргә дә була.* И. Гази.

ЙӨКЛӘҮ II *ф.* 1. Нинди дә булса эш, йомыш һ. б. ш. үтәргә кушу. *Шушы сугышларның берсендә Нуруллинга бик зур бурыч йөкләделәр.* А. Шамов.— *Син миңа авыр эш йөкләдең, шулай да тырышырмын.* Г. Әпсәләмов. // *күч.* Бирү (эш, җәза һ. б. ш.). [*Каюм:*] *Ике җәзаны берьюлы бер кеше өстенә йөкләмәгәндә дә яхшы булыр, минемчә.* Ш. Камал.

2. Нинди дә булса йомыш, эш башкаруны өскә, җаваплылыкка алу. *Дәү апага иреннән соң бөтен хуҗалыкны үз җилкәсенә йөкләү авырга килде.* Ә. Фәйзи. *Йомыш йөкләп юлга чыгып киттем, яз көнендә, юллар өзектә.* С. Баттал. *Әдип Г. Ибраһимов бу әсәрендә Октябрь революциясе барышын башыннан алып хәзерге көнгәчә бөтен көйгә күрсәтүне өстенә йөкләми.* Г. Нигъмәти. // Берәр исемгә лаек булу, шундый исемгә хас эшне башкару. *Җырчы исемен йөкләү Җиңел түгел икән, малайлар.* Х. Туфан.

3. *күч.* Қабул итү, уртаклашу. *Якын гына җирдә юк кардәшең сөйләгән сүзләреңне йөкләргә.* Г. Тукай. [*Бакый:*] *Көтүче мәхәббәтенең хурлыгын йөкли алмый үлдеңме, Хәмдиям?* М. Фәйзи.

ЙӨКЧЕ *и.* 1. Йөк йөртүче, йөк ташучы; олаучы.— *Әһә, Мәскәү юлыннан килә торган йөкчеләр икән, Казанга уза торганнардыр. Ает бабай йөкчеләре түгелме икән?* М. Гали.

2. Йөк төяүче, бушатучы. *Иргәш сәүдәгәр Таҗиның мамык хуҗалыгында йөкче һәм өенә хезмәтче булып урнашты.* Г. Әпсәләмов. [*Яр буендагы*] *тар басмалардан җилкәләренә капчык күтәргән йөкчеләр йөгерә.* Р. Мостафин.

ЙӨНДӘҮ *ф. иск.* Ябага йонын йолку (сыерның, дөянең һ. б.). *Юаш сыер йөндәүгә яхшы.* Мәкаль. *Өндәүгә килмәсә, йөндәүгә килер.* Мәкаль.

ЙӨНТӘЙ *с. диал. к.* йөнтәс. *Бүлмәдә йөнтәй битле, ир уртасы берәү, уналты яшьләрендә бер малай утыралар иде.* А. Таһиров.

ЙӨНТӘС *с. к.* йонлач. *Йөнтәс бүрек. Йөнтәс койрыклы мәче. Йөнтәс күкрәкле кеше.* □ *Ул өстенә йөнтәс кыска туның* [*киде*]. А. Расих.

ЙӨНТӘСЛӘҮ *ф.* Төкләндерү, йөнтәс итү.

ЙӨНТӘЧ *с. к.* йонлач. *Зур йөнтәч сары эт.* □ *Урманнарны корыта торган йөнтәч бөжәкләрне күп кенә кошлар ауламыйлар. Чөнки бу йөнтәч бөжәкләр аларның авызларын уялар.* Г. Галиев.

ЙӨРГЕЗҮ *ф. иск. к.* йөртү. *Һөнәрле ком өстеннән көймә йөргезә.* Мәкаль. *Астыртын кеше салам астыннан су йөргезә.* Мәкаль.

ЙӨРГЕСЕЗ *с.* Чыгып, үтеп йөри алмаслык. *Адәм йөргесез буран. Юл ярып йөргесез пычрак.*

ЙӨРЕЛҮ *ф. з-сыз. к.* йөрү.— *Аланбашка бит су кузгалган чакларда әнә кайлардан йөрелә.* Г. Бәширов.— *Гафу итегез, соңгарак калынды, эш белән йөрелде.* Г. Ахунов.

ЙӨРЕМ *и. сөйл.* Йөрүгә чыдамлылык. *Йөргән аякка йөрем ирә.* Мәкаль. *Картлар яшьнең йөремен тели.* Мәкаль.

ЙӨРЕМСЕЗ *с. сөйл. сир.* Акрын, начар йөрешле. *Ялкауның атын алма, йөремсез булыр.* Мәкаль.

ЙӨРЕМСӘК *с.* Бер урында гына торырга, яшәргә, эшләргә яратмый торган; күп йөрүчән, күп йөрергә яратучан. *Йөремсәк кеше.* □ *Бер дә йөремсәк түгел иде Нурулла.* А. Гыйләҗев.

ЙӨРЕМСӘКЛЕК *и.* Күп йөрергә яратучанлык. *Яшьтән гадәтенә кереп калган йөремсәклеге тынгылык бирмәгәндерме, --- ара-тирә Шәмсетдин, читлектәге кош кебек, моңая башлый иде.* Г. Бәширов.

ЙӨРЕМТЕК *с. сир.* Еш кабатлана торган, һәркемгә билгеле. *Эшче --- һәр сыйныф һәм һәр катлау үзенең эгоистик омтылышларын һәм үзенең чын «эчтәлеген» яшерә торган йөремтек фразаларны --- төшенә белергә тиеш.* В. И. Ленин.

ЙӨРЕМТӘЛ *с. сөйл.* 1. Қызу йөрешле, юл йөрүгә чыдамлы (ат турында). *Юртак бик йөремтәл иде.* Б. Камалов. // Бер урында гына торырга яратмый торган, күп йөрүчән.— *Әткәй, мин кола бияне көшәнлим... Бик йөремтәл нәрсә.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл. к.* йөремче.— [*Малайларымның берсе*] *әллә нинди бер җирдә төпләнә алмый торган йөремтәл нәрсә булып чыкты.* М. Әмир.

ЙӨРЕМЧЕ *и. сөйл.* Бер урында төпләнмәгән, бер жирдән икенче жиргә йөреп кәсеп итүче; йөрергә, гизәргә яратучан кеше. [*Хан:*] *Кара, кара, болай йөремче кеше булса да, китап тота белә икән бу.* Н. Исәнбәт.

ЙӨРЕМЧӘК *с.* Эшлексезләнеп яки тынгысызланып, анда-монда йөрергә яратучы (эш урынында утырмыйча). *Қайбер йөремчәк кешеләр кебек,* [*Гафури*] *хезмәт сәгатьләрендә редакциядән чыгып китми.* С. Кудаш.— *Өйдә утырырга яратмый сезнең Садыйков. Йөремчәк кеше.* С. Рафиков.

ЙӨРЕМЧӘН *с. к.* йөремтәл 1. *Малы беткән кешенең әте өрүчән, аты йөремчән була.* Мәкаль.

ЙӨРЕҢҮ *ф.* Арлы-бирле йөрү, туктаусыз йөреп тору. *Нәкъ баягы җирдә --- яңа часовой йөренә башлады.* А. Әхмәт. *Хисмәт яна, ни кылырга белми, Ишекле-тәрле йөренә.* Ш. Маннур.

ЙӨРЕШ *и.* 1. Адым, атлам. *Сыер җиксәң, ат йөрешен көтмә.* Мәкаль. *Ул, авылга кергәч, йөрешен кызулатты.* Ш. Камал. // Йөргәндә аякларны төрлечә басып атлау гадәте, йөрү рәвеше. *Җиңелчә йөреш. Матур йөреш.* □ *Ишек ачылып, салмак, бераз һавалы йөреш белән Фәхри килеп керде.* Г. Ибраһимов. *Карга, тутый кош йөрешен йөрим дип, үз йөрешен оныткан.* Мәкаль.

2. Нинди дә булса юнәлештә бер урыннан икенче урынга күчеш, хәрәкәт. *Поезд йөрешен тизләтте, тирәяктагы каралтылар, телеграф баганалары артка карап ага башладылар.* М. Гафури. *Көймәнең йөреше көчәйгәннән-көчәйде.* Г. Минский. // Хәрәкәт итү тизлеге. *Машина --- тигез таш юл буйлап алга китте. Йөрешне күрсәтә торган стрелка 160 ка җитте.* Ш. Усманов. // Теге яки бу төр транспортның билгеле бер маршрут һәм расписание буенча хәрәкәте. *Автобуслар йөреше расписаниесе.* □ *Эльзас-Лотарингия аркылы --- поездлар йөреше юлга салынмаган.* Г. Гали. // Һәртөрле механизмнарның эш хәрәкәтләре. *Сәгать теле йөреше колак төбендә чаң сукканда яңгырап торды.* К. Латыйпов. // Сыеклыкның (нечкә трубалар, кан тамырлары һ. б. ш. буенча) хәрәкәте, таралуы. *Физкультура, --- кан йөрешен көчәйтеп, каткан сеңерләрне йомшарта.* Т. Гыйззәт.

3. Шахмат уенында фигураларны бер урыннан икенче урынга күчерү. *Утызынчы йөрештән соң ук, мастер аңа [Галимгә] партиясен оттырды.* Г. Әпсәләмов.

4. Кая да булса барып йөрүнең, берәр кайда булуның күрсәткече. *Җыелышларда күбрәк вакыт уку, өлгереш, [дәресләргә] йөреш турында --- сөйлә[деләр].* Н. Фәттах. // *с. мәгъ.* Йөрешне билгели торган. *Йөреш журналы.*

Йөреш хәрәкәте *физ.*— механик хәрәкәтнең иң гади төре. *Күтәрү краны ярдәмендә бер урыннан икенче урынга күчерелә торган йөкнең хәрәкәте, транспортер тасмасына салынган әйберләр хәрәкәте — йөреш хәрәкәтенә мисал булалар.* Физика.

ЙӨРЕШ-ҚИЛБӘТ *җый. и. к.* йөреш-торыш. *Горефгадәтләре һәм йөреш-килбәтләре белән дә коеп куйган әтисе инде Асылгәрәй.* М. Шабай.

ЙӨРЕШЛЕ *с.* 1. Тиз һәм алымлы йөри торган. *Туры атым йөрешле, йөрешләре килешле.* Җыр.

2. Йөри, үтә ала торган. *Суднолар йөрешле елга.* □ *[Әнвәр] сайда йөрешле газоходка утырып кайтырга чыккан.* Э. Касыймов.

3. *ярд. ф. функ.* Тезмә фигыль составында «йөрерлек, йөри торган» мәгънәсен белдерә.— *Кара, миңа икенче килеп йөрешле булмасын.* С. Рафиков.

ЙӨРЕШ-ТОРЫШ *җый. и.* Кешенең аяк-кулларны хәрәкәтләндерү һәм буй-сыннарын тоту рәвеше. *Гаскәр башлыкларының йөреш-торышларына ашыгычлык керде.* М. Гафури.

ЙӨРЕШҮ *ф.* 1. Бер-береңә баргалап тору, әледән-әле бер-берендә булу, якыннан аралашып яшәү. *Менә ничә ел инде без Бибигасма белән йөрешәбез.* Г. Ибраһимов. *Бу ике гаилә үзара бик сирәк йөрешәләр иде.* С. Рафиков.

2. *сөйл.* Мәхәббәт тоту. [*Кыямның*] *Суфия белән йөрешә башлауларына ике елдан артып китте.* И. Гази.

ЙӨРТҮ *ф.* 1. Ярдәм итеп, җитәкләп, озатып яки хәрәкәтенә юнәлеш биреп кем белән булса да йөрү. *Саф һавада йөртү.* □ *Әткәй Алмачуарны [аты] җитәкләп йөртә башлады.* Г. Ибраһимов. // Нәрсә дә булса күрсәтеп, тамаша кылдырып, кем белән дә булса йөрү. *Кунакларны күргәзмәдә йөртү.* □ *Җәй башында әткәй мине үзе белән авылларда йөрткән иде.* Г. Бәширов. // Халыкка күрсәтү өчен кая да булса алып чыгу, алар алдында йөрергә мәҗбүр итү (өйрәтелгән җәнлекләрне, гаепле кешеләрне һ. б.). *Әле берничә ел элек кенә, Вәли белән Сабираны тотып, битләрен корымга буяп, урам буенча йөрткәннәр иде.* Г. Ибраһимов. // «Үзен» яки «үзен үзе» сүзе белән килгәндә: йөрерлек хәлдә булу. [*Вәли бабай*] *әле үзен үзе йөртә ала икән.* Г. Толымбай.

2. Кая да булса алып бару, алып кайту (җәяү, яки атта, машинада һ. б.). [*Кәбир*] *сугыш елларында шофер булган һәм нинди дер армиянең командующие йөрткән.* Г. Әпсәләмов. *Агыйделкәйләрдә ак пароход йөретәдер Мәскәү байларын.* Җыр. // **Төрле** юнәлештә хәрәкәт иттерү (ял итү, күңел ачу, нәрсәгә дә булса күнектерү, өйрәтү һ. б. максатлар белән). *Йөзәләр аккошлар һаман, Тартып зәңгәр көймәне. Күлнең төрле якларында Йөртәләр Миләүшәне.* Ш. Маннур. *Кайбер малайлар, йөгерек атларга атланып, урам буйлап ат йөртергә чыктылар.* Х. Садрый. // Танец биегәндә иптәшеңне үз бию хәрәкәтләреңә иярту, аның хәрәкәтләреңә тиешле юнәлеш бирү. *Кичәләрдә башка берәр кыз белән әйләнергә туры килсә, «син бик әйбәт йөртәсең» дип, мактап та җибәрәләр үземне.* Р. Төхфәтуллин.

3. Нәрсәнең дә булса (поезд, самолет, пароход, машина, атның һ. б.) хәрәкәтенә идарә итү. *Поезд йөртү. Авыр йөк машиналары йөртү.* □ *— Дәү үскәч, Хәсбиулла абыең шикелле, син дә трактор йөртерсең.* Г. Бәширов.

4. Тартып алып бару, ташу. *Йөк йөртү.* □ [*Атлар*] *кырык потны Зәңгәр чишмә белән кала арасында «әһ» дә дими йөртәләр.* Г. Ибраһимов. // Ташу, тарату (җәяү яки атта, машинада). *Кыш көннәре ул почта йөртә торган иде.* Г. Бәширов.

5. **Карау, көтү (терлекне).** *Көтү йөртү.* □ [*Тагиевлар*] *Камышлы авылының матур болыннарын, --- мал йөртү өчен генә саклана торган әрәмәлекләрен үз кулларына төшергәннәр.* Х. Садрый.

6. Хәрәкәткә китерү, эшләтү (механизмнар, энергия чыганаклары, турында). [*Хәлим*] *тегермәннең --- дүртенче катына йөгереп менде. --- Ташны йөртә торган вал нинди зыр-зыр әйләнә.* И. Гази. *Паровозларны йөртә Донбассның күмерләре.* Җыр.

7. Нәрсәне дә булса берәр әйбернең өслегеннән хәрәкәт иттерү. *Каләм йөртү. Смычок йөртү.* □ [*Газизә*] *җитез куллары белән утюгын аллы-артлы йөртә.* Ш. Камал.

8. Нәрсәне дә булса һәрвакыт үз янында саклау, тоту, үзеңнән калдырмау. *Билетны кесәдә йөртү. Кирәкле китапларны портфельдә йөртү.* // Нәрсәне дә булса саклау, караулы тоту, аның яхшы саклануына тиешле игътибар бирү.— *Менә хезмәт кенәгәсен ничек [нәхтә] йөртәләр аны.* А. Алиш. // *күч.* Кемне дә яки нәрсәне **дә булса истә,** күңелдә саклау. *Күңелдә ачу йөртү.* □ [*Лаля:*] *Исемеңне телемдә тәсбих урынында йөрттем, күңелемнең иң тирән урынында иркәләп тирбәттем.* М. Фәйзи.

9. *Сакал, мыек, чәч* сүзләре белән килгәндә: үстерү; нинди дә булса рәвештә тарап, кистереп, алдырып йөрү. [*Бәдри*] *сакал йөртми иде.* Х. Садрый.

10. Кая да яки кем янына да булса килергә яки барырга, чыгып йөрергә мөмкинлек бирү, рөхсәт итү. [*Кабанов Вәлига:*] *Нигә син мондый кешеләрне өеңә йөртәсең?* Т. Гыйззәт. *Өйрәнгән гадәт калмый: Хәнифә әүвәлдәге кебек янына егетләр йөртә башлады.* З. Һади.

11. Кем яки нәрсә дип атау. *Аны авылда аучы Әхмәтвәли дип йөртәләр.* Г. Галиев. // *Исем, фамилия* сүзләре янында килгәндә кем исемендә яки фамилиясендә булуны белдерә. *Үз фамилиясен йөртү.*

12. *күч.* Башкару, алып бару (нинди дә булса эшне).— *Бик җайлы кеше малаең, эшең дә белеп йөртә.* Ф. Хөсни.

13. Җибәрү, тапшыру, тарату. *Почта аша йөртү.* □ *Мәскәү юлларында телеграмм, Чит илләргә хәбәр йөртәдер.* Җыр. *Петроградта хәрби революцион комитет илле меңле гарнизонга үзенең боерыкларын йөртә.* Ш. Камал.

14. Арадашчы, элемтәче итеп файдалану. *Кош телләреп белеп булмый Арабызда йөртергә.* Җыр.

15. *ярд. ф. функ.* Кайбер исемнәр янында килеп, шул исемнәргә бәйләнешле эш-хәрәкәтне үтәүне, башкаруны белдерә; итү. *Исәп йөртү.* □ [*Гөлйөзем:*] *Ялган! Ышанмагыз ул явызга, Уйлап, бикәм, эш йөртегез.* Т. Гыйззәт.

ЙӨРТҮЧЕ: йөртүче ракета — космик корабльләрне тиешле орбитага чыгара торган ракета. *Космик лабораторияне орбитага чыгарырга сәләтле йөртүче ракета.*

ЙӨРӘК *и.* 1. Кан әйләнешен тәэмин итә торган мускуллы капчык сыман үзәк орган. *Йөрәк эшчәнлеге. Йөрәк тибү.* □ *Кичәле-бүгенле йөрәккә ябышты. Чәнчеп-чәнчеп авырттыра.* Э. Касыймов. // Күкрәк куышының сул ягында шушы орган урнашкан урын.— *Менә, ышанмасаң, йөрәгемне тотып кара, балык кебек тыпырдый.* А. Шамов. *Мин сугышка керсәм, дошманымның Йөрәгенә төзәп атамын.* Ф. Кәрим // тарт. форм. *ирк. шигъ.* **йөрәгем.** Ярату хисе белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Саниям, җавап хатыңны көтәм, йөрәгем.* М. Әмир.

2. *күч.* Кешенең һәртөрле хис, тойгы, кәеф, кичерешләр җыелмасы символы. *Сәрвигә булган тойгысы аның бөтен тормышын, йөрәген, күңелен биләп алды.* Э. Фәйзи. *Бу көйдән --- халыкның йөрәк тавышы килә.* Г. Бәширов. // Мәхәббәт хисләрен белдерә торган символ. *Кемне сөя икән Гөлчирәбез, Кемдә икән аның йөрәге?* Ф. Кәрим.

3. *күч.* Кешенең эчке дөньясы (рух, җан, күңел, хәтер). *Карама белөккә, кара йөрәккә.* Мәкаль. *Юлбашчы юк — юлы калды. Көрәш сафы тулы калды, Йөрәкләрдә сүзе калды, Һәр сүзендә үзе калды.* Ф. Бурнаш. // Кешенең эч сере, яшерен уйлары.— *Үзеңнең иң якын, иң яраткан кешеңнең йөрәген белмисең!* Р. Ишморат.— *Ну, Булат, малай, егет икәнсең, йөрәктәгене әйттең дә салдың бит!* К. Тинчурин. // **Кайбер сыйфатлар** янында килгәндә, кешенең эчке табигатен, характерын белдерә. *Саф йөрәк. Таш йөрәк. Чуар йөрәк.* □ *Сезнең йөрәк булса каты тимер, Безнең йөрәк каты корытан.* М. Гафури.

4. *күч.* Көч-куәт, гайрәт, кыюлык.— *Чынлап, Максудовның, эшкә булса, йөрәге дә бар, кулы да бар, теле дә бар. --- Кызлар өчен булса, берсе дә юк.* Р. Ишморат. *Сафыйга каршы торырлык йөрәк [Гайнидә] күптән үлгән иде инде.* Г. Гали. // Намус, вөҗдан. *Мин кабыздым җырда ялкын итеп Йөрәгем һәм хаклык кушканны.* М. Җәлил.

5. *күч.* Нәрсәнең дә булса үзәге, төп өлеше. *Сугыш башланып өлгермәде, дошман безнең илебезнең йөрәгенә сузыла башлады.* **И. Гази.**

Йөрәк авырулы — йөрәк авыруы белән җәфаланучы. *Ул үзе йөрәк авырулы иде.* Г. Ибраһимов. **Йөрәк ите** — атның тояк астындагы йомшак жире. *Туры бия аксап калды, йөрәк итенә бер-бер нәрсә кергән, ахры.* Г. Ибраһимов. **Йөрәк ярылу** — 1) йөрәк урнашкан карынчык стенаның шартлавы (куркудан һ. б.). *Куркакны беренче пуля үтерә, пуля тимәсә дә үлә ул. Куян шикелле, йөрәге ярылып үлә ул.* Г. Әпсәләмов; 2) *күч.* бик каты курку. *Әнкәй каргагач, урманга баргач, Йөрәгем ярылды, зур имән аугач.* **Г. Тукай.**

◇ **Йөрәге боз (салкын)** — хиссез, дәртсез.— [Акыллы малай] *син, Фазыл. --- Тик йөрәгең салкын.* Р. Ишморат. **Йөрәген алу** — бик каты куркыту, хафага салу. [*Гыйльми карчык*], *бер-берсеннән куркыныч сүзләр белән куркытып, Галимә апаның да, әнинең дә йөрәген ала.* М. Гафури. **Йөрәген бозу** — кәефен җибәрү, рухи газаплау.— *Зинһар дип әйтәм, син минем йөрәгемне бозма, елама.* Г. Камал. **Йөрәген телеп алу** — кемнең дә булса хисләренә бик көчле тәэсир итү. *Бу елмаю Сөләйманның йөрәген телеп алды.* К. Тинчурин. **Йөрәген яралау** — кемне дә булса рухи газапларга дучар итү.— *Ирен ярасы ничек тә бер төзәлер. Сез менә минем йөрәгемне яраладыгыз.* Ф. Хөсни. **Йөрәгенә ия булу** — кемнеңдер мәхәббәтенә ирешү. *Инде җитәрлек түздем; Дәртең булса, йөрәгемә ия бул.* Ф. Кәрим. **Йөрәк алыну (кубу)** — бик каты курыкканда әйтелә. *Миңеште тамагына җиткән саен [Кифаяның] йөрәге алына барды.* Х. Сарьян. *Куркудан йөрәгем купты, җан ачу белән кычкырып жибәрдем.* Г. Ибраһимов. **Йөрәк атылып чыгарга җитү** — йөрәкнең бик каты тибүе (бик нык дулкынланудан, ачудан яки куркудан). **Йөрәк ачыну** — *к.* йөрәк әрнү. *Мәулиха түти, Нәфисәнең --- бөгелеп төшүен күреп, янына ашыкты, күз яшен күреп, йөрәге ачынды.* Г. Бәширов. **Йөрәк ачысы** — газап, дәһшәт. *Нәфрәтеннән, йөрәк ачысыннан Көзге урман шашып шаулады.* М. Җәлил. **Йөрәк аша үткәреп** — тирән аңлап, акыл белән тоеп. [*Хәмдия:*] *Егет булса, нинди бүләк икәнен йөрәге белән сизеп, йөрәгә аша үткәреп бирсен.* М. Фәйзи. **Йөрәк басылу** — курку, шомлану, борчылу хисләреннән котылу, тынычланып калу. *Шул теләкләрем кабул булса, басылыр да иде йөрәгем.* Г. Тукай. **Йөрәк бушату** — күңелдә җыелып килгән яшерен уйларны, кайгы-хәсрәтләрне сөйләү, кем белән дә булса уртаклашу яки җыелып килгән ачу-үпкәләрне әйтү. [*Фәрхи карчык*] *Мохтарның күзенә чагылса, ул, әлбәттә, эндәшми калачак түгел, йөрәген бушатачак иде.* Ш. Камал. **Йөрәк белән** — хис, акыл, бөтен барлыгы белән; җаны-тәне белән. [*Тол аналар*] *балаларның ятимлеген дә, ялгызлыкның нинди фаҗига икәнен дә үз йөрәкләре белән татып белгәнгә.* Н. Дәүли. [*Хәмдия:*] *Ил егетләреннән мәхәббәтен тел белән, йөрәк белән аңлата алганына барырга телим.* М. Фәйзи. **Йөрәк бәгырем (парәм, маем** *диал.*) — ярату хисе белән, иркәләп, якын итеп әйтелә торган тәгъбир. *Гыйззәтем син, кадерем син, минем йөрәк бәгырем син.* Г. Тукай. *Каләм алып хатлар яздым йөрәгем парәсенә.* Җыр.— *Вәт монысы өчен рәхмәт, йөрәк маем.* Ә. Айдар. **Йөрәк дусты** — сөйгән яр; сердәшче. *Аерылганда миңа йөрәк дустым Бүләк итте ефәк яулыгын.* М. Җәлил. **Йөрәк жуу итү** — бик каты курку. *Фәтхетдиннең йөрәге жуу итеп китте, өстенә салкын су сипкәндәй булды.* Х. Кәрим. **Йөрәк итен ашау (талау, телгәләү)** — рухи газаплау, бик нык борчу, һич тынычлык бирмәү.— *Жиде ел эчендә син минем шактый йөрәк итләремне ашадың.* Г. Камал. *Кая гына баш куйсам да, Кайгы талый йөрәк итемне.* М. Җәлил.— *Ник минем йөрәк итемне телгәлисең, [балам]? Ничек бер дә кызганмыйсың?* М. Максуд. **Йөрәк итенә ябышып үсү** — оныта алмау; һәрвакыт истә, күңелдә булу (сөйгән, яраткан кеше турында). *Дәүләтшинның бәхетсезлегенә каршы, бу кыз аның йөрәк итенә ябышып үскән.* И. Гази. **Йөрәк итенә үтү** — бик авыр кичерешле, газаплы булу. *Бу сагышның авырлыгы үтте йөрәк итемә.* Җыр. **Йөрәк кагу** — 1) тирән борчылудан, шатлыктан һ. б. ш. кичерешләрдән йөрәкнең бик көчле, деп-дөп итеп тибүе. *Ялгызлыктан колак шаулый, йөрәк кага.* Қ. Нәҗми; 2) юрганда өзек-өзек эч авазлары чыгару, бавыр тавышы чыгару (көр атлар турында). *Бахбайлар, --- ялларын җилфердәтеп, йөрәк кагып кына йөриләр.* А. Гыйләҗев. **Йөрәк кайнау** — 1) зур тынычсызлык, борчу. кичерү. *Шундый уйлар, шундый ашкынулар белән йөрәге кайнаган хәлдә, Шәрифуллин авыл уртасындагы кечкенә күпергә килеп керде.* С. Рафиков; 2) бик нык ачулану, ярсу, нәфрәтләнү. [*Тоткыннан*] *сүз әйттерә алмауның хурлыгы аның [приставның]*

миен каплый, йөрәген кайната. Г. Ибраһимов. **Йөрәк калмау** — бик каты курку.— *Фу, йөрәгем калмады. Йә, кая качып йөрисең инде, Карачәч апа?* Н. Исәнбәт. **Йөрәк кандырып** — туйганчы, рәхәтләнеп, ләззәтләнеп. *Беләк талдырып эшләсәң, Йөрәк кандырып ашарсың.* Мәкаль. **Йөрәк киселү** — ачлыктан бик нык интегү, **йөдәү турында.** *Ардым инде, михнәт бетерде; Ач йөрүдән йөрәк киселде.* Ф. Бурнаш. **Йөрәк кешесе** — кешелекле, йомшак күңелле. [*Нуруали*] *йөрәк кешесе булганга күрә, хайваннарның кичерешләренә бервакытта да салкын канлы булып кала алмый иде.* Ә. Еники. **Йөрәк кузгалу** — кинәт кәеф бозылудан, тирән дулкынлану, борчылудан йөрәк авырта башлау; йөрәк өянәге **башлану.** *Карт актыккы сүзләрне әйткәндә, тавышлары үзгәреп китте: йөрәге кузгалганлык күренеп тора иде.* Ш. Камал. **Йөрәк кымыржу** — нәрсәдән дә булса шүрләп, куркып кую, тынычсызланып китү. [*Кузнецов:*] *Ул хәтле булмады булуын, шулай да чак кына йөрәк кымыржып куйды.* Ш. Камал. **Йөрәк кысылу (ою)** — кемгә-нәрсәгә теләктәшлек күрсәтү йөзеннән туган көчле кызгану хисе турында. *Тау башында бер үзе генә басып тор.ан анасының шәүләсен күрүгә, Сөләйманның йөрәге кысылды.* К. Тинчурин. [*Хәмдия:*] *Шул хайваннарны кызганып, йөрәкләрем ойый инде.* А. Расих. **Йөрәк майларын имү** *гади с.*— талау, тәмам бөлгенлеккә төшерү. *Ике өлкәнең сәүдәгәрләре ярлыларның йөрәк майларын имеп килгәннәр.* Х. Садрый. **Йөрәк мүкләнү** — *к.* йөрәккә йон үсү. [*Мичтак абзыйның үзенең дә, хатынының да], карт булсалар да, йөрәк яшь, йөрәк мүкләнмәгән.* Г. Толымбай. **Йөрәк серенә керү** — кемнең дә булса эчке уй-тойгыларын белү. *Теләсәң, мәңге якын дустың булыйм, Мин дә керим йөрәк сереңә.* Ә. Фәйзи. **Йөрәк сугу (сикерү)** — *к.* йөрәк кагу (1 мәгъ.).— *Бераз йөрәк сикерә сикерүен, шулай да --- сер бирергә ярамый.* Г. Камал. **Йөрәк (мае) сызу (сызылу)** — сагышлану, кызгану, әрнү, юксыну, ниндидер шомлы хисләр эчендә булу. *Зәкия апа да сөекле энесенең нәрсәдәндер йөрәк мае сызылуын ишектән керүгә сизеп алды.* Ш. Хөсәенов. **Йөрәк сүзе** — 1) чын күңелдән, ихлас белән әйтелгән сүз, фикер; 2) хисләргә бай, тирән мәгънәле уй, фикер. *Шигырь ул — кешегә кирәкле йөрәк сүзе.* Г. Хуҗиев. **Йөрәк таш булып кату** — 1) кырыслану, усаллану. [*Сафура:*] *Йөрәгең таш булып катканга охшый, кияү... Югыйсә, бу чаклы үк кырт кисеп сөйләшмәс идең.* К. Нәҗми; 2) хиссез, өнсез калу. *Елый алмадым, йөрәгем таш булып катты.* Г. Ибраһимов. **Йөрәк ташу** — *к.* йөрәк кайнау. *Таһирҗан хәлфәнең көнчелек тамырлары хәрәкәткә килер, --- ачуыннан йөрәге ташыр.* З. Һади. **Йөрәк тойгысы (хисе, сагышы) белән** — мәхәббәт, сагыну, юксыну һ. б. ш. хисләр белән. *Эч өзгеч йөрәк тойгысы белән сине хыялымда иркәлим, башыңнан сыйпыйм, маңгаеңнан үбәм.* Ш. Камал. **Йөрәк түрендә йөртү (саклау)** — онытмау, һаман да якын итү. *Ничә ел ул шул егетне йөрәк түрендә йөртә.* Ә. Ерикәй. **Йөрәк урынына утыру** — *к.* йөрәк басылу. *Зөләйха абыстайның да йөрәге урынына утыра башлады.* Г. Ибраһимов. **Йөрәк урынында түгел** — көчле борчылу, дулкынлану турында. *Егетнең дә йөрәге урынында түгел иде.* Ф. Хөсни. **Йөрәк урыныннан кубу (кузгалу)** — бик нык курку яки тынычлыкны югалту, борчулы хисләр биләп алу. *Йөрәгем урыныннан купты.* [*Бу*] *дәһшәтле фаҗига минем --- түземлелегемне җиңде, тешләрем шыкырдады.* Ф. Кәрим. **Йөрәк чуарлану** — дәртләнү, талпыну, ниндидер ашкынулы хисләр барлыкка килү. *Кыр казлары, торналар кузгалган чакта, йөрәге чуарланып, ул да бер кыбырсып ала иде.* Г. Бәширов. **Йөрәк ялгау** — бераз ашап алу; ашыйсы килүне басу. *Төенчекләребездәге майлы күмәч, пешкән йомыркалар белән йөрәк ялгадык.* Г. Галиев. **Йөрәк ялкыны** — дәртле, ашкынулы хис. *Сүндерә алмый аптырыйсың Йөрәгең ялкыннарын, Мин дә егет, дигән булып Йөргән буласың тагын.* Х. Җәмил. **Йөрәк яну (ут булу)** — 1) бик нык кайгыру, борчылу; кайгы-хәсрәт басу. *Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин.* Г. Тукай. *Булатның йөрәге ут булды.* Г. Ибраһимов; 2) кызыгу; мәхәббәт хисләре уяну. *Керфегеңнән гөлләр тама, Күрсәм йөрәгем яна.* Җыр; 3) көнләшү. *Янсын дошман йөрәкләре, Без баскан эзләргә бас.* Җыр. **Йөрәк ярасы** — 1) баштан үткән нинди дә булса фаҗигале, газаплы вакыйганың күңелдә калган эзе. *Әгәр дә бу хат йөрәк яраңа кагыла торган булса, минем гафу ит.* Г. Бәширов; 2) күңеле, мәхәббәте төшкән **кеше.** *Алар арасында бит инде Николайның йөрәк ярасы да бар.* И. Гази. **Йөрәк яргыч** — бик көчле, коточкыч. *Кинәт мин, каяндыр, йөрәк яргыч ачы бер аваз ишеттем.* Н. Исәнбәт. **Йөрәк ярсу (өзгәләнү)** — артык дулкынлану, борчылу; хисләрнең чиктән ашуы. *Йөрәк ярсуы билән алган Әхмәди, үз-үзе белән көрәшә-көрәшә, өйдән чыгып [китте].* Г. Иделле. *Башта шулай йөрәк өзгәләнә, Серле тоела башлый яшәве.* М. Җәлил. **Йөрәк ятмау** — ошатмау, яратмау, теләмәү. **Йөрәк яшерү** — сер саклау, эч серләрен уртаклашырга теләмәү. [*Зөлфия Гафурга:*] *Партоешма секретареннан йөрәгегезне яшерергә тырышу һич аңлашылмый.* Р. Ишморат. **Йөрәк эрнү (өзелү, телгәләнү, парчалану)** — 1) бик нык кызгану, аяу. *Бу фаҗигане үз күз алдында уздырып, җаны тетрәгән, йөрәге телгәләнгән Хәдичә солдат артыннан йөгерде.* Г. Бәширов.— *Карт аягыма егылды, шундый бер яман җылады, йөрәгем парчаланды.* Г. Ибраһимов; 2) чиктән тыш борчылу, тынычсызлану. *Ай-һай, дуслар, яшь йөрәгем нигә өзелә икән.* Җыр. *Юк, түзәлмим йөрәк әрнүемә, Ачуыма, нәфрәт утыма.* Ш. Маннур. **Йөрәк өзгеч (эрнеткеч)** — 1) көчле тәэсир итә торган, үзенә нык җәлеп итә торган. *Ишеттем мин, кичә ул җырлады Йөрәк өзгеч матур моңлы җыр.* Ә. Ерикәй; 2) куркынычлы, бик шомлы, бик кайгылы. *Фронтлардан һәр көнне йөрәк өзгеч хәбәрләр килеп торды.* А. Шамов. **Йөрәк үлү** — ваемсыз булу, дәрт булмау. [*Нәфисә:*] *Йөрәге үлмәгән бәндә мондый вакытта ни җаны белән кешедән калсын?* Г. Бәширов. **Йөрәк җилкенү (ашкыну, алгысу)** — нәрсәгә дә булса омтылу, дәртләнү, берәр нәрсәне дулкынланып, түземсезлек белән көтү. *Ике ялкын бергә тоташып, Ике йөрәк бергә җилкенде.* М. Җәлил. *Куллар рульдә, күзләр ераста; Күзләр балкый, йөрәк алгысый.* Ә. Юныс. **Йөрәк җиту** — нинди дә булса эшне эшләргә батырчылык итү. *Әсирлектән качарга йөрәк җиткән кеше, тотыла калса, үзен ни көтәсен алдан үк белә.* Г. Әпсәләмов. **Йөрәк җылысы** — яхшы теләк, якын итү хисе. *Украина, сиңа ераклардан Алып килдем йөрәк җылымны.* С. Хәким. **Йөрәккә басу** — кеше күңеленә көчле тәэсир итәрлек итеп уйнау (нинди дә булса уен коралында) яки җырлау, бию турында. [*Ибрай:*] *Йөрәккә генә басалар бит, ә, Габделмән абый.* М. Фәйзи. **Йөрәккә боз булып утыру** — бик авыр, ямьсез, күңелсез тәэсир калдыру. **Йөрәккә йон (мүк) үсү** — дәртсез, ваемсыз, сүлпән булу. [*Карт:*] *Яшь килеш йөрәгенә йон үстереп, кайда түмгәк — шунда имгәк булып басып торучыларга ачу итеп яшәрәсем килә.* Ф. Хөсни. *Мондый кичәләрнең ләззәтен аңламаган кызлар аңа җансыз, йөрәкләренә мүк үскән тере мәет булып күренделәр.* Ш. Хөсәенов. **Йөрәккә кабу (кабыну)** — берәр эш, хәл яки хәбәрнең начар тәэсир итүе турында.— *Аның белән тагын сүгешеп тора алмыйм, әле дә йөрәккә кабып бетте.* Ф. Әмирхан. **Йөрәккә кадау** — кимсетү, рәнҗетү, рухи газаплау. *Чәнечкеле сүзләр белән йөрәгемә кадама.* Җыр. **Йөрәккә кадалу** — нәрсәнең дә булса кешегә көчле, газаплы тәэсир итүе, рухи газап тудыруы турында.— *Ил өстенә килгән һәр каза, авылдашларыбыз өстенә килгән һәр бәхетсезлек безнең дә йөрәккә кадалмыймыни, кызым!* М. Әмир. **Йөрәккә (кара) кан саву** — чиктән тыш газаплану, кайгыру, хафалану

турында. [*Җәмилә:*] *Шул баланы уйлый-уйлый йөрәгемә кан савып бетте инде.* Г. Камал.— *Син минем йөрәгемә кара кан саудырыр өчен генә йөрдеңмени?* Г. Бәширов. **Йөрәккә керү (кереп утыру)** — 1) онытылмаслык булып истә калу. *Бу сүз Нәгыйләнең йөрәгенә кереп утырды.* Г. Ибраһимов. *Йөрәктән чыккан гына йөрәккә керә.* Мәкаль; 2) ышаныч, хөрмәт казану; мәхәббәт яулап алу. *Якын туганыбыз, яраткан дустыбыз булып йөрәккә кердең син,* [*Хәлим*]. К. Нәҗми.— *Унөч яшемнән алып йөрәгемә кереп утырган Хәлилем бар чагында,* [*Исмәгыйльнең*] *кызыксыз байлыгына бер дә исем китми.* М. Фәйзи. **Йөрәккә май (кебек) булып яту** — шатландыру, күтәренке яхшы хис тудыру, тынычландыру турында.— *Абдулка турында бер әйбер дә, йөрәккә май булып ятарлык бер генә юньле хәбәр дә белмисең икән? Ә?* К. Нәҗми.— *Бик рәхмәт, башта бик матур сүзләр сөйләдең, йөрәгемә май кебек ятты.* А. Шамов. **Йөрәккә сеңдерү** — хәтердә калдыру, онытмаслык итеп үзләштерү. [*Фәһимә Йомабайның*] *җанга үтемле матур җырларын --- һәммәсенең йөрәгенә сеңдерә барды.* Г. Бәширов. **Йөрәккә тию** — 1) йөрәк эшчәнлегенә зарар китерү.— [*Кофе*], *балам, йөрәгеңә тияр, берәр нәрсә кабарга кирәк.* Г. Ибраһимов; 2) кәефне бозу, начар тәэсир итү. **Йөрәккә тоз салу** — бик нык кәефне җибәрү, газаплау, ачуландыру (авыр, кайгылы, борчулы һ. б. ш. сүз, хәбәр сөйләп).— *Зинһар, йөрәгемә тоз салма, минем аннан башка да йөрәк итләрем телгәләнеп беткән.* М. Гафури. **Йөрәккә төшү** — 1) бик нык җәфалау, интектерү (авырту, каты салкын, ачлык һ. б. ш. турында). *Яраларым инде савыкмандыр, Йөрәгемә төшми сызлавы.* Х. Камалов; 2) аптырату, йөдәтү.— *Я, әйт сүзеңне, Иван Иванович, шуннан соң да план-план дип йөрәгебезгә төшәсеңме?* А. Расих; 3) нинди дә булса көчле хис, тәэсир калдыру. [*Җырчының*] *көе, тавышы бик әйбәт, бик моңлы, ничектер йөрәккә төшә.* Г. Ибраһимов. **Йөрәккә ут кабу** — 1) нык гашыйк булу. [*Кызны*] *күрәч үк йөрәгемә ут каптыры.* А. Шамов; 2) нык борчылу. *Нәфисә, баласына каты авыру эләккән анадай, йөрәгенә ут кабып, агроном янына чапты.* Г. Бәширов. **Йөрәккә ут (ялкын) салу** — 1) мәхәббәт хисе уяту, гашыйк итү. *Уйламаган җирдән син килдең дә Ут салдың йөрәгемә.* Ә. Ерикәй. *Уразгөл --- беренче күрүдә үк кешенең йөрәгенә ялкын сала, дулкынландыра торган кызларның берсе.* Ә. Айдар; 2) нәрсәгәдер омтылыш, дәрт бирү.— *Синең сүзләрең йөрәгемә ут салды, бабай.* М. Фәйзи; 3) борчылу, курку хисләре тудыру; бик нык кәефне бозу, ачуландыру. *Тәрәзә төпләребез, үрмәле гөлләребез; Күп дошманның йөрәгенә ут салган көннәребез.* Җыр. **Йөрәккә чыдый алмау** — нәрсә эшләргә белмичә тынычсызлану, борчылу. [*Габдулла*] *мәдрәсәдә утыра алмады, йөрәгенә чыдый алмый, урамга чыкты.* Ә. Фәйзи. **Йөрәккә якын алу** — нәрсәгә дә булса бик зур игътибар бирү, бик зур теләктәшлек күрсәтү; нинди дә булса хәлне бик тирән кичерү. *Бернәрсәне дә артык йөрәгенә якын алмыйча, --- авыр көннәрне тыныч кына, гамьсез генә үткарергә ниятләгән иде Фәрдәнә.* М. Әмир. **Йөрәккә якын итү** — чын күңелдән ярату, ихтирам итү, үз күрү. *Шулкадәр йөрәккә якын итеп бала күлмәген бары тик ана кулы гына сыпыра ала.* Г. Әпсәләмов. **Йөрәккә ял булу** — кайгы-борчылулар онытылу, тынычлану; кәеф күтәрелү. *Бер елмаеп кара әле: йөрәгемә ял була.* Җыр. **Йөрәккә яту** — 1) күңелгә ошау, канәгатьләндерү. [*Сәйфулла кызга:*] *Сүзләрең йөрәгемә ята. Тик ишетеп бетерә алмыйм тәрәзә аша.* Ф. Бурнаш. *Йөрәккә ятмагач, күңелең тыныч булмагач — эшең эш түгел инде.* М. Әмир; 2) тәмле булу, яратып ашау (аш-су турында). *Аш-суы йөрәккә ята торган итеп хәзерләнгән булыр.* **Йөрәккә ятышлы** — күңелгә ошый торган, матур. *Син йөрәккә ятышлы гаҗәеп бер елмаю белән минем иренәремә карадың.* Г. Кутуй. [*Җаббарның*] *лекция яки чыгышлары һәрвакыт әйбәт, йөрәккә ятышлы була иде.* М. Әмир. **Йөрәккә үткәреп** — тәэсирле, эчке сизү белән тоярлык, яхшы аңларлык итеп (әйтү, җырлау, язу турында).— *Кем язган аны шулай йөрәккә үткәреп?* К. Нәҗми. **Йөрәккә җылы керү** — шомлану, курку, тынычсызлану хисләре бетү, юкка чыгу.— *Яхшы хәбәрең өчен рәхмәт, туганкай, йөрәккә җылы керде.* К. Нәҗми. **Йөрәкне ачу** — 1) кем белән дә булса үзенең кичерешләре, серләре белән уртаклашу; эч серен сөйләү. [*Гайшә сердәш җиңгәсенә*] *йөрәген ачты, шуның аркылы егеткә үзе башлап сүз җибәрде.* Г. Ибраһимов; 2) мәхәббәт хисләре турында ачыктан-ачык әйтү, белдерү. *Күпме хатыңа бер җавап язмадым, йөрәгемне ачмадым.* Х. Вахит. **Йөрәкне кимерү (тырнау)** — бик нык борчып, тынычсызлап тору. *Шул шик йөрәгемне кимерүдән туктамады.* Г. Ибраһимов. *Ул көннәрнең мәңге кайтмас булып ерак калулары аның йөрәген тырный.* А. Алиш. **Йөрәкне кисү** — көчле рухи газапка дучар итү, бик зур борчу салу. *«Сугыш» дигән хәбәр йөрәкләрне кисеп үтте.* Ә. Фәйзи. **Йөрәкне кытыклау (кытыкландыру)** — тәэсирләндерү, җиңелчә ярсыту. *Акчарлаклар, --- көлгән яисә үчегеп ярсыган шикелле гыйгылдап, йөрәкне кытыкландыралар.* Ш. Камал. **Йөрәкне талау** — *к.* йөрәк итен ашау. [*Мәүлиха*] *Ул чүмәләләр кыш буе минем йөрәгемне талап чыктылар.* Г. Бәширов. **Йөрәкне учта (уч төбендә) кысып (йомып, тотып)** — бик нык куркып, борчылып, дулкынланып. *Шушы вакыйгадан соң йөрәгемне учымда кысып йөрдем.* Э. Касыймов. **Йөрәкне эретү** — ачуны, үпкәне юкка чыгару, күңелне йомшарту. *Синең хатыңдагы ягымлы җылылык йөрәгемне эретте.* Ш. Камал. **Йөрәкне өзү** — көчле кызгану хисе яки гашыйк булу хәле тудыру. *Авыру тагын йөрәкне өзәрлек ыңгыраша.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Кашы кара бер матур бар, йөрәгемне өзәдер.* Җыр. **Йөрәктә саклау (йөртү)** — онытмау, хәтердә саклау. *Йөрәкләрдә йөртеп Сергоны без Гел командарм итеп күрербез.* Г. Кутуй. **Йөрәктән алу** — мәхәббәт хисе уяту. *Суык колактан алыр, Сылу йөрәктән алыр.* Мәкаль. **Йөрәктән кан таму** — зур авырлык, газаплар кичерү. *Егет кеше мал тапканда йөрәгеннән кан тама.* Г. Тукай. **Йөрәктән кичерү** — нәрсәне дә булса тирән дулкынлану, борчылу белән хис итү, тою. [*Тәзкирә*] *Айдар белән ике арада урын алган бу салкын җитдилекнең авырлыгын аеруча чын йөрәктән кичерә.* Ф. Хөсни. **Йөрәктән серләшү** — мәхәббәт турында сөйләшү, аңлашу. *Йөрәктән серләшү, Ялкынлы үбешүләр Вакыты якынлаша бит!* М. Җәлил. **Йөрәктән сөйләшү** — ачыктан-ачык, бернәрсәне дә яшермичә аңлашу. **Йөрәктән төшкән** — үз каныннан барлыкка килгән (бала турында). [*Гайшә:*] *Йөрәктән төшкән булгач, бар дөньяң шул бала өчен.* Ш. Камал. **Йөрәктән чыккан** — чын күңелдән әйтелгән (сүз, сәлам һ. б. ш.). *Тираннарга каршы ядрә иттем Йөрәгемнән чыккан җырымны.* Г. Кутуй. **Йөрәктән чыкмау** — онытылмау, истән, хәтердән китмәү. *Ул әрнүләр әле Мәликәнең йөрәгеннән чыгып бетмәгән иде.* А. Шамов.

ЙӨРӘКЛЕ *с. күч.* Батыр, кыю; дәртле, гайрәтле. *Минем исә бу кызыйга ничек тә күпне белүче йөрәкле малай булып күренәсем килә иде.* Г. Бәширов.— *Кара әле, Шәрифҗан, --- синең егетләрең арасында йөрәкләре бардыр бит?* И. Гази. / *рәв. мәгъ. Йөрәкле барабыз сугышка, Сакларга Советлар йөрәген!* М. Җәлил. // Дәртле, көчле. *Яшь чак — йөрәкле чак.* Әйтем.

ЙӨРӘКЛЕЛЕК *и.* Батырлык, кыюлык; гайрәтлелек. *Йөрәклелек аның яшьлеген бизәде. Ул үзеннән соң бөтен авыл, бөтен тирә-як сөйләрлек батырлыклар күрсәтеп үлде.* Г. Галиев.

ЙӨРӘКЛӘНҮ *ф.* Батырлану, кыюлану. *Ил кирәге өчен йөрәкләнеп Алга барган батыр яшьләрнең Дәртләренә, кыю эшләренә Семафоры ачык Мәскәүнең.* М. Җәлил.

ЙӨРӘКСЕЗ *с.* 1. Куркак, кыюсыз; дәртсез, юньсез. *Бер кеше --- шулкадәр йөрәксез булган, хәтта, кояш баегач, хатыныннан башка ишек алдына чыга алмый икән.* Г. Бәширов. *Урамыгыз кар икән, узып булмый көрәксез, Шәфәкъ баткан; кеше яткан, нигә килми йөрәксез.* Җыр.

2. Усал, рәхимсез, каты күңелле.

ЙӨРӘКСЕНҮ *ф.* Батырчылык итү, кыюлык җитү. *Бу араларда Гыймазов Вәлиевләрнең күзләренә күтәрелеп карарга да йөрәксенми йөрде.* С. Рафиков. *Кыз килмәде, егет тә, йөрәксенеп, үзе аның янына бармады.* А. Гыйләҗев. // Дәртләнү, ашкыну; гайрәтләнү. *Яшь идем мин ул заманда, көчле идем, Йөрәксенгән нәкъ арыслан төсле идем.* М. Гафури. *Колхозчылар --- яңа хуҗаның эшкә йөрәксенеп торуын күреп йөри.* Г. Ахунов.

ЙӨРӘКСҮ *и.* 1. Нәрсәгә дә булса омтылу, ашкыну. // *рәв. мәгъ.* **йөрәксеп.** Ашкынып, дәртләнеп. [*Сәфәргали*] *кубызын йөрәксеп-йөрәксеп һәм әйбәт итеп уйнады.* Ф. Хөсни.

2. Газаплану, әрнү, борчылу. *Мин дә беләм аналарның йөрәк серен, Бала өчен янып-көеп йөрәксүен.* И. Салахов.

ЙӨРӘКЧЕЛ *с.* Кимсетүне күтәрә алмый торган, гарьчел.— [*Талип*] *бик йөрәкчел малай, суга ташлануынитүе бар.* Ә. Фәйзи.

ЙӨРҮ *ф.* 1. Атлап, аякларны хәрәкәт иттереп бер урыннан икенче урынга күчү (кеше һәм хайваннар турында). *Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер.* Мәкаль. *Биек тауның башларында атлар йөри чабышып.* Җыр. // Атлап хәрәкәт итү сәләтенә ия булу, хәрәкәт итәрлек хәлдә булу (кеше һәм хайваннар турында). *Яралылар яткан урыннарыннан башларын күтәрәләр, ә йөри алганнары* [*Мөхәммәтнең*] *янына үк килеп утыралар.* Г. Әпсәләмов. // *с. мәгъ.* **йөргән.** Һәрвакыт хәрәкәттә булган; күп җирдә булган. *Йөргән таш шомара.* Мәкаль. *Йөргән кеше һәммәсен дә күрә.* М. Гафури.

2. Билгеле бер маршрут буенча билгеле бер вакытта хәрәкәт итү (поезд, машина, пароход, самолет һ. б. йөреше турында). *Юк, бу инде элекке Идел генә түгел икән, --- анда хәзер диңгез пароходлары йөри икән.* Г. Бәширов. *Трамвайлар йөри башлады.* И. Гази. // Хәрәкәттә булу, хәрәкәт итеп тору (төрле механизмнарның эше турында). *Стенада сәгать йөри, Саный минут исәбен.* Җыр.

3. Нинди дә булса транспорт төренә утырып хәрәкәт итү (кая да булса бару, ял итү, күңел ачу һ. б. ш. максатлар белән). *Велосипедта йөрү.* □ *Бу автомобильгә күбесенчә райбашкарма председателе Галиуллин утырып йөри.* Г. Кутуй. *Алар Мансур белән Казанка елгасына җилкәнле көймәдә йөрергә төштеләр.* Г. Әпсәләмов. // Шуу (чаңгыда, конькида). [*Хәлим*] *йокы алдыннан берәр физик эш эшләп керергә гадәтләнде: кар көрәде, утын ярды яки чаңгыда йөрде.* Г. Гобәй.

4. Берәр максат белән кая да булса бару (төрле юнәлештә даими кабатланып торган хәрәкәт турында). *Эшкә йөрү. Театрга йөрү. Мәктәпкә йөрү. Кунакка йөрү.* □ *Кешеләр шул урманнарда гомер сөргәннәр, ауга йөргәннәр.* А. Гыйләҗев. // Кемнең дә булса янына килгәләп тору.— *Минем йөрүемне бер дә күпсенми тор! Йөресәм сиңа йөрмим, --- үземнең туганыма йөрим.* Ш. Камал.

5. Үтү, керү, чыгу (каян да булса). *Урамны кар басты. --- Капкадан йөрергә мөмкин түгел.* Г. Ибраһимов. *Бар шундыйлар: күрәләтә Акны ак түгел диләр, Я ишектән йөрмичә, Тәрәзәдән йөриләр.* Ә. Фәйзи.

6. Ял итү, прогулка ясау, тамаша кылу максаты белән берникадәр вакыт кайда да булса булу. *Музейда йөрү. Урманда йөрү.* □ *Мәҗит белән йөрергә чыксам да, ярты юлда, хәл беткәч, өйгә борыла идек.* Г. Тукай.

7. Йөреш ясау (шахмат уенында). *Ат белән йөрү.* □ *Шаһвәлиев аңа дүрт йөрүдә мат куйды.* Г. Ибраһимов.

8. Кайда, кемнәр арасында булу. *Сугышта йөрү. Читтә йөрү.* □ *Кичә көндез кайда йөрдең? Нурлы йөзең күрмәдем.* Җыр. *Кеше арасына керәсе килсә, Газизгә кибеттә күренгәләп, --- агай-эне арасындарак йөрергә кирәк шул.* Ф. Әмирхан. // Кайда, кем яки нәрсә янында булу, күренү. *Җәй көннәрендә Курайлы елга буенда яңгырлар еш йөри.* Г. Галиев. [*Исмәгыйль Галиябануга:*] *Синең тирәдә козгыннар йөри диләр. Расмы әллә шул сүз?* М. Фәйзи.

9. Кемдер булып эшләү, кайда да булса хезмәт итү. *Бурлакта йөрү. Солдатта йөреп кайту.* □ *Әнкәем Нури хажиларда көнлектә йөри.* Г. Толымбай.

10. Берәр нәрсә белән мәшгуль булу. *Эш артыннан йөрү.* □ *— Бүген менә таныш бер егет үлгән, шуның кайгысы белән йөрибез, иртәгә күмәргә кирәк.* Ш. Камал. // Нәрсә белән дә булса шөгыльләнү, шуның белән кәсеп итү. [*Мулла Бикчәнтәйгә:*] *Маймыл, аю биетеп йөрү — мөселманлык эше түгел.* Т. Гыйззәт.

11. *күч.* Яратышу, сөешү; гыйшык тоту. *Кызлар белән йөрмим әле, йөргәч аласы була.* Җыр. // Шундый мөнәсәбәт күрсәтергә омтылу, тырышу. [*Бибкәй Гыйлемдарга:*] *Йөрмә миңа тагылып, мин сине сөю түгел, күрәсем дә килми.* Т. Гыйззәт.

12. Нинди дә булса киемдә, формада, рәвештә булу. *Күзлектән йөрү. Кышкы пальтодан йөрү. Яланаяк йөрү. Биткә кершән ягыныпйөрү.* □ *— Әхмәт, сиңа әйтәм, атаңның ничек эче пошмый ул кадәр чәчеңне үстереп йөрүеңә.* Г. Камал.

13. Нинди дә булса хәлдә яки хис-тойгы, кичерешләр эчендә булу, яшәү. *Эшсез йөрү.* □ [*Мәүлихә жиңги*], *тыштан сиздермәскә тырышса да, бу көннәрне бик боек йөри башлады.* Г. Бәширов. *Хәзрәт һаман үзенең карасына көеп йөри.* Г. Ибраһимов.

14. *күч.* Хәрәкәт итү, эшләү (куллар турында). *Аның эшкә чыныккан һәм сәләтле куллары бик җитез йөриләр.* М. Гафури.

15. Сөйләнү, таралу, ишетелү (фикер, сүз, хәбәр һ. б. турында). *Икенче көнне иртән бу җыелыш турында кызыклы сүзләр дә йөрде.* И. Гази. *Аның әтисенең үлеме турында төрле хәбәрләр йөрде.* Г. Ахунов. // Бер-беренә җибәрү, үзара алмашу (хат турында). [*Егет*] *белән Зәйнәп арасында өзлексез хатлар йөри башлады.* М. Гафури.

16. Нишли яки ничек дип уйлау, исәпләү, санау.— *Хәзергә хәтле без сине балалыгы белән юләрләнә дип йөрдек.* Ф. Әмирхан. *Фәйзи белән* [*Мохтар*] *икәвесе дә соң вакытларга хәтле Сәхипне Корбангалинең үз кызы дип --- йөрделәр.* Ш. Камал.

17. Нәрсә дә булса эшләргә ниятләнү, уйлау.— *Мин үзем дә килгән көнеңнән бирле* [*эшкә керү мәсьәләсен*] *кузгатып карыйммы әллә дип йөри идем.* Э. Касыймов.

18. *Ырга-ергә* формасындагы фигыльләрдән соң килгәндә: нәрсә дә булса эшләргә җыену, уйлау, ниятләнү. *Күрешергә дип йөргән идек, күрешеп булмый тиз генә.* Җыр.— *Мин авылга, крестьян арасына, тимерче булып китәргә йөрим.* Т. Гыйззәт.

19. *күч.* Кешенең үз-үзен ничек тотуы турында.— *Килен бит һаман минем күз алдымда: --- бик акыллы, бик әйбәт йөри.* Г. Бәширов. [*Хөсәен Газизәгә:*] *Шуны бел: болай йөрүеңә безнең күңел бик рәнҗи.* Ф. Әмирхан.

20. *күч.* Кемчә булу, эшләү, яшәү.— *Бу эштә син аның* [*әнкәңнең*] *сүзен тыңла, атаңча йөр.* Ф. Хөсни. // Кемнең дә булса кушуы, әйтүе яки күрсәтмәләре нигезендә эш итү, эшләү. [*Мохтар Фәйзигә:*] *Правлениегә җыен контр меньшевиклар утыртып куйгансыз да, шуларның сүзләре белән йөрисез.* Ш. Камал.

21. *күч.* Яшәү, **тору.**— ***Нинди җилләр ташлады, Сәлим? Исән-сау йөрисеңме?*** Г. Әпсәләмов.— *Хафизаны Хафиз кулыннан тартып алмасам, дөньяда исемем Кәрим булмасын, дөньяда йөрмим.* Г. Камал.

22. *күч.* Кулланышта, әйләнештә булу; кулланылу. [*Хөснулла Әмирҗанга:*] *Сиңа микалай акчалары кирәк идемени? Алар йөрмиләр бит хәзер.* Ш. Камал. // *күч.* Законлы яки авторитетлы көчкә ия булу, үтәлү (сүз, боерык, приказ һ. б. ш. турында). *Хәзер анда йөрми бай фәрманы.* М. Гафури.— *Бер-ике кичкә булса да* [*кунакка*] *барасы иде, әтисе. Правлениедә дә каршы килмәсләр, синең сүзең йөри бит.* Г. Галиев.

23. *ярд. ф. функ.* 1) субъект хәрәкәтеннән аңлашылган эшкә дәвамлылык төсмере өсти. *Күченеп йөрү.* ☐ *Фәхри --- Гәрәй* ***мирзаларга килеп-китеп йөри*** *иде.* Г. Ибраһимов. *Бу чыгып йөрүләрдән Мостафин көч җыеп, рухланып кайта торган иде.* Ә. Еники; 2) билгеле **бер вакыт эчендә чагыштырмача даими эшнең дәвамлы һәм өзлексез булып торуын белдерә.** ***Укып йөрү. Авырып йөрү. Күзәтеп йөрү.*** ☐ *Ничә еллар күзем салып* ***йөрим сиңа, балдызым.*** Җыр.

Йөреп кайту (керү, килү) — кая да булса барып килү, прогулка ясау, саф һава алырга чыгу. *Бер елны, җәйнең иң матур көннәрендә, миңа Ык буеннан йөреп кайтырга туры килде.* Г. Галиев. *Әзрәк йөреп керик дип, мин Фазыйлны алып чыгып киттем.* Г. Ибраһимов. **Йөреп китү** — 1) баланың яки авыру кешенең, **сәламәтләнеп, аякка басып йөри башлавы;** 2) нинди дә булса механизмның, төзәлеп, хәрәкәт итә башлавы. *Майлагач, стена сәгате йөреп китү;* 3) җигүгә өйрәнү, күнегү (ат турында).— *Ярый инде,* [*кара туры*] *чыгымламый-нитми йөреп китсә.* Г. Толымбай. **Йөреп эшләү** — эшкә кайтып-килеп йөрү. *Миңсылу белән* [*Нәгыйм*] *йөреп эшләргә булдылар.* Ш. Камал. **Йөреп чыгу (әйләнү)** — тикшерергә, күрергә, белергә кирәк булган объектларны алар урнашкан җиргә барып карап чыгу. *Бригадаларны йөреп әйләнгәннән соң, Тимери, бөтен авылны аякка бастырырга ниятләнеп, кайтырга чыкты.* Г. Бәширов.

ЙӨТКЕРЕК *и. диал. к.* ютәл. *Ютәл йөткерекне баса.* Мәкаль.

ЙӨТКЕРЕНҮ *ф. к.* йөткерү. *Бервакыт өстәл янына утырганда, мин ничектер катырак йөткерендем.* Ш. Камал.

ЙӨТКЕРЕШ *и. сир. к.* ютәл. *Бер хатынның картлык йөткереше белән йөткерә-йөткерә чыгып килгәнлеге сизелде.* Ф. Әмирхан.

ЙӨТКЕРҮ *ф.* Өзек-өзек калтыраулы, гыжылдап торган тавышлы тын чыгару (гадәттә, тын алу юллары сәламәт булмау аркасында); ютәлләү. *Егет, күкрәген тотып, буылып йөткерергә тотынды.* А. Шамов. *Әллә кайда караңгылык эчендә йөткергән, --- кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышлары җир астына җан кертте.* М. Гафури.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, I том.
Т23 Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.
476 б.

Сүзлектә татар әдәби теленең XIX гасыр ахырыннан алып хәзерге көнгә кадәр гомумкулланышта булган лексик һәм фразеологик байлыгы тупланган. Аңлатмалы сүзлек киң катлау укучылар өчен чыгарыла. Ул өч томнан тора.

Т $\frac{0715—111}{М132(03)—76}$ —76 С(Тат)(03)

ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В ТРЕХ ТОМАХ. ТОМ I.

Тышлык художнигы *И. И. Субаев*
Художество редакторы *Э. Е. Сподикова*
Техник редакторы *З. А. Ибрагимова*
Корректорлары *И. Х. Уразова, С. В. Абдуллина, М. М. Мирсалихова, Р. С. Хәмидуллина*

ИБ № 56

Наборга бирелде 17/IX-1974 ел. Басарга кул куелды 16/II-1977 ел. Типография кәгазе № 1, 84×108$^1/_{16}$. Учетн.-изд. табагы 81,16. Якынча басма табагы 51,66. Заказ П-948. Тираж 25 000. Бәясе 3 сум 36 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

Типография гаебе белән киткән җитди хаталар

Бит	Багана	Юл		Басылган	Укырга
		өстән	астан		
XIII	II	—	10	җан дуслар куркак	җан дуслар, куркак
12	I	8	—	бар	бер
18	II	—	19	вакыта	вакытта
19	I	29—30	—	юлынсалар	юлыксалар
20	I	9	—	бәхәсләшү	бәхәсләшүе
25	I	—	1	*рев.*	*рәв.*
61	I	—	34	сими(чә)	сизми(чә)
65	II	—	34	торалыгыз	таралыгыз
87	II	—	22	[Милли уллары турында:]	[Мулла уллары турында:]
99	II	29	—	уртаклашыю	уртаклашып
112	I	26	—	(бак)	(бақ)
120	II	8	—	балчыкланып, беткән	балчыкланып беткән
128	I	—	18	унайла	уйнала
133	II	—	27	шунда	шуңа
170	II	—	29	Углеводороды	Углеводородлы
203	II	33	—	безгә	бәзгә
208	II	—	6	*к.* бергәләү.	*к.* бәргәләү.
255	II	9—10	—	гайриләргә	гайреләргә
283	II	—	13	анда	аңда
310	II	—	32	[докылдау]	[доқылдау]
357	II	—	7	күрсәтмәссен	күрсәтмәссең
357	II	—	8	булсан	булсаң
371	II	33	—	сынар	сыңар
376	II	17	—	Киен	Каен
377	II	—	4	(кеше	(кеше)
378	I	—	20	бирә	бирсә
393	I	35	—	**ИНДИВИДУАЛИ́СТИК** *и.*	**ИНДИВИДУАЛИ́СТИК** *с.*
397	I	25	—	**ИНСТИТУТТАШ** *и.*	**ИНСТИТУТТАШ** *с.*
406	II	25	—	**иркен.**	**иркең.**
434	I	—	36	күмгәч, үзеңне	күмгәч үзеңне
438	I	—	1	Әллә □	□ Әллә